ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**Ф. С. Хәкимҗанов**

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ФРАЗЕОЛОГИЗМНАР СҮЗЛЕГЕ

**ТОТРЫКЛЫ СҮЗТЕЗМӘЛӘР ҺӘМ ТӘГЪБИРЛӘР**

**I том**
**А – Б**

Казан
2022

УДК 81'374.3=512.145
ББК 81.632.3-4
Х 86

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

**Фәнни мөхәррир:**
филология фәннәре докторы, профессор Ф. З. Яхин

**Бәяләүчеләр:**
филология фәннәре кандидаты, доцент Э. Х. Кадирова
филология фәннәре кандидаты Г. Н. Ниязова

**Хәкимҗанов Ф. С.**
Х86 Татар теленең фразеологизмнар сүзлеге: тотрыклы сүзтезмәләр һәм тәгъбирләр: Өч томда. I т. (А–Б). – Казан, 2022. – 672 б.
ISBN 978-5-93091-435-1

Укучыларга татар теленең фразеологик әйтелмәләр хәзинәсен үзенә туплаган (бу томга 10 500 дән артык тотрыклы сүзтезмә кертелде) күләмле яңа сүзлек тәкъдим ителә. Әлеге хезмәттә татар телендәге гыйбарәләрнең мәгънәләре аңлатыла, куллану формалары күрсәтелә, матур әдәбияттан, вакытлы матбугаттан, җанлы сөйләмнән алынган үрнәкләр ярдәмендә мәгънә төсмерләре ачыклана.

Сүзлек татар телен яхшы белүчеләргә (галимнәргә, язучыларга, журналистларга һ.б.) генә түгел, телне яңа өйрәнеп килүчеләргә дә кызыксындырган гыйбарәне җиңел табу һәм аңлау уңайлы булырга тиешлеген күз уңында тотып төзелде.

ISBN 978-5-93091-435-1

© ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2022
© Хәкимҗанов Ф.С., 2022

# СҮЗ БАШЫ

Сүзлек төзергә алынган кешенең алдына «Бу хезмәткә нинди сүз берәмлекләре керергә тиеш һәм аларны ничек тасвирлап бирергә кирәк?» дигән ике мөһим сорау килеп баса. Билгеле, сүзлекнең төренә бәйле рәвештә, бу сораулар үзенчәлекле хәл ителәләр.

Фразеология тармагының төп берәмлекләре саналган *тотрыклы сүзтезмәләрнең* табигатен ачыклауга карата галимнәр арасында төрле фикерләр яшәп килә. Бер төркем телчеләр [Л. Л. Реформатский, Н. М. Шанский, Г. Х. Ахунҗанов һ.б.] бу гыйбарәләр эченә мәкаль-әйтемнәрне, табышмакларны, канатлы сүзләрне, тезмә терминнарны һ.б. да кертәләр. Ш. Балли, В. В. Виноградов, В. Х. Хаков кебек галимнәр әйтелмәләрне, төзелеш һәм мәгънә үзенчәлекләрен асыл сыйфат итеп алып, берләшү дәрәҗәләре нигезендә фразеологик ныгымалар (идиомалар), фразеологик бердәмлекләр һәм фразеологик тезмәләргә (атамаларда төрлелек булырга мөмкин) аерып карыйлар.

Шулай ук Ш. А. Рамазанов тәкъдим иткән өченче фикер дә игътибарга лаек. Галим тотрыклы сүзтезмәләрне ике төркемгә бүлү кирәклеген алга сөрде, ягъни тотрыклы гыйбарәләрне идиоматик әйтелмәләргә һәм фразеологик әйтелмәләргә аерып тикшерде[1]. Соңрак фразеологизмнарны махсус диссертация кысаларында төрле яклап өйрәнеп, Г. Х. Ахунҗанов «идиоматика» дигән терминны кулланышка кертүне тәкъдим итте. Идиоматик әйтелмәләрне, аларның күчерелмә мәгънә аңлатуыннан тыш, эчке формаларының онытылу-югалу дәрәҗәсен дә исәпкә алып, *бердәмлек* һәм *берекмә* дигән төрләргә бүлде һәм, гомумән алганда, идиоманың 12 төркемчәсе барлыгын ассызыклады: идиоматик әйтем *(әйттем исә кайттым; ай күрде, кояш алды)*, аналитик идиома *(ак икмәк, ак өй)*, афоризм-идиома буларак мәкаль *(үзе юкның күзе юк, утсыз төтен булмый)*, әйтем белән мәкаль арасындагы арадаш идиомалар, канатлы сүзләр, ягъни китап идиомасы *(Кысканга былтыр кычкыралар димени быел – Г. Тукай; Үлем турында уйлама, илең турында уйла – Ф. Кәрим)*, кинетик идиома *(аяк чалу, кул кысу)*, лексик-грамматик идиома *(чана шуу)*, «фигыль + фигыль» калыбындагы идиома (*коелып төшү, очып куну*), «мөстәкыйль сүз + ярдәмлек сүз» калыбындагы идиома *(артыгы белән, әйтмә дә, күңел өчен)*, ярдәмлек сүзләрдән оешкан идиома *(әмма ләкин, иллә дә мәгәр)*, термин идиома *(сару кайнау, үги ана яфрагы)* һ.б.[2]

Бүгенге көндә фразеология өлкәсендә башкарылган соңгы фәнни тикшеренү итеп өч томлы «Татар лексикологиясе»[3] хезмәтен санарга кирәк (аның I томында 191–277 нче битләрдә «Хәзерге татар фразеологиясе» дип аталган бүлекчә, III томның 2 нче кисәгендә 252–269 нчы битләрдә «Фразеологик сүзлекләр» исемле мәкалә бар). Бу хезмәттә татар тел белемендә фразеологик әйтелмәләрне ныгымалар, бердәмлекләр, тезмәләр һәм тәгъбирләр дип, дүрт төркемгә аерып карауның киң таралуы ассызыклана, төрле яктан аларның үзенчәлекләре ачып бирелә.

Тәкъдим ителә торган сүзлектә без төп игътибарны идиоматик әйтелмәләргә юнәлттек. Моннан тыш, бөтен тулылыгы белән булмаса да, фразеологик бердәмлекләр белән фразеологик тезмәләрне дә сүзлеккә керттек.

Телдә *алкыш* һәм *каргыш* дип төркемләнә торган тезмә сүзләр дә билгеле бер дәрәҗәдә сүзлеккә кертелде. Мәсәлән, мунча кереп чыккан кешегә рус телендә кулланыла торган «с легким паром» сүзтезмәсеннән тәрҗемә ителгән «җиңел пар белән» дигән теләкне еш ишетергә туры килә. Ләкин әлеге гыйбарә урынына татар теленең сүзлек хәзинәсендәге «шифалы булсын» дигән мәгънәдәш төрен куллану мөмкинлеген күпләр белми.

Бу сүзлек беренче чиратта татар телен яхшы белүчеләрне генә күз уңында тотып түгел, ә телне башлап өйрәнергә, аның телбизәкләрен аңлап кулланырга, төрле гыйбарәләрне төшенергә теләүчеләр өчен әзерләнде.

---

[1] *Рамазанов Ш. А.* Татар теле буенча очерклар. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – Б. 129–132.

[2] *Ахунҗанов Г. Х.* Татар теленең идиомалары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1972. – Б. 14–36.

[3] Татар лексикологиясе: өч томда, т. I / Проект җит. М. З. Зәкиев; ред. Г. Р. Галиуллина. – Казан: ТӘһСИ. – 2015. – 352 б.; т. II. – 2016. – 392 б.; т. III, 1 нче кис. – 2017. – 536 б.; 2 нче кис. – 2018. – 464 б.

## ФРАЗЕОЛОГИК ҺӘМ ФРАЗЕОЛОГИК БУЛМАГАН ӘЙТЕЛМӘЛӘР

Хәзерге көндә телнең фразеология дип аталган тармагының аерым категория буларак билгеләре күрсәтелеп, бу төр әйтелмәләрнең кушма сүздән, сүзтезмәдән һәм җөмләдән аермалары ачыкланганлыгын ассызыкларга кирәк. Шул ук вакытта телнең хәрәкәттәге күренеш икәнлеген, һәрвакыт үзгәрешләр кичерергә сәләтле булганлыгын искә алсак, билгеле бер сыйфаты белән фразеологик әйтелмәгә охшаш гыйбарәләрнең, вакытлар үтү белән, тотрыклы сүзтезмәгә күчүе дә ихтимал. Һәм киресенчә, ике сүздән гыйбарәт булып, аерым язылып килгән сүзтезмә, кушылып языла башлау нәтиҗәсендә, кушма төзелешле мөстәкыйль сүзгә әйләнә ала. Чаг. *Буш бугаз син!* (Г. Кутуй. Шатлык җыры) ~ *Картның һәрвакыт аны шулай бушбугаз итеп калдыруы Ризванның кытыгын китерә иде* (Г. Бәширов. Җидегән чишмә).

Фразеологик әйтелмә буларак танылып, сүзлеккә алынган сүтезмәләр ирекле сүзтезмәдән түбәндәге сыйфатлары яки билгеләре белән аерылып торырга тиешләр:

1) төзелеше ягыннан кимендә ике сүздән оешу мәҗбүри. Чаг. *авыз почмакландыру, әлифне таяк дип тә белмәү, төндә (төнлә) туган, үлән астыннан ут йөртү* һ.б.

*Искәрмә.* Кайбер тикшеренүчеләр тарафыннан фразеологизм дип танылган *алаймы-болаймы, ачыктан-ачык, әйттем-бетте, әледән-әле, бетте-китте, булды-бетте, куласты, пычакка-пычак* кебек корылмалар сүзлеккә кертелмәде;

2) фразеологик әйтелмәдә тулаем мәгънә нинди дә булса читләтелгән төшенчәне аңлатырга тиеш (*табан ялтырату* «тиз арада юк булу», *буй язу* «йөреп килү», *теңкәгә тию* «йөдәтеп бетерү, тәмам тинтерәтү» һ.б.). Ягъни сүзтезмәне оештырган һәр сүзнең туры мәгънәсе сакланганда, ул фразеологик әйтелмә була алмый. Чаг. *балта кителү, су басу, өстенә су сибү* һ.б. Билгеле, идиомалардан аерылып торган фразеологик тезмәләрдә (моның эченә фразеологик берәмлекләрне дә кертеп карыйбыз), гадәттә, күчерелмә мәгънәлелек сизелми: аларда, сүзләрнең туры мәгънәләре сакланган хәлдә, бер төшенчә белдерелә: *бөтен көченә (көчкә)* «бар булган көчен җыеп, җан-фәрманга», *газап чигү* «газаплану», *иңне иңгә куеп* «янәшә», *көн дими, төн дими* «бернигә дә карамыйча» һ.б.

Бераз образлылыкка ия булган, әмма терминлашкан *көтүче бүреге, саз күгәрчен күзе, сөләйман мөһере, үги ана яфрагы, шайтан таягы* кебек үсемлек, *бөтерчек баш, җәннәт кошлары, ихахай ябалак, яңгыр теләнчесе* кебек кош атамаларын, төрле оешма-берлекләрнең рәсми исемнәрен, *ат елы, куян елы, сыер елы* һ.б. кебек борынгы төрки ел исемнәрен фразеологик тезмәләргә кертеп карау өчен нигез юк. Шулай ук алдына теләсә нинди сүз куярга мөмкинчелек биргән үзенчәлекле калып рәвешендә тәкъдим ителгән *...дигән кебек, ...дип әйтеп, дип әйтеп әйтү, ...дип әйтеп булу, ..дип әйткәннән, ...дип бару (куәтләү, раслау), ...дип торсам, кая... анда, ...дисәң дә була* кебек тезмәләрне дә конкрет лексик берәмлек итеп карау хаклы булмас.

## ЛЕКСИКОГРАФИК ЧЫГАНАКЛАР

Әхәтов Г. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 176 б.

Байрамова Л. К. Учебный тематический русско-татарский фразеологический словарь. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1991. – 158 с.

Гали Х. Мәкальләр һәм әйтемнәр. – Казан, 1941.

Гаффарова Ф. Ф., Саберова Г. Г. Татарча-русча идиомалар сүзлеге. – Казан, 2006. – 232 б.

Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 томда / Фән. ред. В. Х. Хаков. – Казан: Татар. кит. нәшр.: Т. 1 – 1989 (А–К). – 495 б.; Т. 2. – 1990 (Л–Һ). – 365 б.

Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге. – Яр Чаллы: «Идел-йорт» нәшр., 2001. – 236 б.

Мәхмүтов Х. Габдулла Тукайның канатлы әйтелмәләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 128 б.

Русча-татарча фразеологик сүзлек / Төз.: Н. Б. Борһанова, Л. Т. Мәхмүтова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – 180 б.

Сафиуллина Ф. С. Татарча-русча фразеологик сүзлек. – Казан: Мәгариф, 2001. – 336 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. Т. 1 (А–Й). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – 476 б.; Т. 2 (К–С). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 728 б.; Т. 3 (Т–Һ). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 832 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / Баш ред. Ф. Ә. Ганиев. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 6 томда. Т. I. (А–В) / Фән. ред.: Ф. Ф. Гаффарова, Г. Г. Саберова, Ф. И. Таһирова. – Казан: [ТӘһСИ], 2015. – 712 б.; Т.II (Г–Й) / Фән. ред.: Ф. Ф. Гаффарова, Г.Г. Саберова, Ф.И. Таһирова. – Казан: [ТӘһСИ], 2016. – 748 б.; Т. III (К) / Фән. ред.: Ф. И. Таһирова, Р. Т. Сәфәров, Ф. Ф. Гаффарова. – Казан: [ТӘһСИ], 2017. – 744 б.; Т. IV (Л–Р) / Фән. ред.: Ф. И. Таһирова, Р. Т. Сәфәров. – Казан: [ТӘһСИ], 2018. – 760 б.; Т. V (С–Т) / Фән. ред. Ф. И. Таһирова. Р. Т. Сәфәров. – Казан: [ТӘһСИ], 2019. – 908 б.; Т.VI (У–Я) / Фән. ред.: Ф. И. Таһирова, Р. Т. Сәфәров. – Казан: [ТӘһСИ], 2021. – 912 б.

Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре / Төз.: Л. Җәләй, Н. Борһанова, Л. Мәхмүтова; җав. ред. М. Зәкиев. – Казан: Таткнигоиздат, 1957. – 244 б.

Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәре / төз. Х. Ярми. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – 244 б.

Хәкимҗан Ф., Хәкимҗан Д. 1001 әйтем. – Казан: Gumanitarya, 2004. – 244 б.

## СҮЗЛЕКТӘН ФАЙДАЛАНУЧЫЛАР ӨЧЕН БЕЛЕШМӘ

Сүзлеккә кертелгән фразеологик әйтелмәләр, беренче сүзнең фонетик төзелешен тулаем искә алып, алфавит тәртибендә бирелде, (алфавит тәртибе сызыкча аша язылган кушма сүзләрдә дә сакланды).

*АТ*[1] ❖ **АТ АЕНДА, ИР ЕЛЫНДА СЫНАЛУ.**
**АТ АЛМАСЫ ДА БУЛМАУ.**
**АТ АЛУ (ТАРАЛУ)** һ.б.
**АТ ЯХШЫ – ҖИЛ КАРШЫ.**

Аннан соң гына беренче сүзе «ата» булган әйтелмә куела.

*АТА* ❖ **АТА БАЙ.**
**АТА БАЛАНЫ (УЛНЫ), БАЛА (УЛЫ) АТАНЫ БЕЛМӘҮ (КҮРМӘҮ).**
**АТА БАЛАСЫ.**

Сүзлек мәкаләсе әйтелмәдән, аның аңлатмасыннан (яки башка әйтелмәгә сылтамасыннан; берничә мәгънә булган очракта, алар саннар белән күрсәтеләләр), аңлатмаларда әдәби әсәрләрдән яки вакытлы матбугаттан алынган үрнәк җөмләләр белән ныгытудан гыйбарәт. Сөйләм теленнән алынган җөмләләр җәя эчендә «сөйләм» дип билгеләнәләр. Соңыннан бу әйтелмәнең төрдәшләре урын ала.

Әйтелмәләрнең беренче сүзе, грамматик төзелешен дә саклаган хәлдә, алга чыгарылып, авыш хәрефләр белән башкача язылып күрсәтелде.

*АБРУЙГА* ❖ **АБРУЙГА ҖИЛ ТИЮ.**
**АБРУЙГА СУГУ.**
**АБРУЙГА ТИЮ.**

Әйтелмәдәге сүзнең лексик варианты түгәрәк җәяләрдә күрсәтелә. Әмма бу ысул беренче сүздән соң бик сирәк очракларда (оешачак яңа әйтелмәне табуны кыенлаштырмаса гына) кулланыла.

**БОРЫН БЕЛӘН БОЗ ЕРТУ (ТИШҮ; ЧОКУ; ЯРУ).**
**ИКЕ БОЗАУГА КИБӘК (БАШАК) АЕРА АЛМАУ (БЕЛМӘҮ).**
**«ЭХ» («ЭҺ») ДИГӘНЧЕ.**

Очлы җәяләрдә әйтелмәнең факультатив кисәкләре күрсәтелеп, китерелгән төп әйтелмәгә яңа мәгълүмат өстәлә. Ләкин түгәрәк һәм очлы җәяләрдәге сүзләр яки хәрефләр алфавит тәртибенә үзгәреш кертмиләр.

**«Ә» ДИГӘНГӘ «Ә» (« ҖӘ») <«ҖӘ» ДИГӘНГӘ «ҖӘ»> ДИП ЙӨРҮ (ТОРУ; УТЫРУ).**
**ИСЕҢ КИТКӘН ИСКЕ ЧИКМӘНГӘ, <БЕЗДӘ АНЫҢ ЯҢАСЫ ДА БЕР ТИЕН>.**
**СУЙГАН ДА КАПЛАГАН (КУЙГАН), <НӘКЪ АТАСЫ-АНАСЫ>**
**АШЫ<ЙСЫ>Н АШАГАН, ЯШ<ИС>ЕН ЯШӘГӘН.**

Мәгънәләре охшаш әйтелмәләр, *к.* кыскартылмасын кулланып, бер-берсенә кайтару юлы белән аңлатылалар.

**АЯКТАН ЯЗУ** *к.* аяктан калу.
**ҮКЧӘСЕ ҖИРГӘ ТИМӘҮ** *к.* «а» дигәнче.

Чагыштыру мәгънәле әйтелмәләрдә «кебек» бәйлеге генә кулланыла, ул башка барлык чагыштыру чараларын да алмаштырып килә, ягъни баш әйтелмәдә «кебек» кулланылса да, үрнәк мисалларда *кеби, күк, төсле, сыман* һ.б. да булырга мөмкин.

Кайбер куе төс белән бирелгән баш әйтелмәнең алдында очлы җәя эченә алынган «үз» алмашлыгы куелырга мөмкин, ләкин ул алфавит тәртибен бозмый һәм конкретлаштыру максатыннан гына кулланыла, чаг.: <ҮЗ> **БУМАСЫ ТОТУ** – мондый очракта әйтелмәне «б» хәрефеннән башлап эзләргә кирәк.

## ШАРТЛЫ КЫСКАРТМАЛАР

*әкият*. – әкияттән
*гади с.* – гади сөйләм
*диал.* – диалекталь
*дини* – дини
*ирон*. – ирония белән
*иск.* – искергән
*к.* – кара
*карг.* – каргау
*кимс.* – кимсетү
*киная* – киная
*кит*. – китап сүзе
*кис.* – кисәтү
*көл.* – көлеп әйтү
*күч.* – күчерелмә
*миф*. – мифология
*махс.* – махсус
*мыск.* – мыскыллау
*тар*. – тарихи
*тирг.* – тиргәү
*ТТДС* – Татар теленең диалектологик сүзлеге
*туп.* – тупас
*фолькл.* – фольклор
*хәрби* – хәрби
*хупл.* – хупламау
*хурл.* – хурлау
*һ.б.* – һәм башкалар
*шаярт*. – шаярту
*эвф.* – эвфемизм (читләтеп әйтү)

## ТАТАР АЛФАВИТЫ

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Аа | Дд | Зз | Мм | Пп | Үү | Чч | ь |
| Әә | Ее | Ии | Нн | Рр | Фф | Шш | Ээ |
| Бб | Ёё | Йй | ң | Сс | Хх | Щщ | Юю |
| Вв | Жж | Кк | Оо | Тт | Һһ | ъ | Яя |
| Гг | Җҗ | Лл | Өө | Уу | Цц | Ыы | |

# А

*А* ❖ **«А, Б»ДАН БАШЛАУ**. Сүзне башыннан башлап, төгәлләп сөйләү. – *Бик чәчелеп сөйләмә, «а, б»дан башла* (Сөйләм).

Төрдәше: әлиф-бидән башлау; әлифтән башлау; бисмилласыннан башлау.

**«А» ДИГӘНЧЕ.** Бик тиз, шул ук мизгелдә, озак уйлап тормыйча. *Шул күкрәк өстендәге авырлыкны бер илле күтәрә алса, «а» дигәнче шуып чыгып китәр иде* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

Төрдәше: ай бирде, кояш алды (күпсенде); ай күрде, кояш алды; ай күрде, кояш алды, җил очырып китте; ай күрде, көн алды (йотты); ай күреп кояш алганчы; айт дигәндә; артыннан күз дә иярмәү; ат белән чаба атна аралары; аһ! дигәнче; аһ диярргә дә өлгермәү; аягың җиргә дә тимәсен; аяк җиргә (идәнгә) тимәү 1; аяк җиргә тияр-тимәстән; аяк очы җиргә тимәү 1; аяк табаннары гына ялт итеп калу; аяк табаннарына ут капкандай; аяк тигән җиргә тия, тимәгән җиргә тими (юк); аякның кая басканын белмәү; «ә» дигәнче; «ә» дигәнче хап итү; «әһ» дигәндә (дигәнче); бар көченә; бер аягың анда, берсе (икенчесе) монда булсын; бер аягың монда, берсе (икенчесе анда (тегендә) булсын; бер аягың өйдә калсын; бер минут эчендә; бер секунд эчендә; бизгәк кызулыгы белән; борылып карарга да өлгермисең; җан-фәрманга <чабу>; җилдәй очу; керфек кагып, күз ачып йомарлык ара<да>; китап күләгәсе күмелеп тормады; койрыгын да күрми калу; көн күрде, кояш алды; күз ачып йомарлык (йомган) ара<да>; күз ачып <күз> йомган<чы>; күз йомган арада; күз йомганчы; күз күрде, кулга тимәде; күзгә күренде, кулга эләкмәде; күләгәсен дә күрми калу; күргәне күреп калсын, күрмәгәне торып калсын; кызу тоту; өч басасын бер басу; сул кулың белән биргәнне уң кулың күрмәсен; ут алырга кергәндәй; ут булды да су булды; ут урынына куыру; ут урынына чабышу; үкчәсе җиргә тимәү; «һә» дигәнче; «эх» («әһ») дигәнче; ялт иттерү; янгынга чапкан кебек; яшен аткан шайтан кебек; яшен ташыдай <кылану>; яшен тизлеге белән (тизлегендә); яшен төсле атылу; яшендәй узу; яшеннән качкан шайтан төсле.

**«А» ДИГӘНЧЕ, «Б» ДИЯСЕҢНЕ ИСТӘ ТОТУ.** Әйтәсе сүзләреңне ахырга кадәр уйлап сөйләргә кирәклеге хакында. *«Әгәр мөфти Илдус Фәизов шушы очракны истә тотып әйткән булса, вәгазендәге «а» дигәнче, «б» диясеңне истә тот» дигән сүзләрен, машаллаh!!!* (dumrt.ru).

**«А» ДИГӘЧ, «Б»НЫ ӘЙТҮ.** Сүзне сөйли башлагач әйтеп бетерү. *Азаматовның тулы битенә, яхшы галстугына карап чәнечте: – Госман, «а» дигән кеше «б»ны әйтергә тиеш* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр).

Төрдәше: агын әйткәч, күген дә әйтү; «а»ны әйткәч, «б»ны да әйтү; «а»сын әйткәч, «б»сын да әйтү.

*АБАГА* ❖ **АБАГА ЧӘЧӘК АТКАЧ (АТКАНДА).** Беркайчан да булмаячакны аңлата. – *«Беркайчан да булмас», диясе урынга ул «Абага чәчәк аткач булыр», ди* (musulman.ru. «Ислам – Татарлар һәм мөселманнар»). *Ә бит Габдулла абыйдан мактау сүзе ишетү – абага чәчәк атканын күрү белән бер; бик бәхетле кешеләр генә лаек була аның мактавына* (В. Нуруллин. Ике урам арасы).

Төрдәше: агач башында сумса, кайчан бал булып тамса; алганга (алганда; алучыга) алты да әз, биргәнгә (биргәндә; бирүчегә) биш тә күп; алганда баш ию, алгач артны ию; алганда – бисмилла, биргәндә – әстәгъфирулла; алырсың аннан куянга койрык үссә; әтәч азан әйткәндә; әтәч күкәй салганда; баеган көннең иртәгесен (икенче көнендә); бозау арты белән агачка (киртәгә) менгәндә; дөя койрыгы җиргә тигәндә (тигәч); каз казык какканда; карт алаша тай булгач; кояш кире яктан чыкканда; кызыл кар яугач; таудан кысла сызгыру; таудан кысла сызгырганны көт; таш табак кош табак булгач; төянең

койрыгы җиргә тигәндә; уч төбенә йон чыкканда; эт тизәге черегәндә.

*АБАГЫ* ❖ **АБАГЫ ДА ҖАБАГЫ**. Тәрбиясез, үзенең тотышы һәм киенүе турында уйланмый торган. *Миңлебану ипсез, иләмсез, абагы да җабагы, ятимлектә үскән, әти-әни тәрбиясе күрмәгән, шулар өстенә авызлыга сүз бирмәс, җәяүлегә юл бирмәс, мәгънәсез дә кыз* (И. Нәбиуллина. Миләш тәме).

*АБАЙ* ❖ **АБАЙ БУЛУ.** Сак, дикъкатьле булу, якягыңа караштыргалап тору. – *Тәмле суларга алданып, стансаларда адашып калмас өчен, абай булырга кирәк* (А. Гыйләҗев). *Әгәр абай булмасаң, дәррәү бәхетсезлеккә очравың бар* (А. Расих. Кәгазьдәгеләр һәм хәтердәгеләр).

Төрдәше: агай, алга (алдан) сагай; алга-артка карану; алга-артка карап; алдын-артын җыю (җыеп йөрү); алдын-артын карау (исәпләү; тикшерү; уйлау; үлчәү) 1; алны-артны кыйнап йөрү; арт итәгеңне җыеп йөрү; артыңны җыеп йөр; бер алга (алдына), биш артка (артына) карау; күз-колак булу 2; сак булу; уңга-сулга карау.

*АБАЙЛАМАГАН* ❖ **АБАЙЛАМАГАН ҖИРДӘ (ҖИРДӘН).** Көтмәгәндә, сизмәгәндә, һич уйламаганда. *Абайламаган җирдән бер атлы килеп чыкты* (Сөйләм).

*АБАЙЛАМЫЙ* ❖ **АБАЙЛАМЫЙ КАЛУ**. Нәрсәгә булса да тиешенчә игътибар итмичә, вакытында сизми калу. – *Абайламый калдым, кунаклар кайчан шыңкайды*? (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Ничектер абайламый калганмын, саллы бер йомарлам кар сул күземә килеп тимәсенме* (А. Тимергалин. Игезәкләр).

Төрдәше: абайлап җиткермәү.

*АБАЙЛАП* ❖ **АБАЙЛАП ҖИТКЕРМӘҮ** *к.* абайламый калу. *Карт әңгәмәне икмәкккә таба юллап җибәрсә дә, Нәфисә аның тел төбендә ни ятканын абайлап җиткермәгән иде әле* (Г. Бәширов. Намус). *Язмышында хәвеф тууын, кызган кыршауның тормышын сытып кысарга торуын абайлап җиткермәде Айдаш* (М. Хуҗин. Чөй).

Төрдәше: абайламый калу.

**АБАЙЛАП КАРА.** «Дикъкать ит» мәгънәсендә. *Чагыштыру мисалында, хайванат дөньясыннан ташбака, фил кебек җәнлекләрне абайлап кара: күз карашлары, гәүдә төзелешләре, бирчәйгән тән-җисеме бу җан ияләренең туфани борынгылыкка ия икәнен раслап тора* (М. Галиев. Тимә, яшәсен).

*АБА<У>* ❖ **АБА<У>, ХАРАП ИКӘН.** Яхшы танышың масая башласа яки, үпкәләп, ялындыра башласа, аны кисәтү буларак әйтелә. – *Аба, харап икән бу кунаклар...* (Г. Ибраһимов). *Абау, харап икән, яңа итек кигән дә әллә кем булган* (Сөйләм).

Төрдәше: бер дә харап икән; харап икән.

*АБАУ* ❖ **АБАУ АЛЛА.** Соклануны йә шомлануны белдерә. «*Абау Алла Йосыф!» диеп аһ иттеләр. – «Вай, алдырдык бит Йосыфны!» – диләр инде* (Кол Гали. Кыйссаи Йосыф).

**АБАУ ГЫНА ДА ДИМӘС ИДЕМ**. Очраклы килеп чыгу, үкенерлек ва-кыйга; офтанып тормау. *Үкенмәс идем, офтанып та тормас идем шулай гарип кенә булып калган булса, абау гына да димәс идем, балаларга ата булыр иде, дип офтанды* (Г. Гафурова).

*АБДУЛЛА* ❖ **АБДУЛЛА БИЯСЕ МЫШШ.** Тик утырганда авыр сулап мышнап куйган яки йоклап киткән кеше турында. – *Карале теге почмакка, Абдулла биясе мышш* (Сөйләм).

*АБЗАР* ❖ **АБЗАР АРТЫНДА** *мыск.* Юкны таләп итеп ваксынучы кешегә дорфа рәвештә әйтү (ихтыяҗларны башкару урынына ишарә итү). *Абзаловлар умартачылык белән дә шөгыльләнәләр, ә җыеп алган балның бер өлешен ел саен балалар һәм картлар йортларына бүләк итәләр. Абзар артында!* («Самара татарлары яңалыклары»). – *Монда юк, дидем ич, абзар артында табарсың!* (Сөйләм).

**АБЗАР ИЯСЕ** *миф.* Хуҗалыктагы хайваннарның хуҗа заты буларак билгеле, йорттагы мал-туар да аның карамагында. *Сыер төнлә бозаулаганда, абзар иясе, хуҗага килеп: «Сыерың бозаулады!» – дип кычкыра, ди* (Татар мифлары, I. 216).

**АБЗАР КЕРҮ** *диал.* Көзен терлекне көтүгә кумыйча, йортта асрый башлау. *Суыклар башлангач, бездә абзар керү башлана инде* (Сөйләм).

**АБЗАР КОЙРЫГЫ.** Абзар-кура арты, бәрәңге бакчасы. – *Абзар койрыгына чыгарып куй шунда* (Сөйләм).

**АБЗАР ТАЗАРТУ (ЧИСТАРТУ).** Пычрак эш башкару. *Шакирҗан белән Габделхәким дә әтисе янында кайнаша. Алар әлегә абзар тазарта* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым). *Мал карыйсы, абзар чистартасы юк* (Н. Акмал. Күгәрчен сөте).

*АБЗАРЫННАН* ❖**АБЗАРЫННАН САЕСКАН ОЧУ.** Өе түбәсез, йорт-җире киртәсез. – *Фәкыйрь хуҗалыкларны күргән бар иде, әмма бу бөтенләй башка – абзарыннан саескан оча* (Сөйләм).

*АБЗЫЙ* ❖ **АБЗЫЙ КЕШЕ.** Үзеннән олырак таныш булмаган кешегә эндәшү сүзе. – *Анысын дөрес әйттең, абзый кеше!* (А. Алиш. Якты күл буе). – *Әллә йолкыш шагыйрьме мин, абзый кеше, / Әҗерен, дим, күпме түләең!..* (Г. Морат. Аччы, туташ, ишегеңне...).

*АБЗЫКАЕМ* ❖ **АБЗЫКАЕМ АК МЫЕК.** «Таныш, ышанычлы кеше» мәгънәсендә. – *Шикләнмә, бездән ул, абзыкаем ак мыек* (Сөйләм).

Төрдәше: агай-эне – ак мыек... ; үз кеше.

**АБЗЫКАЕМ ФӘРХЕТДИН, ТҮБӘТӘЕҢ БӘРХЕТТИН** *киная* Тышкы кыяфәте ялтырап та, акыл ягыннан мактана алмаган кеше турында. *Аңа шул «абзыкаем Фәрхетдин, түбәтәең бәрхеттин» дип кенә әйтәсе калган* (Сөйләм).

*АБРУЙ* ❖ **АБРУЙ АРТУ.** Исеме тагын да күбрәк макталу, күбрәк хөрмәт ителү. *Кесәсе калынайгач, абруе арткач, ул Иван углы Степанга әверелде* (В. Имамов. Утлы дала). *Алтын биреш-ми, алтын – буржуй, бәһасе – абруе арта, күтәрелә генә бара!* (Ш. Галиев. Илһамым-мәхәббәтем).

Төрдәше: абруй күтәр<ел>ү; дәрәҗә арту (күтәрелү); дәрәҗәгә менү.

**АБРУЙ ҖУЕЛУ.** Абруе, дәрәҗәсе бетү, сүзен дә, үзен дә санга сукмау. *Берсенең асылынуыннан куркабыз (асылыныр, көт!), икенчесенең абыйсыннан, өченчесенең югары оешмаларга язган жалобаларыннан!.. Нәтиҗәдә әдәбиятыбызның дәрәҗәсе төшә, язучы һөнәренең абруе җуела бара* (М. Шабаев. Төшсез чикләвекләр...).

Төрдәше: абруй<ны> җую; абруй куагын җил селкетү; абруй төшү; абруй түгелү 2; абруй<ны> югалту; абруй югалу; абруйга җил тию; абруйга сугу; абруйга тию; авторитет шүрлеген сүтү; базарлыгы калмау; базары бетү 2; базары калмау; базары торган, <бәясе чыккан>; базары төшү 1; базары узу (үтү); базары юк; дан сату; дан чәчү; дан черетү; дан чыг<ар>у 2; данга калу 2; дәрәҗә кимү (төшү); исем буяу; исем сату 1; исемгә тап төшерү; күздән төш<ер>ү; счет төймәсеннән төшеп бару.

**АБРУЙ<НЫ> ҖУЮ** *к.* абруй җуелу**.** *Кеше шәхесенә рухи юаныч, өмет, кодрәт бирүчән шул рәвешен санга сукмыйча, аны бары тик җимерү, юк итү максаты белән эш итте һәм шуның белән кешеләр җанында үзенең абруен җуйды, дәрәҗәсен төшерде* (Ф. Дунай. Иманнар какшаган дәвер). *Оешма ягыннан карасаң, Татар иҗтимагый үзәге абруен җуйды* (Р. Юныс. Татар гаме).

Төрдәше: абруй җуелу һ.б.

**АБРУЙ КАЗАНУ.** Халык арасында хөрмәте үсү, яхшы исем алу. *Власть каршында абруй казану, юньлерәк җәйләүгә хуҗа булу, старшина дәрәҗәсен саклап калу өчен көрәшә башлаячак* (В. Имамов. Сәет батыр). *Урыс телен ипилектозлык кына белгән татар малайларын ул үз күреп, яратып, малайлар арасында зур абруй казанды* (Д. Каюмова. Урланган бәхет).

Төрдәше: абруй күтәр<ел>ү; ат алу (таралу) 1; ат казану; ат калдыру; ат кайнату; ат күтәрү 1; ат чыгару; ат чыгу 1; ат-атагы чыгу (таралу); атагы чыгу 1; атак күтәрү (чыгу); атка калу; атка сабу; аты чыгу 1; аты-саны чыгу; базары арту; базары күтәрелү (үсү); дан алу (казану; таралу; тоту); дан даулау; дан җәелү; дан җырлау; дан итү; дан калдыру; дан китү 1; дан китү 2; дан күтәрү 2; дан тоту; дан чыг<ар>у 1; данга калу; данга чыгу; даны-шавы чыгу (таралу); дөньяга китү; изге ат чыгу; исем җәелү; исем казану; исем китү 1; исем чыг<ар>у 2; исемгә китү; исемгә лаек булу; исеме җәелү; исеме-даны чыгу; исеме-чабы таралу 1; исем-шөһрәт казану; кеше нам казану; халык теленә керү.

**АБРУЙ КИРЛӘҮ.** Дәрәҗәсен, абруен таба алмый аптырау. – *Абруе кирләгәнгә, урын таба алмыйча йөри бугай, мескен* (Сөйләм).

**АБРУЙ КУАГЫН ҖИЛ СЕЛКЕТҮ** *к.* абруй җуелу. *Хәзер Сәкинә Бариевнаның абруй куагын җил селкетә башлаган иде инде, аның*

*дару сатып көн үткәрүен беләләр иде* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: абруй җуелу һ.б.

**АБРУЙ КҮТӘР<ЕЛ>Ү.** Хөрмәткә ирешү турында уйлау һәм аны тормышка ашыру. *Шушы вакыйгадан соң, Хәтирәнең абруе тагын да күтәрелде* (М. Галәү. Мөһаҗирләр). *Германия белән таныш булуы халык алдында аның абруен күтәрде* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).
Төрдәше: абруй арту; дәрәҗә арту; дәрәҗә күтәрелү; дәрәҗәгә менү.

**АБРУЙ ТӨШҮ.** Хөрмәте, дәрәҗәсе кимү яки бөтенләй бетү. *Казандагы «Үзәктә» интеллигенция вәкилләре күп, алар эш югалтудан, абруй төшүеннән куркып, алдын-артын карап кына хәрәкәтләнәләр* (З. Әһлиуллин. Татарстан: кичә, бүген, иртәгә). *Йолдызлар аллеясында әле исән-сау мәшһүр җырчыларыбыз Илһам Шакиров белән Әлфия Афзалова йолдызлары кабыначак. Йолдызлар арта, абруй төшә* («Татарстан яшьләре» газ.).
Төрдәше: абруй җуелу һ.б.

**АБРУЙ ТҮГЕЛҮ.** 1. Оятка калу, хур булу. *Уйламыйчарак әйтеп ташлады бугай, абруе түгелгәнен үзе дә сизде кебек* (Сөйләм).
2. *к.* абруй җуелу. *Ялган булса тел, бары ялган килер. Шул сәбәпле абруе түгелер...* (Х. Миңнегулов. Иҗади гамәлле шәхесләр).
Төрдәше: абруй җуелу һ.б.

**АБРУЙ<НЫ> ЮГАЛТУ** *к.* абруй җуелу. *Аннары бит, министр каршысында йөз суын түгәргә, абруйны да югалтырга ярамый* (Ф. Яхин. Оптимальлек заманы). – *Ә бер тапкыр абруй югалтсаң, аны кайтарып алу җиңел эш түгел* (А. Расих. Айлы төннәр).
Төрдәше: абруй җуелу һ.б.

**АБРУЙ ЮГАЛУ** *к.* абруй җуелу. *Шуның өчен генә булса да инженерның абруе югалуга чик куярга вакыт* (Ю. Кожевников. Вузның иртәгәге көне). *Тарихның фаҗигале елларында ата-бабаларымның каны коелган туфрагында аларның сөяге яткан җирдә туган телебез ят телгә әйләнеп киткән. Аның абруе югалган* (М. Юныс. Телсезләнү: тамыры һәм җимешләре).
Төрдәше: абруй җуелу һ.б.

*АБРУЙГА* ❖ **АБРУЙГА ҖИЛ ТИЮ** *к.* абруй җуелу. – *Амбиция өчен генә, абруена җил тигән өчен генә кеше гомерен корбан итәргә кемнең хакы бар, Фазылҗан Җангирович?* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).
Төрдәше: абруй җуелу һ.б.

**АБРУЙГА СУГУ** *к.* абруй җуелу. *Аның теге көнне урамда кызмача килеш җырлап йөрүе абруена шактый сукты* (Сөйләм).
Төрдәше: абруй җуелу һ.б.

**АБРУЙГА ТИЮ** *к.* абруй җуелу. *[Мусин] Сез, Вәли бай, юкка гаскәрнең абруена тиясез* (Ф. Бурнаш. Таң).
Төрдәш: абруй җуелу һ.б.

*АБРУЙЛЫ* ❖ **АБРУЙЛЫ КЕШЕ.** Хөрмәткә, игътибарга лаек булган кеше. *Ул, әлбәттә, абруйлы кеше иде, әмма бу дәрәҗәдә баш орырлык зат түгел* (М. Кәбиров. Бердәнбер һәм кабатланмас).
Төрдәше: өстен кеше.

*АБУ* ❖ **АБУ ИТҮ.** Балалар белән сөйләшкәндә, бәрелүне, авыртуны белдерә. *Илүзә елаганымны сизсә, борчыла: «Ник елыйсың, кайсы җирең абу итте, дип, мине аптырата, юата башлый», – ди ана* («Татарстан яшьләре» газ.).

*АБУЗ* ❖ **АБУЗ ӨСТЕНДӘ АРЫШ СУГУ.** 1. Йөктән урлау, ташу, үзенеке итү. *Ул тир түгеп маташмый, күбрәк абуз өстендә арыш сугу белән көн күрә* (Сөйләм).
2. Ялкау, эшләмичә ашаучы турында. *Бездә абуз өстендә арыш сугуны яратучы кеше юк кебек* (Сөйләм).
Төрдәше: авызга чәйнәп каптырганны (салганны; куйганны) көтү (көтеп утыру); авыр аяклы 1; авыр гәүдәле; авыр кеше; авыр санлы; авыр сөякле; аз ашыйм, авырмас башым; аркылы саламны буйга да алып куймау; аркылы ятканны буйга алып куймау (салмау); аш янында ат кебек, эш янында эт кебек; бармак <та> кыймылдатмау; бармакка бармак <та> сукмау; балта да чапмау; бармакны бармакка сукмау; бот күтәреп, түшәмгә төкереп яту; бот күтәреп яту; иренгән ике тычкан җиккән; күләгәдә күрәзәлек итү; кыл <да> кыймылда<т>мау; кыл <да> кыймылдатмыйча яту; мич (пич) башында яту; салам да селкетмәү; тик яту; түбә тактасы санап яту; түшәм санап яту 2; түшәмгә төкереп яту; түшәмдә таракан санау; түшәмнән исәп алу; эт ассаң муеныңа, җиргә тимәс; эшкә кушсаң – эчбаш, егет килсә – пеш-баш; ялкау симертү.

*АБЫЗҖАН* ❖ **АБЫЗҖАН АГАЙ.** Н. Исәнбәтнең әйтүенә күрә, элек җиңгиләрнең каен энеләренә (ирләренең энеләренә) кадерләп һәм тел яшереп эндәшү сүзләре.

*АБЫНСА* ❖ **АБЫНСА, ЕГЫЛЫП ЯТУ.** 1. Бик хәлсез булу. *Абына күрмәсен, абынса, егылып ятачак – кем күтәреп кайтачак ул пәһлеванны?* (Сөйләм).

2. «Бер хата җибәрсә, аны төзәтә алмаячак» мәгънәсендә. *[Мәрәс] Көчегез бар чак иде анысы. Абынсагыз, торалмый егылып ятыр чагыгыз җитте, диюем түгел, шулай да...* (Р. Хәмид. Актамырлар иле).

*АБЫН-ТӨБЕН* ❖ **АБЫН-ТӨБЕН ЙӨРҮ (АТЛАУ; КИЛҮ).** Як-якка аугалап йөрү. *Абын-төбен атлап капкадан чыкканда да, тәрәзәдән яшелле-зәңгәрле тавыш яңгырады* (Ф. Баттал). – *Син теге абын-төбен йөргән абыйны әйтәсеңме?* (Сөйләм).

Төрдәше: апын-төпен йөрү (атлау; килү).

*АБЫНЫП* ❖ **АБЫНЫП КАЛУ.** Сынату, ялгыш юлга китү. *Абынып калу гынамы, ул бөтен киләчәген шик астына куйды* (Сөйләм). *Менә әтиең белән әниеңнең безнең өчен бүгенгә кадәр сер булган фаҗигале язмышларын ачыкладың, үзеңнең исән-иминлегеңне күрдек, тормыш сикәлтәләрендә абынып калмыйча кеше булуыңа сөендек* (Г. Тавлин. Афәт).

*АБЫСТАЙ* ❖ **АБЫСТАЙ, НИЧӘ ӘЙТСӘҢ ДӘ БЕР СҮЗ, ИКЕ КЕШЕГӘ ДҮРТ КҮЗ.** Берәр гаеп эш өчен «Нигә күрмәдең?» дип, икенче кешене гаепләгәндә җавап сүзе. – «*Ишегалдыннан велосипедны алып чыгып киткәннәр бит, син кая карадың?*» – «*Абыстай, ничә әйтсәң дә бер сүз, ике кешегә дүрт күз*» (Сөйләм).

**АБЫСТАЙ РОМАНЫ.** Хатын-кызлар өчен махсус язылган әсәр. *Кибет киштәләре абыстай романнары, башваткыч детективлар, һәртөрле уйдырма «фикшннар», тарихи фэнтезилар белән тулды* (А. Тимергалин. Сүнмәс ут янында уйда без...).

*АВАЗ* ❖ **АВАЗ АЛЫШУ (БИРЕШҮ).** Бер-берењә кычкырып хәбәр итү. *Сөнҗәрә шакылдавык шакылдатты, кычкырды, сызгырды, ара-тирә дус кызлары белән аваз алышты – аңа куганда бару кызык иде* (Л. Зөлкарнәй).

**АВАЗ БИРҮ.** 1. Эндәшү, дәшү. *Йә, аваз бир, кыпчак, /кардәш коман, / Йә аваз бир, үле мәмләкәт!* (Роб. Әхмәтҗан. Атлантида). *Син миңа да сер чишмәссең инде? Ниһаять, батыр да аваз бирде* (В. Имамов. Казан дастаны).

Төрдәше: аваз салу 2.

2. Җавап бирү. *Хуҗасы әйткәнгә аваз бирә, тыңлый, янәсе* (М. Рәфыйков. Урманчы малае).

**АВАЗ САЛУ.** 1. Көчле тавыш чыгару; үзеңнең барлыгыңны белдерү. *Һаваларда очкан кошлар / Җиргә аваз салганда, / Ул авазны юра, илем, / Без тапшырган сәламгә* (Х. Туфан. Илгә сәлам). *Ләйлә ни дә булса әйтергә өлгермәде, тышта әтәч яңадан аваз салды* (Г. Бәширов).

2. Сүз башлау, дәшү, эндәшү, сөйләү. – *Ягез, кызлар, китик инде, кич җитә,* – *дип аваз салды берсе* (Ф. Латыйфи. Хыянәт). – *Бар, өйгә кайт!* – *дип, берзаман Тимерҗан ялварулы аваз да салып карады* (В. Имамов. Тозлы яра).

Төрдәше: аваз бирү 1.

3. Хәбәр итү, чыгыш ясау. *Ат җиктереп арба-трибунага, / Авылларга китеп барганын, / Аны яклап аваз салганын / Белә идек инде* (Х. Туфан). *Йә, ишетим тавышыңны, бер аваз сал, җый халыкны, патша төшерәбез* (Г. Бәширов).

4. Каты итеп кычкыру. *Айтуганның әйтеп бетерүен дә көтмәделәр, берничә хатын-кыз белән яшүсмер берьюлы аваз салдылар* (Г. Бәширов). *Җиһанша кем аваз салуын ишеткәч, бәлки, ай-йолдыз күкнең җиденче катына яшеренгәндер* (Н. Гыйматдинова. Күке төкереге).

5. Баланың туарга вакыты җитү. – *Беренче авазын салырга вакыты җитә нәнинең,* – *дип инде кичә үк уйлаганыем,* – *диде кендек әбисе, Газзәбануны күрү белән* (Г. Галиева. Газзәбану).

*АВАЗГА* ❖ **АВАЗГА ЧЫГУ.** Танылу, билгеле булу. *Мокан чокыры безнең авыл малайлары, әбиләре арасында үзенең суы, эре кура җиләкләре белән авазга чыккан* (С. Җәләл).

*АВАНС* ❖ **АВАНС БИРҮ.** 1. Киләчәктә кем белән булса да бәйле өметләр. *Яшь авторга, аванс биреп, җылы сүзләр сөйләделәр* (Сөйләм).

2. Айлык эш хакының ай башында бирелә торган өлеше. *Тегү фабрикалары күлмәкыштан өләшкән, аванс итеп: получкада өсләреннән чыккач, кире салып биргәннәр* (К. Кәримов. Бака каргышы).

*АВАР* ❖ **АВАР ЯККА ТАБА ТЕРӘҮ САЛУ**. Булышлык иткән булып, хәлне начарлату. *Юкка бу эшкә син дә килеп катнашкансың, авар якка терәү салу белән бер булган бит бу* (Сөйләм).

*АВГИЙ* ❖ **АВГИЙ АБЗАРЫ** *миф.* Борынгы Юнанстан патшасы Авгий исеме белән бәйле. Түшәменә кадәр тирес белән тулган 3 мең атлык абзарны Һеракл елга агышын үзгәртеп юдырган. *Авгий абзарларын юган кебек, / Юдырырга иде шул урамны, / Тазартырга – көчле ташкын белән!..* (Л. Шагыйрьҗан).

*АВРОРА* ❖ **АВРОРА, ТУПТАН АТ.** 1917 елгы түнтәреш башлануына сигнал биргән «Аврора» крейсерына ишарә ясалган, «башла!» мәгънәсендә. *[Зирәк] Әйдә, икәү көрәшик! Аврора, туптан ат!* (Х. Ширмән. Авылым учагы).

*АВТОРИТЕТ* ❖ **АВТОРИТЕТ ШҮРЛЕГЕН СҮТҮ** *к.* абруй җуелу. *Шулай да бүген минем авторитет шүрлеген нигәдер җимертеп сүтә ул* (М. Хуҗин. Курагай атлары).
Төрдәше: абруй җуелу һ.б.

*АВТОРИТЕТЛЫ* ❖ **АВТОРИТЕТЛЫ РӘВЕШТӘ.** Каршы әйтерлек урын калдырмаслык итеп. *Ләкин, иптәшләр, мин сезгә шушы җыелышта авторитетлы рәвештә әйтеп куям* (В. Нуруллин. Күпер чыкканда). *[Нури] Кызлар белән сөйләшкәндә генә әйтелгән сүз – сүз түгел. Үлән тәкъдимен, беренче булып, авторитетлы рәвештә менә мин кертәм* (Г. Халит. Таләпчән һәм эзләнүчән талант).

*АВТОРИТЕТНЫ* ❖ **АВТОРИТЕТНЫ КҮТӘРҮ** *к.* абруен күтәрү. *Шушы кечкенә нәрсә дә аның авторитетын кызлар алдында тагын да күтәрә төште: әйе, әдәпле дә ул, игътибарлы да ул, үзен әнә ничек тота да белә, эчә дә белә...* (Ә. Еники. Рәшә).
Төрдәше: абруен күтәрү һ.б.

*АВЫЗ* ❖ **АВЫЗ АЕРУ.** Бер гаиләдә кемне дә булса кыерсытып, начаррак ашату. – *Авыз аерып торма инде, барысына да бертигез бүл* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз аралау; тамак аеру.

**АВЫЗ АЛДА<ЛА>У.** Ашыйсы килгәндә, нәрсә булса да капкалап алу. – *Мә, тик утырганчы, айбагар яр. Авыз алдарга ярый ул* (А. Гыйләҗев. Берәү).

**АВЫЗ АРАЛАУ** *к.* авыз аеру. – *Юньле кеше гаиләсендә авыз аралау белән маташмый инде* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз аеру һ.б.

**АВЫЗ АЧАРГА <ДА ИРЕК> БИРМӘҮ.** 1. Бер сүз дә әйттермәү, сүз әйтергә мөмкинлек тудырмау. *Җирәнтийгә авыз ачарга да ирек юк* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Эчке күлмәктән генә, җилтерәп, әбисе килеп керде, авыз ачарга да ирек бирмичә, чәт-чәт тезә башлады* (Ф. Латыйфи. Ак-карага тимәскә).
Төрдәше: авыз ачарга <да> урын калдырмау; авыз биклә<н>ү; авыз каплану 1; авыз капла<т>у 1; авыз томалану 1; авыз тыгылу 1; авыз шап <итеп> ябылу (каплану); авызга йодрык тыгу; авызга кургашын кою; авызны бикләү 1; авызны йозаклау; авызны йом<дыр>у 1; авызны каплап ябу; авызны мүкләү; авызны тегү; авызны томалау 1; авызны тоту; авызны тыгу (тыгылдыру) 1; авызны <шап> ябу 1; авызы ябылу; җилле кундыру; телгә йозак салу 1; телдән яздыру 2; телне кисү 1; телне кыскарту 1; телне тыю 1; телсез калдыру.

2. Башкаларны тыңламау, үз фикерен генә алга сөрү, үзенекен итү. *Җиһан чынлап һәм өзеп сөйләшергә калган икән, Хафизга авыз ачарга да ирек бирмәде һәм аны комганын кире җиргә куеп сөйләшергә мәҗбүр итте* (Ә. Фәйзи).

**АВЫЗ АЧАРГА КУРКЫП ТОРУ.** Сүз әйтергә яки сөйләшү башларга курку. *Хатыны Сылу белән башка кызлар авыз ачарга да куркып торалар иде* (М. Галәү. Болганчык еллар). *Базардагы итек сатучылар бигрәк кыюсыз, авыз ачарга куркып торалар* («Безнең гәҗит» газ.).
Төрдәше: авыз ачып ләм-мим сүз дәшмәү.

**АВЫЗ АЧАРГА <ДА> УРЫН КАЛДЫРМАУ** *к.* авыз ачарга <да> ирек бирмәү. *Бер сүзенә мең җавап табып, Фәхриҗамал абыстайны да авыз ачарга да урын калдырмаган иде* (К. Бәкер).
Төрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1 һ.б.

**АВЫЗ АЧАРЛЫК ТҮГЕЛ.** «Сөйләү түгел, хәтта уйлау да мөмкин түгел» мәгънәсендә. *Буе-сыны дип тә авыз ачарлык түгел* (Ф. Сафин. Аяусыз әүлия). *Туфанның милли хәрәкәт өлкәсендә фидакяр эшчәнлеге чыннан да искиткеч икән*

*бит! Ләкин бу турыда үзе исән чагында авыз ачарлык түгел иде шул – Туфан моны белгән, әлбәттә* (Х. Туфан һәм Гаяз Исхакый).

**АВЫЗ АЧМАСЛЫК ИТҮ.** Оялту, орышу. *Авызын ачмаслык итте аны / Батыр җанлы, кыю егетләр* (Г. Афзал). *Гөлшәһидәгә әйткәндәй авызын ачмаслык итеп каплаганны көтәме?* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**АВЫЗ <ДА> АЧМАУ.** Эндәшмәү, бөтенләй сөйләшмәү; каршы әйтмәү. *Нәбиуллин авыз да ачмады. Аркасындагы тулы капчыгын тиз генә сәкегә куеп чишә башлады* (А. Әхмәт). *Ләкин тутай бу үзгәрешнең сәбәбен аңлатмак өчен авыз ачмады...* (Р. Батулла. Сөембикә).

Төрдәше: авыз йозаклы (йозакта) булу; авыз йому (йомып калу; тору; утыру); авыз ябу; авызга йозак асу (салу; элү); авызга йөзек кабу (яшерү): авызга йөзек кабып утыру; авызга каз мае кабу (алу); авызга <сары> май кабу (алу); авызга су кабу (алу; кабып тору); авызга су кабып алу; авызга су кабып йоту: авызга су кабып тору; авызга су кабып утыру; авызга су кабып шым булу; авызга су капкан кебек (төсле, шикелле); авызга сумала кабу; авызга сумала чабу; авызга таш тутыру; авызга төймә кабу; авызга чиләге белән су кабу; авызда амбар йозагы булу; авызда йозак булу; авызны биктә тоту; авызны җиде йозакка бикләү; авызны җиде йозакта тоту; авызны йому (ябу); авызны йомып тору; авызны пичәтләү (пичәтләп кую); авызны убырлы карчык пичәтләп китү; авызны чөйгә элү 1; авызны <шап> ябу; авызы <шап> ябылу; ак димәү, кара (күк) димәү 3; «ә» дә, «җә» дә димәү; «ә» дип тә, «җә» дип тә; «ә» юк, «җә» юк; балык кебек дәшмәү; ләм дә юк, мим дә күренми; ләм-мим авыз ачмау; ләм-мим әйтмәү; ләм-мим дәшмәү; ләм-мим дию; ләм-мим сөйләшмичә; ләм-мим сүз; суык су кабып утыру; тел йозакта <булу>; телгә йозак асу; телне йоту; телне кыскарту 2; телне теш арасында (артында) тоту; телне тешкә кыстыру; телне тешләү (тешләп тору / йөрү); телне тыю; тел-теш кузгатмау; тешне кысу.

**АВЫЗ АЧСА, КЕЧЕ ТЕЛЕ КҮРЕНҮ** 1. Ябык, үләр хәлгә җиткән булу; аягында көчкә басып тору. *– Көчле җил искәндә, егылмаса ярый инде: авызын ачса, кече теле күренә бит* (Сөйләм).

Төрдәше: авызын ачса, үпкәсе күренү; ач яңаклы; әрвахка охшаган; әрем ышыклары да юк <бит, ичмасам>; бер карга туярлык ите юк; борыннан кыссаң (тотсаң), җаны чыгарлык (<очып> чыгарга тору); борынны кыссаң, җаны күккә очу; борыны гына утырып калган; ите бетеп, сөяккә калу; йөз сулу; кабырга араларына карга оялырлык; кабырга арасыннан җил йөрү; кабырга беленү; кабырга кабыргага <терәлеп кенә тору>; кабыргасы күренеп тору; кабыргасы саналу (саналып тору); как сөяккә калу; кипкән балык; коры гәүдә калу; коры сөяккә калу; корып кипкән; сөяк патшасы; сөяк сарае; сөяк тәтире; сөяккә калу; тәнендә карга чукырлык та ите юк; элеп киптергән кебек; энә йоткан; эче эчкә ябышкан; эченнән инә үтәрлек.

2. Бик фәкыйрь булу. *Йорт-җире турында сорама инде, авызын ачса, кече теле күренә* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз ачса, үпкәсе (бавыры) күренү 2; авыздан үпкә күренү; аның ишегеннән дә керә, тишегеннән дә керә 2; аның каккан казыгы да юк; ат юк, арба юк, аннан калган бар да юк; әҗәллек тә юк; бер күлмәк белән калу; байда булса – котлы булсын, ярлыда булса – кемнеке?; берсе кешенеке, берсе күршенеке; бете дә юк; икесе кешенеке, өчесе күршенеке; каккан казыгы да юк; каккан казык та булмау; кара җәяү<гә> калу; кесә сызлау; күзгә кырып салырга да юк; күзгә чеметеп салырга да юк; мал очу; морҗадан очу 1; ни керәте юк, ни кетәге; өрергә эте дә юк; таштан юкә сую; теш казырга да юк; шайтаннан да ярлы; юк шөкергә тук шөкер; юкка мин үзем дә тук; юкның аты юк; юктан бар; юктан кодагый; ярлы – тапканда, бай – сагынганда; ярлының акчасы торна булып кычкыру.

**АВЫЗ АЧСА, ҮПКӘСЕ (БАВЫРЫ) КҮРЕНҮ.** 1. *к.* авыз ачса, кече теле күренү 1. *Ачлы-туклы яшәүдән, арудан авызын ачса, үпкәсе күренерлек хәлгә килгән Бибиҗамал апа* (Ш. Хөсәенов).

Төрдәше: авыз ачса, кече теле күренү 1 һ.б.

2. *к.* авыз ачса, кече теле күренү 2. *[Әхмәдиша] Әмма фәкыйрьләрнең соңгы тәгам ризыкларын тартып алуны туктатыгыз. Болай да авызларын ачсалар, үпкәләре күренә аларның* (Ю. Әминов. Умырзая чәчәкләре).

Төрдәше: авыз ачса, кече теле күренү 2 һ.б.

**АВЫЗ <ДА> АЧТЫРМАУ** *к.* авыз ачарга да ирек бирмәү. 1. Бер сүз дә әйттермәү. *Һәр җыелышта үзең сөйлә дә тор, / Бүтәннәргә авыз ачтырма* (Г. Афзал. Җитәкче урында үз-үзеңне тоту турында).

2. Башкаларны тыңламау, үзенекен итү. *Ләкин Анна авызын ачтырмаенча, икенче көнне үк эш эзләргә тотынды* (Г. Исхакый. Ул әле өйләнмәгән иде).

Төрдәше: аваз ачарга <да> ирек бирмәү һ.б. (ике маддә өчен дә).

**АВЫЗ АЧТЫРУ** *дини.* Ураза вакытында, кояш баегач, җимеш һәм тоз кабып, уразаны өзү. *Һәр көнне (һәм чират белән әле!) авыз ачтыру – ифтар мәҗлесләре* (Б. Рәхимова. Бакый сагыш).

Төрдәше: авыз ачу 3; ифтар кылу.

**АВЫЗ АЧУ.** 1. Тавыш бирү, эндәшү, сүз башлау, сүз әйтү. *Шәмси авыз ачып өлгергәнче, Митричев аты, ялт борылып, Даниловны тешләп алырга да өлгергән* (Г. Бәширов. Сиваш). *Мин һаман бизгәк турында сөйләнәм, карты хакында сорашам, ә кыз турында авыз ачарга куркам* (И. Гази. Югалган Мәрзыя).

Төрдәше: сүз ачу (ачып җибәрү); сүз башлау (башлап җибәрү); сүз кату; сүз катып әйтү; сүз кузгалу; сүз кузгату; сүз кушу 2; сүз чыг<ар>у; тел ачылу 2, 3; тел кату; тел чишелү (чишелеп китү); телгә килү 1, 2.

2. Сөйлә<ш>ү. – *Мине мулласыз күмегез!* – *дип авызын ачмас иде, аны Биктимер абзый башына да китерә алмый* (Г. Толымбай. Нигә кыр үрдәге булмаганнар). *Без дәшмәгәч, ул авызын да ачмый* (Ә. Еники. Гөләндәм туташ хатирәсе).

Төрдәше: авыздан чыгару 1; гәп йомгагын сүтү; гәп кору; гәп куерту; гәп сату; гәп сугу; сүз алып бару; сүз алышу (алмашу); телгә алу 3.

3. *дини, к.* авыз ачтыру. *Ахыр без, җыйнаулашып дигәндәй, карчыкны бүген китмәскә, авыз ачып, куна калырга кыстый башладык* (Ә. Еники. Курай). *Безнең ише яланаякларны, кичен авыз ачар алдыннан, урам буенча шаулап кайтыр өчендер инде, азан тыңларга җибәрә торганнар иде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: авыз ачтыру; ифтар кылу.

4. *шаярт.* Тузып ертылган, сүтелгән аяк киеме турында. *Бозау тиресен аннан-моннан иләп теккән итекләр авыз ачкан* (В. Имамов. Казан дастаны). *Җитмәсә, тагын олтаны да авызын ача башлаган* (Г. Шәрәфи. Тәфтиләү).

Төрдәше: авызын ачу 2.

5. Каршы сөйләү. *Сөбханкулов иптәшләргә авыз ачар заман түгел иде* (Б. Камалов).

6. Аптырап калу. – *Рулевой авызын ачмаса, шулай да котылырлар...* (Ш. Камал. Акчарлаклар).

7. Шаккату. *Класс, авызын ачып, хәйран калып тыңлап утыра* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы).

Төрдәше: авыз ачып <карап> тору 3; аһ итү 7; әчәч, печкән этәч!; менә бер әкәмәт!; менә бер әкият!; менә бер галәмәт!; менә бер тамаша! менә <сиңа> кирәк булса!; менә сиңа бер кыйсса!; менә сиңа галәмәт!; менә сиңа мә 2!

**АВЫЗ АЧЫП БАРУ (ЙӨРҮ).** 1. Дикъкатьле, сизгер, уяу булмау. *Теге йөзе карага: «Котларын алдым!» – дип мактанырлык та булмасын, чамасыз гамьсезләнеп, бик үк авыз ачып йөрергә дә ярамый* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Малайларның колагына киртләп куясы булыр: ул тирәләрдә сак булу кирәк, авызларын ачып йөрмәсеннәр* (А. Тимергалин. Таш алиһә).

Төрдәше: авыз ачып <карап> тору 1; авыз ачып тыңлау 2; авыз ачып көтеп тору (утыру) 2; авыз белән карга (кош, чыпчык) аулау 2; авыз күтәреп йөрү; авызда чебен уйнату; авызны ачып карап тору.

2. Мәлҗерәп йөрү. *Шуңа күрә суга сусаган карга сыман авыз ачып йөрмә* (В. Имамов. Сөләйман солтан).

3. Юкка-барга исе китеп, кирәкле эшне эшләмәү. *Ярый алайса, бар, эшлә, тик моннан соң авызыңны ачып йөрмә!* (Ә. Еники). *Ләкин меңбашлары авыз ачып бару аркасында, Мәскәүнең бер зур олавы белән Болгар каласыннан бирле килгән ризык-шайман тулы арбалар бер кичүгә килеп тыгылганнар* (В. Имамов. Карабәк).

Төрдәше: авызда чебен уйнату 3.

**АВЫЗ АЧЫП КАЛУ.** 1. Сизми калу. *Алпут дигәнең үзе урып алмагае... Авыз ачып калуың мөмкин...* (И. Гази. Онытылмас еллар).

2. Буш, коры, өлешсез калу. – *Гомәр, ал кистәнне, кара, авыз ачып калма!* (Г. Ибраһимов). *Нугай, Хаҗитархан, Кырымнар Мәскәү белән сату итсә, Казан, Себер, Бохара яклары авызларын ачып калачак* (Р. Батулла. Сөембикә).

Төрдәше: авыз күтәреп калу 2; буш <кул белән> калу; иренне ялап калу; исен иснәп кенә калу; колак кагу; колак кактыру; коры калу; өлешсез калу.

3. Урлату. *Сатучыларның, арадашчыларның сөйләгән сүзен тыңлап торсаң, мөлкәтеңнән авызыңны ачып калырсың, валлаһи* (Р. Батулла. Сөембикә).

Төрдәше: колак кагу.

4. Форсаттан файдалана алмау. *[Суфи] Вакыттан файдалана белүчеләр бәхетлеләр, безнең шикелле авыз ачып калучылар мәңге бәхетсезләр һәм гомер буе шулай бәхетсез булып калачаклар* (К. Тинчурин). *[Икенчесе] Монда правило көтеп торсаң, авызыңны ачып калырсың!* (Г. Камал. Безнең шәһәрнең серләре).

Төрдәше: авыз күтәреп калу 1.

5. Гаҗәпләнү, аптырау. *Без шаккатып авызларны ачып калдык. Менә сиңа мә! Фатыйма түтине күрмәде дә бит ул!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Ул арада Марва Мәлих бүлмәсендәге әйберләрне күздән кичерәсе иткән иде, керә-керүгә авыз ачты да калды* (Ә. Баянов).

Төрдәше: авызны ачып (ачкан килеш) катып калу 1; акыл баштан китү (чыгу) 3; аягүрә (аяк үрә) катып калу; аяз көндә (көнне) яшен <ату> кебек; аяз көндә (көнне) яшен сугу; аяз көндә (көнне) яшен суккан кебек; аяз көндә яшен яшьнәгәндәй <булу>; аяз көнне (көндә) яшен сукты диярсең; аяз күккә яшен ташы атылу; аяз күктән яшен суккан (яшьнәгән) кебек; күзләр акаю (алару); башка таяк белән суккандай булу; башка сыймау (сыйдыра/ сыя алмау; сыешмау); башка сыя торган түгел; башка яшен суккан кебек <булу>; гаҗәп калу; гаҗәпләнеп күз акаю; телсез калу 1; телсез-авызсыз калу 1; катып калу; кичә үлсәм (үлгән булса), белми үләсем (ишетми үләм) икән; колаклар үрә тору 2; күзләр акаю (алару), күз әсәрү; күз<ләр> шарлану (шар<дай> булу); ни <күзем белән> күрим!; нием калган; таң<га> калу 2; чәч үрә тору 1; шак кату 1.

6. Соклану; гаҗәпләнү. *Агыйделгә төшеп калдым. Тотмадың беләгемнән... – дип, бер сызгырып җибәреп, мәҗлес халкы авыз ачып тын кала, кат-кат җырлавын сорый башлый* (Ә. Моталлапов. Мәхшәр).

Төрдәше: авыз ачып көтеп тору (утыру); авыз ачып тыңлау (карау); авыз ачып хәйран булып кату (катып калу); авызны ачып (ачкан килеш) катып калу 2; вәйран булу 3; вәйран калу; гаҗиз булу (калу); ике күз дүрт булу; искә төшсә, исе китү; иске авыздан яңа сүз; истән таю; кайдан җил ташлады (ыргытты); таң<га> калу 1; хәйран калу; чәч үрә тору 2; шак кату 2; юкәдә икән чикләвек!; имәндә икән чикләвек!

**АВЫЗ АЧЫП КӨТЕП ТОРУ (УТЫРУ)**. 1. Кемгәдер ышанып, гамьсез генә көтү. *Кем соң шулай авызын ачып көтеп утыра. Кара син ә!* (Г. Бәширов). *Авыз ачып көтеп утырудан файда чыкмасын аңлагач, кайсыбер адәмнәр, пессимистлар һәм атеистлар сүзен колакка алмыйча, әмәлен эзли башлады* (З. Мурсиев. Солтанъяр).

2. Игътибарсыз, ваемсыз булу. *Ник авызыңны ачып көтеп торасың?! Боларны шкафка алып куй!* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз ачып бару (йөрү) 1 һ.б.

3. Гаҗәпләнеп, сокланып карау, тору. – *Сез ике җүләр, сөләгәй агызып: а, шәп кеше икән, харап икән, дип авыз ачып утырасыз, ди* (Г. Ибраһимов).

Төрдәше: авыз ачып калу 6 һ.б.

**АВЫЗ АЧЫП ЛӘМ-МИМ СҮЗ ДӘШМӘҮ.** Нинди булса да сәбәптән сүз дәшмәс булу. *Малай шулхәтле шүрләде, өенә кайтканчы авыз ачып ләм-мим сүз дәшмәде* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз ачарга куркып тору.

**АВЫЗ АЧЫП <КАРАП> ТОРУ**. 1. Сизгер булмау, ваемсыз булу, аңгыраланып тору. *Һич кеше китереп бирмәс – алыгыз дип, / Үзебез авыз ачып карап торсак* (М. Гафури). *Агач бүкән шикелле төз катып авыз ачып торды да тиз арада өенә тыраклады* (Ә. Баянов).

Төрдәше: авыз ачып бару (йөрү) 1 һ.б.

2. Алдан хәстәрен күрмәү. *Кеше хәзер барысы да, яше тулып җитәр-җитмәс борын, улларын өйләндерәләр. Без авызыбызны ачып карап тордык* (Г. Камал).

3. Шаккатып, сокланып карап тору. *Син бер матур әкият уйлап чыгар, / Авыз ачып торсын тыңлаучылар* (Г. Афзал).

Төрдәше: авыз ачу 7 һ.б.

**АВЫЗ АЧЫП ТЫҢЛАУ.** 1. Гаҗәпләнеп, бирелеп, сокланып тыңлау. *Бертуктаусыз сайраган хатынны Җәмилә авыз ачып тыңлады* (Н. Гыйматдинова. Кыргый).

Төрдәше: авыз ачып калу 6 һ.б.

2. Дөньясын онытып, ваемсыз булып, дикъкатьсез. *Авызын ачып тыңлап тора торгач, барасы җирен дә онытты* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз ачып бару (йөрү) 1 һ.б.

**АВЫЗ АЧЫП ХӘЙРАН БУЛЫП КАТУ (КАТЫП КАЛУ).** Шаккату, чиктән тыш гаҗәпләнү. *Бары да, авызларын ачып, хәйран булып, бу асыл сөяк колынга карап каталар* (Г. Ибраһимов. Алмачуар).

Төрдәше: авыз ачып калу 6 һ.б.

**АВЫЗ АШКА ТИСӘ, БОРЫН ТАШКА ТИЮ.** «Кулыңа дәүләт-мал керсә, бәла көт тә тор» мәгънәсендә. *Ә үзем өнемдә беркайчан да әйтмәгән: «Нигә минем авызым ашка тисә, борыным ташка тия», – дип өзгәләнепме-өзгәләнәм икән* (Г. Галиева. Өзелгән өмет).

Төрдәше: авыз балга тигәндә, борын җиргә тию.

**АВЫЗ АШКА ТУЮ.** Туйганчы ашау, ризык кытлыгын белмәү. *Авылга кайтып, эшли башлагач кына, авызым ашка туйды минем* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз ипигә (икмәккә) тую; авыз тую.

**АВЫЗ <НИ / НӘРСӘ> ӘЙТКӘННЕ КОЛАК ИШЕТМӘҮ.** Телгә ни килсә, шуны сөйләү; алдын-артын уйламау. *Авызың ни сөйләгәнне колагың ишетәме синең, Арслан агай?* (Ә. Баянов).

Төрдәше: алны-артны уйламыйча; баш ватып, күз чыгарып тормыйча; баш-күз акаю (тогу) 1.

**АВЫЗ<ЛАРЫ> БАЛ ДА МАЙ <БУЛСЫН>!** «Бәхет эчендә, муллыкта яшәсеннәр» теләге. *– Әйе, әйе, гомерләре озын булсын, бала-чагалары мул, абзар тулы мал, авызлары бал да май булсын!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: авыз балда, кул майда булсын!; авыз-борын май булсын; авызына (авызыңа; авызыгызга) бал <да май>!; авызына май!; авызыңа бал да май, алды-арты хәерле (хәерлегә; яхшы) булсын (була күрсен)!; артыңа колын тай; авызыңа бал да яу!; авызыңа баллы яу; авызыңа баллы җофар җау!; авызыңа каз боты (мае)!; авызыңа сары май; бер кулың балда, икенчесе майда булсын.

**АВЫЗ БАЛГА ТИГӘНДӘ, БОРЫН ҖИРГӘ ТИЮ** *к.* авыз ашка тисә, борын ташка тию. *– Кер тизрәк, – ди. Әмма ләкин авыз балга тигәндә, борын җиргә тиде. Тәрәзәдән башымны тыгарга гына өлгергән идем, кемдер ботаклы таяк белән сырт буйлап шарт берне!* (Г. Әпсәләмов).

Төрдәше: авыз ашка тисә, борын ташка тию.

**АВЫЗ БАЛДА, КУЛ МАЙДА.** Байлыкта, мул тормышта яшәү. *– Мәскәүдә төпләнгән идем, авызым балда, кулым майда* (Н. Гыйматдинова. Ачкыч).

Төрдәше: авыз балда, майда (балда-майда) булу (йөзү); авыз-борын балда, майда; авыз-борын майга буялу; авызы-борыны (кулы) балда-майда; ашаганы алдында, ашамаганы артында; аш<лы>-сулы булу; ашы – май, эче бөйрәк, сөт өсте каймак; аю аяк очы җиргә тимәү 2; аю башы гына юк; бал да май эчендә йөзү; бал белән майда йөзү; бал да май эчендә тору (яшәү); бал-май <гына> ашап тору; бал-май эчендә <йөзү>; бал-май эчендә тәгәрәү; бал-май эчендә тору (йөзеп йөрү; яшәү); бал-майда йөзү; белен кабып яшәү; бер кул майда, бер кул балда; бот күтәреп, түшәмгә төкереп яту; бояр булып утыру (яту); дөньясы киң (иркен); дөньясы түгәрәк, тормышы бөтен; иркен<лектә> яшәү; иркен тормышта яшәү; кош сөте генә юк (җитмәү); күгәрчен сөте генә юк; май эчендә бөердәй (бөер кебек); май эчендә яшәү; майда йөзгән кебек <бару>; майда йөзү; майда шуган кебек бару; майлаган кебек; майланган шикелле (майлангандай); сандугач теле генә юк; шуып баргандай муллыкта яшәү; пычак майда йөзү; сары май эчендәге балавыз кебек.

**АВЫЗ БАЛДА, КУЛ МАЙДА БУЛСЫН!** *к.* авыз<лары> бал да май <булсын>! *Яшь гаиләгә авыз балда, кул майда булсын! дип кенә әйтәсе килә* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз<лары> бал да май <булсын>! һ.б.

**АВЫЗ БАЛДА, МАЙДА (БАЛДА-МАЙДА) БУЛУ (ЙӨЗҮ)** *к.* авыз балда, кул майда. *– Авызы балда-майда булыр, ичмасам! Кулында – эше, кесәсендә – акчасы!* (Ф. Яхин. Мөдәмир, яки «Тәрәзә төбең үрмә гөл!..»). *Химия, авиация, техник белгечлекләр буенча китсәң, авызың балда-майда йөзәр, торган җирен шәһәр үзәгендә, кайнар сулы өйдә булыр* (Т. Галиуллин. Ул яшәсә, без бәхетле).

Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

**АВЫЗ БАРМАУ.** Әйтергә оялу, кыймау, батырчылык итә алмау. – *Бик кыстама инде, әйтә алмыйм, авызым бармый* (Сөйләм).
Төрдәше: тел бармау (әйләнмәү).

**АВЫЗ БАШ <БУЛУ>.** Лыгырдавык кеше хакында. *Берәүнең йөзендә борын – хәким, икенченең йөзендә авыз – баш* (Ш. Галиев. Канатлы сүзләр).
Төрдәше: йөздә авыз баш <булу>.

**АВЫЗ БЕЛӘН ӘЙТ, БОРЫН БЕЛӘН ТАРТ.** Каргаган вакытта «каргышың үзеңә кайтсын» мәгънәсендә. *Авыз белән әйт, борын белән тарт* (Ай колакланса, ни була?).
Төрдәше: авызыңнан чыгып, җылы куеныңа керсен; җылы авызыңнан җылы куеныңа.

**АВЫЗ БЕЛӘН КАРАУ.** 1. Саксыз эш итү, игътибарсыз булу. *Авыз белән карадыңмы әллә, бер сарыгың юк бит!* (Сөйләм).
2. Аптырап калу, җебеп калу. *Инде авыз беләнрәк караса, бетте диген!* (Ш. Камал. Акчарлаклар).
3. Хушланып, яхшы ният белән карау (күбрәк сәнгатькә бәйле). – *Телим – чекрәеп карыйм, телим – авызымны ачып, авызым белән карыйм. – Авызың белән карасаң, әйбәтрәк булыр иде* (Ф. Садриев. Кыргый алма әчесе).

**АВЫЗ БЕЛӘН КАРГА (КОШ; ЧЕБЕН; ЧЫПЧЫК) АУЛАУ.** 1. Уңай мизгелне ычкындыру. – *Ни өчен разведчиклар авызлары белән карга аулыйлар? – дип кычкырды Нәдерша* (И. Туктаров). *Авызың белән кош аулап йөрисең. Бу вакыт эчендә син түгел, мин үземә каратыр идем инде* (Ш. Бикчурин).
2. Сизгер, уяу булмау. *Колхоз рәисен әйтер идем, авызы белән чыпчык аулап йөри, борын астында ни-нәрсә майтарганнарын күрми* (М. Әмирханов).
Төрдәше: авыз ачып бару (йөрү) 1 һ.б.

**АВЫЗ БЕЛӘН КОШ КЫНА ТОТМАУ.** Мактану, булдыра алмаганны сөйләү. *Авызың белән кош тотма, барасы юлыңа бак* (Х. Әюп). *Үзен авызы белән кош тота ала торган кеше итеп күрсәтергә маташу галәмәте юкмы?* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).
Төрдәше: авыз белән <урак> уру 1; авыз исемле капчыктан учлап борчак ату; авыздан кош очыру 2; авыздан күбек чәчү; авыздан тере саескан очыру 2; акча бездә бер чорма; акча бездә – үлсәң, кәфенең чорнарга җитәрлек; акча <бездә> бер букча; акчасын тавык та чүпләп бетерә алмый (бетермәс); борчак ат<тыр>у 1; борчак чәчү 1; борчак яру; саескан очырту; тел белән ярма яру; тере саескан очы<р>у.

**АВЫЗ БЕЛӘН КОШ ТОТАРЛЫК.** Уңган, матур. – *Сөбханалла, күз тимәсен, авызы белән кош тотарлык булып җиткән* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз белән кош <карга> тоту 2.

**АВЫЗ БЕЛӘН КОШ (КАРГА) ТОТУ**. 1. Сизгер, уяу булмау, игътибарсызлык күрсәтү. – *Арбаларны кешесез калдырмыйм, авызы белән кош тотып йөрмәсен, – ди* (А. Гыйләҗев). *Авызың белән кош тотма, / Барасы юлыңа бак. / Замана – кроссовкада, / Син һаман яланаяк* (Х. Әюп. Син һаман яланаяк).
Төрдәше: авыз белән карга (кош, чебен, чыпчык) аулау 2.
2. Бик булдыклы, зирәк. – *Үзе ул бик зирәк хатын иде, теле дисәң – авызы белән кош тотар, ярыйм дисә – иблискә яучы булыр, инде кеше тикшерә башласа – инә күзеннән үткәрә торган иде* (Ә. Еники. Йөрәк сере).
Төрдәше: авыз белән кош тотарлык.
3. Телгә оста булу, үткен телле. *Бу – осталык, авыз белән кош тоту, судан коры чыга белү, ләкин чынлабрак уйлап карасаң, бу әле егет юлы түгел яки, дөресрәге, егет юлы болай гына булырга тиеш түгел* (Ф. Хөсни).
Төрдәше: авызга җен төкерү һ.б.
4. *диал.* Аңгыра. *Көне буе авызы белән кош тотып йөри шунда* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл<га; -дан> җиңеләю 1 һ.б.

**АВЫЗ БЕЛӘН ТӘЛИНКӘ АРАСЫНДА ЙӨРҮ.** Кашык белән тиз-тиз ашау. *Кашыгы күз иярмәс тизлектә авыз белән тәлинкә арасында йөрергә кереште* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).

**АВЫЗ БЕЛӘН ТЫҢЛАУ.** Сөйләгәнгә игътибар булмаганда әйтелә. *Колагы белән карап, авызы белән тыңлаган кеше ничек борылсын!* (А. Гәрәева. Ни һоу! Нихәл?).
Төрдәше: бер колактан кереп, икенчесеннән чыгу (чыгып китү / сызу); колак кырыеннан үткәрү (шудыру); колак очы белән тыңлау; колакка да кермәү (элмәү); тишек колак.

**АВЫЗ БЕЛӘН <УРАК> УРУ.** 1. Кул белән эшлисе урынга тел белән мактану. *Авызың белән яхшы урасың уруын, нәтиҗәсен генә кайчан күрербез икән?* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз белән кош кына тотмау һ.б.
2. Кеше тапкан ризыкны ашау. *Моның акча җимеше икәнен уйламый да, авызы белән ура гына* (Сөйләм).
Төрдәше: кеше җилкәсендә яшәү.

**АВЫЗ БЕЛӘН ЧЕБЕН АУЛАУ** *мыск.* Берни эшләми, тик утыру, эшлексез. *[Хөбәйбә] Тота, мулла абзый, авызы белән чебен тота* (Т. Гыйззәт).
Төрдәше: авыз күтәреп йөрү; арка җылытып яту 2; арка киптерү 2; арка кыздыру 2; ат тизәге тибү (тибеп йөрү); аяк тигенгә кабару; боз киптерү; бот күтәреп, түшәмгә төкереп яту; бот күтәреп яту; буш йөрү; буш тору (булу; яту); бушны бушка (юкка) бушату (аудару, әйләндерү); бушка вакыт уздыру; вакыт узсынга (узганга), чабата тузсынга (тузганга) йөрү; вакытны бушка әрәм итү; вакытны бушка уздыру (уздырып йөрү); вакытны бушка үткәрү; вакытны исраф итү; гомер сату 2; гомер уздыру (үткәрү) 2; гомерне зая<га> уздыру; җил куу; җил куып йөрү; киләп сару (сарып йөрү)); койрыкны сыртка салу 2; комнан бау (аркан) ишү 2; корыны бушка авыштыру 2; корыны бушка аудару 2; куыш карбыз тибеп йөрү; күктән каргалар санау; суык туңдырып йөрү; т<ы>рай тибү (тибеп йөрү; үткәрү); тик яту; түбә тактасы санап яту; түшәм санап яту; түшәмгә асып киптерү; түшәмгә төкереп яту; түшәмдә таракан санау; түшәмнән исәп алу; унны тугызга әйләндереп йөрү; шар сугу 2; шар сугып йөрү (яту); шар тибү; эт <көтүе> куу (куып йөрү); эт сугару (сугарып йөрү); эт типкеесендә йөрү; эткә печән чабу (чабып йөрү); юкны бушка авыштыру; юкны бушка аудару; юкны бушка бушату (тутыру); юкны бушка йөкләү; юкны бушка төяү.

**АВЫЗ БЕР БУЛУ.** Алдан сөйләшү нигезендә бердәм булу. *Янә моның морадифы: Күп авыз бер булса, бер авыз юк булыр* (К. Насыйри). *Бүре күргән этнең авызы бер булыр* (Мәкаль).

**АВЫЗ БИКЛӘНҮ** *к.* авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1. *Әмма куркудан телем ябышкан, авызым бикләнгән иде* (Ф. Яхин. Сихерче кызы). *Берәр юньлерәк сүз әйтмәсме дип, барысы да Гарәфи картка борылдылар, тик аның да авызы бикләнгән иде* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1 һ.б.

**АВЫЗ БИКЛӘҮ.** Сөйләшмәү яки сөйләшүдән туктау. *Сиңа ошар өчен генә пәрәнҗә ябынып, авызымны бикләп утырып булмас инде* (Т. Әйди. Божра). – *Сайлауларда депутат итәләр дә, авызымны бикләп, сүз әйттермиләр!* (А. Хәлим. Трофей).
Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗ БИКТӘ БУЛУ.** Күп сөйләмәү, сер саклый белү. – *Аягың җитез, зиһенең йөгерек, кулың нык, сүзең акыллы, йортың таза, авызың биктә булсын!* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).
Төрдәше: авыз <тулы> <кара> кан булса да, дошман (чит кешеләр) алдында төкермәү (төкерергә ярамау); авыз <эче> тулы <кара> кан булса да, <дошман (чит кешеләр) алдында> төкермәү (төкерергә ярамау); авыз тулы <кара> кан булу; авызга ия булу 1; авызга кан килсә дә төкермәү; авызга хуҗа булу 1; авызда кан булса да, кеше алдында төкермәү; авызда кара кан булса да төкермәү; авыздагы кара канны йоту; авыздан сүз чыкмау; авыздан кан килсә дә төкермәскә; капчыгы чишелмәү; сер итеп саклау (тоту); сер итү; сер сыю; сер сыя торган <кеше>; сүзенең ире булу; үз сүзенә үзе хуҗа.

**АВЫЗ БОЗУ.** 1. Канәгатьсезлекне, ризасызлыкны, мыскыллауны белдерү (авыз яки иреннәрне кыегайту). *Авыз бозып карауларына күнегеп киләм инде* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү); авыз кыйшайту; авыз чалшайту; авыз ямьшәйтү.
2. Телгә алып сөйләргә җирәнерлек нәрсә сөйләү. *Үз сүземне сүз итәм дип, аның белән авыз бозып утырасым килми әле* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз буяу; авыз пычрату 2.

**АВЫЗ БОЗЫЛУ.** Ашау-эчү гадәтләре үзгәрү. *Тик соңгы елларда гына чәйгә бик кинәндермиләр, халыкның да авызы бозылды, элек такта чәй кунак чәе иде, хәзер салып кара такта чәйне, бала-чагаларына хәтле: «Бу нинди чүп тутырдыгыз: агач тузаны, авызга керә», – дип мырылдый башлый* (А. Гыйләҗев. Җомга көн кич белән...). *Ипи түгел, авыз бозылгандыр яки*

*акула йөзгечләре, трюфель гөмбәләре һәм чама хисләре...* («Туган як» газ.).

**АВЫЗ БӨРЕШТЕРҮ (БӨРШӘЙТҮ).** 1. Ризасызлык белдереп, иреннәрен эчкә бөгү. *Җиңгәсе, авызын бөрештереп, көйли-көйли әйтеп куйды* (Г. Бәширов. Намус).
Төрдәше: авыз бозу һ.б.

2. Үпкәләү, төшенкелеккә бирелү, өметсезләнү; күңел сүрелү. *Үпкәләсен, үпкә ашар, нинди балалар холкы, бер сүз әйтер хәл юк, авызын бөрештереп үпкәләргә генә тора, көннәр буе сөйләшми* (К. Кара. Көнбагыш сатучы).
Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2; авыз купайту; авыз күпертү 1; авыз салу; авыз салын<дыр>у; авыз түбән җибәр<еш>ү (боз<ыш>у; китәр<еш>ү) 2; авыз турсайту; авыз-баш салын<дыр>у; авыз-борын салын<дыр>у; авыз-борынны турсайту; әвен яну; әвене янган кеше кебек; әвене янганмыни; әвене янып барганда; әвененә ут кабу; балта<сы> суга төшү (төшкәндәй) <кебек>; балтасы суга төшкән кешедәй (адәмдәй); балтасын җуйган кеше кебек; балтасын суга төшерү; баш җиргә төшү; баш ию 2; башка көл сибү (кою); башны асу; башны кырын салу; башны <аска; түбән> салындыру (төшерү); бәгырь бозга әйләнү; боек күңел<ле> 2; борын асылындыру; борын салу; борын салын<дыр>у (төш<ер>ү) 1; борын сал<ындыр>ып йөрү; борын сал<ындыр>ып утыру; бүлтәйгән нәрсә; ваемга салу; дөнья вату; дөньяга каш җимерү (җыеру); йөрәктә утыру (утырып калу); кара болыт булып йөрү; карага бату; карага батып йөрү; карага коелып йөрү; кәеф боз<ыл>у; кәеф китәрелү; кәеф китү; кәеф кырылу; кәеф төшү; кәефкә көя төшү; кәефне җибәрү (төшерү); кәефне кыру; кибәне янган; күңел боек булу; күңел җәберсенү; күңел кырылу; күңеле китек; күңелсезгә күлмәк кигертмиләр; нөктә тоту (саклау); серкәсе су күтәрмәү; сөмсере коелу; сүз күтәрмәү 1; сынган күңел; сынык күңел; төшенке күңел; үпкә кабару; үпкә ташу; үпкә тоту (саклау); хәтер калу.

**АВЫЗ БУЯУ** *к.* авыз бозу 2. – *Авызымны буяп булса да әйтим инде* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз бозу 2; авыз пычрату 2.

**АВЫЗ БҮЛТӘЙТҮ (БӘЛШӘЙТҮ)** 1. *к.* авыз бөрештерү (бәлшәйтү) 2. – *Дуня! – диде Нина, авызын бүлтәйтеп, – син нәрсә?* (Д. Каюмова. Сабырлык). *<...> малайның йөзе бозылды, ул, гарьләнеп, авызын бәлшәйтеп елап җибәрде* (Д. Булатова. Күлмәк).
Төрдәше: авыз бөрештерү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

2. Ачу хисе барлыкка килү, ачулану. *[Хәмидә] (авызын бүлтәйтеп, бик ачу белән, бер торып, бер утырып). Ишкәннәр икән, вәгъдә бүләгендә үк алай итеп мыскыл иткәч, башкаларында алар тагын да изәрләр* (Г. Камал. Бүләк өчен).
Төрдәше: авыз турсайту; авыз-борын турсайту (турсаю); ачу бүртү; ачу итү; ачу кабарту; ачу <болыты> кабару; ачу кабызу; ачу кабыну; ачу казаны ташу; ачу <казаны> кайнау; ачу килү; ачу китерү; ачу кубу; ачу кузгалу; ачу куыгы кабару; ачу кую; ачу утын кабарту; ачу күмеренә җил өрү; ачу уты салу; ачу утын кабарту; ачу чыгару 1; ачу чыгу; ачуга ирек бирү; ачудан кара көю; ачудан ут очкыны кебек кызу; бәбәк акайту; буасы ташып чыгу; гайкасын бору (кысу) 1; дөньясын астын өскә китерү; җен ачуы килү (кузгалу; чыгу); җен ачуын чыгару; җене кубу; җене кузгалу; җене тору; йөзе кара коелу 1; йөзе кара көю; йөзе караю; йөзе күбенү; йөрәккә чыдый алмау; кан кайнату; кан кайнау 2; кан кату 2; кинә тоту; күкерт кебек (күкерттәй) кабыну; күңелдә кер йөртү (саклау); кызып китү; үт сытылу; чыгырдан чыгу (ычкыну).

**АВЫЗ БЫЛЧАЙТЫП ТОРУ** *гади с.* Кеше күңелен күрер өчен, елмаеп тору. *Мин үзем аларның шулай дип ялганлаганнарын тыңлап, бик бәхетле булып күренер өчен, авызымны былчайтып торганым бар. Ләкин бәхетле була алганым юк* (Ф. Әмирхан).
Төрдәше: авыз белән карга (кош, чыпчык) аулау; авыз белән кош тотарлык.

**АВЫЗ ЕРШАЕП КИТҮ** *гади с.* Ихтыярсыздан авыз бер якка кыегаеп, чалышаеп китү (ачы әйбер капканда, еларга җыенганда). *[Карт] еламаска тырыша иде, ләкин ихтыярсыз авызы ершаеп китте* (Ш. Камал).

**АВЫЗ ЕРУ**. 1. Җитди сөйләшкәндә, дәшмичә, мыскыллап елмаю. *Син, Газиз, чынлап сөйләшкәндә, авызыңны ерма әле* (Ф. Әмирхан). *Үзең галстук таккансың, үзең шуны да белмисең дигәндәй, зур канәгатьлек белән авызын ерды* (З. Хөснияр).

2. Юк-барга көлү. – *Ярар, егет, авызыңны күп ерма! Кешесенә карап ера торган бул*

(Ф. Әмирхан). *А, юк, бу әкият түгел, бу чын, бу дөрес, ләкин карт аны кемгә генә сөйләсә дә, а в ы з е р а л а р* (Н. Гыйматдинова. Китәм, димә...).

3. Ачык рәвештә, яшермичә. *Алар бездән а в ы з е р ы п көлделәр* (Г. Толымбай. Мужик фәлсәфәсе). *Хәйдәр абыйга нәрсә, а в ы з ы н е р а торгандыр инде* (К. Кәримов. Бака каргышы).

4. Бик нык шатлану, шатлык эчкә сыймау. – *А в ы з ы ң н ы бик ж ы р м а, күрше* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә). *Ярый әле, ике-өч атнадан соң яннарына Яхшыбай бәк а в ы з ы н е р ы п кайтты* (В. Имамов. Карабәк).

Төрдәше: авыз ерык <булу>; авыз ерылу; авыз җәелү; авыз җәю (җәеп тору); авыз иләк кадәр булу; авыз колакка (колак артына) җитү (китү); авыз колакка кадәр <колагынача> ерылу (җитү); авыз колакта, <колак еракта; маңгайда>; авызны бөтен колакка еру; авызны җыя (җыеп ала) алмау 3; авызны колак артына элү; авызны колакка кадәр еру; аҗаган яктысы уйнау; айга сикерү 3; ак җәймәле көн туу; атка менгәндәй булу; аяклар җиргә (идәнгә) тимәү 1; баш күккә (түбәгә; түшәмгә) тию (күтәрелү; бәрелү); баш күккә (түбәгә) тиярдәй булу; баш түбәсе күккә тию; башы түбәгә (түшәмгә) тию; бәгырь сикерү; җиде кат күк өстенә менеп утыру; җиде<нче> кат күктә < тою>; җиде<нче> кат күктә хис итү; җиденче кат күккә очу; җиденче кат күккә чөю; җиденче кат күктә таган атыну; җире-күге белән шатлану; йөз ачылу (ачылып китү; балку); йөзе кояш <булу>; йөзе көн кебек; йөзе ай дә кояш; йөзе яктыру (яктырып китү); кош тоткандай булу; күккә ашу 2; күккә сикерердәй булу; күккә сикерү 1; күккә (күкләргә) чөю; көлгән авыз күрекле булу; күңел җиденче кат күктә; түбә күккә (түшәмгә) тию; түбә түшәмгә очу; түбәсе күккә ашу; түбәсе күккә җитү (тию); түбәсе күктә <булу>; түбәсе түшәмгә тию; шатлык басу; шатлык кичерү; шатлык ташу; шатлыктан тел югалу.

**АВЫЗ ЕРЫК <БУЛУ>.** Елмаю, көлү. *Ә кече улының а в ы з ы е р ы к, үзе артыннан хатынын да түргә әйди бирде* (Ф. Яхин. Бар икән күрәселәр).

Төрдәше: авыз еру 4 һ.б.

**АВЫЗ ЕРЫЛУ.** Шатлык эчкә сыймау, үтә куанудан киң итеп елмаю. *Апайның безне күргән саен а в ы з ы е р ы л а да, ничек тә булса берәр нәрсә әйтәсе килгәне сизелә иде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: авыз еру 4 һ.б.

**АВЫЗ ЕРЫП КАРАУ.** Җитдилекне аңламау, ирония белән карау. – *Сезнең фидакярлеккә а в ы з е р ы б р а к карарга өйрәндекме?* (Т. Миңнуллин).

**АВЫЗ ҖӘЕЛҮ.** Куанычтан киң итеп елмаю. *Үзенең шулай тапкыр шаяртуыннан бик канәгать иде бүлмә хуҗасы: а в ы з ы җ ә е л д е, болай да кызгылт йөзе тагы да кызара төште* (Р. Кәрами. Сөеп туймас чакларың).

Төрдәше: авыз еру 4 һ.б.

**АВЫЗ ҖӘЮ (ҖӘЕП ТОРУ).** Урынлымы-урынсызмы, килешәме-килешмиме, авызын киң итеп елмаеп тору. *Кочкан тезләрен ычкындырып, Гыйрфан, ниһаять, кымшанып куйды һәм зәһәр көлемсерәп а в ы з ы н җ ә й д е* (Э. Касыймов. Һаваларда тургай).

Төрдәше: авыз еру 4 һ.б.

**АВЫЗ ҖЕБЕГӘН< БУЛУ>.** 1. Сер саклый алмау. – *А в ы з ы җ е б е г ә н б у л г а ч, нигә соң аңа сөйләдең?* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз иләк белән бер <булу>; авыз тишек <булу>; авызда сер (сүз) тотмау (тормау) 2; авызына сүзе сыймау 2; авызына теле сыймау 2; авызының тоткасы юк; аран авыз; ачык авыз<лы> 6; ачык капкага кем кермәс; иләктә су тормау; ияге тишек; ияк асты тишек; капчык <төбен; төбеннән тотып> селкү; капчык чишелү; күәс төбен кагу; сер ачылу; сер капчыгы ертылу; сер капчыгын <төбеннән тотып; чыгарып> селкү; сер пәрдәсен каплау; сер сандыгын ачу; сер сандыгыннан сандугач очу; сер сату; сер сүтү; сер сынату (сыймау); сер тишелү; сер тишү; сер төенен тишү (чишү); сер түгел; сер чишелү; серне ачу (ача төшү); теле авызга сыймау 5; теле тышау тотмый; теленә сүзе сыймау; чабатасы тишек; эчендәге тышында.

2. Сүзен аңлаешлы итеп әйтә алмаган, мескен кыяфәтле кеше турында. *А в ы з ы җ е б е г ә н б у л г а н г а, аның ни гаебе бар инде* (Сөйләм).

Төрдәше: авызына сүзе сыймау 1.

**АВЫЗ ҖЕБЕТҮ** *гади с.* 1. Бераз гына эчеп алу. – *Әйдәгез, ул килгәнче, менә монда а в ы з н ы җ е б е т ә торыгыз, – дип, егетләрне тире-яры тутырган кладовойга алып кереп, бал эчерергә тотынды* (М. Гали).

Төрдәше: авыз чайкау 4; авыз чылату (чылатып алу); авызга алу 3; авызга каплау; авызны җылыту 2; Аллага тапшыру 3; берәрне астына салып кую; берәрне сындыру (сындырып кую); берәрне тө-

шерү; берне кагу; бөкләп салу; бугаз тузанын юу; кагып алу; кызмача баш; сөякләрне йомшар<т>у; тамак астын чылату; тамак җебетү; тамак җылыту; тамак йомшарту; тамак майлау; тамак чайкау (чайкап алу); тамак чылату (чылатып алу); тегенди-мондыен тоткалау.

2. Кыйнау, тукмау. *Урамдагы малайлар ят малайны авызын җебетеп җибәрделәр* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз капла<т>у 3; авыз кара кан белән тулу; авыз томалау 3; авыз тирәсенә менеп төшү; авыз-борынны кан итү; авыз-борынны кара кан белән юу; авызга бирү; авызга йодрык иснәтү; авызга кундыру; авызга кую; авызга <берне> менеп төшү; авызга салу (салып җибәрү); авызга сылау 1; авызга <берне> тамызу; авызга <берне> тондыру; авызга утырту; авызга чалт иттереп кую; авызга чалтырату; авызга чәпәү 2; авызга <берне> ямау; авызны җылыту 1; авызны канга туздыру; авызны кара кан белән юу; авызны кара кан итү; авызны кара канга буяу (батыру); авызны кызылга буяу; авызны өшетү; авызны турайту; авызын өзү; авыз<ны>-борынны кан итү; авыз<ны>-борынны кара кан белән юу; акыл бирү 3; акылга утырту 3; анадан имгән сөтләрен авызына китерү; анасын таныту; арка кашу 1; арка <тиресен> тукмау; арка <тиресен> каезлау (тунау); арт<тагы> сабакны тыңлату 2; арт сабакны укыту 2; арт чүмеченә тибү (бирү); ата<сын>-анасын таныту; ата-бабасын таныту; атасын таныту; әбҗәден әйттерү; әби<с>ен таныту; әбисенә иман укыту; Әлхәм сүрәсен укыту; әттәхияткә утырту; әттәхиятне укыту; баранка итеп бөгү (баранка ясау) 2; баш кашу (кашып тору) 2; баш төю; баш түбәсенә <китереп> бирү; баш түбәсенә кундыру; башка <китереп> бирү; башка кундыру; башка күсәк белән ору; башка тамызу; башны көл итү; башны төю; башны чәлпәрәмә китерү; бер-бер артлы кундыру; бер-ике рәт манчу; берне кундыру (тамызу); берне ман<ч>у; берне сылау (ямау); берне чалтырату; бисмилласын укыту 2; борынга кундыру; борынга кызыл таракан җибәрү; буен-сынын үлчәү; бүреген тышлап бирү; гөпелдеген чыгару; дуңгыз урынына илертеп кисү; дуңгыз урынына яру; дыкын чыгарганчы тукмау; дыңкып ташлау; җиде бабасын санау; җиде бабасын таныту (таптыру; хәтерләтү); җилкә кашу 1; җилкә кимерү; җилкә тамырын төю; җилкәсенә <берне> кундыру (бирү); җилкәсенә <берне> тамызу; җир күмере ясау; зөбә (зәбә) кабыргасын санау; измәсен изеп, арыш кабартмасы ясау; измәсен изү 1; иманын көйдерү; иманын өшкерү; иманын укыту; иңсәне сындыру; ипи шүрлеген җимерү (ямьшәйтү); ипи шүрлегенә менү (менеп төшү); ипи шүрлегенә эләгү; кабыргаларны кашу; ияк астына бирү (җибәрү; кундыру; тондыру; утырту); ияк астына дыңк иттерү; кабыргаларны санау (каезлау; сыйпау; тунау); кабыргаларны тетү; кабыргасын яру (сүтү); кан иму; канга батырганчы кыйнау; канга батыру; кирәкне бирү 3; кул күтәрү 8; кул тидерү 2; кул ягу; сабагын (сабакларын) укыту 2; салма савытына менеп төшү; салма савытының читен китү; тетмәне тетү 3; теш казнасын кулына тоттыру; тешләрен суырып кулларына тоттыру; тешләрен учлап китү; тешләрен кыскарту; тешләрен санау; тешләрен учына тоттыру; тешләрен чүпләү; эшне бетерү; яңагына менеп төшү; яңак буйдан ут күрсәтү; яңак сөякләрен кулга тоттыру; яңак төбен чиләк төбе итү; яңак төбенә берне җибәрү; яңак төбенә менеп төшү (сибәү; утырту); яңак төбеннән ут чыгару; яңак төбеннән чиләк төбе ясау; яңак төбенә ямау; яңак төпкә салу (салып җибәрү); яңак төпкә утырту; яңакка <берне> бирү (чәлтерәтү; эләктерү); яңакка <китереп> салу (салып җибәрү); яңакка кундыру; яңакка күмәч ябыштыру; яңакка менеп төшү; яңакка ут күренерлек итеп <берне> бирү; яңакка утырту (ямау); яңакка чабу; яңакка чалтырату; яңакка ялтырату; яңакны җимерү; яңактан аллы-гөлле утлар чыгару; яңактан ут <көлтәсе> чәчрәтү (чыгару; чыгу); яңактан чакма кабызып алу.

**АВЫЗ ҖЕБҮ.** Булдыксызлану, җебеп төшү. *Бер егет үбә килеп, ике егет, / Фатыйманың да кала аузы җебеп* (Г. Тукай).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**АВЫЗ ҖЫЕРУ.** Авыз яки иреннәрне төрлечә кыландыру. *«Чү! Кем әле бу!» – Сабый авызын җыерып торды да елап җибәрде* (Р. Сибат. Ялгызак).

**АВЫЗ ҖЫЮ** *к.* авыз бикләү. *Аны күргәч, мондагылар авызларын җыйдылар* (А. Гыйләҗев. Тәрәзәләр).

Төрдәше: авыз бикләү һ.б.

**АВЫЗ ИЛӘК БЕЛӘН БЕР <БУЛУ>** *к.* авыз җебегән <булу> 1. – *Син авылга үпкәләмә, энекәш,*

*аның авызы иләк белән бер, су тормый, минем дә исемемне йөзгә төрләндерәләр, менә үзең үк Кәтәнә – адәм актыгы дисең, әйеме?* (Н. Гыйматдинова. Кәтәнә).

Төрдәше: авыз җебегән <булу> 1 һ.б.

**АВЫЗ ИЛӘК КАДӘР БУЛУ.** Шатлыктан авыз ерылу. *[Мифтах] Нинди җавап бирәсен әйтәсең ич, синең яучыны буш кайтарып җибәргән кеше юк, бу эшкә куанычыннан авызы иләк кадәр булган* (И. Багданов. Помада мәсьәләсе).

Төрдәше: авыз еру 4 һ.б.

**АВЫЗ ИЛӘК КЕБЕК ҖӘЕЛҮ.** Еларга әзер булу. *Чөнки бераз кабып алса, иреннәрен җыя алмый, авызы иләк кебек җәелергә тора иде* (М. Әмирханов).

**АВЫЗ ИПИГӘ (ИКМӘККӘ) ТУЮ** *к.* авыз ашка тую. *Сугыштан соңгы авыр елларда тотынды Мөслах карт бу эшкә. Авылның авызы ипигә туймаган чакта* (Ф. Яруллин. Соңгы балкыш). *Юкса авызның икмәккә туйганы юк ләбаса* (Ә. Гаффар. Энә күзе).

Төрдәше: авыз ашка тую; авыз тую.

**АВЫЗ ИСЕМЛЕ КАПЧЫКТАН УЧЛАП БОРЧАК АТУ.** Мактану, шапырыну. *Авыз исемле капчыктан борчакны учлап кына ата* (Г. Тукай).

Төрдәше: авыз белән кош кына тотмау һ.б.

**АВЫЗ ИТТЕРҮ.** 1. Ашату, ашатып карау. *Габделхәй ничек кенә булса да аны коньяктан авыз иттерергә тырышты* (Ә. Галиев).

2. Атка камчы белән сугу. *Ә урамга чыккач, болай да ашкынып торган атка чыбыркыдан «авыз» иттердем* (М. Харисов. Укытучы иртә чалара).

3. Җенси мөнәсәбәттә булу *гади с. – Алмадымы Мирзаһитың, алмады! Авыз иттергән син аңа, түзмәгән* (А. Гыйләҗев. Язгы кәрваннар).

**АВЫЗ ИТҮ.** 1. Ашамлыкны кабып карау, тәмен татып карау. *Итекче Гыйлаҗи, мыекларын рәтләп: – Кая, Камәретдин дус, барыбер бүгенге төн үтте инде, китер теге, ничек әле, «юбилей» дисеңме, авыз итик инде... – дип* (К. Тинчурин. «Юбилей»). *Тездән чумып салкын чыкларына, / Авыз итик каен сулышын* (Зөлфәт. Канат җиле).

Төрдәше: авыз тидерү; авызга алу 2; аш тию; ашап карау; тәмен белү; тәмен тату.

2. Бераз гына ашау, ашый башлау. *[Локман] Курыкма, сеңел, җиңгәң үзе дә авыз итте* (Ш. Камал). *Күпме көтәсе билгесез, иртән кунакханә буфетындагы коры-сарыдан гына авыз иткән килеш* (М. Хуҗин. Җитәкләшкән таллар).

3. *күч.* Татып карау. *Касәсеннән хәятның, раст, авыз итсәм дә, ләкин әле төбенә хәтле эчкәнем юк* (С. Рәмиев). *Югыйсә бәхет, шатлык, сөенечтән бер мәртәбә инде авыз иткәне булса, соңгы утыз ел буена шуларның берсен дә тулаем татымыйча, җир тудырган бәхет-сәгадәттән өлеш алмыйча яши алыр идеме* (А. Гыйләҗев. Өч аршын җир).

4. *гади с.* Ирлек вазыйфасын башкару (айгыр турында). *Мескен айгыр, гомерендә бер генә тапкыр булса да нәсел калдыру куанычыннан авыз итмәгән хәлдә, үзенең ирлеген югалтты* (А. Расих. Ишан оныгы).

**АВЫЗ ИТҮЧЕ.** Тәмен татып караучы яки ашаучы. *Беренче өлгергән редискалардан беренче авыз итүче дә, ихтимал, мин булдым бугай* (Р. Төхфәтуллин. Җиләкле аланнар).

**АВЫЗ ЙОЗАКЛЫ (ЙОЗАКТА) БУЛУ.** Дәшми калу; ярамаганны сөйләмәү. *Дилең өчен телең булсын тозаклы – / Йөз аклыгың өчен аузың йозаклы* (Дәрдемәнд. Куанды ил...). *Аны әйткәнче бер шартым бар, синең ни эшләгәнеңне, сарайдан нинди йомыш алуыңны <...> һичберкем белергә тиеш түгел. Авызың йозакта буласы...* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).

Төрдәше: авыз бикләү һ.б.

**АВЫЗ ЙОМУ (ЙОМЫП КАЛУ / ТОРУ / УТЫРУ).** 1. Эндәшмәү, сүзгә катнашмау. *Ә син нигә авыз йомып тордың?* (Г. Ибраһимов). *– Наташа белән ярышу алай ансат булса, синнән олыраклар авызын йомып утырыр идемени?* (Г. Бәширов).

2. Сөйләүдән тukталу, сүзсез калу. *Каты ызгышка китүдән үзен тыярга теләсә дә, бөтенләй авыз йомып калырга көче җитмәде* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).

3. Җавап таба алмыйча, дәшми калу. *Ә мин авызымны йомып, аның шул ачык ялганына ышанган күренеш белән калдым* (Ф. Әмирхан). *Кызның соңгы сүзләрен ишеткәч, ул авызын йомды һәм, уңайсызланып, командирга күз төшереп алды* (А. Шамов).

Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗ ЙОМЫП ҮТКӘРҮ.** Сүзгә катнашмыйча, дәшмичә калу; *шулай ук к.:* авыз йому (йомып калу / тору / утыру; ябу). *Мин бөтен җыелышны авыз йомып үткәрдем* (Сөйләм).

**АВЫЗ КАЗАНЫНДА БОТКА ПЕШЕРҮ (ПЕШЕРЕП АЛУ).** Сүзен-җөмләсен рәтләп әйтә алмау, сөйләгән сүзе аңлашылмау, мыгырдану. *Яратмыйм шул авыз казанында ботка пешергән кешеләрне* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз казанында шулпа кайнату; авыз эчендә (эченнән) боламык болгату (пешерү) 2; авыз эчендә (эченнән) ботка пешерү (болгату), авыз эченнән 2; авыз эченнән нидер (ботка) пешерү (пешереп алу); авызда бәрәңге (ботка) пешерү (кайнату); борын эченнән ботка пешерү; боткага әйләнү 2; утын тел; утын төю.

**АВЫЗ КАЗАНЫНДА ШУЛПА КАЙНАТУ** *к.* авыз казанында ботка пешерү (пешереп алу). – *Утырсын инде, авыз казанындагы шулпасы кайнады бугай* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз казанында ботка пешерү (пешереп алу) һ.б.

**АВЫЗ <ТУЛЫ> <КАРА> КАН БУЛСА ДА, ДОШМАН (ЧИТ КЕШЕЛӘР) АЛДЫНДА ТӨКЕРМӘҮ (ТӨКЕРЕРГӘ ЯРАМАУ).** Сер бирмәү, эчтән начар булса да, аны сиздермәү. – *Соң, син, Зиннур, аны беләсең бит. Авызы тулы кан булса да, кеше алдында төкерми* (Ф. Садриев. Кышкы яшен).

Төрдәше: авыз <эче> тулы <кара> кан булса да, <дошман (чит кешеләр) алдында> төкермәү (төкерергә ярамау), авыз тулы <кара> кан булу; авызга ия булу 1; авызга кан килсә дә төкермәү; авызда кан булса да, кеше алдында төкермәү; авызда кара кан булса да төкермәү; авыздагы кара канны йоту; берни дә булмагандай; берни гә дә карамыйча (карамастан).

**АВЫЗ КАПЛАНУ.** 1. Сүз әйтсә, каршы җавап бирә алмас хәлдә калу. *[Фатих] Малаеңның авызы шап итеп капланды!* (Г. Камал. Безнең шәһәрнең серләре). – *Мактанчык син! – диде Һарун, кырт кисеп. Илгизнең шундук авызы капланды* (Н. Фәттах).

Төрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1 һ.б.

2. Берәр сүз, фикер һ.б. белән килешү, тартышудан туктау. *Менә өйләнешерсез дә шуның белән бөтенесенең авызы капланыр* (М. Маликова). *Җантимернең авызы капланды, студентлар эндәшмәделәр. Сөйләшү темасы югалды* (Ф. Яхин. Илаһи канун).

3. Сый-хөрмәт итеп, акча биреп, берәр эшне яки хәлне үз файдаңа хәл итү – *Тәкъвә халык бик рәхмәтле. Бу килүемдә дә анда сезнең исәнлеккә гыйбадәт үткәрдем. Ханның авызы капланды һәм тәүге әңгәмә митрополит файдасына тәгәлләнде* (М. Әмирханов. Ир-Мамай).

Төрдәше: авыз капла<т>у 2; авыз майла<н>у; авыз томалану 4; авыз тыгылу 2; авызга тыгу; авызны бикләү 2; авызны йомдыру 2; авызны каплап ябу; авызны томалау 2; авызны тыгу (тыгылдыру); авызны <шап> ябу 2; арт ишектән 2; әҗер бирү (төртү); бугазын каплау; май белән юу; ришвәт бирү; ришвәт төртү; өстәп бирү; сатып алу; телгә йозак салу 2; телдән яздыру 3; телне кисү.

**АВЫЗ КАПЛА<Т>У** 1. *к.* авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1. 1. *Фатыйхлар бик яхшы иткәннәр, моның авызын каплаганнар* (Г. Камал. Безнең шәһәрнең серләре). *Якуб көлеп җибәрде: «Каплаган бу кеше мулланың авызын!»* (И. Гази. Онытылмас еллар).

Төрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1 һ.б.

2. *к.* авыз каплану 3. *Кечеләрнең авызын каплау өчен, биләмә-калаларны читтән эзләү отышлырак та бит, ләкин энекәшләрдән тыш бу дөньяда Юрий белән Константинның үз малайлары да бар бит әле* (В. Имамов. Утлы дала). *Җәләйнең авызын капларга хәзергә шул җитеп торды* (Ә. Галиев).

Төрдәше: авыз каплану 3 һ.б.

3. *к.* авыз җебетү 2. *Солдат аның авызын капларга сузылган иде, эләкмәде* (Ш. Камал).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

4. *к.* авыз бикләү. *Бүлмәдә хәтта чебен очканны ишетерлек тынлык урнашты. Мин, ашыгып, авызымны каплап, партага сеңә төштем* (И. Диндаров. Яхшылык бәласе).

Төрдәше: авыз бикләү һ.б.

**АВЫЗ КАРА КАН БЕЛӘН ТУЛУ.** Авызга сугу, кыйнау, сугышу. *Авыл кешесенең шул инде: шатлыгын уртаклаша башласа да, авызы кара кан белән тула* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АВЫЗ КИБҮ.** Сусау, эчәсе килү. *Инде чабу кая, тамырлар куырылды, ирен, авыз кипте, тын*

*алсаң, эчкә ялкын керә, – шул чаклы киптек, ау, бер генә тамчы су эчәргә яраса!* (Г. Ибраһимов. Табигать балалары).
Төрдәше: авыз чатнау (чатнап тору).

**АВЫЗ КИЛМӘҮ.** Сорарга яки әйтергә батырчылык итмәү, шикләнү, уңайсызлану. *Аңлашылып җитмәгән урыннары булса да, кеше алдында сорарга авызым килмәде* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз күпмәү; авыз оешмау.

**АВЫЗ КОЛАККА (КОЛАК АРТЫНА) ҖИТҮ (КИТҮ)** *к.* авыз еру 4. *Зәйнәгытдиннең авыз колакка җитә* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә). *– Газизә Кәримовна... – дип төзәтте сүзен авызы колакларына җиткән яшь солдат* (М. Маликова. Язгы такыялар).
Төрдәше: авыз еру 4 һ.б.

**АВЫЗ КОЛАККА КАДӘР <КОЛАГЫНАЧА> ЕРЫЛУ (ҖИТҮ)** *к.* авыз еру 4. *Баязидның авызы колагынача ерылган, йөзе көлә, күзендә ут уйный иде* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр).
Төрдәше: авыз еру 4 һ.б.

**АВЫЗ КОЛАКТА, <КОЛАК ЕРАКТА; МАҢГАЙДА>** *к.* авыз еру 4. *Әнинең авызы колакта, бер тиенсез өйгә килен кайткан, янәсе* (Ф. Хөсни. Йөзек кашы). *Кайтып керделәр, мин сиңа әйтим, авызлары – колакта, колаклары – маңгайда* (Ф. Яхин. «ЗИЧ-5»).
Төрдәше: авыз еру 4 һ.б.

**АВЫЗ КОРЫТУ.** Ымсыну, хушлану. *Түгелдер ул, авыз корытып, / Матур кыз дип сөйләр вакыт* (Р. Гаташ. Кырык яшьлек дуска). *Авыз корытып сөйләнеп торган булам, мин – тиле!* (Г. Гыйльманов. Оча торган кешеләр).
Төрдәше: авыз сулары килү 1, 2; авыз сулары<н> кор<ыт>у 1; авыз суларын китерү; авыз суларын түгү; авыз су<лар>ын аг<ыз>у; авыз су<лар>ы кибү (кору) 1; авыз су<лар>ын йоту; авызга селәгәй килү; авызга сулар килү (китерү); авыздан селәгәй агу (килү; китү); авыздан селәгәй бүленү; авыздан су агызу; авыздан сулар килү (китерерлек; китерү).

**АВЫЗ КОТЫРТУ.** Ашыйсы килү тойгысы туу. *– Алып куй әле шул өчпочмакларыңны, авыз котыртып утырма* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз үртәлү.

**АВЫЗ КУПАЙТУ.** Төшенкелеккә бирелү, кәефсезләнү; үпкәләү; боегу; өметсезлеккә, чарасызлыкка бирелү; күңел төшенкелеген тою, элекке тәкәббер торышын югалту. *Әмма йөрәккә оялаганы һаман авызын купайтып тора иде әле* (Н. Гыйматдинова. Мәхәббәттә гөнаһ бар).
Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**АВЫЗ КҮБЕРТЕП <СӨЙЛӘҮ>.** Буш сүз сөйләү, йөзләрчә сөйләгәнне кабатлау. *Юкка авыз күбертеп сөйләп утырасың, берсе дә аңа дикъкать итмәячәк* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз күгәртеп сөйләү; авыз күгәртү; авыз күпертү.

**АВЫЗ КҮГӘРМӘСЕН ӨЧЕН ГЕНӘ.** Авыз тик тормасын дип, сүз юктан гына. *Мин дә, авыз күгәрмәсен өчен генә, бер-ике сүз кыстырган булдым* (Сөйләм).

**АВЫЗ КҮГӘРТЕП <СӨЙЛӘҮ>** *к.* авыз күбертеп (сөйләү). *Болай булгач, тел талдырып, авыз күгәртеп сөйләп торасы да юк* (К. Тинчурин).
Төрдәше: авыз күбертеп <сөйләү> һ.б.

**АВЫЗ КҮГӘРТҮ** *к.* авыз күбертеп <сөйләү>. *Утырышка барып, вакыт кына әрәм иттем: шактые авыз күгәртү белән маташты* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз күбертеп <сөйләү> һ.б.

**АВЫЗ КҮК ТӘМӘЙТҮ.** Авызның тәме китү. (Күк тәме – ачышкан металл тәме). *Нәрсәдәндер авызым күк тәмәйтеп тора* (Сөйләм).

**АВЫЗ КҮПЕРТҮ** 1. *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. *Ә тегесе, аның мөшкелләнеп утыруын анлап җиткермичә: «Нигә көйсез кияү шикелле, авыз күпертеп утырасың?» – дип шелтәләп тә алды* (Х. Хәйруллин. Ургыл).
Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

2. *к.* авыз күбертеп <сөйләү>. *Нурия дә, ачуыннан буылып, Өннәшкә ябышты: – Өннәш әбә, син дә тагы «колхоз, колхоз» дип, авыз күпертеп утырган буласың* («Казан утлары» ж.).
Төрдәше: авыз күбертеп <сөйләү> һ.б.

3. Гаҗәпләнү, аптырау яки башка хисләрдән авыз аз гына ачылып калу. *Акрын гына сызгыруга, Гөлфинур, аяк очларына гына басып, калкулык янына килде һәм гаҗәпсенүдән түгәрәкләтеп, авыз күтәреп сөйләргә дә тормый, ләкин мундир мәртәбәсе диген бер әшәке нәрсә бар* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**АВЫЗ КҮТӘРЕП ЙӨРҮ.** Эшсез йөрү. – *Әй син, Картлач! Йөрмә бушка авыз күтәреп!..* (М. Гафури).
Төрдәше: авыз белән чебен аулау һ.б.

**АВЫЗ КҮТӘРЕП КАЛУ.** 1. Берәр нәрсәгә өметләнеп йөреп тә аннан мәхрүм булу; аңгыраланып калу. *[Факиһә] Җизниләр әле алар үткән атнаны плашкига да чыктылар. Без анда да авызыбызны күтәреп калдык* (Г. Камал. Беренче театр).
Төрдәше: авыз ачып калу 4.
2. Күрә торып, өмет иткәннән өлешсез, коры калу. *Без барырбыз да җирен дә алырбыз. [Исмәгыйль] Кесәдә бөтенләе биш тәңкә акча бар, аны да биреп, үзем авыз күтәреп калыйммы?* (Г. Камал. Өйләнәм... Ник өйләндем?). *Урманын да кисәрбез, ә син авызыңны күтәреп калырсың әле* (И. Гази).
Төрдәше: авыз ачып калу 2 һ.б.

**АВЫЗ КҮТӘРЕП КӨЛҮ.** Юк-барга кычкырып көлү. *Шултикле кеше алдында авыз күтәреп көлеп утыруы да уңайсыз бит* (Н. Кәримова. Кода килде).
Төрдәше: авыз күтәрү.

**АВЫЗ КҮТӘРЕП СӨЙЛӘҮ.** Юк кына нәрсәне дә зур вакыйгага әйләндереп сөйләү. *Фермерлар дип авыз күтәреп сөйләгән булалар, бездә дә бар иде алар, арзан хакка техника сатып алып җыйдылар да җиргә борылып та карамыйлар* (К. Кара. Зур акчалар).

**АВЫЗ КҮТӘРЕП ЯТУ.** Эшләмичә тик яту. *Ничә ай бит инде авыз күтәреп тик ятасың!..* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз белән чебен аулау һ.б.

**АВЫЗ КҮТӘРҮ** *к.* авыз күтәреп көлү. *Хәзергеләр әйткән булалар, имеш, ул заманда кәгазь биреп алдалап йөрткәннәр сезне, дип авыз күтәргән булалар* (К. Кара. Зарифа).
Төрдәше: авыз күтәреп көлү.

**АВЫЗ КЫЙМЫЛДАУ.** Иреннәр селкенү. *Ләкин Илсөяр шулхәтле әкрен әйтте, ят бабай аның сүзләрен бөтенләй ишетмәде, бары тик авызы кыймылдавын гына күреп калды* (Г. Гобәй. Маякчы кызы).

**АВЫЗ КЫЙШАЙТУ** *к.* авыз бозу 1. *Кемнедер сытып, изеп ташласыннар өчен, сезнең авыз кыйшайтуыгыз, кырын карап алуыгыз да җитә калган заман бит!* (А. Тимергалин. Фәтхулла хәзрәтләре).
Төрдәше: авыз бозу 1; авыз чалшайту; авыз ямьшәйтү.

**АВЫЗ КЫРЫЕ (ЧИТЕ) БЕЛӘН <ГЕНӘ>.** Уңайсыланып яки мыскыллап әйтүне (елмаюны) белдерү. *Бу сүзләрне ни дәрәҗәдә җитди икәнлеген бик яхшы белгән кызый авыз кырые белән көлемсерәде* (Җ. Юныс. Сугыштан соң).

**АВЫЗ КЫЧЫТУ.** Нәрсәдер әйтәсе яки сөйләшәсе килеп тору. *Аңа каршы сүз әйтергә, дәлилләр белән фикерен юкка чыгарырга авызы бик кычытты, ләкин дәшмәүне хәерлерәк күрде* (Сөйләм).
Төрдәше: тел кычыту.

**АВЫЗ МАЙЛА<Н>У** *к.* авыз каплану 3. *Өй кузгаткач, андый-мондый кирәк булса, авызы майлана торсын* (Ф. Хөсни). *Авызын да майлаганнар бугай* (М. Фәйзи. Кызыл йолдыз). *Тикшерүченең авызын капларга, директорның авызын майларга кирәк* (Ә. Галиев. Авылдашлар).
Төрдәше: авыз каплану 3 һ.б.

**АВЫЗ ӨШҮ.** 1. Эшкә җиңел каравы аркасында уңышсызлыкка очрау, гайрәте чигү. – *Алайса, нигә бер агач та калмаган? – Нигә көләсең? Көлмә кешедән – авызың өшегән....* (Р. Кәрами. Олы юл да сикәлтәле). *Минминлеге аркасында авызы өшеде инде аның* (Сөйләм).
2. Тәҗрибәсе аз булып та, мактанган кешенең чирканчык алып җебеп калуы. *«Юкка тотындым, ахры», – дип уйлады ул, авызы өшегәнен сизеп* (Сөйләм).
Төрдәше: авызын өшетү; өшегән авыз.

**АВЫЗ ПЕШЕП КАЙТУ.** Урын йә табыш өмете белән барган җирдән эш чыгара алмыйча кайту. *Шәйхи, шулай итеп, үз гомерендә беренче мәртәбә авызы пешеп кайтып китә <...>* (Р. Мирхәйдәров. Иртәләгән агыш).

**АВЫЗ ПЕШЕП <ТӘ>, ӨРЕП КАПМАУ.** *Нәрсә дисең, мең кат авыз пешеп, Һаман / Өреп капмый торган юләр?!* (Р. Гаташ).

**АВЫЗ ПЕШҮ.** 1. Алдану. *Егет тотты да башка кызга өйләнде, хәзер очраганда мыек астыннан гына көлеп үтә... Авызы чамасыз нык пешкән*

*иде Луизаның* (А. Гыйләҗев. Өч тәгәрмәчле арба). *Үзе генә күп белә, гел өйрәтеп торырга ярата, бигрәк тә егетләрдән бик сак булырга куша (әйтерсең, үзенең авызы пешкәне бар!)* (Ә. Еники. Гөләндәм туташ хатирәсе).

2. Кыен, уңайсыз хәлдә калу; уйламый башлаган эштә уңышсызлыкка очрау. – *Бер тапкыр кенәзнең авызы пеште бит инде, миңа калса, бу тарафларга яңадан килмәс әле* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы). *Авызы пешкән – суны өреп каба* (Мәкаль).

3. Сабак алу, тәҗрибә туплау. *Матур вәгъдәләрне күп ишетте. / Ачык авыз иде бабагыз, / Акыл керү белән авыз пеште, / Салкын суга өреп кабабыз* (Г. Афзал). *Польша сәфәре белән авызы пешкән Бибисарага өрмичә генә Фәнзилә янә кайнар шулпа каптыра!* (Н. Гыйматдинова. Син түгел бу, син түгел...).

**АВЫЗ ПОЧМАКЛАНДЫРУ** *к.* авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү). *Телефоннан сөйләшә башласам, йокыдагы Илдарыбыз дерт итеп уяна да, авызын почмакландырып, үпкә белдереп, еларга тотына* (Ә. Маликов. Тылсымлы хатлар).

Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү).

**АВЫЗ ПЫЧРАТУ.** 1. Азга да риза булу. *Моның белән генә авызны пычратыймммы икән соң?* (Сөйләм).

2. Яман кешене, сөйләргә җирәнерлек нәрсәләрне сөйләү. *Шактый вакыт ни әйтергә белми торгач, ул, иреннәрен бүлтәйтеп: – Авызыңны пычратып, ничек телгә аласың шул кабахәтне, Кадыйров?* (Г. Тавлин. Афәт).

Төрдәше: авыз бозу 2; авыз буяу.

**АВЫЗ РАДИОСЫ.** Кайдадыр укыган яки ятлаган нәрсәне матур итеп сөйләү. – *Мин аларны китаптан ятладым, син дә ятла, кызлар белән чүкер-мүкер итәм дисәң, авыз радиосын кабызасың да сиптерәсең генә* (Н. Гыйматдинова. Кәтәнә).

**АВЫЗ САГЫЗЫ ЧӘЙНӘҮ.** Күп сөйләшү. *Тик аз сүзле карт белән карчык теләсә кем каршында авыз сагызы чәйнәргә ашыкмыйлар иде, ахрысы* (Р. Хәмид. Актамырлар иле).

**АВЫЗ САЛУ** *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. *Янәсе, ник анда авызыңны салып, балачагаланып торасың?* (Д. Булатова. Сайлау).

Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**АВЫЗ САЛЫН<ДЫР>У** *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. *Ул бу вакытта чыннан да авызы салынып төшкән бала сыман кыяфәттә иде бугай?* (Ф. Яхин. Күзгә яңгырга кадәр). *Әмма никадәр генә авыз салындырсам да, укытучым сүзләрендәге ачы дөреслекне күрергә сәләтле идем* (Х. Ширмән).

Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**АВЫЗ СЕЛКЕТЕП ЙӨРҮ.** Хөрмәтсез кеше кебек йөрү. – *Кияү мулла, авыз селкетеп, урам буенча җәяү йөрсенме?* (Г. Исхакый. Кияү).

**АВЫЗ СУЛАРЫ КИЛҮ.** 1. Берәр азык турында уйлап яки аның исен сизеп, кызыгу, ашыйсы килү. «<...> *ата-анасы бик бай кешеләр, бакчаларында ун төрле йөзем, әфлисун, хөрмә, алма агачлары сыгылып утыра», – дип язган, ди, бу... Малайның авыз сулары килде* (А. Хәлим. Кыйбла). *Балчык кумәч, чыннан да, ипигә охшаган иде. Исмәгыйльнең авыз сулары килде* (М. Галәү. Болганчык еллар).

2. Берәрсенә (хатын-кызга яки ир-атка) нәфес төшү; соклану, ымсыну. *Бит очлары алсу алмадай янып, күкрәкләре симез күркә түшедәй сикергәләп торган Җиһаниягә карап, кайсы авыл иренең генә авыз сулары килмәде икән?* («Казан утлары» ж.).

Төрдәше: авыз корыту һ.б.

**АВЫЗ СУЛАРЫ<Н> КОР<ЫТ>У** 1. *к.* авыз корыту. – *Чибәрләр үзебезнең авылда беткәнмени? Хәзер бит кызлар белән хет тегермән бөя! Матур дип авыз сулары корыды ич* (Г. Бәширов. Сарут). *Ул шашлыкның тәмлелеген көтүче Йосыф ярты ел сөйләп авыз суын корытты* (Р. Зәйдулла. Сөембикә).

Төрдәше: авыз корыту һ.б.

2. Берәр кеше яки берәр нәрсә белән мавыгып, һаман аның турында гына сөйләү, даулау. – *Ниемә хаҗәт соң ул чолан актару? – дип, сүзгә кушылды секретарь ханым. – Мирас, мирас диешеп, авыз сулары корый инде* (Н. Гыйматдинова. Алан уртасында ялгыз йорт).

Төрдәше: авызда бер үк җыр <булу>; авызда гел <балалары гына> булу; авыздан өзелмәү 2; авыздан <бер дә> өзмәү; авыздан өзми дә куймый; авыздан салмау; авыздан төшмәү (ташламау; төшермәү) 2; балык башы урынына чәйнәү; балык башын чәйнәү; бер <үк> балык башы; бер <үк> балык башын чәйнәү; бер биш тиен; бер үк сүзне тугылау (тәпәү); берне тәпәү; бетмәс балык

башы; дип теше төшү; иске куыкны шартлату; колакка туку; ничә әйтсәң дә, бер <үк> сүз; ничә чәйнәсәң дә, бер <үк> балык башы; сүздән ботка кайнату (пешерү); һаман бер балык башы.

3. Озак итеп берәрсен (хәлне, шөгыльне һ.б.) бик еш телгә алу.– *Җитәр инде, Гарәфи абзый, шул Газинур белән авыз суларың корыды, – диде Сәлим* (Г. Әпсәләмов. Газинур). – *Без монда тырышып-тырышып үскән социализм төзеп ятабыз, ә кайбер элементлар нindидер өрәккә ышана, ырым-шырымны яклый, «изге су», «шифалы су» дип авыз суын корыта* (Г. Бәширов. Җидегән чишмә).

4. Бирелү, мавыгу. – *Милләтче бик куркак бит ул, судан курка, / Гәрчә милләт диеп авыз суын корта* (Г. Тукай. Милләтчеләр). – *Без – социаль гаделсезлек корбаннары, тик кеше хакына авыз суы корытмыйбыз* (Ә. Гаффар. Богау).

5. Гашыйк булып яисә сагынып шуны гына сөйләү. *Исең китте шул Мәдинәгә, авыз суың корыды хәтта, Мәдинә дигән булып* (Ш. Камал). *[Гөлбану] Сәлви дип авыз суыңны корыткан булдың, аны алып киттеләр* (Н. Исәнбәт. Хуҗа Насретдин).

**АВЫЗ СУЛАРЫН КИТЕРҮ.** Кызыктыру, ымсындыру, *шулай ук к.:* авыз корыту. *Авыз суларын китереп: – Их, алма булса икән хәзер, алма! Йә әчерәк кенә җимеш суы. Тик алмага җитми инде. Их, алма!.. – диде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: авыз корыту һ.б.

**АВЫЗ СУЛАРЫН ТҮГҮ** *к.* авыз корыту. *Әмма яшь офицерлар авыз суларын түгеп, ымсынып карасалар да, аларның берсе дә Алмабикәгә сүз катарга җөрьәт итә алмый, чөнки аңа карт офицер тырнакларын нык батырган* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

Төрдәше: авыз корыту һ.б.

**АВЫЗ СУ<ЛАР>ЫН АГ<ЫЗ>У** *к.* авыз корыту. *Берсеннән берсе матур [булкалар], авыз суларым акты* (М. Маликова. Арыш тәме). *[Галимә] (көлеп). Читтән генә авыз суын агызып утырырга калдымы?* (М. Фәйзи. Галиябану).

Төрдәше: авыз корыту һ.б.

**АВЫЗ СУ<ЛАР>Ы КИБҮ (КОРУ).** 1. Өзгәләнү, тилмерү. *Дилбегәне миңа биргәннәрен көтә-көтә авыз суларым кибеп бетә* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз корыту һ.б.

2. Түземсезлек белән көтү. *Тын кысылды, / Авыз суы кипте. / Уен-көлке чыкмый бер сүз дә* (Г. Афзал).

3. Курку, шомлану. *Дәшсәм – сискәнер, җайсыз борылып, җилдән авышып китәр, дигән уйдан авыз суы кибеп, орынсам – тайпылыр да авар, дип шомланудан чарасыз калып, һушын җуяр дәрәҗәгә җиткән иде...* («Казан утлары» ж.).

**АВЫЗ СУЫ КИПМӘГӘН.** Малайлыгы чыгып бетмәгән, тәҗрибәсез. *Безнең белән барырга авыз суы кипмәгән әле аның* (Сөйләм).

Төрдәше: авыздан ана сөте <дә> кипмәү; авыздан сабый <бала> сарысы кипмәү; авызы пешмәү; авызында ана (әнисе) сөте кипмәү (кибеп җитмәү); авызыннан әнисенең <ими> сөте <дә> кипмәү; алны-артны белмәү; ана куеныннан чыгып җитмәү; ана сөте кипмәгән (кибеп җитмәгән); арышны бодайдан аермау; аягына бозау (сыер) басмаган; баба шулпасын эчмәгән; бала акылы чыкмау (чыгып бетмәү); башакка да юк, саламга да юк; башы яшь <әле>; Болак суы эчмәгән; бодай белән кибәкне бутау; бодай гомердә иснәмәгән дә; гомерне зая<га> уздыру; гомерне яндыру; дары исен иснәмәгән; дан борайны аера белмәү (алмау); борын асты (төбе) кипмәү (кибеп җитмәү); борын асты юешләнү; борын кибеп бетмәү; борын төбе кипмәү; борыны кибеп җитмәү (бетмәгән); борынына борыч кермәгән; борынына су кермәү, башына уй кермәү; дөнья күрмәгән; ирененнән ими сөте <дә> кипмәү; иреннән <ана> сөт<е> кипмәү; иреннәреннән (иреннәрендәге) ана сөте кипмәгән; йомырка сарысы кипмәгән; йомыркадан әле <яңа гына> чыккан; йомыркадан чыккан чебеш; кәбестә шулпасын аз эчкән; күкәй кабыгыннан чыкмаган (чыгып җитмәгән) 1; Лаеш шулпасы эчмәгән; Лаешта булмаган; Минзәлә шулпасы эчмәгән; минем кызым кияү күргәнмени; нужа калачын аз ашаган; сөт тешләре дә төшеп бетмәгән; сөте кипмәгән; суган суы эчмәгән; тормыш өйрәсен күрмәгән.

**АВЫЗ СУ<ЛАР>ЫН ЙОТУ** *к.* авыз корыту. *Кеше ашаганны карап, авыз суларыңны йотып утыру яхшы түгел, ди әни* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: авыз корыту һ.б.

**АВЫЗ СУ<ЛАР>ЫН КИТЕРЕРЛЕК.** Кызыктыргыч, ымсындыргыч. *Өй эченә ит бәлешенең*

*авыз суларын китерерлек тәмле исе тарала башлаганда, урамда таныш машина күренде* (Д. Булатова. Соң түгел).

<...> **АВЫЗ СҮЗ.** 1. Берничә сүз. *Кайтыр юлда Илһам хан бер авыз сүз катмады* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).

2. Кыска гына сөйләшү яки язу. *Шушы берничә авыз сүздән соң алар икесе ике якка аерылып киттеләр* (Ф. Хөсни. Җәй башы). *«Җиңелүе турында Гитлердан белешмә яздырып алам да кайтырга чыгам», – дип, өч-дүрт кенә авыз сүз язган иде ул* (Ф. Шәфигуллин).

**АВЫЗ СҮЗДӘН БУШАМАУ.** Күп сөйләү. *Җитезнең җитезе, бөтерчектәй бөтерелә. Үзе тел бистәсе, авызы сүздән бушамый* (М. Әмирханов. Мәхәббәт мәктүбе).

**АВЫЗ ТАЛДЫРЫП.** Файдасызга, бушка көч, акыл әрәм итеп. *Мусин кем дә, мин кем? «Подписка» дип йөргән булам, авыз талдырып* (В. Нуриев. Мусинны күрү).

**АВЫЗ ТӘМЕ.** Аппетит, иштиһа. *Хәләл ипи диган нәрсә / Авыз тәме, яшәү яме бирде миңа* (М. Хужин. Кадер).

**АВЫЗ ТӘМЕ БЕТҮ (КИТҮ; ЮК).** 1. Аппетит булмау, ризык тәмен тоймау. *Өй артыннан эз киткән, / Ак калфаклы кыз киткән, / Авызының тәме киткән, / Кайсы вафасыз үпкән* (Жыр). *Картайды бит инде, мин киткәндә: «Авызымның тәме юк», дип калды* (Ф. Яруллин. Сара түти шәһәргә бара).

**АВЫЗ ТӘМЕН ҖИБӘР<ЕШ>Ү (БОЗ<ЫШ>У; КИТӘР<ЕШ>Ү).** 1. Аппетитны бозу. *Йөредең инде әрле-бирле авыз тәмен бозып* (Сөйләм).

2. *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. *Ике-өч сум акча өчен күрше белән авыз тәмен җибәреп тормам инде* («Сөембикә» ж.).

3. Талашу, кычкырышу. *Китә шуннан соң авыз тәмен җибәрү, ике яктан ике якның ата-анасын гаепләү* (М. Әхмәтҗан. Галәм. Мәхәббәт. Гаилә. Балалар). *Яшәү өчен җан тартышы кичергән бу халыкларга авыз тәмен бозышу һич килешми* (Р. Вәлиев. Җанга уелган уйлар).

4. Күңел тартмаган кеше белән сөйләшүнең кирәксезлеге турында. *Әй, аның белән авыз тәме җибәреп торганчы, сөйләшмичә генә китәм дә барам* (И. Гафаров. Мишәрләр).

**АВЫЗ ТИДЕРҮ** *к.* авыз итү. *Мәҗлестәгеләр, бәлешкә авыз тидерү белән: «Телеңне йотарсың, шундый тәмле», – диешеп, өзлексез сөйләнеп, мактап, күтәреп шаулаштылар* (Г. Ибраһимов).

Төрдәше: авыз итү; авызга алу 2; аш тию; ашап карау; тәмен белү; тәмен тату.

**АВЫЗ ТИРӘСЕНӘ МЕНЕП ТӨШҮ.** Авызга сугу. *Шырпы сызып, авыз тирәсенә менеп төшә* (М. Мәһдиев. Мәңгелек яз).

Төрдәше: авыз җебетү 2; авыз капла<т>у 3; авыз кара кан белән тулу; авыз томалау; авызга бирү; авызга йодрык иснәтү; авызга кундыру; авызга кую; авызга <берне> менеп төшү; авызга салу (салып җибәрү); авызга сылау 1; авызга <берне> тамызу; авызга <берне> тондыру; авызга утырту; авызга чалт иттереп кую; авызга чәпәү 2; авызга <берне> ямау; авызны җылыту 1; авызны канга туздыру; авызны кара кан белән юу; авызны кара кан итү; авызны кара канга буяу (батыру); авызны кызылга буяу; авызны өшетү; авызны турайту; авыз<ны>-борынны кан итү; авыз<ны>-борынны кара кан белән юу; авызын өзү.

**АВЫЗ ТИШЕК <БУЛУ>** *к.* авыз җебегән булу 1. *Ләкин, кызганычка каршы, тел ягыннан оста кешеләрнең дә бер кимчелеге бар – аларның авызлары тишек була* (Ф. Яхин. Без дә монда бар идек). *Авыз тишек бит, тик тормый. Күрәсең, кайбер канәгатьсезлекләремне дә әйткән булганмындыр* (Ә. Рәшитов. Һәркемнең үз хакыйкате).

Төрдәше: авыз җебегән булу 1 һ.б.

**АВЫЗ ТОМАЛАНУ.** 1. *к.* авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1. *[Бәдри] Дөньяны дер селкетеп тора, Фатихларның да авызы томаланыр иде* (М. Фәйзи. Галиябану). *Гади генә булып күренгән берәү белән сөйләшә башлыйсың, ике-өч сүз әйтүдән авыз томалана. Ул сиңа Гегель, Кант исемнәрен әйтә, аларның хезмәтләре турында сөйли* (Т. Миңнуллин. Яшьләр колагына бер сүз).

Төрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1 һ.б.

2. Дәгъвалашудан, тавышланудан туктау, җиңелүне аңлау. *Башта бик гайрәтләнгән иде, файдасызга икәнлеген аңлагач, авызы томаланды* (Сөйләм).

3. Бушбугаз кешене фаш итү. – *Илләм әгәр андый көчекләрнең авызлары томалансын*

*өчен, Даян вәзир янына, әйдә, мине дә җибәр* (В. Имамов. Казан дастаны).

4. *к.* авыз каплану 3. *Авызы томаланса, бәлки, бу эш безнең файдага тәмамланыр* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз каплану 3 һ.б.

**АВЫЗ ТОМАЛАУ 1.** *к.* авыз бикләү. <...> *фаҗигасен яшерми, ачыктан-ачык җир тырнап елар, поезд кадәр поездны туктатыр хәлдә дә һушын җыеп, авызын томалый алды Өммегөлсем* (А. Хәлим. Кыйбла).

Төрдәше: авыз бикләү һ.б.

2. *к.* авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1. – *Самуил Абрамович, сез болай да безне еллар буе тыеп килдегез, – диде Юматша, – авызыбызны томаладыгыз* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

Төрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1 һ.б.

3. *к.* авыз җебетү 2. *Авызын томаларга, ягъни кыйнарга, аяк астына салып таптарга, изәргә кушты* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!).

Төрдәше: авыз җебетү һ.б.

**АВЫЗ ТӨРТҮ.** 1. Кая булса да килеп урнашу. *Рәсәйнең бәрәкәтле туфрагына авыз төрткән комсыз колонистлар бик тиз үрчегәннәр* (К. Нәҗми).

Төрдәше: борын төртү.

2. Тәмен тату, табышлы булуын сизү. *Белмичә авыз төртмәгәннәр алар бу җиргә* (Сөйләм).

**АВЫЗ ТУЗУ.** Эшкә яраксыз булу. *[Мисбах] Кеше куркытммыйча гына әйтсәң, авызың туза дип курыктыңмы әллә, саескан?* (К. Тинчурин. Җилкәнсезләр).

**АВЫЗ <ЭЧЕ> ТУЛЫ <КАРА> КАН БУЛСА ДА, <ДОШМАН (ЧИТ КЕШЕЛӘР) АЛДЫНДА> ТӨКЕРМӘҮ (ТӨКЕРЕРГӘ ЯРАМАУ).** Кайгыхәсрәт зур булса да чыдау, сер бирмәү. – *Анысы дөрес, – дип сүзгә катышты Әгъди абзый, – дошманнар да күп, әмма авызың тулы кан булса да, дошман алдында төкермә, дигән сүз дә бар бит, Фазыл туган!* (Ә. Фәйзи. Тукай). – *Ерак бабаларың дошманга тез чүкмәде, авызы тулы кан булса да, дошманы каршында төкермәде* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).

Төрдәше: авыз <тулы> <кара> кан булса да, дошман (чит кешеләр) алдында төкермәү (төкерергә ярамау) һ.б.

**АВЫЗ ТУЛЫ <КАРА> КАН БУЛУ** *к.* авыз <тулы> <кара> кан булса да, дошман (чит кешеләр) алдында төкермәү (төкерергә ярамау). *Караболак халкы, гомумән, дөньяга бераз өстен торып, фәлсәфи күзлектән карый, авызы тулы кан булса да, аны кешегә күрсәтми...* (Ф. Бәйрәмова. Караболак). *Авызы тулы кан булыр, әмма сирәк тешләрен кысып булса да елмаер* (Р. Габделхакова. Зинһар, югалма...).

Төрдәше: авыз <тулы> <кара> кан булса да, дошман (чит кешеләр) алдында төкермәү (төкерергә ярамау) һ.б.

**АВЫЗ ТУРСАЙТУ.** Хәтер калу, ачулану; үпкәләү; ризасызлыгын белдерү. – *Һәр әйткән сүзенә авыз турсайта башласаң, иренең кабартма булыр* (Р. Вәлиев. Иске сәгать дөрес йөри). – *Матур булсам, абыең ташламас иде әле, дип, балалар кебек үпкәләп, авыз турсайтты Җәмилә* (Н. Гыйматдинова. Ак торна каргышы).

Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**АВЫЗ ТУТЫРУ (ТУТЫРЫП).** 1. Иркенләп, рәхәтләнеп. *Утызынчы елларда ук татар язма теленнән сөрелгән «урыс» дигән сүзне авыз тутырып әйтә һәм яза башлады ул* (А. Тимергалин. Юл чаты). *Кайда гына яшәсәләр дә, татарлар үзебезнең телебездән оялмасыннар, туган телдә рәхәтләнеп авыз тутырып сөйләшсеннәр, татар булулары белән горурлансыннар иде* (Г. Шәйхи. Муса).

2. Берәр нәрсәгә исем биргәндә, җисеменә исемен туры китереп, бер якны да үпкәләтми торган исем табу. *Диңгез дисәң, бик зурдан кубу булыр, буа дисәң, хәтере калыр, бик кечерәйтеп, ямен җибәреп әйтү булыр дигәннәрдер, авыз тутырып, Карабаш күле дип йөртәләр* (Г. Афзал. Карабаш күлендә).

**АВЫЗ ТУТЫРЫП АШАУ.** Туйганчы ашау. *Әллә кайчаннан бирле инде рәхәтләнеп авыз тутырып кызыл кесәл дә ашаганым юк* (Г. Камал).

**АВЫЗ ТУТЫРЫП ӘЙТЕРЛЕК.** Горурланып, мактанып әйтү. – *Минә, ичмасам, Яңасаладан берәр зәмләмир чыкса, фельшерме анда, адвокатмы чыкса, авыз тутырып әйтерлеге дә булыр иде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**АВЫЗ ТУТЫРЫП ӘЙТЕРЛЕК ТҮГЕЛ.** Мактарлык түгел. *Авыз тутырып әйтерлек*

*түгел, ә болай вак-төяк кенә* (Ә. Мушинский. Һаваларда – ак күгәрчен).

**АВЫЗ ТУТЫРЫП ӘЙТҮ (СӨЙЛӘҮ).** 1. Рәхәтләнеп, тарсынмыйча, иркенләп сөйләү. *Бик әйбәт, таза-сау яшәүләрен әйтте, нәниенең тупырдап үсүе хакында авыз тутырып сөйләде* (Э. Касыймов).
Төрдәше: авыз тутырып әйтерлек.

2. Курыкмыйча, туры әйтү. *«Куркам» дип авыз тутырып әйтергә кыймадым* (З. Хәким). – *Кибетне сатучылар яндыру турында гади халык авыз тутырып сөйли, ә еракта чакыртылган профессионаллар, гаеплеләрне йомып, «эш»не ябып куйдылар...* (Ә. Моталлапов. Елан җылыга елыша).

3. Зур сүз итеп сөйләү. *Урыс җире өчен дүрт йөз ел эчендә һәлак булган татарлар хакында авыз тутырып берәр сүз әйткәнебез бармы безнең?..* (А. Гыйләҗев).

**АВЫЗ ТУТЫРЫП ҖЫРЛАУ**. Бөтен тавышка, кычкырып җырлау. *Авыз тутырып кычкырып җырлаганны җене сөймәгән мөгаллим егет, үз гомерендә беренче тапкыр сөрән салып, илһамланып, кайчандыр Тау ягында ишеткән җырны сузып җибәрде* (Т. Мөбарәков).

**АВЫЗ ТУЮ** *к.* авыз ашка тую. *Безнең ише авылда ипигә авыз туймаган малайлар өчен шул «бушка куелган» коммунизм ипиеннән дә зур байлык, шуны ашаудан да зуррак ләззәт, тәмлелек булдымы икән?* (Р. Зарипов. Тирән тамырлы Түнтәрем).
Төрдәше: авыз ашка тую һ.б.

**АВЫЗ ТЫЮ.** 1. Бик күп ашамаска (эчмәскә) дип, үзеңне тыеп килү. *Күзең авыртса – кулыңны тый, эчең авыртса – авызыңны тый* (Мәкаль).

2. *к.* тел тыю. *Әйтмәс җирдә авызың тый, кычытмас җирдә кулың тый* (Мәкаль).

**АВЫЗ ТЫГЫЛУ** 1. *к.* авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1. *Авызы тыгылдымы малаеңның!* (Г. Камал. Безнең шәһәрнең серләре).
Төрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1 һ.б.

2. *к.* авыз каплану 3. – *Сез әйткәннәр иске ысул була, / Бүләк бирик, авызы тыгылсын!* (Г. Афзал. Тактика). – *Юк, синең медаль белән авызың тыгылды, гаделлекне дә оныттың!* (Х. Камалов. Үлгәннән соң яздым).
Төрдәше: авыз каплану 3 һ.б.

**АВЫЗ – УРАК, КУЛ – ЧУЛАК.** Берәр нәрсәне авызы белән сүздә генә эшли белү, кулыннан эш килмәү. *Авыз тегермәне яхшы эшләгәнен беләбез, авызы – урак, кулы – чулак аның* (Сөйләм).

**АВЫЗ ҮЛЧӘ<Ш>Ү.** Үбешү. *Син тагын минем хатын белән ничек авыз үлчәшкәнең дә сөйләргә уйламыйсыңмы?* (Г. Бәширов).

**АВЫЗ ҮРТӘЛҮ** *к.* авыз котырту. *Торам кафе ишеге төбендә, авыз үртәлә генә бит!* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз котырту.

**АВЫЗ ФӘЛСӘФӘСЕ.** Сүз өчен генә сөйләү. *Мин үземнең бернәрсә дә белмәүне, минем һәр сүзем коры «авыз фәлсәфәсе» генә идекен бүген, Каһиров белән сөйләшкәннән соң, ачык белдем* (Г. Ибраһимов. Уты сүнгән җәһәннәм).

**АВЫЗ ХӘБӘРЕ.** Телдән таралган, рәсми булмаган хәбәр. *Авыз хәбәре генә бу, җитдигә алма* (Сөйләм).

**АВЫЗ ЧАЙКАУ**. 1. Кем турында булса да гайбәт сөйләү, үзе югында яманлап сөйләү. *Тагын Сәлахларга авыз чайкарга азык булачак* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Хан исеме белән авыз чайкаган кеше якты дөньяда озак тормас* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).
Төрдәше: авызны иләктәй җәю; Агыйделнең аръягында бер (ике) инәгә (энәгә) бер сыер; Агыйделнең аръягында бер энәгә бер дөя, <ансат икән дөнья>; Агыйделнең аръягында каз бәбкәсе кунаклый; адәм <итен> чәйнәү; аркадан сөйләү; артта сөйләү; арттан сөйләү; артында <гайбәтен> сөйләү; артында чәйнәү; артыннан сөйләү; ару суны куерту; аяклы хәбәр; белербелмәс көйгә әйтү (сөйләү); бер энәгә бер сыер; боламык болгату 1; Бохарада бер энәгә бер сыер, <барып баксаң, ни дә юк>; бытбылдык сату; бытыр-бытыр чәйнәү; гайбәт арбасыннан төшеп калу; гайбәт боткасы; гайбәт бураны кубу; гайбәт җыю; гайбәт итү (кылу); гайбәт йөртү; гайбәт китү; гайбәт корымына буяу; гайбәт пәрәвезен үрү; гайбәт сату; гайбәт сагате каплау; гайбәт сөйләү; гайбәт тарату; гайбәт ташлау; гайбәт ташу; гайбәт тозына манчу; гайбәт чәйнәү; гайбәт чәчелү; гайбәт чәчү; гайбәт чигешен чигү; гайбәт чүбеген чәйнәү; гайбәткә керү; дегетле мичкә тәгәрәтү; дөнья болгату; иләкнекен чиләккә авыштыру

(бушату) 2; кеше өстенә тел сөйләү; колак сасыту; колактан-колакка ирештерү 2; колактан колакка сөйлә<ш>ү 2; кырык өйнең түбәсен ачу; ләскит сату; ләчтит сату; пычрак ату (ташлау; ыргыту; ягу); суган сату 2; сүз йөртү 2; сүз тарату; тел болга<т>у 1; тел кашу; тел чайкау; телгә керү; телгә-тешкә керү; теле авызына сыймау 4; теле-теше тию; телне гайбәт тозына манчу; тубал киеп чәчеп йөрү; тугыз өйнең түбәсен тишеп; урам авыз; чүбек чәйнәү 2; элеп алып селкеп салу 2; яман ат сату.

2. Бер нәрсәне кат-кат телгә алу. *Алар күптән үк шул туй белән* ***авыз чайкаганнар*** *булса кирәк* (Г. Бәширов. Сарут). – *Монда Гыймади исеме белән шактый* ***авыз чайкадылар,*** *– дип башлап китте* (И. Гази).

3. Вакыт әрәм итеп сөйләшеп тору. – *Һи-и, сезнең белән* ***авыз чайкап*** *ятарга монда, – дип, Зөлхәбирә сагызын гына бер чартлатып ала иде* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә). *Хатын, синең белән ник* ***авыз чайкап*** *торам соң әле дигәндәй, кырт кына борылды да Кабан күленә таба китте* (З. Хөснияр).

4. *ирон.* Исерткеч эчемлек эчү. *Бер-ике мәртәбә «Хан аракысы» белән* ***авыз чайкап*** *алгач, ул күлмәк сәдәфен чишеп җибәрде* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз җебетү 1 һ.б.

**АВЫЗ ЧАЛШАЙТУ** *к.* авыз кыйшайту. – *Безнең арада тыкрык бар бит. Ә хәзер инде тыкрык кына да түгел. – Ул,* ***авызын чалшайтып,*** *ямьсез иттереп көлде. – Күршеләр... Безнең арада – oho-ho!* (З. Хәким. Легионер).

Төрдәше: авыз кыйшайту.

**АВЫЗ ЧАПЫЛДАТУ.** Уйламыйча күп сөйләү. *Элек авызында амбар йозагы иде. Алай җәелеп* ***авыз чапылдатма*** *әле, кодагый* (Н. Гыйматдинова. Сихерче).

**АВЫЗ ЧАТНАУ (ЧАТНАП ТОРУ).** Бик нык эчәсе килү. *Йә, күп лыкылдамый гына сал әле,* ***авыз чатнап тора*** (М. Фәйзи).

Төрдәше: авыз кибү.

**АВЫЗ ЧИТЕ БЕЛӘН <ГЕНӘ>.** Кешенең эчке халәтен (мәс., уңай хис белән яки мыскыллап елмаюны сиздерү; гомумән тискәре уйны) белдерү өчен, ирен читләренең төрле торыш алуы. – *Таныш фамилия, – дип,* ***авыз чите белән*** *көлемсерәде ул* (Р. Вәлиев. Мирас).

**АВЫЗ ЧИШҮ.** 1. Серне алу. *Аның* ***авызын чишүне*** *булдыра алырмын дип уйлыйм* (Сөйләм).

2. Эчтә киртә булып торган төенне чишеп алып, рәхәтләнеп сөйләшеп утыру. *Учак янында утырганда,* ***авызын чишәргә*** *дә тели, әмма нәрсәдер комачаулый иде* (Сөйләм).

Төрдәше: тел чишү.

**АВЫЗ ЧЫЛАТУ (ЧЫЛАТЫП АЛУ)** *к.* авыз җебетү 1. *Вакыйф, Ибрайга үтә сынаулы карап, туйганчы бер болганырга, маҗара чыгарырга, шул уңайдан буза сымак күтәрергә дә, ахырдан шул хөрмәткә* ***авыз чылатырга*** *чамалаган – уен-муен шул иде* (Ә. Гаффар. Богау).

Төрдәше: авыз җебетү 1 һ.б.

**АВЫЗ ШАП <ИТЕП> ЯБЫЛУ (КАПЛАНУ).** Артык шапырынган, юк-бар сөйләгән һ.б. эшләр эшләгән кешене дәлилле җавап, тапкыр сүз, ришвәт белән тынарга мәҗбүр итү. *[Фатих] Малаеңның* ***авызы шап итеп капланды!*** *(Көлешәләр)* (Г. Камал. Безнең шәһәрнең серләре). *Галимнең әлеге сөйкемле* ***авызы шап итеп ябылды,*** *моңа да өстәп, ул үзенең кепкасы аша гына баш түбәсен кашып куйды* (Т. Нурмөхәмmәтов. Кабан күле, әй, алкын).

Төрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1 һ.б.

**АВЫЗ ЫРЖАЙТУ.** Ямьсез итеп яки урынсыз көлү. *Кеше өркеткеч сыман* ***авызын ыржайткан*** *серле аллага түгел, аңлаешлыгы чат үзенеке булуы кызыктырып, тартып торучы тормыш югарылыгына гына теләп тартыла* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

Төрдәше: теш ыржайту.

**АВЫЗ ЭЧЕНДӘ (ЭЧЕННӘН) БОЛАМЫК БОЛГАТУ (ПЕШЕРҮ)** *кимс.* 1. Үзалдында сөйләнү, мыгырдану. *Белгәнне дә чатнатып әйтеп бирә алмыйбыз. Тик торабыз шунда* ***авыз эченнән боламык болгатып*** (Ф. Шәфигуллин).

2. Аңлаешсыз итеп сөйләү. *Нәрсә* ***авыз эчендә боламык пешереп*** *утырасың!* (К. Тинчурин. Назлы кияү). – *Мин, мин, – дип,* ***авыз эченнән боламык болгатып*** *торам шулай администратор каршында* (Ф. Шәфигуллин. Ләмига-Сәмига).

Төрдәше: авыз казанында шулпа кайнату һ.б.

**АВЫЗ ЭЧЕНДӘ (ЭЧЕННӘН) БОТКА ПЕШЕРҮ (БОЛГАТУ)** *кимс., к.* авыз казанында ботка пешерү (пешереп алу). *Сафа абый, чәен*

*шупырдата биреп, «Юк, түгел» дигән сыман, авыз эченнән ботка пешереп алды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). – *Нәрсә син авыз эчендә ботка болгатасың?* (М. Маликова. Юкә чәчәк аткан чак иде).

Төрдәше: авыз казанында ботка пешерү (пешереп алу) һ.б.

**АВЫЗ ЭЧЕННӘН.** 1. Башкаларга ишеттермичә генә, үзалдына. *Мостафин шунда ук авыз эченнән көйләргә кереште – дулкынланган чагында ул һәрвакыт шулай берүзе генә аңлый торган сүзсез җырны суза торган иде* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

2. Мыгырдану. *Кыз, һаман шулай читкә карап торган килеш: – Әни ич, – дип, авыз эченнән мыгырданып калды* (Ф. Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы).

Төрдәше: авыз казанында ботка пешерү (пешереп алу) һ.б.

**АВЫЗ ЭЧЕННӘН КӨЛҮ.** Тавышсыз көлү, елмаю. *Солдат авыз эченнән генә көлеп куйды* (Г. Бәширов. Намус).

**АВЫЗ ЭЧЕННӘН НИДЕР (БОТКА) ПЕШЕРҮ (ПЕШЕРЕП АЛУ)** *к.* авыз казанында ботка пешерү (пешереп алу). *Сәлимә, кеше алдында һич тәкәллефсез басып калуыннан уңайсызланып, авыз эченнән генә нидер пешерә* (Ф. Хөсни). *Сафа абый, чәен шупырдата биреп: – Юк, түгел, – дигән сыман, авыз эченнән ботка пешереп алды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: авыз казанында ботка пешерү (пешереп алу) һ.б.

**АВЫЗ ЯБУ** *к.* авыз <да> ачмау. *Ахырында бераз гына үкереп, авызын япты* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).

Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗ ЯМЬШӘЙТҮ** *к.* авыз бозу 1. *Альбина авызын ямьшәйткән, борынын җыерган, тик бер сүз дә дәшмәгән* (Ф. Җамалетдинова. Көзге тамчылар).

Төрдәше: авыз бозу 1 һ.б.

*АВЫЗ-БАШ* ❖ **АВЫЗ-БАШ САЛЫН<ДЫР>У.** Үпкәләү, турсаеп йөрү. *Авыз-баш салындырып йөргәнче, бераз утын ярып ал* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

*АВЫЗ-БОРЫН* ❖ **АВЫЗ-БОРЫН БАЛДА, МАЙДА** *к.* авыз балда, кул майда. *Байлар балда, / Авызы-борыны майда, / Ярлыларга май кайда?* (К. Мотыйгый).

Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

**АВЫЗ-БОРЫН ҖЫЕРУ** *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү). *Бераз авызын-борынын җыерып торды да, кабалана-кабалана, урамга чыгып йөгерде* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**АВЫЗ<Ы>-БОРЫН<Ы> КЫЙШАЙМАУ.** Ваемсыз булу, ис китмәү. *Юкка өметләнмә, аның авыз-борыны да кыйшаймас* (Сөйләм).

Төрдәше: алты – так, җиде – җөп; анда теләсә, дөнья асты өскә килсен; анда теләсә дөньяны су бассын (ут алсын) 1; әлә дә түгел, фәлә дә түгел; барга сөенми, юкка көенми; диңгез ташыса, тубыгына җитми 2; диңгез тубыктан 1; дөнья тубыктан; дөньяны иләккә төяү; дөньяны су басса, үрдәккә ни кайгы?; җилкә чокырымны күрми торам, <сине дә күрми торырмын әле>; ике дөнья бер кәнди; ике дөнья – бер кыяр; ике дөнья – бер морҗа, <морҗа саен бер марҗа>; ике дөнья – бер морҗа, төтене кайтмаса ярый; ике дөнья – бер морҗа, төтене өйгә керми, күзне әчеттерми; ике дөнья – бер тиен; ике дөнья – бер, уртасы камыр; ике тиен – бер акча 1; ике чабата – бер кием, <ике дөнья – бер тиен>; ике ятып, бер төшкә керү (кермәү) 2; иртәгәне ишәк кайгыртсын; иртәгәсе өчен ишәк кайгырган; ис китмәү; исең киткән иске чикмәнгә, <бездә аның яңасы да бер тиен>; ишеткәннәрне ияк кагу белән уздыру; йөрәк мүкләнү 2; йөрәккә йон үс<тер>ү 2; йөрәккә мүк үсү 2; кайгысы юк кара судан симергән; килешкәне килендә; килешкәне туйда; килсәң кунак, китсәң ерак 1; кирәк икән чукынып китсен; кирәкле кишер яфрагы 2; киртәсенә керсә ярар; кияүгә бирәсе кыз түгел, ашка саласы тоз түгел; колак арттан җибәрү 2; кырык чөйләре кырылып бетсен; миңа димәгәе үлән үсмәсен 1; миңа дисә; миңа дисә, дөньяның асты өскә килсен; миңа дисә, ни эссе түгел, ни суык түгел; синең ачуың – минем аякчуым; сыртымны күрми торам, сине дә шулай ук; тиресе калын; тисә – тиенгә, тимәсә – ботакка; тисә – кошка, тимәсә – бушка; тисәң – ти тиңгә, тимәсәң – читәнгә; төкереп тә бирмәү 1; төкереп тә куймау 1; үзе кунак чакырган, үзе баланга киткән; эчендә җаны юктыр 2.

**АВЫЗ-БОРЫН МАЙ БУЛСЫН!** *к.* авыз<лары> бал да май <булсын>! *Җамаякка салган маен аңа суза. – Кап, кызым, кап (аркасыннан сөеп), авыз-борыныгыз май булсын...* (А. Шамов).
Төрдәше: авыз<лары> бал да май <булсын>! һ.б.

**АВЫЗ-БОРЫН МАЙГА БУЯЛУ.** Байлыкта, муллыкта яшәү. *Әмма алай гына түгел икән шул, хәтта авыз-борыны да майга тәмам буялып беткән, үзе дә май чүлмәгенә әверелгән ул...* (Ф. Яхин. Ат урлауның ние бар…).
Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

**АВЫЗ-БОРЫН САЛЫН<ДЫР>У.** 1. Кәефсезләнү, күңел төшенкелегенә бирелү. *Дусларның авыз-борын салынды* (Н. Гыйматдинова. Кем беренче?).
2. *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. *Башка – бүрек, өскә – пальто, / Бияләй кигән көйгә, / Авыз-борын салындырып, / Янып-пешеп, тиргә батып / Кайтып китәсең өйгә* (Ф. Тарханова. Бу кышка нәрсә булган?).
Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б. (ике маддә өчен дә).

**АВЫЗ-БОРЫН ТӨЙНӘП УТЫРУ.** Берәрсенә ачулану яки үпкәләү. *Әнисә, авыз-борынын төйнәп, залның бер почмагында утыра иде* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

**АВЫЗ-БОРЫН ТУРСАЙТУ (ТУРСАЮ)** *к.* авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2. *Минем авыз-борыным турсайды* (Х. Ширмән. Ерактагы йолдызым). *Шомарган таш күрсәтеп, / Кабреңдә ятарсың шул, / Авыз-борын турсайтып* (Ф. Яхин).
Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

*АВЫЗ<НЫ>-БОРЫННЫ* ❖ **АВЫЗ<НЫ>-БОРЫННЫ ҖИМЕРТЕП ЙӨРҮ.** Күп мәртәбә кыйналу, җәбер күрү. *Тегеләрдән авыз-борынны җимертеп йөри торгач, ниһаять, мин дә «каешландым»* (Аманулла. Үзем турында үзем).
Төрдәше: арка чиләтү 2; арканы кашыту.

**АВЫЗ<НЫ>-БОРЫННЫ КАН ИТҮ** *к.* авыз җебетү 2. *Әгәр Назимованың кулын тотып өлгермәгән булса, ул ак чәчле полякның авыз-борынын кан иткән булыр иде* (Г. Әпсәләмов. Газинур).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АВЫЗ<НЫ>-БОРЫННЫ КАРА КАН БЕЛӘН ЮУ** *к.* авыз җебетү 2. *Берничә кеше: «Тотыгыз, тотыгыз шул бәдбәхетне, җибәрмәгез, авыз-борынын кара кан белән юыгыз», – дип кычкыра-кычкыра, Фәтхи бабайга ташланды* (М. Шабай. Уйналмаган скрипка).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

*АВЫЗ-БОРЫНЫ* ❖ **АВЫЗ-БОРЫНЫ КЫЕК БУЛСЫН, БАЙНЫҢ УЛЫ СӨЙЛӘСЕН** *иск.* Җитәкчеләрнең сүзе дөрес була дип ышануга ишарә. *Авызберлек белән без яшәсәк, / Кузгатмасак дөнья гаугасын. Авызы кыйшык булса да, / байның улы сөйләсен* (xacitarxan.narod.ru).
Төрдәше: авызы кыек булса да, бай сөйләсен; байның авызы кыек булса да, сүзе төз; бай кешенең авызы кыек булса да, төтене туры йөри; байның морҗасы кыек булса да, төтене туры чыгар.

*АВЫЗ-БОРЫНЫГЫЗ* ❖ **АВЫЗ-БОРЫНЫГЫЗ МАЙ БУЛСЫН!** *к.* авыз<лары> бал да май <булсын>! *Килен төшүгә, аңа каршы чыгып, аяк астына юрган җәеп җибәрә, <...> җамаякка салган маен аңа суза: – Кап, кызым, кап (аркасыннан сөя), авызыгыз-борыныгыз май булсын...* (А. Шамов).
Төрдәше: авыз<лары> бал да май <булсын>! һ.б.

*АВЫЗГА* ❖ **АВЫЗГА АВЫЗ <СӨЙЛӘШҮ>.** 1. Дусларның икәү генә ишетерлек итеп сөйләшүе, серләшүе. – *Без артистлар белән, синең кебек, авызга авыз түгел* (Н. Гыйматдинова. Үзем генә беләм).
2. Ачыктан-ачык, яшермичә. *Берзаман Мәскәүгә барышлый икесе бер купега туры килделәр дә юл буе авызга авыз сөйләштеләр* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: авызга авыз куеп; авыздан авызга; авызны авызга куеп; колактан колакка; телдән телгә (ике маддә өчен дә).

**АВЫЗГА АВЫЗ КУЕП** *к.* авызга авыз <сөйләшү> 1. *Бары тик почмакта бер пар утыра, авызга авыз куеп пышылдашалар* (Г. Исхакый. Тәүбәгә килгән хатын).
Төрдәше: авызга авыз <сөйләшү> 1 һ.б.

**АВЫЗГА АВЫЗ ЯШӘҮ.** Дустанә, тату гомер итү. *Алар инде күп еллар буе авызга авыз яшиләр* (Сөйләм).
Төрдәше:дус тору.

**АВЫЗГА АК ЭТ КЕРЕП, КАРА ЭТ ЧЫГАРУ.** Яман телле кеше турында (яхшы сүзе дә яман чыгу). *Юкка аның белән бәйләнгәнсең, авызына ак эт кертеп, кара эт чыгара бит ул!* (Сөйләм).

**АВЫЗГА АЛГЫСЫЗ (АЛМАСЛЫК).** 1. Тәмсез, чи, начар ризык турында. *[Мәликә] Бер көннәре мин чүпче Әхмәтләргә ашка барган идем, үрдәк бөккәннәре бер дә пешмәгән, авызга алгысыз чи иде, бөтенләй лычкылдап тора* (Г. Камал. Банкрот).

2. Начар, җирәнгеч кешегә карата. *Ул авызга алгысыз кешенең исемен дә ишетәсем килми* (Сөйләм).

3. Оятсыз, кабахәт (сүз турында). *Кәлимулла агай авызга алмаслык сүзләр белән сүгенә* (М. Гафури).

**АВЫЗГА АЛДЫ, ИНДЕ ӨЗМӘС ТӘ, КУЙМАС ТА.** Бер сүзне кат-кат әйтеп сукранган (яки мыгырданган) кеше турында. *Җитә калды бу моңа, инде авызына алды, өзмәс тә, куймас та* (Сөйләм).

**АВЫЗГА АЛМА ТЫГУ, АРТЫҢА ТИГӘНӘК** *туп.* Алдыңда сине мактап, артыңда хурлап сөйләү (икейөзле кеше турында). *Авызга алма тыгып, артыңа тигәнәк җайлап гомере үтте шунда* (Сөйләм).

Төрдәше: ике йөзле <кеше>; ике йөзле пычак (пәке); ике яклы пычак (пәке; фин хәнҗәре); илгә барса – илгәзәк, өенә барсаң – бик мәзәк; ишеккә карап елап, түргә карап көлеп; өйгә кереп ашын ашый, урамга чыгып башын кашый; өстән ялтырый, астан калтырый; сиңа да ярый, миңа да ярый; тыштан ал да гөл, эчендәген үзең бел; тыштан ялтырау, эчтән калтырау; тышы бизәк, эче тизәк; тышы гөл кебек, эче көл кебек; тышы җаймә җәя, эче пилмән бөгә; тышы камыр җәя, эче умач уа; тышы мамык, эче кабык; тышы ут, эче мут.

**АВЫЗГА <ДА > АЛЫП КАРАМАУ.** Нәрсәне булса да ашаудан, эчүдән баш тарту. *Үз гомерендә әче балдан башка исерткечне авызына алып карамаган Мөслах карт ярты чакрымнан улының эчкәнлеген сизә иде* (Ф. Яруллин. Соңгы балкыш). *Революциягә кадәр татар авылларында хәмерне авызга да алып карамаганнар* («Безнең гәҗит» газ.).

**АВЫЗГА АЛМАУ.** 1. Исерткеч эчемлек кулланмау. *Нинди зур кичереш! Тамчы да авызга алмый хәзер* (М. Насыйбуллин. Телсез шаһитләр).

2. Кайбер вакыйгалар, хәлләр һ.б. турында сөйләмәү; сөйләмдә кайбер сүзләрне кулланмау. *Ялгызы урман кисеп утын ташуларын, ашлык сатарга калага йөрүләрен авызга да алмады* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).

**АВЫЗГА АЛУ.** 1. Кемне (яки нәрсәне) булса да искә алу, тел белән сөйләү. *Башмак турында сүз чыккач, уклау белән биргәнен дә авызга алды* (Г. Ибраһимов).

Төрдәше: авызга алу 1; баштан чыкмау; башына алу; истә тоту; колакка алу; колакка керү (кереп калу) 2; колакка салу (салып кую); күңелгә беркетү (беркетеп кую); күңелгә бикләү; күңелгә сеңү (сеңеп калу); күңелдә тоту; күңелдән китмәү; күңелдән чыкмау; телдә саклану; хәтергә алу (беркетү); хәтергә сең<дер>ү (сеңеп калу); хәтердә калдыру; хәтердә саклау (тоту); хәтердән чыкмау.

2. *к.* авыз итү. *Аның бер генә йотымы да кешеләрне терелткән. Ул суларны авызга алу белән үк, эреп юкка чыккан* (А. Нәҗми. Карлыгач).

Төрдәше: авыз итү; авыз тидерү; аш тию; ашап карау; тәмен белү; тәмен тату.

3. *к.* авыз җебетү 1. *Сирәк-мирәк кенә, кирәге чыкканда гына авызына ала* (Ә. Моталлапов. Рисвайлык).

Төрдәше: авыз җебетү 1 һ.б.

**АВЫЗГА БАЛ ДА МАЙ БУЛЫП КЕРҮ.** Төче телле, юмакай, ялагай кеше турында. *Һай, түзеп торып буламы соң аңа, авызыңа бал да май булып керә бит ул* (Сөйләм).

Төрдәше: арбаның күчәр башын үбү; арт санын ялау; артына бер төшеп, алдына биш төшеп; аяк табанын ялау; балавыз булу (булып эрү) 1; башы кендегенә ябышкан; бер алга (алдына), бер (биш) артка (артына) төшү (чыгу); бер артына, бер (биш) алдына төшү (чыгу); берәүнең күмәченә май ягу; биеп йөрү 2; җил ягына (уңаена) кабык сөяү (сөяп кую); җил ягын<н>а<н> салам кыстыру; итәген тоту; йон уңаена (җаена; уңаеннан; ягына; ятышына) сыпыру (сыйпау); йонны уңай якка (җайга) сыйпау (сыпыру); йонны ыспаена сыпыру; кеше ашына катык булу 1; кеше кубызына (кураена) бию; кулын ялау; салам кыстыру 1; салпы ягына салам кыс-

тыру 1; табан астын ялау; тәлинкә (тәрилкә) тоту (ялау); төче тел<ләнү>.

**АВЫЗГА БАРМАК КАБУ (КАБЫП ТОРУ).** Ялгышын сизеп, җавапсыз калу, дәшмәс булу. *[Фатих] Авызына бармагын кабып, шаккатып карап калдымы?* (Г. Камал. Безнең шәһәрнең серләре). *[Гөлҗамал] Әйтмичә, сезнең алдыгызда авызына бармак кабып тормас бит* (Ф. Бурнаш. Яшь йөрәкләр).

Төрдәше: бармакны авызга кабу.

**АВЫЗГА БАРМАК ТЫККАЧ ТА ТЕШЛӘМӘҮ.** Артык юаш, мескен кеше турында. – *Авызына бармак тыккач та тешләми торган кеше инде ул!* (Сөйләм).

**АВЫЗГА БЕР ЛОКМА КУЮ.** Ашау, ризык кабул итү. – *Кичәгедән бирле авызыма бер локма куйганым, бер чынаяк чәй эчкәнем юк,* – *диде* (Г. Исхакый).

**АВЫЗГА БИРҮ** *к.* авыз җебетү 2. – *Салып торып авызына бирәсе калган нәгъләтнең!* (Ш. Камал. Таң атканда).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АВЫЗГА БОРЫЧ КАБУ**. Ачулы кешенең йөзе борыч капкан сыман бөрешеп тору. *Кафедрадан гайрәт чәчеп чыгыш ясаган кечкенә генә буйлы, сары чәчле бер хатынның «Газиз халкым минем, Сөембикә магарасына ай куярга вакыт!» дигән сүзләрен ишеткәч, Иннокентий авызына борыч капкандай, чыраен сытты* (З. Мәхмүди. Тәмуг чәчәге).

**АВЫЗГА ҖАНЫ КИЛГӘНЧЕ (ЧЫККАНЧЫ) ТЫРЫШУ.** Бөтен көчне биреп, тырышыптырмашып, хәле беткәнче эшләү. *Авызына җаны килгәнче тырышты Мансур, әмма биргән сүзендә торды* (Сөйләм).

Төрдәше: баш белән <эшкә> чуму; баштан пар чыгу; баштан эшкә чуму; баштанаяк эшкә бирелү (чуму); башы белән (баштан) чуму; бер җиңнән ике кул чыгарып эшләү; билдән алъяпкыч төшмәү; билне бишкә (биш җирдән) бөреп (бөрмәп); билне бишкә (биштән) буу; бит белән җир себерү; бишкә өзелү; борын белән боз ерту (тишү; чоку; яру) 2; борын белән җир сөрү; дүрт куллап ябышу; җанны бирү <эш өчен>; җанны фида кылу <эш өчен>; җир тырмашу; җирдә елан кебек ишелү; ике бите белән җир себерү; йөз белән җир ерту; маңгай тире белән табу; маңгай тирен түгеп (чыгарып) эшләү; теш-тырнак белән ябышу; тырнак-теш белән тырышу; үзен үзе белмичә (белештерми) эшләү; чәч белән җир себерү.

**АВЫЗГА ҖАН КИЛҮ.** Кинәт бик каты курку, курку биләп алу; борчылу. *Шыгырдауны ишетсәм, аузыма җаным килә* (Г. Тукай).

Төрдәше: артын кысу; аска җибәрү; бала йоннары кабару (тырпаю); баш югалту 2; бер курыккан эт өч көн өрү; җан авызга килү; җан алыну; җан табан астына качу; җан табан астына китү; җан табан астына төшү; җан табанга китү; җан табаннан чыгу; җан уч төбенә (бармак очына; бугазга) килү; җан уч төбендә (учта булу) <булу>; җан уч төбендә генә тору (калу); җан үкчәгә төшү, җан үпкәгә төшү; җанны уч төбенә (учка) йомарлап; җанны уч төбендә йомарлап тоту; йөрәге юк; йөрәк авызга каплану; йөрәк алыну; йөрәк аска төшү (төшеп китү); йөрәк атылып чыгарга җитү; йөрәк аяк астына (табанына) төшү; йөрәк бугазга килеп терәлү (тыгылу); йөрәк жу (жу-у) итү (итеп алу); йөрәк җитмәү; йөрәк калмау; йөрәк кубу; йөрәк өзелеп төшкәндәй булу 1; йөрәк өшү (өшеп китү); йөрәк сискәнү; йөрәк табан астына (табанга) төшү; йөрәк табанга төшеп чуму; йөрәк тетрә<н>ү; йөрәк туктау (туктап калу); йөрәк урыныннан кубу (кузгалу; чыгу) 3; йөрәк уч төбенә төшү; йөрәк уч төбендә <генә калу (тору)>; йөрәк чыга язу; йөрәк шу-у итү; йөрәк ярылу (ярыла язу); йөрәккә ут өстәлү; йөрәкне учта (уч төбендә) йомып тоту; калтырап төшү; кан калтырап тору; кан калтырау (калтырап төшү; калтырап яшәү); кан кату 3; кан табан астына төшеп китү; кара курку; койрыгы бот арасында <булу>; койрык <койрыгын бот / аяк араларына> кысу 3; койрыкны бот арасына кыстыру 1; койрыкны кысу 2; кот алыну; кот болт тирәсендә йөрү; кот ботка (бот тирәсенә) төшү (җитү); кот ботта <булу>; кот <-кон> калмау; кот китү; кот очарлык; кот очу; кот табанга төшү; кот үкчәгә төшү; кот чыгу; котсыз куян; котны <җыеп> алу; коты ботына китү (төшү); коты култык астында; курку алу (басу); курку эченә китәргә; куркуга төшәргә; куркудан үлә язу; курыкканга куш, <койрыгы белән биш>; куырылып төшү; күзләр дүрт булу 2; күңелгә курку салу; күңелгә таракан керү 1; өн алыну; салкын су сипкән кебек булу;

тетрәп төшү; төс калмау; төтеннән куркып, утка керү; үз күләгәсеннән үзе курыккан; чырай китү; чырайдан төшү; шалкан кабыгы кию; шыр җибәрү; эч шу итеп китү.

**АВЫЗГА ҖЕН ТӨКЕРҮ.** Шома һәм оста сөйләү, сүз әйтергә аптырап тормау, тапкыр телле булу. *Бу Бикмулланың авызына җен төкергәндер, каян таба, гыйбрәт!* (Ә. Еники).

Төрдәше: авызга саескан төкерү; авызга Хызыр <Ильяс> төкерү; авызга шайтан (иблис) төкерү 2; авызы белән кош кына тотмый (кош тотардай); авызына каратып катыру; авызына каратып тору; авызында кош уйнату; авызыннан ут бөркелү; авызыннан утлар чәчү; авызыннан энҗеләр чәчү; әйбер өчен <эзләп> кесәгә кермәү; бал<лы> тел<ле>; баллы сүз; бер сүзгә биш (кырык) җавап <табу>; бер сүзгә мең җавап; ике тапкыр кесәсенә сүз эзләп кермәү; кесәсеннән сүз эзләп тормау; сандугач күк сайрау; сүз артыннан кесәгә кермәү; сүз өчен кесәгә кермәү; сүз өчен кеше кесәсенә керә торган түгел; сүз эзләп кесә актармау; сүз эзләп кесәгә кермәү; сүз эзләп күршегә кермәү; сүз эзләп тормау; сүзгә кесә актармау; сүзгә кесәгә кермәү; сүзгә кеше (күрше) кесәсенә кермәү; сүзгә күршегә кермәү; сүзләре ялкын кебек; сүзне кесәдән эзләмәү; тасма тел<ле>; тасма тел<ле> <булу>; телгә оста булу; телгә шайтан төкерү 1; телдә сандугач биетү; теле телгә йокмау; теле шома; өздереп сөйләү.

**АВЫЗГА ИЯ БУЛУ.** 1. *к.* авыз <тулы> <кара> кан булса да, дошман (чит кешеләр) алдында төкермәү (төкерергә ярамау). *Шул бер авызыңа да ия була белмәссең икән!* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз <тулы> <кара> кан булса да, дошман (чит кешеләр) алдында төкермәү (төкерергә ярамау) һ.б.

2. Юк-барны сөйләмәү; уйлап, чамалап сөйләү. *Булмас ла, авызына ия була белә ул, юкбар белән маташмый* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга хуҗа булу 2; авызны белеп ачу; авызны үлчәп ачу; авызны чамалап ачу; авызны шәйләп ачу; беленне белеп изү; дилбегәне кыскарту; дилбегәңне кыскарт; дилбегәңне тыя төш; сүзне үлчәп сөйләү; тел белән түгел, акыл белән фикер йөртү; телне кыскарту; телне кыска тоту.

**АВЫЗГА ЙОДРЫК ИСНӘТҮ** *к.* авыз җебетү 2. *Ә моның өчен, билгеле, авызга йодрык иснәтмиләр иде* (Н. Гыйматдинова. Син түгел бу, син түгел...).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АВЫЗГА ЙОДРЫК ТЫГУ.** 1. Сүз әйтергә ирек бирмәү. *Ату бөтенесе авызга йодрык тыга* (Н. Гыйматдинова. Мәхәббәттә гөнаһ бар). *Ничә еллар безне сүз әйтү хокукыннан мәхрүм итеп, авызга йодрык тыгып, куркытып, күз буярга мәҗбүр итеп, өнсез яшәттеләр* («Татарстан яшьләре» газ.).

Төрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1 һ.б.

2. *к.* авыз <да> ачмау. *Сөйләүчеләрнең сүзләрен кире кагу өчен, берничә мәртәбә урыныннан торырга ниятләгән иде, ләкин авызына йодрык тыгып булса да түзде, «колак та салмаслар» дип уйлады* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗГА ЙОЗАК АСУ (САЛУ; ЭЛҮ)** *к.* авыз <да> ачмау. – *Карагыз аны, хатыннар, – диде Мария ахырдан, – авызыгызга йозак салынган булсын: бу турыда сез беләсез дә мин беләм* (И. Гази). *Ул Рөстәмнең дә авызына йозак элер дәрәҗәгә җитте* (З. Мәхмүди. Тәмуг чәчәге).

Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗГА ЙӨЗЕК КАБУ (ЯШЕРҮ).** Дәшмәү; уйлап кына сөйләү; сөйләгәндә сак булу. *Авызына йөзек яшергәндәй, / Җавап кайтармады Җәмилә* (С. Кудаш). *Күр, без вагонга утырганнан бирле яткан урыныбыздан кузгалганыбыз юк, авызыбызга йөзек капкан шикелле, һичкем белән сөйләшмибез, ә ул һаман кешеләр арасында* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗГА ЙӨЗЕК КАБЫП УТЫРУ** *к.* авыз <да> ачмау. – *Ничу авызга йөзек кабып утырырга, сөйләгез!* (Г. Әпсәләмов).

Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗГА КАЗ МАЕ КАБУ (АЛУ)** *к.* авыз <да> ачмау. *[Гөлүзә] Нигә авызыңа каз мае кабып йөрдең? Хәер, миңа ни әйтсәләр дә бата шул* (Ю. Әминов. Өти Балак).

Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗГА КАН КИЛСӘ ДӘ ТӨКЕРМӘҮ** *к.* авыз <тулы> <кара> кан булса да, дошман (чит кешеләр) алдында төкермәү (төкерергә ярамау).

*Тик ул – авызына кан килсә дә төкерми торган түзем вә горур бала* (М. Әмирханов. Зиннәтулла хәзрәт).

Төрдәше: авыз <тулы> <кара> кан булса да, дошман (чит кешеләр) алдында төкермәү (төкерергә ярамау) һ.б.

**АВЫЗГА КАПКЫСЫЗ** *к.* авызга алгысыз (алмаслык) 1. *Тукта, тукта, алмый тор, абзый, кабып карыйк әле башта кәбестәсен. Тфү, әчегән. Авызга капкысыз!* (Р. Кукушкин. Диңгезче егет моңы).

Төрдәше: авызга алгысыз (алмаслык) 1.

**АВЫЗГА КАПЛАУ** 1. *к.* авыз җебетү 1. *Күңелсез хатирәләр, чыннан да, Миңнехановның йөрәген кузгатты бугай, ул сөйләвеннән аз гына вакытка бүленде дә бер рюмка хәмерне авызына каплады* (В. Имамов. Нәзер).

Төрдәше: авыз җебетү 1 һ.б.

**АВЫЗГА КАПТЫРГАН <САРЫ> МАЙНЫ ДА ЙОТА БЕЛМӘҮ.** Булдыксыз, бернәрсәгә дә ярамаган кеше турында. – *Авызына каптырган сары майны да йота бемәгәч, нинди кыз чыгар аңа?!* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз җебү һ.б.

**АВЫЗГА КАПТЫРГАННЫ ДА ЙОТМАУ** *к.* авыз җебү. *Авызына каптырганны чәйнәп йота белмәгәнлеге аеруча ачуны кабартты* («Кызыл таң» газ.).

Төрдәше: авыз җебү һ.б.

**АВЫЗГА КАПТЫРУ (САЛУ).** Бар нәрсәне җентекләп аңлатып бирү. *Үзенең нинди капкынга эләгүе хакында ул бик соңлап кына аңлады, анысын да танышлары, аннары юристлар чәйнәп авызга каптыргач кына* («Сөембикә» ж.).

**АВЫЗГА КАРАТУ (КАРАТЫП АЛУ / ТОРУ).** 1. Сүз белән игътибарны җәлеп итү, бик оста сөйләү. *Армия хәлләрен кызык итеп, мәзәккә әйләндереп сөйли белгән бу егет тәмам авызына каратты* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).

Төрдәше: авызга җен төкерү; дөнья күкрәтү 2 һ.б.

2. Мәҗлесне тоту. *Хәлфә исә, «ишан хәзрәтләренең» бердәнбер бер якын кешесе буларак, мәҗлеснең иң түрендә утыра һәм үзенең зирәклеге, тапкыр сүзләре белән бик күпләрне авызына каратып өлгерә* (Ә. Еники. Чикерткә).

3. Сүзен үткәрә белү. *Судтагыларны авызына каратып торып, ярты сәгать сөйләде Ивановның начальнигы* (Т. Мөбарәков). – *Анда болгарларны авызына каратып тора торган Мөкътәсир бәгебез бар* (В. Имамов. Казан дастаны).

4. Үзенә ияртү, буйсындыру. *Ә Рухияне авызына караткан әлеге Эшләпә күрер күзгә дә алай бөтенләй үк бетереп ташларлык нәрсә түгел* (В. Нуруллин. Әгәр син булмасаң).

Төрдәше: авызга каратып катыру; авызга каратып тоту; авызга <гына> карау (карап тору) 2; авызда кош сайрату (уйнату); авыздан ут бөрк<ел>ү (бөркетү; чәчү; чәчрә<т>ү) 2; авыздан ут чыгып тору (ургылу) 1; авыздан утлар чыг<ар>у 1, 2; авыздан энҗеләр чәчү; авыздан энҗе-мәрҗән (бриллиант, гәүһәр) кою (сибү, чәчү) 1.

**АВЫЗГА КАРАТЫП КАТЫРУ.** Оста сөйләп, кешене хәйран калдыру һәм үзеңә карату. *Авызына каратып катырды шунда барысын да!* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга карату (каратып алу / тору) 4 һ.б.

**АВЫЗГА КАРАТЫП ТОТУ** *к.* авызга карату (каратып алу / тору) 4. *Мәһдиев барысын да авызына каратып тотты* (В. Нуриев. Мәһдиев һәм...).

Төрдәше: авызга карату (каратып алу / тору) 4.

**АВЫЗГА <ГЫНА> КАРАУ (КАРАП ТОРУ).** 1. Берәүнең һәр әйткән сүзен тыңлау; хөрмәт итеп ышаныч белдерү. *Залдагы җәмәгать һәм Муса әфәнде, ни укыр икән инде дип, старшина авызына караганнар иде* (З. Бигиев). *Гаяз булганда, Әдип тә этисенең авызына гына карап тора иде, Гөлчәчәкнең дә артык сүзе юк иде* (Д. Булатова. Соң түгел!).

Төрдәше: авызга керердәй булып.

2. Хәйран калып, бик яратып тыңлап тору. *Аның тирәсендә, әлбәттә, зуррак шәкертләр була, ваклар читтән торып аның авызына карыйлар* (Ш. Камал. Мине кемнәр, нәрсәгә өйрәттеләр).

Төрдәше: авызга карату (каратып алу/ тору) 4 һ.б.

3. Хөрмәт итү, ышаныч белдерү. *Ярдәмчеләре дә аның бу гадәтенә күнегеп беткәннәр иде, гел аның авызына карап торалар: менә баш инженер әйтер, менә ул эш кушар* (И. Гази).

4. Ни кушсалар, шуны берсүзсез үтәү. *Син баштан ук үзеңнән өстеннәргә буйсынып, алар*

*авызына карап, алар әйткәнне генә кабатлап килдең* (Ә. Еники. Төнге тамчылар).

**АВЫЗГА КЕРГӘНЕН ЭТ ҖИМӘС (АШАМАС).** Сүгенеп, әдәпсез сөйләшү турында. *Ходаем, кайда үскән бу егет, аның авызына кергәнне эт тә җимәс бит!* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга шайтан (иблис) төкерү 3; авыздагы сүзен эт җимәс (җыймас); авыздагын эт җимәс (җыймас); авызыннан чыкканны эт тә җимәс (ашамас); дөнья бетереп 2; пычрак авыз.

**АВЫЗГА КЕРГӘННЕ ЙОТМАУ (ЧӘЙНӘМӘҮ)** *к.* авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү. *Нәрсә көтәргә була аннан, авызына кергәнне дә йотмый бит ул* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**АВЫЗГА КЕРЕРДӘЙ БУЛЫП.** Дикъкать белән тын да алмыйча тыңлау. *Шәйхи баядан бирле Закир абыйның авызына керердәй булып утыра иде, ахрысы, түзмәде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: авызга керү (кереп бетү) 2; күзгә керү.

**АВЫЗГА КЕРҮ (КЕРЕП БЕТҮ).** 1. Тыйнаксызлык. *<...> егетнең авызына үзе керерлек булып йөри* (Ф. Хөсни).

2. Йотылып тыңлау. *Әти авызына кереп, үзенә кирәкле акыллы сүзне генә йотып утыра иде* (Г. Ахунов. Чикләвек төше).

Төрдәше: авызга керердәй булып; күзгә керү.

**АВЫЗГА КОШ КАНАТЫ ТӨШҮ.** Тәкәббер кыяфәт чыгару, үзенә-үзе исе китеп һавалану. *Өстенә җөббә, башка зәңгәр фәс, күзгә күзлек, аякка ботинка кигән, авызына кош канаты төшәрлек дәрәҗәдә борынын күтәреп барган бер мәгърур шәкерт* (Г. Тукай).

**АВЫЗГА КУНДЫРУ** *к.* авыз җебетү 2. *Кемдер ялгады: – Авызына кундыру кирәк!* (Ш. Камал).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АВЫЗГА КУРГАШЫН КОЮ.** Бер сүз дә әйтә алмаслык итү. *Яз көне карга боткасында түбән оч Сәйфи улының авызына кургашын койган Хөрбану әле син* (М. Фәйзи).

Төрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү һ.б.

**АВЫЗГА КУЮ** *к.* авыз җебетү 2. *– Хәер, авылныкы булгач, сез аны белмәссез, бик һәйбәт кеше иде, – Сафаны күрсәтеп, – әнә шундый агач авызларга күп лыгырдарга бирмидер иде ул; чалт иттереп авызга куя да җибәрә: чүплә инде аннан соң тешләреңне идән буеннан...* (Ш. Камал. Акчарлаклар). *Күп уйлап тормадым, авызына куйдым тегенең, җиргә кадәр бөгелеп төште* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АВЫЗГА <САРЫ> МАЙ КАБУ (АЛУ)** *к.* авыз <да> ачмау. *Мин һаман да авызыма май каптым* (Ф. Яхин. Әхмәтвәлинең гыйшкы).

Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗГА <САРЫ> МАЙ КАБУ (АЛУ)** *к.* авыз <да> ачмау. *– Сиңа әйтәм, нигә авызыңа май каптың?* («Безнең гәҗит» газ.). *Әмма бу турыда авызларына май каптылар* («Ватаным Татарстан» газ).

Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗГА <БЕРНЕ> МЕНЕП ТӨШҮ** *к.* авыз җебетү 2. *Комиссарның төрлесе була, ди. Тагы сөйләсә, авызына берне менеп төшим дигән идем* (Ш. Усманов).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АВЫЗГА НИ КИЛСӘ, ШУНЫ КЫЧКЫРУ (СӨЙЛӘҮ).** Уйламыйча сөйләү, теләсә ни сөйләү. *Һәм күп вакытта утырып та тормыйча, авызына ни килсә, шуны сөйләп, бүлмәне бер шаулатып, тизрәк чыгып китә иде* (Ә. Еники. Әйтелмәгән васыять).

Төрдәше: әйтә салу; әйтеп җибәрү; әйтеп салу (ташлау); кирәкмәсне ычкындыру; серне ачу (ача төшү); ычкындырып җибәрү (ташлау).

**АВЫЗГА САЕСКАН ТӨКЕРҮ** *к.* авызга җен төкерү. *[Әптери] Булат дус, авызларына саескан төкергән бу халыкны сүз белән җиңә алмассың* (К. Тинчурин. Зәңгәр шәл).

Төрдәше: авызга җен төкерү һ.б.

**АВЫЗГА САЛГАННЫ (САЛГАН САРЫ МАЙНЫ) ЙОТА БЕЛМӘҮ.** Булдыксызлык, кулына төшкән бәхетне ычкындыру. *[Мөгълифә] Авызыңа салган сары майны хәзер йота белмәсәң, соңыннан үзең телләреңне салындырып җалманып, эзләп йөрерсең әле* (Г. Камал. Уйнаш).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**АВЫЗГА САЛГАННЫ ЙОТМАУ** *к.* авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү. *Авызга салганны да йотмагач, нинди егет инде ул?* (Сөйләм).
Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**АВЫЗГА САЛГАННЫ КӨТМӘҮ (КӨТЕП УТЫРМАУ).** Кемнеңдер нәрсә булса да эшләвен (бирүен һ.б.) көтеп тормыйча, үзе эшкә тотыну. *Авызына салганны көтеп утырмый, кирәк булса, кеше авызындагын тартып алырга да күп сорамый* («Сөембикә» ж.)

**АВЫЗГА САЛУ (САЛЫП ҖИБӘРҮ)** *к.* авыз җебетү 2. *[Маһирә] Менә салып торып җибәрермен авызыңа берне дә әйләнеп барып төшәрсең, икегә бөкләнеп...* (Ф. Бурнаш. Камали карт).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АВЫЗГА СЕЛӘГӘЙ КИЛҮ** *к.* авыз корыту. *Юкка авызыңа селәгәйләрең килә, синең өчен түгел ул* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз корыту һ.б.

**АВЫЗГА СУ АЛГАН (КАПКАН) КЕБЕК.** Эндәшми торуны чагыштыру. *Ә менә йортларга кереп халыкны җыйганда, Зәйтүнә авызына су алгандай өнсез кала* (И. Салахов. Фаҗига). *Бу сүзләрне ишетү белән, Миңнулла-моряк авылга кадәр авызына су капкан кебек тын гына кайткан, ди* (Н. Гамбәр. Әткәй белән сөйләшү).
Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗГА СУ ДА САЛМАУ.** Ялгыз хәлдә үлү. *Ир бәндәсе таш кебек каты бәгырьле, авызыңа су да салмас* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: авызга су салыр кеше булмау.

**АВЫЗГА СУ КАБУ (АЛУ; КАБЫП ТОРУ).** 1. Эндәшмәү, сораганга җавап бирмәү; артыгын сөйләмичә, сөйләгәндә сак булу. *Ник әле мин / Авызга су каптым? / Җыр тавышым әллә чиклеме?* (Ш. Маннур. Ник әле мин...). *Авызына су капкан егетләрне кыз-ыркын халкының яратмавын белгәнгә, минем дә даным таралмасын дип борчыла да иде* (Г. Мөхәммәтшин. Йөрәктәге эзләр).

2. Кинәт кенә сөйләүдән туктап калу. *Микрофонны күргәч, хатыннарның икесе дә авызларына су каптылар* (Ф. Латыйфи. Ак-карага тимәскә). *Башланып та өзелеп калган әңгәмәгә дәвам кирәк иде. Авызга су кабып торыр чак түгел* (Г. Әдһәмова. Үкенечкә калмасын).
Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б. (ике мәддә өчен дә).

**АВЫЗГА СУ КАБЫП ЙОТУ** *к.* авыз <да> ачмау. *Шул килеш кенә кал инде син, Җәмилә хатын, дәшмә! Авызыңа су кабып йот!* (Н. Гыйматдинова. Кыргый).
Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗГА СУ КАБЫП КАЛУ.** Эндәшмәү, җавап бирергә өлгермәү. *Тагын авызыма су кабып калдым, тагын берни әйтә алмадым* (Г. Мөхәммәтшин. Юкәләр чәчәк атканда). *Биреләге халык исә авызына су кабып калмый, Әфләтунов командасыннан зарланып хатлар яза* («Акчарлак» газ.).
Төрдәше: авыз <да> ачмау.

**АВЫЗГА СУ КАБЫП УТЫРУ.** Сөйләшмичә, сүзсез утыру. *«Берсе караклык өчен эләккән – биш ел биргәннәр, икенчесе талауга катнашкан – сигезне ямаганнар, берсенең дә сандыгы буш түгел, ә бишенче кеше почмакта авызына су кабып утыра икән»* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Исәпкә бар, санга юк дигәндәй, алар барыбер җыелыш беткәнче авызларына су кабып утырачак* (В. Имамов. Кәнәфи).
Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗГА СУ КАБЫП ШЫМ БУЛУ.** Дәшмәскә, бер сүз дә әйтмәскә. *Аңа хәзер бер генә юл – эчендәген тышына чыгармау, авызга су кабып шым булу* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).
Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗГА СУ КАПКАНМЫНИ.** Катып калган кебек, сөйләү сәләтен югалту. – *Авызына су капканмыни! Дәшмичә бара, түлә этең өчен дә! – дип, кондуктор янаулы кыяфәт белән әлеге кешегә атлаган иде, эт сикереп торып, гәүдәсе белән яңа хуҗасын каплап, тешләрен ыржайтып, шундый ырлады, кондуктор алгы ишеккә чаклы атылып китте* (Р. Батулла. Кияү).
Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗГА СУ КИЛҮ.** 1. Бик нык ашыйсы килүдән яки тәмле ризык исен иснәгәннән соң, бизләрнең күп итеп сүл чыгаруы. *Өстәлне күргә, авызга су килә торган иде* (Ж. Рәхимов. Тәвәккәл таш яра).
Төрдәше: авызга су тулу.

2. Нәрсә булса да әйтергә теләү. *Бибинурның күзләре кызыгып яна, хәтта авызына су килә, шулай да бирешми* (А. Гыйләҗев. Җомга көн кич белән...).

**АВЫЗГА СУ САЛЫР КЕШЕ БУЛМАУ** *к.* авызга су да салмау. *Анда фәкыйрь юк, ач-ялангач теләнчелек иткән зәгыйфь юк, актык сулышында авызына су салырга кешесе булмаган авыру юк, золым юк, әйбер юк, һәр җирдә тигезлек, һәр җирдә гадәләт* (Г. Исхакый. Тормышмы бу?).

Төрдәше: авызга су да салмау.

**АВЫЗГА СУ ТУЛУ** *к.* авызга су килү. *Әллә кайчаннан бирле өзелеп ашыйсы килә иде. Авызга су тулды, түземлегем төкәнде, йөзлеккә барып утырдым* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: авызга су килү.

**АВЫЗГА СУГУ**. Күп шапырынганны кеше алдында оятка калдыру. – *Бу юлы суктымы авызыңа Җәмилә, шулай була ул!* (Сөйләм). *Мәскәү авызга сукты, «милли мәгариф системасы» дигән төшенчә ул әле күпләргә аңлашылып җитми бугай* («Безнең гәҗит» газ.).

**АВЫЗГА СУГЫП ӘЙТТЕРМӘҮ (СӨЙЛӘТМӘҮ).** «Нәрсәне булса да әйтергә сине берәү дә көчләмәде, үз теләгең белән сөйләдең» мәгънәсендә. – *Шулай диделәр ич! Үз теләкләре. Авызларына сугып әйттермәдем* (С. Якупова. Ятим йорт). *Авызына сугып сөйләтмәде ич аңа Равил* (В. Нуруллин).

Төрдәше: телдән тартай тартты.

**АВЫЗГА СУККАНДАЙ ТЫНУ.** Кинәт сөйләүдән, көлүдән туктау. *Галимҗанны күргәч, һәммәсе авызларына суккандай тынды* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).

Төрдәше: авызны җыю.

**АВЫЗГА СУЛАР КИЛҮ (КИТЕРҮ)** *к.* авыз корыту. *Абыйсы да үтереп мактады бит: хур кызы кебек, диде, күзләре зур, керфекләре озын, диде, түбән генә карап тора, диде, аннары, авызына сулар китереп: «Бик нәгыйшь», – дип тә җибәрде* (Ә. Еники. Рәшә).

Төрдәше: авыз корыту һ.б.

**АВЫЗГА СУМАЛА КАБУ** *к.* авыз <да> ачмау. *Равил «болар әллә авызларына сумала капканнар микән» дип уйлап куйды* (Ә. Хәсәнов. Бәхет кайда оя кора?).

Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗГА СУМАЛА ЧАБУ** *к.* авыз <да> ачмау. *Авызына сумала чапкан* (К. Насыйри).

Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗГА СҮЗ СЫЙМАУ**. Кабаланып, бутап, ашыга-ашыга сөйләү. *Күп дәшми торгач шулай була ул, аннан соң сүзләр берсе өстенә икенчесе өелеп, авызга сүз сыймый башлый* (Сөйләм).

**АВЫЗГА СҮЗ ТӨШМӘҮ**. Әйтергә сүз таба алмый тору. *Авызыңа сүз төшмәгән әле синең, бар, утырып бераз уйлап ал* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга төеп тутыру 2.

**АВЫЗГА СЫЛАУ** 1. *к.* авыз җебетү 2. *Чабатадай җәелгән авызына берне сылыйсым килеп китте* (Ф. Латыйфи).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

2. Җавап бирә алмаслык итеп тапкыр сүз әйтү. *Фиргали аңа ачуланмады, башкалар белән бергә кычкырып көлде һәм тегенең авызына сылап та куйды: – Беләсең килсә: шадра йөрәк яндыра ул, энем* (С. Рәфыйков. Тын елга буенда).

**АВЫЗГА <БЕРНЕ> ТАМЫЗУ** *к.* авыз җебетү 2. *Гамир түзеп-түзеп торды да шыпырт кына күршесенә: «Авызына берне тамызыйммы әллә?» – диде* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АВЫЗГА ТАШ ТУТЫРУ.** Дәшмәү, сөйләшмәү. *[Хөсәен] Хәсән, син нигә авызыңа таш тутырдың?* (Р. Хәмид).

Төрдәше: авыз <да> ачмау; һ.б.

**АВЫЗГА ТӘМ КЕР<Т>Ү.** Капкаларга, бераз ашап алырга. *Капкаларга бирәр нәрсәң юкмы, авызга тәм кертеп аласы иде* (Сөйләм).

Төрдәше: ашап алу, тамак ялгану; тамак<ка> ялгау (ялгап алу).

**АВЫЗГА ТЕЛ СЫЙМАУ, <ТЕЛГӘ СҮЗ СЫЙМАУ>.** Кирәкмәгән җирдә артыгын урынсыз сөйләү. *[Городовой] Соңгы вакытларда сүзгә бик остарып киттегез, авызыгызга телегез сыймый башлады* (Г. Камал. Өч тормыш). – *Авызына теле сыймаган килен белән*

*сөйләшергә әтинең башына тай типмәгән!* (Н. Гыйматдинова. Шырагай).

Төрдәше: озын тел<ле>; тел авызга сыймау; тел сөяксез; теле озын; теле беләк буе; телнең сөяге юк.

**АВЫЗГА <БЕРНЕ> ТОНДЫРУ** *к.* авыз җебетү 2. *– Мә сиңа шуның өчен! – дип, башта авызына берне тондырдым, аннары селтәнеп алып күпердән ыргыттым* (В. Нуруллин. Күпер чыкканда). *Егет Хисаминың җавабын көтеп тормады, очып килеп, боксерларча кискен генә аның авызына тондырды* (Ф. Абдуллин. Чүл бүресе).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АВЫЗГА ТӨЕП ТУТЫРУ.** 1. Ашаганда, авызга ризыкны бик күп итеп алу. *Авызыңа шулхәтле төеп тутырма, сулыш та ала алмыйсың бит!* (Сөйләм).

2. Сүз әйтә алмый тору *мыск.* *Ул сүзләрен авызына төеп тутырган, аннан сорамагыз да, көтмәгез дә* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга сүз төшмәү.

**АВЫЗГА ТӨЙМӘ КАБУ** *к* авыз <да> ачмау. *– Авызына төймә капкан ул, сорамагыз* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗГА ТӨШКӘННЕ АШЫЙ БЕЛМӘҮ** *к.* авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү. *Шулхәтле пешмәгән булырсың икән, авызыңа төшкәнне дә ашый белмисең* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**АВЫЗГА ТӨШКӘННЕ КӨТЕП ЙӨРҮ (ЯТУ)** *к.* авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү. *Безнең җизни мәми авыз бит ул. Алманы агачыннан өзеп ашый белми, авызына төшкәнне көтеп йөри* (Ф. Яруллин). *[Алия] Мин әйтәм, бер яктан караганда, эшләгән кешегә заманасы да кулай килә икән аның, ялкау белән пешмәгән кайсы гына заманда да алма пешкәнне, авызга төшкәнне көтеп яткан инде, шулай бит?* (Х. Ширмән. Мәхәббәтнең соңгы көне).

**АВЫЗГА ТУРЫ КИЛҮ (КИЛЕП ТОРУ).** Уйламаганда-көтмәгәндә әйтеп кую. *[Хәмидә] Кода булачакка күрә, авызыма шулай туры килеп торадыр инде* (Г. Камал. Бүләк өчен).

**АВЫЗГА ТЫГУ** *к.* авыз каплану 3. – *Син алган бүләкләреңне өләшеп бетерә күрмә, каравылчының да авызына тыгарга кирәк булачак* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз каплану 3 һ.б.

**АВЫЗГА УТЫРТУ** *к.* авыз җебетү 2. *Тегесе чапалана: «Җибәр, җибәр, – ди. – Җибәрмәсәң, авызыңа утыртам», – ди. Үзе бер дә сукмый, бары тик шарык-шорык көлүен генә белә* (С. Рәфыйков. Тын елга буенда).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АВЫЗГА ХУҖА БУЛУ.** 1. *к.* авыз биктә булу. *Үз авызыңа үзең хуҗа була белмәгәч, нинди егет син!* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз биктә булу һ.б.

2. Соңыннан ни булачагын уйлап сөйләү. *Әнисе әйтмешли, аракы кешенең, дәрәҗәсеннән алып, һәммә нәрсәсен түбән төшерә, бер авызыңа хуҗа булмасаң, синең турындагы фикернең үзгәрүе дә бар* (Ф. Садриев. Адәм әүлиясы).

Төрдәше: авызга ия булу 2 һ.б.

3. Дәшми кала белү. *Тамагыңны телең белән туендыргач, авызга хуҗа булырга туры килә шул* (Н. Гариф. Мин сезнең арада яшәдем).

Төрдәше: авыз йому (йомып калу / тору / утыру); телне тыю.

**АВЫЗГА ХЫЗЫР <ИЛЬЯС> ТӨКЕРҮ** *к.* авызга җен төкерү. *Шәкерт арасында аны илһами дип, авызына Хызыр-Ильяс төкергән дип, укымый белә дип йөртәләр* (Г. Ибраһимов). *Авызына Хызыр төкергән бу баланың, дип уйлап куйды Зиннәтулла, балалыктан да бик иртә сикергән* (М. Әмирханов. Зиннәтулла хәзрәт).

Төрдәше: авызга җен төкерү һ.б.

**АВЫЗГА ЧАЛТ ИТТЕРЕП КУЮ.** 1. *к.* авыз җебетү 2. *<...> чалт иттереп авызга куя да җибәрә: чүплә инде аннан соң тешләреңне идән буеннан...* (Ш. Камал).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АВЫЗГА ЧӘЙНӘП КАПТЫРГАННЫ (САЛГАННЫ) КӨТҮ (КӨТЕП УТЫРУ).** Кеше әзерләп биргәнне өмет итү; берни дә эшләмәү. *Ә дөрес нәтиҗәне укучы үзе ясый алыр дип уйлыйм мин – авызына чәйнәп салганны көтеп утыра торган яшьтә түгел ул хәзер* (Ф. Хөсни. Йөзек кашы). *Әрәмтамак булып*

*тик утырма, авызыңа чәйнәп салганны да көтмә!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**АВЫЗГА ЧӘЙНӘП САЛГАННЫ (КАПТЫРГАННЫ) ЙОТМАУ (ЙОТА БЕЛМӘҮ)** *к.* авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү. – *Башка кешене тап, ул бит авызга чәйнәп салганны да йота белми* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**АВЫЗГА ЧӘЙНӘП САЛУ (КАПТЫРУ; КУЮ).** Җентекләп, бәйнә-бәйнә аңлатып бирү. *Башка студентларның стационарга ябышып ятулары шуннан: алар әзер белемне генә үзләштереп, авызларына чәйнәп салганны яраталар* (М. Юныс. Тозлы җил).

Төрдәше: авызга чәйнәп каптырганны (салганны; койганны) көтү (көтеп утыру).

**АВЫЗГА ЧӘПӘҮ.** 1. Каты, кискен җавап бирү. *Мин шунда, иртәгә урамга чыккач, ачуны китергән малайларның авызына китап сүзләре белән чәпәргә дип уйлап куйдым* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

2. *к.* авыз җибетү 2. *Латыйф, дустының чыраена карамас өчен, башын аска иде (кул кычыта, их, авызына чәписе иде!)* (Н. Гыйматдинова. Кем беренче?).

Төрдәше: авыз җибетү 2 һ.б.

**АВЫЗГА ЧИЛӘГЕ БЕЛӘН СУ КАБУ** *к.* авыз <да> ачмау. *Гамил дә, Чулмания дә, Сәеф тә, мунча турында ярты сүз дә кузгатырга куркып, авызларына чиләге белән су кабалар* (Ф. Яхин. Мунча пары...).

Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗГА ЧӨЙ КАГЫП.** Тавышны ишеттермичә. *Авызыңа чөй кагып җырласаң, һичберкем дә сүз әйтмәс* (Г. Коләхмәтов).

**АВЫЗГА ШАЙТАН (ИБЛИС) ТӨКЕРҮ.** 1. Аздыручы, бозыклыкка өндәүчегә карата әйтелә. – *Җәмәгать, нәрсәгә без шуны тыңлап торабыз. Аның авызына иблис төкергән ләбаса* (Г. Кутуй. Нишләргә). *Авыл халкының күңеленә тәки шом салды авызына шайтан төкергән карчык!* (З. Хөснияр).

2. *к.* авызга җен төкерү. *Иллә мәгәр тел дигәндә авызына иблис төкергән инде!* (Г. Ибраһимов. Табигать балалары). *Авызына шайтан төкергән кеше булып чыкты. Бөтен мәҗлесне көлдерә-көлдерә сөйләгәннән соң, Мәдинә ханым белән Әбүзәр абзый һәм Сәхипҗамал җиңги исәнлегенә аерым-аерым тостлар күтәртте* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

Төрдәше: авызга җен төкерү һ.б.

3. Әдәпсез сүзләр сөйләүче турында. – *Теленә тилчә... Азгын, имансыз!.. Авызыңа шайтан төкергән!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Сатып алсаң да, үзең аңлыйсың, хәзерге кешенең бит аның авызына шайтан төкергән – пычратырга, берсен берсе кабып йотарга гына тора, малайкаем* (А. Хәлим. Кыйбла).

Төрдәше: авызга кергәнен эт җимәс (ашамас) һ.б.

**АВЫЗГА ЭЛӘКМӘҮ.** Нәрсәнедер үзендә булдыра алмау, мөмкинлектән файдалана алмау. *Күренеп тора: аптыраганнан инде, чөнки башында уй: күзгә күренде, авызга эләкмәде, диярга калмасмы?* (Р. Зарипов. Тирән тамырлы Түнтәрем).

**АВЫЗГА <БЕРНЕ> ЯМАУ** *к.* авыз җибетү 2. *Санька ачудан йодрыкларын төйнәде, бу тавыш иясенең авызына ямаудан нинди рәхәт татыячагын уйлап, тешләрен шыгырдатты* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).

Төрдәше: авыз җибетү 2 һ.б.

*АВЫЗГА-АВЫЗ* ❖ **АВЫЗГА-АВЫЗ КУЕП <СӨЙЛӘШҮ>.** Серле сүз сөйләшү, шыпырт кына сөйләшү. *Бик якын кешеләр кебек, авызга-авыз куеп сөйләшә-көлешә дә башладылар, Энҗе тәмам аңа сыланып бетте* (Р. Кәрами. Сөеп туймас чакларың).

Төрдәше: авызны авызга куеп.

**АВЫЗГА-АВЫЗ СӨЙЛӘШҮ.** Якын дуслар булуга ишарә. – *Белми идеңмени аларның күп вакытта бергә йөрүләрен, авызга-авыз сөйләшүләрен?* (Сөйләм).

Төрдәше: агай-эне ак мыек, бер-беребезне какмыек һ.б.

*АВЫЗДА* ❖ **АВЫЗДА АМБАР ЙОЗАГЫ <БУЛУ>.** Күп сөйләшмәү яки күбрәк дәшми тору. *Күрәм: телләшергә дә остаргансың, Җәмлә. Элек авызыңда амбар йозагы иде* (Н. Гыйматдинова. Кыргый).

Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗДА АНАСЫ.** «Анаңны, анасын» сүзен ялгап сүгенә торган кеше турында. *Авызында «анасы да анасы», атасы юкмыни аның?!* (Сөйләм).

**АВЫЗДА БӘРӘҢГЕ (БОТКА) ПЕШЕРҮ (КАЙНАТУ)** *к.* авыз казанында бәрәңге пешерү. *– Айса, ник бәрәңге пешерәсең авызыңда? – дип ачуланды Гыймран бабай* (Ш. Маннур). *– «Авызында ботка пешерүче»ләрне аңлый алмый интегүнең бер сәбәбе – шуларны төгәл, ачык әйтмәүдә* (И. Кыямов).
Төрдәше: авыз казанында бәрәңге пешерү һ.б.

**АВЫЗДА БЕР ҮК ҖЫР <БУЛУ>.** Һаман да бер үк нәрсәне сөйләү. *Сәүдәгәрләр бие Иркәнәшне чакырып сораштырдыңмы, тегенең авызында гел бер үк җыр* (В. Имамов).
Төрдәше: авызда гел <балалары гына> булу; авызда иске җыр <булу>; авыздан өзелмәү 2; авыздан <бер дә> өзмәү; авыздан өзми дә куймый; авыздан салмау; авыздан төшмәү (ташламау; төшермәү) 2; балык башы урынына чәйнәү; балык башын чәйнәү; бер <үк> балык башы; бер <үк> балык башын чәйнәү; бер биш тиен; бер үк сүзне тугылау (тәпәү); берне тәпәү; дип теше төшү; иске куыкны шартлату; колакка туку; ничә әйтсәң дә, бер <үк> сүз; ничә чәйнәсәң дә, бер <үк> балык башы; сүздән ботка кайнату (пешерү); һаман бер балык башы.

**АВЫЗДА ГЕЛ <БАЛАЛАРЫ ГЫНА> БУЛУ** *к.* авызда бер үк җыр <булу>. *Ул бәгырь кисәкләрен өзгәләнеп елап озаткан әни-әбиләрнең дә авызында гел шулар гына бит хәзер* (Л. Хәмидуллин. Кыш үткән юлдан).
Төрдәше: авызда бер үк җыр <булу> һ.б.

**АВЫЗДА ГЫНА ТОТАРЛЫК.** Гүзәл кыз турында. *– Әйтмә дә инде, авызда гына тотарлык гүзәл* (Сөйләм).
Төрдәше: атлылар атыннан төшеп, җәяүлеләр ятып карарлык; атлысы атып, җәяүлесе ятып карау; баксаң багардай, базардагы товардай; бер кашык су белән <кабып; суырып> йотарлык; бер кашык су белән кап та йот; бер кашык суга сал да йот (салып йоту); йөзе тулган ай кебек; кашык очына элеп йотардай; кашыкка <гына> салып йотарлык (йотардай); килмәгән җире юк; коеп куйгандай; коеп куйган кәртинкә; коеп куйган сын төсле; койган шәм шикелле; кура җиләге кук; күзнең явын алырлык 1; күреклегә күмер кабы да килешә; матур чәчәкне кырау тиз ала; су сөлеге кебек; суырып йотарлык; теленне йотарлык; урта бармак шикелле.

**АВЫЗДА ИСКЕ ҖЫР <БУЛУ>.** Һаман да бер үк сүзне яки фикерне кабатлау. *Аның авызында да иске бер җыр: – Олуг кенәз ярлыгын миңа кайтарыгыз!* (В. Имамов. Карабәк).
Төрдәше: авызда бер үк җыр <булу> һ.б.

**АВЫЗДА ЙӨЗАК БУЛУ** *к.* авыз <да> ачмау. *– Йә, йә, ир җанашым, авызымда йозак!* (Н. Гыйматдинова. Мәхәббәттә гөнаһ бар). *Ил эчендә кара даулар бара, / Һәр милләтне бүлгән упкыннар; / Азатлыкның авызында йозак, / Бу илдә без – коллар, тоткыннар!* (С. Гәрәева).
Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗДА КАН БУЛСА ДА, КЕШЕ АЛДЫНДА ТӨКЕРМӘҮ.** Үзенә авыр булса да, кешегә сиздермәү. *Авызында кан булса да кеше алдында төкерми ул – безнең кеше!* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз <тулы> <кара> кан булса да, дошман (чит кешеләр) алдында төкермәү (төкерергә ярамау) һ.б.

**АВЫЗДА КАРА КАН БУЛСА ДА ТӨКЕРМӘҮ** *к.* авыз <тулы> <кара> кан булса да, дошман (чит кешеләр) алдында төкермәү (төкерергә ярамау). *Чын егет булсаң, түз – авызыңда кан булса да, төкермә* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз <тулы> <кара> кан булса да, дошман (чит кешеләр) алдында төкермәү (төкерергә ярамау) һ.б.

**АВЫЗДА КОШ САЙРАТУ (УЙНАТУ).** Сөйләргә оста булу; уңган кеше турында. *– Берәүләр авызларында кош сайратып дан ала, – диде Чалдаев, аякка басып, – икенче берәүләр сука сукалауны артыграк күрә* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).
Төрдәше: авызга карату (каратып алу / тору) 4 һ.б.

**АВЫЗДА СЕР (СҮЗ) ТОТМАУ (ТОРМАУ).** 1. Күп сөйләү, такылдык булу. *Геофактан практикага килүчеләр арасында авызында бер сүз тотмый торган, күңеленә ни килсә, шуны теленнән әйтеп ташларга яратучы бер кыз бар иде* (М. Әмир).

2. *к.* авыз җебегән <булу> 1. *Өстеңдәге күлмәгеңнең / Җиң очлары каралы; / Авызыңда сүз тормыйдыр – / Тешең бигрәк аралы* (Хал. җыры).
Төрдәше: авыз җебегән <булу> 1 һ.б.

**АВЫЗДА СҮЗ ЭРЕТҮ.** Бик акрын сөйләү. *Докладчы, авызында сүз эретеп, күпләрне оетып җибәрде* (Сөйләм).

**АВЫЗДА ТӨКЕРЕК КОРУ.** Һаман бер нәрсә белән мавыгып сөйләү, күп сөйләү. *Һаман шул машина да машина, авызында төкерәге корыгандыр инде* (Сөйләм).

**АВЫЗДА ЧЕБЕН УЙНАТУ** 1. *к.* авыз ачып бару (йөрү) 1. *Алар синең улың кебек авызларында чебеннәр уйнатмыйлар* (Һ. Такташ).
Төрдәше: авыз ачып бару (йөрү) 1 һ.б.

2. *к.* авыз ачып бару (йөрү) 3. *Авызыңда чебен уйнатып йөрмәсәң, чүпне кем утый?!* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз ачып бару (йөрү) 3 һ.б.

**АВЫЗДА ЭТ БАЛАЛА<Т>У.** 1. Бер сүз белән генә әйтәсен күп сүз белән әйтергә маташу. *Авызында эт балалатучы тележурналист еш кына хыял белән чынбарлыкны бутый башлады* (Р. Гыйлемханов).

2. Туктаусыз буш сүз сөйләүче, мәгънәсез, лакылдык кеше турында. *Авызында эт балалатып ничек туймады икән ул?!* (Сөйләм).

*АВЫЗДАГЫ* ❖ **АВЫЗДАГЫ БОТКАНЫ КИРЕ ЯККА БОЛГАТУ.** Икенче нәрсә турында сөйли башлау. *Моңарчы төп гаепне мәрхүмнәрнең үзләренә аударып утырган җитәкчеләр, теге чәчбинең коткысына бирелеп, авызларындагы ботканы кире якка болгата башладылар* (М. Маликова).

**АВЫЗДАГЫ КАРА КАННЫ ЙОТУ** *к.* авыз <тулы> <кара> кан булса да, дошман (чит кешеләр) алдында төкермәү (төкерергә ярамау). *Шәмсегаянның әтисе авызындагы кара канны йотып булса да, ризалашты* (А. Гыйләҗев. Өч аршын җир).
Төрдәше: авыз <тулы> <кара> кан булса да, дошман (чит кешеләр) алдында төкермәү (төкерергә ярамау) һ.б.

**АВЫЗДАГЫ СҮЗЕН ЭТ ҖИМӘС (ҖЫЙМАС)** *к.* авызга кергәнен эт җимәс (ашамас). *Таптыгыз үрнәк алырдай кеше, аның авызындагы сүзен эт җимәс* (Сөйләм).
Төрдәше: авызга кергәнен эт җимәс (ашамас) һ.б.

*АВЫЗДАГЫН* ❖ **АВЫЗДАГЫН АЛДЫРУ** *к.* авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү. *Мансур рәхәтләнеп көлә: – Ә тегесе, дәү әти, йомыкый. Авызындагын алдырды* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).
Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**АВЫЗДАГЫН КАЕРЫП АЛУ.** Кеше кулындагын ничек булса да әрсезләнеп алу. *Ышанма син аңа, авыздагын каерып ала торган кеше ул* (Сөйләм).

**АВЫЗДАГЫН ЭТ ҖИМӘС (ҖЫЙМАС)** *к.* авызга кергәнен эт җимәс (ашамас). *Кемнең авызындагын эт җыймас икәнен беләсегез киләме?* (Сөйләм).
Төрдәше: авызга кергәнен эт җимәс (ашамас) һ.б.

*АВЫЗДАН* ❖ **АВЫЗДАН АВЫЗГА.** 1. Кешедән кешегә, нәселдән нәселгә. *Чөнки, бая әйткәнемезчә, «Халык әдәбияты» дип, язылган вә мәзбут нәрсәләргә әйтелмичә, авыздан авызга сөйләнеп йөртелгән нәрсәләргә генә әйтеләдер* (Г. Тукай).

2. Сер итеп, шыпырт кына. *Ике ел аерылышып торган бу ике дус бакчаның аулак бер җирендә, күзгә-күз карашып, авыздан авызга бик озак сөйләштеләр* (Г. Ибраһимов).
Төрдәше: авызга авыз <сөйләшү> 1; авызга авыз куеп; авызны авызга куеп; колактан колакка; телдән телгә.

**АВЫЗДАН АВЫЗГА <СҮЗ> КИТҮ (КҮЧЕП ЙӨРҮ).** Хәбәр таралу. *Димәк, Нәҗип гаиләсе хакында гайбәтләр авыздан авызга күчеп йөри!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**АВЫЗДАН АКТЫ, ТАМАККА КЕРМӘДЕ.** Алданып торып калу, була-була дип өметләнеп торганда, сиңа эләкмәү). *Без дә киттек анда, авыздан акты, тамакка гына кермәде* (Сөйләм).

**АВЫЗДАН АЛДА АРТЫ КЫЧКЫРУ** *гади с.* Яман хәбәр таратудан әүвәл аның билгесе мәгълүм булу. *Бераз көтик, ашыкмыйк, авыздан алда артлары кычкыра башлар әле* (Сөйләм).

**АВЫЗДАН (ЙОЛКЫП; ӨЗЕП; СУЫРЫП; ТАРТЫП> АЛУ.** 1. Тансык булган берәр нәрсә кулга керде дигәндә генә, аның башкага күчүе. *Мәсәлән, бездә, ягъни көньякта гына үсә торган җимешләрне, безнең авыздан алып төньякның читендә яшәүче чукчаларга, не-*

*нецларга җибәрәләр* (Т. Миңнуллин. Үзгәрү). *Үзең күзләреңне чиләндереп аларга эшләп йөр, ә шул вакытта алар сөйгән кызыңны авызыңнан тартып алырга план корсыннар* (Ф. Хөсни). *Ә ул соң семьясын ташлап, ел буена балаларының авызыннан өзеп алынган акчага яшәгәндә, безне кызганганмы?* (А. Расих. Сынау).

2. Әңгәмәне дәвам иттерү өчен, көч биреп тору. *Җанлы эфирдагы сөйләшүне шушында туктатып булмый бит инде, авызыннан сүзен тартып алырга туры килә* (Сөйләм).

3. Үзең әйтергә җыенган сүзне, фикерне кемдер алданрак әйтеп өлгерү. *Фәйзерахман сүзне Галимҗанның авызыннан өзеп алды: – Имеш. төзелеш кирәкләрен ташыйлар!* (Г. Мөхәммәдова. Яшьлек көннәре). *Татлы сүзләр, гүзәл вә ләззәтле җырлар, сарайның зәүкый ләззәт сибә торган хәзинәсе, алтынлы мәрмәр сандали-тәхетләр, «аһ, сөбһаналлаһ» сүзен авызыннан тартып ала* (Р. Батулла. Сөембикә). *– Хатыным бул! Әйтә алмый йөри идем, үзең авызымнан тартып алдың менә* (М. Маликова. Язгы такыялар). *Тамара сүземне авызымнан йолкып алды: – Шома егетне беренче тапкыр очратабыз* (И. Салахов. Күкчәтау далаларында).

Төрдәше: авыздан алып әйтү.

4. Комачаулау, максатына ирешкәндә генә аяк чалу. *Ә бит без аны <кызны> киявенең авызыннан диярлек тартып алып китәбез* (Ф. Хөсни).

5. Күз алдында алып китү. *Моннан ун еллар элек, Хаҗиның исән чагында, менә шул менгәнегез сынлы асыл юрганын каракларның авызыннан тартып алып биргән идем* (Г. Ибраһимов).

6. Коткару. *Аңлатырга дип, авызымны ачкан гына идем, Надир, авызымнан суырып алып, үзенчә борып-борып аңлатты да барыбызны да коткарды* (Сөйләм).

**АВЫЗДАН АЛЫП ӘЙТҮ** *к.* авыздан <тартып> алу 3. *Мин бит элек тә урман эшендә аз-маз маташкалаган кеше, пример, оят булса да әйтим, Газинур минем авызымнан алып әйтте* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

Төрдәше: авыздан <тартып> алу 3.

**АВЫЗДАН АНА СӨТЕ <ДӘ> КИПМӘҮ.** Яшь, тәҗрибәсез, акылы утырмаган кеше яки анасы кулы астында йомшак, иркә булып үскән турында. *– Тотышның авызыннан ана сөте кипмәгән* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур). *Танылган әдипләр генә түгел, авызыннан сөт кипмәгән малайлар да монда политика, әдәбият, сәнгать диңгезендә колачлап йөзәләр* (И. Нуруллин).

Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

**АВЫЗДАН АШ ТӨШҮ (КИТҮ).** Ашый алмау. *Дәүләтша агайның да авызыннан аш төште* (З. Һади. Фәтхулла хәзрәт).

Төрдәше: аппетит булмау; аш бармау; аш үтмәү <тамакка; эчкә>; ашаудан калу; ашау-эчүдән калу; аштан баш тарту 1; аштан калу (язу); ашый алмау; тамактан калу; тамактан (тамакка) <аш> үтмәү; тамактан язу.

**АВЫЗДАН АШЫН ТАРТЫП АЛУ.** Кешене эшсез калдыруның нәтиҗәсе буларак күрү. *– Димәк, вак фермаларга, кечкенә хуҗалыкларга көн бетә, аларның кулыннан эш, авызларыннан аш тартып алабыз дигән сүз* («Татарстан яшьләре» газ.).

**АВЫЗДАН ҖАН ЧЫГУ.** Үлү. *– Сез тагы бигрәк, авыздан җан чыгарга тормый ич әлегә, – дип, мендәрне алып атты* Сәфәргали (Ф. Хөсни. Язмыш). *«Авыр тормыш та куркытмады. Авызымнан җаным чыкканда да сине онытасым юк, кызым!» – диде* («Сөембикә» ж.).

Төрдәше: адәм башкайларын салу; азирәти дөньяга китү; Алла каршына (каршысына; хозурына; янына) китү; арадан китү; ахирәт кешесе булу; ахирәт сәфәренә китү; ахирәткә китү (күчү); аяк селкү; аяк сузу 2; әҗәле җиту; әҗәлсез үлү; бакый дөньяга (йортка) күчү; бакыйга китеп бару; бакыйга (бакыйлыкка) күчү; бакыйлыкка китү; баш белән хушлашу (саубуллашу); баш бетү 2; баш гүргә керү; баш китү 1; баш<ны> салу 2; баш югалу; баштан колак кагу; баштан язу; башны башка, аякны аякка (ботны-ботка) ботарлау; башсыз атка менү; бездән китү; вафат булу; Газраил чүпләү; Гайсә торган (киткән) җиргә китү (юл алу); Гайсә янына китү; гомер агачы кору; гомер бетү; гомер елгасы кибү; гомер бирү; гомер җебе ычкыну; гомер <җебе> киселү (өзелү); гомер кояшы баю; гомер кылы өзелү; гомер очлану; гомер сыну; гомер чикләнү; гомергә нокта кую; гомере төгәнү (төкәнү); гомерне очлау 2; гүр иясе булу; гүр куенында яту; гүр тишегенә керү; гүргә

иңү (керү); дөнья белән бәхилләшү; дөнья белән исәпләшү; дөнья белән хисапны өзү; дөнья йөзендә (дөньяда) йөртмәү; дөнья кичү; дөнья кую; дөньядан башы китү; дөньядан китү (кичү; күчү; узу; үтү); дөньядан югалу; дөньяны <артка> ташлау 1; җан бирү; җан җую; җан кыю; җан тәслим кылу; җан чыгу; җаннан аерылу; җаны күккә ашу; җиңсез-якасыз күлмәк кию; җир куенына кереп яту; җир куенына тапшыру; җир куенында; ишек-тәрәзәсез йортка күчү (китү); йөзтүбән китү; кабергә керү; кәкре каен астына китү; китеп бару; күзләрне йому; күзләр йомылу; кырылып бетү; кылычтан кичерү; мәңгегә күзләрне йому; мәңгелек йокыга талу; мәңгелек йортка күчү (озату); мәңгелек юлга озату; мәңгелеккә иңү; мәңгелеккә китү (күчү); мәңгелеккә күзне йому; өзелеп китү; ризык киселү; ризык өзелү; соңгы юлга озату; сулыгы өзелү; сулыш өзелү; тәпи сузу; теге дөнья; теге дөньяга ашыгу (китү; күчү); төтенсез авылга күчү (китү); үзенә үзе кул салу; үлем ике килми; үлем кычкыра килми; фани дөнья белән бәхилләшү, фани дөньядан бакый дөньяга күчү (китү); Ходай алу; ... хозурына күчү; якты дөньядан китү; яшәү дәфтәреннән сызу.

**АВЫЗДАН ҖАНЫ ЧЫГАРГА ТОРУ (ҖИТЕШҮ).** Бик бөтешкән, хәле беткән, үләр алдыннан соңгы сәгатьләрен кичерү. – *Сез тагы бигрәк, авыздан җан чыгарга тормый ич әлегә,– дип, мендәрне алып атты Сәфәргали* (Ф. Хөсни. Язмыш).

Төрдәше: азаккы сулыш (сулу); азаккы сулышны алу; актык гомерендә; актык сәгатьләр<ендә>; актык<кы> сулыш (сулу) <алу>; актык тәрәшлегә ябышу 1; актык тәрәшлеләрне эрли (тарый) башлау; актык тәрәшлене элү; атлар җигүле булу; ахыргы сулыш (сулу) <алу>; ахыргы сулышны алу (сулау); аягы кабер якасында; әҗәл түшәгендә; әҗәл якадан тоту; әҗәл якасында яту; Әҗәлетдин бабайдан хәбәр килү; бер аягы белән кабергә басу; бер аягы гүрдә (кабердә) <тору>; бер аягы җирдә, бер аягы (икенчесе) гүрдә 2; бер аягы кабер якасында булу; бер аяк белән кабер якасында булу (тору; якасына басу); бер аяк монда, икенчесе кабер бусагасында; гомер җебе тартылу; гомер кыл өстендә тору; гомернең ахыры; гүр авызында булу; җаны эләгеп кенә тору; җир җимеше булып яту; кабер якасында булу (тору; яту); кабер янына басу; көч-хәл белән сулыш алу; соңгы сулыш (сулу); соңгы тартыш; үләр хәлгә җитү; үлем алдында тору; үлем белән тартышу; үлем газабы; чыкмаган җаны гына бар.

**АВЫЗДАН ҖАНЫ ЧЫККАНЧЫ.** Үлгәнчегә кадәр, бу дөнья белән саубуллашканчы. *Җаным чыкканчы авызымнан, / Йөрермен һәрвакыт бергә* (М. Гафури).

**АВЫЗДАН ЙОЗАКНЫ АЛУ.** Сөйләргә мөмкинлек бирү, сөйләттерү. *Ап-ак кашлы дәү шыксыз борынлы бу доктор аның авызыннан йозакны алды, түбәләмә тулган капчыкны чишеп җибәрде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**АВЫЗДАН КАН КИЛСӘ ДӘ ТӨКЕРМӘҮ** *к.* авыз биктә булу. *Ләйлә ханым, үзенә ничек кенә авыр булмасын, ире кыланышларына түзеп, йөрәк әрнүләрен, рәнҗешләрен чит-ятларга чыгарып түкмәде. Кем әйтмешли, авызыннан кан килсә дә төкермәде* (Н. Хәсәнов. Чөй).

Төрдәше: авыз авыз биктә булу һ.б.

**АВЫЗДАН КЕРЕП, ЭЧТӘН ҮТӘ ЧЫГУ.** Юхаланып, зәһәрләнеп булса да үзенекен эшли алу. *Сак бул, авыздан кереп, эчеңнән үтә чыга ул андый мокыт кешеләр* (Сөйләм).

Төрдәше: ишектән кертмәсәләр, тәрәзәдән керү, <тәрәзәдән кертмәсәләр, морҗадан төшү>.

**АВЫЗДАН КОШ ОЧЫРУ.** 1. Алдау, ялган хәбәр тарату. – *Сак бул, авызыннан кош очырырга ярата ул* (Сөйләм).

Төрдәше: агач атка (аргамакка) атландыру; аргамак биленнән селтәп төшереп, ишәккә атландыру; арттан тере саескан очыру; аттан иңдереп, җәяүлегә калдыру; аттан төшереп, ишәккә мендерү; аттан төшереп – тайга, тайдан таякка атландыру; баганага сөяү (терәү); баллы су дип әрем төнәтмәсе каптыру; балта сабына утырту; бармагы бау ишү; бармакка урау (чорнау); баш<ны> әйләндерү 5; берне биш итү; бодай күрсәтеп, арпа сату; бозга атландыру; бозга таяндыру; бозга утырту; борчак ат<тыр>у 2; борчак сибү; борчак чәчү 2; борчак шартлату; борчак шыттыру; борчак яру 2; ботакка атландыру; бүрәнә аркылы (артыннан; аша) бүре куу; бүрәнә аркылы (аша; үтә) бүре күрү; бүрек астыннан бүре күрү; галошка утырту; дәрьядагы балык сату; дуракка чыгару; йонсыз мендәргә яткыру; каеш биреп юкә алу; казык башына утырту;

казыкка утырту; карама көленә утырту; кәкре каенга (каенны) терә<т>ү (сөяү); комга утырту; коры елгага батыру; кош тоттыру; көймәне коры комга утырту; күз буу; күз буяу; күзгә карап алдау (ялганлау); күзгә карап җан ашау; күзгә карап төтен җибәрү; күзгә кибәк тутыру; күзгә көл сибү; күзгә төтен җибәрү; төтен өрү; кыл чабата киендерү; <тере> саескан очыр<т>у; сакал тегү; саламга сөяү; салкын су белән майлау; су болгату; су язып, май чыгару; тавык кетәгенә кертү; тишек кәлүшкә (көймәгә) утырту; төтен җибәрү; төтен салу; төп башына утырту; төп кочаклату; төпкә утырту; төпсез арбага (чанага; чуманга) утырту; төпсез кәлүшкә (көймәгә) утырту; төпсез коега төшерү; төпсез тагаракка утырту; үрдәк биреп, каз алу; чабатага утырту; читән аша бүре күрү; юкә агачына атландыру.

2. Мактану. *Карт кабыкны чатнатып, / Чәчрәп чыгарсың әле. – Таң туганда котылып, / Авызыңнан кош очырып* (Н. Измайлова).

Төрдәше: авыз белән кош кына тотмау һ.б.

3. Нәрсәне булса да артык күпертеп сөйләү, вак нәрсәгә зур әһәмият бирү. – *Шөрепләре бушаган, – дип, озак кына авызыннан кош очырды һәм нәтиҗә ясады: – Акчаң юк икән, без синең хәлгә кереп, бурычны әйберләтә алырга риза, – диде ул, иптәшенә күз кысып* (Т. Галиуллин. Сәет Сакманов).

Төрдәше: авызыннан тере саескан очыру; артык бөгеп җибәрү; бергә бишне кушу (кушып сөйләү); берне биш (ун) итү 2; берне биш, койрыгы белән куш итеп; инә күзеннән дөя күрү; инәдән дөя күрү; инәдән дөя ясау; инәне бүрәнә итү; инәне дөя итү; инәне лом итү; төймәдән дөя ясау 1; төймәдән тәва ясау; төймәне төя итү; чебеннән фил ясау.

**АВЫЗДАН КУЫК ОЧЫРУ.** Буш сүз сөйләргә ярату, алдашу. *Андый җыелыш – сөйләргә, авызларыннан куык очырырга яратучылар өчен бик җай нәрсә* (Х. Камалов).

Төрдәше: ахмак<лык> сату; әкият сату; әкият сөйләү; әтәк-сәтәк сүз сиптерү; барны юкка алыштыру; буш куык ату (очыру); буш куыклану; буш сүз 2; җүләр сату; куык очырту; күз буяу; күзгә ком сибү; күзгә көл сибү; күзгә <карап> төтен җибәрү; күзгә <карап> төтен өрү; ләгу кайнату; ләкләкә сату; ләктә сату; ләчтит сату; лыгыр сату; лыгырдап утыру; лыгырдык сату; лыклыка сату; сабын куыгы (күбеге) очыру; сүзенең атасы-анасы булмау; тузга язмаган сүз; тузга язмаганны сөйләү; тузга язмаганны таз укыр; һавадан алып сөйләү; чүбек чәйнәү 1; юләр<лек> сату.

**АВЫЗДАН КҮБЕК ЧӘЧҮ.** Бик гайрәтләнеп сөйләү, мактану, кычкыру һ.б. *<...> волостьта хатын-кызлар арасында иң активы, чибәрлеккә чибәр булса да, бу минутларда тәмам төсен җуйган иде, аңа якын килергә, сүз кушарга куркыныч, йодрыгын өскә күтәреп, авызыннан күбек чәчә башлады: – Башларын Себер җибәреп бетерәсе калган икән, иптәш вәкил, авыл контрлар кулында!* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).

**АВЫЗДАН КҮК СӨРЕМНӘР ЧЫГАРУ.** 1. Гел «уф» та «уф» килеп сукранырга ярату. *Авыздан күк сөремнәр чыгарырга кирәк булса, Мәфтуха түтидән генә сора, ул – аның остасы* (Сөйләм).

2. Ямьсез итеп тәмәке тарту. *Кыланып утыра инде шунда, авызыннан күк сөремнәр чыгарып* (Сөйләм).

**АВЫЗДАН КҮК (БАКЫР КОМГАН) ТӘМЕ КИЛҮ.** Авызның тәме китү, кабып карыйсы да килмәү. *Берәр татлы әйберең юкмы, авыздан ачышкан тимердәге күк тәмнәре килә* (Сөйләм).

Төрдәше: күк тәмәйтү.

**АВЫЗДАН ОЧЫП КЫНА ЧЫГУ.** Бик тиз җавап бирү. *Рабига, кибеттән кайткач, теге өйдә озак булашуы хәйләсе тотылуына ык-мык итеп тормады, җавабы, балалар бәхәсләшкәндәгегә охшап, авызыннан очып кына чыкты* (М. Хуҗин. Иңә дә иңә карлар).

**АВЫЗДАН ӨЗЕЛЕП ТӨШҮ.** 1. Бер-берләренә бик нык охшаш булу, «һәр нәрсәнең үз ише бар» мәгънәсендә. *Кара, кара тегеләргә, авыздан өзелеп төшкәннәр диярсең* (Сөйләм).

Төрдәше: агачына күрә алмасы, <кешесенә күрә киеме>; ашына күрә катыгы; ашына күрә табагы, балына күрә калагы; бер тамчы су кебек; бөтенләй үзе: ике тамчы су кебек; каплаган да куйган; кисеп каплагандай; кискән дә каплаган (куйган); коеп куйган (куйгандай) 3; койган да куйган; нәкъ атасы (анасы); өзгән дә куйган; өзелгән дә төшкән; өзелеп төшкән; өстенә юнып куйган; суеп каплаган; суйган да каплаган (куйган), <нәкъ атасы-анасы>; сылаган да куйган; тамып төшкән; уйган да куйган, нәкъ үзе.

2. Әйтелгән, игълан ителгән. *Түрәләр авызыннан өзелеп төшкән һәр әмерне сәгатеминуты белән тормышка ашырырга әзер ялагайлар, рухына коллык күндәмлеге сеңгән бәндәләр азмыни?!* (Ә. Рәшитов. Без кемнән ким).

**АВЫЗДАН ӨЗЕЛМӘҮ.** 1. Һич тә онытмау, һәрвакыт сөйләп тору. *Кем өйрәткәндер, «көлмә кешедән, авызың өшегән» дигән мәкаль һич авызыннан өзелми* (Сөйләм).

Төрдәше: авыздан <бер дә> өзмәү 1; авыздан ташламау 1; авыздан төш<ер>мәү 1.

2. Бер нәрсәне һаман кабатлап тору. *Кирәксә дә, кирәкмәсә дә кабатланып, «Алла бирсә», «Аллага шөкер» сүзләре авызыннан өзелмәгәч, күпләр аны диндар кеше дип уйлый иде* (Сөйләм).

Төрдәше: авыздан ташламау 2; авыздан төш<ер>мәү 2.

3. Нужа күрмәү, тормышта кытлык кичермәү. *Ата-анасыз үссә дә, туганнары һәрдаим янында булды, ашау ягы авызыннан өзелмәде* (Сөйләм).

Төрдәше: авыздан <бер дә> өзмәү 2.

**АВЫЗДАН ӨЗЕП АШАТУ (КАПТЫРУ).** Үз өлешен бүлеп, кемгә булса да бирү, соңгысын да кызганмыйча, башкалар белән бүлешү. *Үз авызыннан өзеп, аларга каптырды, бар тапканын үзе өчен тоту турында уена да китермичә, аларга сарыфлады* (Д. Булатова. Җантөяк). *Мондый киңәшне бала чыгарган, айлар буе үз авызыннан өзеп ашаткан, үстергән, очарга өйрәткән, киләчәген шушы газиз бала дәвам итәчәгенә инанган җан иясе генә шундый тавыш чыгара ала* (М. Юныс. Альбатрос язмышы).

Төрдәше: авыздан өзеп бир<ел>ү; авыздан өзеп җыю (тырышу) 2; авыздан өзү (өзеп бирү; озату) 1.

**АВЫЗДАН ӨЗЕП БИР<ЕЛ>Ү** *к.* авыздан өзеп ашату (каптыру). *Бу өлеш үз авызыңнан өзеп бирелгән булырга тиеш!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: авыздан өзеп ашату (каптыру) һ.б.

**АВЫЗДАН ӨЗЕП ҖЫЮ (ТЫРЫШУ).** 1. Ашауэчү ягын кысып, акча туплау. *Самокатка дигән акчаны да ул авызыннан өзеп җыйды, үзе бит оекның оегын ямау өстенә ямау салып кия...* (Т. Гарипова. Умырзая гөленең гомеркәе).

2. Актык телем икмәге белән бүлешү. <...> *ничек кенәләр итеп Сөмбелгә авыз иттермисең?! Чәй эчкәндә, әнисе биргән кәнфитне үз авызыннан өзеп җыеп барды да миңа шул дүрт почмаклы тәмлеләрдән-тәмле дүрт кәнфитне шырпы кабына салды* <...> (А. Хәлим. Кыйбла).

Төрдәше: авыздан өзеп ашату (каптыру) һ.б.

**АВЫЗДАН <БЕР ДӘ> ӨЗМӘҮ.** 1. Кем яки ни белән булса да мавыгып, һаман шул турыда сөйләү. *Кыланырлыгы да бар иде – Бачман баһадир кызы аның кулында, димәк, Күлкән углан аякка басачак, чөнки сырхау бала: «Сөмбелә, Сөмбелә», – дип авызыннан да өзми иде* (М. Хәбибуллин. Хан оныгы Хансөяр).

Төрдәше: авызда бер үк җыр <булу> һ.б.

2. Тәмәкене өзлексез тарту турында. *Тәмәкене бер дә авызыннан өзми иде, берсе бетсә, икенчесен кабызып кына тора* (Сөйләм).

**АВЫЗДАН ӨЗМИ ДӘ КУЙМЫЙ.** Кем яисә ни белән булса да мавыгып, туктаусыз шуны сөйләү. *Нәрсә булган моңа, шул җырчының исемен авызыннан өзми дә куймый!* (Сөйләм).

Төрдәше: авызда бер үк җыр <булу> һ.б.

**АВЫЗДАН ӨЗҮ (ӨЗЕП БИРҮ; ОЗАТУ).** 1. Юмарт кеше турында әйтелә: бүленгән ризыкның үз кисәген дә кешегә бирү. *Кешегә йөз итим диде, / авызлардан өзсә-өзеп* (Х. Әюп). *Фронтка ашлык, бәрәңге-яшелчә, ит озаттылар. Авызларыннан өзеп озаттылар* (Г. Камалов. Гомер кичендә).

Төрдәше: авыздан өзеп ашату (каптыру).

2. Кеше ризыгын талап, тартып алу. *Минем газиз балаларымның авызыннан өзеп алган хәрәм сый-нигъмәтләр ул убырның тамагына аркылы да тормый ичмасам!..* (В. Имамов. Тозлы яра).

**АВЫЗДАН ПУЛЕМЁТ АТТЫРУ.** Туктамыйча сөйләү, кычкырышу. *Вилория белән Рәсим тел сугышы оештырганнармыни, авызларыннан пулемёт аттыралар иде* (Н. Гыйматдинова. Үзем генә беләм...).

**АВЫЗДАН САБЫЙ <БАЛА> САРЫСЫ КИПМӘҮ** *к.* авыз суы кипмәгән. *Буталып йөрмә әле минем аяк астында, авызыңнан сабый сарысы кипмәгән килеш!* (Б. Камал. Өметең өзелмәсен).

Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

**АВЫЗДАН САГЫЗНЫ АЛУ.** Кешенең серен белү, сөйләтү. <...> *хәйлә белән углан авы-*

*зыннан сагызны алганын, хасыйле әлям, һәрни булган вакыйгаларын падишаһка сөйләде* (К. Насыйри).

**АВЫЗДАН <ТЕРЕ> САЕСКАН ОЧЫРУ.** 1. Юкны бар итеп, үзе йә эшләгән, йә күргән кебек итеп сөйләүче турында. *Җыелышларда, ай-һай, үзен чын инкыйлабчы, Мәмәт патшадан да өстен итеп күрсәтергә, йодрыкларын болгый-болгый сөйләргә, авызыннан, кем әйтмешли, саескан очырырга ярата иде ул* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).

2. Мактану. – *Авызыңнан тере саескан очырып утырма инде, без беләбез бит сине!* (Сөйләм).

Төрдәше: авыздан кош очыру; борчак ат<тыр>у 1; борчак чәчү; тере саескан очыру; саескан очыр<т>у.

**АВЫЗДАН САЛМАУ.** Нәрсәне булса да һаман да кабатлау. *Мин яшь чагымда «Кигән кием ничек туза, яшь гомер шулай уза» дигән җырны бик ярата, ирексез үк шуны авыздан салмый йөри идем* (Г. Ибраһимов. Сөю – сәгадәт).

Төрдәше: авыздан өзелмәү 2 һ.б.

**АВЫЗДАН СЕЛӘГӘЕН (ЛАЙЛАСЫН) АГЫЗЫП.** 1. Кеше кулындагы нәрсәгә кызыгучы турында. *Авыздан селәгәен агызып, шул алтын каләмле ручкасына кызыгып тормаса* (Сөйләм).

2. Хатын-кыз артыннан сөйрәлүче турында. *Һәр күргән итәге артыннан авызыннан селәгәен агызып чаба торганнардан түгел ул* (Сөйләм).

**АВЫЗДАН СЕЛӘГӘЙ АГУ (КИЛҮ)** *к.* авыз корыту. *Ләкин мәсхәрә урынына үзенең авызыннан селәгәй акты бугай* (Г. Ибраһимов). *Кырыкка җиткәндә дә әле, миңа карап, синең кебекләрнең авызыннан селәгәй агачак* («Матбугат.ру» порталы).

Төрдәше: авыз корыту һ.б.

**АВЫЗДАН СЕЛӘГӘЙ БҮЛЕНҮ** *к.* авыз корыту. *Без Көнбатышка карап баш чайкадык, тел шартлаттык, авыздан мул итеп селәгәй бүленде* (Р. Зәйдулла. Син, мин, Мөхәммәтәмин...).

Төрдәше: авыз корыту һ.б.

**АВЫЗДАН СЕЛӘГӘЙ КИБҮ (КИТҮ).** «Инде балигъ булгансың, үзеңне егетләрчә тотарга кирәк» мәгънәсендә. *Селәгәең авызыңнан кипкән бит инде, юньлерәк сөйләшергә өйрән* (Сөйләм). *Ишеттек: үзең белән бергә авызыннан селәгәе китмәгән яшь малай ияртеп килгәнсең* (Ә. Шамин. Яңа язлар).

**АВЫЗДАН СӨТ КИПМӘҮ** *к.* авыздан ана сөте <дә> кипмәү. *Танылган әдипләр генә түгел, авызыннан сөт кипмәгән малайлар да монда политика, әдәбият, сәнгать диңгезендә колачлап йөзәләр* (И. Нуруллин).

Төрдәше: авыздан ана сөте <дә> кипмәү.

**АВЫЗДАН СУ АГЫЗУ** *к.* авыз корыту. *Аның кыяры, шалканы, кишере хакында сөйләмә дә инде – алар бөтен авылның авызыннан суыны агыза, бөтен авылны кызыктыра иде* (Г. Исхакый).

Төрдәше: авыз корыту һ.б.

**АВЫЗДАН СУЛАР КИЛҮ (КИТЕРЕРЛЕК; КИТЕРҮ)** *к.* авыз корыту. *[Гөлбану] Әллә нинди тәмле кәнфит исләре килеп тора. Авыздан сулар килерлек* (Г. Камал. Көндәшләр). *[Хәкимҗан] Минем үземнең дә авыздан сулар килә* (К. Тинчурин. Беренче чәчәкләр).

Төрдәше: авыз корыту һ.б.

**АВЫЗДАН СҮЗ АЛА АЛМАУ.** 1. Кирәкле сүзне авызыннан алуы читен булу. *Әйе дә димәде, юк та димәде – авызыннан берниди сүз ала алмадылар* (Сөйләм).

2. Тотлыгып сөйләү. *Вакытлары бик аз иде шул, авазларны суза-суза нидер әйтергә маташуын көтеп тора алмадылар, авызыннан аңлаешлы сүз ала алмыйча китеп бардылар* (Сөйләм).

3. Аз сөйләүче. *Бер киресенә килсә, авызыннан сүз ала алмассың* (Сөйләм).

Төрдәше: авыздан сүзне аркан белән дә тартып алып булмау; авыздан сүзне кыпсуыр (келәшчә) белән дә <тартып; йолкып> алып булмау (ала алмау) 3; авыздан сүзне тартып ала алмау.

**АВЫЗДАН СҮЗ ҖЕБЕН ТАРТУ.** Нәрсә әйтергә теләгәнне белергә тырышу. – *Йә, йә, әлсә, әйт, Баязитова, тел яшергән оялчан килендәй кыйланма, – диде һәм аның авызыннан сүз җебен тартып* (Н. Гыйматдинова. Кыргый).

**АВЫЗДАН СҮЗ ТАРТУ.** Сорау алу. – *Көн саен безнең авыздан сүз тарттылар* (Н. Гыйматдинова).

**АВЫЗДАН СҮЗ ТАРТЫП АЛЫП БУЛМАУ (АЛА АЛМАССЫҢ)** *к.* авыздан сүз ала алмау 1. – *Бу кадәр әтиең булырсың икән, авызыңнан һичбер сүз тартып ала алмассың!* (Г. Гобәй).
Төрдәше: авыздан сүз ала алмау 1 һ.б.

**АВЫЗДАН СҮЗ ЧЫКМАУ** 1. *к.* авыз биктә булу. *Тешсез авызлардан сүз чыкмады, хатыннар иртәгә тагын Зәйнәп катына баш орып киләселәрен чамалап тындылар, шым гына таралдылар* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: авыз биктә булу һ.б.

2. *к.* авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү. – *Миләүшәне күрсә җебеп төшә, авызыннан сүзе чыкмый иде мескеннең* (Сөйләм).
Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

3. Сүз әйтерлек хәлдә булмау. *Тәмам хәле бетеп, күзеннән яшь, авызыннан сүз чыкмый башлагач кына тукталып, йоклап китте ул…* (В. Нуруллин. Яшьнәп үткән яшьлек).

**АВЫЗДАН СҮЗНЕ АРКАН БЕЛӘН ДӘ ТАРТЫП АЛЫП БУЛМАУ** *к.* авыздан сүз ала алмау 3. – *Кайдан таптыгыз бу кешене, авызыннан сүзне аркан белән дә тартып алып булмый* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан сүз ала алмау 3 һ.б.

**АВЫЗДАН СҮЗНЕ КЫПСУЫР (КЕЛӘШЧӘ) БЕЛӘН ДӘ <ТАРТЫП; ЙОЛКЫП> АЛЫП БУЛМАУ (АЛА АЛМАУ)**. 1. *к.* авыздан сүз ала алмау 1. 1. *Малай минем телсез, аның авызыннан сүзне келәшчә белән дә тартып ала алмассың* (Ф. Хөсни).
Төрдәше: авыздан сүз ала алмау 1.

2. *к.* авыздан сүз ала алмау 2. *Сүзләрен кыпсуыр белән дә тартып ала алмыйсың, алсаң да аңлавы кыенрак шул* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан сүз ала алмау 2.

3. *к.* авыздан сүз ала алмау 3. *Сүзгә катнашасы килмәсә, авызыннан сүзне кыпсуырың белән дә ала алмассың* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан сүз ала алмау 3 һ.б.

**АВЫЗДАН ТАРТЫП АЛЫРГА ТОРУЧЫ.** Ертлач, чәлдерүче. *Хәзерге вакытта авыздан тартып алырга торучылар күбәя башлады* (Сөйләм).

**АВЫЗДАН ТАРТЫП ӘЙТҮ** *к.* авыздан алып әйтү. *Уңайсызланамы юкса, үзең генә авызыннан тартып әйт инде* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан алып әйтү.

**АВЫЗДАН ТАШЛАМАУ.** 1. *к.* авыздан өзелмәү 1. *Алар укытучыларының исемен авыздан ташламыйлар, җай чыккан саен, аны искә алып сөйлиләр* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан өзелмәү 1; авыздан <бер дә> өзмәү 1; авыздан төш<ер>мәү 1; телдән төш<ер>мәү.

2. *к.* авыздан өзелмәү 2. *Авыл урамнарында җегетләр, көз көне никрутлар, яңа көйдән тәмам ихласлары кайтып, туеп бетмичә торып, аны авызларыннан ташламыйлар* (Г. Тукай).
Төрдәше: авыздан өзелмәү 2; авыздан төш<ер>мәү 2.

**АВЫЗДАН ТЕРЕ САЕСКАН ОЧЫР<Т>У.** Булмаганны бар дип, үзе күргән яки эшләгән сыман хәбәр таратучы турында. – *Сөйләвен сөйлә, ләкин авызыңнан тере саескан очырма, – дип яңадан чәнчеп алды Гречуха* (Г. Әпсәләмов).

**АВЫЗДАН ТӨКЕРЕК ЧӘЧЕП.** Бик нык дулкынланып, кызып-кызып сөйләү (бәхәсләшү, дәлилләү). *Ишәк акырган кебек ямьсез тавыш белән, эчендә янган ачу белән, күзеннән төтен пыскытып, авызыннан төкерек чәчеп, башлады, ди, сүз Капкорсак-Туймас күз* (А. Алиш. Капкорсак патша).

**АВЫЗДАН ТӨТЕН ЧЫГ<АР>У.** 1. Мәшәкатькә тарып, берәр эш артыннан йөреп, тын алырга да бушамау. – *Авыздан төтен чыкканчы эшләрмен, ләкин бүген бетерермен* (Сөйләм).

2. Кайгылы булу. *Күңелсез хәбәр алганмы әллә, авызыннан төтен чыгарып утыра* (Сөйләм).

**АВЫЗДАН ТӨШ<ЕР>МӘҮ.** 1. *к.* авыздан өзелмәү 1. *Сезнең исемеңезне мин зикер кебек, дәрвишнең зикере кебек әйтәм. Авызымнан төшермим* (Г. Исхакый. Мөгаллимә).
Төрдәше: авыздан өзелмәү 1; авыздан <бер дә> өзмәү 1; авыздан ташламау 1; телдән төш<ер>мәү.

2. *к.* авыздан өзелмәү 2. *«Без яшь чакта» да «без яшь чакта»ны бер дә авызыңнан төшермисең, бераз үсәргә вакыттыр инде!* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан өзелмәү 2 һ.б.

**АВЫЗДАН УТ БӨРК<ЕЛ>Ү (БӨРКЕТҮ; ЧӘЧҮ; ЧӘЧРӘ<Т>Ү).** 1. *миф.* Аждаһа, еланнарның көчен күрсәтүе. *Шулвакыт сәке астыннан, борыла-сарыла, көтүче чыбыркысыдай озын кара елан чыкты да, авызыннан ут бөркеп, аңа таба шуышып килә башлады* (М. Әмирханов. Гәүһәршад). *Фриц ашыга, чөнки аның артыннан, авызыннан ут бөркеп, фронт куып җитеп килә иде* (Ф. Хуҗин. Күкләр шаһит).

2. Гайрәтләнеп, ялкынланып оста сөйләү. *Һәм үрә торды батырның чәчләре, / Газбилә аузыннан утлар чәчрәде* (Г. Тукай. Печән базары, яһуд Яңа Кисекбаш). *Кайткач, исе киткәндәй: «Кара, безнең татар иптәшләр дә авызларыннан ут чәчәргә остарып беткән ләбаса», – дип сөйләнә* (Ә. Еники. Гөләндәм туташ хатирәсе).

Төрдәше: авызга карату (каратып алу / тору) 4 һ.б.

3. Бик каты талашу. *Тез башыннан бүреген алып киертте дә, сагызын бер чартлатып, авызыннан ут чәчте* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).

4. Гайрәт, көч күрсәтү. *Авызыннан ут чәчеп торган бу керәшен хатынын җиңә алмады Сөнгатулла* (Ф. Бәйрәмова. Нух пәйгамбәр көймәсе).

**АВЫЗДАН УТ ЧЫГЫП ТОРУ (УРГЫЛУ).** 1. *к.* авыздан ут бөрк<ел>ү (бөркетү; чәчү; чәчрә<т>ү) 2. *Сөйләгәндә дә авызыннан ут ургыла диярсең, кем аның белән көч сынашыр?* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга карату (каратып алу / тору) 4 һ.б.

**АВЫЗДАН УТЛАР ЧЫГ<АР>У.** 1. Ялкынланып, гайрәт чәчеп сөйләү. – *Юаш кына булсаң да, бер кызсаң, авызыңнан ут чыга икән* (Г. Ибраһимов. Яшь йөрәкләр).

Төрдәше: авызга карату (каратып алу / тору) 4 һ.б.

2. *к.* авыздан ут бөрк<ел>ү (бөркетү; чәчү; чәчрә<т>ү) 3. – *Кыздырмагыз минем хатынны, бер башласа, авызыннан утлар чыгара ул* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга карату (каратып алу / тору) 4 һ.б.

**АВЫЗДАН ҮПКӘ КҮРЕНҮ** *к.* авыз ачса, косе теле күренү 2. – *Актык чиккә терәлдек бит инде, авыздан үпкә күренә* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: авыз ачса, кече теле күренү 2 һ.б.

**АВЫЗДАН ЧЫГАРУ.** 1. Сөйләү. <...> *сөйләр сүзен дә авызыннан көчкә чыгара торган бер малай иде* (Г. Толымбай. Кызыл Армиядән кайткач).

Төрдәше: авыз ачу 2 һ.б.

2. Ялгыш сөйләп ташлау. *Һәрхәлдә, Хәлимнең болар үз теле, үзе әйтергә теләгәннәре һәм авызыннан чыгарга тиешле гыйбарәләре түгел* (Ф. Яхин. Куш каен аланлыгы).

Төрдәше: авыздан ычкындыру; әйтеп кую 1; әйтеп салу (ташлау); телдән ычкындыру.

**АВЫЗДАН ЧЫГУ.** Хәзерге мизгелдә әйтелү. *Авыздан чыккан сүз – аткан ук* (Мәкаль).

**АВЫЗДАН ЧЫГУГА (ЧЫККАНЧЫ) ЭЛӘКТЕРҮ (ЭЛӘКТЕРЕП / ЭЛЕП КЕНӘ АЛУ).** Кеше сүзен әйтеп бетергәнче, мәгънәсен аңлап алу; акыллы, зиһенле кеше турында. *Аның тагын бер искиткеч осталыгы бар иде, кешенең авызыннан сүз чыкканчы, ул аны эләктереп ала белә иде* (Сөйләм).

Төрдәше: аек акыл <белән>; аек акыллы; аек баштан (баш белән) 2; аек <күздән> карау; аек караш<лы>; аек күз белән карау; аек фикер иясе; аек фикерле; алтын акыл; алтын баш<лы> 2; акыл иясе; акыл капчыгы 1; акыл кергән; акылга беткән; акылга утырган; акылга хәзинә; акыллы баш<лы> 1; акылы<ң> алтын <икән> 1; акылы башында; акылы җирендә <булу>; акылы камил; акылы сау; акылы тулы; акылы түгәрәк; акылы хәзинә; акылы эшләү; баш<ы> йөрү; башлы булу; башлы кеше (егет; малай һ.б.); башлы көлтә; башы йомры; башы түгәрәк; башы эшләү; башың – тегермән ташы; бер сүзе мең алтын; ике башлы <булу>; иллә дә баш үзендә; тирән акыллы; фикер иясе; хикмәт иясе.

**АВЫЗДАН ЭНҖЕЛӘР ТҮГЕЛҮ.** 1. Тирән мәгънәле сүзләр сөйләү. *Авыздан энҗеләр түгеп сөйли белүчеләр күп түгел ул* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга ия булу 2 һ.б.

2. Матур тешләрен күрсәтеп елмаю. *Фоторәсемдә ул авызыннан энҗеләр түккәндәй елмаеп тора* (Сөйләм).

Төрдәше: авыздан энҗе-мәрҗән (бриллиант, гәүһәр) кою (сибү, чәчү) 1.

**АВЫЗДАН ЭНҖЕЛӘР ЧӘЧҮ (САЧМАК).** Матур итеп сөйләү. *Агыздан энҗеләр сачып, / Сөйләш дию бәян итдим* (Г. Кандалый. Сахибҗәмал). *Әнә Зөлфәт олыларча, кулларын болгыйболгый, авызыннан энҗеләр чәчә; Фәрит*

*Гыйльми яңа хикәясен төгәлләгән икән* (Н. Гамбәр. Яшәү тамыры).
Төрдәше: авызга карату (каратып алу / тору) 4 һ.б.

**АВЫЗДАН ЭНҖЕ-МӘРҖӘН (ГӘҮҺӘР; БРИЛЛИАНТ) КОЮ (СИБҮ; ЧӘЧҮ).** 1. Бик оста сөйләү. *Авызыннан энҗе-мәрҗән койган / Түрәләрен мактап дөньяның* (Г. Афзал).
Төрдәше: авызга карату (каратып алу / тору) 4 һ.б.

2. *к.* авыздан энҗеләр түгелү 2. *Елмаю белән авызыннан гәүһәр сибәдер* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан энҗеләр түгелү 2 һ.б.

**АВЫЗДАН ЫЧКЫНДЫРУ** *к.* авыздан чыгару 2. *Фатыйма абыстайның морады: Укы, галим булырсың, димәк иде; әгәр дә Җиһаншаның фикерендә булган нәрсәләрне белсә, мулласына иптәш мулла булудан куркып, ул сүзне авызыннан ычкындырмаган булыр иде* (З. Һади. Җиһанша хәзрәт).
Төрдәше: авыздан чыгару 2; телдән ычкындыру.

**АВЫЗДАН ЫЧКЫНУ.** Көтмәгәндә-уйламаганда әйтеп кую. – *Тфү-тфү, нәләт, авыздан ычкынды, иптәш Шәмтиев* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң). *Инде соравы бер авыздан ычкынгач, уңайсызланып, җавапны көтми хәле юк иде* (Т. Әйди. Елан угы).

*АВЫЗЛАРЫ* ❖ **АВЫЗЛАРЫ АВЫЗДА.** Дус, тату яшәү. *Алар икесе бергә яшиләр, янәшә эшлиләр, авызлары авызда, күзләре бер-берсен һич югалтмыйлар иде* (А. Гыйләҗев). – *Авызлары – авызда, мин сиңа әйтим. Самат бик кызык нәрсә сөйли иде, ахрысы* (Г. Галиева. Тулгак).

*АВЫЗЛЫГА* ❖ **АВЫЗЛЫГА СҮЗ БИРМӘС, ҖӘЯҮЛЕГӘ ЮЛ БИРМӘС.** Үҗәт кеше турында: беркемгә дә сөйләргә ирек бирмәс, берәүгә дә юл куймас. *Миңлебану ипсез, иләмсез, абагы да җабагы, ятимлектә үскән, әти-әни тәрбиясе күрмәгән, шулар өстенә авызлыга сүз бирмәс, җәяүлегә юл бирмәс, мәгънәсез дә кыз* (И. Нәбиуллина. Миләш тәме).

*АВЫЗЛЫГЫН* ❖ **АВЫЗЛЫГЫН ТАРТЫП ТОРУ.** Тәртипне бозмасыннар, начарлык эшләмәсеннәр өчен, игътибарлы булу кирәклеге турында. *Малайларыңны артык иркенлеккә чыгарма, ара-сыра авызлыкны да тартып тору зарар итмәс* (Сөйләм).

**АВЫЗЛЫГЫН ТЕШЛӘП <ҖАН-ФӘРМАНГА> ЧАБУ.** Берәүгә дә баш бирмичә, үзе теләгәнне генә эшләп йөрү. *Аның, авызлыгын тешләп, җан-фәрманга чапкан чаклары узар* (Г. Ахунов).
Төрдәше: авызлыкны тешләү.

*АВЫЗЛЫК* ❖ **АВЫЗЛЫК КИДЕРҮ.** Кешене тулысынча үз ихтыярыңа буйсындыру, сүз дәшмәс итү. *Туктады нидер сизеп, / Туктады уйлар агышы, / Авызлык кидерделәр* (Р. Гаташ. Сагышлы моңнар).
Төрдәше: авызлыклап алу; авызлыклап башка (муенга) менеп атлану; авызлыклап тотмастай; авызлыклап тоту; аяк-кулдан бау ишү; баш идерү; билне сугып сындыру 1; бишкә бөкләү (бөгү) 2; бугалак ташлау; грифтар итү; дуга кебек бөгү; камыт киге<д>р<т>ү; тез астына <бөгеп; бөтереп> салу.

**АВЫЗЛЫК ТЕШЛӘҮ.** 1. *к.* авызлыгын тешләп <җан-фәрманга> чабу. *Артист бер авызлыкны тешләп алса, сөйләүдән тиз генә туктар димәгез* (Г. Әпсәләмов).
Төрдәше: авызлыгын тешләп <җан-фәрманга> чабу.

2. Нинди булса да эшне олы максат ниятеннән үзе теләгәнчә эшләмәү. *Ун олыс түрәләре, берләшеп, авызлык тешләп, явызлык ташыган бу чыгымчы мирзаны акылга утыртырга булдылар* (Р. Батулла. Сөембикә).

*АВЫЗЛЫКЛАМАКЧЫ* ❖ **АВЫЗЛЫКЛАМАКЧЫ БУЛУ.** Баш булмакчы, кулда тотмакчы булу. *Сизәсезме, егетләр, безне авызлыкламакчы булалар* (Ш. Усманов). *Сизенүемчә, кайбер райком работниклары мине авызлыкламакчы булулар* (А. Расих).

*АВЫЗЛЫКЛАП* ❖ **АВЫЗЛЫКЛАП АЛУ** *к.* авызлык кидерү. *Алар мине бик нык авызлыклап алмакчылар иде дә, булдыра алмадылар* (М. Фәйзи).
Төрдәше: авызлык кидерү һ.б.

**АВЫЗЛЫКЛАП БАШКА (МУЕНГА) МЕНЕП АТЛАНУ.** Күндәм кешене буйсындырып, үзе теләгәнчә эш итү. *Ирләренең муеннарына тәмам менеп атланганнар да, ирләрен авызлыклап, боргычлап алганнар* (Г. Камал).
Төрдәше: авызлык кидерү һ.б.

**АВЫЗЛЫКЛАП ТОТМАСТАЙ.** Буйсындырып тота алу. – *Әллә мине үзең шикелле генә*

*картлачны авызлыклап тотмастай дип уйлыйсыңмы?* (Ә. Гаффар. Бодай бөртеге һәм тегермән ташы).
Төрдәше: авызлык кидерү һ.б.

**АВЫЗЛЫКЛАП ТОТУ** *к.* авызлык кидерү. *Ул тәүлек чамасы үзен авызлыклап тотты тотуын, әмма хәзер ул читлектән ычкынган ач арыслан иде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: авызлык кидерү һ.б.

*АВЫЗЛЫКНЫ* ❖ **АВЫЗЛЫКНЫ КУЛДАН ЫЧКЫНДЫРУ.** Буйсындырып тота алмау, тыңлата алмау. *Шул бер хатынга баш була алмады, авызлыкны кулдан ычкындырды шул!* (Сөйләм).
Төрдәше: авызлыкны салу; авызлыкны читкә чөю.

**АВЫЗЛЫКНЫ САЛУ.** Тыюлардан котылу, теләгәнеңне эшләү. *Узган кыш патша төшерелгәч, шәкертләр хөррият диделәр дә бөтенләй авызлыкларын салдылар* (Ә. Еники. Коръәнхафиз).
Төрдәше: авызлыкны кулдан ычкындыру; авызлыкны читкә чөю.

**АВЫЗЛЫКНЫ ТЕШЛӘҮ** *к.* авызлыгын тешләп <җан-фәрманга> чабу. *Ә Емелькинга җитә калды, бөтенләй авызлыгын тешләп алды бу... Ни әйткәнен белми, сибә генә* (Ә. Еники. Без дә солдатлар идек).
Төрдәше: авызлыгын тешләп <җан-фәрманга> чабу.

**АВЫЗЛЫКНЫ ЧИТКӘ ЧӨЮ.** Кемгә, нәрсәгә булса да буйсынудан азат булу. *Авызлыкны, читкә бер чөйгәч, яңадан кабасы килми* (Ш. Маннур).
Төрдәше: авызлыкны кулдан ычкындыру; авызлыкны салу.

*АВЫЗЛЫКСЫЗ* ❖ **АВЫЗЛЫКСЫЗ КАЛУ.** Тыңлата алмау хәленә килү, тотнаксызлану, башбаштаклана башлау. *Әле хәзердән үк болай җенләнгән анасы, Шибай карт үлеп, йөгәнсез, авызлыксыз калса, зур уллары ташлап чыкса, бәйләүдән ычкынган эткә әйләнер* (Г. Ибраһимов).

*АВЫЗЛЫКТАН* ❖ **АВЫЗЛЫКТАН ЫЧКЫНДЫРУ.** Тыңлата, буйсындыра алмау. *Мин моны сизәм, болай кычкырырга ярамаганлыгын аңлыйм, әйтерсең башка бер көч мине авызлыктан ычкындырып ярсырга мәҗбүр итә* (Х. Ширмән. Ерактагы йолдызым).

*АВЫЗНЫ* ❖ **АВЫЗНЫ АВЫЗГА КУЕП** *к.* авызга авыз куеп <сөйләшү>. *Авызны авызга куеп, / Сер сөйләүләре бар* (Г. Афзал).
Төрдәше: авызга авыз <сөйләшү> 1 һ.б.

**АВЫЗНЫ АКАЙТЫП КҮЗНЕ ЙОМУ.** Киресенчә эшләүне аңлата. – *Сөйләшкән идек бит инде, нигә авызыңны акайтып күзеңне йомдың?* (Сөйләм).

**АВЫЗНЫ АРАНДАЙ АЧУ**. Авызны киереп иснәү (әдәпсезлек билгесе). – *Кеше алдында авызыңны арандай ачма инде* (Сөйләм).
Төрдәше: авызны басу капкасы хәтле ачу.

**АВЫЗНЫ АЧЫП ЙӨРҮ.** Тормышны алып бару өчен иң мөһим нәрсәләрне (мәс., атны) урлату турында. – *Менә йөр син авызыңны ачып! Бер төн эчендә кара җәяү калуың бар!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**АВЫЗНЫ АЧЫП КАРАП ТОРУ.** Ваемсыз, дикъкатьсез булу. *Без авызыбызны ачып шаккатып карап торган арада, бу айлар да яшелләнә башлап, инде аларның янына, ярымтүгәрәк ясап, тагын берәр ай кызарып чыкты* (Ф. Тарханова. Килделәр).
Төрдәше: авыз ачып бару (йөрү) 1 һ.б.

**АВЫЗНЫ АЧЫП (АЧКАН КИЛЕШ) КАТЫП КАЛУ.** 1. Көтелмәгән хәлдән, сүздән аптырап, шаккатып калу. *Ифрат нык гаҗәпләнеп, кухня ишеге ярыгыннан карап торган Сәбилә бу күренештән авызын ачып катып калган иде* (З. Мурсиев. Елан оясы).
Төрдәше: авыз ачып калу 5; күзләр акаю (алару).

2. *к.* авыз ачып калу 6. *Әмма ат янына ук килеп җитә алмадым, тарантасны алсу күлмәкле кыз баланы күреп, баскан урынымда авызымны ачып катып калдым* (Ш. Алпар. Милләт өмете).
Төрдәше: авыз ачып калу 6 һ.б.

**АВЫЗНЫ АЧУ.** Уйлаганыңны ирекле рәвештә әйтү мөмкинлеге. *Русиядә 1905 елда кабынып киткән инкыйлаб сүз иреге, матбугат иреге алып килде, авызларны ачты* (М. Әмирханов. Зиннәтулла хәзрәт).

**АВЫЗНЫ БАСУ КАПКАСЫ ХӘТЛЕ АЧУ** *к.* авызны арандай ачу. *Авызны басу капкасы хәтле ачып көлү бер дә килешә торган эш түгел инде!* (Сөйләм).
Төрдәше: авызны арандай ачу.

**АВЫЗНЫ БӘЙЛӘҮ.** Кемне дә булса үзенә тулысынча буйсындыру. *[Бәдигылҗамал] Хәзер инде Ибраһим безнең улыбыз түгел, алар аны инде үзләренә тәмам кол итеп бетерделәр. Ибраһимның авызын бәйләп бетерделәр* (Г. Камал. Кайниш).
Тәрдәше: телне бәйләү.

**АВЫЗНЫ БӘЛШӘЙТҮ.** Үпкәләп елау, авызның бәлеш кебек җәелүе. *<...> кеше булып, торымнан-торымга дәрәҗәләрен бер баскыч югары күтәрә-күтәрә балда-майда йөзгәндә, ул «чирләдем!» дип авызын бәлшәйтеп, ата-ана җилкәсенә кайтып төшәчәк* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**АВЫЗНЫ БЕЛЕП АЧУ** *к.* авызга ия булу 2. *Авызыңны белеп ач, ни сөйлисең син!* (Х. Ибраһим. Килмешәк).
Тәрдәше: авызга ия булу 2 һ.б.

**АВЫЗНЫ БЕР АЧСА ЯБА (ЙОМА) БЕЛМӘҮ.** Сөйли башласа, башкаларга ирек бирмичә, үзе генә сөйләү. *Таҗетдинов авызын бер ачса йома белми иде. Шуңа күрә Тәнзилә капылт кына ишеккә борылды. – Тыңлап бетер инде* (А. Гыйләҗев).

**АВЫЗНЫ БИКЛӘҮ.** 1. Сүз әйтә яки җавап бирә алмаслык хәлгә кую. *– Нигә тын калдыгыз, авызларыгызны бикләделәрме әллә? – диде* (А. Алиш. Якты күл буе).
Тәрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1 һ.б.
2. *к.* авыз каплану 3. *Сайлауларда депутат итәләр дә, авызымны бикләп, сүз әйттермиләр!* (А. Хәлим. Трофей).
Тәрдәше: авыз каплану 3 һ.б.

**АВЫЗНЫ БИКТӘ ТОТУ.** Кирәкмәгән сүз сөйләмәү. *Авызыңны биктә тота белсәң, әтәч булып кычкырмый* («Казан утлары» ж.).
Тәрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗНЫ БИЯЛӘЙДӘЙ ИТҮ.** Иреннәрен сузгалап, юньсез сүзләр сөйләү. *Шул башың белән авызыңны бияләйдәй итү сиңа бер дә килешми* (Сөйләм).

**АВЫЗНЫ БИШКӘ БӨРҮ (БӨГҮ).** Ялагайланып сөйләшү. *«Сезне фәлән кеше фәлән дип әйтте» дип, куштан хатыннарча авызын бишкә бөгеп, тәмләп-тәмләп, үзенчә бер нәзакәтлелек белән сөйләргә керешә* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

**АВЫЗНЫ БӨТЕН КОЛАККА ЕРУ** *к.* авыз еру 4. *Ходай үзенә болай да сайлап биргән авызын бөтен колагына ерып, сәхнә артыннан Гаптери ашыгып чыккач кына исебезгә килеп, кул чабарга тотындык* (Г. Шәрәфи. Тәфтиләү).
Тәрдәше: авыз еру 4 һ.б.

**АВЫЗНЫ БҮЛТӘЙТҮ.** Ачу кабарудан яки үпкәләүдән авыз-иреннәрнең бүлтәюе. *[Мөгълифә] (мыскыл итеп карап, авызларын бүлтәйтеп үчекләп). Алла, харап итте, мине куркытмакчы булып маташа* (Г. Камал. Уйнаш).

**АВЫЗНЫ БҮЛШӘЙТҮ.** Авызны бәлеш сыман җәю яки үпкәләп елау. *– Ничек диде соң әле төштә теге, кем... Һәр кешедә Наполеон кодрәте бар, дидеме? – Һәм ул, авызын бүлшәйтеп, уянырга исәбе дә булмаган хатынына карады* (М. Галиев. Төнге кыюлык).
Тәрдәше: авызын бәлеш кебек җәю; авызын бәлшәйтү; авызын сурәтләндерү.

**АВЫЗНЫ БЫЛЧАЙТЫП, <ИРЕННЕ КЫЙШАЙТЫП>.** Үпкәләүчән яки тиз ярaклaнучан кешенең сөйләү рәвешенә карата. *Президент, авызын былчайтып, мыгырдап куйды: – Кем кулыннан һәлак булсаң да барыбер түгелмени?* (З. Мәхмүди. Эзләмә).

**АВЫЗНЫ ЕРТКАН КОРЫ КАШЫК.** Фәкыйрь, ярлы-ябага нәсел турында. *Ә риясыз әнисенең [шәҗәрәсе] һаман авызны ерткан коры кашык, алар батрак кавеме* (Н. Гыйматдинова. Кем беренче?).

**АВЫЗНЫ <ИЛӘКТӘЙ> ҖӘЮ.** Бик рәхәтләнеп кеше гайбәтен сөйләү. *Ул тегеләй, ул болай дип, авызын җәеп, ул да кешене сөйләп утырган була, затсыз* (Я. Вәли).
Тәрдәше: авыз чайкау 1 һ.б.

**АВЫЗНЫ ҖӘЙМӘ ИТҮ.** Авызны зур ачып елау. *Урам буйлап, авызын җәймә итеп, / Елыйелый кайтты өенә* (Һ. Такташ).

**АВЫЗНЫ ҖӘЙМӘҮ.** 1. Кеше сүзенә игътибар итмичә, мыскыллы елмайган кешегә карата. *– Авызыңны җәймә шулкадәр, бераз кеше сүзенә дә колак сал* (Сөйләм).

2. Ымсынмау, үзеңнеке итәргә теләмәү. – *Кызыкай, син бик авызыңны җәймә бай егетләргә, генерал хатыны булу өчен, лейтенантка кияүгә чыгарга кирәк* («Матбугат.ру» порталы).

**АВЫЗНЫ ҖИДЕ ЙОЗАККА БИКЛӘҮ**. Бер сүз дә әйтмәү, сөйләшмәү. – *Әйт сеңелеңә: әгәр Раджа белән алга таба да очрашасы килсә, авызын җиде йозакка яхшы бикләсен* (Х. Ширмән. Яшәү моңы).
Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗНЫ ҖИДЕ ЙОЗАКТА ТОТУ** *к.* авыз <да> ачмау. – *Сезгә иң башта авызыгызны җиде йозакта тотарга кирәк* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗНЫ ҖЫЕП СӨЙЛӘШҮ.** Теләсә кем алдында уйламыйча сөйләргә ярамаганлыкка, чама белергә кирәклеккә ишарә. *[Баһаветдин] Син бит... Син шәкерт булсаң, авызыңны җыеп сөйләш* (Н. Исәнбәт. Һиҗрәт).
Төрдәше: авызны җыя төшү.

**АВЫЗНЫ ҖЫЛЫТУ.** 1. Сугып, авызны канату. – *Мин барып җиткәнче, аның авызын җылытып өлгергәннәр иде инде* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

2. *к.* авыз җебетү 1. Аракы белән сыйлап, үз тарафдары итү. – *О-о, исәнме мулла! – диде ул Мөбәрәктән көләргә исәп итеп, тәкәбберләнеп. – Әрмән коньягыннан авыз җылытып бакмыйсыңмы соң, милорд?* (М. Шаһимәрдән. Татлы агу).
Төрдәше: авыз җебетү 1 һ.б.

**АВЫЗНЫ ҖЫЮ.** Сөйләүдән, көлүдән туктау. *Әмма, картның үтә дә җитди йөз-чыраен күргәч, шундук авызын җыйды* (Г. Гыйльманов. Исемең ничек, Гадел?).
Төрдәше: авызга суккандай туктау.

**АВЫЗНЫ ҖЫЯ (ҖЫЕП АЛА) АЛМАУ.** 1. Күп көлү, көлеп тору. *Аңа күз ташлаган саен, гәрәйлеләр елмаймыйча калмый, аларның канәгать йөзләрен күреп, әмир үзе авызын җыя алмый* (В. Имамов. Карабәк).

2. Кешегә ачык йөз белән елмаеп тору. *Мокыт булса да булыр икән, биялэй авызын җыя алмыйча, мескенләнеп басып тора* (М. Әмирханов).

3. *к.* авыз еру 4. *Алга китеш бар; күптәнме әле без үзебезнең обком секретаре залга «Хурматлы дуслар!» дип мөрәҗәгать иткәч, авызны җыя алмыйча кул чаба идек, ә монда Мәскәү түрәсе!* (Р. Зәйдулла. Кармазин).
Төрдәше: авыз еру 4 һ.б.

4. Кирәкмәгән сүз әйтү, кирәген әйтә алмау. *Ул да минем шикелле каушаган, ахры. Шуңа авызын җыя алмый торгандыр* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**АВЫЗНЫ ҖЫЯ ТӨШҮ.** Уйлабрак, тыйнаграк сөйләү, тыйнаксыз булмаска чакыру. *[Кәрим] Авызыгызны җыя төшегез, малайлар! Юк исә, тешләрегезне җирдән җыеп алырсыгыз!* (Г. Камал. Хафизалам, иркәм).
Төрдәше: авызны җыеп сөйләшү.

**АВЫЗНЫ ЙОЗАКЛАУ** *к.* авызны ачарга <да> ирек бирмәү 1. *Галимҗан Зобаниның авызын йозакларга сүз бирә* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).
Төрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1 һ.б.

**АВЫЗНЫ ЙОМ<ДЫР>У** 1. *к.* авызны ачарга <да> ирек бирмәү 1. *Укытучының авызын йомдырды* (А. Гыйләҗев. Әтәч менгән читәнгә).
Төрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1 һ.б.

2. *к.* авыз каплану 3. *Әмма тәм-том авызымны йомдырды, хәтеремне адаштырды* (Ф. Яхин. Иделем акчарлагы).
Төрдәше: авыз каплану 3 һ.б.

**АВЫЗНЫ ЙОМУ (ЯБУ).** 1. Сөйләүчеләрнең көчле дәлилләре тәэсирендә дәшмәскә мәҗбүр булу. *Мәче шундый усал итеп карады, хәтта тәнемнән электр тогы узгандай булды. Шунлыктан авызны йомарга туры килде* (З. Мәхмүди. Профессор Мияугөл).
Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

2. *к.* авыз капла<т>у. *Ул, минем кебек, килене дә авызын йомар дип уйлаган* (Н. Гыйматдинова. Фәрештәләр).
Төрдәше: авыз капла<т>у.

**АВЫЗНЫ КАМАШТЫРУ.** Нинди булса да әче әйбернең авызны бөрештерүе. *Чәчрәп чыккан әчкелтем алма суы авызын камаштыргач, йөзен чытып, анысын да күпер баганасына томырды* (Г. Әдһәм. Асылмалы күпер).

**АВЫЗНЫ КАНГА ТУЗДЫРУ** *к.* авыз җебетү 2. *Авызын канга туздырып җибәрделәр бугай теге авыл егетенең* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АВЫЗНЫ КАПЛАП ЯБУ.** Берәрсен дәшмәскә мәҗбүр итү (гадәттә ришвәт биреп). *Иң курыкканнары күрше абзые иде, аның да авызын каплап ябып куйдылар* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1 һ.б.

**АВЫЗНЫ КАРА КАН БЕЛӘН ЮУ** *к.* авыз җебетү 2. – *Эт баш... авызын кара кан белән юганны көтәдер... явыз... – кеби сүзләре ишетелә башлады* (Г. Ибраһимов. Йөз ел элек).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АВЫЗНЫ КАРА КАН ИТҮ** *к.* авыз җебетү 2. *Түзеп-түзеп тордылар да түзмәделәр, авызын кара кан иткәнче дөмбәсләделәр тегене* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АВЫЗНЫ КАРА КАНГА БУЯУ (БАТЫРУ)** *к.* авыз җебетү 2. *Аның белән санашмыйча, кызны озатып йөргән Гамилнең авызын кара канга батырып, тешен койды...* (М. Маликова. Чәчкә балы).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АВЫЗНЫ КӘМШӘЙТҮ.** Ясалма рәвештә олысымак сөйләшү. *Мөкаррәмәне дә буш калдырмады. «Имиең дә чыкмаган килеш ничек итеп балаңны имезерсең соң? – диде, авызын кәмшәйтеп* (М. Әмирханов. Мөкаррәмә).

**АВЫЗНЫ КОЛАК АРТЫНА ЭЛҮ** *к.* авыз еру 4. *Ул номер сипкелле малайга эләкте, менә ул хәзер авызны колак артына элеп чыгып бара* (Г. Ахунов).
Төрдәше: авыз еру 4 һ.б.

**АВЫЗНЫ КОЛАККА КАДӘР ЕРУ** *к.* авыз еру 4. – *Котлыйм, туган! – диде ул, авызын колакка кадәр ерып* (Э. Шәрифуллина. Бишботлар юкка тавык суймый).
Төрдәше: авыз еру 4 һ.б.

**АВЫЗНЫ КҮБЕКЛӘТҮ.** Сөйләү, әйтү. *[Тимеркәй] Әсин, бабай, юкка авызыңны күбекләтәсең: монда калып, сезнең этләрегездән талатыр хәлем юк...* (Г. Ибраһимов. Яңа кешеләр).

**АВЫЗНЫ КҮККӘ ЧӨЕП ЙӨРҮ.** Юкка-барга, гамьсез рәвештә һаваланып йөрү. *Авызыңны күккә чөеп йөрисең* (Г. Зәйнашева).

**АВЫЗНЫ КҮТӘРЕП ТОРУ.** Бернәрсә дә аңлатмаган кыяфәт белән тору. *Син нәрсә авызыңны күтәреп торасың монда, сала гыйбады?!* (М. Мәһдиев).

**АВЫЗНЫ КЫЗЫЛГА БУЯУ** *к.*авыз җебетү 2. *Теге сүзләрең өчен алама егетнең менә бу дуамал йодрыгы авызыңны кызылга буяганда да яраган булыр иде* (М. Фәйзи. Кызыл йолдыз).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АВЫЗНЫ МҮКЛӘҮ** *к.* авызны ачарга <да> ирек бирмәү 1. – *Нәрсә, авызыңны мүкләделәрме әллә?* (Ф. Баттал. Җиллекәй).
Төрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1 һ.б.

**АВЫЗНЫ ӨШЕТҮ.** Теленә хуҗа була алмаган кешене кыйнап акылга кертү. *Туйдырды бу Мансур, авызын өшетмичә булмас!* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АВЫЗНЫ ПИЧӘТЛӘҮ (ПИЧӘТЛӘП КУЮ)** *к.* авыз <да> ачмау. *Берәү тыңламаса киңәшне рәтләп, / Телең тешлә, авызың куй пичәтләп* (У. Имәни. Киңәш).
Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗНЫ ТЕГҮ.** Берәр кешене сөйләшмәслек иттерү. *[Хәлил] Кешенең авызын тегеп буламыни?* (М. Фәйзи. Галиябану).
Төрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1 һ.б.

**АВЫЗНЫ ТОМАЛАУ.** 1. *к.* авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1. *Гайнан уенча, Камил Чаллы буасының койрыгы бу тирәгә кадәр менеп җитмәячәген белеп кайтырга да Ризванның авызын бер сүз белән томаларга тиеш иде* (Г. Бәширов. Җидегән чишмә).
Төрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1 һ.б.

2. *к.* авыз каплану 3. *Адвокатның мыегын майларга, тикшерүченең авызын томаларга, эш судка барып җитсә, судьясын йомшартырга кирәк* (К. Кара. Уфа – Афина).
Төрдәше: авыз каплану 3 һ.б.

3. Кешене куркытып яки боерып сүз әйтмәслек хәлгә китерү. *Ә Гайнүш, Зәйнүшенең авызын шулай ансат кына томалап, гаять зур дәрт белән Майбәдәр карчыкның туган көненә әзерләнә башлады* (Ә. Еники. Майбәдәр карчыкның туган көне).

4. Тиешле яки каты сүз әйтеп, дәшмәс итү. *Нәфисә андыйларның бер сүз белән авызларын томалый иде* (Г. Бәширов. Намус). *Нәрсә*

*булса да берәр каты сүз әйтеп, тегенең авызын томалау нияте белән, ишек алдына таба атлады* (Ф. Хөсни. Күршеләр).

5. Кешенең гражданлык хокукын чикләү, сүз әйтергә ирек бирмәү. *Авызны томалый торган вакытлар бетте инде* (М. Хәсәнов).

Төрдәше: авыз капла(т)у; авызны бикләү; авызны тыгылдыру; авызны ябу; телне кисү.

**АВЫЗНЫ ТОТУ** *к.* авыз ачарга да ирек бирмәү 1. *Ул бу юлы авызын тотмакчы иде, җаен таба алмады. Урыныннан кузгалды да: «Кеше түгел икән», – дип, сүгенеп китеп барды* (Ф. Яхин. Кеше түгел).

Төрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1 һ.б.

**АВЫЗНЫ ТУРАЙТУ** *к.* авыз җебетү 2. *Исенә төшердек, авызы кыегайган икән, турайтып бирдек* (Ф. Яхин. Империалист).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АВЫЗНЫ ТЫГУ (ТЫГЫЛДЫРУ)** 1. *к.* авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1. *Менә, Садыйк абзый, болар берлә сөйлә. Үз сүзең берлә үз авызыңны тыгалар* (Г. Исхакый. Алдым-бирдем). *– Сөйләүчеләрнең авызын тыгып булмый, әни. Алар бары наданлыкларыннан, мине күрә алмауларыннан гына сөйлиләр* (Һ. Такташ).

Төрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1 һ.б.

2. *к.* авыз каплану 3. *[Шакир] <…> боларның гына авызларын тыгылдырып чыгарып җибәрим әле, шуннан соң мин сиңа тиздән, берничә көннән үк табып бирермен* (Г. Камал. Безнең шәһәрнең серләре). – *Юк, синең медаль белән авызың тыгылды, син гаделлекне дә оныттың* (Х. Камалов).

Төрдәше: авыз каплану 3 һ.б.

**АВЫЗНЫ ТЫРПАЙТУ (ТЫРПЫЧЛАНДЫРУ).** Авызын-иреннәрен кабартып, тәкәббер кыланып сөйләгән кеше турында әйтелә. – *Тырпайтмасана шул авызыңны, болай да карарлыгы юк* (Сөйләм).

**АВЫЗНЫ УБЫРЛЫ КАРЧЫК ПИЧӘТЛӘП КИТҮ** *к.* авыз <да> ачмау. *«Нигә алар каф тавы артында?» дип сорарга тели Бибинур карчык, иреннәре йомык, ачылмый... Авызын убырлы карчык пичәтләп киткән, имеш...* (А. Гыйләҗев. Җомга көн кич белән...).

Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АВЫЗНЫ ҮЛЧӘП АЧУ.** Кирәкмәгән, ярамаган сүзне сөйләмәү, уйлап сөйләү. – *Син авызыңны үлчәп ач, арба чәкүшкәсе, – ди. – Шымчы булмаска соң!..* (Г. Сабитов. Кәккүк ялгыша икән).

Төрдәше: авызга ия булу 2 һ.б.

2. «Сүзеңне белеп-чамалап сөйлә» мәгънәсендә кисәтү. – *Сиңайтәм, күрше, авызыңны чамалап ач, хәзрәтнең колагы очлы* (Г. Ахунов).

Төрдәше: авызыңны җыеп сөйләш; авызыңны җыя төш; авызыңны шәйләп (шәйләбрәк) ач (ике маддә өчен дә).

**АВЫЗНЫ ЧАБАТАДАЙ ЕРУ (КИЕРҮ).** Кешедән көлүчене сурәтләгәндә кулланыла. *Гыйбадулланың авызы чабатадай ерылды, ди әни* (А. Гыйләҗев).

**АВЫЗНЫ ЧАМАЛАП АЧУ** *к.* авызга ия булу 2. *[Габделхәй] Авызыңны чамалап кына ач, кордаш. Әле Илһамның язмышын беркем белми* (Ф. Бәйрәмова. Сандугачның балалары).

Төрдәше: авызга ия булу 2.

**АВЫЗНЫ ЧИШЕП ҖИБӘРҮ.** Күп сөйләшү. *Ике йөз грамм аракы бер үк вакытта күңелне дә, янчык авызны да чишеп җибәрде* (Ф. Хөсни).

Төрдәше: авызны яба белмәү; авызы тынмас; авызы ябылмау; авызын бер ачса, яба (йома) белмәү; әңгәмә куер<т>у; әңгәмә сату; сүз боткасы куер<т>у; сүз куер<т>у; сүзе сүзгә охшамый, авызы сүздән бушамый; тегермән тарта, он чыкмый 1; тегермән тарт<тыр>у авызының туктасы юк; тегермән <шәп (әйбәт)> тарту 2; тел белән дөнья гизү; тел сүздән бушамау; тел белән тегермән корма, аннан барыбер он чыкмас; тел белән тегермән кору; тел белән тегермән тарт<тыр>у; тел белән чумар ишү; тел сүздән бушамау; телгә салыну (салынып тору; салышу) 1; теленә тилчә чыккыры; теленә шайтан төкергән; теленең тупсасы юк, авызының туктасы юк; телең чыптадан булса, әллә кайчан тузып беткән булыр иде; чүбек чәйнәү; һавадан алып сөйләү.

**АВЫЗНЫ ЧИШМӘГӘ ТЫГУ.** Яхшылык эшләү, ярдәм итү. *Коляга рәхмәт, ул минем авызымны чишмәгә тыкты, – дип, бу күк язулы яшерен басма кәгазь белән партиянең үзәк органын кайдан, ничек алып баруын сөйләде* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр).

**АВЫЗНЫ ЧӨЙГӘ ЭЛҮ.** 1. Сүзгә катнашмау, дәшмичә калу (утыру). *Ләкин мәҗлес – мәҗлес инде ул, авызыңны чөйгә элеп утыру килешми* (М. Әмирханов).
Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.
2. *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. *Кемнең тагын бер-ике сәгать авызын чөйгә элеп утырасы килер икән* (Н. Фәттах).
Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.
3. Ач тору, ашарга-эчәргә булмау. – *Минем үземнең пенсиям күп дигәндә өч көнгә бара. Шуннан авызны чөйгә әләм* (К. Кара. Депрессия).
Төрдәше: нәфил уразасын тоту.

**АВЫЗНЫ ШАЙТАН ЯЛАУ.** Уйламыйча сөйләү, юк-бар сөйләү. *Күрсәттең инде менә кемнең җүләр икәнлеген, бөтен авылга фаш иттең. Авызыңны шайтан ялаган нәрсә* (Ә. Баянов).
Төрдәше: авызы ни сөйләгәнне (әйткәнне) колагы ишетмәү; артыкны ычкындыру (ычкындырып ташлау); күңелендә (уенда) ни, телендә шул; сөяксез тел; сөяксез тел ни әйтмәс?; сөяксез телдә сүз борчаклары сикертү; сөяктән он тарттыру; тел авызга сыймау; тел бәрәңге түгел, изелми, теләсә ни сөйли; тел сөяксез <бит ул>; теле дилбегә буе; теленә нәрсә килсә, шуны әйтү; телең ни сөйләгәнне колагың ишетсен; телеңә хуҗа булу; телнең сөяге юк; яссы телең ни әйтмәс?

**АВЫЗНЫ ШӘЙЛӘП АЧУ** *к.* авызга ия булу 2. – *Авызыңны шәйләп ач, апа, утыртып куюлары бар* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).
Төрдәше: авызга ия булу 2.

**АВЫЗНЫ ЫРГАКТАН ЫЧКЫНДЫРУ.** Ирексездән авызны ачып катып калу. *Күзен ачкач, ул битендә чытлы каны калмаган килеш авызын ыргагыннан ычкындырып катып калды* (М. Мәһдиев).
Төрдәше: багана булып кату (катып калу/тору); багана кебек басып тору; баганадай (багана кебек / шикелле / сыман) катып калу (тору); катып калу (тору); тораташ <булып> кату; тораташ кебек катып калу (тору).

**АВЫЗНЫ ЯБА БЕЛМӘҮ.** Такылдау, берөзлексез сөйләү. – *Кайдан таптыгыз бу кешене, авызын һич яба белми – мотор аскан диярсең* (Сөйләм).
Төрдәше: авызны чишеп җибәрү һ.б.

**АВЫЗНЫ <ШАП> ЯБУ** 1. *к.* авыз ачарга ирек <тә> бирмәү 1. – *Торып авызын шап ябыйм дигән идем, өй тулы юл кешесенең татлы йокыларын тәмсезлисем килмәде* (Р. Төхфәтуллин). – *Бюрократлар, акыл һәм талант иясенә караганда, ялагай һәм кулай бәндәләрне югарыга тизрәк күтәрәләр, – дип, Рәйсә ханым икеөч сүз белән аның авызын япты* (В. Имамов. Күке).
Төрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү 1 һ.б.
2. *к.* авыз каплану 3. *«Өстәгеләр барысын да уйлап эшләде: иң күп кычкырып йөрүчеләргә, янган акчалары әллә ни күп булмаган кешеләргә акча биреп, авызларын яптылар. Александра белән дә нәкъ шундый хәл булды», – дип сөйләде Зәйнуллин* («Әлмәт таңнары» газ.). *Моның да җаен таптылар, авызын «шап» яптылар* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз каплану 3 һ.б.

*АВЫЗНЫҢ* ❖ **АВЫЗНЫҢ КАШЫГЫ ТҮГЕЛ.** «Ике кеше бер-берсенә тиң була алмый, алар яраша алмый» мәгънәсендә. *Күп нәрсәгә өметләнмә, син авызның кашыгы түгелсең* (Сөйләм).

**АВЫЗНЫҢ САЛМА САВЫТЫ.** Кешенең авызы. *[Нигъмәт] Хафаланма, бирешмәбез, тырышырбыз, әгәр дә бик ачуны китерсәләр, мәми авызларының салма савытларына менеп төшәргә дә бик кыйбат алмабыз* (Г. Камал. Хафизалам, иркәм).

**АВЫЗНЫҢ ТОТКАСЫ ЮК.** Авызында сүз тормаучы кеше турында. *Авызының тоткасы юк, теленең туктыйсы юк* (Мәкаль).
Төрдәше: авыз җебегән <булу> 1 һ.б.

*АВЫЗ-ТЕЛ* ❖ **АВЫЗ-ТЕЛ БӘЙЛӘНҮ.** Аптыраудан сүз әйтә алмый тору. *Менә аның шундый ягымлылыклары мине бөтенләй эретеп бетерде. Авызым-телем бәйләнеп, әйтә торган сүземне әйтә алмадым* (М. Гали).
Төрдәше: сабын ашадыңмы әллә?; тел әйләнмәү; тел бармау 1; тел бәйләнү 1; тел күтәрелмәү 1; тел тамакка ябышу 1; тел югалу; телдән калу; телне йоту; телне тешләү.

*АВЫЗЫ* ❖ **АВЫЗЫ ӘЙТКӘННЕ КОЛАГЫ ИШЕТҮ.** Әйткән сүзеңне уйлап әйтергә кирәклеге турында. *Нәрсә сөйли инде бу мишәр хатыны, ә? Моның авызы әйткәнне колагы*

*ишетәме икән, ә?* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

Төрдәше: авызың әйткәнне колагың белән ишетү; авызың ни әйткәнне колагың ишетсен.

**АВЫЗЫ БАР, ТЕЛЕ ЮК.** Юаш, карусыз кеше турында. *Бигрәк карусыз булып туган инде, авызы бар, теле юк* (Сөйләм).

**АВЫЗЫ БӘХЕТЛЕ <БУЛУ; ИКӘН>.** Аш-су әзерләнгән вакытта килгән кеше турында. *[Хуҗа] Авызыгыз бәхетле икән, тәкъсир* (Н. Исәнбәт. Хуҗа Насретдин). *Җитмәсә, «Гыйрфан мулланың җире яхшы», «аңа Ходай Тәгалә үзе ярдәмгә килә», «аның авызы бәхетле» кебек сүзләр канат җәеп таралган авылда* (С. Поварисов. Пәйгамбәр таңы).

**АВЫЗЫ БЕЛӘН ИЯГЕН БЕР ИТЕП ЕЛАУ.** Озак итеп, бик каты елау. *Габдулла өенә кайтып кергәндә, чыннан да, түр башына кабык бишек асылган, аның эчендә Габдулланың энекәше «үә», «үә» дип, авызы белән ияген бер итеп, елап ята иде...* (Ә. Фәйзи. Тукай).

**АВЫЗЫ БЕЛӘН КОШ КЫНА ТОТМЫЙ (КОШ ТОТАРДАЙ)** *к.* авызга җен төкерү. *Шуннан соң вәгъдәләр бирә, авызы белән кош кына тотмый инде* (Сөйләм). *Әгәр биш-алты кеше бергә җыела икән, шулар арасында бүтәннәрнең күңелен ачардай бер җор кеше, халык әйтмешли, авызы белән кош тотардай берәр «тел бистәсе» булмыйча калмый* (infourok.ru).

Төрдәше: авызга җен төкерү һ.б.

**АВЫЗЫ КИПМӘГӘН (КИБЕП ҖИТМӘГӘН)** *к.* авыз суы кипмәгән. *Аның әле авызы кипмәгән, ә син аңа шундый авыр эш йөклисең* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

**АВЫЗЫ КЫЕК БУЛСА ДА, БАЙ СӨЙЛӘҮ** *иск., к.* авыз-борыны кыек булсын, байның улы сөйләсен. *Безнең баш ялгыш сөйләмәс, борынгыдан калган бит инде: авызы кыек булса да, бай сөйли* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз-борыны кыек булсын, байның улы сөйләсен һ.б.

**АВЫЗЫ ЛАКАН ЧИЛӘГЕ КЕБЕК.** Кешеләр турында һәрвакыт начар сүз генә сөйли торган кеше турында. *Авызы лакан чиләге кебек ерык, әйтерсең лә күптәнге танышын очраткан* (М. Әмирханов. И кылган догам минем).

**АВЫЗЫ НИ СӨЙЛӘГӘННЕ (ӘЙТКӘННЕ) КОЛАГЫ ИШЕТМӘҮ.** Уйламыйча сөйләү. *Күбесенең авызы сөйләгәнен колагы ишетми башлады, сүзләре чуала, фикерләре бутала, телләре бәйләнә, башлары әйләнә башлады* (А. Алиш. Кем көчле?).

Төрдәше: авызны шайтан ялау һ.б.

**АВЫЗЫ ПЕШКӘН.** Хәзерлексез тотыну сәбәбеннән, уңышсызлыкка очрау. *Польша сәфәре белән авызы пешкән Бибисарага, өрмичә генә, Фәнзилә янә кайнар шулпа каптыра!* (Н. Гыйматдинова. Син түгел бу, син түгел...).

Төрдәше: авыз пешеп кайту.

**АВЫЗЫ ПЕШКӘН ӨРЕП КАПКАН (ЭЧКӘН).** Дөнья күреп, сабак алган, тәҗрибә туплаган. *Авызы пешкән – өреп эчкән, ди. Әмма вак-төяк каршылыкларын өркергә ният юк* (Д. Зөбәерова. Дустым авазы).

Төрдәше: авызы пешкән салкын суга (суны) да өреп капкан (эчкән); аркылысын-буен үтү 2; ачы белән төчене тату; ачы яшь эчү; ачыган шулпасын чөмерү; ачыны да, төчене дә тату; ачыны тату; ачы<ны>-төчене (ачысын-төчесен) тату (кичерү; күрү); әчене-төчене тату; әчесен-төчесен кушучлап чөмерү; әчесен-төчесен күрү; әче-төчене күрү; бергәләп тоз ашау; дары <исен> иснәү 2; дөнья ачысын тату; дөнья күрү; дөньяны тату; дөньяның ачысын (әчесен)-төчесен тату (белү; күрү); дөньяның эссесен-суыгын күрү; елан аягын кискән; йөргән аякка җим иярү; йөргән таш шомару, яткан таш мүкләнү; йөргән аякка җим иярү; казанда кайнау; карт ат буразнаны бозмый; карт бүре; карт бүре көрт ера; карт чыпчык кибәккә алданмас; күпне күрү; Лаеш суларын (шулпасын) эчеп узу; Лаеш шулпасын эчү (чөмерү); михнәт чигү; нужа калачын ашау; нужа камытын кию; нужа куу (чигү); таба майлаган саен шомару; тормыш казанында кайнап чыгу; тояк суы эчкән; ут<ны>-су<ны> кичү; ут<ны>-су<ны> кичү һәм шомарып бетү; ут<лар>-сулар кичкән; уттан-судан һәм кара төнлектән үтү; шомарган таш; эт ашаган.

**АВЫЗЫ ПЕШКӘН САЛКЫН СУГА (СУНЫ) ДА ӨРЕП КАПКАН (ЭЧКӘН)** *к.* авызы пешкән өреп капкан (эчкән). – *Хатын-кызлардан куркам мин, Зәйнәп. Бер авызы пешкән*

*салкын суны да өреп каба...* (Г. Тавлин. Афәт). *Авызы пешкән салкын суны да өреп капкан, диләр бит* (Р. Кәрами. Кая чабасың, гомер юртагы?).

Төрдәше: авызы пешкән өреп капкан (эчкән) һ.б.

**АВЫЗЫ ПЕШМӘҮ** *к.* авыз суы кипмәгән. *Дөнья күрмәгән, тормыш тәҗрибәсе булмаган, моңарчы алданып авызы пешмәгән Муйнакка бу бик кызык тоелды* (А. Хәсәнов. Тормыш мәктәбе).

Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

**АВЫЗЫ ТАБА ХӘТЛЕ.** Авызны зур итеп ачу. *Шигыремдәге алтын таба, авызын таба хәтле итеп: «Эшләп ашарга кирәк!» – дип, көлеп тора* (Р. Миңнуллин. Алтын таба).

**АВЫЗЫ ТӘМ СИЗҮ (ТОЮ).** Төшемле, сыйлы урынны белүче кеше турында. *Әйтсәң дә, шифалы бальзам икән, баш авыруы да басылды, авызы да тәм сизә башлады* (К. Кара. Чуклы карават).

Төрдәше: борыны ис сизү.

**АВЫЗЫ ТҮБӘН.** Күңелсез кыяфәттә, йөзе аска салынган. *Биек тауга чык төшкән, / Ник төшмәгән үләнгә? / Авызы түбән, күзе сүнгән, /Ниләр булган гүзәлгә?* (Жыр).

Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**АВЫЗЫ ТЫНМАС.** Эндәшми тора алмау. *Булса да, аның кебек авызы тынмас кеше юктыр* (Сөйләм).

Төрдәше: авызны чишеп җибәрү һ.б.

**АВЫЗЫ УЙМАК, БИТЕ КОЙМАК.** Кечкенә авызлы, яратып туймаслык кызны сурәтләү. *Авызың гына уймак, / Битең коймак, Телең генәй / Оҗмах ачычы* (Жыр). *Чәче бөдрә, үзе искиткеч мөлаем. Сөйләшкәндә бит очындагы чокырлары уйнаклап-уйнаклап ала. Мөгаен, авызы уймак, биле коймак дип шундыйларга карата жырлыйлардыр* (М. Әмирханов. Мөкәррәмә).

**АВЫЗЫ УЙМАК, КАРЫНЫ КАПЧЫК.** Матур, кечкенә авызлы булып та күп ашаучы хатын-кыз турында. *Авызы уймак, карыны капчык дигәннәре шул үзе инде* (Сөйләм).

**АВЫЗЫ УН ТАПКЫР ПЕШСӘ ДӘ, ӨРЕП КАБАРГА ӨЙРӘНМӘГӘН.** Тормышта күп нәрсәне күрсә дә, акыл туплый алмаган кеше турында. *Авылда үскән, авызы ун тапкыр пешсә дә, өреп кабарга өйрәнмәгән Акмал шундук тынычланды* (Г. Ахунов. Этләр патшасы).

**АВЫЗЫ ЭШЛӘГӘН ХАТЫННЫҢ КҮЗЛӘРЕ ТОМАЛАНГАН БУЛУ.** *Авызлары эшләгән хатыннарның күзләре томаланган була* (А. Гыйләҗев. Җомга көн кич белән...).

**АВЫЗЫ ЯБЫЛМАУ.** Бер дә туктамыйча сөйләү. *<...> кабарынкы алсу иреннәре хәзердән үк аның киләчәктә бу дөньяның бер гүзәленә әйләнәчәгенә ишарә итә иде, һич тиктормас авызы ябылмас, сырланырга, юмаларга кемнән өйрәнгән диярсең* (К. Кәрим. Кызлар кия кызыл күлмәк).

Төрдәше: авызны чишеп җибәрү.

**АВЫЗЫ ЯБЫЛУ** *к.* авыз ачарга <да> ирек бирмәү. *Каршы әйтергә йөрәгем җитмәде... Гомеремдә бер мәртәбә авызым ябылды* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *<…> булды ич инде, хәзер урамда кешеләрнең күзенә туры карап сөйләшәсездер дип уйлыйм, гайбәтләр беткәндер... Хисамның авызы ябылды, ни дип акланырга да белмәде* (М. Әмирханов. И кылган догам минем).

Төрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү һ.б.

*АВЫЗЫ-БОРЫНЫ* ❖ **АВЫЗЫ-БОРЫНЫ (КУЛЫ) БАЛДА-МАЙДА** *к.* авыз балда, кул майда. *– Борчылмагыз, иптәш мөдир, һич борчылмагыз! – диделәр.– Сый-хөрмәттән өзмәбез үзен! Авызы-борыны майда-балда гына булыр!* (В. Монасыйпов. Казан кешесе).

Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

*АВЫЗЫГЫЗНЫ* ❖ **АВЫЗЫГЫЗНЫ ҖИЛ АЛСЫН (АЛГЫРЫ)!** «Әйтә күрмә; андый күңелсез сүзне сөйләмә» мәгънәсендә; ягъни әйткән начар сүзең яки хәбәрең тормышка ашырыла күрмәсен. *И-и, авызыгызны жил алгыры, сүз сөйлисез инде сез дә кеше рәтеннән* (З. Зәйнуллин. Әбиләр).

Төрдәше: авызыңнан җил алсын, <илтеп дәрьяга салсын>; авызыңнан җил алсын, илтеп куеныңа салсын; авызыңнан җилләр урласын; авызыңнан чыгып җылы куеныңа керсен; җылы авызыңнан җылы куеныңа; теле коргыры; теләңә телчә чыксын.

*АВЫЗЫН* ❖ **АВЫЗЫН АЧКАН, АШАРГА СОРЫЙ.** Аяк киеменең берәр җире кубып, төзәтү

кирәклеге турында. – *Әй, дустым, бу туфлиең ашарга сорый бугай, авызын ачкан* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз ачу 2; авызын ачу 2; ашарга сорау.

**АВЫЗЫН АЧСА, ҮПКӘСЕ КҮРЕНӘ, БОРЫНЫНА ЮКӘ ҖИТМИ.** Ярлы тәкәббер, мактанчык. – *Әй, сөйләнгән була тагын, авызын ачса, үпкәсе күренә үзенең, борынына юкә җитми* (Сөйләм).

**АВЫЗЫН АЧТЫРУ** *к.* авызын ачу 1. – *Юкка авызын ачтырырга тырышасың, җаена тормасаң, бер сүз дә әйтми ул* (Сөйләм).

Төрдәше: авызын ачу; телен чишү.

**АВЫЗЫН АЧУ** 1. Нәрсә булса да сөйләргә мәҗбүр итү. – *Аның авызын ачарга күп көч куярга туры киләчәк* (Сөйләм).

Төрдәше: авызын ачтыру; телен чишү.

2. *к.* авыз ачу 2. *Лилиянең кышкы итеге дә ашарга сорап авызын ачкан, ремонтка бирсәң дә быелга чыдарлык түгел <…>* (К. Кара. Зур акчалар).

Төрдәше: авыз ачу 2; авызын ачкан, ашарга сорый; ашарга сорау.

**АВЫЗЫН БӘЛЕШ КЕБЕК ҖӘЮ** *к.* авызны бүлшәйтү. «*Нәрсә авызыңны бәлеш кебек җәйдең?! Кыз сине көтеп тора, ди, бар... күбрәк мескенлән...*» (Л. Шәех. Уңышсыз көн).

Төрдәше: авызны бүлшәйтү; авызын бәлшәйтү; авызын сурәтләндерү.

**АВЫЗЫН БӘЛШӘЙТҮ** *к.* авызны бүлшәйтү. *<…> балда-майда йөзгәндә, ул, «чирләдем!» дип, авызын бәлшәйтеп, ата-ана җилкәсенә кайтып төшәчәк* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: авызны бүлшәйтү; авызын бәлеш кебек җәю; авызын сурәтләндерү.

**АВЫЗЫН БЕР АЧСА, ЯБА (ЙОМА) БЕЛМӘҮ.** Бер сөйли башласа туктый алмый торган кеше турында. *Таҗетдинов авызын бер ачса, йома белми иде. Шуңа күрә Тәнзилә капылт кына ишеккә борылды* (А. Гыйләҗев).

Төрдәше: авызны чишеп җибәрү һ.б.

**АВЫЗЫН ИЛӘК БЕЛӘН КАПЛЫЙ (ЯБА) АЛМАУ <ИЛНЕҢ>.** «Кеше сүзен туктата, урнашкан фикерне үзгәртә алмассың» мәгънәсендә. *«Ил авызын иләк белән каплый алмыйсың» дигән шикелле, җәмгыятьтә урнашкан карашны берничек тә җиңә алмыйсың* (Н. Измайлова. «Океанның аръягында...).

**АВЫЗ<ЛАР>ЫН КОРТ ЧАККЫРЫ!** Ачу килгәндә әйтелә. *Сүз дә юк, бик хәйләкәр бәндә бу, авызын корт чаккыры!* (В. Имамов. Сәет батыр). – *Уйлап карасаң, баштан нинди генә заманалар узмады, ә? Авызын корт чаккыры!..* (Н. Хәсәнов. Кушамат).

Төрдәше: авызыңнан җил алсын, <илтеп дәрьяга салсын>; авызыңнан җил алсын, илтеп куеныңа салсын; авызыңнан җилләр урласын; авызыңнан чыгып, җылы куеныңа керсен; Алла орсын!; Алла суксын (суккыры)!; Алланың каһәре суккан (суккыры; суксын)!; Алланың каһәре төшкән нәрсә!; Алланың <ачы; әче> каһәре төшсен (төшкере; суккыры)!; анагыз (анаң; аналары) яламаган <нәрсә>; анагызны (анаңны) корт чаккыры!; анагызны куян үпкән нәрсә; аналарын эт еккыры; анаңның ян сөяге; анасы яламаган; анасын ач урыс алсын; анасын саткыры (саткан; сатыйм); анасын эт типкере; анасын эт ялагыры; арпаң-көрпәң аш булсын, тамагыңа таш булсын; аты беткере; аты җиткере; аты коргыры 2; атым корысын; бугазыңа аркылы килгере; җаның җәһәннәмгә олаккыры; җаның чыксын (чыккыры); җылы авызыңнан җылы куеныңа; йөзе кара булган <булгыры; булсын>; кадалып киткере; күзең чәчрәп чыксын; күрми күмер булсын; муеннары аска килеп, кәкрәеп үлсен иде!; муены асты өскә килгере!; муены астына килгере (килсен)!; муены сынгыры!; муены чыккыры!; муеның астыңа килсен; муеның аяк астына килгере; мур булгыры!; мур кыргыры!; мур талагыры!; мур тигере!; нәләт төшкере (яусын); пычак кергере (керсен); тамагыңа таш кергере; теле коргыры; телеңә тилчә чыккыры (чыксын); телеңә тилчә чыкса иде; уты-җаны бер көн булсын; уты-суы бер көн булсын; уты-ялкыны бер көн булсын; үләт еккыры!; үләт кыргыры!; чәнчелеп бет; чәнчелеп кит<кере!>; чәнчелсен бөтен дөньясы; чыңрак үтә кит; шайтан алгыры<сы>!; шайтан алсын!; шайтан еккыры!; шайтаныма олак!; эчең чыккыры!; эченә бирән булгыры!; эчеңә пычак кергере!; эчеңә таш булып утырсын!

**АВЫЗЫН КӨРӘК БЕЛӘН <ТӨРТЕП> ТИШКӘН** *мыск.* Кирәк сүзен әйтә алмыйча авыз ачып торучыга карата әйтелә. – *Нигә авызыңны көрәк белән төртеп тишкән кебек катып калдың?* (Сөйләм).

**АВЫЗЫН ӨЗҮ.** Кирәкмәгәнгә тыкшынып, бәйләнеп йөрүчене кыйнап өйрәтү. *Авызыңны өзәрләр, кирәкмәгән җиргә тыгылган өчен* (Ф. Хөсни).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АВЫЗЫН САЛУ (САЛЫНДЫРУ)** *к.* авызы-башы салыну. – *Аңламассың бу ирләрне, кыз туса, кайсы шатлана, кайсы авызын салып кайтып китә, – дип сөйләнә-сөйләнә, үзе чыккан ишектән ялт кереп китте* (Г. Исхакова. Кара чемодан).

Төрдәше: авызы-башы салыну.

**АВЫЗЫН СУРӘТЛӘНДЕРҮ** *к.* авызны бүлшәйтү. *Нәрсә әйтергә дә белмәссең аңа, авызын сурәтләндерә дә аркасы белән борылып утыра* (Сөйләм).

Төрдәше: авызны бүлшәйтү; авызын бәлеш кебек җәю; авызын бәлшәйтү.

**АВЫЗЫН ЧЕМЕТИМ.** Берәр эшнең җаен таба алмаганда яки сүгенгәндә әйтелә. – *Их, авызын чеметим, мондый ваклыкларга тикле уйлап бетерелмәгән шул, аһ, баш җитмәгән!* (В. Имамов. Карабәк).

*АВЫЗЫНА* ❖ **АВЫЗЫНА АЛДЫ ИНДЕ, ӨЗМӘС ТӘ КУЙМАС.** Бер сүзне кат-кат әйтүче, сукранчык; лыгырдавык. – *Әйдә, киттек моннан, минем апа авызына алды инде, өзмәс тә куймас* (Сөйләм).

Төрдәше: әбрәкәй сандугачы; бер авызына алса, <һич> төшерми (куя белми); бер авызына алса, <һич> куя белми; борчак авыз.

**АВЫЗЫНА АЛМА ТӨШКӘННЕ КӨТҮЧЕ (КӨТЕП ЯТУЧЫ).** Ялкауланып, китереп кулына тоттырганга өметләнүче. *Улмы соң авызына алма төшкәнне көтеп ятучы?* (Р. Габделхакова. Зинһар, югалма...).

**АВЫЗЫНА БАЛ <ДА МАЙ>!** Яхшы теләк теләүчегә, яхшы сүз китерүгә җавап буларак әйтелә. *Авызыгызга бал да май сезнең, күршеләр! «Шәфкать», «мәрхәмәт», «туганлык», «үзара ярдәм», «өмә» дигән олы сүзләрнең күптәннән сезнең янавыч телләргә кергәне юк бит инде, Сәләхетдин белән Мирфатыйх!* (А. Гыйләҗев. Җомга көн кич белән...). – *Инде яңа өегез тагын да бәхетлерәк булсын! – Рәхмәт, авызыңа бал да май, туганай!* (Г. Бәширов. Намус)

Төрдәше: авыз<лары> бал да май <булсын>! һ.б.

**АВЫЗЫНА КАРАТЫП КАТЫРУ** *к.* авызга җен төкерү. – *Теге авызына каратып катырган егет синең абыең идемени ул?* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга җен төкерү һ.б.

**АВЫЗЫНА КАРАТЫП ТОРУ** *к.* авызга җен төкерү. *Ә менә ничә еллар буена бар Төркәйне авызыма каратып торган, мәдрәсәләр тоткан ир бит әле* (В. Имамов. Тозлы яра). *Аның кебек челтерәтеп көлә белгән кешене очратканы булмады, ул бөтен кешене үз авызына каратып тора иде* (З. Кадыйрова. Сагынырсың – мин булмам).

Төрдәше: авызга җен төкерү һ.б.

**АВЫЗЫНА КЕРГӘНЕН ЭТ ҖИМӘС (АШАМАС; ҖЫЙМАС)** *к.* авызга кергәнен эт җимәс (ашамас) 1. *Кайдан таптың бу кешене, аның авызына кергәнен эт җимәс бит!* (Сөйләм).

Төрдәше: авыга кергәнен эт җимәс (ашамас) һ.б.

**АВЫЗЫНА МАЙ** *к.* авыз<лары> бал да май <булсын!>. *Авызыңа май, кызым, авызыңа бал!* (М. Фәйзи).

Төрдәше: авыз<лары> бал да май <булсын>! һ.б.

**АВЫЗЫНА СҮЗЕ СЫЙМАУ.** 1. Сүзләрен бутап, уйламыйча сөйләү. *Авызына сүзе сыймаган кешедән нәрсә көтәргә мөмкин?* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз җебегән <булу> 2; авызы ни сөйләгәнне (әйткәнне) колагы ишетмәү; авызына теле сыймый, теленә сүзе сыймый; күңелендә (уенда) ни, телендә шул; теленә нәрсә килсә, шуны әйтү; теле ни сөйләгәнне колагы ишетмәү; теленә хуҗа була алмау.

2. *к.* авыз җебегән <булу> 1. – *Нигә аның белән бик ачылып сөйләшәсең, авызына сүзе сыймаганын белмисеңмени?* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз җебегән <булу> 1 һ.б.

**АВЫЗЫНА ТЕЛЕ СЫЙМЫЙ, ТЕЛЕНӘ СҮЗЕ СЫЙМЫЙ.** 1. Ни сөйләгәнен уйламыйча сөйләүче, кычкырынучы, әдәпсез кеше турында. *Бу, авызына теле сыймаган, теленә сүзе сыймаган кешедән башканы таба алмадыңмыни?* (Сөйләм).

Төрдәше: авызы ни сөйләгәнне (әйткәнне) колагы ишетмәү; авызына сүзе сыймау; күңелендә (уенда) ни, телендә шул; теленә нәрсә килсә, шуны әйтү; телең ни сөйләгәнне колагың ишетсен; теленә хуҗа булу.

2. Сертотмас кеше турында. *Аңа ышанып буламыни: авызына теле сыймый, теленә сүзе сыймый бит аның* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз җебегән <булу> 1.

**АВЫЗЫНА ЧӘЙНӘП КУЮ.** Бөтен нәрсәне дә әзерләп бирү. – *Авызына чәйнәп куйганны көтә бугай бу* (Сөйләм).

*АВЫЗЫНДА* ❖ **АВЫЗЫНДА АНА (ӘНИСЕ) СӨТЕ КИПМӘҮ (КИБЕП ҖИТМӘҮ)** *к.* авыз суы кипмәгән. *Авызында ана сөте кипмәгән, шулай да олылар сүзенә тыгыла* (М. Галәү. Мөһаҗирләр).
Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

**АВЫЗЫНДА АНАСЫ.** Әшәке телле кеше турында («ана» сүзен кушып сүгенә). *Күршебезнең авызында «анасы» да «анаңны», «атасы» гына каядыр киткән* (Сөйләм).

**АВЫЗЫНДА АШЫ, КҮЗЕНДӘ ЯШЕ.** 1. Рәхәттә яшәп зарланучы кеше турында. *Кыланган була тагын, авызында ашы, күзендә яше үзенең* (Сөйләм).
2. Кайгы-хәсрәтле кеше турында. *Ятимнең авызында ашы, күзендә – яше, чыгып киттем Үзбәкстанның Коканд дигән шәһәренә* («Татарстан яшьләре» газ.).
Төрдәше: авызыннан төтен чыгу; аһ булу; аһ ору; ачы күрү; ашау-эчүдән калу; баш катыру; баш таштай кату; башны бәйләү; башны җую 2; башны суга салу; җәфа чигү; иза чигү; йөрәк әрнү; йөрәк итен ашау (йолку; талау; тешләү); йөрәк кузгалу; йөрәк яну 1; йөрәккә боз булып утыру; йөрәккә боз укмашу; йөрәккә каб(ын)у; йөрәккә <барып> кадалу (тию) 2; йөрәккә кара кан саудыру; йөрәккә таш булып утыру; йөрәккә тигәнәк кадалгандай булу; йөрәккә тоз салу; йөрәккә <корт> төшү; йөрәккә ут салу; йөрәкне әрнетү; йөрәкне тырнау (тырмау; тырнап тору); кайгы басу; кайгы дөрләү; кайгы йоту; кайгы калҗасын кабу; кайгы тамакта төен булып тору; кайгы эчү; кайгы юктан кайгыдыр каенанаң кайгысы; кайгыга калу; кайгыга салу; кайгыга чуму; кайгыга керү; кайгыда тору; кайгылы кайгысын сөйләгәндә, кайгысызның башы авырту; кайгыны эчкә йоту; кайгысы булмаган каенанасы өчен кайгырган; кайгысы юк үги әнисе өчен кайгырган; кайгы-хәсрәт чигү; кан йоту; канга тоз салу 1; кеше кайгысы иртә керә, кич чыга; кеше кайгысы төштән соң; кеше канына тоз салу; кешенеке кештәктә, <үзеңнеке үзәктә>; күңел ярасына тоз сибү; кысыр кайгы; моңлы моңын сөйләгәндә, моңсызның башы авырту; хәсрәт болыты басу; эчтән сөрем чыгу.

**АВЫЗЫНДА БАЛ ДА МАЙ.** Күңел күтәргеч матур сүзләр сөйләргә яратучы хакында. *Бу Миннур бигрәк тә: һичкайчан зарлану-сыктану белмәс, авызында гел бал да май* (Э. Касыймов).

*АВЫЗЫНДАГЫН* ❖ **АВЫЗЫНДАГЫН АЛДЫРУ** *к.* авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү. – *Ә тегесе, дәү әти, йомыкый. Авызындагын алдырды* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).
Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

*АВЫЗЫННАН* ❖ **АВЫЗЫННАН ӘНИСЕНЕҢ (ИМИ) СӨТЕ <ДӘ> КИПМӘҮ** *к.* авыз суы кипмәгән. *Ә Әкрам? Авызыннан әнисенең сөте кипмәгән Әкрам?* (Ә. Шамин. Яңа язлар). *Авызыннан ана сөте кипмәгән, үз әтисенә фәлсәфә сата бит...* (М. Галәү. Мөһаҗирләр).
Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

**АВЫЗЫННАН КИСӘГЕН ТАРТЫП АЛУ.** Берәү эше бетте дип уйлаганда гына, икенчесе аның өлешен үзенеке итү. *Яңа җиһазның эше бетәр-бетмәс башка берәүнең авызыннан кисәген тартып алып, аны рәсмиләштереп, патент алып куймаса, премия күрәчәк түгел иде* (Сөйләм).

**АВЫЗЫННАН СҮЗ ДӘ ТАРТЫП АЛА АЛМАУ.** Күп сөйләмәү, аз сүзле булу. *Кая инде шигырь сөйләтү, еш кына авызыннан сүз тартып ала алмыйбыз!* (Сөйләм).
Төрдәше: авызыннан сүзен тартып алып булмау.

**АВЫЗЫННАН УТ<ЛАР> ЧӘЧҮ** *к.* авызга җен төкерү. *Син трибунадан, авыздан ут чәчеп, өметле, шәп нотыклар сөйләдең, дип, ерак йолдызлардагы адәми затлар галәм киңлекләре аша сәлам җибәрергә ашыкмыйлар* (Г. Афзал. Бер сенсация тарихы).
Төрдәше: авызга җен төкерү һ.б.

**АВЫЗЫННАН ЧЫККАННЫ ЭТ ТӘ ҖИМӘС (АШАМАС)** *к.* авызга кергәнен эт җимәс (ашамас). *Динә апаның әти-әнисе, туганнары, күршеләре белән дус булган Азат хәзер акылдан язган тилене хәтерләтә, авызыннан*

*чыкканны эт җимәс, гел оятсыз сүзләр, ди* («Кызыл таң» газ.).

Төрдәше: авызга кергәнен эт җимәс (ашамас) һ.б.

*АВЫЗЫҢ* ❖ **АВЫЗЫҢ ӘЙТКӘННЕ КОЛАГЫҢ БЕЛӘН ИШЕТҮ.** Юк-бар яки гайбәт сөйләүче кешенең сүзе үзенә әйләнеп кайту ихтималы барлыгына ишарә. – *Түти, авызың әйткәнне колагың белән ишетәсеңме син?* (Сөйләм).

Төрдәше: авызы әйткәнне колагы ишетү; авызың ни әйткәнне колагың ишетсен.

**АВЫЗЫҢ БЕЛӘН ӘЙТ, БОРЫНЫҢ БЕЛӘН ТАРТ.** «Үз каргышың үзеңә кайтсын» мәгънәсендә. *Авызың белән әйт, борының белән тарт* (Ай колакланса ни була? 1 нче кит.).

**АВЫЗЫҢ НИ ӘЙТКӘННЕ КОЛАГЫҢ ИШЕТСЕН** *к.* авызың әйткәнне колагың белән ишетү. – *Авызың ни әйткәнне колагың ишетсен, андый тәкъдимнәрең белән монда килеп йөрмә* (Сөйләм).

Төрдәше: авызы әйткәнне колагы ишетү; авызың әйткәнне колагың белән ишет.

*АВЫЗЫҢА* ❖ **АВЫЗЫҢА БАЛ ДА МАЙ, АЛДЫ-АРТЫ ХӘЕРЛЕ (ХӘЕРЛЕГӘ; ЯХШЫ) БУЛСЫН (БУЛА КҮРСЕН)!** *к.* авыз<лары> бал да май <булсын>! *Безнең бабайлар әйтмешли, авызыңа бал да май, алды-арты яхшы булсын, дип теләп калды аның артыннан әнисе* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз<лары> бал да май <булсын>! һ.б.

**АВЫЗЫҢА БАЛ ДА МАЙ, АРТЫҢА КОЛЫН ТАЙ.** Сөенечле хәбәр китергәнгә җавап итеп әйтелә. *Авызыңа бал да май, артыңа колын тай* (Р. Абдуллина. Сөйләм культурасы).

Төрдәше: авыз<лары> бал да май <булсын>! һ.б.

**АВЫЗЫҢА БАЛ ДА ЯУ** *к.* авыз<лары> бал да май <булсын>! (яу < йаг = май). – *Һай рәхмәт төшкере! Авызыңа бал да яу!* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз<лары> бал да май <булсын>! һ.б.

**АВЫЗЫҢА БАЛЛЫ ЯУ** *к.* авыз<лары> бал да май <булсын>! – *Борынгылар әйтмешли, авызыңа баллы яу гына килеп торсын, ахирәт* (Сөйләм).

**АВЫЗЫҢА ҖОФАР ҖАУ (ЯУ)** *к.* авыз<лары> бал да май <булсын>! (яу/җау < йаг = май). *Авызыңа баллы яу* (Ш. Маннур).

Төрдәше: авыз<лары> бал да май <булсын>! һ.б.

**АВЫЗЫҢА КАЗ БОТЫ (МАЕ)!** Сөенечле хәбәр китергәндә, егетләр «сиңа шәп сый булачак» мәгънәсендә әйтәләр. *Шәп иткәнсең, авызыңа каз боты!* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз<лары> бал да май <булсын>! һ.б.

**АВЫЗЫҢА КАЗ МАЕ КАПКАН ИДЕҢМЕ ӘЛЛӘ?** Кирәк эшне сизмичә яки кирәк сүзне әйтмичә калганда әйтелә. – *Нигә тагын кайчан киләсен сорамадың, авызыңа каз мае капкан идеңме әллә?* (Сөйләм).

**АВЫЗЫҢА САРЫ МАЙ** *к.* авыз<лары> бал да май <булсын>! *Авызыңа сары май!* (Р. Абдуллина. Сөйләм культурасы).

Төрдәше: авыз<лары> бал да май <булсын>! һ.б.

**АВЫЗЫҢА ТАШ ТЫГЫЛСЫН** *карг.* Әшәке телле кешегә карата әйтелә. *Авызыңа таш тыгылсын* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).

Төрдәше: алганың (йотканың) эчең тишеп чыксын; Алла орсын!; Алла суксын (суккыры)!; Алланың каһәре суккан (суксын)!; Алланың <ачы; әче> каһәре төшсен (төшкере; суккыры)!; анагызны (ананңы) корт чаккыры!; аналарын эт еккыры; анасын ач урыс алсын; анасын сатыйм; анасын эт типкере; анасын эт ялагыры; арпаң-көрпәң аш булсын, тамагыңа таш булсын (торсын); артыңа көл!; атаңа ләгънәт, авызыңа таш!; атаңа нәләт; аты беткере; аты коргыры; атым корсын; әпсе булгыры!; баш түбән дөмеккере; башы беткере (олаккыры)!; башы <гына> бетсен; башы йөзтүбән килгере; башына кадалсын!; бәбәгең чергере (чыккыры); бит астына кергере; бугазыңа аркылы килгере; дөмегепләр киткере; җаның җәһәннәмгә олаккыры; җаның чыксын (чыккыры); җәһәннәм<нең> төбенә китсен!; җәһәннәм утына китегез!; җәһәннәм утында; иң түбән җәһәннәмнең уртасында!; йөзе кара булган <булгыры; булсын>; йөрәген таракан ашасын; кадалып киткере; күзең чәчрәп чыксын; күрми күмер булсын; муеннары аска килеп, кәкрәеп үлсен иде!; муены асты өскә килгере!; муены астына килгере (килсен)!; муены сыңгыры!; муены чыккыры!; муеның астыңа килсен; муеның аяк астына килгере; мур булгыры!; мур кыргыры!; мур талагыры!; мур тигере!; нәләт төшкере (яусын); пычак кергере (керсен); тамагыңа таш кергере; уты-җаны бер көн булсын; уты-суы бер көн булсын; уты-ялкыны бер көн булсын; үз башына булгыры!;

үләт еккыры!; үләт кыргыры!; чәнчелеп бет; чәнчелеп кит<кере!>; чәнчелсен бөтен дөньясы; чыңрак үтә кит; шайтан алгыры<сы>!; шайтан алсын!; шайтан еккыры!; шайтаныма олак!; эчең чыккыры!; эчеңә бирән булгыры!; эчеңә пычак кергере!; эчеңә таш булып утырсын!

**АВЫЗЫҢА ТӨКЕРИМ.** Орышу сүзе. – *Син генә кирәгиең монда, авызыңа төкерим, ат карагы!* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

*АВЫЗЫҢДАГЫН* ❖ **АВЫЗЫҢДАГЫН КАЕРЫП АЛУ.** Кеше кулындагы әйберне ничек булса да үзенә алырга тырышучы турында. – *Тиз арада бу мәсьәләне хәл итмәсәң, туганың авызыңдагын да каерып алачак – көт тә тор!* (Сөйләм).

*АВЫЗЫҢНАН* ❖ **АВЫЗЫҢНАН ҖИЛ АЛСЫН, <ИЛТЕП ДӘРЬЯГА САЛСЫН>** *к.* авыз<лар>ын корт чаккыры! *[Галиябану] Авызыңнан җил алсын! Мин бәхетемнең канатлы булуын теләмим* (М. Фәйзи. Галиябану). *Авызыңнан җил алсын, илтеп дәрьяга салсын, исән булса, атасына гына гына әйтер идең дә бит* (Ә. Хәсәнов. Әҗәт).
Төрдәше: авыз<лар>ын корт чаккыры! һ.б.

**АВЫЗЫҢНАН ҖИЛ АЛСЫН, ИЛТЕП КУЕНЫҢА САЛСЫН.** «Яманлык теләп әйткән сүзләрең үзеңә кайтсын» мәгънәсендә каргыш. *Күбрәк шулай сөйләнеп йөр әле. Авызыннан җил алсын, илтеп куеныңа салсын* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз<лар>ын корт чаккыры! һ.б.

**АВЫЗЫҢНАН ҖИЛЛӘР УРЛАСЫН** *к.* авыз<лар>ын корт чаккыры! *Бүгеннән соң кыска күлмәк дигән сүзне / Авызыңнан җилләр урласын...* (Һ. Такташ).
Төрдәше: авыз<лар>ын корт чаккыры! һ.б.

**АВЫЗЫҢНАН ЧЫГЫП, ҖЫЛЫ КУЕНЫҢА КЕРСЕН** *к.* авыз<лар>ын корт чаккыры! *Начар теләк әйткән кешегә дә җавап гыйбарәсе бар. Аңа: «Җылы авызыңнан чыгып, җылы куеныңа керсен!» – дип әйтәләр (ягъни «тел-авыз белән әйткәнең үзеңә кайтсын»)* (Р. Абдуллина. Сөйләм культурасы).
Төрдәше: авыз<лар>ын корт чаккыры! һ.б.

**АВЫЗЫҢНАН ЧЫКМАСЫН!** Башка кешеләргә сөйләргә ярамаганлыкны кисәтү. *«Ул качкан падишаһ мин булырмын. Бу сүз авызыңнан чыкмасын», – диде* (К. Насыйри).

*АВЫЗЫҢНЫ* ❖ **АВЫЗЫҢНЫ АЧЫП КАЛМА!** *к.* авызыңны ачып торма! *Совет хакимияте чорында тәрбияләнгән психология үзенекен итә. Сине талыйлар, син дә авызыңны ачып калма* (Т. Галиуллин. Тәүбә).
Төрдәше: авызыңны ачып торма!

**АВЫЗЫҢНЫ ДА АЧМА (АЧАСЫ БУЛМА).** «Берәрсеннән нәрсә булса да сорама яки даулама» мәгънәсендә. – *Кара аны, авызыңны да ачасы булма, ахыры начар бетүе ихтимал* (Сөйләм).

**АВЫЗЫҢНЫ ЧӨЙГӘ ЭЛМӘ, ТАНАВЫҢНЫ КҮТӘРМӘ.** Сүз сөрешен аңламыйча борчылып утырган кешегә карата әйтелә. – *Мин дә боларны аңлап бетерә алмыйм. Юкка авызыңны чөйгә элмә, танавыңны да күтәрмә* (Сөйләм).

**АВЫЗЫҢНЫ ШӘЙЛӘП (ШӘЙЛӘБРӘК) АЧ.** «Бик артык җәелеп китмә, кем алдында сөйләгәнеңне уйлабрак сөйлә» дип кисәтү. *Авызыңны шәйләбрәк ач!* (Г. Насрый).
Төрдәше: авызыңны үлчәп (чамалап) ач 1, 2.

*АВЫЛ* ❖ **АВЫЛ АГАЕ.** Авылда авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнгән өлкәнрәк яшьтәге кеше. *Әти кунакны ничек кенә кыстаса да, авыл агае алай кинәттән генә кашыкка үрелми* (А. Хәсәнов. Бахбайлар ял йортында).
Төрдәше: авыл гыйбаты; авыл бәрәңгесе; авыл кабартмасы; авыл кешесе; җир кешесе; сала гыйбаты; сала кешесе.

**АВЫЛ БӘРӘҢГЕСЕ** *кимс., к.* авыл агае. *Калганын юлдашым, кайтырга чыккач, өстәп төшендерде. «Дөнья күрмәгән шул син, авыл бәрәңгесе» дигән төслерәк бер мәгънә төшендерде ул* (Ф. Хөсни. Кара кофе).
Төрдәше: авыл агае һ.б.

**АВЫЛ ГЫЙБАТЫ** *иск., кимс.* Элекке заманда кулланылган: кара, надан авыл кешесе икәнлеген белдергән гыйбарә. *Укыганда безнең ише авыл гыйбатларын санга сукмаган Эльвина, мәгәр минем «сөт заводы директоры» дигән даным барып ирешмәсә, ул «Корстон» ишеге төбендә үк мине аягын сөртеп узар иде, мөгаен* (Н. Гыйматдинова. Сөйлим, тыңла...).
Төрдәше: авыл агае һ.б.

**АВЫЛ КАБАРТМАСЫ** *к.* авыл агае. *«Без – авыл кабартмалары, кара сөяк; укып мулла, чукып карга буласың юк, ике аягыңның берсен атлама!» – дип, үсмер егетнең күзен ачтырмадылар* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: авыл агае һ.б.

**АВЫЛ КЕШЕСЕ** *к.* авыл агае. *Авыл кешесе өйдә утырмый бу вакытта* (А. Гыймадиев. Үзең булып кал!..).
Төрдәше: авыл агае һ.б.

**АВЫЛ ПАТШАСЫ.** Әтәч. *Авыл патшасы – әтәч кычкырды. Әтәч – авылның байрагы, таңның шаһиты* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

*АВЫЛГА* ❖ **АВЫЛГА, БАБАЙГА.** Кемгә булса да берәр нәрсә җибәргәндә, адресы тулысынча язылмау яки гомумән күрсәтелмәү. *Ул безнең өчен, ни дисәң дә, Чеховның Ванька Жуковы кебек, «шәһәрдән авылга бабайга» кайтып җирләнергә тиешле, шуңа хокукы булган авылдашыбыз иде...* (А. Хәлим. Штабтан шалтыратмадыларм ы?).

**АВЫЛГА ЙӨЗ БЕЛӘН.** Авыл халкының яшәешенә, тормыш-көнкүрешенә, авыл хуҗалыгының ихтыяҗларына күбрәк дикъкать итү. – *«Авылга йөз белән!» дисез дә, хөкүмәт бик йөз белән борылмый шул әле!* (И. Гази. Канатланыр чак). *«Авылга йөз белән» нәрсә ул?» дип сорау хәер бик соң кебек инде* (Һ. Такташ).

*АВЫЛДАН* ❖ **АВЫЛДАН БАЗАРГА КИТЕРГӘН, ЧЫПТА ТИШЕГЕННӘН БАШЫН ЧЫГАРГАН КАЗ КЕБЕК.** Элегрәк вакытта катыргы ак яка тагып, үзләрен тәкәббер тотып йөргән кешеләр хакында. *Патша заманында катырып куелган ак якалар тагып, горур кыяфәт белән борын өстеннән аска карап йөргән ирләр авылдан базарга китергән, чыпта тишегеннән башын чыгарган казлар кебек күренгәннәр* (Сөйләм).

*АВЫЛНЫҢ* ❖ **АВЫЛНЫҢ КЫЧЫГЫ ДА АВЫЛГА КАРАП ӨРӘ.** Туган җирне хөрмәт итүне аңлата. *Дустым син шуны онытма: авылның кычыгы да авылга карап өрә* (И. Гафаров. Мишәрләр).

*АВЫП* ❖ **АВЫП ЙӨРҮ.** 1. Каз кебек алпан-тилпән килеп йөрү. *Авып йөргән Зөфәрнең малае бит инде ул* (Сөйләм).

2. Бер якка авышыбрак йөрү. *Токарьмы әллә син, бер якка авып йөрисең?* (Сөйләм).

3. *күч.* Берәрсен яратып, күңеле төшеп йөрү. *<...> көең Гүзәл, язганың «Гүзәл», үзең шул кызга авып йөрүең түгелме, бала?* (Н. Исәнбәт).

4. *күч.* Үз фикере булмыйча, ярарга тырышып яшәүче хакында. *Бу – җил кайсы яктан иссә, шуңа авып йөри торган япәтник-фәлән түгел* (В. Имамов. Тозлы яра).

**АВЫП КИТҮ** *(беренә).* Берәүнең фикеренә кушылу, аның тарафдары булу. *Шуңадыр, ахры, гади халык, батыр табылды дигәндәй, аңа авып та киткән иде* (Ә. Еники. Рәшә).

*АВЫР* ❖ **АВЫР АВЫРУ.** Җиңел яки тиз генә савыктыру мөмкин булмаган авыру. – *Берәр им-том белән дә кузгатып булмый микән, ә, Миңнисәттәй? – Авыр авыру бу, кызым* (Г. Гыйльманов. Шартлау).
Төрдәше: җитди авыру.

**АВЫР<ГА> АЛУ.** Берәр сүзгә рәнҗү, үпкәләү. – *Ләкин, гафу итегез, әгәр мин хәзерге көндә сезгә дә аеруча сизгер флюгер кирәк дип әйтсәм, һәм, ни... зинһар, авырга алмагыз* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Кыскасы, килешүне юк дип исәпләргә бик риза иде Газзә. Әмма аны хуҗалар авырга алды* (М. Маликова. Язгы такыялар).
Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**АВЫР АЯК<ЛЫ>.** 1. Ялкау, акрын кыймылдаучан. *Мин, авыр аяк, исемә килгәнче, җитез Равил килеп тә җитте, Фәритне күлмәк якасыннан сөйрәп тартып та чыгарды* (А. Гыйләҗев. Истә, һаман да истә...).
Төрдәше: авыр гәүдәле; авыр кеше; авыр санлы; авыр сөякле; адымын санап атлау; аз ашыйм, авырмас башым; аркылы саламны буйга да алып куймау; аркылы ятканны буйга алып куймау (салмау); аш янында ат кебек, эш янында эт кебек; аягын санап атлау; аягыңа ат басмаган бит; әрнәш тегермәне; балта да чапмау; бармак башы да кыймылдатмау; бармак <та> кыймылдатмау; бармакка бармак <та> сукмау; бармакка урарлык (чорнарлык) та акылы юк; бармакны бармакка сукмау; бот күтәреп, түшәмгә төкереп яту; бот күтәреп яту; дандарага җон тетү; иренгән – ике тычкан җиккән; күләгәдә күрәзәлек итү; кыл <да> кыймылда<т>мау; кыл <да> кыймылдатмыйча яту; салам да селкетмәү.

2. Берәр эшкә яки өйгә уңышсызлык, кайгы китерүче. *Бәлки, Мирвәли шушы якты дөньяга, зәп-зәңгәр күкле, сихри сабан тургайлы дөньяга, ут-кояш янына, энҗе йолдызларга иптәшкә* *а в ы р а я к л ы*, *җәфаланган, таланган йөрәкле, йончыган күңелле булып тугандыр?* (А. Гыйләҗев. Өч аршын җир). *Нинди кара мәче аркылы чыкты да, кайсы* *а в ы р а я к л ы с ы* *очрады икән?* (Ф. Яхин. Ак Ай буендагы кич).

Төрдәше: аягы авыр.

3. Балага узган, йөкле булу. *Чыннан да, хатыны авырга узган икән, ягъни* *а в ы р а я к л ы* *икән* («Чура батыр» дастаны).

Төрдәше: авырга калу 2; авырга узу; авырлы булу; адәм авыруы булу; аягы авыр; балага авырлы; балага авыру; балага калу; балага узу; бәбәйгә кысылу; бәбәйгә узу; буенда бар; буйга калу; буйга узу; буйда булу; гөмәнгә калу (узу); гөмәненә кадәм төшү; йөкле булу (калу); корсак күтәрү; корсак ясау; корсакка калу; корсакка узу; корсаклы булу; көмәнгә калу (узу); көмәненә кадәм төшү; көмәне бар.

**АВЫР АЯК ТАВЫШЫ.** Каты басып йөрү. *Шулчак шыгырдап ишек ачылды,* *а в ы р а я к т а в ы ш л а р ы* *ишетелде* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).

**АВЫР БАШЫ ТӨШҮ (ТИЮ, ТУРЫ КИЛҮ, ЭЛӘГҮ).** Эшнең авыры тию, төп авырлык (кыенлык)ны өстенә алу. *[Фәния] Иң* *а в ы р б а ш ы* *сезгә* *т ө ш ә* *инде, Максут абый. Сезгә качарга иде* (Ю. Әминов. Умырзая чәчәкләре). *Әмма яңгырлы көннең иң* *а в ы р б а ш ы* *бораулаучыларга* *т ө ш ә* (Г. Ахунов).

Төрдәше: авыр башын күтәрү.

**АВЫР БАШЫН КҮТӘРҮ** *к.* авыр башы төшү (тию, туры килү, эләгү). *Планның* *а в ы р б а ш ы н* *шушы меңнәр* *к ү т ә р е п* *баралар* (И. Гази. Гади кешеләр). *Еш кына хатын-кызга да тормыш агачының* *а в ы р б а ш ы н к ү т ә р е р г ә* *туры килә* (Б. Рәхимова. Бакый сагыш).

Төрдәше: авыр башы төшү (тию, туры килү, эләгү).

**АВЫР БОЗНЫ КУЗГАТЫП ҖИБӘРҮ.** Булыр дип берәү дә ышанмаган эшне башлап җибәрү. *Камышев баштарак бик сөенеп йөрде: янәсе, килеп җитәр-җитмәс, ул әнә нинди* *а в ы р б о з н ы к у з г а т ы п җ и б ә р ә* *алды* (И. Гази).

**АВЫР БУЛУ.** 1. Кәефкә начар тәэсир итү. *Пудраланган, кызыл иннекләр сөрткән Фатыймага арткы рәттә утыру* *а в ы р б у л а*... (А. Алиш. Якты күл буе).

2. Мәшәкать китерү, кыен булу. – *Гөлфинур Хәяливна, – диде ул, тавышына үтә төче төсмер биреп, – Гөлфинур Хәялиевна, сезгә бик* *а в ы р б у л м а с а*, *бире килегез әле, зинһар!* (А. Вергазов. Үзеңә кайту). – *Сиңа үзеңә генә балаларны күтәрергә* *а в ы р б у л а ч а к* (А. Нәҗми. Кояш җилләре).

**АВЫР ГӘҮДӘЛЕ.** 1. Нинди булса да эшкә теләмичә генә алынучы, әкрен кыймылдаучан; ялкау. – *Карап торуга үшән сыманрак, салмак хәрәкәтле,* *а в ы р г ә ү д ә л е* *Әлфитнең келәмдәге җитезлегенә Хөрмәт шаккатты* (Р. Кәрами. Кая чабасың, гомер юртагы?).

Төрдәше: авыр аяклы 1 һ.б.

2. Симез, таза кеше. *Теге* *а в ы р г ә ү д ә л е* *качак җәпләкәдән аршын чамасы түбәнрәк кәүсәсе җиргә утыртылган баскычка менәргә азаплана* (М. Хуҗин. Качаклар).

**АВЫР ЕЛЛАР.** Яшәү шартлары кыенлашкан, зур мәшәкатьләр килеп чыккан вакыт. *Шул* *а в ы р е л л а р д а* *башка чыгып, йорт-җир җиткереп, үз көчләренә таянып яшәделәр* (М. Хуҗин. Ак колын).

**АВЫР ЙӨК.** Җанга тынычсызлык китергән мәшәкать; авырлык, кыенлык. *Нинди* *а в ы р й ө к*, *моң һәм сагыш йөкләп киттең син миңа, Азат Сәйдәшев* (А. Тимергалин. Игезәкләр).

**АВЫР ЙӨК БУЛЫП ТӨШҮ.** Бересенә артык авыр эш яки кирәкмәгән мәшәкать булып чыгу. *Соңгы елларда агрореформалар болай да күпне күргән колхоз-совхозларның өстенә* *а в ы р й ө к б у л ы п т ө ш т е* (М. Абдуллин. Авыл яшәсә, ил яшәр).

Төрдәше: көч килү.

**АВЫР ЙӨК ТӨШКӘНДӘЙ <БУЛУ, КАЛУ>.** Җиңеләеп, иркенәеп калу. *Хәбир, телеграмма сукты да, өстеннән нindидер бер* *а в ы р й ө к т ө ш к ә н д ә й*, *җиңел сулап куйды* (Н. Акмал. Күгәрчен сөте).

**АВЫР КАБУЛ ИТҮ.** Кирәкмәгән мәшәкать дип санау, ошатмау; ризасызлык белдерү. *Ни хакың бар синең моны һуш җуярлык дәрәҗәдә* *а в ы р к а б у л и т ә р г ә ?* (Ә. Баянов). *Дөрес, кыйммәтле кәгазьләрне ифрат ышанычлы жиргә*

*ярыгы кабык бераи...* — no

*яшереп куйган Саматова Хәлил Газизовичның мондый хәбәрне авыр кабул итәсен сизенсә дә, болай ук бәргәләнер дип күз алдына китерә алмаган иде, сыер түйганчы чәйнәп төкергән чүпрәк хәленә кергән ирне кызганып куйды* <…> (Т. Галиуллин. Төнге юллар).

**АВЫР КЕШЕ.** 1. Салмак, акрын кыймылдаучан. – *Ул тере булсын, артык җанлы булсын, мин үзем дә авыр, басынкы кеше* (Г. Ибраһимов).

Төрдәше: авыр кубу; авыр кузгалу; авыр кыймылдау.

2. Холыксыз, үзсүзле кеше хакында. *Ә бит ул кешеләр белән аралашу мәсьәләсендә авыр кеше, аның белән үзара бәйләнешкә керү – марсианин белән контактка керү белән бер* (Ә. Мушинский. Һаваларда – ак күгәрчен). *Русия өчен ул авыр кеше, аның белән эшләве дә авыр булачак* («Өмет» газ.).

Төрдәше: авыр табигатьле; авыр холыклы.

**АВЫР<ГА> КИЛҮ.** 1. Бик күп көч түгү, хәл бетү. *Йөзе кайгылы, сабыр, ләкин бу сабыр кайгы аңа бик авырга килә, ахрысы, чөнки ул көннән-көн ябыга бара* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Үр менгәндә, моторга авыр килде бугай: төчкерә һәм тончыккалый башлады* (А. Тимергалин. Таш алиһә).

2. Берәр эшне йөкләргә яки үтәргә авырсынырга. *Кара әле, Мөхәммәтгәрәй, күңелеңә авыр килә күрмәсен...* (Ш. Камал). – *Монда тигез, авырга килмәс атка* (М. Хуҗин. Чеметемнән – табышларга...).

Төрдәше: кыенга <туры> килү.

**АВЫР КӨН КҮРҮ.** Мәшәкатьле, ярлы яшәү. *Синең авыр көн күрүеңә карап, минем йөрәгем әрнер* (К. Тинчурин).

**АВЫР КУБУ.** Әкрен кыймылдау; ялкау гына, салмак хәрәкәт итү; эшкә керешкәнче, озаклап уйлау. *Туры карт, утырган эскәмиясеннән авыр кубып, кулын кызга таба сузды* (Э. Касыймов. Җир балкышы).

Төрдәше: авыр кеше 1 һ.б.

**АВЫР КУЗГАЛУ** *к.* авыр кубу. *Ул беравык ни кылырга белмичә торды да, авыр кузгалып, пошилар артыннан иярде...* (В. Имамов. Ир канаты).

Төрдәше: авыр кеше 1 һ.б.

**АВЫР КУЛЛЫ.** 1. Көчле, нык куллы. *Садыйк кулак бер генә минутка да тик торырга ирек бирми иде, бик авыр куллы кеше иде* (А. Юсупов. Полкташымныңякты язмышы).

2. Кешегә кул күтәрүдән баш тартмаучы. *Аның турында берникадәр мәгълүматлы, тегесен-монысын ишеткән авыр куллы, гарьчел авыл егетләре дә бу гадәтеннән биздерә алмадылар: берсендә үзен кыйнарга дип чыккан сыеграк гәүдәле ике-өч яшүсмерне уңлы-суллы бәреп кенә екты* («Ватаным Татарстан» газ.).

3. Эш уңмаганда, сылтау өчен кулланыла. *Чәчәкләремне авыр куллы кешеләргә биргәнгәдерме, кул китте* («Шәһри Казан» газ.).

Төрдәше: аю кул 1; кулы авыр.

**АВЫР КҮҢЕЛ.** Рухи төшенкелекле бер халәт. *Мин авыр күңел белән капкадан чыгып киткәндә, Әсхәдулла абзыйның ачыгъланган тавышы яңгырап калды* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).

**АВЫР КҮТӘРҮ.** 1. Хәтер калучанлык, уен сүзне кабул итә алмау. – *Ләкин бер нәрсәне исеңнән чыгарма: ул шаяртуларны авыр күтәрә* (Сөйләм).

2. *к.* авыр<га> алу. *Сәбәпсезгә төшкән җәберләрне / Чиста җаның авыр күтәрде* (М. Шиһапов). *Ялгышларны авыр күтәрүе, Җиңел түгел табу дөресне* (Ф. Яхин. Дөнья авар, диләр…).

Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**АВЫР КЫЙМЫЛДАУ** *к.* авыр кубу. *Ташбакадай авыр кыймылдап килгән кәрванның кала капкаларына таба якынайганын көтә-көтә түземлеге сынды* (В. Имамов. Утлы дала).

Төрдәше: авыр кеше 1 һ.б.

**АВЫР НОКТАГА ҖИТҮ.** Хәлиткеч хәленә, мизгеленә, торышына килеп җитү. *Бервакыт аның авыруы үзенең иң авыр ноктасына җитте* (Ә. Фәйзи. Тукай).

**АВЫР САБЫРЛЫ.** Бик тыныч, тотнаклы, түземле. *Авыр сабырлы булуы йөзенә чыккан* (atnya-rt.ru).

**АВЫР САБЫРЛЫЛЫК.** Салкын канлылык, каушап калмау, тотнаклылык, тыйнаклык, тынычлык. *Көчле характер, авыр сабырлылык – акыл ияләренә хас сыйфатлар* (Л. Хәмидуллин. Кичке шәфәкъ).

**АВЫР САНЛЫ** *к.* авыр гәүдәле 1. – *Һи-и, кеше көлдермәсәнә! Бу авыр санлы ат йөз метрлар китүгә күбеккә батачак* (К. Тимбикова. Сөлге булсын бүләгем!).
Төрдәше: авыр аяклы 1 һ.б.

**АВЫР СӘГАТЬЛӘР.** Бәла-казаның иң үкенечле, хәлиткеч хәлләре. *[Әх-мәт] Бәхетсезлегемнең иң авыр сәгатьләре килеп җитте* (Г. Камал. Дәҗҗал).

**АВЫР СӨЯКЛЕ** *к.* авыр гәүдәле 1. *Авыр сөякле, гаҗәеп киребеткән Йосыфның холкы яман булса да, үзе ул бик гадел иде* (М. Галәү. Болганчык еллар).
Төрдәше: авыр аяклы 1 һ.б.

**АВЫР СУЛАУ**. Борчылу, кайгыру. *Наилә авыр сулады, дәшмәде, кулы белән балаларга төртеп күрсәтте* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**АВЫР СҮЗ**. 1. Күңелне рәнҗетерлек начар сүз. *Нәфисә хәзер дә аңа авыр сүз әйтергә теләмәде* (Г. Бәширов. Намус*). Кызлар хәтта дулкынланудан бер-берсенә бераз гына авыр сүзләр дә әйтеп алдылар* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).

2. Урынсыз гаепләү. *Шәриф абзый, эшнең әзме-күпме икәнлеге турында әйтергә иренен кыймылдатса да, малаена авыр сүз әйтеп хәтерен калдырудан курыкты* (А. Алиш. Яңа килен).

**АВЫР СҮЗНЕ КҮТӘРӘ АЛМАУ**. Хәтер калдырырлык, урынсыз гаепләүне һ.б. сүзләрне кабул итә алмау. *Фәридун үзе, эчендәге тышында булып, ни уйласа шуны әйтсә дә, авыр сүзне күтәрә алмый, шуңа күрә минем авыр сүз әйтеп, аның мондый нечкә күңелен ялалыйсым килми* (Х. Сарьян. Башкорт кызы).

**АВЫР ТАБИГАТЬЛЕ (ХОЛЫКЛЫ).** Карулашуны сөйгән, киңәш тыңламаган, игә-җайга килми торган кеше. *Аларның һәркайсы билгеле бер сыйфатка ия булган; бүре – комсыз, усал, куян – куркак, аю – авыр табигатьле, төлке – мәкерле, хәйләкәр, бик ялагай, куштан һәм алдакчы, ат – бик турылыклы, сарык – аңгыра, кәҗә тапкыр һәм хәйләкәр итеп сурәтләнә* (5 кл. Әдәбият дәреслеге). *– Ул – бик авыр холыклы кеше*, *берүк баламны үз канат астыңа алсана, миннән хәер-дога, дөнья-ахирәт бәхетле булыгыз, – диде* (Г. Бәширов. Намус).
Төрдәше: авыр кеше 2.

**АВЫР ТАРТУ.** Үлчәүгә авыр килү. *Талир тәңкә авыр тарта, / Алты мыскалдан арта* («Чулпы» җыры).

**АВЫР ТИЮ** *к.* авыр алу (күтәрү). *Нахак сүз кемгә дә авыр тия шул ул* (В. Нуруллин. Җавап бир, кеше).
Төрдәше: авыр алу (күтәрү); авырга алу.

**АВЫР ТОРМЫШ**. Мохтаҗлыкта яшәү. *Карт белән карчыкның авыр тормышы, хәерчелеге аларның зар-моңнарын оныттырды* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**АВЫР ТУФРАГЫ ҖИҢЕЛ БУЛСЫН**. Үлгән кешене хәер белән искә алганда әйтелә. – *Шуның атларын карады, ә үзе гомере буе ат күрмәде, мәрхүм, авыр туфрагы җиңел булсын…* (Г. Сабитов. Айбаш).
Төрдәше: авыр туфрагы салмак<лы> булсын; Алла авыр туфрагын җиңел кылсын; Алла авыр туфрагыңны салмак<лы> итсен; Алла җирен җәннәт кылсын; ахирәттә очрашырга насыйп итсен; гүрең якты булсын.

**АВЫР ТУФРАГЫ САЛМАК<ЛЫ> БУЛСЫН.** Хәерсез кеше үлгәндә, киная белән әйтелә. *Картлар беләдер, аның тавышы гаҗәп зәһәр иде, аннары ул үзе дә авылда беренче усал карчык иде, авыр туфрагы салмаклы булсын мәрхүмнең* (А. Шамов).
Төрдәше: авыр туфрагы җиңел булсын һ.б.

**АВЫР ТЫНЛЫК**. Кайгы, борчу һ.б.дан туган сүзсезлек. *Авыр тынлыкны күтәрә алмады Сәет, күзләрен читкә күчерде, карашы бүлмә эчендәге җиһазлардан, түшәм, тәрәзә буйларыннан йөгереп узды* (Ф. Латыйфи, Хыянәт).

**АВЫР УЙ.** Даими борчып торган, үкенечле һ.б. төрле уй. *Күзләренә нindидер авыр уй чыкты: «Бозылырга теләмәсәләр, ни кылырбыз?»* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *Минем күңелемә авыр уйлар оялаган, өйләнешкәннән бирле мин ни каенатам, ни каенанам белән көрешмәгән килмешәк килен идем* (Н. Гыйматдинова. Сөйлим, тыңла...).

**АВЫР ХӘЛ.** Чишелүе авыр, үкенечле хәл. *Якынрак баргач, тагы авыр хәл: минем Алмачуарым, аяк-кулы бәйләнеп, арбага салынган…* (Г. Ибраһимов. Алмачуар). *Бу минем өчен иң авыр хәл иде. Әгәр әнием яңадан иргә чыкса,*

*без әтиемне дә каядыр калдырып китәбез төсле* (Н. Дәүли. Язмышка юл).

**АВЫР ХӘЛГӘ КУЮ.** Уңайсыз, кыен бер торышка дучар итү. – *Сез мине авыр хәлгә куйдыгыз, тиз генә берни дә әйтә алмыйм, – диде ул* (Т. Сәгыйтов. Буыннар язмышы). *Ногайлардан килгән бу төркем сугышчыларда ниндидер өмет уятса да, Мәмешнең үзен бик авыр хәлгә куйды. Болай да авыр чакта мондый хәбәр алу аны бөтенләе белән төшенкелектә калдырды* (Н. Гариф. Мәмеш Бирде).

**АВЫР ХӘЛГӘ ТӨШҮ.** Уңайсыз, кыен бер торышка дучар булу. *Күренә ки, ул вакытта минем Вәлиди белән көрәшүемнән һичбер төрле файда чыкмаса да, ул башкорт поездындагыларга күренеп йөрүем белән үземне бик авыр хәлгә төшү ихтималына да дучар иткәнмен икән...*(Г. Баттал-Таймас. Мин бер яктылык эзләгән идем).

**АВЫР ХӘЛДӘ КАЛУ.** Уңайсыз, кыен бер торышта булу. *Рөстәм үзенең нинди авыр хәлдә калуын хәзер генә аңлады: димәк, әнисе аны күрми һәм күрмәячәк* (Г. Кутуй. Рөстәм маҗаралары). *Үзенең авыр хәлдә калуын аңлата торгач, кичке унбергә кадәр күтәргә куштылар* (Н. Акмал. Кол).

**АВЫР ХӘРӘКӘТЛЕ <КЕШЕ>.** Ниндидер сәбәптән кыенлык белән генә хәрәкәтләнүче. *Карап торырга чибәр генә, авыр хәрәкәтле кеше иде ул* (Сөйләм).

Төрдәше: акрын кыймылдаучан кеше.

**АВЫР ХӘСРӘТ, КАТЫ КАЙГЫ.** Башка төшкән төрле хәсрәтләрне гомумиләштереп әйтү. *Ачы буран, суык җил / Чиметә ике битемне; / Авыр хәсрәт, каты кайгы / Ашый йөрәк итемне* (Хал. җыры).

**АВЫР ХИС.** Кешедә тискәре тойгылар уяткан халәт. *Мәчет Кларада ятсыну һәм шомлануга охшаган ниндидер бер авыр хис уятты* (Ә. Еники. Туган туфрак). *Бу сыкрау күңел сызлавы булып, җанга үтеп керде, йөрәкне бертуктаусыз ниндидер авыр хис талады* (Х. Ширмән. Еракташы йолдызым).

**АВЫР ЧИР.** Котылуы, арынуы бик читен булган нәрсә. 1. Хәтәр, җитди хасталык. *1999 елның сентябрь урталарында мине көтмәгәндә авыр чир аяктан екты* (Т. Галиуллин. М. Мәһдиев йолдызлыгы).

2. Кайгы-хәсрәтле, күңелдә борчу тудыра торган халәт. *Язучы өчен иң авыр чир – яза алмау чире* (Ф. Яруллин. Хәтер төпләрендә утлы күмер). *Ә ялгызлык – иң авыр чир ул. Аның белән хасталансаңмы? Терелә димә...* (Р. Сибат. Ялгызак).

Төрдәше: авыр яра.

**АВЫР ЯЗМЫШ<ЛЫ>.** Тормышта төрле бәхетсезлекләрне күргән кеше турында. *Тик шулай да авыр язмыш Акбүрене тулысынча тыныч калдырмаган* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур). *Авыр язмышлы шагыйрьләр арасында аеруча күзгә ташланганы – Нәҗип Думави* (М. Мәһдиев. Таң атар, башланыр ак тормыш...).

**АВЫР ЯРА.** Мәңге онытылмаслык кайгы-хәсрәт, борчу. *Соңыннан, кирелеге суынгач, ул әтисенең хәтерен калдыруын, аның карт йөрәгенә бик авыр яра салганлыгын аңлап сагышлана башлады* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

Төрдәше: авыр чир 2.

**АВЫР ЯРАЛЫ.** Мәңге онытылмаслык кайгы-хәсрәтле, борчулы. *Каргышлары өстебезгә иңгән / Һәм йөрәкләр авыр яралы!* (Ф. Яхин).

Төрдәше: җитди ярасы булган.

**АВЫР ЯТУ.** Бик каты авыру. *Сезне шундук таныдымы соң ул, әти? Авыр ятамы?* (Ә. Мохтар. Чинар).

*АВЫРАЕП* ❖ **АВЫРАЕП (АВЫРАЙТЫП) ТОРУ.** Йокы баскан кебек хәлсезләнеп тору, начар хис итү. *Шаһия (чыгып). Әби авыраеп тора* (Г. Каюмов. Юбилей).

*АВЫРГА* ❖ **АВЫРГА КАЛУ.** 1. Кыенлашу, авырлашу. – *Көн итү бик авырга калса да, барына шөкер итеп торабыз әле, мондый чакта зарлану язык булыр, нишлисең инде!* (Ә. Еники. Рәшә).

2. *к.* авыр аяк<лы> 3. – *Авырга калачаксың син, кызым, – диде ул, Фәүзия торып утыргач* (М. Кәбиров. Мәхәббәт яңгыры).

Төрдәше: авыр аяк<лы> 3 һ.б.

**АВЫРГА УЗУ** *к.* авыр аяк<лы> 3. *Авырга узганы мәгълүм булгач, бүлмәсенә бикләнеп, шатлыгыннан өч көн, өч төн елады* (М. Әмирханов. Гәүһәршад).

Төрдәше: авыр аяк<лы> 3 һ.б.

*АВЫРЛЫ* ❖ **АВЫРЛЫ БУЛУ** *к.* авыр аяк<лы> 3. *Ә кайткач та, Гөлсия аңа үзенең авырлы булуы турында әйтте* (А. Нәҗми. Азат).
Төрдәше: авыр аяк<лы> 3 һ.б.

*АВЫРЛЫГЫМ* ❖ **АВЫРЛЫГЫМ ШУНДА КАЛСЫН.** Хәл җыярга утырган җирдән торып киткәндә, шулай әйтәләр дә төкереп китәләр (иске йолалардан калган). – *Хәл керде бугай, авырлыгым шунда калсын, кояш байый башлаганчы, чишмә буена барып җитәргә кирәк* (Сөйләм).

*АВЫРЛЫК* ❖ **АВЫРЛЫК БЕЛӘН.** 1. Җәфаланып, интегеп. *Ислам, чокыр янында урын табып утырып, китапны тезенә куеп, бик авырлык белән укый* (А. Гадел. Хикмәт бабай хикмәтләре). *Зур авырлык белән күзләрен ачып сәгатькә карады* (В. Исламетдин. Шлем).

2. Зур көч түгеп, акча тотып; кыенлык, мәшәкать белән. *Ярыш авырлык белән булса да бу цехка да керде* (А. Алиш. Якты күл буе). *Шулай кадерсезләнеп, ул Мәскәүгә кайтты һәм авырлык белән бер кибет ачып җибәрде* (З. Мурсиев. Мин сезнең хатыныгыз).

3. Теләмичә, авырсынып. *Алар чалгыларын бертигез, салмак көч, авырлык белән, ачулы, изелгән йөзле хәлдә тоталар* (А. Алиш. Көршеләр). *Баштарак ул хатынын юньләп тыңламады, сөйләгән сүзләре аңына авырлык белән барып җитте* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: дөнья бәясенә.

4. Көч-хәл белән, көчкә-көчкә генә. *Шатлыгыннан җилкенеп торган йөрәген авырлык белән тынычландырып, йөзенә кайгылы чырай чыгарып, Фәзилә Хәмитовна кызларына борылды* (Г. Мирһади. Килмешәк).

**АВЫРЛЫК КҮРҮ (КҮТӘРҮ).** Кыенлык күрү, мәшәкать чигү; бәла-казага очрау. *Ә менә авырлык күргән, олы кайгы күргән, кеше газабын үз йөрәге аша үткәрә белгән кешеләр яши* (Э. Шәрифуллина. Мәхәббәтнең җиде төсе).
Төрдәше: авырлык төшү; баш ярылып, күз чыгу.

**АВЫРЛЫК ТӨШҮ** *к.* авырлык күрү (күтәрү). *Авырлык төшсә түз, сер бирми-нитми, / Ни хәлләр яшь егеткә килми-китми* (Г. Тукай). *«Авырлык төшсә, түз, сер бирми-нитми, / Ни хәлләр яшь егеткә килми-китми»* (Р. Харрасова. Уйлар Тукайга илтә).
Төрдәше: авырлык күрү (күтәрү) һ.б.

*АВЫРЛЫККА* ❖ **АВЫРЛЫККА ҖИҢЕЛЛЕК!** «Авырлыклар югалсын» мәгънәсендә. *Китә куану, соклану, кайсы карда ауный, кайсы: авырлыкка җиңеллек! – дип сикергәләргә тотына* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

*АВЫРЛЫКЛАРГА* ❖ **АВЫРЛЫКЛАРГА БАШ ИМӘҮ.** Тормышта авырлыклар очраганда аптырап калмау, аларны үтеп чыгу юлын эзләү. *Әти тәрбиясе аямаганнарга дөнья океаннарын хәвефсез үтүе, кыенлыклар белән көрәшүе авыр. Чөнки әтиләр авырлыкларга баш имәскә өйрәтәләр* (М. Әхмәтҗан. Шигърият аша тәрбия).

*АВЫРЛЫКНЫ* ❖ **АВЫРЛЫКНЫ <КЕШЕГӘ> САЛУ.** Борчу-мәшәкатьләрне башкалардан хәл иттерү, кешегә салыну. *Шушы ук омтылыш-тартылышлар хәтта кочаклашкан, хәтта үбешкән чакта да аермачык булып күңелгә шом сыман бер авырлык салды һәм <...> бер атна чамасы вакыттан соң эшләгән җиренә шалтыраткан идем, Нәзилә каядыр чыкты, диделәр* (Ә. Баянов. Аязучан болытлы һава...). – *Ярата ул бөтен авырлыкны кешегә салырга, бу юлы үзе бераз баш ватсын әле* (Сөйләм).

*АВЫРНЫҢ* ❖ **АВЫРНЫҢ ӨСТЕННӘН, ҖИҢЕЛНЕҢ АСТЫННАН.** 1. Җиңел генә яшәү җаен эзләү турында. *Мин бу эшне ышанып тапшырырлык кеше күрмим, авырның өстеннән, җиңелнең астыннан яшәргә күнеккәннәр* (Сөйләм).

2. Дөньядагы төрле авырлык-каршылыкларны үтә белгән булдыклы, эшчән кеше хакында. *«Без авырның өстеннән, җиңелнең астыннан чыгарга исәп тотмадык», – ди ул, фронтовикларның ул чактагы бердәм халәтен белдереп* (Р. Фәйзуллин).
Төрдәше: азау тешен ашаган; акылга беткән; акылга утырган; алгыр булу; алтын бишектән төшкән; алтын кул<лы>; арбасын тауга менгергән; арыслан сырты; арыслан тырнаклы; астан кереп, өстән чыгу; барын бал итеп; бер дә килмәгән җире юк; бер дигән; билне буып туган; бөтен кеше; дөнья җимертеп эшләү; дөнья корып яшәү; дөнья күргән; егет дисәң дә егет; егет желеге; егет солтаны; елан аягын кискән; җепне тешләгән җиреннән өзү; җиде бабадан килгән; җиңел аяклы; җиңел сөякле;

җиңелнең астыннан; җылан күзле; кулдан эш килү; таякны тоткан җирдән сындыру; өлгер тоту; өстенә кояш чыгармау; пешеп чыккан; таш астыннан чыккан; тел чарлаган; төскә матур, эшкә батыр; төшеп калганнардан түгел; тугыз мурдан үткән; унике фән күргән; ут егет; ут күл; ут кебек йөрү; ут уйнату; ут чәчеп, буран уйнатыр; эш җанлы; эш рәтен белү; эшкә кулы яту; эшкә оста, сүзгә кыска; югын бар итеп; яшен ташы кебек.

*АВЫРТКАН* ❖ **АВЫРТКАН БАРМАКНЫ КИСЕП ТАШЛАУ.** Җитешсезлекнең сәбәбен ачыклап тормастан, шуңа дучар булучыны юк итү. *<Әдәбиятта> аерым җитешсезлекләрне-авыруларны бетерү турында чаралар күрү урынына авырткан бармакны кисеп ташлау сәясәте тоту* (Г. Гали).

**АВЫРТКАН БАШКА <ТИМЕР> ТАРАК (ТАЯК; ТУКМАК).** Үз борчуы өстенә яңасы өстәлеп тору; бәла өстенә бәла килү. – *Ни дип мин авырткан башыма тимер тарак алыйм, Әбүзәр абзый?* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Аннан соң авырткан башка тукмак дигәндәй, <...> авылның крестьяннарын миңа каршы котыртып ята икән* (Д. Таҗи. Кыям Җәгъфәров: автобиографик истәлекләр).

Төрдәше: авыртмаган башка тимер тарак 3; бәла өстенә бәла; тоз өстенә торма <кушу>; торма өстенә тоз; уттан котылу, суга төшү; уттан ялкынга; чөй өстенә тукмак; чүм өстенә чүмәлә; чүп өстенә чүмәлә.

**АВЫРТКАН ҖИР (УРЫН).** 1. Һәрвакытта да борчып торган, сызлану тудырган мәсьәлә. *Бүгенге көндә халык телендәге, халык бәгырендәге иң авырткан җир – эш хакы, дисәм, моңа беркем дә каршы килмәстер* (Р. Вәлиев. Дөнья гаме). *Хәер, ул сызланып кына калмый, үзенең шигырьләрен әнә шул «авырткан җирләребезгә» дәва итеп яба да сыман* (Л. Шагыйрьҗан. Шагыйрь буласың килсә – бул).

Төрдәше: четерекле мәсьәлә.

2. Зур кичерештән, бәхетсезлектән соң калган йөрәк ярасы. *Нәфисә, әгәр синең авырткан җиреңә кагылсам, син гафу ит* (Г. Бәширов. Намус).

**АВЫРТКАН ҖИР БӘРЕЛҮЧӘН БУЛА.** Үзен кызыктырганны гына сөйләү. *Шагыйрь, халык теле белән: «Авырткан җир бәрелүчән була», дип тә өзгәләнә* (Л. Шагыйрьҗан. Шагыйрь буласың килсә – бул).

Төрдәше: авырткан җирдән кул китмәү.

**АВЫРТКАН ҖИРГӘ БАСУ (БӘРЕЛҮ; КАГЫЛУ; СУГУ; ОРЫНУ; ТИЮ; ТӨРТҮ).** 1. Берәр үкенечле вакыйганы, күңелсез хәлне яңадан искә төшерү; гаебен яки кимчелеген төрттереп әйтү. *Аның авырткан җиренә сугарга булдым* (З. Галимов). – *Син дә минем авырткан җиргә кагылма инде, яме!* (Н. Акмал. Тәнзиләкәй-өлкәй).

2. Авыр кичерештән соң калган йөрәк ярасын искә төшерү. *Авырткан җиргә сукты Зарифулла* (Ф. Шәфигуллин). *Әллә нидә бер сүз кушып, анда да кызның авырткан җиренә кагылуы өчен, Равил күңеленнән тагын да үзен нык кына битәрләп алды* (В. Нуруллин).

3. Дөресен әйтү. *Шуңадыр да, Зарифның авырткан җиренә орынмас өчен, берәттән үзен дә кушып: – Картаябыз, Зариф. – диде* (Г. Минский. Канәфер чәчәге).

Төрдәше: авырткан сөялгә басу; сөялгә (сөяленә) басу.

**АВЫРТКАН ҖИРДӘН КУЛ КИТМӘҮ** *к.* авырткан җир бәрелүчән була. *Әле бит халыкта «Авырткан җирдән кул китмәс», – дип тә әйтәләр. Харрас Әюповның да нәкъ шулай: хәтта шуның аркасында булса кирәк, ул бераз «монотематизм» белән дә авырый* (Л. Шагыйрьҗан. Шагыйрь буласың килсә – бул).

Төрдәше: авырткан җир бәрелүчән була.

**АВЫРТКАН ҖИРДӘН КУЛ КИТМӘҮ, СӨЙГӘН (ЯРАТКАН) КЕШЕДӘН (ЯРДАН) КҮЗ КИТМӘҮ.** «Күзләр һаман да яраткан кешеңә карыйлар» мәгънәсендә. *Авырткан җирдән кул китми, сөйгән ярдан күз китми дигәндәй, тик егетнең күзләре Зөлхәбирәдә* (Ф. Абдуллин. Чуерташ). *Авырткан җирдән кул китмәс, яраткан кешедән күз китмәс шул* (Н. Көбәш. Замана кызы).

Төрдәше: бер яшьлектә, бер картлыкта; берәү яшьлектә, берәү картлыкта; гыйшык җәзасы; гыйшык тотарлык; гыйшык тоту (төшү); гыйшык уты; гыйшык утын<д>а яну; гыйшык чәчәк ату; гыйшык чире; гыйшыкны гыйшык китәрү; карт гыйшык яман булу; күз ату 2; күз атып йөрү (тору); күз төшерү 2; күз төшү 2; күңел салу 1; күңелгә кәгъбә итү; күңелгә ут салу (ягу); мәхәббәт бәйлау; мәхәббәт<еңне> белдерү; мәхәббәт газабы;

мәхәббәт җәзасы; мәхәббәт сату; мәхәббәт тоту; мәхәббәт төшү; мәхәббәт уены; мәхәббәт уены уйнау; мәхәббәт утында яну; мәхәббәт утырту; мәхәббәт учагы кабызу; мәхәббәт шаукымы кагылу; мәхәббәт ямау теләми; мәхәббәтнең кызыл гөлләре чәчәк ату; мәхәббәттән яну; сөю угы<н> кадау; үлеп тору; үлеп ярату.

**АВЫРТКАН СӨЯЛГӘ БАСУ** *к.* авырткан җиргә басу (бәрелү; кагылу; сугу; тию; төртү). *Таһиров Яңгураның иң авырткан сөяленә басты* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Бу сүзләре белән ул Хөснулланың авырткан сөяленә басты булса кирәк, колхоз рәисенең кашлары дугаланып килде* (Р. Низами. Шахмат дәресләре).
Төрдәше: авырткан җиргә басу (бәрелү; кагылу; орыну; сугу; тию; төртү) 1, 2, 3; сөялгә (сөяленә) басу.

*АВЫРТМАГАН* ❖ **АВЫРТМАГАН БАШКА ТИМЕР ТАРАК (ТАЯК).** 1. Көтелмәгән борчулар килеп чыгу**.** *Бер айдан соң ун гына җәйдак иярткән Бирдебәк авыртмаган башка тимер тарак кебек кайтып җитсә, Җанибәк хан сырхавыннан туктап, аягына басарга җыена икән* (В. Имамов. Карабәк). *– Авыртмаган башка тимер таяк булдыгыз бит!* (Т. Гарипова. Умырзая гөлнең гомеркәе).

2. Гаепсез кешегә тик торганда гаеп ташлау. *Авыртмаган башка тимер тарак дигәндәй, таякның юан очы Сөләйманның түбәсенә төште. – Мин кайчаннан бирле солтан галиҗәнапларының дошманына әверелдем әле?* (В. Имамов. Сөләйман солтан).

3. Бер бәла өстенә яңасы өстәлеп тору. *– Авыртмаган башка тимер тарак кына түгел, тимер таба да була икән, – диде ул, күзләрен сөртә-сөртә* (М. Миншин. Кызыл диплом). *Миңа авыртмаган башка тимер таяк. Димәк, Сөмбелгә генә түгел, энесенең дә юлына аркылы төшкән, аның алдында да гаепле булып чыкты* (З. Кадыйрова. Сагынырсың – мин булмам).
Төрдәше: авырткан башка <тимер> тарак (таяк; тукмак) һ.б.

**АВЫРТМАГАН ЯККА ЯТУ.** Җайлашу, җаен табу, чамаңа карап эш итү (күбрәк сатулашканда кулланыла). *– Миңа барыбер, димә әле, кеше дә авыртмаган ягына ята* (Сөйләм).
Төрдәше: авыртмаган якны карау; аткан саен үрдәккә тимәү; басуда балык булмау; башыңа төшсә, башмакчы булырсың; биргән бигә яраган, бирмәгән нигә яраган; җайга салу; җирле җирендә, җикән күлендә; кайсысына көй кирәк, кайсысына чөй кирәк; көен табу; көн дә көн бәйрәм булмый; күперне чыкканчы шайтанга да әти диярсең (дисең); капкан саен калҗа булмый <бәрәңгесе дә эләгә>; салган саен кармакка балык эләкми; сырлы йомырка сабан туенда гына була; үз җаеңны үзең кара; үз ибенә яту; үз уңаен карау; хайванның бавыры башка; һаман-һаман майлы аш та туйдыра; һәр эш җае белән, ботка пешә мае белән; һәр эшнең җае бар, һәр ашның тәме бар; эт симез дә, ашарга ярамый; ялан-ялан майлы ботка булмый; ялан-ялан ни талан.

**АВЫРТМАГАН ЯКНЫ КАРАУ** *к.* авыртмаган якка яту. *Ал, дип, көчләмим, авыртмаган ягыңны кара* (Сөйләм).
Төрдәше: авыртмаган якка яту һ.б.

*АВЫРТМАС* ❖ **АВЫРТМАС БАШКА ТИМЕР ТАРАК (ТАЯК)** *к.* авыртмаган башка тимер тарак (таяк). *Туйган ул азаплардан! Авыртмас башка тимер тарак табып йөргән Мәрьям үзе юләр!* (М. Маликова. Казан каласы). *Хакимият тә, авыртмас башка тимер таяк, дип фикер йөртмәгән* (Ә. Исхаков. Табыш).
Төрдәше: авыртмаган башка тимер тарак (таяк).

*АВЫРУ* ❖ **АВЫРУ БАШТАН САУ БАШКА АУДАРУ (АВЫШТЫРУ).** Үз гаебеңне башка берәүгә сылтау. *Авыру баштан сау башка аударырга тырышма әле, булганын сөйлә* (Сөйләм).
Төрдәше: авыртмаган башка тимер тарак (таяк) 2; авыру баштан сәламәт башка; ак эт бәласе<н> кара эткә; ак эт бәласен кара эткә ягу; ак этнекен кара эткә.

**АВЫРУ БАШТАН СӘЛАМӘТ БАШКА** *к.* авыру баштан сау башка аудару (авыштыру). *– Синең бу сүзләрең авыру баштан сәламәт башка кебегрәк тоела, ышандырыбрак сөйлә* (Сөйләм).
Төрдәше: авыртмаган башка тимер тарак (таяк) 2; авыру баштан сау башка аудару (авыштыру); ак эт бәласе<н> кара эткә; ак эт бәласен кара эткә ягу; ак этнекен кара эткә.

**АВЫРУ ҖИРГӘ ТОЗ БУЛУ.** Начар кәефне яки борчылуны тагын да көчәйтеп җибәрү. *– Ят, йокла, – дип, берсе артыннан берсе сүзләр чәчә*

*башладым. Бу авыру җиргә тоз булды, күрәсең* (Г. Кутуй. Фарзана).

**АВЫРУ КӨЕН КӨЙЛӘҮ.** Авыру кешене тәрбияләү, аны карау. *Көннәр берсе артыннан икенчесе авыру көен көйләп үтәләр* (Сөйләм).

*АВЫРУГА* ❖ **АВЫРУГА САБЫШУ.** 1. Нәрсәдән булса да тәмам йөдәп, авыру кебек хәлгә әйләнү. *Әни бөтенләй авыруга сабышты. Иләс-миләс килеп ары сугыла, бире сугыла, хәле беткән сыман сәке кырыена килеп утыра* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

2. *к.* авыруга салыну. *Сәлахның бәлагә таруын, намус судына тартылачагын һәм бары тик авыруга сабышын йөрүе аркасында гына, судның кичектерелеп торуын Янгура да белә иде* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

Төрдәше: авыруга салыну.

**АВЫРУГА САЛЫНУ.** Сау башы белән үзен авыру итеп күрсәтү. *Матур Гөлчәһрәнең анасы, кызының матурлыгы, зифалыгы берлә алдырыр өчен, кич берлә ястүдән соң авыруга салынып, мулланы «Ясин» укытырга чакырырга җибәрде* (Г. Исхакый. Мәдрәсә җимеше).

Төрдәше: авыруга сабышу 2.

*АВЫРУЫ* ❖ **АВЫРУЫ ТОТУ**. 1. Кешедә булган авыру үзен сиздерү. *Сөйләшеп утырганда, карчыкны йөрәк авыруы тота: калтырана башлый, тыны кысыла...* (М. Яһудин. Тормыш бу...).

2. Эпилепсия (бума) башлану. *Авыру тотып алганда: «Эх, терелсәмме, бары сәламәт яшәү рәвешен генә алып барыр идем. Барлык начар гадәтләрне дә ташлаячакмын», – дип уйлый күп кеше* («Шәһри Казан» газ.).

Төрдәше: <үз> бумасы тоту; өянәге кузгалу; өянәге тоту; тотмасы башлану; <үз> чире тоту; үз авыруы кузгалу; үзенеке куркыту; үзенеке тоту.

*АВЫРЫП* ❖ **АВЫРЫП ЯТУ.** Үз аягы белән йөри алмыйча, урын-җирдә ятып авыру. *Гөлфинурның авырып ятуы хакында күбесе белми иде* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

Төрдәше: түшәк саклау 1; урын хастасы; хаста яту; ятып чирләү.

*АВЫШ* ❖ **АВЫШ ЯККА САЛАМ КЫСТЫРУ.** 1. Ялагайлану, үз алдында мактаган булып үсендерү. *Йә, сөйлә-сөйлә, авыш якка салам кыстырырга яратасың да инде* (Сөйләм).

Төрдәше: җаена тору 1; җил ягына (уңаена) кабык сөяү (сөяп кую); җил ягын<н>а<н> салам кыстыру; йон уңаена (җаена; уңаеннан; ягына; ятышына) сыпыру (сыйпау); йонны уңай якка (җайга) сыйпау (сыпыру); йонны ыспаена сыпыру; салам кыстыру 1; салпы ягына салам кыстыру 1.

2. Хәйләләү. *Әкиятләрдәге төлкене дә уздырды бугай, алай итте, болай итте, авыш ягына салам кыстырып, үзенә кирәген белде* (Сөйләм).

Төрдәше: койрык болгау (болгату) 1; койрык боргалау; койрык бору 2; май ашаган песи кебек күзләрне уйнату; тегермән кору; чөй кагу; шомарып бетү 2; юкә чөй кагу.

*АВЫШ-КЫЕШ* ❖ **АВЫШ-КЫЕШ КИТЕРГӘЛӘП (КИТЕРЕП).** Тормышта килеп туган бер кыенлыкны икенчесе белән каплап, аннан-моннан гына маташтырып яшәү. *[Әби] Шөкер әле, бер көе генә авыш-кыеш китергәләп гомер итеп килгән булам шунда* (Г. Камал. Хафизалам, иркәм).

Төрдәше: авыш-түеш (тәвеш) китерү 3; әвеш-түеш (тәвеш) китерү 1.

*АВЫШ-ТҮЕШ* ❖ **АВЫШ-ТҮЕШ (ТӘВЕШ) КИЛҮ.** 1. Буталу, чуалу, урыннары алмашынып бетү. *Шкафтагы әйберләрнең рәте бетеп, әвеш-түеш килеп беткәннәр иде* (Сөйләм).

Төрдәше: әвеш-кыеш китерү 1; әвеш-түеш (тәвеш) килү 1; бутай мунчаласы кебек <булу; булып бетү>.

2. Ава-түнә атлау. *Камыт аяклары белән авыш-тәвеш килеп, урамнан бер юантык карчык барса, ул – Газзәтти* (М. Мәһдиев).

Төрдәше: алпан-тилпән бару.

**АВЫШ-ТҮЕШ (ТӘВЕШ) КИТЕРҮ.** 1. Бутау, чуалту, берсе урынына икенчесен куеп, килеп чыккан мәсьәләләрне хәл итеп бару. *Кам каткан кургашыннарга бик озак нидер сөйләде, кулына алып, авыш-түеш китерде* (М. Хәбибуллин. Илчегә үлем юк).

Төрдәше: авыш-кыеш китергәләп (китереп); әвеш-түеш (тәвеш) китерү 1.

2. Алыш-биреш белән шөгыльләнү. *Ташкентка бераз тансык мал алып барып авыш-тәвеш китерсәгез, кесәгезне тишмәс иде* (Т. Әйди. Елан угы).

3. Аннан-моннан гына маташтыру (ашык-пошык эшләп ташлау). *Шәһәр исемнәрен бер генә тапкыр да түгел, ике-өч тапкыр авыштүеш китерәләр, Сумканы яңадан Сомка дип язасы авырмы икән?* («Яшел Үзән» газ.).

Төрдәше: авыш-кыеш китергәләп; әвеш-түеш (тәвеш) китерү.

*АВЫШЫП* ❖ **АВЫШЫП КАЛУ.** Берәр сәбәптән акылга җиңеләеп калу. *Хастаханәдә ятуы эзсез калмаган, кешеләрдән аның авышып калуы турында ишетте* (Сөйләм).

*АГАГА* ❖ **АГАГА ЭНЕ, ЭНЕГӘ АГА.** Кешелекле, олы-кечегә ихтирамлы, кардәшлеккә хөрмәт белән караучы кеше. *Аның танышлары арасында агага эне, энегә ага кешеләр күп түгел* (Сөйләм).

*АГА-ҖИҢГӘ* ❖ **АГА-ҖИҢГӘ КУЛЫНА КАЛУ.** Туган-тумача тәрбиясендә яшәүнең кыенлыгы хакында. *Ага-җиңгә кулына калырга язмасын, әти-әнигә гомер бирсен* (Җ. Вәлиди).

*АГАЙ* ❖ **АГАЙ, АЛГА (АЛДАН) САГАЙ.** Һәрчак та сак булырга кисәтү. *Халыкта «агай, алдан сагай» дигән гыйбарә бар* (Х. Миңнегулов. Гасырар өнен тыңлап...).

Төрдәше: абай булу һ.б.

**АГАЙ ОЛЫ, МИН ЗУР.** 1. Яше зур булмаса да, нидән булса да үзен зурга куючы. – *Әгәр, – диде, – инде син агай – олы, мин – зур, дисәң, Нурый белән Фәтхияне калдырабыз да яшь хатының белән сине җибәрәбез <...>* (Г. Ибраһимов).

2. Агайдан элек өйләнү турында. *Агай олы да, ләкин мин зур булып чыктым шул* (Сөйләм).

**АГАЙ ОЛЫ, МИН ЗУР, АТКА ПЕЧӘН КЕМ САЛА?** Эшлисе килмәгән эшне берсе икенчесенә, икенчесе өченчесенә кушып үтәмичә калу; яисә яшь булса да, дәрәҗәсе булудан яки башка яктан үзен өстен куеп, бернәрсәдә дә булышмаучы. *Агай олы, мин зур, атка печән кем салыр?* (Мәкаль).

Төрдәше: бар да хан, бар да түрә – атка печән кем сала; Гали – Вәлигә, Вәли – Галигә ышану; син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала?; эт эткә, эт койрыкка җибәрү.

*АГАЙ-ЭНЕ* ❖ **АГАЙ-ЭНЕ, АВЫЛ-КҮРШЕ.** Бер-берсе белән аралашып, бер ил булып яшәү хакында. *Күршеләре көрәкләр күтәреп, буа буарга киткәч, «агай-эне, авыл-күрше» дип, Мансур да алар артыннан теркелдәде* (Сөйләм).

**АГАЙ-ЭНЕ – АК МЫЕК.** 1. Кода-кодагыйлык, үз туган-тумачаңны гына кайгырту. *Агай-эне – ак мыек... әһле әдәбият шул тәртип белән гөр килеп яши бирә* (Ә. Баянов).

2. Үз кеше. – *Күрдеңме, агай-эне ак мыек, өйрәнеп тордыңмы? – ди Озын дустым* (Г. Мөхәммәтшин). – *Егетләр, агай-эне ак мыек, Зиннуров килә* (М. Хәбибуллин).

Төрдәше: агай-эне ак мыек, чабата башы кыек.

**АГАЙ-ЭНЕ АК МЫЕК, БЕР-БЕРЕБЕЗНЕ КАКМЫЕК.** Гомергә дус булып яшәү теләге. *Агай-эне ак мыек, / Бер-беребезне какмаек; / Каккан-суккан арасында / Бер-беребезне яклаек* (Җыр).

Төрдәше: авызга-авыз сөйләшү һ.б.

**АГАЙ-ЭНЕ АК МЫЕК, ЧАБАТА БАШЫ КЫЕК** *к.* агай-эне – ак мыек 1, 2. – *Әй, агай-не – ак мыек, чабата башы кыек. Абый кеше, ике ара, син әйткәнчә, ун-унбиш метрлар гына булыр, бар* (А. Хәсәнов. Җәнбәт җәвере).

**АГАЙ-ЭНЕ ТАРТЫШЫ – ТУЙ БҮЛӘГЕ ЕРТЫШЫ.** Элегрәк туй вакытында бүләк итеп бирелгән тукыманы ерту йоласы булган. *Агай-эне тартышы – туй бүләге ертышы* (Мәкаль).

*АГАСЫ* ❖ **АГАСЫ СУЛАР АККАН, КИТӘСЕ КАЙГЫЛАР КИТКӘН.** Эшләгән эшкә (яки үткән вакыйгага) үкенүдән файда юк мәгънәсендә. *Агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән инде* (Н. Гыйматдинова. Күңел).

Төрдәше: аккан сулар кире кайтмау; аткан ук кире кайтмау; атын урлаткач, абзарын бикләү; бармак тешләү 2; башны ташка бәреп булмый 2; бер кискән икмәк кире ябышмау; буласы булган инде; буласы булган, туны тузган; буласы булды (булган), буявы сеңде (сеңгән); буласы эш (нәрсә) булган (булды), <буявы сеңгән (уңган)>; буласы эш (нәрсә) булган, өстенә кар яуган; булган эш (нәрсә) булган, <буявы сеңгән>; булган эш (нәрсә) булган, буявы уңган, базары торган; булган-беткән, өстенә мүк үскән; бүген үткәнгә иртәгәгә көрсенү; җилкә кашу 3; терсәк тешләү; терсәкне эзләү; узган эшкә салават; үгезе үлгән, уртагы аерылган; үлгәннән соң

тәүбә юк; үткән эшкә салават; үткән-беткән, өстенә үлән үскән; үткән-кочкан – җилгә очкан; үткәндәге – сүткән, өстенә үлән үскән; янгыннан соң буш көпшә белән селтәнү; янгыннан соң насос; янгыннан соң су эзләп чабу; янгыннан соң суның кирәге юк.

*АГАЧ* ❖ **АГАЧ АВЫЗ<ЛЫ>** *тирг.* 1. Тупас телле, рәтсез кеше. *Шәрәфи карт, аңар җавап бирмичә, сүзендә дәвам итеп: – Хәер, авылныкы булгач, сез аны белмисез, бик һәйбәт кеше иде, – Сафаны күрсәтеп, әнә шундый агач авызларга күп лыгырдарга бирмидер иде ул, чалт иттереп авызга куя да җибәрә <...>* (Ш. Камал. Акчарлаклар). – *Бар бит агач авызлы бүкәннәр!* (А. Гыйләҗев. Әтәч менгән читәнгә).

2. Матур итеп, төзек җөмләләр белән сөйли белмәгән кеше хакында. *Агач авыз, яхшылап сөйләшә дә белмисең* (Һ. Такташ).

3. Кирәкле сүзен дә әйтә алмый торган. – *Бигрәк агач авыз инде син, җизни. Беренче көннәрдә «баллы балдызым», «балдызымкарбызым» сүзләрен әйткәли идең, хәзер аларны да оныттың* (Ф. Яруллин).

Төрдәше: агач тел<ле> 1.

4. Аңгыра. *Әзерлексез чыккан без агач авызларга да чәй чираты җитте, теләгәнчә кинәндек* (А. Гыйләҗев. Язгы кәрваннар). *[Ситдыйк хәзрәт] Ахмак! Агач авыз! Бохараи шәриф хакында ни сөйлисең?* (Г. Исхакый. Кыямәт).

**АГАЧ АВЫЗЛАНУ.** Тупас сөйләшү. *Минем белән бер вахтада торучы сигналчы Прокофьев исә, бик белдекле кыяфәт белән, агач авызланып: «Берничди комиссар да, хәбәрче дә түгел, командующийның сөяркәсе ул», – диде* (С. Сабиров. Утлы фарватердан).

**АГАЧ АКЧА.** Кыйммәте, абруе булмаган (яисә ялган) акча. *Ә агач акча бәйләменең күләме вакыт узган саен зурая баргандай тоела* (Т. Галиуллин. Сәмруг кош). *Кызганыч, бу хакта уйлаучы юк, инде болай да халык арасында агач акча дип йөртелгән рублебез аз мәтәлгән, ахры* («Безнең гәҗит» газ.).

**АГАЧ АКЧАГА АЛУ.** 1. Ялган акчага яки бурычка алу. *Син хәзергә агач акчага алып тор, соңрак түләрсең* (Сөйләм).

2. Сум белән сатып алу. *Агач акчага сатып алырга уйлыйсыңмы? Сатмыйм, миңа чит ил акчасы кирәк* (Сөйләм).

**АГАЧ АРАСЫННАН (АРТЫНДА; АРТЫННАН) УРМАН КҮРМӘҮ** *ирон., шаярт.* Аңгыра кешегә карата әйтелә; вак-төяккә дикъкать итеп, зуррак, җитдирәк нәрсәләрне күрә алмау. *Боларга карап кына «Тирән тамырлар»ның уңышлы якларын томаларга тырышу – бу «агачлар артыннан урманны күрмәү» булыр иде* (Г. Ибраһимов).

Төрдәше: агач артындагыны күрмәү; агачны күреп <тә> урманны күрмәү; борын төбеннән ары күрмәү; вак бөҗәкне күреп тә, филне абайламау.

**АГАЧ АРТЫНДАГЫНЫ КҮРМӘҮ** *ирон., шаярт., к.* агач арасыннан (артында; артыннан) урман күрмәү. – *Син миңа иптәшкә агач артындагыны күрмәгән кешене тәкъдим итмә инде* (Сөйләм).

Төрдәше: агач арасыннан (артында; артыннан) урман күрмәү; агачны күреп <тә> урманны күрмәү.

**АГАЧ АТ.** Алдар өчен ясалган нәрсә. *Сөю шигыре – агач аттыр, «Вакыт»ча, / Зарар юк, ул сөйләр анчак вакытча* (Г. Тукай). *Утырабыз һаман хәер эстәп / Язмышларның агач атында* (Г. Морат. Тәүбә).

**АГАЧ АТ ӨСТЕНӘ АТЛАНДЫРУЧЫ.** Алдакчы кеше хакында. ... *Кайвакыт мәҗнүн кеби көлмәс вә шатланмас идем, / Син агач ат өстенә атландыручы булмасаң* (Г. Тукай).

**АГАЧ АТКА (АРГАМАККА) АТЛАНДЫРУ** *к.* авыздан кош очыру 1. *Күчерә-күчерә агач атка атландыруыгызны азсынып, әллә инде йолдызларга атландырмакчы буласыңмы?* (К. Тинчурин. Җилкәнсезләр). *Агач атка атландырмакчымы? – Бетте! Җитте сиңа – яначаксың!* (Зөлфәт. Җәза).

Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

**АГАЧ АТКА (АРГАМАККА) АТЛАНУ (АТЛАНЫП КАЛУ).** Алдану, өметләнеп көткәнгә ирешә алмау. *(Әзни җаниб) бу тарафта нишлиләр соң? / – Алданган һәм агач атларга атланган* (Г. Тукай. Бер гәзитә идарәсе хәленнән). *Шул вакытта иптәшлеккә алдылар да / Акыртынлап агач атка атландылар* (З. Бәшири).

Төрдәше: аттан иңеп җәяүгә калу; аттан кәҗәгә (тайга) калу; аттан таякка калу; аттан төшеп, ишәккә менү; аттан төшеп, тайга, тайдан төшеп, ишәккә атлану; бәрән йонын алдыру; бишкә

алып бергә сату; бозга атлану; бозга таяну; бозга утыру; булыр-булмаска ышанып, кулга төшкәннән аерылу; галошка утыру; кәкре каенга терәлү; кәкре каенны терәү; комга утыру; көймә комга терәлү 1; күктәге торнага ышанып, кулдагы кошны очыру; күрер күз күрмәс булу; сакал учлап калу.

**АГАЧ БАШМАК** *мыск.* Фикерсез, иярчен, туңбаш кешене хурлау сүзе. – *Җитәр инде сиңа агач башмак булып сөйрәлеп йөрергә, бераз күкрәгеңне киер* (Сөйләм).

Төрдәше: агач матрос 1.

**АГАЧ БАШЫ ТӘСБИХ ӘЙТҮ.** Агач башыннан искән җил белән яфракларның лепердәп чайкалып торуы. *Агач башкайлары тәсбих әйтә / Акрын гына искән җил белән* (Җыр).

**АГАЧ БАШЫНДА СУМСА, КАЙЧАН БАЛ БУЛЫП ТАМСА** *к.* абага чәчәк аткач (атканда). *Аптырама, агач башында сумса, кайчан бал булып тамса, бурычын да бирер* (Сөйләм).

Төрдәше: абага чәчәк аткач (атканда) һ.б.

**АГАЧ БАШЫНДА ҮСМИ** *мыск.* Кайбер нәрсәләрнең (мәс., икмәкнең) агач башында үсә дип уйлауларыннан көлеп әйтү. Димәк, һәрнәрсәне сатып алырга кирәк. *Тик, җанкисәкләрем, дөньяның бер почмагында да акча агач башында үсми икән* (Ф. Хөсни. Куркыныч йорт).

**АГАЧ БАШЫНДАГЫ КАРГА АВЫЗЫННАН КАЛҖА ТАРТЫП АЛУ.** Кеше өлешен еракткан торып тартып алырлык үткен кеше турында. *Әйтим, андый үткен кешеләр күп түгелдер, теләсә – агач башындагы карга авызыннан калҗасын тартып алыр* (Сөйләм).

**АГАЧ БАШЫННАН ЙӨРМИ, <КЕШЕ (АДӘМ) БАШЫННАН ЙӨРИ>.** «Бәлаләр һәм газаплар кешеләр өстенә төшә» мәгънәсендә. *Авыру агач башыннан йөрми...* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). – *Сәвит тартып алган йорт турында әйтәм инде, бүре авыз Мәрдәннәр турында. Агач башыннан йөрми ул, адәм башыннан йөри* (Г. Ахунов. Идел кызы).

**АГАЧ БҮКӘНЕ** *к.* авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү. *Сафринә белән йоклаган бәндә – агач бүкәне ул!* (Н. Гыйматдинова. Бер тамчы ярату).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**АГАЧ ҖАН<ЛЫ>.** Кешеләргә яхшылык итми торган, хиссез, мәрхәмәтсез; куркак. *Аппаратка кереп оялаган бюрократларны, коммунизмга сигездән дүрткә хәтле генә хезмәт итүче түрәләрне, агач җанлы төрле чиновникларны аппараттан «өфертергә» кирәген әйтте* (И. Гази. Канатланыр чак).

Төрдәше: агач йөрәк<ле>; агач күңел; таш йөрәк<ле>.

**АГАЧ – ҖИМЕШЕ БЕЛӘН, КЕШЕ – ЭШЕ БЕЛӘН.** «Эш, хезмәт кешегә яшәү чыганагын да бирә, хөрмәт тә китерә» мәгънәсендә. *«Агач – җимеше белән, кеше эше белән билгеле» дип, юкка гына әйтмиләрдер* («Биектау хәбәрләре» газ.).

Төрдәше: арка бөгү (бөгеп тору) һ.б.

**АГАЧ ИГӘҮ.** Фикерен тормышка ашыра алмаучы, бушка мыгырдаучы кеше турында. – *Иптәшеңә дә берәр эш биреп карыйк әле, агач игәү булмаса, үзебездә калдырырбыз* (Сөйләм).

Төрдәше: агач пәке.

**АГАЧ ЙӨРӘК<ЛЕ>** *к.* агач җан<лы>. *Хатынның бу кадәр дә агач йөрәкле булуыннан гаҗәп калган Фәрит ашык-пошык киенде дә эшкә китте* (И. Шиһапов. Дәва).

Төрдәше: агач җан<лы> һ.б.

**АГАЧ КОРТЫ.** Тынгысыз кеше, тиктормас. *Хуррәмнең агач корты шикелле көн-төн кимерүләренә түзеп тора алмады, Сөләйман солтан көннәрдән бер көнне фәрман яздырттырды* (В. Имамов. Сөләйман солтан).

**АГАЧ КУЛ.** Булдыксыз, эшкә яраксыз кеше. – *Ялап ал! Телең белән ялап ал! Агач кул, арбалы!* (Л. Ихсанова. Ил кызы).

Төрдәше: агач бүкәне; агач матрос; агач пәке; изрәгән арыш боламыгы; тасламаган утын яркасы; пешмәгән кеше; балта-пычак тимәгән; уңмаган утын тукмагы; урманда туган; утын кисәве; үтмәс балта белән юнган; чапмаган да юнмаган.

**АГАЧ КҮҢЕЛ** *к.* агач җан<лы>. *Таш бәгырь, агач күңел, тумас борын картайган йөрәк! Әле алай сайланып йөрсәң, түбә чәчләрең генә*

*коелып калмас...* (Ф. Шәфигуллин. Фисалия һәм профессор).

Төрдәше: агач җан<лы>; агач йөрәк<ле>; таш йөрәк<ле>.

**АГАЧ КҮРКЕ – ЯФРАК, АДӘМ КҮРКЕ – ЧҮПРӘК.** «Агач яфрагы белән, кеше киеме белән матур» мәгънәсендә. *Бозауны сатып, кәчтүм алып дөрес эшләдек, кеше арасында ким булырлык түгел, агач күрке – яфрак, адәм күрке – чүпрәк димәсләрне!* (Р. Хәбибуллина. Мулла килене).

Төрдәше: агач яфрак белән, адәм чүпрәк белән; тауның күрке таш белән, башның күрке чәч белән.

**АГАЧ МАТРОС.** 1. Үз башы белән хәрәкәт итмичә, кеше кушканча гына хәрәкәт итә белүче аңгыра, ахмак кеше. *Йөзендә аның борчылуын аңлаганлыгы чагылгандай булды, шул ук вакытта «Әй син, агач матрос, нишләп үз комбатың белән аңлаша алмыйсың!» дигән шелтә дә бар иде кебек* (Х. Камалов. Һәркемнең бер гомере бар).

Төрдәше: агач башмак.

2. Җеп белән тартып идарә ителә торган курчак белән чагыштыру. *Тик шул вакытта кайберәүләр, җырлаганда кымшанырга куркып, агач матростай катып торганда да, авыз гына селкенеп тора бит* («Яшел Үзән» газ.).

**АГАЧ МЫЛТЫК.** Корыга, файдасызга шапылдап йөрүче кеше турында. *[Сәйфулла] Әй, агач мылтык! Ишетмәсәң, колагың тык!* (Ф. Бурнаш. Яшь йөрәкләр).

**АГАЧ ПӘКЕ.** Сүзен җиткереп әйтә белмәүче, сүзе үтмәс кеше. – *Баш бар синдә <...> Агач пәке түгел син* (Ә. Хәсәнов. Әҗәт). – *Агач пәке инде ул, әйдә, икебез тегендә кереп сөйләшик әле* (Сөйләм).

Төрдәше: агач игәү.

**АГАЧ ПРУЖИНАГА ТИМЕР ДРУЖИНА.** Исеме җисеменә туры килмәү хакында (Гражданнар сугышы вакытында туган). *Исеме «тимер» үзе, әмма кораллары агач – агач пружинага тимер дружина инде* (Сөйләм).

**АГАЧ ТЕЛ<ЛЕ>.** 1. Тупас телле. *Агач телле авыл малае бит әле мин* (Ш. Маннур. Агымсуларга карап). *Әнисенең күңеле әллә шушы агач телле җансыз йөзле кешедәме?* (Г. Мөхәммәтшин. Хуҗалар).

2. Матур итеп сөйләшә алмый торган. – *И-и, агач тел! Сөекле Гыймалетдин бабамыз диген!..* (А. Хәлим). – *Миңа – агач телгә – гафу дияргә иде дә бит* (Н. Гыйматдинова. Сөйлим, тыңла...).

3. Бик нык дулкынланганда, төзек җөмләләр кора алмау. *Ләкин авыз эчендәге агач тел нәрсәдер әвәләде дә әвәләде, әллә җөмләләр, әллә авазлар...* (Н. Гыйматдинова. Нурулла).

Төрдәше: агач авыз<лы> 1, 2, 3.

**АГАЧ ЧЫБЫК ЧАКТА БӨГЕЛҮ.** «Кеше яшь чагында гына тәрбияләнеп, башкалар әйткәнне үзләштереп, үзен дә үзгәртә ала» мәгънәсендә. *Агач чыбык чакта бөгелә* (Мәкаль).

Төрдәше: агачны яшь чагында (яшьли; яшьтән) бөгү.

**АГАЧ ЯФРАК БЕЛӘН, АДӘМ ЧҮПРӘК БЕЛӘН** *к.* агач күрке – яфрак, адәм күрке – чүпрәк. *Агач яфрак белән, ә кеше кием белән гүзәл ди халык мәкале* (Туйлар.ру).

Төрдәше: агач күрке – яфрак, адәм күрке – чүпрәк; тауның күрке таш белән, башның күрке чәч белән.

*АГАЧНЫ* ❖ **АГАЧНЫ КҮРЕП <ТӘ> УРМАННЫ КҮРМӘҮ** *шаярт., ирон., к.* агач арасыннан (артында; артыннан) урманны күрмәү. *Агачны күреп тә урманны күрмәгән кеше белән танышасым килмәде минем* (Сөйләм).

Төрдәше: агач арасыннан (артында; артыннан) урман күрмәү; агач артындагыны күрмәү.

**АГАЧНЫ ЯШЬ ЧАГЫНДА (ЯШЬЛИ; ЯШЬТӘН) БӨГҮ** *к.* агач чыбык чакта бөгелү. *Ләкин агачны яшьтән бөкмәсәң, картайгач кыенга килә икән шул* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

Төрдәше: агач чыбык чакта бөгелү.

*АГАЧТАН* ❖ **АГАЧ<ТАН> САНДУГАЧ КЫНА ЯСАМАУ.** Башлаган теләсә нинди эшне башкарып чыга алучы, оста куллы, булган кеше турында. *Булдырмаганы юк, агачтан сандугач кына ясамый торгандыр* (Сөйләм).

Төрдәше: агачтан төен төю; агачтан төймә генә төймәү; алтын кул<лы>; балта белән төймә төю; баскан җирдә тимер сындыру; бармагыннан бал таму; баскан җирдән ут чыгару; баскан эздән су чыг<ар>у; без дә төшеп калганнардан түгел; без дә юкәдән тегелмәгән; буран уйнату 2; вак балыклар арасында йөзгән чабаклар түгел; җаны барның җиле булу; җилле булу;

җир астындагы еланны да белү; җир астыннан җиз инә табып ала торган кеше; җир өстеннән кереп, җир астыннан чыгу; җитезгә йөз өлеш, йомшакка бер өлеш; җитмәгән җире юк; көлдән төймә генә төймәү; кулда ут уйнату; кулдан гөл генә таммау; кулдан <эш> килү; кулдан ут чәчү; куллар ятып тору; кулы белән төймә генә коймау; кулы биш; кулы ут уйнату; кулы-кулга йокмау; кулына туфрак учласа, алтын итү; кулыннан килмәгән эш юк; кулыннан төймә генә коймау; күзе ачык кеше; күрекленең башы бүрекле; кылны кырыкка яру; май чүлмәге тышыннан билгеле; өстенә кояш чыгармау; судан шайтаныңны чыгару; таш астында көн күрү; таш астыннан чыгу 2; таш тишегеннән чыгу; таш яру 2; ташта борчак үстерү 2; тәне-башы үзе белән; төкерек төшкәнче эшен бетерү; төшеп калган<нардан> түгел; түбәңнән кереп, табаннан чыгу 2; ут борчасы; ут уйната торган кеше; ут уйнату 1; ут уйнатып (өереп; чыгарып) эшләү; ут чаткысы кебек; утка керсә чыгар төсле; утлы табага бастыра торган; утта янмау, суда батмау; уттан да чыгар; хәерче кесәсендәге шикәр кебек шомару; чакма ташымыни; югын бар итү, барын юк итү; яшен ташы.

**АГАЧТАН ТӨЕН ТӨЮ** *к.* агач<тан> сандугач кына ясамау. *Алтын куллы егет, агачтан төен төя дип, юкка гына әйтмиләр икән* (Сөйләм).
Төрдәше: агач<тан> сандугач кына ясамау һ.б.

**АГАЧТАН ТӨЙМӘ ГЕНӘ ТӨЙМӘҮ** *к.* агач<тан> сандугач кына ясамау. *Агачтан төймә генә төйми, диләр аның турында, кулыннан килмәгән эше юк, имеш* (Сөйләм).
Төрдәше: агач<тан> сандугач кына ясамау һ.б.

*АГАЧЫНА* ❖ **АГАЧЫНА КҮРӘ АЛМАСЫ, <КЕШЕСЕНӘ КҮРӘ КИЕМЕ>** *к.* авыздан өзелеп төшү 1. <…> *атның иргә канат булуы турында. Йә булмаса агачына күрә алмасы булу һәм алма агачыннан ерак төшми икәнлекләре турында мәкаль чыгару өчен Мәккәгә яки Тулага бару, кемнән дә булса хикмәт ишетеп кайтуның кирәге юк* (Н. Исәнбәт. Мәкальләребез турында).
Төрдәше: авыздан өзелеп төшү 1 һ.б.

*АГ<Ы>ЛЫЙ* ❖ **АГ<Ы>ЛЫЙ БЕЛӘН ТАГ<Ы>ЛЫЙ <ЙӨРҮ>** *ирон.* Бер-берсеннән аерылмыйча, һәрвакыт бергә, мөстәкыйль булып җитешә алмаган кешеләр. *Чыннан да, чишмәгә суга бару – бу Аглый белән Таглыйның яраткан шөгыльләреннән берсе* (М. Хуҗин. Көрәшче). *– Йә ярый! Кем кирәк иде, Агылый белән Тагылый! – дип кинәт җитдиләнде Марат* (Ф. Латыйфи. Ак-карага тимәскә).
Төрдәше: Аг<ы>лыйга Таг<ы>лый дип йөртү; Агылы белән Тагылы булу; Агылый белән Тагылый кебек; Агылыйга Тагылый; Алапай белән Шалапай; Әҗәк белән Күҗәк; Әкеле дә Күкеле; Әлмән белән Сәлмән; Әмәк белән Җәмәк (Шәмәк / Шөмәк) кебек; Әсәк белән Күсәк; бер-берсеннән калмас; Житәк белән Тотак; Исәмби белән Күсәмби; иш белән хуш; иш ише белән; Ишәй белән Кушай; Өрем белән Төрем булып яшәү; тигәнәк белән сырганак.

**АГ<Ы>ЛЫЙ БЕЛӘН ТАГ<Ы>ЛЫЙ ДИП ЙӨРТҮ** *ирон., к.* Аг<ы>лый белән Таг<ы>лый <йөрү>. *Минә шул Лотфый белән безне Аглый белән Таглый дип йөртәләр* (Н. Әхмәдиев).
Төрдәше: Аг<ы>лый белән Таг<ы>лый <йөрү> һ.б.

*АГУ* ❖ **АГУ БУЛЫП ТӨШҮ.** Әрнетү, зарарлы булып кабул ителү. *[Әсма] (күзене сөртә-сөртә, тунын киеп). Ашамыйм, агу булып төшмәсен!* (Г. Исхакый. Өч хатын белән тормыш). *Хатынның әшәке сүзләре Йосыфның кайнар канына агу булып төштеләр* (Г. Гыйльманов. Фәрештә).
Төрдәше: йөрәккә агу булып төшү; күңелгә агу булып төшү.

**АГУ ЙОТКАН.** Һәрвакыт зарар итәргә генә торган, зәһәр, явыз кеше турында. *Син дә шул диңгез ярында, агу йоткан көчек, телләрең сузган буласың, җитми, җитми, кил күчеп* (Г. Тукай).

**АГУ ТЕЛ<ЛЕ>.** Һәрвакыт рәнҗетеп сөйләү, явыз, зәһәр телле. *Яшертен генә берләшеп алган ыспай киемле, уклаудай төз сынлы, шома, «дөрес» агайлар агу телле, бил бирмәс («Бирмә биленне!.. Бирмә!..) Мөдәррисне әллә өнәп бетерәләр дисезме?* (Н. Гамбәр. Ерактан килгән – еракка китәр...).
Төрдәше: агу чәчкәсе; агулы тел; ай-һай телең, тел очында безең (чама белер идең); ала еланның авызын чагу; ачы тел<ле> (сүзле); ачы тел<ле>ләнү; әче тел<ле>ләнү; без телле; билчән тел; бритва тел; очлы телле; тел очында безең; теле кылычтан үткен; теле табан астын тазарта; теле табанына җиткән; теле тоздан

да әче; теле туң җирне тишәрлек; төртмәр тел<ле>; төртмәле телле; үткен күзле, арыслан тырнаклы; үткен (үткер) тел<ле>; шук тел<ле>.

**АГУ ЧӘЧКӘСЕ** *к.* агу тел<ле>. *Күзенең агы белән каш астыннан гына карап ала да китереп чага, гүя агу чәчкәсе. Ничек сүзләрен табып бетерә?* (М. Әмирханов. Үрбәт ханәкә гыйшкы).

Төрдәше: агу тел<ле>; агулы тел; ай-һай телең, тел очында безең (чама белер идең); ала еланның авызын чагу; ачы тел<ле> (сүзле); без телле; бритва тел; очлы телле; тел очында безең; теле кылычтан үткен; теле табан астын тазарта; теле табанына җиткән; теле тоздан да әче; теле туң җирне тишәрлек; төртмәр тел<ле>; төртмәле телле; үткен (үткер) тел<ле>; шук тел<ле>.

**АГУ ЧӘЧҮ.** 1. Мәкерлек эшләү. *Онытмыйсың, ләкин әле һаман / Елан сыман ыслый теләгең. / Кешелеккә агу чәчмәк була / Явыз канлы усал йөрәгең* (В. Галиев. Бәхет таңым).

2. Зәһәр сүзләр белән сүгү. *Тегесе исә, бары тик чарасыздан гына әйтергә мәҗбүр булган кеше сыман, зәһәрләнеп агу чәчә башлады...* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!..).

*АГУЛЫ* ❖ **АГУЛЫ ЕЛАН**. 1. Исерткеч эчемлек, аракы. *Эчмәсен. Күпме яшь егетләр бозыла шушы «агулы елан»нан!* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

Төрдәше: агулы су; ак баш; ак су; ак ябалак сөте; аккош сөте; арыслан сөте; арыш мае; ачы су; әбелхаят чишмәсе (суы) 2; Әбүҗәһил куасы (квасы); әче су; батырлык даруы; Бөгелмә килене; елан агуы; иблис сидеге; иблис суы; иблис төкереге; иблис ширбәте; казна суы; кара сыер сөте; котырган сыер сөте; күз яше; лачын сөте; мактанчыклар чәе; пыяла самавыр; пыяла чикмән; рус әчесе; тел ачтырттыргыч; утлы су; үгез каны; хәерче малае; Чистай малае; чуваш малае, шайтан ачыткысы; шайтан зәмзәме; шайтан малайлары; шайтан селәгәе; шайтан сидеге; шайтан сөте; шайтан суы; шайтан төкереге; ябалак шурпасы; яшел елан.

2. Эчкерле, явыз уйлы, мәкерле кеше турында. *Әйе, иң агулы елан син!* (Ә. Баянов. Аязучан болытлы һава).

**АГУЛЫ СУ** *к.* агулы елан 1. *Белсә дип, Фатыйманы томмас иде, / Көн саен агулы су йотмас иде* (Г. Тукай).

Төрдәше: агулы елан 1 һ.б.

**АГУЛЫ СҮЗ.** Зәһәр, кешегә рухи газап китерә торган сүз. *Яңгырбай белән Арысланбай ярым көлкеле, ләкин агулы сүз белән чәнчешеп тә алдылар* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).

**АГУЛЫ ТЕЛ.** Даими рәвештә әшәкелек сөйли торган явыз кеше хакында. *Агулы тел чакса, / Шөпшә чага, тешли кигәвеннәр, / Җәфалана адәм баласы* (И. Гыйләҗев. Агулы тел чакса).

Төрдәше: агу тел<ле> һ.б.

**АГУЛЫ УК ОЧЫРУ.** Ачулы караш ташлау. – *Туташ, – дип төзәтте Сәрия һәм Фәрдәнә тарафына агулы ук очырды* (Н. Гыйматдинова).

*АГЫ* ❖ **АГЫ АП-АК, КАРАСЫ КАП-КАРА.** Кызларны мактаганда, тәненең аклыгын, чәче-кашының каралыгын сыйфатлау. *Күрше кызы күзнең явын алырдай чибәр: агы ап-ак, карасы кап-кара иде* (Сөйләм).

**АГЫ ДА, КАРАСЫ ДА КҮЗГӘ КҮРЕНМӘҮ (КҮРЕНЕРЛЕК БУЛМАУ).** *Шул бала рәтләнмичә, тормышның агы да, карасы да күзгә күренерлек булмады* (Л. Хәмидуллин. Кичке шәфәкъ).

*АГЫЗМАГАН* ❖ **АГЫЗМАГАН БАЛ.** Кул тимәгән, гыйффәтле кыз яки самими, саф кеше турында. *Алсае җаный, алсае, / Агызмаган баллар булсае, /Хәләл малларыңны биреп, / Кул тимәгән ярлар булсае* (Жыр).

*АГЫЙДЕЛНЕҢ* ❖ **АГЫЙДЕЛНЕҢ АРЪЯГЫНДА БЕР (ИКЕ) ИНӘГӘ (ЭНӘГӘ) БЕР СЫЕР** *к.* авыз чайкау 1. *Имеш, анда җирнең дисәтинәсен бер такта чәйгә сатып алып була... Сафуш көрсенеп куйды: – Агыйделнең аръягында бер инәгә бер сыер, барып карасаң, берни дә юк, ди, беләсеңме?* (Ә. Фәйзи. Тукай). – *Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер!* (Р. Хәбибуллина. Зәйтүн илендә).

Төрдәше: авыз чайкау 1 һ.б.

**АГЫЙДЕЛНЕҢ АРЪЯГЫНДА БЕР ЭНӘГӘ БЕР ДӨЯ, <АНСАТ ИКӘН ДӨНЬЯ>** *к.* авыз чайкау 1. – *Агыйделнең аръягында бер энәгә – бер дөя, ансат икән дөнья, – дип сөйләнде-сөйләнде дә Гөлтуташ, әле кышын ук яшереп куйган ике пар йон оекбашын алып, юлга кузгалырга карар итте* (В. Имамов. Тозлы яра). *Агыйделнең аръягында бер энәгә*

*бер дөя дип, Мәскәү кадәр Мәскәүгә товарга киттем берчакны* (Р. Шәрипова. Бүләккә энәме, дөяме?).
Төрдәше: авыз чайкау 1 һ.б.

**АГЫЙДЕЛНЕҢ АРЪЯГЫНДА КАЗ БӘБКӘСЕ КУНАКЛЫЙ** *к.* авыз чайкау 1. *Бераздан инеш буендагы тал астына ясаган эскәмиядән Фәридун абзыйның таныш тавышы яңгырый: Агыйделнең аръягында каз бәбкәсе кунаклый...* (В. Юныс. Шайтан бар ул, бар!..).
Төрдәше: авыз чайкау 1 һ.б.

*АГЫ-КАРАСЫ* ❖ **АГЫ-КАРАСЫ <КҮЗГӘ> КҮРЕНМӘҮ.** Ашыкканлыктан яки рухи халәткә бәйле рәвештә бернәрсәне дә аермау, игътибар итмәү. *Гыймай – булган егет, атларын йөгертеп кенә йөри, күзенә агы-карасы күренми, акчадан башкага күңеле төшми* (Ф. Яхин. Бар бер авыл, Чокал, диләр...).
Төрдәше: ак-кара <күзгә> күренмәү 1; ак<ны>-караны аермастан (аермыйча; күрмичә); ак-караны белмичә; ак-караны күрмәү (шәйләмәү); арт ягына ут капкандай чабу; артка ут капкан кебек; артына да карамау; артына нашатыр кыстыру; артына ут капкан кебек; артына ут якканнармыни; әвененә ут капканмыни; кая басарга (басарын) белмәү; кече морҗасына ут капкандай кабалану; көтүче хатыны кич киенә; күзгә ак-кара күренмәү 2; күңел талпыну; ут алган кебек; ут капкан кебек йөрү; ут капкан кебек кылану; ут капкандай 1; утка баскан песи кебек йөрү; уттан качкан кебек качу; эт, койрыгына су тигәч, йөзү.

*АГЫЛЫ* ❖ **АГЫЛЫ БЕЛӘН ТАГЫЛЫ БУЛУ** *к.* Аг<ы>лый белән Таг<ы>лый <йөрү>. *Агылы белән Тагылы булып күзгә ташланып йөрмәскә тырышу* (Ф. Хөсни).
Төрдәше: Аг<ы>лый белән Таг<ы>лый <йөрү> һ.б.

*АГЫЛЫЙ* ❖ **АГЫЛЫЙ БЕЛӘН ТАГЫЛЫЙ КЕБЕК** *к.* Аг<ы>лый белән Таг<ы>лый <йөрү>. *Үстек шулай, Агылый белән Тагылый кебек* (М. Хуҗин. Кулъяулык). – *Рәсимә исемле бер кыз белән йөриләр икән... Агылый белән Тагылый кебекләр, ди* (Ф. Латыйфи. Ак-карага тимәскә).
Төрдәше: Аг<ы>лый белән Таг<ы>лый <йөрү> һ.б.

*АГЫЛЫЙГА* ❖ **АГЫЛЫЙГА ТАГЫЛЫЙ.** Теләсә кемгә иярүче турында. – *Агылыйга тагылый шикелле гел бергә йөри идек* (Ф. Имамов. Кемгә өйләним?).
Төрдәше: Аг<ы>лый белән Таг<ы>лый <йөрү> һ.б.

*АГЫМ* ❖ **АГЫМ АСТЫНА АГУ (БАРУ; ЙӨЗҮ).** 1. Тормыш барышына буйсынып яшәү, пассив рәвештә эшләү, яшәү. *[Салих] Агым астына ул үзе дә бара* (Г. Исхакый. Җәмгыять). *Киләчәк турында бик уйлана дип әйтмәс идем, агым астына ага да ага иде ул* (Сөйләм).

2. Үз фикерең булмау. *Җирле комитет рәисенең чыгышы да аерылып тормады, ул да агым астына йөзде* (Сөйләм).
Төрдәше: агым уңаена (җаена) агу (бару; йөзү); агымга ияру; агымга ятып йөзү.

**АГЫМ СУ КЕБЕК.** Бик тиз узып китүчән. *Еллар агым су кебек акты да акты* («Мәйдан» ж.).
Төрдәше: аккан су кебек; аткан ук кебек; атылган ук кебек 1.

**АГЫМ УҢАЕНА (ҖАЕНА) АГУ (БАРУ; ЙӨЗҮ).** Шартларга ярашып-буйсынып эшләргә, яшәргә һ.б. *Ләкин ул бер нәрсәне бик яхшы белеп тора: яшәр өчен, тормышны үзең теләгәнчәрәк корыр өчен, һичшиксез, агым уңаена агарга кирәк, заманага аркылы килүдән сакланырга кирәк, һәрвакытта уяу, тыйнак, мыштым булырга кирәк* (Ә. Еники. Рәшә).
Төрдәше: агым астына агу (бару; йөзү) һ.б.

*АГЫМГА* ❖ **АГЫМГА ИЯРҮ.** Күпчелеккә иярү, башкалар ни эшләсә, шуны эшләү; заманча кылану. – *Шиклерәк агымга ияреп китте әле ул...* (Ф. Садриев. Ялгышны төзәтү).
Төрдәше: агым астына агу (бару; йөзү) һ.б.

**АГЫМГА КАРШЫ АГУ (БАРУ; ЙӨЗҮ; ЧЫГУ).** 1. Каршылыклар белән көрәшеп, тормышта үз юлыңны салу. *Аларда язмышның бу агымына каршы барырлык куәт юк* (Г. Ибраһимов). *Әгәр Таһир абыйның агымга каршы йөзеп, хаклык өчен көрәшүен, үзенең дөреслеген дөрес итеп танытуын күрмәсәм, мин дә, бәлки, үз дөньямда бикләнеп яшәр идем* (Н. Гыйматдинова. Ханым-солтаным).

2. Тискәреләнеп, бер нәрсәгә каршы бару. *Кода, син агымга каршы йөзәсең түгелме?* (Р. Төхфәтуллин).

**АГЫМГА ЯТЫП ЙӨЗҮ.** Тормыш җаена буйсынып, пассив рәвештә эшләү, яшәү. *Безнең*

*тормыш барышына буйсынганыбыз менә шушы агымга ятып йөзү белән бер инде* («Казан утлары» ж.).

Төрдәше: агым астына агу (бару; йөзү) һ.б.

*АГЫМЫНА* ❖ **<ҮЗ> АГЫМЫНА КАЙТУ (ТӨШҮ).** Эшләр элеккечә тәртип белән бару, җайга салыну. *Эшләр рәтләнде, яңадан үз агымына кайтты* (С. Баттал).

*АГЫН* ❖ **АГЫН ӘЙТКӘЧ, КҮГЕН ДӘ ӘЙТҮ** *к.* «а» дигәч, «б»ны әйтү. – *[Кифая] Оныкларыңны да исеңә төшер бер рәттән! Агын әйткәч, күген дә әйт. Берсен дә онытып калдырма!* (Р. Хәмид. Актамырлар иле).

Төрдәше: «а» дигәч, «б»ны әйтү һ.б.

*АГЫНА* ❖ **АГЫНА ДА, КҮГЕНӘ ДӘ ЯРАУ.** Бөтен кешегә дә ярый торган «җайлы» кеше хакында. *Түрәләр арасында кайнашып, агына да, күгенә дә ярап, кешелеккә өйрәнеп беткән, чукынчык* (Ф. Яхин. Ак Ай буендагы кич).

*АГЫП* ❖ **АГЫП КИТӘРСЕҢ ИНДЕ (СЫМАН).** 1. Чәйне бик күп эчкән кешегә карата әйтелә. – *Икенче самавырга тотындың түгелме, агып китәрсең әле* (Сөйләм).

2. Күп елаган кеше хакында. *Мөлдерәмә күз яшьләрең, сөеклем, / Чишмә булып агып китәрсең сыман* (Х. Гайнетдинов. И күңелле, рәхәт иде).

*АГЯҺ* ❖ **АГЯҺ БУЛУ.** (агяһ < фарс.: белеп торучы). Хәбәрдар, сак, игътибарлы булу, *Күрегез, бу сезгә сабак булсын, сезне дә алда шул көннәр көтә, агяһ булыгыз!» – дигәндәй, яшьле күзләре белән аларга тилмереп карап торды <...>* (К. Тинчурин. Кара көннәрдә).

**АГЯҺ ИТЕП КУЮ** *кит., иск.* Алдан кисәтеп, искәртеп кую. – *Бар, агяһ итеп куй, без килгәнне көтсеннәр* (Сөйләм).

*«А»ДАН* ❖ **«А»ДАН «Я»ГА КАДӘР ҮТӘРГӘ.** Баштан ахыргача карап чыгарга, тикшерергә. *Үттек юлны «а»дан «я»га кадәр, / Канатлана күңел, шатлана* (М. Каюмов).

*АДАШКАН* ❖ **АДАШКАН ПУЛЯ (ЯРЧЫК).** Очраклы рәвештә эләккән ярчык; төзәп атылмаган пуля. – *Алай батырлансаң, сине адашкан пуля да юк итәр...* (Б. Камалов. Кала бизгәге).

*АДӘМ* ❖ **АДӘМ АВЫРУЫ БУЛУ** *к.* авыр аяк<лы> 3. *Күрше хатынында инде өченче мәртәбә адәм авыруы булган* (Сөйләм).

Төрдәше: авыр аяк<лы> 3 һ.б.

**АДӘМ АЖДАҺАСЫ.** Үтә явыз, зәһәр кешегә карата. *Ә озакламый дөньяга коточкыч афәт килде, адәм аждаһасы кешеләр өстенә ыжгырып ябырылды, яшьләрнең баллы-ширбәтле көннәре дип тормады* (Ә. Хәсәнов. Сабыр төбе сары сагыш).

**АДӘМ АКТЫГЫ** *хур.* Кешене кимсетү сүзе (бик әшәке кеше). *[Бәдигыйльҗамал] Аларның җибер шикелле бер-бер артлы тупырдаган адәм актыгы кызларына кияү чыксын да, аның бердәнбер алма шикелле газиз баласына кияү чыкмасын, имеш* (Г. Камал. Кайниш). – *Синең аркада әнә составны тотып торам, адәм актыгы!* (И. Салахов. Ана тавышы).

Төрдәше: адәм аламасы; адәм җәфасы; адәм имгәге; адәм калдыгы; адәм кисәге 2; адәм көеге; адәм көлкесе; адәм күсәге; адәм мәсхәрәсе; адәм мәсхәре; адәм рисвае; адәм тәганәсе; адәм тилчәсе; адәм үләксәсе 1; кеше көлкесе; соңгы адәм актыгы.

**АДӘМ АКТЫГЫНА (АХЫРЫНА) КАЛУ.** Барыннан да артта калу; иң ахырга калу. *Уйлады бугай шул чагында ук: «Күзләре бик ут яна бу зимагор татарның, эшләре тирәнгә киткәндер, поп башың белән соңыннан адәм актыгына калуың бар», дип пичәт сугып куйды бугай* (Ф. Хөсни. Поп кызы Әхсәнә).

**АДӘМ АКТЫГЫНА КАЛДЫРУ.** Хурлыклы хәлгә төшерү. *Кем дә кем төп кода белән кодагыйны адәм актыгына калдыра?* (Н. Яһудин. Казаклар).

Төрдәше: хур итү.

**АДӘМ АКЫЛЛЫ.** 1. Аңлы, кешеләрчә уй-фикер йөртә белгән (күпчелектә хайваннарга карата). *Фатыйма карчык песиен ничек кенә өйгә якын китермәскә тырышмасын, адәм акыллы Актүшне тыярлык түгел иде* (М. Кәбиров. Бердәнбер һәм кабатланмас).

2. Аңлаешлы, кеше аңларлык. *«Адәм акыллы» программа шундый фикергә килгән: фотода – мин* («Безнең гәҗит» газ.).

3. Кеше көлдермәслек. *[Габсаттар] Шундый малайга бармаса, юньлерәк, адәм акыл-*

*лырак кеше төслерәк кеше беткән иде микәнни?* (Г. Камал. Көндәш).

Төрдәше: акылга муафыйк.

**АДӘМ АЛАМАСЫ.** 1. Чүп кеше, сатлыкҗан. *Әйе, үскәндә әнә шулай олы хыяллар белән янып йөрисең дә, шул хыяллар тәмам чынга аша дигәндә генә, нindiдер бер адәм аламасы һәммәсен дә чәлпәрәмә китерә* (Ф. Зыятдин. Көн вә өн).

Төрдәше: адәм актыгы һ.б.

2. Йолкыш. *Чабаталы аягын сый-нигъмәт тулы мәҗлес өстәленә куйган адәм аламасы белән бер үк чамадалар, коточкыч хәл!* («Мәдәни җомга» газ.).

**АДӘМ АХЫРЫ.** Кешеләрнең эштә иң ахырга калып йөри торганы. *И адәм ахыры! Син дә сөйләшкән буласың тагын* (Г. Камал).

**АДӘМ АЯГЫ БАСМАГАН.** Моңа кадәр бер кеше дә булмаган җир. *Монда адәм аягы басмаган, сукмак салынмаган тирән кардан башка нәрсә юк иде* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).

**АДӘМ АЯКЛАНМАСЛЫК.** Кеше йөри алмаслык. *Урамда адәм аякланмаслык пычрак* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

**АДӘМ ӘЙТЕП, АДӘМ БЕТЕРМӘС (БЕТЕРӘ АЛМАСТАЙ).** Кеше теле белән әйтеп бетерә алмаслык дәрәҗәдә. *Ул өшәнчеге, бирнәсе дисәң, адәм әйтеп, адәм бетермәс, әйтәм бит, өеңә сыймас* (Г. Ибраһимов. Табигать балалары).

**АДӘМ ӘЙТЕП, АДӘМ ЫШАНМАС.** Бөтенләй булмастай эш яки хәл турында, кеше ышанмаслык. *Адәм әйтеп, адәм ышанмас бит, сары майның кадагы сигез сум илле тиен, ди, шикәрне әйтмә дә инде* (Г. Камал). *Адәм әйтеп адәм ышанмас, хәтта кайбер агач башларында инженерлар да үсә!* (Б. Ислам. Балачак хатирәләре).

Төрдәше: адәм әйтеп ышанмаслык.

**АДӘМ ӘЙТЕП БЕТЕРГЕСЕЗ.** Бик күп, исәпсез-хисапсыз. *Монда һәр ел адәм әйтеп бетергесез җиләк була* (Г. Ибраһимов).

**АДӘМ ӘЙТЕП ЫШАНМАСЛЫК.** 1. Гаҗәп, искиткеч. *Ә адәм әйтеп ышанмаслык берсен язарга көчем җитмәде, күрәсең* (М. Хуҗин. Чеметемнән табышларга...). *Адәм әйтеп ышанмаслык хәл: Саба эченнән үзәк шифаханәгә төшәргә юл юк* (Т. Нәҗмиев. Сабаларда эчәр суым булгач...).

2. Ялган икәнлеге ап-ачык. – *Адәм әйтеп ышанмаслык буш хыял бит бу! – диде ул. – Иң элек японнарның мөселман булу ихтималлары юк* (М. Мәһдиев. Буш кыңгырау).

Төрдәше: адәм ышанмаслык. Ике маддә өчен дә.

**АДӘМ ӘҮЛИЯСЕ КЕШЕ.** Бөтен яктан да үрнәк булырдай. – *Шундаен адәм әүлиясе кеше иде ул – беркайчан да бер үпкә белдермәде, беркайчан бер ачулы, кочел сүз әйтмәде* (Н. Фәттах. Мәдинә).

**АДӘМ БАККЫСЫЗ.** Кеше күзенә күренергә оят хәлдә. *Өйгә адәм баккысыз булып балчыкка буялган хәлдә сыңар итектән кайтып керде* (Г. Ахунов).

Төрдәше: адәм карагысыз.

**АДӘМ БАЛАСЫ (УГЛЫ).** Кеше заты; ата-анасы бар. *Ләкин адәм баласы, мәгълүм булганча, барысына да күнегә, һәм мин дә, билгеле, әкренләп күнектем* (Ә. Еники. Без дә солдатлар идек). *Адәм баласының җайлашмый, иярләшми торган нәрсәсе юктыр, ахрысы* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).

Төрдәше: адәм зат<ы>; адәм токымы; адәми зат; ата баласы.

**АДӘМ БАШ ТЫККЫСЫЗ.** Кеше бик күп булган җир. – *О-о-о, монда адәм баш тыккысыз икән!* (Сөйләм).

Төрдәше: алма төшәр<лек> урын булмау (юк); аяк басар (атлар) урын (җир) юк (калмау); аяк басар<лык> урын да юк; аяк баскан<ым> юк; аяк баскысыз; аяк тыккысыз; әйләнер урын да юк; бармак төртер урын юк; баш төртергә дә урын юк; баш тыгар урын юк; баш тыгар хәл дә юк; баш тыгарлык түгел; баш тыккысыз (тыга алмаслык) 1; борын төртер<гә> (төртерлек) дә урын булмау; борын тыгар урын юк; бүрек төшәр урын юк; Духонин штабына җибәрү; инә төртерлек (төртер<гә> дә; төшәр) урын (җир) юк (булмау; калмау); инә чәнчерлек тә урын калмау; кара чәүкә кебек; кара чебен шикелле; корт кебек сорып алу; тыгыз җиргә тыгынчык; тыгын җиргә тана башы; шыгрым тулы; энә төртер җир (урын) калмау (юк); энә төшәр<лек> урын булмау (юк).

**АДӘМ БАШКАЙЛАРЫН САЛУ.** Кеше үтерү. *Адәм башкайларын монда күп салдылар – шәһәр әйләнәсендәге ачык кырда безнекеләрнең үлек гәүдәләре сибелеп ята, ә шәһәрнең эчетышы немец үлекләре белән тулы...* (Ә. Еники. Без дә солдатлар идек).

Төрдәше: айкап чыгу 4; ахирәт күлмәген кигезү; әбиен таныту; әбиеңнең әбиләренә олактыру; әбисенең әбиләре янына олактыру; баш очу; башка җитү 3; башны ашау; башны башка, аякны аякка (ботны ботка) ботарлау 2; башын бетерү; башны җию; башны җую; башны култык астына кыстыру; гомерне изү; гомерне кисү; гомерне кыйдыру; гомерне кыю; гомерне очлау 1; гомерне өзү; гомерне чикләү; гыжылдавыгын өзү; гылдавын өзү; җанны алу 1; җан<ны> кыю; кеше башына җитү; кеше җаны кыю; муенын астына китерү; муенын бору (борып ыргыту) 2; муенын сындыру; теге дөньяга озату (җибәрү).

**АДӘМ БАШЛЫ БУЛУ.** Акыллы, аңлы булу. *Балык башлы булырсың да булырсың. Адәм башлы булырга гына читенрәк* (Ф. Бурнаш).

**АДӘМ БАШЫ.** Гомумән кеше. *Бәла агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри* (Мәкаль). *Адәм башы ниләр күрми, ниләргә күнекми!* (Г. Ибраһимов. Табигать балалары).

**АДӘМ БЕЛӘН АДӘМ БУЛУ.** Кешелекле булу. *– Ташла ул тырт-мырт сөйләшүеңне – адәм белән адәм булырга кирәк* (Сөйләм).

Төрдәше: кеше белән кеше булу.

**АДӘМ БЕЛМӘГӘН, <АДӘМ ИШЕТМӘГӘН>.** Кеше өчен ят авазлар, хәлләр турында. *Очсыз-төпсез сәхрә шикелле үзенең тирә-ягы адәм белмәгән, адәм ишетмәгән куркыныч тавышлар илән тулган* (Г. Коләхмәтов).

**АДӘМ БУЛДЫ ДИГӘНДӘ ГЕНӘ <ӘРӘМ БУЛУ>.** Үсеп, белем алып, тормышка аяк басканда гына үлү яки бәлагә очрау. *Адәм булды дигәндә әрәм булды* (Р. Абдуллина. Сөйләм культурасы).

**АДӘМ БУЛУ.** 1. Кеше булу, кешелекле булу. *Узган килүемдә үк сезнең укымышлы адәм булуыгызны күреп киттем* (А. Хәсәнов. Данәгөл). *Иманлы адәм буларак, син мине тәрбияләргә генә тиеш* (З. Мәхмүди. Елак агач).

2. Каты авырудан савыгу. *Адәм булам гына дигәндә, грипп аяктан екты* (Сөйләм).

3. Тормыш итәрлек кеше булу. – *Адәм булып буйга җиткәч кенә нигә йөзгә төкерә ул?* (В. Имамов. Нәзер). *Адәм булдым дигәндә генә әрәм булырсың* (И. Гази).

4. Кеше булып танылу. *Өмәләрдә, кайбер кунак-төшем чорларында бер-икене кагып аласың икән – анысы инде адәм булган һәркемдә булды* (Г. Ибраһимов. Табигать балалары).

**АДӘМ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КИЕМЕНДӘ.** Шәрә хәлдә, ялангач. *Иртән күл янына барсам, берәү адәм галәйһиссәлам киемендә су коенып ята иде* (Сөйләм).

Төрдәше: Адәм рәвешендә (рәвешле) булу; анадан тума.

**АДӘМ ГАРИБЕ.** 1. Бичара кеше, эшкә яраксыз; ялгыз баш, йорт-җирсез. *Айдан артык нәрсә юк, / Кара болыт басмаса, / Адәм гарибе шул булыр, / Кайтып илен тапмаса* (М. Җәлил).

2. Имгәнгән кеше, гарип. *Адәм гарибе дип тормый, спорт белән дә шөгыльләнә* (Сөйләм).

**АДӘМ ДИҢГЕЗЕ.** Зур төркем булып бер урынга җыйналган халык. *Клубның эченә кергәч, хәзрәтнең башы әйләнеп китте: кеше чамасыз күп, хатын-кызлар «фәрештәләнгәннәр», һәркемнең йөзендә шатлык һәм матурлык, адәм диңгезе бер бүлмәдән бер бүлмәгә агылып тора иде* (Ф. Әмирхан. Фәтхулла хәзрәт).

Төрдәше: кара чәүкә кебек; кара чебен шикелле.

**АДӘМ ДИСӘҢ – КОНЫ (СЫНЫ; ЮНЕ) ЮК, ХАЙВАН ДИСӘҢ – ЙОНЫ ЮК.** Кирәксез, файдасыз кеше турында. *Кем җибәргән бу егетне безнең бүлеккә? Адәм дисәң, коны юк, хайван дисәң – йоны юк* (Сөйләм).

Төрдәше: аңардан сөт тә юк, йон да юк; ит тә юк, сөт тә юк; йон да юк, сөт (ит) тә юк; ни он, ни йон; ни он, ни камыр; ни он суы, ни тоз суы; ни ултара (ылтара), ни пултара (пылтара); он да <юк>, йон (җон; сөт) да юк; он да <юк>, тоз да юк; он суы да, тоз суы да юк; хайван дисәң – йоны юк, адәм дисәң – коны юк; эт дисәң – койрыгы юк, сыер дисәң – мөгезе юк.

**АДӘМ ҖАНЫН КЫЮЧЫ.** Кеше үтерүче. *Кемдер, көмеш дага сакаллы, йомшак кара кәләпүш кигән берәү, бармагын төртә-төртә, аңа гел бер сүз сөйләде: «Укып кем буласың инде син?*

*Адәм җанын кыючы палач буласыңмы?»* – *дип сорады...* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**АДӘМ ҖӘФАСЫ.** 1. Имгәк булып ятучы, чирле кеше. *Аягына баса алмас инде бу мескен, адәм җәфасы булып кына ята* (Сөйләм).

2. Азып-тузып беткән, әшәке телле кеше турында. *Паркта кеше күп иде: монда ачык йөзле, мөлаем кешеләр дә, адәм җәфалары да бар* (Сөйләм).

Төрдәше: адәм имгәге.

**АДӘМ ЗАТ<Ы>** *к.* адәм баласы (углы). *Тауныташны җил бозар, адәм затны сүз бозар* (Мәкаль). *Җитмәсә, ялан җир, үкереп еласаң да адәм заты юк* (А. Тимергалин. Таш алиһә).

Төрдәше: адәм баласы (углы); адәм токымы; адәми зат; ата баласы.

**АДӘМ ИМГӘГЕ.** *мыск.* 1. Булдыксыз кеше, башкаларга йөк, хәсрәт булып ятучы урын сырхавы. – *И адәм имгәкләре! – ди бу. Бигрәк тә уңмаган нәрсәләр икәнсез!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). – *Тегесе тагын кайда йөри, адәм имгәге?* (Ф. Бурнаш).

Төрдәше: адәм җәфасы 1.

2. Аңгыра, тиле-миле. *[Вәли] Әнә шул, бар ич әле, адәм имгәге Биби, шуңа сүз аңлата алмыйча аптырап беттем* (Г. Камал. Беренче театр).

Төрдәше: адәм актыгы һ.б.

**АДӘМ ИСЕН ЧЫГАРУ** *эвф.* Җил җибәрү, арт яктан һава чыгару. – *Түзәр хәлем калмады, бераз адәм исен чыгарасы булыр* (Сөйләм).

**АДӘМ <ИТЕН> ЧӘЙНӘҮ** *к.* авыз чайкау 1. *[Себер бае] Ә адәм итен чәйнәү, көн буе гайбәт сатып утыру – анысы хәрам түгел* (Г. Камал. Безнең шәһәрнең серләре).

Төрдәше: авыз чайкау 1 һ.б.

**АДӘМ ИТҮ.** Кеше арасына керерлек дәрәҗәгә үстерү, тәрбияләү. *Яхшы гадәт адәм итәр, яман гадәт әрәм итәр* (Мәкаль). *Безне адәм иткән – уку, / Адәмне алга илткән – уку* (С. Рәмиев).

**АДӘМ ЙӨЗЕНӘ (КҮЗЕНӘ) ЧЫГАРЛЫГЫН (КҮРЕНЕРЛЕГЕН) КАЛДЫРМАУ** 1. Кем булса да мыскыллап көлү; хурлыклы хәлдә калу. *Ул: – Адәм йөзенә чыгарлыгымны калдырмады бит! – дип сүгенде* (Г. Камал). – *Ир булып йөрүең корсын, мескенкәем! дип, җегетнең адәм күзенә күренерлеген калдырмадылар* (Г. Ибраһимов).

Төрдәше: адәм көлкесе итү; адәм көлкесенә калдыру; адәм мәсхәрәсе итү (ясау); адәм мәсхәрәсенә калдыру; адәм рисвае итү; адәм хурлыгы итү; адәм хурлыгына төшерү; адәм хуры итү (ясау); биткә кара ягу; биткә корым ягу; биткә кызыллык (оят<лык>) китерү; биткә төкерү; биткә ут (ялкын) кабу; битне кызарту; галәм рисвае (хуры) итү; дөнья мәсхәрәсе итү (ясау); йөз каралту; йөз карасын китерү; йөзгә кара ягу; йөзгә корым ягу; йөзгә кызыллык китерү; йөзгә пычрак ату; йөзне кара итү (кылу); йөзне кызарту; коры җирдә суга батыру; көлкегә калдыру; күзләреңне бәйлә дә кая; оятка калдыру; оятлы итү. оятлылыкка калдыру; рисвай итү; хур итү; хурлыкка калдыру (төшерү); хур-рисвай итү.

2. Бөлгенлеккә төшерү. – *Кайчандыр черегән бай иде, хәзер адәм күзенә күренерлеген калдырмадылар мескеннең* (Сөйләм).

**АДӘМ ЙӨРГЕСЕЗ.** Бик пычрак, кеше күп булу яки башка сәбәптән йөрерлек булмау. *Каралты алды адәм йөргесез баткаклык иде* (Сөйләм).

**АДӘМ КАЛДЫГЫ**. «Кеше түгел син» дигән мәгънәдә хурлау сүзе. *[Мөстәкыйм] (тамашачыларга). Кичә генә адәм калдыгы идем, ә хәзер...* (Д. Салихов. Таш сандык).

Төрдәше: адәм актыгы һ.б.

**АДӘМ КАРАГЫСЫЗ** *к.* адәм баккысыз. *Куллары салынып төшкән, йөзләре адәм карагысыз булып яраланган...* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр).

Төрдәше: адәм баккысыз.

**АДӘМ КАРАСЫ.** Эңгер-меңгердә, томанда, буранда күренгән кеше сыны. *Бер сәгатьтән соң кар баскан яланда көчкә бер адәм карасы күренде* (Н. Исәнбәт).

**АДӘМ КИСӘГЕ.** 1. Кеше булмаган җирдә берәрсе күренгәндә әйтелә. *Ни гомерләр урманда адашып йөргәч, ахырында көчкә бер адәм кисәге күренде. Бу – иңбашына мылтыгын аскан бер аучы иде* (К. Бәкер). *Аларын да үткәч, бер бүлмәгә эләкте: өстәл артында җирән сакаллы, акайган күзле, борын сөяге төпкә баткан бер адәм кисәге утыра иде* (И. Хуҗин. Егетнең кайтуы).

2. *к.* адәм калдыгы. *Бигрәк тә шунысы, эшләргә яратмый, оятсыз һәм әрсез бер адәм кисәге иде* (И. Хуҗин. Алда дембель көтә).
Төрдәше: адәм актыгы һ.б.

**АДӘМ КӨЕГЕ**. Җәфа, хәсрәт китерүче. *Адәм көеге булганчы, урман киеге булу артык* (Мәкаль). *Их син, адәм көеге!* (К. Нәҗми).
Төрдәше: адәм актыгы һ.б.

**АДӘМ КӨЛДЕРЕП ЙӨРҮ.** Исереп йөрүе, искемоскы киемнәрдән булуыннан яки башка сәбәптән кешеләрнең аннан көлүе. *Нигә, дисән, бүрек эченә кәгазь тутырып адәм көлдереп йөргәнче, бар күк тапканны ашап, аннары тагын иптәшләр белән әллә нидә бер төшергәләп йөрүдән дә яхшысы юк икән* (Ф. Хөсни. Йөзек кашы).

**АДӘМ КӨЛКЕСЕ** *к.* адәм актыгы. *Утыз өч яшендә гарип, инвалид, адәм көлкесе, аяклы каза, җәфа, бәла һәм моннан ары бары тик хәсрәт-газаплар гына китерәчәк бичара* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Ул эчтән генә үзенә әйтеп барды: шундый көннәрдә өеңдә сырхауланып ятма, туган! Бу бит инде адәм көлкесе, валлаһи* (А. Расих. Ямашев).
Төрдәше: адәм актыгы һ.б.

**АДӘМ КӨЛКЕСЕ БУЛУ** *к.* адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1. *Кәримнең иярченнәре берсе өстен берсе сөйләп, бутап бетереп, адәм көлкесе булып беттеләр* (Г. Камал). *<...> бу тәвәккәллек энесенең тракторын ташлап, исереп ятуына, нәселләрен рисвай итеп, адәм көлкесе булып йөрүенә һәм, ниһаять, авыру әнисен соң чиккә җиткерүенә котылгысыз җәза иде* (А. Вергазов. Үзенә кайту).
Төрдәше: адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1; дөнья мәсхәрәсе <булу> һ.б; шулай ук к.: битен куярга урын тапмау; биткә ут (ялкын) кабу; битне кая куярга белмәү; йөз каралу; йөзгә кызыллык йөгерү; көлкегә калу; оятка калу; оятлы булу; хурга калу; хурлыкка калу (төшү).

**АДӘМ КӨЛКЕСЕ ИТҮ.** Адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1. *Бөтен халык алдында адәм көлкесе итсеннәр, имеш! Юри эшләгәннәр дип торырсың* (Н. Фәттах. Мөдир Саҗидә).
Төрдәше: адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1 һ.б.

**АДӘМ КӨЛКЕСЕНӘ КАЛДЫРУ** *к.* адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1. *Араларында бер күк бияне бик мактап сөйлиләр, үткән ел Өфе каласында чаптырганда, бөтен атларны адәм көлкесенә калдырган, диләр* (Г. Ибраһимов. Алмачуар).
Төрдәше: адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1 һ.б.

**АДӘМ КӨЛКЕСЕНӘ (МӘСХӘРӘСЕНӘ) КАЛУ** *к.* адәм көлкесе булу. *Аңа гына сыенып, аны гына назлап тора торган чәчәктәй нәфис Нажиясе белән ул кешеләр алдында горур һәм бәхетле булыр кебек, әмма шул ук вакытта берни белми, берни уйламый торган җилбәзәк хатын белән адәм көлкесенә калыр һәм тирән бәхетсезлеккә төшәр шикелле...* (Ә. Еники. Саз чәчәге).
Төрдәше: адәм көлкесе булу һ.б.

**АДӘМ КҮСӘГЕ.** Бозыклыкка бирелеп, тупасланып беткән кеше. *Әй матур, әй кечкенә инсан, адәмлек кисәге, дип суеп кара тузабыз без, адәмнәр күсәге* (Н. Думави).
Төрдәше: адәм актыгы һ.б.

**АДӘМ КҮТӘРГЕСЕЗ (КҮТӘРМӘСЛЕК).** Бик авыр, башкарып чыгарга көч җитмәслек (газап чигү). – *Кайгым адәм күтәргесез, – диде хатын* (Ф. Җамалетдинова. Гомер тукталышлары).

**АДӘМ КЫЯФӘТЕ КАЛМАУ.** Ниндидер сәбәптән (исереклек, авыру) кеше рәвешеннән чыгу. *Ә Мәмәшевнең күзләре тонган, авызыннан бау кебек селәгәе асылынган. Адәм кыяфәте калмаган иде* (Х. Камалов. Үксезләр).

**АДӘМ МӘСХӘРӘСЕ (ХУРЫ)** *к.* адәм актыгы. *[Габсаттар] Һи, адәм мәсхәрәсе! Самавыр җизе төсле сары пышлак бер малай, нурлы йөзле буласы, имеш!* (Г. Камал. Көндәш). *[Суфи] Алла миңа күз бирсә, минем дә синең кебек адәм мәсхәрәсе булып калуымда шөбһә юк* (К. Тинчурин. Беренче чәчәкләр).
Төрдәше: адәм актыгы һ.б.

**АДӘМ МӘСХӘРӘСЕ (ХУРЫ) БУЛУ** *к.* адәм көлкесе булу. *[Гөлбану] Әллә юк исә... әстәгъфирулла-тәүбә... тфү, тфү, безнең карт шулай картайган көнендә адәм мәсхәрәсе булып өйләнергә йөриме, әллә ниләр күрерсең* (Г. Камал. Көндәш).
Төрдәше: адәм көлкесе булу һ.б.

**АДӘМ МӘСХӘРӘСЕ ИТҮ (ЯСАУ)** *к.* адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1. *Аннары адәм мәсхәрәсе итеп, Бауман почмагына сурәтеңне ясап куярлар* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).
Төрдәше: адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1 һ.б.

**АДӘМ МӘСХӘРӘСЕНӘ КАЛДЫРУ** *к.* адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1. *Аңа сүзен өскә чыгарырга кирәк. Сүзен боз капламасын. Кешеләр арасында адәм мәсхәрәсенә калдырып, аның өчен яшәү җәймәсе булып җәелгән вазифасыннан кибәк урынына җилпеп ташламасыннар* (С. Поварисов. Пәйгамбәр таңы).
Төрдәше: адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1 һ.б.

**АДӘМ МӘСХӘРӘСЕНӘ КАЛУ** *к.* адәм көлкесе булу. *Синең аркада, «кое казытам» дип, адәм мәсхәрәсенә калдым, – дип, әнине сүкте* (Д. Булатова. Кое).
Төрдәше: адәм көлкесе булу һ.б.

**АДӘМ РӘВЕШЕНӘ (РӘТЕНӘ) КЕРТҮ.** 1. Кешеләрчә кыяфәтле, кеше дип әйтергә лаеклы хәлгә китерү; яхшы якка үзгәрү нәтиҗәсендә кешеләр арасында абруй казана башлау. *[Фаизә] Мин аны кеше итәргә, адәм рәтенә кертергә тырышам, ә ул мине карчык дип яманлап йөри* (К. Тинчурин. Йосыф белән Зөләйха).

2. Тәртипкә китерү, җыйнаклау. *Кунаклар килер алдыннан, клубны бераз адәм рәвешенә кертсен* (Р. Галиуллин. Әдрән). *Сатасы әйбер-караны кичен үтүкләп «адәм рәтенә» керткәннәр иде* (Р. Кәрами. Олы юл да сикәлтәле).

**АДӘМ РӘВЕШЕНӘ (РӘТЕНӘ) КЕРҮ.** 1. Белеме, эше, үзен тотышы белән кеше рәтендә саналып йөрү; яхшыру, яхшы якка үзгәрү. *Монда кайтып, адәм рәвешенә кереп йөрисең. Безнекеләр исән кайткан булса, аяк астындагы ыштырга тормас идең син, хашәрәт* (Р. Зарипов. Тирән тамырлы Түнтәрем). *Армиягә китеп кенә кеше рәтенә кереп кайтты* (Х. Камалов. Куян күзе нигә кызыл?).
Төрдәше: адәм рәвешендә (рәвешле) <булу> 2; адәм рәтенә килү; адәм рәтле булу; адәм санына керү 1; кеше санына керү.

2. Кешеләр белән аралашу. *Кичләрен клубка чыгып, адәм рәтенә керә башлады инде* (Сөйләм).

3. Яхшыра төшү, элеккеге хәленә кайту. *Салкын су белән битләребезне югач, бераз адәм рәтенә кергәндәй булдык* (М. Әмир).
Төрдәше: кеше рәтенә (санына) керү.

**АДӘМ РӘВЕШЕНДӘ (РӘВЕШЛЕ) <БУЛУ>.** 1. Шыр ялангач ир кеше. *Хава хәлендә калган табигать балалары, Адәм рәвешендәге бу егетнең монда качып утырганлыгын белсәләр, кызык өчен генә булса да аны хур итү җаен табарлар иде* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).
Төрдәше: адәм галәйһиссәлам киемендә; анадан тума.

2. Кеше сыман тәртипле, кешегә лаек төстә. *Сөйләшә дә, ашый да белмәгән авыруны адәм рәвешендә яшәтү өчен, 24 сәгать буена аяк өстендә булырга кирәк, чөнки ул төннәрен дә тыныч йокламый* («Туган як» газ.).
Төрдәше: адәм рәвешенә (рәтенә) керү 1; адәм рәтенә килү; адәм рәтле булу; адәм санына керү 1; кеше санына керү.

**АДӘМ РӘТЕНӘ КЕРМӘГӘН.** Игелексез, юньсез, мәгънәсез кеше турында. *Адәм рәтенә керманән кешедән игелек көтмә* (Сөйләм).

**АДӘМ РӘТЕНӘ КИЛҮ.** Кешелек сыйфатларына ия булу. *Бәлки, аңа хәтле адәм рәтенә килмәсме, белеп булмый бит, чыгымчы хайван да кайчагында рәтләнеп куя* (Ш. Камал).
Төрдәше: адәм рәвешенә (рәтенә) керү 1; адәм рәвешендә (рәвешле) <булу> 2; адәм рәтле булу; адәм санына керү 1; кеше санына керү.

**АДӘМ РӘТЕНӘ СУКМАУ**. Кеше дип тә исәпләмәү. *Син аны ничә еллар буе адәм рәтенә сукмыйча, балаң итмичә йөр дә, ул синнән килеп киңәш сорамагае* (Г. Ахунов).

**АДӘМ РӘТЛЕ.** 1. Яхшы, затлы; кеше күзендә рәтле саналырлык. – *Шулай да ник адәм рәтле тормыш күрмәдем мин?* (И. Гази. Онытылмас еллар). *Егетләрнең күбесе кичәгә барудан баш тартты; кайсының костюмы юк, кайсының ботинкасы адәм рәтле түгел иде* (М. Мәһдиев. Ут чәчәге).
Төрдәше: адәм сынлы; адәм төсле 1.

2. Уңган, әйбәт, юньле; ярарлык. *[Габсаттар] Хәер лә, хәзер инде аның адәм рәтле*

*кешесе дә калмады* (Г. Камал. Көндәш). *Гомерендә бер адәм рәтле атка тиенгән иде, анысының да рәхәтен күрә алмады* (И. Гази).

3. Яхшылап, әйбәтләп; кешеләрчә итагатьле итеп. *Кешеләр белән адәм рәтле сөйләшә белмәвенә аның үз-үзенә чынлап ачуы килде* (Ә. Еники. Рәхмәт, иптәшләр).

**АДӘМ РӘТЛЕ БУЛУ** *к.* адәм рәвшендә (рәвешле) <булу>. Кеше сыман тәртипле, кешегә лаек төстә булу. – *Бу сакал-чәчләреңне кыскартсаң, карап торырга адәм рәтле булыр идең ичмасам!* (Сөйләм).
Төрдәше: адәм рәвешенә (рәтенә) керү 1; адәм рәвешендә (рәвешле) <булу> 2; адәм рәтенә килү; адәм санына керү 1; кеше санына керү.

**АДӘМ РӘТЛЕ ИТЕП.** Җайлы, юньле итеп. – *Эшне адәм рәтле итеп куяр өчен, ул гына җитми, әлбәттә, – диде Каюм, – безгә губзомотдел ярдәм итә: ун ат, биш пар үгез бирергә ышандырдылар* (Ш. Камал. Матур туганда).

**АДӘМ РИСВАЕ**. Хурлыклы эш-хәл; *шулай ук к.* адәм актыгы. – *Һәм мондый адәм рисвае да булмаска тиеш!* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).
Төрдәше: адәм актыгы һ.б.

**АДӘМ РИСВАЕ БУЛУ** *к.* адәм көлкесе булу. *Алла сакласын, капылт аякларының җегәре китеп, тигез урында егылуың бар. Адәм рисвае булырсың!..* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы).
Төрдәше: адәм көлкесе булу һ.б.

**АДӘМ РИСВАЕ ИТҮ** *к.* адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1. *Менә шул адәм рисвае итеп китте бит, имансыз нәрсә* (Г. Мөхәммәтшин. Ике әби бәрәңге ала...).
Төрдәше: адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1 һ.б.

**АДӘМ<ГӘ> САНА<Л>У.** Кеше арасына керү. *Юк, ярамый, үпкәләр, рәнҗер, бозык адәмгә санап, алдагы очрашулардан баш тартыр* (А. Хөснуллина. Язмыш кайтавазы). *Син шымчылык эшен үтәсәң һәм агентка җиткереп торсаң гына, тулы хокуклы адәм саналасың* (Х. Камал. Каһәр).
Төрдәше: адәм санына керү.

**АДӘМ САНЫНА КЕРҮ.** 1. Игътибар казану, кеше буларак санала башлау. *Инде бер адәм санына кергәч, мондый өс-баш белән дә йөреп булмый бит* (М. Гафури).
Төрдәше: адәм рәвешенә (рәтенә) керү 1; адәм рәвешендә (рәвешле) <булу> 2; адәм рәтенә килү; адәм рәтле булу; кеше санына керү.

2. *кимс.* Сан исәбенә генә алыну. *Мине дә 23 нче сан астына теркәп куйдыра, димәк, мин дә адәм санына кердем* (Сөйләм).
Төрдәше: адәм<гә> сана<л>у.

**АДӘМ САНЫНА КЕРТҮ.** Кешеләргә хас сыйфатларын танып, исәпләшә башлау. – *Әле мине адәм санына керткән кеше калганмыни?* (М. Гафури).

**АДӘМ СИЗМӘС, ЭТ ӨРМӘС.** Берәүгә дә сиздермичә, астыртын эшләнгән эш. – *Аларныкын белмәссең, ни кыралар, ни эшлиләр – адәм сизмәс, эт өрмәс* (Н. Исәнбәт).

**АДӘМ СӨЙЛИ, ЯЗМЫШ КӨЙЛИ.** «Кешенең һәр уйлаганы да тормышка ашмый» мәгънәсендә. *Адәм сөйли, язмыш көйли, ди. Әлеге ниятне беразга кичектереп торырга туры килде* (М. Әмирханов. Тәхетсез патша).

**АДӘМ СӨЙЛИ, ЯЗМЫШ КӨЛӘ.** Язмыштан узып, аны үзеңә буйсындырырга маташуның файдасыз икәнлегенә ишарә. *Адәм сөйли – язмыш көлә, дип, юкка гына әйтмәгән борынгылар* (Х. Камалов. Үксезләр).

**АДӘМ СӨЯГЕ.** Күтәртеп кенә йөрергә яраткан баланы яки йөри алмаган авыруны караучының никадәр авыр булуына ишарә. – *Көн саен аны күтәреп йөреп кара әле, җиңел дип уйлыйсыңмы әллә – адәм сөяге бит ул!* (Сөйләм).

**АДӘМ СЫНЛЫ.** Кешенең баштанаяк буй-сыны, кыяфәте һәм киеме тиешлечә булу; исән-сау хәлдә. – *Байтүрәнең эте булып, яман кимперләрдән кыйналуым күп ел гомеремне кыскартты. Инде калганын адәм сынлы үткәрсәм иде!* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). – *Нинди сөяркә? Әйт инде, адәм сынлы, кем эзләде?* (И. Салахов. Имәннәр тамыр җәйгәндә).
Төрдәше: адәм рәтле 1; адәм төсле 1.

**АДӘМ ТӘГАНӘСЕ.** 1. Адәм мәсхәрәсе булуын аңламаган кеше. *Үземнең хатын да, гомердә булмаганны, капка төбенә үк чыгып каршы алды, адәм тәганәсе* (Р. Зәйдулла. Шүрәле). – *Ике төшенә ике чүпрәк каплаган. Карап тор-*

*саң – адәм тәганәсе менә!* (Г. Мөхәммәтшин. Ике әби бәрәңге ала...).

2. Кешелек кыяфәтен югалткан. *Тирә-яктагы бөтенлекне, тигезлекне тамаша кылып килә-килә, Нәҗип як-ягын үз авылларындагы ташландык урам-тыкрыклар, керсәң чыга алмаслык юллар, бетәшкән өйләр, адәм тәганәсенә әйләнгән чирле әти-әнисе белән янәшә куеп карады* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: адәм актыгы һ.б.

**АДӘМ ТИЛЧӘСЕ.** *кимс.* Сүзе белән дә, холкы белән дә кешенең теңкәсенә тиюче кеше. – *Тәмам адәм тилчәсе булдың инде, ичмасам, бар, кибеткә барып кайт* (Сөйләм).

Төрдәше: адәм актыгы һ.б.

**АДӘМ ТОКЫМЫ** *к.* адәм заты (углы). *Нигә шундый җәлпәк танаулы, кашсыз кырыс адәм токымына шундый шигъриятле фамилия такканнар икән, дип баш ватып та йөрдем бугай* (А. Гыйләҗев).

Төрдәше: адәм баласы (углы); адәм заты; адәми зат; ата баласы.

**АДӘМ ТӨСЕ КЕРҮ.** Йөзгә сәламәтлек төсе керү. *<…> карт үзе дә, ил халкы да бик кадерләсәләр дә, артык тазара алмады, шулай да адәм төсе керде* (Г. Ибраһимов).

**АДӘМ ТӨСЛЕ.** 1. Кеше арасына киеп чыгарлык өс-баш, кыяфәт. – *Иртәгә кунакка барабыз, кыяфәтең адәм төслерәк булсын* (Сөйләм).

Төрдәше: адәм рәтле 1; адәм сынлы.

2. Кешечә, кешеләргә хас булган рәвештә. *[Әхмәт] Иң элек яхшы гына, адәм төсле тора башлыйсың, иртә белән яңгыр булу ихтималы бар икән <...>* (Г. Камал. Көндәш). *[Сабира] (яман чәпчеп). Яз башыннан колагыңа тукыйм, тәки шул капка күгәнен адәм төсле майлап куялмадың, авыр аяк* (А. Гыйләҗев).

3. Кешеләргә хас булган рухи сыйфатка ия булу. *Әйе, халкыбызны адәм төсле, чын мәдәниятле итеп тәрбияләү өчен, әле безгә бик күп тоз ашарга кирәк, океан кадәрле сулар агызасы бар икән шул* («Татар әдипләре» порталы).

4. Сүзнең асыл мәгънәсе аңлаткан сыйфатларга туры килү, күнегелгән хәлдә булу. *Кышның «адәм төсле» булмавы аркасында, гасырлар буе итек басып, шуны сатып гомер иткән гаиләләргә авырга туры килә* («Ватаным Татарстан» газ.).

**АДӘМ ТҮГЕЛ.** *кимс.* Кешелексез, миһербансыз. – *Бушлары да юньле адәм түгел, үзе ата жулик ул* (Р. Габделхакова. Кояшлы мизгел).

**АДӘМ УГЛЫ.** Кеше затыннан. *Адәм углы, йөри торгач, / Әйләнгән дә үзенә кайткан* (Ф. Зыятдинова. Хаклык).

**АДӘМ ҮЛӘКСӘСЕ** *мыск.* 1. Кара фикерле, беркемгә дә игелек күрсәтмәгән начар кеше. – *Әй син!.. Адәм үләксәсе! Кайда яшереп тотасың алтыныңны?* (Г. Гыйльманов. Албастылар).

2. Артык ябык, бетеренгән кеше. *Әйтәм ич, бер адәм үләксәсенә барып сөртенәселәре килсә алсыннар* (Г. Камал. Хатын алу турында).

Төрдәше: адәм актыгы һ.б.

**АДӘМ ХУРЛЫГЫ ИТҮ** *к.* адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1. – *Әйдә, үзен адәм хурлыгы итик әле, бик борынын күтәреп йөрмәсен!* (Сөйләм).

Төрдәше: адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1 һ.б.

**АДӘМ ХУРЛЫГЫНА КАЛДЫРУ (ТӨШЕРҮ)** *к.* адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1. – *Нигә кирәк булды шулай җентекле сөйләргә, адәм хурлыгына төшердең бит син мине* (Сөйләм).

Төрдәше: адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1 һ.б.

**АДӘМ ХУРЛЫГЫНА КАЛУ (ТӨШҮ)** *к.* адәм көлкесе булу. *Хәзер әнә Капелло да, Бразилиядә адәм хурлыгына калу тәҗрибәсен истә тотып, 2018 елга җиңүче ком анда идеясе белән «яна»* («Матбугат.ру» порталы).

Төрдәше: адәм көлкесе булу һ.б.

**АДӘМ ХУРЫ** Кеше күзендә хур булып йөргән кеше. *Син үл генә, Сиңа дөнья хәрәм, / Адәм хуры, йөрмә, диделәр* (М. Җәлил). *Ә туган авылында аны искә алып бер хөрмәтләүче юк, адәм хуры* (В. Имамов. Ир канаты).

Төрдәше: адәм актыгы һ.б.

**АДӘМ ХУР<ЛЫГ>Ы БУЛУ** *к.* адәм көлкесе булу. *Нигә ул адәм хуры булсын икән?* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Адәм хурлыгы булдык бит* (Ф. Яруллин).

Төрдәше: адәм көлкесе булу һ.б.

**АДӘМ ХУРЫ ИТҮ (ЯСАУ)** *к.* адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1. *Инде күләр, адәм хуры итәр, / Харап кына булды башкаем!* (Г. Афзал. Шофер). *Курка идем, тагын күрерләр дә адәм хуры ясарлар* (Г. Рәхим. Саргаймагыз, каштаннар...).

Төрдәше: адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1 һ.б.

**АДӘМ <ИТЕН> ЧӘЙНӘҮ** *к.* авыз чайкау 1. *[Себер бае] Ә адәм итен чәйнәү, көн буе гайбәт сатып утыру – ансы хәрам түгел?* (Г. Камал. Безнең шәһәрнең серләре).

Төрдәше: авыз чайкау 1 һ.б.

**АДӘМ ЧЫРАЕ КАЛМАГАН (ЮК).** Төссез, авыру. *Бабайга нәрсәдер булган, ахрысы, битендә адәм чырае юк* (И. Гафаров. Мишәрләр).

**АДӘМ ШАЙТАНЫ.** Котыртучы, туры юлдан чыгаручы. *Алла шайтанынннан адәм шайтаны яман, дигәнен ишеткәне бар аның* (С. Поварисов. Пәйгамбәр таңы).

**АДӘМ ЫШАНМАСЛЫК.** 1. Шаккатарлык. *Адәм ышанмаслык хәл. Рабига күле янында көянтә-чиләкләр күтәргән биш-алты кыз балага юлыктык* (А. Тимергалин. Юл чаты).

2. Ялган, уйдырма. *Бер айдан адәм ышанмаслык хәбәр куып җитте* (В. Имамов. Казан дастаны). *Санап китсәң, адәм көләрлек, адәм ышанмаслык, чәчләр үрә торырлык җыр сүзләре бар бүгенге көндә* (Р. Вәлиев. Сагындыра моңлы җыр...).

Төрдәше: адәм әйтеп ышанмаслык (ике маддә өчен дә).

*АДӘМИ* ❖ **АДӘМИ ЗАТ** *к.* адәм баласы (углы). *Мин әйтер идем, ул – адәми затның иксез-чиксез куәте* (Г. Бәширов. Намус). *Ләкин адәми затлар арасында бу канун яшәсә дә, үрчем мул булса да, моның кире нәтиҗәле имәнгеч ягы бар* (Р. Батулла. Сөембикә).

Төрдәше: адәм баласы (углы) һ.б.

*АДӘМЛЕКТӘН* ❖ **АДӘМЛЕКТӘН ЧЫГУ.** Фәкыйрьләнү, бөлү яки әхлакый бозыклык сәбәбеннән кешелек кыяфәтен югалту. *Үзе адәмлектән чыкканның киеме киемлектән чыгар* (Мәкаль).

*АДИСОН* ❖ **АДИСОН (ЭДИСОН) УТЫ.** Электр нуры, яктысы. *Күзләренең һәр карашыннан берәр шигырь тезәм, / Ихтыяҗы юк аның һичбер Адисон утына* (З. Ярмәки).

*АДРАЕП* ❖ **АДРАЕП ЙӨРҮ** *диал.* Гайрәтләнеп, этәчләнеп, җилкенеп йөрү. *Күршегә берәр нәрсә булганмы юкса, иртәдән адраеп йөри* (Сөйләм).

**АДРАЕП КИЛЕП КЕРҮ** *диал.* Иләсләнеп, күзбашы аларып керү. *Өйалды ишеге шыкылдап ябылганы ишетелде, өйгә Галия адраеп килеп керде* (Сөйләм).

*АДРЕС* ❖ **АДРЕС ЯЗАРЛЫК <КЫНА>.** «Бераз булса да яза белү» мәгънәсендә. *Вывескалар укырлык, адрес язарлык русчасы да бар* (Ә. Еники. Истәлекләр).

*АДРЕСНЫ* ❖ **АДРЕСНЫ БУТАУ.** 1. Кирәкле җирнең яки берәрсенең кайда яшәгәнлеген ялгыштыру. – *Адресны бутаганмын, ахры, гафу* (Н. Гыйматдинова. Алан уртасында ялгыз йорт).

2. Әйтәсе сүзләрне ялгыш башкасына әйтү. *Әзи, авыл главаларының язгы чәчүгә нинди катнашы бар соң? Әзи! Адресны бутадыгыз түгелме?* («Матбугат.ру» порталы). – *Сез адресны бутыйсыз кебек, мин дә Фәридә, ләкин фамилиям башка* (Сөйләм).

*АДРЕСЫНА* ❖ **АДРЕСЫНА КАРАТА.** Кемнең дә булса исеменә төбәп. *Әмма Туктамышны эзәрлекләп барганда, Идегәй үз адресына карата да кискен шелтә-гаепләү сүзләре ишетә* (М. Бакиров. «Идегәй» дастанына яңа караш).

*АДЫМ* ❖ **АДЫМ АТЛАРГА ДА БИРМӘҮ.** Нәрсә турында булса да сүз әйтергә яки каядыр барырга ирек бирмәү, аркылы төшү. *Кем нәрсә әйтә, барысын да язып барыгыз – адым атларга бирмәгез* (Сөйләм).

**АДЫМ АТУ.** 1. Йөрер өчен аягын алга таба хәрәкәт иттерү. *Карап-карап торды да сак кына адым атты* (Сөйләм).

2. *күч.* Беренче мәртәбә нинди булса да эшкә керешү. *Аның ачыш тантанасында Гази университеты ректоры, профессор Рыза Айһан, Нәүрүзнең яңадан туу, җир йөзенә бәрәкәт иту, яңа башлангычларга адым ату көне булуын белдереп, студентларны төрекләрнең Яңа елы белән котлады* («Татар-информ»).

**АДЫМ ДА АТЛАМАСЛЫК.** Нниндидер сәбәптән адым атлау, йөрү мөмкинлеге булмау. *Ә бүген аңардан башка адым да атламаслык* (Л. Хәмидуллин. Буранлы төндә).

**АДЫМ <ДА> АТЛА<Т>МАУ.** Кая яки кемгә булса да барудан бизү, анда җибәрмәү. *Ә гүзәллек, матурлык дөньясында бер булган кеше тормышта ялгыш адым атламас, чын кеше булып гомер итәр* (Р. Зарипова. Бала күңеле).
Төрдәше: адым ясамау.

**АДЫМ ДА БАСМАУ** *к.* адым <да> атла<т>мау. *Шул вакыйгадан соң мин ул урынга адым да басмадым* (Сөйләм).
Төрдәше: адым <да> атла<т>мау; аяк та атламау.

**АДЫМ САЕН.** 1. Һәрвакыт, даими рәвештә. *Ул Мансурның һаман күңелсез йөрүен күрә, ләкин адым саен аны борчып торудан саклана иде* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Ә телевизорда адым саен реклама, әллә ниткән «Натс» та «Сникерс»лар, «Чупа-Чупс»лар, «Марс»лар* (Д. Булатова. Ачык ишекләр көне).
Төрдәше: аяк атлаган саен.

2. Бик еш, бик күп. – *Хәзер машина адым саен, менә шундый мал табып карагыз! – ди торган иде ул тирә-юнь колхозлары башлыкларына* (Б. Камалов. Мәрдән сукмагы). *Урал ягында завутлар адым саен, диләр, барам да берәрсенә керәм* (В. Имамов. Казан дастаны).

3. Берәр эш башлаганда, һәр эштә, һәр адымда. *Безнең юлга дошман кулы белән / Адым саен киртә салына* (М. Җәлил). Сине табу бик кыен. *Чөнки адым саен сине йә яраталар, йә дошман итәләр* (З. Хәким. Кайда син, Аттила?!).

**АДЫМ ЯСАТМАУ.** 1. Рәхәт хәрәкәт итүенә комачаулау максатыннан, даими рәвештә каршылыклар уйлап чыгару. *Лицейга Сәнгать университетыннан килеп төшкән илчеләр исә чыгарылыш сыйныфында укучы кызның лирик-колоратура сопраносын ишетеп, уңга да, сулга да бер адым ясатмыйлар* («Сөембикә» ж.).

2. *к.* адым <да> атла<т>мау. *Табибә Екатерина Андреева – үз эшенең остасы, шәфкать туташларын да сайлап алганнар диярсең, һәр авыруга игътибарлы, артык бер адым ясатмыйлар* («Хезмәт даны» газ.).

*АДЫМ-АДЫМ* ❖ **АДЫМ-АДЫМ АТЛАП.** Әзлекле рәвештә; берсе артыннан икенчесен чиратлатып эшләү. *Ә максатына ул адым-адым атлап бара* («Сөембикә» ж.).

*АДЫМЫН* ❖ **АДЫМЫН САНАП АТЛАУ.** Салмак кына атлап йөрү. *Бүтән берәү булса, һәр адымын санап атлар иде* (Р. Кәрами. Батулла). *Адымнарым санап атлар идем, / Якын булса йөрер юлларым* (Ф. Яхин).
Төрдәше: авыр аяк<лы> 1 һ.б.

*АЕК* ❖ **АЕК АКЫЛ <БЕЛӘН>.** Һәр яктан уйланылган. *[Фирүзә] Бу хакта аек акыл белән уйлап карадыгызмы?* (Ю. Әминов. Язылмаган законнар). *Теләсә нинди темага сөйләшеп була торган, тормышка аек акыл белән караучы сылу гына гәүдәле отличница* (Х. Ширмән. Ерактагы йолдызым).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә алу) һ.б.

**АЕК АКЫЛЛЫ.** Һәр нәрсәне уйлап, акыл белән эш итүче. *Дөнья тоткасы безнең кулда дип йөрсә дә, ул – аек акыллы, чынбарлыкка хак бәя бирергә сәләтле кеше* (З. Хөснияр. Гарасат).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә алу) һ.б.

**АЕК АКЫЛЛЫЛЫК.** Сау фикерлелек, дөрес уйлау. *Сабырлык һәм аек акыллылык күрсәтә. Нәтиҗәдә ире белән араның төзәлүенә ирешә* (Ф. Галимуллин. Халатың ак, күңелең пакь булсын…).

**АЕК БАШТАН (БАШ БЕЛӘН).** 1. Аек көенчә, исерек булмаган хәлдә. *Аек баштан үзең шәйлә уңны-сулны, / Ничек списать итәргә ун меңсумны?!* (Г. Афзал. Банкет). *Яңа елны мин аек баш белән каршыларга булдым* (Г. Тавлин. Афәт).
Төрдәше: айнык баштан.

2. Акыл белән, уйлап. *Ул аек баш белән бөтенесен күз алдыннан кичереп алды* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).
Төрдәше: айнык акыл белән.

**АЕК ЗИҺЕНЛЕ.** Һәр эшен алдан бөтен яклап уйлап эшләүче. *Мәмләкәт чаклы мәмләкәткә йөгән кидергән таҗдарга салкын канлы, аек зиһенле, булса отышлырак та бит, мәгәр олы юл башында канат җилпеп гайрәт күрсәтү дә бик кирәкле шәйдер* (В. Имамов. Карабәк).

**АЕК <КҮЗДӘН> КАРАУ.** Объектив фикер йөртү. *Сугыш һәркемне тамак мәсьәләсенә аек карарга өйрәтте* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә алу) һ.б.

**АЕК КАРАШ<ЛЫ>.** Тормыштан аерылмаган, җитди уйланылган, фикерле. *Аны [Казанның рус гаскәре тарафыннан алынуны] нәфрәт кабызу өчен түгел, татар һәм урыс тарихына аек караш булдыру максатында файдаланырга кирәк* (Р. Хәким. Кем син, татар?). *Димәк, аек карашлы тәнкыйтьче булырга* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә алу) һ.б.

**АЕК КҮЗ БЕЛӘН КАРАУ** *к.* авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә алу). *Тормышка аек күз белән караучы кеше буларак, ул үзенең хыялына җиңел генә ирешә алмаячагын аңлый иде* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә алу) һ.б.

**АЕК ФИКЕР ИЯСЕ**. Акыл иясе, гадел фикер йөртүче, *шулай ук к.* аек акыллы. *Четерекле мәсьәләләрне хәл иткәндә, аек фикер ияләренең сүзләренә колак салырга кирәк* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп; элеп кенә алу) һ.б.

**АЕК ФИКЕРЛЕ** *к.* авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә алу). *Шушыны [җәдитчеләр белән кадимчеләр көрәшен] әйтү генә дә аның үз халкының язмышына, аның киләчәгенә битараф булмаган, үз кыйбласыннан бервакытта да тайпылмаган аек фикерле гаярь шәхес булганлыгын икрар итәргә этәрә* (Р. Зарипов. Тирән тамырлы Түнтәрем).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә алу) һ.б.

*АЕ-КӨНЕ* ❖ **АЕ-КӨНЕ БЕЛӘН.** Нәкъ әйткән вакытта, төгәл үз вакытында. – *Ә хәрбиләрчә конкретрак итеп әйтсәң? Ягъни ае-көне белән...* (Р. Кәрами. Ирекко чыктык).

**АЕ-КӨНЕ ҖИТКӘН.** Йөкле хатынның бала табу вакыты җитү. *Тамчыгөлгә әйтегез, чиләкләп су ташымасын – ае-көне җиткән бит инде* (Сөйләм).
Төрдәше: ай-көне җитү.

*АЕМ* ❖ **АЕМ ТУРЫ БАККАНДА, ЙОЛДЫЗЛАРГА ЙОДРЫК.** «Ирем ратса, беркемгә дә исем китми» мәгънәсендә. – *Сөйләгез, сөйлә, бер дә исем китми. Минем әби, «Аем туры баккан-да, йолдызларга йодрык», дия торган иде* (Сөйләм).

*АЕН* ❖ **АЕН – КӨН, ЕЛЫН АЙ ҮСҮ.** Бик тиз үсеп китү, зураю. *Аен – көн, елын ай үсәсең. / Теземнән бигрәк тиз төшәсең* (Таңчулпан. Кызыма).
Төрдәше: ай үсәсен көн үсү, <ел үсәсен ай үсү>; ел үсәсен ай үсү; су сибеп үстергәндәй.

*АЕНА* ❖ **АЕНА УТЫЗ КӨНГӘ ЯЛЛАНУ** *ирон.*, *шаярт.* Бушка, тамак ялына эшләү. – *Күршене аена утыз көнгә ялланган диделәр, дөресме бу?* (Сөйләм).
Төрдәше: айга утыз көн.

*АЕҢ-КӨНЕҢ* ❖ **АЕҢ-КӨНЕҢ УРТАК БУЛМАСЫН.** Намуссыз, начар холыклы кешедән ераграк булырга тырышу. – *Рәшитме?! Әйттең сүз, аның белән аең-көнең уртак булмасын!* (Сөйләм).
Төрдәше: Алла каберен якын итмәсен; каберең ерак булсын; каберең минекенә якын булмасын, <кереп талап чыгарсың>; каберең янәшә (якын) булмасын, <кәфенеңне талар>.

*АЕРМАЛЫ* ❖ **АЕРМАЛЫ БУЛАРАК.** Бер әйбернең (вакыйганың, күренешнең һ.б.) башкасыннан үзгәлеген күрсәтү. – *Беренчедән, – диде ул, – мин әче балга, башкаларадан аермалы буларак, чүпрә салмыйм* (Г. Галиева. Газзәбану).

*АЕРМАСЫ* ❖ **АЕРМАСЫ – БЕРСЕ КАРА, БЕРСЕ КАШКА.** Икесе дә бер үк заттан, аерма тик вак-төяктә генә. *Икесенә ике төрле ярлыкябыштырылса да, мин аларда аерма күрмим, эти әйтмешли, аермасы – берсе кара, берсе кашка* (Сөйләм).

**АЕРМАСЫ ҖИР БЕЛӘН КҮКТӘ (КҮК) КЕБЕК.** Ике затның яки әйбернең сыйфат ягыннан бик нык аерылганлыгы турында. *Элеккеге мөдир дә, яңасы да – хатын-кызлар, ләкин аермалары җир белән күк кебек* (Сөйләм).

*АЕРЫ* ❖ **АЕРЫ СӨЯК КИМЕРҮ.** Мөстәкыйль тормыш кору. – *Минем Рахманга егерме биш яшь тулып килә инде, әле һаман үзенә аеры сөяк кимереп караганы юк* (В. Имамов. Казан дастаны).

**АЕРЫ СУНУ**. Шөһрәте, вакыты узу. *Нигә һаман аны сөйлисез, аеры сунган бит инде* (Сөйләм).

*АЕРЫЛМАС* ❖ **АЕРЫЛМАС ДУС.** Гомерлек дус, җан дус. *Алар бит аерылмас дуслар, анысының башына җитсәк, тегесе дә качкан җиреннән күренми калмас* (Ф. Яхин. Пәйгамбәребез Мөхәммәд).

Төрдәше: аерылышмас дус; ахирәт дуслар; сер дусты; сер сандыгы.

*АЕРЫЛУ* ❖ **АЕРЫЛУ ШӘМЕН ЯГУ.** Аерылу теләген белдерү. *Мин мәхәббәт нуры дим, / Ул аерылу шәмен яга* (С. Рәмиев).

*АЕРЫЛЫП* ❖ **АЕРЫЛЫП КИТКӘН ҖИРЕНӘ АК АЕРЫК ҮСКӘН, ТУЛГАНЫП КИТКӘН ҖИРЕНӘ ТУБЫЛГЫ ҮСКӘН.** Аерылу билгесе югалмый саклануын, иске хәленә кайту мөмкинлеге булуын белдерә. *Безнең аерылуны мәңгелек дип уйламыйм, әкиятче булсам, болай дияр идем: аерылып киткән җиренә ак аерык үскән, тулганып киткән җиренә тубылгы үскән* (Сөйләм).

**АЕРЫЛЫП ТОРУ.** Нindидер сыйфаты белән калкуланып тору. *Урам уртасындагы йорт ике катлы булуы белән аерылып тора иде* (Сөйләм).

**АЕРЫЛЫП ЧЫГУ**. 1. *к.* башка чыгу. *Бу угылларның һәммәсе өйләнеп, дүртесе күптән үк аерылып чыккан, йортта калган өчесе исә күптән таралырга теләсәләр дә Нурый карт ирек бирмәгәнгә, мәҗбүри генә бергә торалар иде* (Г. Ибраһимов).

Төрдәше: башка чыгу.

2. Зур төркемнән бүленеп, мөстәкыйль яши башлау. *Ул [Кара бәк] Алтын Урдадан аерылып чыккан Болгар олысының (Казан ханлыгының) ханнарыннан иң соңгыларыннан була* (И. Хуҗин. Топонимнар).

**АЕРЫЛЫП ЧЫККАН ЙОРТ КЕБЕК.** Йорт-курасыз, җирсез, күлмәк-ыштаннан гына калу. *Хәле авыр мескеннең, аерылып чыккан йорт кебек яши* (Сөйләм).

*АЕРЫЛЫШМАС* ❖ **АЕРЫЛЫШМАС ДУС** *к.* аерылмас дус. *Кан да кызган төсле, күңел дә ачылып китә, вакыт та тизрәк үтә, серләр бирегә, аерылышмас дус-ахирәткә әйләнәсең* (К. Кара. Көнбагыш сатучы).

Төрдәше: аерылмас дус; ахирәт дуслар; сер дусты; сер сандыгы.

*АЕРЫМ* ❖ **АЕРЫМ АЛГАНДА.** Махсус караганда; нәрсәне булса да атап әйткәндә; бигрәк тә, аеруча. *Көнчыгыш әдәбиятлары, аерым алганда, Урта гасыр фарсы маҗаралы-авантюр романнары стиленә тугрылык саклый* (А. Әхмәдуллин. Офыклар киңәйгәндә).

Төрдәше: аерып алганда; атап әйткәндә 1.

**АЕРЫМ БАРЫП, БЕРГӘ БУЛУ.** Төрле юллар, ысуллар кулланып, уртак фикергә килү. *Аның дөреслеген тикшереп караганда, төрле-төрле ысуллар кулланганнар, ләкин, ничек кенә булмасын, аерым барып, бергә булганнар* (Сөйләм).

**АЕРЫМ ОЯ КОРУ.** Үзенең йортын, хуҗалыгын булдыру. *Ни генә булмасын, күчемдә нindидер салкынлык калыккан, кызларым белән бергә аерым оя кору турында уй бөреләнергә өлгергән иде инде* (Ж. Рәхимов. Өлешенә тигән көмеше).

**АЕРЫМ ФИКЕР.** Башкаларныкы белән туры килмәгән фикер. *Кәлямчеләрнең аерым фикер һәм карашларын тәнкыйть иткәндә дә, мәгърифәтчеләр рационализм принципларына таяналар* (Я. Абдуллин. Дини тәгълиматка һәм суфичылыкка каршы).

*АЕРЫП* ❖ **АЕРЫП АЛГАНДА.** Аеруча, бигрәк тә. *Егерменче-утызынчы елларда татар-башкорт эмиграциясе лидерлары көчле әдәби эшчәнлек башлап җибәрде. Муса Бигиев, Абдулла Баттал-Таймас, Әхмәтзәки Вәлиди, Гаяз Исхакый һәм башка кайберләрнең китаплары дөнья күрде. Аерып алганда, Баттал-Таймас 1925 елда Стамбулда басылып чыккан «Төрки Казани» китабының соңгы бүлекләрен татар милли хәрәкәтенең тарихына багышлый* (М. Абдуллин. Халыкка каршы).

Төрдәше: аерым алганда; атап әйткәндә 1.

**АЕРЫП ӘЙТҮ.** 1. Ассызыклау, басым ясау. *Әгәр дә инде кемне дә булса аерып әйтәселәре килә*

*икән, алар «Гөлия сеңлем яки апам» диеп аерып әйтәләр* (А. Нәҗми. Азат). *Аерып әйтергә кирәк, Казанда Татар коммунистик университетын тәмамлаган яшьләргә шактый киң юл ачылган* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).

2. Нык ышанып әйтү. *Бу Азия җирләре дип, Меот сазлары (Азов диңгезенең төньяк-көнчыгышында) дип аерып әйтелә* (И. Хуҗин. Татар тарихы). *Әмма малай үзе белән сөйләшкән хатын-кыз турында ялтыравык сары йозаклы сумкасыннан башка бер төсмерен дә аерып әйтә алмады* (Т. Әйди. Божра).

**АЕРЫП ЧЫГАРУ.** Ишле гаиләдән аерып, яңа өйләнгәннәрне мөстәкыйль хуҗалык белән яшәүгә күчерү. *Аптырагач, Миргалим ишегалдына үзләренә бер бәләкәй насыпушка салып, бу скандалистларны аерып чыгарды* (Д. Гыйсметдин. Һәркемнең үз кайгысы).

Төрдәше: башка чыгару.

*АЕРЫ-ЧӨЕРЕ* ❖ **АЕРЫ-ЧӨЕРЕ КИЛҮ (БУЛУ).** Таркалып һәм чуалып бетү; *шулай ук к.* азар-бизәр килү (булу). – *Безгә хәзер аеры-чөере килмәскә, бер йодрык булып сугарга кирәк* (Ф. Садриев. Бәхетсезләр бәхете).

Төрдәше: азар-бизәр килү (булу).

**АЕРЫ-ЧӨЕРЕ ИТҮ (КИТЕРҮ).** Таркату һәм чуалту; *шулай ук к.* азар-бизәр итү (китерү). *Алар бу эшне аеры-чөере китереп йөртмичә берьюлы тәмамларга карар биргәннәр иде* (Ш. Маннур).

Төрдәше: азар-бизәр итү (китерү).

*АЖГЫРЫП* ❖ **АЖГЫРЫП ТОРГАН.** Атылып-ашкынып торган кеше, ат һ.б. турында. *Һәр көймәдә ажгырып торган утыз-кырык ир гайрәтләнеп ишкәк ишteләр, төннәрен исә яр буйларына ялга туктадылар* (Ф. Бәйрәмова. Күчем хан).

*АЖДАҺА* ❖ **АЖДАҺА ЕЛАН ҮЗӘГЕ КЕБЕК.** Фольклорда үтә шәп, гайрәтле ат турында. *Була бит, агай, аждаһа елан үзәге кебек кыз!* (Н. Исәнбәт).

**АЖДАҺА КЕБЕК КИКЕРҮ.** Әкиятләрдәге аждаһа еланның йоткан кешене кикереп чыгару үрнәгеннән: бик яман, ямьсез кикерү. – *Нәрсә аждаһа кебек кикерәсең, баланы куркытасың ич!* (Сөйләм).

*АҖАГАН* ❖ **АҖАГАН КАЙНАУ (КАЙНАГАН УРЫН).** Хәрәкәт күп булган урын, ыгы-зыгы. *Аҗаган кайнаган урыннарга керергә куркып, читләтеп үтәргә тырыша* (Сөйләм).

**АҖАГАН ЯКТЫСЫ УЙНАУ.** Бик нык шатлану. *Ата-ана күңелендә моның өчен аҗаган яктысы уйнаячак* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).

Төрдәше: авыз еру 4 һ.б.

*АҖУННЫҢ* ❖ **АҖУННЫҢ АСТЫН ӨСКӘ ӘЙЛӘНДЕРҮ.** Тулысынча үзгәртеп кору, чуалчыклык тудыру. – *Ыру кайгысын кайгыртып йөри, имеш, – үле бүреләр күргән дә, аҗунның астын өскә әйләндерергә дә күп сорамас!* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).

Төрдәше: дөньяның астын өскә әйләндерү.

*АЗ* ❖ **АЗ АЗЫКЛЫ, КҮП ЯЗЫКЛЫ.** Изгелеге аз, гөнаһысы күп булу (кешенең гомерлек эшләгәненең яхшысы һәм начары үлчәме). – *Изгелеген әйтә алмыйм, аз азыклы, күп языклыдыр, ихтимал* (Сөйләм).

**АЗ АЛГАНДА.** Ким дигәндә, кимендә, бер дә булмаса. *Аз алганда, аның аты чабышта өченче урыннан да артта калмаска тиеш* (Сөйләм).

Төрдәше: аз дигәндә; иң азында; иң кимендә.

**АЗ АШЫЙМ, АВЫРМАС БАШЫМ.** Ялкау кеше турында. *Эшкә чыгарга чакырырга килгәндә, аның җавабы әзер: миңа күп кирәк түгел, аз ашыйм, авырмас башым, дип кенә тора ул* (Сөйләм).

**АЗ БУЛСА ДА, КҮП ИТЕП <КҮРЕП> АЛ.** 1. Бүләк яки күчтәнәч тапшырганда әйтелә торган теләк. *Аз булса да, күп итеп ал* (Р. Абдуллина. Сөйләм культурасы). – *Сиңа кечкенә генә күчтәнәч әзерләгән идем, аз булса да, күп итеп күреп ал, зинһар* (Сөйләм).

2. Бурычка биргәндә әйтелә. – *Аз булса да күп итеп ал, соңыннан хисаплашырбыз* (Сөйләм).

Төрдәше: азны күп итеп ал.

**АЗ ГЫНА.** Күп булмаган, күп түгел. *Кешеләрнең күңелен төшермәс өчен, аз гына утанган булып та куя ул* (Сөйләм).

Төрдәше: әз генә; бәләкәй генә; диңгездән бер тамчы 1; кечкенә генә; нәни генә; печтик кенә; тамчы гына.

**АЗ ГЫНА ДА.** Һич тә, бөтенләй. *Дөньяда шундый могҗиза булыр дип, аз гына да башыма китерә алмый идем* (Г. Ибраһимов).
Төрдәше: бөртек тә; тамчы да.

**АЗ ГЫНА ДА ШИКЛӘНМИ<М>.** Бернинди дә шик-шөбһә булмау. *Аның уңышка ирешәчәгенә аз гына да шикләнмим* (Сөйләм).
Төрдәше: шикләнүнең әсәре дә (эзе дә) юк.

**АЗ ДА ТҮГЕЛ, КҮП ТӘ ТҮГЕЛ.** Нәкъ кирәкле күләмдә, артыгы да юк, киме дә. *Аз да түгел, күп тә түгел, бүген үк яучы җибәрерлек килен ләбаса бу сылу-җанашкаем!* (В. Имамов. Карабәк).

**АЗ ДИГӘНДӘ** *к.* аз алганда. – *Аз дигәндә бер капчык цемент кирәк бирегә* (Сөйләм).
Төрдәше: аз алганда; аз куеп (куйганда); иң азында; иң кимендә.

**АЗ КУЕП (КУЙГАНДА)** *к.* аз алганда. *Нәрсә озак уйлап торырга, аз куйганда ун процент табыш бирсә җитәр* (Сөйләм).
Төрдәше: аз алганда; иң азында; иң кимендә.

**АЗ СҮЗЛЕ.** Күп сөйләшми торган. *[Назлыбикә] Ай-яй, иптәшегез бигрәк тә аз сүзле икән* (Ю. Әминов. Язылмаган законнар). *«Ул аз сүзле малай, диләр. Хәтта «телсез!» – диләр иде* (Р. Мингалим. Күңелсез малай).
Төрдәше: сүзгә саран.

**АЗ ТӨШҮ.** Эш хакының зур булмавы. *Эшкә, авылга, малайларга, әтисенең ачуланып чеметеп алуларына, ниһаять, акча аз төшүгә ияләшеп килгәндә генә, бу авылдан китәргә туры килде* (Ф. Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы).

**АЗ ЭШЛИ ДӘ КҮП ТЕШЛИ.** Азрак эшләп, күбрәк акча алырга тырышу. *Аның кыйбласы аз эшлә дә күп тешләүгә корылган, озын акча гына булсын* (Сөйләм).
Төрдәше: аз эшләп күп тешләү.

*АЗА* ❖ **АЗА КУБУ** *диал.* шаяру, азу. – *Нигә әле син һаман Азали дип аза кубасың?* (Х. Сарьян. Башкорт кызы).

*АЗАВЫН* ❖ **АЗАВЫН СЫНДЫРУ.** «Азау тешне сындыру»дан ясалган – комсыз, әрсез кешегә каршы төшү. – *Азавын сындырмыйча булмас, ахрысы, бу юньсезнең* (Сөйләм).

*АЗАГЫ* ❖ **АЗАГЫ ХӘЕРЛЕ БУЛСЫН.** Берәр эшнең уңышлы бетүен теләү. *Хәзер ни эшләмәк кирәк, чыгып качып булмый бит, азагы хәерле булсын* (З. Кадыйрова. Көтеп узган гомер).

*АЗАГЫНА* ❖ **АЗАГЫНА КАДӘР ҖИТКЕРҮ.** Нинди дә булса нәтиҗәгә килү, нәтиҗә алу. *Ул ничектер җаен табып, стипендияне, тарта-суза, ай азагына кадәр җиткерә иде* (Р. Вәлиев. Эт кояшы). *Сезгә урман кисү һәм ташуны азагына кадәр җиткерү бурычы йөкләнә* (Н. Әхмәдиев. Мөнирстан).

**АЗАГЫНА ЧЫГУ.** 1. Төгәлләү, тәмамлау. – *Гомернең азагына чыкмадык бит әле, Габделбәр энем, – диде. – Бурычлы булып калмабыз* (Б. Камалов. Күршеләр).

2. Мәсьәләне тикшереп хәл итү. *Кая ул, Гөлсем эндәшми, азагына чыкмый кала торган кешеме – иртән барыбер әйтте, күрмәдеңме, дип сорамады, ә шундук: – Син генә алгансың, – диде* (Ә. Әминев. Танкист).

*АЗАК* ❖ **АЗАК КИЛЕП.** Соңгы чара итеп; иң ахырында (соңында). *Азак килеп, ул катгый карар кабул итте: мондагы барлык кешене шаккатырып, ашханәдә күрешкәнче, үзе генә чакта кереп сүз башларга* (Б. Камалов. Гомер кичендә).
Төрдәше: азак чиктә; азаккы исәптә (чутта); актык<кы> исәптә; актык чиге<ндә>; актык<кы> чик<тә>; актык чиккә җитү; актык<кы> чиккә кадәр; актык чутта; ахыр чиккә җитеп; ахыр чиктә (чутта); буылып үләр хәлгә җитү; соңгы чиктә (чутта).

**АЗАК ЧИКТӘ** *к.* азак килеп. *Әсәр башындагы түйдә күтәрелгән «гөнаһсыз» стаканнар тора-бара, сиздермичә генә, уңган колхозчы Миңлегалинең чиренә әверелә, шул аркада чибәр килен Айсылу, азак чиктә ирен, гаиләсен ташлап, үз авылына кайтып китәргә мәҗбүр була* (Г. Рамазанов. Заманыбыз шундый булгач...).
Төрдәше: азак килеп һ.б.

*АЗАККА* ❖ **АЗАККА КАДӘР.** Үлгәнчегә кадәр, соңгы сулышын биргәнчегә хәтле. *Азакка кадәр сөйләшеп ятты мәрхүмә* (К. Кара. Күрше хакы). *Тик чыдарга, бу көрәшне дә азакка кадәр җиткерергә кирәк иде* (Р. Мулланурова. Ялгыз каеннан да ялгыз...).
Төрдәше: актыкка кадәр (тикле; хәтле; чаклы); ахырына кадәр; соңына кадәр.

**АЗАККА КАЛДЫРУ**. Иң соңгы эш итеп башкарырга. *Иң шикле кеше – Тол Таҗи йортын тентүне иң азакка калдырганнар иде* (М. Галәү. Болганчык еллар).
Төрдәше: актыкка калдыру.

**АЗАККА КАЛУ.** Барыннан да артта калу. *Терсәкләре янә тишелеп чыккан кофтасын кеше юкта гына кияргә исәпләп, Зифа ул көнне класста иң азакка калды* (В. Имамов. Тозлы яра).
Төрдәше: актыкка калу.

*АЗАККЫ* ❖ **АЗАККЫ<СЫ> БУЛСЫН** *кисәт.* «Башка кабатланмасын, соңгы мәртәбә булсын» теләге. *[Дружинин] Ярый, мә книжкаңны. Бу исеңә төшерү азаккысы булсын* (А. Алиш. Күршеләр).
Төрдәше: азаккысы-соңгысы булсын; актыгы булсын; соңгысы булсын.

**АЗАККЫ ИСӘПТӘ (ЧУТТА)** *к.* азак килеп. *Кыш килешмәгәнне кыланган кебек, яңгырлап сәерсендерсә дә, азаккы чутта, үз сукмагын тапты* (Б. Камалов. Өметең өзелмәсен).
Төрдәше: азак килеп һ.б.

**АЗАККЫ СУЛЫШ (СУЛУ).** Үлем алдыннан кешенең тартылып куюы. *Янындагы шәфкать туташлары яралының азаккы сулыш алуын шәйләп алдылар* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

**АЗАККЫ СУЛЫШ (СУЛУ) АЛУ.** Үлем хәленә җитү. *Инде үлә, азаккы сулышын ала дигәндә генә, күзләрен ачып, нәрсәдер әйтергә омтылды* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

**АЗАККЫ СУЛЫШКА (СУЛУГА) КАДӘР (ХӘТЛЕ).** Үләр көннәренә (минутларына) кадәр. *Гвардиячеләр азаккы сулышларына кадәр дошманны шәһәр читеннән үткәрмичә сугышканнар* (Сөйләм).
Төрдәше: актык патронга кадәр; актык<кы> сулышка (сулуга) кадәр (хәтле); ахыргы сулышка (сулуга) кадәр (хәтле); кабергә кергәнче; соңгы сулышка (сулуга) кадәр (хәтле); тамчы кан калганчы.

**АЗАККЫ СҮЗ**. Соңгы фикерен яки карарын әйтү. *<...> хәбәрне «атау төшемендәге иягә ярашып әйтелгән азаккы сүз» дип тәгъриф итәргә туры килә* (Г. Алпаров. Сайланма әсәрләр).
Төрдәше: актык сүз; соңгы сүз.

**АЗАККЫ СҮЗ ИТЕП.** Нәтиҗә ясап әйтү. *Азаккы сүз итеп шуны әйтәсем килә: мин кайтканда, ишегалдында берәү дә юк иде* (Сөйләм).
Төрдәше: актык сүз итеп; ахыр<гы> сүз итеп; соңгы сүз итеп.

**АЗАККЫ ЧИКТӘ.** Иң ахырында. *Гаепсез кешеләргә үчлелек, азаккы чиктә дөреслеккә, законга үчләнүгә кайтып кала бит!* (Г. Әдһәмова. Үкенечкә калмасын).
Төрдәше: азак килеп һ.б.

**АЗАККЫ ЮЛ.** Зиратка илтеп күмү. *Яңгыр булуга да карамастан, авыл картын азаккы юлга озатырга шактый күп кеше җыелган иде* (Сөйләм).
Төрдәше: ахыргы юл; актык юл; соңгы юл.

*АЗАККЫСЫ-СОҢГЫСЫ* ❖ **АЗАККЫСЫ-СОҢГЫСЫ БУЛСЫН** *кисәт., к.* азаккы<сы> булсын. *– Мыегыңа ура, бу азаккысы-соңгысы булсын, кабатланса – сөйләшеп тору булмас!* (Сөйләм).
Төрдәше: азаккы<сы> булсын; актыгы булсын; соңгысы булсын.

*АЗАКТАН* ❖ **АЗАКТАН <САНАГАНДА> БЕРЕНЧЕ** *ирон., шаярт.* Ярышта, эштә һ.б.да соңгы урындагы. *Татарстан спорт командалары гел азактан беренче булса ни сөйләр идегез икән?* («Матбугат.ру» порталы). *Ул район ярышларында да азактан санаганда беренче килә* (Сөйләм).
Төрдәше: арттан <караганда; санаганда > беренче; арттан караганда алдынгы (алда; беренче); ахырдан <санаганда> беренче.

*АЗАН* ❖ **АЗАН ӘЙТМИ, КАМӘТ ТӨШЕРМИЛӘР.** Эшнең рәтен-тәртибен, кагыйдәсен бозу турында (мәзин азан әйтми торып, намаз укырга керешмиләр). – *Ашыкма, сабыр ит, азан әйтми торып, камәт төшермиләр* (Сөйләм).

*АЗАП* ❖ **АЗАП БЕЛӘН.** Көчкә, көч-хәл белән. *Колчактан өмете киселгәч, Фазыл мең азап белән башкортларга килеп кушылган* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр).

**АЗАП КӨЧӘЮ** *шаярт., ирон.* Көчле теләк туу, бик кирәк булу. *Беркөнне концертта ялтырап торган баянны күреп, азабы гына көчәйде* (Сөйләм).

**АЗАП КҮРҮ (ЧИГҮ).** 1. Рухи җәфалану, эчке кичерешләргә дучар булу. *Ул бу арада әллә нинди хыялый төшләр белән азап чигә иде* (Г. Ибраһимов). *Ни өчен мин өйдән өйгә кунакка йөреп азап чигәргә тиеш?* (Ф. Хөсни. Сабан туе). *Үз-үземнән туйдым?/ Синең өчен булмый, кем өчен мин / Азап чиктем, тойгы?* (Ә. Фәйзи. Флейталар).

2. Кыенлыклар кичерү, азаплану, михнәт күрү. *Бүгенгә кадәр татарларның күбесе игенне Нух заманыннан калган ысул белән игәләр. Шуңа күрә ачлык булган елларда аларның күбрәк азап күрүләре гаҗәп түгел* (Р. Сабиров. Татарстан Җөмһүриятенең икътисади хәле һәм ачлык). – *Сугыштагылары анда кырылыр, мондагылар ятим калып азап чигәр, – диде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: арка тиресен <этләрдән> тунату; арка чиләтү 1; арка чиләндерү; баш нужадан чыкмау; газап күрү (чигү); газап чигеп йөрү; дөнья уңлы-суллы яңаклау; җәфа чигеп йөрү; кайнар тир тозын тату; кара сакал; көн бетү; көн булмау; көн юк; нужа чигү; тарлыкта изелү; тәмуг газабы; эт көнен күрү (ике маддә өчен дә).

*АЗАР-БИЗӘР* ❖ **АЗАР-БИЗӘР ИТҮ (КИТЕРҮ).** 1. Туздыру; әрәм-шәрәм итү; пыран-заран китерү. *Кайберәүләр аларның кадерен белмичә, азар-бизәр китереп, түгеп-чәчеп бетерәләр* (metod-kopilka.ru).

Төрдәше: азар-бизәр килү (булу); аеры-чөере итү (китерү); пыран-заран китерү.

2. Аздырып бетерү, җәфалау, йөдәтү. Баларны *балык тотарга өйрәтәм дип, иртән сәгатьтән күлгә алып китү аларны азар-бизәр китерә генә кебек* (Сөйләм).

3. Күңелне җилкендерү, иләсләндерү. *Күңелне азар-бизәр китерә башлый* (Г. Ахунов).

Төрдәше: аеры-чөере итү (китерү); пыран-заран китерү.

**АЗАР-БИЗӘР КИЛҮ (БУЛУ).** Башсызлану, азу-тузу, мал-мөлкәт тузу. *Хыялый үсмернең күңеле азар-бизәр килмәс борын, аны эш белән күмеп ташларга кирәк* (Г. Ахунов. Этләр патшасы).

Төрдәше: азар-бизәр итү (китерү); аеры-чөере килү (булу); пыран-заран булу.

*АЗАРТ* ❖ **АЗАРТ БЕЛӘН.** Нык мавыгып, дәртләнеп. *Бу юлы алар аеруча көчле азарт белән уйный башладылар һәм, көндәшләре капкасына бер-бер артлы туп кертеп, җанатарларны сөендерделәр* («Әгерҗе хәбәрләре» газ.).

*АЗАРТКА* ❖ **АЗАРТКА БИРЕЛҮ.** Артык мавыгып китү. *Куплетлар танец биюгә күчә, Ризван белән Шәмсия азартка бирелә баралар* (Х. Вахит. Күк капусы ачылса).

*АЗАТ* ❖ **АЗАТ БУЛУ.** 1. Тоткынлыктан яки коллыктан котылу. *Без инде җиребез азат булганчы дип өмет белән яшибез, шатлык көтәбез* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары). *Аның исеме дә Азат, ул гомер буе азат булырга тиеш* (А. Нәҗми. Азат).

Төрдәше: азатлык кояшы туу.

2. Арыну, бушау. *Ясак түләүдән, аманат кызлар озатудан азат булачаксың* (В. Имамов. Казан дастаны).

**АЗАТ ИТҮ.** 1. Эштән, вазыйфа башкарудан азат итү. *Икенче көнне Рәҗәпов хезмәткә китте һәм, бүтән шәһәргә күчәргә җыенуы сәбәпле, үзен эштән азат итәргә сорады* (Г. Кутуй. Вөҗдан газабы). *Хәер, ул вакыйгадан соң, бер атна үттеме-юкмы, аны секретарьлык эшеннән азат иттеләр* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

2. Эшне җиңеләйтү йөзеннән, авыр эштән азат итү. *Кычыткан җыеп, алабута җыеп балаларга аш әзерләп йөргән хатын-кызларны авыр хезмәттән азат итәргә* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).

3. Иреген чикләү. *Азат итүнең төрлесе була. Эштән азат иткәннәр берәүне. Һәм төрмәгә япканнар. Иректән азат иткәннәр булып чыга* (Ш. Галиев. Аклы-каралы дөнья).

4. Тоткынлыктан чыгару. *Инде тоткынлыктан азат ителәсе калган* (Ш. Галиев. Аклы-каралы дөнья). *Чын җинаятьче табылгач, әлбәттә, Муса Салихов азат булачак* (М. Бигиев. Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә).

*АЗАТЛЫК* ❖ **АЗАТЛЫК ҖИЛЛӘРЕ.** Ирекле-лек, бәйсезлек сизелә башлау. *Ниһаять, ирек, азатлык җилләре исә башлагач, ирекле, цивилизацияле дөнья белән арада булган «тимер пәрдә» алып ташлангач, татар халкы, Татарстан күтәрелә башлады: гасырлар буе көткән мостәкыйльлек игълан ителде, татар гимназияләре ачылды, рухи-хакыйкый-бакый юлга чакырып, мәчетләр төзелә башлады* (И. Вәлиулла. Яңа маяклар эзләгәндә...).

**АЗАТЛЫК КОЯШЫ ТУУ.** Иреккә чыгу, тоткынлыктан азат булу. *Мазлумнарга якты, нурлы көннәр килде, – / Азатлыкның кояшы тугды имди* (Г. Тукай).

Төрдәше: азат булу 1.

*АЗАУ* ❖ **АЗАУ ТЕШ КҮРСӘТҮ.** Усаллану, үткенләнү. *Соңгы вакытларда, менә, гел азау тешен күрсәтә башлады, абыйсының бер генә фәрманын да күндәмлек һәм итагать белән кабул иткәне юк* (В. Имамов).

**АЗАУ ТЕШЕ ЧЫГУ (ЧЫГАРУ).** Күпне күрү, нинди дә булса эшнең бөтен нечкәлекләрен белү. *Комсомолда тәрбияләнгән, профсоюзда азау теше ярган, меңнәрнең күңеленә рөхсәтсез кереп гадәтләнгән Латыйпов Наиләнең ни өчен йөргәнен ишек бавына тотынгач та белгән иде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: азау теше чыккан <инде>; азу теше чыккан <инде>; аның бу эштә теше коелган инде; азау ярган.

**АЗАУ ТЕШЕ ЧЫККАН** *к.* азау теше ярган <чак> 1–5. *Ә ул букчаны тукталышта алып чыгып киткән кешене сез азау теше чыккан бандит яисә карак дип уйлыйсызмы?* (Р. Зәйдулла. Син, мин, Мөхәммәтәмин...).

Төрдәше: азау теше ярган <чак> 1–5.

**АЗАУ ТЕШЕ ЯРГАН <ЧАК>.** 1. Балигъ булган, акыл теше чыккан. 1. *Егетнең нәкъ азау төше ярган чагы инде, Разия карчыга тырнагына эләккән чебеш кенә булган шул ул чакларда...* (Т. Мөбарәков). *Яшүсмер түгел инде ул хәзер, барысын да аңлый – азау теше ярган чагы* (Сөйләм).

2. Тәҗрибәле, күпне күргән (25–26 яшь тирәсе). *Моңа кадәр гади гражданнар алдында аклануның ни икәнен белмәгән, азау теш ярган участок милиционеры әле генә әйтелгән каһәр сүзләреннән шомланып калды* (Н. Әхмәдиев. Мөнирстан). / Аерылу мәсьәләсен хәл итү. *Анда үзе генә әвеш-тәвеш китереп кайтты, бу мәсьәләдә алар азау теше ярган нәсел, тәҗрибәле* (Р. Мөхәммәтша. Тырыйк).

3. Гайрәтле, усал, баш бирми торган кеше турында. *Шундый халык авылда биш-алтыга җыелды. Иң азау теше ярган икесен утырттылар* (Г. Ахунов. Чикләвек төше). *Әлбәттә, азау ярган авыл бичәләре аны өнәмәде, хәтта ки исемен оныткан төсле, «теге йомыкый» дип кенә җибәрәләр иде* (Н. Гыйматдинова. Кәтәнә).

4. Яше җитеп узган сазаган кыз турында. *Инде аларның Гөлҗамалларының азау теше ярганына да ун еллап бардыр* (Г. Камал).

5. Елкы көтүенең башы булган көчле, усал, тешләк айгыр. – *Көтүгә якынлашма! Күрмисеңмени, азау теше ярган айгыр сиңа ничек карап тора* (Сөйләм).

Төрдәше: азау <теш> яру; азу теш чыккан (ярган) (барлык мәддәләр өчен дә).

**АЗАУ ТЕШЕН АШАГАН.** 1. *к* авырның өстеннән, җиңелнең астыннан 2. *Аның шикелле азау тешен ашаган кешеләрне эзләп табарга кирәк әле!* (Сөйләм).

Төрдәше: авырның өстеннән, җиңелнең астыннан 2 һ.б.

2. Күп яшәгән, азау тешләре беткән; булдыклы кеше турында. *Авылда халык кимегән хәзер, азау тешен ашаган картлар гына калган диярлек* (Сөйләм).

**АЗАУ ТЕШЕН КҮРСӘТҮ.** 1. Усал булу, үз сүзеңне үткәрә белү. *Ә урыслар Бату бабабыз аларның олыс-калаларын буйсындырганнан бирле узган йөз илле елдан соң беренче мәртәбә Урда гаскәренә азау тешен күрсәтте* (В. Имамов. Карабәк).

**АЗАУ ТЕШЕН ЧЫГАРУ.** Үткенләнү, баш бирмәү. *Тегеләр дә азау тешен чыгарган эт җаннар, чатан әмирнең мәкерен алдан ук сизенеп, Нур-Суардан качып өлгергәннәр* (В. Имамов. Казан дастаны). *Сәясәттә азау теше чыгарган – Ышандыра... ышана үз сүзенә!* (Р. Рахмани. Тынычлык).

2. Тәҗрибә туплау. *Шулай беркөнне редакциядә азау теше чыгарган хезмәттәшләре Мансурның кулына «Теләнче журналист» кагыйдәләре җыелмасын тоттырдылар* (М. Әмирханов). – *Мин Мәскәүгә азау тешен чыгарган, чәч чаларган әмиремне кудым, ә ул Сарайны тизәккә батырып, аны сатып кайтты* (В. Имамов. Карабәк).

**АЗАУ ТЕШЛӘРЕН ҖИМЕРҮ (КОЮ, СУЫРЫП АЛУ)** *к.* авыз җебетү 2. *Шиңдердек без [дошман] кикриген, / Азау тешен алдык суырып* (Ш. Маннур).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АЗАУ ЯРГАН.** Күпне белүче, тәҗрибәле. – *Ул инде азау ярган бүре* (Р. Батулла). – *Үтә хәйләкәр, мәкерле бу адәм бер үк вакытта Германия һәм Япония файдасына эшләүче азау ярган шпион, корткыч та* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет). *Тәҗрибәсе җитәрлек, азау ярган спортчы* (М. Әмирхан).

Төрдәше: азау теше чыккан <инде>; азу теше чыккан <инде>; аның бу эштә теше коелган инде.

**АЗАУ <ТЕШ> ЯРУ** *к.* азау теше ярган <чак> 1– 5. *Бар өммәтең, / Шәрәлекнең җитте чигенә. / Азау ярган вәзир-яраннарың / Шәрә калдырмасмы сине дә?* (Г. Морат. Шамакай).

Төрдәше: азау теше ярган <чак> 1–5.

*АЗАУЛЫГА* ❖ **АЗАУЛЫГА БАР ЗАМАН, АЗАУСЫЗГА ТАР ЗАМАН**. Гади һәм гадел кешеләргә авыр чор килүен белдерә. *Яңалык түгел бу, ничәмә дәвер шулай килгән инде: азаулыга бар заман, азаусызга тар заман* (Сөйләм).

*АЗГА* ❖ **АЗГА ШӨКЕР ИТҮ**. Булганына да канәгать булып яшәү. *Гомумән, ул бик азга да шөкер итәргә өйрәнгән, ахрысы* (Ә. Еники. Туган туфрак).

*АЗГАН-ТУЗГАН* ❖ **АЗГАН-ТУЗГАН БӘРӘҢГЕ.** Туры һәм күчерелмә мәгънәләрдә кулланыла – төрен-шәкелен югалткан, сорты башка сортлар белән катнашкан, үзле-базлы бәрәңге. – *Кара инде кыяфәтенә, бөтенләй азган-тузган бәрәңге булып беткән* (Сөйләм).

*АЗГЫН* ❖ **АЗГЫН ТАМАК.** Гел аны-моны кабарга эзләнеп йөрүче ашамсак кеше. *Теге азгын тамак Фәхри килеп җиткәнче, ишекне ябып куябызмы әллә?* (Сөйләм).

**АЗГЫН ТӘН.** Кабарчыклар чыга торган, аллергияле тән. – *Аның тәне артык йомшак шул, азгын тән* (Сөйләм).

*АЗГЫНЛЫК* ❖ **АЗГЫНЛЫК САЗЫНА БАТУ.** Әхлакый һәм җенси бозыклыкта булу. *Төзәтсә, кабер генә төзәтә алыр аны – азгынлык сазына кереп баткан ул* (Сөйләм).

*АЗДАКЫ* ❖ **АЗДАКЫ КӨЯНТӘСЕ (КҮВӘНДӘСЕ).** Усал карчык, убыр. *Теге аздакы көянтәсенә кара әле, чыннан да Аздакы нәселеннәндер ул* (Сөйләм).

*АЗДАН* ❖ **АЗДАН <ГЫНА> КАЛУ.** Аз гына булмый калу. *[Шульдери] (халыкка). Җитми егеткә... Бик аздан калган* (Д. Салихов. Гыйлаҗ тәрәзәләре).

**АЗДАН КҮҢЕЛ БУЛУ, АЗДАН (ЮКТАН ДА) ХӘТЕР КАЛУ.** Кешегә яшәү өчен күп кирәк түгеллеге хакында. *Аздан күңел була, аздан хәтер кала, диләр бит* («Арча хәбәрләре» газ). *Аздан күңел була, юктан да хәтер кала, диләр* («Безнең гәҗит» газ.).

**АЗДАН <ГЫНА> ТОРУ.** Эш бик кечкенә, әһәмиятсез нәрсәгә терәлеп калу. ...*Ә чын язмыш / Үзең язган гына. / Аздан тора дәвам, / Аздан гына...* (Р. Миңнуллин).

*АЗМЫ* ❖ **АЗМЫ ҮТКӘН, КҮПМЕ ҮТКӘН** *әкият.* Шактый гына вакыт үтү. – *Азмы үткән, күпме үткән тигәнәк кебек кыз гүзәл бер сылу булып үсеп җиткән* (Сөйләм).

*АЗНЫ* ❖ **АЗНЫ КҮП ИТЕП АЛ** *к.* аз булса да күп итеп <күреп> ал 1. *Азны күп итеп ал* (Р. Абдуллина. Сөйләм культурасы). – *Аз булса да, ихлас күңелдән, азны күп итеп ал* (Сөйләм).

Төрдәше: аз булса да, күп итеп <күреп> ал 1.

*АЗРАЕП* ❖ **АЗРАЕП ЙӨРҮ** *диал., к.* адраеп йөрү. *Күршеләрдә нәрсәдер булган, ахры, иртәдән азраеп йөриләр* (Сөйләм).

Төрдәше: адраеп йөрү; адраеп килеп керү.

*АЗРАК* ❖ **АЗРАК БАШ-КҮЗ АЛУ.** Мәшәкатьтән арыну, тынычланып иркенәеп калу, бушау. – *Азрак баш-күз алыйк, хәл җыйыйк, аннары инде бу хакта да уйлашырбыз* (Ә. Еники. Рәшә).

*АЗУ* ❖ **АЗУ ТЕШ ЧЫККАН (ЯРГАН)** *к.* азау теше ярган <чак> 1–5. *Милиция постлары оешырырга, азу теше ярган хулиганнарны җыеп ябарга кирәк* (Г. Ахунов. Ардуан батыр).

Төрдәше: азау теше ярган <чак>; азау <теш> яру.

**АЗУ ТЕШЕ ЧЫККАН <ИНДЕ>** *к.* азау теше чыккан <чак> 2. – *Азу теше чыккан инде, аңа акыл өйрәтәсе юк* (Сөйләм).

Төрдәше: азау теше чыккан <чак> 2; аның бу эштә теше коелган инде; азау ярган.

**АЗУ ЯРГАН.** Усал, үткен**.** *Мондый егетләрне табуы кыен булмас анысы: акча дигәндә, теләсә нинди эшкә бара торган азу ярган егетләр бар...* (Х. Ширмән. Ерактагы йолдызым).

**АЗУ <ТЕШ> ЯРУ** *к.* азау <теш> яру 3. *Ни дисәң дә, малай-шалай түгел болар – азмы-күпме күргән, азу теше ярган, салмакланган ирләр* («Казан утлары» ж.).
Төрдәше: азау <теш> яру 3.

*АЗЫН* ❖ **АЗЫН КҮП САНАП, КҮБЕН ЮК САНАУ.** Чынбарлык белән исәпләшмичә, үзенә кирәгенчә чынбарлыкны бозып сөйләү; юкны бар итеп, барны күрмәмешкә салыну. – *Бик авызыңны җәеп тыңлап утырма, азын күп санап, күбен юк санап яшәргә күнеккән ул* (Сөйләм).

*АЗЫП-ТУЗЫП* ❖ **АЗЫП-ТУЗЫП БЕТҮ.** Азгынлыкка чыгу, кешелек сыйфатларын югалту. *[Былбыл] Нәрсә өчен? Азып-тузып беткән Шәйхенурларны якларга теләмәгәнем өченме?* (Ю. Әминов. Язылмаган законнар).
Төрдәше: азып-тузып йөрү; уйнаш итү.

**АЗЫП-ТУЗЫП ЙӨРҮ.** Әхлак нормаларына сыймаган рәвештә яшәү. *[Фәтхерахман] Азып-тузып йөргән Әнвәр бай, акчага сатылган Мөгълифә ярдәмендә бәхетле, яңача тормышлар вәгъдә итеп, аны алдый, сөяркә итеп тотмакчы була* (Г. Камал. Уйнаш). – *Синең хакта сораша да җылый, аннан бөртекләп сарайга: «Анысы да шәһәргә китеп азып-тузып йөрмәсен...» – ди* (А. Алиш. Якты күл буе).
Төрдәше: азып-тузып бетү; уйнаш итү.

*АЙ* ❖ **АЙ АЛЛА<М> (АЛЛАКАЕМ; АЛЛАКАЙ ГЫНАМ).** Чиксез гаҗәпләнү яки ризасызлык белдерү, шатлану кебек хисләрне белдерү өчен кулланыла. *[Әсма] Ай Алла, әллә йорт анасы чуалткан инде, һич чишәр хәл юк* (К. Тинчурин. Казан сөлгесе). – *Ай Аллакаем, минем өчен борчыла ул...* (И. Нәбиуллина. Ташта үскән гөл).

**АЙ ӘТТӘ <ГЕНӘСЕ>.** Борчылу ымлыгы – берәр эштә кинәт тоткарлык, комачау килеп чыкканда, ризасызлык, борчылу белән әйтелә. *Ай әттә генәсе, минем Җәмиләмнең борынын җимермцсәләр ярар иде* (М. Фәйзи).

**АЙ БАТЫП, ЧУЛПАН КАЛЫККАНЧЫ.** Төн буе йокламыйча, зарыгып көтү турында. *Өйдәгеләр, буран ыжгыруын тыңлап, ай батып чулпан калыкканчы, хуҗаның кайтуын көттеләр* (Сөйләм).

**АЙ БЕЛӘН КӨНДӘЙ, ҺӘРКЕМГӘ БЕРДӘЙ.** Һәр кешегә дә игелекле, яхшы булу. *Яхшы кеше ай белән көндәй: яхшылыгы һәркемгә бердәй* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

**АЙ БИРДЕ, КОЯШ АЛДЫ (КҮПСЕНДЕ).** Күзгә бик азга гына күренеп, тиз югалу турында. – *Чишмә янында ялгыш кына бер тапкыр шәл чите ачылып киткән иде. Ай бирде, кояш алды...* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).
Төрдәше: «а» дигәнче; ай күрде, кояш алды 1; ай күрде, кояш алды, җил очырып китте; ай күрде, көн алды (йотты); ай күреп кояш алганчы; айт дигәндә; артыннан күз дә иярмәү; ат белән чаба атна аралары; аяк җиргә тимәү 1; аяк җиргә тияр-тимәстән; аяк идәнгә тимәү; аяк очы җиргә тимәү; аяк табаннарына ут капкандай; аяк тигән җиргә тия, тимәгән җиргә тими (юк); «ә» дигәнче; «әһ» дигәнче; бар көченә; бер аягың өйдә калсын; бер аяк анда, бер минут эчендә; берсе монда <булу>; җан-фәрманга <чабу>; җилдәй очу; керфек кагып, күз ачып йомарлык ара<да>; күз ачып йомган (йомганчы); күз ачып йомган арада; китап күләгәсе күмелеп тормады; койрыгын да күрми калу; көн күрде, кояш алды; күз ачып йомарлык (йомган) ара<да>; күз ачып <күз> йомганчы; күз йомган арада; күз йомганчы; күз күрде, кулга тимәде; күзгә күренде, кулга эләкмәде; күләгәсен дә күрми калу; күргәне күреп калсын, күрмәгәне торып калсын; кызу тоту; өч басасын бер басу; сул кулың белән биргәнне уң кулың күрмәсен; ут алырга кергәндәй; ут булды да су булды; ут урынына куыру; ут урынына чабышу; үкчәсе җиргә тимәү; «һә» дигәнче; «эх» («эһ») дигәнче; ялт иттерү; янгынга чапкан кебек; яшен аткан шайтан кебек; яшен ташыдай <кылану>; яшен тизлеге белән (тизлегендә); яшен төсле атылу; яшендәй узу; яшеннән качкан шайтан төсле.

**АЙ БИТЕН ЮУ.** Яңа ай башында яңгыр булганда әйтелә. *«Ай битен юганда» – аның тарафыннан зур көч куеп, унбиш ел дәвамында алып барылган эшнең нәтиҗәсе* [tt.wikipedia.org].

**АЙ ДА ВАЙ.** Елаш-көлеш, ызгыш-талаш, буталыш барганны әйтү. *Кузгатыйк без эшчән илнең дәрт-моңын, / Яңгырасын җирдә шатлык ай да вай!* (Н. Исәнбәт).

**АЙ ДА КОЯШ КЕБЕК.** Үзара яхшы мөнәсәбәттә булган кешеләрнең якты чырайлы, тату яшәүләрен чагыштыру. *Күршеләр ни гомер*

*инде ай да кояш кебек: талаш-низаг да юк, бер-берсеннән көнләшү, юк-бар сүз сөйләү дә юк* (Сөйләм).

Төрдәше: ай кебек калкырга да кояш кебек балкырга; ай-кояш кебек.

**«АЙ» ДИП ҖИБӘРҮ.** Кинәт килеп туган нинди булса да бер сәбәптән (авыртудан, куркудан, гаҗәпләнүдән һ.б.) «ай» дигән аваз чыгару. *Җилкәсенә кагылган идем, һич көтмәгән, ахрысы, «ай» дип җибәрде* (Сөйләм).

**АЙ ДИСӘҢ АВЫЗЫ, КӨН ДИСӘҢ КҮЗЕ.** Бик матур, күркәм кеше турында (ай һәм кояш белән чагыштыру). *Ай дисәң авызы, көн дисәң күзе инде, башка әйтерлек бер сүзем дә юк* (Сөйләм).

**АЙ, ҖЫК ТИГЕРЕ.** Каргау сүзе; эшне бозачак яки бозган вакытта әйтелә (авыру бул). *Сыерлар мөгрәгән, бозаулар кычкырган, кәҗәләр бакырган, «Түгәнәй, кая барасың, ай, җык тигере, җибәрмә, Галәви», кебек тавышлар ишетелә* (М. Фәйзи).

**АЙ ИКЕГӘ ЯРЫЛУ.** Искиткеч могҗизаны тиңләштереп әйтү. *Пәйгамбәрнең вафатыннан соң асла могҗиза булмас, / Ярылмас ай икегә, һәм кара таштан төя тугмас* (Г. Тукай. Могҗиза). *Бервакыт корәеш кабиләсе кешеләре Мөхәммәт галәйхиссәламнән могҗиза күрсәтүен үтенгәч, ул күктәге айны икегә аерган* (А. Тимергалин. «Миллият» сүзлеге).

**АЙ ЙӨЗ<ЛЕ>.** Ягымлы, ачык чырайлы. *Әгәр җәннәттә күрсәм бән йөзеңне, / Күрермен ай йөзеңдә үз йөземне* (Г. Тукай). *Йолдыз күзле, ай йөзле, / Зифа буйлы бер кыз бар* (М. Җәлил).

Төрдәше: ай кебек.

**АЙ ЙӨР, АМАН ЙӨР.** Юлга чыкканда яхшы теләк буларак әйтелә. *Юлга озатканда: «Ай йөр, аман йөр!»* (Р. Безертинов. Тәңречлек).

Төрдәше: ай йөре дә сау йөре; айдан ару бул, ак булсын юлың, уң булсын; Алла Тәгалә әүвәлен, ахырын хәерле кылсын!; Алла Тәгалә изге сәгатьтә кылсын!; Алла юлдаш булсын!; Алладан кайтсын; аман йөре дә сау йөре; Аллаһы Тәгаләнең амин дигән сәгатенә туры килү; барыр юлларында Ходай һидаятен ачсын; йөргән аягың савапка бетсен; фәрештә юлдашың булсын!; фәрештәләр юлыңа ак гөлләр чәчсен; хәерле сәгатьтә булсын; хәерле сәфәр!; хәерлегә булсын; юлларыгыз (юлларың) уң булсын; юлларыңа ак җәймә!; юлыгызга фәрештәләр гөл сипсен!; юлың ак сөттәй <булсын>; юлыңа <ак> җәймә!

**АЙ ЙӨРЕ ДӘ САУ ЙӨРЕ** 1. *к.* ай йөр, аман йөр. *Аз йөре дә сау йөре!* (Р. Безертинов. Тәңречелек).

2. Берәр егет белән дуслашып йөргән вакытында буй җиткән кызга кисәтеп әйтелә. – *Кызым, дустың бик шома егеткә охшап тора, ай йөре дә сау йөре!* (Сөйләм).

Төрдәше: ай йөр, аман йөр һ.б. (ике маддә өчен дә).

**АЙ КЕБЕК.** Айга охшаш яшь, чибәр һәм ачык йөзле булу. *Күз кырые белән бер генә мәртәбә карап күрде ки, тулган ай кебек нурлы йөзе кичәләрдә айга, көндезләрдә кояшка ихтыяҗ калдырмас, җәмал бакчасыны алмасы тәмам пешеп җиткән вә кәмаль гөлстаныының гөлләре тәмам ачылган* (К. Насыйри. Әбүгалисина кыйссасы).

Төрдәше: ай йөз<ле>.

**АЙ КЕБЕК КАЛКЫРГА ДА КОЯШ КЕБЕК БАЛКЫРГА** *к.* ай да кояш кебек. *Ай кебек калкырга да кояш кебек балкырга* (К. Насыйри. Мәкаль һәм әйтемнәр).

Төрдәше: ай да кояш кебек.

**АЙ КИТКӘН, ЕЛ КИТКӘН, ЭНӘ БУЕ ҖИР КИТКӘН** *әкият.* Әкияттән алынган: теле белән күп сөйләсә, дә бер урында таптануы турында. *<...> чират та кузгала: әкрен генә бер алга этеләләр, бер артка чигәләр. Ай киткән, ел киткән, энә буе җир киткән шул үзедер, мөгаен* (Р. Мулланурова. Ялгыз каеннан да ялгыз...).

**АЙ КҮРДЕ, КОЯШ АЛДЫ.** 1. *к.* «а» дигәнче. *Зөлфияне ай күрде, кояш алды, көтү куалар икән* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала). *Әткәйне ай күрде, кояш алды: мин аны куып җиткәндә, ул урам коесы турында иде инде* (Н. Гамбәр. Әткәй белән сөйләшү).

2. Кинәт юк булу. *Кызыллар тәмам якынлашкач кына киткәндер, мөгаен, ләкин без белми дә калдык. Әйтерсең ай күрде, кояш алды бу бик сәер әфисәр абыйны!..* (Ә. Еники. Соңгы китап). *Ай күрде, кояш алды*

*дигәндәй, көннәрнең берсендә чуар тавык каядыр югалды* (А. Алиш. Чуар тавык).
Төрдәше: «а» дигәнче һ.б. (ике маддә өчен дә).

**АЙ КҮРДЕ, КОЯШ АЛДЫ, ҖИЛ ОЧЫРЫП КИТТЕ.** Тиз генә арада юкка чыгу (күбрәк күреп-күрешеп киткән кеше турында). *Ай күргән, кояш алган, җил очырып киткән* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.). *Күрәсең, бу сүзләрне ай күргән, кояш алган, җил очырып киткән һәм вәссәлам!* («Шәһри Казан» газ.).
Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**АЙ КҮРДЕ, КӨН АЛДЫ (ЙОТТЫ)** *к.* «а» дигәнче. *Минем бәхетем-шатлыгым китте, ай күрде, көн алды* (С. Сөләйманова).
Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**АЙ КҮРЕНГӘНЕН ТИЛМЕРЕП КӨТКӘН ЯБАЛАК КЕБЕК.** Гашыйк кешенең сөйгәнен көткән халәте белән чагыштыру. – *Аңлыйсыңмы, сөеклем, ай күренгәнен тилмереп көткән ябалак кебек зарыгып көтәм мин сине* (Сөйләм).

**АЙ КҮРЕП КОЯШ АЛГАНЧЫ** *к.* «а» дигәнче. *Аларның һәммә эт тәртибен белүенә, ялт иттереп, ай күреп кояш алганчы башкарып ташлауларына сокланмый мөмкин түгел иде* (Ф. Яхин. Багана фалы).
Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**АЙ ӨЗЕГЕ.** Бер ай бетеп, икенчесе башланганчы, кайвакыт була торган яңгырлар чагы. – *Ай өзеге булса, килеп йөрмә* (Сөйләм).

**АЙ РӘХМӘТ ТӨШКЕРЕ, <КУЛЫҢА ГӨЛЛӘР ҮСКЕРЕ>.** Яхшылык эшләгән өчен рәхмәт сүзе. *Хуҗа хатын, җиңел сулап: – Ай рәхмәт төшкере! – дип куйды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Ай рәхмәт төшкере, кулыңа гөлләр үскере!* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).

**АЙ СУККАН <КЕШЕ>** *ирон.* Айга карап моңаеп, бер-бер хыялга бирелгән кеше, гашыйк яки меланхолик. – *Ай суккандыр аңа, һәр көн кичен шушы баскычка чыга да айга күзен тегеп утыра* (Сөйләм).

**АЙ ТОТЫЛУ.** Ай белән кояш арасына җир шары кереп узган вакытта айның күренмәве. *Кылны кырыкка ярырдай булып Болгар диварлары тышында йөгергән чакта кирмән эченнән ай тотылган төсле гаҗәп хәбәр* (В. Имамов. Карабәк). – *Чираттагы ай тотылу кайчан булырга мөмкин, хәзрәт, минем бик беләсем килә, – дип, Гәүһәршад көтепханәчегә үтенечле караш ташлады* (М. Әмирханов. Гәүһәршад).

**АЙ ҮСӘСЕН КӨН ҮСӘ, КӨН ҮСӘСЕН ЕЛ ҮСӘ** *ирон.* Үрчемәгән эш турында (баланың тиз үсүен истә тотып, киресенчә булганлыгына ишарә). – *Алай бик ашыкма, бабайлар ни дигәннәр: ай үсәсен көн үсә, көн үсәсен ел үсә* (Сөйләм).

**АЙ ҮСӘСЕН КӨН ҮСҮ, <ЕЛ ҮСӘСЕН АЙ ҮСҮ>** *к.* аен – көн, елын ай үсү. *Бу егетләр, ай үсәсен көн үсеп, ел үсәсен ай үсеп дигәндәй, бик тиз вакыт эчендә дәү булып җиткәннәр, ди* («Таңбатыр» әкияте). *Тап ярыңа гөл орлыгы төшсә, / Ай үсәсен, никтер, көн үсә* (Зөлфәт. Коргылды).
Төрдәше: аен – көн, елын ай үсү; ел үсәсен ай үсү; су сибеп үстергәндәй.

**АЙ ЮКТАН ЧЫРА<Г>.** Асыл, төп әйбер булмаганлыктан, башка затсыз нәрсәгә канәгать булырга мәҗбүрлек. – *Ай юктан чыра дип, табында булган белән сыйланыгыз инде* (Сөйләм).

**АЙ ЯКТЫСЫ СУ КЕБЕК.** Айлы аяз төн. – *Тын бакчада кошлар сайрый, / Ай яктысы су кебек; / Көмеш төсле ай нурлары / Нигәдер моңсу кебек* (Ә. Ерикәй).

*АЙ-ВАЕНА* ❖ **АЙ-ВАЕНА КАРАМАСТАН (КАРАМЫЙ).** Кешенең каршы килүенә дикъкать итмичә, көчләп булса да берәр нәрсәне эшләтү. *Нәҗип Йосыф улы Нургалиевнең кыюлыгы җитәр, ярдәмче марҗаның ай-ваена карамастан, ул Фәридун Фазлыевны җитәкләп, Иван Иванович янына барып керер <...>* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: ай-ваена куймау.

**АЙ-ВАЕНА КУЙМАУ**. Риза булмау, каршы торуга карамастан уйланылган эшне эшләү. *Алай итеп булмаган, / Ай-ваена куймаган* («Исхак бай» бәете). *Отчетны уңышлы тапшырган куанычтан Гайния ашап тормаска, хәзер үк кайтып китәргә дә риза иде. Кая ул – Мисбах абыйсы ай-ваена куймады* (Н. Әхмәдиев. Мөнирстан).
Төрдәше: ай-ваена карамастан (карамый).

*АЙ-ВАЙ* ❖ **АЙ-ВАЙ ИТҮ.** 1. Берәр нәрсәгә каршы килү, риза булмыйча еламсырап кычкыру; айвайлау. *Иртәгесен сыерым җитәкләп, мин / Алып киттем күрше базарга; / «Ай-вай!» итеп, үкереп-үкереп елап, / Хатын егылып калды амбарда* (Ш. Маннур).

2. Кычкыру, сөрән салу. *Күп тә үтмәде, өй эченнән «ай-вай» иткән тавышлары ишетелә башлады* (Сөйләм).

3. Авыртудан ыңгырашу. *Теге егеткә нәрсәдер булдымы шунда, эш коралын ташлап, «ай-вай» итә башлады* (Сөйләм).

**АЙ-ВАЙ КИЛҮ.** 1. Бәла-каза, кайгы, үлем килсә елау-сыктау. *Машина каза урынына килеп җиткәндә, анда «ашыгыч ярдәм машинасы» утларын яндырып тора, ай-вай килүләр дә тына башлаган иде* (Сөйләм).
Төрдәше: ай-вай салу 1.

2. Куанычтан шаулау. *Ярышта беренчелек аларга бирелү хәбәрен алуга, бүлмәдәгеләр, сикергәләп, ай-вай килә башладылар* (Сөйләм).
Төрдәше: ай-вай салу2.

**АЙ-ВАЙ САЛУ.** 1. Акыра-бакыра башлау. *Почтадан алып кайткан хатны укып та бетермәде, куллары калтырап китте һәм ай-вай салырга тотынды* (Сөйләм).
Төрдәше: ай-вай килү 1.

2. Каравыл кычкыру. *Артына борылып караса, кара битлекле кешене күрде дә ай-вай салырга тотынды* (Сөйләм).
Төрдәше: ай-вай килү 2.

*АЙ-ВАЙГА* ❖ **АЙ<ГА>-ВАЙГА КАРАМАУ (КАРАМАСТАН; КАРАМЫЙЧА; КУЙМЫЙЧА).** Ризасызлык яки каршылыклар белән хисаплашмыйча. *[Җәмилә] Аннан чыккач, Вәли бай Мәфтухасына да кереп чыктым, ул да, ай-вайга карамыйча, чәй эчертте* (Г. Камал. Бәхетсез егет). *Аннары миндә җыр-музыкага күпмедер сәләт барлыгын белгәч, әнием әтиемнән, ай-ваена карамыйча, пианино да алдыртты* (Ә. Еники. Гөләндәм туташ хатирәсе).
Төрдәше: вайга карамау.

*АЙГА* ❖ **АЙГА БЕР <ДӘ> КАЙДА БЕР <ДИГӘНДӘЙ>.** Ара-тирә, сирәк күренә торган тансык әйбер турында. *Яхшымы-яманмы, телевидениедән айга бер, кайда бер дигәндәй, төрле милләтләрнең әдәбиятына, мәдәниятенә кагылышлы тапшырулар күрсәтәләр иде* (Р. Вәлиев. Дөнья гаме).
Төрдәше: айда бер <дә> кайда бер <дигәндәй>.

**АЙГА КҮЛМӘК КИЕРТМӘҮ.** «Табигый матур кешене киендерергә-ясандырырга кирәкми» мәгънәсендә. *[Мөгълифә] Зарар юк, зарар юк, матур булгач, киенмәсәң дә ярый ул. Айга күлмәк киертмиләр* (Г. Камал. Уйнаш).

**АЙГА <-КӨНГӘ> СИКЕРҮ.** 1. Артык масаю, үз чамасын белми кылану. – *Үз чамагызны онытып, ахмак арысландай айга сикерәсез...* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *Болай үзе күрер күзгә әллә ни зур бай булып та кыланмый, сөйләшкәндә дә айга сикереп сөйләшми иде, ә үзе шулай да эшне зурдан йөртә торган кеше икән* (Ф. Хөсни).

2. Азу-тузу. *Кайсысы, бераз «тотып» алуга, айга сикерә иде, минкемлек дәгъвасын өстәлгә ыргытып, афәринлек келәменең тузанын кагарга тотына* (Ф. Яхин. Атаман).

3. Бик нык шатлану. *Откан көнне айга сикерә, кузналарын саный, аларны яшереп куя да: – Әни, ашыйсым килә-ә! – дип кычкыра* (Р. Батулла. Апуш-Тукай). – *И сөенеченнән айга сикерә* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: авыз еру 4.

**АЙГА УТЫЗ КӨН** *ирон.,шаяру к.* аена утыз көнгә яллану. *[Тимербай] Күпме жалованиe бирәләр? [Мәтәли] Айга утыз көн, ди* (Т. Гыйззәт).
Төрдәше: аена утыз көнгә яллану.

**АЙГА ШЫҢШЫГАН ЭТ КЕБЕК** *мыск.* 1. Җырлыйм дип, авыз күтәреп улап утыру. *Мин үзем җырга һәвәс түгел, Газиз, айга шыңшыган эт кебек кенә, ләкин җырлаган кешеләргә мөкиббән китәм* («Мәйдан» ж.).

2. Кирәкмәгәнгә шыңшып елау. – *Ачуымны китереп, айга шыңшыган эт кебек утырма инде, сөрт күзләреңне* (Сөйләм).

*АЙГАЙ* ❖ **АЙГАЙ САЛУ.** 1. Төрле сәбәпләргә (шатлану, бәла-каза һ.б.) бәйле булган шау-шу тавышлары. – *Нәрсә анда күршеләр айгай сала, берәр нәрсә булган мәллә?* (Сөйләм).

2. Җыр-көй, музыка тавышын көчәйтү. – *Бераз айгай сал әле, машинада кем килгәнен күрсеннәр* (Сөйләм).

*АЙГЫР* ❖ **АЙГЫР АШАК.** Тик тора алмаучы, нәрсәгә булса да атланырга торучы кыбырсык кеше турында. – *Синең белән килгән теге айгыр ашак кем ул?* (Сөйләм).

**АЙГЫР КЕБЕК.** Ат кебек таза. *Ул да түгел, айгыр кебек бер тазасы кочаклап алды да, көлә-көлә, колак төбемдә әллә ниләр пышылдарга тотынды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Айгыр кебек мужик рәхәтләнеп пенсия алып ятсын, имеш!* (Аманулла. Үтүк).

**АЙГЫР КЫТЫГЫН КАЧЫРУ.** Кулга өйрәнмәгән кырыс айгырны дулатып чаптырып, камчы һәм авызлыкка күнәргә мәҗбүр итү. *Бүген айгырның кытыгын качырып карарга кирәк булыр, диде* (Ф. Хөсни).

*АЙДА* ❖ **АЙДА БЕР <ДӘ> КАЙДА БЕР <ДИГӘНДӘЙ>** *к.* айга бер <дә> кайда бер <дигәндәй>. *Шуңа күрә Шәңгәрәй дә мондый эшләрне вакка санап, алар турында айда бер дә, кайда бер генә исенә төшерә...* (И. Гази. Тел ярасы). *Сирәк-мирәк, айда бер, кайда бер дигәндәй, намазлык өстенә менеп төшкәләсә дә, Кыяметдин бабай моңарчы артык диндар карт түгел иде...* (Г. Сабитов. Хәвефле җәй).
Төрдәше: айга бер <дә> кайда бер <дигәндәй>.

**АЙДА БЕТМӘС АЮ ИТЕ.** Гел кабатланып туйдыра торган, озак сузылган эш турында. – *Каян таптың бу акчасы да төшәрлек булмаган эшне, бабай әйтмешли, айда бетмәс аю ите* (Сөйләм).

*АЙДАГЫ<Н>* ❖ **АЙДАГЫ<Н> АЙГА.** Үтисе эшне үз вакытында эшләү. *Айдагын айга түләп барганда, кыйбатлыгы әллә ни сизелми икән* (Сөйләм).
Төрдәше: айны айга ялгау (ялгап бару); айныкы<н> айга.

*АЙДАН* ❖ **АЙДАН АЙГА.** Һәр ай саен. – *Фатирыңны айдан айга алыштыр!* (Г. Исхакый. Тартышу). *<...> билгеле бер яшькә җиткәч, хәтта пенсия алырга хокуклы булулары (пенсия взносын башка һөнәр кешеләре кебек үк, әлбәттә, айдан айга алар үзләре түләп баралар) безне бик гаҗәпләндерде* (Ә. Рәшит. Һәркемнең... үз хакыйкате).

**АЙДАН АРУ БУЛ, СУДАН СЫЛУ БУЛ.** Гөнаһсыз чиста, су-елга кебек ямьле, матур бул теләге. *Үсмерләргә теләк: Айдан ару бул, судан сылу бул!* (Р. Безертинов. Тәңречелек).

**АЙДАН КЫЕП АЛГАНДАЙ.** Матур булып тулган айның бер кырыен кисеп алган кебек. *Матур-матур көннәрдә кулына айдан кыеп алгандай тәмле кыерчык ипи тотып, безнең тәрәзәгә карый-карый, көлә-көлә, чәйни-чәйни рәхәтләнеп урам уза* (Ә. Баянов).

**АЙДАН ТӨШКӘН (ИҢГӘН) <КЕШЕ> КЕБЕК.** 1. Үз кешеләре арасында тартынып утыру, ят кеше итеп тою. *Әбәү, айдан төшкән кеше кебек сөйләшеп утырмачы* (Р. Төхфәтуллин).

2. Барлык кеше белгәнне дә белмәү; тормыштан хәбәре булмаган, сәер сораулар бирүче турында. *Айдан иңгән кеше кебек көянтәгә күзләрен түгәрәкләндереп карады да: «Моның белән нишлиләр?» дип пышылдады* (Сөйләм).
Төрдәше: айдан төштеңме әллә?

**АЙДАН ТӨШТЕҢМЕ ӘЛЛӘ** *к.* айдан төшкән (иңгән) кебек. *Айдан төштегезме әллә, Нәүруз быел булды инде* («Матбугат.ру» порталы).

*АЙДЫР* ❖ **АЙДЫР ӘГӘР.** Үз сүзләренә ышандыру өчен танык итеп әйткән ант сүзе. *Кояштыр алмадым, айдыр әгәр. Алган булсам, кояш йөзен күрмим, Җир йотсын* (Н. Исәнбәт. Әйтемнәребездә тарихилык).
Төрдәше: айдыр менә; ант әгәр<е>; ант беркетү; ант бирү 2; ант итү; ант китерү; ант менә; ант тоту; ант <касәләре; сулары> эчү; антка тап кундырмау; антка тап төшермәү; антында тору; әйткән сүздә тору; әйткән сүздән кайтмау; башымны кисәргә бирәм, <муен калса җитәр>; башымны биреп әйтәм; билләһи әгәр; вәгъдә<ләрне> беркетү; вәгъдә бирү (итү; кую); вәгъдә кулын күтәрү; вәгъдә кылу; вәгъдә шулпасы белән сыйлау; вәгъдәдә тору; гаһед бирү; гаһед итү; дөнья йөзен күрмим; җир йотсын <әгәр>; ике күзем сукырайсын; ике күзем тишелеп аксын; ике күзем чәчрәп чыксын; ике мәчет арасына кысылып үлим <әгәр>; икмәк өстендә әйтү; икмәктер менә; ипи күрмим; ипидер менә; кояш йөзен (чыраен) күрмим; кояш яктысын күрмим; кояштыр әгәр!; кояштыр менә!; мәңге кояш йөзен күрмим; менә сыртым көйсен; муенны кисмәгә бирү; сүз бирү 2; ямин итү.

**АЙДЫР МЕНӘ** *к.* айдыр менә. *Инсаф кулларын югары күтәреп такмакларга тотынды: – Кояштыр, айдыр менә, яздым* (Ф. Абдуллин. Еракка китеп кара).
Төрдәше: айдыр әгәр һ.б.

*АЙКАП* ❖ **АЙКАП ҖИБӘРҮ (ЧЫГУ).** 1. Берәр нәрсәне әйләндерә-тулгандыра һавада селкү яисә суда чайкалдыру. *Айкап җибәр, чайкап җибәр / Шул казакның камчысын* (Җыр). *Коткыга бирелгән имансыз Гомәр кулына кылычын алды һәм, аны айкап-айкап җибәрде дә, ахмаклык юлына керде* (Ф. Яхин. Пәйгамбәрләр тарихы).

2. Берәр җирне дикъкать белән карау; әйбернең эчен-тышын әйләндерә-әйләндерә тикшерү; эзләнү, актарыну. *Башка чарам булмагач, аларга ияреп, чирек сәгать эчендә бөтен шәһәрне айкап чыктым* (А. Тимергалин. Игезәкләр).

3. Берәрсенең көн итүенә карышып, тормышын бутау. *«Тәтештән дә шулай ук кайтарып җибәргәннәр иде!» дигән уй Вәзирәнең күңелен айкап чыкты* (Р. Гаязетдин. Тәүбә көче).

4. Үтерү. *Ябай халык бер котырса, кулындагы чалгы-сәнәк илә үзләренең батырларын вә старшиналарын да айкап чыкмасмы?* (В. Имамов. Сәет батыр).
Төрдәше: адәм башкайларын салу һ.б.

*АЙ-КОЯШ* ❖ **АЙ-КОЯШ БУЛУ.** 1. Тар даирә кешеләренең бер-беренә җылы мөнәсәбәттә булулары хакында. *Исмәгыйльне зур соры күзле, өреп тутырган кебек таза, ап-ак тамак аслары сырланып-сырланып торган аш-су бүлүче Наташа ай-кояш булып каршы ала* (Ә. Хәсәнов. Исемнәре Исмәгыйль).

2. Матурлыклары ягыннан бер-берсенә тиң. *Сөйлисе дә юк, койган да куйган ай-кояш булганнар!* (Сөйләм).

**АЙ-КОЯШ КЕБЕК** *к.* ай да кояш кебек. *Яраткан кешеләр ай-кояш кебек бер-берсенә тартылучан булалар* (Ф. Яхин. Йөрәкнең учка тәгәрәп төшкән чаклары).
Төрдәше: ай да кояш кебек.

*АЙ-КӨНЕ* ❖ **АЙ-КӨНЕ ҖИТҮ** *к.* ае-көне җиткән. *Хатыныңның ай-көне җитәдер инде?* (Сөйләм).
Төрдәше: ае-көне җиткән.

*АЙЛАРДАН* ❖ **АЙЛАРДАН АЙ, ЕЛЛАРДАН ЕЛ ҮТҮ** *әкият.* Айлар, елларның хәрәкәттә узуын тасвирлау. *Айлардан ай, еллардан ел үтте, Мирвәли дә зур егет булып җитте* (Сөйләм).

*АЙЛЫК* ❖ **АЙЛЫК АКЧА.** Ай саен бирелә торган эш хакы. *Төрле җирләрдә эшләүче мөхәррирләргә айлык акча шул илдә яшәү дәрәҗәсенә карап билгеләнә икән* (Т. Нәҗмиев. Сабаларда эчәр суым булгач...). *Бөтен айлык акча шул, саклабрак тот* (Ф. Яруллин. Качу).
Төрдәше: хезмәт хакы; хезмәт ялы.

**АЙЛЫК ҖИРНЕ АЛТЫ АТЛАП, ЕЛЛЫК ЮЛНЫ ҖИДЕ АТЛАП** *әкият.* Тиз һәм зур-зур атлап йөрү. *Айлык җирне алты атлап, еллык җирне җиде атлап, Алпамыш батыр Хантәңри тавына барып җитте* (Әкияттән).

*АЙЛЫКЛАП* ❖ **АЙЛЫКЛАП АЛУ.** Эш хакын ай саен алып эшләү. – *Эш хакын айлыклап алып барырсыз* (Сөйләм).

*АЙМЫЛ* ❖ **АЙМЫЛ БУЛМАУ.** Очрашу, юллар туры килү. *Зәй шул вахтадан аймыл булмыйм дип бара иде* (Х. Камалов. Түләнмәгән күз яше). *Хакыйкатьтән аймыл булмаган ул, / Тик канаты гына каерылган* (Ч. Мусин. Гомер юлы).

*АЙМЫЛЫШКА* ❖ **АЙМЫЛЫШКА ЯҢГЫЛЫШ.** Юлда аймылыш булу аркасында бөтенләй башка җиргә килеп чыгу. *Ә тегеләр, ягъни без, аймылышка яңгылыш дигәндәй, адаша-адаша, әллә ниткән поездларга эләгеп, тиле кеше әйтмешли, Урал тауларын урап, Алтайларны айкап, көч-хәл белән килеп аудылар ласа азаккы пунктка* («Казан утлары» ж.).

*АЙНЫ* ❖ **АЙНЫ АЙГА ЯЛГАУ (ЯЛГАП БАРУ).** 1. Матди авырлыкларны зур кыенлык белән кичерү. *Тормыш чынбарлыгы күрсәтүенчә, айны айга ялгап, Себер тарафларында авыр эштә хезмәт салучыларның «көрәп алган» акчасы да җиптерергә түгел, кешечә яшәргә генә җитә...* («Кызыл таң газ.).

2. *к.* айдагы<н> айга. *Айны айга ялгап барганда, яшәү шактый кулайлана икән* (Сөйләм).

**АЙНЫ АРКАНЛАП АЛЫП ТӨШҮ.** Сөйгәненең өчен үти алмаслыкны да үтәү. – *Синең кебек*

*чибәр кыз өчен егетләр күктән айны аркан-лап алып төшәргә тиешләр* (Х. Ширмән. Ерактагы йолдызым).

**АЙНЫ КӘЛӘПҮШ БЕЛӘН КАПЛАРГА МАТАШУ.** Нәрсәгә булса да аяк чалырга маташуның урынсыз икәнлеге турында. – *Ул соң айны кәләпүш белән капларга маташу булып чыкмыймы?* (Г. Бәширов. Җидегән чишмә).

**АЙНЫ УЧЛАП ТОТАР ИДЕ, БУЕ ҖИТМИ.** Комсыз, эгоист кеше турында. *Ничек мондый кешене җитәкче итеп куйганнар: айны учлап тотар иде, буе гына җитми* (Сөйләм).

*АЙНЫК* ❖ **АЙНЫК АКЫЛ БЕЛӘН.** Аек баштан (баш белән) 2. *Яңалыкны шау-шусыз, ләкин айнык акыл белән бик тиз сизеп ала торган өченчеләре, бераз вакыт бүрекләре белән киңәш итеп утырганнан соң, үзләре үк Җамалиев ягыннан сукаларга тотындылар, бергә кушылуның яңадан-яңа файдалы якларын күрсәтеп, аңа әзер торганлыкларын* (Ф. Хөсни. Җәй башы).

**АЙНЫК БАШТАН** *к.* аек баштан (баш белән) 1. *Мондый эшләрне яхшы уйлап, айнык баштан эшләргә кирәк шул* (Сөйләм).

Төрдәше: аек баштан (баш белән) 1.

*АЙНЫ-КОЯШНЫ* ❖ **АЙНЫ-КОЯШНЫ АЕРМАС ХӘЛГӘ КИЛҮ.** 1. Көнне төнгә ялгап эшләп айнымау. *Ирем кырдан кайтып керми, айны-кояшны аермас хәлгә килде бугай инде* (Сөйләм).

Төрдәше: көне дә, төне дә юк; көне дә юк, төне дә юк; көнен төнгә, төнен көнгә ялгау; көнен-төнен аермыйча; көне-төне; көнне төнгә ялгау.

2. Күп төрле эшләрне ял итмичә бер-бер артлы эшләп, алҗып, йөдәп бетү. – *Шулхәтле эш йөкләмә малаеңа, айны-кояшны аермас хәлгә килгәнен көтәсеңдер инде* (Сөйләм).

*АЙНЫКЫ<Н>* ❖ **АЙНЫКЫ<Н> АЙГА** *к.* ае айга. *Безнекеләр акчаны да айныкын айга алып бара* (Р. Габдехакова. Нишләттегез Гөлкәйне?!).

Төрдәше: ае-айга; айдагы<н> айга; айны айга ялгау (ялгап бару).

*АЙНЫКЫН* ❖ **АЙНЫКЫН АЙГА ҖИТКЕРҮ.** Айлык алынган хезмәт хакын шул айның ахырынача җиткереп бару. *Хезмәт хакын айныкын айга җиткерә алмый йөдәгән Әхтәри эт үрчетеп карарга булды* (Ф. Зариф. Ак бүре рухы саумы?!).

*АЙНЫМАС* ❖ **АЙНЫМАС СЫРХАУ.** Өзлексез рәвештә бер авыруга дучар булу. *Айнымас сырхау булырсың, / Ятлар керсә куеныңа* (Җыр).

Төрдәше: өметсез авыру.

*АЙНЫҢ* ❖ **АЙНЫҢ ҖИДЕНЧЕ КИЧЕ.** Тиз генә аңлый алмаслык серле булу турында. *Син – айның җиденче киче, / Күзләрең – төннең төсе* (Р. Гаташ. Җиде төн).

**АЙНЫҢ ТҮБӘСЕНӘ СИКЕРҮ.** Тормышка ашмас, бик ерак хыяллар эчендә булу. – *Яшь чагында кем генә хыялында айның түбәсенә сикереп менмәгән соң?!* (В. Имамов. Карабәк).

**АЙНЫҢ УНДҮРТЕНЧЕ КИЧӘСЕ КЕБЕК.** Бик чибәр, шат чырайлы (тулган ай кебек) кешене тиңләү. *Тәрәзәне ачса, картның кырык беренче кызы айның ундүртенче кичәсе күк балкып тора, ди* (Г. Рәхим). *Шул вакытта, председатель узган мизгелдә генә, келт итеп капка ачылды да аннан, айның ундүртенче кичәседәй балкып, үги ана килеп чыкты* (М. Мәһдиев. Мәңгелек яз). *Ничек мине сайладың / Ундүртенче кичәсен күрсәтергә айларның* (Н. Измайлова).

Төрдәше: айның унбишенче кичәседәй.

**АЙНЫҢ УНБИШЕНЧЕ КИЧӘСЕДӘЙ (КИЧӘСЕНДӘГЕ КЕБЕК)** *к.* айның ундүртенче кичәсе кебек. *Йөзе айның унбишенче кичәседәй табак-түгәрәк тә түгел, озаеп-очланып та китмәгән, шулхәтле килешле кимәлдә, шикләнми әйтергә мөмкин, күпләрне ымсындырырлык* (Б. Камал). – *Әле шулай укмыни?! – диде ул, айның унбишенче кичәсендәге кебек балкып* (М. Миншин. Кызыл диплом).

Төрдәше: айның унүртенче кичәсе кебек.

*АЙНЫТЫП* ❖ **АЙНЫТЫП ҖИБӘРҮ.** Аңга китерү, хыял дөньясыннан чыгару. *Без яхшы ук тирәнгә кереп киткәнбез, ахры. Мостафаның кинәт сүзне бүлүе безне айнытып җибәргәндәй булды* (Г. Кутуй. Яшен).

*АЙТ* ❖ **АЙТ БУЛСЫН** *гади с.* «Куйган урынында мәңге калсын» мәгънәсендә. – *Селкетмәгез инде, айт булсын шунда* (Сөйләм).

**«АЙТ» ДИГӘНГӘ «ТАЙТ» («ҺАЙТ») ДИЮ (ДИП ТОРУ).** Кушкан эшне шунда ук йөгерәчаба башкарырга әзер булу. *«Айт» дигәнгә «тайт» дип торулар да барыбызга әллә уртакмы?* (Н. Нәҗми). *Әллә ничек, «айт» дигәнгә «тайт» дип кенә торган була үзе* (М. Маликова. Оҗмах балалары). *«Айт» дигәнгә «һайт» дип торма, үз башың бар, гыйлемең җитәрлек...* (Г. Шәрәфи. Аккошлар кайтыр әле).
Төрдәше: «айт» дигәндә «тайт» дип тору (тайт итү).

**«АЙТ» ДИГӘНДӘ** *к.* «а» дигәнче. *«Айт» дигәндә минем янга йөгереп килеп җитә иде ул* (Сөйләм).
Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**«АЙТ» ДИГӘНДӘ «ТАЙТ» ДИП ТОРУ (ТАЙТ ИТҮ)** *к.* «айт» дигәнгә «тайт» («һайт») дию (дип тору). *Чөнки шунсыз аны «ихтирам итмәячәкләр», ул «айт» дигәндә, «тайт» дип калтыранышып тормаячаклар* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң). *«Айт дигәндә «тайт» диючеләрне әйтәсең инде син, Хәсән абый* (Х. Хәйруллин. Картлык... Кешегә шатлык).
Төрдәше: «айт» дигәнгә «тайт» («һайт») дию (дип тору).

**«АЙТ» ДИГӘНДӘ, ЯЛТ ИТЕП ТОРУ.** Ымлап эндәшүгә эт кебек уяу булып тору. *Ә бит Гагау элегрәк хатын буласы асыл затның үзенә сүзсез буйсынып, олылап, «айт» дигәндә ялт итеп торучы булуын тели иде...* («Ватаным Татарстан» газ.).

*АЙТ-ДВАГА* ❖ **АЙТ-ДВАГА БАСТЫРУ.** Бернәрсә дә уйламыйча, автомат рәвешендә тәртипкә буйсындыру. *Патша хөкүмәтенең бөтен эше халыкны казарма системасына буйсындырып, айт-двага бастыру иде* (Ф. Сәйфи-Казанлы).

**АЙТ-ДВАГА БАСУ.** Берсүзсез буйсыну яки буйсынырга мәҗбүр булу. *Билемә каеш будым. / Кая инде атлап йөрү – / Айт-двага басабыз* (Р. Гайнанова).

*АЙХАЕНДА* ❖ **АЙХАЕНДА ДА ЮК.** Уйлап та карамау, гаменә дә кермәү. *[Кифая] Калхузның айхаенда да юк. Чучка фермасы тирәсендә күренгәлиләр* (Р. Хәмид. Актамырлар иле).

*АЙХАЙЛҮК* ❖ **АЙХАЙЛҮК БУЛЫП ЙӨРҮ.** Эчеп, болагайланып йөрү; тәртиптән чыгу. *Нигә болай айхайлүк булып йөрисең, дисең инде, ә!* (Г. Бәширов).

*АЙ-ҺАЙ* ❖ **АЙ-ҺАЙ, ВАЙ-ҺАЙ КҮП БУЛУ.** Сугыш, туй, җыен, мәҗлес һ.б.да шатлык, үкенеч, көенеч авазларының күп булуына ишарә. *Бөтен мал-мөлкәтен су агызып алып киткәндә, ай-һай, вай-һай бик тә күп булды* (Сөйләм).

**АЙ-ҺАЙ ДА ГЫНА ДИМИ.** Нинди булса да яңа әйбер туар (иҗат ителер) өчен хисле-тойгылы вакыйга булу кирәклегенә ишарә. *Ай-һай да гына дими көйләр килми, / Кайгылар ук күрми ир булмый* (Хал. җыры).

**АЙ-ҺАЙ ДА ЮК.** Гамьгә дә кереп чыкмый, кайгы да юк. *Ләкин безнең ай-һай да юк, язын тау битләре ачылу белән, өстән салып атабыз да көзен җир туңмыйча кимибез* (Х. Сарьян).

**АЙ-ҺАЙ ЛА <ЛАБАСА>.** Борчылып үкенеч катыш кызгануны белдерү йә сагыштан уфылдау. *Чөнки сине «ай-һай лабаса, кыйнаганнар бит!» дип, берәү дә кызганып каршы алмаячак* (Г. Бәширов. Намус).

**АЙ-ҺАЙ МИНЕМ ҮЗ ӨЕМ, КИҢ САРАЕМ, БҮЗ ӨЕМ.** «Һәркемнең үз уе-фикере бар» мәгънәсендә. *«Ай-һай минем үз өем, киң сараем, бүз өем», – дигән берәү* (М. Госманов. Мәкальләр – тарихи чыганак).

**АЙ-ҺАЙ САЛУ (САЛЫП ЙӨРҮ).** Кайгыдан, сагыштан яки ни эшләргә белмичә, аһ-ваһ килеп йөрү. *Нәкъ шуның күк бер заманны / дөньясын типкән халык /Инде алҗып тик йөриләр, / сызгырып ай-һай салып* (Ш. Бабич).

**АЙ-ҺАЙ ТЕЛЕҢ, ТЕЛ ОЧЫНДА БЕЗЕҢ <ЧАМА БЕЛЕР ИДЕҢ>.** Үткен, әче телле кешегә карата әйтелә. *Сиңа, ай-һай, телең, тел очында безең, дисәләр, бер дә үпкәләмә, чөнки холык-фигылең шундый* («Мәдәни җомга» газ.). *– Ай-һай телең, – диде Бикбулат, – чама белер идең* (М. Әмирханов. Тәхетсез патша).
Төрдәше: агу тел<ле> һ.б.

**АЙ-ҺАЙ, ШӘЙХЕЛ, ТӨЛКЕ МИКӘН, КОЙРЫГЫ ОЗЫН.** Ялган сөйләүченең ялганы сизелгәнлеген белдерү, шуңа төрттерү (төлке куабыз дип, эт куу турындагы мәзәккә ишарә). *Мирхәйдәр сөйләүченең бүртә-бүртә сүз сиптерүенә түзмәде, «ай-һай, Шәйхел, төлке*

*микән, койрыгы озын» дип төрттереп куйды* (Сөйләм).

*АЙ-ҺАЙ-АУ* ❖ **АЙ-ҺАЙ-АУ САЛДЫРУ.** Көч куллану, көчләү. *Ура башлаган җирләрне бетерергә түгел ертылай куелган чумәләңне очларга да ихтыяр бирмәделәр: патшадан фәрман килеп төшүгә, әллә ничә җегетне ат мендереп басуга чыгардылар да, ай-һайлап ай-һай-ау салдырып, һәммә халыкны куып кайтардылар* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр).

*АЙ-ҺАЙСЫЗ* ❖ **АЙ-ҺАЙСЫЗ ДӨНЬЯ КУУЧЫЛАР**. Дөньяның вак-төякләренә игътибар итмичә, кайгырмыйча яшәүчеләр. *Бишектән алып сакалы агарганчы өс-баш дигән әйбергә исләре китмичә, «хикмәт бишмәттә түгел – эштә» дип, ертык җиң төбе, сүтелгән сүрү белән ай-һайсыз дөнья куучылар моннан биш-былтыр элек өзелгән төймә урыннарын учлары белән капларга ашыгалар, һәркем аның күзенә чалынырга, йөрәгенә ятардай сүз әйтергә тырыша* (Г. Мөхәммәтшин. Хуҗалар).

*АЙ-ЯЙ* ❖ **АЙ-ЯЙ <СИН> НИЧЕК.** Гаҗәпләнү һәм кисәтү. *Ай-яй син ничек, ашыгып ашка пешә күрмә!* (Сөйләм).

*АК* ❖ **АК АЛТЫН.** Мамык (кайбер җирдә – су энергиясе, тоз). *Каракалпак кызы Сарыгөл, / Синең якта үскән, ай, ак мамык / Ак алтын дип илдә дан тота* (К. Булатова). *Бик авырлыклар белән генә юнәтеп, «ак алтын»ны, ягъни тозны бармак очы белән генә теленә тидереп карый* (Т. Нәҗмиев. Тагын… тагын… Саба мәзәкләре).

**АК – АК КЫНА, КАРА – КАРА ГЫНА БУЛА АЛМАУ.** Дөньяда бөтен нәрсә дә йә яхшы, йә начар гына була алмау. *Дөрес, эшли-эшли, яши-яши, акның – ак кына, караның – кара гына була алмавын аңлады* (Д. Булатова. Соң түгел!).

**АК АШ.** Сөтле ашамлык. *Аның ашказаны авырта башлаган икән, докторлар аңа «ак аш» (сөт, катык, эремчек) белән генә торырга кушканнар...* (Ә. Еники. Рәхмәт, иптәшләр).

**АК АЯК.** «Касәнең төбе-агы күренгәнче эч» мәгънәсендә әйтелә (аяк – касә, савыт). *Бездә чәйне ак аягы күренгәнче эчәләр* (Сөйләм).

**АК ӘЛӘМ БОЛГАУ** *к.* ак әләм күтәрү. *Дивар өстендәге биек манарадан ап-ак әләм чыгарып болгадылар* (В. Имамов. Карабәк).
Төрдәше: ак әләм күтәрү.

**АК ӘЛӘМ КҮТӘРҮ**. *Кулына ак әләм күтәргән, биреге таба килә бит* (В. Имамов. Утлы дала). *Инде өч атналап камалуда торуга карамастан, воевода Протасов ак әләм күтәрергә ашыкмады* (Р. Вәли).
Төрдәше: ак әләм болгау.

**АК БАБАЙ.** Карт кешене хөрмәтләп әйтү сүзе, ягъни хөрмәтле, юмарт кеше. *Шулай беркөнне Хәлим Ак бабай янына йөгереп чыгып китте* (Г. Гыйльманов. Албастылар).

**АК БАЛА.** Аксөяк, югары катлам кешесе баласы. *[Хәмдия] Рәхимханмы, нинди дә булса ак баламы?* (М. Фәйзи. Ак калфак).

**АК БАШ.** 1. Ак чәчле (альбинослар) яки чәчләре чаларган кешеләр. *Тез буыннарым калтырап, өстәл янына барып җиткәч, Ак баш Марс Шабайга әйләнеп күтәрелде һәм... күз алдында зураеп китте* (М. Гали. Догалы еллар).

2. *к.* агулы елан 1. *Хуҗа, караватастына ертылаш кереп, «ак башларны» тартып чыгарды* (Ә. Еники). *Ир-ат бит: ничек инде андый көнне алларына берәр ак баш утыртып, бераз гәпләшеп утырмасыннар, ди* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!).
Төрдәше: агулы елан 1 һ.б.

**АК БАШЛЫ.** Ак төстәге баш киеме кигән кешеләр (чалмалы дин әһелләре, яулыклы хатын-кызлар һ.б.). *Менә бу сүзләр илә милләтне җуатып, милләтнең һушы китеп, гакылсыз ятканда, милләтне ашаган, кабыргаларын тишкән оятсыз ак башлы каргаларны, кәкре башлы, яшел яки сары гәүдәле Бохара козгыннарыны куып җибәрик* (Г. Тукай. Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?). *Ак башлы, кара бишмәтле хатыннар шуннан ерак түгел йөргән биләрне корыклап китерәләр дә савып йөриләр* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).

**АК БӘЛА.** Наркотик. – *Үзе наркоман, үзе шул ук ак бәлане сатучы* (Н. Хәсәнов. Хакыйкать хакы).

**АК БӘХЕТ.** Тапсыз, керсез, якты бәхет. *Ак бәхетләр тели-тели, / Озатканда карап калам, / Күз керфегем талганчы* (М. Фәйзи).

*Хәерле юл теләү миңа, Фатыйма, ә мин сиңа ак бәхетләр теләп, юл буе дога укып барырмын* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы).

**АК БӘХЕТ ТЕЛӘҮ.** Керсез, якты бәхет теләү. *Үткер-тапкыр, шаян яшьлек белән ак бәхетләр телик бүтәннәргә* (Г. Афзал).

**АК БЕЛӘН КАРАНЫ АЕРМАУ (АЕРА БЕЛМӘҮ; КҮРМӘҮ).** 1. Яхшы белән начарны аера алу тәҗрибәсе булмау; томана булу. *Дөньяның агы белән карасын аера алмый торган унҗиде яшьлек тиле кыз чагы түгел бит инде* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Тез буыннарына кадәр калтыранып, күзе ак белән караны аермады* (Ә. Галиев).

Төрдәше: акны карадан аермау (аера алмау/белмәү); ат тизәге тәгәрмәч, ат тизәге пәрәмәч.

2. Булдыксыз, бернәрсәгә яраксыз булу. – *Кемгә охшап тугандыр, ак белән караны да аера белми бит, мескен* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**АК БЕЛӘН КАРАНЫ АЕРУ (БЕЛҮ; БУТАМАУ; ТАНУ).** 1. Аңлы, яхшы белән яманны аерырлык дәрәҗәдә булу. *«Болар инде безнең кебек туң баш түгел, ак белән караны аера беләләр», – дип уйлады Габделнур, залдан залга күчеп йөргәндә иптәшләренә дә күз ташлап* (Р. Кәрами. Олы юл да сикәлтәле).

Төрдәше: ак<ны>-караны белү; акны карадан аеру; акны-караны аеру (тану); актан караны аеру.

2. Укый-яза белү, грамоталы булу. *Шулай маташа торгач, ул ак белән караны аерырлык булган иде* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).

Төрдәше: ак<ны>-караны белү; акны карадан аеру; акны-караны аеру (тану); актан караны аеру.

**АК БИЛЕТ.** Солдат хезмәтенә яраксыз дип табылган кешегә бирелә торган таныклык. *[Әхмәтсәгыйр] Түгел, хәзрәт, ак билет бирлә калды* (Г. Исхакый. Алдым-бирдем). *Кемнәр алынганын, кемнәргә ак билет, кәҗә билеты бирелгәнен хәбәр итә* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).

Төрдәше: кәҗә билеты.

**АК БИТЛӘР.** Җәмәгатьчелек фикереннән яшерелгән, билгеле булмаган яисә ялгыш аңлатылган нәрсәләр. *Татар халкы тарихындагы «ак битләр» тарихчылар тарафыннан яңача языла, әкренләп булса да матбугат әлеге оныттырылган тарихыбызны ясаган, XX йөз башында патша хөкүмәтенең милли сәясәте астында изелеп яшәгән милләткә «җан өргән» милли хәрәкәт җитәкчеләренә багышланган хезмәтләр чыгып килә* (С. Максуди. 1906–1924 еллар). *Тарих миндә хәтер дип атала…/ Ак битләре инде аз аның. / Очы да юк аның, уртасы да, / Күреп булмый аның азагын* (Р. Вәлиев. Көз балкышы).

**АК БИТТӘН БАШЛАУ.** Тормышны яңа юнәлештән, эчтәлегенә яңа мәгънә салып башлау. *Гомерне өр-яңадан, чиста ак биттән башлап китәргә иде* (Р. Мулланурова. Ялгыз каеннан да ялгыз…). – *Димәк, тормышны яңадан, кем әйтмешли, ак биттән башларга булдык инде* (З. Мурсиев. Солтанъяр).

**АК БОЛЫТ.** Кайдадыр билгесез җирдә калган яки торган нәрсә турында. *Балачакның татлы ак хыялы ак болыт өстендә тирбәлде, күктәге ак кыялар эргәсенә кунды* (В. Нуриев. Җиденче палата). *Мин каян киләм, кая барам, кайда югалам? Белмим. Мин – ак болыт. – Кайтыйк, Җил, сагындырды туган җир* (З. Мәхмүди. Ак болыт).

**АК БОЛЫТЛАРДА ЙӨЗҮ.** Буш хыялларга бирелү. *Ул үзен ак болытларда йөзгән күк хис итте* (Ф. Яхин. Илаһи канун). *Мин кечкенәдән ак болытларда йөзәргә, зәңгәр күкләргә менәргә хыялландым* («Өмет» газ.).

**АК БУЛСЫН ЮЛЫҢ, УҢ БУЛСЫН.** Юлга чыкканда әйтә торган теләк. *Ак булсын юлың, уң булсын, / кире кайтыр юл булсын* (К. Булатова).

**АК ДИМӘСТӘН, КАРА (КҮК) ДИМӘСТӘН.** 1. Каршылыксыз, берсүзсез ризалашу; кемнең кем икәнен аермыйча, аңа ияреп йөрү. *Рөстәм чакыргач, ак димәстән, кара димәстән берсүзсез риза булдым да машинасына кереп утырдым* (Сөйләм).

2. Барына риза булу, тикшереп, талымлап тормау; талымламый ашау. *Шундый ашыйсы килгән иде, ак димәстән, кара димәстән кичәге борчак ашын ашарга тотындым* (Сөйләм).

Төрдәше: ак димәү, кара (күк) димәү 1, 2; ак та димәскә, кара да (күк тә) димәскә; ак-кара димәү.

**АК ДИМӘҮ, КАРА (КҮК) ДИМӘҮ.** 1. *к.* ак димәстән, кара (күк) димәстән 1. *Ак димәдем, кара димәдем – сүзсез генә Низамга иярдем* (Ф. Шәфигуллин).

2. *к.* ак димәстән, кара димәстән 2. *Ак димәде Зөфәр, кара димәде, дуслары күрсәткән машина янына килде дә дәшми-тынмый гына әрҗәгә үрмәләде* (Җ. Дәрзаман. Җир авазы).

Төрдәше: ак димәстән, кара димәстән 1, 2 һ.б. (ике маддә өчен дә).

3. *к.* авыз <да> ачмау. *Ак димим, күк димим, белми торсын әле* (А. Гыйләҗев. Язгы кәрваннар).

Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**АК ЕГЕТЛӘР.** Тәрбияле, ачык күңелле егетләр *[Хәмдия] Хәмдиянең йөрәгенең изге уйларын аңлата алган, ак егетләр эчендә син асылы булган бер яры бар иде* (М. Фәйзи. Ак калфак). *Ак күңелле батыр ак егетләр* («Сөембикә» ж.).

**АК ҖАН.** Гөнаһсыз, эчкерсез кеше. *Әйләнде дә үтте тормыш суы, / Ак җаннарны төпкә ташлады* (Ф. Яхин). *Ак җанымны җилләренә җәеп, / Шул дөньяда йөзен каралттым* (Х. Әюп).

**АК ҖӘЙМӘ.** Берәр нәрсәнең тоташ ак төстә булуы (мәс., кар каплау). *Еракта, ак җәймә шикелле җәелеп яткан киң күл өстендә, алар тын алалар, бераздан икенче тауга менәләр, тагын түбән төшеп китәләр* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

Төрдәше: ак тун; ак чаршау; ак чикмән; ак юрган.

**АК ҖӘЙМӘ ҖӘЕП КАРШЫЛАУ.** Елмаеп, якты йөз белән каршылау. *Ак җәймә җәеп кенә каршы алмыйлар иде аны* (Ә. Еники. Йөрәк сере).

Төрдәше: ак җәймә көн кебек.

**АК ҖӘЙМӘ КӨН КЕБЕК** *к.* ак җәймә җәеп каршылау. *Кунакларны ишек төбендә ак җәймә көн кебек хуҗалар каршы ала иде* (Сөйләм).

Төрдәше: ак җәймә җәеп каршылау.

**АК ҖӘЙМӘЛЕ КӨН ТУУ.** Шатлыклы, бәхетле көн туу. *Марсель өчен ак җәймәле көн туды* (М. Әмирханов. Әлвидаг). *Кыскасы, Габделнур атлы егет өчен, халык әйткәнчә, ак җәймәле көн туды* (Р. Кәрами. Кая чабасың, тормыш юртагы?).

Төрдәше: авыз еру 4 һ.б.

**АК ҖЕП БЕЛӘН ТЕГЕЛҮ (ҖӨЙЛӘНҮ; ТИПЧЕЛҮ).** Нәрсәне дә булса ипсез рәвештә аннан-моннан гына яшерергә маташу, бу яшерү күзгә бәрелеп, беленеп тору. *Район халык суды карарын республика югары суды расламады дигән хәбәр гаҗәпләндермәде Денис Ивановичны, чөнки барлык «Эш»ләр ак җеп белән тегелгәнен ул сизә, белә иде* (Ә. Баянов).

**АК ҖИР.** Дала җир, сөрелмәгән җир. *Мөхәммәд пәйгамбәрнең әйткәннәреннән чыгып, китаплар Каф тавы артында бер ак җир булуын язалар* (Ф. Яхин. Иман).

**АК ИТЕП КҮРСӘТҮ** *к.* ак калу. *Гадәти тормышта кешеләрнең күпчелеге үзен ак итеп күрсәтергә тырыша, эчендәге каралыкны яшерә* (М. Маликова. Өермә).

Төрдәше: ак калу.

**АК ЙӨЗ.** 1. Намуслы, вөҗданлы. *Йөземнең ак икәнлеген аларга да күрсәтеп, үзем сөенергә телим!..* (А. Гыйләҗев. Өч аршын җир).

2. Төссез, чырайсыз. *Эреде һәм, шәмдәй ак йөз буенча тәгәрәп төшкәч, ирен читендә туктап калды* (Ә. Гаффар. Кашан җыры).

Төрдәше: ак күңел<ле>.

**АК ЙӨЗНЕ САРЫ АЛУ (САРУ).** Уй-сагышлардан, мәшәкатьләрдән йөз саргаю. *Ак йөземне сары сарды* (Р. Фәйзуллин). *Ак йөземне сары алды/ – Бар да дөнья сагышы* (Җыр).

**АК КАЛУ.** Намусына хыянәт итмәү. *«Чәнчелеп китсен дөньясы, син генә ак калырга димәгән...»* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Заманасы корымланган чакта үзең генә ничек ак каласың* (Х. Әюп).

Төрдәше: ак итеп күрсәтү.

**АК КАНАТ БУЛЫП <ҮСҮ>**. 1. Иркә үсү. *Шулай ул зур, эшчән семьяда ак канат булып үсте, укуының да рәте булмады* (Г. Әпсәләмов).

2. *күч.* Иркә булу, эш сөймәү. *Ач ишекне, Тормыш, киң дөньяга, / ак канатлар үсте, тоям җанда* (Роб. Әхмәтҗан. Сәхипҗамал).

**АК <ТА> КАРА БУЛЫП КҮРЕНҮ.** Еш кабатланганда, бөтенләй каршы фикер дә дөрес булып кабул ителергә мөмкин. *Әмма кеше акылы гаҗәп корылган, ешрак кабатлана башласа, ак та кара булып күренә* (К. Кара. Депрессия).

**АК, КАРА ХАЛЫК.** Бөтен халыкны, дәрәҗәләренә, кайда эшләү һәм ничек яшәү аермаларына карамыйча, бердәй санау. *Халыкның агы да, карасы да кара сарык көтүенә әйләнә барганын Сөмбелә куркынып, коты очып күзәтте* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**АК КАРГА.** Тирә-яктагыларга бөтенләй охшамаган, алардан аерылып торган кеше. *Офицерлар арасында берданбер ак карга булган докторның гражданкага китүенә командование каршы килмәгән* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет). *Нигә без башкаларныкыннан үзгә фикерле кешеләрне өнәмибез, арабыздагы андый «ак карга»ларны нишләп сөймибез, күрәлмибез – аңлашылмый* (Г. Тавлин. Афәт).

**АК КАРГА КЕБЕК КҮЗГӘ БӘРЕЛҮ.** Тирә-юньдәгеләрдән нык аерылып тору. *Тик алар төркемдәге ак карга кебек күзгә бәрелеп торалар* (М. Әмирханов. Тояк эзе).

**АК КӘГАЗЬГӘ ТӨШЕРҮ.** Уй-фикерне кәгазьгә язу. *Билгеле, мондый шартларда язучыга үзенең хисләрен, сагыну-сагышларын ак кәгазьгә төшерергә туры килә* (Г. Бәйрәмова. Күңеленә дөнья сыйган).

**АК КӘҖӘ СИНЕКЕ, КАРАРАГЫ МИНЕКЕ.** «Акны карадан аерыйк, бергә куеп бутамыйк» мәгънәсендә. *Тукта, ашыкма әле, барысын да бер казанга салып бутама, «ак кәҗә синеке, карарагы минеке» дия торган иде безнең бабай* (Сөйләм).

**АК КӘЛӘПҮШ.** Суфичылыктан читкә чыкмаган кеше (салкын суфи, коры суфи, суган суфие). *Шул ак кәләпүш муллалар нинди эшләпә икәнен белмиләр* (К. Насыйри).

**АК КЕЛӘТ.** Җаен кеше тора торган, күпчелек очракта буй җиткән кыз ята торган тәрәзәле келәт. *Булгач-булгач, ак келәт булсын дип, моңа кечерәк кенә бер тәрәзә куйдырырга исәплим* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр). *Мунчадан чыккач та, мине ак келәткә, кияү янына чакырдылар.* (Ә. Еники. Җиз кыңгырау).

**АК КЕР.** Юылган, чистартылган кер. *Иң уртасын сайлап зур шәһәрнең, / Ак кер элеп йөри бер апа* (Г. Гыйльманов. Кер элүче хатын).

**АК КЕШЕ.** Начар хисләрдән азат булган пакь кеше. – *Димәк, син гомереӊ буена ак кеше булгансың икән* (Ә. Еники. Әйтелмәгән васыять).

**АК КИЕЗГӘ КҮТӘРҮ.** Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, хан итеп игълан итү билгесе. *Нәтиҗә шул: байлар, сәүдәгәрләр ул елны ак киезгә Үзбәкне күтәрә* (В. Имамов. Карабәк).

Төрдәше: тәхеткә күтәрү.

**АК КИЕМ.** 1. Ачык төстәге кием; шулай ук *к.* ак җәймә. *Алда зур алан иде, ә аланлыкта озын ак кием кигән, ак битлекле кешеләр нидер эшләп йөриләр* (Ф. Бәйрәмова. Туфаннан таралган татарлар).

2. Чиста, пакь кием. *Кечкенә чагымда / Әнигә охшарга тырыштым: Елауда, көлүдә, ашауда, / Йоклауда... / Халкымны, илемне сөюдә... / Чәчемне үрүдә... / Ак кием, пакь кием киюдә, / Хәтта төш күрүдә / Әнигә охшарга тырыштым* (Ш. Җиһангирова).

**АК КИТӘН КЕБЕК.** Берәр сәбәптән йөз агару. – *Чатырга кайтканда, каратут, кыллы таҗикларның йөзләре ак китән кебек иде* (Ә. Салах. Соңгы вальс).

**АК КОЙРЫКЛЫ ЧӘЙ.** Татарлар һәм башкортлар яратып эчкән һинд чәе, чәй бөртекләре арасында ак кыл кебек койрыклы бөртекләр була. *Ул вакытлар, беләсеӊ бит, ахирәт, хәзрге кеби, әллә нинди канәфер тәмнәре килә торган чәй юк иде: кара, ак койрыклы чәй иде* (Г. Исхакый. Шәкерт абый).

**АК КӨЙ.** Кайгы-хәсрәтсез, күңелгә җылылык биргән көй. *Ак бәхет, ак көйләремне күрми гүргә кермимен* (Г. Гайнуллин-Чокалый. Газраилгә).

**АК КӨН.** Бәрәкәтле, күңелдә яхшы хисләр тудыра торган көннәр. *Ак көннәр дә, кара көннәр дә туктамыйлар – берсе артыннан берсе агыла* (И. Салахов). *Күрәм микән алда мин дә ак көн... (Сорап кара шуны мелладан!)* (И. Башмаков. Уйлану).

**АК КӨНГӘ ДӘ, КАРА КӨНГӘ ДӘ ҖИТӘРЛЕК <САЛЫНУ>.** Яшәү өчен җитәрлек күләмдә мал яки акча туплану. <...> *чөнки фатир, икесенеӊ дә машинасы бар, тормыш башларга – ак көнгә дә, кара көнгә дә акча салынган иде* (Д. Салихов. Чукрак).

**АК КУЛ<ЛЫ>.** 1. Физик эш сөйми торган кеше. – *Син аның ак кулларына кара, гомердә көрәк тотмаган бу* (Сөйләм).

2. Кул хезмәте белән шөгыльләнмәүче кеше, аксөяк. <...> *тагы кирәк булса, ак кул – үзенең ак хезмәтендә көнenә ике-өч сәгать утыра да аннан ары буш* (Г. Ибраһимов. Яшь йөрәкләр).

Төрдәше: ак сөяк<ле>.

3. Кеше көченнән файдаланып яши торган кеше. *Анда дөнья якты, ефәкләр, алтыннар эченә күмелгән ак кул халык бәйрәм итә, музыка күңелле көйләр уйный иде* (Г. Ибраһимов).

**АК КҮБЕК БУЛГАН.** 1. Озак һәм нык чабудан атның тирләре күбекләнү (ат турында). *Бераздан борылыштан ак күбек булган Исмай аты күренде* (Сөйләм).

Төрдәше: ак күбеккә бату (манчылу; төшү).

2. Нинди булса да ак төстәге әйберләрнең бур урында тупланып, күбекләнеп, күперүләре. *Алар [кар бөртекләре]берсе артыннан берсе чайкалып, ак канатларын салмак кына җилпеп төшәләр дә, ак күбек булып, һаман күперәләр, һаман калка баралар* (И. Салахов. Имәннәр тамыр җәйгәндә).

**АК КҮБЕККӘ БАТУ (МАНЧЫЛУ; ТӨШҮ)** *к.* ак күбек булган 1. *Ак күбеккә төшкән атның урман юлыннан чабып килгәне күренгән* (Ф. Хөсни). *Мансур белән мин ак күбеккә баткан айгырны кызганып йөрдек* (Г. Ахунов. Йолдызлар калка).

Төрдәше: ак күбек булган 1.

2. *к.* ак күбек булган 2. *Минзәдәңә / Ак күбеккә баткан чияләр* (М. Шабаев).

Төрдәше: ак күбек булган 2.

**АК КҮГӘРЧЕН ОЧЫРТУ.** Үзара аңлашуны өмет итеп, изге теләк теләү. *Очыртып фикернең ак күгәрченен, / Белмәдем йөрәкнең, аһ, түзәчәген* (Ф. Яхин).

**АК КҮКЕ – ЯТ КҮКЕ.** Башкаларга катышмый, ияләнми торган үзгә бер ят төр, ят кеше. *Ак күке – ят күке булып калмаммы?* (Ш. Маннур).

**АК КҮМӘЧ БЕЛӘН АШАРЛЫК.** Һаваның чисталыгы турында. *«Валлаһи, и валлаһи, и валлаһи, / Бәхте барлар кырда җәйли, валлаһи! / Ак күмәч белән ашарлык саф һава* (Г. Тукай).

**АК КҮМЕР.** Электр энергиясе алу өчен турбинага буадан агып төшә торган су көче, су. *Себер ягы электр тогы эшләп чыгару өчен «ак күмергә» гаять тә бай* (Сөйләм).

**АК КҮҢЕЛ<ЛЕ>.** Намуслы, саф, изге кеше. *[Идея] (тауларга ышыкланып). Бар синең дустың, бар ул, / Ул гали, ул ак күңел...* (Һ. Такташ. Җир уллары трагедиясе). – *Димәк, син гомереңбуе ак кеше булгансың икән. Ак күңелле, пакь күңелле кеше...* (Ә. Еники. Әйтелмәгән васыять).

Төрдәше: ак йөз.

**АК МАЙ.** Кайнаган сыер сөте өстеннән яисә каймактан ясалган май. *Атланмайны (ак май да диләр) яңа аерткан каймактан ясыйлар* (Татар хал. ашлары).

Төрдәше: атланмай; гөбе мае; сыер мае.

**АК МУНЧА.** Төтене морҗа аша чыга торган, ябык мичле, чиста мунча. *Ак мунчада чабындым, / Ак кершәннәр ягындым* (Җыр). *Хәзер кеше саен ак мунча, бер-берсенә кермиләр, мунчага әйтмиләр...* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).

**АК НӘСЕЛ** *иск.* Затлы, югары нәсел, аксөякләр. – *Алар гына минем ак нәселдән һәм нинди семьядан чыкканымны әйтә алалар* (М. Җәлил).

Төрдәше: асыл нәсел.

**АК НӘСЕЛНЕҢ ТАМЫРЫН ЧЕРЕТҮ.** Югары катлам буржуаз аксөякләр нәселен юк итү сәясәте. *[Сәлим] (яшн суккан кебек була). Ялчылар белән минем арага кереп, нәселнең йөзенә кара ягып килгән кыз, бүген бер көтүчегә төшәчәк таякны да үзенә йөкләп, ак нәселнең тамырын черетте* (М. Фәйзи. Ак калфак).

**АК НОКТА.** Аз өйрәнелгән яки бөтенләй өйрәнелмәгән өлкәләр. *Тик ул картада ак нокталар күп әле* (Ф. Кәрим).

Төрдәше: ак тап.

**АК ОФИЦЕР** *тар.* Гражданнар сугышы вакытында ак армия офицеры. *Ак офицер, кылычларын шалтыратып, / Әмер бирде, бугазларын калтыратып* (Н. Исәнбәт).

**АК ӨЙ.** Куш өйнең кунак кертелә торган ягы (аерым да салынырга мөмкин). *Чәйдән соң бу өйдән чыгып, аңар каршырак салынган ак*

*өйгә кердек* (Г. Тукай). *Хатынның ак өйне бер мәртәбә дә күргәне юк иде. Тыштан гына оя сыман икән ул, ә болай йокы бүлмәсе, залы белән иркен генә йорт икән* (Н. Гыйматдинова. Үзем генә беләм...).

**АК ӨСТЕНӘ КАРА БЕЛӘН <ЯЗ<ЫЛ>У>.** Ачык итеп, ап-ачык, бик аңлаешлы рәвештә; ике төрле уйларга урын калмаслык итеп төгәл язылган. *[Батырҗан] Мөмкин түгел бит ул. Ак өстенә кара белән язылган – эш беткән инде* (Т. Гыйззәт).
Төрдәше: акка кара белән <яз<ыл>у> 1.

**АК ӨСТЕНӘ КАРА ТӨШЕРҮ.** Гаепсез кешегә яла, әләк ягу. *Авылда ак өстенә кара төшерү белән мавыккан кеше берәү генә* (Сөйләм).
Төрдәше: пычрак ату ташлау (ыргыту).

**АК ӨСТЕНДӘ КАРА АЕРУ (ТАНУ).** Укый-яза белү, грамоталы булу. *Безнең уку ак өстендә караны аерырлык кына* (Х. Сарьян). *Үзегез дә ак өстендә кара танайсыз, бакчы, Аллага шөкер* (Н. Думави).

**АК ӨСТЕНДӘ КАРА КЕБЕК**. 1. Күзгә бәреп тору, ачык аерылып тору. *Дулкынланып, гөрләп торган бу халык диңгезе эчендә, ак өстендә кара кебек, бераз мөселман агай-эне дә күренде* (Г. Ибраһимов).

2. Ят нәрсә булып тору. *Җитмәсә, түшенә ак өстендә кара кебек бер нәрсә дә капты-рып куйган* (Сөйләм).

**АК ПАТША** *иск.* Рус патшасы турында. *Ул бит – ак патша зинданыннан да исән-имин чыккан кеше* (Р. Низами. Сәйдәшнең соңгы елы). *– Анысына ук бармаслар инде, хәзрәт, мәчет-мәдрәсәләрнең тыны да чыкмый бит, ак патшага дога кылып утыралар, – дип, тагы бераз каршы төште Мөхәммәтҗан карт* (Ф. Бәйрәмова. Һиҗрәт).

**АК ПЕРЧАТКА КИЮ.** 1. Гаепсез булып калырга тырышу. *Югыйсә бергә кыйнаганнар, бергә талаганнар, ак перчатка киеп, читтә калып булмый* (Сөйләм).

2. Эшкә турыдан-туры катнашмау. *Революцияне ул ак перчатка киеп кенә ясамакчы* (Ф. Хөсни). *– Кем инде мондый көнне ботинка киеп чыга? Ак перчатка киеп төземиләр шәһәрне...* (Р. Вәлиев. Мирас).

**АК ПЕРЧАТКАДА ТУУ.** Гаепсез, гөнаһсыз булу. *Әлеге шул ихлас күңелдән туган ачуын һич тыя алмыйча, «Нишләмәк кирәк, анадан ак перчаткада туа алмагандыз, бигайбә», – диде* (Ф. Хөсни).

**АК САКАЛ АЛДАН ЙӨРҮ.** Кешенең үзен күргәнче үк, аның турында хәбәр алдан таралу. *Аны тукмап җибәрүемне Митрофан һәркемгә сөйләп, минем авторитетны тагын да үстерде, кая барсам да, шунда казанган «ак сакалым» алдан йөрде* (Ф. Яхин. Татар).

**АК САКАЛЛЫ АГА БУЛЫРЛЫК.** Бертигез кимәлдә, дәрәҗәдә булу. *Дөрес, ак кашка шикелле очып тора торган үткен, сабантуйларында беренче килә торган булмаса да, әмма сабан сөрүгә килгәндә, ак кашкага ак сакаллы ага булырлыгы бар иде* (К. Тинчурин. Хәкимҗан агай).

**АК САКАЛЛЫ КАРТ БУЛУ (БУЛГАН БУЛЫР ИДЕ).** Тәҗрибә җитмәүдән берәр ялгышка, хатага үкенеч белдерү. *Врачлар тагын әллә нихәтле киңәшләр биреп, – ул киңәшләрнең барысын төгәл үтәсәң, ак сакаллы карт булыр идең, – чыгып киткәч, ике кулын баш астына куеп, бер сәгать чамасы беркем белән дә сөйләшмичә ятты* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Ярый, иртәгәге таңны аттырсак, без дә ак сакаллы карт булырбыз дип йокларга яттык* (Ф. Латыйфи. Себер хикәяте).

**АК САЛУ.** Күзгә ак төшү, ак яры капланып сукыраю. *Җәйге көзгелектә, җир-су алышынганда, ул аякның ничекләр итеп гөбе кебек шешеп киткәнен һәм тәннең үтәкүренмәе ярыга әйләнгән тиресе аша эчтән шомырт кебек караеп күренгән ядрә сәйләнен, шул чем-кара сәйләннең үз тирәсендә күзенә ак салган башмак күзе сыман агарып үлекләгән күзен күрсәгез иде сез!* (А. Хәлим. Әкчин).
Төрдәше: ак төшү.

**АК САМАВЫР.** Никель самавыр. *Ул шактый йомшаган булса да, сер белдермәс өчен, Саҗидәгә ак самавыр, яхшы чынаяклар, яхшы тәрилкәләр, мискиләр, кашыклар, ике җиз комган, зар бакыр таз, зур һәйбәт сандык алып кайтты* (Г. Исхакый. Кияү). *Җылы өйгә тагын да ныграк җылылык, рәхәтлек тойгысы өстәп,*

*идәндә мич алдында ак самавыр гөрләп утыра иде* (Н. Фәттах. Артта калган юллар).

**АК СӨЯК<ЛЕ>.** 1. Кара эш эшләмәгән, тәрбия күреп үскән. *[Вәли] Ул шул инде ак сөяк нәселдән яратылган* (Г. Камал. Беренче театр). *Без һәммәбез тигез. Кая? Кемнәр ак сөякле, зәңгәр канлылар?* (Р. Фәйзуллин).

2. *күч.* Затлы, назлы. *Аның кулында назлы романслар, иркә мелодияләр уйнарга өйрәнгән «ак сөяк» – нәфис гармонь* (Г. Бәширов).

**АК СУ** 1. Кар яки боз эрү нәтиҗәсендә таулардан яки күлдән аккан су. *Урта Азиядә «ак су» дип кар суын, «кара су» дип җирдән чыккан суны әйтәләр. Бездә «ак су» күлдән агып чыккан су була* (Й. Гәрәй. Күтәреләсе үрләр күп әле). *Төшләрендә тауның ургый ак су, / ургый ак су – тыелгысыз ярсу...* (Ә. Баян. Казан чишмәсе).

2. *к.* агулы елан 1. *Гәрәевнең тапкан ак суыннан дивизия мулласы Сафиуллин бер-ике рюмка салгач, сүзгә тагын да юмартланды* (А. Таһиров).

Төрдәше: агулы елан 1 һ.б.

3. Гомумән ак төстәге сыеклык. *Аш соңында вак савытлар белән ак су төсендә эчемлекләр китерделәр* (Р. Зәйдулла. Ташка ордым башымны).

4. Чиста су. *Барып җиттем күшек тиргәсенә, / Җирдән ак су атылып чыгадыр. / Шул чагында кемдер суга таба / Су эчәргә кулын сузадыр* (Г. Сөнгати. Хозер).

5. *күчм.* Сыек чәй турында. *Чәй дип ниндидер ак су китерделәр шунда* (Сөйләм).

**АК ТА ДИМӘСКӘ, КАРА ДА (КҮК ТӘ) ДИМӘСКӘ** *к.* ак димәстән, кара (күк) димәстән. *Ак та димәдем, күк тә димәдем, алып бирермен дип вәгъдә бирдем* (Г. Ахунов. Фатих малае).

Төрдәше: ак димәстән, кара (күк) димәстән һ.б.

**АК ТА, КАРА ДА ДИМИ** *к.* ак димәстән, кара (күк) димәстән. *Хатыны ак та, кара да дими, шыпырт кына өенә кереп китә* (Сөйләм).

Төрдәше: ак димәстән, кара (күк) димәстән һ.б.

**АК ТАП**. Әлегә ачыкланмаган, өйрәнелмәгән; билгесез булган. *Бу чор – әдәбиятыбызның «ак табы»* (Л. Әхмәдиева. Язмыш һәм иҗат).

Төрдәше: ак урын.

**АК ТӘПИ.** Усал, хәйләкәр, кабахәт кеше турында. *Шулар... Җыен жулик, җыен ак тәпи* (Х. Туфан).

**АК ТӘТӘЙ.** Балалар сөйләмендә бертуган олы апаларын олылап һәм хөрмәтләп әйтү сүзе. *– Ак тәтәй, миңа тәти алып килдеңме?* (Сөйләм).

Төрдәше: ак тута<й>.

**АК ТӘҮБӘ <ДӘ> КАРА ТӘҮБӘ.** Эшеннән яки әйткән сүзеннән кире кайтканда әйтелә. *[Сәйфулла] Шул салма борын янына барып шулай булдым. Шуннан соң ак тәүбә дә кара тәүбә...* (Ф. Бурнаш. Яшь йөрәкләр).

Төрдәше: шәүләсен аша кисеп чыкмау.

**АК ТЕЛӘК.** Изге теләк. *Ханчасы – олуг теләк. Ихласлыгы өчен җанның / Ак теләк өчен бүләк?* (Р. Гаташ).

**АК ТОКЫМ.** Югары катлам кешеләре нәселе, аксөякләр. *Ак токым кешеләренең тормышлары бөтенләй башка бит аларның* (Сөйләм).

Төрдәше: аксөяк нәсел; асыл нәсел.

**АК ТОРМЫШ.** Кайгы-хәсрәтсез, бәхетле тормыш. *[Галимә] Ходай ак тормышлар бирсен инде* (М. Фәйзи. Галиябану). *Чын бәхет, ак тормышым чөн талпынам мин, җилкенәм* (Г. Гайнуллин-Чокалый. Газраилгә).

**АК ТӨШҮ** *к.* ак салу. *Абдулның кызамык авыруыннан соң бер күзенә ак төшеп калган* (Ф. Хөсни).

Төрдәше: ак салу.

**АК ТУГАН.** Өлкән туганны олылап, хөрмәтләп әйтү сүзе. *Ак туганың өйдә юкмыни?* (Сөйләм).

**АК ТУН** *к.* ак җәймә. *Менә ак тун киеп инде күңелсез кыш килә башлый* (Г. Тукай).

Төрдәше: ак җәймә; ак чаршау; ак чикмән; ак юрган.

**АК ТУТА<Й>** *к.* ак тәтәй. *– Төлке, төлке, төләйман, / Төнлә кая барамың? – Ак тутамны ир алган, / Шуны куа барамын* (Әйтеш).

Төрдәше: ак тәтәй.

**АК УЙ.** Игелекле, изге уй. *Кара халыкның эче, уе ак була* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым). *Шуннан да ак уйлар, / Саф хисләр булмастыр* (И. Юзеев. Тыңлачы, сандугач).

**АК УРЫН** *к.* ак тап. – *Бу минем азаккы сүзем түгел, әле өйрелмәгән ак урыннар да бар* (Сөйләм).
Төрдәше: ак тап.

**АК ФЛАГ КҮТӘРҮ (ТАШЛАУ).** Бирелү. *Юк-юк, Таһирҗанның тормыш сынаулары каршында ак флаг күтәрергә уйлаганы да юк* (Р. Низами. Бомж).

**АК ЧАРШАУ** *к.* ак җәймә. *Ак чаршау белән капланган басуны узгач, атыбыз урман эченә керде* (Сөйләм).
Төрдәше: ак җәймә; ак тун; ак чикмән; ак юрган.

**АК ЧӘҮКӘ** *к.* ак карга. *Төп герой Нуриәсма, – һәр авылда яшәгән «ак чәүкә» кебек, халык күзенә дә, җитәкчеләр күзенә дә ерактан күренеп торган аерым бер тип* (Ә. Низаметдинов. Кузгалды уйларым).
Төрдәше: ак карга.

**«АК ЧӘЧӘКЛӘР».** Табиблар. *Казан белгечләре китте дә югалды, җирле табиблар тел тешләде. Тынды «ак чәчәкләр»!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**АК ЧӘЧКӘ.** Ап-ак сакаллы һәм кызыл чырайлы карт кеше. – *Безнең авылдагы ак чәчкәне беләсеңдер әле* (Сөйләм).

**АК ЧИКМӘН** *к.* ак җәймә. *Тирә-якны аклык басты, агачлар да ак чикмән киделәр* (Сөйләм).
Төрдәше: ак җәймә; ак тун; ак чаршау; ак юрган.

**АК ШАЙТАН** *шаяру.* Хатын-кыз. *Алмабикә сүзсез генә утыра бирде: ни «а», ни «б». «Әллә йоклап киткәнме соң бу ак шайтан?» – дип борчылды Галимҗан* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

**АК ШАЙТАН, КАРА ШАЙТАН, КӨЧ-ХӘЛ, ИЛАЛЛА БЕЛӘН.** «Берәр зур бәлага эләккәндә, яхшы һәм явыз көчләрнең барысын да ярдәмгә чакыру» мәгънәсендә. *Гөлсем авыз эченнән генә «ак шайтан, кара шайтан, көч-хәл, илалла белән» дип пышылдады да лапас эченә атлады* (Сөйләм).

**АК ШИГЫРЬ.** Рифмасыз шигырь. *Башта ак шигырь белән мавыкты. Хәзер чыкылдап торган эче ритмлы, музыкаль агышлы рифмаларга күчте* (А. Хәсәнов. Җәнбәт җәвере).

**АК ЭТ БӘЛАСЕ<Н> КАРА ЭТКӘ.** Бер кешенең гаебен икенче кешегә сылтау, аудару. – *Берәрсе урамнан кереп ясап чыккандыр әле. Аның бу сүзләрен күтәреп алдылар: – Ак эт бәласе кара эткә* (Ф. Садриев. Тургай). *[Хатыйп] Менә! Ак эт бәласе кара эткә. Үзең карыйсың ич* (Ю. Әминов. Язылмаган законнар).
Төрдәше: ак эт бәласен кара эткә ягу (сыл<т>ау; тагу); ак этнекен кара эткә; гаепсездән гаепле; торма ачысы шалканда.

**АК ЭТ БӘЛАСЕН КАРА ЭТКӘ ЯГУ (СЫЛ<Т>АУ; ТАГУ)** *к.* ак эт бәласе<н> кара эткә. *[Рахмай] Ак эт бәласен кара эткә ягасызмы?* (А. Гыйләҗев). *Ак эт бәласен карага сылтау гадәте анда да бар* (Н. Әхмәдиев. Мөнирстан). *Шул ук вакытта аны борчыган, хәтерен калдырган нәрсә дә бар иде: Алафузов аны күрәләтә алдаган, ак эт бәласен кара эткә сылаган икән бит* (З. Фәтхетдинов. Үлем элмәге).
Төрдәше: ак эт бәласе<н> кара эткә һ.б.

**АК ЭТ НИ, КАРА ЭТ НИ <– БАР ДА ЭТ>.** Төс-формалары төрле булса да, табигате, эчтәлеге бер үк булганны белдерә. – *И сеңлем, безнең әткәй: «Ак эт ни, кара эт ни – бар да эт», – дип әйтә торган иде* (М. Әмирханов. Мөкәррәмә).

**АК ЭТНЕКЕН КАРА ЭТКӘ** *к.* ак эт бәласе<н> кара эткә. *Ак этнекен кара эткә аударып маташа берәве* (Сөйләм).
Төрдәше: ак эт бәласе<н> кара эткә һ.б.

**АК ЭЧЛЕ.** Саф күңелле, кешегә яхшылык теләүче, эчкерсез кеше. *Кем кара эчле, кем ак эчле, моны ачыклыйсы да ачыклыйсы әле...* (М. Әмирханов. Гәүһәршад).

**АК ЭШ.** Физик көч куллану таләп ителмәгән эш, чиста эш. *Ак эш, кара эш дип сөйләүчеләрне белмибез* (Г. Әпсәләмов. Миңа унтугыз яшь иде).

**АК ЮЛ.** 1. Намуслы, яхшы уйланылган, изге дип саналырга хаклы юл, юнәлеш. *Бөтен институтны гаҗәпкә калдырып, Капия шул ярышта беренче урынны алды. Шуннан соң кыз өчен әйтерсең ак юл ачылды* (В. Имамов. Кәнәфи). *Адашканда, ак юл күрсәтүче / Күңел күзе ул – сез икән* (С. Әхмәтҗанова. Гәрәбә).

2. Сәфәргә чыгучыларга изге теләк. *Бирем әкә мөсафирга ак юл теләп калды* (Г. Ибраһи-

мов. Казакъ кызы).– *Ак юл сиңа, Тотыш би, – диде Тәңкә* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).

Төрдәше: хәерле сәфәр!

3. Бәхетле яңа тормыш теләү. – *Түзәрмен, тик газиз төпчегемне сакла, аңа ак юл күрсәт!* (Ф. Латыйфи. Хыянәт). *[Назлыбикә] Китсәң еламый булмас инде. Ак юл, теләсәң, бүген үк кит!* (Ю. Әминов. Язылмаган законнар).

4. Нинди булса да эштә уңыш теләү. *Ак юл теләргә генә кала, әйдә, башлап кара* (Сөйләм). *Анда ямь, анда матурлык, анда аклыклар тулы, / һәм теләкләргә туры бер якты ак юл ялтырый* (Г. Рамазанов. Япан).

5. Әсәрләрдә, язуларда язмыйча, буш калдырылган юл. *Мулланур Вахитов рухына / Соң дәвердә юксыл шәрекъ тарихы / Бер бит булсын, ак юл – сәтыр күрмәде* (Р. Гаташ. Шәрекъ нуры).

6. *ирон.* «Китә бир, синең монда кирәгең юк» мәгънәсендә әйтелә. – *Әйдә, сөйләнеп торма, бара бир, ак юл сиңа!* (Сөйләм).

**АК ЮЛ ХӘЗЕРЛӘП (ХӘСТӘРЛӘП) КУЮ.** Изге дип саналырга хаклы, бәрәкәт бирә торган юл язмыш тарафыннан алдан сайлап куелганлыкка ишарә. *Тәкъдир дигәнең барысын да алдан күреп, ак юл хәзерләп куйган лабаса* (Р. Низами. Сәйдәшнең соңгы елы).

**АК ЮЛГА КАРА ЕЛАН ЯТУ.** Яхшылыкка илтә, уңыш китерә торган юлда каршылыклар, явызлыклар очрау. *Тик синең ак юлыңа һаман шул кара елан сузылып ята. Атна чамасы вакыт үтеп китте – очрашып булмый алтын башлы остазны* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

**АК ЮРГАН** *к.* ак җәймә. *Җиргә ак юрган җәйделәрмени, бар дөнья акка төренде* (К. Тәхау. Кыштуган).

Төрдәше: ак җәймә; ак тун; ак чаршау; ак чикмән.

**АК ЯБАЛАК СӨТЕ** *к.* агулы елан 1. *Стаканнарда «ак ябалак сөте» һәм вәссәлам!* (Ш. Маннур).

Төрдәше: агулы елан 1 һ.б.

**АК ЯК.** 1. Казаннан төньякка таба җәелгән төбәкне (нигездә, Алат юлы буенда) «ак як» диләр. *Казан артында элекке авылларны «ак як», «кара якә»дип бүлгәләп йөрткәннәрен әйткән идек* (М. Мәһдиев. Шагыйрьнең бишеге).

2. Өйнең түр зал ягы. *Ак яктагы лампыга ут кабызып җибәрегез әле* (И. Гази). *Ә олы як – кунаклар кабул итә торган урын, ак як дип атала* (Ф. Бәйрәмова. Кырык сыпт).

**АК ЯКА<ЛАР>.** 1. *иск.* Элекке яшь зыялылар, алар, модага ияреп, европалыларча ак катыргы яка тагып йөргәннәр. *Ул зыялыдыр, беләмсез, мәгърифәт-хикмәт сата; / Манжет алган ун тиенгә / биш тиенгә ак яка* (Г. Тукай).

2. Кадимчеләрнең җәдитчеләрне мыскыллап атаулары. *Бераздан, инде өйләренә якынлашып килгәндә, әлеге ак яка тагын очрады* (Н. Фәттах). *Шәкерт булсам булдым, заграничный сүзләрне бик тә авыз чәпелдәтеп яудыручы бу укымышлы Ак яканы артык тилертү юлына басмадым* (Ф. Хөсни. Кара кофе).

3. Өстәл артында, зур эш эшләгән кебек, кәгазьләрне арле-бирле куйгалап, әмер биреп утырырга яратучы. *«Ак яка» булып йөргәнче, / Ул эш эшләсен, – дигән* (Х. Хөснуллин. Кәгазь җыю кооперативы).

**АК ЯКАЛЫ** *иск, ирон.* Кара эш эшләмәгән, кәгазь эше белән шөгыльләнүче, бюрократ. *Болар һәммәсе ак якалы иде, ләкин һәммәсе исерекләр, һәммәсе качырып тора торган сөяркәләре янынннан кайтып баралар шикелле иде* (Ф. Әмирхан. Хәят).

**АК ЯКТАН КУСАҢ, КАРА ЯКТАН КЕРҮ.** Әрсез, йөдәтүче кеше турында. – *Белмисеңмени аны, ак яктан кусаң, кара яктан килеп керә бит ул!* (Сөйләм).

Төрдәше: ишектән куганда тәрәзәдән (тишектән) керү; ишектән кусаң, тәрәзәдән керү; ишектән кусаң – тишектән, тишектән кусаң – тәрәзәдән, тәрәзәне япсаң – морҗадан төшү; ишектән чыгарсаң, морҗаңнан төшү.

**АК ЯҢГЫР.** Берничә көн буенча бөтен тирә-якны аксыллык белән каплап ява торган болытсыз яңгыр. *Кара яллы, көмеш чуклы / Ак яңгыр тулпарына / Алтын кояш дуга элде / Салават күпереннән* (Ф. Яхин). *Әллә кырлардан, әллә урманнан / Ишетелә моңлы Сак-Сок тавышы. / Ак яңгыр сыман, күзләрдә томан* («Казан утлары» ж.).

**АК ЯРЛЫЛЫК.** Физик эш белән бәйсез хезмәттә булып, мохтаҗлыкта яшәү. *Ләкин шул ук вакытта ак ярлылыктан да туеп беткән иде инде ул* (Ф. Хөсни).

*АКАЕП* ❖ **АКАЕП КАРАП ТОРУ.** Күзләре атылып чыгардай булып карау. *Минәт, нәрсәнедер төшенергә теләгәндәй, аңа акаеп карап торды* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

*АКАЙ* ❖ **АКАЙ КҮЗ.** 1. Агы зур булып чыгып торган күзле. *Эләксә, иң соңгы балыкны / Ашар идеңме, акай күз* (Ш. Гаделша. Аучы җыры).

2. Ярамаганны күрүче. *Кара, нинди акай күз, күрше ишектән кемнеңдер чыгып китүен күреп калган* (Сөйләм).

3. Игътибарсызлыктан аны-моны күрмәүчегә әйтелә. *Минем иркемдә булса, синең ише «акай күз»ләрнең талонын тишү генә түгел, бөтенләй машинасын алып калыр идем...* (М. Зарипов. Үзеңнеке – үзәктә...).

Төрдәше: алакайган күз.

**АКАЙ КҮЗЛЕ** *ирон., шаярт.* Үткен күзле, кирәкмәгәнне дә күрүче. *Яныңда акай күзле Мидхәт булганда, сиңа нәрсәгә бинокль?* (Сөйләм).

*АКАЙ-ЧУКАЙ* ❖ **АКАЙ-ЧУКАЙ КЕШЕ.** Буталучан, сүзе-хәрәкәте белән төрле нәрсә белән мавыгучан. *Акай-чукай кеше бит ул, аның һәр сүзенә ышана башласаң* (Сөйләм).

**АКАЙ-ЧУКАЙ КИЛҮ (КИЛЕП БЕТҮ; КИТЕРҮ).** 1. Баш-күз әйләнү, буталу; мавыгу. *Ә без көтүдән калган аңгыра сарыклар шикелле кая барып сыенырга белмичә акай-чукай килеп торабыз* (М. Әмирханов. И кылган догам минем).

2. Тәртипсезләнеп йөрү. *Орлов кебек үк, Потемкин да императрицага өйләнергә карар кылып, акай-чукай килеп бетә. Морадына ирешер өчен ул төрле хәйләләр корып карый* (М. Евгеньева. Әби патшаның сөяркәләләре).

Төрдәше: акай-шакай килү.

*АКАЙ-ШАКАЙ* ❖ **АКАЙ-ШАКАЙ КИЛҮ** *к.* акай-чукай килү (китерү) 2. *Акай-шакай килмәсәң, илнең күзе очлы аның, күрерләр, бәхет күгәрченең үзе үк иңбашыңа килеп кунар* (Ф. Хөсни).

Төрдәше: акай-чукай килү (китерү).

*АКБУЗ* ❖ **АКБУЗ АТ.** 1. Халык авыз иҗатында мактаулы ат (аксыл көлсыман төстә). *Иле өчен яуга чыккан ирнең / Акбуз аты җилсә далада* (Зөлфәт). *Акбуз ат симез булмас, / Бик симерсә, уйнаклар* (Җыр).

2. Халык авыз иҗатында боз катуны аңлата. *Акбуз атым басма булды, / Буйдан-буйга тасма булды* (Табышмак).

*АККА* ❖ **АККА ЙОКМАУ (ТАММАУ).** Намуслы, изге күңелле кешеләр хакында гайбәт сүзләре сөйләмәү. – *Мансур – ак кеше ул, әшәкелек акка йокмый ул* (Сөйләм).

**АККА КАРА БЕЛӘН <ЯЗ<ЫЛ>У>** 1. *к.* ак өстенә кара белән. *Менә монда акка кара белән аермачык итеп язган: «Шәрык илләренә сатылып киткән кыз-кардәшләремезнең язмышы ифрат дәрәҗәдә аянычь вә өметсездер»* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: ак өстенә кара белән.

2. Чын, инкяр итеп булмый торган, дәлилләнгән; законлаштырылган. *Акка кара белән язылган икән, ул инде документ* (Ф. Латыйфи. Ак-карага тимәскә). *«Башкиры» дип язылган авыллар Мәскәүдәгеләрендә акка кара белән «татары» һәм «черемисы» дип язылган* (И. Хуҗин. Топонимнар).

**АККА КАРА ДИЮ.** Нәрсәне яки кемне булса да аклау, яхшы күрсәтү өчен, булган әйберне күрә торып инкарь итү, яхшыга чыгару. *Акка кара дия-дия, депутат та булып куйды* (Сөйләм).

Төрдәше: акны ак димисең, караны – кара; акны кара <дип>, караны ак дип әйтү (дию; тану); акны кара дип раслау; акны кара дию; ап-акны кап-кара дип әйтү.

**АККА КАРА ЯМАУ.** 1. Нәрсәне булса да төзәтәм дип бозып кую. *Киемең каюы да акка кара ямау булып күренер синең өстеңдә* (М. Хуҗин. Уеннан – уймак).

2. Оста хәйләли белмәү, хәйләләгәне сизелеп тору. *Хәйләң акка кара ямау шул, сикрит-микритләреңне мич башында сөйләшерсең* (Б. Камал).

**АККА КҮЧЕРҮ.** Караламаны чисталап ак кәгазьгә күчерү. *Женни Маркс әсәрләрен акка күчергән, аларны массага таратырга булышкан, Маркс өчен хатлар язган* (Г. Кутуй. Тапшырылмаган хатлар).

Төрдәше: ак кәгазьгә күчерү; акка язу.

**АККА СӨЙРӘҮ.** Яхшы яшәргә тырышып, кулдан килгәнне эшләү. *Карт түгел бит, мин әле*

*тап-таза ять-яшь бер кеше, / Тормышымны акка сөйрәүгә чын керешкән ир кеше* (Г. Гайнуллин-Чокалый. Газраилгә).

**АККА ТУК <ЯШӘҮ>.** Сөт-катык кебек сөт азыгы мул булу. *Акка тук, печмәгә киндере юк* (Мәкаль).

**АККА ЯЗУ** *к.* ак кәгазьгә күчерү. *[Муса мирза] Салих әфәнде! Син аны инде акка яз* (Г. Исхакый. Җәмгыять).

Төрдәше: ак кәгазьгә күчерү; акка күчерү.

*АККАН* ❖ **АККАН СУ КЕБЕК** *к.* агым су кебек. *Ләкин вакыт аккан су кебек үтте дә китте, институт белемнәре дә аз-азлап онытылды, искерде, аларны яңартырга вакыт тимәде* (Ф. Садриев. Шаһзаманов эше).

Төрдәше: агым су кебек; аткан ук кебек; атылган ук кебек 1.

**АККАН СУЛАР КИРЕ КАЙТМАУ** *к.* агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән. *Аккан сулар кире кайтмый, / Яшь гомерләр дә шулай* (Хал. җыры).

Төрдәше: агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән һ.б.

*АК-КАРА* ❖ **АК-КАРА ДИМӘҮ** *к.* ак димәстән, кара (күк) димәстән. *Күнегелгән кагыйдәләр буенча, ул картка ак-кара димәде, кайтарып җавап бирмәде, юрган астында йодрыгын йомарлап, кемнәр беләндер бәхәсләшеп, талашып ятты...* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: ак димәстән, кара (күк) димәстән һ.б.

**АК-КАРА <КҮЗГӘ> КҮРЕНМӘҮ.** 1. Ашыкканлыктан яки рухи халәткә бәйле рәвештә бернәрсәне дә аермау, игътибар итмәү. *Минем күзгә ак-кара күренмәде* (Ф. Хөсни. Алтын көз). *Болакны кичеп, Арча кырына таба үтәсе полкларның хурлыклы чигенүе кызу канлы, сүзе аста калганны бер дә күтәрә алмаган Иоанн Васильевичны ярсытыр, күзенә ак-кара күренмәс хәлдә, тагын-тагын яңа гаскәрләрне суга ташлар дип көткәннәр иде* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).

Төрдәше: агы-карасы <күзгә> күренмәү һ.б.

2. Караңгылык иңү, тирә-як күренмәс хәлгә килү. *Инде без генә, чана шуучы малайлар гына калдык. Аларның да, уенга әлмәшләнеп, күзенә ак-кара күренми башлаганнары гына* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: агы-карасы <күзгә> күренмәү; ак<ны>-караны аеру (күрү).

**АК-КАРА ТАНЫМАУ.** Бөтенләй надан, грамотасыз булу. *Минем бабай ак-кара танымый иде, гомер буе җирдә эшләгән* (Сөйләм).

Төрдәше: «а»ны «б» га куша белмәү; артка калу 3; артта булу 2; аягыннан алып (тотып) селексәң дә булмый (чыкмый; бер тиен / әлиф / хәреф төшми) 1; аягыннан тотып селкесәң дә, мәгънәле сүз төшмәс; әлифне (әлепне; әлефне) таяк дип <тә> белмәү; әлифне таяк, вауны чукмар дип тә белмәү; әлифне таяктан аермау; әтәч синең хәрфе җөреңне каян белсен?; бармак исәбен дә белмәү; башына чүбек тутырылган; бер әлиф тә танымау; ботыннан тотып селексәң, авызыннан бер әлиф (өч хәреф) тә төшмәс; ботыннан тотып селексәң дә юк (булмый); буш баш<лы>; буш чарлаклы; гыйлемнән җәяү <качу>; ике аягыннан (аякларыннан) тотып селкесәң дә әлиф төшмәс; кара калу; кара халык; ләм-мим белми; ни «а», ни «б»; өшегән күркә; сукыр бәрәңге; сукыр тавык; сукыр тавыкка бар да бодай; сыйфырга якын; тотып селексәң дә юк.

*АК<КА>-КАРАГА* ❖ **АК<КА>-КАРАГА КАРАМЫЙ<ЧА>.** Яхшысын да, яманын да, бернигә дә игътибарга алмыйча, эшлекле хәрәкәт итү. *Зачетлар бетү белән, акка-карага карамый, өйгә ашыктым* (Ш. Камал).

*АК-КАРАДАН* ❖ **АК-КАРАДАН БЕР СҮЗ ӘЙТМИЧӘ.** Сүзнең яхшысын да, начарын да әйтмәү. *Күзен чеп-чеп йомгалап торды да, ак-карадан бер сүз әйтмичә, бүлмәдән чыгып китте* (Сөйләм).

Төрдәше: актан-карадан <бер> сүз <дә> әйтмәү.

*АК<НЫ>-КАРАНЫ* ❖ **АК<НЫ>-КАРАНЫ АЕРМАСТАН (АЕРМЫЙЧА; КҮРМИЧӘ)** *к.* агы-карасы күзгә күренмәү. *Ә Нургалинең кешеләрдә эше юк, сыртына каты чыбыркы төшкән яшь ат шикелле, ул ак-кара күрмичә чабуын белә* (Ә. Еники. Рәхмәт, иптәшләр). *– Менә шунда күрәм: солдатларның бик күбесе Колчак станына ак-караны аермастан саташып килеп кергәннәр* (Р. Низами. Сәйдәшнең соңгы елы). *Бу саннар тирә-юньне тутырып выжылдап оча башлагач, Зөләйха, коты чы-*

*гып, ак-караны аермыйча, битен каплап, алга чапты* (А. Гыйләҗев. Яра).
Төрдәше: агы-карасы <күзгә> күренмәү һ.б.

**АК<НЫ>-КАРАНЫ АЕРУ (КҮРҮ).** 1. *к.* ак белән караны аеру. *Ул үзе дә бит мал дигәндә акны-караны аермый торган кеше – соңыннан йортыңа чынлап торып хуҗа булып алмасмы?* (Ә. Еники. Рәшә). *Әле яңа гына ак-караны аерыр хәлгә килгән Сәет керфекләрен челтчелт йомды* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).
Төрдәше: ак белән караны аеру һ.б.

**АК-КАРАНЫ БЕЛМИ<ЧӘ>.** Бик ашыгып, бернигә дә карамыйча. *Боларга ак-караны белми яуга томырылу, каннар коя-коя, яра ала-ала батырлыклар кылу һич мәҗбүри түгел* (В. Имамов. Утлы дала).
Төрдәше: агы-карасы <күзгә> күренмәү һ.б.

**АК<НЫ>-КАРАНЫ БЕЛҮ** *к.* ак белән караны аеру. *Ак-карага ник өйрәндек икән? / Ак-караны беләмени бу?* (Ф. Яхин). *Әле телем яңа гына ачылып килгән чакта ук, акны-караны белә башлаганда ук, мондый сүзләрне күп ишеткәнем булды* (Н. Дәүли. Язмышка юл).
Төрдәше: ак белән караны аеру һ.б.

**АК-КАРА<НЫ> КҮРМӘҮ (ШӘЙЛӘМӘҮ).** Бер нәрсәгә дә дикъкать итмәү. *Урамда бала-чага уйныймы, кош-корт, мал йөриме, ак-караны күрми, дөнья туздырып чаба* (Р. Батулла. Сөембикә).
Төрдәше: агы-карасы <күзгә> күренмәү һ.б.

*АККОШ* ❖ **АККОШ ҖЫРЫ.** Берәүнең соңгы, гадәттә иң мөһим булган әсәре, нәрсәнедер башкару, күрсәтү һ.б. *Карчыкларның бер мизгелгә генә тыныч дөньяларын давылга урап, ялгыз аккош җыры яңгырады: – Тәнзилә, дим! Китмә!* (М. Кәбиров. Елмаю). *«Әйтелмәгән васыять»не минем әдипнең «аккош җыры» (лебединая песня) дип атыйсым килми* (М. Юныс. Акъәбинең кабере янында).

**АККОШ ОЧЫР(Т)ЫП БАЮ.** 1. Акча уйнап отып баю (көмеш акчаны тырнак очында чөю). *Мидхәт аккош очырып баеган да хәзер кинога барырга җыена* (Сөйләм).

2. Ялган көмеш акча сугып байлык туплау. *Безнең күрше аккош очырып баеган икән, шуның өчен таш капчыкка ябып куйганнар* (Сөйләм).

**АККОШ СӨТЕ** *к.* агулы елан 1. *Ул бай була тәтәйләрдә типкән чакта; / Аккош сөте бераз башка киткән чакта* (З. Бәшири).
Төрдәше: агулы елан 1 һ.б.

*АККОШТАН* ❖ **АККОШТАН ЫЧКЫНДЫРУ.** Көмеш акча белән хәер-садака бирү. – *Теге эшләпәле фырт агай миңа аккоштан ычкындырды!* (Сөйләм).

*АКЛЫ* ❖ **АКЛЫ СИТСА.** Җырларда саф мәхәббәт, ихлас күңелне белдереп, бизәк итеп алу ысулы. *Аклы ситса күлмәгемнең / Табалмадым ишләрен; / Гомерем буйларына, Рәйхан, / Оныталмасам нишләрмен?* («Рәйхан» хал. җыры).

*АКЛЫ-ЯШЕЛЛЕ* ❖ **АКЛЫ-ЯШЕЛЛЕ АВАЗ (ТАВЫШ) ЧЫГАРУ.** Бик югары нотаны алып, чыелдавык тавыш чыгару. *Ишек артында, пианино тавышын басып, кемнеңдер аклы-яшелле авазлар чыгарганы ишетелә башлады* (Сөйләм).

*АКМА* ❖ **АКМА КОЛАК.** 1. Кеше сүзен тыңламый торган, игътибарсыз, хәтерсез кеше. – *Акма колакка сөйләгәнче, язып кына җибәр идең* (Сөйләм).

2. Колагы ага торган кеше. *Аръяк Габдүшен хәтерли идеңме, колагына җил өргән дә хәзер акма колак булып калды* (Сөйләм).

*АКМАН-ТАКМАН* ❖ **АКМАН-ТАКМАН БУРАНЫ.** Март аенда бер атнага якын була торган буран. *Әнә шуның өчен дә, имештер, мартта була торган алты көнлек буранга «акман-такман» бураны дигәннәр* (Х. Мәхмүтов. Ел тәүлеге – 12 ай).

*АКМАСА* ❖ **АКМАСА ДА ТАМУ (ТАМЧЫЛАУ).** Аз-азлап булса да файда килеп тору. *[Мөхәммәтҗан] Сезнең әле акмаса да тама торгандыр* (К. Тинчурин. Йосыф белән Зөләйха). *Утын чыгару солы ташу түгел, икмәк тирәсендә акмаса да тама шунда, кыска җәйдә болай да ныгып җитмәгән бахбайлар утынга йөри башлагач, тагын йөгәнеп калдылар* (А. Гыйләҗев. Язгы кәрваннар).
Төрдәше: бер атканда (атуда) ике (куш) куян алу; ике куянны бер атуда егу; ике куянны берьюлы ату;

ике куянны берьюлы куу; ике куянны берьюлы тоту; ике куянның койрыгын <берьюлы> тоту.

*АКНЫ* ❖ **АКНЫ АК ДИМИСЕҢ, КАРАНЫ – КАРА.** Чынбарлыкны дөрес күрсәтмәү. *Акны ак димисең, караны – кара... И барысы да үз урынына утыра* (Ф. Латыйфи. Ак-карага тимәскә).
Төрдәше: акка кара дию һ.б.

**АКНЫ АК <ДИП>, КАРАНЫ КАРА ДИП ӘЙТҮ (ДИЮ; ТАНУ)**. Дөреслекне сөйләү, тану. *Чын бөеклек, чыннан да, гадилектә. Акны ак дип, караны кара дип әйтә белүгә* (Р. Сверигин. Кеше үзе җавап бирә...). – *Ике мәртәбә яраландым. Акны ак дип, караны кара дип таный беләм* (Г. Ахунов. Чикләвек төше).
Төрдәше: башка бәреп әйтү; дөреснең аргы ягында булу; йөрәккә үткәреп әйтү (язу); морҗасы кәкре булса да, төтене туры; туры сүз; туры юл табу.

**АКНЫ КАРА <ДИП>, КАРАНЫ АК ДИП ӘЙТҮ (АҢЛАТУ; ДИЮ; ТАНУ)**. Ялганлау, яхшыны яман дип әйтү. *Акны кара, караны ак диюләргә/ Күнмәдем* (Р. Мөхияр. Сынмадым). *Тик моның өчен ниндидер чорда Йосыф морзага акны – кара дип, караны ак дип танырга туры килер, ягъни урыслар белән килешкәндәй итәргә булыр* (М. Хәбибуллин). – *Оратор куәте дә Ходайга шөкер. Ә халык үзе акны кара дип аңлатуларыннан гаҗиз иде* (Г. Ахунов. Чикләвек төше).
Төрдәше: акка кара дию һ.б.

**АКНЫ КАРА ДИП РАСЛАУ** *к.* акны кара <дип>, караны ак дип әйтү (дию; тану). *Акны кара дип расларга мәҗбүр ителгән совет әдәбият белеме бу төр әсәрләрне иске җәмгыятьнең тончыктыргыч шартларын, начар, тискәре якларын ачы тәнкыйтьләп, буржуаз дөньяны фашлауга багышланганнар дип бәяләде* (А. Әхмәдуллин. Тормыш сабаклары сынавында).
Төрдәше: акны ак димисең, караны – кара; акны кара <дип>, караны ак дип әйтү (дию; тану); акны кара дию; ап-акны кап-кара дип әйтү.

**АКНЫ КАРА ДИЮ** *к.* акны ак димисең, караны – кара. *Акны кара дию җитмәсә, һәй / Бүтән корал ала теләсә* (Г. Афзал. Торичелли бушлыгы). *Ә халык үзе акны кара дип аңлатуларыннан гаҗиз иде* <...> (Г. Ахунов. Чикләвек төше).
Төрдәше: акка кара дию һ.б.

**АКНЫ КАРАДАН АЕРМАУ (АЕРА АЛМАУ / БЕЛМӘҮ)** *к.* ак белән караны аермау (белмәү; күрмәү). *Акны карадан аермау / Ул – афәтнең төбе* (Л. Шагыйрьҗан. Алар – сугыш шаһитлары). *Бүген кайбер игелексез адәмнәр шул чорның Тукай, Исхакый, Гафури кебек шәхесләренә күсәк күтәрә икән, бу фәкать наданлыктан, акны карадан аера белмәү аркасында гына* (Ә. Рәшит. Һәркемнең... үз хакыйкате).
Төрдәше: ак белән караны аермау (белмәү; күрмәү) 1, 2 һ.б.

**АКНЫ КАРАДАН АЕРУ.** Аз-маз гына белү, яхшы белән начарны аера белү. *Алданмаска ляземдер, Аерып акны карадан* (Г. Тукай. Тәүлек). *Инде хәзер Илсөяр, Бикмуш бабайча әйтсәк, акны карадан аера белә башлаган иде* (Г. Гобәй. Маякчы кызы).
Төрдәше: ак белән караны аеру; ак<ны>-караны белү; акны-караны аеру (тану); актан караны аеру.

*АКНЫ-КАРАНЫ* ❖ **АКНЫ-КАРАНЫ АЕРМАУ** *к.* ак белән караны аермау (белмәү; күрмәү). *Ул үзе дә бит мал дигәндә акны-караны аермый торган кеше – соңыннан йортыңа чынлап торып хуҗа булып алмасмы?* (Ә. Еники. Әйтелмәгән васыять).
Төрдәше: ак белән караны аермау (белмәү; күрмәү) 1 һ.б.

**АКНЫ-КАРАНЫ АЕРУ (ТАНУ)** *к.* ак белән караны аеру. *Белеме зур кешегә акны-караны аеруы җиңелрәк, күп җиңел* (М. Хуҗин. Юлмәти бәйрәме).
Төрдәше: ак белән караны аеру һ.б.

**АКНЫ-КАРАНЫ КҮРМӘҮ** *к.* ак белән караны аермау (белмәү; күрмәү) 1. *Без акны-караны күрмәстән, кая басканны белмәстән, Зәңгәр чишмәгә чаптык* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр). *Миранша*һ*, бәйге сызыгына баскан чабыш аты кебек, акны-караны күрми, алга томырылды* (В. Имамов. Карабәк).
Төрдәше: ак белән караны аермау (белмәү; күрмәү) 1 һ.б.

*АКНЫҢ* ❖ **АКНЫҢ АК, КАРАНЫҢ КАРА ГЫНА БУЛА АЛМАВЫ.** Берәр нәрсәнең чип-чиста

гына тора алмавы, аңа башка төрле нәрсәләр катнашырга мөмкин булуы хакында. *Дөрес эшли-эшли, яши-яши, акның – ак кына, караның кара гына була алмавын аңлады* (Д. Булатова. Соң түгел!).

*АКРЫН* ❖ **АКРЫН БАСЫП, ВАК-ВАК АТЛАП.** Хатын-кызларның матур һәм килешле атлап йөрүләре турында. *Ай диләр, вай диләр, / Таяналар бөергә; / Акрын басып, вак-вак атлап, / Чык каршыма биергә* (Җырдан).

*АКСАГАН* ❖ **АКСАГАН БЕЛӘН АКСАУ.** Ялагайлану, берәрсенең күңелен күрү өчен, анда булган кимчелекне үзеңдә бар итеп күрсәтү. *Хуҗаң шундый булгач, нишлисең, аксаган белән аксау гына кала инде* (Сөйләм).

**АКСАГАН ЯК (ҖИР).** Җитешмәгән, кимчелекле урын. – *Башта син аның аксаган ягын тап, аннан соң күз күрер* (Сөйләм).

*АКСАК* ❖ **АКСАК АКЫЛ.** Аек акыл белән эш итү сәләтен югалту; уйлый алмау, фикер йөртү сәләте кимү. *Аты аксак булса да, акылы аксак түгел аның* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым). *Аксакал бул, аксак акыл булма* (Ш. Галиев. Канатлы сүзләр).

Тәрдәше: акыл бетү; акыл <баштан> китү (чыгу); акыл җилгә очу; акыл<га; -дан> җиңеләю 1; акыл<га> зәгыйфьләнү; акыл савыты сыегу сыегаю); акыл саегу (саегаю); акыл сидрәү; акыл сыеклану; акыл тартмасындагы шөреп төшү (төшеп калу); акыл чуалу; акыл чыгу; акыл шөребе коелу; акыл шөребе югалу; акылга зарар (зыян; зәгыйфьлек) килү; акылга кимчелек килү; акылга көч килү (китерү); акылдан сабу; акылдан тайпылу (таю); акылдан шашу; акылдан ычкыну; акылдан язу; акылны җую (югалту); акылсыз баш; аны Гөләп җиңги дә (Мәнди анасы да; эт тә) белә; аңга зыян килү; аңгыра баш<лы>; аңгыра бәләк (бәлеш; бәрән; бозау; күке; сарык; тавык; ябалак); аңгыраның да аңгырасы; атаңның баш сөяге; ахмак баш<лы>; ахмакның ахмагы; баш сыеклану; башның винтлары бушау; башка чүбек (кибәк) тутыр<ыл>у; бүрекле карга; гайкасы бушау; гайкасы йомшак; гайкасы йөрми, тутыккан; гакыл бетү; гакылдан сабу; гөмбә баш; дебет колак 2; Мәнди анасы да белә; ми сыеклану; ми түнү 1; ми черү (череп йөрү); ми шулпалану; ми эрү; моны эт тә белә, тавык та; туң баш; туң бәрәңге; туң күчән; шөрепләре какшау.

**АКСАК АТКА МЕНЕП АТЛАНУ.** 1. Эшкә яраксыз, җимерек нәрсә алу. – *Сатып алганда, нигә яхшылап карамадың, аксак атка менеп атлангансың бит – моторын алыштырырга кирәк моның!* (Сөйләм).

2. Тормыш итәргә сәләтсез кеше белән мөнәсәбәттә булу, гаилә корырга җыену. *Күзең бәйләнгән килеш аксак атка менеп атлангансың икән* (Н. Гыйматдинова. Күке төкереге).

*АКСӨЯК* ❖ **АКСӨЯК НӘСЕЛ.** Затлы, югары катлам нәселе. *[Вәли] Ул шул инде аксөяк нәселдән яратылган. Ә безнең нәрсә, без бит мужик!* (Г. Камал. Беренче театр).

Тәрдәше: ак токым; асыл нәсел.

*АКСӨЯКЛЕ* ❖ **АКСӨЯКЛЕ БУЛУ.** Затлы, югары нәселдән булган кеше. *[Вәли] Безнең шикелле кара икмәк ашап үскән кешегә кая инде ул аксөякле булу!* (Г. Камал. Беренче театр).

*АКТАН* ❖ **АКТАН АК, КАРДАН (СУДАН) ПАКЬ.** Һичбер гөнаһы булмаган. – *Минме, мөселман мин. Актан ак, кардан пакь мөселман мин!* (Сөйләм).

Тәрдәше: судан ак, кардан пакь.

**АКТАН КАРАНЫ АЕРУ** *к.* ак белән караны аеру. *Юкса үзе затлы исемен йөртә, / Аерал-мый актан караны* (Л. Янсуар).

Тәрдәше: ак белән караны аеру һ.б.

**АКТАН ДА, КАРАДАН ДА ДӘШМӘҮ.** *Кичтән өзелгән контактны ялгамак булып, Фәләх иртән сүз катып караса да, Роза әйтерсең телен йоткан иде: актан да, карадан да дәшмәде* (В. Нуруллин. Фаҗига).

Тәрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

*АКТАН-АК* ❖ **АКТАН-АК, ПАКЬТАН-ПАКЬ ИТЕП КҮРСӘТҮ.** Булмаган дәрәҗәдә, югары сыйфатлы итеп күрсәтү. *Революционерларны исә актан-ак, пакьтан-пакь итеп күрсәтә, күккә күтәреп мактый* (Р. Мостафин. Төгәл булыйк!).

*АКТАН-КАРАДАН* ❖ **АКТАН-КАРАДАН <БЕР> СҮЗ <ДӘ> ӘЙТМӘҮ** *к.* авыз <да> ачмау. *Мулла абзый актан-карадан сүз әйтми чыгып киткәч, ботак-чатаклы җикерүләр, тупас аяк*

*тавышлары тынгач исә, өй эче, аның барлык почмаклары тыярга тырышып та тыела алмаган үксү, сулкылдау авазлары белән тулды* (Ә. Баянов). *Дружиначы егет ара-тирә: «Солыны таптамагыз!», «Юлның уң ягына чыкмагыз: килгән шәпкә атлар уң якка туры бәреп кереп китә, тояк астында калырсыз»... кебек кырыс-кырыс кисәтүләр ясап торгаласа да, Гөлҗиһанга актан-карадан сүз әйтмәде* (К. Тимбикова. Сөлге булсын бүләгем!).
Төрдәше: авыз <да> ачмау 1.б.

*АКТАРЫП* ❖ **АКТАРЫП ТАШЛАУ <ЭШНЕ>** *гади с.* Эшне тиз генә эшләп кую. *Күнегелгән эш булгач, озак уйлап тормадык, актарып ташладык* (Сөйләм).

*АКТУАЛЬ* ❖ **АКТУАЛЬ БУЛМАГАН (ТҮГЕЛ).** Бик мөһим булмаган. *Сирәк булса да, актуаль булмаган тема өстендә эшләүче кешеләр бар бит әле* (Ф. Мостафин. Бәхетле кеше).
Төрдәше: икенче дәрәҗәдәге; мөһим булмаган.

**АКТУАЛЬ МӘСЬӘЛӘ.** Билгеле бер вакытта иң әһәмиятле, мөһим, көнүзәк мәсьәлә. *Ул вакытта бу актуаль мәсьәлә иде: Оренбургта. Уфада. Казанда үткәрелгән съездларда конференцияләрдә бу турыда бәхәсләр, чыгып сөйләүләр белән генә чикләнмәделәр, ә кулларына корал тотып, канлы бәрелешләрдә һәм сугыш хәрәкәтләрен башлап җибәрүгә кадәр барып җиттеләр* (Г. Ибраһимов. Автобиография).
Төрдәше: көн кадагына суккан.

*АКТЫГЫ* ❖ **АКТЫГЫ БУЛСЫН!** «Берәр эш яки нәрсә соңгы мәртәбә булсын, башка кабатланмасын» мәгънәсендә. *[Гарифә] Менә моннан соң актыгы булсын, кызымны Ибраһим янына чыгармыйм!* (Г. Исхакый. Алдым-бирдем).

*АКТЫГЫН* ❖ **АКТЫГЫН АШАУ.** Нәфесен тыя алмау, бар тапканын тамагын туйдыру өчен бетереп бару. *Актыгын ашап баргач, ничек акча җитсен инде аңа* (Сөйләм).

**АКТЫГЫН ТЫГ<ЫН>У** *хурл.* Ач күз; бар тапканын эчеп бетерү, кешедән дә тартып алып эчеп бетерү. – *Туемсыз нәрсә, актыгын тыгынып йөрмәсәң...* (Сөйләм).
Төрдәше: бирәнен тыгу.

*АКТЫК* ❖ **АКТЫК БИРНӘ** *этн.* Кияүгә чыкканда, кыз ягыннан сандык белән килә торган мал, кода-кодагыйларга бирелә торган бүләкләр; халык йоласы. *Актык бирнәгә дә чачагы-чугы белән бик әйбәт калын ука тирәле асыл бирмәкче булалар* (Г. Камал).

**АКТЫК ГОМЕРЕНДӘ.** Үләр көннәре алдыннан, гомеренең соңгы көннәрендә. *Болар җөмләсеннән мәшһүррәге Муса бине Габдерәшид Мәмсә авылында имам-мөдәррис булып гомер кичереп, актык гомерендә хаҗ сәфәренә китеп, кайтышында Искәндәрийәдә вафат булган* (Р. Зарипов. Тирән тамырлы Түнтәрем).
Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

**АКТЫК ҖАВАП.** Катгый, хәлиткеч карар, җавап. *Ачык, актык җавап өч көннән калмасын, юкса мин берүзем керешәм* (Г. Ибраһимов).

**АКТЫК<КЫ> ИСӘПТӘ** *к.* азак килеп. *Актык исәптә өлкән буынның үлемтеккә дигән маясына да урын табылды...* (Р. Зарипов. Тамчы гөл).
Төрдәше: азак килеп һ.б.

**АКТЫК КАЗЫК.** Соңгы казык. *Үлеп китсәм, актык казыгым әзерләп куелган инде* (Сөйләм).

**АКТЫК КАТ.** Нәрсәнең дә булса иң соңгысы. *Һәм актык кат, бөтен көчен куеп, / Җиде катлы итеп сүгенде* (Ф. Яруллин).
Төрдәше: соңгы кат (мәртәбә; тапкыр).

**АКТЫК КАТ ӘЙТҮ.** Нәрсә турында булса да кисәтүнең азаккысы. *[Галәви] Актык кат әйтәм, чыгасыңмы?* (К. Тинчурин. Зәңгәр шәл).
Төрдәше: соңгы тапкыр (мәртәбә) әйтү (кисәтү).

**АКТЫК КӨНГӘ КАЛУ.** Түбәнлеккә төшү. *Чәчсакалы үсеп-укмашып беткән, кием-салымының да исеме генә калган, бөтенләй актык көнгә калган* (Сөйләм).

**АКТЫК КӨНГӘЧӘ.** Гомеренең соңгы көненә кадәр. *Актык көнгәчә ул эшләвен ташламады: нәрсәдер язды, сызды-боздды, китаплар актарды* (Сөйләм).

**АКТЫК КҮЛМӘК.** 1. Бернәрсәсе дә калмыйча бөлү. *Бар нәрсәсен төяп алып киттеләр, актык күлмәге белән утырып калды* (Сөйләм).
2. Комарлы уен уйнап, соңгы күлмәгенә кадәр оттыру. *Әхтәри уйнау яхшылыкка илтмиул, әнә Рөстәм дә актык күлмәген оттырып, яланөс калган, диләр* (Сөйләм).

3. Мохтаҗ кешегә соңгы кулмәгән булса да бирү. *Гаптери хакында ярдәм сораган кешегә актык кулмәген дә кызганмас дип сөйлиләр* (Сөйләм).

**АКТЫК МОГИКАН.** Нәрсәнең дә булса (нәселнең, берәр төркемнең һ.б.,) соңгы вәкиле. – *Аның кебек кешеләр хәзер юктыр дип уйлыйм, булса да – актык могиканнар* (Сөйләм).
Төрдәше: соңгы могикан.

**АКТЫК ПАТРОНГА КАДӘР.** Соңгы патронга кадәр атып, каршылык күрсәтү. *Егетләр үзләре теләп әсир төшмәгәннәр, актык патронга кадәр сугышканнар, яраланып егылгач кына, дошман аларны кулга алган* (Г. Әпсәләмов).
Төрдәше: азаккы сулышка (сулуга) кадәр (хәтле) һ.б.

**АКТЫК СӘГАТЬЛӘР<ЕНДӘ>.** Үлем ятагында, үләр чагында. *Карагыз, кара, кабахәтләр, актык сәгатьләрегез җитә* (Г. Әпсәләмов. Миңа унтугыз яшь иде).
Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

**АКТЫК<КЫ> СУЛЫШ (СУЛУ)** *к.* авыздан җаны чыгарга тору (җитешү). *Актык сулыш басмасына баскан иде, – дип, газетаның соңгы көннәрендәге хәле, бу күңелсезлекләр акчасыз калу сәбәпле дип ачыктан-ачык билгеле* (М. Гайнетдин. Йосыф Акчура).
Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

**АКТЫК<КЫ> СУЛЫШ (СУЛУ) АЛУ** *к.* авыздан җаны чыгарга тору (җитешү). *Хастаханәгә алып киткәнлектән, Марат әттсенең актыккы сулыш алуын күрә алмады* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү һ.б).

**АКТЫК<КЫ> СУЛЫШКА (ЧИККӘ) ҖИТҮ.** Экономик яки башка яктан соңгы чиккә җитү. *Аларның бу остаханәләре актык сулышына килеп җиткән иде инде, нишлисең, аны ябарга булдылар* (Сөйләм). *Качып баручы җинаятьчеләр дә актык чиккә җитеп арыганнар иде, күрәсең, көчкә-көчкә атлыйлар – аякларына гер элгәннәр диярсең* (Ш. Шәйдуллин. Юрист язмалары).
Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

**АКТЫК<КЫ> СУЛЫШКА (СУЛУГА) КАДӘР (ХӘТЛЕ).** Үлгәнчегә кадәр сугышырга, көрәшергә, якларга вәгъдә бирү. *Без барыбыз да халыктан чыккан һәм актык сулышыбызга кадәр халыкка хезмәт тә итәргә тиешбез...* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).
Төрдәше: азаккы сулышка (сулуга) кадәр (хәтле) һ.б.

**АКТЫК<КЫ> СҮЗ.** 1. Йомгаклау чыгышы (сүзе). *Карлыгач, боларга карамастан, сүзендә нык торды, елавыннан туктап, ишек яңагына барып сөялде дә актык сүзен әйтте* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).

2. Хөкем карарыннан соң гаепләнүчегә бирелә торган сүз. *Көндезгә ашка таралып, кичке алтыда яңадан хөкем ачылгач, гаепләнүчеләрнең актык сүзләре башланды* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар). *Актык сүзне тоткыннарның бөтенесе исеменнән Муса сөйләде* (Г. Әпсәләмов).

3. Саубуллашканда, бәхилләшкәндә әйтелә торган сүз. *Менә инде, җәмәгать, актык сүз: мин инде карт кеше* (Г. Исхакый. Җәмгыять). *Актык сүзләр* (Г. Тукай әсәренең исеме; үләр алдыннан әйтелгән сүзләр).

4. Алыш-бирештә әйбернең килешенгән бәясе. – *Кыскасы, Сергей Леонидович, сезгә актык сүзем шул: йортыгызга миннән төгәл өч йөз мең!* (Ә. Еники. Рәшә).

5. Карар, нәтиҗә буларак әйтелгән сүз. *Кыскасы, гаиләдә баш кеше чынлыкта Фәнирә иде, ул әйткән сүз актык сүз була иде* (З. Мифтахов. Күрәчәгең булса...).
Төрдәше: азаккы сүз; соңгы сүз.

**АКТЫК<КЫ> СҮЗ ИТЕП** *к.* азаккы сүз итеп. *Актык сүзем итеп, Ленар, сиңа әйтәм: / Какма, зинһар, минем кызымны* (Р. Зарипов. Тирән тамырлы Түнтәрем).
Төрдәше: азаккы сүз итеп; соңгы сүз итеп.

**АКТЫК<КЫ> СҮЗНЕ ӘЙТ<ТЕР>Ү.** Кемнең булса да соңгы сүзен (карарын) үз авызыннан әйттерү. *[Хәдичә] Син миңа актык сүземне әйттермә!* (Г. Ахунов. Утлар яна учакта).

**АКТЫК СҮЗЛӘР БЕЛӘН СҮГҮ.** Берәрсен иң әшәке сүзләр белән тиргәү. *Ул актык сүзләре белән тиргәнеп, табактан торды* (Р. Фәизов. Яңа күршеләр).

**АКТЫК СЫНЫКНЫ <БЕРГӘ> БҮЛЕШҮ.** Иң авыр көннәрне бергә кичерү, чын дуслар булу. *Алар, телләре, гореф-гадәтләре үзгә, илләре аерым булса да, менә шушы изге көрәштә бер йодрык булып укмашканнар, актык*

*сыныкларын бүлешкәннәр, бертуганнар кебек аяусыз көрәшкәннәр* (Р. Кәрами. Әдрән диңгез буенда).

**АКТЫК ТАМЧЫ КАН.** Берәр максат өчен көрәшкәндә, гомерен корбан итәчәгенә ишарә. *Актык тамчы кан... Кашыклы кан... Бу кайдадыр ишетелгән сүз* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

**АКТЫК ТАМЧЫ КАНГА КАДӘР (КАЛГАНЧЫ).** Берәр идеал юлында тормышын да кызганмыйча, үзен корбан итүгә хәтле барачагын белдерү. *Юк, иртәгә аңа шундый зур эш йөкләсәләр, Шәяхмәт кашыклы канга түгел, ә актык тамчы канга калганчы халык өчен эшләр, көрәшер...* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала). *Дошман белән актык тамчы каныбызга кадәр якалашабыз* (Г. Әпсәләмов. Миңа унтугыз яшь иде).

Төрдәше: актык тамчы канны да кызганмау.

**АКТЫК ТАМЧЫ КАННЫ ДА КЫЗГАНМАУ.** Үлгәнче көрәшү. *[Раушанов] Илнең азатлыгы юлында актык тамчы каныбызны да кызганмабыз* (Ф. Бурнаш. Таң).

Төрдәше: актык тамчы канга кадәр (калганчы).

**АКТЫК ТАМЧЫ КАННЫ СУЫРЫП АЛУ**. Тәмам теңкәгә тию, авыр хәлгә кую. *Сез инде, ахры, минем актык тамчы канымны суырып алганга кадәр артымнан калмассыз* (Г. Камал).

Төрдәше: актык тамчы канны эчеп бетерү.

**АКТЫК ТАМЧЫ КАННЫ ЭЧЕП БЕТЕРҮ.** Залим кешенең явызлыгы үлеменә кадәр дәвам итәчәгенә ишарә. *[Гайшә] Залим ире хатынның актык тамчы канын эчеп бетереп, гүргә кергәнчегә кадәр бара* (Г. Камал. Бәхетсез егет).

Төрдәше: актык тамчы канны суырып алу.

**АКТЫК ТАМЧЫ ЯШЬ.** Кешенең үлгән вакытта тамган соңгы тамчы яше. *Актык тамчы яшь* (Г. Тукай шигыренең исеме).

**АКТЫК ТАМЧЫСЫНА КАДӘР.** Бөтенләй беткәнче, ахырына кадәр биреп бетерү (агызу, куллану һ.б.). – *Мин үзем дә тормыштан барысын алыр идем, үземнән дә барысын, актык тамчысына кадәр бирер идем* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**АКТЫК ТӘРӘШЛЕ.** 1. Гомерендә җыйган малының иң соңгысы, шуларны тоту. *Хатын чоланда саклаган йонның соңгысын тәрәшләп куйды, актык тәрәшлесе иде бу аның* (Сөйләм).

Төрдәше: актык тәрәшлегә ябышу 2.

2. Гомеренең соңгы көннәрен уздыру. *Күршеләре әйтмешли, Бибиәсма карчык актык тәрәшле көннәрен уздыра иде* (Сөйләм).

**АКТЫК ТӘРӘШЛЕГӘ ЯБЫШУ**. 1. *к.* авыздан җаны чыгарга тору (җитешү). – *Әй мескен, актык тәрәшлегә ябышырга гына калган аңа* (Сөйләм).

Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

2. Соңгы запасларын тоту. *Ларны себереп, булганын казанга салдым, аннары актык тәрәшлегә ябышасы булыр инде* (Сөйләм).

Төрдәше: актык тәрәшле 1.

**АКТЫК ТӘРӘШЛЕЛӘРНЕ ЭРЛИ (ТАРЫЙ) БАШЛАУ** 1. *к.* авыздан җаны чыгарга тору (җитешү). *Күршең актык тәрәшлеләрне эрли башлаган бугай* (Сөйләм).

Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

2. Буранның бик нык котыруы *күч.* – *Бөтенләй харап, Шәрәфи абзый, актык тәрәшлеләрне эрли башлады. Әгәр тагы 10 чакрым барсаң – тончыгырсың да үләрсең* (А. Шамов).

**АКТЫК ТӘРӘШЛЕНЕ ЭЛҮ** *к.* авызыннан җаны чыгарга тору (җитешү). – *Бик каты бәрелмә, актык тәрәшлене элгәнгә охшап тора* (Сөйләм).

Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

**АКТЫК ТЕЛЕМ (СЫНЫК).** Кулда булган соңгы икмәк кисәге. *Аның өчен татар, үзбәк, алтай һәм бүтән ят түрк халкы юк – ул аларның һәммәсен газиз Кыбрыс төрегедәй үз күрә, шуларның һәммәсе өчен утка-суга керергә, актык телем икмәген уртаклашырга әзер тора* (Т. Әйди. Истанбул очрашулары).

**АКТЫК <БЕР> ТИЕН.** Бөтенләй акчасыз калу. *Әнисе эшли, туйдыра, өс-башын карый, ә бусы теләнә-теләнә, җылый-җылый аның актык тиеннәрен суырып, алкашлыкта йөри* (Ш. Маннур. Чын сөю бармы?).

**АКТЫК ТИРЕН СЫГУ.** Соңгы тамчы тирен сыкканчы эксплуатацияләү. *Бу китапта хуҗалыктагы ялчыларының актык тирен сыгып*

*яшәүче байлар турында тәфсилләп язылган* (Сөйләм).

**АКТЫК ТУЕ.** Җеназасын озату. *Үлчәп алыгыз / Зифа буйларым. / Ашыктырмагыз, / Актык туйларым…* (Х. Хәйруллин. «Мәхәббәт сыгавы» сыгау үтә).

**АКТЫК ЧИГЕ<НДӘ>** *к.* азак килеп. *Кызык та нәрсә инде бу дөнья дигәннәре: кеше бала чагыннан алып картаеп-бөкрәеп, чүгеп беткәнгә чаклы шушы җирдә казына, чиләнә һәм үз гомер юлының актык чигендә шул җиргә кереп тә ята – каты, салкын җиргә* (Л. Вәлишина. Серле күгәрчен).

Төрдәше: азак килеп һ.б.

**АКТЫК<КЫ> ЧИК<ТӘ>** *к.* азак килеп. *Безнең бер агай-эне әйтә торган иде: актык чиктә кабер туфрагын күтәреп чыгып була, әмма яхшы кәгазь астыннан шайтан үзе дә чыга алмый* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Камалуда калган бүре актык чиктә кая ташлана?* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: азак килеп һ.б.

**АКТЫК ЧИККӘ ҖИТҮ.** Әйбернең күренеш яки вакытның иң ахырында булуы. *Ләкин күләм җәһәтеннән актык чиккә җиттек бугай инде* (З. Мифтахов. Азат булмасак, артык булырбыз...).

Төрдәше: азак килеп һ.б.

**АКТЫК<КЫ> ЧИККӘ КАДӘР.** Азаккача, соңгы чигенә җиткереп. *Артта качып котылу юлы калмавын белгән гаскәр дошман белән актык чиккә кадәр аяусыз сугышырга тиеш булган* (Х. Мәхмүтов. Гыйбарәләр тарихына сәяхәт).

Төрдәше: азакка кадәр һ.б.

**АКТЫК ЧУТТА** *к.* азак килеп. *Инде, актык чутта, Софи Лорен белән Брижит Бардоның да кайсы фильмнарда уйнаганы мәгълүм иде...* (М. Мәһдиев. Каз канатлары).

Төрдәше: азак килеп һ.б.

**АКТЫК ЫШТАН.** Кешенең соңгы малы (фәкыйрь булуын яки тулысынча бөлгенлеккә төшүен белдерә). *Күп чакта шулай бит ул: актык ыштанын салдыра башлаганчы түзә кеше...* (Ш. Маннур. Агымсуларга карап). *– Түрәләргә акча җитми... Хәерченең актык ыштанын салдырмасалар ни булган?* (Н. Хәсәнов. Золым).

**АКТЫК ЫШТАНЫН САЛЫП БИРҮ.** 1. Үтә яраучан кеше, куштан турында. *Үзенең минминлеге юк аның, орышмасыннар гына – актык ыштанын да салып бирергә әзер* (Сөйләм).

2. Үтә юмарт кеше турында. *Булмас дөньяда андый юмартлар, кеше өчен актык ыштанын да салып бирер иде* (Сөйләм).

**АКТЫК ЮЛ** *к.* азаккы юл. *Танылган артистны актык юлга озатырга килүчеләр белән урам тулган иде* (Сөйләм).

Төрдәше: азаккы юл; ахыргы юл; соңгы юл.

*АКТЫККА* ❖ **АКТЫККА КАДӘР (ТИКЛЕ; ХӘТЛЕ; ЧАКЛЫ)** *к.* азакка кадәр. *Актыкка кадәр яныннан китмәскә иде, бәлкем, файдалы берәр сүз ишетер идең* (Сөйләм).

Төрдәше: азакка кадәр һ.б.

**АКТЫККА КАЛДЫРУ** *к.* азакка калдыру. *– Мин Сезгә бит әле иң кызык әйберемне күрсәтмәдем, актыкка калдырдым, – дидем* (Г. Рәхим).

Төрдәше: азакка калдыру.

**АКТЫККА КАЛУ** *к.* азакка калу. *[Биктимер] (карап) Ул һаман шулай иң актыкка калып эшли инде* (А. Алиш. Күршеләр).

Төрдәше: азакка калу.

*АКТЫККЫСЫ* ❖ **АКТЫККЫСЫ БУЛСЫН** *к.* актыгы булсын. *Вахит: «Бу актыккысы булсын! Моннан соң тагын миңа шулай бәйләнәсең икән, мине бу йортта башка күрмәссең!» – ди* (М. Яһудин. Тормыш бу...).

Төрдәше: актыгы булсын.

*АКУЛА* ❖ **АКУЛА БАЛЫГЫ** *күч.* Ерткыч, тәвәккәл, принциплары булмаган кеше. *– Ә бит Семёнов шикелле аумакай меньшевик этләрнең революционный демократия дигәннәре, шул әлеге Михаил Степанович, Федор Спиридонович шикелле юан корсак акула балыклары ич!* (Ш. Камал. Таң атканда).

*АКЧА* ❖ **АКЧА АЛМАШЫНУ.** *Ә январь башында акча алмашынды* (Х. Сарьян. Бер апаның биш улы).

**АКЧА АРТЫННАН КУУ.** Бары тик күбрәк акча эшләү турында уйлау. *– Арыйсың инде, балам. Нигә шулкадәр акча артыннан куасыңдыр, – дип шелтәли иде* (Ф. Яруллин. Кыйбласызлар).

**АКЧА АШАУ** *к.* акча туздыру. *Акча ашап, акча косучы син, – / Шул акчаңнан җитәр әҗәлкаберең!* (Л. Шагыйрьҗан. Акча колына).

**АКЧА ӘТӘЧ БУЛЫП КЫЧКЫРУ.** 1. Гади кешенең кулына акча керсә, шунда ук беленүе. *Юк, кесәмә акча керсә, шул акча әтәч булып кычкыра башлый* (Н. Акмал. Кол).

2. Кайбер кешенең кулына акча керсә, аны тотарга гына торуы. *Бурычларын түләгәннән соң, кулында калган акча әтәч булып кычкыра башлагач, Румия базарга чыгып китте* (Р. Габделхакова. Көмеш тун).

Төрдәше: әтәч булып кычкыру.

3. «Акчагыз бик күпме әллә» мәгънәсендә. *Әлегә аңа әйтми торам, көләр, акчаң әтәч булып кычкыра башладымы әллә, дияр* (Р. Габделхакова. Нишләттегез Гөлкәйне?!).

**АКЧА БАЛАЛАТУ.** Акчаны сәүдә әйләнешенә кертеп, аны арттыру. *Күрәсең, минем «акча балалату»да ул хәтле өмет бирерлек нәрсә булмагандыр* (Ш. Маннур).

**АКЧА БАРДА БҮРЕДӘЙ, АКЧА ЮКТА ШҮРЕДӘЙ.** *Нариман, – Айзатның ярты кабымлык икмәкне икегә бүлеп каба торган, бер җептәге ике төймә, бер төптәге ике тирәк шикелле яшәгән дусты, – акча барда бүредәй, акча юкта шүредәй бергә көн күрүче, эч серләрен уртаклашучы элекке старшина түр почмактагы урыныннан аңа карап-карап ятты да торып янына килде* (Г. Мөхәммәтшин. Йөрәктәге эзләр).

**АКЧА БЕЗДӘ БЕР ЧОРМА** *ирон.* Ирония белән әйтү (янәсе, бозылмасын өчен, акчасын чормага менгезеп куйган – *Ф. Хөсни аңлатмасы*). – *Бер дә аптырама – акча бездә бер чорма* (Сөйләм).

Төрдәше: акча бездә – үлсәң, кәфенең чорнарга җитәрлек; акча <бездә> бер букча; акчасын тавык та чүпләп бетерә алмый (бетермәс).

**АКЧА БЕЗДӘ – ҮЛСӘҢ, КӘФЕНЕҢ ЧОРНАРГА ҖИТӘРЛЕК** *ирон. к.* акча <бездә> бер букча. – *Миндәме акча юк дисең, акча бездә – үлсәң, кәфенең чорнарга җитәр* (Ш. Усманов).

Төрдәше: акча бездә бер чорма һ.б.

**АКЧА БЕЛӘН АВЫЗЛАНДЫРУ.** Кече яшьтән үк акча бирүләренә күнегеп, азып-тузып йөрергә өйрәнү турында; шуңа игътибар итмәү. – *Хәзердән үк акча белән авызландырма, үскәч тә теңкәңә тияр әле* (Сөйләм).

**АКЧА БЕЛӘН БАШМА-БАШ.** Сату-алуда әйтелә, ягъни товар үзенең акча бәясенә тиң. – *Өстәлгә җәеп куйган малы да акча белән башма-баш иде* (Сөйләм). – *Акча белән башма-баш* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).

**АКЧА <БЕЗДӘ> БЕР БУКЧА.** Мактану йөзеннән әйтелә; акчаның исәбе-хисабы юклыгына да, акчаның коры кәгазь булуына да ишарә. *[Исерек татар]<…> бездә акча бер букча, мә ал, пирут ал акчаны* (Г. Камал. Уйнаш). – *Әллә тагын өйләнеп ташлыйсыңмы, Сираҗетдин? Хәзер акчаң бер букча, ә?* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы).

Төрдәше: акча бездә бер чорма һ.б.

**АКЧА БҮСЕРЕ.** Акчаны күп бетерүче, тотучы. *Бу акчаны ничек җиткерергә, тәмам акча бүсере булдың!* (Сөйләм).

Төрдәше: акча убыры.

**АКЧА ВАКЛАУ.** Эре акчаны вакка алыштыру. *Кибетчеләр бик шатланып эшли аны. Чөнки көне буе акча ваклауларын үтенеп, аларның үзәкләренә үтәләр* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).

Төрдәше: акча вату.

**АКЧА ВАТУ** *к.* акча ваклау. *Шушы акчаны унлыклар белән ватып бирә алмыйсызмы?* (Сөйләм).

Төрдәше: акча ваклау.

**АКЧА ДУСТЫ.** 1) Берәрсенең кесәндә акча барында гына дус булуы. – *Ә шулаймы? – Акча барда бар да дуст шул, бар да яр* (Г. Тукай).

2. Акча туплый торган кеше. *Ул ничаклы саран, ничаклы акча дусты булса да, хатын вә балаларын да шуңа якынрак рәвештә киендерә* (Г. Ибраһимов).

**АКЧА ҖӘЛЛАДЫ.** Тапкан бар акчасын бетереп баручы кеше. – *Тәрәзә янында утырган кешегә игътибар беләнрәк кара, акча җәллады ул* (Сөйләм).

**АКЧА ҖИМЕШЕ.** Акчага сатып алынган. *Бу иптәшләр, әлбәттә, русчаның «Он денег стоит» дигәнен татарча әйтергә уйлаганнар,*

*ягъни «аңа бит акча түләнгән», «ул бит акча җимеше» дип әйтәселәре килгән, әмма «ул акча тора» җөмләсенең татарча мәгънәсен белмәүләре сәбәпле, бөтенләй башка мәгънәле җөмлә килеп чыккан, ягъни «ул акча тора» дигәндә без: ул акча тора, тотылмаган, куйган кнлеш тора дип аңлыйбыз* (Х. Сарьян. «Алай да була!» – булмасын).

**АКЧА ҖИМЕШЕ ТҮГЕЛ, БАКЧА ҖИМЕШЕ (БАКЧАНЫКЫ).** Сатып алынмаган, хуҗалыкта җитештерелгән (кыстаган вакытта әйтелә, ягъни тартынмагыз). *Апасы кап-кара эре карлыганнарны юып өстәлгә куйды да, «тартынмагыз, акча җимеше түгел, бакча җимеше бу», диде* (Сөйләм). *– Акча җимеше түгел, бакчаныкы, үзебезнең хәзинә,– диде канәгатьлек белән Касыйм* (А. Гыйләҗев. Урамнар артында яшел болын).

**АКЧА ИСЕ ЧЫГУ.** Акча барлыгын сизү. *... Акча исе чыкмый торса, бар да яныңнан таяр!* (Г. Тукай).

**АКЧА КАЕРУ.** Акчаны күп итеп эшләп алу, акчалы булу. *– Имансыз да икән! Ну каера инде акчаны!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: акча кою (коеп алу); акча көрәү (көрәп алу); акча сугу 1; акча эшләү; акча яву; акча ясау; акчага бату; акчага коену; акчаны <көрәк белән> көрәп алу; аның ишегеннән дә керә, тишегеннән дә.

**АКЧА КАПЧЫГЫ (ЯНЧЫГЫ).** Акча җыеп ятучы. *Алла боерса, утыннарын кисеп бетерсәләр, Соргылт абзыйлары кичләтеп кайтып керсә, сөйләшенгән биш кубик метрыннан чыгып исәпләгәндә, бу акча капчыгы булган абзыйга галифе кесәсеннән кыршылып беткән биш тәңкә урынына сайрап торган ун тәңкә чыгарып бирү нәрсә тора инде?!* (А. Хәлим. Читтә).

**АКЧА КЕРҮ.** Акча эшләп алу. *Күңелләр күтәренке, эш тәмамланган, алдагы базарда кулга акча керәчәк...* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).

**АКЧА КОЛЫ.** Акчаны бар нәрсәдән дә өстен куючы, акча өчен җанын сатучы. *Их, син, Мәликә! Их, син, акча колы!* (Н. Гыйматдинова. Сөйлим, тыңла...).

Төрдәше: акча өчен анасын (җанын; иманын) саткан; акчага чукынган.

**АКЧА КОРТЫ.** Акча эзләп, акча даулап кына торучы. *Ул акча кортын бу нияттән кире бору – мохал [мөмкин булмаган] бер эш* (Ш. Маннур). *Аның җанын акча корты ашап бетергән иде инде* (Р. Нуруллин. Төеннәр иле).

**АКЧА КОЮ (КОЕП АЛУ)** *к.* акча каеру. *Якында гына урман, үзләрендә алтын куллы осталар бар, тугым-тәгәрмәчне әйләнә-тирәдәге колхозлардан өзлексез сорап торалар – коеп утыр акчаны* (Ф. Хөсни. Җәй башы).

Төрдәше: акча каеру һ.б.

**АКЧА КӨРӘҮ (КӨРӘП АЛУ)** *к.* акча каеру. *– Хәрам, имеш! Әле берсенең дә корсагы тишелеп акмый, сатып акча көриләр* (Н. Гыйматдинова. Бер тамчы ярату). «*Аның хәсрәте юк инде, акча көри, безнең кебек көне-төне эштә эшләми, гаҗизләнми һәм җәфаланмый», – дип, атакайны ачулана тордылар* (Ф. Яхин. Изге атакай фәлсәфәсе).

Төрдәше: акча каеру һ.б.

**АКЧА КУБЫЗЫНА БИЮ.** Бөтен нәрсәне, аның кыйммәтен акча белән генә исәпләү. *Бу яктан, шөкер, «Казан утлары» үзенең күркәм традицияләрен дәвам итеп, вакланмыйча, очсыз рекламашоудан, түбән инстинкт уята торган язмалардан өстен булып, акча кубызына биимичә, милләтебезнең әхлак кодексына лаек әсәрләр язып, халкыбызның төп җитди журналы булып кала алды* (Р. Фәйзуллин. Мең сан – миллион уй).

**АКЧА КУЛГА ЙОКМАУ.** Акчаның (яки эш хакының) аз булуы. *Әткәйнең акчасы кулга йокмый, әнкәй әйтмешли, кереп җитмәс борын бармак арасыннан шуып чыга да китә* (Ф. Латыйфи).

**АКЧА<НЫҢ> КҮЗЕНӘ КАРАМАУ (КАРАП ТОРМАУ)**. Акчаны кулда сакламау, кергән берен тота бару. *Бигрәк тә ашарга дигәндә акчаның күзенә карамыйм* («Татарстан яшьләре» газ.).

Төрдәше: акчаның күзен чыгару.

**АКЧА КЫЧЫТУ.** 1. Акча күп булганлыктан, аны кая куярга белмәү. *– Акча кычыткангатүгел, кирәге туган өчен алам бит* (Ә. Моталлапов. Мәхшәр).

2. Акчаны тота белмәү. *– Акчасы кычытамы-юкмы, анысын мин белмим* (Ф. Яруллин. Чигүле күлмәк).

**АКЧА ӨЧЕН АНАСЫН (ҖАНЫН; ИМАНЫН) САТКАН** *к.* акча колы. Акчадан башка бернинди идеалы, иманы булмаган, комсыз кеше. *Бер яртылык акча өчен аналарын сатарга әзер булган, кешелеген югалткан затлар өчен күпме кәеф-сафа корырлык сәмән* («Матбугат.ру» порталы). *Алар үзләре лә Аллам сакласын! – акча өчен җаннарын сатарга әзер* (Ә. Салах. Соңгы вальс).

Төрдәше: акча колы һ.б.

**АКЧА САЛЫШЫП.** Бергәләшеп акча җыеп мәҗлес үткәрү. *Шуннан ук үзара акча салышып, авылга алып кайтырга, сыйлар алырга булдылар* (Г. Камал). *Акча салышып, барынча гына чәй табыны әзерләттек. Бернинди эчемлек юк (аны кирәк дип тә белмибез), аның каравы, җыр, музыка, шигырь сөйләү белән бик күңелле узган иде ул кичә!* (Ә. Еники. Муса Җәлил хатлары).

**АКЧА СЕБЕР КИТҮ.** Әрәм булу, бушка китү. *– Сайламый гына алган идем, акчам себер китте, капчыкка чүп тә мул салынган* (Сөйләм).

**АКЧА – СЕЗНЕКЕ, МАЛ – БЕЗНЕКЕ**. «Теләсәң аласың, теләмәсәң юк» мәгънәсендә. – *Абзый, йоклыйсың мәллә, алсаң ал, алмасаң юк – акча сезнеке, мал – безнеке* (Сөйләм).

**АКЧА СУ КЕБЕК <АГУ>.** 1. Акчаның кулда тормавы турында, ягъни су кебек агып китә. *Ә су акча билгесе икән, хәзер кергән акча су кебек агып чыга* (Ф. Зариф. Ак бүре рухы саумы?!).

2. Табыш алу. *Кыскасы, мәктәпнең махсус счетына акча су кебек ага башлый* (Т. Нәҗмиев. Сабаларда эчәр суым булгач...).

**АКЧА СУГУ.** 1. *к.* акча каеру. *Алар [базарчылар] акчаны суга!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). – *Күбрәк аның тирәсендә бөтерелерсең. Ул сине акча сугарга өйрәтер, – диде мәскәүле апа* (Н. Гыйматдинова. Ачкыч).

Төрдәше: акча каеру һ.б.

2. Акча эшләп чыгару. *Талибның соңрак идарә иткән улы Мөэмин бер үк вакытта Суарда, Болгарда да акча суккан* (Р. Фәхретдинов. Татар халкы һәм Татарстан тарихы).

3. Ялган акча ясау. *Дәүләтле һәр милләт ялган акча суккан* («Матбугат.ру» порталы).

4. Акча урлау *гади с.* *«Менә бу егетнең акчасын сукканнар, анысын эзләмисез, мине интектерәсез», – дип үчекләшмәкче иде дә, сүзенең мәгънәсезлек булачагын сизеп, тыелып калды* (Н. Акмал. Күгәрчен сөте).

5. Уен исеме. *Бергә таш белән «акча суктык», «ачуклы» уйнадык, үзебез ясаган кәрт белән, чебенле, чәбәйле, шаралы, качышлы, унике чыбыклы, лапталы, клүкле, чокыр туплы, туп яшерешле, кыршау куышлы, диварга бәреп акчалы, «шкиндерле» һәм тагын әллә нинди уеннар уйный торган идек* (З. Зәйнуллин. Урам).

**АКЧА СЫГУ.** 1. Куркытып, эшмәкәрләрнең акчаларын талау. *Башта үзенең яшьтәшләре белән Вахитов районындагы коммерция киоскаларын куркытып тотты: алардан акча сыкты* (З. Мәхмүди. Серле кунак).

2. Кемгә булса да күрсәткән хезмәте өчен бәяне арттырып алу. – *Туристлардан акча сыга кытайлар* (Н. Гыйматдинова. Кәтәнә).

**АКЧА ТАБУ.** Эшләп акча алу, кулга акча керү. *Ә мин – олы малай, хәзер инде эшкә ярыйм, хәтта чүбек җыеп акча да табам, әни каршында дәрәҗәм бөтенләй күтәрелеп китте* (Ш. Маннур. Яңа җыр килде). *Көне-төне эшләп, акча тапты* (Ә. Моталлапов. Мәхшәр).

Төрдәше: акча төшерү 1.

**АКЧА ТАКЫР.** «Акча юк» мәгънәсендә. *Акча такыр* (К. Насыйри).

**АКЧА ТӘМЕН БЕЛҮ.** Акчаның әһәмиятен, кадерен белү. *Яшь әле, акча тәмен белми, дип уйлады ул* (Х. Камалов. Куян күзе нигә кызыл?). *Хәер, бездә бер акча тәмен белеп алган халык беркем башына да килмәгән ысуллар да уйлап чыгара ул* («Татарстан яшьләре» газ.).

**АКЧА ТОЗАГЫ.** Эшкә ярамый яки бик кирәкле булмаган, ләкин бик кыйммәт торган нәрсә. *Кичтән әтисе селфи-таяк та алып кайтып бирде бит әле, җитмәсә (туктый калсам, чүплеккә чыгасы да тагын бер акча тозагы артты, димәк)* («Идел» ж.) *Нур чәчеп торган киоскларда – дистәләгән төр салкын эчемлек, сигарет, сагыз, акча тозагы булган бүтән вак-төяк* (К. Тинчурин. Американ).

**АКЧА ТОРНА БУЛЫП КЫЧКЫРУ.** Акча саклый белмәү, булган акчаны тиз бетерү. *Әмма Тукайның кесәсендәге акча торна булып кычкыра* (gabdullatukay.ru).

**АКЧА ТОРУ.** 1. Бәһале әйбер турында, бәя тору. *[Искәндәр] Ул аларның акча торганын белә, җанын биргәндә дә бушлай бирмәс* (К. Тинчурин. Американ). *Беренчедән, акча тора, икенчедән, табуы җиңел генә түгел, кытлык була аңа ул чорда* (К. Җәмит. Килмешәк).

2. Акчага сатарга, акча эшләп алырга мөмкин булу. *(Шешәне күрсәтеп). Бу бит акча тора. Моңар бит бер кадак икмәк алып ашап, тамак туйдырырга мөмкин* (Г. Камал).

3. Акчаны саклап тота алган кеше хакында. – *Шунда да, Апуш, бик кызык, синдә акча торуы кызык, – диде карый* (А. Расих. Айлы төннәр).

**АКЧА ТОТ<ЫЛ>У.** Акчаны кирәк-яракка файдалану, чыгымнар булу. *Рәхмәт, анасы, рәхмәт! Мине дә күп акча тотудан коткардың* (Г. Камал). *Мәҗлескә шактый акча тотылган иде* (М. Мәһдиев. Мәңгелек яз). *Алар дәрәҗәсенә ирешү өчен, өр-яңа таш биналар төзергә, дөнья кадәр акча тотарга кирәк иде* (Ф. Нуруллин. Әгәр син булмасаң).

Төрдәше: акча чы<гар>у.

**АКЧА ТОТА БЕЛМӘҮ.** Акчаның бәясен белмәгәнлектән, зур чыгымнар ясау. *Шулай да акча тота белмәве дә хатын өчен бик күп кайгылар тудыргалады* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).

**АКЧА ТӨРТҮ.** Ришвәт бирү. *[Хәтирә] Бүтәннәр андый урындык өчен акча да төртерләр иде, ә син…* (Ю. Әминов. Кан-кардәшләр).

**АКЧА ТӨШЕРҮ.** 1) *к.* акча сугу 1. – *Әти, эш әйбәт туры килеп, акча төшерә алсак, миңа Вәлиәхмәтнеке төсле кәләпүш алырбызмы? – дип сорап куйды* (Ф. Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы).

Төрдәше: акча каеру һ.б.

2) Бераз акча эшләп алу. *«Сантехприбор» ишегалдын, хуҗалык биналарын чүп-чардан арулап шактый акча төшергәннәр – Нәҗип җиде шешә сыра алып кергән* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). <…> *өстәвенә әле тегү машиналары ремонтлап та акча төшерү җаен таба иде* (Г. Ахунов. Эт патшасы).

**АКЧА ТӨШҮ.** 1. Акча эшләп алу мөмкинлеге булу. *Килер иде, сулар үргә акса, / Качып йөрмәс иде, әй, бәхет тә / Акча төшми, акча…* (Р. Гаташ. Иске китапка зимагор бабайлар язган җыр).

2. Акчаның үзкыйммәте кимү. *Акча төште – базар бәяләре төшмәде* (Х. Сарьян. Бер апаның биш улы).

**АКЧА ТУЗДЫРУ.** Кирәк булмаганга, юкка акча әрәм итү. *Тикшергәннән соң, акча туздыруы билгеле булгач, моңа бик күп нәрсәсен сатарга туры килгән* (Г. Бәширов). *Эшеннән куылгач, ул байтак еллар зират тирәсендә ышкынган, кабер казыган, маклерлык иткән, «уңайлы, коры, сукмаклы якка» урын вәгъдә итеп, мәет иянәреннән сәмән аерган, марҗалар белән се-берелгән, акча туздырган* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: акча бетерү; акча түгү: акчаны әрәм-шәрәм итү; акчаны җилгә очыру (ату); акчаны суга салу.

**АКЧА ТҮГҮ.** Акчаны әрәм-шәрәм итү. – *Минем өчен шулкадәр акча түк-мәсәгез инде* (Ф. Яруллин. Гөлҗиһан малайлары). – *Бер кирәкле нәрсәне таба алмадым, акча түгеп кенә кайттым* (Сөйләм).

Төрдәше: акча туздыру һ.б.

**АКЧА ТҮЛӘП АКЫЛДАН ЯЗУ.** Эчеп акылын бетерү. *Шулай да, эчүне «егетлеккә» санап, акча түләп акылдан язуны да аңлый алмыйм* («Матбугат.ру» порталы).

**АКЧА УБЫРЫ** *к.* акча бүсере. *Җитмәсә, бу комбинат безнең Казанңа өзеләчәк корылма кебек акча убыры түгел – 1 млрд 200 миллион сумлык кына* («Безнең гәҗит» газ.)

Төрдәше: акча бүсере һ.б.

**АКЧА ЧӨЕП УЙНАУ.** Акча отыш уены: акчаның иләк яки күн ягы төшүенә карап, отыш ачыклана. *Малайлар чикләвек сатып алалар да, шуны бергә өеп, акча чөеп уйнарга керешәләр* (М. Галәү. Болганчык еллар).

**АКЧА ЧЫГ<АР>У** *к.* акча тот<ыл>у. *Бу арада Мәскәүгә барып, акча күп чыкты* (Ә. Камал).

Төрдәше: акча тот<ыл>у.

**АКЧА ЧЫЛТЫРАУ.** Табыш керү. *Кесәдә акча да чылтырый башлады* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**АКЧА ШӘҮЛӘСЕ БЕЛӘН КҮЗЛӘРЕ СУКЫРАЮ.** Акча күрү белән, фикерләү сәләте югалу. *Булыр, аларның планнары качкан, акча*

*шәүләсе белән күзләре сукырайган...* (М. Латыйфуллин. Курайчы малай).

**АКЧА ЭШЛӘҮ.** Нәрсә булса да эшләп, эш хакы буларак акча алу. *Шулай итеп, мин акча эшлим, баю юлларының беренче сукмагыннан атлыйм* (Ш. Маннур. Яңа җыр килде). *Ә Гөлчәчәк авыру килеш тә, хатын-кыз башы белән дә акча эшләргә тырышып йөргән булган иде* (Д. Булатова. Соң түгел!).
Төрдәше: акча каеру һ.б.

**АКЧА ЯВУ** *к.* акча каеру. *Кеше сыман күктән акча яуганны көтеп ятмадылар* (Р. Шәрипова. Шайтан таягы).
Төрдәше: акча каеру һ.б.

**АКЧА ЯНЧЫГЫН ЧИШҮ (ЧИШЕП ҖИБӘРҮ).** Юмартлану, акчаны кызганмау. *Кызганычка каршы, берничә мәртәбә җыелышып киңәшсәләр дә, алар арасында акча янчыгын чишәргә атлыгып торган кеше табылмый* (Р. Вәлиев. Дөнья гаме).

**АКЧА ЯСАУ.** Төрле эшләр эшләп, акча туплау. *Өстәвенә шәкертләргә китап төпләп, вак-төяк нәрсәләр эшләп, бераз акча да ясый* (Г. Ибраһимов. Диңгездә).
Төрдәше: акча каеру һ.б.

**АКЧА-АКЧА ❖ АКЧА-АКЧА КАР ЯВУ.** Эре-эре көмеш тәңкә сыман кар яву. *Акча-акча карлар ява, / Кара җирне агарта* (Җыр).

*АКЧАГА* ❖ **АКЧАГА ӘЙЛӘНДЕРГӘНДӘ (ӘЙЛӘНДЕРЕП ИСӘПЛӘГӘНДӘ).** Акчага күчереп исәпләгәндә. *Бу, безнең акчага әйләндергәндә, 14 миллион чамасы була* (Т. Нәҗмиев. Сабаларда эчәр суым булгач...). *Акчага әйләндереп исәпләгәндә, бу 1 миллиард 57 миллион сум тәшкил итә* («Ватаным Татарстан» газ.).

**АКЧАГА ӘЙЛӘНДЕРҮ.** Акчага күчерү, сатарга мөмкин нәрсәләрне сату. *Теләсә ничек акчага әйләндерергә кирәк кавынны* (Т. Әйди. Мәҗит Бәй). *Ә эш тәмамланып берничә ай үткәч, монда караклар, кереп, борынгы акчаларны, орденнарны, көмеш савытларны, гомумән, акчага әйләндерергә мөмкин булган нәрсәләрне кырып-себереп алып киткәннәр* (З. Мурсиев. Солтанъяр).

**АКЧАГА БАТУ** *к.* акча сугу 1. *Дөбетен сата, акчага бата, / Тотмый кәҗәне юкка, бушка* (В. Ильясов. Кәҗә). *– Сөйгәнем кочагында акчага батып үлсәм иде! – дисеңме?* (matbugat.ru).
Төрдәше: акча сугу 1 һ.б.

**АКЧАГА КОЕНУ** *к.* акча сугу 1. *– Мансур, чукрак, акчага коенабыз дип асрый* (Н. Гыйматдинова. Нурулла).
Төрдәше: акча сугу 1 һ.б.

**АКЧАГА ЧУКЫНГАН** *к.* акча колы. Акча өчен җанын да, иманын да сатарга әзер булу. *Башкалар бер тиен таба алмый яше күздән акса да; / Кызганып кылмый иганәт, ул чукынган акчага* (М. Гафури). *– Шулай булмаса, ул акчага чукынган, җанын саткан!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).
Төрдәше: акча колы һ.б.

*АКЧАДАН* ❖ **АКЧАДАН КЫЙБАТ.** Кыйммәтен акча белән исәпләп булмый торган. *Намус акчадан кыйбат* (Мәкаль). *Алар махсус җайланманы бик очсыз бәягә өләшеп, балалар сәламәтлегенең акчадан кыйбатрак икәнен раслаячак* («Ватаным Татарстан» газ.).

**АКЧАДАН УЙНАУ.** Акча отышлы уен уйнау. *Әгәр гяһан уйнасаң, акчадан уйнама. Акча белән нәрд вә шатранҗ уйнамак комар* (К. Насыйри).

*АКЧАЛАРЫН* ❖ **АКЧАЛАРЫН БАШЛАРЫНА ЧӘЙНӘП ЯКСЫННАР.** Намуссыз юл белән табылган акчаларның кирәк түгеллеген кискен белдерү. *[Фатих] Акчаларын башларына чәйнәп яксыннар, аларның хәрам акчаларының бер тиене дә кирәк түгел, диде* (Г. Камал. Безнең шәһәрнең серләре).

*АКЧАНЫ* ❖ **АКЧАНЫ ӘРӘМ-ШӘРӘМ ИТҮ** *к.* акча туздыру. *– Теге атнада калдырган акчаны әрәм-шәрәм итеп бетердеңме?!* (Сөйләм).
Төрдәше: акча туздыру һ.б.

**АКЧАНЫ ҖИЛГӘ ОЧЫРУ (АТУ)** *к.* акча туздыру. *– Бу айда ике йөз тотылган. Күпме акчаны җилгә очырганбыз, – ди* (Р. Бәшәр. Ачык капка). *Тукай көне-төне эшли, ә хәләл җефете акчаны җилгә очыра!* (Ф. Бәллүр. Кем син, Рабит Ора бит?).
Төрдәше: акча туздыру һ.б.

**АКЧАНЫ <КӨРӘК БЕЛӘН> КӨРӘП АЛУ** *к.* акча каеру. – *Бу хайван [дуңгыз] тиз үрчи, артымы зур, ике-өч елда акчаны күрәк белән күрисең, Азизов* (Н. Гыйматдинова). *Дөрес булса, адвокатлар хәзер акчаны көрәп ала, имеш* (Ф. Яруллин. Гөлҗиһан малайлары).

Төрдәше: акча каеру һ.б.

**АКЧАНЫ СУГА САЛУ** *к.* акча туздыру. *Сынык аяклы бозау өчен Агыйделнең аръягына чыгарга, акчаларны суга салып кайтырга язган булган шул, һични эшләр хәл юк!* (Ф. Яхин. Бакыр бозау артыннан). *[Люция] Телескоп дип күпме акча суга салдың!* (М. Гыйләҗев. Баскетболчы).

Төрдәше: акча туздыру һ.б.

**АКЧАНЫ ЯБЫП КАЛУ.** Алган бурычны түләмәү. *[Әхмәт] – Ай-һай, без, Әхмәт, аңа сатабыз сатуын да, ул безнең акчаны ябып калмас микән, – ди* (Г. Камал. Дәҗҗал).

*АКЧАНЫҢ* ❖ **АКЧАНЫҢ ЙӨГӘНЕ ЮК (БУЛМАУ).** Акчасын тота белмәгән кешегә ишарә. *Акчаның йөгәне юк шул, күпме керсә, шулай чыгып бара* (Г. Мөхәммәтшин. Йөрәктәге эзләр).

Төрдәше: акчаның күзе юк.

**АКЧАНЫҢ КҮЗЕ ЮК.** Акчаны нәрсә өчен бирәсең, аны күрә алмау; *шулай ук к.* акчаның йөгәне юк (булмау). *Гаепләп әтүем түгел. Акчаның күзе юктан гына әйтүем* (Х. Хәйруллин. Картлык... Кемгә шатлык?!). *Акчаның күзе юк: күпме керсә, шуның кадәр чыга – анысы хак* («Сөембикә» ж.).

Төрдәше: акчаның йөгәне юк (булмау).

**АКЧАНЫҢ КҮЗЕН ЧЫГАРУ** *к.* акча<ның> күзенә карамау (карап тормау). – *Акчаның күзен чыгарырга оста да инде минем хатын* (Сөйләм).

Төрдәше: акча<ның> күзенә карамау (карап тормау).

**АКЧАНЫҢ ОЧЫН ОЧКА ЯМАУ.** Яшәү өчен акчаны көч-хәл белән җиткерү. *Әҗәтем күп, ямый алмыйм / Акчаның очын очка* (Н. Салихов. Киңәш).

*АКЧАҢНЫ* ❖ **АКЧАҢНЫ ТЕШЛӘП ҮЛӘРСЕҢ.** Акча булып та, аңа ризык таба алмаганда әйтелә. – *Юл буйлап көн буе бардым, ник бер алачык, ник бер кеше очрасын* – ачтан *акчаңны тешләп үләрсең* (Сөйләм).

**АКЧАСЫ КУЛГА ЙОКМАУ.** Кулда булган акчадан файда булмау. *Әткәйнең акчасы кулга йокмый. Әнкәй әйтмешли, кереп җитмәс борын бармак арасыннан шуып чыга да китә* (Ф. Латыйфи. Бәйсез этләрне атарга).

*АКЧАСЫЗ* ❖ **АКЧАСЫЗ КӘМИТ (КОМЕДИЯ).** Көтмәгәндә килеп чыккан кеше көлдерерлек берәр хәлне күзәтеп тору. – *Кичә трамвайда акчасыз кәмит карап кайттым әле* (Сөйләм).

**АКЧАСЫЗ КЕСӘ**. Ярлы кеше. *Ә мин кем? Акчасыз кесә. Менә мин кем* (Ф. Хөсни. Йөзек кашы).

**АКЧАСЫЗ ФАТИР.** Төрмә. *[Әптери] Эләгерләр әле, акчасыз фатирга кергәннәрен сизми дә калырлар* (Г. Камал. Уйнаш).

*АКЧАСЫЗДАН* ❖ **АКЧАСЫЗДАН АТА КАЗ.** 1. Акча юкта һич көтмәгәндә шәп сыйга тап булу. *Йомыш белән Мансурларга барып чыккан идем, бергә хезмәт иткән дусты килеп төшкән икән: акчасыздан ата каз дигәндәй, анда кунак булып кайттым* (Сөйләм).

2. «Акчам юк» дип сыкранучыдан көтелмәгән чыгым ясату. *Кесәсеннән акча чыгарырга яратмаган Рәшитнең «әйдәгез, үзем сыйлыйм» дигән сүзләре акчасыздан ата каз кебегрәк яңгырады* (Сөйләм).

*АКЧАСЫН* ❖ **АКЧАСЫН БИРГӘН МАРҖАСЫ (УРЫСЫ) ҮЛГӘН.** Алган бурыч үтәлмичә янга калу («акча каян килгәнен сорама» мәгънәсендә). – *Бая гына, акчам юк, дигән идең бит әле – акчасын биргән урысы үлгәнме юкса?..* (Сөйләм).

**АКЧАСЫН ТАВЫК ТА ЧҮПЛӘП БЕТЕРӘ АЛМЫЙ (БЕТЕРМӘС).** Байлыкка, зур милеккә ия булу, мул-иркен тормышта яшәү. *Аның акчасын тавык та чүпләп бетермәс, мең сумын гына әҗәткә биреп торыр әле* (Сөйләм).

Төрдәше: акча бездә бер чорма һ.б.

*АКШАРЛЫ* ❖ **АКШАРЛЫ КЫЗ** *иске.* Сатлык кыз, фахишә. *Фәкать бер бүлмәдә һич кемсә күрмәс, / Китерттек берничә акшарлы кыз да* (Г. Тукай).

*АКЫЛ* ❖ **АКЫЛ АВЫРАЮ.** Бик нык үпкәләү, дөрес аңламау хәлгә җиту. *Әмма хисләр үртәлгән, йөрәк ярсыган, акыл авырайган иде* (А. Гыйләҗев).

**АКЫЛ АЛДАН ЙӨРҮ.** Алдан күреп, уйлап эш итү. *Болай каударлану хан кызын бизәми, акылы алдан йөрергә тиеш, дип хәл итте* (М. Әмирханов. Гәүһәршад).

**АКЫЛ АЛУ.** 1. Акыл, фикер туплау. *Кешеләрдән акыл алгандыр дияр идең, елына берәр тапкыр Казанга барып кайтуларын санамаганда, читкә, зур дөньяга чыкканы да юк* (В. Нуруллин. Җавап бир, кеше).

2. Булган хаталарны кабатламас өчен, кыенлыклар күреп, нәрсәгә булса да өйрәнү, үрнәк алу. *Тормыш дигән карурманда / Акыл аласың икән* (Г. Афзал. Яңа күрсәтмәләр килгәч...). *Заһидулланың, төрмәгә ябылып, бераз акыл алып кайтуын Сәләмә Габдрахман бик теләгән иде* (Р. Сибат. Кайту).

Төрдәше: гыйбрәт алу; гыйбрәт-сабак алу; сабак алу 2.

**АКЫЛ АРТТАН ЙӨРҮ.** Берәр вакыйганы вакытында аңлап җиткереп, сүз яки эш-хәрәкәт белән җавап бирә алмау. *«Ачу – алдан, акыл арттан йөри», – ди* (Р. Низами. Без яшибез...). *Акыл арттан йөри, ди халык әйтеме, моңысы, күрәсең, типик психологик ситуациядер* (Р. Абдуллина. Сөйләм культурасы).

Төрдәше: туйдан соң дөмбергә (думбыра).

**АКЫЛ АЧЫК <БУЛУ>.** Фикерләү сәләте, зиһене яхшы эшләгән вакыт. *Гүя кәефе яхшы, акылы ачык вакытта таркау уйларын җыярга, әйтәсе сүзләрен хәтеренә төшерергә тырыша* (Ә. Еники).

Төрдәше: акыл ачыклану.

**АКЫЛ АЧЫКЛАНУ** *к.* акыл ачык <булу>. *Әле акыл ачыклана, әле тагын караңгы упкынга очып онытылам* (Г. Әпсәләмов. Миңа унтугыз яшь иде).

Төрдәше: акыл ачык <булу>.

**АКЫЛ АША УЗДЫРУ.** Ныклап уйлау, тирәнтен фикерләү. *Синең өчен күрше кайгырмас, алдан ук һәрнәрсәне акыл аша уздырып куярга кирәк иде* (Н. Гыйматдинова).

Төрдәше: акыл белән уйлау (уйлап карау); акыл белән үлчәү (үлчәп карау); акыл бизмәненә салу (салып карау; үлчәү); акыл бизмәнендә үлчәү (үлчәп карау); акыл иләге аша уздыру (үткәрү); акыл йөртү (йөртеп карау); акыл чал(ы)шайту; аңга сеңдерү; ачык зиһен; баш ватарлык; баш<ны> вату; баш<та> йөртеп карау; баш кайнау; баш катыру; башка салу; башны җигү; биш үлчәп бер кисү; фикер иләгендә иләү; фикер иләгеннән уздыру.

**АКЫЛ БАШКА КИЛҮ.** 1. Уйлау-фикер йөртү сәләтенә ия булу. *Инде аннан киткәч, акылы башына килдеме?* («Татар заманы» газ.). *Хәзер инде утырган җиреннән төрле нәрсәләр кычкырып утырмый, акылы башына килде бугай* (Сөйләм).

Төрдәше: акылга килү (кайту).

2. Эш үткәч үкенү. *Балыкның ауга эләккәч кенә акылы башына килә* (Мәкаль). *Тик балыкның ауга эләккәч кенә акылы башына килә дигән сүз шул буладыр инде...* (Татар электрон китапханәсе).

**АКЫЛ <БАШТАН> КИТҮ (ЧЫГУ).** 1. *к.* аксак акыл. – *Картлыгым җитеп, акылым китеп калдымы?* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).

Төрдәше: аксак акыл һ.б.

2. Ни эшләгәнне белмәү, хис ташыган чакта үз-үзеңә контрольне югалту. *Кулларын болгый-болгый җикеренә, акылы чыга башлаган, ахрысы* (Сөйләм).

3. Гаҗәпләнү. *Шундый бәләкәй малайның зурлар эшли алмаган нәрсәләргә башы җитүенә акылым китте* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз ачып калу 5 һ.б.

**АКЫЛ БЕЛӘН.** 1. Белемгә нигезләнеп. *Аны тау куышыннан алып кайталар, тыйб гыйлеменә өйрәтәләр, камил акыл белән бүләклиләр* (Г. Госман. Гармун телләре унике).

2. Ныклап уйлап. *Хәзерге акыл белән фикер йөртеп карыйм, ул сепаратка рәхмәттән башка сүзем юк* (А. Гыйльми. Сепарат кыйссасы).

Төрдәше: акыл аша уздыру һ.б.

3. Нинди дә булса максатны истә тотып хәрәкәт итү, башкару. *Менә бүгенге акыл белән шул дорфарак сүзләрнең рифма өчен генә әйтелмәгәнлеген чамалыйсың* (А. Тимергалин. Игезәкләр). *Гөлшаһидә үз хисләренә чик куярга булды, акыл белән яши башларга бик вакыт* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**АКЫЛ БЕЛӘН УЙЛАУ (УЙЛАП КАРАУ)** *к.* акыл аша уздыру. *Хәзер, саф акыл белән уйлаганнан соң, ул монда тагын бер шкаф куярга булды* (А. Тимергалин. Таш алиһә).

Төрдәше: акыл аша уздыру һ.б.

**АКЫЛ БЕЛӘН ҮЛЧӘҮ (ҮЛЧӘП КАРАУ)** *к.* акыл аша уздыру. *Йөрәгең ни кушса, шулай эшләрсең, әмма акылың белән дә үлчәп кара* (Ә. Еники).
Төрдәше: акыл аша уздыру һ.б.

**АКЫЛ БЕЛӘН ЭШ ИТҮ.** Эш-гамәлләрне уйлап башкару, яхшылап уйламыйча, аңламыйча эшкә тотынмау. *Әмма Рябушинский акыл белән эш итә, тотылган капиталның иртәме-соңмы артыгы белән кире кайтачагын ул бик яхшы аңлый* (М. Зарипов. Киңлекләр).
Төрдәше: акыл аша уздыру һ.б.

**АКЫЛ БЕРГӘ ДӘ ТУЛМАУ.** Өстән генә, төптән уйламыйчарак эш итү, акылга чамалы. *Мин үзем дә шундый: буйга – ун карыш, акылга – бергә дә тулмый* (Ф. Яхин. «Өфет мае»).
Төрдәше: акыл казаны тишек; акыл сайлыгы; акыл сыйдыра алмау; акыл тәпәне саегу; акыл чамалы <булу>; акыл ягы сай; акыл ягы такыр; акылга әйле-шәйле; акылга бертөрле; акылга җиңел; акылга зәгыйфь; акылга сай; акылга туймау (туймый калу); акылга таман<ча>; акылга тулы булмаган; акылга тулы түгел; акылга туяр-туймас; акылга түгәрәк түгел; акылга чак; акылга чамалы; акылны кәҗә ашау 1; акылы бармакка урарлык (чорнарлык) та юк; акылы кыска; акылы өчле-тугызлы <гына>; акылы таман<ча>; акылы – төпсез чиләк; акылы тубыгында; барып җитмәгән нәрсә; баш юка <булу>; башта бушлык <булу>; башта җил уйнау; башы җиңел; бер тактасы җитми (ким); винтлары бушау; гайкасы бушаган; гәрәнкәсе җиңел; гөрәнкәсе җиңел; йөзгә бер тулмаган; кыска акыллы; кырыкка бер тулмаган; савыты тулмаган; тугыз төймә; туксан тугызлы <гына>; тулы түгел; утыз тугызлы <гына>; утыз тугызлы – кырыкка бер тулмаган; үлчәве җитмәү; үлчәве таманрак; шөрепләре бушау; шөрепләре какшаган; шөрепләре тулы түгел (булмау).

**АКЫЛ БЕТҮ.** Тилерү, үз-үзен белмәү. – *Акылым беткән, шуңа тиле кебек моңланам, ахрысы, – диде Аксюша түти, һаман дөресен әйтмичә* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Теге вакытта эчергән даруларның, агуларның нәтиҗәседер, аңы да юк, акылы да беткән, бөтен нәрсәсе астында* (Ф. Бәйрәмова. Кырык сырт).
Төрдәше: акыл <баштан> китү (чыгу) 1 һ.б.

**АКЫЛ БИЗМӘНЕНӘ САЛУ (САЛЫП КАРАУ).** Төптән, төрле яклап, ныклап уйлау. *Сания үзенең нишләгәнен акыл бизмәненә салып үлчи башлагач уңайсызланып китте* (М. Әмир).
Төрдәше: акыл аша уздыру һ.б.

**АКЫЛ БИЗМӘНЕНӘ УТЫРТУ.** Тиргәү, орышу. *Ул яшен ташыдай атылып килеп җитәчәк тә малаен акыл бизмәненә утыртып кайтып китәчәк* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).
Төрдәше: акылга утырту; анадан алган сөтләрен китерү; анадан имгән сөтләрен авызына китерү; аркадан сыйпамау; арт сабакны тыңлату 1; арт сабакны укыту 1; әйбер әйтү; баштан сыйпамау; бер мәчегә ике (дүрт) эт ябышу; безгә бастыру; борчакка тезләндерү; борычлап-суганлап пешерү; борычлап-тозлап сүгү; борычлап-тузанлап эләктерү; буран куптару (күтәрү, очыру, туздыру, чыгару): буран уйнату; җиде бабасына җитү 1; иманын көйдерү; иманын өшкерү; иманын укыту; йонны очыру; кадак өстенә бастырып, яктан кыздырып тору; кирәкне бирү; күрмәгәнне күрсәтү; кызган (кызу, утлы, эссе һ.б.) табага бастыру (бастырып биетү); кызган табада биетү; мунча кертү 1; мунча кызу булу; мунча чабындыру; пыр китерү (тетү); пыр туз<дыр>у 1; пыр тузып ташлау; себеркесез <мунча> чабындыру; суганлап-борычлап кыздыру; таш-талканын чыгару; тетеп салу; тетеп ташлау; тетмәне тетү 1; утлы күмер өстендә биетү; утлы күмергә бастыру; утлы табага бастыру 1; утлы табага утырту 1; элеп алып, селкеп салу 1; эссе табага бастыру; эт итеп ташлау (сүгү; кыйнау һ.б.); эттән алып эткә салу.

**АКЫЛ БИЗМӘНЕНДӘ ҮЛЧӘҮ (ҮЛЧӘП КАРАУ)** *к.* акыл аша уздыру. *Хатын-кыз теләсә нинди баш әйләндергеч вәсвәсәгә бирешмәскә мөмкин, әмма кияүгә чыгу турында ишеткәч, аның күңелендә барысының да асты өскә килә, саклык, чамалап эш итү, акыл бизмәнендә үлчәп карау дигән нәрсәләр бер дә булмагандай юкка чыга* (Р. Мирхәйдәров. Иманыңнан бер язсаң). *Өсләренә ишелеп төшкән бу кадәр вәгъдәне акыл бизмәнендә тагын бер кат үлчәп, мигә сеңдереп бетерәсе бар иде* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).
Төрдәше: акыл аша уздыру һ.б.

**АКЫЛ БИРҮ.** 1. Өйрәтү, ничек яшәргә, эшләргә кирәклеге турында киңәшләр бирү, үгетләү. *[Касыйм] Шулай дигәч, мин аңа акыл бирергә тотындым, яхшы адвокаттан да остарак сөйләдем* (И. Багданов. Помада мәсьәләсе). – *Йә, шул чакта син ни эшләрсең, ни дип җавап бирерсең, хәлбуки яныңда акыл бирергә мин дә булмасам?..* (Ә. Еники. Чикерткә).
Төрдәше: акыл өйрәтү һ.б.

2. Үз карашын үткәрергә тырышу. *Ибрашов урынбасарына тагын акыл бирде* (Г. Толымбай. Яз көне). *[Әббән] Аңлаган саен, син акыл бирергә торасың. Мин нәрсә дим?* (Г. Кутуй. Шатлык җыры).

3. *к.* авыз җебетү 2. *Кичен, берничә малай җыелышып, акыл бирделәр үзенә* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АКЫЛ БИРҮЧЕ (БИРЕП ТОРУЧЫ).** Киңәшче, акыл өйрәтеп торучы. – *Әй олуг морза, бар халыкка син баш, син юл күрсәтүче һәм акыл бирүче* (З. Мурсиев. Ташмәчет).

**АКЫЛ БУ.** 1. Нинди дә булса файдалы киңәшне кабул иткәндә әйтелә. *«Кичрә алсаң, кичер, Салих ага! <...>Безгә сабак, бездән соң килүчеләргә акыл бу!»* (Р. Фәйзуллин. Илбагар уйлар).

2. Киләчәктә гыйбрәтле сабак булырдай икәнлеккә ишарә ясау. – *Шәһәрдә калсам, хатынны укытырга, аннан эшкә тартырга мөмкин булачак. – Бу акыл бу, Фәтхи* (Ш. Камал. Матур туганда).
Төрдәше: акыл булсын.

**АКЫЛ БУЛСЫН.** «Киләчәктә сабак булсын» мәгънәсендә. *[Минһаҗ]. Минем алда да әйтмә! Акыл булсын моннан ары* (Р. Хәмид. Тигезәкләр).
Төрдәше: акыл бу 2.

**АКЫЛ БУТАЛУ.** Аңламау, төшенә алмау. *Дөньяның бер шомлы чагы иде, хәйрәтеннән акыл буталган* (С. Рәмиев).
Төрдәше: аксак акыл һ.б.

**АКЫЛ ҖИЛГӘ ОЧУ** *к.* акыл <баштан> китү (чыгу) 1. – *Тәмам акылың җилгә очканчы, авылга күчәр идең, – диде Сәйдәш, картны жәлләп* (Н. Гыйматдинова. Китәм, димә...).
Төрдәше: акыл <баштан> китү (чыгу) 1 һ.б.

**АКЫЛ<ГА; -ДАН> ҖИҢЕЛӘЮ.** 1. Элек акыллы булса да, хәзер иләс-миләсле булу. – *И карчык, тәмам акылым җиңеләеп бара, ничә тапкыр әйттем инде мин сиңа: «Сәгыйдулласы Галимулла түгел, Галимулласы Сәгыйдулла!»* («Акыл җиңеләю» мәзәгеннән). *[Гөлҗиһан] «Әллә, абыстай, син дә инде акылга җиңеләя башладыңмы?* (Г. Камал. Банкрот).
Төрдәше: аксак акыл һ.б.

2. Юләрләнү; саташу, белештерми башлау. «*Килен кичерде, хатының кичерде бит», – дип сөйләнеп йөрүче хатынның чәчләре акбур яккандай ап-ак, ә үзе акылга җиңеләйгән иде* (В. Имамов. Утлы дала). *Тик бу могҗиза инде сөендермәс, чөнки акылы җиңеләйгән иде аның* (З. Мәхмүди. Әче балан).
Төрдәше: акыл зәгыйфьләнү; акыл савыты сыегу; акыл саегу (саегаю); акыл сидрәү; акыл сыеклану; акыл томалану; акыл чуалу; акыл шашып калу; акыл шөребе коелу; акыл шөребе югалу; акылга зарар (зәгыйфьлек; зыян) килү; акылга җиңел; акылга җиңеләю; акылга кимчелек килү; акылга көч килү (китерү); акылдан ычкыну; акылдан язу; акылын югалту; берәү тулмый; гакылдан сабу; җүләргә сабышу; исәргә сабу (сабышу); ми сыеклану; ми шулпалану; ычкына башлау.

**АКЫЛ ҖИТЕНКЕРӘМӘҮ.** 1. Тиле-милерәк булу, акыл ким булу. – *Тышкы кыяфәтенә карама син, аның бераз акылы җитенкерәми, диләр* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

2. Тормыш тәҗрибәсе булмаудан, кайбер вакытларда мантыйксыз эш эшләү яки сүз сөйләү. *Аңа нибары унсигез яшь, бу яшьтә тормышның бөтен катлаулылыгын төшенүе кыен, тәҗрибә, акыл җитенкерәми* (Г. Әпсәләмов. Күк күкрәр). – *Табигать сиңа барысын да биргән: буй-сын дисеңме, сөйкемле чырай дисеңме... Ә менә иң кирәклесе – акыл җитенкерәми. Балалыгың белән ундүрт яшеңдә ялгыш юлга тайпылгансың икән, ул ялгышыңны төзәт хәзер, төзәт!..* (Р. Ишморатова. Язмышлар).
Төрдәше: акыл чамалы <булу> һ.б.

**АКЫЛ ҖИТЕШҮ.** *Акылым тиз үк җитешмәс* (Г. Тукай. Мәкаләи махсуса). *Тормышта һәрвакыт шулай – акыл җитешмәүне мускуллар белән тулыландырырга тырышалар* (Р. Хәкимов. Татар рухы).
Төрдәше: акыл җитү; акыл ирешү; акыл керү; акыл утырту; акыл<га> утыру; акылга килү (кайту) 4; аң җитү; аң керү; аң үсү; сапка утыру.

**АКЫЛ ҖИТМӘГӘНЛЕК.** Белем җитмәүдән аңлый алмау. – *Кара, ничек тиз генә җаен таптың, мин исә күпме азапландым – акыл җитмәгәнлектәндер инде* (Сөйләм).

Төрдәше: акыл чамалы <булу>; акылга җиңел; акылга таман<ча>; акылга тулы түгел; акылы таман<ча>; акылы тулы түгел; баш юка; бер тактасы җитми (ким); әтәч баш; гәрәнкәсе җитми; гөрәнкәсе җитми; гөрәнкәсе җиңел; гәрәңкәсе ...; йөзгә бер тулмаган; кабак баш; капчык белән суккан; кибәк баш; кишер башлы; күке баш; кырыкка бер тулмаган; мәкинә баш; савыты тулмаган; тавык баш; тугыз төймә; туксан тугызлы; тулы түгел; утыз тугызлы; утыз тугызлы – кырыкка бер тулмаган; чүбек баш.

**АКЫЛ ҖИТМӘСЛЕК** *ирон.* Беленмәгән, күрелмәгән искиткеч бер хәлне аңлый, төшенә алмау. *Кунак кабул итү – олы һәм акыл җитмәслек четерекле фән ул!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Гөл апаның «минем акыл җитмәслек эше» тоташ ялгышлардан гыйбарәт иде* (Н. Гыйматдинова. Фәрештәләр).

Төрдәше: акыл иләгеннән иләнерлек; акыл ирешә алмаслык; акыл ирешмәле түгел; акыл ирешмәслек; баш җитмәслек.

**АКЫЛ ҖИТМӘҮ.** 1. Аңлап бетермәү. *Хатның бу кадәр озак килмәвенә Хәдичәнең акылы җитми иде* (З. Бигиев). *Тик менә Хафизамның, миңа күз төшермичә, шул шыр ялангач ярлы Хафизны сөюенә генә бер дә акылым җитми* (Г. Камал).

Төрдәше: акыл җитмәгәнлек һ.б.

2. Уйлап җиткермәү, бик үк дөрес эшләмәвен соңыннан искәртү. *Акылың җитмәсә, өлкәннәрдән сорар идең бераз* (Сөйләм).

Төрдәше: аң җитмәү.

3. Кеше ышанмаслык хәл, күренеш, аның дөньяда булмаганлыгына инану. *Күктә ике арыслан сугышканын күргән, имеш, аларга җирдә урын беткәнмени – акылым җитми моны аңларга* (Сөйләм).

**АКЫЛ ҖИТҮ.** Үз акылың белән дөрес итеп эшләү. – *Ярый әле, улым, синең акыл җиткән, югыйсә әтәчебез әрәм буласы икән* (Н. Дәүли. Язмышка юл).

Төрдәше: акыл ирешү; акыл керү; акыл утырту; акыл<га> утыру; акыл үт кенләнү (үткерләү); акылга килү (кайту) 4; аң җитү; аң керү (ачылу); аң үсү; сапка утыру.

**АКЫЛ ҖЫЮ.** 1. Күп сөйләшмичә, белем туплау. *Шактый гына акыл да җыярга мәҗбүр итте шикелле* (Ә. Баянов).

2. Бар белгәнен туплап, уйлап алу. *Мөгаллим, акыл җыйгандай, чигәләрен угалап алды, дәрес башлангандагы кебек тамагын кыргалады* (Г. Бәширов. Гыйбрәт). *Ул, алдындагы әйберләрне берсен тегендә, берсен монда күчергәләп, акыл җыеп утырды-утырды да гайрәтләнә төшеп: – Ярар, Мөхәммәтҗан, – диде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: акыл туплау; акыл шөрепләрен тыгызлау; акылны башка алу; акылны <башка> җыю.

**АКЫЛ<ГА> ЗӘГЫЙФЬЛӘНҮ** *к.* акыл <баштан> китү (чыгу) 1. *[Мөршидә]. Ләкин кемгә кирәк акылы зәгыйфьләнеп килгән кам һәм аның таш шәмаиле?* (М. Хәбибуллин. Илчегә үлем юк). *Син дә акылга зәгыйфьләнә барасың, Кәим, сизәсеңме шуны?*(З. Хәким. Мин төш күрдем...).. *Әллә күңеле утырып җитмәүдән, әллә соң, ни, акылы зәгыйфьләнәме?* (Ф. Яхин. Август ае).

Төрдәше: акыл <баштан> китү (чыгу) 1 һ.б.

**АКЫЛ ИЛӘГЕ АША УЗДЫРУ (ҮТКӘРҮ)** *к.* акыл аша уздыру. *Тыңлый бел дә, ишеткәннәреңне акыл иләге аша үткәрә бел...* (М. Галиев). *Синең өчен күрше кайгыртмас, алдан ук акыл иләге аша уздырып куярга кирәк иде* (Н. Гыйматдинова).

Төрдәше: акыл аша уздыру һ.б.

**АКЫЛ ИЛӘГЕННӘН ИЛӘНЕРЛЕК** *к.* акыл җитмәслек. *Бу һич кенә дә акыл иләгеннән иләнерлек хәл түгел иде* (Н. Гыйматдинова. Ачкыч).

Төрдәше: акыл җитмәслек һ.б.

**АКЫЛ ИРЕШӘ АЛМАСЛЫК** *к.* акыл җитмәслек. *Каршыбызда акыл ирешә алмаслык сер булып, бөтенләй диярлек ялангач кыз басып тора иде* (М. Әмир).

Төрдәше: акыл җитмәслек һ.б.

**АКЫЛ ИРЕШМӘЛЕ ТҮГЕЛ** *к.* акыл җитмәслек. *Акыл ирешмәле түгел, бу биеклеккә бернинди җиһазсыз ничек менеп җитә алган ул?* (Сөйләм).

Төрдәше: акыл җитмәслек һ.б.

**АКЫЛ ИРЕШМӘСЛЕК** *к.* акыл җитмәслек. *Акыл ирешмәслек хәл: шешәдәге суны*

*күзләре бәйләнгән килеш стаканнарга тутырып чыкты* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл җитмәслек һ.б.

**АКЫЛ ИРЕШМӘҮ.** Аңлый алмаслык, зиһен җитмәү. *Бу минутта Фәрдәнәгә Карповның бөтен җире искиткеч гүзәл булып, акылирешмәс дәрәҗәдә серле булып күренде* (М. Әмир).
Төрдәше: акыл җитмәү; акыл ирешә алмаслык; акыл шөребе югалу; акылын югалту; ми сыеклану; ми шулпалану.

**АКЫЛ ИРЕШҮ** *к.* акыл җитү. *Монда эш акыл ирешү яки ирешмәүдә түгел, ничек ул анда барып чыккан?* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл җитү һ.б.

**АКЫЛ ИЯСЕ.** 1. Бик акыллы, зирәк кеше хакында. *Казакъ халкының бөек акыл иясе Абай әйткән: «Сүзнең эче алтын, тышы көмеш», – дигән* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында). *Анда атмосфера, ясалма авырлык булдырылган, безнең кебек үк акыл ияләре яши* (Р. Фәизов. Ә җирдә тереклек бармы?!).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә алу) һ.б.

2. Галим кеше. – *Һи-и-и, дигән акыл иясе… – Һи-и-и… Бу – беләсеңме нәрсә?* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).
Төрдәше: акыл капчыгы; акылга беткән; акыллы баш 1; акылы алтын <икән> 1; башы йомры; тирән акыллы; фикер иясе.

**АКЫЛ ИЯСЕ ҖҮЛӘР (ЮЛӘР).** Юләр сыман кыланып эшләүче яки яшәүче акыллы кеше хакында. *Ай акыл иясе җүләр, агачта дуңгыз буламыни?* (Ю. Әминов).
Төрдәше: акыллы дивана; башны җүләргә салу.

**АКЫЛ ЙӨРТҮ (ЙӨРТЕП КАРАУ).** Уйлау, тирәнтен фикерләү. *Рөстәм үз язмышын үзе хәл итәргә тиеш икәнлекне аңлады һәм зурларча акыл йөртә башлады* (Г. Кутуй. Рөстәм маҗаралары).
Төрдәше: акыл аша уздыру һ.б.

**АКЫЛ КАЗАНЫ БУШ ТҮГЕЛ.** Фикерләү дәрәҗәсе түбән түгел, акыл белән эш итә белү. *Күренеп тора, акыл казаны буш түгел моның* (Ф. Сафин. Тулган ай).
Төрдәше: башка ат (тай) типмәгән; башка ишәк типмәгән; маңгайга тай типмәгән.

**АКЫЛ КАЗАНЫ БУШАУ** *кимс.* Акыл кимү, зиһен таралу. *Картның акыл казаны бераз бушаган әле аның, уйлап җиткерә алмый ул* (М. Гали).
Төрдәше: аксак акыл һ.б.

**АКЫЛ КАЗАНЫ ТИШЕК** *к.* акыл бергә дә тулмау. *Анда күбрәк башка мәдрәсәләргә үтә алмаган сыек бәдәнле йә акыл казаны тишек, яисә инде керделе-чыктылы шәкертләр җыелган* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛ КАЙМАК КЕБЕК КУЕРУ.** Фикерләү кимәлен тулысынча эшләтә башлау. *Олысында акыл каймак кебек куерган иде инде: – Буе кыска патамушты, – диде* (Н. Гыйматдинова. Кәтәнә).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә алу) һ.б.

**АКЫЛ КАПЧЫГЫ** 1. Бик акыллы, күпне белүче. – *Алар фикеренчә, без мәктәпне тәмамлаганда, акыл капчыгы булып чыгарга тиеш идек* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә алу) һ.б.

2. *ирон.* Акыл өйрәтергә яратучы. – *Үзен акыл капчыгы дип хис итә бугай, һәр нәрсәгә борынын тыга* (Сөйләм).

**АКЫЛ КЕРГӘН** *к.* авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә алу). – *Син акыл кергән егет инде, – дип, кадрлар бүлеге начальнигы аңа тагын да текәлебрәк күз салды* (Т. Сәгыйтов. Күккә гашыйк егет). *Олыгайган, акыл кергән, / Сабырлык бар* (М. Шабаев). *Аңа акыл кергән. Динә апасының: «Китмә авылдан, ташлама нигезеңне!» – дип эчкерсез әйткән сүзләре күңеленә нык кына сеңеп калды* (Ахир. Таш калада баш кала).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә алу) һ.б.

**АКЫЛ КЕРЕП ТӘ ЧЫКМАГАН.** Үзе уйлый, фикер йөртә алмый торган, акыл әсәре дә күренмәгән буш кеше турында. – *Моңа, билләһи, акыл кереп тә чыкмаган әле!* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл кермәгән.

**АКЫЛ КЕРМӘГӘН.** Яшь, тәҗрибәсез. – *Берсенә бала булып акыл кермәгән, икенчесенә картаеп та керәсе юк* (М. Хуҗин. Айның уты сүнгән).
Төрдәше: акыл кереп тә чыкмаган.

**АКЫЛ КЕРҮ.** 1. Тормыш тәҗрибәсе алу, аңлылану. *Ләкин мин ыжлап та бирмәдем, чөнки җәй көне миңа шактый акыл кергән иде инде* (В. Нуруллин. Ике урман арасы). *Ә бит мине бергә эшләгән укытучыларым да, укучыларым да акыл кергән, төпле кешегә санаулар* (А. Нәҗми. Казан).
Төрдәше: акыл җитү һ.б.

2. Сабак алу; белемле, тәҗрибәле булу. *Инде чәчем агарып бара, акыл керергә дә вакыт югыйсә, ә шуклыкларны эшләргә генә торам* (А. Хәсәнов. Көзге урман аланында).
Төрдәше: акыл утырту һ.б.

**АКЫЛ КИРЕГӘ АВЫШУ (КИТҮ).** Үткәннәрне бүгенге кебек күрү. *Камилланың акылы кирегә авыша мәллә?* (Н. Гыйматдинова. Китәм, димә...). *Күп йөрүдән, фәкыйрьлек, михнәттән, мөгаен, акылы кирегә китә башлагандыр Әхмәт бабайның!* (Ф. Гыйльми. Салават күпере).

**АКЫЛ КИРТӘСЕННӘН ТЫШ БУЛУ.** Бик күп уйланудан баш эшләми башлау. *Соң чакларда аклым киртәсеннән тыш булырга кирәк, бәгъзе мәсьәләләр турысында уйлый-уйлый эч пошуга сабыштым...* (Ш. Камал. Эч пошулы).

**АКЫЛ КИТЕЛҮ.** Акылга зыян килү. *Габделнурның акылы кителгән, ул бөтен булмышы белән җүләр иде* (Н. Гыйматдинова. Кәтәнә).
Төрдәше: акыл <-га; -дан> җиңеләю 1, 2.

**АКЫЛ КИТҮ** *к.* акыл <баштан> китү (чыгу) 1. – *Күр әле син шушы Төпҗазның зурлыгын, чын кала бит, әй, акыллары китеп йөриләр иде* (А. Хәсәнов. Бахбайлар ял йортында). *Кыз әйтте: «Әй егет, акылың киттеме әллә?»* (Г. Гыйльманов. Сагышың булса, суга сал).
Төрдәше: акыл <баштан> китү (чыгу) 1 һ.б.

**АКЫЛ КОТ <БУЛУ>** *к.* акылың алтын икән. *Акылың кот икән, таптамый тор әле!* (В. Имамов. Казан дастаны).
Төрдәше: акылы алтын икән.

**АКЫЛ КӨЙМӘСЕНДӘ ЧАЙКАЛУ.** Уйлау, уйлану. *Сәвилә ачуланмады. Баядан бирле акыл көймәсендә чайкалалар* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: фикер иләгендә иләү; фикер иләгеннән уздыру.

**АКЫЛ КӨЧЕ.** Аң-белем дәрәҗәсе, тәҗрибәле булу. – *Хәзер синдә акыл көче түгел, хатын-кызда була торган хисләр уянды* (А. Нәҗми. Карлыгач). – *ин генә ярдәм итә алырлык булгач, монда яки хис, яки акыл көче турында сүз барадыр инде* (М. Кәбиров. Бердәнбер һәм кабатланмас).

**АКЫЛ КУЕРТУ**. Нәсыйхәт бирү, нәрсәне булса да «аңлату». *Әйдә, алар йөрсен уч төбендә, / «Аксакалдай» акыл куертып* (Г. Садә).

**АКЫЛ КУШКАНЧА.** Төрле яктан уйлап, аңлап. *Беренче бөтендөнья сугышыннан соңгы чорда башка милләтләр һәм дәүләтләр, сәламәт акыл кушканча гамәл кылып, фән кушканча алга атлаганда, Сталин «Джугашвили»ның дөньяда тиңе булмаган канлы хакимияте безне, чабуыбыздан тартып, артка сөйрәде* (Г. Бәширов. Гыйбрәт).

**АКЫЛ КУШЛАНУ.** Зиһен аеруча яхшы эшли башлау. *Шаһимәрданның акылы кушланып, шунда ук бер фикергә килде: күрше-тирә авылларга хәбәр салырга, юлга чакырырга, әрәмәлекләргә каравыллар куярга тиеш ул* (Ф. Яхин. Ат урлауның ние бар...).

**АКЫЛ КҮЗЕ.** Акыллы караш; берәр нәрсәгә яки кешегә дикъкать белән карау, аңа карата эчке кызыксыну уяну. <...> *хәтер яңара, уйлау сәләте арта, хисләр тирәнәя, ниндидер сүз белән әйтеп биреп булмый торган акыл күзе ачыла, йөрәк игелеккә тиенә* (З. Мурсиев. Солтанъяр). *Тик беркем дә үтә алмый / Үтә тар күңеленә. / Акыл күзең томаланган / Байлыгың, барлыгыннан* (Ә. Низамова. Тар күңелле кешегә).

**АКЫЛ КҮЗЕ БЕЛӘН КҮРҮ.** Уйлап эш итү, тәнкыйть белән карау. *Бер дә шуларны акыл күзе белән күрүче булмады микәнни?* (Ш. Маннур). *Монда маңгай күзе белән генә эш чыкмый, күбрәк акыл күзе кирәк* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**АКЫЛ КҮЗЕ ҖИТҮ.** 1. Төптән, җентекләп уйлау. – *Моның очына чыгар өчен акыл күзе генә җитә ала* (Сөйләм).

2. Алдан күрү. *Акыл күзе җитмәслек* (Һ. Такташ).

**АКЫЛ КҮЧӘРДӘН ЫЧКЫНУ.** Уйланылмаган, акылсыз булган эшләр башкару. *Вакыт-вакыт акылы күчәреннән ычкынган Габделнур үз-үзен тыялмый, гүя аның күкрәгенә эт кыяфәтендә алагаем зур шайтан оялаган һәм шул кабих котырып-котырып өрә иде* (Н. Гыйматдинова. Кәтәнә).
Төрдәше: акыл өйдә булмау.

**АКЫЛ КЫСКА<ЛЫК>.** Төптән уйлый алмау, баш эшләмәү. *[Камали] Шулай, шулай, шайтан алгырлары. Акыллары кыска бит аларның, акыл дигән хәзинәләре бик чак* (Ф. Бурнаш. Камали карт). *Зур эштә акыл бирергә оста, вак эшне аерырга акыл кыска* (Мәкаль).

**АКЫЛ МИНУТЫНДА КЫРЫК ТӨРЛЕГӘ ҮЗГӘРҮ.** Ныклы итеп, төптән уйлый алмау. *Әмма, Гафиятнең акылы минутына кырык төрлегә үзгәрсә дә, аның салпы ягына салам кыстыруы ансат түгел* (М. Хуҗин. Килен төшкәч).

**АКЫЛ ОЮ.** Акыл белән түгел, хис белән генә эш итү. *Ләкин аның акылы тәмам оеган һәм сизгерлеге тәмам сүнгән иде* (Ә. Еники. Бер генә сәгатькә).

**АКЫЛ ӨЙДӘ БУЛУ (БУЛМАУ)** *к.* акыл башта булу; акыл күчәрдән ычкыну. – *Ә мәхәббәт уңышсызлыгына очраган кыз, уйлап та тормастан, күңеленә кинәт килеп киткән беренче тойгыга бирелеп (андый чакта акыл өйдә булмый бит): «Юк, мин башта үземнең туган авылыма кайтып эшләргә телим», – дип кырт кисте* (Г. Әпсәләмов).
Төрдәше: акыл башта булу; акыл күчәрдән ычкыну һ.б.

**АКЫЛ<ГА> ӨЙРӘТҮ.** 1. *к.* акыл бирү 1. *Икенче ягымда яткан җырчы Әхмәт, күзен йомган килеш кенә, мин арада иң кечкенә малай булгангадыр инде, акыл өйрәтергә тотынды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

2. *ирон. к.* акыл сату 1. *[Назлыбикә] Миңа акыл өйрәтеп, мораль укып маташалар* (Ю. Әминов. Язылмаган законнар). *Атаңа акыл өйрәтә башладыңмыни?* (А. Алиш).
Төрдәше: акыл бирү 1, 2 һ.б.

**АКЫЛ ӨЛӘШКӘНДӘ, АБЗАР АРТЫНДА <ЙОКЛАП> КАЛУ** *мыск., ирон.* Акылсыз, фикерсез, ахмак, фәкать буй үстерүче кеше турында. *Акыл өләшкәндә, абзар артында калган* (tazbash.ru). *Күршеләре, мондый көндә чана тагарга маташуына сәерсенеп: «акыл өләшкәндә, абзар артында йоклап калган, ахрысы», – дип уйлап куйдылар* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл өләшкәндә, ак тана (ак кәҗә; пумала) астында ятып калу; акыл өләшкәндә, биләмдә (урманда) калу; акыл өләшкәндә, җыенда (идән астында; капчыгын тотып) калу; акыл өләшкәндә, йоклап калу; акыл өләшкәндә, коры калу; акыл өләшкәндә, мич башында (өй / абзар артында; мунчада) булу (калу; яту); акыл өләшкәндә, өйдә (урынында) булмаган; акыл өләшкәндә, торып калу; акыл үзенә кереп тә чыкмаган; бер тактасы ким; йөзгә бер тулмаган; күзле багана; кырыкка бер тулмаган; тугыз төймә; туксан тугыз<лы> 1; утыз тугызлы.

**АКЫЛ ӨЛӘШКӘНДӘ, АК ТАНА (АК КӘҖӘ; ПУМАЛА) АСТЫНДА ЯТЫП КАЛУ** *к.* акыл өләшкәндә, абзар артында <йоклап> калу. *Сүзеңне бүлмә, кызым. Безнең арада акыл өләшкәндә, пумала астында калган бер мескен җан иясе бар* (Г. Әпсәләмов. Газинур).
Төрдәше: акыл өләшкәндә, абзар артында <йоклап> калу һ.б.

**АКЫЛ ӨЛӘШКӘНДӘ, БИЛӘМДӘ (УРМАНДА) КАЛУ** *к.* акыл өләшкәндә, абзар артында <йоклап> калу. – *Иртән чәйләп алгач, урманга китә бит ул. Акыл өләшкәндә дә урманда калгандыр* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл өләшкәндә, абзар артында <йоклап> калу һ.б.

**АКЫЛ ӨЛӘШКӘНДӘ, ҖЫЕНДА (ИДӘН АСТЫНДА; КАПЧЫГЫН ТОТЫП) КАЛУ** *к.* акыл өләшкәндә, абзар артында <йоклап> калу. – *Аңа тагын, акыл өләшкәндә, капчыгын тотып калган бит ул!* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл өләшкәндә, абзар артында <йоклап> калу һ.б.

**АКЫЛ ӨЛӘШКӘНДӘ, ЙОКЛАП КАЛУ** *к.* акыл өләшкәндә, абзар артында <йоклап> калу. *Укучыны кимсетергә: «Бу кадәр дә акылсыз класс күргәнем юк иде!», «Аллаһ акыл өләшкәндә, син йоклап калгансың,*

*ахры!»* һ.б. («Ялкын» ж.). *Сәер нәрсә юк монда, акыл өләшкәндә, йоклап калгандыр ул* (Сөйләм).

Төрдәше: акыл өләшкәндә, абзар артында <йоклап> калу һ.б.

**АКЫЛ ӨЛӘШКӘНДӘ КОРЫ КАЛУ** *к.* акыл өләшкәндә, абзар артында <йоклап> калу. *Акыл өләшкәндә, коры калгандыр ул, башка нәрсә әйтим инде* (Сөйләм).

Төрдәше: акыл өләшкәндә, абзар артында <йоклап> калу һ.б.

**АКЫЛ ӨЛӘШКӘНДӘ, МИЧ БАШЫНДА (ӨЙ / АБЗАР АРТЫНДА; МУНЧАДА) БУЛУ (КАЛУ; ЯТУ)** *к.* акыл өләшкәндә, абзар артында <йоклап> калу. *Акыл өләшкәндә, өй артында калгансыңдыр син, башкача булмас...*(М. Хәсәнов. Язгы аҗаган).

Төрдәше: акыл өләшкәндә, абзар артында <йоклап> калу һ.б.

**АКЫЛ ӨЛӘШКӘНДӘ, ӨЙДӘ (УРЫНЫНДА) БУЛМАГАН** *к.* акыл өләшкәндә, абзар артында <йоклап> калу. *Дөрес, акыл өләшкәндә, син өйдә булмагансың, ләкин хәйләкәрлек синдә җитәрлек икән* (Т. Гыйззәт).

Төрдәше: акыл өләшкәндә, абзар артында <йоклап> калу һ.б.

**АКЫЛ ӨЛӘШҮ** *к.* акыл бирү. *Дин – әфиүн диеп сөйләшкән дә, фәйләсуфлар акыл өләшкән* (Г. Афзал).

Төрдәше: акыл бирү 1 һ.б.

**АКЫЛ ПЫЧАГЫН КАЙРАУ.** Белем алу, акылтәҗрибә туплау. *Укымак – <...> гакыл пычагын гыйлем вә мәгърифәт кайрагына чынлап кайрамак дигән сүздер* (Г. Тукай).

**АКЫЛ САВЫТЫ.** Баш мие. *Урынсыз бер сүз акыл савытының буш икәнлеген расларга мөмкин* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).

**АКЫЛ САВЫТЫ СЫЕГУ (СЫЕГАЮ)** *к.* акыл баштан китү (чыгу) 1. *– Кырык бердә ирләрнең акыл савыты сыега. Бигрәк тә ялгызларның* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

Төрдәше: аксак акыл.

**АКЫЛ САЕГУ (САЕГАЮ)** *к.* акыл баштан китү (чыгу) 1. *– Синең, әткәй, акылың саекты мәллә?* (Н. Гыйматдинова. Ачкыч). *Менә шулай акыл саегаеп китте* (Г. Мөхәммәтшин. Шикаять).

Төрдәше: аксак акыл.

**АКЫЛ САЙЛЫГЫ** 1. *к.* акыл бергә дә тулмау. *Без татар халкы куркакмы, куштанмы, акыл сайлыгы җәфалыйммы,... миңа калса, җылы урынга кереп утырган түрәләр (шул ук депутатлар да) бары үзләре турында гына кайгырта* («Матбугат.ру» порталы).

Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

2. Акылсызлык. *Сине тәнкыйтьләгән барлык кешене дә дошман дип санау – акыл сайлыгыннан килә* (Сөйләм).

Төрдәше: акыл өләшкәндә, абзар артында йоклап калу һ.б.

**АКЫЛ САКАЛДА ТҮГЕЛ – БАШТА.** Акылның яшь белән бәйле булмавына ишарә. *Әүвәлгеләр, «акыл сакалда түгел – башта» дип, белми әйтмәгәннәрдер* (Сөйләм).

**АКЫЛ САТУ.** 1. Белдекле булып, кешеләрне өйрәтү. *Кан җибәргәч, җиңел була, диеп, / Бөтен төркем миңа акыл сата* (М. Әгъләм). *Рәис аның сүзләрендә акыл сату чалымнарын шәйләп алды* (Ф. Латыйфи. Ак-карага тимәскә).

Төрдәше: акыл бирү 1 һ.б.

2. Артык күп сөйләү. *Башта бу миңа бик сәер тоела иде, борчып та куйгалый иде, ләкин тора-бара аңлагандай булдым. Салих асылда җитди мәсьәләләр турында акыл сатарга, күп сөйләргә яратмый торган кеше булса кирәк* (Ә. Еники. Гөләндәм туташ хатирәсе). *Әнә телевизордан да шулай сөйлиләр, газета-журналлар да гел шуның турында акыл сата* (Х. Ширмән. Мәхәббәтнең соңгы көне).

Төрдәше: акыл өләшү.

**АКЫЛ САТУЧЫ.** Белсә-белмәсә дә кешеләрне өйрәтергә яратучы кеше. *Ихтимал, бакыр чыкмас җирдән алтын эзләмә, шундый мәхәббәт буламыни дип акыл сатучылары да табылыр, бу ташка үлчим мәхәббәтне ташларга киңәш бирүчеләр дә, дөнья аңа терәлгәнмени, нигә бөтен күгеңне шул бер Мансур каплаган дип тирә-ягына карарга чакыручылар да табылыр* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**АКЫЛ САУ <БУЛУ>.** Акыл кимәле бозылмау. *Авыру чагым – уйда җаным, / Акыл – сау, фикер – кылыч* (Р. Гаташ).

**АКЫЛ СИДРӘҮ** *к.* аксак акыл. *Акылы сидрәгән кешеләр авылда элек тә булгалаган* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).
Төрдәше: аксак акыл һ.б.

**АКЫЛ СОРАП КҮРШЕГӘ КЕРМӘҮ (КЕРМӘЛЕ ТҮГЕЛ).** «Үз акылыбыз үзебезгә җиткән» мәгънәсендә. – *Безнең Айзат, Аллага шөкер, кайберәүләр шикелле акыл сорап күршегә кермәле түгел* (Г. Мөхәммәтшин. Йөрәктәге эзләр).

**АКЫЛ СҮЗДӘН АЛДА ЙӨРҮ.** Һәрвакыт, һәр нәрсәне уйлап сөйләү. *Акылы сүздән алда йөри булса кирәк* (Ә. Еники. Рәшә).

**АКЫЛ СҮНҮ.** Уйлый алмас хәлгә килү. *Шушы минутларда ни уйлавымны, нәрсә теләвемне һич белмим, хәтерләмим – акылым тәмам сүнгән иде* (Ә. Еники. Без дә солдатлар идек).
Төрдәше: баш мие сыегаю (шулпалану); баш миен сыек хәлдә күз алдына китерү; баш миенә тондыру.

**АКЫЛ СЫЕКЛАНУ.** 1. *ирон., к.* акыл баштан китү (чыгу) 1. *Карчыклар баш чайкый, Ада түтинең акылы сыеклнган ләбаса* (Хал. әкияте).
Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.
2. Уйлау сәләте начарлану. – *Мин картайдым, сакалым билемә җитте, акылым сыекланды* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).
Төрдәше: аксак акыл һ.б.

**АКЫЛ СЫЙДЫРА АЛМАУ (СЫЙДЫРМАУ).** Ышанып булмастай эш яки сүз турында. *Юк, аның бөтен җаны-тәне моңа каршы тора, болай үлүне аның акылы сыйдыра алмый иде* (Г. Бәширов). *Акыл сыйдырмый, күңел кабул итми моны... безнең кеше эше түгел бу* (Ә. Еники. Рәхмәт, иптәшләр).
Төрдәше: акылга сыймас<лык>; акылга сыймастай; акылга сыймау (сыймый торган); аң сыйдырмау; аңга сыймаслык; акылдан тыш фикер; баш сыйдыра алмау.

**АКЫЛ ТАБУ.** Четерекле хәлне хәл итү чарасын табу. *Мин озак уйладым инде бу четерекле хәлдән чыгу юлларын: һич акыл табып булмады* (Сөйләм).

**АКЫЛ ТАҖЫ.** – Акыл-белем бирә торган мәркәз, кылган гамәлнең иң акыллысы һ.б. *Сезнең акыл таҗы бүген ил язмышы белән бәйле* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

**АКЫЛ ТАР <БУЛУ>** Белем җитмәү, акыл җитеп бетмәү. *Тормыйм инде, бу дөньядан туйдым инде, / Моңарчы да торганмын мин гакыл тарга.* (Г. Тукай). *Куар дөнья акыл тарга* (Г. Кандалый).
Төрдәше: акыл җитмәгәнлек һ.б.

**АКЫЛ ТАРАЛУ.** Ничек аңларга, ни дип уйларга да белмәү. *Аның да, синең кебек, акылы таралган иде, ахрысы, апа* (Н. Гыйматдинова. Үзем генә беләм...). *Керсәләр, исләре китте, акыллары таралды, ди; камыр сыны, малай булып, кәҗә бәтиләре белән уйнап йөри икән* («Камыр батыр» әкияте).

**АКЫЛ ТАРАУ.** Мөстәкыйль фикер йөртә алмау хәленә җиткерү, үз ихтыярына буйсындыру. *Ә атаман дигәннәре тирә-яктагыларның акылын тараган «тимер тарак» икән* (Н. Гыйматдинова. Синдә минем хакым бар).

**АКЫЛ ТАРТМАСЫНДАГЫ ШӨРЕП ТӨШҮ (ТӨШЕП КАЛУ)** 1. *к.* акыл <-га; -дан> җиңеләю 1, 2. *Билгеле инде, бу хәсрәтләреңне кешегә ача калсаң, ике бармагы белән генә маңгай чигенә чиртеп, көлемсерәп куячак: ни түгелме, янәсе, акыл тартмаңдагы берәр шөребең төшеп калмаганмы?* (Ш. Маннур. Чын сөю бармы?).
Төрдәше: акыл <-га; -дан> җиңеләю 1, 2 һ.б.
2. Һаман да аңламаган, гыйбрәт алмаган. *Ничә мәртәбә аңлаттым үзенә, авызына чәйнәп салган кебек булган идем – ташка үлчим, акыл тартмасындагы шөребе төшеп калган булган, күрәсең* (Сөйләм).

**АКЫЛ ТӘПӘНЕ САЕГУ** *к.* акыл бергә дә тулмау. – *Менә син, ә, баш җитмәде караватны борырга. Акыл тәпәне саеккан, хәйран саеккан...* (М. Хуҗин. Игелек).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛ ТӘПӘНЕ ТУЛЫ БУЛМАУ** *к.* акыл бергә дә тулмау. – *Ай-һай, акыл тәпәнем тулы түгел, дип ялгышасың син* (М. Хуҗин. Осталар).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛ ТЕШЕ.** 1. Егерме яшьләрдә чыга торган иң кырый азау теше. *Сорадым мин әниемнән: – Акыл теше кемгә чыга?* (Ш. Галиев. Акыл теше кемгә чыга?).

2. *күчм.* Мантыйксыз яки уйланылмаган эшләр эшләгән кешенең акыл теше чымавы турында. *Уйлыйм куркып: юкмы әллә акыл тешебез* (Р. Гаташ). *Кайвакыт акыл теше үтмәгәнне чибәрлек җиңә* (М. Әмирханов. Гәүһәршад).

**АКЫЛ ТЕШЕ ЧЫГУ.** 1. Үсү, балигъ булу. – *Балалар кебек кыланма, сиңа акыл теше чыккан инде. – Әтисенең үпкәләве сизелә иде* (Сөйләм).

2. Тормышның ачысын-төчесен тату, эштә сыналу; тәҗрибә туплау. *Галимнәр, сез бомба ясаганда, / Әниләр бит безне тудырган. / Безгә күптән инде акыл теше чыкты*... (Р. Вәлиев. Мин яшьтәше атом бомбасының...).

**АКЫЛ ТОМАЛАНУ.** Аңламый, зиһен эшләми башлау. *Егетнең бу сораулардан башы кабарды, акылы томаланды* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр).

Төрдәше: акыл <-га; -дан> җиңеләю 1, 2 һ.б.

**АКЫЛ ТУБАЛЫ.** 1. Гыйлем-белемне тәртипсез рәвештә башына туплаган кеше. *Акыл тубалы – аяклы энциклопедия, белем капчыгы, beләмән* (А. Тимергалин. «Милләт» энциклопедиясе). – *Бездә акыл тубалы бер кеше бар, ләкин аның сөйләгәннәрен соңыннан иләк аша үткәрергә кирәк булачак* (Сөйләм).

2. *мыск.* Акыл бирергә яратучы кеше. *Теге акыл тубалы бик озак акыл сатты үзеңә* (Сөйләм).

Төрдәше: акыл бирү 1; акыл өйрәтү; акыл өләшү; акыл сату 1; акылга өйрәтү; акылга утырту; үгет-нәсыйхәт бирү.

**АКЫЛ ТУПЛАУ** *к.* акыл җыю 2. *Калган ягын тормыш үзе биргән / Кеше эшләп акыл туплаган* (И. Гыйләҗев. Бик мөмкин хәл).

Төрдәше: акыл җыю 2 һ.б.

**АКЫЛ ТУПСАСЫНА УТЫРМАГАН** *ирон.* Малайчарак җиңел акыллы, карашы ныгып җитмәгән. – *Аңа бер тупса табып бирергә кирәк, акыл тупсасына утырмаган әле ул* (Сөйләм).

**АКЫЛ УТЫРТУ** *к.* акыл җитү. *Утызга җитеп килә торган, акыл утырткан, төчесенә караганда, тормышның ачысын мулрак эләктергән егет, башкалар чуар күңелле җилбәзәк дип санаган, куркыныч матурлыкка ия булган шушы кыз белән ничек таныша, дуслаша алды икән?* (А. Гыйләҗев. Өч тәгәрмәчле арба). *Зирәкләндең, акыл утырттыңмы, / Нинди уйлар белән яшисең?* (Р. Гарифуллина. Яшьлек белән сөйләшү).

Төрдәше: акыл җитү һ.б.

**АКЫЛ<ГА> УТЫРУ.** 1. *к.* акыл керү. *Кинәт Гөлшәһидә кырт борылды да больница юлына төшеп китте. Җитте инде, акылга утырырга вакыт!* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). – *Баш эшләмәде шул, акыл утырмаган иде* (М. Хуҗин. Ага да ага сулар).

Төрдәше: акыл җитү һ.б.

2. Әти-әнисе сүзен тыңлау. *Гайшә акылга утырмады* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар). *Менә балалар исәйсен, ныгысын, акылга утырсын*... (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

3. Сабак алу. – *Инде моның белән дә акылга утырмасаң, эт урынына өеннән куып чыгарачак*... (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Мин «калошка утырмыйча гына» / Утырмакчы идем акылга* (Х. Туфан. Иске көнгә, нәләт төшерергә).

Төрдәше: фикер туплау; баш белән уйлау; башка килү.

4. Акыл кереп, тәмам өлгереп җитү. *Ул аңа буе-сыны белән өлгереп җиткән, акылга утырган, холкы күркәм булып камилләшкән чын ирегет булып күренде* (Ә. Еники. Бер генә сәгатькә).

Төрдәше: акыл җитү һ.б.

**АКЫЛ ҮЗЕНӘ КЕРЕП ТӘ ЧЫКМАГАН** *к.* акыл өләшкәндә, абзар артында <йоклап> калган. – *Авыз ачма әле шуның турында, аның үзенә акыл кереп тә чыкмаган* (Сөйләм).

Төрдәше: акыл өләшкәндә, абзар артында <йоклап> калу һ.б.

**АКЫЛ ҮЛЧӘШҮ.** Сүз көрәштерү, бәхәсләшү. – *Акылларны үлчәшеп, вакытны уздырмыйк, туганнар!* (Г. Бәширов).

**АКЫЛ ҮСҮ.** Тәҗрибә арту, акыл туплану; *шулай ук к.*: акыл җитү. *Акыллы белән алышсаң – акылың үсәр, ахмак белән булышсаң – дәрәҗәң төшәр* (Ш. Галиев. Илһамым-мәхәббәтем).

Төрдәше: акыл җитү һ.б.

**АКЫЛ ҮТКЕН <БУЛУ>.** Зирәк, тапкыр кеше хакында. *Акылы үткен теленнән билгеле* (Мәкаль). *Фәһме үткен – зиһене, акылы үткен* (Г. Тукай).

**АКЫЛ ҮТКЕНЛӘҮ (ҮТКЕРЛӘҮ).** Аң үсү, аңлы кешегә әйләнү. *Батырлык һәм көрәш аркылы, / Шунда чыныктырдык без йөрәкне, / Шунда үткенләдек акылны* (М. Җәлил).
Төрдәше: акыл җитү һ.б.

**АКЫЛ ФӘЛСӘФӘСЕ.** Тормышны, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне акыл белән уйлап аңлату. *Мин үземнең бернәрсә дә белмәүне, минем һәр сүзем коры «акыл фәлсәфәсе» генә идекен бүген, Каһиров белән сөйләшкәннән соң, ачык белдем* (Г. Ибраһимов).

**АКЫЛ ЧАЛ<Ы>ШАЙТУ.** Уйлану. *Шулай бик озак баш ватып, фикер җимереп акыл чалышайтып утырганнан соң, Дафар: – Эврика-а! Таптым! – дип кычкырды һәм туп-туры капитан янына килде* (Р. Батулла. Җинаять).
Төрдәше: акыл аша уздыру һ.б.

**АКЫЛ ЧАМАЛЫ <БУЛУ>** *к.* акыл бергә дә тулмау. *Дөрес, Туктамышның да, Мамайның да акыл бик чамалы* (В. Имамов. Карабәк). *Акылым чамалы булса, шундый урынга куймаслар иде, куйсалар да, озак тотмаслар иде* («Безнең мирас» ж.).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛ ЧАНАСЫНА УТЫРУ.** Һәрнәрсәне акыл белән уйлап хәл итү. *Инде Галимҗанга килсәк, ул да, акрынлап, акыл чанасына ныклап утырды бугай* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).

**АКЫЛ ЧӘЧЕЛҮ.** Төрлечә уйлап карау аркасында ныклы фикергә килә алмау. *Җәббар фатирына ашыкты. Хатын: «Акылым чәчелде, ахры», – дип, баскыч култыксасына сөялде* (Н. Гыйматдинова. Кыргый).

**АКЫЛ ЧӘЧЛӘРЕ БАШНЫ ТАШЛАУ** *ирон.* 1. Картаеп чәч коелу. – *Бераздан мин сине куып җитәм, акыл чәчләрем башымны ташлады инде* (Сөйләм). *Акыл чәчләре башын ташлаган* (Ай колакланса, ни була?).

2. Акылсызлана башлау. – *Атасы-анасы булмаган сүзләрне ычкындыра башлады теге, әллә инде акыл чәчләре башын ташлый башлаганмы югыйсә* (Сөйләм).

**АКЫЛ ЧӘЧҮ** 1. *к.* акыл бирү 1. *Шундый тын, дөньяның зыңлаган тавышы ишетелә, дөнья сабырлык, акыл чәчә, кызыл шар инде күмелеп бара, җир әйләнә, ә мин шушы мәһабәт тынлык уртасында, торналар төшкән җирдә берүзем басып торам* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә). – *Син йорт тоткасы, акыл чәчеп йөрмә алай* (Н. Гыйматдинова. Күке төкереге).
Төрдәше: акыл бирү 1 һ.б.

**АКЫЛ ЧИШМӘСЕ.** Фикерләү сәләте югары дәрәҗәдә булган, зиһенле, акыллы кеше хакында. *Болар аклану түгел, хакыйкатьнең үзе, вакыйгаларның бәяныннан хак сүзләр иделәр, Җантимернең акыл чишмәсе саекканмы, әллә инде аклана да белмиме?* (Ф. Яхин. Илаһи канун). <…> *киңәш өйрәнергә Халид агайга килерләр иде. Гүя аны бер акыл чишмәсе дип саныйлар иде* (С. Максуди. Мәгыйшәт).
Төрдәше: гакыл чишмәсе.

2. Китапның акыл чыганагы икәнлеген ассызыклау. *Чөнки, китап ул – белем һәм акыл чишмәсе!* (Ш. Фәрхетдин. Шифалы су).

**АКЫЛ ЧУАЛТУ.** Фикерне саташтыру. *«Йә анаң, йә мин», – дип акылын чуалтты бит, аңнымиңне ясады, шул хәлдә авылдан чынып китте Хәлим* (Р. Зәйдулла. Кызыл сыер). – *А, чуалтмагыз минем акылны!* (Ф. Бурнаш).

**АКЫЛ ЧУАЛУ** *к.* аксак акыл. *[Шәрифҗан] Хуш, хуш, тәмам акыл чуалды* (К. Тинчурин. Сакла, шартламасын).
Төрдәше: аксак акыл һ.б.

**АКЫЛ ЧЫГУ** *к.* акыл баштан китү (чыгу) 1. *Ага су. Әйләнә чарык. / Тегермән тарта тора. / Бабай акылы чыга тора, / оныкның – арта тора* (Р. Фәйзуллин).
Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.

**АКЫЛ ЧЫЛБЫРЫННАН ЫЧКЫНУ.** Акылсызлану, акылсыз хәрәкәтләр ясый башлау. *Йә, кем акыл чылбырыннан ычкына?* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: акыл <-га; -дан> җиңеләю 1, 2 һ.б.

**АКЫЛ ШАШЫП КАЛУ** *к.* акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б. *Йолдызларны айкап йөрим кичтә, / Күндезләрен очам болынга / Һәм мәңгелек сөю кочагында / Акыл шашып кала тагын да* (Ф. Яхин).
Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.

**АКЫЛ ШӨРЕБЕ КОЕЛУ.** Уйлау, фикер йөртү сәләте начарлану, тиле-милеләнү. – *Әнкәй, – диде Фәйрүзә, чәчрәп торып. – Синең улыңның акыл шөрепләре коелган* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: аксак акыл һ.б.

**АКЫЛ ШӨРЕБЕ ЮГАЛУ** *к.* акыл баштан китү (чыгу) 1. – *Акыл шөребең югалдымы әллә, миңа мелт-мелт карап торасың?* (Сөйләм).
Төрдәше: аксак акыл һ.б.

**АКЫЛ ШӨРЕПЛӘРЕН ТЫГЫЗЛАУ** *к.* акыл җыю 2. *Барчасы, чарасыз калып, акыл шөрепләрен ни-нәрсә белән дә тыгызлап өлгерергә җай тапмаганнар* (Ф. Яхин. Бер авыл бар, Чокал, диләр).
Төрдәше: акыл җыю 2 һ.б.

**АКЫЛ ЮЛ БИРМӘҮ.** Аң-акыл үсеш дәрәҗәсе, алган тәрбиясе нәрсәнедер эшләргә ирек бирмәү. *Әмма кеше баласына тияргә акылы гына юл бирмәгән* (Ф. Яхин. Маҗаралы Гыйльметдин).

**АКЫЛ ЯГЫ САЙ** *к.* акыл бергә дә тулмау. *Берсеннән-берсе көлкеле , кайчак, акыл ягы сай булган кешеләрдән генә чыгуы мөмкин булган тәкъдим-закон проектлары инициативалары белән чыгучы депутатларыбыз юкмы?* («Мәдәни җомга» газ.).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛ ЯГЫ ТАКЫР** *к.* акыл бергә дә тулмау. *Вакытында халкының яратуыннан, казанган абруеннан көнләшеп, авылның акыл ягы такыр, эче тулы мәкер булган Куяновлар нәслен өскетеп, болай да болганчык заманның очсыз-кырыйсыз җылашларында теләсә нәрсә сөйләттереп, Абдуллинны да ул эшеннән төшерткән иде инде* (Г. Мирһади. Ике яшәр Газнәви).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛ ЯКТЫСЫ.** Акыллылык, төптән уйлап эшләү. *Шуның өстенә тагын бу йөздә кешене үзенә җәлеп итә торган ниндидер акыл яктысы чагыла кебек иде* (М. Әмир).

**АКЫЛ ЯКТЫРУ.** Фикер йөртү сәләте ачылу. *Аның хәтта тәне, һавада йөзгәндәй, җиңеләеп калды, акылы, ничектер, бердән яктырып китте, сизгерлеге искиткеч үткенләште* (Ә. Еники. Кем җырлады?).

**АКЫЛ ЯЛГЫШУ.** Хаталану, дөрес уйламау. *Ләкин сугышның һәр авылдагы ачлыкның иң авыр бер вакытында – 1943 елның җәендә – Әсма карчыкның акылы ялгышу халыкны сискәндереп куйды* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).

**АКЫЛ ЯНЧЫГЫН ТӨБЕНӘ КАДӘР СЕЛКҮ.** Фикерне тулысынча, ахырына кадәр белү. *Шулай да нидер уйлагач, кулын селтәп, яңадан утырды: – Әйдә, селек акыл янчыгыңны төбенә кадәр* (Г. Бәширов. Җидегән чишмә).

*АКЫЛ-ӘМӘЛ* ❖ **АКЫЛ-ӘМӘЛ ИТҮ.** Бер эшне (мәсьәләне) хәл итү өчен, чаралар, хәйләләр эзләү, уйлашу. – *Монда акыл-әмәл итеп алырга кирәк, бар, Түбән оч Гаптерине чакыр* (Сөйләм).

*АКЫЛГА* ❖ **АКЫЛГА АВЫЗЛЫК САЛУ.** Акылсыз, уйланмаган эшләр эшләргә мәҗбүр итү. *Арык тәннән умырып ал мине юкса, йә акылыңа салам,– диде, – авызлыкны* (Р. Рахман).

**АКЫЛГА ӘЙЛЕ-ШӘЙЛЕ <БУЛУ>** *к.* акыл бергә дә тулмау. – *Аңа бик өметләнмә, акылга әйле-шәйлерәк ул* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛГА БЕРТӨРЛЕ** *к.* акыл бергә дә тулмау. – *Нәрсә тыңлап торасың аны, акылга бертөрле бит ул* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛГА БЕТКӘН** *к.* авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә алу) һ.б. – *Крестьян – гомергә кара акылга беткән нәрсә, аны тиз генә борып булмый* (Х. Камалов. Безне өйдә көтәләр).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә алу) һ.б.

**АКЫЛГА БУЙСЫНДЫРУ.** Ныклап уйлау. *Ул үзенең тәнендәге бөтен әгъзаларын акылга буйсындыра килде* (Ф. Яруллин. Кыйбласызлар).
Төрдәше: акылы башында; акылы җирендә <булу>; акылы камил; акылы сау; акылы тулы; акылы түгәрәк.

**АКЫЛГА БЫЛЧЫРАК (ПЫЧРАК) БАУ САЛУ.** Бутау, саташтыру. *Болай да баш авыртып тора, син дә акылга былчырак бау салып утырасың* (Сөйләм).
Төрдәше: баш әйләндерү 2; баш<ны> бутау.

**АКЫЛГА ҖИҢЕЛ.** 1. Акылга зәгыйфьрәк, тилемиле. *Әйе, ул акылга җиңелрәк бер бәндә иде, көл төсле йончу йөзендә саран гына сирпелгән елмаюы да, ничектер, гадәти кешеләргә хас булмыйча, үтә дә моңсу һәм газаплы иде шул аның* (Н. Гамбәр. Ма-ту-у-у!!!).
Төрдәше: акыл җитмәгәнлек һ.б.

2. Өстән генә уйлаучы. *Ул идарә хезмәткәре җир кишәрлегенә бер күз генә атып, «Аңлашылды, әйдә, киттек, башкаларын офиста сөйләшеп бетерербез» дигәч, үлчәпнитеп тә тормады, әллә акылга җиңелрәк адәм микән соң, дип шөбһәләнеп тә куйды* (Сөйләм).

**АКЫЛГА ҖИҢЕЛӘЮ**. Элек акыллы булып та, хәзер иләс-миләсләнү, юләрләнү. *Хәер, бик үк акылга җиңеләйгән дип әйтеп булмый* (М. Хәбибуллин. Илчегә үлем юк). *Бер айдан соң торды, ләкин торганда инде элекке Коркул түгел иде, мескен. Акылга җиңеләеп калды* (Н. Фәттах. Аклан).
Төрдәше: аксак акыл һ.б.

**АКЫЛГА ЗАРАР (ЗӘГЫЙФЬЛЕК; ЗЫЯН) КИЛҮ.** Ми зарарлану, акылдан язу. *Доктор әфәнде, алайса, сез Сираҗетдин әфәнднең акылына зарар килү хак дисез?* (Г. Камал. Банкрот). *Хәтимә, иренең акылына зыян килгән дип уйлап, бүтән гапләшмәскә булды* (З. Мәхмүди. Ахырзаман шаукымы).
Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.

**АКЫЛГА ЗӘГЫЙФЬ** *к.* акыл бергә дә тулмау. *[Зариф] Соң акылга зәгыйфь булмасаң, урман хәтле урманга килеп йөрер идеңмени* (З. Хәким. Телсез күке). *Акылга да зәгыйфь бала түгел, вакыт узгач кына уйлап ала* (К. Сибгатуллин. Күз тимәсен).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛГА КИЛМӘГӘН.** 1. Һич башка килмәгән, гаҗәеп бер эш яки фикер. *Бөтен тирә-якта дан тоткан Күк бияне узып китү Алмачуар өчен һичкемнең акылына килмәгән бер бәхет иде* (Г. Ибраһимов. Алмачуар).

2. Һич аңламаган, сабак алмаган. *15 тәүлек рәшәткә артында утырып та акылга килмәгән, кабат-кабат исерек килеш тотылып, шул җәзаны «рәхәтләнеп» үтәүчеләр бар икән* («Безнең гәҗит» газ.).

**АКЫЛГА КИЛҮ (КАЙТУ).** 1. Кемнең булса да аңына барып җитү; кемнең булса да аңында барлыкка килү. *Акылына килмәсә, яхшы эшме, начар эшме – тикшереп тормый, киреләнә* (Г. Толымбай. Яз көне). *[Бәдри] Акылга килдеңме? Мең сум диләр аны* (М. Фәйзи. Галиябану).
Төрдәше: акыл башка килү.

2. Акыл хасталыгыннан соң сәламәтләнү. *– Акылыма килгәч, шулай дип сөйләделәр, юкса үзем барын да хәтерләмим* (К. Тинчурин. Дачалар мөбарәк булсын!). *Телсез гашыйк Хәйдәр тәки акылына килә алмады* (Р. Фәизов).

3. Тәртибе яхшыру, үз-үзен кулга алу. *Бераз дөнья күрсен, кешеләр белән аралашсын, бәлки, акылына килер* (Сөйләм). *– Акылыңа кил, кан үчеңне учларыңа биклә* (В. Имамов. Карабәк).

4. Уйлабрак эш итә башлау; нәтиҗә ясау. *Инде Хисамый Әсмасы да акылына килер, Галиябануны көнләп үлеп бара иде* (М. Фәйзи. Галиябану). *Святослав һаман акылга килмәде, коры сөяккә калган кардәшләрен һаман алга куды* (В. Имамов. Казан дастаны).
Төрдәше: акыл җитү һ.б.

5. Нәрсә турында булса да фикер туплап, аны хәл итәргә тырышу. *Ни булса да акылына килер, атасы янына кайтмый калмас* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).
Төрдәше: акыл<га> утыру һ.б.

**АКЫЛГА КИМЧЕЛЕК КИЛҮ** *к.* аксак акыл. 1. *Четерекле мәсьәләләрдән читләшергә теләптерме, Вәлитов тынып калды. Ул акылына кимчелек килгән кешегә охшый иде* (М. Насыйбуллин. Телсез шаһит).
Төрдәше: аксак акыл һ.б.

**АКЫЛГА КИТЕРҮ.** 1. Акылын җуеп авырганнан соң савыктыру. *– Әнкәне бастыр, – диде. – Көйлә-чөйлә, акылына китер* (Н. Гыйматдинова). *Баламны акылына китерче, дип, көн дә Аллаһымнан ярдәм сорыйм, кызганам үзен, – диде ул, яшь аралаш уфтанып* («Безнең гәҗит» газ.).

2. Ялгышларын аңлатып, дөрес юлга чыгару. *– Йөрәгеңдә җылы юк икән, тол хатыннар сөеп кенә дәва таба алмассың, – дип, аны акылга китерергә омтылып карады* (В. Имамов. Нәзер). *Әхмәтсафа, сабырлыгын җуймаска тырышып, бу чик-чаманы белмәүче бәндәне акылга китерергә азапланган арада, Сәгыйтов өстәлдә яткан мәкаләсен шатыр-*

*датып тартып алды да каты басып чыгып китте* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).

**АКЫЛГА КӨЧ КИЛҮ (КИТЕРҮ)** *к.* аксак акыл. *Бу турыда уйланырга әле сиңа да иртәрәк, балам, балигъ булмаган акылыңа көч килер* (Т. Мөбарәков, Хәтер аланы).
Төрдәше: аксак акыл һ.б.

**АКЫЛГА МУАФЫЙК.** Төпле, уйлап эшләнгән. *Бу тойгыны акылга муафыйк итеп аңлата алмыйм...* (А. Тимергалин. Игезәкләр). *Туган телнең кануннарга таянып кына бәгъзе шартларда яклануына өмет багълауны һич тә акылга муафыйк талпыныш дип булмый* (Р. Зарипов. Кояшка каршы һөҗүм).
Төрдәше: адәм акыллы; акылга ятышлы.

**АКЫЛГА ӨЙРӘТҮ.** 1. Үскән чагында әти-әнисенең өйрәтүен яратмаган үсмерне тормышның бәргәләп-суккалап «акылга өйрәтүе» хакында. *Шуның артыннан ук яңа бер дәлил китереп, кызны бераз акылга өйрәтергә теләде* (Ф. Хөсни. Чишмә).

2. *к.* акыл бирү 1. *Апасыннан ким дигәндә егерме биш яшькә кечерәк булса да, ул үзен олысымак тота һәм баланы өйрәткәндәй, Мәһимәне акылга өйрәтә иде* (М. Маликова. Ак давылда тал бөресе).
Төрдәше: акыл бирү 1 һ.б.

3. *к.* авыз җебетү 2. *Тибенә, таптана башласа, таягы белән акылга өйрәтә. Теге миңа бәйләнеп йөдәткән Тәкә Әнәсне шушы егет акылга өйрәтте инде менә* (В. Нуруллин. Әгәр син булмасаң...).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АКЫЛГА САЙ**. 1. Бигүк акыллы түгел, аңлата алмаслык нәрсәләр эшли торган; *шулай ук к.* акыл бергә тулмау. *Иҗат кешеләренә карата әйтелгән «Хискә бай – акылга сай» дигән әйтем миңа да кагыла дип уйлыйм* (Р. Вәлиев. Җанга уелган уйлар).

2. Тилемсә, фикерли алмый торган, белемсез. *Кеше үз хыялында тудырган андый тылсымлы затларны берникадәр акылга сайрак, «утыз тугызрак», мәнсезрәк итеп иҗат кыла* (Г. Бәширов). *Акылга сай бөкре каенсеңел аралап алып келәткә өстерәп кергәндә, ул һуштан язган иде* (Н. Гыйматдинова. Кыргый).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛГА САЙЛЫК** *к.* акыл сайлыгы. *Акылга сайлык, булсын ярар* («Матбугат.ру» порталы).
Төрдәше: акыл сайлыгы һ.б.

**АКЫЛГА САЛУ (САЛЫП КАРАУ).** Төрле яклап, ныклап уйлап карау. *Әмма акылга салсаң, һәммәсендә дә ул бер «оправдание» таба, ләкин эчендә бер елан һаман да чагуында дәвам итә иде* (Г. Газиз. Олуг ләгънәт).
Төрдәше: акыл аша уздыру һ.б.

**АКЫЛГА СЫЙМАС<ЛЫК> (СЫЙМАГАН).** 1. Кеше ышанмаслык, кеше акылы кабул итә алмаслык сәер эш. *Ә мондый акылга сыймас нәрсәләрнең чынбарлык икәнен аңлаудан үзеңне кечкенә һәм көчсез итеп тоясың* (М. Кәбиров. Бердәнбер һәм кабатланмас). *<...> ут һәм тимер өермәсенең кемнең дә булса җитәкчелек итүе, бу коточкыч давылның кемнеңдер ихтыярына буйсынуы акылга сыймаслык бернәрсә кебек тоела* (Г. Әпсәләмов. Газинур).
Төрдәше: акылга сыймастай; акылга сыймау (сыймый торган); акылдан язар дәрәҗәдә (язып).

2. Аңлашылмый торган, аңлатуы мөмкин булмас кебек. *Нинди акылга сыймас нәрсә бу – үлем!..* (Ә. Еники. Гөләндәм туташ хатирәсе). *«Франция җитәкчеләре, аның хөкүмәте дөнья җәмәгатьчелеге алдында акылга сыймаслык ахмаклык эшли!»* (А. Хәсәнов. Данәгөл).

3. Гаҗәп, искитәрлек. *Акылга сыймаслык нәрсә: аның былбыл булып сайравына ышаналар бит!* (Ә. Мушинский. Һаваларда – ак күгәрчен). *Моңа кадәр аның акылга сыймаган гыйбрәтләрен ишетсәм дә, үткәреп җибәргән идем* («Ватаным Татарстан» газ.).

**АКЫЛГА СЫЙМАСТАЙ** *к.* акылга сыймас<лык> (сыймаган) 1, 2, 3. *Акылга сыймастай мондый хыялый уйга мин кайчан һәм ничек килдем соң?* (А. Тимергалин. Юл чаты). *Каласын һәм бикәсен уч төбендә диярлек Сүбәдәйгә тоттырды ләбаса! Акылга сыймастай хата кылды* (М. Хәбибуллин. Хан оныгы Хансөяр).
Төрдәше: акылга сыймас<лык> (сыймаган); акылга сыймау (сыймый торган); акылдан язар дәрәҗәдә (язып).

**АКЫЛГА СЫЙМАУ (СЫЙМЫЙ ТОРГАН).** 1. Мөмкин булмаслык нәрсә; *шулай ук к.* акылга сыймас<лык> (сыймаган). *Чыннан да, кыз, алган тәкъдирдә дә, нишләп инде сәгатьне чемоданына салып куйсын ди! Урлатылыр өченме?*

*Акылга сыймый!* (Ә. Еники. Кыз һәм сәгать). *Бер гайбәткә ышанып кына ташламас иде, өйләнүе дә акылга сыймый* (Н. Гыйматдинова).

Төрдәше: акылга сыймас<лык> (сыймаган); акылга сыймастай.

2. Аңламау. *Бусы Исламнарның акылына сыймады, ул өнсез калды, аны очкылык тотты, ямьсез очкылык тавышына кунакчаның иң биегенә менеп йокымсыраган әтәч җиргә егылып төште* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Бу минем башыма да, акылыма да сыймый, мин чиксезлекне күз алдыма китерә алмыйм, ул мине куркыта* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы).

3. Ышандырмау. *Боларны укыганда, башлар әйләнә, бу хәтле мәгълүмат акылга сыймый, хәтта ышанып та бетеп булмый* (Ф. Бәйрәмова. Нух пәйгамбәр көймәсе). *Өйләнүе дә акылга сыймый* (Н. Гыйматдинова. Күке төкереге).

**АКЫЛГА ТАМАН<ЧА>** *ирон.* 1. *к*: акыл бергә дә тулмау. *Олы гәүдәле сабый кебек акылга таман бу кешене без үртәргә ярата идек* (М. Гали. Догалы еллар). *Акылга таман саналучы бу кеше сугышларда катнаша, берничә тапкыр өйләнә* (М. Хуҗин. Саннардагы чагылыш).

Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

2. Акылсыз, дивана. *Чөнки: «Дүсем – буйга үсем, акылга – таман!» – диләр шул* (Ф. Яхин. «Өфет мае»). *[Кара Шәүлә] Ниләр бар икән дип кызыксынып йөрүчеләр. Кайбер оешмаларның шымчылары һәм акылга таман – шизофрениклар* (Р. Батулла. Җимерелгән бәхет).

Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛГА ТУЙМАУ (ТУЙМЫЙ КАЛУ).** Акыл ягыннан җитлекмәгән. *Яше алтмышка җитеп тә акылга туймады* (М. Маликова. Тылсым). *[Хәдичә] Ничек булсын инде, гомер буе акылга туймады* (Г. Ахунов. Утлар яна учакта).

Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛГА ТУЛЫ.** Акыллы, фикерләү дәрәҗәсе югары. *Субайда акылга тулы кеше юк бит анда* (З. Хәким. Телсез күке). *Чөнки шактый озын саташулы бәян акылга тулы кеше уйлап чыгара алырлык түгел дигән ышаныч туа* («Безнең гәҗит» газ.).

Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) әләктерү (әләктереп / элеп кенә) алу) һ.б.

**АКЫЛГА ТУЛЫ БУЛМАГАН (ТҮГЕЛ)** *к.* акыл бергә дә тулмау. *Йөзен күрмәсәм дә, төшенеп алам – акылга тулы түгел бит бу* (Ш. Галиев. Илһамым-мәхәббәтем). *Акылга тулы булмаган нәрсә кебек сәер генә атлап, авылыннан китеп бара* (К. Җәмит. Килмешәк).

Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛГА ТУЯР-ТУЙМАС** *к.* аксак акыл. *Акыллы дип танылган бер кеше акылга туяр-туймасрак бер хатынга өйләнгән* (Мәзәктән).

Төрдәше: аксак акыл һ.б.

**АКЫЛГА ТҮГӘРӘК ТҮГЕЛ** *к.* акыл бергә дә тулмау. *Безнең авылда бер абый бар иде. Дивана дип әйтимме? Кыскасы, акылга түгәрәк түгел* (И. Гази).

Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛГА УТЫРГАН** *к.* авыздан чыгуга (чыкканчы) әләктереп (элеп кенә) алу. *Ул аңа буе-сыны белән өлгереп җиткән, акылга утырган, холкы күркәм булып камилләшкән чын ир-егет булып күренде* (Ә. Еники. Бер генә сәгатькә).

Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) әләктереп (элеп кенә) алу һ.б.

**АКЫЛГА УТЫРМАГАН.** 1. Яшь, тәҗрибәсез. *«Бу Алмаченко һаман акылга утырмаган», – дип уйлап куйды ул тагын* (А. Хәлим. Бөркетле баганалар).

Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

2. Яшьлек җүләрлегеннән айнымаган, малайлыктан чыкмаган, тасвир ителгән. *Акылга утырмаган җилбәзәк кыз Кадрия, маена чыдый алмыйча дигәндәй, өйдән качып китә, якындагы зур шәһәрдән берсенә барып, тиз генә эшкә урнашмакчы, үзенчә яшәмәкче, үзе теләгәнчә тормыш кормакчы була* (Ф. Хөсни. Кайда сез, олы язмышлар?).

3. Җитәкчеләр сүзеннән читкә китеп, үз акылы, уй-фикере белән мөстәкыйльрәк яшәргә тырышучылар хакында. *Университетта гомумән хөр фикер йөртү әэзәрлекләнә, әйтеп-әйтеп тә акылга утырмаган галимнәр эштән куыла* (Т. Әйди. Дунай буендагы кардәшләр).

4. Акыл кермәгән, сабак алмаган кеше. *Әмма бу кеше акылга утырмаган, ноябрь аенда аны полиция хезмәткәрләре тагын рульдә исерек килеш тоткарлаган* («Яшел Үзән» газ.).

**АКЫЛГА УТЫРТУ.** 1. Кешене төпле бер уйга китерү, тормыш-тәҗрибәгә өйрәтү. *Бай, кызына карап, көлеп куйды: – Азымбайны акылга утырткан ул кәкре агач кыйммәткә төште* <...>. (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *Минем пәһлеваным Клупай бу башсыз егетне тиз акылга утыртыр* (М. Җәлил).
Төрдәше: акыл бирү 1 һ.б.

2. Гыйбрәт булырлык сүзләр, үрнәкләр ярдәмендә кешегә тормышында ярдәм итү, ничек яшәргә кирәклеген өйрәтү. *Безгә дә Византия тарафларына яу кузгалып, бер җайдан Сарманай каханны да акылга утыртып кайту мәслихәт булыр иде, – диде* (М. Хәбибуллин). *Ничек итеп Дамирны акылга утыртырга, ничек итеп Асияга әйләнеп тә карарга җөрьәт итмәслек хәлгә куярга дип, кызлар бик озак баш ваттылар* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).
Төрдәше: сабак бирү 1.

3. *к.* авыз җебетү 2; җәза бирү. *Миңа син ахмакны чүлмәк ватканчы акылга утыртасы калган да, махы биргәнмен* (Г. Әпсәләмов. Сүнмәс утлар). *Балаларына карата гадел, каты куллы Савелий Кузьмич улын акылга утыртырга да күп сорамас иде, тик җиткән егетне базар уртасында тотып яруның килешеп бетмәячәген аңлый, тагын кул селти* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

4. Өйрәтү, орышу. «*Тоталитар дәүләт оештырган җәзалау системасы барыннан да бигрәк тән җәзасына йөз тота, акылга утыртуның бердәнбер чарасы итеп шуны саный*» (А. Гыйләҗев. Йөгез, бер дога!). *«Рәтләп кенә әйтәсе урында, акылга утыртырбыз, авызы пешмәгәндер әле, имеш...»* (И. Гази. Тел ярасы).
Төрдәше: акыл бизмәненә утырту һ.б.

5. Алданганлыгын белдереп, игътибарсыз кешегә хатасын күрсәтү. – *Йә, ничек акылга утыртты икән ул сине?* (Г. Бәширов).

**АКЫЛГА ҮСМӘГӘН.** Бик үк акыллы түгел. *Буйга үскән, акылга үсмәгән икән бу егет* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛГА ХӘЗИНӘ** *к.* авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктереп (элеп кенә) алу. – *Син түбән оч Мостайларга барып кил әле, акылга хәзинә кеше ул, ярдәм итми калмас* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктереп (элеп кенә) алу һ.б.

**АКЫЛГА ЧАК** *к.* акыл бергә дә тулмау. – *Мыштым гына түгел, акылга чак дип әйтер иде мин аны* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛГА ЧАМАЛЫ** *к.* акыл бергә дә тулмау. *Укырга өйрәнеп алгач, авыл китапханәсенә барган иде бит әле ул, анда да Мәүли абзый, малайны бернигә яраксыз, акылга чамалы кеше күреп, китап бирми чыгарган иде* (З. Мурсиев. Ачылмаган тәрәзә).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛГА ЯЛКЫН КАБУ.** Кинәт көчле кызып китү. *Бу мокытның исемен ишетү гарьлегеннән күз алларым караңгыланып китте. Акылыма ялкын капты. Мин, үз-үземне белештермичә, капкага таба ыргылдым* (М. Галиев. Тимә, яшәсен!).

**АКЫЛГА ЯТУ.** Ышанырга мөмкин, акыл кабул итәрлек. – *Әйе, бер уйлаганда, акылга яткан төсле тоела бу фикер* (Ш. Камал).

**АКЫЛГА ЯТЫШЛЫ** *к.* акылга муафыйк. *Акылга ятышлы бүтән аңлатма булмаганда, мондый аңлатма да ярап тора иде* (Н. Фәттах. Ерак гасырлар авазы).
Төрдәше: акылга муафыйк.

*АКЫЛДА* ❖ **АКЫЛДА ТОТУ.** Онытмау. – *Борчылма, син әйткәннәрне онытмадым, акылда тотам мин аларны* (Сөйләм).
Төрдәше: башта кал<дыр>у; борынга киртләү (киртләп кую); истә калу; истә тоту; колакка киртү (киртләү; киртеп / киртләп кую) 1, 2; колакка туку; күңелгә салу (салып кую); мыекка урау (чорнау); хәтергә беркетү; хәтергә салу (салып кую); хәтергә сеңеп калу; хәтергә сең<дер>ү; хәтердә тоту.

*АКЫЛДАН* ❖ **АКЫЛДАН БАШ ТАРТУ.** Акыл белән яхшылап уйламыйча, хис-тойгы нигезендә эш итү. *Илдәге акыллы башлар / Баш тартканда акылдан – / Мин менә кайттым илемә, / Ычкынсам да акылдан* (Зөлфәт. Игенче).

**АКЫЛДАН БУШ (КОРЫ) КАЛУ.** Акыл, белем, тәҗрибә алмыйча үскән; мокыт булып калган. *«Акылдан буш калу» дигәндә, халык зиһене гадәти, нормаль рәвештәге акылдан мәхрүм булуны түгел, бәлки бөтенләй икенче*

*нәрсәне, ягъни буыннардан буыннарга – аталардан балаларга тапшырылырга тиешле хәтер-мирассыз калуны күз уңында тота бугай* («Шәһри Казан» газ.).

**АКЫЛДАН САБУ.** Тилерү, юләрләнү. *Монда Исак үз алдына, кеше саен, акылдан сапкан кешечә җикеренеп йөри, кеше саен бәйләнә* (Ш. Камал. Акчарлаклар).

Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.

**АКЫЛДАН САПКАН** *к.* акылны җую (югалту). *Аны күбрәк акылдан сапкан егет дип кенә беләләр, ә ни сәбәптән – анысын берәү дә белми иде* (Сөйләм).

Төрдәше: акылны җую (югалту) һ.б.

**АКЫЛДАН ТАЙПЫЛУ (ТАЮ)** *к.* акыл баштан китү (чыгу) 1. *Берәүләр, кризис кичерә башлагач, җиңелчә генә акылдан тайпылалар* (А. Хәсәнов. Җәнбәт җәвере).

Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.

**АКЫЛДАН ТЫШ ФИКЕР** *к.* акыл сыйдыра алмау (сыйдырмау). *Уйга калабыз. Миңа акылдан тыш бер фикер килә* (Х. Камалов. Сугыш зигзаглары).

Төрдәше: акыл сыйдыра алмау (сыйдырмау) һ.б.

**АКЫЛДАН ЧЫГАРУ.** 1. Әүвәл уйланган фикердән ваз кичү; онытып җибәрү. *Тәмле булмас дип уйладым да ак май урынына сыек май куллану фикеремне акылымнан чыгардым* (Сөйләм). *Акылга сыешмас гаҗәп бер хәл бит ул: иң элек ир-ат акылыннан чыгар дәрәҗәгә җитеп юхалана* (Р. Мөхәммәдиев. Кенәри – читлек кошы).

Төрдәше: баштан җилләтеп бетерү; баштан чыгару (чыгарып ташлау) 1; күңелдән йолкып ату; күңелдән йолкып бетерү; күңелдән коеп төшерү; күңелдән кырып ташлау; күңелдән сызу (сызып ату; сызып ташлау); хәтердән чыгару (чыгарып ташлау).

2. Онытырга тырышу, кем яки нәрсә турындадыр уйламаска тырышу. – *Исемә төшкән саен кәефем бозыла, әкренләп булса да акылдан чыгардым мин ул вакыйганы* (Сөйләм).

3. Булмаганны уйлап чыгару. *Беркем дә күрмәгән бит, акылыңнан чыгардыңмы әллә бу сүзне?* (Сөйләм).

Төрдәше: баштан чыгару (чыгарып ташлау) 2.

**АКЫЛДАН ЧЫГУ (ЧЫГЫП КИТҮ).** Оныту, онытып җибәрү. – *Карале, акылымнан чыгып киткән, иртәгә балыкка барабызмы?* (Сөйләм).

Төрдәше: акылдан чыгару 1 һ.б.

**АКЫЛДАН ШАШАР<ЛЫК> ДӘРӘҖӘДӘ.** Акылны югалту кимәлендә булган. *Минем күңелне җилкетә торган, акылдан шашарлык дәрәҗәдә ашкындыра торган берничә җыр бар иде* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).

**АКЫЛДАН ШАШТЫРУ.** Кем яки нәрсә беләндер артык мавыгып китү. *Маһирә ханымның кара болыт кебек чәчләре вакыт-вакыт аны акылдан шаштырыр хәлгә җиткерә иде* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

Төрдәше: акылдан яздыру; акылны алу; баш<ны> әйләндерү 1; баш<ны>-күзне әйләндерү; күз-баш әйләнү.

**АКЫЛДАН ШАШУ.** 1. *к.* акыл баштан китү (чыгу) 1. *Белмим, һәммәсе акылдан шашкан, белмим, кыямәт булган: кешеләр ни эшләгәннәрен белмиләр, күзләрен кан баскан...* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр).

2. *күч.* Берәр кеше яки нәрсә белән артык мавыгу; артык соклану. *Галишә, башын бер яккарак салып, алтын телле дәү гармунын уйный башласа, бөтен авылның кызлары акылларыннан шашалар* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Әле алай гынамы, егет мине уйлап, акылдан шаша, әгәр ярты сәгать күрмәсә, йөрәге ярылып үләргә дә мөмкин икән* (Н. Гыйматдинова. Сөйлим, тыңла...).

Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б. (ике маддә өчен дә).

**АКЫЛДАН ЫЧКЫНУ** *к.* акыл баштан китү (чыгу) 1. *Инспектор акылдан ычкына башлады бугай, бер аягы белән сикергәләп тумбочка янына килде дә, ниндидер кәгазь битенә зур хәрефләр белән намус дигән сүзне язып, чәйничәйни йотып куйды* (З. Мәхмүди. Ахырзаман шаукымы). *Ул, фәлән еллар буе сәйяхлыкта йөргәннән соң гына кәләш изүенә борынын төртү бәхетенә ирешкән яшь кияү шикелле, бөтенләй акылдан ычкынды, күрәсең* (В. Имамов. Казан дастаны).

Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.

**АКЫЛДАН ЯЗАР ДӘРӘҖӘДӘ (ЯЗЫП).** Гадәттән тыш, чиктән тыш вакыйга һ.б. булганда кулланыла; *шулай ук к.:* акылга сыймаслык. *Нурулла бу минутта чынлап та акылдан язып бара иде* (Г. Гыйльманов. Хак чишмәсе). *Адәм баласының еллар узгач үз асылына кайтуы – табигый хәл, ә менә яшьли үз милләтеңне «акылдан язар дәрәҗәдә» ярату һәркемгә бирелмидер ул* («Ватаным Татарстан» газ.).
Төрдәше: акылга сыймас<лык> (сыймаган) 1; акылга сыймастай 1; акылдан шашар<лык> дәрәҗәдә.

**АКЫЛДАН ЯЗДЫРУ** 1. Үзеңә карату, нечкә хис уяту, гашыйк итү. *Кемнәрне генә акылдан яздырмады ул* (Ә. Дусайлы. Өермә). *Баксаң, мәхәббәт тә адәм баласын акылдан яздыра икән* (Н. Гыйматдинова. Кем беренче?).
Төрдәше: акылдан шаштыру һ.б.

**АКЫЛДАН ЯЗУ** *к.* акыл баштан китү (чыгу). *[Рушан] Ни эшлисең, туташ? Акылдан яздыңмы әллә?* (М. Фәйзи. Ак калфак). – *Әй, улым, – диде Фатыйма, – Биктаһир бабаңнан сорыйларны соң. Акылдан язган ич инде ул: үлмәс борын кабер урыны сайлап, рәшәткәләр тоттырып куйды бит* (И. Гази. Онытылмас еллар).

2. *к.* акылдан шашу 2. *Сагынудан акылымнан язам, / Һич югында хат язып сал – Көтәм мин* (М. Фазлуллина). *«Мин акылдан язам…» диеп бастың/ Киткән эзләреңә – яңадан* (Г. Газизова. «Уйлап кара; без булмаган бер көн килер...»).
Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) һ.б. (ике маддә өчен дә).

**АКЫЛДАН ЯЗУ ХӘЛЕНДӘ.** Акылдан язу чигенә килеп җитү. *Кем уйлаган аны, шул кыз белән бөтен дөньясын онытып, аны акылдан язу хәлендә күрербез дип* (Сөйләм).

*АКЫЛЛЫ* ❖ **АКЫЛЛЫ БАШ<ЛЫ>.** 1. Эшне акыл белән йөртә белүче тәҗрибәле кешене белдерә. *Минап абый / Уйлый үзен / Иң акыллы башлы кеше дип* (Х. Туфан). *Үзең императорский указларны укыштырган акыллы баш бул, авыл сине күз өстендә каш кебек күргән, үзең, Алла колы, сенатның саф дөрес карарын сәмруг кошлы кәгазьгә күчертеп сиңа таптырасы обер-секретарьның ак кулына «алтын йөгертә» белмә, имеш!..* (М. Рәфыйков).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә алу) һ.б.

2. *ирон.* Бик белдекле булып, үзе дә белмәгәнне кешегә өйрәтергә маташучы. *Анда да райкомдагы бер акыллы баш: «Нишләп сезнең фамилия морзаларныкы сыман яңгырый?» – дип җанга тигән иде* (А. Тимергалин. Игезәкләр). – *Урыслаштыруга омтылучы акыллы башлар күбәйде!* (Р. Низами. Сәйдәшнең соңгы елы).

3. *мыск.* Үз мәнфәгатьләрен кайгыртырга тырышучылар. *[Мисбах] Кара син, акыллы башлар, бумажникны азсынып, милли сандыкка ук ябышканнар* (К. Тинчурин. Җилкәнсезләр). *«Юк, кадерле ирем, син миннән алай тиз генә котыла алмассың, – дип уйлыйм усалланып. – Кара син аны, акыллы баш, ул укып түрә булмакчы, мин монда бер бүлмәле фатирда аның нәселе, балалары белән хәсрәт чигеп ят»* (Г. Ахунов. Чикләвек төше).

**АКЫЛЛЫ БАШ <БУЛГАН> БУЛУ.** Олы кыяфәттә, фикерле сыман. *Низами моңа каршы, бик акыллы баш булган булып, Бостанга бер карап алды һәм белдекле кыяфәт белән: – Сез, яшьләр, үзегез дә кызык кына кешеләр, урын таптыгызмы, эшне, тисә – тиенгә, тимәсә – ботакка, дигәндәй, аннан-моннан гына эшләргә яратасыз* (С. Җәләл. Юләр).
Төрдәше: акыллы башлану (баш булып).

**АКЫЛЛЫ БАШЛАНУ (БАШ БУЛЫП)** *ирон.* Үзен акыллы итеп күрсәтергә тырышу. *Ул утырган бик матурлап һәм акыллы башланып, / Уйга чумган, җиргә күз теккән, җиһаннан баш алып* (Г. Тукай. Песи кыяфәте хакында).
Төрдәше: акыллы баш <булган> булу.

**АКЫЛЛЫ ГАВАМ.** Белемле, зиһенле халык. *Чөнки бездә «акыллы гавам» нәни аермалы буларак, уртаклык юк, һәркайсыбыз үзгә зат* (Н. Гыйматдинова. Фәрештәләр).

**АКЫЛЛЫ ДИВАНА** *к.* акыл иясе җүләр (юләр). *Автор әти булырга җыенган Аязны акыллы дивана итеп сурәтләгән* («Сөембикә» ж.).
Төрдәше: акыл иясе җүләр (юләр); башны җүләргә салу.

**АКЫЛЛЫ ТИТИБАШЛАР** *ирон.* Акылсыз башлылардан мыскыллап көлү. *Тинчуринның пьесалары тыелгач, Сәйдәшнең дә күп кенә җырлары үзеннән-үзе эфирдан, сәхнәдән коелып калды. Кайбер акыллы титибашлар*

*аны, янгын куркынычын сәбәп итеп, кырга алып чыгып яндырмасалар ярый да бит...* (Р. Низами. Сәйдәшнең соңгы елы).

*АКЫЛ-МАКЫЛ* ❖ **АКЫЛ-МАКЫЛ ИТЕП АЛУ (КАРАУ)** *гади с.* Бер эш яки хәл турында акыллы фикергә килгәнче киңәшләшеп алу. *Моны буйый башлаганчы, без бераз акыл-макыл итеп алыйк әле* (Сөйләм).

*АКЫЛНЫ* ❖ **АКЫЛНЫ АЛУ** *к.* акылдан яздыру. Бөтен күңелне биләп алу. – *Шул ак айгырыңны бер ай эчендә урламасам, исемем Шәкүр булмасын. Белдеңме, энем! – дип, Шаһимәрданның акылын алды* (Ф. Яхин. Ат урлауның ние бар...). *Ул ихтыярсыз буйсындыра, акылны ала* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: акылдан шаштыру һ.б.

**АКЫЛНЫ АЯККА ТӨШЕРҮ.** Бернәрсә дә уйламыйча, аяк белән генә эшләү (туп уйнау, типкәләү һ.б.). *Ә тибүчеләр, акылын аягына төшереп, отыры кыза гына бара* (М. Галиев. Тимә, яшәсен!).

**АКЫЛНЫ БАШКА АЛУ.** Бөтен белемне, зиһенне башка туплау. *Бөтен булган акылын башына алып, таң атканчы өстәл артында утырды, нәрсәдер сызды-бозды* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл җыю 2 һ.б.

**АКЫЛНЫ ҖИГҮ.** 1. Акыл белән уйлап эш итү. *Йөрәк хәл итәсе мәсьәләгә акылны җиксәң, шулай була шул инде...* (М. Маликова. Арыш тәме). *Хәзер дә ул, бөтен акылын җигеп, ике коммунист арасындагы конфликтны аңларга, шуны ачык итеп билгеләргә тырыша иде* (Ә. Еники. Рәхмәт, иптәшләр).
Төрдәше: акыл аша уздыру һ.б.

2. Бөтен игътибарны туплау. *Берничә секунд ул бөтен акылын җигеп уйланды* (Ә. Еники). *Эчмәсә, ниләр булганын хәтерләр иде... Радик тагын бар акылын җикте* (М. Кәбиров. Бердәнбер һәм кабатланмас).

**АКЫЛНЫ ҖУЮ (ЮГАЛТУ).** 1. *к.* акыл баштан китү (чыгу) 1. – *Анысын язма, исәр хатын сүзе ул, белеп сөйләгән сүз түгел! Ире үлгән, кайгыдан акылын җуйган* (Г. Ахунов. Идел кызы). *Мәхәббәт ташып акылны җуйган тәкъдирдә дә хатын артыннан куып бармас Саматныкылар* (Н. Гыйматдинова. Күке төкереге).
Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.

2. Уйламыйча эшләү. – *Мин эчсәм дә, акылымны җуя торган кеше түгел* (Ә. Еники. Кыз һәм сәгать).

3. Берәр хәл алдында аптырап, шашып калу. *Халык, моны ишеткәч, тәмам акылын җуйды* (А. Расих). *Күзен кан баскан, акылын җуйган Сабит җавап кайтармады, хатынның дерелдәгән сылу гәүдәсен почмакка кысрыклады* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**АКЫЛНЫ <БАШКА> ҖЫЮ** *к.* акыл җыю 2. *Ләкин Наилә акылын җыеп өлгерде, котырган үгез сыман янында торган Сабитның култык астыннан шамбы балыгы сыман шуып чыкты, ул «тоттым» дигәндә, яңагына берне чалтыратты* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: акыл җыю 2 һ.б.

**АКЫЛНЫ КӘҖӘ АШАУ** *мыск.* 1. Акылы булмау яки картаю сәбәбеннән, бала акылы кергән кеше хакында. *Аның белән сөйләшүдән файда юк, акылын күптән кәҗә ашаган инде* (Сөйләм).

2. Сүзенең рәте булмауны аңлата. *Акылын гына түгел, телен дә кәҗә ашаган аның* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛНЫ КИҢ ЙӨРТҮ.** Берәр нәрсә әйткәнче төплерәк уйлап карарга кирәклеге хакында. – *Син егерме ел элек бер каты сүз ишеткән булсаң, мин аның белән кырык ел талаш кылганмын: мәгәр акылыңны киң йөртергә кирәк!* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).

**АКЫЛНЫ КӨЯ КИСҮ.** Акылсызлык эшләү, юләр булу. – *Ата – улына, энесе абзыйсына каршы кылыч күтәреп, бертуктамый җан кыя торган, акылларын көя кискән нинди халык соң без?* (В. Имамов).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛНЫ КУШЫП ЭЧҮ.** Ахмакка әйләнү (исерткеч эчемлек эчүчеләр хакында). *Аракысына акылын да кушып эчә бит, җүнсез нәрсәкәй* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: акылын эчү.

**АКЫЛНЫ КҮЗГӘ ЧАЙКАП ЭЧҮ.** Эчә-эчә, күзләргә хәтле акаеп чыгу. – *А-а, акылын күзләренә чайкап эчкән бу, тизрәк «ашыгыч ярдәм» чакырыгыз!* (Сөйләм).

**АКЫЛНЫ КҮМЕП КИТҮ.** Көчле ярсу, ачулану вакытында акылсыз нәрсәләр туарга мөмкинлегенә ишарә. *Айныткычтан кайтканда, иренең кыланышлары сабак булырга җитте дә бит, тик ярсу-ачу шулкадәр ташый, акылны күмеп китә* (М. Маликова. Арыш тәме).

**АКЫЛНЫ ТАРАУ.** Зиһенен туплап, фикер йөртә алмый тору. *Ислай Сәлимов «һәйкәле» акылын тараган иде, ачуы җиһанга сыймаган ир турларында кукрайган «Ока»ны әз генә тибеп җибәрмәде* (Н. Гыйматдинова. Кем беренче?).

**АКЫЛНЫ ТОМАЛАУ.** Фикер йөртә алмаслык хәлгә килү. *Әмма Рафаил күзгә чалынса, ул хис яңадан актарылып чыгып, акылны томалый иде* (Н. Гыйматдинова). *Исәр, хыялый рәссам аны да саташтырды, юлыннан яздырды, гүя күзен бәйләде, акылын томалады* (Р. Габделхакова. Кояшлы мизгел).

**АКЫЛНЫ ЭЧҮ.** Фикер йөртә алу сәләтен югалтканчы исерткеч эчемлек кабул итү. – *Кара инде кемгә әйләнгән, бөтен акылын эчеп бетергән* (Сөйләм).

Төрдәше: акылны кушып эчү.

**АКЫЛНЫ ЭШЛӘТҮ.** Төрлечә уйлап фикер йөртү. – *Кемнән булырга мөмкин икән бу хат дип, акылын кызу-кызу эшләтә башлады* (Сөйләм).

Төрдәше: акыл аша уздыру һ.б.

**АКЫЛНЫ ЮГАЛТУ** *к.* акылны җую. *Разия аның саен акылын югалтып, егетне шаыртты* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр).

Төрдәше: акылны җую һ.б.

*АКЫЛСЫЗ* ❖ **АКЫЛСЫЗ БАШ.** Акылын югалтып тилерү; *шулай ук к.:* акыл баштан китү (чыгу) 1. *Эчтән генә үзен тиргәп тә алды: акылсыз баш аякка тынгылык бирәмени ул, дип әрнеде* (С. Поварисов. Пәйгамбәр таңы). *Әй эченнән куана – Акылсыз баш, дивана!... / Ә ялкын шул арада / Кибәнне камап ала* (Х. Җәләй. Шәрә бүре).

Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.

*АКЫЛСЫЗЛАР* ❖ **АКЫЛСЫЗЛАР ЙОРТЫ.** Юләрләнә башлаган авыруларны дәвалау хастаханәсе. *Озак йөри алмаган, акылсызлар йортына алып киткәннәр мескенне* (Сөйләм).

Төрдәше: җүләрләр йорты; сары йорт; тилеләр йорты.

*АКЫЛ-ТАКЫЛ* ❖ **АКЫЛ-ТАКЫЛ ИТЕП АЛУ** *гади с., к.* акыл-макыл итеп алу (карау). – *Бераз бушагач, миңа кереп чык әле, акыл-такыл итеп алырбыз* (Сөйләм).

Төрдәше: акыл-макыл итеп алу (карау).

*АКЫЛЫ* ❖ **АКЫЛЫ<Ң> АЛТЫН <ИКӘН>** 1. Бик акыллы, башлы, сәләтле булганлыгы сизелеп тору. *Алтын икән акылы,/ Дөрес җавап егеткә / Табып бирде, ахыры* (Ә. Исхак). *Әллә, акылың алтын икән. Элек башлаган кеше элек әйтә* (М. Фәйзи).

Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктер (эләктереп /элеп кенә) алу һ.б.

2. *ирон., шаярт.* Үзен башкалардан өстен кую, бик акыллы санап, башкаларны җүләр дип уйлау (шуннан файдаланып, кайвакыт күбрәк өлеш алырга тырышу). *[Айнур] Акылыгыз алтын икән, күрми генә торыгыз* (Т. Миңнуллин. Кулъяулык). – *Акылың алтын икән! Өйрәнмирәк тор әле* (Г. Сабитов. Урман кызы Таңсылу).

Төрдәше: акыллы баш; акылың алтын икән, сука калагы белән алмашмыйсыңмы?; акылың Әфләтун!

**АКЫЛЫ БАРМАККА УРАРЛЫК (ЧОРНАРЛЫК) ТА ЮК** *к.* акыл бергә дә тулмау. – *Балачага түгел бит инде, ә акылың бармакка урарлык та юк* (Сөйләм).

Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛЫ БАШЫНДА.** Һәр нәрсәне яхшылап уйлап, үзе теләгәнчә эшләү. *Рифат, бар акылын башында туплап, бөтен белгән-күзаллаган әдәп тойгыларын мәйданга чыгарды* (Ф. Яхин. Чәчәкләр ул ал да гөл була).

Төрдәше: акылга буйсындыру һ.б.

**АКЫЛЫ ҖИҢЕЛ** *к.* акыл бергә дә тулмау. *«Ә сез яшьләр бүген бик кызык: ул нәселдә акылы җиңел биш туган бар, әмма барыбер шул гаиләгә килен булып төшәргә җыенасыз»* («Сөембикә» ж.).

Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛЫ ҖИРЕНДӘ <БУЛУ>.** Акыл ягыннан кимчелекләр булмау. *Шөбһәләнерлек нәрсә юк,*

*синең белән миннән аермасы юк – акылы җирендә аның* (Сөйләм).

Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктереп / элеп кенә) алу һ.б.

**АКЫЛЫ КАМИЛ.** Акылы тулы, һәр яктан җитеш булу; акыллы кеше турында. *Солтан Хәбибуллин бу класста укыса, «Пушкинның акылы, бабай әйтмешли, камил акыл булган шул», дияр иде, дип уйлады* (Г. Кутуй. Солтанның бер көне). *Парлап кына парлап ат җиктергән, / Кайсы илләрдән килгән бу түрә? / Бу түрәлек сиңа бирелгәндер / Акылларың камилгә күрә* (Җыр).

Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә алу) һ.б.

**АКЫЛЫ КЕРӘЛЕ-ЧЫГАЛЫ (КЕРДЕЛЕ-ЧЫКТЫЛЫ).** Тотышы, сүзләре белән бер юләр, бер акыллы күренгән кеше турында. *Кыш алдыннан диңгезнең дә акылы керәле-чыгалы бит, – дип, тинтерәткән испан башкисәрләренә король җавапны да җиңел генә тапты* (В. Имамов. Сөләйман солтан). «*Юк, укытучының гаебе-мазары юк, терлекче Прыкул – үзе кыешрак адәм, акылы керделе-чыктылы, каушап китә торган гадәте дә барлыгын иптәш Михайловны каршылаганда бөтен авыл күрде, бv юлы да шулай саташып куйгандыр», – дип аңлатма биргәннәр* (А. Гыйләҗев. Кылдан нәзек, кылычтан үткен).

**АКЫЛЫ КЫСКА.** 1. *к.* акыл бергә дә тулмау. *Күп сөйләүче була аз белгән, / Акылы кыскаларның теле озын* (Н. Арсланов). *Куяннарын да әйтер идем инде... шул хәтле үрчемәсәләр... Аларның бит колаклары гына озын, акыллары кыска!* (Ш. Фәрхетдин. Ала карга хәйләсе).

Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

2. Тиз кызучан. *Аның бу гыйбарәсе Федор дәдәйне кузгата, ачуын кабарта. Шунлыктан ул, үзен-үзе тыя алмас дәрәҗәгә җитеп: – акылың кыска булды синең!* (Ф. Яхин. Август ае). *Акылы кыскамы әллә аның – уйламыйнитми һәркемгә бәйләнергә тора* (Сөйләм).

Төрдәше: күкерт кебек (күкерттәй) кабыну; кызып китү; сыер дуласа, аттан яман; җай типсә, аттан яман; үгез дуласа, арба ватар; чыгырдан чыгу (ычкыну).

**АКЫЛЫ ӨЧЛЕ-ТУГЫЗЛЫ <ГЫНА>** *к.* акыл бергә дә тулмау. *Моны эшләп чыгарга башы җитәр микән, акылы өчле-тугызлы бит аның* (Сөйләм).

Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛЫ САЙ** *к* акылга сай. *Күзләрендә үтенеч иде этнең – кешеләр, сез минем хуҗамны кимсетмәгез, аның акылы сайрактыр, әмма ул тиле түгел, читләштермәгез аны үзегездән, ялгызлыктан күп интеккән ул, кешеләр, аңа иптәш булудан оялмагыз, хуҗама минем генә иптәш булуым җитми...* (М. Хуҗин. Айның уты сүнгән). – *Минем кебек акылы сай, гыйлеме тар, күңеле суык кешегә нинди мохтаҗлыгыгыз төште? – дип сорадым* (Ф. Яхин. Ясалма кешеләр, яки хикәят бакчасы кешеләре).

Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛЫ САУ.** Акылы яки фикерләве ягыннан кимчелеге булмаган сәламәт кеше турында. *Телем, акылым сау көндә ул кордашымның ризалыгын алып, Найман балалары белән килештереп китсәм икән, дим...* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).

Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктереп / элеп кенә) алу һ.б.

**АКЫЛЫ ТАМАН<ЧА>** *к.* акыл бергә дә тулмау. *Аны йә акылы таман адәм актыгы кылган, йә булмаса махсус оештырылган, дошманнардан котылу өчен, акча табып бүлешү өчен* («Безнең гәҗит» газ.).

Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛЫ – ТӨПСЕЗ ЧИЛӘК.** «Акылы бөтенләй юк» мәгънәсендә; *шулай ук к.* акыл бергә дә тулмау. *Шундый ук тәкъва һәм дә һиммәт иясе зирәк. Тик Иоанның акылы – төпсез чиләк, әнә, һич уйламаганда, тәхеткә басурманлыктан чыгып та җитмәгән Бикбулатны утыртып куйды бит әле* (М. Әмирханов. Тәхетсез патша). *Диваналанган кешеләргә авыл җирендә «акылы – төпсез чиләк» дип тә җибәрәләр* (Сөйләм).

Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛЫ ТӨШТӘН СОҢ** *ирон.* Вакытында карар кабул итә алмаган**,** һәрнәрсәне соңга калып хәл иткән кеше турында. – *Барыбызның да акылы төштән соң шул безнең, җәмәгать, – диде ул, сүзгә катышып* (М. Галәү. Мөһаҗирләр).

**АКЫЛЫ ТУБЫГЫНДА.** Буйга озын, тилемсәрәк кеше турында. *Озын кешенең акылы тубыгында була, имеш* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.). *Акылы тубыгында булмаса, шулай дип әйтә идеме ул?* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛЫ ТУКСАН ТУГЫЗЛЫ <ГЫНА>** *к.* акыл бергә дә тулмау. – *Акылы туксан тугызлы димме соң теге абзыйның* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛЫ ТУЛЫ** *к.* авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктереп / элеп кенә) алу. *Нишләп минем ачуым килсен. Субайда акылы тулы кеше юк бит анда* (З. Хәким. Телсез күке).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктереп / элеп кенә) алу һ.б.

**АКЫЛЫ ТУЛЫ ТҮГЕЛ** *к.* акыл бергә дә тулмау. – *И-и-и, улым, акылы тулы түгел бит аның, бичараның, җитмәсә теле юк, ни сөйләсәң дәшми* (Х. Мөдәрисова. Бәйге хакы).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛЫ ТҮГӘРӘК** *к.* авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктереп / элеп кенә) алу. *Зартугайның чишмәләрен тазартып йөри, беркем кушканны да көтмичә, тегермән бинасының түбәләрен сипли. Исәр дияр идең, акылы бик түгәрәк* (Г. Ахунов. Идел кызы).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктереп / элеп кенә) алу һ.б.

**АКЫЛЫ УТЫЗ ТУГЫЗЛЫ <ГЫНА>** *к.* акыл бергә дә тулмау. *Акылы утыз тугызлы гына дисәләр дә, башкарылан эшне җиренә җиткереп үти иде* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**АКЫЛЫ ҮЗЕ БЕЛӘН.** Холыксыз, теләсә нәрсә эшләве мөмкин дигәнне аңлата. *Тик аның акылы үзе белән, керәле дә чыгалы* (М. Әмирханов. Әлвидаг). *Җәмилә җиңгинең акылы үзе белән, тәки ашка төшкән таракан булыр* (М. Хәсәнов. Саф җилләр).
Төрдәше: атнасын<д>а биш <җиде> җомга; бүген болай, иртәгә тегеләй; икеле-микеле; ике төрле сөйләшү; үзгәреп тору.

**АКЫЛЫ ҮСМӘГӘН (ҮСМИЧӘ КАЛГАН)** *к.* акылга сай 1. – *Сакал җибәрсәң дә, акылың үсмәгән шул* (В. Имамов. Утлы дала). – *Синең акылың үсмәгән әле, Рәсим! – диде дә, кисәк кенә борылып, коридор буйлап китеп барды* (Ф. Яхин. Йөрәкнең учка тәгәрәп төшкән чаклары).
Төрдәше: акылга сай 1 һ.б.

**АКЫЛЫ ХӘЗИНӘ.** Күпне белүче, зиһенле, акыллы кеше турында. *Рәхмәт яугыры, кызның акылы хәзинә икән, очрашуны бакчаның иң түрендә, иң аулак җирендә тәгаенләгән* (М. Әмирханов. Әлвидаг).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктереп / элеп кенә) алу һ.б.

**АКЫЛЫ ЭШЛӘҮ.** Акылына зәгыйфьлек килмәгән, зиһене бөтен булу. *Шулай да аның акылы эшли тора, зиһене әзер тамашаны күзәтә, әкүңелендә көлке катнаш сыкрау* (Ф. Яхин. Көзге яңгырга кадәр).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктереп / элеп кенә) алу һ.б.

**АКЫЛЫ ЮЛДАН АДАШМАСЛЫК КЫНА** *к.* акылы үсмичә калган. *Акылы юлдан адашмаслык кына булса да, ул әйбәт кенә гомер иткән* (Сөйләм).
Төрдәше: акылы үсмичә калган.

*АКЫЛЫМ* ❖ **АКЫЛЫМ КЫСКА, ТЕЛЕМ ГАҖИЗ.** Зур фикерле яисә талантлы кешенең уңай сыфатларын әйтүдән үзен түбән санап, олылап сүз башлау. *Акылым кыска, телем гаҗиз икәнлеген хәтерләтеп, сүземне башларга булдым әле* (Сөйләм).

*АКЫЛЫН* ❖ **АКЫЛЫН АЛУ** *к.* акылдан яздыру. – *Найманнар белән дүрткаралар һәр ике йортның мазасын китәрәләр, кызларын урлыйлар, җәйләүләрен басып алалар, аяклы малларын куып китәләр; сарманнар белән кара-айгырларның кода булып кушылулары дошманның йөрәгенә ут салыр, башыннан акылын алыр, кодалык котлы булсын! – диде* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).
Төрдәше: акылдан шаштыру һ.б.

**АКЫЛЫН ЭЧЕП БЕТЕРГӘНЧЕ.** Бик күп исерткеч эчемлек эчкәннән соң, тирә-якны аңлый алмаслык хәлгә килү. *Акылын эчеп бетергәнче, төн буе һич белмәгән кешеләр белән кафеда утырып чыккан* (Сөйләм).
Төрдәше: акылын эчкән; аягында да басып тора алмый; баш әйләнү 7; башка бәрү 2; башка

йөгерү; башка китү 2; башка менү 2; баш-күз акаю (тону) 2; башлары кайда, аяклары кайда икәнен белмәү; бер тиенлек эчеп, өч (биш; ун; егерме) тиенлек исерү; дуңгыз булганчы <эчү>; дупыл исерек; лаякыл булганчы; лаякыл исерек; ләх булганчы; ләх исерек; лык булу; лыкы<н> булганчы; эчеп акылын югалтканчы; эчеп дуңгыз булганчы.

**АКЫЛЫН ЭЧКӘН**. Эчүгә салынып, кеше көлкесенә калган, тирә-якны аңлый алмый торган хәлгә килгән. *Нинди шәп кеше иде, хәзер акылын эчкән, диләр* (Сөйләм).
Төрдәше: акылын эчеп бетергәнче һ.б.

*АКЫЛЫНА* ❖ **АКЫЛЫНА ХӘЛӘЛ КИЛҮ** *иск.* Акылга кимчелек килү, баш эшләми башлау. *Аны тыңлап торган кәнизәк, хакимнең акылына хәләл килгән бугай, дип, мышык-мышык елап җибәрде* (З. Мәхмүди. Елак агач).
Төрдәше: аксак акыл һ.б.

*АКЫЛЫН-ФИГЫЛЕН* ❖ **АКЫЛЫН-ФИГЫЛЕН БЕЛҮ.** Берәр кешене сынап карау, холкын белү. *Акылын-фигылен белмичә, / Алданмагыз матурга* (Җыр).

*АКЫЛЫҢ* ❖ **АКЫЛЫҢ АЛТЫН ИКӘН, СУКА КАЛАГЫ БЕЛӘН АЛМАШМЫЙСЫҢМЫ?** *к.* акылы<ң> алтын <икән>! 2. – *Үзең уйлап чыгардыңмы моны – акылың алтын икән, сука калагы белән алмашмыйсыңмы?* (Сөйләм).
Төрдәше: акылың алтын <икән>! 2 һ.б.

**АКЫЛЫҢ ӘФЛӘТУН!** Кешене җүләргә санап, аны алдап отарга уйлаучыга әйтелә. – *Акылың Әфләтун икән, бар, башта тышка чыгып, тәмәке пыскытып кер* (Сөйләм).
Төрдәше: акылы<ң> алтын <икән>! 2 һ.б.

*АКЫЛЫҢНАН* ❖ **АКЫЛЫҢНАН КУАН.** «Акылыңны җуймаганыңа шатлан» мәгънәсендә. *Халыкчан сөйләм гыйбарәләренең әйтелү ситуацияләрен аңлатыгыз. – Акылыңнан куан. Алладан кайтсын* (Р. Абдуллина. Сөйләм культурасы).

*АКЫРЫП* ❖ **АКЫРЫП ЕЛАУ (ЕЛАП ҖИБӘРҮ).** Каты итеп кычкырып елау. – *Әтине үтерделәр, инде мине дә тереләй ашамакчылар, – дип, акырып елап җибәрдем, бар көчем белән ишекне шакылдатып ябып, чыгып киттем* (Г. Ибраһимов. Көтүчеләр).
Төрдәше: үкереп елау.

*АКЫШ-МАКЫШ* ❖ **АКЫШ-МАКЫШ КИТЕРҮ** *диал.* Рәтен бозып, буташтырып бетерү. *Вәзыйх хәйләләп, акыш-макыш китереп, бер-ике участок бодайны, үзе теләгәнчә, солычаны «провокацияләп» чәчә алды* (Х. Камалов).

**АКЫШ-МАКЫШ ТЕЛ** *диал.* Төзелеше бозык, рәтсез. *Шул ике тел катнашып, керәшен акцентын да өстәгәч, нindидер акыш-макыш тел килеп чыга* («Безнең гәҗит» газ.).

*АЛ* ❖ **АЛ БЕЛМИ, ЯЛ БЕЛМИ <ЭШЛӘҮ>.** Көнтөн дип карап тормыйча, туктамыйча эшләү. *Минем әти колхозда ал белми, ял белми 35 ел эшләгән* (Сөйләм).
Төрдәше: ал димәү, ял димәү; ал <да> юк, ял <да> юк; алны-ялны белмичә; ал-ял белмәү; ал-ял белмичә (күрмичә); ал-ялны оныту; арка турайтмыйча; баш-күз алмыйча <эшләү>; бер караңгыдан икенче караңгыга<ча>; бер таңнан икенче таңга кадәр эшләү; таңнан таңга кадәр.

**АЛ БИРМӘҮ.** Беренчелекне кулдан ычкындырмау. *Эшкә гаярь булды ул, көчен җәлләмәде, куәтен биргән иде Ходай Тәгалә, уртларын чәйнәп, беркемгә ал бирмәскә тырышты* (К. Кара. Зарифа).

**АЛ БИРҮ.** 1. Юл бирү, үзеңнән алга китәргә мөмкинлек бирү. <...> *Газинурга шаянлык белән җавап кайтарды: Ал биргәннәргә – ал бирәм, Гел биреп тормыйм әле* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

2. Юклык шәкелендә: алга чыгармау. *«Әйдә инде, малкай, канатым, кеше алдында мәсхәрә итмә, күрсәт үзеңне, оч канатланып, ал бирмик башкаларга»* (Х. Мөдәррисова. Сабантуйдан соң).

**АЛ ДА ГӨЛ <БУЛУ>.** Бик яхшы, матур. *[Җәмилә] Шулай шул. Бик әйбәт, бик ачык йөзле кеше, бик кешене таный торган кеше. Һәркемгә ал да гөл* (Г. Камал. Бәхетсез егет). *Билгеле, һаман болай ал да гөл генә булып тормый* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).
Төрдәше: ал да гөл барысы; ал да гөл итү; ал да гөл кебек; ал да гөл <кебек> тору; ал да гөл яшәү (гомер итү); дөнья түгәрәк <булу>; игелек күрсәтү (күргәзү; күрү); сөттән ак, судан пакь; яхшыга яман юк.

**АЛ ДА ГӨЛ, АРТТА КЫЧЫТКАН.** «Хәлләр ничек?» соравына җавап йөзендә кулланылган «ал да гөл» җавабының артында кыенлыклар да барлыгына ишарә. – *Сорап торма инде ачу китереп, ал да гөл шунда, артта кычыткан* (Сөйләм).

Төрдәше: ал да гөл, артта тигәнәк.

**АЛ ДА ГӨЛ, АРТТА ТИГӘНӘК** *к.* ал да гөл, артта кычыткан. – *Ал да гөл, артта тигәнәк дисең, тигәнәк бастымы әллә бакчагызны?* (Сөйләм).

Төрдәше: ал да гөл, артта кычыткан.

**АЛ ДА ГӨЛ БАРЫСЫ.** «Тормышта барысы да яхшы» мәгънәсендә. *Аның очен җанын бирергә әзер сыман, очраша калсаң, шатлыгың ташып бара, сөйләшеп сүзләр бетми, ал да гөл барысы* (К. Кара. Депрессия).

Төрдәше: ал да гөл <булу> һ.б.

**АЛ ДА ГӨЛ, БӘДИГЫЛЬ, КАЛГАНЫН ҮЗЕҢ БЕЛ.** Егет һәм кызлар, ирләр һәм хатыннар исәнләшкәндә, араларында булган вакыйгаларга, хәлләргә ишарә. – *Кәефләр ал да гөл, бәдигыль, калганын үзең бел* (Сөйләм).

**АЛ ДА ГӨЛ, БЕР КАРАСАҢ – ҖИЛ-ДАВЫЛ.** «Нигездә барысы да яхшы, ләкин күңелсезлекләр дә булгалый» мәгънәсендә. *Бер карасаң ал да гөл, бер карасаң – җил-давыл* (М. Фәйзи. Ак калфак).

**АЛ ДА ГӨЛ ДИП ӘЙТЕП БУЛМЫЙ.** «Бик яхшы дип әйтеп булмый» мәгънәсендә. – *Сорама инде, һәрвакыт ал да гөл дип әйтеп булмый* (Сөйләм).

Төрдәше: менә дигәннәрдән түгел.

**АЛ ДА ГӨЛ ИТЕП <КҮРҮ; УЙЛАУ** һ.б.>. 1. Тормыштагыдан идеаллаштырып, яхшырак итеп, кимчелексез, һәр ягы килгән дип күрү. *Безнең кулыбыздан килсә, ал да гөл итеп куяр идек икегезне* (М. Фәйзи. Асылъяр). *Әмма Камали агай, язучы буларак, бөтен нәрсәне дә ал да гөл итеп кенә күрергә өйрәнгән кеше иде* (Ә. Еники. Бүрек... түгәрәк була).

2. Тормышның һәр ягы килгәнлегенә ишарә. *Минем гомеремдә һичбер хатынны алдаганым юк. Һәммәсен дә ал да гөл итеп тотам* (Г. Камал).

**АЛ ДА ГӨЛ ИТҮ.** Матурлау, күркәм итү. *Мин бөтен дөньяны ал да гөл итеп, бөтен кешеләрне тигез, шат, бәхетле итеп, үземне исә бәхетнең җиде кат күгендә итеп күрә башладым* (Ә. Еники).

Төрдәше: ал да гөл <булу> һ.б.

**АЛ ДА ГӨЛ, КАЛГАНЫН ҮЗЕҢ БЕЛ.** «Нихәл» дип сораганда, җавап буларак әйтелә («бер караганда бар да яхшы кебек, ә күренмәгән якларын үзең чамала инде» мәгънәсендә). *Башымны череттең инде: минем барысы да ал да гөл, калганын үзең бел* (Сөйләм).

**АЛ ДА ГӨЛ КЕБЕК.** Барысы да яхшы, үз урынында. *Шуннан бернichә атналар буенча майлаган кебек, ал да гөл кебек чибәр йөри* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми).

Төрдәше: ал да гөл <булу> һ.б.

**АЛ ДА ГӨЛ КЕБЕК ТОЕЛУ.** Тормышның яхшы якка үзгәрүен сизү. *Беренче тапкыр аңа өйдәге тормыш, мәдрәсәдә яшәүнең михнәтләре белән чагыштырганда, ал да гөл кебек тоелды* (Ә. Фәйзи. Тукай).

**АЛ ДА ГӨЛ <КЕБЕК> ТОРУ.** «Һәр ягы килгән, бик матур, шәп» мәгънәсендә. *Ал да гөл кебек, пар күгәрчен кебек гөрләшеп торабыз* (Г. Ибраһимов). *Менә шуннан бирле ал да гөл торалар* (А. Шамов. Фатирда).

Төрдәше: ал да гөл <булу> һ.б.

**АЛ ДА ГӨЛ <ИТЕП> ТОТУ.** Төзек, кимчелексез хәлдә. *Мәдрәсәне, ашханәне ал да гөл итеп тота* (Г. Ибраһимов. Диңгездә).

**АЛ ДА ГӨЛ ЧАГЫНДА БҮРЕДӘЙ, ЮК ЧАГЫНДА ШҮРЕДӘЙ.** Тормышы яхшы барганда, малы, акчасы булганда, үзен әллә кем итеп тоту, башка вакытларда мескен сыман, гади кеше булу. *Тик бар алар, барысы да ал да гөл чагында бүредәй, юк чагында шүредәй яшәргә күнегелгән гадәт мантырга ирек бирми* (Ә. Моталлапов. Рисвайлык).

Төрдәше: бар чагында бүредәй, юк чагында шүредәй.

**АЛ ДА ГӨЛ, ЧӘЧӘГЕ ГЕНӘ ЮК.** «Күренеше белән гөл кебек булса да, чәчәге коелган инде» мәгънәсендә (кайбер хатын-кызларга төрттереп әйтү). – *Галияне яшь кызлар кебек диденме, булыр-булыр, барысы да ал да гөл, тик чәчәге генә юк* (Сөйләм).

**АЛ ДА ГӨЛ ЯШӘҮ (ГОМЕР ИТҮ)** *к.* ал да гөл барысы. *[Бәдига] Әлхәмделилла, яучы булып бирдергән кызлары барысы да ал да гөл булып гомер итәләр* (М. Фәйзи. Галиябану).
Төрдәше: ал да гөл <булу> һ.б,

**АЛ ДИМӘҮ, ЯЛ ДИМӘҮ** *к.* ал белми, ял белми. *Ал дими, ял дими, көнне төнгә ялгап эшли* (Сөйләм).
Төрдәше: ал белми, ял белми <эшләү> һ.б.

**АЛ КҮЗЛЕКТӘН (КҮЗЛЕК АРКЫЛЫ / АША) КАРАУ.** Кимчелекләрне күрмәү, идеаллаштыру. *Ни хәл итим? Бер киңәш бир әле, / Ал күзлегем төшеп ватылды* (К. Булатова).
Төрдәше: ал төстә күрү; алсу күзлек; алсу күзлекләр кию; алсу күзлектән (күзлек аркылы; аша) карау; дөньяга алсу күзлектән (күзлек аркылы / аша) карау; зәңгәр күзлектән карау.

**АЛ ТӘГӘРМӘЧ КАЙДАН БАРСА, АРТЫ ДА ШУННАН ТӘГӘРӘҮ.** Иярүчәнлек (яки ярашу) хакында. *Ал тәгәрмәч кайдан барса, арты да шуган тәгәрәргә тиеш була түгелме?* (Р. Кәрами. Кая чабасың, гомер юртагы?).
Төрдәше: ал тәгәрмәч кайдан йөрсә (барса), арт тәгәрмәч шуннан йөрү (тәгәрәү); ал тәгәрмәч кая тәгәрәсә, арт тәгәрмәч тә шуннан тәгәрәү; арбаның ал көпчәге кайдан тәгәрәсә, арты шул эздән тәгәрәү; кәҗә койрык күтәрә дип сарык та койрык күтәргән; кәкреләр янында кәкре, бөкреләр янында бөкре булу; кем<нең> арбасына утырса, шуның җырын җырлау; кемнең көймәсендә, шуның көендә; кендегеә тоташу (бәйләнү; ябышу); кендек берегү; кендек береккән (бәйләнгән) булу; кеше җырын җырлау; кеше көен көйләү 1; кеше кубызына (кураена) бию 2; кеше куян куа дип, син дә куян ку тагы; кеше сүзенә ияру; кеше сүзенә карау; койрык булу; күрше күрше кылана; саескан (карга) сандугач йөрүен йөрим дип, үз йөрүен оныткан; урамдагы ташны күзлеген салып карый; <кемнең дә булса> чанасына кырын ятып җырлау; чүлмәкчедән күрмәкче; эт артыннан койрык; эт артыннан койрык, мәче артыннан йөгерек; Эт, нигә өрәсең? – Син өргәнгә мин өрәм; эт чаба дип бет чаба.

**АЛ ТӘГӘРМӘЧ КАЙДАН ЙӨРСӘ (БАРСА), АРТ ТӘГӘРМӘЧ ШУННАН ЙӨРҮ (ТӘГӘРӘҮ).** *к.* ал тәгәрмәч кайдан барса, арты да шуннан тәгәрәү *[Шамил] Калдырмасаң, менә шул: без арт тәгәрмәчләр. Алгылары – сез. Ал тәгәрмәч кайдан барса, арт тәгәрмәч шуннан тәгәри*(Х. Вахит. Карлыгач канат кага).
Төрдәше: ал тәгәрмәч кайдан барса, арты да шуннан тәгәрәү һ.б.

**АЛ ТӘГӘРМӘЧ КАЯ ТӘГӘРӘСӘ, АРТ ТӘГӘРМӘЧ ТӘ ШУННАН ТӘГӘРИ** *к.* ал тәгәрмәч кайдан барса, арты да шуннан тәгәрәү. *Өммегөлсем карчык та белә һәм беркайчан да исеннән чыгармый: һәр киемнең ата һәм ана каптырмасы була: ал тәгәрмәч кая тәгәрәсә, арт тәгәрмәч тә шуннан тәгәри...* (А. Хәлим. Кыйбла).
Төрдәше: ал тәгәрмәч кайдан барса, арты да шуннан тәгәрәү һ.б.

**АЛ ТӨСТӘ КҮРҮ** *к.* ал күзлектән (күзлек аркылы; аша) карау; *Кияүгә барганчы, Нәгыймә дөньяны ал төстә итеп күрә иде* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).
Төрдәше: ал күзлектән (күзлек аркылы; аша) карау һ.б.

**АЛ <ДА> ЮК, ЯЛ <ДА> ЮК** *к.* ал белми, ял белми <эшләү> . *[Әхмәт] Ә син, син шуларның бәлаләреннән котылыйм дип, көн эшлә, төн эшлә, алай да көчкә генә тамагыңны туйдырасың. Һичбер ал да юк, ял да юк* (Г. Камал. Өйләнәм... ник өйләндем). *Алы юк, ялы юк, эшнең һич очы-башы юк* (Г. Кашшаф).
Төрдәше: ал белми, ял белми <эшләү> һ.б.

*АЛА* ❖ **АЛА БАҺ, МАҺ!** Минзәлә сөйләшендә хуш иссез ак чәчәккә охшаган пападия чәчәге. Н. Исәнбәт әйтүенчә, ак чәчәген өзеп, калган сары төпчегенә балалар «ала баһ, маһ» дип, җылы тын өреп, кат-кат әйткәч, кара бөҗәкләр чабышып чыгалар икән.

**АЛА ДА БАР, КОЛА ДА БАР.** «Барысы да бер үк төрле түгел, төрле кешеләр, үзенчәлекле нәрсәләр бар» мәгънәсендә. *Идегәй токымында ала да бар, кола да бар, баба, – диде Сөем тутай* (Р. Батулла. Сөембикә).

**АЛА ДА ТҮГЕЛ, КОЛА ДА ТҮГЕЛ.** 1. Бер төргә дә кертеп булмый торган. – *Ерактан гына күрдем: ала да түгел, кола да түгел – белмим тагын* (Сөйләм).

2. Бернинди сыйфатын билгели алу мөмкин булмаган. *Кем белә инде, ала да түгел, кола да да түгел* (Сөйләм).

3. *күч.* Бертөрле дә мәсләге булмаган кеше турында. – *Таза егет күренәсең, кызганыч, ала да түгел, кола да түгел икәнсең, әйдә, кирпеч ташырга булышырсың* (Сөйләм).

**АЛА ДА ЯРАМЫЙ, КОЛА ДА ЯРАМЫЙ**. Көйсез кешегә карата әйтелә. *Ала да ярамый, кола да ярамый торган кешеләр була бит, Әхәт тә шундыйлардан иде* (Сөйләм).

Төрдәше: алай да ярамый, болай да ярамый.

**АЛА ЕЛАННЫҢ АВЫЗЫН ЧАГУ.** Усал телле булу. – *Теленә эләгә күрмә, ала еланның авызын чага ул* (Сөйләм).

Төрдәше: агу тел<ле> һ.б.

**АЛА ЙӨРӘК.** 1. Тыштан дус, эчтән дошман булып йөрү. – *Дошманнан курыкма, ала йөрәкләрдән саклан син, – диде шунда берсе* (Сөйләм).

2. Мәхәббәттә тотнаксыз. – *Син сак бул, кызый, аның ала йөрәк дигән даны таралган* (Сөйләм).

**АЛА КАНАТ.** 1. Авылдан китеп, заводка килеп, вакытлыча эшләүче. *[Камил] Туйдың Донбасстан, вәгъдәләрең кая, ала канат, ә?* (Һ. Такташ. Камил). *Китегез моннан. Кош-ш, ала канатлар!* (Г. Ахунов. Хыялый Хәйрүш егетләре).

2. Авылдан бөтенләй аерылып, үзенә бәхет эзләп йөрүче, зимагур. *«Бәхет-бәхет» дидем мин дә... / Күп эзләдем, ала канат булдым гомергә* (Х. Туфан). *Болай әйтсә, алмаячак аны карт. Ала канат кирәкми безгә, диячәк* (Ж. Дәрзаман. Җир авазы).

3. Эшләргә яратмаган, анда-монда күченеп йөрүче.– *Ә без балаларыбызны ала канат итеп, эшкә җирәнеп карый торган итеп үстерәбез* (Г. Ахунов. Этләр патшасы). *Кара син аны, ала канат, нинди көфер сүзләр сөйли* (Р. Низами. Шахмат дәресләре).

4. Элек күчмә тормышта яшәүчеләргә бирелгән исем (култык асларында башка төрле материалдан тегелгән өстәлмә булган), җиңнәрен җилпетеп атта барганда, кошларга охшаш булганнар. Күчмә башкортларны да шулай атаганнар. – *Безнең авыл читендә ала канатлар да күренгәли башлады* (Сөйләм).

**АЛА КАНАТЛАР ӨСТЕНДӘ ОЧУ.** Авылдан читтә йөреп кайтканнардан үзен өстен кую *Хәтеремдә, фронтта хыялланган вакытларымда, исән-сау кайтсам, бу урамнардан ала канатлар өстендә очармын, бөтен кеше мине таныр, мин үзем дә очраган бер кешенең, күңелемнән генә булса да, кулын кысып үтәрмен дип уйлый идем* (Ә. Еники. Икенче көнне).

Төрдәше: ала канат 2.

**АЛА КАР.** Язын эреп бетмәгән карларның җир йөзендә аклы-каралы булып күренүе. *Өч йөз чакрымны җәяү кил дә, уен эшме! Җитмәсә, ала кар мәле* (Т. Гарипова. Умырзая гөлнең гомеркәе).

**АЛА КАР ВАКЫТЫ ҖИТҮ.** Җир өстенең эреп бетмәгән (яки яңа яуган) кардан аклы-каралы булып торуы. *Ала кар вакыты җиткән, тиздән чәчәкләр дә баш калкытыр* (Сөйләм).

**АЛА КАРГА.** Чит-ят нәрсә, кеше. – *Әйдә, синең ала карганы да шулай сынап карыйк* (В. Имамов. Казан дастаны). – *Әйдә, бистәнең ала каргалары белән дуслаштырам* (Н. Гыйматдинова. Җәза).

**АЛА КАРГАДАН АЛАЧАГЫҢ БУЛСЫН.** Биргән бурычыңны алу өмете җылылык бирү. *Бармыйсыңмы әллә, алырбыз әле, ала каргадан алачагың булсын* (К. Кара. Зур акчалар).

**АЛА КАРГАДАЙ АЛДАН АЛА (АЛДАН-АЛЫ) КЫЧКЫРУ.** Булмаган эшне була дип алдан шапырыну. – *Анда да, Бикмулла абзый, ала каргадай алдан ала кычкырмаска кирәк иде* (Г. Бәширов).

Төрдәше: алда булачак туй өчен атна-ун көн элек бии башлау; алда булачак туй өчен хәзердән биеп тору; алдан кычкырган күкенең башы таз була; алдан кычкырган күкенең башы тишелгән (авырткан; ярылган); алдан ук барабан кагып кычкыру; алдан шапырыну; алдар борчагын чәчү; алмаган ат (бия), тумаган тай (колын); алмаган ат, тумаган тай, атланып (атланма) билен сындырырсың; алмаган тавык, салмаган йомырка; атмаган аюның тиресен бүлү (тунау); атмаган куян, асмаган казан; атылмаган төлкенең тиресен тунау; аюны үтермәс борын тиресен сатмыйлар; аюны<ң> үтермәс борын <тиресен> тунау (салдыру; сату); иртә кычкырган этәчнең башы ярыла; иртә кычкырган күкенең башы авырта; куянны тотканчы куыру; күкәй

салмас тавык көн элгәре кытаклый; сөрмәгән җир өстендә тумаган куян баласы; тавыгы йомырка салмаган, чебешләрен инде сатарга уйлау; тумаган атка йөгән ясау; тумаган балага бишек кору; тумаган тайга атлану; тумаган тайны дагалау; тумаган тайның билен сындыру; чыкмаган кояшка кызыну; үтермәгән аюның тиресен тунау; эрләмәгән-сукмаган, әби, <менә> сиңа ыштанлык; эрләмәгән-сукмаган, биатайга күлмәклек; ябага тайны хурлама, язга чыкса ат булыр; яумаган яңгырга балаган кору.

**АЛА КАРГАДАЙ КАЙТЫП ТА ҖИТҮ.** Киткән җиреннән тиз әйләнеп кайтучы кеше. *Аны авылдан чыгып киткән дисәләр дә, бу югалуы озакка бармады, ала каргадай кайтып та җитте* (Сөйләм).

**АЛА КАРГАДАН ХӘБӘР КӨТҮ.** Китәсе булганда, китәргә теләмичә, юк-бар сылтау табып яту. – *Бар, күршенең хәлен белеп чык, китмәде әле ул: ала каргандан хәбәр көтеп ята* (Сөйләм).

**АЛА КОШ.** 1. Ала карга; саесскан кебек сайрый да, җырлый да белми торган кошлар. *Бу агачлыкта ала кошлар гына күренә* (Сөйләм).

2. Затсыз кеше. *Ала кошларга бакмакчы, / газизем, булма такмакчы, / Матур гөлләргә бул былбыл, / нәзакәт багына сакчы* (Дәрдемәнд. Шагыйрьгә).

**АЛА КҮЗ.** Берәрсенә яки нәрсәгә булса да күзен алартып, дошманлык белән карау. *Ни сөйләшсен ул андый ала күз белән!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: акай күз.

**АЛА КҮЗ БЕЛӘН КАРАУ.** Дошман күрү. – *Карамасана ул кош баласына ала күз белән, күзең сукыраер! – диде кинәт Фатихәттәй, Гөлшәһидәнең Гөлчәчәккә кырын карап торуын күреп* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**АЛА КҮҢЕЛ.** Эчтән явыз ниятле кеше. *У..., ала күңел, китсә китә белмәде инде!* (Сөйләм).

**АЛА СЫЕР ТИРЕСЕ.** Язын җирләр анда-монда ачылу турында. *Кая карама, анда ала сыер тиресе: кайда кар, кайда юк* (И. Гази).

**АЛА ТАЗ.** Чәче урын-урын коелып, башы ала калган таз турында. *Сәхнә түрендә ала тазлар белән тулы тазлар гына утыра иде* (Сөйләм).

**АЛА ЭЧ.** Тышкы яктан дус кебек, эчтән исә кара дошман булган кеше. *Кем аны шундый әшәке, ала эч кеше дип уйлаган, авыр чакта ярдәм кулын сузарга әзер кебек иде бит* (Сөйләм).

*АЛАБУТА* ❖ **АЛАБУТА ЕЛЫ.** Икмәк булмаганлыктан, ачлык елында алабута орлыгыннан икмәк пешереп ашаган ел. *Алабута елы иде ул. Халык ише-ише белән читкә китте, ачтан үлде, ә без тары әпәе ашап чыктык* (М. Хәбибуллин. Чоңгыллар).

**АЛАБУТА КҮМӘЧЕН ТАТУ.** Үзләрен таныту өчен башка сыймаслык гамәлләр кылучылар (мәсәлән, табутны ашап бетерү) турында әйтелә, ачлык елларында алабута орлыгыннан икмәк пешерү күзаллана. *...Татымаган тоталитар алабута күмәчен...* (З. Мансуров. Шайтан шамакае).

*АЛАГАЕМГА* ❖ **АЛАГАЕМГА АЛГАНДА (ӘЙТКӘНДӘ).** Гомумән әйткәндә. *Алагаемга алганда, быел авыл советларына сайлау яхшы үтте* (С. Атнагулов).

*АЛАГАЙ-БОЛАГАЙ* ❖ **АЛАГАЙ-БОЛАГАЙ БУЛУ (КИЛҮ).** Бер-бере белән бозылышу. *Алар бер өч ай тирәсе бер-берсе белән алагай-болагай булдылар* (Сөйләм).

*АЛАГАЙГА* ❖ **АЛАГАЙГА ЙӨРҮ.** Бушка йөрү. *Исмәгыйль башкалар катарында алагайга йөрмәс...* (М. Фәйзи. Галиябану).

*АЛАЕН* ❖ **АЛАЕН <УЛ> АЛАЙ ДА.** Бер дәлил китергәндә, аның белән килешеп бетмичә, каршы дәлил ихтималы табылып, кире кагуны аңлата; әйтелгән сүз, фикер белән килешеп җитмәүне белдергәндә кулланыла; шулай (яки дөрес), ләкин... *[Нуретдин] Анысы алаен алай да бит* (К. Тинчурин. Җилкәнсезләр).

*АЛАЙ* ❖ **АЛАЙ БИК...** Нәрсәнеңдер артык югары кимәлдә түгеллеген белдерә. *Алай бик борыныңны күтәрмә, ай ахырында ничек буласын карарбыз* (Сөйләм).

**АЛАЙ БУЛГАЧ.** Алай сез әйткәнчә булгач; әгәр шулай икән; алайса; нинди булса да билгеле бер шартларда. *[Гафифә] Әй! Алай булгач, бик читен икән. Кирәкми, бармыйбыз* (Г. Ка-

мал. Беренче театр). – *Ә ник алай булгач кызарасыз? – дип, шактый гына сүз кызган иде, шул арада үзен философ күрсәтергә тырыша торган бер байбәтчә бер мәчене тотты <...>* (Г. Газиз. Яшьләр кичәсе).
Төрдәше: алайга китсә.

**АЛАЙ БУЛСА.** Алайса, ул вакытта, әгәр дә алай икән. – *Алай булса, хатынсыз тор, өйләнмә, / «Киңәш бир дә фәлән бир», – дип сөйләнмә* (Г. Тукай). *Бит аның бар эше безнең күз алдыбызда, әгәр алай булса, синең белән мин дә...* (А. Алиш. Якты күл буе).

**АЛАЙ БУЛСА БЕР АКЧА ДА, БОЛАЙ БУЛСА БЕР БАКЫР.** «Безнең өчен барыбер» мәгънәсендә. *Үзең кара шунда, минем өчен алай булса бер акча да, болай булса бер бакыр* (Сөйләм).

**АЛАЙ БУЛСА ДА.** Андый очракта. *Алай булса да ашыгырга кирәк түгел* (Сөйләм).
Төрдәше: алай да; алайса; аңа да карамастан; шулай булса да; шулай да; шуңа да карамастан.

**АЛАЙ ГЫНА.** 1. Тырышлык куймыйча. *Ләкин Гыймран абзаңны алай гына чыгырдан чыгара алмассың* (Г. Ахунов. Хыялый Хәйрүш егетләре).
2. Бернинди нәтиҗәсез; җәзасыз. *Алай гына котылырмын дип уйлама, соңрак ныклап сөйләшербез* (Сөйләм).

**АЛАЙ ГЫНА БАРЫП ЧЫКМЫЙ**. «Алай җиңел генә булмый» мәгънәсендә. *Моны, утырып, яхшылап уйларга кирәк, алай гына барып чыкмый* (Сөйләм).
Төрдәше: алай гына <да> түгел; алай гынамы; аннан да бигрәк.

**АЛАЙ ГЫНА МУЛЛА (ПАТША; ХАН) КЫЗЫНДА ДА БУЛА.** 1. Начарлык килеп чыгу ихтималы өчен ачуланмауны үтенү. *Ялгыш гөлнең ботагын сындырганмын, үпкәләмә инде – алай гына патша кызында да була* (Сөйләм).
2. Нәрсәдер эшләнеп бетмәүне танырга теләмәү – «кечерәк гаепне кичерергә дә ярый» мәгънәсендә. *Буяп бетермәгәнгә нигә кызасың – алай гына хан кызында да була* (Сөйләм).
Төрдәше: андый гына <гаеп> кемдә дә була; андый гына <гаеп> мулла (патша; хан) кызында да була; аның ише (кадәр; кебек; чаклы) гаеп патша (мулла; хан) кызында да була; дүрт аяклы ат та абына (абынып куйгалый; сөртенә); дүрт аяклы хайван да сөртенә; кояшта да таплар була; сөртенмәс тояк юк (ике маддә өчен дә).

**АЛАЙ ГЫНА <ДА> ТҮГЕЛ.** 1. Җөмләдә кереш сүз буларак кулланылып, үзеннән соң килгән кисәкнең мәгънәсе әһәмиятлерәк икәнлеген күрсәтә. *Алай гына да түгел, ул азамат ир урыныннан тормаячак* (А. Гыйләҗев). *Алай гына да түгел, бөтен бүлекнең абруена да кагыла бу* (М. Миншин. Кызыл диплом).
Төрдәше: алай гына барып чыкмый; алай гынамы; аннан да бигрәк.
2. «Моның белән генә бетми, тагын монысы да бар» мәгънәсендә. *Алай гына да түгел, ул азамат ир терелеп тормаячак* (А. Гыйләҗев).
Төрдәше: алай гынамы.

**АЛАЙ ГЫНАМЫ.** «Ул гына түгел, тагын бар» дип өстәп кую; шуның өстәвенә; *шулай ук к.:* алай гына <да> түгел. *Алай гынамы – Әмирхан Еники бабай үлеп киткәч, Язучылар берлегендә дә...* (З. Мифтахов. Битараф түгелмен).
Төрдәше: алай гына <да> түгел; аннан да бигрәк.

**АЛАЙ ДА.** 1. Әйтелгән белән килешеп, башка фикер дә бар дип өстәгәндә кулланыла; бернигә дә карамастан. *Алай да әнием бер дә сер сынатмый, мине шатланып каршы ала, булганы белән сыйларга тырыша.* (А. Расих). *Алай да аның баш сөяге астында да ниндидер уй кебек нәрсә булган икән* (Р. Зәйдулла. Коршау).
2. Кире җөмләне баш җөмләгә бәйләгәндә кулланыла; барыбер; ләкин. *Алай да, кыбырсынып йөри торгач, Әнәс Нурның кылларын чиертеп караган иде.* (Н. Гыйматдинова. Алан уртасында ялгыз йорт).
Төрдәше: алай булса да; алайса; аңа да карамастан; шулай булса да; шулай да; шуңа да карамастан.

**АЛАЙ ДА БОЛАЙ <ДА>.** Төрле яклап. – *Нәрсәгә? – диде карчык, кулындагы яулыкны алай да, болай да күрсәткәләп* (А. Гыйләҗев. Җомга көн кич белән...).

**АЛАЙ ДА БУЛМАСА.** Ул чара белән генә барып чыкмаса. *Агачлар астына сыгына балалар барчасы бергә, / Алай да булмаса, барсы төшәләр, / Сикерешеп күлгә* (Г. Тукай).

**АЛАЙ ДА ВАЙ, БОЛАЙ ДА ВАЙ.** Тегеләй дә начар, болай да әйбәт түгел. *Алай да вай, болай да вай. Белмәссең, нәрсә кирәк аңа* (Сөйләм).
Төрдәше: ала да ярамый, кола да ярамый.

**АЛАЙ ДА ИТҮ, БОЛАЙ ДА ИТҮ.** Төрлечә эшләп карау, ләкин файда булмау. *[Әптерәш] Шуннан, алай да итте, болай да итте, мескен Холмогор, ләкин канга сусаган бүре аягын җибәрми* (Т. Гыйззәт. Мактаулы заман).

**АЛАЙ ДА ЯРАМЫЙ, БОЛАЙ ДА ЯРАМЫЙ.** «Вакчыл кешегә ничек тә ярап булмый» мәгънәсендә. *Алай да ярамый, болай да ярамый, ничек кирәген берәү дә белми* (Сөйләм).
Төрдәше: ала да ярамый, кола да ярамый.

**АЛАЙ ДИГӘН БЕЛӘН ДӘ.** Шулай эшләгәндә очы-очка ялганмауга ишарә; «ул рәвешле эш иткәндә, нәтиҗә булмас» мәгънәсендә. *«Алай дигән белән дә», – дип әйтәсе килде* (Г. Бәширов).

**АЛАЙ ДИП ӘЙТЕР ИДЕҢ ДӘ.** «Эш турында бер яктан гына карап уйлавы кыен, икенче ягы да килеп чыгарга мөмкин» мәгънәсендә: әмма ләкин; хәлбуки. *Алай дип әйтер идең дә, шулай булганын берәү дә күрмәгән* (Сөйләм).
Төрдәше: алай дисәң.

**АЛАЙ ДИСӘҢ** *к.* алай дип әйтер идең дә. *Алай дисәң, һаман әле тынычланып җитмәгән хатын-кыз тавышы* (К. Нәҗми).
Төрдәше: алай дип әйтер идең дә.

**АЛАЙ ИКӘН.** «Димәк, эш шулай тора» мәгънәсендә. – *Ә, алай икән, синнән дә көчлерәк зат бир икән, мин шуны белми йөрим икән* (А. Алиш. Эт үзенә ничек хуҗа эзләгән?). *Алай икән! Ниләр җимертеп йөрисең болай, кодача?* (Г. Бәширов).

**АЛАЙ ИТЕП, БОЛАЙ ИТЕП.** Бер хәлгә төшкәндә, аннан чыгу өчен төрле юллар эзләп карау, маташу. *Алай итеп, болай итеп / Уза безнең гомерләр* (Җыр). *Алай итте, болай итте, боргаланды-сыргаланды да, борынын чөя төшеп, чыбыгын болгый-болгый, җил-бил атлап китеп тә барды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**АЛАЙ МИКӘН?** Шөбһәләнеп сорау бирү. – *Алай микән? – диде Күрән би, эчен уып* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).

**АЛАЙ ТҮГЕЛ – БОЛАЙ УЛ, АРПА ТҮГЕЛ – БОДАЙ УЛ.** Нәрсәнең булса да өстән караганча гына түгел, ә җитди булуына ишарә. *Сөйләүчене тыңлап утырды-утырды да, сикереп торып аңлатырга тотынды – янәсе «алай түгел – болай ул, арпа түгел – бодай ул»* (Сөйләм).

**АЛАЙ УК.** Ул кадәр (берәр нәрсәне арттырып сөйләгәндә, киметү максатында кулланыла). *Бераз арттырасың, алай ук булмады ич* (Сөйләм).
Төрдәше: алай бик.

**АЛАЙ УК ТҮГЕЛ.** Нәрсәне дә булса да арттырып сөйләгәндә әйтелә. – *Арттырма инде, алай ук түгел лә* (Сөйләм).

**АЛАЙ ҮТКӘНДӘ ДӘ, БОЛАЙ СҮТКӘНДӘ ДӘ.** Төрле тарафларга әрле-бирле йөрү. *Тутай тирмәсе янынннан алай үткәндә дә, болай сүткәндә дә бабаның тамак кыргалап куйганын ул ишетеп ятты* (Р. Батулла. Сөембикә).

*АЛАЙ-БОЛАЙ* ❖ **АЛАЙ-БОЛАЙ ӘЙТҮ.** Җаен табып әйтү. *[Фаизә] Алай-болай әйтә башласаң, контрибуция, ди* (К. Тинчурин. Йосыф белән Зөләйха).

**АЛАЙ-БОЛАЙ БУЛМАСЫН (БУЛА КҮРМӘСЕН).** Һәрнәрсәдән шикләнеп яшәү. *Ә миңа солдатымны вакытында ашатып, алай-болай булмасын дип хафаланып (чөнки башка частьләрдә ялгыш пуля тиеп. танкка тапталып үлүчеләр дә булды!), кыскасы, хәрби уставтагы бөтен таләпләрнең төгәл үтәлешенә ирешергә кирәк иде* (Ә. Рәшит. Һәркемнең үз сукмагы).
Төрдәше: андый-мондый хәл булмасын (була күрмәсен).

**АЛАЙ-БОЛАЙ БУЛСА (БУЛЫП КУЙСА; БУЛА КАЛСА).** Эшләр ике яклы булып, киртәгә очрау яисә кирәкмәгән якка авышу ихтималын күздә тотып әйтү. *Алай-болай булса, Гафур кисәтер һәм хатын, һичшиксез, каядыр китеп кунар иде.* (Н. Гыйматдинова. Үзем генә беләм...).

**АЛАЙ-БОЛАЙ БУЛУ.** Кирәкмәгән, көтелмәгән хәл килеп чыгу. *Әмма шул ук вакытта нәкъ*

*менә шушы «алай-болай булып», ягъни үлеп китүен уйлап, ул үзенең гомер иткән почмагыннан чыгып китәргә дә теләми иде* (Ә. Еники. Әйтелмәгән васыять).

**АЛАЙ-БОЛАЙ ГЫНА.** Ашык-пошык, аннан-моннан гына. *Амбар артында алай-болай гына әмәлләп куйган сарай тора иде* (Сөйләм).

**АЛАЙ-БОЛАЙ ГЫНА ТҮГЕЛ.** Берәр әйбернең яки эшнең мөһимлеген, кыйммәтен яки катлаулы булганлыгын күрсәтергә кирәк булганда әйтелә. *Алай-болай гына түгел ул, башта сызымын сызарга кирәк* (Сөйләм).

**АЛАЙ-БОЛАЙ ИТКӘЛӘГӘНЧЕ.** Вак-төяк эшләр белән маташканда, тиз арада. *Алай-болай иткәләгәнче кояш та баеды* (Сөйләм).

**АЛАЙ-БОЛАЙ ИТҮ (КИТЕРҮ).** 1. Ничек җитте алай әмәлләү. *Алай-болай итеп, көчкә иллалла үзебезнең авыл урманына чыгып котылдык* (М. Гали). *Минһаҗетдин, күп дип фараз кылган гакылын ходка җибәреп, алай-болай итеп, хатынын юатты* (К. Тинчурин. Ак чирбик).

Төрдәше: әвеш-тәвеш китерү.

2. *к.* азар-бизар итү (китерү) 1; кеше күрмәгәндә, әйтергә ярамаган бозыклыклар эшләү. *Бу калку күкрәкле килендә кайчандыр минем күңелем бар иде, бервакыт аз-маз «алай-болай итеп тә» алгалаган идек* (Г. Ибраһимов). *Әгәренки бухгалтерия сумманы алай-болай итә икән, тиешлесе суд тәртибендә табыла иде* (Ә. Гаффар. Кәфенгә кесә текмиләр).

Төрдәше: азар-бизәр итү (китерү); пыран-заран итү (китерү) 1.

**АЛАЙ-БОЛАЙ КИЛҮ.** Нинди булса да хәлгә, үзгәрешкә, ыгы-зыгыга ишарә итү. *Кинәт кенә идарә ишегалдында алай-болай килә башладылар* (Сөйләм).

*АЛАЙГА* ❖ **АЛАЙГА КАЛГАЧ (КАЛСА).** Көтелмәгән хәл килеп чыкканда, «бездә аңа каршы чарасы бар» кебек әйтем. *Алайга калгач, булмый инде ул дип, бер якка карап, уң кулын селтәде* (М. Гали).

Төрдәше: алайга китсә (китә икән; киткәч).

**АЛАЙГА КИТСӘ (КИТӘ ИКӘН; КИТКӘЧ)** *к.* алайга калгач (калса); ягъни «ул чагында; ул очракта». – *Алайга киткәч, авырны да җиңеп чыгарга кирәк шул, кызым.* (Г. Бәширов). – *Алайга китсә, Туктамышта Чыңгызхан йә Искәндәр түгел инде, – дип, Ширин бәк дөрләп янган утка дары сипте* (В. Имамов. Карабәк).

Төрдәше: алайга калгач (калса).

**АЛАЙГА ТАБА.** Хәрәкәт юнәлешен билгеләү. – *Без алайга таба борылып китәр дип көтмәгән идек!..* (Ф. Яхин. Оптимальлек заманы). *Любань станциясе Петербургтан болайга таба 75 км ераклыкта булса да алайга таба поездлар йөри һәм мондый шәһәр яны поездларында документ-фәлән сорамыйлар иде* (Г. Баттал-Таймас. Мин бер яктылык эзләгән идем).

*АЛАЙМЫ* ❖ **АЛАЙМЫ БУЛГАН, БОЛАЙМЫ БУЛГАН** *әкият.* Сәбәбен ачыкламыйча гына, «эш шуннан гыйбарәт» дигән кебегрәк сүзне дәвам итү. *Алаймы булган, болаймы булган, имештер, бик борынгы бер заманда кошлар белән дүрт аяклы хайваннар арасында бик каты сугыш булган* (Әкияттән). *Алаймы булган, болаймы булган – хәзер моны тикшереп торуның кирәге юк, алга карап эш итик* (Сөйләм).

*АЛАЙМЫНИ* ❖ **АЛАЙМЫНИ ӘЛЕ.** Янау белән бергә шелтәләп әйтү. *Ат түләтү турындагы хәбәр Васфикамалны чыгырыннан чыгарды.* – *Әһә-ә-ә, алаймыни әле?* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

*АЛАКАЙГАН* ❖ **АЛАКАЙГАН КҮЗ** *к.* акай күз. *Алакайган күзләр, шуны да күрмиләр* (Г. Камал).

Төрдәше: акай күз.

*АЛАК-ЙОЛАК* ❖ **АЛАК-ЙОЛАК КАРА<Н>У.** Туктаусыз як-якка карану, шикләнүле карашлар ташлау. *Казан каласының тимер юл вокзалыннан, алак-йолак каранып, корак-корак йөткереп, кулына иске чемодан тоткан бөкре бер карт килеп чыкты* (З. Мәхмүди. Серле кеше).

Төрдәше: алак-ялак кара<н>у; алан-йолан кара<н>у; алан-ялан кара<н>у (тору); алдын (алтын)-йолтын карану.

*АЛА-КОЛА* ❖ **АЛА-КОЛА ГАББАС КОДА.** Гомумән алганда кирәге булмыйча, кода булганлыгы өчен генә кирәк кеше турында. – *Әтисе, чык әле монда, ала-кола Габбас кода килгән* (Сөйләм).

*АЛАК-ТАЛАК* ❖ **АЛАК-ТАЛАК ЙӨРҮ**. Төрле егетләр белән дус булган булып, кыланып йөргән җилбәзәк турында. *Алак-талак йөри торган кыз түгел, ул-бу калса, авылда ишетелми калмас иде* (И. Нәбиуллина. Миләш тәме).

*АЛАК-ТИЛӘК* ❖ **АЛАК-ТИЛӘК КЫЛАНЫШ** *гади с.* Җиңелчә кыланыш, әйберләрнең берсен алып, икенчесен кую, шуны берничә кат кабатлау. *Аның тузгыган чәчләре белән алак-тиләк кыланышлары да кешене үзеннән читкә этәрә торган иде* (З. Бәшири).

*АЛАК-ШАЛАК* ❖ **АЛАК-ШАЛАК ЙӨРҮ** *диал.* Җавапсыз, ваемсыз булу. *Нурлыгаян малаен егет итте, ир итте, алак-шалак йөргән кешедән ударник ясады, Казанга механизаторлар конференциясенә бергәләп бардылар, Мәскәүдә Калинин белән рәттән утырып, карточкага төшеп кайттылар* (А. Гыйләҗев. Язгы кәрваннар).

*АЛАК-ЯЛАК* ❖ **АЛАК-ЯЛАК КАРА<Н>У.** Як-ягына караклар кебек, ялт-йолт яки шикләнеп карану. *Тутай алак-ялак карангалап, чүлне тыңлады* (Р. Батулла. Сөембикә). *Бәрәкәт, акча түгелме соң бу.? Унлык икән. (Алак-ялак каранып, кесәсенә сала)* (А. Әхмәт).
Төрдәше: алак-йолак кара<н>у һ.б.

*АЛАМ-САЛАМ* ❖ **АЛАМ-САЛАМ КЕШЕ.** Җавапсыз, җыйнаксыз кеше. [*Гөлүзә] Алам-салам кеше белән бусаганы да атлатмый ул* (Ю. Әминов. Өти Балак).

*АЛАН-ЙОЛАН* ❖ **АЛАН-ЙОЛАН КАРА(Н)У.** Хәвеф-хәтәрдән сакланып, як-ягына караклар кебек ялт-йолт каранып йөрү. *Каратамак атавына җиләккә яисә чикләвеккә кергәч, куак кыштырдаган саен тирә-ягыңа алан-йолан каранмыйсың...* (Ф. Шәфигуллин. Ак маңгайлы бүреләр). *Кулъяулыгын кесәсенә тыгып, алан-йолан карап алган чакта, аның карашы Нуриәсманың тишәрдәй булып төбәлгән күзләре белән очрашты* (Ф. Садриев).
Төрдәше: алак-йолак кара<н>у һ.б.

**АЛАН-ЙОЛАН КИЛҮ.** Күзне бер нәрсәдән икенче нәрсәгә күчерү. *Шушы дәртле аваздан болай да ярсыган, ашкынуы һич кенә дә сүрелмәгән халык, үзенең кайда торганын да, әле генә сукрана-сукрана кемнәрнедер аты-юлы белән эчтән генә сүгеп торуын да кинәт онытып, кая карарга белмичә алан-йолан килә башлады* (Р. Кәрами. Олы юл да сикәлтәле).

*АЛАН-ЯЛАН* ❖ **АЛАН-ЯЛАН КАРА<Н>У (ТОРУ).** *Аның артыннан, алан-ялан каранып, тавыклар атлый* (К. Әмири). *Болай зурга киткәч, әнисе яклап калыр дип өмет иткән иде Әсфән, кая ул: – Бар-бар, нәрсә алан-җалан килеп торасың, күрше хакларын өйрәнерсең, – дип сыптырып чыгарды* (Г. Сабитов. Күрше хакы).
Төрдәше: алак-йолак кара<н>у; алак-ялак кара<н>у; алан-йолан кара<н>у.

*АЛАҢГЫР* ❖ **АЛАҢГЫР ТИШЕГЕ КЕБЕК.** 1. Җирдә ямьсез зур булып өскә актарылып чыккан, алаңгыр (зур бер мифик җан) ясаган тишек белән чагыштыру. *Иң алда, алаңгыр тишеге кебек борыннарын киңәйтеп, Гариф абзыйның ак күбеккә баткан туры айгыры килә иде* (Сөйләм).

2. Кирәгеннән артык зур ертык, тишекләр. *Колгаларга тарттырып куелган тукымаларда алаңгыр тишеге кадәр ертыклар күренә иде* (Сөйләм).

*АЛАП* ❖ **АЛАП АВЫЗ** *кимс.* 1. Бик зур авыз. *Авылның һәр атламына килеп кысыла торган алап авыз Талия карчык: – Йөрсен, йөрсен выжлап, ачка койрык чәнчеп кайтыр, күрегез дә торыгыз. Ата-ана фатыйхасыннан йөз чөергән бәндәнең уңганы юк әле! – дип, учын чиләндереп каргап озатты егетне* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: алап кадәр 1.

2. Авызында сүз тормаган кеше (теле авызына сыймаган). *Ул бит гомер буена шулай, алап авыз булып кычкырып йөри* (Т. Гыйззәт).
Төрдәше: алапай авыз<лы>; бияләй авыз; борчак авыз; сер тотмас үрдәк; сирәк иләк биш юкә; сирәк теш; тишек авыз, <сирәк теш>; тишек чиләк.

**АЛАП АЯК** *кимс.* Әйберләргә бәрелеп-сугылып йөри торган ипсез, зур аяклы кеше. – *Буе, аягы зур булса, «бу кеше алап кебек», «бу кешенең аягы алап аяк икән» дип чагыштыралар* (Ф. Гарипова. Авылларыбыз тарихы).

**АЛАП КАДӘР** 1. *к.* алап авыз 1. *Ат дагалаганда аяк ботын кыстырган кебек, алап кадәр авызын тутырып сөйләнгән була, тәмле сүзнең ямен җибәрә* (А. Гыйләҗев).

2. *диал.* Төпкә кадәр җәенке, килбәтсез зур. *Базардан килбәтсез, алап кадәр бер торба күтәреп кайткан* (Сөйләм).
Төрдәше: алапай олы.

**АЛАП СУГЫП АТ ӨРКЕТҮ.** 1. Юктан гына кинәт тавыш чыгарып, юкны бар итеп күрсәтеп, кешене куркыту; ипле барган эшнең рәтен бозу. *Андый алап сугып ат өркетеп, юлчыларның арбаларын аудартудан кызык табучы малайларның артларын кычыткан белән генә пешерергә кирәк* (Н. Исәнбәт).
Төрдәше: алап сугып чәүкә куркыту.

**АЛАП СУГЫП ЧӘҮКӘ КУРКЫТУ.** «Юк белән өркетә алмассың» мәгънәсендә кулланыла. *Алап сугып чәүкә куркыту заманнары узып китте инде* (Сөйләм).
Төрдәше: алап сугып ат өркетү.

*АЛАПА* ❖ **АЛАПА КҮТӘРҮ** *диал.* 1. Малны бүлгән вакытта гауга чыгару (< гар. «мал», «трофей»). *Яудан кайткач, алапа күтәрүләр дә булгалаган* (Сөйләм).
2. Шау-шу, гауга чыгару. *Алар, «кемдер алапа күтәрә бугай» дип, ишегалдына чыгып киттеләр* (Сөйләм).

*АЛАПАЙ* ❖ **АЛАПАЙ АВЫЗ<ЛЫ>** *к.* алап авыз<лы>. *Алар башта әнә шул аяклы хәбәрне алапай авыз казанында кайната, аннан үткер кылыч тешләре белән тураклый, шуннан соң ул сүз, шөпшәгә әверелеп, гавам халкына тарала* (С. Поварисов. Пәйгамбәр таңы).
Төрдәше: алап авыз<лы>.

**АЛАПАЙ БЕЛӘН ШАЛАПАЙ.** Әзерне алырга, алдап-юлдап, юләр сатып көн итәргә калган, ир булып җитмәгән, малайлыкны узган ике юньсез тагылдык. *Шулай да Алапай белән Шалапай кебек карашып торуның сукыр бер тиенлек тә фәтвасы юк* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).
Төрдәше: Аг<ы>лы<й> белән Таг<ы>лы<й> <йөрү> һ.б.

**АЛАПАЙ ОЛЫ.** Төпкә таба җәенке булган килбәтсез нәрсә. *Алапай олы мичне сүтеп ташлады* (С. Рәфыйков).
Төрдәше: алапа кадәр 2.

*АЛАР* ❖ **АЛАР АРАСЫНА КАРА КҮЛӘГӘ ЯТУ**. Бер-береңнән читләшү, мөнәсәбәтләр начар якка үзгәрү. *...Шулай да алар арасына кара күләгә ятты шикелле, Мостафин шулайрак сизә, ләкин мөнәсәбәтләре хәзергә искечә бара* (Ә. Еники).
Төрдәше: аңлашылмаучылык чыгу; ара бозга әйләнү; ара бозылу; ара салкын булу; ара салкынаю; ара суыну (өзелү; суыклану); арага <кара> елан керү (яту); арага кара күләгә яту; арага кара мәче (песи) керү (яту); арага киртә кыру; арага күләгә төшү (яту); арага кырау төшү; арага салкын (суык) йөгерү (төшү); арага чөй кагу; арага шайтан керү; арада бушлык ачылу; арада кара елан йөрү; арада<н> салкын (суык) җил исү; арада салкын җилләр хасил булу; арадан аксак эт узу; арадан елан узу; арадан кара мәче (песи) узу (үтү); аралары боз белән тоз кебек; арты белән карату; аяк эзе суыну; боз белән тоз кебек; бугазга бугаз килү; дуслык бетү; дуслык җимерелү; ике арада<н> кара мәче узу (үтү); ике куйның башы бер табакка сыймау; ике тәкә башы бер казанга сыймас; икесен бер казанга салып кайнатсаң да, өреләре бергә кушылмау; кара мәче пәйда булу; кара мәче узу (үтү); кырын <күз белән> карау; мөгезгә мөгез килү; пешермичә ашау; пычакка-пычак (килү); пычакны бугазга терәү; салкын карый башлау; татулык бетү; татулык китү; тереләй йоту; тереләй <тотып> ашау; эт белән мәче дуслыгы кебек; эт белән мәче сыман <яшәү>; этле-мәчеле; этле-мәчеле көн итү (тору; үткәрү; яшәү).

*АЛАРНЫКЫН* ❖ **АЛАРНЫКЫН БЕЛМӘССЕҢ.** Бертөрлелек булмаганлыктан, аларны аңлавы кыен. – *Ләкин аларныкын белмәссең, әллә керәләр, әллә юк, – дип сөйләп китте* (Ф. Яруллин. Кайгырту).

*АЛАСЫ* ❖ **АЛАСЫ БАР, КОЛАСЫ ЮК.** «Теләк бар, ләкин акча (хәл) һ.б. юк» мәгънәсендә. *Нәрсә дияргә инде: дөнья бу, аласы бар, коласы юк* (Сөйләм).

*АЛА-ЧАЛА* ❖ **АЛА-ЧАЛА ГЫНА** *диал.* Аз-маз күзгә чалынган нәрсә. *Мин аны яхшылап белмим, ала-чала гына шунда* (Сөйләм).

*АЛАША* ❖ **АЛАША ИРЕН.** Салпы ирен (аскы ирене салынып төшкән). – *Нәрсәсен таптың шул алаша иреннең* (Сөйләм).

*АЛАШАНЫ* ❖ **АЛАШАНЫ ТӘРТӘ ӨЙРӘТӘ БАШЛАУ.** 1. Алаша юлны үзе белә, җитмәсә

хуҗасы да бар (эшче белән начальник арасына тыгылып, теләсә кем хуҗа (яки белдекле) булып өйрәтә башлаганда әйтәләр). *Алашаны тәртә өйрәтә башлады, менә нәрсә ошамый миңа. Икенче эш, әйтик, районнардагы кешеләр* (Ф. Хөсни).

2. Буйсынмый йөрүчене мәҗбүри булган кагыйдә генә өйрәтә алу. – *Дустыңа әйт әле, эш вакытында әллә кайларга китеп йөрмәсен, уңайсызлансаң, менә бу көн тәртибен кулына тоттыр – алашаны тәртә өйрәтә башлый* (Сөйләм).

3. Буйдакның гаилә коруы һәм хатыны өйрәтә башлавы турында. *Яшь хатын, алашаны тәртә өйрәтә башлый, дип, ахрысы, гаилә дилбегәсен үз кулына алган* (Сөйләм).

*АЛАШАСЫ* ❖ **АЛАШАСЫ <ДА> КОЛЫНЛАУ.** 1. Юк җирдән баю, көтмәгәндә малы ишәю. – *Артында Төрек белән Кырым торса, синең алашаң да колынлар иде, – дип көлемсерәде Булат бәк.* (М. Әмирханов. Гәүһәршад). *Шуннан соң алашасы колынлады Галиәкбәрнең* (Ш. Мөхәммәдев).

Төрдәше: этәче дә йомырка (күкәй) сала һ.б.

2. Эше алга бару. *Алашасы колынлап китте теге училищедан килгән малайның, тиздән осталар рәтенә дә басар* (Сөйләм).

*АЛАЮК* ❖ **АЛАЮК ЧАГЫНДА** *диал.* Башка вакытта. – *Бүген авылга кайтып киләсе бар иде, алаюк чагында бакчага килеп чыкмыйсыңмы?* (Сөйләм).

*АЛАЮККА* ❖ **АЛАЮККА АЛУ** *диал.* Түләүсез яки бик очсыз алу. – *Син аның кыршылган булуына карама, алаюкка алдым мин аны* (Сөйләм).

*АЛАЯК* ❖ **АЛАЯК / АЛА АЯК АТ.** Бәкәле ак булып, башка җирләре бүтән төсле булган ат. *Ат яхшыкайлары алаяк, / Тун яхшыкайлары төлке аяк, / Бер без генә мактамыйбыз, / Безне мактый бөтен тирә-як* (Җыр).

*АЛБАСТЫ* ❖ **АЛБАСТЫ БУЛЫП ЯТУ.** Кылынган явызлыкларга ишарә. *Әти, кулларын айкап, алпавыт җирләрен күрсәтте: – Әнә теге яктан безнең җирдә албасты булып Цызган ята, бу яктан – Черпак алпавыты* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**АЛБАСТЫ ПӘРИЕ.** Кеше куркытырлык ямьсез, рәтсез кеше. – *Әйдә, киттек моннан, тагын теге албасты пәрие килә* (Сөйләм).

*АЛГА* ❖ **АЛГА АЛУ (АЛГАН ЭШ).** Күз алдында тоту; уйланылган, максат итеп куелганны гамәлгә ашырырга керешү. *Йөрде алар капитал койрыгына ялганып, / Ташлап вөҗданны, мөнафикълыкны алга алып* (Г. Камал).

Төрдәше: алга кую.

**АЛГА БАРУ (КИТҮ).** 1. Берәр өлкәдә үсешкә ирешү, үсештә булу; нәтиҗәле эш алып бару. *Ал җәсарәт, алга омтыл, һич ялыкмый алга бар!* (Г. Тукай). *Революциядән соң Грузия культурасы киң адымнар белән алга китә* (Г. Кутуй. Язучылар экскурсиясе Грузиядә).

2. Авыруның саулыгы яхшыра башлау. *Хастаханәдә ятуына ике атна булды инде, әмма алга китү сизелми* (Сөйләм).

Төрдәше: алга барыш; алга китеш; алга китү (ике маддә өчен дә уртак).

**АЛГА БАРЫШ** *к.* алга бару 1, 2. *Ә тормышның шул остадан башка / Алга барыш һәм көе юк* (И. Юзеев). *Төрле дарулар эчеп карый, ләкин алга барыш кына сизелми* (Сөйләм).

Төрдәше: алга бару (китү); алга китеш; алга китү.

**АЛГА БАСТЫРУ.** Күзалларга ярдәм итү. *Съезд менә шуларның барысын да күз алдына китереп бастыра* (Г. Кутуй. Журналист язмалары. Беренче хат).

**АЛГА БАСУ.** 1. Мөһим эш-вакыйга килеп җитү. *Эшче кылычы алга басканда, / Шәфкать нуры чиктән ашканда, / Җир калтырап, тетрәп китте* (М. Җәлил).

2. Нәрсәне булса да үтәү көне, хәлиткеч мизгел җитү. *Татар опера театрының төзелүе реаль бурыч булып алга басу һәм аңа репертуар кирәк булуы татар композиторларының игътибарын опера иҗат итүгә борды* <...> (М. Җәлил).

3. Нәрсәне булса да күзаллау. *Әсәрдәге Бикчәнтәев образы әнә шул ялчыларның җыелма образы рәвешендә алга баса* (Л. Минһаҗева. Бөркет чебеннәр ауламый).

Төрдәше: алга килеп басу.

**АЛГА ҖИБӘРҮ.** Эшне, тормышны һ.б.ны үстерү, җайга салу. *Күпләр яңа җитәкченең оешма эшен алга җибәрәчәгенә ышанган иделәр* (Сөйләм).

**АЛГА КАРАУ.** Киләчәк белән яшәү, киләчәкне күздә тотып эш итү. *Елдан-ел алга китүнең*

*җимеше булып, күзеңне биш кенә елга булса да алга текәп карадыңмы?* (Г. Кутуй. Журналист язмалары. Беренче хат).

**АЛГА КИЛЕП БАСУ** *к.* алга басу 1. *Шуннан соң гына икенче бер уй алга килеп баса* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Аның әдәби мирасына, халыкка иткән хезмәтенә объектив бәя бирү ихтыяҗы шул көннәрдә үк алга килеп баса* (М. Мәһдиев. Яңа бистә Прометее).
Төрдәше: алга басу 1.

**АЛГА КИЛҮ.** 1. *к.* алга килеп басу. *Ләкин, кайчан да булса, кинәтме, әкренләпме барыбер алга киләчәк шундый хәлгә – гәзитләрне һәркем бары тик саф үз теләге белән укый башлаячак чорга әзерләнә торырга кирәк* (З. Мифтахов. Битараф түгелмен).
Төрдәше: алга басу 1 һ.б.

2. Нәрсә булса да тормышка ашу. *Уйга килгән алга килә* (Мәкаль). – *Күңелгә килгән нәрсә алга килми калмый шул* (В. Нуруллин. Яшьнәп үткән яшьлек).

3. Берәр эш-вакыйга белән очрашмый торып, аның асылын белә алмау. *Алга килми белеп булмый / Башның ни күрәчәген* (Җырдан).

4. Өстәлгә ризык китерелү. *Пичәтләнгән шәрабләр алга килгән* (Г. Тукай). *Тозлы кыяр тозлы гөмбә, алма белән, / Алын сайлап, аралашып алга килгән* (Г. Афзал. Банкет).

**АЛГА КИТЕШ.** Үсеш алу. *Төптән фикерләп баксаң, шактый күңелсез хәл килеп чыга: терлекчелек – хуҗалыкның төп тармагы, совхозның алга китеше, яисә, киресенчә, артка калуы терлекчелекнең ничек эшләвенә бәйләнгән* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).
Төрдәше: алга бару һ.б.

**АЛГА КУЮ** *к.* алга алу. *Төгәлрәк әйткәндә, вакыт, информация, материя сыйфатларын тикшереп, болар бер үк нәрсә түгелме соң? дигән фикерне алга куйган идек* (З. Мурсиев. Нокта).
Төрдәше: алга алу.

**АЛГА СИКЕРҮ.** Кабаланып, эш-хәрәкәтнең башкарылу тәртибен бозып, нәрсәнедер элегрәк эшләү. *Тыйнаклыкка килгәндә, шагыйрь төрле очрашуларга атлыгып тормый, рәсми чараларда алга сикереп чыкмый иде* (Г. Гомәр. Шәхесләр һәм шәрехләр).

**АЛГА СӨРҮ (СӨРЕЛҮ).** 1. Беренче урынга кую, үстерергә тырышу. *Кыш көне председатель сайланган чагында, беренче чиратта кандидат итеп Каюм алга сөрелгән иде* (Ш. Камал).

2. Кемгә яки нәрсәгә булса да өстенлек бирү, фикерне куәтләү. *Ул балалар татар театрын булдырырга күптән вакыт дигән фикерне алга сөрде* (А. Әхмәт).

**АЛГА ТАБА.** Моннан соң, киләчәктә. *Училищены исән-сау тәмамлап булса, алга таба укырга кирәк, һәм, һичшиксез, сайлаган юлны үзгәртергә кирәк булыр* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары). *Алга таба яшисең килсә, телеңне читлектә тот, янәсе...* (Р. Низами. Бомж).

**АЛГА ТӨШҮ** *күч.* Юлны нәрсә белән булса да киртәләү; юлга аркылы төшү. *Бер надзиратель минеп алга төште. Бу – саклык чарасы* (И. Салахов. Фаҗига). – *Ислам кинәт кенә урыныннан купты да әнисенең алдына төште* (М. Хәбибуллин. Айбиби).

**АЛГА ЧЫГАРМАУ.** Беренчелекне үз кулында тотып, аны башкаларга бирмәү. *Акмулла – атаклы шагыйрь, акын һәм галим; үзе ясаган ике тәгәрмәчле арбага утырып авылдан авылга, Уралдан Себергә, Төркестанга кадәр йөреп, һәркайда шигырь ярышлары ясап, беркемне дә үз алдына чыгармаган кеше* (Н. Исәнбәт. Унсигезенче елдан бер сәхифә).
Төрдәше: алга чыг<ар>у; алгы сафта бару; алда бару; алдын чыгу; алны бирмәү; беренчелекне бирмәү; җиңеп чыгу, көчлерәк булганыңны күрсәтү; өскә чыгу; өстен булу; өстен калу; өстен тору; өстен чыгу; өстенлек алу; өстенлеккә ирешү; югары булу; югары тору; яхшырак булу.

**АЛГА ЧЫГ<АР>У.** Белемдә, һөнәрдә яки берәр ярышта җиңү, алга китү. *Сәүдәне киң колач белән җәелдерүне, – үзенең дәүләтен экономик яктан һәм культура өлкәсендә алга чыгаруда иң ышанычлы рычагларның берсе саналган Чыңгызхан* (А. Хәсәнов. Җәнбәт җәвере). *Аңлармынмы берзаман, белмим. Алга чыга алмадым, узып киттеләр, узып!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: алга чыгармау һ.б.

*АЛГА-АРТКА* ❖ **АЛГА-АРТКА КАРАМЫЙЧА.** Бернәрсә дә уйламыйча, сакланмыйча.

*Ничектер, һич ялгансыз, алга-артка карамыйча, бер беребезгә эчләрне бушата идек* (Х. Камалов).

Төрдәше: алдын-артын карамыйча; артка-алга карамау.

**АЛГА-АРТКА КАРАНУ.** Бик дикъкатьле, сак булу; яхшылап уйлап җиткермичә, бернәрсә дә эшләмәү. – *Явыз кешеләр бик күп хәзер, аларга явызлык эшләргә ирек бирергә ярамый, – ди ул, аларның икесен дә кисәтеп. – Алдына-артына, як-ягына каранып йөрсәң дә таман гына бу дөньяда* (М. Миншин. Кызыл диплом).

Төрдәше: абай булу һ.б.

**АЛГА-АРТКА КАРАП** *к.* абай булу. *Бер төрлесе, бик сакланып, алдына-артына карап кына сөйләде* (И. Гази. Онытылмас еллар).

Төрдәше: абай булу һ.б.

*АЛГАЙ-САЛГАЙ* ❖ **АЛГАЙ-САЛГАЙ ЙӨРҮ.** Килбәтсез, эленке-салынкы кыяфәттә булу. *Алгай-салгай йөрмә. Тәртипсез киенсәң, йөрешең үзеннән-үзе эленке-салынкыга әйләнә дә* куя (М. Хуҗин. Айның уты сүнгән...).

*АЛГАНГА* ❖ **АЛГАНГА (АЛГАНДА; АЛУЧЫГА) АЛТЫ ДА ӘЗ, БИРГӘНГӘ (БИРГӘНДӘ; БИРҮЧЕГӘ) БИШ ТӘ КҮП** *к.* абага чәчәк аткач (атканда). *Алуы җиңел дә, бирүе генә авыр: алганда алты да әз, биргәндә биш тә күп, диләр бит* (Сөйләм).

Төрдәше: абага чәчәк аткач (атканда) һ.б.

*АЛГАНДА* ❖ **АЛГАНДА БАШ ИЮ, АЛГАЧ АРТНЫ ИЮ.** Бурычка сораганда – иелү-бөгелү, ялагайлану, алгач – сәлам дә бирмәү яки оныту. – *Син нигә аңарга бурычка бирдең, ул бит алганда гына башын ия, ә алгач инде артын иярргә тотына* (Сөйләм).

Төрдәше: абага чәчәк аткач (атканда) һ.б.

**АЛГАНДА – БИСМИЛЛА, БИРГӘНДӘ – ӘСТӘГЪФИРУЛЛА.** Берәр нәрсәне чит кешелән алганда, шатланып алу, бурычны биргәндә, үзеңнекен биргәнгә кәеф кырылу. – *Җүләр, нигә ышандың аның тәмле теленә; алганда, билгеле, бисмилла, биргәндә, көт тә тор, әстәгъфирулла диячәк* (Сөйләм).

Төрдәше: абага чәчәк аткач (атканда) һ.б.

**АЛГАНДА ҮЗЕМ ГЕНӘ АЛГАН ИДЕМ, САТКАНДА ӘТИ БЕЛӘН ДӘ САТА АЛМЫЙМ.** Берәр нәрсәне кыйммәтен белмичә сатып алып, кирәге булмагач, тәҗрибәле ярдәмчеләр белән дә сата алмау. – *Акыл бирүче дә булмаган, алганда үзем генә алган идем, ә сатканда әти белән дә сата алмыйм* (Сөйләм).

Төрдәше: алдым файда итәргә, белмәдем кая илтергә.

*АЛГАНЫҢ* ❖ **АЛГАНЫҢ (ЙОТКАНЫҢ) ЭЧЕҢНЕ ТИШЕП ЧЫКСЫН**. Каргау сүзе (кеше хакын тартып алып ашаучы турында). *Алганың эчеңне тишеп чыксын* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).

Төрдәше: авызыңа таш тыгылсын һ.б.

*АЛГАРАК* ❖ **АЛГАРАК КИТЕП.** Алдан, эзлеклелек сакламыйча. *Монда алгарак китеп булса да, кайбер нәрсәләрне ачыклап китәргә кирәктер* (И. Хуҗин. Татар тарихы)**.** *Бераз алгарак китеп, шунысын да әйтик: Солтанның күренекле большевик Хөсәен Ямашевның вафатына карата язылган мәкаләсе дә шул ук газетада басыла* (М. Мәһдиев. Солтан Рахманколыйның иҗади эшчәнлеге).

*АЛ-ГӨЛ* ❖ **АЛ-ГӨЛ ИТҮ.** Бик яхшы, матур итү. *Ничә еллар инде ир кулы тимәгән квартираны ал-гөл итеп куйды* (С. Сөләйманова. Ялгыз торна).

*АЛГЫ* ❖ **АЛГЫ АЯГЫН АТЛАГАНЧЫ, АРТКЫ АЯГЫН ЭТ АШАУ.** Пошынмый торган, үшән кеше турында. *Бигрәк тә пошынмас кеше булыр икән, алгы аягын атлаганчы, арткы аягын эт ашап китәр* (Сөйләм).

**АЛГЫ ИТӘГЕҢНЕ БАЛА БАССЫН, <АРТ (АРТКЫ) ИТӘГЕҢНЕ МАЛ БАССЫН>.** «Балаларың күп булсын, мал-туарың нык үрчесен» мәгънәсендә. – *«Алгы итәгеңне бала бассын, арт итәгеңне мал бассын» дигән сүзләрне кабатларга ярата иде картәти* (С. Поварисов. Пәйгамбәр таңы). *Яшь киленгә әйтелә торган теләк: «Алгы итәгеңне бала бассын, арткы итәгеңне байлык бассын!»* (Р. Безертдинов. Тәңречелек).

Төрдәше: өегезгә бәрәкәт явып торсын.

**АЛГЫ САФТА БАРУ** *к.* алга чыгармау. *Чөнки илебездәге сыйнфый көрәш, пролетариат диктатурасын ныгыту, гражданнар сугышы, социализм төзү процесслары – барысы да комсомолның актив катнашы, батырлар-*

*ча актив катнашы, алгы сафта баруы белән характерлы булдылар* (М. Җәлил). *Син һәрвакыт алгы сафта бардың, / Эш атыдай тырыш идең син* (Р. Зарипов. Тирән тамырлы Түнтәрем).
Төрдәше: алга чыгармау һ.б.

**АЛГЫ СЫЗЫК.** Дошманга иң якын позиция. *Ул арада алгы сызыкта гөрселдәүләр кинәт тынып калды, шундук бөтен фронт буйлап «ура» кычкырган тавышлар ишетелде* (Г. Бәширов. Сиваш). *– Минә Кавказдан кузгалганга ай була, – диде татарча белгәне. – Фронтка, алгы сызыкка барабыз* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).

**АЛГЫ СЫЗЫКТА МӘЙДАН ТОТУ.** Иң кирәкле, файдалы дип саналу. *Кайчандыр алгы сызыкта мәйдан токтан үлемсез бәрәңге, лаеклы ялга чыккан ветерандай, чәчәк тутәлләре камалышында калган* (Ф. Шәфигуллин. Ак маңгайлы бүреләр).

*АЛГЫР* ❖ АЛГЫР БУЛУ. Уңган, үткен булу. – *Алгыр бул. Зирәк-уңган була күр* (М. Хуҗин. Айның уты сүнгән...).
Төрдәше: авырның өстеннән, җиңелнең астыннан 2 һ.б.

*АЛГЫ-САЛГЫ* ❖ **АЛГЫ-САЛГЫ ГОМЕР УЗДЫРУ (УЗДЫРЫП ЙӨРҮ).** Файдасыз эш белән шөгыльләнү, юкка көч сарыф итү. *Ударниклар шул, синең шикелле алгы-салгы гомер уздырып, чабата туздырып йөрмибез* (Т. Гыйззәт).
Төрдәше: әтәч белән сука сөрү; диңгезгә су кату (ташу); диңгездән кәрзин белән су ташу; җәен өйдә боз киптереп, кышын суган сату; иләк белән җил тоту (тотып маташу); иләк белән кояш ташу; иләк белән су сөзү; иләк белән су ташу; иләк белән якты ташу; иләк белән якты ташып, өйне яктырту; иләкнекен чиләккә авыштыру (бушату) 1; иләктән чиләккә авыштыру; иләктән чиләккә, чиләктән – иләккә; кияү килгәч, тек тә тек, кияү киткәч, сүт тә сүт; комнан бау (аркан) ишү 1; корыны бушка авыштыру 1: корыны бушка аудару 1; корыны бушка әйләндерү 1; кысыр сыерны бозаулату; кычытмаган җирне (арканы) кашу (тырнау); кычытмаганны кашу; сәнәк белән җил куу; сәнәк белән су сөзү; су чыкмаган җирдә кое казу; тигез урында түмгәк булып яшәү; тубал белән якты ташу; чабата туздыру (туздырып йөрү); юкны бушка авыштыру; юкны бушка аудару 1; юкны бушка әйләндерү; юкны бушка бушату; юкны бушка йөкләү; юкны бушка төяү; юкны бушка тутыру.

*АЛГЫСЫ* ❖ **АЛГЫСЫ КӨН.** Алда булачак көннәр. *Алгысы көндә нишләрбез, ике тамак бит әле без* (Ш. Маннур).

*АЛДА* ❖ **АЛДА БАРУ** *к.* алга чыгармау. *Ул да үзе җитәкләгән колхозның алда баруын тели* (В. Нуруллин. Җавап бир, кеше).
Төрдәше: алга чыгармау һ.б.

**АЛДА БУЛАЧАК ТУЙ ӨЧЕН АТНА-УН КӨН ЭЛЕК БИИ БАШЛАУ** *к.* ала каргадай алдан ала (алдан-алы) кычкыру. – *Безнең Гадәния абыстаебыз шулай чуар йөрәк инде ул, ханбикә, алда булачак туй өчен атна-ун көн элек бии бишлый, – дип кеткелдәде күршесе* (М. Әмирханов. Гәүһәршад).
Төрдәше: ала каргадай алдан ала (алдан-алы) кычкыру һ.б.

**АЛДА БУЛАЧАК ТУЙ ӨЧЕН ХӘЗЕРДӘН БИЕП ТОРУ** *к.* ала каргадай алдан ала (алдан-алы) кычкыру. *Алда булачак туй өчен хәзердән биеп торма* («Туйлар.ру» порталы).
Төрдәше: ала каргадай алдан ала (алдан-алы) кычкыру һ.б.

**АЛДА – ГӨЛ, АРТТА – ЧӘЧӘК (КЫЧЫТКАН; ТИГӘНӘК).** «Нихәл?» дип сорагангa «ал да гөл» булып бетмәү җавабы, ягъни күренеп торганы гына яхшы икәненә ишарә. *– Шуның өчен кызларны сайлаганда, белеп сайларга кирәк, күлмәк эчендә икән алар. Алда – гөл, артта чәчәк дигәндәй...* (Ш. Маннур. Агымсуларга карап...).

**АЛДА ИРКӘЛӘҮ, АРТТА ТИПКӘЛӘҮ.** Кеше алдында яхшы сөйләп, үзе югында начар итеп сөйләү. – *Алдыңда матур сүзләр сөйләп иркәләгән, артыңда пычракка батырып типкәләгән кешеләрдән сак бул!* (Сөйләм).

**АЛДА ЙӨРҮ.** 1. Башлап йөрү. *Алда йөрсәң генә абруең үсәчәк* (Сөйләм). *Сакал бар бу хайванда, мөгез дә ярыйсы, койрык ягы дан түгел түгелен, сөтне дә аз бирә, аның каравы көтүдә алда йөри, юлбашчы, әйтергә кирәк* (Р. Зарипов. Тамчы гөл).

2. Хөрмәтләнү; өстен исәпләнү. *Акылы сүздән алда йөри булса кирәк* (Ә. Еники. Рәшә). *Чөнки агай-эне арасында исеме Сибгат Хәким, Шәйхи Маннур, Гали Хуҗи, Шәрәф Мөдәррисләрдән алда йөри ул чакта* (Г. Гомәр. Шәхесләр һәм шәрехләр).

Төрдәше: алдан йөрү.

**АЛДА КҮРҮ.** Игътибарга алу, күз уңында тоту; өстенлек бирү. *Шулай да бу соңгы ике партиянең кайсы дөрест юл белән бара; без кайсын алда күрергә тиеш – моны аера алмый идек, икесенең дә бара торган юлы, теләге бертөсле күренә иде* (Рухи мирас – 2016).

Төрдәше: алда тору; алда тоту; алдын күрү; күз уңында тоту.

**АЛДА ТОРУ.** Кайбер эшләрнең беренче чиратта эшләнүе. *Алда торган хәл итәсе мәсьәләләрнең тагын да берсе ул – дәреслекләр һәм уку әсбаплары язып бастыру* (А. Әхмәдуллин. Офыклар киңәйгәндә).

Төрдәше: алда күрү һ.б.

**АЛДА ТОТУ**. 1. Башкалардан өстен санау, югарырак күрү. *Бер җирдә аулак өй булып, кызлар җыелса, җырда да, уенда да: «Куйчы шуны, җырла «Моңлы Гайшәне!» – дип, һәрвакыт аны алда тоталар икән* (Г. Ибраһимов). *Бигрәк тә төрле халык тәҗрибәләре, авылның тарихы турына ярлы һәм урта тормышлы, аңлы, тәҗрибәле авыл картларын алда тотарга кирәк* (Г. Рәхим).

2. Истә тоту, әһәмиятле санау.– *Хикмәт шунда ки, Рәсәйнең хакимият даирәләре борынгы заманнардан ук тышкы сәясәтне эчке сәясәттән алда тотканнар* (Р. Юныс. Татар гаме).

Төрдәше: алда күрү һ.б. (ике маддә өчен дә уртак).

*АЛДА-АРТТА* ❖ **АЛДА-АРТТА СӨЯВЕ БУЛУ.** «Алда да, артта да таянырга балам бар» мәгънәсендә. – *Аллага шөкер, алда-артта сөявем булган балаларым бар* (Сөйләм).

Төрдәше: алды-артымда сөявем бар.

*АЛДАГЫСЫН* ❖ **АЛДАГЫСЫН АЛЛА БЕЛӘ.** «Алда ни булачагын белмим» диясе урында кулланыла. *Биек тауда бер авыл, / Ничек күтәрми давыл. / Алдагысын алла белә, / Хәзергесе бик авыр* (Җыр).

**АЛДАГЫСЫН ИШӘК КАЙГЫРТСЫН.** Киләчәк турында түгел, бүгенгесе турында уйларга кирәклеге хакында. *Алдагысын ишәк кайгыртсын, дип юатты ул үзен, ичмасам, ахирәт-дусларның эчләре бер янсын әле!* (Ә. Еники. Фәридун белән Фирая)

*АЛДАГЫЧ* ❖ **АЛДАГЫЧ КАПЧЫГЫ.** Кеше алдап яшәүче, үтә ялганчы. *Ул шулай гомере буенча алдагыч капчыгы булып яшәде инде* (Сөйләм).

Төрдәше: алдакчы капчыгы.

*АЛДАКЧЫ* ❖ **АЛДАКЧЫ КАПЧЫГЫ** *к.* алдагыч капчыгы. *Алдакчы капчыгы, үз-үзеңне алдыйсың кебек тоеламы кайчак, ничек үзең белән дөрес булырга?* («Ялкын» ж.).

Төрдәше: алдагыч капчыгы.

*АЛДАН* ❖ **АЛДАН АЛУ (АЛЫП ТОРУ).** Буласы эшне алдан белеп, шуңа хәстәрләнеп тору. *Авыруны алдан ал* (Мәкаль). *Әмма син шул көнне китәргә тиеш, билетлар алдан алып куелган иде* (Р. Мулланурова. Ялгыз каеннан да ялгыз…).

Төрдәше: алдан аяк киенү; аяк киенү (киенеп кую / тору); аяк чолгауларын алдан ук әзерләп кую; аякка алдан киенү (киенеп тору); аякны алдан киенү (киенеп кую); аякны киенә тору; аякны киенү.

**АЛДАН АШАУ.** Килергә тиешлене (яки саклык ризыкны) ваклап алып бетерү. *Алачак бурычыңны алдан ваклап ашап бетергәч, каян сизелсен ди ул* (Сөйләм). *Ә күп вакыт аны берәр атна алдан ашап куялар* (Т. Нурмөхәммәтов. Кабан күле, әй, алкын).

**АЛДАН АЯК АТЛАУ (ЯЛАУ), АРТТАН ҮКЧӘ ТЕШЛӘҮ.** Ялагай, икейөзле кеше хакында. – *Кайдан килеп чыкты бу алдан аяк ялап, арттан үкчә тешли торган кеше?* (Сөйләм).

Төрдәше: астыннан кисеп, өстеннән ямау; бирәдә алабай, аргы якта ялагай; ике йөзле Янус; өстән кармый, астан тырмый; өстеннән уя, астыннан суя; эчле-тышлы бияләй.

**АЛДАН АЯК КИЕНҮ** *к.* алдан алу (алып тору). – *Ә без быел язын, колхоз правлениесенең алдан аяк киенмәве аркасында, тавыкларыбыз бер чеметем фуражсыз, яшь кычыткан ашатып асрадык* (Ф. Хөсни. Җәй башы). *Торам да аптырап як-ягыма күз ташлыйм – дачалар-*

*да басып яшәүчеләр калмады, бик күпләр алдан ук аякларын киенделәр* (А. Гыйләҗев).
Төрдәше: алдан алу (алып тору) һ.б.

**АЛДАН ӘЙТКӘНЕМ БУЛСЫН.** «Әйтеп куям, соңыннан әйтмәде, димәгез» мәгънәсендә. *Алдан әйткәнем булсын, туй дип кенә ике кулыма ике сумка тотып, кон-төн базар юлын таптар хәлем юк* (Ф. Хөсни).

**АЛДАН ӘЙТҮ.** Фараз итү, нәрсәнеңдер булачагын белдерү. *Әмма Газинур турында алдан әйтә алам: югалмас бу егет!* (Г. Әпсәләмов. Газинур). *Беренчесендә дә сәер карт дөресен әйткән дип уйлады тутай, йолдыз киләсен ул алдан әйтте, сүзе рас килде* (Р. Батулла. Сөембикә).

**АЛДАН БАРУ.** Алдынгы булу. – *Ул үзе дә начар түгел! Районда һәрвакыт алдан бара* (Г. Әпсәләмов. Газинур). *Адашкан җаннарга юл күрсәтеп, / Күңелгә ышаныч, дәрт биреп, / Алдан барыр фидакярлар кирәк* (Г. Сафин. Иж буенда).
Төрдәше: юл сабу (яру).

**АЛДАН БҮРЕК САЛУ.** Ни кушсалар шуңа колларча риза булып, алдан ук әзер булып тору. – *Сезнең арагызда да алдан бүрек салу дигән нәрсә бардыр, таныштыр әле берәрсе белән* (Сөйләм).

**АЛДАН ЙӨРҮ** *к.* алда йөрү. *[Муса мирза] Вәт, милләткә хезмәт эшендә алар, вәт, үзләре алдан йөри торган кешеләрдер?* (Г. Исхакый. Җәмгыять). *Афанасий тырышты инде, ул алдан йөрде* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).
Төрдәше: алда йөрү.

**АЛДАН ЙӨРҮЧЕ.** Әйдәп баручы, җитәкчелек күрсәтүче. *1968 елның язында миңа, алдан йөрүче администратор булып, килешүләр төзеп кайту бурычы йөкләнде* (Ә. Зарипов. Кадерле хатирәләр…). *Сез бит инде рәсми рәвештә тәгаенләнгәнче үк шул староста вазыйфаларын башкардыгыз, һәр гомум эштә алдан йөрүче, халыкны оештыручы булдыгыз!* («Кызыл таң» газ.).
Төрдәше: башлап йөрүче.

**АЛДАН КАЛГАНЧЫ <АШАУ>.** Тәмам туйганчы. *Аның бер гадәте бар иде: ул, алдан калганчы ашаганнан соң гына, өстәл артыннан тора иде* (Сөйләм). – *Мин сине бу хәтле юмарт дип уйламаган идем. Алдан калганчы ризык!* (Х. Хәйруллин. Ургыл).
Төрдәше: алдындагын чистартып кую; алдыннан-артыннан калганчы; алкымыннан килгәнче <ашау>; бөкләп кую; гарык булганчы ашау.

**АЛДАН КАЛУ.** Бик мул, артыгы белән булу. – *Барысын да өстәлгә утыртма инде, күбесе алдан калачак бит аларның* (Сөйләм). *Туйганчы бер! / Алдан калганчы бер! / – Барып ашыйм икән кайларга?..* (С. Рәхмәтуллин. Тешләр).

**АЛДАН КАРМАКЛАУ.** Чамалап, өметләнеп тору. *Тәкбиров аны алдан кармаклап йөргән иде* (Н. Мусин).

**АЛДАН КӘГАЗЬ ЙӨРҮ.** *[Габделхәй] Элекке заман түгел бу, авылдан-авылга качып йөрергә. Алдан кәгазең йөри* (Ф. Бәйрәмова. Сандугачның балалары).

**АЛДАН КИРТӘЛӘҮ.** 1. Үз файдасын карау. *Беренчедән, бу безгә тагын бер сабак, «иртәгесен алдан киртәләргә» өйрәнергә вакыт дигән сүз* («Татарстан яшьләре» газ.).

2. Көтелгән хәвеф-хәтәргә әзер булып тору. *Алдагысын алдан киртәләргә өйрәнгән хуҗа кеше, шуңа күрә, ахрысы, бәяләр үзгәрүгә артык коелып төшмәде* («Ватаным Татарстан» газ.).

**АЛДАН КУЛ ЮУ.** Гаеп ителүе мөмкин эшкә катнашудан баш тарту, үзен аклап кую. *Алайса мин алдан ук кулларымны юдым, чәнчелеп китегез* (А. Расих).

**АЛДАН КҮРЕЛМӘГӘН.** Исәптә тотылмаган, булачагы көтелмәгән. *ВАЗ бүгенге көн биеклегеннән, КамАЗ белән чагыштырып караганда, Кама ярлары буенда күпсанлы, алдан күрелмәгән кыенлыкларны җиңгәннән соң гына чагыштырмача җиңел ватыла торган «чикләвек» булып тоела* (В. Шәрипов. Сынаулар аша).

**АЛДАН КҮРҮ.** Булачакны алдан ук белеп тору, чарасын күрү; сизгер булу. *Яхшы, әйдәгез, бу сүзләрне алдан күрү дип түгел, кисәтү дип кенә кабул итик* (А. Тимергалин. «Инкыйраз»га йөз ел).

**АЛДАН КҮРҮЧӘН.** Ни буласын алдан белеп тору; зирәк, акыллы. *Артык нәрсәләр алдан күрүчән Сираҗетдин абзыйның буш базы өстенә куелды* (К. Тинчурин. Дачалар мөбарәк булсын!).

**АЛДАН КЫЧКЫРГАН КҮКЕНЕҢ БАШЫ ТАЗ БУЛА** *к.* ала каргадай алдан ала (алдан-алы) кычкыру. *Алдан кычкырган күкенең башы таз була, ди* (Ш. Фәрхетдин. Ала карга хәйләсе).

Төрдәше: ала каргадай алдан ала (алдан-алы) кычкыру һ.б.

**АЛДАН КЫЧКЫРГАН КҮКЕНЕҢ БАШЫ ТИШЕЛГӘН (АВЫРТКАН; ЯРЫЛГАН)** *к.* ала каргадай алдан ала (алдан-алы) кычкыру. *– Алдан кычкырган күкенең башы ярыла, алдан мактанма әле, – диде Бибигайшә җиңги, көлеп* (Г. Әпсәләмов. Газинур). *Әти-әнисе белән әлегә уртаклашмый торырга булган, алдан кычкырган күкенең башы авырта, дип аңлатты* (Ф. Мөслимова. Алдадым Гөлданияне!).

Төрдәше: ала каргадай алдан ала (алдан-алы) кычкыру һ.б.

**АЛДАН СҮЗ КУЕШКАНДАЙ.** Бер үк нияттәге кешеләрнең бер үк юлда очрашулары турында. *Без, алдан сүз куешкандай, тагын шул тауга килдек* (Ә. Еники).

**АЛДАН ТАЧЫЛДАП ТОРУ.** Башка кешегә әйтергә ирек бирмәү, кешедән алда сөйләргә ашыгу. *Тик әллә нидәй итеп, алдан тачылдап торуына ачуым килде* (М. Фәйзи).

**АЛДАН УК БАРАБАН КАГЫП КЫЧКЫРУ** *к.* ала каргадай алдан ала (алдын-алы) кычкыру. *– Ашыкма, хәбәр килсен әле, алдан ук барабан кагып кычкырма, азагын көтәргә кирәк* (Сөйләм).

Төрдәше: ала каргадай алдан ала (алдан-алы) кычкыру һ.б.

**АЛДАН УК ЙОМШАК САЛАМ ТҮШӘҮ.** Нәрсәнең булса да ничек үзгәрәчәген (нинди нәтиҗә булачагын һ.б) тоемлап, шуңа әзер булып тору. *Үзеңә-үзең алдан ук йомшак салам түшәп куймасаң, егыла башлагач соң булыр!* (Р. Вәли. Шөһрәт).

**АЛДАН ХӘБӘР БИРҮ.** Алдан әйтү. *Бу ни гамәлдер ки. Кыйсмәтнең алдан хәбәр бирүеме бу...* (Р. Батулла. Сөембикә).

**АЛДАН ЧЫГУ.** Өстенлек алу, җиңү. *– Алпамша, ди, син үзең бик куәтле малай, ди, менә шул тауда чабыш була шушы көннәрдә, ди, шунда алдан чыккан кешегә патша Сандугач исемле кызын бирә икән, ди* (Әкияттән). *Ярышның уртасында. / Аларның һаман йә берсе, / Йә берсе алдан чыга* (К. Булатова).

Төрдәше: өстен чыгу.

**АЛДАН ШАПЫРЫНУ.** Булмаган эшне булган кебек алдан шауларга ярату. *– Алдан шапырынмыйк, – дип, ирен тыя Зәйнәп* (Т. Әйди. Капкалар ачылды). *– Алдан шапырынып, быел да оятка каласым килми, вәт!* (Г. Бәширов).

Төрдәше: ала каргадай алдан ала (алдан-алы) кычкыру һ.б

**АЛДАН ЭШЛӘҮ (КИЛҮ** һ.б.). Әйтелгән вакыттан элек, вакыты җитмичә. *Ә мин киттем, / Иртә торып, алдан эшләп, / Кызык иттем!* (Ш. Галиев. Уяткыч сәгать). *Ул һәр кичен алдан килеп, иң соңыннан китә, әле җитмәсә, көндезләрен дә яртышар көн утырып чыккалый торган иде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

*АЛДАП* ❖ **АЛДАП <-ЙОЛДАП> ЙӨРТҮ.** Нәрсә булса да вәгъдә итеп, вәгъдәсен үтәмәү, даими рәвештә алдалау. *Тик күңелдә һаман ялган юрау / Алдап йөртә безне әле дә* (К. Булатова. Җиде тубал бәхет). *Ул бит этеп-төртеп, алдап-йолдап йөртә торган кеше түгел иде. Шул ук көнне Луиза Батыр-Болгарины чакыртты* (Ю. Сафиуллин. «Әйләнә сәхнә...»).

Төрдәше: тәти күрсәтеп йөртү.

*АЛДАП-ЮЛДАП* ❖ **АЛДАП-ЮЛДАП ЮЛГА САЛУ.** Төрлечә юмалап, алдашып, үз ягыңа аудару. *Алган ярың яшь икән, Алдап-юлдап юлга сал* (Җырдан).

*АЛДАР* ❖ **АЛДАР БОРЧАГЫН ЧӘЧҮ.** Алдап шапырыну. *Хөсәен абзый шаярып, кеше көлдереп алдар борчагын уңлы-суллы чәчеп яши иде* (Г. Мөхәммәтшин).

Төрдәше: ала каргадай алдан ала (алдан-алы) кычкыру һ.б.

**АЛДАР ТАЗ** *фолькл.* Хәйләкәр, шома кеше. *Хәйлә капчыгы ул, алдар таз, көнче күбәләк, аның юньле кеше юлына тәбе корудан башка шөгыле юк та!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: елан маен ялаган; елан яшен ялаган; карт төлке; карт чыпчык; койрыксыз төлке; шомарган таш 2.

*АЛДЫ* ❖ **АЛДЫ БАРНЫҢ АРТЫ БУЛУ (БАР).** «Эшне башласаң, аның нәтиҗәсе дә була» мәгънәсендә. *Алды барның арты бар тагын, урманнан рөхсәтсез агач кисүләрне тыя алабыз әле* («Татарстан яшьләре» газ.).

**АЛДЫ – ДОШМАН, АРТЫ – ПОШМАН.** Бәхетсез кеше турында: алды дошманнар белән тулы, артын үкенечләр баскан. *Туганда бәхетсез булып туган инде ул, алды – дошман, арты – пошман* (Сөйләм).

*АЛДЫ-АРТЫ* ❖ **АЛДЫ-АРТЫ АРАСЫ КИСЕЛМӘҮ.** Өзлексез рәвештә, тоташтан. *Алды-арты киселмәгән уен төнгә кадәр дәвам итте* (Сөйләм).

**АЛДЫ-АРТЫ ХӘЕРЛЕ (ХӘЕРЛЕГӘ; ЯХШЫ) БУЛСЫН (БУЛА КҮРСЕН)!** 1. Хәвеф-хәтәр, югалтулар мөмкин булганда әйтелә торган теләк. – *Ярар, алды-арты хәерле булсын, сандыгыңны әтиең кичкә китерер, – дип, ничек тиз керсә, шулай тиз чыгып та китте* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

Төрдәше: Алла ахырдан хәерле кылсын!; Алла әвәлен-ахырын хәерле кылсын!; Алла куәт (ярдәм) бирсен (итсен)!; Алла өчен; Алла планыңны юлдаш кылсын; Алла Тәгалә әүвәлен, ахырын хәерле кылсын!; Алла Тәгалә изге сәгатьтә кылсын!; Алла юлдаш булсын!; арты хәерле булсын!; атын мин куштым, ахыры хәерле булсын; әй уңгыры, бер башың мең булгыры!

2. Берәр эшне башлаганда әйтелә. – *Менә бу киртәңне вакытлыча алып торсам гына инде, – дип, абзый колга киртәгә күрсәтте. <…> Менә шулай диген, алды-арты хәерле булсын!* (Т. Нурмөхәммәтов. Кабан күле, әй, алкын).

**АЛДЫ-АРТЫ ЮК**. 1. «Гайбәт итеп, артта сөйләү түгел» мәгънәсендә. *Минем сүзләрнең алды-арты юк, теләсә кайда кабатлый алам* (Сөйләм).

Төрдәше: алдында ни, артында шул.

2. Өзлексез агым. *Юлдагы машиналарның алды-арты юк, әйтерсең, кайдадыр бөяләп торганнар да, хәзер иреккә чыгарганнар* (Сөйләм).

*АЛДЫ-АРТЫМДА* ❖ **АЛДЫ-АРТЫМДА СӨЯВЕМ БАР** *к.* алда-артта сөяве булу. – *Ялгыз яшәүнең ни кызыгы булсын ди, минем, ичмасам, алды-артымда сөявем бар* (Сөйләм).

Төрдәше: алда-артта сөяве булу.

*АЛДЫ-АРТЫНА* ❖ **АЛДЫ<НА>-АРТЫНА КАРАМЫЙ<ЧА>.** 1. Һич тә шикләнмичә һәм курыкмыйча сөйләү, язу. *Ул, җыелган кешеләргә күз ташлады да, алды-артына карамый сөйли башлады* (Сөйләм).

2. Бернәрсәгә дә карамыйча кызу йөгерү яки курыкмыйча хәрәкәт (эш) итү; тәвәккәл булу. <…> *Тычкан, күп уйламыйча, камыллар, чирәмнәр, куе үләннәр арасыннан килеп, үзе кеби кечкенә генә бер ит кисәген злде дә алды-артына карамый сызды* (Г. Тукай). *Ул, алдына-артына карамыйча, Маһинур карчыкларга йөгерде* (М. Әмирханов. Гөлнәзирә).

*АЛДЫН-АРТЫН* ❖ **АЛДЫН-АРТЫН ҖЫЮ (ҖЫЕП ЙӨРҮ).** «Начар эшләргә катнашудан сак булу, җыйнак йөрү» дигәнне аңлата. *Алдыгызны-артыгызны җыеп йөрегез!* («Ватаным Татарстан» газ.).

Төрдәше: абай булу һ.б.

*АЛДЫМ* ❖ **АЛДЫМ ФАЙДА ИТӘРГӘ, БЕЛМӘДЕМ (БЕЛМИМ) КАЯ ИЛТЕРГӘ (ИТӘРГӘ).** Әйберне сатып алуы җиңел, ә сатып җибәрү авыр икәнлегенә ишарә. *Алдым файда итәргә, белмим кая итәргә* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

Төрдәше: алуын ялгыз алдым, сатуын эти белән дә сата алмыйм һ.б.

*АЛДЫМ-БИРДЕМ* ❖ **АЛДЫМ-БИРДЕМ БУЛУ.** Гакыд нигезендә ирле-хатынлы булу. *[Хәлил] Мин әлдә әле алдым-бирдем булуына ышанмыйм* (Г. Исхакый. Алдым-бирдем).

**АЛДЫМ-БИРДЕМ, КИТТЕМ-БАРДЫМ.** Алыш-бирештә яки бурычка алу-түләү хакында сүз куешып, тормышка ашырылгач та юк булу. *Гомумән, алдым-бирдем, киттем-бардым итеп карамаганлыгы күренеп тора иде* (Ф. Хөсни).

**АЛДЫМ-БИРДЕМ ЯСАУ.** 1. Гакыд нигезендә кыз белән егетне ирле-хатынлы дип таныту. *[Гафифә] (ишек артыннан). Алар алдым-бирдем ясаганнар, ди* (Г. Исхакый. Алдым-бирдем).

2. Сату, сатып алу кәсебе белән шөгыльләнү. *[Бики] Ул дивана уйлап торганчы, алдым-бирдем ясап, эшне бетереп куярга кирәк* (Н. Исәнбәт. Хуҗа Насретдин).

Төрдәше: алыш-биреш итү 1; алыш-биреш ясау.

*АЛДЫН* ❖ **АЛДЫН АРТКА <КУЕП>.** Булырга тиешлечә түгел, булырга тиешленең киресе. *Авторлар Габдулла Тукай әкиятен әвеш-тәвеш китереп, сюжетын алдын артка куеп әвәлиләр дә, яңа әсәр иҗат иттек дип, горурланып йөриләр* (И. Хәйруллин. Үз тарихын белмәгәннең киләчәге юк). *[Гөлчирә] Җәбриләр кебек алдын артка куеп сөйләшмә* (Т. Миңнуллин).

**АЛДЫН АРТКА КИДЕМ, КАРТ, МИН ДӘ ТУЙГА КИЛДЕМ, КАРТ.** Кешелек киеме булмаганда, көндәлек киемен үзгәртеп кию, ягъни юкны бар итеп булса да, кешедән төшеп калмаска тырышу. *Карты гаҗәпләнеп карагач, хатыны туктап та тормый: мин дә туйга килдем, карт, алдын артка кидем, карт, дигән имеш* (Мәзәктән).

**АЛДЫН КҮРҮ** *к.* алда тоту. *Хәтта күрше кавемнәр көчле Болгар иленә сыенып, буйсынып яшәүне алдын күрәләр, дошман килгән чакта, бу илне яклау, саклау юлына басалар* (Т. Гыйләҗев. Онытылган әсәрләр).

Төрдәше: алда тоту һ.б.

**АЛДЫН ЧЫГУ.** Ярышта беренчелекне алу. *Егет боларның берсендә дә сер сынатып сыртка төшмәгән, барысында да алдын чыккан* («Казан утлары» ж., 2003, 9).

Төрдәше: алга чыгармау һ.б.

*АЛДЫНА* ❖ **АЛДЫНА КИЛГӘН БӘХЕТТӘН КОЛАК КАГУ.** Бәхетенә туры килгән уңыштан мәхрүм калу. *Булмады, бәхетем алдыма килгән иде, аннан да колак кактым* (Сөйләм).

**АЛДЫНА КИЛГӘНЕН ТЕШЛӘП, АРТЫНДАГЫСЫН ТИБЕП.** Тормышта яки ярышта үзенең барлык көчен куеп, теше-тырнагы белән юл салу. *Минем өчен яңа булган бу урында алдыма килгәнен тешләп, артымдагысын тибеп, үземне танытырга тырыштым* (Сөйләм).

*АЛДЫН-АРТЫН* ❖ **АЛДЫН-АРТЫН БЕЛМИ<ЧӘ>** 1. *кимс.* Үзенең артындагы гаепләрен белмичә, алдындагысын да уйламыйча, кеше турында теләсә нәрсәләр сөйләүчегә карата. *– Үзен генә белеп утырса иде, алдын-артын белми, кеше тикшереп маташа* (Сөйләм).

2. Бернәрсәгә дә дикъкать итмичә. *Хәер, кеше дә бит шулай, нәкъ корыч рельс шикелле, алдын-артын белми эшли-эшли дә көтмәгәндә генә берәр төрле үзгәрештән соң кылт итеп сына да куя* (Л. Хәмидуллин. Буранлы төндә).

**АЛДЫН<А>-АРТЫН<А> КАРАМЫЙ<ЧА>** *к.* алга-артка карамыйча. *Ә ул алдын-артын карамыйча сөйләвен дәвам итә* (Сөйләм).

Төрдәше: алга-артка карамыйча.

**АЛДЫН-АРТЫН КАРАУ (ИСӘПЛӘҮ; ТИКШЕРҮ; УЙЛАУ; ҮЛЧӘҮ).** 1. *к.* абай булу. *– Хәзерге заман кешеләре алдын-артын каткат уйлап, уйларын мең кат уйдырып яши...* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *– Бик үлчәп, алдыңны-артыңны карап йөр... Иң мөһиме – халыкта ризасызлык тудырырлык булмасын* (Ф. Латыйфи. Ак-карага тимәскә).

Төрдәше: абай булу һ.б.

2. Берәр эш-гамәлнең тарихи үзгәрешен, киләчәге ничек булачагын уйлап, төшенеп хәрәкәт итү. *Ул бу көнгә чаклы бер дә алдынартын, киләчәген уйламый йөрде* (М. Гафури). *Балаңны кеше баласы кебек киендерә, тәрбияли алмыйсың икән, ятканда, алны-артны уйлыйсың...* (Р. Зәйдулла. Инкыйраз).

*АЛДЫНГЫ* ❖ **АЛДЫНГЫ СЫЗЫК** *к.* алгы сызык. *Барсы да ашыга шәһәргә, / Билләһи, кызык та соң! / Ни калган инде колынга / Алдынгы сызыкта соң?* (С. Хәким).

Төрдәше: алгы сызык.

*АЛДЫНГЫЛЫККА* ❖ **АЛДЫНГЫЛЫККА ЧЫГУ.** Алга чыгу, башкаларга үрнәк булу, алдынгы эшче-хезмәткәр саналу. *Бүтән җәһәттән алдынгылыкка чыкмаса да, үлемдә беренче нәүбәт аныкы икән* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: алдынгылыкны алу.

*АЛДЫНГЫЛЫКНЫ* ❖ **АЛДЫНГЫЛЫКНЫ АЛУ** *к.* алдынгылыкка чыгу. *Ләкин берсе дә Миңлебай кулындагы алдынгылыкны ала алмады* (Н. Яһудин. Казаклар).

Төрдәше: алдынгылыкка чыгу.

*АЛДЫНДА* ❖ **АЛДЫНДА БАШ ОРУ (ИЮ).** 1. Буйсыну яки талантын хөрмәтләп иелү. *Падишаһ Ибраһим пәйгамбәрне үз янына китерттe, аның алдында баш орды һәм сорады* (Ф. Яхин. Пәйгамбәрләр тарихы).

Төрдәше: алдында бүрек салу; алдында җир үбү; алдында сәҗдә кылу (итү) 1; арка бөгү (бөгеп

тору) 1; әйткәненә күнеп, әйдәвенә йөреп; баш бирү 1; баш бөгү 1; баш ию 1; баш ору 3; баш<ны> салу 2; башмагы астында; бил бөгү 1; бит бирү; бишкә бөкләү (бөгү) 1; буй җирү; буй бөгү 1; дөньяга баш бирү (ию).

2. Мәхәббәтеннән баш ору. *Хан кызы оялып торган Тиле янына килгән дә аның алдында баш орган* (Г. Гыйльманов. Тиле Мәргән).

**АЛДЫНДА БҮРЕК САЛУ.** 1. Дәрәҗәсен танып ихтирам күрсәтү. *Ләкин татар учреждениедә патша сурәте алдында бүреген салса да, түбәтәен салмаган* (Н. Исәнбәт).

Төрдәше: алдында баш ору (ию) 1.

2. Түрәләр алдында бүрекне кулга тотып баш ию. *Тарантас авылга якынлашкан саен, алдында бүрекләрен салып, баш иеп торучылар саны артты гына* (Сөйләм).

**АЛДЫНДА ҖИР ҮБҮ.** Дәрәҗәгә табыну, сәҗдә итү. Элеккеге заманнарда патшалар алдында җир үбү гадәтеннән калган. *Галәветдиннең анасы хан алдындагы җирне үпте дә өенә кайтып китте* («Галәветдин һәм сихерле лампа» әкияте).

Төрдәше: алдында баш ору (ию) 1 һ.б.

**АЛДЫНДА НИ, АРТЫНДА ШУЛ.** «Гайбәт итеп сөйләвем түгел, үзе барында да, үзе югында да бер үк нәрсә сөйлим» мәгънәсендә. *Валлаһи дип әйтәм, бер мыскал да арттырмадым: алдында ни, артында шул* (Сөйләм).

Төрдәше: алды-арты юк 1 һ.б.

**АЛДЫНДА ПЫЛАВЫ, ЙӨРЕРГӘ ОЛАВЫ.** Бай кешенең юлга чыгарга һәрвакыт әзер торуы турында – кием-салымы да, ризыгы да, аты да, арба-чанасы да әзер. *Алдында пылавы, йөрергә олавы* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.). – *Син Зөфәр хаҗи белән тиңләшмә – аның алдында пылавы, йөрергә олавы* (Сөйләм).

Төрдәше: аңарда елан мөгезе дә бар.

**АЛДЫНДА СӘҖДӘ КЫЛУ (ИТҮ).** 1. Аллага табынган кебек йөзен аягына тидерү, ягъни берәрсенә тулысынча буйсыну. *«Җирләрдә һәм күкләрдә булган барча мәхлүклар кайберләре ихтыярый вә кайберләре ихтыярсыз Ходайга сәҗдә кылырлар вә иртәләрдә һәм кичләрдә үзләре сәҗдә кылганда күләгәләре дә сәҗдә кылыр»* (З. Хөснияр. Козгыннар йолдыз чүпли).

Төрдәше: алдында баш ору (ию) 1 һ.б.

2. Олы хис, моң, гүзәллек һ.б. сокландыргыч нәрсәләрне хөрмәт итү билгесе. <…> *сихри елмаюы белән әсир итүче Леонардо да Винчиның Луврдагы Мона Лиза (Джоконда) рәсеме алдында сәҗдә кыласың* (Р. Гаташ). – *Табынып, алдында сәҗдә кылырлык олы сөюләр булган!* (Ә. Гаффар. Энә күзе).

Төрдәше: алдында баш ору (ию) 1 һ.б.

**АЛДЫНДА ТУГЫЗГА БӨГЕЛҮ.** Кирәгеннән артык ярарга тырышып ялагайлану. – *Йә, йөз суыңны түгеп, алдында тугызга бөгелдең, файдасы булдымы соң?* (Сөйләм).

*АЛДЫНДАГЫН* ❖ **АЛДЫНДАГЫН (АЛДЫНДАГЫСЫН) АЛТЫ АЙ ЭЗЛӘГӘН** *кимс.* Хәтерсез кешеләрнең әйбер эзләүләреннән көлү. *Алдындагын алты ай эзләгән шушы буладыр инде, Әминә, күзлегеңне нигә маңгаеңа күтәреп куйдың?* (Сөйләм).

Төрдәше: астындагын (алдындагысын) алты ай эзләгән; башындагы бүреген бер көн буе эзләгән.

**АЛДЫНДАГЫН ЧИСТАРТЫП КУЮ** *сөйл., к.* алдан калганчы <ашау>. – *Без назланып утырганда, Самат алдындагын чистартып куйган иде инде* (Сөйләм).

Төрдәше: алдан калганчы <ашау> һ.б.

*АЛДЫН-ЙОЛДЫН* ❖ **АЛДЫН (АЛТЫН)-ЙОЛДЫН КАРАНУ.** Як-ягына тиз-тиз, ялт-йолт шикле карану. *Тиз генә алдын-йолдын каранды да бакча капкасыннан кереп китте* (Сөйләм).

Төрдәше: алак-йолак кара<н>у һ.б.

*АЛДЫН(Ң)НАН* ❖ **АЛДЫН(Ң)НАН АРТЫ(Ң)!** Күрәсең килмәгән кешене озатканда әйтелә торган сүз. – *Әйдә, әйдә, кайтып биштәреңне җыя тор. Алдыңнан артың!* (Сөйләм).

Төрдәше: алдыннан арты матур (әйбәт; күркәм; сылу; хәерле; ыспай; ямьле; яхшы); алдың – Казан өлгесе, артың – Мәскәү көзгесе; алдыңнан артың, <үкчәңне күтәр (калкыт)>; алдыңнан артың яхшы (әйбәт; күркәм; матур; сылу; хәерле; ыспай; ямьле), <юлларыңа ак җәймә>; артыңа көл; артыңнан бер чабата (чиләк) көл (ком); артыңнан иске чабата; гадәмеңә хәсәнат; дүрт ягың кыйбла; ике дога бер хәер; килгән юлыңа киртә кормаган (тотмаган); килгәндә китә йөр.

**АЛДЫННАН АРТЫ МАТУР (ӘЙБӘТ; КҮРКӘМ; СЫЛУ; ХӘЕРЛЕ; ЧИБӘР; ЫСПАЙ;**

**ЯМЬЛЕ; ЯХШЫ).** «Тизрәк китсә иде» дигән мәгънәдә кулланыла. – *Алдыннан арты яхшы, йөргән җирендә дөмегеп калса, бигрәк тә яхшы, – дип уйланды* (Г. Ибраһимов). *Ә теге пумала баш Люся, үзенә күрә түгел, чынлап үпкәләгән булып, бөтенләй үк чыгып киткән. Китсен, алдыннан арты чибәррәк!..* (Ә. Еники. Рәшә). *Юк, юк, алдыннан арты яхшы. Үгезе үлгән, уртагыннан аерылган* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур). – *Минем төкерек чәчрәсә, сөйләттермә, алдыңнан артың матур, малай* (Н. Гыйматдинова. Ачкыч).

Төрдәше: алдын(ң)нан арты(ң)! һ.б.

*АЛДЫННАН-АРТЫННАН* ❖ **АЛДЫННАН-АРТЫННАН КАЛГАНЧЫ** *к.* алдан калганчы <ашау>. *Менә егет ичмасам, алдыннан-артыннан калганчы өстәл яныннан тормый* (Сөйләм).

Төрдәше: алдан калганчы <ашау> һ.б.

*АЛДЫҢ* ❖ **АЛДЫҢ – КАЗАН ӨЛГЕСЕ, АРТЫҢ – МӘСКӘҮ КӨЗГЕСЕ** *к.* алдын(ң)нан арты(ң)! – *Һай, җаным, алдың – Казан өлгесе, артың – Мәскәү көзгесе икән синең! Әллә шуны раслап җибәрәсеңме* (Сөйләм). *Алдың – Казан өлгесе, артың – Мәскәү көзгесе* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

Төрдәше: алдын(ң)нан арты(ң)! һ.б.

*АЛДЫҢА* ❖ **АЛДЫҢА АК КӨН ТУСЫН!** Якты киләчәк теләү. *Алдыңа ак көн тусын!* (Р. Безертинов. Тәңречелек).

Төрдәше: бәхетенә ай бул!; йөзең ак булгыры!; өегезгә бәрәкәт явып торсын; теләк булу; теләккә ирешү; Ходай ак тормышлар бирсен!; Ходай хәерле итсен!

**АЛДЫҢА КАРА ДА АТЫҢНЫ КУАЛА.** «Юлыңны бел дә эшеңне бел» мәгънәсендә. *Сөйли бирсеннәр, ә син алдыңа кара да атыңны куала* (Сөйләм).

*АЛДЫҢДА* ❖ **АЛДЫҢДА АШЫҢНЫ, АРТЫҢДА БАШЫҢНЫ АШАУ.** Эченнән дошман булса да, тыштан дус булып йөрү. *Чит кешеләр янында сак бул, алдыңда ашыңны, артыңда башыңны ашамасыннар* (Сөйләм).

*АЛДЫҢНАН* ❖ **АЛДЫҢНАН АРТЫҢ, <ҮКЧӘҢНЕ КҮТӘР (КАЛКЫТ)>** *к.* алдын(ң)нан арты(ң)! *Карале, дус кеше, алдыңнан артың ямьле, яхшы чакта үкчәңне күтәр әле син моннан!* (Сөйләм).

Төрдәше: алдын(ң)нан арты(ң)! һ.б.

**АЛДЫҢНАН АРТЫҢ ЯХШЫ (ӘЙБӘТ; КҮРКӘМ; МАТУР; СЫЛУ; ХӘЕРЛЕ; ЫСПАЙ; ЯМЬЛЕ), <ЮЛЛАРЫҢА АК ҖӘЙМӘ>** *к.* алдын(ң)нан арты(ң)! *Бар, бар, энем, хакыңны алдың. Алдыңнан артың яхшырак* (Т. Гыйззәт).

Төрдәше: алдын(ң)нан арты(ң)! һ.б.

*АЛДЫР-БОЛДЫР* ❖ **АЛДЫР-БОЛДЫР СӨЙЛӘГӘН, ТОМЫРГАН ДА СӨЯГӘН.** Сүзне аннан-моннан ярты-йорты гына сөйләүче, үзе дә сүзе кебек бер рәтсез кеше. *Районыбызда Мансур кебек ордым-бәрдем кеше башка юктыр, алдыр-болдыр сөйләгән, томырган да сөягән, дия торган иде безнең бабай аның турында* (Сөйләм).

*АЛДЫРГАН* ❖ **АЛДЫРГАН – АТАСЫНЫҢ КУЕНЫН АКТАРГАН.** Үзенеке булмаган әйберләрне урларга яратучы; карак. *Алдырган – атасының куенын да актаргач, барып чыккан инде ул* (Сөйләм).

Төрдәше: аның кулы кәкре; кәкре кул<лы>; кул артлы кеше; кырын куллы; начар куллы; суык куллы; туры куллы түгел.

*АЛДЫРЫР* ❖ **АЛДЫРЫР КӨН ЯЗДЫРЫР.** «Ник алганыңа үкенерсең» мәгънәсендә. *Кичерегез, авылдашлар. Алдырыр көн яздырыр, ди. Гаепле. Нинди җәза бирсәгез дә күтәрермен, өтермәгә генә утыртып куймагыз, биш балам кала бит* (Г. Ахунов. Гомер юлы).

*АЛИҺӘ* ❖ **АЛИҺӘ АВЫРУЫ.** Мәхәббәт авыруы. *Элек бу урында тире һәм алиһә авырулары хастаханәсе иде, хәзер ул каядыр күченгән* (Сөйләм).

*АЛКЫМЫННАН* ❖ **АЛКЫМЫННАН КИЛГӘНЧЕ <АШАУ>** *к.* алдан калганчы <ашау>. *Әйдә, бу ашханәгә кереп, алкымыбыздан килгәнче ашап чыгыйк әле* (Сөйләм).

Төрдәше: алдан калганчы <ашау> һ.б.

*АЛКЫШЛАП* ❖ **АЛКЫШЛАП КАРШЫЛАУ (КАРШЫ АЛУ).** Лаеклы, яраклы дип санау; сәламләү. *Өлгергән арыш, үзенең башакларын селкеп, аны сәламлап калды, чәчәкләргә җөренгән кыр алкышлап каршы алды* (А. Алиш.

Нечкәбил). *Үзен дәрәҗәсен бик белеп кенә тота. Шуңа да Шәзамның келәмгә чыгуын алкышлап каршыладылар* (И. Илдарханов. Ул бөек иде, ләкин…).
Төрдәше: лаек дип табу; лаек күрү; лаек санау; мәгъкуль күрү; муафыйк дип табу; хуп күрү (табу).

*АЛЛА* ❖ **АЛЛА АВЫР ТУФРАГЫН ҖИҢЕЛ КЫЛСЫН** *к.* авыр туфрагы җиңел булсын. *Ул чәчен бер якка сыйпап куйды да эчтән генә «Алла авыр туфрагын җиңел кылсын!» дип пышылдап куйды* (Сөйләм).
Төрдәше: авыр туфрагы җиңел булсын һ.б.

**АЛЛА АВЫР ТУФРАГЫҢНЫ САЛМАК<ЛЫ> ИТСЕН** *к.* авыр туфрагы җиңел булсын. *[Сәфәргали] Хуш, карчык! Алла планыңны юлдаш кылып, авыр туфрагыңны салмак итсен…* (К. Тинчурин. Йосыф белән Зөләйха).
Төрдәше: авыр туфрагы җиңел булсын һ.б.

**АЛЛА АНЫ ДӨНЬЯНЫҢ БЕР ҖИРЕ БУШ КАЛМАСЫН ДИП ЯРАТУ.** Буш, мәгънәсез кеше турында. *Әйтмә дә инде, Алла аны дөньяның бер җире буш калмасын дип кенә яраткан бугай* (Сөйләм).
Төрдәше: адәм дисәң – коны (сыны; юне) юк, хайван дисәң – йоны юк.

**АЛЛА АХЫРЫН ХӘЕРЛЕ КЫЛСЫН!** Нинди дә булса эшнең, вакыйганың уңышлы тәмамлануын теләү. *[Мөхәммәтҗан] Алла ахырын хәерле кылсын… Кая, бер дога кылыйк…* (К. Тинчурин. Беренче чәчәкләр).
Төрдәше: алды-арты хәерле (хәерлегә; яхшы) булсын (була күрсен)! һ.б.

**АЛЛА ӘВӘЛЕН-АХЫРЫН ХӘЕРЛЕ КЫЛСЫН!** *к.* алды-арты хәерле (хәерлегә; яхшы) булсын (була күрсен)! *[Мөхәммәтҗан] Алла әвәлен-ахырын хәерле кылсын!* (К. Тинчурин. Беренче чәчәкләр).
Төрдәше: алды-арты хәерле (хәерлегә; яхшы) булсын (була күрсен)! һ.б.

**АЛЛА ӘҖЕРЕН БИРСЕН.** «Алла яхшылыкның савабын бирсен» дип теләү. *Бик рәхмәт, бик күп ярдәм иттең инде аңа, Алла әҗерен бирсен* (М. Фәйзи). *[Хатын] Рәхмәт инде, хаҗи абзый, балаларны шатландырган өчен Алла әҗерен бирсен* (Г. Камал).

**АЛЛА ӘШКӘРТҮ.** Кыен хәлдә нәрсә эшләргә белмичә торганда, кинәт кенә бу хәлдән котылу юлы башка килү. *Ярый, Алла әшкәртте, мин моның чәчләреннән эләктердем һәм ярга сөйрәп чыгардым* (Н. Исәнбәт).

**АЛЛА БӘНДӘСЕ.** Беркатлы, юаш, бичара кеше. *Бөтен табигате белән ул, ничек дим, кешеләрнең шактый тупасланган күңелләрендә ирексездән шәфкать-миһербанлык хисләре уятучы бер Алла бәндәсе иде* (Ә. Еники. Соңгы китап). – *Алла бәндәсе! Ярар дим бит инде, ә!* (Ә. Гаффар. Дәрья башы).
Төрдәше: Алла бозавы; Алла колы; Ходай бәндәсе.

**АЛЛА БЕЛӘ (БЕЛЕР).** 1. Аллаһ һәр нәрсәне белә. *Бара болар. Күпме баргач, Алла белә, / Юл өстендә үлгән Бүре башын таба* (Г. Тукай. Кәҗә белән Сарык). *Үзеңнең сүтеп ташлыйсы иске өеңә кара син, иске өеңә! Кайчан янтаеп төшәсен Алла белер* (Р. Гаффар. Калай түбәдә эт эзе).
Төрдәше: Алла белсен (белгән); Аллага мәгълүм; Аллаһ кына белә; бер Аллага мәгълүм.

**АЛЛА БЕЛӘН ЮЛЛАШКАН ИШЕ.** Дин әһеле яки аның гаиләсеннән берәрсе яки шуңа мөнәсәбәте булган кемсә. – *Йә, Алла белән юллашкан ише, итәгеңә карап утырма…* (Ә. Гаффар. Дәрья башы).

**АЛЛА БЕЛСЕН (БЕЛГӘН).** 1. *к.* Алла белә. *Ничә еллар таныш икән инде алар, Алла белсен…* (К. Кара. Көнбагыш сатучы). *Әле ерак булачакмы ул, якынмы – Алла белгән* (З. Мәхмүди. Әче балан).
Төрдәше: Алла белә һ.б.

2. «Беркемгә дә мәгълүм түгел» мәгънәсендә билгеселек төсмере булганда кулланыла. – *Алла белсен, / бу китаптан иске дуслар үчләшер! / Һич белер хәл юк җиһанны, / әллә бар да дуслашыр* (Ш. Бабич). *Күн фуражка гына киеп йөри. Ә бу? Алла белсен…* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).
Төрдәше: кем белсен; шайтан белсен.

**АЛЛА БИРӘ.** «Бөтен нәрсә дә Алладан» мәгънәсендә. *[Галия] Файданы Алла бирә ич. [Ибраһим] Алла бирә бирүен дә. Без 12–13 әр сәгать эшләгәнгә бирә шул ул!* (Г. Исхакый. Алдым-бирдем).

**АЛЛА БИРГӘН.** 1. Алла кушуы буенча бирелгән. – *Ә менә безгә Алла биргән чаклысын яшәргә кирәк, – дип очлый ул сүзен* (А. Тимергалин. Игезәкләр).

2. Бушлай килгән. *Алла биргән сырны тешләп Карга иптәш, / Агач башына кунып бисмилла иткәч, / Күзе төште: Төлке килә биеп-биеп* (Г. Афзал. Төлке белән Карга).

**АЛЛА БИРГӘН БУЛСА.** Насыйп булу. *Үзегезнең эшегезне китерер, / Алла биргән булса* (Н. Думави).

Төрдәше: Алла бирсә; Алла боерган булса; Алла боерса; Алла кушкан булса; Алла кушса; Алла теләсә; Алла язган булса; Алла язса; насыйп булса; Ходай кушса; Ходай язса.

**АЛЛА<НЫҢ> БИРГӘНЕ** *иск.* Берәр нәрсәнең, эш яки хәлнең бер-бер артлы килеп торуын хуплап телгә алу. – *Барсы да Аллаһ биргәне!* – *диясеңме* (Ф. Яхин. Гөлбануның кызыл чәчәкле гөле). – *Алла биргәне, сөбханалла, күз генә тимәсен, үсеп беткән ич малай!* (Х. Хәйруллин. Ургыл).

**АЛЛА БИРСӘ** *к.* Алла биргән булса. *Мәҗлесләрдә җырлыйм әле мин аны. Алла бирсә, фашисттан тере калган җыр итеп...* (Ә. Еники. Без дә солдатлар идек). *Пенсиягә чыккач, Алла бирсә, / Алга таба кыю барырмын, / Тыныч күңел белән тыныч кесә, / Дөреслекне ярып салырмын* (Г. Афзал. Тун астында кыюлык).

Төрдәше: Алла биргән булса һ.б.

**АЛЛА БИРСЕН (ЯЗСЫН).** Нәрсә булса да теләгәндә әйтелә. *Алла бирсен инде... Быел язда зур сабан туе ясап, теге әтәчләрнең борынына суктырыйк инде, хәзрәт* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). *Планнары да зур, Алла бирсен, тормышка ашырсын иде диясе генә кала* (М. Миначев. Авылларга барган идем).

**АЛЛА БОЕРГАН БУЛСА** *к.* Алла биргән булса. *Аның яшерен хыяллары чынга ашачак, Алла боерган булса* (Р. Низами. Шәһәр өстендә акчарлак). *Кайтыр, Алла боерган булса, исән-имин кайтыр* (В. Имамов. Утлы дала).

Төрдәше: Алла биргән булса һ.б.

**АЛЛА<һ> БОЕРСА** *к.* Алла биргән булса. *[Сәгыйть] Ул да шулай, башка мәсьәләләр шикелле үк. Алла боерса, юкка чыгар иде* (К. Тинчурин. Беренче чәчәкләр). *Хәер, Сөембикә тутай югала торган бала түгел, исән-сау кайтыр, Аллаһ боерса!* (Р. Батулла. Сөембикә).

Төрдәше: Алла биргән булса һ.б.

**АЛЛА БОЗАВЫ** *к.* Алла бәндәсе. *[Садыйк] Алла бозауларының берсе инде ул!* (К. Тинчурин). *Ханәфи авырып китеп бригадирлыктан төшерелгәч, әнә шул «Алла бозавы»на тикле танымаслык булып үзгәрде <...>* (В. Нуруллин. Җавап бир, кеше).

Төрдәше: Алла бәндәсе һ.б.

**АЛЛА ДА БЕР, ШАЙТАН ДА БЕР.** Икесеннән дә тартынып тормауны, үз кирәгенә карап кайсын булса да чара итеп куллануны аңлата. – *Эшләр зурга китсә, барлык карталарны ачып салачакмын. Миңа үзең беләсең, Алла да бер, шайтан да бер* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**АЛЛА ДИГЕН.** «Бик узынма, Аллаһ ярдәменнән ташламасын дип әйт» мәгънәсендә. – *Моны мин әйтәм сиңа, Лео. И-и, Алла, диген!* (А. Хәсәнов. Данагөл). – *Алла диген, бер Хода диген* (Г. Каюмов).

**АЛЛА ҖАНЫМ.** Берәрсенең хәленә кереп, аны кызганып яки берәр нәрсәдән җирәнеп, шулай ук кызыгып әйтү. *Алла Духованың дөньякүләм билгеле «Тодес» бию төркеме махсус биюләр куя. Алла җаным, шатландырып та карый бит егетләребез* («Идел» ж.).

**АЛЛА ҖИРЕН ҖӘННӘТ КЫЛСЫН** *к.* авыр туфрагы җиңел булсын. *[Мәрьям] Алла җирен җәннәт кылсын* (Г. Камал. Бәхетсез егет. I вариант).

Төрдәше: авыр туфрагы җиңел булсын һ.б.

**АЛЛА<һ> ИМӘН ТАЯГЫН АРКАСЫНА ЮЛДАШ ИТСЕН.** «Кешене җәберләүчегә Аллаһ таягы белән кундырсын» дигән теләк-әйтем. – *Теге юньсезгә Алла иманын түгел, имән таягын юлдаш итсен!* (Сөйләм).

**АЛЛА, ИНДЕ БИГРӘК.** Бик ялындыра торган кешегә карата әйтелә. *Алла, инде бигрәк, әйтмәгән була* (М. Фәйзи).

**АЛЛА ИРКЕНӘ (ИХТЫЯРЫНА) ТАПШЫРУ (КУЮ).** Берәр кешенең (яки нәрсәнең) язмышын Алла теләгенә бәйләү, аны үз карамагына калдыру. *Сәхип Гәрәй ханны бөтен токы-*

*мы берлә Аллаһ ихтыярына тапшырырга да, аның урынына Бакчасарай тәхетенә сәүгелегез Дәүләт Гәрәй шаһзадәне багышларга лаземдер, ихтимал* (Р. Батулла. Сөембикә). – *Син кичер аларны, Аллаһы Тәгалә ихтыярына куй* (Г. Гыйльманов. Албастылар).

**АЛЛА ИРКЕНДӘ (ИХТЫЯРЫНДА).** «Алла ни теләсә, шул булачак»; «Алладан узып берни эшләп булмый» мәгънәсендә. *Бар нәрсә Аллаһы Тәгалә иркендә, ул – һәммәбезнең аңында, безнең аң – аның ихтыярында* (Ә. Эминев. Бер көймәдә...). – *Мин ярдәм итәчәкмен сезгә, – ди Ут өләшүче, Алла ихтыярына каршы төшеп, – мин сезне бәхетле итәчәкмен!* (М. Кәбиров. Бердәнбер һәм кабатланмас).

**АЛЛА ИТЕП КҮРҮ (КАРАУ).** Табынган берәрсен, мөкиббән китеп, Аллага тиң итеп кабул итү. *Фәләх аспирантурада укый башлагач, аны бөтенләй Алласы итеп күрде* (В. Нуруллин. Һәлакәт). *Димәк, әгәр: «Хатын-кызны Алла итеп күрәм», – дисәм, мин аның пәйгамбәре булып чыгам* (М. Кәбиров. Яратам хатын-кызны).
Төрдәше: Алла урынына күрү.

**АЛЛА<һ> ЙОРТЫ.** Гыйбадәтханә, мәчет. «*Алла йорты»на беренче атлап кергәндә, хәйран калдым* (И. Салахов. Тайгак кичү). *Мәчетләр күп. Хан сараена җиткәнче үк, Карабәк утыздан артык Аллаһ йортын санап үтте инде* (В. Имамов. Карабәк).

**АЛЛА КАБЕРЕН ЯКЫН ИТМӘСЕН.** Гүрдә дә тынгылык бирмәс дип шөбһәләнеп, теләк теләү. *Алла каберен якын итмәсен* (Ай колакланса, ни була?1 нче кит.).
Төрдәше: каберең ерак булсын; каберең минекенә якын булмасын <– кереп талап чыгарсың>; каберең янәшә (якын) булмасын, <кәфенеңне талар>.

**АЛЛА КАЗАСЫ.** Уйламаган-көтелмәгән вакытта зур казага очрау. *Шундый бер күңелле көнне, гает бәйрәмендә бу кадәр кайгы килерен Габдулланың кечек энесе Хөсәен берни төшенмичә шашып калып, кешеләрнең «Алла казасы инде» дигән сүзләренең нәрсә икәнен аңламыйча, исе китеп аптырап тора һәм үзенең дөньяны белә башлавыннан бирле Алла белән куркыту сүзләрен кат-кат ишеткәнгә, Алладан куркып, нәүмиз хәлдә бер читкә поскан да, туганы Габдулланы кызганып, үксеп-үксеп егълый иде* (Х. Хәмидулла. Тәкъдир каршында).

**АЛЛА КАРГАГАН (КАҺӘРЛӘГӘН).** 1. Уңышсызлыкка яки даими рәвештә бәлага очраган кеше турында. *Тик Алла каргаган булса кирәк үзләрен, берсе дә кайтып җитә алмаган: кайсы ваба авыруыннан, кайсы бизгәктән юлда гүр иясе булган, ә кайберләре Истанбулда, Измирдә, Әдернәдә тоткарланып, ахырда шунда торып калганнар* (М. Галәү. Мөһаҗирләр).

2. Уңышсыз, уңмый торган урын турында.– *Әйдә, качыйк бу Алла каргаган җирдән* (М. Әмирханов. Әлвидаг). *Менә шундый Алла каргаган җирдә дә суган, кәбестә, бәрәңге, шалкан ише вак-төякне тырмаша-тырмаша үстереп ята халык* (В. Имамов. Тозлы яра).

3. Күңел кайтаргыч, пычрак эш. *Бу Алла каргаган эштән хатын-кыз да читтә калмый (ире яки кул арасына керердәй улы булмаганнарның бөтен авырлык үз җилкәләренә төшә): тула яки йон оекларын салып ташлап, озын ыштан балакларын сызганып, күлмәк итәкләрен ыштан бөрмәсенә кыстырып тирес басалар* (Р. Кәрами. Олы юл да сикәлтәле).

**АЛЛА КАРШЫНА (КАРШЫСЫНА; ХОЗУРЫНА; ЯНЫНА) КИТҮ** *к.* авыздан җан чыгу. *Бүген инде Миркасыйм ага да, Туфан ага да Аллаһ хозурына китеп барды* («Мәдәни җомга» газ.). *Йә динеңә ышанычың сынар, / Йә Аллаһ янына китәрсең!..* (Г. Сафин. Иж буенда).
Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

**АЛЛА КОДРӘТЕ БЕЛӘН.** Алланың ихтыяры, хәлиткеч көче. *Боерган булса, зур кеше булачак Нәҗип Нургалиев! Алла кодрәте белән цех начальнигы, баш инженер, директор булып китәр...* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**АЛЛА КОЛЫ** *кимс., к.* Алла бәндәсе. – *Тимәсәнә шул Алла колына, – диеште кызлар, әмма уена кергән әйберне эшләмичә туктамаган «әҗен тубалы», йөгереп барып, арты белән торган карчыкны этеп җибәрде* (Н. Гыйматдинова. Кыргый). *Алла колы ул. Ләкин дирижер пультына бастымы, камыштай таякчыкны кулына алдымы – бүтәннәр генә түгел, хәтта Сәйдәш үзе дә үзен үзе танымаслык илаһи бер халәткә керә иде* (Р. Низами. Сәйдәшнең соңгы елы).
Төрдәше: Алла бәндәсе һ.б.

**АЛЛА КОШЫ.** Кеше булып формалашып җитмәгән берәрсе турында. *Вәли карт: «Җиңеләя башлаганмы әллә бу Алла кошы?» – дип уйлады да бик тиз ул уеннан кире кайтты – карчыкның бөтен кыяфәтеннән, бөтен тотышыннан тирән кайгы кичерү бөркелеп тора иде* (А. Гыйләҗев. Җомга көн кич белән...).

**АЛЛА КУӘТ (ЯРДӘМ) БИРСЕН (ИТСЕН)!** Берәр эшне башкарганда әйтелә торган изге теләк. *Хәкимулла кепкасын басыбрак киде дә эчендәге ярсуын сиздермәскә тырышып сүз катты: – Алла куәт бирсен!* (Ф. Шәфигуллин. Эшлексез). *Алла ярдәм бирсен, Әмир абый!* (В. Имамов. Тозлы яра).

Төрдәше: алды-арты хәерле (хәерлегә; яхшы) булсын (була күрсен)! һ.б.

**АЛЛА КУЛЫНДА.** Ни язылган булса, шул булыр. *Болар барысы да кодрәтле Алла кулында* (А. Нәҗми. Урман сере). *Барыбызның да язмышларыбыз Аллаһы Тәгалә кулында* (Г. Галиева. Газзәбану).

**АЛЛА КУНАГЫ.** Чакырылмыйча да бик вакытлы килгән кеше. *«Чакырылмый килгән – Алла кунагы» дигән тәгъбир дә бар бит* (Х. Мәхмүтов. Изге китаплар кайтавазы). *Дәрвиш: – Дәрвиш Алла кунагы, инсафыңа кил, дивана, кабул ит! Кунак ит!* (Л. Хәйдәрова. Кырым хикәясе).

**АЛЛА КУШКАН БУЛСА** *к.* Алла биргән булса. *Мондый бозык елларны***,** *Алла кушкан булса, шуның белән дә рәткә керер* (Г. Толымбай. Нигә кыр үрдәге булмаганнар).

Төрдәше: Алла биргән булса һ.б.

**АЛЛА КУШСА** *дини, к.* Алла биргән булса. *Бүген сине, чибәркәй, хәләл җефетеңә илтеп ташларбыз, Аллаһ кушса...* (К. Нәҗми). *Алла кушса, Шаһиәхмәт белән абыйсы да, әтиләре кебек, икәү генә баскычта серләшер* (Н. Гыйматдинова. Шырагай).

Төрдәше: Алла биргән булса һ.б.

**АЛЛА КҮРЕРГӘ ЯЗМАСЫН** *дини.* Берәр яман хәлнең яки бәланең кешегә килмәвен теләү. *Мондый авырлыкларны Алла күрергә язмасын инде* (Сөйләм).

Төрдәше: Алла<h> сакласын! һ.б.

**АЛЛА КҮРСӘТМӘСЕН** *дини, к.* Алла<h> сакласын! *[Әхмәдулла] Алла күрсәтмәсен. Җаным чыга язды!* (Г. Исхакый. Зөләйха). *Нуриянең йөрәге «жу» итеп китте, күңеленә мондый уй килгәч, картлар кебек, як-ягына төкергәләнеп куйды: «Аллам күрсәтмәсен! Әйттем исә кайттым!»* (Я. Зәнкиев. Өтелгән мәхәббәт).

Төрдәше: Алла<h> сакласын!; Алла язмасын!; Аллаһы Тәгалә сакласын!; Ходай сакласын!

**АЛЛА МӘХЛУГЫ** *дини, к.* Алла бәндәсе. *Гамбәргә килененең «ачышы» кызык түгел, чөнки нинди генә кушамат таксалар да, ул үзенең Аллаһ мәхлугы икәнен белә иде* (Н. Гыйматдинова. Үлмәс).

Төрдәше: Алла бәндәсе һ.б.

**АЛЛА НАСЫЙП ИТСӘ (ИТСЕН)** *дини.* Берәр эшкә керешкәндә, алладан да яклау теләү. *Карт кечкенә ак сакалын кәкре бармаклары белән астан өскә тараштырып, Зөфәргә әйтте: «Менә кем, Зөфәр туган, бакчада хәзер җил дә йөрер, кояш та күп, җимеш тә мул булыр, Алла насыйп итсә!» – диде* <...> (Ә. Еники. Рәшә).

**АЛЛА НИ ДӘ, КАРГА НИ.** Аермасы юк. *Аларга Алла ни дә, карга ни. Матур гына булсын* (М. Фәйзи).

Төрдәше: алла да бер, шайтан да бер һ.б.

**АЛЛА ОРСЫН!** *дини.* «Аллаһ үз җәзасын бирсен» мәгънәсендә. *– Валлаһи, билләһи, аллам орсын, җир Йотсын диген?* (К. Кәримов. Ком сәгате).

Төрдәше: Алла суккыры! һ.б.

**АЛЛА ОРУ.** Алланың җәза бирүе. *[Зәйнәп] Күп яши алмассың. Алла орыр әле* (Г. Камал. Каениш). *Хисам абый: – Аллаһы орган икән! – дип җибәрде. – Ничек күрдең?* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**АЛЛА ӨЧЕН**. Нәрсәнедер бик көчле үтенгәндә кулланыла. *– Булды, булды! Җитәр, җитәр, Алла өчен җитәр инде, Гайса, синең белән сөйләшү мөмкин түгел! – дип, Гайса әфәнденең сүзен кисте Хисаметдин* (М. Акъегет. Хисаметдин менла). *Шунда вәзир куенынннан бер кәгазь чыгарып әйтте: – И падишаһ, Алла өчен, бу кәгазьне укы* (К. Насыйри).

Төрдәше: алды-арты хәерле (хәерлегә; яхшы) булсын (була күрсен)! һ.б.; *шулай ук к.:* Алла ризалыгы өчен (ризалыгына) һ.б.

**АЛЛА ПЛАНЫҢНЫ ЮЛДАШ КЫЛСЫН.** «Алланың рәхимлеге сиңа җитсен» мәгънәсендә. *[Сәфәргали] Хуш, карчык! Алла планыңны юлдаш кылып, авыр туфрагыңны салмак итсен...* (К. Тинчурин. Йосыф белән Зөләйха).
Төрдәше: алды-арты хәерле (хәерлегә; яхшы) булсын (була күрсен) һ.б.

**АЛЛА РИЗА (РАЗЫЙ) БУЛСЫН.** Кешенең кылган фигыль-гамәлләре Аллаһы Тәгалә тарафыннан хупларлык дип фараз итү. *Әниең мәрхүмә, рәхмәт, Алла разый булсын, яшь вакытымда бик зур файдалар итте* (Г. Исхакый). – *Бик яхшы, Алла разый булсын, – диде карчык, олуг юристның сүзе белән килешкәндәй итеп* (З. Бигиев. Зур гөнаһлар).

**АЛЛА РИЗАЛЫГЫ ӨЧЕН (РИЗАЛЫГЫНА)** *к.* Алла өчен. – *Бай, Алла ризалыгы өчен, ятим баланы кызганып булса да ал инде, Алла аның өчен сиңа башка җирдән бирер, – дип ялварды* (К. Тинчурин. Кара көннәрдә). *Мөселманның чын максаты – Алланың ризалыгына ирешүдер* (Р. Аляутдинов. Дини бәйрәмнәр).
Төрдәше: Алла өчен һ.б.

**АЛЛА<һ> САКЛАСЫН!** «Була күрмәсен» мәгънәсендә. *Өйлә намазына дип тәһарәт яңарткан хәзрәт үзенең фамилисен шул секундта «Йолдыз» битләрендә итеп күз алдына китерде. Алла сакласын, Алла сакласын* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала). *Алла сакласын, юл аулак, кеше-мазар күренми, ташланырга да күп сорамаслар* (М. Әмирханов. Зиннәтулла хәзрәт).
Төрдәше: Алла күрсәтмәсен! һ.б.

**АЛЛА САКЛАСЫН, АРБА БАСМАСЫН, ТАЙ ДУЛАМАСЫН.** «Көтелмәгән җирдән бәла-каза чыкмасын» дип теләү. *Почмакта шыпырт кына утырган бабай да сүзгә кушылды: «Алла сакласын, арба басмасын, тай дуламасын»* (Сөйләм).
Төрдәше: Алла күрсәтмәсен! һ.б.

**АЛЛА САКЛАСЫН, КАРА ЕЛАН ЧАКМАСЫН!** «Бәла дошманыңнан килмәсен» мәгънәсендә. *«Дөньяда әллә нинди кешеләр бар, Аллам сакласын, кара елан чакмасын», – дип елап җибәрде әни* (Сөйләм).
Төрдәше: Алла күрсәтмәсен! һ.б.

**АЛЛА САРЫГЫ.** Карусыз, бичара кеше турында. *Аннан нинди зыян булсын ди, Алла сарыгы бит ул* (Сөйләм).
Төрдәше: алла бәндәсе һ.б.

**АЛЛА, САТАША КҮЗЕМ, ӘЛЛӘ САТАШАМ ҮЗЕМ.** Кешене танымый торганда, аны танырга тырышканны белдерә. *Парк сукмагы буйлап барганда, өлкәрәк яшьтәге берәү: «Алла, саташа күзем, әллә саташам үзем», – дип, абыйның җиңенә орынды* (Сөйләм).

**АЛЛА СИҢА ИСӘНЛЕК БИРСЕН!** Берәрсенең исән-сау булуын теләү (уңай һәм тискәре мәгънәдә кулланыла). *Алла сиңа исәнлек бирсен, тиздән үзеңне кәҗүнни йорт көтә...* (Р. Зәйдулла. Ак эт).

**АЛЛА СУККЫРЫ (СУКСЫН)!** *карг., к.* авыз<лар>ын корт чаккыры! *Иреннәрен / Бер чылатыр иде – су канлы. / Алла суксын! / Шаһгалиләр мине / Урысларга сатып куанды* (Рәш. Әхмәтҗан). – *Бу антымны бозсам, Аллаһ суксын* (Р. Батулла. Сөембикә).
Төрдәше: авыз<лар>ын корт чаккыры! һ.б.

**АЛЛА<НЫ> СҮГҮ.** Аллага каршы начар сүзләр сөйләү. *Беренче дәрестә үк динне, Алланы сүкте, йортта булган Коръән, намазлык, гарәп хәрефле бөтен китапларны, мәктәпкә алып килеп, мичкә ташларга кушты* (М. Мәһдиев. Мәңгелек яз).

**АЛЛА СЫЕРЫ** *мыск.* Бушлай эшләп йөрүче артык юаш кеше. – *Алла сыеры булып йөрүдән туймадыңмы әле?* (Сөйләм).

**АЛЛА ТӘГАЛӘ ӘҮВӘЛЕН, АХЫРЫН ХӘЕРЛЕ КЫЛСЫН!** *к.* алды-арты хәерле (хәерлегә; яхшы) булсын (була күрсен). *Мөбарәк мәҗлесләр булсын, Алла Тәгалә әүвәлен, ахырын хәерле кылсын!* (Г. Исхакый. Алдым-бирдем).
Төрдәше: алды-арты хәерле (хәерлегә; яхшы) булсын (була күрсен) һ.б.

**АЛЛА ТӘГАЛӘ ИЗГЕ СӘГАТЬТӘ КЫЛСЫН!** *к.* алды-арты хәерле (хәерлегә; яхшы) булсын (була күрсен). *[Гарифә] Туй гына ясыймыз, Алла Тәгалә изге сәгатьтә кылсын!* (Г. Исхакый. Алдым-бирдем).
Төрдәше: алды-арты хәерле (хәерлегә; яхшы) булсын (була күрсен) һ.б.

**АЛЛА ТЕЛӘСӘ** *к.* Алла биргән булса. *Без, Алла теләсә, иртәгә кичкә сәфәргә чыгабыз инде* (Ф. Әмирхан). *Андрейның җавабы шактый дорфа чыкты: – Ул – минем варисым. Алла теләсә, олуг кенәз булыр* (В. Имамов. Утлы дала).
Төрдәше: Алла биргән булса һ.б.

**АЛЛА ТЫРНАГАН ЙӨЗ.** Чәчәк авыруыннан бозылып чуарланган йөз. *Мондый чутыр, Алла тырнаган йөзне күргәнем юк иде әле* (Сөйләм).

**АЛЛА УРЫНЫНА КҮРҮ.** Аллага инанган кебек инану. *Юкка гынамы аны Алла урынына күрәләр: кинофильмнар төшерелгән, китаплар язылган, рәсемнәр ясалган* (Р. Кәрами. Олы юл да сикәлтәле).
Төрдәше: Алла итеп күрү (карау).

**АЛЛА ҮЗЕ КУШКАН** *дини.* Сөйләшенгәнне эшләүне әхлак бурычы итеп кабул итү. *Аларга бер гаилә булып яшәргә, туганлашырга Аллаһы Тәгалә үзе кушкан булып чыга* (Ф. Мөслимова. Гөлбүләк).

**АЛЛА ХАКЫНА ДА ЮК.** «Ничек ялынсаң да юк» мәгънәсендә. – *Мескенләнмә инде, Алла хакына да юк* (Сөйләм).

**АЛЛА ХАКЫНА (ХАКЫ ӨЧЕН)** *к.* Алла өчен. *Бөтенләй ташлап бетермәссең инде. Алла хакына дип сорыйм...* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!). *[Сәрбиҗамал] Зинһар әйт, Алла хакы өчен әйт, әллә... ничәме?* (Г. Камал, Уйнаш).
Төрдәше: Алла өчен һ.б.

**АЛЛА ХЕЗМӘТЧЕСЕ (ЯЛЧЫСЫ).** Тәкъва иясе, гомерен дингә багышлаган. *Измайлов башы белән галерея ягына ишарә ясады. – Яле, Алла хезмәтчесе, йозакны келт итеп кенә ач әле* (З. Фәтхетдинов. Үлем элмәге). – *Мулла бар. Мулла белер. / Ул бит – Алла ялчысы!..* (Ф. Яхин).
Төрдәше: Алла юлында йөрүче 1, 2; Алла юлындагы кеше; Аллага ышанучы.

**АЛЛА ХОДАЕМ.** 1. Сәер булып күренгән нәрсәгә дикъкатьне юнәлтү өчен әйтелә. *Ай, Алла Ходаем, кәҗә кайткан түгелме соң?– диде ана* (Р. Батулла. Юл буенда зәңгәр чәчәк).

2. Үпкәләү сүзе буларак әйтелә. *[Шәкүр] Алла Ходаем, куркыттың, котым ботыма төште* (Т. Миңнуллин. Диләфрүзгә дүрт кияү).

**АЛЛА ШАҺИТ.** Ант иткәндә, Алланы таныкитеп алу. – *Алла шаһит, Зөфәр туган, мин сиңа әйтсәм, бары саф дөресен генә әйтәчәкмен* (Ә. Еники. Рәшә). *Үпкәм юк аларга, Аллаһ шаһит* (Р. Батулла. Сөембикә).

**АЛЛА ЮЛДАШ БУЛСЫН!** Бәрәкәтле яшәп, эшләрне уңышлы алып бару теләге. *Алдагы көннәрегездә дә Аллаһ юлдаш булсын, Даимә апа!* («Сарман» газ.).
Төрдәше: алды-арты хәерле (хәерлегә; яхшы) булсын (була күрсен) һ.б.

**АЛЛА ЮЛЫНДА ЙӨРҮЧЕ.** 1. Аллага ышанучы кеше, диндар. – *Димәк, ул ихластан Алла юлында йөрүче түгел, ә котүгә ияргән юлдаш – попутчик* (Ә. Зарипов. Әманәт).

2. *к.* Алла хезмәтчесе (ялчысы). *Коръәни сыйфат аерым мәнәҗәтләрнең бердәнбер темасына әверелә, биредә әлеге сыйфатка ия булган пәйгамбәрләр турында сүз бара; сабыр кешеләр, Алла юлында йөрүчеләр оҗмахка илтүче сират күперен дә җиңелрәк үтәләр* (XII–XX гасыр башы татар әдәб. дини фольклор).
Төрдәше: Алла хезмәтчесе (ялчысы) һ.б.

**АЛЛА ЮЛЫНДАГЫ КЕШЕ** *к.* Алла юлында йөрүче 1, 2. *Күп хатынлык дигәннән, безнең авылның данлыклы мулласы да икенче хатын алам дип бик янып-көеп йөргән иде, хатыны тиз суытты. Алла юлындагы кеше хуплагач, димәк, бу гөнаһ түгел* («Матбугат.ру» порталы).
Төрдәше: Алла хезмәтчесе (ялчысы) һ.б.

**АЛЛА ЯЗГАН БУЛСА** *к.* Алла биргән булса. *Сәрвәр әби эләктереп алды: – Алла язган булса, берни кылыр хәлең юк, кызым* (Н. Дәүли. Язмышка юл). *Менә, Алла язган булса, киләчәктә, ватык сәгатьләрен күтәреп, Тайфун да, дуслар-танышлар да Шәмси янына йөгерәчәкләр әле...* (Җ. Юныс. Сугыштан соң).
Төрдәше: Алла биргән булса һ.б.

**АЛЛА ЯЗГАНЫ** *дини.* «Кешенең гомере, аның агышы алдан ук Алаһы Тәгалә тарафыннан билгеләп куелган була» дигән фараз. *Йөртә, диләр, шайтаны, / күрмәгән тик беркем аны, / бар да Алла язганы* (Р. Зәкуан. Авыл моңы).

**АЛЛА ЯЗМАСЫН!** *к.* Алла күрсәтмәсен! – *Аттан бер колак кактыңмы, бетте инде аннары,*

*бала-чагаң белән өелешеп үләргә генә кала!.. – Алла язмасын берүк!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).
Төрдәше: Алла күрсәтмәсен! һ.б.

**АЛЛА ЯЗСА** *к.* Алла биргән булса. *Көлеп җибәрде. – Бик әйбәт, туй уйнарбыз, Алла язса. Мин киленле булырмын* (И. Салахов. Хәсрәт төенчекләре).
Төрдәше: Алла биргән булса һ.б.

**АЛЛА ЯЗУЫ.** Гарәп хәрефле язу. *Үз күзләренә ышанмыйча, йөрәкнең зурайтылган фотосурәтен карый – шакката, ә иң мөһиме – йөрәктәге Аллаһ язуы адәм баласының асылы нинди булуыннан бәйле түгел икән* (nur.tatar).

**АЛЛА ЯРДӘМ БИРСЕН! СӘЛАМӘТ БУЛ!** Берәр эш белән мәшгуль кешегә сәлам (яки авыру кешенең хәлен белгәндә әйтү) һәм шуңа җавап. – *Исәнмесез, апалар! Алла ярдәм бирсен! – Рәис үзен иркен тотты, авыл җирендәгечәрәк итеп исәнләшергә тырышты* (Ф. Латыйфи. Акка-карага тимәскә).
Төрдәше: Алла куәт бирсен!

*АЛЛАГА* ❖ **АЛЛАГА БЕТСӘҢ, БЕР ТИЕН АКЧАМ ЮК.** Әгәр ышансаң. *Аллага бетсәң, бер тиен акчам юк* (К. Насыйри).

**АЛЛАГА БЕТҮ.** Бөтен җаны-тәне белән Аллага ышану, инану. *Әмма Толстой соңгы сулышына кадәр Аллага беткәнче ышанган кеше булып калды. Һәм берәүнең дә башына аны атеист итү кебек тузга язмаган уй килмәячәк* (Ә. Еники. Ялганны яклау).

**АЛЛАГА ДА <ЮК>, БӘНДӘГӘ ДӘ (МУЛЛАГА ДА) ЮК.** Ялкау, эшлексез кеше турында. *Бигрәк пешмәгәнсең икән: синнән Аллага да, муллага да юк* (Сөйләм).
Төрдәше: авызга каптырганны йотмау һ.б.

**АЛЛАГА КАЙТУ.** 1. Яңадан динле булу, дингә кайту. – *Авылны коткарыйк дисәк, Аллага кайту фарыз, җәмәгать!* (З. Мәхмүди. Һәркемнең үз юлы).

2. Бик диндарлану, тәүвалану. *Аллага кайту, тәүбә итү, җимерелгән мәчетләрне кайтару, яңадан торгызу чорына килеп җиттек, шөкер* (Р. Батулла. Илбашы).

**АЛЛАГА МӘГЪЛҮМ.** *к.* Алла белә (белер). – *Кальбебез бер Аллага мәгълүм бит* (С. Зыялы. Кара таплы бизәк).
Төрдәше: Алла белә (белер) һ.б.

**АЛЛАГА ТАПШЫРУ.** 1. Эшкә керешү, тәвәккәлләү. *Салих абзый, Аллага тапшыр, кызың шундый зур, гыйлем кешеләредәй бервакытта да хур булмас, дигән* (Г. Толымбай. Читән буе).
Төрдәше: Аллага тапшырып, муллага башырып (баш орып); Аллага тәвәккәл; Ходайга тапшыру.

2. «Кулдан килгән кадәресен башкардык, калганын Алла ярдәмендә бетерербез» мәгънәсендә. *Тегеләр, ахры, риза булганнардыр, без дә, Аллага тапшырып, бер җомга көн шунда күчендек* (Г. Ибраһимов. Көтүчеләр). *[Гарифулла] Йә, ярый, Аллага тапшырдык* (А. Алиш. Күршеләр).

3. Куелган эчемлекне эчеп кую. *Без инде берәр стаканны Аллага тапшырып, бүгенге кичне күңелле генә уздырырга дип исәпләп тора идек* (М. Мәһдиев. Сабантуй көнендә).
Төрдәше: авыз җебетү 1 һ.б.

**АЛЛАГА ТАПШЫРЫП, МУЛЛАГА БАШЫРЫП (БАШ ОРЫП).** «Ни булса да булыр, тәвәккәлләп» мәгънәсендә. – *Мин эшне башлап җибәрү өчен акча таптым, әйдә, Аллага тапшырып, муллага баш орып, тәвәккәлләп карыйк* (Сөйләм).
Төрдәше: Аллага тапшыру 1 һ.б.

**АЛЛАГА ТӘВӘККӘЛ** *к.* Аллага тапшыру 1. *Азардым, бузардым, шапкам кызарды, / Һәр төскә буяндым, дидем: Аллага тәвәккәл!* (Дәрдемәнд).
Төрдәше: Аллага тапшыру 1 һ.б.

**АЛЛАГА ШӨКЕР!** 1. Хәл-әхвәлне сорашканда, канәгать булуны белдереп җавап бирү. *Аллага шөкер, мин дә бөтенләй һөнәрсез малай түгел инде, дип уйладым* (Ф. Әмирхан). *Ә безнең колаклар, Аллага шөкер, ишетә бит әле* (Г. Мөхәммәтшин. Ике әби бәрәңге ала...).
Төрдәше: әлхәмделилла шөкер!

2. Бик күп, зур. *Күкрәк тә киң, корсак та Аллага шөкер* (А. Расих). *Бу авылда Чистай, Спасс якларыннан игенен, мал-туар байлыкларын үзләре аркылы үткәреп, Казанга, Сембергә икмәк, тире-яры куеп торучы һәм шуның өстенә бернечә урында кызыл мал кибетләре тотучы II гильдия купец Вильдановлар ише данлыклы байлар булганы кебек, кәҗә савып*

*кына көн күрүче ярлы-ябагай да Аллага шөкер иде* (Ф. Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы).
Төрдәше: Хакка шөкер!; Ходайга шөкер!

**АЛЛАГА ШӨКЕР, МУЛЛАГА ФЫТЫР, СИНЕҢ БЕЛӘН МИҢА ШЫМЫТЫР** *ирон.* Дәрәҗәләрдән, акчалы бүләкләрдән, төрле өлешләрдән коры калганда әйтелә; ягъни Алланың биргәненә рәхмәт, муллага фытыр садакасы бар, ә безгә бернәрсә дә эләкмәде. *Безнең бабай: «Аллага шөкер, муллага фытыр, синең белән миңа шымытыр», – дия торган иде, хәзер без дә шундый хәлдә* (Сөйләм).

*АЛЛАДАН* ❖ **АЛЛАДАН ВӘГЪДӘ ҖИТСӘ (ҖИТКӘЧ БИРҮ)** *дини.* «Тәкъдирдә язылганның вакыты җитсә, чара юк» дигәнне аңлата. *– Бирермен, Алладан вәгъдә җиткәч бирермен, – ди, үзе кесәсе төбеннән киндер янчыгын эзләп таба* (А. Алиш. Якты күл буе).

**АЛЛАДАН ҖӘЯҮ (ҖӘЯҮЛӘП) КАЧУ.** 1. Динсез, имансыз, игелексез. *Ул Алладан җәяү качкан нәрсәләр авыру кешегә нигә кирәкләр иде?* (Г. Толымбай. Нигә кыр үрдәге булмаганнар).
2. Намуссыз, миһербансыз, ышанычсыз. *Әй, мөртәт, Алладан җәяү качкан нәрсә!* (К. Насыйри). *Әллә мине алладан җәяү качкан дип белдеңме?* (Ф. Хөсни).
Төрдәше: Алланың дәргяһыннан сөрелгән.

**АЛЛАДАН ҖӘЯҮ КАЧКАН ШАЙТАН КЕБЕК.** Нинди дә булса шөбһәдән куркып качучы турында. *Таң ату белән, Шәйхи Алладан җәяү качкан шайтан кебек, ашыга-ашыга олы юлга таба китте* (Сөйләм).

**АЛЛАДАН ИҢГӘН** *дини.* Уйлап чыгарылган түгел, мәңгелеккә күктән төшкән. *Иркенме синдә колач? / Ирек тә, җыр да, Иман да – / Алладан иңгән мирас!* (Ф. Гыйззәтуллина. Яңу дәверләрендә).

**АЛЛАДАН КАЙТСЫН** *дини.* Сый-хөрмәт күргәндә, рәхмәт әйтү (ягъни күрсәткән хөрмәтең артыгы белән кайтсын). *– Ашадык-эчтек, күңелле генә сөйләшеп утырдык, хөрмәтләрең артыгы белән Алладан кайтсын* (Сөйләм).

**АЛЛАДАН КУРЫК.** «Ярамаган эш эшләсәң, Алла җәзасын көт тә тор» мәгънәсендә. *– Алай ярыймы соң, улым. Кияү муллага каршы алай итәргә Алладан курык!* (Г. Исхакый. Кияү).

**АЛЛАДАН КУРЫКМЫЙ, БӘНДӘДӘН ОЯЛМЫЙ.** Начарлык эшләүдән чирканмаган явыз кеше хакында. *– Намус дигән буласың тагын, Алладан курыкмый, бәндәдән һич оялмый ич ул* (Сөйләм).

*АЛЛАНЫ* ❖ **АЛЛАНЫ АЛГА АЛЫП, ТАКЫЯНЫ КУЛГА АЛЫП** *әкият.* Алланың ярдәменә таянып, куркыныч юлга чыгу алдыннан әйтелә. *Алланы алга алып, такыяны кулга алып, куе агачлыкка таба атладылар* (Сөйләм).

*АЛЛАНЫҢ* ❖ **АЛЛАНЫҢ БАР ИТКЕРЕ** *мыск.* Теләк. *Карале, карале, барган җиреннән йоклый бит, Алланың бар иткере!* (Ш. Маннур).

**АЛЛАНЫҢ <ҺӘР> БИРМЕШ КӨНЕ** *к.* Алланың язмыш көне. *Алланың бирмеш көне ферма мөдиренә ябырыла, и тирги, и ача җитешсезлеген!* (Г. Ахунов. Без бит Арча яклары). *Алланың бирмеш көнендә иртән торсаң, баш авырта* (Ф. Имамов. Әйбәт кәләш).
Төрдәше: Алланың язмыш көне.

**АЛЛАНЫҢ ДӘРГЯҺЫННАН СӨРЕЛГӘН** *к.* Алладан җәяү (җәяүләп) качкан 2. *– Алланың дәргяһыннан сөрелгән хаин син, яэҗүз-мәэҗүз булып кубарылган ерткыч вәхши син, җир күтәрмәс нәҗес, кабих зиначы син* (Ә. Еники. Коръәнхафиз).
Төрдәше: Алладан җәяү (җәүләп) качкан 2.

**АЛЛАНЫҢ КАҺӘРЕ СУККАН (СУККЫРЫ; СУКСЫН)!** *карг.* Начарлык эшләгән өчен каты каргау сүзе, ягъни «Аллаһ үз җәзасын бирсен». *– Алланың каһәре суккан нәрсәкәй, әбиең белән бабаңны картаймыш көннәрендә бөтен авылга рисвай итәргә кайттыңмыни күзеңнебашыңны тондырып, дие, менә әпекәйдер!* (Г. Мөхәммәтшин. Ике әби бәрәңге ала...). *– Хәзер үк... илтеп... бушат йөгеңне, Алланың ачы каһәре суккыры! – дип гыжылдады.* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).
Төрдәше: авыз<лар>ын корт чаккыры! һ.б.

**АЛЛАНЫҢ КАҺӘРЕ ТӨШКӘН НӘРСӘ** *к.* авыз<лар>ын корт чаккыры! *– Алланың каһәре төшкән нәрсә, бераз читкәрәк куярга ярамадымыни!* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз<лар>ын корт чаккыры! һ.б.

**АЛЛАНЫҢ <АЧЫ; ӘЧЕ> КАҺӘРЕ ТӨШСЕН (ТӨШКЕРЕ; СУККЫРЫ)!** *карг. к.* авыз-

<лар>ын корт чаккыры! *Хәммәт, каршы торуның мәгънәсезлеген аңлагач: «Алланың әче каһәре төшсен!» – диде дә ятим агачка таба йөзеп китте* (З. Хәким. Тын океанда көрәш). *[Сәрбиҗамал] Алланың каһәре төшсен сезгә... җир йотсын... сезне!* (Г. Камал. Уйнаш). *Кавышуыбызның нәкъ алтынчы көнендә, Алланың каһәре төшкере, сугыш Сабирымны кайнар куенымнан суырып алды да ут эченә илтеп салды* (Г. Галиева. Тулгак).

Төрдәше: авыз<лар>ын корт чаккыры! һ.б.

**АЛЛАНЫҢ КАШКА ТӘКӘСЕ** *мыск.* Үзе турында бик югары фикердә булган кеше турында мыскыллап әйтү. *Ә шул чагында – тегеләр салкын бураннарда, тауларда, чүлләрдә, диңгезләрдә, ил иминлеген саклап мәшәкатьле гомер кичергәндә – бер егет, Алланың кашка тәкәсе кебек, бөтен кызлар арасында берүзе кәпрәеп йөри* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә). *– Мәчетең юк, тегермәнең аякка басмаган, аннан килеп, арба-чана ясый торган осталарыңа, тимерчеләреңә алачык та юк икән – син үзеңне Аллаһның кашка тәкәсе санап, күкрәк киереп йөрмә инде, туган* (В. Имамов. Карабәк).

Төрдәше: Алланың кашка тәкәсе кебек (тәкәсемени); дөнья кендеге; үзен үзе дөнья тоткасы (терәге) дип уйлау.

**АЛЛАНЫҢ КАШКА ТӘКӘСЕ КЕБЕК (ТӘКӘСЕМЕНИ)** *мыск. к.* алланың кашка тәкәсе. *– Анда да, Аллаһның кашка тәкәсе сымак, гел атларда инде* (В. Имамов. Карабәк). *Әнә хәзердән үк Хәлисә янында ничек кукраеп, Алланың кашка тәкәсе кебек тота үзен* (В. Нуруллин. Ике урам арасы).

Төрдәше: Аллаһның кашка тәкәсе; үзен үзе дөнья тоткасы (терәге) дип уйлау.

**АЛЛАНЫҢ КАШКА ТӘКӘСЕ ТҮГЕЛ<ДЕРСЕҢ>.** Кемнеңдер башкалардан бернинди аермасы булмаганлыгына ишарә. – *Язу белгән кешеләр дә Алланың кашка тәкәсе түгел, алар да без йөргән сукмактан йөри* (Г. Бәширов). *Кәтиб Хафизның гаебе бар икән, үз җәзасын алыр, Алланың кашка тәкәсе түгел* (М. Хәбибуллин. Илчегә үлем юк).

Төрдәше: дөнья сиңа гына terәлмәгән; кашкалы түгел; мөгезле түгел.

**АЛЛАНЫҢ РӘХМӘТЕ.** 1. Эзләп йөреп, берәр нәрсә яки кеше көтелмәгәндә табылганда әйтелә. *– И, Алланың рәхмәте, күпме эзләдем бит бу акчаны, китап эчендә яткан икән!* (Сөйләм).

2. Халәт яхшы булганда әйтелә. *[Әкълимә] И-и-и, Алланың рәхмәте, матур юллардан да йөрисе көннәр булыр икән* (А. Гадел. Безнең авыл Наполеоны). *Алланың рәхмәте, берсен дә тормышка ашыра алмадым* (Ф. Садриев. Көлми торган кеше).

**АЛЛАНЫҢ РӘХМӘТЕНДӘ БУЛСЫН.** Үлгән кешене телгә алганда әйтелә. *Соңыннан 1867 елның декабрь аенда, әни (Алланың рәхмәтендә булсын) гайрәт итәрәк, мине Оренбург губернасында Чиләбе өлкәсендә Әлмән карьясына укуга җибәрде* (Г. Ибраһимов. Дәүре галәм). *Узган ел, Алланың рәхмәтендә булсын, картым да вафат булып китте* (Г. Камал).

**АЛЛАНЫҢ СӨЙМӘС ТӘКӘСЕ.** Беркем дә сөйми торган, кагылып-сугылып йөрүче кеше. *Бар кеше дә бер булмый, араларында Алланың сөймәс тәкәсе дә килеп чыга* (Сөйләм).

**АЛЛАНЫҢ ҮГИ УЛЫ** *ирон.* 1. Кеше белән аралашмыйча, үзен читтәрәк тотучы мескен кыяфәтле кеше. – *Нигә Алланың үги улы кебек почмакка сыенган ул?* (Сөйләм).

2. Зимагур. *Зимагурлыкта йөреп, Алланың үги улына әверелеп беткән бу* (Сөйләм).

**АЛЛАНЫҢ ЯЗМЫШ КӨНЕ.** Һәр көн. *Алланың иртәгәсе киләчәк язмыш көнендә фотоаппаратымны алып, урманга китәрмен, ахрысы* (Сөйләм).

Төрдәше: Алланың <һәр> бирмеш көне.

*АЛЛАР* ❖ **АЛЛАР БЕТЕП ГӨЛЛӘР ҮСҮ.** Нәрсәне булса да арттыру. *Барма, җаный, су читенә, / Су чәчрәр битеңә. / Аллар бетеп, гөлләр үскән / Безнең җаный битенә* (Җыр).

*АЛЛАҺ<Ы>* ❖ **АЛЛАҺ<Ы> ӘКБӘР.** 1. Ашапэчкәннән соң, амин тотканда әйтелә. *Алдыартлы ике чынаяк чәй ясап бирде; кучер исә, авыз пешүнең ни икәнен белмәгән сыман, кызукызу эчте дә: «Булдым... Аллаһы әкбәр», – дип чыгып китте* (Г. Ибраһимов).

2. Берәр эшне тәмамлау уңаеннан әйтелә. *Хәзрәт, бу исемне әйтеп, Нурҗиһанның ике ягын да икешәр мәртәбә өшкерде, тагын «Аллаһы әкбәр»ен әйтеп дога кылды* (Г. Бәширов. Нурҗиһан).

3. Нәрсәдән булса да мәхрүм калуга, нәрсәнең булса да юк ителүенә карата әйтелә. – *Ел коры килде, көйдерде дә салды, Аллаһ әкбәр! Гектарга нибары тугыз-ун центнер белән калдык, вәт* (Г. Бәширов). *[Бари] Егетләр, аклар фронтны өзгәннәр. Сарапул – Аллаһы әкбәр* (Ю. Әминов. Умырзая чәчәкләре).

**АЛЛАҺ ҖЕБЕНӘ ТОТЫНУ.** Дин тәгълиматы белән танышу. – *Сез әле яшьләр, башыгызга сынау килгәнне көтеп йөрмәгез, вакытында Аллаһ җебенә тотыныгыз, үскәнем...* (Л. Муллагалиева. Тыңла, Нәфисә!).

**АЛЛАҺ ЙОРТЫННАН КУГАН КЕБЕК КУАРГА.** Ачу белән, башка кире кайтмаслык итеп куып чыгарырга. *Кинаяләп булса да, матур гына әйткәнне аңламагач, хуҗалар аны, Аллаһ йортыннан куган кебек, куып чыгардылар* (Сөйләм).

**АЛЛАҺ ТАШЛАМАСА, БҮРЕ АШАМАС.** Алланың рәхимлегән бар нәрсәдән дә өстен кую. *[Шаһенгәрәй] Кайгырма, кызым, кайгырма, Алла ташламаса, бүре ашамас, диләр* (Г. Камал. Дәҗҗал). – *Хәерлегә калсын, иншаллаһ, Алла ташламаса – бүре ашамас, – дип, авыр-озак дога кылдылар* (Ф. Яхин. Яшел чәчәк).

**АЛЛАҺ ТӘГАЛӘ ШАТЛЫК НАСЫЙП ӘЙЛӘСЕН** *к.* алдыңа ак көн тусын. *[Мансур] Хуш, сәламәт булыгыз, мин кайтыйм, Аллаһ Тәгалә шатлык насыйп әйләсен* (Г. Камал. Бәхетсез егет. I вариант).

Төрдәше: алдыңа ак көн тусын һ.б.

*АЛЛАҺЕ* ❖ **АЛЛАҺЕ ТӘГАЛӘ ХУР ИТСЕН** *карг.* Ниндидер начарлык эшләгән өчен каргау сүзе. *[Зәйнәп] Мине болай хур иткәнегез өчен, Аллаһе Тәгалә сезнең үзегезне хур итсен* (Г. Камал. Кайниш).

Төрдәше: Алла орсын һ.б.

*АЛЛАҺТАН* ❖ **АЛЛАҺТАН ВӘГЪДӘ ҖИТҮ** *дини.* Тәкъдирдә дип вәгъдә ителгәннең (никах, үлем һ.б.) көне-сәгате килү. – *Бирермен, Аллаһтан вәгъдә җиткәч бирермен, – ди* (А. Алиш. Якты күл буе).

*АЛЛАҺУ* ❖ **АЛЛАҺУ КЕШЕ (ХАЛЫК).** Югарыдан төшкән фәрманнарны гына үтәүче, катып калган тәгълиматларга гына буйсынучы, үзбашсыз. *Аллаһу халык хәзер юк дәрәҗәсендә дип әйтергә дә мөмкин, замана үзгәрә, аның белән бергә кеше дә үзгәрә* (Сөйләм).

**АЛЛАҺЫ ӘКБӘРГӘ <ЭШЛӘҮ; ЙӨРҮ>.** Бары тик рәхмәт сүзен ишетү өчен генә. *Алар авылдан олы юлга кадәр барып, Аллаһы әкбәргә кар көрәп кайттылар* (Сөйләм).

**АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ САКЛАСЫН!** *к.* Алла күрсәтмәсен! *Аллаһы Тәгалә сакласын, без күргәннәрне аларга күрергә язмасын* («Яшел Үзән» газ.).

Төрдәше: Алла күрсәтмәсен! һ.б.

**АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ ЯРДӘМЕННӘН ТАШЛАМАСЫН!** Яхшы теләк. – *И оланнар, бик тә рәхмәтле эш башлагансыз икән, Аллаһы Тәгалә ярдәменнән ташламасын, дип, берсеннән-берсе матур теләкләр теләп, үсендереп чыгып китәләр иде* (Н. Гамбәр. Ма-ту-у-у!!!).

*АЛЛЫ-ГӨЛЛЕ* ❖ **АЛЛЫ-ГӨЛЛЕ ФИКЕР ЙӨРҮ.** Искиткеч яхшы, ачык. *Үсә торган кадр булып күренер өчен, Синең хакта аллы-гөлле фикер йөрсен* (Г. Афзал. Киңәш).

*АЛМА* ❖ **АЛМА АГАЧЫННАН ЕРАК ТӨШМӘҮ (ТӘГӘРӘМӘҮ).** Ата-ана сыйфатлары балаларга күчү. *Әнисе аркасында Сөембикәгә дә, «алма агачыннан ерак төшми» дип карадылар* (Ф. Садриев. Бәхетсезләр бәхете). *Алма агачыннан ерак тәгәрәми, диләр, хак икән* (Н. Гыйматдинова. Сихерче).

**АЛМА АПА(Й).** Балаларның апалалары белән бертуган апаларына яратып эндәшүләре. *«Син ашыкма, Алма апа, ял итә-итә генә эшлә!» дип, акыл саткан булалар тагын!* (Г. Әдһәм. Күзгә-күз).

**АЛМА АРТЫННАН ТОРМА** 1. Эшне рәтсез, тәртипсез тәмамлау. – *Нигә инде сызымыңдагы туры сызыкларың тоташмаган, алма артыннан торма килеп чыкккан түгелме?* (Сөйләм).

2. Яхшы гына барган сөйләшүне, әңгәмәне яисә күрсәткән хөрмәтне ямьсез итеп бетереп кую. *Матур гына озатып җибәрәсе иде, нигә инде алма артыннан торма биреп ямьсезләнергә?* (Сөйләм).

Төрдәше: аш артыннан горчица (ике маддә өчен дә уртак).

**АЛМА БАЕ** *иск.* Авылдан авылга йөреп алма сатучы. *Сабан урагы бетеп тә җитмәде, авылга алма байлары килә башлады* (И. Гази).

**АЛМА БЕЛӘН АЛМА КЕБЕК ЯШӘҮ.** Дус булып, бер-береңне аңлап, бер үк максат белән тату яшәү. *Ләкин киселгән икмәкне ничек кенә ябыштырсаң да барыбер җөе кала бит аның. Алма белән алма кебек яшәү инде мөмкин түгел иде* (М. Әмирханов. Үрбәт ханбикә гыйшкы).

Төрдәше: авыздан-авызга сөйләшү һ.б.

**АЛМА БИТ<ЛЕ> (ЙӨЗ<ЛЕ>).** 1. Түгәрәк алсу йөзле яшь кыз. *И алма бит, алма бит, / Алма битләр кала бит* (Жыр). *Ул кызчыкның алма битеннән үбеп алды* (Г. Әдһәм. Мин, ул, без).

2. Сөйгән яр яки бала. *Алма битем, нихәл итим, / Каласың бит ятларга* (Жыр). *Илаһи зат, алма битең уртасында / Ни өчен мин бер кечкенә миң түгел?!* (Г. Мөхәммәтшин. Робагыйлар бакчасы).

**АЛМА БИТЛЕ КАРА КАШ.** Алсу йөзле яшь кызлар турында. *Бер тарафта уйнап-көлеп утыралар. Ачык йөзле, алма битле кара кашлар* (М. Гафури).

**АЛМА БУЛЫП ЙӨРҮ.** Макталу, хөрмәт ителү. – *Үзем дә төшеп калганнардан түгел, буровойга боргычлап торба ташыйм, алдынгылар арасында алма булып йөримен* (Г. Ахунов. Хуҗалар).

**АЛМА КЕБЕК <ЧАК>.** 1. Яңа гына буйга җитеп, тулышып җиткән чак (күбрәк кызлар хакында). *Буйга тиз үстеләр, кыскасы, аларның алма кебек чаклары иде* (Ә. Хәсәнов. Әнис алмалар).

2. Урта яшьләргә җитмәгән, тулып, пешеп торган хатын-кыз турында. *Алма кебек чакларында, 25–30 яшьтә, ирсез калып, яңадан бала табу бәхетен дә татый алмадылар* (И. Нәбиуллина. Сыңар канат).

3. Бераз гына тулырак гәүдәле яшь кыз. *Гөлнара кебекләрне борынгы бабаларыбыз тулы матур гәүдәле булганга, «Алма кебек» дип, яки «Тутырган тавык кебек» дип йөрткәннәр* (Г. Даутов. Дөрес яшә).

Төрдәше: тутырган тавык кебек.

4. Таза бала-чагага карата әйтелә. *Өй эче алма кебек бала-чага белән тулган* (Сөйләм).

**АЛМА ПЕШ, АВЫЗЫМА ТӨШ <ДИП ТОРУ (ЯТУ)>.** Әзерне генә көтеп ятучы ялкаулар турында. *Алма пешеп, безнең авызга үзе килеп төшмәс, кузгалыйк, диде* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар). – *[Давыт] Сәлам, Җиләкле Сазның могтәбәр кешеләре, патша хәзрәтләренең күз өстендәге кашлары! Алма пеш, авызыма төш дип утырасызмы?* (Ю. Әминов. Умырзая чәчәкләре).

Төрдәше: авызга чәйнәп каптырганны (салганны; куйганны) көтү (көтеп утыру).

**АЛМА САТУ.** Кызлар белән дуслашып йөрү, гыйшык тоту. *Дидем: яндым, көйдем, ай-һай матур кыз! / Кайчан соң без икәү алма сатарбыз?* (З. Ярмәки).

**АЛМА ТӨШӘР<ЛЕК> УРЫН БУЛМАУ (ЮК).** Бик кысан, тыгыз булып, буш җир калмау. – *Вокзалда алма төшәргә дә урын юк* (Б. Камалов). <...> *үз балалары өстенә җәмәгате Җәләлетдин мулла ягыннан берничә ятимне сыендырганнар, өйләрендә алма төшәрлек тә урын юк, ди* (М. Әмирханов. Зиннәтулла хәзрәт).

Төрдәше: адәм баш тыккысыз һ.б.

**АЛМА ТУБЫ.** Туп кебек түп-түгәрәк булып үскән бала. *Хуплар хубы, / Алма тубы, / Пешкән, тулгансың, / Бу чагында / Син тагын да / Чибәр булгансың* (Дәрдемәнд. Бәллү).

**АЛМА ШАЛКАН, КОМ ТАЛКАН, ЧЫПЧЫК ТИЗӘГЕ КАНӘФЕР.** Нәрсәнең нәрсә икәнен таный-аера белмәү. *Нәрсә авызыңны ачып, аны тыңлап торасың, аның өчен алма шалкан, ком талкан, чыпчык тизәге канәфер бит* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**АЛМА – ШАЛКАН, ЧУМАРА ТАЛКАН** *к.* авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү. – *Әй, син нәрсә аңлыйсың соң? Сиңа алма – шалкан, чумара талкан,* – *дип кырт кисәр* (Ф. Мөслимова. Хыянәт).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

*АЛМАГАН* ❖ **АЛМАГАН АТ (БИЯ), ТУМАГАН ТАЙ (КОЛЫН)** *ирон., к.* ала каргадай алдан ала (алдан-алы) кычкыру. <...> *үзегезнең*

*кулыгыздан килмәде, без чыгарып бирдек ташыгызны,димәсләрме? – Алмаган ат, тумаган тай. Әле ташның чыгасы бар* (Ф. Хөсни. Мәйдан).

Төрдәше: ала каргадай алдан ала (алдан-алы) кычкыру һ.б.

**АЛМАГАН АТ, ТУМАГАН ТАЙ, АТЛАНЫП (АТЛАНМА) БИЛЕН СЫНДЫРЫРСЫҢ** *к.* ала каргадай алдан ала (алдан-алы) кычкыру. *Тыңла: «Алмаган ат, тумаган колын. Атланма, улым, билен сындырырсың», – диләр* (Р. Мөхәммәдиев. Кош булып очар идем...).

Төрдәше: ала каргадай алдан ала (алдан-алы) кычкыру һ.б.

**АЛМАГАН ТАВЫК, САЛМАГАН ЙОМЫРКА** *к.* ала каргадай алдан ала (алдан-алы) кычкыру. *Алмаган тавык, салмаган йомырка, чебешләрне сата башлама* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

Төрдәше: ала каргадай алдан ала (алы) кычкыру һ.б.

*АЛМАЗ* ❖ **АЛМАЗ КҮЗ.** Бар нәрсәне тиз һәм тулысынча күреп алу сәләтенә ия булучы. *Юлда машина күренсә, алмаз күз Рәшит шунда ук безгә хәбәр бирәчәк* (Сөйләм).

Төрдәше: без күз һ.б.

*АЛМАККА* ❖ **АЛМАККА БАР, БИРМӘККӘ ЮК.** Үзенә алып, кешегә бирмәскә күнеккән кеше; бурычка алып, түләргә яратмаучы турында. *Син ул кешенең «алмакка бар, бирмәккә юк» дип яшәгәнлеген белми идеңмени?* (Сөйләм).

*АЛМАЛАРЫ* ❖ **АЛМАЛАРЫ СУГА ТУЕНУ.** Күзләре яшь белән тулу (бала-чага турында). *Алмалары суга туенган* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

Төрдәше: балавыз <капчыгы> сыгу (түгү); болыт баскан, яңгыр яварга тору; болытлар куерган, явам-явам дип тору; бөкесе атыла, шешәсе тулган; елганың яры тулган; еласа, кашы-күзе кара булу; кан елау; көннәр яшәреп тору; күз суы агызу; күздән сарымсак суы сыгу; күз яше түгү; күз яшенә бату; күзләрдән яшь мөлдерәү; күңел нечкәрү; күңелне нечкәртү (нечкәртеп җибәрү); күңел тулу; күңел тулып ташу; күңел ташыну; сытылырга тору; тәгәрмәчләре суга баткан; тәгәрмәчләре суда йөзә; урман буйлары яшәргән; чишмәсе тулган; эрене сытылырга тора; юеш сөлге сыгу; яры тулган; яшь агызу; яшь йоту; яшь кою; яшь урынына кара кан сыгу; яшь сыгу; яшь түгү; яшькә коену.

*АЛМАЛЫДА* ❖ **АЛМАЛЫДА БЕР КӨН, САЛМАЛЫДА БЕР КӨН.** Бер урында озак утырмаган, яшәү урынын еш алмаштырган кеше хакында. *Үзе генә хәбәр бирсә инде, ул бит бер урында озак калмый: Алмалыда бер көн, Салмалыда бер көн* (Сөйләм).

*АЛМАНЫ* ❖ **АЛМАНЫ КҮРЕП, АШАМЫЙ ТОРГАН ТЕЛ ЯРЫЛУ.** Ымсынган нәрсәдән, буш вәгъдәләргә алданып, коры калу. – *Үткән ел да, хәзер дә күзеңне чекрәйтеп торасың, кайчан ирең алып бирә әле аны, алманы күреп, ашамый торган тел ярыла ул – әйдә, акчаң барында алып кал* (Сөйләм).

*АЛМА-ТИЛМӘ* ❖ **АЛМА-ТИЛМӘ КИТЕРҮ** *диал.* Әйберләрне бер-берсе белән чалыштырып бетерү; бер-берсен алмаштыру. *Бөтенесен алма-тилмә китереп бетергәнсең, башын-ахырын табып булмый* (Сөйләм).

*АЛМАШ-ТИЛМӘШ* ❖ **АЛМАШ-ТИЛМӘШ КАРАУ.** Ике әйбернең әле берсенә, әле икенчесенә тиз-тиз карап алу. *Карый әфәнде, күзләрен акайтып, ялт-йолт китереп, Садыйкның бер башына, бер аягына алмаш-тилмәш карап утыра* (С. Рәмиев).

*АЛНЫ* ❖ **АЛНЫ БИРМӘҮ.** Беркемне дә алга чыгармыйча, беренчелекне үз кулында тоту. *Кәрим карт үз гомерендә һичбер чалгыга алын бирмәде, диләр* (Г. Ибраһимов. Табигать балалары).

Төрдәше: алга чыгармау һ.б.

*АЛНЫ-АРТНЫ* ❖ **АЛНЫ-АРТНЫ БЕЛМӘҮ** *к.* авыз суы кипмәгән. – *Бар нәрсәгә дә сабый күзе белән карый әле ул, дөньяны да, алны-артны да белми* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

**АЛНЫ-АРТНЫ КАРАМЫЙЧА.** Бернәрсәгә дә дикъкать итмәстән, саклык кирәклеген онытып. *Аның алны-артны карамыйча, канатланып, шушы ярга үрмәләп менүе файдасыз булмады* (Ә. Гаффар. Бодай бөртеге һәм тегермән ташы).

Төрдәше: алны-артны күрмәү; алны-артны уйламыйча; алны-артны, уңны-сулны белми; баш ватып, күз чыгарып тормыйча; уңга-сулга карамыйча.

**АЛНЫ-АРТНЫ КҮРМӘҮ** *к.* алны-артны карамыйча. *Күрмимен алны вә артны, и чабам мин, и чабам* (Г. Тукай. Су анасы).
Төрдәше: алны-артны карамыйча һ.б.

**АЛНЫ-АРТНЫ КЫЙНАП ЙӨРҮ** *к.* абай булу. *Тик син Хамматовның чыкканын көт инде. Башкача эләкмәскә тырыш, алдыңны-артыңны кыйнап йөре...* («Казан утлары» ж.).
Төрдәше: абай булу һ.б.

**АЛНЫ-АРТНЫ УЙЛАМЫЙЧА.** Нәтиҗәсен дә төшенмичә, бернәрсә дә уйлап тормыйча. *Алны-артны уйламыйча, ачык авызланып, дус кызымны иремә күрсәттем* (Т. Галиуллин. Төнге юллар).
Төрдәше: авыз <ни/нәрсә> әйткәнне колак ишетмәү һ.б.

**АЛНЫ-АРТНЫ, УҢНЫ-СУЛНЫ БЕЛМИ<ЧӘ>** *к.* алны-артны карамыйча. *Шундый тын, яхшы һавада безнең утынчы исә / Алны-артны, уңны-сулны белмичә утын кисә* (Г. Тукай. Шүрәле).
Төрдәше: алны-артны карамыйча һ.б.

*АЛНЫ-ЯЛНЫ* ❖ **АЛНЫ-ЯЛНЫ БЕЛМИЧӘ.** Бер дә ял итмичә, ара биреп тормыйча, эш белән мәшгуль булу. *Хәер, кәефенә килгәндә, алны-ялны белмичә, лобогрейка белән көнгә алты-җиде гектар иген урып ташлау дисеңме, тонналап ашлыкны җилкәсеннән үткәреп, заготзернога машиналар төяп озату дисеңме – теләсә нинди эшнең борынына чиертә иде ул* (Р. Төхфәтуллин. Авылдашым Нәби). *Көн эссесендә билдән чишенеп ташлап, алын-ялын белми эшләгән егеттән көн буена күзен ала алмады ул* (И. Иксанова. Сугыш корбаннары).
Төрдәше: ал да юк, ял да юк һ.б.

*АЛПАВЫТ* ❖ **АЛПАВЫТ АЛАШАСЫ ТҮГЕЛ.** «Яхшы азык кына ашап симергән, нәсел аты түгел» мәгънәсендә. *Тарткан саен йөк салырга ул бит алпавыт алашасы түгел* (Ә. Фәйзи).

*АЛПАВЫТНЫҢ* ❖ **АЛПАВЫТНЫҢ ТЫРНАГЫННАН ЫЧКЫНУ.** Гадел булмаган, башка кеше хезмәтен файдаланып табыш алып яшәүчедән котылу. *Шуның рөхсәте белән генә алты авыл крестьяннары кансыз алпавытның тырнагыннан ычкынып калганнар...* (М. Рәфыйков. Йомышчы Әбүбәкер, яки «ни булса, ни була...»).

*АЛПАК* ❖ **АЛПАК ТА КЫСТЫЙ, КАЛПАК ТА КЫСТЫЙ.** Ике яктан ике патшалык (яки ике хуҗа, сәяси берлек һ.б.) үз кул астына керергә кыстау. *Кайсына өстенлек бирергә дә белмим, Алпак та кыстый, Калпак та кыстый* (Сөйләм).

*АЛПАМЫШ* ❖ **АЛПАМЫШ <БАТЫР> ЙОКЫСЫ.** Озакка сузылган тирән йокыга китү. *Егет кичке унбердә генә өенә кайтып керде дә, идәнгә генә авып, Алпамыш йокысы белән йокыга талды* (Сөйләм).

*АЛПАН-ТИЛПӘН* ❖ **АЛПАН-ТИЛПӘН БАРУ** *к.* авыш-түеш (тәвеш) килү 2. *Алпан-тилпән барган кеше тыкрыкка кереп китте* (Сөйләм).
Төрдәше: авыш-түеш (тәвеш) килү 2 һ.б.

*АЛПАР* ❖ **АЛПАР ХӘЕРЧЕСЕ (ТЕЛӘНЧЕСЕ).** Оста теләнә белеп, теләгәнен ала торган кеше. *– Алпар теләнчесе кебек кыланма әле, сиңа түгел, үземә дә юк* (Сөйләм).

*АЛПАРЫНА* ❖ **АЛПАРЫНА КҮРӘ ТУЛПАРЫ.** Алпар – баһадир, батыр. «Батыр сугышчының аты да үзенә тиң», ягъни «исеме җисеменә, формасы эчтәлегенә туры килергә тиеш» мәгънәсендә. *Алпарына күрә тулпары да, диләр бит, бу нәни гәүдәле, курчактай чырайлы сабыйга Тимер исемен биреп булмый бит инде* (Сөйләм).
Төрдәше: исеменә күрә җисеме.

*АЛСА* ❖ **АЛСА ДА АЛУ, АЛМАСА ДА АЛУ.** Теләсә нинди очракта да хуҗасы булу. *Тотыш атны алса да алды, алмаса да алды* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).

*АЛСУ* ❖ **АЛСУ ЙӨЗЛЕ.** Йөзе һәрвакыт алсу яки алсу-кызгылт булган кеше турында. *Җәй көнен яздым бераз; / Язмыйм әле кыш, көзләрен, / Алсу йөзле, кара кашлы, кара күзле кызларын* (Г. Тукай). *Алсу йөзле кояш кызыдыр син, / Нигә яшьләреңне тыймыйсың?* (А. Нәҗми. Кояш кызы).

**АЛСУ КҮЗЛЕК.** Берәр төшенчәгә бәйле рәвештә, чынбарлыкны беркатлы, хыялый кабул итү. *Чынбарлыкка алсу күзлек аша / Юанганбыз карап – чыдарлык! / Ал пыяла күпме алдый ала? / Алсу ялган – кара чынбарлык*! (Л. Шагыйрьҗан).
Төрдәше: ал күзлектән (күзлек аркылы; аша) карау һ.б.

**АЛСУ КҮЗЛЕК КИЮ** *к.* ал күзлектән (күзлек аркылы; аша) карау. *Алсу күзлек киеп күзебезгә, / Кырын карап туган телебезгә. / Чабатаны элеп түребезгә. / Юкка гына йоклап йөрибез лә!..* (Р. Закиров. Без уянсак кына).

Төрдәше: ал күзлектән (күзлек аркылы; аша) карау һ.б.

**АЛСУ КҮЗЛЕКТӘН (КҮЗЛЕК АРКЫЛЫ) КАРАУ** *к.* ал күзлектән (күлек аркылы; аша) карау. *Шуның өстенә бар нәрсәгә дә әле алсу күзлектән караучан* (Х. Камалов).

Төрдәше: ал күзлектән (күзлек аркылы; аша) карау һ.б.

*АЛТМЫШ* ❖ **«АЛТМЫШ<ЛЫ> КАДАК»ЛАР.** Себер тиречеләренә элекке вакытта бирелгән исем (бер пот урынына, алдап, алтмыш кадак җыйганнар). *Алты почмаклы, такта белән ябулы өен алтмыш кадак онга сатты* (Г. Ибраһимов. Адәмнәр). *«Алтмышлы кадак»лар. Кыргыз-казакътан йон-ябага җыйганда, бер пот урынына алдан үлчәп алтмыш кадай җыйганлыклары өчен шулай аталган* (Идел буе халыклары традицион мәдәнияте – 2016).

**АЛТМЫШ КОЛАЧ АЛАЙГЫР (АЛА АЙГЫР).** Әкият батырлары атлана торган мифик ат исеме. *Аның шатыр-шотыр сынган тавышына* син *базыңнан сикереп чык та бик тизлек белән әлеге алтмыш колачлы ала айгырга атланырга тырыш* (Әкияттән).

*АЛТМЫШНЫКЫ* ❖ **АЛТМЫШНЫКЫ БЕТӘ, АЛТЫНЫКЫ КАЛА.** Балачактан алып, тупланып килгән белемнең алтмышка җиткәч бетә баруына ишарә. *Алтмышныкы бетә, алтыныкы кала* (К. Насыйри. Мәкаль һәм әйтемнәр).

Төрдәше: алтыда белгән алтмышта да онытылмау; алтыдагы алтмышка(та).

*АЛТЫ* ❖ **АЛТЫ АВЫЗ<ЛЫ>.** Күп сөйләшүче, теләсә ни сөйләүче; гайбәтче. *Алты авыз аны, бик тиз әйләндереп, тиешле урынга озата* (Ф. Яруллин. Нурмигөл түти догасы). *Алар авылында алты авызлы Бикә апа бар иде, урыны оҗмахта булсын* (Р. Газиз. Тәрәзәләр).

Төрдәше: гайбәт капчыгы; гайбәт тегермәне; гайбәт чиләге; озын тел<ле>; сүз йөртүче; теле дилбегә буе; теле озын; телнең сөяге юк; усал тел.

**АЛТЫ АЛАСЫМ ЮК, БИШ БИРӘСЕМ ЮК.** Бурычка алып яшәмәү: «кешедән аласым да, бирәсем дә юк» мәгънәсендә. *Аллага шөкер, алты аласым юк, биш бирәсем юк, үземнеке үземә җитә* (Сөйләм).

Төрдәше: биш бирәсем юк, алты аласым юк.

**АЛТЫ АЛЫШЫМ ЮК, БИШ БИРЕШЕМ ЮК.** Ул кеше белән бернинди мөнәсәбәтем, алыш-бирешем юк. *Кем соң ул, минем аның белән алты алышым юк, биш бирешем юк* (Сөйләм).

**АЛТЫ КОЛАК, ДҮРТ КҮЗ БЕЛӘН.** Бересен бик күреп сөйләшәсе килү, аны зарыгып көтеп алу. *Кисәк кенә, бу улмы соң, алты колак, дүрт күз белән көткән иреме соң, дигән уй йөрәген телеп алды* (Р. Кәрами. Каргышлы этаплар). *Тик безне «алты колак, дүрт күз белән» каршы алмадылар* (Р. Гыйлемханов һ.б. Истә калганнар).

**АЛТЫ СУККАНГА БЕР АТЛАГАН БИЯ КЕБЕК ЙӨРҮЧЕ.** Иренчәк, пырдымсыз кеше турында. – *Юк, җәмәгать, алты сукканга бер атлаган ала бия кебек йөрүчеләргә миннән пуҗады булмаячак* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

**АЛТЫ – ТАК, ҖИДЕ – ҖӨП.** «Аңа барыбер, ишле белән ишсезне дә аермый» мәгънәсендә. *Селкетерсең аны, алты – так, җиде – җөп дип яшәгән кешенең тиресе калын була* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз<ы>-борын<ы> кыйшаймау һ.б.

**АЛТЫ ТУГЫЗГА ҖИТМИ.** Алты ай эшләгәннең тугыз ай буенча ашарга җитмәгәнен белдерү. *Сорап торма инде, иске эштә алты тугызга җитми иде* (Сөйләм).

**АЛТЫ ХАТЫН – БЕР БАЗАР.** Берничә хатынкыз бергә җыелса, базардагы кебек шау-шу, ыгы-зыгы чыгу турында. *Алты сәгатЬ буена нон-стоп режимда баш әйләндергеч тамашада алты хатын – бер базар – шум-гам* ([bulmas.ru] «Татар эстрадасы, йолдызлар...»).

*АЛТЫ-БИШ* ❖ **АЛТЫ-БИШ КАРАМА БҮКӘНЕ.** Дивана, тилемсә. *Нәҗип авылдан «киребеткән», алты-биш «карама бүкәне» кебек кушаматлар ияртеп чыгып китте* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: алты-биш кеше; әтәч баш; җебегән авыз; җил як; салам баш (түбә); тавык мие эчкән

(ашаган); тавык ми<ле>; тилгән мие ашаган; тилебәрән котырыгы; тилебәрән орлыгы ашаган; төнлә туган; урман сарыгы; үлчәве таманрак; чәүкә мие эчкән; черек ми; чүбек баш.

**АЛТЫ-БИШ КЕШЕ** *к.* алты-биш карама бүкәне. *Ә күрше хатын әйтте, йөзгә бәреп әйтте: «Дурак, юләр, алты-биш!» – диде* (Р. Вәлиев. Эт кояшы). *«Күрсәтермен мин сезгә алты-бишне!» – дип, авылы ягына шактый ныгыган йодрыгын күрсәтте* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: алты-биш карама бүкәне һ.б.

*АЛТЫГА* ❖ **АЛТЫГА АЛ ДА (АЛЫП) БИШКӘ САТ, АТЫҢ (ИСЕМЕҢ) БУЛСЫН СӘҮДӘГӘР.** Исем тоту өчен, зарарга сатып җибәрү. – *Кайгырма, абый, – дигән. – Алтыга ал да бишкә сат, атың булыр сәүдәгәр, – дигән* («Алтыга алып бишкә сату» мәзәге).

*АЛТЫДА<ГЫ>* ❖ **АЛТЫДА БЕЛГӘН (АЛТЫДАГЫ) АЛТМЫШКА БАРУ.** «Балачактагы холык, гадәтләр олыгайгач та югалмый» мәгънәсендә. *«Алтыда белгән алтмышка бара» дип, юкка гына әйтмәгәннәр картлар* (Сөйләм).

Төрдәше: алтыда белгән алтмышта да онытылмау; алтыдагы алтмышка(та).

**АЛТЫДА БЕЛГӘН АЛТМЫШТА ДА ОНЫТЫЛМАУ** *к.* алтыда белгән (алтыдагы) алтмышка бару. *Алтыда белгән алтмышта да онытылмый* (Г. Мөхәммәтшин. Йөрәктәге эзләр).

Төрдәше: алтыда белгән (алтыдагы) алтмышка бару; алтыдагы – алтмышка(та).

**АЛТЫДАГЫ АЛТМЫШКА ТӨРЛӘНҮ.** Балачакта булганның вакыт үтү белән бөтенләй үзгәреп бетүенә ишарә. *Алтыдагы алтмышка төрләнә дигәндәй, рәткә барыбер кермәс төсле ул миңа* (Ә. Моталлапов. Мәхшәр).

**АЛТЫДАГЫ – АЛТМЫШКА(ТА)** *к.* алтыда белгән (алтыдагы) алтмышка бару. *Алтыдагы – алтмышка. Башта шулай ук икән, яңадан холкы үзгәрер дисеңме аларның?* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).

Төрдәше: алтыда белгән (алтыдагы) алтмышка бару; алтыда белгән алтмышта да онылылмау.

*АЛТЫДАН* ❖ **АЛТЫДАН АЕРЫМ-АЕРЫМ.** Искедән калган әйтем, ягъни тәбәне алты йомыркадан яса, ләкин өчәр итеп аерым-аерым. – *Карале, озакка сузмыйча гына, алтыдан аерым-аерым яса әле* (Сөйләм).

**АЛТЫДАН БИШКӘ КҮЧҮ.** Фикерен төгәл әйтмичә, шуның тирәсендә йөрү. – *Син, Сафиулла абзый, әрләмә инде, – диде Габдулла, алда әйтәсенә алдан үзе көлеп. – Алтыдан бишкә күчмә инде. Нәрсә аны – турысын әйтәм дигәч әйт* (Ә. Гаффар. Дәрья башы).

*АЛТЫН* ❖ **АЛТЫН АКЫЛ.** Белемле, зиһенле кеше турында. *Алтын сүз әйтү өчен, алтын акыл кирәк* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).

Төрдәше: алтын баш<лы> 2; аяклы тарих; аяклы хәзинә 1; аяклы энциклопедия; беләмән – акыл тубалы; белем капчыгы; биш мулланы бер кунычка кыстыру; шулай ук к.: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә алу) һ.б.

**АЛТЫН АЛМА КЕБЕК.** Төскә чибәр булган, исән-сау, таза балалар турында. *[Карт] Шул үнәрне өйрәтүем өчен, алтын алма кебек ике баламнан яздым* (Ф. Бурнаш. Хөсәен мирза).

**АЛТЫН АЛМАМ.** Балаларны яки сөйгән кызны назлау әйтеме. – *Әйдә, алтын алмам, күзләреңне йом да матур төшләр күр* (Сөйләм).

Төрдәше: алтын күбәләгем.

**АЛТЫН БАГАНА.** 1. Илнең, җәмгыятьнең иң танылган кешеләре. *Үзәк газетаның өтек бер хәбәрчесе шәһре Казанның гына түгел, Татарстан җөмһүриятенең алтын баганаларына кизәнә* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

2. Кешеләргә терәк булырга ярардай, илгәгаиләгә файдалы кеше. *Сез – төрки-татар халыклары әдәбиятының алтын баганасы* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым). *Бабай минем өчен, чыннан да, кул җитмәслек биеклектәге изге, мәртәбәле кеше, алтын багана иде* (Р. Низами. Кояш – минем авылдашым).

Төрдәше: алтын бусага; алтын тотка.

**АЛТЫН БАКЫРГА ӘЙЛӘНҮ.** Затлы, кадерле булган нәрсәнең кыйммәте бетү. *[Фазыл] Алтын кыз бакырга әйләнде, сдача урынына кулдан-кулга йөри* (Г. Кутуй. Шатлык җыры).

Төрдәше: абруй җуелу һ.б.

**АЛТЫН БАЛЫК** *куч.* Бәхетле мөмкинлек, форсат. *Яшьлек хыяллары – алтын балык, күңел төпләрендә яталар* (Ф. Яхин).

**АЛТЫН БАЛЫК ЭЛӘКТЕРҮ (ТОТУ).** Бәхетле мөмкинлек туу. – *Без шушы болганчык елларда алтын балык эләктереп калырга тиешбез* (Ф. Яруллин. Кыйбласызлар).

**АЛТЫН БАШ<ЛЫ>.** 1. Сәләтле кеше (туры һәм ирونияле мәгънәдә). *Шул егермеләп төрки телне берләштереп, алардан бер тел ясау һәм шуны мәктәптә укыту кирәклек турында фәлсәфә сатучы «алтын башлар» булмады түгел* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында). *Юк, Исмәгыйль абзый шаталак яки һөнәр белмәс адәм булмаган. «Алтын куллы, алтын башлы» диләр иде аның турында, мондый сүзләрне Рушан да бер генә ишетмәде* (Р. Мирхәйдәров. Иртәләгән сагыш).

2. Акыллы, зиһенле кеше (туры һәм ирونияле мәгънәдә). *Боз белән утның мәңге каршылыклылыгын әллә белмиме аның каршында торган алтын баш?* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында). *Алдан килешеп куелган кеше, кагыйдә буларак, ул йә берәр үзебезнең укытучы, йә шәһәрдән кайткан бер «алтын баш» була, мәсьәләләрне чишәргә әзер* («Ватаным Татарстан» газ.).

Төрдәше: алтын акыл һ.б.

**АЛТЫН БӘРАБӘРЕНӘ.** Бик кадерле, кыйммәтле. *Бу җәһәттән Сөембикә ханбикә – алтын бәрабәренә тиң кәләш* (М. Әмирханов. Гәүһәршад). *Алтын бәрабәренә торырдай матур сүз баштагы томанны тарата, миеңә акыл оеткысы сала, күңелеңә зәвык бирә* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

Төрдәше: алтын бәясе <тору>; алтын бәясе (бәясенә) торырлык (торырдай); алтын бәясенә йөрү.

**АЛТЫН БӘЯСЕ (БӘЯСЕНӘ) ТОРЫРЛЫК (ТОРЫРДАЙ)** *к.* алтын бәрабәренә. *Тукайның халык зур, көчле, моңлы, шагыйрь, әдип булуы турындагы сүзләре алтын бәясенә торырлык* (С. Поварисов. Утлы дуга кыңгыравы).

Төрдәше: алтын бәрабәренә һ.б.

**АЛТЫН БӘЯСЕНӘ ЙӨРҮ** *к.* алтын бәрабәренә. *Калан мехы дөнья базарында алтын бәясенә йөри* (Ә. Маликов. Куриль чәчәкләре).

Төрдәше: алтын бәрабәренә һ.б.

**АЛТЫН БЕЛӘН.** Кадерле, кыйммәтле кешеләрнең исемнәрен телгә алганда, кыйммәтле язулы мирас белән бәйле рәвештә әйтелә. *Ихтимал, исемең алтын белән язылыр* (Г. Тукай). *Аягым җиргә тияр-тимәстән чабып, язу өстәленә килдем, анда тузылган китаплар, дәфтәрләр ята, шулар өстендә алтын белән язылган кыйммәтле кәгазь ялтырый иде* (Г. Ибраһимов. Яз башы).

Төрдәше: алтын хәреф<ләр> белән <язылу>.

**АЛТЫН БИРСӘЛӘР (БИРӘМ ДИСӘЛӘР) ДӘ.** Иясе өчен бик кыйммәт һәм кадерле әйбер хакында. *Бу мәрмәр сынны алтын бирәм дисәләр дә сатмыйм* (Сөйләм).

**АЛТЫН БИШЕКТӘН ТӨШҮ.** 1. Бәхетле кеше турында, көтмәгәндә баеп китү. *Әйе, без мокыт инде, барыбыз да синең кебек туугa алтын бишектән төшмәгән бит (ул ни өчендер мине әнисе белән генә үскән авыл кызы икәнлегемне онытып җибәргән)!* («Идел» ж.).

Төрдәше: әтәче дә йомырка (күкәй) сала; әтәче дә кубыз уйнау; алашасы <да> колынлау; бар булса – күрәлми, юк булса – бирәлми; бәндәнең бәхете алга киткәндә, кулына алса, алтын була ди; бәхетленең әтәче дә йомырка (күкәй) салу; бәхетленең сарыгы да юрга тота; бүресе улау; дуңгызы да боламык ашау; кеше тавыгы да каз булып күренү; кеше тавыгы каз кебек, йомыркасы баш кебек; көнче күбәләк; күрше тавыгы күршегә күркә булып күренү; май кайнаткан көнне туу; мәчесе дә куян тоту; тавыгы да юргалау; үгезе дә бозаулаган вакыт; үгезе дә сөт бирү, <үрдәкләре дә>; үгезе дә тешене бозаулау; үрдәкләре дә каз кебек.

2. Үзләрен тумыштан ук дәрәҗә иясе булып яратылган кебек тотучылар хакында. *Асыл булып үсеп җитте төпчеге. – Асыл гаебем дә шул дип саныйм… Асылгәрәевләр алтын бишектән төшкәнме?* («Сөембикә» ж.).

**АЛТЫН БУСАГА** *к.* алтын багана. *Безнең өчен түгел / бөек Тукай / Атлап кергән алтын бусага* (Рәш.Әхмәтҗанов. Бу мәңгелек, кочакларын җәеп).

Төрдәше: алтын багана.

**АЛТЫН БУСАГАМ ЮК.** Хатын кешенең ирен уйлап әйтү. *«Әрекмән белән кычыткан үскән һәр җирдә татар бар» дип әйтү дә, хатын кешенең ирен уйлап «алтын бусагам юк шул» диюе дә, «йомыркадан җөй эзләп йөрмә, яме»*

*дигән кызыклы гыйбарәләр дә һәм уңышлы кулланылган төбәк сүзләре дә әсәрнең кызыклыгын, үзенчәлеген дә арттыралар* (М. Вәли-Барҗылы. Тормыш дулкыннары).

**АЛТЫН ГАСЫР.** Бер илнең, дәүләтнең яки халыкның төрле яклы үсеше белән балкыган, дан тоткан шәп чагы. *Үзбәк хан дәүләт башында тору вакытын Алтын Урданың алтын гасыры дип әйтергә мөмкин* (Сөйләм).

Төрдәше: алтын дәвер; алтын чор.

**АЛТЫН ДӘВЕР** *к.* алтын гасыр. *Юнан мәдәниятенең алтын дәверендә без дин әһеле шулай дип үзен акларга тырышканын күрәбез* (Г. Ибраһимов).

Төрдәше: алтын гасыр; алтын чор.

**АЛТЫН ДУГА.** Салават күпере. *Идел аркылы алтын дуга ташладым* (Табышмак).

**АЛТЫН ЙӨГЕРТҮ.** 1. Нинди булса да эшләнмәнең өстен алтын белән каплату. *Тагын әле җиз шәмдәлләр, инкрустацияләп эшләнгән сугыш балталары, тимергә алтын йөгерткән шешәк, инкрустицияле һәм гарәп хәрефләре белән язулы көмеш яки чуен пайцза хәтсез күп* (Р. Фәхретдинов. Татар халкы һәм Татарстан тарихы). *Алтын йөгерткән шикәр савыты... ярты кадак* (А. Тимергалин. Таш алиһә).

2. Берәр нәрсәгә алтын сыман саргылт яктылык төшү яисә әйбер шундый төскә керү. *Кояш шушы яшеллеккә алтын йөгертергә тели, тирләп-пешеп нурларын коя* (В. Нуриев. Җиденче палата). *Аерма тик шунда гына: ул чакта көз иде, өрәңге һәм элмә яфракларына алтын йөгертелгән* <...> (В. Нуруллин. Әгәр син булмасаң).

**АЛТЫН ЙӨРӘКЛЕ.** Игелекле, шәфкатьле, ихлас күңелле кеше хакында. *Алтын йөрәкле кеше булса иде икән!* (Р. Кәрами. Олы юлы да сикәлтәле).

**АЛТЫН КАГЫЙДӘ.** Бозарга ярамаган җитди тәртип, гадәт. *Ленинград сәхнәсендә биегән елларында Рудольф Нуриев шундый гадәтне үзенең алтын кагыйдәсе иткән иде...* (Р. Вәли. Канатлы татар).

**АЛТЫН КАПЧЫГЫ (КАПЧЫК).** Хәзинә туплау, мал җыю җире; бик бай кеше хакында. *Ни хикмәте булган ул капчыкның, / йорттан йортка кереп йөрерлек? / алтын капчык эзләп йөгергәнбез, / булмаганбыз серен белерлек* (В. Фатыйхов. Язлар көтә күңел).

**АЛТЫН КЕШЕ.** Ышанычлы, арка терәге булырдай, олы җанлы, асыл зат. – *Их, Булатов! Алтын кеше иде ул, алтын...* (А. Алиш. Якты күл буе). *Юк, синең апаң алай ук хәтерсез кеше түгел! Ул – алтын кеше!* (Р. Кәрами).

**АЛТЫН КОШ ТОТКАН БАЛАДАЙ.** Нәрсәгә булса да чамасыз шатлану. *Гыймайның көн буе таш кисеп кайтканнан соң, рамнар ясарга чыгып китүе кулына бераз акча керсә, алтын кош тоткан баладай, сөенә-сөенә акчаларын Фатыймага тоттыруы һәм кечкенә сумма өчен дә эчке горурлык кичерүе хатынга һич ошамый* (Н. Гыйматдинова. Сөйлим, тыңла...).

Төрдәше: алтын кош тоткан кебек.

**АЛТЫН КОШ ТОТКАН КЕБЕК** *к.* алтын кош тоткан баладай. *Сүзге-бикәнең көтелмәгән бу тәкъдименнән Күчем хан башта югалып калды, аннан, алтын кош тоткан кебек, сөенеченнән яктырып китте* (Ф. Бәйрәмова. Күчем хан).

Төрдәше: алтын кош тоткан баладай.

**АЛТЫН КӨЗ.** Көзен агач-куакларның, үсемлекләрнең яфраклары саргайган вакыт. *Төбәгебезгә сап-сары, ал-кызыл яфраклары белән алтын көз килде* (А. Хәсәнов. Көзге урман аланында).

**АЛТЫН КӨЗГӘ КЕРҮ.** Иң биремле чор, иң югары уңышка ирешү чоры. *Көнләшмәгез җиткән уңышымнан / Мин дә кердем алтын көземә* (Л. Шагыйрьҗан).

**АЛТЫН КУЛ<ЛЫ>** *к.* агач<тан> сандугач кына ясамау. *Алтын куллы халык булсаң да, син / Бәхет йөзе күрә алмадың* (Х. Туфан). *Беренчедән, бу Луизаның алтын җепләр белән чигү чигүенә ишарә булып яңгыраса, икенчедән, Луиза – чын мәгънәсендә алтын куллы сәнгать остасы* (Н. Гамбәр. Кояшлы тауга күтәрелү).

Төрдәше: агач<тан> сандугач кына ясамау һ.б.

**АЛТЫН КҮБӘЛӘГЕМ** *к.* алтын алмам. *Йокы аралаш Нурия ягымлы, көйле бер тавыш ишетте: алтын күбәләгемдер шул, былбыл гөлемдер шул, арып киткән булган бит* (Г. Ахунов).

Төрдәше: алтын алмам.

**АЛТЫН КЫЙММӘТЕНӘ ЙӨРҮ.** Нәрсәнеңдер бәясе артык кыйммәт булу. *Кайчандыр тоз алтын кыйммәтенә йөргән дип сөйлиләр* (Сөйләм).

**АЛТЫН ӨЙДӘН БАШ КЫЙБАТ <БУЛУ>.** Кешенең гомере иң кыйммәтле нәрсә икәнлегенә ишарә. *«Син ул нәрсәңне монда калдырма инде, кайдан алдың, дип теңкәмә тиярләр, минем алтын өйдән башым кыйбат»* (Сөйләм).

**«АЛТЫН САНДЫККА» БИК САЛУ.** Фараз ителгән файдага өметләнеп, уңыш китерә торган эштән ваз кичү. *Сәүдәм матур гына табыш китергәндә, дипломга алданып, «алтын сандык»ка бик салу үзе үк ахмаклык иде* (Н. Гыйматдинова. Сөйлим, тыңла...).

**АЛТЫН САРАЙ** *ирон., шаярт.* Патша сарае кебек зиннәтле, зәвыклы бина. *Мин башта ук сезгә кистереп әйтергә тиешмен: сез миңа бер бүлмә түгел, алтын сарай тәкъдим итсәгез дә бармыйм* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**АЛТЫН СӘГАТЬ ТАГУ.** Начар җенси авыру (сифилис) эләктерү (дәвалануы кыйммәткә төшү). – *Ишеттеңме, күрше Гафур алтын сәгать таккан икән дә хәзер шифаханә юлын таптый!* (Сөйләм).

**АЛТЫН СҮЗЛӘР.** Бик акыллы, тормышта үрнәк булырлык сүзләр. *Еллар үткәч, яшьлегем юләрлеген җилләр куып тараткач, Дәүләтша бабайның алтын сүзләре хәтердә яңгырар, билгеле* (Н. Гыйматдинова. Сөйлим, тыңла...).

**АЛТЫН ТАВЫ ТОТТЫРУ (УЧЛАТУ).** Берәрсен юмалау, үзенә карату яки ышандыру максаты белән, булдыра алмаслык нәрсәләр (байлык, муллык, бәхет) вәгъдә итү. – *Касыйм капкынына эләккән син беренчесе түгел, алтын тавы тоттырырга шомарган ул* (Сөйләм).

Төрдәше: алтын таулар вәгъдә итү; тау хәтле вәгъдәләр бирү.

**АЛТЫН ТАУ ӨЙМӘҮ.** Әллә нәрсә юк, артык түгел. *Читкә чыгып та, курыкма, алтын тау өймәгәннәр* (З. Галимов).

**АЛТЫН ТАУЛАР ВӘГЪДӘ ИТҮ** *к.* алтын тавы тоттыру (учлату). *Алтын таулар вәгъдә итәм, / киләм-китәм, туйны көтәм, / Телдән төшми «җаным», «иркәм»* (Г. Афзал. Мин кем микән...).

Төрдәше: алтын тавы тоттыру (учлату); тау хәтле вәгъдәләр бирү.

**АЛТЫН ТАШУЧЫ (ТҮГҮЧЕ)** *иск.* Бәдрәф чистартучы. Бу атама элекке вакытларда ат арбаларына мичкә куеп ташудан калган. *Алтын ташучылар төнгә таба гына эшкә чыгып, озын саплы чиләкләрен күккә төбәп, урамнардан кичәләр иде* (Сөйләм).

**АЛТЫН ТАШЫ** *иск.* Урта гасырларда төрки халыкларда кулланылган алтын-көмеш үлчәме. *Заманында Бабур падишаһ алтын ташының биш йөз мыскалга [1 мыск.= 4.266 г] тиң булуын язган иде* (Сөйләм).

Төрдәше: көмеш ташы.

**АЛТЫН <БӘЯСЕ> ТОРУ** *к.* алтын бәрабәренә. *Кеше буларак та, башка күп яклары белән дә алтын бәясе хатын бит ул* (Г. Тавлин. Афәт). *И-их, әрәм иттеләр алтын бәясе кешене* (Г. Сабитов. Калай күке).

Төрдәше: алтын бәрабәренә һ.б.

**АЛТЫН ПОГОННАР** *тар.* Патша армиясе офицерлары. *Инде бу зур корсаклар, бу алтын погоннар, ут эчендә янып ята торган иптәшләребез өчен хисап бирергә тиешләр, аларны хәзер үк ут янына тезеп куегыз! – диде* (Һ. Такташ. Караборынның дусты).

**АЛТЫН СУ.** 1. Алтын йөгертү өчен әзерләнгән сыекча. – *Алтын су әзерләп куйдыңмы, яңгыр ява башлаганчы, тыштагы язуларны яңартырга кирәк* (Сөйләм).

2. Сары шешәләргә тутырылган сыеклык исеме. *Кайбер илләрдә энҗе чәчәк бәлзәмнәрен алтын төсендәге шешәләрдә саклаганнар һәм алардагы шифалы сыеклыкны «алтын су» дип атаганнар* («Көмеш кыңгырау» газ.).

**АЛТЫН ТОТКА.** *мыск., к.* алтын багана. *Демонстрация үтүгә, алар, Татарстанның алтын тоткалары, савылып өлкә комитеты буфетына керәләр, аягүрә басып кына берике чәркә коньяк йотып, кара икра, семга телемнәре белән авызларын кинәндергәч таралалар* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?)

Төрдәше: алтын багана; алтын бусага.

**АЛТЫН ТУЙ.** Өйләнешеп илле ел бергә яшәү туе. – *Ник алтын туй үткәрмибез, картым, – Кушылганга илле ел инде?* (З. Нури. Катkат бүленгән стаж).

**АЛТЫН УРТАЛЫК.** Бер якка да авышмыйча, тигезлек саклап, тыныч яшәү рәвеше. *Шул вакыт эчендә кафедра әгъзалары белән уртак тел табып, кеше белән эшләүдә алтын урталыкны күрүче, шәхси иректе танучы һәм хуплаучы буларак танылды* (Ф. Латыйфи. Себер хикәяте). *Румиянең читтән торып уку бүлегенә кучүен язган идек инде. Ниһаять, алтын урталыкны тапкан – гастрольләргә дә йөри, укуда да уңышларга ирешә* («Кәеф ничек?» газ.).

**АЛТЫН УРТАСЫН ТАБУ** *к.* алтын урталык. *Ике арадагы мөнәсәбәтләрне юлга салганчы, аның алтын уртасын табарга кирәк иде* (Сөйләм).

Төрдәше: алтын урталык.

**АЛТЫН ФОНД (ХӘЗИНӘ).** Иң яхшы, чагыштырырлыгы булмаган. *Фразеологик әйтелмәләр телдә алтын фонд булып санала* (Хаков укулары – 2013).

**АЛТЫН ХӘРЕФ<ЛӘР> БЕЛӘН <ЯЗЫЛУ>** *к.* алтын белән. *Бик күп галимнәребезнең исемнәре дөнья фәне тарихына алтын хәрефләр белән язылган* (Я. Шәфыйков. Бер очрашу – бер гомер).

Төрдәше: алтын белән.

**АЛТЫН ЧИШМӘ.** Табыш чыганагы булып хезмәт иткән нәрсә. *Бөтен яклап алтын – халыкка алтын бәясенә төшкән әйбер, ә бюджетка – алтын чишмә* («Безнең гәҗит» газ.).

Төрдәше: табышлы урын.

**АЛТЫН ЧОР** *к.* алтын гасыр. *Татар әдәбиятының «алтын чор»ы – XX йөз башы – әдәбият белеменең даими игътибар үзәгендә тора* (Ә. Закирҗанов. Татар әдәбият белеме).

Төрдәше: алтын гасыр; алтын дәвер.

**АЛТЫН ЭЧЕНДӘ ЙӨЗҮ.** Бик бай яшәү. *Алар үзләре Швейцариядә рәхәтләнеп яталар, монда кайтсалар да, алтын эчендә йөзеп йөриләр* (Г. Ибраһимов).

Төрдәше: алтынга күм<ел>ү (бат<ыр>у); алтынга ману 3; алтынга чуму; алтын-көмешкә чумдыру; байлыкка чуму; дөньясы бай, дөньясы бөтен.

**АЛТЫН ЮБИЛЕЙ.** Нинди булса да вакыйганың 50 еллыгы. *Салаховлар гаиләсе белән әлеге очрашуымның сәбәбе исә – алтын юбилей* («Әлмәт таңнары» газ.).

**АЛТЫН ЯНЧЫГЫ** *к.* алтын капчыгы (капчык). – *Бездән сорама инде син, сиңа алтын янчыгы Мансур кирәк* (Сөйләм).

Төрдәше: алтын капчыгы (капчык).

**АЛТЫН ЯҢГЫР.** Бик зур керемле эш белән шөгыльләнү. *Бүтәннәрне дә, үзен дә алдады кеше, / Авызы белән кош тота алмады кеше, / Алтын яңгырда коенып туймады кеше* (Г. Афзал. Ягымлы елмаеп сөйләшү). *Һай, нинди шәп булачак иде бу! Җирдә шундый оҗмах тудырган галим өстенә алтын яңгыр явачак иде...* (М. Маликова).

*АЛТЫНГА* ❖ **АЛТЫНГА ӘЙЛӘНДЕРҮ.** Алтынга яки чит ил акчасына алмаштыру. *1933 елның ахырларында аның хуҗалары бер ат йөге кадәре акча белән Кашгар якларына җибәрәләр. Кәгазь акчаларны металлга, ягъни алтынга әйләндереп кайту өчен* (М. Госманов. Чәчелгән орлыклар).

**АЛТЫНГА ДА ТАБЫП БУЛМАУ.** Бик күп акча биреп тә табып булмый торган кыйммәтле нәрсә. – *Ул даруны монда алтынга да табып булмый* (Сөйләм).

**АЛТЫНГА КҮМ<ЕЛ>Ү (БАТ<ЫР>У).** Бик күп акча эшләп, байлык эчендә яшәү. *Ефәккә төренү, алтынга күмелү – хатын-кыз хыялыдыр* (М. Хәбибуллин. Илчегә үлем юк). *Аны алтынга батырдым инде мин (көлешәбез)* («Акчарлак» газ.).

Төрдәше: алтын эчендә йөзү һ.б.

**АЛТЫНГА КҮМСӘЛӘР ДӘ** *к.* алтын бирсәләр дә. – *Алтынга күмсәләр дә сатачагым юк* (Сөйләм).

**АЛТЫНГА МАНУ.** 1. Саргылт төскә кертү. *Ак кардай халатыннан төшкән нур аның бит очындагы эре-эре сипкел бөртекләрен алтынга манып, матурлап күрсәтә иде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

2. Алтын суы йөгертү. *Мәмәт аганың көмеш чәнечкеләргә дә, алтынга манган савыт-сабага да исе китмәде* (А. Тимергалин. Таш алиһә).

3. Муллыкта яшәү; байлыкка күмү, сөйгән ярын яки сөяркәсен бизәк-зиннәтләр белән иркәләү. *Нәрсә генә алмады ул яшь хатынына, кыскасы, алтынга манды ул аны* (Сөйләм). – *Син миңа биш-алты юлбасар үстереп бирерсең, мин сине алтынга манача кмын...* (Р. Батулла. Сөембикә).

Тәрдәше: алтын эчендә йөзү һ.б.

**АЛТЫНГА ЧУМУ** *к.* алтын эчендә йөзү. *Диңгез арты килмешәкләренә дә, «кара алтын» чыгарып, сары алтынга чумарга хыялланган башка капиталист һәм промышленникларга да насыйп булмаган ул нефтьне табу* (Ш. Бикчурин. Тамырлар).

Тәрдәше: алтын эчендә йөзү һ.б.

*АЛТЫН-КӨМЕШКӘ* ❖ **АЛТЫН-КӨМЕШКӘ ЧУМДЫРУ** *к.* алтын эчендә йөзү. *Затлы келәмнәр түшәлгән бу бүлмәне алтын-көмешкә чумдырганнар* (Сөйләм).

Тәрдәше: алтын эчендә йөзү һ.б.

*АЛТЫННАН* ❖ **АЛТЫННАН КОЕЛГАН, БАКЫРГА МАНЫЛГАН.** Кыйммәтле асыл нәрсәнең, затсыз кулларга эләгеп, кадерен, бәясен җую. *Элекке заманнарда берәр-берәр данә генә эшләнелгән әйберләр алтыннан коелган, бакырга манылган хәлгә килделәр* (Сөйләм).

**АЛТЫННАН КЫЙБАТ (КАДЕРЛЕ; КЫЙММӘТ).** Бик кадерле һәм кыйммәтле булган нәрсә турында. *Өстәге каттан су үткән, ул берничә җирдән стена буйлап идәнгә, Мирза картның гомер буе алтыннан кыйммәт күреп җыйган китапларына ага иде* (Г. Исхакова. Китү).

*АЛТЫННЫ* ❖ **АЛТЫННЫ БАКЫРГА САТУ**. Кыйммәтен, кадерен җую, дәрәҗәсен төшерү; кадерсезгә калу. *Юк булмады, кыйммәтен, үз кадерен белмичә, атасы яшендәге кешегә киявгә чыккан, алтынын бакырга саткан* (Ә. Салах. Каеннар юлы). *Хәзинә таптым – чүпкә аттым, алтын таптым – бакырга саттым* (Мәкаль).

*АЛТЫНЧЫ* ❖ **АЛТЫНЧЫ КАПЧЫКНЫҢ АВЫЗЫН БӘЙЛӘҮ.** Алтынчы унны (алтмыш яшен) тутыру. *[Мөхәммәт җан] Без дә синең белән алтынчы капчыкның авызын бәйлибез бугай инде* (К. Тинчурин. Йосыф белән Зөләйха).

**АЛТЫНЧЫ КАПЧЫКНЫҢ АВЫЗЫН ЧИШҮ.** Илле яшьне тутырып, алтмышынчы яшькә чыгу. *Йә, дускай, син дә алтынчы капчыкның авызын чиштеңме?* (Сөйләм).

**АЛТЫНЧЫ ТОЙГЫ.** Күңел сизенү. *Алдан ук утырасы килмәде бит шушы машинага. Күңеле сизгән икән. Алтынчы тойгы диләр аны* (Г. Исхакова. Алтынчы тойгы). *Серле мизгел итеп сизәбез; / Акыл көче аны аңлаталмый, / Бу – алтынчы тойгы дигән сүз* (Х. Бәдигый. Яшел чирәм).

*АЛТЫНЫ* ❖ **АЛТЫНЫ БИШКӘ САТУ** *к.* алтыга алып бишкә сату. *Дәрәҗәңне төшермәс өчен, кайвакыт алтыны бишкә сатарга да туры килә* (Сөйләм).

Тәрдәше: алтыга алып бишкә сату.

*АЛТЫҢ* ❖ **АЛТЫҢ АЛТЫ ЯККА КИТҮ.** Төрле якларга таралу. *Алтың алты якка киткәч, дуслык турында сүз йөртергә мөмкинме соң?* (Сөйләм).

*АЛТЫРАГЫНА* ❖ **АЛТЫРАГЫНА ДА ТОРМАУ** *гади с.* Бернәрсәгә дә яраксыз, кирәге булмаган нәрсә. *Белмим, син нәрсә уйлый торгансыңдыр, ләкин, минемчә, кеше буларак, ул Мәрьямнең алтырагына да тормый* (Сөйләм).

Тәрдәше: аның итек табанына да тормау (торырлык түгел); Тәрдәше: бер тырнагына да тормау; кисеп ташлаган тырнакка да тормау; олтанына да ярамау; олтырагына да ярамау; олтыракка да ярамау.

*АЛУЫН* ❖ **АЛУЫН ЯЛГЫЗ АЛДЫМ, САТУЫН ӘТИ БЕЛӘН ДӘ САТА АЛМЫЙМ** *к.* алдым файда итәргә, белмәдем (белмим) кая илтергә (итәргә). *Кем уйлаган аны шулай мәшәкатьле булыр дип, сатып алуын ялгыз алган идем, ә сатуын әти белән дә сата алмыйм* (Сөйләм).

Тәрдәше: алдым файда итәргә, белмәдем (белмим) кая илтергә (итәргә).

*АЛЫ* ❖ **АЛЫ БУЛДЫ, ГӨЛЕ КИРӘК.** Нәрсәгәдер тулысынча ирешү өчен, беренче адымнар эшләнде, нәтиҗәсе эшне дәвам итүгә бәйле булуына ишарә, ягъни башлаган эшне ярты юлда туктатырга ярамый. *Алы булды – инде гөле кирәк!* (Р. Вәли. Шәһрәт).

**АЛЫ БУЛЫП ҖИТМИЧӘ, ГӨЛЕН ДАУЛАУ.** Яхшыдан яхшыракны даулау. *Баш врач хәтта*

*сызгырып җибәрде. – Сезнең хыялыгыз ай-яй шәп оча, Гөлшәһидә Бәдриевна, – диде ул, бу юлы артык ачуланмыйча. – Алы булып җитмәгән иде, гөлен даулыйсыз* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

*АЛЫМ* ❖ **АЛЫМ ДА БУЛСЫН МӨЛТӘКИГӘ, ГӨЛЕМ ДӘ БУЛСЫН МӨЛТӘКИГӘ <ДИГӘН КЕБЕК>**. Исем-дәрәҗә, бүләкләр һаман да бер кешегә бирелү. *Өйләре күрше булгач та, бездә башка лаеклылар да бар, алым да булсын Мөлтәкигә, гөлем дә булсын Мөлтәкигә генә димәгән* (Сөйләм).

*АЛЫНГЫ* ❖ **АЛЫНГЫ КАТЛАУ.** Алда баручы, аңы-фикерләве белән заманга туры килгән кешеләр. *Алда авылның алынгы катлавы, безнең белән бергәләшеп, яңа тормышка юнәлтә атламын* (К. Нәҗми).

*АЛЫП* ❖ **АЛЫП АВЫЗ.** Лыгырдавык, гайбәтче. *Теге алып авыз авыл тормышыннан нинди гаепләр табып алды икән?..* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: алап авыз 2 һ.б.

**АЛЫП БАБАЙ ЧАБАТАСЫН КАККАН ҖИР.** Калкулыклар яки биек булмаган таучыклар. *Авыл саен диярлек Алып бабай чабатасын каккан кыганлы җирләрем...* (А. Тимергалин. Сүнмәс ут янында уйда без...).

**АЛЫП БАРУ.** Җитәкчелек итү, башканлык вазыйфасын башкару. *Яшисеңме мәңге шул хаклыкны / Бар халыкка ачып, күрсәтеп, / Алып барамсың таңга бар халыкны / Алда матур, якты юл ачып?* (М. Җәлил).

**АЛЫП БАРУЧЫ.** Җыелышның, тамашаның үткәрелеш тәртибен саклаучы кеше, сәхнәдә башкарылачак номерларны игълан итеп торучы. *Пәрдә ачылыр алдыннан, алып баручы пәрдәнең тышкы ягына чыга* (Г. Камал. Өч тормыш). *Алып баручыларның кыланмышыннан һәм билдән түбән юморыннан уңайсызланып, йә булмаса бөтенләй оялып кына утырасың күп вакытта концертларда* («Матбугат.ру» порталы).

**АЛЫП БАРЫП ЧЫГУ <ОЧЫНА>.** Берәр эшне нәтиҗәгә ирешкәнче дәвам итәргә. – *Моны Галимовка тапшырырга кирәк, алып барып чыгачак ул бу эшне* (Сөйләм).

**АЛЫП БИРЕП.** Кинәттән орыша башлау, тиргәү. *Берәү дә көтмәгән иде, җитәкчебез алып бирер тотынды малайларны орышырга* (Сөйләм).

**АЛЫП ЙОКЫСЫ** *к.* Алпамыш йокысы. *Көн буе атта чапкан егетләрне алып йокысы алды бугай, иярләрен баш асларына куеп, киртә тирәсенә урнаштылар* (Сөйләм).

Төрдәше: Алпамыш йокысы.

**АЛЫП ЙӨРӘК.** Курку белмәс, гайрәтле кеше хакында. *Алып йөрәк (борынгы төркичәдән) – батыр йөрәк* (А. Тимергалин. Миллият сүзлеге).

Төрдәше: батыр йөрәк.

**АЛЫП КАДӘР.** Бик зур гәүдәле кеше турында. *Әти алды да китте мине пристаньга. Анда Алып кадәр бер грузчик янына барды да әйтте* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: алып кебек; алыптай гәүдәле; аю егарлык <егет>; аю кебек; әвен кебек ир; әзмәвердәй таза; басса бакыр өзәрдәй, биттән кан таму; гернадыр (гөрнәдер / гөрнәдир; гренадер) кебек; гүәрдин кебек <таза>. сукса тимер өзәрдәй; сукса тимер өзәрлек, басса бакыр изәрлек; сукса, тугыз көн чумар ашамассың; сукса, чумарыңны чыгарыр; таза Мортаза; типсә тимер өзәрдәй; үгез кебек.

**АЛЫП <БИРЕП> КИТҮ.** Чыгымчылап чабып китү (ат турында). *Ат ничек алып киткәнне / Күргәнең булса әгәр, / Аңларсың, гашыйк егеттә / Була шул андый хәлләр...* (Зөлфәт. Каны кызган кыргый ат).

**АЛЫП МАКТАРЛЫК ТҮГЕЛ, САЛЫП ТАПТАРЛЫК ТҮГЕЛ.** Дан, дәрәҗә турында әйтелә: «мактарлыгы да юк, хурларлыгы да юк, урта дәрәҗәдә» мәгънәсендә; урта дәрәҗәдә, ярый шунда. – *Ничек, дип, шул инде: алып мактарлык түгел, салып таптарлык түгел дигәндәй, бер көйгә шунда...* (М. Хәсәнов. Саф җилләр).

Төрдәше: салып таптарлык түгел.

**АЛЫП ОРЛЫГЫ.** Бик зур гәүдәле, эре сөякле кеше турында, ягъни Алып батыр нәселеннән булуына ишарә. *Алып орлыгы, Алпамыш йокысы, Алпамыш батыр йокысы белән йоклый әйтемнәрендә Алып исеменең деонимизация кичерүен күзәтергә мөмкин* (Татар лексикологиясе, III том).

**АЛЫП ТА ЕГА, ЧАЛЫП ТА ЕГА.** Гадел дә, гаделсез дә, теләсә ничек кыланып, һәрвакыт өстен чыгу. Хәлле, дәрәҗәле кулында хөкем көче булган кеше белән алышуның файдасызлыгын күрсәтә. – *Хаклык эзләп, аның белән юкка көрәшәсең, ул – бүгенге система кешесе, андыйлар алып та ега, чалып та ега* (Сөйләм).

**АЛЫП УЗУ**. Масаю, үзен әллә кемгә кую. – *Тәмам алып узды бу ярлы-ябага!* (Ф. Имамов. Кризис) – *Гел җәүнәй җөреп, дегет саткан акчаның да җартысын гына кайтарып, гел симерүе җитте, гел алып узды, шуңар чыгып качты инде шул! – дип өстәде әни кеше* (Ш. Маннур. Агымсуларга карап).

Төрдәше: амбициягә бирелү; әллә кем булу; әтәчкә дә сәлам бирмәү; әтәчләнеп йөрү; баш күтәреп, баш текә <булу>; баш чыю; тамак кырып, мыек борып <йөрү>; борын аша карау 2; борын белән багана аудару (аударып йөрү); борын белән болыт сукалау (сөзү); борын белән күкне сукалау (сөрү); борын белән сөйләү 2; борын күктә; борын күтәр<ел>ү; борын тишеге белән карау; борын түшәмгә тию; борын түшәмне тишү; борын чөйдә булу; борын чөерү 2; борын чөю (чөеп йөрү); борынга көянтә элү; борынга чиләк элү; борынны күккә (болытка) чөю; борынны күтәрү; борынны югары тоту (чөю); борынны маңгайдан югарырак чөю; борынны түшәмгә элү; борынны чөйгә элү; борынны югары тоту (чөю); борыны югары; борынына тугыз күркә кунарлык (сыярлык) 2; борынына чиләк эләрлек; борынына шакшы юкә буйламый; бөерәккә таяну; бөергә таяну 1; буш куыклану; бүксә киерү; казанга сыймас кабырга; кара куйдан ак туган, башын әллә кая куйган; күлмәксездән күлмәкле булган, башын әллә кемгә куйган; кыланышы кикертте; кыланышы кырга (өйгә) сыймау; кыланышы үзеннән зур; кылтаюы кырга сыймау; күлен танымаган күк бака; кысыр тавык күп кытаклау (булдыксыз кеше күп сөйли, мактана); мае басып киткән; маена түзә (чыдаша; чыдый) алмый; май баскан; мин аны әлмисактан бирле беләм; мин аны белеп оныткан; мин аны тумас борын белгән; «мин беләм» кеше; мин белмәгән аз булыр, Бохардагы таз булыр; «мин кем?» диеп йөрү; мин минме икән, мин кем икән?; сүзләр бөердән чыгу; танауны күккә чөю; үзен әллә кемгә кую; үзен <үзе> зурга кую; үзен үзе әллә кемгә кую; эре бавырлы.

*АЛЫПТАЙ* ❖ **АЛЫПТАЙ ГӘҮДӘЛЕ** *к.* алып кадәр. *Ишек-тәрәзәләренә бик эләргә әзерләнеп йөргән чакта Нәҗметдин хаҗиның кечкенә кибетенә алыптай гәүдәле, таныш түгел ират килеп керде* (В. Имамов. Япон татары).

Төрдәше: алып кадәр һ.б.

*АЛЫРСЫҢ* ❖ **АЛЫРСЫҢ АННАН КУЯНГА КОЙРЫК ҮССӘ** *к.* абага чәчәк аткач (атканда). *Акчаны биргәндә уйлап бирәләр аны, хәзер көт инде – куянга койрык үссә, бәлки, алырсың аннан* (Сөйләм).

Төрдәше: абага чәчәк аткач (атканда) һ.б.

**АЛЫРСЫҢ ШАЙТАННАН ИМАН.** 1. Акчага, малга табынган комсыз кешенең кеше хакын басып алуы. *Әүвәлгеләрен дә бирермен дигән була, алырсың инде шайтаннан иман!* (Г. Камал).

Төрдәше: алырсың эт авызыннан сөякне (беленне); бер тиен өчен кара тиргә төшеп сатулашу.

2. Кирәк әйберне бирми дә, вакытлыча да биреп тормаган саран кеше турында. – *Тапкансың сорарлык кеше, кышын кар да бирми бит ул, алырсың шайтаннан иман!* (Сөйләм).

Төрдәше: алырсың эт авызыннан сөякне (беленне); алыш-бирешк(т)ә бик кысмыр; анасының имчәген имгәндә, икенчесен кулы белән җибәрми тотып тору; аннан алган йомырканың эчендә сарысы булмас; аннан әйбер алганчы, тавыктан сөт саварсың; аннан раштуада яуган карны ала алмассың; аңардан кышын кар сорап ала алмассың; аңардан сорап томау да ала алмассың; бармак арасына (арасыннан) кысу (сыту; бармак арасыннан кысып кына; бармактан кысып чыгару; баштан бөркәнеп ашау; бер кашык су салмас; бер тавыкны унга бүлү; бер тиен өчен дереллдәп тору; бер тиен өчен җанын сату (бирү); бер тиен өчен җәһәннәмгә керү; бер тиен өчен кара тиргә төшеп сатулашу; бер тиен өчен туганын сатарга әзер тору (булу); бер тиен өчен үлгән (үлеп тору); бер тиен өчен чәрәеп кату; бер тиен өчен чукыну (чукынып тору); бер тиенгә бетәшкән; бер тиене онытылып калса, йөз чакрым кире кайту; бер төйнәгән йодрыгын патша килсә дә ачмау; бер шырпыны бишкә ярып кабызу; бет<ен> ашаган; бетәшкән нәрсә; бетен

сытып канын эчкән; еланнан авыруга дару сорау; ике тишекле бер тиен бирмәү; каты борчак; каты җирдә как тору; керпенең аягын күреп булмау; кулыннан кош туймый; печән өстендәге эт кебек; раштуада бер көрәк кар бирмәс; саран бака; саран кулда мал тору; сорап томау да ала алмассың; суны да үлчәп эчү; учыннан акканны ялаучы; учына кысып кына тоту; учыннан кысып кына чыгару; үзе дә ашамас, кешегә дә бирмәс; үлгән вакытында бер йотым (эчем) су бирмәс; чепере май, чирек май, иртәгә дә калсын май; эт авызындагы сөяк; эт тизәгеннән кош туймас; эттән сөяк артмас.

**АЛЫРСЫҢ ЭТ АВЫЗЫННАН СӨЯКНЕ (БЕЛЕННЕ)** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. *[Әхмәди] Мин алып кайткач! Алырсың эт авызыннан сөяк* (Г. Камал. Өч тормыш). *Хәтта усал телле Заһидулла да: – Алырсың эт авызыннан сөякне, – дип куюдан ары уза алмады* (Ә. Фәйзи).
Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

*АЛЫРЫН* ❖ **АЛЫРЫН БЕЛӘ, БИРЕРЕН БЕЛМИ.** Бурычка алырга яратып, кире кайтарырга яратмаучы белән бәйле. – *Нигә бурычка биреп торырга ашыгасың: алырын белгәч, биререн дә бел* (Сөйләм).

*АЛЫШ-БИРЕШ* ❖ **АЛЫШ-БИРЕШ ИТҮ.** 1. *к.* алдым-бирдем ясау. *Алыш-биреш итү уе белән иртән иртүк күрше авылдагы олы базарга юл алды* (Сөйләм).
Төрдәше: алдым-бирдем ясау; алыш-биреш ясау.

2. Сөйләшү, аралашу. *Уңмаган, булдыксыз кешеләрне җене сөйми, андыйлар белән алыш-биреш итәргә дә теләми, исәпләшми дә иде* (Г. Бәширов).
Төрдәше: гәп йомгагын сүтү; гәп кору; гәп куерту; гәп сату; гәп сугу.

**АЛЫШ-БИРЕШ ШУЛ ТИКЛЕ ГЕНӘ.** Мөнәсәбәт, бәйләнеш зәгыйфь булу. *Әйтергә кирәк, мөселман дине белән дә алыш-биреше шул тикле генә* (Г. Гобәй. Без үскәндә).

**АЛЫШ-БИРЕШ ЮК.** Уртак бернәрсә лә булмау. *Нәсимәнең дин белән артык алыш-биреше юк* (Ш. Камал). *Бераз кызып йөрер дә суыныр әле, минем аның белән алыш-бирешем юк* (Сөйләм).

**АЛЫШ-БИРЕШ ЯСАУ** *к.* алдым-бирдем ясау. *Илләр бер-берсе белән сату иткәндә, минем белән алыш-биреш ясыйлар* (infourok.ru).
Төрдәше: алдым-бирдем ясау 1; алыш-биреш итү.

**АЛЫШ-БИРЕШК(Т)Ә ❖ АЛЫШ-БИРЕШК(Т)Ә БИК КЫСМЫР.** Артык саран кеше турында; *шулай ук к.* алырсың шайтаннан иман 2. – *Юкка аның янына барып, вакытын әрәм итә: алыш-бирешкә бик кысмыр кеше ул* (Сөйләм).
Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

*АЛЫШ-БИРЕШНЕ* ❖ **АЛЫШ-БИРЕШНЕ ӨЗҮ.** 1. Аласын алып, бирәсен биреп бетерү, исәп-хисапны төгәлләү. *Аласыларын да алып, бирәселәрен дә биреп, алыш-бирешне өзде дә гаиләсе белән шәһәргә күчәргә булды* (Сөйләм).

2. Барлык бәйләнешләрне, аралашуны туктату. *Кергән бар табышны предприятиене зурайтуга, киңәйтүгә тота торгач, ике җиргә дә өлгерми башлап, элекке эше белән алыш-бирешне өзде* (Д. Булатова. Җантөяк).
Төрдәше: ара өзек (өзелгән).

3. *к.* ачу алу. *Мидхәт белән алыш-бирешен өзеп, Себер ягына чыгып китәргә булды* (Сөйләм).
Төрдәше: ачу алу һ.б.

*АЛЫШ-ТИЛЕШ* ❖ **АЛЫШ-ТИЛЕШ КИТЕРҮ.** Берсеннән алып икенчесенә биреп, чуалтып бетерү. *Соңгы вакытта мәктәп китаплары язучылар тарафыннан кабул ителгән «алыш-тилеш китерү»* ысулына бина корыбрак *язылган* (Г. Камал).

*АЛЫШТЫРЫП* ❖ **АЛЫШТЫРЫП КУЙГАН КЕБЕК <БУЛУ>**. Бөтенләй үзгәрү, икенчеләнү. – *Мин дә, сиздермәскә тырышып, хуҗа хатынга күз салгалап алам. Ул да бүген алыштырып куйган кебек* (М. Хәсәнов. Дулкынар ярга тәгәри).

*АЛЬФА* ❖ **АЛЬФА ҺӘМ ОМЕГА.** Нәрсәнең булса да башы һәм ахыры. – *Бакча өчен, җиләк-җимеш кую өчен баз ул, малай, латинчалап әйткәндә, альфа и омега... Калганы барысы да вакытлы гына* (Ф. Хөсни. Циклон). *Бу очракта «беренче һәм соңгы» һәм «Альфа һәм Омега»* арасында *бернинди дә аерма юк* (jw.org).

*АЛ-ЯЛ* ❖ **АЛ-ЯЛ БЕЛМӘҮ** *к.* ал <да> юк, ял <да> юк. *Каландырукның кешеләре, ал-ял белми, аны эзләделәр* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).
Төрдәше: ал <да> юк, ял <да> юк һ.б.

**АЛ-ЯЛ БЕЛМИЧӘ (КҮРМИЧӘ)** *к.* ал <да> юк, ял <да> юк. *Теге елларда ил җимреклекләрен төзәттеләр, аннан тыныч тормышта тынычсыз дөньяны тәртипкә китерделәр, еллар буе ал-ял күрмичә, тырышып эшләделәр дә эшләделәр* («Татарстан яшьләре» газ.).
Төрдәше: ал <да> юк, ял <да> юк һ.б.

*АЛ-ЯЛНЫ* ❖ **АЛ-ЯЛНЫ ОНЫТУ** *к.* ал <да> юк, ял <да> юк. *Ал-ялны онытты егет, көн сәгатьләре җитми башлады, төннәрен, урлап-юллап, бакча җиренә такта, бүрәнә, кадак ташыды* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: ал <да> юк, ял <да> юк һ.б.

*АМАЙДАГЫ* ❖ **АМАЙДАГЫ, МАМАЙДАГЫ.** Бик күптән, Мамай мирза заманында булган хәлләр. – *Син инде амайдагы, Мамайдагы хәлләрне дә искә төшереп утыр хәзер* (Сөйләм).

*АМАН* ❖ **АМАН ЙӨРЕ ДӘ САУ ЙӨРЕ** *к.* ай йөр, аман йөр. *Сиңа теләк шул гына инде: аман йөре дә сау йөре, сине монда көтеп калалар* (Сөйләм).
Төрдәше: ай йөр, аман йөр; ай йөре дә сау йөре.

*АМБИЦИЯГӘ* ❖ **АМБИЦИЯГӘ БИРЕЛҮ.** Тәкәбберләнеп, артык масаеп китү; узыну. *Сезнең мәзәкчел кеше икәнлегеген аңламаган берәү булса, әлбәттә, бик нык амбициягә бирелер иде* (Ә. Фәйзи).
Төрдәше: алып узу һ.б.

*АМБРАЗУРАГА* ❖ **АМБРАЗУРАГА КАПЛАНУ**. Берәрсен яклап, коткарып калырга тырышу. *Ир, абыйсын яклап, күкрәге белән хатын амбразурасына капланды. Хатасын аңлады ул* (Н. Гыйматдинова. Шырагай).

*АМЕРИКА* ❖ **АМЕРИКА АЧУ** *ирон.* Моңарчы билгеле булган нәрсәне яңалык итеп белдерү яки сөйләп тору. – *Әмма ул сәләт белән генә безнең заманда Америка ачып булмый* (Г. Бәширов. Җидегән чишмә).
Төрдәше: яңа Америка ачу.

*АМИН* ❖ **АМИН ТОТЫП ТОРУЧЫ.** Ялагай, куштан; ярарга тырышып, башлыкларның һәр сүзенә амин әйтеп торучы. *Безнең эш булмәсендә дә хуҗаларга һаман амин әйтеп торучы берәү бар* (Сөйләм).
Төрдәше: арбаның күчәр башын үбү һ.б.

**АМИН ТОТЫП ЯШӘҮ.** Теләсә нинди нәрсәне «яхшы булган» дип кабул итеп тору. *Кеше кылган һәр ахмаклыкка шөкрана итеп, амин тотып яши алмый тарих* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

**АМИН ТОТУ.** Ашаганнан соң дога кылу. *Гамәлендә азат адәми зат / Амин тотсын яки чукынсын* <...> (Зөлфәт. Тылсым).

*АМУР* ❖ **АМУР СӨҢГЕСЕ.** Кешеләрнең йөрәкләрен яралаучы мәхәббәт символы. *Очып барган идең каршысына, /сынып килде Амур сөңгесе* (С. Сөләйманова).

*АНА* ❖ **АНА БӘГЫРЬЛЕ.** *Кыз бала ана бәгырьле була, диләр* (Б. Камалов. Гомер кичендә).

**АНА БӘПКӘ.** Түбә кыегындагы ике атламаның ырмаулысы, кирт ясаганы. *Атламаларның ана бәпкәсен эшләп бетердегезме?* (Сөйләм).

**АНА БУЛЫРЛЫК (БУЛЫРДАЙ; БУЛЫРГА ЯРАРЛЫК).** Бала тудыра алырдай яки башка хатыннан туган балаларны үзенеке кебек карап, тәрбия бирерлек хатын-кыз хакында. *Үзенә тугрылыклы хатын, кызларына кайгыртучан, мәрхәмәтле, кин күнелле ана булырлык кеше таба* (Ә. Салах. Аккан сулар).

**АНА ИТӘГЕННӘН (ЧАБУЫННАН) ТӨШҮ (АЕРЫЛУ)** *ирон. Ана итәгеннән аерылу өчен генә булса да армиягә барырга кирәк дип саныйм* («Авыл офыклары» газ.). *Һаман анаң итәгеннән аерыла алмыйсың, имгәк* («Мәйдан» ж.).

**АНА ЙОНЫ.** Йөздә һәм тәндә булган гаять юка һәм нечкә йон. *Колынның ана йоны кояшта ялтырый иде* (Сөйләм).

**АНА ЙОНЫ ТЫРПАЙТУ.** Карышу, нәрсәгә булса да каршы килү, үзсүзләләнү. *Звенодагыларның ана йон тырпайтуы борчакка чыккан көнне үк сизелде. Иң элек Рамил җебеп төште* (Ф. Садриев. Арыш басу икмәге).

**АНА КАРЫНЫНДА ЯТКАН КЕБЕК.** Мәшәкатьсез генә әзерне ашап-эчеп, кешедән асра-

тып яшәү турында. *Бер мулланың әйтүенчә, ана карынында яткан кебек гомер итүе, ихтимал, карында чагында фәрештәнең программалаштырырга онытуына бәйледер* (Сөйләм).

Төрдәше: арка кимерү; аркага атландыру; аркага <менеп> атлану; дөнья корткыч; җилкәгә атлан<дыр>у; җилкәгә <менеп> атлану; җилкәгә салыну; җилкәгә утырту; җилкәгә <менеп> утыру; җилкәдә утыру; җилкәдә яту; җилкәне кимереп яту; җилкәсен каерып яту; җилкәсенә салыну; җилкәсендә рәхәт чигү; кеше җилкәсе белән эш күтәрү; кеше җилкәсе өстеннән ашау; кеше җилкәсенә салыну; кеше җилкәсендә тору; кеше җилкәсендә утыру; кеше җилкәсендә яту; кеше җилкәсендә яшәү; кеше икмәген ашау; кеше ипиен ашау; кеше кулы белән ут тоту; кеше кулы белән утлы көл (күмер) көрәү (тоту); кеше кулы белән учактан күмер алу; кеше хакын ашау; көн күрсәтмәү; муенга <менеп> атлану; муенга тагылу; соры корт булу.

**АНА КЕБЕК** *к.* ана булырлык (булырдай; булырга ярарлык). *Шулай да ул, баласы булмаса да, ана кебек* (М. Хуҗин. Арыш көлтәсе).

Төрдәше: ана булырлык (булырдай; булырга ярарлык).

**АНА КУЕНЫННАН ЧЫКМАУ (ЧЫГЫП ҖИТМӘҮ)** *ирон., к.* авыз суы кипмәгән. *Ана куеныннан чыкмаган меңбашлар кирәкми* (М. Хәбибуллин. Илчегә үлем юк). *Мин кызларны «ана куеныннан чыгып җитмәгән»гә чутлап бик ялгышканмын икән* (Р. Гыйлемханов һ.б. Истә калганнар).

Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

**АНА КҮРГӘН.** Анасының тәрбиясен күргән, аннан үрнәк алган. *Ана күргән – тун печәр* (Мәкаль). *Ата-ананың кәсеп-һөнәре, сәләтләре, әлбәттә, балаларга да мирас булып калырга тиешле санала: – Ата күргән – ук юнар, ана күргән – тун печәр* (Н. Исәнбәт. Мәкальләребез турында).

**АНА СӨТЕ БЕЛӘН КЕРМӘГӘН ТАНА СӨТЕ БЕЛӘН КЕРМӘҮ.** Ана тәрбиясен күрмәгән баладан әдәпле, миһербанлы кеше чыкмаячагына ишарә. *Ана сөте белән кермәгән тана сөте белән керми* (Мәкаль). *[Кәрим] Ана сөте белән кермәгән тана сөте белән кермәс, аңар биргән үгетне бер этккә бирсәң, ул да бераз әдәпләнер иде* (Г. Камал. Бәхетсез егет. I вариант).

**АНА СӨТЕ БЕЛӘН КЕРҮ (СЕҢҮ).** Нәрсәне булса да белеп туу. *Ана сөте белән кермәгәнне / Тормыш үзе кертә Күңелгә. / Ана сөте белән кергәнне дә / Үзгәртәләр безнең гомерләр* (Х. Туфан. Башлана башлады).

**АНА СӨТЕ КЕБЕК ХӘЛӘЛ.** Кадер-хөрмәт күрү, мирас тию яки мал керү бик урынлы күренеш булу. *Баш иеп каршылый үзбәк, тартынма, вакыт тыгыз,/ Ана сөте кебек хәләл тустагандагы кымыз* (Г. Нәваи. Газәлләр – Р. Зәйдулла тәрҗемәсе).

**АНА СӨТЕ КИПМӘГӘН (КИБЕП БЕТМӘГӘН / ҖИТМӘГӘН)** *к.* авыз суы кипмәгән. *Ат азгыны тайга иярә дигәндәй, Фәхри дә, җитмәсә тагын, сакаллы башы белән, шул иреннәреннән ана сөте кипмәгән малайны – тракторчы Шәяхмәтне – яклап тыгылды* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).

Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

**АНА ТЕЛЕ БЕЛӘН.** Туган телендә аңлашу, сөйләү. *Русиядә көн күргән һәр халыкның үз туган җире генә түгел, ана теле белән бергә, үз мәгърифәте, тарихы, сәнгате, иманлы кешеләренә үз дине булырга тиеш...* (М. Хәбибуллин. Идел буе болгар-татар дәүләте).

*АНА<СЫ>-АТАСЫ* ❖ **АНА<СЫ>-АТАСЫ ЮК.** 1. Нәтиҗәсе, файдасы булмау. *Күзлеген салып, сөртеп тә карады, аннан, «ана-атасы юк моның» дигәндәй, кулын селкеп китеп барды* (Сөйләм).

2. Рәте, җае, мәгънәсе булмау, эшкә ярамау. *Мастер, килеп, сызымнарын да борып-борып карады, ләкин рәтен таба алмады, эченнән генә «анасы-атасы юк бу нәрсәнең» дип уйлап куйды* (Сөйләм).

Төрдәше: ата<сы>-анасы юк.

*АНАГЫЗ* ❖ **АНАГЫЗ (АНАҢ; АНАЛАРЫ) ЯЛАМАГАН <НӘРСӘ>.** Күбрәк очракта тәрбиясез, әдәпсез, шапшак үсмерләрне тиргәгәндә, сүккәндә кулланыла. *Телефонны шактый боргаласа да, тегe башта алмадылар, ахры, председатель әче итеп сүгенеп җибәрде: – Утыралар шунда аналары яламаган нәрсәләр, сагыз чәйнәп!* (А. Гыйләҗев. Язгы

кәрваннар). – *Арканы җылытып ятсаң ни булган, анаң яламаган нәрсә! – дип куйды Хәсән абзый...* (Г. Сабитов. Елмаю).

Төрдәше: Аллаһның каһәре төшкән нәрсә!; анагызны (анаңны) корт чаккыры; анагызны куян үпкән нәрсә; аналарын эт еккыры; анаңның ян сөяге; анасыз нәрсә; анасын ач урыс алсын; анасын сатыйм; анасын эт типкере; анасын эт ялагыры.

**АНАГЫЗНЫ (АНАҢНЫ) КОРТ ЧАККЫРЫ** *к.* анагыз (анаң; аналары) яламаган <нәрсә>. – *Сугыш булгач, чын булмый димени, анагызны корт чаккыры!* (М. Мәһдиев. Ут чәчәге).

Төрдәше: анагыз (анаң; аналары) яламаган <нәрсә һ.б.

**АНАГЫЗНЫ КУЯН ҮПКӘН НӘРСӘ** *к.* анагыз (анаң; аналары) яламаган <нәрсә>. *Шакир сугышта, солдатта, төрмәдә, алган барлык начар сүгенү сүзләре белән боларны кабахәтләп куа: – Чәнчелеп китегез, анагызны куян үпкән нәрсәләр!* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр).

Төрдәше: анагыз (анаң; аналары) яламаган <нәрсә>! һ.б.

*АНАДАН* ❖ **АНАДАН АЛА ДА ТУА, КОЛА ДА ТУА.** «Туган туганга охшамый» мәгънәсендә. *Анадан ала да туа, кола да туа* (К. Насыйри. Мәкальләр һәм әйтемнәр).

**АНАДАН АЛГАН СӨТЛӘРЕН КИТЕРҮ** *к.* акыл бизмәненә утырту. – *Бар, Илгизне чакыр әле яныма, белмәгән эшкә тыгылмаслык итәм, анасыннан алган сөтләрен китерәм мин аның хәзер!* (Сөйләм).

Төрдәше: акыл бизмәненә утырту һ.б.

**АНАДАН БҮГЕН (БҮГЕН ГЕНӘ; ХӘЗЕР ГЕНӘ; ЯҢА ГЫНА) ТУГАН <КЕШЕ> КЕБЕК.** Башында гөнаһлы уй булмаган, саф, сау-сәламәт. *Хәзер анадан яңа туган шикелле тап-таза йөрим, ди* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Йөрәгем рәхәт булып тибә, миңа гомумән бик рәхәт. Анадан яңа туган кебек, диләр бит әле, яисә яңа гына мунчадан тазарынып кайтып яткандагы шикелле* (Х. Камалов. Сугыштан кайткан сөю).

Төрдәше: бүген генә туган кебек.

**АНАДАН ИМГӘН СӨТ БОРЫНГА КИЛҮ.** Күңел бөтенләй суыну, ягъни бөтен күргән яхшылыклар яманга әйләнү. *Кемгә дә булса күңел суынган вакытта: «Анадан имгән сөтем борыныма килде», – дип әйтәләр* (Т. Нәҗмиев. Балалы өйдә гайбәт булмас).

**АНАДАН ИМГӘН СӨТЛӘРЕН АВЫЗЫНА КИТЕРҮ** 1. *к.* акыл бизмәненә утырту. *Мастер аның кыланышларына озак түзде һәм, ниһаять, беркөнне, сабыр казаны шартлап, анадан имгән сөтләрен авызына китерергә уйлады* (Сөйләм).

Төрдәше: акыл бизмәненә утырту һ.б.

2. *к.* авыз җебетү 2. *Кеше бик каты кыйналганда: «Анадан имгән сөтен авызына китердем...»* (Т. Нәҗмиев. Балалы өйдә гайбәт булмас).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АНАДАН КҮЛМӘКЛЕ КИЛЕШ ТУУ.** Бәхетле, уңышка ирешүчән булу. – *Анадан күлмәкле килеш тугандыр ул мөртәт, – дип тузынды Чура Нарыш, – алашасы да колынлыйдыр, валлаһи...* (М. Әмирханов. Гәүһәршад).

Төрдәше: бәхет йолдызы астында туу; бәхет йөзеге белән туу; бәхет йөзлеге белән туу; бәхет йөзлеге эчендә туу; бәхетле йолдыз астына туры килү (астында туу); бәхетле сәгатьтә туу; белен яуган көнне туу; ишәк төчкергәндә туу; йөзлек белән туу; кап (сүрү) эчендә туу; чикләвекле имән өскә аву.

**АНАДАН НИК ТУГАНГА ҮКЕНҮ.** Бик авыр, бәладән котылу юлын таба алмас кебек тоелган мизгелләргә ишарә. *Минем гомеремдә анамнан ник туганга үкенгән чакларым булмады түгел, сирәк булса да булды* (Сөйләм).

Төрдәше: ник туганга үкенү.

**АНАДАН ТУМА.** 1. Тумыштан. *Янә минем рөхсәтем илә анадан тума сукырны син күрер иттең, тилчә тәнлене савыктырдың, мәетләрне минем рөхсәтем илә терелттең* (Ф. Урманче. Могҗизалар дөньясына сәяхәт). *Анадан тума саңгырау икән ул* (Сөйләм).

2. Шыр ялангач. *Алар артыннан анадан тума чишенеп, барча кызлар да суга чумды* (Р. Батулла. Сөембикә). *Егетләрне башта бишәр-бишәрләп төркемнәргә бүлделәр дә анадан тума чишендерделәр* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).

3. Хәерче хәлендә, бернәрсәсез. *Бүген авыл анадан тума, шыр ялангач калган мескен сыман утыра* (В. Имамов. Тозлы яра). *Соңгы*

*орышта болар хәерчелеккә төшкәнче, анадан тума калганчы сугышканнар, беренчеләре яланаякка чабаталар киеп, икенчеләре шәрә тәнгә галстук тагып торып калган...* (А. Тимергалин. Айга ашкыну һәм «Алга! Марска таба!»).
Төрдәше: Адәм галәйһиссәлам киемендә.

*АНАЙ* ❖ **АНАЙ ГЫНАМ!** Артык гаҗәпләнгән вакыттта әйтелә. *Анай гынам! Синме бу, күземә күренәсең дип торам!* (Сөйләм).

*АНАЛАРЫ* ❖ **АНАЛАРЫ БЕР КОЯШТА КИНДЕР КИПТЕРҮ (ТУКМАКЛАУ)** *ирон., шаярт.* Араларында бернинди дә туганлык мөнәсәбәте булмаганны аңлата, ягъни бертуган түгелләр. *Мөгаен, безнең әниләр бер кояшта киндер киптергәннәрдер...* (Г. Бәширов. Кара төндә нур чәчеп).
Төрдәше: бер кояш астында җылыну; бер кояшта киндер (чабата) киптерү; капка баганалары бер урманда үскән; капка баганалы (баганалары) бертуган; күпер башында киндер киптерешкән; күпер башында күчәр башлары эләккән (эләгешкән); күпер башында сугышкан кебек кардәшлек; күпер башында тәртәләре очрашкан; күпердән кичкәндә, тәртә башлары орынган; күпердән кичкәндә тиеп киткән.

**АНАЛАРЫ ҮЛГӘН АЗЫКСЫЗ КАРЛЫГАЧ БАЛАЛАРЫ КЕБЕК.** Ятим калган сабый балаларны чагыштыру. *Бу ятим сабыйларны мин аналары үлгән азыксыз калган карлыгач балалары кебек күрәм* (Сөйләм).

**АНАЛАРЫН ЭТ ЕККЫРЫ** *к.* анагыз (анаң; аналары) яламаган <нәрсә>. *Сул яктагысы хәтта сизелер-сизелмәс кенә күз кысып, орынып та узды. Тәмам азганнар, аналарын эт еккыры кәнтәйләр* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы).
Төрдәше: анагыз (анаң; аналары) яламаган <нәрсә> һ.б.

*АНАҢ* ❖ **АНАҢ УЛЫ – КАЙМАК БУРЫ, АТАҢ УЛЫ – АТ БУРЫ** *шаярт.* Берәрсе турында үзе хакында читләтеп әйтү. *Мин, мин дип шапырынып утырма әле, уйлап карасаң: анаң улы – каймак буры, атаң улы – ат буры* (Сөйләм).

*АНАҢНЫҢ* ❖ **АНАҢНЫҢ ЯН СӨЯГЕ** *к.* анагыз (анаң; аналары) яламаган <нәрсә> – *Карагансың, анаңның ян сөяге! Ярый Хәмит бар, югыйсә нишләр иде сабый?* (Ә. Моталлапов. Рисвайлык).
Төрдәше: анагыз (анаң; аналары) яламаган <нәрсә> һ.б.

**АНАҢНЫҢ ТҮБӘН АВЫЗЫНА ТЕШ КУЮ** *гади с.* Берәрсенең кая киткәнлеген сорап туйдырып бетергәндә әйтелә. – *Ә Милза абый кайда, кая китте Милза абый? – Анаңның түбән авызына теш куярга! Тай, тай моннан, сыпырт, мәхлук!..* (Т. Мөбарәков).

*АНАСЫ* ❖ **АНАСЫ КЕБЕК КҮРҮ.** Иң якын кеше кебек күрү. *[Бакый] (аның янына утыра). Бабай, миңа ачуланма, мин менә бу сахраларны, иркенлекне, аның анам кебек күреп сөюче бер баламын* (М. Фәйзи. Ак калфак).

**АНАСЫ КЫЗЫ (УЛЫ; МАЛАЕ)** *ирон.* 1. Бөтен яктан да анасына охшаган кыз (ул). *Миңа охшамыйча, кемгә охшасын – анасының кызы бит ул* (Сөйләм).
Төрдәше: әти малае.

2. Артык иркә кыз (малай). *Урталык юк. Башта анасы малае, аннары хатыны малае* («Матбугат.ру» порталы). *Шулхәтле иркә булып үсәләрмени бу заманда, шөбһәсез, анасының кызыдыр ул* (Сөйләм).
Төрдәше: анасына беткән; анасының баласы.

**АНАСЫ ТАНЫМАСЛЫК ИТҮ** *к.* авыз җебетү 2. – *Килеп кенә карасын, анасы танымаслык итеп җибәрербез, – дип тынычландырды Илшат* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АНАСЫ ЯЛАМАГАН <НӘРСӘ>** *тирг.* 1. Азгын, тәртипсез. – *Син анаң яламаган нәрсә! – дип сукранды Хак. – Елавыңнан туктыйсыңмы, юкмы?* (Р. Сибат. Исабәт).

2. Мескен кыяфәттә булу. *[Нургали] Соң, тора анасы яламаган төсле башын иеп, ризалашып* (А. Гыйләҗев).

3. Шапшак. – *Анасы яламаган бозаумы әллә сез?* (Р. Батулла).
Төрдәше: анагыз (анаң; аналары) яламаган <нәрсә> һ.б.

*АНАСЫЗ* ❖ **АНАСЫЗ НӘРСӘ.** Тиргәгәндә әйтелә («тәрбиясез» мәгънәсендә). – *Анасыз нәрсә, нигә тиясең ул балага?!* (Сөйләм).
Төрдәше: анагыз (анаң; аналары) яламаган <нәрсә>.

*АНАСЫН* ❖ **АНАСЫН АЧ УРЫС АЛСЫН** *к.* анагыз (анаң; аналары) яламаган <нәрсә>. *Анасын*

*ач урыс алсын* (А. Гыйләҗев. Әтәч менгән читәнгә).

Төрдәше: анагыз (анаң; аналары) яламаган <нәрсә> һ.б.

**АНАСЫН ӨШКЕРҮ.** Каргау. *Их, Гитлерның анасын өшкерим! Нинди кеше сез?..* (Ә. Еники. Рәшә). *Анасын өшкерәм әле мин аның* (Г. Гомәр).

Төрдәше: авыз<лар>ын корт чаккыры! һ.б.

**АНАСЫН САГЫНЫП ЕЛАУ (ЕЛАП УТЫРУ)** *мыск.* Балигъ булган кеше үз алдына елаганда мыскыллау. – *Карале теге сакаллы сабыйга, анасын сагынып елап утыра!* (Сөйләм).

**АНАСЫН САТКЫРЫ (САТКАН; САТЫЙМ)** *к.* авыз<лар>ын корт чаккыры! *Җаны бар микән ул анасын саткан нәрсәнең?* (В. Нуруллин. Әгәр син булмасаң). *Озак кына кабызалмый азапланачак, берничә шырпыны сындырып, аты-юлы белән: «анасын сатыйм фәләнтөгән», – дип җикеренәчәк, ниһаять, кабынгач, комсызлана-комсызлана төтенен үпкәсенә тутырачак* (Р. Зәйдулла. Коршау).

Төрдәше: авыз<лар>ын корт чаккыры! һ.б.

**АНАСЫН (АТАСЫН) ТАНЫТУ** *к.* авыз җебетү 2. *Аталарын танытыр идем мин аларның!* (М. Фәйзи). *Бер караңгы почмакта тотып алып, анасын танытырга кирәк үзенең* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АНАСЫН ЭТ ТИПКЕРЕ** *к.* анагыз (анаң; аналары) яламаган <нәрсә>. – *Нинди бит контрреволюция тарата. Мошенник, анасын эт типкере!* (Ш. Камал. Таң атканда).

Төрдәше: анагыз (анаң; аналары) яламаган <нәрсә> һ.б.

**АНАСЫН ЭТ ЯЛАГЫРЫ** *к.* анагыз (анаң; аналары) яламаган <нәрсә>. – *Дөрес, синеке дә дөрес, энекәш, бик җилле кайтып булмый бит, анасын эт ялагыры, колын бик арыды, ашыйсы да килгән* (Г. Бәширов. Сарут).

Төрдәше: анагыз (анаң; аналары) яламаган <нәрсә> һ.б.

*АНАСЫНА* ❖ **АНАСЫНА (АТАСЫНА) ТАРТУ.** Баланың анасы яки атасы ягына охшаш булуы. *Булдыра торган егет ул – атасына тарткан* (Сөйләм).

**АНАСЫНА БЕТКӘН** *к.* анасы кызы (улы; малае). *Бигрәк тә анасына беткән инде бу кыз – төсе-кыяфәте белән генә түгел, холкы белән дә* (Сөйләм).

Төрдәше: анасы кызы (улы; малае) һ.б.

**АНАСЫНА КЫЗ.** «Бу нинди кыз?» – дип сораштырганда, усалланып, аның кыз түгеллеген искәртү. – *Ишек янында нинди кыз ул? – Анасына кыздыр шул* (Сөйләм).

*АНАСЫНЫҢ* ❖ **АНАСЫНЫҢ БАЛАСЫ** *к.* анасы кызы (улы; малае). – *Нигә ул хәтле аптырап карап торасың, анасының баласы бит ул!* (Сөйләм).

Төрдәше: анасы кызы (улы; малае) һ.б.

**АНАСЫНЫҢ ИМЧӘГЕН ИМГӘНДӘ, ИКЕНЧЕСЕН КУЛЫ БЕЛӘН ҖИБӘРМИ ТОТЫП ТОРУ** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. – *Юкка өметләнмә, башкасыннан сора – кечкенә чагында да анасының имчәген имгәндә, икенче кулы белән җибәрми тотып торган ул* (Сөйләм).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**АНАСЫНЫҢ КАРЫНЫНДА НИЧЕК ТУГЫЗ АЙ ДА УН КӨН ЧЫДАП ТОРГАН.** Үтә түземсез, ашыгучан кеше турында. – *Ай-яй кызу кеше, анасының карынында ничек тугыз ай да ун көн чыдап торган бу?!* (Сөйләм).

*АНДА* ❖ **АНДА АТАҢ БЕЛӘН АНАҢ ГЫНА ЮК.** Базарда (күргәзмәдә), кешенең, малның бик күп булуы турында. – *Бүген «Колхоз базары»на барган идем, атаң белән анаң гына юк икән анда* (Сөйләм).

Төрдәше: анда әти белән әни генә юк.

**АНДА АЯК АТЛЫЙСЫ (БАСАСЫ) БУЛМА!** Кемне дә булса барып-килеп йөрүдән тыю. *Кяферләр, кара аны, моннан соң анда аяк атлыйсы булма* (Т. Гыйззәт).

Төрдәше: аяк атлар хәл (дәрман; көч; рәт; чама) юк (булмау; калмау); аяк атларга (басарга) ирек бирмәү; аяк <та> атлатмау (атларга да бирмәү); аяк атлыйсы (басасы) булма; аяк <та> бастырмау (басып карамау; басасы булмау).

**АНДА ӘТИ БЕЛӘН ӘНИ ГЕНӘ ЮК** *к.* анда атаң белән анаң гына юк. – *Базарның зурлыгы, байлыгы, этенми-төртенми йөреп тә булмый – анда әти белән әни генә юк* (Сөйләм).

Төрдәше: анда атаң белән анаң гына юк.

**АНДА БАШКА АЯК ТА АТЛАМАУ (БАСМАУ).** Билгеле булган бер җиргә башка бөтенләй бармау. – *Дөрес ишеткәнсең, анда башка һич аягымны да атламам* (Сөйләм).

Төрдәше: аяк <та> атламау (атлыйсы булмау); аяк <та> басмау; ике аякның берсен <дә> атламау (басмау); эзне дә күрсәтмәү.

**АНДА БЕР, МОНДА БЕР.** 1. Аз-азлап төрле җирдә, урыны белән генә. *Анда бер, монда бер чокыр казый, әмма ни өчен икәнен сөйләми* (Сөйләм).

2. Очраклы рәвештә генә, вакыт-вакыт, сирәк кенә. *Анда бер, монда бер күренеп китә, койрыгын һич тә тотып булмый* (Сөйләм).

**АНДА ДА.** 1. Бу очракта да, шул вакытта да. *Без аның белән театрда очраштык, анда да чишенү бүлмәсе янында гына* (Сөйләм).

2. Барыбер, әмма ләкин. *Бик үтенгәч, китап эчендәге фоторәсемне алып күрсәтте, анда да бер кырыен кулы белән каплады* (Сөйләм).

**АНДА ДА, МОНДА ДА.** Төрле урыннарда. *Бүлмә эчендә тулы тәртипсезлек иде, анда да, монда да ниндидер хайванның аяк эзләре күренә* (Сөйләм).

**АНДА (АҢАРДА) ЕЛАН МӨГЕЗЕ ГЕНӘ ЮК.** Дөньяда булган бөтен нәрсә дә бар; булмаган нәрсәсе юк («байлыкта-муллыкта бәхетле яши» мәгънәсендә). – *Дөресен сөйлиләр, Мәхмүттә бөтен нәрсә бар, аңарда елан мөгезе генә юк* (Сөйләм).

Төрдәше: елан мөгезе генә юк.

**АНДА ҖИЛӘК... КЫЗЫЛ ЧИКМӘН КЕБЕК.** Җиләк бик күп булып үскән җир. – *Әйдә, мин сине бер җиргә алып барам, анда җиләк… кызыл чикмән кебек* (Сөйләм).

**АНДА МИНЕМ (СИНЕҢ; АНЫҢ) НИ ЭШЕМ (ЭШЕ; ЭШЕҢ) БАР?** «Башкаларның эшенә тыгылуның кирәге юк, ул шәхси эш» мәгънәсендә. *Көлсә көлсен, шул кирәк шул; / анда синең ни эшең?* (Г. Тукай). – *Уйласыннар, анда минем ни эшем бар, – ул, ярсулы хәрәкәт белән түргә узып, Рәфиснең янына ук килеп утырды* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

Төрдәше: анда минем эшем юк.

**АНДА МИНЕМ ЭШЕМ ЮК** *к.* анда минем (синең; аның) ни эшем (эшең; эше) бар. *[Шәйхи] Башкалар ни әйтер, анда минем эшем юк, әмма мин үзем авыру кеше, картлыгым да бар, эшләп йөри алмам шул* (Т. Гыйззәт). *Зәкиягә үзең теләсә ничек аңлатырсың, анда минем эшем юк. Ә мин моннан соң синең белән бер табында утырып ашый алмаячакмын* (Ф. Яруллин. Туй алдыннан).

Төрдәше: анда минем (синең; аның) ни эшем (эшең; эше) бар.

**АНДА СИН ТҮГЕЛ, СИНЕ АШАГАН КАРГА ДА БАРЫП ҖИТМӘС.** Булдыра алмаслык бик ерак җирләргә барырга хыялланган кеше турында. – *Арктика да Арктика дисең, анда син түгел, сине ашаган карга да барып җитмәс* (Сөйләм).

**АНДА СУГЫЛУ, МОНДА СУГЫЛУ.** Нәрсә эшләргә белмичә, төрле җирләргә, урыннарга барып карау. *Шуннан соң Гыймади анда сугылды, монда сугылды, ахырда дамелла Фәриделгасри димләве буенча совхозга, Вәли Хәсәнов кул астына хезмәткә ялланды* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).

**АНДА ТЕЛӘСӘ, ДӨНЬЯ АСТЫ ӨСКӘ КИЛСЕН.** 1. Барыбер булу; бернәрсәгә дә ис китмәү, бернәрсә белән дә исәпләшмәү. *Анда теләсә, дөнья асты өскә килсен, ташу суы безгә килеп җитми ул* (Сөйләм).

2. Битараф калу. – *Кара, кара, теге этне, боз кисәгендә агып бара. Акса соң, анда теләсә, дөнья асты өскә килсен* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз<ы>-борын<ы> кыйшаймау һ.б.

**АНДА ТЕЛӘСӘ, ДӨНЬЯНЫ СУ БАССЫН (УТ АЛСЫН)** *к.* авызы-борыны кыйшаймау; анда теләсә, дөнья асты өскә килсен 1, 2. *Юкка борчылма, анда теләсә, дөньяны су бассын, безнең янда елга юк* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз<ы>-борын<ы> кыйшаймау һ.б.

**АНДА ТОЗЛЫ СУ СИПКӘННӘР АХРЫ.** Кемнең дә булса һаман бер җиргә барырга атлыгып торуы турында. *Укудан кайтып, букчасын ата да шугалакка китә, анда тозлы су сипкәннәр ахры* (Сөйләм).

**АНДА ҮСКӘН, ШУНДА ҮСКӘН, БҮТӘКӘЛЕ КҮЛДӘ ҮСКӘН.** Туган илен-йортын белмәгән нәселсез, йортсыз-тораксыз кеше хакында. *Техникумны тәмамлагач, туган ягына кайтмыйча,*

*каядыр китеп барды – анда үскән, шунда үскән, бүтәкәле күлдә үскән шул* (Сөйләм).

*АНДАМЫНИ* ❖ **АНДАМЫНИ ЭШ.** «Төп хикмәт башка эштә, анда түгел» мәгънәсендә. *Чынлыкта ул егетнең төрле чаклары була, ләкин андамыни эш* (Ф. Хөсни).

*АНДЫЙ* ❖ **АНДЫЙ ГЫНА <КИМЧЕЛЕК> БОХАР КИЯВЕНДӘ ДӘ БУЛА** *к.* алай гына мулла (патша; хан) кызында да була. *Аяк киемем чалбар төсеннән аерылыбрак тора дип борчылма, андый гына кимчелек Бохар киявендә дә була* (Сөйләм).

Төрдәше: алай гына мулла (патша; хан) кызында да була; андый гына <гаеп> кемдә дә була; андый гына <гаеп> мулла (патша; хан) кызында да була; аның ише (кадәр; кебек; чаклы) гаеп патша (мулла; хан) кызында да була; дүрт аяклы ат та абына (абынып куйгалый; сөртенә); кояшта да таплар була; сөртенмәс тояк юк.

**АНДЫЙ ГЫНА <ГАЕП> КЕМДӘ ДӘ БУЛА** *к.* алай гына мулла (патша; хан) кызында да була. *Тапкансың борчылырлык нәрсә, андый гына гаеп кемдә дә була* (Сөйләм).

Төрдәше: алай гына мулла (патша; хан) кызында да була һ.б.

**АНДЫЙ ГЫНА <ГАЕП> МУЛЛА (ПАТША; ХАН) КЫЗЫНДА ДА БУЛА** *к.* алай гына мулла (патша; хан) кызында да була.. *[Бәдри] Бозыклыгы дип, андый гына хан кызында да була* (М. Фәйзи. Галиябану).

Төрдәше: алай гына мулла (патша; хан) кызында да була һ.б.

**АНДЫЙ НӘРСӘ УЗМАС.** Уйлаган яки башкарылган эшнең тормышка ашмаячагы турында. *Юкка ашыктылар, андый нәрсәнең узмаслыгы билгеле иде инде* (Сөйләм).

Төрдәше: мондый тамаша үтмәс.

**АНДЫЙ<ЛАРДАН> ТҮГЕЛ.** Нинди булса да сүзне, фикерне инкяр итү. *Ләкин, әдәп саклап, дәү әнисе белән сүз көрәштермәде, бары тик: – Юк, мин алай дип уйламыйм. Ул андыйлардан түгел, – диде* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**АНДЫЙ ХАТЫН-КЫЗГА СЕБЕРКЕ АСТЫ САЕН КИЯҮ** *хурл.* Ирләр белән сөберелергә яратучы, һәрвакыт «кияү табучы» хатын-кыз хакында. *Миңа калса, бер дә аптырарлыгы юк: андый хатын-кызга себерке асты саен кияү* (Сөйләм).

**АНДЫЙ ЭШЛӘР БАКУДА.** Берәр эшкә, әйбергә аванс сораганда, тискәре җавап буларак кулланыла. *Булмас, андый эшләр Бакуда, кулыма китереп тоттыр, шунда акчасын алырсың* (Сөйләм).

*АНДЫЙ-МОНДЫЙ* ❖ **АНДЫЙ-МОНДЫЙ ХӘЛ БУЛУ.** Һич көтелмәгән хәл килеп чыгу. *Андый-мондый хәл булмаса, бер сәгать эчендә урман читенә чыгып була лабаса* (А. Тимергалин. Таш алиһә).

**АНДЫЙ-МОНДЫЙ ГЫНА.** Нинди булса да; яхшы да, начар да түгел – ярый шунда. *Сәгате андый-мондый гына түгел, үзең теләгән шәһәрләрдә вакыт күпме икәнлеген дә күрсәтә* (Сөйләм).

**АНДЫЙ-МОНДЫЙ КЕШЕ.** Ни җитте, әһәмиятсез, артык гади. *[Исерек татар] Кемлегемне кергәч күрерсең әле, андый-мондый кеше түгел, кызлар өчен уңайлы кеше* (Г. Камал. Уйнаш).

**АНДЫЙ-МОНДЫЙ ХӘЛ БУЛМАСЫН (БУЛА КҮРМӘСЕН)** *к.* алай-болай булмасын. *Андый-мондый хәл булмасын өчен, аңа күз-колак булырга кирәклеген уйлап алып, ул ниятеннән дә кайтты* (Г. Бәширов).

Төрдәше: алай-болай булмасын.

**АНДЫЙ-МОНДЫЙ ХӘЛ БУЛСА (БУЛА КАЛСА; БУЛА КАЛГАНДА).** Бер дә көтелмәгән хәл килеп чыкса. *– Андый-мондый хәл була калса, – дип кисәтте Хәят, – сумка синеке түгел* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!).

Төрдәше: андый-мондый хәл килеп чыкса.

**АНДЫЙ-МОНДЫЙ ХӘЛ БУЛУ.** Һич көтелмәгән хәл турында. *Андый-мондый хәл булып, Себер киткәндер дип уйлап йөри идем* (К. Нәҗми).

**АНДЫЙ-МОНДЫЙ ХӘЛ КИЛЕП ЧЫКСА (ТУСА)** *к.* андый-мондый хәл булса (була калса; була калганда). *Монысын мин андыймондый хәл килеп чыкса дип әйтәм* (Н. Акмал. Үз урамым).

Төрдәше: андый-мондый хәл булса (була калса; була калганда).

*АНДЫЙНЫ* ❖ **АНДЫЙНЫ КӨНДЕЗ ЧЫРА ЯНДЫРЫП ТА ТАБА АЛМЫЙСЫҢ (АЛМАССЫҢ).** Әллә нидә бер табыла торган, гадәти булмаган һәм бик сирәк очрый торган кадерле нәрсә (кеше). – *Шәп кеше мәгәр. Андыйны көндез чыра яндырып эзләсәң дә табып булмый* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

Төрдәше: аяз көндә (көнне) <чыра яндырып та> таба алмыйсың (алмассың).

*АНЕКДОТ* ❖ **АНЕКДОТ САТУ (САТЫП УТЫРУ / ТОРУ / ЯТУ)**. Анекдот, мәзәкләр сөйләү. *Бүрәнә өстендәге ирләр анекдот сатып утыралар иде* (Сөйләм).

*АНЛЫК* ❖ **АНЛЫК ТОРМЫЙ.** 1. Җиңелчә генә булышлык өчен рәхмәт әйткәндә, каршы әйтү сүзе. *Алай бик зурга алмагыз, анлык тормый* (Сөйләм).

2. Танылган берәр әйбер яки макталган әдәби әсәр ул мактауларга лаек булмаганда әйтелә. – *Кайберәүләр бу роман турында мактау сүзләрен сиптеләр, минемчә, ул анлык тормый: автор әсәрен тапталган сюжетка корган һәм бернинди яңалыгы да күренми* (Сөйләм).

*АННАН* ❖ **АННАН АЛГАН ЙОМЫРКАНЫҢ ЭЧЕНДӘ САРЫСЫ БУЛМАС.** Бик саран, кешегә игелек күрсәтми торган, һәрвакыт үзенә генә файда күрергә тырышучы кеше турында. – *Син кайчан аның берәр кешегә яхшылык иткәнен күргәнең бар, аннан алган йомырканың да эчендә сарысы булмас* (Сөйләм).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**АННАН <ДА> АҢ БУЛ.** «Аны да бел, хәбәрең булсын» мәгънәсендә. *Ачу килгән чакта Хода истән чыга. Аннан аң бул* (М. Фәйзи).

**АННАН АРТЫҢА КОЯШ ЧЫКМАС.** Берәр нәрсә сораганда бирмәүчегә әйтелә. – *Бирмисеңмени, йә, ярар, аннан артыңа кояш чыкмас әле* (Сөйләм).

**АННАН АРЫ <КИЛЕП>.** Аннан соң, аннары, аның соңында. *Әгәр дә аждаһа тирә-якка зыян тидермәсә, меңгәчә яши икән дә, ди, аннан ары «юха» еланга әйләнә икән, ди* (Г. Ибраһимов. Яз башы). *Ул ниткән олтан? Ә? Аннан ары килеп, патша дуңгыз көтәмени* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: аннары килеп.

**АННАН ӘЙБЕР АЛГАНЧЫ, ТАВЫКТАН СӨТ САВАРСЫҢ** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. – *Алдый, Сәвия, алдый! Аннан әйбер алганчы, тавыктан сөт саварсың! – диде икенче яңгыравык тавышлысы* (Т. Нурмөхәммәтов. Кабан күле, әй, алкын).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2.

**АННАН БАШКА.** Шулай ук, өстәмә рәвештә. *Әнә ул Казанга 1901 дә түгел, 1905 тә килсен, аннан башка бунда бер әйтеп китәргә тиешле кимчелек бар* (Г. Ибраһимов). *Шундый авыр елда да сыер юнәтү хәстәрен күргән ул, аннан башка, гаиләң ишле булмаса да, көн итү авырлыгын аңлаган* (Р. Рахман. Аңлашылу).

**АННАН БАШКА ДА.** Нәрсәнедер (яки кемнедер) исәпкә алмыйча да, *шулай ук к.* ансыз да. – *Юк, чакырып торма, моны аннан башка да хәл итеп була* (Сөйләм). *Районда бит әле аннан башка да җинаятьләр бетмәгән* (А. Нәҗми. Урмандагы ау).

Төрдәше: ансыз да; болай да.

**АННАН БАШЛЫЙ, МОННАН ТАШЛЫЙ.** Сөйләүнең (язуның, хәбәр бирүнең, әйтергә кушканның һ.б.) эзлеклелегә булмау, тәртипсез рәвештә кирәкле фактларны төшереп калдыру. *Икенче юлы мине мондый очрашуларга чакырма, бүген үзәктән килгән кунакның чыгышының да рәте булмады: аннан башлый, моннан ташлый, ык итә, мык итә* (Сөйләм).

Төрдәше: аннан бер, моннан бер.

**АННАН БЕР, МОННАН БЕР** *к.* эзлекле сөйләмәү (әйтергә кушканны тапшырмау; хәбәр итмәү; язмау һ.б.), кайбер нәрсәләрне төшереп калдыру. *Сәхнәгә сикереп чыгып, нәрсә әйтергә теләгәндер – Алла белсен, бездә андый очракта «аннан бер такта, моннан бер такта җыеп йөри» диләр* (Сөйләм).

Төрдәше: аннан башлый, моннан ташлый.

**АННАН БИГРӘК.** Бигрәк тә, мөһимрәк, аннан да ныграк. *Һәр тарафтан бөек дәрәҗәгә ирешкән улына, аннан бигрәк килене Ида Михайловнага ярарга тырыша, аш-суын бөртекләп әзерли, мунчасын җиренә җиткереп яга* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**АННАН БИРЛЕ КҮП<МЕ> СУЛАР АКТЫ.** Күп вакыт үткәнлегенә, билгеле бер вакыттан соң

күптөрле үзгәрешләр булуына ишарә (гадәттә, үткәннәрне искә төшергәндә кулланыла). *Онытқандыр да, аннан бирле күпме сулар акты* (З. Хөснияр). *Бәхетемнән иркә акккош булып, / Зәңгәр дулкыннарда йөздем мин. / Аннан бирле күпме сулар акты, / Җырлап үтте күпме язларым* (Р. Вәлиева).

**АННАН ДА БИГРӘК** *к.* алай гына <да> түгел; алай гынамы. *Аннан да бигрәк, яшел йә зәңгәр плүштән жакет тектерергә бик һәвәс иделәр* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: алай гына барып чыкмый; алай гына <да> түгел; алай гынамы.

**АННАН ИТ ТӘ ЮК, ЙОН (СӨТ) ДА ЮК.** Булдыксыз, файда китерми торган кеше хакында; «ул кешедән (малдан һ.б.) бер бәрәкәт тә юк» мәгънәсендә. *Нәрсәгә дип эштә тоталардыр үзен, аннан он да юк, йон да юк* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**АННАН КАЛА.** Әйтелгән нәрсәләрдән тыш, тагын да. *Бер сүзне кабатлап тору әтисенең күңеленә тиде бугай, малаен кырт кисте: «Нигә булсын, мир газиз дә җир, аннан кала ир газиз», – дип сөйләнә торган гадәте бар иде мәрхүмнең* (Р. Вәлиев. Яшисе килә). *Бу төркемдә барысы биш кеше: иң өлкәне – топограф Рәфис Нигъмәтуллин, аннан кала геолог Александр Межков һәм өч эшче бар иде* (И. Хуҗин. Аю).

**АННАН КАЛГАННЫ ЭТ АШАМАС.** Берсен дә калдырмый кабахәт сүзләр белән сүккән кеше турында. *Берсен дә калдырмыйча эт итеп сүкте, шундый әшәке сүзләрне кайдан табып тора диген, аннан калганны эткә бирсәң, эт тә ашамас* (Сөйләм).

**АННАН КИРЕ.** Мөһимрәк нәрсәләрне санаганнан соң, мөһимсезрәкләрен атаганда әйтелә. *– Аннан кире, шушы басулар, урманнар, таулыклар, чокырлар буйлап йөрик... Су коеныйк, чишмәләрдән сулар эчик, җимеш кыйыйк...* (Ә. Баянов. Яшьлегемне эзлим).

**АННАН ОН ДА ЮК, ЙОН ДА ЮК** *к.* авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү. *Юкка йөри булдыра алмаганына, аннан он да юк, йон да юк* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**АННАН ОН СУЫ ДА ЮК, ТОЗ СУЫ ДА ЮК** *к.* авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү. *– Безнең белән тауларга чыгып йөрмәсен, аннан он суы да юк, тоз суы да юк* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**АННАН РАШТУАДА ЯУГАН КАРНЫ АЛА АЛМАССЫҢ** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. *– Тапкансың ышанырлык кеше, аннан раштуада яуган карны да ала алмассың* (Сөйләм).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2.

**АННАН СОҢ ЭЗЛӘ ИНДЕ СИН АНЫ!** «Эзләп табуы мөмкин булмаячак» мәгънәсендә. – *Урманга барып җитсә, табып булмаячак, аннан соң эзлә инде син аны!* (Сөйләм).

Төрдәше: <аның> койрыгын тотарсың!

**АННАН ТЕЛӘСӘҢ, МИНЕ ТАЛКЫП ЙОН ЭРЛӘ.** Бик мохтаҗ булып ярдәм сораганнан соң әйтелә. *Бик уңайсызланып кына берәр нәрсә сорады да: «Аннан теләсәң, мине талкып йон эрлә», – дип өстәп куйды* (Сөйләм).

**АННАН ТЕШЛӘРЕҢНЕ ЧҮПЛӘ ҖИРДӘН.** Берәрсе белән ызгышлы бәйләнешкә керүнең хәтәр нәрсә икәнлеген кисәтү. – *Син бу тирәдә бик болганып йөрмә, башта сүз артыннан сүз китәр, аннан тешләреңне чүплә җирдән* (Сөйләм).

**АННАН <ӘЙТҮЕМ> ТҮГЕЛ.** Аның өчен түгел, башка бер нәрсә өчен. – *Ә сез минем китүемне теләгән идегез инде, әйе? – Аннан әйтүем түгел* (В. Нуруллин. Күпер чыкканда).

**АННАН ФАЙДА КҮРГӘНДӘ, АЛЛАДАН КАЗА КҮРЕРСЕҢ.** Үз файдасы өчен генә тырышучы, явыз кеше хакында. «*Уртак эш башлыйбыз» дисең, яхшылап уйладыңмы: аннан файда күргәндә, Алладан каза күрерсең* (Сөйләм).

**АННАН ЭШ КАЛМАС.** Берәр эшкә (мәсьәләгә) киртә булыр дип уйлаган нәрсәнең әһәмияте булмавын белдерә. *[Гали] Кара аны, Хәлил, туйда сыйны мул яса. [Хәлил] Аннан эш калмый* (М. Фәйзи. Галиябану).

Төрдәше: аннан эш тормас.

**АННАН ЭШ ТОРМАС** *к.* аннан эш калмас. *[Әхмәтҗан] Аннан эш тормас, синең эшләр ничек?* (Т. Гыйззәт).
Төрдәше: аннан эш калмас.

*АННАН-МОННАН* ❖ **АННАН-МОННАН ӘЙТҮЕМ ТҮГЕЛ.** «Сүзне гайбәт буларак яки үз мәнфәгатен күз уңында тотып әйтү түгел» мәгънәсендә. *Син тагы «бүген дә шулай сәдака өмет итеп килгән» дип уйлый күрмә. Аннан-моннан әйтүем түгел* (Г. Камал).

**АННАН-МОННАН ГЫНА.** Тиз-тиз генә, ничек туры килсә шулай; ярты-йорты гына эшләнгән эш. – *Аннан-моннан гына марля ураган, кан саркып торган нинди генә яралыларны күрмисең анда!..* (Ә. Еники. Без дә солдатлар идек).
Төрдәше: аннан-моннан эшләү; ашык-пошык эшләү; аягүрә эшлә<н>гән эш; әш<т>ер-өш<т>ер китерү; әштер-өштер генә; әштер-өштер ит<тер>ү; әштер-өштер, кандаладан ботка пешер; биисе килмәгән аюга урын тар; биисе килмәгәннең көе килми; миннән киткәнче – иясенә <барып> җиткәнче <дип эшләү>; ничек җитте алай (шулай); ничек туры килсә шулай; өй салуның ние бар: мүклисе дә чутлыйсы; элкенде-селкенде эшләү; эт ашы – арыш боламыгы итеп эшләү.

**АННАН-МОННАН КАПКАЛАУ.** 1. Төрле ризыкларның тәмен белү өчен, һәрберсен аз-азлап кабып карау. *Бәдәр аш җиткерде, ашны, итле бәрәңгене аннан-моннан капкаладылар* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

2. Ашык-пошык, тиз-тиз генә ашап алу. *Егетләр нигәдер ашыгалар иде, коймакны аннан-моннан капкалап, берәр генә чынаяк чәй эчтеләр дә кияүгә хәер-дога теләп, урыннарыннан тордылар* (Ә. Еники. Истәлекләр).

**АННАН-МОННАН СУКАЛАУ.** 1. Юл яру, эз салу. Өстән-өстән, җиренә җиткермичә генә. *Бакчаны аннан-моннан сукалады да атны алып чыгып китте* (Сөйләм).

2. Бер телдә бераз укый-сөйләшә белү. *Русчаны аннан-моннан гына сукалаганлыктан* (Ш. Маннур).

**АННАН-МОННАН УКУ.** Өзек-өзек уку; тулысынча укымау. *Аннан-моннан гына укыды да мәктәбенә йөгерде* (Сөйләм).
Төрдәше: күз йөртеп алу (чыгу); өстән- өстән карап чыгу; өстән генә укып алу; өстән-өстән уку.

**АННАН-МОННАН ЭШЛӘҮ.** Сыйфатлылык турында уйламыйча, ашык-пошык эшләү. *Әйтик, әгәр аны (хезмәт көнен) бирәү эшләми генә яисә аннан-моннан эшләп кенә ала икән, ул инде авылдашларыныкын, күршеңнекен, кардәшеңнекен урлау* (А. Шамов).
Төрдәше: аннан-моннан гына һ.б.

*АННАРЫ* ❖ **АННАРЫ КИЛЕП** *к.* аннан ары <килеп>. *Аннары килеп, әтинең энесе Миңнулла абый да сугышта иде бит әле* (В. Нуруллин. Ике урам арасы). *Аннары килеп, бу адәмнең күз-күз тишекле зәңгәр свитер киеп, ул тишекләрдән мохер җеп төсле ап-ак йоннар чыгып торуын, борын астында уртача буяу пумаласы кадәр мыегы барлыгын да өстәргә кирәк* (Ф. Садриев. Адәм әүлиясы).
Төрдәше: аннан ары <килеп>.

**АННАРЫ ТАГЫН ШУЛ ЧАКЛЫСЫ БАР.** «Өстәвенә тагын шунысы яки шул хәтәр ягы бар» мәгънәсендә. *Аннары тагын шул чаклысы да бар. Тартыша торгач, ике арадагы мәхәббәт җебенең өзелеп китүе дә мөмкин бит* (Ф. Хөсни).
Төрдәше: ан<ы>сы <аның> <да> бер хәер; ан<ы>сы бер хәл иде.

*АНСАТКА* ❖ **АНСАТКА КИЛҮ.** Җиңеләю; җайлы, уңайлы булу. *Кибеткә кул арбасы өстерәп баргач, ансатка килде* (Сөйләм).

*АН<Ы>СЫ* ❖ **АН<Ы>СЫ <АНЫҢ> <ДА> БЕР** ХӘЕР. «Берәр нәрсә белән килешергә булыр иде, ләкин икенчесе дә бар» мәгънәсендә. *Нишә ай килми торды соң? Өч ай егерме бер көн. Ансы аның бер хәер, эш анда түгел, анда бит минә аклар булды* (А. Шамов).
Төрдәше: аннары тагын шул чаклысы бар һ.б.

**АН<Ы>СЫ БЕР ХӘЛ ИДЕ** *к.* ан<ы>сы аның (да) бер хәер. *Булмаса булмый икән, барыбер кызны карата алмады. Әле анысы бер хәл иде. Әллә кайларга китеп югалып, кешеләр арасында нинди сүзләр кубарып, мең утларга салды ул Рафисны* (С. Рәфыйков. Тын елга буенда).
Төрдәше: аннары шул чаклысы бар һ.б.

**АН<Ы>СЫ ГЫНА ҖИТМӘГӘН ИДЕ** *ирон.* Ул гына җитмәсә, өстәвенә тагын; бер мәшәкать өстенә икенчесе килеп өстәлү. *Ансы гына җитмәгән иде, кадрлар бүлегеннән кичкә*

*кадәр гаиләдәге кешеләр саны турында белешмә сорадылар* (Сөйләм).

**АН<Ы>СЫ ДА МОН<Ы>СЫ.** 1. Уйнап сөйләшер вакыт бетте, җитди сөйләшергә кирәк. *Ансы да монсы, Биктимер абзый, бу бурсык балалары белән нишлибез икән?* (Т. Гыйззәт).

2. Юк-бар кешеләр (нәрсәләр). *Ишегалдына чыгар хәл юк, ансы да монсы: «Бу курткаңы кайдан алдың?» – дип аптыратып бетерде* (Сөйләм).

**АН<Ы>СЫ ДА МОН<Ы>СЫ, БЕР ЙОМЫРКА ВАТЫЛДЫ.** Юктан гына эш бозылып китү хакында. *«Анысы да монысы, бер йомырка ватылды» дигәндәй, көпчәкнең тыны тәмам чыгып бетеп, туктап калдык* (Р. Гыйлемханов һ.б. Истә калганнар).

**АН<Ы>СЫ МИНЕМ ЭШ ТҮГЕЛ.** «Ул эшнең миңа кагылышы юк» мәгънәсендә. *Мин: Буксировка өчен машинаны каян табарга? Ул: Ансы минем эш түгел* (Ф. Яруллин. Хәтер төпләрендә утлы күмер). *Кала архивын ике ел саен алыштырып торалар аны. Ярар, анысы минем эш түгел* (М. Хәбибуллин. Илчегә үлем юк).

Төрдәше: анысы миңа карамый (кагылмый); ан<ы>сында минем эшем юк.

**АН<Ы>СЫ ТАГЫН БЕР ХӘЛ.** «Килеп чыккан хәл белән ризалашыр идең дә, аннан да кыенрагы бар» мәгънәсендә. *Иптәш кызына төрле әшәке сүзләр әйткән, анысы тагын бер хәл, ә нигә ул аның баш яулыгын урлаган?* (Сөйләм).

**АН<Ы>СЫ ХАКЫНДА ТАРИХ ЭНДӘШМИ (КЫЧКЫРЫП СӨЙЛӘМИ).** Эшнең ул ягы караңгы, яшерен, аны ачыклар өчен мәгълүмат та юк. *Шуннан соң клубка йөрүләр язгы һәм җәйге көннәрдә йорт-курада эш күбәю аркасында сирәгәйде. Бәлки, башка сәбәп тә булгандыр, анысы хакында тарих кычкырып сөйләми* (Ә. Баянов. Җәй белән җәй арасы).

**АН<Ы>СЫ ХАТ БАШЫНДА.** «Әүвәл эшләнәчәк эш бар, һәм ул көн кебек ачык (ягъни хат башындагы калыплашкан сүзләр кебек), ә күрәчәгең әле алда» мәгънәсендә. *Иртәгә сиңа полициягә чакырган язу киләчәк – анысы хат башында. Дәвамы соңыннан булыр* (Сөйләм).

Төрдәше: анысы әле баласы<-чагасы> гына, мичтә ята анасы; әле бу бит уены, шуннан соң булыр дуены; әле бусы баласы, <мичтә калган анасы>; ...баласы гына, мичтә икән (калды) анасы; ...бисмилласы гына; бу әле баласы <гына>, мич башында (мичтә ята) анасы; бу бит уены гына, шуннан соң булыр дуены; монысы әле баласы, алда булыр анасы; монысы әле баласы, мичтә (пичтә) калгандыр (калды) анасы; монысы мәсьәләнең баласы гына, менә монда анасы; монысы төтене <генә>, алдарак әле пожары; тегесе баласы гына.

*АНСЫЗ* ❖ **АНСЫЗ ДА** *к.* аннан башка да. *Ләкин ансыз да беренче балыкны үзем алыр төсле тоям, һәр минутта менә эләгә, менә эләгә... дип тора идем* (Г. Ибраһимов. Яз башы).

Төрдәше: аннан башка да; болай да.

**АНСЫЗ – ДӨНЬЯ САНСЫЗ (ФАЙДАСЫЗ).** Бик кирәкле, зарурый булган әйбер турында. *– Ансыз – дөнья сансыз дигәндәй, миннән фатиха алайса!* (Ә. Еники. Рәшә). *Ул балага Аллаһы Тәгалә үзе дога кылган, фәрештәләр яклый аны, изге җан ул. Ансыз дөнья сансыз булыр иде* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).

*АН<Ы>СЫ-МОН<Ы>СЫНА* ❖ **АН<Ы>СЫ-МОН<Ы>СЫНА КАРАМАСТАН.** Җайсызлыкларны, каршылыкларны игътибарга алмыйча. *Дөягә кара: бернәрсәгә дә карамыйча бара да бара һәм юлын уңышлы үтә, син дә, анысы-монысына карамастан, үз эшеңдә бул* (Сөйләм).

*АН<Ы>СЫН* ❖ **АН<Ы>СЫН АЛАЙ, МОН<Ы>СЫН БОЛАЙ ИТҮ.** Төрле эшләрне эшләп, җайлап рәткә китерү. *Хәдичә ханым исә анысын алай, монысын болай итеп йөрештереп торды* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

**АН<Ы>СЫН АЛЫП, МОН<Ы>СЫН БИРЕП.** Берәр нәрсәне кулга төшерү өчен, алышбиреш эшләү хакында. *Миңа калса, безнең атакай ул чакларда да тик ятмагандыр, якынтирә авылларда аның танышлары күп иде, анысын алып, монысын биреп дигәндәй, кирәк нәрсәне тапкандыр, мөгаен* (Ә. Еники. Соңгы китап).

**АН<Ы>СЫН ГЫНА БЕЛӘБЕЗ.** Артык гади әйберләрне тәфсилләп аңлатырга маташканда үпкәләбрәк әйтелә. *Биктагиров сүзен дәвам итте: – Анысын гына беләбез* (Ф. Садриев.

Шаһзаманов эше). *«Кустым» дигәне башкортча, безнеңчә «энем» була инде. Анысын гына беләбез* (Р. Миңнуллин).

**АН<Ы>СЫН КУЙ ДА МОНЫСЫН ӘЙТ.** «Ул әйбер белән чагыштырганда, монысы мөһимрәк, шуны сөйләшик» мәгънәсендә. *Юкбар белән маташма әле, калдыр ул сүзеңне, анысын куй да монысын әйт* (Сөйләм).

*АН<Ы>СЫНДА* ❖ **АН<Ы>СЫНДА МИНЕМ ЭШЕМ ЮК** *к.* ан<ы>сы минем эш түгел. *[Биктимер] Ул кадәр колхоз җырларен кем генә җыеп бетерер икән соң? [Галимә] Анысында минем эшем юк* (А. Алиш. Күршеләр). *Дәфтәргә теркәп барасыңмы, исемнәрен ятлап каласыңмы – анысында минем эшем юк* (В. Имамов. Нәзер).

Төрдәше: ан<ы>сы минем эш түгел; анысы миңа карамый (кагылмый).

*АН<Ы>СЫННАН* ❖ **АН<Ы>СЫННАН ДА БИГРӘК** *к.* аннан да бигрәк. *Ансыннан да бигрәк, мине аяк бармагындагы сызлау борчый* (Сөйләм).

Төрдәше: аннан да бигрәк.

**АН<Ы>СЫННАН ЭШ КАЛМАС.** «Әгәр шул гына эшкә киртә булып торса, зарары юк, хәл итәрбез» мәгънәсендә. – *Якты чырай күрсәтсәгез, безнең бүтән кайгы юк. – Якты чырай, такта чәй! Анысыннан эш калмас* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). – *Сүз биргәнмен икәнмен, анысыннан эш калмас. Син дә минем шартны үтә: ташла җыртып шул боерык кәгазен!..* (В. Нуруллин. Аккан су юлын табар).

*АНТ* ❖ **АНТ АЛЫНУ.** Биргән антын бозарга рөхсәт алу. *Һәрбер кыз өстеннән ант алыначак* (Р. Батулла. Сөембикә).

**АНТ ӘГӘР<Е>.** «Ант итеп әйтәм» мәгънәсендә. – *Әйтмим, апа, әйтмим. Бетте. Ант әгәр!* (Г. Үзиле. Ленин, Дарья Петровна, мин һәм башкалар).

Төрдәше: айдыр әгәр һ.б.

**АНТ БЕРКЕТҮ**. Катгый ышандырып әйтү, сүзендә нык торачагын вәгъдә сүзе белән ныгыту, биргән сүзен үтәү. – *Менә шул чакта ук бабай илә кияү бер-берсенә аркадашлар булырга ант беркеткәннәр* (В. Имамов. Карабәк).

Төрдәше: айдыр әгәр һ.б.

**АНТ БИРҮ.** 1. Тантаналы рәвештә ышандыру. *Илең кешеләреннән / Атаң Адәм, Анаң Һава алдында / Тантаналы ант бир!* (М. Кәбиров. Җир уллары фаҗигасе).

2. Сүз бирү, вәгъдә бирү. *Шул чакта мин үз-үземә ант биргән идем: бу кызны мин беркайчан да югалтмам, үскәч, шуңа өйләнәм, дидем* (З. Мурсиев. Солтанъяр).

Төрдәше: айдыр әгәр һ.б.

**АНТ БОЗУ.** 1. Биргән вәгъдәне бозу, биргән сүзен үтәмәү, сүзендә тормау. – *Шул көннән антымны боздым, кукалның, кара чикмәннең канын коюдан, малын куудан күңелем суынды* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *Чит берәүгә гашыйк булып, / кәләшем антын бозды* (Г. Садә).

Төрдәше: антны эчү; әманәткә хыянәт; вак таракан ашау; вәгъдә «вау»ы кырылу; вәгъдә йоту; вәгъдәгә хилаф итү; вәгъдәдә тормау; вәгъдәдән «вау»ы гына калу; вәгъдәдән йөз чөерү; вәгъдәдән кайту; вәгъдәдән кич<ег>ү (чиг<ен>ү); вәгъдәләр «вау»сыз булу; вәгъдәне вак таракан ашау; вәгъдәне бозу; вәгъдәне йоту; вәгъдәне<ң «вау»ын> вак таракан ашау; сүздә тормау; тукран тәүбәсе; эт, җәйгә чыккач, сөяктән сарай салыр идем дип әйтә ди, җәйгә чыккач, аны оныта, ди; сүздән чыгу.

2. Хыянәт итү. – *Әгәр явыз ният белән бу тантаналы антымны бозсам…* (Г. Әпсәләмов. Газинур). *Бик теләсә дә, кала алмады шул. Илгә, Ватанга биргән атын боза алмады* (А. Хәсәнов. Данәгөл).

Төрдәше: вәгъдәне бозу; вәгъдәне йоту; вәгъдәнең вавы кырылу; вәгъдәне<ң вавын> вак таракан ашау; сүздә тормау; тукран тәүбәсе; эт җәйгә чыккач, сөяктән сарай салыр идем дип әйтә ди, җәйгә чыккач, аны оныта, ди.

**АНТ ИТЕП (ЭЧЕП).** Вәгъдә сүзе белән ныгытып, катгый ышандырып. *Солдат намусы белән ант итеп әйтәм: үзем тәрҗемә иттем!* (В. Нуруллин. Ике урам арасы). *Бачман тархан хан сараеннан ул вакыт кабат мәңге аяк басмаска антлар эчеп чыгып киткән иде* (В. Имамов. Утлы дала).

**АНТ ИТКӘН ТӨСЛЕ.** Эшне бөтен шартын җиренә җиткереп эшләп тә, уңай нәтиҗә булмаса әйтелә. – *Моторын сүтеп, яңадан җыйган идем бит инде, ант иткән төсле тавыш та чыгармый ичмасам* (Сөйләм).

**АНТ ИТТЕРҮ.** Вәгъдә бирергә мәҗбүр итү. *Шуннан болар карчыкны ант иттерәләр* («Таңбатыр» әкияте).
Төрдәше: антка китерү.

**АНТ ИТҮ** *к.* ант бирү 2. *Менә – балам. / Син әнкәсе аның, / Балабызны тотып ант итәм...* (Ф. Кәрим). *Мин ант иттем, янмам гомергә дип, / Ул чак инде ерак...* (Р. Гаташ. Төш һәм өн).
Төрдәше: айдыр әгәр һ.б.

**АНТ КИТЕРҮ** *к.* айдыр әгәр. *Юлда чакта ук ишәк урынына кыйналган бичаралар кереп бил бөгәргә яисә ант китерү өчен авыз ачарга да өлгерми, Бирдебәк һәрберсенең йә билен сындыртып, йә сыйдырып бара* (В. Имамов. Карабәк).
Төрдәше: айдыр әгәр һ.б.

**АНТ МЕНӘ** *к.* айдыр әгәр. – *Ант менә, икенче елга кил, диләр. Быел урын юк, диләр* (Н. Гыйматдинова. Кем беренче?).
Төрдәше: айдыр әгәр һ.б.

**АНТ ОРГАН.** Биргән антны бозу зур җинаять саналу, антын бозган кешене анты аның үзен орган дип кабул итү. – *Мансурнымы, белми ни, ант орган егет булып калды ул минем хәтердә* (Сөйләм).
Төрдәше: анты башына җиту (төшү); анты тоту (ору).

**АНТ ОРСЫН** *карг.* Биргән сүзне бозучыны аны анты ора дип ышану. *Ант орсын* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).
Төрдәше: ант орсын, кояш орсын әгәр.

**АНТ ОРСЫН, КОЯШ ОРСЫН ӘГӘР** *карг.* Анты орган кешене кояш та орачак дигән ышануга бәйле ант. – *Иртәгә үк китереп бирәчәкмен, ант орсын, кояш орсын әгәр* (Сөйләм).
Төрдәше: ант орсын.

**АНТ ТОТУ** *к.* айдыр әгәр. *Сезнең кәгазьдә, сүздә биргән антларыгыз күп булды, сез ул антларның берсен дә тотмадыгыз* (Х. Камалов).
Төрдәше: айдыр әгәр һ.б.

**АНТ <КАСӘЛӘРЕ; СУЛАРЫ> ЭЧҮ** *шигъри, к.* айдыр әгәр. *Ләкин бу үчне кайтармый калмам дип, эченнән зәһәрләнеп ант эчте* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). *Яшел җәйдә – яшел яшьлегемдә / Без ант эчкән изге урында / Күзге җилләр бүген яфрак сибә...* (Н. Гамбәр).
Төрдәше: айдыр әгәр һ.б.

*АНТЕЙ* ❖ **АНТЕЙ БУЛУ.** Нык рухлы, авырлыкларга бирешмәс булу. *...Антей булган. Ул җиңелмәс булган, / Җиргә тигән булган тәпие* (Р. Идиятуллин. Кайту).

*АНТКА* ❖ **АНТКА КИТЕРҮ.** Вәгъдә бирдерү. – *Менә шунда тәмам антка китердем инде мин аны...* (Р. Төхфәтуллин. Авылдашым Нәби).
Төрдәше: ант иттерү.

**АНТКА ТАП КУНДЫРМАУ.** Антка туры булу. *Соңгы тамчы каным тамса тамсын, / Тик антыма таплар кунмасын* (М. Җәлил. Кичер, илем!). *Үз-үзләрен аямыйча, ил халкын сугыш мәхшәрләреннән коткарып, намуслы хезмәт юлы үтеп, гомерләрен кыл өстенә куеп, котылгысыз үлем шәүләсе белән күзгә-күз очрашудан курыкмаган һәм илне саклау антына тап кундырмаган сугыш һәм хезмәт ветераннары, инвалидларына бүген мәдхия җырланды* (tat.tatar-inform.ru).
Төрдәше: айдыр әгәр һ.б.

**АНТКА ТАП ТӨШЕРМӘҮ** *к.* антка тап кундырмау. *Антына тап төшермә, дошманга әсирлеккә бирелмә, дип күпме мәкаләләр, шигырьләр язды ул, ә үзе...* (Г. Әпсәләмов. Агыла болыт).
Төрдәше: айдыр әгәр һ.б.

*АНТ-ШАРТ* ❖ **АНТ-ШАРТ ИТЕП.** Дәүләтара эшләрдә шарт куешып, ант биреп имзалау. *Вәкаләтләре булган җаваплы кешеләр ант-шарт итеп, килешүне имзаладылар* (Сөйләм).

*АНТЫ* ❖ **АНТЫ БАШЫНА ҖИТҮ (ТӨШҮ).** Бозылган антның каһәрен күрү. – *Кара аны, вәгъдәңне бозма, югыйсә антың башыңа җитәр, Алла орыр үзеңне* (Сөйләм).
Төрдәше: ант орган; анты тоту (ору).

**АНТЫ ТОТУ (ОРУ)** *к.* анты башына җитү (төшү). *Нәгыймәгә ни булды икән, саргаеп йөри, биргән анты тоткан мы әллә?* (Сөйләм).
Төрдәше: ант орган; анты башына җитү (төшү).

*АНТЫНДА* ❖ **АНТЫНДА ТОРУ** *к.* айдыр әгәр. *Кая антында торган тугры дуслар?/ Кая сүзендә торган чын гүзәл яр?* (Имадетдин Нәсими газәлләре. Ә. Исхак тәрж.). *Туйдан соң Ирек*

*гафу иткәч, ул бит үз-үзенә меӊ мәртәбә антлар биргән иде: янадан мәӊге андый юлга басмаска, гомеренеӊ азагына кадәр Ирекккә тугры булырга, анын табанының туфрагын яларга. Ә антында тора алмады* (Ф. Садриев. Бәхетсезләр бәхете).

Төрдәше: айдыр әгәр һ.б.

**АНТЫӉ ❖ АНТЫӉ БАШЫӉА ҖИТСЕН** *карг., к.* ант орсын. *Антыӊ башыӊа җитсен* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).

Төрдәше: ант орган; ант орсын.

**АНТЫӉ БАШЫӉА ТӨШМӘСЕН.** Теләсә нинди эшен дә ант итеп ышандырырга яратучыга карата. *Раббани шушы чирдән эчкечелектән котылырга телиме, нинди юллар сайлый ул? (Уфада больницада дәвалана, үз-үзенә сүз биреп карый, инде бөтенләйгә дәваланып кайттым дигәннән соӊ, әнисе алдында ант итә, башкача эчмим дип. Әнисе аӊа; «Антыӊ башыӊа төшәр, ант итмә», – ди)* (tvov.ru).

**«А»НЫ ӘЙТКӘЧ, «Б»НЫ ДА ӘЙТҮ** *к.* «а» дигәч, «б»ны әйтү. – *«А»ны әйткәч, «б»ны да әйт инде , эчеӊдә калмасын* (Сөйләм).

Төрдәше: «а» дигәч, «б»ны әйтү һ.б.

**«А»НЫ «Б»ГА КУША БЕЛМӘҮ.** Кешенеӊ наданлыгына ишарә. – *Әллә син мине «а»ны «б»га куша белми дип уйлыйсыӊмы?* (Сөйләм).

Төрдәше: ак-кара танымау һ.б.

*АНЫ* ❖ **АНЫ ӘЙТ ТӘ МОНЫ КУЙ** *к.* ан<ы>сын куй да мон<ы>сын әйт. – *Турыдан сөйләшик! Аны әйт тә моны куй, кич утырырга кертәсезме?* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: ан<ы>сын куй да мон<ы>сын әйт һ.б.

**АНЫ ӘЙТ ТӘ МОНЫ СӨЙЛӘ, ЙОМЫРКАНЫ ТҮЛӘ.** «Сөйләвен сөйлисеӊ, ә эшеӊ кайда?» мәгънәсендә. Бурычын, йөкләмәләрен үтәмичә, буш сүз сөйләп кенә котылмакчы булган кешегә карата. – *Тукта әле, ул кадәр ашыкма, аны әйт тә моны сөйлә, йомырканы түлә* (Сөйләм).

**АНЫ ӘЙТКӘН ДӘ ЮК.** Анысы үзеннән-үзе билгеле; әйтеп торасы да түгел. *Аны әйткән дә юк, каладан укып кайтты да, ата каз кебек, муенын сузып йөри* (Сөйләм).

Төрдәше: әйтмә дә инде!

**АНЫ БЕЛМӘГӘН ГЕНӘ БЕЛМИ, БЕЛГӘН КОЙРЫГЫНА ДА ЭЛМИ** *мыск.* Яхшы белгән нәрсәне аӊлатып торуга каршы мыскыллы көлү. *Анда барып, вакытымны әрәм итәсем юк әле, ул сөйләгәннәрне аны белмәгән генә белми, белгән койрыгына да элми* (Сөйләм).

**АНЫ ГӨЛӘП ҖИӉГИ ДӘ (МӘНДИ АНАСЫ ДА; ЭТ ТӘ) БЕЛӘ** *мыск.* Аӊгыралыктан көлеп әйтү. *Ләкин рәис Нәҗиб Кәмал аны нәфрәт белән тыӊлады: русча уку кирәк, инде аны Мәнди анасы да белә, ләкин аныӊ кирәклеге турында ник Кәрим Гайфине китереп тыгарга* (Г. Ибраһимов).

Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.

**АНЫ ДА ӘЙТ, МОНЫ ДА ӘЙТ, КАМЫР БУЛСА, САЛМА САЛ.** Тегесен-монысын, барысын да макта, әмма аларны бер читкә куеп, үзебезнеӊ салмалы ашны пешер – «тормышта кирәк сүзне генә сөйләп, кирәген генә эшлә» мәгънәсендә. *Хатыннар белән нигә сөйләшеп утырмаска, бар, җилләнеп кайт, аны да әйт, моны да әйт, камыр булса, салма сал* (Сөйләм).

**АНЫ КАРА** *кис.* «Шуны исеӊнән чыгарма» дип кисәтү. *Чөнки апай бик нык кисәтеп куйды: «Аны кара! Киндер өстенә казлар «яшел чикләвеген» салып калдырса, Кибәхуҗа җыеныннан колак кактым дип бел!»* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**АНЫ КӨТСӘӉ, КАРТ КЫЗ БУЛЫП УТЫР ДА КАЛ.** Күпме көтсәӊ дә көтеп ала алмассыӊ. *Читкә китәм дип, күзе акайган! Аны көтсәӊ, карт кыз булып утыр да кал!* (А. Гыйләҗев).

Төрдәше: аны көтсәӊ, күзеӊ күгәрер; көтә-көтә бәбәкләр тишелү; көтә-көтә көтек булу (булып бетү); көтә-көтә күз күгәрү; күз<ләр> күгәрү; күзләр күмергә әйләнү.

**АНЫ КӨТСӘӉ, КҮЗЕӉ КҮГӘРЕР** *к.* аны көтсәӊ, карт кыз булып утыр да кал.– *Бер чыгып китсә, тиз генә кайтмый инде ул. Әйдә, утырып чәй эчә торыйк, аны көтсәӊ, күзеӊ күгәрер* (Сөйләм).

Төрдәше: аны көтсәӊ, карт кыз булып утыр да кал һ.б.

**АНЫ КУЙ ДА МОНЫ ӘЙТ.** «Анысына караганда мөһимрәк булган башкасы бар, әйдә,

шуның хакында сөйләшик» мәгънәсендә. *[Бәхтияр] (серле итеп) Аны куй да моны әйт, батыр түрәм: димәк, сиңа да чын асыл ат алырга вакыт!* (Р. Мингалим, Р. Хәмид. Идегәй).

Төрдәше: аны әйт тә моны куй һ.б.

**АНЫ МӘНДИ АНАСЫ ДА БУЛДЫРА (ЭШЛИ).** Эшнең гадилеге турында, аны аңгыра кеше дә башкара ала, имеш. *Кара эшне аны Мәнди анасы да булдыра...* (М. Мәһдиев).

**АНЫ МОНДА АРКАН БЕЛӘН ДӘ <ӨСТЕРӘП; СӨЙРӘП; ТАРТ<ТЫР>ЫП> КИТЕРӘ АЛМАУ.** Кузгатып булмау, чакырып-чакырып та килми торган кеше хакында. *Мидхәт китапханәнең кайда икәнен дә белми бугай, аны монда аркан белән дә тарттырып китерә алмассың* (Сөйләм).

Төрдәше: аркан белән дә <өстерәп; сөйрәп; тарт<тыр>ып> китерә алмау; аркан белән дә тарттыра алмассың.

**АНЫ ТИК ИРЕНЧӘК КЕНӘ КЫЕРСЫТМЫЙ.** Һәркем тарафыннан кыерсытылырга мөмкин булган мескен турында. *Уткән бере аны ничек булса да кыерсытып китәргә тырыша иде, аны тик иренчәк кенә кыерсытмый иде кебек* (Сөйләм).

**АНЫ ҺӘРКЕМ ҮЗ КАЛЫБЫНА САЛЫП, БАЛЧЫК (КИРПЕЧ) УРЫНЫНА СУГА.** Юаш, күндәм кеше турында. – *Артык йомшак кеше дә инде синең күршең, минемчә, аны һәркем үз калыбына салып,кирпеч урынына суга ала* (Сөйләм).

Төрдәше: җылыга еланияләшү; йомшак авыз; йомшак агачны корт басу; песи <кебек> булу; песи кебек <кенә йөрү>; юаш бозау; юаш юанайса, ишеккә сыймый; юашның ачуы яман; юаштан юан чыгу (чыгып куймагае).

**АНЫ ЭШЛӘҮ БЕЗГӘ ТИШЕКЛЕ БЕР ТИЕН ДӘ ТОРМЫЙ.** «Бу эш бик җиңел, без аны хәзер үк эшләп куябыз» дигәнне аңлата. – *Борчылма, бер сәгатьтә эшләп ташларбыз, аны эшләү безгә тишекле бер тиен дә тормый* (Сөйләм).

*АНЫККА* ❖ **АНЫККА ТАНЫК <БУЛУ (БУЛЫП ТОРУ)>** *ирон., шаярт.* 1. Әзерне генә яратучы, башкалар тапканга хуҗа булу. *Агротехника буенча эшләп җиткермибез – акыл үшәнлеге һәм бәлтерәгәнлек күрсәтәбез. Аныкка танык булу, икенче төрле әйткәндә, көч түкми яшәү...* (З. Мансуров. Гакълым берлә... кул талаша).

Төрдәше: әзергә бәзер (хәзер); әзергә бәзер яшәү; әзергә хәзер, хәзергә назир; бәхет өләшкәндә йоклап калган нәрсә; гомер бәй.

2. Мәгълүм нәрсәгә (яки көчле якка) шаһит булу. *Аныкка танык булып тору читен булмас, машина өстенә агач ауганлыгын әйтергә кирәк иде* (Сөйләм).

*АНЫКЫ* ❖ **АНЫКЫ ИЛНЕКЕННӘН (ИЛДӘГЕДӘН) ИКЕ ИЛЛЕ АРТЫК БУЛЫР** *көл.* Үзеннән кушып, сүзне арттырып әйтү. – *Саграк бул, һәр әйткән сүзенә ышанып утырма, аныкы илдәгедән ике илле артык була* (Сөйләм).

**АНЫКЫ ТАШКА БАСКАН.** Башкарган эшне вакытында, төгәл итеп башкару, вәгъдәдә тору. – *Бер дә шөбһәләнмә, әйтсә, сүзендә тора торган егет ул – аныкы ташка баскан* (Сөйләм).

*АНЫКЫН* ❖ **АНЫКЫН БЕЛМӘССЕҢ.** Фикере, гамәле үзгәреп торучы, ышанычсыз кеше. *Аныкын белмәссең: әллә дөресен әйтә, әллә шаярта* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *[Хәдичә] Аныкын белмәссең, кодача, әллә нәрсәләр бутады-бутады да, җен суккан кебек, чыгып чапты* (Г. Ахунов. Утлар яна учакта).

*АНЫ-МОНЫ* ❖ **АНЫ-МОНЫ.** Кирәкмәгән нәрсәне. *Юк, бер дә аны-моны ашамады* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала). *Газзә аны-моны әйтми генә урыннан кузгалды* (М. Маликова. Язгы такыялар).

**АНЫ-МОНЫ АБАЙЛАМЫЙ<ЧА>.** Әйләнә-тирәгә игътибар итмичә, берни дә сизмичә. *Ләзидә исә, аны-моны абайламый, буранга каршы атлап, бераз алга киткән иде* (Д. Каюмова. Буранлы юллар).

Төрдәше: алны-артны карамыйча; алны-артны күрмәү; алны-артны уйламыйча; алны-артны, уңны-сулны белми; баш ватып, күз чыгарып тормыйча; җан-фәрманга; уңга-сулга карамыйча.

**АНЫ-МОНЫ ӘЙТМӘҮ.** Бернинди дә яңа нәрсә сөйләмәү, кисәтмәү. *Кәбир, аны-моны әйтмичә, таш багананың таш капкачын ачып, аны җиргә куйды* (Н. Фәттах. Аклан).

**АНЫ-МОНЫ БЕЛМИЧӘ.** Бер нәрсәдән дә шикләнмичә, шөбһәләнмичә. *Кемнәрдер, аны-моны белмичә, үз көенә генә яшәде, ә кайберәүләр ул «кабахәтләр» явызлыгыннан һаман арына алмый* («Туган як» газ.).
Төрдәше: алны-артны карамыйча һ.б.

**АНЫ-МОНЫ КАРАМЫЙ<ЧА> (КАРАП ТОРМЫЙЧА).** Бер нәрсәгә дә игътибар итмичә. *Яшь атның, аны-моны карап тормыйча, басу ригасына атылып-бәрелеп үзе килеп керүе булгандыр* (Ф. Хөсни). *Аны-моны карамый, / Иртән китә хезмәткә, / Кичегергә ярамый* (М. Җәлил. Хәдичә).
Төрдәше: Төрдәше: алны-артны карамыйча һ.б.

**АНЫ-МОНЫ СӨЙЛӘҮ (СӨЙЛӘШЕП АЛУ).** Тормыш хәлләре турында фикер алышу. *Керде дә, аны-моны сөйләмәстән, билгеле, сәхнә аркылы үтеп, почмакка кереп басты* (А. Тимергалин. Таш алиһә). *Юлда аны-моны сөйләштеләр* (З. Кадыйрова. Сагынырсың – мин булмам).

**АНЫ-МОНЫ УЙЛАМАСТАН (УЙЛАП ТОРМАСТАН; УЙЛАМЫЙЧА).** Бер нәрсәдән дә шөбһәләнмичә; озак уйламыйча. *Чаналы малайларга сер бирәсе килмәгән Биктимер, аны-моны уйлап тормастан, кулын-дагы табасын куя да, шуңа утырып, шугалактан тау астына шуып төшеп китә* (Ф. Хөсни. Сөйләнмәгән хикәя).
Төрдәше: алны-артны карамыйча һ.б.

*АНЫҢ* ❖ **АНЫҢ АЛТЫНЫ ЯНЧЫКТА ТҮГЕЛ, КАПЧЫКТА.** Югары дәрәҗәдә, бик тә бай. *Аның алтыны янчыкта түгел, капчыкта шул, беләсегез килсә...* (gabdullatukay.ru).
Төрдәше: алтын эчендә йөзү; алтынга күм<ел>ү (бат<ыр>у); алтынга ману 3; алтынга чуму; алтын-көмешкә чумдыру; аның алтыны янчыкта түгел, капчыкта; байлыкка чуму.

**АНЫҢ БАВЫ БЕЛӘН КОЕГА ТӨШӘ АЛМАССЫҢ.** Берәүнең ярдәме ышанычсыз булу турында. *Бер дә ышанычлы кешегә охшамаган, аның бавы белән коега төшә алмассың* (Сөйләм).

**АНЫҢ БАШЫ БУЛСА.** «Әгәр дә акылы булып, фикерле белсә» мәгънәсендә. – *Аның башы булса, мондый җүләрлекне эшләмәс иде* (Сөйләм).

**АНЫҢ БЕЛӘН БАЛА ЧУКЫНДЫРАСЫ ЮК.** Уртак яки кадерле бернәрсә дә булмау, *Артыгын кыса башласа, берәр районга укытучы булып китәр дә барыр анысы, эз югалту өчен. Аның белән бала чукындырасы юк* (Г. Гомәр. Мөһер).
Төрдәше: бергә бала чукындырасы юк; чиркәү чаңы кагып бала чукындырасы юк.

**АНЫҢ БЕЛӘН БОРЧАК ПЕШМӘҮ.** Берәрсе белән уртак фикергә килү мөмкинлеге булмау; ышанырга мөмкин түгел. *Аның белән борчак пешмәде* (М. Маликова. Арыш тәме). *Аннары хатыннарга сүз катты: – Сезгә яңа зоотехник алып килдем – Исрафилов Рәфис Гәрәевич... Аның белән дә борчагыгыз пешмәсә, без бүтәнчәрәк нәтиҗә ясарбыз* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

2. Берәр эшнең, ниятнең тормышка ашмавы. *Җәрингә икенче бүлмәгә күчәргә кирәк, барыбер аның белән борчак пешмәс* (Н. Фәттах). *«Ә Платон Платонович?» – дип сорады ул, төкселәнеп. «Аның белән борчагыбыз пешмәде», – диде һаман хәйләгә остармаган Нургалиев* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: аның белән ботка пешерелмәс; аның белән эшең пешмәс; борчак бүртмәү 1; борчак пешмәү (пешерә алмау) 1.

**АНЫҢ БЕЛӘН БОТКА ПЕШЕРЕЛМӘС** *к.* аның белән борчак пешмәү 1. – *Ныклабрак каты уйлап кара, аның белән ботка пешерелмәс кебек* (Сөйләм).
Төрдәше: аның белән борчак пешмәү 1 һ.б.

**АНЫҢ БЕЛӘН КАБЕРЕҢ ЯНӘШӘ (ЯКЫН) БУЛМАСЫН, <КАБЕРЕҢӘ КЕРЕП КӘФЕНЕҢНЕ ТАЛАП ЧЫГАР>.** Бик әшәке кеше турында сөйләгәндә кулланыла. *Аһ! Аның белән каберең якын булмасын... Ә менә Хисаметдиннең беренче хатыны, Зөбәйдәнең әнисе, алтын иде* («Казан утлары» ж.). – *Бу Маликныкылар белән каберең янәшә булмасын, каберең... – дип зарлана башлады ул, – кабереңә кереп, кәфенеңне талап чыгарлар…* (И. Гази).
Төрдәше: агу тел<ле> һ.б.

**АНЫҢ БЕЛӘН ЧӘКҮШКӘҢ ЭЛӘКМӘСЕН.** «Бик җәнҗалчы кеше белән эләгешергә туры килмәсен» мәгънәсендә. *Әле ярый теге көнне атчы Фатыйх белән сүзгә кермәгән, аның*

*белән чәкүшкәң эләкмәсен, атна буе телдән төшермәс* (Сөйләм).

Төрдәше: агу тел<ле> һ.б.

**АНЫҢ БЕЛӘН ЭШЕҢ ПЕШМӘС.** «Бергәләшеп эш эшләп булмаячак» мәгънәсендә. – *Юкка өметләнәсең кебек, иманым камил – аның белән эшең пешмәс* (Сөйләм).

Төрдәше: аның белән борчак пешмәү 1 һ.б.

**АНЫҢ БИТЕ ЮМАГАН.** Әрсез, оятсыз кеше турында. – *Аның бите юмаган икәнен белмисеңмени, хәзер инде исеңдә тот* (Сөйләм).

Төрдәше: әрсез алабай; әрсез балта сабы; бите җәһәннәмгә керсә дә кызармас; битен юмаган; битенә дуңгыз тиресе каплау; битенә күн теккән; битенең керенә биш эт туярлык; биткә олтан салу; биткә ыштыр каплау (ябу); битсез кеше; эт каешы <булу>; шомарган таш.

**АНЫҢ БУ ЭШТӘ ТЕШЕ КОЕЛГАН ИНДЕ.** Бик зур тәҗрибә туплау, эшенең остасы булып җитешү. *Аның бу эштә теше коелган* (Р. Абдуллина. Сөйләм культурасы).

Төрдәше: азау теше чыккан <инде> һ.б.

**АНЫҢ БҮРЕСЕ УЛЫЙ** *к.* аларның әтәче дә йомырка (күкәй) сала. *Күтелмәгән берәр нәрсә килеп чыкмаса, аның бүресе улаячак инде, байлыгын тагын да арттырачак* (Сөйләм).

Төрдәше: аларның әтәче дә йомырка (күкәй) сала һ.б.

**АНЫҢ ДУҢГЫЗЫ ДА БОЛАМЫК АШЫЙ** *к.* аларның әтәче дә йомырка (күкәй) сала. – *Бер сүзем дә юк, аның дуңгызы да боламык ашый дип әйтергә генә кала* (Сөйләм).

Төрдәше: аларның әтәче дә йомырка (күкәй) сала һ.б.

**АНЫҢ ИТЕК ТАБАНЫНА ДА ТОРМАУ (ТОРЫРЛЫК ТҮГЕЛ).** – *Син сокланган буласың тагын, аның итек табанына да тормый бит ул!* (Сөйләм).

Төрдәше: алтырагына да тормау һ.б.

**АНЫҢ ИШЕ** *мыск.* Берәр кеше яки нәрсә турында сүз барганда, тискәре мөнәсәбәтне белдерү өчен кулланыла. – *Аның юше эшмени ул, кәҗә савып утыралар шунда...* (А. Алиш. Якты күл буе...). *Аның юше ирнең булуыннан булмавы артык* (Ф. Нуруллин. Күпер чыкканда).

**АНЫҢ ИШЕ ТҮГЕЛ.** 1. Бер-берләренә пар түгелләр. – *Юкка таныштыргандыз аларны, Миләүшә аның юше түгел* (Сөйләм).

2. Икесенең берсе артык шәп булу. *Бу ике кыз башкалардан аерылып торсалар да, аларда да Гөлнара тәрбиясе белән дә, кеше белән мөгамәләсе белән дә өстенрәк, икенчесенең аның юше түгеллеге күзгә бәреп тора иде* (Сөйләм).

**АНЫҢ ИШЕ (КАДӘР; КЕБЕК; ЧАКЛЫ) ГАЕП ПАТША (МУЛЛА; ХАН) КЫЗЫНДА ДА БУЛА** *к.* алай гына мулла (патша; хан) кызында да була. *Авыз тутырып сөйләп торган була, аның юше гаеп хан кызында да була* (Сөйләм).

Төрдәше: алай гына мулла (патша; хан) кызында да була һ.б.

**АНЫҢ ИШЕГЕННӘН ДӘ КЕРӘ, ТИШЕГЕННӘН ДӘ КЕРӘ.** 1. Дәүләте арту, эше уңышлы барып, күп итеп акча эшләү. *Аның ишегеннән дә керә, тишегеннән дә керә* (К. Насыйри. Мәкальләр һәм әйтемнәр).

Төрдәше: акча каеру һ.б.

2. Ярлы кеше турында: торагының һәр җиреннән җил өрү, суык керү. *Кышны ничек чыгар инде, мескен, аның ишегеннән дә керә, тишегеннән дә керә иң* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз ачса, кече теле күренү 2 һ.б.

**АНЫҢ ЙӨРӘГЕ АЛТЫН.** Кешегә һәрчак ярдәм итә торган, миһербанлы кеше. *Хәзер мин андый кешеләрне сирәк очратам, аның йөрәге алтын* (Сөйләм).

**АНЫҢ КАЙГЫСЫ ТҮГЕЛ (ЮК).** Кем яки нәрсә турындадыр уйларга яки сөйләргә теләге юклык; аннан да зуррак мәшәкатьләр булу. *Ләкин хәзерге минутта җыру җырлап утырып булмый, аның кайгысы түгел, кызның соравына төгәл җавап бирергә кирәк* (Р. Кәрами. Кая чабасың, гомер юртагы?).

**АНЫҢ КАККАН КАЗЫГЫ ДА ЮК.** Йортҗире дә, ягъни бер нәрсәсе булмаган кеше турында. *Нинди кыз аңа килсен, аның каккан казыгы да юк бит!* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз ачса, кече теле күренү 2 һ.б.

**АНЫҢ КАРА КАШЫ ӨЧЕН ДИП.** Күз өстендә каш итеп иркәләнеп яшәргә гадәтләнгән кешегә аның хакына дип юл куеп килү. *Ничә еллар буе аңа тел-теш тидермичә саклап килдек, инде хәзер аның кара кашы*

*өчен дип, үземнең тормышымны бозасым юк* (Сөйләм).

Төрдәше: аның кашы кара <булган> дип (өчен).

**АНЫҢ КАРАВЫ (КАРУЫ).** Шулай да, шулай булса да. – *Аның каруы, синең йортың шәп!* – *диде рәис* (Н. Гыйматдинова. Нурулла). *Аның каравы, пар җирләре күп калдырыла, ә анда исә азык мул иде* (Ш. Маннапов. Янгыннан калган баганалар).

**АНЫҢ КАРГА БАСКАНДА КАЛГАН ЭЗЕ ГЕНӘ ДӨРЕС.** Кешенең бер эше дә дөрес булмыйча, кардагы эзе генә дөрес дип санау (ләкин аны да җил себереп алып китәргә мөмкин). *Заманалар үзгәрә бара, кайсы дөрес, кайсы дөрес түгеллеген аеру да кыенлашты, кеше дә шулай ук – аның карга басканда калган эзе генә дөрес* (Сөйләм).

**АНЫҢ КАШЫ КАРА <БУЛГАН> ДИП (ӨЧЕН)** *к.* аның кара кашы өчен дип. *Аның кашы кара дип, тормышымны һәлакәт астына куясым юк* (Сөйләм).

Төрдәше: аның кара кашы өчен дип.

**<АНЫҢ> КОЙРЫГЫН ТОТАРСЫҢ!** *к.* аннан соң эзлә инде син аны! *Бер иркенлеккә чыгып ычкынгач тотарсың аның койрыгын!* (Сөйләм).

Төрдәше: аннан соң эзлә инде син аны!

**АНЫҢ КӨЛКЕСЕ ДӘ ЧЫН, ЧЫНЫ ДА КӨЛКЕ.** Уен-көлкеле, кызык сүз, көлке астында исә чынлык яту (Ш. Бабич хакында М. Гафури шулай дип әйткән). *Гаҗәеп кеше, аның көлкесе дә чын, чыны да көлке* (Сөйләм).

**АНЫҢ КӨНЕ АЛГА БАРА.** Тормышы, эше уңышлы бара. *Хәзер инде малай хакында борчыласы юк, аның көне алга бара* (Сөйләм).

**АНЫҢ КУЛЫ КӘКРЕ** *к.* алдырган – атасының куенын актарган. *Авылдашлары аның кайтуына сөенмәде, киресенчә, кара кайгыга батты. Ник дигәндә, Гаптеринең кулы кәкре, аңа «Каптырый» дигән кушамат та тагылган иде* (Н. Гыйматдинова. Син түгел бу, син түгел...).

Төрдәше: алдырган – атасының куенын актарган һ.б.

**АНЫҢ КУЛЫ КҮТӘРЕЛМӘС.** Кыйнамас, сукмас. *Бу сүзләргә ышанасы килми, хатын-кызга аның кулы күтәрелмәс* (Сөйләм).

**АНЫҢ КҮЛЕ ТИРӘН.** 1. Бай кеше турында. *Аның күле тирән. Ягъни бай* (К. Насыйри. Мәкальләр һәм әйтемнәр).

2. Тирән уйлый, тирән фикерле. *Улыгыз бөреләнеп кенә килә әле (балалыктан үсмер чорга керү матурлыгы). Аның күлы тирән.* (Р. Абдуллина. Сөйләм культурасы).

**АНЫҢ НИ ЭШЕ БАР.** «Ул кешенең бу эшкә бернинди катнашы юк, нигә тыгыла» мәгънәсендә. *[Нурфатих] Синең башта аның ни эше бар?!* (Д. Салихов. Гыйләҗ тәрәзәләре). *Инде Сәгыйть шулай да оныта алмаса, аның икенче кешене сөйгәнен белеп кайгыга сабышса, анда аның ни эше бар?* (Н. Фәттах).

**АНЫҢ ӨСТЕНӘ.** Өстәвенә, шуның белән бергә. *Аның өстенә машинасы да һаман әле кайтып җитмәгәч, тәмам җене чыгып, бу хатын җиллесен җилле дә, ләкин миңа кырысрак буылрга туры килер дип, күңеленә салып куйган иде* (В. Нуруллин. Һәлакәт).

Төрдәше: аның саен.

**АНЫҢ САЕН.** Тагын да ныграк, отыры, аның өстенә, бигрәк. *Әтинең ачуы торган саен күперә бара, аның саен күзләре усалрак карый* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Имеш, куучылар, артыннан җитеп, атына «тпру» дип дәшеп караганнар, ат аның саен элдереп чаба икән* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

Төрдәше: аның өстенә.

**АНЫҢ САНДУГАЧЫ САЙРЫЙ.** Эшнең җайга салынуы, яхшы баруы. – *Дустыңа кара; аның сандугачы сайрый бугай, ә син нигә бирешәсең?* (Сөйләм).

Төрдәше: аларның әтәче дә йомырка (күкәй) сала һ.б.

**АНЫҢ САРЫГЫ ДА БҮРЕ ТОТА** *к.* аларның әтәче дә йомырка (күкәй) сала. – *Син безне чагыштырма,* – *диде ир, көрсенеп,* – *мин алган эш хакымны тартып-сузып яшим, ә аның сарыгы да бүре тота* (Сөйләм).

Төрдәше: аларның әтәче дә йомырка (күкәй) сала һ.б.

**АНЫҢ СОҢГЫ СӘГАТЕ.** Үлем алдыннан калган соңгы вакыты. *Шулай да ул Тимерче ягына таба шактый кара үтте, аркасына килеп кадалган сөңге аның соңгы сәгате сугуын хәбәр иткәнче, унлап дошманның башын кисеп өлгерде* (З. Мурсиев. Куелган язмыш).

Төрдәше: соңгы сәгате.

**АНЫҢ СУЛАГАЙ КУЛЫ БАР.** Уң кулы белән эшләгәнне сул кулы белән алып калган (ягъни мут, үз файдасына эшләүче) хыянәтчел кеше турында. – *Аның сулагай кулы бар, диделәр, бездә озак эшли алмас ул* (Сөйләм).

**АНЫҢ ТАВЫГЫ ДА ЮРГАЛЫЙ** *к.* аларның әтәче дә йомырка (күкәй) сала. *Аның тавыгы да юргалый; хәле начар булганда: авызында – аш, күзендә – яшь* (Р. Абдуллина. Сөйләм культурасы).

Төрдәше: аларның әтәче дә йомырка (күкәй) сала һ.б.

**АНЫҢ ТАЛКАНЫ КОРЫ.** Һәр җирдә дә эшне коры тотучы, кырыс кеше. *Җор һәм тапкыр сүзле, туры фикерләр булуы белән ул беркемне дә битараф калдырмый торган үзенчәлекле шәхес, аның талканы коры, таләбе каты булуын белсәң дә, ихласлыгына таянып, курыкмыйча сөйләшергә, аңлашырга була иде* (Р. Зарипов. Тирән тамырлы Түнтәрем).

Төрдәше: аның тирәсендә талкан коры, су салкын.

**АНЫҢ ТЕРӘГЕ ИМӘН, ТЕРӘСӘ, КАТЫ ТЕРИ.** Дәлилле, бәхәстә куәтле, нык кеше турында. *Аны җиңү миңа берни тормый, дип, өстән генә фикер йөртмә, аның терәге имән, терәсә, каты тери* (Сөйләм).

**АНЫҢ ТИРӘСЕНДӘ ТАЛКАН КОРЫ, СУ САЛКЫН** *к.* аның талканы коры. *Аның белән сөйләшкәндә, шаяртулар белән бик мавыкма, аның тирәсендә талкан коры, су салкын* (Сөйләм).

Төрдәше: аның талканы коры.

**АНЫҢ ТҮБӘСЕ КАРАБОДАЙ САЛАМЫ БЕЛӘН ЯПКАН.** «Безнең телне белә, артыгын ычкындырма» дип кисәтеп кую. – *Бик күп сөйләшмә, яныңда торган кешенең дикъкать белән тыңлавын сизәсеңме, аның түбәсе карабодай саламы белән япкан бугай* (Сөйләм).

**АНЫҢ ҮГЕЗЕ ДӘ БОЗАУЛЫЙ (БОЗАУЛАГАН ВАКЫТ)** *к.* аларның әтәче дә йомырка (күкәй) сала. *Кара, нинди канәгать кыяфәт белән йөри, аның үгезе дә бозаулаган вакыт, ахрысы* (Сөйләм).

Төрдәше: аларның әтәче дә йомырка (күкәй) сала һ.б.

**АНЫҢ ҮГЕЗЕ ДӘ СӨТ БИРӘ** *к.* аларның әтәче дә йомырка (күкәй) сала. – *Аның үгезе дә сөт бирә бит, ничек көнләшмисең монда* (Сөйләм).

Төрдәше: аларның әтәче дә йомырка (күкәй) сала һ.б.

**АНЫҢ ҮГЕЗЕ ДӘ ТЕШЕНЕ БОЗАУЛЫЙ** *к.* аларның әтәче дә йомырка (күкәй) сала. *Әйтсәң, кеше ышанмас, аның үгезе дә тешене бозаулый* (Сөйләм).

Төрдәше: аларның әтәче дә йомырка (күкәй) сала һ.б.

**АНЫҢ ҮГЕЗЕ ДӘ ҮКЕРӘ.** Бәхете арта бару, эше нык алга китү. *Бәрәкәтле елга туры килде Мансур, аның үгезе дә үкерә* (Сөйләм).

**АНЫҢ ҮРДӘГЕ (ТАВЫГЫ) ДӘ КАЗ КЕБЕК, <ЙОМЫРКАСЫ БАШ КЕБЕК>.** 1. Байның һәрнәрсәсе гади кешенекенә караганда, мулрак, эрерәк була. *Бай кешенең һәр нәрсәсе кешенеке кебек түгел, аның тавыгы да каз кебек, йомыркасы баш кебек* (Сөйләм).

Төрдәше: аларның әтәче дә йомырка (күкәй) сала һ.б.

2. Шапырынып сөйләүчедән көлеп әйтелә. *Кит аннан, аның тавыгы да каз кебек дисеңме?! Ә син төш күрмәдеңме?* (Сөйләм).

**АНЫҢ ХАКЫНДА ТАРИХ ЯЗМЫЙ (ЭНДӘШМИ).** Берәр нәрсә хакында гомумән мәгълүмат булмау. – *Аның хакында тарих эндәшми, булганмы ул вакыйга, булмаганмы – әйтә алмыйбыз* (Сөйләм).

**АНЫҢ ЭШЕ КОМ ТИБӘ** *к.* аның сандугачы сайрый. – *Кара Әтәч Әнвәренә, ничек кукраеп йөри – аның эше ком тибә шул* (Сөйләм).

Төрдәше: аларның әтәче дә йомырка (күкәй) сала һ.б.

**АНЫҢ ЯСИНЫ УКЫЛГАН.** Кешенең үлем минутлары якынаю. *Тирә-юньдәгеләр үлем ятагында яткан белән бәхилләшеп калырга ашыктылар, чөнки аның Ясины укылган иде инде* (Сөйләм).

*АНЫСЫ* ❖ **АНЫСЫ АНДА, МОНЫСЫ МОНДА.** Теләсә кайда; берәрсе нәрсәнеңдер урыннарын карыштырып сөйләгәндә әйтелә. *Бүлмәдәге әйберләрнең рәте-чираты беткән иде, анысы анда, монысы монда тәгәрәгән* (Сөйләм).

Төрдәше: анысы башка мәсьәлә.

**АНЫСЫ ӘЛЕ ӘБИЕҢ НИНДИ ТӨШ КҮРЕР.** «Адагы эшне юрап утырудан файда юк» мәгънәсендә. *Нәрсә дип монда «анысы әле әбиең*

*нинди төш күрер» дип утырырга, урынына барыйк та анда күз күрер* (Сөйләм).

**АНЫСЫ ӘЛЕ БАЛАСЫ <-ЧАГАСЫ> ГЫНА, МИЧ БАШЫНДА (МИЧТӘ) ЯТА (УТЫРА) АНАСЫ.** «Күрәселәр алда әле, монысы кечкенә эш, зурысы алдарак» мәгънәсендә. *Анысы әле баласы, мич башында яткан анасы дигәндәй, киленнең каенанасы шактый таләпчән, уңган, явызлыгы йөзендә чалкан яткан хатын булып чыга* (Т. Галиуллин. Сәет Сакманов).

Төрдәше: әле бу бит уены, шуннан соң булыр дуены; әле бусы баласы, <мичтә калган анасы>; монысы әле баласы, алда булыр анасы; монысы әле баласы, мичтә (пичтә) калгандыр (калды) анасы; монысы мәсьәләнең баласы гына, менә монда анасы; монысы төтене <генә>, алдарак әле пожары; тегесе баласы гына.

**АНЫСЫ БАШКА МӘСЬӘЛӘ.** Сөйләнелә торган сүзнең, мәсьәләнең башка өлкәгә караганлыгы турында. *Урынлымы ул, урынсызмы – анысы башка мәсьәлә* (Н. Әхмәдиев. Мөнирстан).

**АНЫСЫ КАЛЫП ТОРСЫН.** «Мәсьәләнең ул ягын тикшерми торыйк, башка мөһимрәге бар» мәгънәсендә. – *Ярар, анысы калып торсын, соңыннан хәл итәрбез. Ә хәзер безнең өчен иң важные – алтын запасы* (С. Сабиров. Алтын балдаклы абыстай). *[Гөлнара] Ярый, анысы калып торсын. Хәрби звание. Монысын – солдат белергә тиеш инде* (Т. Миңнуллин. Яшьлегем-юләрлегем...).

Төрдәше: анысы качмас; монысы әллә ни түгел.

**АНЫСЫ КАЧМАС.** «Бу эш ашыгыч түгел, ул әһәмиятле дә түгел, бераз көтеп тора ала» мәгънәсендә. – *Тик моның өчен нотариальный конторага барырга кирәк була торгандыр. – Барырбыз, анысы качмас* (Ә. Еники. Рәшә).

Төрдәше: анысы калып торсын; монысы әллә ни түгел.

**АНЫСЫ МИҢА КАРАМЫЙ (КАГЫЛМЫЙ)** *к.* анысы минем эш түгел. – *Юк, болай гына,* – *дип хатирәләреннән арынырга тырышкандай, башын чайкап куйды ул. – Анысы миңа кагылмый иде* (М. Маликова. Кызыл гөл). *Анысы миңа карамый, унбишенче бүлмәгә бирегез* (Сөйләм).

Төрдәше: анысы минем эш түгел; анысында минем эшем юк.

**АНЫСЫ МИҢА КАРАҢГЫ.** Берәр нәрсә турында гомумән хәбәр, мәгълүмат булмау. – *Артык чынмы, ялганмы бу хәлләрең – анысы миңа караңгыдыр* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы). *Гомумән, педагогия күзлегеннән карaганда, эткәй дөрес эшләгәндерме-юкмы – анысы да караңгы миңа <...>* (Н. Гамбәр. Әти белән сөйләшү).

*АҢ* ❖ **АҢ АЧЫКЛАНУ.** Зиһен ачылу, тирә-якны аңлый башлау. *Әле аңым ачыклана, әле тагын караңгы упкынга очып онытылам* (И. Гази. Йолдызлы малай).

Төрдәше: акыл җыю 2 һ.б.

**АҢ АЧЫЛУ.** Тормышның серләренә төшенү. *Аңым бераз ачылды, тик һаман да үземне уратып алган чынбарлык белән килешә алмыйм әле* (Х. Ширмән.Ерактагы йолдызым).

**АҢ БУЛ!** «Дикъкатьле бул, сак бул!» дип кисәтү. *[Габсаттар] Ләкин кара аны, аң бул! Бер юлга кичерәм* (Г. Камал. Көндәш). *[Исмәгыйль] Ачу килгән вакытта Ходай истән чыга. Аннан да аң бул* (М. Фәйзи. Галиябану).

**АҢ ҖИТМӘСЛЕК** *ирон., к.* акыл җитмәслек. *Шуңа күрә дә безнең дәрәҗәдән ул микропланетар дәрәҗәгә күчеп, үтеп кереп тә булмаска тиеш. Чөнки вакыт тизлегенең аермасы аң җитмәслек зур* (Ж. Юныс. Глобаль идея).

Төрдәше: акыл җитмәслек һ.б.

**АҢ ҖИТҮ** *к.* акыл җитү. *Намусыңны яшьтән сакла, диләр. Онытабыз, әллә аң җитми* (Н. Әхмәдиев. Намус турында).

Төрдәше: акыл җитү һ.б.

**АҢ ЖУЮ** *к.* аң китү. *Мәхәббәттән аңын җуйган егет / Кызның күндәм колы шикелле* (М. Җәлил). *Муен тамырына каты сугудан ул чынлап торып аңын җуйган иде* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).

Төрдәше: аң китү; аң югал<т>у; аңнан язу; аңсыз калу; ис югалту; иссез калу; истән аву; истән таю; истән язу; һуш китү; һуш югалу; һушны жую; һушны югалту; һуштан таю; һуштан язу.

**АҢ ЖЫЮ.** Күпмедер вакыт аңсыз торганнан соң, тирә-якны шәйли башлау. *«Хуш!» – дип әйтерлек тә түгел идем, / Сагыш томанында аң жыйдым* (Ф. Яхин). *Ишекләр ябылгач, чылтырап йозаклар бикләнгәч, Булат бәк*

*аркасы белән ишеккә сөялде дә, булган хәлгә чарасыз калып, аңын җыя торды* (М. Хәбибуллин).

Төрдәше: акылга килү һ.б.

**АҢ КЕРТҮ.** Аң бирергә, аңлы итәргә. *[Кыям] Соң син ничек уйлыйсың, синең үзеңнең күпме аңың бар?! (Үчекләп). Аң кертергә. Һи-һи һи! Йоклаган халыкка аң кертергә...* (К. Тинчурин. Беренче чәчәкләр).

**АҢ КЕРҮ (АЧЫЛУ).** Тирә-якны аңлый алырлык хәлгә килү. *Аң кергәч, торып караса, каршында учак күрде* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).

Төрдәше: акыл җитү һ.б.

**АҢ КИТҮ.** Вакытлыча аңны югалтып тору. *...Әмма минем тагын аңым киткән* (М. Хуҗин. Ышаныч). *Хәер, яшен ташы булып, / Берне китереп бәрсә / Аң китә, кошлар киткән күк, / Ояларыннан өркеп* (Р. Харис).

Төрдәше: аң җую һ.б.

**АҢ СЫЙДЫРМАУ (СЫЙДЫРА АЛМАУ)** *к.* акылга сыймау. *Ләкин лотереяга куелган сораулар терармеецларны аптыратырлык аңлаешсыз, шулай ук терармеецлар аңнары сыйдырмаслык зур мәсьәләләрдән булмаска тиешле...* (Һ. Такташ). *Суздаль юлында, машинасы белән бәрелеп, Шикоянның һәлак булуын һич кенә дә аңына сыйдыра алмый иде ул* (М. Галиев. Сатурн һәм умач).

Төрдәше: акылга сыймау (сыймый торган).

**АҢ ҮСҮ** *к.* акыл җитү. – *Гади генә түгел бу мәсьәлә. Реггиналь аң үсте, дигән идем* (Р. Юныс. Татар гаме). *Ул туып, аңы үсеп исәйгәннән бирле карчык-корчыклар: «Алда адәм уллары вагаячак...»* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: акыл җитү һ.б.

**АҢ ЧАТНАУ.** Бернәрсә дә аңлый алмас хәлгә килү. *Магомед карт белән сөйләшкәндә, чатнап китте аңым бер мәлгә* (Р. Харис).

**АҢ ЮГАЛ<Т>У** *к.* аң китү. *Аңын югалткан, битләре, иреннәре мәрмәр кебек ак, маңгаенда салкын тир бөртекләре, сулышы беленер-беленмәс кенә* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Мин бит бу сүзне аңымны югалткан минутларда да исемнән чыгармадым, гүя чигәмдәге кан тамыры шикелле ул өзлексез тибеп торды* (Ә. Еники. Гөләндәм туташ хатирәсе).

Төрдәше: аң җую һ.б.

*АҢА* ❖ **АҢА ӘЙТКӘННЕ ТАШКА ӘЙТСӘҢ, ТАШКА ДА ҖАН КЕРЕР ИДЕ.** Ялварып, өзелеп әйткән сүзләрнең дә тәэсире булмау турында. *Булыр икән каткан бәгырьләр, аңа әйткәнне ташка әйтсәң, ташка да җан керер иде* (Сөйләм).

Төрдәше: аңа әйткәнче, бер ташка әйтсәң, таш җанланыр иде.

**АҢА ӘЙТКӘНЧЕ, БЕР ТАШКА ӘЙТСӘҢ, ТАШ ҖАНЛАНЫР ИДЕ** *к.* аңа әйткәнне ташка әйтсәң, ташка да җан керер иде. *Аңа әйткәнче, бер ташка әйтсәң, таш җанланыр иде* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

Төрдәше: аңа әйткәнне ташка әйтсәң, ташка да җан керер иде.

**АҢА ӘЙТТЕҢ НИ, СТЕНАДАГЫ БҮРӘНӘГӘ ӘЙТТЕҢ НИ.** Кеше сүзен, үтенечен тыңламаучы; әйтүнең файдасы булмавы турында. *Аңа әйттең ни, стенадагы бүрәнәгә әйттең ни – йөзендәге бер мускулы да селкенмәде* (Сөйләм).

Төрдәше: әйттең ни <дә>, әйтмәдең ни; бүрәнәгә борчак аткан (атмак) кебек; бүрәнәгә борчак бәрү белән бер.

**АҢА БИЧУРАЛАРЫ БУЛЫША, АХРЫ.** Мифологиядә аңлатуларга күрә, бичура хуҗасына ияләшсә, аңа яхшылыклар да эшли икән. *Бу йортның хуҗасы нидәндер кинәт кенә баеп китте, аңа бичуралары булыша, ахры* (Сөйләм).

**АҢА ДА КАРАМАСТАН** *к.* алай да. *Фоат абый, йөгергән вакытта аягында авырту сизә башлаган, ләкин, аңа да карамастан, финишка беренче булып килде* (Сөйләм).

Төрдәше: алай да; алай булса да; алайса; шулай булса да; шулай да; шуңа да карамастан.

**АҢА ҖИРНЕҢ ӨСТЕ ДӘ БЕР, АСТЫ ДА БЕР.** Яшәве белән дә, үлеме белән дә хисаплашмый торган куркусыз, үтә кыю кеше хакында. *Бигрәк курку белмәс булып үскән инде, үлемне бар дип тә белми, күрәсең, аңа җирнең өсте дә бер, асты да бер* (Сөйләм).

**АҢА ҖИТӘРГӘ ЕРАК ӘЛЕ.** Ниндидер шәхси сыйфаты, эшкә карашы белән алдын булган

кеше хакында. *Сезгә аңа җитәргә ерак әле, бер пот кына түгел, бәлкем, ике пот тоз ашарга кирәктер* (Сөйләм). *Ләкин миңа аңа җитәргә ерак әле, аның кадәр булдыра алмыйм, мин оялчанрак* («Кәеф ничек?» газ.).

**АҢА КАЛГАН.** Кулыннан килмәгән эшкә тотынучыдан көлеп әйтелә. *Касыймның осталар ярышында катнашачагын ишеткәч, аңа калган тагы, дип, бертавыштан каршы төштеләр* (Сөйләм).
Төрдәше: аңа тагын.

**АҢА КАЛГАН КӨН ЮК.** «Дөнья, эш аңа терәлмәгән, бәйләнмәгән» мәгънәсендә. *Байтирәк хәерчеләренә калган көн юк әле* (Г. Бәширов). *Малайларның икесе дә бертавыштан, мин түгел, диде; кияве эре генә, аңа калган көнем юк, дип җаваплады* (Ә. Әминов. Танкист).

**АҢА КАЛСА.** 1. Эш алайга китсә, терәлсә. *Аңа калса, без дә хәерче арбасыннан төшеп калган шөшле-мазар түгел, урысның «нет» белән «нельзя» дигәнен генә аңлыйбыз бит инде* (В. Имамов. Тозлы яра).

2. Аныңча, аның уенча. *Аңа калса, Яңгура нәкъ менә шулай гына сөйләргә, шулай гына әйтергә тиеш иде* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).
Төрдәше: аңа китсә.

**АҢА КАРАП.** Ул сәбәптән генә, алай булуга яки шулай иткәнгә карап кына. *Аңа карап, аларның язмышлары җиңеләйми* (К. Нәҗми). *Билгеле, аңа карап, бер укытучы да тел генә укытмады, тел белән әдәбият мөмкин булган кадәр бергә алып барыла иде* (Б. Рәхимова. Бакый сагыш).

**АҢА КИТСӘ** *к.* алайга китсә; әгәр эш алайга әйләнсә. *[Сәкинә] Аңа китсә, акчаны да урлап була* (Г. Каюмов. Упкын өстендә уен...).
Төрдәше: алайга китсә; аңа калса.

**АҢА КӨН ДӘ БӘЙРӘМ, <КӨН ДӘ ТУЙ>.** Ваемсызлык. – *Күршедән үрнәк алма син, аңа көн дә бәйрәм, көн дә туй* (Сөйләм).

**АҢА КҮРӘ.** 1. Аның фикеренчә, аныңча. *Аңа күрә, алар хакында бер фикер бәян итә алырбыз дип уйлыйм* («Гасырлар авазы» ж.).

2. Нәрсәгә булса да таянып, шуннан үрнәк алып. – *Кайсы мәмләкәттә була торган нәрсә булса, аңа күрә гамәл кылырмыз, – диде* (К. Насыйри, Әбүгалисина кыйссасы).

**АҢА НӘРСӘ БУЛСЫН!** «Шикләнерлек, шөбһәләнерлек бер сәбәп тә юк» мәгънәсендә. *Исән микән ул хатын? Хәер, аңа нәрсә булсын* (Ф. Яхин. Август ае). *Бу уй Фирәзәне айнытып җибәрде: – Юләр, и-и, юләр дә соң инде мин. Аңа нәрсә булсын, мин исән-сау, сәламәтләгемә зарланмыйм* (Г. Үзиле. Гыйфрит).

**АҢА НИГӘ БАЛТА (КҮСӘК) КҮТӘРӘСЕҢ.** Берәр нәрсә сораганга җавап итеп тупас кычкырган кешегә каршы әйтелә. – *Аңа нигә күсәк күтәрәсең, тыныч кына әйтеп булмыймыни?* (Сөйләм).

**АҢА НИГӘ ҮТЕҢ СЫТЫЛА (СЫТЫЛЫП БАРА).** Кеше эшенә тыгылып, аның уңышын күреп, зәһәрен чәчеп утыручыга карата. *Аңа нигә үтең сытыла, әллә үзеңнең эшләп карыйсың киләме?* (Сөйләм).

**АҢА НИГӘ <БИК> ЭЧЕҢ КҮБӘ (ЕРТЫЛА; КӨЯ; ПОША).** Берәр эш хакында урынсыз төпченү, һәрчак шуңа әйләнеп кайтуга бәйле әйтелә. *Аңа нигә бик эчең поша, синең келәтеңне тикшермиләр бит* (Сөйләм).

**АҢА ПЕШКӘН ДӘ СОСКАН (ТӨШКӘН) БУЛСЫН.** Әзерне генә көтеп ятучы әрәмтамак хакында. *Белмисеңмени, аңа пешкән дә соскан булсын, тутырып сал ашыңны* (Сөйләм).
Төрдәше: аныкка танык <булу (булып тору)> 1 һ.б.

**АҢА<Р> СЕБЕР<ЕҢ> НИ, СЕМБЕР НИ.** Бернинди аерма юк, барыбер– тәвәккәлләп яки башбаштакланып закон бозучылар хакында. *Шундый карчык ул, / Аңар Себерең ни, Сембер ни!* (Г. Тукай).

**АҢА ТАГЫН** *к.* аңа калган. *[Кәрим] Берәү булса, әллә кайчан фатир алган булыр иде инде. [Гөлсинә] Алыр. Аңа тагын* (Г. Каюмов. Упкын өстендә уен).
Төрдәше: аңа калган.

**АҢА ҮГЕЗ САУ ДА СӨТ БИР.** «Бернигә дә карамастан, чыгар да бир» мәгънәсендә. – *Иртә дими, кич дими, аңа үгез сау да сөт бир* (Сөйләм).
Төрдәше: үгез савып сөт бир, арба ватып утын бир.

**АҢА ҺӘММӘСЕ ДӘ «КЫРЫККАН» ИНДЕ.** Сүзен бирмәс өчен, акны кара дип әйтеп, үлгәнче каршы торган кеше хакында. *Күбрәк ышан аның сүзенә, аңа һәммәсе дә «кырыккан» инде* (Сөйләм).

**АҢА ЧЫККАН.** Аңа тиң булган. *Йөгерүдә, суда йөзүдә дә аңа чыккан кеше юк* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр).

**АҢА ЭШЕҢ ТӨШМӘСЕН.** Ярдәмчел булмаган кеше хакында. – *Тагын барырга уйлыйсыңмы, берничә мәртәбә очрашып инандың бит инде – сөйләшүен матур сөйләшә, ләкин аңа эшең төшмәсен* (Сөйләм).

*АҢА-МОҢА* ❖ **АҢА-МОҢА КАРАМАСТАН (КАРАМЫЙ<ЧА>).** Кыенлыкларны җиңеп, һичнәрсәгә карамыйча. *Әбу-Талиха, аңа-моңа карамастан, аны җәясенә корды, шунда кураны ук итеп очырды* (Ф. Яхин. Пәйгамбәребез Мөхәммәд).

*АҢАР* ❖ **АҢАР КАРАП КОЯШ ТА ТОТЫЛМАС, ҖИР ДӘ СЕЛКЕНМӘС.** Бик каты куркытырга маташучы, зур шау-шу кубарырга азаплanучы хакында. – *Тыныч бул сана, котырсын, аңар карап кояш та тотылмас, җир дә селкенмәс* (Сөйләм).

**АҢАР ЧЫГАР ДА САЛ БУЛСЫН.** Әзергә генә яшәргә күнеккән кеше турында. *Туйдырды инде ул мине, бармагын да селкетми, аңар чыгар да сал гына булсын* (Сөйләм).

Төрдәше: аныкка танык <булу (булып тору)> 1 һ.б.

*АҢАРДА* ❖ **АҢАРДА ЕЛАН МӨГЕЗЕ ДӘ БАР** *к.* алдында пылавы, йөрергә олавы. *Әйтсәм ышанмассың – аңарда елан мөгезе дә бар* (Сөйләм).

Төрдәше: алдында пылавы, йөрергә олавы.

*АҢАРДАН* ❖ **АҢАРДАН АКЧА СОРАУ – ҮГЕЗ САВУ БЕЛӘН БЕР.** Саран кешедән акча сорауның никадәр авыр икәнлегенә ишарә. – *Йә, йә, бар кереп кара, аңардан акча сорау – үгез саву белән бер* (Сөйләм).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**АҢАРДАН ЕРАГРАК КИТӘ ТӨШСӘҢ, АЛЛАГА ЯКЫНРАК БУЛЫРСЫҢ.** «Начар кешедән ерактарак булуың мәслихәт» мәгънәсендә. *Аның янында бик күп булырга тырышма, аңардан ераграк китә төшсәң, Аллага якынрак булырсың, дигәннәр картлар* (Сөйләм).

Төрдәше: Алла каберен якын итмәсен һ.б.

**АҢАРДАН КЫШЫН КАР СОРАП АЛА АЛМАССЫҢ** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. *Аның турында бик яхшы фикердә икәнсең, әлеләсеңме: аңардан кышын кар сорап ала алмассың* (Сөйләм).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**АҢАРДАН СӨТ ТӘ ЮК, ЙОН ДА ЮК.** Берниди файдасы юк. *Йөри шунда селкенеп, юкны бушка уздырып – аннан сөт тә юк, йон да юк* (Сөйләм).

Төрдәше: адәм дисәң – коны (сыны; юне) юк, хайван дисәң – йоны юк һ.б.

**АҢАРДАН СОРАП ТОМАУ ДА АЛА АЛМАССЫҢ** *к.* алырсың шайтаннан иман 1. – *Кеше көлдермә, аңардан бурычка акча түгел, сорап томау да ала алмассың* (Сөйләм).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

*АҢАРЧЫ* ❖ **АҢАРЧЫ ТИГЕЗ ҖИРЛӘР ТҮМГӘККӘ ӘЙЛӘНЕР ӘЛЕ.** «Бик ерак киләчәк турында уйлама, мәңгелек бернәрсә дә юк, барысы да үзгәрә» мәгънәсендә. *Без иртәгә нәрсә булачагын белмибез, ә син күз күрмәгән, колак ишетмәгән киләчәк турында сүз йөртәсең – аңарчы тигез җирләр түмгәккә әйләнер әле* (Сөйләм).

*АҢГА* ❖ **АҢГА АК НУР ҖЫЮ.** Белем алу. *Мулла абзый гавамны, шул исәптән Бәһрәмиянең үзен якты чырай белән каршы ала, аңнарына ак нур җыярга теләгән өчен мактый һәм үсендерә* (Ә. Баянов).

**АҢГА БАРЫП ИРЕШҮ.** Берәр нәрсәне аңлый башлау. *Соңыннан аңына барып ирешә: чынлап та өчәүләп йөргәннәре юк икән бит!* (Г. Гыйльманов. Исемең ничек, Гадел?).

Төрдәше: акылга килү һ.б.

**АҢГА ЗЫЯН КИЛҮ** *к.* акыл баштан китү (чыгу) 1. – *И-и, бала-бала,– диде ана кеше, тәмам рәнҗүле гаҗиз төстә авыр сулап. – Аңыңа зыян килгән, ахрысы?* (Х. Камалов. Үксезләр).

Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.

**АҢГА КАЙТУ** *к.* аң җыю. *Шымчы Малай иң башлап аңына кайта һәм, чалбар кесәсен-*

*нән пәке алып, Бурнашка ташлана, Хәстәрче аны тотып алмакчы була, теге җәһәт читкә тайпыла* (М. Хуҗин. Качаклар). *Хәзер килеп, аңыбызга кайтыйк кире, / Һәр төбәктә шаулап үссен татар теле, / Үссен, ныгысын, көч җыйсын татар иле* (З. Мурсиев. Солтанъяр).
Төрдәше: акылга килү һ.б.

**АҢГА КЕРТҮ.** 1. Тормыш серләренә төшендерү. *Шулай ук кереш өлештән соң Ш. Мәрҗанинның тормыш юлын, аның татар иҗтимагый аңына керткән өлеше, татар мәгърифәтчесенең хезмәтләренә багышланган бер төркем чыгышлар яңгырады* («Безнең мирас» ж.). *Аны [тәҗрибәле, җаваплы кешене] югалту гына җиңел, кабат тәрбияләү, аңга кертү искиткеч кыен эш* («Татар язучылары» порталы).

2. Бераз тәнкыйтьләп (яки суккалап) акылга утырту. *Ә инде толерант булыйк дип, безгә акыл сатасы юк, каныбызга сеңгән, аны башкаларның аңына кертәсе иде* («Безнең гәҗит» газ.).
Төрдәше: акыл бирү 1 һ.б.

**АҢГА КИЛӘ АЛМАУ.** *Авыру ара-тирә ыңгырашкалый, әмма һаман да аңына килә алмый иде әле* (Г. Бәширов). *Гыймайның исе-акылы киткән, аңына килә алмый хәйран итеп йөргән* <…> (Ф. Яхин. Бар бер авыл, Чокал, диләр...).

**АҢГА КИЛҮ.** 1. *к.* акылга килү. *Ярый әле, егетләр тиз үк аңга килделәр, менеп йөгерешә башладылар* (Х. Ширмән. Ерактагы йолдызым). *Җылы өйдә аңыма килдем* (Р. Зәйдулла. Мәгарә).
Төрдәше: акылга килү һ.б.

2. Нинди хәлгә эләгүе турында фикер йөртә башлау. *Ул аңына килгәнче, яңадан сыбызгы тавышы яңгырады, һәм тагын бер түшәк су аның өстенә шуып төште* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары). *Иң башлап Сәйферан аңына килде* (М. Хуҗин. Куларада кәлтә уйный).

3. *к* акыл бирү 3. *Тиз арада табибны чакырып алып, башына кигән оекны салдырып, салкын су белән битен югач, 20–22 яшьләрдәге ират аңына килә* (А. Нәҗми. Казан).
Төрдәше: акыл бирү 3 һ.б.

**АҢГА КИТЕРҮ.** Фикерли, уйлый алырлык сәләтенә кайтару. *Күрәсең, мине аңга китерер өчен, күп тырышканнар* (Г. Әпсәләмов. Миңа унтугыз яшь иде). *Аңа су бөркеп аңына китерделәр* (Н. Гыйматдинова. Кыргый).
Төрдәше: акылга килү һ.б.

**АҢГА СЕҢДЕРҮ** *к.* акыл аша уздыру. *Берьюлы аңга сеңдерү авыр булган нәрсәләр торабара гына беркадәр ачыклана башлады* (Г. Әпсәләмов. Агыла болыт). *Башына кинәт китереп суккан бу хәлне ничектер аңга сеңдерергә, аңларга һәм балта белән чапкандай өзгәләнеп, чәбәләнеп беткән уйларының бер очын табарга, шуңа тотынырга кирәк иде* (Х. Камалов. Безне өйдә көтәләр).
Төрдәше: акыл аша уздыру һ.б.

**АҢГА СЫЙМАСЛЫК** *к.* акыл сыйдыра алмау (сыйдырмау). *Шунда кинәт болар тыныч телгә күчте һәм Мәҗитнең аңына да сыймаслык тәкъдим ясап ташладылар* (З. Мурсиев. Бүре шәһәре).
Төрдәше: акыл сыйдыра алмау (сыйдырмау) һ.б.

*АҢГЫ-МИҢГЕ* ❖ **АҢГЫ-МИҢГЕ БУЛЫП ТОРУ.** Тирә-якны тоя, аңлый алмый торган хәлдә калу. *Һавага чыккач та, озак кына аңгы-миңге булып торды ул* (Р. Зәйдулла. Кыз-хатын).

**АҢГЫ-МИҢГЕ БУЛУ (КИЛЕП; ҮТКӘРҮ; ХӘЛДӘ; ХАЛӘТТӘ).** Һични уйлый алмаслык хәлгә килү. *[Сары сакал] Төне буена клубта утыралар да аннан ары көн буена аңгымиңге килеп йөриләр* (Г. Камал. Безнең шәһәрнең серләре). *Төнне аңгы-миңге үткәргән Маһинур, улкаен юып кәфенләгән-чалмалаган вакытта да, шулай ук ушсыз булып утырып торды* (И. Иксанова. Балан чәчәге).

*АҢГЫРА* ❖ **АҢГЫРА БАШ<ЛЫ>.** Кимсетү өчен әйтелгән сүзләр (ачык авыз; томана һ.б.). – *Аңгыра баш булмасалар, ник шуны аңламыйлар?* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). – *Минә нәрсә, аңгыра баш, малай актыгы, халык дошманы,* – *диде ул миңа.* – *Бу китапны мин үзебезгә алып кайтып куям. Бер кешегә дә ләммим әйтәсе булма* (Г. Үзиле. Ленин, Дарья Петровна, мин һәм башкалар).
Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.

**АҢГЫРА БӘЛӘК (БӘЛЕШ; БӘРӘН; БОЗАУ; КҮКЕ; САРЫК; ТАВЫК; ЯБАЛАК)** *к.* аңгыра баш<лы>. *[Нуретдин] Минә шашкан аңгыра тавык!* (К. Тинчурин. Җилкәнсезләр).

*[Мөгълифә] Әй, аңгыра ябалак, матур булмагач, мин сиңа китерәмме соң аны* (Г. Камал. Уйнаш). *Шул, аңгыра сарык, күзле бүкән кебек башта миңа игътибар итмәгән булды* (Ф. Шәфигуллин).
Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.

**АҢГЫРА КАТЫК** *мыск.* Оеткысыз яки оеткы кулланып та начар оеган катык (иләс-миләс йөргән кеше турында). *Төшенде Исмәгыйль. Ул аңгыра катык булып йөри икән ич!* (Ә. Хәсәнов. Исемнәре Исмәгыйль).

**АҢГЫРА КҮКЕ<ЛӘНҮ>** *көл.* Кайбер кешеләрнең ялгызлыктан аңгыраулануларын күке кебек ялгыз яшәүдән күрүләре. *Ятам – сыңар, торсам – сыңар, аңгыра күкедәй, кая барсаң – анда берүзең!* (Г. Бәширов). *Нишләгәнен үзе дә белми аптырап, аңгыраеп йөри торган кешеләрдән көлеп, «тиле кәккүк, аңгыра күке (аңгыра күкеләнү)» дию очрый* («Фәнни Татарстан» ж.).

**АҢГЫРА САРЫК БӘРӘНЕ** *мыск.* Күбрәк үсмерләрне мыскыллау өчен кулланыла. – *Белдеңме? Ишеттеңме, аңгыра сарык бәрәне! Ишеттеңме, дим?! – диде ул* (Г. Үзиле. Ленин, Дарья Петровна, мин һәм башкалар).

*АҢГЫРАНЫҢ* ❖ **АҢГЫРАНЫҢ ДА АҢГЫРАСЫ.** Тулысынча аңгыра, тиле. – *Аңгыраның аңгырасы инде. Аңгыраның үсеш перспективасы зур булгач сөенечтер дә, бәя үсүе алай ук куанычлы хәл түгел шул!* («Матбугат.ру» порталы).
Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.

*АҢКЫ-ТИҢКЕ* ❖ **АҢКЫ-ТИҢКЕ ЙӨРҮ.** Йокылыуяулы бер хәлдә булып, төзек йөри алмау. *Истән чыкмый шашып яратудан / Аңкы-тиңке йөргән чакларым* (И. Гыйләҗев. Хәерлегә юрыйк).

*АҢЛАВЫН* ❖ **АҢЛАВЫН АҢЛАДЫМ, ТӨШЕНӘСЕ ГЕНӘ БАР (ТӨШЕНӘ ГЕНӘ АЛМАДЫМ).** Шаяртып әйтү. «Аңлап җиткермәдем» мәгънәсендә. *Аңлавын аңладым, төшенә генә алмадым* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).

*АҢЛАТМА* ❖ **АҢЛАТМА БИРҮ** *к.* изах итү (кылу). *Монысына нинди аңлатма бирәсез?* (А. Хәсәнов. Данәгөл).
Төрдәше: изах итү (кылу) һ.б.

*АҢЛАШЫЛМАУЧЫЛЫК* ❖ **АҢЛАШЫЛМАУЧЫЛЫК ЧЫГУ** *к.* алар арасына кара күләгә яту. *Югары белем бирү институтында ни гомерләр яшьтән ректор булып, анда да галимнәр арасында аңлашылмаучылык чыккан очракларны күп күргән иде ул* (Ф. Яхин. Көзге яңгырга кадәр).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

*АҢНАН* ❖ **АҢНАН ЯЗДЫРУ.** Зиһен эшләү, фикерләү сәләтен югалту. *Якын мираж кебек ерак шатлык бик еш кына аңнан яздыра* (Р. Харис. Кадрия).

**АҢНАН ЯЗУ** *к.* аң китү. – *Матурым, өч мәет була бит хәзер, әзрәк юлга кара инде, – диюемә, артка борылып карады да, авызыннан күбек килеп ятучы кайнешне күреп... аңыннан язды* (И. Кашфразыев. Корт чаккыры).
Төрдәше: аң җую һ.б.

*АҢНЫ* ❖ **АҢНЫ АЧУ.** Аң-белемен, фикерләү дәрәҗәсен үстерү. *Шушы хозурлык аның авышырга җыенган аңын ачты* (М. Хуҗин. Айның нуры сүнгән...).
Төрдәше: акыл җитү һ.б.

**АҢНЫ БУТА<ШТЫР>У (ЧУАЛТУ).** Акылны томаландыру. *Болар малайның җитлекмәгән аңын бутыйлар гына* (А. Тимергалин. Игезәкләр). *Бу хәбәр аның тәмам аңын чуалткан иде* (М. Әмирханов. Тояк эзе).
Төрдәше: акылга былчырак (пычрак) бау салу һ.б.

**АҢНЫ ТОМАЛАУ.** Фикер йөртү сәләте югала башлау. *Йолдыз! Бу серле сүз минем аңымны томалады, кинәт кенә нидер булды* (Х. Ширмән. Ерактагы йолдызым).
Төрдәше: акыл <-га; -дан> җиңеләю 1, 2 һ.б.

*АҢСЫЗ* ❖ **АҢСЫЗ КАЛУ** *к.* аң китү. *Телсез генә түгел, аңсыз калдыра язды аны алдында ачылган табигать дөньясы* (Г. Гыйльманов. Албастылар).
Төрдәше: аң җую һ.б.

**АҢСЫЗ РӘВЕШТӘ.** Гадәткә нигезләнеп, кагыйдә буларак. *Буталуның актык чутына җиткән Гыйззәтуллин бервакыт аңсыз рәвештә клубның ишеген төбенә хәтле ачты да саф һава сулады* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).
Төрдәше: гадәт буенча.

*АҢ-ТАҢ* ❖ **АҢ-ТАҢ БУЛУ (КАЛУ).** Гаҗәпләнүдән аптырап, шаккатып калу. *Куанды ил, канат какты мәләкләр, / Шашып, аң-таң булып, шайтан төкерде* (Дәрдемәнд. Куанды ил...).
Төрдәше: таң калу.

*АҢЫНЧЫ* ❖ **АҢЫНЧЫ БУЛМАУ** *иск.* Ул арада, ул да түгел, ул дигәнче, шул арада һ.б. *Күпме үгетләсә дә, аңынчы булмады, ул авылдан чыгып киткәндә, таң да атмаган иде* (Сөйләм).

*АП* ❖ **АП ИТЕП ТОРУ.** 1. Сагынып көтү, ике куллап каршы алырга әзер тору. *Дәү әнине әйтмим дә инде, ул, оныгым кайчан килер икән, дип, ап итеп тора* (Сөйләм).

2. Нәрсәне дә булса сусап, кабып йотардай сабырсызланып көтү. *Мондый эшкә ап итеп торучы күп була* (И. Рәми). *Балаларны әйтсәк, алар инде, билгеле, табышмак дигәндә ап итеп торалар* (Н. Исәнбәт. Балалар фольклоры).

*АПАК* ❖ **АПАК АБЫСТАЙ.** Олылап эндәшү (гадәттә, әниләре белән бертуган апага балалары һәм кардәшләре эндәшә). *Тумачи җиңгиләр, апак абыстайлар алар – үз кеше* (Г. Камал).

*АП-АК* ❖ **АП-АК БУЛУ.** Куркудан йөздән кан качу, агарып чыгу. *– Йоклый?! – дип кычкырып җибәргәнен Рәфис үзе дә сизми калды. Нәсимәнең йөзе ап-ак булды* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

**АП-АК КАЛУ.** Яхшы исемле булу. *Адәм рәтле генә буйсынып йөргән булса, бәлки, Тахучар да нойон, сәрдәр дәрәҗәсенә чаклы үсеп җитәр, исеме дә оныклары өчен ап-ак калыр иде* (В. Имамов. Карабәк).

*АП-АКНЫ* ❖ **АП-АКНЫ КАП-КАРА ДИП ӘЙТҮ** *к.* акны кара <дип>, караны ак дип әйтү (дию; тану). *– Ап-акны кап-кара дип әйтеп утырма инде, чынлыктан аерылма* (Сөйләм).
Төрдәше: акны кара <дип>, караны ак дип әйтү (дию; тану) һ.б.

*АПАК-ЧАПАК* ❖ **АПАК-ЧАПАК БУЛЫШУ.** Очрашканда-күрешкәндә, куаныч күрсәтеп сөйләшү. *Алар, иске танышлар кебек, апак-чапак булышып торалар иде* (Сөйләм).

*АПАҢ* ❖ **АПАҢ МАТУРМЫ, АПАҢ НИ АТЛЫ.** Берәрсе сыйлап, юк-бар нәрсә күрсәтеп, алдарга маташканда, аңа җавап итеп әйтү яки берәр нәрсәне алмаганда, сүз белән уйнау. Ягъни «шаярма минем белән, алдап утырма, апаңны алсам, җизни диярсең» кебегрәк кисәтеп кую. *[Шкафчы] Апаң булса алам. Апаң матурмы? [Кыз] Йә инде, шаярма, алсаң ал, алмасаң бир кәләпүшләрне* (Г. Камал. Безнең шәһәрнең серләре). *– Карале, бигрәк затлы нәрсә, әллә алып җибәрәсеңме? – Апаң матурмы? Апаң ни атлы?* (Сөйләм).

*АПАРА* ❖ **АПАРА КЕБЕК КАБАРУ.** Тиз ачуы килү. *Бу ачу кисмәктәге апара кебек еллар буе кабарып килгән* («Безнең гәҗит» газ.). *Ул әйбер чынлыкта апара кебек кабара бара һәм аны беркем туктата алмый* («Татар заманы» газ.).
Төрдәше: ачы катык кебек кабару; күркә кебек кабару (кабарыну).

**АПАРА КОРСАК** *мыск.* Зур корсаклы, күп ашаучы кеше. *[Кәрим партиясе] (җырлый). Хафиз киткән ил буена, / Илдән хәер сорарга, / Хафиз бүкән, апара корсак, илдән хәер сорарга* (Г. Камал. Хафизалам, иркәм).
Төрдәше: апара мичкәсе; ач бәбәк; ач бет 1; ач күз<ле>; бирән корсак; бирән тарган; бирәнен йоткан; Габдулла биясе; гөбән корсак 1; гуҗ карын (тамак); гуҗ корсак; дөбрән корсау; кап корсак; мичкә корсак; чүпрә корсак.

**АПАРА МИЧКӘСЕ** *мыск., к.* апара корсак. *Җае чыккан саен «апара мичкәсе» дип кычкыргаласа да, үз иренең бәясен бик яхшы белә иде ул* (Г. Кашапов). *Белмәгән, белмәгән Фәндәрия Мирбатның тымызыклыгын, тып-тын яткан «апара мичкәсе» әнә ничек күпереп чыкты!* («Казан утлары» ж.).
Төрдәше: апара корсак һ.б.

**АПАРА ЧУМАРЫ.** *мыск.* Таркау, булдыксыз кеше. *Һәй, син дә йөргән буласың аяк астында буталып, апара чумары!* (Сөйләм).
Төрдәше: авызындагын алдыру һ.б.

*АП-АЧЫК* ❖ **АП-АЧЫК ЯЛГАН.** Ялган икәнлеге ачыктан-ачык күренеп тору. *Күренеп торган, ап-ачык ялган бит бу!* (Сөйләм).
Төрдәше: чеп-чи ялган.

*АППЕТИТ* ❖ **АППЕТИТ АШАГАНДА КИЛҮ.** Баштагы кечерәк булган уңыштан соң тагын зурракка омтылу. *Аппетит ашаганда килә дигәндәй, И. Исмәгыйлев татар милләтеннән булган Советлар Союзы Геройлары*

*исемлегенә язмыш авырлыкларын күп татыган генерал-майор Пётр Георгиевич Новиковны да керткән* (Р. Зарипов. Онытылган Алтын Йолдыз иясе).

**АППЕТИТ БУЛМАУ.** Ашарга теләк булмау. *Аппетит булмаса да, якындагы ашханәгә сугылып, тиз генә капкалап килдем* (Ш. Шәйдуллин. Чүлләр буйлап җәяү йөрдем...).

Төрдәше: авыздан аш төшү һ.б.

*АПТЫРАГАН* ❖ **АПТЫРАГАН (ҖӨДӘГӘН / ЙӨДӘГӘН), АРТЫН МИЧКӘ ТЕРӘГӘН.** Кыен чакта үзеңә-үзең тагын кыенлык ясауга карата. *«Аптыраган, йөдәгән, артын мичкә терәгән» дигәндәй, «Жигули»ны шул элекке урынына этеп илтеп куйгач кына, күңел бераз тынычланды* (Ә. Рәшит. Һәркемнең... үз хакыйкате).

**АПТЫРАГАН СӨЛЕК ЮКӘ АГАЧЫН ТЕШЛӘР.** Гаҗизлектән ни эшләргә белмәү. *Аптыраган сөлек юкә агачын тешләр* (К. Насыйри. Мәкальләр һәм әйтемнәр).

**АПТЫРАГАН ҮРДӘК СУГА (КҮЛГӘ) АРТЫ БЕЛӘН ЧУМУ.** Аптыраганнан уйланылмаган гамәлләр башкару. *Аптыраган үрдәк / Арты белән чумган,/ Нидер тели йөрәк,/ Никтер күзләр тонган* (Г. Афзал. Язмыш). *[Җиһанша] О, Тукай ул – Тукай. Сезнең кебек аптыраган үрдәк шикелле, арты белән күлгә чумып йөри торган түгел ул Тукай* (Ә. Фәйзи. Тукай).

**АПТЫРАГАН ҮРДӘК ХӘЛЕНӘ ТӨШҮ.** Нәрсә эшләргә белмәгән торышта калу, аптырау. – *Болай ни дә булса өмет итеп баруым түгел инде, тәк, аптыраган үрдәк хәленә төшкәнгә күрә генә, – ул заман бит минем ише каңгырап йөрүче председательләр күп иде* (Ә. Еники. Әзер хикәя).

Төрдәше: аптырап калу; аптырауга төшү; аптырауда булу; аптырашка калу (төшү); аптырашка салу; аптыраშта калу; бармак тешләү; бармак чәйнәү; баш әйләнү 3; баш буталу; баш кату; башны ташка бәрер (орыр) хәлгә җитү; гаҗәпкә калу; зиһен тар<к>алу (таралып китү; чуалу) 1; каушап калу; коелып төшү; ни эшләргә (әйтергә) белмәү; таң<га> калу; таралып калу; үз-үзеңне югалту; хәйран калу; һуш таралу (китү); югалып калу.

*АПТЫРАГАННАН* ❖ **АПТЫРАГАННАН ГЫНА СУЯМ, КӘҖӘКӘЕМ.** Гаепсез кешеләрне юк итүне аларны артык яратуларыннан дип аңлату. – *Үпкәләмә, аптыраганнан гына сине суйдым, кәҗәкәем* (Сөйләм).

*АПТЫРАП* ❖ **АПТЫРАП КАЛУ.** Каушау, нишләргә белмәү. *Галәметдин, кинәт бирелгән бу сорауга ничек җавап бирергә белмичә, азрак аптырап калды* (Ш. Камал).

Төрдәше: аптыраган үрдәк хәленә төшү һ.б.

*АПТЫРАУГА* ❖ **АПТЫРАУГА КАРШЫ.** Көтелмәгән-уйламаган җирдән. *Минем аптырауга каршы, елмаеп дәште ирем* («Сөембикә» ж.). *Аптыравына каршы, алгы бүлмәдә табын әзерләнгән* (А. Расих).

**АПТЫРАУГА ТӨШҮ** *к.* аптырап калу. *Бу сүзләрдән соң Суфиян, шактый аптырауга төшеп, җилкәсен кашырга тотынды* (Н. Дәүли. Адашкан мәче).

Төрдәше: аптыраган үрдәк хәленә төшү һ.б.

*АПТЫРАУДА* ❖ **АПТЫРАУДА БУЛУ** *к.* аптырап калу. *Синнән мәкер чыкса, / Миңа нәрсә кала? дигәндәй, / Дөнья бүген аптырауда булса – / Туфан күтәрәм күк, йа Ходай!* (Ф. Яхин).

Төрдәше: аптыраган үрдәк хәленә төшү һ.б.

*АПТЫРАШ* ❖ **АПТЫРАШ БЕЛӘН ЙӨДӘШ КЕРГӘННӘР ӨЙДӘШ...** Ике яшь әзерлексез гаилә корганда әйтелә торган сүз. – *Аптыраш белән йөдәш кергәннәр өйдәш... икесе тик шул хәлдә калсыннармы?* (М. Хуҗин. Айның уты сүнгән...).

*АПТЫРАШКА* ❖ **АПТЫРАШКА КАЛУ (ТӨШҮ).**
1. Аптыраган хәлдә булу, гаҗәпсенү. *Һәркем байларның комсызлыкларына аптырашка калды* (М. Гафури). *Иртән уянганда, мине өйдә гадәттән тыш тынлык аптырашка калдырды* (А. Тимергалин. Игезәкләр).
2. Чарасыз булу хәле. *Чатыр эчендә элек Курсыбайда йөзбашы булып йөргән Атлашны да күргәч, Ибраһим шактый тирән аптырашка калды* (В. Имамов. Казан дастаны). *Кәримә, тәмам аптырашка төшеп, ни әйтергә дә белмәде* (Ф. Яхин. Умырзая).

Төрдәше: аптыраган үрдәк хәленә төшү һ.б. (ике мәгънәгә дә карый).

**АПТЫРАШКА САЛУ.** Аптыраган хәлгә кую. *Күренеп тора: Хәйдәр абыйның сүзләре аны тәмам аптырашка салды* (К. Кәримов. Бака каргышы).
Төрдәше: зиһен тар<к>алу (таралып китү; чуалу) 1; каушап калу; коелып төшү; ни эшләргә (әйтергә) белмәү; таралып калу; үз-үзеңне югалту; һуш таралу (китү); югалып калу.

**АПТЫРАШТА БУЛУ** *к.* аптырашка калу (төшү). *Мин җиде көн дәвамында аптырашта булдым: кайдан килгән ул муллык-байлык аларга, нинди яшерен запасларыннан?* (М. Зарипов. «Кара май»ның калҗасы).
Төрдәше: аптыраган үрдәк хәленә төшү һ.б.

**АПТЫРАШТА КАЛДЫРУ** *к.* аптыраган үрдәк хәленә төшү һ.б. *Шул бер минут эчендә күзгә-күз карашның бөтен бер гомер алмаштырмаслык кыйммәте, мәгънәсе Искәндәрне аптырашта калдырып, Гөлфәрваз кулының кулыннан ычкынганлыгын сизмичә, сүзне кайдан башларга аптырап каушап калды* (К. Тинчурин. Искәндәр).
Төрдәше: аптыраган үрдәк хәленә төшү һ.б.

**АПТЫРАШТА КАЛУ** *к.* аптыраган үрдәк хәленә төшү һ.б. – *Берьюлы ике чибәрне күргәч, Инсаф аптырашта калды, – диде ул. – Кайсын сайларга да белми* (М. Миншин. Кызыл диплом).
Төрдәше: аптыраган үрдәк хәленә төшү һ.б.

*АПУШ* ❖ **АПУШ КОРСАК** *хурл.* Күбенгән корсак, күбенүдән мышный торган олы корсаклы кеше. *Аны җиңәчәк чакны / Кемдә көч күп, байдамы? / Апуш корсак, майдамы?* (Г. Камал). *Мәсәлән: күзле бүкән, апуш корсак, җебегән салма, исерек баш <...>.* (Г. Рәхим. Сүгүләр һәм мыскыллы исемнәр).

*АПЫЙ* ❖ **АПЫЙ МУЛЛА** *киная.* Кат-кат киенгән кеше. Казан артындагы Бәрәзкә мулласы кыяфәтеннән телгә кереп калган. *Тәмам Апый мулла булгансың икән!* (Сөйләм).

*АПЫЛЫ* ❖ **АПЫЛЫ ДА КАПЫЛЫ.** Яманлыкта берсе икенчесеннән калышмаган ике дус хакында.

*АПЫН-ТОПЫН* ❖ **АПЫН-ТОПЫН ЙӨРҮ (АТЛАУ; КИЛҮ)** *к.* абын-төбен йөрү (атлау; килү). *Бераздан урам чатыннан безгә таба апын-топын килгән бер кешене шәйләдек* (Сөйләм).
Төрдәше: абын-төбен йөрү (атлау; килү).

*АР* ❖ **АР ЯГЫНА (ЯККА) <БАРЫП> ЧЫГУ.** Чигеннән ашкан, үтә яхшы яки үтә начар булу. *Авызыңда әзрәк хәмер исе сиздеме, дулый да чокырга илтеп тондыра, хайван! Бозылуның ар ягына чыкты* (И. Юзеев). *[I егет] Уку дәверендә ар якка чыккан инде ул* (Ф. Бурнаш. Камали карт).

*АРА* ❖ **АРА АЙКАУ.** Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне бозу, дошманлаштыру. *Ара ки, җаным, кара ки, / Без кигән караларны. / Язгы кар сулары кебек / Айкыйлар араларны* (Җыр).
Төрдәше: ара бозу; ара бутау; арага керү 1; арага салкынлык кертү; арага ут җибәрү (салу); арага чөй кагу; арага шайтан тавы үстерү; араны начарайту; бәхеткә кул сузу; дошманлык салу; дуслыкны җимерү.

**АРА БОЗГА ӘЙЛӘНҮ.** Мөнәсәбәтләр өзелү, дуслык бетү. *Гафифә белән кызның арасы бозга әйләнде* (Ә. Моталлапов. Абыну).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРА БОЗУ.** 1. Дуслыкны бетерү. *Арагызны бозасым килми, Мансур* (Ф. Яруллин. Кызлар күңеле – тирән сер). *Атлы кеше белән ара бозу яхшы түгел, алга таба да яшисе бар* (И. Нәбиуллина. Сыңар канат).
Төрдәше: ара төшү.

2. *к.* ара айкау. *Ходай Тәгаләнең Шәмсениса белән арасын бозасы килмәде, ахрысы* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы). *Бездәй асыл ирләргә шундый юк-бар өчен ара бозу данмыни?* («Казан утлары» ж.).
Төрдәше: ара айкау һ.б.

3. Ызгыш, талаш чыгару. *Талашу, хатынына кул күтәрү, ара бозу түгел иде аның уенда* (Д. Каюмова. Буранлы юллар).

**АРА БОЗ(ЫШТЫР)УЧЫ.** Интригалар, ызгыш-талашлар оештыручы кеше. – *Күршенең ара бозучы икәнен белмисеңмени син?* (Сөйләм).

**АРА БОЗЫЛУ.** Дуслык бетү. *Җегетнең күз алды караңгыланып китте: бер яктан найманнар белән талашу бара;, юлбашчы булган*

*Сарсымбай һәм Калтай атасы Сарыбайлар белән ара бозылачак* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту.

**АРА БОЛГАТУ (БУТАУ)** *к.* ара айкау. *Һәдиянең колагына нык кына киртеп куйыйк, – әгәр сарыкларын әйбәтләп карыйсы урында, ялган таратып ара бутап йөри икән, Нургали абыйдан үзебез сорап, фермадан кудырабыз!* (Ә. Еники. Рәхмәт, иптәшләр). *Белсәң иде, кемнәр икән араны бутаучылар* (Хал. җыры).
Төрдәше: ара айкау һ.б.

**АРА ЕРАГАЮ.** Дуслык бетеп, аралар суыну; читләшү. *Бу вакыйганың нәтиҗәсе беребезгә дә файда китермәде, киресенчә, аралар гына ерагайды* (Сөйләм).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРА ҖЫЛЫНУ.** Дуслык мөнәсәбәләре ныгу. *Әллә табигый йомыкыйлыгы комачаулады, әллә хезмәткәрләр үз итмәде – аралары җылынмады* (К. Кара. Депрессия).
Төрдәше: арага алу.

**АРА КАЛДЫРУ.** 1. Хәрәкәт вакытында билгеле бер араны саклау. *Карый торгач, зур эзләрнең урман ягына таба зур-зур аралар калдырып йөгереп кереп киткәнен күрсәттеләр* (А. Нәҗми. Урмандагы ау).

2. Берәрсе белән дуслык мөнәсәбәтләрендә булмау, ерактарак булырга тырышу. *Кыз бала, белеп торыгыз, бусы инде «Алсу апаң» кызы, сүзгә урын юк, Хәлил абыйсына, теләсә, теләмәсә дә, ике араны калдырырга туры килер* (Х. Вахит. Күк капусы ачылса...).
Төрдәше: ара төзек булмау.

**АРА ӨЗЕК (ӨЗЕЛГӘН)** *к.* алыш-бирешне өзү 1, 2. *Туган теле белән ара өзек, / «Бөек» телдә хутлы сүгенә...* (Р. Зарипов. Әфлисун җиле). *– Аның белән безнең ара өзек хәзер. Берни аңламыйча тын калам* (Ә. Баянов. Декабрьнең уночение көне).
Төрдәше: алыш-бирешне өзү 1, 2.

**АРА ӨЗЕЛҮ.** 1. Якынлык һәм туганлык мөнәсәбәтләре бетү. *Бер-берсеннән бик еракта булсалар да, акбүреләр, казаяклар элегрәк бер-берсе белән аралашып торалар иде. Болгарлар белән ара өзелгәч, алар белән дә өзелде* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).

2. *к.* алар арасына кара күләгә яту. *Тап үзенә тиңне. Безнең ара өзелгән.. Минем гаебем юк* (Г. Гомәр. Гармун теле унике). *Моннан соң килмәсен дә, йөрмәсен дә! Бетте, ара өзелде!..* (Ә. Сәйфуллин. Кешене өмет яшәтә).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРА САЛКЫН БУЛУ** *к.* алар арасына кара күләгә яту. *Җыелмас бер урынга һичвакыт хаклык белән алтын, / Алар бер-берсенә дошман, аларның арасы салкын...* (М. Гафури).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРА САЛКЫНАЮ** *к.* алар арасына кара күләгә яту. *Иренең әбәтне өйгә кайтып ашамавын Рәйсә үзенчә юрады: аларның арасы салкынаю галәмәте түгелме икән ул, янәсе* (Р. Батулла. Юл буенда зәңгәр чәчәк).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРА СУЫНУ (СУЫКЛАНУ)** 1. *к.* алар арасына кара күләгә яту. *Атасы белән арасы суыкланганга күрә, аңардан бер тиен дә акча алмаска тели* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

2. Мәхәббәт сүнү. *Күңел сүрелгән, аралар суынган, үткәннәрне кире кайтару мөмкин түгел* (М. Маликова).

3. Мөнәсәбәтләр начар якка үзгәрү. *Хәтта Асиядан килгән хатларны җавапсыз калдырсам, бүтән язмасам, акрынлап ара суынып, мин аны, ул мине онытыр дип уйлап, хат та язмыйча торып карады* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).

4. Аерылу. *Кайткач, дәгъвалап та йөрде Сәхау. Шуннан аның белән аралар суынып, юллар аерылган иде* (Р. Кәрами. Каргышлы этаплар).

**АРА ТӨЗЕК БУЛМАУ.** Дус, тату булмау. *Нургали белән арабыз төзек түгел* (Т. Гыйззәт). *Ә аралар төзек булмаса, бер-берең өчен борчылу да калмый, кардәшлек рухы да югала* («Яңарыш» газ.).
Төрдәше: ара калдыру.

**АРА ТӨШҮ.** Кемнәрнеңдер дуслыгын бозу. *Әллә мин ара төштем микән / Үлчәү белми чабып, йөгереп?* (К. Булатова).
Төрдәше: ара бозу һ.б.

**АРА ЯКЫН БУЛУ.** Бере белән иптәш, дус булу. *Аралар якын булса да, / Сүзсез бару күңелсез* (Ф. Яруллин. Сорау билгесе).
Төрдәше: ара якынаю.

**АРА ЯКЫНАЮ.** Бер-берeңне аңлый башлау, дуслашып китү һ.б. *Бигрәк тә Мостафа белән аның арасы якынаеп китте* (Ф. Хөсни). *Көннәр җылынган саен, Фәзилә белән Лираның арасы да якынайды, мөнәсәбәтләренә элеккеге җылылык кайтты* (Г. Мирһади. Килмешәк).
Төрдәше: ара якын булу.

*АРАБЫЗДАН* ❖ **АРАБЫЗДАН ҖИЛ КАКМАУ, КАПКАБЫЗДАН ЭТ БАКМАУ.** Үзара тату, тыныч яшәү. *Күршебез белән егерме ел яшәдек, әйтер идем, арабыздан җил какмады, капкабыздан эт бакмады* (Сөйләм).
Төрдәше: алма белән алма кебек яшәү һ.б.

*АРАГА* ❖ **АРАГА АЛУ.** Үз итеп, тиң итеп санау, үз ишләре арасына кертү. *Танымыйлар да түгел, арага алырга, ярдәм итәргә теләмиләр дә түгел* (М. Мөлеков. Халык күңелендә калган моң).
Төрдәше: арага алу; арага басма сузылу; арада «шаян песи» йөрү; арада нечкә җеп сузылу; баш-күз бәйләнү.

**АРАГА БАСМА СУЗЫЛУ.** Дуслык мөнәсәбәтләре урнаштыру. *Лейтенант арага басма сузыламы дип, кызга карады, юк икән, кыз шаярта гына икән* (Х. Камалов. Һәркемнең гомере бер генә).
Төрдәше: арага алу һ.б.

**АРАГА БОТНЫ КЫСТЫРУ.** Кешеләр сөйләшкәндә, тәрбиясезләнеп, килеп кысылу. *[Шәехмирза] Ә син, шәкерт хәлфәсе, ике галим сөйләшкәндә, арага ботыңны кыстырма* (К. Тинчурин. Американ).
Төрдәше: арага керү 4; борын сузу; сүзгә кысылу (тыгылу).

**АРАГА ҖИЛ ДӘ ҮТМӘҮ (КЕРМӘҮ).** Бик якын дус, бик каты гашыйк булу турында. *Алар икенче курста укыган вакытта танышып киткәннәр иде, аннан соң инде араларына җил дә үтмәслек булды* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан-авызга сөйләшү һ.б.

**АРАГА <КАРА> ЕЛАН КЕРҮ (ЯТУ)** *к.* алар арасына кара күләгә яту. *Менә инде шулчакта / Арага елан ята, / Күңелең таштай ката, / Чүкеч алып кем вата?* (В. Хәйдәрова). *Ә асылда, кызы белән кияве арасына кара елан кергәнен күңеле сизгән иде...* (Ф. Абдуллин. Чүл бүресе).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРАГА ЙОЗАК ТАГУ.** Дуслык мөнәсәбәте булмаса да, бер-берсен аңлап, тату яшәү. *«Арабыз бер генә яшь булса да, Шамил минем белән уйнамый иде, – дип елмая Фазыйлә. – Арабазга йозак такса да»* («Сөембикә» ж.). *Арабызга җилләр кертми яшик, / Арабызга йозак такса да* (matbugat.ru).

**АРАГА КАРА МӘЧЕ (ПЕСИ; ШАЙТАН) КЕРҮ (ЯТУ)** *к.* алар арасына кара күләгә яту. – *Арагызга кара мәче кердеме әллә, Шәмсеҗиһан?* (Ф. Шәфигуллин). *Шулар аркасында, шуларның Тотыш атлы юлбасарлары аркасында би кызы әнә чиргә сабышты, атасы белән икесенең арасына кара мачы ятты* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРАГА КАРА ПЕСИ ҖИБӘРҮ.** Ике кеше (халык, гаилә һ.б.) арасын бозу өчен коткы тарату. *<...> халык тикле халыкның изге иманыннан көлеп, шагыйрь үлгәннән соң 76 ел үткәч, аның канынннан керле анализ алалар һәм «Агыйдел» журналында «Милләте, каны ягыннан Тукай башкорт булган икән» дигән сыман бер дә кирәкмәгән ачыәшлар ясыйлар һәм гаепсез халыклар арасына кара песи җибәрәләр, һәм шуннан ары «изгелек»не эшли алмыйлар* (adiplar.belem.ru).
Төрдәше: ара айкау һ.б.

**АРАГА КАРА ТАРАКАН КЕРҮ (БУЛЫП ТӨШҮ).** Ике кеше арасына кереп, комачаулап йөрү. *«Әнис алмалар» әсәрендә күп кенә кайгы-хәсрәтләр күргән Әнис һәм Әнисә мәхәббәтләренә тугрылык саклап көрәшүләре нәтиҗәсендә бергә кавыша, алар арасына кара таракан булып төшкән, кызны мәсхәрәләгән Идмас язмыш тарафыннан җәзалана* (А. Әхмәдуллин. Якты иҗат).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРАГА КЕР ТӨШҮ.** Татулыкта матур гына яшәгән ике кешенең берсенең күңеленә шик керү, татулык бетү. *Гомер иткән саен, бер кеше*

*белән үпкәләшергә туры киләдер вә арага кер төшәдер* (Г. Чыгтай).

**АРАГА КЕРҮ (ТӨШҮ).** 1. *к.* ара айкау. *Син безнең арага кермәкче буласыңмыни?* (М. Фәйзи. Галиябану). *Сезгә, безнең арага керү өчен, бер пот тоз ашарга кирәк* (Д. Салихов. Таш сандык).
Төрдәше: ара айкау һ.б.

2. Сугышкан кешеләрне аралау. *Николай белән Шәрәфи агай да, инде өстәл артыннан чыгып, арага керделәр* (Ш. Камал. Акчарлаклар). *Фәхри бабай, берничә кеше арага төшүгә карамастан, һаман Галимә апа ягына тартыла һәм аны кыйнамакчы була иде* (М. Гафури. Кара йөзләр).
Төрдәше: арага төшү 2.

3. Берәр төркемнең үз кешесе булып китәргә тырышу. *Чит хатын-кызларның безнең арага керүләрен теләмим мин* (А. Шамов).
Төрдәше: арага алу һ.б.

4. Берәр эшкә яки сүзгә тыкшыну. *Якубтан нидер сорамакчы иде ахры, арага Шәрифҗан кереп бүлдерде* (И. Гази).
Төрдәше: арага ботны кыстыру һ.б.

**АРАГА КИРТӘ КОРУ** *к.* алар арасына кара күләгә яту. *Безнең өчен тырышалармы? Тырышалар. Киртә корма син безнең арага* (К. Тинчурин).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРАГА КҮЛӘГӘ ТӨШҮ (ЯТУ)** *к.* алар арасына кара күләгә яту. *Бу яктан алар Гәүһәршад белән су тамчылары кебек охшашканнар: икесе дә дан-шөһрәт ярата, хакимлеккә дәгъва итә. Ихтимал, араларына күләгә ятуның сәбәбе дә шуның белән аңлатыладыр* (М. Әмирханов. Гәүһәршад).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРАГА КЫЛ ДА СЫЙМАУ** *к.* авыздан-авызга сөйләшү. *Белүемчә, кенәз, Витаутас белән сезнең ике арага да кыл сыймый иде* (М. Әмирханов. Ир-Мамай).
Төрдәше: авыздан-авызга сөйләшү һ.б.

**АРАГА КЫЛ ДА СЫЙМЫЙ, БАЛТА САБЫ ДА (БҮРӘНӘ ДӘ) БУШ.** Мөнәсәбәтләр тыштан гына яхшы кебек күренеп, чынлыкта аралары салкын булу. – *Бик тиз нәтиҗә ясарга ашыкма, дөрес, тыштан караганда, арага кыл да сыймый, балта сабы да буш* (Сөйләм).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРАГА КЫРАУ ТӨШҮ** *к.* алар арасына кара күләгә яту. *Бүрәнәләрне ат белән ташу турысында беркөнге сүзгә килешүдән соң болай да араларына кырау төшкән вакытлар иде бу, шуңа күрә Нәби Сәрвәрнең кайтуын аеруча көтеп алган иде* (Р. Төхфәтуллин. Авылдашым Нәби).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРАГА КЫСЫЛУ.** Ике сөйгән яр, ике якын дус арасына тыкшыну, ике кешенең сөйләшкән сүзенә килеп катышу. *Бу юләре дә шул чакта арага килеп кысыла бит!..* (Г. Бәширов). *Араларына кысылмадым! Үзләре хәл итте бит. Йоланта үзе китте!* (М. Хуҗин. Чеметемнән – табышларга...).
Төрдәше: арага ботны кыстыру һ.б.

**АРАГА МЫЛТЫК САЛУ.** Ике кешенең берсе кулга алыну, аерылу. *Арага мылтык салдылар* (Р. Абдуллина. Сөйләм культурасы).

**АРАГА САЛКЫН (СУЫК) ЙӨГЕРҮ (ТӨШҮ).** Кызыксыну кимү, ерагаю, читләшү; *шулай ук к.* алар арасына кара күләгә яту. – *Төрмәдә черетерләр! – диде, шуннан бирле араларына суык йөгерде* (Ф. Яхин. Умырзая).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРАГА САЛКЫНЛЫК КЕРТҮ (ТӨШҮ).** Мөнәсәбәтләрне бозу, дошманлаштыру. *Аңа ничек тә ике яшь арасына салкынлык кертергә кирәк, «Саньканың күңеленә иләслек саласы бар, ә моның өчен дин кануннары иң кулай нәрсә инде* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).
Төрдәше: ара айкау һ.б.

**АРАГА САЛЫП.** Килеп чыккан кыенлыкны, мәсьәләне ачыктан-ачык сөйләшеп, бергәләп хәл итү. *Әдәбият, сәнгать һәм көндәлек яшәеш, сәясәт мәсьәләләрен арага салып сөйләшенгән ул кичәләргә Рәмиевләрнең танышбелешләре генә түгел, шәһәргә килеп чыккан һәр яңа фикер иясе дә катнаша алган* (Л. Хәмидуллин. Офыктагы рәшәләр).
Төрдәше: уртага салып.

**АРАГА САФ ТАРТУ** *иск.* Сугыша торган ике як арасына туры сызык сызу. *[Янгураз] Баба-*

*лардан калган йола: / Мин арага саф тарттым / (Кылычы белән җирне сыза). / Сугышып үләргә булдык без, / Чыксын, бармы батырың?* (Н. Исәнбәт. Түләк).

**АРАГА СҮЗ КЕРҮ.** Ике кеше турында сүз ишеттерү. *Нинди сүз кергәндер араларына – беркем белми* (Л. Фәттахова. Җир астыннан юллар бар...).

**АРАГА ТАРАКАН КЕРҮ.** Арага ят нәрсәләр, ямьсезлекләр керү, татулык бетү, һич кирәкмәгән кеше катышу. *Нәрсә булганын бераү дә белми, ләкин араларына таракан кергән, дип сөйли башладылар* (Сөйләм).

Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б

**АРАГА ТАУ ҮСҮ**. Аралар ерагаю, очрашу, кавышу өчен үтә алмаслык киртәләр хасил булу. *Сак белән Сок күек кавышалмыйсыз, арагызга тау үсте* (Н. Гыйматдинова. Күке төкереге).

**АРАГА ТАЯК ТЫГУ (КЫСТЫРУ)** *к.* ара айкау. *Оппозиция оешмалары татар теле яклы булырга тырышып йөри, татарлар белән урыслар арасына таяк тыкмакчы* («Мәйдан» ж.).

Төрдәше: ара бозу һ.б.

**АРАГА ТӨШҮ.** 1. *к.* ара айкау. – *Юк, малай Вакыйф, арага төшмә инде син* (В. Нуруллин. Ике урам арасы).

Төрдәше: ара айкау һ.б.

2. Сугышкан кешеләрне аерырга тырышу. *Шул арада булмады, Гариф арага төште* (Ш. Камал. Акчарлаклар).

Төрдәше: арага керү 2.

3. Үз араларына кабул итү. *Мин дә, горурлыктан рәхәт чигеп, егетләр-кызлар арасына төштем* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).

Төрдәше: арага алу һ.б.

**АРАГА ТЫГЫЛУ** *к.* арага кысылу. *Эчкәнсең икән, буеңа сеңдер! – дип кызып китте Закиров. – Безнең арага тыгылма* (З. Фәтхетдинов. Ачылган серләр).

Төрдәше: арага кысылу.

**АРАГА УТ ҖИБӘРҮ (САЛУ)** *к.* ара айкау. *Ике хан арасына ут җибәрергә ярамаганын беләләр иде алар, көйрәгән утны ялкынландырып җибәрү аларның икесен тиң кыен хәлгә калдыруы бар иде* (М. Хәбибуллин). *Арага – тоз, арага ут сала дошманнар, корыч булсам да, бер эрер идем...* (С. Сөләйманова).

Төрдәше: ара айкау һ.б.

**АРАГА ЧӨЙ КАГУ (КЫСТЫРУ; СУГУ).** Кешеләрнең мөнәсәбәтен бозу өчен, хәйлә-мәкер эшләү. *Ата белән ул арасына чөй кагып кем нәрсәгә ирешергә тели?..* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).

Төрдәше: ара айкау һ.б.

**АРАГА ШАЙТАН КЕРҮ** *к.* алар арасына кара күләгә яту. *Арага шайтан кереп куймасын* (М. Гафури). *Егетен чын сөйгән кызлар арага шайтан керүдән курыкмый дисеңме?* (М. Фәйзи).

Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРАГА ШАЙТАН ТАВЫ ҮСТЕРҮ** *к.* ара айкау. *Иллә мәгәр, нинди генә ачы хәлләр булмасын, ике арага шайтан тавы үстерергә ярамый* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).

Төрдәше: ара айкау һ.б.

*АРАДА* ❖ **АРАДА БУШЛЫК АЧЫЛУ.** Кешеләрнең аралары бозылу. *Ләкин шул, әлеге уңышсыз «китә башлауның» ачы нәтиҗәсе буларак, аның белән эшчеләр арасында кап-кара бер бушлык ачылды* (Ш. Камал. Козгыннар оясында).

Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРАДА ГЫНА КАЛСЫН.** «Башка кешенең колагына ишетелмәсен, икебез генә белик» мәгънәсендә. *Бу елмаю Ярмөхәммәткә «Дөрес, Ярмөхәммәт, мин синең Алиһәң. Изге серебез ике арада гына калсын» булып аңлашылды* (Р. Батулла. Юл буенда зәңгәр чәчәк).

Төрдәше: ике арада калсын.

**АРАДА КАРА ЕЛАН ЙӨРҮ** *к.* алар арасына кара күләгә яту. – *Мөбахис мәзин белән әти арасында кара елан йөри* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).

Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРАДА КҮЛӘГӘ ЯТУ.** *Ихтимал, араларында күләгә ятуның сәбәбе дә шундадыр* (М. Әмирханов. Гәүһәршад).

Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРАДА НЕЧКӘ ЕФӘК ҖЕП СУЗЫЛУ.** Дуслык мөнәсәбәтләре башлану, дуслашып китү. *Шул ашлык сукканда, эскерт башыннан кочаклашып бергә егылганнан бирле, безнең арада*

*ниндидер бер нечкә ефәк җеп сузылган кебек булды* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр).
Төрдәше: арага алу һ.б.

**АРАДА<Н> САЛКЫН (СУЫК) ҖИЛ ИСҮ** *к.* алар арасына кара күләгә яту. *Тиз генә аңлаша алмаулары сәбәпле, арада салкын җил дә исеп узды шикелле* (Р. Низамиев. Беренче мунча).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРАДА САЛКЫН ҖИЛЛӘР ХАСИЛ БУЛУ.** Дуслык бетү. *Монда якынаерга теләвем дип әйтү дә дөрес түгел, гомумән, араны өзү дигән башыма да кереп чыкмады, ә арадагы салкын җилнең хасил булуы көн кебек иде* (Н. Нәҗми).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРАДА СҮЗ ЧЫКМАУ.** Артык яки гомумән сөйләшмәү. *Каенана белән ике арада артык сүз чыкмады, тик бер генә тапкыр килен үзе сүз башлады* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).
Төрдәше: авыз бикләү һ.б.

**АРАДА ТАШ СТЕНА (БУЛУ).** Дуслык бетү. *– Кызыксынып, әллә өметләнәсеңме? – дип сорадым әле. Юк, хәзер безнең арада таш стена, диде* (Ә. Моталлапов. Мәхшәр).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРАДА ҮЛГӘН МӘЧЕ ЯТУ.** Бер-берсенә салкын мөнәсәбәттә булу, мәңгелеккә дошманлашу. *Гөлүсә авыл советы секретаре янына ярдәм сорап юкка киткән, арада үлгән мәче яткач, уртак тел таба алмас ул* (Сөйләм).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРАДА «ШАЯН ПЕСИ» ЙӨРҮ.** Дуслашып китү, бер-берсен ярата башлау. *Үзенең Кызыл Армиягә киткән улы белән бу кыз арасында «шаян песи» йөргәнлеге, бу ике яшьнең берсен-берсе яратышканлыклары кайчандыр Әсәтнең колагына кереп калган иде, шуның өчен булса кирәк, Әсәт хәйләкәр бер төс белән, әллә кайлардан уратып-уратып һаман сораштырды* (Ф. Хөсни. Үтеп барышлый).
Төрдәше: арага алу һ.б.

*АРАДАН* ❖ **АРАДАН АКСАК ЭТ УЗУ** *к.* алар арасына кара күләгә яту. *Сәлмәннекеләр белән Мәрәк Фәсхи арасыннан кайчандыр аягы капкынга эләккән аксак эт узып киткән икән, бар кешенең дә юлына андый аксак эт очрый дигән закон юктыр ич* (Ф. Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРАДАН АЛЫП КИТҮ.** Кемне булса да бездән аеру. *Мәрхәмәтсез үлем аны моннан ике ел элек – 2005 елның маенда арабыздан алып китте* (Казан утлары, 2007, 8. Гел сагындырачак тәрәзә).

**АРАДАН ЕЛАН УЗУ** *к.* алар арасына ара күләгә яту. *Бәхетем күпкә бармады, / Арадан елан узды* (Г. Садә).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРАДАН ҖИЛ ДӘ ҮТМӘҮ** *к.* авыздан-авызга сөйләшү. *Ничә ел инде күзгә-күз генә карашып торалар, араларыннан җил дә үтми, дип сокланалар иде* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан-авызга сөйләшү һ.б.

**АРАДАН ҖИЛ ҮТМӘСЛЕК** *к.* авыздан-авызга сөйләшү. *Кайчандыр араларыннан җил үтмәслек иде бит, шуны искә алдылар* (Я. Зәнкиев. Өтелгән мәхәббәт).
Төрдәше: авыздан-авызга сөйләшү һ.б.

**АРАДАН ИЯРҮ.** Олауда булган кайбер атларның ат тотучысыз үзләре белеп баруы. *Кайбер атларга атчы да кирәкми, алар үзләре арадан ияраләр* (Сөйләм).

**АРАДАН КАРА МӘЧЕ (ПЕСИ) УЗУ (ҮТҮ; ЧЫГУ)** *к.* алар арасына кара күләгә яту. *Билгеле инде, башта ук безнең арадан йолкыш кара мәче узгач, килешеп, тату гына эшләү мөмкин булмаячак иде* (Ә. Еники. Без дә солдатлар идек). *Патша үз илендәге патриарх Никон белән килешә алмый, алар арасыннан «кара мәче йөгереп үткән»* (М. Мәһдиев. Җир йөзендә алты кыйтга...).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРАДАН КИТҮ** *к.* авыздан җан чыгу. *Шул ук елның декабрь башында оныкларына миһербанлы күршеләренә, авылдашларына хәер-фатыйхасын биреп, арабыздан китеп барды* (В. Гали. Соңгы тамчы күз яше).
Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

**АРАДАН САЛКЫН ҖИЛ ҮТҮ** *к.* ара айкау. *Ләкин башкаларныкы кебек аларның дуслыгы шулай да ант эчүгә, бер-берсенең тәнен җә-*

*рәхәтләп, бер-берсенен канын татуга кадәр барып житмәде. Көтмәгәндә алар арасына салкын җил үтеп керде* (Н. Фәттах. Аклан).
Төрдәше: ара айкау һ.б.

*АРАКЫ* ❖ **АРАКЫ КҮРСӘ, ТАМАГЫН БЕТЛӘР АШАУ.** Эчкечелеккә сабышкан кешенең, аракы күргәндә, тамагы кычыта башлавына ишарә. *Күрше ирнең эчәргә яратканын, аракы күрсә, тамагын бетләр ашаганын да сөйләп бирде* (Сөйләм).

**АРАКЫ МИЧКӘСЕ** *шаярт., мыск.* Эчкече, аракы эчеп исереп йөрүче. *Ә икенчесе – Солодун фамилиялесе – аракы мичкәсе иде инде* (Т. Нәҗмиев. Тагын... Тагын...). *У-у! Элек аракы мичкәсе идем* (Г. Мөхәммәтшин).

*АРАЛАР* ❖ **АРАЛАР ҖЫЛЫНУ.** Мөнәсәбәтләрне яхшырту. *Нишләп газиз туганы белән аралары җылынмый икән?* (Н. Гыйматдинова. Шырагай).

*АРАЛАРЫ* ❖ **АРАЛАРЫ БОЗ БЕЛӘН ТОЗ КЕБЕК.** Бер-берсен ашарлык хәлдә дошман булу турында, *шулай ук к.:* алар арасына кара күләгә яту. *Бер караганда уйламассың да, чынлыкта исә аралары боз белән тоз кебек икән* (Сөйләм).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АРАЛАРЫ ҖЫЛЫНМАУ.** Үзара мөнәсәбәтләрен яхшырта алмау. *Әллә табигый йомыкыйлыгы комачаулады, әллә хезмәткәрләр үз итмәде, аралары җылынмады* (К. Кара. Депрессия).

**АРАЛАРЫ СУЫНУ** *к.* алар арасына кара күләгә яту. *Еллары да үткән саен, аралары суына барды* (К. Кара. Депрессия).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

*АРАЛАРЫН* ❖ **АРАЛАРЫН БОЗУ** *к.* ара айкау. *Тора-бара Гөлчирәнең хас дошманына, көндәшенә әверелде. Араларын бозарга тырышты* (Д. Каюмова. Урланган бәхет).
Төрдәше: ара айкау; ара бозу ( бутау); арага керү 1; арага салкынлык кертү; арага ут җибәрү (салу); арага чөй кагу; арага шайтан тавы үстерү; дошманлык салу; дуслыкны җимерү.

**АРАЛАРЫН СУ БЕЛӘН ДӘ, УТ БЕЛӘН ДӘ АЕРЫП БУЛМАУ** *к.* авыздан-авызга сөйләшү. *– Һич борчылма, дуслыклары бер-ике айлык кына түгел, аларның араларын су белән дә, ут белән дә аерып булмый* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан-авызга сөйләшү һ.б.

*АРАЛАРЫНА* ❖ **АРАЛАРЫНА ҖИЛ ДӘ ҮТМӘҮ (ҮТЕП КЕРӘ АЛМАУ)** *к.* авыздан-авызга сөйләшү. *Араларына җил очып үтеп керә алмас дуслар да хәтта, ни хикмәт, мондый вакытларда кан дошманнарга әвереләләр* (Ф. Яхин. Көзге яңгырга кадәр).
Төрдәше: авыздан-авызга сөйләшү һ.б.

**АРАЛАРЫНА СУ ДА ҮТМӘҮ** *к.* авыздан-авызга сөйләшү. *Бүген аларның араларына су да үтмәс дигән тәэсир калды* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан-авызга сөйләшү һ.б.

**АРАЛАРЫННАН ҖИЛ ДӘ, <СУ ДА> ҮТМӘҮ** *к.* авыздан-авызга сөйләшү. *Алар шулай кулга-кул тотынышып, араларыннан җил дә, су да үтмәячәгенә инанып, шаярышып-көлешеп болын буйлап киттеләр* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан-авызга сөйләшү һ.б.

**АРАЛАРЫННАН ҖИЛ ҮТМӘСЛЕК** *к.* авыздан-авызга сөйләшү. *Кайчандыр араларыннан җил үтмәслек иде бит, шуны искә алдылар* (Я. Зәнкиев. Өтелгән мәхәббәт).
Төрдәше: авыздан-авызга сөйләшү һ.б.

**АРАЛАРЫННАН КЫРАЧ ҖИЛЕ ДӘ ИСМӘҮ (ИСӘРЛЕК ТҮГЕЛ)** *к.* авыздан-авызга сөйләшү. *Араларыннан, кем әйтмешли, кырач җиле, ягъни сырт җиле дә исәрлек түгел* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).
Төрдәше: авыздан-авызга сөйләшү һ.б.

**АРАЛАРЫННАН СУ ДА ҮТМӘҮ** *к.* авыздан-авызга сөйләшү. *Бигрәк тә бер-берсенә тиң килгәннәр инде, араларыннан су да үтмәс* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан-авызга сөйләшү һ.б.

**АРАЛАРЫННАН СУ ДА ҮТМӘС, ҖИЛ ДӘ** *к.* авыздан-авызга сөйләшү. *– Бәхәсләшәсең киләме, юк, мин бәхәсләшеп тә тормыйм, боларның араларыннан су да үтмәс, җил дә* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан-авызга сөйләшү һ.б.

**АРАЛАРЫННАН ЧЕБЕН ДӘ ОЧМАУ** *к.* авыздан-авызга сөйләшү. *– Хәзер андыйлар сирәк, –*

*диде карт, бераз хәсрәтләнеп, – кара, араларыннан чебен дә очмый бит* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан-авызга сөйләшү һ.б.

*АРАН* ❖ **АРАН АВЫЗ.** 1. *к.* авыз җебегән <булу> 1. *– Аран авыз Госманга нигә сөйләдең, аның теле авызына сыймаганын белмисеңмени?* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз җебегән <булу> 1 һ.б.

2. *к.* алты авыз<лы>. *Авылда кичен булган вакыйганы аран авызлар иртүк кырыкка борып тарата башлыйлар* (Сөйләм).
Төрдәше: алты авыз<лы> һ.б.

*АРАНЫ* ❖ **АРАНЫ БОЛГАТУ** *к.* ара айкау. *Тик, кодам Җамалый, / Чамаламый ярамый. / Болгатмасыннар араны, / Сак була күр, кара аны* («Кода белән кодача» җыры).
Төрдәше: ара айкау һ.б.

**АРАНЫ КӨЙЛӘҮ.** Мөнәсәбәтләрне яхшырту. *– Һәшия, җә инде, араны көйлик, бозылышмыйк* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: араны ныгыту.

**АРАНЫ НАЧАРАЙТУ** *к* ара айкау. *Араны начарайтырга теләмәде* (Х. Камалов).
Төрдәше: ара айкау һ.б.

**АРАНЫ НЫГЫТУ** *к.* араны көйләү. *Мәскәү белән дустанә яшәү – бик тә мөһим сәясәт, хан, әмма ут күршеләремез нугайлар илә араны ныгыту – иң олы вазгыятьләрнең берсе* (Р. Батулла. Иреккә чыгасы уйлар).
Төрдәше: араны көйләү.

**АРАНЫ ӨЗЕЛДЕГӘ САНАУ.** Мөнәсәбәтләр өзелү; аерылу. *Шуның белән бүгенге араны өзелдегә санап, тиз генә китеп тә барды* (Ф. Хөсни).
Төрдәше: ара бозылу һ.б.

**АРАНЫ ӨЗҮ.** 1. Кем белән булса да булган мөнәсәбәтләрне туктату. *Монда якынаерга теләвем, дип әйтү дә дөрес түгел, гомумән, араны өзү дигән башыма да кереп чыкмады, ә арадагы салкын җилнең хасил булуы көн кебек иде* (Н. Нәҗми). *Дөрес сөйлиме Шәмсия? Әллә Мостафа белән җаннары бер егет җитмәгәнне аңлап, шушы сәбәп белән араны өзү, өйдән чыгып китү җаен карыймы?* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).
Төрдәше: араны начарайту һ.б.

2. Бурычларны түләп бетерү. *Җәүдәт бүгеннән калмый бу егетләр белән араны өзү турында уйласа, болар, киресенчә, бүгеннән калмый бу тәти, җебегән салманың аягына ныклы богау салуны планлаштырганнар иде* (А. Гыйләҗев).

**АРАНЫ САЛКЫНАЙТУ** *к.* араны начарайту. *Бу нәрсә май янына килеп кушылды да, җизни белән безнең араны тагын да салкынайта төште* (Ф. Хөсни. Без ни өчен беренче җизнидән биздек?).
Төрдәше: араны начарайту һ.б.

**АРАНЫ СУЫТУ** *к.* араны начарайту. *Шулай да безнең аерым яшәү ничектер араларны суыта башлаган шикелле тоела* (Ш. Маннур. Агымсуларга карап). *Сәгыйдулласы үлгәндә әйтте: «Карчыккаем, – диде, – берүк туганнар белән араны суытма, балалар аралашып үссеннәр», – диде* (Ф. Садриев. Таң җиле).
Төрдәше: араны начарайту һ.б.

*АРАСЫ* ❖ **АРАСЫ ҖИР БЕЛӘН КҮК КЕБЕК (АРАСЫ КАДӘР).** Бер-берсеннән бик нык аерылып тору, бер-берсенә бөтенләй охшамау. *[Наил] Күрше белән күрше арасы җир белән күк арасы кадәр икән!* (А. Гыйләҗев). *Күз белән колак арасы дүрт бармак иңе генә, ә күргән белән ишеткәннең арасы җир белән күкнеке кадәр* («Казан утлары» ж.).

**АРАСЫ ТАЯК ТАШЛАМ.** Бик якын. *Син анда бик тиз барып җитәрсең, арасы таяк ташлам гына* (Сөйләм).
Төрдәше: бер адым; борын төбендә; кул сузымы.

*АРАЧЫГА* ❖ **АРАЧЫГА АЛТЫ ТАЯК.** Кемнәрнең булса да араларына керүчегә күбрәк кыен төшүне аңлата. *– Ире белән хатыны ызгышканда, араларына кермиләр, арачыга алты таяк төшәр, диләр* (Сөйләм).

*АРБА* ❖ **АРБА АРТЫНА ТАГЫЛГАН ДЕГЕТ ЧИЛӘГЕ.** Ияреп, тагылып йөри торган. *Әмма бүген бер чараң юк, Илтотмыш хан олуг бәккә санап туйга дәшә икән, син арба артына тагылган деген чиләге түгел дигән сүз бу, юлга җыен инде, Карабәк – Габдулла хан...* (В. Имамов. Карабәк).
Төрдәше: арбага таккан деген чиләге.

**АРБА БЕЛӘН КУЯН КУУ (ТОТУ).** Гаделсез, ярамаган яки кирәксез бер эш эшләү – бер кеч-

кенә максат өчен зур чаралар оештырып, зур чыгымнар чыгарып йөрү. *Бу хәл теге арба белән куян куу кебегрәк килеп чыгачак инде. Ләкин кем белә тагы!* (А. Расих. Каһарманнар юлы). *Юньсез сунарчы арба белән куян тотар* (Ай колакланса ни була? 2 нче кит.)

Төрдәше: ат белән чыпчык куу.

**АРБА ВАТЫЛСА – УТЫН, ҮГЕЗ ҮЛСӘ – ИТ!** Пошынмас кешенең ваемсызлыгы турында. *Булат бәк өчен арба ватылса – утын, үгез үлсә – ит иде. Казанлылар белән кырымлылар никадәр генә батыр атышмасын, Казан җиңеләчәк, Иван бөтен илне басып алачак* (Р. Батулла. Сөембикә).

Төрдәше: арба ватылса – утын, үгез үлсә – ит һ.б.

**АРБА ВАТЫП УТЫН БИР.** «Хәзер үк табып бир» мәгънәсендә. – *Миңа ашыгыч рәвештә кирәк иде, әйдә, арба ватып утын бир* (Сөйләм).

Төрдәше: үгез савып сөт бир, арба ватып утын бир; үгез сау да сөт бир.

**АРБА ДА ТҮГЕЛ, ЧАНА ДА ТҮГЕЛ.** Көзнең җир өсте катып аяк батмый торган чагы. *Хәзер инде «арба да түгел, чана да түгел». Арба җиксәң тәгәрәми, чана җиксәң шумый* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**АРБА САКЛАСЫН, ТРАМВАЙ БАСМАСЫН.** «Алай булма күрмәсен» мәгънәсендә. *[Фазыл] Бетте, бетте. Арба сакласын, трамвай басмасын, кызып китә күрмә* (Г. Кутуй. Шатлык җыры).

**АРБА ТӨБЕННӘН ТӨШЕП КАЛГАН.** Кем икәнен белүе читен кеше турында. *Аның белән исәнләшәләр икән, димәк ки, ул тишек арба төбеннән төшеп калганнардан түгел* (С. Поварисов. Пәйгамбәр таңы).

Төрдәше: арбадан төшеп калган.

*АРБАГА* ❖ **АРБАГА БИШЕНЧЕ ТӘГӘРМӘЧ ТАГУ.** Кирәк булмаган, артык эш эшләү. – *Син нәрсә, малай, арбага бишенче тәгәрмәч тактың?* (Н. Гыйматдинова. Алан уртасында ялгыз йорт).

**АРБАГА ТАККАН ДЕГЕТ ЧИЛӘГЕ (ЛАГУНЫ)** *к.* арба артына тагылган дегет чиләге. – *Авыл мужигы – арбага таккан дегет лагуны, – диде әти* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). – *Берәр батальонына сыла мине, Мәхмүт галиҗәнаплары, тик арбага таккан дегет чиләге итеп түгел, бәлки...* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

Төрдәше: арба артына тагылган дегет чиләге.

**АРБАГА ТАККАЧ, ДЕГЕТ ЛАГУНЫ ДА ЙӨРИ.** Кирәклеге булса да, пычрагы йогудан куркып, кадерсез булу турында (ияреп, тагылдык булып кына йөри). *Арбага таккач, дегет чиләге йөри бит, мин дә нәкъ шуның кебек инде. Ят дисәләр – ятам, тор дисәләр – торам* (М. Әмирханов. И кылган догам минем).

Төрдәше: арбага таккач, дегет чиләге дә хаҗга бара.

**АРБАГА ТАККАЧ, ДЕГЕТ ЧИЛӘГЕ ДӘ ХАҖГА БАРА** *к.* арбага таккач, дегет лагуны да йөри. *Татар фольклорында «Арбага таккач, дегет чиләге дә хаҗга бара» дигән мәкаль бар* (Л. Җамалетдинов. Татар әкиятләрен барлау юлында).

Төрдәше: арбага таккач, дегет лагуны да йөри.

**АРБАГА УТЫРУ.** Кемгә булса да ияреп, аның фикер-гамәленә тулысынча буйсыну. *[Миңлегаян] Син, шәкерт энем, егет кеше буласың килсә, минем арбага утыр* (К. Тинчурин. Зәңгәр шәл). *Сабит арбасына утырып җырлый башлаган Нәҗип шул мизгелдә үзен үтәли күрде!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: арбасына утыру һ.б.

*АРБАГАЙ* ❖ **АРБАГАЙ ДА ТЫРБАГАЙ.** Төрле якка тырпаеп, кабарып торган нәрсә. *Капчык төбенә арбагай да тырбагай яткан озынча нәрсәләр күренә иде* (Сөйләм).

*АРБАДАН* ❖ **АРБАДАН ТӨШЕП КАЛГАН.** 1. Җәмгытьтәге дәрәҗәсе төшү, абруе югалу. *Шаһимәрдан алай ук арбадан төшеп калганнардан түгел иде* (Ф. Яхин. Ат урлауның ние бар…). – *Егетнең үзенә дә әйттем, дөньялар ничек кенә болганса да, барыбер безнең нәсел арбадан төшеп калмады, иҗтиһад иттек* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).

2. Берәүнең кем икәнлеген белә алмаганда әйтелә. – *Бәләкәй чакта без анын наменнән дә, төпчек булуыннан да «арбадан төшеп калган, арбадан» дип кенә көлә идек* (В. Имамов. Утлы дала).

*АРБАНЫҢ* ❖ **АРБАНЫҢ БИШЕНЧЕ КӨПЧӘГЕ (ТӘГӘРМӘЧЕ).** 1. Бернәрсәгә дә кирәк

булмаган артык әйбер яки кеше. *Ничек каршы алырлар, ничек карарлар миңа, ят халык арасында арбаның бишенче тәгәрмәчедәй буталып кына йөрергә туры килмәсме?* (Ә. Еники. Җиз кыңгырау). *Мудрый шулай дип әйтеп өлгерүгә, Наилә тагын җылап җибәрде. «Мин – арбаның бишенче тәгәрмәче. Кирәгем шулхәтле генә»* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: бишенче көпчәк (тәгәрмәч) һ.б.

2. Картайганчы өйләнмәгән кеше, буйдак. – *Гомереӊ буена фәрештә кияве, арбаның бишенче көпчәге булып яшәдеӊ шунда, гаиләң дә юк, су бирер кешең дә юк* (Сөйләм).

**АРБАНЫҢ КҮЧӘР БАШЫН ҮБҮ.** Берәрсе янында куштанлану, аның тирәсендә сырпалану, ярарга тырышу. – *Арбаның күчәр башын үбәргә яраткан кешене тиз генә үзгәртә алмассың аны* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга бал да май булып керү һ.б.

**АРБАНЫҢ ТӨБЕ ЮК, АЛЛАНЫҢ (БӘНДӘНЕҢ) КЕМЕ ЮК.** Нәселе, милләте кемлеге беленмәгән кеше турында сораганда әйтелә, ягъни берәр төпсез арбадан төшеп калган бер нәрсәдер мәгънәсендә. *Аннан соң, арбаның төбе юк, Алланың кеме юк дигәндәй, ялгыз йөри торган хатын турындагы берәүнең гайбәте бик тиз урам авызына күчә* (С. Поварисов. Пәйгамбәр таңы).

*АРБАҢ* ❖ **АРБАҢ ЮЛЫҢДА БУЛСЫН**. «Тукталып, кеше эшенә тыгылма, бар, юлыңда бул» мәгънәсендә. *Юньләп әйткәнне тыңламасаң, мин сиңа икенче төрле аңлатырмын! Бар, ычкын, артыңа да борылып карама! Арбаң юлыңда булсын!* (Р. Кәрами. Кая чабасың, гомер юртагы?).

*АРБАСЫ* ❖ **АРБАСЫ АЛДА, АТЫ АРТТА.** Арттырып сөйләү. *Үзегез әйткәнчә, арбасы алда, аты артта булганда, хокуклар өчен көрәшү һәм нәрсәгәдер ирешү мөмкинме?* (shahrikazan.ru).

**АРБАСЫ СУГА АВУ.** Үкереп елау. *Гомәр, сеңлесенең үкереп елый башлавын күреп, «арбасы суга ауды бугай», дип уйлады һәм кесәсеннән кулъяулыгы чыгарып, аңа сузды* (Сөйләм).

Төрдәше: яшь урынына кара кан сыгу.

*АРБАСЫН* ❖ **АРБАСЫН ТАКЫРГА ЧЫГАРУ.** Эшен юлга салу, җайлау. *Ул, туктап калган эшен дәвам иттерү өчен, бурычка акча алды да әкренләп арбасын такырга чыгарды* (Сөйләм).

**АРБАСЫН ТАУГА МЕНГЕРҮ.** Уңган кеше турында: эшен югарыга үрләтү. *Кешенең уңганлыгын, тырышлыгын аңлаткан фразеологизмнар иң зур күләмле тармакларның берседер, мөгаен: алтын кул; алтын куллы; арбасын тауга менгергән; арыслан сырты* <...> (Татар лексикологиясе, Т. 1).

Төрдәше: авырның өстеннән, җиңелнең астыннан 2 һ.б.

*АРГАМАК* ❖ **АРГАМАК БИЛЕННӘН СЕЛТӘП ТӨШЕРЕП, ИШӘККӘ АТЛАНДЫРУ.** Бер нәрсә вәгъдә итеп, сүз биргәннең начаррагын бирү яки тәкъдим итү. *Аргамак биленнән селтәп төшереп, ишәккә атландырып куйган кебегрәк кимсетү булды бу* (М. Галиев. Тимә, яшәсен!).

Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

*АРГЫ* ❖ **АРГЫ ЯГЫНА ЧЫГУ.** Артык, үтә дәрәҗәдә. *Горностаев Татарстан өлкә профсоюзы вәкиле, чандырлыкның аргы ягына чыккан бәләкәй бер карт* (Г. Ахунов). *Явызлыкның аргы ягына чыккан бәндәдән чын яхшылыклы кеше ясагансың. Хәер, болар бит синең хыялларың...* (А. Тимергалин. Игезәкләр).

*АРДАКСЫЗНЫҢ* ❖ **АРДАКСЫЗНЫҢ АРКАСЫ ТУЗУ.** Кадер-хөрмәт күрмәгән кеше бик тиз абруен югалту. *Ардаксызның аркасы туза* [tatarca-text.narod.ru] Татарча текстлар). – *Ул бу урында да озак утыра алмады, ардаксызның аркасы туза, диләрме әле?* (Сөйләм).

*АРЕНАГА* ❖ **АРЕНАГА ЧЫГУ (КИЛҮ).** Билгеле бер өлкәдә эшчәнлек күрсәтә башлау. – *Иптәш Алемасов вакытында сәяси аренага чыкты ул* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).

*АРЕНАДАН* ❖ **АРЕНАДАН КИТҮ.** Эшчәнлек өлкәсеннән китү яки китәргә мәҗбүр ителү. *Әдәбият дөньясы да таркау, чуар; өстәвенә зур фигуралар аренадан китеп бара. Г. Исхакый – эмиграциядә, Такташ инде юк. Г. Камал яңа гына вафат. Г. Ибраһимов – авыру, Казаннан еракта, Кырымда яши. Г. Газиз – Бакуда. Г. Кутуй. Н. Исәнбәтләр «җидегәнчелек»тә гаепләнеп, әдәби хәрәкәттән читләштерелгән. Г. Бәширов, С. Баттал, Ә. Еникиләр – әле яшь, башлап язучылар санала...* (Р. Фәйзуллин. Гыйбрәтләр алырдык үткән юл).

*АРЕСТ* ❖ **АРЕСТ САЛУ.** Кулланырга, таратырга, сатарга тыю; сак астына алу. *Ул дәфтәрләргә арест салуның бердәнбер сәбәбе – аларда М. Гафури шигырьләре бар икән* (М. Мәһдиев. М. Гафури). *Утәү срогы чыккан, һәм, димәк, көн тәртибенә сезнең мөлкәткә арест салу мәсьәләсе килеп баса* (З. Мифтахов. Бизнес мәктәбе).

*АРЕСТКА* ❖ **АРЕСТКА АЛУ.** Тотыклау. *Казанда автобус шоферын ун тәүлеккә арестка алдылар* («Безнең гәҗит» газ.). *Моннан тыш, приставлар 18 машинаны арестка алган* («Әлмәт таңнары» газ.).

Төрдәше: кулга алу 3.

*АРЗАН* ❖ **АРЗАН ДА, ШӘП ТӘ.** Бәясе дә кыйммәт түгел, яхшы, сыйфатлы да эшләнгән. – *Теге күлмәккә кара әле: үзе арзан да, шәп тә* (Сөйләм).

*АРЗАНГА* ❖ **АРЗАНГА КУЮ.** 1. Бәясен киметү, төшерү; нәрсәгә булса да түбән бәя кую. *Нәшер итүчеләр, табыш алуны максат итмичә, изге нияттән чыгарганга күрә, бу кыйммәтле китапка бәяне дә бик арзан куйганнар* (Яңа китап – «Казан утлары» ж., 1996, 7).

2. Дәрәҗәсен төшерү. *Нинди генә төркемдә дә – беренче. Үзен һичкайчан арзанга куймас* (Ә. Гаффар. Олы юлның тузаны).

**АРЗАНГА ТӨШЕРЕП.** Бик арзан бәягә, бушлай диярлек. *Калганы, бердән, дәүләткә калып, бюрократлар кулында була, икенчедән, шул бюрократлар аның яхшы гына өлешен теге яңа байларга, ягъни безнең жуликларга саталар, арзанга төшереп* (Р. Юныс. Татар гаме).

**АРЗАНГА ТӨШМӘҮ (КИЛМӘҮ).** Күп акча торарга туры килү. *Кыбрысны Төркиягә кушканда, илле мең яугиребез шәһит киткән, Самсун фетнәсен бастыру да безгә арзанга төшмәде* (Т. Әйди. Оҗмах утравы).

*АРИАДНА* ❖ **АРИАДНА ҖЕБЕ (ЙОМГАГЫ).** Ариадна биргән йомгагын (җепне) кулланып чыга алмый торган урыннан чыгу юлын табу (юнан мифологиясеннән). *Обкомда кабинетлар йөз, Ариадна йомгагы кулыңда булса эзләп тап Вафа Сафичны лабиринттан!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Ариадна җебе мине исә яңадан Мәскәү – Казан поездының бөркү, кызу вагонына кайтарды* (Л. Фәттахова. Җир астыннан юллар бар...).

*АРКА* ❖ **АРКА БЕЛӘН БОРЫЛУ (ӘЙЛӘНҮ).** 1. Сөйләшергә теләмәүне белдереп, кире борылып утыру. *Фатирымны да сатмыйм, баламны да бирмим, дип, иренә дә, иленә дә бөтенләй арка белән борылып кайтты Җәүһәрия* (М. Маликова. Өермә).

Төрдәше: арка бирү 1–4 ; арка куеп 1; арка күрсәтү; аркан борылу (әйләнү).

2. Качу, чигенү, орышны ташлап качу (арканы күрсәтү). *Таурлар аркалары белән борылгач та, Тини бәк атуны туктатырга кушты* (Н. Фәттах. Аклан).

Төрдәше: арка бирү 2 һ.б.; арт бирү 3 һ.б.

3. Тыңламау, буйсынмау. *Шул рәвешле кинәт кенә ата-анага арка белән борылып була микәнни?* (М. Маликова. Чәчкә балы). – *Җир читенә китеп олаксаң да, сала мужигыннан котылу юк икән, – диде дә дорфа гына, Мортазинга аркасы белән борылып утырды* (В. Имамов. Күке).

Төрдәше: арка бирү 3 һ.б.

4. Санламау, ваз кичү. *Хикмәт Көнчыгышка арка белән борылып, Көнбатышка йөз тотуда түгел, ә дөньядагы барлык әһәмиятле нәрсәләрне үзләштерүдә* (Р. Хәкимов. Татар рухы).

5. Уңышлы булачак дип көткәннең киресе килеп чыгу. *Әмма бәхет аңа аркасы белән борылды* (Х. Миңнегулов. Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты).

**АРКА БЕЛӘН СИЗҮ (ТОЮ).** Нәрсәдер булачагын алдан сиземләү. *Тагын аның өчен иң куркынычлысы шул иде – тыштан никадәр генә ул үзенең исемен, дәрәҗәсен сакларга тырышмасын, әмма халык күзеннән акрынлап төшә баруын, коммунистларларның аңа кырын карауларын, бер язучы әйтмешли, аркасы белән тоеп йөри иде* (Ә. Еники. Саз чәчәге). *Бер-берсенең күлмәк салу хәрәкәтләрен арка белән сизеп, тоеп тордылар* (Р. Низами. Беренче мунча).

**АРКА БИРҮ.** 1. *к.* арка белән борылу (әйләнү) 1. *Һәм әнием әйтте: – Бер-беребезгә арка биреп утырырга ярамас бу чакта, – диде ул* (Н. Дәүли. Язмышка юл).

Төрдәше: арка белән борылу (әйләнү) 1 һ.б.

2. *к.* арка белән борылу (әйләнү) 2. *Әмма форсат табып, дошманга галиб килсәң вә*

*дошманың арка биреп качса, тамгы итеп, тиз артына төшеп кума* (К. Насыйри).

Төрдәше: арка белән борылу (әйләнү) 2 һ.б.

3. *к.* арка белән борылу (әйләнү) 3. *Бирдең арка ңны моңарчы, инде бир бит әмеренә* (Г. Тукай). *Хатыннар миңа арка биреп китәргә бер-ике адым атладылар* (Ф. Әмирхан).

Төрдәше: арка белән борылу (әйләнү) 3 һ.б.

4. *к.* арка белән борылу (әйләнү) 4. *Француз һәм немец университетларына барып уку хыяллары белән, Бохарага арка бирeп, Көнбатыш уку йортларына йөз бирәләр* (Б. Урманче. Исәнбәтнең урыны).

Төрдәше: арка белән борылу (әйләнү) 4 һ.б.

**АРКА БӨГҮ (БӨГЕП ТОРУ).** 1. Тулысынча буйсыну. *Һәр күзәнәк уяу һәм сак – әйләнәдән / Сигнал сөзә: кабул итә, бәйли, өзә. / Артык йөккә арка бөгеп сабыр итә* (С. Гәрәева. Йолдыз яңгырлары).

Төрдәше: әйткәненә күнеп, әйдәвенә йөреп һ.б.

2. Хезмәт күрсәтү. *Аяк-кулларым сау булса, үзем дә шушы килмешәккә арка бөгәр идемме соң, солдатка китеп барыр идем, ди* (М. Әмирханов. И кылган догам минем).

Төрдәше: агач – җимеше белән, адәм – эше белән һ.б.

**АРКА БӨКРЕСЕ ЧЫГУ (ЧЫГЫП БЕТҮ).** Авыр эштә озак һәм артык күп эшләп газап чигү, бөкрегә әйләнү. *Әнә күршегез Хәмзулла абзаң, эшли-эшли арка бөкресе чыгып беткән булса да, үзеннән ун-унбиш яшькә генә яшьрәк шул «Москвич»ыннан аерыла алмый һаман* (Ф. Имамов. Машиналы кызга).

Төрдәше: арка бөкресен чыгару һ.б.

**АРКА БӨКРЕСЕН ЧЫГАРУ.** Авыр эш башкарып газаплану. – *Шушы яшьтә арка бөкреңне чыгарып капчыклар ташып йөрмәсәң!* (Сөйләм).

Төрдәше: арка бөкресе чыгу (чыгып бетү) һ.б.

**АРКА ҖЫЛЫТЫП ЯТУ.** 1. Кояшта кызыну. *Әле кайчан гына Ельцин ягына авышканын сиздермәгән, Кырымда арка җылытып яткан өчен Шәймиевкә әллә нинди гаепләр тагарга әзер идем* (А. Гыйләҗев. Гомернең бер елы).

Төрдәше: арка киптерү 1 һ.б.

2. *күч.* Эшсез йөрү, эшсез яту. *Тыныч күңел белән, инде биш йөз еллап мич башында арка җылытып яткан килеш дөньясына төкереп яшәргә өйрәнеп җиткән татарның мүкле җаны өчен йомшак тавышлы, баллы-майлы газеталарыннан да яхшысы юк икән* (Ф. Яхин. Куш каен аланлыгы).

Төрдәше: авыз күтәреп яту һ.б.

**АРКА ЙОНЫН КАБАРТУ (ТОРГЫЗУ).** Усаллану, зәһәрләнү, холыксызлану. *Караборын, бу көтелмәгән шәһәр киемендәге кунакларны куркытырга теләп, арка йоннарын торгызып, аларга ташланды* (Һ. Такташ. Караборынның дусты).

**АРКА <ТИРЕСЕН> КАЕЗЛАУ (ТУНАУ)** 1. *к.* авыз җебетү 2. *Тал чыбыгы белән аркаңны каезлады, иеме?* (А. Вергазов. Үзеңә кайту). *Мин бер дәшмәм, ике дәшмәм, аннан соң, юк, мин сине тотып, арка тиреңне тунармын моның өчен, белдеңме?* (Ә. Фәйзи). *Ул арада Сәмига маңгаен тотып иелгән ирнең якасыннан эләктереп алды да уклау белән аркасын каезларга тотынды* (З. Тимергалиев. Сәмига).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

2. Кешенең эшеннән файдалану, аны изү, көчен, малын талау. *Арка тиреңне тунасалар тунасыннар, толерантный булу әйбәтрәк дип, алдакчылар сүзен кабатлыйкмы?* («Матбугат.ру» порталы).

Төрдәше: арка тиресен тукмау; җилкәне кимерү (кимереп яту); кан имү; кеше җилкәсе белән эш күтәрү; кеше кулы белән ут тоту (күсә); кеше кулы белән утлы көл (күмер) көрәү (тоту); кеше кулы белән учактан күмер алу; көн күрсәтмәү; сорыкорт булу.

**АРКА КАШУ** 1. *к.* авыз җебетү 2. *<...> аның белән талашып та алдык. Кулы бар, имеш, аның, кашытсаң, арканы кашыйсы* (Ф. Хөсни. Йөзек кашы). – *Карак! – Латыйф букчасы белән Ислайның аркасын «кашыды»* (Н. Гыйматдинова. Кем беренче?).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

2. Кимчелекләрен күрсәтү, тәнкыйтьләп алу. *Начальникларның иң кәттәсе! Мәскәүгә арка кашытырга бара!* (А. Гыйләҗев). *Хуҗалары янына курка-курка гына киткән иде, чынлап та, аркасын кашып кайтарганнар* (Сөйләм).

3. Бераз борчу тудыру, кәефне бозу. – *Әллә кайчан булган хәлләрне искә төшереп, арканы кашып утырма әле!* (Сөйләм).

Төрдәше: аркасын кашып алу.

**АРКА КАШЫРГА (КАШЫРЛЫК) ДА ВАКЫТ (АРА) ЮК.** Эш бик күп булу. *Баш мөхәр-*

*рирнең җәелеп аркасын кашырга да вакыты юк шул* (Т. Галиуллин. Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы). – *Кем эшләр соң синең ул бакчаңда? Үзеңнең арка кашырлык та вакытың юк, хатының...* (Ф. Хөсни. Үземне югалттым!)

**АРКА КИМЕРҮ** *к.* ана карынында яткан кебек. *Ә бит бу арка кимерүче аны чыннан да сатарга мөмкин* (Ә. Мушинский. Һаваларда – ак күгәрчен). *Барыбер гади халыкның аркасын кимерүдән башка эшләре юк* («Матбугат.ру» порталы).

Төрдәше: ана карынында яткан кебек һ.б.

**АРКА КИПТЕРҮ** *к.* арка җылытып яту 1. – *Арка киптереп ятып туймадыңмы әле, берәр нәрсә эшләп алыр идең* (Сөйләм).

Төрдәше: арка җылытып яту 1 һ.б.

2. *к.* авыз күтәреп яту. – *Алай әйтергә ярамый ул, арка киптереп яткан кешегә берәү дә китереп бирми* («Ватаным Татарстан» газ.).

Төрдәше: авыз күтәреп яту һ.б.

**АРКА КОЧТЫРЫП.** Җилкәгә атландырып яки арт яктан муеннан кочаклатып. *Имеш, бер егет карт авыру әнисен, арка кочтырып, өч мең чакрым ераклыктагы изге суга алып барып кайткан* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә). *Берсеннән-берсе вак, дистәләгән баланы кайсын арка кочтырып, кайсыларын өчәрен берьюлы кулына күтәреп, алга да, артка да сукмак ерып, үзе буе булып үскән «кыргый дәрья» белән көрәшкән* (Э. Шәрифуллина).

**АРКА КОЧТЫРЫП АЛУ.** Кызга аның әти-әнисе фатыйхасыннан башка өйләнү. *Арка кочтырып алып китәргә риза иде, ләкин Зәйтүнә үзе риза булмады* (Ф. Хөсни). *Ул беренче хатынын күрше авылдан арка кочтырып алган иде* (Сөйләм).

**АРКА КУЕП.** 1. Арка белән тору; утыру, яту, ягъни күрәсе килмәү, хупламау. *Шулай диде дә, сөйләр сүзем бетте, моннан ары соңга калып йөрсәң, ишек тә ачмам, дигән төсле иренә арка куеп әйләнде дә ятты* (Р. Ишморатова. Рәйханә). *Валия белән Ярмөхәммәт аркага арка куеп яттылар* (Р. Батулла. Юл буенда зәңгәр чәчәк).

Төрдәше: аркан тору; аркасы белән тору.

2. Аркаланып, таяныч дип кабул итеп. *Милли хисләргә арка куеп, юлыгызны ары дәвам итсәгез, сезне дә упкын көтә, Сәетгалив иптәш* (Р. Мөхәммәдиев. Сират күпере).

**АРКА КУЮ** *к.* арка белән борылу 1–4. *Адымымны гел күзәтеп йөрде, куйдырмады дуска аркамны* (Х. Әюп). *Ачуланган вакытлар бар дөньялыкта. ә ул чакта сиңа бер дә арка куймам* (Р. Рахман). *Аның чибәрлеген уйлап, махсус үзенә аталганлыгын хыял итеп, гүзәллектә тиңе булмаган үз хатынына аркасын куйды* (Ф. Яхин. Сөю-сәгадәт алмасы).

Төрдәше: арка белән борылу 1–4 һ.б.

**АРКА КҮРСӘТҮ** *к.* арка белән борылу 1–5. *Ана угълан, хатын дустын югалта,/ Ятимнәргә гомер күрсәтә арка* (С. Сүнчәләй). *Әнисенең әйткәне бар иде: «Әтиеңә бәхет-уңыш дигән нәрсә гел аркасын күрсәтергә ярата», – дигән иде* (Р. Төхфәтуллин. Гомеремнең кырык сигез минутын). *Хуҗа, елмаеп, аңа аркаларын күрсәтә башлаган солдатларга дәште* (Р. Кәрами. Олы юл да сикәлтәле). *Шәһәр бәге, Болгар вилаятенең идарәчесе, хан казнасының башлыгы, әмирләр нәселеннән булган Бәйбарс бәк, арка күрсәтмичә, арсландай көч белән дошманнарга каршы торды* (Казан ханлыгы чорындагы татарча чыганаклар).

Төрдәше: арка белән борылу 1–5 һ.б.

**АРКА КЫЗДЫРУ** 1. *к.* арка җылытып яту 1. *Мин Салабаш урманында – карама төбендә, ул исә берәр кояшлы утрауда арка кыздырадыр* (Н. Гыйматдинова. Мәхәббәттә гөнаһ бар).

Төрдәше: арка җылытып яту 1; арка киптерү 1.

2. *к.* авыз күтәреп яту. *Айзат Табагачта озак кына «арка кыздырды». Казан – Уфа пароходы төш узгач кына килде* (Г. Мөхәммәтшин. Йөрәктәге эзләр).

Төрдәше: авыз күтәреп яту һ.б.

**АРКА КЫМЫРҖУ (КЫМЫРҖЫП ТОРУ).** 1. Берәр сәбәптән тәннең чирканган яки эсселесуыклы булуы. *Хәер, Айбиби әле булса, Гаязетдинне күргән саен, аркасы кымырҗып куюын тоя* (М. Хәбибуллин. Айбиби).

Төрдәше: арка кычыту 1; арка чымырдау (чемердәү).

2. *ирон.* Җәза сорап тору. – *Аркаң кымырҗып торамы әллә югыйсә, кирәк дисәң, аны тынычландырырбыз* (Сөйләм).

Төрдәше: арка кычыту 2; арка чымырдау (чемердәү).

**АРКА КЫЧЫТУ** 1. *к.* арка кымырҗу (кымырҗып тору) 1. *Аны күрүгә, аркасы кычытып, юл*

*уртасында яткан чиләк төпләрен исенә төшерә дә, булган хәлләрне, юкларын да кушып, уйлап куя* (Ф. Яхин. Тәүбә-тәүбә, әстәгъфируллаһ!).

Төрдәше: арка кымырҗу (кымырҗып тору) 1 һ.б.

2. *ирон., к.* арка кымырҗу (кымырҗып тору) 2. *Аркаң кычыта, ахрысы, синең. Бераз каезлап алсыннар* (Г. Әпсәләмов).

Төрдәше: арка кымырҗу (кымырҗып тору) 2 һ.б.

**АРКА ӨСТЕ.** Кыр-далалар аркасы, күтәрелеп торган киң, яссы җир. *Вә йәнә күрдек шул [...] тып тарта [...] берлән бер арка өстенә ясаганнар [...]* («Гасырлар авазы» ж.). *Кырның аркасы өстенә кемдер өч аяклы агач билге утыртып куйган* (Сөйләм).

**АРКА СӨЯГЕ ЙОМШАК <БУЛУ>.** Принципсыз; тотрыклы карашы булмау. *Ул егетнең арка сөяге йомшак булуы сизелеп тора иде* (Сөйләм).

Төрдәше: арка сөяксез; арка үзәксез.

**АРКА СӨЯГЕН СЫНДЫРУ.** Вакытлар узу белән, хуҗалар сүзен генә кабатлаучыга, үз фикерен әйтергә курка торган кешегә әверелү. *Хакимият оешмаларында күп эшләп, моның арка сөяген сындырганнар* (Сөйләм).

2**.** Кемнең яки нәрсәнең булса да үзлеген бетерү, мөстәкыйльлеген юкка чыгару. *[Любица] Шатланыгыз, әфәндем, хәзер генә радиодан тыңладык, Кызыл Армия Киев шәһәрен алган. Немецларның тагын бер кат арка сөяген сындырган* (Т. Гыйззәт).

**АРКА СӨЯКСЕЗ** *к.* арка сөяге йомшак <булу>. *Иманым камил, бу халыкны арка сөяксез, умырткасыз булырга дәүләт өйрәткән* (Ә. Борһанов. Ясалма дәүләт, ялган кыйммәтләр, тамырсыз халык һ.б. турында). *Татарның кадим мәдрәсәләре андый арка сөяксез, буш хыял белән гомер черетүчеләрне заманында дистәләп, йөзләп тормыш мәйданына ыргытты, дип саный алам* (Ибраһим Нуруллин – галим, тәнкыйтьче, прозаик).

Төрдәше: арка сөяге йомшак <булу> һ.б.

**АРКА СУГЫП СӨЙЛӘШҮ.** Тартынмыйча, уңайсызланмыйча, үз кешеләр кебек сөйләшү. *Ләкин Ахунҗановка килеп җиткәч, аның алай тугарылып китмәгәнлеген күреп, уңайсызланыбрак калалар: яңа кеше белән арка сугып сөйләшүне, теге үзе эчмичәрәк утыргач, авызына ук коюны килештермиләр иде* (Ф. Хөсни. Мәйдан).

**АРКА ТАЯНУ.** Кемнеңдер ярдәменә сыену, аркалану. *Ләкин шул ук мәгъзурлык аларны, рус вә башка милләт сәхнәчеләренә арка таянудан мәхрүм итеп, тагы көчсезләндерәдер* (Г. Исхакый).

**АРКА ТАЯНЫЧЫ (ТЕРӘГЕ) <БУЛУ>.** Булышчы, төп ярдәмче, ярдәм кулы сузардай кеше. *Бер мизгелдә башын әллә кайларга алып чыгып китәрдәй булып җилкенде ул (белә иде югыйсә: бу яшьтә, бу хәлдә беркая да китә алмаячак!), икенче минутта гомере соңында үзенә арка таянычы табар сыман, әллә ниләр өметләнеп алды...* (Б. Камалов. Гомер кичендә). <...> *Моңарчы үзе белмәгән кемнеңдер яклау таянычы, арка терәге булу хисе котылгысыз дулкын булып күтәрелә, шушы ярдәмчесез җан иясе өчен утка-суга керергә әзерлеген күрсәтергә чакыра кебек иде* (Ф. Латыйфи. Аяклы каза).

Төрдәше: арка терәр җир булу; арка терәү 2; кул арасына (астына) керү (керә башлау).

**АРКА ТЕРӘП <СӨЙЛӘШҮ>.** Үзеңне нык тоту; үз-үзеңә ышанып сөйләшү. *Җангали бичарагамы мәҗлестә болай аяк вә арка терәп сөйләшү, кем авызыннан җай сүз чыгар дип көтеп торыр-торыр иде дә, бичара, иснәп утыра башлар иде* (М. Хәбибуллин).

Төрдәше: аяк терәп.

**АРКА ТЕРӘР ҖИР БУЛУ (ТАБУ)** *к.* арка таянычы (терәге) <булу>. *Ул арка терәр җир тапкан, шуңа күрә сүзен курыкмыйча әйтеп, иркенләп сөйләшә алачак* (Сөйләм).

Төрдәше: арка таянычы (терәге) <булу> һ.б.

**АРКА ТЕРӘҮ.** 1. Әйткән сүздә нык тору, кире чигенмәү. *Алар да безнең тозга бәйләнгәнне күргәч, арка терәгәннәр: пыяла ташырга җидешәр тәңкә сорыйлар* (Ф. Сәйфи-Казанлы. Крушниклар).

Төрдәше: аяк терәү.

2. *к.* арка таянычы (терәге) <булу>. *Халыкның көн күрү якларына, икътисади хәле астына посмакчы булды. Милләтнең сәяси хокукларына арка терәп сөйләмәкче булды* (Г. Исхакый). *Аларга бүтән чара калмаган иде инде, биш татар бу якка, биш татар куып килүчеләргә борылып, аркага арка терәп, аркадаш*

*булып, соң көчләренәчә сугышырга тотынды* (Р. Батулла. Сөембикә).
Төрдәше: арка таянычы (терәге) <булу> һ.б.

**АРКА ТИРЕ БЕЛӘН.** Тир түгеп, зур көч куеп эшләү. – *Ул награт алырга тели, ә без, җүләр җилкәләр, арка тиребез белән аңар награт әзерлибез, – диде* (А. Алиш. Якты күл буе).
Төрдәше: арка тирен агызу.

**АРКА ТИРЕН АГЫЗУ.** *к.* арка тире белән. *Яшермим, <…>, мышкылдый-мышкылдый, авыр капчыклар тәгәрәтәп, маңгай һәм арка тирләрен агызган, тургайлар җырын тыңларга яраткан бәләкәй малай бик ошый* (Ф. Миңнуллин. Туган җир җылысы).
Төрдәше: арка тире белән.

**АРКА <ТИРЕСЕН> ТУКМАУ** *к.* авыз җебетү 2. *Аларның кызларын алып киткән өчен, авыл егетләре бер кичне Мидхәт белән икебезне бер караңгы почмакта тотып, арка тиребезне тукмадылар* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АРКА ТИРЕСЕН <ЭТЛӘРДӘН> ТУНАТУ**. Яшәргә мөмкинлек бетү, авыр хәлгә төшү. – *Шулай ук сиңа да киңәш бирмим, кешене кызганам дип, арка тиреңне этләрдән тунатудан башка нәрсә чыкмас* (Т. Гыйззәт. Наёмщик).
Төрдәше: азап күрү (чигү) һ.б.

**АРКА ТУРАЙТМЫЙЧА.** Бернәрсәгә дә карамыйча, ялсыз эшләү. *Әлбәттә, эш шартлары авыр булган, урманда, мастерскойда, аркаңны да турайтмыйча, агач белән эш итү үзенекен иткән – ул һөнәри авыру алган* («Яңа Чишмә хәбәрләре» газ.).
Төрдәше: ал белми, ял белми <эшләү> һ.б.

**АРКА ҮЗӘКСЕЗ** *к.* арка сөяге йомшак <булу>. *Бюрократ дигән кешеләрнең аркалары үзәксез була аның, агайне* (Сөйләм).
Төрдәше: арка сөяге йомшак <булу> һ.б.

**АРКА ЧИЛӘН<ДЕР>Ү.** Мәшәкатьле, авыр эштә озак эшләп җәфа чигү. *Бу адым авыл халкында, гомер буе шул колхозда тиеннәр бәрабәренә арка чиләндереп эшләгән кичәге колхозчыларда коточкыч гарьләнү хисе тудырды* (matbugat.ru).
Төрдәше: азап күрү (чигү) һ.б.

**АРКА ЧИЛӘТҮ** 1. *к.* азап күрү (чигү). *Эсседә дә, яңгырда да аңа, арка чиләтеп, капчыклар ташырга туры килде* (Сөйләм).
Төрдәше: азап күрү (чигү) һ.б.

2. Кыйналу. *Бу юлы ул качып котыла алмады, күпер өстендә тотып, егетләр аркасын чиләтеп җибәрделәр* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз<ны>-борынны җимертеп йөрү һ.б.

**АРКА ЧЫМЫРДАУ (ЧЕМЕРДӘҮ)** *к.* арка кымыржу (кымырҗып тору) 1. *Боларны хәтерләсәң, аркалар чымырдап китә* (З. Мурсиев. Соңлау).
Төрдәше: арка кымыржу (кымырҗып тору) 1 һ.б.

*АРКАГА* ❖ **АРКАГА АЛУ.** Берәр эшне эшләүне үз-үзенә йөкләү. *«Графман» кәлимәсенең дә сүзгә-сүз эчтәлеге бер, шулай ук фикер үсеше тарихында аркасына алган йөге һәм, аннан килеп, телдә кулланылышы белән бергә, безнең үзебезнең ул гыйбарәне аңлау дәрәҗәбез* («Матбугат.ру» порталы). *Рөстәм карт эшчене ризалатуны үз аркасына алды* (Сөйләм).

**АРКАГА АРКА КУЕП <ЯШӘҮ>.** Дус, тату яшәү. *«Язгы кәрваннар»да – иң кыен сугыш елларында ачлыкка да, ялангачлыкка да бил бирмәгән, аркага арка, иңсәгә иңсә куеп, егыла-тора булса да Җиңүне якынайткан апалар, сеңелләр, япь-яшь малайлар* (А. Гыйләҗев. Истәлекләр).
Төрдәше: аркага арка терәп; башны башка тидереп; бер авызлар; иңгә иң куеп; иңсәгә иңсә куеп <яшәү>.

**АРКАГА АРКА ТЕРӘП.** Бергәләшеп, берберенә ярдәм итеп. – *Аркага арка терәшеп яшәрдәй күрше түгел Сәлимә* (Н. Гыйматдинова. Үзем генә беләм…).
Төрдәше: аркага арка куеп <яшәү> һ.б.

**АРКАГА АТЛАНДЫРУ.** Кешене үзенә баш итү, узындыру, асрау. *Сүзең гел бер булды: «Баланы аркага атландырмыйлар, бер атландырсаң төшми алар, җанны корыта»* (Я. Зәнкиев. Иртеш таңнары).
Төрдәше: ана карынында яткан кебек һ.б.

**АРКАГА <МЕНЕП> АТЛАНУ.** Баш булып алу, җилкәгә салыну. *Атланырга атың булмаса, атаң аркасына атлан* (Р. Батулла). *Үзе беркайда да эшләми, атасының аркасына менеп атланган да инде утыз ел төшәргә җыенмый* (Сөйләм).
Төрдәше: ана карынында яткан кебек һ.б.

**АРКАГА (АРКАСЫНА) БОЗЛЫ (КАЙНАР; САЛКЫН; ЭССЕ) СУ КОЙГАН (СИПКӘН) КЕБЕК БУЛУ.** Кинәт куркыныч йә күңелсез хәбәрне ишетүдән сискәнү, чирканып китү. *Күрде Винитар король Бож кенәзнең елмаюын һәм аркасына салкын су койгандай өшеп китте һәм, җан ачуы чыгып, чөй ясаган монахка камчысы белән кизәнде* (М. Хәбибуллин. Атилла). – *Ә теге яңа егет калдымыни? – Зинаның аркасына салкын су койгандай булды. – Калды, – диде атын сөюче* (Р. Зарипова. Атилла Расих: тормышы һәм иҗаты).

Төрдәше: аркадан бозлы (кайнар; салкын; эссе) су койган кебек булу; баштан салкын су койган (сипкән) кебек <булу>.

**АРКАГА ПЫЧАК (ХӘНҖӘР) КАДАУ.** 1. Биргән вәгъдәңне бозу, иптәшләреңне куркыныч астына куеп, үз мәнфәгатеңне генә кайгырту. – *Асылда, Габдулла, миңа аркама пычак кадамый торган тугры җаннар, теләктәшләр кирәк* (В. Имамов. Карабәк).

2. Хыянәт итү; уңай мизгелдән файдаланып, яшерен һөҗүм ясау. *Бәлки, ул империализм козгыннарының, шул идеалларына яңадан ирешү өчен, хәзерге «дусларының» аркасына елмаяелмая һәм шуннан аеруча бер ләззәт табып хәнҗәр кадарга хәзер торуларын ачыграк итеп аңлатырга кирәктер!* (Г. Бәширов).

Төрдәше: аркадан пычак (хәнҗәр) кадау; арткы яктан пычак кадау; арттан <сыртка> пычак (хәнҗәр) кадау.

**АРКАГА САЛУ.** 1. Җиңү. *Ата-бабалардан кигән татарча көрәшнең төп мәгънәсе – күтәреп алып аркага салу* (intertat.ru).

Төрдәше: аркан төшү 2.

2. Ышаныч казану. *Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга, дигәндәй, Мөхәммәт хан ачыктан-ачык сөйләве белән Ростов кенәзен аркасына салды* (В. Имамов. Казан дастаны).

**АРКАГА ТӨШҮ.** 1. Берәрсенең аркасына нәрсә белән булса да сугу. *Мәгәр нугай мулладан безнең аркабызга төшкән яман таяк эзләреннән башка һичбер нәрсә калган юк* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *Аның сукса тимер өзәрлек йодрыгы бер-бер артлы әни аркасына төшә башлады* (А. Алиш. Якты күл буе).

2. Арка белән егылу, аркан яту. *Кулындагы гөлгә зыян китермәс өчен аркасына төшкән икән ул, ә таянырга куллары буш түгел* (Г. Гыйльманов. Гөлләр дә елый).

**АРКАГА ЫШЫКЛАНУ.** Кемгә булса да ышану, таяну. *Элекке шикелле Солтангәрәйнең аркасына ышыкланыр чакмыни?* (Г. Бәширов). – *Җилгә каршы кемнәрнеңдер аркасына ышыкланып бару – хурлык, үзеңне алдан ук тар кабыкка төрү, канатларыңны алдан ук кисү, вак мещан тормышына алдан ук әзерләү* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

Төрдәше: аркаланып йөрү.

*АРКАДА* ❖ **АРКАДА КАЛДЫРУ.** 1. Арт тарафта; хәрбиләрдә: гаскәрнең тылында. *Ләкин монголларга күп гарнизон тупланган мондый көчле ныгытманы аркада калдыру да файдага түгел* (И. Хара-Дауан. Үткән зурлыкларга кайту. – М. Галиев тәрҗемәсендә).

2. Ярышта үзеннән алга чыгармау, узып китү. *Башына кызыл чүпрәк бәйләгән малайның аты мактаулы бияне аркада калдырды* (Сөйләм).

**АРКАДА <КАТЫ> КАМЧЫ УЙНАУ.** Камчы белән кыйнау. *Бер нәрсә аның күңеленә ярağанча эшләнмәсә, бер әйбер югалса, яисә хатынына, баласына ачуланса – һәммәсе өчен безнең ялангач аркада каты камчы уйный иде, ди* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).

**АРКАДА<Н> ТАРАКАННАР (КЫРМЫСКАЛАР) ЙӨ<ГЕ>РҮ (ЙӨГЕРЕП ҮТҮ).** 1. Бик нык туңу, өшү. *Ишек төбен озаграк саклап торды бугай – табан асларында гына түгел, аркасында да кырмыскалар йөгереп үткән кебек тоела башлады* (Сөйләм).

Төрдәше: аркадан бозлы кырмыскалар йөгерү 1; җелеккә (җилеккә) <ачы җил> үтү 4; каз тәне каплау (чыгу); күркә тәне чыгу; салкын тәнне чиметү; тавык тәне кебек булу; тән чымырдап (чемердәп) китү.

2. Көчле куркудан, дулкынланудан яки салкыннан тәндә җиңелчә калтырану тою, эсселе-суыклы булып китү. *Л. Толстойның «Воскресенье»сын укыганда, йөрәкләр кысылып, аркада кырмыскалар йөргәндәй була* (М. Гайнуллин). *<...> дигән юлларны ул аркадан тараканнар йөгереп китә торган итеп әйтә белә иде, соңыннан йомшаграк тавыш белән: «Сез һаман бергә икән,*

*бергә икән...», – дип тәмамлап куя* <...> (И. Нуруллин).

Төрдәше: аркада суык йөгертү; аркадан бозлы кырмыскалар йөгерү 2; борча-кырмыскалар көтүе чабышу; салкын тәнне чеметү; тән чымырдап (чемердәп) китү.

**АРКАДА СУЫК ЙӨГЕРТҮ** *к.* аркада<н> тараканнар (кырмыскалар) йө<ге>рү (йөгереп үтү) 2. *Гаскәрлек тормышында мондыйларны бик күп күргән булса да, бу тавышлар бүген аркасында суык йөгертте* (Г. Исхакый. Өйгә таба).

Төрдәше: аркада< н> тараканнар (кырмыскалар) йө<ге>рү (йөгереп үтү) 2 һ.б.

**АРКАДА ТАТУ**. Үз башыннан кичерү, йөрәгә аша үткәрү. *Егетләребез: «Әйдәгез, безнең белән бергә клубка биергә! – дип чакырып азапландылар да, безнең нинди биючеләр икәнлегебезне үз аркаларында татыган кеше буларак, кул селтәп, авылга төшеп киттеләр* («Сөембикә» ж.). *Көчле җил белән көрәшә-көрәшә, тау түбәсенә чыгуның авырлыгын үз аркасында татырга туры килде* (Сөйләм).

Төрдәше: үз җилкәсендә тату.

*АРКАДАН* ❖ **АРКАДАН БОЗЛЫ КЫРМЫСКАЛАР ЙӨГЕРҮ** 1. *к.* аркада<н> тараканнар (кырмыскалар) йө<ге>рү (йөгереп үтү) 1. *Тәнге суык үзенекен итә башлады, җилеккә үтеп, аркадан бозлы кырмыскалар йөгерергә тотынды* (Сөйләм).

Төрдәше: аркада<н> тараканнар (кырмыскалар) йө<ге>рү (йөгереп үтү) 1 һ.б.

2. *к.* аркада<н> тараканнар (кырмыскалар) йө<ге>рү (йөгереп үтү) 2. *Мөхсиновның аркасыннан көтүе белән бозлы кырмыскалар йөгереште* (Г. Бәширов).

Төрдәше: аркада<н> тараканнар (кырмыскалар) йө<ге>рү (йөгереп үтү) 2 һ.б.

**АРКАДАН БОЗЛЫ (КАЙНАР; САЛКЫН; ЭССЕ) СУ КОЙГАН КЕБЕК БУЛУ** *к.* аркага (аркасына) бозлы (кайнар; салкын; эссе) су койган (сипкән) кебек булу. *Муса тагын җиргә сеңгән күк булды, тагын аркасыннан бозлы су белән коендырган төсле булды* (Г. Рәхим).

Төрдәше: аркага (аркасына) бозлы (кайнар; салкын; эссе) су койган (сипкән) кебек булу һ.б.

**АРКАДАН КАГУ.** Җиңелчә генә аркага дусларча суккалау. *Ул, Алла боерса, киленкәем дип, аркасыннан кагып кына тотар* (Г. Ибраһимов. Табигать балалары). *Җизни, көлеп, әтинең аркасыннан кагарга тотынды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**АРКАДАН <КИЛЕП> ПЫЧАК (ХӘНҖӘР) КАДАУ** *к.* аркага пычак (хәнҗәр) кадау. *– Алай-болай син монда энекәш мине суеп ташламасын, аркадан пычак кадамасын дип шөбһәләнмисеңдер бит, өлкән абый?* (В. Имамов. Сөләйман солтан).

Төрдәше: аркага пычак (хәнҗәр) кадау һ.б.

**АРКАДАН СӨЕП БАШКА БИРҮ.** Тыштан шәфкатьле булып күренеп, чынында кешене җәберләү хакында. – *Аркадан сөеп башка бирү гомергә бетәчәк түгел, колагыңны сак тот* (Сөйләм).

**АРКАДАН СӨЙЛӘҮ** *к.* авыз чайкау 1. *Авылга кайткач, үзенчә бернинди дә кирәкмәгән эш эшләмәде кебек, әмма аркадан сөйләүләр тиз генә бетмәде* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз чайкау 1 һ.б.

**АРКАДАН СЫЙПАМАУ (СӨЙМӘҮ).** «Рәхмәт әйтмәсләр, хупламаслар» мәгънәсендә. *Утенәм, бу язуны утта яндыр, ату мондый эшләр өчен икебезнең дә аркадан сыйпамаслар* (Г. Мөхәммәтшин). *Ә кузгалырга кирәк, аны өйдә көтәләр. Бригадир да аркадан сыйпамас, кичкә урап кайтасың дип кенә җибәргән иде...* (М. Әмирханов. Убыр уты).

Төрдәше: акыл бизмәненә утырту һ.б.

**АРКАДАН СЫЙПАУ.** Мактау, хуплауны белдерү. *Минем үземнең дә күпләрне әрләгәнем бар, мине дә гел аркадан сыйпап кына тормыйлар, әмма беркайчан да болай җебегәнем юк иде* (М. Хуҗин. Исәнме, Раушания!..). *Гел мине мактап, аркадан сыйпап торсыннар иде* (Г. Афзал. Беренче гонорар).

*АРКАЛАНЫП* ❖ **АРКАЛАНЫП ЙӨРҮ.** Кемнең дә булса ярдәменнән файдалану, аркалану. *Әтием көтүче булса, ике дә уйламас идем. Әтиеңә аркаланып йөрисең, дигән сүз инде бу!* (Г. Нәбиуллин. Ярдәмчеләр).

Төрдәше: аркага ышыклану.

*АРКАЛЫКНЫ* ❖ **АРКАЛЫКНЫ БУШАТУ.** Башка нәрсә турында уйламыйча, рәхәтләнеп. *Ашын пешертәсең, бәлешен әзерләтәсең дә, күңелне киң тотып, аркалыкларны бушатып бәйрәм итәсең* (Ф. Яхин. Бар икән күрәселәр).

*АРКАМ* ❖ **АРКАМ БИШЕКТӘ, КҮЗЕМ ТИШЕКТӘ ТҮГЕЛ.** «Мин хәзер кечкенә бала түгел, барысын аңлап, белеп торам» мәгънәсендә. *– Һаман да өйрәтмә инде, аркам бишектә, күзем тишектә түгел бит, үзем дә башкарып чыгармын* (Сөйләм).

*АРКАН* ❖ **АРКАН БЕЛӘН ДӘ <ӨСТЕРӘП; СӨЙРӘП; ТАРТ<ТЫР>ЫП> КИТЕРӘ АЛМАУ** *к.* аны монда аркан белән дә <өстерәп; сөйрәп; тарт<тыр>ып> китерә алмау. *Җыелышларга йөрергә яратмый иде ул. Аны аларга аркан белән дә өстерәп китерә алмыйлар иде* (Сөйләм).

Төрдәше: аны монда аркан белән дә <өстерәп; сөйрәп; тарт<тыр>ып> китерә алмау һ.б.

**АРКАН БЕЛӘН ДӘ ТАРТТЫРА АЛМАССЫҢ** *к.* аны монда аркан белән дә <өстерәп; сөйрәп; тарт<тыр>ып> китерә алмау. *Өмәгә килсә килер, әмма түләүсез эшлисе җиргә аны аркан белән дә тарттыра алмассың* (Сөйләм).

Төрдәше: аны монда аркан белән дә <өстерәп; сөйрәп; тарт<тыр>ып> китерә алмау һ.б.

**АРКАН БОРЫЛУ (ӘЙЛӘНҮ)** *к.* арка белән борылу 1–5. *– Югал күз алдымнан! – Янгура аркан борылды* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Нәтиҗә буларак, әдип әсәрләре яңадан басылмый, татар театры репертуарыннан пьесалары чыгарып ташлана, матбугат идарәләре аңа аркан борыла* (Р. Әмирхан. Әмирханнар). *«Шунда кайбер танышларым миңа аркан борылуын күргәч, йөрәк әрнеде», – дип искә ала Сәләй ага* (Р. Зарипов. Тирән тамырлы Түнтәрем). *Хәят үкчәләре өстендә җәһәт кенә анасына аркан әйләнде* (Ф. Әмирхан. Хәят). *– Синме? – дип сорады ул карлыккан тавыш белән. Аркан әйләнеп карамады. Карарга шикләнгәнен сизде* (Ә. Гаффар. Утын).

Төрдәше: арка белән борылу 1–5 һ.б.

**АРКАН БУЕ.** Якынча биеклекне яки озынлыкны белдерә. *Инсаф күзен ачканда, кояш Караташ өстеннән аркан буе күтәрелергә өлгергән иде, һәм зәп-зәңгәр* (Т. Гарипова. Ялгыз бөркет күктә бөтерелә). *Ярый әле су муеннан артмады. Инде өч аркан буе җитәрлек иде – яныбызга шап итеп аркан башы килеп төште* (Х. Сарьян. Бер ананың биш улы).

Төрдәше: дилбегә буе.

**АРКАН ИШӘРЛЕК.** Кирәгеннән артык күп. *«А-ах-ух»тан соң пуф-пуф тәмәке, / Өйдә төтен – аркан ишәрлек, – / Агыла тәрәзәдән* (Р. Идиатуллин).

**АРКАН ОЧЛАРЫН ҖИБӘРМӘҮ.** Нәрсәнең булса да барышын үз ихтыярыңа буйсындыру. *Әмма кулына кергән аркан очларын Сабир җибәрергә теләмәде* (Ф. Яхин. Бакыр бозау артыннан).

**АРКАН САЛУ.** 1. Аркан ярдәмендә тотыклау. *Күтәреп алыйм дип иелсәм, муеныма аркан салдылар...* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр).

Төрдәше: арканлап тоту.

2. *к.* аркага салу 1. *Ирләр бил алышканда, җиде бүз баланы аркан салды* (А. Гадел. Шәһри Болгар калфагы).

Төрдәше: аркага салу 1.

**АРКАН ТОРУ** *к.* арка куеп. *Аннары, паром бәйли горган баганага сөялеп, җилгә аркан торган Хәлимәне үз янына чакырды* (Л. Ихсанова. Мин әле бу). *Күзлекле кеше тезләнеп торды, мүкәләп, кузов кырыена хәтле килде, җилгә аркан торып, аягүрә басты.* (И. Салахов. Күкчәтау далаларында).

Төрдәше: арка куеп һ.б.

*АРКАНЛАП* ❖ **АРКАНЛАП КИТЕРҮ.** Каршы торуына карамастан, көчләп китерү. – *Миңа хәзер үк склад мөдирен алып килегез, киреләнсә, арканлап китерегез* (Сөйләм).

*АРКАНЫ* ❖ **АРКАНЫ АРКАГА ТЕРӘП** *к.* аркага арка терәп. *Хәзер инде аңа бала турында хыяллану да көлке, ә җанына якын берәр хатын белән арканы аркага терәп, чөкердәшеп яшәү комачауламас иде* (Н. Әхмәдиев. Мөнирстан). *Озак еллар арканы аркага терәп эшләү нәтиҗәсендә, почтальоннар, ышанычлы дусларга әйләнеп, тәмам үз булып беттеләр* («Татарстан яшьләре» газ.).

Төрдәше: аркага арка терәп.

**АРКАНЫ БЕТ АШАУ, ЭШЛӘГӘННЕ ЭТ АШАУ.** Мохтаҗлыкта яшәү; «эшләп тапканы

кешенең үзенә бернинди файда бирми» мәгънәсендә. *Арканы бет ашый, эшләгәнне эт ашый* (К. Насыйри. Мәкальләр һәм әйтемнәр). *Әнә халыкның аркасын бет ашый, эшләп тапканын эт ашый – түрәләр кимерә* (Ф. Баттал. Ка-аш-мар!).

**АРКАНЫ ЕЛДЫРЫМ ПЕШЕРҮ.** Эсселесуыклы булып китү. *Андрейның эченә салкын йөгерде, аркасын кайнар елдырым пешереп үтте* (Х. Камалов).

**АРКАНЫ КАР ИЛӘП ТОРУ.** Арканы туңдырып тору. *Өйгә кирәргә кирәк, нәрсәдер арканы кар иләп тора* (Сөйләм).

**АРКАНЫ КАШЫТУ**. Кыйналу. – *Үзенең бер дә арканы кашытасы килми...* (И. Гази. Онытылмас еллар).

Төрдәше: авыз<ны>-борынны җимертеп йөрү һ.б.

**АРКАНЫ ТЕРӘП АЛУ.** Ышанычлы урын, эш яки таянырлык кеше табу. *Хикмәт, арканы терәп алырлык берәр нәрсә табармын әле, дип, шәһәргә юл тотты* (Сөйләм).

*АРКАСЫН* ❖ **АРКАСЫН ӘЙЛӘНҮ.** Сөйләшүдән баш тарту, игътибар итмәү, араны өзү; читләшү. *Ире нәрсәдер әйтергә омтылып караса да, ул аңа аркасын әйләнеп ятты* (Сөйләм).

Төрдәше: арка белән борылу (әйләнү) 1–4 һ.б.; арт бирү 2; баш каеру; борын чөерү 1; йөз чөерү 1; күңел кайту.

**АРКАСЫНА УКЛАУ ТЫГУ.** Иелмичә-бөгелмичә төз йөрү. *Аркаңа уклау тыкканмы, бөкерәя алмыйсың* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.). *Аяк-куллар сызлый, арка уклау тыккандай катып калган, муенны борып булмый* («Татарстан яшьләре» газ.).

Төрдәше: уклау йоту.

*АРКЫЛЫ<ГА>* ❖ **АРКЫЛЫ<ГА> ҖӘЕЛҮ** *ирон.* 1. Артык симереп, гәүдә киңәю. *[Зәмзәмбану] Арыш боламыгы кебек аркылыга җәелә* (Т. Гыйззәт). *Аның аркылыга җәелгән, әмма бик тере, хәрәкәтчән хатыны почмак ягыннан: – Дөрес, атасы, дип аваз бирде* (Р. Вәлиев. Дөнья гаме).

Төрдәше: аркылы<га> үсү; аркылыга яр да буйга кис 2; аркылыга-буйга җәелү 2; аркылысы-буе бер; буе аркылыгына китү; ит бүкәне; ит кисмәге; ит тавы; ит чүмәләсе; муенына тышау да җитмәс (җитәрлек түгел); муенына тышау алсаң, тышау да җитмәс; чи<е>ртсәң, май чыгар.

2. Аяк киеме җәелеп таркала башлау. *Аркылы җәелеп, ашарга сорый башлаган бу башмаклар күпмегә чыдаган икән?* (Сөйләм).

**АРКЫЛЫ КЕШЕ.** Җайлап булмый торган тискәре кеше. *Бигрәк тә аркылы кеше инде, шулкадәр кире сыйфатларны ничек җыеп бетергәндер* (Сөйләм).

**АРКЫЛЫ КИЛҮ (ТӨШҮ).** 1. Сөйләгәннең киресен сөйләү, каршы төшү. *Ул кызыл гөл – назлы гөлгә тимәгән дошман кулы. / Сузды исә пычрак кулын, шунда ук аңа килә аркылы* (М. Гафури). *Бибинур гел минем сүзгә аркылы төшеп, теңкәмә тия, мыскыл итә* (Ш. Камал).

Төрдәше: аркылы сөйләшү.

2. Эшкә каршы килү, комачаулау. *Бөтенесе каядыр бара, ул – Акбар күпмесенең усал ниятенә аркылы төште, яхшысына сөенде* (Ә. Гаффар. Акбар).

Төрдәше: аркылы яту; арт белән тору 2; аяк чалу 1; бәхеткә аяк чалу; бәхеткә киртә булу; бәхеткә тешне батыру; бәхетне керпе чәнчү (тишкәләү); бәхетне керпе тишкәләгәч, ни уфыр, ни пуфыр; бәхетне керпе үбү; бәхетне кисү; бәхетне (бәхеткә) кырау сугу (тию); бугазга аркылы сөяк булып кадалу (яту); бугазга таш булып утыру; кару кайтару; каршы килү; киртә булу (кору; кую; салу); тәртәгә аркылы килү; тешетырнагы белән каршы; юлга аркылы төшү; юлга бүрәнә тәгәрәтү; юлга кара елан сузылып яту; юлга киртә булу; юлга таяк ташлау (ике маддә өчен дә).

**АРКЫЛЫ КОРСАК** *мыск.* Корсагы җәелеп үскән юан кеше. *Кызыл комач җәйгән өстәл артына кара әле, бөтен аркылы корсак кешеләр шунда тупланган* (Сөйләм).

**АРКЫЛЫ САЛАМНЫ БУЙГА ДА АЛЫП КУЙМАУ.** Ваемсыз, ялкау; йорт эшләренә гомумән катнашырга яратмаган кеше. <...> *ә яңа салынып ята торган колхоз сыер абзарына барып, анда аркылы саламны буйга да алып куя алмый* (А. Шамов).

Төрдәше: аркылы ятканны буйга алып куймау (салмау); аркылыны буйга салмау; бармак <та> кыймылдатмау; бармакка бармак <та> сукмау;

бармакны бармакка сукмау; кыл да кыймылдатмау; салам да селкетмәү.

**АРКЫЛЫ СИКЕРҮ.** Азып китү, артык тотнаксыз, әдәпсез булу. *Монысы инде бөтенләй аркылы сикерү булып, бернинди законга да, логик киртәләргә дә сыя торган түгел!* (З. Мифтахов. Латин графикасы дигән кәнфитне татар авызына төеп кертәләр).

**АРКЫЛЫ СӨЙЛӘШҮ.** *Элек аның төмсә йөзе ошамый иде бит югыйсә, гел аркылы килеп сөйләшүе дә тешкә тия иде, хәзер менә сагынам үзен* (М. Галиев. Нигез).

Төрдәше: аркылы килү (төшү) 1.

**АРКЫЛЫ ТАККАН.** Рус милләте кешесен күздә тотып әйтү. – *Ә мин сине аркылы таккан дип торам* (К. Кәрами. Каргышлы этаплар).

**АРКЫЛЫ<ГА> ҮСҮ** *к.* аркылы<га> җәелү. *Гәүдәгә төптән юанаеп чыккан имәндәй, аркылыга үскәнгәме икән, кызу-кызу атлап йөргәндә, чыннан да, туп кебек тәгәри ул* (matbugat.ru).

Төрдәше: аркылы<га> җәелү 1 һ.б.

**АРКЫЛЫ<П> ЧЫККАН.** Кирәгеннән артык дәрәҗәдә, җитеп арткан. *Машинасын 100 меңгә бирсә дә аркылып чыккан инде, юк бит, 150 не сорый* (Сөйләм).

**АРКЫЛЫ<ГА> ЯТКАННЫ БУЙГА АЛЫП КУЙМАУ (САЛМАУ)** *к.* аркылы саламны буйга да алып куймау. *Нурулла хуҗалыкта эшләүне өнәми, аркылы ятканны буйга да алып салмый, бер минут буш вакыты булса, газета-журнал, китап укырга тотына иде* (Ф. Садриев. Шаһзаманов эше). *Синең исә аркылы ятканны буйга да алып салганың юк* (Н. Әхмәдиев. Амбирак).

Төрдәше: аркылы саламны буйга да алып куймау һ.б.

**АРКЫЛЫ ЯТУ** *к.* аркылы килү (төшү) 1, 2. *Аның астыртын эш йөртүчеләрнең мәнфәгатенә суга, Мәскәүнең өметләренә аркылы ята иде* (Р. Батулла. Сөембикә). *Халык та каршы килмәс, имам хәзрәтләре дә аркылы ятмас дип уйлыйм, ә?!* (М. Хәбибулин).

Төрдәше: аркылы килү (төшү) 2.

*АРКЫЛЫГА* ❖ **АРКЫЛЫГА ДА, БУЙГА ДА ӘЙЛӘНЕП (ЙӨРЕП) ЧЫГУ.** Җәяүләп кенә бөтен тирү-якны өйрәнеп, тикшереп чыгу. *Мин бу агачлыкны аркылыга да, буйга да йөреп чыктым, ләкин нинди булса да сирәк үсемлек таба алмадым* (Сөйләм).

Төрдәше: аркылыга-буйга айкау; аркылыга-буйга актару; аркылыга-буйга гизү; аркылыга-буйга иңләү (йөрү; йөреп чыгу); аркылыга-буйга кыдыру; аркылыдан буйга әйләнеп (йөреп) чыгу; аркылыдан буйга узу (үтү); аркылысыннан алып буенача; аркылысын буйга иңләү; аркылысын-буен айкау (әйләнеп чыгу; иңләү; йөреп чыгу); аркылысын-буен үтү; аркылысыннан алып буенача; аркылысыннан-буйга ярып чыгу; дөнья күрү 3; дөньяны аркылыга-буйга сукалау; иңгә-буйга айкау.

**АРКЫЛЫГА ТОРКЫЛЫ.** Бер тискәре нәрсәгә (кешегә) икенче тискәресе килеп өстәлү. *Нәгыймә апаны гүяки җен алыштырган диярсең, фикере-уе да таркау, кулындагы эшләре дә аркылыга торкылы килеп кенә тора* (Ф. Яхин. Куш каен аланлыгы).

**АРКЫЛЫГА ТОРКЫЛЫ БУЛУ.** Эш-хәлнең комачаууга очравы, кире килеп тору. *Туры гына канау казып килә идек, кирәк бит, аркылыга торкылы булып, бер зур ташка килеп терәлдек* (Сөйләм).

**АРКЫЛЫГА ЯР ДА БУЙГА КИС.** 1. Эш тәртибен белмәү, киресен эшләү. – *Күп уйлап торма, аркылыга яр да буйга кис шунда – берәр нәрсә килеп чыгар әле* (Сөйләм).

2. *киная* Артык юан адәм турында. *Аның бер ботын булса да аркылыгы яр да буйга кис, минеке хәле өчәү чыгар* (Сөйләм).

Төрдәше: аркылы<га> җәелү 1 һ.б.

*АРКЫЛЫГА-БУЙГА* ❖ **АРКЫЛЫГА-БУЙГА АЙКАУ** *к.* аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу. *Койрыгын сыртына салып, ишегалдын аркылыга-буйга Чатан сыйрак айкый* (А. Хәсәнов. Бүре баласы Чатан). *Ничә көн инде урманны аркылыга-буйга айкаса да, сукмак кына да очратканы юк...* (Н. Сәйяр. Дию кызлары).

Төрдәше: аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу һ.б.

**АРКЫЛЫГА-БУЙГА АКТАРУ** *к.* аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу. *Мондый тормышины төшләрендә дә күрмәгән кавем йортны*

*аркылыга-буйга актарып чыкты* (Р. Габделхакова. Соңгы сорау).

Төрдәше: аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу һ.б.

**АРКЫЛЫГА-БУЙГА ГИЗҮ** *к.* аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу. *Чегән өере белән бергә Украина далаларын аркылыга-буйга гизгән чакта, ул берничә тапкыр качып китәргә омтылып та карады* (И. Диндаров. Соңгы әманәт).

Төрдәше: аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу һ.б.

**АРКЫЛЫГА-БУЙГА ҖӘЕЛҮ.** 1. Бер очыннан икенче очына, бер кырыйдан икенче кырыйга кадәр. *Ташу суы, аркылыга-буйга җәелеп, иңкүлекне тутыргач, сукмаклар буйлап әкрен генә югарыга шуыша башлаган* (Сөйләм).

2. Бик нык тазару, симерү. *Тыйнак кына кыз иде яшьлегендә, бригадирга кияүгә чыгып куйгач, тәмам узынды, авызы тулы алтын теш, колагында да әлләниләр ялык-йолык килә, үзе аркылыга-буйга җәелде, имәнгеч* (А. Гыйләҗев. Җомга көн кич белән...).

Төрдәше: аркылы<га> җәелү 1 һ.б.

**АРКЫЛЫГА-БУЙГА ИҢЛӘҮ (ЙӨРҮ; ЙӨРЕП ЧЫГУ)** *к.* аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу. *Бата-чума, әрәмәлекне аркылыга-буйга иңләде, ташу суы элеп калдырган чүп-чардан, ләмле камыш, күрән, җикән сабакларыннан аралап, талчыбыкларның нәзеген, ботаксызын, камчы кебекләрен җыйды* (Л. Зөлкарнәй. Сафа). *Безнең, горур совет диңгезчеләренең кесәләрендә гондолага түгел, диңгез трамваена түләрлек тә валюта юк, шуңа күрә без Венецияне «унберенче трамвай» белән аркылыга-буйга йөреп чыгабыз* (М. Юныс. Су, күк һәм җир турында хикәяләр).

Төрдәше: аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу һ.б.

**АРКЫЛЫГА-БУЙГА ЙӨЗҮ.** Берәр һөнәрдә осталыкка ия булу. *Миңа монда, янәсе, халыкара дуслык һәм Совет заманында бик популяр булган интернационализм темасын аркылыга-буйга йөзәргә мәйдан ачылачак...* («Шәһри Казан» газ.).

**АРКЫЛЫГА-БУЙГА КЫДЫРУ** *к.* аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу. *Безнең урман зур түгел, ул аны аркылыга-буйга кыдырган* (Сөйләм).

Төрдәше: аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу һ.б.

**АРКЫЛЫГА-БУЙГА ҮЛЧӘҮ.** 1. Булган яки булачак хәлләрне, эшне, урынны һ.б.ны төрле яктан уйлап, тикшереп чыгу. *Минем драматик поэманы аркылыга-буйга үлчиләр, кисәләр, сыталар, сыгалар, яңадан ялгыйлар һәм кабат килешенәләр* (Ф. Яхин. Шөкерсез Шакир Һабиловның абынуы). *11 чакрым дидем, ул – аның әйләнәсе, ә аркылыга-буйга үлчәсәң, өчәр чакрымнан арта* (Р. Фәхретдинов. Болгар шәһәрләре).

2. Берәр кешенең торышын, эшен, хәлен һ.б.ны төрле яклап тикшереп чыгу. – *Ул, гәүдәмне аркылыга-буйга үлчәгәндәй, үтәли тишеп карады* (Т. Гарипова. Исле гөл). *Мин Туфанны аркылыга-буйга үлчәп, аңлап бетердем һәм аңа үземнең кирәклегемне тоям* («Камал театры офоциаль сайты»).

*АРКЫЛЫДАН* ❖ **АРКЫЛЫДАН БУЙГА ӘЙЛӘНЕП (ЙӨРЕП) ЧЫГУ** *к.* аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу. *Күреп сөйләшү өчен, Илсөянең Себер якларын аркылыдан-буйга әйләнеп чыгуын көтәргә туры килде* (Сөйләм).

Төрдәше: аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу һ.б.

**АРКЫЛЫДАН БУЙГА УЗУ (ҮТҮ)** *к.* аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу. *«Йомшак әйтелде» дип уйлаган сүзе, белми дә калырсың, үткен кылыч булып аркылыдан-буйга узар да китәр* (Ф. Яхин. Сәламәгаләйкүм, «ишан хәзрәтләре!»).

Төрдәше: аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу һ.б.

*АРКЫЛЫНЫ* ❖ **АРКЫЛЫНЫ БУЙГА <АЛЫП> САЛМАУ** *к.* аркылы саламны буйга да алып куймау. *Ялкаулыгыгыз аркасында җитештә төн күрмисез бит! Эш сөймисез, аркылыны буйга алып салмыйсыз, телегез генә тәтелдәргә оста* (Н. Гыйматдинова. Бер тамчы ярату). *Йә ашка тозны аз (күп!) салганнар, йә кызы артык кыска итәк кигән, йә улы аркылыны буйга алып салмый икән* (К. Кара. Депрессия).

Төрдәше: аркылы саламны буйга да алып куймау һ.б.

*АРКЫЛЫНЫ-БУЙНЫ* ❖ **АРКЫЛЫНЫ-БУЙНЫ ҮЛЧӘҮ** *ирон.* Берәр нәрсә беләр аркага суккалап кыйнау. *Уклау белән аркылысын-буен үлчәп тәүбәгә китергән* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

*АРКЫЛЫСЫ-БУЕ* ❖ **АРКЫЛЫСЫ-БУЕ БЕР.** Бик юан, симез, *шулай ук к.* аркылы<га> җәелү. *Укучылар бик бердәм, аларны әнисе, апасы, абыйсы белән генә үскән аркылысы-буе бер чамада булган Миннәхмәт исемле малай цемент кебек ныгыта* (Р. Газиз. Тәрәзәләр).
Төрдәше: аркылы<га> җәелү һ.б.

*АРКЫЛЫСЫН* ❖ **АРКЫЛЫСЫН БУЙГА ИҢЛӘҮ** *к.* аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу. *Файдалы казылмалар эзләүче геологлар партиясе белән Себернең аркылысын буена иңләде* (Ә. Моталлапов. Сәфәр).
Төрдәше: аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу һ.б.

**АРКЫЛЫСЫН ТОРКЫЛЫ ДА САЛМАУ** *к.* аркылы<га> ятканны буйга алып салмау (куймау). *Аркылысын торкылы да салмыйм* (Ю. Әминов).
Төрдәше: аркылы<га> ятканны буйга алып салмау (куймау).

*АРКЫЛЫСЫН-БУЕН* ❖ **АРКЫЛЫСЫН-БУЕН АЙКАУ (ӘЙЛӘНЕП ЧЫГУ; ИҢЛӘҮ; ЙӨРЕП ЧЫГУ)** *к.* аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу. *Кешенең күңел галәмендә аркылысын-буен айкап, кешегә бөек мәгънә эзләнергә һәм табышырга кирәк* (Ф. Садриев. Бәхетсезләр бәхете). *Күлнең аркылысын-буен иңләгән балыкчылар исә бу утрауда төрле сәер хәлләр булу хакында сәгатьләр буе сөйли ала* (М. Кәбиров. Бердәнбер һәм кабатланмас).
Төрдәше: аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу һ.б.

**АРКЫЛЫСЫН-БУЕН ҮЛЧӘҮ (ҮЛЧӘП КАЛУ).** 1. Төрле яклап уйлау.– *Ширкәт дигәннән, уйлана бит әле халык... Аркылысын-буен үлчи* (М. Маликова. Язгы такыялар).

2. Кешенең киемен, үз-үзен тотышын тикшерү, гайбәтен сату. *Яшьрәк чакта Евгений белән Рәшидә андыйларга, ягъни гаиләсен саф мәхәббәткә нигезләп түгел, акыл белән чамалап, аркылысын-буен үлчәп, нәсел-нәсәбен тикшереп корган кызларга, «самка» дип кенә карый торганнар иде* (М. Маликова. Мендем биек тауларга).
Төрдәше: иңен-буен белеп (үлчәп) калу.

**АРКЫЛЫСЫН-БУЕН ҮТҮ.** 1. Күп йөрү, күпне күрү. *Бездә илнең аркылысын-буен үтеп, чит илләрдә дә булырга тырышкан* (Сөйләм).
Төрдәше: аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу һ.б.

2. Берәр эштә тәҗрибәсе зур булу. – *Бар, мастер янына барып кил, ул ярдәм итәр дип уйлыйм, лекальщик һөнәренең аркылысын-буен үткән ул* (Сөйләм).
Төрдәше: авызы пешкән өреп капкан һ.б.

*АРКЫЛЫСЫННАН* ❖ **АРКЫЛЫСЫННАН АЛЫП БУЕНАЧА.** Бер җирен дә калдырмыйча, үтәдән-үтә. *Мин ул күлне аркылысыннан алып буенача үтеп чыктым, балыклы урыннарны яхшы беләм* (Сөйләм).
Төрдәше: аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу һ.б.

**АРКЫЛЫСЫННАН КӨН (КӨН ЯКТЫСЫ; КҮРШЕ АВЫЛ) КҮРЕНӘ** *ирон.* Үтәли күренү. *Диеталар белән коры сөяккә генә калган инде, аркылысыннан күрше авыл күренә* (Сөйләм).

*АРКЫЛЫСЫННАН-БУЙГА* ❖ **АРКЫЛЫСЫННАН-БУЙГА ЯРЫП ЧЫГУ** *к.* аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу. *Җамали бу дөньяны аркылысыннан-буйга ярып чыкты, тик өмет өзде* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).
Төрдәше: аркылыга да, буйга да әйләнеп (йөреп) чыгу һ.б.

*АРЛЫ-БИРЛЕ* ❖ **АРЛЫ-БИРЛЕ БӘРЕЛҮ (СУГЫЛУ).** 1. Эч пошып, нишләргә белмичә аптырап, борчылып йөрү. *Хәкимҗан белән без, уртага узарлык буш ара эзләп, арлы-бирле сугылган арада, тагын байтак вакыт узды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).
Төрдәше: ары әйләү, бире әйләү; ары барып, бире килеп; ары бәрелү, бире сугылу; ары сугылу, бире сугылу; ары сугылып, бире бәрелеп; арык-сурык йөрү; әрле-бирле бәрелү (сугылу) 1; әрле-бирле йөрү 1; әрле-бирле килү 1.

2. *күч.* Төрле уйлар уйлау, фикер эзләү. *Хатынның сүзләре бер колагыннан керә тор-*

*ды, икенче колагыннан чыга торды, хәтер тартмасында тукталыр урын таба алмыйча, арлы-бирле сугылып, икенче колагыннан чыга барды* (Ф. Яхин. «Бакыр бозау» артыннан). *80 ел буена үз традицияләрен югалткан татар янә арлы-бирле бәрелә башлады* («Матбугат. ру» порталы).

Төрдәше: ары бәрелү, бире сугылу; ары сугылу, бире сугылу; ары сугылып, бире бәрелеп; әрле-бирле бәрелү (сугылу) 2; әрле-бирле йөрү 2; әрле-бирле килү 2.

*АРМАЙ* ❖ **АРМАЙ СУГУ** *иске.* Мәдрәсәдә «армай сугу» уенын уйнаганда, талчыбык белән суктыру җәзасы. *Талчыбык белән кешене суктыру җәзасы. Сугучы «армай» дип аталган* (Н. Исәнбәт).

*АРМЫЙ* ❖ **АРМЫЙ ЭШЛӘ! – САРЫ МАЙ ТЕШЛӘ! <КИСМӘГЕНӘ ТӨШМӘ!>.** Кырда эшләгән вакытта исәнләшү-сәламләшү төре («армый эшлә!» («Эшегез уңышлы булсын!») дигән теләккә «сары май тешлә!» дип җавап биргәннәр). *Ак майдан эретеп ясала торган сары май атамасы изге теләктә (армый эшләгез, сары май тешләгез!) кулланыла* («Фәнни Татарстан» ж., 2017, 4). *«Армый эшләгез!» дигән кешегә «Сары май тешләгез! Кисмәгенә төшмәгез! дип шаяртып калалар* (Р. Абдуллина. Сөйләм культурасы). *Без дә аларга кычкырабыз: – Армый эшләгез! – Сары май тешләгез! – Кисмәгенә төшмәгез!* (Ш. Маннур. Агымсуларга карап).

Төрдәше: алды-арты хәерле (хәерлегә; яхшы) булсын (була күрсен)! һ.б.

*АРПА* ❖ **АРПА КАМЫРЫ.** Уңмаган, булдыксыз кеше. *Беләмсез, туташ, нинди генә эш булса булсын, аның башында хатын-кыз йөрәге кушылмаса, ул арпа камыры булып чыга* (Г. Исхакый. Мөгаллимә).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**АРПА КҮРСӘТЕП, БОДАЙ САТУ.** Хыянәтле сәүдә турында. – *Син әле иске гадәтләреңне ташламадыңмы, һаман да арпа күрсәтеп, бодай сатып йөрисеңме?* (Сөйләм).

**АРПА СУЫ.** Сыра. <…> *Арпа суы болыннарын, кайнап торган яшьлек дәртен кая куярга белмичә, бөтен көтүе белән басу чабып узуларны яңадан күз алдына китергәндер?* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**АРПА ТАЛКАНЫ.** Оешмаган эш, оешып бетмәгән халык. *Коммуна оештырабыз дип берләшкәннәр, әмма арпа талканы килеп чыккан* (Сөйләм).

**АРПА ЧӘЧЕП, БОДАЙ АЛЫРГА ТЫРЫШУ.** Булмас эшкә тотынырга маташу. *Арпа чәчеп, бодай алырга тырышкансыз сез, машинаның рәтен белүчегез булмагач, нигә дип остаханә оештырып маташтыгыз?* (Сөйләм).

**АРПА ЭЧЕНДӘ БЕР БОДАЙ.** Халык эчендә хөрмәткә лаек булган кеше. *Халык, халык дисәк тә, кешеләрне барысы да бер үк түгел, арпа эчендә бер бодай да була* (Сөйләм).

*АРПАНЫ* ❖ **АРПАНЫ КИБӘКТӘН АЕРМАУ (АЕРА БЕЛМӘҮ; АЕРА АЛМАУ)** *ирон.* авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү. – *Әгәр блокларны үзебез коеп карасак? – Бу эштә арпаны кибәктән аера белмичә торыпмы?* (Рав. Вәлиев. Каурыйлар чыныкканда).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

*АРПАҢ-КӨРПӘҢ* ❖ **АРПАҢ-КӨРПӘҢ АШ БУЛСЫН, БУГАЗЫҢА ТАШ БУЛСЫН (ТОРСЫН)** *к.* авыз<лар>ын корт чаккыры! *Арпаң-көрпәң аш булсын, бугазыңа таш булсын* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).

Төрдәше: авыз<лар>ын корт чаккыры! һ.б.

*АРСАҢ* ❖ **АРСАҢ, АТ ЯЛЛА, <ҮЗЕҢ ҖӘЯҮ БАР>.** «Арыдым» дигәнгә җавап буларак әйтелә. – *Йә, булдыңмы инде, Равил абый? Арыдыңмы? – Арсам, ат яллармын, Рухия, – диде Равил* (А. Нуруллин).

*АРТ* ❖ **АРТ АЧЫЛУ.** Гаеп ачыклану, яшерен эш фаш булу. *Имән өстәле артында тыныч кына утырырга уйлаган иде, ләкин булмады: арты ачылып, рәсми органнар тикшерү эшен башлап җибәрделәр* (Сөйләм).

**АРТ АЯГЫНА УТЫРГАН ЭТ КЕБЕК.** Буйсынучан булып, бик түбәнсенеп, яраклашып хезмәт күрсәтү. *Кыяфәтенә дә тыныч кына карап булмый, әйтерсең арт аягына утырган эт кебек* (Сөйләм).

Төрдәше: арт аягына чүгәләү.

**АРТ АЯГЫНА ЧҮГӘЛӘҮ** *к.* арт аягына утырган эт кебек. *Арт аягына чүгәләгәнмени, башын, мескенләнеп, аска игән, тавышы да ярым ишетелерлек кенә* (Сөйләм).

Төрдәше: арт аягына утырган эт кебек.

**АРТ АЯКЛАРЫ БЕЛӘН ТӘПИЛӘП ТОРУ.** Ялагайлану, ничек булса да ярарга тырышу. *Сүзем авыр булмасын, мәрхүм гел байлар тирәсендә арт аяклары белән тәпиләп тору, ярлыларны талап йөдәтүдән башканы белмидер иде* (Ш. Камал).

Төрдәше: арт аякларында йөрү (тору); арт аякта бию; өлтерәп йөрү (тору) 2; табан астын ялап яшәү; табан ялау; тәлинкә (тәрилкә) тоту (ялау).

**АРТ АЯКЛАРЫНДА ЙӨРҮ (ТОРУ)** *к.* арт аяклары белән тәпиләп тору. *Анда синең ише ахмаклар гына түгел, арыслан ишеләр дә бер шакмак шикәр өчен арт аякларында торалар* (Т. Миңнуллин).

Төрдәше: арт аяклары белән тәпиләп тору һ.б.

**АРТ АЯКТА БИЮ** *к.* арт аяклары белән тәпиләп тору. *[Юаныч] Урыслар алдында арт аякларында биеп йөриләр* (Р. Хәмид).

Төрдәше: арт аяклары белән тәпиләп тору һ.б.

**АРТ БЕЛӘН КИРТӘ ҖИМЕРМӘҮ** *ирон.* Урта куллы, башкалардан бернәрсә белән дә аерылып тормаган. *Гайшәбикә – Фатыйманың киресе ул – арты белән киртә җимерми: булса – шатлана, булмаса – хафаланмый* («Шәһри Казан» газ.).

Төрдәше: ах итәрлек (килерлек) түгел; әйтеп мактарлык түгел, салып таптарлык түгел; әллә кая сикермәү; әллә кем түгел; әллә ни (нәрсә) түгел (ни юк); әллә нинди ... түгел; искитәрлек түгел; ул кадәр ... түгел; урта кул.

**АРТ БЕЛӘН КИРТӘ ҖИМЕРҮ.** Киреләнү, юкка көчәнү, эшне бозу (булмас эшкә гайрәт күрсәткән кеше турында). – *Нишләп әле син, яхшыдан яман туган нәрсә, артың белән киртә җимереп йөрисең, ә?* (Ә. Еники. Рәхмәт, иптәшләр). *Артың белән киртә җимерә алмыйсың. Тик кемгә барып егылырга?* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: арт белән киртә ярату.

**АРТ БЕЛӘН КИРТӘ ЯРАТУ** *к.* арт белән киртә җимерү. *Иван Ивановичка кушылып, аның дәртен кушайтып, «Шулай итәбез!», «Җиңәбез дошманны!», «Козецкийны кәҗәгә атландырабыз!» дип, Басыйр Бариевич нәгърә орса да, иртәгесен, Шидловскийның холыксызлыгын, арты белән киртә яратуны белгәнгә, Мәскәүгә барырга аягы тартмады* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: арт белән киртә җимерү.

**АРТ БЕЛӘН ТЕГЕРМӘН ТАРТУ** *тупас.* Эшләмичә ашау, тик яткан җирдән туену. – *Тәки тормышка җайлашып китте Госман, арт белән генә тегермән тарта* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз белән чебен аулау һ.б.

**АРТ БЕЛӘН ТОРУ.** 1. Тискәре тору, йөз бирмәү, кабул итмәү. *Ләкин, юк, төп бәла кодалыктакардәшлектә түгел. Казан морзалары курчак ханга арты белән торуны барыбер туктамады* (В. Имамов. Сөләйман солтан).

Төрдәше: күз дә салмау; күңел кабул итмәү (күрмәү); күңел суыну 3; күңел сүрелү; күрә алмау; кырын карау; үлеп тормау.

2. Тормыш турында: кыенлыклар китерү, каршылыклы булу. *Тормыш Сибайга гел арты белән торды* (Г. Бәширов). *Хәер мөстәкыйльлеге тартып алынган милләтләргә арт белән торган иҗтимагый-сәяси яшәеш шартларында әдәби сүзнең журнал сыйфатында чираттагы елда да өйләребезгә үтүе – үзе үк сөенеч түгелмени?!* (Р. Харрасова. Уйлар Тукайга илтә).

Төрдәше: аркылы килү (төшү) 2 һ.б.

**АРТ БЕЛӘН ТЫН АЛУ** *тупас,* Тын да алмыйча утыру. *Бәһрәмия китаплар тулы күрше бүлмәгә кереп шыла һәм, халык үзе әйткәнчә, арты белән генә тын алып утырса, остабикә исә, хәлне аңламыйча, өйгә басып керүчеләрне Алладан куркырга, тәмуг кисәүләренә әверелмәскә үгетләп ялварды, бичара* (Ә. Баянов).

**АРТ БЕЛӘН ТЫҢЛАУ** *ирон.* Бөтенләй тыңламау, игътибар бирмәү. – *Кичә мин сөйләгәннәрне арт белән тыңламаган булсаң, мондый хаталар җибәрмәс идең* (Сөйләм).

**АРТ БЕЛӘН УТЫРУ.** Тискәре мөнәсәбәтне белдерү, күрәсе дә килмәү. *Яшь хәлеңдә торма бу картың белән, / Сөймә картны, утыр артың белән* (Г. Тукай).

**АРТ БИРҮ.** 1. Рәхмәтле булмау, яхшылыкка яманлык белән җавап бирү, битараф булуны сиздерү. *Һич боларның җитмәде ул кадәренә, / Җитмәсә, арт бирде Тәңре әмеренә* (Ш. Бабич). *Әйтик, син татарлыкка, мин чувашлыкка арт бирә алырбызмы?* (З. Бәшири).

2. Бизү, читләшү. *Буртас үлгәч, мукшы, чирмеш бер-бер артлы арт биргәннәр* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).

Төрдәше: аркасын әйләнү һ.б.

3. *сөйл.* Качып китү, карышу. *Дошман гаскәрләре җиңелде, дошман арт бирде* (Н. Фәттах. Четерекле булды безнең заман).

Төрдәше: арка белән борылу (әйләнү) 2 һ.б.

**АРТ БИТЕ.** Кешенең арт ягындагы билдән түбән өлеше. *Арт битенә аның – кызган тимер! – Һоп-па! – Шул учакның уртасына!* (Зөлфәт). *Алып бирдем һәм арт битемнең уттай кызышып алуын сизмичә дә калдым.* (Н. Гамбәр. Әткәй белән сөйләшү).

**АРТ ИТӘГЕ ЙОМАРЛАНГАНЧЫ ӨЙДӘ УТЫРУ.** Өйләрендә беркая да чыкмыйча утыра торган кызлар турында. *Бөтен эш тә шунда: ул арт итәге йомарланганчы өйдә утыра торган кызлар рәтеннән санала* (Сөйләм).

**АРТ ИТӘГЕҢНЕ ҖЫЕП ЙӨРҮ** *к.* абай булу. *Болынга кичке уенга төшкәч, арт итәгеңне җыеп йөр* (Сөйләм).

Төрдәше: абай булу һ.б.

**АРТ ИШЕКТӘН.** 1. Кибеттән танышлык белән, яшертен рәвештә мал алу. *Эзидән ипи кайтса кайта, кайтмаса – юк, кайтарсалар да безнең ише карт-корыга тәтеми, хәзер арт ишектән бүлешеп бетерәләр* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

2. Ришвәт, майлау ярдәмендә укырга яки эшкә урнашу, дәрәҗә алу. *Кем белә, бәлки, берәр татар сексоты, шымчы, җасус, тарихка арт ишектән булса да кереп калу нияте белән, хатирәләрен язып баргандыр* (А. Тимергалин. Сүнмәс ут янында уйда без...).

Төрдәше: авыз майла<н>у; авызга тыгу; әҗер бирү (төртү); май белән юу; ришвәт бирү; ришвәт төртү; сатып алу.

**АРТ КАПКА.** Йорт ихатасының абзар як капкасы. *Ераккарак, аулаграк җиргә, һәм мин абзарларга таба уздым да шундагы арт капкадан болынга, Түреш буена чыгып киттем* (Ә. Еники. Җыз кыңгырау).

**АРТ КУЮ.** Сый-хөрмәтне яманлык белән кайтару. *Бөтенләй үк башсыз булмаса, ризыкка арт куймас* (Ә. Камал. Үз юлыннан).

Төрдәше: ашаган табакка (савытка; табынга) төкерү (пес итү; чүгәләү); ашка таш ату; ашка таш белән бәрү (җавап бирү; кайтару); ашъяулыкны пычрату; яхшылыкка начарлык белән җавап бирү; яхшылыкка яманлык белән кайтару.

**АРТ КЫЗДЫРЫП ЙӨРҮ.** Эшсез йөрү. – *Уборкы вакытында ничек шулай арт кыздырып йөрү ул? – диде* (З. Мәхмүди. Тәмуг чәчәге).

Төрдәше: авыз белән чебен аулау һ.б.

**АРТ МАҢГАЕ ЧОКЫРЛЫ.** Ялганчы кеше турында. *Ялганчы чокырына кара, арт маңгае да чокырлы бит аның!* (Сөйләм).

**АРТ САБАГЫН ИСКӘ ТӨШЕРҮ**. Үткәндәге гыйбрәтле хәлләрне искә төшерү. *Беренче чананы куып уза башлагач ук, аңа кышкы юл турындагы күптән онытылып беткән арт сабакларын искә төшерергә туры килде* (М. Әмир).

**АРТ<ТАГЫ> САБАКНЫ ТЫҢЛАТУ**. 1. Нык ачулану, тиргәү. – *Дөрес тә, – диде карт, – азрак арттагы сабакларын тыңлаткан-да зарар булмас иде булуын; юк шул инде, картаям, егетләр!* (Ш. Камал. Акчарлаклар).

Төрдәше: акыл бизмәненә утырту һ.б.

2. *к.* авыз җебетү 2. *Арт сабагыңны тыңлатырга хәзер дә кыйбат алмам* (А. Шамов. Кыз урлау).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

3. Гаскәр туплап, көндәшен җиңү. *Бу юлы зур гаскәр җыеп яу белән килүчеләрнең арт сабакларын тыңлатты* (Сөйләм).

4. Җәза бирү, орышу. *Буржуйларның арт сабакларын тыңлатырга кирәк* (Ф. Хөсни).

Төрдәше: акыл бизмәненә утырту һ.б.

5. Хатаны төзәтү. *Хәлфә ялгыш укучыларны тыңлып торды-торды да, талчыбык алып, арт сабакларын тыңлатырга кереште* (Сөйләм).

**АРТ САБАКНЫ УКЫТУ** 1. *к.* акыл бизмәненә утырту. *Кыштан ук уенга салып әйтә килде: – Нурый абзый, мине җибәр, арт сабакларын бер укытып кайтыйм шул тел*

*бистәләренең, – диде* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). *«Туган итеп» арт сабагын укытачак әле ул аның!..* (Г. Бәширов. Сарут).
Төрдәше: акыл бизмәненә утырту.

2. *к.* авыз җебетү 2. *Үземә үзем ант итеп куйдым: арт сабагын укытам мин ул дуңгызның* (Ф. Хөсни. Йөзек кашы).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

3. *к.* арт<тагы> сабакны тыңлату 3. *Әйдә, бергәләшеп арт сабагын укытыйк. Гаскәр туплап бар да олуг кенәз ярлыгын миңа кайтар* (В. Имамов. Карабәк).
Төрдәше: арт<тагы> сабакны тыңлату 3.

4. Җәза бирү, орышу. – *Ул, моннан ике ел элек үк, безнең муллаларның арт сабагын укыткан иде* (А. Шамов. Фатирда).
Төрдәше: арт<тагы> сабакны тыңлату 4 һ.б.

**АРТ САНГА КОЯШ ТӨШКӘНЧЕ.** Ялкаулык, кояш көн үзәгенә җиткәч кенә йокыдан тору. – *Беләсеңме, нигә арт саныма кояш төшкәнче йоклыйм, нигә кәеф кенә яшим мин?* (Г. Бәширов. Җидегән чишмә). – *Энекәш! Арт санына кояш төшкәнче йоклый торган халыкка камчы кирәк* (Д. Салихов. Чукрак).
Төрдәше: абуз өстендә арыш сугу 2 һ.б.

**АРТ САНГА УТ ТӨРТҮ.** Начарлык эшләү (эшеннән алдырту һ.б.). – *Озаграк эшләп партиягә керсә, синең дә арт саныңа ут төртә иде* (Д. Салихов. Чукрак).

**АРТ САННАРЫН КОРТ ЧАККЫРЫ!** Ошаган нәрсә турында шаяртып әйтү. *Бигрәк тә моңлы җырлыйлар, арт саннарын корт чаккыры!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**АРТ САННЫ КОЯШ КЫЗДЫРА БАШЛАУ** *к.* абуз өстендә арыш сугу 2. – *Кайчан тора икән соң ул? Арт санын кояш кыздыра башлагачмы?* (Г. Бәширов).
Төрдәше: абуз өстендә арыш сугу 2 һ.б.

**АРТ САННЫ (ЧҮМЕЧНЕ) КОЯШТА КЫЗДЫРУ.** Эшсез тик яту. *Арт санын кояшта кыздырып ятуның да, намаз укып, яулыгыңны ябып, оныкларыңны үз яныңа җыеп, коймак пешерүнең дә үз вакыты булырга тиештер...* («Шәһри Казан» газ.).
Төрдәше: абуз өстендә арыш сугу 2 һ.б.

**АРТ САННЫ КҮТӘРӘ АЛМАУ**. 1. Урыныннан авырлык белән күтәрелү. *Башта ул тезләнде, аннары кулларына таянды, шуннан соң гына ястык кебек арт санын күтәрә алды* (М. Хәбибуллин. Хан оныгы Хансөяр). *Моңсу коңгырт күзләрен тутырып, әле пычак кайрап торган әтигә, әле арт санын күтәрә алмыйча бәргәләнгән бәрәнгә карады да: – Тимә, яшәсен, нарасый гына бит әле, кызганыч... – диде* (Ш. Маннапов. Мәңгелектән елмаю).

2. Эшкә-йомышка дигәндә озак селкенүчән, иренчәк. *Аны алганчы вакыт уза, башкалардан артта каласың. Димәк, арт саннарын күтәрә алмый калганнар һәм, әлеге дә баягы, кылычларына абынып соңарганнар белән беррәттән атка атлану күнегүләрен кабатларга мәҗбүр буласың* (Р. Сафин. Атландым атның биленә).
Төрдәше: арты авыр <тарта> (ике маддә өчен дә).

**АРТ САНЫН КОРТ ЧАККЫРЫ** *карг.* Авыр кыймылдаучан, ялкау кешеләрне сүгү сүзе. – *Аһ син, арт санын корт чаккыры! Ялгыш ычкынган бит, әй, ялгыш!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**АРТ САНЫН ЯЛАУ** *эвф.* – *Митрәй кенәз, ул тәхеттә калсын дип, юкка гына Туктамышның арт санын тугры эттәй ялый* (В. Имамов. Карабәк).
Төрдәше: авызга бал да май булып керү һ.б.

**АРТ САРУЫН КАЙНАТЫП ЙӨРҮ** *эвф.* Йөдәткеч, бәйләнчек, күңел болгаткыч кеше турында. – *Бар, эшеңдә бул, арт саруын кайнатып йөрмә әле монда!* (Сөйләм).

**АРТ ТАЙДЫРУ** *эвф.* Эштән, берәр чарага катнашудан баш тарту, җаваптан, сүздән качу. – *Ә син җаваплылыктан арт тайдырасың, качасың! – дип чәңчеде Зәйнагов. – Ә намусың?* (Х. Камалов. Үксезләр).

**АРТ ТИДЕРҮ.** Утыру. *Карабәк үзе дә – Сарай тәхетенә ике тапкыр арт тидергән таҗдар* (В. Имамов. Карабәк).

**АРТ ЧҮМЕЧНЕ (САННЫ) КОЯШ<ТА> КЫЗДЫРУ.** Эшсез тик яту, кызынып яту. *Хәмзәләр таң тишегеннән үк, тавык сыман чүпләнә, ә менә көмәнле Рокыя арт чүмечен кояш кыздырганчы йокы симертә* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: авыз күтәреп яту һ.б.

**АРТ ЧҮМЕЧНЕ СИКЕРТҮ.** Санга сукмау. – *Әтүсә нишләп безнең түрдән үткәндә, арт чүмечеңне сикертәсең?* (Н. Гыйматдинова).

**АРТ ЧҮМЕЧКӘ МЕНЕП ТӨШҮ.** Башның артына яки муенга сугу. *Арт чүмечеңә менеп төшәргә дә күп сорамый җизнәкәй* (Ф. Зыятдинов. Авылдашның авыр юл башы).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АРТ ЧҮМЕЧКӘ ТИБҮ (БИРҮ)** *к.* авыз җебетү 2. *Ул, йөгереп килеп, таныш булмаган малайның арт чүмеченә берне бирде* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АРТ ЧҮМЕЧТӘН ҮКЧӘГӘ ДУЛКЫН ЙӨГЕРҮ.** Гәүдә буенча ток йөгереп үткән кебек хис кичерү. *Хамисәнең арт чүмеченнән үкчәсенә дулкын йөгерде, дөнья зең итеп куйды: күрде! Ниһаять игътибар итте!!* (Ә. Дусайлы. Өермә).

**АРТ ЯГЫ СЫЕК.** Хәлдән килмәү, булдыра алмау. – *Арт ягы сыек икән, ник батырлар арасына кысыла?!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**АРТ ЯГЫ (АРТЫ) ЮЕШ.** Гаебе булу турында. *Сәяхнең дә арты юеш* (Х. Камалов). – *Куркытмакчы буласыңмы? Булдыра алмассың! Арт ягың юеш синең, арт ягың!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: алай гына мулла (патша; хан) кызында да була.

**АРТ ЯГЫНА АЯК САЛЫНДЫРУ.** Билгеле бер яшь тулып китү турында. *Ә егетнең – кызкыркын куркытырлык яшькә үрмәләгән, утызның арт ягына аяк салындырган карт буйдакның – хатын-кыз исе дә иснәгәне юк* (Н. Гыйматдинова).

**АРТ ЯГЫНА УТ КАПКАНДАЙ ЧАБУ** *к.* агы-карасы <күзгә> күренмәү. – *Семен инде хәзер арт ягына ут капкандай чабып йөрсә дә өлгерә алмаячак* (В. Имамов. Карабәк).

Төрдәше: агы-карасы <күзгә> күренмәү һ.б.

**АРТ ЯК.** 1. Өйнең аркасында булган кара як, йортның абзар ягындагы очы. *Без, куркудан дер-дер килеп, арт як капкага таба елыша башладык* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

2. *иске.* Нәсел-нәсәп, чыгышы. *Аларның арт якларын ачыклый башласаң, аннан әллә кемнәр килеп чыгуы мөмкин* (Сөйләм).

**АРТ ЯК АЯЗ.** Яшерә алмаган гаебе ачык күренеп тору. *Ә ул яктан минем арт як аяз... Соңгы вакытларда юк-бар нәрсәгә бирелеп китүчән адәмгә әйләндем* (Ф. Хөсни).

**АРТ ЯК ТАЗА ТҮГЕЛ.** Артында начар эшләре, гаепләре булу. *Әле ярый төпченеп тормадылар, югыйсә аның арт ягы таза түгел* (Сөйләм).

**АРТ ЯККА ЙОМШАК.** Җенси тотнаксызлык. *Белми дип уйлыйсыңмы әллә, аның арт якка йомшак икәнлеге күпләргә билгеле* (Сөйләм).

**АРТ ЯККА НАШАТЫР КЫСТЫРУ.** – *Арт ягына нашатыр кыстырсалар, бүтән кая качсын?* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: агы-карасы <күзгә> күренмәү һ.б.

**АРТ ЯККА ТӨТЕН ҖИБӘРҮ.** Шөбһәләндерү, куркыту. *Син бит, Рәис Фәтхуллович, Тяжельниковның арт ягына төтен җибәрдең* («Кызыл таң» газ.).

**АРТ ЯККА УТ ТӨРТҮ.** Куркыныч хәлгә кую, авыр хәл ителә торган торышны китереп чыгару. *Малаеның арт ягына ут төртсәң, әтисенең дә теле ачылыр* (М. Миншин. Кызыл диплом).

Төрдәше: арт якка ут ягу; артка ут кабу.

**АРТ ЯККА УТ ЯГУ** *к.* арт якка ут төртү. *«Көязләндерермен әле мин сине, – дип усалланып уйлады Әдибә, – арт ягыңа ут ягармын* (И. Нәбиуллина. Миләш тәме).

Төрдәше: арт якка ут төртү һ.б.

**АРТ ЯКТАН ТӨТЕН (ПАР) ЧЫГУ** *гади с.* Тирләп-пешеп эшләү, туктап ял итәргә дә вакыт булмау. *Иртәдән кичкә кадәр ашыга-ашыга эшләргә туры килде, арт яктан төтеннәр чыкты* (Сөйләм).

Төрдәше: арттан төтен (пар) чыгу.

**АРТ ЯКТАН ТЫН АЛЫП ЯШӘҮ.** Шауламыйча, бер нәрсәгә дә тыгылмыйча, тын яшәргә тырышу. *Минем күңел иркен, бүген арт якларыннан тын алып яшәгән Мәскәү белән Рәзәненә дә чапкын җибәрттерәм, эчләре янсын ла, чукынып китмәгәе!* (В. Имамов. Карабәк).

*АРТКА* ❖ **АРТКА БОРЫЛЫП (ӘЙЛӘНЕП) КАРАУ.** Үткәннәр турында уйлану, фикер йөртү. *Нигә, Мирвәли илле сигез еллык гомерен дә артына борылып карамыйча үткәрә алды ич!* (А. Гыйләҗев. Өч аршын җир).
Төрдәше: артка карау.

**АРТКА ҖӘЕЛҮ (ҖӘЕЛЕП УТЫРУ).** Эчне алга чыгарып, артка ятыбрак утыру. *Ишек төбендәге куркынган хатыннарга, өстәл артына җәелеп утырган Чолыкка күз генә салып алды да, хатыннарга карап, исәнләшеп тә тормыйча кырысланды* (З. Зәйнуллин. Каршы таулар).

**АРТКА КАЛУ.** 1. Мәдәнияттә, икътисади торышта һ.б. тармакларда эш начар тору, яки таләпләренә җавап бирмәү. *XXI гасыр үсештән артта калган телләргә карата тагы да аяусызрак булырга охшый* (А. Тимергалин. Айга ашкыну һәм «Алга! Марска таба!).

2. Ярышта яки бүтән бәйгедә башкаларны уза алмау. *Тирә-якка аталы Кәрим миннән күз күреме җир артка калып килде* (Г. Ибраһимов. Табигать балалары).
Төрдәше: артта булу; артта калу (ике маддә өчен дә).

3. Надан калу, тормыш таләпләренә җавап бирерлек хәлдә булмау. *Мөселманнарның артка калуларына дин сәбәп булырга да мөмкин түгел* (Г. Бубый. Хатыннар).
Төрдәше: ак-кара аермау һ.б.

**АРТКА КАРАУ.** Үткәннәрне искә төшерү. *Артка караса – үкенечләр, алда – кара пәрдә...* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Җылылык тоеп кара да язга, Артка карамый бар син сөюгә* (А. Нәҗми. Идарә).

**АРТКА КИТҮ.** Нәрсә дә булса начарлану. *Көннән-көн эшләр артка китеп, өмидләр өзелгәндә, / Кайгылар, бәхетсезлек, мохтаҗлыклар күз алдына тезелгәндә* <...> (Г. Камал. Истикъбаль). *Бер ел эчендә никадәр үзгәрү, бер ел эчендә никадәр артка китү!* (Г. Исхакый. Тартышу).

**АРТКА КУЙМАУ.** «Уңайсыз, килешмәс дип тормау» мәгънәсендә, ягъни карышмый, баш тартмый, гөнаһ дип санамый. – *Корбангали тегүчене тамак колы дип булмаса да,* <...> *«казна суын» артка куймаганлыгын беләбез* (Ф. Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы).

**АРТКА КУЮ.** Баш тарту, ташлау. *Ә шулай да, ярый әле өметләнә, хыяллана аласың, юкса бу тормышны әллә кайчан ташлап, артка куеп качар идең!* (Ф. Яхин. Август ае).

**АРТКА ТАШЛАУ.** Калдыру, кую, берәр шөгыль белән мәшгуль булуны туктату. ... *Өлгер күңелем, сары көзне артка ташлап, / Инде кышкы йокысында булган икән* (Г. Гыйльманов. Албастылар).

**АРТКА ТИБҮ (ТИБЕП ЧЫГАРУ).** 1. Куып чыгару. *Начальникләр үзләренә эшләттеләр-эшләттеләр дә артыма типтеләр* (Х. Камалов). – *Өч көннән сессия, синең артыңа тибәчәкләр* (Н. Гыйматдинова).

2. *к.* дөньяның артына тибү. *Шәрифҗан кебек, искенең артына типкән, күңеле белән яңага бәйләнеп өлгергән кешеләр өчен кара көннәр алып килә дошман* (И. Гази. Онытылмас еллар).
Төрдәше: артына тибеп яшәү.

**АРТКА ТУБАЛ ТАГУ.** Гаиләсе яки үзе карамагында берәр кеше булып, шуның мәшәкатен күрү. – *Әлегә минем артыма тубал тагылмаган* (Ә. Хәсәнов. Әнис алмалар).

**АРТКА УТ КАБУ.** Гаепләре ачыклану, законга каршы килгән эшләре билгеле булу. – *Ә-ә, артыгызга ут капкач, шәрә икәнегез исегезгә төштемени?* (Р. Габделхакова. Зинһар, югалма...). *Артына ут капканны сизмичә, өске катта яткан! Ә Гөлчәчәк авыру килеш иде, хатын-кыз башы белән дә акча эшләргә тырышып йөргән булган иде* (Д. Булатова. Соң түгел!).

**АРТКА УТ КАПКАН КЕБЕК** *к.* агы-карасы <күзгә> күренмәү. – *Алай артыңа ут капкан кебек чапкач, сәбәбе бардыр инде* (В. Имамов. Казан дастаны).
Төрдәше: агы-карасы <күзгә> күренмәү һ.б.

**АРТКА УТ КУЮ.** Кирәкләрен бирү. *[Бәкер] Без аларның артларына бик тиз ут куярбыз* (Ф. Бурнаш. Таң).

**АРТКА УТ ЭЛҮ.** Уйландыру, берәр мәсьәләне хәл итәргә этәрү. – *Син хәзер җирлек башлыгының артына ут эл. Халык белән сөйләшеп, синең файдага карар кабул итсен* (Н. Гыйматдинова. Үзем генә беләм).

*АРТКА-АЛГА* ❖ **АРТКА-АЛГА КАРАМАУ** *к.* алга-артка карамыйча. – *Сез хикәянең ахырын укы-*

*ганда, уңга-сулга һәм артка-алга карамыйча, ашыккансыз, – дип елмайды, аның киңәеп елмаюында хыялны чынга тиңли алуы көче һәм чынны хыялга корып тасвирлый белүе кодрәте ялтырап чагылды – сер пәрдәсен ябарга хәйлә дә кирәк ич!* (М. Хуҗин. Чомбырак).

Төрдәше: алга-артка карамыйча һ.б.

*АРТКЫ* ❖ **АРТКЫ АКЫЛ.** Эше беткәннән соң гына башка килә торган, ачы тәҗрибә белән килгән акыл. *– Ах, – дисен, – ул миңа алай әйткәндә, мин болай әйтәсе калган икән, мин сүземне менә ничек-ничек дәлилләргә тиеш булганмын: ах, ник шулай дип кенә әйтмәдем: менә бит, шулай бер генә сүз белән әйтергә булган! – дип, сиңа хәзер арткы акылың исеңә төште, бу акыл хәзер «дошман»ны бер бәрүдә кисәрлек яңа һәм үткен бер фраза булып туды, ул синең телеңдә кат-кат әйтелә торгач, матур да, шома да булып китте, мәгънәсе дә аның саен конкретлаша барды* (Н. Исәнбәт. Мәкальләребез турында).

**АРТКЫ АКЫЛГА БАЙ КЕШЕ.** Алдан уйламыйча кызуланып эшләп ташлап, соңыннан ачы тәҗрибә алып үкенгән кеше. *Безнең һәрберебез кайвакыт арткы акылга бай кеше булып китә* (Сөйләм).

**АРТКЫ ПЛАНГА ЭТӘРҮ.** Хәзерге вакытта бик мөһим эш дип санамау. *Гаиләгезгә язуым бернинди арткы планга этәрү белән түгел иде* («Матбугат.ру» порталы).

**АРТКЫ ЧИСЛО БЕЛӘН.** Соңыннан, вакыты үткәннән соң. *Акчаны узган айлар өчен бирми калачаклар дип куркырга кирәкми: гыйнвардан бирле җыелган бурычны әниләргә арткы число белән исәпләп бирәчәкләр* («Татарстан яшьләре» газ.).

**АРТКЫ ЯК.** 1. *к.* арт як 1. *Без килгәндә, Рөстәм абыйның өендә йозак, үзе арткы як бакчада казына* («Ирек мәйданы» газ.).

2. Рәсми булмаган яшерен юл. *Кичкә таба арткы яклап кына урманчы янына барып килерсең* (Сөйләм).

**АРТКЫ ЯКТАН ПЫЧАК КАДАУ** *к.* аркага пычак (хәнҗәр) кадау. *Аларга сатылгандыр, арткы яктан пычак кадамасын, дип сөйләшүчеләр дә байтак кына* (В. Имамов. Казан дастаны).

Төрдәше: аркага пычак (хәнҗәр) кадау һ.б.

*АРТНЫ* ❖ **АРТНЫ БЕЛМӘҮ.** 1. Үзенең кимчелекләрен, гаебен белмәү, башкаларны тикшерергә ярату. *– Әгәр дә улыңа җәбер һәм җәфа салмасаң, мөселман булганлыгы өчен алдыңны һәм артыңны белми җәберләмәсәң, ул вакытта аны сиңа бирербез, – диде* (Ф. Яхин. Пәйгамбәребез Мөхәммәд). *Үзенең артын белми, кешеләрне тикшергән була тагын* (Сөйләм).

2. Нәрсә белән бетәчәген белмәү. *Килгән саен, бер угылыңа баш була алмыйсың, артыңы белмәгәч өйләндермәскә кирәк иде, дип әрлиләр* (Г. Ибраһимов). *Эш моның белән генә бетте дип уйлама, артын белмичә, шапырынырга ашыкма* (Сөйләм).

**АРТНЫ ҖЫЕП ЙӨРҮ.** Уяу булу, кайда нәрсә эшләвеңне уйлап, сак йөрү. *Кара аны! / Ни эшләгәнеңне белеп эшлә! / Артыңны җыеп йөр!* (Г. Рәхим).

Төрдәше: абай булу һ.б.

**АРТНЫ ИСӘПЛӘҮ.** Әйткән сүзнең яки кылган гамәлнең ахыры ни белән бетәчәген алдан уйлау. *[Әхмәт](үзалдына), Әхмәт алай артын исәпләми эш кыла торган кеше түгел!* (Г. Камал. Өйләнәм!.. Ник өйләндем).

**АРТНЫ КУЗГАТА (КҮТӘРӘ) АЛМАУ.** Авыр кузгалу, утырган урыныннан торырга яратмау. *Әлфия апаны бик хөрмәт итәм. 75 тә очып җырлап йөри әле, ә бу вакытта кайберәүләр артын күтәрә алмый хәтта* (bulmas.ru).

Төрдәше: авыр кеше 1 һ.б.

**АРТНЫ КУЮ.** Нәрсәне булса да тормышка ашырмас өчен киртә ясау. *Әллә шайтан аяк чалды, әллә Ходай тагын артын куйды* (В. Имамов. Карабәк). *Үзе дә бу көтмәгәндә артын куйган төссез дөньясыннан онытылырга тырышты Фәнзилә* (Г. Мирһади. Килмешәк).

**АРТНЫ КЫСУ (КЫСЫП ТОРУ)** *эвф.* Үзенең гаепле икәнен белеп, телен тыеп тору, эндәшмәү. *Авыл араларына чыгып, кире беткән аңгыра халыкка бераз җикеренеп кайтуны ниятләп торган исправник та әлеге хәбәрне ишетеп артын кысты* (М. Галәү. Мөһаҗирләр).

**АРТНЫ САЛЫП УТЫРУ.** Урыныннан кузгалмаска теләгәндәй җәелеп утыру, утырып торырга гына яратучы. *Патша тәхете буш торамы? Юк! Аңа менеп, артын салып утырырга теләүчеләр бихисап* (Р. Сибат. Инабәт).

**АРТНЫ ТӨРТҮ.** Берәр җиргә (нәрсәгә) утыру. *Бәхетсезлегенә күрә, яшь автор үзе дә ишек төбендәге урындыкка артын төртергә батырчылык иткән, имеш* (К. Кара. Депрессия).

**АРТНЫ ЭШЛЕЯ КЫСУ.** Инсанның ирегән чикләү. *Совет кешесе булып торганда да, инде хәзер үз көеңне үзең күрү ирегә бирелгән сыман тоелгач та авыздан авызлык чыкмый, муеннан камыт, аркадан ыңгырчак төшми, артны эшлея кыскан бит* (Ә. Гаффар. Богау).

*АРТНЫ-АЛНЫ* ❖ **АРТНЫ-АЛНЫ АБАЙЛАП (КАРАП)** *к.* алны-артны карап. – *Сез юкта, әллә нинди провокация оештырулары мөмкин. Гомумән, артны-алны карап йөрергә кирәк* (Г. Әпсәләмов). *Артын-алдын абайлап, яңадан трамвай-фәләнгә утырып азапланмадым, капчыгымны җилкәгә асып, җәяү генә киттем* (Г. Луч. Кадерле көчек. – Г. Сабитов тәрж.).
Төрдәше: алны-артны карап.

*АРТТА* ❖ **АРТТА БУЛУ. 1.** Кайсыдыр өлкәдә начар нәтиҗә күрсәтү. *Җәмгыять артта булганда, кайсы тармакка кагылсаң да – артта* (Ш. Галиев. Илһамым-мәхәббәтем).
Төрдәше: артка калу 1, 2 һ.б.

2. *к.* ак-кара аермау. *Киресенчә, халык, билгеле, ул вакытларда фән һәм техника ягыннан артта булган, әллә нихәтле хорафәткә, мифләргә ышанган* (Н. Исәнбәт. Мәкальләребез турында).
Төрдәше: ак-кара аермау һ.б.

**АРТТА КАЛУ** *к.* артка калу. *Тик бүген ул үсештә артта калды, чөнки эчке сәбәпләр генә түгел, тышкы сәбәпләр дә әдәбиятыбызның үсешен тоткарлыйлар, аңа үсәргә ирек бирмиләр* (А. Тимергалин. Сүнмәс ут янында уйда без...).
Төрдәше: артка калу 1, 2 һ.б.

**АРТТА СӨЙЛӘҮ**. Үзе югында, аның турында сөйләү. *Сез артта сөйлисез: Таһия Вилдән акыллырак дип. Чынлап та шулай* (Х. Камалов. Үксезләр).
Төрдәше: авыз чайкау 1 һ.б.

**АРТТА ТОРУ**. 1. Игътибар үзәгендә булмау, икенче планга калу. *Медицина алга киткән, ә халык артта торып калган* (З. Мурсиев. Хастаханә хастасы).

2. Исемлектә яки сафта соңгы урында булу. *Телгә батыр алда торыр, телгә фәкыйрь артта торыр* (Р. Абдуллина. Сөйләм культурасы).

*АРТТАН* ❖ **АРТТАН АТУ** *к.* аркага ату. *Арттан аталар хыянәтчеләр – / Шундый кануннар яшиләр бүген* (Ф. Мөслимова. Алтын йозак).
Төрдәше: аркага ату.

**АРТТАН АШАУ.** Өстәл янында ашамаган булып утырып, кеше югында ашау. *Аның сәер бер гадәте бар иде: табын янында чемченеп кенә утыра да, кеше таралгач, арттан ашый торган иде ул* (Сөйләм).

**АРТТАН БАРУ.** 1. Кемнең дә булса тарафдары, фикердәше булу. *Ул да шул, синең артыңнан бармакчы була, әллә нәрсәләр язган иде, хәлфәләремез андый, хәлфәләремез мондый, дигән булган* (Г. Исхакый. Мөгаллимә).

2. Кемнән яки нәрсәдән булса да үрнәк алу. *Башкача әйтсәк, «куркыгыз» дигән сүзне минем арттан барыгыз, инаныгыз һәм дин тотыгыз дип аңларга кирәк* (Р. Хәкимов. Татар гаме).

**АРТТАН <КАРАГАНДА; САНАГАНДА> БЕРЕНЧЕ** *ирон., шаярт., к.* азактан <санаганда> беренче. *Латвия исә бу җәһәттән [балалар саны буенча] СССР күләмендә арттан беренче. Ә без – икенче, шулай ук призлы урында* (Т. Әйди. Кечкенә дә төш кенә). – *Арттан караганда, билләһи, беренче, бу читекне моңар бирергә кирәк! – дип, шау-шу килеп көлештеләр* (М. Гали).
Төрдәше: азактан <санаганда> беренче һ.б.

**АРТТАН КАРАГАНДА, АЛДЫНГЫ (АЛДА)** *ирон., шаярт., к.* азактан <санаганда> беренче. *Арттан караганда алда, үзе һаман алда* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).
Төрдәше: азактан <санаганда> беренче һ.б.

**АРТТАН ЙӨРҮ (ЧАБУ)** *куч.* 1. Юллау, хәстәрен күрү. *Әтәй көзге чәчү артыннан йөри* (Ш. Маннур. Агымсуларга карап). – *Мин артыннан йөрсәм, рөхсәт алмый калмыйм. Ризамы?* (Х. Камал. Каһәр).

2. Кемне дә булса яратып, аны үзеңә каратырга тырышу. *[Гыйльметдин] Әчмуха махоркага акчаң булмасын имеш тә, оялмыйча кызлар артыннан йөр*... (Ф. Бурнаш. Яшь йөрәк-

лəр). – *Укыганда, минем арттан йөргəн иде* (Ə. Хəсəнов. Бəхет кайда оя кора?).

**АРТТАН <СЫРТКА> ПЫЧАК (ХƏНҖƏР) КАДАУ** *к.* аркага пычак (хəнҗəр) кадау. *Һич көтмəгəндə-уйламаганда арттан килеп пычак кадады Козецкий!* (А. Гыйлəҗев. Балта кем кулында?). – *Арттан сыртка пычак кадардай йə аумакай көч калдырып булмай* (В. Имамов. Карабəк).
Төрдəше: аркага пычак (хəнҗəр) кадау һ.б.

**АРТТАН СӨЙЛƏҮ** *к.* авыз чайкау 1. – *Юкка борчылма, арттан сөйли торган гадəте юк аның* (Сөйлəм).
Төрдəше: авыз чайкау 1 һ.б.

**АРТТАН ТЕРЕ САЕСКАН ОЧЫРУ** *к.* авыздан кош очыру 1. *Лəкин ул бүрəнə аркылы бүре күрə. Артыннан тере саескан очыра ул. Ул үзе мəсьəлəнең ничек булганын бик яхшы белə* (М. Əмир).
Төрдəше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

**АРТТАН ТӨТЕН (ПАР) ЧЫГУ** *гади с., к.* арт яктан төтен (пар) чыгу. *Бераз утырып ял ит, арттан пар чыга бит инде* (Сөйлəм).
Төрдəше: арт яктан төтен (пар) чыгу.

**АРТТАН ТӨШҮ.** Берəрсен эзəрлеклəү. *Качып киткəн дунхулар кире килеп арттан төшмəкче булалармы, əллə бөтенлəй башка төрле ягылармы?* (Н. Фəттах. Сызгыра торган уклар).

*АРТТЫРЫП* ❖ **АРТТЫРЫП ҖИБƏРҮ** 1. Тиешеннəн уздырып җибəрү, артыгын кылану, шаяру, чамасын белмəү. – *Абый, син инде бигрəк арттырып җибəрə башладың* (Г. Камал).
Төрдəше: артыграк<ка> китү; артыкка китү (җибəрү); артыгын җибəрү; артыгын кылану; зурдан кубу; олыдан кубу; чамадан уздырып җибəрү.

2. Модага ияреп, башкалардан аерылып тору өчен, əдəп, гадəт нормаларын читкə тибəрү. *Арттырып җибəрə башладылар хəзерге яшьлəр. Тəртə аттан элек йөгерə, йомырка тавыкны өйрəтə башлады, менə шул* (Ф. Хөсни).

**АРТТЫРЫП СӨЙЛƏҮ.** Күргəнне яки башкасыннан ишеткəнне сөйлəгəндə, үзеннəн өстəп яки башка төрлерəк сөйлəү. *Хатыннар, баярбикəлəр арттырып сөйли дип уйлады ул* (Р. Батулла. Сөембикə).
Төрдəше: үзеннəн өстəү (кушу).

*АРТТЫРЫП-КИМЕТЕП* ❖ **АРТТЫРЫП-КИМЕТЕП ƏЙТҮЕМ ТҮГЕЛ.** «Дөп-дөрес итеп гадел сөйлим» мəгънəсендə. *Бер дə арттырып-киметеп əйтүем түгел, үз күзем белəн күргəнне генə сөйлим* (Сөйлəм).
Төрдəше: артыгы-киме юк.

*АРТЫ* ❖ **АРТЫ АВЫР <ТАРТА>** *к.* арт санны күтəрə алмау. – *Койма башына менəргə арты авыр, астан керергə корсагы сыймый* (Ф. Яруллин. Кыйгак, кыйгак каз кычкыра).
Төрдəше: арт санны күтəрə алмау.

**АРТЫ АЧЫЛУ.** Яшерен эше билгеле булу, гаебе фаш ителү. *Гөнаһларын озак яшереп йөри алмады, аның да арты ачылды* (Сөйлəм).
Төрдəше: ачып бирү; ачып салу; аяк эзе ачылу; битлеген ачу (алып ташлау); битлеген ерту; битлеген салдыру; гаебен ачу; йөз<лəр>ен ачу (ачып бирү); маскасын ачу; маскасын ерту; маскасын салдыру; фаш итү.

**АРТЫ БЕЛƏН КАРАТУ.** Мөнəсəбəтлəр начарлану, дошманлашу. – *Бүген яратыр да бит, кем белə, иртəгə арты белəн каратыр?* (Г. Бəширов. Туган ягым – яшел бишек).
Төрдəше: алар арасына кара күлəгə яту һ.б.

**АРТЫ БЕЛƏН КҮЛГƏ (СУГА) ЧУМГАН ҮРДƏК КЕБЕК.** Аптыраганнан нəрсə эшлəргə белмəү. *Алай да, арты белəн күлгə чумган үрдəк кебек, яшелчə базасына кагылып чыгарга булды* (А. Гыйлəҗев. Балта кем кулында?).

**АРТЫ БЫЛЧЫРАК** *гади с.* Тышкы яктан рəтле кеше кебек күренсə дə, җинаятьчел, бозык булу. *Беренче карашка тəртипле кеше кебек, кем уйлаган аны арты былчырак булыр дип* (Сөйлəм).

**АРТЫ КЫЧЫТУ** *дорфа.* Кирəкмəгəн нəрсəгə тыкшынып, бəла-мəшəкать казып чыгару. – *Башка эшең юк идемени шуны җимермəсəң, артың кычытып торамы əллə югыйсə!* (Сөйлəм).

**АРТЫ ХƏЕРЛЕ БУЛСЫН.** Нинди булса да эшнең эшлəнүен күргəндə яки ишеткəндə, нəтиҗəсенең яхшы булуын телəп əйтелə. *Ерганак аркылы күпер сала башлаганнар икəн, арты хəерле булсын* (Сөйлəм).
Төрдəше: авыз<лары> бал да май <булсын>! һ.б.; ахыры хəерле булсын.

**АРТЫ ЮЕШ<ЛӘНГӘН>** *к.* ас булу. – *Аңа Мәскәү гәзитендә компромат чыккан, ди. Үзенең арты юеш чагында синең гозереoriginал бер колагыннан керде, икенче колагыннан чыкты* (Х. Камалов. Үксезләр).
Төрдәше: ас булу; аска җибәрү.

**АРТЫ ЯБЫШКАН** *эвф.* Урыннан калкырга теләмәгәндә, торырга авырсынганда әйтелә. *Җиңелчә чайкалгалап, ипле генә юлын дәвам иткән трамвайга әйтерсең лә арты ябышкан аның* (Р. Мөхәммәдиев. Кенәри – читлек кошы).

*АРТЫ-АРАСЫ* ❖ **АРТЫ-АРАСЫ КИСЕЛМӘҮ.** Эшләп торган конвейердагы кебек, берсе артыннан икенчесе өзлексез хәрәкәт итү. *Күл өстеннән арты-арасы киселмәгән бер рәвештә кыр казлары очып үтте* (Сөйләм).

*АРТЫГРАК<КА>* ❖ **АРТЫГРАК<КА> КИТҮ** *к.* арттырып җибәрү 1. *Сөйләшәсе килгәндер дә, артыграк киткән инде* (Ф. Садриев. Шаһзаманов эше). *Монысы инде артыгракка китте* (Г. Әдһәм. Йолдызлар елмая).
Төрдәше: арттырып җибәрү 1 һ.б.

*АРТЫГЫ* ❖ **АРТЫГЫ БЕЛӘН.** Берәр нәрсә өчен кирәк булганнан да артык. *Аңар ялгышлары өчен артыгы белән түләргә туры килгән* (А. Тимергалин. «Инкыйраз»га йөз ел).
Төрдәше: чамадан тыш.

**АРТЫГЫ БЕЛӘН ҖИТКӘН.** Артыгы кирәк түгел, шул кадәресе дә җиткән. *Гаҗәп, «халыкчанлык, халыкчанлык» дип, авыз суын корыталар, чынлыкта исә әдәбиятка кара халыкчанлык түгел (анысы артыгы белән җиткән), бәлки аристократизм җитми* (А. Тимергалин. Игезәкләр).
Төрдәше: җитеп арткан.

*АРТЫГЫ-КИМЕ* ❖ **АРТЫГЫ-КИМЕ ЮК.** «Чын дөресен әйтәм» мәгънәсендә. *Белемнең артыгы-киме юк диләр, менә бит – тормыш булгач, укыганнарның файдасы тигән – хәзер ул үз диваннарын ясатып, халыкка тәкъдим итә* («Безнең гәҗит» газ.).
Төрдәше: арттырып-киметеп әйтүем түгел.

*АРТЫГЫН* ❖ **АРТЫГЫН БӨГҮ.** Кирәгеннән артык көч кую, эшләп ташлау, чиккә җиткерү. *Кайчагында кызып китеп, артыгын бөгә төшә ул* (Ш. Шәйдуллин. Бүре өнендә).

**АРТЫГЫН ҖИБӘРҮ.** Исерткеч эчемлек эчүнең чамасыннан ашу. *Соңгы вакытта артыгын җибәрәсен, ә ул психикаңа бәрә* (Ә. Салах. Соңгы вальс).
Төрдәше: арттырып җибәрү 1.

**АРТЫГЫН КЫЛАНУ** *к.* арттырып җибәрү. *Анысы да артыгын кылана, юри «энекәш» дип ычкындыра* (Н. Акмал. Игезәкләр).
Төрдәше: арттырып җибәрү 1.

**АРТЫГЫН СӨЙЛӘП ТАШЛАУ.** Кирәкмәгәнне (ярамаганны) әйтү (сөйләү). *Кам өйгә килеп керүгә, артыгын сөйләп ташламагае дип, Алпарына ишегалдына чыгып торырга кушты Туйбикә* (М. Хәбибуллин. Илчегә үлем юк).
Төрдәше: артыгын ычкындыру.

**АРТЫГЫН ЫЧКЫНДЫРУ** *к.* артыгын сөйләп ташлау. – *Алар сөйләгәннән артыгын ычкындырырмын дип куркасызмы?* (Т. Әйди. Бoжра).
Төрдәше: артыгын сөйләп ташлау.

*АРТЫК* ❖ **АРТЫК БӨГЕП ҖИБӘРҮ.** 1. Алдалау, арттырып сөйләү. *Сәфәргалигә Фәсхи, теге вакыттагы кебек, артык бөгеп җибәрә бугай* (Ф. Хөсни). *Артыгын бөгеп җибәреп, андый-мондый берәр мөгез чыгарып куя күрмәгез анда...* (Р. Вәли).
Төрдәше: авыздан кош очыру 3 һ.б.

**АРТЫК БҮРӘНӘ БАШЫ БАР** *кис.* «Безнең арада чит кеше бар, сак бул» мәгънәсендә. *Карале, Рәшит, сиңа әйтмәкче идем: бездә артык бүрәнә башы бар* (Сөйләм).

**АРТЫК ҖӘЕЛМИЧӘ.** Күп сүз сөйләмичә генә. *Рәшидә бу хакта сөйләргә бер дә теләк сиздермичә, бераз уйланып, көттереп ятты, шуннан соң гына, артык җәелмичә, кыска гына сөйләп бирде: әйе, аның ире булган* (Ә. Еники. Рәшә).
Төрдәше: артык сүз куертмыйча.

**АРТЫК ҖИБӘРЕЛҮ.** Артык чамасыз җәелеп, шапырынып яки кирәкмәгәнне сөйләү. *Ул өйгә кайтып кергәндә, абыйсы, артык җибәрелеп, ничек паркта йөрүләре турында сөйләп утыра иде* (Сөйләм).
Төрдәше: авызга тел сыймау һ.б.

**АРТЫК ҖИРЕ ЮК.** Башкалардан берни белән аерылмый, гадәти нәрсә. *[Сары сакал] Бусының*

*да аннан артык җире юк!* (Г. Камал. Безнең шәһәрнең серләре).

**АРТЫК ИТЕНҮ (КЫЛАНУ).** Тыйнаксызлану, чаманы белмәү. – *Алар сезгә бүтән тимәсләр, син дә яклаучым бар дип артык итенмә* (idmedina.ru). *Бу кадәр кирәкми иде, Гамир артык кыланган* (Х. Ширмән. Язмышлардан юк ла узмышым...).
Төрдәше: аръягына чыгу һ.б.

**АРТЫК ЙӨК.** 1. Кирәкле дәрәҗәне узган авырлык. – *Димәк, җитмеш килоң артык йөк булган икән бит синең!..* (Ф. Баттал. Кадерем арта, бәям күтәрелә!).

2. Тормышны бозган, яшәү өчен авырлык китергән нәрсә. *Йә, нигә сиздермәдең бер / Артык йөк икәнемне?* (Н. Гамбәр).

**АРТЫК КАШЫК** *ирон.* Мохтаҗлыкта яшәгән гаиләдә күпчелек очракта кемне булса да асрау хакында. *[Мәхмүдә] Бүгенге хәлендә бу дөньяга кирәк кеше түгел син. Артык кашык, әрәм тамак син!..* (Ю. Әминов. Гөлҗәннәтнең җәннәте).
Төрдәше: артык тамак.

**АРТЫК КОЛАК** *ирон.* Синең сөйләшүеңне тыңлап торучы чит кеше. *Артык колак юклыктан файдаланып, сорап калырга ашыктым* (Р. Габделхакова. Тау астында кояш бар).

**АРТЫК КҮЗ** *ирон.* Бер гаиләдә яки оешмадагы эшләрнең кирәген-кирәкмәсен күзәтеп торган ят кеше; астыртын эшләнгән яшерен эшләрне күрергә кирәк түгеллеккә дә ишарә ясау. *Уйлап эш итәргә кирәк, артык күз, артык колак зыян салырга мөмкин* (Г. Гомәр. Мөһер).

**АРТЫК (АРТЫГРАК) КҮРҮ.** Өстенлек бирү, тагын да югарырак бәяләү. *Минем кебек сөйгән кешедән бер наданны артык күрмә* (Г. Тукай).
Төрдәше: артык санау; өстен кую (күрү); югары кую (күрү).

**АРТЫК КЫЛАМ ДИП ТЫРТЫК КЫЛУ.** Артык остарып китеп, эшнең асыл сыйфатын бозу. *Мин аны тиз генә эшләп ташлыйм, дип тотынган иде, тик артык кылам дип тыртык кылган булып чыкты* (Сөйләм).
Төрдәше: каш ясыйм дип күз чыгару.

**АРТЫК САЙРАУ.** Сүзгә мавыгып, башкалар белергә тиеш булмаганны сөйләп җибәрү. *Үзенең артык чишелеп китмәвенә, кирәгеннән артык сайрамавына куанып куйды* (С. Рәфыйков. Тын елга буенда).
Төрдәше: авызга тел сыймау, <телгә сүз сыймау> һ.б.

**АРТЫК САНАУ** *к.* артык күрү. *Гафу үтенүне, аңлашуны артык саный иде, күрәсең* (В. Имамов. Утлы дала). *Сәбәпләрен аңлатуны артык санады* (Х. Камалов. Һәркемнең гомере бер генә).
Төрдәше: артык күрү һ.б.

**АРТЫК СҮЗ КУЕРТМЫЙЧА** *к.* артык җәелмичә. *Ата белән ул шулай кул кысышып, артык сүз куертмыйча гына аерылыштылар* (Р. Кәрами. Олы юл да сикәлтәле).
Төрдәше: артык җәелмичә һ.б.

**АРТЫК СҮЗ СӨЙЛӘ<Ш>МӘҮ.** Кирәкмәгән нәрсә турында сөйләшмәү. *Болай итәбез: тапшырылган эшне җиренә җиткереп башкарабыз, беркемгә дә тел-теш тидермибез, артык сүз сөйләшмибез* (Р. Хәбибуллина. Мулла килене).
Төрдәше: авызга ия булу 2 һ.б.

**АРТЫК ТА, КИМ ДӘ (АРТЫК ЙӘ КИМ) ТҮГЕЛ.** Нәкъ кирәклесе булу, төп-төгәл. *Артык йә ким түгел, / төгәл ун санында...* (М. Мирза. Артык йә ким түгел).

**АРТЫК ТАМАК** *к.* артык кашык. *Хатынның килене, артык тамактан котылыр өчен, Сөннәтче бабайның сүзен бик ипләде* (Г. Исхакый. Сөннәтче бабай).
Төрдәше: артык кашык.

**АРТЫК ТОЗЛАУ** *күч.* Сүзгә мавыгып, мәҗлеснең ямен бозарлык нәрсәләр сөйләп ташлау. *Әлбәттә, һәр эштә чама кирәк – артык тозлап җибәреп тозсызландырырга да ярамый* (Ш. Галиев). *Мәҗлестә иреңә күз-колак бул әле, сүзләрен артык тозлау белән мавыкмасын* (Сөйләм).

**АРТЫК ЭЧКӘ КИТҮ.** Эчке тирән хисләргә кагылып яки яшерен серләрне ачып сөйләү. *Сүз сүзне тартты, теләмәстән, гүя үзеннән-үзе артык эчкә киттеләр* (Г. Ибраһимов).

*АРТЫККА* ❖ **АРТЫККА КИТҮ (ҖИБӘРҮ)** *к.* арттырып җибәрү 1. *Үземне кимсетүегез дә артыкка китте...* (К. Тимбикова. Кышкы былбыллар).
Төрдәше: арттырып җибәрү 1.

*АРТЫКНЫ* ❖ **АРТЫКНЫ ЫЧКЫНДЫРУ (ЫЧКЫНДЫРЫП ТАШЛАУ).** Чаманы югалтып, кирәкмәгән сүзгә кереп китү. *Чамадан артыкны ычкындыруын, «сөйләү» белән «образлы сурәтләү» арасында упкын ятканын аңлаган тәнкыйтьче хәзер «заманча фикер йөртә» кебек: чуерташ фразаларга теркәү тери башлый* (А. Хәлим. Сез беләмсез кая барганны?).

Төрдәше: авызны шайтан ялау һ.б.

*АРТЫМДА* ❖ **АРТЫМДА КҮЗЕМ ЮК.** Арттагы кешегә бәрелгәндә яки берәр нәрсәне төшереп ватканда әйтелә. *Беләсең ич: минем артымда күзем юк* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

*АРТЫН* ❖ **АРТЫН УЙЛАМАУ (УЙЛАП ҖИТКЕРМӘҮ).** Эшне башлаудан элек, аның нәтиҗәсе белән кызыксынмау. *Алдан әйткәнче, артын уйла* (Мәкаль). *Моны эшләп бетергәч, артын уйламадыгызмыни – кемгә бүләк итәчәксез, ничек бирәчәксез һ.б.?* (Сөйләм).

*АРТЫНА* ❖ **АРТЫНА БЕЗ (ИНӘ; ЧӨЙ) КАККАН.** Кыбырсык кешенең бер урында гына утырып тора алмавы турында. *Артына без какканнармыни, йә уңга борылып, нәрсәдер сорый, йә сулга борылып пышылдашып ала, йә булмаса, алда утырган берәрсе янына барып килә* (Сөйләм).

**АРТЫНА БЕР ТӨШЕП, АЛДЫНА БИШ ТӨШЕП** *к.* авызга бал да май булып керү. *Кечкенә булса да, олы булса да, хуҗа – хуҗа инде, шулай булгач, артына бер төшеп, алдына биш төшеп булса да, аның игътибарын җәлеп итәргә тырышты* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга бал да май булып керү һ.б.

**АРТЫНА ГЕР (ТАШ) ТАГУ** *к.* артын кузгата (күтәрә) алмау. *Аркасындагы букчасының авырлыгы, әйтерсең артына гер такканнар!* (Сөйләм).

Төрдәше: артны кузгата (күтәрә) алмау.

**АРТЫНА ДА КАРАМАУ.** Бернәрсәгә дә игътибар итмичә, бик ашыгып (яки качып) баручы кеше турында. *Вокзалга таба баручы кеше артына да карамый, тиз-тиз бара да бара* (Сөйләм).

Төрдәше: агы-карасы <күзгә> күренмәү һ.б.

**АРТЫНА ҖИТКӘН** *дорфа.* Эше тыгызланган, вакыты аз калган. – *Комачауламагыз инде, болай да артыма җиткән, сәгать дүрткә өлгертәсем бар* (Сөйләм).

**АРТЫНА КОРТ ТӨШҮ** *дорфа.* Тиктормас, кыбырсык, һәрнәрсәгә тыгылып, кагылып йөрүче турында. *Тегенең артына корт төшкән бугай, үзенә урын таба алмыйча йөри* (Сөйләм).

Төрдәше: артына таракан керү һ.б.

**АРТЫНА НАШАТЫР КЫСТЫРГАН КЕБЕК.** Нәрсә эшләгәнен белмичә кабалану, әрле-бирле чабу; ашыгу. *Ул, артына нашатыр кыстыргандай, арлы-бирле чабулап, түбәсенә урнаштырылган тавыш көчәйткечләрдән бер үк сүзләрне кабатлады: «Бирелегез!... Бирелсәгез, икмәк һәм су бирәчәкбез...»* (Р. Мөхәммәдиев. Утлы таба өстендә).

Төрдәше: ак-кара <күзгә> күренмәү һ.б.

**АРТЫНА ПЕЧӘН АШАТУ.** Кеше эшенә тыгылып офтану, көчәнү. *Машинасын аргы яктагы Мансурга сатты дип, нигә артыңны печән ашатасың? Синекен сатмагандыр ич* (Сөйләм).

**АРТЫНА САЛАМ КЫСТЫРУ.** Кешене алдында мактаган булып, үз җаеңа китерү, тарафдарың итү. *Акылсызның артына салам кыстыралар* (Н. Исәнбәт. Мәкальләр).

**АРТЫНА СУ КЕРҮ (ҮТӘ БАШЛАУ).** Начар хәлгә төшү, чигенер мөмкинлек калмау. *Хәйбиевнең артына су керде – ел саен миллионлап печән сата алмый* («Безнең гәҗит» газ.).

Төрдәше: аска су җибәрү; аска су кергәч <кенә> йөзә башлау; аска су йөгерү; аска су керү (үтү) 2.

**АРТЫНА ТАРАКАН КЕРҮ** *к.* артына корт төшү. *Артына таракан кергән булырга кирәк, бик кыбырсынып тора* (Сөйләм).

Төрдәше: артына корт төшү һ.б.

**АРТЫНА ТЕГЕРМӘН ТАШЫ ТАГУ** *к.* артына гер (таш) тагу. – *Артына тегермән ташы такканмы әллә, борыны белән җиргә кадалырга җыенгандай атлый* (Сөйләм).

Төрдәше: артына гер (таш) тагу.

**АРТЫНА ТИБЕП ЯШӘҮ.** Бу дөньяда кәеф-сафа корып яшәү хакында. *Ничек кенә димә, фани дөньяның артына тибеп яшәрлек дәрте дә, дәрманы да бар әле* (Б. Камалов).

Төрдәше: артына тибү (тибеп яшәү) 2.

**АРТЫНА ТӨШҮ.** Эз югалтырга тырышучының эзенә төшү, эзәрлекләү. *Теге икесе Вәкилнең артына төштеләр* (К. Булатова). *Атилла хан бу сугышта да оста һәм хәйләкәр каһарман булып кала: ул бер түбәнен елганың өске ягыннан кичәргә һәм легионерларның артына төшәргә әмер бирә* <...> (М. Хәбибуллин. Атилла).

**АРТЫНА УТ КАПСА ДА, КЫЙМЫЛДАМАС (КЫЙМЫЛДЫЙ ТОРГАН ТҮГЕЛ).** Ашыкмас, кузгалырга яратмый торган кеше. *Әйттең сүз, артына ут капса да, кыймылдый торган кеше түгел ул* (Сөйләм).
Төрдәше: арба ватылса – утын, үгез үлсә – ит һ.б.

**АРТЫНА УТ ЯККАННАРМЫНИ** *к.* ак-кара <күзгә> күренмәү 1. *Әле генә монда иде, сикереп торды да, артына ут якканнармыни, ишектән тышка атылды* (Сөйләм).
Төрдәше: ак-кара <күзгә> күренмәү 1 һ.б.

**АРТЫНА УТЫРА БЕЛМӘҮ** *к.* артына корт төшү. *Басылып, артына утыра белмәде инде: сикерә дә тора, сикерә дә тора* (Сөйләм).
Төрдәше: артына корт төшү һ.б.

**АРТЫНА УТЫРТУ** *гади с.* Көч кулланып, мәрхәмәтсез рәвештә бастыру, әйтәсе сүзен әйттермәү, хаксызлык эшләү. *Бераз түзеп тордылар да, җитәр сиңа артыгын кыланырга дип, артына утырттылар* (Сөйләм).

**АРТЫНА УТЫРУ.** 1. Бәбинең мөстәкыйль утырып тора башлавы. – *Малайны карале, үзе артына утыра башлады!* (Сөйләм).

2. Тынгы белми торган кешенең тынычлануы, төпләнүе. *Башсыз бер егет иде, ниһаять, артына утырды бугай* (Сөйләм).

**АРТЫНА ЧУАН ЧЫГУ** *к.* артына корт керү. – *Бәйләнмәгез әле шуңа, урынында тик кенә утыра белми бит ул, артына чуан чыккандыр*(Сөйләм).
Төрдәше: артына корт төшү һ.б.

*АРТЫНДА* ❖ **АРТЫНДА <ГАЙБӘТЕН> СӨЙЛӘҮ** *к.* авыз чайкау 1. *Әләкләү, үч алу, кеше артында сөйләү гадәтем юк* (Ә. Әминов. Йолдызак).
Төрдәше: авыз чайкау 1 һ.б.

**АРТЫНДА ПАТШАНЫ ДА СҮГӘЛӘР.** Теләсә кем артыннан гайбәт сөйләнергә мөмкин. *Артында патшаны да сүгәләр* (К. Насыйри. Мәкальләр һәм әйтемнәр).

**АРТЫНДА ЧӘЙНӘҮ** *к,* авыз чайкау 1. *Башка сүз таба алмыйсызмы, шул егетне артында чәйнәмәсәгез?* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз чайкау һ.б.

*АРТЫННАН* ❖ **АРТЫННАН БАРУ (ИЯРҮ).** 1. Кемнән яки нәрсәдән булса да үрнәк алу. *Укучы, әйтерсең лә, язучы сурәтләгәннәр артыннан барып, бу фикергә үзе килә, нәтиҗәне үзе таба* (А. Әхмәдуллин. Офыклар киңәйгәндә).

2. Кемнең дә булса фикердәше, дәвамчысы булу. *Ул яшәгән дөнья бүген кем артыннан бара?* (А. Әхмәтгалиева. Синең өчен яшим).

**АРТЫННАН ҖИБӘРҮ.** 1. Берәрсен чакырырга дип, махсус кеше җибәрү. *Ул зарыгып, атасы артыннан җибәргән чапкынын көтте* (М. Хәбибуллин. Хан оныгы Хансөяр).

2. Берәрсе аркылы нәрсә булса да җибәрү. *«Бүген үк хатымны язып да Зәкия артыннан җибәрим», – дип уйлап куйды Газзәбану* (Г. Галиева. Газзәбану).

**АРТЫННАН ҖИР КАПКАН.** Тәбәнәк буйлы, кыскарак аяклы кеше. *Хәзер дә кыскарак аяклы яисә чүгәләбрәк йөрүче кешеләргә «артыннан җир капкан» дип калу гадәте бар* (Г. Гыйльманов).

**АРТЫННАН КОТЫРГАН ЭТ КАПСА ДА ПЫЖЛАМЫЙ (ВЫЖЛАМЫЙ)** *к.* арба ватылса – утын, үгез үлсә – ит һ.б. *Артыннан котырган эт капса да пыжламый* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).
Төрдәше: арба ватылса – утын, үгез үлсә – ит һ.б.

**АРТЫННАН КУУ.** Нәрсә белән булса да артык мавыгып, башкаларны читтә калдыру. *Шуңа күрә безгә бу очракта төрек агайлар артыннан куу кирәкме соң дигән сорау туа* (А. Тимергалин. Кая таба һәм кая тикле?).

**АРТЫННАН КҮЗ <ДӘ> ИЯРМӘҮ** *к.* «а» дигәнче. *Аларның инде салкында җиде сәгать эшләүләренә ышанасы да килми – куллары артыннан күз иярми* (Р. Мостафин. Җиде эзең калсын).
Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**АРТЫННАН ТЫН АЛУ** дорфа. Гаебен сизмәсеннәр өчен, куркып, дәшми тору. *Директор мине*

*күрмәсен дип, артыннан тын алып, почмакка сыенды* (Сөйләм).

**АРТЫННАН ЧЫГАРУ** *дорфа.* Уйдырма, уйлап чыгару; ялган сөйләү. *Беренче төрлесенә карата халыкта бик тә төгәл һәм бик тә усал әйтем дә бар – «артыннан чыгарды», ди* (Ф. Хөсни. Орлыклар кая төшә?).

Төрдәше: бармак очыннан (бармактан) суыру (суырып чыгару); бармак очыннан тамызу; бармактан шыттыру; түшәмнән алып әйтү; үзеннән уйлап чыгару; һавадан алып (эләктереп) сөйләү (әйтү).

**АРТЫННАН ЭТ ЖИТКӘЧ, КОЙРЫГЫН БОРУ** *ирон.* Тотыла башлагач, хәйләләп котылмакчы булу. *Бурычыңны кайчан түлисең инде, әллә һаман да искечәме, артыңнан эт житкәч, койрыгыңны бормакчы буласыңмы?* (Сөйләм).

**АРТЫННАН ЯУ КУГАН КЕБЕК.** Бик көчле чабып бару. – *Артыңнан яу куамы, ник шулчаклы ашыгасың?* (М. Фәйзи).

Төрдәше: аяк җиргә тимәү 1 һ.б.

*АРТЫҢ* ❖ **АРТЫҢ БЕЛӘН МИЧКӘ КЕРСӘҢ ДӘ ТАНЫЙМ.** «Син билгеле кеше, мин сине бик яхшы беләм» мәгънәсендә. *Мин сине артың белән мичкә керсәң дә таныйм. Монсы үзара гына... Сине яхшы беләм дип әйтүем* (Ш. Бикчурин).

*АРТЫҢА* ❖ **АРТЫҢА КӨЛ** *к., карг.* алдын(ң)нан арты(ң)! *«Артыңа көл!» дип әйтү, бәлки, кеше яңадан килмәсен өчен, аның артыннан көл тутырган чабата ату йоласы белән бәйләнгәнде* (Сөйләм).

Төрдәше: алдын(ң)нан арты(ң)! һ.б.

**АРТЫҢА КУЛЫҢ ҖИТСЕН.** Кереп-чыкканда ишекне яба белмәгән кешегә кисәтү. *«Артыңа кулың җитмиме әллә?» – дип тирги әти* (goxi.ru).

**АРТЫҢА НАШАТЫР (НИШАТЫР) СӨРТКӘНМЕ (СӨРТТЕЛӘРМЕ) ӘЛЛӘ** *к.* артына нашатыр кыстырган кебек. – *Урыныңда бер дә утыра алмыйсың, артыңа нашатыр сөртеләрме әллә?* (Сөйләм).

Төрдәше: артына нашатыр кыстырган кебек һ.б.

**АРТЫҢНАН БЕР ЧАБАТА (ЧИЛӘК) КӨЛ (КОМ)** *к., карг.* алдын(н)нан арты(ң)! *Мөсафиры ишетмәсен дип, әчтән генә «артыңнан бер чабата көл» диде дә ишекне ябып куйды* (Сөйләм).

Төрдәше: алдын(ң)нан арты(ң)! һ.б.

**АРТЫҢНАН ИСКЕ ЧАБАТА** *к., карг.* алдын(ң)нан арты(ң)! *Электә чыраен күрәсе килмәгән кеше чыгып киткәндә, артыннан: «Артыңнан иске чабата! – дип әйтеп кала торган булганнар* (А. Тимергалин. Чабата).

Төрдәше: алдын(ң)нан арты(ң)! һ.б.

*АРТЫҢНЫ* ❖ **АРТЫҢНЫ БЕЛ, <ЫШТАНЫҢА ҖИБӘРМӘСЕН>** *дорфа.* Үз-үзен белмичә, хәзерлеге чамалы булып та, башкаларны тикшерә башлаган кешегә әйтү сүзе. – *Сөйләп торган буласың тагын, артыңны бел, ыштаныңа җибәрмәсен!* (Сөйләм).

Төрдәше: артыңны биш җирдән кысып тор.

**АРТЫҢНЫ БИШ ҖИРДӘН КЫСЫП ТОР** *к.* артыңны бел, <ыштаныңа җибәрмәсен>. *Аңа алдан ук «артыңны биш җирдән кысып тор» дип кисәтсәләр дә чыдамады, мескен, яңадан акыл сатарга тотынды* (Сөйләм).

Төрдәше: артыңны бел, <ыштаныңа җибәрмәсен>.

**АРТЫҢНЫ ҖЫЕП ЙӨР.** «Уяу бул, тирә-ягыңа карап, сак йөр» мәгънәсендә. *Артыңны җыеп йөр!* (Г. Рәхим).

Төрдәше: абай булу һ.б.

*АРУ* ❖ **АРУ АЗЫК АЛДЫМНАН КАЛГАНЧЫ СЫЙЛАДЫҢ.** Кунак булып, зур сый-хөрмәткә каршы җавап сүзе. – *Рәхмәт инде, сыйладыгыз, ару азык алдымнан калганчы сыйладыгыз* (Сөйләм).

**АРУ СУНЫ КУЕРТУ.** 1. *к.* авыз чайкау 1. Яхшы барган эшне бозу. – *Минем ни зыяным тия инде аларга, – диде Әхияр, ачулы сукранып. – Нигә мине күрәлмиләр, нигә ару суны куерталар. Күзләренә кылчык булып кердем инде, валлаһи* (Г. Мөхәммәтшин. Авылда бер...).

Төрдәше: авыз чайкау 1 һ.б.

2. Арадагы мөнәсәбәтләрне бозу максатыннан, кемнеңдер араны бутавы. – *Нишләп йөри икән Абдулла абый безнең институтта, тагын берәрсе белән араны бозарга теләп, ару суны куертырга телиме әллә?* (Сөйләм).

**АРУ ҮЛЕМ, АК КӘФЕН.** Үз үлеме белән табигый үлем килүен теләү. *[Икенче йөзбашы] Ары*

*ниләр булгандыр – язмышын белмим... Башын җуйган булса, ару үлем – ак кәфен бирсен!* (Р. Миналим, Р. Хәмид. Идегәй). *Ару үлем, ак кәфен* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).

*АРУСЫЗ* ❖ **АРУСЫЗ ВАКЫТ.** Күрем вакыты. *Арусыз вакытың бәйрәм көннәренә туры килә икән* (Сөйләм).

*АРУ-ТАЛУНЫ* ❖ **АРУ-ТАЛУНЫ БЕЛМӘҮ.** Тырышып, арыганлыкны сиздермичә, эш вакытында тәнәфесләр ясамыйча эшләү. *Гомер буе кулы эштән бушамаган, ару-талуны белмәгән кадерле әтисенә карата аның күңелендә чиксез зур уллык мәхәббәте ташыды* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

*АРХИВКА* ❖ **АРХИВКА ТАПШЫРУ (ЧЫГАРУ)** *кит.* Искергән, яраксыз дип игътибар итмәү, тапшырган эшне, вазыйфасын башкара алмый дип эшеннән азат итү. *Кульязмалар арасыннан да «безнең идеологиягә, сәясәткә туры килми» ише җөмләләр сырланып, архивка тапшырылган мәкаләләргә тап булдым* (Р. Галиуллин. «Чын журналистика – иманга тугрылык ул»).

*АРШЫН* ❖ **АРШЫН ЙОТКАН КЕБЕК (ДИЯРСЕҢ).** Гәүдәсен туры тотып, төп-төз йөргән кеше турында. *Мәйданда кеше күп булса да, аның аршын йоткан кебек гәүдәсен бутау мөмкин түгел иде* (Сөйләм).
Төрдәше: уклау йоткан кебек.

*АРШЫНГА* ❖ **АРШЫНГА САТУ.** Аршынлап сату. *Ул кибеттә тукымаларны аршынга саталар* (Сөйләм).

*АРШЫНЛЫ* ❖ **АРШЫНЛЫ МАЛ.** Затлы мал, ефәк тукыма. *Аршынлы маллар (сукно, ситсы, яулык, шәл-шарф) илә сәүдәләр бар* (Р. Фәхретдинов).

*АРШЫНЫ* ❖ **АРШЫНЫ БЕЛӘН ҮЛЧӘҮ.** Берәр эш яки кеше турында шәхсән уйлавың нигезендә генә фикер йөртү. – *Бөтен нәрсәне дә әтмитке аршыны белән үлчәп булмый болай булгач* (С. Лашманчы. Алман көчтәнәче). *Атарның гамәлләрен хатын-кыз аршыны белән үлчәп: «Мин алай итмәс идем, болай эшләмәс идем», – дип фикер йөртеп, хөкем итә башласаң, белмим, кая барып чыгарсың...* (К. Тимбикова. Юкә чәчәк аткан чак иде).
Төрдәше: үз аршины (аршыны) белән үлчәү һ.б.

*АРЪЯГЫНА* ❖ **АРЪЯГЫНА <ГЫНА> ЧЫККАН.** Чынбарлыктагыдан да зурысы (артыгы, начары, тәртипсезе һ.б.) булырга мөмкин булмау. *Шул хәлдән соң, җаны кыйналуның аръягына чыккан Иргали абый да түзмәде, болай диде: «Нәрсә, акчагыз бик күпме әллә? Көн дә кызмача булуыгызны әйтәм. Барасы юллар озын...»* (М. Хәсәнов. Язгы аҗаган). *Моннан да артык тәрбиясезләнсә, аръягына гына чыккан дияргә мөмкин* (Сөйләм).

**АРЪЯГЫНА ЧЫГУ.** Рөхсәт ителгәннән ашып китү, үтеп чыгу; чикне аркылы чыгу. *Аптырауның аръягына чыккан Инсаф байтак кына кузгала алмый торса да, җиңгәсе аны шәйләмәде кебек* (Т. Гарипова. Ялгыз бөркет күктә бөтерелә).
Төрдәше: ашаган тамакка ни бармас (бармый; китмәс) һ.б.

*АРЫ* ❖ **АРЫ ӘЙЛӘҮ, БИРЕ ӘЙЛӘҮ** *к.* арлы-бирле бәрелү (сугылу). *[Хәерниса] Ары әйләдем, бире әйләдем, байның төшкәнен берничә сәгать сагалап тордым* (Г. Камал. Өч тормыш).
Төрдәше: ары-бире бәрелү (сугылу) һ.б.

**АРЫ БАРЫП, БИРЕ КИЛЕП.** Нәрсә эшләргә белмичә аптырап йөрү, бер тегендә бару, бер монда килү. *Ары барып, бире килеп, / Нишләп йөрисез болай? / Безнең уйлар сездә булса, / Сез дә йөрерсез шулай* (Җыр).
Төрдәше: ары-бире бәрелү (сугылу) һ.б.

**АРЫ БӘРЕЛҮ, БИРЕ СУГЫЛУ** *к.* арлы-бирле бәрелү (сугылу) 1. *Мин моннан ун бүрек тегәм, беләсеңме, ун бүрек! – дип ары бәрелде, бире сугылды* (А. Хәсәнов. Төп мәсьәләгә кагылмый да...).
Төрдәше: ары-бире бәрелү (сугылу) һ.б.

**АРЫ ДӘШ ДИСӘҢ, КИРЕ.** Тискәре, кире кеше турында. *Безнең якта ары дәш дисәң, кире бер кеше бар, андыйларны күргәнең юктыр әле* (Сөйләм).
Төрдәше: кайчы белән кырыккан; кире<гә> беткән; кире чабата; тирес чабата; кире киткән үрдәк күлгә арты белән чума; мүкләк сыер кебек.

**АРЫ КАГЫЛЫП, БИРЕ СУГЫЛЫП <ЙӨРҮ>.** Файдасызга, кергәләп-чыккалап, тегендә-монда йөрү. *Ары кагылды, бире сугылды, бичара, тик пенсия яшендәге кешене эшкә алырга*

*атлыгып торучы гына табылмады* («Безнең гәҗит» газ.).
Төрдәше: арлы-бирле бәрелү (сугылу) һ.б.

**АРЫ КИТМӘГӘН.** Кемнән яки нәрсәдән булса да яхшырак түгел. *Зәвыклары шуннан ары китмәгән кешеләргә шул бик җиткән, – диде Никола Максимович* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Эчке аң үсеше кая ул югары баскычка күтәрелү, бер җамаяк боткадан да ары китмәгән гидайны Комиссарлар советына керт, имеш* (Т. Әйди. Елан угы).

**АРЫ СУГЫЛУ, БИРЕ СУГЫЛУ** *к.* арлы-бирле бәрелү (сугылу) 1. *Өйләренә чыккач, Таймас, эш табалмыйча, ары сугылды, бире сугылды* (А. Тимергалин. Таш алиһә). *Булат йомыркасы бар тавык кебек йөри башлады. Ары сугылды, бире сугылды* (В. Нуриев. Җиденче палата).
Төрдәше: ары-бире бәрелү (сугылу) һ.б.

**АРЫ СУГЫЛЫП, БИРЕ БӘРЕЛЕП** *к.* арлы-бирле бәрелү (сугылу) 1. *Ысылдаган булды, ары сугылып, бире бәрелеп, галәмәт кәҗәләнде* (А. Хәсәнов. Гөлмәрфуга).
Төрдәше: ары-бире бәрелү (сугылу) һ.б.

**АРЫ ТОРСЫН.** 1. Башкасы (тагын да яхшырагы) кирәк түгел. *Һәм ни күрсен... урам буйлап бер чибәр килә. Венераларың, Афродиталарың ары торсын!* (З. Мурсиев. Зариф, Зәлифә). *– Риза кебек «дуслар» ары торсын икән, Дустың булса, менә шундый булсын икән...* (Р. Вәлиева. Кояшлы яңгыр).

*АРЫ-БИРЕ* ❖ **АРЫ-БИРЕ БӘРЕЛҮ (СУГЫЛУ).** Аптырудан төрле урыннарга барып килү, андамонда эшле-эшсез йөрү. *Һади, кая барып керергә белмичә, ары-бире сугылды, экскаваторның җир казыганын күзәтеп торды* (А. Гыйләҗев. Тәрәзәләр). *Ни булыр икән дип күзәтүчеләр дә, шүрләп, ары-бире сугыла, кая барып тотынырга белми, кычкыра, бакыра, елый, белгән догаларын укый* (Г. Гомәр. Шаһмирай).
Төрдәше: арлы-бирле бәрелү (сугылу) 1; ары әйләү, бире әйләү; ары барып, бире килеп; ары бәрелү, бире сугылу; ары сугылу, бире сугылу; ары сугылып, бире бәрелеп; арык-сурык йөрү; әрлебирле бәрелү (сугылу 1); әрле-бирле йөрү 1; әрле-бирле килү 1.

**АРЫ-БИРЕ КИЛҮ.** 1. *к.* ары-бире бәрелү (сугылу) 1. *Урам тулы халык, ары-бире килеп йөриләр* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы). *Гөлсинә керүгә, Хафиз белән Вәсилә, алтын күкәйне кая яшерергә белмичә, ары-бире киләләр* (Л. Лерон. Бәхетле биш минут кала).
Төрдәше: ары-бире бәрелү (сугылу) һ.б.

2. Урынында булмау; таралып юк булу (әйберләр турында). *Өстәл тартмасындагы әйберләр ары-бире килеп беткәннәр* (Сөйләм).
Төрдәше: аеры-чөере китерү.

**АРЫ-БИРЕ КИТЕРҮ.** 1. Кая туры килсә шунда тәртипсез урнаштыру. *Фатыйма, анда-монда таралып яткан әйберләрен ары-бире китерде дә, барып ишекне ачты* (Сөйләм).

2. Азык-төлек, акча һ.б.ларны теләсә нәрсә өчен файдалану. *Җитәкчелектән аларга бүлеп бирелгән акчаларны ары-бире китереп бетергәннәр* (Сөйләм).
Төрдәше: арысын аударып, биресен түнтәреп.

3. Ашыгыч рәвештә урнаштыру, алып кую, сату, яшерү һ.б. *Кортларны суыкта ары-бире китерер хәл юк иде* (Б. Камалов. Урамнар киңәя).
Төрдәше: арысын ары, биресен бире китерү.

*АРЫК* ❖ **АРЫК АТ ЯБЫКЛЫГЫН БЕЛДЕРМӘСКӘ СЫРТЫН КАБАРТУ.** Үз гаебен сиздермәс өчен, башка нәрсә хакында сөйли башлау яки берәрсен тәнкыйтьләргә тотыну. *– Карале, безнең Рәшит, арык ат ябыклыгын белдермәскә сыртын кабарткан кебек, артыгын кылана башлады түгелме?!* (Сөйләм).

*АРЫК-СУРЫК* ❖ **АРЫК-СУРЫК ЙӨРҮ** *к.* арлы-бирле бәрелү (сугылу) 1. *Ничә кызның башын әйләндергән, төн йокыларын алган егетнең болай җиңел генә өйләнүенең сәбәбе дә ачык: армия хезмәте башлана, инде арык-сурык йөри алмаячак* (Ф. Яхин. Сөйкемле сөяк).
Төрдәше: арлы-бирле бәрелү (сугылу) 1 һ.б.

*АРЫСЛАН* ❖ **АРЫСЛАН АВЫЗЫНА КЕРҮ.** Батыр, курыкмый торган булу турында. *– Куркытырсың Гафиятне: җир дигәндә, ул арыслан авызына керергә хәзер...* (И. Гази. Онытылмас еллар).
Төрдәше: арыслан авызыннан сөяк алырдай; арыслан йөрәк<ле> <булу>; басса бакыр изәрлек, <типсә тимер өзәрлек>; батыр йөрәк санау; батыр каны

йөрәккә таму; гайяр булу 2; өркә торган куян түгел; сырты сынар, сер сынатмас; сырты сынса да, сер сынатмас; тимер йөрәк<ле>; һәлакәт күзенә карау.

**АРЫСЛАН АВЫЗЫННАН СӨЯК АЛЫРДАЙ** *к.* арыслан авызына керү. *Курыкмагыз, монда арыслан авызыннан сөяк алырдай егетләр бар әле* (М. Фәйзи. Асылъяр).

Төрдәше: арыслан авызына керү һ.б.

**АРЫСЛАН ЙӨРӘК<ЛЕ>** <**БУЛУ**> *к.* арыслан авызына керү. *Мин аны кызганам: ул батыр егет. Ул арыслан йөрәк. Әмма алдана.* (Г. Ибраһимов). – *Беләсеңме, иптәш партионный секретарь, жир йөзендә йөз ел куян йөрәкле булып яшәгәнче, бер ел арыслан йөрәкле булып яшәвең әйбәтрәк* (Г. Ахунов. Идел кызы).

Төрдәше: арыслан авызына керү һ.б.

**АРЫСЛАН СӨТЕ** *ирон., шаярт., к.* агулы елан 1. *[Өстәлдә] ике-өч бутылка арыслан сөте илә төрле закускалар әзер иде* (Ш. Мөхәммәдов).

Төрдәше: агулы елан 1 һ.б.

**АРЫСЛАН СЫРТЫ.** Булдыклы, гайрәтле, көчле кеше. *Барысын да ачыклап кайту өчен, арыслан сырты егетләрне җибәрделәр* (Сөйләм).

Төрдәше: тимер йөрәк<ле>; ут уйната торган кеше; яшен ташы.

**АРЫСЛАН ТОТАР ДӘРӘҖӘГӘ ҖИТҮ.** Батырланып китү. *Кыюланып, арыслан тотар дәрәҗәгә җитеп кенә, алдан әзерләп куйган капчыкларны алып, хәвефле юлга тәвәккәлләделәр...* (Ф. Шәфигуллин. «Мотор» операциясе).

**АРЫСЛАН ТОТАРЛЫК КЫНА ЭЧҮ (ҖИБӘРҮ; КАПКАЛАУ; КӘГҮ; СЫЙЛАНУ; ПИРӘШЛӘП АЛУ).** Гайрәт керерлек кенә эчеп алу. *Арыслан тотарлык кына җибәргәч, җырлыйсы да килеп куя егетләрнең* (Т. Нәҗмиев. Эчендәге... тышында). *Кыюлык өчен, арыслан тотарлык кына кәгәрбез* (Т. Әйди. Елан угы). *«Арыслан тотарлык кына пирәшләп тә алдык бугай әле* (Э. Гадел. Сагындырып искә төшәләр шул...).

Төрдәше: арыслан тотып менәрлек кенә җибәрү.

**АРЫСЛАН ТОТЫП МЕНӘРЛЕК КЕНӘ ҖИБӘРҮ** *к.* арыслан тотарлык кына эчү (җибәрү; капкалау; кәгү; сыйлану; пирәшләп алу). *Чират Айдатка җитте... Эләккәндә арыслан тотып менәрлек кенә җибәргәли иде* (Г. Мөхәммәтшин).

Төрдәше: арыслан тотарлык кына эчү (җибәрү; капкалау; кәгү; сыйлану; пирәшләп алу).

*АРЫСЫН* ❖ **АРЫСЫН АРЫ, БИРЕСЕН БИРЕ КИТЕРҮ** *к.* ары-бире китерү 1, 2, 3. *Ат белән алып кайткан печәнне тиз генә арысын ары, биресен бире китереп, кеше күзеннән ераккарак куярга тырыштылар* (Сөйләм). *Арысын ары, биресен бире китерде дә иптәш кызлары янына йөгерде* (Сөйләм). *Атна башында гына кибеттән ике букча тутырып азык-төлек алып кайткан иде, арысын ары, биресен бире китерә торгач, ул да бетеп килә* (Сөйләм).

Төрдәше: ары-бире китерү 1, 2, 3 һ.б.; арысын аударып, биресен түнтәреп 2.

**АРЫСЫН АУДАРЫП, БИРЕСЕН ТҮНТӘРЕП** *к.* ары-бире китерү 2. *Тамагымны кысып, алдашып, арысын аударып, биресен түнтәреп тутырган идем, бушавын бик тиз бушады* (Ф. Хөсни. Йөзек кашы).

Төрдәше: ары-бире китерү 2 һ.б.

*АРЫШ* ❖ **АРЫШ БЕТЕ <КЕБЕК>.** Вак нәрсә, бик кечкенә. – *Без дә арыш бете түгел, дускай* (М. Әмирханов). *Бер селтәнүдә кесәсеннән яшел купюр суырып чыгарды да өстәлгә бәрде, янәсе, без дә арыш бете түгел дә арыш бете түгел* (М. Әмирхан. Дөя муены).

**АРЫШ БОЛАМЫГЫ.** 1. Булдыксыз, җебегән кешегә карата әйтелә. *[Гайни] Ул да шул бер изелгән арыш боламыгыдыр әле, бер дә артык җирләре булмас* (Г. Камал. Бәхетсез егет). *...Бар, чык әле, анасы. Мин аны чакырып алып азрак арт сабагын укытыйм, җебегән арыш боламыгының...* (М. Фәйзи. Асылъяр).

2. Артык юаш кеше. *Болай арыш боламыгы булып йөрсәң, ыштансыз калырсың* (Н. Фәттах).

Төрдәше: арыш камыры (салмасы) (ике маддә өчен дә).

**АРЫШ КАМЧЫЛАУ.** Арыш өлгереп килгән вакыттагы яшенле, күк күкрәүле яңгыр яву. *Бу арыш камчылаган кич иде* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

**АРЫШ КАМЧЫСЫ.** Аҗаган. *Арышларны кыйнап үстерәме / аҗаганнар – арыш камчысы?* (З. Мансуров. Җәрәхәтле йөрәк жылырак).

**АРЫШ КАМЫРЫ (САЛМАСЫ).** Авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү. *Килен булып төшкәннең икенче көнендә үк арыш камыры шикелле изелеп төшә бу* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Әй, җебегән арыш салмасы! Иске кое бит ул, бурасы черек!* (А. Гыйләҗев).
Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**АРЫШ КАПЧЫГЫ ЭЧЕНДӘ БӘЙЛӘП ЯШӘТҮ.** Хатын-кызның гомерен арыш уру һәм шул арыштан мичтә икмәк пешерү белән генә чикләү хакында. *Элекке ата-бабалар шикелле, хатынын арыш капчыгы эчендә бәйләп яшәтүне яратмый* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

**АРЫШ КУЯН КУУ.** Арышның серкә очырганда җил белән айкалуы һәм дулкынлануы. – *Арыш куян куа, әнә күрәсезме? – диде, басуда уйнаган дулкыннарга күрсәтте* (Р. Хафизова).

**АРЫШ МАЕ** *эвф., к.* агулы елан 1. *Хуҗа хатын өстәлгә бер шешә болганчык су китереп утыртты. Бусы ни булды тагы? Арыш маемы?* (М. Әмир).
Төрдәше: агулы елан 1 һ.б.

**АРЫШ МАЕ БЕЛӘН ЧЫЛАТЫП ҖЕБЕТҮ.** *[Сәмигулла] Соң сез ни эшләп бераз арыш майлары белән чылатып җебетмисез, аннан соң ул бераз йомшарыр иде* (Г. Камал. Дәҗҗал).
Төрдәше: арыш мае белән җебетеп чылату.

*АРЫШНЫ* ❖ **АРЫШНЫ БОДАЙДАН АЕРМАУ** *к.* авыз суы кипмәгән. *[Зиннәт] Яшь шул, арышны бодайдан аера белми* (Ю. Әминов. Тамырлар).
Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

*АС* ❖ **АС БУЛУ.** 1. Үз эшенең остасы булу. *Әмма немец очучылары үзләре нинди генә ас булсалар да, хәрби заданиегә беркайчан да ялгыз очмаганнар* (Р. Ибраһимов. Бөркетләр кыядан курыкмый).
2. Түзә алмыйча, кече хаҗәтен башкару. *Яндырып, бака исеннән хәл ас булдылар* (К. Насыйри. Әбүгалисина кыйссасы).
Төрдәше: аска җибәрү; асты юеш.

**АС САЛУ.** Аяк киеменең табанына олтан кую (ябыштыру). *Нуретдин, тәбәнәк өстәл янында утырып, иске киез итекләргә ас сал* (К. Тинчурин).
Төрдәше: аслык салу; олтан салу; олтан сугу; олтан тегү; табан салу; табан сугу; табан тегү; төп салу.

*АСАБА* ❖ **АСАБА БАШКОРТ.** Төп җир хуҗасы саналучы башкорт. – *Иптәшләр, менә сезгә Ашказар буе асаба башкортларының беренче курайчысы – минем Вәли әфәнде* (Г. Ибраһимов).

*АСАУ* ❖ **АСАУ АЙГЫР.** Кулга өйрәтелмәгән айгыр, өер айгыры. – *Асау айгыр өйрәткәнең бармы? – диде* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы); *Дүртбиш адым ара калдырып, янә ун алпамша тезелеште. Асау айгыр кебек таптанышып торалар* (М. Әмирханов. Әлвидаг).

*АСКА* ❖ **АСКА ҖИБӘРҮ** 1. *туп., к.* авызга җан килү. *Валлаһи, дим, Мөтби Гөргөричнең шашкан кыяфәтен күреп аска җибәрдем* (Р. Сибат. Ялгызак).
Төрдәше: авызга җан килү һ.б.
2. *к.* ас булу. – *Безнең бик батыр бер янарал бермәлне немечнең янтавына шәп кенә итеп берне тондырган иде, немечең гүпчи астына ук җибәрде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). – *Апа, мин үзем дә унҗидегә кадәр аска җибәрә идем* (Р. Кәрами. Өч көннән чалырсыз).
Төрдәше: ас булу; асты юеш.

**АСКА КАЛДЫРУ.** 1. Үтенечне, сүзне тыңламау. *Бу хакта Илһам хан белән сөйләшү булмаган иде, әмма Артык баһадирның әмир сүзен аска калдырасы килмәде* <…>. (М. Хәбибуллин. Хан оныгы Хансөяр).
2. Башка эш-хәлләрнең әһәмиятен киметү, онытттыру. *Кешенең дини тойгылары, денәнә бирелгәнлек бөек хис булган мәхәббәтне дә аска калдыра* (А. Әхмәдуллин. Офыклар киңәйгәндә).
3. Җиңү, өстен чыгу. *Менә шуның өчен дә инде халык арасында низаг хөкем сөрә... Һәрбер имам, үзен өскә чыгарыр өчен, бер-берсен шулай аска калдырырга тырыша* (matbugat.ru).
Төрдәше: аска калу; аста калдыру; аста калу.

**АСКА КАЛУ** *к.* аска калдыру 1, 2, 3. *Тарих, комга күмелеп, аска калды* («Шәһри Казан» газ.). *Үзенә тапшырылган хатны бүген укырмын дигән иде, әмма ул да аска калды* (Сөйләм). *Бы-*

*елгы Сабан туенда җиңеп чыгармын дип өметләнгән иде, соңгы орышта хата җибәреп, аска калды* (Сөйләм).

Төрдәше: аска калдыру 1, 2, 3; аста калдыру; аста калу.

**АСКА КАРАУ.** Карашны идәнгә (җиргә) төбәп тору. *Аска карап буен сындырып, Нәҗип мунча ишегенә кереп югалды, шабырдатып утын яркаларын идәнгә койды* <...> (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). – *Син нәрсә, төне буе шунда басып торырсыңмы? Рәния аска карады* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

Төрдәше: күзне аска алу; күзне түбән төшерү.

**АСКА СУ ҖИБӘРҮ** *к.* артына су керү (үтә башлау). – *Аксак Тимер кайсы хаким астына су җибәрә, кемгә бармак яный – безгә шул отышлы* (В. Имамов. Карабәк).

Төрдәше: артына су керү (үтә башлау) һ.б.

**АСКА СУ ЙӨГЕРҮ.** Авыр хәлдә калып, эш начарлану. *[Актай] Астыңа су йөгерсә, әлләниләр әйтерсең, кызым* (Н. Фәттах. Кол Гали).

Төрдәше: артына су керү (үтә башлау) һ.б.

**АСКА СУ КЕРГӘЧ <КЕНӘ> ЙӨЗӘ БАШЛАУ.** Куркыныч белән очрашкач кына, аның турында уйлый башлау. *Кайберәүләр, һәрнәрсәне тыныч кабул итәләр дә асларына су кергәч кенә йөзә башлыйлар* (Сөйләм).

Төрдәше: артына су керү (үтә башлау) һ.б.

**АСКА СУ КЕРҮ (ҮТҮ)** *гади с.* 1. Вакыты килеп җиткәч кенә, ашыгыч рәвештә эшкә керешү. *Зотов та авызын йомып калмады, уенын-чынын бергә кушып: – Үзегез әйтмешли, аска су үтә башлагач, селкенерсез небось!.. – диде* (М. Хәсәнов. Саф җилләр).

Төрдәше: аска су кергәч <кенә> йөзә башлау.

2. *к.* артына су керү (үтә башлау). *Астыгызга су үткәнче кыймылдарга кирәк иде аны* (М. Хәсәнов).

Төрдәше: артына су керү (үтә башлау) һ.б.

*АСКЫ* ❖ **АСКЫ ИРЕННЕ ЧӘЙНӘҮ (ЧӘЙНӘП БЕТЕРҮ).** Үз-үзен кулда тотарга, чыдарга тырышу. *Бер түздe, ике, аскы иренен чәйнәп бетерде, ниһаять, чыдамады, колонналар өстендә чайкалган зур-зур портретларны янәшә баскан укучыларына күрсәтеп, шаркылдап көләргә тотынды* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**АСКЫ ЯК.** Нәрсәнең (мәс., киемнең) булса да эчке ягы, астары. – *Аскы якка кызыл төсле материал алсаң, матуррак булыр* (Сөйләм).

Төрдәше: кире як; сул як; тискәре як; тирес як; эчке як.

*АСЛАМ* ❖ **АСЛАМ МАЛ.** Элегрәк заманнарда кулдан күтәреп йөртеп сатылган мал, нигездә, тукымалар. *Элегрәк заманда аның әтисе аслам мал белән сату иткән бугай* (Сөйләм).

*АСЛАРЫ* ❖ **АСЛАРЫ КҮЛ БУЛУ** *күч., тупас.* Бик нык хисләнү. *Көмеш телләрдән коелган моңнардан кыз-кыркынның аслары күл була, мин сезгә әйтим* (А. Хәлим).

*АСЛЫК* ❖ **АСЛЫК САЛУ** *к.* ас салу. *Шамил эчтән генә көлемсерәде. – Көя кискән киез итеккә аслык салган кебек, һәр тишеккә үз теориягезне китереп кыстыра беләсез инде* (З. Фәтхетдинов. Үлем элмәге).

Төрдәше: олтан салу; олтан сугу; олтан тегү; табан салу; табан сугу; табан тегү; төп салу.

*АСМАКТАН* ❖ **АСМАКТАН ТӨШКӘН.** Бик явыз кеше турында, ягъни асарга хөкем ителеп тә, муенына элгән элмәктән, аскылыктан төшкән. – *Безнең авылда асмактан төшкән берәү бар иде, Аллага шөкер, ул да әллә кая китеп югалды* (Сөйләм).

*АСРАМАГА* ❖ **АСРАМАГА АЛЫНГАН КЫЗ (МАЛАЙ).** Гаиләдә яшәү, тәрбияләп үстерү өчен читтән алынган бала. *Әлфия исә шулай ук аның кызы, ләкин үзенеке түгел, асрамага алынган кызы* (А. Расих. Сынау).

*АССАЛАР* ❖ **АССАЛАР ДА СҮЗЕННӘН КАЙТМАС.** Принципларыннан читкә тайпылмый торган, сүзендә торучы кеше. *Мин андый кеше белән беренче кат очраштым, ул ассалар да сүзеннән кайтмас кеше иде* (Сөйләм).

*АСТА* ❖ **АСТА КАЛДЫРУ** *к.* аска калдыру 1, 2, 3. *Үз туганы Туранны узып китү, аста калдыру, җиңү Түлгәннең төп максатына, яшәү рәвешенә әйләнде* (Ф. Бәйрәмова. Нух пәйгамбәр көймәсе). – *Халык минеке кебек шигырьләрне дә укырга тели... – диде ул, үз сүзен аста калдырасы килмичә* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!). *Минәт, Мәхмүтне аста калдырып, күкрәге белән җиргә кысты* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

Төрдәше: аска калдыру 1, 2, 3; аска калу; аста калу; бөгеп салу.

**АСТА КАЛУ** *к.* аска калдыру 1, 2, 3. *Хаклык һич аста калмый* (Г. Исхакый. Өч хатын белән тормыш). – *Йә, кем аста калды да кем өскә чыкты?* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Нәрсә белән беткән булыр иде мондый көрәш-орыш, аста калган иптәшен дөмбәсли башлаганда гына әгәр тегесенең әнисе килеп чыкмаган булса* (К. Җәмит. Килмешәк).
Төрдәше: аска калдыру 1, 2, 3; аска калу; аста калдыру.

*АСТАН* ❖ **АСТАН АШАУ.** Алдан кеше белән бергә ашагандай күренсә дә, арттан яшереп ашый торган; дәүләтнекен урлашу. – *Син нәрсә, бездә астан ашый торган кешеләр юк дисеңме?!* (Сөйләм).

**АСТАН ӘЙТҮ (ӘЙТЕП ТОРУ).** Сиздермичә генә пышылдау, астыртын әйтү. *Бөтенесен бераз «интектерер» өчен, урыннарны астан әйтә башлыйлар* («Безнең гәҗит» газ.).

**АСТАН БАРМАК УЙНАУ.** 1. Тыштан шома күренсә дә, яшертен генә этлек эшләү. *Бу эштә аның астан бармагы уйнавы турында шик тә юк* (Сөйләм).
Төрдәше: астан кул уйна<т>у.

2. Кибеттә әйберне үлчәп сатучыларның үлчәүгә яшертен генә бармак белән басулары. *Мөнирәнең еш кына астан бармагы уйный иде, шунлыктан ул бу урында озак эшли алмады* (Сөйләм).

**АСТАН БОЛЫТ ТА АК КҮРЕНӘ.** «Гомуми беренче караш һәрвакытта да дөрес фикер бирми» мәгънәсендә. *Астан болыт та ак күренә, баксаң аңарда да кара таплар бихисап, чөнки кара әйләндереп, җирдәге пычрак суны йота* (Н. Гыйматдинова. Нурулла).

**АСТАН ГЫНА.** Яшерен рәвештә, сиздермичә генә. *Сатучы аңа астан гына бер төргәк шудырды* (Сөйләм).
Төрдәше: астыртын гына; бармагы роль уйнау; бармак белән уйнату; бармак уйнату; бармау уйнау 2; бармакта биетү; бармакта уйнату.

**АСТАН ДА, ӨСТӘН ДӘ ЙӨЗҮ.** Сиздереп тә, сиздермичә дә эшләү. *Сокланырлык дәрәҗәдә эш йөртә белә бу халык: астан да, өстән дә йөзәргә өйрәнеп килә* (Р. Батулла. Сөембикә).

**АСТАН ЙӨР<Т>Ү.** Эшне яшертен эшләү. *Шунысы бар: сайланган деканга яңа якын торучылар уңышны үзләре астан йөрткән эш нәтиҗәсе дип аңлатсалар, тавыш җыя алмаган кандидатка җиңелүендә, аңа барыбер икәнлеген белмәгәндәй, тегене яки бу мескенне гаепле итеп күрсәттеләр* (Р. Рахман. Сайлау).

**АСТАН КАЗ<ЫН>У.** Кешенең гаебен табып фаш итү өчен эзләнү, чокчыну. *Илдус әфәнде, Сезнең тармакта алай түгелме? Астан казымыйларны фундаментларыгызны, безнең тармакта ничек икәнлееe укый торган статьяларда күренә, ичмасам* («Безнең гәҗит» газ.).

**АСТАН КЕРЕП, ӨСТӘН ЧЫГУ.** Булдыклы кеше турында. *Астан кереп, өстән чыккан* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).
Төрдәше: авырның өстеннән, җиңелнең астыннан 2 һ.б.

**АСТАН КИСЕП (УЕП), ӨСТӘН ЯМАУ** *ирон.* Тыштан яхшылык эшләгән булып, асылда, зарар бирү, ягъни хәйлә белән эш итү, икейөзле булу; хәйләкәр, астыртын булу. *Гайшә апа: «Сак бул, кызым, астан кисеп, өстән ямый торган кыз ул», – диде аның турында* (Н. Фәттах. Мөдир Саҗидә).
Төрдәше: астан кисү; астан тешләү; астан уеп, өстән җую; астан ут җибәрү (җибәреп яту); астан ут йөртү; бу кешенең юлы җир астыннан йөри; итәк астыннан ут (эш) йөртү; итәк астыннан ут уйнату (җибәрү); итәк кисеп җиң ялгау (ямау).

**АСТАН КИСТЕРӘ ТОРГАН.** Астыртын рәвештә эш иткән икейөзле кешеләр турында. *Чүпрәледән тагын да арырак китсәк, Иске һәм Яңа Чокал авыллары булып, берсендә мишәрләрнең астан кистерә торганы, икенчесендә телгә-күзгә елгырлары яши* (Ф. Яхин. Бар бер авыл, Чокал, диләр...).

**АСТАН КИСҮ.** Тыштан дус, теләктәш булып, астыртын гына зыян эшләү. *Конфликтка керергә яратмыйм үзем, ләкин миндә астан кисү дигән әйбер бар* («Матбугат.ру» порталы).
Төрдәше: астан кисеп (уеп), өстән ямау һ.б.

**АСТАН КӨЛҮ.** Астыртын, хәйләле, чәнечкеле көлү. <…> *тел-стиль чаралары, композициясе, алардагы антитезалар, киная, астан көлү кебек шигъри алымнар җентекләп тикшерелә* (Ф. Урманчеев. Халык хикмәте әсәрләре).

**АСТАН КУЛ УЙНА<Т>У.** Астыртын рәвештә әшәкелек эшләү, дошманлык тудыру. *Хәлләрнең бергә-бергә килеп чорналышуымы, әллә астан берәр кул уйныймы?* (Х. Камалов).
Төрдәше: астан бармак уйнау.

**АСТАН ТЕШЛӘҮ** *к.* астан кисеп (уеп), өстән ямау. *Заманга яхшы яраклашып, астан тешли торган адәмне кем диләр?* («Матбугат.ру» порталы).
Төрдәше: астан кисеп (уеп), өстән ямау һ.б.

**АСТАН ТОЛЫП, ӨСТӘН ТУН.** Кеше фикеренә колак салмый торган, һәрвакыт үз сүзен дөрес дип санаучы турында. *Үз сүзен бирә торган кеше түгел ул, астан толып, өстән тун кигән ул* (Сөйләм). *Астан толып, өстән тун* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

**АСТАН УЕП, ӨСТӘН ҖУЮ** *к.* астан кисеп (уеп), өстән ямау. – *Урыслар нишләптер песи булдылар, бу һич тә аларга охшамаган, – диде чираттагы чапкын, – астан уеп, өстән җуеп куймагайлары* (М. Әмирханов. Үрбәт ханәкә гыйшкы).
Төрдәше: астан кисеп (уеп), өстән ямау һ.б.

**АСТАН УРТ САЛУ (ҖИБӘРҮ).** Араны бутау, дошманлык тудыру (урт салу – былтыргы коры үләнгә, камылга ут төртү). *Һәр сүзгә дә ышанырга ашыкма, монда астан урт җибәрергә яратучылар шактый булыр* (Сөйләм).
Төрдәше: ара айкау һ.б.

**АСТАН УРТЫН ЧӘЙНӘҮ.** Тыштан сиздермәсә дә, эчтән үзен үзе ашау. *Ул аларга бер күз белән булса да карап ала да, башкаларга сиздермәскә тырышып, астан гына уртын чәйни иде* (Сөйләм).

**АСТАН УТ ҖИБӘРҮ (ҖИБӘРЕП ЯТУ).** Астыртынлык, икейөзлелек, эчкерлелек күрсәтү; *шулай ук к.* астан ут йөртү. *Астан ут җибәреп яту* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).
Төрдәше: астан кисеп (уеп), өстән ямау һ.б.

**АСТАН УТ ЙӨРТҮ.** Астыртын эшләү; хәйлә, мәкер кору. *Яңгырбай астан ут йөртте: «Уналты еллык калымлыгын тартып алганда да үз баласын яклый белмәгән ыругның намусы кайда икән?» – дип, коткыны туктатмады* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).
Төрдәше: астан кисеп (уеп), өстән ямау һ.б.

**АСТАН ЧИКМӘН, ӨСТӘН ТУН.** Эшне киресенчә эшләп куйган кешегә карата әйтелә. *Аңа ышанып, эш тапшырып буламыни, астан чикмән, өстән тун булган аның* (Сөйләм).

**АСТАН ЭШ ЙӨРТҮ (ИТҮ).** Бар нәрсәне яшерен эшләү. *Гәүһәршад бикә янә иренә бакты да янә үз алдына әйтте: – Ю-ук, бу карт качар, астан эш йөртү остасы булса да, бер ялгызы гына бу эшне майтара алмас* (Р. Батулла. Сөембикә).
Төрдәше: астан кисеп (уеп), өстән ямау һ.б.

*АСТЫ* ❖ **АСТЫ<Н> ӨСКӘ.** Җаен, тәртибен бозу; булырга тиешле тәртипнең нәкъ киресен эшләү. *Чынлап та, бөтен өйнең астын өскә китерсәләр дә, малайлар хат түгел, сыңар кәгазь дә таба алмаганнар иде* (А. Гыймадиев. Үзең булып кал!..).
Төрдәше: асты өскә айкалу; асты өскә актарылу; асты өскә әйләнү; асты өскә килү; асты – өскә, өсте аска әйләнү; вәйран булу 1; дөньяның асты өскә килү; зир-зә(ә)бәр килү; өсте аска килү.

**АСТЫ ӨСКӘ АЙКАЛУ.** Зур чуалчык, буталыш барлыкка килү; әйберләрнең рәте-башы калмау; булырга тиешленең киресе. *Әйе, тормышның асты өскә айкала, кешеләр, су өстендә йөзгән йомычкадай, төрле якка чайкала...* (Т. Гыйззәт).
Төрдәше: асты<н> өскә һ.б.

**АСТЫ ӨСКӘ АКТАРЫЛУ** *к.* асты өскә айкалу. *Шуннан соң күп тә үтми, Фәгыйлә белән Шакирҗан эштә вакытта боларның өенә кемнәрдер кергән, бөтен әйбер асты өскә актарылган була* (С. Сабиров. Алтын балдаклы абыстай).
Төрдәше: асты<н> өскә һ.б.

**АСТЫ ӨСКӘ ӘЙЛӘНҮ** *к.* асты<н> өскә. *Әйтерсең лә дөньяның асты өскә әйләнде, һәм моңа сәбәпче ул иде* (Ф. Садриев. Шаһзаманов эше).
Төрдәше: асты<н> өскә һ.б.

**АСТЫ ӨСКӘ КИЛҮ** 1. *к.* асты<н> өскә. – *Бөтен өй кайнады, бөтен йортның асты өсткә килде* (Г. Исхакый. Кияү). *Асты өскә*

*килгән дөнья бүген, / Чакрым саен җиде борылыш* (К. Булатова).

Төрдәше: асты<н> өскә һ.б.

2. Эштә, тормышта чуалчыклар туу, зур фаҗыйга хасил булу. *Шул чагында кинәт кояш сүнде, шул чагында кинәт җирнең асты өскә килде!* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур). *Өйнең асты өскә килгән, / Асты өскә килгән күңел / Нахак белән килешмәде* (М. Әгъләм).

Төрдәше: асты<н> өскә һ.б.

**АСТЫ – ӨСКӘ, ӨСТЕ – АСКА ӘЙЛӘНҮ** *к.* асты<н> өскә. *Асты – өскә, өсте – аска / әйләнде дөнья безгә! / Колмак бата, таш йөзә... / Йөрәк тузды, баш түзә* (Р. Фәйзуллин).

Төрдәше: асты<н> өскә һ.б.

**АСТЫ – ТӘПИ, ӨСТЕ – ТӘТИ**. Тишек аяк киеме турында. *Асты – тәпи, өсте – тәти* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

**АСТЫ ЮЕШ** *к.* ас булу. *Нәзир гаепле кыяфәттә, асты юеш бала кебек, хатыны янына килеп туктады* (Х. Мөдәррисова. Яр).

Төрдәше: ас булу 2 һ.б.

*АСТЫН* ❖ **АСТЫН ӨСКӘ (ӨСТЕНӘ) АЙКАУ (ӘЙЛӘНДЕРҮ; КИТЕРҮ).** 1. Бозып бетерү, буталчык тудыру. *[Закир] Аһ, йөзе кара! Минем бөтен зиһеннәремнең астын өстенә китерде* (Г. Камал. Бәхетсез егет). *[Кара фикер] Ләкин бөтен дөньяның астын өскә әйләндерергә теләгән Кызыл фикерне башыңа кертеп харап булдың* (Г. Коләхмәтов. Ике фикер).

Төрдәше: пыран-заран китерү.

2. Тузгыту, туздыру. *[Җиләкче] Шаярмагыз, абзыйга әйтәм, дачаңның астын өскә китерер* (К. Тинчурин. Йосыф белән Зөләйха). – *Каганның астын өскә китерермен, / Аппагымны тартып алырмын* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).

Төрдәше: әвен сугу; вәйран итү 1; көлен күккә очыру; пыран- заран китерү; себереп түгү; тар-мар итү; тетмәне тетү 2; чәлпәрәмә китереп җимерү; эттән алып эткә салу.

3. Гадәти тәртипне бозу, әйберләрнең тәртибен югалту; тәртипсезлек ясау. *Бу малайлар әнә шул газиз балалык дөньясын озакламыйча астын өскә китерәчәкләр* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *[Назимә] Кайтуына өенең астын өскә китергәннәр* (З. Хәким. Телсез күке).

4. Җирне сөреп яки казып чыгу. *Башнясын артка таба борган танк трактор сабаны белән йөз илле гектар җирнең астын өскә китерде* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

**АСТЫН ӨСКӘ ӘЙЛӘНДЕРЕП КОРУ**. Өр-яңадан башлау. – *Шундый кешеләр бар, алар дөньяны... (Һәм Якуб дөньяның астын өскә әйләндереп кору турында үзенең белгәннәрен сөйләп бирде)* (И. Гази. Онытылмас еллар).

*АСТЫНА* ❖ **АСТЫНА УТ ҮРЛӘТҮ.** Куркыту. – *Кстати, Сөләйман малаен кисәт: язга бакчаңны чистартсын. Ату жалу язам дип, астына ут үрләт!* (Н. Гыйматдинова. Үзем генә беләм...).

Төрдәше: башыңны борып атармын!; борын төбендә бармак уйнату; дөнья тетрәтү; дөньяны тетрәтеп тору (тоту); җанны бармак очына китерү; җанны басу; җанны табан астына качыру; җаның үкчәңә төшәр; җаныңны алып, ярыкка кыстырырмын; йөрәген алу; йөрәкне калтырату; йөрәкне өшетү; кан калтырату; койрыкны кысу 1; кот очыру; котны <җыеп> алу; котны үкчәгә төшерү; муеныңны сындырырмын; хафага салу.

*АСТЫНДАГЫН* ❖ **АСТЫНДАГЫН АЛТЫ АЙ ЭЗЛӘГӘН** *кимс., к.* алдындагын (алдындагысын) алты ай эзләгән. *Мисал итеп, елкы күтәргә яллаган Мокыт агайның, үзе атланган атны исәпкә кертмичә, бер атым югалды дип, ат эзләп йөрүе турындагы мәзәкчәдән алып әйтелгән астындагын алты ай эзләгән әйтелмәсен китерергә була* (Татар лексикасы I).

Төрдәше: алдындагын (алдындагын) алты ай эзләгән һ.б.

*АСТЫННАН* ❖ **АСТЫННАН ЙОМРАН КАЗЫП ҮТКЕСЕЗ.** Каршыда зур, калын киртә булу турында. *Егет күзен ачса, <...> астыннан йомран казып үткесез калын таш коймa белән әйләндерелгән зур бер кала тора иде* (Әкияттән).

*АСТЫРТЫН* ❖ **АСТЫРТЫН ГЫНА** *к.* астан гына. *Очрашып сөйләшкәндә, елмаеп кына сөйләшсә дә, астыртын гына мәкерле уен тормышка ашыра барды* (Сөйләм).

Төрдәше: астан гына һ.б.

**АСТЫРТЫН УЙ.** Бер төрле сүз сөйләп, башында икенче төрле план саклау. *Аның очрашыр-*

*га теләвендә бернинди дә астыртын уй, мәкер, өмет юк* (Р. Кәрами. Кая чабасың, гомер юртагы?).
Төрдәше: яшерен фикер.

**АСТЫРТЫН УТ ЙӨРТҮ** *к.* астан ут йөртү. – *Ул кунтр, ул, Колчак безгә килгәндә, ишанда качып ятты, астыртын ут йөртте, дип сөйләгәннәр, ди* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).
Төрдәше: астан ут җибәрү (җибәреп яту) һ.б.

*АСУЛЫ* ❖ **АСУЛЫ КАЗАН, ПЕШҮЛЕ АШ (ЯГУЛЫ УТ).** Пешереп куйган ризыкка туры килгән кунакны каршылаганда әйтелә. *Хуҗа ипи көрәге шикелле зур учы белән Айдатның кулын кысты. – Асулы казан, пешүле аш бар. Рәхим итегез!* (Г. Мөхәммәтшин. Йөрәктәге эзләр). *Асулы казан, ягулы ут* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).
Төрдәше: мактап йөрисең икән.

*«А»СЫ* ❖ **«А»СЫ ГЫНА.** Нәрсәнең булса да кереше, башы гына. – *Алай җиңел котылам дип уйлама, «а»сын гына күрдең әле...* (Сөйләм).
Төрдәше: анысы әле баласы <-чагасы> гына, мич башында (мичтә) ята анасы һ.б.

**«А»СЫ ГЫНА, «Б»СЫ...** «Бу әле башы гына, дәвамы соңрак» мәгънәсендә. – *Ашыккан ашка пешкән, – диде. – Монысы әле хикәянең кереш өлеше генә иде. «А»сы гына, «б»сы аның артыннан булыр* (Г. Мөхәммәтшин. Йөрәктәге эзләр).
Төрдәше: анысы әле баласы <-чагасы> гына, мич башында (мичтә) ята анасы һ.б.

*АСЫЛ* ❖ **АСЫЛ ВАТАН**. Кешенең туган җире, ятар туфрагы булган урын. – *Әйе, бабалары җирен күпләр асыл Ватан дип йөртә* (Р. Юныс. Татар гаме). *Ә аннан, ул җирдән кире кайтасы түгел. Ул – төп йорт, асыл Ватан* (Ф. Яхин. Яшәеш казанышлары).

**АСЫЛ ВАТАНГА КАЙТУ**. Үлгәч, туган җиренең туфрагына күмелү. *Түр тәрәзәкәйне ачып ук куегыз, / Ялан җиргә карап ла ятыем, / Алып килегез мулла, укысын ясин, / Асыл ватаныма кайтыем* (Җыр). *Сез күп еллар элек Казанга, асыл Ватанга кайтам, дип кайттыгыз бит инде* (Р. Юныс. Татар гаме).

**АСЫЛ ЕГЕТЛӘР.** Кешелекле, абруйлы, чын егетләр. *Илнең асыл егетләре / Ай йөзеңә сокланган* (М. Фәйзи. Ак калфак). *Ничек инде асыл егет Зарифның хисләрен «ихлас» дия алсын?* (Ф. Яхин. Таң кызы).

**АСЫЛ ЗАТ.** 1. Дәрәҗәле, хөрмәтле кеше; югары, өстен зат *[Хәмдия] Илнең асыл затлары өчен генә яралган кызыңның пакь исемен буявыңны мин күтәрә алмыйм, атакай* (М. Фәйзи. Ак калфак).

2. *иск*. Морза нәселеннән, аксөяк. *[Шаһтимер] (нык итеп). Син бер асыл зат!* (М. Фәйзи. Ак калфак).

3. *к.* асыл мал 1, 2. *Калымлык өчен йөз кара, биш йөз сум акча, ике сандык асыл зат алып куйганнар...* (Г. Ибраһимов). *Кулыңа төшкән икән инде шундый бер асыл зат... аны сыйпап кына, саклап кына, кадерләп кенә тоталар...* (Н. Кәримова. Ак әрем чәчәге).
Төрдәше: асыл мал 1, 2.

**АСЫЛ КЕШЕ.** Акыл, белем, кешелеклелек ягыннан абруйлы шәхес. *Асыл кеше сөя – бары / Җаны гүзәл җанлыны* (Х. Туфан). *Бирәү сөя маллыны, / Бирәү сөя данлыны, / Асыл кеше сөя бары / Җаны гүзәл җанлыны* (И. Нәбиуллина. Әйләнә дөнья).

**АСЫЛ КОШ.** 1. Матур сайрый торган кош; сандугач. *Йөрәккә асыл кош/ Тикмәгә кунмастыр* (И. Юзеев. Тыңлачы, сандугач). *[Тавыш] Җәйнең ямьле көннәрендә асыл кошлар кычкыра, / Әллә нинди җәбегән авыз / Егет саен кочтыра* (М. Фәйзи. Галиябану).

2. *ирон.* Затлы, гүзәл хатын-кыз. *[Фәтхерахман] Менә синең шикелле матур егетләр шул асыл кошларны эләктерергә бакчага чыгалар* (Г. Камал. Уйнаш).

3. *к.* асыл зат 1. *[Камали] «Кичә Сабитовның өенә кергән каракның берсе шул», – диермен. Асыл кош аягыннан тотылды* (Г. Камал. Бәхетсез егет). *Әйе, Сәйдәш кебек «асыл кош»ның бер-бер гаебен табып, тәпиеннән эләктерсәләрме?..* (Р. Низами. Сәйдәшнең соңгы елы).
Төрдәше: асыл зат 1.

**АСЫЛ КОШ АЯГЫННАН ЭЛӘГҮ.** Чибәрләргә битараф булмау, алар белән якыннан танышу, дуслашып китү. *Нихәл, асыл кошлар, яхшы эләктегезме! Шулай ул, асыл кош аягыннан эләгә, ди ул* (Г. Камал). *Үзе исә, гүя якын ук килгән асыл кошны куркытмас өчен, артык*

*хәрәкәт ясаудан тыелып, тик кенә утыра бирде* (Ә. Еники. Рәшә).

**АСЫЛ КҮЛМӘК.** Уң ягы ялтыравыклы ефәк, сул яңы исә ялтыравыксыз материядән тегелгән күлмәк. *Мәһитап кием шкафыннан бер асыл күлмәк алып бирер, Сәхибә китәр* (Г. Ильяси. Бичара кыз). – *Сез кем, фәләнетдин, үз кызыңны дүрт йөз сум акча, бер ука чачаклы асыл күлмәк бәрабәренә Биктимер Зәйнетдин угылына бирдеңме?* (Ф. Әмирхан. Татар кызы).

**АСЫЛ МАЛ.** 1. Алтын-көмештән, асыл-ташлардан эшләнгән әйберләр; кызыл мал. *Асыл мал: / Кызларының эчке күлмәгендә / Яшереп теккән ташлар табылган* (Х. Туфан. Урал эскизлары).

2. *күч.* Чибәр, сылу хатын-кыз. – *Игелеген күрергә насыйп булсын, бик тә асыл мал, берүк бәла-казалардан, яман күзләрдән саклый күр инде... – дип хуплап каршы алды аны бабасы* (З. Зәйнуллин. Үрләр аша).

**АСЫЛ НӘСЕЛ** *к.* ак токым. *[Сәлим] Асыл нәсел бер мирза кызы көтүчегә төшәчәк таякны үзенә алырга мөмкинме?* (М. Фәйзи. Ак калфак).
Төрдәше: ак токым;. аксөяк нәсел.

**АСЫЛ НӨСХӘ.** Төп нөсхә, язучы үзе кул куйган төп нөсхә әсәре, оригинал. *Фәкать «Пожар вакытында» дигән кечкенә сатирик мәкаләсеннән асыл нөсхә бар* (Р. Харрасова. Уйлар Тукайга илтә).

**АСЫЛ СӨЯК<ЛЕ>.** 1. Нәселле, яхшы тәрбия күргән; *шулай ук к.:* асыл зат. *Асыл сөяк зур булмас, кайда барса да хур булмас* (Мәкаль). – *Ярар, ул очракта үзеңнән кадерле зат, асыл сөяк кыйлансаң да була* (В. Имамов. Утлы дала).
Төрдәше: асыл зат.

2. Нәселле, яхшы нәселдән булган хайван. *Асыл сөяк чабышкы атлар, үз тирәсендә исем казанган көрәшчеләр, шәп йөгерүче җегетләр бу җыенга йөзәр чакрымнан киләләр – көч сынамакчылар, үзләрен күрсәтмәкче, дан казанмакчылар* (Г. Ибраһимов. Алмачуар).
Төрдәше: асыл токым.

3. *иск.* Морза нәселеннән чыккан кеше. *[Бакый] (кире торып). Гаеп итмә, мирза, бер көтүче асыл сөяк бер мирза баласының дусты була алырмы?* (М. Фәйзи. Ак калфак).
Төрдәше: асыл зат.

**АСЫЛ ТОВАР.** Сәүдәдә сирәгрәк булган һәм кыйммәтле саналган затлы әйбер. *Асыл товарны мыскаллап саталар* (Мәкаль).

**АСЫЛ ТОКЫМ.** Нәсел токымы. *Безнең хуҗалыкка да бер асыл токым кайтты* (Сөйләм).
Төрдәше: асыл сөяк<ле> 2.

**АСЫЛ ЯР.** Вәгъдәсендә торучы сөйгән яр, ышанычлы сөекле. *Безнең ярлар асыл яр иде!* (Зөлфәт. Канат җиле). *Үз ярыңа асыл яр була белүдән тора* (Ф. Мөслимова. Асылъяр, кошкаем).

*АСЫЛАСЫ* ❖ **АСЫЛАСЫ НӘРСӘ** *карг., тирг.* «Дарга асылып үлмичә, бу явыздан котылып булмас» мәгънәсендә каргау сүзе. *Бер тынгытынычлык юк теге асыласы нәрсәдән* (Сөйләм).

*АСЫЛГА* ❖ **АСЫЛГА ТӨРЕНҮ.** Затлы кием киенү, байлык-зиннәт эчендә. *Без әмир өчен штурмларга барганда, хәзер революционер исемен күтәрүче яшь бохаралыларның байтагы өенә бикләнеп, асылга төренеп, пылау белән сыйланып кына ятты, дигән!* (Т. Әйди. Елан угы).

*АСЫЛЫНА* ❖ **АСЫЛЫНА КАЙТУ (ӘЙЛӘНҮ).** Элекке хәленә әйләнү, килү. *Дөньяда һәр нәрсә дә үз асылына бер әйләнә* (Г. Тукай). *Әгәр дә галимәнең фаразлары дөрескә чыкса, төркиләрнең латин әлифбасына кайтуы асылына кайту шикелле вакыйга булачак* (А. Тимергалин. «Инкыйраз»га йөз ел).

**АСЫЛЫНА <ТӨШЕП> КАРАГАНДА.** Мәсьәләне төбеннән, төп нөсхәдән һ.б.ны тикшергәннән соң. *Язмаларының асылына караганда, Күлтәси дингә ышанмагандыр дип тә уйларга мөмкин* (К. Фасеев, Ә. Булатов. Мәгърифәтче галим Шәмсетдин Күлтәси).

**АСЫЛЫНА ТАРТУ.** Нәселдән килгән сыйфатларның балада (яки өлкән кешедә) сиземләнүе. – *Һәр нәрсә үз асылына тартыр, – дип сөйләнә* (Ә. Баян. Уйлар дәрьясында). *И бәхетсез, килбәтсез, нәҗес татар, / Асрама эт баласын – асылына тартыр!* (Ф. Яхин).

*«А»СЫН* ❖ **«А»СЫН ӘЙТКӘЧ, «Б»СЫН ӘЙТҮ** *к.* «а» дигәч, «б»ны әйтү. – *Нигә туктап калдың, «а»сын әйткәч, «б»сын да әйтеп бетер инде* (Сөйләм).
Төрдәше: «а» дигәч, «б»ны әйтү һ.б.

*АТ* ❖ **АТ – АЕНДА, ИР ЕЛЫНДА СЫНАЛУ.** Атның холкын белү өчен бер ай җитсә, ир кешенең холкын белү өчен бер ел кирәклегенә ишарә. *Ат аенда сыналыр, ир елында сыналыр* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

**АТ АЛМАСЫ ДА БУЛМАУ.** «Чиста, пөхтә булсын» мәгънәсендә. – *Абзарыңда кульяулыкка төреп алырлык та «ат алмасы» булмасын* (Г. Мөхәммәтшин. Сер итеп кенә...).

**АТ АЛУ (ТАРАЛУ).** Абруй казану, танылу, мәшһүр булу. *Көчсез кешеләр түгел – / Бәлки, алар – үзсүзлеләр, йөрәклеләр, / Көчлеләр дип ат алганнар* (Р. Гаташ).
Төрдәше: абруен күтәрү һ.б.

**АТ АРБАСЫННАН МӘТӘЛМӘҮ.** Белемле, тәрбияле булу турында. – *Авыл дигәч тә тагы <...> без дә ат арбасыннан мәтәлмәгән: радио тыңлыйбыз, телевизор кабызабыз, гәзит укыштырабыз* (Н. Гыйматдинова. Китәм, димә...).

**АТ АЧУЫН АРБАДАН (ТӘРТӘДӘН).** Берәрсеннән үчен ала алмагач, аны көче җиткән башкасыннан алу. *Һәлакәткә китергән бәрелеш Сакманов өчен табышмак, башкатыргыч бер нәрсә булды. Ат ачуын тәртәдән алдылар* (Т. Галиуллин. Төнге юллар).
Төрдәше: аты бармагач, тәртәне кыйнау.

**АТ АЯГЫ ТӘРТӘГӘ БӘРЕЛҮ.** Яшәү, тормыш итү авырлашкач, башка җиргә күченү. – *Аптырагач, әнинең авылына күчендек ләса, бала, аптырагач, ат аягы тәртәгә бәрелгәч* (Н. Гыйматдинова).

**АТ АЯГЫН СУЗГАН ҖИРГӘ БАКА БОТЫН КЫСТЫРУ** *к.* ат аягын дагалаганда, бака ботын кыстыру. *Ат аягын сузган җиргә бака ботын кыстырган кебек, син дә дару юк дип тормасаң иде* (Т. Гыйззәт).
Төрдәше: ат <аягын> дагалаганда, бака ботын кыстыру һ.б.

**АТ <АЯГЫН> ДАГАЛАГАНДА, БАКА БОТЫН КЫСТЫРУ.** Кирәкмәгән җиргә кысылу, урынсыз җирдә вакытсыз мәсьәләләр күтәрү. – *Ат аягын дагалаганда, бака да ботын кыстырган, ди. Ниемә дип җыеп төштең монда ул җыен мәчет өрәген!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).
Төрдәше: ат аягын сузган җиргә бака ботын кыстыру; ат тоягын куйганда, бака ботын кыстыру; сыймаган җиргә чөй кагу; сүзгә кысылу (тыгылу); татар чумарасына катык (кату) катып утыру.

**АТ БАЗАРЫ ЯСАУ.** Халык тупланган җирдә тәртипсезләнү, шау-шу чыгару, сатулашу. – *Тукта, дим, ат базары ясама син безнең утырышны* (К. Тинчурин).

**АТ БАР, АРБА ЮК, КАЗАН КАЙНЫЙ, ЯРМА ЮК, <АННАН ТҮБӘН БАР ДА ЮК>.** Фәкыйрьлектән бер нәрсә булса, икенчесе булмаганлыгын күрсәткән гыйбарә. – *Ни дип әйтергә инде, безнеке билгеле: ат бар, арба юк, казан кайный, ярма юк* (Сөйләм).

**АТ БАШЧЫ БУЛЫП АТ БАШЫНА УТЫРУ**. Кузлага утырып, атны тотып бару. *Минем иң яратканым ат башчы булып ат башына утыру иде* (Сөйләм).
Төрдәше: ат башы тоту 1; ат башында йөрү (бару) 2; ат тоту 2; ат тотучы 2; ат тотып йөрү.

**АТ БАШЫ** *к.* ат башчы булып ат башына утыру. *Бара-тора һәр җомга көнне иртә берлә, Сорур остабикә берлә Хәйдәр хәзрәт артка утырып, Зариф алга – ат башына утырып, Садыйк абзыйларга барулары гадәт хөкемгә керде* (Г. Исхакый. Мәдрәсә җимеше).
Төрдәше: ат башчы булып ат башына утыру; ат башы тоту; ат башында йөрү (бару) 2.

**АТ БАШЫ ТОТУ.** 1. *к.* ат башчы булып ат башына утыру. *Ат башы тоткан армас* (Мәкаль).
Төрдәше: ат башчы булып ат башына утыру; ат башында йөрү (бару) 2; ат тоту 2; ат тотучы 2; ат тотып йөрү.

2. Бәрәңге утыртканда яки төбенә өйгәндә, атны тотып, турылап алып бару. *Яланаяклы, ат башын тотып йөрүче малайлар белән дә ул, бураэна кырына ятып, тәмәкесен көйрәткән, киләчәк рәхәт тормыш турында хыялланган* (Н. Хәсәнов. Игеннәр шавы).

3. Элегрәк, туйга ат белән килгәндә, ат башы тоту йоласы булган. *Шунда чаярак берәр бабай йә әби кияү машинасы каршына чыгып баса: янәсе, «ат башы тота»* («Татарстан яшьләре» газ.).

**АТ БАШЫНА МЕНӘРЛЕК МАЛАЙ.** Атка атланып, тезген белән идарә итәрлек 6–7 яшьлек

малай. – *Күп уйланма, күрше, синең ат башына менәрлек малаең бар инде* (Сөйләм).

**АТ БАШЫНДА ЙӨРЕРЛЕК.** Кузлага утырып, дилбегә тотарлык. – *Миңа алмашка ат башында йөрерлек егетләр үсеп килә, шөкер... – диде дә Теләй абзый арбадан бер дәү генә төенчек алып, аны чишеп җибәрде* (Р. Ахунҗанова. Шәһре Биләрдә кунакта).

**АТ БАШЫНДА ЙӨРҮ (БАРУ).** 1. Атка атланып, кыр эшләрендә катнашу. *Миңа ат башында йөрергә туры килде. Мин төпкә җигелгән ике атның берсенә атланам, алдагы ике атның дилбегәләре кулда була* (М. Гафури).

2. *к.* ат башчы булып ат башына утыру. *Йорт караучы да, су ташучы да, ат башында йөрүче дә булып торган, бер кулы чулак, аягы чатан Зарифны ат башына утыртып чыгып киттем* («Казан утлары» ж.). – *Калага ашлык сатарга барам, икенче ат башында барырсыңмы? – ди* («Тишек чикмән ник яхшы?» мәзәге).

Төрдәше: ат башчы булып ат башына утыру; ат башы тоту 1; ат тоту 2; ат тотучы 2; ат тотып йөрү.

3. Дугага тагылып кую (кыңгырау турында). *Кайчандыр, моннан бик күп еллар элек, туйга яки кунакка баран чагында, ул, кара дугага тагылган килеш, ат башында йөри иде* (Ә. Еники. Җиз кыңгырау).

**АТ БӘЯСЕ.** Зур бәя, кыйбат хак, зур акча сорый торган әйбер. *Мондагы бер-бер савыт, бәлкем, үзе ат бәясе торадыр* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). – *Бинагыз кечкенә, ат бәясе алмаслар* (Н. Гыйматдинова. Син түгел бу, син түгел...).

**АТ БЕЛӘН ЧАБА АТНА АРАЛАРЫ** *к.* «а» дигәнче. *Вакыт үткәнен сизми дә каласың, әйтерсең ат белән чаба атна аралары* (Сөйләм).

Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**АТ БЕЛӘН ЧЫПЧЫК КУУ** *к.* арба белән куян куу. *«Килешең ат белән чыпчык куган шикелле бит, тиңең белән тибеш», – ди, шулай булса да башын читкә бора, әле бер аягында, әле икенчесендә генә басып тора* (Х. Хәйруллин. Ургыл).

Төрдәше: арба белән куян куу.

**АТ БИРЕП БАШЛАТУ, ТАЙ БИРЕП ТУКТАТУ.** Ялындырып кына җырларга яки биергә башлап, аннан туктатуы авыр булган кеше турында. *Безнең кызлар ялындырырыга ярата шул, ат биреп башлатасың, тай биреп туктатасың* (Сөйләм).

**АТ ДОЗАСЫ.** Кирәгеннән бик күпкә артык доза. – *Син бит аңа ат дозасы әзерләп куйгансың!* (Сөйләм).

**АТ ҖАНЛЫ.** Ат яраткан кеше хакында. *Ат җанлы ул! / Шәкүр абзагызның / Сөлектәй ат булыр сөйгәне* (Ә. Шәфигуллина. Ак бүре турында баллада). *«Ат җанлы булган ул. Ат җараткан. Атның тирен, исен исни торган булган»* (С. Поварисов. Яшьлек иртәсе).

Төрдәше: ат җене кагылу (сугылу).

**АТ ҖЕНЕ КАГЫЛУ (СУГЫЛУ).** Ат ярату, ат ярышларында катнашу белән яшәү. *Малай чагында әти «ат җене сугылган синә» ди торган ие* (Г. Толымбай. Читән буе). *Әнкәй бер көлә, бер ачулана: – Сиңа, ахры, ат җене кагылгандыр, торсаң – шул, ятсаң – шул, бар белгәнең шул булды, – ди* (Г. Ибраһимов. Алмачуар).

**АТ ҖИГӘ БАШЛАУ.** Атлы булу, ат сатып алу. *Синең хуҗаң хәзер мин, бахбай, – дип сөйләнә-сөйләнә, Надер ат җигә башлады* (Р. Батулла. Юл буенда зәңгәр чәчәк).

**АТ ҖИЛЕ КАГЫЛУ.** Атта җилдереп йөрүләрдән туган баш авыртуы. *Баш авырта да баш авырта дисең, ат җиле кагылгандыр сиңа* (Сөйләм).

**АТ ҖИТКӘН, ХАТ ҖИТКӘН ҖИР.** Иң ерак җирләргә кадәр хәбәр күндерү. *Патша, ат җиткән җиргә ат җибәреп, хат җиткән җиргә хат җибәреп, төрле якка эзләүчеләр җибәреп, хатынны эзләргә тотынды* (Әкияттән).

Төрдәше: ат-хат җиткән җир.

**АТ ИТЕ АШАГАНГА КЫЗЫККАН УРЫС МАЛАЕ КЕБЕК.** Кешенең үзенә ярамаган нәрсәгә ымсынуы турында. *Ат ите ашаганга кызыккан урыс малае кебек, күзеңне ялтыратып утырма, врач сиңа аны бирергә кушмады* (Сөйләм).

**АТ ИТЕП ҖИГҮ, СЫЕР ИТЕП САВУ, <ЭТ ИТЕП СУГУ, ИШӘК УРЫНЫНА ДА КҮР-**

**МӘҮ>.** Кемгә дә булса һичбер хөрмәт, йомшаклык күрсәтмичә, тормыш итәргә ирек бирмәү. *Кодалар белән телефон аша элемтәгә кергәч, шул мәгълүм булды: боларның кызы тегеләрнең малаен ат итеп җиккән, сыер урынына сауган, эт итеп сүккән, ишәк урынына да күрмәгән икән* (Ф. Садриев. Адәм әүлиясы).
Төрдәше: көн күрсәтмәү.

**АТ КАЗАНУ** *к.* абруен күтәрү һ.б. – *Син, күбәләк, түгәрәк, үз туганыңа каршы чыгасың, әллә шуның белән яхшы ат казанасыңмы?* (А. Алиш. Кем көчле?). *Андыйлар астыртын сүз йөртмәде, корыны бушка авыштырып, ат казанырга тырышмады* (А. Гыйләҗев. Күңел яктылыгын раслау).
Төрдәше: абруен күтәрү һ.б.

**АТ КАЙНАТУ** *к.* абруен күтәрү һ.б. *Бу вакыйгадан соң һәр җирдә аның аты кайный башлады* (Сөйләм).
Төрдәше: абруен күтәрү һ.б.

**АТ КАЛДЫРУ.** Үзеннән соң исемен яхшылык белән искә алырлык эшләр калдыру. *Ат калдырыйк туган илгә, / Сагынып сөйләрлек гомергә* (Г. Камал).
Төрдәше: абруен күтәрү һ.б.

**АТ КӘМИТЕ** *гади с.* Элекке заманнарда сөйләм телендә цирк, балаган. *Тукайны иске «Кисекбаш»ка нәзыйрә язуга этәргән төп вакыйга – дөньяны шаулаткан төрек баһадиры Карахмәтнең Казандагы Никитин циркында (татарлар аны ат кәмите дип йөрткәннәр) чыгышлар ясавы* («Фән һәм тел» ж.).

**АТ КӘМИТЕ КҮРСӘТӘЛӘРМЕНИ?** Күп халык җыелып, нәрсәне булса да исе китеп карап торганда әйтелә. *«Ат кәмите күрсәтергә җыенасызмы?– дип кергәләп чыгучы карт-коры да булды, һәрберсен гайре бер кызыксыну биләгән иде* (А. Әхмәтгалиева. Синең өчен яшим). *Бу чаклы ук җыелмасалар да була иде, ат кәмите күрсәтергә җыенмыйлар ләбаса...* (husnutar.ru).
Төрдәше: аю биетәләр мәллә?

**АТ КЕБЕК.** 1. Зур, таза гәүдәле кеше. *Хәзер дә әле ат кебек таза, көчле, дисезме?* (А. Шамов. Кыз урлау). *Бура кебек калын, ат кебек биекләр* (З. Мурсиев. Таш артында).

2. Авыр эшләрне башкару, *к.* ат кебек эшләү. *Кеше ат кебек эшләп йөри-йөри дә беркөнне... Кадерен белмиләр кешенең... Барыбыз да шунда барасы...* (Г. Афзал. Инфаркт). *Бернichә елдан, шулай ат кебек эшләп, яңа өй салырга агач-таш юнәтә* (Д. Каюмова. Буранлы юллар).
Төрдәше: ат кебек эшләү; ат урынына җигелү (эшләү).

3. Ат кешнәвенә охшатып көлү. *Мин килеп кергәндә, Бакый баш өстендәге радиосын тыңлап ята, Сабит Садыкович газета укый һәм, ат кебек, ара-тирә пошкырып көлеп җибәрә* (З. Хөснияр. Кичү).

**АТ КЕБЕК АТ ТИПСӘ БЕР ХӘЕР ИДЕ, АНЫҢ ДА КОРЧАҢГЫСЫ ТИБЕП ХУР ИТӘ.** Яхшы, адәм рәтле кешенең берәр әшәке кешедән хурлык күргән вакытында гарьләнүе. *Кем әйтә бит моны, айнык көне булмаган Мансур бит – башкасы әйтсә, ул кадәр күңелне кырмас иде. Ат кебек ат типсә бер хәер иде, аның да корчаңгысы тибеп хур итә, дип, белми әйтмәгәннәр аны* (Сөйләм).

**АТ КЕБЕК АШЫЙ, АТ КЕБЕК ЭШЛИ.** Нык эшли дә туйганчы ашый. – *Ак кебек ашый, дисең, шуңа күрә ат кебек эшли дә ул* (Сөйләм).

**АТ КЕБЕК ЭШЛӘҮ.** Ял белмичә, көнне төнгә ялгап, тирләп-пешеп эшләү. *Болыннан һәр елны ат кебек эшләп менәсең, түләгәннәре ашаганны капларга да җитми* (Р. Газиз. Болында).
Төрдәше: ат урынына җигелү; ат урынына эшләү.

**АТ КУНА БАРУ.** Авылда җәйләрен эштән кайткач, малайлар һәм егетләрнең төнлә ат сакларга барулары. *Ә кичләрен малайлар белән ялангa яисә урманга ат куна бару аның иң яраткан эшләренең берсе була* (М. Хәсәнов).

**АТ КУШАСЫҢМЫ ӘЛЛӘ?** Әзер җавап. Кемдер берәүне исеме белән эндәшкәнгә «әү!» дигән җаваптан соң яңадан исеме белән эндәшкәндә әйтелә. *[Мөштәри] Анасы, дим! [Кифая] (ачуы чыгып). Ат кушасыңмы әллә?! Анасы да анасы!* («Казан утлары» ж.).

**АТ КУШЛАУ.** Пар ат җигү. *Шунда ук ат кушлау – пар ат җигү* (А. Тимергалин. «Миллият» сүзлеге).

**АТ КУШУ.** 1. Балага исем кую. *Әсма әйтә: ир булсын да сиңа охшасын иде, без аңар*

*«Тимербулат» дип ат кушар идек, ди* (Г. Ибраһимов. Табигать балалары). *Шөл елны Сөенбикәдән бер ир бала туып, аңа Үтәмешгәрәй дип ат куштылар* (Һ. Атласи. Сөен-бикә).

2. Кушамат уйлап чыгару. *Ат кушам, димәк, кушамат тагам. Сабада бик борынгыдан кушылганнар алар. Мәсәлән, Каләм Каш Сабиры, Төлке Гарифы, Акыллы Йосыфы һ.б.* (Т. Нәҗмиев. Тагын... тагын... Саба мәзәкләре).

**АТ КҮЗ.** Акай күзле кешегә әйтелә. *Моңарчы үзенә генә атап әйтелгән «бәгырькәем»гә хәзер Ат күз Шамилнең дә хуҗа булуына рәнҗеп, Зарифның ике күзеннән яшьләре атылып чыкты* (Г. Әдһәм. Сөйгәнем – «Куркак куян»).

**АТ КҮК КЫЗ.** Зур буйлы, көчле гәүдәле, таза, җитешкән кыз. *Төче телле, / Ат күк кыз* (Г. Рәхим).

Төрдәше: ат хәтле.

**АТ КҮТӘРҮ.** 1. Нинди булса да мактаулы исеме булган белем иясе (сәнгатькяр) яки башка төрле исеме булу. *Ничә дистә ел инде ул «аяклы тарих» дигән ат күтәреп йөри* (Сөйләм). *Кичә Никола, Ян, Григорий, Вазген, Анионио, Пьер Лье, Робану, Ганс, Франц, Арон, Йосиф дигән ат күтәреп йөргәннәр, бүген алар – Нәҗип, Мөбарәк, Габдулла, Раббани, Йосыф, Хәйретдиннәр* (В. Имамов. Сөләйман солтан).

2. Берәрсе турында яман сүз сөйләү; яман ат чыгару, дәрәҗә төшерү. – *Әз тотмыйм, күп тотам! Саран дигән ат күтәрмим, – дип ярсыды Нурулла* (Н. Гыйматдинова. Нурулла). *Әйе, нәселең белән бур атын күтәр дә ярлы-ябага бул* (Р. Камал. Озынтал).

Төрдәше: ат сату; ат тагу; ат чыгару; ат чыгу 2; атагы чыгу 2; атак күтәрү (чыгу); аты-чабы китү (җәелү; таралу); аты-чабы чыгу; аты-чуы чыгу; дан китү (югалу); дан сату; дан черетү; дан чыг<ар>у 2; данга калу 2; исем буяу; исем китү 2; исем чыг<ар>у; исем сату; исемгә тап төшерү; иseме-чабы таралу (чыгу) 2; йөз суын түгү; кеше арасына исем чыгу; кеше сүзенә эләгү; яман ат күтәрү; яман ат (яманаты) чыгу; яман атын (яманат) сату.

**АТ КЫЕЛУ.** Мавыгып, сүз сөрешеннән читкә китү. *Әй лә, тагын әллә кайларга кереп киткәнмен ләса. Әйтмисез дә, туктатмыйсыз да, ичмасам, Гайҗан, атың кыелды, дип* (Г. Үзиле. Ленин, Дарья Петровна, мин һәм башкалар).

**АТ МӨГЕЗЕ КЕБЕК.** 1. «Хәлләр ничек?» – дип сораганга җавап, ягъни «дөньяда булмаганча» мәгънәсендә. *Ат мөгезе кебек, ди безнең бабай мондый чакта* (Г. Тарханова. Ирек маҗаралары). – *Хәлләрең ничек, Гөлүзә әби? – Ат мөгезе кебек, балам, ат мөгезе кебек!* (Л. Ибраһимова).

*2. Гомердә булмаганча. Тагын шунысы гаҗәп: яңа хаким пәйда булган тәүге көндә үк Биләр каласының ярлы-ябагае аңа «ат мөгезе кебек уяу колаклы хан» дигән кушамат – бәһа биреп тә өлгергән иде* (В. Имамов. Утлы дала).

**АТ САТУ** *к.* ат күтәрү 2. *[Гафифә] Сорур янына килгән. Минем кызымның атын сатма* (Г. Исхакый. Алдым-бирдем). – *Син... оятсыз... мәдрәсәнең атын сатып йөрисең килә... икән... явыз... – дип, яңагына салып җибәрде* (Г. Ибраһимов).

Төрдәше: ат күтәрү 2 һ.б.

**АТ СУЫТУ.** Тирләгән атны, ашарга-эчәргә бирмичә, бераз бәйдә тоту. – *Улым, атны суытырга кирәк, – диде әтисе атны тугара башлаган малаена* (Сөйләм).

**АТ ТАГУ.** Кушамат бирү. *Җәлләмәгән дә безне, үч алырлар дип куркып та тормаган, үзенә «әләкче» дигән яман ат тагарлар дип тә борчылмаган...* (М. Әмир. Без бәләкәй чакларда).

Төрдәше: ат күтәрү 2 һ.б.

**АТ ТАПКАН, ЙӨГӘН ТАПМАГАН.** Иң авырын эшләп тә, кечкәнесенә җегәре җитмәү. – *Син бигрәк инде: ат тапкансың, ә йөгән тапмагансың – балага альбом алгансың, ә төсле карандашларың кайда?* (Сөйләм).

**АТ ТЕЗЕННӘН.** Шактый калын яки тирән икәнлеген белдерү. *Авыл шактый ерак, җитмәсә, басу-юлларны ат тезеннән кар каплаган көн иде* (matbugat.ru). – *Ат тезеннән пычрак, батарсың, йөрмә, инешнең дә котырган чагы, – диде ул* (gabdullatukay.ru).

**АТ ТИЗӘГЕ ТӘГӘРМӘЧ, АТ ТИЗӘГЕ ПӘРӘМӘЧ.** Яхшыны яманнан аера алмый торган юньсез, игътибарсыз кеше турында. – *Аңа нәрсә, безнең бабай әйтмешли, ат тизәге тәгәрмәч, ат тизәге пәрәмәч* (Сөйләм).

Төрдәше: ак белән караны аермау (аера белмәү; күрмәү) 1 һ.б.

**АТ ТИЗӘГЕ ТИБҮ (ТИБЕП ЙӨРҮ).** Эш эшләмичә вакыт үткәрү. *Җир алып, эшкә керешергә дигәндә, башны җүләргә салып, ат тизәге тибеп йөрергәме?!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: авыз белән чебен аулау һ.б.

**АТ ТИЗӘГЕ – ШАЛКАН, СЫЕРНЫКЫ – ТАЛКАН.** Аш-суны аермаучы, тормыш белән дөнья кайгысын уйламаучы ваемсыз кеше турында. *Кем турында сөйлисең син, аңа ат тизәге – шалкан, сыерныкы – талкан бит* (Сөйләм).

**АТ ТОТУ.** 1. Ат асрау. *Һәрхәлдә, аңа, үз вазифаларын башкарганда, җигеп йөрү өчен, тарантаслы бер ат тотарга рөхсәт ителә иде* (А. Хәсәнов. Бахбайлар ял йортында).
2. *к.* ат башчы булып ат башына утыру. *Һәм малай чакта ат тотканда, ике нәрсәдән курка идем: кышын хәйләкәр чананың чалу-салуда әйләнүен, җәен юырттырганда, миннән яшеренеп кенә арт тәгәрмәч төшеп калуы ихтималы өркетә иде* (М. Хуҗин. Чеметемнән табышларга).
Төрдәше: ат башчы булып ат башына утыру һ.б.
3. Аты, олавы, йөкче-атчысы булып, шуларны эш башкару өчен биреп торып кәсеп итү; яки кымыз сату өчен ат көтүе асрау. *Анысы көтү-көтү ат тоткан байлар кымызын сатып көн күрде* (В. Имамов. Тозлы яра). *Товарларын Иске бистә байларына сатканнар, хәллерәкләре ат тоткан, ямщик булып йөргән, һөнәрсезләре Усиядә крушник булып йөк ташыган* («Казан утлары» ж.).

**АТ ТОТУЧЫ.** 1. Хуҗалыгында ат асраучы, тәрбияләүче. *Шәһәр шартларында ат тоту җиңел түгел. Безнең урамда ат тотучы бер күзенә ак төшкән Сабир атлы кеше генә* (Сөйләм).
2. *к.* ат башчы булып ат башына утыру. *Күчәр башында утырган ат тотучы йокымсырап бара* (М. Хәбибуллин. Айбиби).
Төрдәше: ат башчы булып ат башына утыру һ.б.

**АТ ТОТЫП ЙӨРҮ** *к.* ат башчы булып ат башына утыру. *Ләкин Фәһимгә дә озаклап ат тотып йөрергә туры килмәде* (Т. Нурмөхәммәтов. Кабан күле, әй, алкын).
Төрдәше: ат башчы булып ат башына утыру һ.б.

**АТ ТОЯГЫН КУЙГАНДА, БАКА БОТЫН КЫСТЫРУ** *к.* ат <аягын> дагалаганда, бака ботын кыстыру *«Ат тоягын куйганда, бака ботын кыстырыр» дигән кеби, Вәли мулла да, Зингер баеганда, үзенең «дин»ен китереп кыстырган* (Г. Тукай. Өч баш).
Төрдәше: ат <аягын> дагалаганда, бака ботын кыстыру һ.б.

**АТ УЙНАТУ.** 1. Атта йөрүдә осталык, егетлек күрсәтү. *Исмәгыйль нөкәрләре читтәрәк ат уйнатып мәш килә: хуҗаларының ят дәрвиш белән сөйләшеп бетергәнен көтә* (Р. Батулла. Сөембикә).
2. *күч.* Җиңелчә исем, дан алу. *Ә милли хәрәкәт мәйданында 1905 еллардагы Й. Акчура позициясендә С. Максуди (Г. Исхакый ярдәмендә) ат уйната* (М. Гайнетдин. Йосыф Акчура).

**АТ УРЫНЫНА АШАУ.** «Бик күп, кирәгеннән артык ашау» мәгънәсендә. *Ат урынына ашый икән бу егет, эшләве дә шулай микән?* (Сөйләм).
Төрдәше: әвен сугу; тишек тамак тик тормау; үзе сөйли, үзе чөйли; шартлаганчы ашау; ярылганчы ашау.

**АТ УРЫНЫНА ҖИГЕЛҮ.** Күп эшләү, авыр эшләрдә катнашу. *Кайтып керүенә, анасын жәлләп, ат урынына җигелеп эшкә тотынды* (Г. Галиева. Газзәбану). *Бер карасам, / Күрәм аның ат урынына җигелгәнен. / Ләкин һич тә мин күрмәдем кайгылардан / Җебегәнен, җиңелгәнен* (Р. Рәкыйпов).
Төрдәше: ат кебек эшләү һ.б.

**АТ УРЫНЫНА ЭШЛӘҮ** *к.* ат кебек эшләү. – *Ир кеше ул – әгәр чын ир булса, – диде Саттар, бу урында үзенең фикерен белдереп, – ат урынына эшләсен, хатынын, гаиләсен тәрбияләсен* (Н. Акмал. Күгәрчен сөте).
Төрдәше: ат кебек эшләү һ.б.

**АТ ХӘТЕРЕ.** Хәтере яхшы булган кеше турында. – *Таныдыгыз, ат хәтере икән үзегездә, Мирсәет абый* (Г. Тавлин. Афәт).

**АТ ХӘТЛЕ** *к.* ат күк кыз. *Ул шадра йөзле, ат хәтле таза хатын* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).
Төрдәше: ат күк кыз.

**АТ ЧЫГАРУ.** Начар исем тарату, яман ат бирү. *Әмма ахыр сүзен ул да, хастаханәнең яман атын чыгармыйк, дип бетерде* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Телеңне тешләп узып китсәң, үзе бер җайсыз, ә инде кире борылсаң, «Котан!»*

*дип атыңны чыгарачаклар* (Т. Нурмөхәммәтов. Кабан күле, әй, алкын!).
Төрдәше: ат күтәрү 2 һ.б.

**АТ ЧЫГУ** 1. *к.* ат күтәрү 1. *Явызлыктан саклан. Юмартлык белән атың чыксын* (К. Насыйри). *Барлык илләргә изге аты чыкты* (Н. Хисамов. Татар шагыйрьләре).
Төрдәше: ат алу (таралу) һ.б.

2. *к.* ат күтәрү 2. *Әмма театрда сәнгатьтән ерак торган, әхлаксызлыгы белән аты чыккан адәмнәр дә була* (Г. Тукай). – *Ахирәтем, бу арада әле Әхәтнең илгә аты чыкты. Имештер, ул Миңсафа кызы Вәсимә белән чүмәлә артында чуалган, ди* (А. Алиш. Яңа килен).
Төрдәше: ат күтәрү 2 һ.б.

**АТ ЭЗЕ САЛМАУ.** Килмәү. *Юкка өметләнеп көткәннәр, ат эзен салмаган* (Сөйләм).

**АТ ЭЗЕ ЭТ ЭЗЕ БЕЛӘН БУТАЛУ.** Олы белән кечене, сыйфатлы белән сыйфатсызны һ.б. ны аермау, буталу. *Моңарчы да әллә ни түгел иде, хәзер башында ат эзе белән эт эзе бөтенләй буталып бетте* (Сөйләм).

**АТ ЮК, АРБА ЮК, АННАН КАЛГАН БАР ДА ЮК.** Бернинди хуҗалыгы да булмау; фәкыйрьлектә яшәү. *Сылаган читән өйдә яши мескен, ат юк, арба юк, аннан калган бар да юк* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз ачса, кече теле күренү 2 һ.б.

**АТ ЯНЫННАН (ЯНЫНДА) БОЗАУ ЭЗЛӘҮ.** Әйберне булмас җирдән эзләү, өмет итү. *Ат яныннан бозау эзләгән* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

**АТ ЯРАШТЫРУ** *к.* аяк кыздыру. – *Ярышларга күп калмады, атны яраштырырга онытмыйсыңмы?* (Сөйләм).

**АТ ЯХШЫ – ҖИЛ КАРШЫ.** «Теләк булганда, сәбәп табыла» мәгънәсендә. – *Менә-менә, ат яхшы да җил каршы дип зарлана торган чак түгел, углан, – диде мөсафир, – ниһаять, синең бүреләреңнең улар вакыты җитте* (М. Әмирханов. Ир-Мамай).
Төрдәше: аты чуман, чуман булса да чаба – юлы яман; ат тартмаса, сыныкка сылтау.

*АТА* ❖ **АТА БАЙ.** Бик бай булу. *Атабай авылы аша бер кеше узып барганда, авылның матурлыгына бик сокланган һәм туктап: «Сез монда ата бай булып яшисез икән», – дигән* (Ф. Гарипова. Авылларыбыз тарихы).

**АТА БАЛАНЫ (УЛНЫ), БАЛА (УЛЫ) АТАНЫ БЕЛМӘҮ (КҮРМӘҮ).** Олы буталыш, берберeңне танымаслык ызгыш, орыш чыгу турында. *Ата баланы күрмәс, бала атаны күрмәс, туган туганнан качар, кыямәт шундый көн, анда беркем беркемне күрми* («Казан утлары» ж.).
Төрдәше: ата улны, ана кызны белмәү; ата улны, туган туганны белмәү; эт иясен танымау.

**АТА БАЛАСЫ** 1. *к.* адәм баласы (углы). *Тик тәрбиячегә «балама чөгендер ашатмагыз, көндез йоклатмагыз», дип ничек әйтәсең, әйтсәң дә файдасыз, чөнки аның кул астында кырык ата баласы – һәркайсының көен көйли башласаң!* (Д. Булатова. Командировка).
Төрдәше: адәм баласы (углы) һ.б.

2. Билгеле бер ата-анадан туып, аларның тәрбиясендә үскән. *Менә яхшы ата баласы дип ышанып йөр син аңа!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**АТА БӘПКӘ.** Өйнең түбә кыегы атламаларының эләктереп куела торганы. – *Бу атламага кирт ясама, ата бәпкә булыр* (Сөйләм).
Төрдәше: ата кайчы.

**АТА ДИЮ ЮК, АНА ДИЮ ЮК.** Ата-ана белән киңәшмичә, үз белдеге белән эшләп ялгышлык кылу. *Ата, боларны ишеткәч, хурлыгыннан ертыла язды: – Ни эшләдең?.. Җир тишегенә керерлек бит. Ата дию юк, ана дию юк* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).

**АТА ДОШМАН.** Иң явыз, төп дошман. *Шулай итеп, СССРның дөм караңгы бер почмагында «ата дошман» Исхакыйның пьсасын карап ләззәт тә алганнар икән!* (А. Тимергалин. «Инкыйраз»га йөз ел!). *Кырым татарларын гел «хаиннар» дип гаепләргә, И. Гаспралыны исә «ата дошман» рәвешендә танырга, танытырга күнеккән чиновникларның, «Россия и Восток» китабын укып карагач, тупсалары бераз йомшарып, позицияләре дә беркадәр үзгәрә төшкән...* (М. Госманов. Режиссер хыялы һәм кырыс чынбарлык).

**АТА ҖИЛ.** Көчле искән җил. *«Ата җил» диләр көчле, каты җилгә* (Ш. Галиев. Әнкәйләрнең

күркәм сабырлыгы). *Ата җил степькә балчыкташлар, / Киләдер чыйнап егълашкан тавышлар* (Д. Гобәйди. Башкорт кызы Маһинур).

**АТА ЙОРТ<Ы>.** 1. Туган йорт, төп йорт. *Карун, холыксыз атасы йортыннан китүгә Мирвәли үзе дә куанмадымы әллә?..* (А. Гыйләҗев. Өч аршын җир). *Атам йорты, туган-үскән авыл, / Иркен болын, урман, кырлар, күл* (В. Галиев. Җырларымда гомрем дәвамы).

2. Киң мәгънәдә – ватан, туган ил. *Кеше кайда гына булмасын, кайда гына йөрмәсен, күңеле ата йортына тарта* (Сөйләм). *Ниһаять, ханбикә белән Җан Гали хан яклы булган кешеләрне суеш башлана икән дигән шомлы чышын-пошыннар күбәйгәч, Сөембикә якыннары белән атасы йортына – Нугайга, Сарайчык каласына кайтып китте...* (Р. Батулла. Сөембикә).

**АТА КАЗ БОТКАСЫ** *ирон.* Яфрак тәмәке, махорка. *Хәзер безнең авылда ата каз боткасы белән маташкан кеше калмады инде* (Сөйләм).

**АТА КАЗ КЕБЕК ЙӨРҮ**. 1. Муены авырту сәбәпле, аны бер якка да бормыйча, алга сузыбрак, туп-туры тотып йөрү. *Кәрим, аяк астына чуерташ сибелгәндәй, вак-вак атларга тырышып, ата каз кебек, сәер муенын сузып йөри торган иде* (Сөйләм).

2. Боегып, каңгырып йөргән ир кеше турында. *Ялгыз ирләр генә сыңар ата каз кебек йөриләр, ә хатыннар гөрләтеп яши* («Матбугат.ру» порталы). *Менә шул көннән бирле, анасын җуйган ата каз кебек, тик йөрим шунда боегып* (Т. Гыйззәт).

**АТА КАЗ МУЕНЫ.** Авыру хәлдә булу (салкын тиюдән яки башка сәбәптән муенны бора алмау). *Чормага менеп җитүгә ул,бәрелә-сугыла, ата каз муены шикелле тырпаеп утырган морҗа янына китте* (З. Хөснияр. Сыңар канат).

**АТА КАЗГА СӘЛАМ БИРҮ.** Муен бөгелә алмау (*к.* ата каз муены) бәласеннән котылу өчен, юк кеше алдында да баш ияргә мәҗбүр булу. *– Менә шулай, энем, кайбер вакытта безгә дә ата казга сәлам бирергә, дуңгызга «җизни» диярге дә туры килә инде, – дип китеп барган* (Т. Нәҗмиев. Тагын... Тагын...). *– Мин аккош, дип кәпрәймә, бар, Гамил, ата казга сәлам бир* (Н. Гыйматдинова. Бер тамчы ярату).

**АТА КАЗЫҢ (КАЗЫГЫЗ) КҮКӘЙ САЛАМЫ?** *мыск., ирон.* Сөйләшерлек сүз беткәч әйтелә торган гыйбарә. *– Нихәл, дуслар! – ди Ибрай абзый безгә. Ата казларыгыз күкәй саламы?* (Ш. Маннур. Агымсуларга карап). *Сүз юктан сүз булсын, ата казың күкәй саламы, дигәндәй, бушка сүз куертмыйлар* (А. Хәлим. Читтә).

**АТА КАЙЧЫ** *к.* ата бәпкә. *Бу йортның ата кайчысы шактый нык ярылып киткән* (Сөйләм).

Тәрдәше: ата бәпкә.

**АТА КАНАТЫ АСТЫНДА ЯТУ (ЯШӘҮ).** Ата йортында авырлык күрмичә яшәү. *Бетте Алмазның ваемсыз чаклары. Ата канаты астында яшәгән чаклары* (Ф. Бәйрәмова. Болын). *Мыек тибә башлаган егет кеше гомер буе ата канаты астында ятмас* (С. Рәфыйков).

**АТА КАРАК.** Әйбер урлауда даны чыккан кеше, караклар башлыгы. *Хәтта ата карак, исерек Атай да кулын гына селтәде, андый кушаматлы ат алып языклы булыр хәлем юк әле, янәсе* (Р. Зәйдулла. Алла). *Тукта, ата каракның биргән акчасын, кияргә сырмасын алып дөрес эшләдемме мин?* (Г. Тавлин. Афәт).

**АТА КЕБЕК.** Өлкән яшьтәге ир кеше яки шул вазыйфаны башкара алырлык. *Төрек хөкүмәте үзенең бичара халкына әнә шундый мәхәббәтсез үги ата кебек* (М. Галәү. Мөһаҗирләр).

Тәрдәше: ата тиешле; ата яшендәге; атаң булырлык (булырдай; булырга яраклы).

**АТА КУЛТЫГЫНА КЕРТҮ**. Балага үги ата табу. *Ул Гарифны ата култыгына кертмәкче иде* (Н. Дәүли. Кар нинди җылы...).

**АТА КҮРКӘ** *күч.* Үтә һавалы, тәкәббер кеше. *– Шаярып кына әйттем, теге ата күркә түгел, (тавышын йомшартып) минеке килә, минеке* (А. Алиш. Күршеләр). *Әле кичә дә, ураза аенда мәчетләрне ачтырмыйсың, дип бәйләнде бит миңа. Ата күркә дип мыскыл итте* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).

**АТА КҮРҮ.** Ата тәрбиясе күргән, аның үрнәгендә үскән бала. *Ата күргән ук юнар, ди халык* (Ә. Хәсәнов. Сабыр төбе сары алтын). *Бердәнбер хат килде иреннән. / Төпчекләрен күрми киткән иде, / Ата күрми үсте күпмеләр!)* (К. Булатова).

**АТА МАЛЫ.** Атасы тапкан һәм аннан калган мирас. – *Ата малы белән бала көн күрми* (В. Юныс. Шайтан бар ул, бар!..). *Безнең халыкта «Ана малы белән кыз тормый, ата малы белән ул тормый» дигән мәкаль бар* <...> (Н. Гариф. Мин сезнең арада яшәдем).

**АТА МАЛЫ БҮЛӘСЕЗМЕ ӘЛЛӘ?** Нәрсәне булса да бүлә алмаганда әйтелә. *Нәрсә шулай озак маташырга, ата малы бүләсезме әллә – шобага тотышыгыз да эше бетте!* (Сөйләм).

**АТА<Й> МАЛЫ КАТАЙ <МАЛЫ>** *ирон.* Атасының малын уңга-сулга туздырып бетерү. – *Әллә шундый тракторчылар булмый дисезме? Була, атай малы катай, дип эшләүчеләр турында әйтүем* (Г. Мөхәммәтшин. Гөлҗәүһәр аланында). *Атай малы катай дисең инде, алайса?!.* (З. Мәхмүди. Улым үземә охшаган).

Төрдәше: бабаныкы – илнеке, <әйдә, ашагыз (авыз итегез)> <дип әйтте ди бер борынгы кияү>; үзем тапкан мал түгел, атай тапкан (әтинеке) җәл түгел.

**АТА МАЛЫ КУЛГА ЙОКМАУ.** Атаңнан калган мирасның озакка җитмәве, аны күбәйтү турында үзеңә уйларга кирәклеге хакында. *Ата малы белән бала көн күрмәс, дигәннәр борынгылар – ата малы кулга йокмый ул, тиз очып бетә* (Сөйләм).

**АТА МӘЧЕ КҮЗ ЯШЕ.** Бик аз. *Эш күп, торагыбыз бик кысан (вагонда барганны хәтерлә), борылыр да хәл юк. Димәк, язарга мөмкинлек – ата мәче күз яше* (М. Әмир. Сугышчан сәлам белән. И. Гази хатлары).

Төрдәше: песи төкереге.

**АТА САКАЛ.** Ирен асты чокырында калдырыла торган сакал. *Җитмәсә кечкенә генә ата сакалы да тырпаеп тора* (Сөйләм).

**АТА САКАЛЫ АВЫЗЫНА ҖИТҮ.** Тәмам олыгаеп җитү. *Хәзер инде синең адашыңның да ата сакалы авызына җитте* (Сөйләм).

**АТА СӨРХӘНТӘЙ.** Артык ялкау кеше турында. *Төгәннең малае – ата сөрхәнтәй, урта мәктәпне этә-төртә бетерткәннәр иде, икенче елын тырай тибеп йөри...* (М. Хуҗин. Озын күләгә).

Төрдәше: ата ялкау.

**АТА ТИЕШЛЕ** *к.* ата кебек. *Касыгына килеп бәрелгән Арслан терсәгеннән сискәнеп, янәшәсендә басып торган ата тиешле кешенең күзенә карады* (Д. Салихов. Чукрак).

Төрдәше: ата кебек; ата яшендәге; атаң булырлык (булырдай; булырга яраклы).

**АТА ТӨЛКЕ.** Бик хәйләкәр, үткен һәм астыртын кеше. *Рудольф, ата төлке, мондый гына сорауларны күп ишеткән кеше* (Рав. Вәли. Канатлы татар).

**АТА ТУФРАГЫ.** Ватан, туган җир. – *Атагызның туфрагын ташлар хәлем юк* (К. Нәҗми).

Төрдәше: ата-баба туфрагы.

**АТА УЛНЫ, АНА КЫЗНЫ БЕЛМӘҮ** *к.* ата баланы (улны), бала (улы) атаны белмәү. *Ата улны, аны кызны белми торган болгавыр заман башлана* (А. Тимергалин. Карурман аша). *Халык паникага бирелеп, ата улны, ана кызны белмичә чабышып йөри* (Г. Ахунов).

Төрдәше: ата баланы (улны), бала (улы) атаны белмәү (күрмәү) һ.б.

**АТА УЛНЫ, БОЗАУ ҮГЕЗНЕ, УЛ КЫЗНЫ БЕЛМӘҮ** *к.* ата баланы (улны), бала (улы) атаны белмәү. *Шундый ызгыш, шундый талаш башланды ки, ата улны, бозау үгезне, ул кызны белми* (Сөйләм).

Төрдәше: ата баланы (улны), бала (улы) атаны белмәү (күрмәү) һ.б.

**АТА УЛНЫ, ТУГАН ТУГАННЫ БЕЛМӘҮ** *к.* ата баланы (улны), бала (улы) атаны белмәү. *Бу чараны кылырга вәзир Исхак үзе мәҗбүр итте, үзенә үпкәләсен. Юкса Болгарда ата улны, ана кызны, туган туганны белми башлар иде* (М. Хәбибуллин. Илчегә үлем юк).

Төрдәше: ата баланы (улны), бала (улы) атаны белмәү (күрмәү) һ.б.

**АТА ХАКЫ.** Аталарга ихтирам, аларны олылау. *Аллаһы Тәгалә хакыннан соң ата хакы, ата хакыннан соң ана хакы, ана хакыннан соң күрше хакы, – иң беренче, иң асыл хаклар* (А. Хәлим. Күрше хакы). *«Ата хакы – олы хак ул, белегез сез, – ди автор мөнәҗәт калыбында язылган «Ата хакы...» әсәрендә. – Ата хакын хаклау юлын күрегез сез»* (З. Мансуров. Гыйбрәтле күңел галәме).

**АТА ШАЙТАН.** Яшүсмерләрне төрле уен-көлкегә, шуклыкларга әйдәп йөрүче. *Ата шайтан акыл өйрәтә: – Ялгышыңа карап, койрык кысып, / Олы булып булмый, әлбәттә* (Г. Афзал. Торичелли бушлыгы).

**АТА ЮЛЫН КУУ.** Ата-баба гореф-гадәтләрен, кагыйдәләрен тоту. *Әтисе аның өчен һәр нәрсәдә үрнәк иде, һәм ул атасының юлын кууны дәвам итте* (Сөйләм).

**АТА ЯЛГАНЧЫ.** Артык ялганчы, ялганларга яратучы. *Баҗайның менә шул кече малае өч-дүрт айда ата ялганчыга әйләнде бит* (Ф. Садриев. Ак эт бәласе – кара эткә).

**АТА ЯЛКАУ.** Ялкауларның ялкавы, артык ялкау. *– Өйдә эшләмисең, ата ялкау, спорт белән, физик эш, хәрәкәт белән дус булсаң, кайбер кимчелекләрең тизрәк узар иде* (А. Гыйләҗев. Әтәч менгән читәнгә).

Төрдәше: лыштыр башмак.

**АТА ЯШЕНДӘГЕ** *к.* ата кебек. *Ул урта буйлы, ата яшендәге бер кеше иде* (Сөйләм).

Төрдәше: ата кебек һ.б.

*АТА-АНА* ❖ **АТА-АНА ИРКӘСЕН БЕЛГӘН (КҮРГӘН).** Бала чагында әти-әнисенең мәхәббәтен татыган. *Аның бала чагы да, үсмерлеге дә әтисе-әнисе янында үтте, ата-ана иркәсен күреп, тәрбияле бер егет булып җитеште* (Сөйләм).

**АТА-АНА КАШЫГЫНА КАРАП ЯШӘҮ.** Ничә яшьтә булуына карамастан, һаман да әти-әнисе җилкәсендә яшәү. *Унсигездән узган баланың һаман әле ата-ана кашыгына карап яшәвен бәндәчелек тә, шәригать тә килештерми* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).

**АТА-АНА ХАКЫ.** Ата-анасының баласы белән бәйле бурычлары. *Иң олысы ата-ана хакы, җәннәт алар аяк астында* (А. Нәҗми. Хаклар). *Ата-ана хакы дигән нәрсә бар ул бу дөньяда….* (Ә. Хәсәнов. Ефәк пәрәвез).

**АТА-АНА ХАКЫН ХАКЛАУ.** Ата-ананы хөрмәт итү, тәрбияләү. *Татар халкына хас сыйфатлар: чисталык, кунакчыллык, олылар, ата-ана хакын хаклау югалмасын иде* («Татарстан яшьләре» газ.).

*АТА-АНАГА* ❖ **АТА-АНАГА КАРШЫ БАРУ.** *Атасы көчләгәч: – Язмышым шулдыр. Ата-анага ничек каршы барасың, – диде дә канлы күз яше түгеп риза булды* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).

*АТА-АНАҢ* ❖ **АТА-АНАҢ ГЫНА ЮК.** «Барысы да бар, барысы да җитеш» мәгънәсендә. *Монда бар да әзер, бар да бар, тик ата-анаң гына юк* (Сөйләм).

*АТА<СЫ>-АНАСЫ* ❖ **АТА<СЫ>-АНАСЫ БЕЛӘН <СҮГ<ЕН>Ү>.** Яман сүзләр белән тиргәшү. *Ызгышның чигенә килеп җитүне аның атасы-анасы белән сүгенә башлавыннан да белергә мөмкин* (Сөйләм).

Төрдәше: ата-бабасы <кабере> белән сүгү; ата-бабасына җитү; ата<сын>-анасын кушып; аты-чуты белән; аты-юлы белән 1; аты-юлы белән җибәрү (җикеренү; сүг<ен>ү); әби-бабаларына җитү; әнисен (анасын) кушып сүгү; дөньядагы белән җибәрү (сүгенү).

**АТА<СЫ>-АНАСЫ БУЛМАУ (ЮК)** *к.* ана-<сы>-атасы юк 1, 2. *Ләкин бу укып йөрүнең бер дә ата-анасы булмады* (Ә. Еники. Соңгы китап). *Тик сөйләшүнең генә бер дә ата-анасы юк, күп сүзләрне бозып әйтә, «халык» диясе урында «калык» дип кенә куя, гомумән, шактый тупас, үзбуйлы, түрәләрне дә бер дә санга сукмый торган бер бәндә иде* (Р. Фәизов. Садыйк абзый әмәле).

Төрдәше: ата <сы>- анасы күренми.

**АТА<СЫ>-АНАСЫ КҮРЕНМИ** *к.* ата-<сы>-анасы булмау (юк). *Күп сүз сөйләделәр, ләкин төпле фикергә килерлек ата-анасы гына күренми* (Сөйләм).

Төрдәше: ата <сы>- анасы булмау (юк).

*АТА<СЫН>-АНАСЫН* ❖ **АТА<СЫН>-АНАСЫН КУШЫП** *к.* ата<сы>-анасы белән <сүг<ен>ү>. *Өй артында ата<сын>-анасын кушып бик каты ызгышалар иде* (Сөйләм).

Төрдәше: ата<сы>-анасы белән сүг<ен>ү һ.б.

**АТА<СЫН>-АНАСЫН ТАНЫТУ** *к.* авыз җебетү 2. *Бераз киңәшләшеп алганнан соң, теге чит кешегә атасын-анасын танытып җибәрергә булдылар* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**АТА-АНАСЫН ҮТЕРГӘН КЕБЕК ЙӨРҮ.** Кешегә ачулы кыяфәттә йөрү. *Бүген аның*

*белән күрешеп-сөйләшмәсәң яхшы булыр иде, ул ата-анасын үтергән кебек йөри* (Сөйләм).

Төрдәше: ачу давылы; ачу күзе белән карау; ачу саклау (саклап йөрү); ачу тоту 1; ачу ташы (ачуташ) йоткан; ачу төене чияләнү; ачу төене чияли бәйләнү; бинә куу.

*АТА-БАБА* ❖ **АТА-БАБА БЕЛМӘГӘН (КҮРМӘГӘН).** Нинди булса да бер яңа әйбер яки күренеш хакында сөйләгәндә кулланыла. *Элек мондый машиналарны ата-баба белмәгән дә, күрмәгән дә* (Сөйләм).

**АТА-БАБА ЗАМАНЫ.** Үткән гасырлар, борынгы тарихи заман. *Ата-баба заманында булган вакыйга бу* (Сөйләм).

**АТА-БАБА ЙОЛАСЫ.** Бөтен яшәеш борынгылардан килгән гореф-гадәтләр, әдәп-тәртипләр нигезендә корылу.– *Ата-баба йоласы, ата-баба түрәсе барлык кеше өчен бер: ...бигә дә, чурага да...* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).

**АТА-БАБА КҮРМӘГӘННЕ КҮРҮ.** Һич уйламаган бәлаләрне күрү. *Без, тау башына үрмәләгәндә, ата-баба күрмәгәнне күргәнбездер* (Сөйләм).

**АТА-БАБА ТУФРАГЫ** *к.* ата туфрагы. *Кан береккән, җан береккән инде безнең ул авылга. Ата-баба туфрагы бит* (Р. Вәлиев. Яшисе килә).

Төрдәше: ата туфрагы.

*АТА-БАБАДАН* ❖ **АТА-БАБАДАН КАЛГАН (КИЛГӘН).** Борынгыдан килгән, мирас булып калган. *Ул кызына ата-бабадан калган олы эшкә һәрвакыт әзер булып, аякны киенеп торырга кирәклекне әйтте* (Ф. Хөсни). *Татар авылларында мондый гаиләләр күбрәк, безнең милли традицияләребез, бала тәрбияләүдә ата-бабадан килгән гореф-гадәтләребез мәңге югалмаячак* (atnya-rt.ru).

*АТА-БАБАСЫ* ❖ **АТА-БАБАСЫ <КАБЕРЕ> БЕЛӘН СҮГҮ** *к.* ата<сы>-анасы белән сүг<ен>ү. *Ферма мөдире атчыны ата-бабасы белән сүгеп ташлады* (Сөйләм).

Төрдәше: ата<сы>-анасы белән сүг<ен>ү һ.б.

*АТА-БАБАСЫН* ❖ **АТА-БАБАСЫН ТАНЫТУ** *к.* авыз җебетү 2. *Күрше урам малайлары ата-бабасын танытып кайтарганнар* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

*АТА-БАБАСЫНА* ❖ **АТА-БАБАСЫНА ҖИТҮ** *к.* ата<сы>-анасы белән сүг<ен>ү. *Алар бербересенә нәрсә генә әйтеп бетермәделәр, ата-бабаларына кадәр җиттеләр* (Сөйләм).

Төрдәше: ата<сы>-анасы белән сүг<ен>ү һ.б.

*АТАВЫҢА* ❖ **АТАВЫҢА ЧЫКСЫН** *диал.* Берәрсенә йомыш белән кергәндә, тегесе (я икенчесе) кызганып бирмәсә, каргыш буларак әйтелә (атау – мәет ашы, ягъни үзең үлгәч, ул нәрсәне мәет ашыңа бирсеннәр (Н. Исәнбәт)). *Атавыңа чыксын* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).

*АТАГА* ❖ **АТАГА БЕРЛЕ.** – Атаның бердәнбер улы. *Алмаслар инде, малай, мине, – ди. – Атага берле бит. Картларны карарга кушалар икән* (Ш. Маннур).

*АТАГЫ* ❖ **АТАГЫ ИЛГӘ ҖӘЕЛГӘН.** Исеме-даны илгә, халыкка таралган. *Газетадан укымадыңмыни, аның бит атагы бөтен илгә таралган* (Сөйләм).

Төрдәше: атагы чыгу 1.

**АТАГЫ ЧЫГУ** *гади с.* 1. Танылу, исеме таралу (яхшы мәгънәдә). *Ул үзе гаҗәп зирәк булды. Моның белән атагы чыкты* (Г. Ибраһимов). *Атагы чыккан Ильяс, даһи бер ир* (В. Ильясов. Низамига).

Төрдәше: ат алу (таралу) һ.б.

2. *к.* абруй җуелу. – *Беләм мин аны, атагы чыккан кыз инде ул, теләсә кем белән йөрде* (Р. Кәрами. Кая чабасың, гомер юртагы?).

Төрдәше: ат күтәрү 2 һ.б.

*АТАГЫЗНЫҢ* ❖ **АТАГЫЗНЫҢ МАЛЫН БҮЛӘСЕЗМЕ?** Каты тавыш, ызгыш чыкканда әйтелә. – *Нәрсә шау-гөр киләсез монда, атагызның малын бүләсезме?* (Сөйләм).

*АТАЙ* ❖ **АТАЙ БУЛЫП ӘЙТҮ.** Әтисе булырлык өлкән кеше киңәш бирү. *Сез моны нәкъ атай булып әйттегез, минем әти дә шулай сөйли иде* (Сөйләм).

*АТАК* ❖ **АТАК КҮТӘРҮ (ЧЫГУ)** *гади с., к.* ат күтәрү 2. *[Баязид] Үзе гаҗәп зирәк булды. Моның белән атагы чыкты* (Г. Ибраһимов).

Төрдәше: ат күтәрү 2 һ.б.

*АТАК<КА>* ❖ **АТАККА АЛУ** *гади с.* Данлау, мәшһүр итү. *Әлбәттә, һәркемнең яхшы атак аласы киләдер* (Г. Тукай).

**АТАККА АЛЫП СӨЙЛӘҮ** *гади с.* Көлеп, мыскыллап сөйләү. *[Хәтерсез Хәллә] Төшкә хәтле сөргән җиремне төштән соң таба алмыйча, плуг эзләп йөргәнемне атакка алып сөйли бит* (Ф. Хөсни).

*АТАЛМАГАН* ❖ **АТАЛМАГАН БАЛА АТАСЫННАН КҮРҮ.** Макталмавын, югары уңышка ирешмәвенең сәбәбен башкалардан эзләү. *Аталмаган бала атасыннан күрә, дип, юкка әйтмәгәннәр, дисертацияңнең урта куллы булуын җитәкчеңә сылтама* (Сөйләм).

*АТАМ* ❖ **АТАМ ИРКӘСЕ<МЕНИ>.** Артык иркәләү турында. *Фидакарьләрчә, чөнки Үрбәт кечкенәдән атам иркәсе булып үсте, Атае да, анае да төпчекләрен бик үсендерделәр* (М. Әмирханов. Үрбәт ханәкә гыйшкы).

*АТАҢ* ❖ **АТАҢ БАШЫ** *сөйл.* 1. Тиргәү, каргану сүзе. *Атаң башы! Чехмы, мехмы! Безгә барыбер түгелмени?* (Г. Ибраһимов).

2. Берәрсенең фикеренә ирония белән әйтелә. *Безнең балыкчы бабай, мохаль бернәрсәне ишеткән сыман, бик кызык иттереп көлде дә: – Чыгарсың анда, атаң башы! – диде* (М. Гафури. Хан кызы Алтынчәч).

**АТАҢ БАШЫ ГЫНА ЮК.** «Булырга мөмкин булган барлык нәрсә бар» мәгънәсендә. *Бөтен нәрсә бар иде анда, фәкать атаң башы гына юк* (Сөйләм).

**АТАҢ БАШЫ КИРӘКМЕ ТАГЫН.** «Монысы җиткән, артыгын таләп итмә» мәгънәсендә. *– Соң, атаң башы кирәкме тагын сиңа – хатын-кызга?* (К. Тимбикова. Аным уртасында).

**АТАҢ БЕЛӘН АНАҢ ГЫНА ЮК.** «Атаң белән анаңнан башка барлык нәрсәң дә бар» мәгънәсендә. *Кирәк-яракка кытлыгың юк, ашауэчүең дә мулдан – бар да бар, атаң белән анаң гына юк* (Сөйләм).

**АТАҢ БУЛЫРЛЫК (БУЛЫРДАЙ; БУЛЫРГА ЯРАКЛЫ)** *к.* ата кебек. *– Атаң булырлык кешегә кул күтәрергә... – дип сөйләнде, үзе һаман ат башы тирәсенә ышыкланды* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

Төрдәше: ата кебек һ.б.

**АТАҢ МАЛЫ ТҮГЕЛ.** Хакы булмаса да, кеше малы яки дәүләт малын даулаучы турында. *– Теләсә кемгә биреп җибәрергә ул сиңа атаң малы түгел, – ди кырыс чырайлы завод директоры* (М. Зарипов. Ут бригадиры).

**АТАҢ ПЫЯЛАЧЫМЫ ӘЛЛӘ** *мыск.* Алга килеп басып, гәүдәсе белән яктылыкны каплап торганда әйтелә. *– Кара, атаң пыялачымы әллә, яктылыкны капламасаң...* (Сөйләм).

*АТАҢА* ❖ **АТАҢА ЛӘГЪНӘТ, АВЫЗЫҢА ТАШ!** *карг.* «Сине тудырып үстергән атаңа ләгънәт булсын һәм тамагың тыгылсын» мәгънәсендә. *Атаңа ләгънәт – авызыңа таш* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).

Төрдәше: атаңа нәләт!; җаның җәһәннәмгә олаккыры; җаның чыксын (чыккыры); җәһәннәм<нең> төбенә китсен!

**АТАҢА НӘЛӘТ!** *к.* атаңа ләгънәт, авызыңа таш! *– Һәй, атаңа нәләт, нугай урыс!* (М. Галәү. Мөһаҗирләр).

Төрдәше: атаңа ләгънәт, авызыңа таш! һ.б.

*АТАҢНЫ* ❖ **АТАҢНЫ ЙӨТКЕРЕРГӘ ӨЙРӘТМИЛӘР.** Үз эшенең остасына яки күп яшәп, күпне күреп, гореф-гадәтләрне яхшы белгәнгә, һәвәскәрләрнең киңәше кирәк булманга ишарә. *Икенче юлы, өлкәннәргә акыл бирә башлаганчы, яхшылап уйла: атаңны йөткерергә өйрәтмиләр!* (Сөйләм).

Төрдәше: балыкны йөзәргә өйрәтмәү; Илһамны җырларга өйрәтмиләр; каргага парашют кирәкми (кирәк түгел); үгезне сөзәргә өйрәтмиләр; этне өрергә өйрәтмәү.

*АТАҢНЫҢ* ❖ **АТАҢНЫҢ БАШ СӨЯГЕ** *карг.* Аңгыра, аңсыз кеше («атасыннан баш мие аласы урынга, баш сөяген генә алган» мәгънәсендә). *Атасын да яхшы белә идем, әмма малае атасының баш сөяге генә* (Сөйләм).

Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.

2. Атасы йортының данын арттырасы урынга аны бөлдереп, атасының баш сөяге белән уйнаучы (борынгы кыргый кабиләләрдә, эчү өчен, баш сөягеннән тустаган ясаганнар). *Күз явын алырлык нинди хуҗалык иде бит, бөтен мал малае кулына кергәч, атасының баш сөяге булып калган* (Сөйләм).

**АТАҢНЫҢ ТУНЫ БАРМЫ, МИНДӘ КИТКӘН, АРТЫМНАН КАЛМЫЙ ЙӨРИСЕҢ?** *мыск.* Кешегә тагылып яки артыннан эзәрлекләп йөрүчегә әйтелә. – *Карале, дус кеше, атаңның туны бармы, миндә киткән, артымнан калмый йөрисең?* (Сөйләм).

*АТАП* ❖ **АТАП ӘЙТКӘНДӘ.** 1. *к.* аерым алганда. *Ә ярты гасыр элек (атап әйткәндә, 1949 елларда) СССРда татар язучысы Гаяз Исхакый исеме дә, аның «Инкыйраз»ы да тәмам онытылган иде* (А. Тимергалин. «Инкыйраз»га 100 ел). *Чөнки төркиләр, атап әйткәндә, Дәшт-и Кыпчак турындагы һәртөрле язмада каткат үзгәртелгән, бозыып беткән* (З. Мурсиев. Хөкем).

Төрдәше: аерым алганда һ.б.

2. Исеме белән конкрет әйткәндә. *Атап әйткәндә, ул венгр тюркологы И. Кунош тарафыннан Беренче дөнья сугышы чорында әсир төшкән татар солдатларыннан язып алынган фольклор әсәрләрен дөньяга чыгару һәм үзебезгә кайтару юлында гаять зур тырышлык күрсәтте* (Л. Җамалетдинов. Татар экиятләрен барлау юлында).

**АТАП КИЛҮ.** Берәрсенә махсус, туп-туры килү. *Атап килеп борчыдың, маңгаемда тамгам юктыр бит?!* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы). *Курсыбай башкисәрләрен нәкъ мәчеткә атап килүен ул күңеленең кайсыдыр бер өлеше белән хаталанмый-нитми тоемлады* (В. Имамов. Утлы дала).

Төрдәше: атлап-данлап килү.

**АТАП КУЮ.** Малны яки башка берәр нәрсәне кемгәдер бирергә дип хәл итеп кую. *Трактор дигәннән, пенсиягә чыккач та унбиш ел хезмәтен дәвам итүче ветеранга, ялга туктаганда бүләк итү өчен, хуҗалык җитәкчесе Илшат Раилевның атап куйганы барлыгын да белдек бу баруыбызда* (Т. Нәҗмиев. Сабаларда эчәр суым булгач...).

*АТАРДАЕН* ❖ **АТАРДАЕН АТЫП, СУГАРДАЕН СУГЫП** *әкият.* Дошманнары белән каракаршы килеп, аларны җиңүне тасвирлаганда әйтелә. *Атардаен атып, сугардаен сугып, солдат юлын дәвам итә* (Сөйләм).

*АТАСЫ* ❖ **АТАСЫ<НЫҢ> БАЛАСЫ.** Атасына бик нык охшаган, атасы кулы астында үскән бала. – *Шул куштан булмый, кем әйтсен, – диде Альберт. – Атасы баласы* (Р. Батулла. Юл буенда зәңгәр чәчәк).

**АТАСЫ БОЛАН АТМАГАННЫ, БАЛАСЫ КУЯН АТМАС**. Яшь буынның өлкәннәрдән үрнәк алуы турында. *Башта борчак үстерү, мүкләк сыер, башына тай типмәгән, атасы болан атмаганны, баласы куян атмас фразеологизмнары авылда гына туа ала* (nsportal.ru)

*АТАСЫН* ❖ **АТАСЫН САГЫНУ.** Җор сүз; авыз пешеп, бик каты йөткереп, калкынып һ.б. вакытында күздән яшь чыкканда әйтелә. *Өстәл артында утырган берәү, кайнар аш ашап утырганда, тиз генә кашыгын куеп, авызын җилләтә башлагач, «атасын сагына бугай» дип куйды* (Сөйләм).

**АТАСЫН САТАР.** Кешенең намуссызлыгын белдерү. *Карап-карап тордым да тагын бер карап куйдым, «атасын да сатар бу малай» дигән уй килде башыма* (Сөйләм).

**АТАСЫН ТАНЫТУ.** «Әти!» дип акырып елаганчы кыйнау. *Үзен әллә кемгә куеп, безнең кызлардан көлеп йөргән була, атасын танытабызмы әллә?* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

*АТАСЫНА* ❖ **АТАСЫНА ТАРТУ** *к.* анасына тарту. *Йөз-кыяфәте атасына тарткан Идрисне йортта күрүгә үк төсмерләп алды Әхияр. Булса да булыр, нәселләре белән мактанчык, борынлы, тәкәббер* (Р. Мулланурова. Өрәңге өрәге).

*АТАСЫНЫҢ* ❖ **АТАСЫНЫҢ БҮРЕГЕН КИГӘН.** Ишсез нәрсә, мәсәлән, кечкенә савытка зуррак капкач кую. *Өстәл кырыенда атасының бүреген кигән шикәр савыты да утыра иде* (Сөйләм).

**АТАСЫНЫҢ <ӘТИСЕНЕҢ> КЫЗЫ.** Кызы бөтен яктан да әтисенә охшаганда әйтелә. – *Мин күбрәк әти кызы* (Р. Туфитулова. Язмыш җиле).

**АТАСЫНЫҢ <ӘТИСЕНЕҢ> САКАЛЫ БЕЛӘН УЙНАУ.** Югары дәрәҗәле, зур урындагы кешеләргә малайларча бәйләнү. *Елыйсы килгән бала әтисенең сакалы белән уйнар* (Мәкаль). – *Атасының сакалы белән уйный димәкче буласыңмы?* (husniar.ru).

*АТ-АТ* ❖ **АТ-АТ УЙНАУ.** Бау бәйләгән берәр баланы ат итеп, чыбыкка атланып, ул бауны кулына тотып йөгерешү. *Без уйнарга тотындык: ат-ат уйнадык* (Ф. Әмирхан).
Төрдәше: атлы уйнау.

*АТ-АТАГЫ* ❖ **АТ-АТАГЫ ЧЫГУ (ТАРАЛУ).** Атышөһрәте чыгу, даны таралу. *Озак көтәргә туры килмәде, тиз арада аның ат-атагы тирәякка таралды* (Сөйләм).
Төрдәше: ат алу (таралу) һ.б.

*АТАУ* ❖ **АТАУ ЙОРТ.** 1. Урта йөзләрдә төркиләр, кияү белән кәләшкә никах укылганнан соң, зөфаф киче өчен аерым тирмә, ап-ак киездән ясалган атау йорт корып куя торган булганнар, соңрак вакытларда аерым бүлмә яки шул вазыйфаны үти торган мунча әзерләгәннәр. *Тирмәләрдә, атау йортларда, кәрвансарайларда, кала өйләрендә берсеннән-берсе шомлырак, берсеннән-берсе сәеррәк хәбәрләр йөрде* (Р. Батулла. Сөембикә).

*АТКА* ❖ **АТКА КАЛУ**. Исеме чыгу, даны таралу. *Сәхипҗамал миңа гашыйк /Диеп үк атка калмышлар* (Г. Кандалый).
Төрдәше: ат алу (таралу) һ.б.

**АТКА МЕНГӘНДӘЙ БУЛУ** *к.* авыз еру 4. *Малаебыз атка менгәндәй булды, авызын җыеп ала алмый гына бит* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз еру 4 һ.б.

**АТКА МЕНГӘЧ, ЫШТАНЫМНЫ ЯМАП БИР** *мыск.* Алдан эшлисе эшен соңракка калдырып, буталып беткән кеше турында. – *Вакытында селкенмәдең дә, хәзер инде миңа «атка менгәч, ыштанымны ямап бир» дип утырасың* (Сөйләм).

**АТКА САБУ** *к.* ат алу (таралу). *Атка саптым еллар үтү белән...* (Сөйләм).
Төрдәше: ат алу (таралу) һ.б.

*АТКАН* ❖ **АТКАН САЕН ҮРДӘККӘ ТИМӘҮ.** «Һәр нәрсәнең җаен белергә кирәк» мәгънәсендә. *Беркөн балыкка барып, чуртан эләктереп кайткач, көн саен күл янына йөреп тә берни тота алмады. Бабасы, оныгының кәефен кырмас өчен, йомшак кына: «Аткан саен үрдәккә тими ул, улым, булганына канәгать кала белергә кирәк», – дип, башыннан сыйпады* (Сөйләм).
Төрдәше: авыртмаган якка яту һ.б.

**АТКАН УК КЕБЕК.** Үтә тиз, җилдәй тизлек белән үтү (барып җитү). *Аткан уктай, искән җилдәй килә кызу, / Камчы белән як-ягына оргымакта* (Ф. Бурнаш. Казакъ кызы). *Ә Наиләнең аткан уктай атылып чыгуын, ире янына барып капланып, дөнья сасытып акыруын күрмәскә сукырмы әллә алар?..* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: аккан су кебек һ.б.

**АТКАН УК КИРЕ КАЙТМАУ** *к.* агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән. *Күпме генә өзгәләнсәң дә, ялварсаң да, аткан ук кире кайтмый шул* (Сөйләм).
Төрдәше: агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән һ.б.

*АТЛАГАН* ❖ **АТЛАГАН САЕН** 1. *к.* адым саен. *Гомер күзләренә кергән кешене сөендерергә күп кирәкмени, аяк атлаган саен уланнарга бәхет, озын гомер теләделәр* (А. Хәертдинова. Ак сирень).
Төрдәше: адым саен.

2. Һәр урында бар, еш очрый торган. *Олы юлда, атлаган саен, маяк кадамыйлар* (А. Тимергалин. Сүнмәс ут янында уйда без...). *Кайтыр юлында атлаган саен зур-зур шәһәрләр, шахталар, заводлар булган Англияне кичеп, диңгез ярына килеп чыга* (А. Хәсәнов. Бүре баласы Чатан).

3. Гел, һаман-һаман. *Безнең ватандашларымыз русларның атлаган саен бәйрәмнәре була* (Г. Тукай). *Начар трактор бирдегез, атлаган саен ватыла дип әйтмәдемме?* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

*АТЛАМЫШ* ❖ **АТЛАМЫШ БАТЫР ЙОКЫСЫ БЕЛӘН ЙОКЛАУ** *к.* Алпамыш йокысы. *Тирмәнең бер почмагында арып кайткан сугышчы Атламыш батыр йокысы белән йоклап ята иде* (Сөйләм).
Төрдәше: Алпамыш йокысы.

*АТЛАНЫП* ❖ **АТЛАНЫП ТАЛАУ.** Оятсыз-әрсез рәвештә, күрәләтә малын-милкен, эшен-көчен басып алып талау. *Чөнки илне атланып талаучы бу зәхмәтләр чирүенә милләтләрен күрсәтү һич кирәк нәрсә түгел. Милләтен документта танытасы килмәгән бер генә халык бар* (matbugat.ru).

*АТЛАП-ДАНЛАП* ❖ **АТЛАП-ДАНЛАП КИЛҮ** *к.* атап килү. Берәр кешегә (яки урынга) хөрмәт

итеп махсус килү. *Бу йорт шәхси милек саналса да, анда хөрмәтле язучы яшәгәнлектән, музей санап, атлап-данлап киләләр иде* (Сөйләм).
Төрдәше: атап килү һ.б.

*АТЛАП-ТУНЛАП* ❖ **АТЛАП-ТУНЛАП КИЛҮ.** Хәлле-маллы, әүкатлы кешеләр үз транспортлары белән килү. *Бу истәлекле урын бер тау сыртына урнашкан булса да, аңа атлап-тунлап киләләр иде* (Сөйләм).

*АТЛАР* ❖ **АТЛАР ҖИГҮЛЕ БУЛУ.** Үләргә әзер булу. *Инде йөзне тутырганда, китәргә атлары җигүле булганда, ягъни бүген-иртәгә җир куенына керергә торганда, ул янә әйтте, үзалдына түгел аякларын бөкләп келәмдә утыручы, хикәясен тәмам итеп, дога кылучы дәрвиш ишетсен дип әйтте* (Р. Батулла. Сөембикә).
Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

*АТЛАУ* ❖ **НЫГРАК АТЛАУ.** Сүзне үтемлерәк итәргә тырышу. *Иренең болай йомшарганын күргәч, Фәтхия катырак кагылды, ныграк атларга тырышты* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми).

*АТЛЫ* ❖ **АТЛЫ БАРЫП (КИЛЕП), ҖӘЯҮ КАЙТУ.** Файдасызга, бушка йөреп кайту; буш кул белән кайту. *Алдан сөйләшенеп-килешеп барган булса да, атлы барып, җәяү кайтырга туры килде* (Сөйләм).

**АТЛЫ БУЛУ.** 1. Исеменә тап төшермәү, яхшы исемле булып калу. *Үзе генә хөкүмәт әгъзасы алдында яхшы атлы булып калса калгандыр, ләкин халык алдында алай түгел* (Г. Баруди. Хатирә дәфтәре).

2. Кыяфәткә керү, кылану. *Алар шул хәлләреннән килмәгән көйгә күп чәчеп, советка яхшы атлы булалар* (А. Алиш. Күрше). *Берсе дә чыгарга ашыкмады: Булыгинның соравын ишетмәгән атлы булып, башларын аска иеп, куркышып утыралар* (В. Нуруллинан Ике урам арасы).

**АТЛЫ КАЗАК** *тар.* 1. Элекке вакытта далаларда төрле кешеләрдән, халыклардан тупланып, юлдагыларны талау яки түләүле гаскәр буларак ялланып көн күрүчеләр. *Анда Кондратий Булавин атлы казак, үзенең кул астына дистә меңгә якын җайдак туплап, Донның башкаласы булган Чиркәс каласына һөҗүм әзерли икән* (В. Имамов. Сәет батыр).

2. Патша заманында атлы полиция һәм жандармнар. *Бүлмәгә көйгән-кызган ис таралуга, хуҗабикә, атлы казак сыман, өскә килеп керә* (В. Имамов. Күке). *Күрше авылгача ияреп килгән кылычлы атлы казак Сәмигулла, аңардан тәки бер мәгъричлек акча кысып, төн авызына кереп югалды* (Ф. Яхин. Ат урлауның ние бар?).

**АТЛЫ КАЗАК БУЛМА.** Кеше янында һаман басып торып, кәефен бозучыга; гайрәт орып, кешегә әмер бирүчегә; гел үрә басып әтәчләнүчегә; җикеренергә яратучыга кисәтү ясау. *Артымда атлы казак булып торма әле, эшең булса, утыр каршыга* (Сөйләм).
Төрдәше: атлы казак кебек өстендә тору; кичә калган намазым шикелле өстемдә тору.

**АТЛЫ КАЗАК КЕБЕК <ӨСТЕНДӘ> ТОРУ** *к.* атлы казак булма. *Тор инде, алайса, атлы казак кебек* (Г. Каюмов. Морза).
Төрдәше: атлы казак булма; кичә калган намазым шикелле өстемдә тору.

**АТЛЫ КЕШЕ ТӨШЕП КАРАРЛЫК.** Кызларның матурлыгы турында, бик көчле соклану. *Аның гүзәллегенә сокланып, атлы кеше төшеп карарлык иде* (Сөйләм).
Төрдәше: авызда гына тотарлык һ.б.

**АТЛЫ <БУЛЫП> КЫЛАНУ.** Кыяфәте белән акыллы, белдекле итеп күрсәтү. *Гыймади тагын: – Һым!.. – дип йөткереп, атлы кылангән булды* (Ә. Гаффар. Дәрья башы).

**АТЛЫ УЙНАУ** *к.* ат-ат уйнау. *Малайлар белән атлы уйнаган булып, урманга алып барсыннар* (Г. Гобәй).
Төрдәше: ат-ат уйнау.

**АТЛЫ ХӘЕРЧЕ.** Элекке вакытларда ат җигеп, тәртә башларын утта көйдереп, янгынга дучар булдык дип, авылдан авылга хәер өстәп йөрүчеләр. *Юлыңда атлы хәерчеләр очрамадымы?* (Сөйләм).

*АТЛЫГЫП* ❖ **АТЛЫГЫП ТОРУ.** Теләү, омтылу. *Бу ике егет аңа [Низамовка] эшкә атлыгып торулары белән ошады* (Г. Әпсәләмов). *Хатын-кызын да әйтим, озак яшәргә нинди чос халык булса да, Җантай әбине алмаштырыр-*

*га берсе дә* ***атлыгып тормый*** (Р. Зәйдулла. Ак эт).

*АТЛЫ-ҖӘЯҮЛЕ* ❖ **АТЛЫ-ҖӘЯҮЛЕ СӨЙЛӘҮ.** Сүз сөйләгәндә, әле кызу-кызу, әле салмак, кирле-мырлы бутап сөйләү. – *Юк, Рөстәм сөйләмәсен, аның атлы-җәяүле сөйләвен аңлавы кыен булачак, башка берәрсен табыгыз* (Сөйләм).

*АТЛЫЛАР* ❖ **АТЛЫЛАР АТЫННАН ТӨШЕП, ҖӘЯҮЛЕЛӘР ЯТЫП КАРАРЛЫК** *к.* авызда гына тотарлык. *Тәрәзә каршына ак башлык, ак халат кигән, тал чыбыгыдай зифа буйлы, атлылар атыннан төшеп, җәяүлеләр ятып карарлык томырап торган чибәр кыз килеп басты* (Г. Мөхәммәтшин. Хуҗалар).

Төрдәше: авызда гына тотарлык һ.б.

*АТЛЫСЫ* ❖ **АТЛЫСЫ АТЫП, ҖӘЯҮЛЕСЕ ЯТЫП КАРЫЙ** *к.* авызда гына тотарлык. – *Төн йокыларын качырырлык гүзәл икәнлеген белми идеңмени, аны очраткан бер атлысы атып, җәяүлеләр ятып карый* (Сөйләм).

Төрдәше: авызда гына тотарлык һ.б.

*АТЛЫ-ТУНЛЫ* ❖ **АТЛЫ-ТУНЛЫ КЕШЕ.** Элекке вакытта үз транспорты булган хәлле-маллы кеше. *Атлы-тунлы дөнья тоткасы кешеләр өчен ишек яңагы ни дә, аңа сөялгән Шәмсетдин ни – икесе дә бер* (Г. Бәширов).

*АТМАГАН* ❖ **АТМАГАН АЮНЫҢ (КУЯННЫҢ) ТИРЕСЕН БҮЛҮ (ТУНАУ)** *к.* ала каргадай алдан ала (алдан алы) кычкыру. – *Атмаган куянның тиресен бүлешмәгез әле, – дип туктатмаса, Нәсимә белән Рәсимә байлар кибетендәге яхшы әйберләрнең бөтенесен өйләренә ташып бетергән булырлар иде* (Ф. Яруллин. Кыйбласызлар).

Төрдәше: ала каргадай алдан ала (алдан алы) кычкыру һ.б.

*АТМАГАН* ❖ **АТМАГАН КУЯН, АСМАГАН КАЗАН** *к.* ала каргадай алдан ала (алдан алы) кычкыру. – *Атмаган куянга, асмаган казанга кунак чакырасың* (В. Имамов. Тозлы яра).

Төрдәше: ала каргадай алдан ала (алдан алы) кычкыру һ.б.

*АТМАС* ❖ **АТМАС ТАҢ, ЧЫКМАС КӨН БУЛУ.** «Баш чыкмас мәшәкатькә тару» мәгънәсендә. *Кем уйлаган аны шундый атмас таң, чыкмас көн булачагын* (Сөйләм).

*АТНА* ❖ **АТНА АРТЫННАН АТНА ҮТҮ.** Вакытның бик тиз, сизелмичә үтүенә ишарә. *Атна артыннан атна үтте. Разилә һаман да юк иде.* (Р. Рахман. Тауның башын болыт кисә).

**АТНА БАСАР.** Еш килә торган кунак (кешеләрнең ял көннәрен басып алучы). *Эшкә йөримени, якшәмбе җиттеме, теге атна басар Мансурның килеп кергәнен көт тә тор* (Сөйләм).

**АТНА КИЧ САБАГЫ <УКЫТУ>** *иск.* Әзерләгән эшеннән хисап алу һәм җәзага тарту. Элек мәдрәсәләрдә атналап өйдә ятлау өчен эш биргәннәр – шуны тикшерү. – *Атна кич сабагыңны әзерләдеңме, иртәгә хәлфәгә тыңлатасың бар* (Сөйләм).

Төрдәше: арт сабагын укыту.

*АТНАСЫН<Д>А* ❖ **АТНАСЫН<Д>А БИШ (ҖИДЕ) ҖОМГА.** Үзенең ниятләрен, карарларын һ.б.ны бик җиңел һәм тиз үзгәртү. *Аның өчен атнасына биш җомга булды инде* (sahrikazan.ru). *Акыллары атнасына җиде җомга ясагандай алышынып тора* (В. Имамов. Утлы дала).

Төрдәше: акылы үзе белән һ.б.

*АТНЫ* ❖ **АТНЫ АРБА АРТЫНА ҖИГҮ** *гади с., мыск.* Нинди булса да бер эштә яки хәрәкәттә кабул ителгән тәртипне, эзлеклелекне бозып, мантыйксызлык ясау. *Без әле һаман да авыл хуҗалыгының кайбер юнәлешләрендә атны арба артына куеп җигәргә тырышабыз* («Ватаным Татарстан» газ.).

**АТНЫ ҖИККӘНЧЕ ЧЫБЫРКЫЛЫЙ БАШЛАМАУ.** Төп мәсьәләне хәл итми торып, аңа бәйле булган икенчел дәрәҗә бурычларга тотынмау. – *Ашыкмагыз, атны җиккәнче үк чыбыркылый башламыйлар, Ирек. Бераз сулу алырга бирегез* (Г. Тавлин. Афәт).

**АТНЫ ТӨГЕ БЕЛӘН, ДӨЯНЕ ЙӨГЕ БЕЛӘН ЙОТУ.** Бик талымсыз азгын, кап-йот кеше турында. – *Һай, Ходаем, бу иптәшегез атны төге белән, дөяне йөге белән генә йота, тамагына тыгылмасын* (Сөйләм).

*АТРАФЛЫ* ❖ **АТРАФЛЫ БАШ ЙӨРТҮ** *иск.* Һәр ягын яхшы уйлап эш итү. *Мин иң әүвәл әнә теге*

*егетнең сүзенә колак салыр идем, атрафлы баш йөртә ул* (Сөйләм).

*АТСА* ❖ **АТСА УГЫ, ЧАПСА КЫЛЫЧЫ БУЛУ.** Берәрсенең уң кулы булып, һәр әйткәнен үтәү. *Ханның дуслары атса угы, чапса кылычы булганнар* (Сөйләм).

*АТСЫЗ* ❖ **АТСЫЗ АРБА** *иск.* Автомашина. *Хәзрәт башына: – Ник мине, атсыз арбага утыртып, мыскыл итәргә, әллә мине Хуҗа Насретдин дип белдегезме? – дип, утырмаска теләп тә, ахырдан утырды* (Ф. Әмирхан. Фәтхулла хәзрәт).

*АТТА* ❖ **АТТА ГАЕП БУЛГАН ШИКЕЛЛЕ, ТӘРТӘДӘ ДӘ <ГАЕП> БАР.** Гаеп бер якта гына түгел, икесе дә гаепле. *[Кәрим] Атта гаеп булган шикелле, тәртәдә дә гаеп бар* (Г. Камал. Бәхетсез егет. I вариант).

Төрдәше: атта да <гаеп> бар, тәртәдә дә; атта да, тәртәдә дә бар.

**АТТА ДА <ГАЕП> БАР, ТӘРТӘДӘ ДӘ** *к.* атта гаеп булган шикелле, тәртәдә дә <гаеп> бар. *Димәк, гаеп бер Тәүхиттә генә булмаган, гаеп, димәк, атта да бар, тәртәдә дә булган* (Г. Ахунов. Эт патшасы).

Төрдәше: атта гаеп булган шикелле, тәртәдә дә <гаеп> бар һ.б.

**АТТА ДА, ТӘРТӘДӘ ДӘ БАР** *к.* атта гаеп булган шикелле, тәртәдә дә <гаеп> бар. *Юкка ызгышмагыз, гаеп икегездә дә, ягъни атта да, тәртәдә дә бар* (Сөйләм).

Төрдәше: атта гаеп булган шикелле, тәртәдә дә <гаеп> бар һ.б.

**АТТА ЯЛ, АДӘМДӘ МАЛ КАЛМАУ.** Бөлгенлек, кырылыш булу. *Ачлык еллары булганлыгын беләсездер инде, ул вакытта атта ял, адәмдә мал калмаган* (Сөйләм).

*АТТАН* ❖ **АТТАН АЛА ДА ТУА, КОЛА ДА ТУА.** Һәрвакытта да бер үк төрле булып тормауга ишарә. *Дөрес, арада «аттан ала да, кола да туа» дигән сүзләрне әйтеп, аны ничектер акларга тырышучылар да бар, тик ничек кенә булмасын, атның монда гаебе юк, ат үз гомерендә тарта алган чаклы тарткан, аның хәзер кешеләрдән аклау сүзләре түгел, ә бәлки хөрмәт сүзләре ишетәсе килә иде* (Ф. Хөсни. Түбән оч).

**АТТАН ИҢДЕРЕП (ТӨШЕРЕП), ҖӘЯҮЛЕГӘ КАЛДЫРУ** 1. *к.* авыздан кош очыру. *Син бу кешегә бик ышанып бетмә, аттан иңдереп, җәяүлегә калдырмасын* (Сөйләм).

Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

2. Тәмам бөлдерү. *Күршенең яшь хатыны, уйланмаган зур чыгымнар ясап, хуҗасын аттан төшереп, җәяүлегә калдырды* (Сөйләм).

**АТТАН ИҢЕП, ҖӘЯҮГӘ КАЛУ** *к.* агач атка (аргамакка) атлану (атланып калу). *Аттан иңеп, җәяүгә калу* (К. Насыйри. Кабуснамә).

Төрдәше: агач атка (аргамакка) атлану (атланып калу) һ.б.

**АТТАН КӘҖӘГӘ (ТАЙГА) КАЛУ** *к.* агач атка (аргамакка) атлану (атланып калу). *Мәхмүт, мескен, шул кеше сүзен тыңлап, аттан кәҗәгә калды да инде* (Сөйләм).

Төрдәше: агач атка (аргамакка) атлану (атланып калу) һ.б.

**АТТАН ТАЯККА КАЛУ.** Хәерчеләнү, бөлгенлеккә төшү, шулай ук *к:.* агач атка (аргамакка) атлану (атланып калу). – *Күрше йорттагы Чәлмәннең аттан таякка калуы миңа сабак түгелмени?* (Сөйләм).

Төрдәше: агач атка (аргамакка) атлану (атланып калу) һ.б.

**АТТАН ТӨШЕП, ИШӘККӘ МЕНҮ** *к.* агач атка (аргамакка) атлану (атланып калу). – *Мондый юлга бассаң, аттан төшеп ишәккә менүеңне көт тә тор* (Сөйләм).

Төрдәше: агач атка (аргамакка) атлану (атланып калу) һ.б.

**АТТАН ТӨШЕП, ТАЙГА, ТАЙДАН ТӨШЕП, ИШӘККӘ АТЛАНУ** *к.* агач атка (аргамакка) атлану (атланып калу). – *Дөрес юл сайламаганыңны сизәсеңме, эшең артка тәгәри бит, аннан соң аттан төшеп, тайга, тайдан төшеп ишәккә атланырга да күп калмый* (Сөйләм).

Төрдәше: агач атка (аргамакка) атлану (атланып калу) һ.б.

**АТТАН ТӨШЕРЕП, ИШӘККӘ МЕНДЕРҮ** *к.* аттан иңдереп, җәяүлегә калдыру 1, 2. – *Ул кәсепче белән сак бул, күп кешене аттан төшереп, ишәккә мендерде инде ул* (Сөйләм).

Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

**АТТАН ТӨШЕРЕП – ТАЙГА, ТАЙДАН ТАЯККА АТЛАНДЫРУ** *к.* аттан иңдереп, җәяүлегә калдыру 1, 2. – *Дус-дус дип йөрисең, үзеңне аттан төшереп – тайга, тайдан таякка атландыруын көтәсеңме?* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

**АТТАН ТӨШСӘ ДӘ, ӨЗӘҢГЕДӘН ТӨШМӘҮ.** Дәрәҗәдән төшсә дә, бөтенләй егылып калмау. *Урыныннан алынуы авыр булса да, «ни харап» дип йөрмәде – аттан төшсә дә, өзәңгедән төшмәде* (Сөйләм).

**АТТАН (АЛАШАДАН) УЗЫП ЙӨГЕРӘ ТОРГАН ТӘРТӘ.** Көтелмәгән яңалык, сәер нәрсә. – *Әйдә алайса, алашадан узып йөгерә торган карама тәртә янына киттек, безнең анда карарлык нәрсәләр табылыр, – дип, ачыктан-ачык сизелми торган мактану тоны белән әйтеп куйды ул һәм кунакны туп-туры тавык фермасы ягына алып китте* (Ф. Хөсни. Җәй башы).

*АТ-ТУН* ❖ **АТ-ТУН БАР, МОХТАҖЛЫК ЮК.** Тормышның җае белән генә баруы. *Шул рәвешчә, шома гына бара тормыш, әкрен генә үтә гомер, ат-тун бар, мохтаҗлык юк, кардәш-ыру күп, кунак-төшем дә күп, туйлары да һаман булып тора* (Ә. Еники. Соңгы китап).

**АТ-ТУН ТУЗУ.** Тормышның рәте китү, яшәү өчен кыенлыклар туу. *Айлар-еллар үтте, илдә юньле ир-ат калмады, ат-тун тузып бетте, яланнарны ягы-ягы белән сарут басты, хәтта авылда күгәрченнәр кимеп, каргалар ишәеп киттеләр, әмма сугышның очы-кырые күренми иде* (Ә. Еники. Тауларга карап).

*АТТЫМ-БӘРДЕМ* ❖ **АТТЫМ-БӘРДЕМ, КИТТЕМБАРДЫМ.** Дуамаллану. – *Юкса миңа, яныңда тыяр атасы, тыяр анасы булмаган җил-як кешегә, күпме кирәк. Дәреслекләр тутырган сумкамны аттым-бәрдем, киттем-бардым* (Ф. Хөсни).

*АТ-ХАТ* ❖ **АТ-ХАТ ҖИТКӘН ҖИР.** Бик ерак җир. *Тиз генә җыенды да ат-хат җиткән җиргә китте дә барды* (Сөйләм).

*АТЫ* ❖ **АТЫ АРГАЧ (БАРМАГАЧ), ТӘРТӘСЕН КЫЙНАУ.** Акылга сай һәм гаҗиз булган кеше, сәбәбен уйлап тормыйча ачуын алу; шулай ук *к.* ат ачуын тәртәдән алу. *Аты бармагач, тәртәсен кыйный* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).
Төрдәше: ат ачуын тәртәдән алу.

**АТЫ АРТТА, ТӘРТӘСЕ АЛДА.** Булмаганны өстәп, арттырып сөйләү. – *Ышанасыңмы шуның сүзләренә, аның аты артта, тәртәсе алда бит* (Сөйләм).

**АТЫ БЕР БУЛСА ДА, ЗАТЫ БАШКА.** «Исеме адаш булса, да сыйфаты төрле булырга мөмкин» мәгънәсендә. *Исемгә генә карап, бернәрсә дә белеп булмый, аты бер булса да, заты башка булуы ихтимал* (Сөйләм).

**АТЫ БЕТКЕРЕ** *к.* авыз<лар>ын корт чаккыры! *Су буена, кем, кайсыгыз соң әле, аты беткере!* (Н. Кәримова. Сагынасыңмы, дип сорыйлар...).
Төрдәше: авыз<лар>ын корт чаккыры! һ.б.

**АТЫ БУЛСА, ЙӨГӘНЕ (КАМЫТЫ) ТАБЫЛУ.** «Теләкнең зурысына ирешелсә, кечкенә чарасы җиңел табылыр» мәгънәсендә. – *Ярар, аты булса, камыты табылыр* (Ә. Әминев. Бер көймәдә...). *Әнә, министрларны да алып ыргыталар безнең заманда – елаганнарын күргән юк. Әти мәрхүм әйтмешли, аты булса, йөгәне табылыр...* (И. Сабиров. Тормыш язган хикәяләр).

**АТЫ БУЛСА, ЧАНАСЫ (АРБАСЫ) БУЛМЫЙ (ЮК).** Тормышта һәр нәрсә дә җитеш түгел – берсе булса, икенчесе булмый. *Аты булса, арбасы-чанасы юк, чәчүлек орлыкны да Кукмарадан йә Мамадыштан чаналар белән тартып ташырга туры килгән* («Хезмәт даны» газ.). *Аты булса, арбасы юк, арбасы булса, аты дигәндәй, атка яраклы җайланмаларны көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмассың хәзер. Ә чәчәргә кирәк* (М. Әмирхан. Дөя муены).

**АТЫ ДА ЮК, ЗАТЫ ДА ЮК.** Үзе дә юк, эзе дә юк (яки исеме дә юк). *Сөйләшенгән урынга барган идем, анда аның аты да юк, заты да юк* (Сөйләм).

**АТЫ ҖИТКЕРЕ.** Берәрсенең исеме (яки бер нәрсә) искә төшмичә әйтә алмый торганда, карганырга яратучылар «аты коргыры» дип әйтәләр, кайберләре исә, кешегә ихтирам йөзеннән, «аты җиткере» дип сүз кереше кыстыралар. *Әй, аты*

*җиткере, кем Әхмәте соң әле?* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).
Төрдәше: авыз<лар>ын корт чаккыры! һ.б.

**АТЫ КОРГЫРЫ** 1. *к.* аты җиткере. *[Хәйри] Әле берсекөннәрдә генә күрдем, байларның теге, исемен дә әйтә белмим, аты коргыры, нәрсә соң әле <...>* (Г. Камал. Өч тормыш).
Төрдәше: аты җиткере.

2. *к.* авыз<лар>ын корт чаккыры! *Юк, алай түгел, иң авыры – психология. Аты коргыры фән!* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).
Төрдәше: авыз<лар>ын корт чаккыры! һ.б.

**АТЫ КОРГЫРЫ, ИСЕМЕН ТЕЛГӘ АЛСАҢ, ТЕЛ ӘРӘМ.** Начар кешене телгә алырга мәҗбүр иткәндә, исемен каргап телгә алу. *Мәҗбүр итмәгез инде мине шуның исемен телгә алырга. Аты коргыры, исемен телгә алсам, тел әрәм* (Сөйләм).

**АТЫ ОЛЫ, КАБЫРГАСЫ КОРЫ.** Ат казанган, ләкин бөтен көчен куеп эшләмәгән кеше хакында. *Барлык дәрәҗәле кешеләр дә җиң сызганып эшләргә яратмый шул: аты олысын олы да, кабыргасы коры* (Сөйләм).

**АТЫ ЧАПТЫР, КЫЛЫЧЫ ҮТКЕР.** Батыр сугышчыларны сыйфатлау гыйбарәсе. *Аты чаптыр, кылычы үткер баһадир мәйдан уртасына чыкты* (Сөйләм).

**АТЫ ЧУМАН, ЧУМАН БУЛСА ДА, ЧАБА – ЮЛЫ ЯМАН** *к.* ат яхшы – җил каршы. *Аның аты ялкаурак шул, салмак кына йөрергә күнеккән – аты чуман, чуман булса да, чаба – юлы гына яман* (Сөйләм).
Төрдәше: ат яхшы – җил каршы һ.б.

*АТЫ-БАШЫ* ❖ **АТЫ-БАШЫ ЮК.** Сөйләвенең рәте булмау, аңлаешлы, төзек җөмлә кора алмау. – *Сүзенең аты-башы юк* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).

*АТЫЛГАННАН* ❖ **АТЫЛГАННАН КАЛГАН ЧЫПЧЫК.** «Куркытырга маташма, мин үлем күргән кеше» мәгънәсендә. *Юк, Андрей Андреич, син мине провоцировать итмә, мин «атылганнан калган чыпчык»* (Х. Камалов).

*АТЫЛМАГАН* ❖ **АТЫЛМАГАН ТӨЛКЕНЕҢ ТИРЕСЕН ТУНАУ** *к.* ала каргадай алдан ала (алдан алы) кычкыру. – *Кеше көлдереп, атылмаган төлкенең тиресен тунап маташма инде!* (Сөйләм).
Төрдәше: ала каргадай алдан ала (алы) кычкыру һ.б.

*АТЫЛЫП* ❖ **АТЫЛЫП БӘРЕЛҮ.** Нәрсә эшләргә дә белмәү; тегендә-монда сугылу. *Атылып бәрелмәкче икән. Шулай да сабырлык җиле аның ачу канатларын сындырган* (Ф. Яхин. Бар бер авыл, Чокал, диләр...).
Төрдәше: үрле-кырлы сикерү.

**АТЫЛЫП ТОРУ** *к.* атлыгып тору. *Егетләр бабайның әйтеп беткәнен дә көтмиләр, барабызбарабыз дип атылып торалар* (Г. Ибраһимов. Табигать балалары).
Төрдәше: атлыгып тору.

*АТЫМ* ❖ **АТЫМ АЧ ТОРЫРГА ӨЙРӘНГӘЧ КЕНӘ ҮЛЕП КИТТЕ, ДИГӘН КЕБЕК** *ирон.* Акчасын артык кысып, ашап-эчүенә игътибар бирмәү турында. *Ул төшке ашка бер тәлинкә кысыр шулпа ашый да, шуның белән вәссәләм, атым ач торырга өйрәнгәч кенә үлеп китте дигән кебек булыр әле* (Сөйләм).

**АТЫМ КОРЫСЫН** *карг.* «Шулай итмәсәм, исемем калмасын» мәгънәсендә. *Мин үчемне аямасам, Баба Түкләс бабам биргән Идегәй атым корысын!* («Идегәй» даст.).
Төрдәше: авыз<лар>ын корт чаккыры! һ.б.

**АТЫМ ЮК УРАМДА, КАЙГЫМ ЮК БУРАНДА** *к.* арба ватылса – утын, үгез үлсә – ит. *Олы апам гына, иртән торгач, буран бураганны күреп, әтинең кәефен күтәрергә теләгәндер инде, бичара: – Атым юк урамда, кайгым юк буранда, – дип шаяртып караган иде дә соң, барып чыкмады* (К. Миңлебаев. Акыллы атын мактар...).
Төрдәше: арба ватылса – утын, үгез үлсә – ит һ.б.

*АТЫН* ❖ **АТЫН МИН КУШТЫМ, ЯШЕН АЛЛА БИРСЕН.** Яхшы теләк. Бәбигә исем кушканнан соң әйтелә. *Баланы алгач, өстәл артына утырып Коръән укыла, дога кылына, изге теләкләр теләнә: «Атын мин куштым, яшен Алла бирсен», «Киемең тузсын, үзең үс», «Бәхетле, тәүфыйклы бала булсын»* (Татарская фольклористика, 2012).

**АТЫН УРЛАТКАЧ, АБЗАРЫН (КАПКАСЫН) БИКЛӘҮ.** «Узган-үткәнгә үкенүдән

файда юк» мәгънәсендә. – *Атын урлаткач, капкасын бикләгән адәм шул булды инде, – ди* (Г. Ибраһимов).

Төрдәше: узган эшкә салават; үлгәннән соң тәүбә юк; үткән эшкә салават; янгыннан соң буш көпшә белән селтәнү; янгыннан соң насос; янгыннан соң су эзләп чабу; янгыннан соң суның кирәге юк.

*АТЫП* ❖ **АТЫП ЙӨРҮ.** Бакча-паркларда кызлар яки егетләр белән танышу максатында йөрү. *Ул пудра ягынган, һәрбер яшь егетне атып йөрүче ханымнардан түгел* (Һ. Такташ).

**АТЫП КАЛУ.** Эшне үз вакытында башкарырга өлгерү. *Ятып калганчы, атып кал* (Мәкаль). *Соңга калганчы, атып кал: ишетмисең бит син, бәгырькәем!* (Л. Лерон. Бәхеткә биш минут кала).

*АТЫ-САНЫ* ❖ **АТЫ-САНЫ БАР.** Кешеләр арасында исеме, дәрәҗәсе бар. *Мал-мөлкәте, кешеләр арасында аты-саны бар – тагын нәрсә кирәк инде* (Сөйләм).

**АТЫ-САНЫ ЧЫГУ** *к.* ат алу (таралу). *Тиздән аның аты-саны чыгып, күрше өлкәләргә таралды!* (Сөйләм).

Төрдәше: ат алу (таралу) һ.б.

*АТЫ-ЧАБЫ* ❖ **АТЫ-ЧАБЫ КИТҮ (ҖӘЕЛҮ; ТАРАЛУ)** *к.* ат күтәрү 2. *Күп ханнарны һәм урдаларны үзенә бактыра, аты-чабы дөньяга җәелә* (Г. Рәхим).

Төрдәше: ат күтәрү 2 һ.б.

**АТЫ-ЧАБЫ ЧЫГУ** *к.* ат күтәрү 2. Уңай яки кире яктан даны чыгу. *Тагы шундый бик күп имешләр, гайбәтләр чәчелде. Кызның аты-чабы чыкты* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар). *[Гөлнур] Атыгыз-чабыгыз чыкмас борын, туйны тизрәк итеп калыйк* (К. Тинчурин. Сүнгән йолдызлар).

Төрдәше: ат күтәрү 2 һ.б.

*АТЫ-ЧУТЫ* ❖ **АТЫ-ЧУТЫ БЕЛӘН.** Бик әшәке итеп сүгенү. *Ул үзе эчке күлмәктән генә, күпшек түшен кашый, зур тимер люстраның яна торган бердәнбер лампочкасына акаеп-акаеп карангалап куя, исерек башына килгән кемнәрнедер, косып җибәрүдән тыелып, тавышын күтәрмичә генә аты-чуты белән сүгепме-сүгә* (А. Толстой. Инженер Гаринның гиперболиды. Тәрҗ. К. Миңлебаев).

Төрдәше: ата<сы>-анасы белән сүг<ен>ү һ.б.

*АТЫ-ЧУЫ* ❖ **АТЫ-ЧУЫ ЧЫГУ** *к.* ат күтәрү 2. – *Ярый ла кеше теленә эләкмәсәк! Кунак кызының атын-чуын чыгармасалар!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: ат күтәрү 2 һ.б.

*АТЫ-ЮЛЫ* ❖ **АТЫ-ЮЛЫ БЕЛӘН.** 1. *к.* ата<сы>-анасы белән сүг<ен>ү; *Янына Бакрова белән Нигъмәтуллин килеп керсә, мөгаен, Кадрия аларны аты-юлы белән куып чыгара да алган булыр иде* (В. Имамов. Кәнәфи).

Төрдәше: ата<сы>-анасы белән сүг<ен>ү һ.б.

2. Әйберне яки кешене исеме белән әйтеп сөйләү. *Гәзит мәкаләсендә Рабит Батулла: «Валерия Пороховада да, Мөхәммәд Алида да «тамчы су» урынына аты-юлы белән «сперматозоид» дип, күп кенә атаклы төрек галимнәренең тәрҗемәсендә «мәни, шәһвәт» дип языла килә* (А. Тимергалин. Әстәгъфирулламы? Юк, Сөбханалла!).

Төрдәше: аты-юлы белән әйтү (сөйләү).

**АТЫ-ЮЛЫ БЕЛӘН ӘЙТҮ (СӨЙЛӘҮ).** Яшермичә, барысын да ачыктан-ачык сөйләү. – *Аты-юлы белән әйт, сиңа әйтәм, безгә ул чагында көтүче Сәхәп малае Сәфәр килде ич* (Ф. Хөсни. Чакыру билеты).

**АТЫ-ЮЛЫ БЕЛӘН ҖИБӘРҮ (СҮГЕНҮ)** *к.* ата<сы>-анасы белән сүг<ен>ү һ.б. *Акрын гына чайкала-чайкала өстерәлеп баручы вагонны иртәнге якта кемнәрнеңдер шаркылдап көлүе, кемнәрнеңдер аты-юлы белән сүгенү авазлары уятты* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет). *Дөрестән дә, аты-юлы белән пыр тузып сүгенешкән тавышларга корал корган аваз – затвор чыңлавы кушылды* (М. Закир. Чебен).

Төрдәше: ата<сы>-анасы белән сүг<ен>ү һ.б.

*АУ* ❖ **АУ КОРУ.** Хәйлә тозагы әзерләү. *Почмак тарафларына бөтенләй барыр хәл дә юк: анда усал үрмәкүчләр ау корганнар* (Г. Тукай). *Миндә ирек, хөррият! Сафин Җәббарга ау корам* (Н. Гыйматдинова. Кыргый).

*АУГА* ❖ **АУГА ТӨШЕРҮ (КАПТЫРУ; ЭЛӘКТЕРҮ).** Уйланылган хәйләне тормышка ашыру. *Сез карт чыпчыкны ауга төшерә алмассыз;* /

*җә, сөйләңез инде, нигә кычкырдыңыз?* (Г. Тукай). *XVII–XVIII гасырларда патша хөкүмәте татарны җаны-тәне белән тәмам кол итеп мескенлеккә төшерү, шул юл белән исемен дә, җисемен дә дөньяда калдырмау өчен, вакытлыча төрле материаль интереслар күрсәтеп ауга төшерергә керешә: һәр чукынган татарга мул гына акчалар түли, аны солдатка алудан, имана түләүләрдән дә азат итә* (Н. Исәнбәт).

**АУГА ТӨШКӘН МАЙМЫЛ КЕБЕК.** Боргалану, сикергәләү һ.б. хәрәкәтләр ясау. *Бу биюнең бер төре дигәч кенә, ауга төшкән маймыл кебек кыылануларын бераз карап тордым да чыгып киттем* (Сөйләм).

**АУГА ТӨШҮ (КАБУ; ЭЛӘГҮ).** Башка берәрсенең тозагына төшү турында. *Ауга төшкән балык кеби, ары бәрелдем, бире бәрелдем – һичбер эш чыгара алмадым* (Г. Исхакый. Очрашу, яки Гөлгыйзар). *Гөлфәрваз, ауга эләккән күгәрчендәй сирпелә торгач, көчле кочактан ычкынып, чабып киткәч кенә, Искәндәр, <...> ашыкмыйча гына, әлеге кызыл ком сибелгән аллеяга чыкты* (К. Тинчурин. Искәндәр).

**АУГА ЧЫГУ.** Сугышта әсир алырга чыгу. *Дүрт ай госпитальдә яттым, дүрт ай ауга чыкмадым, иптәш командир* (А. Әхмәт).

**АУГА ЭЛӘККӘН БАЛЫК КЕБЕК.** Тыпырчыну, боргалану. *Ауга эләккән балык кебек тыпырчынулары да егетнең кочагыннан шуып чыгарга ярдәм итмәде* (Сөйләм).

*АУДАРУ* ❖ **АУДАРУ ДА ТӨЯТҮ** *шаярт.* Һич онытa алмау, һәрвакыт истә тоту. – *Ләхәулә вә куәтә, аудара да төятә дигәндәй, кич ятсам да, иртән торсам да исемнән чыкмый Ниязкаем* (Ф. Баттал. Мистер-абсолют).

*АУДАРЫП* ❖ **АУДАРЫП ТАШЛАУ.** – Бетерү, юк итү. *Сезнең чыгышта без барыбыз да нәфрәт белән карый торган самодержавиене бөтенләйгә аударып ташлаячак киң массаларның революцион кузгалышын күрәбез, – дип язалар алар* (К. Нәҗми).

Төрдәше: балта чабу 3; җир йөзеннән кырып (себереп) ташлау (түгү); кара көл итү; көл итү; көлен күккә очыру; оясы белән актару; себереп түгү; тамырын балта белән кисү; тамырын корыту; тамырына балта чабу; чәлпәрәмә китерү.

*АУЛАК* ❖ **АУЛАК СҮЗ** *диал.* Яшерен сүз, сер. *Аулак сүз бар, әүвәл киңәшергә кирәк!* (Р. Шәрипов. Мәңгелек сер).

**АУЛАК ЧӘЕ.** Бер-ике кеше ял иткән вакытта, чәй эчеп, сөйләшеп утыру. *Башлангыч класслар укытучысы Нәзирәне аулак чәе эчәргә үзләренә чакырды* (Г. Әдһәмова. Үкенечкә калмасын...).

*АУМАКАЙ* ❖ **АУМАКАЙ БУЛУ.** Һәрнәрсәгә дә яраклашу. *Ханның сиртмә койрык-селкенчәктәй гел аумакай булуын сизеп, бәкләр катырак сөйли башлады* (Р. Батулла. Сөембикә).

**АУМАКАЙ КЕШЕ.** Тотрыксыз, төрле якка авыша торган принципсыз кеше. *Ә теге ул (сүз каяндыр килеп эшли торган тотнаксыз секретарь турында бара) аумакай кеше* (Г. Галиев. Землемер баганасы).

Төрдәше: аумалы да тәүмәле; тотрыксыз (тотнаксыз) кеше.

*АУМАЛЫ* ❖ **АУМАЛЫ ДА ТӘҮМӘЛЕ** *к.* аумакай кеше. *Бу җиһан <...> аумалы да тәүмәле* (Ш. Бабич).

Төрдәше: аумакай кеше.

*АУНЫЙ-ТӘГӘРИ* ❖ **АУНЫЙ-ТӘГӘРИ КӨЛҮ.** Бик көлкеле вакыйгадан эчне тота-тота көлү. *Халык ауный-тәгәри көлә* («Шәһри Казан» газ.).

*АФӘРИН* ❖ **АФӘРИН УКУ.** Мактаулар сөйләү, хуплау. *Шаһзадә афәрин укыды, янчыкны чыгарып, боларның алдына куйды* (Мәҗмугы-л хикәят).

*АФИШАГА* ❖ **АФИШАГА БАККАН КӘҖӘДӘЙ КАРАУ (КҮЗӘТҮ; ТЕКӘЛҮ).** *Рәхмәт, инде ничәмә көннәр афишага баккан кәҗә кебек күзәтә идем* («Матбугат.ру» порталы). *Әхмәт, афишага баккан кәҗәдәй, сакалын күтәреп, миңа текәлде* (Җ. Нурани. Мәкерле көндәш – Ш. Маннапов тәрҗ.).

Төрдәше: яңа капкага текәлгән бәрән (сарык) кебек карау.

*АХ* ❖ **АХ АЛЛА ТРАНСПОРТЫ.** 1. Җәяүле сәфәр. *Анда машина үтә алмый, ах алла транспорты белән барырга туры килер* (Сөйләм).

Төрдәше: унберенче номер.

2. Ике тәгәрмәчле кулара арбасы. *Без, кечкенәләр, бөтен нәрсәне шул ах алла транспортына салып ташый идек* (Сөйләм).

Төрдәше: уфалла арбасы.

**АХ ИТӘРЛЕК (КИЛЕРЛЕК) ТҮГЕЛ.** Сокланырлык яки шаккатырлык җире булмаган. *Болай матур бизәлгән үзе. Концерты ах итәрлек түгел иде* (Ф. Яруллин. Хәтер төпләрендә утлы күмер).
Төрдәше: әллә нинди түгел; ис китәрлек түгел; ул кадәр... түгел.

**АХ ИТЕП ТОРУ.** Соклануны белдерү яки сокланудан «ах!» авазы чыгарып, көч биреп тору. *– Иллә мәгәр киленнән уңдым, Аллага шөкер, – дип куйды, – әйтмәгәнем булсын, туган атасын да болай карамас кеше, ах итеп тора шул җанкисәгем, әтекәй дип тора* (А. Расих. Ямашев).

**АХ ИТЕП ЯШӘҮ.** Куанып, сокланып гомер итү. *Тик мин шул карларым белән / Бергә китәргә тиеш, / Ах! итеп яшәү мәгънәсен / Эзләп йөрегән килеш...* (Н. Измайлова).

**АХ ИТҮ.** Шатлану, аптырау һ.б. хисләрне белдерү. *Озакламый китап үзе дә дөнья күрде һәм, укып баккач, әдәби мохит бердәм «ах» итте. «Афәрин!», «машалла!» диган сүз иде бу* (Н. Гамбәр. Күңел кошының биек очышы).

**АХ ХӘЛГӘ ТӨШҮ.** 1. Үкенечле, ах-вах итәрлек хәлгә төшү. *Бераз мал туплап кайтырмын дип киткән иде, ах хәлгә төшеп кайтты* (Сөйләм).
Төрдәше: ахәлгә төшү 1.
2. Ару-талудан, көч-хәл белән. *Былчыракны ера-ера, ах хәлгә төшеп, авылларына кайтып җиттеләр* (Сөйләм).
Төрдәше: ахәлгә төшү 2.

*АХАХАЙЛАП* ❖ **АХАХАЙЛАП КӨЛҮ.** Иркен җәелеп, кычкырып көлү. *Әхмәт ахахайлап көлде* (Х. Кәрим).

*АХӘЛГӘ* ❖ **АХӘЛГӘ ТӨШЕРҮ** *гади с.* Соңгы чиккә, гайрәт чигү хәленә китереп җиткерү; йөдәтү, тәмам тинтерәтү. *Үзен кулга алырга тырышып, түзеп килде, ләкин берчак аның сабыр казаны ташыды – атна саен акча сорап килүләр аны да ахәлгә төшерде* (Сөйләм).
Төрдәше: бәгырьне әрнетү; бөеракка төшү; бөергә төшү; җанны әрнетү; җанны әрнетү-телү; җанны бимазалау; җанны газаплау; җанны елату; җанны игү (игәү); җанны изү; җанны иңрәтү (талау); җанны камчылау; җанны канату; җанны каһәрләү; җанны кимерү; җанны кисеп төшү; җанны куыру; җанны кыерлау; җанны кыйнау; җанны өзгәләү; җанны өшетү; җанны суыру; җанны сызлату; җанны сыкындыру; җанны талау; җанны талку; җанны тапау; җанны телгәләү; җанны телү (телеп үтү); җанны тешләү; җанны тетрәтү; җанны тешләү; җанны тишү; җанны томалау; җанны тунау; җанны турау; җанны тырмау; җанны тырпау (авырттыру); җанны ут көйдерү; җанны ут телү; җанны чуку; җанны яндыру; җелекне киптерү (корыту); йөрәген кырык хәнҗәр белән чәнчү; йөрәк тамырын кимерү; йөрәккә төшү; йөрәкне ашау; йөрәкне әрнетү; кан корыту; мине черетү; сорап теңкәгә тию; тәкатьне алу; теңкә<не> корыту; теңкә-бәгырьне корыту; теңкәгә тию (тиеп алу); теңкәне корытып алу; тешләрне камаштыру; үзәккә үтү (сеңү; төшү); яра өстенә тоз сибү; ярага тоз ишү (салу); шулай ук к.: бавырга боз урнашу.

**АХӘЛГӘ ТӨШҮ** *гади с.* Гайрәт чигү, йөдәү. *Синең бу кыланышлрыңны күреп, ахәлгә төшми калу мөмкинме соң* (Сөйләм).
Төрдәше: бәгырь кибү; йөрәк әрнү 1; йөрәк итен чуку-талау; йөрәк телгәләнү.

*АХ-ВАХ* ❖ **АХ-ВАХ ИТҮ.** Зарлану, сыкрану. *Иренә малай бүләк итәсе, / Яки гаиләне кызчыклы итәсе, /Ах-вах итәләр ике гаилә дә* (А. Нәҗми. Җан һәм кан чакыруы).
Төрдәше: ах-вах килү; аһ-ваһ итү; ух итү.

**АХ-ВАХ КИЛҮ** 1. *к.* ах-вах итү. *– Синең Пирукаң ах-вах килеп сырхауланып ята* (Г. Сабитов. Әйттем – бетте).
Төрдәше: ах-вах итү һ.б.
2. Төрле уңай хисләрне белдерү. *Менә ул, ах-вах килеп, алачыкка атылып чыкты* (Р. Низамиев. Беренче мунча).

**АХ-ВАХ КИЛҮЧЕЛӘР.** Зарланучылар. *[Рөкыя] Сугыш бетә дип ах-вах килүчеләр бар* (К. Тинчурин. Җилкәнсезләр).

*АХ-ЗАР* ❖ **АХ-ЗАР БУЛУ.** Мохтаҗ булу, интегү. *Без аларны иртәнге якта көткән идек, алар исә, ах-зар булып, төшке аштан соң гына килеп җиттеләр* (Сөйләм).

*АХИЛЛ (АХИЛЛЕС)* ❖ **АХИЛЛ (АХИЛЛЕС) ҮКЧӘСЕ.** Кемнең яки нәрсәнең булса да физик яки әхлакый зәгыйфь урыны (ягы).

*Ахиллес үкчәсен генә күрә башлый* (Р. Низами. Яшьлеккә хат).
Төрдәше: йомшак җире; йомшак як (ягы).

*АХИРӘТ* ❖ **АХИРӘТ АЗЫГЫ** *дини.* Фани дөньяда кылган яхшылыклары, изге гамәлләре. *Аны безгә алдан җибәрелгән бер савап кыл, безнең өчен бер ахирәт азыгы, әҗере әйлә, аны безгә шәфәгатьче кыл* (Дога китабы).

**АХИРӘТ ДУСЛАР.** Фани дөньяда да, бакый дөньяда да аерылмаска, ташлашмаска вәгъдәләр куешкан ике сердәш. *Актырнак Сарыбайга кул бирде, бөтенләй ахирәт дуслары булдылар* (Г. Тукай).
Төрдәше: авызга-авыз сөйләшү һ.б.

**АХИРӘТ ЙОРТЫ.** Теге дөнья, бакый дөнья. *Иман китереп, Аллаһуга тәкъвалык кылган кешеләргә ахирәт йорты хәерледер, әллә шуны аңлый алмыйсызмы?* (Ф. Яхин. Коръән).
Төрдәше: бакый бабай бакчасы; бакый дөнья; бакыйлык йорт; мәңгелек дөнья; теге дөнья.

**АХИРӘТ КЕШЕСЕ БУЛУ** *дини.* Үлү, вафат булу. *Хәзрәт үзе ахирәт кешесе иде* (Г. Ибраһимов).
Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

**АХИРӘТ КОШЫ.** Үләр вакыты җиткән, бик бетәшкән. *Чөнки мөселманнар – дөнья кешеләре түгел, ахирәт кошлары* (Г. Исхакый).

**АХИРӘТ КҮЛМӘГЕ.** Беренче кат кәфен. *Икесенең дә сандыгында ап-ак ахирәт күлмәге саклана иде* (Н. Гыйматдинова. Бер тамчы ярату).

**АХИРӘТ КҮЛМӘГЕ КИГЕЗҮ.** Үтерү. *Ниндидер могҗиза белән хан шымчыларының тырнагына эләкми калган Чура морза әле һаман ахирәт күлмәге кигезү турында хыяллана иде* (М. Әмирханов. Гәүһәршад).
Төрдәше: адәм башкайларын салу һ.б.

**АХИРӘТ РИЗЫГЫ.** Һава. *– Ул, ни, бер дә дөнья малын ашамый, ахирәт ризыгы белән генә тукланып тора, – дигән* (Ф. Яхин. Бар бер авыл, Чокал, диләр...).

**АХИРӘТ СӘФӘРЕНӘ КИТҮ** *к.* авыздан җан чыгу. *– Хәзрәтне кыйнап ташладылар... Аз калды – ошбуның сәбәбеннән ахирәт сәфәренә китмәде* (Р. Фәхретдинов).
Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

**АХИРӘТ ТИРМӘНЕ.** Төрле диннәргә караган руханиларның бер үк нәрсәне хуплап сөйләүләре. *Ахирәт тирмәне кору / Ятмый минем күңелгә* (М. Саттаров. Ахирәт тирмәне).

*АХИРӘТИ* ❖ **АХИРӘТИ ДӨНЬЯГА КИТҮ** к. авыздан җан чыгу. *Чөнки изге-илаһи догаларны гына шулай кадерләп тоталар, шулай бирелеп, серле-сихерле, ахирәти дөньяга китеп, онытылып укыйлар* (Г. Гыйльманов. Мөсәллим карт догалары).
Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

*АХИРӘТКӘ* ❖ **АХИРӘТКӘ КИТҮ (КҮЧҮ)** *к.* авыздан җан чыгу. *Күчтең инде дөньябыздан ахирәткә, хуш, песи, / Байлыгың белән иманың, изгелектә күч, песи* (Г. Тукай).
Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

*АХИРӘТТӘ* ❖ **АХИРӘТТӘ АЛДЫҢДА БУЛСЫН.** «Бу дөньяда эшләгән этлекләреңнең җәзасы ахирәттә үзеңне каршы алсын» мәгънәсендә. *Ахирәттә алдыңда булсын* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).
Төрдәше: авыз белән әйт, борын белән тарт һ.б.

**АХИРӘТТӘ АЛТЫН ТӘХЕТ.** «Хөкемдарлык символы булган алтын тәхет гыйшык тоткан кызларга да лаек» мәгънәсендә. *Ахирәттә алтын тәхет / Егет сөйгән кызларга* (Җыр).

**АХИРӘТТӘ ДУҢГЫЗ БУЛЫП КУБАРЫЛУ.** Сүзенең дөрес һәм туры икәнлеген раслау гыйбарәсе. *Ялганласам, ахирәттә дуңгыз булып кубарылыйм менә!* (Х. Мәхмүтов. Изге китаплар кайтавазы).

**АХИРӘТТӘ ИКЕ КУЛЫМ ЯКАҢДА БУЛСЫН** *дини.* Бу дөньяда бурычын ала алмаган кеше теге дөньяда даулап булса да алачагы хакында. *– Юкка борчылма, күрше, ахирәттә ике кулым якаңда булсын* (Сөйләм). *Ахирәттә ике кулым якаңда булсын!* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).

**АХИРӘТТӘ ОЧРАШЫРГА НАСЫЙП ИТСЕН.** Игелекле теләк. *– Ах, дустым, бу дөньяда гына түгел, ахирәттә очрашырга да насыйп итсен* (Сөйләм).
Төрдәше: авыр туфрагы җиңел булсын һ.б.

*АХМАК* ❖ **АХМАК БАШ<ЛЫ>** *гади с.* Акылсыз, аңгыра. *Ләкин аның үзенә генә тапшыру мөмкин*

*түгел иде, ул ахмак башы белән әллә ниләр бутап бетерер дип курыктылар* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).
Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.

**АХМАК БУЛЫП КЫЛАНУ.** Үзен тилемсә итеп күрсәтү. – *Күтле-киреле сүз сөйлә дә тор. Ахмак булып кылана алсаң, бигрәк тә әйбәт* (Ф. Садриев. Бәхетсезләр бәхете).
Төрдәше: башны дивайлыкка салу; башны аңсызга салу; башны диванага салу; башны дураклыкка салу; башны җүләргә (тинтәккә; юләргә) салу; башны миңгерәүлеккә салу; башны тилегә (аңгырага) салу.

**АХМАК<ЛЫК> САТУ.** Юк сүз сөйләү. *Инде социаль челтәрләр ахмак сата башлагач, тыйган идем* («Безнең гәҗит» газ.).
Төрдәше: авыздан куык очыру һ.б.

**АХМАК СҮЗ.** Мәгънәсез сүз. *Миңа калса, мин барлык сүзләрне мәгънәле һәм ахмак сүзләргә бүлеп карар идем* (Сөйләм).
Төрдәше: тузга язмаган сүз.

**АХМАК СҮЗ СӨЙЛӘҮ (ӘЙТҮ).** – *Ахмак сүз сөйләп, кеше көлдереп утырма инде* (Сөйләм).
Төрдәше: тузга язмаганны сөйләү; тузга язмаганны таз укыр; һавадан алып сөйләү; чүбек чәйнәү 1.

*АХМАКЛЫК* ❖ **АХМАКЛЫК САТУ** *к.* авыздан куык очыру. *Иң кызыгы: йорт алдына чыгып, Гыйлаҗиның анасын тотканмын да: «Миңа кызың Гайнияне бир, мин аңа гашыйк булдым, ул тирә-якта бер кыз!» – дип, ахмаклык сатып беткәнмен* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр).
Төрдәше: авыздан куык очыру һ.б.

**АХМАКЛЫК ЭШЛӘП ТАШЛАУ.** Акыл белән аңлый алмаслык эш эшләү. *Мәхәббәтнең күзе сукыр, диләр, йә берәр ахмаклык эшләп ташларсың* (Н. Әхмәдиев. Амбирак).
Төрдәше: кирәкмәс эшләр эшләп ташлау.

*АХМАКНЫҢ* ❖ **АХМАКНЫҢ АХМАГЫ.** Әйләнеп чыккан тиле. *Ахмакның ахмагы Шәңгәрәй аңларлык булгач, нәрсә дип уйлады икән битендәге миңен?* (Т. Гарипова. Мөгри-мөгри килә Бөйрәкәй).
Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.

*АХМАЛЛАРГА* ❖ **АХМАЛЛАРГА ТӨШҮ.** Зарлану, сыкрану; шулай ук к. аһ-зар булу (кубу). *Аның каравы, караңгыда капшангандай итеп, буаз базар сумкасын күтәргән, телен аркасына әйләндереп салып ахмалларга төшкән Соргый абзый үзе кайтып керә* (А. Хәлим. Читтә).
Төрдәше: аһ-зар булу (кубу).

*АХ-УХ* ❖ **АХ-УХ КИЛҮ.** Ахылдау, уфылдау. *Ах-ух килде, иреннәрен ялаштырып алды, үзе сөйләнә бирде* (Ф. Яхин. Ярым килолы кура җиләге).

*АХЫР* ❖ **АХЫР ГОМЕР<ЕНДӘ>.** Соңгы, үләр көннәрендә. *Ахыр гомер мәңге өстегездә / Мәрсияләр көйләп торырмын* (Ш. Бабич).

**АХЫР ҖАН** *кимс., к.* адәм актыгы. *Анасы даһи табиблар китертеп дәва иттермәк үзрә икән, сырхавы каты булып, ахыр җан тәслим кыйлды* (К. Насыйри).
Төрдәше: адәм актыгы һ.б.

**АХЫР ЗАМАН**. 1. *дини.* Дөнья бетәр алдыннан булачак вакыт арасы. *[Салих] Каравыл лапасы алдында, халык, малай, халык анда!.. Ахыр заман, кыямәт!..* (К. Тинчурин. Казан сөлгесе).
Төрдәше: заман ахыры.

2. *куч.* Чамадан тыш тәртипсезлек. *Шуны һәрничек булса да бастырырга тырышыгыз. Югыйсә ахыр заман булыр* (А. Тимергалин. «Миллият» сүзлеге).

**АХЫР ЗАМАН БАЛАСЫ.** Яшенә күрә акылы иртә үскән хәзерге заман баласы. – *Әни, колак биткә кирәме ул, әллә башкамы? – дип, ачыклык керткән ахыр заман баласы* (Т. Нәҗмиев. Тагын... Тагын...).

**АХЫР ЗАМАН КИСӘВЕ** *мыск.* «Әллә кем кебек кыланма» мәгънәсендә. *Мөгез ясаган кеше кебек утырма, ахыр заман кисәве!* (Д. Салихов. Гыйләҗ тәрәзәләре).

**АХЫР ЗАМАН ФЕТНӘСЕ.** Тыңламас, үҗәт кәҗә турында. *Киртә тәбәнәк, киртә аша бик җиңел сикереп үтә инде бу ахыр заман фетнәсе* (Ф. Шәфигуллин. Соңгы кәҗә).

**АХЫР ЗАМАНГА КАДӘР (КАРШЫ; ЗАМАНГАЧА).** Дөньяның ахырына кадәр. – *Кара син, Әхмәт, әле ахыр заманга каршы ниләр чыкты бит дим, – дип, борылып-борылып, тирә-якны карангалый бара иде* (Ф. Әмирхан. Фәтхулла хәзрәт).

**АХЫР КИЛЕП.** 1. Ниһаять, иң актыгында; барысының да нәтиҗәсендә. *Коргак-Күлдә булуын, Биремҗан аксакалга ни өчен килүен сөйләде, ахыр килеп, теге дивана карчыкның – Миндинең таягына тукталды* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).
Төрдәше: ахыр чиктә.

2. Ахырда, соңыннан; бернинди чара калмыйча, бик кирәк булганда (соңгы мөмкинчелек). *Ахыр килеп, корабны яңадан төзек хәленә кайтарып булырмы?* (З. Мифтахов. Яшел планета серләре).
Төрдәше: ахырдан килеп.

**АХЫР СӘГАТЬТӘ.** 1. Иң соңгы мизгелдә. *Иң ахыр сәгатьтә үзенең алып килгән кара алтынлы куш беләзеген яшь бикәчкә бүләк итте* (Г. Ибраһимов).

2. Үлем сәгатендә. *Ахыр сәгатьтә ул оныгын үз янына чакырды* (Сөйләм).
Төрдәше: ахыр сулышында (сулуларында).

**АХЫР СУЛЫШЫНДА (СУЛУЛАРЫНДА).** Үләр алдыннан соңгы тын алулары. *Ахыр сулышында өзгәләнгән: «Сандугачлар... Чишмә... Карурман.., Васыятем аңа тапшырыгыз»* (И. Юзеев. Карурман).
Төрдәше: ахыр сәгатьтә.

**АХЫР<ГЫ> СҮЗ.** Нәтиҗә ясау өчен әйтелгән соңгы сүз. *Ахыргы сүз булсын, кил шушында, / Әйтер сүзләреңне әйтсәнә!* (М. Җәлил). *Ниһаять, аңа ахыр сүз бирделәр. Ул әйтер фикерен табалмый җәфаланды* (А. Хәмзин. Имгәк).

**АХЫР<ГЫ> СҮЗ ИТЕП** *к.* азаккы сүз итеп. *Ахыр сүз итеп: – Иптәшләр, үзеңездәге нәрсәләрне төрле кулларга биреңез, ныграк яшереңез: хәзер тентүләр, тотып ябулар, асу-кисүләр башланыр, – диде* (Г. Ибраһимов).
Төрдәше: азаккы сүз итеп.

**АХЫР ЧИГЕНДӘ** *к.* азак килеп. *Шактый бәхәсләшкәннән соң, ахыр чигендә бу хезмәтне кулланма итеп кабул итәргә булдылар* (Сөйләм).
Төрдәше: азак килеп һ.б.

**АХЫР ЧИККӘ ҖИТЕП.** 1. Тәмам, бик нык. *Туфанның да, ахыр чиккә җитеп, ихтыяры какшый башлаган чаклары була* (Р. Мостафин. Репрессияләнгән татар әдипләре).

2. Түзә алмаслык хәлдә. *Айсылу, ахыр чиккә җитеп: «Артык түзә алмыйм, ялгызлыктан туйдым, колхозсыз тора алмыйм, үзем колхозга керәм», – ди дә, шәлен ябынып, тиз-тиз чыгып китә* (М. Җәлил).
Төрдәше: азак килеп һ.б.

**АХЫР ЧИКТӘ (ЧУТТА)** *к.* азак килеп. – *Ахыр чиктә атаманнары миңа бер сакчы куйган* (В. Имамов. Карабәк).
Төрдәше: азак килеп һ.б.

*АХЫРГА* ❖ **АХЫРГА (АХЫРЫНА) <КАДӘР (ТИКЛЕ; ХӘТЛЕ; ЧАКЛЫ)> ҖИТКЕРҮ** *к.* азакка кадәр. *Илсөярне бизи торган бик матур сыйфат – аның башлаган эшен ахырына кадәр җиткерүе* (Г. Гобәй. Маякчы кызы).
Төрдәше: азакка кадәр һ.б.

**АХЫРГА КАЛДЫРУ** *к.* азакка калдыру. *Мине ул, иң ахырга калдырып, үземне генә кертте* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).
Төрдәше: азакка калдыру һ.б.

*АХЫРГЫ* ❖ **АХЫРГЫ ӘТӘЧ.** Әтәчнең таң алдыннан өченче кычкыруы. – *Мәхәббәт белән уйнамыйлар! Ахыргы әтәч булуың ихтимал* (Ә. Хәсәнов. Әнис алмалар).
Төрдәше: таң әтәче; әтәчнең таң алдыннан өченче кычкыруы.

**АХЫРГЫ ИСӘПТӘ** *к.* актык чиктә. *Ләкин ахыргы исәптә адәмнәр аларның изгелеген таныячак* (А. Тимергалин. Фәтхулла хәзрәтләре).
Төрдәше: актык чиктә.

**АХЫРГЫ МӘРТӘБӘ (ТАПКЫР)** *к.* азаккы мәртәбә (тапкыр). *Бу аның үз гомерендә беренче һәм ахыргы мәртәбә әйтә алган бердәнбер фәлсәфи сүзе иде* (М. Галәү. Мөһаҗирләр).
Төрдәше: азаккы мәртәбә (тапкыр) һ.б.

**АХЫРГЫ СУЛЫШ (СУЛУ)** *к.* азаккы сулыш (сулу). *Аның ахыргы сулышы күкеле сәгатьнең җиденче мәртәбә тавыш бирүенә туры килде бугай* (Сөйләм).
Төрдәше: азаккы сулыш (сулу) һ.б.

**АХЫРГЫ СУЛЫШ (СУЛУ) АЛУ** *к.* авыздан җаны чыгарга тору (җитешү). – *Урта ишекне каты итеп яп. Ахыргы сулышларымны сулыйм мин, кызым* (Н. Гыйматдинова. Мәхәббәттә гөнаһ бар). *Беләм, минем җаным ахыргы су-*

*лыш алуымда җәннәткә җитә* (Н. Абдулкаримова. Джордано Бруно).
Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

**АХЫРГЫ СУЛЫШКА (СУЛУГА) КАДӘР (ХӘТЛЕ)** *к.* азаккы сулышка (сулуга) кадәр (хәтле). *Ярату – ахыргы сулышка кадәр тугры калган синең карар ул* (glagolitsa-rt.ru).
Төрдәше: азаккы сулышка (сулуга) кадәр (хәтле) һ.б.

**АХЫРГЫ ЧИК** *к.* актык чик. *Ә хәер сорашу – ахыргы чик!* («Безнең гәҗит» газ.).
Төрдәше: актык чик.

**АХЫРГЫ ЧИККӘ** *к.* актык чиккә кадәр. *Көне буе рәхимсез эссе Кавказ кояшы астында пешеп ахыргы чиккә кадәр талчыккан кызылармеецлар кайсы котелок, кайсы пилотка белән су эчәргә тотынды* (Ә. Галиев. Һәр солдатның үз уе).
Төрдәше: актык чиккә кадәр.

**АХЫРГЫ ЧИККӘ ҖИТҮ** *к.* актык чиккә җитү. *Хәзрәт ахыргы чиккә җитте. Куллары, тезләре бушап, калтырана башлады, хәтта мендәрләре янына барырлык та хәле калмады* (Г. Мөхәммәдова. Яшьлек көннәре).
Төрдәше: актык чиккә җитү.

*АХЫРГЫСЫ* ❖ **АХЫРГЫСЫ БУЛСЫН** *к.* азаккысы булсын. Башка кабатланмасын, соңгы мәртәбә булсын кебек кисәтү. *[Ләйлә] Ялган барыбер бер беленә ул. Бу – ялганнарның ахыргысы булсын* (Илһам канатында. 2 нче кит.).
Төрдәше: азаккысы булсын һ.б.

*АХЫРГЫСЫ-СОҢГЫСЫ* ❖ **АХЫРГЫСЫ-СОҢГЫСЫ БУЛСЫН** *к.* азаккысы булсын. *Бу бүгенге кыенлыкларның ахыргысы-соңгысы булсын иде* (Сөйләм).
Төрдәше: азаккысы булсын һ.б.

*АХЫРДАН* ❖ **АХЫРДАН АХЫР.** Ахырның да ахырында, соңгы чиктә. *Ләйсән ахырдан ахыр чыгыш ясаучы булып калды* (Сөйләм).
Төрдәше: ахырларның ахырында.

**АХЫРДАН <КАРАГАНДА; САНАГАНДА> БЕРЕНЧЕ** *ирон., шаярт., к.* азактан санаганда беренче. *Шулай итеп ахырдан беренче төркемдәгеләргә мең сум, икенчеләренә бишәр йөз тәңкә акча өләшеп чыкты* («Татар заманы» газ.).
Төрдәше: азактан <санаганда> беренче һ.б.

**АХЫРДАН КИЛЕП** *к.* ахыр килеп 2. *Ул, башта берничә җиргә кагылып та, ялгызы гына, зур муаффәкыять казана алмагач, ахырдан килеп, Камиләгә бәйләнде* (Г. Ибраһимов).

*АХЫРЛАРНЫҢ* ❖ **АХЫРЛАРНЫҢ АХЫРЫНДА** *к.* ахырдан ахыр. *Нә исә ахырларның ахырында сукыр тычканнар берсе артыннан берсе җир өстенә чыгып...* (Г. Тукай).
Төрдәше: ахырдан ахыр.

*АХЫРЫ* ❖ **АХЫРЫ БУЛСЫН!** Берәр эшне яки хәлне башка кабатларга ярамаганлыгы хакында кисәтү. *[Тимерхан] Иштең ишәк чумарын! Ахыры булсын! Моннан мин сине яшьләр мәҗлесенә алып килсәм, ир булып та йөрмим!* (К. Тинчурин. Беренче чәчәкләр).

**АХЫРЫ ХӘЕРЛЕ БУЛСЫН!** Көтелмәгән берәр хәл килеп чыкканда, уңай теләк рәвешендә әйтелә. *Мөмкин түгел, әлегә кадәр күңеле тарткан хатын-кызны очратканы булмады, ахыры хәерле булсын* (М. Хәбибуллин. Атилла).
Төрдәше: авызыңа бал да май, алды-арты хәерле (хәерлегә; яхшы) булсын (була күрсен)! һ.б.

*АХЫРЫН* ❖ **АХЫРЫН ИСӘПЛӘҮ.** Нәрсәнең дә булса нәтиҗәсен уйлау, аны ачыклау. *[Гомәр] <...> һәр эшнең ахырын исәпләргә кирәк, соңыннан эш узгач үкенүдә файда булмас* (Г. Камал. Өч бәдбәхет = Уйнаш). *Кеше сүзен тыңлап, аңа ярдәм итәр өчен вакытыңны, күңелеңне, көчеңне бирәсең, ә ул, бу гамәлеңнең ахырын исәпли-исәпли ахмаклыкка башын катыра* (Ф. Яхин. Умырзая: Озакка сузылган үлем).

*АХЫРЫНА* ❖ **АХЫРЫНА ҖИТКЕРҮ.** Төгәлләү, эшләп бетерү. *Беркемне дә тыңламагыз, үзегез уйлаганны ахырына җиткерегез!* (Ә. Галиев. Җимерелгән хыяллар). *Илдәге соңгы көннәрнең баш әйләндергеч вакыйгалары аны ахырына җиткерүгә киртә була* (Г. Баттал. Казан төркиләре).

**АХЫРЫНА ЧЫГУ** *к.* азагына чыгу. *Ләкин бу эшнең ахырына чыгар өчен, күп көч түгәргә, йокы калдырырга, аш вакытын истән чыгарып, онытылып эшләргә туры килде* (Г. Кутуй. Тапшырылмаган хатлар).
Төрдәше: азагына чыгу.

*АҺ* ❖ **АҺ БУЛУ.** Дулкынланулы, хисләргә тулы. *Гашыйкларның күңелләре гел аһ булыр,/*

*Шул аһларны гаеп итү гөнаһ булыр* (Г. Мөхәммәтшин).
Төрдәше: авызында ашы, күзендә яше һ.б.

**АҺ! ДИГӘНЧЕ.** Бик тиз, шул ук мизгелдә. *А һ дигәнче, мүкле ташны тырнап, / Упкынга оча, / бушлыкка оча* (Г. Афзал).
Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**АҺ! ДИП СУЛЫШ АЛУ.** Борчулы, кайгы-хәсрәтле булу. *«А һ!» дип тирән сулыш алгач, Гаҗилә болдырга менеп китте* (Ә. Гаффар. Богау).

**АҺ ДИЯРГӘ ДӘ ӨЛГЕРМӘҮ.** Бик тиз арада булу. *Кыз а һ диярг ә д ә өлгермәде, ике кулыннан тотып, машина эченә утырттылар* (Сөйләм).
Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**АҺ ИТКӘН.** Сокланган, гашыйк булган. *[Шаһтимер] Сөенегез, Хәмдия өчен а һ иткән егетләр* (М. Фәйзи. Ак калфак). *Сугышта йөргәндә, ул Украинадагы бакчаларны күреп а һ иткән иде* (Ф. Яруллин. Соңгы балкыш).

**АҺ ИТҮ.** 1. Кайгыру, борчылу. *«Шәмсетдин дус, – диде, – шул Нәфисә тәмам башымны әйләндерде бит, – диде, – ашаганым аш түгел, йоклаганым йокы түгел, ышан, – диде, – аягүрә төш күреп йөрим», – диде. Егетем а һ итә* (А. Шамов. Кыз урлау). *Син юк инде, күптән юк, / Үпкәләп а һ иткән юк* (М. Әгъләм).
Төрдәше: аһ ору; аһ-ваһ итү 1; аһ <та>-ваһ кылу 1; әләм чигү; баш кату 4; башка ут кабу 1; башны кайнату; елан кебек чагу; җан ачу (ачыру; ачыту); җан көйдерү; җан көю; җан сызлану; җанга тию; җанга төшү; җанга ут җибәрү; җанны борча ашау; йөз сулу; йөзгә кара коелу 2; йөрәк әрнү; йөрәк урынында булмау (түгел); күңел газабы; күңел газаплану; күңел даруы; күңел җәрәхәте; күңел кытыклану 1; күңел пырдымсызлану; күңел сызлану; күңел сызу; күңел тынычлыгын бозу; күңел тырнау; күңел уйнаклау; күңел уйнау 1; күңел урында булмау; күңелгә кагылу; күңелгә кайгы салу; күңелне җәрәхәтләү; күңелне тырнап тору; ут йоту; ут йотып йөрү; ут йотып яну; утта тору; үзәкне өзү; үзәккә үтү (сеңү; төшү); хәсрәт йоту; хәсрәт кочагында бөгәрләнү; хәсрәт тарту; хәсрәт уты йоту; хәсрәт утында яну; хәсрәт чигү; хәсрәткә бату; хәсрәткә салу; хәсрәткә төшү; хәсрәтне эчкә йоту 1; эч көю; эч кытыклану; эч пош<ыр>у; эч тырнау; эч <ут> яну; эче-тышы сарыга манчылу; эчкә пошаман төшү; эчкә салкын йөгерү 1; эчкә ут йөгер<т>ү (кабу); эчкә ут салу; эчкә ут төшү; эчне кара мәче тырнау; эчне каралы-аклы мәчеләр тырнау; эчне кимерү; эчне кыру; эчне мәче кимерү; эчне өзү; эчне пошыру; эчне яндыру; эчтән корт кимерү (талау); эчтән сызу; эчтән яну.

2. Соклану, шаккату. *Яр өстенә тезелешеп баскан бичаралар да, Туктамышка ияреп килгәннәр дә – һәммәсе аһ итте* (В. Имамов. Карабәк). *Менә бүлмәдәге егермеләп пар күз миңа төбәлде, кызлар кулымдагы чәчәкләрне күреп а һ иттеләр, егетләр терсәкләре белән берберсенә төртешеп куйдылар* (Х. Ширмән. Ерактагы йолдызым).
Төрдәше: авыз ачу 7 һ.б.

**АҺ ОРУ.** Өзгәләнү, бик нык кайгыру. *Шунда уйларсың, бу шагыйрь бушка а һ орган, диеп* (Г. Тукай). *...Мин бит монда бер яшәгән идем, / Мәгарәдән чыктым, а һ ордым* (Зөлфәт. Яшәгән идем...).
Төрдәше: аһ итү һ.б.

*АҺ-ВАҺ* ❖ **АҺ-ВАҺ ИТҮ.** 1. Кайгыру, борчылу. *Әйе, күпме генә а һ - в а һ итсәм дә, бу ике кешенең берсе син идең* (Г. Кутуй. Тапшырылмаган хатлар).
Төрдәше: аһ ору һ.б.

2. Нык ашыгудан яки арудан хәлсезләнү. *Көндезгә сәгать уннар тирәсе булгандыр, бер көтмәгән җирдән, әтинең район үзәгендә үз гаиләсе белән тормыш кичерүче сеңлесенең 19 яшьлек кызы Әнүзә апа, а һ - в а һ итеп, безгә килеп керде* («Туган як» газ.).
Төрдәше: аһ <та>-ваһ кылу 2; аяк атлар хәл (дәрман; көч; рәт; чама) юк (булмау; калмау); аяк бетү; аяк калмау; аяк эштән чыгу; аяксыз калу; аяктан егылу; аяктан егылырдай булу; аяктан егылыр хәлгә (чиккә) җитү; аяктан калу (язу); җеп өзәрлек дәрман (хәл) <дә> калмау; табаннар таш булу; ух итү; хәлдән таю; хәлдән төшү; эт булу (булып бетү); эт булып ару; эштән чыгу 3.

**АҺ <ТА>-ВАҺ КИЛУ** 1. *к.* аһ ору. – *Харап итәсез! Товарны бозасыз! – дип а һ т а в а һ к и л е п, арбаларны капларга тотынды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Төрмә хастаханәсендә төрле чирләрдән а һ - в а һ киләләр: берсе бавыры белән бөгәрләнеп сызлана, икенчесе йөрәгән*

*тота, өченчесенең ашказаны бозык, дүртенчесе бөер белән иза чигә* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).
Төрдәше: аһ ору һ.б.

2. *к.* аһ-ваһ итү 2. *Чуар тавык, чебешләрен генәияртеп, аһ-ваһ итеп кайтып керде* (А. Алиш).
Төрдәше: аһ-ваһ итү 2 һ.б.

3. Уңай хисләр тою. *Шәехзадә Бабич белән дуслашып китүләре дә шуннан килә иде булса кирәк, чөнки Бабич юмористик, сатирик әсәрләрен укыганда, шәкертләр, аһ-вах килеп, эчләре катканчы бер көлеп алалар иде* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

**АҺ-ВАҺ КИТЕП СӨЙЛӘНҮ.** Кайгырып-хәсрәтләнеп сөйләү. *Юл буе диярлек хатынына аһ-ваһ китеп сөйләнеп барды* (Д. Булатова. Соң түгел!).

*АҺ-ЗАР* ❖ **АҺ-ЗАР БУЛУ (КУБУ).** Ниндидер фаҗыйгадан зарлану, кайгыру-хәсрәтләнү. *Тормыш турында гына сөйли башлаган иде, тыңлаучылар җанланды, аһ-зарлар купты* (Сөйләм).
Төрдәше: зар булу.

*АҺ-ЗАРСЫЗ* ❖ **АҺ-ЗАРСЫЗ ЕЛАУ.** Зарланмыйча, тавыш-тынсыз гына елау. *Һаман көтте, кешеләргә белдерми генә, аһ-зарсыз, кан-яшьсез генә елады* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).

*АЧ* ❖ **АЧ ӘРВАХ.** 1. Ябык, ач кеше. *Чиркәү яннары, мәйданнар хәер сорашып утыручы гарип-гораба һәм ач әрвах белән тулы* (В. Имамов. Утлы дала).
Төрдәше: авыз ачса, кече теле күренү; авызын ачса, үпкәсе күренү; ач яңаклы; ачар бак; әрвахка охшаган; әрем ышыклары да юк <бит, ичмасам>; бер карга туярлык ите юк; борын гына утырып калу; борыннан кыссаң (тотсаң), җаны чыгарлык (<очып> чыгарга тору); борынны кыссаң, җаны күккә очу; борыны гына утырып калган; дуңгызны койрыгыннан йоту; дуңгызны төге белән бергә йоту; ите бетеп, сөяккә калу; йөз сулу; кабырга араларына карга ояларлык; кабырга арасыннан җил йөрү; кабырга беленү; кабырга кабыргага <терәлеп кенә тору>; кабыргасы күренеп тору; кабыргасы саналу (саналып тору); как сөяккә калу; кипкән балык; коры гәүдә калу; коры сөяккә калу; корып кипкән; сөяк патшасы; сөяк сарае; сөяк тә тире; сөяккә калу; танавы гына тырпаеп калу; тәнендә карга чукырлык та ите юк; элеп киптергән кебек; энә йоткан; эче эчкә ябышкан; эченнән инә үтәрлек.

2. Туя белми торган, комсыз кеше. *Бер ач әрвах җиңгәсе бар, / Бер салмалык он сорый* (Такмак). *Элек гомер буе байлар абзарында ат карауч булып йөргән бер ач әрвах* (В. Имамов. Тозлы яра).
Төрдәше: ач бәбәк; ач бет 1; ач күз<ле> 2; ач кернә.

**АЧ БӘБӘК.** Туймас, комсыз. *<...> үзләренә үлем җәзасы янаудан курыкмыйча, бәлагә юлыккан әсирләрне ач бәбәк тырнагыннан йолып алу чарасын табалар иде* («Казан утлары» ж.).
Төрдәше: ач әрвах 2 һ.б.

**АЧ БЕТ** *тупас, ирон.* 1. Ачлы-туклы яшәүче, фәкыйрь, ябык кеше турында. *[Кәрим] Кем белән сөйләшкәнебезне бик яхшы беләбез, ач бет! Хәерче!* (Г. Камал. Хафизалам, иркәм).
Төрдәше: ач әрвах 1 һ.б.

2. Күп ашаучан, туймас тамак; комсыз. *Таш күңелле, рәхимсез һәм ач бет күзле, / Сәнәк төсле куллар белән тартты-өзде* (Б. Мирзанов. Сулган чәчәк).
Төрдәше: ач әрвах 2 һ.б.

**АЧ БУЛСАҢ, ТУЕП (АШАП) КИЛ!** Берәрсе тыштан ишек шакып, «ач!» дигәндә әйтелә торган шаян җавап. *[Сабах] Ягез инде, кызлар, ишекне ачыгыз! [Римма] Ач булсаң, туеп кил, бер янчык акча алып кил!* (Р. Зәйдулла. Саташкан сандугач).

**АЧ БҮРЕДӘЙ**. Комсызланып, ач күзләнеп. *Килеп җитәрләр дә, ач бүредәй комсызланып, ярга ташланырлар иде* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).
Төрдәше: ач күзләнү.

**АЧ ЙӨРӘК.** Ашамаган-эчмәгән хәлдә булу. *Башкалар, җыелып, үлгән мәче баласына карыйлар. Ач йөрәк куркудан ярылып чыга язды* (Һ. Такташ). *Кәнфит урынына тешләп кенә кабасың да, тагын йөрәк ач* (С. Сөләйманова).

**АЧ КАНДАЛА КЕБЕК <ЯБЫШУ>.** 1. Тамак ач булудан, ашыга-ашыга ашый башлау. *Ул ике әйттереп тормады, ач кандала кебек, тиз генә коймакка ябышты* (Сөйләм).

2. Берәрсенең үзенә ярдәмче булачагын белеп (яисә нәрсәдер алырга теләп) бер адым

да калмаска. *«Би-Би-Си»не тыңлый / Көмеш кебек зәңгәр кичләрдә. / Ач кандала кебек сырыша иде / Чит илләрдән килгән утильгә* (Г. Афзал).

3. Кешегә ябышып талашу. *Башка малайларның да әчеләве җиткән, күрәсең: ач кандала кебек ябыштылар* (М. Әмир. Үсә төшкәч).

**АЧ КАРЫН<ГА (КАРЫНЛАЙ)>.** Ашамаган-эчмәгән килеш. *Йосыф башын чайкады, һичнәрсәгә исе китмәде, бирсәләр ашады, бирмәсәләр, ач карынга ятып йоклады* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: ач килеш.

**АЧ КАРЫНГА ӘЧЕ ИКМӘК.** Бик мохтаҗ булган әйбернең нәкъ кирәк вакытында кулга төшүе. *Ничек кенә дисәк тә, безнең ул минуттагы ач карынга әче икмәк булды ул* (Ф. Хөсни).

**АЧ КАРЫНГА САРЫМСАК.** Көтелмәгән күңелсезлек. *Бер атнадан ач карынга сарымсак булып яңа хәбәр ишетелде – кич белән өенә кайтканда, абыйны машина бәргән икән* (Сөйләм).

**АЧ КЕРНӘ** *к.* ач әрвах 2. *Бер әйбер калыр хәл юк, ач кернә балаларына кертә дә тыгындыра* (М. Гафури).
Төрдәше: ач әрвах 2 һ.б.

**АЧ КИЛЕШ** *к.* ач кары<нга> (карынлай).*Чыннан да, эт көнозын ач килеш куышта бикләнеп ята икән ич...* (Г. Гобәй. Маякчы кызы).
Төрдәше: ач карынга (карынлай).

**АЧ КӨЕНЧӘ КОС<ТЫР>У.** Берәрсенең мәгънәсез, күңел болгаткыч, тозсыз мәзәкләр сөйләвенә ишарә. *Юк, үзегез генә барыгыз инде, анда барып, ач көенчә костыра торган мәзәкләрен тыңлап утырасым килми* (Сөйләм).

**АЧ КҮЗ<ЛЕ>** 1. Ябык кешенең эчкә баткан күзләре турында. *Ертык күлмәкле, ябык, кара сары йөзле, нурсыз ач күзле бер киленчәк керде* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).

2. *к.* ач бәбәк.– *Ач күзле иде элек халык, нәрсә очратса, шуны, әрлән төсле, үзенең өенә тарттыра, «чү, бу кешенеке», «чү, илгә булсын» дими* (Ф. Хөсни. Тынгысыз кеше). – *Әниләре кем? Кара бай кызы! Ач күз!* (Г. Әпсәләмов. Күк күкрәр).
Төрдәше: ач әрвах 2 һ.б.

3. *күч.* Кайбер табигать күренешләрен чагыштыру. *Бу Идел бигрәк ач күзле, һичбер вакыт туя белми* (Г. Тукай).

**АЧ КҮЗЕҢНЕ, ДӨНЬЯ БУ.** «Булмаганны сөйләмә әле, күзеңне ачыбрак тирә-ягыңа кара» мәгънәсендә. *Ләкин... ач күзеңне, дөнья бу – кемгә михраб, кемгә нинди михнәтләр әзерләп куелгандыр бит әле* (Р. Низами. Сәйдәшнең соңгы елы).

**АЧ КҮЗЛӘНҮ.** Комсызлану, туймастай кылану. *«Нигә нужалана инде бу карчык?» – дип уйлаучылар да, «һаман да җитмәс икән, ач күзләнү җүнлегә илтми ул!» – дип әйтүчеләр дә табыла араларында* (Р. Газизов. Күккә ябышкан болыт).

**АЧ КҮЗЛЕЛЕК.** Комсызлык. *Ул күренмәкче була инде тамагы тук кеби, / Күп ашау, ач күзлелек бер дә үзендә юк кеби* (Г. Тукай).

**АЧ ОРЛЫК.** 1. Башаклы үсемлекнең орлыгы җитешеп бетмәү. *Өскә йөзеп чыкканнарны алып ташлыйм: алары ач орлык була аның* («Сөембикә» ж.).

2. *күч.* Тәне җитешмәгән кешене охшату. *Машинада утырганы – җитешергә өлгермәгәне бер ач орлык шунда* (Сөйләм).

**АЧ ТАМАГЫҢ – ТЫНЫЧ КОЛАГЫҢ.** «Ач калсам да, күңелем тыныч» мәгънәсендә. *Аларга, туган авылларыннан чыгып, «читтә» яшәгән ике дуска, ач тамагым – тыныч колагым, рәхәт, күңелләре көр – шунысы мөһим* (А. Хәлим. Читтә).

**АЧ ТАМАК.** Ач кеше. *Казакълар гаҗәпләнеп баш кактылар, аннары Дорды белән килешеп, дөрес шул, тамак яман нәрсә, ач тамак барысын да, хәтта өзелгән аякны да оныттыра, диешteләр* (Ә. Еники. Без дә солдатлар идек).

**АЧ ТӘКӘББЕР** *ирон.* Хәерче булса да, горурлыгын югалтмау турында. *Теге ач тәкәббер, акчасы булмаса да, таксига утырып йөргән була* (Сөйләм).

**АЧ ҮЗӘГЕ ӨЗЕЛҮ.** Иң нечкә җиргә тәэсир итү. *Егетнең бу сүзләреннән соң аның ач үзәге өзелеп китте* (Сөйләм).
Төрдәше: ач үзәкне өзү; йөрәк бәгырен өзү.

**АЧ ҮЗӘКНЕ ӨЗҮ** *к.* ач үзәге өзелү. *Суда сусар йөзәдер, / Су салкынын сизәдер; / Кашын-күзен мимылдатып, / Ач үзәгем өзәдер* (Жыр).

**АЧ ҮЛЕМ.** «Даими рәвештә җанга каныккан үлем» мәгънәсендә. *Ач үлем аларга да якынлашып килә иде* (М. Галәү. Болганчык еллар).

**АЧ ҺӘМ ЯЛАНГАЧ.** Ашарына да, кияренә дә булмаган кеше турында. *Афина / Җылы нур сипсә дә Күкләп, / Ач һәм ялангач күпләр...* (И. Юзеев). *Туңып беткән бабай белән / Эткәенә аның ни калган? / Икесе дә ач һәм ялангач – / Как сөяк тә бары ми калган* (Ф. Зыятдинов. Безнең гомер).

**АЧ ЧИКЛӘВЕК.** 1. Бик кечкенә төшле яки буш чикләвек. *Кызык әйткәннәр, тук чикләвек, ач чикләвек* (Ш. Галиев).

2. *күч.* Эчтән буш кеше. *Кыз, күзен бераз кысты да, «нәрсәгә кирәк миңа ул ач чикләвек» дип, башын читкә борды* (Сөйләм).

**АЧ ЭТНЕҢ АРТЫН ТУК ЭТ ЯЛЫЙ** *дорфа.* Хәлле кешенең яки берәр түрәнең мохтаҗ кешедән ришвәт соравы. *«Ач этнең артын тук эт ялый» дигән сүз дөрес икән, дип уйлап куйды ул мөдир ярдәмчесе бүлмәсеннән чыкканда* (Сөйләм).

**АЧ ЯҢАКЛЫ.** Ябык, яңаклары эчкә баткан. *Ач яңаклы шәкертнең бу сүзләре Әүхәдинең йөрәгенә ябышты, аны сызлатты* (К. Тинчурин. Мәрҗәннәр). *Базарның урта бер җирендә зур фанерга ач яңаклы, таза беләкле кеше рәсемен ясап куйганнар* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

Төрдәше: авызын ачса, кече теле күренү һ.б.

*АЧАЛАК-ЙОМАЛАК* ❖ **АЧАЛАК-ЙОМАЛАК БУЛУ (КИЛҮ; ТОРУ).** 1. Көннең бер аяз, бер болытлы булуы. *Бүген ни яумый, ни ачылмый, ачалак-йомалак була да тора* (С. Рәхимов).

2. Йокыдан (яки исерткеч эчемлектән соң) айнып житмәү. *Егетнең ачалак-йомалак торган күзләре бердән ачылып китә* (М. Фәйзи).

3. Челт-челт ачылып ябыла торган күзләр турында. *Аның челт-челт итеп, ачалак-йомалак килгән күзләре нindидер уенчыкны хәтерләтә иде* (Сөйләм).

4. *күч.* Кеше белән ачуланышып, бер ачык чырайлы, бер караңгы чырайлы йөрү. *Шулай итеп, ачалак та йомалак булып йөри торгач, ахырында аңлаштык* (С. Рәхимов).

**АЧАЛАК-ЙОМАЛАК ЙӨРҮ** *к.* авыз ачып бару (йөрү). *Ачалак-йомалак йөрмәсен, күзен ачып карасын иде. Дүрт күз белән карасаң да таманга килә дөньяда* (Б. Камалов. Өметең өзелмәсен).

Төрдәше: авыз ачып бару (йөрү) 3 һ.б.

*АЧАМАЙ* ❖**АЧАМАЙ КИЛҮ** *диал.* Уңай бармау, кирегә килү, комачаулау (эш турында). *Бу эшне бер атнада бетерербез дип уйлаган идек, кем уйлаган аны ачамай килеп чыгар дип* (Сөйләм).

*АЧАР* ❖ **АЧАР БАК** *к.* ач әрвах 1. *Безнең авылда ачар баклар бар* (Ә. Фәйзи).

Төрдәше: ач әрвах 1 һ.б.

*АЧАРБАКЛАНЫП* ❖ **АЧАРБАКЛАНЫП АШАУ.** Комсызланып ашау (тыгыну). – *Син нәрсә ачарбакланып ашыйсың, атна буе ризык күрмәдеңме әллә?* (Сөйләм).

*АЧКА* ❖ **АЧКА КАКЛАНУ.** Ачыгудан ябыгу, кибү. *Анда ачка какланып ятма* (С. Кудаш). *Кайсысыннан ярыйсы гына канәгать булып, кайсыларыннан игътибарсызлыкка гаҗизләнеп, ачка какланып кайткан еллары да булды* (Ә. Салах. Каеннар юлы).

Төрдәше: ачка киселү; ачка койрык чәнчеп йөрү (яту); ачка тук.

**АЧКА КИСЕЛҮ** *к.* ачка каклану. *Илдә чыпчык үлми дигәндәй, безнең Бәдретдин дә, бик интегеп, ачка киселеп булса да, укуын әнә шулай алып бара иде* (Ә. Еники. Матурлык). *Миңгата абзый Хәсәншин, ачка киселгән сигез баланы кабат арбасына утыртып, авылга кайтырга чыга* (Ә. Салах. Аккан сулар...).

Төрдәше: ачка каклану һ.б.

**АЧКА КОЙРЫК ЧӘНЧЕП ЙӨРҮ (ЯТУ).** Карын ач булу. *Син ачка койрык чәнчеп йөргәндә, миндә сохарилар була торган ие* (И. Юзеев. Онытылмас бәет). *Мең чакрым юл үтеп кил дә ачка койрык чәнчеп ят менә!* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).

Төрдәше: ачка каклану һ.б.

**АЧКА ТУК** *ирон.* Даими ач, ачлыктан интеккән. *Шонкар бу мизгелне иртәдән бирле көтә инде. Көтмичә теге ачка тук булып йөреп кара әле син* (М. Әмирханов. Ир-Мамай). *Аның да минем шикелле «ачка тук» булып йөргәне әллә каян ук сизелеп тора* (Ш. Маннур. Агымсуларга карап).
Төрдәше: ачка каклану һ.б.

*АЧКЫЧ* ❖ **АЧКЫЧ ТАБУ.** Якын килү, мөнәсәбәт кору өчен уңай юл табу. *Күрше авылда торып урман чыгарганда, бу егет моңа «ачкыч» тапкан* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә). *<...> татарчасына җавап булмаса, русча частенә, командирына язачакмын, ләкин хәзергә мин бер нәрсәдә бик канәгать калдым: күңелендә уянган шундый саф өметен бала миңа ышанып әйтә икән, димәк, мин аның күңеленә ачкыч тапканмын* (Ф. Хөсни. Без яшь идек...).

*АЧМАГАН* ❖ **АЧМАГАН ИШЕГЕ, КЕРМӘГӘН ТИШЕГЕ (УРЫНЫ) ЮК.** Үткен, әрсез кеше хакында. – *Акланыр. Аның бит, Искәндәр абый, ачмаган ишеге, кермәгән тишеге юк, диләр, – диде Илдар, нәфрәтен баса алмаган Револь сүзенә куәт өстәп* (Г. Үзиле. Гыйфрит).

*АЧУ* ❖ **АЧУ АКЫЛ КИТӘРҮ.** Ярсу хисе өстенлек иткәндә, акыл эшчәнлегенә зыян килү. *Ачу акыл китәрәме әллә? – / Күзләр күрми, колак ишетми* (Ш. Маннапов. Багана юл).

**АЧУ АЛКЫМЫНА ҖИТҮ.** Ачуына буылу, ачу бугазга кадәр җитү. *Түзде, тешләрен кысып булса да түзде, әмма ачуы алкымына җитте* (Сөйләм).

**АЧУ АЛУ.** Әшәкелек эшләгән кешегә җавап йөзеннән әшәкелек эшләү. *[Бакый] Сәлим мирзадан синең ачуыңны алырга вакыт көтәрмен* (М. Фәйзи. Ак калфак). *Биш-ун минут шулай утырганнан соң, мин күз яшьләремне сөрттем дә ачу алу кайгысына төштем* (Ф. Әмирхан. Нәҗип).
Төрдәше: ачу кайтару; ачу куу; ачу түгү 2; йөзе белән кайтару 1; үч алу; үч кайтару; үч куу.

**АЧУ БАСЫЛУ**. Тынычлану. *Сөекле Гарифҗанын исенә төшерсә, ачуы басыла* (К. Фәсәхов). *Йә, нишләргә? Дамирны изеп ташларгамы (ичмасам, ачу басылыр), әллә Равия белән араны өзәргәме?* (Н. Гыйматдинова. Аргы очта, бирге очта).

**АЧУ БҮРТЕЛҮ.** *Күрәсең, аның ачуы бүртеп, тиресен кабарткан иде, кизәнгәндә, костюм җиңе шытырдап ертылды* (Н. Гыйматдинова. Нурулла).
Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

**АЧУ ДАВЫЛЫ.** Кемгә-нәрсәгәдер көчле ачу хисе туган вакыт. *Ачу давылында күтәрелгән / Хыялымны сездән яшермим...* (Ф. Кәрим). *Кушаев читкә борылды, чыраенда дәһшәт, ачу давылы, Иван да ни кылырга белми иде* (Х. Камалов. Үксезләр).

**АЧУ ИТҮ.** 1. *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. *Башым алып олагамын мин дачага, / Ачу итеп кода белән кодачага* (Г. Афзал. Утырышу).
Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

2. Үч алырга теләк туу, үчләнү. *Сиңа ачу итеп урлагандыр инде* (З. Хәким. Очраклы очрашу). *Рәдиф үзе шуны әйтте: «Сәкинәңә ачу итеп, сине минем урынга куясы булганга үч итеп кенә алдаштым мин», – ди* (В. Нуруллин. Күпер чыкканда).
Төрдәше: күңелендә таш итеп йөртү; күңелдә төен (төер) калу; теш кайрау 1.

**АЧУ ЙОТУ (ЙОТЫП КАЛУ).** Беркемгә дә ачуын белдермичә, эчендә саклау. *Чын ир өчен сабыр итү күп артык, / Ачуың йот, аңа син катмачы ук* (Г. Утыз Имәни. Сабыр итү турында). *Ачу йоту – тау йоту, диләр* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).
Төрдәше: ачуны эчкә йоту.

**АЧУ КАБАРТУ.** Ачу хисе арту. *Аның сүзләре һәрвакыт Газинурның ачуын кабарта иде* (Г. Әпсәләмов. Газинур). *Менә әле дә төрле кыяфәттә булган хатын-кыз рәсемнәре ачуын кабартты аның* (К. Кара. Депрессия).
Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

**АЧУ <БОЛЫТЫ> КАБАРУ.** Бик нык ачу хисе кузгалу һәм арта бару. *Аның бөтен йөзе, колаклары ут эчендә янган хәлдә, ни дип җавап бирергә белмичә, башын иеп тик торуы генералның ачуын тагын да кабарта төште* (М. Әмир). *Василийның Санькага ачуы кабарганнан-кабара, кайчагында, буылыр хәлгә җитеп, аны сүгә башлый, каргый, ләгънәтли* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).
Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

**АЧУ КАБЫНУ** *к.* аыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2. *Гасыйм Сәләховичның эчендә кинәт дөрләп ачу кабынды* (Ә. Еники. Тынычлану). *Ахырда, кинәт ачуы кабынып китеп, барлык көче белән көзгегә сукты* (Х. Сарьян).
Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

**АЧУ КАЗАНЫ ТАШУ.** Каты ачулану, нәтиҗәдә төрле явызлыклар эшләргә сәләтле булу. *Өтермәннән кайтышлый, ялгыш тәрәзәсен ваткан иде малай, шуңар ачу казаны ташыгандыр убырның* (Н. Гыйматдинова. Күке төкерегә).
Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

**АЧУ <КАЗАНЫ> КАЙНАУ**. Каты ачулану (яки ачу килү)халәте дәвам итү. *Эчемдә бөтен туклар дөньясына ачу кайный* (Г. Ибраһимов). *Эчләрендә гел ачу кайный, нервлары бик тартылган, юктан да ызгышып китәргә әзер торалар* (Ә. Еники. Без дә солдатлар идек).
Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

**АЧУ КАЙТАРУ** *к.* ачу алу. *Яки кайбер әдәби әсәрләрдә үзләрен таныганнар да язучы өстеннән донос язып ачу кайтарганнар* (М. Мәһдиев. Татар провокаторлары). *Син моның белән миннән биштәремне тутырышырга рөхсәт итмәвем өчен ачуыңны кайтарасың булыр, ахрысы?!* (Р. Гаязетдин. Тәүбә көче).
Төрдәше: ачу алу һ.б.

**АЧУ КАНАТЛАРЫН СЫНДЫРУ.** Берсенә карата туган ачу хисе бетү. *Шулай да сабырлык җиле аның ачу канатларын сындырган* (Ф. Яхин. Бар бер авыл, Чокал, диләр...).
Төрдәше: ачу кибәне ишелү; ачу урталай өзелү; ачу чыгару 2; ачудан айну; ачудан тиз кайту.

**АЧУ КИБӘНЕ ИШЕЛҮ** *к.* ачу канатларын сындыру. *Гөлфиянең ачу кибәне ишелә иде* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: ачу канатларын сындыру һ.б.

**АЧУ КИЛГӘН ЧАК, КУЛДА (КУЛЫМДА) ПЫЧАК, <ТЫКТЫМ ЧЫГАРДЫМ>.** «Ачулы вакытым, мине артык кыздырмагыз» мәгънәсендә. *Ачу килгән чак, кулда пычак дигәндәй, алай-болай яныбызга йөри калса, кирәген алмагае* (Р. Төхфәтуллин).

**АЧУ КИЛҮ** *к.* авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2. *[Фаизә] Кеше сөйләгәч, ачу килә шул* (К. Тинчурин. Йосыф белән Зөләйха). *Болай актарынуга Нечкәбил иптәшенең ачуы килде* (А. Алиш. Нечкәбил).
Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

**АЧУ КИТЕРҮ** *к.* авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2. *[Габделкәрим] Ачу китереп, лыгырдап килеп йөргән бу карчыгын әйтер идем* (Г. Камал. Кайниш). *Бик ачуымны китерсәләр, үз әтием янына китәрмен дә барырмын, рәхәтләнеп аның янында яшәрмен!* (А. Әхмәтгалиева. Минем әтинең кызы).
Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

**АЧУ КУБУ** *к.* авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2. *Гаян аның хатын дикъкать белән укуын, йөзендә канәгатьләнү яки ачу кубу чаткыларының еш алмашынуын эндәшми генә күзәтеп утырды* (М. Хуҗин. Урак өсте болытлары). *Су өстендә чайкалган әйберләрнең кешеле булганнары бердәй дөбердәргә керешкәч, аюның да ачуы кубып, сыйлану өмете җилдәй юкка чыкты да, шашканнар тирәсеннән тиз генә яңадан урманга сызудан башка җай тапмады ул* (Ә. Баянов. Тавыш – табигать бүләге).
Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

**АЧУ КУЗГАЛУ** *к.* авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2. *Картны артыннан килеп кочаклаган кешегә Мәрьямнең күңелендә ачу кузгалды* (Ш. Камал. Козгыннар оясында). *Кайвакыт ябылып ятудан тәмам туеп, ачуы кузгала да, ярсып ук китә* (С. Шәмси. Ут хәйләсе).
Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

**АЧУ КУУ.** Булган ачуны онытмау, үч алырга йөрү. – *Күаме гөнаһсыз кызларга, аларның әтиәниләренә хөсетлек белән ачу куучы кешеләрдән бинахак сүзләр күтәрергә туры килгән! – дидем* («Матбугат.ру» порталы). *Әмма кызып китсә дә, сүгенә белми үзе, ачу кумый* (Т. Әйди. Бożра).
Төрдәше: ачу алу һ.б.

**АЧУ КУЫГЫ КАБАРУ** *к.* авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2. *Каенатаның да зәһәре суынып, ачу куыгы кабарган җиреннән шиңеп төшкән* (Ф. Яхин. Сөйкемле сөяк).
Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

**АЧУ КУЮ** *к.* авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2. *Бу сүзләре өчен мин аңа ачу куярга уйлаган идем дә, аннан соң бәйләнмәскә булдым* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

**АЧУ КҮЗЕ БЕЛӘН КАРАУ.** Ачулы булганлыгын әйтмичә, ачуын эчтә саклау; кинә тотып йөрү. *Фәтхулла хәзрәт муллага ачу күзе белән карап алды да: – Динне бетергән икәнсез инде. Ходай каршында син җаваплы инде, – дип җавап бирде* (Ф. Әмирхан. Фәтхулла хәзрәт).

Төрдәше: ата-анасын үтергән кебек йөрү һ.б.

**АЧУ КҮМЕРЕНӘ ҖИЛ ӨРҮ.** Берәрсенә карата булган ачу тагын да арту. *Эчендә пыскыган ачу күмерләренә җил өрдемени – бу уйлардагы нәфрәт хисе тагын да яңарак көч белән яна башлады* (Д. Булатова. Соң түгел!).

Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

**АЧУ ӨСТЕНӘ АГУ.** Ачу-үпкәне тагын да арттыру максатыннан, начар сүзләр, хәбәрләр өстәп тору. *Ачу өстенә агу дигәндәй, болай да янган йөрәккә ачу уты сала бу этләр* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

**АЧУ САКЛАУ (САКЛАП ЙӨРҮ)** *к.* ачу күзе белән карау. *Зиннәтнең ачу саклап йөрүен теләми иде, шатлыгын да күп татыган, дөньяны күргән* (Г. Бәширов. Намус).

Төрдәше: ата-анасын үтергән кебек йөрү һ.б.

**АЧУ САКЛАУЧАН.** Кемгә булса да ачуланып, ачуын онытмыйча көн күрү; кара эчле, үчле. *Баланы һәрвакыт җәберләсәләр – ул кызып китүчән, ачу саклаучан һәм үч алучан булып үсә* («Сабантуй» ж.).

Төрдәше: нөктә тотучан (саклаучан).

**АЧУ ТАБАН АСТЫНА ҖИТҮ (ТӨШҮ).** Ярсуы чиктән тыш булу. *Бер барганда, Зобани «Ач корсак!» дип кычкырып җибәргәч, башы әйләнеп, ачуы табан астына җитте аның* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

**АЧУ ТАШЫ (АЧУТАШ) ЙОТКАН.** Үтә үчле, ачуын кемнән алырга белмичә зәһәрләнеп йөрүче кеше хакында. *Ул хәзер бу ачуташ йоткан агай белән сүз көрәштереп канын бозарга һич теләми иде* (Ф. Хөсни).

Төрдәше: ата-анасын үтергән кебек йөрү һ.б.

**АЧУ ТОТУ** 1. *к.* ачу күзе белән карау. *Сиңа атса берәр адәм әгәр таш, / Ачу тотма, үзең ат син аңа аш* (Г. Утыз Имәни. Татулык турында). *Куларага җиткәндә, Сәйфран: – Ачу тоталардыр, – диде, кемгә икәнен әйтмәде* (М. Хуҗин. Кударада кәлтә уйный).

Төрдәше: ата-анасын үтергән кебек йөрү һ.б.

**АЧУ ТӨЕНЕ ЧИШЕЛҮ.** Ярсуының, үпкәләвенең сәбәбе ачыклану, беленү. *Менә кая җиткәч кенә ачу төене чишелә башлады әле аның* (М. Хуҗин. Курагай атлары).

**АЧУ ТӨЕНЕ ЧИЯЛӘНҮ.** Ачуын озак вакытлар күңелендә саклау. *Үпкәләшүләрен онытырга теләде, әмма ачу төене шактый эчкә китеп чияләнгән иде* (Сөйләм).

Төрдәше: ата-анасын үтергән кебек йөрү һ.б.

**АЧУ ТӨЕНЕ ЧИЯЛИ БӘЙЛӘНҮ** *к.* ачу төене чияләнү. *Ул ерактан уратып башлады – һәм без аның ачу төене чияли бәйләнгәнен шунда ук сиздек* (М. Хуҗин. Курагай атлары).

Төрдәше: ата-анасын үтергән кебек йөрү һ.б.

**АЧУ ТҮГҮ.** 1. Булган ачуны туп-туры әйтеп бирү. *Сүз арты сүз китте дә түзмәде, моңарчы саклап йөргән бөтен ачуын түкте дә куйды* (Сөйләм). – *Туган-тумачаны, дус-ишне, үзенә кирәкле кешеләрне тәэмин итеп тору өчен, балык күп кирәк шул, – дип ачуын түкте Әхтәм* (Ә. Моталлапов. Балыклы күл буенда).

2. *к.* ачу алу. Саклап йөргән ачуыннан арыну. *Җыелган ачуны кемгә дә булса түгәргә кирәк иде* (Р. Зәйдулла. Коршау).

Төрдәше: ачу алу һ.б.

**АЧУ УРТАЛАЙ ӨЗЕЛҮ** *к.* ачу канатларын сындыру. *Хәмит абзыйның ачуы урталай өзелеп кала* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).

Төрдәше: ачу канатларын сындыру һ.б.

**АЧУ УТЫ САЛУ** *к.* авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2. Берсенең күңелендәге ачуны тагын да арттыру. *Ачу өстенә ачу дигәндәй, болай да янган йөрәккә ачу уты сала бу этләр* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

**АЧУ УТЫН КАБАРТУ** *к.* авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2. *Бер-берсенә «син нәрсә, ә син нәрсә?» дип очынып килгән егетләр арасына берсенең абыйсы килеп керү ачу утын кабартты гына* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

**АЧУ ЧЫГАРУ** 1. *к.* авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2. *Асаф тагын кабатлады. Хатын йөзенә ясалма*

*ачу чыгарды* (М. Мәһдиев. Ут чәчәге). *Куфи язуы белән язылган хәбәр сөнни мәзһәбтәге Казан ханының ачуын чыгара* (А. Тимергалин. Милли казаныш).
Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

**АЧУ ЧЫГУ** *к.* авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2. *Бака чыраен сыткан, / Билгеле, ачуы чыккан* (С. Хәким). *Бу шашкын башсызлыгы Әкрәмовның ачуын чыгарыр, ахыр чиктә үзенә зарары тияр дип уйлап та карамады* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).
Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

**АЧУ ШИҢҮ** *к.* ачу канатларын сындыру. *Бүлмәдәшенең мут егете, кызны алдап, шәһәрдән китеп баргач, Матрена түтинең ачуы шиңде дә куйды* (К. Тимбикова. Агым уртасында). <...> *тун төймәсен ычкындырган Саҗидәнең нәни генә түгәрәк шар «йотканын» шәйләгәч, ачуы шиңде* (Н. Гыйматдинова. Нурулла).
Төрдәше: ачу канатларын сындыру һ.б.

*АЧУГА* ❖ **АЧУГА ИРЕК БИРҮ** *к.* авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2. Эчендә ярсу, ачу булганын сиздерү. – *Соң! – диде бикә, ачуына ирек биреп, – Синең атаң Шилке минем туган ыруымны туздырды, атамнан-анамнан аерды* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур). *Менә аяклы каза, дип ачуына ирек бирде Уралов, Соня чыгып киткәч* (Х. Камалов).
Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

*АЧУДАН* ❖ **АЧУДАН АЙНУ** *к.* ачу канатларын сындыру. <...> *борын тартып торуы гына һаман әле ачудан айнып җитмәвен аңлата иде* (К. Нәҗми).
Төрдәше: ачу канатларын сындыру һ.б.

**АЧУДАН КАРА КӨЮ.** Ачуы-зәһәре йөзенә бәреп чыгу. *Сарсымбай белән байбичә, башларын уып, ачудан кара көйделәр* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *Мин әткәй белән әнкәйгә шашкан кебек акаеп карадым. Ачуымнан кара көйдем* (Ә. Еники. Яз баласы).
Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

**АЧУДАН ТИЗ КАЙТУ.** Бик тиз ачуланып, шулай ук ачуын тиз онытучан кеше хакында. *Тиз кызып китеп, эт итеп сүгеп ташласа да, ачуын эчендә озак сакламый, ачудан тиз кайта иде ул* (Сөйләм).
Төрдәше: ачу канатларын сындыру һ.б.

**АЧУДАН УТ ОЧКЫНЫ КЕБЕК КЫЗУ.** Ачуыннан шартлар дәрәҗәгә җитә торган кеше турында. *Мастерның ачудан ут кебек кызганын күргәч, Алмас тиз генә чыгып шылу ягын карады* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

**АЧУДАН ҮЗ-ҮЗЕН ТОТА (ТЫЯ) АЛМАУ.** Ачулы булу сәбәбеннән, ни эшләгәнен белмичәрәк хәрәкәтләр ясау. *Белгечләр әйтүенчә, ачуыннан үз-үзен тыя алмый кычкыручы кешеләрнең ачу өянәкләре басылып, ике сәгать үтүгә, йөрәк өянәге кичерү куркынычы 5 тапкырга артык* («Шәһри Казан» газ.).

*АЧУ-КЫЧУ* ❖ **АЧУ-КЫЧУ БУЛУ.** Үзара ачу-үпкә тоту. *Николай патша белән Франц Йосиф һәм кайзер Вильгельм арасында ачу-кычу яки нинди дә булса бер-берсен рәнҗетә торан дошманлык булган икән, ник алар үзләре генә сугышмыйлар?* («Безнең мирас» ж.).

*АЧУЛАНЫШТАН* ❖ **АЧУЛАНЫШТАН БУЛМАСЫН.** Берәрсенә йөзенә бәреп турысын әйтергә җыенганда яки үзара килешкәндә, шарт куешканда, алдан кисәтеп кую. *[Нурәхмәт] Тик ачуланыштан булмасын. Дөнья шулай бара* (Т. Миңнуллин. Нигез ташлары). *Тик ачуланыштан булмасын, иртәгәдән – эшкә!* (Н. Акмал. Кол).

**АЧУНЫ ТЫЕП КАЛУ.** Кемгәдер кызып, *Сабан туенда җиңелгәннән соң кузгалган ачуын тыеп калырга тырышты* (М. Галәү. Болганчык еллар). *Ләкин звено җитәкчесе Ибәтулла Шәяхмәтовның йончыган күзләрендә нинди дер тылсымлы нурларны күреп, ул ачуын тыеп калды, шулай да сүзне коры тотты* (Ф. Хәбибуллин. Ышанып атлыйбыз).

**АЧУНЫ ЭЧКӘ ЙОТУ** *к.* ачу йоту. *Габдулла хан, ачуын эченә йотып, сүзне тәмамларга мәҗбүр булды* (В. Имамов. Казан дастаны). *Бригадир, ачуын эчкә йотып, шаркылдап көлә башлады* (М. Галиев. Арыслан йокысы).
Төрдәше: ачу йоту.

*АЧУТАШ* ❖ **АЧУТАШ КАПКАН КЕБЕК.** Йөзен ачы җыерган кеше турында. *Ачуташ капкан кебек йөзе җыерылды* (Ә. Хәсәнов. Әнис алмалар). *Бульдозерчы егет, ачуташ капкандай чыраен сытып, башын кискен генә бер якка*

*кыйшайтып ала* (Ф. Абдуллин. Тормышка юл ярганда).

*АЧУЫ* ❖ **АЧУЫ БОРЫН ОЧЫНДА <ГЫНА>.** Холкы тиз ярсып китүчән, кылтаючан кеше турында. *Хәмәй карт кылтыкай, ачуы борын очында гына* (Х. Кәрим).

**АЧУЫ ЙӨЗЕНӘ <БӘРЕП> ЧЫГУ.** Кешенең эчке ярсуы аның йөзендә сизелү. *Винитарның ачуы йөзенә үк бәреп чыкты, яңак итен чәйни башлады...* (М. Хәбибуллин. Атилла). *Карт диваннан торып ук китте, хәрәкәтләре кырысланды, ачуы йөзенә чыкты* (Ә. Әминев. Усман ташы).

*АЧУЫМ* ❖ **АЧУЫМ АЧУ...** Кисәтү йөзеннән әйтелә, ягъни ачуымны китермәсен, юкса... – *[Мөршидә] (кизәнеп). Китегез янымнан! Ачуым ачу! (Өйдән чыгып китә.)* (З. Хәким. Кайда син, Аттила?!). *Ачуым ачу, табам ананасын да. Дөньясын актарам...* (Ә. Фазылҗанов. Без кемнән ким?).

**АЧУЫМ ДА КИЛМӘСӘ.** «Ачудан әллә нәрсә әйтеп ташлармын» мәгънәсендә; бик ярсып сөйләгәндә, сүз арасына кыстырыла. *Тьфу! Ачуым да килмәсә* (М. Фәйзи).

Төрдәше: ачуым <да бер> килмәгәе; ачуымны китерсәң.

**АЧУЫМ <ДА БЕР> КИЛМӘГӘЕ** *к.* ачуым да килмәсә. *Без дә чеган арбасыннан төшеп калмаган, ачуым да бер килмәгәе!* (Ф. Баттал. Мистер-абсолют). *Начальствоның күзенә чәчрәп керергә кирәк, югыйсә ул сине күрми, кырык тапкыр алдынгы бул, ачуым килмәгәе* (Г. Афзал. Дан яулаганда).

Төрдәше: ачуым да килмәсә һ.б.

**АЧУЫМНЫ КИТЕРСӘҢ** *к.* ачуым да килмәсә. *Ачуымны китерсәң, кире тыктым куйдым булыр урынына, ди* (Т. Миңнуллин. Мулла). *– Ачуымны китерсәң, валлаһи әгәр, танышмый калмам!* (Ш. Рәкыйпов. Таңнар һаман матурмы?).

Төрдәше: ачуым да килмәсә һ.б.

*АЧУЫНА* ❖ **АЧУЫНА БАРУ.** Эчендә ачуын саклап йөреп, аны әйтү һәм нәрсә булса да башкару. *Хәерченең төрттереп әйткәне Тукайның ачуына барып кадалды, ул: – Яп авызыңны! – дип кычкырды* (Р. Батулла. Апуш – Тукай).

*АЧУЫҢ* ❖ **АЧУЫҢ КИЛСӘ, БОРЫНЫҢНЫ (ТЕРСӘГЕҢНЕ) ТЕШЛӘ.** «Ачуым килде» дигән кешегә шаярып җавап бирү гыйбарәсе (ягъни юкка ачуы килүне сиздерү). *Ачуың килсә, борыныңны тешлә, миңа димәгәе* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

*АЧЫ* ❖ **АЧЫ АНТ <ОРУ>.** Ләгънәтле ант. *Булыр бер көн, ачы антым, торырмын, / Бөтен дөньясын ләгънәт орырмын* (С. Рәмиев).

**АЧЫ БАЛ.** *Түрдәге сәкедә таныш түгел ике кеше чәй чокыры белән ачы бал чөмереп утыралар иде* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала). *Андый эшләрне ул салырга ярата торган ир-атларны кушып эләтә дә соңыннан ачы бал белән сыйлап җибәрә* (В. Нуруллин. Ике урам арасы).

Төрдәше: әче бал.

**АЧЫ БЕЛӘН АВЫЗЛАНУ.** 1. Михнәтле, авыр тормышта туу, үсү. *Василий ачы белән авызланды. Шактый озак татыды ул ачыны* (А. Гыйләҗев).

2. Үткен сүзле, усал булу. – *Уф, телең, чыдарлык түгел, син ачы бал белән авызлангансың, ахрысы* (Сөйләм).

**АЧЫ БЕЛӘН ТӨЧЕНЕ ТАТУ.** Тормышның яхшысын да, начарын да кичерү (күрү); «күпне күргән, тормыш тәҗрибәсе бар» мәгънәсендә. *– Мин сине бер кеше белән таныштырыйм әле: ул күп җирдә булган, ачы белән төчене татыган* (Сөйләм).

Төрдәше: авызы пешкән өреп капкан (эчкән) һ.б.

**АЧЫ ИКМӘК <БУЛУ>.** Ташланмый торган әйбер, берәр кара эштә ярарлык нәрсә. *Олыгайган көнеңдә ачы икмәк ашыйсың килмәсә, ачуыңны, проблемаларыңны балаңда чыгарма* («Кызыл таң» газ.). *Күгәреп беткән бу велосипедын ул әтисе «ташлама син моны, берәр вакыт ачы икмәк булып куяр» дигәнгә генә саклый иде* (Сөйләм).

**АЧЫ ИШЕТҮ.** Җан әрнеткеч сүзләр ишетү. *Бичара Мәрьям бу кадәр ачы ишетсә дә түзде* (М. Гафури).

**АЧЫ КАЙГЫ КИЧЕРҮ.** Җан ачысы китерә торган фаҗыйгa кичерү. *Берничә ел элек Кәримовларга ачы кайгы кичерергә дә туры килә – 24 яшьлек уллары Рамил юл һәлакәтендә вафат була* («Матбугат.ру» порталы).

*Ачы кайгы кичерсә дә, гаилә үзендә яшәүгә көч таба, Алсу Мансуровна җиң сызганып дөнья көтә, баласының якты киләчәге өчен кулыннан килгәннең барысын да эшли, бүген әнисе дә аның тәрбиясендә яши* («Әлмәт таңнары» газ.).

**АЧЫ КАТЫК КЕБЕК КАБАРУ.** Юкка-барга ачуланучан, тиз үпкәләүчән кеше турында. *Сөембикә ачы катык шикелле кабарып чыкты* (М. Әмирханов. Әлвидаг).
Төрдәше: апара кебек кабару һ.б.

**АЧЫ КӨЛҮ.** Зәһәр сүз белән чагып көлү, агулы көлү. *Шулвакыт колак төбемдә мыскыллы ачы көлү яңгырады* (Х. Ширмән. Ерактагы йолдызым).

**АЧЫ КҮЗ ЯШЕ.** Зур гаделсезлекләр, золымҗәберләр, зур кайгы-хәсрәттән туган күз яшьләре. *Кем минем ачы күз яшьләремне туктатыр?* (Ф. Яхин).

**АЧЫ КҮЗ ЯШЬЛӘРЕ ТҮГҮ (КОЮ).** Ачыныпачынып елау. *Юкка гына халык әйтмәгән. / Күпме кеше нахак рәнҗетелеп, / Ачы күз яшьләре түкмәгән* (К. Фатыйхова-Бәдертдинова).
Төрдәше: ачы күз яшьләренә буылу.

**АЧЫ КҮЗ ЯШЬЛӘРЕНӘ БУЫЛУ** *к.* ачы күз яшьләре түгү (кою). *Мин, ачы күз яшьләремә буылып, яр буена сузылып, үкси-үкси еладым…* (Г. Галиева. Барсам).
Төрдәше: ачы күз яшьләре түгү (кою).

**АЧЫ КҮРҮ.** Ачы кайгы-хәсрәтләр күрү. *Читтән карап торганда, бу кеше бик күп ачы күргәнгә охшый* (Сөйләм).
Төрдәше: авызында ашы, күзендә яше 2 һ.б.

**АЧЫ СУ.** 1. Углекислоталы минераль су; тозлы су. *Нефтьчеләр Олы су башында, Карама куышта, ике җәй яттылар, нефтьләре чыкмаган, казыган тишекләреннән ачы су ургылып ага, ди* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
2. Исерткеч эчемлек. *Казанчы Сафиулла белән олаучы Кузьмич, салмак кына агылган олауның уртасында барган чагында, стаканнан бер-бер артлы «ачы су» эчеп куйдылар* (Ә. Гаффар. Дәрья башы).
Төрдәше: агулы елан 1 һ.б.

**АЧЫ ТАҢ.** Төн караңгысы бетеп, таң сызылу алды. *Иртән ачы таң тишегеннән – басуга* («Туган як» газ.).
Төрдәше: ачы таңнан (таң белән); әче таңнан; таң күзеннән; таң тишеге <белән>; таң тишегеннән.

**АЧЫ ТАҢНАН (ТАҢ БЕЛӘН).** Таң атып җиткәнче; бик иртә, кояш чыгу белән. *Карчыклар югалганның өченче көнендә, ачы таң белән, Кампәрлегә берьюлы өч милиция машинасы килеп керде* (Г. Гыйльманов. Албастылар).
Төрдәше: ачы таң һ.б.

**АЧЫ ТӘҖРИБӘ.** Авыр сынау, тормыш тәҗрибәсе. *Ачы тәҗрибә нәтиҗәсе инде, кат-кат авыз пешү нәтиҗәсе* (М. Әмир). *Гүя арадагы сагышлы, сугышлы ачы тәҗрибә еллары булмаган да, 12 елдан соң да, кичәге сүзен дәвам иттергәндәй, шул ук «Шатлык шигыре»* (М. Гайнетдин. Гасырлар мирасы).

**АЧЫ ТЕЛ<ЛЕ> (СҮЗЛЕ)**. Усал, төрттереп, чәнчеп әйтә торган кеше. *[Гөлбану] (үзалдына). Кара син аны нинди ачы телле! Әле килеп тә җитмәгән, беренче күрүендә үк инәне йөрәгемә кадый башлады* (Г. Камал. Көндәш). *Безнең барыбыз өчен ачы телле, күзлекле, язучылык стажы Рафаил белән икебезнекен бергә кушканда да бер-ике мәртәбә артып китә торган Ибраһим Гази сөйләде* (Г. Ахунов. Йолдызлар калка).
Төрдәше: агу тел<ле> һ.б.

**АЧЫ ТЕЛЕ ЧЫГУ.** Тирләп-пешеп эшләгәндә, төрле сүзләр әйтелергә мөмкинлегенә ишарә. *Эшләгән кешенең тире чыга, тире белән ачы теле чыга, теле ачы* (Д. Булатова. Соң түгел!).

**АЧЫ ТЕЛ<ЛЕ>ЛӘНҮ.** Усал, төрттереп сөйләшү. *Бермәлне шул турыда ачы телләнеп алуым да хәтердә: – Син, Алиш, зря болай шалишь! Коеп куйган Кавказ егетедәй башың белән, шундый галстук тагып йөрергә ничек оялмыйсың икән* (Р. Кукушкин. Шигъри әкиятләр остасы).
Төрдәше: агу тел<ле>.

**АЧЫ ТЕЛЛӘР.** Усал рәвештә, төрттереп сөйләргә яратучылар хакында. *Ачы телләр, пычрак уйлар белән / Кагылмагыз, күңел чаң кебек* (Х. Мөдәррисова. Шәмәхә төн).
Төрдәше: усал телләләр.

**АЧЫ ТИР**. Авыр физик эш хакында әйтелә. *Безнең күпме ачы тир сыгылып салынган ул сабынга* (Ә. Фәйзи). *Гомер-гомер / Кулы яргаланган / Ач кешеләр ачы тир түккән* (Г. Афзал. Җанга якын урыннар).

**АЧЫ ТИР ТҮГҮ.** Тир агыза-агыза эшләү. *Нәсел даны шулай килә. Ачы тир түгеп, сөялле куллар белән яуланган ул* (Т. Сәгыйтов. Буыннар язмышы).

**АЧЫ ТОРМА КАПКАН КЕБЕК.** Кешенең берәр сәбәптән (йөзгә бәреп әйтү, мыскыллау һ.б.) кәефе китеп, чырае үзгәрү. *«Галия» хакимияте башлыгы йөзендәге кара күләгә залда утырган башка бәгъзе бер шәкертләргә дә тәэсир иткәнлекне сизми калмады Галимҗан. Чөнки аларның да йөзе ачы торма капкан кешенекедәй чытылды* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).

**АЧЫ ХАКЫЙКАТЬ.** Ошау-ошамауга бәйле булмаган тормыш чынлыгы. – *Асылханның әле һаман да бу ачы хакыйкать белән килешәсе килми иде* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!).

**АЧЫ ЯЗМЫШ.** Бәхетсезлек, җәфалы гомер. *Бүтәннәр алдагы көн, буш хыяллар белән яшәмиләр, алар өчен бүгенге ачы язмыш хакыйкате генә бар* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Бу сарайны салган останы да ачы язмыш көткән соңыннан* (Г. Садә).

Төрдәше: кара бәхет; кара язмыш; кире язмыш; кара таплы бәхет; сукыр бәхет; шүр язмыш.

**АЧЫ ЯШЬ ТҮГҮ.** Нык кайгырып елау, өзелү. *Минем лә генә ачы яшь түгүем / Мәгълүм микән әнием кәбәмә?* (Хал. жыры). *Ачы яшь түгеп / Йөрәгемә ачы хәбәр сукты, / Синсез инде таңнар атармы?!* (А. Гадел).

Төрдәше: ачы яшь эчү; ачыган шулпасын чөмерү; ачыны да, төчене дә тату; ачыны тату; ачы<ны>-төчене тату; ачысын-төчесен тату (кичерү; күрү); әчесен-төчесен куш учлап чөмерү; әчесен-төчесен күрү (тату); әче-төчене күрү; башка эш төшү; бергәләп тоз ашау; дөнья күрү; дөньяны тату; дөньяның ачысын (әчесен)-төчесен тату (белү); елан аягын кискән; михнәт чигү; нужа калачын ашау; нужа камытын кию; нужа куу (чигү); күпне күрү; Лаеш суларын (шулпасын) эчеп узу; Лаеш шулпасын эчү; тормыш казанында кайнап чыгу; тояк суы эчкән; ут<ны>-су<ны> кичү; ут<ны>-су<ны> кичү һәм шомарып бетү; ут<лар>-сулар кичкән; уттан-судан һәм кара төнлектән үтү; эт ашаган.

**АЧЫ ЯШЬ ЭЧҮ.** Зур авырлыклар кичерү, кыенлыклар күрү. *Җан түзмәслек авыр вакытларда / Какшамады рухы, төшмәде. / Ачы яшьләр кайчак эчсә дә ил, / Митридаттай агу эчмәде* (Н. Арсланов).

Төрдәше ачыган шулпасын чөмерү; ачыны да, төчене дә тату; ачыны тату; ачы<ны>-төчене (ачысын-төчесен) тату (кичерү; күрү); әчене-төчене тату; әчесен-төчесен куш учлап чөмерү; әчесен-төчесен күрү (тату); әче-төчене күрү; бергәләп тоз ашау; дөнья күрү; дөньяны тату; дөньяның ачысын (әчесен)-төчесен тату (белү; күрү); елан аягын кискән; казанда кайнау; күпне күрү; Лаеш суларын (шулпасын) эчеп узу; Лаеш шулпасын эчү (чөмерү); михнәт чигү; нужа калачын ашау; нужа камытын кию; нужа куу (чигү); тормыш казанында кайнап чыгу; тояк суы эчкән; ут<ны>-су<ны> кичү; ут<ны>-су<ны> кичү һәм шомарып бетү; ут<лар>-сулар кичкән; уттан-судан һәм кара төнлектән үтү; эт ашаган.

*АЧЫГАН* ❖ **АЧЫГАН ШУЛПАСЫН ЧӨМЕРҮ** *к.* ачы яшь эчү. *Асраулыкның ачыган шулпасын күп чөмерде, әмма мескен-бичара булып калмады, җай чыкканда шаян-җор да була белә!* (М. Маликова. Язгы такыялар).

Төрдәше: ачы яшь эчү һ.б.

*АЧЫГУНЫҢ* ❖ **АЧЫГУНЫҢ АРЪЯГЫНА ЧЫГУ.** Ачулану, кирәгеннән артык кызып китү. – *Ачыгуның аръягына чыккансыздыр* (Г. Мөхәммәтшин. Хуҗалар).

*АЧЫГЫН* ❖ **АЧЫГЫН ӘЙТЕП <СӨЙЛӘШҮ>.** Хәлнең дөресен яшермичә әйтеп сөйләшү. *Бу мәсьәләнең очына тизрәк чыгу өчен, ачыгын әйтеп сөйләшергә кирәк* (Сөйләм).

*АЧЫК* ❖ **АЧЫК АВЫЗ<ЛЫ>.** 1. Җебегән, булдыксыз. – *Хәзер мин аны, амриканксий дип, бер ачык авызга саттым; / Бу кулымдагы йөзлекне дә шуннан алдым...* (Г. Тукай. Сәүдәгәр).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

2. Гамьсез, игътибарсыз. *Без – Рәсәйнең ачык авызлары, / Без торабыз көн-төн гә-*

*зит күшәп* (Г. Афзал). *Кладовойчы да, Фазылҗанов ачык авыз да ишетми калганнар, шулай ук без дә менә, башыбызны кашып, аптырап утырабыз: чынлап та, нәрсә турында булды икән ул кыска-кыска сүзләр?* (Ф. Хөсни. Җәй башы).

3. Уйламыйча артыгын сөйләүче кеше. *Бу ачык авыз – мулла абзыйның хезмәтчесеме, ат караучысымы – сүзен бетергәч, итекчеләр бер-беренә мәгънәле генә карап алалар да, бер-берсен сүзсез аңлап, вакытларын бушка уздырмыйча, үзләре эшкә төшкән авылга юл тоталар* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы).

Төрдәше: авызга тел сыймау, <телгә сүз сыймау> һ.б

4. Азган, әхлаксыз. *«Син, Наилә ханым, ирен сатып йөрүче ачык авыз түгел»* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

5. *к.* ак белән караны аермау 1. – *Ачык авыз! Шул яшькә җитеп, ярты тиенлек акылың юк...* (К. Нәҗми).

Төрдәше: ак белән караны аермау 1 һ.б.

6. Сер саклый белмәгән кеше. *Ачык авыз булып, концерттан кайтышлый шулхәтле чишелмәсә һәм үзенең авылча беркатлылыгын күрсәтмәгән булса, әлбәттә, эшләр болай ук тирәнгә китмәячәк иде* (В. Нуруллин. Һәлакәт).

Төрдәше: авызы җебегән <булу> 1 һ.б.

**АЧЫК АВЫЗ, ЙОМЫК КҮЗ.** Бу дөньяда ашау өчен генә яшәүче; ашаудан башка бер нәрсәне дә белергә теләмәүче. *Аның кебек ачык авыз, йомык күз кешеләр дөньяда сирәктер* (Сөйләм).

**АЧЫК АВЫЗ<ЛЫ>ЛЫК.** 1. Булдыксызлык, җебегәнлек. *Ләкин бу әсәрләрдә инде кешеләргә хас гомуми кимчелекләрдән – ачык авызлык һәм комсызлыктан көләнә* (Л. Җамалетдинов. Татар әкиятләрен барлау юлында).

2. Гамьсезлек. *Менә шулай ачык авызлылыгы аркасында бу коллыкка килеп капты инде* (В. Имамов. Карабәк).

**АЧЫК БАНКАГА КАГУ.** Хәл ителгән билгеле нәрсәне хәл иткән булып маташу. *Нәрсә эшлисең анда, ачык банкага кагасыңмы?* (Сөйләм).

Төрдәше: ачык ишеккә бәреп керү (ачкыч ярату); ачык ишекне ватып (бәреп; җимереп) керү; ачык ишекне (капкага) кагу.

**АЧЫК БУЛУ.** Ачык йөзле, һәркем белән дустанә мөнәсәбәттә булу. *[Красильников] Сез аның болай ачык булуына карамагыз. Кайвакыт шулай була – ул атналар буена бер сүз эндәшми* (Ф. Бурнаш. Хөсәен мирза).

**АЧЫК ЗИҺЕН.** Уйлап, акыл белән эшләү. *Ул әзер булып торырга тиеш, әйе, зиһене ачык, теле бар чакта ул үзенең соңгы теләген, соңгы васыятьләрен әйтеп калырга тиеш* (Ә. Еники. Әйтелмәгән васыять).

Төрдәше: акыл аша уздыру һ.б.

**АЧЫК ИТЕП.** 1. Яшермичә, дөрес итеп. – *Шәмсүн әнә сезнең шикелле хәйләләп-шомартып маташмый, ачык итеп яра да сала* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

2. Гади һәм аңлаешлы итеп. *Нурҗиһан һәр сүзен, китаптан укыгандай, ничектер тел очы беләнрәк бик пөхтәләп, ялгышмагаем дигәндәй, ачык итеп әйтә иде* (Г. Бәширов. Нурҗиһан). *Тик аны менә шушылай, синеңчә ачык итеп әйтеп бирә генә алмый идем...* (В. Нуруллин. Һәлакәт).

3. Тулысынча, бөтен нечкәлекләре белән. *Гомерендә беренче тапкыр яхшы күзлек кигән һәм шунлыктан гомерендә беренче тапкыр табигатьнең бөтен буяуларын ачык итеп тойган күрә карау кеше сыман таң калып, якягына каранды* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**АЧЫК ИШЕК БАРЫНДА (БАР ЧАГЫНДА) КЕРЕП КАЛУ.** Берәр эшкә мөмкинлек ачылу. *Төрле тыюлар уйлап чыгара башлаганчы, бисмилла әйтеп, ачык ишек бар чакта кереп калырга кирәк* (Сөйләм).

**АЧЫК ИШЕККӘ БӘРЕП КЕРҮ (АЧКЫЧ ЯРАТУ)** *к.* ачык банкага кагу. *Ачык ишеккә ачкыч яратып маташасың түгелме, бу проблема хәл ителгән бит инде!* (Сөйләм).

Төрдәше: ачык банкага кагу һ.б.

**АЧЫК ИШЕКЛӘР КӨНЕ.** Берәр уку йорты, оешма, ширкәт һ.б. үзләренең эшләре белән таныштыру йөзеннән, реклама чарасы үткәрү. *Бүген алар үзенә күрә «Ачык ишекләр көне» үткәреп, бераз «җилләнеп алдылар»* (Д. Булатова. Ачык ишекләр көне).

**АЧЫК ИШЕКНЕ ВАТЫП (БӘРЕП; ҖИМЕРЕП) КЕРҮ** *к.* ачык банкага кагу). *Ачык*

*ишекне ватып кермиләр* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).

Төрдәше: ачык банкага кагу һ.б.

**АЧЫК ИШЕКНЕ (КАПКАГА) КАГУ** *к.* ачык банкага кагу. *Ачык ишекне кагасың түгелме соң син?* (Сөйләм).

Төрдәше: ачык банкага кагу һ.б.

**АЧЫК ЙӨЗ.** Яхшы уй белән; ягымлы, шатланып. *Нәгыймә карчык аны бик ачык йөз белән каршы алды* (Ш. Камал. Таң атканда). *Яшь ананы без ачык йөз белән каршыладык* (Ш. Маннур. Агымсуларга карап).

Төрдәше: ачык чырай.

**АЧЫК ЙӨЗ КҮРСӘТҮ.** *Башта ул ревизия кешеләре белән, дәрәҗәсен саклап, әмма ачык йөз күрсәтеп, әйбәт кенә сөйләште* (Ә. Еники. Рәшә). *Рәхмәт булсын сезләргә, / Ачык йөзгез күрсәтеп, / Шат булдыгыз безләргә* (Х. Усадова. Саф күңел).

**АЧЫК ЙӨЗ (ЧЫРАЙ), ТӘМЛЕ СҮЗ.** Килүчене якты йөз, ягымлы сүз белән каршы алу. *Андый чагында һәркемгә ачык чырай да тәмле сүз* (edutatar.ru).

**АЧЫК ЙӨЗЛЕ <БУЛУ>**. Ягымлы, мөлаем, сөйкемле. *[Җәмилә] Шулай шул, бик әйбәт, бик ачык йөзле кеше, бик кешене таный торган кеше* (Г. Камал. Бәхетсез егет). *Ильич күңелендә гомере буе бала чагы яши: Кокушкиносы, «ачык йөзле» Апакае, түбәтәйле, чыбыркылы, ялан аяк Баһавилары белән...* (М. Рәфыйков. Шигърият үрләре).

Төрдәше: ачык күңел<ле>; ачык чырай<лы>; якты йөзле; якты чырайлы.

**АЧЫК ЙӨЗЛЕЛЕК.** Ягымлылык, сөйкемлелек. *Ата-анасыннан матурлык белән ачык йөзлелектән башка нәрсә алып кала алмаган 11–12 яшьлек бу ятим кызны атасы ягыннан тиеш Тәхәү үз тәрбиясенә алды* (М. Әмир). *Табигать Ф. Ильскаяга ачык йөзлелек, гадилек сыйфатлары белән бергә искиткеч иҗади сәләт һәм гаҗәеп интеллектуаль талант биргән* (А. Арсланов. Истәлекләр).

**АЧЫК КАЛУ.** Хәл ителмичә, тиешле карар кабул ителмичә калдырылу. *Күренә ки, бу мәсьәлә ачык кала* (К. Гыйззәтов. Нәфасәт). *Вәкаләт мәсьәләсе ачык калды, чөнки китап корты исәпләнгән комендант үзе дә бу сүзнең мәгънәсен аермачык итеп әйтеп бирә алмады* (А. Тимергалин. Таш алиһә).

**АЧЫК КАПКАГА КЕМ КЕРМӘС** *к.* авызы җебегән <булу> 1. *Колхозда бригадир булып эшли, бар нәрсә аның кулында. Мотоциклда гына йөри. Аннан килеп, үзең беләсең, ачык капкага кем кермәс!* (Т. Галиуллин. Мәкер).

Төрдәше: авызы җебегән <булу> 1 һ.б.

**АЧЫК КАРАШЛЫ**. Алдынгы, аңлы, укымышлы. *Аның каршында элекке ачык карашлы, кояштай елмаюы белән Газинуры басып тора иде* (Г. Әпсәләмов. Газинур). *Шагыйрь үзен шул чорның, үз халкының тулы канлы, ачык карашлы, димәк, хакыйкать сүзе әйтергә сәләтле зирәк вәкиле саный* (Р. Әхмәтов. Шәмдәлләрдә – якты утлар...).

Төрдәше: ачык фикерле.

**АЧЫК КЕШЕ.** Ачык йөз белән каршы алучы, киң күңелле кеше. *Инженер Булатов ачык кеше иде* (А. Алиш. Якты күл буе). *Яшь кияү – бик ачык кеше, әби дип үлеп тора* (Р. Кәрами. Гөрләвекләр ага челтерәп).

**АЧЫК КУЛЛЫ.** Юмарт, кунакчыл, ярдәмчел кеше. *92 нче тәрбия. Әй угыл, халык каршында гыйззәтем вә хөрмәтем артык булсын дисәң, ачык куллы вә икмәкле-тозлы, җумарт бул* (К. Насыйри. Китаб әт-тәрбия).

**АЧЫК КҮЗ.** Игътибар, айнык баш. *Үткән хәятымны ачык күз алдыма китерсәм, ике хәл ярылып ята: берсе – ниһаясе булмаган өмид, икенчесе – шул өмиднең бертуктаусыз җимерелә, юкка чыга баруы* (Г. Ибраһимов. Сөю – сәгадәт).

**АЧЫК КҮЗ БЕЛӘН КАРАУ**. Барысын да аңлап, фикердәш-теләктәш булып. *Ул Нәҗипкә дә, Наиләсенә дә ачык күз, яхшы теләкләр белән карап, үзеннән дә, оештырган сәяхәтеннән дә бик канәгать иде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**АЧЫК КҮЗЛЕ.** Зиһенле, аңлы, тормыш мәсьәләләренә уяу караган, дөньяның, сәясәтнең торышыннан хәбәрдар булган. *Мәфтуханың ире Көяз Галәветдин заманына күрә мәдрәсәдә ярыйсы гына белем алып чыккан ачык күзле кеше иде* (Г. Бәширов. Менә сиңа, мә!). *Ачык күзле, сәләтле егетне хезмәтендә тиз күреп*

*алдылар, слесарь-токарь буларак, эш тәртибенә төшенүгә, аны Ленин исемендәге колхозда техника куркынычсызлыгы буенча инженер итеп билгелиләр* (Р. Зарипов. Тирән тамырлы Түнтәрем).

**АЧЫК КҮЗЛЕЛЕК.** Сизгерлек, уяулык. *Бу көннәрдә авыл коммунистларыннан аеруча бердәмлек һәм ачык күзлелек сорала* (Ф. Хөсни).

**АЧЫК КҮҢЕЛ<ЛЕ>**. Бернинди начар фикер төшенмичә, ачык рәвештә әйтүчән; эчкерсез, саф. *Атасы кебек җитез, хәрәкәтчән, ачык күңелле, сүзгә дә юмарт икән* (Ә. Еники. Соңгы китап). *Безне аларның ачык күңелле, хөр, кунакчыл булулары таң калдырды* (А. Нәҗми. Азат).
Төрдәше: ачык йөзле һ.б.

**АЧЫК КҮҢЕЛ БЕЛӘН.** Бернәрсәне дә яшермичә, намус белән, ихлас күңелдән. *Рангазар ачык күңел белән таң аттыра торган авыл булып чыкты* (Ф. Яхин.Тәкъдир хөкеме). *Чит кешеләргә ачык күңел белән караганнарының биш-алты тәрәзәсе урам якка борылган булса, кеше сөйми торганының бер-ике генә микән?..* (Р. Гаязетдин. Тәүбә көче).

**АЧЫК КҮҢЕЛЛЕЛЕК.** Намуслы, ихлас күңелле булу. *Шунлыктан бу көннәрдә авыл коммунистларыннан аеруча бердәмлек һәм ачык күңеллелек сорала* <…> (Ф. Хөсни. Җәй башы).

**АЧЫК <КЫНА> ИТЕП ӘЙТКӘНДӘ.** Яшермичә, аңлаешлы итеп әйткәндә. *Төгәлрәк һәм ачык итеп әйткәндә, иң элек Рәхимовка, аның тирәсендәге аппаратка хакимияткә озаграк калыр өчн кирәк бу* (Р. Вәлиев. Җанга уелган уйлар).

**АЧЫК ТА ТИШЕК.** Тоташ ярык (яки тишек, ертык) тулган. *Өстенә кигәнен кием дисәң, үпкәләр – ачык та тишек* (Сөйләм).

**АЧЫК ТА ТИШЕК, ТӘРӘЗӘ ДӘ ИШЕК.** Һәр ягыннан җил уйнаган ярлы өй. *Авыл читендә салам түбәле бер алачык тора иде – ачык та тишек, тәрәзә дә ишек* (Сөйләм).

**АЧЫК ФИКЕРЛЕ.** Акыллы, дөрес уйлаучы. *Хәсән мулла үзе дә ачык фикерле бер мулла иде* (З. Һади. Җиһанша хәзрәт). *Мөгаллимнәр өчен дарел-мөгаллимин кирәклеге вә иске мәдрәсәләрнең эшкә ярамаганлыгы да ачык фикерле кешеләр арасында кат-кат сөйләнә башлады* (Г. Исхакый. Ике йөз елдан соң инкыйраз).
Төрдәше: ачык карашлы.

**АЧЫК ХАТ.** 1. Почта карточкасына язылган хат. *Авылга шул көннәрдә генә өтермәдән ачык хат (открытка) килеп төшә* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).

2. Берәр кешегә атап, вакытлы матбугатта бөтен кеше укырлык итеп бастырылган хат. *«Татар кызларына» шигыре белән бер үк вакытларда әдип «Фикер» газетасында «Уральск имамнарына ачык хат» дигән мәкаләсен бастыра* (Р. Фәтхрахманов. Габдулла Тукай).

**АЧЫК ҺАВА.** 1. Бина тышы, саф һава. *Бәйрәм ачык һава астында дәвам итте* («Авыл таңнары» газ.).

2. Ялан, кыр. *Көзге юлда күрелгән кыенлыкларга караганда, Идел яры буенда, ачык һавада пароход көтүнең газабы зуррак булды* (К. Тинчурин. Мәрҗәннәр).

**АЧЫК ЧЫРАЙ<ЛЫ>.** Ягымлы, сөйкемле, мөлаем. *Әтинең ачык чырайлы булуы минем өчен дә күңелле иде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). – *Бүтән көннәрдә дә килеп йөр, энем,* – *дип, ачык чырай белән озатып калды* (В. Нуруллин. Ике урам арасы).
Төрдәше: ачык йөз һ.б.

**АЧЫК ЧЫРАЙ (ЙӨЗ) БЕЛӘН КАРШЫ АЛУ.** Килгән кешене хуш күңел белән елмаеп каршылау. – *Әссәлемегаләйкем, хуш киләсез,* – *дип, ачык чырай белән каршы алды Нигъмәти* (М. Әмирханов. Әлвидаг).
Төрдәше: кочак җәеп каршы алу.

**АЧЫК ЧЫРАЙ (ЙӨЗ) КҮРСӘТҮ.** Ягымлылык, мөлаемлык күрсәтү. *Һәркайсына ихтирамлы, игътибарлы булды, ачык чырай күрсәтте* (М. Галәү. Мөһаҗирләр). <…> *биргән вәгъдәсен онытмады, юлыннан читкә тайпылмады, юкбар кеше белән аралашмады, туган-тумачаны үзе аралашкан түгәрәккә кертмәде, ачык чырай күрсәткән туганнарың, берзаман өскә менгәч, ямаулык сорап киләчәген белә иде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**АЧЫК ЧЫРАЙ – ТАКТА ЧӘЙ.** Кунакчыл булу туында. *Ачык чырай – такта чәй дигәндәй, Газинур берьюлы тартынуын онытты*

(Г. Әпсәләмов. Газинур). *Әйе, Гөлзәрияне сорарга кайтуы бушка булмады, кем әйтмешли, вакыт уздырып, чабата туздырып йөрмәде, эш пеште – егетне бусагадан кире борып җибәрмәделәр, аңа кадер-хөрмәт күрсәттеләр, ачык чырай – такта чәй булды* (Р. Кәрами. Кая чабасың, гомер юртагы?).

Төрдәше: ипи-тоз – якты йөз.

*АЧЫКЛЫК* ❖ **АЧЫКЛЫК КЕРТҮ.** Яхшы аңлашылсын өчен, хәлне җентеклерәк төшендерү. *Бу мәсьәләгә ачыклык кертү кирәк дип уйлыйм* (Ә. Кәримуллин. Тел тарихы – халык тарихы ул). *Шушында мин хикәямә ачыклык кертергә тиешмен* (А. Тимергалин. Юл чаты).

*АЧЫКТАН-АЧЫК* ❖ **АЧЫКТАН-АЧЫК ӘЙТҮ (СӨЙЛӘҮ).** Яшереп тормыйча, барысын төгәл иттереп әйтеп бирү. *Әйе, Дикопольцев турында артында да әйтергә ярамаган нәрсәләрне үз күз алдында, ачыктан-ачык әйтә дә сала бит шул Айбулатов* (Г. Кашапов. Язмышыңа ышан).

*АЧЫК-ТИШЕКНЕ* ❖ **АЧЫК-ТИШЕКНЕ ЯМАУ (КАПЛАУ; ТЫГУ).** 1. Ертык яки тишек урыннарга ямау салу. *Урманга барыр өчен дип, киеменең ачык-тишекләрен ямап куйды* (Сөйләм).

2. Хуҗалыктагы җитешсезлекләрне төзәтү, рәтләү. – *Андрей Акимович, безнең хуҗалыкка моннан бик күп утын запасы кала бит. Ачык-тишекне тыгарга шәп була әле бу* (С. Рәфыйков. Тын елга буенда).

3. Тормышны бераз җайга салу. *Ләкин әле моның белән генә бөтен ачык-тишекләр ямалмый, хәл кыласы байтак мәсьәләләр бар, барсына берьюлы кул җитеп бетми иде* (С. Рәфыйков. Тын елга буенда).

*АЧЫЛА* ❖ **АЧЫЛА ТӨШҮ.** Төксе кыяфәтле кешенең, сөйләшә торгач, йөзе-теле ачылып китү. *Мәдинә апа, Әбүзәр абзый, Фатихәттәй гел сөйләп торганга, чәй яны бик ямьле иде, Гөлшәһидәнең дә күңеле ачыла төште, тартынулары кими башлады* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

Төрдәше: ачылып китү (сөйләшә башлау); ачылып ташлау.

*АЧЫЛЫП* ❖ **АЧЫЛЫП КИТҮ (СӨЙЛӘШӘ БАШЛАУ)** *к.* ачыла төшү. *Ләкин генерал һаман полковникны тотмакчы, аның берлә ачылып китмәкче булды* (Г. Исхакый. Өйгә таба). *Бермәлне, ачылып китеп, әтием сөйләгән иде үземә* (А. Әхмәтгалиева. Минем әтинең кызы).

Төрдәше: ачыла төшү һ.б.

**АЧЫЛЫП СӨЙЛӘШҮ.** <...> *ул әллә ничә мәртәбә бу хакта Шәмсүн белән ачылып сөйләшергә омтылды, ләкин һәр очракта ниндидер күзгә күренмәс киртәгә сөртенә килде* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

**АЧЫЛЫП ТАШЛАУ.** Ачык итеп сөйләшә башлау. *Әллә үзем аңсыз рәвештә артык ачылып ташладыммы? Нәрсәгә өмет итеп, минем дәрәҗәне төшерә?* (Х. Камалов. Үксезләр). *Димәк, куркытулары нигезсез, кемнең дә булса сынып, ачылып ташлавына өметләнәләр* (Ф. Садриев. Бәхетсезләр бәхете).

Төрдәше: ачыла төшү һ.б.

*АЧЫЛЫ-ТӨЧЕЛЕ* ❖ **АЧЫЛЫ-ТӨЧЕЛЕ БУЛУ (ЯШӘҮ).** Тату яшәмәү, берәрсе белән вакыт-вакыт кычкырышу, гауга чыгару. *Тормышта барысы да тыныч кына акмый инде, ачылы-төчеле булган вакытлар да килеп чыга* (Сөйләм).

*АЧЫЛЫШЛЫ* ❖ **АЧЫЛЫШЛЫ БУЛУ.** 1. Берәрсе алдында гаепле, яманатлы булып калу. *Берәү, биләгән дәрәҗәсеннән файдаланып, үз мәнфәгатен кайгырта, берәү, җәмгыятьчелек тәртибендә гомум эш өчен ачылышлы булып, ара бозып йөри...* (Ш. Галиев. Илһамым-мәхәббәтем).

2. Ике кешенең, бер-берсен рәнҗетеп, аралары бозылу. *Балаларың белән ачылышлы булып, хәбәрләрен дә ишетмичә яшәргә ярамый иде* (Н. Гыйматдинова. Үзем генә беләм...).

*АЧЫНЫ* ❖ **АЧЫНЫ ТАТУ.** Күп кайгылар күрү. *Ачыны татымаган – татлының тәмен белмәс* (Мәкаль).

Төрдәше: авызы пешкән өреп капкан (эчкән) һ.б.

**АЧЫНЫ ДА, ТӨЧЕНЕ ДӘ ТАТУ** *к.* авызы пешкән өреп капкан (эчкән). *Биштәрен җилкәсенә асып авылдан чыгып киткәч, аңа ачыны да, төчене дә татырга туры килде* (Сөйләм).

Төрдәше: авызы пешкән өреп капкан (эчкән) һ.б.

*АЧЫП* ❖ **АЧЫП БИРҮ.** 1. Ялган сөйләгәнен, начар эш эшләгәнен, зыян китергәнлеге һ.б. ны ачык итеп күрсәтеп бирү. *Шулай итеп, төрмә башлыгы, аерылышыр алдыннан, Самара егетенә НКВДның тагын бер вәхшилеген ачып бирә* (Д. Гыйсметдин. Атта да, тәртәдә дә...).

Төрдәше: ачып салу; битлеген ачу (алып ташлау): битлеген ерту; битлеген салдыру; гаебен ачу; йөз<ләр>ен ачу (ачып бирү); фаш итү.

2. Сөйләп бирү, серне чишү. *Берничә мәртәбә миңа үзенең серен дә ачып бирде* (А. Шамов. Кыз урлау).

3. Аңлатып бирү. *Карлы бозны эретердәй җылы / Язлар җитү белән теләгем. / Бар күңелемне ачып бирер идем, / Аңлаучысы булса йөрәгем* (А. Нәҗми. Аңларсыңмы?).

4. Сурәтләү, тасвирлау (сәнгатьтә һ.б.). *Куркам, аның иҗатын, аның шигъриятен бөтен тирәнлеге, зурлыгы белән ачып бирә алмам кебек...* (Г. Бәйрәмова. Яхшы атлар үргә чабып менә).

**АЧЫП ҖИБӘРӘ АЛМАУ.** Аңламау, сәбәбенә төшенә алмау. *Полковникның күз алдында бернәрсәне ачып җибәрә алмады, фәкать күңелен сыкратты, эчен әллә ник яндырды* (Г. Исхакый. Өйгә таба).

**АЧЫП САЛУ** *к.* арты ачылу. *Беркөнне алар барлык эч серләрен бер-берсенә ачып салдылар* (А. Алиш. Якты күл буе).

Төрдәше: арты ачылу һ.б.

*АЧЫ-ТӨЧЕ<НЕ>* ❖ **АЧЫ-ТӨЧЕ<НЕ> ЯРАТУЧЫ.** Кызыктыргыч ашамлыкларны яратучы. *Безнең өйдә ачы-төчене яратучы берәү генә, ул да булса – минем хатын* (Сөйләм).

*АЧЫСЫН-ТӨЧЕСЕН* ❖ **АЧЫСЫН-ТӨЧЕСЕН ТАТУ (КИЧЕРҮ; КҮРҮ)** *к.* ачы яшь түгү. *Әйдә булгач, әйдә! Язын-көзен гел бергә, рәхәтен-михнәтен, ачысын-төчесен бергә татыдык* (Г. Бәширов. Намус).

Төрдәше: ачы яшь түгү һ.б.

*АЧЫ<НЫ>-ТӨЧЕНЕ* ❖ **АЧЫ<НЫ>-ТӨЧЕНЕ ТАТУ (КИЧЕРҮ; КҮРҮ)** *к.* ачы яшь түгү. *Күп татыдым ачы-төчене мин / Туксан еллык тормыш юлымда* (М. Җәлил). *Бусы да буш түгел – ачы-төчене татыган хатын. Башыннан шактый күп нәрсә узган: мәхәббәт, бала табу, яраткан кешесеннән күңел бизү...* (М. Маликова. Басып сайрар талы бар).

Төрдәше: ачы яшь түгү һ.б.

*АШ* ❖ **АШ АЛДЫ <ЯСАУ>.** Ашау алдыннан, «аш сеңдерү» өчен диган булып, мәй эчү. *Кайтып табынга утыргач, аш алды ясап, әз генә кәефләнеп тә алганнан соң, тагын нигәдер Муса исенә төште* (Ш. Маннур. Муса).

**АШ АРТЫ.** 1. Ашаганнан соң, соңында бирелә торган җимеш суы яки башка төрле җиңелчә кабымлык. *Карчык аш арты кертә, ашыйлар* (Г. Исхакый. Мөгаллим). *Аш арты урынына да җиләк кенә хезмәт итә* (Р. Зарипов. Тирән тамырлы Түнтәрем).

2. *мыск.* Ахырдан сүз алып, кеше сөйләгәнне кабатлап сөйләү. – *Менә сезгә тагын бер генә татлы аш арты: бер оратор басып, саташкан күке кебек, кешеләр сөйләгәнне әйе-әйе дип кабатлап төште* (К. Тинчурин).

**АШ АРТЫННАН ГОРЧИЦА** *к.* алма артыннан торма 1, 2. *Хуҗа хатынның гына аштан соң бурыч турында сүз кузгатуы аш артыннан горчица кебек килеп чыкты* (Сөйләм).

Төрдәше: алма артыннан торма 1, 2.

**АШ АРТЫННАН – ЧӘЙ ШАРТЫННАН.** Аш артыннан чәй эчү табынның шарты саналу. *Бераз гына түзегез, борынгылар гадәте буенча, аш артыннан – чәй шартыннан: хуш исле чәй пешерәм сезгә* (Сөйләм).

**АШ АШАЛУ, ЯШЬ ЯШӘЛҮ.** Тормышында булган рәхәтен дә, михнәтен дә күргән; күп гомер иткән, күпне күргән. *Туксан тулгач, үкенеч юк, дисең, / Аш ашалган, яшем яшәлгән...* (Ф. Гыйззәтуллина. Их, яшисе килә!).

Төрдәше: ашасын ашаган, яшәсен яшәгән; ашыйсын ашаган, эчәсен эчкән; ашыйсын ашаган, яшисен яшәгән; ашы<йсы>н ашаган, яш<ис>ен яшәгән, <сөйгәнен сөйгән>; гомер узган, тун тузган, <буявы купкан>; җыры җырланган; туе узган, кием (туны) тузган; туй узган, тун тузган; эрлисе эрләнгән, бәйлисе бәйләгән; ясины укылган; яше яшәлгән, ашы ашалган; яшисен яшәгән, ашыйсын ашаган.

**АШ АШАП (АШАГАНГА) ҮЛМӘҮ.** Ашның файдалы гына булганлыгына ишарә. *Өстәл янына утыр әйдә, моңа кадәр берәүнең дә*

*аш ашап үлгәнен ишеткәнем булмады* (Сөйләм).

**АШ АШКА УРЫН БИРҮ.** Сый-хөрмәттән баш тартырга ярамауга ишарә. *Бер дә тартынып утырма, аш ашка урын бирә ул* (Сөйләм).
Төрдәше: аш ашка урын табу; аш ашка, урыны башка; төрле ашка – урын башка.

**АШ АШКА УРЫН ТАБУ** *к.* аш ашка урын бирү. – *Аш ашка урын таба, оланнар. Бер чыккач, озак итеп йөрисегез дә бар, талдырмасын* (М. Рәфыйков. Урманчы малае).
Төрдәше: аш ашка урын бирү һ.б.

**АШ АШКА, УРЫНЫ БАШКА.** 1. «Сыйлаганда һәр ризыкка, сыйга урын табыла, ашказаны кабул итә» мәгънәсендә. *[Хуҗа] Аш ашка, урын башка, Күктәге фирештәләр генә ашамый торалар, хәзрәт* (Н. Исәнбәт. Хуҗа Насретдин). – *Яңадан керәсез. Аш ашка, урыны башка* (Ф. Латыйфи. Себер хикәяте).

2. *шаярт., ирон.* «Һәрнәрсәнең файдаланыла торган үз урыны бар» мәгънәсендә. – *Мин инде ашап кына килгән идем килүен. – Аш ашка – урыны башка...* (Н. Исәнбәт).
Төрдәше: аш ашка урын бирү һ.б. (ике маддә өчен дә).

**АШ БАРМАУ.** Ниндидер сәбәптән бернәрсә дә ашый алмау (мәс., үңәчтән аш үтмәү; ризыкны ашказаны кабул итмәү һ.б.). *Табибларыбыз бер нәрсә дә таба алмыйлар, әллә табып тп әйтә алмыйлар. Тамагыма аш бармый* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).
Төрдәше: авыздан аш төшү һ.б.

**АШ БЕЛӘН АТКАНГА (АТКАНДА) ТАШ БЕЛӘН АТУ (ОРУ).** Яхшылыкка яманлык белән җавап бирү, хөрмәтсезлек күрсәтү. *Укыганда, колхоз ярдәм итеп тора да, аш белән атканга таш белән орып, кире кайтмыйча шәһәрдә калган иде!* (Г. Мөхәммәтшин. Якташлар).
Төрдәше: гөбәдиягә арт кую.

**АШ БЕЛӘН КАРШЫ АЛУ (ОЗАТУ).** Ачык йөз күрсәтү. *Андагы халык аларны кайнар аш белән каршы алды* (З. Зәйнуллин. Каршы таулар). *Ә гомер юлдашы һәрвакыт әзер аш белән каршы ала, озатып кала* («Әлмәт таңнары» газ.).
Төрдәше: ачык йөзле <булу> һ.б.

**АШ БИРҮ.** Кемне дә булса ашату-эчертү, аңа якты йөз күрсәтү. *Ташына аш бирсәң, бервакыт алдыңа килеп тезләнә* (С. Поварисов. Пәйгамбәр таңы). *Сине төн кунарга сыйдырганмы, җылы аш биргәнме?* (В. Имамов. Утлы дала).
Төрдәше: ачык йөзле <булу> һ.б.

**АШ БУ СИҢА.** 1. Күңелгә яту, файдалы ризык булу. – *Менә әни сиңа дип чишмә суында гына тавык пешереп җибәргән иде, аш бу сиңа* (Сөйләм).

2. Онытмаска акыл булу, сабак булу. *Минем Ибраһимымны бөтенләй үзеңә багындырып бетердең, Ибраһимны сарыга сабыштырып бетердең! Аш бу сиңа* (Г. Камал. Кайниш).
Төрдәше: аш булу.

**АШ БУЛДЫРУ.** 1. Гомумән ризык, азык-төлек булдыру. *Монда баит татар милләтен зурлау гына түгел, ә күпме кешегә эш һәм аш булдыру дигән сүз бу* («Безнең гәҗит» газ.).

2. Шулпалы ашны пешереп, өстәлгә куярлык итеп әзерләү. <…> *Хәйрия аш булдырырга торганда, Сәрвиназ ашыгып киенә башлады* («Казан утлары» ж.).

**АШ БУЛСЫН!** Кунакның сый-хөрмәт өчен рәхмәтенә каршы хуҗа әйтә торган изге теләк. *Хезмәтчесенә: «Су китер», – дип хитап кыйлганда, хезмәтчесе: «Аш булсын», – дип, су китереп бирде* (К. Насыйри). – *Аш булсын, – диде Фатихәттәй һәм, савыт-сабаларын җыештыра-җыештыра, үзалдына сөйләнә бирде* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).
Төрдәше: авызыңа бал <да май!> һ.б.

**АШ БУЛУ** *к.* аш бу сиңа 1, 2. *Шушы җирдә авызыңны ямьшәйтеп җибәргәндә дә, аш булыр иде бу инде сиңа* (М. Фәйзи).
Төрдәше: аш бу сиңа 1, 2.

**АШ КАЙТАРУ.** 1. Ашап туюны белдереп, кунакның ашъяулык читен бөкләве; аштан соң дога кылу. *Дога кылып, аш кайтаргач, ул, йомшак диванга утырып, чәй көткәндә, изрәп тә китте* (Г. Исхакый. Ул икеләнә иде).

2. Ашта булганнан соң, җавап итеп хуҗаларны да кунакка дәшү. *Татарларда кунакта булып кайткач, хуҗаларны да үзеңә ашка дәшү, ягъни аш кайтару гадәте бар* (Сөйләм).
Төрдәше: ашка аш белән җавап бирү; ашка аш <белән>, ташка таш <белән>; ашка каршы аш белән ату (кайтару); аш-су кайтару.

**АШ КӨТТЕРҮ.** Аш табынга китерелгәннән соң, сүз белән мавыгып китеп, яисә берәрсен көтеп, ашарга тотынмау. *Башланган сүзләрен бетереп, аш көттереп булса да, табын тирәсенә урнаштылар* (Сөйләм).

**АШ ОРЫР.** Аш-суны гаепләүгә каршы әйтелә. *Аш-суны хурларга ярамый, аш орыр үзеңне* (Сөйләм).

**АШ ӨСТЕ.** 1. Аш куелган табын. *Нинди ял сиңа. / Нинди аш өсте? / Һәрвакыт әзер./ Син бит баш өсте!* (Ш. Галиев. Өсте һәм асты).

2. Җентекләп, ваклыкларына кадәр өйрәнү, тикшерелү. *Шул кичне Әхмәдиләрдәге дуст-иш мәҗлесендә мәсьәлә бөтен аш өсте белән тикшерелде* (Г. Исхакый. Ул икеләнә иде).

3. Сүзнең дөреслеген раслауда аш-суны таныл итеп алу. – *Шул зобаный, шул хәсис мине контр дип сөйләшеп йөргән, имеш. Теле коргыры! Менә, аш өсте, шулай дигән, ди* (М. Хәсәнов. Язгы аҗаган).

**АШ ТАЛЫМЛАУ (ҮЗГӘЛӘҮ).** Бик сайланып, ашны-ризыкны аерым ашау. *Әмма дә балаларның рәхмәте аңа зур булды, алар безнең кебек аш талымлап тормады* (Т. Нурмөхәммәтов. Кабан күле, әй, алкын).

**АШ ТАШЫГАНДА – ЧҮМЕЧ, ТУФАН ТАШЫГАНДА – КӨЙМӘ <БУЛУ>.** Берәр нәрсәгә ихтыяҗ туганда, һаман бер кеше янына килеп җитүгә ишарә. – *Аш ташыганда – чүмеч, туфан ташыганда – көймә. – Андый сүз юк, Шәрифулла абзый. Син һәрвакыт колхозның терәге булдың* (Х. Сарьян. Бер ананың биш улы).

**АШ<ЛАР> ТӘМЛЕ БУЛСЫН.** Табын янына туры килгәндә, ашап утыручыларга әйтү сүзе. – *Исәнмесез, әфәнделәр. Аш тәмле булсын* (И. Нуруллин. Хәсрәт бакчасы). *«Ашыгыз тәмле булсын» дип әйтүчеләргә дә җавап кайтармый* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**АШ ТИЮ.** Ашарга мөмкинлек чыгу. *Тагы ун көн үткәч, кияү бөтен хәзерләнгән нәрсәләрне ашап бетереп кайтып китте, тагы Галәүләрнең авызларына кайнар аш тиде* (Г. Исхакый. Кияү).

Төрдәше: авыз итү һ.б.

**АШ ТӨРЛӘНДЕРҮ.** 1. Ашар өчен төрле-төрле ризык әзерләү. *Аш төрләндерергә кирәк, манный боткасы да туйдыра* (Р. Кәрами. Кая чабасың, гомер юртагы?).

2. Йөкле хатыннарның аш талымлавы. *Хатын-кыз балага узгач, аңарда аш төрләндерү ихтыяҗы туа* (Сөйләм).

3. *күч.* Нindидер бер объектны алыштыру. *Аш төрләндерер өчен, Казаннан танылган җырчылар Илсаф белән Илнар Сәйфиев тә киләчәк* («Кызыл таң» газ.).

4. Рухи бозыклык, сөяркә булып яшәүгә күнегү, женси тотнаксызлык. *Вакыт-вакыт «сулга каеру»дан туктап та карады, әмма, ире киткәч, тагы иске сукмакка баса иде, күрәсең, күңел азуы чиргә, «аш төрләндерүе» гадәткә әйләнгәндер* (Р. Кәрами. Сөеп туймас чакларың). *Шулай, кызым, ирләргә бервакытта да ышанып бетәргә ярамый, аш төрләндерергә яраталар алар* (Ә. Еники).

**АШ ТУЛЫ ЧҮЛМӘКТЕР, ЧӘЧРӘП КИТИМ, ШУЛАЙДЫР.** Сүзенең дөреслеген раслау өчен аш-су белән әйтелгән ант сүзе. – *Валлаһи, алдамыйм, ашы тулы чүлмәктер, чәчрәп китим, шулайдыр* (Сөйләм).

Төрдәше: айдыр әгәр һ.б.

**АШ ТҮГЕЛ (БУЛМАДЫ).** Рухи тынычсызлык барлыгын аңлата. *Һаман да әти белән әнинең йоклаганнары йокы, ашаганнары аш түгел* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**АШ УЗДЫРУ.** Табын әзерләп, мәҗлес үткәрү. *[Хәерниса] Бүген ул Бигәнәй ишанны чакырып аш уздыра икән, кибеткә бөтенләй төшмәс дигәч, аз булса да бирep җибәрмәсме, диеп, менә үзем килдем* (Г. Камал. Өч тормыш).

**АШ ҮТМӘҮ <ТАМАККА, ЭЧКӘ>** *к.* авыздан аш төшү. *Мансурның да, Татьяна Степановнаның да тамагыннан аш үтмәде* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

Төрдәше: авыздан аш төшү һ.б.

**АШ ХАКЫ.** Аш-сыйның дәрәҗәсе зур булуны аңлата. – *Егетне алдадым бит, ничек итеп рәнҗетмәскә? Аш хакы бар бит, дип ул да яшь түкте* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

Төрдәше: аш хакын саклау (хаклау).

**АШ ХАКЫН САКЛАУ (ХАКЛАУ)** *к.* аш хакы. – *Аш тозы, яки натрий хлориды – яшәү өчен*

*бик тә кирәкле матдә. Аш хакын хаклап баруыбыз, – дип җаваплады* («Заман сулышы» газ.).
Төрдәше: аш хакы.

**АШ ЯНЫНДА АТ КЕБЕК, ЭШ ЯНЫНДА ЭТ КЕБЕК.** Ашарга яратса да, эшләргә яратмаучы, ялкау. *Аш янында ат кебек, эш янында эт кебек* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).
Төрдәше: ашаганда ат кебек, эшләгәндә тай кебек <кенә>; ашаганда бүредәй, эшләгәндә шүредәй; эшләгәндә шүре күк, ашаганда бүре күк.

*АША* ❖ **АША БАРСА.** 1. «Урының булса, ашавыңны дәвам ит» мәгънәсендә. *Айсылу минем тезелеп киткән татлы ризыкларга ымсынып күз атуымны эләктереп алды булса кирәк, «уңайсызланып торма, аша барса» дип куйды* (Сөйләм).
Төрдәше: аша китсә 1.

2. Артыкка китсә, бик күп булса, бары тик. *Хәзер инде хәлфәләрдән курка торган заман түгел. Аша барса... мәдрәсәдән куарлар* (Г. Ибраһимов).
Төрдәше: аша китсә 2; күпкә китсә.

**АША КИТСӘ** *к.* аша барса 1, 2. – *Гөбәдияләре бигрәк тә тәмле, тагын аша китсә, – дип кыстады апа, чәй ясый-ясый* (Сөйләм). *Бүтәннәр бер мең дә ике мең, аша китсә биш мең биргәндә, мин үзем бер үзем илле мең бирдем!* (Х. Сарьян. Бер ананың биш улы).
Төрдәше: аша барса 1, 2.

**АША КИТҮ (УЗУ; ЧЫГУ).** Тиешле чамадан артып китү, артыгы белән, чамадан тыш. *Иң элек шушындый аша чыккан бдительныйлардан чистарырга кирәк иде безгә...* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**АША СУККАН ҖИЛ.** Үтәли исә торган җил (мәс., өйдә ишек тә, тәрәзә дә ачык булганда). *Аша суккан җил яман* (Мәкаль).

*АШАГАН* ❖ **АШАГАН АШКА ЙӨРҮ.** Чакырган кунак мәҗлесләренә йөрү. *Безнең әби, яше шактый булса да, ашаган ашка йөрергә ярата* (Сөйләм).

**АШАГАН БАР, ТУЙГАН ЮК.** Ашап туйгысыз тәмле сый, ашап туярлык түгел. – *Казанга баргач, «Чәй йорты»на керәм: андагы өчпочмакларны ашаган бар, туйган гына юк* (Сөйләм).

**АШАГАН ҖИРЕНӘ СЫЕР ДА КАЙТУ.** Берәрсе яшәгән яки кунакка төшкән җиренә озак кайтмый торганда әйтелә. – *Борчылма, әллә кая китмәс, ашаган җиренә сыер да кайта* (Сөйләм).

**АШАГАН ТАБАККА (САВЫТКА; ТАБЫНГА) ТӨКЕРҮ (ПЕС ИТҮ; ЧҮГӘЛӘҮ).** Игелексез, яхшылыкның кадерен белми торган; яхшылык иткән кешегә усаллык кылу. *[Бәкер] Хәзер инде менә, пожалуйте. Ашаган табакларына чүгәлиләр* (Ф. Бурнаш. Таң). – *Белемең бик сай, шулай да, олы яшьтә булуыңа карамастан, укуга теләгең барлыкны искә алып кабул иткән идек үзеңне мәдрәсәгә, әмма ашаган табагыңа төкерә торган кеше булып чыктың* <...> (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында). *Мәскәү кенәзе Бәчли, Кече Мөхәммәд әмерен тыңлап, шул кышлакка һөҗүм итте. Ашаган табагына төкергән нәрсә!* (Р. Зәйдулла. Илбәк).
Төрдәше: ашка таш ату; ашка таш белән бәрү (җавап бирү); ашъяулыкны пычрату; яхшылыкка начарлык белән җавап бирү; яхшылыкка яманлык белән кайтару.

**АШАГАН ТАМАККА НИ БАРМАС (БАРМЫЙ; КИТМӘС).** Чаманы белмәү, талымсыз булу. *Ул күп ашауны, тәмле тамаклыкны, корсак колы булуны зур түбәнлек саный («ашаган тамакка ни бармый!»), үзе шушы режимны тайпылышсыз саклаганга, үлгәнче зифа, ыспай гәүдәгә ия була* (Р. Әмирхан. Әмирханнар).
Төрдәше: аръягына чыгу һ.б.

**АШАГАН ТАМАККА ТАШПУЛАТ КИТҮ** *к.* ашаган тамакка ни бармас (бармый; китмәс). – *Ашаган тамакка ташпулат китә, диләр, китер монда чиле-пешле бәрәңгеңне* (Сөйләм).
Төрдәше: ашаган тамакка ни бармас (бармый; китмәс) һ.б.

**АШАГАН ТӘНГӘ ЯТМАУ.** Ашаганның файдасы күренмәү (ягъни тазаруы сизелмәү). *Кайвакытта агай-эне әти янына килеп зарлана иде: ат ябыга, ашаган тәненә ятмый* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).
Төрдәше: ашаган эчкә йокмау 1.

**АШАГАН ЭЧКӘ ЙОКМАУ.** 1. *к.* ашаган тәнгә ятмау. *Ашый, ашый, әмма файдасы күрен-*

*ми, ашаганы эченә йокмыймы әллә?* (Сөйләм).

Төрдәше: ашаган тәнгә ятмау.

2. Ашап туймау. *Теге ябык егет ашаган кебек тә түгел, ашаганы эченә йокмый, күрәсең* (Сөйләм).

*АШАГАНДА* ❖ **АШАГАНДА АТ КЕБЕК, ЭШЛӘГӘНДӘ ТАЙ КЕБЕК <КЕНӘ>.** Ашаганда яхшы ашап та, аз эшләүче турында. *Ашаганда ат кебек, эшләгәндә тай гына / Мукшы һәм әрзә телләреннән / Төн узмыйча көн килми* («Казан утлары» ж., 1980, 8).

Төрдәше: аш янында ат кебек, эш янында эт кебек һ.б.

**АШАГАНДА БҮРЕДӘЙ, ЭШЛӘГӘНДӘ ШҮРЕДӘЙ** *к.* аш янында ат кебек, эш янында эт кебек. *Ашаганда бүредәй, эшләгәндә шүредәй булган егет тә сезнең бригададанмы?* (Сөйләм).

Төрдәше: аш янында ат кебек, эш янында эт кебек һ.б.

*АШАГАННАРЫН* ❖ **АШАГАННАРЫН НИЧЕК КОСАРГА БЕЛМӘҮ.** Урлап яки кеше милкен туздырып тотылгач, ничек итеп акланырга белмичә азаплану хакында. *Хатынның сумкасын тартып алып качканда, җиңелрәк кебек иде, тотылгач, хәзер инде ашаганнарын ничек косарга белми* (Сөйләм).

**АШАГАННАРЫН ЧЫГАРУ.** Байлыкны урлаган, үзләштергән өчен үкенерлек итү. *– Ашаганнарын чыгарам мин аларның, – дип яный ул* (Т. Нәҗмиев. Сабаларда эчәр суым булгач...).

*АШАГАННЫ* ❖ **АШАГАННЫ АШ ИТМИ, ТАШ ИТӘ.** Вакланучы кешегә, «мин шулай эшли идем» дип җанга тиючегә карата әйтелә. *Ләкин ашаганны аш итмичә, таш итә башлагач, бу хәлгә Шәмсенур апа да түзмәде, беркөн «винегрет» ботканы кашыгы белән авызына китергәч, капмыйча туктап калды* (Т. Нурмөхәммәтов. Кабан күле, әй, алкын).

**АШАГАННЫ ЙОТЫП.** Иреннәрен ялап, ач күз белән карап торган кешегә карата. *Кеше ашаганны йотып тору яхшы кешенең эше түгел* (Н. Исәнбәт. Хуҗа Насретдин).

**АШАГАННЫ КАН ИТЕП КОСУ.** Нәрсәнедер намуссыз яки хаксыз рәвештә үзеңнеке итүне йөрәге белән кабул итмәү, шуннан газап чигү. *Кеше әйберен хаксыз рәвештә «ашаганлыгын» соңрак кына аңлый башлады, ашаганны кан итеп косу хәленә үк килеп җитте* (Сөйләм).

**АШАГАННЫ КАРА КАН ИТҮ.** Начар холыклы кешенең табын янында кычкырышып, талашып, ашарга ирек бирмәве. *Мәҗлес нигездә матур гына үтте, теге холыксыз Хәйдәр генә ашаганны кара кан итәргә маташты* (Сөйләм).

**АШАГАННЫ КИРЕ КОСТЫРУ.** Эшләгән яхшылыгын гел искәртеп, җанга тию. *Шуңа күрә аның Ниса апага: «Ашаганны кире костырып чыгарма», – дип әйтергә тулы хакы бар* (Т. Нурмөхәммәтов. Кабан күле, әй, алкын).

Төрдәше: ашатканын кире костыру.

*АШАГАНЫ* ❖ **АШАГАНЫ АЛДЫНДА, АШАМАГАНЫ АРТЫНДА.** Алды-арты ризык белән тулы, муллыкта яшәү. *Ашаганы алдында, ашамаганы артында, ит ашыйсың да май ашыйсың, Алланың биргәненә шөкер* (Милли-мәдәни мирасыбыз: Әстерхан татарлары).

Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

**АШАГАНЫ АШ ТҮГЕЛ.** 1. Ризыкның тәмсез булуына ишарә. *Хуҗаларны үпкәләтмәс өчен генә, өстәл артында бераз капкалап утырды, әма ашаганы аш түгел иде* (Сөйләм).

2. Рухи авырлыктан яки башка төрле сәбәптән ашый алмау, үзеңне көчләп кенә ашау. *Ашаганы аш түгел, ризык яна да бетә, күпме ашаса да, тәнгә сихәте юк* (Ә. Баянов. Аязучан болытлы һава).

Төрдәше: ашаганы аш <түгел>, йоклаганы (йокысы) йокы түгел (булмый); ашаганы аш <түгел>, күргәне көн түгел; ашаганы аш түгел, таш булып төшү; ашың аш, йокың йокы түгел (булмый); йокысы йокы, ашаганы аш түгел; эшләгән – эш, ашаган аш түгел; эчкән чәем чәй түгел, ашаганым аш түгел.

**АШАГАНЫ АШ <ТҮГЕЛ>, ЙОКЛАГАНЫ (ЙОКЫСЫ) ЙОКЫ ТҮГЕЛ (БУЛМЫЙ).** Ашаган ризык тамактан үтмәү, тамакка тыгылу. *Көннәр буе шул кызны уйлый, ашаганы аш түгел, йокысы йокы түгел* (Әкияттән). *Хатыннар да тынгы бирмиләр – ашаган аш түгел, йоклаган йокы түгел* (З. Зәйнуллин. Ат караклары).

Төрдәше: ашаганы аш түгел һ.б.

**АШАГАНЫ АШ <ТҮГЕЛ>, КҮРГӘНЕ КӨН ТҮГЕЛ** *к.* ашаганы аш түгел. *Ашаганым аш түгел, күргәнем көн түгел, башым тәмам диванага сабышып бетте инде* (Г. Камал).
Төрдәше: ашаганы аш түгел һ.б.

**АШАГАНЫ АШ ТҮГЕЛ, ТАШ БУЛЫП ТӨШҮ** *к.* ашаганы аш түгел. *Ашаганым аш түгел, таш булып төште дип нәкъ менә минем табын артыннан кузгалгандагы халәтем турында әйтәләрдер* (С. Якупова. Уран).
Төрдәше: ашаганы аш түгел һ.б.

**АШАГАНЫ БАЛ ДА МАЙ, <КАЗЫ ДА ЯЛ>** *к.* авыз балда, кул майда. *Белмим, ни җитмидер аларга: ашаганнары бал да май, казы да ял* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

**АШАГАНЫ ҮТМИ, КАПКАННЫ ДА КӨТМИ, НИ АШАСА, ШУЛ ҖИТМИ** *шаярт.* Азык биреп җиткерер хәл юк (ашказанының бик яхшы эшләве хакында). *Нигә ул шул кадәр симергән дисеңме? – Ашаганы үтми, капканны да көтми, ни ашаса, шул җитми* (Сөйләм).

*АШАДАН* ❖ **АШАДАН АША.** 1. Буй яткан әйберне аркылыга иңләп чыгу. *Берәве машинасына төягән бүрәнәләрен юлда аударып калдырган да, аңа ашадан аша чыгарга туры килде* (Сөйләм).

2. Тулып ташу. *Кечкенә генә инеш, эрегән кар суыннан тулышып, ашадан аша җәелә башлаган* (Сөйләм).

*АШАЛАМЫ* ❖ **АШАЛАМЫ ӘЛЛӘ.** Саранлыгыннан үзендә булган берәр нәрсәне башка кешегә биреп тормаучы турында. *Йә, бер үпсә шунда, нәрсә була инде, ашаламы әллә?..* (Х. Ширмән. Асылъяр).

*АШАМАГАН* ❖ **АШАМАГАН ИРЕНГӘН – ЭШЛӘМӘГӘН КӨСЕНГӘН**. *Аннан соң ул яшел тышлы китапта синең ишеләр турында бар, ди: «Ашамаган иренгән – эшләмәгән көсенгән» дип ташка басылган, ди* (Г. Мөхәммәтшин. Хуҗалар).

*АШАМАСТАН* ❖ **АШАМАСТАН ТАНА БАШЫН АШАГАНДАЙ.** Башта назланып утырып, акрын-акрын күп нәрсәләр ашап бетерү. *Бигрәк тә кызык кеше инде: башта сырмаланып, ялындырып утырды да, ашамастан тана башын ашагандай, алдындагыны ялтыратып куйды* (Сөйләм).
Төрдәше: ашамыйм дигән килен ашады җитмеш белен (алтмыш коймак ашаган); ашамыйм-ашамыйм дип, алтмыш белен ашаган; көязнең кулы җитмәс, назлының эше бетмәс.

*АШАМЫЙ* ❖ **АШАМЫЙ КОСАСЫМ КИЛӘ (КОСАРЛЫК БУЛДЫМ).** Күңел болгаткыч начар кеше яисә аның, «мин ашатам» дип, күзгә төртеп ашатуы турында. – *Уф, Аллам, аның үзеннән дә, сүзеннән дә ашамый косарлык булдым* (Сөйләм).

*АШАМЫЙМ-АШАМЫЙМ* ❖ **АШАМЫЙМ-АШАМЫЙМ ДИП, АЛТМЫШ БЕЛЕН АШАГАН** *к.* ашамастан тана башы ашагандай. *Ашамыйм, ашамыйм дигән алтмыш белен ашаган, дигән сыман, бүтән җырламам инде дигән Салават 10 августта башланачак киләсе сезон концертына чакырды* («Тамаша» ж.).
Төрдәше: ашамастан тана башын ашагандай һ.б.

*АШАМЫЙМ* ❖ **АШАМЫЙМ ДИГӘН КИЛЕН АШАДЫ ҖИТМЕШ БЕЛЕН (АЛТМЫШ КОЙМАК АШАГАН)** *к.* ашамастан тана башы ашагандай. *Ашамыйм дигән килен ашады җитмеш белен* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).
Төрдәше: ашамастан тана башын ашагандай һ.б.

*АШАМЫЙЧА* ❖ **АШАМЫЙЧА БЕТКӘН, КИМИЧӘ ТУЗГАН.** Берәр әйбернең кая юкка чыгуын белмәгәндә әйтелә. – *Минем яңа галстугым кая китте икән, ашамыйча беткән, кимичә тузганмы югыйсә?* (Сөйләм).

**АШАМЫЙЧА <ДА> ТУК БУЛУ.** 1. Яраткан ризыгыңны күреп тә тамак тую. – *Кызык та инде, тәлинкәгә түгәрәкләп тезгән кәләвәне күреп, ашамыйча да тук булдым* (Сөйләм).

2 *шаярт.* Берәр ризыкны артык мактаудан, аны күрмичә-ашамыйча да тамак тую. – *Булды-булды, артык мактама, ашамыйча да тук булдым кебек* (Сөйләм).

3. Яраткан кешеңнең йөзен күреп тә күңел булу. *Аны күргәч, мин, ничектер, тынычланып, рәхәтләнеп китәм, ашамыйча тук булган кебек* (Сөйләм).

*АШАП* ❖ **АШАП АЛУ.** Тиз генә ризык капкалау. *Шунда чәй кайнатып, кабыклы бәрәңге ашап алабыз да тагын эшкә тотынабыз* (Э. Мөэминова. Без дә үсеп җиттек).
Төрдәше: тамак ялгану; тамак<ка> ялгау (ялгап алу).

**АШАП КАРАУ** *к.* авыз итү. – *Бу аланда җиләк шундый күп, шулкадәр тәмле, син дә ашап кара әле, – диеп, уч тутырып җиләк алды да иренә сузды* (Д. Йосыпова. Аерма, язмыш!).
Төрдәше: авыз итү һ.б.

**АШАП ТУЙГАЧ – ТОЗЫ ЮК** *ирон.* Вакчыл, бәйләнчек кеше хакында (үзенә кирәге беткәч, кешегә яки әйбергә гаеп сылтау). *Әле генә белдеңмени аның кем икәнен – ашап туйгач – тозы юк* дигәндәй, гаеп эзләргә генә тора ул (Сөйләм).

**АШАП ТУЙМАГАННЫ ЯЛАП ТУЙМАССЫҢ.** «Һәр нәрсәнең чамасын белергә кирәк» мәгънәсендә. *Ашап туймаганны ялап туймассың диләрме әле?* (Ф. Хәбибуллин. Заман имтиханы).

**АШАП ҮТЕРҮ.** Бик каты тиргәү, орышу. – *Зинһар, итагатьлерәк бул. Мәрвияне дә ашап үтерәсең бугай, гел боек йөри* (Н. Гыйматдинова. Елан).

*АШАП-ЭЧЕП* ❖ **АШАП-ЭЧЕП ЙӨРҮ.** Кабак-рестораннарда акча туздырып йөрү. *Кәримнән изгелек көткәндә, әүвәл көндүк төн уртасына кадәр ашап-эчеп йөреп, исереп кайтудан башка файда күрсәтмәде* (Г. Исхакый. Бай угылы).

*АШАР* ❖ **АШАР АШЫ ЮК, КИЯР КИЕМЕ ЮК.** «Бик ярлы, бичара адәм» мәгънәсендә. *Бөлгенлеккә төшкәннән соң, ашар ашы юк, кияр киеме юк мескеннең* (Сөйләм).

**АШАР ТАМАК, ЙОТАР ЯТКЫЛЫК.** Әзерне ашап ятучы, әрәм тамак хакында. *Ничектер безнең тирәдә ашар тамак, йотар яткылык кешеләр артып китте әле* (Сөйләм).
Төрдәше: әрәмтамак булу һ.б.

*АШАРГА* ❖ **АШАРГА (АШАРЫНА) СОРАМЫЙ.** «Кирәге булмаса да, тик ятсын, берәр вакыт кирәге чыгар» мәгънәсендә. *Шулай борынгылар әйтмешли, һөнәр ашарга сорамый, һөнәр үзе ашата* (М. Хуҗин. Айның уты сүнгән). *Безгә кадәр торган, бездән соң да торсын, ашарга сорамый бит, дип кенә җавап биргәннәр* (Ә. Мәхмүди. Әче балан).

**АШАРГА СОРАУ.** Аяк киеме ябыштырган яки теккән җиреннән куба-сүтелә башлау. *Лилиянең кышкы итеге дә ашарга сорап авызын ачкан, ремонтка бирсәң дә быелга чыдарлык түгел, үзенә дә яхшы бүрек кирәк, ир кешенең бит башта йөзенә карыйлар, хатын-кызның гына ул аякларын тикшерәләр* (К. Кәрим. Зур акчалар).

*АШАРДАЙ* ❖ **АШАРДАЙ <БУЛЫП; ИТЕП> КАРАУ.** Ачуланып, нәфрәтләнеп (яки кызыгып) карау. *(Сәлимҗан ашардай булып карап тора, Зөләйха җыларга тотына, яшенә карлыгып)* (Г. Исхакый. Зөләйха). *Җитмәсә, ашханә төбендә тәмәке көйрәп утырган эшсез һәм кыяфәтсез мужиклар аларган күзләре белән аңа ашардай итеп карадылар* (Ф. Яхин. «Татар»).
Төрдәше: ашарлык булып карау.

*АШАРЛЫК* ❖ **АШАРЛЫК БУЛЫП КАРАУ** *к.* ашардай <булып; итеп> карау. – *Ир-ат халкының гадәте инде ул хатын-кызга ашарлык булып карау* (Ә. Сафиуллин. Кешене өмет яшәртә).
Төрдәше: ашардай <булып; итеп> карау.

*АШАСАҢ* ❖ **АШАСАҢ, АЗЫК ТҮГЕЛ, ТҮКСӘҢ, ЯЗЫК ТҮГЕЛ (АШАМАСАҢ ЯЗЫК ТҮГЕЛ).** Начар әзерләнгән, сыйфатсыз аш-су. – *Балыкның яхшысын токкансың, тик балык ашы гына ашасаң, азык түгел, түксәң, язык түгел – берәр остадан өйрән* (Сөйләм).

*АШАСЫН* ❖ **АШАСЫН АШАГАН, ЯШӘСЕН ЯШӘГӘН** *к.* аш ашалу, яшь яшәлү. *Ләкин бу үткән белән юану, гомер юлының байтак өлешен узган, кем әйтмешли, ашасын ашаган, яшәсен яшәгән, күрәсен күргән кешенең яшьлекне сагынуы, гап-гади бер җирсү генә түгел* (Ф. Латыйфи. Ат җене).
Төрдәше: аш ашалу, яшь яшәлү һ.б.

*АШАТКАНЫН* ❖ **АШАТКАНЫН КИРЕ КОСТЫРУ.** Ашатканын һәрвакыт искә алып, шуның белән теңкәгә тию. *Теңкәгә тидең инде табада пешергән бәрәңгеңне сөйләп, ашатканыңны кире костырырга маташуыңмы?* (Сөйләм).
Төрдәше: ашаганны кире костыру.

*АШАТЫП-ЭЧЕРТЕП* ❖ **АШАТЫП-ЭЧЕРТЕП ТОТУ.** Туендыру, тәрбияләп үстерү. *Ашатып-*

*эчертеп торсагыз, аннары, үзегез кайткан-да, мине дә Казанга алып кайтсагыз, – шул җитә* (З. Бигиев. Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә).

*АШАУ* ❖ **АШАУ БАЙДАН, ҮЛЕМ (ӘҖӘЛ) ХОДАЙДАН** *ирон., шаярт.* 1. Авырлыклар күрмичә яшәү. – *Сез чолан күләгәсендә генә утырып, каравылчы-нидән курыкмыйча, әзер юкә мунчаладан гына, иртәдән кичкә кадәр чабата үреп утырырга риза булырыегызмы? Өстәвенә тагы... ашау – байдан, үлем – Ходайдан, дигәндәй* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы).

2. *к.* арба ватылса – утын, үгез үлсә – ит. *Ашау байдан, үлем ходайдан дигәндәй, нимес килергә дә уйламый ахрысы бу якка* (З. Зәйнуллин. Каршы таулар).

Төрдәше: арба ватылса – утын, үгез үлсә – ит һ.б.

**АШАУ ӨЧЕН <ГЕНӘ> ЭШЛӘҮ.** Дөньяда ашаудан башка бернинди кайгысы булмаган кеше турында. *Ә сез ашау өчен эшлисезме, әллә эшләү өчен ашыйсызмы?* («Заман сулышы» газ.).

Төрдәше: ашау өчен <генә> яшәү; әвен чыпчыгына әверелү; тамак өчен <генә> эшләү.

**АШАУ ӨЧЕН <ГЕНӘ> ЯШӘҮ** *к.* ашау өчен <генә> эшләү. *Бу карт гүя ашау өчен генә яралган, ашау өчен яши һәм ашап үләчәк икән диярсең: бөтен эше шуңа җайланган, сүзе дә шуңа корылган иде* (Х. Хәйруллин. Ургыл).

Төрдәше: тамак өчен <генә> яшәү.

**АШАУ – ПЫЛАУ, ЙӨРҮ – ЫЛАУ.** Ваемсыз кешеләр хакында; казна хисабына командировкага йөрүчеләр хакында да. *«Ашау – пылау, йөрү – ылау» дип, күбрәк җылы якларга йөрергә ярата иде* (Сөйләм).

Төрдәше: йөрү – ылау, ашау – пылау.

**АШАУ УЗМАУ (ҮТМӘҮ)** *к.* аппетит булмау. *Көндез тамактан ашау үтмәде* (Н. Гыйматдинова. Җәза). – *Фәнис абый, башта ашау үтми, дигән идегез* (Т. Нәҗмиев. Тагын... Тагын...).

Төрдәше: аппетит булмау һ.б.

*АШАУГА* ❖ **АШАУГА АЛДАНЫП, АЧ КАЛУ** *шаярт.* Нәрсәләрдер капкалап, көндезге яки кичке ашка өлгермәү. *Күршеләрдә билле перәннек ашауга алданып, ач калганмын* (Сөйләм).

*АШАУДАН* ❖ **АШАУДАН АНСАТ, ЙОКЛАУДАН ҖИҢЕЛ.** Кайбер эшне җиңелгә санап башкару. – *Өчпочмак пешерүме – борчылма, син йоклап алганчы, өстәлдә елмаеп утырыр – минем өчен ашаудан ансат, йоклаудан җиңел эш ул* (Сөйләм).

**АШАУДАН КАЛУ** *к.* авыздан аш төшү. – *Ашаудан калып, саргаеп кипкән идем, шушы суны эчә башлавым булды, аппетитым ачылды, күпмедер вакыттан бүре урынына ашый башладым, рагым да юкка чыкты, ди* (Ф. Садриев. Кышкы яшен).

Төрдәше: авыздан аш төшү һ.б.

*АШАУ-ЭЧҮДӘН* ❖ **АШАУ-ЭЧҮДӘН КАЛУ** *к.* авыздан аш төшү. *Апам тәмам авыруга сабышты, ашау-эчүдән калды* (Ф. Төхбәтуллин. Өй артында шомыртым бар). *Ашау-эчүдән калган, йокысы качкан кызын Таймус патша Мисыр хөкемдарына кияүгә бирергә ризалаша* (Р. Зәйдулла. Татар тажы).

Төрдәше: авыздан аш төшү һ.б.

*АШКА* ❖ **АШКА АЛУ.** Кунакка, аш мәҗлесенә чакыру. <…> *ул шул арада капка төбенә ашка алырга килгән кешене күрсәтеп: «Остазбикә калсын, без Корбанколый агай белән бергә китик инде», – дия иде* (Г. Исхакый. Сөннәтче бабай). *Әле дә булса хәтерендә Асылханның, этисе зурдан кубып, Табул ягыннан кайткан бер атаклы Себер баен ашка алырга дип әзерләнеп йөрде* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!).

**АШКА АШ БЕЛӘН ҖАВАП БИРҮ** *к.* аш кайтару 2. *Игелекне аңлап, берәр заман ашка аш белән җавап бирмәсләрме?...* (В. Имамов. Утлы дала). *Язучы андыйларга ашка аш белән җавап бирергә, ягъни үзе дә аларны төрлечә мактарга, күтәрергә тырыша* («Казан утлары» ж., 1983, 12: Яңа бурычлар).

Төрдәше: аш кайтару 2 һ.б.

**АШКА АШ <БЕЛӘН>, ТАШКА ТАШ <БЕЛӘН>.** «Кешегә яхшылык итсәң, – яхшылык, яманлык итсәң яманлык кайтыр» мәгънәсендә. *Күпчелектә ашка – аш белән, ташка таш белән кайтаралар* (Сөйләм).

Төрдәше: аш кайтару 2 һ.б.

**АШКА ДИСӘҢ – ЗӨБӘЙДӘ, ЭШКӘ ДИСӘҢ – ЮК ӨЙДӘ.** Эштә күренмәсә дә, табын янында урыны түрдә булучан кеше турында. *Түр башында утырган ханымны күрәсеңме,*

*«ашка дисәң – Зөбәйдә, эшкә дисәң – юк өйдә» дип, аның турында әйтәләр* (Сөйләм).

**АШКА КАРШЫ АШ БЕЛӘН АТУ (КАЙТАРУ).** Яхшылыкка яхшылык белән җавап бирү. *Аяз абыйның тагын бер күркәм ягы – ашка каршы аш белән кайтаруыдыр* (А. Гыйләҗев. Истәлекләр). *Ташка аш белән түгел, ашка аш белән атсак иде без...* («Безнең гәҗит» газ.).

Төрдәше: аш кайтару 2 һ.б.

**АШКА КӨЯ БУЛЫП ТӨШҮ** *к.* ашка <кара> таракан булу (булып төшү; төшү) 1. *Безнең ашка көя булып / Бүтән төшмәсен, дигән* (Х. Хөснуллин. Кәгазь җыю кооперативы).

Төрдәше: ашка <кара> таракан булу (булып төшү) һ.б.

**АШКА <КАРА> ТАРАКАН БУЛУ (БУЛЫП ТӨШҮ).** 1. Аш мәҗлесенә җыелган кешеләр ашый башлауга, кирәкмәгән берсе килеп керсә, аны да табын янына чакырырга мәҗбүр булу; чакырылмаган кунак. *Тир түгеп тапкан ашыма гел таракан булды кемдер?!* (Р. Рахмани. Кемдер...). *Карале, малай, безнең ашка үзеңнең таракан булып төшүең җитмәгән, инде тагын бер кияү алып килгәнсең түгелме?* (Җ. Дәрзаман. Җир авазы).

2. Берәр киңәш-табыш, әңгәмә вакытында чит кешенең килеп керүе. – *Ярамый, Гафур Сөләйманович, ярамый! Син нәрсә, абзыйларның ашына таракан булып төшәсеңме?* (Н. Гыйматдинова. Үзем генә беләм...).

3. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәткә тыгылу. *Дүрткүз гашыйкларның ашына кара таракан булып төште тәки* (М. Әмирханов).

Төрдәше: ашка төшкән таракан <кебек карау> (өч маддә өчен дә).

**АШКА ТАРАКАН САЛУ.** Кемгә булса да астыртын рәвештә әшәкелек, яманлык итү. – *Дөнья бу... Ашына таракан салдыңмы?* («Кызыл таң» газ., 29.06.2013).

**АШКА ТАШ АТУ** *к.* ашаган табакка төкерү (пес итү; чүгәләү). *Нифаковның ашка таш атуы барысын да нык гаҗәпләндерде* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым). *Ашка таш атып җавап саплый торган нинди нәгаләт бу?!* (В. Имамов. Сөләйман солтан).

Төрдәше: ашаган табакка төкерү (пес итү; чүгәләү) һ.б.

**АШКА ТАШ БЕЛӘН БӘРҮ (ҖАВАП БИРҮ; КАЙТАРУ)** *к.* ашаган табакка төкерү (пес итү; чүгәләү). – *Миңа бер олуг изгелек эшләгән идең инде, монысы икенчесе. Гомеремдә дә онытмам. Ашка таш белән җавап бирә торган кеше буласым килми* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет). – *Әлбәттә, ашка таш белән кайтару хата булыр!* (Ф. Яхин. Ясалма кешеләр, яки Хикәят бакчасы җимешләре).

Төрдәше: ашаган табакка төкерү (пес итү; чүгәләү) һ.б.

**АШКА ТӨШКӘН ТАРАКАН <КЕБЕК КАРАУ>** *к.* ашка <кара> таракан булу (булып төшү; төшү) 3. *Бар да үз кешеләр, ә менә мин чит кеше, – диде ул үз-үзенә. – Ашка төшкән таракан* (А. Вергазов. Үзеңә кайту). *Аларга Шәмси мулла белән остабикә генә ашларына төшкән таракан кебек итеп карыйлар иде* (М. Галәү. Мөһаҗирләр).

Төрдәше: ашка <кара> таракан булу (булып төшү; төшү) 3.

**АШКА ТӨШКӘН ЧЕБЕН КЕБЕК.** Һич көтмәгәндә, уйламаганда булган эш (вакыйга, хәл һ.б.) хакында. *Маузер кайчан авылга кайтып төште соң әле ул? Көтмәгәндә, уйламаганда, ашка төшкән чебен кебек* (Р. Зәйдулла. Кыска ялганыш).

*АШКАЗАНЫ* ❖ **АШКАЗАНЫ КОТЫРУ.** Бик нык ашыйсы килү. *Кичке ашны ашамаган ашказаны котырып китте* (А. Гыйләҗев. Өч тәгәрмәчле арба).

Төрдәше: ашказаны котыру; ашказанын мәчеләр тырнау; ашказанында <ач> бүреләр улау; ашказанында көчекләр өрә башлау; ашказанында өч тешле тегермән ташы әйләнү; ашказанында шүрәлеләр утын кисү; бил каешы бушау; вак эчәкләрне саву 2; эчтә <ач> бүреләр улау; эчтә көчек өрү; эчтә «оркестр» улау; эчтә шайтаннар утын кисү; эчтә этләр улау.

**АШКАЗАНЫ ЭШЛӘМӘҮ.** Кешеләрдә яки хайваннарда аш кайнату органының бозылуы. *Анннары ашказаны эшләми, эч кибә һәм башка чирләр бар дип зарланабыз* («Безнең гәҗит» газ.). *Каен бөресе төнәтмәсе ашказаны эшләмәгәндә тире, буын авырулары, подагра булганда, салкын тигәндә файдаланыла* («Шәһри Казан» газ.).

*АШКАЗАНЫН* ❖ **АШКАЗАНЫН МӘЧЕЛӘР ТЫРНАУ** *к.* ашказаны котыру. *Ашказанымны мәчеләр тырный... Көндез ипи кисәге капкан килеш...* (Н. Гыйматдинова. Сөйлим, тыңла...).
Төрдәше: ашказаны котыру һ.б.

*АШКАЗАНЫНДА* ❖ **АШКАЗАНЫНДА <АЧ> БҮРЕЛӘР УЛАУ** *к.* ашказаны котыру. *Ике порция туралган яшелчә, ягъни мәсәлән, винегрет, манный ботка, ике стакан чәй һәм ярты батон белән ашказанында улаган бүреләрне бер-ике сәгатькә тынычландырып була* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет). *Ә гарип ир, чыннан да, инде ничәмә-ничә тәүлек буена бер кабым икмәк тә күрми тилмерә, ашказанында бүреләр улый иде.* (В. Имамов. Утлы дала).
Төрдәше: ашказаны котыру һ.б.

**АШКАЗАНЫНДА ЙӨЗ БҮРЕ ТУЙ ҮТКӘРҮ** *к.* ашказанында <ач> бүреләр улау. – *Әни, капкалап алырга берәр нәрсә юкмы, ашказанымда йөз бүре туй үткәрә минем!* (Сөйләм).
Төрдәше: ашказанында <ач> бүреләр улау һ.б.

**АШКАЗАНЫНДА КӨЧЕКЛӘР ӨРӘ БАШЛАУ** *к.* ашказанында ач бүреләр улау. *Абый белән су велосипедында йөри-йөри ашказанында көчекләр өрә башлагач, йөгереп диярлек өйгә кайтып, ипи белән казылык ашап куйган идем шул* (Р. Бәшәр. Ачык капка).
Төрдәше: ашказаны котыру һ.б.

**АШКАЗАНЫНДА ӨЧ ТЕШЛЕ ТЕГЕРМӘН ТАШЫ ӘЙЛӘНҮ** *к.* ашказаны котыру. *Ашказанында әйләнгән өч тешле тегермән ташларыннан кая ди дөнья матурлыгы, кызлар матурлыгы турында да җырлыйсы килми* (А. Хәлим. Читтә).
Төрдәше: ашказаны котыру һ.б.

**АШКАЗАНЫНДА ШҮРӘЛЕЛӘР УТЫН КИСҮ** *к.* ашказаны котыру. *Кемдер әйтмешли, ашказанында шүрәлеләр утын кисә...* (Р. Низами. Бомж).
Төрдәше: ашказаны котыру һ.б.

*АШЛЫ* ❖ **АШЛЫ СУ.** Эремәләр катышкан каты су, болгатып әзерләнгән туклыклы сыекча, крахмаллы су. *Мин сиңа ашлы су чиләге түгел, савыт-сабаны ә-нә кайда юалар* (Н. Әхмәдиев. Амбирак). *Өйдән, малларга дип, ашлы су күтәреп чыккан Мөсмирәнең, капка төбендә ят кеше күреп, чиләге чак кына кулыннан төшеп китмәде* (Р. Кәрами. Каргышлы этаплар).

*АШ-СУ* ❖ **АШ-СУ КАЙТАРУ** *к.* аш кайтару 2. *Кече атнада алар аш-су кайтару мәҗлесенә әзерлек башладылар* (Сөйләм).
Төрдәше: аш кайтару 2 һ.б.

**АШ-СУ КҮРГӘН.** Кунак булып йөрешкән кешеләр турында. *Аш-су күргән дус-ишләрем бары да миннән качып беттеләр, һәммәсе кырын күз белән карыйлар* (Г. Камал). *Бергә гомер иткән, яхшылыгын, яманлыгын бергә кичергән, бергә аш-су күргән кешеләр онытыламыни* (Г. Ибраһимов).

**АШ-СУ ТӨРЛӘНДЕРҮ** *к.* аш төрләндерү. *Дөресен әйткәндә, төпкелдә яшелчә-җимеш үстерүгә, алардан аш-су төрләндерүгә бигүк илтифат итеп бармаганнар* («Кызыл таң» газ.).
Төрдәше: аш төрләндерү.

*АШ<КА>-СУГА* ❖ **АШ<КА>-СУГА ЙӨРҮ.** Кунакка бару, аш мәҗлесләренә йөрү. *Тракторга утырып басу сөрдек, / Бәйрәмнәрдә ашкасуга йөрдек – / Каян килсен безгә дошманлык!* (Г. Афзал. Бергәлек).

*АШ-СУДАН* ❖ **АШ-СУДАН ЗУР (ОЛЫ; ӨСТЕН; ЮГАРЫ) БУЛУ.** Сый-хөрмәттән баш тарту, ризыкны хөрмәт итмәүгә ишарә. – *Чакырганда, кил, табын янына утыр: аш-судан олы булма* (Сөйләм).
Төрдәше: аштан зур (олы; өстен; югары) булу.

**АШ-СУДАН КАЛДЫРМАУ.** «Кунак җыйганда, безне дә калдырмый» мәгънәсендә. *Шуңа күрә алар еш күрешәләр, бер-берсен аш-судан калдырмыйлар, рәхәтләнеп эч серләрен бүлешәләр* (Ф. Яруллин. Күршеләр).

*АШ<ЛЫ>-СУЛЫ* ❖ **АШ<ЛЫ>-СУЛЫ БУЛУ** *к.* авыз балда, кул майда. *Өй салганда, нигезгә, беренче бүрәнә астына, көмеш тәңкә куеп калдыралар. Шулай иткәндә, бу өй эче ашлысулы була, өй хуҗасы бай була, имеш* (В. Булатов. Гореф-гадәт, йолаларыбыз).
Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

*АШ-СУЫМНЫ* ❖ **АШ-СУЫМНЫ ЭЧТЕҢ, ЙӨЗ СУЫМНЫ ТҮКТЕҢ.** Гадәттә чакрылмаган кунакны яки күңеленә хуш килмәгән кешене ашатып-эчертеп озатканда, аның артыннан

әйтелә. *[Хуҗа] Аш-суымны эчтең, йөз суымны түктең! (Артыннан табагы белән суны сибә)* (Н. Исәнбәт. Хуҗа Насретдин).

*АШТАН* ❖ **АШТАН БАШ ТАРТУ.** 1. *к.* авыздан аш төшү. *Сәлимә, кипкән иреннәрен көчкә әйләндереп, тамагыннан азык үтмәүне сылтау итеп, аштан баш тартты, кулы белән Салихҗанга ишарәләп, нидер аңлатырга тырышты, сүзен әйтергә хәле җитмәде, тотлыгып калды* (Г. Исхакова. Урланган бәхет).
Төрдәше: авыздан аш төшү һ.б.

2. Ашарга теләмәү. *Явыз ниятле кеше генә аштан баш тарта ул* (А. Шамов). *Хөсәен, ашыгып, баскычтан менде, хатынына бер-ике җылы сүз әйтте, тик өйгә керү белән аштан баш тартып, китап, брошюралар актарырга тотынды* (А. Расих. Ямашев).

**АШТАН ЗУР (ОЛЫ; ӨСТЕН; ЮГАРЫ) БУЛУ** *к.* аш-судан зур (олы; өстен; югары) булу. *– Кем, Якуб, син алай аштан зур булма әле, – дип, Гафият башта әйбәтләп, симез сарык итеннән пешергән токмач ашап, чәй эчеп алуны яклады* (И. Гази).
Төрдәше: аш-судан зур (олы; өстен; югары) булу.

**АШТАН КАЛУ (ЯЗУ).** Ризык ашый алмас хәлгә килү; *к.* авыздан аш төшү. *Шәяхмәт аштан язды. Саргайды, кипте* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала). *Югыйсә аштан калды, саргайды, чак кына кузгатсаң, сөякләре шылтырар сыман* (М. Хәбибуллин. Хан оныгы Хансөяр).
Төрдәше: авыздан аш төшү һ.б.

**АШТАН ОЛЫ ТҮГЕЛСЕҢ (БУЛМАССЫҢ).** Аш ашаганда килеп кергән кеше табынга утырудан баш тартканда әйтелә (ризыкны хөрмәт итмәүгә ишарә). – *Аш өстенә килеп кергәнсең икән, табынга уз. Аштан олы түгелсеңдер* (М. Маликова. Кызыл гөл).

*АШЪЯУЛЫКНЫ* ❖ **АШЪЯУЛЫКНЫ ПЫЧРАТУ** *к.* ашаган табакка төкерү (пес итү; чүгәләү). *Нәкъ болар шикелле үк качак Туктамышны унике ел элек колач җәеп каршылаган иде дә бит, әнә мәрхәмәт белмәс ул соран җан аның ашъяулыгын пычратып җавап бирде* (В. Имамов. Карабәк).
Төрдәше: ашаган табакка (савытка; табынга) төкерү (пес итү; чүгәләү) һ.б.

*АШЫ* ❖ **АШЫ БАРНЫҢ ЭШЕ БАР.** «Һөнәре яки кәсебе булган кешенең ашарына ризыгы да бар» мәгънәсендә. *Борчылма, ул бу дөньяда югалып калмас – ашы барның эше бар, диләр* (Сөйләм).

**АШЫ – МАЙ, ЭЧЕ БӨЙРӘК, СӨТ ӨСТЕ КАЙМАК.** Бик муллыкта, кадердә яшәүче кеше турында. *Фольклор әсәрләрендә «аның ашы – май, эче бөйрәк, сөт өсте каймак» дигән гыйбарә юк-юк та очрый* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

**АШЫ ЮК.** Ашарлык ризыгы булмау. *Останың осталыгын кимсетү булып яңгырамасын берүк, ләкин Фәһим – әйбәт мәгънәдә «эш аты» (эше юкның ашы юк, ләбаса)* (Н. Гамбәр. Кояшлы тауга күтәрелү).

**АШЫ ЮК УРАЗА ТОТАР, ЭШЕ ЮК НАМАЗ УКЫР** *иске, киная.* Фәкыйрь кешеләрнең еш кына ашарына булмавы, ә эшләргә яратмаганнарның мәчет тирәсендә чуалулары турында. *– Ашы юк ураза тота, эше юк намаз укый* (В. Имамов. Нәзер).

*АШ<ЛАР>ЫГЫЗ* ❖ **АШ<ЛАР>ЫГЫЗ ТӘМЛЕ БУЛСЫН!** Ашарга җыенган яисә аш ашап утырган кешегә яхшы теләк, итагать сүзе. *«Ашыгыз тәмле булсын» дип әйтүчеләргә дә җавап кайтармый* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

*АШЫГЫП* ❖ **АШЫГЫП АЛГАРАК КИТҮ.** Нәрсәне булса да, эзлеклелеген, чиратын сакламыйча, алданрак эшләп кую. – *Син, дустым, ашыгып алгарак киткәнсең, хәзер сиңа кирәкле детальне көтеп торасың инде* (Сөйләм).

*АШЫГЫЧ* ❖ **АШЫГЫЧ АВЫЛ КЕШЕСЕ** *шаярт.* Ашыгыч кешедән көлеп әйтелә. – *Теге ашыгыч авыл кешесе ут төрткән кебек тагын чыгып йөгерде* (Сөйләм).

**АШЫГЫЧ РӘВЕШТӘ.** Тиз арада, кыска вакыт эчендә. *[Беренгард] Безгә ашыгыч рәвештә аларга каршы чара күрергә кирәк* (А. Алиш. Кечкенә тоткын).

**АШЫГЫЧ ТҮГЕЛ.** Ашыгасы юк, көтәргә була. – *Сәдакасы качмас, анысы ашыгыч түгел, – дип, кырын-кырын гына басып, акрын гына чыгы китте* (Ф. Әмирхан. Фәтхулла хәзрәт).

*Муенсаларны төштән соң да тезәргә була, ашыгыч түгел...* (М. Галәү. Болганчык еллар).

**АШЫГЫЧ ЭШКӘ ШАЙТАН КАРЫША (КАТЫША).** «Ашыгып эшләгән эшнең нәтиҗәсе начар булырга мөмкин» мәгънәсендә. *Ашыгыч эшкә шайтан катыша* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

*АШЫГЫЧЛЫК* ❖ **АШЫГЫЧЛЫК БЕЛӘН.** 1. Кызып китеп, белешмичә. *Саф мәхәббәтнең аңлашылырлык вакыты юк – ашкына ул, ашыгычлык белән ике арага кергән ялгышларны язмыш итәргә ашкына* (К. Кәримов. Сакау күке).

2. Бик тиз, кичекмәстән. *Аларга кирәк булган вак кисәкләрен дә ашыгычлык белән җибәрүне сорыйбыз* (А. Алиш. Якты күл буе).

*АШЫЙК* ❖ **АШЫЙК ТА КАЧЫЙК ДИГӘН КЕБЕК.** Очраклы туры килгән кунакта яки мәҗлестә тиз генә ашап бетереп, чыгып китәргә ашыккан кеше турында (гадәттә, уен сүз буларак әйтелә). *«Ашыйк та качыйк» дигән кебек, чынаягын каплады да урыныннан торды* (Сөйләм).

*АШЫЙСЫН* ❖ **АШЫЙСЫН АШАГАН, ЭЧӘСЕН ЭЧКӘН** *к.* аш ашалу, яшь яшәлү. *Кортка ашыйсын ашаган, эчәсен эчкән* (Н. Гыйматдинова. Синдә минем хакым бар).

Төрдәше: аш ашалу, яшь яшәлү һ.б.

**АШЫЙСЫН АШАГАН, ЯШИСЕН ЯШӘГӘН** *к.* аш ашалу, яшь яшәлү. *Гомер юуе дигәндәй колхоз идарәсендә җыештыручы булып эшләп, ике ел элек кенә лаеклы ялга чыккан кешене ашыйсын ашаган, яшисен яшәгән дип әйтергә тел әйләнмәс* (Ә. Әминев. Усман ташы).

Төрдәше: аш ашалу, яшь яшәлү һ.б.

*АШ<ЫЙС>ЫН* ❖ **АШ<ЫЙС>ЫН АШАГАН, ЭЧӘСЕН ЭЧКӘН, <СӨЯСЕН СӨЙГӘН>** *к.* аш ашалу, яшь яшәлү. *Ашын ашаган, яшен яшәгән ак сакаллы картның киңәшуңышы да төпле-иплле чыкты* (В. Имамов. Утлы дала). *Миннән үч алырга йөрмә, хан, мин инде ашыйсын ашаган, эчәсен эскән, сөясен сөйгән хатын-кыз затындагы кеше* (М. Хәбибуллин. Атилла).

Төрдәше: аш ашалу, яшь яшәлү һ.б.

*АШЫККАННЫҢ* ❖ **АШЫККАННЫҢ АШЫГЫ ЧЫГУ.** «Ашыгам» дигән кешегә җавап буларак әйтелә. *Ашыкканның ашыгы чыккан* (Мәкаль).

*АШЫКМА* ❖ **АШЫКМА, КӨТ, БОРЫНЫҢНЫ СӨРТ.** Чираты җитеп, әйбере беткәндә яки булачак нәрсәнең булмаячагын белгәндә әйтелә. *– Яңаларын чыгармаслар, дип күңелеңне төшермә, ашыкма, көт, борыныңны сөрт* (Сөйләм).

**АШЫКМА, КЫЗЫМ, АБЫНЫП ЕГЫЛЫРСЫҢ.** Китәргә ашыккан кешегә төрттереп кую. *[Нурия] Әйдә, әти, киттекме? [Әхтәри] Ашыкма, кызым, абынып егылырсың* (Т. Гыйззәт).

*АШЫК-ПОШЫК* ❖ **АШЫК-ПОШЫК ИҢДЕРҮ.** *Тамчы ташны тишә. Җанибәкне, ашык-пошык кына, тәхеткә иңдерделәр* (В. Имамов. Карабәк).

*АШЫМ* ❖ **АШЫМ АШ <ТҮГЕЛ>, ЙОКЫМ ЙОКЫ ТҮГЕЛ.** Бик борчулы хәлдә икәнлегенә, йокы ләззәтеннән мәхрүм булуына ишарә. *Кайтып күземә күренгәнче ут йотып торам, ашым аш, йокым йокы түгел* (Р. Габделхакова. Кояшлы мизгел).

Төрдәше: авыздан аш төшү һ.б.

*АШЫ<ЙСЫ>Н* ❖ **АШЫ<ЙСЫ>Н АШАГАН, ЯШ<ӘС>ЕН ЯШӘГӘН** *к.* аш ашалу, яшь яшәлү. *Моңа карыйм да аптырыйм; карт җитмеш еллар гомер иткән, ашын ашаган, яшәсен яшәгән, шулай да үлемнән бу дәрәҗәдә курка* (Г. Ибраһимов. Диңгездә). *Кайчандыр тар суларда аккош төсле горур йөзеп гомерен уздырган бу пароход, хәзер инде ашын ашаган, яшен яшәгән бабайга охшап, киң Идел уртасыннан ашыкмыйча гына түбән төшеп китте* (Ә. Еники. Шаяру).

Төрдәше: аш ашалу, яшь яшәлү һ.б.

*АШЫНА* ❖ **АШЫНА КҮРӘ КАТЫГЫ** *к.* авыздан өзелеп төшү 1. *– Бу галстугыңны алыштыр әле, «ашына күрә катыгы» дигәндәй, зәңгәр күлмәгеңә килешми бу* (Сөйләм).

Төрдәше: авыздан өзелеп төшү 1 һ.б.

**АШЫНА КҮРӘ ТАБАГЫ, <БАЛЫНА КҮРӘ КАЛАГЫ>** *к.* авыздан өзелеп төшү 1. *Ашына күрә табагы, балына күрә калагы* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.). *Ашына күрә табагы дигәндәй, бу хәлендә аңа Байбосын*

*Хаҗи кызыннан да ким кәләш килешми иде* (М. Әүезов. Өйләнү. Тәрҗ. Л. Хәмидуллин).
Төрдәше: авыздан өзелеп төшү 1 һ.б.

**АШЫНА КҮРӘ ТАБАГЫ, ЭШЕНӘ КҮРӘ ТАМАГЫ** *к.* авыздан өзелеп төшү 1. – *Дөрес әйттең, Факиһә күбәләгем! Ашына күрә табагы, эшенә күрә тамагы!* (Ш. Бикчурин. Тирән катлам).
Төрдәше: авызыннан өзелеп төшү 1 һ.б.

*АШЫҢ* ❖ **АШЫҢ АШ, ЙОКЛАГАНЫҢ ЙОКЫ ТҮГЕЛ (БУЛМЫЙ)** *к.* ашаганы аш түгел. – *Нинди йокы булсын ди. Иртәгә чаңгы ярышына барасы бар – ашың аш, йоклаганың йокы түгел!* (Сөйләм).
Төрдәше: ашаганы аш түгел.

*АШЫҢНЫ* ❖ **АШЫҢНЫ ДА АШЫЙ, БАШЫҢНЫ ДА АШЫЙ.** Берсенең яманлык эшли торган, сатлык, явыз, хыянәтчел булуына ишарә итү. *Бу хикәядә ашыңны да ашый, башыңны да ашый торган бер кеше хакында язылган* (Сөйләм).

*АШЫҢ-ЧӘЕҢ* ❖ **АШЫҢ-ЧӘЕҢ ТӘМЛЕ БУЛСЫН** *к. аш булсын! Ашың-чәең тәмле булсын* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.). – *Самавырдан чәй эчү рәхәттер, ашың-чәең тәмле булсын!* (Сөйләм).
Төрдәше: аш булсын!; аш<лар>ыгыз тәмле булсын!; чәегез тәмле булсын.

*АШЫП* ❖ **АШЫП КИТКӘН (УЗГАН).** 1. Бик күп, тиешле күләмнән (дәрәҗәдән) арткан. *Журналның тиражы 100 мең данәдән ашып киткән уңышлы еллар да булган* (А. Тимергалин. Сүнмәс ут янында уйда без...).

2. Төзәлә, үзгәрә торган түгел (кеше турында). *Тазалыгы ташып торган, өнсез булуы, дәшми-тынмый йөрүе ашып киткән Насихны менә ничек кузгатырга?* (Р. Мәхмүдов. Шәйморза кешеләре).

*АШЫРЫП* ❖ **АШЫРЫП МАКТАУ.** Чамадан артык мактау, данга күмеп ташлау. *Ашырып мактау белән мавыкмагыз, зарар гына китерерсез* (Сөйләм).
Төрдәше: күккә ашыру; күккә (күкләргә) күтәрү; күккә (күкләргә) чөю 2.

*АЮ* ❖ **АЮ АВЫРУЫ** *шаярт.* Куркудан яки нервылар какшаудан эч китә башлау. – *Карале, синең дустыңның аю авыруы беттеме әле?* (Сөйләм).

**АЮ АРТЫНА (КОЙРЫК АСТЫНА) ЯРА БУЛУ.** Кечкенә генә җәрәхәткә дә чыдый алмаган кеше турында. *Аю артына яра булган, ялый-ялый җаны чыккан* (Мәкаль).
Төрдәше: аю ботына шырпы кадалу.

**АЮ АЯК.** Ипсез, тупас итеп, лап-лоп басып йөрүче кеше. *Аның бер үзенчәлекле билгесе бар: аю аяк ул, лап-лап басып йөри* (Сөйләм).

**АЮ БАШ.** Аңгыра баш, миңгерәү. *Ләкин аю баш очында селкенеп торган кәҗә ботына күз дә салмады – тамагы тук иде* (С. Радзиевская. Мең еллык төн. Тәрҗ. Л. Ихсанова).

**АЮ БАШЫ ГЫНА ЮК.** 1. Шулкадәр муллык, юк нәрсә юк. *Беләсеңме, аның өендә аю башы гына юктыр – ныклап карасаң, бәлки, ул да чыгар* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

2. Бернәрсә дә табып булмаслык тәртипсезлек, әйбернең рәте-чираты юк. – *Синең аның бүлмәсенә кергәнең юкмы, бет базарындагы бар нәрсә бардыр – аю башы гына юк* (Сөйләм).

**АЮ БАШЫ ДА ЧЫДАМАС.** Әйбер туздыра торган кеше турында. – *Бер көндә бу хәтле акча туздыруыңа аю башы да чыдамас* (Сөйләм).

**АЮ БЕЛӘК.** Аю кебек көчле, нык беләкле кеше. *Аның белән көч сынашудан Аллам сакласын, ул аю беләк билеңне сындырыр* (Сөйләм).

**АЮ БЕЛӘК, ТАШ ЙӨРӘК.** Физик куәтле, тупас табигатьле, кырыс кеше турында. *Тазасын таза да, әмма аю беләк, таш йөрәк ул, саграк бул* (Сөйләм).

**АЮ БИЕТӘЛӘР (КҮРСӘТӘЛӘР) МӘЛЛӘ?** *к.* ат кәмите күрсәтәләрмени? – *Аю биетәләр мәллә монда? – ди ул, беренче сүзе белән үк энәләрен калкытып* (Ф. Хөсни. Адәм балалары). – *Нәрсә, анда аю биетәләр мәллә?* (Рөст. Вәлиев. Дөнья гаме).
Төрдәше: ат кәмите күрсәтәләрмени?

**АЮ БОРЫНЫННАН БАЛ АШАП КАРАУ.** Тормышта иң куркыныч хәлләрдән курыкмау, тәвәккәллек күрсәтү. *«Әле сезнең аю*

*борыныннан бал ашап караганыгыз юк, әгәр минем кебек 50 гә кадәр ямьшек булып йөрсәгез, “юл газабы гүр газабы” икәнен белер идегез» – ди* (А. Шамов).

**АЮ БОТЫ АБУ ИТҮ.** Балалар сөйләмендә: баланың берәр җире авыртып китсә, аны юату өчен әйтелә. *«Аю боты абу иткән икән», – дип, баланың башыннан сыйпарга кереште* (Сөйләм).

**АЮ БОТЫНА ШЫРПЫ КАДАЛУ** *ирон., к.* аю артына (койрык астына) яра булу. – *Абау, аю ботына шырпы кадалган икән, табиб чакырырбыз инде* (Сөйләм).
Төрдәше: аю артына (койрык астына) яра булу һ.б.

**АЮ ЕГАРЛЫК <ЕГЕТ>.** Нык, таза гәүдәле кеше турында. *Ул юбилей уздыргалый, / Ун елга бер булса да. / Ә үзе аю егарлык… / Алтмыш яше тулса да* (Р. Миңнуллин).
Төрдәше: алып кадәр һ.б.

**АЮ КЕБЕК.** Аюдай атлау, карау яки көчле булу һ.б. *Урмановка, кинәт, йөрәгенә чыдаша алмыйча, урыныннан сикереп торды да, куакларны аю кебек вата-сындыра, алга ташланды, бөтен тавышына кычкырып җибәрде* (Г. Әпсәләмов. Алтын йолдыз).
Төрдәше: алып кебек һ.б.

**АЮ КЕБЕК ӨЕННӘН ЧЫКМАУ (ӨЕНДӘ ЯТУ).** Күбрәк өйдә утырырга күнеккән, хәрәкәтләнергә яратмаган кеше хакында *Шулай шактый гомер аю кебек үз өенендә бикләнеп ятты ул* (Ф. Бәйрәмова. Кырык сырт).

**АЮ КУЛ** 1. *к.* авыр куллы 1. *Әмма шул мизгелдә аны аю кул артыннан килеп эләктереп ала* (Т. Нәҗмиев. Өеңдәге... тышында).
Төрдәше: авыр куллы 1 һ.б.

2. Шапшак, юылмаган яки йонлач кул. *Ишектән кергән ир кешенең аю кулында авыр сумка бар иде* (Сөйләм).

**АЮ КҮРДЕГЕЗМЕ ӘЛЛӘ?** *к.* аю биетәләр (күрсәтәләр) мәллә. – *Нәрсә күзләрегезне акайттыгыз? Аю күрдегезме әллә?* – дип кычкырды (М. Галәү. Мөһаҗирләр).
Төрдәше: ат кәмите күрсәтәләрмени? һ.б.

**АЮ МАЕ СӨРТҮ.** 1. Урлау, талау, сорамыйча алу. *Кыскасы, әллә әфтәрләгәннәр, әллә «аю мае сөрткәннәр» инде...* (Т. Нәҗмиев Утырып уйлар уйладым).
Төрдәше: аяк кую; бармакка йогу.

2. Куркыныч, хәтәр нәрсәгә әйләндерү. *Талашып, бөтен урамга фаш булдыгыз. Аю мае сөрткәннәрме әллә шушы йортка?* (А. Гыйләҗев). *Иске мотоциклга «аю мае сөрткән» күрше улының рәшәткә артына эләгүен теләмәүчеләр «электрон шымчы» хезмәтеннән файдалана ала* («Кызыл таң» газ.).

3. Кызык, дикъкатьне үзенә тарткан нәрсә. *Ә без, аю мае сөрткәннәрмени, дөя яныннан китмибез* (А. Гыйләҗев. Истәлекләр).

**АЮ ТАБАН<ЛЫ>.** 1. Уентысы булмаган, яссы табанлы кеше турында. *Ул «аю табан»лы, бер урында озак басып тору аның өчен үлем белән бер* (Ф. Садриев. Тургай).
Төрдәше: аю тәпие; яссы табан.

2. Авыр басып йөрүче кеше. *Үзем бит мин юньләп йөгерә дә алмыйм..., аю табан...* (З. Зәйнуллин. Үрләр аша).

3. Ялкау, йөрергә яратмаучы. *Иренең коры һәм аю табанлы бер нәрсә булганлыгын яхшы белгәнлектән, үзенең эч серен аңа һичбер ачып салмый иде ул* (Ф. Яхин. Август ае).

**АЮ ТАЛАГАН КЕБЕК.** Өс-башы сәләмә хәлгә килгән, йолкынган. *Паркның аулак башындагы эскәмиядә аю талаган кебек сәләмә киемле бер кеше утыра иде* (Сөйләм).

**АЮ ТӘПИЕ** *к.* аю табан<лы> 1. *«Бу балада тумыштан калган «аю тәпие» юк,» – диде* (М. Маликова. Арыш тәме).
Төрдәше: аю табан<лы> һ.б.

**АЮ ТҮГЕЛ, АШАМАМ.** Ир-егетләрнең тартынучан кызларга әйтә торган сүзләре. *Аю түгел, ашамам, / Якынрак ят, җаный* (Такмак).

**АЮ ТЫРНАК.** Тырнагын кисмичә, ямьсез үстергән, тырмавыч тырнаклы кеше хакында. – *Аю тырнак буласың киләме әллә синең, нигә тырнакларыңны кисмисең?* (Сөйләм).

**АЮ УРЫНЫНА УМЫРУ.** «Зур кабып, күп ашау» мәгънәсендә. – *Аю урынына умырып ашавын кара әле тегенең – атна буе ашамаган, күрәсең!* (Сөйләм).

**АЮ ХЕЗМӘТЕ <КҮРСӘТҮ>.** Яхшылык эшлим дип зыян ясау. *Моңарчы эндәшми утырган*

*Юрий Львович көтмәгәндә Гөлшаһидәне яклап чыкты: – Врач авторитетын төшермик дип, мәсьәләне йомып калдырдык, һәм, күрәсең, Саматовка аю хезмәте күрсәткәнбез* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

*АЮ-БҮРЕЛӘР* ❖ **АЮ-БҮРЕЛӘР БЕЛӘН КУЛ БИРЕШҮ.** Таза, көчле вакыт. *Ул чагында Насретдин абзыйның, кем әйтмешли, аю-бүреләр белән кул бирешеп, исәнләшеп йөргән чаклары иде* (Г. Мөхәммәтшин. «Вәйт минем кия-ә-әүлә-әр!»).

*АЮГА* ❖ **АЮГА ШЫРПЫ КАДАЛГАН** *мыск. к.* аю артына (койрык астына) яра булу. *Бармагыңа кура чәнечкесе кадалган икән, шулхәтле кычкырмасаң – аюга шырпы кадалган* (Сөйләм).

Төрдәше: аю артына (койрык астына) яра булу һ.б.

*АЮДАН* ❖ **АЮДАН АЮ ТУАР.** Балаларның ата-аналарына охшап тууларына ишарә. *Аның атасы әзмәвер кеше иде, ә табигать кануннары буенча, аюдан аю туарга тиеш иде, ә монда, киресенчә, аюдан кәрлә эт яралган* (Н. Гыйматдинова. Кәтәнә).

**АЮДАН КАЧКАН – БҮРЕГӘ.** Бер куркынычтан, хәтәрдән котылып, тагын да хәтәррәгенә килеп эләгү. *«Аюдан качкан – бүрегә» килеп чыккан инде бу – еланнан качканда, чокырга төшеп аягын сындырган* (Сөйләм).

*АЮНЫ* ❖ **АЮНЫ ДА БИЕРГӘ ӨЙРӘТӘЛӘР.** Берәр кеше «мин булдыра алмыйм» дип, баш тартканда әйтелә. *Йә, артык киреләнмә инде, аюны да биергә өйрәтәләр* (Сөйләм).

Төрдәше: кеше түгел, аю да кулга ияләшә (биергә өйрәнә).

**АЮНЫ КҮРӘ ТОРЫП ЭЗЕН ЭЗЛӘҮ** *ирон.* Дошманыңны каршыңда күреп тә, көрәшү урынына көрәш турында гына сөйләшү (хакыйкатьне халыктан яшереп, боргаланучылар хакында да әйтелә). – *Күпернең ишелеп төшүен субайларының сыйфаты белән бәйләмәс идем, субайларны көчле ташу вакытында су ашаган. – Кара, кара, аюны күрә торып эзен эзләп маташа түгелме?* (Сөйләм).

**АЮНЫ ҮЗ МАЕ БЕЛӘН МАЙЛАУ.** 1. Аюның тиресен тунап, итен бүлешкәч, үз маенда куырып ашау. *Ә хәзер инде аюны үз мае белән майласаң да ярый* (Сөйләм).

2. Берәрсен бәладән коткарырга яки дәрәҗәгә ирешергә булышкач, барлык чыгымнарны да күтәрү өстенә, аның хисабына сыйлану. Уйланган эшләр бетте бугай инде, *ә хәзер аюны үз мае белән майлап алсаң да була* (Сөйләм).

**АЮНЫ ҮТЕРМӘС БОРЫН ТИРЕСЕН САТМЫЙЛАР** *к.* ала каргадай алдан ала (алдан алы) кычкыру. *Аюны үтермәс борын тиресен сатмыйлар* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

Төрдәше: ала каргадай алдан ала (алдан алы) кычкыру һ.б.

**АЮНЫ<Ң> ҮТЕРМӘС БОРЫН <ТИРЕСЕН> ТУНАУ (САЛДЫРУ; САТУ)** *к.* ала каргадай алдан ала (алдан алы) кычкыру. – *Бераз дәшми тор, ичмасам, аюның үтермәс борын тиресен тунамыйлар* (Сөйләм).

Төрдәше: ала каргадай алдан ала (алдан алы) кычкыру һ.б.

*АЮНЫКЫН* ❖ **АЮНЫКЫН БҮРЕГӘ.** Көчле яки түрә кешенең гаебен гади кешегә аудару. – *Аюныкын бүрегә аударырга күнеккәннәр алар, мин, гариза язып, прокуратурага барачакмын* (Сөйләм).

*АЯГӨСТЕ* ❖ **АЯГӨСТЕ ГЕНӘ.** Аякта басып торган килеш кенә, тиз генә. *Ә малайлар өягөсте генә тегеннән-моннан капкалап китәләр* (Ф. Яруллин. Гөлҗиһан малайлары).

Төрдәше: аягүрә генә; аяк өсли <генә>; аяк өсте (өстеннән); аяк өсте <килеш>; аяк өсте генә; аякка басып.

*АЯГҮРӘ* ❖ **АЯГҮРӘ АШАРГА КАРГА БОТКАСЫ ТҮГЕЛ БУ.** Ризыкның тәмен ләззәтләнеп тату өчен, утырып ашау кирәклегенә ишарә (берәр җитди эшне, мәсьәләне ачыклау, хәл итүдә уйланылып, акыл белән башкарылырга тиешлеген дә үз эченә ала). *Аягүрә ашарга карга боткасы түгел бу* (Х. Мәхмүтов. Изге китаплар кайтавазы).

**АЯГҮРӘ ГЕНӘ** *к.* аягөсте генә. *Моның турында башкаларның фикерен дә белергә кирәк, аны аягүрә генә хәл итеп булмас* (Сөйләм).

Төрдәше: аягөсте генә һ.б.

**АЯГҮРӘ (АЯК ҮРӘ) КАТЫП КАЛУ**. Ят яки хәтәр берәр нәрсә күрүдән гаҗәпләнеп яисә бик нык куркып калу. *Сискәнеп безнең егет, катып кала аяк үрә, / Аңламастан, каршысында әллә нинди «ят» күрә* (Г. Тукай. Шүрәле).

Төрдәше: авыз ачып калу 5 һ.б.

**АЯГҮРӘ САТАШУ.** Аяк өстендә, уяу хәлдә юкны бар кебек күргәндәй хис итү. *Их, тотып карыйсы иде ул мамыктай йомшак кулларны!.. Тукта, җитте, Ходайдан курык! Коры куык, хыялый, бу бит – аягүрә саташу гына* (М. Әмирханов. Әлвидаг).

**АЯГҮРӘ ТЕЗЛӘНҮ**. Нәрсә беләндер килешү яки буйсыну. *Мин генәме бергәләнәм, / Мин генәме эзләнәм. / Мин генәме, мин генәме / Аягүрә тезләнәм* (Л. Лерон).

**АЯГҮРӘ ТӨШ КҮРҮ.** Ялгыш уйлап, саташып, аңгыраеп йөрү. *Мин дә инде аягүрә төш күрә башладым* (А. Шамов. Кыз урлау). – *Нәрсә, аягүрә төш күрәмме югыйсә, – диде Газинур үз-үзенә, кулын күзләреннән алды* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

**АЯГҮРӘ ЭШЛӘ<Н>ГӘН ЭШ** *к.* аннан-моннан гына, ныклап уйламыйча гына эшләнгән. – *Бу эшне аягүрә генә эшләгәннәр, ахрысы, бер төртсәң, авып китәргә тора* (Сөйләм).

Төрдәше: аннан-моннан гына һ.б.

*АЯГЫ<Ң>* ❖ **АЯГЫ АВЫР** 1. *к.* авыр аяк<лы> 3. *Күршеләр гаиләсендә тагын бер бала артачак, киленнәренең аягы авыр, диделәр* (Сөйләм).

Төрдәше: авыр аяк<лы> 3 һ.б.

2. Берәрсенең уңышсызлык китерүен фараз итеп, сәбәбен шул кешегә сылтау. *Юлыбыз уңмаса: «Их, тегенең аягы авыр икән», – дип уфтанабыз* («Сәхнә» ж.). *Тависның аягы авыр булып чыкты, ул көнне авыллардагы хәлләр бик тә ачуны китерде* (М. Маликова. Кызыл гөл).

**АЯГЫ АТ, КУЛЫ КАМЧЫ.** Җәяүләп тиз-тиз йөрүче, бәла-казадан үзен җиңел коткарып чыгучы кеше турында. *Миннән интервью сорап йөдәтүче булмады, аягым ат, кулым камчы, шоп-шома чыктым да киттем* (Ф. Хөсни).

**АЯГЫ БЕЛӘН КЕРӘНДИЛ (КРЕНДЕЛЬ) ПЕШЕРҮ.** 1. Исерек булудан аяклары чалышчолыш булып тору. – *Һай, Ходаем, эш хакы алган, ахрысы, аягы белән керәндилләр пешерә башлаган* (Сөйләм).

2. Биегәндә, аяклары белән алка хәрәкәтләре ясау. *Оста биючеләр аяклары белән әллә нинди крендельләр пешерә беләләр* (Сөйләм).

**АЯГЫ ҖЕП КҮК, ЭЧЕ ГӨП КҮК.** Азык яки витамин җитмәүдән рахит авырулы чирле бала хакында. *Мескенемнең аягы җеп күк, эче гөп күк* (Сөйләм).

**АЯГЫ ҖИҢЕЛ <БУЛУ>.** 1. Йөреше, хәрәкәте җитез; хәрәкәтчән. *Гәүдәсе сылу, аягы җиңел иде аның, Галия түти әйтмеше, аккош сыман оча иде* (Сөйләм).

2. Бер кешедән соң башкасы кергәндә әйтелә. *Аягы җиңел булсын, әнә үзе дә килә* (А. Гадел. Безнең авыл Наполеоны).

3. Берәр хәл-күренеш уңай нәтиҗә биреп, үсеш-үзгәреш өчен юл күрсәткәндә әйтелә. *Бу беренче шигырь китабының аягы җиңел булды, бер-бер артлы дигәндәй, «Гөлләр елы», «Зәңгәр эңгер», «Таң чыңы» китаплары туды* (Б. Рәхимова. Бакый сагыш).

Төрдәше: аягы уңу.

**АЯГЫ<Ң> ҖИҢЕЛ БУЛСЫН!** 1. Өмет бирүче бер теләк. Берәр эш башлаганда, яхшы теләк буларак әйтелә. *Төкле аягың белән килсәңче, Хөсбиулла туган!.. Аягың җиңел булсын!* (Г. Бәширов). – *Ну, Гомәр, аякларың җиңел булсын!.. Яңадан әйләнеп кайтырга...* (Ә. Еники. Бер генә сәгатькә).

Төрдәше: аягы<ң> төкле булсын!; әй уңгыры, бер башың мең булгыры!; котлы аягың белән!; төкле аягың белән (илә)!; төкле аяк белән атлап кер; төкле аягың белән үт<егез>!

2. Килен төшкәндә, «йортка бәхет, бәрәкәт, үрчем алып кил» дигән теләк белән әйтелә. – *Карлыгач-Сылу, аягың җиңел булсын! – дип, өйләр тирәсендә тышта калдылар.* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).

3. Авыру кешенең хәлен белергә килүченең артыннан әйтеп калалар. *Докторлар, иң авыр чагы узды инде, диделәр. Аягың җиңел булсын!* (Сөйләм).

Төрдәше: аягы<ң> төкле булсын! һ.б.

**АЯГЫ ЙОРТЛАРЫНЫҢ СЫҢАР ИДӘНЕНӘ ДӘ БАСМАУ** *к.* анда башка аяк та атламау.

*Җеназага кадәр ничек аягы йортларының сыңар идәненә дә басмаса, аннан соң да Бәрия түти кабат күренмәде* (Ф. Яхин. Багана фалы).
Төрдәше: анда башка аяк та атламау һ.б.

**АЯГЫ КАБЕР ЯКАСЫНДА** *к.* авыздан җаны чыгарга тору (җитешү). *Бу әйтем картайган, үлеме якынлашкан кешене сыйфатлый һәм бездәге «Бер аягы кабер якасында гүрдә!» дигәнгә туры килә* (А. Вәлиева. Тел дәрьясының ике ярында).
Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

**АЯГЫ КАЯ БАСКАННЫ БЕЛМӘҮ.** 1. Куанычтан сикергәләү, артык очыну. *Укырга керүчеләр исемлегендә үзенең фамилиясен күргәч, Фазыл аягы кая басканны белмәде* (Сөйләм).
2. «Эш кызу, аякта басып торырга вакыт юк» мәгънәсендә. *Көн буена аягым кая басканны белмим. Ни кушсалар, шуны эшлим* (Г. Ибраһимов).

**АЯГЫ КЕРСӘ, БАШЫ (ТАЯГЫ) КЕРМӘГӘН.** «Аз вакыт үткән, күптән түгел» мәгънәсендә. – *Каян әле барысын да белеп бетерү? – аягы керсә, башы кермәгән әле аның* (Сөйләм).
Төрдәше: башы керсә, аягы кермәгән, <аягы керсә, таягы кермәгән>.

**АЯГЫ КЕРСӘ, ТОЯГЫ КЕРҮ.** Әрсез булу турында; әз генә юл куйсаң, бөтенләе белән кереп урнашу. *Сак бул: аягы керсә, тоягы да керәчәк аның* (Сөйләм).

**АЯГЫ ПОЧМАКТА, БАШЫ УЧАКТА.** «Рәтсез, ипсез, тыгын җир» мәгънәсендә. *Аягы почмакта, башы учакта. / Агач морҗа, мич – такта* (Такмаза).

**АЯГЫ ТАЗА (НЫК).** Аяклар авыртмау, адымнар нык булу. *Йөремсәк булган. Үзе әйтмешли, «аягы таза чыккан»* (Г. Вәлиева. Күңел күзе).
Төрдәше: аякка таза (нык).

**АЯГЫ<Ң> ТӨКЛЕ БУЛСЫН!** *к.* аягы<ң> җиңел булсын! – *Килен, аягың төкле булсын, гомерең озын булсын, бәхетең мул булсын! – дип каршы алды аны каенанасы Гайнисә түти* (М. Хәсәнов).
Төрдәше: аягы<ң> җиңел булсын! һ.б.

**АЯГЫ УҢУ.** Берәр кеше эшкә керешкәннән соң, эшнең уңайга китүе хакында. *Киленнең аягы уңмады, ахры, ел да яңгырлы туры килде, эшләр дә бәрәкәтсез* (А. Шамов).
Төрдәше: аягы җиңел <булу> 3.

**АЯГЫ ЧЕРҮ** *хурл.* Аягын юньләп атламаучы, атларга теләмәүче. *[Сәхипҗамал абынып егылгач, Җамали:] Һәй, аягың черегән нәрсә!* (А. Әхмәт).

**АЯГЫ ЧОКЫРДА.** Бик карт кеше турында (тигез җирдә дә чокырга баскан кебек ава-түнә атлау). – *Нигә бәйләнәсез ул бабайга, аягы чокырда бит инде аның* (Сөйләм).

*АЯГЫН* ❖ **АЯГЫН ДАГАЛАУ.** Эшкә күндерү. *Булмас бу болай, малайның әкренләп аягын дагаларга кирәк булыр* (Сөйләм).

**АЯГЫН КЫСКАРТУ.** Йөргән җирдән биздерү, тыю. – «*Мин сине үлемнән коткардым» дип килә дә керә. – Аягын кыскартырга кирәк алайса аның! – дидем мин* (А. Гыйләҗев. Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят).

**АЯГЫН САНАП АТЛАУ.** Ашыкмыйча гына, акрын-үшән атлап йөрүче, ялкау. – *Атла инде җәһәтрәк, соңга калабыз бит, аягыңны санап атлыйсыңмы югыйсә?* (Сөйләм).
Төрдәше: авыр аяк<лы> 1 һ.б.

**АЯГЫН ТОТУ** *эвф.* Аягыннан тотып, кечкенә баланы тышка чыгару. *Әнкәй баланың аягын югарырак тотарга кушты* (Сөйләм).

**АЯГЫН ТЫККАЧ, ТАЯГЫН ДА ТЫГАСЫ.** Хушлану, кызыгып, ымсынып карау; үзенеке итәргә өметләнү. *Аягын тыккач, таягын да тыгасы* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).
Төрдәше: аяк керсә, башкасы иярү; аяк керсә, тояк керү; тырнак керсә, бармак керү.

*АЯГЫНА* ❖ **АЯГЫНА БАСКАН, АРТЫНДА (ТӨБЕНДӘ; КҮТЕНДӘ) ШУГАНЫ – БАРЫСЫ ДА (БЕРСЕ ДӘ КАЛМАГАН)**. Бөтен халык, берсе дә калмыйча. *Авыл көнен бәйрәм итәргә дип, аягына баскан, артында шуганы – барысы да бәйрәмчә киенеп килгән иде* (Сөйләм).

**АЯГЫНА БОЗАУ (СЫЕР) БАСМАГАН** *к.* авыз суы кипмәгән. – *И балам, мин дә синдәй, бала*

*көннең аягына бозау басканның берсе гуй, – дип башлады ул авыр сүзен* (И. Салахов. Имәннәр тамыр җәйгәндә). – *Урта мәктәпне бетергәндә нинди булган булсаң, шулай. Аягына сыер басмаган шул, нужа күрмәгән* (А. Ганиев. Иман).

Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

**АЯГЫНА ЕГЫЛУ** 1. Тирән хөрмәт итеп табыну, гафу үтенү, сәҗдә итү. *Хәзер барырга да туганнарның аягына егылырга кирәк* (А. Гыйләҗев. Өч аршын җир).

Төрдәше: аяк астына егылу 1; аякка егылу 1.

2. Ялыну, ялвару. *МТСка чабарга туры килде, механикның аягына егылдым* (М. Мәһдиев). *[Габдулла] Минем бөтен көчем бетте, артык чыдый алмыйм, туташ! Синең мәрхәмәтеңә, шәфкатеңә килдем... (Аягына егыла)* (Г. Исхакый. Мөгаллимә).

Төрдәше: аяк астына егылу 2; аякка егылу 2; аякка егылып сорау (үтенү; ялвару; ялыну); баш ору 1.

**АЯГЫНА ТАШ ТИСӘ, МИННӘН КҮРЕР.** Һәр уңышсызлыгын, булдыксызлыгын башкалардан күрү, аларны гаепләү. *Мин аның бу сәер гадәтенә күнектем инде, булдыксызлыгын күрсәтәсе килми аның – аягына таш тисә дә, миннән күрә* (Сөйләм).

*АЯГЫНДА* ❖ **АЯГЫНДА БАСЫП ТОРА АЛМАУ.** Чамасын белмәс дәрәҗәдә исерткеч эчемлек эчеп, үзен аңламас хәлгә килү. *Урам чатындагы кеше баганага ябышкан, аягында басып тора алмый* (Сөйләм).

Төрдәше: лаякыл исерек; ләх исерек.

*АЯГЫННАН* ❖ **АЯГЫННАН АЛЫП (ТОТЫП) СЕЛЕКСӘҢ (СЕЛКЕСӘҢ) ДӘ БУЛМЫЙ (ЧЫКМЫЙ; БЕР ТИЕН / ӘЛИФ / ХӘРЕФ ТӨШМИ).** 1. Юньсез, надан, томана. *Кечкенә чагында егылып, башына зыян килгән аның, аягыннан алып селкесәң дә берни чыкмас* (Сөйләм). *Ике аягыннан тотып селексәң, әлиф төшмәс* (Х. Мәхмүтов. Изге китаплар кайтавазы).

Төрдәше: ак-кара танымау һ.б.

2. Ач хәерче. *Аның киртә тотарлык бернәрсәсе дә юк бит, эшне дә сөйми, аягыннан тотып селкесәң дә булмас* (Сөйләм).

Төрдәше: аягыннан алып (тотып) селкесәң (селексәң) дә бер тиен (бер әлиф / хәреф) төшмәс 1, 2 һ.б.

**АЯГЫННАН ТОТЫП СЕЛЕКСӘҢ, БЕТ ТӘ КОЕЛМАС** *к.* аягыннан алып (тотып) селкесәң (селексәң) дә булмас (чыкмас) 2. *Аягыннан тотып селексәң, бет тә коелмый иде, ә?* (Р. Зәйдулла. Ташка ордым башны).

Төрдәше: аягыннан алып (тотып) селкесәң (селексәң) дә булмас (чыкмас) 2 һ.б.

**АЯГЫННАН ТОТЫП СЕЛКЕСӘҢ ДӘ, МӘГЪНӘЛЕ СҮЗ ТӨШМӘС** *к. ак-кар*а танымау. *«Андыйларның ике аягыннан тотып селкесәң дә, авызларыннан мәгънәле сүз төшми», диләр* (Ф. Яхин. Конференция йомгаклары).

Төрдәше: ак-кара танымау һ.б.

**АЯГЫННАН ҖИР ТАРТКАН, <БАШЫННАН ҺАВА БАСКАН>.** Кыска буйлы, карсак кеше. *Аягыннан җир тарткан, кәтүк кенә булса да, полк элитасына керә иде ул* («Казан утлары» ж.).

**АЯГЫННАН ЭЛЕК ТАЯГЫ КЕРҮ.** Әрсез кеше турында. *Ишек аз гына ачылса да, аның аягыннан элек таягы кереп китә* (Сөйләм).

Төрдәше: ишектән кусаң – тишектән, тишектән кусаң – тәрәзәдән, тәрәзәне япсаң – морҗадан төшү; ишектән чыгарсаң, морҗаңнан төшү.

*АЯГЫҢ* ❖ **АЯГЫҢ ҖИРГӘ ДӘ ТИМӘСЕН** *к.* «а» дигәнче. – *Кешеләр җыелганчы, бар, ферма мөдирен чакырып кил әле, аягың җиргә дә тимәсен!* (Сөйләм).

Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**АЯГЫҢ ТӘПЕЛДӘМӘСӘ (ЛАПЫЛДАМАСА), АВЫЗЫҢ ЧӘПЕЛДӘМӘС (ШАПЫЛДАМАС)** *к.* агач – җимеше белән, адәм – эше белән. *Безнең татарда «аягың лапылдамаса, авызың шапылдамас» дигән сүз дә бар* (А. Хәсәнов. Гөлмәрфуга).

Төрдәше: агач – җимеше белән, адәм – эше белән һ.б.

**АЯГЫҢА АТ БАСМАГАН БИТ.** Аягын атларга да иренгән яки авырсынып атлаган кеше турында. – *Кызурак атла инде, соңга калабыз ич – аягыңа ат басмаган бит* (Сөйләм).

Төрдәше: авыр аяк<лы> 1 һ.б.

*АЯГЫҢНЫҢ* ❖ **АЯГЫҢНЫҢ ТУФРАГЫ БУЛЫЙМ.** Теләсә нинди теләкне, үтенечне үтәргә әзер булу. *[Бакый] Боер, мирзам,*

*аягыңның туфрагы булыйм* (М. Фәйзи. Ак калфак).
Төрдәше: аяк астында туфрак булыйм.

*АЯЗ* ❖ **АЯЗ КӨН КЕБЕК АЧЫК.** Тулысынча аңлашылган, бернинди дә сорау тудырмаган нәрсә яки хәл хакында. *Хәсипнең исән калуы аяз көн кебек ачык. Димәк, ул һаман исән* (Р. Сәгъди. Канга буялган алтыннар). *Аяз көн кебек ачык мәсьәлә тирәсендә сүз куертмастан, Алабуга педагогия институты педагогика кафедрасы укытучысы Тәзкирә ханым Шәрипованың миңа язган хатыннан гына бер гыйбрәтле өзек китереп үтәсем килә* (Т. Галиуллин. Замана балалары).

**АЯЗ КӨНДӘ (КӨННЕ) <ЧЫРА ЯНДЫРЫП ЭЗЛӘСӘҢ> ДӘ ТАБА АЛМАССЫҢ** *к.* андыйны көндез чыра яндырып та таба алмыйсың (алмассың). *Тимердән эшләнгән мондый чәчәкне аяз көнне чыра яндырып эзләсәң дә таба алмассың* (Сөйләм).
Төрдәше: андыйны көндез чыра яндырып та таба алмыйсың (алмассың).

**АЯЗ КӨНДӘ (КӨННЕ) ЯШЕН <АТУ> КЕБЕК.** Көтмәгәндә, уйламаганда бик тиз булган вакыйга турында. *Әллә кайсы гына үр менгәндә, / күз нурымның угын җил алды, / аяз көндә чыккан яшен кебек, / мәхәббәтем ничә югалды...* (Р. Фәйзуллин. Әй, кайтасым килә кайчакта...).
Төрдәше: авыз ачып калу 5 һ.б.

**АЯЗ КӨНДӘ (КӨННЕ) ЯШЕН СУГУ.** Көтмәгәндә, уйламаганда кинәт килеп чыккан күңелсезлек, куркыныч хәбәр. *Аяз көндә, димәк, һич көтмәгәндә, яшен сугу ничек әсәр итсә, патшаның бу фәрманы аңардан яманрак булды...* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр). *Өйләнмим дисә, аяз көнне яшен сугар, ошамый дисә, теле корыр тагы!* (Н. Гыйматдинова. Сихерче).
Төрдәше: авыз ачып калу 5 һ.б.

**АЯЗ КӨНДӘ (КӨННЕ) ЯШЕН СУККАН КЕБЕК** *к.* аяз көндә (көнне) яшен сугу. *Герман белән сугыш турындагы хәбәр аяз көнне яшен суккандай тәэсир итте* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр). *Әлтафи аяз көндә яшен суккандай телсез калды: морҗа туп-туры бәбкә киштәсенә туры килә иде* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).
Төрдәше: авыз ачып калу 5 һ.б.

**АЯЗ КӨНДӘ ЯШЕН ЯШЬНӘГӘНДӘЙ <БУЛУ>.** *Аяз көндә яшен яшьнәгәндәй булды бу* (Г. Гыйльманов. Исемең ничек, Гадел?).
Төрдәше: авыз ачып калу 5 һ.б.

**АЯЗ КӨННЕ ЯШЕН СУКСЫН (АТСЫН)** *карг.* «Көтмәгәндә каһәр орсын үзеңне» мәгънәсендә. *Ярабби, безне рәнҗеткән өчен аяз көнне яшен суксын!* (Г. Бәширов). *Ни карыйсыз сез, җәмәгать? / Әйтмәде ул ни генә... / Аяз көнне яшен суксын! – / Патшага тел тидерә!* (И. Юзеев).

**АЯЗ КӨННЕ (КӨНДӘ) ЯШЕН СУКТЫ ДИЯРСЕҢ** *к.* аяз көндә (көнне) яшен <ату> кебек. *<...> шатлыклы хәбәрләр көтеп торганда, аяз көндә яшен сукты диярсең: бөтен бер батальон, барлык коралларын алып, совет партизаннары ягына чыксын әле!* (Г. Әпсәләмов).
Төрдәше: авыз ачып калу 5 һ.б.

**АЯЗ КҮККӘ ЯШЕН ТАШЫ АТЫЛУ.** Тыныч кына аккан тормышында көтелмәгән хәл булу. *Яңа тойгылар, яңа шөгыльләр белән узган көннәрнең берсендә аяз күгемә яшен ташы атылды* (А. Расих. Ишан оныгы).
Төрдәше: авыз ачып калу 5 һ.б.

**АЯЗ КҮКТӘН ЯҢГЫР КӨТҮ.** Юк җирдән булмастайны өмет итү. *Өзгәләнгән безнең хәтерләр. / Тарих җуйган ничә кыз һәм угыл / Аяз күктән яңгыр көтәрләр* (Ф. Яхин).

**АЯЗ КҮКТӘН ЯШЕН СУККАН (ЯШЬНӘГӘН) КЕБЕК** *к.* авыз ачып калу 5. *Менә шулай безнең тулы бәхетебез өчен малларын гына түгел, җаннарын да кызганмый яшәгән көннәрендә, аяз күктән яшен суккандай, ике кызы бербер артлы тол калды аларның* (Э. Шәрифуллина. Мәхәббәтнең җиде төсе).
Төрдәше: авыз ачып калу 5 һ.б.

*АЯК* ❖ **АЯК АРТЫ ҖИҢЕЛ БУЛСЫН** *к.* аягы<ң> җиңел булсын! – *Синең аяк артың җиңел булды, ахрысы, Бибинур, тагын кемдер бар* (А. Гыйләҗев. Җомга көн кич белән...).
Төрдәше: аягы<ң> җиңел булсын! һ.б.

**АЯК АСТЫ.** 1. Аяк басып йөри торган җир. *Кыш әле килмәгән, аяк асты каткак, кар катыш боз, каты балчык* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә). *Чак-чак егылмыйча калдым, чөнки*

*аяк асты тайгак булып чыкты* (А. Тимергалин. Юл чаты).

2. *күч.* Кеше күп йөри торган, ыгы-зыгылы урын. *«Аяк асты тынгач, төгәлләп бүлешербез» дип сүз куештык* (А. Гыйләҗев, А. Литвин. Августның алтысыннан соң...). <...> *иң әйбәте шул: кеше аяк асты түгел, ял итәргә килүчеләр күлнең бу ягына чыкмыйлар икән, дөнья безгә генә калгандай иркен, тын, тыныч* (Л. Ихсанова. Кемгә сөйлим серләремне?).

3. *күч.* Вак-төяк, әһәмиятсез, дәрәҗәсез. *Аяк асты кешеләрдән беренче булып, кирпеч өй салырга* (Р. Газизов. Ак болыт).

**АЯК АСТЫ ИТҮ (ЯСАУ).** 1. Ыгы-зыгылы урын итү, үтеп йөри торган итү. *Спорт мәйданчыгын аяк асты итеп бетерделәр инде – урам буйлап әйләнеп үтәсе килмәгән кеше шуннан гына кисеп чыга* (Сөйләм).

Төрдәше: аяк астына әйләндерү.

2. Басымчак итү. *Халык мәнфәгатьләрен аяк асты ясау сәясәте нигә кирәк?* (Сөйләм).

**АЯК АСТЫ НЫК <БУЛУ>.** Шикләнү, икеләнү өчен сәбәп булмау. *Үзен депутат итеп сайлаячакларына бер дә шикләнми, чөнки аяк асты нык иде* (Сөйләм).

**АЯК АСТЫ ТЕТРӘП КУЮ.** Куркыныч хәл киләчәген сизү. *Ләкин шушы уйларга бирелеп йөргән чакта гына Зөфәрнең аяк асты кинәт кенә бер тетрәп куйды* (Ә. Еники. Рәшә).

**АЯК АСТЫ ШИЛ БУЛГАЧ.** Эңгер-меңгер төшеп, үтеп йөрүчеләрнең аяк тавышы басылгач. *Көндезләрен начальниклары, старшийлары бик күп йөргәнгә, мин аяк асты шил булгач кына, поверкалар беткәч кенә яза идем* (Г. Исхакый. Зиндан).

**АЯК АСТЫ ШЫП БУЛУ.** Адымнарның тавышы ишетелмәү, аяк тавышы ишетелми башлау. *Урамнан үтеп китүчеләрнең аяк асты шып булды, өйдә дә тынлык урнашты* (Сөйләм).

Төрдәше: шып-керт басылу (тыну).

**АЯК АСТЫН<ДАГЫ ТУФРАКНЫ> НЫГЫТУ.** 1. Ныклап урнашып калу. *Шуның белән мәртәбәсен тагын да күтәрде, аяк астын ныгытты* (Ф. Яхин. Күзле бүкәннәр).

2. Ышаныч казану. *Айдарның үзенә аяк астындагы туфракны ныгыта төшәргә кирәк иде әле* (Ф. Хөсни).

**АЯК АСТЫН ТИКШЕРМИЧӘ, УРМАН АСТЫН ТИКШЕРҮ.** Үзен белмичә, башкалардан гаеп эзләү. *Аяк астыңны тикшермичә, урман астын тикшерү җиңел бит ул* (Сөйләм).

Төрдәше: борын астын күрми, <урман артын (астын) күрә (тикшерә)>; борын астындагы бүрәнәне күрми, урман артында очкан (артындагыны) кошны күрә; борын астындагыны күрмәү; бүрек астындагын күрми, бүрәнә артындагын күрә.

**АЯК АСТЫНА ӘЙЛӘНДЕРҮ** *к.* аяк асты итү (ясау). *Бу урынны аяк астына әйләндергәнче, монда бер киртә торгызырга кирәк булыр* (Сөйләм).

Төрдәше: аяк асты итү (ясау).

**АЯК АСТЫНА БАСУ.** Үтенечне, сүзне һ.б.ны игътибарга алмау, санламау. *[Хәлил] Сез шәригатьне дә аяк астына басып, әллә ниләр кылмакчы буласыз* (Г. Исхакый. Алдым-бирдем).

Төрдәше: аяк астына салу 1; аяк астына салып изү 2; аяк астына салып таптау 1; аяк белән таптау.

**АЯК АСТЫНА ЕГЫЛУ** *к.* аягына егылу 1, 2. *Әгәр бүген берр азәри йә фарсы «солтаным» дип аяк астына егылса, хәтта синең дә теге колны җирдә сөйрәп торгызырга хокукың юк* (В. Имамов. Сөләйман солтан). *Лиза аларның аяк астына егылып ялварды* (Г. Әдһәм. Әтнәби).

Төрдәше: аягына егылу 1, 2 һ.б.

**АЯК АСТЫНА КЕЛӘМ (ПАЛАС) ҖӘЮ (ТҮШӘҮ).** Дәрәҗәле, олы кешеләрне каршы алганда, аяк астына келәм җәю гадәтенә ишарә. – *Авызына бал белән май каптыра алмадык, аяк астына келәм җәеп булмады, урындыгына мендәр түшәмәдек* (Б. Камалов. Өметең өзелмәсен).

**АЯК АСТЫНА САЛУ** 1. *к.* аяк астына басу. *Җаны карышса да, малаеның сүзен аяк астына салырга базмады* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).

Төрдәше: аяк астына басу һ.б.

2. Әрәм-шәрәм, исраф итү. *Теге юньсезнең атасыннан калган малны аяк астына салганын халык күрми-белмимени?* (Сөйләм).

3. Берәрсенең ихтыярына буйсыну. – *Икенче берәү булса, бөтен нәрсәсен – җанын да, байлыгын да Рәшидә кебек хатынның аягы астына салыр иде!* (Ә. Еники. Рәшә).

4. Берәрсен тәнкыйтьтә, бәхәстә хурлыклы рәвештә җиңү. *Зур аш мәҗлесендә, өлкән байлар алдында, заманының иң зур хәзрәтләрен, иң зур мөдәррисләрен мантыйк, кәлям мәсьәләләрендә аптыратып, мөсәлләм иткән кебек, бу зур шаушулы җыелышны да аяк астына салачак* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр).

**АЯК АСТЫНА САЛЫП ИЗҮ.** 1. Хур, мәсхәрә итү. <…> *борынгы кыйлган эшләре өчен милләт аларны аяк астына салып изсен, һич дөньяга килмәгән кеби итсен, каргаларны муеныннан кысып борынгы ашаганнарын кырылдатып чыгарсын* (Г. Тукай. Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?).

2. *к.* аяк астына басу. – *Теге вакытта безнең мәхәббәтне аяк астына салып изгән кыз язмышы турында кое-что ишеттем* (Т. Галиуллин. Итле пәрәмәч).

Төрдәше: аяк астына басу һ.б.

**АЯК АСТЫНА САЛЫП ТАПТАЛУ.** Үтенеч, карар, сүз, изге хисләр һ.б. танылмау, юкка чыгарылу, мәсхәрә ителү. *Инде нишлим, ал чәчәктәй яшьлегемне / Кара болыт төсле кайгы каплагач, / Саф йөрәктән булган мәхәббәтем / Аяк асларына салып тапталгач* (Т. Гыйззәт).

Төрдәше: аяк астында таптату.

**АЯК АСТЫНА САЛЫП ТАПТАТУЧЫ.** Үтенече, сүзе, изге хисе һ.б. исәпкә алынмаган, мәсхәрә ителгән кеше турында. *Ләкин юк, Нургали үз хакын, үзенең яхшы исемен аяк астына салып таптатучылардан түгел* (Ә. Еники).

**АЯК АСТЫНА САЛЫП ТАПТАУ.** 1. *к.* аяк астына басу. *Моның өчен кемгә ләгънәт укырга, кемне аяк астына салып таптарга?* (Г. Ибраһимов. Яшь йөрәкләр). *Җаны борчылган Тузгак эргесен / Аяк астына салып таптадым* (М. Җәлил. Алтынчәч).

Төрдәше: аяк астына басу һ.б.

2. Берсе хакында начар сөйләү, тискәре фикер тудыру. *Ә яман хәтер иң изге теләкне дә яман итүчән, кылынган игелекне аяк астына салып таптаучан була* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).

Төрдәше: бәла салу (тагу); бәла ябу (ягу); бәла-каза китерү 2; гаеп ату (ташлау); кара пычрак ату; кара ягу; күләгә төшерү; пычрак ату (ташлау; ыргыту); пычрак ягу; пычракка йөз белән егу; пычракка салып таптау; яла ягу.

3. Санламау; үтенечне кире кагу, игътибарга алмау. *[Хәйретдин] Ә мин аның бердәнбер васыятен аяк астына салып таптадым* (А. Әхмәт. Үги кыз). *Моңарчы беркайчан күрелмәгән мәнсезлек, БМОның иң төп кагыйдәләрен аяк астына салып таптау, ачыктан-ачык янау иде бу* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).

Төрдәше: аяк астына салу 1; аяк астына салып изү 2.

4. Юкка чыгару. *Ике төрле мораль белән яшәүче җәмгыять үзенең идеалларын, үзе дә сизмәстән, аяк астына салып таптады* (Р. Низами. Яшьлеккә хат).

**АЯК АСТЫНА ТАШЛАУ.** 1. *к.* аяк астына салу 1. *Юк дип уйлады ул, мондый матурлыкны, камиллекне, ялынып барып, Рәшатның аяк астына ташламыйча яхшы итте* (А. Гыйләҗев. Өч тәгәрмәчле арба).

Төрдәше: аяк астына салу 1.

2. Кеше күрерлек итеп махсус урнаштыру. *Балтасын, капчыгын да юри аяк астына ташлаган* (М. Насыйбуллин. Телсез шаһитләр).

**АЯК АСТЫНДА.** Якында гына. *Алланың рәхмәте белән бәхетең аяк астында гынадыр әле* (А. Гадел. Безнең авыл Наполеоны). – *Бәла аяк астында була дип әйтәләр иде, хак икән бит әй!* (Г. Сабитов. Ярсулы яз).

Төрдәше: бәла аяк астыннан чыгу.

**АЯК АСТЫНДА <АУНАП> ЯТМАУ.** Булдыклы, үзенең кадерен белгән кеше турында. – *Ә сәләт аяк астында аунап ятмый* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Вадим кебек ирләр аяк астында ятмыйлар* (А. Хәсәнов. Җәнбәт җәвере).

**АЯК АСТЫНДА АУНАУ.** 1. Урынына куелмаган, рәтсез-тәртипсез яткан нәрсә турында. *Нубидә генә түгел, Либи дигән илдә дә алтын-көмеш аяк астында аунап ята икән* (Н. Фәттах. Аклан).

2. Кадереңне белмәү, кадерсез булу; сиңа кимсетеп карау. *Этка ыргытылган сөяк кебек, / Аяк асларында аунадың* (Х. Туфан).

**АЯК АСТЫНДА (АРАСЫНДА) БОЛГАНУ (БОЛГАНЫП ЙӨРҮ; ЙӨРҮ).** Комачаулап, каршылыклар ясап йөрү. *Кит, аяк астында йөрмә, дип, дәрвишне орышырлар иде, үтерермез, дип куркытырлар иде* (К. Насыйри). *Клубка*

*бер кереп, бер чыгып, аяк астында болганалар* («Сөембикә» ж.).

Төрдәше: аяк астында буталу (буталып йөрү;) 1; аяк астында уралу (уралып йөрү) 1; аяк астында чуалу (чуалып йөрү) 1; аякка уралу (чорналу).

**АЯК АСТЫНДА БУТАЛУ (БУТАЛЫП ЙӨРҮ)** *к.* аяк астында (арасында) болгану (болганып йөрү; йөрү). *Аяк астында буталып, комачаулап йөрмәсен өчен, ул аны ябылуга хөкем иткән иде* (А. Тимергалин. Таш алиһә).

Төрдәше: аяк астында болгану (болганып йөрү; йөрү) һ.б.

**АЯК АСТЫНДА ҖАНЫМ ЧЫКСЫН.** Вәгъдә сүзе. *[Бакый] Ярым, дисең, туташ, – бәхетем бәйрәм итсен; түгел, диген, – аяк астыңда җаным чыксын!* (М. Фәйзи. Ак калфак).

Төрдәше: айдыр әгәр.

**АЯК АСТЫНДА ҖИР УБЫЛГАНДАЙ БУЛУ.** Үзеңә булган ышаныч бетә башлау, башлаган эшеңне уңышлы башкарып чыгачагыңа шикләнү һ.б. *Миңа бүген дә, эштән кайтып барганда, аяк астында җир убылгандай булды, бер коймага гына сөялеп калды* (З. Кадыйрова. Сагынырсың – мин булмам).

**АЯК АСТЫНДА<ГЫ> ҖИР ЧАЙКАЛУ.** Бер мизгелгә баш әйләнеп китү. *Берничә тапкыр алар Заһриның бакча башында яшерен генә очраштылар, кайнар тәнле бу кызый аны беренче кичне үк үбеп алгач, Нәбиуллин аяк астындагы җирнең кинәт чайкалганын сизде* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

**АЯК АСТЫНДА ҖИР<ЛЕК>НЕ ЮГАЛТУ.** Ныклы нигез бар дип башлап, эштә ышанычны югалту; өметсезлеккә бирелү. *Мин тагын аяк астында җирне югалттым* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).

**АЯК АСТЫНДА<ГЫ> ҖИР (ТУФРАК) ЯНУ.** 1. Бик тиз йөгереп үтәргә мәҗбүр булу. *Әйтерсең аяк астында җир яна диярсең, бу араны безгә җан-фәрманга чабып үтәргә туры килде* (Сөйләм).

Төрдәше: аяк баскан җир (туфрак) яну (ике маддә өчен дә).

2. Кылган җинаять өчен җавап бирергә кирәклеге турында. *Бүген исә ул хакта уйламаска, аяк астында җир яна – шуңа хәзерлек күрү кирәк* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).

**АЯК АСТЫНДА КАТЫ ҖИР СИЗМӘҮ.** Ышанычсызлык, терәк сизмәү. *Ләкин Чибәркәева әле һаман да аяк астында каты җир сизми, һаман шикләнә* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**АЯК АСТЫНДА ТАПТАТУ** *к.* аяк астына салып тапталу. *[Ибраһим] (кызарып). Ул, бердән хатыннарның наданлыгыннан, үзләренең хакларыны белмичә, үзләрен аяк астында таптаталар* <...> (Г. Исхакый. Алдым-бирдем).

Төрдәше: аяк астына салып тапталу.

**АЯК АСТЫНДА<ГЫ БЕЛӘН> ТУЕНУ.** 1. Терлекнең, кош-кортның анда-монда үсеп чыккан түгем-чәчем яки игелми калган җирләрдә туенуы. *Әтәч берәр җим тапса, тавык халкын чакыра да шул аяк астында туеналар* (Сөйләм).

2. *шаярт. Бушка килгән ризык. – Симермәсәм ярый инде, аяк астындагы белән туена башладым хәзер* (Сөйләм).

3. *күч.* Кайда булса да ничек туры килсә шулай табылган ризык. – *Түбән очта аш мәҗлесе оештыралар икән, барып, аяк астындагы белән туенып кайтыйм әле, куып чыгармаслар* (Сөйләм).

**АЯК АСТЫНДА ТУФРАК БУЛУ.** Корбан булу дәрәҗәсендә буйсынып яшәү, җан-тән белән хезмәт итү. *[Габделхак] Камилә туташ, сез мине кызганыгыз, аяк астыгызда туфрак булыйм* (Ш. Камал. Хаҗи әфәнде өйләнә). *[Шаһтимер] Ата тарафыннан куылган кызның аяк астында туфрак булырга хәзер йөрәкләр барын онытма!* (М. Фәйзи. Ак калфак).

Төрдәше: аягыңның туфрагы булыйм һ.б.

**АЯК АСТЫНДА УРАЛУ (УРАЛЫП ЙӨРҮ).** 1. *к.* аяк астында (арасында) болгану (болганып йөрү; йөрү). *Ачу килгәндә, аяк астында уралган бала кәефне боза, малайларны пыркытып чыгардылар* (А.Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

2. Эшсез йөрү. *Аяк астында уралудан башка эшең юктыр шул* (Сөйләм).

Төрдәше: аяк астында (арасында) болгану (болганып йөрү; йөрү һ.б. (ике маддә өчен дә).

**АЯК АСТЫНДА ЧУАЛУ (ЧУАЛЫП ЙӨРҮ).** 1. *к.* аяк астында (арасында) болгану (болганып йөрү; йөрү). – *Аяк астында чуалып йөрмәгез, мине хур итәрлек булмасын берүк* (Ф. Бат-

тал. Мистер-абсолют). – *Нәрсә шәлперәйгән тавык сыман аяк астында чуаласың, Дәүләтьяров?* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).

Төрдәше: аяк астында (арасында) болгану (болганып йөрү; йөрү) һ.б.

2. *к.* аяк астында уралу (уралып йөрү) 2. *Юк икән, аяк астында чуалып, сару кайнатып йөрмә* (Т. Әйди. Божра).

Төрдәше: аяк астында уралу (уралып йөрү) 2.

**АЯК АСТЫНДА ЯТКАН ХӘЗИНӘ.** Әзер мал, байлык; бушка килгән байлык. *Нәфисә ашлыгы – ул инде аңа аяк астында яткан хәзинә* (Г. Бәширов. Намус).

**АЯК АСТЫНДА ЯТМАУ.** Нәрсәнеңдер бик аз булуы, сирәк очравы яки бушка килмәве турында. – *Һәм мондый сүз аяк астында ятмый, ул колактан колакка, шәһәрдән шәһәргә, илдән илгә тарала* (З. Мурсиев. Соңлау).

**АЯК АСТЫНДАГЫ ТУФРАКНЫ АШАУ.** Берәр нәрсә сорарга килгәч, бөтен шартларга да риза булу. *Утлы табада биерсең әле, үрмәләп, шуышып килерсең дә аяк астындагы туфракны ашарсың, тик мәрхәмәт, рәхимшәфкать көтмә миннән!* (Ә. Гаффар. Богау).

**АЯК АСТЫНДАГЫ ТУФРАКНЫ НЫГЫТУ.** 1. Ныклап урнашып калу. *Айдарның үзенә аяк астындагы туфракны ныгыта төшәргә кирәк иде әле* (Ф. Хөсни).

2. Ышаныч казану. – *Син монда яңа кеше әле, иң әүвәле аяк астыңдагы туфракны ныгытырга кирәк: сүзеңдә тора алсаң, күпне өмет итә алачаксың* (Сөйләм).

**АЯК АСТЫННАН ГЫНА.** Көтелмәгәндә, көтмәгән-уйламаган җирдән. *Ләкин өченче көнне төштән соң, инде бетерәбез дип аеруча тырышып йөргәндә, аяк астыннан гына бәхетсезлек килеп чыкты* (Ф. Хөсни. Язмыш).

**АЯК АСТЫННАН КЫСЫР ХӘСРӘТ.** Булмаган, уйдырма нәрсә белән борчу китереп чыгару. *Мәнә сиңа аяк астыннан кысыр хәсрәт. Маһинур әйтмешли, урамга чыгар хәл юк, очраган берсе: – Йә, агай, туй кайчан? – дип, җәрәхәткә тоз сала* (И. Салахов. Хәсрәт төенчекләре).

**АЯК АСТЫННАН <КИЛЕП> ЧЫГУ.** Уйламаганда, көтмәгәндә барлыкка килү (бәла һ.б.). *Полициягә минем керүем бөтен полицияне гаҗәпкә калдырды. Алар үзләренең 11 ай эзләгән кешеләренең аяк астыннан чыгуына исләре китте* (Г. Исхакый. Зиндан). *Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, тагын бер «туган көн» аяк астыннан килеп чыкты. Нindие диген!* (Ә. Еники. Майбәдәр карчыкның туган көне).

Төрдәше: аяк астыннан чыккан бәла.

**АЯК АСТЫННАН ЧЫККАН БӘЛА.** Көтелмәгән һәм уйламаган җирдән чыккан мәсьәлә. *Верстагы янында әле теге эшенә, әле монысына тотынып караган була да, берни дә барып чыкмагач, бөтенесен атып бәрә: – Мәнә сиңа аяк астыннан чыккан бәла! Каян шуның белән башын бәйләгән бу кызый!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: аяк астыннан <килеп> чыгу.

**АЯК АТЛАГАН САЕН** *к.* адым саен 1–3. *Аяк атлаган саен эзгә сыңар яфрак өзелеп төшәр иде* (Э. Гадел. Көзнең сары көле яуганда). *Татарстанның үзендә аяк атлаган саен төрле дәрәҗәдәге, битен төрле маска белән каплаган Шаһгалигә килеп юлыгасың* (Р. Вәлиев. Җанга уелган уйлар).

Төрдәше: адым саен 1–3.

**АЯК АТЛАГАН ЯККА.** Бернинди максатсыз, теләсә кайсы юнәлештә хәрәкәт итү. *Ул юл аерылышына кадәр җитте дә, берни дә уйламыйча, аягы атлаган якка китеп барды* (Сөйләм).

Төрдәше: аяк кая таба атласа, шунда.

**АЯК АТЛАГАНЧЫ, БАСАР ТӨШНЕҢ НЫКЛЫГЫН КАПШАУ.** Берәр гамәл кылганчы, аңа бәйле хәбәрнең дөреслегенә инану. *Гатаулла аума кеше түгел, ишеткәненә дөреслеген төпченмичә ышанмый, кылганны зарурлыгына инанмыйча эшләми, кем әйтмешли, аягын атлаганчы, басар төшенең ныклыгын капшап карый* (М. Хуҗин. Өч каен ышыгында).

**АЯК <ТА> АТЛАМАУ (АТЛЫЙСЫ БУЛМАУ; БАСМАУ).** 1. Бервакытта да бармаска. *Һәм сүзендә торды: шуннан соң Сабан туйларына аяк атламады* (Г. Ибраһимов. Алмачуар). – *Рәхмәт әйт тә бүтәнчә бирегә аяк атлыйсы булма!* (Р. Низами. Бомж).

2. Берәрсе белән араны өзү, үзеңне барыпкилеп йөрүдән тыю. *Шушы актыгы булсын.*

*Моннан ары аяк та атлыйсы кеше түгел ул!* (И. Гази. Онытылмас еллар).

Төрдәше: анда башка аяк та атламау һ.б. (ике маддә өчен дә).

**АЯК АТЛАР ХӘЛ (ДӘРМАН; КӨЧ; РӘТ; ЧАМА) ЮК (БУЛМАУ; КАЛМАУ).** 1. Бик нык ару; хәлсезләнү. – *Шул Саесканнарга килен сорарга дип аягымны атлар хәлем юк!* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). – *Әйдәгез, кайтаек та ятаек. Болай да аяк атлар хәл калмады* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).

Төрдәше: аяк аяктан үтмәү; аяк<лар> бетү; аяк<лар> калмау; аяк эштән чыгу; аяксыз итү (калдыру); аяктан егылу; аяктан егылырдай булу; аяктан егылыр хәлгә (чиккә) җитү; аяктан калу 1; аяктан язу 1; аяксыз калу 2; баш кату 3; буын бетү; буыннар коелып төшү; буыны бушау. җеп өзәрлек дәрман (хәл) <дә> калмау; табаннар таш булу; хәлдән таю; хәлдән төшү; эт булу (булып бетү); эт булып ару; эштән чыгу 3.

2. «Аяк басарга мөмкинлек юк» мәгънәсендә. *Дөньяны тоҗым җебе чорнап алган, аяк атлар хәл юк, ятьмәгә эләгәсең. Дөньяны, тормышны, кешеләрне аңлау өчен, төпкә төшеп күзәтүсез генә ирешеп булмый* (matbugat.ru). *Аяк атлар хәл юк, бөтен җирдә тайгыч* («Безнең гәҗит» газ.).

3. «Бөтен тирә-як тулган» мәгънәсендә. *Әхнәф урамга чыкса, аяк атлар хәле юк, әллә кайдан малай-шалай килеп чыга, тотыналар үсмер егетне мыскылларга, үртәргә* («Казан утлары» ж.). *Аяк атлап йөргән җиребездә намаз да укыйбыз. Аяк атлар хәл юк* («Безнең гәҗит» газ.).

Төрдәше: аяк атларга (басарга) да ирек бирмәү; аяк <та> атлатмау (атларга да бирмәү); аяк бастырмау.

**АЯК АТЛАРГА (БАСАРГА) ДА ИРЕК БИРМӘҮ.** Бернинди дә мөстәкыйль хәрәкәткә рөхсәт бирмәү, ирексезләү, эзәрлекләү. – *Атналар буе кайда югалып йөрүеңнең дә, аяк атларга ирек бирми сырпалануыңның да сере ачылды хәзер, – дип куйды әни* (М. Хуҗин. Өч каен ышыгында).

Төрдәше: анда аяк атлыйсы (басасы) булма! һ.б.

**АЯК <ТА> АТЛАТМАУ (АТЛАРГА ДА БИРМӘҮ).** Кемне дә булса өенә кертмәү, килеп-китеп йөрүдән тыю. *Ләкин ниндидер көч аяк атларга бирмәде* («Сөембикә» ж.).

Төрдәше: анда аяк атлыйсы булма!; һ.б.

**АЯК АТЛАУ.** 1. Атлап йөрү рәвеше, үзенчәлеге. *Аяк атлап йөрешенә кадәр ярата* (А. Хәйртдинова. Язмыш сынавы).

2. Кая булса да бару, керү, чыгу. *Инде иртәгәдән соң бу төбәккә аяк атламас, чөнки ул моннан ары бөтенләй яңа кеше, замана кешесе булачак* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

3. Нинди дә булса эштә нәтиҗәгә ирешүне күрсәтү. *Утырдым мин фәнни хезмәт язып, / Килеп җитте менә яклау көнем, / Галимлеккә аяк атлау көнем* (М. Саттаров). *Гадиләштереп әйткәндә, бу инде – реализмга аяк атлау дигән сүз* (Э. Нигъмәтуллин. Тәҗрибә һәм белем алмашып…).

Төрдәше: аяк басу (өч маддә өчен дә).

**АЯК АТЛЫЙСЫ (БАСАСЫ) БУЛМА!** *к.* анда аяк атлыйсы булма! *Моннан соң минем өемә аяк басасы булма, сабаке* (М. Мәһдиев. Ачы тәҗрибә). *Кыз аңа табан атламакчы була. – Аяк атлыйсы булма!* (Г. Каюмов. Упкын өстендә уен).

Төрдәше: анда аяк атлыйсы (басасы) булма! һ.б.

**АЯК АЯКТАН ҮТМӘҮ.** Адым ясар өчен дә чама калмау. *Шунда егылып үләм дип торам, аягым аяктан үтми башлады* (Сөйләм).

Төрдәше: аяк атлар хәл (дәрман; көч; рәт; чама) юк (булмау; калмау) 1 һ.б.

**АЯК БАСАР (АТЛАР) УРЫН (ҖИР) ЮК (КАЛМАУ).** 1. *к.* алма төшәр<лек> урын булмау (юк). *Капчыклар тегендә-монда чәчелде, юлда аяк басар урын юк, караңгыда бер-берсен этеп-төртеп, машинада урын алып калырга ашыктылар* (К. Кәрим. Зур акчалар).

Төрдәше: алма төшәр<лек> урын булмау (юк) һ.б.

2. Бик пычрак яки әйбер-кара таралып яткан җир. *Бүлмә эче урамнан җыелган чүп-чар, ниндидер иске-москы белән тулган, аяк басар урын калмаган* (Сөйләм).

**АЯК БАСАЧАГЫ ЮК (БАСАЧАК ТҮГЕЛ).** Билгеле булган бер җиргә бармаячакны белдерү. – *Минем анда аяк басачагым юк. Ул ихатаны сатарга куйдым мин* (Д. Булатова. Соң түгел!).

**АЯК БАСКАН ҖИР (ТУФРАК)** *к.* аяк астындагы җир. *Кеше аяк баскан җир түгел бу* (Г. Гыйльманов. Албастылар).
Төрдәше: аяк астындагы җир.

**АЯК БАСКАН ҖИР (ТУФРАК) ЯНУ** *к.* аяк астында<гы> җир (туфрак) яну 1–2. *Сазга батырган тракторны исенә төшергән саен, аягы баскан туфрак янган сыман була иде* (Сөйләм).
Төрдәше: аяк астында<гы> җир (туфрак) яну 1–2.

**АЯК БАСКАН<ЫМ> ЮК** 1. Барган яки килгән булмау. *Ул якларга күптән аяк басканым юк* (Д. Каюмова. Син бик серле, язмыш).

2. *к.* алма төшәр<лек> урын булмау (юк). *Мотоциклдан егылып, аягын имгәткәч, инде ничә ел Сабан туйларына аяк басканы юк – борын төртерлек тә урын булмау бер хәер, сау аягын таптатудан курка башлады ул* (Сөйләм).
Төрдәше: алма төшәр<лек> урын булмау (юк) һ.б.

**АЯК БАСКЫСЫЗ**. 1. *к.* алма төшәр<лек> урын булмау (юк). *Елганың малларны сулауга төшерә торган урыннарын читтән генә карап торалар – хәзер анда аяк баскысыз әрмәлек* (М. Кәбиров).
Төрдәше: алма төшәр<лек> урын булмау (юк) һ.б.

2. Аяк асты баткак, пычрак. *Һәм моннан ел ярым чамасы элек разведкага артистлар килүен исенә төшерде. Аяк баскысыз пычрак иде* (М. Зарипов. Соңгы вахта).

**АЯК БАСМАГАН.** 1. Берәү дә булмаган, яшәмәгән. *Татарстан туфрагында туып та, нужа куа-куа Урал якларына сугылган, шунда кеше аяк басмаган бер җирдә урман төпләп, азмаз чәчүлек җир булдырган* (Г. Әпсәләмов).

2. Бер тапкыр да килмәгән, кермәгән җир. *Гомеренә бу йортка аяк басмаган Хафиз түрдә, алдына тастымал салып, чәй эчеп утыра* (Ә. Фәйзи. Тукай).

**АЯК <ТА> БАСМАУ** *к.* аяк <та> атламау. *Трудармиядән азат ителү белән монда бер көн тормаска, алтын сарайлар вәгъдә итсәләр дә, кабат тимер юл эшенә аяк басмаска ант иткән көннәре дә күп иде* (Л. Хәмидуллин. Кичке шәфәкъ).
Төрдәше: аяк <та> атламау (атлыйсы булмау); ике аякның берен <дә> атламау (басмау); эзне дә күрсәтмәү.

**АЯК <ТА> БАСТЫРМАУ** *к.* анда аяк атлыйсы (басасы) булма! *[Хәерниса] Тәүбә-тәүбә, йортыма аяк бастырачагым юк* (Ю. Әминов. Тамырлар). *Аларны белмәсәң, тулаем конспектыңны тикшермичә, яңадан имтиханга аяк та бастырмый, имеш* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).
Төрдәше: анда аяк атлыйсы (басасы) булма! һ.б.

**АЯК БАСУ.** 1. Кая да булса керү, килү, узу. *Камилла үзенең әллә нинди ят дөньяга аяк басуын тойды* (Н. Гыйматдинова. Китәм, димә...).

2. Вакыт узып, бераздан яңадан башлап җибәрү. *Актык килүендә ул Сәлахны куып чыгарды, минем өемә яңадан аяк басасы булма, диде* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

3. Беренче кат килеп керү. *Ул бит больницага аяк баскан көненнән үк врач булу турында хыяллана иде* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

4. Килеп җитү. *Ике ай дигәндә, ул Болгар җиренә аяк басты* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).

5. Кайда да булса эшчәнлек күрсәтә башлау. *Шактый гына уйлангач, аның әдәбият юлына аяк басу сәбәпләре миңа аңлашыла башлый сыман* (М. Вәли-Барҗылы. Тормыш дулкыннары).

6. Гомер сөрешендә билгеле бер яшькә җитү яки вакыт белән бәйле нәрсәдер башлану. *XX гасыр башында туган композитор 64 нче яшенә аяк басты* (Р. Низами. Сәйдәшнең соңгы елы).
Төрдәше: аяк атлау һ.б. (барлык мәддәләр өчен дә).

**АЯК БАШЫННАН АЯК БАШЫ ҮТМӘҮ** *к.* аяк аяктан үтмәү. *Көне буе авызына бер валчык икмәк тә капмыйча, тузан туздырып барабара, аяк башыннан аяк башы үтмәс хәлгә җиткән иде* (Сөйләм).
Төрдәше: аяк аяктан үтмәү һ.б.

**АЯК БЕЛӘН ТАПТАУ** *к.* аяк астына салу 1. *Тырнак астыннан кер эзләргә яраткан тирә-күршеләргә чәйнәргә генә булсын, алар аның саф хисләрен дә пычрак аяклары белән таптап рәнҗетмәсләрме <...>?* («Шәһри Чаллы» газ.).
Төрдәше: аяк астына басу һ.б.

**АЯК БЕЛӘН ТИБЕП КЕРҮ.** Әрсез рәвештә, рөхсәтсез берәр җиргә килеп керү яки сөйләшүгә тыкшыну. *Кайчандыр хулиганлык өчен үзе бикләнеп яткан камераларга ул инде аяк*

*белән генә тибеп керә иде, бирегә инде башкаларны тибеп кертә иде...* (Ф. Бәйрәмова. Нух пәйгамбәр көймәсе).

**АЯК БЕЛӘН ЭШЛӘҮ (РЕМОНТЛАУ; ЯЗУ).** Нәрсәне булса да сыйфатсыз, ничек туры килде шулай башкару. «*Аяк белән эшләсәң, баш белән җавап бирерсең!*» (Ш. Галиев. Илһамым-мәхәббәтем).

**АЯК БЕТЕРЕП ЙӨРҮ (БАРУ; КИЛҮ)**. Күп йөрүдән аяк кырылу. – *Аягыңны бетереп яшелчә складына барып йөрмә, андагылар кайтып киттеләр инде* (Сөйләм).

Төрдәше: аяк ите ашалу 1; аяк итен ашату (бетерү); аяк итен ашатып (бетереп) йөрү (бару; килү); аяк талдырып (әрәм итеп) йөрү (бару; килү).

**АЯК<ЛАР> БЕТҮ** *к.* аяк атлар хәл (дәрман; көч; рәт; чама) юк (булмау; калмау) 1. *Менә сәламәтлек кенә какшады, аяклар бетте* (Т. Нәҗмиев. Сабаларда эчәр суым булгач...).

Төрдәше: аяк атлар хәл (дәрман; көч; рәт; чама) юк (булмау; калмау) 1 һ.б.

**АЯК БИЕТҮ** Тиз-тиз генә эшләү (язу, ясау, ашау һ.б.). *Һөнәр училищесы формасы кигән өч үсмер алларына пилмәнле тәлинкәләр куйганнар да баш калкытмыйча аяк биетәләр*. (Г. Мөхәммәтшин. Хуҗалар).

**АЯК ҖИРГӘ (ИДӘНГӘ) ТИМӘҮ.** 1. Берәр эш артыннан чабу, нәрсәне булса да бик җитез эшләү. – *Нәфисә апа, сине ындыр табагына чакыралар... Тиз, диделәр, аягы җиргә тимәсен, диделәр* (Г. Бәширов. Намус). – *Бар чап, аягың җиргә тимәсен, – диде...* (Н. Гыйматдинова. Күке төкереге).

Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

2. Куанып, дәртләнеп йөрү яки бию. – *Тикшергәннәр, ахры, егетне, аягы идәнгә тими, – диешеп калдылар* (И. Гази).

Төрдәше: аяк идәнгә тимәү.

**АЯК ҖИРГӘ ТИЯР-ТИМӘСТӘН** *к.* «а» дигәнче. *Аягым җиргә тияр-тимәстән чабып, язу өстәленә килдем; анда тузылган китаплар, дәфтәрләр ята, шулар өстендә алтын белән язылган кыйммәтле кәгазь ялтырый иде* (Г. Ибраһимов. Яз башы).

Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**АЯК ИТЕ АШАЛУ.** 1. Күп йөрүдән аяк кырылу. *Бүген бүлмәдә генә эшлим әле, йөри-йөри аяк итем ашалды бугай* (Сөйләм).

Төрдәше: аяк бетереп йөрү (бару; килү) һ.б.

2. Күп йөрү, йөрергә мәҗбүр булу. *Электрон кәгазь әйләнеше замананыда яшибез, ник һаман да аяк ите ашала соң?* (intertat.tatar).

**АЯК ИТЕН АШАТУ (БЕТЕРҮ).** аяк бетереп йөрү (бару; килү). *Мидхәт райүзәккә бүген үк китәр һәм, аяк итен ашатып бетерсә бетерер, ашлама табар* (М. Хәбибуллин).

Төрдәше: аяк бетереп йөрү (бару; килү) һ.б.

**АЯК ИТЕН АШАТЫП (БЕТЕРЕП) ЙӨРҮ (БАРУ; КИЛҮ)** *к.* аяк бетереп йөрү (бару; килү) һ.б. *Нигә әле ул, аяк итен ашатып, аны эзләп йөрергә тиеш* (Р. Кәрами. Кая чабасың, гомер юртагы?).

Төрдәше: аяк бетереп йөрү (бару; килү) һ.б.

**АЯК ИТЕН ТУЗДЫРУ.** Мәгънәсез һәм файдасыз эш артыннан йөрү. *Юк, җаным, йөрмә фалчыга. / Туздырма аяк итең. / Ышан син, хатлар алдамый! / Аерылу, беләм, читен...* (Г. Латыйп).

**АЯК КАЙМЫГУ.** Аяк буыннары урыннынан чыгу, таю. *Кеше чигенгәч, чигендем дә юлдан яздым, җитмәсә, аяк каймыкты, дияр* (И. Низамов. Колаксыз Зариф).

**АЯК<ЛАР> КАЛМАУ** *к.* аяк атлар хәл (дәрман; көч; рәт; чама) юк (булмау; калмау). *Трактор частьлары эзләп аягым калмады, кайсыгыз күрде?* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

Төрдәше: аяк атлар хәл (дәрман; көч; рәт; чама) юк (булмау; калмау) һ.б.

**АЯК КАЯ ТАБА АТЛАСА, ШУНДА** *к.* аяк атлаган якка. *Мин озак уйлап тормадым: аяк кая таба атласа, шунда киттем* (Сөйләм).

Төрдәше: аяк атлаган якка.

**АЯК КЕРМӘС ҖИРГӘ БАШ КЕРҮ.** Хәтәр, мәшәкатьле җиргә килеп эләгү хакында. *Рекламага ышанып, җыенып киткән иде, кем уйлаган аны аяк кермәс җиргә башы керер дип* (Сөйләм).

Төрдәше: бәла агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри; бәла аяк астында булу (йөрү); бәла аяк астыннан чыга; бәла анасы буаз; бәлагә кабу (тару; очрау; төшү; угърау); бәлагә юлыгу; бәла-

гә уралу; бәла-казага очрау (калу; тару; төшү; юлыгу); бәхетсезлеккә төшү; вәйран булу 2.

**АЯК КЕРСӘ, БАШКАСЫ ИЯРҮ.** Әрсез кеше; аз гына юл бирсәң, бөтенләй кереп урнашу. *Аяк керсә, башкасы да шуңа ияреp әле* (Р. Зәйдулла. Ташка ордым башны).
Төрдәше: аягын тыккач, таягын да тыгасы һ.б.

**АЯК КЕРСӘ, ТОЯК КЕРҮ** *к.* аяк керсә, башкасы ияру. *Исеңнән чыгарма: борынгылар «аяк керсә, тояк керәчәк», дигәннәр* (Сөйләм).
Төрдәше: аягын тыккач, таягын да тыгасы һ.б.

**АЯК КИЕМЕ ТУЗДЫРУ** *ирон., шаярт.* Кирәкмәгән эш белән йөрү. *Ике атна шулай бер нәтиҗәсез, аяк киеме туздырып йөреп үтте дә китте* (Р. Габделхакова. Нишләттегез Гөлкәйне?!).

**АЯК КИЕНГӘНЧЕ.** Җыенганчы, әзер булганчы. *Яңа ел киче дип тормыйлар, Октябрь бәйрәме дә аларга песи төчкерүе белән бер – чыгалар да китәләр, бүтәннәр аяк киенгәнче, ташып, тутырып та куялар* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**АЯК КИЕНЕП КАЛУ.** Мөмкинлек, көч, вакыт бар чагында берәр эшнең хәстәрен алдан күрү. *Менә хәзер, беләктә көч, йөрәктә дәрт бар чакта аяк киенеп калмагач, картлык көнендә ятарсың аннары* (Р. Төхфәтуллин. Авылдашым Нәби).
Төрдәше: аяк киенү (киенеп кую); аяк чолгауларын алдан ук әзерләп кую.

**АЯК КИЕНҮ (КИЕНЕП КУЮ / ТОРУ).** Ниятләгән эшнең алдан ук хәстәрен күрү. *Кыскасы, итәк-җиңне җыеп, аякны киенеп, бии башларга әзерләнеп торырга кирәк* (Ф. Хөсни. Җәй башы). *Кайтырыгызны белмәдек, кайтырыгызны, чүтеки аяк киенеп торыр идек* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: алдан алу (алып тору) һ.б.

**АЯК КУЮ** *гади с., к.* аю мае сөртү 1. *Телефон икенче көнне үк юкка чыкты, үзе аякландымы, аяк куйдыларммы...* (Ю. Дәүликамова. Беләзек).
Төрдәше: аю мае сөртү 1 һ.б.

**АЯК КЫЗДЫРУ (КЫЗДЫРЫП ЙӨРҮ).** Чабышкыны Сабан туе ярышларына әзерләү. *Яңа аяк кыздырган – җиңел атлыйлар* (Ш. Галиев).

**АЯК КЫСКАРТУ** *гади с.* Берәрсен кая да булса йөргән җиреннән туктату. *– Ни кирәктер бу эшем иясенә?! «Мин сине үлемнән коткардым», – дип килә дә керә. – Аягын кыскартырга кирәк, алайса, аның! – дидем мин* (А. Гыйләҗев. Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят).

**АЯК ОЧЛАШ.** Ятканда, аяк очларын туры китереп, сузылып яту. *Аяк очлаш яту* (Ай колакланса, ни була. 2 нче кит.).

**АЯК ОЧЫ.** Хуҗалыкта каралты, абзар-кура артындагы бакча. *Шуның ише көндәлек уйлары белән җитәкләшеп, Маһирә «аяк очыннан» – бәрәңге бакчасы артындагы печәнлектән – бер кочак ат кузгалагы йолкып менде* (Ф. Мөслимова. Нәфисәнең әнисе бар).

**АЯК ОЧЫ БЕЛӘН ГЕНӘ (ОЧЫНА ГЫНА) БАСЫП ЙӨРҮ (ҮТҮ; ЯКЫНЛАШУ** һ.б.**).** Сак кына, тавыш чыгармыйча, бармакларга гына басып йөрү. *Бакчада аның палатасы турысыннан узганда, тынлык саклыйлар, ул яшәгән корпуста коридордан узганда, аяк очына басып кына йөриләр иде* (М. Мәһдиев. Ачы тәҗрибә).

**АЯК ОЧЫ ҖИРГӘ ТИМӘҮ** 1. *к.* аяк җиргә тимәү. *Борылдым гына, шунда ук юк булды – аяк очы да җиргә тимәде* (Сөйләм).
Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

2. Хөрмәт һәм муллыкта яшәү. *Кадерен белеп яшәсәң, аяк очың да җиргә тимәс, гел күтәреп йөртерләр* (М. Хәбибуллин).
Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

**АЯК ОЧЫНА ГЫНА КАРАП ЙӨРҮ.** «Тәүфикълы, әдәп саклап» мәгънәсендә. *Аяк очына гына карап йөргән кыз бала турында «бигрәк тә тәүфикълы инде, тәрбияле» кебек сүзләр йөри башлады* (Сөйләм).

**АЯК ӨЗӘҢГЕДӘ <БУЛУ>.** «Йомышыңны куш кына, хәзер үтибез аны» мәгънәсендә. *Шунда Гомәр, шаярган итеп, «аякларыбыз өзәңгедә, хуҗам, әмереңне генә бир» дип, кулын чигәсенә тидереп алды* (Сөйләм).

**АЯК ӨСКӘ.** 1. Аякка бастыру, үзенең хакларын хаклап, фетнә оештырырга чакыру. *Алар һәммәсе дә тирән фикергә чумган, халыкны ничек ачарга, халыкны аяк өскә бастырырга, халыкны нурландырырга уйлыйлар, алдагы көнне төшенәләр: гали вә мөкатдәс максатка юнәлгәннәр* (Ш. Камал. Авыл мөгаллиме).

2. Савыктыру, сәламәтләндерү. <...> *энесен Абдулланы носилкы белән госпитальдән китереп калдырганнар, үпкәсе аша пуля үткән, алты ай госпитальдә яткан, аяк өскә баса алмаганнар* (В. Ильясов. Айша җаным).

3. Атның, гайрәтләнеп яки өркеп, арт аякларына басуы. *Айгыр, колакларны ярырлык итеп кешнәде дә, аяк өскә басып, бәкәлләрен селкеткәләде* (Сөйләм).

Төрдәше: үрә торып.

**АЯК ӨСЛИ <ГЕНӘ>.** Утырып тормыйча, аякта баскан килеш; ашык-пошык, күп уйлап тормыйча. *Шуннан соң яңадан өстәл янына килде, яза башлаган мәкаләсенә аяк өсли генә күз ташлады* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

Төрдәше: аягөсте генә һ.б.

**АЯК ӨСТӘН (ӨСТЕ; ӨСТЕНДӘ; ӨСТЕННӘН) ЙОКЛАУ (ЙОКЛАП ЙӨРҮ).** 1. Дәртсез, рухсыз, пошмас кыяфәттә булу. – *Без әле килербез, менә бабай әзрәк ял итеп кенә алсын. Югыйсә менә аяк өстендә йоклый башлады, – диде Җәмилә, көлеп* (Г. Әпсәләмов. Яшел яр). *Күр инде, аяк өстеннән йоклап бара, бичара* (Ф. Шәфигуллин).

2. Кулдан эш килмәү, булдыксыз. *[Тамчы] Егетләр, кайгырмагыз, иртәгә читкә киткән бик күп кызларыбыз кайта башлаячак. Аяк өсте йоклап йөрмәсәгез, үзегезгә тиңен табарсыз* (Г. Тарханова. Шүрәлеләр илендә).

Төрдәше: авызга каптырганны йотмау һ.б.

**АЯК ӨСТЕ (ӨСТЕННӘН).** Баскан көенчә, аягүрә басып. *Ничек, ул аяк өсте авырыймыни?* (А. Алиш. Якты күл буе). *Мондый зур мәсьәләне аяк өстеннән генә хәл итеп булмый* (И. Гази).

Төрдәше: аягөсте генә һ.б.

**АЯК ӨСТЕ ГЕНӘ** *к.* аягөсте генә. – *Ә без аяк өсте генә... Әйдәгез, толыпларны кимичә генә утырышыгыз!* (Ә. Еники. Рәшә).

Төрдәше: аягөсте генә һ.б.

**АЯК ӨСТЕ (ӨСЛИ; ӨСТЕННӘН) ТӨШ КҮРҮ (КҮРЕП ЙӨРҮ)** 1. Тормыштагы сәер вакыйганы төш итеп кабул итү. *Үземне мин өндә түгел, аяк өсте төш күрәм итеп тойдым, әти. Син кулга алынганның иртәгесен мәктәпкә баргач, иптәшләрем, фашист дип мәсхәрәләп, дәррәү ябырылып дөмбәсләделәр* (Г. Тавлин. Афәт).

2. *к.* авызга каптырганны йотмау. – *Син мине икенче аяк өсли төш күреп йөргән егет белә таныштырма* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга каптырганны йотмау һ.б.

**АЯК ӨСТЕНДӘ <КИЛЕШ>** 1. *к.* аягөсте генә. *Ерактан ак таң беленгәндә, җәйләү аяк өстендә иде инде* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *Бу төнне алар аяк өстендә үткәргәннәр, ахры, әнә бит – йөзләре шешенгән, күз алмаларына кызыл пәрәвез эленгән...* (Г. Гыйльманов. Албастылар).

Төрдәше: аягөсте генә һ.б.

2. *к.* аяк өстендә булу 3. *Җидедә барлык делегатлар аяк өстендә иде инде* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Кояш әле чыгам дип хәбәр генә биргән, ә Зөһрә инде күптән аяк өстендә* (Х. Сарьян).

Төрдәше: аяк өстендә булу 3.

**АЯК ӨСТЕНДӘ БУЛУ.** 1. Йокыдан торган булу. *Эшюикә Бәхтиевнаның классы җиденче яртыда тулысы белән аяк өстендә була* (М. Маликова. Оҗмах балалары). *Үзе таң тишегеннән аяк өстендә булгач, мине дә үзе кебек тургай дип беләдер* (Р. Галиуллин. Кафе).

2. Йөри алу, исән-сау булу. *Билгеле, бу кышкы газап-михнәтләрне һәркем үзенчә кичерде, туңды-өшеде, ач яшәде, безне дошман эзәрлекләгәндә, хәлдән таеп егылганчы, туктаусыз аяк өстендә булды, Севастополь язмышы, үз язмышы турында, туганнары турында уйлады* (И. Верасов. Кырым партизаннары).

3. Иртәнге сәгатьтән эшне башларга әзер булу. *Ә иртән, сәгать биштән дә соңга калмыйча, син инде аяк өстендә булырга тиеш* (В. Нуруллин. Әгәр син булмасаң).

Төрдәше: аяк өстендә <килеш> 2.

**АЯК ӨСТЕНДӘ КӨЧКӘ БАСЫП ТОРУ.** Исерткеч эчемлек эчүдән яки башка сәбәптән егылам-егылам дип тору. *Ниһаять, кичке уникеләр тирәсендә аяк өстендә көчкә басып торган абыйсы күренде* (Сөйләм).

**АЯК ӨСТЕНДӘ ТАПТАНУ (ТАПТАНЫП ТОРУ).** Китмичә, һаман бер җирдә таптанып тору. *Тәрәзә янындагы егет, китмичә, аяк өстендә таптанып торуын дәвам итте* (Сөйләм).

**АЯК ӨСТЕНДӘ ТОРУ.** Утырмыйча яки ятмыйча, аякта калу, басып тору. *Сафа белән Солдат,*

*чак-чак кына аяк өстендә торып кочаклашкан көе, лабаз артыннан килеп чыктылар* (Ш. Камал. Акчарлаклар).

**АЯК ӨСТЕНДӘ ЧАБУ.** Эшсез тора алмаган, һаман нәрсәдер эзләгән, эшләгән тиктормас кеше хакында. *Көне-төне* аяк *өстендә чапкан бу кырыклар тирәсендәге түгәрәк битле, зур моңсу күзле кеше минем янга керер, тәмәке пыскытып, әзрәк ял итеп утырырга ярата иде* (Ә. Еники. Без дә солдатлар идек).

**АЯК ӨСТЕННӘН ГЕНӘ ЭШЛӘҮ.** Эшне сыйфатсыз башкару, игътибарсыз эшләү. *Эшләргә алынса, күңелен биреп эшли ул, аяк өстеннән генә эшләргә күнекмәгән* (Сөйләм).
Төрдәше: аннан-моннан гына.

**АЯК САЛУ** *гади с.* Аяк киемен салып, оекчан калу. *Мин дә көнаралаш кичке кояш нурлары астында көймәдә, көймә булмаса, итәкләремне җыеп, сиңа, синең бүлмәңә ашыга идем* (Г. Кутуй. Тапшырылмаган хатлар).

**АЯК СЕЛКҮ** *к.* авыздан җан чыгу. *Мин бу чирдән котыла алмам, ахры, дип, аягын селкергә әзерләнеп ятмады – аяк-кулын хәрәкәтләндерергә тырышты, табиб биргән даруларны эчте* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

**АЯК СӨРТҮ (СӨРТЕП УЗУ).** Исәпкә алмау, мыскыллау, хурлау. *Туган телгә аяк сөртә алар, / Күрмәмешкә салышып йөрибез* (Р. Зәкуан. Синдә калам). *Укыганда безнең ише авыл гыйбатларын санга сукмаган Эльвина, мәгәр минем «сөт заводы директоры» дигән даным барып ирешмәсә, ул «Корстон» ишеге төбендә үк мине аягын сөртеп узар иде, мөгаен* (Н. Гыйматдинова. Сөйлим, тыңла...).

**АЯК СУЗУ.** 1. Үлем түшәгенә яту. *Җитмәсә, «Син ил ямен боздың» диеп, / «Иркебезгә син аяк суздың» диеп, / Ибраһимны янган утка аттылар, / Аттылар да мәңгелеккә яктылар* (М. Җәлил). *Минем әле үләргә аяк сузганым юк* (Г. Насрый). *[Рәзинә] Аяк сузарга аларга... иртәрәк әле, Расих абый* (Х. Ширмән. Авылым учагы).

2. *к.* аваздан җан чыгу. – *Миңа – абын, тоз гына, / Эчем тулы боз гына; / Дөньяда кызык калмады, / Инде аякны суз гына* (Г. Камал. Буржуй зары). – *Чит-ят җирдә аяк сузып булмас, – диде ата кеше, Рахманның яраннары керткән сөҗүне суыргалап* (В. Имамов. Казан дастаны).
Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

3. *күч.* Бетү, юк булу. *[Давыт] Шушы минуттан башлап сездә Совет власте аягын сузды* (Ю. Әминов. Умырзая чәчәкләре).
Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

4. Теләгәнчә, бирелеп эшләү. *Колхозың бай булмагач, аягыңны әллә ни киереп суза алмассың* (А. Гыйләҗев).

**АЯК СУЗЫП ЯШӘҮ.** Иркен яшәү, иркен эш итү. *– Давай, атай, онытыйк, кешечә аяк сузып яшик* (Н. Гыйматдинова. Мәхәббәттә гөнаһ бар).
Төрдәше: аякны озын сузу.

**АЯК СУЫТУ.** 1. Ат чабышында яки Сабан туе ярышында катнашкан чабышкыны арлы-бирле йөртү, тынычландыру. – *Булдырдың, энекәш, – диде абый, минем аркадан сөеп, – хәзер атның аягын суытырга кирәк* (Сөйләм).

2. Чыгып китү, качарга җыену. *Иптәшләрем миңа таба борылып баскан кызның аяк суытуын сизенми иделәр* (Ф. Яхин. Сихерче кызы).

**АЯК ТАБАННАРЫ ГЫНА ЯЛТ ИТЕП КАЛУ.** «а» дигәнче. *Күл өстеннән юк булды: аяк табаннары гына ялт итеп күренеп калды* (И. Гази. Онытылмас еллар).
Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**АЯК ТАБАННАРЫНА ЙӨГЕРҮ.** Күңелгә тынычлык, рәхәтлек бирә торган хис туу. *Розаның кинәт башы әйләнеп китте, аяк табаннарына рәхәт бер курку йөгерде* (Р. Низамиев. Беренче мунча).

**АЯК ТАБАННАРЫНА УТ КАПКАНДАЙ** *к.* «а» дигәнче. *Аксак әмир эзенә баскан гына иде, тегесе урау юллар аша, аяк табаннарына ут капкандай, кабат үзенең Сәмәрканд ягына борылып киткән* (В. Имамов. Карабәк).
Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**АЯК ТАБАННАРЫНА УТ ҮРЛӘТҮ.** Кемгәдер куркыныч тудырырга тырышу. *Карабәк үзе дәшми йөрсә дә, башкалар аның аяк табаннарына ут үрләтте* (В. Имамов. Карабәк).

**АЯК ТАБАНЫ КЫЧЫТУ.** Бер урында утырып тора алмау яисә кая булса да китеп ял итү теләге туу. *Аяк табаның кычытса, Кырымга*

*кит, Кавказ тауларына мен, нарзан ванналарында кайна* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**АЯК ТАБАНЫН ЯЛАУ** *к.* авызга бал да май булып керү. – *Шушы эт җан, аяк табаннарын ялау өчен, ничек итеп яңа хуҗаларны юллап тапкандыр?* (В. Имамов. Казан дастаны).

Төрдәше: авызга бал да май булып керү һ.б.

**АЯК ТАЛДЫРЫП (ӘРӘМ ИТЕП) ЙӨРҮ (БАРУ; КИЛҮ)** *к.* аяк бетереп йөрү (бару; килү). *Аяк талдырып йөрүнең пычагыма да кирәге юк, диде* (А. Гыйләҗев). *Аякларын талдырып җәяү йөрмәсен, машинага гына утырып йөрсен! – дигән ул бу хәлдән бик аптыраган кешеләргә* (Р. Фәизов. Кызган бодай исе).

Төрдәше: аяк бетереп йөрү (бару; килү) һ.б.

**АЯК ТАРТКАН ЯККА** *к.* аяк атлаган якка. *Кайткач, малайларны чыгарып җибәрер дә Чирик, аяк тарткан якка юлланыр* (К. Кара. Күрше хакы).

Төрдәше: аяк атлаган якка һ.б.

**АЯК ТАРТМАУ (БАРМАУ).** Берәр җиргә барырга яки эшне башларга икеләнеп тору, теләмәү. – *Ямгырча бигә кода булып керик тә, калымны түлик тә, кайтыйк та китик! Алмаш ханга никтер аяк тартмый!* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).

**АЯК ТАРТУ.** Каядыр барырга омтылып тору; теләк булу. *Ахырдан гына белдем: бу гаҗәп аяк тарту, йолдызнамәләр белән генә аңлата алырлык аяк тарту булган икән* (Р. Хисмәтулла). *Аягы кыз ягына тартты, әмма мие аларга икенче якка барырга боерык биреп өлгергән иде инде* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).

**АЯК ТАЮ.** Ялгышу, хаталану. *Әгәр инде бу сүзләрдә хатам булса, олуг аганың ак күңеле мине кичерер; илченең аяк тайган җирләрен күрсәтер, төз юлга барырга акыл бирер, безнең теләгебез шул, – дип тәмамлады* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).

Төрдәше: балагын җыя белмәгән (алмаган); ишә ишәк чумарын; ишкән икән; ишкәнсең <икән> ишәк чумарын; ишкәнсең ишек бавын; иштең арыш чумарын; иштең ишәк чумарын; иштең ишек бавын.

**АЯК ТЕРӘП**. 1. Бик нык каршы тору. *Сафаның гомерендә беренче тапкырдыр бу рәвешле кирле-мырлы сөйләшүе, аяк терәп әтисенә каршы әйтүе иде* (Ф. Яхин. Тәүбә-тәүбә, əстәгъфируллаһ!). *Шул ук вакытта алучы күбәя башласа, хуҗаларның да аяк терәп маташулары көчәя* (Ә. Еники. Рәшә).

2. Ныклы рәвештә, даулап; курыкмыйча. *Монысына да аяк терәп каршы торучы батыр табылмады* (М. Маликова. Язгы такыялар). *Үз буыны исеменнән / Җиргә / Аяк терәп сүз алырга килә* (М. Әгъләм).

3. Хаклыкка инанып сөйләшү. *Шулай да ул хуҗалар белән аяк терәп сөйләшергә булды* (Ә. Еники. Рәшә). – *Алай булмаса, ничек шултикле аяк терәп сөйләшер иде икән теге зимагур?* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: ныклык белән.

4. Барлык көчне кулланып. *Якты, җылы фатирда яшәгән, йомшак караватларда йоклаган, тәмледән тәмлене генә ашаган безнең ише халык, шушы капкадан кермәс өчен, аяк терәп карышырга тиеш иде.* (Н. Гыйматдинова. Сөйлим, тыңла...).

Төрдәше: аяк терәү (барлык маддәләр өчен дә).

**АЯК ТЕРӘП КАРШЫ КИЛҮ (ТОРУ; ТӨШҮ).** 1. Үз принципларыңны, фикереңне, карашларыңны ныклы рәвештә һәм катгый яклау. *Башка карагруһчы көчләр аяк терәп каршы килгәндә, татар яшьләренә төрле әдәбимузыкаль кичәләр үткәрергә, спектакльләр уйнарга фатиха бирә* (Р. Әмирхан. Әмирханнар).

2. Нәрсәгә булса да кискен каршы килү, үзеңнең ризасызлыгыңны белдерү. *Белеп торам: күпчелек аяк терәп каршы киләчәк* (З. Хөснияр. Эттән туган).

**АЯК ТЕРӘП СӨЙЛӘШҮ.** Курыкмыйча, үз сүзеңдә нык торып сөйләшү. *Хаклы булуына инанган чагында, район башлыкларына да баш бирми: аяк терәп сөйләшә торган иде* (В. Нуруллин. Ике урам арасы). – *Алай булмаса, ничек шул тикле аяк терәп сөйләшер иде икән теге, зимагур?* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**АЯК ТЕРӘП ТАРТУ.** Барлык мөмкинлекләрне файдаланып, барлык көчен кулланып тарту. *Арбачы, дилбегәне аяк терәп тартса да, атларны тыя алмады* (М. Хәбибуллин. Илчегә үлем юк). *Җиң сызганып сыныйк әле, / Дәрт-дәрманнар арткан мы, / Аяк терәп тартып карыйк / Мөстәкыйльлек арканын* (Ш. Галиев).

**АЯК ТЕРӘҮ.** 1. Катгый рәвештә; бик нык каршылык күрсәтеп, *шулай ук к.* аяк терәп. – *Без дә аяк терәдек, меңен алтыдан ким чыгармыйбыз, өстәвенә кеше башына ике полштуф сорыйбыз* (Ф. С.-Казанлы. Крушниклар). *Үләрлек икән, бу инде башка мәсьәлә: акчаны аяк терәп сорарга, кире кайтарып калырга кирәк!..* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: әйткән – беткән (бетте)! һ.б.

2. Бөтен көчен, осталыгын кулланып. *Шагыйрь аяк терәп иҗат иткән, терәге нык булган* (Б. Рәхимова. Бакый сагыш). *Азаматка тел-теш тидерерлек түгел, – аяк терәп дөнья көтә торган ир-егет* (А. Әхмәтгалиева. Синең өчен яшим).

**АЯК ТИБЕП КЕРҮ.** Әрсезләнү; каршылыкларны җиңеп, үзенекен эшләү. *Шәһәргә шулай аяк тибеп керсә дә, өйдәгеләр арасында үз тәртибен урнаштыру җиңел булмады аңа* (Ф. Бәйрәмова. Нух пәйгамбәр көймәсе).

**АЯК ТИБЕП КЫЧКЫРУ.** Берәрсенә каты итеп кычкыру. – *Ычкын моннан, селәгәй авыз! – дип, аяк тибеп кычырды* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

**АЯК ТИБЕП <ЭЧҮ>.** Ачуланып, тавышланып, барысын да онытып. *Ата-анаң, әби-бабаң белән бала-чага гөрләтеп, аяк тибеп аракы эчкәч, нинди киләчәге булсын бу милләтнең...* («Безнең гәҗит» газ.).

**АЯК ТИБЕП ЯШӘҮ.** *Акча, дәрәҗә дигәндәй... Рәхәтләнеп, аяк тибеп яшәп була!* (Г. Мирһади. Килмешәк).

**АЯК ТИБҮ.** Куркыту. – *Тәңре ихтыяры белән таләп итәм: нәсел-нәсәбемә җитәрлек, тау кадәр он тартып бир миңа! – дигән ул, аяк тибеп* (Г. Гыйльманов. Тылсымлы тегермән).

**АЯК ТИГӘН ҖИРГӘ ТИЯ, ТИМӘГӘН ҖИРГӘ ТИМИ (ЮК)** *к.* «а» дигәнче. *Зөлфияне капкадан кертеп җибәрде дә өенә атылды Зөлфәт, оча инде, аяк тигән җиргә тия, тимәгән җиргә юк* (Р. Газиз. Тәрәзәләр). *– Аягың тигән җиргә тисен, тимәгән җиргә тимәсен, югыйсә камырым ташый, хәзер үк кайт* (Ф. Хөсни. Сөйләмәгән хикәя).

Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**АЯК ТИГЕНГӘ КАБАРУ.** Кадерле вакытны заяга уздыру; (*тиген* – буш калдыру). *[Кызыл фикер] Аякларың тигенгә кабармасын...* (Г. Коләхмәтов. Ике фикер).

Төрдәше: авыз белән чебен аулау һ.б.

**АЯК ТИК ТОРМАУ.** 1. Бер урында гына тормыйча, төрле җирләрдә йөрү, нәрсәдер эзләү, табу. *Аягы тик тормады, кулына ял бирмәде, тора-бара теше-тырнагы белән ябышты!..* (А. Гыйләҗев).

2. Бер урында хәрәкәтсез тора алмау. *Әгәр дә кеше дулкынланса (ә ялганлаганда кеше бик нык борчыла), аның аягы тик тормый, кул ишарәләре дә күбәеп китә* (caydaq.tatar).

**АЯК ТУЗАНЫ БУЛУ.** Көчле мәхәббәттән яки башкача коллыкка төшүдән кешегә хезмәт итү. *Аяк тузаны булдым, и җаным, синең аркада* (Сәгъди. Бабахан дастаны. Тәрҗ. Ф. Яхин).

**АЯК ТУЗДЫРЫП ЙӨРҮ** *к.* аяк бетереп йөрү (бару; килү). *[Сакчы] Фатих абзый бернәрсә дә әйтмәде, «барыбер, барсаң да аяк туздырып йөрүе генә калыр, җыелмаслар» диде* (Г. Камал. Безнең шәһәрнең серләре).

Төрдәше: аяк бетереп йөрү (бару; килү) һ.б.

**АЯК ТУН.** Төлкенең аяк тиресеннән тегелгән тун. *Иң яхшы тун саналган аяк тун тирәякта Вәли байда гына бар* (Сөйләм).

**АЯК ТҮШӘМДӘ, БАШ ИДӘНДӘ.** Кайда, ничек йоклаганын белмәүче, рәтсез йоклаучы хакында. – *Абыемның кыланышларына сәерсенмә: аягы түшәмдә, башы идәндә кеше ул* (Сөйләм).

**АЯК ТЫГУ.** Кеше җирендә йөрү, печән чабу һ.б. *– Минем болын бу, – диде ир, – аңа беркем дә аяк тыкмый* (Н. Гыйматдинова).

**АЯК ТЫККЫСЫЗ** *к.* алма төшәр<лек> урын булмау (юк). *Быелгы Сабан туена күрше авыллардан да, каладан да кеше күп килгән иде: көрәш мәйданы аяк тыккысыз җиргә әйләнгән* (Сөйләм).

Төрдәше: алма төшәр<лек> урын булмау (юк) һ.б.

**АЯК ТЫНУ**. Аяк тавышлары ишетелми башлау. *Өске каттагылар нидер бәйрәм итте бугай, иртәнгә таба гына аяк тыну башланды* (Сөйләм).

**АЯК УҢУ.** Берәр эшнең башлануында, уңышлы баруында кемнеңдер катнашуы сәбәпче булуга ишарә итү. *Килённең аягы уңмады, ахры, ел*

*да яңгырлы туры килде, эшләр дә бәрәкәтсез* (А. Шамов). *Мәрфуга түтинең безнең белән җиләккә баруыннан аяк уңды – һәрберебез берәр чиләк җир җиләге җыйдык* (Сөйләм).

**АЯК УРЫНЫНА ТАЯК (ТОЯК).** 1. Ат сатып тай алган кебек, ягъни кирәкле әйбер табылмаганда, аны башка нәрсә белән алыштырып тору. *Аяк урынына тояк дигәндәй, атакай әлеге арык карт алашаны карарга, ашатырга, җәрәхәтен дәваларга тотынды* (Ә. Еники. Соңгы китап).

2. Эш башына ул эштән бөтенләй хәбәрдар булмаган кешене кую. *Аяк урынына таяк дигәндәй, китапханә мөдирен авыл хуҗалыгы министры ярдәмчесе итеп куйганнар* (Сөйләм).

3. Мәҗлестән аерылган кунаклар урынына башкалары килеп керү (гадәттә, китүче кунаклар әйтеме). *Менә сиңа аяк урынына тояк, хуҗалар нишләр инде хәзер?* (Сөйләм).

**АЯК УРЫНЫНА ТОЯК, ТОЯК УРЫНЫНА СЫЙРАК, СЫЙРАК УРЫНЫНА ТАЯК, ТАЯК УРЫНЫНА МАЯК.** Чын нәрсәне алыштырган ясалма нәрсәләр (протез, җиләк исе урынына химик катнашма исен куллану һ.б.). *Кибеттә әфлисун исле ниндидер аштәмләткеч сатуга чыккан, бигрәк тә инде, суга әфлисун тамчысы тамызып саталармы югыйсә – аяк урынына тояк, тояк урынына сыйрак, сыйрак урынына таяк булган түгелме соң!* (Сөйләм).

**АЯК ҮЗЕҢНЕКЕ ТҮГЕЛ <КЕБЕК>.** Сәламәтлек какшау сәбәбеннән, аяк барлыгын тоймый башлау. *Җайсыз ятканга күрә микән, аяк үзеңнеке түгел кебек тоела башлады, кул бармаклары да чемер-чемер килә* (Сөйләм).

**АЯК ХАКЫ.** Йомыш үтәгән өчен бирелә торган акча яки әйбер. – *Мә, бу сиңа аяк хакы, тиз генә дуңгызны урыска сатып кайт* (Н. Гыйматдинова. Бер тамчы ярату).

Төрдәше: аяк ялы; кул-аяк ялы; тел ялы.

**АЯК ЧАЛУ.** 1. Бер эшне эшләүгә махсус комачау тудыру, каршы килү. *Кемнәрнедер яклатмадылар, аларга аяк чалдылар, аларның бер төрлесе шәһәрен алмаштырды, икенче төрлесе инфаркт, инсульт алды...* (М. Мәһдиев. Ачы тәҗрибә). *Аяк чалып маташмагыз, / Күктән очып үтәрмен* (Р. Мөхияр. Имән мин).

Төрдәше: аркылы килү (төшү) 2.

2. Төрле юллар табып, эшкә зарар китерү. *Яки кешене сүгүдән, аның эшен юкка чыгарудан, аңа аяк чалудан туктыйсыз... яки инде, бигайбә, саубуллашырга рөхсәт итегез!* (Ә. Еники. Рәхмәт, иптәшләр). *Керсез күңелле Ильяс аңа аяк чалырдай кеше түгел* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).

Төрдәше: таяк тыгу; тәгәрмәчкә таяк тыгу.

**АЯК ЧАЛЫП ЕГУ.** 1. Аяк белән кемнең дә булса аягын эләктереп, җиргә егу. *Ә озын тәнәфестә Бибисара Илханны аяк чалып екты* (Н. Гыйматдинова. Син түгел бу, син түгел...).

2. Эшләргә ирек бирмәү, комачаулык итү. *Аяк чалып ексалар да, / Күтәрелер көч табып / Яшәгән чаклар булган бит* (Ә. Ситдыйкова. Утлы җимеш).

**АЯК ЧОЛГАУЛАРЫН АЛДАН УК ӘЗЕРЛӘП КУЮ** *к.* алдан алу (алып тору). *Югыйсә мең сәбәп табар, кем әйтмешли, аяк чолгауларын алдан ук әзерләп куяр иде* (З. Хөснияр. Гарасат).

Төрдәше: алдан алу (алып тору) һ.б.

**АЯК ЭЗЕ АЧЫЛУ.** Җинаять ачылу. *Шуның аркасында башкаларның аяк эзләре дә ачыла башлады* (Г. Ибраһимов).

Төрдәше: арты ачылу һ.б.

**АЯК ЭЗЕ БАСЫЛУ (ТЫНУ)** *к.* аяк тыну. *Тик хәзер түгел, кеше аяк эзе басылгач, беренче әтәч кычкыргач килерсең* (Т. Гыйззәт). *Аның белән бер фикердә булганнар күп, без аны кеше аяк эзе басылгач, төнлә, таң вакытында тотып алырбыз да туп-туры шәһәргә озатырбыз* (Р. Низами. Сәйдәшнең соңгы елы).

Төрдәше: аяк басылу.

**АЯК ЭЗЕН ӨЗМӘҮ (СУЫТМАУ).** Еш килү. *Шәһәрнең икенче очына күчеп китсәләр дә, алар аяк эзен суытмадылар* (Сөйләм).

**АЯК ЭЗЛӘРЕ СУЫНУ.** Мөнәсәбәтләр өзелү, дуслык бетү. *Аяк эзегез суынып бетмәгән, тоталар да сезне яманларга тырышалар* (А. Гыйләҗев).

Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**АЯК ЭШТӘН ЧЫГУ** *к.* аяк атлар хәл (дәрман; көч; рәт; чама) юк (булмау; калмау) 1. *Сылу рухсыз гына уйнады, юл каткагына бәрелеп, аның аяклары эштән чыккан, бармаклары авыр-*

*та иде, туфлиләрен кия алмады, бай кызы сәхнәгә резин галошлар белән чыкты* (М. Мәһдиев. Ут чәчәге).

Төрдәше: аяк атлар хәл (дәрман; көч; рәт; чама) юк (булмау; калмау) 1 һ.б.

**АЯК ЮЛЫ** *җанлы с.* Бәдрәф. – *Күбрәк ашалды бугай, аяк юлына барып килергә кирәк* (Сөйләм).

**АЯК ЮЛЫ БАСЫЛУ.** Кеше килеп-китеп йөри торган юл, сукмак. *...Кичке аяк юлы басылгач, Фәниянең ишеген шакыдылар...* (Ә. Моталлапов. Гамь).

**АЯК ЮЛЫ ӨЗЕЛМӘҮ.** Кешеләр туктаусыз узып йөри тоган җир. *Кичкә кадәр бу мәйданга аяк юлы өзелми* (Сөйләм).

Төрдәше: юлга тузан төшермәү.

**АЯК ЯЗ<ДЫР>У.** Аякларны хәрәкәт иттерү, бераз йөреп алу. *Минем күршем ничек утырган булса, шул килеш кымшанмаган да иде. – Аяк яздырып кирәсегез калган* (Р. Кәрами. Ир баласы). *Аяк язу дигәннән, Зиннәт бабай Сабан туенда да әкәмәт кыланып ташлады* (Ш. Галиев).

**АЯК ЯЛГЫШТЫРУ (САЙЛАШТЫРУ; БУТА<Л>У).** Бер аяктан йөргәндә яки бию хәрәкәтләрен башкарганда хаталану. *Ярамаган эш эшләвен никадәр генә аңласа да, ул, юри аягын ялгыштырып, ритмны бозудан тыелып кала алмады* (Г. Рәхим. Саргаймагыз, каштаннар...). *Аякларны бутап ала дөнья, / Тайгак юлга кертә хәтта тигез / Җирдән генә көлеп барганыңда* (Ф. Яхин. Хак һәм ялган).

**АЯК ЯЛЫ** *к.* аяк хакы. *Ул үзенә тел ялы, аяк ялы ала* (Г. Чыгтай). – *Алайса, ни инде минә... аяк ялы булсын, – дип, Мәүлиха әби Галәүгә биш сум акча сузды* (Л. Ихсанова. Үкенү).

Төрдәше: аяк хакы һ.б.

**АЯК ЯЛЫ ТҮЛӘҮ (БИРҮ)** *к.* ришвәт бирү. *Шул эшне безнең файдага башкарып чыгарса, аяк ялы күчтәнәчен бирерсез* (Т. Гыйззәт).

Төрдәше: ришвәт бирү.

*АЯККА* ❖ **АЯККА АЛДАН КИЕНҮ (КИЕНЕП ТОРУ)** *к.* алдан алу (алып кую). *Безнең хезмәт шундый, аякка алдан киенеп торганда да бик таманга килә* (Р. Мөхәммәдиев. Сират күпере).

Төрдәше: алдан алу (алып тору һ.б.)

**АЯККА БАСА АЛМАУ.** Рәтләнә алмау. *[Ибраһим] Үзе һаман әле аягына баса алмый* (Г. Исхакый. Алдым-бирдем). *Хезмәткә (солдатка) киткәндә, рәтләп аягына да баса алмаган Шакирҗаны хәзер ыржыктай егет иде инде* (К. Тинчурин. Хәкимҗан агай).

**АЯККА БАСТЫРУ (ТОРГЫЗУ).** 1. Сәламәтләндерү, эшкә яраклы итү. *[Шөҗаг] Бүген инде минем сине аякка бастыруның актык минутлары!* (Г. Камал. Дәҗҗал). *[Зиннур] Мине әтиең карап аякка бастырды* (Ю. Сафиуллин. Идегәй).

2. Төзекләндерү, хуҗалыкны торгызу. *Өй күтәрәм, өмәгә! – чакыру ишетелү белән, Әхмәдиләр, Шәяхмәтләр, Шәнгәрәйләр, Ситдыйклар, Җиһанша бабайлар җыелып килделәр дә, иртәнчәк кояш белән бергә тотынып, төш авуга, өйне аякка бастырдылар* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар). *Ә ул эшләмәде түгел, эшләде, кырылып бетеп барган ферманы аякка бастырып бирде* (Ә. Еники. Рәхмәт, иптәшләр).

3. Эшкә кузгату, оештыру; актив рәвештә эшкә тотынырга этәрү. *«Чулпан»ның абруен саклап калыйм дисең икән, бөтен халкыңны аякка бастыр* (Г. Бәширов. Намус). *Бәлки, ул, Болгар җирен аякка бастырып, урыс явына киртә була алыр?* (Р. Зәйдулла. Илбәк).

4. Мөстәкыйль (яки балигъ) булганчы тәрбияләү, карау. *Ә баланы үстерергә, аякка бастырырга кирәк* (Ф. Бәйрәмова. Нух пәйгамбәр көймәсе). – *Моннан ары аларны исән-сау үстерү, аякка бастыру – сезнең җилкәгездә* (В. Имамов. Карабәк).

5. Тормышны матди яктан яхшырту. *Һәм тиешле шартлар тугач, [яһүдиләр] үз дәүләтләрен яңадан аякка бастырдылар* (Р. Мостафин. Төгәл булыйк!).

6. Хәрәкәткә китерү. *Ике-өч минут эчендә мәктәп интернаты кешеләрен, колхоз ашханәсе кешеләрен аякка бастырды* (М. Мәһдиев. Ачы тәҗрибә).

**АЯККА БАСУ.** 1. Сәламәтләнү, эшкә яраклылану. *Шул авыр михнәт елларын кичергәч, ат тагын аякка басты* (Г. Ибраһимов. Алмачуар). *Ничек тә тизрәк торырга, аякка басарга, хәтта авыруымны йомарга, яшерергә!..* (Ә. Еники. Гөләндәм туташ хатирәсе).

Төрдәше: аякланып бару; аякланып китү 1; баш-күз алу 3.

2. Үсеп җитү; алга китү. – *Безгә артыгы кирәкми. Балалар аякка басып килә...* (Ф. Латыйфи. Хыянәт). *Берсен дә какмый ул, / Бертигез ярата / Балалар тупырдап / Басалар аякка* (М. Әгъләм. Җир-ана, Кояш һәм кешеләр).

Төрдәше: тәпи басу.

3. Беркемнән дә ярдәм көтмәстән, сорамастан, үз тормышыңны үзең кору; тормышны матди яктан яхшырту. *Без бурлы бия аркасында аякка бастык* (Г. Ибраһимов. Алмачуар). *Моннан ике ел элек кичү янында болгарлар белән бәрелештә җиңелеп, күп талау күрсә дә, тиз арада ул аякка басты* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).

Төрдәше: кеше булу.

4. Берәр эшне башкарырга әзер булу. *Бөтен авыл, гаҗәпләнү катнаш хәвефләнү белән, аякка басты* (Ф. Хөсни). *Баштарак кешедән калыша-калыша эшләсә дә, берничә көннән башкалар белән бер аякка басты* (Г. Сабитов. Сопкаларда шәфәкъ шәүләсе).

5. Хәлләнү, төрнәкләнү; корылу, төзелү. *Оттырган берәрсе, яңадан «аякка басар өчен», аңардан әллә нихәтле имәнеп, ялынып акча сораса да, ул: – Әллә мин акча ясыйммы?! Вәт, дурак! – дип, кыска гына кайтарып җибәрә иде* (Ш. Камал. Ата). – *Аның [Болгарның], аякка баса алмыйча, ятим баладай мәгыйшәт кичерүе – безнең өчен дә гарьлек* (В. Имамов. Карабәк).

Төрдәше: аякка калку 2; аякка күтәрелү; баш-күз алу 1.

6. Шау-шу, ыгы-зыгы башлану. *Бөтен авыл аякка басты. Халык, капка төпләренә, каравыл өе тирәсенә җыелып, иртәдән кичкә кадәр түрәләрне сүгәргә, заманаларның авырлыгыннан зарланырга тотынды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Бөтен йорт аякка баса, ду-чат килә: – Әби килгән! Гайнә әби килгән!* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).

**АЯККА БАУ БӘЙЛӘГӘН КЕБЕК.** Тышау салган сыман кая булса да барырга мөмкинлек бирмәү. *Дустымның кичә сөйләгән сүзләре аякка бау бәйләгән кебек тәэсир иттеләр* (Сөйләм).

Төрдәше: аякка бау бәйләү; аякка тышау белән; аякка тышау булу (булып уралу); аяк-кул бәйләнү; аяк-кулны бәйләү; аяк-кулын<нан> бәйләү; аякны багълау; ике аягын (аякны) бер балакка (кунычка) тыгу.

**АЯККА БАУ БӘЙЛӘҮ** *к.* аякка бау бәйләгән кебек. *Нигә син бөтен кеше сүзен тыңлыйсың, алар бит синең аягыңа бау бәйлиләр* (Сөйләм).

Төрдәше: аякка бау бәйләгән кебек һ.б.

**АЯККА БӘЙЛӘНГӘН ТАШ БУЛУ.** Артык йөк булу, комачаулау. – *Сезнең аякка бәйләнгән таш булмабыз, – диде Байкин* (Х. Камалов).

Төрдәше: аякка гер таккан (аскан; бәйләгән) кебек; аякка <тагылган> таш булу.

**АЯККА БОЗАУ (СЫЕР) БАСМАГАН** *к.* авыз сулары кипмәгән. *Аягына сыер басмаган, һаман очмассың, канатларың сәлперәер әле* (Б. Камалов). *Беләр-белмәс көйгә сөйләмә юкны, энем, аягыңа бозау басмаган әле, яшьлегеңә барасың* (Г. Мөхәммәтшин).

Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

**АЯККА ГЕР ТАККАН (АСКАН; БӘЙЛӘГӘН) КЕБЕК** *к.* аякка бәйләнгән таш булу. *Сәяхәткә күршенең малаен да алу аякка гер таккан кебек булып чыкты* (Сөйләм).

Төрдәше: аякка бәйләнгән таш булу һ.б.

**АЯККА ЕГЫЛЫП СОРАУ (БАШ ОРУ; ҮТЕНҮ; ЯЛВАРУ; ЯЛЫНУ)** *к.* аягына егылу 2. – *Моннан соң инде үзләре килеп аякка егылып, ялынып, ялварып сорасалар да, барасым юк! – дип, күңелемә бик нык беркетеп куйдым* (Ш. Усманов. Ачылган йозак).

Төрдәше: аягына егылу 2 һ.б.

**АЯККА ҖИЛ ДӘ ИЯРМӘҮ.** Бик тиз хәрәкәт итү (йөгерү, качу, юкка чыгу) *Хәйрүшнең аягына җил дә иярмәгән иде ул чакта* (Р. Зәйдулла. Тәре).

Төрдәше: агы-карасы <күзгә> күренмәү һ.б.

**АЯККА КАЛКУ.** 1. Торып басу. *Иртә белән таң атар-атмас, авылның төрле очындагы нәни кызлары букчалар күтәреп ишекне шакый башлагач та, икесе дә аякка калкалар* (Г. Исхакый. Остазбикә).

2. *к.* аякка басу 5. *Чынлыкта ул Госманлы хәлифәтенең купшы, корама сарай әдәби теленнән бөтенләй аерылган яңа төрек теленә – дөньяви рухта аякка калыккан Төркия Җөмһүрияте әдәби теленә әйләнде <…>* (Т. Әйди. Телләр якын, теләкләр бер).

Төрдәше: аякка басу 5 һ.б.

**АЯККА КҮЗ ИЯРМӘҮ**. Бик җитез бию. *Килеп керүе булды, әй китте бөтерелеп, аягына күзләр дә иярми!* (Г. Бәширов). *Ә зал уртасында ду китереп бииләр, оста биючеләр берсен берсе алмаштырып кына торалар, аякларына күз иярми* (С. Сөләйманова. Легендар Ленинградта).

**АЯККА КҮТӘРЕЛҮ** *к.* аякка басу 5. *Иплеимин биш ел дәверендә Болгар белән Казан калалары да, Җүкәтау белән Кашан кирмәннәре дә диварларга төренеп, аякка күтәрелде* (В. Имамов. Карабәк).

Төрдәше: аякка басу 5; аякка калку 2.

**АЯККА СЫЕР БАСУ.** 1. Өйләнү, гаиләле булу. *Бабайлар әйткәндәй, аягыңа сыер баскач, һаман очмассың, канатларың сәмгерәер әле* (Б. Камалов). – *Йөреп калсын, карчык, аягына сыер баскач, йөри алмас, – дип кенә җибәрде* (К. Миңлебаев).

2. Тормыш тәҗрибәсе туплау. *Яшь лейтенантның аягына сыер басмаган, гаиләсе дә юктыр, күрәсең* (Х. Камалов). – *Син яшь әле, аягыңа сыер басмаган. Хуҗалыкта бернәстә дә артык түгел...* (Р. Зәйдулла. Йорт иясе).

**АЯККА ТАГЫЛГАН АВЫР ГЕРЛӘРГӘ ӘЙЛӘНҮ.** Комачаулык ясаучы әйбер булу. *Ул бит хәзер дәрәҗәле кеше, үсеп бара торган кеше, бәс, шулай булгач, сәүдәгәр абзыйлар, сәүдәгәр бабайлар киләчәктә аның аягына тагылган авыр герләргә әйләнмәсләрме?* (Ә. Еники. Рәшә).

**АЯККА ТАГЫЛГАН ТАШ <БУЛУ>** *к.* аякка бәйләнгән таш булу. *Мин синең аягыңа тагылган таш булып сөйрәлергә теләмим* (Г. Бәширов).

Төрдәше: аякка бәйләнгән таш булу.

**АЯККА ТАРАКАН КЕРҮ.** Бик нык туңу. – *Минем аякларыма таракан керә башлады. Миңнулла абзагызга әйтәм, әйдә кайтыйк, катырып үтерәсең ич, дим* (И. Гази. Онытылмас еллар). – *Бездә инде кыш. Аякка таракан керә башлады* (А. Гыйләҗев. Җомга көн кич белән...).

**АЯККА ТАРТСАҢ, БАШКА ЮК, БАШКА ТАРТСАҢ – АЯККА ЮК.** Кирәкле әйбернең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы, бик аз икәнлеге хакында. *Аякка тартсаң, башка юк, башка тартсаң – аякка юк* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

**АЯККА ТИМӘҮ (ЙОКМАУ)** *к.* аяк җиргә дә тимәү. *Егет бик оста бии икән, аягы аякка йокмый* (Н. Гыйматдинова. Су хикәяте).

Төрдәше: аяк җиргә тимәү.

**АЯККА ТОРГЫЗУ** *к.* аякка бастыру. *Рәтрәт итеп гаскәрен куйгач тезеп, / Һәм дә җиткергәч аякка торгызып* (Г. Тукай).

**АЯККА ТӨШҮ.** 1. Бөтен арыганлык аякка туплану. *Утырсаң, «утыру» аякка төшә, тәнгә куна, йокыга, мәрткә тарта башлый* (Г. Гыйльманов. Албастылар).

2. Аякка авырлык китерү, авырту тудыру. *Сүбәдәй баһадирның тел төбен аңламаган Плоскина баһадирның аягына төште* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).

3. Күңел кабул итмәү. *Җырда – көй аякка төшү тойгысы* (М. Галиев. Гаҗиз сорау).

Төрдәше: кәеф китәрелү; кәеф китү; күңел җәберсенү; күңел кырылу; хәтер калу.

**АЯККА ТЫШАУ БЕЛӘН.** Берәр эштә алга баруга комачау булу, мәшәкать салу. *Әйтер булсак, туры сүзең чәйнәрләр, / Аяк-кулың тышау белән бәйләрләр* (Ю. Сафиуллин. Акмулла). *Кайбер гадәтләрне һаман да саклап килү, минемчә, аякка тышау белән якынлашу кебек күренә* (Сөйләм).

Төрдәше: аякка бау бәйләгән кебек һ.б.

**АЯККА ТЫШАУ БУЛУ (БУЛЫП УРАЛУ)** *к.* аякка бау бәйләгән кебек. – *Аягыма тышау булып уралдың да яшьлегең җәйләвендә генә тотасың...* (Ә. Гаффар. Бодай бөртеге һәм тегермән ташы).

Төрдәше: аякка бау бәйләгән кебек һ.б.

**АЯККА УРАЛУ (ЧОРНАЛУ)** *к.* аяк астында болгану (болганып йөрү). *Үзенә кирәккәндә, Хәлил дуңгызга да «исәнме, кодагый» дип эндәшүдән оялып тормый, мунчаладай аякка урала, өлгергән кырмавыктай балакка ябыша белә* (Т. Галиуллин. Элмәк).

Төрдәше: аяк астында болгану (болганып йөрү) һ.б.

**АЯККА ЯЛ БИРҮ.** Утырып тору. – *Әйдә, кунак, аягыңа ял бир, – диде* (И. Нуруллин. Ике Апуш). *Шунда Хәлим дә аякларына ял бирергә кирәклеген төшенде* (Ф. Яхин. Куш каен аланлыгы).

*АЯК-КУЛ* ❖ **АЯК-КУЛ БӘЙДӘ (БӘЙЛЕ) <БУЛУ>.** Кемгә-нәрсәгә булса да бәйле булу, ташлап китә алмау. *Егет чакта иреккә өйрәнгән Иршат өйләнүенең беренче айларында, ничектер, боегып калды, тышауланган ат кебек талпынып-талпынып карый, ләкин аяк-кул бәйле шул* (Р. Кәрами. Өч монолог).

**АЯК-КУЛ БӘЙЛӘНҮ** *к.* аякка бау бәйләгән кебек. *Бөтенләй бәйләнә анда аяк-кул, / Җүләрлек ул – өйләнмәк, гайре мәгъкуль* (Г. Тукай. Өйләнү – түгел сөйләнү).

Төрдәше: аякка бау бәйләгән кебек һ.б.

**АЯК-КУЛ ТИМӘГӘН**. Беркемнең дә аягы да йөрмәгән, кулы да тимәгән. *Әле кеше аягы-кулы тимәгән урман, яшенле-күкрәүле яңгыр!* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы).

*АЯК-КУЛДАН* ❖ **АЯК-КУЛДАН БАУ ИШҮ.** Кемнеңдер ихтыярын тулысынча үзенә буйсындыру. – *Аяк-кулларыңнан бау ишәм, – ди тегесе, бүксәсен киергәннән-киерә төшеп* (Р. Төхфәтуллин. Җиләкле аланнар).

Төрдәше: авызлык кидерү һ.б.

*АЯК-КУЛЛАР* ❖ **АЯК-КУЛЛАР АЛЫНУ.** Аяк һәм куллары хәрәкәтләнә алмау. *Аяк-куллары алынгач, күзләре белән генә сөйләшә башлаган иде, мәрхүм* (Ф. Шәфигуллин. Ялгыз өрәңге).

Төрдәше: аяк<сыз>-кулсыз калу 2.

**АЯК-КУЛЛАРЫ<Ң> СЫРХАУСЫЗ (СЫЗЛАУСЫЗ) БУЛСЫН!** Ярдәм иткән кешеләргә әйтелә. – *Ярый әле, син очрадың... Аяк-кулларың сызлаусыз булсын, – диде карчык, миңа рәхмәт укып* (Н. Фәттах. Әттә!). *Кеше хәленә керә белә, аяк-куллары сырхаусыз булсын* (М. Маликова. Арыш тәме).

*АЯК-КУЛНЫ* ❖ **АЯК-КУЛНЫ БӘЙЛӘҮ** *к.* аякка бау бәйләгән кебек. *Тагы бер якка да хәрәкәт итә алмаенча, аягы-кулы бәйләнгән батыр кебек, үземә, үземнең шулай булуыма сәбәп булучы кызларга, ниһаять, дәрәҗә ачуым килә* (Г. Исхакый. Тормышмы бу?). *Сүз белән тыя алмагач, ирләр, ат дилбегәсе алып чыгып, аның аягын-кулын бәйләделәр дә урам уртасындагы чирәмгә салдылар* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).

Төрдәше: аякка бау бәйләгән кебек һ.б.

*АЯК<СЫЗ>-КУЛСЫЗ* ❖ **АЯК<СЫЗ>-КУЛСЫЗ КАЛУ.** 1. Гаиләдә эшкә яраклы кешенең үлеп китүе. *Ул күз алдында кибә-корый башлый, бөтенләй аяк-кулсыз кала, тәнендәге һәр тишектән кан бәреп чыга* (Ф. Бәйрәмова. Кырык сырт).

2. *к.* аяк-куллар алыну. *Шул хәбәрдән соң, аяк-кулсыз калып, озак авырдым, табиблар нервыныкы диделәр* («Татарстан яшьләре» газ.).

3, Гаять кирәкле, зур белгечнең эштән китүе. *Ярдәмчесе дә эштән киткәч, алдынгы хуҗалык башлыгы буларак танылган Азат Латыйпович аяксыз-кулсыз калды* (Сөйләм).

**АЯК-КУЛЫН<НАН> БӘЙЛӘҮ** *к.* аякка бау бәйләгән кебек. *Сугыш дәвам итә, һәм ул, Русиядә реформалар үткәрү өчен, В. Путинның аяк-кулын бәйләп торачак* («Татарстан яшьләре» газ.).

Төрдәше: аякка бау бәйләгән кебек һ.б.

*АЯКЛАНЫП* ❖ **АЯКЛАНЫП БАРУ.** Авырганнан яки авыр кайгыдан соң яңа йөри башлау. *Ире эш эзләп Бакуга киткәч, беренче балалары үлде. шуның кайгысыннан яңа аякланып бара иде* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).

**АЯКЛАНЫП КИТҮ.** 1. *к.* аякланып бару. *Урын өстендә ятып авырса да, төшенкелеккә бирелмәде һәм, ниһаять, аякланып та китте* (Сөйләм).

2. Кешедән кешегә көчеп таралу (сүз турында). *«Яралар, имеш, яргач, кем үтергәнен шунда ук беләләр, имеш, белгәч, тотып аталар, имеш...» дигән хәбәрләр урамның бер башыннан Рәгыя аркылы аякланып киттеләр* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).

3. Хәлләнү, тормыш җайлану. *Аякланып киткәч, сезне дә үз яныма кайтып алмый калмам* (В. Имамов. Тозлы яра).

Төрдәше: аякка басу 5.

4. Үсеш алу, мәгълүм булу. *Ә бит Мәскәү кенәзләренә дәүләтчелеккә таба аякланып китүдә нигез ташын Алтын Урда ханнары сала...* (М. Хәбибуллин. Түрә-бүреләр, диннәр һәм халык).

*АЯКЛАП* ❖ **АЯКЛАП <СУГЫМ> СУЮ.** Ат-сыер, сарык кебек аяклы малны аяк исәбеннән уртакка сую. – *Былтыр көз көне, инеш каткач, аяклап сугым суярга җыендык* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

*АЯКЛАР* ❖ **АЯКЛАР ИДӘНГӘ (ҖИРГӘ) ТИМӘҮ.** 1. Бик нык шатлану. *Өйгә кайтыш. /*

*Аяклар җиргә тими* (Х. Бәдигый. Яшел чирәм). *Кызчык, сандалиларын киеп, бүлмәдән-бүлмәгә коштай очып йөрде, аяклары идәнгә тимәде дә бугай* («Ялкын» ж.).

Төрдәше: авыз еру 4 һ.б.

2. Дәрт кереп китү, дәртләнеп-дәртләнеп бию. *Татар халык көйләре яңгыраса, биегәндә, аякларың идәнгә тими иде* («Безнең гәҗит» газ.).

Төрдәше: канатландырып җибәрү (чыгару); канатланып йөрү (китү; чыгу); күңелгә канат кую; күңелне җилкендерү; күңелне канатландыру; күңелне күтәреп җибәрү; күңелне очындыру.

3. *к.* «а» дигәнче. *Булатның аяклары җиргә тимәде дә, Гәбиулла абыйларның бакчасына очып диярлек килеп керде* (С. Зыялы. Ике дөнья арасы). *Бер атнадан бу да Ак байталга атланып чыгып китә. Ат шәп, аяклары җиргә тими, кош кебек оча* (Татар хал. әкияте).

Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**АЯКЛАР ТАЮ.** Тормышта ялгыш, куркыныч юлга басу. *Элек минем аякларым тайган чакларым булды* (Г. Ибраһимов). *Әмма аларның «аяклары тайса да», һич тә туры юлдан ялгышка таба кереп китмәгәннәр, хаталанганлыкларын бик тиз сизеп алганнар һәм Аллаһы Тәгаләдән тәүбә үтенгәннәр* (Ф. Яхин. Иман).

**АЯКЛАР ЮРГАНЫҢА КАРАП СУЗЫЛУ.** Мөмкинлегеңә карап эш итү; чаманы белү. *Безнең бу аяклар элек / Юрганына карап сузылса, / Безнең юрган инде / Аякларга карап сырыла* (Х. Туфан. Урал эскизлары).

Төрдәше: бөртекләп тоту; булса булсын туярлык, калганын җыеп куярлык; күләгәңә карап күчергеч алу; күлеңә карап чуму; сыер мөгезенә кар кундырмау; түшәккә карап (күрә) аягыңны сузу; учына салып уртына кою; үлчәүсез кием кисмәү; чиген белеп эш итү; шеш тулганчы йөрү; юрганыңа карап аяк сузу.

*АЯКЛАРНЫ* ❖ **АЯКЛАРНЫ ДАГАЛАУ.** Эшкә тарту, эшләргә күндерү. *Аны бу килеш кенә яңа цехка күчерергә ярамый, бераз яңа эшкә аякларын дагалыйк, аннан соң өйрәнүен үзе дәвам итәр* (Сөйләм).

**АЯКЛАРНЫ СӨЙРӘП БАРУ** *к.* аякларны көчкә атлау (сөйрәү). *Агачтан егылып төшкәч, ул бераз вакыт аякларын сөйрәп барды* (Сөйләм).

Төрдәше: аяк аяктан үтмәү; аяк башыннан аяк башы үтмәү; аяк<лар>ны көчкә атлау (сөйрәү); аякны чак сөйрәп бару; көчкә атлау; көчкә бару; өстерәлеп бару; сөйрәлеп бару.

**АЯКЛАРНЫ ТЫШАУДАН ЫЧКЫНДЫРУ.** Ирек алу; аерылу. *Билгеле инде, хөрлекне сагынып өлгергән Фәридун аякларын тышаудан бик тиз ычкындырды* (Ә. Еники. Фәридун белән Фирая).

*АЯКЛАРЫ* ❖ **АЯКЛАРЫ ТӨКЛЕ БУЛСЫН!** Берәрсе килгәндә, «мал-дәүләт ишәйсен, йортка бәрәкәт килсен» дип теләк теләү. *<Беренче биюче> Яшь килен кайта, яшь килен! <Һәммәсе бергә> Аяклары төкле булсын!* (Г. Исхакый. Зөләйха).

Төрдәше: аягың җиңел булсын! һ.б.

*АЯКЛЫ* ❖ **АЯКЛЫ БӘЛА (КАЗА; ҖӘФА)** *хур.* 1. Булдыксыз, ялкау, эшкә яраксыз; кешегә сарылып яшәүче. *Кайдан килеп чыкты аяклы бәла?* (Г. Мөхәммәтшин. Кояш кызы). *[Габдуллаҗан] Бик күп акча чыгып, бик аңгыра булып, аяклы каза булырлык булса, мин нишләрмен?* (Г. Камал. Бүләк өчен).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

2. Шук бала. *Килеп керүгә үк, нәкъ ишек төбендәге утыргычта «аяклы каза»ны күреп алды* (Ф. Латыйфи. Аяклы каза).

**АЯКЛЫ БӘЛЕШ.** Симез, көр хатын-кызга әйтелә. *Шаһ-Солтанны үзара аяклы бәлеш дип йөртәләр. Ләкин ханбикәгә ошбу кушамат һич тә туры килми* (М. Әмирханов. Тәхетсез патша).

**АЯКЛЫ БӘХЕТ**. Тормышка ашкан бәхет; көч түкмичә килгән байлык. *Мүкләк Гайфул һәм шуның ише тагын берничә «ач күз», үзе килеп кергән аяклы бәхет барлыгын сизеп, тизрәк аның мөгезеннән эләктереп калырга ашыктылыр* (Ф. Хөсни).

**АЯКЛЫ БОЛЫТ.** Яңгыр алып килеп, тукталып тормыйча, явып үткән болыт. *Аяклы болыт булды бу, туктап та тормады* (Сөйләм).

**АЯКЛЫ ГРАДУСНИК.** Кешеләрнең тышкы кыяфәтләренә карап, үз фикерен белдереп йөрүче. *Хәтта егетләрнең матур булу-булмавын билгеләүдә аяклы градусник булып йөргән Лиза да түзмәде, кычкырып ук: «Нинди чибәр,*

*үбәсе килә каһәрне, – дип, – һәм, сине сөйләтеп карар өчен, яныңа барды»* (Г. Кутуй. Тапшырылмаган хатлар).

**АЯКЛЫ КЕЛӘТ.** 1. Астын ачык калдырып, баганаларга утыртып салынган келәт, амбар. *Иске келәтебез аяклы келәт иде, хәзер инде таштан нигезгә утырттык* (Сөйләм).

2. *күч.* Ни ашаса да симерми торган зур арык ат. *Безнең күршенең бер алашасы бар да, бер аяклы келәте бар* (Сөйләм).

**АЯКЛЫ КИТАПХАНӘ.** Бик күп укыган, күп нәрсә белгән мәгълүматлы, белемле кеше. *Кайчандыр Лирон Хәмидуллиннан файда күргән затлар аны тикмәгә генә «аяклы китапханә»гә тиңләмидер* (З. Мансуров. Рухият югарылыгына).

Төрдәше: аяклы тарих; аяклы хәзинә 1; аяклы энциклопедия; беләмән – акыл тубалы; белем капчыгы.

**АЯКЛЫ КОЛАК.** Шымчы. *– Бөтен тирә-юньдә аяклы колак йөри, иплән кенә сөйләш, – дип кисәтте Даян* (В. Имамов. Казан дастаны).

**АЯКЛЫ МАЛ.** Терлек-туар, йорт хайваны. *Йортта табылган нәрсә-кара барысы да чаналарга төялде. Аяклы мал, мунчаклатып, чана артларына тагылды* (М. Галәү. Мөһаҗирләр).

**АЯКЛЫ МӘЗӘК.** Еш телгә алына торган мәзәк. *– Хәер, сезнең өчен без аяклы мәзәк инде, дим Артемга* («Сөембикә» ж.).

**АЯКЛЫ РАДИО** *шаярт.* Кеше. *– Әйдә идарәгә, анда аяклы радио барысын да аңлатыр* (Сөйләм).

**АЯКЛЫ ТАРИХ.** Күп тарихи истәлекләр, мәгълүмат белә торган кеше. *Аяклы тарих – Җиһанша бабай – тагын үзенең йөрәгенә-миенә кан белән, газап белән язылган вакыйгаларга кереп китте* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар). *Яким күчтем турында аңа нәкъ менә катиб Хафиз: «Телгә җор, аяклы тарих», – дип әйткән иде* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).

Төрдәше: аяклы китапханә һ.б.

**АЯКЛЫ ФЕТНӘ.** Тыныч яши алмый торган, начар кеше. *Ләкин әлеге теге басу култыгындагы бәрелештән соң, ул катгый карарга килде – бу аяклы фетнәдән тизрәк котылу ягын карый башлады* (Ф. Хөсни).

**АЯКЛЫ ХӘБӘР.** Кемнәндер ишеткән сүз, гайбәт сүзе. *Бу «аяклы» хәбәр Зыя Камалига барып ишетелә* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).

Төрдәше: авыз чайкау 1 һ.б.

**АЯКЛЫ ХӘЗИНӘ.** 1. *к.* аяклы китапханә. *Безнең аяклы хәзинәбез икенче катта утыра, әйтсә – ул гына әйтер* (Сөйләм).

Төрдәше: аяклы китапханә һ.б.

2. *к.* аяклы мал. *– Әйтмә дә инде, ат – авыл җирендә аяклы хәзинә ул* (Сөйләм).

**АЯКЛЫ ХӘСРӘТ** *к.* аяклы бәла (каза; җәфа). *Газинурның юклыгыннан файдаланып, Миңнурыйга сумала кебек ябышмыймы икән ул аяклы хәсрәт анда?* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

Төрдәше: аяклы бәла (каза; җәфа) һ.б.

**АЯКЛЫ ЭНЦИКЛОПЕДИЯ**. Теләсә нинди сорауга белешмә алырлык кеше; *к.* аяклы китапханә. *Идрисне аның белән беренче кабат таныштырганда, китапханә мөдире аны «Аяклы энциклопедиябез» дип әйткән иде* (Х. Сарьян).

Төрдәше: аяклы китапханә һ.б.

*АЯКНЫ* ❖ **АЯКНЫ АЛДАН (ӘЛЛӘ КАЙЧАН) КИЕНҮ (КИЕНЕП КУЮ)** *к.* алдан алу (алып тору). *Малай, торырга иренеп урынында гына аунап ятса да, күңеленнән аякны әллә кайчан киенеп куйган иде инде* (Ф. Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы). *Инде акыл керде: аякны алдан киенеп куярга кирәк* (Г. Мөхәммәтшин. Әсир кунак).

Төрдәше: алдан алу (алып тору) һ.б.

**АЯКНЫ АЛЫШТЫРЫП КУЮ (АЛУ; БАСУ).** Сул аяк урынына уң аякны басу яки киресенчә. *Кичә көн чалт аяз иде, кояш җылысы кар юрганының өстен эреткән, көртләр юка боз элпәсе белән капланган, аякны алыштырып баскан саен, боз чатнаганы ишетелә* (А. Расих. Айлы төннәр).

**АЯКНЫ – АТ, КУЛНЫ КАНАТ ИТЕП (ИТӘСЕҢ ДӘ).** Канатлы кебек итеп, аякларны куллар белән тоту. *Аякны – ат, кулны канат итәсең дә, сикерә-сикерә сызгыра башлыйсың* (Сөйләм).

**АЯКНЫ БАГЪЛАУ** *к.* аякка бау бәйләгән кебек. *Ләкин һәр адымда белем азлык аякларын багълаганга, уйлаганына ирешү өчен укырга карап йөргән* (Г. Ибраһимов).

Төрдәше: аякка бау бәйләгән кебек һ.б.

**АЯКНЫ ҖИРГӘ БАСЫП АЛУ.** «Эшне яки торышны җайга салу, ныгу» мәгънәсендә. *Төпләнү өчен урын эзләп йөрүче ирләр, чиста сулы инеш табып, шуның янында аякларын җиргә басып алдылар* (Сөйләм).

**АЯКНЫ КИЕНӘ ТОРУ** *к.* алдан алу (алып тору). *Кичке ашны ашап утырганда, Корбангали абзый һич тә көтелмәгән бер вакытта: – Быел, Алла боерса, сине дә алып барам, Сәфәргали, аягыңны киенә тор,* – дип өстәп куйды (Ф. Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы).
Төрдәше: алдан алу (алып тору) һ.б.

**АЯКНЫ КИЕНҮ** *к.* алдан алу (алып тору). *Хатын выжлавыннан гарык, язны көтә-көтә саташып беттем, көннәр җылына башлауга, аякны киенеп алдым, белеш-танышлардан сораштырып, ары-бире юргаларга тотындым* (Җ. Мостафин. Шәҗәрә).
Төрдәше: алдан алу (алып тору) һ.б.

**АЯК<ЛАР>НЫ КӨЧКӘ (КӨЧ-ХӘЛ БЕЛӘН) АТЛАУ (СӨЙРӘҮ).** Аяк зәгыйфьләнү яки хәл бетү сәбәбеннән, авырлык белән адым атлау. *Мифтах картның уң аягы Герман сугышыннан ук биртелеп кайтканга күрә, ул аягын көчкә сөйрәп йөри иде* (Ш. Алпар. Милләт өмете).
Төрдәше: аяк аяктан үтмәү һ.б.

**АЯКНЫ САНАП АТЛАУ.** Ялкау гына, ашыкмый гына атлап йөрү. *Төшке аштан соң бераз һава суларга чыккан ирләр, аякларын санап атлап, әрле-бирле йөриләр иде* (Сөйләм).
Төрдәше: авыр аяк<лы> 1 һ.б.

**АЯКНЫ <ОЗЫН> СУЗУ (СУЗЫП ЯШӘҮ)** *к.* аяк сузып яшәү. Иркен яшәү, иркенәю. *Чөнки Шәвәлинең чүлмәк сатудан килгән барлы-юклы акчалары аякны ул кадәр озын сузарга мөмкинлек бирмиләр* (С. Рәфыйков). – *Сузарлык хутың булганда, аягыңны нигә бөтен буена сузып яшәмәскә?* (А. Хәсәнов).

**АЯКНЫ ТӨРЕП КУЮ (ТОРУ)** *к.* алдан алу (алып тору). *Көннәр җылынгач, сәяхәткә чыгарга да вакыт җитәр, аякны төреп торырга кирәк булыр* (Сөйләм).
Төрдәше: алдан алу (алып тору) һ.б.

**АЯКНЫ ТЫШАУЛАУ.** Нәрсәнедер эшләргә яки каядыр барырга рөхсәт итмәү. – *Аларның аягын тышауларга син кем дә мин кем!* (Н. Гыйматдинова. Кәтәнә). *Аякларым тышауланган бу гасырда. / Җибәрмиләр көзләр үзеннән... / «Ярдәм» диеп пышылдыймы иреннәрем?/ Йөз терелгән инде, мең үлгән / Йөрәк...* (Ф. Мостафина).

**АЯКНЫ ЧАК СӨЙРӘП <БАРУ; КИЛҮ; УЗУ һ.б.>** *к.* аяк аяктан үтмәү. *Аякларны чак сөйрәп урамнар, йортлар яныннан узуы җан газабы икән* (З. Мурсиев. Солтанъяр).
Төрдәше: аяк аяктан үтмәү һ.б.

**АЯКНЫ ЯЛТЫРАТУ** *к.* ай күрде, кояш алды 2. *Кыз бу сүзләргә әһәмият бирмәде, ишегалдыннан тиз генә аягын ялтыратты* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: ай күрде, кояш алды 2 һ.б.

*АЯКНЫҢ* ❖ **АЯК<ЛАР>НЫҢ ЕГӘРЕ КИТҮ.** Бик нык ару, хәлсезләнү. *Алла сакласын, капылт аякларыңның җегәре китеп, тигез урында егылуың бар* (Т. Мөбарәков). – *Уф, аякларның егәре китте, бераз утырып торыйм әле* (Сөйләм).
Төрдәше: аяк калмау һ.б.

**АЯКНЫҢ КАЯ БАСКАНЫН БЕЛМӘҮ** *к.* «а» дигәнче. *Авыз-күзе көлә, елмая, аяклары кая басканын белми, ашыга, йөрәгенең дөпелдәвен нәрсәгә дә тиңләштерерлек түгел* («Сөембикә» ж.).
Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**АЯКНЫҢ ТУФРАГЫ БУЛУ** *к.* аяк астында туфрак булу. – *Син минем аякның туфрагы булырга әзерме соң?* (Сөйләм).
Төрдәше: аяк астында туфрак булу.

*АЯКСЫЗ* ❖ **АЯКСЫЗ ИТҮ (КАЛДЫРУ)** *к.* аяк атлар хәл (дәрман; көч; рәт; чама) юк (булмау; калмау) 1. – *Мәнә синең ботинкаң нинди усал, – диде ул Урмановка, ярым үпкәләп. – Бөтенләй аяксыз калдыра язды бит* (Г. Әпсәләмов. Алтын йолдыз). *Тик кинәт биле тотты. – Ах-х, ү-үтерде... Уф, аяксыз иткәне җитмәгән, шул хәзер билдән яздыра* (Р. Уразголов. Сандык).
Төрдәше: аяк атларлык хәл (дәрман; көч; рәт; чама) юк (булмау; калмау) 1 һ.б.

**АЯКСЫЗ КАЛУ.** 1. Йөри алмас хәлгә калу (төшү). – *Докторлар бер сүз дә әйтмиләр, аяксыз калам, ахрысы* (Сөйләм). *Җиденче*

*дистәсен ваклаган хаҗи көннәрдән бер көнне бөтенләй аяксыз калды* (В. Имамов. Япон татары). *Әнә шул сүзем өчен Алла каргады микән, аяксыз калуым әллә шуннан микән, дим* (З. Мурсиев. Солтанъяр).

Төрдәше: аяктан калу 2; аяктан язу 2.

2. Бик нык арудан яки башка сәбәптән йөри алмас хәлгә килү. *Кинәт кенә аяксыз калган олы гәүдәле карт кеше шикелле ыңгырашып, уһылдап җиргә ауды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Эчсәк, хәзер аяксыз калабыз, бара алмыйбыз* (З. Зәйнуллин. Үрләр аша).

Төрдәше: аяк атлар хәл (дәрман; көч; рәт; чама) булмау (калмау) 1 һ.б.

*АЯКСЫЗДАН* ❖ **АЯКСЫЗДАН КҮТСЕЗ.** Күпсанлы яшь балалар булу турында. *Чираттагы өйдә чыбыркы тотарлык исәү бала юк, җыенысы аяксыздан күтсез, боларга ышанып малларны тапшырсаң, кышка итсез каласыңны көт тә тор!* (А. Гыйләҗев).

*АЯКТА* ❖ **АЯКТА КӨЧКӘ <БАСЫП> ТОРУ** *к.* аяк аяктан үтмәү. *Аның йөзе ап-ак, күзләре эчкә баткан, үзе бик ябык, аягында көчкә тора* (Г. Әпсәләмов. Газинур). *Ул аягында көчкә тора иде. Дулкын шулкадәр көчле бәрә, ян белән бассаң гына аңа каршы торырга мөмкин* (Р. Кәримов. Йөрәгемне ут алган).

Төрдәше: аяк аяктан үтмәү һ.б.

**АЯКТА НЫК <БАСЫП> ТОРУ.** Ярдәмгә мохтаҗ булмау, мөстәкыйль хәл итү. *Колхозлар аягында басып тора торуын, шул ук вакытта аңа бер агым – фермерлыкка да «яшел ут» кабыздылар; кредит ал, эшлә, авыл хуҗалыгын текә күтәрергә ярдәм ит* (Р. Низами. Шахмат дәресләре).

*АЯКТАН* ❖ **АЯКТАН ЕГАРЛЫК.** Искиткеч, шаккатырырлык. – *Ә син бик матурлап, аяктан егарлык итеп, эскизыңны яса* (М. Маликова). *Чибәрлеге теләсә кайсы ир-егетне аяктан егарлык* (Г. Гомәр. Шәхесләр һәм шәрехләр).

**АЯКТАН ЕГУ**. 1. Бәреп җиргә төшерү. *Ишектән ургылып кергән көчле һава агымы инде болай да хәлсезләнгән Айвазны аяктан екты* (З. Мәхмүди. Айваз – Болгар улы).

Төрдәше: бәреп егу; сугып егу.

2. Хәлдән тайдыру, басып тора алмаслык итү. *Сүзесүз итәм дип, әтием яшендәге ул өлкән агайларны да аяктан екканчы эшләтергә ярамый ич инде!...* (В. Нуруллин. Күпер чыкканда).

Төрдәше: бәреп егу; сугып егу; үтереп салу.

3. Авыру аркасында йөри алмаслык хәлгә китерү, хасталану. – *Ләкин мондый матур тормыш миңа озак елмаймады, явыз чир мине аяктан екты... җиденче ел инде шул чир белән интегәм* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Ул [грипп] ике-өч көн эчендә бер-бер артлы унбер кешене аяктан екты* (Г. Сабитов. Сопкада шәфәкъ шәүләсе).

Төрдәше: бәреп егу; сугып егу; үтереп салу.

4. *күч.* Эшне катлауландырып, авыр, кыен хәлдә калдыру; чарасыз итү. *Менә бу хәл Нурыйны аяктан екты* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). *Аяз көнне яшен сукканнан да хәтәррәк бу хәбәр Салих Сәйдәшевне аягыннан ега язды* (Р. Низами. Сәйдәшнең соңгы елы).

Төрдәше: бәреп егу, сугып егу; үтереп салу.

5. *күч.* Шаккатыру, гаҗәпләндерү. *Менә шулай картын юксынып йөргән моңсу көннәрендә көтелмәгән бер хәл Мәфтуханы бөтенләй аяктан ега язды* (Г. Бәширов). *Дөрестән дә бу җавап падишаһны аяктан екты* (Р. Батулла. Сөембикә).

Төрдәше: бәреп егу, сугып егу; үтереп салу.

6. Рухи төшенкелеккә дучар итү. *Бу хәл аны бөтенләй аяктан ук екты* (Г. Толымбай. Нигә кыр үрдәге булмаганнар).

Төрдәше: бәреп егу, сугып егу; үтереп салу.

7. Үлемгә китерү; юк итү. – *Монавы үләтләр Ысысырны таркаткач кына, партияне аяктан еккач кына китте ул тактаның кадере* (А. Хәлим. Кыйбла). – *Урдабызны аяктан ега алырдай бердәнбер кара һәм бердәнбер хәвеф – безнең мәмләкәт эчендәге низаг, тарткалашу вә таркалу* (В. Имамов. Карабәк).

Төрдәше: бәреп егу, сугып егу; үтереп салу.

**АЯКТАН ЕГЫЛГАНЧЫ.** Ниндидер сәбәптән йөри алмаслык хәлгә җиткәнче аякта калу. *Бу «эт» минем күкрәктә күп еллар өрде, ләкин мин аның белән исәпләшмәдем, докторларга вакытында күренмәдем һәм... үземә-үзем җәза алдым, йөрәгемнең тамыры тыгылып, аяктан егылганчы йөри бирдем* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

Төрдәше: хәлдән тайганчы.

**АЯКТАН ЕГЫЛУ.** Йөри алмый торган хәлгә төшү; нык ару; аякка басып та тору алмау. *Әле*

*бүген дә, әллә нидән сүз итеп, Шәяхмәт Саткайны хурлый башлаган, азакты әйләнгәндә, малайның маңкалары акты, тагын бер-ике атларга булса, аяктан егыла иде, дип көлгән...* (Г. Ибраһимов. Табигать балалары).

Төрдәше: аяк атлар хәл (дәрман; көч; рәт; чама) юк (булмау; калмау) 1 һ.б.

**АЯКТАН ЕГЫЛЫРДАЙ БУЛУ** *к.* аяк атлар хәл (дәрман; көч; рәт; чама) юк (булмау; калмау) 1. *Удачин взводы аяктан егылырдай булып арыган иде* («Матбугат.ру» порталы).

Төрдәше: аяк атлар хәл (дәрман; көч; рәт; чама) юк (булмау; калмау) 1 һ.б.

**АЯКТАН ЕГЫЛЫР ХӘЛГӘ (ЧИККӘ) ҖИТҮ** *к.* аяк атлар хәл (дәрман; көч; рәт; чама) юк (булмау; калмау) 1. *Әмма Иргали һичкайчан да ару-талудан зарланмады. Аяктан егылыр хәлгә җиткәндә дә, күңеле көр, тәнендә <...> ниндидер рәхәтлек, олы ләззәт, хозурлык ала, канәгатьләнү хисе кичерә иде* (М. Хәсәнов. Язгы ажаган).

Төрдәше: аяк атлар хәл (дәрман; көч; рәт; чама) юк (булмау; калмау) 1 һ.б.

**АЯКТАН КАЛУ.** 1. *к.* аяк атлар хәл (дәрман; көч; рәт; чама) юк (булмау; калмау) 1. *Бу шигырьләр турындагы язмалар белән жандармерия канцеляриясендәге папкалар тулачак, бер оешмадан икенче оешмага кәгазь ташып, яшерен почта йөртүчеләр аяктан калачак* (М. Мәһдиев. М. Гафури). *Икенче көнне авыл өстенә яман хәбәр бик тиз таралды: Фәрхад аяктан калган* (Р. Зәйдулла. Каты күзле хатын).

Төрдәше: аяк атлар хәл (дәрман; көч; рәт; чама) юк (булмау; калмау) 1 һ.б.

2. Хәлсезлектән, оюдан, аякларда берәр хасталык булудан аяклар йөри алмас хәлгә килү. *Тора-бара ул бөтенләй аяктан калган, гел урын өстендә генә ята башлаган* (В. Нуруллин. Күпер чыкканда). *Атасы аяктан калгач та, Йосыф бөтен йорты белән Сарайчыкка килгән иде* (Р. Батулла. Сөембикә).

Төрдәше: аяксыз калу 1 һ.б.

**АЯКТАН ТАЯККА КАЛУ.** Култык таякларына таянып йөрерлек хәлгә төшү. – *Аяктан таякка калганны күрмисеңмени, кая инде ул хәзер табигатькә чыгып йөрергә!* (Сөйләм).

**АЯКТАН ТОТЫП СЕЛКЕСӘҢ ДӘ ЮК** *к.* аягыннан алып (тотып) селкесәң (селексәң) дә булмас (чыкмас) 2. *Хәзерге тук чырайлы, затлы киемнәр кигән, иң соңгы марка автомобильләрдә җилдерүче, вакытында ике аягыннан тотып селкесәң, сыңар «А» хәрефе дә төшмәслек* <...> (Ә. Рәшит. Һәркемнең... үз хакыйкате).

Төрдәше: аягыннан алып (тотып) селкесәң (селексәң) дә булмас (чыкмас) 2 һ.б.

**АЯКТАН ЯЗУ** *к.* аяк атлар хәл (дәрман; көч; рәт; чама) булмау (калмау) 1 һ.б. *Әле менә күрше авылга барып, аяктан язып кайттым* (Г. Гыйльманов. Тозлы яңгыр). *Атлаган саен эчем ашлары уздырып аяктан язабыз, онытканда бер Коръән укытып, савапка кул сонабыз* (Н. Миңнеханова. «А» хәрефенә башланган җөмләләр).

Төрдәше: аяк атлар хәл (дәрман; көч; рәт; чама) булмау (калмау) 1 һ.б.

2. Бөтенләй йөри алмас хәлдә булу. *Әни дә шулай авырды, кан басымы бик югары булды, тыны кысылды, аяктан язып үлде* (Ф. Бәйрәмова. Татар Караболагы – 50 ел үлем кочагында).

Төрдәше: аяксыз калу 1; аяктан калу 2.

*АЯК-ТАЯК* ❖ **АЯК-ТАЯК СӨЙРӘҮ.** Аяк һәм йөргәндә таяну өчен хезмәт иткән әйберләр бергә. *Бу ял йортының бакчасында аяк-таяк сөйрәп йөрүчеләр дә күренгәли иде* (Сөйләм).

*АЯНЫЧКА* ❖ **АЯНЫЧКА КАРШЫ.** Аяныч, кызганыч булган. *Әткәсе язмышы хакында уйлап, ул бернәрсә төшенде: кешегә игелек күрсәтеп, аннан рәхмәт өмет итү, аянычка каршы, бу дөньяда иң зур тилелек бугай...* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).

Төрдәше: кызганычка каршы.

*АЯУЛЫЛАР* ❖ **АЯУЛЫЛАР (АЯУЧЫЛАР) АЯГЫН СУЗУ.** Бик аяныч, фәлән-фәлән дип сөйләүчеләргә «аяулылар үлгәннәр, без әле андый мескеннәрдән түгел» мәгънәсендәге әзер җавап. *Очраган кайбер танышлар «бик аяныч, китабыгызны басмадан алганнар икән» дип, теләктәшлек күрсәтә башлагач, «аяулылар аягын сузган» дип әйтергә генә калды* (Сөйләм).

# Ә

*Ә* ❖ **«Ә» ДӘ, «ҖӘ» ДӘ ДИМӘҮ** *к.* авыз <да> ачмау; бер сүз дә дәшмәү. *Иске-москы җыючы «ә» дә, «җә» дә димәде, безгә каш астыннан гына карап алды да мәче җитезлеге белән якындагы кычыткканлыкка үрелде* (Ф. Латыйфи). *Ата сүзсез калды: «ә» димәде дәрвиш, «җә» димәде* (Р. Батулла. Сөембикә).

Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**«Ә» ДИГӘНГӘ «Ә» («ҖӘ») <«ҖӘ» ДИГӘНГӘ «ҖӘ» > ДИП ЙӨРҮ (ТОРУ; УТЫРУ).** Һәр сүзен хуплап, канәгать булып тору, шундук җавап биреп, һәр сүзне җөпләү. *Чын дуслык «ә» дигәнгә «җә» дип пичәт сугып утыру гына түгел, бәхәс-ярышларга да мәйдан җитәрелек бирәдә* (Р. Низами. Яшьлеккә хат). *Җанатар ул вакытта, сезнеңчә, без барыбыз да бу әсәрне Зөлфәт язганга гына мактап утырырга тиеш булып чыгабызмы? Бер соры масса булып, «ә» дигәнгә «ә» дип, «җә» дигәнгә «җә» дип кенә утырырга, фикерли алмый торган бер кавем булып калырга?!* («Матбугат.ру» порталы).

Төрдәше: «ә» дигәнгә «мә» дип тору<чы>; «ә» дигәндә «җә» дип (дияргә әзер) тору; «ә» дисәң, «җә» дип әйтү (тору); «ә» дисәң – «мә» дип тору; кеше кубызына (кураена) бию.

**«Ә» ДИГӘНГӘ «МӘ» ДИП ТОРУ<ЧЫ>** *к.* «ә» дигәнгә «ә» («җә») <«җә» дигәнгә «җә»> дип йөрү (тору; утыру). *Алексей патша уң кулы итеп үз кырына дан сөюче, шөһрәт яратучы митрополит Никонны ала – «ә» дигәнгә «мә» дип торучы митрополит прихожаннар өчен чиркәү реформасы уздыра* (М. Хәбибуллин. Ялганга йөз тоткан сәяхәтнамәгә ышанырга ярыймы?..).

Төрдәше: «ә» дигәнгә «ә» («җә») <«җә» дигәнгә «җә»> дип йөрү (тору; утыру) һ.б.

**«Ә» ДИГӘНДӘ «ҖӘ» ДИП (ДИЯРГӘ ӘЗЕР) ТОРУ** *к.* «ә» дигәнгә «җә» дип йөрү (тору). *Ил кайгысын әле һаман ныгып җитмәгән тар һәм сыек иңнәренә күтәрергә мәҗбүр булган яшь кенәз, ачуына түзә алмыйча, тәхет кәнәфиеннән кинәт сикереп торды һәм әйләнәсендәге «ә» дигәненә күптән «җә!» дияргә әзер торган боярларыннан беренчесенең якасыннан алды* (Р. Вәли). *Адресы төгәл әйтелде, килерләр, «ә» дигәндә «җә» дип торырлар* (Р. Низами. Бомж).

Төрдәше: «ә» дигәнгә «ә» («җә») <«җә» дигәнгә «җә»> дип йөрү (тору; утыру) һ.б.

**«Ә» ДИГӘНЧЕ** *к.* «а» дигәнче. *Чуар бабай «ә» дигәнче йөген төйи дә кайта икән* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала). *Арслан, ул дәшүгә, «ә» дигәнче килеп җитте, аның кушканнарын «ярар, карчык, ярар, матурым» дип йөгерә-йөгерә үтәде* (Ф. Садриев. Кышкы яшен).

Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**«Ә» ДИГӘНЧЕ ХАП ИТҮ.** Кеше сүзен бетергәнче бик тиз эләктереп алу. – *Мин сөйләгәнне тыңлап бетер инде, «ә» дигәнче хап итәргә ашыкма!* (Сөйләм).

Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**«Ә» ДИП ТӘ, «ҖӘ» ДИП ТӘ.** Бернәрсә дә. *Зарифуллин «ә» дип тә, «җә» дип тә әйтә алмады, звонок булуга класстан чыгып китте дә учительскаяның мичe артына кереп, рәхәтләнеп бер елады* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).

Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**«Ә» ДИСӘҢ, «ҖӘ» ДИП ӘЙТҮ (ТОРУ)** *к.* «ә» дигәнгә «ә» («җә») <«җә» дигәнгә «җә»> дип йөрү (тору; утыру). – *Атаң да әйтә, кайтса туйганчы бер сөйләшербез дип, сөенеп көтеп торган ием, юкка гына сөенгәнмен – утырып ике авыз сүз дә сөйләшкәнебез юк малай белән, ә дисәң, җә дип әйтә дә, бүтән сүзе юк, ди* (Г. Мөхәммәтшин. Йөрәктәге эзләр).

Төрдәше: «ә» дигәнгә «ә» («җә») <«җә» дигәнгә «җә»> дип йөрү (тору; утыру) һ.б.

**«Ә» ДИСӘҢ – «МӘ» ДИП ТОРУ** *к.* «ә» дигәнгә «ә» («җә») <«җә» дигәнгә «җә»> дип йөрү

(тору; утыру). *«Ә» дисәң, «мә» дип торулары теңкәгә тия башлады, мин урамга чыгып торыйм әле* (Сөйләм).
Төрдәше: «ә» дигәнгә «ә» («җә») <«җә» дигәнгә «җә»> дип йөрү (тору; утыру) һ.б.

**Ә ШУЛ УК ВАКЫТТА.** Бер вакытта башкарылган ике эшне чагыштырып карау өчен кулланыла. *Ике хатын капка төбендә тәмләп-тәмләп урам яңалыкларын бүлешкәннәр, ә шул ук вакытта юньсез малайлар, арт капкадан кереп, бакчадан кыярларын җыеп чыгып киткәннәр* (Сөйләм).

**Ә ШУЛАЙ ДА.** Алда әйтелгән сүзгә каршы куюны көчәйтү өчен кулланыла. *Юл баткаклык булган, машина үтә алмас дип кисәткәннәр иде, анысы, ә шулай да барып карыйм әле, минем чит ил машинасы ерып чыгарга тиеш* (Сөйләм).

**«Ә» ЮК, «ҖӘ» ЮК.** Бер сүз дә дәшмәү. *– «Ә» юк, «җә» юк, хатыны Бибиәсхәбҗамалны аты белән юл уртасында калдыра да, үзе корт иле артыннан кыр өсләтеп урманга таба йөгерә башлый* (Ф. Хөсни. Тынгысыз кеше).
Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

*ӘБӘК-ЧӘБӘК* ❖ **ӘБӘК-ЧӘБӘК УЙНАУ.** Берәрсе белән очрашудан качып йөрү. *«Туйдым бу әбәк-чәбәк уйнавыңнан», – диде ул, Гүзәлнең кулыннан тотып* (Сөйләм).

*ӘБДӘН* ❖ **ӘБДӘН МАЕ БУЛУ**. Җиңелчә генә исереп китү. *Яңа җәйләүнең саф һавасында майлы ит белән карынны тутырып, кымызны әбдән мае булганчы эчеп, илнең өлкәннәре көн буенча киңәшмә үткәрделәр* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *[Акмулла] Кымыздан әбдән мае булдым, ахры* (Ю. Сафиуллин. Акмулла).
Төрдәше: баш җиңеләю 1.

*ӘБЕЛХӘЯТ* ❖ **ӘБЕЛХӘЯТ ЧИШМӘСЕ (СУЫ)** *күч.* 1. Һәртөрле сафландыра, яшәртә торган нәрсә. (Әбелхәят – *миф.* тереклек суы). *Юкка гына борынгылар тереклекне әбелхәят чишмәсенә охшатмаганнар икән* (Ә. Еники. Тауларга карап). *Китер әбелхәят суын – бер генә йотым китер* (Р. Гаташ).

2. *күч.*, *к.* агулы елан 1. – *Синдә «әбелхәят суы» идән асты тулы, ахры* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: агулы елан 1 һ.б.

**ӘБЕЛХӘЯТ КОЧАГЫНДА.** Бәхетле тереклек. *Әбелхәят кочагында саф тулы чишмә, шул чишмә моңына тиң җыр, ике йөрәкнең бер серле көйгә тибүе – бу халәт аларның икесен генә түгел, бәлки авылны, авылны гына түгел, ә бәлки бөтен дөньясын бер бишектә тибрәтте* (З. Хәким. Легионер).

*ӘБҖӘДЕН* ❖ **ӘБҖӘДЕН ӘЙТТЕРҮ** *к.* авыз җебетү 2. – *Әйдә, берәр кич моның әбҗәден әйттерәбез, беләме икән?* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

*ӘБИ* ❖ **ӘБИ АВЫЗ.** Өске ирене нечкә, аскысы калын һәм салынкы булып тору. – *Врачка алып барам да теге дырылдавык машина белән барын чүпләтәм. Йөр әби авыз булып* (А. Гыйләҗев. Урамнар артында яшел болын). – *Корты бар аның, – ди әнәй аптырагач – Тешеңне корт ашап бетерер дә әби авыз булып калырсың!..* (Ш. Маннур. Агымсуларга карап).

**ӘБИ ПАТША.** 1. Русия патшасы Екатерина II нең халык арасындагы исеме. *Тик Петр I дән соң Екатерина II (Әби патша) вакытында гына, татарларны дин җәһәтеннән кысу бераз йомшара, ә кайбер фамилияләргә, шул җөмләдән Еникеевлар белән Терегуловларга да морзалыклары яңадан кайтарыла* (Ә. Еники. Соңгы китап).

2. *күч.* Идарә итәргә яратучы хатын-кыз җенесеннән булган кеше. *Кая ул кызлар гына – классның барлык малайлары да, аларның каты йодрыкларыннан куркып, дер-дер калтырап, бу ике «әби патшаның» күзләренә генә карап тора икән. Шулай итеп, сүзне сүз тартты, алар әңгәмә кабартып җибәрделәр* (Г. Мөхәммәтшин. Тәрбия сәгате). – *Ул әби патша үзе искелек калдыгы, аңладыңмы син, чешуя?* (З. Хөснияр. Гарасат).

**ӘБИ ПАТША ЗАМАН<АС>Ы.** Бик күптән, әллә кайчан (Екатерина II дәвере күз уңында тотыла). *Анысы әби патша заманасында дигәннәре бик карт дип әйтүләре генә инде, билгеле* (И. Гази. Тургай картаямы икән?). *Күмәләр да тагын актаралар, әби патша заманы балдакларын табып, археологлар: – Ха-ха! – көләләр* (Роб. Әхмәтҗан. Таң шәһәре).
Төрдәше: борын-борын заманда, Нух пәйгамбәр заманында; хан заманында.

**ӘБИ ПАТШАДАН КАЛГАН.** Бик борынгы, искергән нәрсә. *«Болар әби патшадан калгандыр, ахры, – диде ул, пыяла астындагы балдакларга күрсәтеп* (Сөйләм).
Төрдәше: борын-борыннан калган; Нух пәйгамбәр заманыннан калган; хан заманыннан калган.

*ӘБИ-БАБА* ❖ **ӘБИ-БАБА ЙОРТЫ**. Туган җир, нәселләре яшәгән йорт. *Якын икән әби-баба йорты, / Кая гына китсәң дә* (З. Газизов).
Төрдәше: әби-бабай туфрагы.

*ӘБИ-БАБАЙ* ❖ **ӘБИ-БАБАЙ ТУФРАГЫ** *к.* әби-баба йорты. *Әби-бабай туфрагы турында күп сөйләмәсә дә, ул аның хәтереннән чыкмый иде* (Сөйләм).
Төрдәше: әби-баба йорты.

*ӘБИ-БАБАЛАРЫНА* ❖ **ӘБИ-БАБАЛАРЫНА ҖИТҮ.** Әшәке сүзләр белән кемнедер бик каты сүгү, тиргәү. *Шулай да әби-бабаларына хәтле үк җитәргә ярамый бит. Ничек уйлыйсың?* (Ш. Камал).
Төрдәше: ата<сы>-анасы белән сүг<ен>ү һ.б.

*ӘБИ<С>ЕН* ❖ **ӘБИ<С>ЕН ТАНЫТУ** 1. *к.* авыз җебетү 2. – *Артык үзсүзләнеп китте бу, әбисен танытырга вакыт җитте кебек* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

2. *күч.* Тукмау, җиңелүгә дучар итү. *Сталинградта немецларның әбиләрен танытканнар* (Ш. Маннур).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

*ӘБИ<С>ЕНЕҢ* ❖ **ӘБИ<С>ЕНЕҢ ӘБИЛӘРЕ ЯНЫНА ОЛАКТЫРУ.** Янау; үтерү, үтереп ташлау. – *Бик киреләнсәң, әбиеңнең әбиләре янына олактырырга да күп сорамам!* (Сөйләм).
Төрдәше: адәм башкайларын салу һ.б.

*ӘБИЕҢ* ❖ **ӘБИЕҢ СЫЗГЫРА БЕЛӘМЕ**? *ирон.* Кешене өйрәтергә яратучы, дәгъва кеше турында. *[Ханнан] Әбиең сызгыра беләме диярсең...* (Ю. Әминов. Умырзая чәчәкләре). *Әбиең сызгыра беләме?* (Г. Афзал).
Төрдәше: курай уйный беләсеңме?

*ӘБИЕҢӘ* ❖ **ӘБИЕҢӘ СӘЛАМ ӘЙТ, <БАБАҢ УТЫРМАГА (УТЫРМАЛЫЙ) КИЛСЕН>.** Юкны, булмасны дәгъва кылучыга, акыл өйрәтергә яратучыга әйтелә (мәгънәсез, рәтсез сүзгә карата). – *Әбиеңә сәлам әйт! Булмаганны!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). – *Сабыр да сабыр... әбиеңә сәлам әйт, бабаң утырмалый килсен!* (И. Гази. Онытылмас еллар). – *Бар, бар, юлыңны кара. Әбиеңә сәлам әйт, бабаң утырмага килсен!* (Ф. Шәфигуллин. Якты хатирәләр).

*ӘБИЛӘР* ❖ **ӘБИЛӘР АТНАСЫ** *к.* әбиләр чуагы. *Бу соңгы җәй, халык әйтмешли, «карчыклар җылысы» яисә «әбиләр атнасы» – минем* (Г. Рәхим).
Төрдәше: әбиләр җәе; әбиләр көне; әбиләр чуагы; карчыклар чуагы.

**ӘБИЛӘР ӘКИЯТЕ.** Тормышта, чынбарлыкта булмаган, уйдырма нәрсә. *Әбиләр әкияте сөйләп, юк-бар белән башны катырып утырма әле!* (Сөйләм).

**ӘБИЛӘР ҖӘЕ** *к.* әбиләр чуагы. *Әбиләр җәе дә үтеп китте, көннәр, ниһаять, бозылды, көзге салкын вак яңгырлар башланды* (Ә. Еники. Без дә солдатлар идек). *Иртәгәсен әбиләр җәе башланды* (Д. Әхмәтова. Тәте).
Төрдәше: әбиләр атнасы; әбиләр көне; әбиләр чуагы; карчыклар чуагы.

**ӘБИЛӘР КӨНЕ** *к.* әбиләр чуагы. – *Әйдә урманга, әбиләр көненнән файдаланып калыйк* (Сөйләм).
Төрдәше: әбиләр атнасы һ.б.

**ӘБИЛӘР ЧУАГЫ.** Көз ахырында бер атна-ун көнгә сузылган җылы көннәр. *Әниләр елмаюы кебек ягымлы җылы көннәре, көмеш тожымнары, салкын төннәре белән әбиләр чуагы да узып киткән* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Әбиләр чуагы соңлады, / Кемнеңдер гозерен тыңлады* (Р. Мөхияр. Әбиләр чуагы).
Төрдәше: әбиләр атнасы һ.б.

*ӘБИЛЕК* ❖ **ӘБИЛЕК ИТҮ (КЫЛУ).** Корсаклы хатыннарга бала тапканда ярдәм күрсәтү. *Аллага шөкер, егерме биш ел әбилек итәм, бер генә дә ялгышканым юк* (А. Шамов).
Төрдәше: кендек әбисе.

*ӘБИСЕ* ❖ **ӘБИСЕ ӨШКЕРГӘН.** Бик кадерле, сирәк табыла торган әйберне сораучыга бирмәгәндә әйтелә. *Сиңа тәмәке бирү түгел, үземә дә бер урарлык кына, чөнки кешедән бер тартырлык теләнеп алдым. Әбисе өшкергән аның* (Г. Ризван).

*ӘБИСЕНӘ* ❖ **ӘБИСЕНӘ ИМАН УКЫТУ** *к.* авыз җебетү 2. *Бүре чыбагачлары белән кистәннәр булса, ул погромның әбисенә иман укытачакбыз* (К. Тинчурин).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

*ӘБИ-ЧӘБИ* ❖ **ӘБИ-ЧӘБИ ГАЙБӘТЕ.** Карчыклар гайбәте. *Вәли белән Айратның үз дөньясы иде, әби-чәби гайбәтенә колак салмадылар* (В. Имамов).

*ӘБРӘКӘЙ* ❖ **ӘБРӘКӘЙ САНДУГАЧЫ** *туп.* Күп сөйләүче кеше, лыгырдавык. – *Кайчан туктыйсың инде, әбрәкәй сандугачы?* (Сөйләм).
Төрдәше: авызына алды инде, өзмәс тә куймас һ.б.

*ӘБҮҖАҺИЛ* ❖ **ӘБҮҖАҺИЛ ДӨЛДЕЛЕ.** «Наданның наданы» мәгънәсендә. (Әбүҗаһил (наданның этисе, ата надан) – Мөхәммәд пәйгамбәрнең иң явыз дошманы; Дөлдөл – хәзрәте Гали атланып йөргән качыр, әкиятләрдә – канатлы ат). *[Сәфәргали] Мин ул Әбүҗаһил дөлделен күрәсем дә килми* (К. Тинчурин. Йосыф белән Зөләйха).

**ӘБҮҖАҺИЛ КУАСЫ (КВАСЫ)** *сөйл.* Йорт шартларында әзерләгән исерткеч эчемлек, көмешкә, шулай ук *к. агулы елан* 1. *[Мәрди] Их, хәзер моның янына теге әбүҗаһил квасы табып булса. Бер йотым гына!* (Н. Исәнбәт).
Төрдәше: агулы елан 1 һ.б.

*ӘВӘРӘ* ❖ **ӘВӘРӘ БУЛУ (БУЛЫП ЙӨРҮ).** 1. Бер эш яки бер мәсьәлә белән генә мавыгу, мәш килеп йөрү. *Коймак тирәсендә әвәрә булып йөрүче Маһирә күрми дә калды, малай таякны ялт итеп караватастына шудырды* (А. Гыйләҗев. Тәрәзәләр). *Чаршау белән бүленгән аш-су пешерү почмагында Ак әбинең әвәрә булып йөргәне ишетелә, ул тагын тәмле таба исләре чыгарган иде* (А. Тимергалин. Карурман аша).
Төрдәше: әвәрә килү.

2. Берәр нәрсәгә юлыгу, дучар булу. *Без бит әле еш кына театрны кәмиткә әйләндереп, ахух килеп буфетка чабып та әвәрә булабыз* (Т. Әйди. Кечкенә дә төш кенә). *Карасана, синең белән әвәрә булып, эшнең иң әһәмиятлесен оныткамын ич* (А. Расих. Ямашев).

**ӘВӘРӘ БУЛЫП КАЛУ.** Бернәрсә белән генә мавыгу, мәш килү. *Ни чара кыйлсын, дәрдмәнд бичара әвәрә булып калды* (К. Насыйри. Әбүгалисина кыйссасы). *Әсәрнең «геройлары» – кая тартсаң шунда бара торган затлар – тагы да бер кат әвәрә булып калулары мөмкин...* (И. Нуруллин).
Төрдәше: әвәрә китереп йөртү.

**ӘВӘРӘ ИТҮ (КЫЛУ).** Берәрсен нинди булса да эш яки мәсьәлә белән йөдәтеп, аптыратып бетерү, тинтерәтү. *Шәкертләр аның зифа буена дәртле йөзенә сокланалар, русчасы ватыпҗимереп булса да, аны сүз белән әвәрә кылалар* (М. Галәү. Болганчык еллар). *Ничек болай әвәрә итте соң әле ул бөтен тамашачыны?* (М. Маликова. Юкә чәчәк аткан чак иде).

**ӘВӘРӘ КИЛҮ** 1. *к.* әвәрә булу (булып йөрү). *Гадел, шулай сөйләнә-сөйләнә, кухняда әвәрә килде* (Ш. Маннап). *Әвендә гел бергә әвәрә киләләр, амбар ширкәте, үзе бер дәүләт бит ул* (Ф. Бәйрәмова. Караболак). *Көн дә чират торасыңдыр, / Син дә, әвәрә килеп* (Г. Морат. Төнге әверелеш).
Төрдәше: әвәрә булу (булып йөрү).

2. Җенси мөнәсәбәткә керү. *Гаеп шул: менә дигән сөлектәй кара карга егетләре була торып, нигә, нигә әле ул, – җир бит! – башка кош егетләре белән әвәрә килгән!!!* (З. Хөснияр. Козгыннар йолдыз чүпли).

**ӘВӘРӘ КИТЕРЕП ЙӨРТҮ.** Бер тирәдә әйләндерү-тулгандыру. *Шулай үзалдына сөйләнәсөйләнә, Газинур Гөлнәзирәне киң түшәк өстендә әйләндергәләп, әвәрә китереп йөртә башлады...* (Г. Гыйльманов. Аллалар кайда яши?).
Төрдәше: әвәрә булып калу.

*ӘВЕН* ❖ **ӘВЕН ӘҮЛИЯСЕ.** Юк сүзне күпертеп, кат-кат сөйләүче. *Эш кешесе, имеш. Һе! Әвен әүлиясе, мунча тараканы!* (Ш. Камал).

**ӘВЕН БАЗАРЫНА КИТҮ (ОЛАГУ).** Йоклау. – *Йокым начар дигән буласың, фәлән-фәсмәтән. Яту белән, моннан әвен базарына олагасың* (Ә. Маликов). *Озакламый алар әвен базарына китте. Галимҗан исә йоклый алмады* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).
Төрдәше: әвен базына аву.

**ӘВЕН БАЗЫНА АВУ.** Йокымсырап йөрү. *Кайтканнан бирле әвен базына ава бу сылукай* (Н. Гыйматдинова. Китәм, димә...).
Төрдәше: әвен базарына китү (олагу).

**ӘВЕН БАШЛЫ.** Чәчләре тырпаеп тузгыган. *Бигрәк тә әвен башлы инде синең теге танышың* (Сөйләм).

**ӘВЕН ИЯСЕ** *миф.* Көлтәләрне корытырга куйган каралтыда яшәүче рух. *Кырдан китерелгән беренче көлтәне, әвен иясенә дип, утка ташлаганнар* (Сөйләм).

**ӘВЕН КЕБЕК** *к.* Алып кебек.– *Үзең әвен кебек, йөрисең шунда хатын-кыз арасында тырма тотып* (Сөйләм).

Төрдәше: алып кебек һ.б.

**ӘВЕН СУГУ (СУГЫП АЛУ; СУКТЫРУ).** 1. Әвендә киптерелгән көлтәләрне сугу (суктыру). *Карт хәзрәт: «Алай икән, кызым! Син әвен сугарга чыкмадыңмыни?..» – диде дә озын гына иттереп кызын сөзде* (Г. Исхакый. Остазбикә).

2. *күч.* Бик авыр эш эшләп ару, хәлдән таю. *Сәхипҗамал күрше, син безне әллә әвен сугып килде дип белдеңме* (А. Әхмәт). *Сорур чынлап сөешергә өлгерә алмады, ул өч көн бербуйдан әвен суккан кеше кеби йокыга китте* (Г. Исхакый. Мәдрәсә җимеше).

Төрдәше: әвен сугып кайту (килү); җеп өзәрлек дәрман (хәл) <дә> калмау; хәлдән таю; хәлдән төшү; эт булу (булып бетү); эт булып ару; эштән чыгу 3.

3. *күч.* Тиз-тиз ашау. *Кара әле тегеләргә, ничек әвен сугалар!* (Сөйләм).

Төрдәше: ат урынына ашау; тишек тамак тик тормау; үзе сөйли, үзе чөйли; шартлаганчы ашау; ярылганчы ашау.

4. *күч.* Нәрсәнедер тузгытып ташлау (әвенгә куелган көлтәләрне суктырганда күтәрелгән тузанга, шау-гөр килүгә ишарә). – *Аннары, кырын ятып, Гитлерга әвен сугарга вәгъдәм дә бар иде* (Г. Әпсәләмов).

Төрдәше: астын өскә (өстенә) айкау (әйләндерү; китерү) һ.б.

**ӘВЕН СУГЫП КАЙТУ (КИЛҮ).** Бик нык ару һәм ачыгу. *Малайларга коймак та, майлы бәрәңге телемнәре дә. Сөмбелә апаларының җылы карашы, татлы теле дә ифрат ошады, алар, әвен сугып кайткан егетләрдәй, ризыкларны сыпырып куйдылар* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: әвен сугу (суктыру) 2 һ.б.

**ӘВЕН ХӘТЛЕ ИР** *к.* алып кадәр. *Зөһрә озын юл килеп арыган, шешкенгән аяклары белән арбадан төшә алмыйча азапланып торган арада, әвен хәтле бер ир заты килеп, арбадан сөйрәп төшерде* (Р Шәйдуллина. Карт шомырт хатирәсе).

Төрдәше: алып кадәр һ.б.

**ӘВЕН ЧЫПЧЫГЫ** *мыск.* Бер дә китми торган кунак (әвендә яши торган чыпчык белән чагыштыру). – *Әтисе, кунагың әвен чыпчыгы түгелдер ич, үзе белән сөйләшеп кара әле* (Сөйләм).

**ӘВЕН ЧЫПЧЫГЫНА ӘВЕРЕЛҮ.** Фәкать ашау, корсагын тутыру турында гына кайгыру. *Аннан әвен чыпчыгына әверелүеңне көт тә тор* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

Төрдәше: ашау өчен <генә >эшләү һ.б.

**ӘВЕН ЯНУ** *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү). *Тезләрен тезгә куеп, диванда Әхмәт утыра. Әвене янган егетнең* (А. Гыйләҗев). – *Синең әвенең яндымы әллә? Юкка кайгырма, ватан саклыйм дип тә баш ватма, кил, тәмәке тарт, бүген кич барыбер китәбез бит* (А. Таһиров).

Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

*ӘВЕНЕ* ❖ **ӘВЕНЕ ЯНГАН КЕШЕ КЕБЕК.** Кашын-күзен җимереп, караңгы чырай белән йөрүче; бәла-казага очраган кыяфәттә булу. *[Сиби] Нихәл, иптәш, монда бер ялгызың гына әвене янган кеше шикелле, борыныңны салындырып, ни эшләп утырасың?* (Г. Камал. Хафизалам, иркәм). *Хәкимҗан абый, әвене янган кеше сыман, башын кыйгайтып, шунда утыра иде* (А. Гыйләҗев. Язгы кәрваннар).

Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**ӘВЕНЕ ЯНГАНДАЙ (ЯНГАН КЕШЕДӘЙ) ЙӨРҮ** *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. *Соңгы көннәрдә бигрәк тә. Әвене янгандай йөри* (Б. Камалов. Мәрдән сукмагы). *Тик Саматов үзе генә әвене янган кеше төсле йөри* (Г. Ахунов. Чикләвек төше).

Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**ӘВЕНЕ ЯНГАНМЫНИ** *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. *Әвене янганмыни, почмакта берүзе борынын салындырып утыра* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**ӘВЕНЕ ЯНЫП БАРГАНДА** *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. – *Әвенең янып барганда, сиңа йокы тансык, – дип ысылдады Хәбри. – Сораганга җавап бир: ире белән аерылды түгелме ул синең ахирең?* (Г. Сабитов. Калай күке).
Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

*ӘВЕНЕНӘ* ❖ **ӘВЕНЕНӘ УТ КАБУ.** Кирәкле әйберен югалту, кайгылы, борчулы булу. – *Әвененә ут капмагандыр бит, бикә, нигә шулкадәр кабаланасың, – диде Булат Ширин кергә-керешкә* (М. Әмирханов. Гәүһәршад).
Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**ӘВЕНЕНӘ УТ КАПКАНМЫНИ** *к.* ак-кара <күзгә> күренмәү 1. – *Түбән оч Рәшитне күрдеңме, әвененә ут капканмыни, оча гына* (Сөйләм).
Төрдәше: ак-кара <күзгә> күренмәү 1 һ.б.

*ӘВЕРЕП* ❖ **ӘВЕРЕП АЛУ.** 1. Бәргәләп алу; эләктерү. *Кем пулән белән, кем көрәк белән яланга чыктык. Шәлеләр дә усаллар, безне шактый әвереп алдылар* (Ф. Сәйфи-Казанлы. Крушниклар). *Ул дәү кочагына берьюлы ярты чүмәләне әвереп алып, эчкә йөгерде* (Г. Бәширов).

2. Сихерләгән кебек, үзенә, авызына карату. *Теге Дөбъяз егетенең укырга килүенә бер ай гына булды кебек, ничек төркемнең иң чибәр кызын әвереп ала алган ул?* (Сөйләм).

*ӘВЕШ-КЫЕШ* ❖ **ӘВЕШ-КЫЕШ КИТЕРҮ.** 1. *к.* авыш-түеш (тәвеш) килү 1. *Хатыны әле һаман да, әйберләрне әвеш-кыеш китереп, нәрсәдер эзли иде* (Сөйләм).
Төрдәше: авыш-түеш (тәвеш) килү 1 һ.б.

2. Вак-төяк эшләр белән маташу. *Әллә ни артык эшләр булмаса да, тамагың тук булып, көннәрне әвеш-кыеш китерерлек булса, риза инде шунда, безнең дөньяда күп торасы калмаган инде <...>* (Г. Камал).
Төрдәше: әвеш-түеш (тәвеш итү); әвеш-түеш (тәвеш) китерү; әвештереп тору; әвеш-түеш итү.

3. Аннан-моннан гына нәрсәдер эшләү. *Мансур лапас тирәсендә әвеш-кыеш китерде дә балтасын алып чыгып китте* (Сөйләм).
Төрдәше: авыш-кыеш китергәләп (китереп) һ.б.

*ӘВЕШТЕРЕП* ❖ **ӘВЕШТЕРЕП ТОРУ.** Ничек җитте шулай көн итү, вак-төяк алыш-биреш белән киченү. *Ул карчыгы белән булган вак-төякне әвештереп торып гомер итә иде* (Сөйләм).

*ӘВЕШ-ТҮЕШ* ❖ **ӘВЕШ-ТҮЕШ (ТӘВЕШ) ИТҮ** *к.* авыш-түеш (тәвеш) китерү. *Карт толчокта иске тимер-томырлар белән әвеш-түеш итте* (Ш. Камал).
Төрдәше: авыш-түвеш (тәвеш) китерү һ.б.

**ӘВЕШ-ТҮЕШ (ТӘВЕШ) КИТЕРҮ** *к.* авыш-түеш (тәвеш) китерү 1. *Карт, әвеш-түеш китереп чәйнәгән ипиен йотып җибәргәннән соң, Гөлкәйгә төбәлеп сорап куйды* (Х. Ширмән. Асылъяр).
Төрдәше: авыш-түеш (тәвеш) китерү 1 һ.б.

2. *к.* авыш-түеш (тәвеш) китерү 2. *Эшләнәсе теге вакытны вагын-төяген сатып, кала белән авыл арасында әвеш-түеш китереп йөрүче бер бәндәгә киткән иде* (Г. Бәширов). *Анда бал кортлары, анда табигать, анда бернинди әвеш-тәвеш китерү юк* (З. Хәким. Мылтык).
Төрдәше: авыш-түеш (тәвеш) китерү 2 һ.б

3. *к.* авыш-кыеш китергәләп (китереп). *Шиферны әвеш-түеш китерә дә теләнергә чыгып китә* (А. Гыйләҗев).
Төрдәше: авыш-кыеш китергәләп (китереп) һ.б.

4. Очын очка ялгау, көннәрне ничек тә үткәрү. *Сутә дә бәйли, сутә дә бәйли – шулай итеп әвеш-тәвеш китергәч, кышка да ярый, җәйгә дә* (Сөйләм).
Төрдәше: авыш-кыеш китергәләп (китереп) һ.б.

*ӘГӘР* ❖ **ӘГӘР АЛАЙ ДИП ӘЙТЕРГӘ ЯРАСА.** Шулай булганлыгына ышанып җитмичәрәк, фараз итеп. *Мөселман әдәбиятының бер «гыйльми», документаль, әгәр алай дип әйтергә яраса, тармагы «сийәр» («сирә») дип атала* (giylem.tatar).

**ӘГӘР ДӘ МӘГӘР.** 1. «Төрле фаразларны һәм ихтималларны уйлап эш иткәндә» мәгънәсендә. *Аннары шунысы да хан булып, әгәр дә мәгәр Бүре кавеме аерым фирка оештырса, коткы кулланып, басып алулар башлап, Шүрәлеләрнең соңгы тамчы хокукларын да тартып алу хәвефе бар* (Ә. Гаффар. Богау).

2. Шулай булгач, шулай икән. *Әгәр дә мәгәр язын боз өстенә чыга икән, аның суга чумачагын көт тә тор* (Сөйләм).

*ӘГУЗЕСЕННӘН* ❖ **ӘГУЗЕСЕННӘН ЭЛЕК ӘЛХӘМЕ.** «Һәр нәрсәнең ахыры яхшы бетсен яки файдалы булсын» дигән мәгънәдә.

*– Син әгузесеннән элек әлхәмен уйла, әлхәмен* (Сөйләм).

*ӘГЪВАЛАП* ❖ **ӘГЪВАЛАП ЙӨРҮ.** Котыртып йөрү. *– Үзе әгъвалап йөрде, йөрде дә каядыр юкка чыкты* (Сөйләм).

*ӘГЪЛА* ❖ **ӘГЪЛА СУРӘТТӘ.** Иң югары дәрәҗәдә, сокланырлык. *Берәү дә аның яңа картинасы шундый әгъла сурәттә уңышлы чыгар дип уйламаган иде* (Сөйләм).

*ӘГЯҺ* ❖ **ӘГЯХ БУЛУ** *кит.* Хәбәрдар булу, белеп тору. *– Әгях булып тор, кулларыңны юмыйча, бу китапка тотынма* (Сөйләм).

*ӘДА* ❖ **ӘДА КЫЛУ** *иск., кит.* Башкарып чыгу, үтәү. *Муса әфәнде илә Нигъмәтулла әфәнде мәҗлесдән ивләренә кайтуб кәлгәч, тәһарәтләнүб, салаваты гасырла салаваты мәгърибне әда кылуб, ахшам йиде сәгатьдә чәй эчдекләре вакытда политсә кәлүб, Муса әфәндене арестовайть идүб, хәбесханәйә алуб китделәр* (З. Бигиев).

*ӘДӘБИ* ❖ **ӘДӘБИ КАРАКЛЫК**. Башка берәрсенең әсәрләрен өлешчә яки тулысынча күчереп алып, үз исемеңне куеп чыгару. *Мондый алым Шәрык шагыйрьләренә хас, ул сарика (плагиат, ягъни әдәби караклык) булып исәпләнми* (А. Тимергалин. Ике сандык йакут).

*ӘДӘБИЯТ* ❖ **ӘДӘБИЯТ ГЕНЕРАЛЫ.** Әдәбият өлкәсендә әсәрләре яки фәнни хезмәтләре белән танылган өлкән яшьтәге кеше. *Кызыл комач ябылган өстәл артына берничә әдәбият генералы утырган* (Сөйләм).

*ӘДӘБИЯТЫБЫЗНЫҢ* ❖ **ӘДӘБИЯТЫБЫЗНЫҢ ЙӨЗЕК КАШЫ.** Яратып укыла торган, иң яхшы әсәрләре белән мәшһүр булган әдипләр. *Кыскача әйткәндә, диде Фатыйха апалары, сезгә шундый сөаль, балалар, нигә Тукай татар әдәбиятының, атап әйткәндә, татар балалар әдәбиятының йөзек кашы саналган, инде менә дистәләрчә буынны тәрбияләгән «Шүрәле» поэмасының төп каһарманы итеп адәмнәрне кытыклап үтерүче, шыксыз, ямьсез, куркыныч Шүрәлене сайлаган?* (А. Хәлим. Хунвуйбин).

*ӘДӘП* ❖ **ӘДӘП ЙӨЗЕННӘН**. Йола һәм кагыйдә нормасын саклап, әдәп саклап. *Айбулат әдәп йөзеннән тагын берничә кәлимә сүз алышты да: – Ярый, егетләр, миңа бу якка, – дип, уңга борылды* (Т. Әйди. Божра).

**ӘДӘП КАЧУ.** Тупаслыкка, тәрбиясезлеккә салыну. *Бер әдәп качкач, сөйләп тә була, кылып та була* (Г. Исхакый. Өч хатын белән тормыш).

Төрдәше: әдәп таптау; әдәп-изәт белмәү; әдәп-мазу белмәү; әдәпкә сыймау.

**ӘДӘП КИРТӘСЕНӘ СЫЮ.** Кеше арасында үзеңне әдәпле тота белү. *– «Чүкеч» журналының нашире һәм редакторы Тимерша Соловьёвның журналында әдәп киртәсенә сыймаган (бигрәк тә «Әлислах белән «Яшен»гә карата) язмаларга урын бирүенә ишарә* (gabdullatukay.ru).

Төрдәше: әдәп саклау; әдәпле тоту; әдәплелек әрҗәсенә утыру.

**ӘДӘП САКЛАУ.** Үзеңне гомум кабул ителгән нормалар кысасында тоту. *Нәҗип, әдәп саклап, әнисенең киңәшләрен тотып, исән калган, сирәгәйгән күрше-каршыларга, чыбык очы агай-энеләргә тиз-тиз кереп, сәлам алышып чыккалаган иде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Ләкин кетердәп торган бәрәңге белән тулы табаны өстәл өстенә китереп куюга (кая ул әдәп саклап тору), иң беренче булып калакка тотына* (В. Имамов. Күке).

Төрдәше: әдәп киртәсенә сыю һ.б.

**ӘДӘП ТАПТАУ** *к.* әдәп качу. *Чабатаң берлә, нинди мәнфәгать бар соң, әдәп таптап?* (Г. Тукай).

Төрдәше: әдәп качу һ.б.

*ӘДӘП-ИЗӘТ* ❖ **ӘДӘП-ИЗӘТ БЕЛМӘҮ** *иск.* Тәрбиясезлек, үзен тота белмәү. *Билгеле, әдәп-изәт белмәгән кешегә җәмгыятьтә уңай фикер тудыру авыр* (Сөйләм).

Төрдәше: әдәп качу һ.б.

*ӘДӘП-МАЗУ* ❖ **ӘДӘП-МАЗУ БЕЛМӘҮ** *к.* әдәп качу. *Әдәп-мазу белмәгән кыланчыкларның, сәхнәгә менеп, боргалану-сыргалланулары берничнди дә кызыксыну уятмый* (Сөйләм).

Төрдәше: әдәп качу һ.б.

*ӘДӘПКӘ* ❖ **ӘДӘПКӘ КИЛҮ (УТЫРУ).** Әдәплегә әйләнү, тәртипләнү, тәртипләргә буйсыну, инсафлану. *Икәүдән-икәү калгач, әдәпкә килеп,*

*бер-берләренең кадерен белеп кенә яшәргә иде дә бит* (Ф. Тарханова).

**ӘДӘПКӘ ӨЙРӘТҮ.** – *Сине, әти, әдәпкә өйрәтер өчен, ибтидаи мәктәпкә бирми ярамый,* – *диде* (Ф. Әмирхан. Фәтхулла хәзрәт). *Җыр текстларын тикшерәләр, үгет-нәсыйхәт бирәләр, әдәпкә өйрәтәләр* (К. Кәримов. Уен).

**ӘДӘПКӘ СЫЙМАУ.** Гомум кабул ителгән әхлак-әдәп кагыйдәләренә туры килмәү. *Шуның аркасында җавабы әдәпкә сыйса, табышмагы сыймый, яки табышмагы сыйса, җавабы мәҗлес түренә узмыйча төшеп кала* (Н. Исәнбәт. Татар хал. табышмаклары). *Университет ректоры Кремлев әфәнде икеләнә, фән йортына полиция кертү – әдәпкә сыймый, яманатыбыз бөтен Россиягә таралыр, ди* (Г. Әпсәләмов).

Төрдәше: әдәп качу һ.б.

*ӘДӘПЛЕ* ❖ **ӘДӘПЛЕ ТОТУ** *к.* әдәп киртәсенә сыю. *Ләкин син фатирга төшкәч тә, концерттан кайтып, ашап-эчеп утырган чакта да, үзеңне гаҗәеп тыйнак, әдәпле тота белдең* (Ә. Еники. Рәшә).

Төрдәше: әдәп киртәсенә сыю һ.б.

*ӘДӘПЛЕЛЕК* ❖ **ӘДӘПЛЕЛЕК ӘРҖӘСЕНӘ УТЫРУ** *к.* әдәп киртәсенә сыю. *Дөрес, соңгы вакытта әдәплелек әрҗәсенә утыра башлады* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).

Төрдәше: әдәп киртәсенә сыю һ.б.

*ӘДРӘС* ❖ **ӘДРӘС БИШМӘТ, ТЕЛӘСӘҢ НИШЛӘТ.** Таныш булмаган кешегә, киеменең шәплегенә карап, тулысынча буйсыну. – *Галимҗан абзый яхшы гына киенгән берәү белән китте, «әдрәс бишмәт, теләсәң нишләт» дип уйлагандыр, ахрысы* (Сөйләм).

*ӘЕМ* ❖ **ӘЕМ ЛӘ.** Нәрсәдәндер баш тартуны белдерә. *Менә ул чакта Шакир җизни... әем лә, ул чакта җизни түгел лә... шыпырт кына хат төртә иде* (Ә. Еники. Җиз кыңгырау).

*ӘҖӘК* ❖ **ӘҖӘК БЕЛӘН КҮҖӘК** *к.* Аг<ы>лый белән Таг<ы>лый <йөрү>. *Аларны бер-берсеннән аерып булмый, Әҗәк белән Күҗәк кебек йөриләр шунда* (Сөйләм).

Төрдәше: Аг<ы>лый белән Таг<ы>лый <йөрү> һ.б.

*ӘҖӘЛ* ❖ **ӘҖӘЛ АВЫЗЫННАН ТАРТЫП АЛУ.** Кешене үлемнән коткару. *Менә шулвакыт өметен сүндермичә, аны әҗәл авызыннан тартып ала белсәң, иң зур бәхет шунда* (Ш. Маннур. Һаман да истә).

**ӘҖӘЛ ДАРУЫ.** Бик сирәк булган, авыр табыла торган нәрсә турында. *Хәбәрсез җаннарны / Юксынсаң гаятьләр, / Әҗәл даруы икән / Сүрәләр, аятьләр* (Л. Шагыйрьҗан. Юк инде, юк алар...). *Кибетче апа: «Әҗәл даруы урынына», – дип кенә аның әнисенә шикәр үлчәп бирде* (Н. Гыйматдинова. Алан уртасында ялгыз йорт).

Төрдәше: әҗәлгә дару.

**ӘҖӘЛ ҖИТҮ (КИСЕЛҮ, ӨЗЕЛҮ).** Үләр вакыт җитү. – *Нәрсә дип кайнаткан булып суның тәмен бетерәләр икән, әҗәлең җиткән булса, теләсә нинди су эч – барыбер кәкрәерсең,* – *ди ул* (А. Алиш. Якты күл буе).

Төрдәше: аваздан җан чыгу һ.б.

**ӘҖӘЛ КОШЫ.** Үлем вакыты җиткәнен белдереп очып килгән кош (төрле кошлар булырга мөмкин). *Әҗәл кошы очып йөрде / Һәр сулышын аның санап* (Г. Садә. Көмеш йөзек).

**ӘҖӘЛ ТАГАРАГЫ.** Бик начар һәм ышанычсыз бәләкәй өй, көймә һ.б. – *Сез үзегезне берәр нәрсә беләм дип уйлыйсыз инде, әҗәл тагарагы!* (А. Гыйләҗев. Өч аршын җир). *Аның дулкыннары да башкача, безнең «әҗәл тагарагы»н йомычкадай уйната башлады* (Ш. Маннур).

**ӘҖӘЛ ТАРТУ.** Үлеменә сәбәпче булган берәр нәрсәгә омтылу. *«Әҗәлем, актык сулышым шушы икән, Мәскәүгә әҗәлем тартып китергән икән!»* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**ӘҖӘЛ ТАРТЫШЫ.** Үлем газабы. *Кеше берничә мәртәбә соңгы сулышын алгач, әҗәл тартышы башлана* (Сөйләм).

Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү).

**ӘҖӘЛ ТҮШӘГЕНДӘ.** Үлеме котылгысыз авыру турында. *Әҗәл түшәгендә яткан ана сихәтләнеп китте, аркасын ястыгына терәп утырып тора башлады* (Т. Мөбарәков. Гөл әни).

Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

**ӘҖӘЛ ХАСТАСЫ.** Үлемгә сәбәп булган авыру. *Икенчесенә әҗәл хастасы эләккән дә узган атнада гүр иясе булган* (Г. Бәширов).

**ӘҖӘЛ ЭЧЕНДӘ.** Әҗәле җитү, үлемгә дучар булу. *Әллә нинди сулар, үләннәр, яфраклар, тузлар җыйнаган да, әҗәл эчендә яткан агасын юып, бәйләп йөри* (Г. Ибраһимов).
Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

**ӘҖӘЛ ЯГАСЫНДА ТОРУ** *к.* әҗәл түшәгендә. – *Әҗәл ягасында торган кешене калдырып киттем дип, гомер буе вөҗдан газабы белән интегергәме?* (А. Гыйләҗев. Өч аршын җир).
Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

**ӘҖӘЛ ЯКАДАН ТОТУ** *к.* авыздан җаны чыгарга тору (җитешү). – *Әҗәлең якаңнан тотса, чүмечтәге суга батасың, дип юкка әйтмәгәннәр* (Г. Тавлин. Афәт).
Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

**ӘҖӘЛ ЯКАСЫНДА ЯТУ.** Үлем хәлендә булу. *Кайната әҗәл якасында ята* (А. Гыйләҗев).
Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

*ӘҖӘЛГӘ* ❖ **ӘҖӘЛГӘ ӘЙЛӘНҮ.** Рухи газап бирә торган хәл булу. *Боларның барысын да күтәп яту минем өчен әҗәлгә әйләнде* (Ш. Маннур. Агымсуларга карап).

**ӘҖӘЛГӘ ДАРУ** *к.* әҗәл даруы. *Әҗәлгә дару юк, диләр, / Мәхәббәткә бар микән?* (Җырдан). *Һәммәсе дә әҗәлгә дару юк, әйдә, үз урынында тыныч кына җан бирсен, борчымыйк, дип, карт турында бөтенләй онытткандай булдылар* (М. Галәү. Мөһаҗирләр).
Төрдәше: әҗәл даруы.

*ӘҖӘЛЕ* ❖ **ӘҖӘЛЕ ҖИТКӘНДЕР.** Үлеменә сәбәп, янәсе; «бу кеше үлеменә артык кайгырмагыз» мәгънәсендә. – *Мин каян белим! Йә карчыга типкәндер, йә әҗәле җиткәндер* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**ӘҖӘЛЕ ҖИТҮ** Үлем сәгате җитү. *Кырык ел кырылыш булса да, әҗәле җиткәннәр генә үлә, дигән...* (Х. Сарьян. Бер ананың биш улы).
Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

*ӘҖӘЛЕН* ❖ **ӘҖӘЛЕН АВЫЗЫНА ТЕШЛӘҮ.** Үлемнән курыкмыйча, тәвәккәлләп. *Өстенә чылатылган капчык япкан егет, әҗәлен авызына тешләп, ут эченә атлады* (Сөйләм).
Төрдәше: арыслан авызына керү һ.б.

*ӘҖӘЛЕТДИН* ❖ **ӘҖӘЛЕТДИН БАБАЙДАН ХӘБӘР КИЛҮ.** Үлеме якынлашу. – *Әҗәлетдин бабайдан хәбәр килде бугай? Һи! – дип куйды* (А. Гыйләҗев. Әтәч менгән читәнгә).
Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

*ӘҖӘЛЛЕК* ❖ **ӘҖӘЛЛЕК ТӘ ЮК.** Гомумән бернәрсәсе дә булмау. – *Синең әҗәллегең дә юк бит, сөйләшеп торган буласың. – Булмаса, әҗәткә биреп торырлар әле* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз ачса, кече теле күренү 2 һ.б.

*ӘҖӘЛНЕҢ* ❖ **ӘҖӘЛНЕҢ КҮЗЕНӘ БАРЫП КЕРҮ.** Яхшылап уйлап бетермичә, үзенең тормышын яки эшен куркыныч астына кую. *Имештер, мин бер дә кирәкмәскә әҗәлнең күзенә барып керәм* (Ф. Хөсни. Йөзек кашы).

*ӘҖӘЛСЕЗ* ❖ **ӘҖӘЛСЕЗ ҮЛҮ.** Җаны-тәне газаплanudан үзенә тәкъдирдә язылган гомерне яшәмичә үлеп китү. *Уфаларга бардың инде, / Нилӓрең алдың инде? / Янам инде, көям инде, / Әҗәлсез үләм инде* (Җыр).
Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

*ӘҖӘТЕМӘ* ❖ **ӘҖӘТЕМӘ ХАҖӘТЕМ БАР.** «Кирәге юк» мәгънәсендә. – *Юкны сөйләмәсеннәр, безнең ул малга бернинди ихтыяҗыбыз юк, бабаларыбыз «әҗәтемә хаҗәтем бар» диярләр иде* (Сөйләм).

*ӘҖӘТКӘ* ❖ **ӘҖӘТКӘ КЕРҮ.** Берәр кешедән бурычка акча яки башка нәрсә алып тору. *Җавап табарга аптырап, кешегә әҗәткә керми* (Ф. Хөсни).

*ӘҖӘТЛЕ* ❖ **ӘҖӘТЛЕ БУЛЫП КАЛМАУ.** Төрттереп әйтелгән сүзгә каршы авыз йомып калмыйча җавап бирү. *Хәер, Сәфәргали дә әҗәтле булып калмый* (Ф. Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы).

*ӘҖЕ-ГӨҖЕ* ❖ **ӘҖЕ-ГӨҖЕ АЙЛАРЫ.** Яшьләрнең өйләнешкәннән соң беренче айлары. – *Карале, кодагый, яшьләр әҗе-гөҗе айларын кайда үткәрәчәкләр?* (Сөйләм).
Төрдәше: ширбәт ае һ.б.

**ӘҖЕ-ГӨҖЕ КИЛҮ (ИТҮ).** 1. Кемнеңдер янында мәш килү. *Җиденче Рафаэль, халат итәге белән битен сөртә-сөртә, карчык тирәсендә әҗе-гөҗе килергә тотынды* (Г. Бәширов. Җидегән чишмә). – *Шулай итеп, Зөһрә белән кода һәм кодагый булып, әҗе-гөҗе килеп яшисе көннәр бар әле безнең* (Р. Төхфәтуллин. Авылдашым Нәби).

2. Гөж килү, кумәкләшеп әвәрә килү. *Һәрвакыт тезгә тез куешып утыралар да әҗе-гөҗе киләләр* (Г. Камал. Кайниш). *Ә ул, хыянәтче, сатлык, хаин, басурман татарлар белән әҗе-гөҗе килеп, сыгылып торган табын янында урысларны каргыйдыр әле* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).
Төрдәше: әпә-чәпә килү 2 һ.б.

*ӘҖЕМ* ❖ **ӘҖЕМ КАЗЫ.** Йөзә белмәгән кеше турында. *Су буенда яшәп, син ничек әҗем казы булып калдың соң?* (Сөйләм).

*ӘҖЕР* ❖ **ӘҖЕР АЛУ.** Каләм хакы, гонорар. *Беренчесендә шактый гына сумалы әҗер алгач, дуслары, иптәшләре белән шәпләп типтергәннәр иде* (Р. Батулла. Җинаять).

**ӘҖЕР БИРҮ (ТӨРТҮ)** *ирон., к.* авыз каплану 3. *Бик шәп урынга урнашкансың, күпме әҗерен төрттең?* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз каплану 3 һ.б.

*ӘҖЕРЕН* ❖ **ӘҖЕРЕН КАЙТАРУ.** Түләү, яхшылыкка яхшылык белән җавап бирү. – *Бу җөгәннәрнең әҗерен быелтыр гына кайтардылар,* – *диде кодасы, горурланып* (А. Хәлим. Читтә).

**ӘҖЕРЕН КҮРҮ.** 1. Бирεп торган әйбернең артыгы белән кире кайтуы; савап булу. *Күршем, җиләкләрен эшкәртергә дип, җиләк сыткычымны сорап торган иде, шуның әҗерен дә күрдем: сыткычым белән бергә бер литр тирәсе җиләк суы да кертте* (Сөйләм).
2. *җанлы с.* Тел ялы, гонорар. *Сораган язманы тиз генә әзерләп биргән идем, яхшы гына әҗерен дә күрдем* (Сөйләм).

*ӘҖНӘБИ* ❖ **ӘҖНӘБИ КЕШЕ** *иск.* Чит ил кешесе. *Әҗнәби, ягъни чит ил акчасы булган кешеләр өчен Берлинда тормыш арзан иде* (Г. Исхакый).

*ӘЗ* ❖ **ӘЗ ГЕНӘ** *к.* аз гына. *Барысын да алып китмәдем... Сакларга дип әзен генә алдым* (Н. Акмал. Күгәрчен сөте).
Төрдәше: аз гына һ.б.

**ӘЗ ГЕНӘ ДӘ.** Бөтенләй, һич. *Күп уйлап торырга вакыт юк иде, әз генә дә курыкмадым, аркылы ауган агач өстеннән инешнең икенче ярына чыктым* (Сөйләм).

**ӘЗ ДӘ ТҮГЕЛ, КҮП ТӘ ТҮГЕЛ.** Кирәгенчә генә, җитәрлек күләмдә (дәрәҗәдә). *Бер машина тутырып китергән таш әз дә түгел, күп тә түгел иде, юлның баткаклыкка әйләнә башлаган җиренә түшәргә җитте* (Сөйләм).

**ӘЗ ДИГӘНДӘ.** Ким дигәндә, иң азында. *Шушы туйларның һәрберсенә иң әз дигәндә 20 шәрмең сум туздырырга тиеш булсам да, күпме акча кирәгер иде* (Ш. Алпар. Милләт өмете). *Безнең борынгы бабаларыбызның кара урманнар уртасын килеп утырып «базу» җирләрне иген чәчә башлауларын күп дигәндә мең, әз дигәндә 200–300 ел үткәндер* (З. Мифтахов. Сүз хикмәте – тамырда).

**ӘЗ КУЕП, КҮП СОРАМАУ.** «Әз чыгымланып, күп табыш ала алмассың» мәгънәсендә. *Әз куеп, күп сорарга күнеккән Булат бу юлы да үзенә тиешле табышын арттырырга тырышты* (Сөйләм).

**ӘЗ СҮЗЛЕЛӘНҮ (СҮЗЛӘНҮ).** Күп сөйләшми торган булу. *Яшьли имгәнү Хәйдәрнең бөтен характерына билгеле бер эз салыр, ул үз эченә бикләнер, әз сүзләнер, йомылып калыр, дип уйларга мөмкин иде* (Р. Мостафин. Үз көең булсын).

*ӘЗДӘН* ❖ **ӘЗДӘН ГЕНӘ ЫЧКЫНДЫРМАУ.** Ялгыш сүз әйтүдән үз-үзен тотып калу. *Берсендә Нурсөя «ул ерткыч» дигәнең иркәләгәндә, аю кебек йомшара дип, әздән генә ычкындырмады* (Н. Гыйматдинова. Җәза).

*ӘЗЕР* ❖ **ӘЗЕР АШ.** Тамак туйдыру өчен берәрсе әзерләгән ризык. *Әзер аш, әзер чәй, тәһарәт алырга һәрвакыт җылы су булып, чалма, чапаннан, зур таяк тотып, биш вакытның һәммәсенә дә мәчеткә йөри торгандыр...* (Г. Ибраһимов. Көтүчеләр).

**ӘЗЕР БУЛУ (ТОРУ).** Әзерләнеп тору. *[Шәркан] (серле елмаеп). Ә хәзер әзер бул, сихерли башлыйм* (А. Гадел. Шайтан гына өметсез...). *Озын сөякчел бармаклары да, һичшиксез, кети-кети уйнарга әзер торырга тиеш...* (А. Тимергалин. Таш алиһә).

**ӘЗЕР КАБЕР ҮЛЕСЕ, ӘЗЕР ТУЙНЫҢ ТИЛЕСЕ** *ирон.* Әзергә генә яшәп, әзергә үләргә җыенган кеше. *Тормышында әллә ни мәшәкать күрмәде ул, танышлары әйтмешли, «әзер кабер үлесе, әзер туйның тилесе» булып яшәде* (Сөйләм).

*ӘЗЕРГӘ* ❖ **ӘЗЕРГӘ БӘЗЕР (ХӘЗЕР).** Әзерне генә эләктерергә карап йөрүче, ялкау. *Газинур әзергә хәзер булып тумады* (Г. Әпсәләмов. Газинур). *«Шулай, тәхетне эләктереп алу – әзергә – бәзер җигелгән арбага сикереп менү генә түгел ул, – дип уйлады сатлык Балак, эченнән генә каһкаһә белән көлеп»* (В. Имамов. Казан дастаны).
Төрдәше: аныкка танык <булу (булып тору)> һ.б.

**ӘЗЕРГӘ БӘЗЕР ЯШӘҮ** *к.* аныкка танык <булу (булып тору)>. – *Ату, әзергә бәзер яшәмәкче, ә! Тот капчыгыңны киңрәк!* (А. Вергазов. Үзеңә кайту). – *Әзергә бәзер яшәргә райком секретаре түгел лә син* (В. Имамов. Күке).
Төрдәше: аныкка танык <булу (булып тору)> һ.б.

**ӘЗЕРГӘ – ВӘЗИР.** Әзерләнгән нәрсәгә баш булу яки акыл биреп тору. *«Әзергә – вәзир» дигәндәй, Марат Мөлеков, Рәшит Ягъфәров, Рашат Сафин, Дамир Исхаков та монда* (З. Зәйнуллин. Ачлык мәйданы).

**ӘЗЕРГӘ ХӘЗЕР, ХӘЗЕРГӘ НАЗИР.** Әзерне генә эләктерергә, алып ашарга хәзер торучы кеше турында. – *Ник алай дисең, без әзергә хәзер, хәзергә назир булып утырырга гына тумаган, кулыбыздан эш килә әле* (Сөйләм).
Төрдәше: аныкка танык <булу (булып тору)> һ.б.

*ӘЗЕРЛӘП* ❖ **ӘЗЕРЛӘП КУЙГАННАР ДИ СИҢА.** Күпне өмет иткән кешегә карата әйтелә. – *Әзерләп куйганнар ди сиңа, тот капчыгыңны!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Әзерләп куйганнар ди сиңа монда сигарет!* (Ж. Юныс. Штаттан тыш).

*ӘЗИ* ❖ **ӘЗИ БЕРГЕНӘСЕ** *диал.* Иркә бала. – *Син генә инде әзи бергенәсе! Ярат әйдә!.. – дип, кул селтәп китеп барды* (Х. Сарьян. Башкорт кызы).

*ӘЗМӘВЕРДӘЙ* ❖ **ӘЗМӘВЕРДӘЙ ТАЗА** *к.* алып кадәр. *Әзмәвердәй таза солдатлар, һичнинди аяну-кызгану күрсәтмичә, хатын-кызын да, бала-чагасын да камчы белән ярды* (В. Имамов. Сәет батыр).
Төрдәше: алып кадәр һ.б.

*ӘЙ ДӨНЬЯСЫ* ❖ **ӘЙ ДӨНЬЯСЫ, КЫЕГАЙГАН МОРЖАСЫ.** Дөньяның бар җире дә камил түгел: бер ягы җитеш булса, икенче ягы җитешсез булуына пошыну. *Әй дөньясы, кыегайган моржасы. Тагын түбәдән су үткән бит* (Г. Зәйнашева).

*ӘЙ, ҖЕГЕТЛӘР* ❖ **ӘЙ, ҖЕГЕТЛӘР, КИБӘ <БИТ> ҖЕЛЕКЛӘР.** Бер эш белән мәшгуль булып, аннан тиз генә котыла алмаганда әйтелә. *Әй, җегетләр, кибә бит җелекләр, ятабыз шушында казынып!* (Сөйләм).

**ӘЙ, УҢГЫРЫ, БЕР БАШЫҢ МЕҢ БУЛГЫРЫ!** *теләк.* Берәр эшнең уңышлы барып чыгуын теләгәндә әйтелә. *Әй уңгыры, бер башың мең булгыры!* (Г. Ахунов).
Төрдәше: аягың җиңел булсын! һ.б.

*ӘЙБӘТ* ❖ **ӘЙБӘТ ЧАКТА.** 1. Ул-бу булганчы. *Синең белән хыялыйлар булып / Бетәрмендер гомер беткәнче. / Әйбәт чакта синнән китү кирәк, / Хыялыйлар булып киткәнче...* (С. Рәхмәтулла. Синең белән хыялыйлар булып).

2. Берәр нәрсә эшләгәнче, усаллыкка киткәнче. – *Кая керәсең, бар, чыгып кит тизрәк, абзаң әйбәт чакта!..* (Г. Гыйльманов. Мәче белән көчек).

*ӘЙБЕР* ❖ **ӘЙБЕР ӘЙТҮ.** Орышу, тиргәү. *Дуңгызны яратып бетермәгән авыл халкы Пауалның дуңгызына әйбер әйтми иде* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә). *Минем бу мавыгуларыма остам әллә ни әйбер әйтмәде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).
Төрдәше: акыл бизмәненә утырту һ.б.

**ӘЙБЕР КАГЫЛУ.** Кешегә чирләр җен-пәриләрдән, төрле ияләрдән килә дип уйлау. *«Кач манган су Тереклек суы дип йөртелә һәм барлык авырулардан, күз тиюдән, әйбер кагылудан имгә ярый», – диләр иде безгә әбиләр* (tuganaylar.ru).
Төрдәше: зәхмәт кагылу (сугу; тию).

**ӘЙБЕР ӨЧЕН (ЭЗЛӘП) КЕСӘГӘ КЕРМӘҮ** *к.* авызга җен төкерү. *«Мәмләкәтнең иң оста зәргәре исемен күтәрүе генә җитмәгән, телгә оста, кирәген әйтер өчен кесәгә керә торганнардан имәстер»* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).
Төрдәше: авызга җен төкерү һ.б.

*ӘЙБЕРГӘ* ❖ **ӘЙБЕРГӘ ТАБЫНУ.** 1. Тотемизм дип аталган борынгы дин. *Адәм баласы Тәңрегә табынмый – әйбергә табына, вөҗданга табынмый – әйбергә табына, туганлыкка табынмый – әйбергә табына, игелеккә табынмый – әйбергә табына* (Ф. Садриев. Бәхетсезләр бәхете).

2. Тормышта нинди булса да әйбергә (кыйммәтле машиналарга, затлы киемгә, алтын әйберләргә һ.б.) ия булуны тормыш максаты итеп яшәү. *Хәер, гел әйбергә табынган, тизлеккә һәм нәтиҗәгә буйсынган аулак уйларының һичбер кадере калмаган бу дөньяда бар микән соң ул якты сагыш дигән нәрсә?* («Сөембикә» ж.).

*ӘЙБЕРЛӘРНЕ* ❖ **ӘЙБЕРЛӘРНЕ ҮЗ ИСЕМЕ БЕЛӘН АТАУ.** 1. Исеме булган әйберне башкача атап, йә алдарга, йә бозарга тырышуга ишарә. – *Һәр нәрсәнең үз исеме бар. Шулай булгач, әйберне үз исеме белән атарга кирәк* (С. Рәфыйков. Тын елга буенда).

2. Үз фикереңне дә, уйларыңны да, йомшарта торган сүзләр эзләмичә, туп-туры әйтеп бирү. *Башкалар турында да аның уенда булганын яшерергә, рия һәм икейөзлеккә батып, буяулы гыйбарәләр кулланырга теләмәгәнлеге, һәр нәрсәне үз исеме белән атаганлыгы ачык күренә* (Иҗтиһад ишекләрен ачучы Мәрҗани: Җыентык).

*ӘЙДӘ-ШӘЙДӘ* ❖ **ӘЙДӘ-ШӘЙДӘ ТОРУ.** Икеләнеп тору, алаймы икән, болаймы икән дип шөбһәләнү. – *Нигә, кашларыңны җыерып, әйдә-шәйдә торасың, булганын әйт тә бир инде* (Сөйләм).

Төрдәше: әйле-шәйле булу (йөрү; килү; тору) 1; әйле-шәйле хәлдә; шик астына алу; шик төшү; шик корты кимерү; шик корты кузгалу; шик уяту; шиккә төшү; шөбһә астына алу; шөбһә күзе белән карау; шөбһәгә төшү.

*ӘЙДҮК* ❖ **ӘЙДҮК, КАРА ЧӘЙНҮК.** Даими рәвештә чәй эчәргә кергән кеше турында. – *Әйдүк, кара чәйнүк! – дип ирештерде аларны малай. Аннан, тауга менә башлагач, елмаеп, кулын болгады* (А. Хәлим. Кыйбла).

*ӘЙЕ* ❖ **ӘЙЕ БИТ.** Үз сүзен тыңлаучыдан раслатып, танык иттерү. *Һәм сез, хәзинә эзләүчеләр, Фарук хатлары чыкмасын дип, әбиегезнең астын өскә китердегез инде, әйе бит?* (А. Гыймадиев. Үзең булып кал!..). – *Монда киләләр, әйе бит, әтием!* (Г. Гобәй. Маякчы кызы).

Төрдәше: әйе диген.

**ӘЙЕ ДИГЕН** *к.* әйе бит. – *Әнә бүген җир кисү чутыннан приговор яздырдык, әйе диген…* (Ш. Камал. Матур туганда). *Булмаса да, әйе диген!* («Сабантуй» ж.).

Төрдәше: әйе бит.

**ӘЙЕ ДИП ТӘ, ЮК ДИП ТӘ <ӘЙТМӘҮ>.** Бер сүз дә дәшмәү, сорауга җавап бирмәү. *Ләкин кызык хәл: мин кызга әйе дип тә, юк дип тә әйтә алмадым* (Г. Әпсәләмов. Миңа унтугыз яшь иде).

**ӘЙЕ ШУЛ.** Әңгәмәгә кушылып, сүзне раслап тору. – *Әйе шул, бар җирем сызлый* (А. Алиш. Яңа килен). – *Әйе шул, ул миңа урманда карабодай коймагы ашаткан иде* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

Төрдәше: әйтсә <дә> юк (түгел); әйтеп торасы да юк; әйтергә дә юк (түгел); әйтерең бармы; әйтерлек тә түгел; әйтмә дә <инде>!

*ӘЙЕ-ӘЙЕ* ❖ **ӘЙЕ-ӘЙЕ ДИП ТОРУ** *к.* әйе шул. *Син дә анда идеңмени, әйе-әйе дип мөһер сугып торасың?* (Сөйләм).

*ӘЙЛӘНӘГӘ* ❖ **ӘЙЛӘНӘГӘ ЭЛӘГҮ.** Каршылыклар, төрле хәлләр катнаш вакыйгаларга карышып китү. *Мондый башка да килмәгән әйләнәгә эләгүемне белгән булсам, авылга кайтмаган да булыр идем* (Сөйләм).

*ӘЙЛӘНӘСЕ* ❖ **ӘЙЛӘНӘСЕН АТ ЧАБЫП УЗГЫСЫЗ.** Үтә зур һәм киң (әкиятчә тасвир итү). *Егет күзен ачса, алдында әйләнәсен ат чабып узгысыз зур кала тора, имеш* (Әкияттән).

*ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘЛИ* ❖ **ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘЛИ ЙӨРҮ.** Эшнең асылына якынлашмыйча, төрле сүзләр сөйләү; аның турында якынча гына сөйләү. – *Нәрсә инде анда боргалый-сыргалый әйләнә-тирәли йөрисең, яшереп торма, туп-туры сөйлә дә бир!* (Сөйләм).

Төрдәше: әйләнгечтән бару; әйләнгечтән юл туры; мәсьәләнең асылына төшеп җитмәү; тирә-юньдә йөрү.

*ӘЙЛӘНГӘЛӘП* ❖ **ӘЙЛӘНГӘЛӘП ЙӨРҮ**. Кирәк сүзне туры әйтмичә, якынча гына аңлату, буш сүзләр сөйләү. *Әле берсе, әле икенчесе берберенең кылын тарткалап әйләнгәләп йөргәч, Әлфит аны суырып алды* (Р. Кәрами. Кая чабасың, гомер юртагы?). *Иң аңлашылмаганы – Медведевның мөһим проблемалар тирәсендә әйләнгәләп йөрүе иде* («Безнең гәҗит» газ.).

*ӘЙЛӘНГӘН* ❖ **ӘЙЛӘНГӘН САЕН.** Һаман-һаман, кайта-кайта, кат-кат. *Әйләнгән саен минем янга йөгереп килмәсеннәр, ә сүзләре булса,*

*синең аркылы гына җиткерсеннәр* (Ә. Еники. Рәшә). *Әйләнгән саен югарырак күтәреләләр, өзлексез кычкыралар...* (Р. Кәрами. Олы юл да сикәлтәле).

*ӘЙЛӘНГЕЧ* ❖ **ӘЙЛӘНГЕЧ ЮЛ.** Туп-туры аңлатмыйча, читләтеп-читләтеп аңлату. *Журналның җаваплы сәркатибе Нил Юзиев мине чакырып алды да, шагыйрьне турыдан-туры акламыйча, әйләнгеч юл белән шундый хакыйкатьне төшендерде* (Н. Хисамов. Күңелдәге сурәт).

*ӘЙЛӘНГЕЧТӘН* ❖ **ӘЙЛӘНГЕЧТӘН БАРУ.** Туптуры әйтергә уңайсызланып, җай эзләп, төрле нәрсәләр турында сөйләшү. *Кызның нечкә күңелен җәрәхәтләүдән куркып, ул төрле нәрсәләр турында сөйләшкәләп, әйләнгечтән барып, төп сүзенә якынлашырга булды* (Сөйләм).

Төрдәше: әйләнә-тирәли йөрү һ.б.

**ӘЙЛӘНГЕЧТӘН ЮЛ ТУРЫ** *к.* әйләнә-тирәли йөрү. Уңышка ирешү өчен, кайвакыт туп-туры эш итү түгел, ә җайлап-җайлап, ашыкмыйча максатка баруның отышлы икәнлегенә ишарә. *Бабайлар: «Әйләнгечтән юл туры...» – дип яшәгәннәр. Ә җитәкчеләребез нәрсә ди: – «Юлның кыскасы...»* (К. Кәримов. Уен).

Төрдәше: әйләнә-тирәли йөрү һ.б.

*ӘЙЛӘНДЕР* ❖ **ӘЙЛӘНДЕР, КАЗ ЯНМАСЫН** *ирон.* «Боргалан, бер ялганнан икенче ялганга күчеп тор, ләкин тотылма» мәгънәсендә. – *Карчык, бар, өйгә кереп чык әле, әйләндер, каз янмасын* (Сөйләм).

*ӘЙЛӘНДЕРЕП* ❖ **ӘЙЛӘНДЕРЕП АЛУ.** 1. Төрле яклатып чолгап алу. *Ык суының терсәкләнеп аккан җирендә култыкланып кергән урынны киртә белән әйләндереп алдылар* (А. Алиш. Яңа килен).

Төрдәше: боҗралап алу, камап алу; сарып алу; сырып алу; чолгап алу.

2. Мавыктыру, үзен яраттыру, үзенә карату. *Әле алай гына да түгел: хикәя башында ук безнең башны әйләндереп алу һәм үзебезне үк көлкегә калдыру белән генә канәгать автор* <...> (М. Вәли-Барҗылы. Тормыш дулкыннары).

**ӘЙЛӘНДЕРЕП САЛУ.** 1. Аркасы белән егу. *Аркасына әйләндереп салдым, үзем калтырыйм* (Г. Галиева. Тулгак).

2. *гади с.* Ашау, төбенә кадәр эчеп кую. *Үз тустаганын әйләндереп салды да, кашык очына эләктереп кенә, берничә бавырсак капты* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

3. Җиңү, кирәгән бирү. *Алай булса, әйләндереп салабыз икән үзләрен, Мироныч, ә?* (Т. Гыйззәт).

*ӘЙЛӘНЕП* ❖ **ӘЙЛӘНЕП КАЙТУ (КИЛҮ).** 1. Һава сулап кайту; йөреп килү. *Менә шуннан соң гына Варифә апа яслегә барып әйләнеп кайтырга уйлады...* (А. Алиш. Яңа килен).

2. Бакчаны, урамны һ.б.ны йөреп килү. *Әллә соң урман тирәсен әйләнеп кайтыргамы?* (А. Тимергалин. Таш алиһә).

Төрдәше: йөреп кайту (керү; килү); урап кайту; ура-тып кайту (килү); һавада йөрү.

3. Чыгып киткән урынга кире кайту. *Әнисе: «Тиз генә әйләнеп кайт, аягыңның берсе монда, икенчесе тегендә булсын», – дип, кат-кат әйтеп чыгарды* (А. Әхмәтгалиева. Табыш). *Саркисян шул китүеннән өенә биш елдан соң гына әйләнеп кайтты* (А. Нәҗми. Азат).

4. Башланган сүзне яки мәсьәләне, сорауны хәл итүне бер арадан соң яңадан дәвам итү. *Торасың да шул бер сорауга әйләнеп кайтасың* (А. Әхмәтгалиева. Минем әтинең кызы). *Без алга таба бу мәсьәләгә дә әйләнеп кайтырбыз, ә хәзергә безне «Алла» төшенчәсенә иҗаби (позитив) карашлар кызыксындыра* (А. Тимергалин. Алла).

**ӘЙЛӘНЕП КАРАГЫСЫЗ.** Карарлык җире дә юк; ямьсез. *Әйләнеп карагысыз күрше хатыны белән бергә клубка таба киттеләр* (Сөйләм).

Төрдәше: битенә катык (каймак) сөртсәң, көчек яламас; катык сөртсәң (яксаң), эт яламас; катыкка манып, эткә ташласаң, эт тә ашамас (яламас); май ягып ташласаң, эт яламас; майга манып, эткә салсаң да яламас; майлап ташласаң, эт яламас; пәри алмаштырган нәрсә; пәри чыбыклаган; чибәрлеккә бик чибәр, күрсәң гайрәтең чигәр.

**ӘЙЛӘНЕП КАРАМАСТАН.** Бер нәрсәгә дә дикъкать итмичә, алга таба хәрәкәт итү. *Әле генә күз йомган арада булган вакыйгадан коты алынган Ихсанбай, артына әйләнеп карамастан, өенә ашыкты* (Т. Гарипова. Мөгри-мөгри килә Бөйрәкәй).

**ӘЙЛӘНЕП КАРАРГА <ДА> ӨЛГЕРМӘҮ** *к.* «а» дигәнче. *Кара мыек әйләнеп карарга өлгермәде, Хәйдәр аның якасыннан каптырып алды* (Т. Миңнуллин. Шикле кеше).
Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**ӘЙЛӘНЕП ТӘ КАРАМАУ.** Бар дип тә белмәү, илтифат итмәү; нәрсә эшләсәң дә, нәрсә сөйләсәң дә, дикъкать итмәү. *Әйләнеп тә карамаслар, / Тотса мәскәүләр якаң!* (Г. Тукай).
Төрдәше: исе дә китмәү; пошмас җан.

**ӘЙЛӘНЕП ТӨШҮ.** 1. Егылу. *Ләкин Хәйбулла аннан җитезрәк булып чыкты, ул, селтәнеп, автомат приклады белән маннергеймчының күкрәгенә бирде. Фин, чинап, әйләнеп төште* (Г. Әпсәләмов. Хәйбулла солдат).
2. Йогынтысына бирелү, җиңелү. *Болай булгач, иске дөнья төбе-тамыры белән әйләнеп төште дә өр-яңасы туды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**ӘЙЛӘНЕП ЧЫККАН.** Артыгы белән булган, исәбе-хисабы юк, муеннан булган. *Шулай уйласа, бу әйләнеп чыккан дивана* (Р. Батулла. Ирекдә чыгасы уйлар).

*ӘЙЛӘНЕР* ❖ **ӘЙЛӘНЕР УРЫН <ДА> ЮК** *к.* алма төшәр<лек> урын булмау (юк). – *Комбайнга түгел, тракторга да әйләнер урын юк ич анда* (Г. Әпсәләмов. Газинур). *Тоткыннар идәнгә чүгәләде: ни утырып, ни ятып булмый – әйләнер урын юк* (Р. Кәрами. Каргышлы этаплар).
Төрдәше: алма төшәр<лек> урын булмау (юк) һ.б.

*ӘЙЛӘНЕШТӘ* ❖ **ӘЙЛӘНЕШТӘ БУЛГАН.** Кулланылган, кабул ителгән. *Теплоходта Аурупа буйлап сәяхәткә чыгучылар арасында чит ил кешеләре дә байтак. Шуңадыр, өстәге палубада чит ил акчасы әйләнештә булган ресторан да хезмәт күрсәтә* (Р. Мирхәйдәров. Диңгез аша ялгыз).
Төрдәше: кулланылышта булган.

*ӘЙЛӘНЧЕК* ❖ **ӘЙЛӘНЧЕК САРЫК.** Берни дә аңлый алмыйча, каңгыраган кеше турында. *Күпме егетне әйләнчек сарык ясады Фәһимә, күпмесен тилмертте, газаплады, тик берсе дә истә түгел <…>* (Н. Гыйматдинова. Елан).

*ӘЙЛЕ-ШӘЙЛЕ* ❖ **ӘЙЛЕ-ШӘЙЛЕ БУЛУ (ЙӨРҮ; КИЛҮ; ТОРУ).** 1. Теләр-теләмәс, икелемикеле хәлдә булу. *Ләкин иренең еллыгы якынайган саен, эчтән кытыклап торган нәни генә бер шиге гел зурая барды, тора-бара күңеле әйле-шәйле үк килә башлады* (Г. Бәширов. Менә сиңа, мә!). – *Әйле-шәйле бер ел тордык микән, өге-җөге айлар узып та китте* (Г. Ахунов. Хуҗалар).
Төрдәше: әйдә-шәйдә тору һ.б.
2. Ике арада калу. *Мин шулай әйле-шәйле булып торган арада, Халисәгә сиздермичә генә, Зәкия, миңа каш сикертеп һәм биш бармагын күрсәтеп, «Була!» дигәнне аңлатты* (В. Нуруллин. Ике урам арасы).

**ӘЙЛЕ-ШӘЙЛЕ КЕШЕ.** Кирле-мырлы, сәер кеше. *Ударниклар тиз сизделәр әйле-шәйле кешене* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

**ӘЙЛЕ-ШӘЙЛЕ КҮРҮ.** Бигүк яхшы күрмәү. – *Күзләре әйле-шәйле генә күрә, колакка да каты* (Н. Гыйматдинова. Нурулла).

**ӘЙЛЕ-ШӘЙЛЕ СӨЙЛӘНҮ.** Тегеләй-болай, икеләнеп сөйләнү. *[Юаныч] Инде Хөсәен дә әйле-шәйле сөйләнә башлады!* (Р. Хәмид).

**ӘЙЛЕ-ШӘЙЛЕ ХӘЛДӘ** *к.* әйле-шәйле булу (килү; тору). *Атна-ун көн ул, яңгыратылган балык шикелле, әйле-шәйлерәк бер хәлдә йөрде* (Ә. Еники. Рәшә).
Төрдәше: әйдә-шәйдә тору һ.б.

*ӘЙРӘН* ❖ **ӘЙРӘН БАШ.** Башы буш, тиле, тинтәк. – *Урманга җибәрергә бер кеше кирәк иде, тик әйрән баш Җантаһир гына булмасын* (Сөйләм).
Төрдәше: алты-биш карама бүкәне һ.б.

*ӘЙТ* ❖ **ӘЙТ ДИГӘНДӘ ТӘЙТ.** Бик тиз булу. *Куян кебек, әйт дигәндә тәйт дип, атылып килеп чыкты шул...* (А. Гыйләҗев).
Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**ӘЙТ ДИГӘНЧЕ ТАЙТ.** Әйтү белән шундук әзер булу. *Аларны озак көтәсе юк, әйт дигәнче тайт итеп алдыңа килеп басалар* (Сөйләм).
Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

*ӘЙТӘ* ❖ **ӘЙТӘ КУЮ.** Кинәт кенә әйтү. *Сарыбай бераз кинаяле мәгънә белән әйтә куйды: – Бай үлде, сиңа тун белән чапан калды, күңелең һаман канәгать түгелме? – диде* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).

**ӘЙТӘ САЛУ** Сөйләүче үзе дә сизмәстән кирәксез сүз ычкындыру. *Уенын-чынын бергә кушып әйтә салды: – Театрның чабата үргәнен көтеп торып булмас...* (Р. Низами. Без яшибез...)
Төрдәше: авызга ни килсә, шуны кычкыру (сөйләү) һ.б.

*ӘЙТӘ-ӘЙТӘ* ❖ **ӘЙТӘ-ӘЙТӘ АҢЛАТУ** *к.* башына туку. *Бүрәнә башын ничек тотып торырга кирәклеген әйтә-әйтә аңлатты* (Сөйләм).
Төрдәше: башына туку.

*ӘЙТӘЛӘР* ❖ **ӘЙТӘЛӘР БИТ.** Сөйли торган фикерне ныгыту өчен, кемнәрнеңдер тәҗрибәсенә сылтау. *Әйтәләр бит сезгә, Кәчеләр кручниктә акчаны күп эшли, дип!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Әйтәләр бит: «Сылу кешегә солы капчыгы да килешә!»– дип, бу сүздә хата да, ялган да булмас* (Ф. Яхин. Сөекле ханымнар күрке).

**ӘЙТӘЛӘР СИҢА!** «Кабатлап әйтәм, ышанмыйсыңмы әллә» мәгънәсендә. *Әллә әйтәләр сиңа, әллә – юк...* (А. Вергазов. Үзеңә кайту). *Әйтәләр сиңа, карт дурман! Улың патша дошманы дип... Аңларга кирәк* (К. Нәҗми. Миңлебикә кодагыйның кайгысы).

*ӘЙТӘМ* ❖ **ӘЙТӘМ АНЫ <ҖИРЛЕ>.** Берәр фикерне куәтләү өчен кулланыла. *Әйтәм аны, әни бүген көне буе печәнлектә йомырка җыеп йөрде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Әйтәм җирле, әнкәң очраган саен мактана иде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: әйттем бит (ич) инде.

*ӘЙТӘСЕ* ❖ **ӘЙТӘСЕ <ДӘ> ЮК (ТҮГЕЛ)!** *ирон.* Сүз җөпләү (беленеп тора инде; күптән билгеле; бик дөрес сөйлисең һ.б.). *Әйтәсе юк, мәрхүм бик сабыр холыклы, чыдам кеше иде...* (Ә. Еники. Ана һәм бала). *Өй иске, анысын әйтәсе түгел, пычкыны да сатса сатсын, мать якасына, балалар ач утырмасын* (К. Кара. Күрше хакы).
Төрдәше: әйе шул һ.б.

*ӘЙТӘСЕН* ❖ **ӘЙТӘСЕН ӘЙТҮ.** Күңелендә тоткан сүзләрен ачык рәвештә йөзенә әйтү. – *Зарланасың килсә, анаңа барып зарлан, миңа түгел, мин әйтәсен әйттем!* (М. Хәбибуллин. Атилла). *Аның өстеннән тау төшкәндәй булды, – ул әйтәсен әйткән иде <...>* (Ф. Бәйрәмова. Күчем хан).

*ӘЙТӘСЕҢНЕ* ❖ **ӘЙТӘСЕҢНЕ ӘЙТЕП КАЛ.** «Әйтер сүзең булса, әйтеп кал» мәгънәсендә. *Әйтәсеңне әйтеп кал, күңелеңдә авыр йөк булып утырмасын* (Сөйләм).
Төрдәше: сөйләп кал әле.

*ӘЙТЕП* ❖ **ӘЙТЕП АДӘМ ЫШАНМАСЛЫК** *к.* адәм әйтеп, адәм ышанмас. *[Җамали] Читек балтырында кырык тугыз мең, диген, ә?! Әйтеп адәм ышанмаслык сүз* (Г. Камал. Банкрот).

**ӘЙТЕП ӘЙТКӘНДӘ КАЛСЫН.** «Монда әйткән монда калсын, кешегә таралмасын» мәгънәсендә әйтелә. – *Мин аны үзем хәл итеп бетерермен, башкалар белмәсә дә ярый – әйтеп әйткәндә калсын* (Сөйләм).
Төрдәше: әйткән әйткән җирендә калсын; әйткән әйткәндә калсын; әйткән урында калсын.

**ӘЙТЕП БЕТЕРГЕСЕЗ (БИРГЕСЕЗ).** Бик күп; бик тә; чиксез. *Ниндидер әйтеп биргесез үкенечле һәм татлы сагыну Хәлил йөрәген әрнетеп, телгәләп җибәрә иде* (Ә. Еники. Төнге тамчылар). *Сәлимнең күзләрендә яшь, йөзендә әйтеп бетергесез борчылу билгесе иде* (А. Расих. Очрашу).
Төрдәше: әйтергә дә түгел 2.

**ӘЙТЕП БУЛМЫЙ.** Нәрсә турындадыр катгый карарга килүне шик астына алу. *Кем йөзе, нәрсә йөзе булуын да әйтеп булмый, шатланамы ул, борчыламы – анысы да мәгълүм түгел* (Г. Гыйльманов. Битлек). *Ни дисең, акны кара дип әйтеп булмый* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**ӘЙТЕП ҖИБӘРҮ** *к.* авызга ни килсә, шуны кычкыру (сөйләү). *Кара-чураны сагынып яшәвен Шәмсегаян, теле белән әйтеп җибәреп, Мирвәлине шаккатырды* (А. Гыйләҗев. Өч аршын җир). ... *Акыллы киңәшне әйтеп җибәрү беркайчан да соң түгел* (Р. Гаязетдин. Тәүбә көче).
Төрдәше: авызга ни килсә, шуны кычкыру (сөйләү) һ.б.

**ӘЙТЕП КАЛДЫРУ.** Халыкта үлә торган кеше үзеннән соң кем үләчәген әйтеп калдыра дигән ышану бар. – *Карт кода кемгә генә әйтеп калдырды икән инде?* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

**ӘЙТЕП КАРАУ.** Нәрсә турында булса да уйфикерне белү өчен, төрле гамәлләр кылу. *Аптырагач, Сафуановны урамда туктатып:*

*«Без Мәмдүдә әбине Әлмәттә күрдек!» – дип әйтеп караган иде, тикшерүченең бер дә исе китмәде. «Күргәнсез икән шул!» – диде* (А. Тимергалин. Таш алиһә).

**ӘЙТЕП КУЮ.** 1. Уйламаганда телдән ычкындыру. – *Саф һавага... – дип, борын астыннан гына әйтеп куйды Рөстәм, гаепле кеше күк аклангандай* (А. Әхмәтгалиева. Кыргый).
Төрдәше: авыздан чыгару 2 һ.б.
2. Алдан кисәтеп кую. *Сабир аларга төнге уникеләрдә эшкә барырга тиешлекне әйтеп куйды* (А. Алиш. Якты күл буе).
Төрдәше: әйтеп узу (үтү).

**ӘЙТЕП МАКТАРЛЫК ТҮГЕЛ, САЛЫП ТАПТАРЛЫК ТҮГЕЛ.** Сокланырлык, шаккатырлык җире юк. *Тормышлары әйтеп мактарлык түгел, салып таптарлык түгел* («Шәһри Казан» газ.).
Төрдәше: әллә кем түгел; әллә ни (нәрсә) түгел; әллә нинди ... түгел; искитәрлек түгел; урта кул.

**ӘЙТЕП САЛУ (ТАШЛАУ).** Сөйләүче, үзе дә сизмәстән, кирәксез сүз ычкындыру. *Беркөнне ял көне иде, иренең гөлләргә су сибеп йөрүен күргәч, Шәмсегаян түзмәде, күңеле тулды һәм күптәннән тел очында кызышып йөргән сүзләрен әйтеп салды* (А. Гыйләҗев. Өч аршын җир). *Ачулары килү аркасында, кешеләрнең бердән һәммә белгәннәрен һәм уйлаганнарын әйтеп ташлау гадәтләре бар* (Ф. Яхин. Серле Камка).
Төрдәше: авыздан чыгару 2 һ.б.

**ӘЙТЕП ТОРАСЫ <ДА> ЮК** *к.* әйтәсе <дә> юк (түгел). *Әтинең кәефе күтәренке, минекен инде әйтеп торасы юк!* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы).
Төрдәше: әйе шул һ.б.

**ӘЙТЕП ТОРУ.** Күп тапкыр әйтү. «*Тукта әле, дим, минем протест ясап китүемә караганда, сүземне туктаусыз трибунадан әйтеп тору отышлырак түгелме икән, дим»* (Р. Фәйзуллин. «Таяныч ул – халык»).
Төрдәше: кат-кат әйтү.

**ӘЙТЕП УЗУ (ҮТҮ).** Искәртү, искә төшерү. *Гарәп һәм фарсы телләрнең тагын бер зур әһәмияте турында да әйтеп узу мөһим* (Ф. Галимуллин. Табигыйлеккә хилафлык). *Үткәннәргә, диләр, салават, / Зарын гына түгел, башкасын да / Әйтеп үтү кирәк, аралап* (М. Сәгъдиев).
Төрдәше: әйтеп кую.

**ӘЙТЕП ЫШАНМАССЫЗ.** Кеше ышанмаслык ят хәбәр, берәр хәл икәнен белдерү. *Әйтеп ышанмассыз, кая карама, безнең яшьләр: кыйммәте бер җәүһәр-байлыклар белән дә алмашынмый торган гөлдәй кызлар, уттай егетләр* (Н. Исәнбәт. Унсигезенче бер сәхифә).

*ӘЙТЕП-ӘЙТЕП* ❖ **ӘЙТЕП-ӘЙТЕП ТӘ.** Ничә (күпме) әйтсәң дә. *Әйтеп-әйтеп тә башыңа кермәс икән* (Сөйләм).

*ӘЙТЕП-СӨЙЛӘП* ❖ **ӘЙТЕП-СӨЙЛӘП БЕТЕРӘ (КИЛЕШТЕРӘ) ТОРГАН ТҮГЕЛ.** Нәрсәнеңдер бик күп булуына ишарә. *Күргәзмәгә куелган асылташларны әйтеп-сөйләп бетерә торган түгел иде* (Сөйләм).
Төрдәше: баштан ашу; баштан ташу (ташып китү); дөнья кадәр (чаклы) 2; дөнья хәтле 1.

*ӘЙТЕР* ❖ **ӘЙТЕР ИДЕМ.** «Ачуымнан әлләниләр әйтеп ташлармын, бу юлы әйтми торыйм әле» мәгънәсендә. *Әй-й, синең фәлсәфәңне әйтер идем, бер сүзеңне аңлап булмый* (Ә. Гадел. Безнең авыл Наполеоны). – *Әй картлач, синең тормышны да әйтер идем инде, чын эт көнендә яшисең бит* (А. Хәсәнов. Эт белән мәче төсле).

**ӘЙТЕР ИДЕМ БЕР СҮЗ – АВЫЗЫМ, СИН ТҮЗ.** Юк-бар белән бәйләнгән кешегә саллы гына итеп әйтергә теләгән сүзне әйтми калу. *Үзенең лыгырдавы белән шундый туйдырды бу кеше, эх, әйтер идем бер сүз – авызым, син түз* (Сөйләм).

**ӘЙТЕР ИДЕМ БЕР СҮЗ, АНЫСЫ ДА ЮНЬСЕЗ.** Әйтәсе сүзне әйтмичә генә, үзенең тискәре мөнәсәбәттә булуын белдерү. *Әйтер идем бер сүз, анысы да юньсез. Әйтер иде Рәсәйнең ярты халкы* («Безнең гәҗит» газ.).

**ӘЙТЕР СҮЗНЕ ӘЙТӘ АЛМАУ.** Ни сәбәптәндер әйтергә уйлаган сүз әйтелмичә калу. *Оялу идеме бу, куркумы – һич аңламады, әмма әйтер сүзен әйтә алмады* (М. Хәбибуллин. Илчегә үлем юк).
Төрдәше: әйтергә авыз бармау; әйтергә йөз (тел) бармау; сүзе тамакка утыру (утырып калу); сүзләре бугазына терәлеп калу.

*ӘЙТЕРГӘ* ❖ **ӘЙТЕРГӘ АВЫЗ БАРМАУ.** Берәрсеннән шөбһәләнү, нәрсәдер әйтер өчен кыюлык җитмәү, кыймау, яки әдәпсенмәү. – *Син дөрес сөйләмисең, алай түгел, менә болай ул, дип, сүзен кисмәкче идем, әйтергә авызым бармады* (Сөйләм).
Төрдәше: әйтер сүзне әйтә алмау һ.б.

**ӘЙТЕРГӘ <ГЕНӘ> АНСАТ.** Нәрсәнең дә булса кыенлыгын ассызыклау. – *Алырсың? – Әйтергә ансат. Кемнән, кайчан, күпме?* (Ә. Еники. Рәшә). *[Рәсүл] Әйтергә ансат, сөйләшеп кара. Мине бит монда беркем дә тулы акыллыга санамый...* (Г. Каюмов. Туу).
Төрдәше: әйтергә ансат <ла> ул; әйтергә <генә> җиңел; әйтүе ансат; әйтүе <генә> җиңел.

**ӘЙТЕРГӘ АНСАТ <ЛА> УЛ** *к.* әйтергә генә ансат. – *Яр буендагы талга тотынырсың. Әйтергә ансат ул* (Р. Вәлиев. Ай юрганы). *«Башла» дип әйтергә ансат ул! Ә нәрсәдән башларга?* (Ш. Рәкыйпов. Кипарислар җыры).
Төрдәше: әйтергә <генә> ансат һ.б.

**ӘЙТЕРГӘ <ГЕНӘ> ҖИҢЕЛ** *к.* әйтергә генә ансат. *Аз гына сөйсәң?.. Әйтергә җиңел!* (А. Гыйләҗев. Мөгаллимә). – *Сезгә әйтергә җиңел, ул курслар өчен бит кимендә мең сум акча түләргә кирәк* («Сөембикә» ж.).
Төрдәше: әйтергә <генә> ансат һ.б.

**ӘЙТЕРГӘ ДӘ ОЯТ.** Уңайсызлану. *Рус мәктәпләрендә укып күңел карала дигән сүзне сезгә әйтергә оят инде!* (Г. Исхакый. Ике йөз елдан соң инкыйраз). *Әйтергә оят, мөселман баласы була торып, мәчеттә үзеңне ничек тотарга икәнне белмә инде!* (З. Мәхмүди. Әче балан).

**ӘЙТЕРГӘ ЙӨЗ (ТЕЛ) БАРМАУ** *к.* әйтергә авыз бармау. *Әйтергә йөзем бармый дип, җыен яланаякны ашатып ятуы үзе бер җинаять!* (Һ. Такташ). *Яшь йөрәккә ут төшә, кан кайный, мәгәр танымады, кем дип сорарга кыймады, сүз әйтергә теле бармады...* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).
Төрдәше: әйтер сүзне әйтә алмау һ.б.

**ӘЙТЕРГӘ КИРӘК.** Сүзгә аеруча басым ясап әйтү. *Дөресен әйтергә кирәк, минем тәҗрибәсезлек тә, кышкы шартлар да – бары да безне җиңелүгә китерделәр* (А. Алиш. Якты күл буе). *Аннары шуны да әйтергә кирәк: ул бик оста бии, биюеннән дә остарак җырлый иде* (А. Шамов. Кыз урлау).

**ӘЙТЕРГӘ ТЕЛӘГӘН <СҮЗ> ТАМАКТА УТЫРЫП КАЛУ.** Нәрсә булса да әйтергә җыенып та әйтмичә калу. *Хәзер сүземне әйтермен дип уйлап утырганда, алдагы рәттә утырган Мәрьям апа, борылып, шундый итеп карады, әйтергә теләгәнем тамакта утырып калды* (Сөйләм).
Төрдәше: әйтергә теләгән сүз тел очында тору.

**ӘЙТЕРГӘ ТЕЛӘГӘН СҮЗ ТЕЛ ОЧЫНДА ТОРУ** *к.* әйтергә теләгән <сүз> тамакта утырып калу. *Болай да, тегеләй дә уйлап карадым, әйтергә теләгән сүз тел очында тора иде инде, янымдагы аркадашым чабудан тарткач, авызымны ачмаска булдым* (Сөйләм).
Төрдәше: әйтергә теләгән <сүз> тамакта утырып калу.

**ӘЙТЕРГӘ <ДӘ> ЮК (ТҮГЕЛ)** *к.* әйтәсе <дә> юк (түгел). *Шәп егет, әйтергә түгел!* (Ш. Камал). *Сүз әйтергә юк анысы, бу юлы көнаралаш хәл белергә килеп йөрде* (Ш. Алпар. Милләт өмете).
Төрдәше: әйе шул һ.б.

2. *к.* әйтеп бетергесез. *Бүлмә эче, әйтергә дә түгел, төрле төстәге тукымалар белән тулган иде* (Сөйләм).

**ӘЙТЕРГӘ ЯРАСА.** «Әгәр шулай дип әйтергә мөмкин булса» дигән мәгънәне күз уңында тотып, берәр сүзне (яки фикерне) йомшарту өчен, яисә аның бик үк төгәл булмавына ишарә ясау өчен кулланыла. *Исән калганнары да, әйтергә яраса, «ирек»кә асыл сыйфатларын җуйган хәлдә, гарипләнеп чыкты* (А. Тимергалин. «Инкыйраз»га йөз ел).

*ӘЙТЕРЕҢ* ❖ **ӘЙТЕРЕҢ БАРМЫ.** Сөйләүче белән тулысынча килешүне белдерә (шөбһәсез; әйе, билгеле). – *Абау, Ходаем, үтереп чыкса! – Әйтерең бармы!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). – *Әйтерең бармы, авызың-борының кыйшайтып, Мансур дус!* (Ә. Еники. Яз баласы).
Төрдәше: әйтәсе <дә> юк (түгел) һ.б.

*ӘЙТЕРЛЕК* ❖ **ӘЙТЕРЛЕК ҖИРЕН КАЛДЫРМАУ.** Тулысынча, төрле яктан сыйфатлап, тасвир итеп бирү. *Нурый әйтерлек җирен калдырмады, эттән алып эткә салып сүкте* (Г. Ибраһимов).

**ӘЙТЕРЛЕК НӘРСӘСЕ ЮК.** Бик үк яхшы (шәп) түгел. *Нәрсә дип әйтим инде, бер дә әйтерлек нәрсәсе юк шул* (Сөйләм).

**ӘЙТЕРЛЕК ТӘ ТҮГЕЛ.** Нәрсәнеңдер бик шәп яки бик начар икәнлеген белдерә. *Тегесенең куанып сайрауларын әйтерлек тә түгел инде* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). – *Әйтерлек тә түгел, мич авызы кадәр, диярсең!* (Ф. Яхин. Казан могҗизасы).

Төрдәше: әйтәсе <дә> юк (түгел); әйтмә дә <инде>! һ.б.

*ӘЙТКӘН* ❖ **ӘЙТКӘН ӘЙТКӘН ҖИРЕНДӘ КАЛСЫН** *к.* әйтеп әйткәндә калсын. *Беләм-беләм, безнең дәү әти дә «әйткән әйткән җирендә калсын» дип кабатлый иде* (Сөйләм).

Төрдәше: әйткән әйткәндә калсын һ.б.

**ӘЙТКӘН ӘЙТКӘНДӘ КАЛСЫН** *к.* әйтеп әйткәндә калсын. *Кеше алдында йөзеңә кызыллык китерәсең килмәсә, әйткән әйткәндә калсын* (Сөйләм).

Төрдәше: әйтеп әйткәндә калсын һ.б.

**ӘЙТКӘН – БЕТКӘН (БЕТТЕ)!** «Нинди дә булса мәсьәләгә, карарга кире кайтуның кирәге юк» мәгънәсендә; сүзне катгый итеп әйтү. *Әмма Рәдиф күп сөйләшеп тормады. – Әйткән – бетте!* (В. Нуруллин. Күпер чыкканда). *Ләкин үзсүзле Галимҗан уйларга да форсат бирми: – Шәкерт абзыкай! Әйткән-беткән, – дип кенә куя* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).

Төрдәше: әйткән икән – чапкан да өзгән; әйткән – кискән!; әйткән сүздән кайтмау; әйткәнем әйткән; әйтте – бетте; бер сүзне ике тапкыр сөйләмәү (әйтмәү; кабатламау); егет кеше ике сөйләшми; ике сөйләмәү; ике сөйләп тормау; кат-кат сөйләргә карчыклар түгел; сүзен бирмәү (бирәсе килмәү); татар ике сөйләмәс; үз белдеге белдек; үз бер тиене бер тиен; үз биш тиене биш тиен; үз бише биш; үз бүрәнәсен каезлау; үз җыруы җыру; үз кәкресе туры; үз киресен туку; үз киресенә бетү; үз кырыгы кырык; үз сиксәне сиксән; үз сүзе сүз; үз сүзен <сүз> итү; үз туксаны туксан, <кешенеке сиксән тугыз>; үз туксанын туглау (дәвам иттерү; туку); үз туксанын туксан итү; үз туксанында булу; үз чөен чөйләү; үзенекен итәргә тырышу; үзенекен каезлау; үзенекен куймау; үзенекен сукалау; үзенекен эшләү.

**ӘЙТКӘН<ЕМ> БУЛСЫН.** Нәрсәдәндер кисәтеп, тыеп әйтү. *Профессор җитдиләнеп китте: – Юк, Фатихәттәй, килсә, дә ишектән кертмә. Әйткән булсын!* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Менә әйткәнем булсын, әгәр исән калсам, бүтән эчмәс идем* (Г. Каюмов. Упкын өстендә уен).

**ӘЙТКӘН ДӘ ЮК ИНДЕ** *к.* әйтәсе дә юк. *Кул эшенә бик оста ул. Аш-суны әйткән дә юк инде* (К. Нәҗми).

Төрдәше: әйтәсе дә юк; сөйләмә дә инде.

**ӘЙТКӘН ИДЕ ДИЯРСЕҢ.** *Кайта безнең абыйлар, билләһи, кайта, менә әйткән иде диярсең! – дидем* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Кайта ул, үзе кайта, менә бу карт тиле әйткән иде диярсең* (И. Шиһапов. Үлмисең...).

**ӘЙТКӘН ИКӘН – ЧАПКАН ДА ӨЗГӘН** *к.* әйткән – беткән (бетте)! *Синең хәер-сәдакаңа калмаган мин. Белеп тор. Әйткән икән – чапкан да өзгән – бер атна срок сезгә!* (Б. Камалов).

Төрдәше: әйткән – беткән (бетте)! һ.б.

**ӘЙТКӘН – КИСКӘН!** *к.* аяк терәү. *Әйткән – кискән инде, нәрсә аны сорап аптыратасың* (Сөйләм).

Төрдәше: аяк терәү һ.б.

**ӘЙТКӘН СҮЗДӘ ТОРУ** *к.* айдыр менә. *Әткәйдән, ул колхоз рәисе иде, кешеләр белән аралашырга, әйткән сүздә торырга өйрәндем* (Р. Вәлиев. Дөнья гаме).

Төрдәше: айдыр менә һ.б.

**ӘЙТКӘН СҮЗДӘН КАЙТМАУ** *к.* айдыр менә. *Башкасын белмим, әмма ләкин әйткән сүзеннән кайтмый торган иде минем әти* (Ф. Хөсни. Йөзек кашы).

Төрдәше: айдыр менә һ.б.

**ӘЙТКӘН СҮЗДӘН ФАЙДАЛАНУ.** Бирелгән сүзне үтәргә мәҗбүр итү. *«Онытма, балаларың алдында сүз birдең» дип, аның әйткән сүзеннән бик оста файдаланган* (Сөйләм).

Төрдәше: бирелгән вәгъдәне бозуга юл куймау; сүз белән эләктерү; сүздән эләктерү.

**ӘЙТКӘН СҮЗЕ ДИЯРСЕҢ.** «Эшнең нәтиҗәсе мин кисәткәнчә булып чыгар» дип кисәтү.

*Кайтасы юлыңны уйламыйча, урманга барма – адашырсың. Ышанмасаң, әйткән сүзе диярсең* (Сөйләм).

Төрдәше: әйтте диярсез.

**ӘЙТКӘН СҮЗЕН ЭТ ҖИМӘС (ҖЫЙМАС)** *к.* авызындагын эт <тә> җимәс (ашамас). *Ә инде «Әйткән сүзен эт җыймас» дигәннәре аңа туры килә торгандыр* (Ш. Маннур).

Төрдәше: авызындагын эт <тә> җимәс (ашамас) һ.б.

**ӘЙТКӘН СҮЗНЕ КИРЕ АЛУ.** Сүзне уйлап әйтергә кирәклегенә ишарә. – *Әйткән сүзне кире алып булмый, килен, – диде саилче коры гына* (Н. Фәттах. Аклан). *Кайчакта әйткән сүзне кире аласы килгән чаклар да була* («Акчарлак» газ.).

**ӘЙТКӘН<ЕМ> УРЫНДА КАЛСЫН** *к.* әйтеп әйткәндә калсын. – *Бер генә үтенеч бар иде: бүген монда сөйләшкәннәр, әйткәннәр урында калсын иде* (Сөйләм).

Төрдәше: әйтеп әйткәндә калсын һ.б.

**ӘЙТКӘН – ЮЛДА, БИРГӘН – КУЛДА.** Әлегә нәтиҗәсе күренмәгән сүздән кулыңда нәрсәдер булу хәерлерәк. *Әйткән – юлда, биргән кулда* (К. Насыйри. Мәкаль һәм әйтемнәр). К. Насыйри «кулда булган байлык – көтәчәктән хәерле» дигән аңлатма бирә.

Төрдәше: һавадагы торна.

*ӘЙТКӘНДӘЙ* ❖ **ӘЙТКӘНДӘЙ БУЛМАГАЕ (БУЛМАСЫН) <ТАГЫН>.** «Берәр начарлык килеп чыкмасын» мәгънәсендә. – *Син як-ягыңа бераз каранып йөр, теге карт әйткәндәй булмагае* (Сөйләм).

*ӘЙТКӘНЕ* ❖ **ӘЙТКӘНЕ КИЛЕП, АТКАНЫ ТИЕП ТОРУ.** Һәр эше уңышлы, һәр сүзе урынлы булу. *И Ходаем, һәр сүзе дөрескә чыга бит, әйткәне килеп, атканы тиеп кенә тора* (Сөйләм).

*ӘЙТКӘНЕМ* ❖ **ӘЙТКӘНЕМ БУЛСЫН.** Берәр нәрсәдән кисәтү, тыю. *Алдан әйткәнем булсын, туй дип кенә ике кулыма ике сумкы тотып, көн-төн базар юлын таптар хәлем юк* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**ӘЙТКӘНЕМ ӘЙТКӘН** *к.* әйткән – беткән (бетте)! – *Әйткәнем әйткән, йә ризалык белән бир яки, валлаһи дип әйтәм, җәһәннәм тишегенә алып китәм!* (И. Салахов. Имәннәр тамыр җәйгәндә).

Төрдәше: әйткән – беткән (бетте)! һ.б.

*ӘЙТКӘНЕНӘ* ❖ **ӘЙТКӘНЕНӘ КҮНЕП, ӘЙДӘВЕНӘ ЙӨРЕП.** Башка кеше әйтүе, күрсәтүе буенча яшәү. *Инде күпме вакыт Мәскәүнең әйткәненә күнеп, әйдәвенә йөреп, Конституциябезне, законнарыбызны федераль закон белән тәңгәлләштерәбез* («Татарстан яшьләре» газ.).

Төрдәше: арка бөгү (бөгеп тору) 1 һ.б.

*ӘЙТКӘНЕНДӘ* ❖ **ӘЙТКӘНЕНДӘ ТОРУ** *к.* айдыр менә. *Ачлы-туклы елларда нинди олы сүз була ул, һәм әйткәнендә тора* (Т. Нәҗмиев. Сабаларда эчәр суым булгач...).

Төрдәше: айдыр менә һ.б.

*ӘЙТКӘНЕҢ* ❖ **ӘЙТКӘНЕҢ ФӘРЕШТӘНЕҢ «АМИН» ДИГӘНЕНӘ (ДИГӘН ВАКЫТЫНА / ЧАГЫНА) ТУРЫ КИЛСЕН.** – *Бирсен Ходай! Әйткәнең фәрештәнең «амин» дигәненә туры килсен!* (Ж. Рәхимов. Батырша).

*ӘЙТКӘННӘН* ❖ **ӘЙТКӘННӘН АВЫЗЫҢ (ТЕЛЕҢ) КАЛМАС <ИДЕ>.** Сүзне вакытында әйтмәгән, йомышны урынында үтәмәгән өчен шелтәләү. – *Нигә абыең кунакка кайтканын әйтмәдең инде, әйткәннән телең калмас иде* (Сөйләм).

*ӘЙТКӘННЕ* ❖ **ӘЙТКӘННЕ АҢЛАУ.** Киңәшләрне тыңлау. *Хәзер бик таламыйлар, / Намус, әдәп белмәгәннәр / Әйткәнне аңламыйлар* (В. Галиев. Бәхет таңым). *Кулын сузып, сабыйга үрелгән хатынны Сәвилә җилтерәтеп, урамга куып чыгарды: – Яхшылык белән әйткәнне аңламыйсың икән, апа. Бер айсыз күземә күренмә!* (Н. Гыйматдинова. Сихерче).

**ӘЙТКӘННЕ ТЫҢЛАУ, СӨЙЛӘГӘННЕ АҢЛАУ.** Кеше әйткәнгә, сөйләгәнгә дикъкать итмичә, үзенекен генә уйлаган кешене күздә тотып әйтелә. *Әйткәнне тыңлап, сөйләгәнне аңлап яшәмәгәч, ничек гомер итәргә уйлыйсың син?* (Сөйләм).

*ӘЙТМӘ* ❖ **ӘЙТМӘ <ДӘ> ИНДЕ!** *к.* әйтәсе дә юк. Сөйләүче фикере белән килешүне белдерә. – *Әйтмә инде, үз хатынына баш була алмаган кеше ничек Рәсәй тикле Рәсәйгә баш*

*була алсын* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). – *Ничек яшәп булыр берьялгыз... – Әйтмә инде...* (Н. Гамбәр. Яшәү тамыры).
Төрдәше: әйе шул һ.б.

**ӘЙТМӘ ДӘ, СӨЙЛӘМӘ ДӘ ИНДЕ** *к.* әйе шул. – *Бу кечкенә кыз да зур эт тотып йөргән була бит. – Әйтмә дә, сөйләмә дә инде* (Сөйләм).
Төрдәше: әйе шул.

*ӘЙТМӘГӘН* ❖ **ӘЙТМӘГӘН САЕН ТЕГЕ.** Берәүнең йомшаклыгыннан файдаланып, аны җәберләү яки булган-булмаган гаепләрне дә аңа тагу. *Әйе, тапканнар бер җүләрне! Әйтмәгән саен теге* (Н. Гыйматдинова. Җәза).

*ӘЙТМӘГӘНЕМ* ❖ **ӘЙТМӘГӘНЕМ <ГЕНӘ> БУЛСЫН.** Уңышлы барган эшкә шатлану начарлык китереп чыгармасын дип шикләнү. *Аннан күрмәкче башкалар да булдыралар, сөйлиләр, карчык, әйтмәгәнем генә булсын!* (Г. Бәширов). *Дөресен әйткәндә, башка калалар белән чагыштырганда, тфү-тфү, әйтмәгәнем булсын, тынычлык әлегә шәһәрдә* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).

*ӘЙТМӘЛЕ* ❖ **ӘЙТМӘЛЕ ДӘ КАЙТМАЛЫ.** Кызып китеп, теләсә нәрсә әйтеп ташлаучы һәм тиз кайтучы, үпкәләвен тиз онытучан кеше. – *Аның сүзләренә бик игътибар итмә, әйтмәле дә кайтмалы кеше ул, кызуы тиз сүрелә, тынычлангач сөйләшерсең* (Сөйләм).

*ӘЙТМӘСӘМ* ❖ **ӘЙТМӘСӘМ ДӘ БУЛМАДЫ**. Начар сүздән соң. – *Син, тишек баш, оныттың да мыни? Их, әйтмәсәм дә булмады* (Сөйләм).

*ӘЙТМИ* ❖ **ӘЙТМИ ДИГӘЧ ТӘ.** «Ачуымны китермә әле» мәгънәсендә. – *Кеше кебек кешеләр иде. Ике аяклы, ике куллы. Әйтми дигәч тә теге* (Н. Гыйматдинова. Җәза).

**ӘЙТМИ КАЛСАҢ, ЭЧЕҢ КҮБӘР ИДЕМЕ.** «Бик күп сөйлисең, сөйләми торсаң яхшырак булыр иде» мәгънәсендә. – *Сиңа кем кушкан сикереп торып сүз сорарга, әйтми калсаң, эчең күбәр идеме?* (Сөйләм).

*ӘЙТСӘ* ❖ **ӘЙТСӘ ӘЙТМӘСӘ.** Нәрсә әйтсәләр дә; әйтсә дә шулай, әйтмәсә дә шулай. *Чакырганнарын көтеп тормам, әйтсә әйтмәсә дә, үзем барып чыгармын* (Сөйләм).

**ӘЙТСӘ ДӘ ӘЙТТЕ!** Сүзне кистереп яки башкалар хәйран калырлык итеп әйтү. *Әнвәр абый әйтсә дә әйтте! Менә бу егет ичмасам!* (Сөйләм).
Төрдәше: менә бу әйтте!

*ӘЙТСӘМ* ❖ **ӘЙТСӘМ ӘЙТИМ.** Тыңлаучыларда кызыксыну уяту өчен басым ясау. *Әйтсәм әйтим, син белеп кал: / Чын атым – Былтыр минем* (Г. Тукай. Шүрәле). – *Әйтсәм әйтим, татарлар тарихы руслар тарихыннан күп тапкыр бай* (М. Хәбибуллин. Лев Гумилёв сабаклары).

**ӘЙТСӘМ – БЕЛМӘС, ДӘШСӘМ – КИЛМӘС.** Аңгыра, мокыт кеше турында. *Чакыруны кәгазьгә язып, малаена биреп җибәрим әле: үзенә әйтсәм – белмәс, дәшсәм – килмәс* (Сөйләм).

**ӘЙТСӘМ, ТЕЛЕМ КӨЯ (ӘЙЛӘНМИ), ӘЙТМӘСӘМ – ҖАНЫМ КӨЯ.** «Дәшми калырга ярамый» мәгънәсендә. *Бер акыллысы белән киңәшеп алмый булмас, булган вакыйганы барып әйтсәм, телем көя, әйтмәсәм – җаным көя* (Сөйләм).
Төрдәше: әйтсәм, хәтерең кала, әйтмәсәм – йөрәк яна.

**ӘЙТСӘМ, ХӘТЕРЕҢ КАЛА, ӘЙТМӘСӘМ – ЙӨРӘК ЯНА.** «Әйтсәм, үпкәләтермен, әйтмәсәм – йөрәк сызлаячак» мәгънәсендә. *Вакытында эшләгәнсең бит инде, утырып ял ит, дип әйтсәм, хәтерең калачак, әйтмәсәм – йөрәк яначак* (Сөйләм).
Төрдәше: әйтсәм, телем көя (әйләнми), әйтмәсәм – җаным көя.

*ӘЙТСӘҢ* ❖ **ӘЙТСӘҢ ДӘ ВАЙ, ӘЙТМӘСӘҢ ДӘ ВАЙ.** Алай эшләсәң дә ярамый, болай да ярамый. *Каян килгән мулла малае, әйтсәң дә вай, әйтмәсәң дә вай* (Сөйләм).

**ӘЙТСӘҢ ТҮЗӘРЛЕК, ТӨРТСӘҢ ТҮНӘРЛЕК.** Кырылырга (егылырга) әзер торган. *Бакчасы ярыйсы гына булса да, әйтсәң түзәрлек, төртсәң түнәрлек зур булмаган йорты бар* (Сөйләм).

*ӘЙТТЕ* ❖ **ӘЙТТЕ – БЕТТЕ** *к.* әйткән – беткән (бетте)! *Аныкы сукты да-күпте дә бит инде: әйтте – бетте* (З. Зәйнуллин. Каршы таулар).
Төрдәше: әйткән – беткән (бетте)! һ.б.

**ӘЙТТЕ ДИЯРСЕЗ.** Алдан хәбәр биреп әйтеп кую. *Бу хатын безне артка утыртып калдыра, әйтте диярсез* (Р. Габделхакова. Соңгы сорау). – *Әйтте диярсез, юкка гына түгел* (Н. Акмал. Тәнзиләкәй-Гөлкәй).
Төрдәше: әйткән сүзе диярсез һ.б.

*ӘЙТТЕМ* ❖ **ӘЙТТЕМ – БЕТТЕ, ИКЕ СӨЙЛӘШЕРГӘ ЯРАТМЫЙМ** *к.* әйткән – беткән (бетте)! *Әйттем – бетте, ике сөйләшергә яратмыйм* (Г. Сабитов. Әйттем – бетте).

**ӘЙТТЕМ – БЕТТЕ КЕБЕК СӨЙЛӘНҮ.** *Сәлимә, Гөлия кебек, җил иссә дә аварга торганга охшамаган, җиргә дә каты-каты басып йөри, уйлап-нитеп тормый, «әйттем – бетте» кебегрәк сөйләнә* (Л. Сабирова. Бәхете булсын, димәгән...).

**ӘЙТТЕМ БИТ (ИЧ) ИНДЕ** *к.* әйтәм аны (җирле). *Әйттем бит инде мин сезгә, бүтәнне яратмыйм, дип* (А. Шамов. Кыз урлау). *Югыйсә кайчан чын дөресен әйтәсең. «Җүләр сатма, яме. Әйттем ич инде – бүген синең көн түгел»* (Л. Шәех. Уңышсыз көн).
Төрдәше: әйтәм аны (җирле).

**ӘЙТТЕМ ИСӘ КАЙТТЫМ, <ӘЙТЕП КЕНӘ БАКТЫМ>.** Ялгыш әйткән сүзеннән кайту, кире алу; «үзегезчә эшләгез, мин катнашмаячакмын» мәгънәсендә. *Анысы шулай инде, шулай, – диде Таибә абыстай, тизрәк килешеп. – Әйттем исә кайттым, көенечкә генә була күрмәсен!* (Ә. Еники. Рәшә). *Закир абый, кулларын күтәреп: – Бетте, бетте! Әйттем исә кайттым, әйтеп кенә бактым! – диде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

*ӘЙТТЕҢ* ❖ **ӘЙТТЕҢ ДӘ, СОҢ ИНДЕ.** Әйткәнгә риза түгеллекне сәерсенеп белдерү. – *Мин сиңа «әйтмәдең» димим ич, әйттең, әйттең дә, соң инде* (Сөйләм).
Төрдәше: әйттең <бер> сүз; таптың сүз.

**ӘЙТТЕҢ НИ <ДӘ>, ӘЙТМӘДЕҢ НИ.** Әйтсәң дә, әйтмәсәң дә барыбер. – *Аңа әйттең ни дә, әйтмәдең ни. Кеше сүзенә колак салмый бит ул* (Ф. Абдуллин. Тормышка юл ярганда).
Төрдәше: аңа әйттең ни, стенадагы бүрәнәгә әйттең ни.

**ӘЙТТЕҢ <БЕР> СҮЗ** *к.* әйттең дә соң инде. *Әйттең сүз! Аларга нигә тагышып торырга, алар болай да бер-берсен бик күптән беләләр* (Ә. Еники. Җиз кыңгырау).
Төрдәше: әйттең дә, соң инде һ.б.

*ӘЙТТЕРЕРСЕҢ* ❖ **ӘЙТТЕРЕРСЕҢ ТАГЫН <ӘЛЛӘ НИ>.** Урынсыз карулашкан кешегә кисәтеп әйтелә. – *Син нәрсә, әйттерерсең тагын. Юк, дигәч, юк!* (Р. Галиуллин. Ялгызлык).

*ӘЙТҮЕ* ❖ **ӘЙТҮЕ АНСАТ.** Нинди булса да авыр эшне эшләү тәкъдименә җавап сүзе. – *Сиңа әйтүе ансат ул, миңа мондый йортка хуҗа булып алгач ни...* (Ә. Еники. Рәшә).
Төрдәше: әйтергә <генә> ансат һ.б.

**ӘЙТҮЕ <ГЕНӘ> ҖИҢЕЛ** *к.* әйтергә <генә> ансат. *Аз гына сөйсәң?.. Әйтергә җиңел!* (Г. Исхакый. Мөгаллимә). – *Сиңа әйтергә җиңел: өч көн кунак буласың да кайтып китәсең, Гөлбану каен сеңлеңне онытма!* (Г. Ибраһимов).
Төрдәше: әйтергә <генә> ансат һ.б.

*ӘЙТҮЕМ* ❖ **ӘЙТҮЕМ ХАК БУЛСЫН.** – *Болары – аның эше, минем дә әйтүем хак булсын* (М. Хуҗин. Билгесезлек чоңгылында).

**ӘЙТҮЕМ ШУШЫ.** Алдан кисәтеп кую; барысын да әйттем, башкасын көтмә. – *Әйтүем шушы, Сәкинә, алай-болай мин кайта алмасам, үлү хәбәре килсә дә, шул хәбәрдән соң бер елсыз кияүгә чыкма!* (В. Нуруллин. Күпер чыкканда).

*ӘЙШӘ-БАТМАН* ❖ **ӘЙШӘ-БАТМАН СӨЛЕГЕ.** Кеше җилкәсендә көн күрүчеләр турында. – *Син аның гәүдә-кыяфәтенә кызыкма, үзе Әйшә-Батман сөлеге булып, кеше җилкәсендә яши шунда* (Сөйләм).
Төрдәше: арка кимерү һ.б.

*ӘЙШӘ-ФАТЫЙМА (ПАТЫЙМА; БАТМА; БАТМАН)* ❖ **ӘЙШӘ-ФАТЫЙМА (ПАТЫЙМА; БАТМА; БАТМАН) КУЛЫ (СҮЗЕ).** Им-томчылар телендә «изге кул» мәгънәсендә йөри. *Әйшә-Патыйма кулы – гади кул түгел, «изгеләр кулы», «ярдәме тия торган кул» мәгънәсендә. Имче карчыклар шул сүзләрне әйтә торган булганнар* (Г. Ильяси. Бичара кыз). *Көндез уйна, кич йокла, / Бәхетле бул, тәүфикълы бул, / Әйшә-Батман (Гайшә-Фатыйма) куллары – / Име-йомы шул булсын* («Фәнни Татарстан» ж., 2014, 1).
Төрдәше: Әйшә-Патыйма кулы, минем кулым түгел; минем кулым түгел, Әйшә-Патима кулы; минем

кулым (сүзем; телем) түгел, Әйшә-Фатыйма (Әйшә-Батман) кулы (сүзе; теле).

**ӘЙШӘ-ПАТЫЙМА КУЛЫ, МИНЕМ КУЛЫМ ТҮГЕЛ** *к.* Әйшә-Фатыйма (Патыйма; Батма; Батман) кулы (сүзе). *[Сәхибә] Әйшә-Патыйма кулы, минем кулым түгел* (Г. Ильяси. Бичара кыз).

Төрдәше: Әйшә-Фатыйма (Патыйма; Батма; Батман) кулы (сүзе) һ.б.

*ӘКӘЛӘ(И)ЛЕ* ❖ **ӘКӘЛӘ(И)ЛЕ ИМӘН АВУ.** Байлык яисә күтәрелмәгән бәхет килү. *Әкәләле имән ауган, дип әйтимме, тавыгыгыз алтын күкәй салган дип үк җибәримме, мәгәр үзең дә чамаларсың, төтенең йөрми түгел, йөри, җиде тулы класс белемең бар* (А. Гыйләҗев. Язгы кәрваннар). – *Әкәләле имән авачак икән моның өстенә, – дип уйлап, әни сүзләрен исемә төшерәм* (Ф. Җамалетдинова. Кояшлы келәмнәр).

*ӘКӘМӘТ* ❖ **ӘКӘМӘТ КАПЧЫГЫ (ТӨЕНЧЕГЕ).** Төрле сәер эшләр эшләп, хикмәт корып йөрүче кеше. *Авылга фольклор җыючы студентлар килгән, әкәмәт капчыгы Хәбри янына җибәрик әле үзләрен* (Сөйләм).

**ӘКӘМӘТ КЕШЕ.** Үз-үзенең тотышы белән башкаларда сәерлек тудырган кеше. *Харисовның гаҗәп әкәмәт кеше булуы яз башлангач тагын да көчәя* (Г. Толымбай. Ослан манаралары). *Афзалов Бакировны шундый әкәмәт кеше дип белми иде* (Ф. Садриев. Ялгышны төзәтү).

**ӘКӘМӘТ КЫЛАНЫШ.** 1. Боргаланыш, боргалану-сыргалану. *Шугалакка килгәннәрнең күбесе саргылт киемдәге бу кызның әкәмәт кыланышларын кызыксынып карый иде* (Сөйләм).

2. Сәерлек, мәзәклек. *Балалар цирктагы артистның әкәмәт кыланышларыннан эчләрен тотып көлделәр* (Сөйләм).

**ӘКӘМӘТ НӘРСӘ (ӘЙБЕР).** Сәер әйбер (эш). – *Теге, әкәмәт нәрсә турында да әйтегез инде, – дип, Гайфуллинга мөрәҗәгать итте ул* (А. Гыймадиев. Үзең булып кал!..). – *Шунда тагы бер әкәмәт нәрсә булып алды* (Р. Сибат. Кайту).

*ӘКӘМӘТКӘ* ❖ **ӘКӘМӘТКӘ КАЛУ.** Көлке бер хәлгә төшү. *Күлне ике бүрәнәдән сал ясап кичмәкче иде, әкәмәткә калды* (Сөйләм).

*ӘКӘМ-ТӨКӘМ* ❖ **ӘКӘМ-ТӨКӘМ ЙӨРЕШЕ.** Бик озак һәм бик әкрен (гадәттә, тизрәк эшләнергә тиешле эш-хәрәкәт турында). *Мондый әкәм-төкәм йөреше белән барсаң, кичкә дә кайтып җитә алмабыз* (Сөйләм).

*ӘКЕЛЕ* ❖ **ӘКЕЛЕ ДӘ КҮКЕЛЕ** *к.* Аг<ы>лый белән Таг<ы>лый <йөрү>. *Алар китапханәгә дә әкеле дә күкеле йөрергә күнеккәннәр* (Сөйләм).

Төрдәше: Аг<ы>лый белән Таг<ы>лый <йөрү>һ.б.

*ӘКЕШ-МӘКЕШ* ❖ **ӘКЕШ-МӘКЕШ КИЛЕП ЙӨРЕШҮ.** Уртак сүз яки бирәр эш булса да, булмаса да бер-береңә барып, сөйләшкәләп утыру. *Күрәм: кызлары, кияүләре белән дә әкеш-мәкеш килеп йөрешүне туктатты бу* (М. Мәһдиев. Ачы тәҗрибә авазы).

*ӘКИЯТ* ❖ **ӘКИЯТ КАПЧЫГЫ.** Бик күп әкиятләр белгән яки кеше ышанмаслык нәрсәләр сөйләүче турында. – *Син инде ул әкият капчыгы, – диде Гаяз, – китапны синнән күп укыган кеше юк монда* (Л. Ихсанова. Яна торган ташлар). – *Башта мин чит дөнья вәкилләре белән элемтә урнаштырам, аларның тавышын тотып алырдай үтә нечкә җиһаз уйлап табам. – Хи-хи, әкият капчыгы син!* (Н. Гыйматдинова. Син түгел бу, син түгел...).

**ӘКИЯТ САТУ.** Юк-барны сөйләү, булмастайны чынга алып сөйләү. *Каравылдан кайткач, шешенгәнче йоклый да торып ашаганнан соң, пожарныйлар янына килеп әкият сата, тәмәке пыскыта* (В. Нуруллин. Күпер чыкканда).

Төрдәше: авыздан куык очыру һ.б.

**ӘКИЯТ СӨЙЛӘҮ.** Булмаган нәрсәләрне сөйләү. *[Әхмәди] Син, Тугдык җиңги, әкият сөйләмә әле!* (Г. Исхакый. Алдым-бирдем). *[Нуретдин] Хәзрәт, эш вакытында әкият сөйләмик* (К. Тинчурин. Җилкәнсезләр).

Төрдәше: авыздан куык очыру һ.б.

**ӘКИЯТ ТӘ ХИКӘЯТ КЕБЕК.** Әкияттәге кебек (ят хәлләр, сәер эшләр турында). *Яшьләр, бер остаханәдә җыелып, әллә нәрсәләр эшлиләр, валлаһи, әкият тә хикәят кебек* (Сөйләм).

*ӘЛӘ* ❖ **ӘЛӘ ДӘ ТҮГЕЛ, ФӘЛӘ ДӘ ТҮГЕЛ.** Барыбер, һич аермасы юк. *Нургали белән Ходайкол угълан мәҗлес башында ук исереп бетте: аларга дөнья хәзер әлә дә түгел, фәлә дә*

*түгел – ике дөнья бер моржа, моржа саен бер маржа иде* (Р. Батулла. Сөембикә).
Төрдәше: авыз<ы>-борын<ы> кыйшаймау һ.б.

**ӘЛӘ-ЛӘ-ЛӘ ӘЙТТЕРҮ.** Берәр җирне авырттырганда чыгарган авазлар. *«Әлә-лә-лә»не әйттерә иде ул зәһәр чыбыркы!..* (Ә. Еники. Тынычлану).

*ӘЛӘК<ЧЕ>* ❖ **ӘЛӘК<ЧЕ> КАПЧЫГЫ, <ТӘМӘКЕ ЯНЧЫГЫ>.** Әләкләп йөрүче кеше. – *Әһә, әнә кем әләкләгән икән! Әләк капчыгы!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Әләкчегә хезмәт хакы? Әләкче капчыгы, әләкчеләр иле* («Татарстан яшьләре» газ.).

*ӘЛӘМ* ❖ **ӘЛӘМ ЧИГҮ** *к.* аһ ору. Кайгы кичерү; хәсрәт, җәфа кичерү. *Төрле яктан басмаса гамь, / Һичбер кеше чикмәс әләм. / Хәлем язам тотып каләм, / Бән егъламый кем егъласын* (М. Гафури).
Төрдәше: аһ ору һ.б.

*ӘЛБӘ* ❖ **ӘЛБӘ АШАДЫҢМЫ ӘЛЛӘ?** «Тәмле әйбер ашап, телеңне йоттыңмы әллә?» мәгънәсендә. *Нигә дәшмисең, әлбә ашадыңмы әллә?* (Сөйләм).

**ӘЛБӘ БЕЛӘН КӘБЕСТӘ.** «Нәрсә?» дигән сорауга шаяртып җавап бирү. – *Бүген киного барабызмы? – Нәрсә? – Әлбә белән кәбестә!* (Сөйләм).

**ӘЛБӘ ТАТУ.** Мәшәкать күрмичә, яхшы гына яшәү. *Биш ел «Әлки әлбәсен» татыганнан соң, язмыш Питрәч районына юнәлтә* (К. Сәгъдәтшин. Сыналган бәхет).

*ӘЛВИДАГ* ❖ **ӘЛВИДАГ ӘЙТҮ.** Хушлашу, ураза аен тәмамлаганда, биегрәк урынга (манарага, багана башына һ.б.) менеп, көйләп шигырь әйтү йоласы. *Шәмәк мәдрәсәсендә минем, малайларга кушылып, әлвидаг әйткәнем бар* <...> (Ш. Маннур).

*ӘЛЕ* ❖ **ӘЛЕ АЛАЙ, ӘЛЕ БОЛАЙ.** 1. Тотрыксыз, аумакай кеше турында. *Әле алай, әле болай сөйләнгән кешене бездә бормакай дип йөртәләр* (Сөйләм).
Төрдәше: әле болай, әле тегедәй 1; әле тегеләй, әле болай 1.

2. Төрлечә, төрле рәвештә. *Йөзен кара сакалмыек баскан рум базаргань, юан симез куллары белән аларның билләреннән, беләкләреннән тотты, әле алай, әле болай боргалап, ханга аларны яхшырак карарга булышты, тегесен-монысын әйтеп торды* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).

**ӘЛЕ АНДА, ӘЛЕ МОНДА.** Төрле урыннарга (урыннарда). *Сал өстендә кызу, ашыгыч хәрәкәт, әле анда, әле монда йөгерү башланды* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар). *Ә шул биек, юан таллар арасында әле анда, әле монда төрле зурлыктагы киез итекләр бастырып куелган* (Р. Кәрами. Каргышлы этаплар).

**ӘЛЕ АРТЫНА, ӘЛЕ АЛДЫНА ТӨШҮ (ЧЫГУ).** Ялагайлану, ярарга тырышу. *Әти белән әни аның әле артына, әле алдына төшеп, өрмәгән җиргә генә утыртмадылар* (Г. Ахунов. Чикләвек төше).

**ӘЛЕ БАШТАН.** Шушы яшьтән, хәзердән үк. *Билгеле, әле баштан аны монда, Казанда күрермен дип өмет итмәгән иде ул* (Н. Фәттах). *Әле баштан, Ходай биргән берсен табам, дип торган башбаштак кыздан ни көтәсе?!* («Сөембикә» ж.).

**ӘЛЕ БОЛАЙ, ӘЛЕ ТЕГЕЛӘЙ** *к.* әле алай, әле болай 1, 2. *Йокы Илсөяргә әле болай, әле тегеләй һөҗүм итте – күзен йомдырды, иснәтте, ниһаять, кызны җиңде* (Г. Гобәй. Маякчы кызы). *Бер үк фикерне әле болай, әле тегеләй әйләндерә...* (Р. Рахман. Һәр сыйныфта – сочинение).
Төрдәше: әле алай, әле болай 1, 2 һ.б.

**ӘЛЕ БУ БИТ УЕНЫ, ШУННАН СОҢ БУЛЫР ДУЕНЫ** *к.* анысы әле баласы <-чагасы>, мичтә ята анасы. *Авырлыклар артта калды дип шатланма, әле бу бит уены, шуннан соң булыр дуены* (Сөйләм).
Төрдәше: анысы әле баласы <-чагасы>, мичтә ята анасы һ.б.

**ӘЛЕ БУСЫ БАЛАСЫ, <МИЧТӘ КАЛГАН АНАСЫ>** *к.* анысы әле баласы <-чагасы>, мичтә ята анасы. *Болар – әзерлек төркеменә йөрүче спортчылар гына, әле бусы баласы, мичтә калган анасы дигәндәй, көчлерәкләре соңыннан чыгачаклар* (Сөйләм).
Төрдәше: анысы әле баласы <-чагасы>, мичтә ята анасы һ.б.

**ӘЛЕ БУСЫ БАЛАСЫ, МИЧ БАШЫНДА АТАСЫ** *к.* анысы әле баласы <-чагасы>, мичтә ята анасы. *Әле бусы баласы – атасы мич башында дигәндәй, Хуҗа Насретдин, тфү, Тәлгат Нәҗмиев Мөнир әфәнде белән «Керик әле Саба урманнарына» дигән <…>* (Ф. Яруллин).

Төрдәше: анысы әле баласы <-чагасы>, мичтә ята анасы һ.б.

**ӘЛЕ <ДӘ> БУЛСА**. Бүгенге көнгә кадәр. *Әле дә булса Газим ил белән, ул – борынгы бер карт, борынгы* (С. Хәким. Газим үрендә). *Балтыйк буендагы Новгород каласы әле булса кенәзсез-хакимсез көенчә яшәп ята икән* (В. Имамов. Казан дастаны).

**ӘЛЕ ГЕНӘ.** 1. Күптән түгел генә. *Мин әле генә каладан кайттым* (Р. Ишморат).

2. Ниндидер вакыйганың, хәл-хәрәкәтнең алдында булган. *Айсылу әле генә капка төбендә утыра иде, кая киткәнен күрмәдеңме?* (Сөйләм).

**ӘЛЕ ГЕНӘ БОЛАЙ, УЛ <ДА> ТҮГЕЛ – ТЕГЕЛӘЙ.** *Нәрсә эшләргә тели ул – аңламассың, әле генә болай, ул да түгел – тегеләй* (Сөйләм).

Төрдәше: кырыкмаса кырык төргә керү; минутына кырык төрле акыл (фикер).

**ӘЛЕ ГЕНӘ ЭНӘДӘН ТӨШКӘН КИЕМ КИЮ.** Килешеп торган өр-яңа кием кию. *Клубтагы кызларның күз явын алып, әле генә энәдән төшкән кием киеп килгән иде* (Сөйләм).

**ӘЛЕ ДӘ.** Шушы вакытка кадәр, моңарчы. *Әле дә кичә соң кайтып, / Йоклаган кырын ятып* (М. Җәлил. Хәдичә).

Төрдәше: әлегә кадәр; моңа кадәр (хәтле; чаклы).

**ӘЛЕ ҖИТМӘСӘ.** Моңарчы бәян ителгән хәбәргә яңа мәгълүмат өстәлгәндә кулланыла. *Әле җитмәсә теге, узган-барганда төрткәләп, шапылдаткалап кала, шуңа һич ачуланмый. Ул һәр кичне иң алдан килеп, иң соңыннан китә, әле җитмәсә, көндезләрен дә яртышар көн утырып чыккалый торган иде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**ӘЛЕ КИЧӘ ГЕНӘ.** «Якын көннәрдә, бәлкем, кичәдер» мәгънәсендә. – *Син әйбәт инде, бик, башыңа менеп атлансалар да, өнең чыкмый. Кичә генә институт бетергән бер чебеш урыныңны алды* (Ә. Мохтар. Тап).

**ӘЛЕ НИЧЕК БАР!** Бик мөһим эш барлыгы турында. *Ә әйтерем бар иде бит, / Әле ничек бар иде!* (К. Булатова. Апага).

**ӘЛЕ СИҢА КУЯН ИТЕ <БОЗАУ ИТЕ>, ЯРАМАГАН КАЗ ИТЕ.** Вакчыл кешенең биргән сыйфатлы әйбергә дә риза булмыйча, башкасын таләп итүе. *Әле сиңа куян ите, ярамаган каз ите* (Н. Исәнбәт. Балалар фольклоры).

**ӘЛЕ ТЕГЕ, ӘЛЕ БУ**. Төрле нәрсә турында; төрле-төрле. *Алар, юлда әле теге, әле бу турыда сөйләшкәләп, яки минутлар буена ләм-мим сөйләшмичә, тын гына бардылар* (Ф. Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы).

**ӘЛЕ ТЕГЕЛӘЙ, ӘЛЕ БОЛАЙ** *к.* әле алай, әле болай. *Корбангали абзый, гадәттә, әле тегеләй, әле болай дигән булып, бераз кыстатырга, шуның белән эшенең бәясен күтәрергә өйрәнгән хәйләкәр төлке булса да, бу тел хатынының үзләренә ясаган дәгъвасын искә алып һәм шуның янына тагын бичараның мөлдерәп карап торуына һич тә каршылык күрсәтә алмыйча, бик кыска тотты* (Ф. Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы).

Төрдәше: әле алай, әле болай һ.б.

**ӘЛЕ <ДӘ> ЯРЫЙ, <ШӨКЕР>.** Сөйләүченең канәгатьләнү хисен белдерә: ичмасам, шунысы ярый. – *Мин китәргә уйлаган идем, әле ярый рәтләгәнсез, – дип, бераз тынычланып куйды* (А. Алиш. Якты күл буе). *Әле дә ярый акча үлчәм түгел... Әҗ(е)ре җитмәс аңа бурычлының* (Р. Рахмани. Табу һәм табу).

*ӘЛЕГӘ* ❖ **ӘЛЕГӘ КАДӘР** *к.* әле дә. *Вокзалны да мин әлегә кадәр һичбер күргәнем юк иде* (А. Алиш. Тимер юл).

Төрдәше: әле дә һ.б.

*ӘЛЕГЕ* ❖ **ӘЛЕГЕ ДӘ БАЯГЫ.** Һаман да шул, электәгечә (алда әйтелгәнне яки яхшы билгеле бер нәрсәне телгә алганда кулланыла) – *Әлеге дә баягы, көнчелек ашый адәм баласын* (Ә. Еники. Җиз кыңгырау). *Ике көннең берендә, таң сызылуга, тәрәзә төбендә кем дисең – әлеге дә баягы Мөбарәкша* (Г. Ахунов. Чикләвек төше).

Төрдәше: әлеге дә баягы, Әлдермешләр таягы; әлеге дә баягы, башыңа кисәү таягы; әлеге дә баягы,

баягы шайтан таягы; әлеге дә баягы гадәт; әлеге дә баягы, Галимә җиңги таягы; әлеге дә баягы каенатайның (каенатаң) таягы; әлеге дә баягы, кара сыер аягы; әлеге дә баягы, кәкре шайтан таягы; әлеге дә баягы, Мәһди бабаң таягы; әлеге дә баягы, нужа (Әндри) бабай таягы; әлеге дә баягы, сукыр суфи (ишан хәзрәт) таягы; әлеге дә баягы, шул бер каен таягы; әлеге дә баягы, шул болгаткыч таягы.

**ӘЛЕГЕ ДӘ БАЯГЫ, ӘЛДЕРМЕШЛӘР ТАЯГЫ** *к.* әлеге дә баягы. *Әлеге дә баягы, Әлдермешләр таягы дигәндәй, ишек төбендә бая гына килеп киткән Мансур тора иде* (Сөйләм).
Төрдәше: әлеге дә баягы һ.б.

**ӘЛЕГЕ ДӘ БАЯГЫ, БАШЫҢА КИСӘҮ ТАЯГЫ** *к.* әлеге дә баягы. *Әлеге дә баягы – башыңа кисәү таягы дигән шикелле, сүз бик тиз кызлар тирәсендә әйләнә башлады* (Г. Мөхәммәтшин. Йөрәктәге эзләр).
Төрдәше: әлеге дә баягы һ.б.

**ӘЛЕГЕ ДӘ БАЯГЫ, БАЯГЫ ШАЙТАН ТАЯГЫ** *к.* әлеге дә баягы. *Әлеге дә баягы, баягы шайтан таягы димичә, нәрсә дисең инде – бу юлы машинаның арт көпчәге тишелгән иде* (Сөйләм).
Төрдәше: әлеге дә баягы һ.б.

**ӘЛЕГЕ ДӘ БАЯГЫ ГАДӘТ** *к.* әлеге дә баягы. *Ләкин әлеге дә баягы каударлану гадәтем кайчак мине авыр хәлләрдә калдыра* (А. Расих. Ишан оныгы).
Төрдәше: әлеге дә баягы һ.б.

**ӘЛЕГЕ ДӘ БАЯГЫ, ГАЛИМӘ ҖИҢГИ ТАЯГЫ** *к.* әлеге дә баягы. *Әлеге дә баягы, Галимә җиңги таягы инде, алып торган иттарткычны кертеп чык әле – үземә кирәк* (Сөйләм).
Төрдәше: әлеге дә баягы һ.б.

**ӘЛЕГЕ ДӘ БАЯГЫ, КАЕНАТАЙНЫҢ (КАЕНАТАҢ) ТАЯГЫ** *к.* әлеге дә баягы. *Әлеге дә баягы, каенатайның таягы дигәндәй сөйләшергә ярамый, язык була* (К. Латыйп).
Төрдәше: әлеге дә баягы һ.б.

**ӘЛЕГЕ ДӘ БАЯГЫ, КАРА СЫЕР АЯГЫ** *к.* әлеге дә баягы. – *Әлеге дә баягы, кара сыер аягы инде, бораy биреп тор әле* (Сөйләм).
Төрдәше: әлеге дә баягы һ.б.

**ӘЛЕГЕ ДӘ БАЯГЫ, КӘКРЕ ШАЙТАН ТАЯГЫ** *к.* әлеге дә баягы. – *Әлеге дә баягы, кәкре шайтан таягы, түбән оч Касыйм килә бугай, мине сораса, урманга китте, диген* (Сөйләм).
Төрдәше: әлеге дә баягы һ.б.

**ӘЛЕГЕ ДӘ БАЯГЫ, МӘНДИ БАБАЙ ТАЯГЫ** *к.* әлеге дә баягы. *Туйдырдылар инде, әлеге дә баягы, Мәнди бабай таягы булды бу: тагын җыелышка чакырып кеше җибәргәннәр* (Сөйләм).
Төрдәше: әлеге дә баягы һ.б.

**ӘЛЕГЕ ДӘ БАЯГЫ, НУЖА <ӘНДРИ> БАБАЙ ТАЯГЫ** *к.* әлеге дә баягы. *Минем әти әйтмешли, әлеге дә баягы, нужа Әндри бабай таягы, ярдәм сорап кердем әле: баскычның басмасы сынган, синеке төзектер* (Сөйләм).
Төрдәше: әлеге дә баягы һ.б.

**ӘЛЕГЕ ДӘ БАЯГЫ, СУКЫР СУФИ (ИШАН ХӘЗРӘТ) ТАЯГЫ** *к.* әлеге дә баягы. *[Әсрар] «Әлеге дә баягы, ишан хәзрәт таягы» дигәндәй... минем сиңа гозер дисәм дә, үтенеч дисәм дә...* (Ю. Әминов. Кан кардәшләр).
Төрдәше: әлеге дә баягы һ.б.

**ӘЛЕГЕ ДӘ БАЯГЫ, ШУЛ БЕР КАЕН ТАЯГЫ** *к.* әлеге дә баягы. *Әлеге дә баягы, шул бер каен таягы инде, күрше авылга барып кайтырга велосипедыңны биреп тор әле* (Сөйләм).
Төрдәше: әлеге дә баягы һ.б.

**ӘЛЕГЕ ДӘ БАЯГЫ, ШУЛ БОЛГАТКЫЧ ТАЯГЫ** *к.* әлеге дә баягы. *Әлеге дә баягы, шул болгаткыч таягы, әниеңә телефоннан шалтыраттыңмы әле?*(Сөйләм).
Төрдәше: әлеге дә баягы һ.б.

*ӘЛЕПКӘ* ❖ **ӘЛЕПКӘ БАР, БИГӘ ЮК.** «Бер якка булса, икенче якка юк» мәгънәсендә (элекке замандагы иҗек сабагыннан калган). *Әлепкә бар, бигә юк, / Абзыкайлар өйдә юк, / Тычкан төшкән тәбегә* (Такмак).

*ӘЛЕПНЕ* ❖ **ӘЛЕПНЕ ТАЯК, ВАУНЫ ЧУКМАР ДИП ТӘ БЕЛМӘҮ** *к.* әлифне (әлепне; әлефне) таяк дип <тә> белмәү 1, 2. – *Әлифне таяк дип, вауны чукмар дип белми икән – минем өчен ул бернәрсә дә түгел* (Г. Ибраһимов. Яшь йөрәкләр).
Төрдәше: әлифне (әлепне; әлефне) таяк дип <тә> белмәү 1, 2 һ.б.

*ӘЛҖЕ-МӘЛҖЕ* ❖ **ӘЛҖЕ-МӘЛҖЕ (МӨЛҖЕ) КИЛҮ.** Күзләр томанланып китү. ...*Мөгаллимнең тез буыннары йомшый, күзләре әлҗе-мөлҗе килә* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Хаҗәтнең күзләре әлҗе-мәлҗе килгән, әмма сиздермәгән, «безнең авыл монда кайчан килеп утырган, белмисеңме?» дип сораштыруын дәвам иткән* (Р. Зәйдулла. Ак эт).

**ӘЛҖЕ-МӘЛҖЕ КИТЕРҮ.** Нәрсәнеңдер төрле хисләр уятуы, дулкынландыруы. – *Алар клубка йөрми шул, – ихластан уфтанды Байсар егете, – килгән көннәрендә искитмәле концерт биреп, безнең күңелләрне әлҗе-мөлҗе китерделәр дә хәзер күзгә дә күренмиләр* (Җ. Дәрзаман. Җир авазы).

*ӘЛИЛӘШЕП* ❖ **ӘЛИЛӘШЕП ТОРУ.** Назланышу, иркәләнешү. *Кояш баегач та, алар капка төбендә әлиләшеп тордылар* (Сөйләм).

*ӘЛИФ* ❖ **ӘЛИФ (ӘЛЕФ) ЙОТКАН** *мыск.* 1. Уклау йоткан кебек, гәүдәне туры тотып йөрү. *Шәһәр егете, әлиф йоткан кебек, гәүдәсенең төзлеген саклабрак, урам буйлап китте* (Сөйләм).

2. Алфавитны кулланып, укый-яза белү, укымышлы булу. *Әлеф йоткан тилмермәс* (Мәкаль).

**ӘЛИФ ЯТКЫРУ.** Аякларын суздырып, тезеп, туры яткыру. *[Камали] Улларыгызны, кызларыгызны барысын да әлиф яткырырга да, үзегезне аркылы салып, сабан чыбыркысы белән арт сабакларыгызны укытырга* (Ф. Бурнаш. Камали карт).

**ӘЛИФ ЯТУ.** Аякны сузып, бөгәрләнмичә, туп-туры яту. *Әлиф яткач, урын киңәйде, теге алты малай да арага сыйды* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Аяк астыңда нибары юка палас кына йә бишмәт чабуы гына икәнлеге дә, урын тарлыктан аякларыңны сузып, «әлиф» ятуың да онытыла* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

*ӘЛИФБАДАЙ* ❖ **ӘЛИФБАДАЙ АЧЫК.** Һәр кешегә бала чагыннан ук билгеле булган нәрсә. *Атның тәне чиста булсын өчен, аны атна саен кашавыч белән тазартырга кирәклеге авыл малайларына әлифбадай ачык нәрсә* (Сөйләм).

*ӘЛИФ-БИДӘН* ❖ **ӘЛИФ-БИДӘН БАШЛАУ.** Иң гади нәрсәләрдән башлау. *Гармунда тиз генә өйрәнеп булмый ул, иң әүвәле әлиф-бидән башлыйлар* (Сөйләм).

Төрдәше: «а», «б» дан башлау һ.б.

*ӘЛИФНЕ* ❖ **ӘЛИФНЕ (ӘЛЕПНЕ; ӘЛЕФНЕ) ТАЯК ДИП <ТӘ> БЕЛМӘҮ.** 1. Бөтенләй бернәрсә дә белмәү, аңламау һ.б.; наданлык. *[Мәхүп] – Укыган, улым, укыган, бик зур укыган (халыкка карап). Әлифне таяк дип тә белми...* (Г. Камал. Бүләк өчен). – *Әлифне таяк дип белми. Атасының байлыгы белән ни кыйласың...* (Г. Ибраһимов. Яшь йөрәкләр).

2. Укый-яза белмәү. *Ни дисәң дә, шәкерт шәкерт инде ул, әлифне таяк дип белмәгән күчәнбаш надан малай түгел!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Үзе бертуктаусыз колакка тукый (безнең әти әлепне таяк дип белми, ләкин китап сүзләре кыстырып сөйләргә ярата, аны саваплы эш күрә)* (Г. Гобәй. Без үскәндә).

Төрдәше: ак-кара танымау һ.б. (ике маддә өчен дә).

**ӘЛИФНЕ ТАЯК, ВАУНЫ ЧУКМАР ДИП ТӘ БЕЛМӘҮ** *к.* ак-кара танымау. – *Аның турында уйлама да, әлифне таяк, вауны чукмар дип тә белми ул* (Сөйләм).

**ӘЛИФНЕ ТАЯК ДИП БЕЛҮ.** Хәреф тану, бераз укый белү. *Нигә алай дисең, әлифне таяк дип белә инде ул* (Сөйләм).

Төрдәше: кара тану.

**ӘЛИФНЕ ТАЯКТАН АЕРМАУ** *к.* әлифне (әлепне; әлефне) таяк дип <тә> белмәү 1, 2. *Ислах әлифне таяктан аермагангa күрә, моннан рәт чыкмаячак, дип, мәктәптән куып чыгарылгач, балигъ булып, яше тулгач, колхоз фермасына маллар карарга, сыер асты чистартырга керде* (Д. Салихов. Чукрак).

Төрдәше: әлифне (әлепне; әлефне) таяк дип <тә> белмәү 1, 2.

*ӘЛИФТӘН* ❖ **ӘЛИФТӘН БАШЛАУ.** Берәр эшне башлангыч мәгълүматлардан башлау. *Кыскасы, минем студиячеләр югалып калмады. Шунысына игътибар итәсем килә: болар барысы да миндә әлифтән башлана* (Р. Вәлиев. Җанга уелган уйлар). *Уразаев тамашачысыннан канәгать булмаган актер кебек сүрелә төште. – Сиңа әлифтән башларга кирәк. Зур уең бар икән, хәзердән үк тотын* (М. Галиев. Ул чакта).

Төрдәше: «а», «б»дан башлау һ.б.

*ӘЛКИ* ❖ **ӘЛКИ ТӨЛКЕСЕ.** Бик хәйләкәр кеше турында. – *Ә-ә-ә, кара син нинди хәйләкәр! Әлки төлкесе!* (Г. Мөхәммәтшин. Йөрәктәге эзләр).

*ӘЛЛӘ* ❖ **ӘЛЛӘ БАЛТА БҮКӘН ЯРА, ӘЛЛӘ БҮКӘН БАЛТА ЙОТА.** Булырмы, юкмы – әлегә билгесез. *Аңлашылмый бу минутта: / Әллә балта бүкән яра, / Әллә бүкән балта йота... / Түтәсенә ята балта...* (Р. Харис. Карама яру).

Төрдәше: әллә балта сына, әллә түмәр ярыла; әллә каеш өзелә, әллә юкә өзелә.

**ӘЛЛӘ БАЛТА СЫНА, ӘЛЛӘ ТҮМӘР ЯРЫЛА** *к.* әллә балта бүкән яра, әллә бүкән балта йота. *Бар көченә кизәнеп, алдында утырган агачка авыр балтасы белән китереп сукты – әллә балта сына, әллә түмәр ярыла* (Сөйләм).

Төрдәше: әллә балта бүкән яра, әллә бүкән балта йота һ.б.

**ӘЛЛӘ БАР ГОМЕР, ӘЛЛӘ ЮК ГОМЕР.** Сине алда ни көткәне билгесез. *Ишетеп кал. Әллә бар гомер, әллә юк, дигәндәй, белеп тор!* (А. Гыйләҗев). *Минем дә әллә бар гомер, әллә юк гомер, быел исән чакта Җиңү көнендә Илекәйгә барып кайтабыз микән дигән уй бар иде барын* (Т. Гарипова. Илекәй).

Төрдәше: әллә бар дөнья, әллә юк дөнья.

**ӘЛЛӘ БАР ДӨНЬЯ, ӘЛЛӘ ЮК ДӨНЬЯ** *к.* әллә бар гомер, әллә юк гомер. *Ярмөхәммәт белән Рәйсәгә әллә бар дөнья, әллә юк дөнья* (Р. Батулла. Юл буенда зәңгәр чәчәк).

Төрдәше: әллә бар гомер, әллә юк гомер.

**ӘЛЛӘ ГАЙБӘТ, ӘЛЛӘ ЧЫН.** Дөрестерме, юктырмы – анысы билгесез. *Әллә гайбәт, әллә чын, Камалый фатирында әнгелчән киндереннән тукылып, ике башы да тамбурлап чигелгән зур бер сөлге күргәннәр* (К. Нәҗми).

**ӘЛЛӘ КАЕШ ӨЗЕЛӘ, ӘЛЛӘ ЮКӘ ӨЗЕЛӘ** *к.* әллә балта бүкән яра, әллә бүкән балта йота. *Ә бәлкем, хәзер килешкәндер, картлар әйтмешли, кем белә бит әле, әллә юкә өзелә, әллә каеш* (М. Хәбибуллин. Илчегә үлем юк). – *Кем белгән, Зөбәер, әллә каеш өзелә, әллә юкә өзелә* («Сөембикә» ж.).

Төрдәше: әллә балта бүкән яра, әллә бүкән балта йота һ.б.

**ӘЛЛӘ КАЙ.** 1. Билгеле булмаган, кайсыдыр. *Дөрес, йөрәгемнең әллә кай почмагында сиңа карата хисем бар иде әле* (Г. Кутуй. Тапшырылмаган хатлар). *Әллә кай төшләре бәрелде, әллә кай төштәге сөякләр җылынып китте* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).

2. Кайсы, бөтен. *Зөлфия авылның әллә кай якларын белә* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).

**ӘЛЛӘ КАЙДА.** Билгесез җирдә. *Җан Гали исә кыз куенына кердсе төнне дә әллә кайда йөри...* (Р. Батулла. Сөембикә).

**ӘЛЛӘ КАЙДА <ЕРАКТА> ТҮГЕЛ.** Якында гына, ерак барырга кирәкми. *Безнең йорт әллә кайда түгел, якында гына, җәяү дә барып җитәрбез* (Сөйләм).

Төрдәше: ерак барасы түгел.

**ӘЛЛӘ КАЙДАГЫ.** Кайдадыр билгесез җирдәге. *Әллә кайдагы ул «туган туфрак» дигән нәрсә аңа билгесез, ят иде, шуңа күрә бабасының сүзләре аңарда бернинди теләк тә, кызыксыну да уятмый иде* (Ә. Еники. Кем җырлады?). *Кинәт урман эче яп-якты булып яктырды, әллә кайдагы агачларга хәтле күренде* (И. Гази. Ай юлы).

**ӘЛЛӘ КАЙДАН.** Билгесез урыннан, кайдандыр, белмәгән җирдән. *Әллә кайдан чыгып, аның янын бер-ике мөселман сырып алды* (Г. Исхакый. Өйгә таба). *Әллә кайдан гына килеп чыкты да, туп-туры өстемә сикереп, битемне ялап та алды* (Р. Төхфәтуллин. Җиләкле аланнар).

**ӘЛЛӘ КАЙДАН УК.** Бик ерактан. *Хәзер ул, әллә кайдан ук авызын ерып килеп, кызларга сүз кушты* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**ӘЛЛӘ КАЙДАН, ЫНДЫР АРТЫННАН УРАТЫП ЙӨРҮ.** Туп-туры сөйли башлаганчы (сораганчы һ.б.), кирәкмәгәннәр турында сүз йөртү. *Башта ук шулай дип әйтәләр аны!.. дип шелтәләргә керешә хуҗа аны. – Әллә кайдан, ындыр артыннан уратып йөрисең!* (Ш. Бикчурин).

**ӘЛЛӘ КАЙЛАРГА.** 1. Билгесез яки ерак урыннарга. *Мәнә хәзер дә ул җырын әнә шулай әллә кайларгача җәелеп китәрлек итеп сузып бетерде дә, үзе дә шуңардан әсәрләнеп булса*

*кирәк, кәефләнеп, бер көлеп куйды* (Ә. Еники. Җыз кыңгырау). *Бу тавыш безнең хыялларны әллә кайларга алып китә* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).

2. Кирәк булмаган, тиешсез. *[Камали] Төнлә белән ялангач көенчә чыгып китеп, белешмичә, әллә кайларга китеп, суга барып төшүе ихтимал* (Г. Камал. Банкрот). *– Нигә шулай башсызланып әллә кайларга барып йөрдең?* (В. Нуруллин. Һәлакәт).

Төрдәше: әллә кайларга үрелү.

**ӘЛЛӘ КАЙЛАРГА ҮРЕЛҮ.** 1. Сөйләшкәндә, аңламаган өлкәләргә дә кереп китү. *Ә Һашимов – авыл малае, алай әллә кайларга үрелергә яратмый; әңгәмә әдәбият өлкәсенә күчсә, сүзе Мәһдиев тирәсендә әйләнә, аның «торна»ларын мактый* (Р. Зәйдулла. Бу бишенче курс).

2. Рөхсәт ителмәгән, тиешсез урыннарга сузылу. *Кулы әллә кайларга үрелә* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: әллә кайларга.

**ӘЛЛӘ КАЙЛАРДА.** Кайлардадыр, билгесез урыннарда. *Газизә уйлары белән әллә кайларда – шулай адашып йөри-йөри, ниндидер олы юлга килеп чыкты кебек* (Н. Дәүли. Кар нинди җылы...).

**ӘЛЛӘ КАЙЛАРДАН.** Кайлардандыр, билгесез урыннардан. *Алар басу юлы белән иртүк чыгып китәләр дә, әллә кайлардан әйләнеп, тирләп, тартылып, тез тиңентен пычракка батып, көндез генә кайталар* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**ӘЛЛӘ КАЙЛАРДАН КҮРЕНҮ.** Бик ерактан. *Әллә кайлардан күренеп тора* (Г. Ахунов. Чикләвек төше). *Бронзадан коелып, алтынга манчылган һәйкәл, кояш нурларын чагылдырып, әллә кайлардан күренеп торырлык булды* (Ш. Алпар. Милләт өмете).

**ӘЛЛӘ КАЙСЫ**. Кайсыдыр, билгесез бер җирдән. *Гел генә күз алдында тормаса да, күңеленең әллә кайсы гына почмагында яшеренеп кенә ул яши бирде* (Ә. Еники. Төнге тамчылар).

**ӘЛЛӘ КАЙЧАН.** Бик күптән. *Шауламагыз, бирәсе әйберем әллә кайчан әзерләнгән* (Г. Ибраһимов. Алмачуар). *Арчаның базар мәйданы, без барып җиткәнче, арбалы атлар, җәяүлеләр белән әллә кайчан тулган* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: борын заманда.

**ӘЛЛӘ КАЙЧАН КИРӘК ИДЕ.** Күптән көтелгән эшне (хәрәкәтне һ.б) хуплау. *Әделгәрәй абзый әйтә: – Авылның тоташ колхозлашуы бик шәп эш, – ди. – Әллә кайчан кирәк иде* (Ә. Еники. Яз баласы). *– Әллә кайчан кирәк иде, – дип, Чура морза учларын учка бәргәләп алды, – ух, мин аны, килмешәкне...* (М. Әмирханов. Гәүһәршад).

**ӘЛЛӘ КАЙЧАН КИСЕЛГӘН КЕШТӘК КИСӘГЕ.** Берәрсе белән булган элемтәләрне бетерү. *Әллә кайчан киселгән кештәк кисәгенең кемгә кирәге бар* (Ш. Маннур).

**ӘЛЛӘ КАЙЧАНГЫ.** Күптәнге. *Кош кебек кенә калган самолет Мәрфугага әллә кайчангы, балачактагы ялгыз торнаны хәтерләтә, әллә кайчангы хәлләрне искә төшереп, әллә кемнәрне телгә алып беттеләр* (Ә. Еники. Туган туфрак). *Хәзер инде әллә кайчангы танышлар кебек сөйләшүнең, ике арада дустанә мөнәсәбәт белдерүнең бер хикмәте бардыр* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

**ӘЛЛӘ КАЙЧАННАН.** Күптәннән. *Әти, миңа белдермичә генә, әллә кайчаннан кеч-кенә генә көмеш кыңгырау алып куйган икән* (Г. Ибраһимов. Алмачуар). *Үзем дә белмим, әллә кайчаннан бирле инде госпитальдә, ак палатада ятам* (Ф. Хөсни. Йөзек кашы).

**ӘЛЛӘ КАЯ.** Еракка, каядыр. 1. *Түбәндә типтигез, ап-ак комач өсте – безнең чаналар карны ертып, әллә кая хәтле китәләр* (Ә. Еники. Соңгы китап). *Шактый киткәч кенә, ул, үзенең әллә кая таба баруын төшенеп, урам уртасында туктады, ачуыннан бер төкерде, борылып, кире кайта башлады* (И. Гази. Тел ярасы).

2. Билгесезлеккә. *Һәрнәрсә матур, сөйкемле кебек булып, шатлыгым эчкә сыймый, әллә кая сикерә, әллә нәрсәм әллә ни белән тула да ташып түгелергә тора төсле хис ителә иде* (Г. Ибраһимов. Яз башы). *Кинәндереп җанны сугарды да / Агып тыйнак китте әллә кая!* (Р. Рахмани. Табу һәм табу).

**ӘЛЛӘ КАЯ КИТМӘГӘН.** «Артык чибәр түгел» мәгънәсендә. *«Галия, Галия» дисең, ул да әллә*

*кая китмәгән, башкалардан да артык җире юк* (Сөйләм).

Төрдәше: күз явын алырлык түгел.

**ӘЛЛӘ КАЯ СИКЕРМӘҮ.** Зур уңышларга ирешмәгән, урта куллы кеше турында. *Юлдашым урта яшьләрдән узган, хезмәт юлын гади авыл укытучысы булып башлаган, хәзер дә әллә кая сикермәгән, кечерәк бер фәнни-тикшеренү институтында урта кул сотрудник булып эшләүче, аның үз сүзләре белән әйткәндә, «чалбар төбе шомартудан узмаган», ләкин тормышны шактый күргән, бәлки шул сәбәптәндер, җирдәге хәл-әхвәлләргә, ничектер, юмор аша карарга өйрәнгән бер кеше булып чыкты* (Ф. Хөсни. Кара кофе).

Төрдәше: арт белән киртә җимермәү һ.б.

**ӘЛЛӘ КАЯН.** 1. Кайдандыр, билгесез бер җирдән. *Күрәсең, ул фикер минем башка әллә каян, читтән килеп кермәгәндер* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Әллә каян гына талгын җил чыкты* (А. Гыйләҗев. Өч аршын җир).

2. Кайдан булса да. – *Ләкин сезнең шикелле кечкенә колхозга без әллә каян председатель эзли алмыйбыз* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

**ӘЛЛӘ КАЯН (КАЙДАН) КИЛҮ (КҮРЕНЕП ТОРУ).** Ерактан ук күренү яки сизелү. *Әллә каян күренеп тора, юлы уңган малайның* (Г. Сабитов. Кәккүк ялгыша икән). *Аерылып тора кыяфәте, / Әллә каян килә яктырып* (К. Сибгатуллин. Эштән кайта кеше).

Төрдәше: әллә каян (кайдан) кычкырып (күренеп) тору.

**ӘЛЛӘ КАЯН (КАЙДАН) КЫЧКЫРЫП (КҮРЕНЕП) ТОРУ**. Ерактан ук ап-ачык булып беленеп тору. *Язу югалмаган, һәр хәреф мәк чәчәге кебек янып, әллә кайдан кычкырып тора* (И. Нәбиуллина. Ташта үскән гөл). *Инде егерме еллап вакыт узды, Кәчемир авылында ул буялган мәчет манарасы бүген дә әллә каян кычкырып тора* (З. Мәхмүди. Әче балан).

Төрдәше: әллә каян (кайдан) килү (күренеп тору).

**ӘЛЛӘ КЕМ.** 1. Кемдер, билгесез кеше. *Янында килүче Раузаны хәзер, менә бу секундта, әллә кем аерып алып, ерак кырларга илтеп югалтырга тели шикелле сизенде* (Ш. Усманов. Ил кызы). *Шуннан соң ул җыелган халык арасыннан әллә кемне эзләп табып алды да аңа сорау бирде* (Г. Кутуй. Тапшырылмаган хатлар).

2. *ирон.* Үзе турында югары фикердә булу. *Һәрберсенең күзләре яна, Үзләрен әллә кем итеп тоялар* (А. Нәҗми. Азат). *Ныклап карасаң, әллә ние дә юк кебек, чибәр генә, күзе, кашы... әллә кем диярсең* (Д. Каюмова. Урланган бәхет).

**ӘЛЛӘ КЕМ БУЛУ (БУЛЫП ЙӨРҮ).** Үз-үзен танымас хәлдә эреләнү, үзен зур кешегә санау. *Йөри бит шатланып шунда, Үзенчә әллә кем булган* (Г. Тукай). *Олысы укуда әллә кем булмаса да, хезмәттә-эштә җир җимертте* (Ф. Яхин. Бар икән күрәселәр). *Йөриләр юкка мактанып, / Әллә кем булып һаман, / Беркемнең көче җитмәслек / Мең-мең эш кырган сыман* (Зөлфәт. Эз).

Төрдәше: әллә кемгә кую һ.б. ; әллә кемләнү.

**ӘЛЛӘ КЕМ (НИ) ТҮГЕЛ.** Җәмгыятьтә абруй казанмаган, дәрәҗәсе түбән булган кеше. *[Гөлҗиһан] <...> аларга өстәл булмаса да ярар. Үзләре дә әллә кем түгел* (Г. Камал. Банкрот). *Әллә кем түгел, үзенең кардәш тиешле абыйсы икән лә ул колга егет* (В. Имамов. Ир канаты).

**ӘЛЛӘ КЕМГӘ КУЮ** *к.* әллә кем булу (булып йөрү). *Әй, аның кукраеп, үзен әллә кемгә куеп сөйләшүен күрсәң* (Х. Камалов. Куян күзе нигә кызыл?). *Үзен әллә кемгә куюын сөйләмә дә инде* (Ф. Яхин. Сөйкемле сөяк).

Төрдәше: әллә кем булу (булып йөрү) һ.б.

**ӘЛЛӘ КЕМЛӘНҮ** *к.* әллә кем булу (булып йөрү). *Мәктәптә әллә кемләнеп йөрсә дә, безнең шикелле үк бәрәңге казып ашый икән әле!* (Л. Гыймадиева. Мин аңа бәхет телим). *Солдаттан инде егет бөтенләй зураеп, әллә кемләнеп кайтып керә* (С. Шәмси).

Төрдәше: әллә кем булу (булып йөрү) һ.б.

**ӘЛЛӘ КЕМНӘР.** Күп кеше, билгесез кешеләр. 1. *Ат чабышын карарга килүчеләр арасында әллә кемнәр бар* (К. Тимбикова. Сөлге булсын бүләгем!).

2. Кемнәрдер. *Гомер йомгагымны сүттеләр, / Биек тауга менәм дигән чакта, / Әллә кемнәр аска төрттеләр* (А. Нәҗми. Бәхетле мин).

**ӘЛЛӘ КЕМНӘР ТҮГЕЛ.** Нәрсә беләндер дан тоткан, мәшһүр булган, халыкта яхшы сүз белән

искә алына торганнардан түгел (ягъни гади кешеләр). *Янында яраннары. Әллә кемнәр түгел* (В. Имамов. Казан дастаны). *Мондый җайланманы бер дә әллә кемнәр түгел, кытайлылар ясый икән* (З. Мифтахов. Дөнья кызыклы!).

**ӘЛЛӘ КЕМНӘРГӘ.** Таныш түгел кешеләргә. *Буяучыдан киндер аласы, мал-туар базарында терлек бәяләрен беләсе, <...> заказга ясарга киндер мае белән акбур алып, әллә кемнәргә бирәчәген бирәсе, әллә кемнәрдән алачагын аласы бар...* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Яңа алган һәрбер байлыгыңны / Күрсәтәсең әллә кемнәргә* (С. Хәким. Шагыйрьнең бала чагы).

**ӘЛЛӘ КЕМНӘРДӘН.** Таныш булмаган кешеләрдән. *Шулай ук чын көчем берлән җыйган малымны, шулкадәр зур мәшәкатьләр берлә тапкан дәүләтемне, әллә кемнәрдән туздыртыр микәнни?* (Г. Исхакый. Ике гашыйк).

**ӘЛЛӘ КЕМНӘРНЕ.** Билгесез кешеләрне, кемнәрнедер. *Урамнарда әллә нинди яңа көйләргә җырлыйлар, әллә кемнәрне тиргиләр, ачуланалар, әллә кемнән үч алмакчы булалар иде* (Г. Исхакый. Ул әле өйләнмәгән иде). *Шайтан кушканмыни сиңа әллә кемнәрне укытып йөрергә?* (Г. Кутуй. Тапшырылмаган хатлар).

**ӘЛЛӘ КЕМНӘРНЕҢ.** Таныш булмаган кешеләрнең, кемнәрнеңдер. *Шуның аркасында әллә кемнәрнең тормышы бозыла, кешеләр бер-берсенең кан дошманына әйләнеп бетәләр* (В. Нуруллин. Ике урам арасы). *Үткәннәргә тугры йөрәген / Үзгәртә дә, төзәтә алмый / Елмаюы әллә кемнәрнең* (К. Булатова).

**ӘЛЛӘ КЕМНЕ.** Кемнедер, билгесез кешене. *Икәү бергә залдан чыгып киткәндә, мин әллә кемне эзләгән сыман як-якка карандым.* (Г. Кутуй. Тапшырылмаган хатлар). *Эчке ишекнең тоткасына үрелгәч, хатимә хатынның әллә кемне тозлап-борычлап әрләвен ишетеп туктап калды* (Ә. Әминев. Усман ташы).

**ӘЛЛӘ КҮЗЕҢӘ БӘРӘҢГЕ СӨЯГЕ ҮСТЕМЕ** *ирон.* «Сукырайдыңмы әллә югыйсә» мәгънәсендә; күрә торып та күрмәгәнгә салыну. *Әллә күзеңә бәрәңге сөяге үстеме? Урамда, күрмичә, бәреп китә яздың* (Сөйләм).
Тәрдәше: күзең чыктымы әллә?

**ӘЛЛӘ КҮПМЕ.** Хисапсыз, бик күп. – *Баш кормый кара! Атнакөн кер чайкаган өчен генә дә әллә күпме ыштырау түләтте* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Шул матурлыкның әллә күпме урынында да кымыз ясыйлар* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).
Төрдәше: әллә никадәр<ле> һ.б.

**ӘЛЛӘ МОНДА ТОЗ СУЫ СИПКӘНМЕ?** Нәрсәсе беләндер үзенә тартып торган җир, урын турында. *Нәрсә безнең тәрәзә төбенә җыелдыгыз, әллә монда тоз суы сипкәнме?* (Сөйләм).

**ӘЛЛӘ НӘРСӘ.** 1. Нәрсәдер, нидер. *Әллә нәрсә булды бу малай күңеленә* (Г. Сабитов. Ярсулы яз). *Хәер, сүз дип сүз түгел, әллә нәрсә. Ул күзләрен ямьсез итеп Васфикамалга текәде дә кинәт кенә дерелди, калтырана башлады* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

2. Көтелмәгән төрле нәрсә. – *Син кереп чыга күр инде. Әллә нәрсә булуы бар, – диде* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала). *Сыер дуласа, аттан яман, диләр, сөяленә бассаң, әллә нәрсә майтарып ташлар бу үшән татар* (Р. Зәйдулла. Алла).

3. Нигәдер, ни өчендер. *Әллә нәрсә бик эсселәп торам мин бүген* (Ф. Хөсни. Йөзек кашы).

**ӘЛЛӘ НӘРСӘГӘ.** Ни өчендер, ни сәбәптәндер. *[Әнвәр] (тартманы алып, өстәленә куеп). Ярый, ярый, алма, үпкәң беткәч алырсың, синең әле әллә нәрсәгә кәефең киткән* (Г. Камал). *[Ибраһим] Бүген әллә нәрсәгә төн буе йоклап булмады* (Г. Исхакый. Алдымбирдем).

**ӘЛЛӘ НӘРСӘСЕ.** Үзен белдереп тормаган эчке халәт. *Аның әллә нәрсәсе тагы хурланды, күңеленнән бер күңелсез агу акты* (Г. Исхакый. Өйгә таба). *Әллә нәрсәсе тартып тора шул кызның, карап кына торасы, чәчләренә кагыласы, кулларын тотып карыйсы килә* (Д. Каюмова. Урланган бәхет).

2. Мактанычы, башкалардан аерып торырлык нәрсәсе. *Дөрес, Каракошның хәзергә әле ерактан килгән кунакка мактап күрсәтерлек әллә нәрсәсе юк* (Ә. Еники. Туган туфрак).

**ӘЛЛӘ НИ.** 1. Бигүк. *Тик шулай да безнең бакча тирәсеннән әллә ни ерак китмиләр әле* (И. Гази. Тел ярасы). *Ибрайның салпы якка салам*

*кыстыруына Сөләйнең әллә ни исе китмәде* (Н. Хәсәнов. Язмышың сыналганда...).

2. Бик нык. *Хәер, әллә ни өшемәдем дә, берни булмас әле, Алла бирсә!..* (Ә. Еники. Гөләндәм туташ хатирәсе). *Гыймат абый, башын тавык шикелле кыңгырайтып, күзен әллә ни кыландырган иде, бөтенесе көлеп җибәрделәр* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

3. *к.* әллә нәрсә. *Хөсәен әллә ни генә әйтмәкче иде, Мостафа тагын: – Әйе, китәм, – диде* (Ш. Камал. Буранда). *Тагын әллә ни ертып, / «Мода», – дия күрмәгез* (М. Җәлил. Хәдичә).

4. Ниндидер, билгесез. *Өстәл янында бер карчык әллә ни фикергә калып утыра иде* (Ш. Камал. Ата).

5. Бик тиз. *Әллә ни арада авылның олысы-кечесе капка төпләренә, баскыч алларына чыгып басты* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

6. Бик озак. *Яшьрәк чагында әти суккач, аның бармак эзләре фәлән кешенең яңагында әллә ни көнгә кадәр кара көеп, күпереп йөргән, диләр* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Алтын тәңкә бик зур мал түгел, / Бер дә күрешүләр әллә ни* (Хал. җыры «Бик еракта идек без»).

7. Күп нәрсә. – *Хәзер шул көймәдә булырга мин әллә ниләр бирер идем, – диде Фердинант* (И. Гази. Ай юлы). *Күктә генә түгел, җирдә дә әллә ниләр бардыр!* (А. Гыйләҗев. Әтәч менгән читәнгә).

8. Бик зур. *Ләкин аларга әллә ни зур зыян булмый – җиңелчә контузия генә алдылар* (Ә. Еники. Без дә солдатлар идек).

9. Ул кадәр; шаккатырлык. *Җиләк дигәч тә, ул хәтле дә әллә ни мал, ризык түгел инде ул анысы* (Ә. Гаффар. Әллә тагын). *Хәер, булмагае, алар үзләре дә миннән әллә ни артык түгелләр әле* (Г. Үзиле. Ленин, Дарья Петровна, мин һәм башкалар).

10. Ул кадәр; ныклап. *Әлбәттә, монда чалбар да онытылды, без өйдә әүмәкләшеп котыра-котыра уйнаганбыздыр да – болары әллә ни истә калмаган* (Т. Нурмөхәммәтов. Кабан күле, әй, алкын).

11. Бик кадерле нәрсә. *Ак келәтнең алдыннан / Тәңкә таптым әллә-ли; / Тәңкә табу берни түгел, / Бер сөйләшү әллә ни* (Җыр).

12. Җитәрлек дәрәҗәдә. *Минем акылым әллә ни түгел, талант та юк* (Р. Зәйдулла. Коршау).

13. Зур итеп сөйләрлеге; шактый. *Ләйлә күзләрен каплап әллә ни вакыт ачарга куркып торды* (И. Гази. Ай юлы). *Әллә ние дә юк шикелле үзе, иске ипи, терсәк буе бер тутырма, төрле-төрлесеннән өч кап чәй, ун савыт шәп сыра, өч шешә аракы, ике кадаклап хәлвә, бер калҗа пешкән ит, ысланган балык, алма, ике литрлы савытта үзе тозлаган кара гөреҗдә гөмбәсе...* (Ә. Гаффар. Энә күзе).

14. Нәрсәдер булган кебек, гадәттәге кебек түгел, үзгәргән. *Ике юлын укыды, әллә ни булды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Хөсәен чыдамады: – Мостафа, син әллә ни бүген!.. – диде* (Ш. Камал. Буранда).

15. Башка төрле. *Өй җыештырудан башка әллә ни эш тә булачак түгел икән* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**ӘЛЛӘ НИ ӘЙТТЕРЕРСЕҢ.** Кешенең ачуын китерерлек юк сүз сөйләгән кешегә каршы әйтәләр. – *Авызыңа – сыер боламыгы... Әллә ни әйттерерсең, кияү* (Р. Вәлиев. Мирас). *Фу, әллә ни әйттерерсең, нигә тотасыз бу сәләмәне?* (М. Әмирханов. Тояк эзе).

**ӘЛЛӘ НИ ГОМЕР<ДӘН БИРЛЕ>.** Бик озак вакыт. *Менә инде әллә ни гомердән бирле җир өстеннән җан иясе барлыгын белдергән бер тавыш та килми* (К. Тинчурин). *Менә итле шулпа капмаганына да әллә ни гомер* (И. Гази. Онытылмас еллар).

**ӘЛЛӘ НИ КҮП ТҮГЕЛ.** Бик күп түгел, җитәрлек кенә. *Икеләнми таянырдай ярдәмчеләре әллә ни күп түгел иде* (В. Имамов. Утлы дала). *Ләкин үз исемнәрен үлемсез иҗаты белән дә, батырларча үлеме белән дә мәңгеләштергән шагыйрьләр әллә ни күп түгел* (Р. Мостафин. Өзелгән җыр эзеннән).

**ӘЛЛӘ НИ ТИКЛЕ.** Бик күп. *Аларның анасы белән икесенә менә дигән алты почмаклы яңа йортлары, әллә ни тикле мал-туарлары, йорт җиһазлары бар* (Г. Бәширов. Җидегән чишмә).

**ӘЛЛӘ НИ ТОРУ.** Искитәрлек, бик кадерле, бик кыйммәт булу. *Инглиз язучысы Дж. Олдриджның «Монгол айгыры» исемле әсәре үзе генә әллә ни тора. Акыллы шул атлар, акыллы!* (М. Әхмәтҗан. Тормыш мизгелләре). *Ә иң мөһиме: монда Бурнашевлар гаиләсен ихтирам иткән имам-хатыйб Абдулла Шәмсетдинов эшли, аның белән аралашу, бер күреп сөйләшү үзе әллә ни тора* («Сөембикә» ж.).

**ӘЛЛӘ НИ (НӘРСӘ) ТҮГЕЛ (НИ ЮК)** *к.* ах итәрлек (килерлек) түгел. – *Исе дисәң – хуш исе юк, яфрагы дисәң – яфрагы да әллә ни түгел* (Г. Кутуй. Рөстәм маҗаралары). *Ә кайбер кешеләр исем алмый кала икән, анысы әллә ни түгел* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

Төрдәше: ах итәрлек (килерлек) түгел һ.б.

**ӘЛЛӘ НИ ХИКМӘТ.** Нигәдер, ни өчендер; ни хикмәттер. *Хәзер чәкәләшергә генә торалар иде. Әллә ни хикмәт – дус тора алмыйлар иде* (М. Фәйзи). *Америка империализмының туймас капшагычлары ни өчен шушы төбәккә сузылганын аңлау өчен, әллә ни хикмәт кирәкми* (А. Гыйләҗев. Татарстан могҗизасы).

**ӘЛЛӘ НИГӘ.** Ни өчендер, ни сәбәптәндер; ничектер. *Шул вакытта менә әллә нигә / Тик язасы килә, язасы!..* (М. Җәлил. Була кайчак). – *Әллә нигә уңайсыз бит* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

**ӘЛЛӘ НИГӘ (НИДӘ; НИДӘН) БЕР <ГЕНӘ>.** Даими рәвештә булмаган; вакыт-вакыт кына, сирәк кенә; система рәвешендә булмаган. *Әллә нигә бер килгән кешене чәй эчертми җибәрергә ярыймы соң* (Г. Камал. Кайниш). *Әллә нидә бер мин аны [җиз кыңгырауны] кулыма алып, әкрен генә тыңлап карыйм* (Ә. Еники. Җиз кыңгырау).

Төрдәше: әллә нидән бер; урык-сурык; урыны белән.

**ӘЛЛӘ НИГӘ ДӘ.** Бер нәрсәгә дә, һичбер нәрсәгә дә, андый шартларга һич тә, бернинди нигезсез. *Әллә нигә дә яраксыз бит бу тимер, тимер-томырга гына тапшырырга кирәк* (Сөйләм).

Төрдәше: әллә ниләр бирсәләр дә.

**ӘЛЛӘ НИГӘ КАДӘР.** Бик озак вакыт. *Әни, битенә, керфекләренә кунган салам көлен сыпыргалап, әллә нигә кадәр төкеренеп йөрде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**ӘЛЛӘ НИДӘ БЕР.** Сирә кенә булса да. *Ә кыш көне дисә, әйтик, бүген керфегеңә кунган бер кар бөртеге дә әнкәңнең әллә нидә генә – кемдер чит-ят күреп алганчы ук, иң арып тупасланган урта бармагы белән суллы-уңлы сөртеп алырга өлгергән мул тамчылы тозсу күз яшеннән дә җылырак,баллырак булырдыр иде* (Ә. Гаффар. Энә күзе).

**ӘЛЛӘ НИДӘН.** Ни өчендер, ни сәбәптәндер. *Әллә нидән, бик үк кызык тапмаган Гали атлы бер иптәшебез: – Кич тә булып килә, кайтырга кирәк инде, малайлар, – диде* (Г. Ибраһимов. Яз башы).

**ӘЛЛӘ НИК.** Ничектер, ни өчендер. *Аның диварына асылган харита, аның өстендәге зур-кечкенә шәһәрләрнең ишарәтләренең күзен акайткан кебек каравы аны әллә ник калтыратып җибәрде* (Г. Исхакый. Өйгә таба).

**ӘЛЛӘ НИКАДӘР<ЛЕ>.** Бик күп, сансыз, хисапсыз. *Әбүгалисина белән Әбелхарис шушы вакыт эчендә күп тырышып, күп көч куеп, әллә никадәрле белем алдылар* (К. Насыйри. Әбүгалисина). *Түбән очтан урам тутырып әллә никадәр халык менеп килә.* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: әллә күпме һ.б.

**ӘЛЛӘ НИЛӘР.** Беленмәгән күптөрле нәрсәләр. *Күңелемдә әллә ниләр уйласам да, нигәдер менә тотып кына әйтер сүзем юк* (Ә. Еники. Гөләндәм туташ хатирәсе). *Әллә ниләр үзгәрер күк илдә – / Заманнарның тыны-сулышы кайнар!* (Зөлфәт. Адашкан болыт).

**ӘЛЛӘ НИЛӘР БИРСӘЛӘР ДӘ** *к.* әллә нигә дә. *Иманым камил: һичбер вакытта да, әллә ниләр бирсәләр дә, әйткән сүземдә торачак ул* (Сөйләм).

Төрдәше: әллә нигә дә.

**ӘЛЛӘ НИНДИ.** 1. Ниндидер, билгесез. *Әллә нинди генә шунда, түбәндәге тормыштан аерылу хисен уяткан, бушлык халәтенә якын бер тынлык иде бу...* (Ә. Еники. Туган туфрак). *Әллә нинди шомлы төн булды* бу (Г. Сабитов. Өч күңел).

2. Сәер булган, моңарчы очрашмаган-ишетмәгән. *Чәй эчкәч, әллә нинди Югары Аты, Түбән Аты, Урта Аты авылларын үтеп, төн урталарында үземнең туган авылым Кушлавычка барып кердек* (Г. Тукай. Исемдә калганнар). *Әле дә кечек башларыннан әллә нинди сүзләр чыгарып, телләренә салындылар* (Г. Ибраһимов. Яз башы).

3. Ят, үзенчәлекле. *Әллә нинди икән ул Шүрәле!* (Р. Низамиев. Фәрит Яруллин). *Сөйләшүе дә әллә нинди, йокымсыраган кешенеке шикелле, сәп-сәер иде түгелме соң?* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**ӘЛЛӘ НИНДИ ТҮГЕЛ** *к.* ах итәрлек (килерлек) түгел. *[Бәдерхаят] Бер дә әллә нинди түгел, синең абруең өчен тырышам* (И. Абдуллин. Якты күңел). *Кәгазь дисәң, гап-гади газета иде инде ул, буяу дисәң, анысы да әллә нинди түгел, шуңа барысы да «аһ» итеп сокланды* (Т. Әйди. Хезмәте – сәхнә күрке).

Төрдәше: ах итәрлек (килерлек) түгел һ.б.

**ӘЛЛӘ НИТКӘН.** Ниндидер, билгесез. *Шуларны санга сукмыйча, читтән әллә ниткән марҗа кызы ияртеп кайт, имеш* (Г. Бәширов. Нурҗиһан). *Әллә ниткән саташкан көн булды бу!* (Ф. Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы).

**ӘЛЛӘ НИХӘТЛЕ** *к.* әллә күпме. *Калын тавыш белән җырлап торучы сары яллы попның күз алдында кесәсенә әллә нихәтле алтын тутырып чыга* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Калада төнлә кисәк кенә трибүнә ясыйлар, әллә ниткән утлы көлтәләр һавада йөриләр, ди* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

Төрдәше: әллә күпме һ.б.

**ӘЛЛӘ НИЧАКЛЫ.** Бик күп. *Ана карчыкның бу аерылу елларында әллә ничаклы үпкәләр, шелтәләр, сагышлар, сөю һәм рәнҗү дулкыннары, барысы бергә кайнашып, кара кан булып укмашканнар иде.* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар). *Көнозын шаулаган тормышның кояш баеган чакта тынып, уйга чумып алуында да әллә ничаклы тылсым, сәерлек бар* (Р. Низамиев. Фәрит Яруллин).

**ӘЛЛӘ НИЧӘ.** Бик күп, берничә. *Ул арада чәй хәзерләнеп, әллә ничә айлар сагынып йөргән сыйлар берәм-берәм өстәлгә тезелделәр* (Г. Ибраһимов. Яз башы). *Мин юкагачтан пәке белән сырлы таяк ясап йөргәндә, әллә ничә кеше берьюлы: – Әй, саклан, саклан! – дип кычкырдылар* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**ӘЛЛӘ НИЧӘ АВЫЗЛЫ.** Күп балалы. *Менә шул фәкыйрь вә шуның өстенә әллә ничә авызлы булган семья эченә мин ятим бала булып килеп кергәнмен* (Г. Тукай. Исемдә калганнар).

**ӘЛЛӘ НИЧӘҮ**. Берничә; күп. *Әнә тагын «ул»! Бер-бер артлы әллә ничәү!..* (Ә. Еники. Төнге тамчылар). *Конвойлар әллә ничәү* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

**ӘЛЛӘ НИЧЕК.** Ничектер, ничек икәнлеге билгесез. *Бу арада әллә ничек үзгәреп тора: юкбарга ачулана, якын барсаң, өстеңә йомылып килә* (Г. Ибраһимов. Алмачуар). *Әллә ничек үтте шунда гомер: / Туйганчы бер күрешмәдек тә...* (Х. Туфан. Соңгы очрашу).

**ӘЛЛӘ НИШЛӘМӘГӘЕ.** Теләсә нәрсә эшләсәләр дә, ис китмәүне белдерә. *Әллә нишләмәгәе, бөтен тәрәзәләрдән – син фәлән, син төгән! – дип өстемә төкерсәләр дә, сер бирмәскә иде* (К. Нәҗми).

**ӘЛЛӘ НИШЛӘП.** Ни өчендер, нигәдер. *Хәдичә теге карчыкның чакыруы буенча әллә нишләп шул землянкәгә керде* (С. Рәмиев. Галәветдин хаҗи корбаны – Җаек Хәдичә). *Имән урамын чыгуга, әллә нишләп күңелем тулды* (А. Гыйләҗев. Язгы кәрваннар).

**ӘЛЛӘ НИШЛӘП КИТҮ.** Кинәт кенә аптырап кую. *Гыймади әллә нишләп китте* (Ә. Гаффар. Дәрья башы). *Курнос борынының яфраклары дерелдәп куйганда, Нагаевның карт йөрәге әллә нишләп китә, шайтан алгыры!* (Р. Зәйдулла. Кыз-хатын). *Әллә нишләп китте ул. Көлми, елмаймый, берсенә бер сүз кушмый* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**ӘЛЛӘ НИШЛӘТЕП.** Нәрсәдер эшләп. *Былтыр әнә алма сатучының кызы күңелне әллә нишләтеп китте бит* (Ф. Хөсни. Йөзек кашы).

**ӘЛЛӘ НИШЛӘТЕП ҖИБӘРҮ**. Кинәт сәер бер хис уяту, сискәндерү. *Әллә нишләтеп җибәрде бу караш Диләрәне, әмма ул аны батыр күтәрде, хәтта горур гына башын да чөеп куйды* (Ә. Еники. Шаяру). *Күктән килгән моңсу тавыш йорт казларын әллә нишләтеп җибәрде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**ӘЛЛӘ НИШЛӘҮ.** Эчке халәт үзгәрү. *– Бервакыт бу бөтенләй әллә нишләде, аягын да теләртеләмәс кенә атлый, үзе калтырангандай да итә* (Н. Фәттах. Мәдинә). *Кинәт көн әллә нишләде: сүнеп, сүрелеп калгандай булды* (М. Галиев. Затлы чыбыркы хуҗасы).

**ӘЛЛӘ САТАША КҮЗЕМ, ӘЛЛӘ АДАШАМ ҮЗЕМ.** Озак күрешмәгән яки таныр-танымас кешене танырга тырышканда әйтелә. *Әллә саташа күзем, әллә адашам үзем, син Фәгыйлә түтинең улы Мансур бугай бит?* (Сөйләм).

**ӘЛЛӘ СОҢ?!** Бәлки; югыйсә. *«Әллә соң?!» дигән уй да килгәләде күңеленә...* (Р. Гыйззәтуллин. Багу). *Әллә соң... Үзем генә кайтып китим микән әллә?* (М. Хуҗин. Куларада кәлтә уйный).

**ӘЛЛӘ ТАГЫ<Н>.** «Белеп бетермим; бәлкем» мәгънәсендә. *Эт этлеген итмәсә, эче күгәрә, ди бит. Әллә тагы...* (Г. Әпсәләмов. Газинур). *Хан яшь, каты куллы, үткен күзле, әллә тагын утыз-кырык ел тәхеттә утырыр, кем белә* (Р. Батулла. Сөембикә).

**ӘЛЛӘ УГРЫ, ӘЛЛӘ ТУГРЫ.** «Кем икәнен белмибез, безгә караңгы» мәгънәсендә. *Караңгы иңгәч, авыл башында аркасына биштәр аскан бер кеше күренде, кем белә: әллә угры, әллә тугры шунда* (Сөйләм).

**ӘЛЛӘ УҢАМ, ӘЛЛӘ ТУҢАМ.** Ике хәлнең берсе: йә отам, йә оттырам. – *Әллә уңам, әллә туңам, киттем мин тәвәккәлләп* (Сөйләм).

**ӘЛЛӘ ЭЗДӘ, ӘЛЛӘ ТЕЗДӘ.** Кайларда йөргәнлеге, ниләр эшләгәнлеге билгесез кеше турында. *Кем белә инде аның кайларда йөргәнлеген: әллә эздә, әллә тездә* (Сөйләм).

*ӘЛЛӘ-МӘЛЛӘ* ❖ **ӘЛЛӘ-МӘЛЛӘ ДИП ТОРУ.** Икеле-микеле сөйләшү. – *Ролеңне беләсеңме?* – *Әллә инде.* – *Әллә-мәллә дип тору яшьләр гадәте түгел* (М. Фәйзи).

**ӘЛЛӘ-МӘЛЛӘ ДИЮ.** Икеләнүне белдерү; бәлки. *Гамлет ук мәллә? [Гайсә] Әллә-мәллә...* (Г. Каюмов. Туу...). *Шунда тегермәнче болай аңлаткан: «Хан миңа “әллә-мәллә диде”»* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).

*«ӘЛЛҮР»* ❖ **«ӘЛЛҮР» ДИЮ.** Биредә: «кайдан булса да бик тиз китү, юкка чыгу» мәгънәсендә. – *Шуннан соң мин клиникасына да, Казанына да «әллүр» дип үзебезгә кайттым* (Н. Гыйматдинова. Нурулла).

*ӘЛМӘН* ❖ **ӘЛМӘН БЕЛӘН СӘЛМӘН** *к.* Аг<ы>лый белән Таг<ы>лый <йөрү>. *[Мортаза] Кайчан карама, Әлмән белән Сәлмән кебек сез бергә* (Т. Гыйззәт).

Төрдәше: Аг<ы>лый белән Таг<ы>лый <йөрү> һ.б.

*ӘЛМӘСТӘНЕҢ* ❖ **ӘЛМӘСТӘНЕҢ ӘЛ-КОЙРЫГЫ**. Әйтергә ярамаган әйберне «нәрсә?» дип сораганда әйтелә. *«Нәрсә? Нәрсә?» дип теңкәгә тидең инде – әлмәстәнең әл-койрыгы!* (Сөйләм).

*ӘЛМИСАКТАН* ❖ **ӘЛМИСАКТАН БИРЛЕ.** Бик борынгыдан, ягъни дөнья яратылганнан бирле. *Әнә Ташъелга әлмисактан бирле кымшанмый ята бирә...* (Ә. Әминев. Усман ташы). *Янәсе, без шундый милләтчене / Ничек инде тотыйк үрнәк итеп. / Әлмисактан бирле килә шулай* (Ә. Рәшитов. Язмыш җилләре).

*ӘЛПИНЕ* ❖ **ӘЛПИНЕ УКЫТУ** *к.* авыз җебетү 2. *Кулда форсат барында, әлпиен укытырга кирәк аның* (А. Гыйләҗев. Җомга көн кич белән...).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

*ӘЛФИ* ❖ **ӘЛФИ КАЮ.** Татар читеге каюның бер төре (гарәп әлифбасындагы ләм-әлифкә охшатып чигү. *Аягыңдагы читегең / Әлфи-әлфи каюлы; / Безнең җиңкәйне сорасаң, / Дисбитилнә бай улы* (Җыр).

*ӘЛФИРАК* ❖ **ӘЛФИРАК БУЛУ** *иск.* Бер-береңнән аерым булу, сагышлы сагыну. *Инде булдык, җаный, әлфирак, / Бу фиракдин дәхи кавышмасак, / Үлгәнебез безнең яхшырак* (Җыр).

*ӘЛФИРАКТАН* ❖ **ӘЛФИРАКТАН ӘЛМИСАККА ИЛТКӘН.** Бүгенге сагышлы язмыштан борынгы тамырларга, чыганакларга илтә торган. *Әлфирактан Әлмисакка илткән / Сәнгать юлы төшә, һай, кыйбатка!* (Роб. Әхмәтҗан. Сәхипҗамал).

*ӘЛХӘЛ* ❖ **ӘЛХӘЛ БУЛУ.** Хәл алу, хәл керү. *Ичмасам, лазаретка кереп әзрәк әлхәл булыр идем* (Ф. Хөсни). *Ак калфагым төшеп калды / Уенда әйләнгәндә. / Әзрәк әлхәл буламын / Кичен күз бәйләнгәндә* (Җыр).

*ӘЛХӘМ* ❖ **ӘЛХӘМ СҮРӘСЕН УКЫТУ.** Җәза бирү, кыйнау, шелтәләү. *[Гыйльметдин] Укытканнар икән әлхәм сүрәсен* (Ф. Бурнаш. Яшь йөрәкләр). *Алай дисәң, шундый ук эчтәлек «Әлхәм сүрәсен укыту», «Бисмилласын укыту», «Иманын укыту» һ.б. тәгъбирләр өчен дә хас* (Х. Мәхмүтов. Изге китаплар кайтавазы).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

*ӘЛХӘМДЕЛИЛЛА* ❖ **ӘЛХӘМДЕЛИЛЛА ШӨКЕР** *дини, к.* Аллага шөкер 1. *Мәсудемез хасил улды, Әлхәмделилла шөкер* (Н. Әһудин. Казаклар).

Төрдәше: Аллага шөкер 1.

*ӘЛХӘРӘЙ* ❖ **ӘЛХӘРӘЙ КЕБЕК БАЙ** (әлхәрәй < архиерей) *иск., к.* акча бездә бер букча.

*Бездәге байларны санап карасаң, Кәрим байны гына әлхәрәй кебек бай дип әйтергә була* (Сөйләм).
Төрдәше: акча бездә бер букча һ.б.

*ӘЛЧИ* ❖ **ӘЛЧИ БАСУ.** Көязләрчә, үрә басып йөрү. *Чишмәгә төшсәм, Әхмүш тыкрык буендагы читән тишегеннән үртәп кала: – Әх, йөрүләре – әлчи бас, – ди* (Г. Галиев). *– Астык, бөек кенәз, астык без ул кабихне! – диде баяр, әлчи басып* (З. Мәхмүди. Елак агач).

**ӘЛЧИ КИЮ.** Баш киемен артка этәреп, көязләрчә кию. *Урам буйларыннан һай киләсең, / Бүрекләрне әлчи киясең* (В. Нуриев. Кышның озын бер төне).

*ӘМАНӘТКӘ* ❖ **ӘМАНӘТКӘ ХЫЯНӘТ.** Биргән сүздә тормау, антны бозу ихтималы. *Әманәткә хыянәт, үзең дә беләсең, хыянәт була инде, ләкин син, зинһар өчен, мин язган хат дип уйлый күрмә: мин түгел, дустым сиңа бигаять булган* (К. Тинчурин. Мәрҗәннәр).
Төрдәше: ант бозу һ.б.

*ӘМӘК* ❖ **ӘМӘК БЕЛӘН ҖӘМӘК (ШӘМӘК / ШӨМӘК) КЕБЕК** *к.* Аг<ы>лый белән Таг<ы>лый <йөрү>. *Рамазан сөйләвенә караганда, Әмәк белән Шәмәк кебек булганнар алар* (Ж. Рәхимов. Өлешемә тигән көмешем). *Әмәк белән Шөмәк кебек сельпо бусагасын саклыйлар, эшкә дисәң, эчләре авырта дип, бездән көлгән иде түгелме?* (Н. Дәүли. Тимәгез минем Гөлзадага).
Төрдәше: Аг<ы>лый белән Таг<ы>лый <йөрү> һ.б.

**ӘМӘК ЙӨГЕРГӘНГӘ ШӘМӘКНЕҢ ТАБАНЫ КЫЗУ** *ирон.* Кешедән күреп, аңа иярүдән көлү. *Казаннан нindидер зур кеше килә, алар үтеп киткәнче хәрәкәт тыела. – Әмәк йөгергәнгә Шәмәкнең табаны кыза, ди... – Телеңә салынма, әйткәнне эшлә, – диде милиционер* (М. Әмирхан. Дөя муены).

*ӘМӘЛ* ❖ **ӘМӘЛ КОРУ.** Берәр бәлагә дучар булганда, чарасы табылмаудан йөдәү. *Зал түрендә әрле-бирле йөренгәндә, / Кунакның чәчәк йөзенә күзе төште, / Әмәл кора: «Ничек моны өзәргә?» – ди* (Б. Мирзанов. Сулган чәчәк).
Төрдәше: әмәлең бармы.

*ӘМӘЛГӘ* ❖ **ӘМӘЛГӘ КАЛГАНДАЙ.** Бәлагә каршы. *Әмәлгә калгандай, өйдән чыкканда, паспортымны алырга онытканмын* (Н. Исәнбәт). *Әмәлгә калгандай, ул елны актарылып иген уңды, көн коры чакта эскертләп бетердек* (Ә. Хәкимов. Очар кошлар).

**ӘМӘЛГӘ КАЛГАНДАЙ, ЮЛ ТӨШТЕ МИҢА ДА БАҖАГА КЕРЕП ЧЫГАРГА.** Аптыраганнан бер сылтау табудан көлү. *Урам буйлап барганда, нидәндер сул аягымның чәнчи бармагы әчетә башлады, әмәлгә калгандай, юл төште миңа да баҗага кереп чыгарга* (Сөйләм).

**ӘМӘЛГӘ КАЛУ.** Берәр эштә көтелмәгән авыр хәлгә, кыенлыкларга дучар булу. *«Бездә ул чаклы иген дә, ат һәм арба да юк бит!» – дип карый әмәлгә калган парторг, тик аны ишетергә дә теләмиләр* («Кызыл таң» газ.).

*ӘМӘЛЕН* ❖ **ӘМӘЛЕН КҮРҮ.** Хәл итү юлын эзләү, чарасын күрү. *Ни булса, шул булыр, дип әйтәм инде, болай бичараланып утырганчы, әмәлен күрү яхшы* (З. Мурсиев. Солтанъяр).

**ӘМӘЛЕН ТАБУ.** Берәр авырлыкны хәл итү, чарасын табу. *Үз эшләрен эшлиләр, / Чак кына уйлап яттым. / Шундук әмәлен таптым!* (Л. Шәех. Батырлык).
Төрдәше: авыртмаган якка яту һ.б.

*ӘМӘЛЕҢ* ❖ **ӘМӘЛЕҢ БАРМЫ** *к.* әмәл кору. *– Хан кызын көчләп урлап алып килгәнсең һәм көчләп никах укыткансың. Акланыр әмәлең бармы?* (М. Хәбибуллин. Илчегә үлем юк).
Төрдәше: әмәл кору.

*ӘМӘЛ-ҖӘМӘЛ* ❖ **ӘМӘЛ-ҖӘМӘЛ КИТЕРҮ.** Хәйлә кору, наянлану, нәрсәне булса да хәл итүдән качу. *Ул сарай эчендә озак качып утырырга уйламады да, әмәл-җәмәл китереп, бер черек тактаны каерып, чыгып качты* (Сөйләм).

*ӘМӘЛ-ТАКЫЛ* ❖ **ӘМӘЛ-ТАКЫЛ ИТҮ.** Уйлашу, киңәш-табыш итү. *– Без монда син югында халык белән әмәл-такыл иттек тә, Шәфи энем, «Яңарыш» авыл хуҗалыгы кооперативы оештырырга булдык* (З. Мәхмүди. Ахырзаман шаукымы).
Төрдәше: фикер иләгендә иләү; фикер иләгеннән уздыру.

*ӘМӘЛ-ТҮМЕЛ* ❖ **ӘМӘЛ-ТҮМЕЛ ИТҮ.** Авырганда яки имгәнгәндә төрле им-томнар куллану.

*Утын ташыганда, егылып, аягын тайдырган иде, авылда даны чыккан Гайшә әби килеп, әмәл-түмел итеп китте* (Сөйләм).

*ӘМӘЛ-ЧӨМӘЛ* ❖ **ӘМӘЛ-ЧӨМӘЛ КИТЕРҮ.** Төрлечә боргалау, куеп карау. *Тумбочканы әмәл-чөмәл китергәч, Иван Георгиевич, нәкъ безнең теләкне белгәндәй, ирекле рәсем ясарга кушты* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).

*ӘМЕРЕҢӘ* ❖ **ӘМЕРЕҢӘ ХӘЗЕР.** Башлык һәм түрәләрнең әмерен үтәргә әзер булуны белдерү. *Кушканыңны үтәрмен, янәсе – хезмәтләрең әмереңә хәзер* (М. Фәйзи).

Төрдәше: баш өсте.

*ӘМЕРНЕ* ❖ **ӘМЕРНЕ УҢГА-СУЛГА СИБҮ.** Бөтен кешегә дә җитәрлек итеп, төрле әмерләр бирү. *Апасы әмерләрен уңга-сулга сипте дә тагын бер тапкыр Гүзәлияне, «юып-чайкап», кер бавына «элде»* (Н. Гыйматдинова. Үзем генә беләм...).

*ӘМИН* ❖ **ӘМИН БУЛУ.** Ышану, курыкмау. *«Менә ун еллар инде иртәге көндә ачка үлмәвемнән әмин була алганым юк»* (Г. Ибраһимов. Габдрахман Салихов).

Төрдәше: би сөйләсә – бинеке, кол сөйләсә – колныкы; җан-тән белән ышану; сер сыя торган кеше; ышаныч казану.

*ӘММА* ❖ **ӘММА ЛӘКИН.** Ярдәмлекләрне рәттән куеп көчәйтү. *Әмма ләкин белеп торам: ул мине күрә, минем сүзләремне ишетә, эшләгән эшләремне барлап тора* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

**ӘММА <ДА> СОҢ ИНДЕ.** Бик яхшы, күңелне хушландырган; сокланып әйтү. *Әмма соң инде, тавышлары шулкадәр булып ишетеләдер ки, әмма ләкин мондыйны белгән югые* (Г. Камал).

Төрдәше: бер дигән һ.б.

*ӘНӘ* ❖ **ӘНӘ БАРА ЮЛЫҢ!** Тиргәп куалау сүзе. *Оттыргансың икән, әнә бара юлың*...(В. Имамов. Утлы дала). *Шундый көчсез, таркау күренгән юан, симез кеше Котан бине кинәт якасыннан эләктереп алды да, ишеккә таба төрткәләп: – Әнә бара юлың!* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).

**ӘНӘ НИК (НИЧЕК) ИКӘН.** «Эш менә нәрсәдән гыйбарәт икән, инде белдем» мәгънәсендә. – *Сез әнә ничек икән әле?!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). – *Әйе, Мөхәммәтша дәдәмнең агасы. – Ә-ә, әнә ничек икән!* (Ә. Еники. Туган туфрак).

**ӘНӘ СИҢА КАРАДУГАН ЮЛЫ.** Яныңдагы кешене куып җибәрү өчен әйтелә. – *Шуның белән сүзең беттеме, әйдә, әнә сиңа Карадуган юлы!* (Сөйләм).

**ӘНӘ СИҢА МАЛ, ТАНЫСАҢ АЛ.** Элекке заманда яучы карчык кыз табышканда шулай дигән. *[Мөгълифә] (Әнвәрне тартып). Әнә сиңа мал, танысаң ал, только бер дә елаганына, сыктаганына карап торма* (Г. Камал).

**ӘНӘ ТЕРӘ<К>.** 1. Сүзенә дәлил итеп төртеп күрсәтү. *Әнә терәк, Гариф мөәзиннең күзлекле улы: «Әйдәгез, ашыйк», – дип әйтә икән* (Г. Тукай). *Әнә терә, кызың нишләп йөри, чишмә башында җегетләр белән әүмәкләшеп, җаулыгын җыртып кайткан* (Ш. Маннур).

2. «Менә сиңа кирәк булса» мәгънәсендә. *Минем кыз әнә терәк, укырга кереп кайткач та «телен җимергән» иде!* (Р. Газетдин. Язмыш сәфәре).

**ӘНӘ ЧОРТ, ЧОРТНЫҢ АРТЫННАН ЮРТ.** «Бар кит моннан» мәгънәсендә кулланыла. *Каяндыр «әнә чорт, чортның артыннан юрт» дигән шаян әйтем исенә төшеп, Гайнан үз-үзенә көлеп куйды* (Г. Бәширов).

*ӘНӘК* ❖ **ӘНӘК ЭТЕ СЫМАН ЙӨРҮ.** Үзенә урын, сыеныр җир тапмыйча йөренгән кеше турында. *...Әнәк эте сыман шәһәр урамнары буйлап бик озак каңгырып йөрдек* (З. Мәхмүди. Тәмуг чәчәге). *Йөрисең бит шунда әнәк эте сыман ары тулганып, бире болганып* (Р. Вәлиев. Иске сәгать дөрес йөри).

*ӘНДРИ* ❖ **ӘНДРИ ӘБӘТЕ.** Җиңелчә икенче аш (төшке ашка кадәр яки төшке аштан соң кичке ашка кадәр). *Иртән «Тамагым авырта, сызлый!» дип җылап уянды, әндри әбәтендә урын өстенә бөгәрләнеп ятты, кичкә йөткергән саен тамагыннан кара кан китте* (А. Гыйләҗев. Йәгез, бер дога!).

**ӘНДРИ КАЗНАСЫ <ЮК>.** Бушка бирергә яки ашатырга сораганда (исәпсез-хисапсыз байлык юк мәгънәсендә) әйтелә. *[Фаизә] Миндә Әндри казнасы юк, бар, эшеңдә бул* (К. Тинчурин.

Йосыф белән Зөләйха). *Өч тапкыр ашарга Әндри казнасы бармыни монда?* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).

*ӘНЕКӘЙ* ❖ **ӘНЕКӘЙ ГЕНӘМ!** *гади с.* Нык шаккату сүзе. – *Әнекәй генәм, чыбыкка абынып, егылып китәм дип торам, тотынып калырга синең кебек киң җилкәле ирләр булганда, нинди рәхәт икән бит, – дип сөйләнеп, Сәкинә Нәсихның күкрәген сыйпап торды* (Ш. Алпар. Милләт өмете).
Төрдәше: әтекәй генәм!

*ӘНИСЕ* ❖ **ӘНИСЕ КОЧАГЫНДА (КУЕНЫНДА).** Әнисе янында яшәү. *Әй, рәхәт иде дә шулай кымшанмый гына әнисе куенында ятулары* (М. Хәбибуллин. Атилла). *Аның әле әнисе кочагында назланасы, сөеләсе килә...* (Х. Ширмән. Асылъяр).
Төрдәше: әнисе кызы.

**ӘНИСЕ КЫЗЫ.** Әнисенә охшаган, *шулай ук к.:* әнисе кочагында (куенында). *Кеше белән сөйләшкәндә, кызарырга гына торган нәфис ак йөзле Зөлфияне әнисе кызы дип кем әйтер* (Л. Ихсанова. Гамбәр кызы Зөлфия).
Төрдәше: әнисе кочагында (куенында).

**ӘНИСЕ СӨТЕ КИПМӘГӘН** *к.*авыздан ана сөте <дә> кипмәү. – *Син ул әнисе сөте кипмәгән кызга нинди эш тапшырмакчы буласың?* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан ана сөте <дә> кипмәү һ.б.

*ӘНИСЕН* ❖ **ӘНИСЕН (АНАСЫН) КУШЫП СҮГҮ** *к.* ата<сы>-анасы белән сүг<ен>ү. *Урам малайларына ияреп йөрергә күнеккән малай бераздан әнисен кушып сүгәргә дә өйрәнеп китте* (Сөйләм).
Төрдәше: ата<сы>-анасы белән сүг<ен>ү һ.б.

*ӘҢГӘМӘ* ❖ **ӘҢГӘМӘ ҖЕБЕ СҮТЕЛҮ.** Рәхәтләнеп сөйләшә башлау. *Әңгәмә җебе сүтелә дә сүтелә* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).

**ӘҢГӘМӘ КАБАРТУ.** Сөйләшүнең җанлана баруы. *Шулай итеп, сүзне сүз тартты, алар әңгәмә кабартып җибәрделәр* (Г. Мөхәммәтшин. Якташлар).

**ӘҢГӘМӘ КОРУ.** Кем белән булса да сөйләшеп тору. *Аның артык кечелекле сыйфаты кайчак гаҗәпкә дә калдыра: бер дәрестә шәхес культы, репрессияләр турында, артык җәелеп китә алмыйча гына, әңгәмә корып алган идек* (М. Галиев).

**ӘҢГӘМӘ КУЕР<Т>У.** Берәр нәрсә турында артык күп сөйләшү, гәпләшү. *...Главный мастерскойның токарьный цехында булган зур митингтан соң, Мохтар Булатов, башка вакыттагы шикелле, иптәшләре белән артык әңгәмә куертмыйча, берүзе генә уйлана-уйлана кайтып китте* (Ш. Камал. Таң атканда). *Ут янында утыручылар җай гына әңгәмә куерталар* (М. Госманов. Каурый каләм эзеннән).
Төрдәше: авызны чишеп җибәрү һ.б.

**ӘҢГӘМӘ САТУ.** Берәр нәрсә турында кирәген дә, кирәкмәгәнен дә озак итеп сөйләшеп тору. *Кышкы озын кичләрдә чәй эчеп, лото уйнап, әңгәмә сатып, төрле кызыклы вакыйгалар, шәкерт мәзәкләре сөйләп утыралар* (А. Расих. Ишан оныгы).
Төрдәше: авызны чишеп җибәрү һ.б.

*ӘҢГӘМӘГӘ* ❖ **ӘҢГӘМӘГӘ КИТҮ (ЧУМУ).** Мавыгып сөйләшеп утыру. *Шуңа колак салып, чәйне акрынлап эчеп, кунак белән хуҗа озын-озын әңгәмәгә киттеләр* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *Һәм без шундый рәхәт әңгәмәгә чумдык, безне күзәтеп торган карт мәчегә хәтле барысын да аңлап, караңгы төшәрәк үз эше белән биләмгә чыгып китте* (М. Мәһдиев. Ачы тәҗрибә).

**ӘҢГӘМӘГӘ СУ КУШУ**. Гәпләшүне бозу, аны төп темасыннан читкәрәк алып китү. *Сезнең әңгәмәгә су кушмаммы соң анда?* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).

*ӘҢГӘМӘНЕ* ❖ **ӘҢГӘМӘНЕ ЮЛЛАУ.** Билгеле бер нәрсә турында сөйләшә башлау. *Карт әңгәмәне икмәккә таба юллап җибәрсә дә, Нәфисә аның тел төбендә ни ятканын абайлап җиткермәгән иде әле* (Г. Бәширов. Намус).

*ӘҢГӘМӘНЕҢ* ❖ **ӘҢГӘМӘНЕҢ ДИЛБЕГӘСЕН ҮЗ КУЛЫНА АЛУ.** Әңгәмәнең темасын бозарга ирек куймау. – *Кисәтү ясарлык сәбәп нәрсәдә инде? – диде кызның әтисе, әңгәмәнең дилбегәсен үз кулына алырга чамалап* (М. Миншин. Кызыл диплом).

«*ӘП*» ❖ **«ӘП» ИТЕП КҮРЕШҮ.** Үбешү. – *Кая, җинкисәгем, бер «әп» итеп күрешик әле. – Һәм Гомәрне кочаклап, ике яңагыннан да үбеп ала* (Ә. Еники. Бер генә сәгатькә).

**ӘП ИТҮ.** Үбү, үбеп алу. – *Сагындырдың да соң, каракаш, кил әле бер әп итим үзеңне, – дип, Нәгыймҗан Гөлнәзирәгә үрелде* (М. Әмирханов. Гөлнәзирә).

*ӘПӘ* ❖ **ӘПӘ КЕБЕК ТЕЛСЕЗ КАТЫП ТОРУ.** Сакау яки телсез кеше. *Чөнки әпә кебек телсез катып тору бераүгә дә күңелле түгел иде* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).

*ӘП<П>ӘР* ❖ **ӘП<П>ӘР ИТТЕРҮ.** Нәрсәдән булса да коры калу, буш калу. *Кичә нindидер машинага утырып кайткан идем, бөтен малымнан әппәр иттерделәр* (Сөйләм).

**ӘП<П>ӘР ИТҮ.** 1. Ашаганнан соң, дога кылган кебек битләрне сыйпап алу. *Ашагач әппәр итәргә өйрәтә торган иде* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!). *Әппәр итеп, рәхмәт әйтеп, урамга чыкты* (Р. Газиз. Ак болыт).

2. Югалту; буш калу. *Район Сабан туенда ун мең сум премия алгач, бөтенләй күрмәм инде аларны дип, әппәр иткән иде инде* (В. Гали. Гомер челләсе). *Тиешле документың булса – ашыйсың, булмаса – ашамаган килеш әпәр ит* (Ф. Хөсни. Мәшәкатьле озын сәфәр).

Төрдәше: колак кагу; колак кактыру; коры калу.

3. Юк итү, үтерү. *Әгәр мин синең үзеңне дә әппәр итәргә кушсам?!* (З. Мәхмүди. Елак агач). *Ашык, юкса кызган башлай әппәр итеп куюым бар* (З. Мәхмүди. Серле кунак).

Төрдәше: адәм башкайларын салу һ.б.

*ӘПӘЧ* ❖ **ӘПӘЧ КАКРЫГЫ** *кин.* Аз булуга ишарә ясау. – *Һе, моның белән нишләргә, әпәч какрыгы кадәр дә юк бу!* (Сөйләм).

Төрдәше: этәч какрыгы.

*ӘПӘ-ЧӘПӘ* ❖ **ӘПӘ-ЧӘПӘ СӨЙЛӘШҮ** *гади с.* Озаклап, гөж килеп сөйләшү. *Утырсын Наилә ахирәтләре белән әпә-чәпә сөйләшеп* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: әҗе-гөҗе килү (итү) 2 һ.б.

**ӘПӘ-ЧӘПӘ КИЛҮ.** 1. Ялый-ялый ашау, сыйлану. *Кунак озак ялындырып тормады, алдына куйган кыстыбыйны әпә-чәпә килеп ашарга тотынды* (Сөйләм).

2. *к.* әҗе-гөҗе килү (итү) 2. *Әни янына күрше хатыны кергән дә, әпә-чәпә килеп утыралар иде* (Сөйләм).

Төрдәше: әҗе-гөҗе килү (итү) 2 һ.б.

*ӘПЕН-ТӨПЕН* ❖ **ӘПЕН-ТӨПЕН ЭШЛӘҮ.** Тиз генә, ничек туры килсә шулай. *Алган эшләрне әпен-төпен эшләп бетерергә дә – ычкынырга!* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы).

*ӘПЕ-ЧӨПЕ* ❖ **ӘПЕ-ЧӨПЕ КИЛҮ** *гади с.* 1. Сыйлану, авызны чүпелдәтү. *Нишлисең бит, без бу дөньяга пар-пар булып яшәү өчен, шатлыгын да бергә күреп, кайгысын да бергә кичереп яшәү өчен килгәнбез. Әпе-чөпе килеп кенә, мәхәббәттән исереп кенә яшәү өчен түгел!* (Ф. Баттал).

Төрдәше: әпә-чәпә килү 1.

2. *к.* әҗе-гөҗе килү (итү) 2. – *Ничек түймыйлар болар, инде ике сәгать әпе-чөпе киләләр* (Сөйләм).

Төрдәше: әҗе-гөҗе килү (итү) 2 һ.б.

*ӘПСЕ* ❖ **ӘПСЕ БУЛГЫРЫ!** *к.* авызыңнан җил алсын. *Әпсе булгыры, мондый сүзләрең үз башыңа килсен* (Сөйләм).

Төрдәше: авызыңнан җил алсын һ.б.

*ӘПЧИ* ❖ **ӘПЧИ КАРЧЫК.** 1. Элекке мәҗүсилектә рухани карчык. *[Миләүшә] Мин әпчи карчыклар шикелле бит, Галимулла* (Т. Миңнуллин). – *Егерме беренче гасыр томанасы икән син, әпчи карчык!* (Н. Гыйматдинова. Кыргый).

2. Биләмче карчык: күп сөйләүчән, һәрнәрсәне төпченүче; им-томчы. *Корыны бушка әвеш-тәвеш китереп йөрүче әпчи карчык түгелмен* (А. Гыйләҗев). – *Әпчи карчык Апушның ике күзен дә чүпрәк белән бәйләп куйды* (Р. Батулла. Апуш-Тукай).

3. *күч.* Үлем; газраил. *Ятагында озак ятмады ул, Әпчи карчык аны үзе белән алып китте* (Сөйләм).

*ӘР* ❖ **ӘР ҖЕБЕН ӨЗМӘК БУЛУ.** Башланган талашны бетерергә тырышу. *Сүз болай куергач, Хәлимә түти дә чыдамады, иренә ялварып, әр җебен өзмәк булды* (Б. Камалов. Мәрдән сукмагы).

*ӘРӘМ* ❖ **ӘРӘМ ТАМАК.** Эшләмичә, бушка ашап ятучы. *[Габсаттар] Кара, син, аны йөзе караны, әрәм тамакны* (Г. Камал. Көндәш). *Бирәү дә аңа: «әрәм тамак» дип, «әнкәң җилкәсендә ятасың», дип әйтә алмый* (И. Гази. Онытылмас еллар).

Төрдәше: авыз күтәреп яту һ.б.

**ӘРӘМ ТАМАК БУЛУ** *к.* арка тиресен каезлау 2. *[Фаизә] Бу шифырт халкын уйлап торам-*

*торам да хәйранга калам. Бу кадәр дә әрәм тамаклар булырлар икән* (К. Тинчурин. Йосыф белән Зөләйха).
Төрдәше: арка тиресен каезлау (тунау) 2 һ.б.

**ӘРӘМ ЯТУ.** Нәрсәнедер (яки берәр кешенең сәләтен, осталыгын) файдаланмау. *Укыт мине, газиз атам, / Югыйсә мин таштай катам, / Һич ни белми, һич ни күрми, / Ихтыярсыз әрәм ятам* (Г. Исхакый. Мөгаллимә). *Тукай биографиясендә, тормышында шундый лирик кичерешләр күп. Зәйтүнә үзе кечкенә бер повесть. Әрәм ята* (М. Хуҗин. Уеннан – уймак).

**ӘРӘМ-ШӘРӘМ ИТҮ (ИТЕП БЕТЕРҮ).** Туздыру, мал юк-барга китү. *[Фаизә] Бөтен җиһазларымны әрәм-шәрәм итеп бетерде* (К. Тинчурин. Йосыф белән Зөләйха).
Төрдәше: җилгә ату; җилгә китү; җилгә очкандай булу; җилгә очу; җилгә очыру; җилгә сарыф кылдыру; җилгә ташлау; җилгә туздыру; суга салгандай итү; суга салу; суга ташлау; шулай ук к.: акча әрәм-шәрәм итү.

**ӘРӘМ-ШӘРӘМГӘ ТОТУ** *к.* әрәм-шәрәм итү (итеп бетерү). *Хәтта кызганып куйдым, шундый яхшылап шомарткан тактаны әрәм-шәрәмгә тотып бетерә бит!* (Сөйләм).
Төрдәше: әрәм-шәрәм итү (итеп бетерү) һ.б.; шулай ук к.: акча әрәм-шәрәм итү.

*ӘР-БИТӘР* ❖ **ӘР-БИТӘР БЕЛДЕРҮ (ЯУДЫРУ).** Талаш-ызгыш чыгару. *Хатын-кыз пырдымсыз Рәхимҗанга әр-битәр яудырганда, чыелдап өйалды ишеге ачылды* (Н. Гыйматдинова. Мәхәббәттә гөнаһ бар). *Белми кемгә белдерергә әр-битәр* (Р. Идиятуллин. Хәерле кич).
Төрдәше: әри-пәри килү; борын чәйнәшү; буран чыгу; гауга кубару (куптару; чыгару); давыл кубу; давыл кубару (куптару); давыл күтәрү; дау кубару; дау куптару; дау күтәрү; даулап йөрү; зилзилә чыгару; зилзилә ябу; Сафура бураннары кубару (куптару, күтәрү); сүзгә килешү; сүзгә килү 1; тавыш кубару (куптару); тавыш кубу; тавыш күтәрү 2; тавыш чыгару; тавыш-гауга чыгу; тавышка керү.

*ӘРВАХ* ❖ **ӘРВАХ ИТҮ.** Бу дөньядан теге дөньяга күчү. *Әллә югыйсә Ходай аларның икесен бер көнне үк әрвах итмәк буламы?* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).
Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

*ӘРВАХКА* ❖ **ӘРВАХКА ОХШАГАН.** Өрәккә охшату, бик нык ябыккан кеше турында. *Бу мәчетнең мәзине әрвахка охшаган икән* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз ачса, кече теле күренү 1 һ.б.

*ӘРВАХЛАР* ❖ **ӘРВАХЛАР ШАТ БУЛСЫН.** Вафат булганнарны искә алу, мәҗлесләр үткәрү белән бәйле әйтелә. *Хәерле юлга! / Әрвахлар шат булсын!* (Г. Рәхим).

*ӘРДӘНӘСЕ* ❖ **ӘРДӘНӘСЕ ҖИМЕРЕЛҮ.** Каты итеп кикереп кую. *Минем күршем каклаган каз белән артык дуслашып китте бугай, урыныннан торганда әрдәнәсе җимерелеп китте* (Сөйләм).

*ӘРЕКМӘН* ❖ **ӘРЕКМӘН АСТЫНА КАЧУ.** Җаваплылыкны үз өстенә алмау. *Шулай булмаса, алар без бушка эшләп йөргәндә, әйтик, булган экспонатларны саклап калу ниятеннән музейга магистраль үткәргечтән җылылык кертү өчен күкрәгебез белән диярлек асфальт юл астыннан тоннель тишеп чыкканда, «Первыйның рөхсәте юк», дип, әрекмән астына качмаслар иде* <...> (Н. Гамбәр. Ма-ту-у-у!!!).

**ӘРЕКМӘН БОЛАМЫГЫ.** Булдыксыз, җебегән. – *Бүлдермә, кәҗә катыгы! – Ә син әрекмән боламыгы!* (Г. Ахунов). *Броневигы юк, әмма ул сиңа әрекмән боламыгы түгел, атын да, машинасын да таба әйберне төяп кайтырга* (Т. Галиуллин. Мәкер).
Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**ӘРЕКМӘН КОЛАК.** Кайтарылып торган зур колаклы кеше турында. *Лапасның һәр бүлемен, почмагын дигәндәй карады-тикшерде тычкан күз, әрекмән колак, бәхеткә каршы, кош баласын таба алмады* (Ә. Әминев. Бер көймәдә...). *Ә бу әрекмән колак, изгелеккә явызлык кылгандай, гаҗәп киреләнеп, кулына тоттырган бишмәтен атты да бәрде* (С. Поварисов. Пәйгамбәр таңы).

**ӘРЕКМӘН КЫСТЫБЫЕ.** Һәр нәрсәгә кысылырга яратучы кеше турында. *Бигрәк тә әрекмән кыстыбые инде синең танышың, тыныч кына утыра алмый* (Сөйләм).

**ӘРЕКМӘН ШУЛПАСЫ ЭЧМӘҮ** *к.* авыздан ана сөте <дә> кипмәү. *[Алчын] Әйе, аннан ул сине казыйга тоттырып бирсен дә үзе бик әй-*

*бәтләп торып синең Сәлвиеңә өйләнсен! Әрекмән шулпасы эчмәгәнсең икән әле, егет* (Н. Исәнбәт. Х. Насретдин).
Төрдәше: авыздан ана сөте <дә> кипмәү һ.б.

*ӘРЕМ* ❖ **ӘРЕМ АВЫЗ.** Усал, төртмәле сүзләр әйтүче кеше. *[Гарифә] (салкын гына). Әйбәт әле, әрем авыз, сыткы сагыз* (Т. Гыйззәт).
Төрдәше: әрем тел<ле>; әче тел<ле>; елан кебек чагу 1; елан тел; зәһәр тел; усал телле.

**ӘРЕМ ТЕЛ<ЛЕ>** *к.* әрем авыз. – *Юкны сөйлисең, әрем тел син!* – *диде дә яңадан җаваплашмады, эченнән: «Килерләр, тикшерерләр», – дип уйлап, Җиһанша бабай янына барды* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар). *Аның бит әрем теллесе дә күп, һәр сүзе үтеңне сыта* (Н. Гыйматдинова. Җәза).
Төрдәше: әрем авыз һ.б.

**ӘРЕМ ЫШЫКЛАРЫ ДА ЮК <БИТ, ИЧМАСАМ>**. *Абау, җаным, бигрәк тә ябык икән ич ул, әрем ышыклары да юк бит, ичмасам!* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз ачса, кече теле күренү 1 һ.б.

*ӘРЕМГӘ* ❖ **ӘРЕМГӘ ТАЯНУ (ТАЯНЫП КАЛУ).** Алдану, ялгышу. *Әйдә, җаным, сәхрәләргә, / Таянырсың әремгә, / Таянырсың да калырсың, / Мин булырмын яренгә* (Җыр).
Төрдәше: агач атка (аргамакка) атлану (атланып калу) һ.б.

*ӘРҖӘ* ❖ **ӘРҖӘ ТЕГҮ.** Каты гырылдап йоклау. *Өйнең түр ягында кемнеңдер әрҗә теккән тавышы гына ишетелә иде* (Сөйләм).

*ӘРИ-ПӘРИ* ❖ **ӘРИ-ПӘРИ КИЛҮ.** Бозылышу, әрләшү-талашу, гауга чыгару. *Башта ике хатын сүзгә кергәннәр иде, соңыннан исә бөтен ишегалды әри-пәри килеп бетте* (Сөйләм).
Төрдәше: әр-битәр белдерү (яудыру) һ.б.

*ӘРЛЕ* ❖ **ӘРЛЕ ӘРЛӘНЕП ЙӨРГӘНЧЕ, ӘРСЕЗ АШАП ТУЙГАН.** Оялчан, хәтере калучан кешегә яшәве авырга килү турында. *«Әрле әрләнеп йөргәнче, әрсез ашап туйган» дигәннәр борынгылар, бу тормышта гадирәк булырга кирәк* (Сөйләм).

*ӘРЛЕ-БИРЛЕ* ❖ **ӘРЛЕ-БИРЛЕ БӘРЕЛҮ (СУГЫЛУ)** *к.* ары-бире бәрелү (сугылу). *Кинәт кенә ишек кыңгыравы чылтырый башлагач, Ләйсән, нәрсә эшләргә белмичә, әрле-бирле сугылырга тотынды* (Сөйләм).
Төрдәше: ары-бире бәрелү (сугылу) һ.б.

2. *к.* арлы-бирле бәрелү (сугылу) 2. *Маңгаена салкын тир бәреп чыкты, учлары тирләде, аяклары хәлсезләнде, башында уйлары әрле-бирле сугылды* (А. Нәҗми. Азат).
Төрдәше: арлы-бирле бәрелү (сугылу) 2 һ.б.

**ӘРЛЕ-БИРЛЕ ЙӨРҮ**. 1. Әле бер якка, әле икенче якка хәрәкәт итү. 1. *Президент аңа утырырга кушты, ә үзе, озак кына уйланып, әрле-бирле йөрде* (И. Хуҗин. Кремльдә ыгы-зыгы).
Төрдәше: ары-бире бәрелү (сугылу) һ.б.

2. *күч.* Башта төрле уйлар бер-бер артлы туа тору. *Башында әрле-бирле йөргән уйларыннан ул, корыч атын туктатып, бераз ял итеп алмакчы булды* (А. Нәҗми. Азат).
Төрдәше: арлы-бирле бәрелү (сугылу) 2 һ.б.

**ӘРЛЕ-БИРЛЕ КИЛҮ.** 1. Тегендә-монда йөгерү, кабалану. *Ул, һаман әрле-бирле килеп, кичке ашка әзерләнде* («Казан утлары» ж.).
Төрдәше: ары-бире бәрелү (сугылу) һ.б.

2. *к., күч.* арлы-бирле бәрелү (сугылу) 2. *Килеп чыккан хәлнең ничек итеп очына чыгарга икән дип, кичә дә шактый уйланган иде, менә бүген дә иртәдән үк аның уйлары әрле-бирле килә башладылар* (Сөйләм).
Төрдәше: арлы-бирле бәрелү (сугылу) 2 һ.б.

*ӘРНӘШ* ❖ **ӘРНӘШ ТЕГЕРМӘНЕ.** Әкрен кыймылдаучан, ялкау кеше турында. *Әрнәш тегермәне булма инде, тизрәк киен, театрга соңга калабыз ич* (Сөйләм).
Төрдәше: авыр аяклы 1 һ.б.

*ӘРСЕЗ* ❖ **ӘРСЕЗ АЛАБАЙ.** Чыдам, күндәм, үзе турында әйтелгән төрле сүзләргә игътибар итмәүчән кеше; әрсез, ертлач кеше. *Мин, әрсез алабай, тәвәккәлләп киттем* (Ф. Хөсни). *Аннары Югары очның Хөсәен, әрсез алабай, киң балакларын җилфердәтә-җилфердәтә каршысына төшеп, март ата казы күк тыпырдап торды да, бөгелә-сыгыла, Санияне биергә чакырды* (А. Гыйләҗев).
Төрдәше: әрсез балта сабы; бите җәһәннәмгә керсә дә кызармас; битен юмаган; битенә дуңгыз тиресе каплау; битенә күн теккән; битенең керенә биш эт туярлык; биткә олтан салу; биткә ыштыр каплау (ябу); битсез кеше; эт каешы <булу>; шомарган таш.

**ӘРСЕЗ БАЛТА САБЫ.** Күпне күргән, шунлыктан шомарып беткән. *Әбүбәкер Солдат, әрсез балта сабы, русчага шомарып кайткан, сулдан уңга каләм йөртә белә* (М. Рәфыйков. Йомышчы Әбүбәкер, яки «Ни булса, ни була...»).
Төрдәше: әрсез алабай һ.б.

*ӘРСЕЗГӘ* ❖ **ӘРСЕЗГӘ КИЯ ТОРГАН.** Көндәлек кием. *Әрсезгә кия торган киемнәре бераз туйдырган иде инде, ниһаять, аларны алыштырырга форсат чыкты* (Сөйләм).

*ӘРТИЛ* ❖ **ӘРТИЛ МУНЧАСЫ.** Чисталык белән шапшаклык бергә буталган, төрле исләр, тавышлар, бәхәсләр булган, тәмәке төтене баскан җир. *Тәмәке төтененә буыла-буыла ютәлләүләр дә кушылгач, бүлмә эче әртил мунчасына охшап китте* (К. Тинчурин).

*ӘРХӘРӘЙ* ❖ **ӘРХӘРӘЙ СӘГАТЕ КЕБЕК.** Төгәллекне саклый торган кеше турында. *Ул, әрхәрәй сәгате кебек, төп-төгәл үз вакытында килеп җитәчәк* (Сөйләм).

*ӘСӘК* ❖ **ӘСӘК БЕЛӘН КҮ(Ө)СӘК** *к.* Аг<ы>лый белән Таг<ы>лый <йөрү>. *Әсәк белән Көсәк кебек урам буйлап берни дә сөйләшмичә йөрисең* (Х. Вазыйх).
Төрдәше: Аг<ы>лы<й> белән Таг<ы>лы<й <йөрү> һ.б.

*ӘСӘН* ❖ **ӘСӘН КҮСӘГЕ.** Утын агачы белән чагыштыру. *Әлифне таяк дип белмәгән әсән күсәкләре эшли торган музыка мәктәбенә бирәмме соң мин баламны?!* (Ф. Шәфигуллин).

*ӘСӘР* ❖ **ӘСӘР ИТҮ.** Йогынты ясау, тәэсир итү. *[Галиәкбәр] Халыкка бигрәк әсәр итү өчен, минә сездән комиссия дә ясаттылар* (И. Багданов. Помада мәсьәләсе).

*ӘСӘРЕ* ❖ **ӘСӘРЕ ДӘ ЮК (КҮРЕНМӘҮ).** Нәрсәненңдер бөтенләй юклыгын белдерә. *[Сәфәргали] Үзе чистый балчыктан әвәләгән, сөяк дигән затның әсәре юк* (К. Тинчурин. Йосыф белән Зөләйха).

*«Ә»СЕ* ❖ **«Ә»СЕ ДӘ, «ҖӘ»СЕ ДӘ ЮК.** Бер аваз да чыгармыйча. – *Нурмөхәммәтнең «ә»се дә, «җә»се дә юк инде аның. Бер ноктага баккан да, эшли дә эшли* (Д. Салихов. Чукрак).

*ӘСИР* ❖ **ӘСИР ИТҮ.** Үзенә җәлеп итү, көчле тәэсир ясау. *Сүз белән алдыра торган ирләр була, кайберәүләр буй-сын белән хатын-кызны һушсыз итәләр, өченчеләр кылган гамәлләре белән кыз-кыркынны үзенә тарта, бирген татлы вәгъдәләре белән әсир итә* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). – *Серле кыз карашы / Мине шагыйрь итте! / Кыз тавышы (һәм дәшмәве!) / Мине әсир итте* (Р. Гаташ).

**ӘСИР ТӨШҮ.** Сугышта дошман кулына эләгү. *Минә алар вәхшиләргә әсир төштеләр, кул-аяклары бәйләнгән килеш зинданда яталар* (А. Тимергалин. Таш алиһә). *Урыс баскыннары һәм йомышлы татарлар, кальганы талау белән бергә, әсир төшкән яугирләрне, хатыннарны һәм балаларны юк итү белән дә шөгыльләнделәр* (З. Мәхмүди. Елак агач).
Төрдәше: әсирлеккә төшү.

*ӘСИРЛЕККӘ* ❖ **ӘСИРЛЕККӘ ТӨШҮ** *к.* әсир төшү. *Гумбинен янындагы каты сугышта әсирлеккә төшкән Шәйхине Эчке Германиягә озаттылар* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).
Төрдәше: әсир төшү.

*ӘССАБРЫ* ❖ **ӘССАБРЫ БЕТҮ.** Артык түзә алмау. *Ул, китапчалатып, «әссабрым бетте» диде һәм урамга чыгып китте* (Сөйләм).
Төрдәше: сабыр җебе өзелү; сабыр канатлары сыну; сабыр капчыгы тулу; сабыр капчыгы чишелү; сабыр коесы (коелары) тулу; сабыр көймәсе тишелү; сабыр сабы ычкыну; сабыр сабыннан ычкыну; сабыр савыты ташу (тулу); сабыр сыну; сабыр түкәнү (калмау); сабыр чылбыры өзелү; сабыр <казаны> шартлау; сабыр югалу; сабырлык бетү; сабырлык сыну; сабырлык төкәнү; сабырлыкны җую; сабырлыкны югалту; сабырлыкның күңел алачыгыннан чыгып китүе; сабырсызлык күрсәтү; түзем капчыгы тишелү; түзем төкәнү; түзем чиләге кору; түзем чиләген әйләндереп каплау; түземлеге бетү; түземлек касәсе ташу; түземлек төкәнү (калмау); чыдам касәсе тулу; чыдамнан узу; чыдамлык касәсе ташу; чыдар хәл калмау 1.

*ӘСТ-ВӘСТ* ❖ **ӘСТ-ВӘСТ КИЛҮ.** Яхшы танышлар кебек сөйләшеп тору. – *Ахырга таба карыйм, мастер Потапов безнең горлапан Якимов, Крутяковлар тирәсендә еш чуала башлады. Әст-вәст киләләр* (Н. Хәсәнов. Язмышың сыналганда...).

*ӘСТЕРХАНДА* ❖ **ӘСТЕРХАНДА СЫЕР БЕР АКЧА, КИЛӘ-КИЛӘ МЕҢ АКЧА.** Мәшәкатен уйламыйча, мәнфәгатен генә төшенү.

*Әстерханда сыер бер акча, кил*ә*-кил*ә *мең акча* (К. Насыйри. Мәкальләр һәм әйтемнәр).

*ӘТӘК-СӘТӘК* ❖ **ӘТӘК-СӘТӘК СҮЗ СИПТЕРҮ** *к.* авыздан куык очыру. *Стадион сәкеләрендә бераз әтәк-сәтәк сүз сиптереп утырдык та, аннан өйләргә таралдык* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан куык очыру һ.б.

*ӘТӘМБИ* ❖ **ӘТӘМБИ БӘРӘН.** Көзен туган бәти (зәгыйфь, чирләшкә бала турында). *Әтәмби бәрән кебек булды ул, табибларга күп йөрергә туры килде* (Сөйләм).

**ӘТӘМБИ БӘРӘН УРЫНЫНА БАРЫП ТӨШҮ.** Зәгыйфь, хәлсез булуга ишарә ясау. *Сугып җибәргән саен, әле берсе, әле икенчесе әллә кая әтәмби бәрән урынына тәгәрәп барып төшә* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

*ӘТӘЧ* ❖ **ӘТӘЧ АЗАН ӘЙТКӘНДӘ** *к.* абага чәчәк аткач (атканда). *«Каз казык какканда, әтәч азан әйткәндә» дигән мәкаль исенә төшсә дә, хыяллары зурдан иде әбинең* («Хезмәт даны» газ.).
Төрдәше: абага чәчәк аткач (атканда) һ.б.

**ӘТӘЧ БАШ** *мыск.* 1. Әйдаман, баш булырга яратучы; кукыраеп йөрүче кеше. *Икенче атнага мари урманын әйләнеп кайтмыйбызмы – җитәкче сайлыйсы юк, әтәч башыбыз бар* (Сөйләм).

2. *к.* алты-биш карама бүкәне. *Әтәч баш әйдаманнарыбыз шактый булды инде, юньлерәген табасы иде* (Сөйләм).
Төрдәше: алты-биш карама бүкәне һ.б.

**ӘТӘЧ БЕЛӘН СУКА СӨРҮ** *к.* алгы-салгы гомер уздыру (уздырып йөрү). *Әтәч белән сука сөрү* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).
Төрдәше: алгы-салгы гомер уздыру (уздырып йөрү) һ.б.

**ӘТӘЧ БЕЛӘН ТОРУ.** Бик иртә уяну; иртән иртүк тору. *Габделҗәмил тәүге әтәч белән торып, калага печән сатарга китәргә тиеш иде* (М. Кәрим. Ишеткәннәр, күргәннәр...). *Яз чәчәләр, көзен уралар, / Мәшәкатьле тормыш дәвам итә, / Әтәч белән иртүк торалар* (И. Гыйләҗев. Тормыш туктамас).

**ӘТӘЧ БЕЛӘН ЯТЫП, СЫЕР БЕЛӘН ТОРУ** *ирон.* Күп йоклау. *Ник соңга калсын, әтәч белән ятып, сыер белән тора бит ул!* (Сөйләм).

**ӘТӘЧ БУЛУ.** Җитәкче, башлык вазыйфасын башкару. *Миңа буйсынмыйча, бик тәкәббер әтәч булырга җыенган идең бугай* (В. Имамов. Утлы дала).

**ӘТӘЧ БУЛЫП КУНУ.** Ябырылу, сүз әйтергә дә ирек бирмәү. *Әле Алимбай әкә кул куя башлагач та, Өннәш аның өстенә әтәч булып кунды, кулындагы каләмен тартып* алды (Я. Зәнкиев. Өтелгән мәхәббәт).

**ӘТӘЧ БУЛЫП КЫЧКЫРУ.** 1. Булганны тизрәк сарыф итәргә тору; кулындагы акчаны саклый алмау, аны әрәм-шәрәм итү. *Ярлы кеше акчаны кесәсеннән чыгарасы килми күпме генә кысып торса, акча шулкадәр аның кесәсеннән җиңел шуып чыга. Аның өчен ярлы кесәсендә тынычлык юк. Шуңа күрә «ярлы кешенең акчасы әтәч булып кычкыра» диләр* (Ә. Фәйзи. Тукай).
Төрдәше: акча әтәч булып кычкыру 2.

2. Бернинди дә дәрәҗәсе булмаган кеше югарырак урынга менсә, үзен әллә кем дип уйлый башлавына ишарә. – *Балак бете башка менсә, әтәч булып кычкыра, ди* (В. Имамов. Тозлы яра).

**ӘТӘЧ ГОМЕРЕ.** Бик кыска гомер. *Аның өчен солдатларның гомере әтәч гомере генә булып күренгән кебек* (Сөйләм).

**ӘТӘЧ ҖИБӘРҮ.** 1. Сөйләгәндә яки җырлаганда, тавыш өзелү яки урынсыз һәм сәер яңгыраган тагын да нечкәрәк тавышлар чыгару. *Матур гына җырлап килгән чакта, тагын да югарырак нотаны алырга чамалаган җырчы көтмәгәндә әтәч җибәрде* (Сөйләм).

2. Ут төртү, яндыру. *Әти Себердә, Бояр йортына әтәч җибәргән өчен катыр китте* (Г. Гобәй).
Төрдәше: кызыл әтәч җибәрү; кызыл әтәч куну; кызыл әтәч ялау; кызыл үгез җибәрү; ут төртү.

**ӘТӘЧ ИТҮ.** Берәрсен кукрайтып, юри мактап көлкегә калдыру; мыскыллау. – *Килсен, килсен, без аны йолкынган әтәч итәрбез* (Д. Каюмова. Урланган бәхет).

**ӘТӘЧ КАКРЫГЫ.** Бик аз, кечкенә генә. – *Булышырмын, эшләрмен, дигән буласың, әлегә әтәч какрыгы кадәр дә эшең күренми* (Сөйләм).
Төрдәше: әпәч какрыгы.

**ӘТӘЧ КЕБЕК КУКРАЕП ЙӨРҮ.** Күкрәген киереп йөрү. *Янгын хәрабәләре янындагы шактый*

*зур мәйданда берничә рәткә тезелгән кызылармеецлар алдында, әтәч кебек кукраеп, Миңлебай Атнагулов йөренә* (С. Юзеев. Үлгәннәрне бүлдермә). *Кызлар каратыйм дип, әтәч кебек кукраеп йөрүче егетләрне һич кенә дә күз алдына китерә алмыйм* («Матбугат.ру» порталы).

**ӘТӘЧ КУКРАЮЫ.** Булдыра алмаса да булдырган кеше кебек кылану. *Бу мөдирнең кулыннан эш бик килмәсә дә, әтәч кукраюын яхшы өйрәнгән* (Сөйләм).

**ӘТӘЧ КУРАЗЫ.** Тәкәббер, һавалы кеше; әтәчнең әтәче, мактанчык. *Урам чатындагы йортта яшәгән әтәч куразын белә торгансыңдыр?* (Сөйләм).

**ӘТӘЧ КҮКӘЙ САЛГАНДА** *к.* абага чәчәк аткач (атканда). *Көт, көт, әтәч күкәй салганда алырсың аннан* (Сөйләм).

Төрдәше: абага чәчәк аткач (атканда) һ.б.

**ӘТӘЧ<ЛӘР> КЫЧКЫРГАНЧЫ.** Таң атканчы, яктырганчы. *Аннан соң бер дога бирде: «Боларны, иртә белән әтәч кычкырганчы, бусагага кыстыр», – диде* (Г. Ильяси. Бичара кыз).

**ӘТӘЧ КЫЧКЫРТУ.** Зурдан кубып, күпертеп сөйләү. *Тик үзәк матбугат кына «Казан феномены» дигән уйдырма тирәсендә шактый вакыт әтәч кычкыртты* (Т. Галиуллин. Сәет Сакманов).

**ӘТӘЧ СИНЕҢ ХӘРФЕ ҖӘРЕҢНЕ КАЯН БЕЛСЕН?** Наданлыктан көлеп әйтелә. *Без ышанамыз: – Бенедикта «Яңгыр сарае» бар, ди. Һи, ява, ди, яңгыр, ява, ди. – Әтәч синең хоруфе җәреңне кайдан белсен?..* (Ф. Әмирхан).

Төрдәше: ак-кара танымау һ.б.

**ӘТӘЧ ТӘ КУК (КҮК), МИН ДӘ КУК (КҮК)** *мыск.* Кешенең әтәч кебек кукраеп, үзен генә белеп, мактанып йөрүе турында. *Әтәч тә кук, мин дә кук дигәндәй, Акмал да элекке төсле һәммә нәрсәне гафу итеп торучан авыл мокыты түгел хәзер, йодрык белән уйнауның да кыйммәткә төшүен аңлады бит инде <...>* (Г. Ахунов. Эт патшасы).

**ӘТӘЧ ТӘПИЕ.** Шешә бөкесен ачу боравы. *– Әнисе, безнең әтәч тәпие кая китте икән, күрмәдеңме?* (Сөйләм).

**ӘТӘЧ ТИРЕСЕ <КЕБЕК>.** Юка һәм чыдамсыз материал. *Ләкин ул пәлтә озын гомерле булмады, бер-ике тапкыр кигәч, әтәч тиресе кебек юка чыдамсыз «күн»е умырылып төште* (Батулла. Туган ягым – Зәй төбәге). *Халык, «әтәч тиресе» дип аталып йөртүче плащларга төренеп, иртән эшкә кузгалды* («Безнең гәҗит» газ.).

**ӘТӘЧ ТУК, ЧЕБЕШ ТӘ ТУК.** Ике як та файда күрү. *Ләкин без – яшьләр – акчага исебез китми, барган бер авылыңда «фальшивый» билет белән концерт куясың, әтәч тә тук, чебеш тә тук* (М. Мәһдиев. Ачы тәҗрибә).

Төрдәше: бүре дә, сарык та тук булсын; бүре дә тук булсын, куй да сау булсын; бүре дә тук, сарык та исән <булу>; сарык та исән <калсын>, бүре дә тук <булсын>.

**ӘТӘЧ ФӘХРИ (ПӘХРИ).** Үтә мактанчык кеше. *Икесе дә «Әтәч Фәхри» иде бу минутта. Бу килештән бер-берсенә очып кунудан да ары китмәсләр кебек күренгән иде* (Ф. Хөсни. Мәйдан).

**ӘТӘЧ ШИКЕЛЛЕ СИКЕРЕП КУНУ** *к.* әтәч булып куну. *[Хәбир:] Нигә әтәч шикелле сикереп кунарга гына торасың әле син?* (Ф. Шәфигуллин. Бер малай, өч аргамак).

*ӘТӘЧЕ* ❖ **ӘТӘЧЕ ДӘ ЙОМЫРКА (КҮКӘЙ) САЛА.** Баерга булган кешенең булмас җирдән дә баюы, шуннан көнләшеп әйтү. – *Биргән бит Ходай аларга, аларның әтәче дә йомырка (күкәй) сала* (Сөйләм).

Төрдәше: алтын бишектән төшү һ.б.

**ӘТӘЧЕ ДӘ КУБЫЗ УЙНАУ.** Эше алга китү, бәхете ачылу, мул тормышта яшәү. *Бай кешенең әтәче дә кубыз уйный* (Ай колакланса, ни була?).

Төрдәше: әтәче дә йомырка (күкәй) сала һ.б.

**ӘТӘЧЕ УЯНСА, ҖИЛЛӘНЕП АЛСЫН.** «Нәрсәне булса да башкаруны максат итеп куйса, әйдә, тырышып карасын» мәгънәсендә. *Туктамыш хан һичбер төрле нигъмәтне ят итми, әтәче уянса, җилләнеп тә алсын* (В. Имамов. Карабәк).

*ӘТӘЧЕГЕЗ* ❖ **ӘТӘЧЕГЕЗ КҮКӘЙ САЛАМЫ?** *мыск.* Мыскыллап-көлеп сорау. *Мин куырылып куям: «Ахмак! Әтәчегез күкәй саламы, булды бит бу»* (Р. Сибат. Сәридә).

*ӘТӘЧКӘ* ❖ **ӘТӘЧКӘ <ДӘ> СӘЛАМ БИРМӘҮ.** Үзен югары тоту, кешеләрне танымау. *Хәзер хакимияттә эшли башлагач, әтәчкә дә сәлам бирми, үзен Алланың кашка тәкәсе итеп күрә башлады* (Сөйләм).
Төрдәше: алып узу һ.б.

*ӘТӘЧЛӘНЕП* ❖ **ӘТӘЧЛӘНЕП ЙӨРҮ.** Күкрәк киерү, мактану; шулай ук *к.:* алып узу. *Юкса син, коммунистлар яшь чакта гына әтәчләнеп йөриләр дә, картайгач күбесе Алланы исенә төшерә, дип әйтәсең бит* (Ш. Рәкыйпов). *<...> килә-килешкә ат өстеннән җиргә сикереп төшеп, җилләнеп каршысына килеп баскан комиссар Усмановны күреп, яңа гына әтәчләнеп йөргән командир кисәге бөтенләй мәлҗерәп төште* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).
Төрдәше: алып узу һ.б.

*ӘТӘЧЛӘНЕРГӘ* ❖ **ӘТӘЧЛӘНЕРГӘ ТОТЫНУ.** Үзенең кемлеген күрсәтә, мактана башлау. *Бу аргы як егете моңарчы бер кырыйда мәлҗерәп утырган иде, ничектер айнып китте дә әтәчләнергә тотынды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Кулына озын, штыгы дүрт кырлы, трехлинейка дигән мылтык та килеп кергәч, Габдрәхим әтәчләнергә тотынды* (З. Зәйнуллин. Сугыш алды малайлары).

*ӘТЕКӘЙ* ❖ **ӘТЕКӘЙ ГЕНӘМ** *к.* әнекәй генәм. *– Әтекәй генәм! Карале боларны! – ди ул. – Дөнья малы – дуңгыз каны, дигән олылар. Мал артыннан шулкадәр куармы кеше?!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Кыз, төенчеген кара чемоданы өстенә куеп, Шәрифуллинга күтәрелеп карады һәм, кыю хәрәкәт белән, күрешергә дип, үзе кулын сузды: – Әтекәй генәм, Вәли абый, сез бит бу! Бик исән генәме?* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).
Төрдәше: әнекәй генәм!

*ӘТИ* ❖ **ӘТИ МАЛАЕ.** Бөтен яктан да әтисенә охшаган улы. *Мин – әтиемнең малае, / Ике кулымда һөнәр. / Балтасы да, пычкысы да / Минем кулыма күнәр* (Л. Шәех. Мин кем малае?). *Мин гаиләдә өченче кыз булсам да, әти малае идем* (И. Бәдретдинова).
Төрдәше: анасы кызы (улы; малае).

**ӘТИ ТУМАС БОРЫН, БАБАЙ БЕЛӘН.** «Элекке заманда, үткән бер вакытта» мәгънәсендә кулланыла; гадәттә, әкиятләрнең башламы. *«Бер елны, әти тумас борын, бабай белән Цызгановка ялланырга киттек* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Әти тумас борын, бабай белән өч ага-эне бергә гомер кичердек* («Яңарыш» газ., Төмән).

*ӘТИ-ӘНИ* ❖ **ӘТИ-ӘНИ ФАТЫЙХАСЫН АЛУ**. Берәр нәрсә эшләр өчен ата-анадан рөхсәт алу. *Әмма дәрте ташып торган, әти-әни фатыйхасын алган, җитәрлек белеме һәм тәҗрибәсе бар егет үзенең чират үткәрергә генә килмәгәнлеген күрсәтә алды<...>* («Кызыл таң» газ.). *Элекке заманнар балалар, ата-аналарының фатыйхасын алу өчен, бөтен күңелләрен биреп тырышканнар, үз капризларын шуның хакына корбан иткәннәр* («Матбугат.ру» порталы).

*ӘТРАФЛЫ* ❖ **ӘТРАФЛЫ РӘВЕШТӘ.** Төрле яклап (яктан), җентекләп. *Казып чыгарган балчыгын кала читенә ташып иләргә, табылдыкларны әтрафлы рәвештә өйрәнергә керешкән генә иде әле* (Т. Әйди. Елан уты). *Ленар Шәех сәхнәдән яңгыраган һәр әсәргә әтрафлы рәвештә бәя бирде* («Казан утлары» ж., 2009, 2).

*ӘТРӘГӘЛӘМ* ❖ **ӘТРӘГӘЛӘМ (ӘТРӘК-ӘЛӘМ) БУЛУ.** 1. *тар.* Әсир төшеп, кол гаскәр булу турында. *Кайберәүләр әтрәк-әләм булуны кенәз Владимир Мономах заманында әсир төшкән кыпчак ханы Әтрәк исеме белән бәйлиләр* (Сөйләм).

2. Ялланып эшләү. *Тора-бара шул кадәргә барып җитте, әтрәгәләм булып завод-шахта якларына ычкынды* (А. Расих. Сынау). *Унике ел югалып торганнан соң, әтрәк әләм булып, кайтырга ярамый ич инде* (И. Нуруллин. Тукай).

*ӘТТӘ* ❖ **ӘТТӘ ГЕНӘ ЛӘ (ГЕНӘСЕ).** Соклануны, шөбһәләнүне, күңелсезләнүне һ.б.ны белдерү. *Янчык, кулдан кулга күчеп, Газинурга бушап кайтты. – Әттә генәсе! – диде ул, көлеп* (Г. Әпсәләмов. Газинур). *Һай, әттәгенәсе, / Эзли милициясе, / Кайда әттә генәсе?..* (Ш. Галиев).

*ӘТТӘГЕНӘ* ❖ **ӘТТӘГЕНӘ КҮРСӘТҮ.** Гаҗәпләндерү, сокландыру. *Бар икән әле моның миңа әттәгенә күрсәтәсе. Койрыгыннан тарттым; – Тор, дөнья бу!* (М. Хуҗин. Курагай атлары).

*ӘТ-ТӘХИЯТКӘ* ❖ **ӘТ-ТӘХИЯТКӘ КИТҮ.** Хәлсезләнеп чүгү (намаз укыганда тезләнү).

*– Шүрли ул, шуңа чыкмый! Аның тез буыннары әт-тәхияткә китәргә тора* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**ӘТТӘХИЯТКӘ УТЫРТУ** *к.* авыз җебетү 2. *Без аларга «әһ» итәргә дә ирек бирмәбез, әттәхияткә утыртырбыз* (Р. Хафизова).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

*ӘТТӘХИЯТНЕ* ❖ **ӘТТӘХИЯТНЕ УКЫТУ** *к.* авыз җебетү 2. *– Әти каезлады гына, әттәхтемне укытты, – диде ул* (Ф. Латыйфи).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

*ӘҮВАРӘ* ❖ **ӘҮВАРӘ БУЛЫП ЙӨРҮ.** Алданып йөрү (Г. Камал искәрмәсе). *[Кәрим] Аның киткәнен күреп калаем дип, әүварә булып йөри торгандыр* (Г. Камал. Бәхетсез егет. I вариант).

*ӘҮВӘЛ* ❖ **ӘҮВӘЛ БАШТА.** Иң элек. *Әүвәл башта үкчәсен әләктерергә тырыш, үкчәсен!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**ӘҮВӘЛ БАШТАН.** Башыннан ук. *Салкын һава, сыкылы дөнья мине иңнәремнән тотып күтәрә, әкияти дөньяның сихри манзарасына уралып, телсез калган хәлдә әүвәл баштан тыгыз кар көртләре каплаган тыкрыктан урамга менәм* <...> (А. Гыйләҗев. Күңелем серләре).

**ӘҮВӘЛ БАШТАН, КАЛӘМ КАШТАН.** Хат башы буларак кулланыла. *Әүвәл баштан, каләм каштан бу мәктүбем очып киләдер* (Сөйләм).

**ӘҮВӘЛ ТӘГАМ, СОҢЫННАН КАЛӘМ.** Ач карынга бернинди эш тә башламауга ишарә. *[Хуҗа] Хуш, син бик күп сөйлисең, сүзгә алданып аштан калма. Әүвәл тәгам, соңыннан каләм* (Н. Исәнбәт. Хуҗа Насретдин).

*ӘҮВӘЛГЕ* ❖ **ӘҮВӘЛГЕ КАРЛЫГАЧ.** Котлап каршы алына торган вакыйга-күренеш. *Татар арасында мондый кызларның була башлавын халкыбызның алга китүенең галәмәте дип каршы алынганлыгын сөйләмәкче, аннан соң туташларны «яз җиткәнне белдерә торган әүвәлге карлыгач» булулары белән тәбрик итмәкче иде* (Ф. Әмирхан).
Төрдәше: беренче карлыгач (сандугач).

*ӘҮВӘЛЕ-АХЫРЫ* ❖ **ӘҮВӘЛЕ-АХЫРЫ ШУШЫ (ШУЛ) БУЛЫР (БУЛСЫН).** Башы-ахыры, бөтен булганы шуның белән бетсен, башка булмасын. *[Әхмәтҗан] Ярый алайса, әүвәле-ахыры шул булсын* (Т. Гыйззәт).
Төрдәше: беренчесе һәм соңгысы булсын.

*ӘҮЛИЯ* ❖ **ӘҮЛИЯ ИКӘНСЕҢ!** Алдан ук әйтелгән сүзе рас килгән кешегә әйтелә торган сүз. *– Хак әйттең, энем, әүлия икәнсең. Дөресе дә шулай бит, әй* (М. Әмирханов. Гөлнәзирә).

**ӘҮЛИЯ КҮҢЕЛЛЕ.** Киң күңелле, хәерхак, мөлаем кеше турында. *Гомергә беркемгә авыр сүз әйтмәгән, тәмле телле, әүлия күңелле Хәйретдин агайның авызы бүген иман белән ачылмады* (А. Гыйләҗев. Әтәч менгән читәнгә).

*ӘҮЛИЯЛАР* ❖ **ӘҮЛИЯЛАР КАБЕРЕ.** Изге кеше күмелгән дип танылган кабер, табыну урыны. *Иске зиратта, кемнәрнеңдер әйтүе буенча, әүлиялар кабере бар, имеш* (Г. Әпсәләмов. Күк күкрәр).

*ӘФӘЛӘМ* ❖ **ӘФӘЛӘМ ТӨРЛЕ.** 1. Әллә ниткән, төрле-төрле (мәс., гадәти булмаган, сәер; соклandыргыч), бик күп төрле. *Ул тугайларны әйтсәң, әфәләм төрле, алтын сырлы хуш исле, төрле төсле чәчәкләр белән күмелеп калган* (Н. Исәнбәт). *Сөйләп бирүгә сүз җитмәслек әфәләм төрле матурлыклары белән баш-күземне әйләндерде бит, акылсыз кызкай* (М. Фәйзи).

2. Капризлы, начар холыклы. *Карап торырга ярыйсы гына булса да, гаять әфәләм төрле бер абзый иде ул* (Сөйләм).

*ӘФӘНДЕ* ❖ **ӘФӘНДЕ КАПЧЫГЫ** *тар.* Европача киенгән шәкерт. *Электә европача киенгән шәкертне, көлеп, әфәнде капчыгы дип тә йөрткәннәр икән* (А. Тимергалин. Миллият сүзлеге).

*ӘФЕН-ТӨФЕН* ❖ **ӘФЕН-ТӨФЕН КИТЕРҮ.** Өшкереп-төкереп, тылсымлы сүзләр куллану. *Гафу итегез, ул аны (әйберне) болай әфен-төфен китереп, дога-мазар белән генә үзләштерергә юл эзләде* (Ф. Сәйфи-Казанлы).
Төрдәше: әфсен уку; әфсен-төфсен итү (уку); өфү-төфүләр итү (иттерү); өфү-төфүләр китерү.

*ӘФИСӘР* ❖ **ӘФИСӘР БАРМАГЫ** *иск.* Папирос. *Мөдир урта бармагы белән алтын нигезле күзлеген төзәтеп куйды, ашыкмыйча гына, кесәсеннән затлы пачкалы «әфисәр бармагы»н чыгарды* (Т. Галиуллин. Мәкер).

*ӘФКЯРЕ* ❖ **ӘФКЯРЕ ГОМУМИЯ** *иск.* Җәмәгатьчелек фикере. *Хәзер әфкяре гомумия белән хисаплашырга туры килә* (Ш. Усманов).

*ӘФСЕН* ❖ **ӘФСЕН УКУ** *к.* әфен-төфен китерү. *<...> чүл төркиләре ялмавызның оныгын ялмашайтан диеп атап йөртәләр икән, чөнки ул әфсен укып, тимер кавырсынны кошка әйләндерә ала, килбәте белән ярканатка охшаса да, аңардан мең тапкыр зуррак диеп, татар сәүдәгәрләренә сөйләгәннәр* (В.Ильясов. Әүдек).
Төрдәше: әфен-төфен китерү һ.б.

*ӘФСЕН-ТӨФСЕН* ❖ **ӘФСЕН-ТӨФСЕН ИТҮ (УКУ).** Өшкерү; шулай ук *к.* әфен-төфен китерү. *Кирилл кызларның исемнәрен язып чиләккә салган кәгазьләрне, як-ягына каранып, авыз эченнән генә әфсен-төфсеннәр дә укыпмы, озак бутады* (А. Хәсәнов. Данәгөл).
Төрдәше: әфен-төфен китерү һ.б.

*ӘФТИЯК* ❖ **ӘФТИЯК КАЛЫНЛЫГЫ.** Калын түгел, бик юка. *Алачагы Әфтияк калынлыгы, бирәчәге Коръән калынлыгы* (Н. Исәнбәт).

*ӘФҮ-ТФҮЛӘР* ❖ **ӘФҮ-ТФҮЛӘР БЕЛӘН** *к.* әфен-төфен китерү. *[Бәдигылҗамал] Белмим инде, нинди әфү-тфүләр белән Ибраһимның башын-күзен әйләндергәннәрдер* (Г. Камал. Кайниш).
Төрдәше: әфен-төфен китерү һ.б.

*ӘФЬЮН* ❖ **ӘФЬЮН БИЗМӘНЕ БЕЛӘН.** Даруханә үлчәвендә, төп-төгәл үлчәнгән. – *Шикләнеп карап торма, әфьюн бизмәне белән үлчәдем* (Сөйләм).

**ӘФЬЮН ЙОТКАНДАЙ БУЛУ.** Баш томалану, әйләнү (татлы сүзләрдән). *Бераз утырып торыйм әле, нәрсәдер, әфьюн йоткандай булдым* (Сөйләм).

*ӘХЛАК* ❖ **ӘХЛАК ЙӨЗЕ.** Кешелек дәрәҗәсе. <...> *геройларның хезмәткә, авыл халкына мөнәсәбәте күрсәтелә, бу мөнәсәбәтнең ниндилегенә карап, персонажларның әхлак йөзе, кешелек дәрәҗәсе бәяләнә* (Ф. Хатипов. Үткәннәр аша – киләчәккә).

*ӘХМӘТГАЛИ* ❖ **ӘХМӘТГАЛИ НИ, ГАЛИӘХМӘТ НИ.** Бер-берсенә тиң килгәннәр; монысы ни дә тегесе ни – икесе дә бер үк. – *Аны рәис итеп куюдан берәр нәрсә үзгәрер дип уйлыйсызмы, ялгышмагыз, алар арасында берниндиаерма юк – Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни...* (Сөйләм).
Төрдәше: барын <да> бер аршынга тарту; барын бер кайчы белән кырку; барын <бергә> бер калыпка сугу (салып үлчәү); барын бер күчкә өю; барын бер тактага тезү; бер кайчыдан кырыккан; бер калыпка суккан 1; бер калыптан сугылган (чыккан; яратылган); бер камырдан әвәләнгән; бер очтан киселеп тегелү; бер очтан кискән (каелган); бер сарык ашыгы; бер тагарак дуңгызлары; бер тактага кую; бер чүпрәдә кабару; бер чыбык белән каула<н>у (куала<н>у; сөрелү); бер чыбыктан куалау (куылу); бер чыбык очы 1; бер чыбык очыннан 1; икесе дә бер калыптан; икесе дә бер очтан кискән (киселгән); иш ише белән, дуңгыз түше белән; иш ише белән, иш кушы белән; иш ише белән, Ишмөхәммәт бичәсе белән; иш ише белән, хуҗа ишәге белән; иш ише белән тычкан тишеге белән; иш ишенә, ишәк оясына; иш ишкә куш; иш өстенә (янына) куш; ишәк ише, шайтан мәе; ишкә иш килү (китерү); ишкә куш; ишкә кую; кул түгел; кул булмау; чиләгенә күрә капкачы.

*ӘХТӘРИ* ❖ **ӘХТӘРИ ЯРУ.** Комар уены (карта) уйнау. *[Исмәгыйль] Әхтәри ярабыз, дим, какрас мин әйтәм, минем күптән түгел генә алган атласный әхтәриләрем бар, дим.* (Г. Камал). *Тарихта әхтәри ярып (карта уйнап), атасының бөтен байлыгын оттырган җилбәзәк уллар булганлыгы билгеле* (З. Мәхмүди. Фәлсәфә дәфтәреннән).
Төрдәше: әхтәриләп алу.

*ӘХТӘРИЛӘП* ❖ **ӘХТӘРИЛӘП АЛУ** *к.* әхтәри яру. – *Иптәшләреңә әйт, әйдә, әхтәриләп алабыз* (Сөйләм).

*«ӘҺ»* ❖ **«ӘҺ» ДИГӘНДӘ (ДИГӘНЧЕ)** *к.* «а» дигәнче. «*Шулай итеп, “әһ” дигәндә әгелчәннәрне бөтен калаларын җимереп, кирпечләрен ваттырып, патшаларын плен алдым»* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Әмирнең җансакчылары баһадирны әһ дигәнче бөтереп алдылар һәм сүз әйтергә дә бирми алып та киттеләр* (М. Хәбибуллин. Илчегә үлем юк).
Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

*ӘҺӘМИЯТ* ❖ **ӘҺӘМИЯТ БИРҮ.** Игътибар итү, кыйммәтен белү. *Халык җырларына әһәмият бирергә кирәк, дип, кат-кат әйтелде*

*инде* (Г. Тукай). *Галиулла субай сугучыларга да, бүрәнә төяп китүчеләргә дә артык әһәмият бирмәде* (А. Алиш. Якты күл буе).

**ӘҺӘМИЯТ КӘСЕП ИТҮ.** Әһәмияте булу. *Хөкүмәтнең соң заманнарда сәясәте нәтиҗәсендә (бу мәсьәлә) безнең өчен гадәттән тыш нәзакәт вә әһәмият кәсеп итүенә дә карамастан, Траблис (Триполи. – М.Г.) – Гареп мөхарәбәсе бер мөтдәткә ул мәсьәләне бөтенләй оныттырды* (Ф. Бәкхан. Казаннан).
Төрдәше: әһәмияткә ия.

*ӘҺӘМИЯТКӘ* ❖ **ӘҺӘМИЯТКӘ ИЯ** *к.* әһәмият кәсеп итү. *Бәя биреп бетергесез бик зур әһәмияткә ия фундаменталь хезмәт бу!* (А. Хәсәнов. Гөлмәрфуга). *Аның татармы, чувашмы икәне теге органнар өчен бернинди әһәмияткә ия түгел* (З. Хәким. Искән җилләр көенә).
Төрдәше: әһәмият кәсеп итү.

*ӘҺӘМИЯТСЕЗ* ❖ **ӘҺӘМИЯТСЕЗ НӘРСӘ.** Кадерсез, файдасы булмаган. *Яки әһәмиятсез нәрсә дип ыргыткан булсак?* (Р. Юныс. Татар гаме). *Лейтенант кәгазь өстеннән күз йөртеп чыкты һәм аны бер әһәмиятсез нәрсә кебек кенә итеп катыргысы эченә салды* (Х. Камалов. Үлгәннән соң яздым).
Төрдәше: базар көн<не> поты (бәясе) бер тиен; базар көнне ике тиен тормау; базары бер тиен; бармак очыннан чәйнәп төкерелгән тырнак; батманы өч тиен; башы-тоягы бер тиен; бәһасе сукыр бер тиен; бәясе сукыр бер тиен; бәясе сукыр бер тиен; бер тиен тормаслык (торгысыз); бер тиен тормау; бер тиенгә дә кирәкми (кирәге юк); бер тиенгә дә ярамаган; буш нәрсә; ике тиен бер акча; өч тиен бер акча; поты бер тиен; пүчтәк нәрсә; сукыр бер тиен; тишек<ле> бер тиен; тишек тәңкә.

**ӘҺӘМИЯТСЕЗ НӘРСӘ СӨЙЛӘҮ.** Әһәмияте булмаган, кадерсез. *Галия, гүя йокысыннан уянган кебек, аңар гаҗәпләнеп карады, соңыннан, бик әһәмиятсез нәрсә турында сөйләгән кебек, әкрен генә җавап бирде* (Һ. Такташ. Соңгы елмаю). *«Әй, – дигән булдым мин, әһәмиятсез нәрсә сөйләгәндәй, – анда безнең малайлар группасында Эльмира исемле бик сөйкемле бала бар* (Ф. Яруллин).
Төрдәше: буш нәрсә сөйләү; пүчтәк нәрсә сөйләү; чүп-чар сөйләү.

*ӘҺЛЕ* ❖ **ӘҺЛЕ БАЗАР.** Базарда алыш-биреш итүчеләр, базарчылар. *Әйдәгез, әй әһле базар, Берьюлы Фатиха: Уңсын Карахмәтнең юлы* (Г. Тукай. Печән базары, яхут Яңа Кисекбаш). *Иннокентий, бертуктаусыз бакылдаган Пычракбайны куен кесәсеннән чыгарып, әһле базар кешесыдәй, бар көченә кычкыра башлады* (З. Мәхмүди. Тәмуг чәчәге).

**ӘҺЛЕ ИСЛАМ.** Ислам дөньясы, мөселман халкы. *Анда Печән базарында әһле ислам күтәп тора* (Г. Исхакый. Кыямәт). *Ләкин безгә әһле ислам кадерле һәм бәһале әле* (А. Тимергалин. Миллият сүзлеге).

**ӘҺЛЕ КАЛӘМ.** Каләм көче белән көн күрүчеләр (мәс., газета-журналларда эшләүчеләр, язучылар). *Гаҗәпләнәсе юк: илдә җылы җилләр исә иде; әһле каләм дә шул шаукымда чынлап торып «демократияле» уйнап алды* (Р. Зәйдулла. Премия).

*ӘЧӘЧ* ❖ **ӘЧӘЧ, ПЕЧКӘН ӘТӘЧ!** Көтмәгәндә ят, сәер әйбер күргәндә (ишеткәндә) әйтелә. *Әчәч, печкән әтәч! Кем уйлаган аны шулай булыр дип* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз ачу 7 һ.б.

*ӘЧЕ* ❖ **ӘЧЕ БЕЛӘН ТӨЧЕНЕ АЕРА БЕЛМӘҮ** *к.* авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү. *Соң шул мулла эшеме? / Гомер буе аералмады / Әче белән төчене* (Ә. Хәсәнов).
Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**ӘЧЕ БИРҮЧЕЛӘРГӘ ТӨЧЕ КАПТЫРУ.** Үз-үзеңне яклый белмәү, начарлык эшләүчеләргә баш иеп тору. *Ләкин Вера әче бирүчеләргә төчене каптыра торганнардан түгел* (Ш. Рәкыйпов).

**ӘЧЕ ИКМӘК БУЛУ.** 1. Иң тансык, бәрәкәтле һәм кирәкле нәрсә булу; физик көч куеп тапкан булу. *Төнлә вагоннардан авыр йөкләр бушатып, әче икмәк булып килде ул миңа мотоцикл* (Сөйләм).
2. Күңелне әрнеткеч нәтиҗә. *Җыелган ачуыгызны баладан алмагыз, картлык көнегезгә әче икмәк әзерләмәгез* («Сабантуй» ж.).

**ӘЧЕ КАПКАН КҮСЕ ШИКЕЛЛЕ.** Кая барырга белми торган кеше турында. – *Нигә әче капкан күсе шикелле урам уртасында катып калдың, әйдә, утыр машинага* (Сөйләм).

**ӘЧЕ СУ** *к.* агулы елан 1. *Соңгы баруында Мирхәйдәр абзый аны, хөрмәт итәсе килеп, «әче су» белән сыйлап җибәрде* (Ә. Фәйзи. Тукай).
Төрдәше: агулы елан 1 һ.б.

**ӘЧЕ СҮЗ.** Кешене үпкәләтә торган үткен сүз. *Бередә тагын ирләр һәм хатын-кыз мәхәббәтенең, егет һәм кызлар мәхәббәтенең күптөрле төсмерләре дә: «Йортка керту... Ярага тоз салган / Шушы әче сүзләр өченме? / Сөеп яшәмичә, үз иреңне / Төнлә чыгып эзләр өченме?»* (М. Вәлиев. Киләчәккә кайту). *Кайтуының тәүге көннәреннән үк ул Әхимне тәмам кол итте. Күпме әче сүз, күпме мәсхәрә ишетте ул аннан* (Ф. Зыятдинов. Авылдашның авыр юл башы).

**ӘЧЕ ТАҢНАН** *к.* ачы таңнан (таң белән). *Әче таңнан, урам кичеп, / тәгәрәп чыкты сары көчек* (Роб. Әхмәтҗан. Сары көчек). *Әни шаяртмаган, өздереп сөйләшкән икән, менә бүген без, әче таңнан өчәүләп Кәшерлегә юл тоттык* (Н. Гыйматдинова. Күңел).
Төрдәше: ачы таңнан (таң белән) һ.б.

**ӘЧЕ ТЕЛЛЕ<ЛЕК>** *к.* әрем телле. *Аның әче теллелеген яхшы белгәнгә күрә, Сәлим бу хурлыклы чагыштыруга ачуланмады* (Г. Әпсәләмов). – *Син, казый Нисбах, элек тә әче телле идең, әле дә шул гадәтең ташламагансың икән, – диде Биккол, үрелеп йөзем каба-каба* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).
Төрдәше: әрем тел<ле> һ.б.

**ӘЧЕ ТЕЛ<ЛЕ>ЛӘНҮ** *к.* агу тел<ле>. *Ул да аны әче телләнеп каршы алды* (Л. Хәмидуллин. Буранлы төндә). *Анам әче телләнә башлады* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).
Төрдәше: агу тел<ле> һ.б.

**ӘЧЕ ХАТИРӘЛӘР КАСӘСЕН АКТЫГЫНА КАДӘР ЭЧҮ.** Хатирәләрне сайлап кына искә төшереп булмау турында. *Бу шулай, бу – тормышның үзенә күрә бер кануны булса кирәк, әмма бүген Локман карт әче хатирәләр касәсен актыгына кадәр эчеп бетерергә тиеш иде* (Ә. Еники. Тауларга карап).

**ӘЧЕ ЮЛ.** Тормыш юлларының тигез һәм җиңел булмавына ишарә. *[Давыт] Хакыйкать юлы авыр, әче юл икән!* (Г. Коләхмәтов. Ике фикер).

*ӘЧЕГӘН* ❖ **ӘЧЕГӘН ЙОН** *мыск.* Оешып җитмәгән, булдыксыз кеше. – *Миңа әчегән йонны бирмә, миңа курку белмәс, тәвәккәл егетләр кирәк* (Сөйләм).
Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

*ӘЧЕДЕР* ❖ **ӘЧЕДЕР ТЕЛЕ, ДУАМАЛДЫР ҮЗЕ.** Кызу, усал итеп тирги торган кеше турында. – *Сөйләмә дә инде, аны бутау кыен: әчедер теле, дуамалдыр үзе, дияр идем* (Сөйләм).

*ӘЧЕЛЕШЛЕ* ❖ **ӘЧЕЛЕШЛЕ БУЛУ.** Ачуланышу, үпкәләшү. – *Кая олактың анда? Миңа гына әчелешле булырга дигәнмени?* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *[Әсрар] Сине, әтисеннән качкан кызны, үз йортыма сыендырсам – бетте баш. Синең аркада кардәшләр белән әчелешле булыр хәлем юк* (Ю. Әминов. Кан кардәшләр).
Төрдәше: ачылышлы булу.

*ӘЧЕНЕ-ТӨЧЕНЕ* ❖ **ӘЧЕНЕ-ТӨЧЕНЕ ТАТУ** *к.* авызы пешкән өреп капкан (эчкән). *Әнисе, тормышның әче-төчесен татыган булса да, нык әл, бирешмәс, балалар хакына үзен кулга алыр* (Р. Айзатуллин. Ирекле тоткыннар).
Төрдәше: авызы пешкән өреп капкан (эчкән) һ.б.

*ӘЧЕСЕН-ТӨЧЕСЕН* ❖ **ӘЧЕСЕН-ТӨЧЕСЕН КУШ УЧЛАП ЧӨМЕРҮ** *к.* авызы пешкән өреп капкан (эчкән). *Дөньяны күп күргән, ә сугышларның әчесен-төчесен куш учлап чөмерергә мәҗбүр булган бу агайның, бу өлкән солдатның беренче ишетүгә сәер тоелган үз фәлсәфәсе бар* (Ш. Маннур).
Төрдәше: авызы пешкән өреп капкан (эчкән) һ.б.

**ӘЧЕСЕН-ТӨЧЕСЕН КҮРҮ.** Күп авырлыклар күрү, төрле хәлләр кичерү. *Сугышның әчесен-төчесен күргән, күкрәкләрендә вакыт-вакыт бәйрәмчә медаль һәм орденнарын ялтыратып йөрергә яратучы яшь галимнәр студентларга үзрәк тоелдылар, ә аспирант халкының исә күңелләргә бераз курку салуы сизелә башлады* (Ф. Яхин. Умырзая).
Төрдәше: авызы пешкән өреп капкан (эчкән) һ.б.

*ӘШӘКЕ* ❖ **ӘШӘКЕ ҖАН.** Усал, начар холыклы. – *Ничекләр үлә соң Нерон исемен йөрткән әшәке җан?* (М. Хәбибуллин. Атилла). – *Үлемең алдыннан берәр дога укы, ичмаса, әшәке җан* (В. Имамов. Утлы дала).

**ӘШӘКЕ ТЕЛ<ЛЕ>.** Тупас, сүгенү сүзләре кулланып сөйләшә торган кеше. *[Касыйм] Югары*

*булмый. Ул хәтле әшәке тел белән...* (З. Хәким. Мылтык). *Әшәке тел пычрак авыздан чыга. Әшәке телле малай* (Ш. Галиев. Илһамым-мәхәббәтем).

*ӘШӘКЕЛЕК* ❖ **ӘШӘКЕЛЕК ЭШЛӘҮ**. Явызлык, усаллык эшләү. *Йә булмаса, берәр әшәкелек эшләмәс микән?* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). – *Бик беләсең килсә, әшәкелек эшләмичә торсам, минем бөтен йокым кача* (З. Мәхмүди. Мунча).

*ӘШ-ВӘШ* ❖ **ӘШ-ВӘШ ЯШӘҮ.** Бер-береңне аңлап яшәү. – *Вәт син уйла инде, ни без Фәттах белән әш-вәш яшәмәдек, ә?* (Н. Гыйматдинова. Кәтәнә).

*ӘШ<Т>ЕР-ӨШ<Т>ЕР* ❖ **ӘШ<Т>ЕР-ӨШ<Т>ЕР КИТЕРҮ** *к.* аннан-моннан гына. *Өй эшен җиңелдән генә әшер-өшер китереп ташлаган Әлтафи караватына ята да кеше канына тоз сала башлый.* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).
Төрдәше: аннан-моннан гына һ.б.

*ӘШКӘРӘ* ❖ **ӘШКӘРӘ ИТҮ.** 1. Һәркемгә мәгълүм итү. *Ул аны үз баласы кебек күрде. Ул аны хәзрәте Гайсәгә әшкәрә иткән* (musulman.ru).
2. Халык алдында хурлау, хур итү *диал. Нигә инде җәмәгать алдында әшкәрә итәргә, үзенә генә әйтергә дә булыр иде* (Сөйләм).

*ӘШ-МӘШӘ* ❖ **ӘШ-МӘШӘ КИЛҮ.** Ыгы-зыгы килү, буталып бетү. *Йортларын җиһазлау белән әш-мәшә килеп кайнашкан кырмыскаларның җан ачулары чыкты булса кирәк* (М. Әмирханов. Гөлнәзирә).

*ӘШНӘ* ❖ **ӘШНӘ БУЛУ.** Дусларча мөнәсәбәттә булу. *Япон белән әшнә булып, тигез булып яшим дисәң, аны мыскыл итмә, аның телен өйрән...* (В. Имамов. Япон татары). *Әшнә булып өлгергән мал духтыры Костюк, Твердин, хуҗа әби бәйрәм ясадылар* (Р. Батулла. Юл буенда зәңгәр чәчәк).

*ӘШНӘЛӘР* ❖ **ӘШНӘЛӘР ТӨРКЕМЕ.** Иптәшләр яки фикердәшләр, тарафдарлар төркеме. *Бер читтәрәк әшнәләр төркеме җыелган иде* (Сөйләм).
Төрдәше: җылы компания.

*ӘШТЕР-ӨШТЕР* ❖ **ӘШТЕР-ӨШТЕР ГЕНӘ** *к.* аннан-моннан гына. *Урынын әштер-өштер генә җыештырды да туры лапастан арбага сикереп төште* (А. Тимергалин. Таш алиһә). *Утисыны янына әштер-өштер генә эшләнгән таур кызының ямьсез генә курчагын салдылар* (Н. Фәттах. Аклан).
Төрдәше: аннан-моннан гына һ.б.

**ӘШТЕР-ӨШТЕР ИТ<ТЕР>Ү** *к.* аннан-моннан гына. – *Бу галәмәт әштер-өштер иттерүне үзең уйлап таптыңмы? – дип, турыдан-туры сорады Дасаев* (Р. Мирхәйдәров. Иртәләгән сагыш).
Төрдәше: аннан-моннан гына һ.б.

**ӘШТЕР-ӨШТЕР, КАНДАЛАДАН БОТКА ПЕШЕР** *к.* аннан-моннан гына. – *Эшең барып чыкмаган бит, әштер-өштер китер, кандаладан ботка пешер дигәндәй, ашыкпошык маташуың файдага булмаган* (Сөйләм).
Төрдәше: аннан-моннан гына һ.б.

*ӘШХӘРӘДӘН* ❖ **ӘШХӘРӘДӘН ТӨШХӘРӘ** *диал.* «Бу күпчелеккә мәгълүм нәрсә» мәгънәсендә. *Бизәнү-ясану, киенү-чишенүгә мода үзгәрә килә, җәйге-кышкы көннәр сыман инде: озая да кыскара – әшхәрәдән төшхәрә* (Ш. Галиев).

**ӘШХӘРӘДӘН ТЫШ КИТҮ** *диал.* Артыкка китү, күп булу. *Нигә ул хәтле артык тырышырга, болай да әшхәрәдән тыш киткән инде* (Сөйләм).

*ӘЮП* ❖ **ӘЮП ПӘЙГАМБӘР САБЫР<ЛЫГ>Ы.** Сабыр була белү, үтә сабырлык. *Акрын-акрын, озак-озак, Әюп пәйгамбәр сабырлыгы белән тырышкач, кар юрганы ертылып китте* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

# Б

*БАБА* ❖ **БАБА ТЕЛ.** Бүгенге көндәге милли телләрнең төп чыганагы булып саналган борынгы тел. *Генетик туганлык төшенчәсе бер баба телдән аерылып чыккан дип уйланыла торган телләргә карата гына кулланыла* (Н. Фәттах).

**БАБА ШУЛПАСЫН ЭЧМӘГӘН.** Тәҗрибәсез, тормыштагы яхшылык-начарлыкларны аз күргән (яки күрмәгән). *Аннары башлыгы урыныннан торды да, төсен үзгәртеп, Байкучаровка, баба шулпасы эчмәгән балага карагандай, бер күз ташлады һәм тавышын яңгыратарак биреп дәвам итте* (Т. Әйди. Елак агач).

Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

**БАБА ШУЛПАСЫН ЭЧ<ЕР>Ү.** 1. Коры су эчерү. *[Колый] Баба шулпасы дип, Колый тарханга бер табак су эчертәләр!* (Н. Исәнбәт. Хуҗа Насретдин).

2. Алдап акылга утырту. *[Халык] Ха-ха-ха! Ай, Хуҗа, ант әгәр, ай! Эчерде баба шулпасын ахунга* (Н. Исәнбәт. Хуҗа Насретдин).

3. *к.* ачы яшь эчү. *«Фәнүзәнең миннән уч алуыдыр инде,– дип уйлап куйды эченнән. – Баба шулпасы эчерә бит, каһәр»* (Ш. Бикчурин. Тирән катлам).

Төрдәше: ачы яшь эчү һ.б.

*БАБАГА* ❖ **БАБАГА БИРЕРЛЕК БУЛУ.** Җитәрлек үсү (кечкенә малай турында). *– Карале, безнең күршеләрнең малайлары бабага бирерлек булган икән инде* (Сөйләм).

**БАБАГА БИРҮ.** Йола нигезендә, малайларның җенес әгъзасын очыннан кисү (сөннәткә утырту). *Татарда сөннәткә утыртуны «бабага бирү» дигәннәр* (А. Тимергалин. Миллият сүзлеге).

Төрдәше: бабага утырту; кызыл ыштан кидер(т)ү; сөннәткә утырту 1; чалбар кисү.

**БАБАГА УТЫРТУ** *к.* бабага бирү. *– Әминтәтәйләр бәләкәй малайларын бабага утырттылар бит. Мине дә дәшкәннәр иде* (А. Юнысова. Кич утырганда).

Төрдәше: бабага бирү һ.б.

*БАБАЙ* ❖ **БАБАЙ МИЧ БАШЫННАН БЕЛМИЧӘ ЕГЫЛЫП ТӨШМӘГӘНДЕР.** Белеп, аңлап эшләүне аңлата. *Әмма бездә «бабай мич башыннан белмичә егылып төшмәгәндер» хөсне занына игътикад көчле соң!* (Г. Тукай. Тегеннән-шуннан).

*БАБА<Й>ЛАР* ❖ **БАБА<Й>ЛАР ЙОРТЫ.** Туган җир. *– Борынгы бабаларыбызның йорты бу, – диде Фатих* (Ф. Яруллин. Тамырлар). *Нәсел җебем шушында бәйләнер, балаларым, балаларымның балалары, «бабай йорты» дип, шушы йортка кайтырлар дип өмет иткәндер...* (Л. Ибраһим-Вәлиди. Гаделҗан бабай).

**БАБА<Й>ЛАР СУКМАГЫ (ЮЛЫ).** Борынгы йолалар, традицияләр. *– Бабасының юлы турырак, аның нәтиҗәләре тизрәк күренә* (Р. Вәлиев. Иске сәгать дөрес йөри). *Арадан берсе – аталар һәм бабалар юлына тугрылык – әсәрләрдә бигрәк тә еш күтәрелә* (М. Вәли-Барҗылы. Тормыш дулкыннары).

**БАБА<Й>ЛАР СҮЗЕ.** Канатлы сүзләр. *«Әйләнгечтән юл туры» дигән бабайлар сүзен онытканмы, тыныч кына уйлый-уйлый кайтырмын дип өметләнгәнме, Урал ягыннан кайтышлый авыл юлына каерып кергән дә, асфальтка чыгарга берничә километр кала, көчле яңгырга эләгеп, сазга утырган икән* (А. Тимергалин. Таш алиһә).

*БАБАНЫКЫ* ❖ **БАБАНЫКЫ – ИЛНЕКЕ, <ӘЙДӘ, АШАГЫЗ (АВЫЗ ИТЕГЕЗ)> <ДИП ӘЙТТЕ ДИ БЕР БОРЫНГЫ КИЯҮ>.** Кеше әйбере белән юмартлык күрсәтү, ата-баба малын туздыру. *Беркөнне бер егет иптәшләре белән кайткан да аларны өстәл тирәсенә утыртып сыйлый башлаган: «Тартынмагыз, әйдә, ашагыз, болар бабаныкы – илнеке», – дигән бу* (Сөйләм).

Төрдәше: атай малы – катай <малы> һ.б.

*БАБАҢА* ❖ **БАБАҢА СӘЛАМ ӘЙТ, ӘБИЕҢ УТЫРМАГА КИЛСЕН** *шаярт.* Кеше белән

саубуллашканда, шаяртып әйтелә, «бабаңа» урынына башка кеше яки мал исеме дә куелырга мөмкин. – *Вакыт табып, без дә бер килеп чыгарбыз әле, әлегә бабаңа сәлам әйт, әбиең утырмага килсен* (Сөйләм). *Сыерыңа салам сал!!! Сыерыңа сәлам әйт, әбиең утырмага килсен* («Матбугат.ру» порталы).

**БАБАҢА СӘЛАМ ӘЙТ, ӘБИЕҢ ЭШКӘ КИЛСЕН** *ирон.* «Син әйткән булмас» мәгънәсендә. *[Камил] Бабаңа бәреп сәлам әйт, әбиең шахтага эшләргә килсен* (Һ. Такташ. Камил).

*БАБАҢНЫҢ* ❖ **БАБАҢНЫҢ КАБЕР ТАКТАСЫ.** Сүгенү сүзе. – *У-у, бабаңның кабер тактасы!– дип улады, аты-юты белән сүгенде Мулла. – Булмый болай!* (М. Закир. Чебен).

*БАБАСЫН* ❖ **БАБАСЫН (БАБАЛАРЫН) АТАУ (ИСКӘ ТӨШЕРҮ).** Нәсел башында торучыларын кушып сүгү. *Гауга артканнан-арта барды, бабаларын искә төшереп сүгенүләргә дә чират җитте* (Сөйләм).

**БАБАСЫН ТАМАК КЫРЫРГА ӨЙРӘТҮ.** Өлкәннәрне нәрсәгә булса да өйрәтә башлау («юкка маташма инде» дигән мәгънәдә киная). *Бу юлларны укыганда, мин, мыек астыннан гына елмаеп: «Фатыйма сеңлем, бабаңны тамак кырырга өйрәт!» дип кенә куйган идем* (Җ. Тәрҗеманов).

**БАБАСЫН ТАНЫТУ** *к.* авыз җебетү 2. – *Әйт безнекеләргә: бабасын танытып җибәрсеннәр, йөрмәсен монда иснәнеп* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

*БАБАСЫР* ❖ **БАБАСЫР КЕРГӘН <МӘЛЛӘ>** *гади с.* Урынында тик утыра алмаган кыбырсык кеше турында. – *Кара, нәмә сүләгән була, директорыгыдга әйтергә дә күп сорамам мин, бабасыр кергән күек йөрисең...* («Казан утлары» ж.). *Нигә тыныч кына утырмыйлар соң [әсирләр]? Бабасыр кергән мәллә?* (Ш. Маннур).

*БАБИЛ* ❖ **БАБИЛ МАНАРАСЫ КОРУ (ТОРГЫЗУ).** Буталчыклык, шау-шу, берәү дә аңлый алмаган чуалчык эш. *Бар да шулай, / лаф оралар, / Бабил манарасы коралар* (Н. Исәнбәт). *Йөз егерме төрле шартларда, йөз егерме төрле гореф-гадәт белән яшәп, йөз егерме телдә сөйләшүче, мәдәниятнең төрле баскычларында торучы йөзләрчә халык белән Бабил манарасы салу, ай-һай, мөмкинме икән?!* (Г. Бәширов. Гыйбрәт).

**БАВЫ ӨЗЕЛГӘН КӨЛТӘ КЕБЕК.** 1. Таркалган гаилә. *Алар бергә озак яши алмадылар, бервакыт гаиләләре бавы өзелгән көлтә кебек таркалып китте* (Сөйләм).

2. Таралып барган әйбер. *Юл өстендә, бавы өзелгән көлтә кебек, төрле агач үсентеләре чәчелеп ята иде* (Сөйләм).

3. Җитәкчесез калган халык төркеме. *Әлбәттә, әйдәп баручылар булмаса, татар, Тукай рухы «бавы өзелгән көлтә» хәлендә калыр иде* (Р. Гыйлемханов һ.б. Истә калганнар).

*БАВЫР* ❖ **БАВЫР АКТАРЫЛУ.** Ачулану. *Шунда аның бөтен бавырлары актарылып, җан ачулары чыкты* (Г. Әпсәләмов). *Үз кулларым, үз күзләрем белән озатсам да, юклыгыңа ышана алмый йөдим. Бөтен эч-бавырларым актарылып, үзәгем өзелә* (Э. Шәрифуллина).

Төрдәше: бавыр кабару.

**БАВЫР ИТЕ.** Күңелгә якын, бик кадерле. – *И улым, бала – бавыр ите, дип юкка гына әйтмәгәннәр инде* (Р. Кәрами. Олы юл да сикәлтәле). *Мин бит – бала... Бала – бавыр ите, Өзелеп лә төшкән анадан...* (С. Рәхмәтулла. Туган йортта).

**БАВЫР ИТЕН АШАУ (КИМЕРҮ).** *[Ярославна] Әсирлектә кенәз Василийны күздән яздыручы кем иде? [Сөембикә]Нахак яла безнең бавыр итен, җитәр инде, байтак кимерде* (З. Мансуров).

**БАВЫР КАБАРУ** *к.* бавыр актарылу. *Дамирның көнләшүдән бавыры кабарган, белеп торам, ул минем таныклыкны ике тапкыр сорап алды, кат-кат укып, пичәтен иснәп карады* (А. Гыйләҗев. Язгы кәрваннар).

Төрдәше: бавыр актарылу.

**БАВЫР КАЛКУ (КАТУ; КҮТӘРҮ).** Нык булу, ныгаю («хәсрәт төере булып төенләшү» мәгънәсендә). *Иренең бу галәмәтләреннән нык җәфа күрде, бавыры катты* (Сөйләм).

Төрдәше: бавыр ташка әверелү; бавырга <кара> таш булып утыру; бәгырь төбенә таш булып утыру; бәгырьгә таш булып утыру; бәгырьгә <каты> таш булып яту; бәгырьгә таш сын куйганнармыни; бәгырьгә таш укмашу; буын кату.

**БАВЫР ТАВЫШЫ.** Ат юыртып барганда, эчке органнарның селкенүеннән чыккан гөрт-гөрт иткән тавыш. *Бераз чана чыжлавын һәм туктаусыз гөрт-гөрт итеп торган бавыр тавышын тыңлап барганнан соң, Солтан сорашмый түзмәде* (А. Расих).

**БАВЫР ТАШКА ӘВЕРЕЛҮ** *к.* бавыр калку (кату; күтәрү). *Минзәлә татарының учы суелды, бавыры ташка әверелде* (Ф. Яхин. Ат урлауның ние бар…).
Төрдәше: бавыр калку (кату; күтәрү) һ.б.

*БАВЫРГА* ❖ **БАВЫРГА БАЛА БАСМАУ.** Яшь, тәҗрибәсез хатын-кыз турында. *Ул бик иртә кияүгә чыккан, дөресрәге, мәҗбүр иткәннәр – бавырына бала басмаган әле аның* (Сөйләм).
Төрдәше: бавыры бала басмаган.

**БАВЫРГА БОЗ УРНАШУ.** 1. Бик нык туңу, өшү. *Кар-яңгырлы көз урнашты. Күктугайның бавырына боз урнашты* (Дәрдмәнд).

2. Берәрсен күрә алмау хәленә җитү. *Бу алдаулардан, ялганлаулардан апа бөтенләй үзгәрде, аның бавырына боз урнашты* (Сөйләм).
Төрдәше: бавырда утыру; бавырны ачыту; бавырны тура<кла>у; баш авырттыру; баш агарту; баш<ны> черетү 2; бәгырь айкалу; бәгырь актарылу; бәгырь бәргәләнү; бәгырь ертылу; бәгырь җәрәхәтенә учлап тоз сибү; бәгырь итен кимерү (ашау); бәгырь кайна<т>у; бәгырь капкасына дегет сылау; бәгырь кату; бәгырь кибү; бәгырь киселү (өзелү); бәгырь корыту; бәгырь <кара> көю; бәгырь өшү (туңу); бәгырь парә-парә килү; бәгырь парәсен йолку; бәгырь савылу; бәгырь суырылу; бәгырь сызла<н>у; бәгырь телгәләнү; бәгырь тел<ен>ү; бәгырь теткәлә<н>ү; бәгырь тураклау; бәгырь уелу; бәгырь яну; бәгырьгә ачуташ салу; бәгырьгә йөз энә белән чәнчү; бәгырьгә кадау; бәгырьгә кату чыгу; бәгырьгә керү 2; бәгырьгә пычак кадау; бәгырьгә салу (салып калдыру); бәгырьгә таш булып утыру; бәгырьгә <каты> таш булып яту; бәгырьгә таш сын куйганнармыни; бәгырьгә таш укмашу; бәгырьгә тию; бәгырьгә тоз салу; бәгырьгә төкерү; бәгырьгә төшү 3; бәгырьгә ук булып кадалу; бәгырьгә <таш булып> урнашу; бәгырьгә утлы күмер салу; бәгырьгә үтү (үтеп керү) 1; бәгырьгә чәнчү (чәнчеп тору); бәгырьгә шырпы кадалу; бәгырьгә язу; бәгырьне авырттыру; бәгырьне ашау; бәгырьне бораулау; бәгырьне газаплау (җәфалау); бәгырьне җидегә телү; бәгырьне игәү (игәү белән ышку); бәгырьне имгәтү; бәгырьне кайнату; бәгырьне канату; бәгырьне катыру; бәгырьне кимерү; бәгырьне киптерү (корыту); бәгырьне кисү; бәгырьне корт ашау (кимерү); бәгырьне көйдерү (көйдереп алу); бәгырьне кыйнау; бәгырьне өзү; бәгырьне өшетү; бәгырьне парә-парә китерү; бәгырьне парә-парә тел<гәлә>ү; бәгырьне пычак белән тел<гәлә>ү (телеп алу); бәгырьне саву; бәгырьне сызландыру (сыкрату); бәгырьне сызу; бәгырьне талау; бәгырьне телем-телем кисү; бәгырьне телгәләү (телеп алу); бәгырьне тешләү; бәгырьне туңдыру; бәгырьне тура<кла>у; бәгырьне тырнау; бәгырьне утлы тимер көйдерү; бәгырьне үксетү; бәгырьне үткен пычак телү; бәгырьне ялкын чорнау; бәгырьне яндыру; бәгырьнең астын өскә китерү; җан айкау 2; җан актарылу; җан ачыну; җан ашау; җан әрнү (ачу; ачыну; ачыру); җан борчылу; җан газабы изү (чигү); җан елау; җан киселү; җан кыйналу; җан кычкыру; җан сызлау; җан сыкра<н>у; җан ыңгырашу; җан-бәгырьгә төшү; җанны әрнетү; җанны әрнү (телү); җанны бимазалау; җанны газаплау; җанны елату; җанны игү (игәү); җанны изү; җанны иңрәтү (талау); җанны канату; җанны каһәрләү; җанны кимерү; җанны кисеп төшү; җанны куыру; җанны кыерлау; җанны кыйнау; җанны өзгәләү; җанны өшетү; җанны суыру; җанны сызлату; җанны сыкындыру; җанны талау; җанны талку; җанны тапау; җанны телгәләү; җанны телү (телеп үтү); җанны тешләү; җанны тетрәтү; җанны тишү; җанны томалау; җанны тунау; җанны турау; җанны тырмау; җанны тырпау (авырттыру); җанны ут көйдерү; җанны ут телү; җанны һәлак итү; җанны чуку; җанны яндыру; җелекне киптерү (корыту); йөрәген боз кантары басу; йөрәген кырык хәнҗәр белән чәнчү; йөрәк әрнү 1; йөрәк бозлану (боз булу); йөрәк итен чуку-талау; йөрәк тамырын кимерү; йөрәк телгәләнү; йөрәк яну; йөрәккә боз булып утыру; йөрәккә боз укмашу; йөрәккә бозлы салкын йөгерү; йөрәккә салкын боз булып кадалу; йөрәккә төшү; йөрәкне ашау; йөрәкне әрнетү; кан корыту; сорап теңкәгә тию; тәкатьне алу; теңкә<не> корыту (корытып алу); теңкә-бәгырьне корыту; теңкәгә тию (тиеп алу); тешләрне камаштыру; үзәк өзелү; үзәккә үтү (сеңү; төшү); яра өстенә тоз сибү; ярага тоз ишү (салу); ярага тоз салу.

**БАВЫРГА КЕРҮ (ҮТҮ).** Күңеленә үтеп кереп, сереңне белү. – *Ул төрле мөмкинлекләрне файдаланып, бавырыңа да үтеп керәчәк* (Сөйләм).
Төрдәше: юмалап <кешенең> эч серен белү.

**БАВЫРГА <КАРА> ТАШ БУЛЫП УТЫРУ.** Интектереп, җәфалап, кайгыга төшереп торган бер халәт. *Гөлгенә төрмәдән кайтып бавырына таш булып утыргач, Ихласның берәр тыныч көне булдымы икән?* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Келәмдәге геройга шелтә биргәнне шыгаеп тыңламады председательләр, чөнки Галинурны алып ташларга теләп тә булдыра алмаган секретарьның абруена бик нык суккан, Галинур Айтуганов аның бавырына кара таш булып утырган иде* (Г. Ахунов. Гомер юлы).
Төрдәше: бавыр калку (кату; күтәрү) һ.б.

**БАВЫРГА ТӨШҮ.** Йөдәтә-йөдәтә берәр нәрсә таләп итү, сорау; авыр хисләр тудыру; аптырату, туйдырып бетерү, җәфалап бетерү. – *Син генә миемне череттең! Син генә «кое да кое» дип бавырга төштең. Король бичәсе булдыңмыни? Ике йорт аша суга йөрүе кыен бераүгә* (Д. Булатова. Кое). *Авыр эш бавырга төшә* (Мәкаль).
Төрдәше: бавырга боз урнашу 2; бәгырьгә сызу (сызып алу) һ.б.

**БАВЫРГА ЭНӘ БАРЫП УТЫРГАНДАЙ БУЛУ.** Эч пошырып, авыр хәсрәт булып торган рухи халәт. *Шундый итеп карады Гайнүш бу бичарага, Зәйнинең хәтта бавырына энә барып утыргандай булды* (Ә. Еники. Майбәдәр карчыкның туган көне).

*БАВЫРДА* ❖ **БАВЫРДА УТЫРУ** *к.* бавырга боз урнашу 2. *Милли мәгариф һәм мәдәният мәйданындагы хәлләр һөркайсыбызның бавырында утыра* (М. Вәлиев. Сорау – җавап).
Төрдәше: бавырга боз урнашу 2 һ.б.

*БАВЫРНЫ* ❖ **БАВЫРНЫ АЧЫТУ** *к.* бавырга боз урнашу 2. *Бу нәрсә аның бавырын тәмам ачытты: әллә шулай яратмыйча да «яшәп китү» мөмкин микән?* (А. Хәлим).
Төрдәше: бавырга боз урнашу 2 һ.б.

**БАВЫРНЫ ТУРА<КЛА>У** *к.* бавырга боз урнашу 2. *[Биктимер] Турыйлар бавырны* (М. Фәйзи. Галиябану).
Төрдәше: бавырга боз урнашу 2 һ.б.

*БАВЫРЫ* ❖ **БАВЫРЫ БАЛА БАСМАГАН** *к.* бавырга бала басмаган. *Кызның елау-сыктауларын исенә төшерде. Бавыры бала басмаган булып кыланды бит* (Р. Кәрами. Кая чабасың, гомер юртагы?).
Төрдәше: бавырга бала басмаган.

**БАВЫРЫ ЗУР (ОЛЫ).** «Эчкерсез, киң күңелле» мәгънәсендә. *Мин белгән ханымнар арасында Таһирә апа бавыры олы булу белән аерылып тора иде* (Сөйләм).
Төрдәше: бөтен җаны белән; җаны-тәне белән; чын дөресен әйткәндә; чын күңелдән; чын ихлас белән.

*БАГ* ❖ **БАГ АЛМА<СЫ>.** Балаларны; чибәр, гүзәл кызны чагыштыру. *Минем баг алмасы төсле кызым алай егетләр белән йөрмәс* (Г. Камал). *Бар ике җанга ике баг алмасы: бер кыз, бер ул, / Ир баламны мин сөям, белмим, нигә артыктыр ул* (Г. Харис. Өрәк).

*БАГАНА* ❖ **БАГАНА АРТЫНА ПОСЫП, КУЛ ИЗӘП ТОРУ.** Курку. – *Багана артына посып, кул изәп кенә торыр идең бугай...* (И. Гази. Онытылмас еллар).

**БАГАНА БУЛЫП (КЕБЕК) КАТУ (КАТЫП КАЛУ/ТОРУ).** Нинди булса да сәбәптән (аптырау, гаҗәпләнү, кая барырга белмәү һ.б.) хәрәкәтсез тору. *Ул, багана булып каткан хәлдә, берни белмичә, сары мыеклы сакчы каршында басып тора иде* (А. Алиш. Кадыйр Бикмуллинның җинаяте). *Урамның каршы ягында язгы кояштан карала башлаган көртләр арасында каткан багана кебек басып торган адәм затын шундук шәйләп алды ул* (Г. Гыйльманов. Китек ай).
Төрдәше: катып калу (тору); тораташ <булып> кату; тораташ кебек катып калу (тору).

**БАГАНА КЕБЕК.** Озын буйлы, какча кеше. *Ул арада сызгырып ачылган подъезд ишегеннән Русланның багана кебек озын гәүдәсе сузылып күренде* (А. Әхмәтгалиева. Минем этинең кызы).
Төрдәше: буйга беткән; икенде күләгәсе; килбәтсез озын; колга буйлы; колга кебек; күк терәве; озын торыклы; сажин таягы; сөкәт кадәр гәүдә; телеграм баганасы; чакрым баганасы; чилән аяк; чилән кебек; чожым баганасы.

**БАГАНА <ТӨБЕ> САКЛАУ (САКЛАП ТОРУ).** Баганага сөялеп тору, эшсез басып тору. *Бөтен кешенең үзенә күрә эше бар, ә менә Наҗиянең*

*бер эше дә юк: капка төбендә, багана саклап торгандай, тик басып тора* (Ф. Хөсни). *Ә болай, көннәр буе капка баганасын саклап бер ялгызың утырырга калгач, бигрәкләр читен икән шул!..* (В. Нуруллин. Җавап бир, кеше).

*БАГАНАГА* ❖ **БАГАНАГА СӘЛАМ БИРҮ.** 1. Бик түбәнчелекле булырга мәҗбүр булу. *Югыйсә күрсәтермен мин сиңа балак бетен. Баганага сәлам бирерлек итәрмен!* (М. Хәсәнов).

2. Багана белән кешене аера алмаслык дәрәҗәдә исерү. – *Аңа хәзер барыбер: баганага сәлам бирә дә башлар* (Сөйләм).

Төрдәше: акылын эчеп бетергәнче.

**БАГАНАГА СӨЯҮ (ТЕРӘҮ)** *к.* агач атка (аргамакка) атландыру. *Рәхәтләнә кяфер, сине шулай баганага сөяп киптерә* (Г. Тукай).

Төрдәше: агач атка (аргамакка) атландыру һ.б.

*БАГАНАЛЫ* ❖ **БАГАНАЛЫ ЮЛ.** 1. Элекке замандагы олы юлны күз алдында тотып, тормыш юлы турында. *Адәм баласының тормышта үз йөз тоткан баганалы юлы бар икән, аны көнче этләр өреп кенә читкә бора алмас* (В. Имамов. Нәзер).

Төрдәше: таш юл; олы юл.

2. Билгеле, төп таләпләргә туры килгән. *Такташ <...> социалистик реализмның баганалы юлына аяк басты* (Х. Госман).

*БАГУЧЫЛЫК* ❖ **БАГУЧЫЛЫК ИТҮ.** Күрәзәлек итү. *Йолдызларга карап багучылык итүче берәү, өенә кайтып кергәч, хатынының билгесез бер ир белән утырганын күргән* (Ә. Исхак. Күңелле сәхифәләр).

Төрдәше: фал ачу.

*БАГЫ* ❖ **БАГЫ ИРӘМ**. «Җир оҗмахы» мәгънәсендә. *Керсәләр, ни күрделәр, бер бакча, җәннәт мисаледер ки, аңа нисбәт багы Ирәм бер әүһам (җәннәт бакчасы бер ялгыш уй) вә коры хыялдыр* (К. Насыйри. Әбүгалисина кыйссасы). *Телләреңдер багы Ирәм былбылы, / Нурлы йөзең һәр урында билгеле* (Г. Кандалый).

*БАГЫНЫП* ❖ **БАГЫНЫП УТЫРУ.** Кемгә яки нәрсәгә булса да табыну. *Кичнең кич буе оныкларга әкият сөйлисе җирдә, мөкиббән китеп, телевизорга багынып утыралар да аннары көпә-көндез төш күреп йөриләр...* (А. Тимергалин. Таш алиһә).

Төрдәше: бер тормыйча (кузгалмыйча) утыру.

*БАГЫШ-КҮРЕШ* ❖ **БАГЫШ-КҮРЕШ ИТҮ.** Яңа кода-кодагыйлар белән танышып, күрешеп йөрү яки гомумән бер-берең белән йөрешү. *Ялгыз яшәгән Степан бабайга багыш-күреш итә, көн итәргә булыша башлый* (atnya-rt.ru).

*БАЕГАН* ❖ **БАЕГАН КӨННЕҢ ИРТӘГЕСЕН (ИКЕНЧЕ КӨНЕНДӘ)** *к.* абага чәчәк аткач (атканда). *[Нәҗип] Җитмеш ике сумыңны кайчан түлисең? [Гаяз] Баеган көннең икенче көнендә үк дидем бит инде* (Г. Мөхәммәтшин. Тынгысыз төн). *Шулай акыллы булганың өчен мин сиңа баеган көннең иртәгесен бик җилле берәр нәрсә алып бирермен* (Ф. Яруллин).

Төрдәше: абага чәчәк аткач (атканда) һ.б.

*БАЕР* ❖ **БАЕР ЯК.** Кояш баткан як, көнбатыш. *Печән өстенең киң күңелле юмарт кояшы, Идел буе халкының киң тугайлардагы бетмәс-төкәнмәс печәнен киптереп арыганнан соң, баер якка авышкан иде* (Г. Бәширов).

*БАЕТТЫҢ* ❖ **БАЕТТЫҢ ИНДЕ** *киная.* Файда китерәсе урында зыян китергәндә әйтелә, ягъни «уңдырдың», «кырдың эшемне» мәгънәсендә. – *Сиңа ышанган мин җүләр, баеттың инде, җитәр* (Сөйләм).

*БАЗ* ❖ **БАЗ КАЗУ.** Берәрсен авыр хәлгә кую; бәлаказа әзерләү, һәлакәткә китерү чараларын күрү. *Бер-бер кеше өстен чыкса, аңа баз казый иде* (С. Рәмиев). – *Минем Нургалигә баз казып маташма, барыбер баҗаңны ферма башына утырта алмассың, диярмен, минем Нургалинең кулына су салырга да ярамыйсың, диярмен мин...* (Ә. Еники).

Төрдәше: чокыр казу.

*БАЗАР* ❖ **БАЗАР БОЗУ.** 1. Базардагы уртача бәядән арзанга сатып, базар хакын төшерү. *Базымсыз базар бозар* (Мәкаль).

2. Яхшы гына барган эшне бозып кую (тавыш чыгару, таркау тудыру). *Яшьләрнең шәһәргә агылуы нәтиҗәсендә, телибезме-теләмибезме, каладагы хезмәт базары бозыла* («Әлки хәбәрләре» газ.). *Шулай матур гына ярты ел бергә эшләгән идек, базар бозар дип кем уйлаган аны* (Сөйләм).

**БАЗАР ЙӨРҮ.** 1. Базарда йөренү, тамаша кылу. *Колхозчылар йокларга, базар йөрергә калдылар* (К. Басыйров). *«Казан йөрү», «базар йөрү»*

*дип кенә әйтелә иде. «Йөрү» – зур сүз, бу инде атлау гына түгел, ә ил-җир күрү, агай-эне, татар, урыс, мари, мордва белән аралашу, ипле тормыш кору мәсьәләсен киңәш-табыш итү дигән сүз* (М. Мәһдиев. Шагыйрьнең бишеге).

2. Базар буйлап яки базардан-базарга йөреп сәүдә итү. *Җылкычы ата белән үзе базар йөреп, малның һәммәсен сатты да, тукалны, Гөлчәчәкне алып, Карлыгач-Сылу белән бергә ире, кияве артыннан китте* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *Базар йөреп ит саткан-да, һәр тиенен кат-кат санап торган әни бу акчаларны санамады да, бер-берсенә ябышып торган өр-яңа унбиш унлыкларны бер акчадай берьюлы учына куйды да, күзен текәп тик катты* (Х. Сарьян. Бер ананың биш улы).

Төрдәше: базар чабу.

**БАЗАР КАРГАСЫ.** Гауга чыгарырга яратучы, әшәке телле кеше. – *Йолкыш, базар каргасы, – диде Фатих Әмирхан* (Р. Батулла. Апуш–Тукай).

**БАЗАР КЕРТҮ** *иск.* Базарчыларны кундырып чыгару. *Базар керткән – баеган* (Мәкаль). *Мәрфуга түти базар кертеп кенә акча эшли, шуңа яши* (Сөйләм).

**БАЗАР КОРУ (ЯСАУ).** 1. Эшсез, максатсыз җыелып тору. *Урамда калган подпоручик үзенең һәм поручикның атын солдатларга тоттырды да: «Монда җыелышып тормагыз, базар ясамагыз», – дип, халыкны кисәтеп алганнан соң, шулай ук кәнсәләргә кереп китте* (Ф. Тарханова. Хисләр дәрьясында).

2. Бик нык тавышланып сөйләшү. *Бюро утырышын алып баручы беренче секретарь, өстәлгә сугып: – Син нәрсә, Закиров, монда базар ясыйсың?! Әйтәсе сүзеңне үзеңә чират җиткәч әйтерсең, – дип кычкырып җибәрде* (Г. Галиева. Тулгак). – *Буш сүз белән / Сыйлау нигә бүген халыкны? / Илне базар ясап, / Ничә еллар / Сатулашып гомер уздырдык* (Х. Әюп. Йөрәк яктысы).

Төрдәше: бака туе; ду килү.

**БАЗАР КӨН<НЕ> ПОТЫ (БӘЯСЕ) БЕР ТИЕН** *к.* әһәмиятсез нәрсә. *Хикәя, повесть, язылганда ук, шушы бөек таләпкә җавап бирерлек итеп язылырга тиештер дип уйлыйм мин. Башкача булганда, ул базар көнне поты бер тиен булган макулатура булыр иде* (Н. Шәрифуллин. Фидакярләр кирәк).

Төрдәше: әһәмиятсез нәрсә һ.б.

**БАЗАР КӨН (КӨНЕНДӘ) СУКЫР БЕР ТИЕНГӘ ТОРМАСЛЫК** *к.* базар көн<не> поты (бәясе) бер тиен. *Менә бит, вәгъдә ителгән белемле мөгаллимнәр чакырылмаган, ә хакы базар көнендә сукыр бер тиенгә тормаслык надан назир мәдрәсәдән куылмаган* («Казан утлары» ж.).

Төрдәше: әһәмиятсез нәрсә һ.б.

**БАЗАР КӨННЕ ИКЕ ТИЕН ТОРМАУ.** Мохтаҗлыктан гына кыйммәт торган әйбер турында. *Илмираңны күрмәдем, дим Мансурга, авыр туфрагы җиңел булсын, аның турында авыз күтәреп сүз әйтмим. Әмма бу балдызкай базар көнне ике тиен тормый, дим* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

Төрдәше: әһәмиятсез нәрсә һ.б.

**БАЗАР КҮЗЕНДӘГЕ.** Базарның урта бер җирендәге. *Нәкъ базар күзендәге шушы асты таш, өсте агач зур гына йортны Муллый карт минем атакайга арендага биреп торган* (Ә. Еники. Соңгы китап).

**БАЗАР КЫЧКЫРУ** *иск.* Мөһим хәбәрләрне базарда кычкырып хәбәр итеп йөрү, белдерү. *Кытай турында язмалар, Кытай һәм Азиядән китерелгән товарны сатучы базар кычкыра башлады* (suz.bar).

**БАЗАР МАРҖАСЫ КЕБЕК.** Үзен тупас, кадерсез тотып, вак нәрсәләр турында да сатулашырга яратучы кеше турында. *Рахман абыйның йортка керүен нигә хәбәр итәргә кирәк иде? Базар марҗасы кебек улый башлады...* (А. Гыйләҗев).

Төрдәше: базар хатыны.

**БАЗАР ТЕЛЕ.** Урамдагы тупас, ямьсез сүзләрне кулланып сөйләшү. *Үз чиратында сиңа кысылган «алъяпкыч»ның базар теле белән авызын томаларга кирәк иде дә, ничек инде әдәпәхлак иясе Фәйрүзә Саматовна таудан түбән тәгәрәсен ди!* (Н. Гыйматдинова). *Базар теле түгел, базарлы тел, / Син базарлар теле булырсың. / Кайсы татар кешесе моңа тирән йөрәгеннән: / «Амин, шулай була күрсен!» димәс?!* (Р. Харис).

**БАЗАР ТЕЛЕНӘ ТӨШҮ (ӘЙЛӘНДЕРЕЛҮ).** 1. Телнең вазыйфасын тарайту, кирәксә-кирәкмәсә дә гади сөйләм формаларын куллану. *Әмма татар теле базар теленә әйләнделгән бер мәлдә (мәктәпләр ябыла, рәсми даирәдә татар теле бөтенләй кулланылмый диярлек) Татарстан радиосында «Тел күрке – сүз» тапшыруының башланып китүе үзенә күрә бер революцион күренеш булды* <...> (Н. Гамбәр).

2. Берәр вакыйгага, хәл гайбәт рәвешендә сөйләнә башлау. *Аның урынына Хәсәновлар белән романы бар, имеш, дип, татар базарның теленә төште* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).

**БАЗАР ТОРУ.** 1. Базарда сәүдә итеп тору. *Ул [Шәвәли], көне буе базар торып, бары өч-дүрт кенә чүлмәк саткан...* (С. Рәфыйков). *Базарда торганнардан өч өлеш сәүдә керемен куш. Кайда ул дәүләт байлыгы?* (Р. Батулла. Сөембикә).

2. Яхшы, үтемле мал турында. <...> *ишек янындагы элгечкә элгән караңгы яшел төстәге плащын (ул өр-яңа диярлек плащны күптән түгел әни бер сарык бәясенә Ижау толчогыннан алып кайтып бирде: имеш, апа – җиткән кыз, аның базар торасы бар, ә миңа, гадәттәгечә, һәрвакыт ападан калган кием) беләгенә салып,* <...>*, ашыгып чыгып та китте* (Ф. Төхбәтуллин. Өй артында шомыртым бар).

3. *күч.* Кешенең яшь, көчле, дәрәҗәле чагы турында; дәрәҗәсе белән дан тоту. *Клубка быелларда гына йөри башлаган кыз-кыркын, тәрәзә яктысына кызыккан ут күбәләгедәй, баянчы янына елышкан. Яктылык килеп җитә алмастай читтә базар торырдай яшьтәгеләр* (К. Кәримов. Сакау күке).

4. Ил күзендә абруйлы, иң шәп вакытның үтеп китүе. *Буласы булган, базары торган* (Мәкаль).

**БАЗАР ТОТУ.** 1. Сата торган малы үтемле булу. *Чыршы кирәк дип, урманга барып, кисеп кайтып булмый бит, Чыршылар базар тота* («Шәһри Казан» газ.). *Бизәнү әйберләре һәм сугыш кораллары ясаучы осталар базар тоталар* (Г. Дәүләтшин һ.б. Татарстан тарихыннан хикәяләр).

2. Уңышлы сәүдә итү. – *Син – ун-унбиш ел чамасы элек кенә минем Харәземдә базар тоткан олуг сәүдәгәрсең* (В. Имамов. Утлы дала).

3. Дәрәҗәсе яки исеме белән танылу, абруйлы булу. *Базар тоткан Биләреңнән көлләр калды, / Манараңның алтын аен вәхшәт алды* (Ф. Гатина. Хәтер). *Рәхәттер ул тел чарлавы, акыл / Сатулары базар тота-тота, / Әмма җанга мае булып ягыл, / Хак сүзләрне дөрес ката-ката* (Ф. Яхин).

**БАЗАР ТӨШЕРЕП ЙӨРҮ.** Нindidер эше яки тотышы белән абруен югалта бару. *Шушы кыяфәтең белән базарыңны төшереп йөрисең шунда* (Сөйләм).

**БАЗАР ТӨШЕРҮ**. Дәрәҗәсенә, абруена зыян китерү. *Бүген дә карт ишек төбендәге калын таякка, чөйдәге каеш чыбыркыга, гадәтенчә, берничә күз төшереп алды, ләкин үзен көчлек белән тыйды, яңа катнашкан кодалар алдында, туй көннәрендә базар төшерү була дип уйлады* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми).

**БАЗАР ХАЛКЫ** *к.* әһле базар. *Хәзер баскын кенәз, базар халкы сыман сатулашып, үз бәһасен арттыру ягын гына карап торыр инде* (В. Имамов. Казан дастаны). *Гыймай абый сөйләп бетерер-бетермәстән, базар халкы, дәррәү кубып, мәйданның югарыгы ягына таба йөгерде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: әһле базар.

**БАЗАР ХАТЫНЫ** *к.* базар марҗасы кебек. *Һай, беркатлы син, Галия! Вакыт-вакыт үзеңнең мескен базар хатыны икәнеңне онытып, бәяңне арттырасың* (Н. Гыйматдинова. Бер тамчы ярату). *[Артур] Сиңа бигрәк тә ярамый, Эльза. Син болай да холкың белән базар хатыны* (Т. Миңнуллин. Шәҗәрә).

Төрдәше: базар марҗасы кебек.

**БАЗАР ХӘБӘРЕ.** Төрле имеш-мимеш, гайбәт. <..> *Чернышевның принцесса белән үзен бик тә әдәпсез һәм булачак кияүнең ачуын китерерлек дәрәҗәдә кыю тотуы базар хәбәре булып Петр Федорович кәләшенең Чернышевка дәрт белән күз атуын бик тиз күреп ала һәм хурлана башлый* (М. Евгеньева. Әби патшаның сөяркәләре).

Төрдәше: авызындагын эт <тә> җимәс (ашамас) һ.б.

**БАЗАР ЧАБУ** *иск., к.* базар йөрү 2. *Гомумән, авыл кешесе тик ятарга яратмаган, хәрәкәттә бәрәкәт, дип, буш вакытында һаман базар чапкан, анысын алган, монысын саткан –*

*ничек тә акча табарга тырышкан* (Ә. Еники. Соңгы китап). *Сәлмән <...> йөк өстенә утырып базар чаба* (Ф. Хөсни).
Төрдәше: базар йөрү 2.

**БАЗАР ЮЛЫ<Н> ТАПТАУ.** Базарга еш баргалау. *Алдан әйткәнем булсын, туй дип кенә ике кулыма ике сумкы тотып, көн-төн базар юлын таптар хәлем юк* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Шәленекеләр кечкенәдән базар юлын таптаган халык, мин дә рус кызының адресын алырлык кына русча беләм инде* (К. Кәримов. Кечкенә Камил).

*БАЗАРЛЫГЫ* ❖ **БАЗАРЛЫГЫ КАЛМАУ.** Кадер-хөрмәт, кыйммәте бетү. *Берөзлексез чыр-чыр кычкырып торгач, сүзенең дә базарлыгы калмады* (Т. Мөбарәков).
Төрдәше: абруй җуелу һ.б.

*БАЗАРЫ* ❖ **БАЗАРЫ АРТУ.** Кемнең дә булса абруе арту. *Сәхнәдә «Галиябану» ролен уйнаганнан соң, яшь артистканың базары шактый артты* (Сөйләм).
Төрдәше: абруен күтәрү һ.б.

**БАЗАРЫ БЕР ТИЕН.** Арзан бәяле, бик очсыз; кадерсез. *Сөйләмә дә инде, үзен әллә кемгә куйган була, карасаң – базары бер тиен* (Сөйләм).
Төрдәше: әһәмиятсез нәрсә һ.б.

**БАЗАРЫ БЕТҮ** 1. Кыйммәтле чагы узу; модасы чыгу. *[Шәрипов] Хәзер мулла, мәзиннең базары бетте инде* (Ф. Бурнаш. Камали карт). *Хатлар үлә хәзер Җир йөзендә, / бетеп бара аның базары* (Р. Харис. Кадрия).
Төрдәше: базары калмау 1, 2.

2. Иң абруйлы, матур чаклар үтү; кадер-хөрмәт бетү; гадәт юкка чыгу. *Әлегәчә чабатасы читән башыннан төшмәде, базары бетмәде* (М. Әмирханов. Гөлнәзирә). *Ләкин Сибириянең эченә кергән саен боларның базары бетә барды. Ахыр чиктә шул хәлгә җиттеләр ки, боларны халык та, солдатлар да ачыктан-ачык сүгә башладылар* (Г. Ибраһимов. Дошманнар арасында дүрт ай).
Төрдәше: абруй җуелу һ.б.

**БАЗАРЫ КАЛМАУ.** 1. *к.* базары бетү 1, 2. *Киң балаклы чалбар киюнең базары калмады инде* (Сөйләм). *Үзен «мин-мин» дип, борынын күтәребрәк йөрергә тырышса да, базары калмагач, яңа буын үзен түгел, исемен дә белми иде* (Сөйләм).
Төрдәше: абруй җуелу һ.б.

**БАЗАРЫ КҮТӘРЕЛҮ (ҮСҮ).** 1. Нәрсәнең булса да бәясе арту. *Карабодайның яңадан базары күтәрелгән, диделәр* (Сөйләм). *Автомобиль базары үсә башлауга әзер торырга кирәк* («Алабуга нуры» газ.).

2. *к.* абруен күтәрү. *Шулаен шулай да, сугыштан соң ир-атның базары күтәрелде, торна баласы төсле озын торыклы алты-биш Ширияз Фәрите дә өч-дүрт хатын алып аерды инде!..* (А. Гыйләҗев. Язгы кәрваннар). *Уңган хатын ул таба дигәннәре дөрес булды, ахрысы. Рәйхана малайлар тапкан саен, Миңлебайның базары күтәрелә барды* (З. Зәйнуллин. Үрләр аша).
Төрдәше: абруен күтәрү һ.б.

**БАЗАРЫ КҮТӘРЕНКЕ.** Абруйлы булу, хөрмәт ителү. *Аның базары күтәренке, син аны куып җитә алырсыңмы-юкмы – белмим* (Сөйләм).
Төрдәше: абруен күтәрү һ.б.

**БАЗАРЫ ТОРГАН, <БӘЯСЕ ЧЫККАН>** *к.* абруй җуелу. *Буласы булган, базарың торган* (Мәкаль).
Төрдәше: абруй җуелу.

**БАЗАРЫ ТӨШҮ** 1. *к.* абруй җуелу. *Бер җәйдә моның шөһрәте чыгып, теге биянең базары төшә, онытылырга якынлый* (Г. Ибраһимов. Карак мулла). *Турникта хәтта миннән уздыра. Минем базар шактый төште* (Г. Әпсәләмов. Миңа унтугыз яшь иде).
Төрдәше: абруй җуелу һ.б.

2. *к.* базары бетү 1. *Язучының базары төште хәзер* (А. Тимергалин. Сүнмәс ут янында уйда без...). – *Отмычкаларыңны ал да, әйдә, һөнәреңне күрсәт, – диде Петрович, – югыйсә бай каршында безнең бөтенебезнең базары төшә* (Ш. Усманов. Ачылган йозак).
Төрдәше: базары бетү 1 һ.б.

**БАЗАРЫ УЗУ (ҮТҮ)** 1. *к.* базары бетү 1. *[Садыйк] Хәзер ул сүзләрне сөйләргә соңгарак калдың, аның базары үтте* (Г. Исхакый. Алдымбирдем). *[Бәдигылҗамал] Мин бу хурлыкка чыдый алмыйм, миннән бәддога. [Габделкәрим] Аның базары узды инде* (Г. Камал. Каениш).
Төрдәше: базары бетү 1 һ.б.

2. *к.* абруй җуелу. – *Андый товар тузмый, адәм баласының гына базары уза* (М. Маликова. Фидая). – *Ниндәен кызларны үзенә каратмас иде. Йөрмәс иде инде базары үткәннәргә күз атып* (Р. Фәизов. Телсез).

Төрдәше: абруй җуелу һ.б.

**БАЗАРЫ ЧЫГУ.** Бәясе беленгән, сыналган, тәгаен ителгән әйбер турында. *Җиләкләреңнең базары чыккан иде бит, үзгәртергә уйламыйсыңдыр?* (Сөйләм).

**БАЗАРЫ ШӘП.** Бәянең югары булуы. *Ефәкнең бәһасе күпкә арткан, ташаяк та шактый күтәрелгән, кәгазьнең дә базары шәп икән* (Р. Батулла. Сөембикә).

**БАЗАРЫ ЮГАРЫ.** Дәрәҗәле, абруйлы, хөрмәтле. *Ат хуҗасының базары югары, чөнки ит алса, ул түшкәләп ала, он, ярма алса – капчыклап* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы). *Җыр-шигырьне санга сукмасак та, / Исерткечнең базар югары* (Х. Әюп. Йөрәк атым).

**БАЗАРЫ ЮК** *к.* абруе җуелу. *Базары юк чаклар, җуеп көчен, / Яшәү хакын инде оныттым* (Ф. Яхин).

Төрдәше: абруе җуелу һ.б.

*БАЗАРЫН* ❖ **БАЗАРЫН КҮТӘРҮ** *к.* абруй күтәрелү. *Юлга чыгу алдыннан, Корбангали абзый, үзенең базарын күтәреп, берничә тапкыр төче күмәч салдырып ашап бетерде, шунлыктан аларның капчык төпләре бик такырайган, Асылбикә түти байтактан бирле инде ару азык оны юклыктан сукранып йөри башлаган иде* (Ф. Хөсни). *Бу үзгәреш шул ук оятсызларның базарларын гына күтәрде* (Х. Әюп).

Төрдәше: абруй күтәрелү һ.б.

*БАЗАРЫҢ* ❖ **БАЗАРЫҢ БЕР ТИЕН.** «Үзеңне әллә кемгә куеп сөйләшмә, синең ишеләр тулып ята» мәгънәсендә. *Алай күккә күтәрелмә әле, базарың бер тиен бит синең!* (Сөйләм).

Төрдәше: башы-тоягы бер тиен; бәһасе сукыр бер тиен; бәясе <базар көнне сукыр> бер тиен; бәясе сукыр бер тиен; бер тиен <бакыр>; бер тиен дә тормау; бер тиен тормаслык (торгысыз); бозау бәясе; ике тиен бер акча; ике тиен тормаслык; ике тишекле бер тиен акча; ике тишекле бер тиен дә тормау; кәҗә бәясе; өч тиен бер акча; поты бер тиен; сукыр бер тиен; тишек<ле> бер тиен; тишек тәңкә; шалкан бәясе (ике маддә өчен дә).

*БАЗДА* ❖ **БАЗДА ҮСКӘН БӘРӘҢГЕ САБАГЫ.** Озын буйлы, ябык, аксыл йөзле кеше. *Иртәнчәк китергәннәр иде, әбәд алдыннан шоп-шома, мыеклары майлап таралган, базда үскән бәрәңге сабагы сыман озын, юка бер офицер каршына бастырдылар* (Я. Зәнкиев. Иртеш таңнары). *Базда үскән бәрәңге сабагы кебек озын буйлы, бөкрәебрәк кенә йөри торган малай кайсы ягы белән җәлеп итте соң аны?* («Казан утлары» ж.).

Төрдәше: багана кебек һ.б.

*БАЙ* ❖ **БАЙ БАЕСЫН ДИП ТҮГЕЛ, КОЯШ БАЕСЫН ДИП <ЭШЛӘҮ>** *к.* бай баесынга түгел, кояш баесынга <йөрү>. *Көнлекченең уе бер – бай баесын дип түгел, кояш баесын дип эшләү, акчасы гына вакытында түләнсен* (Сөйләм).

Төрдәше: бай баесынга түгел, кояш баесынга <йөрү>.

**БАЙ БАЕСЫНГА ТҮГЕЛ, КОЯШ БАЕСЫНГА <ЙӨРҮ>.** Элек көнлекчеләрнең көн үтсен дә эш хакын гына алыйк дип йөрүләре турында. *Бай баесынга түгел, кояш баесынга* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

Төрдәше: бай баесын дип түгел, кояш баесын дип <эшләү>.

**БАЙ БУЛ, ТЕГЕРМӘН САЛ, ОННЫ САТЫП АЛ.** Җорланып әйтү. – *Мин каршы түгел, әйдә, бай бул, тегермән сал, онны сатып ал* (Сөйләм).

**БАЙ ИКМӘГЕ КИЛЕШҮ.** Байга эшкә кереп, тазарып киткән хезмәтче турында. *Байда эшли башлагач, бай икмәге килешкән үзенә* (Сөйләм).

**БАЙ КЕШЕНЕҢ АВЫЗЫ КЫЕК БУЛСА ДА, ТӨТЕНЕ ТУРЫ ЙӨРИ** *к.* авыз-борыны кыек булсын, байның улы сөйләсен. – *Туктагыз әле, Гариф бай сөйләсен – бай кешенең авызы кыек булса да, төтене туры йөри* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз-борыны кыек булсын, байның улы сөйләсен һ.б.

**БАЙ КЕШЕСЕ.** Байга хезмәт күрсәтүче, байда ялланып эшләүче. *[Хәмзә] «Хаҗи, син әле башка көнне дә керерсең, син бай кеше, һәрвакытта*

*да вакытың бар; болар бит бай кешесе, җомга көннән башка вакытта вакытлары булмый», – дип, авызын җырып тик тора* (Г. Камал. Беренче театр). *Бай кешесе булса да, Әлхәмгалине ялчыларның күбесе хөрмәт итәләр. Һәрчак тыңлыйлар* (З. Зәйнуллин. Агыйделнең аръягында).

**БАЙ КИСӘ – КОТЛЫ БУЛСЫН, ЯРЛЫ КИСӘ – КАЙДАН АЛДЫҢ.** Ярлы кешегә һәрчак тискәре мөнәсәбәт булу хакында. *[Хуҗа] Менә сиңа мә! Бай кисә – котлы булсын, ярлы кисә – каян алдың!* (Н. Исәнбәт. Хуҗа Насретдин).

Төрдәше: байда булса – котлы булсын, ярлыда булса – кемнеке?

**БАЙ МАЛЫНА БАШ ОРУ.** Маллары булган кешеләргә, түрәләргә сатылу. *[Сәмигулла] Мин бу Әхмәтегезне болай ук дип белмидер идем, бу бөтенләй бай малына баш ора торган кеше икән* (Г. Камал).

*БАЙБАК* ❖ **БАЙБАК КЕБЕК ЙОКЛАУ.** Байбакларның кышны йоклап үткәрүләренә ишарә. *Байбаклар кебек йоклыйсыз – Сакмановны «алырга» кирәк дип, «уңышлы» тәкъдим белән чыкты киптерелгән мүктәй иренле куштаны* (Т. Галиуллин. С. Сакманов).

*БАЙБӘТЧӘ* ❖ **БАЙБӘТЧӘ БЕЛӘН ТУКАЛ КЕБЕК** *иск.* Байның олы хатыны белән кече хатыны арасындагы дошманлык. *Күршеләр арасындагы мөнәсәбәтне сорасагыз, байбәтчә белән тукал кебек яшиләр, дияр идем* (Сөйләм).

*БАЙГА* ❖ **БАЙГА КЕРҮ.** Байга эшкә яллану. <...> *күздән яшь чыгару түгел, «эһ» тә итми идек, ә боларга бармак белән тияргә дә ярамый, алай иркә булгач, байга кермиләр аны! – дип кырт кисәргә ярата иде* (К. Тинчурин. Кара көннәрдә). *Хәзер инде Кадыйр байга кергән. Айга кырык сум ала* (Г. Ибраһимов).

**БАЙГА НИ СӨЙЛӘСӘ ДӘ КИЛЕШӘ.** Элекке вакытта бай кешенең теләсә нәрсә эшли алганлыгына ишарә. *Байга ни сөйләсә дә килешә* (К. Насыйри. Мәкаль һәм әйтемнәр).

*БАЙДА* ❖ **БАЙДА БУЛСА – КОТЛЫ БУЛСЫН, ЯРЛЫДА БУЛСА – КЕМНЕКЕ?** *к.* авыз ачса, кече теле күренү 2. *«Байда булса – котлы булсын, ярлыда булса – кемнеке?» принцибын алга сөрү әле дә булса яши* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз ачса, кече теле күренү 2 һ.б.

**БАЙДА ТОРУ.** Байда хезмәтче булып яшәү. – *Синең абыең «Әрлән» кушаматлы Габдулла байда тора торгандыр* (М. Галәү. Болганчык еллар).

*БАЙЛАР* ❖ **БАЙЛАР БАЛ ЭЧКӘНДӘ, ЯЛАП ЯШӘҮ.** Байдан калган нәрсә хисабына көн күрүгә ишарә. *[Максут] Байлар бал эчкәндә, гомер буена ялап яшәргә риза дисез икән, китегез* (Ю. Әминов. Умырзая чәчәкләре).

**БАЙЛАР БАЛ ЭЧКӘНДӘ, ЯРЛЫЛАР СУ ЭЧҮ.** Кешенең инсани сыйфатларга ия булуы бай яки ярлы булуга бәйле түгеллегенә ишарә. *Байлар бал эчкәндә , су эчсәк тә, / Сер бирмәгән булдык ятларга* (И. Сабиров. Ләззәт ташкыны).

**БАЙЛАР ЗАМАНЫ.** Малга, акчага, байлыкка корылган заман хакында. *Байлар заманыннан калганның күркәм йорты иде ул* (Ә. Моталлапов. Елан җылыга елыша). *Хезмәт хакына яшәвең икеле шул. Бүген байлар заманы. Эт кебек, алдан акча чаба* (Н. Гыйматдинова. Елан).

**БАЙЛАР ТЕЛЕМЕ.** Бик юка итеп киселгән икмәк-күмәч телеме турында. *Өстәл уртасындагы зур сай тәлинкәгә байлар телеме дип аталган юка телемнәр өелгән* (Х. Сарьян).

**БАЙЛАР ТӨСЕ (ЧЫРАЕ)** Кызарып киткән тук кыяфәтле йөз.– *Салкын су җиттеме соң? – дип сорады озын җиңле күлмәк кигән, яулыгын чөеп бәйләгән Тәгъзимә апа, егетнең байлар төсе кергән таза, чиста йөзенә сокланып* (Р. Кәрами. Сөеп туймас чакларың). – *Күр, мәйсез-нисез генә дә байлар төсе иңде лә үзеңә!* (Э. Касыймов. Җир балкышы).

*БАЙЛАРЧА* ❖ **БАЙЛАРЧА ЯШӘҮ.** Муллыкта, байлар кебек яшәү. *Әйтерең бармы: утарбиләмә хуҗалары яңа байларча яши. Урман тикле урман эчендә ярымагачтан, ярымкирпечтән хан сараедай бина салып яталар* (Р. Низами. Без яшибез...).

*БАЙЛЫК* ❖ **БАЙЛЫК АРТЫННАН КУУ.** Бөтен гомерен мал, байлык туплауга багышлау. *Байлыкны баласы дип атый. Байлык артыннан куып, гомерен кыскарта* (А. Нәҗми.

Туран). *Барысыннан да өстен булырга теләү, дан-шөһрәткә сусау, байлык артыннан куу җитә адәм башына* (З. Мәхмүди. Ак болыт).

**БАЙЛЫК ҖЕНЕ КАГЫЛУ (СУГЫЛУ).** Һаман баю турында гына сөйләү. *<...> хатыны Шәмсекамәр абыстайны куркыткалап алганга, хатыны түбәндәге сүзләрне әйтергә мәҗбүр итә иде: – Сиңа әйтәм, сиңа тәгаен байлык җене сугылгандыр, ахрысы* (К. Тинчурин. Йөз мең).

**БАЙЛЫК СИКЕРТҮ (КИКЕРТҮ).** Малы күплектән яки дәрәҗәсеннән масаеп, кирәгеннән артыкны таләп итү, кылану. *Коттеджлар гөмбә сыман үрчи – / Кемнәрнедер байлык сикертә. / Илгә төшкән бөтен авырлыкны / Авыл халкы тарта, кичертә* (Р. Низами). *Сукырның күзен ачарлык, бөкрене турайтып җибәрерлек бер җене бар иде шуның. Байлык сикертә аны, диләр иде...*(М. Галиев. Ерак урман авазы).

*БАЙЛЫККА* ❖ **БАЙЛЫККА ЧУМУ** *к.* алтын эчендә йөзү. *Аны зурладылар, байлыкка чумды. Әмма үләр алдыннан җаны бәргәләнә башлады бахырның, Казанга да кайтып карады* (Т. Миңнуллин. «Кызыл тышлы дәфтәр»дән). *– Акча күл булганда яхшы түгелмени: байлыкка чумып яшисең дә яшисең!* (Ф. Яхин. Ясалма кешеләр, яки Хикәят бакчасы кешеләре).
Төрдәше: алтын эчендә йөзү һ.б.

*БАЙНЫҢ* ❖ **БАЙНЫҢ АВЫЗЫ КЫЕК БУЛСА ДА, СҮЗЕ ТУРЫ.** Кеше ышанмаслык сүз булса да, дөрес дип кабул ителү. *Байның авызы кыек булса да, сүзе туры* (Мәзәкнең исеме).
Төрдәше: авызы кыек булса да, бай сөйләү һ.б.

**БАЙНЫҢ МОРҖАСЫ КЫЕК БУЛСА ДА, ТӨТЕНЕ ТУРЫ ЧЫГАР** *к.* авызы кыек булса да, бай сөйләү һ.б. *Бай димичә, кем дип әйтик инде сиңа, фикергә бай бит син, ә байның морҗасы кыек булса да, төтене туры чыгар аның* (Сөйләм).
Төрдәше: авызы кыек булса да, бай сөйләү һ.б.

*БАЙРАК* ❖ **БАЙРАК АСТЫНА БАСУ.** Сәяси яки милли максат белән көрәш юлына чыгу. *Й. Акчура приоритетларын (фәннилек, миллилек, халыкчанлык – демократизм, гуманизм) кабул итә, гүя аның байрагы астына баса* (М. Гайнетдин. Йосыф Акчура). *Бу турыда Г. Исхакый үзенең 1917 елдагы бер чыгышында болай дип әйтә: «1905 елгы революциядә без сыйнфый байрак астында бардык, хәзер исә милли байрак астына басарга тиешбез»* (С. Максуди. 1906–1924 еллар).

**БАЙРАК КҮТӘРҮ.** Берәр максат юлында көрәш башлау. *Аның башына шул язулар язылган байрак, төрек-татар байрагы – мөселман байрагы күтәрелгән иде* (Г. Исхакый). *Франциядә фестиваль тәмамланганда, һәрбер илнең байрагын күтәрергә кирәк иде. Рәсәй байрагын күтәрергә, диләр. Юк, без Татарстаныбызныкын күтәрәбез, ди Рәшит* (Г. Бәйрәмова. Милли моңнарыбыз илчесе).

**БАЙРАК ТОТУ.** Идеяләр өчен көрәшне җитәкләү. *Яр буйлап отряд бара, алга җилкенә. / Иң алда байрак тоткан командир килә* (М. Җәлил). *Байрак тотып торган Урманов янына ординарецы Силантьев белән комбриг Седой килеп туктады. – Хезмәтегез өчен, иптәш Урманов, рәхмәт, – диде ул, диңгезченең кайнар кулын кысып* (Г. Әпсәләмов. Алтын йолдыз).

*БАЙРАКНЫ* ❖ **БАЙРАКНЫ ЮГАРЫ ТОТУ.** Идеяләр өчн көрәштә үз юлыннан чигенмәү. *Дәверләр аша узгансың, / Син исән, туган телем. / Тукайлар чиккән байракны / Югары тоткан көнең!* (Р. Низами). *20–30 нчы елларда һәм аннан соңрак дөньяга килгән яшьләр иҗат эшендә дә, көрәш юлында да милли байракны югары тота алуларын раслады*лар (Р. Хәйретдинов. Бормалы юллар).

*БАЙСАР* ❖ **БАЙСАР БИКӘСЕ <БУЛЫП УТЫРУ>.** Үзеңне абруйлы кеше итеп тотып, эшкә катышмыйча, назланып утыру. *Байсар бикәсе шикелле кукраеп утыруын күр. Әбелмәлих, авыз эченнән сүгенә-сүгенә, атның аркалыгын күтәрде, авызлыгын каптырды* («Казан утлары» ж.). *Менә шушы бәла оясы, көлеп-елмаеп, аның өендә хуҗа булып утыра. Каян килгән Байсар бикәсе* (М. Әмирханов. Гөлнәзирә).

*БАКА* ❖ **БАКА БАШЛЫ.** Киң, тупак башлы (мәс., аяк киеме). *– Әй, Иркен-ага!.. Алтын башлы хатын булганчы, бака башлы ир булсаң икән ул!..* (А. Хәлим. Хунвейбин).

**БАКА БОТЫНА КӨЙМӘ ТАГУ.** Бик сәер күренеш турында. *– Сезнең өйләнүегез дә бака ботына көймә таккан төсле мәзәк иде* (Н. Гыйматдинова. Кәтәнә).

**БАКА БОТЫННАН ГЫНА** *күч.* Бик сай, артык кечкенә. *Галимҗан да аның сүзләрен куәтләп җибәрде: – Бу өлкәдәге үсешебез әле бака ботыннан гына!* (З. Бәшири. Замандашларым белән очрашулар).

**БАКА ЙОТКАН ЕЛАН КЕБЕК.** 1. Комсызлыгыннан артык ашап, эче күбеп чыгу. *Абзый кеше, бака йоткан елан кебек, кабарган корсагын тотып, аш бүлмәсеннән ухылдап чыкты* (Сөйләм).

2. Дер-дер калтыранып алу. *Ниһаять, машина бака йоткан елан төсле калтыранып куйды һәм, тезгенен бушаткан юргадай, алга ыргылды* (Н. Әхмәдиев. Амбирак).

**БАКА КЕБЕК ҖӘЕЛҮ.** Билсез, симез кеше турында. – *Алайса, ят инде шунда, бака кебек җәелеп* (Ш. Фәрхетдин. Шифалы су!).

**БАКА КҮЛЕ** *к.* базар кору (ясау). – *Туктагыз, бака күле ясамагыз,– диде армиядә танкист булган һәм, аннан кайткач, Актаныш районында ике ел укытып, өс-баш карап запас белән килгән тәҗрибәле Гариф* (Г. Мөхәммәтшин. Йөрәктәге эзләр).
Төрдәше: базар кору (ясау) һ.б.

**БАКА<ЛЫ> ЛАМПА.** Пыскып кына яна торган куыксыз керосин лампасы. *Иң ахырда Фәйзулла куштан: «Мин, силски староста Фәйзулла Җамалетдин углы, гуаһлап кулым куйдым һәм таныклап кәҗүнни мөһер бастым», – дип язды да каравылчы картның бакалы лампасына тотып корымландырылган түгәрәк җиз пичәтен прошениенең ахыргы битенә басты* (М. Галәү. Мөһаҗирләр).
Төрдәше: сукыр лампа; тавык күзе 2.

**БАКА ТЕЛ<ЛЕ>.** Күп сөйләшүче; такылдык. – *Каян килеп чыкты бу бака телле малай?* (Сөйләм).

**БАКА ТЕЛЕ БЕЛӘН ЕЛАН ТЕЛЕ БЕР <БУЛУ>.** Лыгырдавык кеше белән зәһәр телле арасында аерма булмавына ишарә. *Бака теле белән елан теле бер* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

**БАКА ТУЕ <ЯСАУ>.** 1. Җәен сулыкларда бакаларның бакылдавы. *Бака туе баткалакта* (Мәкаль).

2. *күч.* Шау-шулы, тәртипсез җыен; тавышлану. *[Бәкер] Туктагыз әле, бака туе ясамагыз монда. Герой кайтты авылга, герой* (Ф. Бәйрәмова. Сандугачның балалары). *[Мәснәви] Бөтенегез дә берьюлы кычкырып бака туе ясамагыз инде* (Ю. Әминов. Кан-кардәшләр).
Төрдәше: базар кору (ясау) һ.б.

3. Яшьләрнең гармунга ияреп уйный торган биюле уены. *Берсе [гармунчыларның] Буралыга кызлар янына китеп барган, икенчесе Балтамагында туйга чакырулы диделәр. «Сигезле» яисә «бака туе» ише гармунга ияреп уйный торганнардан баш тартырга туры килде инде егетләр белән кызларга* (Р. Гаязетдин. Тәүбә көче).

**БАКА ҮГЕЗ БУЛАМ ДИГӘН КЕБЕК.** Булдыра алмаганны булдырам дип артык көчәнүдән (бака, үгез хәтле булам, дип көчәнсә шартлый) көлеп әйтү. *Ул хәтле бүртенә-бүртенә кычкырма инде, ишеткәнең бармы бака үгез булам дигән кебек көчәнгәч ни булганын?* (Сөйләм).

*БАКСАҢ* ❖ **БАКСАҢ БАГАРДАЙ, БАЗАРДАГЫ ТАВАРДАЙ.** Җиткән кызның матурлыгын мактау. *Аның кебек баксаң багардай, базардагы тавардай кызлар күп түгел алар* (Сөйләм).
Төрдәше: авызда гына тотарлык һ.б.

*БАКТЫҢ* ❖ **БАКТЫҢ ИСӘ.** Әгәр карасаң; ныклап уйлаганда. *Бактың исә, кайсар кызларының йөзен, меңен берүзе алыштыра алырдай чибәркәйләр сездә үсә икән* (В. Имамов. Казан дастаны). *Мин уйлана идем, тормыш юлы / Туры, гадел һәм дә бер генә. / Бактың исә, анда күпме сорау / Дөнья дәрьясыннан түгелә!* (В. Фатыйхов. Мин уйлана идем...).

*БАКЧА* ❖ **БАКЧА ҖИМЕШЕ.** Сатып алынмаган, үз бакчасында үстерелгән. *Ысланган дуңгыз ите тирәли табак-табак тозланган яшелчә, буш урыннарда бакча җимеше, матурлык өчен генә чирекле шешә белән сөтләч көмешкә кукраеп тора, ләкин кунаклар кибет аракысын бушата* (К. Кәримов. Сакау күке).

**БАКЧА ҖИМЕШЕ ТҮГЕЛ – АКЧА ҖИМЕШЕ**. Сатып алган нәрсә турында. – *Ватып кына кара менә! Бакча җимеше түгел ул сиңа, акча җимеше!* (З. Хөснияр. Эттән туган).
Төрдәше: бакчада үсми.

**БАКЧА КАРАЧКЫСЫ.** 1. Кошларны өркетү өчен кеше киемнәре киендерелгән аркылы та-

яклы казык. *Череп беткән сыңар колакчынлы бүрек бакча карачкысы ясарга алып куелды* (Ф. Садриев. Капитуляция).

2. *күч.* Алама киемле яки зәвыксыз киенгән кеше. *Башкорт та, чуваш та аңа ниндидер бер гаҗизанә аптырау белән карый. Һм... Хозыр Ильяс, имеш. Алдый бу бакча карачкысы* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

Төрдәше: бакча куркылыгы.

**БАКЧА КУРКЫЛЫГЫ** *к.* бакча карачкысы 1, 2. – *Әтисе, бакча куркылыгы эшләп куясыңмы әллә?* (Сөйләм). *Бакча куркылыгы кебек йөрмә инде, башка кешеләр ничек киенгәнлегенә кара* (Сөйләм).

**БАКЧА ТӘКӘСЕ.** *шаярт., эвф.* Бәрәңге. – *Бакча тәкәсе янына тозлы су да куеп җибәрик әле* (Сөйләм).

*БАКЧАГА* ❖ **БАКЧАГА ТАШ (ТАЯК) АТУ (ЫРГЫТУ).** 1. Начарлык эшләү. *Очраклы рәвештә туры килгәндерме, минем бакчага таш ату идеме бу – башта аңлый алмадым* (Ш. Рәкыйпов). *Сүзләре, әлбәттә, язучы әфәндебезнең бакчасына таш атуы буларак әйтелгән иде* (Ф. Яхин. Милли «пәрәмәч»нең милли түбәтәйсез калуы).

2. Төрттереп әйтү. *Кыз кемнең бакчасына таш атылганын ачык аңлады* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар). *[Җиһангир] (вәзиргә, акрын). Ишетәсеңме, ул минем бакчага таш ата* (Н. Исәнбәт. Хуҗа Насретдин).

Төрдәше: бакчага таш белән бәрү; бәрә тәртәгә, тия чәркәгә; ерактан әйләнеп сөрдерү; кеше бакчасына таш ату; кыек атып туры тидерү.

**БАКЧАГА ТАШ БЕЛӘН БӘРҮ** *к.* бакчага таш (таяк) ату (ыргыту). *Сәфәргали кызларның бу сүзләрен үз бакчасына атылган таш дип кабул итте, әмма ләкин үзе аларга таш белән бәрергә һич тә җыенмый иде* (Ф. Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы).

Төрдәше: бакчага таш (таяк) ату (ыргыту) 2 һ.б.

*БАКЧАДА* ❖ **БАКЧАДА ҮСМИ.** Бушка килмәгән, акчага алынган. *Акча ул бакчада үсми* (М. Галәү). *Без аңа байтак иман сатабыз. Акча бакчада үсми, әмма... Сездә ничектер, белмим, саран кешене безнең якта «кысмыр» диләр* («Сөембикә» ж.).

Төрдәше: бакча җимеше түгел – акча җимеше.

*БАКЧАСЫНА* ❖ **БАКЧАСЫНА КӘҖӘ КЕРҮ** *киная.* Гыйффәтсезлек турында. *Бу сүзләрдән соң дөрләп киткән Гыйлемхан кулына яфрагы коелган себерке алды да: – Өйләнгәндә, моның бакчасына кәҗә кермәдеме икән дип шикләнеп йөргән идем, хак икән! – дип, бар ачуы белән карчыгының арык кабыргаларын каезлый башлады* (И. Хәйруллин. Алай түгел, болай ул...).

*БАКЫЙ* ❖ **БАКЫЙ БАБАЙ БАКЧАСЫ** *дини.* Ахирәт дөньясы, теге дөнья. – *Сиксәнгә җиттем инде, тиздән Бакый бабай бакчасына күчәргә дә вакыт җитәр* (Сөйләм).

Төрдәше: ахирәт йорты һ.б.

**БАКЫЙ БАБАЙГА БАРУ.** Үлү турында (хатын-кызларга карата). *Бакый бабайга барыр вакыты да җитеп килә инде аның* (Сөйләм). *Үзләре, ярым шаяртып: «Бакый бабайга барабыз!» – дип көлеп кенә куяларые...* (tatarca-text.narod.ru «Татарча текстлар, программалар»).

Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

**БАКЫЙ ДӨНЬЯ** *дини.* Үлгәннән соң күченә торган мәңгелек дөнья. *Бакый дөнья көтеп тора барыбызны – / Анда баргач, ничек булыр, кем белә?..* (Г. Мөхәммәтшин. Робагыйлар). *Кеше хәтере фәкать аның бала чагыннан алып бакый дөньяга күчкәненә кадәрге араны били* (Р. Низами. Сәйдәшнең соңгы елы).

Төрдәше: ахирәт йорты һ.б.

**БАКЫЙ ДӨНЬЯГА (ЙОРТКА) КҮЧҮ** *к.* авыздан җан чыгу. *Кешенең бакый дөньяга күчәр алдыннан хәле яхшыра, диләр* (Н. Сәйяр. Хан кызы Нурсолтан). *Бакый дөньяга күчүе шулкадәр дә җиңел, шулкадәр дә гади хәл булып тоела, курку бөтенләй юкка чыга* (З. Мурсиев. Солтанъяр).

Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

**БАКЫЙ ЙОРТ** *дини, к.* ахирәт йорты. *Ни күзләр берлә күрсен! / Аһлар ормыйча чыдап кара: / Үлеп ятмыш ике шаһзадә, – / Бакый йортка күчкәннәр* (Г. Тукай). *Кара йөзләр кабат ил өстенә / Кызыл бурзайларын өстергән. / Империя дигән каток узган / Бакый йортның таптап өстеннән* (Г. Морат. Дәрдмәнд).

*БАКЫЙГА* ❖ **БАКЫЙГА КИТЕП БАРУ** *к.* авыздан җан чыгу. *Бакыйга гына бик иртә китеп барды Камилә, нибары ун ел гына яшәп калдылар* (М. Әмирханов. Зиннәтулла хәзрәт).

Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

**БАКЫЙГА (БАКЫЙЛЫККА) КҮЧҮ** *к.* авыздан җан чыгу. *Монысы да булгандыр: тыңдаучыларның күпчелеге инде бакыйга күчкән* (М. Әхмәтҗанов).
Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

*БАКЫЙЛЫК* ❖ **БАКЫЙЛЫК ЙОРТ.** 1. *к.* ахирәт йорты. *Хат язып җибәрсәң, алмыйлар; / Ат җигеп җибәрсәң, кайтмыйлар; / Чыгарга ишек тә юк, диеп, / Бакыйлык йортларда йоклыйлар* (Г. Сәмитова).
Төрдәше: ахирәт йорты һ.б.

2. Кабер, мавзолей. *Фотосурәт остасы Хәбибә Насретдиннең дә бакыйлык йорты янәшәдә генә икән* («Мәйдан» ж.). *«Сөембикә» манарасының кечерәйтелгән формасы ясалган кабер ташлы Йосыф Акчураның бакыйлык йорты өсте ямь-яшел үлән белән капланган, ә затлы мәрмәрләр белән әйләндереп алынган Гаяз Исхакый кабере өстендә корып бетәргә торган гөл куагыннан гайре берниди үсемлек үсми* (intertat.ru электрон газ.).

*БАКЫЙЛЫККА* ❖ **БАКЫЙЛЫККА КИТҮ** *к.* авыздан җан чыгу. – *Бакыйлыкка киткәндә, ул да сиксәнне узган иде, белүемчә* (Л. Фәттахова. Җир астыннан юллар бар...). *Шул бөек суда кояш нурларына коенып бакыйлыкка китсәк – дөнья серләрен ачарбыз кебек* (А. Нәҗми. Кояш җилләре).
Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

*БАКЫЛДЫК* ❖ **БАКЫЛДЫК БАКА.** Ямьсез тавыш белән бертуктаусыз сөйләшүче. – *Бераз сөйләми торса ни була инде. Бакылдык бака!* (Сөйләм).

*БАКЫР* ❖ **БАКЫР АКЧА КЕБЕК <ЯЛТЫРАУ>.** Йөзендә бәхет, шатлык тулы бер кыяфәттә. *Авылдан абзыйлары янына – Урал шахталарына барып бер-ике ел эшләде дә, <...> безнең Мәрәк, бакыр акча кебек, тагын Тирәклегә әйләнеп кайтты, тагын Сәлмән байның баскыч төбенә килде* (Ф. Хөсни).
Төрдәше: бакыр биш тиен кебек <ялтырау>.

**БАКЫР БАБАЙ БАКЧАСЫ** *иск.* Элек Казанда рус шагыйре Державинга куелган һәйкәл торган бакча, хәзер бу урында М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры бинасы. *Үсмер чакта яратып йөргән Бакыр бабай бакчасы исә күптәннән юк инде* (Р. Низамиев. Без яшибез...).

**БАКЫР БАШ.** Җирән чәчле кеше. *Әтием кем, кайда ул, нигә безнең белән яшәми, мине сары баш, бакыр баш, рус малае дип үчектерәләр, дип елап сораганы бар бәләкәйрәк чакларында* (Ә. Әминев. Бүре балалары).

**БАКЫР БАШЛАР.** Янгын сүндерүчеләр. *Әүхәдинең йөрәгендә янгын. Мие яна. Әй, бакыр башлар – пожарныйлар – эшкә!* (Г. Кутуй. Сәлимә).

**БАКЫР БӘЯСЕ.** Бик арзан. *Анда бер энәгә бер сыер, ди, бозаулары да бакыр бәясе генә икән* (Ф. Яхин. Бакыр бозау артыннан). *Бу үле таулар да, агуланган елгалар да, чирләш балаларның иртә киселгән гомере – барысы да бакыр бәясе* («Сөембикә» ж.).

**БАКЫР БЕР ТИЕН.** Очсыз; әһәмиятсез, дәрәҗәсез. *Алтын акча дип йөргәнем бакыр бер тиен икән. Күгәргән бакыр!* (М. Насыйбуллин).

**БАКЫР БИШ ТИЕН КЕБЕК <ЯЛТЫРАУ>** *к.* бакыр акча кебек <ялтырау>. *Дөреш күрәзәчесе, өч йомарлам май бәрабәренә багып, үлгәнгә чыгарды, ә егет, сугыш бетеп, ай үтмәде, бакыр биш тиен кебек ялтырап кайтып керде <...>* (А. Гыйләҗев. Яра). – *Сигез елдан бакыр биш тиен кебек ялтырап кайтып төшәр, ни хәлдәсез, мин кайттым, дип* (Д. Булатова. Соң түгел!).
Төрдәше: бакыр акча кебек <ялтырау>.

**БАКЫР БУГАЗ<ЛЫ>.** 1. Көчле тавыш белән, акырып сөйли торган яңгыравык тавышлы кеше; күп сөйли торган кеше. *«Нигә шул бакыр бугазлы кибетчене тотасыз?»* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

2. Акырып-бакырып кына йөргән кеше, гаугачы, җәнҗалчы. – *Кайчан шушы Гыйльми Салихы кебек бакыр бугазларны эш башыннан куу башланыр* (А. Гыйләҗев. Берәү).

**БАКЫР КҮЗ<ЛЕ>.** Тонган, ямьсез карашлы күз. *Зур борынлы, ямьсез бакыр күзле, / Исрек майор өскә калыкты* (М. Җәлил. Вәхшәт). *Мәрхәмәтсез, нурсыз соры-бакыр күзләре һич аңламаслык куркыныч, җирәнгеч агу чәчә* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

**БАКЫР МАҢГАЙ.** Үзсүзле, киребеткән кеше. *Алда килә «мәшһүр» СС полкы, / Бәреп ватты*

*бакыр маңгаен, / Һәм генерал Гудериан дигән / Тавык миле адәм имгәге* (М. Җәлил).

**БАКЫР ТОРБАЛАРНЫ ҮТҮ.** Гомерендә күп авырлыклар күргән, күпне татыган. – *Ничава, моннан әйләнеп кайтканчы прафисыр булырсың әле! – дип елмайды Арслан. – Утны-суны кичеп, бакыр торбаларны үтеп, дигәндәй...* (Ш. Маннур. Муса).

Төрдәше: утны-суны кичү; утны-суны кичү һәм шомарып бетү; ут-суны кичү; уттан-судан һәм кара төннектән үтү.

*БАЛ* ❖ **БАЛ АВЫЗ**. Ягымлы, тәмле телле кеше. *Мактап сөйлим изге эшне – бал авыз мин* (Г. Тукай). – *Менә шулай диген, бал авыз! Җизни диген! Рәхәт булып китте...* (А. Хәлим).

Төрдәше: авызга саескан төкерү һ.б.

**БАЛ АГАЧЫ.** Табышлы урын. *Эзләгән – бал агачын тапкан ди бит* (Г. Әпсәләмов). – *Эзләгән бал агачы тапкан, дигән мәкаль бар мишәрләрдә, княгиня, – диде Марсель, каршыдагы өйгә күрсәтеп, – без эзләгән мишәр бабасы менә шушы сарайда яши дә инде, әйдәгез, рәхим итегез* (М. Әмирханов. Әлвидаг).

**БАЛ АЕ.** Кияү белән кәләшнең өйләнешкәннән соң беренче ае. *Өч атнадан соң, егетемне тагын очратам. Йә, минәйтәм, ничек бал ае?* (Р. Ишморат). *Баласыз бал ае өчен ике атна чамасыз күп дигән фикергә килдек...* («Сөембикә» ж.).

**БАЛ АПА.** Түти (абый, абзый, ана, бабай һ.б.) ягыннан туган апа. *Кызларымны да, телләре ачылган чакта, ук җәмәгатемнең бертуганнарына, аларның үз ягында электән үк Дәү апа, Бал апа кебек якын иту сүзләре булса да, Алма апа, Зур абый дип хөрмәтләп дәшәргә өйрәттек* (М. Вәлиев. Кечкенә эзи – Зур абыем).

**БАЛ АРТЫННАН ГОРЧИЦА.** Матур гына сөйләшкәндә ямьсезләнә башлау, урынсыз ачы сүзләр әйтү. *Бал артыннан горчица ягып утырмасалар, нәрсә булган инде аларга?* (Сөйләм).

**БАЛ, БАЛ ДИЮ БЕЛӘН АВЫЗ ТАТЛЫ БУЛМАУ.** Коры сүзгә генә ышанырга ярамаганлыгы турында (сүз әйтеп кенә үзгәреш булмый, хәрәкәт итәргә кирәк). – *Бал, бал дию белән авыз татлы булмый, аны баллатып җибәрергә кирәк* (Сөйләм).

Төрдәше: бал-бал дигәннән авыз балланмау; бал-бал дип кенә авызда бал тәме сизелмәү; хәлвә дигәннән <генә> авыз татланмау.

**БАЛ БЕЛӘН МАЙ ЭЧЕНДӘ ЙӨЗҮ** *к.* авыз балда, кул майда. *Дөрияләр бал белән май эчендә йөзәләр дигәнне дә Рәиф ишеткәләп үсте* (М. Мәһдиев. Ачы тәҗрибә).

Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

**БАЛ БЕЛӘН МАЙДА ЙӨЗҮ** *к.* авыз балда, кул майда. *Финагент та бал белән майда гына йөзә* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).

Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

**БАЛ БИРИЕМ (КАПТЫРЫЙМ) ҮЗЕҢӘ, БАЛКЫП ЧЫКСЫН ЙӨЗЕҢӘ.** Балдан авыз иткәндә яки кияүнең әтисе кыз әтисенә мәһәргә бал биргәндә әйтелә. – *Мин әбинең бөтен җырларын беләм. Бал каптырыйм үзеңә, / Балкып чыксын йөзеңә; / Балкып чыккан кояш кебек / Күренәсең күземә* (Ф. Яруллин).

**БАЛ ГЫНА.** 1. Артык татлы, баллы. *[Алма җыючы кызлар хоры] Без үстергән алмагачның / Алмалары бал гына. / Алма белән сыйлансыннар / Эштә уңганнар гына* (М. Җәлил). *Тукранбашлар бал гына, / Әйдә, богарлан гына* (Ш. Маннур).

2. «Якын, кадерле» мәгънәсендә. *«Минем иркәм умартачы, / Иреннәре бал гына»* (Җыр). *Бал гына бит син үзең дә, / Шикәр дә син, йөзем дә... / Чәең кайнар, үзең кайнар, / Кайнарланам үзем дә!* (Р. Миңнуллин).

**БАЛ ДА БАЛ, БУ ДА БАЛ.** Бик тәмле, татлы ризык турында. *[Хәерниса] Ашап карасаң әле син аларны. Бал да бал, бу да бал инде* (Ю. Әминов. Тамырлар).

**БАЛ ДА МАЙ, <АЛ ДА ГӨЛ>** *к.* авыз балда, кул майда. *[Олуг Мөхәммәт] Халкымның тормышы бал да май булса, минем дә көн күрешем бал да май булачак* (Г. Исхакый. Олуг Мөхәммәт). *Квартир менә дигән, машина бар, пенсия җитәрлек, шуның өстенә аучылар җәмгыятендә нидер эшләп тә шактый акча төшергәли, кыскасы, әле чак иллесен тутырган полковникның тормышы бал да май, ал да гөл иде* (Ә. Еники. Әйтелмәгән васыять).

Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

**БАЛ ДА МАЙ ЭЧЕНДӘ ЙӨЗҮ** *к.* авыз балда, кул майда. *Бал да май эчендә йөзәргә күнеккәч, монда яшәве авыррак булыр шул* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

**БАЛ ДА МАЙ ЭЧЕНДӘ ТОРУ (ЯШӘҮ)** *к.* авыз балда, кул майда. – *Бал да май эчендә яшәргә күнеккәнсеңдер син, әйдә, башта бәрәңге казып алыйк әле* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

**БАЛ КАШЫГЫ (КАЛАГЫ) БЕЛӘН КАБЫП ЙОТАРЛЫК.** Бик чибәр, сылу кыз турында. *«Әмиргә бал кашыгы белән кабып йотарлык хәләл җефет әзерләп куйсам, шатланыр гына»* (Т. Галиуллин. Мәкер).

Төрдәше: бал кашыгы (калагына) салып йотарлык (йотардай).

**БАЛ КАШЫГЫНА (КАЛАГЫНА) САЛЫП ЙОТАРЛЫК (ЙОТАРДАЙ).** Матур, чибәр. *Буй-сыны бал кашыгына гына салып йотарлык* (М. Әмирханов. Тәкъдир). *Чибәр иде кәләш, бал кашыгына салып йотардай чибәр иде* (М. Әмирханов. Гәүһәршад).

Төрдәше: бал кашыгы (калагы) белән кабып йотарлык.

**БАЛ КЕБЕК ТАТЛЫ.** Сөйкемле, бик тә якын; үтә татлы. *Әнә өскә таба баскан канатының очы яктырып китте, әнә карт өрәңгенең ябалдашы да алтынсуланды – кояш чыга башлады, һава яңа сауган сөт кебек җылы да, бал кебек татлы да* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Синме? Кояш кебек кайнар, камыш кебек сылу, бал кебек татлы син* (Н. Гыйматдинова. Кыргый).

Төрдәше: балдан татлы.

**БАЛ ТАМЫЗЫП СӨЙЛӘШҮ.** Ягымлы сөйләшү. *Шәрәфнең теленнән бал тамызып сөйләшүе кызны куркуга гына салды* (Н. Гыйматдинова).

**БАЛ ТӘТӘЙ.** Ананың сеңлесе яки кардәше. *<…> аннан ярты чакрым Сикертән авылында «Сикертән бал тәтәй», аның улы Гыйлаҗи абзый, әтинең анасы – «Сикертән әби»[тора иде]* (Г. Камал).

**БАЛ<ЛЫ> ТЕЛ<ЛЕ>** *к.* авызга җен төкерү. *Тәмле сыеннан өстәл сыгыла, / баллы теленнән хәмер түгелә* (С. Сөләйманова). *Ул – Мәдинә – баллы телләргә баш ия торганнардан түгел* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).

Төрдәше: авызга җен төкерү һ.б.

**БАЛ ТҮТИ** *к.* бал тәтәй. *Бу юлы алар белән сәхнәгә әти-әниләре, дус кызлары, туганнары – бал түти Клара, ак түти Любалар да күтәрелде: карендәшләрсез бәйрәм бәйрәммени?!* («Сөембикә» ж.).

*БАЛА* ❖ **БАЛА АЕРУ.** Умарта аеру, умартадагы яшь ана корт белән күч аерылып чыгу. *Тәҗрибәле умартачы бала аеру вакытын алдан ук сизеп тора* (Сөйләм).

**БАЛА АКЫЛЫ КЕРҮ.** Картайгач та, үзен балаларча тоткан кешегә карата. *Әллә бала акылы керде инде үзенә – карчыгы Мөсәгыйдәнең күкрәгенә чәчсезлектән ялтыраган башын салып ачыргаланды ул* (М. Хуҗин. Чеметемнән – табышларга). *Олы кешеләр үзләре бигрәк беркатлы халык инде, сабый бала акылы керә кайчакта үзләренә, карап торып сыны катты Илшатның* (К. Кара. Зур акчалар).

**БАЛА АКЫЛЫ ЧЫКМАУ (ЧЫГЫП БЕТМӘҮ).** Буе үссә дә, фикерләве балалар дәрәҗәсендә калган кешегә карата. *Бәлки, бәхет дигәненең кадерен, инде нибар яшәешенә күнеккән Фарукка һәм бала акылы чыкмаган Фәрхүнәгә караганда, тормышы китеклеге кыенлыгын-газабын һаман саен ныграк төшенә баручы Фәридун тирәнтенрәк тә аңлыйдыр* (М. Хуҗин. Айның уты сүнгән).

Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

**БАЛА АНАСЫ.** Ана булган яки балага ана тәрбиясе бирүче хатын-кыз. *Ахырында ул үзенең бала анасы була алмаячагын аңлады, шулай да бирешергә теләмәде* (М. Галәү. Болганчык еллар).

**БАЛА АТАСЫ.** Баланың атасы булган яки ата вазыйфасын башкаручы ир кеше. *Бала атасы булырга җыена бугай, ә үзе һаман Биләр буйлап этләр-мәчеләрне үтереп йөри* (В. Имамов. Казан дастаны).

**БАЛА – БАВЫР ИТЕ.** Баланың үсеп җиткәч тә, үзенең әнисенә кайгы-хәсрәтләр китерә алуына ишарә. *Җанны ярып чыккан бала бавыр ите була алмый, киресенчә, гомер буе ата-анага*

*авыр кайгы-хәсрәтләр китерүче адәм актыгына әйләнә* («Безнең гәҗит» газ.).

**БАЛА БАСУ.** Гаиләдә күп бала туу, балалар белән мәш килү. *[Биктимер] Байны мал басар, ярлыны бала басар, диләр* (А. Алиш. Күршеләр).

Төрдәше: балага бату (уралу).

**БАЛА БУЛУ.** Үзен балаларча тоткан кешегә карата. – *Ярар, тимим бит, йә, бала булма, әйдә ят, йокла рәхәтләнеп, иртәгә сөйләшербез-аңлашырбыз, – дип юатырга тырышты ул ирен* (К. Кара. Чуклы караватъ).

**БАЛА ҖАНЛЫ.** Бала яратучы, бала өчен өзелеп торучы. *Бәлки, шунлыктандыр, бәлки, бик бала җанлы булгангадыр, Җиһан тәтәй һаман минем белән булаша, мине сөйләштерә иде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**БАЛА ИТӘКЛЕ** *сф.* [< рус. *волан*] Хатын-кызлар итәгендәге бөрмәләп тегелгән өстәмә. *Җиде бала итәкле зәңгәр сатин күлмәк кигән Миңлезифа абыстай сәке астыннан күкәй хәтле бер бәрәңге алып Мәрдигә сузды* (Ф. Әсгать. Мәрди).

**БАЛА ЙОН** *мыск.* Сакал-мыек урынына беленер-беленмәс төк үстергән яшүсмер («җитлекмәгән бала-чага» мәгънәсе). *Син чебешкәник сөйләп торган булам соң мин, ни аңлыйсың син, бала йон?* (Ф. Хөсни).

**БАЛА ЙОННАРЫ КАБАРУ (ТЫРПАЮ).** Нык курку (эсселе-суыклы булу) яки ярсу. *Манараның катларын, бизәкләрен, тәрәзәләрен санап маташкан җиреннән кинәт шым булды, эченә җирәнгеч бер курку керде, бала йоннары кабарды* (Ф. Латыйфи. Хыянәт). *Бр-р, бала йоннарым тырпайды* (Н. Гыйматдинова. Мәхәббәттә гөнаһ бар).

Төрдәше: авызга җан килү һ.б.

2. Бик салкын икәнлекне аңлата. *Шул көннәрне күз алдына китергәч, капка төпләрендәге карама бүкәндә утырган Ханәфигә инде хәзер үк салкын өрә башлаган шикелле булды: тәннәре калтыранып, бала йоннары кабарып чыкты* (В. Нуруллин. Җавап бир, кеше).

**БАЛА ЙОНЫН КАБАРТУ (ТЫРПАЙТУ).** Кинәт кычкырына, дулый башлау. *Советлар Союзы турында ишетсә, бала йоннарын кабарта торган кеше* («Безнең гәҗит» газ.).

**БАЛА КАЗ.** Өлкәннәр рәтенә кереп тә, төпле акылы, тәҗрибәсе булмаган кеше. *Йә, Нургали Миңгалиев шушы «бала каз»ны үзе белән тиң күрә аламы?* (Ә. Еники. Уяну).

**БАЛА КИТЕРҮ.** Бала тудыру, бала табу. – *Бала икәвебез өчен дә тере богау булачак сүзләреннән, мине яратсаң, минем белән торырга теләсәң, бала китермә! – дип куркытуга күчтең* (Г. Кутуй. Тапшырылмаган хатлар).

Төрдәше: бала табу; баладан <исән-сау> котылу; бәби китерү.

**БАЛА КӨТҮ.** Балага узып, бала тудырырга әзерләнү. *Ул үзе дә бала көтә, шунлыктан кулына нәни бала алса, күңелләре әллә нишләп китә иде* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**БАЛА ӨСТЕНӘ КИЛҮ.** Баласы булган иргә хатын булып килү. *Дүрт бала өстенә килгән үги аналарын безнең әниләр, шәфкатьсез, миһербансыз дип, ятимнәрне соранырга куып чыгара дип, әледән-әле орышалар* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**БАЛА ТАБУ** *к.* бала китерү. *Аскы өйдә Шәмсениса абыстай бала таба алмый интегә* (Г. Ахунов. Идел кызы). *Бала табу качмас, иң яхшысы – ашыкмау, хәзергә тыелып тору* (Р. Низамиев. Беренче мунча).

Төрдәше: бала китерү һ.б.

**БАЛА ТӨШЕРҮ.** Бала тудырмас өчен, аны махсус операция ясатып алдыру. *Ике тапкыр бала төшергән. Шуннан соң карт әнкәсе, өен ташлап чыгып, безнең мәчеткә җыештыручы булып урнашты* (А. Тимергалин. Юл чаты).

**БАЛА ТӨШҮ.** Бала үле туу. – *Беренче балам төште, дигән идегез* (М. Маликова. Арыш тәме). *Ындыр табагында, җитмеш кило лы капчыклар күтәреп эшләгәндә, баласы төште* (Ф. Абдуллин. Чуерташ).

Төрдәше: баладан калу.

**БАЛА ХАКЫ.** Баланың үсеп кеше булып җиткәнче әти-әнисе тәрбиясендә яшәү хакы. *Белә идем, бу эш ошамый иде ячейка секретарена. Балалар хакы бит, нишлисең* (В. Юныс. Бар, колхозың белән йокла!).

**БАЛА ХОЛЫКЛЫ (ХОЛКЫ ЧЫГЫП БЕТМӘГӘН).** Берәрсенең холкында балаларга хас

сыйфатлар саклану. *Буйга җиткән җитүен, тик бала холкы гына чыгып бетмәгән* (Сөйләм).

**БАЛА ХӨКЕМЕНДӘ.** Мәсьәлә бала хокукына бәйле рәвештә хәл ителү. *Җәмәгать, кризистан балалар өлешенә, бала хөкемендә яшәүче укытучы өлешенә кереп чыкмыйк инде без* (М. Гайфуллина-Хәбибуллина. Акбур алтыннан кыйммәтрәк). *Димәк, мин сине уятучы ата яисә ана булып чыгам. Ә син – бала хөкемендә* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

**БАЛА ЧАК.** Кеше гомереннең үсмерлеккә кадәр булган өлеше. *Бала чагында икәү бергә качышлы уйнап, яшькелт тугайлардан җир җиләге җыеп, кулны кулга тотынып, тузанлы юлдан яланаяк тупырдап чаба-чаба,чирәмлегендә бергә тәгәрәп үскән Гөлфинур* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).
Төрдәше: сабый чак.

**БАЛА ЧЕБЕШ.** Тәҗрибәсез кеше. *Яше арта бара, ә ул һаман да бала чебеш булып кала бирә* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

*БАЛА-БАЛА* ❖ **«БАЛА-БАЛА» ДИ-ДИ БАЛА ЙОННАРЫН КОЮ.** Ата-ананың балалары турында нык борчылуларын аңлата. *«Бала-бала» ди-ди бала йоннарын коеп үстергән фәрештә валчыгыдай бер бөртек кызларының киноларга кем белән йөрүен белергә тиештәр инде алар* (Г. Мөхәммәтшин).

*БАЛАБАН* ❖ **БАЛАБАН КЕБЕК.** Симез һәм тыгыз тәнле. *Мансур балабан кебек ир иде, яшьлегендә көрәш белән шөгыльләнгән, күрәсең* (Сөйләм).

*БАЛАВЫЗ* ❖ **БАЛАВЫЗ БУЛУ (БУЛЫП ЭРҮ)** 1. *к.* авызга бал да май булып керү. *Балавыз булса бай мәһәр хакында, / Тизләтә күр никахын да* (Котб. Хөсрәү вә Ширин). – *Ә мин каршыңда балавыз булып эрергә әзермен, Гөлүсә!* (Җ. Дәрзаман. Җир авазы).
Төрдәше: авызга бал да май булып керү һ.б.

2. Яхшылык (гүзәллек, күңелгә ятышлы һ.б.) күрүдән, күңел йомшау. *Туй бит, минем сыман балавыз булырга ярамый...* («Сөембикә» ж.). *Роза урынында бүтән кыз булса, бу сүзләргә балавыз булып эрер иде* (В. Нуруллин. Һәлакәт).

3. Бик тиз тирән йокыга талу. *Ул шулкадәр арган иде, башын мендәргә кую белән, балавыз булып эреп китте* (Сөйләм).
Төрдәше: балавыз кебек 2.

**БАЛАВЫЗ КЕБЕК.** 1. Балавыз төсендәге, сап-сары. *Балавыз кебек сары чырае бераз алышынып, бит урталарына шәфәкъ кызыллыгы кебек сыек кына матур бер кызыллык чыккан иде* (Ш. Камал. Бәхет эзләгәндә).

2. *к.* балавыз булу (булып эрү) 3. *Сәер хәл, Амата назлаган саен, балавыз кебек кочагында эрер, тансыклавын сиздереп, әллә ниткән сөю хиссиятенә бирелеп, рәхәти халәттә татлы итеп ыңгырашып алыр иде* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы). *Шофёрыбыз, икебезнең уртага кереп утыргач, тәмам балавыз кебек йомшарды. Бераздан гырлап йокыга китте дә борыны белән сызгырып куйгалый башлады* (Т. Нәҗмиев. Изгедер ниятләре).

**БАЛАВЫЗ КЕБЕК САРГАЮ.** Йөзнең саргылт төскә керүе, шәмдәй ябыгу. *Аның яме киткән, төсе балавыз кебек саргайган, күзләре төпкә баткан, кул һәм аягы салкын, күкрәге бер кабарып, бер төшеп, авыр-авыр сулый* (Ш. Камал).

**БАЛАВЫЗ КЕБЕК ЭРЕП АККАН.** Йомшак күңелле, хәзер еларга торучы хакында. *Ул хәтле балавыз кебек эреп аккан булма инде, үзеңне кулыңда тот* (Сөйләм).

**БАЛАВЫЗ СӨЯК<ЛЕ>.** Зифа, сыгылма гәүдәле. *Галиулла абзый да кереп биеп чыккалый. Ну бии картлач! Гүя балавыз сөяк* (М. Фәйзи).

**БАЛАВЫЗ <КАПЧЫГЫ> СЫГУ (ТҮГҮ).** Пышык-пышык елау. *Үлем турында, яралanулар турында берәр сүз ишетсәләр, башларын аска ияләр дә пышык-пышык балавыз сыгарга тотыналар* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр). *Миңзифа җиңги тагын балавыз сыгып алды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).
Төрдәше: алмалары суга туену һ.б.

**БАЛАВЫЗ СЫКТЫРУ.** Елату. *Әдилә, «Мирсәет бәете»н җырлап, карчык-корчыклардан балавыз сыктыра торган хисле, моңлы бала иде бит ул* (А. Гыйләҗев. Язгы кәрваннар).

*БАЛАВЫЗДАЙ* ❖ **БАЛАВЫЗДАЙ СЫГЫЛУ.** Күңел йомшару. *Юыну бүлмәсендәге хәлләр*

*кабатланды, бугазына утырган төер тәмәкесен юньләп тартырга ирек бирмәде, буйдаклар ятакханәсендә сигез еллап торып катып беткән күңеле йомшарган, балавыздай сыгылырга әзер иде* (Ф. Латыйфи. Аяклы каза).

*БАЛАВЫЗДАН* ❖ **БАЛАВЫЗДАН КОЙГАН КЕБЕК.** Йөзе чип-чиста булган, сылу буйлы кеше турында. *Дулкынланып төшкән саргылт чәчләре астындагы йөзе балавыздан койган кебек иде* (Сөйләм).

*БАЛАГА* ❖ **БАЛАГА АВЫРАЮ.** Йөкле хатынның бала табар вакыты якынлашу. *Дамелла хәләл җефете Зөлхәбирәнең икенче балага авыраеп йөргән көннәре* (Җ. Рәхимов. Батырша).

**БАЛАГА АВЫРЛЫ** *к.* авыр аяк<лы> 3. *Фатыйма: «Шуның балага авырлы икәнен ишеткән идем, ни хәле бар икән, исән-сау котылдымы икән?..» – дип сорый* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми).

Төрдәше: авыр аяк<лы> 3 һ.б.

**БАЛАГА АВЫРУ** *к.* авыр аяк<лы> 3. *Бервакыт шуның хатыны, балага авырып, җирдән хәзер генә өзеп алынган яңа җир җиләге тели башлаган* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). *Әйе, балага авырый шул. Ахирәтләр өй кыегындагы күгәрченнәр кебек гөрләшә башладылар* (А. Алиш. Яңа килен).

Төрдәше: авыр аяк<лы> 3 һ.б.

**БАЛАГА БАТУ (УРАЛУ)** *к.* бала басу. – *Бәдәр апа балага батты. Мөгътәс җизни белән сигезне үстереп яталар, тормышлары авыр* (Р. Газиз. Кичер, кичерә алсаң...). *Рәсим бервакыт, Фәүзиянең ялваруына чыдый алмыйча, Илүсәне ата-ана йортына алып кайтырга риза булгач, Кәбирә: «Өемне балага батырдыгыз. Дүртәү баштан ашкан. Кертмим балагызны, алып кайтсагыз да», – дип тавыш-гауга чыгарды* (Ф. Дәүләтгәрәева. Бишенче бәбкә).

Төрдәше: бала басу.

**БАЛАГА КАЛУ** *к.* авыр аяк<лы> 3. *Ләкин сез Сәгыйдәне рәнҗетмәгез. Ул балага калган булса, <...> аның атасы мин булырмын* (Һ. Такташ). *<...> кияүгә чыкмаган килеш балага калуын үзенең яшьтәш-чордашлары өчен гадәти хәл дип саный һәм моны, хәзерге тормыш шартлары белән бәйләп, болай аңлата: тәрәзәгә, тәрәзәдән ишеккә йөргән* («Татар әдипләре» порталы).

Төрдәше: авыр аяк<лы> 3 һ.б.

**БАЛАГА КАНЫККАН (САРЫЛГАН) ЧЕБЕН КЕБЕК.** Берәр нәрсәгә ябырылган, ташланган халык турында (ягъни сан ягыннан күп булу). *Урамдагы бала-чага, аны күрүгә, балага каныккан (сарылган) чебен кебек килеп ябыша иде* (Сөйләм).

**БАЛАГА САНАУ (САЮ).** Кешене баласыту, тәҗрибәсезгә санау. *[Барно] Син безне балага санадыңмы?* (А. Нәҗми. Алтынай).

**БАЛАГА УЗУ** *к.* авыр аяк<лы> 3. *Авыл егете аулак өйдә көчләде, шуннан балага уздым, хәзер дүрт айлык, дип әйтәчәк, бер чара табуын үтенәчәк* (Г. Ибраһимов). *[Җәмилә] Ул солдатка китеп барды. Мин балага узып калдым* (Г. Кутуй. Шатлык җыры).

Төрдәше: авыр аяк<лы> 3 һ.б.

*БАЛАГАН* ❖ **БАЛАГАН КӘМИТЕ (ТАМАШАСЫ).** Бәйрәм көннәрендә оештырыла торган көлкеле тамаша. *Фестивальдә катнашучылар һәм кунаклар өчен яшьләр, балалар, тарифы реконструкция мәйданчыклары эшләячәк, балаган тамашасы тәкъдим ителәчәк* (old.intertat.ru).

**БАЛАГАН КОРУ** *к.* базар кору (ясау). *Шул вакыт «Югары мәйдан» дигән бер җирдә һәр елны балаганнар корыла* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). *Ул чакта: «Бу – безнең театр стиле түгел, Кәшифә балаган кора», – дип әйтүчеләр дә табыла* («Мәдәни җомга» газ.).

Төрдәше: базар кору (ясау) һ.б.

*БАЛАГЫН* ❖ **БАЛАГЫН ҖЫЯ БЕЛМӘГӘН (АЛМАГАН).** Җыйнаксыз, булдыксыз. *Балагын җыя алмаган кеше белән нәрсә турында сөйләшеп торасың анда?* (Сөйләм).

Төрдәше: балагына абыну.

*БАЛАГЫНА* ❖ **БАЛАГЫНА АБЫНУ.** Юньсез, җыйнаксыз кеше турында. *Нәрсә көтәсең ул балагына абынып йөргән кешедән?!* (Сөйләм).

Төрдәше: балагын җыя белмәгән (алмаган).

*БАЛАДАН* ❖ **БАЛАДАН КАЛУ.** Бала тудырмый (яки тудыра алмый) башлау; *шулай ук к.* бала төшү. *Баладан калу – хатын-кыз өчен иң зур җәза ул* (Сөйләм).

**БАЛАДАН <ИСӘН-САУ> КОТЫЛУ.** Баланы җиңел генә табу, бала тудыру. *Тагын берсе, кызым баладан исән-сау котылса, дип, икенчесе, сыерым тана бозау китерсә, дип адарынган икән* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).
Төрдәше: бала китерү һ.б.

**БАЛАДАН САВЫГУ.** Бала тапканнан соң сәламәтләнү. – *Хатының баладан савыгып, хастаханәдән чыктымы әле?* (Сөйләм).

**БАЛАДАН ҮЛҮ.** Бала тапканда яки бала тапканнан соң үлү. *Боларның берсе, ел ярым гына торгач, баладан үлде* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). *Дүрт кызның берсе, төпчегебез, баладан үлде* (К. Булатова).

*БАЛАКЛАРНЫ* ❖ **БАЛАКЛАРНЫ ҖЫЕП ЙӨРҮ.** Җыйнак йөрү, кеше алдында үзеңне тота белү. *Кара аны, балакларыңны җыеп йөр, авыл гыйбады булма* («Матбугат.ру» порталы).

*БАЛАЛАП* ❖ **БАЛАЛАП КАЙТУ.** Табыш алу турында. – *Ике пот он ич ул! Язгы бер пот он көз аенда ике пот булып балалап кайта!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

*БАЛАЛАР* ❖ **БАЛАЛАР ӘКИЯТЕ.** Ялган икәнлеге сизелеп торган сүз, беркатлы уйдырма. *Бу бит әкият! Балалар әкияте! Яшәү өчен акча кирәк!* (Н. Гамбәр).

*БАЛАЛЫК* ❖ **БАЛАЛЫК КҮРСӘТҮ.** Беркатлы булу, зур булса да, үзен балаларча тоту. *Югыйсә ул осталык мәсьәләсендә сәнгатьчеләрнең балалыгын күрсәтер иде* (К. Гыйззәтов. Нәфасәт).
Төрдәше: балалыкка бару.

*БАЛАЛЫККА* ❖ **БАЛАЛЫККА БАРУ** *к.* балалык күрсәтү. *Үз балалыгыңа кайтып булмаса, бүгенге балалыкка барып була, шул күзләр белән күреп, язып-яшәп була!* (Ш. Галиев). *Балалыкка барып утырмагыз инде... Балалыкка бирелгәнсез* («Матбугат.ру» порталы).
Төрдәше: балалык күрсәтү.

*БАЛАЛЫКТАН* ❖ **БАЛАЛЫКТАН АЕРЫЛУ.** Зурларча фикер йөртә башлау, берәр нәрсәне эшләгәндә, төрле яктан уйлау. *Менә хәзер дә аларның инде балалыктан аерылып баруларын, зурлар сафына кереп килүләрен күрде* (М. Әмир).
Төрдәше: балалыктан чыгу.

**БАЛАЛЫКТАН ЧЫГУ** *к.* балалыктан аерылу. – *Әмма соң егетләр, гомергә балалыктан чыга алмассыз икән! – диде, соңра, тагы бераз тыңлап, сүзгә кереште* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). *«Үзе дә балалыктан чыгып җитмәгән шул әле», – дип уйлый иде Илсөяр, аның бу битарафлыгын күреп* (Р. Шәрипова. Шайтан таягы).
Төрдәше: балалыктан аерылу.

*БАЛАН* ❖ **БАЛАН КАБУ (КАПКАН КЕБЕК БУЛУ).** Чырай сыту. *Тәкыя апаның чырае балан капкан кебек сытылды* (Р. Мулланурова. Ялгыз каеннан да ялгыз...). *Уянып күзләрен ачуга, авызы-борыны салынды, сипкелле йөзе, әче балан капкандай, чытылды Инсафның* (И. Диндаров. Боз өстендә).

*БАЛАҢ* ❖ **БАЛАҢ АРКЫЛЫ КИЛСЕН.** Хатын-кызлар арасында ызгыштa кулланыла. *Игелек күрмә, балаң аркылы килсен!* (Г. Бәширов).

*БАЛАСЫ* ❖ **... БАЛАСЫ ГЫНА, МИЧТӘ ИКӘН (КАЛДЫ) АНАСЫ.** *Ләкин моңа кадәрге шаушу баласы гына булган икән, мичтә булган икән анасы* (М. Әмирханов). *[Самат] Монысы әле баласы гына, мичтә калды анасы дигәндәй... сыер дуласа, аттан уза, диләр* (Ю. Әминов. Язылмаган законнар).
Төрдәше: ан<ы>сы хат башында һ.б.

*БАЛ-БАЛ* ❖ **БАЛ-БАЛ ДИГӘННӘН АВЫЗ БАЛЛАНМАУ** *к.* «бал, бал» дию белән авыз татлы булмау. *Халыкта «Бал-бал дигәннән авыз балланмый», дигән гыйбрәтле мәкаль бар* («Шәһри Казан» газ.).
Төрдәше: бал, бал дию белән авыз татлы булмау һ.б.

**БАЛ-БАЛ ДИП КЕНӘ АВЫЗДА БАЛ ТӘМЕ СИЗЕЛМӘҮ** *к.* бал, бал, дию белән авыз татлы булмау. *Бал-бал дип кенә авызда бал тәме сизелми – барлыкка килми бит. Бал бал инде ул, шикәр түгел!* («Матбугат.ру» порталы).
Төрдәше: бал, бал дию белән авыз татлы булмау һ.б.

*БАЛГА* ❖ **БАЛГА ДЕГЕТ ТАМЫЗУ.** *«Сөем утайның ханбикә булуы бөек вакыйга, ә менә Җан Гали кебек пешмәгәнгә хатын булу балга деготь тамызу кебек», дип уйласа да, остаз бу чакыруга риза булды* (Р. Батулла. Сөембикә).

**БАЛГА ЧЕБЕН ТӨШҮ (КУНУ)** *к.* ашка <кара> таракан булу (булып төшү) 3. – *Булды, булды, баһадирым, кызлы йорт баллы була бит, бал-*

*га чебен-черки кунмый торамы, – диде Акбикә, эчке бер горурлык белән гүзәл кызы Сөмбелә өчен кинәнеп* (М. Хәбибуллин. Хан оныгы Хансөяр). *Бакирын калдырды, шушы хәйләкәр хатын белән, йәнәсе, балга чебен кунармы?* (М. Миначев. Авылларга барган идем...).

Төрдәше: ашка <кара> таракан булу (булып төшү) 3.

**БАЛГА ЧЕБЕН ЯБЫРЫЛГАН (ЯБЫШКАН) КЕБЕК.** Нәрсәгә яки кемгә булса да омтылу, аннан аерылырга теләмәү. *Элек мондагы азгын хатын-кызлар кавказлыларга балга чебен ябышкан кебек ябышалар иде* («Матбугат.ру» порталы).

*БАЛДАК* ❖ **БАЛДАК КИДЕРҮ.** Чолганышта калу. *Үткән җәйне, шулай фронт кидерә язган иде миңа балдагын* (С. Хәким).

*БАЛДА-МАЙДА* ❖ **БАЛДА-МАЙДА ЙӨЗДЕРҮ.** Тук һәм рәхәт яшәтү. *Ике арада кодагыйлык җепләре сузганнан бирле, Фәһимәне дә балда-майда йөздерә әле* (Н. Гыйматдинова. Елан).

**БАЛДА-МАЙДА <ГЫНА> ЙӨЗҮ (ЯШӘҮ)** *к.* бал белән май эчендә йөзү. – *Һии, дошманны җиңгәч, иминлек кайткач, балда-майда йөзәрбез әле, Шәйхулла абзый!* (Ә. Еники. Рәшә). *Димәк, балда-майда йөзгән бәхетле дигән сүз дөреслеккә туры килеп бетми* (М. Маликова. Арыш тәме).

Төрдәше: бал белән май эчендә йөзү һ.б.

*БАЛДАН* ❖ **БАЛДАН ТАТЛЫ** *к.* бал кебек татлы. *Баланың баласы балдан татлы* (Мәкаль). *«Шушы кызларның балдан татлы авызларыннан сандугачлар сайрагандай бер кәлимә сүз ишетсәм, мин әйтәм, шушы басып торган җирләремдә җан тәслим кылсам да үкенмәс идем...»* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: бал кебек татлы.

*БАЛДЫЗ* ❖ **БАЛДЫЗ ТУЕ** *шаяр.* Исерткеч эчемлекле мәҗлес оештыру өчен кечкенә генә булса да сәбәп; «кайнана туган көне». *Бәйрәмнәр булмаса, «балдыз туе» оештырырга кирәк* (Сөйләм).

*БАЛИГЪ* ❖ **БАЛИГЪ БУЛУ.** *Балигъ булгач, көндез эшләп, кичен укып, мең бәлане җиңеп белем алды* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Син инде балигъ булып киләсең, барын да үзең хәл ит* (А. Тимергалин. Игезәкләр).

*БАЛКЫП* ❖ **БАЛКЫП ЙӨРҮ.** Шатланып, шатлыгын йөзенә чыгарып йөрү. *Гөлшәһидә ханым, хәтерлисезме, беркөнне сезнең роза чәчәге төсле ачылып, балкып йөрүегезне күргәч, хастаханә коридорында мин сезгә нәрсә әйткән идем?* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

*БАЛЛАП* ❖ **БАЛЛАП БОРЫЧЛАУ.** Мактыймактый ачулану. *Һич көтмәгәндә, ул аны баллап борычларга тотынды* (Сөйләм).

*БАЛЛАР* ❖ **БАЛЛАР ӘЧҮ.** Эшләр җайга салыну. – *Әһә! Баллар әчи алайса. Кемнән, шул Гөлҗиһаннан микән?* (Р. Төхфәтуллин. Авылдашым Нәби).

*БАЛЛЫ* ❖ **БАЛЛЫ КАЛАЧ ТҮГЕЛ.** «Ачы, күңелсез хәл беркемгә дә тансык түгел» мәгънәсендә. *Түбәдән егылып төшү баллы калач түгел* (Сөйләм).

**БАЛЛЫ КҮЛ.** Кешенең иркен, муллыкта тормыш итүе турындагы хыял. – *Баллы күл турында хыялланып утырма, бар, чыгып утын яр бераз!* (Сөйләм).

**БАЛЛЫ СУ ДИП ӘРЕМ ТӨНӘТМӘСЕ КАПТЫРУ.** Алдау. *Ислай баллы су дип ничә тапкыр аңа әрем төнәтмәсе каптырды, ә Латыйф, хәйләсез җан, чыраен сыта-сыта «эчте»* (Н. Гыйматдинова. Кем беренче?).

Төрдәше: агач атка (аргамакка) атландыру һ.б.

**БАЛЛЫ СҮЗ.** Күңелгә ятышлы, *шулай ук к.* авызга җен төкерү. *Бер начар сүз дә әйтмәде, карашы, баллы сүзләре белән юынтык суга коендыргандай итте* (И. Нәбиуллина. Ташта үскән гөл). *Синең баллы сүзләреңнән соң мәхәббәтемә яңадан җан иңгәндәй булды, Гаязетдин бәгырь* (М. Хәбибуллин. Айбиби).

Төрдәше: авызга җен төкерү һ.б.

**БАЛЛЫ ЯҢГЫР ЯВУ.** Акча керү, акчалата бүләкләү. *Нәҗипнең башы урталайга ярыла иде, моңарчы бер дә тәтемәгән «фондтан» нигә бүген баллы яңгыр яуганын тикшереп тормады* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

*БАЛ-МАЙ* ❖ **БАЛ-МАЙ <ГЫНА> АШАП ТОРУ** *к.* авыз балда, кул майда. *[Миңлесылу]. Алар нигә язылсыннар, алар анда язылмый да бал-май ашап торалар* (Һ. Такташ).

Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

**БАЛ-МАЙ БЕЛӘН АВЫЗЛАНМАГАН.** Усал телле кеше турында. Бала тугач та, тәмле сүзле булсын өчен, бал-май белән авызландыру йоласын күрмәү белән аңлатыла. – *Бал-май белән авызланмагандыр ул, авызланса, мондый булмас иде* (Сөйләм).

**БАЛ-МАЙ ЭЧЕНДӘ <ЙӨЗҮ>** *к.* авыз балда, кул майда. *[Хафиз] Ташла, зинһар! Мин сине болай да бал-май эчендә генә тотачакмын* (Р. Ишморат. Гөлзада). *[Майлыбикә] Сугыш елында магазинда эшләгән чагымда миңа да өреп тордылар, ә мин, бии-бии, бал-май эчендә йөзеп йөрдем* (Ю. Әминов. Язылмаган законнар).

Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

**БАЛ-МАЙ ЭЧЕНДӘ ТӘГӘРӘҮ** *к.* авыз балда, кул майда. *Аныңча, мондый шәһәрткә ирешкән кешеләр, бөек затлар, алар тормыш ваклыкларын, мәшәкатьләрне белмичә, бал-май эчендә генә тәгәрәп яшәргә тиешләр иде* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).

Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

**БАЛ-МАЙ ЭЧЕНДӘ ТОРУ (ЙӨЗЕП ЙӨРҮ; ЯШӘҮ)** *к.* авыз балда, кул майда. *Әмма мондый «кавышулар»ның ахыры һаман бертөрле тәмамлана иде: егетләр шул рәвешле өч-дүрт ел бал-май эчендә йөзеп яшиләр дә, диплом алгач, канат җәеп, юллама күрсәтелгән юнәлештә очып китәләр иде* (М. Маликова. Сөю турында кыйссалар). – *Юкка тасма теллеләнмә, бал-май эчендә торырга яратмыйм мин* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

**БАЛ-МАЙДА ЙӨЗҮ** *к.* авыз балда, кул майда. *Хәзер кул куеп, имза сырлап кына яши бирәм, бал-майда йөзәм, җаным теләгәнне ашыйм һәм чит ил машиналарында типтерәм* (Н. Хәсәнов. Имза).

Төрдәше: авыз балда, кул майда һ. б.

*БАЛТА* ❖ **БАЛТА АСАРЛЫК (АСЫП КУЯРДАЙ/ КУЯРЛЫК).** Бик куе төтен, пар һ.б. *Бүлмәдәге болай да балта асып куярдай булган зәп-зәңгәр тәмәке төтене тагын да куера төшә* (Р. Төхфәтуллин). *Җыелыш барган бинада / Балта асарлык төтен* (С. Баттал). *Бүлмә шыксыз. Балта асып куярлык тәмәке төтене* (З. Мәхмүди. Елак агач).

Төрдәше: балта элеп куярлык.

**БАЛТА БЕЛӘН АГАЧ (ТУМАР) АРАСЫ.** Бик хәтәр, куркыныч урын, эш. *Яхшылап уйла, балта белән тумар арасына керүеңне сизәсеңме син?* (Сөйләм).

**БАЛТА БЕЛӘН АГАЧ (ТУМАР) АРАСЫНА БАРМАК ТЫГУ.** Хәтәр эшкә алыну. *Балта белән агач арасына бармак тыгарга картлар кушмаганнар* (К. Тинчурин). *Балта белән агач арасына бармак тыкма* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

**БАЛТА БЕЛӘН ҖИЛ КАЕЗЛАУ** *к.* авыз күтәреп яту. – *Абыеңның богатствосы алай күзеңне кыздыргач, утыз ике яшеңә хәтле зачем балта белән җил каезлап йөрдең?* (Н. Гыйматдинова. Ачкыч).

Төрдәше: авыз күтәреп яту һ.б.

**БАЛТА БЕЛӘН СУ КИСҮ** *к.* авыз күтәреп яту. – *Безгә балта белән су кисеп ятучы кирәк түгел, башка җиргә бар* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз күтәреп яту һ.б.

**БАЛТА БЕЛӘН ТӨЙМӘ ТӨЮ** *к.* агач<тан> сандугач кына ясамау. *Татар агайлары иләнәҗиренә теше-тырнагы белән ябышып, юктан бар кылып, балта белән төймә төеп яшәсә, урыс мужигы артык казганырга яратмый* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы).

Төрдәше: агач<тан> сандугач кына ясамау һ.б.

**БАЛТА БЕЛӘН ЮНГАН.** Тупас кешегә (яки эшкә), булдыксыз кешегә карата. *Балта белән юнган, диеп / Әйтәләр начар эшкә. / Аның эшен күргән кеше / Болай сөйләмәс һич тә* (Н. Курамшин. Балачак бәйрәмнәре).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**БАЛТА БИРЕП ШӨШЛЕ АЛУ.** Алдану (зур бәяле әйбер биреп, арзан бәяле берәр нәрсә алу). – *Балта биреп шөшле алдым – алдаладым татарны булды инде бу, – диде пәрәмәч битле юантык гәүдәле «поселок хатыны» – Зәйтүнәнең әнисе – булачак кияүгә карап* (М. Мәһдиев. Ут чәчәге). *Ташаяк та, кәгазь дә кәрванбаш әйткәннән очсыз, ди. Балта биреп шөшле алу түгелме соң бу* (Р. Батулла. Сөембикә).

Төрдәше: агач атка (аргамакка) атлану (атланып калу).

**БАЛТА ДА ЧАПМАУ** *к.* авыз күтәреп яту. *Бөтен авыл җыелып өмә ясаганда, ул ир башы белән балта да чапмады* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз күтәреп яту һ.б.

**БАЛТА ЙӨЗЛӘТҮ.** Әшәкелек, дошманлык, җинаять эшләргә әзерләнү. *Сөембикә тамырына / Вакыт балта йөзләтә / Йөрәк тибешенә көйләп, / Туфан сәгать төзәтә* (З. Мансуров. Күңел гамәле).

**БАЛТА КЕРМӘГӘН УРМАН.** Кул тимәгән урман. *Балта кермәгән урманнарга чылбырлы пычкылар белән кереп, машина-машина урлап саталар* (Сөйләм).

**БАЛТА КЕРМӘС (КЕРМӘГӘН; КЕРЕРЛЕК ТҮГЕЛ).** 1. Куе, чытырман, ешлык. *Балта кермәгән кара урманнар бар бит безнең бу якларда* (Г. Галиев).

2. *күч.* Кул тимәгән, тикшерелмәгән эш. *Балта кермәгән әле бу эшкә, төрле яклап уйламыйча, тотынырга ашыкмыйк* (Сөйләм).

**БАЛТА КҮТӘРҮ.** 1. Балта тотып һөҗүм итү. *Бәлки, идарә итүчеләр үз дәрәҗәләре, рәхәт яшәүләре өчен гади халыкның рәхәтен, бәхетен тартып алу өчен көрәшкәннәрдер, балта күтәргәннәрдер?!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Моңа килмешәкнең түзәрлеге калмый, кулындагы балтасын күтәреп, төркемгә ташлана* (К. Җәмит. Килмешәк).

2. *күч.* Әйтелгән сүзгә дуамалланып каршы тору. *Юк, сиңа каршы берәү дә балтасын күтәрмәс. Тик шул рухта безнең балаларыбызга да тәрбия кылырга гомерең җитәрме синең?* (Н. Гариф. Мин сезнең арада яшәдем). *Хәзер бит кылыч белән баш кисәрлек кешеләр юк, дуслар. Антагонизм юк, ә син балта күтәрәсең. Мәсьәләләргә субъектив киләсең, бер яктан гына карыйсың...* (Р. Батулла).

**БАЛТА МАЕ ЯЛАГАН.** Гомерендә күп нәрсә күргән, тәҗрибәле. *Әмма бу немец балта мае ялаган кеше иде, ахры, минем мөселман токымыннан икәнемне, ышанычлы һәм карусыз зат булуымны бер карауда сизеп-тоеп алган иде* (М. Әмирханов. И, кылган догам минем...). *Балта ленинизм, совет режимы кулында! Балта мае ялаган адәм* («Матбугат.ру» порталы).

Төрдәше: авызы пешкән өреп капкан һ.б.

**БАЛТА МАЕ ЯЛАТУ** Дөнья күрмәгән кешене кызык итү, көлкегә калдыру. – *Күрше Мансурга балта мае ялатырга кирәк, бик борынын күтәреп йөрмәсен* (Сөйләм).

**БАЛТА САБЫ <БИК> КЫСКА.** 1. Белеме, тәҗрибәсе, булдыклылыгы түбән дәрәҗәдә; акыл дәрәҗәсе дә түбән. *Хәмер капкаларга ияләшеп китүе тагын. Әйе, аның, кем әйтмешли, балта сабы кыска иде* (Ә. Хәсәнов. Әнис алмалар). *Мондый зур эшне аларга ышанып тапшыру ярамас... Рушанның вакыты бик тар, ә тегесенең балта сабы кыска, – диде ул, бераз уйланып алганнан соң* (Р. Мирхәйдәров).

2. Тиз кабынып, кызып китүчән; тиз ачуланучан. – *Мөдир белән очрашканда, аңа каршы сөйләргә тырышма – балта сабы кыскарак аның* (Сөйләм).

**БАЛТА САБЫНА ИЯ БУЛУ.** Дошманга каршы көрәшкә һәрчак әзер булырга кирәклегенә ишарә. *Урысны мактап кына балта сабына ия булырга мөмкин икәнен татарларга моннан күп еллар элек Иван патша сеңдергән* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**БАЛТА САБЫНА УТЫРТУ.** 1. Кире яктан кагып (ягъни бәреп-кыйнап) акылга утырту; алдау. *Ирек күңеленнән генә: «Алдашмыйсыңмы, кызыкай, – дигән сорау бирде, – мине балта сабына утыртырга җыенмыйсыңмы?»* (Р. Кәрами. Кая чабасың, тормыш юртагы?).

Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

2. Кирәкмәгәнгә көттерү, көттереп кенә эшләү. – *Кыймылда инде тизрәк, балта сабына утыртасыңмы югыйсә?* (Сөйләм).

**БАЛТА СОРАГАНГА КӨРӘК (ШӨШЛЕ) БИРҮ (ТОТТЫРУ).** 1. Берәр нәрсә сораганда, бу эш өчен бөтенләй кирәге булмаган башка нәрсә бирү. *Балта сораганга шөшле биреп, / Шаярса да язмыш дигәннәре, / Ил сурәтен ясап түргә элгән / Галиҗәнап халык ирәннәре* (Г. Морат. Халык осталары). *Балта сораганга шөшле тоттырмагыз. Балта сораган кешегә шөшле тоттырган кебек булган бу, чөнки гаражның Хикмәтовныкы икәнлеген раслый торган документлары аның кулында ләбаса* («Безнең гәҗит» газ.)

2. Сораганга бөтенләй туры килмәгән җавап бирү. *Балта сораганга шөшле тоттырды дигәндәй, җавабының да рәте-чираты*

*бетте* (Ф. Латыйфи). *Балта сорагандa шөшле тоттыра дигәндәй, болар Әбелмәлихнең башына кереп тә караган уйлар түгел иде* (М. Әмирханов).

Төрдәше: балта урынына шөшле сузу (тоттыру); иләк сораганда чиләк тотттыру. шөшле урынына балта бирү; ышкы сораганга пычкы бирү (ике маддә өчен дә).

**БАЛТА<СЫ> СУГА ТӨШҮ (ТӨШКӘНДӘЙ) <КЕБЕК>.** Бәла-казага очраган кебек боегып, күңелсез йөрү. *«Бүген үк!» – диде ул, Нәҗип Нургалиевнең балтасы суга төшкәнен, көймәсе комга терәлгәнен сизеп. – Өч айлыкны бүген үк китерәсең!»* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). – *Ә запас көпчәгегез юкмы, шуңа балтагыз суга төштеме?* (Г. Тавлин. Афәт).

Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**БАЛТА ТЕЛ** *к.* әрем <тел>ле. *Сара ханым шундый усал итеп карады миңа – балта тел, дип, үз-үземне сүгеп тә куйдым* (М. Гали. Догалы еллар). *Шундый агач авыз, балта тел инде мин* (М. Әмирханов. Тәкъдир).

Төрдәше: әрем <тел>ле һ.б.

**БАЛТА ТОТУ.** Хуҗалык эшләрен, балта эшен белү. *Сүз ахырында аюдан сораган: – Эт ияртқән, кулына балта тоткан кешене күрмәдеңме?* (А. Алиш. Сертотмас үрдәк). *Нәҗипнең кинәт көләсе, мәйданны яңгыратып: «Балта тоткан куллар кызыл әләмнәрне тотарга да мәҗбүр шул!» – дип кычкырасы килде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**БАЛТА ТОТЫП СӘНӘК ОЧЛАУ** *к.* авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү. *Балта тотып сәнәк очларга кулыннан килми, чалгы алса, адәм уңаена бара алмый* (Г. Ибраһимов. Табигать балалары).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**БАЛТА УРЫНЫНА ШӨШЛЕ <СУЗУ; ТОТТЫРУ>** *к.* балта сораганга көрәк (шөшле) бирү (тоттыру). *Шул рәвешчә, балта урынына шөшле сузучылар күп булды ул көнне* (Ф. Хөсни). *Ә ул юк та юк! Ягъни француз тамашачыларына балта урынына шөшле тоттырып алдыйлар түгелме?* (Р. Вәли. Канатлы татар).

Төрдәше: балта сораганга көрәк (шөшле) бирү (тоттыру) һ.б.

**БАЛТА ЧАБУ.** 1. Балта эше белән шөгыльләнү; агачка балта батыру. – *Балта чапсаң да, такта ышкыласаң да, уңына күбрәк авырга килә* (М. Хуҗин. Айның уты сүнгән). *Нурымга кара син, яше дә кырыкка җитеп бара, гәүдәгә дә чандыр гына, ә балтаны чаба! – йомычкалар гына оча* (З. Мурсиев. Солтанъяр).

2. Ике араны өзү. *...Нигә хәзер үкенечле уйлар / Балта чаба барыр юлларга?* (Э. Шәрифуллина. Син беләсең булыр). *Үткәннәргә балта чапкан чакта, / Телдәдекме шулай булуын: / Хәтта Ленинны да белми үсә / Яңа борынлаган бу буын* (Н. Әхмәдиев. Абага чәчәге).

Төрдәше: күперләрне яндырып китү; күпер<ләр>не яндыру (ягу).

2. Нәрсәне булса да әрәм итү, җимерү, юк итү. *Янәсе, матур, дөрес сөйләргә өйрәтәләр, чынлыкта халык иҗатына балта чабалар* (Н. Фәттах. Беренче шигырь күк балачак). *Һәм төн уртасында сулуы кабып килеп кергән юаш карт Мирвәлинең гомер юлына балта чапты* (А. Гыйләҗев. Өч аршын җир).

Төрдәше: аударып ташлау һ.б.

**БАЛТА ЭЛӘРЛЕК <БУЛУ> (ХӘЛГӘ КИЛҮ)** *к.* балта асарлык (асып куярдай / куярлык). – *Менә «Беломор» дигәнен тартып карыйк әле, шәкерт абый, монысы тагын да шәбрәк аның. Бүлмә эче балта элрлек булган иде инде* (Г. Афзал. Хәл-әхвәлләр). *Палатаның тынчу, сасы һавасы шулкадәргә җитеп тыгызланды ки, балта эләрлек хәлгә килде, тәрәзәләрне киереп ачып җилләтүнең дә файдасы тими башлады* (Н. Әхмәдиев. Мөнирстан).

Төрдәше: балта асарлык (асып куярдай / куярлык); балта элеп куярлык; балта элсәң, төшмәс.

**БАЛТА ЭЛЕП КУЯРЛЫК** *к.* балта асарлык (асып куярдай / куярлык). *Класста балта элеп куярлык тузан...* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы).

Төрдәше: балта асарлык (асып куярдай / куярлык) һ.б.

**БАЛТА ЭЛСӘҢ, ТӨШМӘС** *к.* балта асарлык (асып куярдай / куярлык). – *Тәрәзәне ачыгыз әле, монда балтаңны элсәң дә, төшмәс иткәнсез* (Сөйләм).

Төрдәше: балта асарлык (асып куярдай / куярлык) һ.б.

*БАЛТАГА* ❖ **БАЛТАГА САП БУЛЫП ЙӨРҮ.** 1. Үз эше булмаганлыктан, кешегә йомышчы булып йөрү. *Үзең күз күргән кеше, яхшы ата баласы,*

*болай балтага сап булып йөрүдән аз-маз оялыр идең* (М. Галәү. Мөһаҗирләр).

2. Үз иленә, үз халкыңа дошман булып йөрү. *Балтага сап булып йөргән, дошман кулында үз халкына каршы эшчәнлек алып барган, күз бәйләш уйнаган* («Казан утлары» ж.).

*БАЛТАНЫ* ❖ **БАЛТАНЫ ТАШКА ОРУ (ЧАБУ).** Хата ясау, ялгышу. *Язмаңны газетага тапшырганчы, саннарыңны тикшереп чык, балтаңны ташка ора күрмә* (Сөйләм).

*БАЛТАСЫ* ❖ **БАЛТАСЫ СУГА ТӨШКӘН КЕШЕДӘЙ (АДӘМДӘЙ)** *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. *Зиннәтулла исә, балтасы суга төшкән кешедәй, башын иеп утыра бирде* (М. Әмирханов. Зиннәтулла хәзрәт). *Алтмышка җитеп килсә дә, күңелендә сабыйлыгын саклаган Николай Кузьмич бу хәбәрне күтәрә алмады: ике-өч көн буена балтасы суга төшкән адәмдәй башын иеп, беркем белән дә сөйләшмичә йөрде-йөрде дә бер төнне венасын кисте* (Н. Әхмәдиев. Мөнирстан).

Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

*БАЛТАСЫН* ❖ **БАЛТАСЫН ҖУЙГАН КЕШЕ КЕБЕК** *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. – *Сез никтер һаман, балтасын җуйган кеше кебек, башыгызны аска салып кына йөрисез, – диде ул* (Л. Хәмидуллин. Буранлы төндә).

Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**БАЛТАСЫН СУГА ТӨШЕРҮ** *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. – *Балтасын суга төшергән урыс кебек гел кайгыңа батып йөрисең, – дип шаяртырга уйлаган икән, ул аңа бик пычрак, бик агулы бер сүз генә әйткән дә артык авыз да ачмаган* (Г. Ибраһимов. Яшь йөрәкләр). *Нәҗип Захаров янына әвене янып кергән иде, балтасн суга төшереп чыгып китте* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

*БАЛТАСЫЗ* ❖ **БАЛТАСЫЗ УРМАНГА БАРГАН КЕБЕК.** Максатка чарасын күрмичә баруның буш эш икәнлеген белдерү. *Һай пешмәгәннәр, булмастай кешене балтасыз урманга барган, диләр, сез шуннан да уздырдыгыз* (З. Мурсиев. Таш мәчет).

*БАЛЧЫКТАН* ❖ **БАЛЧЫКТАН ӘВӘЛӘМӘГӘН (ЯСА<Л>МАГАН).** Үзен яклый ала торган, җансыз түгел. *Тагын берсе бик олысымак кына: – Анысы ук булмас инде, Кәрим, Фәтхине дә балчытан әвәләмәгәннәр бит, – дип, каршы якны да җилкендереп куйды* (Ф. Сәйфи-Казанлы. Крушниклар). *Мирза, син дә балчыктан ясалмаган* (М. Фәйзи. Ак калфак).

**БАЛЧЫКТАН ЯРАТЫЛУ**. Дин тәгълиматына күрә, Адәм балчыктан яратылган дип танылa. *Кем белсен, бәлки, Сөннәтче бабай чынында шул өйнең балчыгы берлән бер балчыктан яратылгандыр* (Г. Исхакый. Сөннәтче бабай). *Адәм галәйһиссәлам нәрсәдән яратылган? Энциклопедик сүзлектә «җан өретелгән балчыктан яратылган» диелә* (А. Тимергалин. Милли казаныш).

*БАЛЫГЫННАН* ❖ **БАЛЫГЫННАН БУЛЫРМЫ, БАКАСЫННАН БУЛЫРМЫ.** «Кайсысы насыйп булыр, әлегә билгесез» мәгънәсендә. – *Исәнме, Хәмит, үзең ни эшләр майтарып йөрисең? – Балыгыннан булырмы, бакасыннан булырмы, дип әйләнгәлибез инде шунда* (М. Әмирханов. Тояк эзе).

*БАЛЫК* ❖ **БАЛЫК БАШЫ.** Бер үк нәрсә. *Нәҗипкә әйткәннәре һаман шул ук балык башы булды* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Монысы да акча турында... Һаман бер балык башы...* (Д. Гыйсметдин. Ботак).

**БАЛЫК БАШЫ АШАГАН.** Акылдан язган, шашкан. – *Ышанма син аңа, балык башы ашагандыр ул* (Сөйләм).

**БАЛЫК БАШЫ БУЛУ.** Бер-берсенә охшашлану. *[Гыйльметдин] Миңа, Алла боерса, җитәр көз... игеннәрне эшләрбез... аякта күн итек, башта сибирский бүрек, муенда кәҗә мамык шарф булыр. Барыбыз да балык башы булырбыз әле...* (Ф. Бурнаш. Яшь йөрәкләр).

**БАЛЫК БАШЫ УРЫНЫНА ЧӘЙНӘҮ.** Бер әйберне, бер үк сүзне кайта-кайта сөйләп тору; бер үк сүз (фикер, мәсьәлә) туйдырып бетерү. – *Бар, үзең чыгып сөйләш әле аның белән, мин инде гарык булдым – балык башы урынына чәйнәде ул мөһим мәсьәләсен* (Сөйләм).

Төрдәше: авызда гел <балалары гына> булу һ.б.

**БАЛЫК БАШЫН ЧӘЙНӘҮ** *к.* авызда гел <балалары гына> булу. *Әти кайтса, әни аш сала, солдат та әти дә ахшамнан кайтмас, әни дә аш салмас дип, тагы иске уйга кайтты, тагы*

*балык башын чәйнәргә тотынды* (Г. Исхакый. Солдат).

Төрдәше: авызда гел <балалары гына> булу һ.б.

**БАЛЫК БИРСӘҢ, БӘЙЛӘП БИР, БАШЫН-КҮЗЕН ЧӘЙНӘП БИР** *к.* авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү. – *Балык бирсәң, бәйләп бир, башын-күзен чәйнәп бир, дип көтеп утырма әле – әнә балта, теге корыган агачны чаба башла* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**БАЛЫК БИСТӘСЕ – УН ТИЕН ДИСТӘСЕ.** Арзан нәрсә, ягъни арзан темага арзан фәлсәфә сату. – *Бу сүзләреңне сөйләми тор, башкалар ишетмәсен. Карале, син Балык Бистәсенә барып кайтмагансыңдыр бит, Балык Бистәсе – ун тиен дистәсе дип сөйләгәннәрен ишеткәнем бар иде* (Сөйләм).

**БАЛЫК КЕБЕК ТЕЛСЕЗ.** Берни дәшмичә, сөйләшмичә утыручы турында. – *Йә, йә, авызыңа су алдыңмы әллә? Балык кебек телсез калдың, – дип, иренә ташланды ул* (С. Сабиров. Алтын балдаклы абыстай). *Галимҗан дәресләрдә балык кебек телсез булса да, класстан класска әйбәт кенә күчеп барды* (Р. Төхфәтуллин. Акбүз ат).

Төрдәше: авыз <да> ачмау һ.б.

**БАЛЫК ТИРЕСЕ БЕЛӘН ЭЧЛӘГӘН** *шаяр.* Салкында җылытмый торган сыйфатсыз кышкы кием. – *Бу балык тиресе белән эчләгән киемнән кышны ничек чыгарсың?* (Сөйләм).

**БАЛЫК ТИРЕСЕННӘН ТЕГЕЛҮ.** Бик юка, суыктан саклмый торган. *Яшьләр, мода артыннан куа-куа, үтә күренмәле оек, «балык тиресе»ннән тегелгән юка гына итек киеп салкын тидерәләр дә бала таба алмыйча интегәләр* («Безнең гәҗит» газ.).

**БАЛЫК УРЫНЫНА ЙӨЗҮ.** Нәрсәнедер бик яхшы белү, шул эшнең остасы булу. *Һәрхәлдә, ул моннан ярты сәгать кенә элек балык урынына йөзгән шуклык дулкынында түгел иде хәзер* (Ф. Хөсни. Адәм балалары). *Классташыбыз Габдулла математикадан балык урынына йөзә иде, әллә нинди тигезләмәләрне чикләвек урынына ватып ташлый иде* (Р. Низами. Кояш – минем авылдашым).

Төрдәше: судагы балык сыман йөзү.

**БАЛЫК ШУЛПАСЫ.** Су (чөнки анда балык йөзә). *Шулай да тышы корымланып беткән бәләкәй бидрәне тутырып су кайнаттык. Янәсе, булачак балык шулпасы* (М. Кәрим. Ишеткәннәр, күргәннәр...).

Төрдәше: Лаеш суларын (шулпасын) эчеп узу; Лаеш шулпасын эчү.

**БАЛЫК ШУЛПАСЫНЫҢ ШУЛПАСЫ.** 1. Бер үк эш кешеләре, әмма бер-берсеннән ераграк торалар. – *Без бераз коллегалар, – дидем. – Балык шулпасының шулпасы, – дип үртәде Минский* (Г. Гомәр. Шәхесләр һәм шәрехләр).

2. Кемнәндер ишетеп кенә сөйләү, язу. *Бу басманың баш мөхәррире Миңназыйм Сәфәров әйтүенчә, «балык шулпасының шулпасы» булмасын өчен, ягъни үз күзләре белән күреп, үз колаклары белән ишетсен өчен, протест чарасына алар журналист җибәргәннәр* (azatliq.org).

Төрдәше: куян шулпасының шулпасы.

*БАЛЫКНЫ* ❖ **БАЛЫКНЫ ЙӨЗӘРГӘ ӨЙРӘТМӘҮ.** «Ниндидер өлкәне синнән яхшырак белгән кешене өйрәтмиләр» мәгънәсендә. *Сәлим инде аның күлендә йөзгән. Балыкны йөзәргә өйрәтмиләр* (С. Поварисов. Утлы дуга кыңгыравы). – *Ярый, ярый, балыкны йөзәргә өйрәтмиләр, каргага парашют кирәкми* (Б. Камалов. Узган гомер бигрәк җәл).

Төрдәше: атаңны йөткерергә өйрәтмиләр һ.б.

*БАЛЫКНЫҢ* ❖ **БАЛЫКНЫҢ БАТАСЫ ЮК.** Үзеңнең хәлеңне начарайтудан курыкмыйча эш итү. – *Тәвәккәлләдек инде, балыкның батасы юк аның* (Сөйләм).

*БАЛЫКЧЫ* ❖ **БАЛЫКЧЫ БАЛЫКЧЫНЫ ЕРАКТАН КҮРӘ (ТАНЫЙ).** «Кызыксынулары бердәй, уртак фикерле, тәрбияләре, тормыш тәҗрибәләре тиң булган бер даирә кешеләре яхшы таныш булмасалар да, тиз танышалар, бер-берсен яхшы аңлыйлар» мәгънәсендә. *Ярый, Муса абый, җеп очын чуалтуда мане аз. Балыкчы балыкчыны ерактан күрә* (Г. Әпсәләмов. Агыла болыт). *Балыкчы балыкчыны ерактан күрә, диләр, табышу-аралашу өчен, бурларга да ара ераклыгы комачаулык итми икән, дип уйлап куя Гыймазетдин, хуҗа белән хушлашып, юлга кузгалгач* (Ә. Моталлапов. Йөзә торган арба).

Төрдәше: сунарчы сунарчыны ерактан күрә (таный).

*БАНК* ❖ **БАНК СУГУ (СУГЫП АЛУ).** Банктагы акчаны (комарлы уенда) отып алу. *Бер сугуда 20 тәңкәлек банк сугып алдым, шулай да кесәдә бер тиен акча юк* <...> (М. Гали).

**БАНК ТОТУ.** Комарлы уенда банкка акча куеп, һәр уенчы белән аерым уйнау. *Арада берсе аягүрә баскан, кулында бер колода карта, исерегрәк тавыш белән банк тота* (Г. Ибраһимов).

**БАНК ШАРТЛАТУ.** Бөлгенлеккә төшерү. *Ун ел үтми, акча басып, Мәскәү банк шартлата* (Р. Рахмани. Мәскәү нәрсә шартлата).

*БАП* ❖ **БАП КИЛҮ (ТӨШҮ).** Бик уңай булу; туры, җай килү; уңайга килү. *Семантик җәһәттән күрек «көйрәткеч» мәгънәсенә бик тә бап килә* (Р. Әхмәтьянов. Татар теленең этимологик сүзлеге). *Гомумән, бу процесс «тел ялкаулыгы» закончалыкларына бап килә: сөйләшүчеләр, аңлаешлылыкны саклаган хәлдә, җиңелрәк әйтергә тырышалар* («Фән һәм тел» ж.).

*БАПЛАП* ❖ **БАПЛАП УТЫРУ (СӨЙЛӘШҮ).** Бик иркенләп, озаклап сөйләшеп утыру. – *Бүген кич белән миңа кереп чык әле, баплап утырырбыз* (Сөйләм).

*БАР* ❖ **БАР АВАЗГА КЫЧКЫРУ.** Бөтен көчкә кычкыру. *Акылдан шашкан сыман, дәррәү аяк өстенә сикереп тордым һәм бар авазга кычкырып җибәрдем; – Тәнзил!* (Ф. Шәфигуллин).

**БАР ӘЙБЕРДӘ ЗЫЯН ЮК.** Берәр нәрсә кулыңда булып, тагын шундый ук әйбер кулыңа кергәндә әйтелә. – *Ишләре янына куй шунда, бар әйбердә зыян юк* (Сөйләм).

**БАР БЕЛӘН БАЛКУ.** Күңелендә булганын яшермичә, ачык йөз белән. – *Бер читенә ут капмаган. Бер очрамаса, икенче очрар, кызлар үсә тора, – дип, бар дөньясы белән балкып елмаеп куйды ул шунда* (Р. Мөхәммәдиев. Кош булып очар идем...).

**БАР БЕЛГӘН (БУЛГАН; ТОРГАН).** 1. Бөтен, барча, барлык. *Бар белгән эше киенү дә ясану* (Г. Камал. Кайниш). *Аның бар белгән сүзе: / «Этәрәм» дә «Күтәрәм»!* (Х. Туфан).

2. Бары тик (чикләнгәнлекне белдереп). *Ябык кына, какча гәүдәле бер кеше, бар белгән шөгыле хәер сорашу иде* (Н. Акмал. Миссионер). *Эш килми берниндә дә минем кулдан, бар белгән эшем – кабыклы бәрәңге пешереп тору, эштән кайтканнарга, укып йөргәннәргә* (З. Зәйнуллин. Ат караклары).

**БАР БЕЛГӘНЕ.** Бер эшне гадәт нигезендә яки күп еллар эшләп күнеккәне нигезендә эшләү. *Ул әле ярый, анысына да түзәрсең, безнекенең әнә бар белгәне эчү дә талашу. Бар белгәне – акча күбәйтү* (Ш. Мөхәммәдев).

**БАР БУЛСА – КҮРӘЛМИ, ЮК БУЛСА – БИРӘЛМИ** *к.* алтын бишектән төшү. *Нигә аптырадың аңа, ул һаман шулай яши бит инде: бар булса – күрәлми, юк булса – бирәлми* (Сөйләм).

Төрдәше: алтын бишектән төшү һ.б.

**БАР БУЛУЫ КОРЫСЫН.** Бар булып та, эшкә ярамаган кеше яки әйбер турында. *Бар булуы корысын – бу балта белән ботак та чабып булмый бит* (Сөйләм).

**БАР ДА БАР.** Бөтен нәрсәнең төрлесеннән булганлыгына бернинди шөбһә булмау. – *Кем күргән? – диде Әхмәт. – Әнә Кырлай урманында дисәң, ичмасам, анда бар да бар* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**БАР ДА ХАН, БАР ДА ТҮРӘ – АТКА ПЕЧӘН КЕМ САЛА?** *к.* агай олы, мин зур, атка печән кем сала? *Бар да хан, бар да түрә – атка печән кем сала, дип төркиләр дә зарлана башлаган иде* (М. Хәбибуллин).

Төрдәше: агай олы, мин зур, атка печән кем сала? һ.б.

**БАР ДИМӘСӘҢ, ХӘТЕРЕ КАЛЫР.** Хәтер калмас өчен генә исәпкә керү. *Урманга барганда, Фатыйх бабайны да дәшегез – бар димәсәң, хәтере калыр* (Сөйләм).

**БАР ДИП БЕЛҮ.** *Чыбык белән дә куркытып карады – бар дип беләм! Барыбер сукмый ич ул* (Ш. Маннур. Агымсуларга карап).

**БАР ДИП ТӘ БЕЛМӘҮ.** 1. Игътибарга алмау, барлыгын тоймау. *Күпне күргән «ЗИЛ», түмгәкләрне бар дип тә белмичә, сикерә-янтая, авылга элдертте* (А. Тимергалин. Таш алиһә). *Моңарчы иннек-сөрмәне бар дип тә белмәгән кыз нык кына бизәнергә кереште* (Г. Галиева. Өзелгән өмет).

2. Санга санамау, санлашмау. *«Кибеткә сирәк кенә тәм-том, сыек май кайта, безне*

*бар дип тә белмиләр, төрткәләп чыгаралар»* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Мин саткан урман хисабына баеган шүрәлеләр мине бар дип тә белмәделәр* (Г. Тарханова. Шүрәлеләр илендә).

Төрдәше: башка атлану 2 һ.б.

**БАР ДӨНЬЯСЫН ОНЫТЫП.** Бик яратып, бирелеп (эшләү, ясау һ.б.) *Чыннан да гашыйк егет янындагы гүзәленә бар дөньясын онытып соклана иде* (А. Нәҗмиева. Азат). *Хәйдәр, бар дөньясын онытып, шомырт белән майкасын тутырганда, аста Миңнеханның йөрәк өзгеч тавышы яңгырады: – Ботакка елан уралган!* (В. Имамов. Нәзер).

Төрдәше: дөньясын онытып.

**БАР ИДЕ ДӘ, ЧИРӘМ БАСТЫ ШУЛ ИНДЕ.** Булды да бетте, бөтенләйгә онытылды. – *Сөйләмә дә, балачакта Кара күлгә балыкка йөргән чаклар бар иде – бар иде дә, чирәм басты шул инде* (Сөйләм).

**БАР ИКӘН <БЕР>.** 1. Гаҗәпләнеп гаеп итүне белдергәндә яки кат-кат йөдәтеп бетергәндә әйтелә. *Тагын бер мәртәбә килмәс микән, типкәләп чыгарырмын, бар икән бер гарьсез нәрсә, һич сүккәнне дә белми* (Г. Камал). *Әй Ходаем, тагын ниләр күрәсебез бар икән* (А. Алиш. Күршеләр).

2. Гаҗәпләнүне, соклануны белдерә. *Яшел Үзәндә әтәчләр бар икән әле* (А. Тимергалин. Игезәкләр).*Чакырып торган зәңгәр хыял идең, / Бар икән бер сине күрер чак* (Р. Миңнуллин).

**БАР ИКӘН КҮРӘСЕЛӘР.** Кирәкмәгән мәшәкать килеп чыкканда әйтелә. *Бу хурлыкка түзә алмыйча, кунак кыз иртәгә үк кайтып китәчәк! Бар икән күрәселәр!* (Г. Бәширов, Туган ягым – яшел бишек). – *Бар икән күрәселәр, монда бит тагын мин гаепле. Кеше күзенә ничек күренерсең* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

**БАР ИТҮ.** Булдыру, барлыкка китерү. *Карчык-корчык булмаган йомышын бар итеп кердә, ир-атлар турыдан-туры «шәһәр егете»ннән сораштыру өчен сугылып чыгалар иде* (А. Тимергалин. Таш алиһә). *Мин сездә еш булам икән, Нурисламың янына түгел, юк вакытларымны бар итеп, сиңа ярдәм итәргә дип керәм* (Г. Галиева. Газзәбану).

**БАР КАДӘР.** Күпме булса, шуның кадәр. *Алар бар кадәр даруларын биреп торырга булдылар* (Г. Әпсәләмов. Газинур). *Бар кадәр саннарында Акчураның үз имзасы белән басылган ике мәкаләсе билгеле* (М. Гайнетдин. Й. Акчура).

**БАР КАДӘРЕНЧӘ.** Кулдан килгәнчә, кулда булган кадәренчә (бирү, булышу һ.б.). *Өе элекке кебек бар кадәренчә җыйнак, пөхтә иде* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Әйбәт кенә җыендылар, бар кадәренчә ризыкларын алдылар, азыкка дигән кадерле акчаларын ерак яшерделәр, шуның өстенә капчыкларына иске-москы киемнәр дә салдылар* (Ә. Еники. Соңгы китап).

**БАР КЕБЕГЕ.** Бөтен булганы, исәпкә алырга мөмкин булганы. *Бар кебеген карап чыктык инде, кирәклесен генә таба алмадык* (Сөйләм).

**БАР КЕБЕК.** *Мәхүп әби конверт эчен яхшылап карады. Әллә нинди каты кәгазь бар кебек, батырланып тартып чыгарды* (А. Алиш. Яңа килен). *Янәшә купеда шау-шу бар кебек тоелды – Рөстәм шунда керде* (Г. Кутуй. Рөстәм маҗаралары).

**БАР, КОЙРЫГЫН ТОТ.** «Алдакчы кеше бер кулдан ычкынса, аны тоту мөмкин түгел» мәгънәсендә. – *Аның алдакчы икәнлеген белми идеңмени, хәзер инде, бар, тот койрыгын* (Сөйләм).

**БАР КӨЧЕНӘ.** Бик тиз, туктамыйча. *Поезд бар көченә чаба, безне көлдерерлек дәрәҗәдә бик нык чайкый* (А. Алиш. Тимер юл). *Бертуктаусыз йөгерүдән сулуы капса да, ул туктамады, куркытылган кыргый җәнлектәй бар көченә чабуын белде* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**БАР КӨЧКӘ (ХӘЛГӘ; ТЫНГА).** Армый-талмый тырышып, нәрсәне булса да эшләүдән туктамыйча. *Халыкара низагларда көл булмаган ни генә?! Кеше гүя гомер буе чүлмәк ваткан бар көчкә* (З. Мансуров. Җәрәхәтле йөрәк җылырак). *Киселеп ташланган кулларым, / Нәфрәттән терелеп, бар көчкә /Чиртәләр гитара кылларын...* (Р. Миңнуллин).

Төрдәше: ару-талуны белмичә һ.б.

**БАР, КЫРДАН ЭЗЛӘ ҖИЛНЕ.** «Кире кайтарып булмый, табып булмый» мәгънәсендә. – *Мине көтеп торсын, дип әйттем бит мин сиңа, хәзер, бар, кырдан эзлә җилне* (Сөйләм).

**БАР НИ, ЮК НИ.** Бер нәрсәгә дә исе китмәү, битараф калу. *Тәм-том, чәчәк бәйләмнәре теләсә кайсы тәкәбберне эретер иде, ә моңа бар ни, юк ни* (Д. Сафиуллина. Дару).

**БАР ӨСТЕНӘ БАР – МАЙ ӨСТЕНӘ БАЛ.** *– Бар өстенә бар – май өстенә бал, диләр; нәрсә генә булмасын, Красный-Слабудскийларны мактамыйлар* (Ш. Камал. Акчарлаклар).

**БАР ӨСТЕННӘН.** Була торып, булган килеш. *Ул ни дигән сүз, хатының бар өстеннән әллә нинди кызлар берлә йөрсен, имеш* (Г. Исхакый. Мөгаллим). *Янында җанын бирергә әзер торган фәрештә кебек кызы бар өстеннән миңа килеп ягылмаса соң!..* (М. Хәсәнов. Саф җилләр).

**БАР ПЫЧАГЫМ.** Юкны бар дип раслауга җавап. *– Минем банкта машина алырлык акчам бар, дигән иде. – Бар пычагым* (Сөйләм).

**БАР ТАВЫШКА.** Яшереп тормыйча; ачык рәвештә; бөтен халык өчен. *Башкалар да бу мизгелдә шундый ук күтәренкелек, шатлык-куаныч кичерделәр, җиңелчә генә гөрелдәп-гүләп алдылар, ләкин бар тавышка кычкырырга беркемнең йөрәге җитмәде* (Н. Фәттах. Аклан). *– Объект куркыныч астында, объектны алып калыгыз! – дип, бар тавышка кычкыра иде Егорий* (И. Хуҗин. Егетнең кайтуы).

**БАР ТҮШӘМЕ ШУЛ.** Ирешә алган биеклеген белдерү өчен кулланыла. *Аның бар түшәме шул, ягъни бүлек мөдире булу, аннан артык үсә алмаячак ул* (Сөйләм).

**БАР ТЫНГА.** Бар көченә, бар сулышына. *Бу яшь кызны куып бар тынга, / Ике фашист килә артыннан* (Ф. Кәрим. Пионерка Гөлчәчәккә хат). *И юләр! Җитәрмен ди микән, / Туктамый, йөгерә бар тынга* (Х. Әюп).

**БАР ЧАГЫНДА – БҮРЕ КҮК (БҮРЕДӘЙ), <ЮК ЧАГЫНДА ШҮРЕ КҮК (ШҮРЕДӘЙ)>** *к.* ашаган тамакка ни бармый (китми). *– Без табигатьне савым сыеры итеп савабыз. Бар чагында – бүре күк* (Г. Бәширов. Җидегән чишмә). *Бер агайның тормыш рәвеше – «бар чагында – бүре, юк чагында – шүре» икән. Сугым суйган шәпкә ишекне җылкы боты белән терәтеп йөриләр. Беткәч – соранырга чыгалар* (Ш. Галиев. Гомер тәүлеге).

Төрдәше: ашаган тамакка ни бармый (китми) һ.б.

*БАРА* ❖ **БАРА БУЛАМЫ СОҢ.** «Бармый һәм бармаячак та» дигән мәгънәдә. *– Бара буламы соң ул аларга, аягын да атламаячак* (Сөйләм).

**БАРА ТОРГАЧ.** Бераз вакыт үткәннән соң. *Бара торгач, балалар да булды, бәхет өстенә бәхет!* (Г. Тукай).

**БАРА ЯТКАННЫҢ БАЛТАСЫН, КИЛӘ ЯТКАННЫҢ КИТМӘНЕН АЛЫП.** Нигездә, әкиятләрдә кулланыла: максатка ирешү юлында зур югалтуларга очраган батырның башкалардан ярдәм алуы. *Бара ятканның балтасын, килә ятканның китмәнен алып, егет бераздан урманга таба юл алды* (Сөйләм).

*БАРАБАН* ❖ **БАРАБАН КАГЫП КУЯН (ТЫЧКАН) АУЛАУ.** Эшне эшләгәнче үк кычкыра башлау; шаулап эшне бозу. *«Сабан туенда батыр калачакмын» дип, күпме сөйләнеп йөрде, нәтиҗәсен үзегез күрдегез – барабан кагып куян аулау шушы була инде* (Сөйләм).

**БАРАБАН КОРСАК** *кимс.* Юан кеше турында. *«Әке-сәке, кыек пәке, аксак-туксак, барабан корсак, черек орчык, очып чык» дип санап китте ул, безнең күкрәкләргә төртә-төртә* (Сөйләм).

**БАРАБАН СУГУ.** Тавыш күтәрү, фаш итү. *– Күпме түзеп торырга мөмкин инде, аның бу гаделсезлекләре турында газетага язарга, барабан сугарга кирәк* (Сөйләм).

**БАРАБАН БУГАЗ.** Күп сөйләргә яратучы, лыгырдавык. *Тәнсакчылар саны дүрт йөздән дә артмый, колакларны сытып гәп куерткан барабан бугазлар юк* (В. Имамов. Карабәк).

*БАРА-БАРА* ❖ **БАРА-БАРА БӘЙРӘМ КАЛА БАРУ.** «Вакыт үтү белән һәрнәрсә онытыла бара» мәгънәсендә. *Тиз генә моннан югал да, шәһәргә барып бераз яшәгәч, кире кайтырсың – «бара-бара бәйрәм кала бара» дигәннәр борынгылар, синең вакыйга да онытылыр* (Сөйләм).

Төрдәше: акылдан чыгу (чыгып китү) һ.б.

*БАРАНКА* ❖ **БАРАНКА ИТЕП БӨГҮ (БАРАНКА ЯСАУ).** 1. Көч-куәт ягыннан өстен булу. *Тыңламый карасын, баранка итеп бөгәчәк ул аны* (Сөйләм).

2. *к.* авыз җебетү 2. *Хуҗа булырга теләүчеләр шактый булды монда, егетләр алардан баранка ясап озата тордылар* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

*БАРӘКАЛЛА* ❖ **БАРӘКАЛЛА ДИГЕН.** «Кулыңдагы әйбергә шатланып яшә» мәгънәсендә. *[Леniза] (көлә). Булганына бәрәкалла диген, атасы! Бар өстенә яңаны салып кергәнебезгә дә дистә ел юк ич?* (Р. Хәмид. Тигезәкләр).

*БАРГА* ❖ **БАРГА СӨЕНМИ, ЮККА КӨЕНМИ** *к.* авызы-борыны кыйшаймау. *Барга сөенми, юкка көенми* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).
Төрдәше: авызы-борыны кыйшаймау һ.б.

*БАРГАН* ❖ **БАРГАН САЕН.** Һаман, гел, тагын да ныграк. *Соңыннан, һаман-һаман теорияне тирәнәйтә барган саен, ул мәсьәләдә ачыклык күрә бардым...* (А. Алиш. Якты күл буе). *Кадак бетә барган саен, чүкеч кулга сирәгрәк суга башлады* (Г. Сабитов. Чүкеч).
Төрдәше: торган саен.

**БАРГАН ЮЛЫ.** Барган уңайдан, беррәттән. *[Хәдичә] Шуңа бер пар чиккән өстәл эскәтере, дүрт намазлык, аннан бер пар аяк чолгаулары кирәк буласы иде. Шуларны барган юлы Сираҗетдин Мәскәүдән алып кайтып бирмәс микән дигән идем* (Г. Камал. Банкрот).

*БАРДА* ❖ **БАРДА – ЙӨРЕП КАЛ ПАРДА, ЮКТА ҖӘЯҮ ДӘ ЙӨРИ АЛМАССЫҢ.** «Исән-сау чагында аякларыңның кадерен бел» мәгънәсендә. – *Әйдә, бергәләп паркны әйләнеп кайтабыз, эскәмиядә утырырга өлгерерсең әле – барда – йөреп кал парда, юкта җәяү дә йөри алмассың* (Сөйләм).

*БАРДАН* ❖ **БАРДАН ЮК БУЛУ.** Булган әйберне тиз арада юк итү. *Ишегалдында аунап ятучы чүп-чарлар, төрле кәгазь кисәкләре дә «эһ!» дигәнче бардан юк булды* (Г. Мөхәммәтшин. Сер итеп кенә...).

*БАРДЫҢ* ❖ **БАРДЫҢ ҖӘҺӘННӘМ.** Барырга булып та, нindiдер кыенлык чыгып бара алмау. – *Кичә театрга барырга җыенган идең, ошадымы соң? – Бардың җәһәннәм! Иптәш кызым үзе генә китте* (Сөйләм).

*БАРЛЫК* ❖ **БАРЛЫК ПЕДАЛЬЛӘРГӘ БАСУ** *гади с.* Бөтен мөмкинлекләрдән дә файдалану, бөтен көчкә тырышу. – *Нәрсә, суга төшкән тавык кебек борыныңны салындырып утырасың? Ярдәм итәргә мөмкинлекләре булганнар табылыр, барлык педальләргә басарга кирәк* (Сөйләм).

**БАРЛЫК ЮЛЛАР РИМГА ИЛТӘ.** Мәсьәләне төрле юллар белән хәл итәргә мөмкин, әмма нәтиҗәсе бер үк булачак. *Ә абыйлар җавап бирми, дәрес ятлый / Һаман да бер сүз кабатлый: / – Барлык юллар Римга илтә. Римга илтә / ...Якын Марс авылым! Туган йортым, / туган җирем! / Мин дөньяга чыктым / тәрәзәңнән синең* (Р. Гаташ. Диңгез эзлим). *Барлык юллар Римга илткән кебек, язмыш та Сәйдәшне гел Казанга тартып-йолкып кына тора...* (Р. Низами. Без яшибез...).

*БАРЛЫККА* ❖ **БАРЛЫККА КИЛҮ.** Туу, килеп чыгу, оешу. *Көлгәндә, бит уртасында чокырлар барлыкка килә үзенең* (А. Гыймадиев. Үзең булып кал!..). *Бер генә яратылыш та мәхәббәттән башка гына барлыкка килми* (А. Нәҗмиева. Йолдызлар балкышы).
Төрдәше: вөҗүткә килү; гамәлгә килү; җир астыннан килеп (үсеп; калкып; тишелеп) чыккандай; көтмәгәндә килеп чыгу; көтмәгәндә, күктән төшкәндәй килеп чыгу; мәйданга чыгу; пәйда булу; хасил булу; ялт итеп килеп чыгу.

*БАРЛЫКЛЫ* ❖ **БАРЛЫКЛЫ КЕШЕ.** Хәлле, маллы кеше. *Зиннур да югалып калмады: ике кибет ачты, хәзер барлыклы кешеләр рәтендә йөри* (Сөйләм).

*<ҮЗ> БАРМАГЫ* ❖ **БАРМАГЫ АРКЫЛЫ КАРАУ.** Үзе уйлаганча, теләгәнче генә эшләү. *Бөтен нәрсәне үз бармагы аркылы гына карарга өйрәнгән Галимә киңәше Хәлимгә йогармы?* (Г. Гали).

**БАРМАГЫ БАТМАУ.** Бу эшкә көче җитмәү, аны башкарып чыга алмау. *Бу эшне башкарып чыгарга бармагы батмас дип шикләнә, танышларын чакырырга кирәк булыр* (Сөйләм).

**БАРМАГЫ БАУ ИШҮ.** Оста алдау. – *Һәр сүзенә дә авызыңны ачып ышанып утырма, күрәсеңме, ничек бармагы бау ишә* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

**БАРМАГЫ БЕЛӘН ЧИГӘСЕН (ЧИГӘ ТУРЫСЫН) БОРАУЛАУ.** Тиле дигәнне аңлату ишарәсе. *Туристларның шакмаклы кәпәчлесе,*

*астыртын гына елмаеп, иптәшләренә имән бармагы белән чигәсен бораулап күрсәтте* (Ф. Шәфигуллин. Филен данк). *Ләкин хуҗа кеше, мәсхәрәле төстә күзен кысып, бармагы белән генә чигә турысын бораулап күрсәтте* (А. Вергазов. Кайту).

Төрдәше: бармакны чигәгә куеп бораулау (бораулап алу).

**БАРМАГЫ РОЛЬ УЙНАУ.** Астан эш йөртү. *Соңгы сайлауда волбашкармадан чыгарып ыргытуда да аның бармагы зур роль уйнады* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).

Төрдәше: астан гына һ.б.

**БАРМАГЫ ҮЗ ЯГЫНА БӨГЕЛҮ (КӘКРЕ).** Үз мәнфәгатен генә кайгыртучы кеше турында. *Гомер буе түрә креслосын биләгән кешенең бармагы үз ягына кәкре икәнен яхшы белгәнгә, мин аның депутат булып халыкка тугры хезмәт итәренә тамчы да ышанмадым* (М. Сәлим. Ышандырин).

Төрдәше: бармагы үзенә <таба> кәкре; бармак үз ягына бөгелү; бармак үзеңә кәкре; бизмәнне үз ягына каеру.

**БАРМАГЫ ҮЗЕНӘ <ТАБА> КӘКРЕ** *к.* бармагы үз ягына бөгелү (кәкре). – *Солдат хезмәтендә булган, кайсы йортның холкы нинди, кайсы агайның бармагы үзенә кәкре – биш бармагы кебек белә* (Г. Ахунов. Чикләвек төше). – *Район җитәкчеләре арасында бармаклары үзенә кәкре бердәнбер кеше син,– дигән булам* (Т. Нәҗмиев. Үзенә кәкре).

Төрдәше: бармагы үз ягына бөгелү (кәкре) һ.б.

**<ҮЗ> БАРМАГЫ ШИКЕЛЛЕ БЕЛҮ.** Бик якын таныш булу. *Алар бала чактан бергә уйнап үскәннәр икән, шуңа күрә бер-берсен үз бармагы шикелле беләләр* (Сөйләм).

*БАРМАГЫН* ❖ **БАРМАГЫН ЧӘЙНӘҮ.** Эше барып чыкмагач, үзен үзе битәрләү, үкенү. <…> *тешли алмаса, җиңә алмаса, үз бармагын чәйнәп елый торган Иван, көче җитмәсә дә тырнаша торган Иван, үзенекен итмәсә, астан үч ала торган Иван иде ул* (Р. Батулла. Сөембикә).

*БАРМАГЫННАН* ❖ **БАРМАГЫННАН БАЛ ТАМУ** *к.* агач<тан> сандугач кына ясамау. *Ул тотынса, шик тә юк, ахырына кадәр эшләп чыгачак – аның бармагыннан бал тама* (Сөйләм).

Төрдәше: агач<тан> сандугач кына ясамау һ.б.

*БАРМАГЫҢНЫ* ❖ **БАРМАГЫҢНЫ АВЫЗЫНА ТЫКМА.** Кемнеңдер юаш кеше түгеллеген кисәтеп кую. – *Так что, бу юаш икән дип, бармагыңны авызына тыга күрмә!* (Ә. Еники. Ялгызлык).

**БАРМАГЫҢНЫ ЙОТАРЛЫК (ЙОТАРСЫҢ).** Бик тәмле ашамлык турында. *Аның өчпочмагы шундый тәмле, бармагыңны йотарлык* (Сөйләм).

Төрдәше: телне йотарлык.

*БАРМАК* ❖ **БАРМАК АРАСЫНА (АРАСЫННАН) КЫСУ (СЫГУ).** Чамалап кына; үтә саранлану. *«Хәрәмләште!», «Алдалады, Мөке тәре!..», «Бармак арасына кысып калган ул аны!» дигән тавыш китә. Ә теге, чынлап та, шундыйрак мут малай* (Ш. Маннур. Агымсуларга карап). *Банкка акча аз килә, булганын да бармак арасыннан сыгып кына чыгаралар* (Л. Ихсанова. Кемгә сөйлим серләремне?..).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**БАРМАК АРАСЫННАН АГЫП БЕТҮ.** Кысып кына тотканда да, акчаның (яки башка нәрсәнең) бик тиз бетүе. *Акчаны кысып тотабыз кебек, ләкин бармак арасыннан бик тиз агып бетә* (Сөйләм).

**БАРМАК АРАСЫННАН КЫСЫП <КЫНА>** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. – *Бар белгәнеңне берьюлы чыгарып салма, бармак арасыннан кысып кына уртаклаш* (Сөйләм).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**БАРМАК АРАСЫННАН КЫСЫП (СЫГЫП) ЧЫГАРУ** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. *Персидәтель үзенең эшне куштаннары белән хезмәт хакын соса гына, безгә бармак арасыннан кысып чыгарганы гына кала дип зарланырга аптырамыйм* (А. Давлетбаев. Алабыз, Аллага шөкер). *Дөрес, акча бүлешә Федераль үзәк, әмма иң элек бөтен салымнарны үзенә җыя, аннан соң бармак арасыннан кысып чыгарып тарата башлый* («Ватаным Татарстан» газ.).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**БАРМАК АША (АРАСЫННАН; АРКЫЛЫ; ҮТӘ) <ГЫНА> КАРАУ.** 1. Игътибар итмәү, илтифатсыз булу; махсус күрмәмешкә салышу. – *Шулай да әйтми булмый, ул бу эшкә бармак*

*аша гына карый* (Ф. Хөсни. Җәй башы). – *Димәк, ул, җинаятьчене эш барышында яклаган, ә сез, безнең элеккеге тикшерүчебез, үз вазыйфаларыгызга бармак аша карагансыз* (Х. Ширмән. Тәкъдир).

Төрдәше: күз йому 2; күз йомып калу; күз йомып <тик> тору.

2. Тулысынча битараф булу. *Ул эшкә дә хәзер бармак аша карый башлады* (М. Җәлил).

Төрдәше: арба ватылса – утын, үгез үлсә – ит һ.б.

**БАРМАК БАСЫМЫ.** Бер бармак баскан урын кадәр озынлык үлчәме. *Ике кашың арасы, / Бармак басым арасы* (Җыр).

**БАРМАК БАШЫДАЙ (БАШЫ КАДӘР / ШАЕ).** Бик кечкенә, вак; бик аз. *Бу үзенә күрә инде кечкенә генә, бармак башы кадәр генә булса да, бер революция булды* (Г. Камал). *«Ах-ух килеп урынга аугач исәпләп карыйсың: эшләгән эшең бармак башы шае булган!»* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: бармак белән <генә> санарлык һ.б.

**БАРМАК БАШЫН ДА КЫЙМЫЛДАТМАУ** *к.* авызга чәйнәп каптырганны (салганны; куйганны) көтү (көтеп утыру). *«Алай итәргә кирәк», «болай итәргә кирәк» дип күп сөйли, үзе исә бармак башын да кыймылдатмый* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга чәйнәп каптырганны (салганны; куйганны) көтү (көтеп утыру) һ.б.

**БАРМАК БАШЫНА УРАРЛЫК (ЧОЛГАРЛЫК) ТА.** «Аз гына да белеме (яки акылы) юк» мәгънәсендә. *Үзенең бармак башына урарлык та белеме юк, ә өстәл башында кукыраеп утырган була* (Сөйләм).

**БАРМАК БЕЛӘН ДӘ ЧИЕРТМӘҮ (ЧИЕРТКӘН ТҮГЕЛ).** Кыерсытмау, җәберләмәү. *Апай кеше, күзләрен сөртә-сөртә: – И бичаракаем, кешегә бармак белән генә дә чиерткән бала түгел бит ул* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**БАРМАК БЕЛӘН <ГЕНӘ> (САНАУ) САНАРЛЫК** *к.* бармак башыдай (башы хәтле; шае) (фикердәшләрнең аз булуына да ишарә). – *Сезнең ишеләр бездә бармак белән генә санарлык* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Апрельнең кояшлы, аяз көннәре бармак белән генә санарлык иде* (Х. Ширмән. Ерактагы йолдызым).

Төрдәше: бармак башыдай (башы кадәр; шае) һ.б.

**БАРМАК БЕЛӘН УЙНАТУ.** Буйсындырып тору, үзе теләгәнчә эшләтү. *Хәзер тракторны бармак белән генә уйнатып йөртәдер,ди* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).

Төрдәше: бармакта биетү; бармакта уйнату.

**БАРМАК БИТЕ КАДӘР (ХӘТЛЕ; ЧАКЛЫ)** *к.* бармак башыдай (башы кадәр / шае). *Элек бармак бите кадәр җире дә булмаган гаиләбезгә, мәңге файдаланырга дип, 5 дисәтинә биләргә таныклык тапшырдылар* (Т. Әйди. Әйдә, Бергәлек). *Ач әле изүеңне! / Анда синең сул ягыңда / Нәкъ күкрәгең өстендә / Бармак бите кадәр миң бар* (К. Булатова).

Төрдәше: бармак башыдай (башы кадәр / шае) һ.б.

**БАРМАК БӨГҮ.** Дөресләп бару. *Уткән көнем саен бармак бөгеп торам* (Г. Мөхәммәтшин. Робагыйлар бакчасында). *Санда көннәр, бармак бөккән саен / Арта йөгем, юлым аза* (Ф. Яхин).

**БАРМАК БУЕ (БУЙЛЫГЫ).** Бик кыска, кечкенә. *Урта бармак буйлыгы бар маңлаенда мөгезе* (Г. Тукай. Шүрәле). *Ә бармак буе гын маймычлар, җылы, саф су эзләп, көтүләре-көтүләре белән безнең очка меңәләр* (А. Хәсәнов. Кара еланнар оясы...).

Төрдәше: бармакка урарга да җитми; бармакка урарлык та юк.

**БАРМАК ИЛЛЕ<СЕ>.** Бер бармак киңлегендәге үлчәм. *Мәшәкатьләр дә китерә китерүен, анысы да кызык, чабатага күтәрмә тагын берничә бармак иллесе «үсеп» куясың!* (Ш. Галиев).

**БАРМАК ИМЕП (СУЫРЫП) ЯТУ** *к.* авыз күтәреп яту. *Югыйсә, телевизор карый-карый, рәхәтләнеп бармак суыра-суыра ятасы гына бит инде аңа үз өендә, диде Левин* (Э. Касыймов).

Төрдәше: авыз күтәреп яту һ.б.

**БАРМАК ИСӘБЕ.** Бармак белән санау. *Бармак исәбе бик борынгыдан килгән ышанычлы исәп ул* (Сөйләм).

Төрдәше: бармак чуты; кара исәп.

**БАРМАК ИСӘБЕН ДӘ БЕЛМӘҮ.** Үтә надан, тинтәк булу. – *Ничек инде шушы яшеңә җитеп бармак исәбен дә белмисең?* (Сөйләм).

Төрдәше: ак-кара танымау һ.б.

**БАРМАК ЙӨР<Т>Ү** *к.* астан гына. – *Соловкига озатырлар дип куркышып торганда, Салахи-*

*ев кайлардадыр бармак йөртте дә, бай котылып калды* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).
Төрдәше: астан гына һ.б.

**БАРМАК КҮРСӘТҮ.** 1. Җыелышта сүз сорап бармакны күтәрү. *Ике як тартышуын тыңлап утырды-утырды да түзмәде, кинәт кенә кулын күтәреп бармагын күрсәтте* (Сөйләм).
2. Хәрәкәтсез һәм дәшмичә торырга кирәклегенә ишарә ясау. *Вахит аңа, «тсс» дип бармак күрсәтте дә Әгъдәснең хатын тоттырды* («Казан утлары» ж.).

**БАРМАК <ТА> КЫЙМЫЛДАТМАУ** *к.* аркылы саламны буйга да алып куймау. *Бу четерекле хәлне бер сүз белән хәл итә алса да, ул бармак та кыймылдатмады* (Сөйләм).
Төрдәше: аркылы саламны буйга да алып куймау һ.б.

**БАРМАК ОЧЫН ДА ТИДЕРТМӘҮ.** Бик иркәләп, кадерләп кенә тоту. *Хезмәт иткән җиренә килгән яшь хатынына унсигез тулган иде микән, карап торырга шул тирә иде, ул аңа бармак очы да тидертмәде* (Сөйләм).

**БАРМАК ОЧЫНДА БИЕТҮ** *к.* астан гына. *Җитәрдер, атасын да бармак очында күп биетте* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).
Төрдәше: астан гына һ.б.

**БАРМАК ОЧЫННАН (БАРМАКТАН) СУЫРУ (СУЫРЫП ЧЫГАРУ).** Булмаганны уйлап чыгару. *Ул чигү бизәкләрне күктән дә чүпләми, бармак очыннан да суырып чыгармый, ә тормыштан ала* (Н. Гамбәр. Тәлгәшләрдә сусыл җимешләр). *Эшләп торган кеше турында бармактан суырып чыгарып, юкны бар итеп шундый уса, миһербансыз нәтиҗәләр ясап булуына үз колагым белән ишетмәсәм, хәзер дә күчермәсе алдымда ятмаса, билләһи, ышанмас идем* (Т. Галиуллин. Замана балалары).
Төрдәше: бармак очыннан тамызу.

**БАРМАК ОЧЫННАН ТАМЫЗУ** *к.* бармак очыннан (бармактан) суыру (суырып чыгару). *– Вакыйгаларны бармак очыннан тамызып язарга яратмыйм мин* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).
Төрдәше: бармак очыннан (бармактан) суырып чыгару.

**БАРМАК ОЧЫННАН ЧӘЙНӘП ТӨКЕРЕЛГӘН ТЫРНАК** *к.* әһәмиятсез нәрсә. *Бөек әмиргә моның кирәге юк, ахырынача тез чүктерелгән хан аның өчен – бармак очыннан чәйнәп төкерелгән тырнак, ертык бишмәт, көпчәксез арба, тишек казан кебек* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: әһәмиятсез нәрсә һ.б.

**БАРМАК САНЫ.** Аз санлы (уннан да артмаган) булу. *Үксез ташны баш астына салып, / Йолдыз санап ятам яңадан. / Саташыла, бармак саны җитми...* (Ф. Яхин).
Төрдәше: бармак хисабына да тулмау.

**БАРМАК СЕЛКЕТҮ.** Ачулану, кисәтү, куркыту. *Фәрештәләренә аз гына ым кагуы да, бармагын селкетүе дә җитә* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).
Төрдәше: бармак селкү; бармак янау.

**БАРМАК СЕЛКҮ** *к.* бармак селкетү. *«Әй! Сез! Шәһадәтнамәләрегез кайда?Ниләр укытасыз?» дип бармак селкә, боларны янап тора* (Ш. Камал). *Ишекне узган чакта, кайсыдыр, бармак селкеп: – Сиздем эшегезне! – дип көлеп калды* (А. Алиш. Якты күл буе).
Төрдәше: бармак селкетү һ.б.

**БАРМАК СУЫРЫП ЯЗУ.** Булмаганны уйлап чыгару. *Юкса ул бармак суырып яза башлый* (Ф. Садриев. Бәхетсезләр бәхете).

**БАРМАК СУЫРЫП ЯТУ.** Ашарга җитмәү, кытлык кичерү. *Йорт хуҗасы тавышын күтәрә төште: – Нәрсә, кыш буе бармак суырып ятаргамы? Радикка да шәһәр өчен акча бирергә кирәк* (Ф. Нәгыймов. Кыңгырау).

**БАРМАК СЫЙМАС ҖИРГӘ СЫЙРАК ТЫГУ.** Мөмкин булмаган җиргә баш тыгарга тырышу. *Бармак сыймас җиргә сыйрак тыгып маташма, бу бүлмәгә керергә ярамый, дип әйттеләр бит инде сиңа* (Сөйләм).

**БАРМАК ТА КУЗГАТМАУ (КЫБЫРДАТМАУ; СЕЛКЕТМӘҮ).** *к.* абуз өстендә арыш сугу 2. *Танышы мәхкәмәдәге эшен җайларга сораса да, ул бармак та кузгатмады* (Сөйләм).
Төрдәше: абуз өстендә арыш сугу 2 һ.б.

**БАРМАК ТЕШЛӘҮ (ТЕШЛӘП КАЛУ).** 1. Нәрсә уйларга яки эшләргә белмичә аптырап калу. *Белгән – белгәнен эшләр, белмәгән – бармагын тешләр* (Мәкаль).
Төрдәше: аптыраган үрдәк хәленә төшү һ.б.

2. Уңышсызлыктан үз-үзен битәрләү, үкенү. *[Зәмирә] Авылда, авылда гына түгел, бөтен районда, кемнең туй сәяхәте рәхәтен татыганы бар? Бөтенесе бармак тешләп көнләшәчәк бездән* (А. Гыйләҗев).

Төрдәше: агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән һ.б.

**БАРМАК <БЕЛӘН> ТӨРТҮ (ТӨРТЕП КҮРСӘТҮ).** 1. Берәүнең уңышсызлыгына игътибар юнәлтү. *Авыл халкы Әсхәдулла агайның чын гамәлен һичшиксез белеп торган, әмма ләкин һичкем аңа бармак белән дә төртеп күрсәтмәгән* (Ә. Еники. Соңгы китап).

2. Конкретлаштыру, башкалардан аерып алу. *Җитмәсә, әле аның гаепләрен табып маташыр, бортларның чалышлыгына бармак төртеп күрсәтер иде* (А. Тимергалин. Таш алиһә). *Капкорсакка бармак төртеп берәү дә ыржаеп көлми: халык могҗиза көтә иде* (Р. Батулла. Сөембикә).

3. *күч.* Мыскыллап телгә алу, хурлыкка калдыру. *Җиңел ул, син карак, урлагансың дип, бармак төртеп күрсәтүләре* (К. Кара. Уфа–Афина). *Дусларымны, әйтер идем инде, / Бармак төртеп миннән көләләр* (К. Аманулла. Кандидатлар).

**БАРМАК ТӨРТЕР УРЫН ЮК** *к.* алма төшәр<лек> урын булмау (юк). *Өстәлдә бармак төртер урын юк: тәлинкәләрдә өем-өем төрле камыр ашлары, эреле-ваклы савытларда бал, май, чәкчәк, конфетлар, чирек белән әчеткән бал, нәкъ уртада таба белән коймак...* (Ә. Еники. Җиз кыңгырау).

Төрдәше: алма төшәр<лек> урын булмау (юк) һ.б.

**БАРМАК УЕНЫ УЙНАУ.** Кешене шаярту. *Хәзер сезнең белән бармак уены уйнап алырбыз* («Көмеш кыңгырау» газ.).

**БАРМАК УЙНАТУ** *к.* астан гына. *Читтән торып мәдрәсә эшләрендә бармак уйнаткан байларны буржуйлар, юан корсаклар дип каһәрләделәр* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). – *Гыйшыкмыйшык бармак уйната монда!* (Г. Бәширов).

Төрдәше: астан гына һ.б.

**БАРМАК УЙНАУ.** 1. Берәрсен орышып яки кисәтеп, йөзе алдында бармагын селкеп тору. *Безнең маңгайлар каршында озын бармак уйный* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).

2. Яшерен җинаять эшләү, астыртын эш башкару. *Димәк, бу эштә Язучылар союзының да бармагы уйнаган* (А. Расих). *Ул үзе беркайчан да көрәшнең алгы планына чыкмады, әмма һәр җирдә аның бармагы уйнады* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

Төрдәше: астан гына һ.б.

**БАРМАК ҮЗ ЯГЫНА БӨГЕЛҮ** *к.* бармагы үз ягына бөгелү (кәкре). – *Сиңа файда эшләр дип көтәсеңме әллә – өмет итмә, аның бармагы үз ягына бөгелә!* (Сөйләм).

Төрдәше: бармагы үз ягына бөгелү (кәкре) һ.б.

**БАРМАК ҮЗЕҢӘ КӘКРЕ** *к.* бармагы үз ягына бөгелү (кәкре). *Дөрес, мин үзем, үзара гына әйткәндә, минеке – аныкы булуга караганда, аныкы – минеке булганны яратарак төшәм – нишләтәсең, бармак үзеңә кәкре!* (Ф. Хөсни. Циклон).

Төрдәше: бармагы үз ягына бөгелү (кәкре); бармагы үзенә <таба> кәкре; бармак үз ягына бөгелү.

**БАРМАК ХИСАБЫНА ДА ТУЛМАУ** *к.* бармак саны. – *Синең кәрзиндәге гөмбәң бармак хисабына да тулмый бит, гөмбә җыйдым дигән буласың тагын* (Сөйләм).

Төрдәше: бармак саны.

**БАРМАК ЧӘЙНӘҮ** 1. *к.* бармак тешләү (тешләп калу). *Алдарак олы гына гәүдәле бер поши торганын күргәч, «ничек үтәргә икән моны?» дип, бармагын чәйнәп аптырап калды* (Сөйләм).

Төрдәше: аптыраган үрдәк хәленә төшү һ.б.

2. Уңышсызлыктан үз-үзенә үкенү, нәрсә эшләргә белмәү. *Тешләргә теләсә, тешләп үч алырга өйрәнеп үскән усал Иван иде ул; тешли алмаса, җиңә алмаса, үз бармагын чәйнәп елый торган Иван ул; көче җитмәсә дә тырнаша торган Иван ул; астан үч ала торган Иван ул* (Р. Батулла. Сөембикә).

**БАРМАК ЧУТЫ** *сөйл., к.* бармак исәбе. *Зур-зур каралтыларны, артезиан коесы кебек катлаулы биналарны бармак чуты һәм күз чамасы белән генә эшләп булмый* (Г. Ахунов).

Төрдәше: бармак исәбе һ.б.

**БАРМАК ШАРТЛАТУ.** 1. Бармак буыннарын бөккәләп, үзенчәлекле бер аваз чыгару. *Яким Күчтем бармак шартлатты, шундук ишек артында торган хезмәтчеләре, кенәз*

*бүләкләрен күтәреп, тәхет ягына керә башладылар* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).

2. Бармакларны шул рәвешле уйнатып, куанычны, ис китмәүне, гамьсезлекне белдерү. *Аннан бармак шартлатып, аягын аякка бәргәләп йөренде, тагын уртага тукталды* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә). *Аю һич тә туймый, ди, / Көн-төн гармун уйный, ди. / Маймыл бармак шартлатып, / Урманны яңгыратып: / «Их-ма!» – ди икән* (Ф. Кәрим).

**БАРМАК ЯНАУ.** 1. *к.* бармак селкетү. *Кисекбаш күрде дә бу тәкъваны: «Тимә хатынга!» – диеп бармак яный* (Г. Тукай. Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш). *Игенчеләр шелтә белән миңа / Басуларда бармак янады* (С. Хәким).

Төрдәше: бармак селкетү һ.б.

2. Шаяртып кисәтү. *Мин чаршау кырыеннан ялгыш кына көлеп җибәргәч, җизни миңа күзен кысып бармак янады* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Сирин сурәткә күз кысып елмайды һәм бармак янап куйды. «Кара аны, кызый, мине көтмәсәң, нишләтергә белермен!»* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).

*БАРМАККА* ❖ **БАРМАККА БАРМАК <ТА> СУКМАУ** *к.* аркылы саламны буйга <да> алып куймау. *[Гозәер] Мәхәббәт дип, ярату дип, бармакка бармак белән дә сукмый ич алар хәзер* (Ә. Гаффар). *– Синең Казан каласы янын узуың хакында Хазбулат атлы соран бер ай элек үк чапкын куган иде, ә Дмитрий кенәз бармакка-бармак та сугып карамады* (В. Имамов. Карабәк).

Төрдәше: аркылы саламны буйга <да> алып куймау һ.б.

**БАРМАККА ЙОГУ** *к.* аю мае сөртү 1. *«Шуның өстенә, дәүләт казнасыннан агыласы алтын-көмеш тә бармакка йокмый калмас»* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).

Төрдәше: аю мае сөртү 1 һ.б.

**БАРМАККА УРАРГА ДА ҖИТМӘҮ (ЯРАМАУ).** Аз күләмдә; бик кыска. *[Бикмөхәммәт] Хатыннарның аларның чәчләре генә озын бит, акыллары бармакка урарга ярамый* (Г. Насрый).

Төрдәше: бармак буе (буйлыгы) һ.б.; бармакка урарга да җитмәү (ярамау); бармакка уралык та юк (калмаган).

**БАРМАККА УРАРЛЫК (ЧОРНАРЛЫК) ТА АКЫЛЫ ЮК** *к.* акыл өләшкәндә, абзар артында йоклап калу. *[Хөппемаһи] Синең үзеңнең бармакка урарлык та акылың юк* (Г. Насрый).

Төрдәше: акыл өләшкәндә, абзар артында йоклап калу һ.б.

**БАРМАККА УРАРЛЫК ТА ЮК (КАЛМАГАН)** *к.* бармакка урарга да җитмәү (ярамау). *– Нәрсәгә җитсен бу ябыштыргычың, бармакка урарлык та калмаган бит бу* (Сөйләм).

Төрдәше: бармак буе (буйлыгы) һ.б.

**БАРМАККА УРАУ (ЧОРНАУ).** Алдау. *Миңгерәүләнгән кешене бармакка урау ансатрак бит* (Г. Әпсәләмов).

Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

**БАРМАККА ЧАБАТА КАЙТАРУ.** Сөйләшкәндә мыскыллап, төрттереп утыру. *Яле, Ильяс агай, бармакка чабата кайтарып утырма* (Ә. Баянов).

*БАРМАКНЫ* ❖ **БАРМАКНЫ АВЫЗГА КАБУ.** 1. Ялгышны сизү. *Математика дәресендә бирелгән мәсьәләне ялгыш чишә башлавын сизгәч, бармагын авызына кабып, бераз уйланып утырды* (Сөйләм).

2. Җавапсыз калу. *[Рәхмәтулла бай] Ни эшлисең монда, оятсыз?! (Каюм, калтырап, баш бармагын авызына каба)* (Г. Исхакый).

3. Дәшмәс булу, аптырап (яки хәйран) калу, ни эшләргә белмәү. *Бу мунчаны күргән һәрбер кеше, гаҗәпләнүдән нишләргә белмичә, бармакларын авызларына кабып, хәйран булып торырлар иде* (К. Насыйри).

**БАРМАКНЫ БАРМАККА СУКМАУ** *к.* аркылы саламны буйга <да> алып куймау һ.б. *Ә алар бармакны бармакка сукмый гына, бар планета байлыкларын үзләренә алып баралар* («Безнең гәҗит» газ.).

Төрдәше: аркылы саламны буйга <да> алып куймау һ.б.

**БАРМАКНЫ ЧИГӘГӘ КУЕП БОРГАЛАУ (БОРГАЛАП АЛУ).** «Югыйсә син юләрме? дигән ишарәт. *Теге аңгыра баш, чәчби тәре, чебен тимәс чер итәр, миңа карап алды да, бармагын маңгаена, әй лә, чигәсенә куеп боргалап алды* (Г. Үзиле. Ленин, Дарья Петровна, мин һәм башкалар).

*БАРМАКТА* ❖ **БАРМАКТА (БАРМАК ОЧЫНДА) БИЕТҮ** *к.* бармак белән уйнату. *[Исмәгыйль]*

*Мин сезнең киявегез Хәлил кебекләрнең унавын бер бармакта биетәмен, беләсезме?* (М. Фәйзи. Галиябану).

Төрдәше: бармак белән уйнату һ.б.

**БАРМАКТА БӨТЕРҮЧЕ.** Үзенә буйсындырып торучы, теләгәнен эшләтүче. *Алтын Бәркәне бармакта бөтерүче – Шириннәр* (Р. Батулла. Сөембикә).

**БАРМАКТА УЙНАТУ** *к.* бармак белән уйнату. *[Исмәгыйль] Минем бөтен авыл халкын бармагымда уйнатырга кулымнан килә!* (М. Фәйзи. Галиябану).

Төрдәше: бармак белән уйнату һ.б.

*БАРМАКТАН* ❖ **БАРМАКТАН КЫСЫП ЧЫГАРУ** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. *Сәхап ашлыкны бармак арасыннан кысып чыгарып кына <...> тапшыра иде* (С. Рәфыйков).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**БАРМАКТАН СУЫРУ (СУЫРЫП ЧЫГАРУ).** Уйлап чыгарып сөйләү яисә язу. *Бар бармактан суырып язу* (Ф. Хөсни. Орлыклар кая төшә). *Иң аянычы шунда: бу типның сыйфатларын әдипкә бармактан суырып азапланасы түгел, яшәеш боларга кирәгеннән артык бай* (Р. Фәтхерахманов. Йөрәкнең җеназасы).

Төрдәше: артыннан чыгару һ.б.

**БАРМАКТАН ШЫТТЫРУ** *к.* артыннан чыгару. *Газетага бармактан шыттырып язарга ярамаганлыгын белә торгандыр ул, шәт* (Сөйләм).

Төрдәше: артыннан чыгару һ.б.

*БАРМАЛЫ* ❖ **БАРМАЛЫ ДА КАЙТМАЛЫ.** Дуамал булса да, ачу саклап йөрми торган кеше. *– Син аңа үпкәләмә – бармалы да кайтмалы кеше ул, бик тиз кызып китсә дә, тиз суынучан* (Сөйләм).

Төрдәше: бәреп тә егар, тартып та торгызыр; бер ташып, бер түгелә торган.

*БАРНЫ* ❖ **БАРНЫ ЮККА АЛЫШТЫРУ** *к.* авыздан куык очыру. *Тик бу юлы сәламләшеп, барны юкка алыштырып, шаярып маташмадылар алар* (Ә. Гаффар. Яра). *Барны юкка алыштырып йөреп, / Юкны барда тапкан заман бу, / Йөрәкләрне мең кат телеп-телеп, / Санау арты килә сыналу* (Ф. Яхин).

Төрдәше: авыздан куык очыру һ.б.

**БАРНЫ ЮКТАН ТОРГЫЗУ.** Юкны бар итү. *Йөрде «Әльислах» Вафасы барны юктан торгызып; / Ниндидер дәрман белән кәрван күчеп, эт өрдереп* (Ш. Бабич).

*БАРСА* ❖ **БАРСА КАЙТМАС.** Зират, каберлек турында. *Соңгарак калдың шул, барса кайтмас җиргә китте ул* (Сөйләм).

**«БАРСА КАЙТМАС»КА ГЫНА БАРАСЫ КАЛГАН** *мыск.* Үз илен, туган халкын ташлап, бәхет эзләп, азып-тузып йөрүче хакында. *Бу дөньяда берәүгә дә кирәгем калмаган икән, «барса кайтмас»ка гына барасы калган* (Сөйләм).

*БАРСАМ* ❖ **БАРСАМ ДА БАРДЫМ, БАРМАСАМ ДА.** Сүз өчен генә булса да барып килү. *Барсам да бардым, бармасам да. Бармас идең, яхшы түгел, хәтере калыр. Ни дисәң дә, күрше бит* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**БАРСАМ – КУНАК, КИТСӘМ – ЕРАК.** Ул хәтле үк өзгәләнмәүне аңлата. *Китсәм – ерак, барсам – кунак. Китсәм, ерак шул инде* («Сөембикә» ж.).

*БАРТАН* ❖ **БАРТАН ИТҮ.** Үч итеп, үчне кайтару һәм аның җавабы булган кару кайтару (барымта һәм карымта). *Түбән оч Мидхәтнең коймасы аша чит кеше кергәнен күрсәм дә бартан итеп, дәнми калдым* (Сөйләм).

*БАРУ-КАЙТУ* ❖ **БАРУ-КАЙТУ БИЛЕТЫ.** Бер үк билет белән каядыр бару һәм әйләнеп кайту мөмкинлеге булу. – *Миңа бару-кайту билеты бирегезче* (Сөйләм).

*БАРЫ* ❖ **БАРЫ БЕЛӘН.** Булганы белән, булган кадәренчә. *Кычкырып бирелгән сәламгә каршы башына ак урамал сарган, фәкыйрьчә, ләкин бары белән пакь киенгән бер киленчәк чыкты* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *«Йә, кунаклар, җитешегез. Хәзинәдә бары белән»* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**БАРЫ БЕЛӘН КАНӘГАТЬ.** Бик шәп булмаса да, шартларына күрә әйбәт кенә. *Көндәлек тормышта, үз шәхесеңә кагылган һәр мәсьәләдә – тыйнаклык һәм ни бары белән канәгать булу* (Н. Фәттах. Эшчән һәм турылыклы дустыбыз). *Бары белән канәгать булып, артык модалы киенмәгән бу кыз миндә әллә ни тәэсир калдырмады* (matbugat.ru).

**БАРЫ БЕЛӘН РИЗЫКЛАНЫП УТЫРЫГЫЗ.** «Өстәлгә куелган ашамлык белән сыйланыгыз» мәгънәсендә. – *Яле, бары белән ризыкланып кына утырыгыз әле* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**БАРЫ БЕРГӘ, ЮГЫ – УРТАК.** 1. «Гаиләдә яхшысы да, начары да – барысы да уртак була» дигәнне аңлата. *Кунак кыз дигәндә, бары – бергә, югы – уртак, ничек туры килсә дә гаеп ителми* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). – *«Гаиләдә кем баш?» дип ләчтит сатулар буш нәрсә ул. Анда баш та, муен да, аяк та, кул да юк, анда бөтенесе бергә, «бары бергә, югы – уртак»* (М. Миншин. Кызыл диплом).

2. Актык сыныкны бергә бүлешеп, юклыкмохтаҗлыкны бергә күтәрешеп яшәү турында. *Бары бергә, югы уртак, ни генә булса да ихлас күңелдән* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Барын бергә, югын уртак итеп, / Көннәрне без матур уздырдык* (Г. Латыйп).

**БАРЫ ДА БЕР.** Бернинди дә аерма юк. *[Мөгълифә] Миңа бары да бер. Миңа кем күбрәк акча бирсә, шул ярый* (Г. Камал. Уйнаш).

**БАРЫ ТИК.** Ихтимал, мөмкин булганнардан берсе генә. *Мин аны бары тик хөрмәт итеп кенә сөйләшәсем килә, якыннан таныш буласым килә, дидем* (А. Расих. Ишан оныгы).

*БАРЫБЕР* ❖ **БАРЫБЕР БЕР ҮЛЕМ (ӘҖӘЛ).** Сүзеңне сүз итү өчен, үлемнән курыкмыйча, утка-суга керү. *Барыбер без уйламаганча, көтелмәгәнчә килеп чыккан, әй... Барыбер бер әҗәл бит инде* («Кызыл таң» газ.).

**БАРЫБЕР БУЛСА, ИШЕКТӘН ТҮГЕЛ (ЙӨРМӘСЛӘР), ТӘРӘЗӘДӘН (ФОРТОЧКАДАН) ЙӨРЕРЛӘР ИДЕ.** «Барыбер» дигән сүзгә җавап. *Барыбер булса, ишектән түгел, форточкадан йөрерләр иде* («Матбугат.ру» порталы).

**БАРЫБЕР ҮЛГӘЧ КОРТ АШАР.** Бернинди өметсез яшәгән бозык кешеләрнең бер-беренең кесәсеннән акча чыгару сүзләре. – *Ул хәтле кысып чыгарма инде, барыбер үлгәч корт ашар* (Сөйләм).

*БАРЫН* ❖ **БАРЫН <ДА> БЕР АРШЫНГА ТАРТУ.** Шәхси аермаларына дикъкать итмичә, бар нәрсәгә бертөрле карау (бәя бирү һ.б.). – *Бераз башың белән уйлап кара, барын да бер аршынга тартма инде* (Сөйләм).

Төрдәше: Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни һ.б.

**БАРЫН БЕР КАЙЧЫ БЕЛӘН КЫРКУ** *к.* Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни. – *Китапларның тышлыклары яшел булганга, барысын дин турында язылган дип, барын да бер кайчы белән кыркырга уйлыйсыңмы әллә?* (Сөйләм).

Төрдәше: Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни һ.б.

**БАРЫН <БЕРГӘ> БЕР КАЛЫПКА СУГУ (САЛЫП ҮЛЧӘҮ)** *к.* Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни. – *Чәчләре сары дип, барын бергә бер калыпка сугарга ашыкма әле, эшләп карасыннар, аннан соң күз күрер* (Сөйләм). *Барына шөкер итеп, бәрәкәте белән тотсыннар әйберне. Барын бер калыпка салып үлчәмик* («Туган як» газ.).

Төрдәше: Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни һ.б.

**БАРЫН БЕР КҮЧКӘ ӨЮ** *к.* Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни.– *Барын да бер күчкә өймәгез инде, пластик әйберләрне аерым туплагыз* (Сөйләм).

Төрдәше: Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни һ.б.

**БАРЫН БЕР ТАКТАГА ТЕЗҮ** *к.* Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни. *Кемнең нәрсә эшләгәнен тикшереп тормыйча, барын бер тактага тезеп куйганнар да меңәр сум акча биреп чыкканнар* (Сөйләм).

Төрдәше: Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни һ.б.

**БАРЫН БЕРДӘЙ КҮРҮ.** Барысына да гадел, тигез карау. *Кемнең кем икәнен аермыйча, барын бердәй күргән өчен, аны балалар да яраталар иде* (Сөйләм).

**БАРЫН ЮК САНАП, АЗЫН КҮП САНАП.** Берәрсенең бар эшен дә юкка санап, икенчесенең юк эшен дә бар итеп күрсәтү. – *Бернәрсә дә әйтеп булмый, барын юк санап, азын күп санап, шушы җылы урынында 20 елга якын утырды* (Сөйләм).

*БАРЫНА* ❖ **БАРЫНА ШӨКЕР, ЮГЫНА ТӨКЕР.** Булган нәрсә белән канәгать булып яшәү кирәклеге турында. *Барына шөкер, югына төкер!* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

*БАРЫ(СЫ)ННАН* ❖ **БАРЫ(СЫ)ННАН ДА БИГРӘК.** Иң әһәмиятлесе, иң мөһиме. *Аны,*

*барыннан да бигрәк, шул чибәр, сылу хатынның да барыбер «чәчләре озынлыгы» уйландыра иде* («Казан утлары» ж.). *Нәрсә булды – шул булды, берсен дә күршедән алмадылар һәм, барысыннан да бигрәк, шатлыклары үзләренеке иде* (Ф. Хөсни).

**БАРЫННАН ДА ЭЛЕК (ӘҮВӘЛ).** Иң беренче итеп, башка эшләрне читкә куеп торып. *Узган елгы тәрҗемәләр турында сүз барганда, барыннан да элек, Н. Беляев исемен телгә алып узу урынлы булыр* («Казан утлары» ж.).
Төрдәше: беренче чиратта (нәүбәттә).

**БАРЫННАН ЮГЫ <АРТЫК>.** «Булмаса яхшырак булыр иде» мәгънәсендә. *Ул, эшкә тотыну белән, кайда ни барын, кайсы участокка ни җитмәвен барлады. Барыннан югы күбрәк иде, әлбәттә* (И. Зарипов. Уренгойның ак боланы). *Яман бала атасын сүктерер. Яман баланың барыннан югы* (Н. Исәнбәт. Балалар фольклоры).

*БАРЫП* ❖ **БАРЫП ӘЙТҮ.** Әләкләү. *Әйе, тикшерүче Сафуановка барып әйтәсең дә, ул Мәмдүлә Тәфкилеваны әйбәтләп кенә чакыртып ала* (А. Тимергалин. Таш алиһә). *Берәребезгә вакытында дару китерергә онытсалар яки кәефебез начарлана башласа, хәзер сестрага барып әйтә* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**БАРЫП ЕГЫЛУ.** Ярдәм сорап килү. *Соң алай булгач, нигә аларга барып егылганнар* (Г. Камал). *Иң кыен вакытта, чарасыз калганда доктор Яниска барып егылырга мөмкин икәнлеген беләләр* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).

**БАРЫП ҖИТМӘГӘН НӘРСӘ.** Җитлекмәгән, юньсез, акылы сай. *Шундый барып җитмәгән нәрсә бу, бер сүзне юньләп аңламый* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**БАРЫП ҖИТМӘҮ.** Аңлап бетермәү. *Үзенең фәлсәфәсе миңа бик үк барып җитмәвенә күңеле төште бугай: калын кара кашларын җыерып, әти беркавым уйланып торды* (В. Нуруллин. Әгәр син булмасаң). *Бу сүзләр баштарак Саматның аңына барып җитмәде* (Г. Галиева. Тулгак).

**БАРЫП ҖИТҮ.** 1. Нәрсәгә булса да ирешү. *Бу сүзләр кунакларга нык тәэсир итте, суалчаноялчанның хәтта йөрәгенә үк барып җитте* (А. Алиш. Кем көчле?).

2. Аңлашылу. *Әлеге сүзләрнең мәгънәсе башыма барып җитеп, җирәнүдән косасым килде, башым әйләнеп китте* (А. Әхмәтгалиева. Минем этинең кызы).

3. Ашкынып тору. *Чын диңгез сугышы оештыруга барып җиткәннәр бит, – җилкәнсезләр дими ни диим?* (А. Тимергалин. Ут янында уйда мин...).

4. Нык ярсуы сәбәбеннән начар хәлгә төшү. *Шулай итеп, партиянең бүгенге сәясәте дөрес түгел дигән сүзгә кадәр барып җитте* (А. Алиш. Якты күл буе).

**БАРЫП ЙӨРҮ.** Йөреп, вакыт әрәм итү. *Барып йөрүнең мәгънәсе булмады* (А. Гыймадиев. Үзең булып кал!..).
Төрдәше: юкка барып йөрү; юкка вакыт уздырып, аяк киеме туздырып йөрү.

**БАРЫП КЕРҮ.** Хәтәр эшкә тап булу, ярамаган эшкә эләгү. *Бара торгач, бөтенләй таныш булмаган урынга барып керделәр* (А. Хәсәнов. Бүре баласы Чатан). *Әгәр инде ниндидер чик-киртәләр яши икән, болар кешенең үзен үзе кысан корамага бикләп куюыннан, ихтыяры белән «ясалма коллыкка барып керүеннән»* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

**БАРЫП СУГЫЛУ.** 1. Нәрсә эшләргә белмичә, беренче очраган кешегә мөрәҗәгать итү. *Кая барып сугылма – шунда эш бармый, кем алдына барып тезләнмә – аннан ярдәм юк* (В. Имамов. Сәет батыр). *Аңгыра бәрәндәй, кая барып сугылырга белмичә изаланып йөргәндә, ул солдатларга тап булды* (М. Әмирханов. Утлы камчы).

2. Берәрсенә бернинди эшсез-йомышсыз керү. *Болай да кая барып сугылса, «тегеннән кайткан» исеме маңгаена таш булып бәрә – Гөлчирә җан газабыннан әчтән генә сызлана иде* <...> (А. Әхмәтгалиева. Синең өчен яшим).

**БАРЫП ТА КЕРҮ, ЧЫГЫП ТА КИТҮ.** Берәр сәбәптән бер җирдә озак тоткарланмау. *Сугышка мин барып та кердем, чыгып та киттем, дигәндәй* (М. Хуҗин. Ышаныч).

**БАРЫП ТЕРӘЛҮ.** Берәр нәрсәгә бәйле булып эш тукталу. *[Мифтах] Синең очракта, җиңел генә сөйләшеп булмаса да, эш бит акчага гына барып терәлде...* (Г. Акбар. Чирле түрә). *Бүген СССРда икътисади, сәяси, идеологик про-*

*блемалар милли мәсьәләне хәл итүгә барып терәлә* (Р. Хәкимов. Татар рухы).

**БАРЫП ТИЮ**. Сизенеп, тоеп, нәкъ кирәклесен эшләү яки сөйләү. *Җан тынычлыгым болай да таралган иде, сезнең бер соравыгыз туп-туры йөрәккә барып тиде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**БАРЫП ТОРГАН.** Менә дигән, остарган, бик яраган. *Шулаен ул шулай да. / Ярый ла эш барып торса уңайга* (Г. Тукай). *[Нурый] Гәрәйша абзый барып торган ударник ул* (А. Алиш. Күршеләр).

**БАРЫП ТОРГАН КӨНЕ.** Җайга-көйгә салынган эш. *Ниһаять, Мансурның да барып торган көне килде* (Сөйләм).

**БАРЫП ТОТАШУ.** Берәр эш яки кеше белән тыгыз бәйләнешле яисә чыганагы булу. *Тарихтан билгеле инде: русның күренекле шәхесләре арасында күп кенәсе татар канына барып тоташа (Кутузов, Карамзин, Юсуповлар һ.б.)* (А. Әхмәдуллин. Офыклар киңәйгәндә). <...> *«Болгар тарихы» китабының авторы – Ягъкуб ибне Ногманның оныгы, нәсел җебе Мөхәммәд пәйгамбәргә барып тоташа торган иң абруйлы дин башлыгы* (В. Имамов. Утлы дала).

**БАРЫП ТӨШҮ.** 1. Кунакка килү, туктау. *Карл Маркс урамында торучы танышларыннан берәүгә барып төште* (М. Әмир). – *Мәскәүдә Фәимгә барып төштек, ул безгә ярдәм итте, машина алганда да, машина алганчы аның фатирында тордык та* (В. Ильясов. Фәим кода).

2. Кинәт егылу. *Кинәт бөтенесе чәлпәрәмә килә, чәнчелеп барып төшә, сүнә, түнә, ава....* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**БАРЫП ЧЫГУ.** 1. Уңышлы булу. *[Фазыйлә] Сөрмәм барып чыкканмы?* (К. Тинчурин. Зәңгәр шәл). *[Хәнифә] Безнең егетләрнең башлары бетте, тагын барып чыкмады дигән сүз* (М. Гыйләҗев. Баскетболчы). *Барып чыкканмы минем әкиятем, кай җирләре килешеп җитмәгән – шулар турында сөйләшәсе булыр аның белән* (Р. Төхфәтуллин. Җиләкле аланнар).

Төрдәше: эшкә ашу.

2. Азыну, нык тәртипсезләнү. *Холкы белән ул барып чыккан ялганчы, аумакай һәм көнчел* (Н. Фәттах. Беренче шигырь күк балачак).

**БАРЫП ЧЫККАН.** 1. Үтә чая кеше турында. *Хатынымның икенчесе миннән дә барып чыкканрак булып чыкты* (Ш. Маннур. Чын сөю бармы?).

2. Төгәл, тәмам ясалып беткән. *Үз эшем өчен җавап бирәм. Әмма бусы – сварщикныкы. Барып чыккандырмы, әйтә алмыйм!* (Ф. Яхин. Авыл мөгаллимнәре). *Әйтерлек тә түгел, тәмам барып чыккан тип* (Ф. Хөсни).

3. Авыз ачып калган, үҗәт (гадәттә, тискәре мәгънәдә). *Үзең дә барып чыккан инде, әйтер идем, шуны да ала алмагансың* (Н. Исәнбәт).

4. Авырып яки башка сәбәптән үлем хәленә төшү. – *Ә теге «барып чыккан» малайлар юк инде хәзер, Сәгыйт абый! – диде Володя, кинәт сүзен икенчегә борып. – Аларны, күрәсең, икенче лагерьга күчергәннәрдер* (С. Таҗетдинов. Үлемнән яшәүгә).

5. Акылсызлык эшләү турында. *Барып чыккан икән, хәерсез, салган баштан кеше велосипедын алып чыгып киткән* (Сөйләм).

*(нәрсәдер)* **БАРЫП ЧЫКМАУ**. Теләгән нәрсәңә ирешә алмау сәбәбеннән, көткән өметләрең тормышка ашмау. *Мин инде карап карадым, барып чыкмый* (Г. Камал).

Төрдәше: килеп чыкмау.

*БАРЫР* ❖ **БАРЫР ҖИР, БАСАР ТАУ КАЛМАУ.** Таяныч, ышанычлы урын калмау. *Моннан киткәнгә 30 елдан арткан инде бугай, хәзер исә барысы да ят кебек, барыр җир, басар тау калмаган* (Сөйләм).

Төрдәше: барыр җир, батар күл булмау 1.

**БАРЫР ҖИР, БАТАР КҮЛ БУЛМАУ** *к.* барыр җир, басар тау калмау. *Һичбер барыр җирем, батар күлем булмаса да, абзыйның мине бөтенләй кууы миңа ирек һәм рәхәтлек биргән кебек иде* (М. Гафури).

Төрдәше: барыр җир, басар тау калмау.

**БАРЫР ЮЛ ЯКТЫ КҮРЕНҮ.** Киләчәк өметле булу турында. – *Ә синең барыр юлың якты күренә, күгәрченем, бәхетең ачылырга тора, боерган булса...* (Р. Низамиев. Беренче мунча).

**БАРЫР ЮЛЛАРЫНДА ХОДАЙ ҺИДАЯТЕН АЧСЫН.** Юлга чыкканда, яхшы теләк теләү. *Исән-сау йөрсен, барыр юлларында Ходай һидаятен ачсын, эш-гамәлләре белән халыкны куандырсын, әти-әниләрнең рухына*

*турылыклы булсын* (М. Әмирханов. Зиннәтулла хәзрәт).
Төрдәше: ай йөр, аман йөр һ.б.

*БАРЫСЫ* ❖ **БАРЫСЫ ДА АЛ ДА ГӨЛ.** Барысы да яхшы, борчылырлык урын юк. *Тик бәйләнерлек сәбәп юк – туй итәләр, барысы да ал да гөл* (Ә. Гаффар. Бодай бөртеге һәм тегермән ташы).

**БАРЫСЫ ДА БЕР ОЧТАН СӨРЕЛҮ.** Бернинди аермалары булмау, бер-берсенә охшаш булу. *Тик юкка хафаланган икән, хатын-кызның барысы да бер очтан сөрелгән икән* (М. Әмирханов).
Төрдәше: бары да бер һ.б.

**БАРЫСЫ ДА КИЛГӘН.** Камил, һәрьяктан җитеш булу. *Акылымы дисең, эшкә уңганлыгымы дисең, телгә-сүзгә осталыгымы дисең, тагын буе-сыны дисеңме – барысы да килгән инде* (А. Шамов).

*БАРЫСЫН* ❖ **БАРЫСЫН БЕР ТАРАК БЕЛӘН ТАРАУ.** Кешеләр, хәлләр арасында аерма күрмичә, барысы да бер үк төрле дип уйлау. *Барысын да бер тарак белән тарап, нефтьчеләр әйбәт яши дигән фикердә торучылар байтак бездә* (Ф. Сәлимгәрәев).
Төрдәше: бары да бер һ.б.

**БАРЫСЫН ДА БЕР ЧЫБЫКТАН СӨРҮ** *к.* барысы да бер очтан сөрелү. *[Әхмәди] Синең ул хәзрәтләрең дә шул, барысы да түрәләрең төсле үк бер чыбыктан сөрелгән халыклар!* (Г. Камал. Өч тормыш). *[Демократ] Сез нәрсә, әфәнделәр, сез нәрсә? Нигә барысын да бер чыбыктан сөрәсез?* (Ф. Бәйрәмова. Вакыйга җүләрләр йортында бара).
Төрдәше: бары да бер һ.б.

*БАРЫШЛЫ* ❖ **БАРЫШЛЫ УЙНАУ** *шаяр.* Очраклы рәвештә бару. – *Кара, адашка сугылып, барышлы уйнап алыйм әле* (Сөйләм).

*БАРЫ-ЮГЫ* ❖ **БАРЫ-ЮГЫ БЕР (БӘРАБӘР).** Булса ни, булмаса ни; әһәмияте шулкадәр генә. *Бары-югы бәрабәр* (К. Насыйри. Мәкаль һәм әйтемнәр). *Бик озак уйлап баш ватасы юк – бары-югы бер аның* (Сөйләм).

**БАРЫ-ЮГЫ БЕРГӘ БУЛСЫН.** Аермачылыкка юл куймыйча, бар нәрсә дә уртак булу теләге. – *Әйдәгез, җитешегез, бары-югы бергә булсын!* (Р. Рахман. Сездә нинди хәлләр бар?).

*БАСКАН* ❖ **БАСКАН АЯГЫН СЫЕРДАН АШАТЫП (ЯЛАТЫП) ЙӨРҮ** *мыск.* Теләр-теләмәс кенә, ялкау гына атлау. – *Болай баскан аягыңны сыердан ялатып йөрсәң, автобус сине көтеп тормас, китеп барыр* (Сөйләм).

**БАСКАН ДА КАТКАН** *мыск.* Бер дә кузгалмыйча, балбал кебек басып торган кеше турында. – *Нәрсә ул күлгә карап баскан да каткан, берәр нәрсә бармы әллә анда?* (Сөйләм).

**БАСКАН ҖИРДӘ БИЕП ТОРУ.** Эшсез тик тора алмау, даими рәвештә нәрсә белән булса да мәшгуль булу. *Баскан җирдә биеп торсын, / Булмасын кеше гамьсез* (Ф. Давлетбаев). *Аның ярдәменнән бик тә канәгать калган Золкамал: – И-и-и, рәхмәт төшкере, баскан җирендә биеп торган яшь кызлардан бер дә ким түгел икәнсең әле син, күрше* (Г. Галиева. Газзәбану).

**БАСКАН ҖИРДӘ ТИМЕР СЫНДЫРУ** *к.* агач<тан> сандугач кына ясамау. – *Егетнең дә баскан җирдә тимер сындыра торганына тап булгансың* (Сөйләм).
Төрдәше: агач<тан> сандугач кына ясамау һ.б.

**БАСКАН ҖИРДӘН (ҖИРЕННӘН) УТ ЧЫГАРУ** *к.* агач<тан> сандугач кына ясамау. *Баскан җирдән ут чыгара / Безнең яшьләр, дисеннәр* (Хал. җыры). *Татар кызлары биесә, / Бөтерелеп җил исә. / Баскан җирдән ут чыгара / Өммегөлсем, Әнисә...* (Л. Шагыйрьҗан. Татар биюе).
Төрдәше: агач<тан> сандугач кына ясамау һ.б.

**БАСКАН ҖИРЕМДӘ ҖИР УПСЫН.** «Антын бозучының яки ялган ант итүченең баскан җирендә җир убачак» дигән ышануга бәйле ант итү төре. – *Ходавәндә, меңбаш, баскан җиремдә җир упсын, качты ул хан кияве дигән адәм* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы). *Алдашсам, баскан җиремдә җир упсын, аяз көндә яшен атсын!* (Т. Гарипова. Мөгри-мөгри килә Бөйрәкәй).

**БАСКАН ҖИРЕНДӘ ТАШ ИЗҮ.** Гайрәтле, көчле кеше хакында. *Озын буйлы, текә күкрәкле, зәңгәр күзләре дөньяны тишеп, үтә караган, кешегә ачык, ярдәмчел, кунакчыл, баскан җирендә ташны изгән, тимерне өзгән, җәмәгате белән еш кына тавышланып алырга яраткан Лотфулланы халык «Зимагур» дип атый* (А. Хәлим. Кыйбла).

**БАСКАН ҖИРЕНДӘ УТ УЙНАТУ.** Чая, житез, дәртле, өлгер кеше хакында. *Бар иде бит Шәмсенур әбинең баскан җирендә ут уйната торган яшь, чая чаклары!* (А. Әхмәтгалиева. Синең өчен яшим).
Төрдәше: баскан җиреннән (эченнән) ут чыгару.

**БАСКАН ҖИРЕНДӘ ҮЛӘН КОРУ, <ЭЧКӘН ҖИРЕНДӘ СУ КОРУ>.** Үтә явыз кеше турында. *Наданның аяк баскан җирендә үлән корыр* (Н. Исәнбәт. Балалар фольклоры).

**БАСКАН ҖИРЕННӘН (ЭЗЕННӘН) УТ ЧЫГАРУ** *к.* баскан җирендә ут уйнату. *Баскан эзләреннән ут чыгара* (М. Әмир).
Төрдәше: баскан җирендә ут уйнату.

**БАСКАН ТУФРАГЫ ЯНУ.** Гөнаһлы, гаепле кешенең (гайбәт, ялган сөйләүче, кеше малын урлаучы һ.б.), вакыты җиткәч, җәзасын алачагына ишарә. *Ялганчының, бер көн килеп, / баскан туфрагы яна!* (Р. Фәйзуллин. Ялган).

**БАСКАН УРЫН НЫК <БУЛУ>.** Ышанып, хак сүз сөйләү. *Ләкин Сабирның да баскан урыны нык, теле үз урынында әйләнә иде* (Ф. Хөсни. Җәй башы).

**БАСКАН ЭЗДӘН СУ ЧЫГ<АР>У** *к.* агач<тан> сандугач кына ясамау. *Кем сокланмас көчкә, тимер сынса / Һәм су чыкса баскан эзеңнән* (М. Җәлил. Бер үгет).
Төрдәше: агач<тан> сандугач кына ясамау һ.б.

*БАСКЫЧ* ❖ **БАСКЫЧ ӘЙЛӘНДЕРЕЛЕП КУЕЛУ**. Җәмгыятьнең социаль катламнары дәрәҗәсе тәртибендә урыннар алмашу. *Соңгы вакытта баскыч әйләндерелеп куелды. Тукай әйтмешли, без югарыда дип масайганнар түбән төште, үзләрен бик ипле-әдәпле тоткан түбәндәгеләр югарыга менде* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).
Төрдәше: баскычны әйләндерү; баскычның асты өскә әйләнү.

*БАСКЫЧНЫ* ❖ **БАСКЫЧНЫ ӘЙЛӘНДЕРҮ** *к.* баскыч әйләндерелеп куелу. *Бер адәм килде дә шул чакта, әйләндерде баскычны: / Түбәнге басмалар менде, югаргысы түбән төште* (Г. Тукай. Баскыч).
Төрдәше: баскыч әйләндерелеп куелу; баскычның асты өскә әйләнү.

*БАСКЫЧНЫҢ* ❖ **БАСКЫЧНЫҢ АСТЫ ӨСКӘ ӘЙЛӘНҮ** *к.* баскыч әйләндерелеп куелу. *«Менә, иптәш, нинди хәлләр заһир булды, баскычның асты өскә әйләнде. <...> Кичә хакыңны, намусыңны изгән золым түрәләрнең бүген үзләрен дә мыскыл итеп, көлеп, төрмәгә озаталар»* (Ш. Бабич. Зәңгәр җырлар).
Төрдәше: баскыч әйләндерелеп куелу һ.б.

*БАСМА* ❖ **БАСМА САЛУ.** Дуслык мөнәсәбәтләре урнаштыра башлау. *Димәк, Вәлитова белән эшлекле мөнәсәбәт урнаштыру өчен, басма сала башларга вакыт* (М. Насыйбуллин. Телсез шаһитлар). *Сүзен үзе башласын. / Нигә аңа басма салып торырга?!* (И. Иксанова. Балан чәчәге).

**БАСМА СҮЗ.** Матбугат, газета-журналлар. *Телнең төп сакчыларыннан берсе – язма һәм басма сүз* (Ә. Кәримуллин. Тел язмышы – милләт язмышы). *Басма сүзнең бәһасе үлчәм берәмлекләрендә түгел, мәгънәви, рухи кыйммәтендә* (Г. Бәйрәмова. Күңелләрнең көзге балкышы).

*БАСМАГАН* ❖ **БАСМАГАН, СУКМАГАН, КАКМАГАН ИШЕК КАЛМАУ.** Әрсезләнеп эзләү; бер җирне дә калдырмыйча, актарып чыгу. *Бервакыт үзенә кирәкле әйберен тапмагач, басмаган, сукмаган, какмаган ишек калмады* (Сөйләм).
Төрдәше: басмаган сукмак, какмаган ишек калдырмау.

**БАСМАГАН СУКМАК, КАКМАГАН ИШЕК КАЛДЫРМАУ** *к.* басмаган, сукмаган, какмаган ишек калдырмау. *Басмаган сукмак, какмаган ишек калдырмады* (К. Нәҗми).
Төрдәше: басмаган, сукмаган, какмаган ишек калдырмау.

*БАССА* ❖ **БАССА БАКЫР ИЗӘРЛЕК, <ТИПСӘ ТИМЕР ӨЗӘРЛЕК>** *к.* арыслан авызына керү. *Бер яктан, эшелон-эшелон булып, сугышта имгәнгән кешеләр кайтса, икенче яктан, алар урынына, басса бакыр изәрлек, типсә тимер өзәрлек егетләрнең китә торган чагы* (К. Әмири. Югалган малай). *Зөһрә исемле бер фәкыйрь кыз үзе кебек үк ярлы, әмма басса бакыр изәрлек, типсә тимер өзәрлек көчле һәм кыю бер егетне яраткан* (Т. Нурмөхәммәтов. Кабан күле, әй, алкын).
Төрдәше: арыслан авызына керү һ.б.

**БАССА БАКЫР ӨЗӘРДӘЙ** *к.* алып кадәр. *Дөньялар җитеш дигәндә генә сугыш чыкты, басса*

*бакыр өзәрдәй ир-егетләр яу кырына китте...* (Р. Кәрами. Кая чабасың, гомер юртагы?).
Төрдәше: алып кадәр һ.б.

*БАСТЫРЫКЛЫ* ❖ **БАСТЫРЫКЛЫ СҮЗ.** Кирәксез сүз сөйләүнең файдасыз икәнлегенә ишарә. *Сүзгә бик тә остардык без. / Абау, күп сөйләнәбез, – Сүзегез бастырыклымы? / – Буш бауга төямәгез...* (Зөлфәт. Бастырык бавы).

*БАСТЫРЫП* ❖ **БАСТЫРЫП КИЛҮ.** 1. Арттан куа барып, үкчәгә басып килү. *Гөлгенә дәшә икән, кулындагы зәңгәр кыйгачын болгый-болгый, бастырып килә* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
2. Атның арт аякларына басып ят кешегә һөҗүм итүе хакында. *Кара айгыр типсә – тибә, тешләсә – тешли, ят-чит кеше күрсә – өстенә бастырып килә* (Н. Акмал. Шәкүр).
3. Тиз арада. *[Вәрәкия] Зәкит Әхиярович, сезнең арттан бастырып килдем. Хәзер үк больницага килергә үтенделәр* (А. Гыйләҗев). *Ул якын, ләкин сыбайлы дошманнар бик тиз бастырып килә иде, тагын берничә мизгелдән боларны кылыч белән турап ташлаячаклар* (З. Мурсиев. Ташмәчет).

**БАСТЫРЫП УТЫРУ.** Башын күтәрмичә утыру. *Бу – әтинең фронттан килгән соңгы хаты иде, башымны кулларым белән кыстым да, озак вакытлар шулай бастырып утырдым* (Сөйләм).

*БАСУДА* ❖ **БАСУДА БАЛЫК БУЛМЫЙ** *к.* аткан саен үрдәккә тими. – *Басуда балык булмый, дисең – анысын беләсең икән. Ә нигә белмәгән башың белән түбә ябарга тотындың?* (Сөйләм).
Төрдәше: авыртмаган якка яту һ.б.

*БАСЫМ* ❖ **БАСЫМ ЯСАУ (ЯСАП ӘЙТҮ).** Нәрсәгә булса да аеруча дикъкать итү, аны мөһимрәк дип санау. *Һәр сүз соңгы иҗеккә басым ясап әйтелә, русчадагыча түгел* (И. Гази. Әдәби телебез турында). *Бардыр ла сине сөюче һәм бары сине генә көтеп торучы сөйгән кызың. «Бары сине генә» дигәнне ул басым ясап әйтте* (А. Нәҗми. Азат).

*БАСЫМЧАК* ❖ **БАСЫМЧАК ИТҮ.** Кешене санга сукмау, аны юашка, мескенгә санау. – *Бер дә, ике дә басымчак итәргә Яңасала ул тикле нишләгән? – дип кыкыралар* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Янында аталары булмагач, барысы да басымчак итә икән* (Ф. Бәйрәмова. Соңгы намаз).

*БАСЫП* ❖ **БАСЫП АЛУ.** 1. Яулау, яулап алу. *1942 елның ноябрендә аны [Марсельне] фашистлар басып ала* (А. Хәсәнов. Данәгөл). *Явыз Иван, татар җирен басып алганнан соң, калын тавышлы, таза күкрәкле ир-атларны яшәтмәгән, дөньяга килгәннең берен кырып барган* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: басып керү 2; басып килү 3.
2. Көчләп, мәҗбүри рәвештә тартып алу. *Монголлар басып алган Саксин каласын Җигүлат (Жигули) таулары итәгенә урнаштыру да дөрес түгел, Түбән Иделдә, хәзерге Әстерхан шәһәре тирәсендә булган ул* (В. Имамов. Утлы дала). *Аның карашы буенча, бөтен начарлыклар яһүдлардан килә, имеш, алар бөтен җылы урыннарны басып алганнар һәм кисәкләп бөтен дәүләтне сатып торалар* (В. Исламетдин. Шлем).
3. Таралу, җәелү. *Билчән, кычыткannар басып алган, / Төер-тамыр, чагыр үләне...* (А. Нәҗми. Сабын чәчәге). *Бүлмәне серле караңгылык басып ала* (А. Гадел. Күселәр).
Төрдәше: басып килү 2.

**БАСЫП КАЛ(ДЫР)У.** 1. Алачак бурычын тотып калу. *Бу заманда сәүдәгәрләр һәм байлар арасында эш төзәтү исеме белән хыянәт эшләү һәм кеше хакын басып калулар бар* (Р. Фәхретдин. Сайланма хәдисләр аңлатмасы).
2. Кеше өлешенә керү; бирәчәк бурычын кайтармау, нәрсәне булса да онытканга сабышу. *Мин аңарда җиде ел ялчы булдым, җилкәм чиләнгәнче эшләдем, актыкта тияремне басып калды: кигән чикмәнемне суеп алды!* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). *Хезмәт хакын басып калалар* (И. Гази).
3. Яшереп калу, сер итеп саклау; йомып калдыру. *8 нче ротаның солдатлары бу эштә фельдфебельне гаепләп, аны полк штабы аркылы җавапка тарттырырга дип йөрсәләр дә, ротный командир, аны яклап, бу нәрсәне басып калдырды* (М. Гали). *Калморзада хатыннарны тентемәделәр дә, хөкем дә итмәделәр. Шулай да бер гауганы көчкә басып калдылар* (Р. Хәбибуллина. Миләш елы).

**БАСЫП КЕРҮ.** 1. Һөҗүм итү. *Аксак Тимер Сүриягә басып кергәч, Ибне Халдун Мисыр*

*солтанын Сүриягә озата барып, Аксак Тимергә баш ияләр* (А. Тимергалин. Миллият сүзлеге). *Әмма дошман басып керү Болгар халкын утка ташлаган мәгъдән шикелле укмаштырды, берләштерде генә* (В. Имамов. Утлы дала).

2. Оятсыз рәвештә бәреп керү. *Япуннар белән кытайлар безнең җиргә басып керә башлаганнар, ди* (А. Алиш. Күршеләр). – *Ә син, шул ук урыс төсле, басымчаклык итеп басып кердең* (В. Имамов. Сөләйман солтан).

Төрдәше: басып килү 3.

3. Әрсезләнеп йөрү, талау. *[Гайни] Бар кеше дә синең шикелле рөхсәтсез кеше өенә басып кермиләр* (Г. Камал. Бәхетсез егет). <...> *сары йортны адрес бюросында Америка шпионнары да таба торган түгел, ә ишектән, шакымыйча-нитмичә, көяз атлап, утта янмас, суда батмас Мәхмүт-Мудрый басып керде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?)

**БАСЫП КИЛҮ.** 1. Гайрәтләнеп берәрсенең өстенә килү. *Аңлашыла, ул үзенең өстенә басып килгән Сахибгәрәйне тәхеткә утырган көенчә каршыларга да батырчылык итә алмаган* (В. Имамов. Сөләйман солтан).

2. *к.* басып алу 3. *Балаларның әнә кишер түтәлләрен утыйсы бар. Бөтенләйгә эт эчәгесе басып килә* (А. Хәсәнов. Гөлмәрфуга). *Кем, кайсыгыз чыгу юлын таба / Тутык басып килгән бу илдән?* (К. Булатова).

3. *к.* басып алу 1. *Дәүләт Гәрәй 1572 елда 120 мең гаскәр белән Мәскәү чикләренә басып килде* (Г. Гобәйдуллин. Татарларның килеп чыгуы һәм Алтын Урда). *Тагын да әллә кайларда, кояш баеган якларда, танкка атланып, бала-чагаларны, корт-корыларны таптатып, илгә басып килгән фашистлар бар* (З. Зәйнуллин. Үрләр аша).

Төрдәше: басып алу 1; басып керү 2.

**БАСЫП КУЮ.** Лампа, самавыр кебек әйберләрнең утын киметү, томалау. *Мич алдында иске чүпрәкләр белән басып куйган самавыр акрын гына җырлый* (Ә. Еники. Яз җыры). *Фирдәүсә радионы басып куйды* (Ф. Садриев. Көлми торган кеше).

**БАСЫП УТЫРГАН УРЫН (ҖИР).** Утырып күнеккән урын. *Китапханә уку залының бер почмагында басып утырган урыным бар иде* (Сөйләм).

**БАСЫП УТЫРУ.** 1. Озаклап утыру. *Мәкаләмне тизрәк язып бетерер өчен, төннәрен ут яндырып, басып утыра башладым* (Сөйләм).

2. Бала чыгару чорында йомыркалар өстендә утыру (кош-корт турында). *Аннары тирән эчле калай тәлинкәгә су салды да вак кына итеп ипи туралы, аны өйалдына йомыркаларын басып утырган ана казы алдына чыгарып куйды* (Ә. Гаффар. Әҗәт).

**БАС<ТЫР>ЫП ЧЫГАРУ.** Кулъязманы китап яки мәкалә итеп нәшер итү. – *Кай арада басып чыгардылар икән соң?* (В. Нуруллин. Ике урам арасы).

**БАСЫП ЯТКЫРУ.** Кая булса да яшереп саклау, файдаланмау. *Менә бусы – Заһит проекты буенча материаллар. Бу проектны никадәр вакыт басып яткырдылар* (Г. Иделле).

*БАТАРЕЯ* ❖ **БАТАРЕЯ УТЫРУ.** Берәр җиһазның энергия чыганагы булган элементның көче бетү. *«Батарея утырды» проектын гамәлгә ашыру (аның авторы – якташыбыз Дамир Җиһаншин) файдаланылган батареяларны, кәрәзле телефон аккумуляторларын, ноутбукларны кабул итү пунктларын кешеләр күп яши торган урыннарда урнаштырырга мөмкинлек бирәчәк* («Заря» газ.).

*БАТКАН* ❖ **БАТКАН АЯК ЧЫЛАНГАН, ЧУКЫНДЫРЫП АЛАМ.** «Начар эшне бер эшләгәч, кабатлау кыен түгел» дигәнне аңлата. *[Гөлүзә] Тагын шул биш литр!..* (Уйлап). *Тукта әле, баткан аяк чыланган, чукындырып алам* (Ю. Әминов. Өти Балак).

**БАТКАН (БАТА БАШЛАГАН) КЕШЕНЕ КҮРГӘЧ, АРКАН ИШӘРГӘ ТОТЫНУ** *мыск. «Бата башлаган кешене күргәч, аркан ишәргә тотыналармы?»* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

*БАТКАНДА* ❖ **БАТКАНДА (БАТКАН ЧАГЫНДА) КҮБЕККӘ (САЛАМГА) ТОТЫНУ.** Кыен хәлдә калганда, файдасы булмаслыгын белеп тә, соңгы мөмкинлекне кулланырга тырышу. *Ул бераз тын торды, аннары батучы кеше саламга тотынырга теләгән шикелле, яшерен өмет белән сүзен дәвам иттерде...* (Г. Әпсәләмов).

Төрдәше: батканда <судагы> саламга ябышу; батканнан саламга тотыну; батмастан күбеккә тотыну;

батып барганда, саламга тотыну (ябышу); суга баткан – саламга ябышкан; суга батучы саламга ябышу.

**БАТКАНДА <СУДАГЫ> САЛАМГА ЯБЫШУ** *к.* батканда (баткан чагында) күбеккә (саламга) тотыну. *Ялгыштыкмыни? / Ябыштыкмыни / Батып барганда суда саламга?* (Э. Шәрифуллина. Сүзсез буйсынган). *Бәлки, бу чаралар, вәгазь-фикерләр батканда саламга ябышу гынадыр?* (Р. Зәйдулла. Инкыйраз).

Төрдәше: батканда (баткан чагында) күбеккә (саламга) тотыну һ.б.

**БАТКАНДА ТАРТЫП АЛУ.** Кыен хәлдә калганда ярдәм итү. – *Теге вакытта мин батканда, син мине тартып алган идең* (Сөйләм).

*БАТКАННАН* ❖ **БАТКАННАН САЛАМГА ТОТЫНУ** *к.* батканда (баткан чагында) күбеккә (саламга) тотыну. – *Суга егылсаң онытма: батканнан саламга тотынганда да ярдәме була* (Сөйләм).

Төрдәше: батканда (баткан чагында) күбеккә (саламга) тотыну һ.б.

*БАТМАНЫ* ❖ **БАТМАНЫ ӨЧ ТИЕН** *к.* әһәмиятсез нәрсә. *[Юлай] Син хаклымы монда, Хәсәнме – батманы өч тиен дә тормый хәзер* (Р. Хәмид).

Төрдәше: әһәмиятсез нәрсә һ.б.

*БАТМАСТАН* ❖ **БАТМАСТАН КҮБЕККӘ ТОТЫНУ** *к.* батканда (баткан чагында) күбеккә (саламга) тотыну. – *Батмастан күбеккә тотынма, суга төшкәч тә өлгерерсең* (Сөйләм).

Төрдәше: батканда (баткан чагында) күбеккә (саламга) тотыну һ.б.

*БАТЫЙН* ❖ **БАТЫЙН ҖӘҮҺӘР** *иск.* Күзгә күренми торган өстенлекләр. *Һәр нәрсәнең батыйн җәүһәре бар, җентекләп карарга гына кирәк* (Сөйләм).

*БАТЫП* ❖ **БАТЫП БАРГАНДА САЛАМГА ТОТЫНУ (ЯБЫШУ)** *к.* батканда (баткан чагында) күбеккә (саламга) тотыну. – *Ялгыш машинистка төшереп калдыргандыр, – диде Кәүкәбелҗәннәт, батып барганда саламга ябышып* (Ф. Садриев. Адәм әүлиясы). *Фрицларның әшәкелекләре бөтен дөньяга фаш булып барганда, шулай сөйләү соң дәрәҗәдә түбәнлек, батып барганда саламга тотыну, дип уйлап куйды Сөенчалин* (Х. Камалов. Һәркемнең гомере бер генә).

Төрдәше: батканда (баткан чагында) күбеккә (саламга) тотыну һ.б.

*БАТЫР* ❖ **БАТЫР ЙӨРӘК.** Куркусыз, гайрәтле булуга ишарә. *Аның күкрәгендә дөп-дөп батыр йөрәк тибә* (А. Хәсәнов. төп мәсьәләгә кагылмый да...).

Төрдәше: алып йөрәк.

**БАТЫР ЙӨРӘК САНАУ.** Курку белмәс, батыр кеше дип фараз итү. *Егет үзен батыр йөрәк саный, юк-бардан курку күрсәтергә яратмый иде* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр).

Төрдәше: арыслан авызына керү һ.б.

**БАТЫР<ГА> КАЛУ.** Көрәшчеләр ярышында җиңүче булу. *Әйе, типкәч тимер өзәрлек егет идем, мин шуңа Сабан туйларында ике-өч ел рәттән батыр калып килдем* (А. Шамов. Кыз урлау). *Сабан туенда бил алышып батыр калу хыялы – һәр татар малаеның хыялыдыр* (Г. Шәйхи. Бил алышу – яшәү рәвешем).

**БАТЫР КАНЫ ЙӨРӘККӘ ТАМУ** *к.* арыслан авызына керү. *Ил онытмас, бирсәң каныңны / Ватан өчен изге көрәшкә. / Хаин каны тама чиләккә, / Батыр каны тама йөрәккә* (М. Җәлил).

Төрдәше: арыслан авызына керү һ.б.

*БАТЫРЛЫК* ❖ **БАТЫРЛЫК ДАРУЫ** *мыск., к.* агулы елан 1. *«Батырлык даруы» эчкә керсә, әйтергә сүз табалар дип исәпли хатын* (Ә. Моталлапов. Рисвайлык).

Төрдәше: агулы елан 1 һ.б.

**БАТЫРЛЫК ҖИТҮ.** Нинди булса да эшкә тотынырга яисә берәрсенә сүз әйтергә тәвәккәлләү, кыюлык җитү. *Татар интеллигентлары арасында, Рөстәм Кутуйны искә алмаганда, бу мәсьәләне күтәрергә батырлыгы җиткән язучыны хәтерләмим мин* (М. Юныс. Телсезләнү: тамыры һәм җимешләре). *Минем батырлык та җитә, әмма тәртипне бозу килешми* (Ф. Яхин. «ЗИС-5»).

*БАТЫРЫП* ❖ **БАТЫРЫП ӘЙТҮ.** Курыкмыйча, дөресен әйтү. *Идеология көрәшенең алгы сызыгында торырга тиешле иҗат интеллигенциясе бу якалашта үзенең үтемле сүзен җае килгән саен батырып әйтә торырга бу-*

*рычлы* (Ф. Әгъзамов. Чорның елъязмасы). *Аннары гомерен Чаллы шәһәрендә үткәрде, күпкырлы иҗат белән шөгыльләнде: менә дигән шигырь-поэмалар язды, публицистика өлкәсендә дә үз сүзен батырып әйтте* (Г. Гомәр. Шәхесләр һәм шәрехләр).

**БАТЫРЫП КАРАУ.** Ныгытып, төбәлеп карау. *Фәридун сорашмады, аңлады, бер карады Нәҗипкә, батырып карады* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *– Син дә минем өстән партбюрога яздыңмы? – дип сорады ул, маңгай астыннан батырып карап* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**БАТЫРЫП ЭШЛӘҮ.** Бөтен көчкә тырышып эшләү. *Зурысы, Миңниса, ялан эшләрен батырып эшләде* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). *Тормыш авыр дип тормадылар, батырып эшли дә, гөрләтеп күңел ача да белделәр* (А. Хайртдинова. Язмыш җиле).

*БАУ* ❖ **БАУ УРЫНЫНА ИШҮ.** Тулысынча буйсындыру, үз теләгәнеңне эшләтү. *Һи, син аның кулына төшсәң, ул сине бау урынына ишә* («Казан утлары» ж.).

*БАУГА* ❖ **БАУГА МЕНҮ.** Үзен үзе асу, асылыну. *Ире Арсланның атна буе сорау алучылар кулыннан кыйналып-сугылып, Мотавал өендә газап чиккәннән соң баугa менүе Рәшидәне тәмам аяктан екты* (Д. Салихов. Чукрак).

*БАУДАН* ❖ **БАУДАН ЫЧКЫНУ.** Узыну, тәртипсезләнү. *[Гөлчирә] Ярый инде. Фәритем дә, баудан ычкынып китсәм, «узынма» дия иде* (Т. Миңнуллин). *Ә ул һаман суынмаган, күрәсең, тиздән куып җитте дә, баудан ычкынган кебек исәренеп, тагын бәйләнергә тотынды* (С. Сабиров. Алтын балдаклы абыстай).

*БАҺАДИР* ❖ **БАҺАДИР ЙОКЫСЫ БЕЛӘН (БАҺАДИРДАЙ) ЙОКЛАУ.** Тирән йокыга талу. *Башта ул, кымшанып та карамыйча, баһадир йокысы белән йоклады* (А. Тимергалин. Таш алиһә). *Сезгә бүген баһадирлар йокысы белән онытылып йокларга кирәк* (А. Хәсәнов. Данәгөл).

*БАШ* ❖ **БАШ АВУ.** Башның авыртуын ми бер якка авышкан дип уйлау. *Теге көнне бик миен дә селкеттеләр, башы ауса да аугандыр. Тастымал салып үлчәргә кирәк* (Н. Исәнбәт).

**БАШ АВЫРАЮ.** Баш авырту; фикер томаланып, йокы килә башлау; кәефсезләнү. *Гәүдәсе мамык кебек җиңел, бары тик башы гына, авыраеп, аска таба сөйри* (Р. Вәлиев. Яшисе килә). *Башы авырайды, үзеннән-үзе күзе йомылды* (Д. Каюмова. Сабырлык).

**БАШ АВЫРТТЫРУ** *к.* бавырга боз урнашу. *Күзен дә ачып карыйсы килми иде аның, әрнеп йөрәге сулкылдады, башын авырттырып, рәнҗү басты бар халәтен* (К. Кара. Ак күгәрчен, күк күгәрчен). *Йокысы килеп, башны авырттырып әйләнеп китте* (Ф. Яхин. Умырзая).

Төрдәше: бавырга боз урнашу һ.б.

**БАШ АГАРТУ** *к.* бавырга боз урнашу. *Кайтсын дөньяны тарсынып очкан кошлар. / Агартмыйк баш, бу милләт дип, кайда кышлар?* (Ф. Хөсни. Кичке дога). *Мондый авыр хәбәр олыларның да башын агарта, буйларын сындырып сала* (Н. Дәүли. Язмышка юл).

Төрдәше: бавырга боз урнашу һ.б.

**БАШ АЙКАУ.** Берәр нәрсәне килештермәүдән, ошатмаудан яки гаҗәпләнүдән башны як-якка селкү. *Башын айкый башлый үгез, / Түземе тәмам бетеп* (Ш. Галиев). *Камай Байтимерне урамга таба тартты, ләкин тегесе «юк» дип баш айкады да, алар атлар-атламас кына өй ишегенә таба киттеләр* (З. Хөснияр. Гарасат).

Төрдәше: баш изәү; баш<та> йөртү (йөртеп карау) 2; баш селкү; баш чайкау.

**БАШ АКЧА** *этн.* Кияүдән булачак кәләшенә кием-салым өчен бирелә торган акча. – *Баш акчаңны аерым җиргә куй* (Сөйләм).

**БАШ АЛА.** Бөтенләй, бөтенләйгә, бөтенләе белән. *Уй агышы ирексездән түгел, / Иректә баш ала иркемне* (Б. Рәхимова. Җитә). *Мин икенче мәртәбә Уфага барганчы, җиде-сигез еллар үтеп киткән. Ул җәмгыять баш ала онытылган иде* («Фәнни Татарстан» ж.).

**БАШ АЛГЫСЫЗ.** Ерып чыккысыз тыгын. *Кичәдә баш алгысыз иде, шунлыктан ишек төбендә генә тордык* (Сөйләм).

**БАШ АЛМАСТАН.** Бик нык, бирелеп. <…> *үзенең поэзия көчен эшкә җигеп, әдәби иҗат эшен дәвам иттерә, җәмәгатьчелек эшенә чума, совет дәүләте учреждениеләрендә баш алмастан гражданлык бурычларын үтәргә*

*керешә* (К. Гыйрфанов. С. Рәмиев турында кайбер истәлекләр).

**БАШ<НЫ> АЛУ.** 1. Башны кисү. *Синең өчен хан тагын минем башымны алсынмы?* (Н. Исәнбәт).

Төрдәше: кылычтан кичерү (үткәрү; уздырту).

2. Сәлам бирү өчен, баш киемен салу. *Батыргали агайга бәгъзы белеш-таныш руслары очрап, баш алсалар да, Батыргали агай, бүркен салмаенча, солдатлар кебек честь биреп кенә үтә иде* (Ш. Мөхәммәдев. Япун сугышы, яхуд Доброволец Батыргали агай).

3. Бөтен нәрсәне онытып, уйга бирелү яки кызыксынып күзәтү. *Уйга чумган, җиргә күз теккән, җиһаннан баш алып* (Г. Тукай).

4. Башны калкыту, югары күтәрү. <...> *соңгы тапкыр хушлашырга хокукы булмаганлыгын аңлап, ләхет авызыннан авырлык белән башын алды һәм кара җир куенында ак башак булып яткан Тансыгы өстенә капланды* (А. Хәлим. Кыйбла).

5. Башлану. *Булачак шәһәрнең төп ике магистрале менә шушы өченче ур сыртымнан түбәнгә, үзәнлеккә таба баш ала* (Г. Кашапов. ...һәм башланды яңа көрәш). *Шәҗәрәбез шуннан баш ала, / Минем нәсел шуннан башлана...* (Х. Төхфи).

6. Оныта алмау, сагыну. *Мин дә Атсудан башымны ала алмам. Күпме генә аерым тордык, ә ул сагындыра да башлады* (Ә. Моталлапов. Нигез).

7. «Үз-үзеңне» мәгънәсендә. – *Ярый әле, башыңны алып котылгансың,* – *дип елмая Чыңгыз* (А. Хәсәнов. Бүре баласы Чатан).

8. Чәч алу. – *Баш алдырып кайттым әле, рәхәтләнеп киттем* (Сөйләм).

**БАШ<НЫ> АЛЫП КИТҮ (КАЧУ; ОЛАГУ; ТАЮ һ.б.).** 1. Качып котылу, берәр җирдән аерылу. «*И кызганыч җанвар! Кит, югал күземнән! Тере вакытта тизрәк башыңны алып кач*» (Г. Тукай). *Башым алып олагамын мин дачага, / Ачу итеп кода белән кодачага* (Г. Афзал. Утырышу). *Фәррах Таңчулпаннан башын алып китте* (Б. Камалов. Гомер кичендә).

2. Бик нык гашыйк булу. *Баш алып качып китәрлек икән шул егете дә, кол оста гына димәссең* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).

**БАШ АЛЫП ЧЫККЫСЫЗ.** Буталчык, ыгы-зыгылы, рәтсез. – *Нәрсәгә дип җибәрдең соң миңа бу язуыңны, баш алып чыккысыз бит ул!* (Сөйләм).

**БАШ АРКЫЛЫ (АША) ЕГУ (АЛЫП АТУ; ЫРГЫТУ).** 1. Нигездә, кулбаш өстеннән аударып егу (татарча көрәштәге бер алым). – *Чөеп җибәр! – Баш аркылы ыргыт! Әмма Кәче егете дә уяу шул, каһәр* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Котырган үгез бер кадауда ябык, җиңел гәүдәле хатынны баш аркылы алып аткан иде* (В. Имамов. Тозлы яра).

Төрдәше: баштан аша җибәрү.

2. Нәрсәне булса да ике куллап баш аша артка таба чөю. *Безнең йорттан ераграк киткәч, сеңлеңне кыйбла якка арты белән бастыр да, башы аша ыргыт* («Безнең гәҗит» газ.).

**БАШ АРКЫЛЫ СИКЕРҮ.** Җиңел атлетикада биеклеккә сикерүдә кулланылган алым (йөгереп килеп, биеклек күрсәткеченә арка белән борылып сикерү). *Спортчылар баш аркылы сикерү алымын куллана башлагач, нәтиҗәләре шактый яхшырды* (Сөйләм).

**БАШ АРТЫ <КИЛҮ>**. Ярышта җиңүче артыннан икенче булу. *Чаллы Сабан туенда баш арты килгән атны җир буе җир калдырып килде* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы).

**БАШ АСТЫНА БАЛЛЫ КАШЫК КУЮ.** Йоклау. *Ә баш астына баллы кашык куярга ярамый! Дәресләр бар, мәктәптә сер бирәсе килми* (Б. Камалов. Өметең өзелмәсен).

**БАШ АЧЫЛУ.** Акыл, зиһен эшли башлау. *Бу эшләр белән шөгыльләнгән арада, аның башы бераз ачыла төшкән иде, яңадан әлеге шул берләшү темасына күчеп, сүзләрен берсе артыннан икенчесен мәрҗән кебек тезә-тезә генә сөйли башлады* (Ф. Хөсни. Җәй башы). *Мондый һавада башы ачыла, кайдадыр йокымсырап яткан уй-фикерләре кузгала, өр-яңалары борын төртә* (М. Әмирханов. Гәүһәршад).

**БАШ АША.** 1. Арада булган кешеләр белән исәпләшмичә, санлашмыйча. *Кыз, моны ишеткәч, әрнеп куйды: әгәр аның башы ашасыннан сеңелесенә яучы килә башласа, бу хурлыкка ничек чыдар?* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми).

2. Баш аркылы мәтәлеп китү, егылу. *Байтал, көтелмәгән чокырга килеп эләккән сыман,*

*шундук алгы аякларына тезләнде, Талиб аның башы аша җир өстенә очты* (В. Имамов. Казан дастаны).

3. Төрле яклап уйлау. *Василевский, дусты әйткәнне башы аша уздырып, азрак уйланып утыра иде* (З. Зәйнуллин. Алексей Антонов дигән генерал).

4. *күч.* Төрле яктан яхшылап уйланган, төшенелгән нәрсә. *Дөрем, һәрнәрсә Солтанъяр теләгәнчә үк тиз эшләнми, ләкин монысы инде табигый хәл, ни генә кыланма, үз башың аша атлап чыгалмыйсың* (З. Мурсиев. Солтанъяр).

**БАШ<НЫ> АШАУ.** 1. Һәлак итү, юлдан яздыру. *[Бәдига] Әйе, әйе, кызым, синең башыңны ашарга килдем* (М. Фәйзи. Галиябану). *– И-и, шушы хөрәсән дә кайчандыр аның әтисе Габдулланың башын ашамакчы иде ләбаса. Тфү-ф-фу, нәҗес!* (В. Имамов. Казан дастаны).

2. Хур итү, оятка калдыру. *Газизнең моңа «Юк, ул шарфны миңа минем башымны ашар өчен бүләк иткәннәр» дип җавап бирәсе килде* (М. Әмир).

3. Кемгә булса да көчле зарар ясау; яла ягу, хур итү. *[Зәйнәп] Син минем җиде ел эчендә башымны ашадың* (Г. Камал. Каениш). *[Бәдига] Бәдига карчык башымны ашады, дигәнне бер дә ишеткәнем юк* (М. Фәйзи. Галиябану). *– Карчыкның башын үзең ашадың бит. Шуңа күрә аптырап кына әйтүем* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

**БАШ ӘЙЛӘНДЕРГЕЧ.** 1. Искитәрлек, зур. *Шулай итеп, бу көнне кояш кыздыра башлаганчы ук, ике кеше, баш әйләндергеч карьера ясап, зур мәртәбәгә иреште* (А. Тимергалин. Таш алиһә). *Бу галимнәр өчен баш әйләндергеч могҗиза булып тоелды. – Шаккаткыч, – диештеләр алар, баш чайкап, – бу бит сенсация!* (З. Мәхмүди. Ул җирне сагынган иде).

2. Рәтсез, мәшәкатьле, юньсез (кеше). *Унынчы классны бетереп чыгучыларның болай да баш әйләндергеч мәшәкатьле көннәрендә, кайсы уйлап тапкандыр, төрле профессия кешеләре белән очрашу кичәсе уздыруны билгеләгәннәр иде* (Ф. Хөсни. Берәү бик якын кебек иде).

**БАШ<НЫ> ӘЙЛӘНДЕРҮ.** 1. Үзенә карату, яраттыру. *Кызның өстеннән, чәчләреннән аңкыган хуш исләр егетнең башын әйләндерәчәк бер көч белән дулкынланып килеп кагылалар* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Әйе, кызларның башын әйләндерү миңа кыен булмады (шуннан артыгына җөрьәт итмәсәм дә)* (Х. Ширмән. Ерактагы йолдызым).

Төрдәше: акылдан яздыру һ.б.

2. Аптырату, фикерне чуалту; хаталы нәтиҗәләр чыгарырга этәрү. – *Остарды кеше врачларның башын әйләндерергә!* (Ә. Еники. Тынычлану). *[Кара дус] Кара, Такташ, ул Казанда күп кешенең башын әйләндерде инде. Сак бул, синең дә башыңа җитмәсен* (Ф. Бәйрәмова. Атылган йолдыз).

Төрдәше: башны бутау; йөрәккә төшү; тәкатьне алу; теңкәгә тию; теңкәне корыту.

3. Уйларга мәҗбүр итү, иләс-миләс китерү. *Ләкин нигәдер күңелем курка шул, акыллым: мин юкта берәрсе башыңны әйләндереп, үзенә каратып куймагае?!* (В. Нуруллин. Һәлакәт). *Ул анда баш әйләндереп йөргән вакыт эчендә имтихан билетларын тамгалап та чыктык...* (Г. Акбар. Могҗиза үлеме).

4. Кәефне күтәрү, ләззәт бирү. *Төрле-төрле чәчәкләрдән бергә кушылып аңкыган хушбуй исе башны әйләндерә, йөрәктәге шатлык хисен каядыр югары, төпсез зәңгәр күккә чөя төсле иде* (А. Вергазов. Үзеңә кайту). *[Гөлчәчәк] Суфия апа, бүген урамда искитмәле күңелле, яз исе башларны әйләндерә, борыннарны кытыклый* (А. Гадел. Кияүләргә кытлык юк).

5. Юк-бар сөйләү. *Үз эченнән бу сөальнең кирәге барын аңламады. «Минем башымны юк белән әйләндерә», – дип уйлады* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар). *[Сәет] Ну башны әйләндерәсең син, ә? Дәү әбиең ничек түзә синең* (Т. Миңнуллин. Шәҗәрә).

6. Алдау. *[Харис] Үлеп гашыйк булдым дип башыңны әйләндерергә тырышыр идем* (Т. Миңнуллин. Саташу).

Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

7. Бөтен ихтыяр көчен алу, тулысынча үз теләгенә буйсындыру. *[Гариф] Әйе, ул аның башын әйләндерде, бәгырьләрен пәрә-пәрә телде* (Ф. Бурнаш. Илһам).

Төрдәше: акылдан шаштыру; акылдан яздыру; башны-күзне әйләндерү.

8. *этн.* Кызны кияүгә бирү турында килешү. *Яучы әби алдый-юмалый башларын әйләндереп бетерде дә, ниһаять, кул бирештеләр* (Сөйләм).

**БАШ ӘЙЛӘНҮ.** 1. Эш күплегеннән, кайгыдан, тойгыланудан һ.б.дан ачык аңлау сәләтен югалту. *Балдан, җырдан, шау-шудан минем башым әйләнде, һавага чыгасым килде һәм, ыгы-зыгыдан файдаланып, урынымнан мыштым гына кузгалдым* (Ә. Еники. Җиз кыңгырау). *Ник дисәң, кинәт башым әйләнеп китте минем, өйгә йөгердем* (Ф. Хөсни. Йөзек кашы).

2. Авыру сәбәпле, тотрыклылыкны югалту. *Ләкин... ләкин бер минут килде дә, аның башы әйләнде, күзен кан басты, шуннан ул эченнән куәтле ташкын кебек күтәрелгән ачу вә хурлану тәэсире белән укуны төкереп ташлады* <...> (Г. Ибраһимов. Яшь йөрәкләр). *Дөрес, минем буыннарым хәлсез иде әле, башым да әйләнә иде, ләкин болар гына мине тотамы соң?!* (Ә. Еники. Гөләндәм туташ хатирәсе).

3. Аптырау, нәрсә эшләргә белмәү. *Ләкин көтелмәгән вакытта үзе эләгеп, зинданга утыргач, аның тагы башы әйләнде* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар). *Аптырагач, тәмам баш әйләнгәч, / Уйлыйм үскән җирне ташлап китәргә* (З. Бәшири. Аерылу).

Төрдәше: аптыраган үрдәк хәленә төшү һ.б.

4. Масаю, үз-үзеңне ялгыш бәяләү. *Җиңүләрдә баш әйләнеп исерсәң дә, бик таянма – боз ул һәрчак ап-аек* (З. Мансуров. Кылдан нечкә, кылычтан үткен). *Баш әйләнеп китте уңышлардан, / Күкрәк киереп алга барабыз* (Г. Афзал. Баш әйләнеп китте уңышлардан).

Төрдәше: баш өстеннән карау; борын күтәр<ел>ү (чөю); борыныңны бик күтәрмә, агачка (агач башына) эләкмәсен; борыныңны бик күтәрмә, бүрәнәгә абынырсың; борыныңны бик <югары> күтәрмә (чөймә), чиләк (бидрә) элеп куярлар.

5. Берәр нәрсә белән артык мавыгу. *Хәзерге яшьләр белми аларны. Машина белән башлары әйләнгән* (Г. Ахунов).

6. Хискә бирелеп, үз-үзеңне оныту. *Мәчеттә мулланың бу догасын ишеткәч, башы әйләнде, дөнья кире киткән, тарих артка кайткан кебек булды, ни эшләргә белмәде* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Иртән ул чишмә янында ир-ат аяк эзләренә юлыкты һәм хәсрәтләнде: кыз баланың башлары әйләнгән, йөрәк җилкенгән чак җиткән икән, аның бу ялгышларын Ходай гына төзәтер инде, һай-лай!* (Н. Гыйматдинова. Китәм, димә...).

7. Исерткеч эчемлектән тирә-якны аңлый алмый башлау. *Китте, Нәҗипнең башы әйләнде, ашказаны сулыгып ризык сорады* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *[Марат] Ну... баш әйләнә... күңел болгана... [Таһиров] Тапкансың авыз итәр әйбер!* (А. Гадел. Сулган чәчәк).

Төрдәше: акылын эчеп бетергәнче һ.б.

8. Гашыйк булу. *Сабый Җиһангирның үз башы әйләнде* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Юка башлы Кәбир кызларның кылануларын кайнар хис чагылышы төсле кабул итте, башлары әйләнде дә үз шәхесенә бу кадәр игътибардан, кайсысына тукталырга белми газап чикте* (К. Кара. Депрессия).

Төрдәше: бер күрүдән егылып төшү; күз-баш әйләнү.

**БАШ ӘЛЛӘ КАЙДА <ЙӨРҮ>.** Кеше сүзен игътибарсыз тыңлау; кеше бер нәрсә турында сөйләгәндә, башка нәрсәне уйлау. *Аның башы әллә кайларда гизеп йөри* (Г. Гобәй). *Гәүдәсе дәрестә утырып, башы әллә кайларда «сәяхәт» иткән укучыны ул кабул итми* («Туган як» газ.).

**БАШ БАЛА.** Гаиләдә беренче бала. *Абый кеше энекәшеннән акыллырактыр, чөнки ул баш бала* (Н. Гыйматдинова. Шырагай). *Уртача гына тормышлы, күп балалы гаиләдә баш бала булып дөньяга килде* (Д. Каюмова. Буранлы юллар).

**БАШ БАРМАК.** 1. Булдыклы, бик яхшы. *Көтүчесе кем бит әле, баш бармак ич!* (Г. Галиев). *Чирекне әйбәт башкарып чыктык, өч дүртле, калганнары баш бармак!* (А. Гыйләҗев).

Төрдәше: бер дигән, менә дигән.

2. Баш кеше. *Онык уң кулын биш бармагын җәеп күтәрде. – Бишәү булачак. Сез – баш бармак* (М. Хуҗин. Кочасы иде дөньяны). *Мин баш бармак буламын. Калган барлык бармакларга әмер биреп торамын* (Ф. Яруллин).

**БАШ БАРМАК КЕБЕК (ШИКЕЛЛЕ; БАРМАКТАЙ).** 1. Яхшы. *Бу кияве турында Миассәмә апа: «Ул минем баш бармак кебек!» – ди* («Ирек мәйданы» газ.). *[Юлдаш] Итекче әйткән: «Иртәгә килеп алырсың, итегең баш бармак кебек булыр», – дигән* (И. Юзеев).

2. Уңган, чибәр. *Егет менә дигән. Баш бармак кебек һәр ягы килгән* (А. Гыйләҗев. Өч тәгәрмәчле арба). *Ә чыпчык дигәнегез – баш бармактай егет, аны теләсә нинди капйотка тиңләү урынсыз* (Т. Әйди. Елан угы).

**БАШ БАРМАК<НЫ> КҮРСӘТҮ (ТЫРПАЙТУ).** «Бик яхшы, булдыклы» кебек мәгънәләрне

белдерү. *Ул баш бармагын тырпайтты: Кем әйтмешли, бер кашык су белән йотарлык!* (Ф. Латыйфи. Ак-карага тимәскә). *Рузил баш бармагын тырпайтты да «Во!» дип куйды* (Р. Бәшәров. Ат йөреше). *Балчыктагы бүлбеләре менә мондый булдылар инде! – дип, кыз баш бармагын күрсәтте* (И. Хуҗин. Кызыл тәнлеләр юлбашчысы).

**БАШ БӘЙЛӘНҮ.** Берәрсе белән үзара якынаю, тыгыз мөнәсәбәткә керү. *«Юк инде, артистка белән башың бәйләнә күрмәсен!* (Ә. Еники. Рәшә). *Аның байлыгы, бәлкем, мәхәббәттер. Их, нигә минем башыма бәйләнде ул кыз!* (Ж. Ильясов. Еланнар әфсенләүче).

**БАШ БӘЙЛӘҮ.** Бәйләнештә булу. *Юк, яратам дип, аңа башны бәйләү шактый рискованный эш булыр иде* (Ә. Еники. Рәшә). *– Менә сиңа аяк астыннан чыккан бәла. Каян шуның белән башын бәйләгән бу кызый?* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**БАШ БӘЯСЕ**. Бик кыйммәт. *И, җаным, киез итек баш бәясе тормас инде* (М. Әмир). *– Юрий кенәз шәхсән үзе юллады, һәр минут – баш бәясе, ашыгырга кушты* (В. Имамов. Утлы дала).

**БАШ БӘЯСЕ ТҮГЕЛ.** «Бик кыйммәт торса да, үләрлек түгел» мәгънәсендә. *Ике пот тары белән бер сарык баш бәясе түгел* (В. Имамов. Тозлы яра). *Эшләр идем әле, баш бәясе түгел, табар идем...* (Ф. Шәфигуллин. Өй салуның ние бар?).

**БАШ БЕЛӘН <УЙЛАУ>** *к.* акыл белән. *Мәгърифәт-табигать кануннарын өйрәнүче кешенең чынбарлыктагы урынын билгеләүче башлангыч чор булып тора: ул саф интеллектуаль, «баш белән уйлау» гыйлеме буларак, әлбәттә, кешенең рухи табигатенә әлләни зур йогынты ясый алмый* (Ш. Монасыйпов. Сәйдәшнең сихри моңы). *Янәсе, Шәмсун баш белән эшләмәгән. Рәфис кенә зирәк акыллы* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

Төрдәше: акыл белән һ.б.

**БАШ БЕЛӘН ҖАВАП БИРҮ (ТОТУ).** Кем өчендер, нәрсә өчендер бөтен җаваплылыкны үз өстеңә алу. *– Аның йөзендәге һәр сызык өчен башыгыз белән җавап тотачаксыз!* (Р. Батулла. Сөембикә). *Өстәл кырыендагы кнопкага басып, бер кешене чакырып кертте: «Менә сезгә тагын бер качкын, – диде. – Әгәр тагын качып китсә, башың белән җавап бирәсең»* (Ә. Галиев. Һәр солдатның үз язмышы).

**БАШ БЕЛӘН КҮКНЕ (КҮК ГӨМБӘЗЕН) ТИШҮ.** Бик нык шатлану. *Башы белән күк гөмбәзен тиште, Ходай хозурына ашты имди...* (Г. Афзал. Усал елмаеп сөйләшү).

**БАШ БЕЛӘН УЙНАУ.** Мавыгу аркасында кешене һәлак итәрлек. *Угланнар ут белән генә түгел, тәхет вә баш белән уйный иделәр, аңлаган кеше генә моның хәл икәнлеген ни аяныч сизенергә мөмкин* (Ф. Яхин. Соңарган дастан).

**БАШ БЕЛӘН ХУШЛАШУ (САУБУЛЛАШУ)** *к.* авыздан җан чыгу. **–** *Кара аны, синең бары тик бер генә мөмкинлегең бар. Әгәр шуны кулдан ычкындырсаң, башың белән хушлашырга әзер бул, – диде катгый гына* (А. Галиева. Киләчәккә карап). *Патша беркөнне үзенең вәзиренә әйтә: – Менә сиңа табышмак, – ди, – кырык көн узганда җавабын тапмасаң, башың белән саубуллашасың* (Әкияттән).

Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

**БАШ БЕЛӘН <ЭШКӘ> ЧУМУ.** Нинди булса да эшчәнлеккә, шөгыльгә тулысынча бирелү. *Мәдинә башы белән эшкә чумды, балалар үстерде* (Г. Исхакова. Кара чемодан). *Наз упкынына башы белән чумды да эреп юкка чыкты* (М. Кәбиров. Бердәнбер һәм кабатланмас).

Төрдәше: авызга җаны килгәнче (чыкканчы) тырышу һ.б.

**БАШ БЕЛӘН ШАЯРУ.** «Йә үләчәксең, йә калачаксың» мәгънәсендә. *Болар баш белән шаяру* (В. Имамов. Карабәк). *Кызыл ракета өчен Җантимер башы белән җавап бирә! Шаярмакчы булды микән? Баш белән шаярмыйлар* (Р. Мөхәммәдиев. Кенәри – читлек кошы).

**БАШ БЕТКЕЧ.** 1. Бик күп. *Усаклыда ун-унбиш кенә өй булса да, магазинында китаплар баш бет-кеч икән, ун меңләп бардыр* (Г. Мөхәммәтшин).

2. Бик буталчык, бик хәтәр. *[Нури] Баш беткеч эш, сөтенә су кушты. Чиләген менә болай итеп алды да...* (Ю. Әминов. Өти Балак).

**БАШ БЕТҮ.** 1. Хур булу, абруй төшү; уңышсызлыкка очрау. *[Хәнифә] Безнең егетләрнең*

*башлары бетте, тагын барып чыкмады дигән сүз* (М. Гыйләҗев. Баскетболчы). – *Безне бергә күрсәләр, башы бетте!* (Ә. Гаффар. Бодай бөртеге һәм тегермән ташы).

2. *к.* авыздан җан чыгу. *Эшләмәсәң, тырышмасаң, бетә башың, / Күз алдымда имән дарга асыласың* (Г. Афзал). *[Сәхилә] Бер таудан төшкәндә, башым бетә, дип, үкереп елый башлаган* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

**БАШ БИРМӘС.** Үзсүзле, кеше сүзенә игътибар итмәүче. *Юкса баш бирмәс егетнең кайсы юлдан китәсе ачык түгел иде* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет). *Ни баш бирмәс Дорды да аны тыңларга мәҗбүр, безнең лейтенант та аңа бервакытта да каты бәрелми* <...> (Ә. Еники. Без дә солдатлар идек).

**БАШ БИРҮ.** 1. Буйсыну, тыңлау. *«Йөз дә кырык ике мең сумга төшкән очкыч-портрет җилгә баш бирәме?»* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Шигырьле тел – фанилыкка бәйсез, / Үлемгә баш бирми андый тел* (Зөлфәт. Тылсым).

Төрдәше: арка бөгү (бөгеп тору) 1 һ.б.

2. Ризалашу, килешү, күнү. *Тик шулай да үтә батыр ирләр килмешәккә баш бирергә теләмәгән* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур). *Хаклы булуына инанган чагында, район башлыкларына да баш бирми: аяк терәп сөйләшә торган иде* (В. Нуруллин. Ике урам арасы).

Төрдәше: баш ию 4; баш тартмау; дүрт кул белән; дүрт куллап; дүрт куллап алу; дүрт куллап бирү; ике куллап; ике куллап бирү; колач җәеп; куш куллап; кырын какмау; син (сез) дигәндә, аяк идәндә; син дигәндә, башым (мин) идәндә; син дигәндә, себерке дә идәндә; син дигәндә, төпсез коега төшәргә дә әзер; сорауны җиргә салмау.

**БАШ БИЮ.** Башны төрле якка боргалап, нәрсәнедер санау яки күзәтү. *Кубар төсле башың биеп йөргәч, / Битең, борының кызып бүртенгәч!* (М. Җәлил. Сыра залында).

**БАШ БӨГҮ.** Буйсыну, җиңелү. *Ник баш бөктең залимнәргә, / Ник тыңладың сүзләрен?* (Г. Тукай). *Шулай көннәр уза безнең, фәләк золымына баш бөгеп, / Каты кайгы вә хәсрәтләр эчендә канлы яшь түгеп* (Г. Шәрифи. Сандугач зары).

Төрдәше: арка бөгү (бөгеп тору) 1 һ.б.

**БАШ БУЛУ**. 1. Хуҗа, җитәкче булу, кулда тота алу. *Мохтаров үзенә-үзе бөтенләй баш булып калды* (Ф. Хөсни). *Мин бит яугир, соңра алай башы буласы...* (Г. Каюмов. Ыру).

2. Басып алу; үзенеке итү. – *Нефтьчеләр акчасына баш булмакчы булдыңмы?* (Г. Ахунов. Чикләвек төше).

**БАШ БУРЫЧТАН ЧЫКМАУ.** Бурычлары күп булу. *Җиләк-җимеш, тәмәке, инҗир белән тире сатып кына түләгәч, егерме беренче гасырда да Төркиянең башы бурычтан чыкмаячак дип хафалана әлеге язучы* (Т. Әйди. Күтәһия. Әфәнде күпере. Әнкара юлы). *Ул гомер буе акчага туймады, гомер буе башы бурычтан чыкмады* (Ш. Хөсәенов. Газап диңгезен эчеп...).

**БАШ БУТАЛУ** *к.* аптыраган үрдәк хәленә төшү. *Туктале, нишләптер башы буталды әле аның* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур). *Баш буталып, йөзекне алырга оныткансын* (Н. Гыйматдинова. Кыргый).

Төрдәше: аптыраган үрдәк хәленә төшү.

**БАШ<НЫ> БУТАУ** *к.* баш әйләндерү 2. *[Платон] Әйтә килдем мин сиңа, Сократ күрше!.. Бутама адәмнәрнең башларын, дидем* (М. Гыйләҗев. Баскетболчы). *Менә шул берничә [кыз] булу башны бутады инде* (М. Маликова. Арыш тәме).

Төрдәше: бай әйләндерү 2 һ.б.

**БАШ ВАТАРЛЫК.** Авыр хәл ителә торган берәр мәсьәлә һ.б. *Энәсеннән җебенә кадәр дигән шикелле, һәммәсен дә кат-кат санадылар, «монысы белән нишләрсез икән?» дип баш ватарлык бернәрсә дә килеп чыкмады* (М. Миншин. Кызыл диплом).

Төрдәше: баш<ны> вату.

**БАШ ВАТМЫЙЧА.** Күп уйлап тормыйча. *Бу мәкаләне ул бер утыруда язды, һич тә баш ватмыйча* (Г. Бәширов. Җидегән чишмә). *Аннан бездә, әсәрләргә бәя биргәндә, күп вакытта берьяклылык, ашык-пошык, әллә ни баш ватмыйча гына, мөһер басып раслап куюлар күзгә чалына* (Н. Арсланов. Ачыктан-ачык әйтсәк).

Төрдәше: исәпләп тормыйча.

**БАШ<НЫ> ВАТУ.** 1. Бик тырышып, кат-кат уйлану; нинди булса авыр нәрсәне хәл итәргә тырышу. – *Мин көн-төн баш ватам, уфтанам-ут йотам, ә кешеләр йөземнән эчемдәгеләрне укый*

*башлаганнар инде* (Ә. Еники. Йөрәк сере). *Ни уйларга да белмим, баш ватам* (Ф. Садриев. Ак эт бәласе – кара эткә).

Төрдәше: акыл аша уздыру һ.б.

2. Борчылу. *Мин бу эштә яхшылык кылдыммы, начарлык кылдыммы мәсьәләсе башымны вата башлады* (Г. Исхакый). *Ул үзенең бу мәҗлестә артык кеше булуын сизә, энәләр өстендә утыргандай, үтә киеренкелек белән: «Нишләргә соң, нишләргә?» – дип баш вата иде* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

**БАШ ВАТЫП, КҮЗ ЧЫГАРЫП.** 1. Каршылыктан курыкмыйча, тырышлык белән, үз-үзен аямыйча**.** *Алай бик уйлап тормадык инде, баш ватып, күз чыгарып, тиз генә эшләп ташладык* (Сөйләм).

2. Эшнең рәтен-юнен белмичә, кыйналып, кычкырышып. *Болай караганда, бернәрсәсе дә юк кебек иде, әмма баш ватып, күз чыгарып, берничә сәгать маташырга туры килде* (Сөйләм).

**БАШ ВАТЫП, КҮЗ ЧЫГАРЫП ТОРМЫЙЧА** *к.* алны-артны карамыйча. *Баш ватып, күз чыгарып тормады, аннан соң күз күрер әле дип, имзасын сырлады* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз <ни/нәрсә> әйткәнне колак ишетмәү; алны-артны карамыйча һ.б.

**БАШ ГАРЕШКӘ ЧЫГУ** *дини*. Күкләргә күтәрелү; горурлык хисе кичерү, бик нык шатлану. (гареш – күкнең түре, Аллаһның тәхете урнашкан урын). *Көтмәгәндә мондый хәбәрне ишетүдән башы гарешкә чыккандай булды* (Сөйләм).

**БАШ ГҮРГӘ КЕРҮ** *к.* авыздан җан чыгу. *Мин сине бары ташларым, / Башларым гүргә кергәч* (Хал. җырыннан). *Ишеп-ишеп карлар яуды, табигать елый бугай. / Башларыбыз гүргә керде, язмасын сезгә шулай* (Мөнәҗәттән).

Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

**БАШ ҖИБӘРҮ.** Төрле үсентеләрнең тишелеп чыгып үсә башлавы. *Анда үсә торган, әлегә баш кына җибәрергә өлгергән бодай үсентеләре арасында лачма су икән* (Ф. Яхин. Балачак тәрәзәләре). *Әйтсәм, ышанмассыз: бер төптән берьюлы өч кәүсә баш җибәргән булып чыкты* (Г. Гыйльманов. Китек ай).

**БАШ ҖИҢЕЛӘЮ.** 1. Исерткеч эчемлек эчү, исерү. *Эчүнең исәбе-саны булмады, кымыз күбрәк китерелгән саен, башлар җиңеләя, күзләрдә ут уйный, телләр чәчәнләшә бара иде* (Г. Ибраһимов).

Төрдәше: әбдән мае булу.

2. Яхшы пешерелгән чәй эчү. – *Төш инде, балам, тамагыңа берәр нәрсә кап. Чәй-мазар эчсәң, башың җиңеләеп китәр...* («Казан утлары» ж.).

**БАШ ҖИРГӘ ТӨШҮ** *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. *Бераздан күзләре дымлана башлады, башы, авыраеп, әкрен-әкрен җиргә таба төште* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**БАШ ҖИТМӘСЛЕК** *к.* акыл җитмәслек. *Юлыбызда чүлләр, диңгезләр: / Баш җитмәслек, танып белмәслек эзләр* (Р. Гаташ. Олуг юлда). *Баш җитмәслек эш: ничек килгәнмен мин монда, очыпмы?* (К. Кара. Зур акчалар).

Төрдәше: акыл җитмәслек һ.б.

**БАШ ҖИТМӘҮ.** 1. Аңлый алмау, бөтенләй төшенә алмау. *Монда көнгә йөзләп мичкә бушый, / Башым җитми минем шунсына* (М. Җәлил. Сыра залында). *Аларына синең баш җитмәс. Бригадирга күрсәтерсең* (Ф. Шәфигуллин. Сафура, Бәкер һәм трактор).

2. Уйлап җиткермәү. *Тиз генә хәйлә табып ычкынасы иде дә бит, Зәйтүнәнең анысына башы җитмәде* (А. Гыйләҗев. Урамнар артында яшел болын). – *Их, авызын чеметим, мондый ваклыкларга тикле уйлап бетерелмәгән шул, аһ, баш җитмәгән!* (В. Имамов. Карабәк).

**БАШ ИДЕРҮ** *к.* авызлык кидерү. *Төртеп-төртеп җибәрә, җиргә егып, аны үз алдында тезләндерергә, баш идерергә тели, рәнҗетә, мыскыллый...* (Г. Гыйльманов. Язмышның туган көне).

Төрдәше: авызлык кидерү һ.б.

**БАШ ИЕП БАРУ (КИЛҮ).** 1. «Буйсынырга кирәк булыр» фикере белән бару. – *Хан сараена башың иеп барасыңдыр инде?* (В. Имамов. Утлы дала). – *Дошман каршына баш иеп бару ул дәүләтне югалту һәм мәңгелек коллыкка төшү булыр иде!* (Ф. Бәйрәмова. Күчем хан).

2. Гаепне тану. *Бу аңа баш иеп бару кебегрәк килеп чыгачак, димәк, үзеңне гаепле итеп тану булачак* (Ф. Садриев. Шаһзаманов эше). *Күзне йомып, йөз оятын садагына яшереп, Сафура бикә каршына баш иеп барыргамы, әллә*

*барысына да кул селтәп, җизнәсе угорлар илтотары Куришка юнәлергәме?* (М. Хәбибуллин. Атилла).

**БАШ ИЕП ЯШӘҮ.** Буйсынган хәлдә булу. *Һәм данга менгән Андрей каршында баш иеп яшәүне алар үзләренә кулайрак санады* (В. Имамов. Утлы дала). *Ничек кенә булмасын, ул элеккечә баш иеп яшәмәячәк!* (Д. Булатова. Соң түгел!).

**БАШ ИЗӘҮ** *к.* баш айкау. *– Тик сез саграк, саграк авыз ачыгыз, – дип, Госман хуҗа ишек ягына баш изәде* (Т. Әйди. Елан уты). *Бүлмә җиһазларына баш изәп алды да тотынды, мин сиңа әйтим, шатлана-куана сөйләргә* (Р. Кәрами. Дустым өйләнә).

Төрдәше: баш айкау һ.б.

**БАШ ИКЕ БУЛСА.** Үлем куркынычы белән янау яки шуның белән куркыту. *Башлары ике булса, килеп карасыннар* (М. Җәлил. Алтынчәч). *[Хәлил] Исмәгыйль! Бел шуны, башың ике булса, кер безнең арага* (М. Фәйзи. Галиябану).

Төрдәше: баш ике түгел.

**БАШ ИКЕ ТҮГЕЛ.** Үлем куркынычы, куркыныч барлыгын кисәтү. *[Исмәгыйль] Хәлилнең дә башы ике түгел, белә торып минем арага керергә* (М. Фәйзи. Галиябану). *Төнлә белән япа-ялгыз иске әвеннәр, мунчалар тирәсендә айкалырга минем башым ике түгел!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: баш ике булса.

**БАШ «ИКЕГӘ ЯРЫЛУ».** Артык күп исерткеч эчемлек эчкәннән соң, иртәгесен бик нык баш авырту, махмырга дучар булу. *Иртәгесен боларның башлары «икегә ярылган» иде* (Ф. Яхин. Ак ай буендагы кич).

**БАШ ИМӘС.** Буйсынмас, күнми торган, дуамал. *Бер карасаң, изге кебек, / Кайгы белмәс, башын имәс, / Көлеп торган көзге кебек* (Г. Афзал. Хуҗа Насретдин). *Сукыр кенәзгә бер генә дәүләт яраны да баш имәс иде* (М. Хәбибуллин. Татарлар башкаласы – нурлы Казан).

**БАШ ИМӘҮ** 1. Масаю, санамау. *Әмма Туфан дигән шагыйрьнең үзенчәлекле җанын, моң-сагышка, сөю-мәхәббәткә тулы күңелен бала-чага акылы белән дә тоймый калу, алай гынамы соң, – аңа сокланмау, алдында баш имәү мөмкин түгел иде* (Н. Гамбәр. Яшәү тамыры). *Гомер иткән, тәҗрибә җыйган өлкәннәргә баш имәү – минминлек чире ул* (Д. Каюмова. Буранлы юллар).

2. *к.* баш бирү 1, 2 (тискәре мәгънәдә). *Шәхес культы хакимиятенә, тоталитар көчләргә баш имәү аның бөтен иҗаты буйлап сузыла* (Н. Хисамов. Татар шагыйрьләре). *Беренчедән, Совет власте еллары, безнең бөтен гамәлебез, көнкүрешебез, строебыз аңарда какшатып булмастай ихтыяр көче – кыенлыклар алдында баш имәү көче тәрбияләгән* (Ф. Хөсни. Заманалар һәм язмышлар).

Төрдәше: баш бирү 1, 2 (тискәре мәгънәдә).

**БАШ ИСӘБЕ.** Сыйфат ягына дикъкать итмичә, сан ягын гына карау. *Ватан өчен бар да баш исәбе, / Өмет җыеп туймас җан кисәге!* (Ф. Гыйззәтуллина). *Шуңа күрә, сөте булмаса да, баш исәбе бар* (М. Зарипов. Сыеры барның сые бар).

**БАШ ИСӘН БУЛСА.** «Яшәп булса, саулыксәламәтлек булса» мәгънәсендә. *Ашыйсы ризыгы бетмәс, башы исән булса, адәм баласы бер кайта икән...* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *Һәм ул, барысын да ташлап, дала буйлап көньякка качты, баш исән булса, калганы табылыр, дип уйлады* (Ф. Бәйрәмова. Күчем хан).

**БАШ ИСӘН ЧАКТА.** Яхшы чакта, сау-сәламәт булганда. *– Син, Юныс әкә, – диде, – өлкән булсаң, өлкән була бел, булмасаң, башың исән чакта минем яннан чыгып китә бир! – диде* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *Башыбыз исән чакта без бу егетне берлеккә алып котылыйк, ачуын китермик!* (Р. Кәрами. Башыбыз исән чакта).

Төрдәше: баш исәндә.

**БАШ ИСӘНДӘ** *к.* баш исән чакта. *Яу якадан алганда, / Бер чебендәй җанга көч; / Баш исәндә җан исән, / Ханның башы калсын, – дип, <...> / Ас күчәгә юл алды* («Идегәй» дастаны).

Төрдәше: баш исән чакта.

**БАШ ИСӘНДӘ ҖАН ИСӘН.** Бәла-казалы җирдән ераграк торуны тиеш тапкан очракларда әйтелә. *Баш исәндә җан исән, башка балаларның шарлары агач, ә моның, Әйгәлинең, шары алтын шар икән* (Әкияттән).

**БАШ ИЮ.** 1. Буйсыну; җиңелү. *Мин соң бөркет түгел идеммени? Баш ияргә шуннан башкага!* (М. Җәлил. Кичер, илем!). *Язмышның шундый ерткычлыгына тешеңне кысып баш иярга*

*мәҗбүр булудан да газаплырак тагын ни булырга мөмкин?* (Г. Бәширов. Сиваш).
Төрдәше: арка бөгү (бөгеп тору) 1 һ.б.

2. *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. *Болай ярамаганын үзе дә бик яхшы белә иде. Шулай да, үзе дә сизмәстән, баш ияргә теләмәде* (А. Алиш. Якты күл буе). *Рәфис аптыраган кыяфәттә башын иеп идән буйлап йөрегән җиреннән кинәт кенә аңа борылып карады* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).
Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

3. Хөрмәт күрсәтү. *Әгәр ул ханым белән яңадан очрашырга туры килсә, <...> / Иптәшләрнең якты истәлекләре алдында баш идек* (Ш. Мөдәррис). *Кайчан да бер кайтасылар булыр / Соңгы тапкыр башны ияргә; / Балаң булып, бер шагыйрең булып: / – Хуш, бәхил бул, тавым! – диярга* (Н. Әхмәдиев. Чатыр тавы).

4. Ризалашу; сәламләү ишарәсе ясау. *Аристократларча аяк кагып кына баш ияргә, нәзакәтле ханымнарның кулын үбәргә, патефон музыкасы астында баш әйләнгәнче сихри вальста бөтерелергә...* (А. Тимергалин. Игезәкләр). *Чал Вакытның, дөнья каршысында / Тыптын калып, башын игән мәле* (Х. Әюп).
Төрдәше: баш бирү 2 һ.б.

5. Үтенү, мескенләнү. *[Шаһтимер] Йөрәгемнең тавышын ишеттерергә мәл тапмаган моңлы егет бер көтүче алдында баш иде* (М. Фәйзи. Ак калфак). *Иң тәәссефлесе: милләтнең баш иеп кяфергә кол булуыдыр* (А. Тимергалин. Миллият сүзлеге).

**БАШ ИЮЧЕ.** 1. Хөрмәткә лаек булган кешеләр. – *Туктамышлар, Идегәйләр, Аксак Тимерләр белән мавыгасың икән, бабакай, – диде, – ә минем баш иючеләрем бүтән* (М. Әмирханов. Зиннәтулла хәзрәт).

2. Буйсынучы, күнүче. *Мәфтун – «кол, баш июче» мәгънәсендә* (Г. Гобәйдуллин. Скрипкачы Хөсәен). *Ләкин ышаныгыз, яшьтәшләрем! – Марс – сугыш алласына баш июче булмадым мин* (Р. Гаташ. Игенчеләр иленә хат).

**БАШ ЙӨРМӘҮ.** Дөрес фикер йөртә алмау, уйлый алмау. *[Сиражетдин] И, хатын, хатын, синең бер дә башың йөрми икән* (Г. Камал. Банкрот).
Төрдәше: акыл сүнү һ.б.

**БАШ<ТА> ЙӨРТҮ (ЙӨРТЕП КАРАУ)** 1. *к.* акыл аша уздыру. *Шакирҗан, яткан җиреннән торып утырып, кызыксыну белән сораштыра бирә: – Фәгыйлә, карале, боларны аңларга, болай баш йөртә белергә сине кем өйрәтте?* (С. Сабиров. Алтын балдаклы абыстай). *Ә улы Миргалим Сәлим абзый уйлаганның нәкъ киресен башында йөртте: атасы белән киңәш-табыш кылу кирәк иде аңа* (Ф. Яхин. Без дә монда бар идек).
Төрдәше: акыл аша уздыру һ.б.

2. Баш селкү. *Кыз «юк» дигән мәгънәдә башын йөртеп алды* (М. Яһудин. Мин).
Төрдәше: баш айкау һ.б.

**БАШ<Ы> ЙӨРҮ** *к.* авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә) алу. – *Һи, хатын, хатын, синең бер дә башың йөрми икән* (Г. Камал).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә) алу һ.б.

**БАШ КАБАРУ** *күч.* Арудан уйлый алмас дәрәҗәгә җитү. *Егетнең бу сораулардан башы кабарды, акылы томаланды* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Альбинаның бу уйларыннан һәм онытылып укуыннан башы кабарган төсле иде* (Ф. Яхин. Август ае).
Төрдәше: баш түбәтәйгә сыймау; баш шешү 2.

**БАШ КАГУ.** 1. Нәрсәне булса да эшләргә ым бирү. *Әти, чәчүеннән туктап, аларга кызганган сыман карап торды да миңа баш какты: Җыеп ал!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Ашыгып читкә борылды Сабит, нидер исенә төшкәндәй, маңгаена учы белән сукты, башын кагып, кунакларга үз артыннан барырга боерды* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

2. Ризалыкны белдереп, хуплап баш селкү. *Яулыгын ике кулына тоткан килеш, иптәшләренең мактавына бары баш кагып кына тора* (Ә. Еники. Шаяру). *Барысы да, ризалык белдереп, баш какты* (М. Әмирханов. Зиннәтулла хәзрәт).

3. Сәлам бирү. *Әйткән сәламемә баш кактылар да идарәгә кереп киттеләр* (А. Гыйләҗев. Язгы кәрваннар). *Минем сәламемә картлар да башларын кагып исәнләштеләр* (А. Нәҗми. Казан).

4. Нәрсә беләндер риза булмау. – *Ә без әле бүген дә кешеләрне яшәртү проблемасын хәл итә алганыбыз юк, – дип, профессор баш кагып алды* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Изаел, кыз*

*белән ризалашмыйча, башын кага* (Р. Гаязетдин. Язмыш сәфәре).

Төрдәше: баш тарту 2.

**БАШ КАДАЛА ЙӨРҮ.** Баштүбән йөрү. *Бер аякта сикерәбез, баш кадала йөрибез* (Т. Миңнуллин).

**БАШ КАДӘР АЛТЫН БИРСӘЛӘР (БИРӘМ ДИСӘЛӘР) ДӘ.** Нинди генә байлык тәкъдим итсәләр дә, әйткән сүзеннән ваз кичмәүгә, сүзендә нык торуга ишарә. *Ат башы кадәр алтын бирәм дисәләр дә, бүтән аягымны да атламыйм* («Мәйдан» ж.).

**БАШ КАЕРУ.** Читләшеп китү, бизү. *[Мәйсәрә] Әллә син дә, әллә син дә / Баш каердыңмы миннән?* (К. Тинчурин. Зәңгәр шәл). – *Тик торганнан адәм башын каера, Газраил!* (Р. Камал. Озынтал).

Төрдәше: аркасын әйләнү һ.б.

**БАШ КАЗЫГЫНА ӘЙЛӘНҮ.** Күп мәртәбә кабатланган сүзнең башка ныклап кереп урнашуына ишарә. *Ә соңыннан Рәмзия ханым улы алдында ничә тапкыр «әтиең кешегә дә санамый» дип кабатлады. Яхшы сүз дә кайчан баш казыгына әйләнә икән!* (Ә. Еники. Тынычлану).

**БАШ КАЙГЫСЫ.** Бик җитди уйлап, акыл белән эш итү кирәклеге хакында. – *Хәзер синдә кыз кайгысы түгел, баш кайгысы булырга тиешле!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). – *Әнисе, ул кадәрле бетеренмә әле, бу кайгы баш кайгысы түгел бит!* (Р. Хәбибуллина. Мулла килене).

**БАШ КАЙНАУ** *к.* акыл аша уздыру. *Кайгырып ике ил өчен, башы кайный татарның; / түбәтәен дә каралткан кайгылы башы аның!* (Р. Мингалим. Кем кулларына калдырыйм?). *Уз кичерешләре белән башы кайнаган Вәли дә сүз башламады* (С. Рәфыйков. Авыл иртәсе).

Төрдәше: акыл аша уздыру һ.б.

**БАШ КАЛКЫТМЫЙ<ЧА> <ЭШЛӘҮ>.** Бик тырышып, һич туктамастан. *Йосыф белән Мәрьям дә, бил турайтып ял итәсе урында, үзләрен генә түгел, туган-үскән җирләрен мәңгегә ташлап киткән балаларын да ризыкландырырга мәҗбүр ителеп, ызан белән түтәлдән баш калкытмыйча интегәләр иде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Баш калкытмыйча шактый озак эшләде Җәбир* (Н. Фәттах. Аклан).

Төрдәше: баш күтәрми<чә>.

**БАШ КАЛКЫТУ.** 1. Мөстәкыйль тормышка аяк басу. *Еллар үтә тора, Көнбатыш Германия, хәрабәләрдән башын калкытып, аякка баса, ә завод-фабрикалары нигезләренә кадәр кубарылып, Көнчыгыш тарафка алып кителгән Германия Демократик Республикасы тизләнгән килеш кала* (А. Тимергалин. Игезәкләр). *Атналар, айлар узар, ә аннары безнең илдән күрмеш, бәгъзе халыклар да буржуйлар алдында тез чүгәргә күнеккән башларын калкытырлар* (В. Имамов. Тозлы яра).

2. Үсеп китү. *Сәер халәтен әле үзе дә аңлап бетермәгән Гөлйөземнең китәсе килми, шул ук вакытта ниндидер икеләнү, егетнең үзенә якынаюыннан куркуга охшаш бер хис баш калкыта иде* (Ф. Латыйфи. Хыянәт). *Күңелендә аның, ахрысы, кызгану тойгысы баш калкытты* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).

3. Буйсынмау, көрәшкә күтәрелү. *Инде үлеп беткән өмет әллә кайдан, аның йөрәк төбеннән тагын баш калкытты...* (М. Әмир). *Нигә аеңнан баш калкытасың әле? Тыныңны кысып кына ят* (Н. Гыйматдинова. Кыргый).

Төрдәше: баш күтәрү.

4. Үзен белдерү, уртага чыгу, игълан итү. *Кичә генә Бирдебәк кул астында әмир булып йөргән Хаҗи-Чиркәс Хаҗитархан каласын учына сосып алды һәм хаким кыяфәтендә баш калкытты* (В. Имамов. Карабәк).

5. Тишелеп чыгу, борын төртү. *Җир тын алсын, кардан арынсын, / Баш калкытсын чирәм кырларда* (М. Җәлил. Яз өмәсе).

Төрдәше: баш күрсәтү; баш күтәрү 7; баш төртү 3.

**БАШ КАЛКЫТЫРГА (КҮТӘРЕРГӘ) <ДА> ИРЕК БИРМӘҮ.** Гел боерык биреп кенә тору, зиһен җыярга ирек бирмәү; машина өлешенә әйләндерү. *Әмма шул ук Фәридун әйткәнчә, «җәмгыять җинаятьчеләрдән түгел, гаделләрдән арынырга, намуслылардан котылырга теләгән» илдә игелекле кешегә баш калкытырга ирек бирмиләр* (А. Гыйләҗев. Истәлекләр). *«Анда инде ул немечләргә баш калкытырга ирек бирмәс, – дип, өй саен кереп, Заһирының хатын укып йөрде* (Ф. Төхбәтуллин. Өй артында шомыртым бар).

**БАШ КАҢГЫРУ.** Ми түнү, уй-фикер буталу. *Яу чапканда ни калыр? / Ялгыз башы каңгырып, / Куйдай булып маңгырап, / Чүл-далада тинтерәп, / Дуадактай хан калыр...* (Ф. Бәйрәмова.

Күчем хан). *Яман хатын үлсә – түшәк яңарыр, яхшы хатын үлсә – баш каңгырыр* (Мәкаль).

**БАШ КАПКАЧЫ АСТЫ.** «Ми, акыл» мәгънәсендә. *Большевиклар аны «бөлдергәннәр», гаиләкуышында һәм калын баш капкачы астында ул алардан уч алу теләге асрап йөри* (Г. Ахунов. Ардуан батыр).

**БАШ КАТУ.** 1. *к.* аптыраган үрдәк хәленә төшү. *[Ибраһим] Атна буе уйлый-уйлый башым катты* (Г. Исхакый. Алдым-бирдем). *Буш кул йөзне ертыр, берәр бүләк эзлим дә ни алырга белмим. Башым катты* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: аптыраган үрдәк хәленә төшү һ.б.

2. Туеп бетү. *Йә Алла, башым катты инде* (Г. Камал. Бүләк өчен). *Ихтимал, бу миңа көндәлек эшем җинаятьче элементлар белән очрашудан торганга, аларның эшләрен тикшереп йөреп башым катканга шулай тоелгандыр* (Г. Кутуй. Рөстәм мажаралары).

Төрдәше: гарык булу; җан кыйнау; җелекне киптерү; йөрәккә төшү; кан корыту; колакка-бавырга кереп утыру; тәкатьне алу; теңкәгә тию; теңкәне корыту; тешләрне камаштыру; үзәккә үтү; яра өстенә тоз сибү; ярага тоз ишү; ярага тоз салу.

3. Ару. – *Көн буе ревизия белән азапланып, башларым катып беткән булгандыр инде, Сафиулланы кереп алырга бөтенләй уема килмәгән шул* (В. Нуруллин. Ул яшәргә тиеш иде). *Бүгенге табышын барлый-барлый, Йосыфның башы катты* (Г. Гыйльманов. Фәрештә).

Төрдәше: аяк атлар хәл (дәрман; көч; рәт; чама) булмау (калмау) һ.б.

4. Борчылу. *Бу хурлыгыннан ни эшләргә белми әрнеп, башы катып, өенә кайтты* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). *Акмас инде хәзер яшьләрем, / Каткан инде минем башларым* (М. Җәлил).

Төрдәше: аһ ору һ.б.

**БАШ КАТЫРУ**. 1. Юк-бар белән аптырату. *Вактөяк белән баш катырмагыз, тапкансыз икән – бәхетегез, – диделәр* (А. Тимергалин. Таш алиһә). *Камыр батыр әйтә, ди, байга: – Башымны катырма син минем, – ди. – Алыштанмы, салыштанмы? – ди* («Камыр батыр» әкияте).

2. Туйдырып бетерү. *Кичә тентү вакытында әллә нинди гайбәтләр белән баш катырган иде!* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Һәр көн шулай башны катырып бетерәләр* (Г. Камал. Беренче театр).

3. Арыту. *Тын гына барган Фатыйма толыбын ачты да: – Җәле кара! Баланың башын катырма әле! – дип үрелде дә малайны үз алдына алды* (Ә. Гаффар. Дәрья башы). *Кичә көне буена башны катырдыгыз Хикмәт тә, Хикмәт дип* (А. Гадел. Хикмәтле кәләпүш).

4. Борчу. *Шуңа күрә ул суммасыз баю юлларына керүне уйламый да һәм андый юк эшләр белән башын да катырмый иде* (К. Тинчурин. Йөз мең). – *Мин бәхетле була алмыйм, аңлыйсыңмы? Синең дә башыңны катырып йөрисем килми* (Х. Ширмән. Ерактагы йолдызым).

**БАШ КАШУ (КАШЫП ТОРУ)**. 1. *к.* аптырап калу. – *Шуннан соң гына: «Аһ, белми йөргәнмен! Алай ярамый икән бит!» – дип, баш кашырга тотыначаклар* (Г. Бәширов. Җидегән чишмә). *Тик соңыннан, капчыктан кирпеч килеп чыккач кына, башыңны кашып торасың...* (Ш. Маннур. Яңа җыр килде).

Төрдәше: аптыраган үрдәк хәленә төшү һ.б.

2. Суккалау, кыйнау. *«И кизү! бар китер, ул кайсы таз? Мин башын кашыймчы ул тазның бераз»* (Г. Тукай. Таз). – *Их син, Касыйм, бирсәң ашыйм, бирмәсәң, башыңны кашыйм,* – *дип үчекләште ул* (З. Мурсиев. Солтанъяр).

Төрдәше: акыл бирү 3 һ.б.

**БАШ КАШЫРГА <ДА> ВАКЫТ БУЛМАУ (ЮК).** Эш бик күп булу, башкасына вакыт булмау. *Хоккей уйнаулар. Дәресләр әзерләшү. Баш кашырга вакыт юк иде* (Ә. Гали. Кизләү).

**БАШ КИЛҮ.** Беренче булу, ярышта җиңүче булу. *Йөреп-йөреп баш килсәң, тагын бер хәл. Ә иң актыктан сөйрәлергә калсаң, егыл да үл инде* (Ф. Хөсни. Йөзек кашы). – *Ат чабышлары димәктән, кемнәр-кемнәр аты баш килде соң?* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы).

**БАШ КИТӘРЛЕК.** Куркыныч эш яки сүз. *Ни эшләгәнен үзе дә бик нык исәп биреп җитмәстән, Җиһаншаның җиңенә барып тотынды: – Ни сөйлисең, бабай?! Баш китәрлек сүз әйттең бит! – диде дә киселде* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар). *Купе-камерага бикләнгән җинаятьчеләрдән теләсә нинди «баш китәрлек» эшләр көтәргә мөмкин* (И. Салахов. Ана тавышы).

**БАШ КИТКӘНДӘ КАШ КАЙГЫСЫ.** Зур бәлагә тап булганда, вак-төяк белән маташу. – *Бызылдап йөрмә әле монда, баш киткәндә каш кайгысы юк* (Сөйләм).

**БАШ КИТҮ.** 1. *к.* авыздан җан чыгу. *Ни зыян бар, изге юлда / Мәңгелеккә китсә баш* (М. Гафури). *Янәсе, яхшы карап бирегез, ул-бу булса, башыгыз китәр* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).
Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

2. *күч.* Бәлага тару. *Белмим, белмим, бу мәхәббәт белән Яки тәүфыйклы... яки баш китәр* (С. Хәким. Бакчачылар). *Куркыныч юл, уртасы юк: / Йә китә баш, / Яки көтә әкият кызы* (Р. Гаташ. Тик бер адым...).

3. Зиһене эшләми торган хәлгә килү, тиләләнү. *Егеткә куркынып карады. Башы киткән моның, мөгаен!* (Л. Сабирова. Бәхете булсын, димәгән...).
Төрдәше: баш миңгерәүләнү; баш тубал булу (тубалга әйләнү); баш туктау; баш тулу; баш түнү; баш чүлмәгенең дүрт ягы да тишек булу; башка ат (тай) тибү; башка бозау тибү; башка ишәк тибү; башны томан каплау; зиһен тар<к>алу (таралып китү; чуалу) 1; маңгаена ишәк (ат; тай) типкән; маңгайга тай тибү; һуш таралу (китү).

**БАШ КУШУ.** Берлек төзү, уртакка керү. *Күршеләребез белән бергә бер гаилә кебек торабыз, йортны да алар белән дүрт хуҗа баш кушып салдык* (Т. Әйди. Кечкенә дә, төш кенә). *Әгәр дә төшеңдә бер колны азат итсәң, өнеңдә хатының үзеңә хыянәт итәр, бүтән бер кеше белән башын кушар, диелә шушы ук китапта* (Ф. Яхин. Татар төшләрне юрау китабы).

**БАШ<НЫ> КУЮ.** 1. Ятып ял итү. *Көн кызуында атларга ял бирү өчен, бер урман ышыгында туктап, яшел чирәмдә генә үзебез дә ашапэчеп, әзрәк кенә баш та куеп алдык* (Ә. Еники. Гөләндәм туташ хатирәсе). *[Кыз] Әйт: Кая соң баш куйыйм?* (Ф. Бурнаш. Чәчәктән һәйкәл).
2. Һәлак булу. *Хак эш өчен башын куйды ул* (Ш. Рәкыйпов). *Кирәге юк килер буыннарга / Мәйданнарда егылып баш кую* (Н. Арсланов. Күли-Чурлар кебек).

3. *махс.* Апара ясау, сыек камыр ясау. *Камырны татлы ашлар өчен изгәндә, баш куеп тормыйлар* («Сөембикә» ж.).
Төрдәше: башны салу.

4. Әсәргә яки мәкаләгә исем кую. *«Әсәргә баш кую җиңелме?» дип атала ул* (Р. Рахман. Һәр сыйныфта – сочинение).

**БАШ КҮККӘ (ТҮБӘГӘ; ТҮШӘМГӘ) ТИЮ (КҮТӘРЕЛҮ, БӘРЕЛҮ; ТИЯ ЯЗУ)** *к.* авыз еру 4. *Шатлыктан әнкәйнең башы күккә тиде, ничек итеп рәхмәт әйтергә белми, үзенең чаршавы артыннан, ояла-ояла, әллә ниләр сөйләп бетерде <...>* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр). *Көтелмәгән очрашудан, шатлыктан Салихның башы түшәмгә тиде!* (Р. Низами. Сәйдәшнең соңгы елы).
Төрдәше: авыз еру 4 һ.б.

**БАШ КҮККӘ (ТҮБӘГӘ) ТИЯРДӘЙ БУЛУ** *к.* авыз еру 4. *Хәлимнең капчыгына ярты бөтен икмәк тыкты. Малайның башы күккә тиярдәй булды* (И. Гази). *Берәү мондый уңыштан башы күккә тиярдәй булып шатланыр, урам иңләп, җырлап кайтыр иде* (Р. Кәрами. Төче миләш).
Төрдәше: авыз еру 4 һ.б

**БАШ КҮРСӘТҮ** *к.* баш калкыту 5. *Бераздан аны утый башлый, бераз баш күрсәтү белән, үрдәк-каз тимәсен дип, кечкенә малай төсле итеп куркылыклар куя* (Г. Ибраһимов). *Әле баш күрсәтергә өлгермәгәннәр, шулай да сабаклары ризык булса кирәк* (Ф. Хөсни. Мәшәкатьле озын сәфәр).
Төрдәше: баш калкыту 5 һ.б.

**БАШ КҮТӘРЕП, ТАМАК КЫРЫП, МЫЕК БОРЫП <ЙӨРҮ>.** Дәрәҗәсеннән яки байлыгыннан мактанып, тәкәбберләнеп йөрүчедән көлеп әйтелә. *Яңа килүчеләр арасында баш күтәреп, тамак кырып, мыек борып йөрүче бер ыспай гына ир кеше дә бар иде* (Сөйләм).
Төрдәше: алып узу һ.б.

**БАШ КҮТӘРЕП ЧАБУ** (ат турында). Аеруча тиз һәм гайрәтле чабу. *Борылыштан башын күтәреп чапкан бер җирән ат та күренде* (Сөйләм).

**БАШ КҮТӘРМИ<ЧӘ> (КҮТӘРМӘСТӘН)** *к.* баш калкытмыйча. *Мансур, башка хирурглар кебек үк, башын күтәрмичә эшләде* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Ир-ат баш та күтәрмичә печән чапты; әби-карчык һәм яшүсмерләр, куллары-*

*на тырмалар тотып, чабылган үләнне таратып-әйләндереп йөрде* (М. Галәү. Мөһаҗирләр).
Төрдәше: баш калкытмыйча.

**БАШ КҮТӘРҮ.** 1. Бушану, котылу. *Зиннәт бу кайгыдан башын күтәрергә дә өлгермәде, Советлар Союзына каршы фашистлар сугыш башладылар* (Г. Бәширов).

2. Көрәшкә тотыну, фетнә кубару. *Дошманнарның баш күтәрүе аңа ачык иде* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *Моннан күп еллар элек алпавытларның коточкыч изүенә һәм тормышның чиксез авырлыгына түзә алмыйча баш күтәргән крепостной крестьяннарның юлбашчысы Пугачев күпмедер вакыт Бөгелмә тавында лагерь корып торган* (Г. Әпсәләмов. Газинур).
Төрдәше: восстание күтәрү.

3. Сәламәтләнү, авырудан соң йөри башлау. *Баягы ябык, хәлсез аска караган егет башын күтәрде, шашкан күзләре белән карап торды да, тилергән адәм кебек, Зәбдәгә ташланды* (Г. Ибраһимов). *Яралы да башын күтәрә төште, бер минутка аның әлеге тирәннән караган күзләрендә шатлык, гаҗәпләнү уты ялтырады* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

4. Йокыдан тору. *Кышкы авыл яңа баш күтәрә, ә җәен бу вакытларда халык кырга китеп беткән була инде* (Ә. Еники. Рәхмәт, иптәшләр). *Аннары ул, күзләрен ачып, башын күтәрде дә торып ук утырды* (А. Тимергалин. Карурман аша).

5. Тәкәбберләнү. *Кызның астыртын горурлыгы вакыт-вакыт баш күтәрә* (А. Гыйләҗев). *Аннары кинәт ниндидер бер кискенлек һәм горурлык белән башын күтәреп, түшәмгә текәлде дә, үз-үзенә сөйләгәндәй, ярсып сөйләргә тотынды* (В. Нуруллин. Күпер чыкканда).

6. Төрле хисләрнең көчәюе. *Анасының ялкынлы сүзләре аның күкрәгән бетмәс-төкәнмәс көч, куаныч белән тутырды, болгарларның икенче угыннан соң, атасының каршы килүеннән соң, күңелдә баш күтәрә язган икеләнү, каушау тойгысы кул белән алгандай юкка чыкты* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур). *Баш күтәрсен дөньяда / Вөҗдан, мәхәббәт гөлләре* (Гыйффәт туташ. Даһига).

7. *к.* баш күрсәтү. *Кар китәр-китмәс беренче яз чәчәге – умырзая баш күтәргән* (Г. Әпсәләмов. Газинур). *Сукмак буенда кардан ычкынган былтыргы әрем, тәмлекәй баш күтәреп маташалар* (Ә. Еники. Рәхмәт, иптәшләр).
Төрдәше: баш калкыту 5 һ.б.

8. Сүз тыңламау, үзенчә эшләү. *Бик юаш, сабыр холыклы Мәтрүшкә кешеләргә каршы баш күтәрде* (Р. Фәизов. Мәтрүшкә). *Укытучы Ирханны Адилә исемле кыз янына утыртты, Ирхан баш күтәреп маташмады* (Р. Зәйдулла. Дару).

9. Эштән аерылып тору. – *Ә-ә, Сәрия, сезме? Укып та чыктыгызмыни? Тиз тоткансыз, – диде китапханәче, кәгазьләрдән башын күтәреп* (А. Тимергалин. Таш алиһә). *Кыз дәфтәргә язып утырган җиреннән башын күтәрде: – Ходаем, анысы нәрсә инде тагын?* (А. Гыймадиев. Үзең булып кал!..).

10. Тиешлекне, җаваплылык хисен тою. *Аталарыннан кар ерып кайту белән хуҗа хатынның мондый зур эш тапшыруы аның башын күтәрде, ул, тиз-тиз йортка чыгып, кияү бүлмәсенә йөгерде* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми).

11. Хәл итәргә кирәкле мәсьәлә, эш туу. *Үлем артыннан, калганнар өчен дә мал кайгысы баш күтәрде* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми).

12. Буйсынганлык хәлендә булу. *Салды башны бу мәхәббәт сәмумнарга, / Буйсындырды әллә нинди кануннарга. / – Баш күтәреп карарга да шүрлим хәзер* (Г. Мөхәммәтшин. Робагыйлар бакчасы).

**БАШ КҮТӘРҮЧЕ.** Фетнә чыгаручы. *Гомумән, XVII–XVIII гасырларда юрт татарлары баш күтәрүчеләр белән конфликтка кермәскә тырышкан һәм бу аларның күпмедер дәрәҗәдә куркынычсызлыгын да тәэмин иткән* (И. Торопицын. Юрт татарлары).

**БАШ КЫЗУ.** *Ахыр башлары кызып, йөрәкләре сызып, шәһвәт тамырлары типмәгә башлады* <...> (К. Насыйри. Әбүгалисина кыйссасы). *Баязид карыйның каны кайный, башы кызган, хыялы уянган* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр).

**БАШ КЫСУ.** Башаклану. *Арышлар баш кысып, серкәгә утырды* (Г. Ибраһимов). *Арышның баш кыскан шау мәле / Рәшәле басуның, һәй, яме* (И. Диндаров. Арышның баш кыскан шау мәле).

**БАШ МИЕ СЕЛКЕНҮ.** Зиһен таралу, аек фикер йөртә алмый тору. *Зираттагы тамашадан соң,*

*чын мәгәр, баш мие селкенгән иде* (Н. Гыйматдинова. Кем беренче?). *Әнисе кулыннан ычкынып, читкә тәгәрәгән баланың баш мие селкенә* (Ф. Мөслимова. Һаман яратам).

**БАШ МИЕ СЫЕГАЮ (ШУЛПАЛАНУ).** Зиһенсезләнү, уйлый алмас хәлгә килү. *Шул минутта ул үзенең баш миен бик сыек хәлдә итеп күз алдына китерде. Баш мие шулпаланган. Тизрәк качарга кирәк!* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары). *Ирнең баш мие сыегайган, аңы каткан, акылы томаланган, шуңамы ул ике сүздән торган сөаль аша гына зәгыйфь фикер йөртә иде: «Ни бар? Ни бар? Ни бар???»* (Р. Сибат).

Төрдәше: акыл сүнү һ.б.

**БАШ МИЕН АЧЫП САЛУ** *киная.* Бик озак уйлап, акрын кыймылдаучы кешегә төрттерү. *Мәрхүм әтисе сыман әкрен кыймылдый малай. Баш миен ачып салсаң да файда юк* (Н. Гыйматдинова).

**БАШ МИЕН БОРАУЛАУ.** Бер уй һаман да башыннан китмәү. *Бары «Рита киткәндер» дигән газаплы уй гына аның баш миен бораулламасын* (Х. Ширмән. Яшәү моңы).

Төрдәше: биш миен игәүләү (игәүләп тору).

**БАШ МИЕН ИГӘҮЛӘҮ (ИГӘҮЛӘП ТОРУ)** *к.* баш миен бораулау. *Шул нәрсә, анасын саткыры, әлегә тикле баш миен игәүләп тора* (Ә. Мушинский. Һаваларда – ак күгәрчен).

Төрдәше: биш миен бораулау.

**БАШ МИЕН КАЙНАТУ.** Ниндидер уй (кеше, фикер һ.б.), баштан китмичә, һаман борчып тору. *365 көн буе минем йөрәгемне сызлатты ул, биш миемне кайнатты һәм... көн саен диярлек матчага каратты* (Ф. Баттал). *«Әхлия» сүзе баш миен кайната иде* (Н. Гыйматдинова. Нурулла).

**БАШ МИЕН СЫЕК ХӘЛДӘ КҮЗ АЛДЫНА КИТЕРҮ** *к.* акыл сүнү. *Шул минутта ул үзенең баш миен бик сыек хәлдә итеп күз алдына китерде* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).

Төрдәше: акыл сүнү һ.б.

**БАШ МИЕН ТУРЫЛАУ.** «Тәртипкә китерү, акыл өйрәтү» мәгънәсендә. *Понимаешь, мин сезнең баш миләрегезне турылармын* (Х. Камалов).

**БАШ МИЕН ТҮНДЕРҮ.** Аңламас хәлгә китерү. *– Баш миемне түндереп утырмале, җәме!* (Ә. Гаффар. Богау).

**БАШ МИЕНӘ ТОНДЫРУ** *к.* акыл сүнү. – *Ике күсәк белән берьюлы баш миенә тондырсыннар әле* (Н. Гыйматдинова. Бер тамчы ярату).

Төрдәше: акыл сүнү һ.б.

**БАШ МИҢГЕРӘҮЛӘНҮ** *к.* баш китү 3. *Үзе берәр эшне яхшырак итеп эшләп куйса: «Син пыразит белән яшәп башым миңгерәүләнә шулай ул!» – дип талады* (Ш. Хөсәенов. Мәхәббәт һәм нәфрәт).

Төрдәше: баш китү 3 һ.б.

**БАШ МУЕНГА БЕРЕГҮ.** Төпле кеше турында. – *Ялгышасыз, Мөдәррис Мөгаллимович! Башы муенына нык берекән* (Ж. Дәрзаман. Җир авазы).

**БАШ НА БАШ** *иск., гади с.* Кыйммәтләре бердәй булган нәрсәләрне алмаштыру, сату-алу һ.б. *[Хөсәен] Баш на баш булса – бара, булмаса, кирәкми* (Ф. Бурнаш. Хөсәен мирза). – *Тик шунысы: мин сиңа ярдәм итәм, син миңа. Баш на баш* (М. Маликова. Юкә чәчәк аткан чак иде).

**БАШ НУЖАДАН ЧЫКМАУ.** Мохтаҗлыктан, фәкыйрьлектән котыла алмау. *Заманында батрак Сибай дигән гидай бер егет бар иде... Көн эшләде, төн эшләде. Шулай да башы нужадан чыкмады...* (Г. Бәширов). *Бер гаепсезгә читлеккә ябылган Фәридун Фазлыев... Башы нужадан чыкмаган Ираида Никифоровна...* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: азап күрү (чигү) һ.б.

**БАШ ОЛАГУ.** Әллә нинди ерак җирләргә китеп юк булу. *Теге абзыйны да тотсалар, тагы башым олага инде* (Г. Исхакый. Зөләйха). *[Гөлбану] Шулай ук башы бөтенләй олагыр микәнни моның, тилчәнең?* (Н. Исәнбәт. Хуҗа Насретдин).

Төрдәше: башны олактыру.

**БАШ ОРУ.** 1. Түбәнчелек белән үтенү. *Әгәр син исән булсаң, баш орып синең катыңа гына барыр иде ул!* (А. Гыйләҗев). *Кыпчаклар йә карлуклар эргәсенә барып, башың орып кара* (В. Имамов. Утлы дала).

Төрдәше: аягына егылу 2 һ.б.

2. Хөрмәт билгесе итеп баш ию. *Җир ярсызы күреп минем канны, / Тал-тирәкләр елап баш орды* (М. Җәлил. Аяксыз). *Намазлыгым – кәгазь, баш орасы акка* (Х. Әюп).
Төрдәше: баш ию 3.

3. Буйсынып баш бөгү. *Ахыр бер сәгать мин аңа баш орып, ләгънәт ди, ләгънәт ди үләрмен* (С. Рәмиев). *Баш органнан муен сынмас* (Мәкаль).
Төрдәше: арка бөгү (бөгеп тору) 1 һ.б.

**БАШ ОРУЧЫ.** Үтенеч белән килүчеләр. *[Зәйнәгый] Ишек артында баш оручылар көтә* (Н. Исәнбәт. Хуҗа Насретдин). *Аягы астында ауный-тәгәри ярлыкау теләнеп баш оручы бу мәхлук зат белән сабый хыялындагы мәгърур ханнар арасында бернинди уртаклык юклыкны тойды ул бу мизгелдә* (Р. Батулла. Сөембикә).

**БАШ ОРЫП ЯТУ.** Баш белән билгеле бер якка таба яту, нәрсәгә булса да башны тидереп яту. *Алар җирдә яткан имәнгә баш орып яттылар да аякларын янып торган учакка таба суздылар* (Сөйләм).

**БАШ ОЧУ.** Үтерелү. *Ике моржҗадан төтен чыгаручылар, зиначылар аягы астында келәмнәр дөрләп яна иде, министрлар, янаралларның башлары оча иде!* (А. Хәлим).
Төрдәше: адәм башкайларын салу һ.б.

**БАШ ОЧЫ.** 1. Яткан торышта баш тирәсе. *Гөлкәй урындыгын укытучының баш очына ук китереп куйды да, башын Мансур Ибраһимовичның башына терәп, аның сулышын тойган хәлдә, күзләрен йомды...* (Х. Ширмән. Язардан юк ла узмышым). *[Флорид] Минә чемоданың белән капчыгыңны баш очынарак куям* (Д. Салихов. Гыйләҗ тәрәзәләре).
Төрдәше: баш очында.

2. Баскан торышта башның өске өлеше һәм баш өстендәге биеклек. *Анда-санда безнең баш очы турысыннан озын канатлы акчарлаклар үтеп киткәне күренә* (А. Гыйләҗев. Истәлекләр).

**БАШ ОЧЫНА <КАРА> БОЛЫТ ҖЫЕЛУ (КУЕРУ).** Хәвеф-хәтәр арту; кайгы-хәсрәт, борчулар күбәю. *Тәзкирә әнисен тынычландырырга тырышып караса да, Галимә түтинең баш очына җыелган болытлар алай тиз генә таралмадылар* (Ф. Хөсни).
Төрдәше: баш очында (өстендә) <кара> болыт айкалу.

**БАШ ОЧЫНДА** *к.* баш очы 1. *Баш очында – калынкаш бабайның дәү рәсеме ярты стенаны тотырып тора* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Ул баш очында утырганда, иң көйсез авырулар да ыңгырашмыйлар* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).
Төрдәше: баш очы 1.

**БАШ ОЧЫНДА (ӨСТЕНДӘ) <КАРА> БОЛЫТ АЙКАЛУ** *к.* баш очына <кара> болыт җыелу (куеру). *Андрей баш очында болытлар куеруын сизде һәм яшен чаткыларының йөрәгенә китереп сугуын бик авыр кичереп утырды* (Х. Камалов). *Баш өстемдә болытлар айкалуын сизәм, җыелышта минем турыда да сүз чыгар, ахры* (Сөйләм).
Төрдәше: баш очына <кара> болыт җыелу (куеру).

**БАШ ӨСТЕ.** Эшкә теләп, рәхәтләнеп риза булуны белдереп әйтелә, «әйткәнегез үтәлер» мәгънәсендә. *Әгәр кушсагыз, баш өсте, ни әйтсәгез, шуны кабул итәм* (Г. Камал. Бәхетсез егет). *Карчык моңа баш өсте риза булды* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).

**БАШ ӨСТЕНДӘГЕ КҮК АЯЗ БУЛУ.** Тормыш тыныч, хәвеф-хәтәрсез булу. *Аяз, бик аяз әле баш өстемдәге күгем дә!* (Ә. Еники. Гөләндәм туташ хатирәсе).

**БАШ ӨСТЕННӘН ЙӨРҮ.** Артык узынып китү, санламау. *Ибтидаи (кече) сыйныфларда ыбыр-чыбыр балаларны ничек җитте алай тыңлата алсалар да, рөшдиләрдә (өлкән сыйныфларда) ул бөтенләй көчсез-гаҗиз иде; андагы аттай таза шәкертләр бәләкәй, арык хәлфәнең тәмам башы өстеннән йөриләр иде* (Ә. Еники. Коръәнхафиз).
Төрдәше: башка менү (менеп утыру; атлану; таптау һ.б.).

**БАШ ӨСТЕННӘН КАРАУ.** Масаю, һавалану. *Үпкәләмә, аны эшкә алмабыз, ахры, аның баш өстеннән каравы ошап җитми* (Сөйләм).
Төрдәше: баш әйләнү 4 һ.б.

**БАШ РӘТЛӘНҮ.** *Башы әз-мәз рәтләнгән кебек булса да, җанын һаман нидер тынгысызлады, караса, сул кулының урта бармагына да эт тырнагы чыккан!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**БАШ РОЛЬНЕ УЙНАУ.** Берәр эштә төп урын тоту, иң әһәмиятлесе булу. *Ихтимал, Башкортстанны аерым итүдә аларның да катнашы*

*булгандыр, мәгәр, безнең белүебезчә, Зәки хан (башкортлар үзләре шулай диләр иде) – бу эштә баш рольне уйнаган шәхес* (Ә. Еники). *Уградагы «каршы утрауларда» ул баш роль уйнаган. Әмма Иван III «дуслык күрсәтү»е белән дә, кызы алдында «чүгәләүләре» белән дә аны «йомшартуга» өметләнә алмаган һәм моңа омтылмаганга да охшый* (М. Гайнетдин. Гасырлар мирасы).

**БАШ САБУ.** 1. Башы тузган бияләйгә яки аяк киеменә икенче баш бәйләү, кую. *Тормыш зарарсыз иде, өс бөтен, тамак тук, тау шуарга чана бар, әнинең сеңлесе йомшак бәти йонынннан бәйләп, өстеннән киндер белән баш сапкан бияләй бик җылы* (Г. Камал). *Егетнең өстендә шул ук ситсы тышлы тузган бишмәт, башында каешланып беткән кырпусыз бүрек, аягында баш сапкан күн итек* (А. Расих. Айлы төннәр).

2. Юл яру. *Саклап монгол сөргененнән Ватанны, / Җәлилчеләр чынбарлыкка баш сапты!* (Ф. Гыйззәтуллина. Яну дәверләрендә). *Быел исә Әсләм Шакировның уллары, эшмәкәр этиләре исеме белән бәйләп, республика күләмендә узачак бөтенләй үзгә бәйгегә баш саптылар* («Шәһри Казан» газ.).

**БАШ<НЫ> САЛУ.** 1. Башны түбән ию, боегу, күңелсезләнү. *Азат киңлекләрдә җәйрәп үс, / Башларыңны салма кайгыга* (А. Нәҗми. Аңлашу). *Рөстәм күңелсезләнеп башын салды. Күңеленә ошаган солдатка сүз кушудан да курыксын, имеш!* (Г. Кутуй. Рөстәм маҗаралары).

2. Буйсыну, ялыну-ялвару. *Башыңны сал ялгыз язмышка да, / Ни итсә дә итсен, тыныч бул* (Бикморза. Уйланам). *Бар да озата елап, / Газизә дә башын салган, / Сүз дәшалмый кан елап* (Г. Рәшиди. Көчләп бирелгән кыз).

Төрдәше: арка бөгү (бөгеп тору) 1 h.б.

3. *к.* авыздан җан чыгу. *Үлсәң дә, егет, / үл син дан алып, / Идел ярына / Башыңны салып* (Ф. Кәрим). *Егермедә колхоз төзегән, көрәшкән, утызда яуда башын салган әтиләр* (Р. Гаташ. Яшьлек турында).

Төрдәше: авыздан җан чыгу h.б.

4. *гади с.* Баш киемен салу. – *Бүлмәгә керү белән, башыңны салып, кулыңа тот* (Сөйләм).

**БАШ САЛЫНДЫРУ.** Күңелсезләнү, кайгыру. *Алар өчәүләшеп залга кергәндә, Әбүзәр абзый, башын салындырып, иңенә шакмаклы җылы шәл салып, диванда утыра иде* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Иосиф озаткан икенче гаскәр ике-өч айдан соң, ярык тагарак алдында калган балыкчы карт сыман, башын салындырып, кире кайтып төште* (В. Имамов. Казан дастаны).

Төрдәше: башны асу; башны <аска; түбән> сал<ындыр>у; борын асылындыру; борын салын<дыр>у (төш<ер>ү); борын сал<ындыр>ып йөрү; борын сал<ындыр>ып утыру.

**БАШ САТУ.** 1. Кемгә булса да үзең теләп буйсыну, кул астына керү. *Җиһаз беткәч, нидәрсең? / Киемнәрең сатарсың; / Инде эчәсең килсә, / Алыр башың сатарсың* (К. Насыйри). *Бер башыңны саткач, буйсынмый хәлең юк, барып эшләп кайттылар* (К. Кара. Зур акчалар).

2. *иск.* Элекке вакытта кызны, яраткан егетенә бирмичә, мәһәр бәрабәренә бай урынга бирү. *Әгәр дә хәзердән яучы җибәрмәсәң, күр дә тор, башымны Нурулла байгураның чатан Хәйрүшенә сатачаклар* (К. Тинчурин).

3. Берәрсенә әшәкелек эшләү, рухи зыян китерү. *Калды минем башны саткан «пәһлеваннар», / Мәхлук бәндә, олы гәүдә, кәрлә җаннар* (Э. Шәрифуллина. Тамды яшем).

4. Тормыш авырлыгыннан, тормыш итү өчен әйбер юклыктан зарлану. – *Әй, юк өчен баш сатмасана, әни,– дип чәчрәп чыктым мин, әнинең күзләре яшьләнә башлаганны тыныч кына күтәрә алмыйча* (Ф. Хөсни. Без яшь идек).

**БАШ САУ <БУЛУ>.** Кешенең җаны, тәне сау булу; тереклек итүе. – *И инде, башың сау калганга рәхмәт диген! Каян килгән Камыр батыр! – диде улына Мәрьям апа* (А. Тимергалин. Таш алиһә). *Ләкин юкка кайгырма, иптәш старшина. Баш сау булса, кызлар табылыр* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

**БАШ САУЛЫГЫ.** Бөтен гәүдә саулыгы, җантән саулыгы. *Бүгенге төсле көрчеккә килеп терәлгәндә, Нурия, аны җәлләп, биш-ун сумын, баш саулыгыннан дип, хәер итеп биреп куя* (К. Кара. Көнбагыш сатучы). *Ташлама сорап шалтыратканнар дип уйламагыз, безгә берни дә кирәкми, күңел тынычлыгы белән баш саулыгы гына кирәк* («Безнең гәҗит» газ.).

**БАШ САФ <БУЛУ>.** Акыл, зиһен яхшы эшли торган халәттә булу. *Бәлки, бүген уянмый йоклап булыр. Башның саф булуы кирәк миңа* (М. Маликова. Кызыл гөл). *Кешеләр эшкә иртән*

*барырга яраталар – баш саф чакта, ял итеп яңа көчләр җыйгач, беренче чиратта* (М. Хуҗин. Арыш көлтәсе).

**БАШ СЕБЕР КИТҮ.** Себергә сөргенгә сөрелү. *Хуҗа буны күрүгә куркып, харап итәсез, минем номерыма китереп, кеше үтергәнсез, башым Себергә китте, дип акырып йибәрде...* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Булатов әрәм була. Валлаһи, аның башы Себер китәчәк, җәллим мин аны* (А. Алиш. Якты күл буе).
Төрдәше: Себер китү.

**БАШ СЕЛКҮ.** Риза булу яки булмау ишарәте. *Ислам, ризалыгын белдереп, баш селкеде* (Ф. Садриев. Тургай). *Тыңламаганымны күрсәтмәс өчен генә, ризалыгымны белдереп, баш селкеп куям* (А. Мансуров. Үзем гаепле).
Төрдәше: баш айкау һ.б.

**БАШ СУККАН ЯККА.** Теләсә кайсы юнәлештә китеп бару. – *Башың эшлиме синең әзрәк, юкмы? Башы суккан якка, Зәйгә чыгып китте* («Сөембикә» ж.). *Әйберләрен дә җыясы булмады: ике пар ботинкасы, кешелеккә кия торган бер генә костюмы булган икән, шуларны чемоданына салып, сердәше – гармунын алып, баш суккан якка юл тотты* («Кызыл таң» газ.).
Төрдәше: аяк атлаган якка һ.б.

**БАШ СЫЕКЛАНУ.** Акылдан шашу, җиңеләю. *Әмма акыллы хатын белән яшәгән ирнең берзаман башы сыеклана* (М. Мәһдиев. Мәңгелек яз). *Хәмер пары куергач, башым сыекланып китте* (З. Мәхмүди. Сары каеш – сары сагыш).
Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.

**БАШ СЫЙДЫРА АЛМАУ.** Кабул итә алмау, ышанып бетә алмау. *Шулай да бу куркыныч хәбәрне Фәһим баштарак һич тә башына сыйдыра алмады* (Г. Бәширов. Нурҗиһан). – *Моның өчен генә болай шаяртуыңны башыма сыйдыра алмыйм, – диде Диләфрүз* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).
Төрдәше: акыл сыйдыра алмау (сыйдырмау) һ.б.

**БАШ СЫНУ.** Тыгылу, тыкшыну. – *Кара аны, малай, бик башыңны сынып йөрсәң, башсыз калуың да бар* (Сөйләм).
Төрдәше: баш тыгу.

**БАШ ТА БАШ, БҮРӘНӘ (ШАЛКАН) БАШЫ ДА БАШ.** Берәрсенең аңгыралыгына төрттерү, ягъни баш белән башның аермасы бар. – *Аны башлы кеше дисең, әмма баш та баш, шалкан башы да баш бит* (Сөйләм).

**БАШ ТА, КҮЗ ДӘ <БУЛУ>.** Эшне башкаручы да, аны күзәтеп торучы да үзе. *Эшне эшләтүче дә, күзәтеп контрольлек итүче дә ул, баш та, күз дә иде ул пионерларның кыр эшләрендә* (Г. Гобәй).

**БАШ ТА, ТҮШ ТӘ.** Барысына да берүзе баш, төп хуҗа. (Сөйләм). *Баш та, түш тә үзем, әллә минем янга эшкә керәсеңме?* (Сөйләм).

**БАШ ТА ЮК, АЯК ТА ЮК.** «Тәртипсезлек, хуҗасызлык хөкем сөрә» дигән мәгънәдә. – *Син әйткәч, барып карадым, баш та юк, аяк та юк анда* (Сөйләм).

**БАШ ТА ЮК ТҮГЕЛ.** «Ахмак түгел, акылы бар» мәгънәсендә. *Аннары ул аның көченә, кыюлыгына да ышанды. Шулай ук аның бу уенда баш та юк түгел иде* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).

**БАШ ТАРТМАУ** *к.* баш бирү 2. *Бер хөкем чыгарамын, баш тартмагыз, / Кем дә кемнең гөнаһысы артык булса, / Шул кеше корбан булсын!..* (М. Гафури). *Ул чакта әле авыруга ярдәм кылудан баш тартмау турындагы Гиппократ анты эчкән медикның ни өчен бу очракта вәгъдә бозганын уйлап торырлык хәлем юк* («Ватаным Татарстан» газ.).
Төрдәше: баш бирү 2 һ.б.

**БАШ ТАРТУ.** 1. Каршы килү. *Нишлим, сугыш дустым-пистолетым / Соңгы сүздән кинәт баш тартты* (М. Җәлил. Кичер, илем!). *Биредә тагын шуны өстәп әйтәсем килә: минем атакай, мал бүлешкәндә, өлешкә керүдән баш тарткан икән* (Ә. Еники. Соңгы китап).

2. Ризалашмау, кире кагу. *Әмма председатель алардан баш тартты: тар чалбар киеп, керфек, ирен буяп, кешел өстендә көрәк тотып эшләгән яшь хатыннарны колхоз узган елда бер күргән иде* (М. Мәһдиев. Мәңгелек яз). *Коридорда кызык итеп сөйләнелгән бу юллардан соңрак баш тарттым* (Ә. Баянов).
Төрдәше: баш кагу 4.

3. Хокуктан файдаланмау. *Ул, билгеле, шунда ук Нургалинең усал карашын да, ни өчен соңгы сүздән баш тартуын да аңлап алды* (Ә. Еники. Рәхмәт, иптәшләр).

4. Кабул итмәү; кулланмау. *Утызынчы-кырыгынчы елларда, шулай итеп, безнең авыл кайры туннан баш тартты* (М. Мәһдиев). *Әгәр телеграмма Луизаны үчекләү, аннан баш тарту өчен генә эшләнгән булса?* (А. Гыйләҗев. Өч тәгәрмәчле арба).

5. Ташлау. *Шулай да үзең хак дигән фикерләреңнән баш тарту авыр икән* (Х. Камалов). *Ерткычлардан мәрхәмәтсез / Баласыннан баш тарткан* (Э. Шәрифуллина. Рәнҗү).

Төрдәше: ваз кичү; талак әйтү.

**БАШ ТАШЛАП ЭЧҮ.** Дөньясын онытып йә азынып эчкечелеккә бирелү. *Ярмиев кайгысыннан баш ташлап эчә башлаган* (Р. Төхфәтуллин). *Чөнки инде Ринат Әсгатович, халык әйткәнчә, баш ташлап эчә башлады* (Р. Фәизов. Узган гомер – ташлаган күмер).

Төрдәше: баш ташлау 1.

**БАШ ТАШЛАУ.** 1. Бернигә дә карамыйча, барысын (үз-үзен, эшен, тормышын) оныту. *Әллә кайларга китәсем килә! Баш ташлап качар идем!»* (Ш. Галиев. Илһамым-мәхәббәтем). *Минем өчен син үлдең. Башны ташлап җәһәннәм читенә олактым* (Л. Лерон).

Төрдәше: баш ташлап эчү.

2. Чит җирләргә китеп югалу.– *Кайгысына чыдый алмыйча, баш ташлады, ахры, бичара, – дип, аның югалуына сәбәп тә табып куйган идек инде* (И. Гази). *Сеңлем Фәүзия белән икәү генә калган чакта ул: «Башларымны ташлап качар идем, барыр куыш табар җирем генә юк», – дип өзгәләнә, аһ-зарларын әйтеп, миңа сыенып елый торган иде* (Ә. Рәшит. Һәркемнең... үз хакыйкате).

3. Урылмаган ашлыкның башагы коела башлау. *Арпабыз баш ташларга тора, борчак та өлгергән* (Г. Бәширов. Намус). *Ярар, бер төндә арпа баш ташламас әле, иртәнге автобуска өлгерермен, дип, җиңелчәрәк фикер йөртте – каласы итте* (Р. Мулланурова. Ялгыз каеннан да ялгыз).

**БАШ ТАШТАЙ КАТУ** *к.* авызында ашы, күзендә яше. *Шундый уйлар берлә таштай катты-китте башларым* (Г. Тукай). *Әллә бәрелә-бәрелә күп уйлаудан баш та таш кебек катканмы соң инде?* (Җ. Юныс. Глобаль идея).

Төрдәше: авызында ашы, күзендә яше һ.б.

**БАШ ТӘПӘГӘ АКЫЛ ТУТЫРУ** *к.* акыл бирү 1. – *Рәхмәт сиңа, Баһман абзый, баш тәпәмә акыл тутыруың өчен* (М. Хуҗин. Осталар).

Төрдәше: акыл бирү 1 һ.б.

**БАШ ТЕКӘ <БУЛУ>.** Үзен башкалардан өстен күреп, башын югары күтәреп йөрү. *[Бәкер] Алар кем инде? Ә шуңа карамый баш нинди текә, ә?* (Ф. Бәйрәмова. Сандугачның балалары).

Төрдәше: алып узу һ.б.

**БАШ ТЕЛДӘ БУЛУ.** Уйламыйча сөйләмәү. *[Хуҗа] Һай, кызым, Хамматның башы аның телендә, син үз телеңә баш бул, тор шунда!* (Н. Исәнбәт. Хуҗа Насретдин).

**БАШ ТИРБӘТЕП УТЫРУ.** Нишләргә белмичә аптырап утыру. *Шулай инде, башыңны тирбәт тә утыр инде* (М. Фәйзи).

**БАШ ТОМАН ЭЧЕНДӘ ЙӨЗҮ**. Аңгы-миңге булып тору. *Бу – берничә секунд башының томан эчендә йөзүе иде, бу – тау кебек газапның бик төптән күтәрелеп бугазга килүе иде* (Ә. Еники).

**БАШ ТОТУ** *гади с.* 1. Атаман, әйдаман булу. *Аларда югары очныкылар баш тота, безнең ише малайларны якын да китермиләр!* (Ф. Яхин. Балачак тәрәзәләре).

2. Шобага тотышу. – *Әйдә, баш тотыйк әле, шуннан соң сөйләшербез* (Сөйләм).

**БАШ<НЫ> ТӨЗӘТҮ** *гади с.* Махмырлыкта баш авыртуны бетерү өчен, бераз исерткеч эчү. *[Әби] Иртәгә тагын килеп, баш төзәтергә дип сорарлар әле* (Г. Камал. Хафизалам, иркәм). *Малайны чакыртты да баш төзәтергә китерергә кушты* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр).

**БАШ ТӨРТЕП (ТЕРӘП) АЛУ.** Бераз йоклап алу. *Хәер, ерак юлдан соң чак кына баш төртеп алу зыян итмәс* (Ә. Еники). *«КамАЗ»ыбызны йөк алырга килгән склад каршына китереп туктаттык та, эш сәгате башланганчы, бераз баш терәп алу зыян итмәс иде дип, һәркайсыбыз үзенчә урын хәстәрләргә керештe* (Н. Гамбәр. Ма-ту-у-у!!).

Төрдәше: черем итү (итеп алу).

**БАШ ТӨРТЕП ЧЫГУ.** Тишелеп, шытып чыгу. *Яр битләрендә беренче тере яшь үлән дә баш төртеп чыгып* килә (Ә. Еники). *Нәрсә ту-*

*рында гына язмасын, ул чәчкән бәрәкәтле орлыклардан игелекле үсентеләр баш төртеп чыга* («Мәдәни җомга» газ.).

**БАШ ТӨРТЕРГӘ ДӘ УРЫН ЮК.** Басып тору яки яту өчен, бөтенләй урын булмау. *Мәйданда баш төртергә дә урын юк иде, көрәшүчеләрне карар өчен, агач башына үрмәләргә туры килде* (Сөйләм).
Төрдәше: алма төшәр<лек> урын булмау (юк) һ.б.

**БАШ ТӨРТҮ**. 1. Эшкә урнашу. – *Ә син шулай да тәгаен кай якларга китәргә җыенасың соң, яшьти? Кайда баш төртмәкче?* (В. Имамов. Тозлы яра). *Бер тиен акчасыз калса, кайларга барып баш төртер? Эшләргә эш юк, торып торырга куыш юк, кесәңдә җилләр уйнаганын күреп, элекке дуслар-танышлар борылып та карамаячак, мәсхәрәләп көлләрләр генә, күңел ачарлар* (К. Кара. Уфа–Афина).
2. *к.* баш калкыту 5. *Әле генә, баш төртәсең менә, иске яфрак, камыл арасыннан* (Х. Әюп). *Юл буйларында, кашлак урыннарда үлән баш төртте, тау битләре хәйран яшелләнде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: баш калкыту 5 һ.б.

**БАШ ТӨЮ** *к.* авыз җебетү 2. *Ә син һаман... һаман ләззәтләнеп, / Улларыңның башын төясең* (М. Әгъләм).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**БАШ ТУБАЛ БУЛУ (ТУБАЛГА ӘЙЛӘНҮ).** Төрле сәбәптән баш бик нык ару, миңгерәүләнү. *Аны уйлап башлар тубал булды инде, җүләрләнмәсә ярый кеше* (Э. Касыймов). *Кайчагында уйлыйм-уйлыйм да, аңлый алмыйча, башларым тубал була* (Ф. Латыйфи).
Төрдәше: баш түнү.

**БАШ ТУКТАУ** *к.* баш китү 3. *Безнең якта шундый итеп әчетәләр балны, эчкәннән соң баш туктый, аяклар гына эшли башлый* (Ф. Хөсни. Йөзек кашы).
Төрдәше: баш китү 3 һ.б.

**БАШ ТУЛУ** *к.* баш китү 3. *Күргәнен, ишеткәнен тәртипкә салып бетерә алмаенча, бик арыганга күрә, бераз хәл җыяр өчен ятып алмакчы булды, һәм дә ятты. Башы тулып беткәнгә күрә, рәтләп йокыга китә алмады* (Г. Исхакый. Ике йөз елдан соң инкыйраз). *Шундый авыр уйлар белән башым тәмам тулган иде, рәхмәт инде, тыңлаганың өчен, аңлаганың өчен рәхмәт* (М. Маликова).
Төрдәше: баш китү 3 һ.б.

**БАШ ТҮБӘН ДӨМЕККЕРЕ** *карг.* «Йөзе түбән төшеп үлгере» мәгънәсендә. *Башы түбән дөмеккере* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).
Төрдәше: башы беткере! һ.б.

**БАШ ТҮБӘСЕ.** 1. Башның өске өлеше. *Ул озак уйлап тормады, кулындаг күсәге белән тегенең баш түбәсенә тондырды* (Сөйләм).
2. *к.* баш очы 2. *Сирәк кенә булса да, баш түбәсендә нindидер кош күренгәләп* алды (Сөйләм).

**БАШ ТҮБӘСЕ КҮККӘ ТИЮ** *к.* авыз еру 4. *Имеш, баш түбәм минем дә / Күгемә тигән* (С. Хәким. Туган җир).
Төрдәше: авыз еру 4 һ.б.

**БАШ ТҮБӘСЕНӘ <КИТЕРЕП> БИРҮ.** Берәр нәрсә белән башка сугу. *Альберт аяк астында яткан кыска саплы көрәк белән Кендекнең баш түбәсенә бирмәкче булды* (З. Мәхмүди. Әче балан).
Төрдәше: башка <китереп> бирү; башка сугу; башка тамызу.

**БАШ ТҮБӘСЕНӘ КУНДЫРУ** *к.* авыз җебетү 2. *Шәрәф ачу белән Набиянең баш түбәсенә кундырган* (Н. Гыйматдинова. Күке төкерәге).
Төрдәше: баш түбәсенә <китереп> бирү.

**БАШ ТҮБӘСЕННӘН ОЧУ** *к.* баш түбәсе 2. *Ә бәхет дигәнең бик үз холыклы кош: иң актыккы минутта гына баш түбәңнән очып югалса, нишләрсең?!* (Ш. Маннур).
Төрдәше: баш түбәсе 2.

**БАШ ТҮБӘТӘЙГӘ СЫЙМАУ.** Мәшәкатьнең артык күп булуы турында. *Ханның мәшәкатьләре бихисап бит аның, башы түбәтәйгә сыймаган чаклары да еш була* (М. Әмирханов. Үрбәт ханәкә гыйшкы).
Төрдәше: баш кабару һ.б.

**БАШ ТҮГӘРӘК <БУЛУ>.** Акыллы кеше турында (кайвакыт киная белән әйтелә). – *Үз һөнәренең осталарын яратам мин. / Башың түгәрәк синең...* (Р. Низами. Сәйдәшнең соңгы елы).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктереп (элеп кенә) алу һ.б.

**БАШ ТҮНҮ**. Бернәрсә дә уйлый алмас хәлгә җитү, баш миңгерәүләнү. *Бөтен башым түнеп, өметсез уйларга бирелгән килеш, акрын гына караңгы урамнар буенча атладым* (Ф. Шәфигуллин). – *Билгесезлектән, чуалчык уйларыннан тәмам башы түнгән Савелий Кузьмич ни кылырга, кайдан ярдәм өмет итәргә белми* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).
Төрдәше: баш китү 3 һ.б.

**БАШ ТЫГАР УРЫН ЮК** *к.* баш төртергә дә урын юк. *Галәмәт ул урман сугышы – күк яна, җир яна, сазлык яна – баш тыгар урын юк.* (Г. Әпсәләмов. Ак диңгездә алтын балык).
Төрдәше: алма төшәр<лек> урын булмау (юк) һ.б.

**БАШ ТЫГАР ХӘЛ ДӘ ЮК.** Бик күп; тыгыз, кысан булу. *Вокзалга, буфетка, су киоскларына баш тыгар хәл юк: һәр җирдә халык шыгрым тулган...* (И. Гази).
Төрдәше: алма төшәр<лек> урын булмау (юк) һ.б.

**БАШ ТЫГАРЛЫК ТҮГЕЛ** *к.* баш төртергә дә урын юк. *Пароходка түбән агымга таба билетлар сатылса да, кассага баш тыгарлык түгел* (М. Харисов. Укытучы иртә чалара).
Төрдәше: алма төшәр<лек> урын булмау (юк) һ.б.

**БАШ ТЫГУ** *к.* баш сыну. *Сиңа барыбер түгелмени, сеңлем, кирәк-кирәкмәгән җиргә башыңны тыкма, башсыз калырсың* (Д. Салихов. Таш сандык). *Тик нәкъ менә шул фәлсәфә кысаларына башын тыгып барганлыгын аңлап та, төшенеп тә җитенкерәми әле ул* (З. Хөснияр. Кичү).
Төрдәше: баш сыну.

**БАШ ТЫККЫСЫЗ (ТЫГА АЛМАСЛЫК; ТЫКМАЛЫ ТҮГЕЛ).** 1. *к.* алма төшәр<лек> урын булмау (юк). *Автовокзалда да, аэропортта да баш тыккысыз кеше!* (Р. Газиз. Тәрәзәләр).
Төрдәше: алма төшәр<лек> урын булмау (юк) һ.б.

2. Артык куе (томан, урман һ.б.). *Кар сырдырып йөргән көннәр онытылмый... / Онытылмый яңгыр сеңдергән көннәр дә... / Күз ачкысыз, баш тыккысыз ул көннәрдә* (Р. Харис).

3. Эсселек (мунчада) яки каты суык, күз ачкысыз (буранда). *Кызган ташларга чүмеч белән сыра оргач, баш тыга алмаслык кайнар бу җәелә башлады* (Сөйләм).

**БАШ ТЫКМАУ.** Тиешле-тиешсез берәр эшкә кысылу. *Йортта ир заты барында алар урманга баш тыкмаган, арба-чаналарда көйле шыгырдап, таза ис аңкытып имән яркалар ишегалдына килеп кергән, күңелле булган* (Ш. Галиев).

**БАШ УРТАЛАЙГА ЯРЫЛУ.** Куркыныч хәлгә җитеп баш авырту. *Минем башым урталайга ярыла, мин ятып торам* (З. Хәким).

**БАШ УРЫНЫНА КОЛАК, АЯК УРЫНЫНА ТОЯК.** Зур югалту урынына кечкенәсен биреп котылу. *Тиз генә котыла алмас дип уйлаган иде, баш урынына колак, аяк урынына тояк биреп тә котылу юлы бар икән* (Сөйләм).

**БАШ УТ <БУЛУ>.** Бик күп уйлап, кирәкле нәтиҗәгә ирешә алмагач, башы кызудан ут кебек яну. *Аның башы ут иде. Зиһенендә кочегарның бу залда шаһит булып керүеннән кабынган ялкын иде* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).

**БАШ ХАРАП ИТҮ.** Юкка чыгу, әрәм булу. *[Гарифә]. Ник син кызымның башын харап иттең?* (Г. Исхакый. Алдым-бирдем). *Кинәт Сәлим Газинурның кулына ябышты, үтә ялварган тавыш белән кычкырып җибәрде: – Газинур абый, коткар мине! Башымны харап итәләр...* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

**БАШ ХӘСРӘТКӘ ТӨШҮ.** Кайгыру, борчылу. *Төште хәсрәткә Вәзиләнең башы* (А. Гыйләҗев. Әтәч менгән читәнгә).
Төрдәше: аһ ору һ.б.

**БАШ ЧАЙКАУ.** Аптырау, ризасызлык белдерү. – *Бозылды, бөтенләй киртә сикерде!* – *дип башын чайкап куйды* (Г. Бәширов. Намус). *Без Көнбатышка карап баш чайкадык, тел шартлаттык, авыздан мул итеп селәгәй бүлендә* (Р. Зәйдулла. Син, мин, Мөхәммәтәмин...).

2. Юклыкны белдерү. *Мин, ни диим, бары башымны гына чайкадым* (Ә. Еники. Яшьлек хатасы). *Сирин «Юк!» дигәнне белдереп баш чайкады* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).
Төрдәше: баш айкау һ.б.

3. Гаҗәпләнү, соклану билгесе. *Ара-тирә ул, бүлмә ишегенә килеп, чаршауны ике якка аерып, балаларына карап тора һәм аларның кул-аякларын ташлап, тәмам сеңеп йоклауларын күргәч, көнләшкәндәй сулап, башын чайкап китә* (Ә. Еники). *Җиһангир карт, онытындагы ман-*

*тыйкка һәм акылга гатәпләнеп, баш чайкап куйды* (Ф. Бәйрәмова. Нух пәйгамбәр көймәсе).

**БАШ ЧАТНАУ.** Баш бик каты авырту. *Тик, зинһар, иртәгә сөйләшербез, җизни. Баш чатный. Иртәгә иртән, яме?!* (Э. Касыймов). – *Имансыз сез, хатын-кыз, анагызның тегермәнен ишим, башым болай да чатный, тагын өстәп тә сугалар* (Н. Гыйматдинова. Бер тамчы ярату).

**БАШ<НЫ> ЧЕРЕТҮ.** 1. Юк сүз, юк-бар мәсьәлә белән кешене йөдәтү; шуны уйлап йөрү. *Яхшы сүз таш эретә, яман сүз баш черетә* (Мәкаль). *Шулай булгач, кешенең башын черетмичә генә, барысын да үзең ачыкла* (М. Кәбиров. Бердәнбер һәм кабатланмас).

2. *к.* бавырга боз урнашу. *Аш ташны эретә, Ялган башны черетә* (Мәкаль). – *Ул төшләр минем башны да череткән җирләр, туган* (Х. Хәйруллин. Ургыл).

Төрдәше: бавырга боз урнашу һ.б.

3. Авырлыклар күрү, җәфалану. – *Фатирсыз-нисез, тулай торакларда башны черетәсе килми, шәһәрдә фатирлы кызлар да буа буарлык иде* (Н. Гыйматдинова. Алан уртасында ялгыз йорт).

4. Гомерне бушка әрәм итү. – *Ул туңбашларның бөтен белгәне шул: җыен чүп-чар белән баланың башын черетү!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Мәгәр алар гаскәргә алыну, ягъни егерме биш ел солдатлыкта баш черетү – империя мәнфәгате өчен чит-ят җирләрдә кан кою, шинельле хәлдә «себер сөрелеп» урман кисү, шәһәр-кальгалар салу һ.б. шуның ише мәҗбүри эшләргә тартылу «хокукы»на бугаздан гарык иделәр* (М. Госманов. Чәчелгән орлыклар).

**БАШ ЧЕРҮ.** 1. Күп уйлап, башны авырттыру. *Имтиханнарда башы черегән, җаны өзгәләнгән егетнең тырышлыгы «әйе» дип баш кагарга да җитмәде* (Ф. Яхин. «ЗИЧ-5»). *[Кладовщик] 100 мең потлы амбарга баш булып та баш череп беткән* (Г. Нәбиуллин. Урак өсте).

2. *к.* авыздан җан чыгу. *Әтиләрне милиция алып киткәч, теге апа: «Күрсәттем күрмәгәннәрен, төрмәдә башлары череячәк», – дип кычкырып йөргән* (Т. Миңнуллин). *Намаз укып, вәгазь сөйләп йөрсәң, / Башың черер синең төрмәдә!* (Г. Сафин. Иж буенда).

Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

**БАШ ЧИТКӘ КИТҮ.** 1. Туган илдән ерак җирләргә, чит җирләргә китү. *Сөям сине, сөям сине, / Башым читкә китсә дә* (Җыр).

2. Исереп яки башка сәбәптән чынбарлыкны аңлый алмас хәлгә җитү. *Хәмер эчкән затның башы читкә китә, / Һәр очраган җанны аңарга дус итә* (В. Ильясов. Гөлсу). *Башым урынында минем. Башым читкә китә дип, башым чуалган чак иде: табиблар ярдәме белән бәладән котылдым* («Матбугат. ру» порталы).

**БАШ ЧӨЮ.** Башны горур күтәреп басып тору. *Мөхәммәтҗан солдат халык өстеннән тагын да биегәеп, башын чөеп җибәрде. Аның аксыл чырае кызарып китте* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Илсөяр яныма килеп баскач та, иярләнмәгән ат шикелле баш чөйдем: ахирәтләрем күрәләр микән?!* (К. Кәримов. Уен).

Төрдәше: алып узу һ.б.

**БАШ ЧУАЛТУ.** 1. Бутап бетерү, фикерне карыштыру. *Җыелган кешеләрнең очсыз-койрыксыз сүзләре һәм гыйлем вә җәһел мәсьәләсе хосусында язылган тау-тау кәгазьләре Падишаһның башын гына чуалталар иде* (Г. Тукай. Гауваслар). *<...> колак төбендә яңгыраган туп тавышы берничә секундка аның башын чуалткандай булды* (К. Тинчурин).

2. Нәрсә уйларга (эшләргә) белмәү. *«Фәттахетдин», «Сәид Баттал», «Мәгъриб зәмин»дә «Иран диган шәһәрдә...» дип башлаган хикәяләр, «Гуҗ бине Гонык», «Албасты», «Әбугалисина» кыйссалары адәмне мөбаләгале сүзләргә ышанырга, башларын чуалтырга, хак фикердән ерак булырга сәбәп булалар* (Г. Исхакый. Бай угылы). *[Фәрхәнә] Белмим шул, ул кызның башын тимерче Гаяз чуалткан диләр* (Т. Гыйззәт. Чаткылар).

**БАШ ЧУАЛУ.** 1. Буталып бетү, фикер чуалу. *Аның башы чуалды. Низамилар, Гыймадилар, Фәхриләр өстенә тагын берәү килеп кушылды* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).

2. Нәрсә уйларга (эшләргә) белмәү. *Ул да түгел, кече яктан кызыл башлы ак тастымал тотып чыкты да, нишләтергә белмичә, тәмам башы чуалып, урындыкка килеп утырды* (Г. Бәширов).

Төрдәше: баш-ми чуалу (ике маддә өчен дә).

**БАШ ЧҮЛМӘГЕНЕҢ ДҮРТ ЯГЫ ДА ТИШЕК** *шаярт.* баш китү 3. *Баш чүлмәгенең*

*дүрт ягы да тишек: уй тормый, җил себерә* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: баш китү 3 һ.б.

**БАШ ЧҮМЕЧЕ.** Башның арткы йомры өлеше. *Баш чүмече яңгырап куйды. Чигәләре әле киңәеп алдылар да чатнап авырта башладылар* (Ф. Яхин. Ат урлауның ние бар?). *Сырты, баш чүмече белән җиргә бәрелүдән сыны каткан иде, берникадәр ара тынсыз калып, кузгала алмый ятты* (В. Имамов. Утлы дала).

**БАШ ЧҮМЕЧЕ ЙОМРЫ, СҮЗЕ ТУРЫ.** Туры сүзле, акыллы кеше турында. *Үзебездән өстик: «Баш чүмече йомры» гыйбарәсе акыллы, туры кешегә карата әйтелә* («Матбугат.ру» порталы).

**БАШ ЧҮМЕЧЕН КАШУ** *к.* баш кашу. *Берникадәр вакыт баш чүмечен кашып торуга ук, кенәз Демьян торгакларга таба борылып җикеренде* (В. Имамов. Карабәк). *– Алай, бер фаразан, – дип, карт баш чүмечен кашып алды, – җәл, атыгыз юк, миндә кунак булып китәрсез дип тәкъдим иткән булыр идем* (М. Әмирхан. Әлвидаг).
Төрдәше: баш кашу һ.б.

**БАШ ЧЫГАРУ.** Башаклану. *Игеннәр күзгә күренеп калка, буынга утыра, баш чыгара. Чөгендер, бәрәңге басуларының кара җире күренми башлый* (А. Гыйләҗев). *Арыш унике көн баш чыгара, унике көн серкәдә утыра, унике көн эч иңә* (Хал. афоризмнары).
Төрдәше: баш яру.

**БАШ ЧЫКМАСТАЙ.** Бик катлаулы, мәшәкатьле, буталчык эш турында. *Тагын бер баш чыкмастай эшкә кереп купса, артта калган берәр предприятиене өстерәргә тотынса, күр дә тор, ярты картаясың инде* (Г. Ахунов. Чикләвек төше).

**БАШ ЧЫКМАУ.** 1. Борчу-хәсрәттән котыла алмау. *Сүзләрдән, гайбәттән башы чыкмады* (Г. Ибраһимов). *Нәрсә булды аңа? Җен кебек! Тылкышудан башы чыкмый* (Н. Хәсәнов. Сынады).

2. Көне буе эштә яки башка гамәлләр белән мәшгуль булу. *Өй арасында урала, кыр эшеннән башы чыкмый, өмәләренә, күрше-күләнгә ярдәмгә дә беренче булып барып җитә иде* (А. Гыйләҗев. Өч аршын җир). *[Зәйтүнә] Доклад, беседалардан башым чыкмый* (Ф. Бурнаш. Таң).

3. Бер эшнең даими рәвештә кабатланып, бөтен вакыт шуңа сарыф ителү. *[Зиннәт] Аның бит авылга милиция чакыртудан башы чыкмый* (Ф. Бәйрәмова. Сандугачның балалары).

**БАШ ЧЫҢЛАУ.** Колакта туктаусыз чың ишетелү (кан басымы күтәрелүдән). *Ник бер сызлау, әрнү булсын?! / Башы гына чыңлый да, йөрәге генә тибә...* (Г. Гыйльманов. Шартлау). *Ишеккә приклад белән суктылар. Башым чыңлап китте* (И. Сәләхов. Фаҗига).
Төрдәше: колак чыңлау.

**БАШ ШЕШ<ЕН>Ү.** 1. Күп уйланудан зиһенне туплый алмый тору. *Бу чаклы күп киңәшләрдән соң, Миңзифа әбинең башы шеште. Һәммә сүз бер колагына керде, икенчесеннән чыгып китте* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар). *Бик озак көрсенеп, азапланып ятты ул, өй бөркү булгангамы, йөрәге янганга күрәме, өстеннән калын юрганны да аягы белән ачып ташлады; һәм аның авыр уйлардан шешенгән башы, ничектер, бер арада тынгысыз, сискәнүле йокыга талды* (Ә. Еники. Рәхмәт, иптәшләр).

2. *к.* баш кабару. *– Карале, кичкә таба кая барып кайтасы бар иде әле, баш шешеп, түбәтәйгә сыймый инде* (Сөйләм).
Төрдәше: баш кабару һ.б.

**БАШ ЭЛӘГҮ.** Кулга алыну, хөкемгә тартылу. *Яхшы итеп әзерләнгән идек, дисәләр дә, бер «Аксый»ның гына башы эләкте, башкалар качып котылдылар* (Сөйләм).

**БАШ ЭШЛӘҮ** *к.* авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктереп (элеп кенә) алу. *Димәк, кызымның башы эшли. Тик Искәндәргә ияләшмәве генә мине борчый* (Г. Кутуй. Тапшырылмаган хатлар). *– Белемең бар – ун класс бетергән, башың эшли – анысын хисапчы чагыңда күрдек!* (В. Нуруллин. Күпер чыкканда).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктереп (элеп кенә) алу һ. б.

**БАШ<НЫ> ЮГАЛТУ** 1. *к.* бармак тешләү. *Җиһангир башын югалта, оятны сизми, җылап-җылап, Миңлекәйнең җеназасы артыннан йөгерә* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Күрше Хәдичә, болай йөрсә, ышанам, тиздән башын югалтачак* (Н. Гыйматдинова. Ак торна каргышы).
Төрдәше: бармак тешләү һ.б.

2. Зиһен, акыл белән эш итү сәләтен югалту; хис өстенлек итү. *Бу каты бәрелеш эчендә баш югалткан Сәфәр карт, тилергән тавык кебек, әле ул якка, әле бу якка ташлана* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Кем уйлаган: алтмыш яшенә җиткән ирем башын югалтып гашыйк булыр һәм миңа гомер баешымда иремне югалту куркынычы янар, дип* (Ф. Тарханова. Мине генә ярата, димә).

Төрдәше: акыл бетү һ.б.

3. *к.* авыздан җан чыгу. *[Искәндәр] Чыгарма тавышыңны, башыңны югалтырсың* (Ф. Бурнаш. Таң). *Хәтта дастаннарда калган батыр / Бу зинданда башын югалтыр* (Рәш. Әхмәтҗан. Уян, вөҗдан).

Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

**БАШ ЮГАЛУ.** Кинәт үлеп китү; һәлак булу. *Егетләрдән берсе, авыр гына көрсенеп: – Баш югала торган юлга чыктык,* – <диде> (К. Нәҗми). *Баш югалтып биеп йөргәч кубызга, / Баш югалу серен ачып карыем* («Ватаным Татарстан» газ.).

Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

**БАШ ЮК.** Башы, акылы эшләмәү. *[Кәрим] Шул шул, /Анда бер дә баш юк, / Мие черегән аның* (Г. Камал). *Бездә әнә Рәхмәтуллин дигән бер башсыз министр бар. Башы юк үзенең, әмма урынында нык утыра, бер дә сыгылып төшкәне юк әле, дип юаттым үзен* (Р. Низами. Без яшибез...).

Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**БАШ ЮК, АЯК ЮК.** Тәртипсез, иясе булмаган хуҗалык яки оешма турында. *Юкка гына рәис итеп куйганнар аны. Хәзер кара: баш юк, аяк юк хуҗалыкта* (Сөйләм).

**БАШ ЮКА <БУЛУ>.** – *Мондый эштә миннән нинди киңәш кирәк соң сезгә? Минем баш бик юка, ишеткәнем дә эләгеп тормый хәзер,* – *диде дә Бибинурга карады* (А. Гыйләҗев. Җомга көн кич белән...).

Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**БАШ ЯГАЛАУ** *диал.* Берәр зур эшне башлау. – *Бик күптәнге хәл инде бу, егетләр,* – *дигән булып, баш ягалап җибәрде* (Ш. Маннур. Чын сөю бармы?).

**БАШ ЯКТЫРУ (ЯКТЫРЫП КИТҮ).** Аңлау, төшенү, айну. – *Эшли башлагач килеп чыкты бит, үзеннән-үзе, көтмәгәндә баш яктырып китте дә...* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Мостафаның башы яктырып киткән кебек булды* (Г. Әпсәләмов).

Төрдәше: акыл җиту һ.б.

**БАШ ЯРУ** *к.* баш чыгару. *Бодай да баш ярды бугай инде* (Сөйләм).

Төрдәше: баш чыгару.

**БАШ ЯРЫЛСА, БҮРЕК ЭЧЕНДӘ, КУЛ СЫНСА, ҖИҢ ЭЧЕНДӘ БУЛУ.** Серне башкаларга белдермәскә тырышу хакында. *[Нәгыймә] Бай хатыннары алар бер дә серләрен кешегә сиздерәселәре килми. Аларның башы ярылса, бүрек эчендә, кул сынса, җиң эчендә була* (Г. Камал. Банкрот).

**БАШ ЯРЫЛЫП, КҮЗ ЧЫГУ** *к.* авырлык кичерү. Бәла-каза килү. *Бер көннән баш ярылып, күз чыкмас. Килгән-килгән, җиренә җиткереп кайтырсың* (А. Гыйләҗев).

Төрдәше: авырлык кичерү һ.б.

**БАШ ЯРЫЛЫП, КҮЗ ЧЫКМАГАН.** Ис китәрлек түгел, артык куркыныч түгел. *«Дөрестән дә, нәрсә булган соң әле? Баш ярылып, күз чыкмаган ләбаса!» – дип уйлап куйды ул* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!). *Баш ярылып, күз чыкмаган, тол хатынга хәбәр салучы күп булыр инде* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).

Төрдәше: баш ярылып, күз чыкмаган әле, <кыз чак ике килми>.

**БАШ ЯРЫЛЫП, КҮЗ ЧЫКМАГАН ӘЛЕ, <КЫЗ ЧАК ИКЕ КИЛМИ>** *к.* баш ярылып, күз чыкмаган. *Әйдә, баш ярылып, күз чыкмаган әле, кыз чак ике килми ул* (Ф. Хөсни).

Төрдәше: баш ярылып, күз чыкмаган.

**БАШ ЯРЫП, КҮЗ ЧЫГАРЫП**. Нәрсә эшләгәнне, ни өчен эшләгәнне белмичә, ахырын да уйламыйча, дуамалланып эшләү. *Үзенең милли-мәдәни мохтариятына ышанычы иманына инануы белән бер дәрәҗәдә булса да, баш ярып, күз чыгарып, аңгарга да тотынмады* (Г. Исхакый). *Баш ярып, күз чыгарып йөрүчеләрне әйләнеп узды, колагына чөй тыкканнарны яратмады, аралашмады* (Ә. Хәсәнов. Сабыр төбе сары сагыш).

**БАШ ЯСАУ.** Мич ашы пешергәндә яки квас куйганда, колмак, чүпрә кулланып ачытки әзерләү.

*Тукта әле, безнең авыз да коймак ашап карасын бер, дип, үзеннән-үзе сөйләнеп ала һәм, шулай итеп, коймагына баш ясап куя* (Ф. Хөсни. Сөйләнмәгән әкият). *Мәрьям әби: «Туктале, күәсемә баш ясап, ипи салыйм да Гөләндәмгә шул бурычны үз кулларым белән кертеп бирим әле»* (Ә. Гаффар. Әҗәт).

**БАШ ЯСЫЙМ ДИП КАШ ЯСАУ.** Зурдан тотынып, әһәмиятсез яки кирәксез нәрсә иҗат итү. *Кайсы рәссам, баш ясыйм дип, каш ясый, / Кайсы чүп-чардан җыеп, бер аш ясый* (З. Ярмәки. Барыш).

**БАШ ЯШЬ ӘЛЕ.** Әлегә белеме, тәҗрибәсе җитмәүгә ишарә итү. *[Хәлил] Башыгыз яшь әле, белерсез* (М. Фәйзи. Галиябану).

Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

*БАШАККА* ❖ **БАШАККА ДА ЮК, САЛАМГА ДА ЮК.** Гомумән булдыксыз, надан (күбрәк яшүсмерләр турында). *Нәрсә әйтергә инде, беразөйрәнсен әле, хәзергә аннан башакка да юк, саламга да юк* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

*БАШ-АЯГЫ* ❖ **БАШ-АЯГЫ <БЕЛӘН> БӘЙЛӘНҮ.** Тыгыз, якын мөнәсәбәттә булу. *Шамил еш кына үзенә дә шакката: өйгә алып кайткан көннән бирле шул нәни төенчеккә башаягы белән бәйләнде дә куйды. Шулкадәр якын, шулкадәр газиз, шулкадәр тансык иде бу нарасый!* (А. Әхмәтгалиева. Таллы күлдә былбыл бар).

**БАШ<Ы>-АЯГЫ БЕЛӘН.** Тулысынча, бөтенләй, җаны-тәне белән. – *Чапанның бөтен кибетен башы-аягы белән сатып алам да, үзен куалап, бөтен малын агайнегә таратам* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Бүгенге көн баш-аягы белән, / Бөтен ягы белән өнсез иде...* (М. Әгъләм).

Төрдәше: башы-аягы белән йоту.

**БАШ-АЯГЫ БЕЛӘН САТУ (САТЫП АЛУ).** Хыянәт итү яки бөтенләе белән үз тарафдарың итү. *Өченче көн генә Казанны баш-аягы белән саткан бу бәкләр ни өчен соң кинәт кенә үзгәрде дә кинәт кенә ватанпәрвәргә әверелде?* (Р. Батулла. Сөембикә). *Бу батыр, теләсә, воеводаның үзен дә башы-аягы белән сатып ала* (В. Имамов. Сәет батыр).

**БАШ-АЯГЫ БЕЛӘН ТАБЫНУ.** Җаны-тәне белән бирелү, буйсыну. *Аның хикмәтле җилкәнгә баш-аягы белән табынуы шушы бер ымыннан мәгълүм булды* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**БАШ-АЯГЫ БЕЛӘН ЧУМУ.** Тулысынча мәшгуль булу, бирелү. *Күзләренә операция ясаткач, әнисе, татарча газета-журналларга язылып, татарча китаплар сатып алып, баш-аягы белән укуга чумды* (Ф. Садриев. Кышкы кояш). *Үзен ни көткәнен дә уйламый, башыаягы белән эшкә чумды* (Д. Булатова. Соң түгел!).

**БАШ-АЯГЫ БЕР КАЗАН**. «Кирәгең шуның кадәр генә» мәгънәсендә. – *[Хәйретдин] Чыксаң, уракка хәтле ябышып чыгасың, Сәрби, ә чыкмасаң... Чыкмасаң, баш-аягың бер казан* (Ф. Бурнаш. Яшь йөрәкләр). – *Ярар, кияүгә чыккансың икән, баш-аягың бер казан иде, көн күр – көлдә ауна, дигәннәр* (Ш. Маннур. Чын сөю бармы?).

**БАШ-АЯГЫ БЕР ТИЕН.** «Яраксыз әйбер, кирәге юк» мәгънәсендә. – *Баш-аягы бер тиен булган кешеләр белән таныштырырга ашыкма әле син* (Сөйләм).

*БАШ-АЯК* ❖ **БАШ-АЯК АКТАРЫЛУ**. Тулысынча, бөтенләе белән тикшерелү. *Көн кичкә авышканда, бәрәңге бакчалары, яшертен базлары булмагае дип, баш-аяк актарылып, әрәмәлекләр кат-кат ергаланды* (Ф. Яхин. Ат урлауның ние бар...).

**БАШ-АЯК АЛУ.** Тиз генә җыенып, юлга чыгу. *Юлчылар борсаланып йокламыйча чыкты, ә иртән, чәй дә эчмичә, баш-аяк алды* (Н. Гыйматдинова). *Караңгы кичтә килеп бәйләнгән минем кебек сәер заттан – күрмәгән-белмәгән ир-егеттән баш-аягын алып качасы урынга, кызыксынуын җиңә алмыйча, күземә текәлде* («Мәйдан» ж.).

**БАШ-АЯК БӘЛЕШЕ.** Бар нәрсә дә аст-өст килү, бернәрсә дә аңларлык түгел. *Ә эчендә аның еланнар ысылдый иде: моңа кадәр изеп килдек, моннан соң да рәхим-шәфкать көтмә, безнең кул озын, безгә әле баш-аяк бәлеше пешерергә иртәрәк... Батыр илнең җәнҗалы бетмәс* (М. Әмирханов. Тояк эзе).

**БАШ-АЯК ЙӨРҮ.** Артык тузыну, теләсә нәрсә эшләп йөрү. *Болгарлар кирәгеннән артык туарылып китеп, баш-аяк йөрделәр* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).

**БАШ-АЯК КИЛҮ.** Ыгы-зыгыда мәш килү. *Ике төн буена ул йокы күрмәде, ике көн буена тына белмәде. Өченче көн барысы да баш-аяк килде* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).

**БАШ-АЯК РИЗА БУЛУ.** Тулысынча риза булу. *Бияне яхшы ашатмасаң, колыны начар була, дигән сүз мине җиңде. Мин баш-аяк риза булдым* (Г. Ибраһимов. Алмачуар).

**БАШ-АЯК СЫНДЫРЫП ЧАБУ** *к.* җан-фәрманга очу. *Өйләрдән бандитлар йөгерешеп чыгалар да, атларына атланып, баш-аяк сындырып чабалар* (Н. Дәүли. Язмышка юл).

Төрдәше: җан-фәрманга очу; җан-фәрманга чабу (йөгерү); җан-фәрманга чаптыру (чаптырып китү).

**БАШ-АЯК ЯТУ.** Бөтенләе белән, тулысынча. *Өметләнеп килер көннәремә, мескен гәүдә баш-аяк ятыр* (Ф. Яхин).

*БАШКА* ❖ **БАШКА АКЫЛ КИЛҮ** *к.* акылга килү (кайту) 5. *Бармаклары белән туфракны казыштырып уйланып йөри торгач, аның башына бер акыл килде* (Г. Бәширов).

Төрдәше: акылга килү (кайту) 5 һ.б.

**БАШКА АЛАН (ЯЛАН) ҖИМЕШЕ.** Башка кешеләрдән, кешеләр төркеменнән нәрсәсе беләндер аерылып торучы. *Ә аның улы-кызлары... болар башка ялан җимеше булырга тиеш* (Ә. Еники. Рәшә).

**БАШКА АТ (ТАЙ) ТИБҮ.** «Аңгыралану, юләрләнү» мәгънәсендә. – *Син нәрсә, Хәйдәров, – ди, – Уйласам, минем башыма тай типкән дип беләсеңмени – әллә кем мещанның калдыгы артыннан өстерәлергә!* (Г. Ибраһимов. Яшь йөрәкләр). *Минем башка тай типкәнме әллә?* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: баш китү 3 һ.б.

**БАШКА АҢ КЕРТҮ** *к.* акыл бирү 1. *«Халыкка дөнья гыйлемен өйрәтик, башына аң кертик!» дигән кешеләрне патша бит төрмәгә яба, Себер җибәрә* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: акыл бирү 1 һ.б.

**БАШКА АТ (ТАЙ) ТИПКӘН КЕБЕК.** Дуамаллану, холыксызлану, нәрсә эшләгәнен уйлап җиткермәү. *[Галимә] Башына тай типкән төсле бәрелеп чыгып китте, юләр!* (Ш. Камал. Хаҗи әфәнде өйләнә).

**БАШКА АТ (ТАЙ) ТИПМӘГӘН.** 1. Әлегә акылы башында булу. «Тиле түгел, ул кадәр акылсыз, сантый түгел» дигән мәгънәдә кулланыла. – *Бик шәп аңлыйм! Ул чаклы минем башка тай типмәгән әле!* (А. Вергазов. Үзеңә кайту). *[Беренче кыз] (кызарып). Юк ла, Ханикәм, Алла сакласын. Бикәмнең иренә гашыйк булырга минем башка ат типмәгән әле* (Р. Зәйдулла. Саташкан сандугач).

Төрдәше: башка ишәк типмәгән; маңгайга тай типмәгән.

2. Азмы-күпме тәҗрибә туплаган, бераз булса да акылы бар. *Дәрәҗәгә мендем дип хатын аерып, хатын алып булышырга әллә син мине теге... башыма тай типкән дип белдеңме?* (Н. Исәнбәт). *Өйгә кайтып, хуҗалык эшенә чумарга башка тай типмәгән бит әле* (Ф. Давлетбаев. Юк, җыенмыйм эштән китәргә).

**БАШКА АТЛАНУ.** 1. Артык узыну. *Хөкүмәт иркәләп бетерде. Хәзер менә башка атланалар* (Ф. Яруллин). *«Син кемнәндер булган балаңны Альберт муенына productтың. Хәзер башына атланмакчы буласыңмы?» – диде* («Татарстан яшьләре» газ.).

Төрдәше: башка әтәч булып кунып, кикрикүк дип кычкыра башлау.

2. *к.* бар дип тә белмәү 2. *Әгәр андый булсаң, хәзер сытып-изеп китәләр, башыңа атланалар, ишек катындагы параша янына утырталар* (Р. Кәрами. Сөеп туймас чакларың).

Төрдәше: бар дип тә белмәү 2 һ.б.

**БАШКА ӘТӘЧ БУЛЫП КУНЫП, КИКРИКҮК ДИП КЫЧКЫРА БАШЛАУ** *к.* бар дип тә белмәү 2. *[Баһаветдин] Шулай кирәк ул кәнсәләр халкы белән. Югыйсә, монда башыңа әтәч булып кунып, кикрикүк дип кычкыра башларлар* (Н. Исәнбәт. Һиҗрәт).

Төрдәше: бар дип тә белмәү 2.

**БАШКА БӘЛА.** Үзенә зыян китерү. *Барысы да безнең башка бәла булып туган имгәкләр* (К. Тинчурин). *Иминлекне табар кебек идем, / Исән башка бәла юлыга...* (Ф. Яхин).

Төрдәше: башка бәла алу.

**БАШКА БӘЛА АЛУ** *к.* башка бәла. *Кайгысыз башка бәла алалармы соң?* (Р. Шәрипова. Кеше мода куа дип...). *«Багучыга барма, башка бәла алма» дип, дөрес әйткән икән бабайлар* (Ф. Зариф. Ак бүре рухы саумы?!).
Төрдәше: башка бәла.

**БАШКА БӘЛА ТАГУ.** Гаеп эш эшләгән дип санау. *Ялган акча ясаучы дип, / Башка бәла тактылар* (Т. Гыйззәт). *Сарык табыла. Башка бәлаләр тагып, Хөрмәтулланы барыбер тереләй кабергә күмәләр* («Казан утлары» ж.).

**БАШКА БӘРЕП ӘЙТҮ.** Дөресен туп-туры, ачыктан-ачык әйтү. *Бу юлы инде икеләнеп тормадылар, кимчелекләрен башына бәреп әйттеләр* (Сөйләм).
Төрдәше: биткә әйтү; биткә бәрү (бәреп әйтү); биткә чәпәп әйтү; дөреснең аргы ягында булу; йөзгә бәрү (бәреп әйтү); йөрәккә үткәреп әйтү (язу); күзгә терәп <әйтү>; морҗасы кәкре булса да, төтене туры; туры сүз; туры юл табу.

**БАШКА БӘРҮ.** 1. Артык борчылудан, күп уйланудан баш авырту. *Кирәкмәгән нечкә күңелле нәрсә, уза китеп, башына бәрмәгәе дип тә куркып куям шунда* (Г. Бәширов. Намус). *Ул агып торган су агымы астына кереп басты. Арган тән башка бәрә иде* (А. Нәҗми. Йолдызлар балкышы).

2. *к.* акылын эчеп бетергәнче. – *Аннан соң сыра исе башка бәрә...* (Р. Батулла. Сөембикә). *Чыннан да, аракыны беренче тапкыр татыган Шүрәле Җирән төк углы Яшел Мөгезнең башына бәргән иде* (Ә. Гаффар. Богау).
Төрдәше: акылын эчеп бетергәнче һ.б.

**БАШКА БИРҮ.** *к.* баш түбәсенә <китереп> бирү. *Инде, җаным, дустым, димәм, / Башка бирде соскы белән* (Г. Афзал. Юкка-барга).
Төрдәше: баш түбәсенә <китереп> бирү һ.б.

**БАШКА БОЗАУ ТИБҮ** *к.* баш китү 3 *[Хуҗа] Дәрәҗәгә мендем дип хатын аерып, хатын алып булышырга, әллә син мине теге... башыма бозау типкән дип beләсеңме?* (Н. Исәнбәт. Хуҗа Насретдин).
Төрдәше: баш китү 3 һ.б.

**БАШКА БОЗЛЫ СУ КОЙГАНДАЙ ИТҮ.** *Заһидәнең ярсып түгел, чыгырыннан чыгып та түгел, ә эчке бер ышанычы белән нык итеп әйтелгән бу сүзләре Фирдүснең башына бозлы су койгандай итте* (М. Маликова. Кызыл гөл).
Төрдәше: аркага (аркасына) бозлы (кайнар; салкын; эссе) су койган (сипкән) кебек булу һ.б.

**БАШКА ДА АЛМАУ.** Бар дип тә белмәү, уйлап та карамау. *[Сәҗидә]. Авызыңнан җил алсын. Булмаганны. Андый ямьсез уйны ялгышып та башыңа алма* (Д. Салихов).
Төрдәше: башка да кертмәү; башка да килмәү; башка да китермәү; башка да тыкмау.

**БАШКА ДА КЕРТМӘҮ** *к.* башка да алмау. *Ул вакытларда, үсеп буйга җиткән гөрнәдердәй дүрт улын сугышта югалтырмын, үлгән гәүдәләрен, барып еларга каберләрен дә таба алмам дип башына да кертми* (И. Нәбиуллина. Миләш тәме).
Төрдәше: башка да алмау һ.б.

**БАШКА ДА КИЛМӘҮ** *к.* башка да алмау.– *Сумканы актарып карау башыма да килмәде* (Ә. Моталлапов. Елан җылыга елыша).
Төрдәше: башка да алмау һ.б.

**БАШКА ДА КИТЕРМӘҮ** *к.* башка да алмау. – *Яхшы сугышыр өчен мәктәптә укырга кирәклекне элек башыма да китерми идем* (Г. Әпсәләмов. Газинур).
Төрдәше: башка да алмау һ.б.

**БАШКА ДА ТЫКМАУ** *к.* башка да алмау. *Килешмәүнең, йә булмаса – Ходаем үзең сакла! – карышуның, әрепләшеп торуның дөньяда булуы мөмкинлеген Сәйфетдин башына да тыкмый* (Ш. Хөсәенов. Мәхәббәт һәм нәфрәт).
Төрдәше: башка да алмау һ.б.

**БАШКА ДӘҮЛӘТ КОШЫ КУНУ.** Көтмәгәндә бәхеткә, байлыкка ирешү. *Башларына дәүләт кошы кунган ахрысы, яңа машина алып җибәргәннәр!* (Сөйләм).

**БАШКА ДӘҮЛӘТ ЯУСЫН!** «Байлыкка, уңышка ирешү» дигән теләк. *Башыңа дәүләт яусын!* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).

**БАШКА ҖИТҮ.** 1. Бәхетсезлек китерү, кыен хәлдә калдыру. *[Закир] Минем башыма җиткән шикелле, инде хәзер ул кешенең башына җитмәкче, аның кесәләрен бушатмакчы була торгандыр* (Г. Камал. Бәхетсез егет). *Һе, таза*

*булмаска ни! Яз буе ничә сарыкның башына җитмәгәндер дисең син аны!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

2. Кемне булса да үзенә карату, уй-ихтыярына хуҗа булу. – *Әй, иблис токымы! Тәки кызымның башына җиткәнсең икән! – диде ул, Фәләхнең сәламен дә алып тормыйча* (В. Нуруллин. Фаҗига).

3. *к.* адәм башкайларын салу. – *Төнлә белән кереп анасының башына җиткәннән соң, менә шул матурга ябышканнар* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). – *Ул әнәтерәк мин олы кеше дип тормый, һаман йортыма зыян салып ята. Быел гына да ун тавыгымның, биш казымның башына җитте* (Н. Гыйматдинова. Күке төкереге).

Төрдәше: адәм башкайларын салу һ.б.

4. Юк итү, бетерү; табигатькә һәлакәт китерү. *Борын тишегеннән әрсезләнеп тырпайган төкләрнең башына эскәк җитте* (А. Гыйләҗев. Әтәч менгән читәнгә). *Мәрхүм ире Сапый белән шактый шешәнең башына җитте* (Р. Зәйдулла. Шүрәле).

**БАШКА ҖИТҮЧЕ.** Зыян салучы, начарлык эшләүче. *[Хәйретдин] Мәфтуханың башына җитүче син үзең ул* (А. Әхмәт. Үги кыз).

**БАШКА ҖЫРЛАР ҖЫРЛАУ.** Бөтенләй башка төрле сөйләү. *Ул [абыстай] бөтенләй башка җырлар җырлый иде: ул мужик халкының мулла-мөәзинне карамавыннан зарлана, гошер биреп малыны хәлалләмәенчә ашавына ачулана, ил-көндәге бозыклыкларны шуннан күрә, хатын-кыз мәҗлесендә «гошерсез мал хәрам була-фәлән» дигән сүзләрне мулла хатыныннан да еш ычкындыра иде* (Г. Исхакый. Кияү).

**БАШКА ИШӘК ТИБҮ** *к.* башка ат (тай) тибү. *Заһид Мәхмүдинең башына ишәк типкән!* (magarif-uku.ru).

Төрдәше: башка ат (тай) тибү һ.б.

**БАШКА ИШӘК ТИПМӘГӘН** *к.* башка ат (тай) типмәгән. *Алай дип әйтергә минем башка ишәк типмәгән* (И. Гази).

Төрдәше: башка ат (тай) типмәгән һ.б.

**БАШКА ЙӨГЕРҮ** *к.* акылын эчеп бетергәнче. *Хи-хи, бераз башка йөгерде бугай теге нәмәрсәгез* (Р. Батулла). *Тагын бер нәрсәгә игътибар итте Рәмил, акны йотсаң, бераздан башка йөгерә, мине томалый, телне ача, ә бу хикмәт, шәраб, кан юлларын кыздырды <...>* (К. Кара. Матильда).

Төрдәше: акылын эчеп бетергәнче һ.б.

**БАШКА КАБУ.** Тышкы тәэсирдән баш авырта башлау. *Озак та үтми, бу ятлаулар, кабатлаулар ялыктыра башлый, бозык һава белән шаугөр башларга каба* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Башка каба эфир, кан исе, / Әйтә алмый сабый сүзләрен* (Ф. Кәрим. Гөлсем).

**БАШКА «КАМЫРДАН» <ӘВӘЛӘНГӘН; ЭШЛӘНГӘН>.** Табигате ягыннан бөтенләй башка кеше булу. *Хатыны белән чагыштырганда, Хисмәт әнә бөтенләй башка «камырдан: йомшак та, ягымлы да* (Л. Хәмидуллин. Буранлы төндә). *Бу бөтенләй дә аның килене кебек түгел, бу бөтенләй башка камырдан* (М. Кәбиров. Бердәнбер һәм кабатланмас).

**БАШКА КАН БӘРҮ (САВУ).** *Башына кан бәрде, йөрәге атылып чыгардай булып тибә башлады* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур). *Башка кан сава башлагач, озак түзеп булмый икән ул* (К. Кәримов. Ком сәгате).

Төрдәше: башка кан йөгерү; башка кан китү; башка сугу.

**БАШКА КАН ЙӨГЕРҮ.** 1. Көтелмәгән вакыйга яки хәбәр көчле тәэсир ясау. *Аның сеңерләре бик нык булса да, башына кан йөгерде, колаклары яна башлады* (Г. Исхакый. Кияү). *Сәетнең бугазына төер килеп тыгылды, тагын базардагы халәте кабатланды – башына кан йөгерде, үз-үзен белештермичә, ишек катындагы урындыкка килеп төште* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).

Төрдәше: башка кан бәрү (саву) һ.б.

2. *күч.* Тиз үпкәләү, үз-үзен кулында тота алмау. *Соңыннан Зәйнәп сөйләве буенча, кырда авылның хәзерге председателе Исмәгыйль белән Зәйнәпнең очрашулары, Исмәгыйльнең Зәйнәпне кочаклап үбүләрен күз алдына китерергә тырышты, аның йөрәге ут кебек янды. Башына кан йөгерде* (Һ. Такташ). *Габделнурның башына кан йөгерде, хатны тоткан кулын яза алмады, тыны кысылды. Ике фикер анда нәкъ биш-алты секунд көрәште* (М. Мәһдиев. Ут чәчәге).

Төрдәше: башка кан китү.

**БАШКА КАН КИТҮ** *к.* башка кан йөгерү 2. *Кызның йөргәнә тулкын йөгерде, каны башына китте* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).
Төрдәше: башка кан йөгерү.

**БАШКА КАПЛАУ.** «Теләсә ничек файдалан» дигәнне аңлата: базарда бәядән төшмәгәндә әйтелә. *[Баһаветдин] Башыңа капла. Нәрсәгә дип күтәреп йөрим мин аларны* (Н. Исәнбәт. Һиҗрәт). *Менә моны башына каплыйм әле мин аның!* (М. Маликова. Оҗмах балалары).

**БАШКА КЕЛТ ИТЕП БЕР СОРАУ (УЙ) КИЛҮ (КИЛЕП ТӨШҮ)** *к.* келт итеп искә төшү. *Минем башка келт итеп: – Бәй, бу Гафури үзе микәнни? – дигән сорау килде* (Х. Маннан. Ул минем остазым иде).
Төрдәше: келт итеп искә төшү.

**БАШКА <ДА> КЕРЕП ЧЫКМАУ.** Уйлап та карамау.– *Ярарга тырышыйм, дигән уй, ичмасам, башыгызга да кереп чыкмый* (С. Җәләл. Юләр). *Күл буена кабат килмәбез дип, / Башыма да кереп чыкмады* (И. Гыйләҗев. Кемнән тора соң ул?).
Төрдәше: башка <да> кермәү; башка кертеп карамау; башка <да> килмәү; башка китерә алмау; башка <да> китермәү.

**БАШКА <ДА> КЕРМӘҮ.** Төшенә алмау, аңлый алмау. *Шуңа күрә урманнан качу, кая булса да югалып тору Рөстәмнең башына да кермәде* (Г. Кутуй. Рөстәм маҗаралары). *Мулланың юан корсагын, майлы күзләрен күрдемме, берни башка керми* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).
Төрдәше: башка <да> кереп чыкмау һ.б.

**БАШКА КЕРТЕП АЛУ (УТЫРТУ).** Берәр сүзне, хәбәрне, фикерне хакыйкать дип кабул итү һәм шуннан ваз кичәргә теләмәү. *Әтисе егетнең башка шәһәрдән килгәнлеген белгәч, моны башына кертеп утырткан да «килмешәк егет» дип кенә җибәрә иде* (Сөйләм).

**БАШКА КЕРТЕП КАРАМАУ** *к.* башка да кереп чыкмау. *Вәзилә апасының таләпләре шулай булыр дип белә иде: Зөфәр һәм берзаман ике арада шундый сүз дә чыгар дип башына да кертеп карамаган иде* (А. Гыйләҗев. Әтәч мengән читәнгә). *Мондый кыенлыкка да очрармын дип, Гөлнара Рәшитовна башына кертеп карамаган иде* (Ф. Яхин. Мөгаллимә кыз).
Төрдәше: башка <да> кереп чыкмау.

**БАШКА КЕРҮ.** Аңда туктаусыз, көтмәгәндә барлыкка килү. *Өч тиенгә кирәкмәгән чүп-чар зиһенне чуалтып башка керә, ә өч сум акча кайдан табарга – һич баш җитми* (Г. Афзал. Изгеләр бәянында). *Ниһаять, Газинур барысын да төшенде, бөтен йөзе белән елмаеп: – Башка керде, иптәш капитан! – диде* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

**БАШКА КИБӘК ТУТЫРУ.** Белем бирү урынына, замана өчен искергән, кирәксез нәрсәләр бирү. *Искелекнең кара көче, «гыйлем» дип, аның башына кибәк тутырды* (Ә. Фәйзи. Тукай).

**БАШКА <ДА> КИЛМӘҮ.** Берәр нәрсәне уйлап та карамау. *Нәҗипләрне урман аланына өндәр дип, Сөмбеләнең башына да килмәде, Сабитыннан күргән саран җылылыктан эреп, онытылып йоклап китте* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Аның тавышы бик көчле иде һәм мондый чын тавыш Коръән укып утыручының ат карагы булу мөмкинлеге бирәүнең дә башына килмәде* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).
Төрдәше: башка <да> кереп чыкмау һ.б.

**БАШКА КИЛҮ** *к.* акыл<га> утыру. *Ишеттем мин кичә: бирәү җырлый / Чын безнеңчә матур, милли көй; / Башка килә уйлар төрле-төрле, / – Әллә нинди зарлы, моңлы көй* (Г. Тукай. Әллүки). *Биредән шул үлеп котылсалар гына... Башка килгән уй-фикергә богау сала алмыйсың* (А. Хәсәнов. Данәгөл).
Төрдәше: акыл<га> утыру һ.б.

**БАШКА КИТЕРӘ АЛМАУ.** Эшнең асылын, максатын аңлый алмау. *Нәҗип абыйсының мактанырга атлыгып торуын аңлады, максатын гына башына китерә алмады Сабит, көче-егәре, башкарган зур эшләре белән аны аста калдырырга тели дип уйлады* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: башка <да> кереп чыкмау һ.б.

**БАШКА КИТЕРЕП СУГУ.** Көтелмәгән хәл булу. *Сәмирнең башына китереп суктылармыни, көтелмәгән хәбәрдән имәнеп китте* (Г. Тарханова. Үлемсез мәхәббәт). – *Аны стансадан каршы алырга иде, әни. Хатынның башына китереп сукты* (Н. Гыйматдинова. Елан).
Төрдәше: башка бирү; башка күсәк белән ору 2; башка сугу 2.

**БАШКА <ДА> КИТЕРМӘҮ.** Уйлап та карамау. *Ләкин хөкем залында аның белән очрашу ихтималын бертөрле дә башына китерми иде* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар). *Әнием ул вакытта шигырьнең Тукай тарафыннан үзенә карата язылганлыгын башына да китерми* (А. Расих. Ишан оныгы).
Төрдәше: башка <да> кереп чыкмау һ.б.

**БАШКА КИТЕРҮ (КИТЕРЕП КАРАУ).** Уйлау, фараз итү. *«Мунча түбәсен Сабит яба алмый идеме?» – диде Нәҗип, бүтән уйны башына китерергә теләмичә* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Борын тишекләренә килеп тыгылган кан төерләреннән атның сулышы кысылу һәм шуңарга үрсәләнүен ул ничек башына китерә алсын* (Р. Мөхәммәдиев. Бары тик беренче).

**БАШКА КИТҮ.** 1. Көчле хиснең тәэсире башта калу. *Аның башка барам дип киенгән кыяфәтләре һәммәсе дә искә төшәләр, башка китәләр иде* (Г. Газиз. Олуг ләгънәт).

2. *к.* акылын эчеп бетергәнче. *[Әхмәт] Кара әле, Шөҗаг, миңа җитте, мин эчмим. Болай да инде башка китте* (Г. Камал. Дәҗҗал). *Мәҗлес мәҗлес инде ул, сикрит-микрит түгел, үземнең дә башка китеп өлгергән иде* (Ф. Баттал. Гармунчы Гаптери).
Төрдәше: акылын эчеп бетергәнче һ.б.

**БАШКА КӨЛ СИБҮ (КОЮ)** *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. *Башкаема коеп елыйммыни / Нигеземнән калган көлемне?* (Зөлфәт. Йөрәгемне былбыл чакты). – *Башыңа көл сибәсе генә калды бу кыяфәтең белән* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**БАШКА КУНДЫРУ** *к.* авыз җебетү 2. *Ә Фатихәттәй үзе болай сөйли иде: янәсе, ул, ачуы килеп, җирдән таш алган да атлы казакның башына кундырган* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**БАШКА КҮСӘК БЕЛӘН ОРУ.** 1. *к.* авыз җебетү 2. *Торып утырмакчы булган иде, башына күсәк белән ордылар* (Ә. Хәсәнов. Бәхет кайда оя кора).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

2. Көтелмәгән хәл булу, авыр сүз ишетү. *Әлеге хәбәр аның башына күсәк белән органдай итте* (Ф. Садриев. Адәм әүлиясы). *Гөлүсәнең вафат булганын ишеткәч, миңгерәеп киттем, башыма күсәк белән китереп органдай булды.* (М. Маликова. Арыш тәме).
Төрдәше: башка бирү һ.б.

**БАШКА КЫЗУ КАБУ.** Төрле уйлар буталудан зиһен таралу. *Уф, ыгы-зыгыдан башыма кызу капты* (З. Хәким).

**БАШКА МЕНҮ (МЕНЕП АЛУ; МЕНЕП УТЫРУ)** 1. *к.* бар дип тә белмәү 2. *[Камали] Миңа дигәндә, атасының башына менеп утырган булса да кирәкми* (Ф. Бурнаш. Камали карт). *Балак бете башка менсә, әтәч булып кычкыра, ди* (В. Имамов. Тозлы яра).
Төрдәше: бар дип тә белмәү 2 һ.б.

2. *к.:* акылын эчеп бетергәнче. *Шәраб җылысы канга үтте, башка менде* (Т. Галиуллин. С. Сакманов). *Кемдер анда эшендә халтурить иткән дә иптәшенә сылаган, ә хәзер хәтер калулар, хәмер сулышы башка менә башлагач, калкып өскә чыкты* (А. Расих. Сынау).
Төрдәше: акылын эчеп бетергәнче һ.б.

**БАШКА НИ КИЛСӘ, ШУНЫ ЭШЛӘҮ.** Күңел нәрсәгә төшсә, шуны эшли башлау. – *Башыңа ни килсә, шуны эшләргә тырышма әле, монда тәртип дигән нәрсә бар* (Сөйләм).

**БАШКА САЛУ.** 1. Уйлау, төшенү. – *Моны төзергә Садыйкның акылы ярдәм итте, Фәхри моңа командир булды. Шулай булгач, дус буламы, дошман буламы? Үзең башыңа сал!..* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).
Төрдәше: акыл аша уздыру һ.б.

2. *к.* башка бирү. *Чөнки ул һәркемне бөтен шәкертләр алдында яндырып сүгәргә, аның белән дә канәгатьләнмәсә, ни очраса, шуның берлән алып башына салырга хәзер иде* (Г. Ибраһимов). *[Диләрә] Телефоны белән башына салыр идем!* (А. Гыйләҗев).
Төрдәше: башка бирү һ.б.

**БАШКА СЕҢДЕРҮ** *к.* акыл аша уздыру. *Аны башыңа сеңдереп уйлансаң, әллә кайларга барып чыгарсың* (М. Хуҗин. Чеметемнән – табышларга). *Бүлмәсенә кайткач, ул сөйләгәннәрне бик озаклап миенә, башына сеңдереп утырды Билал* (М. Вәли. Качу).
Төрдәше: акыл аша уздыру һ.б.

**БАШКА СУГУ.** 1. Кинәт искә төшү. *Башка сукты бит бу минем* (М. Әмирханов). *Йокымсырап утырган Барыйның башына суктылармы-*

*ни – ул кинәт сикереп торуын сизми дә калды* (А. Гыймадиев. Үзең булып кал!..).

Төрдәше: акылга килү һ.б.

2. Авыр хис тудыра торган хәбәр, сүз ишетеп кинәт сискәнеп китү. *Җәгъфәр әфәнде, башына суккан кебек, борылды һәм чыга башлады* (Г. Исхакый. Ике йөз елдан соң инкыйраз). *Башыма нидер сукты, телем тотлыкты, сүз әйтә алмый катып калдым* (Г. Ибраһимов. Алмачуар).

Төрдәше: башка бирү һ.б.

**БАШКА СУККАНДАЙ ИТ<ТЕР>Ү.** Кеше белән тупас мөгамәләдә булу. *Ул әнисенең йокы бүлмәсенә килеп керде, башка суккандай иттереп сорады: – Син кайчанга кадәр безгә аяк чалачаксың, әни?* (К. Тимбикова. Тын бакчада). *Мәктәптә татар телен укыту мәсьәләсенә җиткәч, ул «миңа татар теленең кирәге булмады, кирәк тә түгел» дип, минем башыма суккандай итте* («Мәдәни җомга» газ.).

Төрдәше: башка суккандай чыгып китү.

**БАШКА СУККАНДАЙ ЧЫГЫП КИТҮ** *к.* башка суккандай ит<тер>ү. *Төрле сүзләрне тыңлап утырды-утырды да түзмәде, башына суккандай чыгып китте* (Сөйләм).

Төрдәше: башка суккандай ит<тер>ү.

**БАШКА СҮЗЛӘР БЕЛӘН ӘЙТСӘК (ӘЙТКӘНДӘ).** Бүтәнчә, икенче төрле итеп әйткәндә. *<…> көндәлек чынбарлыкның эстетик сәнгатьчә чагылышын таба, башка сүзләр белән әйткәндә, ул «көн кадагындагы» мәсьәләләрне, көчәнмичә генә әдәбиләштереп, укучы алдына ачып сала* (К. Гыйззәтов. Нәфасәт). *Ерак Көнчыгышта аның бу карашын яклаганнарның бер өлеше Советларның цилиндры астында изелделәр. Башка сүзләр белән әйткәндә, сәясәт корбаны булдылар* (Н. Дәүләт. Ерак Көнчыгыштагы татар-башкортларга ни булды?).

Төрдәше: башка төрле әйтсәк (әйткәндә); башкача әйтсәк (әйткәндә).

**БАШКА СЫЙМАУ (СЫЙДЫРА / СЫЯ АЛМАУ; СЫЕШМАУ).** 1. Ышана алмау, аптырау, гаҗәпләнү. *Мондый бер хәл һичкемнең башына сыя алмый* (Г. Ибраһимов. Алмачуар). *Шуңа күрә дә җәйге ял чорында өч ай буенча аерылышып тору беребезнең дә башына сыя алмады* (М. Әмир. Агыйдел).

Төрдәше: авыз ачып калу 5 һ.б.

2. Төшенмәү, акыл ирешмәү, аңлап җиткермәү. *«Син – чиксез», ди. / Әмма бу чиксезлек / Безнең башка сыймый ничек тә* (Х. Туфан). – *Мунчага, изге урынга нигә төн уртасында алып киләләр? / Монысын һич кенә дә башыма сыйдыра алмыйм* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).

Төрдәше: авыз ачып калу 5 һ.б.

**БАШКА СЫНАУ КИЛҮ.** Тормышта авыр хәл белән очрашып, аннан чыгу юлын эзләү. – *Сез әле яшьләр, башыгызга сынау килгәнне көтеп йөрмәгез, вакытында Аллаһ җебенә тотыныгыз, үскәнем...* (Л. Муллагалиева. Тыңла, Нәфисә!).

**БАШКА СЫЯ ТОРГАН ТҮГЕЛ** *к.* башка сыймау (сыйдыра / сыя алмау; сыешмау). *Монысы инде берничек тә башка сыя торган хәл түгел иде* (М. Маликова. Язгы такыялар).

Төрдәше: авыз ачып калу 5 һ.б.

**БАШКА ТАМЫЗУ** *к.* авыз җибәтү 2. *[Бари] Ә мин тормозга дигән күсәк белән менә моның башына җайлап кына берне тамыздым да урманга сөйрәп алып кереп киттем* (Ю. Әминов. Умырзая чәчәкләре).

Төрдәше: авыз җибәтү 2 һ.б.

**БАШКА ТАЯК БЕЛӘН СУККАНДАЙ БУЛУ** *к.* аяз көндә (көнне) яшен сугу. *Ә үземә икенче көнне арттан башка таяк белән суккан кебек кенә булган иде, соңын хәтерләмим* (З. Зәйнуллин. Карбыз сугышыннан чын сугышка). *Кызымның сүзләре башка таяк белән суккан кебек булды* («Кызыл таң» газ.).

Төрдәше: аяз көндә (көнне) яшен сугу һ.б.

**БАШКА ТИЮ.** Баш авыруы башлану. *Машинада хәрәкәтсез утырганга, аның болай да сызланучан аяклары оеп киткән, бензин исе башына тигән иде* (М. Маликова. Язгы такыялар).

**БАШКА ТӨКЕРҮ.** Мыскыллау, түбәнсетү. *Тезгә чүккән кешенең башына төкерәләр, ул хуҗа кимереп ташлаган сөяк-санакны ишек төбендә көтеп утыручы мескен эт баласы хәленә кала икән* (В. Имамов. Казан дастаны).

**БАШКА ТӨРЛЕ ӘЙТСӘК (ӘЙТКӘНДӘ)** *к.* башка сүзләр белән әйтсәк (әйткәндә). *Геноцидның икенче формасы – биологик геноцид, башка төрле әйткәндә, халыкны турыдан-туры үтереп бетерү түгел, ә аны икътисади*

*авыр шартларга куеп, ач-ялангач тоту, биологик яктан юк итү* («Безнең мирас» ж.). *Чөнки бала кечкенәдән үк җаны, йөрәге белән үзенең халкын, телен яратырга, милли горурлык хисләре белән янарга, башка төрле әйтсәк, туган җиребездә ныклы тамыр җәяргә тиеш* («Яңарыш» газ.).

Төрдәше: башка сүзләр белән әйтсәк (әйткәндә) һ.б.

**БАШКА ТӨШКӘЧ.** Бәхетсезлегеңә каршы, күрәсе булгач. *Башка төшкәч, түзәсең икән, мәҗбүрән киттем* (Г. Ибраһимов). *Башка төшкәч, күзге пычракка / Иелмәсен икән кем башы?!* (Рәш. Әхмәтҗан. Карга каргышы).

**БАШКА ТӨШҮ.** Берәр хәлдә калу, шуңа дучар булу. *Бу яратуның авырлыгы, бигрәк тә, Фазыл энем белән минем башка төште* (Ф. Хөсни. Без ни өчен беренче җизнидән биздек). *Башларыңа төшкәч, аңлыйсың шул: / Кошлар юлы нигә туган якка?* (Х. Әюп).

**БАШКА ТУКУ.** Исенә төшереп тору, кат-кат әйтү. *Тормыш башка тукып килә: / дусларыңнан сагай! ди* (Р. Фәйзуллин. Чыныгу). *Совет чоры, коммунистлар «Алла юк, дин – әфьюн» дип, гел башка тукып торсалар да, ышанган кеше ул заманнарда да ышанды* (Д. Гыйсметдин. Һәркемнең үз кайгысы).

Төрдәше: авыздан салмау һ.б.

**БАШКА УТ КАБУ.** 1. Көчле борчылу. *Уйлы башка ут кабар дигән сүз бар бугай* (Ш. Маннур. Чын сөю бармы?). *Башына ут капкан Ихсанбай бәрәңге сабаклары аша лапас астына йөгерде, күзе абзар почмагында торган көрәккә төште, шуны тиз генә эләктереп, кире теге урынга килде* (Т. Гарипова. Мөгри-мөгри килә Бәйрәкәй).

Төрдәше: аһ ору һ.б.

2. Нык гашыйк булу. *Бер шырпыга гына түзеп булыр иде, аның йөрәгендәге шырпылар көн үткән саен да төшми, ахрысы. Башларына ут кабызган кырык шырпы да аның йөрәгендә бугай* (И. Нәбиуллина. Ташта үскән гөл).

Төрдәше: баш әйләнү 8 һ.б.

**БАШКА УТЫН АГАЧЫ ТӨШКӘН КЕБЕК БУЛУ** *к.* аяз көндә (көнне) яшен сугу. *Артта нидер дөбердәгән сыман итте, һәм башыма утын агачы төшкән кебек булды* (Сөйләм).

Төрдәше: аяз көндә (көнне) яшен сугу һ.б.

**БАШКА УТЫРТУ.** 1. Хәтергә сеңдерү, ышандыру. *Буаз дигәч, мин инде аның булачак колынын, әлбәттә, алмачуар дип, чабышкы дип башыма да утырткан, бөтен иптәшләргә дә мактанып беткән идем* (Г. Ибраһимов. Алмачуар).

2. *к.* баш түбәсенә <китереп> бирү. *Күп уйлап тормады, кулындагы казыгы белән тегенең башына утыртты да җан-фәрманга чабып китте* (Сөйләм).

Төрдәше: баш түбәсенә <китереп> бирү һ.б.

**БАШКА ЧӘЙНӘП ЯГУ.** Үзенеке итәргә теләп тә, булдыра алмаганда әйтелә. *[Гөлҗиһан]. Ай, әҗәткана, шулмыни? Сираҗины башларына чәйнәп яксыннар, юләр белән тормасам, миңа ир бетмәгән* (Г. Камал).

**БАШКА ЧҮБЕК (КИБӘК) ТУТЫР<ЫЛ>У.** Аңгыра, тинтәк кеше турында. *[Мәрьям] Әстәгъфирулла! Әллә башыңа чүбек тутырдылармы?* (Ф. Яруллин). *– Беребезнең дә башына чүбек тутырылмаган, йөрәге дә таш түгел* (М. Маликова. Кызыл гөл).

Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.

**БАШКА ЧЫГАРУ.** Аерым яшәр өчен, йорт салу. *– Хәзергә төп нигезгә сыеп торабыз, йортны өлгерткәч, әти безне башка чыгара, диген* (М. Хуҗин. Килен төшкәч). *Моннан ары җиткән кызларыгыз өчен дә, башка чыгарга җыенган улларыгыз өчен дә салым түләячәксез* (В. Имамов. Казан дастаны).

**БАШКА ЧЫГУ.** 1. Аерым йорт салып, ата йортыннан бүленеп чыгу, аерым яши башлау. *Алар күптән түгел генә башка чыкканнар икән* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Болай да җирсезлектән интеккән, җир-сулары төрле яклап кысрыкланган балаларың шуңа баш күтәрә, башка чыкмак булып, күрәсең* (М. Әгъләм).

2. Бер авылдан аерылып чыгып, яңа яшәү урынына нигез салу. *Заманында Иске Сәеттән аерылып башка чыккан һәм, һәр яңа авылга хас булганча, табигатьнең ифрат та гүзәл җиренә урнашкан – аның ындыр артыннан ук катнаш «кара урман» башланып китә* (Н. Гамбәр. Яшьлек хатирәсе).

**БАШКА – ЫШТАН, АЯККА БҮРЕК.** Киресенчә эшләнгән, буталчык эш. *[Баян] Кемгә генә карама – башында ыштан, аягында*

*бүрек, дигәндәй гомер азакларында үкенеп яталар. [Сара] Ата-инәләре риза булмаганда, элек кызлар ябышып кияүгә чыкканнар бит. Ә боларда – Ленар абзый ябышып өйләнгән!* (Р. Хәмид. Тигезәкләр).

**БАШКА ЭССЕ СУГУ.** Эсселектән баш авырту. *Аның башына эссе суккан булып чыкты* («Безнең гәҗит» газ.). *Башка эссе сукканда, бүлмәне җилләтәләр, хастаның башын югарырак күтәреп яткыралар, өстенә юеш җәймә ябалар, салкынча чәй, су эчерәләр* («Ватаным Татарстан» газ.).

**БАШКА ЭШ ТӨШҮ.** Нужа күрү, михнәт чигү. *Шулай булгач, мәкаль булып китәрлек мәгънәне башына эш төшкән һәр кеше үзе чыгарып әйтү шарт түгел, һәм ул тормышта күбесенчә шулай да: башыңа бер эш төшсә, аптырасаң, бар, дөнья күргән берәр акыллы кешегә киңәш ит* (Н. Исәнбәт. Мәкальләребез турында). *Шул кадәр кабаланып китәрлек башына нинди эш төште икән тагы?* (М. Фәйзи).
Төрдәше: ачы яшь түгү һ.б.

**БАШКА ЮЛДАН СҮЗ БАШЛАУ.** Сүз барышында бер темадан икенче темага күчү. – *Ашыкмый тор әле, башка юлдан сүз башларга шомарып беткәнсең син* (Сөйләм).

**БАШКА ЯВУ.** Бәла-каза булып килү. *Меңләгән гаепсезләр башына яуган бу бәла ничек итеп аны читләтеп үтеп китте икән?* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Булат, башына яуган бөтен бәласе өчен, шуны үзенә беренче булып сүз каткан хатыннан үч алган сыман, балтасын җиргә бәрде* (Ә. Гаффар. Энә күзе).

**БАШКА ЯРЫП САЛУ.** Яхшы итеп аңлату. *Халыкта «башына ярып салу» дигән тәгъбир бар. «Яхшы итеп аңлату» мәгънәсендә кулланыла ул* (М. Кәбиров. Җанның ялангач чагы).

**БАШКА ЯШЕН СУККАН КЕБЕК <БУЛУ>** *к.* авыз ачып калу 5. *Бу нәрсә Габдулланың башына яшен суккан кебек тәэсир итте* (Һ. Такташ).
Төрдәше: авыз ачып калу 5 һ.б.

*БАШКА-БАШ* ❖ **БАШКА-БАШ АЛЫШУ.** Берәр нәрсә алышканда, бертигез күләмдә яки микъдарда гына алышу; нәрсәләре ягыннан булса да тиң булу. *Базарларда атны алмашты, / Өстәү бирми – башка-баш кына* (С. Хәким. Газим үрендә).
Төрдәше: башма-баш алмашу.

*БАШКАСЫ* ❖ **БАШКАСЫ МАЙДА ЙӨЗГӘН КЕБЕК БАРАЧАК.** «Башлап җибәрүе генә авыр иде, башлагач бик җиңел дәвам итәчәк» мәгънәсендә. – *Хәзер инде шигем юк, башкасы майда йөзгән кебек җиңел барачак* (Сөйләм).

*БАШКАЧА* ❖ **БАШКАЧА ӘЙТСӘК (ӘЙТКӘНДӘ)** *к.* башка сүзләр белән әйтсәк (әйткәндә). *Ләкин сүз сәнгатенең асылы, көче идеологик факторлардан гына торамы? Башкача әйтсәк, А. Гыйләҗевнең Х. Туфанга карата тискәре бәясе өстен, хәлиткеч булып чыгамы инде?* (С. Хафизов. Ислах, яки Яманаттан ярлыкау).
Төрдәше: башка сүзләр белән әйтсәк (әйткәндә) һ.б.

*БАШ-КҮЗ* ❖ **БАШ-КҮЗ АКАЮ (ТОНУ).** 1. Иләсләнү, үз-үзен белештермәү. *Башы-күзе тонган малайларыбызны кулларыннан ычкындырдылар да, чебендәй сибелешеп, шундук җан-фәрманга йөгерделәр* (Р. Низами. Кояш – минем авылдашым). *Сарык көтүе кичен авылга килеп кергәндә шулай була, шикәр шакмагы хәтле генә тояклары белән тузан туздыра-туздыра, баш-күзләрен акайтып, бар көчләренә чабалар* (З. Хөснияр. Каешлану).
Төрдәше: авыз <ни / нәрсә> әйткәнне колак ишетмәү; алны-артны уйламыйча; баш ватып, күз чыгарып тормыйча; җан-фәрманга; уңга-сулга карамыйча.

2. Исерү. *Баш-күзләре тонган ике егет, чайкала-чайкала, яңадан буфет янына килеп басты* (Сөйләм).
Төрдәше: акылын эчеп бетергәнче һ.б.

3. Үз-үзен белештермәс дәрәҗәгә җитү. *Баш-күз тонып, аңа тәмам капланырга да була иде* (Ә. Еники. Рәшә). *Башы-күзе тонган Шакир килеп керде* (Ә. Фәйзи).

**БАШ-КҮЗ АЛГЫСЫЗ.** Ыгы-зыгы, буталчыклык турында. *Залда баш-күз алгысыз иде: берәүләре ниндидер әрҗәләр ташый, берсе бер почмакка җыелган кешеләргә нидер аңлата, идәндә мүкәләп нәрсәдер үлчәгәннәре дә бар, читтәрәк ике-өч кеше акыллы кыяфәт белән боларны күзәтеп тора иде* (Сөйләм).

**БАШ-КҮЗ АЛМЫЙЧА <ЭШЛӘҮ>.** Ал-ял белмичә, баш күтәрмичә эшләү. *Автобус килгән-*

*че, бакчадагы казу эшләрен бетерәсе иде, шуңа күрә баш-күз алмыйча эшләргә туры килде* (Сөйләм).

Төрдәше: ал белми, ял белми <эшләү> һ.б.

**БАШ-КҮЗ АЛУ.** 1. Рәтләнү, хәлләнү, җайга салу. *[Бәкер] (иркәләп). Менә бераз баш-күз алыйк, буржуйларны дагалап бетерик* (Ф. Бурнаш. Таң). *Яшь баладан бераз баш-күз алган чагы иде Мәрфуганың* (С. Сөләйманова. Ялгыз торна).

Төрдәше: аякка басу 5 һ.б.

2. Тынычлану, форсат алу. *[Бикморза] Югыйсә кояш чыгу белән бер кашык он эзләп килгән карт-корының иге-чиге булмас, баш-күз алырга ирек бирмәсләр* (Ф. Бурнаш. Хөсәен мирза). *Бераз баш-күз алгач, Луиза бүлмәнең гаҗәп чисталыгын, диван-караватка җыеп куелган урын-җирләрнең пөхтәлеген абайлады* (А. Гыйләҗев. Өч тәгәрмәчле арба).

3. Тазару, сәламәтләнү. *Бераз баш-күз алгач, түкми-чәчми генә кыл иләктән иләп карарсың* (Т. Гыйззәт). *Баш-күз алу белән, бер лабораториягә өйрәнчек итеп бирделәр* (Г. Гобәй).

Төрдәше: аякка басу 1 һ.б.

4. Танышу. *Шул ук сәгать үземнән, башкалардан баш-күз алдым да сөйләргә башладым хакны кешеләрнең күз алдында* (Г. Тукай. Пәйгамбәр).

**БАШ-КҮЗ ӘЙЛӘНҮ (ӘЙЛӘНЕП ЙӨРҮ).** 1. Берәр кеше яисә берәр нәрсә белән мавыгып, шуның артыннан чабу. *[Гөлбану] Ахры, өйләнә торгандыр шул, өйләнмәсә, башы-күзе әйләнеп йөрмәс иде* (Г. Камал. Көндәш). – *Унҗиде яшенә кайтты бит. Башы-күзе әйләнде инде, – диде хатын, кул селтәп* (Ә. Моталлапов. Сәяхәт).

2. Нык мавыгу, гашыйк булу. *Башың-күзең әйләнмәслек тә түгел бит, җанкисәгем!* (Г. Бәширов). *Кыскасы, тәмам башы-күзе әйләнгән моның, ул да гашыйк булган, мескенем* (М. Хәсәнов. Саф җилләр).

Төрдәше: баш әйләнү 8 һ.б.

**БАШ-КҮЗ БӘЙЛӘНҮ**. 1. Якын, тыгыз бәйләнешкә керү. *Бераз вакыт үткәч, тирә-юньдәгеләр яшьләрнең баш-күзләре бәйләнүен сизделәр* (Сөйләм).

Төрдәше: арага алу һ.б.

2. Нининдидер эш белән мавыгып китү. *Техник уку йортына кергәч, Мансур очкыч модельләрен ясау белән баш-күз бәйләнеп китте* (Сөйләм).

**БАШ-КҮЗ БУЛУ**. 1. Хуҗа булу. *Замандашларым кебек миңа да кечкенәдән тормыш арбасына җигелергә туры килде: сабый чактан ук ихата-курада баш-күз булсак, мәктәп елларында колхоз эшенә өлкәннәр белән тигез йөрдек* («Маяк» газ.).

2. Карап, барлап тору. – *Мин 3–4 көнгә командировкага барып кайтам, син монда баш-күз булып тор* (Сөйләм).

**БАШ-КҮЗ ТОМАЛАНУ (ТОМАЛАНЫП БЕТҮ).** Нинди булса да шөгыльгә, гамәлгә тулысынча бирелү. *Башы-күзе шул сәхнәсе, уены, җыры белән томаланып беткән* (Ә. Еники. Рәшә).

*БАШ-КҮЗЛЕ* ❖ **БАШ-КҮЗЛЕ БУЛУ.** Өйләнү (яки кияүгә чыгу), гаилә кору. *Күп кешеләр бу гомердә инде югары белем алып, яки берәр һөнәрче, яки дипломлы инженер булып, тормышта үз урыннарын табып, инде башлы-күзле булып, бала-чагалар белән яши башлыйлар* (Н. Дәүли. Ату).

Төрдәше: башлы-күзле булу; башны бәйләү; күзле-башлы булу; кыз алу; кыз чыгару.

*БАШ<НЫ>-КҮЗНЕ* ❖ **БАШ<НЫ>-КҮЗНЕ ӘЙЛӘНДЕРҮ** *к.* акылдан яздыру. *[Бәдигылҗамал] Кызым, асраулардан бик саклана күр, алар бик явыз булалар, Шакир байның да әнә бер асравы, тәмам башын-күзен әйләндереп, кече хатынлыкка чыкты* (Г. Камал. Каениш).

Төрдәше: акылдан яздыру һ.б.

**БАШ<НЫ>-КҮЗНЕ ТОМАЛАУ.** Бер уй-фикергә яки гамәлгә генә өстенлек бирү. *Хәзерге минутта халык аңа, Нургалигә, карата бик үк уңай караш та түгел, Сөләймановның һәм башкаларның тәнкыйте аларның башын-күзен томалап өлгерде, саксыз сөйләп, аларны бөтенләй үзенә каршы аякландырырга мөмкин* (Ә. Еники).

*БАШЛАГАН* ❖ **БАШЛАГАН ӘЛХӘМНЕҢ СӨБХАНӘКӘСЕН УКЫП БИРҮ.** Башланган бер эшне (фикерне) дәвам итү. – *Хәлфә дигәнегез тиктәс кеше түгел икән. Без башлаган*

*әлхәмнең сөбханәкәсен укып бирде бит! – ди сары мыеклы, тере күзле кеше, үзе мыекларын бер якка кыйшайтып көлә* (Ә. Фәйзи. Тукай).

*БАШЛАП* ❖ **БАШЛАП АЛЫП КИТҮ.** Эшкә керешеп китү, эшкә тотыну. *«Студентларның сәяхәтчеләр фестивале үткәреләчәк» дигән хәбәр ишетелгәч, солдаттан кайткан Филүс сәләтләрне барлау эшен башлап алып китте* (Сөйләм).

**БАШЛАП ЙӨРҮЧЕ** *к.* алдан йөрүче. *Яшьтәшләре арасында ул башлап йөрүче, атабай, заманча итеп әйткәндә – лидер исәпләнә* (А. Тимергалин. Таш алиһә). *Башлап йөрүче кем булгандыр инде, анысы хәзер караңгы, тик башыннан ук бу эшнең хәерле бетмәячәген чамалап була иде* (И. Шиһапов. Җыелыш).

Төрдәше: алдан йөрүче.

*БАШЛАР* ❖ **БАШЛАР КҮРӘ.** Кешенең дөньяда булган барлык бәла-казаны, кайгы-хәсрәтне күрүе, газап чигүе хакында. *Озын-озын бүрәнә, / Чанага салсаң, сөйрәлә. / Ата-баба күрмәгәнне / Безнең башлар күрә лә* (Җыр). *...Күзләр – карап кына йөри. / Күрәсен – башлар күрә...* (С. Рәхмәтулла. Кабер ташындагы язу).

*БАШЛАРЫ* ❖ **БАШЛАРЫ КАЙДА, АЯКЛАРЫ КАЙДА ИКӘНЕН БЕЛМӘҮ.** Аунап ятар хәлдә исереп ятучылар турында. *Идәндә тәгәрәп ятучыларның хәлен аңларлык түгел иде, башлары кайда, аяклары кайда икәнен белмәссең* (Сөйләм).

Төрдәше: акылын эчеп бетергәнче һ.б.

*БАШЛЫ* ❖ **БАШЛЫ БУЛУ.** Акыллы кеше турында. *Башлы булу – башлык булу, имеш, / Шулай, имеш, ташка басылган* (Г. Морат. Чыпчык карагы). *Әгәр бик башлы булсаң – үзеңнән башлыраклардан өйрән, шунда булырсың башлы* (З. Мифтахов. Битараф түгелмен).

Төрдәше: авыздан чыгуга (чykканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә) алу һ.б.

**БАШЛЫ КЕШЕ (ЕГЕТ; МАЛАЙ** һ.б.**).** Һәрнәрсәне уйлап эш итә торган, белемле, зиһенле. *Төзелешне механикалаштыру фирмасы башлыгы башлы егет булып чыкты. Эшне майлаган кебек алып бара* (М. Миншин. Кызыл диплом). *– Моны ничек ясаганнар диген. Бар бит дөньяда башлы кешеләр* («Бар икән башлы кешеләр» мәзәгеннән).

Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә) алу һ.б.

**БАШЛЫ КӨЛТӘ.** Халыкка гыйльми-иҗади эш күрсәткән акыллы-булдыклы кешегә карата. *Бу кибәндә бер гаеп бар, сизсә кем дә шелтәләр: / Эреле-ваклы, башлы-башсыз булды куйган көлтәләр, / Нишләтим соң, башлы көлтә чыкмады шул гел генә, / Нәрсә чәчкән халкыбыз – тик мин шуны урдым гына* (Ш. Бабич).

Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә) алу һ.б.

**БАШЛЫ СӨЛГЕ (ТАСТЫМАЛ)** *этн.* Ике башына да кызыл җеп белән татар милли бизәге төшереп тукылган чүпләмле сөлге. *Аларның якынлыкларына карап, әни күбесенчә кызыл башлы тастымалдан әтмәлләгән кечкенә капчыкларына йә йомырка, йә кызыл билле прәннек, йә ак төш салып чыгара* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Ул дулкынланып, уфылдап кече якка керде дә чүпләм башлы тастымал белән төрелгән агач табактагы бәрәңгене алып чыкты* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**БАШЛЫ ШИКӘР** *этн.* Очлы башлы торба шәкелендә коелган эре, каты шикәр. *Шактый вакытлар бу кәефле эш белән маташканнан соң, мин кызыл балчыктан төрле нәрсәләр әвәләргә тотындым: күмәч булды, башлы шикәр булды, ат булды* (Ф. Әмирхан. Нәҗип). *Шулай керделе-чыктылы итеп, килде-китте сөйләнә торгач, Сарник әлеге башлы шикәр сурәте төшерелгән кара тактага ымлады* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

*БАШЛЫК* ❖ **БАШЛЫК СӨРҮ.** Җитәкче, башлык булу. *Мондагы эшнең рәтен белми бит ул, үзеңнән күп белгәннәргә башлык сөр, имеш!* (Ш. Камал. Акчарлаклар).

*БАШЛЫ-КҮЗЛЕ* ❖ **БАШЛЫ-КҮЗЛЕ БУЛУ** *к.* баш-күзле булу. *Ул Сәйфинең башлы-күзле булуын зарыгып көтте* (А. Алиш. Тиздән туй). *Син дә менә башлы-күзле булып кайтырсың дип көтеп алдык без* (С. Хәким. Пар ат).

Төрдәше: баш-күзле булу һ.б.

**БАШЛЫ-КҮЗЛЕ ИТҮ.** 1. Өйләндерү, мөстәкыйль тормыш башлату. *Әнә шул [хезмәт көне]*

*булганда гына Хәкимулланы башлы-күзле итеп булачак, шул булганда гына Нургалигә җиде класс белем алдырып булачак...* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

2. Ярәшү. *Угличка кайтуга ук, егеткә кыз ярәшергә, озак сузмыйча башлы-күзле итәргә кирәк* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).

Төрдәше: башлы-күзле ясау; күзле-башлы итү; семья арбасына җигү; семья куышлыгына тыгу.

**БАШЛЫ-КҮЗЛЕ ЯСАУ** 1. *к.* башлы-күзле итү 1. *Бозык юлга басканчы, тизрәк аны башлы-күзле ясарга кирәк иде* (Сөйләм).

Төрдәше: башлы-күзле итү 1.

2. Ярәшү. *Җегет, арып, авырып, бераз хәл алыйм дип кайтса, аны менә шул хәбәр белән каршы алалар: «Котлы, мөбарәк булсын, без сине башлы-күзле ясадык, – ди* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр).

Төрдәше: башлы-күзле итү 2 һ.б.

*БАШМА-БАШ* ❖ **БАШМА-БАШ АЛМАШУ.** Бер әйбергә бер әйбер, бертигез алмашу. *Йә, инде дөя хәтлек гәүдәле атны бер башмакка башма-баш алмаш инде, ә?* (З. Зәйнуллин. Ат караклары).

Төрдәше: башка-баш алышу.

*БАШМАГЫ* ❖ (берәүнең) **БАШМАГЫ АСТЫНДА.** Кемгәдер тулысынча буйсынган хәлдә. *[Күктимер] Синең кебек хатын башмагы астында олтырак булыргамы?* (Р. Батулла. Гашыйклар кәмите).

Төрдәше: арка бөгү (бөгеп тору) 1 һ.б.

*БАШМАК* ❖ **БАШМАК АСТЫНА ТӨШЕРҮ.** Искә дә алмаска, онытырга тырышу. *Өлкә комитеты тәтемәдә, орденнар яңгыры кыеклап үтте, мин аны иплән-иплән, сиздермәслек итеп, үзенең астына – башмак астына төшерә башладым* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**БАШМАК БУЛУ.** Хатын иркендә булу, аның сүзеннән чыкмау. *Никадәр генә башмак булып йөрсә дә, залим аңа ышанмый* (З. Мәхмүди. Елак агач).

Төрдәше: арка бөгү (бөгеп тору) 1 һ.б.

*БАШ-МИ* ❖ **БАШ-МИ ЧУАЛУ** *к.* баш чуалу 1, 2. *Аның башы-мие шулхәтле чуалган, ул бернәрсә дә рәтләп уйлый алмый иде* (Ш. Камал. Козгыннар оясында).

Төрдәше: баш чуалу 1, 2.

*БАШНЫ* ❖ **БАШНЫ АВЫРУГА САЛУ.** Юри авырган булып кылану. *Килде бит башка юләр уй. Башны авыруга салып кайтып кердем* (М. Әмир. Балыкчы ялганнары).

**БАШНЫ АДАШТЫРУ.** Уй һәм фикерләрне чуалту. – *Бу каһәр суккан Мостафа башыбызны әллә кайларга илтеп адаштыра инде* (Ш. Камал). *Бәлки, русча өйрәнсеннәр диптер, әллә тагын билгесез бер гомуми милләт вәкилләре булып үссеннәр дипме – башларыбызны адаштырдылар, телебезне кисәргә тырыштылар – сәбәбенә төшенә алмыйм* (Г. Госман. Гармун телләре унике).

**БАШНЫ АЙНЫТУ.** Зиһен ачылу, фикерләү дәрәҗәсе яхшыру. *Читтән килгән бу кечкенә ярдәм егетнең башын айнытып җибәрде; ул, дивана кебек, уң кулын маңлаена сукты, бөтенләй ят тавыш белән <...> дип, тереклектән кинәт уянды* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр).

**БАШНЫ АЛА АЛМАУ.** Булган мөнәсәбәтләрне туктата алмау. *Аракы белән арасын өзмәсә, Гафифәдән дә башын ала алмаячак* (Ә. Моталлапов. Абыну).

**БАШНЫ АЛЫП ЧЫГЫП КИТҮ.** Бөтенләй аерылу, башка чыгу. *Тәвәккәлләрлек акча да түгел, миллион эләктерсәң, инде башны алып чыгып китәргә булыр иде берәр якка* (К. Кара. Матильда). *Икәүләшеп, каядыр башны алып чыгып китәргә кирәк безгә* (Х. Мөдәррисова. Яр).

*БАШНЫ* ❖ **БАШНЫ АҢСЫЗГА САЛУ.** Тиле сыман кылану. *Башын аңсызга салып, куллары болгый-болгый, әллә нинди авазлар чыгара башлады* (Сөйләм).

Төрдәше: ахмак булып кылану һ.б.

**БАШНЫ АРТКА ТАШЛАП <ЙӨРҮ>.** Иркенлек алып, башны күтәреп, артка таба салу (эреләнеп китү, кәефләнеп көлү һ.б.). *Яле, исеңә төшереп кара! Әбүзәр, башын арткарак ташлап, ике күзен дә чытырдатып йомды* (А. Тимергалин. Таш алиһә). *Профессор, башын артка ташлап, җан рәхәте белән көлеп җибәрде* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**БАШНЫ АСУ** *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. – *Нәрсә башыңны асып йөрисең, кыйммәтле әйберен югалткан дип уйларлар* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**БАШНЫ АШАУ.** 1. *к.* авыздан җан чыгу. *[Зәйнәп] Син минем җиде ел эчендә башымны ашадың* (Г. Камал. Каениш). *Чөнки явыз кешенең башын нәкъ менә үзенең явызлыгы ашый да бит инде* (Ә. Еники. Коръәнхафиз).
Төрдәше: авыздан җан чыгу. һ.б.

**БАШНЫ БАСТЫРЫКЛАУ, АРТНЫ КАМЧЫЛАУ** *эвф.* Мәҗбүр итеп, көч кулланып. – *Гомеремдә дә эшләмим, дигән иде, башын бастырыклап, арын камчылап алгач, селкенә башлады* (Сөйләм).

**БАШНЫ БАШКА, АЯКНЫ АЯККА (БОТНЫ БОТКА) БОТАРЛАУ.** 1. Танымаслык хәлгә китереп ватып-җимереп ташлау. *Паркка берәү тимер-томырдан гына әмәлләп бер сын ясап куйган иде, әмма икенче көнне үк аның башын башка, ботын ботка ботарлап ташлаганнар* (Сөйләм).

2. *к.* авыздан җан чыгу. *Тикшерүчеләр чыбык-чабык өеме астыннан чыккан гәүдәгә сәерсенеп карап тордылар: аның башын башка, аягын аякка ботарлаганнар иде* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

**БАШНЫ БАШКА ТИДЕРЕП.** Бердәм рәвештә, бергәләшеп. *Башны башка тидереп эшлибез. Кайвакыт әбәтне дә Кәрим ага безгә үзе китерә, Гайшә ханым белән бергә ашарга төшәргә дә вакытыбыз булмый* (И. Гази. Яңа мастер).
Төрдәше: аркага арка куеп <яшәү> һ.б.

**БАШНЫ БӘЙЛӘҮ** *к.* баш-күзле булу 2. *Верстагы янында әле теге эшенә, әле монысына тотынып караган була да, берни дә барып чыкмагач, бөтенесен атып бәрә: – Менә сиңа аяк астыннан чыккан бәла! Каян шуның белән башын бәйләгән бу кызый!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). – *Безгә алып килгән кыз белән сак булсын, башын шуңа бәйли күрмәсен, ди* (М. Маликова. Тылсым).
Төрдәше: баш-күзле булу 2 һ.б.

**БАШНЫ «БЕЛМИМ»ГӘ САЛУ.** Бөтен хәлне белсә дә, читтә калырга тырышу. *«Белмим»нең башы авыртмый, дигәннәр, шунлыктан башны «белмим»гә салуның еш кына файдасы чыга* (Сөйләм).

**БАШНЫ БЕТЕРҮ.** Үтерү, һәлак итү. – *Җибәрмәгез! Ирләр, ялгыз җибәрмәгез! Башын бетерергә йөри, – дип, хатын-кызлар чәрелди башлады* (И. Гази. Ай юлы). – *Син нәрсә, малай актыгы, башыңны бетерәм бит!* (М. Галиев. Затлы чыбыркы хуҗасы).
Төрдәше: адәм башкайларын салу һ.б.

**БАШНЫ БУТАУ.** Бер эш арасына башка эш яки сүз белән тыгылып, уй-фикерне чуалту. *Тәмам башны бутады бу кызый, культура бүлегенә шалтыратырга килгән иде бит әле бу* (А. Гыйләҗев). – *Сәясәт белән башны бутамасыннар! – ди яшь кенә, талантлы гына татар артисткасы* (В. Юныс. Кем син, исмең кем синең?).

**БАШНЫ ГРИФТАР ИТҮ.** Берәрсенең ихтыярына буйсындыру. *[Галиябану] Ходай башымны шул кансызга грифтар итмәсен!* (М. Фәйзи. Галиябану).
Төрдәше: авызлык кидерү һ.б.

**БАШНЫ ДИВАЙЛЫККА САЛУ.** Тиле булып кылану, алдау. *Үткәнендә башыңны дивайлыкка салып котылган идең, инде башка нәрсә уйлап табарга кирәк* (Сөйләм).
Төрдәше: ахмак булып кылану һ.б.

**БАШНЫ ДИВАНАГА САЛУ** *к.* ахмак булып кылану. – *Башны диванага салып йөргән өчен халык үзенә Карак Галибәк дигән кушамат такты* (М. Хәбибуллин. Илчегә үлем юк). *Башын диванага салып йөри бирде* (Ф. Шәфигуллин).
Төрдәше: ахмак булып кылану һ.б.

**БАШНЫ ДУРАКЛЫККА САЛУ** *к.* ахмак булып кылану. – *Башны дураклыкка салып маташмыйк, Сәлмән абзый, – диде Фәсхи, тавышын күтәрә төшеп* (Ф. Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы).
Төрдәше: ахмак булып кылану һ.б.

**БАШНЫ ҖИГҮ** *к.* акыл аша уздыру. *Башны җигәсе юк – кулы үз хуты белән йөри, ә күңеле исә әллә кайларга китеп бара, әйтерсең сафлык һәм яктылык бөркеп торган күлмәк-ыштаннарга, яулык-тастымалларга, чүпрәк-чапрак, чурт-чураманга һич катышы юк* (Р. Зәйдулла. Кабахәт).
Төрдәше: акыл аша уздыру һ.б.

**БАШНЫ ҖИРГӘ ОРУ.** Башны җиргә бәрә-бәрә үтенү. – *Туктамыш угылың, егълый-егълый,*

*башын җиргә орып, синнән янә ярлыкауны сорый, бөек әмир, – дип, келәмнән купмыйча да телгә килде мирза* (В. Имамов. Карабәк).
Төрдәше: башны җиргә төртү.

**БАШНЫ ҖИРГӘ ТӨРТҮ** *к.* башны җиргә ору. *[Бикә] Нигә башларыгызны җиргә төрттегез!..* (К. Тинчурин. Ил).
Төрдәше: башны җиргә ору.

**БАШНЫ ҖИЮ** *к.* адәм башкайларын салу. *Кабахәтлекләрнең барысы Иргали кулы белән эшләнә. Ах, без ничек шуның башын җия алмадык* (Ф. Бурнаш).
Төрдәше: адәм башкайларын салу һ.б.

**БАШНЫ ҖУЮ** 1. *к.* башны ашау 1–3. *Ләкин... / Минә «ләкин» сүзе белән / Күп вакытта башны җуялар* (Һ. Такташ).
Төрдәше: башны ашау 1–3 һ.б.

2. Төшенкелеккә бирелеп, ныклап уйланылмаган эшләр эшләү; ялгыш адымнар ясау; хәсрәтләнү. *Ул да уңга-сулга тайпылмыйча, булачак иренең шапырынулы вәгъдәләреннән исереп, башын җуеп, егетнең шашкан кочагына ташланмадымыни?* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *[Мәрьям] Беренче очрашуда ук башыңны җуйгансың* (Ю. Әминов. Өти Балак).

**БАШНЫ ҖҮЛӘРГӘ (ЮЛӘРГӘ) САЛУ** *к.* ахмак булып кылану. *[Гүзәл] Ә син көлмә. Син башыңны юләргә салып көләсең дә шамакайланасың* (Т. Миңнуллин. Саташу). *[Бәкер] Син, кордаш, башыңны җүләргә салма инде, Сандугач түгелсең* (Ф. Бәйрәмова. Сандугачның балалары).
Төрдәше: ахмак булып кылану һ.б.

**БАШНЫ ҖЫЮ.** Зиһенне туплау, уйлый алырлык хәлгә килү. *Мәрьям, ни эшләгәнен белмичә, кире чигелде; Зыя, бер минутта эшне аңлап, башын җыйды, ләкин берни кыйла алмый катып калды...* (Г. Ибраһимов).

**БАШНЫ КАДЕРСЕЗ ИТҮ.** Үзен үзе хөрмәт итмәү. *Менәтерә бүгенге көндә бозау көтеп йөри үз башын үзе кадерсез итеп* (Г. Мөхәммәтшин. Ике әби бәрәңге ала...).

**БАШНЫ КАЙНАТУ.** Борчылу, күп уйлану. *Хәзер Александра Сигизмундовнаның сүзләре аның башын кайнаттылар* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар). *Йөриләр шунда баш кайнатып, эш күп чагында* (Н. Кәбәш. Мутантлар).
Төрдәше: аһ ору һ.б.

**БАШНЫ КАЯ КУЯРГА БЕЛМӘҮ** *к.* бармакны авызга кабу 1. *Башын кая куярга белмәде егет* (Г. Гобәй).
Төрдәше: бармакны авызга кабу 1.

**БАШНЫ КИРЕ СЕЛКҮ.** Сүзне кире алу, инкяр итү. *Кичә сөйләгәннәреннән риза булмыйча, бүген башын кире селкеде* (Сөйләм).

**БАШ<ЫМ>НЫ КИСӘРГӘ БИРӘМ.** Вәгъдә бирү гыйбарәсе. *Башымны кисәргә бирәм – идән астына да төшермәячәк* (А. Гыймадиев. Үзең булып кал!..). *Башны кисәргә бирәм, үз күзләрем белән күрдем мин аны* (Р. Сәгъди. Изге Мөҗбирнең күккә ашуы).
Төрдәше: айдыр әгәр һ.б.

**БАШНЫ КИСКӘГӘ САЛУ.** Нәрсәне булса да эшләргә башлары белән вәгъдә бирү. – *Сез ике җүләр, ди, башыгызны үзегез кискәгә саласыз!* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар). *Фәез башын кискәгә салган икән, торбалар тиешле урыннарында ятарга тиеш* (Ә. Баянов. Таш китап).

**БАШНЫ КОМГА ЯШЕРҮ.** Килеп чыккан проблеманы хәл итүдән качар өчен, аны күрмәмешкә, ишетмәмешкә салышу. *Ләкин барыбер кемдер үз җилкәсенә салырга тиеш, башны комга яшереп кенә, үзе качмый ул, киресенчә, артыңа китереп тибүе бар* (Р. Габделхакова. Соңгы сорау). *Проблемаларны да, тәвә кошы сыман, башны комга яшереп хәл итә алмыйбыз* («Сөембикә» ж.).

**БАШНЫ КӨЛ ИТҮ** *к.* авыз җебетү 2. *Мин аның башын көл итмәсәмме!* (М. Фәйзи).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**БАШНЫ КУЛТЫК АСТЫНА КЫСТЫРУ.** Үтерү. – *Минем белән очрашканда, бер чакрымнан бүрегегезне салыгыз, юкса башыгызны култык астына кыстырып җибәрермен* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур). – *Кенәзеңне кисәт. Башны култык астына кыстырып кайтуга караганда, алтын очлым киеп китү күпкә шөһрәтлерәк* (В. Имамов. Казан дастаны).
Төрдәше: адәм башкайларын салу һ.б.

**БАШНЫ КУЛТЫККА АЛУ.** Күрә торып үлем хәтәрле эшкә бару. *Озак уйлап торырга вакыт юк иде, башын култыкка алып, ул да күпердән атлады* (Сөйләм).
Төрдәше: башы култыгында; башы өзелсә, култык астына кыстырып йөгерер.

**БАШНЫ КЫРЫН САЛУ.** Уйга чуму; күңелсезләнеп яисә үпкәләп башны салындыру. *Мин килеп җиткәндә, Салих шул саилчеләрдән аз гына читтәрәк, башын кырынрак салып, тик кенә басып тора иде* (Ә. Еники. Гөләндәм туташ хатирәсе). *Кәрим абзый, башны кырынрак салып, Солтанга күзенең агын әйләндереп карый. – Әйе, төшүебез дөрес, – ди Солтан. – Мин, учком рәисе буларак, сигнал алдым, кухарка төнлә рабфакчылар белән шаяра, имеш* (Г. Ахунов. Идел кызы).
Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**БАШНЫ КЫСТЫРУ.** Җәза бирү. *[Гапсаттар] Капчыгыма дөньясын сыйдырыр идем дә, уставына сыймый, башыңны кыстырулары бар* (Ю. Әминов. Тамырлар).

**БАШНЫ МЕСКЕНГӘ САЛ<ЫШ>У.** Бичарага салышып, үзен кызгандыру. *Юк, бирәсе түгел иде Рәкыйпкә акча. Шулай башын мескенгә салышырга өйрәнгән бәндә бит ул* (Х. Хәйруллин. Картлык... кемгә шатлык?). *– Кызлар, ярдәм итәлмәссезме берәрегез? – дип, башын мескенгә салды* («Кызыл таң» газ.).

**БАШНЫ МИҢГЕРӘҮЛЕККӘ АЛУ** *к.* ахмак булып кылану. *– Син аңламаган булып, башыңны миңгерәүлеккә алып утырма монда* (Сөйләм).
Төрдәше: ахмак булып кылану һ.б.

**БАШНЫ ОЛАКТЫРУ** *к.* баш олагу. *Олактырып минем яшь башымны, / Чит илләргә ташлап киттегез* (Һ. Такташ). *Себерләргә башны олактырт та, / Урман кистерт...* (С. Рәхмәтулла. Күп тормабыз без).
Төрдәше: баш олагу.

**БАШНЫ <АСКА; ТҮБӘН> САЛ<ЫНДЫР>У (ТӨШЕРҮ)** *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. *Шуның өстенә ике яктан ике малай гел тынгысызлап тора, башны аска салындырып, моңаеп утырырга ирек бирмиләр* (М. Маликова. Кызыл гөл). *Үзе башын түбән салган, астка караган, бик акрын гына атлый* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). *Мин үзем дә башны аска салдым, / Нишләрмен, дим хәзер эчемнән* (Һ. Такташ). *Әй бераздан кереп китте, ә мин, башымны түбән салындырып, сагыш хөкеменә бирелгән хәлемдә, кар ерып, кырга, болыннарга чыгып, тауларга ашып, каядыр киттем дә киттем* (Ф. Яхин. Коелган мәхәббәт таҗы).
Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**БАШНЫ СУГА САЛУ.** Бик нык кайгыру. *Сихерче тал башын суга салып йоклый. / – Кавышулар вәгъдә итми курган ташлар* (Рәш. Әхмәтҗан. Юри мәллә, нәкъ җиде төн уртасында). *– Син дә ялгыз, мин дә ялгыз, Сорыкай. Үз тиңең очрар әле, башыңны суларга салма, – диде* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: аһ ору һ.б.

**БАШНЫ ТАШ АСТЫНДА АСРАУ.** Куркыныч, һәлакәтле хәлләрдә дә бирешмичә, яшәргә сәләтле тәвәккәл, үткен кеше турында. *Таш астында башын асрар бит. Бер яктан каенатам, бер яктан ирем; ни эшләргә белми әниең мәрхүмәгә кереп җылый идем. Онытыр хәлем юк: утырта, сөйләтә, ашата-эчертә, үгет бирә, күңелемне ала, кайгыларымны тарата иде* (Г. Исхакый). *– Ул таш астында баш асрарга өйрәнгән инде* (М. Хәсәнов).

**БАШНЫ ТАШКА (БҮРӘНӘГӘ; ДИВАРГА) БӘРЕП (ОРЫП) БУЛМАУ.** 1. «Авыр кайгы-хәсрәт, бәхетсезлекләр килгәндә түзәргә кирәк» мәгънәсендә. *Хәзер менә ай түгел, еллар, бөтен гомер аерым уза, башны ташка орып булмый, сабыр итми чараң юк* (М. Маликова). *– Мин моны бер дә хупламадым, хан. Әмма нишләмәк кирәк, башны ташка орып булмый, безнең христиан халкы башка диндәге кешене эттән дә яман күрә* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).

2. «Эш үткәч, үкенүдән файда юк» мәгънәсендә; *шулай ук к.* агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән. *Үзебез үк шул сүзләрне яклап кычкырдык бит. Хәзер инде башны ташка орып булмый* (В. Имамов. Сәет батыр). *Саклап кына куенында йөрткән кадерле әйберсен югалтты ул... «Ярар, башны ташка орып булмый!» – диде егет кисәк кенә һәм карточканы альбомнан куптарып алды да ачу белән тураклап атты* (Р. Кәрами. Олы юл да сикәлтәле).
Төрдәше: агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән һ.б.

**БАШНЫ ТАШКА БӘРЕР (ОРЫР) ХӘЛГӘ ҖИТҮ.** 1. Ярсу, үкенү; берни эшли алмау. *Башыны ташларга орыр, / Сөренмим дип әҗәлләргә* (Г. Кандалый). *Киткәннәр бар, синең кебек / Моңлы бала киткән юк. / Башны ташка ормак булдым* (М. Әгъләм).
Төрдәше: муенга бау салыр хәлгә җитү.

2. Бәлаларга уралу, бөтенләй аптырашка калу. *Җитмәсә, бәлаләрнең кечесе-олысы өсөскә өелә башлады – башны ташка орыр хәлгә җитәм, ахрысы* (Сөйләм).
Төрдәше: аптыраган үрдәк хәленә төшү һ.б.

**БАШНЫ ТАШКА БӘРҮ (ОРУ).** Авыр кайгыхәсрәт килгәндә, башны диварга бәреп тынычлану. – *Теләмәсәм, ни кылыйм? Башымны ташка бәримме?* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *Әле берәүнең дә, кыз таба алмыйм дип, башын ташка бәреп утырганын күргәнем юк* (Э. Яһудин. Соңгы чәчәк).

**БАШНЫ ТАШКА ОРЫРДАЙ БУЛУ.** Чишелешен таба алмаслык хәлгә тап булып, тәмам аптырауга калу. *Кайсыберсе, очын-очка ялгый алмыйча, башын ташка орырдай булып йөри-йөри дә, тәрәзәләренә такта кадаклап, бөтенләй әллә кай җәһәннәмгә олага* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Эшенә барып керүгә үк сизә ул бу юл галәмәтен – иңнәре, янбашлары сызлауга түзә алмыйча, башын ташка бәрердәй була...* (Г. Гыйльманов. Бөкре).

**БАШНЫ ТИЗӘК АРАСЫНА ТЫГУ** *туп.* Терлек фермасында эшләү. – *Аның урынында булсам, хәзерге акылым булса, башымны тизәк арасына тыгар идемме соң?!* (Б. Камалов. Шомырт чәчәкләре).

**БАШНЫ ТИЛЕГӘ (АҢГЫРАГА) САЛУ** *к.* ахмак булып кылану. *[Тиле Даһи] Әйттем мин – син башыңны тилегә саласың, дип* (Ф. Бәйрәмова. Вакыйга җүләрләр йортында бара). *– Бәй, син ничә соң?! Минем күзгә бер генә булып күренәсең бит,– диде ул, юри башын аңгырага салып* (Ф. Садриев. Бәхетсезләр бәхете).
Төрдәше: ахмак булып кылану һ.б.

**БАШНЫ ТОМАЛАУ.** Бер төрдәге фикер генә сөйләп яки сәясәт алып барып, кешене миңгерәүләтү, үзаң эшчәнлегенә зыян бирү. – *Мин әйтәм, аларны сүгәргә дә кеше кирәк ич, алар дин исеменнән халыкның башын томалыйлар, динче, милләтче байраклар белән халыкның миен агулыйлар ич, дим* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Хөкүмәткә кемнәр килсәләр дә, алар түбән катламны алдадылар, үз «политикалары» белән халыкның башын томаладылар* (В. Юныс. Өч маймыл фәлсәфәсе).

**БАШНЫ ТОМАН КАПЛАУ.** Уйлый алмас хәлгә килү. *Карчыкның башын томан каплады* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).
Төрдәше: баш китү 3 һ.б.

**БАШНЫ ТОТТЫРУ.** 1. Берәр нәрсәдә гаепләнеп, яла ягылып кулга алыну. *«Булмаган нәрсә өчен башны тоттырырга монда» дип уйлады да таң атар-атмас авылдан чыгып китте* (Сөйләм).

2. Саксызлык аркасында үз-үзен тоттыру. *«Җиргә салмый, җенгә салам!» – дип әйтә дә, бу «Җир иясе җирән сакал»ларга үзенең пар аты урынына безнең пар башыбызны тоттырып китә...* (Н. Исәнбәт. Унсигезенче еллардан бер сәхифә).

**БАШНЫ ТӨРМӘДӘ ЧЕРЕТҮ.** Төрмәгә утырткан кешене аннан чыкмаслык иттерү; каныгу. – *Йә кызулык белән берәр хәтәр эш эшләп ташлармын, башны төрмәдә черетер* (Р. Кәрами. Кая чабасың, тормыш юртагы?). *Ә ул: «Түләттерми калмыйм, башыңны төрмәдә черетәм түләмәсәң», – диган иде, хи-хи-хикых-кых...* (Д. Булатова. Ачык ишекләр көне).

**БАШНЫ ТӨЮ** *к.* авыз җебетү 2. *Тикшерүченең гадәте – пистолет түтәсе белән башны төю. Тик бу юлы ул гадәтен нигәдер үзгәртте, пистолетын чыгармады* (Г. Әпсәләмов). *Һаман ләззәтләнеп, улларыңның башын төясең* (М. Әгъләм).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**БАШНЫ УЙ БАСУ.** Борчылу, күп уйлану. *Килешә алмый күңелем коллык белән, / Башны һаман шушы уй баса* (М. Җәлил). *Башымны уй баскач, бик таркауга әйләндем шул бу арада* (Р. Габделхакова. Нишләттегез Гөлкәйне?!).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БАШНЫ УТКА САЛУ.** Кешене хурлыкка, газапка, гомерлек үкенечкә дучар итү. *Яшь бер кызны ала ул, / Булган була ана ул; / Үсеп буйга җиткергәч, / Башын утка сала ул* (Г. Тукай). *«Без татарга ярамаган тагы!..» диеп*

*уйлыйбыз / – башларны утка салачак хәтәр белән уйныйбыз* (Р. Харис. Исемсезләр).
Төрдәше: башны харап итү.

**БАШНЫ ХАРАП ИТҮ.** 1. Кешенең бәхетен, киләчәген кисү. *Мисбах исә еш кына сыкрана: «Ну, энекәш, башны харап иттең, ахрысы, – дип, Газинурга үпкәсен белдерә иде* (Г. Әпсәләмов. Газинур). *Нинди матур башны харап иттеләр. Син дә шулар аркасында борынсыз йөрисең бит* (З. Мәхмүди. Йолдызларга – йодрык).
Төрдәше: башны утка салу.

2. Кешенең гомерен, бәхетен, киләчәген кисү. *[Гарифә]Ник син кызымның башын харап иттең?* (Г. Исхакый. Алдым-бирдем). *41 дә ул әткәмне / Мәңгегә алып киткән. / – «Юллар алып китәләр. / Башны харап итәләр», – дип / Әйткән минем ишеләр* (Р. Мингалим. Юллар алып китәләр).

**БАШНЫ ЧАЙКАУ.** Гаҗәпләнү билгесе. *Сабир абзый гаҗәпләнүдән бераз башын чайкап торды* (Ә. Еники). *Шунда булган апалар кайгырышып аһ-ваһ килделәр, башларын чайкадылар* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).
Төрдәше: авыз ачып калу 5 һ.б.

**БАШНЫ ЧАРЛАУ.** Белем алып, тәҗрибә туплап, зиһниятне камилләштерү. *Башны чарлап, кайный йөз төрле уй, бозлы суга сикергәндәй – тән* (С. Сөләйманова).

**БАШНЫ ЧӘЛПӘРӘМӘ КИТЕРҮ.** Сугып, башны тишү, канату. *Әле яхшы, әни кереп өлгерде, кермәсә, башымны чәлпәрәмә китергән булыр иде* (А. Шамов. Кыз урлау).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**БАШНЫ ЭЛМӘККӘ ТЫГУ.** 1. Хәтәр эшкә алыну, катнашу, тыгылу. *Озак аптырап тормады Ахунҗанов – беренче көннән үк аптырый башласаң, аннары башны элмәккә тыгарга кирәк* (Ф. Хөсни. Мәйдан). *– Өйләнеп? Башны бу яшьтән элмәккә тыгаргамы?* (Э. Касыймов. Бир кулыңны, дустым!).

2. Үзеңне һәлакәткә салу. *Бер йоткан, ике йоткан. Өченчесендә үзен элмәккә тыккан* (Мәкаль). *Менә миңа нишләргә хәзер. Башны элмәккә тыгаргамы? Юк-юк, Аллам сакласын!* (Т. Нәбиуллин. Качкын).

**БАШНЫ ЮЛӘРГӘ (ҖҮЛӘРГӘ; ТИНТӘККӘ) САЛУ.** Юләр булып кылану, белмәмешкә салышу. *– Әйдә, башыңны юләргә салма. Утыз метр бер ыштанга кереп бетми* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *[Ата] Без, башны юләргә салып, театр дигән булып уйнап йөрибез* (Г. Каюмов. Упкын өстендә уен).
Төрдәше: ахмак булып кылану һ.б.

*БАШНЫ-КҮЗНЕ* ❖ **БАШНЫ-КҮЗНЕ ӘЙЛӘНДЕРҮ** *к.* акылдан шаштыру 1. *[Мәгъри] Шакир байның дә әнә бер асравы, тәмам башын-күзен әйләндереп, кече хатынлыкка...* (Г. Камал. Бәхетсез егет). *Гәптерәшит урынында бер уңганрак егет булса, күптән башын-күзен әйләндереп алыр иде инде* (М. Фәйзи. Асылъяр).
Төрдәше: акылдан шаштыру 1 һ.б.

2. Мавыктыру, сөйләп-мактап кызыктыру. *[Бәдигылҗамал] Сез, сихерчеләр, сихер белән баламның башын-күзен әйләндереп бетердегез* (Г. Камал. Каениш). *Ә бу малай, Себер, Себер дигәләп, Нателаның башын-күзен тәки әйләндерер* (Г. Мөхәммәтшин. Кояш кызы).

*БАШНЫҢ* ❖ **БАШНЫҢ ВИНТЛАРЫ БУШАУ** *к.* акыл баштан китү (чыгу) 1. *Монда ни булса да эш рәтсез күренә... я бу мине алдап саташтыра яисә үз башымның винтлары бушаган, тигез әйләнми...* (Ш. Камал. Сәмруг кош).
Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.

*БАШСЫЗ* ❖ **БАШСЫЗ АТКА МЕНҮ.** Үлү, җеназасы күтәрелү. *Бу дөньядан күчәрбез, башсыз атка менәрбез* («Фәнни Татарстан» ж.). *Башсыз атка менгән, / Җиңсез күлмәк кигән, / Ашыга-ашыга, ерак сәфәргә китеп бара* (Табышмак: үлү).
Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

**БАШСЫЗ БАЛА (КЕШЕ).** 1. Үтә тәвәккәл, чая кеше турында. *Дуамал, башсыз кеше белән кызыксына башлаган мәр ахирәт дустының энесенә шәһәрнең иң зур яшелчә базасында директор урынбасары булып урнашырга тәкъдим итте* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Татар гомер буе шундый башсыз кешеләрнең берсе булды. Биеклектән курка белмәү сәерлеге бар иде аңарда* (Ә. Баянов. Төлке тоту кыен түгел).

2. Бернинди максатсыз, идеалсыз, болай гына егетлек күрсәтү. *Һәм шундый ук алым белән башсыз кеше дә үстереп була, ә аның өчен башлангыч өлге сыйфатында гади кешенең бер күзәнәген алырга мөмкин дигән фикергә килгәннәр* (З. Мифтахов. Дөнья кызыклы!).

3. Аңгыра, надан кеше. – *Өммикамал ул тикле башсыз бала түгел* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Ишеткәнегез юкмы: «Анда министр акылы бар!» – диләр. Башсыз кеше ул дәрәҗәгә үсә, андый эшне башкара алмый* (Ф. Яхин. Көзге яңгырга кадәр).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**БАШСЫЗ БАРАК, ТЕШСЕЗ ТАРАК.** Начар идарә, башсыз-рәтсез эш. *«Балык башыннан чери» дип кенә әйтәсем килми, «башсыз барак, тешсез тарак» икән сезнең монда* (Сөйләм).

*БАШТА* ❖ **БАШТА БОЛАМЫК <БУЛУ>.** Төгәл фикере булмау, бөтен нәрсә буталып бетү. *Җитмәсә, мин зур гына әсәргә тотынып маташам, башта боламык, уйлар буталчык, илһам качты* (Ф. Садриев. Зөбәйдәнең күңел дәфтәреннән).

**БАШТА БОРЧАК ҮСТЕРҮ** *к.* акыл баштан китү (чыгу) 1. *Башында борчак үстергән кешедән нәрсә көтәргә мөмкин?* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.

**БАШТА БУШЛЫК <БУЛУ>.** Надан һәм аңгыра булу. *Бушлык иде аның башында, котып салкынлыгы биләде күңелен* <...> (К. Кара. Депрессия).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**БАШТА ҖИЛ УЙНАУ.** Җитди уйлый белмәү, акыл белән эшләмәү. *Менә сезнең шикелле башында җил уйнаган бала-чагаларның колагын борып акылга утыртырга* (Ф. Яруллин. Кызлар күңеле – тирән сер). *Тирән белемле, зирәк акыллы, таләпчән Зыя Камали әфәнде эшкә алганда ук чамаларга тиеш мөгаллимнең башында нинди җилләр уйнаганын* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**БАШТА КАЙНАУ.** Уйланып йөргән фикерләр, төрле уйлар булу. *Педагогик тәҗрибәләрем буенча гомер буе язып килгән көндәлекләрем бар, башымда кайнаган фикерләрем* (М. Әмир). *Мин үземнең башта кайнаган уйларымны йөгәнләргә дә тырышып карадым* (Ә. Рәшит. Һәркемнең... үз хакыйкате).

**БАШТА КАЛ<ДЫР>У.** Онытмау, хәтердә тоту. *Айдар ул вакытны ничек өйрәнгән дә ничек башында калдыра алгандыр, гаҗәп...* («Матбугат.ру» порталы). *Ялдан соң йөз китап укыдым!.. Ләкин / башта калганы сирәк* (З. Нури. Ялдан соң).
Төрдәше: акылда тоту һ.б.

**БАШТА САЛАМ СЕЛКЕНҮ** *гади с.* – *Ишеттеңме нәрсә диде, башында салам селкенә башлады бугай?* (Сөйләм).
Төрдәше: каракның бүреге яну.

**БАШТА ТАВЫК МИЕ БУЛУ** *к.* акыл<га; -дан> җиңеләю 1. *Бикә түти моңа бик ачуланды: – Бер дә айгыр булып кешнисе түгел, югыйсә. Башында тавык мие булмаган кешегә аңнарга бакыт* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).
Төрдәше: акыл<га; -дан> җиңеләю 1 һ.б.

**БАШТА ТОМАН.** Ачык фикер-уй, максат булмау. *Җиһангир дәшмәде. Аның башында томан иде* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Ул тагын күзләрен йомды, башта томан, беркемгә берни дә аңлатасы да, шушы караңгылыктан чыгасы да килмәде* (З. Кадыйрова. Көтеп узган гомер).

**БАШТА ТОТУ** *к.* акылда тоту. *Әйе, эше четерекле, районда нинди киңәшмә яки чара буласын, кайсысына кемнәрне чакырасын – барысын да башында тотасы* («Сөембикә» ж.). *Атаңны башыңда тот* (Н. Исәнбәт. Балалар фольклоры).
Төрдәше: акылда тоту.

**БАШТА ШӨРЕПЛӘР ШЫЛДЫРАУ.** Бик үк акыллы булмау. *Башында шөрепләре шылдырый дисәң дә, каенесе закон кешесе иде* (Н. Гыйматдинова. Кәтәнә).

*БАШТАГЫ* ❖ **БАШТАГЫ ВАКЫТТА.** Нәрсәнедер башлаганда, элегрәк. *Баштагы вакытта юкка гына бәйләнүләр, каныгулар үзенекен итте* (Г. Нәбиуллина. Ташта үскән гөл). *Баштагы вакытта күбрәк бүтәннәрне тыңларга, кешеләрне, «уен кагыйдәләрен» өйрәнергә туры килде* («Сөембикә» ж.).

**БАШТАГЫ ЧӘЧ ҖИТМӘҮ.** «Акча җитмәячәк, бик зур чыгымнар сораячак» мәгънәсендә. *– Яллый башласаң, баштагы чәч җитмәс* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).

*БАШТАН* ❖ **БАШТАН АША ҖИБӘРҮ.** Күтәреп, баш аркылы җиргә ыргыту. *Үзеннән шактый*

*авыр көндәшен баштан аша җибәргәч, барысы да аһ итте* (Сөйләм).

Төрдәше: баш аркылы (аша) егу (алып ату; ыргыту).

**БАШТАН АШУ.** Артык күп булу, чиксез күп булу. *Әлхәмделиллаһ, кызымның сөлге-салфеты баштан ашкан* (Г. Исхакый. Кияү). *Мәгәр җитәкче кешенең үз кайгысы, үз мәшәкате баштан ашкан була бит ул* (В. Имамов. Тозлы яра).

Төрдәше: баштан ташу (ташып китү).

**БАШТАН <АЛЫП> АЯГЫНА КАДӘР (ХӘТЛЕ).** Тулысынча, тоташтан; барысын да. *[Гата] <...> соңыннан бөтенләй хәтеремдә син буласың, үлем түшәгендә торган авыру шикелле, бөтен дөнья минеке була. Гүя тәнемә баштан аякка кадәр бер рәхәт, бер тереклек килер* (Г. Камал). *Аннары Хәлимнең баштан аякка кадәр бөтен тәнен җентекләп карый, өйрәнә башлады...* (Г. Гыйльманов. Албастылар).

Төрдәше: баштан <алып> аягынача; баштан аяк; баштан аякка кадәр.

**БАШТАН <АЛЫП> АЯГЫНАЧА** *к.* баштан <алып> аягына кадәр (хәтле). *«Ләкин син этнең эчә торган тагарагыннан эчәргә килгәнсең», – диде. Падишаһ, баштан аягынача кызарып, бик оялды* (К. Насыйри).

Төрдәше: баштан <алып> аягына кадәр (хәтле) һ.б.

**БАШТАН АЯК** *к.* баштан <алып> аягына кадәр (хәтле). *Мөхәммәд баштан аяк диңгез суына коенган, тешләре тешкә тимичә, дер калтырый иде* (В. Имамов. Утлы дала). *Бу мәһабәт мәҗлес алдында тагын баштан аяк / Сөйләде эшне ишәк, һәм Корт тагын бирде җавап* (И. Киләүли. Бал корты белән ишәк тугрысында).

Төрдәше: баштан <алып> аягына кадәр (хәтле) һ.б.

**БАШТАН БӘС КИЧҮ.** Чәчкә бәс төшү, чал төшү, чәч агару. *Башыннан бәс тә кичкән инде үзенең, һаман да егетләрчә кыланган була* (Сөйләм).

Төрдәше: башы бәс кичү; башына кырау тигән (төшкән); башыннан кавык җиле искән; чәчкә, сакалга чал керү.

**БАШТАН БӨРКӘНЕП АШАУ** *мыск.* Үтә саранлык турында. *Дөнья күргән егеткә охшаган үзе, тик башыннан бөркәнеп ашау гадәте генә сәерсетә* (Сөйләм).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**БАШТАН ҖИЛЛӘТЕП БЕТЕРҮ** *к.* акылдан чыгару 1. – *Хәтерләмим дигәч хәтерләмими инде, мин ул вакыйганы күптән баштан җилләтеп бетердем* (Сөйләм).

Төрдәше: акылдан чыгару 1 һ.б.

**БАШТАН КИЧЕРҮ (УЗДЫРУ; ҮТКӘРҮ).** Авыр хәлләргә дучар булу, кыенлыклар күрү. *Беребезнең дә күңел тыныч түгел, һәркайсыбыз соңгы вакытларда үз күңелендә генә йөрткән, моңарчы әле күтәрелеп әйтергә кыймаган борчулы уен баштан кичерә: нәрсә, безне алдарга җыеналармы әллә?* (Н. Акмал. Кол). *Заманында мондый хәлләрне баштан уздырырга туры килде безгә дә* (Х. Галидән. Патша солдаты Әхмәтнасир).

Төрдәше: баштан кичү (узу; үтү).

**БАШТАН КИЧҮ (УЗУ; ҮТҮ)** *к.* баштан кичерү (уздыру; үткәрү). *«Баштан үткәнне сөйлимен, тыңлагыз, / Мин хаҗи – бардым хаҗә туксан тугыз»* (Г. Тукай. Печән базары, яхут Яңа Кисекбаш). *Бу бер елда баштан кичкәннәрдән / Ми күперде, йөрәк кабарды...* (М. Җәлил). *[Рәйян] Үз башымнан үткән бер әйберне сөйлим әле* (Г. Коләхмәтов. Ике фикер).

Төрдәше: баштан кичерү (уздыру; үткәрү).

**БАШТАН КОЛАК КАГУ.** Үтерелү, үлү. – *Иртәгә байлыгыңнан гына түгел, башыңнан да колак кагарсың әле* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур). *[Җиһангир] Укыта алмыйсың икән, башыңнан колак кактың* (Н. Исәнбәт. Хуҗа Насретдин).

Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

**БАШТАН КОЛАК СӘДАКА** *иск.* Зур югалтудан котылу өчен, кечерәк корбанга риза булу. – *Бакчадагы теге кызыл чәчәккә күзе төшкән иде бугай, казып алып куй, баштан колак сәдака – биреп котылыйк шуны* (Сөйләм).

**БАШТАН ОЧУ (ОЧЫП ЧЫГУ).** Онытылу. *Дәресләрдә утырганда, «инфинитив», «перфект», «герундий»лар кемнең генә үзәгенә үтмәгән дә, кемнең генә башыннан очып чыгып китмәгән!* (М. Маликова). – *Язгы чәчүне тизләтергә кушып, районнан кыздыра башлагач, тугым-тәгәрмәч кайгысы баштан очты, бөтен ир-атны кыр эшенә куштык, – дип аңлатып бирде Фазылҗанов* (Ф. Хөсни. Җәй башы).

**БАШТАН ӨМЕТ ӨЗҮ.** Төшенкелеккә бирелү, җаннан өмет өзү. *Моңарчы пыскып кына килгән өмете дә башыннан өзелде, димәк, монда аны бәйләп торган бернәрсә дә калмады* (Сөйләм).

Төрдәше: кул селтә<н>ү (селкү) 1; кул ташлау; өмет җилгә китү; өмет кис<ел>ү; өмет өз<ел>ү; өмет<ләр> сүнү; өмет тамчысы да юк; өмет төшү; өмет шәмен сүндерү; өметенә таш бәйләп суга ташлау (салу); өметсезлеккә бату (бирелү; төшү); рух сүнү; рух сыну; рух сүрелү; рух төшү; сулагай кулны селтәү; тарт танавыңны; тот капчыгыңны; тот капчыгыңны, бодае читкә акмасын.

**БАШТАН ПАР ЧЫГУ.** Тирләп-пешеп эшләү. *Баштан пар чыга* (М. Мәһдиев. Ачы тәҗрибә). *Бу вакытта бөтен класс эшкә тартыла, баштан пар чыга* (Р. Абдуллина. Сөйләм культурасы).

Төрдәше: авызга җаны килгәнче (чыкканчы) тырышу һ.б.

**БАШТАН САЛКЫН СУ КОЙГАН (СИПКӘН) КЕБЕК <БУЛУ>** *к.* аркага (аркасына) бозлы (кайнар; салкын; эссе) су койган (сипкән) кебек булу. *Баштан салкын су койган төсле калтыранып алдым, йөрәгем жу итте, акылымны җуйгандай булдым* (Г. Минский). *Шул мәлне баштан салкын су койган кебек булды, кан тамырлары кысылып, тез буыннары җебеп китте* (В. Нуруллин. Җиденче палата).

Төрдәше: аркага (аркасына) бозлы (кайнар; салкын; эссе) су койган (сипкән) кебек булу һ.б.

**БАШТАН СЫЙПАМАУ (СӨЙМӘҮ)** *к.* акыл бизмәненә утырту. *Бер җирдә шулкадәр куе чәчеп, икенче җирне кысыр калдырырга ярамый. Белә калса, моның өчен район да баштан сыйпамас* (Г. Бәширов). *Ул-бу булса, безнең баштан сыйпамаслар* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

Төрдәше: акыл бизмәненә утырту һ.б.

**БАШТАН СЫЙПАП РӘХМӘТ ӘЙТҮ** *мыск.* Орышу яки җәза алачагына ишарә. *[Малтабаров] Бар, булмаса дөресен сөйләп бир. Башыңнан сыйпап, рәхмәт әйтерләр* (Т. Гыйззәт. Мактаулы заман).

**БАШТАН СЫЙПАП ТОРУ.** Хуплап-җөпләп, юмалап кына тору. *Шуңа күрә мин, әлеге баштан сыйпап тору традициясен бозып, шагыйрәләребезнең үпкә-рәнҗүләрен (ә бәлки, рәхмәтләрендер?!) үзем күтәрергә, аларның кайберләре турында туры сүземне әйтергә кирәк таптым* (М. Шабаев. Шагыйрәләребез). *Без дә баштан сыйпап тора алмабыз: үлемгә – үлем !* (Т. Әйди. Елан угы).

**БАШТАН СЫЙПАУ** *к.* аркадан сыйпау. *Аркадан, баштан сыйпыйлар, и күңелле! и хозур!* (Г. Тукай). *Мин «халыкның дусы» булып торам, / Халык минем «баштан сыйпасын»* (Г. Афзал).

Төрдәше: аркадан сыйпау һ.б.

**БАШТАН ТАШУ (ТАШЫП КИТҮ)** *к.* баштан ашу. *Үз нужасы да башыннан ташып киткән иде әле* (Ф. Хөсни).

Төрдәше: баштан ашу һ.б.

**БАШТАН ҮТҮ.** Үзе күргән, кичергән вакыйга, хәл белән таныштыру. *Кызганычлы бер кыяфәт, яшьле күз берлә мискин Баш болай дип башлый сүз: «Баштан үткәнне сөйлимен, тыңлагыз, / Мин хаҗи – бардым хаҗә туксан тугыз»* (Г. Тукай. Печән базары, яхут Яңа Кисекбаш). *Менә шундый хәлләр, туганкай, баштан үтте. Хәзер рәтләнеп киләм инде* (Г. Әпсәләмов. Икенче гомер).

**БАШТАН ЧЫГАРУ (ЧЫГАРЫП ТАШЛАУ).** 1. Уйланган уйдан баш тарту, ваз кичү, *шулай ук к.* акылдан чыгару. *Ләкин моны бик тиз башыннан чыгарды, ярамас та, кирәкмәс тә дип беркетте* (Г. Ибраһимов). *[Хөснетдин] Тик бары минем Камилә сеңелне кәләшлеккә алу уйларыгызны бөтенләй башыгыздан чыгарып ташлагыз дим ул чагында* (Ш. Камал. Хаҗи әфәнде өйләнә).

Төрдәше: акылдан чыгару 1 һ.б.

2. Уйлап чыгару. *Хәзер минем шәхси тормышымда шушы ашарга юнәтү, өйгә утын юнәтү белән тулы, соң дәрәҗәдә вак мещанлык (гаҗәп түгелме?) интересына гына мәхсүр итеп калдырылган көндәлек тормышымны онытып, баштан чыгарып язасы иде* (А. Шамов. Бер кичәдә).

Төрдәше: акылдан чыгару 3.

**БАШТАН ЧЫГУ (ЧЫГЫП КИТҮ)** *к.* акылдан чыгу (чыгып китү). *«Ашар ризыгы бетмәгән булса, Нәкыйбем кайтыр да, үзе түләр»*

*дигән өмет шулай итте, күрәсең, тора-бара баштан чыккан...* (Ә. Гаффар. Әҗәт). *Бөтен белгәннәрем баштан чыгып очты. Алай да үземне кулга алдым* (З. Мәхмүди. Сары каеш – сары сагыш).
Төрдәше: акылдан чыгу (чыгып китү) һ.б.

**БАШТАН ЧЫКМАУ.** Һәрвакыт аның турында уйлау, онытылмау; уйда, акылда ныклап утыру. *Бу сорау аның башыннан бик озак чыкмады* (К. Нәҗми). *Көндез дә, төнлә дә әти-әни, туганнар баштан чыкмады* (И. Хуҗин. Өченче орден).
Төрдәше: авызга алу һ.б.

**БАШТАН ЭШКӘ ЧУМУ** *к.* авызга җаны килгәнче (чыкканчы) тырышу. *Нинди теләк ди, без ул елларны баштан эшкә чумган идек инде* («Ватаным Татарстан» газ.). *Мондый бармаклы кешеләр арасында гаиләләре һәм шәхси тормышларын онытып баштан эшкә чума торган кешеләр күп* («Өмет» газ.).
Төрдәше: авызга җаны килгәнче (чыкканчы) тырышу һ.б.

**БАШТАН ЯЗУ.** Һәлак булу, үлү. *Әйе, күпме бояр кан сыкты бу тәхет җирлегендә. Гөнаһсыз җөмлә өчен дә башыннан язучылар булды* (М. Әмирханов. Тәхетсез патша).
Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

*БАШТАНАЯК* ❖ **БАШТАНАЯК УЙЛАУ (ТӨШЕНҮ).** Тулысынча, төрле яклап. *Садыйк Гайниҗамалның кочагында тагын үзенең киләчәк ямьсез тормышын баштанаяк уйлады* (Г. Исхакый. Солдат). *Һәрбер эшне баштанаяк уйлаганга, / Тәэсир иттем дөньядагы барча җанга* (М. Гафури).

**БАШТАНАЯК ЭШКӘ БИРЕЛҮ (ЧУМУ)** *к.* авызга җаны килгәнче (чыкканчы) тырышу. *Чынлап та, бу күтәрелеш чорында ул гаять күп эшли, үз-үзен белештермичә, баштанаяк эшкә чума* (А. Вергазов. Үзеңә кайту). *Ләйсәннең фаҗигале үлеме белән бәйле авыр кайгысын оныту өчен, баштанаяк эшкә бирелде, көне-төне төзелештә булды, таш чапты, измә ташыды, шул кызулык белән, үзе дә соңыннан йорт җиткезеп керде* (Г. Гыйльманов. Юл читендәге авыл).
Төрдәше: авызга җаны килгәнче (чыкканчы) тырышу һ.б.

*БАШТҮБӘН* ❖ **БАШТҮБӘН КИЛҮ (КИТҮ).** 1. Мәтәлчек ату. *Ерым төбенә җәйлап кына төшкән җиреннән аягы таеп китте дә, баштүбән килеп, аска мәтәлеп китте* (Сөйләм).
2. *күч.* Чәнчелеп китү, дөмегү. *Гафиятнең тормышы гына түгел, бөтен дөньясы баштүбән китте бит аның* (Сөйләм).

*БАШЫ* ❖ **БАШЫ АВЫРТАДЫР ИНДЕ.** Берәрсе турында бик күп сөйләгәндә әйтелә. *Бүген аның исеме авыздан төшмәде, башы авыртадыр инде мескеннең* (Сөйләм).
Төрдәше: очкылык тота торгандыр инде <үзен>.

**БАШЫ АЯК АСТЫНА КИЛСЕН.** Каргыш сүзе буларак кулланыла. *[Аксакаллар] – Авызыңа бал да май, көтүче Гали! Мөхәммәт солтанның башы аягы астына килсен!* (Н. Фәттах). *[Җәмилә] Эчсен, бетсен, башы аяк астына килсен иблиснең* (Ю. Әминов. Язылмаган законнар).
Төрдәше: Алла орсын! һ.б.

**БАШЫ БАШ ТҮГЕЛ.** 1. «Сәламәтлеге юк» мәгънәсендә. *Ә Парпимның башы баш түгел инде менәтерә. Яшьтән көмешкә эчеп үссә дә, макмыр төшә* (Р. Батулла).
2. Берәрсен бик акыллы, зиһенле дип санау. *Ә тагын (монысы да начар, әлбәттә) җәзасызлыгына бик артык ышанасың, үзеңне гайре табигый шәхескә, артык акыллыга санныйсың, янәсе, аның башы баш түгел, ә Берләшкән Милләтләр Оешмасы!* (Ә. Мушинский. Һаваларда – ак күгәрчен).

**БАШЫ БАШ ТҮГЕЛ, БАШЫ КАРГА ОЯСЫ.** Берәр кешенең тузгыган чәчләрен яки баш киемен чагыштыру. *Кара инде тегенең эшләпәсенә, башы баш түгел, башы карга оясы булган* (Сөйләм).

**БАШЫ БАШЛАЙ, ЭЧЕ ЭЧЛӘЙ.** Һәрнәрсә аеры икәнлегенә ишарә. *Бер яктан алыптай сыер тере килеш кереп китә, ә икенче яктан башы башлай, эче эчләй, каны тагын үзе аеры килеп чыга, имеш* (Р. Вәлиев. Эт кояшы).

**БАШЫ БӘЛАГӘ КАЛУ.** Бәла-казага дучар булу. *Солдатларның да рәхимлеләре булыр икән. Алар да бит патша колы! Юкса башы бәлагә каласын белсә дә, түзмәде, бичара...* (Н. Сәфәров. Каргышлы һәм өметле көн).

**БАШЫ БӘС КИЧҮ** *к.* баштан бәс кичү. *[Лениза] Башы бәс кичкәнче өйләнергә бит исәбе! Бик әйбәт булырие* (Р. Хәмид. Тигезәкләр).
Төрдәше: баштан бәс кичү һ.б.

**БАШЫ БЕЛӘН.** 1. Бөтенләй, тулысынча. *Бүрегә бирсәң – башы белән* (Мәкаль). *Кем дә кем берәр сәүдәгәрне рәнҗетсә, аның бүреген салдырырга башы белән* (А. Гадел. Бәхет кәрваны).
2. Кем булуына карамастан. *Шундый кеше булуына карамастан, аның белер-белмәс башы белән шундый зур рольгә тыкшынуына җене чыккан хәлдә, Хәйдәр каты гына сорап куйды* (Г. Бәширов. Намус). *Укытучы башы белән Фарук төньякның кая икәнен белмәде микәнни?..* (А. Гыймадиев. Үзең булып кал!..).

**БАШЫ БЕЛӘН ЧУМУ.** Тулысынча эшкә бирелү. *Дөресрәге, хезмәтен үзенә кулай табып, башы белән эшкә чумды* (Г. Исхакова. Диплом). *Хак фикерен әйтер, өчен сазлавыкка башы белән чуммый итагатьле казый* (Ф. Гыйззәтуллина. Яну дәверләрендә).
Төрдәше: авызга җаны килгәнче (чыкканчы) тырышу һ.б.

**БАШЫ БЕТКЕРЕ (ОЛАККЫРЫ)!** Үлсен! (каргау сүзе). *[Галимә] (елый башлап). И Ходаем, башы беткере!* (М. Фәйзи. Галиябану).
Төрдәше: Алла орсын! һ.б.

**БАШЫ <ГЫНА> БЕТСЕН** *к.* башы беткере (олаккыры)! *[Җәмилә] (ишектән кереп). Башы гына бетсен йөзе караның!* (Г. Камал. Бәхетсез егет). *Кемдер: «Башы бетсен денсезнең!» – диде* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!).
Төрдәше: башы беткере (олаккыры)! һ.б.

**БАШЫ ГҮРГӘ КЕРҮ.** Кабергә күмелү. *Башларыбыз гүргә керде, / Язмасын сезгә шулай* (Җыр).
Төрдәше: гүргә керү.

**БАШЫ ҖИҢЕЛ** *гади с., к.* акыл бергә дә тулмау. *Теге малайның башы җиңелрәк, ахрысы, карашлары сәер* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**БАШЫ ИКЕ ТҮГЕЛ (БУЛСА; МӘЛЛӘ).** Үлем куркынычы белән янау яки кисәтү. *Галиулла шундук сизеп алды: десятник аны су юлы өстендәге ташландык забойны рәтләргә җибәрмәкче икән. Юк инде, Галиулла анда бармас, аның башы ике түгел* (И. Гази).

**БАШЫ ЙОМРЫ.** 1. Акыллы, зиһенле. *[Фингал] Уф, котылдым. Башың йомры синең, Дездемона, тәгәрмәчләре тәгәри* (М. Маликова. Оҗмах балалары).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә) алу һ.б.
2. Хәйләкәр. *Агай-энеләре моны бик хупладылар: «Кияүнең башы йомры булып чыкты, колхозда эшләп барыбер мантып булмый»* (А. Гыйләҗев. Берәү).

**БАШЫ ЙӨЗТҮБӘН КИЛГЕРЕ** *к.* башы беткере (олаккыры)! *Башы йөзтүбән килгере!* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).
Төрдәше: башы беткере (олаккыры)! һ.б.

**БАШЫ КАБЫККА ТӨРТЕЛГӘНЧЕ ОНЫТМАУ.** «Үлгәнчегә кадәр онытмас» мәгънәсендә. *Рәхмәт сиңа, күрше, яхшылыкларыңны башым кабыкка төртелгәнче онытмам* (Сөйләм).

**БАШЫ КАЙДА – САРАЕ ШУНДА.** 1. Беркая да төпләнмичә, теләсә кайсы җирдә ята-куна йөрүче гамьсез кеше турында. – *Китәм моннан. Башым кайда – сараем шунда. Вәссәләм!* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).
2. Тормышка чыкмаган кызлар турында. *– Йә, кызларың өчен кайгырма. Башлары кайда – сарайлары шунда* (Х. Сарьян).

**БАШЫ КАЙДАНДЫР КАЙТМЫЙ ТОРГАН.** Авыр яки мәҗбүри булган авыр эштән һич котыла алмый торган. – *Аны авылдашлары белән урман кисәргә җибәргәннәр иде. Башы кайдандыр кайтмый торган кеше булып китте шул* (Сөйләм).

**БАШЫ КАЙТМАУ.** 1. Берәр эшкә чыгып китеп, туган җиренә, иленә кайтмау. *Кем белә инде аның кайчан кайтасын, акча эшләргә дип, шахтага китүеннән башы кайтмады әлегә* (Сөйләм). *Кемнең кулы, кемнең аягы, / Кемнең башы кайтмады* (К. Булатова).
2. Бер чыгып китсә, әйләнеп кайтырга кирәклеген оныта торган кеше турында. *[Бәдигыльҗамал] Юк, юк, өйдә юк, аталарына киткән. Аның шуннан башы кайтмый инде* (Г. Камал. Каениш).

**БАШЫ КАРА ТАКТАДАН ЧЫКМАУ**. Һаман тәнкыйтьләнү, начар яктан телгә алыну. *Аның*

*бит инде башы кара тактадан чыкмый* (Г. Бәширов).

**БАШЫ КАРАБОДАЙ БЕЛӘН ЯПКАН.** Сөйләгәнне аңлый, телне белә. *Мондый очракта безнекеләр бер-берсен «башы карабодай белән япкан» дип кисәтеп куючан* («Безнең мирас» ж.).

Төрдәше: башы карабодай саламы белән ябылган (япкан); башы салам белән япкан; башы тишек 1.

**БАШЫ КАРАБОДАЙ САЛАМЫ БЕЛӘН ЯБЫЛГАН (ЯПКАН)** *к.* башы карабодай белән япкан. – *Теге нәрсәнең башы карабодай саламы белән ябылган. Теге егетне дә шул әрәм итте, диләр бит...* (М. Гафури).

Төрдәше: башы карабодай белән япкан һ.б.

**БАШЫ КАТЫ.** 1. Тиз генә төшенә алмый, авыр аңлый торган кеше турында. *Бизнеска башы каты эшләгән егет бу сүзләрдән югалып калды, аның аптыраганын күреп, Харис көлеп җибәрде* (М. Маликова. Өермә).

2. Дилбегә-тезген белән башын каерып борып йөртү авыр булган ат хакында. *Бу атны бик кума, башы каты икәнен дә онытма* (Сөйләм).

**БАШЫ КАТЫ, АРТЫ САСЫ.** Тыңлаусыз, бозык, үҗәт кеше хакында. *Бездә андый юньсез кешеләр турында «башы каты, арты сасы» диләр* (Сөйләм).

**БАШЫ КӘГАЗЬДӘН ЧЫКМАУ.** Язу-сызуларга, китап-дәфтәрләргә күмелеп эшләп утыру. *Ә минеке «Гап-гади бухгалтер. Мытыеста эшлим» дисә дә, башы кәгазьдән чыкмый, кулы чут төймәсеннән аерылмый аның* (Ф. Латыйфи. Бәйсез этләрне атарга).

**БАШЫ КЕНДЕГЕНӘ ЯБЫШКАН.** Кемгәдер ялагайланып, куштанланып йөрүче хакында. *Абзыена артык өметләнеп йөри бугай, башы бөтенләй кендегенә ябышкан* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга бал да май булып керү һ.б.

**БАШЫ КЕРМӘГӘН (СЫЙМАГАН) ҖИРГӘ АРТЫ КЕРГӘН.** Урнашырга, кереп йөрергә хакы булмаган кешенең ришвәт биреп, туган-тумачалык яки әшнәлек ярдәмендә керүе. – *Ишеттеңме, Раил Гомәрович мөдир булган – башы кермәгән җиргә арты кергән, ахрысы* (Сөйләм).

**БАШЫ КЕРСӘ, АЯГЫ (АРТЫ; КОЙРЫГЫ) КЕРМӘГӘН, <АЯГЫ КЕРСӘ, ТАЯГЫ КЕРМӘГӘН>** *к.* аягы керсә, таягы кермәгән. *Башы керсә, аягы кермәгән яшь киленнең, бер-берсенең гадәт-холыкларын белешкәнче үк, сүзне тәнкыйтьтән башлавы, билгеле, Хәйдәргә бик үк ошап бетмәде бетүен* (В. Имамов. Нәзер).

Төрдәше: аягы керсә, таягы кермәгән.

**БАШЫ КУЛТЫГЫНДА** *к.* башны култыкка алу. *Башы култыгында, бераүдән дә калмаска тырышып, һөҗүмгә күтәрелде* (Сөйләм).

Төрдәше: башны култыкка алу һ.б.

**БАШЫ КЫРГАН.** «Татар кешесе» мәгънәсендә (элек татарлар чәчләрен кырып йөргәннәр). *«Башы кырган без такырга» дигән сүзнең татарлар турында баруы аңлашыла* (Татар әдәбияты. 10 кл.).

**БАШЫ ӨЗЕЛСӘ, КУЛТЫК АСТЫНА КЫСТЫРЫП ЙӨГЕРЕР** *к.* башны култыкка алу. *Борчыласы юк, кая барасын белеп бара, башы өзелсә, култык астына кыстырып йөгерер* (Сөйләм).

Төрдәше: башны култыкка алу һ.б.

**БАШЫ САЛАМ БЕЛӘН ЯПКАН** *к.* башы карабодай белән япкан. – *Аның янында бик күп сөйләмәгез, башы салам белән япкан* (Сөйләм).

Төрдәше: башы карабодай белән япкан һ.б.

**БАШЫ СУККАН ЯККА ЧЫГЫП КИТҮ.** Бик күп уйлап тормыйча, башы-күзе кая караса, шул якка юнәлү. *Халитның үгетләрен колагына да элми иде, башы суккан якка тәүлекнең теләсә кайсы вакытында чыга да китә* («Сөембикә» ж.).

Төрдәше: дүрт ягың кыйбла.

**БАШЫ ТИШЕК.** 1. Телне белү (ягъни барысын да аңлый, төшенә, моны яшереп тору кирәкми). – *Ә юк ла, ул городовойның башы тишек түгел. Ул безнеңчә аңламый* (А. Расих. Ямашев). *Татарча аңлаган урысны, башы тишек моның, диләр. Татар сүзләре миенә үтә, дигән сүз* (М. Маликова. Өермә).

Төрдәше: башы карабодай белән япкан һ.б.

2. Хәтерсез (яки киресе; хәтере яхшы булган). *Хатынның «башы тишек» булмаса да, сак кыланды. – Бүген китмәм инде. Иртәгә ир-*

*тән барырмын* (Р. Кәрами. Сөеп туймас чакларың). – *Нинди апа, ни сөйлисең син, малай? – диде көлә-көлә. Башың тишек икән синең. Эләктереп калгансың бит, ә...* («Казан утлары» ж.).

3. Акылсыз, тилемсә. *Һарун әр-Рәшиднең бер бик яхшы шагыйре Хушнавәдән көнләшеп, вәзирләр аның өстеннән шаһка керәләр һәм: Башы тишек, дивана ул, диделәр* (Казан ханлыгы чорындагы татарча чыганаклар).

**БАШЫ ТҮБӘГӘ (ТҮШӘМГӘ) ТИЮ** *к* авыз еру 4. *Таңсылу барыбер канәгать. Сөенеченнән башы түбәгә тигән кебек* (Р. Камал. Таня – Таңсылу). *Куанычыннан әнинең башы түшәмгә тия* (Н. Гыйматдинова. Мәхәббәттә гөнаһ бар).
Төрдәше: авыз еру 4 һ.б.

**БАШЫ ТҮГӘРӘК** *к.* авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә) алу. *Башың түгәрәк икән, хан. Мин дә шулай дип уйлап торадыр идем* (М. Хәбибулин).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә) алу һ.б.

**БАШЫ ЯЛАНБАШ, АРТЫ ЯЛАНГАЧ** *эвф.* Үтә фәкыйрь кеше. – *Абау, башы яланбаш, арты ялангач кешеләр сездә дә бар икән әле* (Сөйләм).

*БАШЫ-АХЫРЫ* ❖ **БАШЫ-АХЫРЫ КҮРЕНМӘҮ.** Ниндидер күренешнең чикләре күренмәү, бер дә бетәчәге юк. *Башы-ахыры күренмәгән җигүле арбалар, җәяүле халкы: картлар, карчыклар, хатын-кыз, бала-чага* (Ә. Салах. Каеннар юлы). *Ә сугышның башы-ахыры күренми* (З. Мәхмүди. Әче балан).
Төрдәше: очы-кырые (очы-башы) күренмәү.

*БАШЫ-АЯГЫ* ❖ **БАШЫ-АЯГЫ БЕЛӘН ЙОТУ** *к.* баш<ы>-аягы белән. *Ләкин кеше суза икән, ул [интернет] аны башы-аягы белән йота; интернетта чыккан яңалыкларга комментарийлар бирү ул яңалыкларны анализлау түгел, сүз осталыгында ярышуга китерә <...>.* (Г. Даутов. Дөрес яшә).
Төрдәше: баш<ы>-аягы белән.

*БАШЫ-БОТЫ* ❖ **БАШЫ-БОТЫ БЕР КАЗАН.** «Бик кирәге бар иде яки кирәге шулхәтле генә» мәгънәсендә. *«Бик әллә кем булып йөрмәсен әле, – диде ул иптәш кызына, – аның шикеллеләрнең башы-боты бер казан»* (Сөйләм).

*БАШЫМ* ❖ **БАШЫМ ДА КҮЗЕМ, ТАНАВЫМ ДА (КҮТЕМ ДӘ) ҮЗЕМ.** «Ялгыз башым, үзем генә» мәгънәсендә; ягъни үземнән башка беркемем дә юк. *Миңа яшәргә күп кирәк түгел, күрәсез ич: башым да күзем, танавым да үзем* (Сөйләм).

*БАШЫМА* ❖ **БАШЫМА КЕРНӘ БУЛДЫ ИНДЕ.** «Йөдәтеп туйдырды инде, котылдым дигәндә генә килә дә йөдәтә башлый» мәгънәсендә (кернә – баш авыртуы). *Кайчан котылырмын инде үзеннән: иртән килсә дә сорый, кич килсә дә сорый – башыма кернә булды инде* (Сөйләм).

*БАШЫМ-АЯГЫМ* ❖ **БАШЫМ-АЯГЫМ БЕЛӘН.** «Баш өсте, бөтен җаным-тәнем белән хезмәтегезне үтәргә әзермен» мәгънәсендә. – *Гамбәр, син миңа бер хезмәт итә аласыңмы? – Башым-аягым белән* (М. Фәйзи).

*БАШЫМНЫ* ❖ **БАШЫМНЫ АЛЛА САКЛАСЫН, АРТЫМНЫ БҮРЕ АШАСЫН** *эвф.* «Башым исән булса, артымда ни калса да ярый» мәгънәсендә. *Ул гомере буенча «башымны Алла сакласын, артымны бүре ашасын» дип яшәде* (Сөйләм).

**БАШЫМНЫ БИРЕП ӘЙТӘМ.** Сүзенең хаклыгына ышандыру гыйбарәсе. *Башымны биреп әйтәм, кичә Мәрьям тәрәзәсен шакып торган кеше күрше авыл егете Мансур иде* (Сөйләм).
Төрдәше: айдыр әгәр һ.б.

**БАШЫМНЫ КИСӘРГӘ БИРӘМ, <МУЕН КАЛСА ҖИТӘР>.** Нәрсәне булса да икеләнмичә, ышаныч белән раслау; берәр нәрсәнең чын булуына ышандыру. *Бер атнадан соң шәһәрдә бер чех солдаты, бер офицер калса, башымны кисәргә бирәм* (К. Тинчурин). *Ревизиянең яхшы үтәчәгенә ышанам мин, башымны кисәргә бирәм* (М. Насыйбуллин. Шөбһә).
Төрдәше: айдыр әгәр һ.б.

*БАШЫН* ❖ **БАШЫН АЛ ДА САЛАМЫНА УТ ТӨРТ.** 1. Файдасы тигәндә генә, кешене танып кирәге беткәч, ташлап калдыру. *[Фәтхерахман] Чү, чү, чү, сабыр ит бераз, алай башын ал да саламына ут төрт дип чыгып китмиләр аны* (Г. Камал. Уйнаш).

2. «Кызына өйлән дә ата-анасы, кардәшләреннән ерак тор» мәгънәсендә. – *Алай кырт кисмә әле син, «башын алам да саламына*

*ут төртәм» дип яшәргә уйласаң, башыңны утка салмыйсыңмы икән?* (Сөйләм).

Төрдәше: бодаен ал да саламына ут төрт (ике маддә өчен дә).

**БАШЫН АЛСА – КОЙРЫГЫ (АРТЫ), КОЙРЫГЫН (АРТЫН) АЛСА, БАШЫ ЯБЫШУ.** Бер бәладән котылыйм дигәндә генә, икенче бәлагә юлыга торган кеше турында. *Башын алса – артын, артын алса, / Башын ябыштырган / Карга сыман, тормыш сазлыгыннан / Чыга алмый торам* (К. Булатова). *Кыскасы, башын алса – койрыгы, койрыгын алса, башы ябыша торган саескан хәлендә бүген авылдагы клуб мөдирләре* («Акчарлак» газ.).

Төрдәше: башын алса, койрыгы ябышу һ.б.

**БАШЫН АЛСА, КОЙРЫГЫ ЯБЫШУ** *к.* башын алса – койрыгы (арты), койрыгын (артын) алса, башы ябышу. *Сумалага кунган саескан хәлен беләсеңдер? Башын алса, койрыгы ябыша. Койрыкны кубарса, башы эләгә. Берүк сак бул...* (А. Гыйләҗев). *Саескан сумалага төшкән. Башын алса, койрыгы ябыша, ди. Безнең дә хәлләр шулайрак булып чыкты* (В. Нуруллин. Яшьнәп үткән яшьлек).

Төрдәше: башын алса – койрыгы (арты), койрыгын артын) алса, башы ябышу һ.б.

**БАШЫН ТАШКА БӘРЕРГӘ (БӘРЕР ӨЧЕН) ТАШ ЭЗЛӘҮ (ЭЗЛӘП ЙӨРҮ).** Файда итәм дип, үз-үзенә зарар әзерләп йөрү. *Хәер, бабай белән әбиләр, әткәй белән әнкәйләр башларын ташка бәрергә таш эзләп йөрмиләр. Быелгы тәкәләрне көтүдән алып калып, ипи, көрпә ашата башлыйлар* (Г. Мөхәммәтшин. Йөрәктәге эзләр).

*БАШЫНА* ❖ **БАШЫНА АЛУ.** Истә калдыру. *Кабатлап торуның кирәге юк иде, әйткәннәрне ул күптән башына алган иде инде* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга алу 1 һ.б.

**БАШЫНА БУЛГЫРЫ!** *к.* Алла орсын! *Кем эте ул шулай улый? Үз башына булгыры!* (Р. Батулла. Юл буенда зәңгәр чәчәк).

Төрдәше: Алла орсын! һ.б.

**БАШЫНА ДА КЕРТМӘҮ (КЕРЕП ЧЫКМАУ).** Уйлап та карамау, тегеләй-болай булыр дип аз гына да шикләнмәү. *Сугышка барырга туры килер дип, башыма да кертмәгән идем югыйсә* (М. Хуҗин. Айның уты сүнгән). *Өйләнүләрең хакында башыма да кереп чыкмады Әгәр яратмасаң, ничекләр итеп чыдармын дип куркып яшәдем* (К. Тимбикова. Уртак яр).

**БАШЫНА ДӨНЬЯ ТАР БУЛУ.** Кыен хәлгә калу, котылгысыз хәлгә тару. *Бер дә уйламаган, көтмәгән вакытта башына дөнья тар булды да куйды* (Сөйләм).

**БАШЫНА КАДАЛСЫН**! *к.* Алла орсын! *Каһәрләре үзенең башына кадалсын!* (Сөйләм).

Төрдәше: Алла орсын! һ.б.

**БАШЫНА КАЙНАР СУ КОЕЛГАНДАЙ** *к.* аркага (аркасына) бозлы (кайнар; салкын; эссе) су койган (сипкән) кебек булу. *Такмагына нокта куйгандай итеп, каш астыннан гына Әхтәмгә карап ала, еш кына егетнең солы саламы төсле алтынсу керфекләре арасыннан сирпелгән зәңгәр яктылыкны күреп, башына кайнар су коелгандай эсселәнеп китә, кызарынып башын ия* (М. Маликова. Язгы такыялар).

Төрдәше: аркага (аркасына) бозлы (кайнар; салкын; эссе) су койган (сипкән) кебек булу һ.б.

**БАШЫНА КАРШЫ.** Эшләгәннәре үзенә начарлык булып кайтырлык, үтә явызлык белән. *Бу эшләреннән ваз кичмәсә, башына каршы хәсрәт кенә чыгарачак* (Сөйләм).

Төрдәше: үз башына.

**БАШЫНА КАРЫНДЫК КИЕП ТУУ** *к.* анадан күлмәкле килеш туу. *Нәрсәгә тотынмасын, барлык эше дә уңышлы бара – башына карындык киеп тугандыр ул* (Сөйләм).

Төрдәше: анадан күлмәкле килеш туу һ.б.

**БАШЫНА КЫРАУ ТИГӘН (ТӨШКӘН)** *к.* баштан бәс кичү. *Күршенең дә башына кырау төшкән – без картаймый кем картайсын инде* (Сөйләм).

Төрдәше: баштан бәс кичү һ.б.

**БАШЫНА ТАУ ТӨШКӘН КЕБЕК.** Бәла-казага очрап, үтә борчылган хәлдә. – *Әле генә Маратны күргән идем, башына тау төшкән кебек, өенә кайтып бара иде* (Сөйләм).

**БАШЫНА УТЫРУ** *к.* бар дип тә белмәү 2. *Йомшаклык күрсәтсәң, башыңа, мәсәлән, менеп утыралар* (Ф. Әмирхан).

Төрдәше: бар дип тә белмәү 2 һ.б.

*БАШЫНДА* ❖ **БАШЫНДА БАР.** 1. Бераз эчкән, кызмача кеше турында. *Әллә башында ук бар инде, тәмам сагызга әйләнде* (Ф. Хөсни).

2. Акыл хастасы турында. *Улы Виталий армиягә дә ярамый, башында бар, укый-яза да алмый* (Ф. Бәйрәмова. Татар Караболагы – 50 ел үлем кочагында).

**БАШЫНДА НИ, ТЕЛЕНДӘ ШУЛ.** Уйлаганны яшереп-нитеп тормыйча, туп-туры әйтеп бирү. *Бездә аңа эшләргә җиңел булмас, кем ярата башында ни, телендә шул булган кешене* (Сөйләм).

Төрдәше: күңелендә ни, телендә шул.

**БАШЫНДА УТЫРУ.** Җитәкчелек итү. *Власть башында утырып, изге саналып йөргәннәрдән алар кай яклары белән ким?!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Шәмсүн яхшы белә: тирә-юньне зур игътибар белән күзәтеп баргандай күренгән хәйләкәр бу бәндә, син хуҗалык башында утырганда, дус булып кыланыр, ә кирәгең беткәч, җай гына читкә шылачак* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

*БАШЫНДАГЫ* ❖ **БАШЫНДАГЫ БҮРЕГЕН БЕР КӨН БУЕ ЭЗЛӘГӘН** *к.* алдындагын (алдындагысын) алты ай эзләгән. *Хәтере юк шул аның, ул башындагы бүреген дә бер көн буе эзли* (Сөйләм).

Төрдәше: алдындагын (алдындагысын) алты ай эзләгән һ.б.

*БАШЫН-КҮЗЕН* ❖ **БАШЫН-КҮЗЕН АЛАРТКАН.** Ашкынулы, әсәренүле яисә ачуыннан алакайган хәлдә. *Ишек кинәт кенә шапылдап ачылды да бүлмәгә башын-күзен аларткан кайнана килеп керде* (Сөйләм).

**БАШЫН-КҮЗЕН БОРУ.** Үзенә карату, гашыйк иттерү. *[Самат] Бер матурга күзем төште. Шуның башын-күзен үземә таба борасым бар* (Ю. Әминов. Язылмаган законнар).

*БАШЫННАН* ❖ **БАШЫННАН АЗАГЫНА (АХЫРЫНА) КАДӘР (АХЫРГАЧА).** Бернәрсә дә калдырмыйча, баштан ахырга кадәр укып чыгу (яки башка бер гамәл кылу). *Сугышның башыннан азагына кадәр сугышта булып, ике тапкыр каты һәм өч мәртәбә җиңелчә яраланып, бик каты ватылачак* (З. Зәйнуллин. Кави Нәҗми дигән язучы).

**БАШЫННАН АРТЫ (САНЫ) АВЫР.** Кузгалырга яратмаучы, гел утырып торучы кеше хакында. – *Бар, Әхмәтне алып чык әле, үзе тиз генә чыга алмас – башыннан арты авыр аның* (Сөйләм).

**БАШЫННАН КАВЫК ҖИЛЕ ИСКӘН** *к.* баштан бәс кичү. – *Карале, синең баштан да кавык җиле искән икән бит* (Сөйләм).

Төрдәше: баштан бәс кичү һ.б.

**БАШЫННАН ЧЫККАН.** Нинди дә булса эшне хәл итүдә бөтен юлларны белү. – *Белмәсәң, Мәрди карттан сорарсың, ул бу эшләрнең башыннан чыккан* (Сөйләм).

*БАШЫҢ* ❖ **БАШЫҢ ИКЕ БУЛСА...** Янау. <...> *өченчесе була торган эш түгел, Талыш бәк, Кошчак угълан булганда, башың ике булса гына моңа тотынырга кирәк* (Р. Батулла. Тарих эчләрендәниләр бар?). *Башың ике булса гына кагыл* (Ә. Баян. Тау ягы повесте).

Төрдәше: башы ике түгел (булса; мәллә).

**БАШЫ<Ң> СЫНГЫРЫ** *к.* башы беткере (олаккыры)! *[Мокамай] Ах, башың сынгыры, кабарга да өлгермәдем, кяфер!* (Һ. Такташ).

Төрдәше: башы беткере (олаккыры)! һ.б.

**БАШЫҢ – ТЕГЕРМӘН ТАШЫ** *к.* авыздан чыгуга эләктереп алу. – *Җай табарга сиңа куш. Башың – тегермән ташы. Шәп әйләнә* (Ә. Гаффар. Яра).

Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә алу) һ.б.

**БАШЫҢ ЯШЬ <ӘЛЕ>** *к.* авыз суы кипмәгән. *Белеп җиткермисең шул, кодача, башың яшь!* (Г. Бәширов. Намус). – *Шиблитка килсәк, мелла Чәйнүш, башың яшь әле, меңне киярсең* (И. Нуруллин. Ике Апуш).

Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

*БАШЫҢА* ❖ **БАШЫҢА ТАЙ ТИПКӘНМЕ ӘЛЛӘ** *к.* башка ишәк типмәгән. – *Башыңа тай типкәнме әллә синең?– ди иде берәү. – Бәласе тиен-тиенгә уртак буласын онытма!* (Б. Камалов. Күңел ярасы).

Төрдәше: башка ишәк типмәгән һ.б.

**БАШЫҢА ТӨШСӘ, БАШМАКЧЫ БУЛЫРСЫҢ.** «Авыр хәлдә калсаң, аннан котылу юлын табачаксың» мәгънәсендә. *Башыңа төшсә,*

*башмакчы булырсың, ди. Башка килгән авырлыкны җиңеп чыгарга кирәк* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).
Төрдәше: авыртмаган якка яту һ.б.

**БАШЫҢА ЧӘЙНӘП ЯК** *мыск.* Берәр нәрсәне сорап-сорап та бирмәгәч яки сатучы әйберенең бәясен төшермәгәндә әйтелә. *[Гөлҗиһан] Сиражҗины башларына чәйнәп яксыннар, җүләр белән тормасам, миңа ир бетмәгән* (Г. Камал. Банкрот).

*БАШЫҢДАГЫ* ❖ **БАШЫҢДАГЫ ЧӘЧЕҢ ДӘ ҖИТМӘС.** «Бик күп чыгым тотарга туры киләчәк» мәгънәсендә. *Хәзер йорт салып чыгу өчен, күпме акча кирәклеген беләсеңме, башыңдагы чәчең дә җитмәс* (Сөйләм).

*БАШЫҢНАН* ❖ **БАШЫҢНАН АРЫСЫН** *диал., к.* авызыгызны җил алсын (алгыры). – *Кеше алдында сөйли күрмә тагын, башыңнан арысын, бәлагә юлыгырсың!* (Сөйләм).
Төрдәше: авызыгызны җил алсын (алгыры) һ.б.

**БАШЫҢНАН ЧЫГАРЫП ТАШЛА.** «Ул фикереңне оныт, хәтта уйлама да» мәгънәсендә. – *Син дә башыңнан чыгарып ташла* (Г. Әпсәләмов. Алтын йолдыз). – *Әйдә, матурлык, гүзәллек дигән романтик төшенчәләрне бер мизгелгә башыңнан чыгарып ташла да эшкә кереш!* (Г. Сабирова. Шпаргалканы ничек кулланырга?).

*БАШЫҢНЫ* ❖ **БАШЫҢНЫ АЛ ДА КАЧ!** «Башың исән чакта бу куркыныч җирдән качып котыл» мәгънәсендә. *Килеп алып китәрләрме, китмәсләрме, дип көтеп утырма, дустым, башыңны ал да кач!* (Сөйләм).

**БАШЫҢНЫ БОРЫП АТАРМЫН!** Янау, куркыту. – *Тагын шулай рөхсәтсез мотоциклны алсаң, башыңны борып атармын!* (Сөйләм).
Төрдәше: астына ут үрләтү һ.б.

**БАШЫҢНЫ ЮККА АВЫРТТЫРМА.** «Юк өчен борчылып хәсрәтләнмә» мәгънәсендә. – *Башыңны юкка авырттырма, синнән башкалар да табылыр* (Сөйләм).

*БАШЫ-ТОЯГЫ* ❖ **БАШЫ-ТОЯГЫ БЕР ТИЕН** *к.* базары бер тиен. *Мстиславский кулын гына селтәде. – Бездә кәттә мехларның да башы-тоягы бер тиен* («Казан утлары» ж.).
Төрдәше: базарың бер тиен һ.б.

*БӘБӘГЕ* ❖ **БӘБӘГЕ ЧЕРГЕРЕ (ЧЫККЫРЫ)** *карг.* Күз алдында торганны яисә кирәк нәрсәне күрмәгәндә әйтелә. *Бәбәге чергере!* (Ш. Маннур).

*БӘБӘЙ* ❖ **БӘБӘЙ ИТӘК** *этн.* Итәккә берничә рәт бөргән тасма ялгау (< рус. *волан*). *Берсеннән-берсе озын биш күлмәген «бәбәй итәк» итеп киеп куйса, аягында йон оеклары өч кат булса, бишмәт тә, киез итек тә кирәкми иде аңа* (Л. Зөлкарнәй. Ком сәгате).

*БӘБӘЙГӘ* ❖ **БӘБӘЙГӘ КЫСЫЛУ** *к.* авыр аяк<лы> 3. – *Юк ла, йөкле хатыннар утырганын күргән идем, шуларның берәрсе бәбәйгә кысылгандыр* (А. Гыйләҗев. Өч аршын җир).
Төрдәше: авыр аяк<лы> 3 һ.б.

**БӘБӘЙГӘ УЗУ** *к.* авыр аяк<лы> 3. *Менә Галия бәбәйгә узды* (Ф. Мөслимова. Ярты алма). *Шулай да ул бәбәйгә узу өметен күңеленнән чыгармады* (Г. Галиева. Тулгак).
Төрдәше: авыр аяк<лы> 3 һ.б.

*БӘБӘЙДӘН* ❖ **БӘБӘЙДӘН КОТЫЛУ.** Балага узгач, корсак төшерү. *Сөембикә ирен күрүгә, бәбәйдән яхшы котылуын әйтергә теләгәндәй, чак кына хан тарафына калкынды да, сагышлы елмаеп, кире ятты* (Р. Батулла. Сөембикә).
Төрдәше: бала төшерү һ.б.

*БӘБӘК* ❖ **БӘБӘК АКАЕП ЧЫГАРГА ҖИТҮ.** Күзләрне аларту, ярсу. *Көндәшенең мондый сүзләрен ишеткәч, Язкилденең бәбәге акаеп чыгарга җитте* (Сөйләм).

**БӘБӘК АКАЙТУ.** Ачудан күзләрне зур ачып карау. – *Нәрсә бәбәгеңне акайттың, сиңа бирәчәгем юктыр ич!* (Сөйләм).
Төрдәше: ачу итү һ.б.

**БӘБӘК БӘГЫРӘЙТҮ.** Күз карасын кысыбрак карау. *Алар, бәбәкләрен бәгырәйтеп, Габбас мулла кызына төбәлерләр* (Г. Ахунов).
Төрдәше: бәбәк чекерәйтү.

**БӘБӘК ТЕРӘҮ.** Текәлеп, күзне-күзгә терәп карап тору. – *Нәрсә бәбәгеңне терәдең? Сиңа ни калган монда? – дип, җен ачуы белән кычкырып җибәрде* (Ф. Хөсни).
Төрдәше: күзне алмау һ.б.

**БӘБӘК ЧЕКЕРӘЙТҮ** *к.* бәбәк бәгырәйтү. *Нәрсәгә бәбәкләрегезне чекерәйттегез?* (Ф. Яруллин. Кызлар күңеле – тирән сер).
Төрдәше: бәбәк бәгырәйтү.

*БӘБӘЛӘН* ❖ **БӘБӘЛӘН ЙОМЫРКАСЫ.** Артык иркә кеше. *Өф-өф итеп кенә үстерәләр үзен, бәбәлән йомыркасы булды инде* (Сөйләм).
Төрдәше: бүректә (бүрек эчендә) үскән; хан кызы (егете; малае) 1; хан кызының кубыз тотып кулы кабарган.

*БӘБДЕ* ❖ **БӘБДЕ БӘҖВИН.** Элекке мәдрәсәләрдә хәтерләргә уңай булсын өчен саннарны сүзләргә әйләндереп төзегән гарәпчә тапкырлау җәдвәле. *Икенче ягыннан тыңлап карасаң, анда бөтенләй башка сүзләр ишетәсең: – Бәбде бәҗвин, бәдбе бәдхиин...* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

*БӘБИ* ❖ **БӘБИ АШЫ** *этн.* Бала тугач та, аш талымлаган анасына якыннары ягыннан китерелә торган төрле камыр һәм мич ашлары. *Кияүдәге кызлары бала тапкан икән дә, шуңа бәби ашы илтә киткәннәр* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**БӘБИ КИТЕРҮ** *к.* бала китерү. *Ат караучы, хатыным бәби китерде, абыстай, атларны улыңыз гына эчерер, дип сорап киткән ие* (М. Хәбибуллин).
Төрдәше: бала китерү һ.б.

**БӘБИ ТУЕ** *этн.* Бала туу хөрмәтенә туганнары һәм якыннары җыелышып, чәй мәҗлесе үткәрү. *Өй түрендә бәби туе атлы мәҗлес чәчәк атты* (В. Имамов. Карабәк). *Бәби туе бала туганнан соң җиденче көн җиткәч, кай очракта (мәсәлән, анадан ятим калганда) ундүртенче көнне үткәрелә* (Ф. Яхин. Татар халкында йола һәм әдәп кагыйдәләре).
Төрдәше: бәби чәе.

**БӘБИ ЧӘЕ** *этн., к.* бәби туе. *Бәби чәе эчәргә кергән күрше-күлән: – Шушы тиклем ошаса да ошар икән, нәкъ менә Зәбирнең үзе инде, суйган да каплаган, – дип шатлана-шатлана, Рәмзиягә күчтәнәчләрен, бүләкләрен тапшырдылар* (А. Гыйләҗев. Камыш бармак, көмеш тырнак).
Төрдәше: бәби туе.

**БӘБИ ЯЛЫ.** Бала табар алдыннан эш хакы саклапып бирелә торган ял. *Дөрес, түгәрәкләнгән гәүдә баскычлардан, коридорлардан элеккечә җиңеллек белән очып кына йөрергә мөмкинлек бирми, алай да бәби ялына киткәнче күп эшләрне очлап чыгасы бар иде* (М. Маликова. Язгы такыялар).

*БӘГРӘННӘГӘН* ❖ **БӘГРӘННӘГӘН НӘРСӘ** *диал.* Күзләрен тәгәрәтеп, берни аңламыйча торучы турында. *Бәгрәннәгән нәрсә, күрмисеңмени, йорт ишелергә тора бит!* (Сөйләм).

*БӘГЫРЬ* ❖ **БӘГЫРЬ АВАЗЫН ҖИТКЕРҮ.** Күңел түреннән чыккан сүзне әйтү. *Пышылдап, ул миңа бәгырь авазын җиткерә иде* (М. Галиев. Тимә, яшәсен!).

**БӘГЫРЬ АЙКАЛУ** *к.* бавырга боз урнашу. *Шуннан соң Фәләхнең бөтен бәгырьләре айкалып китте һәм ул, тиз генә килеп, Рәйхана ханымның иңнәреннән тотты* (В. Нуруллин. Фаҗига).
Төрдәше: бавырга боз урнашу һ.б.

**БӘГЫРЬ АКТАРЫЛУ** *к.* бавырга боз урнашу. *Бу вәхшилекне күреп бәгыре актарылган Идел, чарасызлыктан хәлсезләнеп, тып-тын гына ага* (М. Галиев). *Аңа караган саен, әчеттереп, күзгә яшь төшә, бәгырьләр актарыла* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: бавырга боз урнашу һ.б.

**БӘГЫРЬ БӘРГӘЛӘНҮ.** Рухи газап кичерү, нәрсә эшләргә белмәү. *Сулык-сулык бәгырь бәргәләнә* (Р. Низами).
Төрдәше: бавырга боз урнашу һ.б.

**БӘГЫРЬ БЕТЛӘҮ.** 1. Хиссез, йокымсыраган булу. – *Кайдан таптың бу аяк өстендә йоклап йөргән кешене, бәгъре бетләгәндер аның* (Сөйләм).

2. Кымырҗып утыру. *Эскәмиядә озак утырып бәгъре бетләгән, ахры: боргалана-сыргалана, янына куйган сумкасыннан еш-еш нәрсәдер актара...* (Сөйләм).

**БӘГЫРЬ БОЗГА ӘЙЛӘНҮ.** Бик каты рәнҗү, үпкәләү. *Битарафлык, чарасызлык хисе богауга алган, бәгыре бозга әйләнгән шушы чакта аңа янә Мансур очрады* (М. Әмирханов. Тәкъдир).
Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**БӘГЫРЬ ЕРТЫЛУ** *к.* бавырга боз урнашу. *Аның саен өчесенең дә бәгырьләре ертылып, җан*

*сүрүләре бүселеп алды* (Ф. Яхин. Бакыр бозау артыннан).

Төрдәше: бавырга боз урнашу һ.б.

**БӘГЫРЬ ҖӘРӘХӘТЕНӘ УЧЛАП ТОЗ СИБҮ** *к.* бавырга боз урнашу. *Фәррахның бу йортка килеп урнашуы – аның бәгырь җәрәхәтенә учлап тоз сибү* (Б. Камалов. Гомер кичендә).

Төрдәше: бавырга боз урнашу һ.б.

**БӘГЫРЬ ҖИЛЕГЕ**. Йөрәк (символ буларак). *Юк шул, тәмам бәгырь җилекләремә үтәрлек итеп өйрәтеп җиткермәгән икән* (Р. Төхфәтуллин).

**БӘГЫРЬ ҖИМЕШЕ.** Үз иткән, иң якын кеше (күбрәк – бала) турында. *Бала – бәгырь җимеше* (Мәкаль). *Мәхәббәт – бәгырь җимеше. Аны өзсәң, бәгырь дә өзелә* (Г. Гыйльманов. Оча торган кешеләр).

Төрдәше: бәгырь парәсе; бәлешнең төбе, чананың түре; җил-яңгыр тидермәү; ике туып бер калганым; йөрәк парәсе; йөрәк маем; карап торганы шул; кер кундырмау; кер тидермәү; кешене хөрмәтләү, үзеңне бәяләү; көен көйләү; куенга кыстырып йөрү; кул өстендә генә йөртү; кул тидермәү; кулында гына йөртү; күз алмасы кебек саклап тоту; күз алмасыдай саклау; күз бәбәгедәй саклау; күз карасыдай саклау; күз нурым; күз өстендә кара каш; күз өстендә каш кебек; күкәй эчендәге сары кебек; күңелен күрү; күңелен табу; күтәреп алу; өрмәгән җиргә (урынга) утыртмау; өстеннән бер кош та очыр<т>мау; өстеннән җил дә очыртмау; өф итеп тоту; рәхәттә йөз<дер>ү; салкынга өшетми, кайнарга пешерми; суга төшерми, утка пешерми; урыны түрдә; уч төбендә генә йөртү (тоту); уч эчендә генә йөртү; хәтерен табу; унике үлеп бер калганым.

**БӘГЫРЬ ҖЫЛЫНУ.** Күңелне тынычландыру, рәхәт булып китү. *Кайтыйк әле, Наис, Мөслимгә бер – / Өшәнгән бу бәгырь җылынсын* (Зөлфәт. Канат җиле).

**БӘГЫРЬ ИТЕН КИМЕРҮ (АШАУ)** *к.* бавырга боз урнашу. Җәфалау, теңкәгә тию. *Тагын да бәгырь итемне кимерергә теләсәң – бел: йә Әлфия белән кияү янына китеп яшим, йә булмаса, Әгъдәсләргә үк китәм* (Б. Камалов). *Башта Әминәгә кырылып бәгырь итен ашаган әнкәсе дә тынычланган сыман иде* (Н. Гыйматдинова).

Төрдәше: бавырга боз урнашу һ.б.

**БӘГЫРЬ КАЙНАУ** *к.* бавырга боз урнашу. *Ут төртәләр каныма, ут төртәләр, әйтеп: «Бәгыре кайнасын!..»* (Роб. Әхмәтҗан. Сонгми).

Төрдәше: бавырга боз урнашу һ.б.

**БӘГЫРЬ КАПКАСЫНА ДЕГЕТ СЫЛАУ.** Рухи газап китерү. *[Ярми] (әкрен). Мә соң. Йөр аның бәгырь капкасына дегет сылап* (Ә. Гаффар).

Төрдәше: бавырга боз урнашу.

**БӘГЫРЬ КАТУ.** Бик нык рәнҗү, үпкәләү катыш ачу килү. – *Әти белән сөйләшкәннән соң, мин ничектер усалланып киттем... Бәгърем катты* (Ә. Еники. Йөрәк сере). *Бүгенге көндә дә шуларны уйлады, әмма бәгыре каткан иде, елый алмады* (Д. Салихов. Чукрак).

Төрдәше: бавырга боз урнашу һ.б.

**БӘГЫРЬ КИБҮ** *к.* бавырга боз урнашу. *Хәдичәнең бәгыре кибеп китә. Нәрсә әйтергә дә белми* (Ф. Яхин. Август ае).

Төрдәше: бавырга боз урнашу һ.б.

**БӘГЫРЬ КИСӘГЕ<М> (БӘГЫРЕМ КИСӘГЕ).** Яраткан кеше һәм аңа мөрәҗәгать итү сүзе. – *Балам, бәгырь кисәгем, зинһар, безгә рәнҗемә, сабырлыгыңны җуйма* (Г. Галиева. Газзәбану).

**БӘГЫРЬ КИСЕЛҮ (ӨЗЕЛҮ** һ.б.**)** *к.* бавырга боз урнашу. *Юк, ул җырлый гына түгел, үкереп-үкереп елый да иде бугай. Әмма бу елау асыл ирләрнеке, күз яшьсез, бәгырь киселүе...* (Ф. Яхин. Мөдәмир, яки «Тәрәзә төбең үрмә гөл!..»).

Төрдәше: бавырга боз урнашу һ.б.

**БӘГЫРЬ<НЕ> КОРЫТУ** *к.* бавырга төшү. *Бөтенләй башка нәрсә – яла чагуга нигезләнгән, акылга сыймаслык хаталар дигән булып, бәгырьне корыталар* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң). *Әйе, аны Мукшылар «каратель» дил йөрткәннәр, – диде кылыч борынлы, аларның тәмам бәгырьләрен корыткан* (Х. Камалов. Үксезләр).

Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬ <КАРА> КӨЮ** *к.* бавырга төшү. *Котбетдиннең бәгыре көйдә. Тирә-якта шөһрәтле вә мактаулы Алтын Урдада бара иде шул бу хәлләр* (Ф. Яхин. Соңарган дастан). *Бары Гаязның гаиләсе: хатыны, балалары, туган-тумачасы гына бу гаепнең чеп-чи ялган, яла булуын белеп,*

*нахактан бәгырьләре көйде* (И. Иксанова. Сугыш корбаны).

Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬ ӨШҮ (ТУҢУ)** *к.* бавырга төшү. *Синең хәлдә ничек калып, бәгырь туңды, кан катты* (З. Мансуров. Өстәмә сыер). *Һич уйламыйм тәмугларда яначакны, / Бу дөньяда бәгыремне өшеткәннәр / Анда миңа кайнар учак ягачакны...* (Г. Мөхәммәтшин. Робагыйлар бакчасында).

Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬ ПАРӘ-ПАРӘ КИЛҮ (ТУРАЛУ)** *к.* бавырга төшү. *Әйтешкәч, күңеле тынычланыр кебек иде, хәзер әнә җаны ертылып чыгарга тора, бәгыре парә-парә килә* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы). *Шагыйрьләрдән бер сүз алалмыйча, / Бәгырь парә-парә туралды* (Ф. Гыйззәтуллина).

Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬ ПАРӘСЕ** *к.* бәгырь җимеше. *Ләкин... Бу очракта да бәгырь парәсе, йөрәк ярасы сәбәпче булды...* (М. Маликова. Көмеш билбау).

Төрдәше: бәгырь җимеше һ.б.

**БӘГЫРЬ ПАРӘСЕН ЙОЛКУ** *к.* бавырга төшү. *Актаралар салкын куллар, актаралар йөрәгемне, йолкыйлар шытырдатып бәгърем парәсен – кеше гомерен* (Роб. Әхмәтҗан. Урман җиле).

Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬ САВЫЛУ** *к.* бавырга төшү. һ.б. *Савылсын бәгырь, савылсын, / Китсен соңгы кәррәсе...* (М. Әгъләм).

Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬ СИКЕРҮ** *к.* авыз еру 4. *[Заһирә] Сөенечне ишеткәч, йөрәгең түгел, бәгырькәйләрең сикерер, тавык борын* (К. Тинчурин. Зәңгәр шәл).

Төрдәше: авыз еру 4 һ.б.

**БӘГЫРЬ СУЫРЫЛУ** *к.* бавырга төшү. *Кичләрен җиделе лампа яктысында, ярты литр керосинга да интегә-интегә, шәл бәйләде, тегү текте, бәгырьләре суырылып газапланды* (Н. Хәсәнов. Ак балык).

Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬ СЫЗЛА<Н>У** *к.* бавырга төшү. *Киявенең хәбәрсез-нисез төнлә килеп төшүен белгәч, рәхәтләнеп, матур итеп киявен каршы ала алмаган картның бәгыре янә сызланып куйды* (Г. Әпсәләмов). *Динислам, бәгыре сызласа, хатынын какмады, гадәткә кергән уллык әдәбен саклап, канун ихтыярына буйсынып, дөнья күтәргә күнде* (Г. Якупова. Күперләр).

Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬ ТАШ БУЛУ (БУЛЫП КАТУ).** Кешелексез, бик каты күңелле булу. *[Идегәй] (көлемсерәп). Дөрес әйтәсең, табиб, бәгырем таш булып катты...* (Р. Мингалим, Р. Хәмид. Идегәй). *Ничә көннәр бәгыре таш булып, гүяки суга баткан адәм хәлендә йөрде* (Ф. Яхин. Контора күсесе).

Төрдәше: каты бәгырь<ле>.

**БӘГЫРЬ ТАШУ (ТАШЫП ЧЫГУ).** Йөрәк түреннән, йөрәктән сызып чыккан бик нык сызлану яки сөенү. *Эзлим ул көннәрне, тапмыйм... Кинәт тагын бәгърем таша, ут ала...* (Һ. Такташ. Урман кызы). *Хәер, бу җыр гына түгел, ә яшьлегенең алсу чәчәкләрен вакытсыз койдырган җилбәзәк кыз баланың бәгыреннән ташып чыккан сагыш, әрнү-өзгәләнү, иңрәү авазы иде* (Р. Кәрами. Олы юл да сикәлтәле).

**БӘГЫРЬ ТЕЛГӘЛӘНҮ** *к.* бавырга төшү. *Синең күз яшеңне күрсәм, бәгырем телгәләнә* (Г. Минский). *Узеннең көчсезлегемнән, Айсылуга тырнак очы хәтле генә дә ярдәм итә алмавымнан бәгырем телгәләнә* (Ф. Гыйльми. Салават күпере).

Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬ ТЕЛҮ** *к.* бавырга төшү. *Уйнат пластинкасын, ичмасам, ул бәгыремне телмәсен* (Х. Сарьян).

Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬ ТЕТКӘЛӘНҮ** *к.* бавырга төшү. *Барлы-юклы ашау-эчүләребезнең яме-тәме тоелмый, бәгырьләребез дә теткәләнеп бетә инде!* (И. Туктаров).

Төрдәше: бавырга төшү.

**БӘГЫРЬ ТӨБЕНӘ ТАШ БУЛЫП УТЫРУ** *к.* бавырга таш булып утыру. – *Бар, күз алдыннан югалып тор, ичмасам, бәгырь төбенә таш булып утырган сүзләреңне ишетәсем килми* (Сөйләм).

Төрдәше: бавырга таш булып утыру һ.б.

**БӘГЫРЬ ТӨБЕНӘ УТЫРГАН ТАШНЫ КУЗГАТЫРЛЫК.** Үпкәләү, рәнҗү, рухи газапларны оныта алмау. *Тик бәгырь төбенә утырган ташны кузгатырлык көч юк Мәрфугада* (С. Сөләйманова. Ялгыз торна).

**БӘГЫРЬ ТУРАКЛАГЫЧ.** Күңелдә газап, авыр тойгылар уята торган. *Ни өчен соң азан шулай бәгырь тураклагыч хәсрәт моңына манчылган?* (Р. Батулла. Сөембикә).

**БӘГЫРЬ<НЕ> ТУРА<КЛА>У** *к.* бавырга төшү. *Төпчегемнең елавын тыныч кына тыңлый алмыйм, аның тавышы минем һәрчак сагайган бәгыремне телем-телем тураклый, үзәгемне өзә, кырыкмаса кырык эшем кырылып ятса да, мин, йөгереп, аның янына барып җитәм* (А. Гыйләҗев). *Йөрәктә – узган сугышның / Ярасы сызлый гомергә, / «Сау булсын илем, балам!» – дип, / Бәгырьләр туракланa...* (Ф. Гыйззәтуллина).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬ УЕЛУ** *к.* бавырга төшү. *Бу сүзләрне ишеткән Халисә җиңгинең күзләре маңгаена менеп, бәгыре уелып төште* (Ф. Яхин. Бар икән көрәселәр).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬ ЭРҮ.** Газаплар, үпкә-рәнҗүләр онытылу. *Эреп китә таштай бәгырьләр дә, канатлары аңа тигәндә* (Х. Әюп).
Төрдәше: кайгы китәрү һ.б.

**БӘГЫРЬ ЯНУ** *к.* бавырга төшү. *Газзәнең өстенә кайнар су койдылармыни, тәне генә түгел, бәгыре янды* (М. Маликова. Язгы такыялар). *«Әвене янган татар кебек ятасыз», – ди. Мин әйтәм, әвен түгел, бәгырь яна, дим* (Б. Камалов. Ялыкмаслар).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

*БӘГЫРЬГӘ* ❖ **БӘГЫРЬГӘ АЧУТАШ САЛУ** *к.* бавырга төшү. *Төптәңренең сүзләре егетне тәмам ярсытты, бәгыренә ачуташ салды, йөрәгеннән кан тамардай итте* (М. Хәбибуллин).

**БӘГЫРЬГӘ БӘРЕЛҮ** *к.* бавырга төшү. *Тимерләр бәгырьгә бәрелде, / Кулларны кабартты катысы* (Г. Афзал). *Йомшак күңелле иде... Дөрес сөйлиләр, әмма килешеп бетәсе килми. Бәгыреңә бәрелгәндә, сакланырга кирәктер бит?* (Ш. Галиев. Күңел күзем күргәннәр).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ БОЗ КАТУ.** Кешелек хисләре бөтенләй юкка чыгу, шулай ук *к.* бавырга төшү. *Көз берни сорамый, сораудан узган ул: «Бәгыренә боз каткан и күксел тугайның!»* (Роб. Әхмәтҗан).

**БӘГЫРЬГӘ БӨЯЛҮ.** Елап җибәрү алдында була торган халәт. *Сөембикә инде күптән җылый иде, әмма аның күз яшьләре бәгырьгә бөялгән иде* (Р. Батулла. Сөембикә).

**БӘГЫРЬГӘ ҖИРЛӘҮ** *шигъри.* Мәңге онытылмаслык итеп күңел түренә урнаштыру. *Бүген авыл туксан яшьлек моңын ирләр бәгыренә җирләде* (Х. Әюп).

**БӘГЫРЬГӘ ЙӨЗ ЭНӘ БЕЛӘН ЧӘНЧҮ.** Көчле газап бирү. *Сердәш бәгырьгә берьюлы йөз энә белән чәнчеде* (Н. Гыйматдинова. Җәза).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ КАГЫЛУ** *к.* бавырга төшү. *Нинди моңга, кайсы бәгырьләргә кагылалар минем кулларым?* (Х. Әюп). *Тотам сине – синең кыска дулкын / Бәгыремә кагыла, йөрәккә...* (Роб. Әхмәтҗан).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ КАДА<Л>У** *к.* бавырга төшү. *Ул әле болай, гүя үтеп барышлый гына, кешенең бәгыренә кадап китүне күргәне юк иде әле* (Ә. Еники. Шаяру). *Гөлйөземнең исә һәр аваздан йөрәгенә җәрәхәт ясала, һәр аваз авырттыргыч ук булып бәгыренә кадала иде* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ КАЙНАР СУМАЛА ТАМУ.** Начар хәбәр ишетү. *Шунда бәгырьгә кайнар сумала тамгандай булды* (М. Маликова).

**БӘГЫРЬГӘ КАН САВУ** *к.* бавырга төшү. *Шунда бәгырьгә кан сауган кебек авыр тәэсир калдырган мәлләр булды* («Матбугат.ру» порталы).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ КАН САУДЫРУ** *к.* бавырга төшү. *Бәгыренә кан саудыра әллә Мәскәү каласы, әллә Нугай даласы* (Ф. Габдерәхим. Ханбикә манарасы). *Әйдә, әйдә, тагын бәгыреңә кан саудыр, хатын* (Н. Гыйматдинова. Кәтәнә).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ КАРА КАН БУЛЫП САВУ** *к.* бавырга төшү. *Һәм шушы уйлар ныгып, тамырланып, картның бәгыренә кара кан булып сауды* (Җ. Дәрзаман. Җир авазы).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ КАТУ ЧЫГУ** *к.* бавырга төшү. *Бәгырьләргә кату чыкты, / Җилкәләргә – орылар...* (Э. Шәрифуллина. Җиңү көне).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ КЕРҮ.** 1. Серне белү. *Авыл хатыннары төпченүчән бит ул, йөрәк-бәгырьләреңә кереп баралар, мәңге әйтмәм дигән сереңне дә юмалап-юхалап чиштерә беләләр* (З. Мурсиев. Таш астында).
2. Үзәккә үтү, онытылмаслык булып истә калу. *Яшүсмер чакларда бәгырьгә кереп сеңгән җәфа чигүләр хәзер дә сиздереп тора* (К. Җәмит. Килмешәк). *Беркавым да тынгы бирмәүче, йоклаганда да шыбыр тиргә батырып уятучы бу очрашу, татлы да, газаплы да сулкылдауга әверелеп, гомерлеккә бәгырьгә кереп ояллады* (Л. Зөлкарнәй. Сафа).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ МОҢ ҖЫЕЛУ.** Сагыш туплану, сагышлану. *Ул ерагайган саен, егетнең бәгыренә, саркып, моң җыела, күңеле тула башлады* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).

**БӘГЫРЬГӘ ПЫЧАК КАДАУ.** Үзәккә үтәрдәй каты, авыр сүз әйтү. – *Әти, җаным* – диде ул. – *Рәнҗеттең син мине. Бәгыремә пычак кададың...* (М. Әмир).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ САЛУ (САЛЫП КАЛДЫРУ)** *к.* бавырга төшү. *Карт моны бик яхшы белә, әйе, онытасы юк, сугышның аның бәгыренә салып калдырган тирән ярасы хәзер дә әле кул белән капшап карарлык җөй булып саклана* (Ә. Еники).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ СУЫК ТӨШҮ** *к.* бавырга төшү. *Бүлмә кыса, дөнья кыса, суык / Төшә бәгырьгә, төшә бавырга* (С. Хәким. Кырыгынчы бүлмә).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ СЫЗУ (СЫЗЫП АЛУ)** *к.* бавырга төшү. *Ак кәгазьгә түгел, кара, – / Бәгырьләргә сызып яла яга* (Ф. Яхин). *Менә шулай... гашыйклыкның бәгырьгә сызып төшми торган, өстән генә сирпелеп алган юка катламы да була икән...* (М. Галиев. Тимә, яшәсен!).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ ТАШ АСЫП КУЙГАННАРМЫНИ** *к.* бавырга төшү. *Эчтә, үзәктә бәгырьгә таш асып куйганнармыни – нишләп болай авыр соң, болай ук газапланырлык бернинди кайгы-хәсрәт юк ләбаса* (З. Хәким. Легионер).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ ТАШ БУЛЫП УТЫРУ** *к.* бавырга төшү. *Җә, Ходай, болай булгач, бакыйга да бәгыренә таш булып утырган шушы хәвефле хәбәр озатачак бит инде* (М. Әмирханов. Гәүһәршад). *Мыскыллы язмышына дучар ителүдән туган ачу йомгагы бәгырьгә таш булып утырды...* (Ә. Моталлапов. Мәхшәр).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ <КАТЫ> ТАШ БУЛЫП ЯТУ** *к.* бавырга төшү. *Сәетнең күңелендәге шом, караңгы уйлар таралмады гына түгел, ә тагын да куерып, каты таш булып бәгыренә ятты, авырттырып, йөрәген кыса башлады* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ ТАШ УКМАШУ** *к.* бавырга төшү. *Йөзенә тагын баягы кырыслыгы кайтып, бәгыренә таш укмашты* (Н. Гыйматдинова. Кыргый).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ ТИЮ** *к.* бавырга төшү. *Әле бер йорттан, әле икенчесеннән инрәп чыккан кызганыч балалар елавы бәгырьләргә барып тия* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Сыгыла агач башлары, безнең бәгырьгә тиеп* (Х. Әюп).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ ТОЗ САЛУ** *к.* бавырга төшү. *Ул Җәгъфәрнең, кызы Галиянең бәгырьләренә тоз салырга, гөнаһсыз чиста җаннарына кагылырга, шик яисә үкенү уятырга теләми* (Ф. Латыйфи. Хыянәт). *Бүген ул үзе үтелгән араны ачык күрә, андагы әрнүләрне, күрә караудан иза чиккән сыман капланып йөрүләрнең газапларын, сөрлегү-абынуларын, бәгырьгә тоз салуларын тирәнрәк тоя* (Б. Камалов. Сания).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ ТӨКЕРҮ** *к.* бавырга төшү. – *Лач итеп төкердеме хам күпме яхшылык күрсәткән хатынның нәкъ бәгыренә?* (Ә. Еники. Ялгызлык). *[Хафиз] (сыктанып). Син мине таптадың, бетердең. [Лениза] (усал итеп). Минем сиңа бернинди бурычым юк иде бит* (З. Хәким. Тәрәзәдә һаман ут яна).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ ТӨШҮ.** 1. Ныклап кереп урнашу. *Әллә көй үзе, әллә аның уйнавы шулкадәр бәгырьгә төшә, шулкадәр җанны ләззәтле газапка дучар итә ки, – моны телдән аңлату һич мөмкин түгел, ишетергә, бары тик ишетергә генә кирәк!* (Ә. Еники. Гөләндәм туташ хатирәсе).

2. Аптыратып бетерү. *Ә суык бәгырьләргә төшеп, һаман туңдыра* (В. Нуруллин. Һәлакәт). *«Кайчан алып китәсез!» – дип, бәгырьгә төшteләр инде* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).
Төрдәше: теңкәгә тию 2.

3. Бәйләнү, үзәккә үтү, *шулай ук к.* бавырга төшү. *Һай җаным... үтерер инде. Ах, бәгырьләремә төшә* (Р. Төхфәтуллин). – *Сеңелеңне тый! – диде күркә сыман кабарынган Мәликә. – Бәгыремә төшә, Сәрвәр апа, үләм* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

4. Өзелеп ярату. *Йөрәккә кергән, бәгырьгә төшкән олы хисләргә бай сөюдән ваз кичеп тә, нәрсә өчендер үкенеп тә булмый* (Г. Бәйрәмова. Урау юллар илтә бәхеткә).

5. Сагыну. *Сагышымны күккә чөям, / – Яшен булып кабат кайта. / Бәгыремә төшә дә ул / Йөрәгемне, аһ, каната...* (Г. Гыйльманов).

**БӘГЫРЬГӘ УК БУЛЫП КАДАЛУ** *к.* бавырга төшү. *Бу игълан аларның бәгъренә агулы ук булып кадалды, ахрысы* (Р. Батулла. Сөембикә).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ <ТАШ БУЛЫП> УРНАШУ.** 1. Газап тудырган кеше яки нинди булса да халәт истән чыкмау. *Кайгы, таш булып, аның бәгыренә урнашты* (Г. Ахунов. Гомер юлы).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

2. Гашыйк булган яки берәр эш-гамәле белән бересе һәрвакыт күңел түрендә калу. *Анда синең күптән бәгыреңә кереп урнашкан, дөньяда иң чибәр, иң күркәм, төнлә төшләреңә кереп газаплый торган егетең утыра* (Т. Мөбарәков).
Төрдәше: бәгырьгә язу; истә тоту; күңелгә салу; хәтергә беркетү; хәтергә салу (салып кую); хәтергә сеңеп калу; хәтергә сең<дер>ү.

**БӘГЫРЬГӘ УТ КАБУ.** Нәрсәдер күңеленә, рухына көчле тәэсир ясау. *[Хатын] Теге чакта Фәгыйләнең сүзләрен ишеткән минуттагы кебек, бәгырьгә тагын ут капкандай булды* (М. Маликова. Язгы такыялар). *Аның бәгыренә ут капкан иде, тәненнән күлмәгенә ялкын үрләр төсле тоелды* (Б. Камалов. Мәрдән сукмагы).

**БӘГЫРЬГӘ УТЛЫ КҮМЕР САЛУ** *к.* бавырга төшү. *Бу сүзләре белән Гөлйөземнең бәгыренә тагын утлы күмер салганын ул үзе, әлбәттә, белми иде* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).

**БӘГЫРЬГӘ ҮТҮ (ҮТЕП КЕРҮ).** 1. *к.* бавырга төшү. *Кай җиремдер каймыкты, каерылды, кай җиремдер, сыдырылып, тоташ җәрәхәткә әверелде; тәндәге сызлавык бераздан бәгырьгә үтте, җанга төште, һәм мин үземнең бик уңайсыз бер хәлдә калуымны аңлый башладым* (Г. Гыйльманов. Китек ай).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

2. Күзне йоммыйча, бик җитди текәлеп карап тору. *Кайчан шулай да була: киләләр дә, бәгырьгә үтәрдәй иттереп текәлеп, тирән мәгънәле иттереп карап торалар...* (Зөлфәт. Чытырманда былбыл сайрый). *Кара киемленең исә битендә бер төге дә селкенмәде, ул Сәетнең күзләренә текәлгән һәм моннан унҗиде ел элек Идел дулкыннары кочагында югалган серне белергә теләгәндәй, бәгыренә үтәрдәй булып бораулый иде* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).

3. Гадәтләрнең яки сүзләрнең кешеләр тарафыннан үзләштерелеп, аларның сыйфатларына әйләнү. *Халыкның бәгыренә үтеп кергән шушы имансызлык, әхлаксызлык, кансызлык, шәфкатьсезьек бик күпләрне борчый* (Р. Зәйдулла. Мин, син, Мөхәммәтәмин...). *Шәп сөйли, чукынмыш кызый, сүзләренең аһәңе белән бәгырьләргә үтеп керә белә* (В. Имамов. Кәнәфи).

**БӘГЫРЬГӘ ЧӘНЧҮ (ЧӘНЧЕП ТОРУ)** *к.* бавырга төшү. *Бу сорау Рабиганың бәгыренә чәнечте* (Н. Гыйматдинова). *Көнчелек галәмәте*

*бәгыренә чәнчеп тормаса, колхоздашын мактауга каршы кем күсәк күтәрсен инде?* (Б. Камалов. Күңел ярасы).
Төрдәше: бәгырьгә төшү һ.б.

**БӘГЫРЬГӘ ШЫРПЫ КАДАЛУ** *к.* бавырга төшү. *Авылның бәгыренә шырпы кадалды шул* (Н. Гыйматдинова. Җәза).

**БӘГЫРЬГӘ ЯЗУ** *к.* бәгырьгә <таш булып> урнашу 2. *Ә барыбер исемеңне уеп яздым бәгырьгә* (З. Мансуров. Сер).
Төрдәше: бәгырьгә <таш булып> урнашу 2 һ.б.

*БӘГЫРЬДӘ* ❖ **БӘГЫРЬДӘ УЙНАУ.** Кәефне бозу. *«Күзенә чалынасы булма, килде-китте ясап йөреп, малайның бәгырендә уйнама», – дип фикер йөртте* (Ә. Моталлапов. Мәхшәр).

*БӘГЫРЬДӘН* ❖ **БӘГЫРЬДӘН ӨЗЕЛЕП ТӨШҮ.** Канкардәш булуга ишарә ясау. – *Әстәгъфирулла, тәүбә-тәүбә, диген, син минем кызым Бибихәмдүнәнең бәгыреннән өзелеп төшкән җимеше бит* (М. Әмирханов. Зиннәтулла хәзрәт). *Көй басымы урман эчләрендә – бәгырьләрдән өзелеп төшкәне* (Х. Әюп).

**БӘГЫРЬДӘН СУЫРЫП ТАРТЫП АЛУ**. Рухи газаплау. *Салихҗанның егет көннәрен нурлы-моңлы иткән, инде җаны шунсыз яши алмаган бу матурлык дөньясын көтмәгәндә бәгыреңнән суырып тартып алсыннар әле!* (А. Вергазов. Йөрәк җыр сорый).
Төрдәше: бавырга боз урнашу 2 һ.б.

*БӘГЫРЬНЕ* ❖ **БӘГЫРЬНЕ АВЫРТТЫРУ** *к.* бавырга төшү. *Бүген көне буе җанны борчып, бәгырьне авырттырып йөргән газаплы сорауларга җавап тапкандай җиңеләеп кала* (Ф. Шәфигуллин. Ачуланмасаң, барып карар идем).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ АКТАРУ** *к.* бавырга төшү. *Шырпы кабы чаклы шул гармуны бәгырьләрне салды актарып* (Х. Әюп). *Ирнең төбәп каравы бәгырьне актара, үләселәр килә иде* (Н. Гыйматдинова. Кыргый).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ АЧУ.** Эчендәген яшермичә әйтеп бирү, дөресен сөйләү. *[Кабил] (әзләнеп). Булса ул [дус] сузсын кулын, / Дуслык белән бәгърен ачып* (Һ. Такташ. Җир уллары трагедиясе).

**БӘГЫРЬНЕ АШАУ** *к.* бавырга төшү. *Шик корты кешене эчтән кимерә, күзгә күрсәтми генә бәгырен ашый, тәнен киптерә* (Ф. Латыйфи). *Тәүге минутта әнә шул нәрсә йөрәгемне телде, бәгыремне ашады* (М. Хәбибуллин. Унсигезенче яз).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ БОРАУЛАУ** *к.* бавырга төшү. *Барысы да Әлбинәгә текәлгән сыман. Яндырып, бәгырен бораулап карыйлар...*(Э. Касыймов. Бир кулыңны, дустым!..). *Көн дә бәгъреңне бораулап... / Күзәтәдер кебек кемдер!* (Р. Рахмани. Кемдер...).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ ГАЗАПЛАУ (ҖӘФАЛАУ)** *к.* бавырга төшү. *Әнисә үкси дә башламады, бәгыренең газапларын да тышка чыгармады* (В. Имамов. Күке). *Күкрәгемдәге җаным өзгәләнә, бәгырем җәфалана* («Яшел Үзән» газ.).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ ҖИДЕГӘ ТЕЛҮ** *к.* бавырга төшү. *Гитараның сыкрый җиде кылы, җиделәргә телеп бәгырьне* (С. Сөләйманова).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ ҖЫЛЫТУ.** Уңай тойгылар тудыру, рухи күтәренкелек бирү. *Хәтта котыпта да сине уйлау / гел җылытып тора бәгырьне* (Н. Әхмәдиев. Безнең як). *Ә кем белә, бәлки, шул эш Халитның бәгырен җылытыр, уйландырыр* (А. Расих. Каһарманнар юлы).

**БӘГЫРЬНЕ ИГӘҮ (ИГӘҮ ИЛӘ ЫШКУ)** *к.* бавырга төшү. *Әмма беләм: шушы минуттан минем бәгырьне билгесезлек иги башлаячак* (Ә. Еники. Гөләндәм туташ хатирәсе). *Нигә сез бүтәннәрнең дөньяларына катышмый вә бәгырьләренә игәү илә ышкымый яши алмыйсыз?* (Ф. Яхин. Гади замана).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ ИМГӘТҮ** *к.* бавырга төшү. – *Тешләде мине дөнья! Имгәтте! Җанымны, бәгъремне имгәтте* (Д. Салихов. Чукрак). *Рәфис хыянәте белән бәгырен имгәткәннән соң, ул озак авырды, аның өчен мәхәббәт йогышлы чирдән дә хәтәррәк иде* (Н. Гыйматдинова. Синдә минем хакым бар).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ ЙОМШАРТУ.** Рухи газапны, әрнүне киметү. – *Бар-бар, балакай, каткан бәгырең йомшартып кайт* (М. Хәбибуллин. Айбиби). *Абыйсына карата бәгырен йомшартыр өчен, аның изгелекләрен барлады* (Н. Гыйматдинова. Ачкыч).

**БӘГЫРЬНЕ КАЙНАТУ** *к.* бавырга төшү. *Кайнаталар бәгыремне, ут ягалар, кайнаталар, кайнаулардан – янар таудай, җаным айнымый* (Роб. Әхмәтҗан. Урман җиле). *Васил да үз әйткәненә үзе төшенеп җитмәде кебек, аның бәгырен кайнатып җибәргәндәй булды бу сорау* (С. Рәфыйков. Тын елга буенда).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ КАНАТУ** *к.* бавырга төшү. *Булсын дип сөюең канатлы / Бәгырьне, йә... азмы канаттың* (Р. Рахмани. Йә бар ул, йә ул юк...). *Бәгырьләрнең касәләре тулы, / Бәгырьләрне ашаган. / Бәгырьләрне канатып, шуңа риза да булыйк, ди* («Идел» ж.).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ КАТЫРУ** *к.* бавырга төшү. *Олы улының тәкәбберлегe картның бәгырен катырган иде, ул, ымлап кына, Йосыфтан күзлеген китертте һәм, караватта аягын бөкләп, гәзит укырга керeште* (Н. Гыйматдинова. Ачкыч).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ КИМЕРҮ** *к.* бавырга төшү. *Казаннан кайткач, анасының борчылып, җәберләнеп кенә түгел, хурлыгыннан елап каршы алуы Гайнанның күз алдыннан китмичә, бәгырен кимереп тора* (Г. Бәширов. Җидегән йолдыз). *<...> болай дип йомгак ясады: «Сезнең үтәлми калган, хәзерендә җаныгызны борчып, бәгырегезне кимереп торган берәр олы максатыгыз юкмы?»* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ КИПТЕРҮ (КОРЫТУ)** *к.* бавырга төшү. *Хат язарга да кыенсынды, билгесезлектә яшәү дә бәгырьне киптерде* (Ф. Садриев). *Бөтенләй башка нәрсә – яла ягуга нигезләнгән, акылга сыймаслык хаталар дигән булып, бәгырьне корыталар* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ КИСҮ** *к.* бавырга төшү. *Рабигадан гайре тагын кемнәр аның бәгырен кисеп рәнҗетте икән?!* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ КОРТ АШАУ (КИМЕРҮ)** *к.* бавырга төшү. *Корт тынычлык бирми, корт акрын гына аның бәгырен ашый иде...* (Ә. Еники. Рәхмәт, иптәшләр). *Ләкин ничек кенә үзенең күңелен күтәрергә, иптәшләре алдында шат һәм ваемсыз күренергә тырышмасын, аның бәгырен корт кимерә иде* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ КӨЙДЕРҮ (КӨЙДЕРЕП АЛУ)** *к.* бавырга төшү. *Мәфтуха иренең аны гомере буена алдап, аңа хыянәт итеп яшәвенә бәгырьләреңне көйдереп алырдай итеп рәнҗеде* (Г. Бәширов. Менә сиңа мә!). *Бу сораулар Мортазаның бәгырен утлы тимер кебек көйдерә иде* (М. Маликова. Кызыл гөл).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ КЫЙНАУ** *к.* бавырга төшү. *Кешеләр дөньяга сыеша алмый, бер-беренә бәйләнеп, җанын талап, бәгырен кыйнап яши* (Ш. Галиев. Илһамым-мәхәббәтем). *Күңел чоңгылларында инде мәңгегә чыкмаска, искә төшермәскә, бәгырьне кыйнамаска дип күмелгән хатирәләр тыелгысыз булып баш калкытты* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ ӨЗҮ** *к.* бавырга төшү. *Нәкъ көлә, нәкъ елмая, / нәкъ юри бәгырьне өзә* (С. Рәмиев). *Бишектәге Габдулла әнисен таный башлаган көннәрдә Кушлавыч авылы сандугач моңына тула, сихри көчләр, алсу таңнарда чутылдаган бу кошчыклар гашыйкларның йөрәген телгәли, хәсрәтлеләрнең бәгырен өзә* (М. Мәһдиев. Кушлавыч).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ ӨШЕТҮ** *к.* бавырга төшү. *Битлек төсле җансыз чырае, салкын корычтай күзләре белән бәгыремне генә өшетеп китте* (Ә. Еники). *Бу бәндә миннән ерагайган, бары тик аның белән бәйле гомер кисәгенең кайтавазы гына бәгырьне өшетә иде* (Н. Гыйматдинова. Сөйлим, тыңла...).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ ПАРӘ-ПАРӘ КИТЕРҮ** *к.* бавырга төшү. *Күңел түренә җыелган әнә шул йомарлам хәзер берьюлы чишелеп китте дә, ачы күз яше булып, бәгырьләрне парә-парә китерә торган кайнар хәсрәт булып, тамак төбенә бөялде* (Г. Бәширов. Көзге ачы җилләрдә...).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ ПАРӘ-ПАРӘ ТЕЛ<ГӘЛӘ>Ү** *к.* бавырга төшү. *Гармун ашкынып-талпынып моң түгә, җанга үтеп, бәгырьләрне парә-парә телгәли* (М. Хәсәнов. Язгы аҗаган). – *Бәгыремне парә-парә телмәсәнә, сылу бикәм, мине дә үзең кебек чарасыз итмәсәнә!* (М. Хәбибуллин. Хан оныгы Хансөяр).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б. `

**БӘГЫРЬНЕ ПЫЧАК БЕЛӘН ТЕЛ<ГӘЛӘ>Ү (ТЕЛЕП АЛУ)** *к.* бавырга төшү. *Бала шыңшый да шыңшый, бәгырьне пычак белән телгән кебек итә* (Х. Камалов. Һәркемнең гомере бер генә).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ САВУ** *к.* бавырга төшү. *Мин Разияне искә төшергәлим. Ритадан риза булмаганда, юкка үпкәләп, дәшми йөреп бәгырьне сауганда* (Х. Камалов). – *Мондый атка, – диде ат караучы, / – Тия күрмә, саума бәгырьне!* (Зөлфәт. Ул карашлар истә...).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ САГЫШ ЧЕМЕТЕП УЗУ.** Сагыну, юксынудан төшенкелек туу. *Мөсафирның бәгырен сагыш чеметеп узды* (Р. Батулла. Сөембикә).

**БӘГЫРЬНЕ СЫЗЛАНДЫРУ (СЫКРАТУ)** *к.* бавырга төшү. *Әллә шул йөзләреннән сабыйлык чырайлары да китеп бетмәгән япьяшь кызларның таза ирләр эшенә чыгып тотынуларын күрү аның бәгырен сыкратып җибәрдеме?* (Ә. Еники. Саз чәчәге). *Дөрес, кече залда барган репетициядәге кебек, бер карауда күңелне кузгатып, бәгырьне сызландыра торган, уйландыра торган тирәнлек юк иде бу Кадимбикәдә* (М. Маликова. Басып сайрар талым бар).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ СЫЗУ** *к.* бавырга төшү. *Сыз бәгырьне, ат угыңны, камчың селек-болгала* (З. Бәшири). *Еракларга таралган милләттәшләрнең сагышлы сагыну ачысы, Гайнетдин бабай кебек сөрген җирендә гомере үтеп тә, туган моңнарыбызга күңеле суынмаган кеше язмышы бәгырьне сызып ала* (Ш. Галиев).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ ТАЛАУ** *к.* бавырга төшү. *Һәркемгә үз тиресе бүтәннәрнекеннән кимрәк тоелып җаннарын кимерә, көнчелек уты бәгырьләрне талый иде* (Ф. Яруллин. Бигайбә). *Бәгърен талап өрсә теңләп эте, / Килмәс иде мондый азакка...* (Р. Рахмани. Безнекеләр).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ ТЕЛЕМ-ТЕЛЕМ КИСҮ** *к.* бавырга төшү. *Әлбәттә, Сөләйман малае шаярта иде, ләкин бу шаярту бәгырьне телем-телем кисә иде* (Н. Гыйматдинова. Үзем генә беләм...). *Хәзерге көйләр дә, никтер, йөрәк-бәгырьләрне телем-телем кискәли торган була башлады* (Г. Кашапов. Солдат иртә ир була).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ ТЕЛ<ГӘЛӘ>Ү (ТЕЛЕП АЛУ)** *к.* бавырга төшү. *Бәгырен телгәләделәр ич аның, җанын рәнҗеттеләр, намусына тукындылар* (Б. Камалов. Күршеләр). *Алтынбикә иренең бәгырен телеп алырдай усал сүз эзләде* (Н. Гыйматдинова. Кыргый болан). *Их, теге чакларда бер аулак почмакка кысып, менеп төшәсе булган ипи шүрлегенә, кабыргаларын санарга, болай ук ачы тоелмас иде бәгырьне телгәләгән сүзләре* (К. Кара. Чуклы карават).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ ТЕШЛӘҮ** *к.* бавырга төшү. *Болар исә халыкның терсәген генә түгел, ә, бәлки бәгырен тешләп тотынган* (Ә. Гаффар. Кул).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ ТУҢДЫРУ (ТУҢДЫРЫП ҖИБӘРҮ)** *к.* бавырга төшү. *Клара шактый сүзсез калып утырды, әллә нишләтте аны бу кечкенә хикәя, әйтерсең бәгырен туңдырып җибәрде* (Ә. Еники. Туган туфрак).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ ТЫРНАУ** *к.* бавырга төшү. *Кинәт йөрәгем авыртып кысылды, үкенүмедер, икеләнүмедер – белмим нидер – бәгъремне тырнап куйды* (Ә. Еники. Йөрәк сере). *Шунысын*

*да әйтү урынлы булыр: әлеге гаделсезлек татарның бәгырен даими тырнап тора* (Р. Зәйдулла. Ташка ордым башны).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ УТЛЫ ТИМЕР КӨЙДЕРҮ** *к.* бавырга төшү. *Нурсөянең бәгырен утлы тимер көйдерде, кайсыныңдыр хәтере бер дә саекмый, ахрысы* (Н. Гыйматдинова. Җәза).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ ҮКСЕТҮ** *к.* бавырга төшү. *Бүген менә сулык-сулык / Үксетәбез бәгырьне* (Г. Морат).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ ҮТКЕН ПЫЧАК ТЕЛҮ** *к.* бавырга төшү. *Тик Дәүләтша карт йортының ишеген бикләп, капкасын япканда, бәгыремне үткен пычак телде* (Н. Гыйматдинова. Сөйлим, тыңла...).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ ЧЕМЕТ<ТЕР>Ү (ЧЕМЕТ<ТЕР>ЕП АЛУ / КУЮ).** Борчып тору; дулкынландырып алу. *Алай да хис сүнмәде: акыл тыйса да, ул, кабынып-кабынып, бәгырьне чеметеп куя иде* (Н. Гыйматдинова. Кыргый). *«Шул хәтле жебегән димме, туң йөрәк димме, булырсың икән», дип, егетнең бәгырен чеметтереп ала* (Э. Касыймов. Бир кулыңны, дустым!..).

**БӘГЫРЬНЕ ШИК ЭНӘСЕ ТИШҮ.** Борчылу, шөбһәләнү. *Шәмсиянең көтмәгәндә күңеле кайнарланды, бәгырен шик энәсе тишеп узды* (Ф. Яхин. Бакыр бозау артыннан).

**БӘГЫРЬНЕ ЭРЕТЕРДӘЙ.** Бик ягымлы тавыш белән эндәшү. *Кибәхуҗаларча ягымлы көйли төшеп, бәгырьләрне эретердәй йомшак тавыш белән Фәйзуллага дәште* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**БӘГЫРЬНЕ ЭРЕТҮ.** Күңелне йомшарту, үпкә хисләрен бетерү. *Әллә бер каткан бәгырьне эретү җиңел дисеңме?* (Н. Гыйматдинова. Кыргый). *Бер авыз сүз таш бәгырьне эретә, / Бер авыз сүз матур төшне өн итә* (М. Сәгъдиев).
Төрдәше: күңелне эретү.

**БӘГЫРЬНЕ ЯЗУ.** Күңелне әрнеткән, авырлык китергән нәрсәләрдән арыну. *Ул утырып торган бүрәнәдән иңә башлаган суыктан арынырга, аягын, җанын, бәгырен язарга теләп торды да, <...> өске киеме итәген кайтара төшеп, кулын куен кесәсенә тыгып алды* (Ә. Гаффар. Энә күзе).

**БӘГЫРЬНЕ ЯЛКЫН ЧОРНАУ** *к.* бавырга төшү. *Бәгырен ялкын чорнаган ир кырык тугыз йозакка берьюлы селтәнде* (Н. Гыйматдинова. Үзем генә беләм...).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

**БӘГЫРЬНЕ ЯНДЫРУ** *к.* бавырга төшү. *Үч алу теләге бәгырьне яндырып сызландырды, ихтыярны исә корычтай ныгытты, тәнгә, җанга көч бирде* (М. Маликова. Язгы такыялар). *Һәй, ул карашларның бәгырьләрне яндырып, өтеп, җанны чеметтереп алулары!* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

*БӘГЫРЬНЕҢ* ❖ **БӘГЫРЬНЕҢ АСТЫН ӨСКӘ КИТЕРҮ** 1. *к.* бавырга төшү. – *Нәгыймә түти керсә, шул гайбәт сүзләре белән бәгырьнең астын өскә китереп бетерә иде* (Сөйләм).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

2. Һушландыру, күңелгә рәхәтлек бирү. – *Ай-һай тавыш бу малайда, ай-һай моң! Әллә кай эчкәрелəргә үтеп, бәгырьләреңне астын өскә китерә* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**БӘГЫРЬНЕҢ ҖӘРӘХӘТЕ.** Һич онтылылмаслык авыр хатирә. *Хумаюн солтан никахыннан баш тарту да, ахирәтләрнең фаҗигале язмышы да аның бәгыренең гомергә төзәлмәс җәрәхәте булып калды, һава бозылганда үтереп сызлый торган буын кебек, әледән-әле ачылучы иске яра кебек, әҗәленәчә үзе белән йөрер* (Р. Батулла. Сөембикә).

*БӘГЫРЬ-ҮЗӘК* ❖ **БӘГЫРЬ-ҮЗӘК СЫЗУ** *к.* бавырга төшү. *Синдә халкың сихәт-шөһрәт таба, / Китсә – сыза бәгырь-үзәге...* (Э. Шәрифуллина. Гөлләр иле).
Төрдәше: бавырга төшү һ.б.

*БӘДДОГА* ❖ **БӘДДОГА ТӨШКЕРЕ** *карг.* Явыз догаларның тәэсире булуын теләү. *Корыттыгыз дөньяны, корыттыгыз! Тиз сәгатьтән таралыгыз, бәддога төшкерләре!* (М. Гали). *Бәддога төшкере!* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит).

**БӘДДОГА ЯУДЫРУ.** Туктаусыз каргап тору. *Ул аңа иртә-кич бәддога яудырырга тотынды* (Г. Бәширов). – *Ярты җиһанны манзара кылып үткән сәйяхка үз углына тәһлил әйтергә, ясин чыгарга да җай бирмәгән андый ханиягә барча мөселман халкы ләгънәт вә бәддога яудырыр* (В. Имамов. Утлы дала).

*БӘДРИ* ❖ **БӘДРИ БӘНЕҖ САТЫП БАЮЧЫ** *мыск.* Вак сәүдәгәр, кырыктартмачы. *Хәзер кем генә булсаң да, асылың кырыктартмачы, бәдри бәнеҗ сатып баючы синең* (Сөйләм). *Бәдри бәнеҗ* – элек туннарга бау белән каптырыла торган җиз сабаклы йомры кызыл төймә.

*БӘДЫЙГ* ❖ **БӘДЫЙГ МӘЗИН КҮРКӘСЕ.** Юк кына бер эшне кирәгеннән артык шаулатып игълан итү. *Башыңдагы чабатаңның сиксән сигез серкәсе; / Бу дөньяда шөһрәт алды Бәдигъ мәзин күркәсе* (Г. Тукай). *Менә сиңа Бәдыйг мәзин күркәсе! Дөньяга фаш булган сакалында нибарысы өч-дүрт бөртек төк бар иде!* (А. Гыйләҗев. Йәгез, бер дога!).
Төрдәше: авыздан кош очыру 3 һ.б.

*БӘЗӘГЕ-МӘЗӘГЕ* ❖ **БӘЗӘГЕ-МӘЗӘГЕ БЕРГӘ БУЛУ.** «Барысы да бергә булыр» мәгънәсендә. *Бәзәге-мәзәге бергә булыр... болыннар буйлап барасы, һич югы берәр бытбылдык атарбыз, – дип, тарантас башына мылтык та тыктык* (Ф. Хөсни. Ике агроном, бер овчарка).

*БӘЙ* ❖ **БӘЙ ИТҮ.** 1. Балалар фольклорына караган бишек җырларында кулланыла. *Әлли-бәлли бәй итә, / Балам йокыга китә, / Балам йокыга китмәсә, / Бүкәйләр алып китә* (Р. Ягъфәров. Балалар фольклоры).

2. Бәбиләр хакында сөйләгәндә, «йоклау» мәгънәсендә кулланыла. *[Фәридә] Ә минем Алсу көне-төне бәй итә...* (Р. Хәмид. Актамырлар иле). – *Нигә бәй-бәй итмисең, үскәнем? – диде Идрис, үзенең «бәләкәй тоткын»ын йомшартырга теләп* (А. Гыйләҗев. Урамнар артында яшел болын).
Төрдәше: бәү итү (ике маддә өчен дә).

*БӘЙГАТ* ❖ **БӘЙГАТ БИРҮ.** Берәрсенең хакимиятен тану, аңа буйсынырга сүз бирү. *Шаһ янына керделәр нәүбәтләнеп, / Чыктылар бәйгат биреп, ләгънәтләнеп* (Ш. Бабич).

*БӘЙГӘ* ❖ **БӘЙГӘ КУЮ.** Контрольдә тоту, күзәтеп тору. *Монда мишәр хатыннарының явызлыгы! Ирләрен бәйгә куярлар иде, көчләреннән килсә* (Н. Гыйматдинова. Бердәнберем хакына). *Модница, «Хатын-кызны бәйгә куярга теләү, ирләрнең комплексларыннан гына»* («Матбугат.ру» порталы).
Төрдәше: бәйдә тоту.

*БӘЙГЕ* ❖ **БӘЙГЕ АЛУ (ТОТУ).** Ярышу, көч сынашу; ярышта беренче булу. *Байтал чабып бәйге алмас* (Мәкаль). *Бәйгеләрдә бәйге тоткан / Атың, / Тышауланган килеш аранда, / Сугымчыны көтә...* (Г. Морат. Аран).

*БӘЙДӘГЕ* ❖ **БӘЙДӘГЕ ЭТТӘН БИТӘР.** Явыз, яман холыклы. – *Аллам сакласын, капка төпләреннән дә үтәсем килми, бәйдәге эттән битәр хатын ул* (Сөйләм).
Төрдәше: җелеккә (җилеккә) <ачы җилләр> үтү 2; көн күрсәтмәү; күзе белән ашау; күзләрне акайту; күзләрнең агы белән карау; табаныңны ярып тоз сибү; усал кеше имгә ярый; үткен күзле, арыслан тырнаклы.

*БӘЙДӘН* ❖ **БӘЙДӘН ЫЧКЫНГАН ЭТ КЕБЕК.** Кешегә үч, усаллык белән ташлану. *Инде бәйдән ычкынган эт шикелле кылана торганнардыр* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң). – *Йә, туктале, нәрсә син бәйдән ычкынган эт кебек ябыштың әле?!* (Г. Гыйльманов. Аллалар кайда яши?).
Төрдәше: бәйләвеннән ычкынган эттәй 1.

**БӘЙДӘН ЫЧКЫНУ**. 1. Чаманы оныту, тыятыела алмас хәлгә килү, тәртипсезләнү. *Хатынның тоткасы сынды, бәйдән ычкынды, ул үзе дә моны абайлады, ләкин сүз – очкан кош, тотып кире кайтарырмын димә* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Фәһимәгә болай ук бәйдән ычкынырга ярамый иде, билгеле* (Н. Гыйматдинова. Елан).

2. Мөстәкыйльлек алу. – *Бәйдән ычкынырга вакыт инде безгә, вакыт, вакыт...* (В. Имамов. Казан дастаны).
Төрдәше: буасы ерылу; тоткасы сыну.

*БӘЙЛӘВЕННӘН* ❖ **БӘЙЛӘВЕННӘН ЫЧКЫНГАН ЭТТӘЙ.** 1. *к.* бәйдән ычкынган эт кебек. – *Нәрсә миңа бәйләвеннән ычкынган эттәй каныгасың?!* (Сөйләм).
Төрдәше: бәйдән ычкынган эт кебек.

2. Бәйдән ычкынып, ирек алып, бар көченә чабу. *Ул заман үтеп китте судай аккан, / Матур кыздай ишек ачып, кире япкан; / Аһ орсаң да ул заманнар кире кайтмас, / Бәйләвеннән ычкынган эттәй чапкан* (М. Гафури).

*БӘЙЛӘНГӘН* ❖ **БӘЙЛӘНГӘН ТЕЛ.** Эчеп-исереп көрмәкләнгән тел. *Зиннәт, бармагы белән ишарәләп, бәйләнгән теле белән: – Менә, мә, менә! – дип кычкырып куйды* (Г. Бәширов).

*БӘЙЛӘНДЕ* ❖ **БӘЙЛӘНДЕ БИТ.** 1. Бәйләнчек кешедән гаҗиз булып йөдәгәч әйтелә. *Өченче капчык та бетә дип торганда, бер марҗа бәйләнде бит* (Р. Кәрами. Олы юл да сикәлтәле).

2. Берәр сүзне (шигырьне, җырны һ.б.) туктаусыз кабатлап йөрү. *Бәйләнде бит миңа ике юл шигырь, дога кебек укып барам: Под ним струя светлей лазури, / Над ним луч солнца золотой...* (Г. Афзал. Карабаш күлендә).

*БӘЙЛӘНЕР* ❖ **БӘЙЛӘНЕР УРЫН ЮК.** Бик яхшы эшләнгән булу; кимчелекләре күренмәү. *Язмага исә бәйләнер урын юк, автор мәсьәләне тирәннән өйрәнгән, һәр сүзен нәкъ кирәк җиренә туры төзегән иде* (К. Тимбикова. Тәңкәле тау). *Аның сүзләренә бәйләнер урын юк. Кешеләр шуңа өйрәтелгән иделәр инде* (З. Сафин. Көч җитәрлек).

Төрдәше: шәп эшләнгән.

*БӘЙЛӘСӘҢ* ❖ **БӘЙЛӘСӘҢ, ЭТ ТОРМАС.** Бик начар (фатир, өй һ.б. турында). *Бәйләсәң, эт тормас, подвал* (Ә. Нәҗип).

*БӘЙНӘ-БӘЙНӘ* ❖ **БӘЙНӘ-БӘЙНӘ (БӘЕН-БӘЕН) СӨЙЛӘҮ (ЯЗУ).** 1. Һәр нәрсәне ачыклап язу, сөйләү. *Миңа бәйнә-бәйнә язып хәбәр итеп тор* (Г. Тукай). *Боларның барысы турында да бәйнә-бәйнә яза башласаң, бер китапка гына да сыймас иде* (М. Яһудин. Еллар аша).

2. Төгәл тасвирлама бирү. *Кайбер борынгы халыклар турында бәйнә-бәйнә язылган мәгълүмат юк* (Сөйләм).

*БӘЙРӘМ* ❖ **БӘЙРӘМ АШЫ** *махс.* Бәйрәм көнендә пешерелә торган камыр ашы. *Айбиби өйдән чыкты, бәйрәм ашы әзерләгән пешекчеләргә, бавырчыларга таба атлады* (М. Хәбибуллин. Айбиби). – *Бәйрәм ашы бергә-бергә тәмле була ул* (Р. Батулла. Юл буенда зәңгәр чәчәк).

**БӘЙРӘМ АШЫ – КАРА-КАРШЫ.** «Яманлыкка яманлык, яхшылыкка яхшылык белән җавап кайтарылачак» мәгънәсендә. *Бәйрәм ашы кара-каршы дигәндәй, үзем дә буш калмам* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Бәйрәм ашы – кара-каршы, дип, күршесен үзе дә чибәрләде* (М. Хуҗин. Көрәшче).

Төрдәше: җил чәчеп, давыл уру; соравына күрә җавабы.

**БӘЙРӘМ БЕЛӘН!** Бәйрәм белән котлау сүзе. – *Фатьма, бәйрәм белән! – Фатыйманың кулларын иренenә китерде, йомшак иреннәр кулларга кагылу белән, икесе дә тынсыз катып калдылар, икесен дә әйтеп бетергесез ләззәт утлары чорнап алды* (З. Кадырова. Көтеп узган гомер).

Төрдәше: бәйрәм котлы булсын!; бәйрәм мөбарәк булсын, (мәҗлес түгәрәк булсын!).

**БӘЙРӘМ ИТҮ.** 1. Бәйрәм ясау, шунда катнашу. *Кая монда якты килер көн? / – Сыңар гына калган милләт үзе, / Югалтуын бәйрәм иткәчтен...* (Р. Мөхәммәтшин).

2. *күч.* Куану, шатлану, тантана итү. *Баштан бирле угылы Зыяның муллалар арасында үзен зур тота белүе һәм аңа тирә-яктагы халыкның илтифаты өчен эченнән бәйрәм итеп, шуның кызыгы белән күп сөйләшми торган Җәләл мулла Галим хәзрәтнең бер күзенә, бер селкенеп торган ак сакалына карады да бик кискен тавыш белән угылы өчен җавап кайтарды* (Г. Ибраһимов).

**БӘЙРӘМ КОТЛЫ БУЛСЫН!** *к.* бәйрәм белән – *Бәйрәмнәр котлы булсын! Шушы матур табыныгызга мине дә чакырып куандырганыгыз өчен Алланың рәхмәтләре яусын!* (Г. Галиева. Газзәбану). *Бәйрәм котлы булсын! Гомере озын булсын синең кебек якты баланың!* (Р. Мингалим).

Төрдәше: бәйрәм белән! һ.б.

**БӘЙРӘМ МӨБАРӘК БУЛСЫН (МӘҖЛЕС ТҮГӘРӘК БУЛСЫН)!** *к.* бәйрәм белән! *Бәйрәмебез котлы булсын ! Бәйрәмебез мөбарәк булсын! Бәйрәмебез мөбарәк булсын, кардәшләр-өммәттәшләр!* («Ватаным Татарстан» газ.).

Төрдәше: бәйрәм белән! һ.б.

**БӘЙРӘМБАЙ КЕШЕ.** Тормыш бәйрәм өчен бирелгән дип санаучы, эшләмичә кәеф-сафа

корып яшәүче хакында. – *Минем танышларым арасында бәйрәмбай кешеләр юк* (Сөйләм).

*БӘКӘЛГӘ* ❖ **БӘКӘЛГӘ СУГУ.** Яхшы гына барган эшкә аяк чалу, көтмәгәндә бәла килеп чыгу. *Авыруы торган саен бәкәлгә суга. Тикшерүченең максаты – халык дошманын утырту* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым). *Гамәлгә керә закон: / Бәкәлгә суга закон. / Сөрлеккәч, / Аугач-егылгач, / Гамәлдән чыга закон...* (С. Рәхмәтулла. Законнар илендә).
Төрдәше: аркылы килү (төшү) 2 һ.б.

*БӘЛА* ❖ **БӘЛА АГАЧ БАШЫННАН ЙӨРМИ, АДӘМ БАШЫННАН ЙӨРИ.** Бәланең кешегә килүенә ишарә. *Бәла агач башыннан түгел, адәм башыннан йөри, диләр. Рас сүз икән* (М. Мәһдиев. Каз канатлары).
Төрдәше: аяк кермәс җиргә баш керү һ.б.

**БӘЛА АНАСЫ БУАЗ.** Бәхетсезлекне берәү дә көтеп алмауга, аның көтмәгәндә, кинәт килеп чыгуына ишарә. – *И малай... – диде, авыр сулап. – Бәла анасы буаз, дияр иде безнең әти* (Р. Төхфәтуллин. Кар күзе). – *Аяз көнне нинди яшен ди ул? – Бәла анасы буаз, мырза* (М. Әмирханов. Ир-Мамай).
Төрдәше: аяк кермәс җиргә баш керү һ.б.

**БӘЛА АРТЫННАН БӘЛА АТЫН КАМЧЫЛАП КУУ.** Бер килгән бәла артыннан башкалары да чыга тору. *«Бәла артыннан бәла атын камчылап куа» килә дип тә өстәр иде* (Р. Төхфәтуллин. Кар күзе).

**БӘЛА АЯК АСТЫНДА <БУЛУ; ЙӨРҮ>** *к.* аяк кермәс җиргә баш керү. *[Гөлсылу] Юкны сөйләмә. Бәла аяк астында йөри, ди* (Г. Каюмов. Упкын өстендә уен). *Кызганыч, бәла аяк астында шул, ә икенче колагың ничек пеште?* (З. Мурсиев. Хастаханә хастасы).
Төрдәше: аяк кермәс җиргә баш керү һ.б.

**БӘЛА АЯК АСТЫННАН ЧЫГУ** *к.* аяк кермәс җиргә баш керү. *Халыкта «бәла аяк астыннан чыга» дигән тәгъбир бар* (Г. Тавлин. Афәт). *«Теңкәгә генә тиде бит. Бичура... Очрап торуын күр әле син аның! Бәла аяк астыннан чыгар ди шул», – дип уйлап ала Галәви* (М. Хәсәнов. Бичура җиңги).
Төрдәше: аяк кермәс җиргә баш керү һ.б.

**БӘЛА<ЧЕЛ> КЕШЕ.** Мәшәкать чыгаручы, җәфа салучы. *Шуларга нигезләнеп, мине җәнҗалчы, бәлачел кеше дип атады* (М. Хәсәнов. Инженерлар).

**БӘЛА КУБАРУ.** Җәфа чыгару, җәнҗал кубару. *Янгыннар җитсә, бер бәла куба – янгыннар котыра* («Өмет» газ.). *Юкка кайткансың син монда, бәла кубарып кына йөрисең* (Сөйләм).

**БӘЛА ӨСТЕНӘ БӘЛА** *к.* авырткан башка <тимер> тарак (таяк; тукмак). *[Вәли] (үз-үзенә). Менә бәла өстенә бәла. Мин үзем дә юләр, миңа ни эшкә кирәк иде инде аңа театрга дип сөйләп торырга, мин аңа дәрес әйтәмме?* (Г. Камал. Беренче театр). *Атчабар телмәр боерчылар әлеге фәрманны урамнан урамга оранлап йөрделәр. Файдасы гына тимәде. Бәла өстенә бәла: Арбатны ут ялмап алды* (М. Әмирханов. Әлвидаг).
Төрдәше: авырткан башка <тимер> тарак (таяк; тукмак) һ.б.

**БӘЛА САЛУ (ТАГУ).** Берәрсен гаепләү, ялган сөйләп, исемен пычрату. *Әллә миңа бәла дә такмакчы буласыңмы?* (Г. Камал). *Билгеле бик күпләргә: этләр – тыныч халык, анда-монда барып йөрмиләр бәла салып* («Кызыл таң» газ.).
Төрдәше: аяк астына салып таптау 2 һ.б.

**БӘЛА ЯБУ (ЯГУ)** *к.* аяк астына салып таптау 2. *[Зәйнәп] Алла хакы өчен дип әйтәм, миңа бөһтан бәлаләр якма...* (Г. Камал. Каениш). *Мондый бәла яба башласа, үзеңнең гаепсез икәнлегеңне туфрак ашап ант итсәң дә исбат итә алмассың* (З. Мурсиев. Солтанъяр).
Төрдәше: аяк астына салып таптау 2 һ.б.

**БӘЛА ЯЛГЫЗ ЙӨРМИ.** Бәла белән бергә башка төрле күңелсезлек килү мөмкинлеге турында кисәтү. *Бәла ялгыз йөрми: килсә, бер-бер артлы килә, диләр* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!). *«Бәла ялгыз йөрми» дигәннәре дә дөрестер* (Н. Көбәш. Замана кызы).

*БӘЛАГӘ* ❖ **БӘЛАГӘ КАБУ (ТАРУ; ОЧРАУ; ТӨШҮ; УГЪРАУ).** Көтмәгәндә бер-бер бәлага дучар булу. *Бәлагә төшкәнмен, ни эшлим?* (Г. Тукай). – *Картаеп барган көнемдә синең аркада әллә ниткән бәлаларга тарып, төрмәгә кереп утырыр хәлем җук әле монда!* (В. Нуруллин).
Төрдәше: аяк кермәс җиргә баш керү һ.б.

**БӘЛАГӘ КАЛГАН БАШ.** Бәладән чыга алмау, эшнең бәлале булганлыгын белеп тә тәвәккәлләү. *Бәлагә калган башы белән бу кыенлыкларны да ерып чыкса, мактаудан башка сүзем юк* (Сөйләм).
Төрдәше: беткән баш.

**БӘЛАГӘ КАЛДЫРУ** *гади с.* Кыен, авыр хәлдә калдыру. *Шикләнмә, мин сине бәлагә калдырып китмәм* (Сөйләм).
Төрдәше: бәлагә каршы; бәлагә төшерү; бәлагә тыгу; бәхетсезлеккә төшерү.

**БӘЛАГӘ КАРШЫ.** Бәла-казага очраганда, үкенеп әйтелә. *Бәлагә каршы, ичмасам, кул гранаталарыбыз да юк* (А. Шамов). *Ләкин, бәлагә каршы, бу иптәш слесарь бик «акыллы баш» кеше икән* (gabdullatukay.ru).
Төрдәше: бәлагә калдыру һ.б.

**БӘЛАГӘ ТЫГУ** *к.* бәлагә калдыру. *Олаймыш көнемдә мине бәлагә тыгуың бар бит* (Ә. Фазылҗанов). *Агентура бүлеге башлыгын нindидер бер килмешәк аркасында бәлагә тыгып куйсалар һәм, шулай итеп, Бохара республикасының ышанычлы терәген какшатсалар, – Нурморатов үзен нәкъ менә шундый олы шәхес дип исәпли иде, – моны ни намусы, ни көрәштәшләре беркайчан да гафу итмәс* (Т. Әйди. Елан уты).
Төрдәше: бәлагә калдыру һ.б.

**БӘЛАГӘ УРАЛУ** *к.* аяк кермәс җиргә баш керү. *– Минем ике балам бар. Бәлагә ураласым килми* (М. Кәбиров. Елмаю). *Шул дошман аркасында бу бәлагә уралдым* (Н. Исәнбәт. Хуҗа Насретдин).
Төрдәше: аяк кермәс җиргә баш керү һ.б.

**БӘЛАГӘ ЮЛЫГУ** *к.* аяк кермәс җиргә баш керү. *– Әллә берәр бәлагә юлыктыलармы икән дип борчыла башладым, – диде* (К. Тәхау. Кондызлар илендә). *Алар үз сыңарын бәлагә юлыкса да ташламый...* (Н. Гыйматдинова. Кыргый).
Төрдәше: аяк кермәс җиргә баш керү һ.б.

*БӘЛАДӘН* ❖ **БӘЛАДӘН БАШ-АЯК**. 1. «Кирәге юк, начар эштән читтә торуың хәерле» мәгънәсендә. *Әтисе ул күргәннәрне сөйләсә... бәладән башаяк!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Ул шулай диде, ләкин күңеленнән болай дип уйлады: «Үлә-нитә калса, судтан башың чыкмас. Бәласеннән баш-аяк»* (И. Гази. Онытылмас еллар).
Төрдәше: бәла-казадан баш-аяк; бәласеннән баш-аяк.

2. «Аның белән бәйләнмәвең хәерлерәк» мәгънәсендә. *Ә хәлбуки, соңыннан мәгълүм булганча, барлык район җитәкчеләре, бәладән баш-аяк дигәндәй, Сабан туеның башыннан ук китеп беткәннәр иде* (Ә. Еники). *Даян мәргән беренче төн кергәч, бәладән баш-аяк дип, мич өстенә менеп яткан иде* (В. Имамов. Казан дастаны).
Төрдәше: бәла-казадан баш-аяк; бәласеннән баш-аяк.

3. Хаталанмас өчен, алдан ук хәстәрен күрү. *Бу юлы Мифтах поездның разъездга барып җитүен көтмәскә булды. Бәладән баш-аяк...* (Г. Бәширов. Сарут). *– Бәс, кит син яхшылыкта. Бәладән баш-аяк* (Р. Батулла. Сөембикә).

*БӘЛА-КАЗА* ❖ **БӘЛА-КАЗА КИТЕРҮ** *к.* аяк астына салып таптау 2. *Тик шуннан башлап авылга да бәла-каза китерә башлаган, ди* (Х. Әбделманов. Юха). *Күпме бәла-каза китергән, кеше гомерен өзгән бу афәтле, дәһшәтле, канкойгыч сугышны безгә мәңге онытырга ярамый* («Казан утлары» ж.).
Төрдәше: аяк астына салып таптау 2 һ.б.

**БӘЛА-КАЗА САЛУ** *к.* аяк астына салып таптау 2. *Эшләр гел болай барса, югарыдагыларның, изгеләрнең җирдәге кешеләргә бәла-каза салулары ихтималы икән* (Н. Фәттах. Аклан).
Төрдәше: аяк астына салып таптау 2 һ.б.

**БӘЛА-КАЗАГА ОЧРАУ (КАЛУ; ТАРУ; ТӨШҮ; ЮЛЫГУ)** *к.* аяк кермәс җиргә баш керү. *«Менә сиңа акча, шуны җиткерергә тырыш, әйбәт кенә йөр, бәла-казага тарыма, кайда икәнеңне хәбәр итәрсең», – диде* (Ә. Еники. Тынычлану). *Хәсәнә остабикә һаман тынычлана алмый: – Аның бердәнбер аты бит! Бәла-казага очрамагае, атын бүре бумагае, дим!* (Г. Мөхәммәдова. Яшьлек көннәре).
Төрдәше: аяк кермәс җиргә баш керү һ.б.

*БӘЛА-КАЗАДАН* ❖ **БӘЛА-КАЗАДАН БАШ-АЯК** *к.* бәладән баш-аяк. *Сталин белән бер көндә тугач, ата кешене авылдашлары да, җитәкчеләр дә, үзгәрт, бәла-казадан баш-аяк, дип үгетлиләр* (adiplar.belem.ru).
Төрдәше: бәладән баш-аяк һ.б.

**БӘЛА-КАЗАЛАРЫННАН САКЛАСЫН.** Үзенә, малларына, хуҗалыгына иминлек теләп әйтелә. *Инде Раббыбыз барыбызны да ачлыктан, сугыш афәтләреннән, табигать бәла-казаларыннан сакласын иде* («Татарстан яшьләре» газ.).

*БӘЛАЛӘР* ❖ **БӘЛАЛӘР СӘБӘПЧЕСЕ.** Башкаларның гаебе, җаваплылыгы һәрвакыт аның өстенә төшә торган мәхлук кеше хакында. *Кирәк булганда, бәлаләр сәбәпчесен бик тиз табалар аны* (Сөйләм).

*БӘЛАЛЕ* ❖ **БӘЛАЛЕ ЭШКӘ КАБУ** *к.* аяк кермәс җиргә баш керү. – *Теге вакытта синең сүзеңне тыңлаган булсам, бәлале эшкә капмаган булыр идем* (Сөйләм).
Төрдәше: аяк кермәс җиргә баш керү һ.б.

*БӘЛАНЕҢ* ❖ **БӘЛАНЕҢ БӘЯСЕ ҖИМЕРЕЛҮ.** Бәланең көтмәгәндә, һәркемгә, теләсә кайсы вакытта килү мөмкинлегенә ишарә. *[Әхмәт] Бәланең бәясе җимерелеп, бүген берьюлы мине килеп басты* (Ш. Камал. Дәҗҗал).

*БӘЛАСЕННӘН* ❖ **БӘЛАСЕННӘН БАШ-АЯК** *к.* бәладән баш-аяк. *Үлә-нитә калса, судтан башың чыкмас. Бәласеннән баш-аяк* (И. Гази).
Төрдәше: бәладән баш-аяк; бәла-казадан баш-аяк.

*БӘЛӘКӘЙ* ❖ **БӘЛӘКӘЙ ГЕНӘ** *к.* аз гына. *Документларны тутырганда, бәләкәй генә хата җибәргәннәр* (Сөйләм).
Төрдәше: аз гына һ.б.

*БӘЛЕШ* ❖ **БӘЛЕШ АВЫЗ.** 1. Җәенке зур авыз. *«Бәлеш авыз!» – дип үрти икән малай, кызыйның авызы тагын да бәлшәя икән* (Х. Гайнетдинов. Чигүле кулъяулык).

2. Нәрсәдер өмет итеп, һаман авызын җәеп торган кеше хакында. – *Кем ул макарунник, бабай? Кешеме? Әллә ашый торган нәрсәме? – И, бәлеш авыз! Һәрхәлдә, ботка-мазар түгел, ымсынма!* (А. Хәлим. Хикәяләр).

3. *мыск.* Елак бала. – *Ярар, җитәр инде, ул кадәр бәлеш авыз булма* (Сөйләм).

**БӘЛЕШ ИМГӘГЕ** *мыск.* Кунактан кунакка йөреп, бәлеш кенә ашап торырга яратучы (күбрәк элекке ишаннардан, түрәләрдән, байлардан көлеп әйтелә). *Син бәлеш имгәгенең кем икәнен дә белмисеңме?* (Сөйләм).
Төрдәше: бәлеш козгыны (үләте).

**БӘЛЕШ КЕБЕК.** Җәенке шәкелдә булган нәрсә. *Кап-кара чәч, эчкерсез, самими карашлы куе коңгырт күзләр, әби-чәби «бәлеш кебек» дип сөйли торган калын, йомшак ирен, ә кыскасы, типик татар йөзе* (В. Имамов. Кәнәфи). *Шулай да Камилә ерылган авызын җыярга ашыкмады, минеке исә бәлеш кебек бүселеп китәргә генә тора* (Ф. Яхин. Сихерче кыз).

**БӘЛЕШ КОЗГЫНЫ (ҮЛӘТЕ)** *иске, к.* бәлеш имгәге. *Кермим мин ул бәлеш козгыннары янына* (Т. Гыйззәт). *Ул бәлеш козгынын, ахирәт кошын кирәген биреп чыгарырбыз* (Ш. Усманов).

**БӘЛЕШ ТӨБЕ.** Йомшак табигатьле кеше. *Безнең белән бер сменада Николай дигән керәшен эшли иде. Бәлеш төбе кебек йомшак, тыңлаучан, сабыр, аз сүзле* (Ә. Сәлах. Каеннар юлы).

**БӘЛЕШ ТӨПЛӘҮ.** Бәлешнең иң тәмле җире төбе булганлыктан, шуның белән сыйлануга ишарә. – *Борыны сизгер икән, бәлеш төпләргә килеп җитте бит* (Сөйләм).

*БӘЛЕШНЕҢ* ❖ **БӘЛЕШНЕҢ ТӨБЕ, ЧАНАНЫҢ ТҮРЕ**. Бәлешнең иң тәмле җирен урынның түре белән тиңләштерү. *Бик борынгыдан калган «бәлешнең төбе, чананың түре» дигән гыйбарә дә бар* (Сөйләм).
Төрдәше: чана<ның> түре, бәлешнең төбе.

*БӘЛЕШТӘН* ❖ **БӘЛЕШТӘН КОЙМАККА ЙӨРҮ.** Кунактан кунакка гына йөрү. *Кунактан кунакка гына, бәлештән коймакка гына йөреп, өч-дүрт көннән үк китеп баручылар да, биелгы шикелле корылык булган елларны якты чырай, сөтле чәйгә дә риза булып, унарунбишәр көн утыручылар да булгалый* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

*БӘЛЗӘМ* ❖ **БӘЛЗӘМ АГЫЗУ (ТҮГҮ).** Шатландыру, күңелне хушландыру. *Сәхнәдә сөйләгән сүзләрен йотылып тыңлап утырдым, җаныма бәлзәм түгә иделәр алар* (Сөйләм).

*БӘНДӘГӘ* ❖ **БӘНДӘГӘ БӘНДӘ БУЛУ.** Бик мескен хәлдә калу (колның колы булу). *Гомер кичте булып бәндәгә бәндә. / Тәәссеф шул, аның күңеле бүтәндә* (М. Гафури). *Мин ничек булыша алам инде аңа? Мин үзем бәндәгә бәндә. Колхозның әле үзенә дә берние юк – ашлык өлгермәгән* (Н. Фәттах. Беренче шигырь күк балачак).

*БӘНДӘНЕҢ* ❖ **БӘНДӘНЕҢ БӘХЕТЕ АЛГА КИТКӘНДӘ, КУЛЫНА АЛСА, АЛТЫН БУЛА, ДИ** *к.* алтын бишектән төшү 1. *Берсен дә тыңлама, үзең белгәнчә эшлә – «бәндәнең бәхете алга киткәндә, кулына алса, алтын була, ди» дигәннәр бабайлар* (Сөйләм).
Төрдәше: алтын бишектән төшү 1 һ.б.

*БӘР* ❖ **БӘР ТӘКЪДИР** *иск.* Берәр хәл булып куйган очракта тәкъдирдә язылгандыр дип кабул итү. *Бәр тәкъдир милләтемез үлгән булса, без, үлгән милләтнең башы очында бер кәгазь кисәге булган гәзитәләр шытырдатып, аны уята алырмызмы?* (Г. Тукай. Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?). *Һәм шиблитең дә пычранмый. Бәр тәкъдир, пычрана икән, ул чакта синең өстеңнән киемеңне салдырып, кибәргә элеп куя* (Г. Камал).

**БӘР ФАРАЗ** *иск.* Фараз итсәк, уйлап карасак. *Бәрәкалла, зиһенле егет булып чыктың син, бәр фараз* (Ф. Хөсни).

*БӘРӘ* ❖ **БӘРӘ ТӘРТӘГӘ, ТИЯ ЧӘРКӘГӘ.** Атның бик каты дулап тәртәгә тибүе үз сыйрагына эләгү ихтималы, ягъни урынсыз дуамаллану үзеңә зарар бирәчәк. *Бәрә тәртәгә, тия чәркәгә, кыр инешедәй салмак кына аккан әңгәмәне урталай бүлеп, Мамайга бакты да: – Папа, миңа хан ярлыгы кирәк, – диде* (М. Әмирханов. Ир-Мамай).

*БӘРӘКАЛЛА* ❖ **БӘРӘКАЛЛА – БӘРӘН СЫЙРАГЫ.** Берәр вак-төяк нәрсәне кабул иткәндә яки һич көтмәгәндә табыш килгәндә, югында монысы да ярап торыр, дип, зурлап кабул итү. *[Будик](бинокле аша карап, үзалдына). Бәрәкалла – бәрән сыйрагы. Теге битсез гурт маржаларының берсе ич бу!* (Р. Хәмид. Тигезәкләр).

*БӘРӘКӘТ* ❖ **БӘРӘКӘТ ЯУСЫН.** Берәр нәрсәгә рәхмәтле булганда әйтелә. – *Бәлеш-фәлән пешергәндә, мине бер дә онытмыйсың инде, бәрәкәт яусын үзеңә!* (Сөйләм). *Бәрәкәт яусын!* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).

*БӘРӘН* ❖ **БӘРӘН ЙОНЫН АЛДЫРУ.** Алдану. *Өйгә кайтканда, төсе бөтенләй качкан иде, бәрән йонын алдырып кайткан, ахрысы* (Сөйләм).
Төрдәше: агач атка (аргамакка) атлану (атланып калу) һ.б.

*БӘРӘҢГЕ* ❖ **БӘРӘҢГЕ АВЫЗ.** Булдыксыз, беркатлы кеше. *Тик кенә утырырга ярамадымыни сиңа, бәрәңге авыз, бетең котырдымы?* (Сөйләм).
Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**БӘРӘҢГЕ АЛЫП БАРАМ ДИП ЫШАНДЫРЫП, АЛЫП КАЙТЫРГА СҮЗ БИРМӘҮ.** «Бәрәңге ашап кына кергән көч тиз чыга» мәгънәсендә. *Әйтәләр бит, бәрәңге алып барам дип ышандыра, алып кайтырга сүз бирми, ышандырмый икән* (Б. Камалов).

**БӘРӘҢГЕ АНАСЫ** *миф.* Бик борынгыдан һәр нәрсәнең башында торган анасы бар дигән күзаллауга бәйле. *Кайбер якларда, бигрәк тә Башкортостан татарлары арасында «Бәрәңге анасы», «шалкан анасы», «чөгендер анасы» дигән әйтемнәр ишетергә мөмкин* (Татар мифологиясе I, 233).

**БӘРӘҢГЕ АШАУ БЕЛӘН БЕР.** Бик гади, бик җиңел. *Олы максат – буйсынмас җәенне каптыру, ә вак балык тоту – ул алар өчен кабыклы бәрәңге ашау белән бер* (Ә. Салах. Балыкчы малайлар).
Төрдәше: бәрәңге ашаудан да җиңел.

**БӘРӘҢГЕ АШАУДАН ДА ҖИҢЕЛ** *к.* бәрәңге ашау белән бер. *Егерме биш атлы кеше өчен җәяүле җиде бәндәне җиңү – бәрәңге ашаудан да җиңел булачагы билгеле* (М. Галәү).
Төрдәше: бәрәңге ашау белән бер.

**БӘРӘҢГЕ АШЫЙ БЕЛМӘГӘН АВЫЗЫ БЕЛӘН** *мыск.* Иң гади, җиңел эшне эшли алмаган җебегән кеше турында. *Бәрәңге ашый белмәгән авызы белән кем инде түбә ябарга тотына?* (Сөйләм).
Төрдәше: авызга каптырганны йотмау һ.б.

**БӘРӘҢГЕ БИРСӘҢ – ТАМЫР, САЛМА БИРСӘҢ – КАМЫР.** Ашауга талымсыз, нәрсә бирсәң дә ашый. – *Тиз генә берәр нәрсә пешереп куй шунда, ул алай нәзберек кеше түгел: аңа бәрәңге бирсәң – тамыр, салма бирсәң – камыр* (Сөйләм).

**БӘРӘҢГЕ БОРЫН.** Бәрәңгегә охшап торган борынлы. *Шуннан соң, тыны бетеп уфылдыйуфылдый, төсе-бите белән уртакул сәүдәгәргә охшаган бер алпавыт керде: түгәрәктән*

*китәрткән чәч, түгәрәк сакал, бәрәңге борын, елмаеп ерылган авыз* (М. Галәү. Мөһаҗирләр). *Тукта, нигә мин моңа бәрәңге борын дип әйттем икән?* (Н. Дәүли. Язмышка юл).

**БӘРӘҢГЕ ҖИЛЕ БЕЛӘН.** Бәрәңге ашаган куәт белән. *Өйдән чыккач, бәрәңге җиле белән бер йөк утынны бушатып та куйдылар* (Сөйләм).

**БӘРӘҢГЕ КОРСАК** *мыск.* Бәрәңге ашарга яратучы (күпчелек очракта авыл кешесен белдерә). *Үзе шикелле ачлыктан гаҗиз булгач, тамак хакына хезмәткә биргән малайларга ул хәзер өстән генә карап: – Әй син, мокыт, бәрәңге корсак! – дип кенә эндәшә, туры килгәндә, малайларның яңак төпләреннән утлар да чыгаргалый иде* (К. Тинчурин. Кара көннәрдә).

**БӘРӘҢГЕ СУЫ.** Бик сыек, туклыксыз шулпа. *Хәмдия, йөрәге әрнеп, караңгы чырай белән, бәрәңге суын болгатуында булды* (Н. Фәттах. Артта калган юллар). *Безгә он, бәрәңге суы эчеп яшәргә туры килде, әле кайгысын сөйләсәң, башларың әйләнеп чыгарлык* (З. Мурсиев. Солтанъяр).
Төрдәе: куян шулпасының шулпасы.

**БӘРӘҢГЕ УРЫНЫНА ПЕШЕРҮ.** Авырлык тоймыйча, бик күп итеп эшләп чыгару. *Озакламый без бу детальне бәрәңге урынына пешерергә тотыначакбыз* (И. Гази. Яңа мастер).

*БӘРӘҢГЕДӘ* ❖ **БӘРӘҢГЕДӘ ГЕНӘ ҮСМӘҮ.** Сылу, җыйнак гәүдәле яшь кеше хакында. *Күренә, бер бәрәңгедә генә үсмәгән бу кыз, авыр кара эш аны аркылыга җәймәгән* (Ә. Еники. Саз чәчәге).

*БӘРӘСКӘДӘН* ❖ **БӘРӘСКӘДӘН ЮЛ ТУРЫ** *мыск.* Берәрсе әйләнгеч юлны туры дип әйткәндә, аңа җавап буларак кулланыла. – *Сез, абзый кеше, аермадан сулга китегез, тизрәк барып җитәрсез. – Бәрәскәдән юл турымы?* (Сөйләм).

*БӘРЕЛЕП-СУГЫЛЫП* ❖ **БӘРЕЛЕП-СУГЫЛЫП ЙӨРҮ.** Максатсыз, анда-монда сугылып йөрү. *Урам буйлап бәрелә-сугыла йөри торгач, аның башына бер уй килеп өметләндерә башлаган иде* (Г. Бәширов).

*БӘРЕНГӘН* ❖ **БӘРЕНГӘН НӘРСӘ** *кимс.* Ашкынып, күз-башы тонып, атылып-бәрелеп йөрүче. *Безнең танышлардан бәренгән нәрсә бер Илназ гына* (Сөйләм).

*БӘРЕП* ❖ **БӘРЕП ЕГУ** *к.* аяктан егу 1–7. Яхшырак, өстенрәк булу. *Аның хатыны Гөлҗиһан синең Әсмаңнан мең өлеш артык, синең йөз Әсмаңны бәреп егар, дим* (Г. Камал). *Синең әче балыңмы-ы?! Шампаннарыңны бәреп ега бу!* (Г. Галиева. Газзәбану).
Төрдәше: аяктан егу 1–7 һ.б.

**БӘРЕП ТӘ ЕГАР, ТАРТЫП ТА ТОРГЫЗЫР.** Бик кызу, дуамал, ләкин кызуыннан бик тиз сүрелә торган кеше хакында. *Бүгенгедәй күз алдында: кыю, кызу канлы кеше иде. Бәреп тә егар, тартып та торгызыр* (Ш. Бикчурин).
Төрдәше: бармалы да кайтмалы һ.б.

**БӘРЕП ТӨШЕРҮ** *гади с.* Югары дәрәҗәле кешене урыныннан алып ату. *Алар да, бездән күрмеш, үзләренең илләрендәге шаһ вә корольләрне, солтан вә падишаһларны бәреп төшерерләр* (В. Имамов. Тозлы яра). – *Мине бәреп төшермәкче булдың! – ди староста* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**БӘРЕП ЧЫГУ.** 1. Эчке рухи үзгәрешнең йөздә чагылуы. *Малайның йөзенә кызыл тимгелләр бәреп чыкканны күргәч, үзе дә шикләнә калды бугай* (А. Тимергалин. Таш алиһә). *Бу турыда белгәч, Саимәнең шатлыгы эченә генә сыеп бетә алмады, тышка бәреп чыкты* (Г. Галиева. Тулгак).

2. Металл әйбернең тышкы ягына эчтән берәр үзгәрешле төс калку. *Өстәл өстендә җиз самовар шаулап тора. Аны күптән куймаганнар, ачмаганнар булса кирәк, өстенә тимгел-тимгел тутыклар бәреп чыккан* (А. Шамов).

*БӘРСӘМ* ❖ **БӘРСӘМ, БӘРӘКӘТЕҢ ОЧАР.** Күп гаугалашканда яки дошманың белән бәрелешкәндә, масаеп әйтү. – *Нәрсә күзеңне чекерәйтеп карап торасың: бәрсәм, бәрәкәтең очар!* (Сөйләм).

*БӘҮ* ❖ **БӘҮ ИТҮ** *к.* бәй итү 1, 2. *Әлли-бәлли итәр бу, / Йокыларга китәр бу. / Бәү-бәү итеп, күз йомып, / Изрәп кенә китәр бу* (М. Бакиров. Балалар фольклоры). *Картайган кадак матчада. / – И тирбәлгәндер бишек! / Шыңшыр да*

*кем, фотосурәт / Бәү итәр кебек, төшеп...* (Р. Идиятуллин. Кайту).
Төрдәше: бәй итү 1, 2.

*БӘХӘС* ❖ **БӘХӘС КУБУ.** Һәркемнең үз фикерен яклап сөйләве. *Икенче почмакта ат чабышлары турында бәхәс купкан* (М. Галәү. Мөһаҗирләр). *Алкыш авазлары тынарга өлгермәде, мәхшәр, бәхәс купты* (В. Имамов. Кәнәфи).
Төрдәше: бәхәс куеру (куерту).

**БӘХӘС КУЕРУ (КУЕРТУ).** Бик нык бәхәсләшү. – *Ничек инде син мәхәббәтне дуслык белән бутыйсың? – дип, икенчесе бәхәс куертмакчы булды* (Р. Низами. Без яшибез...). *Менә бүген дә бәхәс куерып килә* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).
Төрдәше: бәхәс кубу.

*БӘХӘССЕЗ* ❖ **БӘХӘССЕЗ НӘРСӘ.** Мәгълүм, апачык, дәлилләргә кирәге калмаган хакыйкать. *Үзләре өчен бүтәннәрне сугыштырып, тәти генә яшәп килүләре ул инде бәхәссез нәрсә* (Г. Бәширов). *Муса Җәлилнең әдип буларак зурлыгы, олылыгы бәхәссез нәрсә* (Р. Фәйзуллин. Илбагар уйлар).

*БӘХЕТ* ❖ **БӘХЕТ АЛГА БАРУ.** Бер-бер артлы уңышка ирешү. – *Карале, ничек ул синең бәхетең туктаусыз алга бара?!* (Сөйләм).

**БӘХЕТ АЛМАСЫНА КОРТ ТЕШЕН БАТЫРУ.** Бәхетенең тормышка ашуын киртәләү. *Шуннан бирле Рәхимҗанның хыялдагы бәхет алмасына корт тешен батырды* (Н. Гыйматдинова. Мәхәббәттә гөнаһ бар).

**БӘХЕТ АЧКЫЧЫ.** Бәхет китерүче. Борынгы мисырлыларда кешегә бәхет китерә торган иероглиф (тормыш ачкычы, Нил ачкычы һ.б. исемнәре билгеле) буларак саналган. *[Бакый] Мирза кызы моңарчы йөзенә карарга да хурланган көтүчесеннән бәхетенең ачкычын тапсын* (М. Фәйзи. Ак калфак).

**БӘХЕТ АЧЫЛУ (АЧЫЛЫП ТОРУ; АЧЫЛЫРГА ТОРУ).** *Белемгә сусаган, моңа кадәр рус мәктәпләренә юл таба алмыйча интеккән Кәрим өчен зур бәхет ачыла. Ул анда да көндез эшли, кичен укый* (Л. Гадилов. Дипломат). *Көтелмәгән бәхет ачылып тора* («Яңарыш» (Төмән) газ.).

**БӘХЕТ АЯККА УРАЛУ.** Уңышка, бәхеткә ирешү. *Бәхете аягына уралган икән, хатыннары өй-каралтыларын, мал-туарын саклаганнар, таратмаганнар* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).
Төрдәше: бәхет басу; бәхет елмаю; бәхет җиңү; бәхет ишеге (капкасы; капусы) ачылу; бәхет йөзе күрү; «бәхеткә» салган балдак; бәхеткә туры килү; сигез оҗмах капкасын ачу.

**БӘХЕТ АЯККА ЧОЛГАНСА ИДЕ.** «Бәхет югалмасын» мәгънәсендә. *Гөлсинә еш кына балконга чыгып баса да тормышы, балалары турында уйлана, үзе дә сизмәстән «бәхет аякка чолганса иде» дип пышылдый иде* (Сөйләм).

**БӘХЕТ ӘСӘРЕ.** Бәхеткә ирешү, бәхет насыйп булу билгесе; бәхет чыганагы. *Аңа һәммәсе дә, бу тиле, ахрысы, дигәндәй, сәерсенеп карый, берсенең дә йөзендә бәхет әсәре күренми* (Н. Гыйматдинова. Ак торна каргышы).
Төрдәше: бәхет йолдызы (кояшы); бәхет кошы; оҗмах кошы; һомай кошы.

**БӘХЕТ БАСУ.** Көтмәгәндә уңышка ирешү. *Өченче көн дигәндә, малайларның бәхете басты* (Ф. Хөсни. Урман сукмаклары). *Әлтафи, җырлаганда, «р» авазларын аеруча яратып, ырылдатып әйтә иде, бу җыр текстында аның бәхете басты, ул туйганчы ырылдады* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).
Төрдәше: бәхет аякка уралу һ.б.

**БӘХЕТ БӘЙРӘМ ИТСЕН.** Яхшы ниятле алкыш. *[Бакый] Ярым, дисең, туташ, – Бәхетем бәйрәм итсен; итсен, диген, – аяк астында җаным чыксын!* (М. Фәйзи. Ак калфак).

**БӘХЕТ ЕЛМАЮ** *к.* бәхет аякка уралу. *Көтмәгәндә бәхет елмайды, колхоз яшь кадрлар: ферма мөдире, ветфельдшер укытырга тиеш* (Ш. Галиев). *Бу яктан да Гөлназга күн төште, ягъни бәхет елмайды* (И. Нәбиуллина. Ташта үскән гөл).
Төрдәше: бәхет аякка уралу һ.б.

**БӘХЕТ ҖИЛЕ (ДАВЫЛЫ).** Бәхет билгесе, бәхет чыганагы (зур шатлык). *Бәхет җиле кагылган күңелгә шулай скрипка моңы да бик кирәк, бик тансык икән ул, һәм шуннан соң инде ул бәхет җиле дигәнебез чын давылга ук әверелә икән. Якынлашып килгән бәхет давылы...* (Р. Төхфәтуллин. Агымсу).
Төрдәше: бәхет әсәре һ.б.

**БӘХЕТ ҖИҢҮ** *к.* бәхет басу. *Иренең сугыш кырыннан исән-сау әйләнеп кайтуын туганнары бәхет җиңүе дип кабул иттеләр* (Сөйләм).
Төрдәше: бәхет аякка уралу һ.б.

**БӘХЕТ ҖИРЕ.** Берәрсенең билгеле бер җиргә барырга (барып урнашырга) хыялланган урын. *Туган илем – илләр иле, / Туган җирем – җирләр җире, / Бәхет җире, нур иле* (Р. Гаташ. Зәңгәр ил – бала чак иле).

**БӘХЕТ ИШЕГЕ (КАПКАСЫ; КАПУСЫ) АЧЫЛУ** *к.* бәхет аякка уралу. *Хәйрулла агай, Мифтах байның җирән алашасы төсле, көнетөне тырышып эшләсә дә, җәйләрен авылда, кыш көне шахталарда хәлдән тайганчы сасы җир астында күмер, тимер казыса да, Алла аңар бәхет ишеген ачмады* (К. Тинчурин. Кара көннәрдә). – *Егетнең бәхет капусы ачылды бит, берьюлы ике кыздан ике хат! – диде* (Г. Әпсәләмов. Газинур).
Төрдәше: бәхет аякка уралу һ.б.

**БӘХЕТ ЙОКЛАУ.** Бәхетсез, мескен кеше турында. *Монда гына егетнең бәхете йоклаган булып чыкты: паром әле генә бу ярдан кузгалып киткән иде* (Э. Касыймов. Бир кулыңны, дустым!..). *«Ялкауның бәхете йокламый» дигән рас киләме?* (Ш. Галиев. Илһамым-мәхәббәтем).
Төрдәше: бәхет кире<гә> китү (киреләү).

**БӘХЕТ ЙОЛДЫЗЫ (КОЯШЫ)** *к.* бәхет әсәре. – *Шул уйларыннан аңа бәхет йолдызы балкыды* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым). *Мин «бәхет» диеп нидә итсәм дә, булмый берни дә; / Баткан ул бәхет кояшы, мисле чыкмас мәңгегә!* (Г. Рамазанов. Көтәм!).
Төрдәше: бәхет әсәре һ.б.

**БӘХЕТ ЙОЛДЫЗЫ АСТЫНДА ТУУ** *к.* анадан күлмәкле килеш туу. – *Бәхет йолдызы астында тугансың, Рәсим, – диде Грегус Григорьевич, мине трюм капкачына илтеп утырткач* (Ф. Шәфигуллин. Өй салуның ние бар...).
Төрдәше: анадан күлмәкле килеш туу һ.б.

**БӘХЕТ ЙОМАРЛАНУ.** Бәхетсезлек билгеләре күренә башлау. *Бәхетең бер йомарланмасын... Аннары бетте диген* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).

**БӘХЕТ ЙӨЗЕ КҮРҮ.** Бәхеткә ирешү, бәхет насыйп булу. *Ана кеше бәхет йөзен күрәчәгенә, кызының табылачагына өметләрен өзми иде* (Сөйләм).
Төрдәше: бәхет аякка чолгану һ.б.

**БӘХЕТ ЙӨЗЕГЕ БЕЛӘН ТУУ** *к.* анадан күлмәкле килеш туу. *Бәхет йөзеге белән туган кешедәй – һәммәсенә тиз генә хуҗа булырга җыендыңмы?* (Т. Галиуллин. Сәет Сакманов).
Төрдәше: анадан күлмәкле килеш туу һ.б.

**БӘХЕТ ЙӨЗЛЕГЕ ЭЧЕНДӘ ТУУ** *к.* анадан күлмәкле килеш туу. – *Җантаһирга бирегезче, ул эшләп карасын – бәхет йөзлеге эчендә туган ул безнең* (Сөйләм).
Төрдәше: анадан күлмәкле килеш туу һ.б.

**БӘХЕТ КАЗАНЫ ЧАЙПАЛМАСЫН.** «Бәхеттән көнләшеп, әшәкелек эшләргә маташмасыннар» мәгънәсендә. *Ярабби, ярабби! Бәхет казаны чайпалмасын, саф күңеленә кара дегет таммасын, күзләрендәге нур сүнмәсен* (Р. Мөхәммәтша. Тырыйк).

**БӘХЕТ КАНАТЫН КАЕРУ.** Бәхетне киртәләү, уңышсызлыкка юл ачу. *Аның бәхет канатын бер каердылар инде...* (Н. Гыйматдинова).

**БӘХЕТ КАРАЛУ.** Берәрсеннән көнләшеп яки үч тотып, аның хакында начар сүзләр сөйләү, әшәкелек эшләү. *Сәбәп: бәхетең каралган саен. / Өмет – хыял булып балкыды* (Ә. Давыдов. Йокысыз төннән соң).

**БӘХЕТ КИРЕ БУЛУ.** Бәхетсезлеккә, бәлагә очрап тору. *Шулай бит ул, бәхтең кире булса, / Табылып тора аның борчасы!* (М. Җәлил. Борча).
Төрдәше: аяк кермәс җиргә баш керү.

**БӘХЕТ КИРЕ<ГӘ> КИТҮ (КИРЕЛӘҮ).** Уңышсызлыкка очрау. *Бәлки, Тукай мәрхүм бәхетенең кирегә китәре вә эшләрнең арты илә әйләнәсен алдарак тотадыр иде* (gabdullatuqay.ru).
Төрдәше: бәхет йоклау.

**БӘХЕТ КОШЫ** *к.* бәхет әсәре. *Бу кош бәхетленең башына үзе килеп куна. Ах, хыял түгел, әллә бәхет кошым сайрыймы, Ходаем?* (М. Фәйзи). *Бәхет кошы синең кулыңа үзе кереп тора, йоклап калма, ычкындырма аны, Мортазин* (В. Имамов. Күке).
Төрдәше: бәхет әсәре һ.б.

**БӘХЕТ КОШЫ КАНАТСЫЗ <БУЛУ>.** Хатыны башка берәүне ярату, ләкин иренә хыянәт итмәү. *Нурулла әкрен генә Энҗенең кулын җиңеннән ычкындырды да, ачынып: – Шәмсулланың бәхет кошы да канатсыз! – диде* (Н. Гыйматдинова. Нурулла).

**БӘХЕТ КОШЫН КУЛДАН ЫЧКЫНДЫРУ.** Саклый белмәү аркасында, килгән бәхетне югалту, кадерен белмәү. *Юкса бәхет кошын кулдан ычкындыруыбыз бик мөмкин* (Ш. Камал). *Шуңа күрә ашыгыгыз, бәхет кошын кулдан ычкындырмагыз!* («Кызыл таң» газ.).

**БӘХЕТ КОЯШЫ КӨЛҮ.** Бәхет-шатлык күрү насыйп булу. *Уем белән яратып / Сагынудан күзләреңдә / Бәхет кояшы көлә* (Л. Шәех). *Һәм, иң гаҗәбе, шундый кешегә дә чын бәхет йөзен күрү насыйп булмаган, Айсылуның үзенә дә бәхет кояшы көлмәде* (Ә. Салах. Соңгы вальс).

Төрдәше: бәхет аякка чолгану һ.б.

**БӘХЕТ КУУ.** Зимагурлыкта читтә йөреп, бәхет өмет итү. *Шахталарга китеп, бәхет куып йөрүчеләрне җене сөймәде аның* (И. Гази. Онытылмас еллар).

Төрдәше: бәхет эзләү.

**БӘХЕТ КҮГӘРЧЕНЕ.** Насыйп яр. *Акай-шакай килмәсәң, илнең күзе очлы аның, күрерләр, бәхет күгәрченең үзе үк иңбашыңа килеп кунар* (Ф. Хөсни).

**БӘХЕТ КҮМӘЧЕ ПЕШҮ (УҢУ).** Зур уңышка ирешү, бик бәхетле булу. *Мәйтәм, улымның бәхет күмәче ишелеп уңды* (Н. Гыйматдинова. Мәхәббәттә гөнаһ бар). *Тулып һәм пешсә берәүнең бәхет күмәче, / Көнчелек кылып турама ваклык токмачы* (Ф. Яхин).

Төрдәше: бәхет күмү.

**БӘХЕТ КҮМҮ** *к.* бәхет күмәче пешү (уңу). *Тагын Галәвине бәхет күмде* (Ф. Яхин. «ЗИЧ-5»). *Мәрьямнең соңгы өч елда Кыш бабайдан сораган бүләге сеңел иде, аны бәхет күмеп китте* («Матбугат.ру» порталы).

Төрдәше: бәхет күмәче пешү (уңу).

**БӘХЕТ МӘТӘЛЧЕК АТУ.** Уңышсызлыкка очрау. *Бәхете мәтәлчек аткан, диделәр* (Р. Зәйдулла. Яшел чирәмдә сары клиндер).

Төрдәше: бәхет сукмагына төшү.

**БӘХЕТ ӨЛӘШКӘНДӘ ЙОКЛАП КАЛГАН НӘРСӘ** *кимс.* Ялкау, егәрсез кеше хакында. – *Каян табасың шул бәхет өләшкәндә йоклап калган нәрсәләрне, юньлерәгә булмадымыни?* (Сөйләм).

Төрдәше: аныкка танык <булу (булып тору)> һ.б.

**БӘХЕТ ӨМЕТЕНӘ КАНАТ КУЮ.** Теләктән, бәхет китерер дип өмтеләнгән нәрсәдән ваз кичтермәү. – *Бик дөрес эшләгәнсез, Гыйрфан кордаш, ифрат мәгъкуль бу – улың Галимҗанны «Галия»гә алып килүең, – дип, аның бәхет өметенә канат куеп тора* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

**БӘХЕТ СӘГАТЕ СУГУ.** Уңышка очрашачагын сизеп-өметләнеп тору. *«Көнем килә, бәхет сәгатем суга!» дип, яшерен өметләр тышка чыга башлаганда, ике үксез сабыйны хатын кулына калдырып, кара гүргә кереп ят инде!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**БӘХЕТ СУКМАГЫНА ТӨШҮ.** Уңышсызлыкка юлыгу. *Кемдер аның бәхет сукмагына төште, кемдер бәхет юлына ут салды* (М. Хәбибуллин).

Төрдәше: бәхет мәтәлчек ату.

**БӘХЕТ СЫНАУ.** Уңышлы булуга өметләнеп, берәр эшкә тәвәккәлләү. *Еллар үткән, Гарәфи берничә тапкыр читкә дә чыгып бәхет сынап караган* (Г. Әпсәләмов. Газинур). *Килмәсеннәр, бәхетләрен сынамасыннар, дип хәбәр итәсе иде дә, тик кем аша?* (М. Хәбибуллин. Хан оныгы Хансөяр).

**БӘХЕТ СЫНАШ (СЫНАМЫШ) УЕНЫ.** Лотерея уены. *Менә быел, Питердагы бәхет сынаш уенында биш сумлык билетка йөз меңгә отарга уйлап, бөтен бер билет алып, йөз меңне отып баю хәстәренә кереште* (К. Тинчурин. Йөз мең).

**БӘХЕТ ТАШУ.** Уңышлары артык күп булу, бәхетле булу. *Бәхетем ташыган көе военкоматка чаптым* (М. Мәһдиев). *Үзе саунага керә алмаса, сыңар күз белән генә шул бәхетләре ташыган ханымнарны карап торасы иде!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**БӘХЕТ ТҮГӘРӘК <БУЛУ>.** Тормышта барысы да яхшы булу, кайгы-хәсрәте булмау. *Әдибәнең үзенең бәхете түгәрәк* (И. Нәбиулли-

на. Миләш тәме). *Бәхетләр булмыйдыр түгәрәк, / Махсусмы бер чите кителә?! / Бәхетне түгәрәк итәм дип, / Түгәрәк йомгаклар сүтелә* (Р. Мөхияр. Асылыма кайтам).
Төрдәше: бәхет түгәрәкләнү.

**БӘХЕТ ТҮГӘРӘК БУЛСЫН.** Һәрчак бәхетле булу теләге. *«Кызыгыздан уңдыгыз, бәхете түгәрәк булсын», диләр* (И. Гази. Югалган Мәрзыя). *Тормыш шундый... / Бәхетләр булмыйдыр түгәрәк, / Бәхетең түгәрәк булсын* (Р. Мөхияр. Асылыма кайтам).

**БӘХЕТ ТҮГӘРӘКЛӘНҮ.** Тормышта барысы да җайга салыну. *Бүген бәхете түгәрәкләнде. Бергәләп сәяхәткә чыктылар. Гәүһәршад гадәттәгечә эчен бушатты* (М. Әмирханов. Гәүһәршад). *Яшь егетнең шушылай «бәхете түгәрәкләнә»* (Ф. Яхин. Таң кызы).
Төрдәше: бәхет түгәрәк <булу>.

**БӘХЕТ ЧӘЧЕП УТЫРУ.** Бик бәхетле кыяфәттә булу. *Сафый абзый елмаеп, бәхет чәчеп утыра* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).

**БӘХЕТ ЭЗЛӘҮ** *к.* бәхет куу. *Элек заманда гына читкә китеп бәхет эзләгәннәр* (Г. Әпсәләмов. Газинур). *Тол дүдәк, ятим-ялпы хатыннар, ирләре бәхет эзләп читкә тайпылган киленчәкләр гел аңа ялынды* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: бәхет куу.

**БӘХЕТ ЭШЕ.** Очраклы рәвештә уңышка ирешү. *Кем кая эләгә, нинди частька, кемнәр белән – бәхет эше* (Р. Кәрами. Олы юл да сикәлтәле). *И мәнә сиңа, түшеңдә орден! Бәхет эше ул, энекәш, сугышы да* (З. Мәхмүди. Сары каеш – сары сагыш).

*БӘХЕТЕ* ❖ **БӘХЕТЕ АЛДЫНА САЙРАП КУНСЫН.** Бәхетне кош сурәтендә күреп, шул кошның алдыңа кунуын теләү. *[Гөләндәм] Бәхетең алдыңа сайрап кунсын* (М. Фәйзи).

**БӘХЕТЕ ҖИҢҮ.** Уңай булу, бәхеткә туры килү. *Ләкин крестьяннарның бәхете җиңде. Яңгырның үзәге уңнан Караюргага карап үтте, монда Исәнбикә өстенә тик бер чите генә эләкте, аз-маз тамчылады, шулай да печәнгә һичбер зыян итәрлек яумады* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). *– Хәзер инде – патша! – ди утынчы егет, кызны шатландырып, бу юлы да Гүзәлнең бәхете җиңә* (Н. Сәйяр. Гүзәлләрнең гүзәле Гүзәл).
Төрдәше: «бәхеткә» салган балдак; бәхеткә туры килү.

*БӘХЕТЕНӘ* ❖ **БӘХЕТЕНӘ АЙ БУЛ!** *к.* алдыңа ак көн тусын! *[Хәмдия] Бар, сөекле балакай, туганыңның бәхетенә ай бул!* (М. Фәйзи. Ак калфак).
Төрдәше: алдыңа ак көн тусын! һ.б.

**БӘХЕТЕНӘ ТӘҮФИГЫ БУЛСЫН.** Бәхетле булу гына түгел, үзенең холкы-фигыле дә яхшы булуны теләү. *Бу бала читкә укырга китә икән, дип ишеттем, бәхетле булсын, бәхетле генә түгел, бәхетенә тәүфигы булсын* (Сөйләм).

*БӘХЕТЕҢ* ❖ **БӘХЕТЕҢ БАР ИКӘН.** Җай килеп тору. *Теге бер күзле нәрсә: – Ну, бәхетең бар икән, тураклап кисмәккә тутырадыр идем, – дип гырылдап калган, ди...*– (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары). *Борчылма, энем, төзәлер. Бәхетең бар икән, сиңа операцияне Марсил Хатипович үзе ясады* (В. Нуруллин. Һәлакәт).

**БӘХЕТЕҢ ЧАЛЫШ АВЫЗ БУЛГАЧ.** Уңышсызлыкка очравының сәбәбен үзеннән генә күреп, башкаларга үпкәләмәвен белдерү. *Бәхетең чалыш авыз булгач, үзеңә генә үпкәләргә кала инде, ичмасам, лотерей дигәннәре дә чыкмый* (Сөйләм).

**БӘХЕТЕҢ ЯР БУЛСЫН.** Бәхетең үзеңнән аерылмас яр-юлдашың булсын теләге. – *Ара-тирә генә булса да, хат язгала, бәхетең яр булсын, аппагым!* (Сөйләм).

*БӘХЕТКӘ* ❖ **БӘХЕТКӘ АЯК ЧАЛУ** *к.* аркылы килү (төшү) 2. *[Галиябану] Минем бәхетемә аяк чалмагыз* (М. Фәйзи. Галиябану). *Язмыштыр инде, заманында егетнең бәхетенә аяк чалды, үзе генә түгел, хатыны белән бергә...* (Ф. Яхин. Август ае).
Төрдәше: аркылы килү (төшү) 2 һ.б.

**БӘХЕТКӘ БАЛТА ЧАБУ**. Үз-үзеңә зыян китерердәй эш эшләү. *[Роза] Барысы да бетте! Үз бәхетемә үзем балта чаптым* (Ә. Исхак). *– Әй, бала, нигә үз бәхетеңә балта чабасың! Мәнә дигән асыл егеткә киреләнәсең бит* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: бәхетне кисү.

**БӘХЕТКӘ ЙОТЫЛУ.** Үзенең бәхетле булуына сөенеп бетә алмыйча, тирә-юньгә дикъкать итмәү. *Ярый әле, бәхетенә йотылган ханым, аны-моны сизмичә (ә бәлкем, сизгәндер дә), үзе яңадан сөйләп китте* (Ә. Еники. Йөрәк сере).

**БӘХЕТКӘ КАРШЫ.** Уйлаган яки эшләгән эш уңышлы чыкса, моны бәхет белән бәйләү. *Бәхеткә каршы, Тукай редакциягә килгән чак була* (А. Расих. Ишан оныгы). *Бәхеткә каршы, була шундый фидакарьләр, мөмкин түгелне дә эшлиләр* (М. Маликова. Арыш тәме).

**БӘХЕТКӘ КИРТӘ БУЛУ**. Берәр төрле уңышка ирешүдә каршылык күрсәтү. *Синең әтиеңнең язмышы шулай ук безнең бәхетебезгә дә киртә булыр микәнни?* (Ш. Хөсәенов). *Укымаганлык бәхеткә киртә булып торырга тиешме?* («Безнең гәҗит» газ.).
Төрдәше: аркылы килү (төшү) 2 һ.б.

**БӘХЕТКӘ КЫРАУ ТИЮ.** Бәхетсезлеккә дучар булу. *Төпчек кызыңның бәхетенә кырау тиде* (Р. Төхфәтуллин).

**«БӘХЕТКӘ» САЛГАН БАЛДАК** *кин., к.* бәхете җиңү. *Берсе Әмир «бәхетенә» салынган балдак булды* (Т. Галиуллин. Мәкер).
Төрдәше: бәхете җиңү һ.б.

**БӘХЕТКӘ ТЕШНЕ БАТЫРУ** *к.* аркылы килү (төшү) 2 һ.б. – *Булмас, – диде хатын, – мин синең бу эшеңә чик куярмын, ерткыч. Бәхетемә тешеңне батырмассың* (Н. Гыйматдинова. Кыргый).
Төрдәше: аркылы килү (төшү) 2 һ.б.

**БӘХЕТКӘ ТУРЫ КИЛҮ** *к.* бәхете җиңү. *Бәхетенә туры килүен күр син аның, ул беренче баруында ук эшен хәл итә алды* (Сөйләм).
Төрдәше: бәхете җиңү һ.б.

*БӘХЕТЛЕ* ❖ **БӘХЕТЛЕ ЙОЛДЫЗ АСТЫНА ТУРЫ КИЛҮ (АСТЫНДА ТУУ)** *к.* анадан күлмәкле килеш туу. *Нинди бәхетле йолдыз астына туры килептер, элегрәк резервта буталып йөрүдән ерак китмәгән, февральдән соң Казанга җибәрелгән* (Ф. Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы). *Шуның белән бергә очраклы, мәгънәсез үлемнән котылуы күңеленә шатлык, юаныч бирә иде. Димәк, ул, кем әйтмешли, бәхетле йолдыз астында туган* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).
Төрдәше: анадан күлмәкле килеш туу һ.б.

**БӘХЕТЛЕ КУЛ.** Уңыш, бәхет китерә торган кешеләр хакында. *Безгә, иртәрәк килгән бәхетле кулларга, байтак вак-төяк эш белән маташырга туры килде* (А. Гыйләҗев. Язгы кәрваннар). *1913 ел. Күренекле композитор А. Шенберг «Бәхетле кул» дигән пьеса язды* (Б. Галиев. Төсле тавыш сәнгате).

**БӘХЕТЛЕ СӘГАТЬТӘ ТУУ** *к.* анадан күлмәкле килеш туу. *[Фәрхи] Бик бәхетле сәгатьтә тугансың икән, бәбкәм* (К. Тинчурин. Сүнгән йолдызлар).
Төрдәше: анадан күлмәкле килеш туу һ.б.

*БӘХЕТЛЕНЕҢ* ❖ **БӘХЕТЛЕНЕҢ ӘТӘЧЕ ДӘ ЙОМЫРКА (КҮКӘЙ) САЛА** *к.* алтын бишектән төшү 1. – *Сөйләмә дә инде, бәхетленең әтәче дә йомырка сала бит аның* (Сөйләм).
Төрдәше: алтын бишектән төшү 1 һ.б.

**БӘХЕТЛЕНЕҢ САРЫГЫ ДА ЮРГА ТОТА** *к.* алтын бишектән төшү 1. *Бәхетленең сарыгы да юрга тота, ди, безнең этләр куян да тота алмый* (М. Әмирханов).
Төрдәше: алтын бишектән төшү 1 һ.б.

*БӘХЕТНЕ* ❖ **БӘХЕТНЕ КЕРПЕ ТИШКӘЛӘГӘЧ, НИ УФЫР, НИ ПУФЫР** *к.* аркылы килү (төшү) 2. – *Саҗидә очрады бит анда сиңа. Бәхетеңне керпе тишкәләгәч, ни уфыр, ни пуфыр, мин дә ул көнне җәйләүдә идем* (Н. Гыйматдинова. Нурулла).
Төрдәше: аркылы килү (төшү) 2 һ.б.

**БӘХЕТНЕ КЕРПЕ ҮБҮ** *к.* аркылы килү (төшү) 2 һ.б. *Бәхетне дә, шатлыкны да, / Бәхетне керпе үпкән дип, / Берәү йөри сүгенеп* (Җырдан).
Төрдәше: аркылы килү (төшү) 2 һ.б.

**БӘХЕТНЕ КЕРПЕ ЧӘНЧҮ (ТИШКӘЛӘҮ)** *к.* аркылы килү (төшү) 2. *«Бәхетеңне керпе чәнчесә шулай инде» дип, үртәлеп уйлады ул* (Р. Зәйдулла. Йорт иясе).
Төрдәше: аркылы килү (төшү) 2 һ.б.

**БӘХЕТНЕ КИСҮ** *к.* аркылы килү (төшү) 2. *Җилләре каршы исте лә, / Җилләрме бәхетен*

*кисте?* (Р. Гаташ. Сәгыйть Рәмиевнең бунт-монологлары). *Илдарның бәхетен кисте чуракай* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: аркылы килү (төшү) 2 һ.б.

**БӘХЕТНЕ (БӘХЕТКӘ) КЫРАУ СУГУ (ТИЮ)** *к.* аркылы килү (төшү). *Төпчек кызының бәхетенә кырау тиде* (Р. Төхфәтуллин). *Бәхетенә иртә кырау суккан иргә теләк тели-тели, Сәвилә тагын күлмәк агызды...* (Н. Гыйматдинова. Сәвилә). *Бәхетемә кырау сукты, / Бар хыяллар юкка чыкты* (Р. Сәгъди. Минем Капурым).
Төрдәше: аркылы килү (төшү) 2 һ.б.

**БӘХЕТНЕ СУГА САЛУ**. Килгән бәхеттән ваз кичү. *Кайгыларым ташлыйм диеп, ялгыш / Бәхетемне суга салганмын* (Ф. Сафин). *– Мәхәббәтен күрдем, беләм, үтүчән вә сагышлы икән, биргән бәхетне суга салган балдай эретә дә юкка чыгара икән* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).

**БӘХЕТНЕ СЫЕР СӨЗҮ.** Күңелсезлекләр белән очрашу. *Бичара, бәхетеңне бер сыер сөзсә... Мари җыры дип җырлаганы тегенең удмурт җыры булып чыккан* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары). *Әмма бәхетен, чыннан да, сыер сөзгән иде* (Ф. Яхин. Ат урлауның ние бар…).
Төрдәше: бәхетнең башын тишү.

*БӘХЕТНЕҢ* ❖ **БӘХЕТНЕҢ БАШЫН ТИШҮ** *к.* бәхетне сыер сөзү. *Ләкин хыялым берничә адым калгач, шушы кәҗә дигән хайван, мөгезе белән кадап, бәхетемнең башын тиште...* (Н. Гыйматдинова. Сөйлә, тыңлыйм...).
Төрдәше: бәхетне сыер сөзү.

*БӘХЕТСЕЗ* ❖ **БӘХЕТСЕЗ БАШ.** Уңышка ирешә алмаган кеше хакында. *Бигрәк мин ул чакта бәхетсез баш икәнмен, бигрәк начар урыннарда вафат булды* (М. Гафури). *Аның теләкләрен тыңлап кара: / Бәхетсез баш инде, хәерсез эш, / Килгән саен, иртәгә кил, имеш...* (Г. Афзал. Үпкәләтмик аны).

*БӘХЕТСЕЗГӘ* ❖ **БӘХЕТСЕЗГӘ ВАКЫТСЫЗ.** Уңышсызлыкка очраган кеше, һәрчак бу сүзләрне әйтеп, үзен тынычландыра. *Торымнан торымга йөрәге кузгала икән аның, дип сөйлиләр иде, бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, шул яман хәл завод тавы өстендә башланган икән...* (А. Гыйләҗев. Язгы кәрваннар).
Төрдәше: бәхетсезгә җил каршы; хәерчегә җил каршы.

**БӘХЕТСЕЗГӘ ҖИЛ КАРШЫ** *к.* бәхетсезгә вакытсыз. *Бәхетсезгә җил каршы, дигәндәй, Филипсонның нәкъ бакчасы белән хушлашып йөргән чагы икән* (Ф. Шәфигуллин. Ак маңгайлы бүреләр). *Бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, май аенда Николай ялга чыкканда, миңа үз исәбемнән дип сорасам да бирмәделәр* (Ш. Алпар. Милләт өмете).
Төрдәше: бәхетсезгә вакытсыз һ.б.

*БӘХЕТСЕЗЛЕККӘ* ❖ **БӘХЕТСЕЗЛЕККӘ КАРШЫ.** Бәхетсезлеккә очраганда әйтелә. *Бәхетсезлеккә каршы, аның авырып китүен хәбәр иттеләр* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Бәхетсезлеккә каршы, нәкъ шул вакыт тагын ишек шакыдылар* (А. Алиш. Якты күл буе).
Төрдәше: гөнаһ шомлыгына каршы.

**БӘХЕТСЕЗЛЕККӘ ТӨШЕРҮ** *к.* бәлагә калдыру. *Ш. Камал үзенең хикәяләрендә гуманлылык, мәгърифәтчелек кешегә бәхет китерә, ә явызлык һәм наданлык кешене бәхетсезлеккә төшерә дигән карашын образлар аша җәмгыятьнең барлык кешеләре өчен дә яраклы бер нәрсә итеп аңлатырга тырышса, «Акчарлак»лар повестенда инде ул моңа омтылмый* («Казан утлары» ж.).
Төрдәше: бәлагә калдыру һ.б.

**БӘХЕТСЕЗЛЕККӘ ТӨШҮ** *к.* аяк кермәс җиргә баш керү. *«Минем аркада бәхетсезлеккә төшмә, сәхнәдәге эшеңә ярдәм итә торган юлны сайла...»* (М. Гайнетдин. Гасырлар мирасы). *Кызы бәхетсезлеккә төшкәннән соң намаз укуын бөтенләй ташлаган ире Җәләйне тиргәштереп ала, аңа үзенең рәнҗүен белдерә* (Н. Яһудин. Казаклар).
Төрдәше: аяк кермәс җиргә баш керү һ.б.

*БӘХЕТТӘН* ❖ **БӘХЕТТӘН ИСЕРҮ.** Уңышларга шатлану, дәртләнү. *Талларны аралап, ике җан суга сикерә. Инде йөрәк янмаганга һәм бәхеттән тәмам исергәнгә, шаян җырлар сиптерүгә дә бик һәвәсләнеп киткән иде дип җырлаганы тегенең удмурт җыры булып чыкты* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары). *Ай нурында коенып, икәү бәхеттән исерә* (Н. Гыйматдинова. Алан уртасында ялгыз йорт).

*БӘХИЛ* ❖ **БӘХИЛ БУЛ.** «Гафу ит», «кичер» мәгънәсендә. *Каргамасыннар. Бәхил булсыннар. Җибәрмәгәч, ризалык бирмәгәч, үзем киттем инде, ди* (А. Алиш. Яңа килен). *Үләр алдыннан ул әнине чакырткан да әйткән: «Әгәр Шәмсетдин исән-сау әйләнеп кайтса, зинһар өчен, әйт: бәхил булсын, минем гаебем юк», – дигән* (А. Шамов. Кыз урлау).

*БӘХИЛЛЕГЕН* ❖ **БӘХИЛЛЕГЕН АЛУ.** Булган гаеп, үпкә-хәтер калуларны кичерүне сорау, ярлыкауны үтенү. – *Ачуын да китергәләдең, бар, бәхиллеген ал* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Матильда, бу шофер миңа яхшылык эшләде, безнең өчен күпме акча түкте, үзенчә бәхиллеген алыйм, дип уйлагандыр* (К. Кара. Матильда).
Төрдәше: бәхиллек сорау.

*БӘХИЛЛЕК* ❖ **БӘХИЛЛЕК СОРАУ** *к.* бәхиллеген алу. *Ялгышуын аңлар да синнән дә бәхиллек сорар...* (Ш. Камал. Козгыннар оясында). *Әллә кул биреп, авыз ачуы Әхнәфтән бәхиллек соравы булдымы?* (Р. Батулла. Юл буенда зәңгәр чәчәк).
Төрдәше: бәхиллеген алу.

*БӘҺАСЕ* ❖ **БӘҺАСЕ КЫЗЫЛ АЛТЫН.** Бик кыйммәтле. *Йөрәксездер колын, әмма бәһасе / Кызыл алтын, үзе инсанга юлдаш* (Дәрдмәнд).

**БӘҺАСЕ СУКЫР БЕР ТИЕН.** 1. Сыйфатсыз, әһәмиятсез. *Китапханәче атаган язучыларның әсәрләрен түгел, исемнәрен дә көчкә исенә төшерде. Бәһаләре сукыр бер тиен* (М. Әмирханов). *Төркиләр турындагы дөреслекне хәтта алар да сөйләмәгәч, университетлары, академияләре бәһасе сукыр бер тиен* (Р. Юныс. Татар гаме).

2. Бик арзан. *Сатуга чыгарылган бу нәрсәнең бәһасе сукыр бер тиен, димәс идем, шулай да шактый очсыз* (Сөйләм).
Төрдәше: базарың бер тиен һ.б. (ике маддә өчен дә).

**БӘҺАСЕ ТӨШҮ.** Арзанаю. – *Солының бәһасе төшеп китте, базарда утыз тиен булды* (Г. Газиз. Яшьләр кичәсе). *Тукай бүләге ияләренең, шагыйрь бөеклегегенә баш игән, аннан рухи көч һәм ныклык алган күп кенә язучыларның, матбугат сүзенең һәм матбугатта эшләүчеләрнең кадере һәм бәһасе төшүгә китерде* («Ватаным Татарстан» газ.).

*БӘЯ* ❖ **БӘЯ БИРҮ.** 1. Кемне яки нәрсәне булса да дөрес, хаклы булганлыгы нигезендә бәяләү. *Һәм егерме бер яшьлек шагыйрь үзенең өлкән каләмдәше турында куйган сораулар (асылда, җаваплар) Исхакыйның шәхесенә һәм хезмәтләренә ачык һәм төгәл бәя бирәләр бит* (А. Тимергалин «Инкыйраз»га – йөз ел). *Андыйларга Ш. Усмановның «Бай кызы» әсәрендәге бер персонаж гаять дөрес бәя бирә* (А. Әхмәдуллин. Офыклар киңәйгәндә).
Төрдәше: бәяли белү.

2. Бер кеше яки нәрсә турында фикер белдерү. *Шагыйрьгә шагыйрьчә бәя бирелсен, ә Наис Гамбәр – чын шагыйрь* (А. Тимергалин. Милли казаныш). *Ай, гүзәлләр! Тач аккошлар! Юк, хур кызлары, хур кызлары болар! – дип, һәркайсы бәя биреп чыкты* (В. Имамов. Карабәй).

3. *күч.* Аңлату, ачып бирү. *Ачуы кабарган чак иде, ачуы кабарганда ул аяусыз, хистойгыларына бәя биреп өлгерә алмый, язгы ташкын кебек вата, җимерә, кыра...* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**БӘЯ<НЕ> КҮПЕРТҮ.** Сата торган әйбернең бәясен махсус артыграк итеп кую. *«Бәяне күпертә», – дип уйлады карт* (Ә. Гаффар. Теге гозер).

**БӘЯ КҮТӘРЕЛҮ.** Әһәмияте арту. *Шәрәфинең башка сүзләренең дә бәясе күтәрелде* (Г. Ибраһимов). *Кадерем арта, бәям күтәрелә! Гаепкә алмагыз, җәмәгать, минем бүген күкрәк суга-суга мактанасым килә* (Ф. Баттал. Кадерем арта, бәям күтәрелә!).

**БӘЯ КҮТӘРҮ.** Дәрәҗә арттыру, дан ясау. – *Ризыклы йорт, ризыклы. Учагында ут сүнми, – дип, әни һаман чибәр апаның бәясен күтәрә, ә Мирһаҗ абый «шулаймы?» дип, әлеге дә баягы сүзен кабатлый иде* (Н. Гыйматдинова. Күңел).

**БӘЯ ТӨШЕРҮ.** Начар хәлдә күренү, хур булу. *Бер сүзеңә, ник әйткәнеңә үкенерлек итеп, мең сүз белән җавап бирә белүче марҗаларга катышып, кыз алдында бәясен төшерәсе, хур буласы килми иде* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).

**БӘЯ<СЕ> ТӨШҮ.** Кадере китү, дәрәҗәсе кимү. *Этләрнең, мәчеләрнең бәясе арта, ә кешенең бәясе төшә!* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Ва-*

*тан бәяләре төшкән саен / Күтәрелә алтын бәяләре* (Г. Морат. Юк).

*БӘЯЛӘП* ❖ **БӘЯЛӘП БЕТЕРГЕСЕЗ.** Бәясен билгеләргә мөмкин булмаган, кыйммәтле. *Аксак Тимер Сәмәркандны чын мәгънәсендә затлы, зыялы, гыйлемле, мәһабәт калага әверелдерә. Туган җирен бар дөньяга танытуда бу гаскәр башлыгының өлеше бәяләп бетергесез* (Г. Шәйхи. Риваятьләр илендә).

Төрдәше: дөнья бәясе (бәһасе) тору (торырлык) 1.

*БӘЯЛИ* ❖ **БӘЯЛИ БЕЛҮ** *к.* бәя бирү 1. *Шулай, изге гамәлләрне, корбан бирүләрне бәяли белердәй хакимнәр юк бездә* (В. Имамов. Казан дастаны). *Чөнки, беренчедән, иҗатың үсүе өчен, язганыңны үзең бәяли белүең бик тә зарур, икенчедән, әсәрең турында матбугатта әйтелгән фикерләрне ясалма тыйнаклыкка бирелмичә яки ачу кабартмыйча исеңдә тотарга тиешсең* (М. Хуҗин. Уеннан – уймак).

*БӘЯСЕ* ❖ **БӘЯСЕ <БАЗАР КӨННЕ СУКЫР> БЕР ТИЕН** *к.* базарың бер тиен. *Әмма мондый фикер нигезле булмаса, киң масса укучылар фикеренә таянмаса, аның бәясе – базар көнне бер тиен* (Р. Мостафин. Төгәл булыйк!).

Төрдәше: базарың бер тиен һ.б.

**БӘЯСЕ КЫЙММӘТКӘ ТӨШҮ.** Табышына караганда мәшәкате күбрәк булу. *Ләкин ул орденның бәясе бик кыйммәткә төште аңа* (В. Нуруллин). *Ялгышуның бәясе кыйммәткә төшәчәк һәм, бу ялгышлары сәбәпле, күпләр бәлагә тарачак иделәр* (Ф. Яхин. Август ае).

**БӘЯСЕ СУКЫР БЕР ТИЕН** *к.* базарың бер тиен. – *Синең үсешеңнең бәясе сукыр бер тиен!* (Б. Камалов. Мәрдән сукмагы). *Акылны артка чигереп, җүләр хискә буйсынган хатын-кызны кичермәсә, ир кешенең бәясе сукыр бер тиен инде* (Н. Гыйматдинова. Ачкыч).

Төрдәше: базарың бер тиен һ.б.

**БӘЯСЕ ЮК.** Шәхси сыйфатлары буенча кемнедер яки нәрсәнедер бик югары бәяләү; бик кыйммәт. *Белүчеләр булмаганда, кешенең бәясе юк* (Ш. Галиев. Илһамым-мәхәббәтем). *Аның үз бәясе юк, ул бәһасез* (А. Нәҗми. Кояш җилләре).

Төрдәше: асыл зат.

*БӘЯСЕННӘН* ❖ **БӘЯСЕННӘН ТОРМАУ.** 1. Алыш-бирештә сатулашмыйча риза булу. *Ул, зур түбәнчелек белән, күрше генә өстәлдә утыручы пеләшемә бер генә бәрәңге бирүләрен үтенә. Бәясеннән тормаячак, Алла сакласын!* (А. Хәсәнов. Бәрәңге).

2. Эшләгән берәр эш өчен хезмәт хакын кызганмыйча бирү. – *Безгә малярлар бик кирәк, училищены ремонтлыйсы бар, укуларың башланганчы син бездә унбиш-егерме көн эшләп алмассыңмы? Бәясеннән тормабыз* (Г. Ахунов. Йолдызлар калка).

*БЕЖГӘК* ❖ **БЕЖГӘК КЕШЕ** *диал.* Сукранучан, юк-барга ачуланучан, мыжык кеше. *Аның кебек бежгәк кешене күргәнем юк иде* (Сөйләм).

*БЕЗ* ❖ **БЕЗ АКЧАНЫ ТАПМЫЙБЫЗ, АКЧА БЕЗНЕ ТАБА.** Мактану, юмарт булып кылану. *Безгә акча жәл түгел, без акчаны тапмыйбыз, акча безне таба* (Г. Камал).

Төрдәше: авыз белән кош кына тотмау һ.б.

**БЕЗ БЕЛӘН КЫРЫНУ.** Уңайсыз шартларда гади корал белән дә тиешле эшне башкара алу мөмкинлеге турында. *Солдатмыни – күпне күреп, күпне белеп, / Кирәк икән, без белән дә кырынмагач* (Ш. Мөдәррис).

**БЕЗ БЕЛӘН ЧӘНЕЧКӘН КЕБЕК <БУЛУ>.** 1. Кинәт көчле авырту тою. *Җирдә яткан капчыклы бәрәңгене күтәрешкән иде, кинәт йөрәк тирәсендә без белән чәнечкән кебек авырту тойды* (Сөйләм).

2. Күңел рәнҗетелүе турында. *Күрше апаның бу сүзләре аның күңелен без белән чәнечкән кебек иттеләр* (Сөйләм).

Төрдәше: без булып кадалу.

3. Кинәт башкарылган эш турында (мәсәлән, сикереп тору). *Кәримнең авызыннан бу сүз чыгып җитә алмады, Җаббар, сыртына без белән чәнечкән кебек, урыныннан сикереп торды да, шаркылдап көлеп җибәрде* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми).

**БЕЗ БЕЛМӘГӘН АЗ БУЛЫР, БОХАРАДАГЫ ТАЗ БУЛЫР.** «Без барын да беләбез» мәгънәсендә. *Шулай да җавабын таптым – Без белмәгән аз булыр, Бохарадагы таз булыр! Кызлар икесе дә көлеп куйды* (В. Нуруллин. Ике урам арасы). *[Гарәфи] Без белмәгән аз булыр, Бохарада таз булыр... хехе...* (Г. Каюмов. Туу).

**БЕЗ БОРЫН<ЛЫ>.** Борыны очлы булган кеше. *Синең янга килеп йөри торган без борынлы кешене мин... кайдадыр күргән идем* (Г. Әпсәләмов). *Саркып чыккан чишмәләр / Тыныч кына акканда, / Без борынлы тукраннар / Агач чукып ятканда* (Ф. Яруллин).

**БЕЗ БӨЛГӘННӘН КЕМ КӨЛГӘН.** Бөлгенлеккә төшкәндә дә сер бирмәүне аңлата. *Эшне җайга салу өчен, банктан бурыч ала алмаса да, «без бөлгәннән кем көлгән» дип, үзен тыныч тотты* (Сөйләм).

**БЕЗ БУЛЫП КАДАЛУ** *к.* без белән чәнечкән кебек <булу> 1–3. *Кеше алдында иелеп түгел, төз булып калаласы. / ...Очларына чәчәк куеп, без булып кадаласы* (Р. Фәйзуллин. Килә...). *Бигрәк тә шунысы бәгыренә без булып кадалды Гыйниятнең: «Сине инде мич сүтәргә өйрәтеп торасы түгел, Гыйният абзый, тәҗрибә бар», дип кенә җибәрәләр* (Ф. Хөсни. Мичче Гыйният).

Төрдәше: без белән чәнечкән кебек <булу> 1–3.

**БЕЗ ДӘ КАРА КАЛА ТҮГЕЛ.** «Без дә мәгълүматсыз, надан түгел» мәгънәсендә. *Алдармын дип көтмәсен әле, без дә кара кала түгел, ак белән караны аера беләбез* (Сөйләм).

**БЕЗ ДӘ СӨРДЕК** *ирон.* «Аны (моны) без дә булдыра алабыз, бездә дә андый һөнәр бар» мәгънәсендә. *Мин дә мин дип шапырынучылар яныннан Габдрахман абзый, «Без дә сөрдек аны яшь чакта» дип, тыныч кына үтеп китте* (Сөйләм).

**БЕЗ ДӘ ТӨШЕП КАЛГАННАРДАН ТҮГЕЛ.** Без дә тормыштан артта калганнардан түгел, кешедән ким түгел дип, сер бирмәскә тырышу. *Күрсеннәр, әйдә, без дә төшеп калганнардан түгел* (В. Имамов. Ир канаты). *Шулай ул менә! Без дә төшеп калганнардан түгел!* (А. Гыймадиев. Үзең булып кал!).

Төрдәше: агач<тан> сандугач кына ясамау һ.б.

**БЕЗ ДӘ ЮКӘДӘН ТЕГЕЛМӘГӘН** *к.* без дә төшеп калганнардан түгел. *–Тектердем шул. Без дә юкәдән тегелмәгән* (В. Нуриев. Кара бишмәт). *Начальнигым, авызын чалшайтып, кәттә генә җавап бирде: – Без дә юкәдән тегелмәгән, Хикмәт туган* (З. Мәхмүди. Тәмуг чәчәге).

Төрдәше: агач<тан> сандугач кына ясамау һ.б.

**БЕЗ КАККАН** *эвф.* Бер урында тик тора алмаган кеше турында. *Тик арткы рәттә утырган җор телле Исмай гына, без каккандай, сикерә дә тора, сикерә дә тора* (Сөйләм).

**БЕЗ КАРТАЙМЫЙ КЕМ КАРТАЙСЫН.** Кечкенә баланың үсеп җитүен күргәч һәм башка шундый үзгәрешләргә тап булгач әйтелә. *[Самат] Берьюлы икәү! Эх, дөнья, без картаймый кем картайсын!* (Ю. Әминов. Язылмаган законнар). *Бүген көләч, шома йөзгә / Сырлар куна, җыерчыклар. / Без картаймый кем картайсын, / Хәтта тына сыерчыклар* (Л. Шәех).

**БЕЗ КИТӘБЕЗ, СЕЗ КАЛАСЫЗ.** Бүген яшәгәннәрнең тормышка ашыра алмаган уй-ниятләрен киләчәк буынның дәвам итәчәгенә өметләнү һәм хуплау. *«Без китәбез, сез каласыз!» дип җырлармын, / Җәсәдемне туфрак белән күмгәндә дә* (Г. Тукай). *Без һәм башкалар килер / Тантананы дәвам итәргә, / «Без китәбез, сез каласыз» сүзен / Мескен түгел, кискен әйтергә!* (Зөлфәт. Шундый чагы әле чагымның).

**БЕЗ КҮЗ<ЛЕ>** *к.* алмаз күз. *Урманнан чыгар, / Койрык асты чуар / Әфләләм төсле; / Алтын сырлы, / дүрт кырлы, / Төймә башлы, без күзле* (Табышмак: кәккүк).

Төрдәше: алмаз күз һ.б.

**БЕЗ ӨЙЛӘНГӘЧ ТӨН КЫСКАРДЫ.** Рәхәт вакытлар тиз үтү турында. *«Киткән башлар» моңа чыннан авырсыналар, «без өйләнгәч, төн кыскарды» диешәләр. Көннәр болай булып торса, үзләре белән алып китәр өчен акча ясап булмау мәсьәләсе анларны тагы ныграк борчый* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). *Бераздан, авыр сулап куйгач: – «Без өйләнгәч, төннәр кыскарды!..» Менә шулайрак әйткәннәрен ишеткән бар иде анысы... – диде, күзләремә туры карап* (Ф. Яхин. Сүз мәгънәсе).

**БЕЗ ТЕЛЛЕ** *к.* ачы тел<ле>. *Без телле, канатсыз – читлектә, / Безне соң монда кем ишетә?* (Б. Ибраһим. Ә Казан алынган). *Каян туган бу без телле булып!* (Сөйләм).

Төрдәше: агу тел<ле> һ.б.

**БЕЗ ТОРАСЫ ТҮГЕЛ, ҮЗЕҢ ТОРАСЫ (ЯШИСЕ).** Гаилә корганда, яшьләргә киңәш буларак

әйтелә. – *Өйләнсә дә, йортка керсә дә – бер дә начар булмас! Без торасы түгел, үзе яшисе, – дип, абыйсын яклап әйтеп куйды* (Ф. Яхин. Куш каен аланлыгы).

**БЕЗ ЧИЛӘК, ДИБЕЗ, УЛ КӨРӘК, ДИ.** Һәркемнең үзен хаклы дип санавы хакында. *[Сәфәргали] Әйе, әйе, мин ишекне ачсам, ул дөбердәтмәс иде. икенче төрле әйткәндә, без чиләк, дибез, ул көрәк, ди* (К. Тинчурин. Йосыф белән Зөләйха).

**БЕЗ ЮК ҖИРДӘ РӘХӘТ <ЯХШЫ>.** Үз илен яманлап, чит җирләрне мактап йөрүчеләр хакында. *Без юк җирдә тормыш рәхәт инде, / Без юк җирдә башка кояштыр* (Ф. Җамалетдинова. Без юк җирдә тормыш рәхәттер).

*БЕЗГӘ* ❖ **БЕЗГӘ БАСТЫРУ (БАСКАНДАЙ ИТҮ).** Кешенең кайда басып торганлыгын белмәслек итеп нык ачулану; җәза бирү. *Менә шул көннән ул, моннан ары болай яшәп булмас, дип, аерылышу хакында уйлана башлады. Чөнки хатынын безгә бастыруның да файдасы тимәс иде* (Р. Кәрами. Кая чабасың, тормыш юртагы?).

Төрдәше: акыл бизмәненә утырту һ.б.

**БЕЗГӘ ДӘ БЕР КОЯШ ЧЫГАР ӘЛЕ.** «Сезгә генә рәхәт күрергә димәгән, безнең дә авырлылар бетәр әле» мәгънәсендә. *Сезнең урамга гына асфальт түшәп калмаслар, безгә дә бер кояш чыгар әле* (Сөйләм).

Төрдәше: безгә дә карга кунар (утырыр) әле; безнең тәрәзәгә (түбәгә) дә кояш төшәр әле; безнең урамга да бәйрәм килер әле; безнең урамда да (бездә дә) бәйрәм булыр әле; җан-тән белән ышану; җаны барның өмете бар; өмет баглау (бәйләү); өмет белән яшәү; өмет итү; өмет күзе белән карау; өмет өзмәү; өмет саклау; өмет сузу; өмет тауларын өю; өмет тарту; өмет тоту; өмет үрләтү; өмет чаткылары (шәме) кабыну; өмет яну; өметсез шайтан гына; өметтә бар (юк түгел); өметтә тору; тарта торгач он булыр; тәмле өмет бирү; төсе бардан төгәнмә; үрдәк биргән каз көткән; чыкмаган җанда өмет бар; шулпа тимәс җирдән калҗа өмет итү; ышанган тауда киек бар; якты өмет.

**БЕЗГӘ ДӘ КАРГА КУНАР (УТЫРЫР) ӘЛЕ** *к.* безгә дә бер кояш чыгар әле. *Борчылмагыз, кала белән тоташтырган юлны гына төзәтеп җибәрик, безгә дә карга кунар әле* (Сөйләм).

Төрдәше: безгә дә бер кояш чыгар әле һ.б.

**БЕЗГӘ ДӨНЬЯ КАРМАЗИН.** «Безгә дөнья ал да гөл» мәгънәсендә (кармазин – кызгылт төс*). Дулкын-дулкын булып рәхәтлек килде. Безгә дөнья кармазин / Их, мать якасын...* (М. Әмирханов. Их, мать якасын, Черчилегезнең сатыйм каргасын...). *Безгә дөнья кармазин. Безгә дөреслек кирәк!* (matbugat.ru).

**БЕЗГӘ КИЛГӘН КАЗА МАЛГА КИЛСЕН.** Берәр бәла-казага юлыкканда, чыгым тотарга туры килүен әйтү. – *Алып кайтасы мал яңгыр астында чыланган, дисеңме, әйдә, безгә килгән каза малга килсен* (Сөйләм).

**БЕЗГӘ КИЛГӘН ТИК ТОРМЫЙ, ТУН ЧАБУЫН УАЛЫЙ (УА ТОРА).** Кунак килгән вакытта, хуҗа хатын, үз эшеннән туктап тормыйча, кунакка да берәр эш кушканда әйтелә. – *Хатын, безгә килгән тик тормый, тун чабуын уалый тора дигәндәй, минем дуска пилмән бөгә торырга куштыңмы әллә?* (Сөйләм).

*БЕЗДӘ* ❖ **БЕЗДӘ АКЧА БЕР БУКЧА** *к.* акча бездә бер букча. *[Исерек татар] Бездә акча бер букча, мә ал, мә, пирут ал акчаны* (Г. Камал). *...Бездә актив студентларны яратмыйлар. «Бездә акча бер букча» дип, бездә акча да юк, тик торган да юк* («Безнең гәҗит» газ.).

Төрдәше: акча бездә бер букча һ.б.

**БЕЗДӘ АКЧА ҮЛСӘҢ КӘФЕНЕҢ ЧОРНАРГА ҖИТӘР** *к.* акча бездә бер букча. – *Син акча турында уйлама – анысын табарбыз, бездә акча үлсәң кәфенең чорнарга җитәр* (Сөйләм).

Төрдәше: акча бездә бер букча һ.б.

**БЕЗДӘ БУЛМАС ГАЕП, ҮЗЕГЕЗДӘН ЧЫКМАСЫН ТАЕП.** Үз гаебен күрмичә, кешедән гаеп эзләргә яратучылар хакында. *Бездә булмас гаеп, үзегездән чыкмасын таеп* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

*БЕЗДӘН* ❖ **БЕЗДӘН АЗАТ, ХОДАЙДАН КАНАТ.** «Инде буе җиткән, балигъ булган, бездән фатыйха» мәгънәсендә. *Инде олы улым мөстәкыйль тормышка аяк басарга тора, бездән азат, Ходайдан канат үзенә* (Сөйләм).

**БЕЗДӘН КАЙТМАСА, ХОДАЙДАН КАЙТСЫН.** Бирәр нәрсә биргәндә яисә сый-хөрмәткә каршы рәхмәт уку. *Ярдәм иткән кешегә теләк <...> – Бездән кайтмаса, Тәңредән (Ходайдан) кайтсын!* (Р. Безертдинов. Тәңречелек).

**БЕЗДӘН КИТҮ** *к.* авыздан җан чыгу. *Әниең... ул бездән китте... / Миннән китте.... / Сездән дә...* (Р. Харис. Исемсезләр). *Шулай итеп, без әнкәйне калдырып кайттык зиратта. Әнкәй мәрхүм бездән китте* (Р. Зарипов. Тирән тамырлы Түнтәрем).

Төрдәше: авыздан җан чыгу һ.б.

**БЕЗДӘН ХАТА, СЕЗДӘН ГАТА.** Гафу үтенү (гата – *гарәп.* багышлау, бүләк). *[Баян] (елмая). Шылды, Разалия туташ: бездән хата, сездән – ката! Кисәтүең өчен рәхмәт* (Р. Хәмид. Тигезәкләр). *Бу стиль сөйләмендә әңгәмәдәштән җиңелчә генә, уйнап кына гафу үтенгән кебек: «Бездән хата, сездән гата», «Минем хәтер калса калсын, синең хәтер калмасын» кебек әйтемнәр белән гафу үтенү дә күзәтелә* (Р. Абдуллина. Сөйләм культурасы).

*БЕЗНЕ* ❖ **БЕЗНЕ БУТАГАННЫҢ ЭЧЕ-БАВЫРЫ БУТАЛСЫН** *карг.* Ара бозучыга карата. *Безне бутаганның эче-бавыры буталсын* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).

*БЕЗНЕКЕ* ❖ **БЕЗНЕКЕ БАРЫП ТА ЧЫГА, БӘРЕП ТӘ ЕГА.** Башланган эшнең һичшиксез уңышлы тәмамланачагын белдерү. *Бу проект өчен төсләрне генә сайлап бетерик, безнеке барып та чыга, бәреп тә ега* (Сөйләм).

*БЕЗНЕҢ* ❖ **БЕЗНЕҢ БҮЛӘРЛЕК НӘРСӘБЕЗ ЮК.** «Ызгыш-талаш чыгару өчен нигез дә, сәбәп тә юк» мәгънәсендә. *Безнең бүләрлек нәрсәбез юк, һәркайсыбыз үзе аңлаганча сөйли* (Сөйләм).

**БЕЗНЕҢ ИШЕККӘ (ӨЙГӘ) АЮ МАЕ СӨРТКӘНМЕ ӘЛЛӘ.** «Ник килмисең, ник биздегез» мәгънәсендә. *– Инде ничә ай безгә аяк басканыгыз юк, нәрсә, безнең ишеккә аю мае сөрткәнме әллә?* (Сөйләм).

**БЕЗНЕҢ КҮҢЕЛ ЗУРДА ТҮГЕЛ.** Тыйнаклык күрсәтү, ягъни без иң югарысына үрелмибез, урта дәрәҗәлесе дә ярый. *Елтыр-елтыр утлар яна, / Бездә түгел, кантурда; / Безнең күңел зурда түгел, / Унсигез яшьлек матурда* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**БЕЗНЕҢ КЫЗ ДА БЕР КИЯҮ КҮРСЕН ДИГӘН КЕБЕК.** Кешедән калышмаска, ким күренмәскә тырышу. *– Карале, әтисе, безнең кыз да бер кияү күрсен дигән кебек, әллә кара мунчаны ишеп, ак мунча салдырабызмы?* (Сөйләм).

**БЕЗНЕҢ ОЧКА ДА БАРЫРСЫҢ.** Бер туры килгәндә, без дә синең кирәгеңне бирербез, дип янау. *Үзебезнең якта дип, бик әтәчләнмә, безнең очка да барырсың әле* (Сөйләм).

**БЕЗНЕҢ САФКА <ДА> БЕРӘҮ АРТТЫ.** Төркемгә яки оешмага тагын бер кеше кушылу хакында. *«Безнең сафка берәү артты», дип, авыз күтәреп сөйлиләр, аннан нәрсә үзгәрер икән соң?* (Сөйләм).

**БЕЗНЕҢ ТӘРӘЗӘГӘ (ТҮБӘГӘ) ДӘ КОЯШ ТӨШӘР ӘЛЕ** *к.* безгә дә бер кояш чыгар әле. *Кайтыр исән булса, безнең тәрәзәгә тагын кояш төшәр, – дип әйтеп куйды* (Ә. Салах. Каеннар юлы).

Төрдәше: безгә дә бер кояш чыгар әле һ.б.

**БЕЗНЕҢ УРАМГА ДА БӘЙРӘМ КИЛЕР ӘЛЕ** *к.* безгә дә бер кояш чыгар әле. *Минем урамга да бәйрәм килер әле, / Көнем чәчәкләргә бизәлер* (Җырдан). *Ниһаять, безнең урамга да бәйрәм килде* (Л. Лерон. Космодром һәм сессия, космонавт Әгъләм).

Төрдәше: безгә дә бер кояш чыгар әле һ.б.

**БЕЗНЕҢ УРАМДА ДА (БЕЗДӘ ДӘ) БӘЙРӘМ БУЛЫР ӘЛЕ** *к.* безгә дә бер кояш чыгар әле. *[Сәфәргали] Тукта, безнең урамда да бәйрәм булыр әле* (К. Тинчурин. Йосыф белән Зөләйха). *Сайрый трамвайдан төшкәч, телгә килде: «Килер бер көн, – диде ул, билгесез киләчәккә йодрык күрсәтеп, – безнең урамда да бәйрәм булыр!»* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: безгә дә бер кояш чыгар әле һ.б.

*БЕЗ-БЕЗ* ❖ **БЕЗ-БЕЗ КИЛҮ.** Сөйләнгәләп, юк сылтаулар табып акланып маташу. *«Мин күргән ачык тәрәзә кайда соң ул?» – дип без-без килә* (А. Хәсәнов. Үтерә күрмәгез!).

*БЕЛ<ЕГЕЗ>* ❖ **БЕЛ<ЕГЕЗ> (БЕЛЕП ТОР) АНЫ.** «Әйткәнне онытма, исеңдә яхшы тот» мәгъ-

нәсендәге кисәтү. *[Әҗәл] Белегез аны, минем кәләшне алып китәсез* (А. Гадел. Бәхет корбаны). – *Шәүкәт энекәш, исән калып котыла алсаң, ерак кач ул аждаһа нәселеннән булган чибәрләрдән, алманың асылын һәрчак корт ашый, белеп тор аны* (К. Кара. Уфа–Афина).

*БЕЛӘ* ❖ **БЕЛӘ ӘТӘЧ ХӘРФЕ ҖӘРЕҢНЕ.** Исемнең ахырын «и» белән укырга кирәклеген белдерә: үз наданлыгын башка нәрсәгә сылтау. *Ләкин: белә әтәч синең хәрфе җәреңне! Ул һаман үз эшендә* (Г. Тукай).

**БЕЛӘ УЛ БАКАНЫҢ КАЙДА КЫШЛАГАНЫН.** Белсә дә, белмәсә дә «беләм» дип сөйләүчегә карата. *Кем ышансын өендә нәрсә барлыгын да белмәгән кешегә – белә ул баканың кайда кышлаганын!* (Сөйләм).

*БЕЛӘ-БЕЛГӘННӘН* ❖ **БЕЛӘ-БЕЛГӘННӘН (КИЛГӘННӘН) БИРЛЕ.** Үзаң керә башлаганнан алып, тирә-якны аңлап белә башлаганнан бирле. *Тик менә мин белә-белгәннән бирле төзүче оешмада начальниклар гына алышына, ә юллар һаман шушындый* (А. Гыйләҗев). *Мин белә килгәннән бирле, елның елында безнең әти Шәфикъ бабай белән бергәләп каравыл ала* (М. Гали. Пожарныйлар).

*БЕЛӘК* ❖ **БЕЛӘК БУЕ ТЕЛЛЕ.** Күп сөйли торган лыгырдавык кеше хакында. *Беләк буе телле Фатыйманың теленә эләксәң, беттең инде* (Сөйләм).

**БЕЛӘК ТАЛДЫРУ.** Ару. *Әнием минем өчен беләкләрен талдырган* (М. Максуд). *Балта беләк талдырамы, пычкы тартып билләр катамы* (З. Мурсиев. Солтанъяр).

*БЕЛӘККӘ* ❖ **БЕЛӘККӘ ТАУ ТӨЯРГӘ.** Бөтен авырлыкны үз өстеңә алырга, үзең башкарып чыгарга. *Нинди сәер кеше соң ми, / Тау төйим беләгемә* (Э. Шәрифуллина. Ышаныч югалгач).

*БЕЛӘКТӘ* ❖ **БЕЛӘКТӘ ТИМЕР СЫНДЫРУ.** Кечкенәдән авыр эш эшләп, чыныгып үсү. *Исмәгыйль абыйның ике малае да, кечедән гәүдәле булып, беләктә тимер сындырып үстеләр* (Ф. Яхин. Багана фалы).

*БЕЛӘМ* ❖ **БЕЛӘМ, БЕЛӘМ, БЕЛӘ ТОРЫП БӨЛӘМ**. «Начар икәнен дә беләм, белгәнемне дә беләм, әмма барыбер эшлим» мәгънәсендә. *«Беләм, беләм, белә торып бөләм!» – дип әйткән ди берәү, комсыз сөяркәсенә актык малын ташый-ташый* (Ш. Маннур).

**БЕЛӘМ ДӘГЪВАСЫ КЫЛУ.** Үзен бар нәрсәне дә беләм дип санау. *Хәкимҗан абзый үзен тәҗрибәле кешеләр җөмләсеннән йөрткәнгә, кемнең ничек баеганын, кемнең нинди юллар белән эш йөрткәнен беләм дәгъвасы кыла торган, кеше эшен тикшереп картаючы салам торханнарның берсе иде* (К. Тинчурин. Йөз мең).

*БЕЛӘМӘН* ❖ **БЕЛӘМӘН – АКЫЛ ТУБАЛЫ.** Булган гыйлемне бернинди системасыз, ничек эләкте шулай туплаган буталчык кеше турында. *Бүген дөньяның белемен башына төягән беләмән – акыл тубалы* (З. Бәшири).
Төрдәше: аяклы тарих һ.б.

*БЕЛӘМЛЕКНЕҢ* ❖ **БЕЛӘМЛЕКНЕҢ БЕЛӘГЕН НЫГЫТУ.** Белгәнлекне раслый белергә дә кирәклек хакында. *Ләкин карт кеше беләмлекнең беләген сүз белән нығытырга ярата шул* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).

*БЕЛӘСЕЗ* ❖ **БЕЛӘСЕЗ ПЫЧАГЫМНЫ** *к.* беләсең кәҗә катыгын. – *Беләсез пычагымны... Ярдәм кирәк, имеш...* (А. Гыйләҗев. Өч аршын җир).

*БЕЛӘСЕҢ* ❖ **БЕЛӘСЕҢ ӘБИЕҢНЕҢ КЕЛӘСЕН.** *[Фәсхетдин мулла ] Беләм, беләм. Нургали энем. [Нургали] (тамашачыга). Беләсең әбиеңнең келәсен!* (Д. Салихов. Мөгезле Мәүлихан).

**БЕЛӘСЕҢ КӘҖӘ КАТЫГЫН.** Белмәгәнен дә «беләм» дип әйтүчегә җавап. *Авызыңны ачып сөйли генә башлыйсың, «ә, беләм мин аны» дип, сүзеңне кискән кешегә «беләсең кәҗә катыгын» дип әйтми ни әйтәсең инде* (Сөйләм).
Төрдәше: беләсез пычагымны.

**БЕЛӘСЕҢ (БЕЛӘСЕГЕЗ) КИЛСӘ.** «Син (сез) уйлаганча түгел, бөтенләй башкача» мәгънәсендә. – *Бик беләсең килсә, әткәй җыймый безне, ә Бату хан җыя! – дигән Гөек җавабын ишеткәч, Бүре солтанның күзләре утлы күмер капкан сыман акаеп чыккан иде* (В. Имамов. Утлы дала). *Андыйга калса, илле сум аз да әле ул, бик беләсең килсә...* (А. Гыймадиев. Без андый малай түгел!).

*БЕЛӘСЕҢМЕ* ❖ **БЕЛӘСЕҢМЕ НӘРСӘ.** Сүз башлар алдыннан кешенең игътибарын җәлеп итү максатыннан әйтелә. *Йөгереп Сәми керә. «Апа, апа, беләсеңме нәрсә? – ди. Ул Айсылуга яңалык сөйли башлый* (М. Җәлил). *– Беләсеңме нәрсә, бүген җәйләүдән кайтышлый уйланып кайта торгач, шундый бер фикер туды башта: без һаман агым уңаена гына яшибез бугай* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

*БЕЛГӘНЕҢ* ❖ **БЕЛГӘНЕҢ – ТУГЫЗ, БЕЛМӘГӘНЕҢ – УТЫЗ.** Дөньяда барлык нәрсәне дә белеп булмауга ишарә. *Белгәнең – тугыз, белмәгәнең – утыз* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

*БЕЛГӘННЕ* ❖ **БЕЛГӘННЕ СЕЛКЕП САЛУ.** Белгән, ишеткән, күргәнеңне тулысынча сөйләп бирү. *Ашадык, эчтек, белгәнебезне селкеп салырга ашыкмыйча гына сөйләшкәләп утырдык* (Ф. Хөсни. Картая белмәде картлык).

*БЕЛДЕК* ❖ **БЕЛДЕК САТУ (КҮРСӘТҮ).** Сорамаганда акыл бирү, минбеләмлек күрсәтү. *Шул ук вакыт белдек сату, кирәк-кирәкмәскә артык кызыксыну һәм һәр белгәнеңне сөйләү гадәтләре макталмый* (Н. Исәнбәт. Мәкальләребез турында).

Төрдәше: белек сату.

**БЕЛДЕК ЭШЕҢНЕ, КОЯРБЫЗ (КЫРЫРБЫЗ) ТЕШЕҢНЕ** *шаярт.* Берәр нәрсәне яшерергә тырышып та, асылы беленгәндә әйтелә. *– Шаяртма, дус кеше! Белдем эшеңне, кырырмын тешеңне!* (Н. Фәттах). *Дөбәрис тә аңа ике урындык чыгарып бирде: – Иркенләп ят, апа. – Рәхмәт! – Ә үзе көлә: – Белдек эшеңне, коярбыз тешеңне* (Р. Кәрами. Кая чабасың, тормыш юртагы?).

Төрдәше: сиздем эшеңне, коярмын тешеңне.

*БЕЛДЕКЛӘНГӘН* ❖ **БЕЛДЕКЛӘНГӘН БУЛУ** *мыск., к.* белдек сату. *Янында утырган кеше, белдекләнгән булып, ара-тирә сүз кыстыргалый иде* (Сөйләм).

Төрдәше: белдек сату (күрсәтү).

*БЕЛДЕКЛЕ* ❖ **БЕЛДЕКЛЕ КЕШЕ.** 1. Тирән белемле, күпне күргән кеше. *Кием әзерләргә кирәк икән, музейга барасың, элекке спектакльләрнең җиһазын күздән кичерәсең, белдекле кешеләр белән киңәшәсең* (Т. Әйди. Хезмәте – сәхнә күрке). *Берәр белдекле кеше белән гәпләшеп алу – укучыларыбыз исеменнән киңәш-табыш итү ихтыяҗы туды* (Р. Юныс. Татар гаме).

2. *күч.* Минбеләмлек күрсәтергә яратучы кеше. *– Акыл сатма. Техникасыз заманда мин кулдан бораулап йөргәндә, син әле атаң башында булгансыңдыр. Мин ничек әйтсәм – шулай эшләгез. Мәдияр белдекле кешенең күңеле кителмәсен, өйрәтсен дигән алымга күчте* (К. Кәримов. Сакау күке). *– Укымышлы кеше бетсә авылда, иң белдекле кеше хатын-кыд булып кала икән ул* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).

*БЕЛДЕМ* ❖ **БЕЛДЕМ, КОЛАГЫМА ЭЛДЕМ, БЕРСЕННӘН КЕРДЕ, БЕРСЕННӘН ЧЫГЫП КИТТЕ.** Сүзне тыңлаган кебек булса да, игътибар итмәү. «Белдеңме?» дип кат-кат сораганга җавап. *Белдем инде, белдем, колагыма элдем, берсеннән керде, берсеннән чыгып китте* (Сөйләм).

Төрдәше: белдем, танавыма элдем; бер колагымнан керде, икенчесеннән чыкты.

**БЕЛДЕМ, ТАНАВЫМА ЭЛДЕМ** *диал., мыск. к.* белдем, колагыма элдем, берсеннән керде, берсеннән чыгып китте. *Ишетмәде дип уйлама: белдем, танавыма элдем* (Сөйләм).

*БЕЛЕК* ❖ **БЕЛЕК САТУ** *к.* белдек сату (күрсәтү). *Белек сата бүтәнгә – шаккатарлык* (М. Сабитов. Татар йоклый).

Төрдәше: белдек сату (күрсәтү).

*БЕЛЕКЛЕСЕН* ❖ **БЕЛЕКЛЕСЕН БЕЛЕКЛЕ ДӘ, БОРЫН АСТЫҢ ҖЕ(И)ЛЕКЛЕ.** Белеме сай булса да, белек сатарга яратучы турында. *– Мин үзем дә белекле. – Белеклесен белекле дә, борын астың җелекле* (Ай колакланса, ни була?).

*БЕЛЕМ* ❖ **БЕЛЕМ КАПЧЫГЫ** *к.* аяклы тарих. *[Әссар] Нажилә – дыңгычлап тутырылган белем капчыгы* (Ю. Әминов. Очрашырбыз, Гөлсылу).

Төрдәше: аяклы тарих һ.б.

**БЕЛЕМ КОЛАКТА БУЛМАУ.** *Хисмәтнең белем колакта түгел иде, әмма да Сабирның һәр сүзен аңа элеп утырды* (Ф. Яхин. Бакыр бозау артыннан).

**БЕЛЕМ КҮТӘРҮ.** Үзеңне яңа, өстәмә белем белән баету. *Мәдрәсәләрдә белем күтәрү*

*белән беррәттән, ул сезонлы эшләрдә катнаша* (М. Мәһдиев. Мәҗит Гафури). *Белемегезне ничек күтәрәсез, Зөлфия?* (Б. Камалов. Күңел ярасы).

**БЕЛЕМ ТУБАЛЫ ЯРТЫЛАШ.** Белем дәрәҗәсе дә җитәрлек булмау. – *Белем тубалың да яртылаш кына бит әле* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

*БЕЛЕН* ❖ **БЕЛЕН КАБЫП ЯШӘҮ.** Мул тормышта яшәү. *Һәм Шакир абзаң «белен кабып» кына яши башлады* (Р. Төхфәтуллин. Авылдашым Нәби).

Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

**БЕЛЕН УРЫНЫНА ӨЛГЕРТЕП (ПЕШЕРЕП) ТОРУ.** Нәрсәне булса да (мәс., язмалар, эшләнмәләр һ.б.) көне-сәгате белән бик тиз әзерләү. *Ул чакта бизнес-планнарны белен урынына пешереп кенә торды Даниф* (М. Маликова. Өермә).

**БЕЛЕН ЯУГАН КӨННЕ** *шаярт.* Үткәндә булган вакыйганың көнен төгәл белмәгәндә, шаяртып әйтелә. *Кайчан, кайчан дип теңкәгә тидең инде, кайчан булсын – белен яуган көнне* (Сөйләм).

**БЕЛЕН ЯУГАН КӨННЕ ТУГАН.** 1. Бәхетле булып туу. *Безнең җизни белен яуган көнне туган, ахрысы, теләгән һәр нәрсәсе тормышка ашып тора* (Сөйләм).

Төрдәше: анадан күлмәкле килеш туу һ.б.

2. Туган көнен белмәү. *Кызык малай иде ул: туган көнен сорагач та, «мин белен яуган көнне туганмын» дип кенә җавап бирә иде* (Сөйләм).

*БЕЛЕННЕ* ❖ **БЕЛЕННЕ БЕЛЕП ИЗҮ** *к.* авызга ия булу 2. *Фатыймага карап: – Ә син, килен, үтә мәюс. Беленеңне белеп из, яме* (Х. Хәйруллин. Ургыл).

Төрләше: авызга ия булу 2 һ.б.

*БЕЛЕП* ❖ **БЕЛЕП БУЛМЫЙ ӘЛЕ.** «Бәлки, алай да түгелдер» мәгънәсендә. *Егет әйтә: – Әллә ул ашар, әллә мин аның башына җитәрмен, анысын белеп булмый әле, ди* (Татар хал. әкиятләре). *Иртәгесен нәрсә югалтасын / Белеп булмый әле бүген дә* (Ф. Зыятдинова. Ник шулхәтле күп соң югалтулар).

**БЕЛЕП БУЛМЫЙ ТАГЫН.** «Икенче төрле булуы да ихтимал» мәгънәсендә. – *Хәер, белеп булмый тагын: ирләр кайсы вакытта бик көлке нәрсәдән дә көлмиләр алар... – диде* (Ф. Әмирхан. Хәят). *Белеп булмый менә кемнәр алар, / Белеп булмый тагын, кирәге чыгуы бар* (matbugat.ru).

**БЕЛЕП ӨРӘСЕҢ, ЭТ БУЛСАҢ, УРАМНАН КЕРМӘССЕҢ** *мыск.* Сөйләгәнен белеп сөйләсә дә, артык күп сөйләүчегә (лыгырдавыкка) карата. – *Син белеп өрәсең, малай, валлаһи дим, эт булсаң, урамнан кермәссең* (Сөйләм).

**БЕЛЕП СУКАЛЫЙ.** «Эшне белеп, төпле итеп сөйли» мәгънәсендә. *Әби тормышны белеп сукалый иде. Бабай кыенрак хәлдә калды* (Ф. Яхин. Август ае). *Булмәдәгеләр, Равилне башта әрләсәләр дә, соңыннан сүрелделәр. Белеп сукалый мөртәт, диделәр* (Г. Мөхәммәтшин. Йөрәктәге эзләр).

*БЕЛЕР-БЕЛМӘС* ❖ **БЕЛЕР-БЕЛМӘС КӨЙГӘ ӘЙТҮ (СӨЙЛӘҮ).** Ахырына кадәр, төпле итеп белмичә. *Белер-белмәс көйгә сөйләмә сәнә, гөнаһысын кая куярсың* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз чайкау 1 һ.б.

*БЕЛЕШ* ❖ **БЕЛЕШ АЮ ТАЛАГАН ТӨСЛЕ.** Тузган, таланган әйбер, кием-салым хакында. *Нәрсә булды сиңа, киемнәрең белеш аю талаган төсле булган?* (Сөйләм).

*БЕЛЕШЛЕК* ❖ **БЕЛЕШЛЕК ҖЕБЕ ӨЗЕЛҮ.** Танышлык, әшнәлек мөнәсәбәтләре бетү. *Шактый түздем мин аңа, төрле җирдә, теләсә кемгә гайбәт сөйли башлагач, белешлек җебен өзәргә туры килде* (Сөйләм).

*БЕЛМӘГӘН* ❖ **БЕЛМӘГӘН КАЯ.** Бик яхшы белгәнлеккә ишарә. – *Һи-һи, аны да белмәскә! Белмәгән кая, бик белдем, Морзаттин туган* (Г. Мөхәммәтшин. Сер итеп кенә...). – *Белерсең анысы, белмәгән кая, тик миңа да синең ничекләр итеп әнкәң белән кире поездга утырып китүеңне белеп калу кирәк, – дип, эченнән генә уйлады хатын* (Н. Гыйматдинова. Елан).

**БЕЛМӘГӘН НӘРСӘСЕ ЮК.** Барын да белүче, бар һөнәргә дә оста. *Аны тыңласаң, баһадир, гел менә хикмәт инде, колакларың үрә торыр. Билләһи дим, белмәгән нәрсәсе юктыр*

(М. Хәбибуллин. Илчегә үлем юк). – *И акыллы, и булган, и башлы, белмәгән нәрсәсе юк, эшләмәгән эше юк, – дип, авыл хатыннарын таң калдырды* (Ф. Садриев. Адәм әүлиясы).

**БЕЛМӘГӘН ЭШЕҢ ЮК, КИНӘНДЕРГӘН ТӨШЕҢ ЮК.** Күп нәрсәне өстән-өстән генә, аннан-моннан ишетеп кенә белә, ә осталыгын күрсәтерлек урыны юк. – *Белмәгән эшең юк, кинәндергән төшең юк дисәм, ничек инде? Аштан-ашка йөрисең дә, әллә кайда гына төшереп алырга да өлгерәсең үзең* (Ә. Гаффар. Дәрья башы).

*БЕЛМӘГӘНГӘ* ❖ **БЕЛМӘГӘНГӘ САЛЫШУ.** Белсә дә, үзен бернәрсә дә белми итеп күрсәтергә тырышу. *Тик күз йомасың, белмәгәнгә салышасың! Ничек оятың җитә?* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). – *Тегермән суындагы җен хакында белмәгәнгә салышып тормале, Рәхилә апа* (Г. Гыйльманов. Сагышың булса, суга сал).

Төрдәше: белмәмешкә салыну; күрмәмешкә салыну.

*БЕЛМӘМЕШКӘ* ❖ **БЕЛМӘМЕШКӘ САЛЫНУ** *к.* белмәгәнгә салышу. *Зөһрә апай башта белмәмешкә салынды да : «Нәфисә матур кыз, андыйларга һәрбер егет «җаным, бәгърем, сине яратам», – ди башлый* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Ашарга кайтышлый, белмәмешкә салынып, керосин, май исләре бөркелеп торган машиналар бүлегенең ишеген ачты* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

Төрдәше: белмәгәнгә салышу һ.б.

*БЕЛМӘССЕҢ* ❖ **БЕЛМӘССЕҢ ТАГЫ.** «Икенче төрле ихтималы да бар, өзеп кенә әйтеп булмый» мәгънәсендә (ягъни белүе читен). *Белмәссең тагы, ихтимал, сезнең мондагы үрдәкләр, сызгырып җибәрүгә, аучының кулына килеп куна торганнардыр* (М. Шабаев). *Шулай да белмәссең тагы. Тәвәккәлләп, каршыдагы ярым ачык ишеккә башны тыктым* (Р. Кәрами. Йомыш).

*БЕЛМИ* ❖ **БЕЛМИ ӘЙТМӘС.** Кеше сүзенә сылтама ясаганда, аның дәрәҗәле һәм ышанычлы икәненә басым ясау. *Сафа хәзрәт, Бохарадан укып, мөдәррис булып кайткан кеше, белми әйтмәс, мин беркөнне сораган идем: «Һич ярый торган эш түгел, чеп-чи харам», – диде* (Г. Камал. Безнең шәһәрнең серләре). *Хак булса, анда быел бер адәмне суеп салганнар, ди. Хактыр инде, халык белми әйтмәс* (В. Имамов. Тозлы яра).

*БЕЛМИМ* ❖ **БЕЛМИМ ТАГЫ (ШУЛ).** Дөрес булуына ышанып белмәгәндә әйтелә. *Зыя аның кулларыннан тотты да: – Белмим шул, Мәрьям... Кем артыннан гына җибәрсәм дә, уңайсызлыклар чыгарга мөмкин бит...* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). – *Кешегә салынып яшәгәнче... Белмим тагы... Юк, син мине бөтенләй кызганмыйсың* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

*БЕЛСӘҢ* ❖ **БЕЛСӘҢ (БЕЛСӘГЕЗ) ИДЕ <ӘГӘР>.** «Хәлне аңласаң (аңлый алсаң) иде» мәгънәсендә. *Их, егетләр, белсәгез иде сез шул чактагы әрнүне* (А. Шамов. Кыз урлау). *Әтием, әтекәем, белсәң иде сине ничекләр сагынып яшәгәнемне?* (А. Әхмәтгалиева. Минем әтинең кызы).

*БЕР* ❖ **БЕР АВЫЗ<ДА> БУЛУ.** Бер сүздә булу. – *Инде кырык вәзирнең барчасы бер авызда булып, бу угланны синең кулыңнан алып, аңа куәт бирмәк теләрләр* (К. Насыйри). *[Ильяс] Ул, мин әйтәм, коммуначылар белән бер авызда булгандыр, юкса монда йөгермәс иде* (Т. Гыйззәт).

**БЕР АВЫЗ СҮЗ.** 1. Бернichә генә сүз, нәрсә булса да. *Кешеләр аңа туры карарга уңайсызландылар, ул үзе беркем белән бер авыз сүз сөйләшмәде* (Ә. Еники. Саз чәчәге).

2. Бернәрсә дә. *Юрган астында бала шикелле сизелер-сизелмәс кенә яткан бу каенана дигән сап-сары йөзле карчыкка аның нидер әйтәсе дә, кайгыртып нидер сорыйсы да килде, ләкин гөнаһ шомлыгына каршы, тел юк – карчык бер кәлимә русча, ә килен бер авыз башкортча белми иде* (Ә. Еники. Әйтелмәгән васыять). *Кайтыр юлда Илһам хан бер авыз сүз катмады* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).

**БЕР АВЫЗ СҮЗ БЕЛМӘҮ.** Кайсы булса да бер телдә гомумән сөйләшә белмәү. *Әкрәм урысча бер авыз сүз белми иде* (М. Галәү. Болганчык еллар). *Ана телендә бер авыз сүз белмәгән Танясын, Женясын өстерәп, әтисе янына кайтсынмыни инде ул...* (Л. Шәех. Бал бабай).

**БЕР АВЫЗ СҮЗ ИШЕТМӘҮ.** Бернәрсә дә ишетмәү, беркем бернәрсә дә сөйләмәү. *Тегендә дә*

*үзебезчә бер авыз сүз ишетергә зарыгып бетәм, малай, ди* (Р. Төхфәтуллин).

**БЕР АВЫЗ СҮЗ СӨЙЛӘШМӘҮ (ӘЙТМӘҮ; ДӘШМӘҮ).** Эндәшми, сөйләшми тору. *Узган ел Сабантуйда бер авыз сүз сөйләшеп булмады – шул күрше егете күзәтте* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала). *Старостаның күзләре акайды, тыны кысылып, бер авыз сүз әйтә алмыйча, арт ягына китереп типмәгәйләре дигәндәй, курка-курка, түбәнгә таба чигенә башлады* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**БЕР АВЫЗГА КИЛҮ.** Килешү, уртак тел табу. *Чекага ревком тәкъдиме белән урнашты урнашуын, тик суллар белән болай урамда әҗегөҗе килеп торгач, белмәссең, бер авызга килеп кыймылдаулары да бик мөмкин* (Т. Әйди. Елан угы).

**БЕР АВЫЗДА ТОРУ.** Барысы да бергә, бер үк вакытта җавап бирү (сорау, соклану һ.б.). *Авыл советы председателенең газиз әткәсе дөнья куйгач, яңа зиратның мәңгелек беренче кунагы, мөгаен, ул булыр дип торганнар иде, агайэнеләр, туганнар, кардәш-ырулар, җыелып, бер сүздә, бер авызда торып, председательне дә җиңделәр* (А. Гыйләҗев. Әтәч менгән читәнгә).
Төрдәше: бер авыздан; бер тавыштан.

**БЕР АВЫЗДАН.** 1. *к.* бер авызда тору. *Бер авыздан бөйлә фөрьяд кыйлдылар: / «Мәрхәмәт ит, и Карахмәт, безгә син, / Безне коткар, из Диюнең измәсен* (Г. Тукай. Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш). *Солдатның Гарифны укымышлыгы белән мактаулары аркасында, бер авыздан аны артельщик итеп сайлаганнар иде* (Ш. Камал. Акчарлаклар).
Төрдәше: бер авызда тору һ.б.

2. Беркем дә каршы булмыйча, барысы да бер булып. *Галимовның яңа хөкүмәтне танырга дигән тәкъдиме, Гайфуллин битараф калган хәлдә, бер авыздан кире кагылган. «Халык власте», «демократия власте», «учредительное собрание» дигән сүзләрне, туксан тугыз төрле уңайга әйләндереп-тулгандырып, чүбек урынына чәйнәкләп бетерәләр* (Ш. Камал. Таң атканда). *Балык дигәч, малайлар бер авыздан Кондызлы күл ягына тарталар* (Г. Ибраһимов. Алмачуар).
Төрдәше: бер тавыштан.

**БЕР АВЫЗЛАР.** Бергә эш итү, бер үк нәрсәне сөйләү. *Алар мишәрне, татарны яманлауда икесе бөтенләй бер авызлар иде* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр).
Төрдәше: аркага арка куеп <яшәү> һ.б.

**БЕР АВЫЗСЫЗ.** Бер сүз дә каршы дәшмичә, бер каршылыксыз. *Мин дә бер авызсыз аңа биреп җибәргән булыр идем* (Сөйләм).
Төрдәше: бер сүзсез.

**БЕР АВЫЗЫНА АЛСА, <ҺИЧ> ТӨШЕРМИ (КУЯ БЕЛМИ).** Һәрчак бер нәрсә турында сөйләнеп, мыгырданып йөрүче турында. *Минем ул урамда тууыма ни булган, бер авызыңа алсаң, һич төшермисең* (Сөйләм).
Төрдәше: авызына алды инде, өзмәс тә куймас һ.б.

**БЕР АВЫЗЫҢ ТЫЯ АЛМАСАҢ, ҖЫЯ АЛМАССЫҢ ЕЛ БУЕ.** Уйламыйча әйтелгән сүзнең нәтиҗәсе бик озакка сузылу хакында. *– Икенче юлы син уйлабрак сөйлән: бер авызыңны тыя алмасаң, җыя алмассың ел буе* (Сөйләм).

**БЕР АВЫЛДАН БУЛУ.** Тарафдар булу. *Анналары иңемә кулын салды: – Син безнең авылдан икән... Хиссез кешеләрне сөймим, – диде* (М. Галиев). *Ярар, бөтенебез бер авылдан булыйк. Ярар, бөтен Рәсәй күләмендә барган «милли геноцид»ка каршы чыга алмасыннар, ди* (matbugat.ru).

**БЕР АГАЧНЫҢ ҖИМЕШЛӘРЕ.** 1. Тышкы кыяфәтләренең охшашлыгына нигезләнеп, аларның туган булуларына ишарә итү. *Кыскача гына әйткәндә, бу милләтләр һәммәсе дә бер агач җимешләре* (milli mejlis.blogspot.com).

2. Холыклары, үзенчәлекләре охшашлыгына ишарә итү. *Алай да, евразиячелек, интернационализм һәм космополитизм – бер үк агачның җимешләре түгелме икән?* («Татарстан яшьләре» газ.). *Легионерлар, әсирләр, икенче, өченче тапкыр камалганнар – болар һәммәсе дә бер агач җимешләре ләбаса!* («Казан утлары» ж.).

**БЕР АДЫМ.** 1. Бик якын, янәшәдә генә. *Мстиславның мондый тәкәбберлегә болай да ярсыган үгезне кызыл чүпрәк күрсәтеп котыртуга тиң бер адым иде* (В. Имамов. Утлы дала).

*Мәхәббәттән нәфрәткә бер адым, диләр. Дөрес икән* (Г. Гыйльманов. Албастылар).

Төрдәше: арасы таяк ташлам һ.б.

2. Аз гына, чак кына. *Кыскасы, кардионевроз, миокардит, күкрәк бакасы, стенокардиягә бер адым калган булган* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Аларны да, үземне дә бәхетле итү өчен, шушы бер адым, нибары бер адым гына кирәк түгелме соң?*(А. Әхмәтгалиева. Минем этинең кызы).

**БЕР АДЫМ АЛГА, ИКЕ (БИШ) АДЫМ АРТКА.** Файдалы, яхшы эш эшлибез дип, ялгыш хаталану. *Чөнки Программадан башка бер адым алга, ике адым артка килеп чыгуы мөмкин* (Р. Вәлиев. Дөнья гаме). *Бер адым алга атласак, ике адым артка чигенәбез, яхшы фикерләр, киңәшләр арасыннан кирәген сайлый белмибез* (М. Миначев. Авылларга барган идем).

**БЕР АДЫМНАН.** Сафка тезелеп, бердәм барган кебек фикердәш булу. *Әүвәле Гали Гәрәевич төркеме белән бер адымнан атласа, аларның фикерләрен хуплап, сүзләрен күтәреп кабул итсә, хәтта мактап та куйгаласа, инде хәзер Наил Фатыйховичны тулысынча диярлек яклау ягына басты* (Ф. Яхин. Көзге яңгырга кадәр).

Төрдәше: бер аякка (аяктан) басу (атлау); бер аякка басып бару; бер аякка (аяктан) йөрү.

**БЕР АКЧА.** 1. Кыйммәте булмаган яки мөһимсез, бернәрсәгә дә ярамый торган нәрсә. *Бер акча торган товарлар киләсе елда кыйммәтрәк булачак* («Darelfønyn» газ.).

2. *иск.* Бик арзан, кыйммәт түгел. *Әстерханда сыер бер акча, килә-килә меӊ акча* (К. Насыйри). *Чатта витамин суы. Таза булыйм дисәң, рәхим ит: бөтен бәләсе бер акча* (А. Шамов. Фронт һәм тыл хатлары).

Төрдәше: базары бер тиен һ.б. (ике маддә өчен дә).

3. Акча белән генә. *Бер акча белән барырмын. Сине үзеңне вобла белән генә түгел, осетрина белән сыйлармын* (Һ. Такташ).

4. Барысы да, тулысынча. *Бу вакытта акча каян булсын? ...Кергән бер акча бетеп тора!* (М. Гафури).

5. *гади с.*Ун сумлык акча. *Унлык – бер акча, йөз сум – бер багана. Ике йөз дә егерме сум дип әйтәсе түгел – ике багана, ике казык* (М. Мәһдиев. Ахири).

**БЕР АКЫЛ КИЛҮ.** Башка берәр уй килү, әмәлен табу. *Бармаклары белән туфракны казыштырып уйланып йөри торгач, аның башына бер акыл килде* (Г. Бәширов. Намус). *Тукта, чү! Тагы бер акыл килеп төште бит әле башка* (Ф. Хөсни. Язмыш шуклыгы).

**БЕР АЛАЙ, БЕР БОЛАЙ.** Төрлечә, төрле рәвештә алмашынып тору. *Әти авырган чакта гел безгә килеп йөргән кара шәлле карчык та түр башына менеп утырган,<...> чыбык шикелле бармаклары белән җепкә тезгән төймәләрне бер алай, бер болай тарта* (Н. Дәүли. Язмышка юл). *Каеннар торалар баш иеп гел шулай, / Болытлар артыннан кояш та күренеп, / Җил белән йөргәндәй бер алай, бер болай* (Ф. Яхин).

**БЕР АЛГА, БЕР АРТКА БИРҮ (ТАРТТЫРУ; ЭТҮ).** Хәрәкәт тукталганда төрлечә кузгаткалау. *Аны ниндидер аулак урыннарга кертеп, бер алга, бер артка тарттыралар* (Н. Гариф. Мин сезнең арада яшәдем). *Һәм шулай итте дә Тимергали карт: танкны бер алга, бер артка биреп, тәүдә гусеницаны бәйләгән тросларны өздерде, аннан урынында гына бөтерелеп, постаментны җимерергә тотынды* (Ә. Әминов. Танкист).

**БЕР АЛГА (АЛДЫНА), БЕР (БИШ) АРТКА (АРТЫНА) КАРАУ** *к.* абай булу. *Бер артка, бер алга карап ала торган вакыт* («Акчарлак» газ.). *Барысы да ишеккә ташландылар – мине чак этәреп төшермәделәр. Сузылыпсузылып, бер алга, бер артка карадылар* (Ә. Еники. Без дә солдатлар идек).

Төрдәше: абай булу һ.б.

**БЕР АЛГА (АЛДЫНА), БЕР (БИШ) АРТКА (АРТЫНА) ТӨШҮ** *к.* авызга бал да май булып керү. *Журналистлар ишек төбен камап алганнар, бер алга, бер артка төшәләр* (Д. Салихов. Таш сандык).

Төрдәше: авызга бал да май булып керү һ.б.

**БЕР АЛГА, ЙӨЗ АРТКА ТӨШҮ** *к.* авызга бал да май булып керү. *Бер алга, йөз артка төштеләр, башын әйләндерепме әйләндерделәр* (Д. Булатова. Чынаяк).

Төрдәше: авызга бал да май булып керү һ.б.

**БЕР АЛДЫН, БЕР (БИШ) АРТЫН КҮРСӘТҮ** *эвф.* Тормышның гел үзгәреп торуы хакында.

*Әле иркәли ул сине, әле яңаклап ташлый, бер көлдерә, бер елата, бер алдын күрсәтсә, биш артын күрсәтә* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Дөнья бу! Исләрең китмәсен – / Күрсәтә бер алдын,бер артын* (Ә. Рәшит. Язмыш җилләре).

Төрдәше: бер алдын күрсәтсә, биш артын күрсәтә; бүген алдын, иртәгә артын күрсәтә.

**БЕР АЛДЫН КҮРСӘТСӘ, БИШ АРТЫН КҮРСӘТӘ** *к.* бер алдын, бер (биш) артын күрсәтү. *Бер алдын күрсәтсә, биш артын күрсәтеп, гел айкалып кына тора дөньялары* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: бер алдын, бер (биш) артын күрсәтү һ.б.

**БЕР АЛДЫНА (АЛГА), БЕР (БИШ) АРТЫНА (АРТКА) ТӨШҮ (ЧЫГУ).** Бөтерелеп, сырпаланып йөрү, ялагайлану; *шулай ук к.* авызга бал да май булып керү. *Мәрьямбикә, «ай билем, һай гәүдәм» дип өзмәс зарланган карчык, керүченең бер алдына, биш артына төшеп, бөгеләсыгыла сәламләде, шуннан соң гына кунак белән таныштырырга булды* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Урыныннан торып, капчыгын җыештырды, яулыкларын, күлмәкләрен рәтләде, үзе, дугага килгән кигәвендәй, Улибаеваның бер алдына, биш артына чыкты* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

Төрдәше: авызга бал да май булып керү һ.б.

**БЕР АЛЛАГА МӘГЪЛҮМ** *к.* Алла белә (белер). *Дустының бераз тынычлануын, үзе белән килешүен күреп, Исмәгыйль сүзен дәвам итте: – Кальбебез бер Аллага мәгълүм бит* (С. Зыялы. Кара таплы бизәк).

Төрдәше: Алла белә (белер) һ.б.

**БЕР АЛМАГАЧ БОТАГЫ.** Бертуганнар булуга ишарә. *Шакирның энесе генә ләбаса. Бер алмагач ботагы ич алар* (Н. Гыйматдинова. Ачкыч).

**БЕР АЛМАГАЧТАН БУЛУ.** Кайсыбер яклары яки нәрсә беләндер бер-берсенә якын булу. – *Без икебез дә бер алмагачтан икәнбез, – диде* (Г. Кутуй. Тапшырылмаган хатлар).

**БЕР АПАЕМ, ДИ, БЕР ӘПӘЕМ, ДИ.** Үзеңә ничек кирәк булса, шундый мөнәсәбәттә булу. *Аңлап бетереп буламыни андый кешене: бер апаем, ди, бер әпәем, ди* (Сөйләм).

**БЕР АПАРА, БЕР КАМЫР – БАРЫСЫ ДА БЕР ТАМЫР.** Бөтенесе бер нәселдән; бер уйдагы, бериш кешеләр. *Күрмисеңмени, алар бер апара, бер камыр – барысы да бер тамыр – бервакытта да берсен берсе әшәкеләмәс* (Сөйләм).

**БЕР АРТЫНА, БЕР (БИШ) АЛДЫНА ТӨШҮ (ЧЫГУ)** *к.* авызга бал да май булып керү. *Эше ашыгычтыр, синең белән сөйләшәсе килеп тормас. Ә син бер артына, биш алдына төшәсең* (А. Расих. Ишан оныгы).

Төрдәше: авызга бал да май булып керү һ.б.

**БЕР АТКА ИКЕ ЙӨГӘН САЛМЫЙЛАР (КИГЕРМИЛӘР).** Берәрсенә үз эшен эшләү өстенә яңа мәшәкать йөкләү.– *Барыбер дә, барыбер түгел дә, атам. Бер атка ике йөгән кигермиләр* (М. Хәбибуллин. Атилла). *Бер атка ике йөгән кигермиләр. Бер атны гына туйдырырлык рәтләре бар иде аларның* (dereksiz.org).

Төрдәше: бер атка ике камыт.

**БЕР АТКА ИКЕ КАМЫТ** *к.* бер атка ике йөгән салмыйлар (кигермиләр). – *Артыгы булмас әле, әйеме? – Ай-йи, тик бер атка ике камут киермиляр...* (К. Тимбикова. Кышкы былбыллар). – *Старосталыкка бармый студент, бер атка ике камыт киермиләр, аның инде шөгыле бар – безгә романнар сөйләү* (Г. Тавлин. Афәт).

Төрдәше: бер атка ике йөгән салмыйлар (кигермиләр).

**БЕР АТКАНДА (АТУДА) ИКЕ (КУШ) КУЯН АЛУ.** Бер эшне үтәп, берничә төрле файда күрү. *Мин бер атуда ике куянны алмак булам: бияне дә сакларга, балык та тотарга* (Г. Ибраһимов. Алмачуар). *Ул киерелеп иснәде һәм бер атуда ике, юк, өч куян алачагы, аларның да ниндиләре кулга төшәчәге күз алдына килүгә, йодрыгы белән бодай көшеленә сугып алды* (Ф. Латыйфи).

Төрдәше: акмаса да таму (тамчылау) һ.б.

**БЕР АТЛАГАЧ, БИШ СӨРТЕНҮ.** Авыр йөк күтәреп бару яки нәрсәдәндер уңайсызлану. *Атлый, көянтәләнгән, баш түбән иелгән, бер атлагач, биш сөртенә* (А. Гыйләҗев).

**БЕР АТЛАП, ИКЕ ЯЛ ИТҮ.** Ялкаулану яки хәлсезлектән аяк атлавы авыраю. *Бер атлыйлар да ике ял итәләр, бу әле көз, язга таба ни булыр?..* (А. Гыйләҗев. Язгы кәрваннар).

**БЕР АТУДА ИКЕ КУЯНГА ТИДЕРҮ** *к.* бер атканда (атуда) ике (куш) куян алу. *Әсма җыңгинең барыннан да элек үз исәбе бар иде: Шәкертҗан Әнүзәгә өйләнә калса, ул бер атуда ике куянга тигезәчәк: каенесен кәләшле дә, өйле дә итәчәк* <...> (Х. Сарьян). *Шулай итеп, үз Альбертын яңача киендерүе белән Рудольф бер атуда ике куянга тидерә алачак!* (Р. Вәли. Шөһрәт).

Төрдәше: акмаса да таму (тамчылау) һ.б.

**БЕР АШ ПЕШЕРЕМЕ ВАКЫТ.** Ике сәгать чамасы вакыт. *Абзый бер аш пешереме вакыт яткандыр, ушым китте, ди* (Х. Кәрим).

**БЕР АЯГЫ БЕЛӘН КАБЕРГӘ БАСУ** *к.* авыздан җаны чыгарга тору (җитешү). *Ләкин һаман да бер аягы белән кабергә баскан картның яткан җиреннән һаман кушып, баш булган булып маташуы аның теңкәсенә тиделәр* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми).

Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

**БЕР АЯГЫ ГҮРДӘ (КАБЕРДӘ) <ТОРУ>** *к.* авыздан җаны чыгарга тору (җитешү). *Тәртә эчендә мәктәп баласы, буй җиткән сылу кыз, бер аягы гүрдә торган карт, карчык* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).

Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

**БЕР АЯГЫ ҖИРДӘ, ИКЕНЧЕСЕ (БЕР АЯГЫ) ГҮРДӘ.** 1. Бик карт кеше турында. *[Карт] Үзеңнең бер аягың җирдә, икенче аягың гүрдә, картайган көнеңдә сиңа мәчет түрендә генә утырырга кирәк иде, – ди* (Г. Камал. Хафизалам, иркәм). *[Карчык] Әй, бәбкәм, бер аягың җирдә, икенчесе гүрдә булгач, җәй көне дә суык тия икән* (А. Әхмәт. Үги кыз).

2. *к.* авыздан җаны чыгарга тору (җитешү). *Карт нәнәсенең үзенең бер аягы җирдә, берсе гүрдә, бу кайгыга түзалмыйча, түшәккә егылды* (Х. Мөдәррисова. Бәйге хакы). *Канифә, төп йортка барып, бер аягы җирдә, бер аягы гүрдә бианасына чәй эчереп кайтмакчы булды* (Н. Көбәш. Замана кызы).

Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

**БЕР АЯГЫ КАБЕР ЯК(Г)АСЫНДА БУЛУ (ТОРУ; ЯКАСЫНА БАСУ)** *к.* авыздан җаны чыгарга тору (җитешү). *Бер аягы кабер якасына баскан карттан үч алудан ни файда хәзер. Тәрәзәсенә таш бәреп киткәннәре дә бик җиткән* («Казан утлары» ж.).

Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

**БЕР АЯГЫ МОНДА, БЕРСЕ (ИКЕНЧЕСЕ) АНДА (ТЕГЕНДӘ).** Бик тиз барып кайту. *– Ярый, барсын, бер аягы монда, икенчесе тегендә булсын! – дип ризалашкан Бүре* (Г. Гыйльманов. Хәйләкәр үрдәк).

Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**БЕР АЯГЫН АТЛАГАНЧЫ, ИКЕНЧЕСЕН ЭТ (КОРТ) АШАУ.** Аягын теләр-теләмәс кенә атлаучы, ялкау һәм үшән кеше турында. – *Һи, үшән, салпы колак, изелеп аккан нәрсә! Бер аягыңны атлаганчы, икенче аягыңны эт ашый!* (Г. Бәширов. Сарут). *«Бер аягын атлаганчы, икенчесен эт ашый» дигән әйтемне бала нәкъ шулай күз алдына китерә дә, шуннан... шуннан соң йөгерергә кирәк, үкчәне тешләмәсен!* (Ш. Галиев. Балалар дөньясы).

Төрдәше: бер аякны алып салганчы, икенчесен маэмай тешләү.

**БЕР АЯГЫНДА ИТЕК, БЕРСЕНДӘ ЧИТЕК.** Ишкә иш туры килмәү, иш-куш рәтен белмәү. *Бер аягында итек, берсендә читек булган Мансур безнең арага ялгыш килеп эләккән бугай* (Сөйләм).

Төрдәше: бер аягында <киез> ката, бер аягында чабата; бер аягында киез ката, икенчесендә күн ката ; бер аягында читек, бер аягында күн итек.

**БЕР АЯГЫНДА <КИЕЗ> КАТА, БЕР АЯГЫНДА ЧАБАТА** *к.* бер аягында итек, берсендә читек. *Бер аягында ката, бер аягында чабата, эндәшми дә тик ята* (Такмаза).

Төрдәше: бер аягында итек, берсендә читек һ.б.

**БЕР АЯГЫНДА КИЕЗ КАТА, ИКЕНЧЕСЕНДӘ КҮН КАТА** *к.* бер аягында итек, берсендә читек. *Бер аягында киез ката, икенчесендә күн ката булган кешеләр ничек синең яныңа гына җыелалар?* (Сөйләм).

Төрдәше: бер аягында итек, берсендә читек һ.б.

**БЕР АЯГЫНДА ЧИТЕК, БЕР АЯГЫНДА КҮН ИТЕК** *к.* бер аягында итек, берсендә читек. *Мокыт дисәм, бик ошамаган да, әмма бер аягында читек, бер аягында күн итек икәнлеге сизелеп тора* (Сөйләм).

Төрдәше: бер аягында итек, берсендә читек һ.б.

**БЕР АЯГЫҢ АНДА, БЕРСЕ (ИКЕНЧЕСЕ) МОНДА БУЛСЫН** *к.* «а» дигәнче. – *Ярый, ярый, Баш сакчы, бар, даирәләр сараеннан Тузганак белән теге болгар кызларын алып кил. Бер аягың анда, икенчесе монда булсын!* (А. Гадел. Алтынчәч). – *Бер аягың анда, икенчесе монда булсын, Исмай абый. Үзең беләсең, ул көттергәнне яратмый* (Ф. Зариф. Ак бүре рухы саумы?).

Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**БЕР АЯГЫҢ МОНДА, БЕРСЕ (БЕР АЯГЫҢ; ИКЕНЧЕСЕ) АНДА (ТЕГЕНДӘ) БУЛСЫН** *к.* «а» дигәнче. *Як-ягына каранганда, күзе миңа төште: – Бар әле, Гумәр, йөгереп кенә! Бер аягың монда, икенчесе тегендә!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). – *Шәех Игнәйне, табиб Хәсәнне, баш казый Ишкулны һәм ханбикә Зөбәрҗәтне дәш. Тиз йөре, бер аягың монда, бер аягың анда булсын* (М. Хәбибуллин. Илчегә үлем юк).

Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**БЕР АЯГЫҢ ӨЙДӘ КАЛСЫН** *к.* «а» дигәнче. – *Бар, тиз генә җизнәңне чакырып кайт әле – бер аягың өйдә калсын!* (Сөйләм).

Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**БЕР АЯК БЕЛӘН КАБЕР ЯКАСЫНДА ТОРУ** *к.* авыздан җаны чыгарга тору (җитешү). – *Калса шул инде бер аяклары белән кабер якасында торучы, таяксыз да атламаслык карт-коры гына....* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).

Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

**БЕР АЯК МОНДА, ИКЕНЧЕСЕ КАБЕР БУСАГАСЫНДА** *к.* авыздан җаны чыгарга тору (җитешү). *Инде кем әйтмешли, бер аягыбыз монда, икенчесе кабер бусагасында дигәндәй...* (Ә. Гаффар. Бодай бөртеге һәм тегермән ташы).

Төрдәше: авыздан җаны чыгарга тору (җитешү) һ.б.

**БЕР АЯККА (АЯКТАН) БАСУ (АТЛАУ).** Бердәм, бер максат белән; бер фикердә булу. *Баштарак кешедән калыша-калыша эшләсә дә, берничә көннән башкалар белән бер аякка басты* (Г. Сабитов. Сопкада шәфәкъ шәүләсе). *Мылтык төбәп өйрәттеләр / Бер аякка атларга. / Халкын басып, буып торткан / Залимнәрне якларга* (Ф. Давлетбаев. Таныш халәт).

Төрдәше: бер адымнан һ.б.

**БЕР АЯККА БАСЫП БАРУ** *к.* бер адымнан. *Мин дә әле менә бер ул үстерәм, / Үлеп-нитеп калсам, ул калыр. / Октябрьның илле еллыгында / Меңнәр белән басып бер аякка, / Шул мәйданга килеп тукталыр* (Һ. Такташ).

Төрдәше: бер адымнан һ.б.

**БЕР АЯККА (АЯКТАН) ЙӨРҮ** *к.* бер адымнан. *Күптән инде шулай бер аякка йөргән юк* (Һ. Такташ). *Чыңлап аккан ил җырына / Бер аяктан йөрегез* (Г. Кутуй).

Төрдәше: бер адымнан һ.б.

**БЕР АЯКНЫ АЛЫП САЛГАНЧЫ, ИКЕНЧЕСЕН МАЭМАЙ ТЕШЛӘҮ.** Ике аягы да авырткан кеше турында. – *Гел юыртып кына булмый ул, агайне, менә бит, кем әйтмешли, бер аякны алып салганчы, икенчесен маэмай тешли* (М. Хуҗин. Игелек).

Төрдәше: бер аягын атлаганчы, икенчесен эт ашый.

**БЕР АЯКТАН**. 1. Бер үк вакытта. – *Менә шунда баргач, бер аяктан ашлама турында да кайгыртырсың* (М. Хәбибуллин).

2. *к.* бер адымнан. *Барысын да заманга сылтап, аның белән бер аяктан атларга тырышып, дөнья куу белән мавыктымы?* (А. Әхмәтгалиева. Синең өчен яшим). *Фәнни-техник революция казанышларын шигърияләштерү шагыйрьләребезнең заман белән бер аяктан атларга омтылулары турында сөйли* (Т. Галиуллин. Буыннар һәм язмышлар).

**БЕР ӘЙТӘМ, СОҢГЫСЫН ӘЙТӘМ.** Башка әйтмәячәге турында кисәтеп кую. – *Колагыңа киртләп куй, бер әйтәм, соңгысын әйтәм – иртәгә балыкка бармыйбыз* (Сөйләм).

**БЕР ӘЙТТЕ, БЕРӘГӘЙЛЕ ӘЙТТЕ.** Яшеренбатырын түгел, уйлаганын йөзенә карап әйтү. *Бер генә сүз әйтте ул миңа. Әмма берәгәйле итеп әйтте: – Юләр! – диде* (В. Нуруллин. Әгәр син булмасаң). *Әти сүзе бер булыр: бер әйтә – берәгәйле әйтә ул!* (Г. Әдһәм. Әни – апай).

**БЕР ӘЙТТЕМ, УН (БИШ) КАЙТТЫМ.** Кеше алдында урынсыз ычкындырган сүзне кире алу. *Ә юк, болай гына әйтәм лә, бер әйттем, ун кайттым, әйтеп кенә бактым* (Г. Газиз). *Юк ла, син тагын! Шаяртып кына әйтүем! Бер әйттем, биш кайттым* (Г. Бәширов. Кара төндә нур чәчеп...).

**БЕР ӘКӘМӘТ.** Гадәттә булмаган сәер хәл, күренеш, хикмәтле эш. *[Нурый] Хәзер сезгә бер әкәмәт күрсәтәм (торып китә, күбесе, «нәрсә бар?» дип, аптырап калалар)* (А. Алиш. Күршеләр). *Әй тотына кайгыртырга, әй кыштырдый, әй сөйләшә башлый ана каз! Бер әкәмәт инде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**БЕР ӘЛИФ ТӘ ТАНЫМАУ** *к.* әлифне (әлепне; әлефне) таяк дип <тә> белмәү. – *Бер әлиф тә танымаган кешеләрне нигә эшкә алыйм мин!* (Сөйләм).

Төрдәше: әлепне таяк, вауны чукмар дип тә белмәү һ.б.

**БЕР БАКЧА ҖИМЕШЕ.** Бер үк төрле тәрбия алган, бер уйдагы кешеләр. *Без аның Җиһанша хәзрәт, Кисекбаш, Хәмзә бай, Вәли бай кебекләр белән бер бакча җимеше булуын танып алабыз* (М.Х. Хәсәнов һ.б. Татар әдәбияты).

**БЕР <ҮК> БАЛЫК БАШЫ** *к.* авызда бер үк җыр <булу>. *Ничә генә укыма – шул бер үк балык башы авылдашлары, Галәвинең чибәр кордашлары…* (Г. Бәширов. Менә сиңа, мә!). *– Группадашыбыз Нурия әйтмешли: «Иртәнге томат соусында килька, төшке ашка килькалы томат, кичкә томатлы килька». Бер балык башы* (Ф. Латыйфи. Себер хикәяте).

Төрдәше: авызда бер үк җыр <булу> һ.б.

**БЕР <ҮК> БАЛЫК БАШЫН ЧӘЙНӘҮ** *к.* авызда бер үк җыр <булу>. *Иске мунча, яңа таш – һаман шул бер балык башын чәйниләр* (К. Тинчурин. Американ). *Нигә һаман бер балык башын чәйнәргә?* (С. Поварисов. Пәйгамбәр таңы).

Төрдәше: авызда бер үк җыр <булу> һ.б.

**БЕР БАРМАКТА БИЕТҮ.** Буйсындырып, куркытып тору. *[Исмәгыйль] Мин сезнең кадерле киявегез Хәлил кебекләрнең унавын бер бармакта биетәмен, беләсеңме?* (М. Фәйзи. Галиябану).

**БЕР БАСАРГА ӨЧ БАСУ.** 1. Дәртләнеп тору, тыпырчыну, кая басарга белмичә, туктаусыз хәрәкәтләнү. *Поезд килүен көтеп, бер басарга өч басып тора торгач, аякларның арыганын сиздем* (Сөйләм).

Төрдәше: бер басасы җиргә (урынга) биш (мең) басу; бер басасын биш басу.

2. Хәсрәт-кайгыдан адымнарны саташтыру. *Ардым инде, кайда актык мәүкыйфем! / Җилкенәмен, бер басарга өч басам* (Г. Тукай).

**БЕР БАСАСЫ ҖИРГӘ (УРЫНГА) БИШ (МЕҢ) БАСУ** *к.* бер басарга өч басу. *Әле болай утыз яшьтә дә бер басасы урынга биш басып йөри торган иде* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында). *Берсе бөтерчекнең-бөтерчеге, бер басасы урынга биш баса* (М. Әмирханов. Зиннәтулла хәзрәт).

Төрдәше: бер басарга өч басу 1 һ.б.

**БЕР БАСАСЫН БИШ БАСУ** *к.* бер басарга өч басу. *Ул бер басасын биш басып, дәртләнеп атлый иде* (Г. Бәширов. Намус).

Төрдәше: бер басарга өч басу 1 һ.б.

**БЕР БАСУДА ҮСКӘН ТИГӘНӘК.** Бер фикердәге начар кешеләр. *Барысы да – шул бер басуда үскән тигәнәкләр* (Ф. Хөсни). *– Аны алыштыра алмас дип куркасыңмыни? Бер басуда үскән тигәнәк икән болар, – дип хәвефләнде Балҗан* (Т. Әйди. Елан угы).

**БЕР БАСЫП, БЕР АБЫНЫП.** Бер егылып, бер аягына басып; сөрлегә-сөрлегә. *Башкалар да кайсы кайда таралдылар, Насрый, бер басып, бер абынып, Госман карт алачыгына барды* (Ш. Камал. Козгыннар оясында).

**БЕР БАШ.** Үзе генә, ялгыз. – *Син, җырлыйҗырлый, бер башың олы су ягыннан югала таба менә идең…* (А. Гыйләҗев. Язгы кәрваннар). *Бер башың бит синең, бер башың! Йодрык чаклы карчыкка күпме сөт кирәк?* (Ф. Шәфигуллин. Гафу үтенергә).

Төрдәше: бер башы да бер бете; бер башы да бер тамагы (бер үзе); бер башына; үзем дә ике күзем; ялгыз Ярулла.

**БЕР БАШКА АЛДАН КИЛҮ.** Бәйгедә финишка бер ат башы үлчәме кадәр алда килү. *Сабан туе чабышында катнашкан аты бик артка калмаса ярар иде, дип көтеп торганда, ул икенче килгән аттан бер башка алдан килде* (Сөйләм).

**БЕР БАШКА ИКЕ ЯЗМЫШ ЮК.** «Һәр кешенең үз гомере, үз язмышы бар» мәгънәсендә. *«Димәк, язмышым шушы» диде эчтән генә. Нишлисең, бер башка ике язмыш юк* (Ф. Җамалетдинова. Догалы корт).

**БЕР БАШЫ ДА БЕР БЕТЕ.** Бернинди мәшәкате булмаган ялгызак кеше турында. *Бала-чагасы юк, каенана-каената белән тормый. Бер башы да бер бете, дигәндәй. Аларның газизләре әллә кайда башларын салды, ә монда кемнәрнеңдер сөйгәннәре тап-таза кайткан, хатыны янында бөркет кебек йөри* (И. Нәбиуллина. Миләш тәме).

Төрдәше: бер баш һ.б.

**БЕР БАШЫ ДА БЕР ТАМАГЫ (ҮЗЕ)** *к.* бер баш. *Әле болай, ичмаса, бер башың да бер үзең* (Г. Камал).

Төрдәше: бер баш һ.б.

**БЕР БАШЫ КАЯ ДА СЫЯР.** «Ялгызак кеше ятар-торыр җиргә аптырамас» мәгънәсендә. *Авылга, дуслар янына кайтып килим әле, бер башым кая да сыяр* (Сөйләм).

**БЕР БАШЫНА.** Ялгыз гына; мөстәкыйль хәлдә. *Һаман яхшысынмады, кешеләрдән оялды. «Бер башына бер бүлмә сорый», – дип әйтүләреннән курыкты* (Г. Әпсәләмов). *Бер башына өч-дүрт күренекле хезмәт. Сембер губернасында Ленин бабай әтисе заманында һәм ведомствосында «караңгы» татар авылында «Русско-татарская школа» ачу!..* (М. Гайнетдин. Гасырлар мирасы).

**БЕР БАШЫНА УРЫН ТАПМАУ.** Тормышта үз урынын, юлын таба алмау; тыныч кына ята алмау. *Ул шулай үзенең ике бүлмәле фатирында бер башына урын тапмый йөргән арада, Рифләр, килеп җитеп, ишектәге кыңгырау төймәсенә бастылар* (Ф. Яруллин. Рәхмәт яусын!). *– Бер башыңа урын тапмадың тәмам! Һәркайсы чиркәү кадәр ике йортка хуҗа булдың. Ярамады* (Ж. Рәхимов. Өлешемә тигән көмешем).

**БЕР БАШЫҢ ИКЕ БУЛУ.** Өйләнгәч, икәвең өчен дә җаваплылык алу. *Өйләнәсең, бер башың ике була. Ул ара өченчесе дә килеп чыга* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Бу юлы ул Низамның ялгыз түгеллеген, өйләнгән, бер башың ике булган дип, андый-мондый хәл була-нитә калса, иң элек хатынына, туган-тумачаларына авырлык киләсе турында сөйләнде* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!).

**БЕР БӘНДӘ ШУНДА** *кимс.* Оешып җитмәгән кеше турында. *[Илдар] Кем булсын – шәһәр хакимиятенең җир комитетының бер бәндәсе шунда* (Г. Акбар. Могҗиза үлеме). *– Сине кем таптаткан булып чыкты соң инде? – Рaушан атлы бер бәндә шунда, Батулла Басып Уланың классташы* (Ф. Бәллүр. Кем син, Рабит Ора Бит?).

**БЕР БӘРҮДӘ ИКЕ КУЯН** *к.* акмаса да таму (тамчылау). *– Күрдеңме, абзаң бер бәрүдә ике куян алды* (Сөйләм).

Төрдәше: акмаса да таму (тамчылау) һ.б.

**БЕР БӘХЕТЕҢ БУЛМАСА, КЫТАЙГА БАРСАҢ ДА (БАРЫП ТА), ЧӘЙ ЭЧӘ АЛМАССЫҢ.** «Бәхетең булмаса, бернәрсә дә эшләп булмый» мәгънәсендә. *Бер бәхетең булмаса, Кытайга барсаң да чәй эчә алмассың дигәндәй, балачагында бәхетнең ни икәнен белмәгән Илһам бүген хатыны белән бергә бала хәсрәте утында яна* («Безнең гәҗит» газ.).

Төрдәше: бер бәхетең булмаса, чәчең белән җир себерсәң дә табып булмау.

**БЕР БӘХЕТЕҢ БУЛМАСА, ЧӘЧЕҢ БЕЛӘН ҖИР СЕБЕРСӘҢ ДӘ ТАБЫП БУЛМАУ** *к.* бер бәхетең булмаса, Кытайга барсаң да (барып та), чәй эчә алмассың. *Бер бәхетең булмаса, чәчең белән җир себерсәң дә, табып булмый икән аны, – диде ул. – Ирем сугышта башын салды, сыңар канат белән дүрт бала үстердем, әле кызыма да өлеш калганмыни...* (М. Миншин. Канәфер чәчәге).

Төрдәше: бер бәхетең булмаса, Кытайга барсаң да (барып та), чәй эчә алмассың.

**БЕР БЕЗ ГЕНӘ ТҮГЕЛ, ИЛ БЕЛӘН.** Бер сиңа яки миңа гына төшмәгән, ил белән күргән хәл. *Биеккәй тауның башында / Самавыр кайный җил белән; / Җыламачы, җаный, ник җылыйсың? / Бер без генә түгел, ил белән* (Җыр).

**БЕР БЕЗДӘН ГЕНӘ КАЛМАГАН.** «Заманасы, йоласы шундый, безгә дә шулай итәргә кирәк» мәгънәсендә. *Дөньяның үз яшәү законнары бар, аны без генә үзгәртә алмыйбыз. Шулай булгач, бер бездән генә калмаган* (Сөйләм).

**БЕР БИРГӘНГӘ БИРӘ.** «Берәүгә һаман да бирелә дә бирелә» мәгънәсендә. *Рахман рәхим, бер биргәнгә бирә бит Хак Тәгалә: абруйлы ахун да, атаклы вә гүзәл гыйлемле дәмелла да халаеклар икърар иткән шагыйрь дә*

(Ж. Рәхимов. Батырша). – *Бер биргәнгә бирә ул... безнең өченче балабыз да туар...* («Үз семьяңа рәнҗеп булмый» мәзәге).

Төрдәше: биргәнгә бирә <еш (бит)>.

**БЕР БИТЕ АЙ, БЕР БИТЕ КОЯШ (КӨН).** Бик гүзәл, тиңсез матур. *Бер бите ай, бер бите кояш төсле патша кызлары артыннан, алтмыш колачлы ала биягә атланып, янартаулар, зәңгәр диңгезләр кичәсең, бакыр, көмеш сарайларда кунак буласың* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *«Бер бите ай, бер бите көн кебек» сылу кыз Алтынчәч үзен алырга килгән «җәенке битле Жаек буе яубасарына» барырга риза булмый гына түгел, ә туган җирен саклау ниятендә кулына корал тотып, дошманга каршы чыга* (М. Мәһдиев. Мәҗит Гафури).

**БЕР БИШ ТИЕН** *к.* авызда бер үк җыр <булу>. – *Гыйззәтҗан тегеңәр һаман үзенекен сайрый, һаман шул бер биш тиен* (Г. Мөхәммәтшин. Балта остасы).

Төрдәше: авызда бер үк җыр <булу> һ.б.

**БЕР БОЛАЙ, БЕР ТЕГЕЛӘЙ КИТЕРҮ.** Нәрсә эшләргә белмичә, төрле якка боргалау, карау. *Җир өстенә чүгәләгән килеш, кулындагы туфракны бер болай, бер тегеләй китереп, «бүреге белән киңәшергә» тотынды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**БЕР БОРЧА ӨЧЕН БЕР ЮРГАН ЯРУ.** Кечкенә җәфага түзә алмыйча, тагын да кыйммәткәрәк төшкән гамәлләр башкару. *Бер борча өчен юрган ярмыйлар* (Н. Исәнбәт. Балалар фольклоры).

Төрдәше: бет ачуын туннан алу; беткә үч (ачу) итеп, тунны утка (мичкә) ягу (ыргыту); торма ачуын (ачысын) тоздан алу; торма өстенә тоз; тунны утка (мичкә) ягу (ыргыту).

**БЕР БОТАК ОЧЫ КАРДӘШ.** Бик ерак кардәш саналган кеше. *Хәзерге көндә туган-тумачага да саналмаган бик ерак бер ботак очы кардәш иде бугай ул Мәликә апасына* (Л. Хәмидуллин. Кичке шәфәкъ).

**БЕР БӨРТЕК.** 1. Бик кечкенә, аз гына. *Ул чорларда бер бөртек шырпының баш бәясе торган чагы* (А. Хәсәнов. Бүре баласы Чатан). *Хан белән сәрдәрләр үзләренә бер бөртек тә байлык таләп итми* (В. Имамов. Утлы дала).

2. Бер генә. *Гаиләдә бер бөртек бала булганга, аны, бәлки, артык иркәли дә торганнардыр, ләкин укуга һәм белем эстәүгә бирелгән малайны әти-әнисенең назы бозып өлгермәде* <...>. (А. Тимергалин. Карурман аша).

3. Бер нәрсә дә, аз гына да. *Юк, ихлас, бер бөртек үземнән кушмадым* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**БЕР БӨРТЕК КОРЫ ҖЕП КАЛМАУ.** Яңгырда баштанаяк чылану, лычма су булу. *Яңгырны чиләкләп койды диярсең, бер бөртек коры җебем калмады* (Сөйләм).

**БЕР БӨРТЕК СИЗЕЛМӘҮ**. Һич, бөтенләй билгеле булмау. *Аксаганың бер бөртек тә сизелми ичмасам! – дип кычкыра малай, – кайткач, Галимә апа да бер нәрсә дә сизмәс!* (Т. Мөбарәков).

**БЕР БӨРТЕК СҮЗ.** Бер генә сүз. *Суккан саен, аның гәүдәсе калтыранып-калтыранып куя, әмма авызыннан бер бөртек сүз чыкмый* (Ф. Латыйфи. Хыянәт). *Йосыф авызыннан сөенеч катыш көенечтән торган бер бөртек сүз атылып чыкты: – Рәмилә-ә-ә!..* (Г. Гыйльманов. Фәрештә).

**БЕР БӨРТЕК ТӘ.** 1. Бер валчык та. *Гомер, бер бөртек тә чәчелмичә, җыелып бара. Сәүбән үз хәтереннән ни дә булса алып атарга теләсә дә булдыра алмас иде* (Г. Гыйльманов. Оча торган кешеләр).

2. Һич тә, бер дә. – *Алла шаһит, Зөфәр туган, мин сиңа әйтәм, саф дөресен генә әйтәчәкмен. Бер бөртек тә шигең булмасын* (Ә. Еники. Рәшә). *Берәр машина туры килер әле дип чыгып китсә дә, әнә бит, юлда бер бөртек тә җан иясе күренми* (Г. Гыйльманов. Албастылар).

**БЕР БУЙДАН.** 1. Бер рәткә тезелеп киткән. *Урманның бер кисәген койма эченә алып ясалган бу бакчаның карт-карт агачлар белән бер буйдан тезелгән топольләре аңкытып ис чыгаралар* (Ф. Әмирхан. Хәят).

2. Бертуктаусыз, өзлексез рәвештә. *Бүлмәнең икенче ягындагы караватта йоклап яткан Фәйзинең бер буйдан мышнап сулыш алулары тышта әллә кайда зур пычкы белән такта ярган шикелле булып ишетелә* <...> (Ш. Камал). *[Барно] Син, оялмыйча, бер буйдан шул ту-*

*рыда сөйлисең. Бу – мәгънәсезлек* (А. Нәҗми. Алтынай).

3. Нинди булса да башка бер эш белән бергә, берләштереп, бер үк вакытта. *Мине шунда бер буйдан эшемнән алырга да ниятләре юк түгел, Гадел абый урынына килгән секретарь шуны үземә дә сиздереп куйган иде* (В. Нуруллин. Күпер чыкканда).

4. Үзен тиң итеп, бер дәрәҗәдә тоеп (сөйләшү турында). *Аның белән бер буйдан сөйләшкән Җик Мәргән дә хан күзенә күренергә куркып йөри* (М. Хәбибуллин. Илчегә үлем юк).

**БЕР БУЛГАН ДА ШЫР БУЛГАН.** Берәү генә булып та, белемсез яки кай яктандыр җитешсез. *– Бер булган да шыр булган, диләр иде дә* (Б. Камалов. Мәрдән сукмагы).

**БЕР БУЛСА ДА БЕРӘГӘЙЛЕ <БУЛЫР>.** «Күп булмаса да, яхшы булыр» мәгънәсендә. *Җиде бәйрәмгә бер туй булыр. Бер булыр – берәгәйле булыр! Тирә-як дер калтырап торыр...* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Сүзгә Фатыйма карчык катнашып китте: – Бер булса да, берәгәйле ул, ун кешене туйдырырлык* (Г. Гыйльманов. Китек ай).

**БЕР БУЛСЫН, БӘРӘКӘТЛЕ БУЛСЫН.** «Аз булсын, ләкин яхшы булсын» мәгънәсендә. *Белешмә сүзлектә вариантлары да бирелгән: «Бер булсын, бәрәкәтле булсын», «Ике булганчы бер булсын да берәгәйле булсын»* (А. Тимергалин. Сүнмәс ут янында уйда без...).

**БЕР БУЛЫП.** Бердәм рәвештә. *«Бөтенебез бер булып күтәрелдек, прокурорга барып җиттек»* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Барысы да янып, үрсәләнгән ирennәр аерыла алмыйча, тулып ташкан рәхәтлектән ялкынланган йөрәкләр бер булып типте* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

Төрдәше: бер авыздан.

**БЕР БУШЛЫК АРА.** Бушаган ара, тәнәфес вакыты. *Безнең ирекә куймадылар, бер дә бии белмәсәм дә, мин, чыгып, бер-ике тапкыр сикердем дә бер бушлык арада оялып чыгып киттем* (М. Гали).

**БЕР ГЕНӘ <БЕР>.** Һич, бер дә; бер мәртәбә дә. *Очсыз-кырыйсыз дала. Анда бер генә бер агач, бер генә бер куаклык юк* (А. Әхмәт). *Чокыр аша салган агачтан ничә мәртәбә чыктым, бер генә егылганым булмады* (Сөйләм).

Төрдәше: бер генә дә; бер дә <генә>.

**БЕР ГЕНӘ ДӘ.** 1. «Бөтенләй дә, аз гына да юк» мәгънәсендә. *Бер генә дә ялгышмады, бөтен сорауларга дөрес җавап бирде* (Сөйләм).

2. Бервакытта да, һичкайчан да. *Аллага шөкер, егерме ел әбилек итәм, бер генә дә ялгышканым юк* (А. Шамов).

Төрдәше: бер генә <бер>; бер дә <генә>.

**БЕР ГЕНӘ КҮЗӘНӘКТӘН ЯРАЛУ** *мыск.* Кешенең холкында кимчелек булганда, төрттереп әйтелә. *Ул бер генә күзәнәктән яралган, хиссез хатын иде, ахрысы* (Н. Гыйматдинова. Нурулла).

**БЕР ГОМЕР.** «Шатлык, рәхәтлек (канәгатьләнү)» мәгънәсендә. *Ул бабай ике сугышта катнашкан – аның белән сөйләшеп утыру үзе бер гомер* (Сөйләм).

**БЕР ДӘ <ГЕНӘ>** 1. *к.* бер генә дә. *Йә, сезнең җаныгызны бер дә борчымыймыни бу нәрсә?..* (Ә. Еники. Әйтелмәгән васыять). *[Сәфәргали] Юк, ул яклар, Аллага шөкер, бар да бар. Тик менә бер дә күңел ышанмый* (К. Тинчурин. Беренче чәчәкләр).

Төрдәше: бер генә <бер>; бер генә дә.

2. Һич кенә дә («искитәрлеге, таң калырлыгы юк» мәгънәсендә). *Бер көнне остаханәсендә рәсемнәрен карап чыккан идем, бер дә генә искитәрлеген тапмадым* (Сөйләм).

Төрдәше: бер дә харап.

**БЕР ДӘ АТАСЫ-АНАСЫ ЮК.** Сөйләвенең, эшенең рәте-чираты юк. *Кулларын болгыйболгый, әллә нәрсәләр аңлатырга тырышты, ләкин бернәрсә дә аңламадым: сүзләрнең бер дә атасы-анасы юк* (Сөйләм).

Төрдәше: ахмак<лык> сату һ.б.

**БЕР ДӘ АХЫЛДАРЛЫГЫ ЮК.** «Башкалардан аерылып торган бернәрсәсе дә юк» мәгънәсендә. *Яңа фикер чыкмасмы дип, күргәзмәгә барган идем – бер дә ахылдарлыгы юк* (Сөйләм).

Төрдәше: ахмак<лык> сату һ.б.

**БЕР ДӘ АХЫЛДАРЛЫК ТҮГЕЛ** *к.* бер дә ахылдарлыгы юк. *Нанотехнология дип, әллә нәрсәләр куеп бетергәннәр, әмма бер дә ахылдарлык түгел* (Сөйләм).

Төрдәше: ахмак<лык> сату һ.б.

**БЕР ДӘ БЕР.** Бервакыт, көннәрдән бер көн. *<...> син миңа көне буе коршау сугып тора алмассың, бер дә бер арырсың, ә мин сабыр кеше, син арып туктауга, үз туксанымны тукый башлыйм: күбәләгем-түгәрәгем һәм башкалар, һәм башкалар* (Г. Ахунов. Ардуан батыр). *Бер дә бер чакны моның шулай йөрүеннән тәмам туеп бетеп, гарык булып, моны бер дә бер өй чормасындагы җыен ташландык, иске-москы әйберләр арасына – кеше-кара күз карашыннан ераккарак яшереп куйганнар, ди* (Ә. Гаффар. Мылтык).

Төрдәше: бер дә бер заман (көнне).

**БЕР ДӘ-БЕР ДӘ.** Һич кенә дә, бер мәртәбә дә, бер вакытта да. *Моннан соң бер дә-бер дә, һич тә Осланга килмәгез, миңа күренмәгез, Ришат, Ходай өчен, барыгыз, китегез, бер дә-бер дә миңа күренмәгез моннан соң!* (Ф. Әмирхан).

**БЕР ДӘ БЕР ЗАМАН (ВАКЫТ)** *к.* бер дә бер. Билгеле бер вакытта, конкрет чакта. *Бер дә бер заманны карасаммы, күрсәмме? Теге атлар чабышындагы килеп җитәрләре урындагы бер абый үз кулындагы аклы-кара шакмаклы флагын күтәрде дә төшерде, күтәрә дә төшерә барды* (Ә. Гаффар. Энә күзе). *Бер дә бер вакытны дию алтын атына атланып, этен ияртеп, күпергә кайтып җитә* (Энҗе чәчтем – энҗе җыям).

Төрдәше: бер дә бер.

**БЕР ДӘ БЕР КӨННЕ.** Бервакыт, көннәрдән бер көн. *Колхоз атларын имгәткән өчен төрмәгә утыртылган теге Тавык Мортыйны хәтерлисеңме? Шул имгәк бер дә бер көнне колхозыбызга кайтты бит* (Г. Әпсәләмов. Газинур). *Бер дә бер көнне, шул гармунын тотып, урамда уйнап йөргән чагында, бездән өч-дүрт яшькә зуррак Шайтан Вагыйз дигән малай, кая, кубызыңны уйнап карыйм әле, дип, сагыз урынына ябышты бит Рәдифкә* (В. Нуруллин. Күпер чыкканда).

**БЕР ДӘ БУЛМАГАНДА.** Ахыр чиктә, юк дигәндә, һич югы, һич югында. *Бер дә булмаганда күршеңә әйтеп җибәр идең* (Сөйләм).

Төрдәше: бер дә булмагач; бер дә булмаса; һич булмаса (булмаганда); һич югында.

**БЕР ДӘ БУЛМАГАЧ.** Башка чара таба алмагач, бер әмәл дә юк икән. *Аннары бер дә булмагач, халык бик аптыраша башлагач, авылда өшкереп-төкереп йөрүче бер әбинең киңәше белән, авылыбызда бер эчеп үлгән кешенең каберенә кырык бер чиләк су да салып карадык* (М. Гали).

Төрдәше: бер дә булмаганда һ.б.

**БЕР ДӘ БУЛМАСА.** *к.* бер дә булмаганда. *Кар астында калып чыга алмаса, бер дә булмаса моны күрерләр дип, үзе янына озына таяк кадап куйды* (Сөйләм).

Төрдәше: һич булмаса (булмаганда); һич югында.

**БЕР ДӘ ГАЛӘМӘТ <ИНДЕ>.** 1. Тамаша, бөтенләй ят-сәер нәрсә. *Бер дә, бер дә галәмәт инде, җаный. Ул кәрәзле баллар дисеңме, башлы шикәрләр дисеңме* (А. Расих).

2. Гаҗәпләнерлек бернәрсәсе дә юк. *Сөйләп торасың шунда, бер дә галәмәт инде, хәзер һәрбер өйдә бар ул* (Сөйләм).

**БЕР ДӘ ГАҖӘП <НӘРСӘ> ТҮГЕЛ.** Булуы бик мөмкин, бернинди катлаулылыгы юк. *Эшләгән булсаң, белер идең. Минем өчен бер дә гаҗәп түгел* (А. Алиш. Кечкенә тоткын). *Шулай, оча торган тәлинкәләр безнең авыл халкы өчен бер дә гаҗәп нәрсә түгел* (И. Шиһапов. Кунаклар).

**БЕР ДӘ КЕШЕЛЕГЕМ ЮК.** «Кәефем начар, эшкә рәтем юк» мәгънәсендә. *Нәрсәдер бүген бер дә кешелегем юк әле, бераз ятып торыйм* (Сөйләм).

**БЕР <ГЕНӘ> ДӘ КИЛМӘГӘН ҖИРЕ ЮК.** Бар җире дә килешле, бик чибәр. *Төс-баш ягыннан да, әдәп-әхлак ягыннан да, әти-әнисе ягыннан да – ну, менә бер генә дә килмәгән җире юк туташның!* (Ә. Еники. Рәшә). *Чибәр иде ул, шайтан кызы, бер дә килмәгән җире юк иде* (В. Нуруллин. Күпер чыкканда).

**БЕР ДӘ СӨЙЛӘП КИЛЕШТЕРӘ ТОРГАН ТҮГЕЛ.** Матурлыгын сөйләп, тасвир итеп бирә торган хәлдә түгел. *Аның айдай йөзен, сыны-гәүдәсен бер дә сөйләп килештерә торган түгел* (Сөйләм).

**БЕР ДӘ ТӨС ТҮГЕЛ.** Килешә торган, лаек булган түгел. *Бу кыланышлары университет студентына бер дә төс түгел* (Сөйләм).

**БЕР ДӘ ХАРАП** 1. Искиткеч, таң калырлык. *Күмәч шундый тәмле булган, бер дә харап, ашап туйгысыз икән* (Н. Исәнбәт).

2. *к.* бер дә 2. *Көн-төн колхозда, көн-төн колхозда. Аңа карап, бик кинәндерерләр үзеңне, бер дә харап. Ирләрне ирләрчәрәк тыңларлар иде* (Р. Төхфәтуллин).
Төрдәше: бер дә 2 һ.б.

**БЕР ДӘ ХАРАП ИКӘН** *к.* аба<у>, харап икән. – *Мә-ә-ә, – дип алды ул, күкрәген тагы да киерә төшеп, вәкарь белән генә. Бер дә харап икән! Исегез киткән иде...* (Р. Мөхәммәдиев. Ак кыялар турында хыял). *Күңел түренә мәхәббәт дигән сандугач оя корырга ниятләсә, бер дә харап икән ул* (А. Хәсәнов).
Төрдәше: аба<у>, харап икән һ.б.

**БЕР ДӘ ХАРАП ИНДЕ.** Берәрсе белән риза булмау, аңа ышанмау яки канәгать булмауны белдерү өчен кулланыла. *Аркылы салынган бүрәнәдән чыккан, имеш, бер дә харап инде – күзләремне бәйләсәгез дә чыгам мин аннан* (Сөйләм).

**БЕР ДӘ ХӘТӘР** *к.* бер дә 2. *<...> бер дә хәтәр эреләнеп, башын тиешеннән артык күккә күтәреп тотынган ди үсәргә, тотынган ди үсәргә* (Н. Исәнбәт).
Төрдәше: бер дә 2 һ.б.

**БЕР ДӘ ЮК ДИГӘНДӘ.** Һич югында, һич булмаса. *Бер дә юк дигәндә, бер кило алма алып керер идең, ичмасам* (Сөйләм).
Төрдәше: иң юк дигәндә.

**БЕР ДӘ ЮК НӘРСӘ ЮК.** Бар нәрсә дә бар. *Алар былтыр Ушабашына җыенга кайтканнар иде, шунда, салып куйган җирендә бөтилеген онытып калдырган. Эчендә бер дә юк нәрсә юк, ди* (Г. Камал).

**БЕР ДӘ ЮККА (ЮКТАН).** Нигезсез, сәбәпсез. *Йә, бәлкем, ул берәр нәрсәгә үпкәләгәндер, йә хәтере калгандыр да бер дә юкка монда килеп, тегермән канатлары әйләндерергә теләмидер, назландырадыр* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Нинди балавыз сыгу бу бер дә юктан* (В. Нуруллин. Һәлакәт).

**БЕР ДӘ ЯЛГАНСЫЗ.** Һичбер нинди алдаусыз. *Бер дә ялгансыз күкәйдән зур таш ул, / Дөньяда юк, булса да тик бер таш ул* (Г. Тукай).

**БЕР ДӘРӘҖӘДӘ.** Бер хәтле, беркадәр. *Шуның белән Карлыгач-Сылу өчен күтәрелән гауга бер дәрәҗәдә басылырга исәпләде* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *<...> бу сәгатьтә Гөлфәрвраздан аерылу аңар җаныннан аерылу белән бер дәрәҗәдә авыр һәм ачы тоелып, ул, үзенең башын җуйган шикелле, вакыты-вакыты белән үзе дә аңламаган көч каршында хисенә каршы баргандай була иде* (К. Тинчурин. Искәндәр).

**БЕР ДИГӘН**. 1. Бик яхшы. *[Сәхилә] Туең да узмаган, туның да тузмаган, менә кызыңны бер дигән байга бирәсең дә, тун киеп, туенда утырасың* (Н. Исәнбәт). *Мәктәпнең бер дигән чаңгычысы иде* (В. Нуриев. Мәһдиев һәм...).

2. Бик матур, уңган. *Без утырабыз кодаларның / Бер дигәннәре белән* (Йола уеныннан). – *Килешкәнсез икән, кавышыгыз! Бер дигән ханым бит Тәрҗемә!* (А. Хайртдинова. Язмыш). *Бер дигән җәйге вакыт иде бу* (Г. Хәсәнов. Абага).
Төрдәше: менә дигән!; тел тидермәслек (ике маддә өчен дә).

**БЕР ДИП ӘЙТКӘНЕ.** Бер дигәне, менә дигәне, яхшыларның яхшысы. – *Мин сиңа чәйнең бер дип әйткәнен бирәм* (Сөйләм).

**БЕР ЕЛГА КУЯН ТИРЕСЕ ДӘ ТҮЗӘ.** *Бер елга куян тиресе дә түзә***,** *ди: киләсе көзгә чикле сабыр итим, тагы яучының бик майлы авызын җибәреп карармын...* (Г. Ибраһимов). *Дөнья күреп тә кайтырсың. Күпкә түгел, бер елга. Әбер елга, әнә Газинур әйтмешли, куян тиресе дә түзә* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

**БЕР ЕЛДА УН ЕЛЛЫК КАРТАЮ.** Берәр йөдәткеч кеше яисә буталчык эш белән маташып вакыт әрәм иткәндә, бик нык борчылганда әйтелә. – *Әти-әни, синең өчен борчылып, бер елда ун еллык картайды. Салкын кыш көнендә ач килеш бала белән кайда йөри, дип борчылдылар* (З. Кадырова. Сагынырсың – мин булмам).

**БЕР ЕЛНЫ БҮДӘНӘ СИМЕРСӘ, ИКЕНЧЕ ЕЛНЫ – ТАРТАР.** «Һәр нәрсә үзгәреп тора, бер ел берсе көчле булса, икенче елда башкасы булырга мөмкин» мәгънәсендә. *Менә бер елны бүдәнә симерсә, икенче елны – тартар... Күрәш әле тукталмаган* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).

**БЕР ҖАВАПКА БИШ ҖАВАП.** Һәрнәрсәгә бик тиз, кайвакыт уйланмыйча, җавап табып

тору. *Чура морза да күкәй салган тавык кебек кыткылдап кына тора, бер җавапка биш җавап, кымыз ару җибеткән тегене* (М. Әмирханов. Гәүһәршад).

**БЕР ҖАН, <БЕР ТӘН> БУЛУ** 1. *к.* авыздан-авызга сөйләшү. *Итик, дуслар, иттифак, бетсен, кадалсын нифак, / Тәнемез аерым булса да, бер җан булыйк бәдәвам* (Г. Тукай). *Леспромхозда Газинурны барысыннан да элек коллектив эшнең колачы, бердәмлеге, урман кисүчеләрнең бер җан, бер тән булып эшләүләре шатландыра һәм сокландыра иде* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

Төрдәше: авыздан-авызга сөйләшү һ.б.

2. Сөешеп кавышу. *Аларның бер җан, бер тән булып яшәүләренә бераүләр соклана, икенчеләре көнләшә иде* (Сөйләм).

Төрдәше: алма белән алма кебек яшәү һ.б.

**БЕР ҖЕПКӘ БӘЙЛӘНГӘН БУЛУ**. Бер-берсенә бик тыгыз бәйле булу. *Без синең белән бер җепкә бәйләнгән* (Ф. Латыйфи). *Тик без моның өчен синең белән бер җепкә бәйләнгән булырга, бер-беребезне сынатмаска һәм сатмаска тиеш* (Н. Акмал. Үз урамым).

**БЕР ҖЕПКӘ ТЕЗҮ.** Булган вакыйгаларны, хәлләрне бер-бер артлы, тоташ бер күренеш итеп карап, нәтиҗә ясау. *Әмма үзен тиз кулга алды, күңелендә кайнаган хис-фикерләрен бер җепкә тезәргә көч тапты* (М. Хәсәнов). *Бүгенге көн өчен вакыйгалар артык күп булса да, бер җепкә тезгәч, алар бары тик бер мәгънә алалар иде, яшәү җиңел булмаячак!* (А. Гыйләҗев. Язгы кәрваннар).

**БЕР ҖЕПТӘГЕ ИКЕ ТӨЙМӘ.** Аерылгысыз дуслар. *Нариман, – Айзатның ярты кабымлык икмәкне икегә бүлеп каба торган, бер җептәге ике төймә, бер төптәге ике тирәк шикелле яшәгән дусты, – акча барда бүредәй, акча юкта шүредәй бергә көн күрүче, эч серләрен уртаклашучы элекке старшина түр почмактагы урыныннан аңа карап-карап ятты да торып янына килде* (Г. Мөхәммәтшин. Йөрәктәге эзләр).

Төрдәше: авыздан-авызга сөйләшү һ.б.

**БЕР ҖИҢНӘН ИКЕ КУЛ ЧЫГАРЫП ЭШЛӘҮ** *к.* авызга җаны килгәнче (чыкканчы) тырышу. *Сазлы җир ул. «Бер җиңнән ике кул чыгарып эшләсәң дә туйдыра алмассың ул бирәнне», – дип көлә Хөббәт* (М. Әмирханов. Убыр уты). *Һаман кеше почмагында яшәмәс өчен, ул бер җиңнән ике кул чыгарып эшләргә дә риза иде* (Р. Кәрами. Кая чабасың, гомер юртагы?).

Төрдәше: авызга җаны килгәнче (чыкканчы) тырышу һ.б.

**БЕР ҖИР БУЕ.** Элек татарлар кулланган мәйдан үлчәү берәмлеге (2 дисәтинәгә тигез, якынча 160 метр). *Шуннан Һадиямне юл кырыена утыртып калдырдым да төенемне бер җир буе алга илтеп куйдым* (Ә. Еники). *Мөхәммәтшакир мулланың өенә каршы үрдә, бер җир буе гына ераклыкта бик борынгы зират шаулап утыра* (М. Мәһдиев. Сасна).

**БЕР ҖИРДӘ ИКЕ СӨЛӘЙМАН, БЕРСЕНӘ ӘЙТСӘҢ, БЕРСЕ СӨМӘЙГӘН.** Ике дус турында – берсенә бер сүз әйтсәң, икенчесенең хәтере калачак. *– Анда баргач, авызыңны белеп ач – картлар әйтмешли, бер җирдә ике Сөләйман, берсенә әйтсәң, берсе сөмәйгән* (Сөйләм).

**БЕР ҖЫРНЫ ҖЫРЛАУ.** Һаман да бер сүзне сөйләү. – *Хыянәтче! Сатлык Синявский, Даниэллар белән бер җырны җырлыйсың икән. Җәбрәилләргә сатылдыңмы?* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Каршы әйтергә, бүлдерергә маташкан һичбер кешенең сүзен колагына элми, сарайда Илһам хан йөзенә текәлеп, гел бер җырны җырлый* (В. Имамов. Утлы дала).

**БЕР ЗАМАН<НАР>.** Билгеле бер вакытта, чорда, берчакны. *Бер заман ул миңа туп-туры әйтеп салды: «Шәмсетдин дус, үзең уйлап кара, – диде ул, – бер кызга ике дус гыйшык торгач, нәрсә булып чыга инде ул?* (А. Шамов. Кыз урлау). *Менә шул чәчәк кебек апасы бер заман күз алдында кибә башлады* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**БЕР ИСӘПЛӘГӘНДӘ.** Бер уйлап караганда. *Ләкин кемгә өйләнергә дә кемне алырга кирәк? Бер исәпләгәндә, өйләнү күңелле нәрсә* (Г. Камал). *Бер исәпләгәндә, Фәррахның бу йортка килеп урнашуы – аның бәгырь җәрәхәтенә учлап тоз сибү* (Б. Камалов. Гомер кичендә).

**БЕР ИТЕП**. 1. Бөтен мәйданны иңләп-буйлап, бер баштан (очтан) икенче башына (очына) кадәр.

*Бөтен авылны бер итеп йөгерешеп кайткан малайлар яшел чирәм каплаган ишегалдына килеп тулалар* (Г. Ахунов Фатих малае). *Бәрәннәр, аяклары җиргә тияргә өлгермәс борын, ишек алдын бер итеп сикереп, чабып йөри башладылар* (Ә. Еники. Ялгыз каз).

2. Бик җентекләп, бер нәрсәне яки урынны да калдырмыйча. *20 еллар әдәбият белеме һәм тарих фәнендә мондый капма-каршылы бүленеш юк, аларның икесе дә бер итеп карала* (М. Хәсәнов). *Аннан соң бөтен утрауны бер итеп тентеп тә чыктылар ич* (М. Кәбиров. Бердәнбер һәм кабатланмас).

**БЕР ИТЕП ЙӨРҮ.** Берәр урынны (авылны, шәһәрне) яки нәрсәне теләгән хәтле күреп, үзенеке итеп йөрү. <...> *бер минут та тик тора алмаган, бөтен өйне бер итеп йөргән өч яшьлек кызы – Чулпаны бар* (Д. Булатова. Ачык ишекләр көне). *Исәнләшергә дә онытты. Бөтен Казанны бер итеп йөрүе булырга кирәк?* (Ф. Яхин. Гыйльменисаттәй кем ул?).

**БЕР ИТЕП ЭШЛӘҮ.** Бик яхшы итеп, килешмәгән җирен калдырмыйча. *Камилә каенатасының сүзеннән төртеп уяткандай сискәнеп куйды һәм уңган килен өлгерлеге белән, ике кулы түгел, дүрт кулы бар төсле, өй эчен бер итеп эшләргә кереште* (Ә. Еники. Бер генә сәгатькә).

**БЕР ИШЕККӘ СЫЕП ҮСҮ.** Бик якын дуслар булу. *Кайчандыр икебез бер ишеккә сыеп үскән балалар бит без!* (Г. Насрый). *Кайчак символга әйләнү вакытында каршылыклы мәгънәләр калка. Кайчандыр икебез бер ишеккә сыеп үскән балалар бит без!* (rudocs.exdat.com).

Төрдәше: авызга-авыз сөйләшү һ.б.

**БЕР ИШТӘН.** Пардан, бер үк төрле булсын дип. – *Тютеевны нишләттегез? – дип сорады Яңгура, башта рюмкасыннан, аннары хуҗа белән бер иштән куелган бәләкәй чынаяктан авыз итеп* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Гөлгамбәр ир балаларына бер иштән, кыз балаларына бер иштән өр-яңа күлмәк-ыштаннар тегеп кидерә* (Ф. Мөслимова. Бу яшәүдән нинди билге калыр?).

**БЕР ЙОДРЫККА (КУЛГА) ТУПЛАНУ (ҖЫЕЛУ).** Бердәм көч булып тору. *Ләкин бер кулга җыелгач, яңа җирләргә күчеп китү, Кытайны барып талау уйлары өскә чыктылар* (Г. Гобәйдуллин. Татарларның килеп чыгышы һәм Алтын Урда). *Шуңа күрә, соңгарак калып булса да, татарның чын ул-кызларына да бер йодрыкка тупланырга, чын-чынлап оешырга, нәтиҗәле, эзлекле эш-гамәлләр кылырга тотынырга кирәктер бит инде* (Н. Шәрифуллин. Зыялылык әгәр җитмәсә).

**БЕР ЙОДРЫККА ТУПЛАУ (ҖЫЮ).** Барысын да бергә берләштерү. *Сүбүдәй гаскәрен, һаман таркатмыйча, бер йодрыкка туплап килә иде* (В. Имамов. Утлы дала). *Шул ук вакытта Русия кенәзләрен дә күздән яздырмый, дистәләрчә еллар үзара сугышып, тәре үбә-үбә бер-берсен үтерешеп яшәгән Русия кенәзләрен бер йодрыкка җыя, димәк, кенәзләрнең тормышын тамырдан үзгәртә, дәүләти тәртип кертә – һәммәсен дә ясакчылары итүгә ирешә* (М. Хәбибуллин. Асылда Батый хан кем булган?).

Төрдәше: бер калфак астына җыю; бер кулга җыю.

**БЕР ЙӨРӘК** *к.* авыздан-авызга сөйләшү. *Димәк, ул Маркс белән бергә тору гына түгел, Маркс белән бергә бер йөрәк, бер хис, бер уй булып яшәгән* (Г. Кутуй. Тапшырылмаган хатлар). <…> *бу якынлык безне тагын да кысыбрак бер җепкә бәйләде шикелле, икебездә бер йөрәк тибүен, тамырларыбызда дулкынланып кан агышын сиздек* (Г. Госман. Гармун телләре унике).

Төрдәше: авыздан-авызга сөйләшү һ.б.

**БЕР ЙӨРӘКТӘН ӨЗЕЛГӘН.** Үзеңнеке, бик кадерле булу. *Икесе дә бер йөрәктән өзелеп төшкән бит алар* (Ф. Хөсни).

**БЕР КАБАР (КАБАСЫ) ҖИРЕМ КАЛМАДЫ** *к.* бер кабарлыгым да юк 2. *[Алмаз] Завгаражга ни ялындым, директор машинасыннан туйдым, бер кабар җирем калмады дип карадым* (А. Гыйләҗев). *Туйдым синнән, бер кабар җирем калмады* (Н. Исәнбәт).

Төрдәше: бер кабарлыгым да юк 2.

**БЕР КАБАРЛЫГЫМ ДА ЮК.** 1. «Туйдым, артык ашый алмыйм» мәгънәсендә. *Шундый тәмләп, рәхәтләнеп ашадым, үпкәләмә, башка бер кабарлыгым да юк* (Сөйләм).

2. *күч.* Берәр кешедән (яки әйбердән) туйю, бизү. – *Үзенә сөйли күрмә тагын, шундый туйдым аның лыгырдап утыруыннан, абый булса,*

*«туйдым, бер кабарлыгым да юк» дияр иде* (Сөйләм).

Төрдәше: бер кабар (кабасы) җирем калмады.

**БЕР КАЗАГА ИКЕ ҖӘЗА.** Бәланең бер үзе генә килмәвенә ишарә. *Бер казага ике җәза гына түгел, аннан да күбрәген татырга туры килде: машинасы гына ватылса ярар иде, юк бит, кысылып кул сынды, юл йөрү кагыйдәләрен бозган өчен дип, штраф салдылар, юл буендагы бәреп сындырган багананың зарарын да түләттеләр* (Сөйләм).

**БЕР <ҮК> КАЗАН ЭЧЕНДӘ ИКЕ ТӘКӘ БАШЫ.** Бер-берсе белән сыеша алмаган ике нәрсәне бергә сыйдырырга тырышу. – *Туктамышның да вафаты хакында хәбәр юк бит әле, ә монда бер үк казан эчендә ике тәкә башы* (В. Имамов. Карабәк).

Төрдәше: бер казанга ике тәкә башы <туры килү>.

**БЕР КАЗАНГА ИКЕ ТӘКӘ БАШЫ <ТУРЫ КИЛҮ>** *к.* бер <үк> казан эчендә ике тәкә башы. *Ул да түгел, арадан бер карт, торып, «ике колхозны берләштергәннән соң, бер казанга ике тәкә башы туры килә түгелме соң, җәмәгать?» дип, ике председательгә киная ясап, барысын да бер көлдереп алды* (Ф. Хөсни. Җәй башы). *Соңыннан Якуб әйтте үзенең иптәшләренә: – Бер казанга ике тәкә башы! сыешып тора алмам мин Дәүләтьяров белән* (И. Гази. Онытылмас еллар).

Төрдәше: бер <үк> казан эчендә ике тәкә башы.

**БЕР КАЗАНГА ИКЕ ТӘКӘ БАШЫ СЫЙМАУ.** Каршылыклы ике нәрсәне бергә китерү мөмкин түгеллеге хакында. *«Бер казанга ике тәкә башы сыймый, эзең дә булмасын!» – дигән* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Малай, <...> өч Газизәгә дә карап алганнан соң – монда башың адашырлык икән, берьюлы ике Фатыйма, өч Газизә! Бер казанга ике тәкә башы да сыймый, дигән булалар тагын!* (Ә. Гаффар. Дәрья башы).

**БЕР КАЗАНГА САЛЫП КАЙНАТУ.** Нәрсәнеңдер бергә катнашмыйча, аерым-аерым булуы турында. *[Искәндәр] Сезнеке – сезнеке, безнеке – безнеке әле. Аларны бер казанга салып кайнатмадылар* (К. Тинчурин. Американ).

**БЕР КАЗЫККА КИТЕРЕП ТЕРӘҮ.** Бәхәсләшү, орышу, талашу һ.б. хәлиткеч мизгеленә килеп җитү. – *Шулай ул озак тиргәнде дә бер күтәрелешкә әзерләнергә казыкка китереп терәде: «Кораллы кирәк!» – диде* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр).

**БЕР КАЙЧЫДАН КЫРЫККАН** *к.* Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни. Бер «калып» кешеләр (кыяфәтләре, чәчләре, киемнәре һ.б. бердәй) хакында. *Рөстәме дә алардан әллә ни аерылмый, алар бер кайчыдан кырыккан, бер балалар йортында тәрбияләнгәннәр* (Сөйләм).

Төрдәше: Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни һ.б.

**БЕР КАЛФАК АСТЫНА ҖЫЮ.** Берләштерү, туплау. *[Камил] Син аларның барысын да бер калфак астына җыеп, көчле бер милләт тудырырга хыял итәсең* (Ш. Усманов. Канлы көннәрдә).

Төрдәше: бер йодрыкка туплау (җыю).

**БЕР КАЛЫПКА ДА СЫЙМАУ.** «Бик алама, тәртипсез, бернигә яраксыз» мәгънәсендә. *Бала-чага түгел бит инде, кыланышлары бер калыпка да сыймый* (Сөйләм).

Төрдәше: бер капкага да сыймау.

**БЕР КАЛЫПКА СУККАН.** 1. *к.* Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни (күбрәк тискәре мәгънәдә). *Барысы бер нәгъләт! Һәммәсен дә бер калыпка суккан! Монда беркемгә ышанырга ярамый* (М. Галәү. Болганчык еллар). *Киң урам, бер калыпка сугып эшләнгән шикелле, берсеннән икенчесен аеруы мөмкин булмаган ике катлы йортлар* (С. Рәфыйков. Тын елга буенда).

Төрдәше: Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни һ.б.

2. Бер сүздә тору. *Бер калыпка суккан диярсең, сүзләре дә бер-берсенекеннән аерылмый* (Сөйләм).

**БЕР КАЛЫПТАН СУГЫЛГАН (ЧЫККАН; ЯРАТЫЛГАН)** *к.* Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни. – *Әле яшьлек тилелеге белән генә сайрыйсың! Барыбыз да бер төсле, бер калыптан сугылган* (Г. Бәширов. Сиваш).

Төрдәше: Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни һ.б.

**БЕР КАМЫРДАН ӘВӘЛӘНГӘН** *к.* Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни. *Чыннан да, акча кодрәте белән дөнья чыгырын әйләндерүче идарә көчләр (алары да күктән төшмәгән, шул бер камырдан әвәләнгән адәмнәр ләбаса!)* (Р. Фәйзуллин.

Илбагар уйлар). – *Ир белән хатын бер камырдан әвәләнгән инде ул, – дип акланмакчы булды ул* (Ф. Садриев. Бәхетсезләр бәхете).
Төрдәше: Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни һ.б.

**БЕР КАНАТ БЕЛӘН.** Гаиләдә йә ана, йә ата гына булу. *Бер канат белән генә бала үстерүнең хәтәрлеген дә искә алды Зәмзәмия* (Ә. Моталлапов. Рисвайлык). *Икенче яктан, аңа да берьялгызына җиңел түгелдер, үзе шулай диде ич. Бер канат белән генә очып булмый лабаса* (Ә. Хәсәнов. Бәхет кайда оя кора).

**БЕР КАНАТ СЫНУ.** Якын, кадерле кешене югалту. *Ярты юлга җитәрәк, Бикмүш бабайның кинәт кенә бер канаты сынган, кырык ел буена бергә гомер иткән карчыгы үлеп калган* (Г. Гобәй). *Хәзергә исә бер канаты сынган очар кош кебек. Очып кына китәр иде – канаты сынган. Аның сөйгәне кай тарафларда икән соң?* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).

**БЕР КАПКАГА ДА СЫЙМАУ** *к.* бер калыпка да сыймау. *Аның кичәге җыелышта үз-үзен тотышы бер капкага да сыймый иде* (Сөйләм).
Төрдәше: бер калыпка да сыймау.

**БЕР КАПКАГА УЙНАУ.** Бер тарафның икенче тарафтан җавапсыз калган эшләре, шөгыльләре һ.б. – *Андый хәдисләрне бер якка гына куллану бер капкага уйнаган футбол кебек була* («Шәһри Казан» газ.). *Илдә бер капкага уйнау башланды. Илдә бер төп канун эшли башлады: акчаң булса, син – кеше, син – власть, син тормышның хуҗасы, акчаң булмаса – син юк!* («Ватаным Татарстан» газ.).

**БЕР КАРАГАНДА.** Бер төрле уйлаганда, бер карашка. *Бер караганда, Изил Латыйпов кебек тә була, икенче караганда, Израил Моисеевичка әйләнеп, тешен ыржайтып тора* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Бер караганда, бу бик гаҗәп, бик зур гаделсезлек шикелле* (В. Нуруллин. Ике урам арасы).

**БЕР КАРАГАНДА – АЛ ДА ГӨЛ, БЕР КАРАГАНДА – ҖИЛ-ДАВЫЛ.** Холкы тиз үзгәрүчән кеше хакында. *Сөйләмә дә инде, бер караганда – ал да гөл, бер караганда – җил-давыл, кайдан гына таптың мондый ирне?* (Сөйләм).

**БЕР КАРАҢГЫДАН ИКЕНЧЕ КАРАҢГЫГА- <ЧА>.** Бик иртә башлап, бик соң тәмамлау, иртә таңнан кичкә кадәр. *[Хөббиҗамал] Әй улым, нинди ял? Бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр йөгерәм* (Ю. Әминов. Язылмаган законнар). *Сез әле минем бер караңгыдан икенче караңгыга эшләгән белән ат түләмәкчемени?* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).
Төрдәше: ал да белми, ял да белми <эшләү> һ.б.

**БЕР КАРАСАҢ – АЛТЫН, ИКЕНЧЕ КАРАСАҢ – ЧУРТЫМ <ДИГӘНДӘЙРӘК>.** Үзенең яхшылыгын холыксызлыгы белән бозучыга карата. *Сәер кеше безнең бу карт. Бер карасаң – алтын, бер карасаң – чуртым, дигәндәйрәк* (Ш. Маннур. Агымсуларга карап).

**БЕР КАРГА ТУЯРЛЫК ИТЕ ЮК** *кимс., к.* авызын ачса, кече теле күренү. *Тоткынның кабыргалары беленеп тора, муены нәзек, озын куллары да коры сөяк, тәнендә бер карга туярлык ите юк* (Р. Кәрами. Каргышлы этаплар).
Төрдәше: авызын ачса, кече теле күренү 1 һ.б.

**БЕР КАРТЛЫКТА, БЕР ЯШЬЛЕКТӘ.** Яшьлектә булган эшләрнең кабатлануы хакында (күпчелектә мәхәббәт белән бәйле). *Баһадирны беренче тапкыр күргәндәге ялкынлы хисе янә бер кабатланды бикәнең. Бер картлыкта, бер яшьлектә, диләр, әллә соң шулмы бу мәхәббәт дигәннәре, дип уйлады бикә* (М. Хәбибуллин. Илчегә үлем юк). *[Шаһия] Анысы, хәер, белеп булмый, бәлки, табып та куярсың. Хыхы-хы! Бер картлыкта, бер яшьлектә, диләр бит...* (Г. Каюмов. Юбилей).
Төрдәше: бер яшьлектә, бер картлыкта; берәүгә яшьлектә, берәүгә картлыкта.

**БЕР КАРЫШ БУЙ.** 1. Кечкенә, кәтәнә. *Бер карыш буе белән бәйрәмдә әләм күтәреп барырга җыенамы югыйсә?* (Сөйләм).

2. *күч.* Күбрәк, артыграк. *Ялгыш газы күбрәк ачылды бугай, бер карыш буе ялкын күтәрелде, аның яктысында Ансар сержантның йөзен танып өлгерде* (К. Кәримов. Сакау күке).

**БЕР КАРЫШ ТА.** Аз гына да, ягъни киерелгән кулның баш бармак очы белән урта бармак очы арасы кадәр дә. *Мин чикмәдем, дускай, бер карыш та, / Батырларча алга атладым* (М. Җәлил). *Акылы бар кеше туган җирен бер карыш та сатмый* (В. Имамов. Утлы дала).

**БЕР КАТАРГА ТЕЗҮ.** Бертөсле итеп кабул итү, тыңлау. *Тукай белән Сәгыйть Рәмиев бер чор шагыйрьләре булсалар да, шигъри алымнарын бер катарга тезеп булмый* (Н. Исәнбәт).

**БЕР КАТАРДАН.** Бертөсле, бер-беренә охшаш. *Алар икесе дә бер катардан* (Н. Исәнбәт).

**БЕР КАТКА ҖИТҮ.** 1. Бер кат киенергә җитәрлек. *Егерме аршын икән, килен... үзеңә дә, балаларыңа да бер катка иркен җитәр* (Г. Ибраһимов).

2. Бер мәртәбә, бер тапкыр (юынып чыгу турында). *[Мәдәния] Мунчага су ташымаган. [Гайсә] Бер катка җитәрлек* (А. Гыйләҗев).

**БЕР КАШЫК ДЕГЕТ.** «Әшәкелек эшләргә аз гына микъдар да җитә» мәгънәсендә. *Шулай да аларның бер-бер этлек кылырга җайлары бар. Бер мичкә балны бер кашык деготь боза!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Шатлыкның төсе качты, куанычлар тәмам басылдылар, «бер мичкә балны бер кашык дегет бозды да куйды»* (Ф. Яхин. Көзге яңгырга кадәр).

**БЕР КАШЫК КАНЫМ КАЛГАНЧЫ.** Җанны фида итеп көрәшергә вәгъдә бирү һәм ант итү. *Кулдан килгән хезмәткә баш өсте, бер кашык каным калганчы йөгерермен, әмма акчага терәлгән эшне Алла разый булсын, зинһар, боермасана* (К. Насыйри).

**БЕР КАШЫК КАНЫННАН КИЧҮ.** Үлем җәзасын гафу белән алыштыруны үтенгәндәге гыйбарә. *Бишектә яткан баласы «Бер кашык каныннан кич», – диде. – Буында типкән кан калсын. Баладан кулың тарт, – диде* («Идегәй» дастаны).

**БЕР КАШЫК СУ БЕЛӘН <КАБЫП; СУЫРЫП> ЙОТАРЛЫК** *к.* авызда гына тотарлык. *Ул күз дисеңме, ул каш дисеңме... кыскасы, бер кашык су белән йотарлык иде* (А. Шамов. Кыз урлау). *Бер кашык су белән йотарлык шундый гүзәлне күрүгә, егетеңнең дә күзе ачылыр* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).

Төрдәше: авызда гына тотарлык һ.б.

**БЕР КАШЫК СУ БЕЛӘН КАП ТА ЙОТ!** *к.* авызда гына тотарлык. *Ул буй-сын, ул бит-күз! Бер кашык су белән кап та йот!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Кем әйтмешли, бер кашык су белән кап та йот. Җитмәсә, үзе шундый сөйкемле, мөлаем, көләч, әйтерсең лә кояш урынына нур сибә* (И. Диндаров. Соңгы аманәт).

Төрдәше: авызда гына тотарлык һ.б.

**БЕР КАШЫК СУ САЛМАС** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. *Мәрхәмәтсезлеге белән танылган бит инде ул – үлгән вакытыңда авызыңа бер кашык су салмас* (Сөйләм).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**БЕР КАШЫК СУГА САЛ ДА ЙОТ (САЛЫП ЙОТУ)** *к.* авызда гына тотарлык. – *Үзе шундый сылу, шундый зифа – тиленеке, бер кашык суга сал да йот...* (Г. Ибраһимов. Табигать балалары). *Бер кашык суга саласың да йотасың* (М. Фәйзи. Кызыл йолдыз). *Унтугыздагы бу кызыйны, кем әйтмешли, бер кашык суга салып йотарлык иде* (М. Закир. Чебен).

Төрдәше: авызда гына тотарлык һ.б.

**БЕР КАШЫК СУДА БАТЫП ЯТУ (КАЛУ)** *кимс.* Кечкенә генә мәсьәләне хәл итә алмый буталып бетү. *Дөресен әйткәндә, кайчак мин үзем дә икеләнәм, әмма күңелдән болай дип тә уйлыйм: дөньялар буталган бу заманда бер кашык суда батып ятканчы, ниндидер ыргым-омтылыш ясау әһәмиятлерәктер* («Ватаным Татарстан» газ.).

**БЕР КАШЫКТАН АШАП ҮСКӘН (ЙӨРГӘН)** *к.* авызга-авыз сөйләшү. *Шәрәф белән Гарәф, бер кашыктан ашап үсмәсәләр дә, бер урам малайлары иде* (Р. Кәрами. Кунак). *Баксаң, ул бер кашыктан ашап йөргән якын дустының шикаяте буенча махсус килгән икән, укытучылар белән әңгәмә, чәй – болар барысы да театр уйнау гына булган икән* (М. Әмирханов. Саба җиле).

Төрдәше: авызга-авыз сөйләшү һ.б.

**БЕР КАШЫКТАН АШАУ**. Кемне булса да бик яхшы белү; озак вакыт бергә яшәп, еш аралашу; бик дус булу. – *Урыс полиция белән бер кашыктан ашый ул эт! – дип, кире утырды* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Бәлкем, әллә аны да Зоя буйларындагы ата-ана нигезен оныттырып, буй шпалны бергә күтәреп, бер кашыктан ашаганы бер-берсенә җан җылыларын бирешеп, күпмедер монда бергә җәфа чиккән җан кардәшләре рухы шушын-*

*да тартып торадыр да* (Л. Хәмидуллин. Кичке шәфәкъ).

Төрдәше: авызга-авыз сөйләшү һ.б.

**БЕР КӘЛИМӘ <СҮЗ>.** Бер авыз сүз. *Газеталар бу хакта әйтергә бер кәлимә сүз тапмадылар, халыкка кәррә чаклы да хәбәр салмадылар, билгеле* (Р. Низами. Сәйдәшнең соңгы елы). *Рахманколда татар мәктәбе түгел иде. Шуңа кызларыбыз бер кәлимә дә татарча шигырь белмиләр* (Р. Сибат. Сәридә).

**БЕР КӘРРӘ.** Бер тапкыр. *Тозакларын вәйран итик: / Тагы бер кәррә кормасын!/ Вәйран итик – туздырыйк, бетерик* (Г. Тукай). *Гомерендә бер кәррә булмаган халәтләр хәзер аңарга килде* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми).

**БЕР КЕСӘДӘН ЧЫГУ.** Төрле-төрле чыгымнарның чыганагы бер булуга ишарә. *[Нариман] Ашаган белми, тураган белә, дигән бабайлар. Бар да бер кесәдән чыга бит ул, егетләр* (Т. Гыйззәт. Мактаулы заман). *Бөтенесе бер кесәдән чыга. Дөресрәге, кереп тә өлгерми – чыга* (Т. Гарипова. Умырзая гөленең гомеркәе).

**БЕР КЕШЕ ИКЕГӘ ЯРЫЛЫРДАЙ ВАКЫТ<ТА> (ЧАК<ТА>).** Кызу эш вакытында, вакыт тыгыз булганда. *Хәзер бит бездә, үзең беләсең, бер кешене икегә ярырдай чак. Печәнне өя башламыйсың, борчагы шартлап өлгерә, борчакны җыеп бетергәнче, арышка төшә башларга туры килә* (Ф. Яруллин. Фаҗига).

Төрдәше: бер кеше икегә ярылырлык.

**БЕР КЕШЕ ИКЕГӘ ЯРЫЛЫРЛЫК** *к.* бер кеше икегә ярылырдай вакыт<та> (чак<та>). – *Бер кеше икегә ярылырлык көннәребез булды* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

Төрдәше: бер кеше икегә ярылырдай вакыт<та> (чак<та>).

**БЕР КЕШЕГӘ ӘЙЛӘНҮ (ӘЙЛӘНЕП БЕТҮ).** Күп еллар бергә тормыш итеп, уртак фикердә, карашларда булу. – *Илле тугыз җыл бергә яшәп, бер түшәктә җоклап, икегез бер кешегә әйләнеп беткәнсез инде* (Г. Мөхәммәтшин. Ике әби бәрәңге ала...). *Күп еллар бергә мәхәббәттә яшәп, без икебез бер кешегә әйләнеп беттек, күрәсең* («Матбугат.ру» порталы).

**БЕР КЕШЕНЕҢ ДӘ САНДЫГЫ БУШ ТҮГЕЛ.** Һәр кешенең үзенә хас уй-теләге, омтылышлары, борчулары, кайгылары һ.б. булу. *Әле генә җир тетрәгәндәй тоелган вакыйгаларны да бер якка этеп, бүтәннәре килеп чыга, һәм, әбиләр әйтмешли, бер кешенең дә сандыгы буш түгел, һәркемнең үз кайгысы, үз борчуы* (С. Сәүбанова. Соңгы әманәт).

**БЕР КИЛЕП.** Бер мәртәбәсендә, кайчан да булса. *Хәзер кадерне белмәсәгез дә, бер килеп исегезгә төшәр әле* (Ә. Еники). *Әхәтләр ягына йодрык күрсәтеп, тагын бер янап алды: – Бер килеп капмассыңмы әле, ристан!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**БЕР КИЛЕШ.** Уртача, яхшы гына; гадәттәгечә. *Тормыш гел бер килеш кенә бармый икән, туган* (В. Нуруллин. Күпер чыкканда). *Акканы да күренми, мәңге бер килеш бәхет-шатлыкта коенып яшәрсең кебек, моның бернинди үзгәреше, борылмасы-сырылмасы, азагы-тукталышы булмас шикелле* (Ф. Садриев. Шаһзаманов эше).

Төрдәше: бер көе<нчә> (көйгә).

**БЕР КИЛМӘГӘН ҖИРЕ ДӘ ЮК (БУЛМАУ).** Барысы да килешеп тору хакында. *[Камилә] Гаптерахман мине алмаска, – минем бер килмәгән җирем дә юк* (Г. Камал. Бәхетсез егет). *Чамасызрак соклана идем шул, бигрәк бер килмәгән җире юк бит* (Г. Галиева. Газзәбану).

**БЕР КИЛҮ БЕЛӘН КИЛҮ.** Бик җилле, үзенә бер төрле, игътибарны үзенә тарта торган йөреш белән килү. *Аның йөрешен ерактан ук танып була, аны бер сүз белән сыйфатлавы да кыен: җилле дә ул, җиңел дә, шул ук вакытта адымнары да нык, гомумән, үзенә генә хас бер килү белән килә иде* (Сөйләм).

**БЕР КИҢӘШТӘН.** Бер карарга килеп. *Икенчесе, инде ничә еллар иңгә-иң терәп, бер киңәштән дөнья йөген тарткан комендант Апанас Степанов* (З. Мурсиев. Солтанъяр). *Маташа торгач, бер киңәштән эшне дәвам итәргә тотындылар* (Сөйләм).

**БЕР КИРЕ КИЛСӘ.** Уңышсызлык артыннан уңышсызлык килү, бәла артыннан бәла булу. *Әмма бер кире килсә килә шул ул. Ире колхоз йомышыннан нәкъ уллары-киленнәре белән*

*бергә кайтып төште* (Ф. Яруллин). *Бер кире килсә, гел шулай була бит. Монда да барып чыкмады* (Ә. Хәсәнов. Әнис алмалар).

**БЕР КИСКӘН ИКМӘК КИРЕ ЯБЫШМАУ** *к.* агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән. *Мин, бер кискән икмәк кире ябышмый, күрәсем дә килми, дидем* (Р. Кәрами. Сөеп туймас чакларың). *«Ник күчтек?» дип үкенгәннәр бугай соңыннан, – бер кискән икмәк кире ябышмый шул* (М. Вәлиев. Гамәл дәфтәре).

Төрдәше: агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән һ.б.

**БЕР КИСМӘК БАЛГА БЕР ТАМЧЫ (КАШЫК) ДЕГЕТ.** Тигез, матур барган тормышны, мәҗлесне, эшне җимерү өчен бик аз гына нәрсә дә җитүе хакында. *Бер кисмәк балга төшкән бер кашык дегет шул булыр* (matbugat.ru).

**БЕР КИЧКӘ КЕР МИЧКӘ.** Кыска вакытлы кыенлыкларга, кимчелекләргә игътибар итмәскә чакыру. *– Гостиницага шалтыратып, Сәмигуллина белән сөйләшеп карагыз әле, бер кичкә кер мичкә дигәндәй, һич булмаса, коридорга җыелма карават куярлар, – дип, минем белән исәп-хисапны өзеп, машинасын ыжгыртып китеп барды* (Ф. Шәфигуллин. Ләмига-Сәмига). *Тагын анда, өч кешегә түгел, үземә дә таман гына да. Нишлисең, әни: «Бер кичкә кер мичкә», – дип, алдан ук кисәтеп куя мине* (Ф. Сафин. Аяусыз әүлия).

**БЕР КОЕДАН СУ ЭЧҮ** *к.* авызга-авыз сөйләшү. *«Димәк, Рөстәм Акчурин белән бер коедан су эчә кызый»* (Н. Гыйматдинова). *Бер бусагадан йөрде, бер коедан су эчте – барыбер читят булды ир белән хатын* («Безнең гәҗит» газ.).

Төрдәше: авызга-авыз сөйләшү һ.б.

**БЕР КОЛАКТАН КЕРЕП, ИКЕНЧЕСЕННӘН ЧЫГУ (ЧЫГЫП КИТҮ / СЫЗУ).** 1. Мәгънәсенә төшенми генә, игътибарсыз тыңлау. *Гөлбану бу турыдагы сүзләрне тыңлады, ләкин аңламады: бер колагыннан кереп, икенчесеннән чыга тордылар* (Г. Ибраһимов). *Ул чакта хуҗа турындагы мәгълүматлар бер колактан керде, икенчесеннән җиңел генә чыгып китте* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

2. Әйтелгән сүзгә игътибар итмичә, үзе белгәнчә эшләү. *Ишеткәннәрем генә... бер колактан кереп, икенчесеннән чыгып киткән. – Без бүген Сөембикә манарасы, аның турындагы чынбарлык һәм риваятьләрне тагын бер кат искә төшерербез* (А. Әхмәтгалиева. Без ачасы серләр бар).

Төрдәше: колак кырыеннан үткәрү (шудыру); колак очы белән тыңлау; колакка да кермәү (элмәү); тишек колак (ике мәддә өчен дә).

**БЕР КОЯШ АСТЫНДА ҖЫЛЫНУ** *к.* аналары бер кояшта киндер киптерү (тукмаклау). *Без аның белән ял йортында таныштык, югыйсә безнең әтиләр бер кояш астында җылынганнар* (Сөйләм).

Төрдәше: аналары бер кояшта киндер киптерү (тукмаклау) һ.б.

**БЕР КОЯШТА КИНДЕР (ЧАБАТА) КИПТЕРҮ** *к.* аналары бер кояшта киндер киптерү (тукмаклау). *Бары аталарыбыз гына бер кояшта чабата киптергәннәр* (А. Шамов). *Мөгаен, безнең әниләр икесе бер кояшта киндер киптергәндер... Берсенә берсе карашып көлеп алдылар* (Г. Бәширов. Кара төндә нур чәчеп...).

Төрдәше: аналары бер кояш астында киндер киптерү (тукмаклау) һ.б.

**БЕР КӨЕ<НЧӘ> (КӨЙГӘ)** *к.* бер килеш. *Торам әле бер көе, очын-очка ялгап барам* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Бер көенчә яшәп яту кайда да берни түгел – әнә шул юллары барысыннан авыр аның, тормышның...* (З. Мифтахов. Битараф түгелмен).

Төрдәше: бер килеш һ.б.

**БЕР КӨЙ** *к.* бер килеш. *[Хәйри] Безнеке инде шул, бер көй дигән шикелле, йөзеп торабыз шунда* (Г. Камал. Өч тормыш). *– Аллага шөкер, балам... шулай бер көй торабыз инде* (Г. Ибраһимов).

Төрдәше: бер килеш һ.б.

**БЕР КӨЙНЕ КӨЙЛӘҮ.** Бер үк нәрсәне кабатлау. *Йодрык төйнәр, өстәл төяр, / Һаман да бер көйне көйләр: / – Давай! Давай! Давай! – дияр* (Ш. Галиев). *– Башта гына сез... Аннары бүтәннәр кебек шул бер көйне көйләрсез...* (А. Вергазов. Кайту).

**БЕР КӨЛТӘ ОЧКЫН БӘРҮ.** Ачулы караш белән карау.*– Ә Фәрхәднең кайсы яклап безнең Урдабызга кендеге тоташкан соң? – дип,*

*янә Туктамыш хан бер көлтә очкын бәрде* (В. Имамов. Карабәк).

**БЕР КӨН ИРТӘ, БЕР КӨН СОҢ.** «Эшнең бер көн элегрәк яки соңрак булуы роль уйнамый» мәгънәсендә. *[Абруй] Теге Каһарман берәр нәрсә эшләмәгәе дип, үзебез дә шикләнеп тора идек, әлләниләр сөйләп йөри, ди. Синдә булса, ул ягы да хәвефсез булыр. [Мөстәкыйм] Менә шул шул. Бер көн иртә, бер көн соң дигәндәй...* (Т. Гыйззәт).

**БЕР КӨН МӨСАФИР, ИКЕ КӨН МӨСАФИР, ӨЧЕНЧЕ КӨННЕ КИТ КЯФЕР.** «Кунак өч көн генә кунак булып саналыр» мәгънәсендә. – *Бер көн мөсафир, ике көн мөсафир, өченче көнне кит кяфер, диярләр* («Чура батыр» дастаны).

**БЕР КӨННӘРЕ.** Үткән көннәрнең берсендә, берничә көн элек. *[Гарифә] Бер көннәре мин Чурчи Әхмәтләргә ашка барган идем, үрдәк бөккәннәре бер дә пешмәгән, авызга алгысыз чи иде, бөтенләй лачкылдап тора* (Г. Камал). *Бер көннәре төшемдә ромашкалар җыйдым* (Г. Әпсәләмов. Агыла болыт).
Төрдәше: бер көннәрне.

**БЕР КӨННӘРНЕ** *к.* бер көннәре. *[Гафифә] Мин аны бер көннәрне Гарифәләргә җибәрдем* (Г. Камал. Беренче театр). *Бер көннәрне тегендә күргән иде* (kitap.net).
Төрдәше: бер көннәре.

**БЕР КӨННЕ.** Билгеле булмаган бер көндә, кайчандыр. *Бер көнне аларга мәктәптә пионерлар турында фильм күрсәттеләр* (А. Хайртдинова. Бәкер чишмәсе). *Һәм менә бер көнне, язгы күкрәү булып, егетләрнең икесенә дә мәхәббәт килгән* (А. Нәҗми. Бабыл шәле).
Төрдәше: көннәрнең берендә.

**БЕР КӨННЕ ХАРИС, ИКЕНЧЕ КӨННЕ ВАРИС.** Кулдан-кулга күчеп йөрү. *Шулай бер көнне Харис, икенче көнне Варис белән дигәндәй, яшь хатын кулдан-кулга күчте, Илгизә «ил гизә» башлады* (Ә. Сәлах. Көт син мине...).

**БЕР КӨРӘККӘ САП БУЛУ.** Бер эшкә дә яраксыз, артык җан булганчы, аз булса да файда китерү. *Болай урамда карга санап йөрүдән, бер көрәккә сап булуың артыграк* (Сөйләм).

**БЕР КУЛ БАЛДА, БЕР КУЛ МАЙДА** *к.* бал белән май эчендә йөзү. *Уллы бул, кызлы бул, / Бер кулың балда булсын, / Бер кулың майда булсын...* (Ф. Урманче. Могҗизалар дөньясына сәяхәт).
Төрдәше: бал белән май эчендә йөзү һ.б.

**БЕР КУЛГА ҖЫЮ.** Бергә туплау. *Чын-чынлап уйлап караганда, төзеп маташкан социализмнары урынына, асылда, барлык җитештерү чараларын, завод-фабрикаларны, җирләрне, колхоз-совхозларны бер кулга җыеп, дәүләт империализмын гына тудырганнар бит!* (Ф. Яхин. Өч көнлек гомер). *Чыннан да, Сибгат Хәкимнең хатларын бер кулга җыеп бастырып чыгару мотлак кирәк* (Н. Нәҗми. Шигырьле сулышлар).
Төрдәше: бер йодрыкка туплау (җыю) һ.б.

**БЕР КУЛГА КЕРЕП БЕТҮ.** Уенда бөтенесен дә бер кеше отып алу. *Кайчагында бөтен кузна бер кулга кереп бетә иде – откан малай ыштан бөрмәсенә кыстырган күлмәгенең эченә тутырып кайтып китә* (Ә. Еники. Соңгы китап).

**БЕР КУЛГА КЫРЫК ЭШ.** Бер кеше берьюлы күптөрле эш эшләгәндә әйтелә. *Бер кулга кырык эш, миңа тапшырылган эшнең барысын да саный башласаң, кулдагы гына түгел, аяклардагы бармаклар да җитмәс* (Сөйләм).

**БЕР КУЛГА ЭШ ИТҮ (ЙӨРТҮ).** Тормышлары һәм хуҗалыклары аерым булса да, астан берләшеп табыш итү. *Кем белә инде аларны, бер кулга эш йөртәләр дип сөйләүчеләр дә бар* (Сөйләм).
Төрдәше: бер кулдан эшләү (эш итү).

**БЕР КУЛДАН ТОТУ.** Бер хуҗалыкта яшәүчеләрнең акчаларын аерым-аерым түгел, бер баш хуҗа кулыннан тоту. *Халык әйтмешли, мондый эшләр мир белән – хәер-садака, зәкят акчаларына төзелсә дә, барысына да тәвәккәлләп алынучы, оештыручы, бер кулдан тотучы үзем, – ди Гыйльмулла хәзрәт* («Безнең гәҗит» газ.).

**БЕР КУЛДАН ЭШЛӘҮ (ЭШ ИТҮ)** *к.* бер кулга эш итү (йөртү). *Бөтен мөселманнарның гам булган ихтыяҗларын бергә оештырып, бер кулдан эшләргә тырышырга тиеш* (Г. Исхакый). *Россия һәм Татарстан Фәннәр*

*академиясенең бер кулдан эшләве нәтиҗәсе булды бу* (Я. Шәфыйков. Бер очрашу – бер гомер).
Төрдәше: бер кулга эш итү (йөртү).

**БЕР КУЛНЫҢ БАРМАКЛАРЫ БУЛЫП ЯШӘҮ.** Бер-береңне хөрмәт итеп, дус яшәү. *Хәтерли әле Йосыф, онытмый, әтисе белән бабасы бер кулның бармаклары булып яшәделәр* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: авызга-авыз сөйләшү һ.б.

**БЕР КУЛСЫЗ КАЛУ.** 1. Ярдәмчесез калу, таяныр кешеңнән аерылу. *Ә монда анасы белән хатыны бер кулсыз калдылар. Бичаралар, бар да истән таеп елыйлар* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). *Аларның аерымлануы – кешенең бер кулсыз калуы кебек* (matbugat.ru).

2. *күч.* Бик кирәкле әйбер табалмыйча аптырап калу. *Бакчада су торбаларын тоташтыра башлаган идем, торбага сыр ясау җиһазымны таба алмыйча, бер кулсыз калдым* (Сөйләм).

**БЕР КУЛЫҢ БАЛДА, ИКЕНЧЕСЕ МАЙДА БУЛСЫН** *к.* авыз<лары> бал да май <булсын>! *Уллы бул, кызлы бул. Бер кулың балда булсын, бер кулың майда булсын...* (Ф. Урманче. Могҗизалар дөньясына сәяхәт).
Төрдәше: авыз<лары> бал да май <булсын>! һ.б.

**БЕР КУНЫЧКА ТЫГА АЛМАУ.** «Белемезиһене булмаса, өстенлеккә ирешә алмаячак» мәгънәсендә. *Белеме зур булмаса, үзенә каршы чыккан генералларны алай барысын бер кунычка тыга алмас иде* (Г. Бәширов).

**БЕР КУРЫККАН ЭТ ӨЧ КӨН ӨРҮ** *к.* авызга җан килү. Курку хисе тиз генә бетмәс, озакка барыр. *Бер курыккан эт өч көн өрер* (К. Насыйри).
Төрдәше: авызга җан килү һ.б.

**БЕР КҮЗ БЕЛӘН КАРАУ.** Һәммәсен тиң күрү. *Ул бүгенге бөек төзелешкә / Айнык бер күз белән каравын, / Заводында барган прорыв өчен / Үзен мәсьүл итеп санавын / Ул әйтергә залга теләде...* (Һ. Такташ. Мәхәббәт тәүбәсе). *Үги баласын да үзенекеннән аермый, бер күз белән карый* (З. Хәким).
Төрдәше: бер күрү.

**БЕР КҮЗЕ МӘГЪРИПТӘ, БЕР КҮЗЕ (ИКЕНЧЕСЕ) МӘШРЫЙКТӘ (МӘШРИКЪТӘ).** Күзләре ике якка карау турында. *Аның бер күзе мәгъриптә, икенчесе мәшрикъта иде шикелле* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым). *Әтисе янына килсә, аның бер күзе мәгърипкә, икенчесе мәшрикъка китеп, үзе зәңгәрләнеп чыккан иде инде* (Б. Ислам. Юмор-сатира).
Төрдәше: бер күзе чәршәмбегә, берсе дүшәмбегә (җомгага; шимбәгә; якшәмбегә) карау.

**БЕР КҮЗЕ ЧӘРШӘМБЕГӘ, БЕРСЕ ДҮШӘМБЕГӘ (ҖОМГАГА; ШИМБӘГӘ; ЯКШӘМБЕГӘ) КАРАУ** *к.* бер күзе мәгъриптә, бер күзе (икенчесе) мәшрыйктә (мәшрикътә). *Озын чәче иңенә ишелеп төшкән, иягендә өч-дүрт бөртек сакал, күзе кылыймы соң – берсе чәршәмбегә, икенчесе бөтенләй якшәмбегә карый* (Р. Зәйдулла. Кабахәт). *Күзләре, саташкан кешенекедәй, берсе чәршәмбегә, икенчесе дүшәмбегә карый иде* (Ф. Хөсни. Циклон). *Бу ике-өч тапкыр төрмәләрдә утырып чыккан, кыйналып, бер күзе чәршәмбегә, икенче күзе шимбәгә карый торган караңгы бер бәндә иде ул* (Ә. Афзалова. Истәлекләр).
Төрдәше: бер күзе мәгъриптә, бер күзе (икенчесе) мәшрыйктә (мәшрикътә).

**БЕР КҮЗЕНӘ АК САЛГАН, ИКЕНЧЕСЕ ЧАК КАЛГАН.** Ике күзе ике төрле кеше хакында. *– Карале, дус кеше, монда бер күзенә ак салган, икенчесе чак калган кешене очратмадыңмы?* (Сөйләм).

**БЕР КҮКРӘКТӘН СУЛАУ.** Берьюлы, бердәм рәвештә сулыш алу. *Председательдән күзләрен алмыйча, аны игътибар белән тыңлап утыручылар барсы да берьюлы, бер күкрәктән иркен итеп суладылар* (Ә. Еники). *Мөһаҗирләр, бер күкрәктән сулагандай, барсы берьюлы авыр сулап куйдылар* (М. Галәү. Мөһаҗирләр).

**БЕР КҮЛМӘК БЕЛӘН КАЛУ** *к.* авыз ачса, кече теле күренү 2. *...Һаман туктамый эчсә, / Гаҗәп түгел ул кеше / Бер күлмәк белән калса* (К. Насыйри). *Ичмасам, хатын да бер күлмәк белән калуны белми, көннәр салкынайды, җылы кием кирәк иде дип борчый* (Г. Толымбай).
Төрдәше: авызны ачса, кече теле күренү 2 һ.б.

**БЕР КҮЛНЕ САСЫТЫП, ИКЕНЧЕ КҮЛГӘ КИЛҮ.** Начар эшләгәнгә, бер җирдән куылып,

башка җылы урын эзләп йөрүче хакында. *Әтисе фамилиясен генерал погоны сыман җилкәсеннән төшермәгәч, ни булсын аңа: бер күлне сасытып, икенче күлгә килгән, диләр* (Сөйләм).

**БЕР КҮРЕРГӘ ЗАР<-ИНТИЗАР> БУЛУ.** Бик нык сагыну. *Аны бер күрергә зар булыр, ләкин мөмкин булмас сагыныр, хәятында ямь вә тәм калмас. Кем белә, тагы ниләр булыр!* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). *Аны, адаштырасы эт баласы сымак, Килем хәтле Килемгә илтеп ташлап, бер күрергә зар-интизар булып, елап ятып булмас* (В. Имамов. Утлы дала).

**БЕР КҮРМӘСКӘ ӘЛЛӘ НИ БИРЕРСЕҢ (БИРЕР ИДЕМ).** Бик ямьсез, котсыз нәрсә турында. *Үзе сүгенгән була: – Бер күрмәскә әллә ни бирер идем шуны, – дип, берәр бәләкәй хулиганны каргый* (М. Мәһдиев. Фронтовиклар).

**БЕР КҮРҮ** *к.* бер күз белән карау. *Әмма күңелен Коръән Кәрим белән ныклап бәйләп куйгач та, Мөсәллим гомере буе йөрәге янында йөрткән «Догалар»ыннан аерылмый, аны, Корьән сүрәләре белән бер күреп, өенең дә, күңеленең дә иң түр шүрлегендә тота...* (Г. Гыйльманов. Мөсәллим карт догалары).

Төрдәше: бер күз белән карау.

**БЕР КҮРҮДӘН ЕГЫЛЫП ТӨШҮ.** Беренче күрүдә үк сихерләнеп мавыгу, гашыйк булу тойгысы уяну. *Сизденме, безнең егет Ләйләне бер күрүдән егылып төште* (Сөйләм).

Төрдәше: баш әйләнү 8 һ.б.

**БЕР КЫЙБЛАГА ЙӨЗ ТОТУ.** Бер максатка, бер идеалга таба бару, көрәшү. *Нәтиҗәдә берничә фирма «Энергия-Сервис» белән килешүләрен өзәргә карар кылган. Нәтиҗәдә бер ноктага бер кыйблага йөз тоттык* (intertat.tatar).

**БЕР МӘГЪНӘ ДӘ БИРЕП БУЛМАУ.** Аңлашылмаган вакыйга, хәл, чыгыш һ.б. *Нәрсә турында сөйләде соң ул, моңа бер мәгънә дә биреп булмый* (Сөйләм).

**БЕР МӘРӘГӘ ТӘГӘРӘҮ.** Бер максатка таба хәрәкәт итү. *Бер мәрәгә тәгәрәй дә тәгәрәй дә тәгәрәй* (Ш. Бабич).

**БЕР МӘЧЕГӘ ИКЕ (ДҮРТ) ЭТ ЯБЫШУ.** Талашу. *Рәсәйдә бер мәчегә ике эт ябышкан дәвер иде, афәтле дәвер* (М. Әмирханов. Әлвидаг).

Төрдәше: әр-битәр белдерү (яудыру) һ.б.

**БЕР МӘШӘКАТЬ ЧЫГУ (ЧЫГЫП ТОРУ).** Кешене мәшгуль итә торган, көтелмәгән бер эш чыгу. <...> *Фәридә көндезләрен генә түгел, ә кичләрен дә колхоз эше диеп өйдән югала: йә идарә утырышына, йә җыелышка китә, йә бүтән бер мәшәкате чыгып тора аның...* (М. Вәли-Барҗылы. Тормыш дулкыннары). *Юлга әзерләнгән чакта гына көтелмәгән бер мәшәкать чыкты: куралар минем чемоданга сыймый икән* (Ә. Еники. Мәк чәчәге).

**БЕР МИНУТ ЭЧЕНДӘ** *к.* «а» дигәнче. *Шул рәвешле, Бәйрәшева бер минут эчендә бөтенесен үз урынына урнаштырып куйды* (А. Тимергалин. Юл чаты). *Ә яңгыр шундый көчәйде, бер минут эчендә шәһәр дә, Кабан да күздән югалдылар* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**БЕР МИНУТТА БИШ ТУҢДЫРЫП, БИШ ЭРЕТҮ** *шигъри.* Сихри гүзәллеге белән бер утка, бер суга салу. *Әй Зөләйха, бер елмайсаң, исертәсең. / Бер минутта биш туңдырып, биш эретәсең* (Ш. Бабич).

**БЕР МИЧКӘ (ТӘПӘН) БАЛГА БЕР КАШЫК ДЕГЕТ <САЛУ (ТӨШҮ)>.** Зур һәм яхшы әйберне боза алырлык вак-төяк турында. *Ләкин, кызганыч, бер мичкә балга бер кашык дегет җитә дигәндәй, сирәк кенә булса да мондый хәлләр дә очрый, һәм алар күңелдә кала* («Сөембикә» ж.). – *Адәми затлар бер мичкә балга бер кашык дегет төшүен, дәрья суларны бер тамчы кан кызылайтуын аңлаудан узганнар иде инде* (Ә. Гаффар. Богау). *Кызганыч, бер тәпән балга бер кашык дегетне белепме-белмичәме кем салды икән?* (И. Садыйк).

**БЕР МЫСКАЛ <ДА>.** Аз гына да. *Сыртланов ул хатынны таныды, ләкин бу аның уйларына бер мыскал да ачыклык кертмәде* (Ш. Хөсәенов). *«Гомеремнең бер мыскалын да / Бирмәм үкенечкә, / Кыялар баш иеп сынар / Безнең гайрәт-көчкә!..»* (Роб. Әхмәтҗан. Татар иртәсе).

**БЕР НАМАЗГА ИКЕ АЗАН ӘЙТЕЛМИ.** Һәр нәрсәнең үз тәртибе, кагыйдәсе булуга ишарә. – *Ә анысы икенче разговор. Бер намазга ике*

*азан әйтелми, ди татар* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**БЕР НӘФЕСЕН ТЫЯ АЛМАУ.** Аз белән канәгатьләнә белмәү, тиешсез эштән тыела алмау. *Бер нәфесен тыя алмаган кешене аны әйтмә инде. Ни үгетләдек, ни әйттек!* (Г. Бәширов). *<...> янәсе, тирә-юнендә шундын-шундый шомлыклар котырып торганда, яхшыдан яман туган балалар, бер нәфесләрен тыя алмыйча, марҗа итәгенә тагылып, деннәрен сатарга йөрсәләр, – Алла сакласын, – илгә әллә ниткән афәтләр килүе бар һәм башка, һәм башка шундый өркетүләр* (Ф. Хөсни. Поп кызы Әхсәнә).

**БЕР НИГӘ <ДӘ> САНАМАУ.** Исәпкә алмау, бик җиңел нәрсә дип карау. *Күтәрелеп килгән көчле җилне бер нигә <дә> санамыйча, ул көймәсен диңгезгә алып чыкты* (Сөйләм).

**БЕР НОКТАГА БАРУ (ЮНӘЛҮ).** Бер максатка юнәлү, һаман бер юнәлештә хәрәкәт итү. *Фикерен бер ноктага юнәлтергә тырышып, тәрәзә каршысында басып торды* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Ул бит әле менә хәзер үк үләргә әзер түгел!.. Ул бит әле аңа кадәр ниндидер бик мөһим бер ноктага барып җитәргә тиеш!* (З. Мифтахов. Күрәчәгең булса...).

**БЕР НОКТАГА БӘРҮ.** Сайлаган юлдан тайпылмау; әйткән сүздән, фикердән ваз кичмәү һ.б. *Ләкин үзенең төп уй юнәлешен югалтмады, инде бөтенләй икенче яктан китереп, шул ук бер ноктага бәрде* (М. Әмир). *Тормышта гел бер ноктага бәр – максатыңа омтыл, бар көчең-сәләтеңне шуңа бир* (Ш. Галиев. Сиңа әйтер сүзем бар).

**БЕР ОЛАУ САЛКЫН ИЯРТЕП.** Кышкы салкында ишекне зур итеп ачып керүчегә әйтелә. *Бер олау салкын ияртеп, ишекне зур-зур ачып килеп кергән кешенең кем икәнен карарга почмак яктан хуҗа хатын килеп чыкты* (Г. Ахунов). *Берсендә, карны шыгырдатып, үзе белән бер олау салкын ияртеп, әти эштән кайтып кергәндә, мин, бишектән егылып төшеп, идәндә шуышып йөрим икән* («Сөембикә» ж.).

**БЕР ОЧТАН.** 1. Бер материалдан. *[Гөлҗиһан] Бик матур, кәнәфиләрен, урындыкларын да – һәммәсен бер очтан шуның белән тышлатканнар* (Г. Камал. Банкрот). *Ул җиһазлары! Безнеке шикелле сырлы-мырлы тузан оясы түгел, бар да бер очтан, бар да импорт, палированный, күзге кебек ялт-йолт итеп кенә тора* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

2. Бер уңайдан *[Галимә] Шунда бер очтан гына Садрыйга да камзуллык алырсың* (М. Фәйзи. Галиябану). *Майя, тарагын алып, Хәлимнең сакал-мыегын тарады, бер очтан маңгаендагы миңенә кагылып үтте...* (Г. Гыйльманов. Албастылар).

**БЕР ОЧТАН КИСЕЛЕП ТЕГЕЛҮ** *күч.* Бер-берсеннән аермалары булмаган, бер иштән, бер төрле булу.). *«Алар икесе дә бер очтан киселеп тегелгән кешеләр ич»* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр).

Төрдәше: Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни һ.б.

**БЕР ОЧТАН КИСКӘН (КАЕЛГАН).** *к.* бер очтан киселеп тегелү. *Без барыбыз да бер очтан каелган... Ходайга шөкер, татарның гены – нәселдәнлеге көчле, «төштән соң» булса да, акылы да бар...* (Б. Рәхимова. Бакый сагыш).

Төрдәше: Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни һ.б.

**БЕР ОЧЫН ИКЕНЧЕ ОЧЫНА КИТЕРҮ (ЯЛГАУ).** Әңгәмәдә, чыгышта, мантыйкны саклап, төп фикердән читләшмәү. *Сөйләде, сөйләде, белгәнен дә, белмәгәнен дә бер өемгә өеп куйды, тик фикеренең бер очын икенче очына китерергә генә онытты* (Сөйләм).

**БЕР ОЯ.** Бик күп. *Уазик шоферын ияртеп, идарәдән Ихлас чыкты, бер оя булып бөялеп торган казанлыларга каш сикертеп сәлам юллады да: «Сыешыгыз!» – дип боерды* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Бер оя бала үстергән Биказаковлар да, «бер ызбага сыешмаган Мокыч баба токымы» да ярлылар чутында йөргәннәр* (Л. Хәмидуллин. Кичке шәфәкъ).

**БЕР ОЯ ЧЕБЕШЛӘРЕ (КАЗ БӘБКӘЛӘРЕ).** Бер тәрбия алып, бергә үскән кешеләр хакында. *Бер оя каз бәбкәләре кебек үскәннәр иде балалары, таралдылар да беттеләр, олы уллары да, монда, авылда, күзгә чалынырлык кызларыгыз да юк дип борын чөеп, Яр Чаллы шәһәрендә яшәүне төс итте <...>* (Ф. Яхин. Куш каен аланлыгы).

**БЕР ПОТ ТОЗ АШАУ.** Берәү белән озак вакыт бергә булып, тормышның яхшылыкларын да, начарлыкларын да тату. *Һәм Зиннуров китте портфель тотып (Бер пот тоз ашамый, ни беләсең?)* (Г. Афзал). – *Мондый гына эшләрдә Айдар абзаң инде бер пот тоз ашаган* (Р. Вәли).

**БЕР РӘТ ШУЛАЙ.** Бервакыт, бер мәртәбә шулай (берәр вакыйга яки мәзәкнең башламы). *Бер рәт шулай җиләк ашап кайтыйм әле дип, урманга юл тоттым* (Сөйләм).

**БЕР РӘТЕН ТАБУ.** Чарасын булу, җайлау, әмәлен табу. *Эшендә берәр төрле тоткарлык килеп чыккандыр дисәң, ул чакта да берәр рәтен табар иде телгән кеше* (В. Нуруллин. Җавап бир, кеше). *Ят кеше алдында сер бирү була дип карады, шулай ук әти-әнисен дә яман яктан күрсәтәсе килмәде, вакыты җиткәч үзләре төшенерләр, әти-таш йөрәкнең башы җитмәсә, әни күңеле чыдамас, ничек тә бер рәтен табар, дип көтте, һәм ул уйлаганча булып чыкты да* (Ф. Хөсни. Гыйльмениса).

**БЕР САМАВЫР КАЙНАРЛЫК ВАКЫТ.** Чирек сәгать вакыт. *Бер самавыр кайнарлык вакыт үтмәгәндер, йортка бала-чага җыела башлады* (К. Нәҗми).

**БЕР САНАУ.** Тиң, бериш күрү; бер дәрәҗәдә кабул итү. *Мәет сыны янына тере кеше сыны куеп калдыру ул тере кешене тереләй күмү белән бер санала иде* (Н. Фәттах. Аклан). *Соңрак хәтта изгеләр каберенә килеп дога кылу хаҗга бару белән бер саналга* (Л. Шәйдуллина. Ислам динендә изге хатыннар культы).

**БЕР САПЛАМ ҖЕП ОЗЫНЛЫГЫ.** Энәгә бер сапларга җитәрлек җеп (кыска булуга ишарә). *Безгә, бер саплам җеп озынлыгында гомер бирелгән Кеше атлы Адәм балаларына, мәңге яшәрташ сын да, шигырьдәгечә, «ак болыт булырга да язмаган»...* (Р. Фәйзуллин). – *Әниең шулай ул. Бер саплам җеп озынлыгы гына уй йөртә ала. Уйны аны еракка төбәргә кирәк* (Х. Камалов. Куян күзе нигә кызыл?).

**БЕР САРЫК АШЫГЫ.** Бер үк фикерле, гадәтләре дә охшаш булган, бер-берсен кабатлый торган кешеләр. *Син сорады дип кенә, башка төрле эшләр дип уйлама – бер сарык ашыгы бит алар* (Сөйләм).

**БЕР САРЫКТАН ИКЕ КАТ ТИРЕ ТУНАУ.** Аяусыз эксплуатацияләү, мәрхәмәтсез булу. *Ул гавамны көн-төн талауны гына белә. Бер сарыктан тирене ике кат тунамакчы* (В. Имамов).

**БЕР САФКА БАСУ.** Дәрәҗәләре бер үк югарылыкта булу. *Бүген алар тигез, Нәҗип – Вафа белән бер сафка басарга ниятләп, юлга чыккан иде!..* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Нәҗип, урта мәктәпне тәмамлагач, уку алдынгысы буларак, үз мәктәбендә калдырыла, остазлары белән бер сафка басып, җиде ел буе балалар укыта* (Г. Гомәр. Шәхесләр һәм шәрехләр).

**БЕР СӘГАТЬЛЕК (КӨНЛЕК) ХӘЛИФӘ.** Кыска вакытка башлык вазыйфаларын башкарган кеше хакында. *Шулай итеп, 1918 ел башында «бер сәгатьлек хәлифә» төсле генә «Болак арты республикасы» яшәп килде* (М. Җәлил). *Теге «Кырык вәзир»дәге «Бер сәгатьлек хәлифә»не укыгансыңдыр, нәкъ шуның сыман* (Х. Мәхмүтов. Изге китаплар кайтавазы).

**БЕР СӘГАТЬТӘ МЕҢ БОТАККА КУНУ.** Үтә кыбырсык, җилбәзәк, тотрыксыз кеше хакында. *Бер сәгатьтә мең ботакка кунарга өлгергән кош кебек, урынында бер дә тик кенә утыра алмый* (Сөйләм).

**БЕР СЕКУНД ЭЧЕНДӘ** *к.* «а» дигәнче. *Бер секунд эчендә шул ачы уйлар аның башыннан кичте* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Капкадан Мөбәрәкҗан кереп килә иде! Бер секунд эчендә Әхмәдинең башыннан бөтен гомере йөгереп узды* (Аманулла. Сөяркә).

Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**БЕР СЕЛТӘҮДӘ.** Берьюлы, бер кизәнүдә. *Корыч-Тимер куанып ырылдап җибәрде, бер селтәүдә Тотышны юк итмәкче булып, Будрач сукман сыман, кылычын ике куллап югары күтәрде* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур). *Җитмеш ел төзегән идек, / Бер селтәүдә җимердек* (Н. Әхмәдиев. Безнең ил, безнең тормыш).

**БЕР СТАКАН СУДА ДАВЫЛ (ТАЙФУН) КУБАРУ (УЙНАТУ).** Әһәмиятсез бер вак-төяк өчен шау-шу чыгару. *Ул шигырьдә әтәчләнми,*

*чәчрәп кычкырмый, бер стакан суда тайфун уйнатмый* (Ә. Зәкиҗанов. Ләбиб Лерон).

**БЕР СУКМАКТАН АТЛАУ.** Фикердәш, тарафдар булу. *Гасыр башында һәм Гражданнар сугышы елларында татарның бик күп алдынгы вәкилләре, большевикларның милли азатлык лозунгларына ышанып, партиягә керделәр, алар белән бер сукмактан атладылар* (Р. Мостафин. Төгәл булыйк!).

**БЕР СУЛЫШТА.** «Ыһ» дигәнче, тын да алмыйча. *Рәфис бер сулышта ашыга-ашыга сөйләп бетерүгә, Васильев акрын адымнар белән стенадагы Татарстан картасы янына килде, бармагы белән салмак кармаланып, Актайны эзләп тапты* (А. Вергазов. Үзеңә кайту). *«Аймыл»ны бер сулышта укып чыктым да шундый фикергә килдем: Әхмәтнең күпчелек әсәрләрендәге төп геройлар – тормыш тарафыннан кагылып-сугылган, рәнҗетелгән, әмма күңелләре белән саф, вөҗданлы, намуслы бәндәләр* (Ф. Садриев. Моңсулык).

**БЕР СҮЗ ӘЙТЕР ХӘЛ ЮК.** 1. Берәрсенең башкалар фикерен тыңламавы, кабул итмәве. *Асрауларның да берсенә дә бер сүз әйтер хәл юк, хәзер үзеңнән битәр, биш өлеш артык итеп кычкырырга торалар* (Г. Камал). *[Антонина] Соңгы айларда аның нервлары бик какшады, бер сүз әйтер хәлем юк, хәзер кабынып китә* (Т. Гыйззәт).

2. Гаеп итү яки каршы килү мөмкинлеге калмау. *Бер сүз әйтер хәл юк, шулай дип авызны томалыйсың* («Көмеш кыңгырау» газ.).

**БЕР СҮЗ ӘШРИКЪКӘ, ИКЕНЧЕСЕ МӘШРИКЪКА КИТҮ.** Төзек итеп сөйләмәү, таркау булу. *Шулай инде, әби мине һәрвакыт: «Бер сөйли башлачаң, бер сүзең әшрикъка, икенчесе мәшрикъка китә», – ди* (Г. Үзиле. Ленин, Дарья Петровна, мин һәм башкалар).

**БЕР СҮЗ БЕЛӘН <ГЕНӘ ӘЙТКӘНДӘ>.** Кыскасы, кыскача әйткәндә. *Бер сүз белән генә әйткәндә, килгән көнне үк үлеп гашыйк булдым мин аңа* (В. Нуруллин. Күпер чыкканда). *Бер сүз белән әйткәндә, яраткан Нурмөхәммәт бу төбәкне* (З. Мурсиев. Ташмәчет).

**БЕР СҮЗ БЕЛӘН СУ АСТЫННАН ШАЙТАНЫҢНЫ ЧЫГАРЫР.** Үтә үткен, гайрәтле кеше хакында. *Үтә чая, бармагыңны каптырсаң, өзеп алырлык, бер сүз белән су астыннан шайтаныңны чыгара торган кыз иде Миләүшә* (Сөйләм).

Төрдәше: су астыннан шайтаныңны тартып (сөйрәп) чыгару.

**БЕР СҮЗ<ДӘ> МЕҢ АЛТЫН.** Сүзнең үтә кыйммәтле нәрсә икәнлеге турында. *«Бер сүздә мең алтын», – дип әйтү бар* («Кызыл таң» газ.).

**БЕР СҮЗ ЮК (БУЛМАУ; ӘЙТМӘҮ).** Каршы килмәү, ризалашу. – *Менә өй артындагы тиреслегебездә, Гөлмәрфуга, син оя кормаган булсаң, безгә дә күңелсез булыр иде. Бер сүзебез дә юк, исән-имин яши күрегез, балалар үрчетегез* (А. Хәсәнов. Гөлмәрфуга). *Маһирәң белән кайтсаң да бер сүзем юк. Әткәй дә олыгаеп бара бит...* (Г. Галиева. Газзәбану).

**БЕР СҮЗГӘ БИШ (КЫРЫК) ҖАВАП <ТАБУ>.** Сүзгә бер дә аптырамау, оста телле булу. *Алла сакласын бу чактагы яшьләрдән, бер сүзгә кырык җавап табалар* (М. Фәйзи. Яшьләр алдатмыйлар). *Гадәттә бер сүзгә биш җавап табучы Зөләбирә нишләрен белмичә ык-мык килде* (М. Миншин. Кызыл диплом).

Төрдәше: авызга җен төкерү һ.б.

**БЕР СҮЗГӘ БИШ (УН; МЕҢ) СҮЗ.** Сүз көрәштереп, карышып тору. *Егетләр – тумышлары белән Казаннан, бер сүзгә ун сүз белән кайтаралар* («Безнең гәҗит» газ.). *<…> сүз саен бүлдереп, бер сүзгә ун сүз белән, бер сорауга 20 җавап белән кимсетәбез... аңардан көләбез...* (matbugat.ru).

Төрдәше: бер телгә биш тел.

**БЕР СҮЗГӘ КИЛҮ.** Килешү; уртак фикер, уй табу. *<…> алар урынна яңа фикер, яңа хис тудырдымы, иллә башкача берәр сәбәп булдымы, алар, яңадан бер мәртәбә сөйләмәенчә дә, шул фикердә Сәгыйдә белән бер сүзгә килделәр* (Г. Исхакый. Остазбикә). *Юк, бездә бер сүзгә килү юк* (Ә. Фәйзи).

Төрдәше: бер сүзле 2; бер фикергә килү; борчак бүрттерү; борчак куыру; борчак пеш<ер>ү; ботка пеш<ер>ү; уртак тел; уртак тел табу; ярма бүртү.

**БЕР СҮЗДӘ <БУЛУ; БАРУ>.** Бер фикердә торып, килешеп эш итү. *Шул инде сезнең... мин*

*сизеп ятам, сез барыгыз да бер сүздә* (Г. Бәширов. Намус). *[Юлай] Бер сүздә булсак, йөзгә бәрелмәсләр* (Р. Хәмид).
Төрдәше: бер сүздә тору.

**БЕР СҮЗДӘ ТОРУ** *к.* бер сүздә <булу; бару>. *«Волостьтан килеп, иснәнеп йөри башласалар, барың да бер сүздә торырга, – бөтен ил белән булгач, бер начальникның да көче җитмәс»* (И. Гази. Онытылмас еллар). *Белеп тор! Ул минем белән бер сүздә тора!* (Ф. Яхин. Серле Камка).

**БЕР СҮЗДӘН БИШ МӘГЪНӘ ЧЫГАРУ**. Әйткән сүзне төрлечә аңлатырга мөмкин булу хакында. *Фәрдәнәнең әнисе Фирая ханым, чыннан да, бер сүздән биш мәгънә чыгара торган хатын иде* (М. Әмир).

**БЕР СҮЗЕ МЕҢ АЛТЫН.** Һәр сүзе уйланылган, мәгънәле, бик кирәкле кеше турында. *Сезгә еракта килгән кеше белән фикер алышырга бармыйча калырга ярыймы соң? Белгәнемчә, аның бер сүзе мең алтын* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан чыгуга (чыкканчы) эләктерү (эләктереп / элеп кенә) алу һ.б.

**БЕР СҮЗЕҢӘ МЕҢ ҖАВАП.** 1. *к.* бер сүзгә биш (ун; мең) сүз. *Бер сүзеңә мең җавап ишетәчәксең һәм һәрвакыт «аста» калып, ахыр чиктә җиңелүдән барыбер тотлыга башлаячаксың!* («Сөембикә» ж.).

2. Җавап табарга аптырамаган, сүзгә оста кеше. *Бер сүзенә мең җавап табып, Фәхриҗамал абыстайны да бер авыз ачарга урын калдырмаган иде* (Я. Вәли). *Ачуланырсың аны! Бер сүзеңә мең җавап таба бит ул!* (М. Хуҗин. Айның уты сүнгән).
Төрдәше: авызга җен төкерү һ.б.

**БЕР СҮЗЛЕ.** 1. Сүзне ике тапкыр сөйләми торган, туры сүзле кеше; катгый итеп әйтү. *Дөресен генә әйткәндә, Одик та, мин дә бик арыган идек, моннан соңгы кибән булыр дип уйладык, әмма Хак бер сүзле икән, күзне дә ачтырмады* (Р. Сибат. Исабәт). *Халыкта «ирдавай» сүзен күтәргән, ирләрчә бер сүзле, таләпчән, ачы телле, усал Ралия Сагитовна була торып та, ничә еллар буе баш иеп яшәде ул шул Килмешәккә* (Г. Мирһади. Килмешәк).
Төрдәше: әйткән – беткән (бетте) һ.б.

2. Фикердәш, тарафдар булу. <…> *ул, Чистайның карагруһлары берлә бер сүзле булып, сайлауларда карагруһларны гына үткәрер өчен, күзгә күренгән бер кешене арестовать итәргә тотынды* (Г. Исхакый. Зиндан). *[Әпрәй] Беләм инде, җыйнаулап бер сүзле булдыгыз да каныктыгыз инде миңа* (А. Алиш. Күршеләр).
Төрдәше: бер сүзгә килү һ.б.

**БЕР СҮЗНЕ ИКЕ ТАПКЫР СӨЙЛӘМӘҮ (ӘЙТМӘҮ; КАБАТЛАМАУ).** Әйткән сүздә тора белү, биргән вәгъдәңне үтәү. *Атакай тугарырга ашыкмый, нидер аңлатмакчы була, ләкин отряд башлыгы, аңа җикеренеп: «Без бер сүзне ике тапкыр кабатларга яратмыйбыз, тиз бул, гражданин!» – дип кенә кычкыра* (Ә. Еники. Соңгы китап). *Бу, без бер сүзне ике сөйләмибез дигән мәгънәне аңлата иде* (Р. Батулла. Сөембикә).
Төрдәше: аяк терәү 1 һ.б.

**БЕР СҮЗНЕ ТУГЫЛАУ (ТӘПӘҮ).** Һаман бер нәрсә турында сөйләү. *Марфаның хәтерендә, еш ишетеп тә, шулайдырмы-юкмы дип уйларга башына да килмәгән, әмма авылдашларыннан да сорашып белешмәгән, һәркемнең телендә йөргән бер сүз тугыланды* (Ф. Яхин. Август ае).
Төрдәше: авызда бер үк җыр <булу> һ.б.

**БЕР СҮЗСЕЗ** *к.* бер авызсыз. *Хатын бер сүзсез ризалык биргән: «Ул мыкты җегет күңелемә яраган иде, өч ел көттем үзен», – дип, бөтенләй вәгъдә биргән* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *Ләмига монысында бер сүзсез буйсына, тик ул хиссез генә сыйлана* (Р. Гаязетдин. Язмыш сәфәре).
Төрдәше: бер авызсыз.

**БЕР ТАБАКТАН АШАУ** *к.* авызга-авыз сөйләшү. *Дус кыланып, бер табактан ашап йөргән сердәшләренең кайсыдыр теленә ирек бирде шул авылда, «җен тубалы» турында күпертелгән-кабартылган гайбәт таралды* (Н. Гыйматдинова. Сихерче). *Шушы көннән башлап, бер йортта яшәгән, бер табактан ашаган ике яшь хатын арасында көрәш башланды* (Д. Булатова. Чынаяк).
Төрдәше: авызга-авыз сөйләшү һ.б.

**БЕР ТАБАННАН ТОРЫП КӨРӘШҮ.** Бер сүздә булып, бер эш өчен бергәләп көрәшү. – *Әйдәгез, егетләр, бер табаннан торып көрәшик, аерым-аерым маташканда, бернәрсә дә барып чыкмас* (Сөйләм).

**БЕР ТАВЫКНЫ УНГА БҮЛҮ** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. *Бер тавыкны унга бүлгән кешене күргәнең бармы, булмаса, иртәгә күрерсең* (Сөйләм).
Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**БЕР ТАВЫШТАН** *к.* бер авыздан 1. *Алдан уйнап килүче оркестрлары булмаса да, сафларга тезелеп, кызыл байракларын күтәреп, бөтенесе бер тавыштан җырлап, чын гаскәрләрчә төп урам буйлап уздылар* (Ә. Еники. Соңгы китап). *– Коляскасы?! – диделәр бар да бер тавыштан* (М.Кәбиров. Канатлы кеше).
Төрдәше: бер авыздан 1.

**БЕР ТАГАРАК ДУҢГЫЗЛАРЫ.** Һәммәсе дә тамакка сатылып, бер тирәдә туенучы кабахәт кешеләр төркеме. – *Килмини, алар барысы да бер тагарак дуңгызлары* (И. Гази. Онытылмас еллар).
Төрдәше: Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни һ.б.

**БЕР ТАКТАГА КУЮ.** Бер нәрсә белән, берберенә тиң санау. *Табучы белән багучыны бер тактага куеп булмый, – диде кәтиб Хафиз. – Ярар, куеп торыйк әле ул хәлләрне* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы). *Хәер, Госкомиздат дигән мәшһүр системада татар халкының бердәнбер китап нәшрияты, русның провинциаль яки ведомство нәшриятларыннан да мескенрәк хәлгә төшерелеп, район газеталары белән бер тактага куелган иде инде* (М. Вәлиев. Гамәл дәфтәре).
Төрдәше: Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни һ.б.

**БЕР ТАКТАСЫ ҖИТМИ (КИМ)** *к.* акыл бергә дә тулмау. *Андый пешеп җитмәгән балаларны коймасының бер тактасы ким дип йөртәләр* («Ватаным Татарстан» газ.).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

**БЕР ТАЛАЙ.** Бераз вакыт, шактый санда. *Дина мине кочаклап үпкәннән соң, бер талай үзем белән ни булганын төшенеп бетмәдем* (В. Ильясов. Балыкчы малай). *Ә күп гасырлар буена килгән гүзәл, мәгънәле исемнәр никтер балаларга кушылмый. Бер талай сүз нигәдер бик тар аңлашылган иптәшләргә* (Й. Гәрәй. Сүз җыярга килегез).

**БЕР ТАМАГЫНА ХУҖА (БАШ) БУЛМАУ (БУЛА АЛМАУ).** Ашаганда чамасын белмәү. *Бер тамагына хуҗа була алмаса, сары йортка озатырга вәгъдә итте сөекле кәләше* (К. Кара. Депрессия). *Югыйсә Мисбах отчет төзергә кирәклеген дә, ул отчетны районга алып барып тапшырыр вакыт җиткәнен дә белә иде. Әмма туя белмәгән бер тамагына баш була алмады* (Н. Әхмәдиев. Мөнирстан).

**БЕР ТАМАША.** Мавыгып карап торырлык бер күренеш. – *Бүгенге дулавыгыз да чираттагы бер тамаша гына* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Ак мәчетнең балкыр яшел гөмбәзе. / Үзе бер тамаша: гадел хезмәт аша / Яктыра лабаса авыл йөзләре* (К. Булатова. Аек булса халкың).

**БЕР <ГЕНӘ> ТАМЧЫ <ДА>.** Һич, бөтенләй; аз гына да. *Картның бер тамчы буш вакыты калмады: әле завод администрациясе белән сөйләшү алып бара; әле забастовка комитеты җыелышында утыра; әле эшчеләр белән сөйләшә* (И. Гази. Онытылмас еллар). *Ә Карабәк бер генә тамчы да кыргыйлык һәм әрсезлек күрсәтмәде, үзен тыя белде* (В. Имамов. Карабәк).
Төрдәше: тамчы да.

**БЕР ТАМЧЫ ДА УРТАКЛЫГЫ ЮК.** Бөтенләй аерылып тору, охшашлык булмау. *Әбелнәгыйм ихатасында чалшайган йорт, тезгә чүккән мунча, ярым җимерек лапас белән бер тамчы да уртаклыгы юк икән бит моның* (В. Имамов).

**БЕР ТАМЧЫ СУ КЕБЕК.** Бик охшаш булу. *Берничә мизгелдән бер-берсенә бер тамчы судай охшаш, баһадир гәүдәле бу кешеләр үз-үзләрен белештермичә кочаклашалар, аркаларына шап-шоп бәрешәләр иде* (Ф. Латыйфи. Хыянәт). *Ул Азатның кызына бер тамчы су кебек охшаган иде* (А. Нәҗми. Азат).
Төрдәше: авыздан өзелеп төшү 1 һ.б.

**БЕР ТАҢНАН ИКЕНЧЕ ТАҢГА КАДӘР.** Төн йокларга да вакыт калдырмыйча эшләү. *Илаһи көч бар үзендә! Бер таңнан икенче таңга кадәр һич тукталмый, өзлексез диярлек бит* (А. Гыйләҗев. Истәлекләр). *Үз гомеремдә авиациядә хезмәт иткәндә, сугыш елларында, бер таңнан икенче таңга кадәр эшләп арыган атлар, алҗып хәлдән тайган кешеләр күргәнем булды минем* (М. Юныс. Европа ат сагына).
Төрдәше: ал белми, ял белми <эшләү> һ.б.

**БЕР ТАПКЫР КИСКӘНЧЕ, МЕҢ (ЙӨЗ) ҮЛЧӘҮ.** Нәрсәнедер үтәргә алынганчы, яхшылап уйларга кирәклеге хакында. – *Төш вакыты үтүгә үк ачып чыга торган ашны пешермәсәнә, бер тапкыр кискәнче, мең үлчәргә өйрән!* (В. Имамов. Карабәк). *Шуңа күрә һәр нәрсәгә игътибарлы булырга, бер тапкыр кискәнче, йөз тапкыр үлчәргә генә кала* («Яшел Үзән» газ.).

**БЕР ТАРАК БЕЛӘН ТАРАУ.** Бөтен нәрсәгә бертөрле бәя бирү. *Барыбызны да бер тарак белән тарап, шалт, иптәш Чанышев, бир кулыңны богау салырга, мине дә утыртып куйдылар, – дип өстәде Габбас* (А. Хәсәнов. Данәгөл). *Шулай, Вакыт Галиҗәнаплары алдында без һәммәбез дә тигез, ул син түрә, син академик дип тормый, барчабызны бер тарак белән тарый* (М. Әмирханов. Тояк эзе).

**БЕР ТАШ БЕЛӘН ИКЕ КОШНЫ ОРУ(БӘРҮ)** *к.* бер атканда (атуда) ике (куш) куян алу. *Хәзер тиз генә чыгып, сүземне әйтәм дә китәм дип уйлаган иде, соңыннан гына бер таш белән ике кошны органлыгын аңлады* (Сөйләм).

Төрдәше: бер атканда (атуда) ике (куш) куян алу һ.б.

**БЕР ТАШЫП, БЕР ТҮГЕЛӘ ТОРГАН.** Тиз кызып, тиз сүрелә торган кеше турында. *Ул бер ташып, бер түгелә торган кеше түгел, төрле яклап уйламыйча, аягын да атламый иде* (Сөйләм).

Төрдәше: бармалы да кайтмалы; бәреп тә егар, тартып та торгызыр.

**БЕР ТӘКЪДИР КУБЫЗЫНА БИЮ.** «Язмыштан узмыш юк» дип яшәү. *Янә дә килеп, болар икесе дә бер үк сират күпере аша үткән, бер үк тәкъдир кубызына биеп йөриләр бит* (В. Имамов. Карабәк).

**БЕР ТӘН, БЕР ҖАН БУЛЫП ЯШӘҮ** *к.* авыздан-авызга сөйләшү. *Унҗиде ел бер тән, бер җан булып яшәгән бербөтен икегә бүленде, араларына беренче тапкыр кара күләгә ятты* (Ф. Латыйфи).

Төрдәше: авыздан-авызга сөйләшү һ.б.

**БЕР ТӘРТӘГӘ ҖИГ<ЕЛ>Ү.** 1. Тигез карау. – *Син үзең белән мине бер тәртәгә җикмә, – дип акырып җибәрде Сәүбән, чыгып китмәкче булып ишеккә ташланды* (Ф. Хөсни). *Марий Элда әйтелгән сүзләрдән соң татар белән башкорт телләре бер тәртәгә җигелгән атлар кебек булырга тиеш* («Самара татарлары яңалыклары»).

2. Бер үк эшне башкару. *Бакый аганың тормыш иптәше Мәдинә апаның да шул ук мәктәптә кулга-кул тотынып, бер тәртәгә җигелеп, укыту тәрбия эшендәге кыенлыкларны бергә чишеп, бер кадакка сугып эшләве дә аерым әһәмияткә ия* (Р. Зарипов. Тирән тамырлы Түнтәрем). *Хәзер алар Лохмачев белән бер тәртәгә җигелделәр. Хәзер «Чолман»да күп нәрсә үзгәрде* (Р. Юныс. Таңда Босфор аша).

**БЕР ТӘРТӘГӘ КЕРҮ.** Бер фикер тарафдары булу, кем беләндер бергәләп эшләү. *Аның җыен җыентык, тәмам яраксызга әйләнеп беткәннәр белән бер тәртәгә кереп, әтрәк-әләмне мичәүдә тартып барасы килмәде* (Ә. Гаффар. Кәфенгә кесә текмиләр).

**БЕР ТЕГЕЛӘЙ, БЕР БОЛАЙ КИТЕРҮ** *к.* бер болай, бер тегеләй китерү. *Өйгә кайткач, бер аулакка постым да күзгене бер тегеләй, бер болай китереп, бер куанып, «тик...» дип, нәрсәнедер әйтми калуына күңлем сүрелеп, йөземнән бик озак Сәлимә әйткәнне күрергә тырыштым* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**БЕР ТЕГЕРМӘН ТӘГӘРМӘЧЕНӘ СУ САЛУ.** Сүздә бертөрле булса да, чынлыкта башкача эш итү. *[Камил] (Хәмзәгә). Шуның өчен [башкорт милләтен берләштерү] көрәшкән буласың. Ә карaганда, бер тегермән тәгәрмәченә су саласың* (Ш. Усманов. Канлы көннәрдә).

**БЕР ТЕЛГӘ БИШ ТЕЛ.** Сүз көрәштерү, эшләмәс өчен төрле дәлилләр китерү. *Урманга җиләк җыярга бармас өчен, бер телгә биш тел белән әллә нинди сылтаулар китереп, өйдә калу өчен тырышты* (Сөйләм).

Төрдәше: бер сүзгә биш (ун; мең) сүз.

**БЕР ТЕЛЕМНЕ <БЕРГӘ; БИШКӘ; УРТАЛАЙ> БҮЛЕШҮ.** Авыр, һәлакәтле көннәрдә соңгы сынык икмәкне бүлешеп, җаннарын саклап калу. *Аның белән күпме сулар кичеп, / Бер телемне бүлдек урталай* (Ф. Яхин). *Икмәге дә уңмады. / Бер телемне бишкә бүлде / Аның ябык куллары* (Г. Латыйп).

**БЕР ТЕЛЕНӘ БАШ (ХУҖА) БУЛА АЛМАУ.** Кызган килеш һич кирәксез сүзләр сөйләү, ни сөйләгәнне белмәү. *Ай Алла, бер теленә баш була алмадың лабаса* (М. Әмир). *Кара инде бу башкисәрне, шунда да бер теленә хуҗа була алмый бит* (Г. Гомәр. Гармун телләре унике).

**БЕР ТИЕН <БАКЫР>.** Бик арзан, очсыз. *Бирсәңезче бер тиен тик, / тәңкә түгел бит, «тиен»!* (Г. Тукай). *Кабак олы, бәһасе бер тиен* (Мәкаль). *Мин аңа кызыгырлык мескен бәндә түгел, аның миңа, гомумән, поты бер тиен!* (В. Имамов. Нәзер).

2. Кыйммәте булмаган, әһәмиятсез, кирәксез. – *Беркем белән дә танышканым юк, – дип мыгырдандым мин, – кирәге-кирәкләре бер тиен* (А. Гыйләҗев. Язгы кәрваннар). *[Хөсәен] Югыйсә миндә менә бу ике аяклы хайваннарның очы-чиге юк... Тик файдалары гына бер тиен бакыр йөрми* (Ф. Бурнаш. Хөсәен мирза).

Төрдәше: базарың бер тиен һ.б. (ике маддә өчен дә).

**БЕР ТИЕН БИРЕП СӨЙЛӘТЕП БУЛМАУ, ИКЕ ТИЕН БИРЕП ТУКТАТЫП БУЛМАУ.** Башта ялындырып та, сөйли башлагач туктатып булмый торган кеше хакында. *Шул иптәш сүз арасында түбәндәге мәкальне китерде: «Аны бер тиен биреп сөйләтә алмыйсың, ун тиен биреп туктата алмыйсың, диләр» – диде* (Л. Җәләй. Афзал Шамовка язган хат).

**БЕР ТИЕН ДӘ ТӨШМӘҮ.** Сатуда товар бәясен һич киметмәү. – *Юк, дус кеше, күршедән сорап кара, мин бер тиен дә төшмим* (Сөйләм).

**БЕР ТИЕН(Е) ДӘ ЮК.** Бернинди дә малы булмаган фәкыйрь кеше хакында. *Ул шыр ятим. Хәзер дә менә кесәсендә бер тиене юк. Иманым камил* (Б. Камалов. Үткәннәргә борылып карасам). – *Юк. – Битарафлык короле башын калкытырга кирәк санады. – Кесәдә шалтырап торган сукыр бер тиен юк, ә өй эче тулы акча...* (Д. Салихов. Гыйләҗ тәрәзәләре).

Төрдәше: авызны ачса, кече теле күренү һ.б.

**БЕР ТИЕН КЕРГӘН БАЙ БУЛГАН (БАЕГАН).** Кечкенә генә табыш алса да, үзен байга санап, масайган кеше турында. *Бер тиен кергән баеган, бер тиен чыккан бөлгән* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

**БЕР ТИЕН КУЯН, УН ТИЕН ЗЫЯН.** Вак кәсеп белән маташып, файдасыннан күбрәк зыяны булу. *Бабасы «бер тиен куян, ун тиен зыян» дип кабатларга яратса да, ул кырыктартмачылыгын каләм кебек вак-төяк сатудан башлады* (Сөйләм).

**БЕР ТИЕН ӨЧЕН ДЕРЕЛДӘП ТОРУ** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. *Тапкансың бурычка сорарга кеше, бер тиен өчен дерелдәп тора бит ул* (Сөйләм).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**БЕР ТИЕН ӨЧЕН ҖАНЫН САТУ (БИРҮ)** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. *[Сәрби] Белмим шул, сыйлар микән! Бер тиен өчен җан бирергә торган кеше дуп-дуамалга нигә сыйласын* (Т. Гыйззәт). *Бер тиен өчен җанын сатарга әзер торган Мәсабих, кызының һәм хатынының күз яшьләренә, ялваруына карамый, ризалыгын шунда ук бирә* (Н. Әхмәдиев. Амбирак).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**БЕР ТИЕН ӨЧЕН ҖӘҺӘННӘМГӘ КЕРҮ** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. *Шахтада эшләгән вакытында ул бер тиен өчен җәһәннәмгә керергә дә риза булган, диләр, аннан соң ни булганын белмим* (Сөйләм).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**БЕР ТИЕН ӨЧЕН ЙОЛДЫЗГА КАРМАК АТУ.** Тормыштагы идеалы – күп акча булу. *Абзыегыз бер тиен өчен йолдызга кармак ату хыялы белән яшәп, теге дөньяга китеп тә барды* (Сөйләм).

**БЕР ТИЕН ӨЧЕН КАРА ТИРГӘ ТӨШЕП САТУЛАШУ** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. *Имәнкол исә бер тиен өчен кара тиргә төшеп сатулаша* (К. Нәҗми). *Көнкүрештә бер тиен өчен кара тиргә төшеп сатулашучы «Саран Исмай», ни гаҗәп, уен чутында юмарт байга әверелә дә куя* (М. Әмирханов. Әлвидаг).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**БЕР ТИЕН ӨЧЕН ТУГАНЫН САТАРГА ӘЗЕР ТОРУ (БУЛУ)** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. *Отставкага чыккач, эшсезлектән кая барып сугылырга белмәгән хәрбиләр дә, майлы бәлеш төбенә исәп тоткан эш сөймәс ата ялкаулар да, бер тиен өчен туганын сатар-*

*га әзер торган, кулына ике сум хәер керсә, берсен – машинага, икенчесен коттеджга багышлап, аерым кесәгә салып куйган комсыз ач күзләр дә, кыскасы, буталчык заманның болганчык суында балык тотарга яратучы кайбер әхлаксыз бәндәләр кайсыбер мәчетләр тирәсенә елышты* (Р. Кәрами. Авыл халкы күрсә...).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**БЕР ТИЕН ӨЧЕН ҮЛГӘН (ҮЛЕП ТОРУ)** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. – *Аерылсын ошамаса, шулай бер тиен өчен үлеп торган карун булгач* (Г. Гомәр. Гармун телләре унике). *Әле кайчан гына бер тиен өчен үлеп китәргә әзер Гомәр хәзер әнә ничек бөеренә таянып сөйләшә* (А. Хәсәнов. Балыкчы маҗаралары).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**БЕР ТИЕН ӨЧЕН ЧЕРӘЕП КАТУ** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. *Аны яшьрәк вакытында бер тиен өчен черәеп каткан, дип сөйлиләр* (Сөйләм).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**БЕР ТИЕН ӨЧЕН ЧУКЫНУ (ЧУКЫНЫП ТОРУ)** *мыск., к.* алырсың шайтаннан иман 2. *Үзе тагын, мәрхүм, йомышка керсәң, йомыш бирми торган, бер тиен өчен чукына торган чиксез саран кеше ие* (Г. Толымбай. Читән буенда). – *Кит, бер тиен өчен чукынасың бит син* (Н. Гыйматдинова).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**БЕР ТИЕН САДАКАГА МЕҢ СУМ ТЕЛӘГӘН ХӘЕРЧЕ (ТЕЛӘНЧЕ) КЕБЕК** *мыск.* Үзе хәерче булып та баю юлларын өйрәткән кеше хакында. *[Зәйнетдин] Хикмәти Хода, барысы да мине баетмакчы булалар. Теге бер тиен садакага мең сум теләгән теләнчеләр төсле. Ха-ха-ха!..* (К. Тинчурин).

**БЕР ТИЕН<ГӘ> ТОРМАСЛЫК (ТОРГЫСЫЗ)**. Бик начар; бернинди кыйммәте, игелеге булмаган нәрсә яки кеше турында. *Карыйсың, хатыны бер тиенгә торгысыз кеше* (М. Мәһдиев). *Җырларының сыйфаты, башкару сәләте, үзләренең әдәплелеге белән бер тиен тормаслык «йолдызлар»ны каян табып бетерәләр диген?* («Ватаным Татарстан» газ.).

Төрдәше: әһәмиятсез нәрсә; базар көн (көнендә) сукыр бер тиенгә тормаслык; бер тиен тормау; бер тиенгә дә кирәкми (кирәге юк); бер тиенгә дә ярамаган; буш нәрсә; пүчтәк нәрсә.

**БЕР ТИЕН <ДӘ> ТОРМАУ** 1. *к.* әһәмиятсез нәрсә. *Әле дә ярты авылның бер тиен тормаган җыен юк-бар әйберенә барлы-юклы онымны әрәм итеп бетердем...* (Г. Ибраһимов. Адәмнәр). *Дөресен генә әйткәндә, сукыр бер тиен тормый торган әсәр язган Гали Кәли иптәш* (Г. Афзал. Ике «ләкин»).

Төрдәше: әһәмиятсез нәрсә һ.б.

2. Мөһим булмаган. – *Саботажник! Райком күрсәтмәсе сиңа бер тиен дә тормый* (Г. Ахунов. Чикләвек төше). *Ананың йокысыз төннәре, аның өчен янып-көюләре бакыр бер тиен тормый* («Безнең гәҗит» газ.).

3. Бик җиңел эшләргә мөмкин булу. *Американы куып узабызмы? Тфү! Ул безгә бер тиен тормый* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Кеше башына җиту аңа бер тиен тормый, тыңлагыз, зинһар, сүзләремне!* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы).

Төрдәше: әһәмиятсез нәрсә һ.б.

**БЕР ТИЕНГӘ БЕР ТИЕН** *мыск.* Сүзгә сүз тәрҗемә итү (начар тәрҗемә). *«Атлый, атлый...» – ул бит русча шагает и шагает... дигәннең коры, җансыз, бер тиенгә бер тиен исәбеннән ясалган тәрҗемә* (Г. Бәширов. Бер хикәя турында). *Чөнки әлеге тикшерелә торган мәкаләләрнең теле мин язган тел түгел, ул – тәрҗемә, өстәвенә әдәби тәрҗемә дә түгел, подстрочник, ягъни сүзгә-сүз, бер тиенгә бер тиен тәрҗемә* (Г. Ахунов. Йолдызлар калка).

**БЕР ТИЕНГӘ БЕТӘШКӘН** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. *Бүтән ялчылар кебек бер тиенгә бетәшеп азапланмавы үзе үк Сәлимне бу шат күңелле егет алдында яшерен шиккә салган иде* (Ф. Хөсни).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**БЕР ТИЕНГӘ ДӘ КИРӘКМИ (КИРӘГЕ ЮК)** *к.* әһәмиятсез нәрсә. *Дәхи аларның Зарифка ихтыяҗы да төшә, ә Нәгыймә бер тиенгә кирәкми* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). – *Докладның миңа бер тиенгә дә кирәге юк, – диде Васильев, кул селтәп* (И. Гази. Онытылмас еллар).

Төрдәше: әһәмиятсез нәрсә һ.б.

**БЕР ТИЕНГӘ ДӘ КУЙМАУ** *к.* бар дип тә белмәү. *Хәсән ага, «Искәндәр Рушан» исеменә төренеп, халык гамен бер тиенгә куймаган «эшлеклеләргә» нәфрәтен белдерде* (Н. Хисамов. Татар шагыйрьләре).
Төрдәше: бар дип тә белмәү һ.б.

**БЕР ТИЕНГӘ ДӘ САНАМАУ** *к.* бер тиенгә дә куймау. *Монда да ирләр, хатыннарына үч итеп, үз башларына җитүне бер тиенгә санамыйлар* (Ә. Моталлапов. Мәхшәр).
Төрдәше: бер тиенгә дә куймау һ.б.

**БЕР ТИЕНГӘ <ДӘ> ЯРАМАГАН (ЯРАКСЫЗ)** *к.* әһәмиятсез нәрсә. *Ашыкмыйк әле. Бәлки, бер тиенгә яраксыз нәрсәләрдер болар* (А. Гыймадиев. Үзең булып кал!..).
Төрдәше: әһәмиятсез нәрсә һ.б.

**БЕР ТИЕНЕ ОНЫТЫЛЫП КАЛСА, ЙӨЗ ЧАКРЫМ КИРЕ КАЙТУ** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. *Бу якынлык халыкның мәкаль-әйтемнәрендә дә искиткеч нык сизелә. Мәсәлән: Бер тиен өчен җанын сатыр, бер тиене онытылып калса, йөз чакрым кире кайтыр* (Татар хал. иҗаты).
Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**БЕР ТИЕНЛЕК <ТӘ>**. Аз гына да, бөтенләй. *Әгәр сез шикләнәсез икән, зинһар, миңа бер тиенлек тә мал сатмагыз* (Г. Камал. Бәхетсез егет). *[Сәфәргали] Бер-бер эшкә керешер идең, кулда бер тиенлек һөнәр юк* (К. Тинчурин. Йосыф белән Зөләйха).

**БЕР ТИЕНЛЕК КИҢӘШ ТӘ ИТМӘҮ.** Киңәш тотмыйча, үз белдегенә эшләү. *Анага бер тиенлек киңәш тә итмичә, зур кызларын, мәһәренә кызыгып: – Йөз илле сум акча алам; ике батман бал алам; болай әйберләтә мәһәрнең исәбе-саны юк, – дип, бер байга хатын өстенә көндәшкә биргән иде* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар).

**БЕР ТИЕНЛЕК КУЯН <ӨЧЕН>, ИКЕ (УН) ТИЕНЛЕК ЗЫЯН** *к.* бер тиен куян, ун тиен зыян. *Шуңа күрә ярсый-ярсый, очынып-очынып сөйләде... – Бер тиенлек куян өчен ун тиенлек зыян ясарга маташмыйк инде, – диде...* (Р. Вәли. Канатлы татар). *[Тәкый] Бер тиенлек куян, ун тиенлек зыян ясаган кеше стахановчы була алмый* (Г. Кутуй. Шатлык җыры).
Төрдәше: бер тиен куян, ун тиен зыян.

**БЕР ТИЕНЛЕК <ТӘ> ОЯТЫ БУЛМАУ.** Оятның нәрсә икәнен дә белмәгән кеше хакында. *– Булыр, булыр аннан – бер тиенлек тә ояты булмаган кешедән нәрсә көтәргә мөмкин* (Сөйләм).

**БЕР ТИЕНЛЕК ЭЧЕП, ӨЧ (БИШ; УН; ЕГЕРМЕ) ТИЕНЛЕК ИСЕРҮ** *к.* акылын эчеп бетергәнче. *[Хәмидә] Күзле бүкәннәр! Җирәнгечләр! Бер тиенлек эчеп, егерме тиенлек исергәннәр* (Г. Камал. Хафизалам, иркәм). *– Гриша бабай бик сирәк эчә, эчсә дә, бер тиенлек эчеп, өч тиенлек исерми иде, – дип, сүзгә кушылды көтүче егет* (Р. Мөхәммәтҗан. Бүре сагышы).
Төрдәше: акылын эчеп бетергәнче һ.б.

**БЕР ТИЕННЕ ИКЕ ИТҮ (ИКЕГӘ БҮЛҮ).** Бөтен көчен, белемен кулланып, тырышып эшләү. *Апасыннан калган бер тиенне ике итә Садыйк* уллары (Н. Әхмәдиев. Дәрдмәнд). *Илне ныклап аякка бастыру өчен, бер тиенне икегә бүләрдәй булып эшли халык* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).

**БЕР ТИЕНСЕЗ.** Гомумән акчасыз, бушка. *Әнинең авызы колакта, бер тиенсез өйгә килен кайткан, янәсе* (Ф. Хөсни. Йөзек кашы). – *Үзең кеше булган булсаң, мин моны бер тиенсез төзәтеп бирер идем* (В. Нуруллин. Җавап бир, кеше).

**БЕР ТИЕНСЕЗ<ГӘ> КАЛУ.** Бөтенләй акчасыз калу, акча бетү, фәкыйрьләнү. *Эзләп йөргәч-йөргәч, җәмәгать, чынлап та, яшереп җыйган өч мең тәңкә акчаны тапты. Бер тиенсез калдым!* (Г. Асхатулла. Кычытмаган җиреңне кашысаң, шулай була икән!). *Мудрыйның бер тиенсез калып, тозга ипи кыерчыгы манып ашаган чаклары булды, ә шулай да Нәҗип Нургалиев катына соранып килмәде, үтенечен таптырмады* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**БЕР ТИРӘ.** 1. Уртача, ярыйсы. *Мондый тирәнлектә суның температурасы да җәен-кышын бер тирә, бер чама* (А. Хәсәнов. Җирдә ни булмас, дисез сез...). *Биредәге һава торышы чагыштырмача Русиядәге белән бер тирә. Монда да: «Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява», – диделәр безгә* (Р. Гыйлемханов һ.б. Истә калганнар).

2. Бер тын алырлык вакыт <эчендә>. *Төп, нигез өлешенең шул бер үк автор (яки авторлар коллективы) тарафыннан, бер тирә вакытта язылган булуы да ихтимал* (М. Гайнетдин. Без элек тә без идек...).

3. Чама белән яшьтәшләр; охшаш булу; якынча бер ук микъдарда һ.б. *Ул – драматик тенор, ә мин – лирик баритон. Шул бер тирә инде* (А. Хәмзин. Маэстро). – *Соң, кызым, һаман-һаман Илвира димичә, күрше кызы ич, яшьләрегез дә бер тирә бугай* (yalkin.com).

Төрдәше: бер чама 1.

**БЕР ТИШЕККӘ ТЫГУ.** Берүзе берничә кешегә каршы тора алу. *«Мулла Әбүннасыйр Бохара галимнәренең һәммәсен бер тишеккә тыгып китте»* (М. Мәһдиев. Шагыйрьнең бишеге). *Типсә тимер өзәрдәй, барыбызны, бөтереп, бер тишеккә тыгардай егет иде* (Д. Салихов. Чукрак).

**БЕР ТИШЕКНЕ ЯМАРГА ЯРАР.** «Начар гына әйбер булса да, берәр җитешсезлекне төзәтергә ярар» мәгънәсендә. *Агачы кыска булса да, өйгә алып кайтыйм әле, бер тишекне ямарга ярар* (Сөйләм).

**БЕР ТӨЕНГӘ ТӨЙНӘҮ (ТУПЛАУ).** Берләштерү, бергә җыю. *Билгеле, сәламәт чакта син аларны күбрәк күрәсең, ләкин тормыш муллыгы, тәэсоратлар күплеге, аларның тиз алмашуы синең игътибарыңны тарката; син, гөлбакчага кергән кеше кайсы чәчәккә карарга белмәгән кебек, күп вакытта бөтен уй-фикереңне бер төенгә туплый алмый каласың, күп нәрсәне мәңгегә югалтасың* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Ир чәчелгән, сибелгән уйларын һич кенә дә бер төенгә төйни алмады* (Н. Гыйматдинова. Үзем генә беләм...).

**БЕР ТӨЙНӘГӘН ЙОДРЫГЫН ПАТША КИЛСӘ ДӘ АЧМАС** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. *Аның урынында бер төйнәгән йодрыгын патша килсә дә ачмый торган йорт җанлы хатын булса, кадерен белер иде ул мондый ирнең* (Г. Мөхәммәтшин. Авылда бер...).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**БЕР ТӨПТӘГЕ ИКЕ ТИРӘК** *к.* авыздан-авызга сөйләшү. *Нариман – Айдарның ярты кабымлык икмәкне икегә бүлеп каба торган, бер җептәге ике төймә, бер төптәге ике тирәк шикелле яшәгән дусты* (Г. Мөхәммәтшин. Йөрәктәге эзләр).

Төрдәше: авыздан-авызга сөйләшү һ.б.

**БЕР ТӨРЛЕ (БЕРТӨРЛЕ) ГЕНӘ.** Бер көенчә, ярыйсы гына, уртача гына. *Тормыш та үз җаена, бертөрле генә бара шунда* (Сөйләм).

**БЕР ТӨРЛЕ (БЕРТӨРЛЕ) ИТҮ.** 1. Кызларны көчләп кияүгә бирү, ябыштырып чыгару. *Усал халыклар, хәерсезләр, бүген болар Мавияне бер төрле итәрләр* (М. Фәйзи).

2. Бер сүзгә күндерү, җайлау. *Аңа Шәрәфне бер төрле итәрмен* (М. Фәйзи).

**БЕР ТӨЧЕСЕН, БЕР ӘЧЕСЕН КАПТЫРУ.** Тормышта барысы да яхшы гына бармый, яхшысы да, начары да була. *Бер төчесен, бер әчесен каптыра, кешеләрне әледән-әле маңгайлары белән чәкәштергәли генә тора, диләр* (А. Гыйләҗев. Өч аршын җир).

**БЕР ТУБАЛ ТАГЫЛГАЧ.** Артында гаилә, бала, хуҗалык булу. *Ир кеше артына бер тубал тагылгач, теләсә кая китеп, теләсә нәрсә эшләп йөри алмый ул* (Сөйләм).

**БЕР ТУКТЫЙ ДА БЕР АТЛЫЙ.** Иренчәк, ялкау кеше хакында. *Мәктәпкә барган вакыт бер туктый да бер атлый* (М. Гафури).

Төрдәше: авыр аяк<лы> 1 һ.б.

**БЕР ТУРЫГА.** Бер мәртәбә. *Йә инде, йә, бер турыга гына җиңгәң сүзен дә тыңла* (Г. Бәширов. Намус).

**БЕР ТҮБӘ (ТҮШӘМ) АСТЫНДА ЯШӘҮ.** Бергә яшәү. *Апасы белән җизнәсе икесе бер түбә астында яшәсәләр дә, җаннары бергә кушылмады, икесе ике ярты булып кала килделәр* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Минем дә әйткәнем бар инде, бер түбә астында яшәү ул әле чыннан да парлы дигән сүз түгел* (Г. Шәйхи. Бер генә тапкыр яраттым).

**БЕР ТҮГӘРӘКТӘ БИЮ.** Бер җирдә, бергәләп эшләү. *Бер түгәрәктә биегәч, башка бүлек җитәкчеләре дә аның сүзен екмый иде* (К. Кара. Өч көнлек дөнья).

**БЕР <ГЕНӘ> ТЫН.** Беркадәр вакыт, чак кына. *Кызлар дәррәү бер тын көлешеп алдылар* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Сулышлары*

*тигезләшкәнче бер тын басып тордылар* (В. Гали. Ипекәй исләре).

**БЕР ТЫН БЕЛӘН.** Берьюлы, тын алмыйча; бер тын алырлык вакыт эчендә, бик тиз. *Берәүләр әнә бер тын белән кирпечтәй роман язып ташлый, ә мин кечкенә генә хикәяләр белән дә күпме җәфа чиккәнмен* (Г. Сабитов. Еллар узгач). *Бер тын белән әйтеп салды. Рапорты чиста, яңгыравык чыкты* (А. Хәсәнов. Данәгөл).

Төрдәше: бер тында.

**БЕР ТЫНДА.** 1. *к.* бер тын белән. *Эре-эре пүләннәргә ярылган каен утын өеме бер тында бушап калды* (А. Хайртдинова. Вөждан газабы). *Юк, «Утлы дала» алай бер тында, йөгерек кенә укыла торган әсәр түгел, бу – саллы тел белән язылган чын тарихи әдәби роман* (В. Имамов. Тозлы яра).

Төрдәше: бер тын белән.

2. Туктап тормыйча. *Уразбикә, мич почмагына сөялеп, бер тында стаканны каплады да ишеккә таба барды* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). <...> *Нәҗип, бер булса да юлбашчыга хөрмәтен белдерергә форсат чыгуыннан файдаланып, мул салынган чәркәне бер тында йотып бетерде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**БЕР ТЫРМАГА ИКЕ ТАПКЫР БАСУ.** Бер эшләгән ялгышны яңадан кабатлау. – *Сүз озайтуның мәгънәсе юк, бояр, бер тырмага ике мәртәбә басмыйлар* (М. Әмирханов. Әлвидаг). *Урыслар бер тапкыр маташып караганнар инде, ала алмаганнар. Бер тырмага ике тапкыр басмыйлар, бу юлы без аны алырга тиешбез* (З. Мурсиев. Ташмәчет).

**БЕР ТЫРНАГЫНА ДА ТОРМАУ** *мыск.* Берәүне икенчесе белән чагыштырганда, абруе да, зиһен-белем дәрәҗәсе һ.б. да түбәнрәк икәнлеген күрсәтү өчен кулланыла. *Сөйләп торма әле шуның турында, ул бит аның бер тырнагына да тормый* (Сөйләм).

Төрдәше: алтырагына да тормау һ.б.

**БЕР УҢАЙДАН.** Бер үк вакытта, бер җайдан. *Алар, буа янында туктап, су коенып чыктылар. Бер уңайдан тикшерүче малайларның «үз хуҗалыклары» белән танышып, утрауны, каланчаны, көймәне карады* (А. Тимергалин. Таш алиһә). *Шәһәргә ул дару алыр өчен килгән, бер уңайдан госпиталь начальнигы санитарлар алып кайтуны да аңа йөкләгән* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

**БЕР УРЫНДА ТАПТАНУ.** Алга да, артка да китмичә, бер урында калу; үсеш булмау. *Ни өчен берләшмәгә аяк баскан урыслар, украиннар һәм башка милләт вәкилләре ел-ел ярым эчендә кинәт кенә үсеп китәләр дә дәрәҗәле урыннарга менеп утыралар. Ә татар белгечләре, татар галимнәре һаман бер урында таптана ?!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Хуҗалык өлкәсенең башка тармакларында да бер урында таптанырга исәп юк* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

**БЕР УТЫРГАН АРАДА.** Эштән бушап, ял итеп алган вакытта. *Кара пәлтәләрне киеп, / Йөри микән калада? / Безне уйлап ала микән / Бер утырган арада?* (Җырдан).

**БЕР УТЫРУ (КҮРЕШҮ; СӨЙЛӘШҮ) – ҮЗЕ БЕР ГОМЕР.** Озак вакытлар күрешми торганнан соң очрашуны, очрашып сөйләшүне гомергә тиңләү. *Җир астыннан юллар булмый, диләр. / Бер күрешү – үзе бер гомер* (Г. Сафин. Дусларга). *Ни дисәң дә, дуслар белән бер утыру – үзе бер гомер ул!* (Ф. Яхин. «Интехбанк» ялкыны).

**БЕР УТЫРУДА.** Бер тапкыр утырып ашауда. *Бер утыруда бер килолы калҗаны, бер кәстрүл ашны ялтыраттым* (Г. Ахунов). *Юлчылар бу нигъмәтне бер утыруда ашап та куя* (З. Мурсиев. Солтанъяр).

**БЕР ҮЗЕНӘ БЕР ЧЕЛЛЕ** *гади с.* Үз юлында йөри бирүче хакында. *Ә табибә медпунктта берүзе, аның булышчысы юк, ул штатта да каралмаган. Бер үзенә бер челле дигәндәй, Саҗидәнең ике кулына мең эш* (Ә. Сәлах. Көт син мине...).

**БЕР ҮК МЕДАЛЬНЕҢ ИКЕНЧЕ ЯГЫ.** Нәрсәнең дә булса тискәре ягы, капма-каршысы. *Яхшылап тыңла, менә монысы – сиңа бер үк медальнең икенче ягы* (Сөйләм).

Төрдәше: медальнең арка (икенче) тарафы (ягы).

**БЕР ФАСОН.** Бер зәвыклы (бер үк төрле кешеләргә карата). *[Галия] Хәзерге егетләрне әйтер идем, барысы бер фасон* (А. Гыйләҗев).

**БЕР ФИКЕРГӘ КИЛҮ** *к.* бер сүзгә килү. *Бу хакта тарихчылар белән телчеләр уртак бер фикергә килергә күптән вакыт* (А. Тимергалин. Әлифба, имля, фәнни истилях). *Кыскасы, кичкә кадәр уйлашыйк, кич белән бер фикергә килербез* (И. Хуҗин. Бату кыйссасы).

Төрдәше: бер сүзгә килү һ.б.

**БЕР ХӘЕР (ХӘЛ).** Яхшы, әгәр; яхшы ла; риза булып була. *Алай дип әйтсә бер хәер* (Г. Камал). *Хәзергечә язылган булса бер хәл, бәлки, Таймас аларны аңлар да иде* (А. Тимергалин. Таш алиһә).

**БЕР ХӘЕР (ХӘЛ) ИДЕ.** «Шулай булса яраган да булыр иде» мәгънәсендә. *Үз күзе белән күрмәгән булса, тагын бер хәер иде* (Ә. Еники. Туган туфрак). *Бу анатомик терминның ни өчен теркәлгәнлеген аңлап булмый, әгәр «корсакта бала ята торган яры капчык» мәгънәсендәге гарәпчә «рөхем» сүзе булса, бер хәл иде* (А. Тимергалин. Яклап һәм каршы).

**БЕР ХӘЛ КУБАРУ.** Тыныч кына торган җирдән гауга ясау. *Үзем дә аңламадым, матур гына сөйләшеп торганда, көтелмәгән бер хәл кубарды* (Сөйләм).

**БЕР ХОДАЙ ҮЗЕ ГЕНӘ БЕЛСЕН.** Күрелмәгән хәл, гомумән ят эш. *Бер Ходай үзе генә белсен кайдан бу хәтле халык чыккан* (Г. Ибраһимов).

**БЕР ЧАБУДА ӨЗҮ (ӨЗЕП ТАШЛАУ).** Берни белән исәпләшмичә, кискен эш итү. *Күреп кенә түгел, бу хәлнең ни белән бетәсен җаны-тәне белән сизеп алган Кадыйр ике яшь йөрәктә бөреләнә башлаган мәхәббәтне бер чабуда өзәргә булды* (М. Хәбибуллин. Хәтер ярлары). *«Бүген булмаса, иртәгә матур!» – ди ул, һәм тигәнәк булып калкыган хәсрәтне нәни генә бер сөенечнең үткен балтасы бер чабуда кырт итеп өзеп ташлый...* (Р. Сибат. Кайту).

**БЕР ЧАКРЫМНАН ӘЙЛӘНЕП ҮТҮ (УЗУ).** Дикъкать итмәү, карышмаска тырышу. *Киләчәктә ул мондый четерекле мәсьәләләрне бер чакрымнан әйләнеп узгандыр дип уйлыйм* (А. Тимергалин. Юл чаты). *Авыл советы, Көнбатыштагы кебегрәк «Кемнең кем икәнлеге турында» дигән еллык журнал чыгармаса да, кемнең яхшы укытучы, табиб, парикмахер, сатучы икәнен белә, ә кайсысын, күрмәскә тырышып, бер чакрымнан әйләнеп үтә* (Р. Мирхәйдәров. Иртәләгән сагыш).

**БЕР ЧАМА** 1. *к.* бер тирә 1, 2. *Минем кар ераграк оча, аның каравы Азат, җитезрәк булу өстенә, турырак та бәрә, һәм, гадәттә, икебезгә дә бер чама эләгә иде* (А. Тимергалин. Игезәкләр). *Өйлә намазы якынаеп килгән бер чамада көнчыгыш якта тузан болыты купты* (В. Имамов. Утлы дала).

Төрдәше: бер тирә 1, 2.

2. Булып җитмәгән, булыр-булмас, көчкә генә. *Әллә барыр иде дә, җиккән аты бер чама* (Н. Исәнбәт). *– Ну, җиксен инде. Аты да, Гаптелвәли дә бер чама* (К. Кәримов. Уен).

**БЕР ЧАМАЛЫ.** Ярый шунда, шәптән түгел. *Өс-башлары да бер чамалырак: гади генә ситсы күлмәк, алларында эре чәчәкле алъяпкыч, башларында артка чөеп бәйләгән гади генә яулык* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

.

**БЕР ЧӘЧ БИШ БУЛГАН ЗАМАН** *кин.* Бик күп эшләр бергә килеп тыгылып, кайсыннан башларга белмичә аптырап, кырыкка ярылырга әзер булу. *Кунакка үзең генә барып кайт инде, беләсең бит, бер чәч биш булган заман* (Сөйләм).

**БЕР ЧЕМЕТЕМ.** Бик аз, кечкенә; аз гына да. *Тормышында бер чеметем дә кайгысы юк диярсең, артын шүрәле кытыклаган кеше төсле, бер очкынсыз кабына да көлә* (В. Имамов. Тозлы яра). *Карт аның бөкесен алды, сул кулының баш бармагы тырнагы өстенә иплән кенә бер чеметем тәмәке салды да, тәмәке савытын яңадан ыштан бөрмәсенә кыстырып, Сафаның сөйләп бетергәнен көтә башлады* (М. Галәү. Болганчык еллар).

**БЕР ЧИТТӘ КАЛУ (ТОРУ).** Катышмау. *Кибетләрдә шундый аура саклана, сизмәстән кеше үзгәрә, дөнья мәшәкатьләре бер читтә кала, көтелмәгән бәйрәмгә юлыккан төсле буласың* (К. Кара. Чуклы караватъ). *Ап-ак тешләрен күрсәтеп бер елмаеп та җибәрсә, «Мисс Европа»ларың бер читтә торсын* (Г. Әдһәм. Йолдызлар елмая).

**БЕР ЧӨЕ ЫЧКЫНУ.** Нервыланып ярсу, акылга җиңеләеп китү. *Картның бер чөе ычкынган*

*вакытка туры килдең, беразданрак кереп чыксаң, яхшырак булыр* (Сөйләм).

**БЕР ЧҮКҮДӘ АЛУ.** Уйламыйча эшләү. *Ни генә булмасын, Даян мәргән бер чүкүдә сугып ала торган аңгыра карга түгел* (В. Имамов. Казан дастаны).

**БЕР ЧҮПРӘДӘ КАБАРУ** *к.* Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни. *Бөтенләй башка була алмый инде, бер чүпрәдә кабарган балалар бит алар* (Сөйләм).

Төрдәше: Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни һ.б.

**БЕР ЧЫБЫК БЕЛӘН КАУЛА<Н>У (КУАЛА<Н>У; СӨРЕЛҮ)** *к.* Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни. *[Галимә] Яшьләр алар ул турыда бары да бер чыбык белән куаланган* (М. Фәйзи. Галиябану). *Түрәләре дә, алпавытлары да – бөтенесе бер шайка, бер чыбык белән сөрелгән* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни һ.б.

**БЕР ЧЫБЫКТАН КУАЛАУ (КУЫЛУ)** *к.* Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни. *Ни гаҗәптер, безнең авыл арасында пожарник белән көтүчеләрне, бер чыбыктан куалап, бик түбәндә сыман йөртәләр иде* (А. Гыйләҗев. Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят). *Алар Сәгыйть Хәмитович кебек бер чыбыктан куалаган кабахәтләр* (Ф. Яруллин. Кыйбласызлар).

Төрдәше: Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни һ.б.

**БЕР ЧЫБЫК ОЧЫ** 1. *к.* Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни. *Сайланып торма инде, бер чыбык очы алар* (Сөйләм).

Төрдәше: Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни һ.б.

2. Бер нәселдән, ерак кардәшләр. *Бабамнар фатир алган йортта да бер чыбык очы туганы пәйда булды* (Э. Шәрифуллина. Мәхәббәтнең җиде төсе). *Хисмәт абзый корсагын кашып алды: – Бер чыбык очы тиешле туганнары бар бугай аларның* (А. Гыймадиев. Үзең булып кал!..).

**БЕР ЧЫБЫК ОЧЫННАН** 1. *к.* Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни. *Алар бер чыбык очыннан, бер балалар йортында үскәннәр бит* (Сөйләм).

Төрдәше: Әхмәтгали ни, Галиәхмәт ни һ.б.

2. *к.* бер чыбык очы 2. *Без бер чыбык очыннан, Әһлетдин абзый* (Г. Әпсәләмов).

Төрдәше: бер чыбык очы 2.

**БЕР ШАЙТАН ЯЛЫН ТАРАУ.** Бер үк нәрсә булу; бер ягы белән дә аерылмау. *Сукыр тиенгә хөкүмәткә эшлисеңме, авыл баена бил бөгәсеңме – бер үк шайтан ялы тарыйсың дип, ул да «әртил көтүе»нә кушылмакчы иде, Мансур тузынды* (Н. Гыйматдинова. Кәтәнә).

**БЕР ШАРМАНКАНЫ ӘЙЛӘНДЕРҮ.** Һаман да иске сүзләрне, фикерне, җыр-музыканы кабатлау. *Мин бу нотыкчыны былтыр тыңлаган идем инде, һаман да бер шарманканы әйләндерә икән* (Сөйләм).

**БЕР ШӨРЕБЕ (ВИНТЫ) БУШАУ (КАКШАУ).** Акылга җиңеләя башлау, мантыйксыз сөйләнү. *Башка чакта теле телгә йокмаган кызның берәр шөребе бушаган мәллә?* (Н. Гыйматдинова. Мәхәббәттә гөнаһ бар). *Фикере ныграк, ачыграк иде, хәзер кайдадыр бер шөребе какшады кебек* (Г. Әпсәләмов. Күк күкрәр).

Төрдәше: акыл сүнү һ.б.

**БЕР ШӨРЕБЕ ҖИТМӘҮ (ТӨШҮ; ТӨШЕП КАЛУ).** Акылга тулы түгел, нормаль түгел. *Гайнан әйтә: – Мотор янган, / Бер шөребе төшеп калган, / Ардым инде үзем дә, – ди* (Г. Афзал. Кино килгән, кино килгән...). *Андыйларның башка «ски»ләре була – йә ул бик каты саран, йә башында берәр шөребе җитми инде аның* (matbugat.ru).

**БЕР ШЫРПЫ БАШЫ ҖИТҮ.** Ут төртү белән янау. *Минем малым дип бик мактанма әле, аларның барысына бер шырпы башы җитә* (Сөйләм).

**БЕР ШЫРПЫНЫ БИШКӘ ЯРЫП КАБЫЗУ** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. *Бер шырпыны бишкә ярып кабыза* (Г. Мөхәмммәтшин).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**БЕР ЭЗ БЕЛӘН БАРУ.** Сайлаган юлдан тайпылмыйча, бергә бару. *Бер эз белән барып һәрвакытта, / Бергә-бергә дөнья көтәргә* (М. Гафури). *Ләкин тормыш бер эз белән генә бармый, хакимнәр киләләр дә китәләр* («Кызыл таң» газ.).

**БЕР ЭЗГӘ ТӨШҮ.** Нәрсәгә булса да җайлашу, күнегү. *Санаторий шартларына ияләштек, ял, дәвалану бер эзгә төште, көннәр, бер-берсенә охшап, сиздермичә генә үтә тордылар*

(Ә. Еники. Йөрәк сере). *Тормышлары, бер эзгә төшеп, матур гына тәгәри башлаган иде...* (Ф. Мөслимова. Ярты алма).

**БЕР ЭЛГӘРЕ, БИШ КИРЕ.** Алга хәрәкәт итүдә тискәре хәрәкәт күбрәк булуы. *Үҗәтнеке бер элгәре, биш кире. Үҗәтнең үз сиксәне сиксән, кешенеке йөз алтмыш* (Н. Исәнбәт).

**БЕР ЭНӘГӘ БЕР СЫЕР** *к.* авыз чайкау 1. – *Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер биргәннәре турында ишеткәнең бармы? Сине кайда көтеп торалар?* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Анда бер энәгә бер сыер, ди, бозаулары да бакыр бәясе генә икән* (Ф. Яхин. Бакыр бозау артыннан).
Төрдәше: авыз чайкау 1 һ.б.

**БЕР ЭССЕ, БЕР СУЫК ХӘЛГӘ ТӨШЕРҮ.** Аптыратып, йөдәтеп бетерү. *Кем бирде дә кем бирде? дип, теңкәмә тиде бит, бер эссе, бер суык хәлгә төшерде* (Сөйләм).
Төрдәше: бизгәк булу.

**БЕР ЭТ БЕЛЕП ӨРГӘН, ДҮРТЕСЕ БЕЛМИ ӨРГӘН.** Хәл-вакыйганың асылына төшенеп тормастан, ызгыш-гаугага кушылу. *Бер эт белеп өргән, дүртесе белми өргән* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

**БЕР ЭШКӘ ЯРАМЫЙ <ТОРГАН>.** Яраксыз, бернәрсәгә дә ярамаган, кирәге булмаган. – *Анда бер йомры елга ташы да бар иде. Калды ул шунда, бер эшкә ярамый ич ул* (Ф. Җамалетдинова. Йөк).

**БЕР ЮЛГА.** Беренче очракта, бер мәртәбәгә. *[Хәдичә] Зинһар инде алайса, бер юлга сүз тыңлап кына шуларны алып кайтып бирсен иде* (Г. Камал. Банкрот). *Шуның өчен аны директор чакырып алды да кабахәтләп сүкте, бер юлга гафу кылыначагын, ләкин тагы сизелсә, <...> школадан куылачагын белдерде* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр).

**БЕР ЯКАДАН ИКЕ БАШ ЧЫГАРУ.** Берләшеп, бер-береңә ярдәмләшеп куәт бирү. – *Син аларны тиз генә күндерермен дип өметләнмә, алар бер якадан ике баш чыгаралар* (Сөйләм).
Төрдәше: сыңар җиңнән ике кул чыгару.

**БЕР ЯККА КАЛДЫРУ (КУЮ).** Калдырып тору, игътибарга алмау. *Баязид өчен бик тирән интереслы нәрсә иде, саклыкны бер якка куйды да колагын стенага ябыштырды* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Вак тиеннәр исәбен инде бер якка калдырып, сәфәр минутларында күңелләре югарырактан оча иде, күрәсең...* (Ш. Камал. Акчарлаклар).

**БЕР ЯКЛЫ БУЛУ.** Ике якның берсе булу, мәсьәләнең кайсы якка булса да хәл ителүе. *Ф. Әмирхан иҗаты турында сүз барганда, гадәттә, аны бөек рус язучысы И.С. Тургеневның шәкерте итеп күрсәтәләр. Бу – бер яклырак караш* (М. Мәһдиев. Яңа бистә Прометее). *Сөйләшү гел бер яклы гына булмасын өчен, бервакыт мин аннан, болай юри генә, сүз булмаганнан сүз булсын дип кенә: – Гөлкәй, ә сиңа берәрсе ошыймы соң? – дип сорадым* (Р. Габделхакова. Нишләттегез Гөлкәйне?!).

**БЕР ЯКЛЫ ГЫНА КАРАУ (ХӘЛ ИТҮ).** Эшне, мәсьәләне тиешенчә карамау. *«Узган елгы шигърияткә бигрәк бер яклы гына карыйсыз инде, уңышсыз мисалларны бигрәк күп табасыз инде!» – дип, һич тә аптырамасын укучы* («Казан утлары» ж.). *Авторның хатасы – парлы сүзләрне бер яклы гына карау, аларның бер генә төренә игътибар итү* («Фән һәм тел» ж.).

**БЕР ЯКСЫЗ БУЛУ.** Гәүдәнең бер ягы хәрәкәтсез калу (параличтан соң). *Паралич шундый ясар, / Бер яксыз булып катар, / Ахры, борны кәкрәеп, / Шуның белән ул катар* (К. Насыйри).

**БЕР ЯКТА (ЧИТТӘ) ТОРСЫН.** Сөйләнелгән әйбердән начаррак. *Алар ерткыч, алардан читтә бул син, / Алар барда бүрең бер якта торсын* (Г. Тукай). *Сабира апа сөйләгәндә, радиоң бер читтә торсын!* (Р. Низамиев. Беренче мунча).

**БЕР ЯКТА ТОРЫП ТОРУ.** Дикъкатькә алмау, чаныштырып карау өчен дә кулланмау. *[Себер бае] Үз турыларына килгәч, тәкъвалык бер якта торып тора икән* (Г. Камал. Безнең шәһәрнең серләре). – *Карагыз, биредә нинди матурлык! Кавказларың, Кара диңгезләрең бер якта торып торсын!* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**БЕР ЯЛГЫЗЫ.** Берүзе генә, бер кешесез. *Әмма тәхет залына кереп утырышкач, аксөяк*

*түрәләрнең күбесе эндәшмәде, баш карачы булып азау тешен чыгара башлаган Дәүләтьяр бер ялгызы дигәндәй җавап тотты* (В. Имамов. Утлы дала).

**БЕР ЯҢАГЫННАН СУГЫП, ИКЕНЧЕ ЯҢАГЫННАН УТ ЧЫГАРУ.** Яңагына каты итеп чабып җибәрү. *Бик юк кына нәрсә өчен бер яңагыннан сугып, икенче яңагыннан ут чыгарулардан котылды* (Г. Ибраһимов).

**БЕР ЯРЫ<ТЫН>.** Берәр якка, берәр җиргә, кая да булса. *Әшең каралганчы, бер ярытын да аяк атлыйсы булма!* (К. Нәҗми). – *Мин, кайту белән, гариза язам, – диде Гөлзәминә, – башкача бер яры чыкмыйм, бәпкәчләрем янында гына торам* (Җ. Рәхимов. Кыядагы чәчәкләр).
Төрдәше: берәр яры.

**БЕР ЯРЫМБИШ.** Элекке җир үлчәме (дисәтинәнең өчтән бер өлеше). *Безнең бакча башында бер ярымбиш тирәсе кысыр җир бар иде* (Сөйләм).

**БЕР ЯШЬЛЕКТӘ, БЕР КАРТЛЫКТА** *к.* бер картлыкта, бер яшьлектә. *Рәмзия сүз эзләп кесәгә керә торганнардан түгел икән: – Бер яшьлектә, бер картлыкта, диләрме әле? Аңа гына калса, үпкән-кочкан – җилгә очкан – гөнаһ саналмас* (Н. Әхмәдиев. Мөнирстан). *Әйдә, бер яшьлектә, бер картлыкта дигәндәй, зиһенеңне уйнат әле бер!* (Э. Касыймов. Һаваларда тургай).
Төрдәше: бер картлыкта, бер яшьлектә һ.б.

*БЕРАВЫЗДАН* ❖ **БЕРАВЫЗДАН (БЕР АВЫЗДАН) САЙЛАНУ.** Уртак фикер белән, каршы тавыш бирүче булмыйча сайлану. *Аның эшчәнлек һәм намуслылыгы белән бергә, коммуна членнарының җыелышларны ясау өчен өйнең иркен булуы да күз алдында танылып, ул – беравыздан председательлеккә, Каюм секретарьлеккә сайланган иделәр* (Ш. Камал. Матур туганда).
Төрдәш: бертавыштан (бер тавыштан) сайлану.

*БЕРАЗ* ❖ **БЕРАЗ ТӨШЕРҮ (ТӨШЕРЕП АЛУ).** Беркадәр исерткеч эчемлек эчү. *Бераз төшереп алган ирләр аның сөйләгәнен, күрсәткән алымнарын кызык итеп кенә кабул иттеләр* (З. Зәйнуллин. Үрләр аша). *Хәкимулла, бераз гына төшереп алса, үгез кебек куәтләнә һәм үҗәтләнә иде – ул түргә узды* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

**БЕРАЗ ШЫТТЫРУ.** Ялганны кушып, арттырыбрак сөйләү. *Һичкемгә белдерергә ярамый иде аңа. Шунлыктан бераз шыттырырга мәҗбүр булды* (Ф. Яхин. Имлачы Хәйдәр). *Кешедә кызыксыну уятасың килсә, бераз шыттырып та җибәрергә кирәк* (Р. Нуруллин. Төеннәр иле).

*БЕРӘМТЕКЛӘП* ❖ **БЕРӘМТЕКЛӘП КЕНӘ САНАРЛЫК.** Бармак белән дә санап чыгарлык. *Күп түгел, аз түгел – берәмтекләп генә санарлык* (Сөйләм).

*БЕРӘР* ❖ **БЕРӘР КАДАК ТУЛМАУ.** Тиле-миле бугай. *[II крестьян] Берәр кадак тулмый, ахры* (Ф. Бурнаш. Илһам).
Төрдәше: чөе бушау; шөребе ычкыну.

**БЕРӘР ЯРЫ** *к.* бер яры. *Яхшы чакта малайны берәр яры озатырга кирәк булыр, дип, әтисе күңеленә беркетеп куйса да, әлегә хәтле икеләнебрәк тора иде* (Л. Ихсанова. Тузганак). *[Әмир] (ашыгып, курткасын кия башлый). Әйдә, Зөлфирә, боларга комачауламыйк. Берәр яры барыйк* (З. Хәким. Язын бозлар акканда).
Төрдәше: бер яры.

*БЕРӘРНЕ* ❖ **БЕРӘРНЕ АСТЫНА САЛЫП КУЮ.** «Аш алды» сылтавы белән берәрне эчеп кую. *Өстәлгә килгән иткә керешкәнче, берәрне астына салып куйыйк* (М. Мәһдиев).
Төрдәше: авыз җебетү 1 һ.б.

**БЕРӘРНЕ СЫНДЫРУ (СЫНДЫРЫП КУЮ).** Берәр шешә исерткеч эчемлек эчү. *Йә, әйдә, Вәлиулла, берәрне сындырып чыгыйк* (М. Фәйзи). *Берәрне сындырып, паштетлар белән закуслап алганнан соң, кәеф тәмам урынына барып басты* (С. Җәләл. Барысы да советски).
Төрдәше: авыз җебетү 1 һ.б.

**БЕРӘРНЕ ТӨШЕРҮ.** Бергәләп берәр шешә аракы эчү. – *Мин сиңа тегендә кертмәкче идем, әйдә әле, монда гына берәрне төшереп җибәр, – диде* (Ш. Камал. Акчарлаклар). *Максуд белән Ислам, күрәсең, тагын берәрне төшереп алганнар – шактый кәефләнеп, ниндидер көй сузалар* (Ш. Хөсәенов. Әниемнең ак күлмәге).
Төрдәше: авыз җебетү 1 һ.б.

*БЕРӘҮ* ❖ **БЕРӘҮ ТАБА, БИШӘҮ КАБА.** Бер кеше эшләп тапканны күп кеше туздыру турында. – *Бер дә аптырама, дөньяда әрсезләр бетмәгән ул – берәү таба, бишәү каба* (Сөйләм).

**БЕРӘҮ ТУЛМЫЙ.** Акылга җиңелрәк булуга ишарә. – *Шул козгын сүзенә ышандыңмы? Тиле син, йөзгә берәү тулмаган, – дип, урыныннан кузгалды* (Х. Хәйруллин. Картлык... Кемгә шатлык?). *Әйтәм бит, кырыкка берәү тулмый аның* (К. Кара. Көнбагыш сатучы).

Төрдәше: акыл җиңеләю 1, 2 һ.б.

*БЕРӘҮГӘ* ❖ **БЕРӘҮГӘ БЕРӘҮ КАЛГАН БУЛУ.** Берең өчен икенчең үзен корбан итәргә әзер тору. *Белмим, бүгенге көндә берәүгә берәү калган булганнар бармы икән? Булса да, бармак белән генә санарлыктыр* (Сөйләм).

**БЕРӘҮГӘ ТИШЕП, БЕРӘҮГӘ ТҮГЕП БИРУ.** *Моңа кадәр хансарайга аяк та басмаган булгансыңдыр әле, хәзер әнә Мәрьям ханбикәнең түшәгендә яубаш кочагында ауныйсың. Берәүгә тишеп, берәүгә түгеп бирә, шулдыр инде ул* (М. Хәбибуллин).

**БЕРӘҮГӘ ЯШЬЛЕКТӘ, БЕРӘҮГӘ КАРТЛЫКТА** *к.* бер картлыкта, бер яшьлектә. *Гомер агышында мәхәббәт тә берәүгә яшьлектә, берәүгә картлыкта килә* (Сөйләм).

Төрдәше: бер картлыкта, бер яшьлектә һ.б.

*БЕРӘҮНЕҢ* ❖ **БЕРӘҮНЕҢ БЕРГЕНӘСЕ.** Ялгыз, кадерле бала. *Гөләндәм туташ берәүнең бергенәсе, хезмәтче белән үсә...* (Т. Әхмәтҗанова. Укучы сүзе).

**БЕРӘҮНЕҢ КАНАТЫ АСТЫНДА БУЛУ.** Кемнеңдер ярдәменә сыену. *Ятимлектә авырлыклар күреп үскән бу балага берәүнең канаты астында булу зыян итмәс иде* (Сөйләм).

**БЕРӘҮНЕҢ КУЕСЫ, БЕРӘҮНЕҢ СЫЕГЫ.** «Дөньяда барысы да син теләгәнчә генә булмый» мәгънәсендә. *[Хуҗа] Берәүнең куесы, берәүнең сыегы, хәзрәт. Кунак үзе өмет иткәнен ашамас, алдына китергәнне ашар* (Н. Исәнбәт. Хуҗа Насретдин).

**БЕРӘҮНЕҢ КҮМӘЧЕНӘ МАЙ ЯГУ.** Берәрсенә ярарга тырышу, куштанлык итү. *Һаман да берәүнең күмәченә май ягып яшәп булмастыр, мөстәкыйльлеккә өйрәнергә вакыт* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга бал да май булып керү һ.б.

**БЕРӘҮНЕҢ ТЕГЕРМӘНЕНӘ СУ КОЮ.** Берәрсенең файдасына сүз сөйләү, нәрсәдер эшләү. *Вакыт-вакыт берәүнең тегермәненә су коярга ярардыр инде* (Сөйләм).

**БЕРӘҮНЕҢ УЛ КАДӘР САРЫГЫ ДА БУЛМАС** *кин.* Балалары күп булганда, киная ясау. *Сөбханалла, гаиләгез никадәр ишле икән, уйлап карасаң, берәүнең ул кадәр сарыгы да булмас* (Сөйләм).

*БЕР-БЕР* ❖ **БЕР-БЕР АРТЛЫ.** Аллы-артлы тезелешеп, берсе артыннан икенчеләре, эзлекле рәвештә. *Нечкәбил авызын ерып көлә дә бер-бер артлы тезеп, сөйләп тә китә* (А. Алиш. Нечкәбил). *<...> тимер юл белән параллель барган таш юлдан Әнисәләр ихатасына таба бер-бер артлы ике машина борылды* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: берсе артыннан берсе.

**БЕР-БЕР АРТЛЫ КУНДЫРУ.** Кыйнау, кат-кат сүгү. *Керде дә, яшелле-мөшелле тавыш белән чәрелдәп, зәһәр орышып, табагачы белән миңа бер-бер артлы кундыра башлады* (А. Шамов. Кыз урлау).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**БЕР-БЕР ХӘЛ БУЛА КҮРМӘГӘЕ (КҮРМӘСЕН).** Берәр төрле хәвеф-хәтәр булмасын дип шомлану. *Яңгыр өчендер – шул-шул. Бер-бер хәл генә була күрмәсен инде үзе белән...* (Г. Гыйльманов. Тозлы яңгыр). *«Шәһәргә ике сәгатьләп кайтасы бар әле, бер-бер хәл була күрмәсен тагын», – дип уйлап куйды Рифат* («Сөембикә» ж.).

**БЕР-БЕРСЕ ӨЧЕН ҮЛЕП ТОРУ.** Берсе икенчесенә тәне-җаны белән бирелгән булу. *Читтә татарлар бер-берсе өчен үлеп торалар* (З. Хөснияр. Кичү). *Бер-берсе өчен үлеп торган ике гашыйк бәхетсез була аламыни инде?!* (М. Кәбиров. Бердәнбер һәм кабатланмас).

**БЕР-БЕРСЕНЕҢ КАРАЛЫГЫНА ГАҖӘПЛӘНГӘН (АПТЫРАГАН) ӨЧ КАРГА (КАРГАЛАР) КЕБЕК.** Күптән булган бер хәлне өр-яңа дип уйлап гаҗәпләнү. *Озын дустым белән кыска дустым һәм алар артында*

*торган эт моны күргәч, бер-берсенең каралыгына гаҗәпләнгән өч карга шикелле, авызларын ачып, шаккатып калдылар* (Г. Мөхәммәтшин). *Солдатлар, бер-берсенең каралыгына аптыраган каргалар шикелле, үзара караштылар. Әмма тораташтай каткан аякларын җирдән аера алмадылар* (Р. Гайнуллин. Боссойко).

*БЕР-БЕРСЕННӘН* ❖ **БЕР-БЕРСЕННӘН КАЛМАС** *к.* Аг<ы>лый белән Таг<ы>лый <йөрү>. *Дүртенче курстагы мин бая телгә алган егет белән кыз бөтенләй бер-берсеннән калмас булганнар – декан янына да бергәләшеп керәләр* (Сөйләм).
Төрдәше: Аг<ы>лый белән Таг<ы>лый <йөрү> һ.б.

*БЕРБУЙДАН* ❖ **БЕРБУЙДАН ЯТУ.** Сузылып яту, ятып тору. *Тагы шуның өстенә теш сызлавы аны өчәр көн бербуйдан ятып торырга мәҗбүр итә иде* (Г. Исхакый).

*БЕРГӘ* ❖ **БЕРГӘ – АЛТЫН, МЕҢГӘ – ҖИЗ.** Әйбернең кыйммәтен, кадерен белгән кеше белән мондый сәләткә ия булмаган кешенең фикерләве бер үк булмау хакында. *Бу җыелышта сыйныфтан тыш тәрбия эшләрен оештыручы хатын гына (ул Айсинәнең бергә алтын, меңгә җиз икәнен аңлый иде) ык-мык итеп торды* (Н. Көбәш. Замана кызы).

**БЕРГӘ БАЛА ЧУКЫНДЫРАСЫ ЮК** *к.* аның белән бала чукындырасы юк. *Үпкәләсә үпкәләр тагын – бергә бала чукындырасыбыз юк әле* (Сөйләм).
Төрдәше: аның белән бала чукындырасы юк һ.б.

**БЕРГӘ БИШНЕ КУШУ (КУШЫП СӨЙЛӘҮ)** *к.* авыздан кош очыру 3. *Кыяктай зәһәр телле җиңгәчәйләр, бергә бишне кушып арттырып сөйләргә йөдәп торучы түтәйләр шунда гына* (М. Хәсәнов. Язгы ажаган). *Адәм баласы хыялый зат бит, бергә бишне кушып сөйли, энәне дөя итеп исбатлау аның өчен берни тормый* (К. Кара. Чуклы караватъ).
Төрдәше: авыздан кош очыру 3 һ.б.

**БЕРГӘ БОРЫН ҖИЛЕГЕ КИПТЕРЕП ҮСКӘН.** Малай чактан бергә уйнап үскән. *Синең белән бергә борын җилеге киптереп үскән Касыйм, минем шельма, әллә кайдагы әләмәтәк белән бергә, иртәгә суд эскәмиясенә утырачак* (Ф. Хөсни). *Шушы ике-өч көн эчендә Идегәй белән Токтамыш, бергә борын җилеге киптереп үскән күрше малайлар кебек, бик тә якынлаштылар* (М. Әмирханов. Ир-Мамай).

**БЕРГӘ БУЛСЫН!** Төрле игелекле теләкләргә җавап сүзе («тәмле булсын», «уң булсын» кебек). – *Чәегез тәмле булсын! – дип сүз кушты. –Рәхмәт, бергә булсын!* (Т. Әйди. Елан угы). *Күрәсебез халкыбыз белән бергә булсын* (Н. Сәйяр. Болгар кызы Алтын бөртек).

**БЕРГӘ КИЛҮ.** Очрашу, туры килү. *Тугыз малай бергә килгәндә, тынычлык каламы?* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Чөнки шул мәгълүм бит: әгәр дә ике серле, сәер җан бергә килеп очраша икән, димәк, монда бер гыйбрәт бар!* (Г. Гыйльманов. Җир астындагы язмышлар).

**БЕРГӘ КУЮ.** Тиңләү, янәшә кую. *Кисәктән генә Сәет кузгалды. Ул үз шигырен яклап кына калмады, ә футурист-абстракционистлар иҗаты белән бергә куеп, бергә бәйләп сүз алып баруларына чын-чыннан үпкәсен белдерде* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!). *Ярый әле ут кабызып, / Яшәү белән көрәшне бергә куйган / Исхакыйлар халык язмышына / Күңелләрен салган* (Ф. Яхин).

**БЕРГӘ МЕҢ ИТЕП КАЙТАРУ.** «Бер яхшылык бик күп яхшылык булып кайтсын» мәгънәсендә. – *Алла үзегезгә бергә мең итеп кайтарсын, – диде* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр).

*БЕРГӘ-БЕР* ❖ **БЕРГӘ-БЕР СӨЙЛӘШҮ (ОЧРАШУ** һ.б.) Шаһитлардан башка, аулак җирдә. *Күзгә-күз, бергә-бер сөйләшеп торганда, Галинең Энҗе бикә тарафыннан чәнчеп үтерелүе шулай ук героик үлем түгел* (Ю. Әминов. Бүгенге драматургиябез турында сөйләшү). – *Мин сине күптәннән бирле сагалап йөрим, менә, ниһаять, бергә-бер очраштык* (К. Шакиров. Курку).

**БЕРГӘЛӘП ТОЗ АШАУ.** Бергәләп авыр хәлләр күрү, аларны бергәләп кичерү. *Әмма шулар – ышану, аңлау. Уртак теләк – алар арасында бармы соң? Хәзергә әйтүе читен, ихтимал, тора-бара, бергәләп тоз ашагач, барысы да булыр* (Ә. Еники).
Төрдәше: ачы яшь эчү һ.б.

*БЕРЕ* ❖ **БЕРЕ КАШЫКТАН АРТУ.** Кунакларга кашык җитмәгәндә, хуҗаны уңайсыз хәлгә куймас өчен әйтелә. – *Уңайсызланырлык бер дә урын юк монда, беребез кашыктан артты бугай* (Сөйләм).

**БЕРЕ ТУКМАК, БЕРЕ ЧӨЙ, БЕРЕН АЛ ДА БЕРЕН ТӨЙ.** Берсен мактап, икенчесен яманлап булмый, икесе дә бер-берәңә тиң заман кешеләре. *Шушы мазалы көннәрнең берсендә аның каршында күктән төшкәндәй Юзекәй мөсафир калкып чыкты. – Бере тукмак, бере чөй, берен ал да берен төй, – диде ул, гадәттәгечә ерактан суктырып. – Әллә көлүе, әллә мыскыл итүе, һич аңламассың* (М. Әмирханов. Ир-Мамай).

*БЕРЕБЕЗ* ❖ **БЕРЕБЕЗ АНДА, БЕРЕБЕЗ (ИКЕНЧЕБЕЗ) МОНДА.** Икесе ике җирдә булып, бер-берен күрергә зар булган кешеләр хакында. *Идел алкын, суы салкын, ишеп булмый салларны; / Беребез анда, беребез монда, белеп булмый хәлләрне* (М. Фәйзи). *Шуннан бирле без урык-сурык, беребез анда, икенчебез монда яшәмәдек, һаман да янәшә булдык* (Ф. Яхин. «Татар»).

Төрдәше: берең азаматта, берең браматта <булу>.

**БЕРЕБЕЗ УРАКТА, БЕРЕБЕЗ ТУРАКТА.** Икесе ике якта, ике кәсептә булу. *Шулай беребез уракта, беребез туракта булып, чит өлкәләрдә генә түгел, чит мәмләкәтләрдә гомер итәбез* (Сөйләм).

*БЕРЕГЕЗ* ❖ **БЕРЕГЕЗ БЕР КАЛМЫЙ.** Барыгыз да, һәммәгез дә. *Берегез бер калмый барыгыз, диде* (Г. Бәширов. Намус).

*БЕРЕННӘН* ❖ **БЕРЕННӘН БЕРЕ.** Берсен икенчесе белән чагыштырганда әйтелә. *Береннән бере уңган ике затның кушылуы, бербөтен тәшкил итүе була* (К. Миңлебаев). *Хәмди байның ике кызы береннән бере матур* (Җыр).

*БЕРЕНЧЕ* ❖ **БЕРЕНЧЕ АДЫМ<НАР>.** Баштагы, башлангыч вакыт; нәрсәнең дә булса үсешендә башлангыч чор. *Тантаналы митингны баш инженер Рейдел ачты. Ул: – Иптәшләр! – дип сүз башлады. – Бу – безнең җиңүләребезнең беренче адымы* (А. Алиш. Якты күл буе). *Билгеле, «ялкынлы фотометр» хәзерге медицинаның соңгы сүзе түгел, ләкин Гөлшәһидә үзе дә аны беренче адым дип кенә карый әле* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**БЕРЕНЧЕ ӘТӘЧ.** Ярты төндә кычкырган әтәч тавышы. (Н. Исәнбәт әйтүенчә, элек авылларда төнге сәгать хисабын әтәч кычкыруы белән санаганнар.) *Соң иде инде, куначада беренче әтәчләр кычкырды, сүзләр кыскарды, юрган астына кергәч кенә, Нәҗип Наиләгә абыйсы белән булган әңгәмәнең кыскача эчтәлеген сөйләп бирде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Әмма барыбер ятарга ярамый. Кайдадыр беренче әтәч тә кычкырды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**БЕРЕНЧЕ БАШЛАП.** Тәүге булып, беренче мәртәбә. *Күп кенә галимнәр атны беренче башлап төркиләр кулга ияләштергән дигән фикердә* (А. Тимергалин «Миллият» сүзлеге). *Октябрьнең беренче көнендә мин, Керәнле авылы белән саубуллашып, беренче башлап килгән юлымнан чыгып киттем* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).

**БЕРЕНЧЕ ВАКЫТТА.** Нәрсәне булса да башлаган вакытта. *Күрәсең, терелү шатлыгы, табибларга булган хөрмәт һәм аларга табыну Асиядә беренче вакытта шулхәтле көчле булган, ул, үз теләген яхшылап ачыкламыйча, элемтәне ташлап, медицинага омтылган* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Беренче вакытта буталчыкларсыз булмас инде* (Г. Шәйхи. Офыклар киңәйгәндә).

**БЕРЕНЧЕ КАРАШКА(ТА).** Беренче караганда, беренче карауда. *Беренче карашка, туган халкы белән бәйләнеше юк дәрәҗәсендә булган бу шәхеснең татарлыгы «ташка үлчим» генә булып күренә* (М. Гайнетдин. Гасырлар мирасы). *Сүрә халыкка шул ягы белән мәшһүр дә һәм, беренче караштa, аның финалы күңелле дә кебек* (Г. Гобәй. Коръән серләре).

**БЕРЕНЧЕ КАРЛЫГАЧ (САНДУГАЧ)** *к.* әүвәлге карлыгач. – *Минә синә марш, минә синә романс!.. Ләкин болар әле беренче карлыгачлар гына...* (Ә. Еники. Гөләндәм туташ хатирәсе). *Беренче карлыгачлар – Галиәсгар Камалның «Бәхетсез егет» һәм Гаяз Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш» пьесалары – унтугызынчы гасырда иҗат ителсә дә, жанр*

*буларак, драма егерменче гасырга кергәч кенә оешты* (А. Яхин. Галиябану мәхәббәте).

Төрдәше: әүвәлге карлыгач.

**БЕРЕНЧЕ КОЙМАК ТӨЕРЛЕ БУЛУ (ЧЫГУ).** «Беренче эш һәрвакытта да уңышлы чыкмый» мәгънәсендә. *Әйдә, эшем пешмәгән икән, киләчәккә сабак булыр, беренче коймагымны төерле чыккан санармын...* (Г. Тавлин. Афәт). *Беренче тәҗрибә, беренче коймак... Беренче коймак төерле булды шул!..* (Ә. Баянов. Ут һәм су).

**БЕРЕНЧЕ КӨННӘРДӘН ҮК.** Башлангычтан, баштан. *Ниһаять, агрегатлар басуга чыкты. Ләкин беренче көннәрдән үк күңелсезлекләр башланды* (Ж. Рәхимов. Кобзарь бүген Тукай кунагы). *Беренче көннәрдән үк төрле эшләр йөкләделәр. Беренче көнне танышудан башладык* («Ялкын» ж.).

**БЕРЕНЧЕ КУЛ.** Иң яхшы эшләүче. – *Алайса булды. Син татардан беренче кул спец буласың* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар). *Бактың исә ул беренче кул балта остасы, беренче кул тугымчы икән* (Г. Ахунов. Чикләвек төше).

**БЕРЕНЧЕ КУЛДАН.** 1. Язгы чәчү вакытында алдан барып, чәчү рәвешен, темпын бирүче кеше. *Борһан инде беренче кулдан – чәчүчеләрнең башында бара белә* (М. Хуҗин. Җир әйләнә сәяхәт).

2. Мәгълүматны арадашчылардан башка туп-туры иясеннән ишетү, алу һ.б. *Ике сүзгә урын юк: сатылган, акча алган, шуның икенче көнендә үзен үзе аскан... Бу хәбәр миңа беренче кулдан мәгълүм* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Кыбрыс төрекләре иде, шуңа күрә мин сәяхәт барышында беренче кулдан легендар утрауның тарихы, тормыш шартлары, соңгы заманда анда дәвам иткән көрәшләр, күренекле шәхесләр турында шактый нәрсә белә алдым* (Т. Әйди. Оҗмах утравы).

**БЕРЕНЧЕ КҮРҮ.** Алдынгы дип кабул итү, беренче дәрәҗәдә санау. *Нәрсә генә әйтсәләр дә, мин аны беренче күрәм, бездә иң катлаулы хәлләрне дә аннан оста көйли белүче юк* (Сөйләм).

**БЕРЕНЧЕ МИНУТЛАРДА.** Башта, әүвәл. *Мин дә, беренче минутларда үземне шактый бәйле хис итсәм дә, ничектер бик тиз тынычландым* (Ә. Еники). *Беренче минутларда дәррәү янгын сүндерергә ташланып ялгыштылар* (В. Имамов. Утлы дала).

**БЕРЕНЧЕ СКРИПКА.** Башлап йөрүче, баш рольне уйнаучы. *Думада кадетлар «эшнең хуҗасы» булып җитә алмасалар да, монда алар «беренче скрипка» булалар* (С. Максуди. 1906–1924 еллар).

**БЕРЕНЧЕ СКРИПКАНЫ УЙНАУ.** Өстенлек итү, әйдәп йөрү. *Икенче бер хасияте һәм бик сирәк очрый торган хаҗәте мәрхүмнең беренче скрипка уйнарга кызыкмавы, һәрбер түгәрәктә рәис булырга омтылмавы иде* (Г. Исхакый). *Уральскида хәзер Тукай һәрьяктан караганда да беренче скрипканы уйный* (И. Нуруллин. Тукай).

**БЕРЕНЧЕ СҮЗДӘН.** Беренче сүзне әйтү белән үк, шунда ук. *Фәтхулланың беренче сүздән төрттереп алуы егетне каушатты, ул «син сорама, мин әйтмим» дигән кебегрәк җавап белән котылып калды* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Кабинетка кергәндә, Васил баш инженер болай беренче сүздән үк каршы төшәр дип уена да китермәгән иде* (С. Рәфыйков. Тын елга буенда).

**БЕРЕНЧЕ ТАШНЫ АТУЧЫ.** Башлаучы, оештырып йөрүче. – *Мине соңгы тапкыр сарайдан куганда, беренче ташны атучы ул булды* (Р. Батулла. Сөембикә).

Төрдәше: берне биш (ун) итү.

**БЕРЕНЧЕ ЧИРАТТА (НӘҮБӘТТӘ)** *к.* барыннан да элек (әүвәл). *Һәрхәлдә, бу салкынлык өчен Рәфис беренче чиратта үзен битәрли, алар белән тәүге очрашуда ук уртак тел табып китә алмавына газаплана иде* (А. Вергазов. Үзеңә кайту). *Миңа беренче чиратта эш, фатир табуымны, алда ничек көн итәремне кайгыртырга кирәк* (Г. Тавлин. Афәт).

Төрдәше: барыннан да элек (әүвәл).

*БЕРЕНЧЕЛЕКНЕ* ❖ **БЕРЕНЧЕЛЕКНЕ БИРМӘҮ** *к.* алга чыгармау. – *Шулай да без беренчелекне бирмибез инде, әйеме?* (З. Мурсиев. Ай нуры). *Чынлап та, ул җебеп тора торганнардан булмый, атларны кулга ияләштерү, чабышларга өйрәтү, Сабантуйда, башка чабыш-*

*ларда беренчелекне бирмәү белән дә дан казана, чын мишәр егете итеп күрсәтә ул үзен яшүсмер чактан ук* («Әлмәт таңнары» газ.).

*БЕРЕНЧЕСЕ* ❖ **БЕРЕНЧЕСЕ ҺӘМ СОҢГЫСЫ БУЛСЫН** *к.* әүвәле-ахыры шушы булыр (булсын). – *Әгәр дә бу тамашаң хакында белә калсалар, синең дә, минем дә башлар Себер китәчәк, төрмәдә черетәчәкләр. Мондый «гастрольләрең» беренчесе һәм соңгысы булсын!»* – *ди* («Безнең гәҗит» газ.).
Төрдәше: әүвәле-ахыры шушы булыр (булсын).

*БЕРЕҢ* ❖ **БЕРЕҢ АЗАМАТТА, БЕРЕҢ БРАМАТТА <БУЛУ>.** Бергә булмыйча, төрле якларда йөрү. *[Сания] Эшмени бу, ничә еллар буе береҢ азаматта, берең браматта...* (Ф. Бурнаш. Таң).
Төрдәше: беребез анда, беребез (икенчебез) монда.

**БЕРЕҢ ИКЕ БУЛМАСЫН, ЙОРТЫҢ-КАРАҢ КАЛМАСЫН** *карг.* «Малың-терлегең үрчемәсен, йортың-дәүләтең бетсен» мәгънәсендә. – *Берең ике булмасын! Йортың-караң калмасын! / Ханнан ханны мин ектым, Хан булып син дә калмассың!* («Идегәй» дастаны).

*БЕР-ИКЕ* ❖ **БЕР-ИКЕ АВЫЗ.** 1. Аз гына, озак түгел (сүз турында). *Сафин үзенең электә бергә хезмәт иткән иптәше Габдулланың кайту шатлыгына «бер-ике авыз» речь тотты* (Ш. Камал. Таң атканда).

2. Бераз, күп түгел. <...> *киң Россиянең буен буйлаган, иңен иңләгән бер картның яшьләргә бер-ике авыз киңәш бирерлек кенә тәҗрибәсе бар* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

3. Берничә сүз белү (чит тел турында). – *Карале, бер-ике авыз сүз белү дә ярап тора икән ләбаса!* (М. Маликова. Арыш тәме).

**БЕР-ИКЕ БӨРТЕК.** Берничә. *Ул вакытта әле колхозда бер-ике бөртек чылбырсыз трактор белән дыңгыр-дыңгыр килеп чабучы «полуторка» машинасыннан башка техника булмаганлыктан, төп йөкне атлар тарта иде* (Ш. Маннапов. Туган якка кайту). *Зур темадан бер-ике бөртек җим табып, укучыга бүләк итәләр дә эзләнү мәйданыннан чыгалар* (М. Зарипов. Заман һәм традицияләр бәйләнеше).

**БЕР-ИКЕ РӘТ МАН(Ч)У.** Берәрсенә берничә кат сугу. – *Патша хөкүмәте бит ул, телне тый, сакла, җүләр!* – *дип, «өтек»кә бер-ике рәт манчыдылар* (Ш. Бабич).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**БЕР-ИКЕ <АВЫЗ> СҮЗ (ГӘП).** Бераз сөйләшү, берничә сүз. *Ул, бер-ике авыз сүз белән карчыктан котылмакчы булып, кыска-кыска гына итеп җавап биргәләде дә читкәрәк китте* (А. Гыйләҗев). *Зөфәрнең Рәшидә белән бер-ике генә авыз сүз булса да сөйләшеп аласы килә иде* (Ә. Еники. Рәшә). *Әле минем сезгә янә бер-ике авыз гәбем бар* (Т. Әйди. Елан угы).

**БЕР-ИКЕ <АВЫЗ> СҮЗ ӘЙТҮ.** Бераз сөйләп алу. *Нәҗип әңгәмәне алга алып китәргә кыймады, бер-ике сүз әйтергә өлгерүгә, моңарчы үзе хакында үзе корган фикерләренең ишелеп төшәсен сизде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Тәүфыйкка да иртән, кичен бер-ике авыз җылы сүз әйтми калмас* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы).

**БЕР-ИКЕ СҮЗ БЕЛӘН ӘЙТЕП БИРҮ.** Кыска гына итеп әйтү. *Бүленгән өлешләргә исем бирү өчен, башта текст эчтәлегенең төп темасын табарга һәм аны бер-ике генә сүз белән әйтеп бирергә тиеш була* (nsportal.ru). – *Әлеге үзәктәге уңайлыклар турында бер-ике сүз белән генә әйтеп бирә торган түгел* (biektaw.ru).

**БЕР-ИКЕ СҮЗ БИРҮ**. Җыелышта сөйләр өчен сүз сорау. *[Шәһид] Председатель иптәш, сез эшләрегезне аннан карарсыз. Ә хәзергә миңа бер-ике сүз бирегез әле* (Ф. Бурнаш. Илһам).

*БЕРКАТЛЫ* ❖ **БЕРКАТЛЫ КӘБЕСТӘ.** Һәр нәрсәгә ышанучан, хәйләсез кеше. *Юк сүз өчен әйткәндер, билгеле, ә мин беркатлы кәбестә, ышангандай булдым* (Х. Камалов). *И беркатлы кәбестә! Аның ни-нәрсә уйлаганы кызга бик мөһим ди* (Н. Гыйматдинова. Җәза).
Төрдәше: беркатлы кеше; беркатлы утын пүләне; беркатлы шалкан; күлмәге белән генә ике кат.

**БЕРКАТЛЫ КЕШЕ.** Хәйләсез, гади, башкаларның һәр сүзенә ышанучан. *Бар иде бездә Сафи атлы кеше, / Бик юаш, бичара, беркатлы кеше* (Г. Тукай). – *Сез әллә беркатлы кеше, әллә бик хәйләкәр* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).
Төрдәше: беркатлы кәбестә һ.б.

**БЕРКАТЛЫ УТЫН ПҮЛӘНЕ** *к.* беркатлы кәбестә. *Сәях – беркатлы утын пүләне – шуларның барысына ышана* (Х. Камалов).
Төрдәше: беркатлы кәбестә һ.б.

**БЕРКАТЛЫ ШАЛКАН** *к.* беркатлы кәбестә. *Хуҗа сер бирмәгән булып шаяртса да, йөрәге каен тузы шикелле бөгәрләнеп, чатнап яна иде, аны гына күз алдына китермәскә Нургали бәк беркатлы шалкан түгел* (В. Имамов. Карабәк).
Төрдәше: беркатлы кәбестә һ.б.

*БЕРКЕМ* ❖ **БЕРКЕМ ДӘ ТҮГЕЛ.** 1. Бик түбән кеше. *– Миннән башка син беркем дә түгел. Ишетәсеңме, беркем дә түгел!* (З. Мәхмүди. Елак агач). *Юк, «затсыз» – син беркем түгел, буш кеше дигәнгә якынрак килә, ахрысы* (Р. Гыйлемханов һ.б. Истә калганнар).

2. Туган-тумача да, таныш-белеш тә түгел. *– Ә Фәтхи... Фәтхи беркем дә түгел миңа, ул – минем өчен юк кеше* (Х. Мөдәррисова. Соңгы сер).

**БЕРНӘРСӘ (БЕРКЕМ) ДӘ ЮК.** Бөтенләй буш булу. *Берсе дә, бернәрсә дә юк, бары – кулына тәсбих тоткан бер татар карчыгы бар* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *– Тарту мәйданында беркем дә юк иде* (А. Алиш. Якты күл буе).
Төрдәше: шар тәгәрәтерлек.

**БЕРНӘРСӘГӘ ДӘ КАРАМАСТАН**. Илтифатсыз булу, дикъкать итмәү. *Без бернәрсәгә дә карамастан чабабыз гына* (Г. Ибраһимов). «*Бернәрсәгә дә карамастан, алга һәм фәкать өскә таба» – бу девизым булышлыгында әлегәчә бар да уңышлы килеп чыга* («Мәдәни җомга» газ.).

*БЕРНЕ* ❖ **БЕРНЕ БИРҮ.** Бер сугып җибәрү. *Нәрсә әйтергә дә белмәде, килгәне бушка китмәсен дип, Гыйззәтуллинның яңагына ут күренерлек итеп берне бирде дә торып чапты* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары). *«Төшереп алган да, иптәшләре белән аз гына чәкәләшеп киткәннәр. Авызына берне биреп, кайтарып җибәрдем»* (З. Мурсиев. Зариф, Зәлифә).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**БЕРНЕ БИШ (УН) ИТҮ.** 1. *к.* авыздан кош очыру 1. *Алар берне биш итеп сөйлиләр, кылны кырыкка яралар иде* (Һ. Атласи). *Аның ничә ел буе берне биш итеп тырышканнары, интегеп, берәмтекләп, дөньялары шулай бик тиз генә юкка чыгармы?* (Д. Булатова. Соң түгел!).
Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

2. *к.* авыздан кош очыру 3. *Ир-атның холкы барысының бертөсле, бераз төшереп алсалар, берне биш итеп мактанырга торалар* (К. Кара. Зарифа). *Сәбәп кенә булсын, Илһам хакында Бәчә берне ун итеп сөйләргә генә тора* (Ф. Садриев. Шаһзаманов эше).
Төрдәше: авыздан кош очыру 3 һ.б.

**БЕРНЕ БИШ, КОЙРЫГЫ БЕЛӘН КУШ ИТЕП** *к.* авыздан кош очыру 3. *Кибетче Зәйнәп, берне биш, койрыгы белән куш итеп, кибеттә очрашуларын үтә ямьсез итеп Ихласка әләкләгән иде инде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: авыздан кош очыру 3 һ.б.

**БЕРНЕ БҮЛЕП, ЯРТЫНЫ ЯРЫП АШАУ.** Авыр көннәрдә (яки вакытларда) мохтаҗлыктан коткарып калганнар хакында. *Югыйсә озын сәфәр вакытында «берне бүлеп», яртыны ярып ашарга да туры килгән булыр иде* (Р. Гыйлемханов һ.б. Истә калганнар).

**БЕРНЕ КАГУ** *к.* авыз җебетү 1. *Миндә бетмәс, мичкә кипмәс, / Тагын берне кагып җибәр. / Авыз итеп ара-тирә, / Ахун китә, ава-түнә* (Г. Афзал. Тотып җибәр, апаем...). *Бүген алай җаен тапты, / Бер башына берне какты. / Закускасы йодрык булгач, / Башына да китте шактый* (Р. Батталов. Гомер учагы).
Төрдәше: авыз җебетү 1 һ.б.

**БЕРНЕ КУНДЫРУ (ТАМЫЗУ).** Йодрык белән ныгытып сугу. *Исәбе: теге филер якынрак килсә, мәсхәрә итеп көлү, яисә исереккә салышкан булып, борынына берне кундыру иде* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Аның кайтканын ишетеп, теге яктан Таңсылу килеп чыкты һәм йөзтүбән капланып яткан Нәҗипнең арык җилкәсенә майлы, симез йодрыгы белән берне кундырды* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Әтисе ватылган чынаяклар өчен Биюшнең йомшак җиренә дәү учы белән бик шәпләп берне тамызгач та яңа көйләр чыкмады* (М. Хуҗин. Ак колын).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**БЕРНЕ МАН<Ч>У** *гади с., к.* авыз җебетү 2. *Нидер ырылдады һәм, кизәнеп,* / Йодрык белән *манды әсиргә* (Ә. Рәшит). *Анысында биек үкчәле француз туфлие белән сиңа да берне манчыган иде бит* (Ф. Имамов. Әйбәт кәләш).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**БЕРНЕ СИБҮ.** Ашлык чәчкәндәге кебек, йодрыкка учлап, колачны җәеп сугу. *Бик каты итеп йодрыклап, минем җилкәгә берне сипте* (М. Гали).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**БЕРНЕ СӨЙЛӘП, ИКЕНЧЕНЕ ЭШЛӘҮ.** Сүзе эшенә туры килмәгән ялганчы хакында. *<…> бу кешеләр – сүзләренә фигыльләре вә гамәлләре туры килмәгән, телдә берне сөйләп, асылда икенчене эшләгән галимнәр булырлар!* (Ф. Яхин. Иман). *Тормышта берне сөйләп, икенчене эшләүдән дә яманы юк* (М. Әхмәтҗан. Тормыш мизгелләре).

**БЕРНЕ СУГЫП, ИКЕГӘ ТИЮ** *к.* акмаса да таму (тамчылау). *Берне сугып, икегә тигән кебек булды бу базарга чыгуым, күптән эзләгән ышкыны таптым, тотармын дип уйлаган акчамның да яртысы кесәдә калды* (Сөйләм).
Төрдәше: акмаса да таму (тамчылау) һ.б.

**БЕРНЕ СЫЛАУ (ЯМАУ).** Йодрык яки нинди булса да берәр әйбер белән бик каты итеп сугу. *Хамис инде аның ягына борылган да иде, кулын да күтәргән иде – көтмәгәндә арттан тагын берне сыладылар* (Н. Фәттах. Аклан). *Бәй, теге явыз җәһәт кенә торды да минем күз төбенә берне ямады* (Г. Афзал. Минем интервью).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**БЕРНЕ ТӘПӘҮ.** Һаман бер сүзне кабатлау, бер нәрсә хакында гына сөйләү. *Киселгән икмәк кире ябышмый! Җитәр, һаман берне тәпәмә!* (Сөйләм).
Төрдәше: авызда бер үк җыр <булу> һ.б.

**БЕРНЕ ЧАЛТЫРАТУ.** Яңакка сугу. *Ләкин Наилә акылын җыеп өлгерде, котырган үгез сыман янында торган Сабитның култык астыннан шамбы балыгы сыман шуып чыкты, ул «тоттым!» дигәндә, яңагына берне чалтыратты* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). – *Әгәр юри оттырсаң, яңагыңа берне чалтыратам ! – дип, малайларча өркетеп тә куйды* (М. Хуҗин. Кадер).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

*БЕРНИ* ❖ **БЕРНИ ӘЙТЕР ХӘЛ ЮК.** 1. Сүз күтәрә алмый торган кеше турында. *Берни әйтер хәл юк, үзенә кагылышлы тискәре сүз ишеттеме, козгын кебек өстеңә ташлана* (Сөйләм).

2. «Гаеп итәрлек җире юк» мәгънәсендә. *[Хәйри] Аларга да берни әйтер хәл юк инде, туганым. Аларның да шул байлары кушканны эшләми хәлләре юк* (Г. Камал). *Берни әйтер хәл юк, чөнки бу бит инде кешедәге рухи таләп* (Н. Исәнбәт. Татар халык табышмаклары).

**БЕРНИ <ДӘ> БУЛМАГАНДАЙ.** Сер бирмәү; эчтән начар булса да, аны сиздермәү. *Икенче көнне фрау, берни булмагандай торып, хуҗалык эшләренә ябыша* (А. Тимергалин. Игезәкләр). *Рәфис Шәмсүнгә күз төшереп, аның халәтен аңлады. Шулай да, берни булмагандай, әңгәмәне дәвам итте* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).
Төрдәше: авыз <тулы> <кара> кан булса да, дошман (чит кешеләр) алдында түкмәү (түкерергә ярамау) һ.б.

**БЕРНИ ДӘ ЮГАЛТМАУ.** Һичнинди зыян күрмәү. – *Күргәзмәгә барасыгыз килсә барыгыз, мин, мәсәлән, бармадым – ләкин берни дә югалтмадым дип уйлыйм* (Сөйләм).

**БЕРНИ <ДӘ> КЫРА АЛМАУ.** Бернәрсә дә булдыра алмау, хәленнән һични килмәү. *Болай ачыктан-ачык талашып, бозылышып берни кыра алмаячагын ул бер тапкыр аңларга тиеш булды* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур). *Өчәүләшеп берни дә кыра алмадылар алар* (К. Кара. Чуклы караваt).

**БЕРНИ <ДӘ> ТОРМАУ.** Башкарасы эшнең җиңеллеге яки әйбернең арзанлыгы хакында; бернәрсә урынына да күрмәү. *Трактор барган шәпкә сикереп төшү аңа берни дә тормый* (Ф. Садриев. Көлми торган кеше). – *Зинһар кирәкми, бер машиналык акча туздырырга, тилеме әллә син? – 2–3 мең доллар миңа берни тормый, Айрат әзи* (Ш. Алпар. Милләт өмете).
Төрдәше: берни <дә> түгел.

**БЕРНИ <ДӘ> ТҮГЕЛ.** 1. *к.* берни <дә> тормау. *Үчекләп утырган малайларны акылга утырту хәзер миңа берни дә түгел* (Г. Бәширов. Туган

ягым – яшел бишек). *Юкса өегезне шартлатам, көлен күккә очырам. Минем өчен ул берни түгел* (А. Хәсәнов. Данәгөл).

Төрдәше: берни <дә> тормау.

2. Гадәти нәрсә, шаккатарлыгы юк. *Әни әйтә: – Рельссыз йөрүләренә гаҗәпләнәсең, ул берни түгел. Биредә трамвайлар җир астында да йөриләр әле, – ди* (А. Алиш. Тимер юл). *Мидхәт иреннәрен киң җәеп, рәхәтләнеп көлеп куйды: – Ничек дип, шул инде: җавабыңны яхшылап бирсәң, берни түгел* (В. Нуруллин. Ике урам арасы).

**БЕРНИ УРЫНЫНА ДА КҮРМӘҮ.** Исәпләшмәү, санламау, түбәнсетү. *Баш икәнеңне онытма, бераз җитдирәк булырга кирәк – юкса үзеңне берни урынына да күрми башлаячаклар* (Сөйләм).

Төрдәше: бар дип тә белмәү һ.б.

**БЕРНИ <ДӘ> ЭШЛӘП БУЛМАУ.** Бернәрсә дә эшләтеп булмаганнан риза булырга туры килү. *Белә торып берни эшләп булмау – иң каты җәза икән бу дөньяда* (Г. Гыйльманов. Тозлы яңгыр). *Тавышлар охшаш икән, монда берни эшләп булмый, Ходай шулай яраткан* (Г. Бәйрәмова. Моңлы көйгә ил колагын салыр).

Төрдәше: берни <дә> эшләр (итәр) хәл юк.

**БЕРНИ <ДӘ> ЭШЛӘР (ИТӘР) ХӘЛ ЮК** *к.* берни <дә> эшләп булмау. *Берни эшләр хәл юк, кунаклар тагын икенче катка менделәр, газета караштырган булып беркавым утырдылар* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Ләкин хәзер берни дә эшләр хәл юк, машина туктатып ваклана башласа, Наиләнең «акчасын кызганды инде бу хәчтерүш, шуңа төшеп калды» дип уйлавы мөмкин иде* (В. Нуруллин. Һәлакәт).

Төрдәше: берни <дә> эшләп булмау.

*БЕРНИГӘ* ❖ **БЕРНИГӘ <ДӘ> КАРАМЫЙ<ЧА> (КАРАМАСТАН).** Бернинди комачауларга да карамыйча, бернинди киртәләргә дә игътибар итмичә. *Чатан гына, бернигә карамый, ишегалдын айкавын белә* (А. Хәсәнов. Бүре баласы Чатан). *Ермак шундый фәрештәдәй затның, нәфис хатын-кызның мондый җиһад хаты язуына бик гаҗәпләнде, бернигә карамастан, Сүзге-бикәне үзенеке итү утында янды* (Ф. Бәйрәмова. Күчем хан).

Төрдәше: берни <дә> булмагандай.

**БЕРНИГӘ КИРӘКСЕЗ.** Бернигә дә яраксыз, файдасыз. *Автомәктәпләр берлеге тәкъдименә килгәндә, бу яңалыкны бернигә кирәксез, мәгънәсез эш дип уйлыйм* («Ватаным Татарстан» газ.).

**БЕРНИГӘ <ДӘ> САНАМАУ.** Исәпкә алмау, берни урынына да күрмәү, үтә җиңелгә санау; берәр кешегә яки берәр нәрсәгә дикъкать итмәү. *Ә менә дошман гомерен ул бернигә санамады* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы). *Күзләрегезне төбәшеп күпме утыргансыздыр, белмим, мин башта бернигә санамаган идем, ләкин сез бер, ике, өч... биш минут шулай чекрәешеп утыра башлагач, күңелемнең әллә кай җирендә нәрсәдер «кырт» итеп өзелгән сыман булды* (Г. Кашапов. Җир җылысы).

**БЕРНИГӘ (БЕРНИЕМӘ) <ДӘ> ЯРАМАУ.** Бөтенләй яраксыз эш яки әйбер хакында. *Инде бернигә ярамый дигән чүп тә эшкә ярап куя – аны, карьерларга тутыра-тутыра, океаннан җир даулап алалар, аннан, шуның өстенә уңдырышлы туфрак өстәп, яшелчә һәм җиләк-җимеш үстерәләр* (Ә. Рәшит. Һәркемнең... үз хакыйкате). *Аны «эшләгән эш бернигә дә ярамас, Фәннәр академиясен оятка калдырырмын» дигән бәйләнчек фикер әзәрлекләгән* («Казан утлары» ж.).

*БЕРНИНДИ* ❖ **БЕРНИНДИ ШИКСЕЗ (ШӨБҺӘСЕЗ).** Дөрес булганлыкка ышану. *Денис Михайлов кул куйган документларга бернинди шиксез ышану гадәткә кергәнлектән, тикшерү машинасы салынган эздән бу очракта да җиңел генә узды* (Ә. Баянов. Урланган ай).

Төрдәше: бернинди шик-шөбһәсез; һичбер шиксез (шөбһәсез); һичбер шик-шөбһәсез.

**БЕРНИНДИ ШИК-ШӨБҺӘСЕЗ** *к.* бернинди шиксез (шөбһәсез). *Моңарчы бу күлгә килгәне булмаса да, ул бернинди шик-шөбһәсез суга кереп китте* (Сөйләм).

Төрдәше: бернинди шиксез (шөбһәсез) һ.б.

*БЕРНИСЕЗ* ❖ **БЕРНИСЕЗ КАЛ<ДЫР>У.** Бар нәрсәсен югалту, буш кул белән калу. *Кенәзлекләр саны аз булганга, соңрак Долгорукий кушаматы бирелгән Юрий бернисез кала* (И. Хуҗин. Татар тарихы). *Ә даими чемпионатны онытсак, киләсе ел безне бернисез калдырачак* («Безнең гәҗит» газ.).

*БЕРСЕ* ❖ **БЕРСЕ АГАРАККА, БЕРСЕ (ИКЕНЧЕСЕ) ТАГАРАККА ТАРТУ.** Бер-берсенә каршы килгән ике якка тарту. *Сөембикә белән Үтәмешнең тәкъдир-кыйсмәт дәфтәренә «коллыкта үләргә» дип язылганмы, батыр җегетләрнең берсе агаракка, икенчесе тагаракка тартуы сәбәпле, бу хәтәр эш бикяр-файдасыз булды.* (Р. Батулла. Сөембикә).

Төрдәше: берсе арба юлыннан, берсе чана юлыннан бару (китү); берсе байга, берсе (икенчесе) сайга өстерәү; берсе дүшәмбегә, берсе чәршәмбегә карап яшәү; берсе уңга ишү, берсе – сулга; берсе чана юлыннан, берсе арба юлыннан бару (китү).

**БЕРСЕ АРАКТА, БЕРСЕ (ИКЕНЧЕСЕ) ТАРАКТА.** Бер-берсеннән ерак тору. *Берсе аракда, берсе таракда* (К. Насыйри. Мәкаль һәм әйтемнәр).

Төрдәше: берсе арапта, берсе (икенчесе) тарапта.

**БЕРСЕ АРАПТА, БЕРСЕ (ИКЕНЧЕСЕ) ТАРАПТА.** Икесе ике якта, аерым юлда, икесе аерым кәсептә. *Ягъни болгар-татарны сәүдәдә алдыйм диюче үзе алданыр, янәсе, берсе арапта, берсе тарапта* яки *Дөбъязларча, берсе аракта, икенчесе таракта* (Н. Исәнбәт. Фразеологик әйтемнәребездә тарихчылык).

Төрдәше: берсе аракта, берсе (икенчесе) таракта.

**БЕРСЕ АРБА ЮЛЫННАН, БЕРСЕ ЧАНА ЮЛЫННАН БАРУ (КИТҮ).** Ике кешенең, аңлаша алмыйча, нәрсәнедер төрле юллар белән хәл итәргә тырышуы. *Алай түгел ул, иптәш Корбанов, безнең беребез арба юлыннан, беребез чана юлыннан бара* (Г. Ахунов).

Төрдәше: берсе агаракка, икенчесе тагаракка тарту һ.б.

**БЕРСЕ АРТЫННАН БЕРСЕ** *к.* бер-бер артлы. *Чәй янындагы алмалар, сырлар, булкилар берсе артыннан берсе безнең эскәтердән югала башлады* (Г. Исхакый. Зиндан). *Газинурлар кайда? Нишләделәр? «Тел» ала алдыларммы? Кем аны килеп коткарыр? Бу сораулар берсе артыннан берсе өелеп киләләр* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

Төрдәше: бер-бер артлы һ.б.

**БЕРСЕ БАЙГА, БЕРСЕ (ИКЕНЧЕСЕ) САЙГА ӨСТЕРӘҮ.** «Икесе ике якка өнди» мәгънәсендә. – *Син кара аларга, берсе байга, берсе сайга өстерәгәндә, нәрсә эшләргә җыеналар соң алар?* (Сөйләм).

Төрдәше: берсе агаракка, берсе тагаракка тарту һ.б.

**БЕРСЕ БЕРНЕ, БЕРСЕ ИКЕНЧЕНЕ ТУКУ.** Бернәрсәне ике төрле аңлату, берьюлы ике кешенең төрлечә сөйләп торуы. *Бу утырышның колхоз җыелышыннан бер дә аермасы юк икән: берсе берне, берсе икенчене тукый* (Сөйләм).

**БЕРСЕ БИШ БУЛУ.** Чәлпәрәмә килеп ватылу, вак-вак кисәкләргә таркалу. *Бичара марҗаның кулындагы чирекле шешәсе йөзгә ватылып, квасыннан мәхрүм калган кебек, урысның таш уенчыклары да берсе биш булды* (Ш. Мөхәммәдев).

**БЕРСЕ ДҮШӘМБЕГӘ, БЕРСЕ ЧӘРШӘМБЕГӘ КАРАП ЯШӘҮ** *к.* берсе агаракка, берсе тагаракка тарту һ.б. *Шәһәр урамнарында «озын акча» артыннан куып йөрүче «ала канат», «адашкан каз» Габдрахман, колхоз өчен резервлар табарга яратучы һәм шуның өчен «син үзең бик зур резерв» дигән мактау сүзләре ишеткән Мәгъсүм агай, берсе дүшәмбегә, берсе чәршәмбегә карап яшәүче ике кода – Сәмигулла белән Сәхип карт, кыек күңелле һәм туры күңелле ике күрше Хөршидә белән Мәрьям – мондый кешеләрнең тормышта барлыгын без гомумән алганда белә идек* (И. Гази. Чирәм ерту – һәр язучы бурычы).

Төрдәше: берсе агаракка, берсе тагаракка тарту һ.б.

**БЕРСЕ ИШҮ, БЕРСЕ СҮТҮ.** «Берәүнең эшләгәнен икенчесе юкка чыгарып бара» мәгънәсендә. *Сәхнәдә иң көчле рухани фаҗига барганда, Мәһдиев белән Баязитская берсе ишә, берсе сүтә тәэсирен бирәләр иде* (matbugat.ru).

**БЕРСЕ КАЛАГА, БЕРСЕ (ИКЕНЧЕСЕ) САЛАГА.** Ике кеше, бер-берсен аңламыйча, төрле нәрсә турында сөйләп утыру. *Берсе колакка катыракмы шунда бу агайларның, берсе калага, икенчесе салага тик сөйләп утыралар* (Сөйләм).

Төрдәше: берсе тугай дип сөйләү, берсе (икенчесе) бугай дип сөйләү; берсе урманга, берсе (икенчесе) печәнгә (тугайга) <китү>.

**БЕРСЕ КЕШЕНЕКЕ, БЕРСЕ КҮРШЕНЕКЕ** *к.* авызны ачса, кече теле күренү 2. *Аның*

*булган, ди, өч өе: берсе кешенеке, берсе күршесенеке, берсе салмаган, бурасын да алмаган, шунлыктан ул алачыкта гына торган, ди* (Татар хал. әкияте).

Төрдәше: авызны ачса, кече теле күренү 2 һ.б.

**БЕРСЕ ӨСТЕНӘ БЕРСЕ.** Берсенә берсе өелү. *Маневр паровозлары вагоннарны төн ката арлы-бирле сөйри, вагоннар берсе өстенә берсе меңәләр, тормозлар исереп чыелдый, буферлар, маңгайга-маңгай килеп, очкын һәм тәмуг авазлары тараталар* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Йолдызлар шундый күп, әйтерсең берсе өстенә берсе кат-кат өелешеп беткәннәр* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

**БЕРСЕ ТУГАЙ ДИП СӨЙЛӘҮ, БЕРСЕ (ИКЕНЧЕСЕ) БУГАЙ ДИП СӨЙЛӘҮ** *к.* берсе калага, берсе (икенчесе) салага. *Берсе тугай дип сөйли, икенчесе бугай дип сөйли* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

Төрдәше: берсе калага, берсе (икенчесе) салага һ.б.

**БЕРСЕ УҢГА ИШҮ, БЕРСЕ – СУЛГА** *к.* берсе агаракка, берсе тагаракка тарту. *Берсе уңга ишә, берсе сулга ишә* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

Төрдәше: берсе агаракка, берсе тагаракка тарту һ.б.

**БЕРСЕ УРМАНГА, БЕРСЕ (ИКЕНЧЕСЕ) ПЕЧӘНГӘ (ТУГАЙГА) <КИТҮ>** *к.* берсе калага, берсе (икенчесе) салага. *Берсе урманга, берсе тугайга киткән* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

Төрдәше: берсе калага, берсе (икенчесе) салага һ.б.

**БЕРСЕ ЧАНА ЮЛЫННАН, БЕРСЕ АРБА ЮЛЫННАН БАРУ (КИТҮ)** *к.* берсе агаракка, берсе тагаракка тарту. *Җавап сүзен малайлар җырлап бирергә тиеш иде. Ләкин, көзге әтәч тавышлары чыгарып, берсе чана юлыннан, берсе арба юлыннан китте* (М. Әмирханов. Мөкәррәмә).

Төрдәше: берсе агаракка, берсе тагаракка тарту һ.б.

**БЕРСЕ ЧӘРШӘМБЕГӘ, БЕРСЕ (ИКЕНЧЕСЕ) ДҮШӘМБЕГӘ (ҖОМГАГА; ЯКШӘМБЕГӘ) КАРАУ.** Кылый күзләр хакында. *Озын чәче иңенә ишелеп төшкән, иягендә өч-дүрт бөртек сакал, күзе кылыйммы соң – берсе чәршәмбегә, икенчесе бөтенләй якшәмбегә карый* (Р. Зәйдулла. Кабахәт). *Күзләре, саташкан кешенекедәй, берсе чәршәмбегә, икенчесе дүшәмбегә карый иде* (Ф. Хөсни. Циклон).

**БЕРСЕ ЧӘРШӘМБЕГӘ, ИКЕНЧЕСЕ ДҮШӘМБЕГӘ ТОРЫП БАСУ.** Тузгыган чәчләр хакында. <...> *әнә аның хәзергә әле таракка чират житмәгәнлектән, берсе чәршәмбегә, икенчесе дүшәмбегә торып баскан куе кара чәче, әнә аның тигез ак маңгае, моңсу-тирән күзләре, бераз калынрак, ләкин кирәк чагында калынлыгы да, юкалыгы да сизелмичә, Хәдичәнең кайнар иренендә эреп бетә торган иреннәре* (Ф. Хөсни. Мәйдан).

**БЕРСЕ ЧӘРШӘМБЕГӘ КИТСӘ, ИКЕНЧЕСЕ – СИШӘМБЕДӘ.** Язуда хәрефләре төз булмыйча, төрле якка караган булу. *Хәрефләре берсе чәршәмбегә китсә, икенчесе – сишәмбедә* (Ф. Шәфигуллин. Әлфинур).

*БЕРСЕН* ❖ **БЕРСЕН БАР ИТЕП, ИКЕНЧЕСЕН ЮК ИТЕП.** 1. Җитешмәүчелекне бетерү өчен, очын очка ялгап яшәү хакында. *Тормыш итү авырая башлагач, Хәдичәгә берсен бар итеп, икенчесен юк итеп яшәргә дә туры килгәләде* (Сөйләм).

2. Башкарып килгән иске эшне юк итеп, яңа эш башлау хакында. *Күршеләреннән күреп, каз асрый башлаган иде, берсен бар итеп, икенчесен юк итеп дигәндәй, тавыклар белән мәш килә башлады* (Сөйләм).

**БЕРСЕН БАШЛЫЙ, БЕРСЕН ТАШЛЫЙ.** Тотрыксыз, принципсыз, карарсыз булу. *Бичара диме ни дисең инде үзен, тәмам аптыраган бит, берсен башлый, берсен ташлый, ни эшләргә белмәгән дивана шикелле* (З. Мурсиев. Солтанъяр). *Берсен башлый, берсен ташлый. Берсен берсе бүлдереп, нидер сөйләшәләр* («Сабантуй» ж.).

**БЕРСЕН КӨЙЛӘП, ИКЕНЧЕСЕН СӨЙЛӘП, <ӨЧЕНЧЕСЕН ЧӨЙЛӘП>.** Төрле юллар белән эшләнгән эш хакында. *Син анда эшеңдә үзеңә урын яулар өчен, берсен көйләп, икенчесен сөйләп инандырдың, ахыр чиге сыналган алымыңны кулландың – шикаять язарга керештең* (Г. Үзиле. Гыйфрит).

*БЕРСЕННӘН* ❖ **БЕРСЕННӘН ИКЕНЧЕСЕНӘ** *к.* авыздан авызга 1. *Сүз чуалды. Берсеннән*

*икенчесенә күчте* (А. Алиш. Яңа килен). *Бу хәбәр әнә шулай, кешеләр арасында берсеннән икенчесенә күчеп, җепшек кар йомгагы шикелле зурая-зурая, көне-сәгате белән авылның бер башыннан икенче башына таралды* (Ф. Абдуллин. Тормышка юл ярганда).
Төрдәше: авызга авыз <сөйләшү> 2 һ.б.

*БЕРТАВЫШТАН* ❖ **БЕРТАВЫШТАН (БЕР ТАВЫШТАН) САЙЛАНУ** *к.* беравыздан (бер авыздан) сайлану. *Бу югары таләпләргә академик Мазһаровның күрсәткечләре тәңгәл килүе ачыкланып, анын кандидатурасы президентлыкка тәкъдим ителә, һәм ул бертавыштан сайлана да* (А. Зыятдинов. Буыннар язмышы).
Төрдәше: беравыздан (бер авыздан) сайлану һ.б.

*БЕРТУГАН* ❖ **БЕРТУГАН БУЛЫП (КЕБЕК) ЯШӘҮ**. Туганнар кебек яшәү, дус яшәү. *Казан һәм Кырым тәхетендә нәсел җепләре бер шәҗәрәгә тоташкан асыл затлар утырганда, һәр ике ханлык бертуган булып яшәде, бер бөеклекнең, галилекнең ике канатына әверелде* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).

*БЕРҮЗЕ* ❖ **БЕРҮЗЕ БЕР ФРОНТ.** Берүзе бер яклы. *Ә Сәлмән карт исә, берүзе бер фронт булып, малайларның һөҗүмнәрен кире кайтарып торды* (Ф. Хөсни).

*БЕРЬЮЛЫ* ❖ **БЕРЬЮЛЫ ИКЕ КУЯН-<НЫ> АТУ (ТОТУ).** Берьюлы ике максатка ирешү. *Моның белән ул берьюлы ике куянны атарга теләгән: бердән, налог түләмәгән сатучыларның мал-мөлкәтләрен өйләреннән төяп китүче милиционерга чыгып, абзасын гел өркетеп тормакчы, икенчедән, заманның кая таба баруын сизеп, «власть кешесе» кулында сакланып калмакчы булган* (Ә. Еники. Саз чәчәге). *Эшне болай сак алып барганда, берьюлы ике куян тотыла: беренчедән, конверт эчендәге хатта нәрсә язылганлыгы (ягъни алар өе өстендә бөтерелеп очып йөри торган тилгәннең кем икәнлеге) мәгълүм була һәм, икенчедән, кыз белән ике ара бозылмыйча кала* (Ф. Хөсни. Җәй башы).
Төрдәше: акмаса да таму (тамчылау) һ.б.

*БЕТ* ❖ **БЕТ АЧУЫН ТУННАН АЛУ**. Гаепсез кешедән үч алу; бер кешегә булган ачуны башкасыннан алу. *Хәзер бет ачуын туннан ала дигәндәй, бар ачуын бездән алачак* (Г. Әпсәләмов). *Әмма бет ачуын туннан алган кеше кебек, укудан, мәгърифәттән ваз кичәргә ярамый* (С. Сабиров. Бишбалта мөгаллиме).
Төрдәше: беткә үч (ачу) итеп, тунны утка (мичкә) ягу (ыргыту); торма ачуын (ачысын) тоздан алу.

**БЕТ<ЕН> АШАГАН** *к.* алырсың шайтаннан иман 2. *Аның кемгә булса да бурычка биреп торганын белмим мин, ул – акча дип бетен ашаган кеше* (Сөйләм).
Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

**БЕТ<ЛӘР> АШАТУ** *мыск.* Берни эшләмичә, тик ашап яту. *Брянский урманнарында күпмедер бет ашатып ятканнан соң, форсатын китереп чыгарып, тагын да дүрт айлык телеграфистлар мәктәбенә укуга ычкына алдым мин* (А. Хәлим. Чын җиңүче кем?).
Төрдәше: авыз күтәреп яту һ.б.

**БЕТ БАЗАРЫ.** Иске-москы базары. *Аның каравы, безнең өйгә якын гына мәйданда элек булмаган җирдә «Бет базары» пәйда булган* (Г. Баттал Таймас. Мин бер яктылык эзләгән идем). *«Бет базары» дип атала торган иске-москы базарында гомер уздыручы «татар сәүдәгәрләре» дә юк түгел иде* (М. Госманов. Чәчелгән орлыклар).

**БЕТ<ЛЕ> ЙӨРӘК.** Гамьсез, ялкау кеше. *Икенче көнне үк эшеннән чөярләр дип курка бет йөрәк* (Ф. Дәүләтбаев. Таяклы карачкы). *Колхозларның таркала башлавын идарә башына бетле йөрәкләрнең килеп оялавыннан да күрәм мин* (Сөйләм).

**БЕТ КЕБЕК.** Бик кечкенә, бик вак. *Ул, бет кебек кечкенә бер фикерен ике җөмлә белән әйтеп кую урынына, 3–4 бит текст яза* («Татар заманы» газ.). *Анысы да бет кебек вак* («Татарстан яшьләре» газ.).

**БЕТ КЕБЕК ЯБЫШУ (ЯБЫШЫП ЯТУ).** Аерыла алмау, каныгу. *Нинди генә роль бирсәләр дә, ул аңа бет кебек ябыша* («Ватаным Татарстан» газ.). *Үзенең өстенә, мышныйм-мышный, Якупның бөтен гәүдәсе белән басып ятуын тоеп, бар көченә этеп җибәрде, тик бет кебек ябышкан Якуптан котылу җиңел түгел иде шул, тавышсыз гына җир идәндә икәү көрәштеләр* <...> (З. Кадырова. Көтеп узган гомер).

**БЕТ СИМЕРТҮ** *мыск.* Берни эшләмичә, тик ашап яту. – *Туган, күңелеңә авыр алма, институт, диләр моны, шәкертләр бет симертеп яткан сала мәдрәсәсе түгел* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң). *Менә шунда Идел буе авылларыннан, Кама аръягыннан һәм шәһәр бистәләреннән белемгә сусаган татар-чуваш-мукшы балаларын, унсигез яшен тутырган яшь-җилбәзәкне дә, солдат шулпасы эчеп, окопта бет симертеп кайткан сакаллы солдатны да, буразнадан гына күтәрелгән гәп авыл мужигын да – барысын бергә китереп тутырдылар* (Г. Ахунов. Идел кызы).

Төрдәше: авыз күтәреп яту һ.б.

**БЕТ ТАЕП ТӨШӘРЛЕК.** Шулкадәр шома, чиста итеп кырынган кеше турында. *Еш кырынудан зәңгәрләнеп торган, бет таеп төшәрлек шома яңакларына, киңчә иягенә генә түгел, егетнең карап торышка матур коңгырт күзләренә дә ул туры карады* (Р. Кәрами. Каргышлы этаплар).

**БЕТ ЧӘЙНӘГӘН** *мыск.* Бик вак сүзле, сатулашырга яратучы, бәйләнчек кеше. *Бет чәйнәгән журналистның / Ав(ы)зын каплатыр идем...* (Р. Рахмани. Заман бае). *Бәрәңгене бирергә дә котылырга бөрмәсеннән бет чәйнәгән ул кабахәттән* (В. Нуриев. Кара бишмәт).

**БЕТ ЧӘЙНӘҮ** *гади с.* Артык ваклану. – *Әнә Газзә карчыкны куярсыз, бет чәйнәп, тик советта утырсын...* (Г. Толымбай. Түбән елгада). *Булдыра алмыйсың икән инде, өстәгеләрне сүгеп, подъезд төбендә «бет чәйнәп» утырма* («Яшел Үзән» газ.).

**БЕТ ЧҮПЛӘҮ.** *күч.* Заманы өчен иске саналган нәрсәләрне туплау. *Һәм бет чүпләргә ябышыр Рәсәй базарыннан – / Охшап кәнтәйгә, урам кызларына...* (Р. Рахмани. Мәскәү нәрсә шартлата?). *Мәскәү бу җитешсезлеге өчен өлкә хөкем оешмасына бармак янаган: «Карагыз аны, сез йә үзегез взяточниклар, йә юк белән шөгыльләнеп, туннан бет чүпләп утырасыз»* (Т. Галиуллин. Элмәк).

*БЕТӘСЕ* ❖ **БЕТӘСЕ БУЛМАДЫ.** Очы-кырые булмады, ялыктырды, туйдырды. Иртәгә-иртәгә дип алдап йөртү белән бәйле. *Синең иртәң бетәсе булмады* (М. Фәйзи). *Ләкин көтелмәгән ачышлар моның белән генә бетәсе булмаган икән әле* (Г. Кашапов. Язмышыңа ышан).

**БЕТӘСЕ ТҮГЕЛ.** Чиктән тыш күп, иге-чиге күренми. – *Эш ул, Газинур, беркайчан да бетәсе түгел* (Г. Әпсәләмов. Газинур). *Аннары әни кушкан йомышлар да бетәсе түгел, аръякның Чтапан кибетеннән коймакка куй мае, бер кадак клиндер, бер чирек чәй, йөзем җимеше, бер шешә крачин алып менәргә кирәк* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

*БЕТӘШКӘН* ❖ **БЕТӘШКӘН НӘРСӘ** *мыск.* Бик саран, вакчыл. – *Бигрәк бетәшкән нәрсә икән. – Юха елан. – Алай димә. – Дию* (Т. Миңнуллин).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

*БЕТЕ* ❖ **БЕТЕ ДӘ ЮК.** Бернәрсәсе дә юк, бик ярлы. *Бете дә юк кеше партия әгъзасы дип кенә безнең хуҗалык башында тора алырмы икән?* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз ачса, кече теле күренү 2.

**БЕТЕ КОТЫРУ** *мыск.* Яхшы тормыштан кәеф-сафа корып узынып китү, азу; ярсу, дәрте тынгы бирмәү. *Аяк-кулларын бәйдән бушаткан арада, бете котырган басмачы аңа чамадан тыш сыланып әрсезләнсә дә, Балҗан чыгымламады, хәлдән тайган кеше сыман, бөтен күкрәге белән аның өстенә ишелеп төште* (Т. Әйди. Елан угы). *Ул киткәч, балдызның бете котыра башласа нишләргә?* (Ф. Яруллин. Урман кызы).

Төрдәше: мае сикертү; мае төртү; маена чыдый алмау; симезлегенә чыдаша алмау.

*БЕТЕН* ❖ **БЕТЕН СЫТЫП (ЧӘЙНӘП) КАНЫН ЭЧКӘН** *мыск.* Комсыз һәм саран кеше хакында, шулай ук *к.* алырсың шайтаннан иман 2. *Бу дөньяда бетен сытып канын эчкән кешеләр юк дисеңме әллә?* (Сөйләм).

Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

*БЕТЕРЕП* ❖ **БЕТЕРЕП ТАШЛАУ.** Бик нык сүгү; артык хурлау, юкка чыгару. *Сынчы бер кызган шәпкә роман язучыларны бетереп ташлады* (А. Тимергалин. Фәтхулла хәзрәтләре). – *Фу, каян казып чыгардыгыз бу алман бетен? – дип, ватандашын бөтенләй бетереп ташлады* (М. Әмирханов. Әлвидаг).

**БЕТЕРЕП ЭЗЛӘҮ.** Бер җирне дә калдырмыйча, актарып эзләү. *Мине хәзер үзебезнең частьта дөнья бетереп эзлиләрдер инде* (З. Хәким. Искән җилләр көенә). *Алар Әбүбәкернең йорт-җирен дә тикшерделәр, авылны да бетереп эзләделәр, ләкин Әбүбәкер суга төшкән кебек юкка чыкты* (И. Хуҗин. Убыр).

*БЕТКӘ* ❖ **БЕТКӘ АЧУ ИТҮ.** Вак-төяк борчучыларга ачу итү. *Һич югы шушы исемне яндырып булса да, Чечен хатын-кызларын, газиз балаларын каннан, үлемнән аралап кала алмам микән диеп ярсынган чагым иде. Беткә ачу итү дип санамыйм мин аны* (Р. Вәлиев. Җанга уелган уйлар). *Беткә ачу итеп / Беткән идек йөдәп-талчыгып, / Беткәнсең бит бигрәк таушалып* (jazucilar.narod.ru).

**БЕТКӘ ҮЧ (АЧУ) ИТЕП, ТУННЫ УТКА (МИЧКӘ) ЯГУ (ЫРГЫТУ)** *к.* бер борча өчен бер юрган яру. *Иренә чыккан ачуын Бәдәрдән алырга маташамы Сөмбелә? Беткә ачу итеп, тунны утка яга!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). – *Болар беткә үч итеп, туннарын утка тотып яккан ие сантый һаман* (В. Имамов. Карабәк).

Төрдәше: бер борча өчен бер юрган яру һ.б.

*БЕТКӘН* ❖ **БЕТКӘН БАШ.** Нindидер бәладән котыла алмаган кеше хакында.– *Иптәшләр,* – *диде бу беткән баш, бер йотым су кабып, егерменче гасырда әдәби-фәлсәфи фикернең үсеше кискен адымнар белән алга китте* (Г. Афзал. Егерме беренче гасырга сәяхәт). *Әти үлгән... Әнинең үләр вакыты җиткән... Мин – беткән баш...* (М. Кәбиров. Бердәнбер һәм кабатланмас).

Төрдәше: бәлагә калган баш.

**БЕТКӘН БАШ БЕТКӘН (БЕТСЕН)**. Ни булса да булыр дип тәвәккәлләп, берәр эшкә тотынырга карар кылу. *Кируш шулай ике арада бәрелеп-сугылып йөрде дә, Гыйбаш абзый көнлекчеләрне алып китә башлагач, «беткән баш беткән» дигәндәй кулын селтәп, үз бәясен кыкырды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). – *Беткән баш беткән, алты ай булса да эштә булган булып калыйм,* – *дидем дә...* (И. Салахов).

**БЕТКӘН БАШ БЕТКӘН, МУЕН КАЛСА ҖИТКӘН.** Хәтәр эштән, хәлдән курыкмыйча, үлемнән көлеп әйтү. *Хәйдәр, «беткән баш беткән, муен калса җиткән!» дип кычкырды да, гранатасын учлап, алга таба шуышты* (Сөйләм).

**БЕТКӘН БАШ БЕТКӘН, СЕБЕР КИТКӘН, МУЕН КАЛСА ҖИТКӘН.** Патша вакытында золымнарга, сөрелүләргә бирешмичә, сер бирмичә яшәү хакында («баш бетеп, җан калса җиткән, тәвәккәлләп яшибез» мәгънәсендә). *Бер дә аптырама, Гаптери, анда да кешеләр яши: беткән баш беткән, Себер киткән, муен калса җиткән* (Сөйләм).

**БЕТКӘН БАШ БЕТКӘН, ЧЫНЫН ӘЙТҮГӘ НИ ҖИТКӘН.** «Башың һәлакәт астында калганда да, дөресен әйтү иң зур тәвәккәллек» мәгънәсендә. *«Беткән баш беткән, чынын әйтүгә ни җиткән» дия иде минем бабай, мин дә алдарга җыенмыйм* (Сөйләм).

**БЕТКӘН БАШ БЕТКӘН, ЯРТЫ ЮЛГА ҖИТКӘН.** Яртысы эшләнгән эшнең калганы хәтәр булса да, аны эшләп бетерү кирәклеге хакында. *Шактыен эшләгәч, ярты юлда ташлап калдыру килешмәс дип уйлыйм, бабайлар юкка гына «беткән баш беткән, ярты юлга җиткән» димәгәннәр бит* (Сөйләм).

**БЕТКӘН КЕШЕ.** Малы-хәле беткән, бөлгенлеккә төшкән кеше. *Без яшибез инде, без – беткән кеше. Язмыш баш очына козгын утырткан* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Газдал «Беткән кеше икәнсең» дигән мәгънәдә кулын селтәп куйды* (Ф. Садриев. Адәм әүлиясы).

*БЕТКЕЛЕ* ❖ **БЕТКЕЛЕ ТҮГЕЛ** *диал.* Бетә торган түгел. *Ильяска шул гына кирәк, такмаклары беткеле түгел, үзенең дә, түгәрәкнең дә күңеле булганчы тезә бирсен әле* (Ә. Баянов. Җәй белән җәй арасы).

*БЕТЛЕ* ❖ **БЕТЛЕ КАРГАЛАР** *к.* авыз ачса, кече теле күренү 2. *Филипсон управляющий кулындагы чыбыркыны тартып алган һәм: «Әле син дә шул бетле каргалар яклымы, әле син дә хыянәт итәсеңме миңа?!» дия-дия, Акмаңгайны чыбыркы белән чаж да чож ярырга керешкән* (Ф. Шәфигуллин. Ак маңгайлы бүреләр).

Төрдәше: авыз ачса, кече тел күренү 2 һ.б.

**БЕТЛЕ КҮЗ** *мыск.* Чепи күз, кысык күз. *Әйт, безнең әнкәй бетле күз Сабир белән буталдымы?* (Р. Батулла. Юл буенда зәңгәр чәчәк). *Аның*

*урынына бетле күз Сабирҗан Галиевне китереп утырттылар* (Ф. Яхин. Контора күсесе).

*БЕТМӘС* ❖ **БЕТМӘС БАЛЫК БАШЫ** *к.* авызда бер үк җыр <булу>. *Нигә поездда түгел соң без, дип сорамады, әйберләрнең барын да төйнәдеңме, дип кызыксынмады, һаман бетмәс балык башы – Карачура* (А. Гыйләҗев. Өч аршын җир).

Төрдәше: авызда бер үк җыр <булу> һ.б.

**БЕТМӘС МОНДА.** «Андыйлар күп булыр, кирәге юк» мәгънәсендә. *Бетмәс монда андыйлар, аларның поты бер тиен* (Г. Камал). *[Альберт] Ярар, бетмәс монда җыен «ботка пештеләр»* (Г. Каюмов. Туу).

*БЕТСӘ* ❖ «**БЕТСӘ БЕТСЕН**»**ГӘ ЭШЛӘҮ.** Эшне булсын дип түгел, тизрәк бетсен дип эшләү. *Алар бетсә бетсенгә эшләп күнекмәгәннәр, мотор ниндидер ят тавыш чыгара башлагач, аны сүтеп, яңадан тикшерергә булдылар* (Сөйләм).

*БЕТТЕ* ❖ **БЕТТЕ БАШ.** «Эләктек, килеп каптык, беттек» мәгънәсендә. *Инде ул йоклый торган җиргә черки явыз үтеп керсә, бетте баш, Хәйретдин агай ул төнен керфек какмыйча да уздыра* (А. Гыйләҗев. Әтәч менгән читәнгә). *Бетте баш, алай булса! Әйдә, үкчәң күтәр, сыптыр тизрәк* (Г. Камал).

**БЕТТЕ БАШ, КАЛДЫ МУЕН ТЫРПАЕП (ЧЕРӘЕП; СЕРӘЕП).** Берәр сәбәптән хәрәкәтсез катып калу. – *Латыйф Гыйздуллович, бетте баш, калды муен тырпаеп. Зираттан берәүнең сынын урлаганнар* (Н. Гыйматдинова. Кем беренче?).

2. Берәр мутлык эшләп йөргәндә, сизелүдән кисәтеп, качарга ишарәт бирү. *Алмагачның ботагына килеп кенә тотынган идем, ишек шыгырдаган колакка килеп керде, бетте баш, калды муен черәеп дигән уй мигә кереп утырганчы, тиз генә борылып, егетләргә кулларны аркылы-торкылы куеп күрсәттем* (Сөйләм).

*БЕТТЕГӘ* ❖ **БЕТТЕГӘ САНАУ.** Эш тәмам булды дип уйлау. <…> *әти-әнисенә айга бер хат язып кына эше беттегә санаган улы Әгъдәскә рәнҗи, егерме яше дә тулар-тулмас кияүгә чыгып киткән кызы Әлфияне тозлап-борычлап сүгә* (Б. Камалов. Күршеләр). *Ваһапов, шуның белән сүзне беттегә санап, кәгазьләренә иелде; Әнвәрне, иптәшләре күреп, шалашка алып керделәр…* (Х. Камалов. Һәркемнең гомере бер генә).

*БЕТТЕ-КИТТЕ* ❖ **БЕТТЕ-КИТТЕ – ВӘССӘЛАМ!** «Шуның белән эш бетте, сөйләшеп тә торасы юк» мәгънәсендә. *Янына хәтта табибны да кертмиләр – бетте-китте, вәссәлам!* (Р. Низами. Сәйдәшнең соңгы елы). *Кем әйтмешли, бетте китте – вәссәлам! Гаифәнең сүзе сүз булып калды* (Ә. Моталлапов. Мәхшәр).

*БЕТҮГӘ* ❖ **БЕТҮГӘ ЙӨЗ ТОТУ.** Милләт, нәсел һ.б.ның кору-бетүгә таба баруы. *Әшкәрә хәбәрдарлык (гласность) сәясәте, Мәскәүдә Михаил Горбачевтан соң илбашы булып Борис Ельцин күтәрелгәч, бетүгә йөз тотты, хәбәрдарлык сүзе актив лексикасыннан төшеп калды* (А. Тимергалин. Миллият сүзлеге). *Ак бүре ыруы бетүгә йөз тота башлады* (Ф. Зариф. Ак бүре рухы саумы?).

Төрдәше: инкыйразга йөз тоту.

*БИ* ❖ **БИ АСТЫНДА БЕР НОКТА.** Бу сүздә икенче, яшерен мәгънә булуына ишарә. – *Һәр сүзләренә дә ышанырга ашыкма, юк-юк та би астында бер нокта ятарга мөмкин* (Сөйләм).

**БИ СӨЙЛӘСӘ – БИНЕКЕ, КОЛ СӨЙЛӘСӘ – КОЛНЫКЫ.** Кешегә карап, ышану дәрәҗәсе төрле булу турында. *Би сөйләсә – бинеке, кол сөйләсә – колныкы дигәндәй, сүзләрнең дә ышандыру көче төрлечә* (Сөйләм).

Төрдәше: әмин булу һ.б.

*БИАТАЙНЫКЫ* ❖ **БИАТАЙНЫКЫ ЯРЫЛДЫ.** Кинәт булган эш яки кинәт ишетелгән тавыш турында. (Киленнәр турындагы мәзәк белән бәйле). *Кинәт өйалдында нәрсәдер шартлаган сыман тавыш ишетелде. – Биатайныкы ярылды бугай, – дип куйды Сәкинә* (Сөйләм).

*БИГАТЬ* ❖ **БИГАТЬ КИТЕРҮ** *иск.* Буйсыну, башлык (хуҗа) итеп тану хакында сүз бирү. *Аерым олыс бәкләре яисә әмирләренең Мамай мирзага теш күрсәтерлек куәте юк иде, барчасы да, юаш бозау сыман, аңа бигать китерде* (В. Имамов. Карабәк).

*БИГАЯТЬ* ❖ **БИГАЯТЬ БУЛУ** *иск.* Гашыйк булуга ишарә. *Малайның ашаганы аш түгел, бигаять булган, ахрысы* (Сөйләм).

*БИЕК* ❖ **БИЕК БОРЫНЛЫ.** Масаючан, үзен әллә кемгә санаучы хакында. *Борынгы ата-баба данын үзенеке санап, «безләр Чыңгыз каныннан» дип шапырынучы буынсыз ханнар, эшлексез бәкләр дошман илләрнең борын төбендә тимер вә утлы кораллы гаскәр тәрбия кылып, калын таш диварлы кальгалар салып, икмәк-тәгамне күп елларга җитәрлек саклап, куәтләнә барганын күрмәс дәрәҗәдә биек борынлы иде* (Р. Батулла. Сөембикә).
Төрдәше: алып узу һ.б.

*БИЕККӘ* ❖ **БИЕККӘ ОЧСА ДА, САЙ ЙӨЗҮ.** Дәрәҗәгә ирешсә, зурдан купса да, мәгънә ягы сай булу. *Директор да ясадылар үзеннән, әмма биеккә очса да, сай йөзүен дәвам итте – элеккечә сүзенең ата-анасы булмаган килеш калды* (Сөйләм).

*БИЕП* ❖ **БИЕП ЙӨРҮ.** 1. Нәрсәне булса да тиз һәм җитез башкару, эшләү. *Бик кирәктә, арбам юлда ташлап, / Синең янда биеп йөрермен* (В. Галиев. Җырларымда гомерем дәвамы). *Башта урман каравылчысын көйли-көйли көнең китә, аннан ай буе, өмәсенә нәрсә әзерлим икән, йөзгә кызыллык килердәй булмасын, дип биеп йөрисең* (Р. Газиз. Нихәлләрдә, кодача?).

2. *к.* авызга бал да май булып керү. *Киленнәре Казан-йортка төшсә, ногайлар да Мәскәү хозурында биеп йөриячәк* (В. Имамов. Сөләйман солтан). *Без сержант алдында биеп йөргән кебек, сержант офицер алдында бии* (З. Мәхмүди. Сары каеш – сары сагыш).
Төрдәше: авызга бал да май булып керү һ.б.

*БИЕТЕП* ❖ **БИЕТЕП АЛУ.** Җәза бирү. *[Сәфәргали] Юкса мин сине миравойга биреп биетеп тә алыр идем* (К. Тинчурин. Йосыф белән Зөләйха). *Мин хәзер уклау алып, сезнең түбәдә шундый итеп биетеп алырмын, гомер буена үзегез газ чыгарып йөрерсез, берәү дә туктата алмас* (Э. Яһудин. Җиһанның серле затлары).

**БИЕТЕП ТОТУ.** Бик кырыс мөгамәләдә булу, каты тоту. – *Танибәк алга табан мәмләкәтне хосусән үзе дә хатыны илә биетеп тотар сыман* (В. Имамов. Карабәк). – *Бөтен тирә-якны үз кулында биетеп тоткан атаңның теләгенә каршы барырга ничек йөрәгең җитте?* (Т. Нәбиуллин. Качкын).

*БИЗӘКЛӘП-СЫРЛАП* ❖ **БИЗӘКЛӘП-СЫРЛАП ТОРМАУ (СӨЙЛӘШМӘҮ).** Гади генә итеп (гади итеп, турысын сөйләү). *Бизәкләп-сырлап тормады* (Ф. Хөсни). *Низамиевлар ясалма түгел, ихлас, «тәти күреник» дип, бизәкләп-сырлап сөйләшмиләр* («Сәхнә» ж.).

*БИЗӘР* ❖ **БИЗӘР БУЛУ** *иск.* Берәр кешедән тәмам тую, бизеп бетү. *Алар ташлар шул ярыннан башкасын / Үзе нәфсеннән һәм дә бизәр булыр* (Ш. Зәки. Бу үлем миңа дошман түгел). *Сафагәрәй хан, бердән, руслар белән сугышуга мәҗбүр булганлыктан һәм, икенчедән, татар морзаларының бер төркеме рус тарафында, икенче төркеме Россия белән дошманлыкта булып, үз араларында өзлексез дәгъвада булуларыннан тәмам бизәр булды* (Р. Фәхретдинов. Болгар һәм Казан төрекләре).

**БИЗӘР САПТЫРМАК.** Йөдәтү, тәмам биздерү. *Аның сөйләшүе генә түгел, кыланышлары да мине тәмам бизәр саптырды* (Сөйләм).
Төрдәше: ахәлгә төшерү һ.б.

*БИЗ-БИЗ* ❖ **БИЗ-БИЗ АВЫРТУ.** Оеш-оеш, күчеп-күчеп авырту. *Кай җирең авырта, дисең, белмим дә инде, биз-биз авырта ул* (Сөйләм).

*БИЗГӘК* ❖ **БИЗГӘК БУЛСАҢ, ҮТЕРМИ (ҖАННЫ АЛМЫЙ) КИТМӘССЕҢ.** Бәйләнчек, йөдәткеч кешегә әйтелә. *Язгы бизгәк булсаң, җанын алмый китмәс идең* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

**БИЗГӘК БУЛУ** *к.* бер эссе, бер суык хәлгә төшерү. *Тирә-якны дер селкетеп, дусларына – терәк, дошманнарына бизгәк булып яшәгән менә шушы кешенең бер генә йомшак ягы пәйда булды: ул да булса – хатыны Зөбәрҗәт* (Х. Мөдәррисова. Яр).
Төрдәше: бер эссе, бер суык хәлгә төшерү һ.б.

**БИЗГӘК КЫЗУЛЫГЫ БЕЛӘН.** Бик тиз, ашыгыч рәвештә. *Ишектән кемдер кергәнне ишеткәч, бизгәк кызулыгы белән хатны китап эченә тыгып куйды* (Сөйләм).
Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

**БИЗГӘК ТОТКАНДАЙ.** Бөтен тән белән калтырану яки нәрсә булса да калтыранып китү.

*Бераздан мин хәл алгач, бизгәк тоткандай калтыранып, Сибгатьне чәйнәп ташлардай булып: «Бу ни эш?» – дидем* (А. Шамов. Кыз урлау). *Паровоз өзек-өзек кычкыртты, поезд бизгәк тоткандай калтыранды* (Н. Гыйматдинова. Син түгел бу, син түгел...).

**БИЗГӘК ТОТУ.** Дер-дер калтырау. *Патшаның теге вакытта көтмәгәндә килеп керүе аны бик тирән борчуга салган иде, хәтта бизгәк тоту авыруы башланган иде* (С. Горский. Явыз Иван хатыннары / Р. Хәмид тәрж.). *Бу әүвәле дә мине әледән-әле җәфалый торган чып-чын бизгәк тоту иде* (Т. Нурмөхәммәтов. Кабан күле, әй, алкын).

*БИЗМӘН* ❖ **БИЗМӘН КЕЧТЕКИ <БУЛУ>.** Барлык нәрсәне дә аңлап бетерә алмауның сәбәбе хакында. – *Их, бабай,бабай! Бизмән бик кечтеки шул безнең!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

*БИЗМӘНГӘ* ❖ **БИЗМӘНГӘ САЛУ (САЛЫП КАРАУ).** Төрле яклап уйлап карау, тикшерү. *Эчке тавышы очраклымы, түгелме икәнне бизмәнгә салырга кушты* (Ф. Садриев. Тургай). *Бизмәнгә салып карасаң, Галимҗан өчен күңелсез яклар күбрәк икән шул* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).
Тордәше: бизмәнгә салып үлчәү.

**БИЗМӘНГӘ САЛЫП ҮЛЧӘҮ** *к* бизмәнгә салу (салып карау). *Бөтенесен бизмәнгә салып мыскаллап үлчи торгач, кискен бер фикергә килделәр* (Г. Бәширов. Гыйбрәт). *Әмма бизмәнгә салып үлчи башласаң, безнең өчебез дә тәхетне дәгъвалау хокукыннан мәхрүм ителмәгән* (В. Имамов. Сөләйман солтан).
Төрдәше: бизмәнгә салу (салып карау).

*БИЗМӘНДӘ* ❖ **БИЗМӘНДӘ ҮЛЧӘНҮ.** Бәя бирелү. *Монафыйклар басты илне – / Тыярмын, димә һич тә; / Бер үк бизмәндә үлчәнә / Фәрештә дә, иблис тә* (Ә. Рәшит. И заман!). *Хәлбуки төшенкелек тә, канәгатьлек тә, асылда, бер бизмәндә үлчәнә* (М. Әмирханов. Ир-Мамай).

*БИЗМӘНЕ* ❖ **БИЗМӘНЕ АВЫР ТАРТА.** 1. Төпле, акыллы кеше хакында. *(102) (Савап) бизмәне авыр тарткан кеше Сәгадәткә ирешкән булыр* (Р. Батулла. Коръән, татар телендә).

2. Яхшылыгы, хезмәте күп тигән кеше белән бәйле. *Ул, кайберәүләр кебек, сикереп чыгып, үзен күрсәтергә ашыкмый, бизмәне авыр тартканнарга хасча, җайлап кына эшли бирә* (Сөйләм).

**БИЗМӘНЕ БИК ҖИҢЕЛ.** Һәрнәрсәгә җиңел караучан, өстән уйлаучан; юмарт. *«Бизмәне бик җиңел» дигәннәр иде, шулайрак икән, хәтта артык җиңел* (Сөйләм).

**БИЗМӘНЕ БИЛГЕЛЕ БУЛУ.** Берәрсенең акылбелем чамасы ачыклану. *Кешенең үзеннән сорама, сүзеннән сора дигәннәр, көрсигә чыгып әйткән берничә сүзеннән бизмәне билгеле булды* (Сөйләм).

**БИЗМӘНЕ ТАРТМАУ (ТУЛМАУ).** Белеме сай, акылы чамалы, эшне белеп җиткермәү. *Мондый җитди бәхәскә бизмәне тартмаган кешеләр белән барып буламы соң?* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

*БИЗМӘННЕ* ❖ **БИЗМӘННЕ ҮЗ ЯГЫНА КАЕРУ.** Үз файдасына гына эшләү. *Коры кул белән тотармын, димә, шома, / Бизмәнен үз ягына каера...* (Н. Хәсәнов. Язмышың сыналганда...).
Төрдәше: бармагы үз ягына бөгелү (кәкре) һ.б.

*БИИСЕ* ❖ **БИИСЕ КИЛМӘГӘН АЮГА УРЫН ТАР.** «Теләп эшләмәгән эшнең нәтиҗәсе дә уңышсыз чыга» мәгънәсендә. – *Шулхәтле кыстама инде: биисе килмәгән аюга урын тар аңа* (Сөйләм).
Төрдәше: биисе килмәгәннең көе килми.

**БИИСЕ КИЛМӘГӘННЕҢ КӨЕ КИЛМИ** *к.* биисе килмәгән аюга урын тар. *Биисе килмәгәннең көе килми* (В. Хаков укулары – 2013).
Төрдәше: биисе килмәгән аюга урын тар.

*БИК* ❖ **БИК БЕЛӘСЕҢ КИЛСӘ.** Үзенең әйткән сүзен раслау өчен кулланыла.– *Аларның чабышта беренче катнашулары түгел, бик беләсең килсә!* (К. Тимбикова. Сөлге булсын бүләгем!).

**БИК ИСЕМ КИТӘ.** Аз гына да ис китмәү, уйлап та бирмәү. *[Әсма] (урыныннан торып) Бик исем китә!* (Г. Исхакый. Алдым-бирдем). *Малайлар мине, «кайниш» тә «кайниш» дип, әллә кайчаннан бирле үртиләр үртәвен дә, бик*

*исем китә!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).
Төрдәше: төкермим дә.

**БИК КИРӘГЕҢ БАР!** Һич кирәге булмаган һәм ихтыяҗ да тумаган нәрсә (кеше) хакында. *[Мөршидә] Бик кирәгең бар иде! [Сажидә] Кирәгем булмаса, нәрсәгә такылдыйсың соң?* (К. Тинчурин. Казан сөлгесе). *Ашамыйсың икән, дөмек шунда, бик кирәгең бар, янәсе...* (Р. Мостафин. Г. Ибраһимовның соңгы көннәре).
Төрдәше: бик кирәк <иде>!; кирәге бар!; кирәге бер тиен иде!; пычагыма килдеңме?; шайтаныма килдеңме?

**БИК КИРӘК <ИДЕ>!** *к.* бик кирәгең бар! *Мең дә бер мәшәкать арасында синең кысыр хәсрәтең бик кирәк ди аңа* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).
Төрдәше: бик кирәгең бар! һ.б.

**БИК КИРӘКЛЕ КИШЕР ЯФРАГЫ.** Үзен бик кирәклегә санаучыга карата. *«Бик кирәкле кишер яфрагы инде мин», – дип сукранасукрана барсам, сөенеч, бер түгел – ике!* (И. Сәләхов. Фаҗига). *Шул ыгы-зыгы арасына – бик кирәкле кишер яфрагы – мин дә килеп кердем* (Ф. Хөсни. Гыйльмениса).
Төрдәше: кирәкле кишер яфрагы.

**БИК КҮПКӘ КИТҮ.** Чамадан ашу, артыкка китү. *Бик күпкә китсә, бер атна дуларлар* (К. Нәҗми). *Бик күпкә киткәч, көннәрдән бер көнне Марс Лотфуллович: – Тәлгат мәзәгендәге кебек, берәр нәрсә эшләми булмагае, – дип куйган* (Т. Нәҗмиев. Мәзәккә – хөрмәт).

**БИК КЫЙБАТ (КЫЙММӘТ) АЛМАУ.** Баш тартмау, тартынып тормау. *Хафаланма, бирешмәбез, тырышырбыз, әгәр дә бик ачуны китерсәләр, мәми авызларының салма савытларына менеп төшәргә дә бик кыйбат алмабыз* (Г. Камал). *Теләсәң, мин синең журналыңны ыргыту түгел, утка тотып ягарга да бик кыйммәт алмам* (Ф. Сәйфи-Казанлы).
Төрдәше: күп алмау; күп сорамау; күп сорап тормау.

**БИК «КЫРЫП АЛЫЙМ» КЕШЕ** *к.* алырсың шайтаннан иман 1. *Вактыңны әрәм итеп, нигә аның янына барып йөрисең – бик «кырып алыйм» кеше икәнен белмисеңмени?* (Сөйләм).
Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 1 һ.б.

**БИК КЫСТАЛЫП КЫНА.** Теләр-теләмәс, ялындырып. *Шул сызымны аңлатып бирергә чакыргач та, бик кысталып кына риза булды* (Сөйләм).

**БИК НЫК ЯКЛАУ** *к.* тау кебек тору. *Яңа промышленность корган Ишморатов идеологиядә кадимчелекне бик нык яклаган һәм Казан артындагы кара реакция җитәкчесе Ишми ишанны яңалыкка каршы гел өстереп торган* (М. Мәһдиев. Шагыйрьнең бишеге).
Төрдәше: тау кебек тору.

**БИК ӨРКЕТТЕҢ, ЧӘНЧӘ (ЧӘНЧИ) БАРМАГЫМНЫ СЕЛКЕТТЕҢ.** «Куркытып маташуыңа бер дә исем китмәде» мәгънәсендә. – *Сезнең урамнан йөрсәм нәрсә булган, бик өркеттең, чәнчи бармагымны селкеттең* (Сөйләм).

**БИК РӘХӘТЛӘНЕП.** Берәр эшне яки йомышны шатланып үтәячәген белдерү. – *Әллә хастаханәгезне күрсәтәсезме? – Бик рәхәтләнеп, – диде Гөлшәһидә, бу тәкъдимгә шатланып* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Закир абый, алдына гына караган килеш, ничектер бик чын күңелдән, бик рәхәтләнеп, беравык көтеп ятты* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**БИК САЛУ.** Киртәләү, юл куймау. *Мондый мәсхәрәгә бик салмакчы булып, Иртеш аръягыннан Җучиның бертуган энекәше Шәйбан ханның туруны Хызыр бәреп кергән* (В. Имамов. Карабәк).

**БИК УГРЫ БУЛМАСА ДА, БИК ҮК ТУГРЫ ТҮГЕЛ.** Аз-маз урлаша, ялганлый. *Бер дә шикләнмә, / Җегет, син; мин карак-угры түгел, / Юл да кисмимен, шулай да мин бик үк тугры түгел* (Г. Тукай. Шүрәле). *Хатын үзе дә бик угры булмаса да, бик үк тугры түгел, ахрысы* (Ә. Баянов).

**БИК ХАҖӘТ.** Бер дә кирәге юк, бернәрсәгә дә яраклы түгел. – *Ул хәерчегә әйләнгән колхозлар безгә бик хаҗәт ди* («Кызыл таң» газ.). *Зөһрә авызын бүлтәйтте дә: – Килә башлаган ди! Бик хаҗәт иде...* (Г. Рәхим).

**БИК ХӘБӘРЕМ ХӘНҖЕМИ ӘЛЕ.** Хәнҗәр кебек чәнчеп бармый, ягъни хәбәремә дә, исемә кереп тормый. *Бик тәфсилләп сөйләп тормасаң да була, бик хәбәрем хәнҗеми әле* (Сөйләм).

**БИК ШӘПТӘН ТҮГЕЛ.** Әллә ни яхшы түгеллекне аңлата (күбрәк «хәлләр ничек?» дип сораганда, җавап буларак кулланыла). – *Ә синең аттестат бик шәптән түгел* (З. Зәйнуллин. Ат классы). – *Хәлең ничек?– диде акрын гына Илья Ильич. – Бик шәптән түгел* (З. Кадырова. Көтеп узган гомер).

*БИКӘ* ❖ **БИКӘ БИЗӘНГӘНЧЕ, ТУЙ БЕТҮ.** Һәр нәрсәне вакытында башкарырга (үтәргә) кирәклеге хакында. – *Мин җыенып килгәнче, алар таралганнар иде инде. – Бикә бизәнгәнче, туй беткән икән алайса* (Сөйләм).

*БИК-БИК* ❖ **БИК-БИК КИРӘК <ИНДЕ>.** Кирәклеге шуның кадәр генә, булса да ярый, булмаса да ярый. *Ул, мөдир әфәндvenең сәркатип кызны «беразга гына калып тор инде, син безгә бик-бик кирәк» дигән сүзләрен үзенчә куәтләгән булып, «бик-бик кирәк инде» дип куйды* (Сөйләм).

*БИКЛЕ* ❖ **БИКЛЕ ТОРМЫШ.** 1. Йомылып, беркем белән дә аралашмыйча яшәү. *Беркая да чыкмыйча, өйдә генә утырып, бикле тормышта яшәве Рәсимәне ялыктыра башлады* (Сөйләм).

2. Төрмә. *Ялыктырды инде бикле тормыш, / Көне-төне һаман бер төрле* (М. Җәлил).

*БИЛ* ❖ **БИЛ АЛЫШУ.** 1. Татар милли көрәш алымы: сөлге белән билдән кысып, баш аркылы ату. *Шул көч кытыгы аны Сабан туйларында мәйданга бил алышырга чыгара бит инде* (Б. Камал. Дөмбер Даниял).

2. Көч сынашып карау, бер-береңнең мөмкинлеген чамалап карау. *Бил алышып авыр еллар белән, / Батырларча мәйдан тоткансың* (Ш. Галиев). *Чәчәннәр ярыша, / Гүя бил алыша* (Р. Гаташ. Бабич).

**БИЛ АСТЫНДА БЕР КОРСАГЫ.** Үзе өчен генә яши торган буйдак (яки тол) кеше. *Бил астында бер корсагы булгач, нигә ул башкалар турында уйласын, ди* (Сөйләм).

**БИЛ БАГЛАУ** *иск.* Нинди дә булса эшкә керешергә әзер тору. *И күңел, бил баглама, / Күбне кичергән дөньядыр* (Кол Шәриф). *Бер үк вакытта ул гайрәтле сугышчы да, иманыбыз өчен бил баглап алышка да чыгарга әзер!* (А. Гыйләҗев. М. Мәһдиевнең тууына 80 ел).

Төрдәше: бил бәйләп (баглап) керешү; бил бәйләү (ныгыту); бил буу.

**БИЛ БӘЙЛӘП (БАГЛАП) КЕРЕШҮ** *к.* бил баглау. <...> *милләт өчен җаннарын корбан итүчеләр вә үзләренең бил бәйләп керешкән юлларыннан, әллә нинди куркынычлар, әллә нинди хәвеф-хәтәрләр очраса да, кайтмый торганнар һәм шулай булырга сәляхиятлеләр дә анчак яшьләремездер* (Г. Тукай). *Насыйрилар тарафыннан башланып та ташланган тел мәсьәләсенә бил баглап керешә* (Рухи мирас: Эзләнүләр һәм табышлар. 3 нче чыг.).

Төрдәше: бил баглау һ.б.

**БИЛ БӘЙЛӘҮ (НЫГЫТУ)** *к.* бил баглау. *Бары Күкчәтау, Акмолла авданнарында гына ун меңнән артык ир-егетләр атка атланып, ни туры килсә шуның белән коралланып, азатлык өчен көрәшкә бил бәйләде* (И. Салахов. Күкчәтау далаларында). <...> *берничә ел производствода эшләп бил ныгыткан Рөстәм Шахмаев әти-әнисенең туып үскән җире – Стәрлетамак районы Талач авылында үз эшен җәелдергән* («Кызыл Таң» газ.).

Төрдәше: бил баглау һ.б.

**БИЛ БИРМӘҮ.** Бирешмәү. *Көрәшчеләр әле бил бирмиләр, чыдасыннар гына сөлгеләр!* (Х. Әюп). *Чибәр кыздай бил бирмәгән / Үйнак тай-елкылары...* (Э. Шәрифуллина. Туган җирнең җылысы).

**БИЛ БӨГҮ**. 1. Буйсыну; кеше файдасына эшләү. *Шәйхиев аңа шәкерт булудан күптән узган инде, үзен бик баш иеп, бил бөгеп тә тормый ул* (Ә. Еники. Тынычлану). *Бригадир Гаяз Ленин ордены алсын өчен, бөтен авыл бил бөктеме – бөкте!* (Д. Булатова. Соң түгел!).

Төрдәше: арка бөгү (бөгеп тору) 1 һ.б.

2. Тырышып эшләү, хезмәт итү. *Билен бөкте бөтен гаиләсе, баганалар барсын күреп торды?* (Х. Әюп). *Шулай, ил-мәмләкәт файдасына тырышып бил бөккәч, ташларга язылып та кала кеше исеме, халык хәтереннән дә озак онытылмый* (В. Имамов. Казан дастаны).

Төрдәше: арка бөгү (бөгеп тору) 2 һ.б.

3. Ялыну, баш ию. *Менә бар инде шул Чатан каршысына, билеңне бөк, башыңны и* (А. Шамов). *Диван әһелләре, ялгышларын төшенеп, кире Сафагәрәйне бил бөгәргә, тәхеткә кайтуын гозерләргә мәҗбүр булдылар* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).

**БИЛ БУУ** *к.* бил баглау. *Бил буарга мәйдан тар дип, ник без, шагыйрьләр, аһ орабыз әле, күз буабыз* (С. Сөләйманова). *Гаскәре аның – мужиклар. / Сакаллы кара халык. / Бил буарга кирәк икән – / Юкә алалар ярып* (И. Кәлимуллин. Бунтарь портреты янында).
Төрдәше: бил баглау һ.б.

**БИЛ БУЫП, ҖИҢ СЫЗГАНЫП.** Ныклап. *Шул минуттан, бил буып, җиң сызганып / Китте һәм иблис хәбис тә баш булып* (Ш. Бабич).
Төрдәше: җиң сызганып, бил буып.

**БИЛ БУЫП ТАРТУ.** Бөтен көчне, осталыкны биреп, тырышып эшләү. *Иген уңышы да үсә, акча өләшү дә арта, ике-өч ел бик ныгытып, билләрне буып тартканнар иде* (Г. Ахунов. Чикләвек төше).

**БИЛ КАЕШЫ БУШАУ.** Ачыгу, карын ачу. *Бил каешы бик нык бушады* (С. Кудаш).
Төрдәше: ашказаны котыру һ.б.

**БИЛ КАТЫРЫП ТОРУ.** Үз-үзен зурга куеп, эшләмичә тик тору. *Тегермән тартканда да, мөшкә авызыннан он тутырганда да, әтисенең капчыгы авыун күрә торып: «Әти! Капчыгың ава!» дип, бил катырып торган иде бит* (Н. Хәсәнов. Ак балык).

**БИЛ КУЗГАЛУ (КУЗГАЛЫП ТОРУ / КИТҮ).** Бил авырту. – *Син бик таза малай күренәсең, әйдә, безгә утын бушатыш. Үземнең билем кузгалып тора...* (Р. Сибат. Сәридә). – *Мин үзем дә алар белән идем. Тик минә бил кузгалып китте дә...* (С. Шәкүров. Сәхнәнең кыл уртасында).

**БИЛ СЫЕК БУЛУ.** Хәлсез булу, көч җитмәү. – *Анда ачыган сөт эчеп ятканга билең сыек синең* (Ф. Яруллин). *[Идегәй] Нигә билең сыек?* (Ю. Сафиуллин. Идегәй).

**БИЛ СЫНУ.** Көчен югалту, көчсезләнү. *Март башында кышның биле сына, Мулрак түгә кояш яктысын* (Н. Булатова. Бәйрәм белән сине, кыз туганым!). *Баш түбән иелә, бил сына, яшәү кырын үтеп чыкканчы, син йомык күңелле бичарага әйләнәсең* (А. Гыйләҗев. Командор).

**БИЛ ТИҢЕНТЕН.** Аяктан алып билгә кадәр. *Бил тиңентен кар ерып, мышный-мышный, текә ярдан күпер өстенә менәбез* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Чишмә буена яңадан кайтып, йотлыга-йотлыга, тешләрне сындырырлык салкын су эчәсе, бил тиңентен чишенеп, пошкыра-пошкыра юынасы килде* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

**БИЛ ТОТУ.** Бил авырту, гәүдәне турайта алмау. *Тик кинәт биле тотты. – Ах-х, у-утерде...* (Р.Уразголов. Сандык). *Соңгы елларны гына күрәшми. Биле тотты* (Р. Бәшәр. Ачык капка).

*БИЛӘМДӘ* ❖ **БИЛӘМДӘ ЙӨРҮ.** Өйдән-өйгә эчен бушатып, кеше хәлләрен белеп, вакыт уздырып йөрү. – *Мин каян белим аны, биләмдә йөридер, – диде әни, плитә янында маташа биреп* (С. Сабиров. Хәвефле сәфәр). *Тәскирәсе дә юк, ичмаса, биләмдә йөри* (Г. Галиева. Газзәбану).

*БИЛӘНКЕ* ❖ **БИЛӘНКЕ БУЛУ** *махс.* Артык авыр күтәрү сәбәпле, хатын-кыз билен яза алмас хәлгә килү. – *Гөлҗиһан түтине көтмәгез, аңа биләнке булган, диделәр* (Сөйләм).
Төрдәше: биләнкегә сабышу.

*БИЛӘНКЕГӘ* ❖ **БИЛӘНКЕГӘ САБЫШУ** *к.* биләнке булу. *Күрше хатыны бу көннәрдә өендә генә утыра: биләнкегә сабышканмы шунда, аңлап бетерә алмадым* (Сөйләм).
Төрдәше: биләнке булу.

*БИЛӘП* ❖ **БИЛӘП АЛУ.** 1. Басып алу. *Ишегалдының яртысын диярлек биләп алган бакчада әтисен күрде* (Г. Әпсәләмов. Газинур). <...> *сугышчыларның тыгыз сафлары тора-бара киң мәйданның барча почмагын да биләп алды* (В. Имамов. Утлы дала).

2. Үзенә җәлеп итү. *Елга үзәне буйлап бераз өстәрәк каяндыр югарыдан гөбердәп ишелеп төшкән су тавышы биләп алды аны* (А. Хәлим. Кыйбла). *Кыз менеджер булып эшли башлагач, Рәйханның идеясе аны да биләп алды, хәтта, компаниене үстерү өчен, хуҗадан да күбрәк көч салды* (З. Мурсиев. Мин сезнең хатыныгыз).

3. Уйлар, хисләр чолгап алу. *Шушы уй аның бөтен барлыгын биләп алды* (Ш. Хөсәенов). *Анда яңа чәчәкләр күргәч, мине нindидер каршылыклы, көнчел һәм гадел булмаган хисләр биләп алды* (А. Тимергалин. Игезәкләр).

*БИЛӘҮСӘДӘН* ❖ **БИЛӘҮСӘДӘН ЧЫКМАУ.** Кеше кул астыннан чыкмау; ата-анага, кешегә салыну. *Инде гаилә дә корып җибәргән, ләкин әле һаман да биләүсәдән чыкмаган* (Сөйләм).

*БИЛБАВЫ* ❖ **БИЛБАВЫ БУЛМАСА, ЭЧЕ ШАРТЛАРЛЫК.** Күп ашау турында. – *Карале, үзе яшь кенә кеше, ә билбавы булмаса, эче шартларлык* (Сөйләм).

*БИЛБАУ* ❖ **БИЛБАУ АСТЫ БУШ<АУ>** *к.* ашказаны котыру. – *Каян аласың аны? Ит дисең... әле башка нәрсә булса да ярап торыр иде. Билбау асты бигрәк тиз бушый* (Р. Кәрами. Каргышлы юллар).
Төрдәше: ашказаны котыру һ.б.

*БИЛГӘ* ❖ **БИЛГӘ-БИЛ КАЛУ.** *Малайларга сиздермичә генә, Давыл белән билгә-бил калдым* (Зөлфәт. Алдым көймә... Киттем диңгезгә...).

**БИЛГӘ КӨЯНТӘ ТЫККАН КЕБЕК.** Бөкрәеп йөрүчене чагыштыру. *Әйе, еллар үзенекен ала шул, кара инде Гөлчирәттәйгә, биленә көянтә тыккан кебек* (Сөйләм).

**БИЛГӘ СУГУ.** Кыен хәлдә калдыру. *[Паровозны] Березниковскийга җибәртеп, билгә суктылар да куйдылар бит* (Ш. Камал). *Техника эштә җиңеллек китерсә дә, мәсьәләнең икенче ягы билгә сукты...* (miss.ru).

*БИЛДӘ* ❖ **БИЛДӘ ЫШТАН, ТЕЛДӘ СҮЗ ТОРМАУ.** Картлыкның ике галәмәтен санаганда, җорланып әйтелә. *Без картларның шул инде, билдә ыштан, телдә сүз тормый* (Ф. Хөсни. Картая белмәс картлык).

*БИЛДӘН* ❖ **БИЛДӘН АЛЪЯПКЫЧ ТӨШМӘҮ.** Һәрвакыт эштә булу, көне-төне эшләү. *Бигрәк тә хезмәтне сөя инде Каюм абзый, бер дә биленнән алъяпкычы төшми* (Сөйләм).
Төрдәше: авызга җаны килгәнче (чыкканчы) тырышу һ.б.

**БИЛДӘН БУЛУ (ИДЕ).** Бик күп булу. *Аның әле теш кайрардай вак-төяк дошманнары да билдән* (В. Имамов. Карабәк). *Урын түрдән, хезмәт билдән иде* (В. Галиев. Җырларымда гомерем дәвамы).

**БИЛДӘН ЯЗДЫРУ.** – *Ах-х, ү-үтерде... Уф, аяксыз иткәне җитмәгән, шул хәзер билдән яздыра* (Р. Уразголов. Сандык).

*БИЛЕ* ❖ **БИЛЕ БӨКРӘЙГӘН, КҮЗЕ ЧЕКЕРӘЙГӘН.** Бик картаю, бетеренү. *Авылдан китүенә утыз елдан артык вакыт узган иде, авылдашлары аны танымадылар да: биле бөкрәйгән, күзе чекерәйгән, сакал үстереп җибәргән* (Сөйләм).

*БИЛЛӘҺИ* ❖ **БИЛЛӘҺИ ӘГӘР.** Нәрсәнең дә булса дөреслегенә ышандырып ант итү. *Өзлексез чиртә дә тора инде менә билләһи әгәр* (Ш. Камал. Матур туганда). – *Билләһи әгәр, ипидер. Баскан урынымда чәчрәп үлим, бер генә сүзем ялган булса* (Г. Ахунов. Идел кызы).
Төрдәше: айдыр әгәр һ.б.

*БИЛНЕ* ❖ **БИЛНЕ БИШ ҖИРДӘН БӘЙЛӘП ТОРУ.** Нинди дә булса эшкә әзерләнеп тору. *Мин инде билне биш җирдән бәйләп торган идем, син генә соңардың* (Сөйләм).

**БИЛНЕ БИШКӘ (БИШ ҖИРДӘН) БӨРЕП (БӨРМӘП).** 1. Түбәнчелек күрсәтеп, ярарга тырышып. *Билен биш җидән бөрмәп, аның күзенә бик чалынырга тырышкан иде дә, тырышлыклары бушка китте* (Сөйләм).

2. *к.* авызга җаны килгәнче (чыкканчы) тырышу. *Авылда гына түгел, заводта да билне бишкә бөреп эшләмәсәң, тормышың юньсез булачак* (Сөйләм).
Төрдәше: авызга җаны килгәнче (чыкканчы) тырышу һ.б.

**БИЛНЕ БИШКӘ (БИШТӘН) БУУ** *к.* авызга җаны килгәнче (чыкканчы) тырышу. *Моның өчен, кем әйтмешли, билеңне биштән буып, уртыңны чәйни-чәйни, тешеңне кысып, даими укырга кирәк* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында). *Ихата тутырып мал асрый, билне бишкә буып эшли, мул тормышта яшиләр* («Акчарлак» газ.).
Төрдәше: авызга җаны килгәнче (чыкканчы) тырышу һ.б.

**БИЛНЕ БУЫП ТУУ.** Эшчән, тырыш, уңган. *Эшләргә җир генә булсын... Без шуның өчен билне буып туган инде* (М. Фәйзи. Асылъяр).
Төрдәше: авырның өстеннән, җиңелнең астыннан һ.б.

**БИЛНЕ ДҮРТКӘ-БИШКӘ БОРГАЛАУ.** Боргаланып-сыргаланып йөрүдән башканы белмәү (күбрәк кызлар хакында). *Миңа бик-бик матурлыгың ни эшкә? Билеңне боргалавың дүрткә-бишкә?* (Д. Гобәйди. Матур кызга).

**БИЛНЕ <СУГЫП> СЫНДЫРУ.** 1. Буйсындыру. – *Болгар билен сугып сындырсалар, аһ, көчәясе, көрәясе булган урысларның!* (В. Имамов. Казан дастаны). *Әмма румлылар ул менгән атның билен сындырырга чамалыйлар, аның мең газаплар белән җыйган илен-көнен туздырырга хыялланалар* (Р. Зәйдулла. Тәңре кылычы).

Төрдәше: авызлык кидерү һ.б.

2. Тормышны кыенлаштыру, төрле авырлыкларга дучар итү. *Шул ике бәла аның билен сындырды, бәхетен кире җибәрде* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *[Сәлим] Билемне сындырды. Дөньямны екты. Ах, ах, ах...* (М. Фәйзи. Ак калфак).

Төрдәше: билсез калдыру.

*БИЛСЕЗ* ❖ **БИЛСЕЗ КАЛДЫРУ.** Бил бөгелмәү яки тырая алмау. – *Корыч-Тимерне ул билсез калдырган* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).

Төрдәше: билне <сугып> сындыру 2.

*БИЛЧӘН* ❖ **БИЛЧӘН ТЕЛ.** Усал, төртмә телле. *Һай, билчән тел дә инде минем кайнана!* (Сөйләм).

Төрдәше: агу тел<ле> һ.б.

*БИМАЗАЛАП* ❖ **БИМАЗАЛАП ЙӨРҮ.** Җәфалап, борчып йөрү. *Бу вакытта нишләп кеше бимазалап йөрисең, дип әйтмәгәе дип, шикләнеброк кенә бардым мин моның катына* (В. Нуруллин. Ике урам арасы). *Вакыты белән күңел түрендә күптәннән бирле яшеренеп яткан, күптәннән бирле бимазалап йөргән гүзәл моң туа...* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!).

*БИНӘ* ❖ **БИНӘ КУУ.** Ачу тоту, үпкәләү. *Ир-егетләр арасында ни булмас: кызып алган да суынган, аңлаштылар, бинә куу булмады, ара бозылмады* (Ш. Галиев).

Төрдәше: ата-анасын үтергән кебек йөрү һ.б.

*БИР* ❖ **БИР БИШНЕ, <ТОТ ДҮРТНЕ>.** Исәнләшер өчен кулын бирүне сорау. – *Булды, Разия, бир бишне!* – *диде* (А. Алиш. Якты күл буе). *Син үз юлыңа, мин үз юлыма. Бир бишне, тот дүртне!* – *диде Хәйдәр һәм шап итеп учын Касыймның учына сукты* (Г. Минский).

**БИР ДИСӘҢ – ДӘШМӘҮ, МӘ ДИСӘҢ – КУЛ СУЗУ.** Алырга яратып, бирергә яратмаучы хакында. *Синең авылдашың мулла нәсленнән, ахрысы: бир дисәң – дәшми, мә дисәң – кулын суза* (Сөйләм).

**БИР МИҢА ДА МИН – СИҢА.** Исәпкә корылган мөнәсәбәт турында. *«Бир миңа да мин – сиңа» дигән килешү турында ишеткәнең бармы, бәлки, безгә дә шуны яңартыргадыр?* (Сөйләм).

*БИРӘ-БИРӘ* ❖ **БИРӘ-БИРӘ БЕТ БАСУ.** Һәр сораган кешегә бирә башласаң, бөлгенлеккә төшүең бар. *Миннән сукыр бер тиен юк. Болай да бирә-бирә бет басты инде* (К. Тинчурин).

Төрдәше: бирә-бирә бизгәккә сабышу; бирә-бирә бирән булу (бирәнгә сабышу).

**БИРӘ-БИРӘ БИЗГӘККӘ САБЫШУ.** Юмартланып бөлгенлеккә төшү, ник бирдем икән дип калтырауга калу. – *Әйтмә дә инде, бирә-бирә бизгәккә сабыштым* (Сөйләм).

Төрдәше: бирә-бирә бет басу һ.б.

**БИРӘ-БИРӘ БИРӘН БУЛУ (БИРӘНГӘ САБЫШУ)** *гади с.* Сораган саен биргәч тә, сорап йөдәтүгә ризасызлык күрсәтү, туеп бетү. *Бирә-бирә, бирән булып бетәрсең* (А. Шамов).

Төрдәше: бирә-бирә бет басу һ.б.

*БИРӘМ* ❖ **БИРӘМ (БИРИМ) ДИГӘН КОЛЫНА ЧЫГАРЫП КУЯР ЮЛЫНА.** «Тырышып эшләгән кешегә Аллаһы Тәгалә ярдәм итәр» мәгънәсендә яки бик тырышып эзләгән әйбер көтмәгәндә җиңел генә кулга төшкәндә әйтелә. *Бирим дигән колына чыгарып куяр юлына, ди* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы). *«Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына» дигәндәй, Фәһим моны Алла бүләге дип кабул итә* (Н. Гамбәр. Кояшлы тауга күтәрелү).

Төрдәше: бирәсе килгән колына чыгарып куяр юлына.

*БИРӘН* ❖ **БИРӘН БУЛГАН МӘЛЛӘ.** Бөтен нәрсәне авызына каба, тешли торган атка әйтәләр. – *Чү, дим, чү... Нишләдең инде, бирән булган мәллә, кепканы тешлисең...* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).

**БИРӘН КОРСАК.** Ашап туймас кеше, ач күз. – *Кузналарыңны җелеген суырырга саклыйсыңмыни, әй, бирән корсак!* (Ә. Еники. Яз баласы). *Чыраен да сытмый, бирән корсак* (Ф. Шәфигуллин. Гафу үтенергә).

Төрдәше: апара корсак һ.б.

**БИРӘН ӨЗГЕРЕ!** *карг.* Үләр хәле җиткәндә дә ашау-эчүне кайгырткан кешегә карата. *Ах, бирән өзгере, убырлы карчык! Ярты җаның кабергә киткән... Урлап бал эчәргә йөрисең бит!* (М. Әмир).
Төрдәше: бирәнгә сапкыры; эчеңә бирән булгыры!

**БИРӘН ТАРГАН** *к.* апара корсак. – *Синең абыеңа бирән тарганмы әллә, һич өстәл яныннан алып китеп булмый* (Сөйләм).
Төрдәше: апара корсак һ.б.

*БИРӘНГӘ* ❖ **БИРӘНГӘ САБУ** *сөйл.* Күп ашап, туймас тамакка әверелү, сары су авыруына дучар булу. *Ходай күрсәтмәсен байларның, елкы ите ашап, бирәнгә сабуын!* (Ш. Мөхәммәдев).

**БИРӘНГӘ САПКЫРЫ** *карг.* Кеше хакын ашаучы, ач күз кешене каргау сүзе. *Тфү, бирәнгә сапкыры! Ах, чүперә корсак!* (Ш. Мөхәммәдев).
Төрдәше: бирән өзгере! һ.б.

*БИРӘНЕ* ❖ **БИРӘНЕ ЕРТЫЛГЫРЫ!** *карг.* Йә талап, йә кеше малын басып калып, кеше хакын ашаучыны каргау сүзе. *Утын кискән өчен сөйләшенгән акчаның яртысын гына бирде, бирәне ертылгыры!* (Сөйләм).
Төрдәше: бирәне сытылгыры! (чәчрәп киткере!; шартлагыры!).

**БИРӘНЕ СЫТЫЛГЫРЫ! (ЧӘЧРӘП КИТКЕРЕ!; ШАРТЛАГЫРЫ!)!** *к.* бирәне ертылгыры! *Ишегалдындагы тавышка йөгереп чыксам, дәү әни, кулындагы себеркесен селти-селти, «бирәнең сытылгыры!, кикрикле зөбани» дип, күрше әтәчен куып йөри иде* (Сөйләм).
Төрдәше: бирәне ертылгыры!

*БИРӘНЕН* ❖ **БИРӘНЕН ЙОТКАН** *к.* апара корсак. *Бай бит ул, бирәнен йоткан кебек, ашаган саен ашыйсы, эчкән сан эчәсе килеп, азап чигә* (gabdullatukay.ru).
Төрдәше: апара корсак һ.б.

**БИРӘНЕН ЭЧКӘН.** Акчасын эчеп бетерә торган исерек ир турында. – *Ә, син теге, бирәнен эчкән кешене сорыйсыңдыр әле, икенче катта яши ул* (Сөйләм).

*БИРӘНЕҢӘ* ❖ **БИРӘНЕҢӘ ЯК** *карг.* Бер дә туймас, комсыз кешегә әйбер биргәндә әйтәләр. – *Теңкәмә тидең инде, мә, бирәнеңә як!* (Сөйләм).
Төрдәше: бирәнеңне тык.

*БИРӘНЕҢНЕ* ❖ **БИРӘНЕҢНЕ(Ә) ТЫК** *карг.*, *к.* бирәнеңә як. *[Интизар] Фатирыңны бирәнеңә тык, ә сызымнарны кире кайтар!* (Р. Зәйдулла).
Төрдәше: бирәнеңә як.

*БИРӘННЕ* ❖ **БИРӘННЕ КОТЫРТУ.** Комсызланып ашау, һич туймау. *Сабый чагында тавыкларга сипкән ярманы чүпләп, ярма ташы ялап теңкәгә тигән малай үскән саен бирәнен котыртты, ашады да ашады* (А. Гыйләҗев. Яра).

*БИРӘСЕ* ❖ **БИРӘСЕ КИЛГӘН КОЛЫНА ЧЫГАРЫП КУЯР ЮЛЫНА** *к.* бирәм (бирим) дигән колына чыгарып куяр юлына. *«Бирәсе килгән колына чыгарып куяр юлына» дигән әйтем дөрес икән* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).
Төрдәше: бирәм (бирим) дигән колына чыгарып куяр юлына.

*БИРГӘЛӘП* ❖ **БИРГӘЛӘП АЛУ.** Бераз бәргәләп, суккалап алу. *Батырхан туган, бик ачуланма инде. Йөрәк түзмәде... Әләккәч, бераз бәргәләп алдык* (Г. Ибраһимов). *Газиздән башка тагын өчәүне иярттем: Әбеч Хәмитен, Ташкергән Һадиен, Әбеч Сәхиен, Хәмит бармаска итеп карышып караганые, сугышалар алар, дип, аңа әзрәк биргәләп алырга туры килде* (З. Зәйнуллин. Кыз куенына кергәнче).

*БИРГӘН* ❖ **БИРГӘН АЛЛА АЛГАН.** Үлем-китем булганда, аһ-ваһ килеп, бәрелеп-сугылып йөрүнең мәгънәсезлеге хакында. *Биргән Алла үзе алган аны, чәч йолкып, аһ-ваһ килеп утыру килешмәс* (Сөйләм).

*БИРГӘН* ❖ **БИРГӘН АНТНЫ БОЗМАУ** *к.* антка тап кундырмау. *Биргән антны бозмаганнар / Биргән антны бозмас халкына* («Мәдәни җомга» газ.).
Төрдәше: антка тап кундырмау һ.б.

*БИРГӘНГӘ* ❖ **БИРГӘНГӘ БИРӘ <ЕШ (БИТ)>.** «Берәүгә гел бирелә дә бирелә» дигән мәгънәдә. *Адәм баласының түгел, фәрештәнең авыз сулары корыр тегеләй. Биргәнгә бирә бит Хода...* (Б. Камалов. Күршеләр). *Биргәнгә бирә еш, бирмәгәнгә чирәеш* (Мәкаль).

**БИРГӘНГӘ БИШ ТӘ КҮП, АЛГАНГА АЛТЫ ДА АЗ.** Биргәндә үзеңнекен бирүгә, алганда исә үзеңә алуга ишарә. *«Биргәнгә биш тә*

*күп, алганга алты да аз» дигән нәрсә борынгыдан килә ул – шөбһәләнмә, җиде итеп кайтарырмын* (Сөйләм).

**БИРГӘНГӘ ШӨКЕР.** Булган кадәрлесенә, саулыгына риза булып яшәүне аңлата. *Ходайның биргәненә шөкер, кода* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *«Бу Ходайның / Биргәненә шөкер, биргәненә»* (Г. Морат. Урам кызы).

*БИРЕДӘ* ❖ **БИРЕДӘ АЛАБАЙ, АРГЫ ЯТА ЯЛАГАЙ.** Икейөзле кеше турында. *Бир*е*дә алабай, аргы якта ялагай* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).
Төрдәше: алдан аяк атлау (ялау), арттан үкчә тешләү һ.б.

**БИРЕДӘ АХЫЛДАРЛЫК ТҮГЕЛ** Бигүк матур булмаган урын хакында. *Биредә ахылдарлык түгел икәнлеген алдан ук төшенгән идем, шулайрак икән шул* (Сөйләм).

*БИРЕЛГӘН* ❖ **БИРЕЛГӘН ВӘГЪДӘНЕ БОЗУГА ЮЛ КУЙМАУ** *к.* сүздән эләктерү. *Кулыннан килгәннең барысын да эшләде, бирелгән вәгъдәне бозуга юл куймады* (Сөйләм).
Төрдәше: әйткән сүздән файдалану һ.б.

*БИРНӘ* ❖ **БИРНӘ БИРГӘН БИКӘ КИЛЕН ДИМӘСЛӘР ӘЛЕ.** Күпме яраргa тырышсаң да, кадереңне белмәсләр, рәхмәт әйтмәсләр. *Төн йокыларын калдырып, алар эше белән йөрсәң дә, бирнә биргән бикә килен димәсләр әле* (Сөйләм).

**БИРНӘ САНДЫГЫ** *махс.* Элегрәк вакытларда кызлар кияүгә чыгар алдыннан әйберләрен шуңа җыеп барганнар. – *Ямансула, дускаем, минем «бирнә сандыгында» сиңа чаклы таман кызыл күлмәк бар, мин аны базардан шудырган идем* (Н. Гыйматдинова. Сөйлим, тыңла...).

*«БИР»НЕҢ* ❖ **«БИР»НЕҢ АТАСЫ ҮЛГӘН.** «Бир, бир» дип йөдәтеп торучыга бирмәс булганда әйтелә. – *Син башка монда килеп йөрмә инде, «бир»нең атасы үлгән* (Сөйләм).

*БИРСӘҢ* ❖ **БИРСӘҢ, БӘЙЛӘП БИР, БАШЫН-КҮЗЕН ЧӘЙНӘП БИР** *к.* авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү. *«Балык бирсәң, бәйләп бир, башын-күзен чәйнәп бир», – дигәннәрме әле? Менә шулай. Нефтьчеләрнең берәр метрлы труба белән мәшәкатьләнәселәре килми* (Ш. Бикчурин. Могҗиза тудыручылар).
Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**БИРСӘҢ – БИРЕП АШЫЙ, БИРМӘСӘҢ – ТАЛАП АШЫЙ.** Әрсез, ертлач, басымчак турында. – *Син Әхмәткә дә бер өчпочмак калдыр инде: беләсең бит аның бирсәң – биреп ашый, бирмәсәң – талап ашый торган кеше икәнен* (Сөйләм).
Төрдәше: әрсез алабай һ.б.

*БИСМИЛЛАНЫ* ❖ **БИСМИЛЛАНЫ ӘЙТҮ.** Изге саналган урынга бисмилла әйтеп керүгә ишарә. – *Урманчы гозерен тыңлап, Ринат энекәшең белән бергә утыртышкан каенлыкка таба кире китәсең дә һәммәсенә – туфрактан күккә тиклем – бисмиллаңны әйтә-әйтә барып керәсең* (Ә. Гаффар. Күл).

*БИСМИЛЛАСЫ* ❖ **БИСМИЛЛАСЫ БУЛУ.** Бер-бер эшнең башлангычы булу. *Бусы шушы күңелле көннәрнең бисмилласы булыр* (М. Фәйзи). *Милләтнең эчке бүленүенә китергән мондый гамәлләрне эшләмәү уртак эшебезнең бисмилласы булырга тиеш иде югыйсә* (Р. Зәйдулла. Игътибар үзәгендә – балалар әдәбияты).
Төрдәше: бисмилласы шушы булсын.

**...БИСМИЛЛАСЫ ГЫНА** *к.* анысы әле баласы<-чагасы>, мичтә ята анасы. *Әмма болар һәммәсе дә Сабан туеның бисмилласы гына әле* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Куллардан балта-чүкеч төшкәч, эш кимер кебек күренгән иде дә, Мөслах карт әйтмешли, өй ул эшнең бисмилласы гына булып чыкты* (Ф. Яруллин).
Төрдәше: анысы әле баласы <-чагасы>, мичтә ята анасы һ.б.

**БИСМИЛЛАСЫ ШУШЫ БУЛСЫН** *к.* бисмилласы булу. *Шәйхразый, улының авылның иң ярлы кешесенең кызын алуын ишеткәч, иң элек, бисмилласы шушы булсын, дип, хатынына берне чалтыратты* (А. Гыйләҗев).
Төрдәше: бисмилласы булу.

**БИСМИЛЛАСЫ ЭЧЕНДӘ.** «Табакта ашы күп булмаса да, туклыклы һәм бәрәкәтле» мәгънәсендә. – *Әйдәгез, бераз капкалап алыгыз, бисмилласы эчендә аның* (Сөйләм).

*БИСМИЛЛАСЫЗ* ❖ **БИСМИЛЛАСЫЗ ТУЯРЛЫК** *к.* авызга җен төкерү. *[Хатыйп] Әмма тел дә инде үзеңдә – бисмилласыз да туярлык* (Ю. Әминов. Язылмаган законнар).
Төрдәше: авызга җен төкерү.

**БИСМИЛЛАСЫЗ ХӘТЕМ УКУ.** Хәтердән чыгу. *...Тагын кемнәр бисмилласыз / Укый анда хәтемне?* (Г. Морат. Хәтер көне).

*БИСМИЛЛАСЫН* ❖ **БИСМИЛЛАСЫН ОНЫТУ.** Ашавыннан туктый, туя алмау. *Түргә мендем, алда ашъяулык вә тездә тастымал: бал да май, коймак та каймак, кайсын алсаң – шунсын ал! Әллә бисмилламны әйтергә оныттым? Нә исә, бер заман коймак шәрифләрдән тәмам җилләр исә* (Ш. Бабич).

**БИСМИЛЛАСЫН УКЫТУ** 1. *к.* акыл бирү 1. Бик каты ачулану. *Малайның бисмилласын укыттым әле, алайса компьютерын ача да сугыш уеннарын уйнап тик утыра* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл бирү 1 һ.б.

2. авыз җебетү 2. *Алай дисәң, шундый ук эчтәлек «Әлхәм сүрәсен укыту», «Бисмилласын укыту», «Иманын укыту» һ.б. тәгъбирләр өчен дә хас* (Х. Мәхмүтов. Изге китаплар кайтавазы). *– Кая, мин дә берне тондырыйм әле колак төбенә, бисмилласын укытыйм!* (Р. Кәрами. Кая чабасың, гомер юртагы?).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

*БИСМИЛЛАСЫННАН* ❖ **БИСМИЛЛАСЫННАН БАШЛАУ.** Эшне башыннан, нигезле рәвештә башлау, ордым-бәрдем генә эшләмәү. *– Нигә бер очы озынрак килеп чыккан, дөрес үлчәмәдеңме әллә – бисмилласыннан башларга кирәк иде, энем* (Сөйләм).
Төрдәше: «а», «б»дан башлау һ.б.

*БИСМИЛЛАҺИ* ❖ **БИСМИЛЛАҺИ АЛЛАҺЫ ӘКБӘР.** Озак уйлап тормыйча, тиз генә эшләп ташлау. *Кайталар да, җиңел кулдан бисмиллаһи Аллаһы әкбәр... бер кәҗәне егалар да суялар* (Ф. Хөсни. Йөзек кашы).

*БИТ* ❖ **БИТ АЛГА БУЯЛУ.** Кызару, оялу. *Битең алга буялды* (Ю. Әминов).
Төрдәше: бит кызару һ.б.

**БИТ АСТЫНА КЕРГЕРЕ** *карг.* Кешегә яманлык теләү. *Тышта күрше кемнедер «бит астына кергере, койма янында яткан бакалы алып китмәсәң!» дип сүгеп ята иде* (Сөйләм).

**БИТ БЕЛӘН ҖИР СЕБЕРСӘҢ ДӘ ЯРЫЙ АЛМАССЫҢ.** «Берәүнең колы, хезмәтчесе булсаң да ярый алмаячаксың» мәгънәсендә. *Ул хуҗалыкның хуҗасы шундый вакчыл кеше, бит белән җир себерсәң дә ярый алмассың* (Сөйләм).

**БИТ БЕЛӘН ҖИР СЕБЕРҮ** *к.* авызга җаны килгәнче (чыкканчы) тырышу. *[Батырҗан] Нишләргә инде? Көне-төне эшлисең, битең белән җир себерәсең, шулай да сиңа нәрсә диләр бит, «суктырырмын», имеш!* (Т. Гыйззәт. Наемщик). *– Минме тырышмадым, битем белән җир себердем, – диде Рита, борынын мышкылдата-мышкылдата* (Х. Камалов).
Төрдәше: авызга җаны килгәнче (чыкканчы) тырышу һ.б.

**БИТ БИРҮ.** Буйсыну, күнү (арка бирүнең киресе). *Кайт, и нәфсе мотмәиннәм! Бар, юнәл, кит Тәңреңә; / Бирдең арканы моңарчы, инде бир бит әмренә* (Г. Тукай).
Төрдәше: арка бөгү һ.б.

**БИТ ЕРТУ.** 1. Кешенең намусына тукыну; кеше алдында оятка калдыру, аның турында гайбәт сөйләү. *Яубаш белән тиң булырга йөргәне өчен генә түгел, битен ертып, яшь бикәсе Ләйләне сатарга сораган өчен дә* (М. Хәбибуллин). *Авыр сүз әйтеп, битен ертма Шәмсетдин кияүнең* (Ш. Янбаев. Диңгез акчарлагы).

2. Түбәнсенү, әрсезлеккә бару; үз кадереңне үзең җибәрү. *– Синең өчен генә. Югыйсә йөз суын түгеп, бит ертып йөрмәс идем* (Ф. Шәфигуллин). *Әйтмәс идем, битен ертып ләкин көн дә / Бу ыштыр бит һаман хайван өммәтендә* (Р. Шәрипов. Юл башы).
Төрдәше: йөз ерту (ике маддәгә дә карый); кеше йөзен ерту.

**БИТ КАЙТУ.** Гайрәт чигү, күңел кайту, өмет өзү, бизү. *Битем кайтты аларның затсыз җырларыннан* (Сөйләм).

**БИТ КЫЗАРТУ.** Оялту, уңайсыз хәлгә кую. *Син бик дөрес хатын икәнсең. Солдат иреңнең битен кызартмассың* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).
Төрдәше: биткә кызыллык китерү; биткә (оят<лык>) китерү; битгә белен пешерү; йөзгә кызыллык йөгерү; йөзгә кызыллык китерү.

**БИТ КЫЗАРУ** 1. *к.* бит алга буялу. *Моның өчен иң беренче аның бите кызара, колхозлар эшендәге бөтен кыенлыкны иң башлап ул күтәрә иде* (Г. Бәширов). *Сөмбел Булатның ни әйтергә теләгәнен бик яхшы аңлады, уңайсызланып, битләре кызарып чыкты, кулы белән эчен каплады, җилкәсен җыерды* (З. Кадыйрова. Сагынырсың – мин булмам).

Төрдәше: бит алга буялу һ.б.

2. *к.* адәм көлкесе булу. *Бите кызарган Төлке! – / Булабыз хәзер көлке!..* (Л. Шәех. Керпе ничек энәле булган?). *Вак-төяк кимчелекләрне, кайберәүләрнең битләре кызарып чыгуын исәпкә алмаганда, эксперимент уңышлы башкарылды дип санарга була* (Җ. Рәхимов. Тәвәккәл таш яра).

Төрдәше: адәм көлкесе булу һ.б.

**БИТ ПЕШҮ** *к.* адәм көлкесе булу. *Малайлар җиңде, гауга бетте, ә табында пилмән юк, итле шулпа бу атып пешми. Бит пешә, бит!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *«Кунак килсә, ит пешә, ит пешмәсә, бит пешә» – коры өстәл артында кара-каршы озак утыра алмыйсың* (Г. Бәйрәмова. Үз хәлемне үзем беләм).

Төрдәше: адәм көлкесе булу һ.б.

**БИТ СЫП<Т>ЫРУ (СЫЙПАУ).** 1. Дога кылу. *<...> мендәрләр өстендә аяк бөкләп утырып, каймаклап чәй эчә калдылар, яшьрәкләр бер-ике чынаякны бушаттылар, бит сыйпап, дога кылган сыман иттеләр дә йортка чыктылар* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). *Мулла абзый, укып бетереп, битен сыйпады да Рушанияга бик дикъкать белән карап алды* (З. Кадыйрова. Көтеп узган гомер).

2. Исәптә ялгышу (уйланган уй-хыялларның тормышка ашмавы). *Гайрәт җыйгач дию пәрием, / Өй почмагын сүтеп чыгып качты, / Битен сыйпап калды кариэң...* (Э. Шәрифуллина. Тамды яшем...). *Сандык өсте гөрселдәп ябыла... [Җәмилә] (халыкка). Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, әристәкрәтләр димчесе дөмекте... Битен сыпыра* (А. Гадел. Кияүләргә кытлык юк).

*БИТАМАН* ❖ **БИТАМАН БИЗГӘГЕ БУЛУ.** Кат-кат калтырауга төшереп, кешене йөдәтү (элек Битаман тирәсендәге күл-сазлыкларда бизгәк таралган булган). *Тик монда кигәвеннәр Битаман бизгәге шикелле йөдәткеч икән, ябышырга гына торалар* (М. Әмирханов. Мөкәррәмә).

*БИТАРАФ* ❖ **БИТАРАФ БУЛУ (ТОРУ).** 1. Бер якка да кушылмау. *Шуның белән бергә, миһербанлы кеше буларак, ул аерым шәхес язмышына да битараф була алмый* (А. Әхмәдуллин. Офыклар киңәйгәндә). *Кырым җиңелгәндә, Казан, Нугай, Хаҗитархан битараф торган* (Л. Галитзуллина. Китапларда – тарих сурәте).

2. Мөнәсәбәтләр начар булу. *Киресенчә, Фәләх аларның һәркайсын Роза белән чагыштырып карый, аңа тиңләргә, аңа охшатырга тырыша, әмма берсе дә Розага җитми: үлчәү тәлинкәсе гел Роза ягына баса, һәм Фәләхнең күңеле алардан бик тиз суынып, битараф булып кала килде* (В. Нуруллин. Әгәр син булмасаң). *Ул хатынының аңа карата салкын, битараф булуына күнеккән һәм моңа исе дә китми иде* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

**БИТАРАФ КАРАУ** *к.* бармак аша карау. *Үз буыным вәкиле буларак, аның язмышына мин битараф кына карый алмыйм* (М. Шабаев. Төшсез чикләвекләр...). *Әгәр без, шушы җирнең хуҗалары икәнне онытып, аңа битараф карыйбыз икән, киләчәк буын безгә ни дияр?* (Ш. Маннапов. Мәңгелектән елмаю).

Төрдәше: бармак аша карау.

**БИТЕ ӘДӘП БЕЛМӘГӘН, АРТЫ ТӘРӘТ КҮРМӘГӘН.** Бернинди әдәп, тәрбия белмәүче, надан, тупас кеше турында. *Бите әдәп белмәгән, арты тәрәт күрмәгән кешене күрәсең килсә, аның үрнәге – Шүрәле Касыймы үзе инде* (Сөйләм).

**БИТЕ ҖӘҺӘННӘМГӘ КЕРСӘ ДӘ КЫЗАРМАС.** Артык оятсыз, әрсез. *Бер дә аптырама, Фазыл абыеңның бите җәһәннәмгә керсә дә кызармас* (Сөйләм).

Төрдәше: әрсез алабай һ.б.

**БИТЕ КОМАЧ КАПЛАГАН КҮК** *к.* бит алга буялу. *Ул җавап итеп бер сүз дә дәшмәде, бары бите генә комач каплаган күк булды* (Сөйләм).

Төрдәше: бит алга буялу һ.б.

**БИТЕ ОРЛЫК ПӘРӘМӘЧЕ КЕБЕК.** Битен куе итеп сипкел баскан кешегә карата әйтелә.

*– Борчылма, аны тануы бик җиңел, бите орлык пәрәмәче кебек* (Сөйләм).

Төрдәше: битенә иләк каплаган кебек; сипкелле – сөйкемле.

*БИТЕ-ЙӨЗЕ* ❖ **БИТЕ-ЙӨЗЕ УТЫРУ.** «Үзе дә монда күз алдында утыра» мәгънәсендә. *Юк, һич онытканым юк, бите-йөзе һаман да күз алдында утыра* (Сөйләм).

*БИТЕН* ❖ **БИТЕН КУЯР ҖИР ТАПМАУ.** Оятыннан битен кая яшерергә белмәү. *Бай кеше ярлы булса, битен куяр җир тапмас* (Мәкаль).

Төрдәше: битне кая куярга белмәү.

**БИТЕН ЮМАГАН.** Оятсыз, намуссыз, вөҗдансыз, әрсез. *Чырылдашып кычкырдылар: / Бу – надан! Тумышыннан бирле битен юмаган! / Харап итәр безне монда калса ул, / Вузда укып галим була алса ул...*(Ф. Гыйззәтуллина. Яну дәверләрендә). *Карт чын-чынлап шөбһәгә төште. Салдырыр да бу имансыз. Аның битен юмаган* (А. Хәлим. Татар вакыты).

Төрдәше: әрсез алабай һ.б.

*БИТЕНӘ* ❖ **БИТЕНӘ БОЗ ЯУГАН.** Шадра кеше хакында. *Анда бер кулына дипломат, икенче кулына пистолет тоткан киң эшләпәле, сакал-мыеклы, битенә боз яуган уртача яшьләрдәге кеше басып тора иде* (З. Мәхмүди. Эшләпә).

Төрдәше: битендә шайтан борчак сугу; борчак бурасына (бүлмәсенә) егылган; шадра йөрәк яндыра.

**БИТЕНӘ ДУҢГЫЗ ТИРЕСЕ КАПЛАУ.** Әрсез, оятсыз, һәр җиргә борынын тыга торган кеше турында. *Платонга ул вакытта нибары егерме өч кенә яшь, шуңа карамастан ул алдын-артын салкын канлылык белән нык уйлап эш итүче, битенә дуңгыз тиресе каплаган циник кеше була. Императрицаны ул бик тиз арада үз кубызына биетә башлый* (М. Евгеньева. Әби патшаның сөяркәләре / Р. Хәмид тәрҗ.).

Төрдәше: әрсез алабай һ.б.

**БИТЕНӘ ИЛӘК КАПЛАГАН КЕБЕК.** Сипкелле кеше турында. *Чәче җитешле егет янында гына пышылдады: – Карале теге кызга, битенә иләк каплаган кебек* (Сөйләм).

Төрдәше: бите орлык пәрәмәче кебек һ.б.

**БИТЕНӘ КАТЫК (КАЙМАК) СӨРТСӘҢ, КӨЧЕК ЯЛАМАС** *мыск.* Чырае, бите бик ямьсез. *Битенә катык сөртсәң, көчек яламас* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

**БИТЕНӘ КҮН ТЕККӘН** *к.* битенә дуңгыз тиресе каплау. *Битенә күн теккән дип уйларсың, кем белән сөйләшкәнен дә, нәрсә турында сөйләшкәнен дә белми* (Сөйләм).

Төрдәше: әрсез алабай һ.б.

**БИТЕНӘ ТӨКЕРСӘҢ, ТАМЧЫ (ЯҢГЫР) ТАМА ДИП ТОРУ** *мыск.* Оят-намус дигәннең ни икәнен дә белмәү; гарьсез, тупас кеше. *Битенә төкерсәң, яңгыр тама дип торган оятсыз, намуссыз адәмнәрнең сыңары иде шул ул* (Р. Галиуллин. Боссоойко).

**БИТЕНӘ ЫШТЫР КАПЛАУ (ЯБУ).** Кылган яманлыгыннан оялмаучы турында. *Күрше кызының битенә ыштыр япкан иде шул, үз буасын ерды: – И апа бәгырькәем, разве мин җизнәкәй белән бәйләнешәм инде* (Н. Гыйматдинова. Син түгел бу, син түгел...). *Курыкмагыз миннән, ялгыз хуҗалык дигәч тә, Ярулла кешелеген югалтып, битенә ыштыр каплаган залим бәндә түгел* (Г. Тавлин. Афәт).

Төрдәше: әрсез алабай һ.б.

**БИТЕНӘ ЯМАУ САЛУ.** Бите сугылып яки кыйналып күгәрү. *Аңа күтәрелеп карарлык түгел иде, битенә ямау салган кебек, алланып-шәмәхәләнеп беткән* (Сөйләм).

*БИТЕНДӘ* ❖ **БИТЕНДӘ БЕЛЕН ПЕШЕРҮ** *к.* биткә кызыллык китерү. *Аның төкреген чәчә-чәчә сөйләгәннәре кызның битендә белен пешерергә мәҗбүр итте* (Сөйләм).

Төрдәше: биткә кызыллык китерү; биткә (оят<лык>) китерү; битне кызарту; битне пешерү; йөзгә кызыллык йөгерү; йөзгә кызыллык китерү.

**БИТЕНДӘ ШАЙТАН БОРЧАК СУГУ** *к.* битенә боз яуган. *Башканы димләгән булса, әйтик, боярыня Марфа Демьяновны, битендә шайтан борчак суккан дип тормас идең, ярәшү балдагын шуңа кидерер идең* («Казан утлары» ж.). *Берсе кара тут йөзле, чеп-чи шадра, әйтерсең лә битендә шайтан борчак суккан* (М. Әмирханов. И, кылган догам минем...)

Төрдәше: битенә боз яуган һ.б.

*БИТЕНЕҢ* ❖ **БИТЕНЕҢ КЕРЕНӘ БИШ ЭТ ТУЯРЛЫК.** Бик пычрак кеше; әрсез, оятсыз. *Аның*

*турында сөйләнеп, авызымны да пычратасым килми, битенең керенә биш эт туярлык* бит (Сөйләм).
Төрдәше: әрсез алабай һ.б.

*БИТЕННӘН* ❖ **БИТЕННӘН БАСЫП КЕРҮ** *диал.* Рөхсәт сорап тормыйча, өйгә бәреп керү. *Рәхилә күп уйлап тормаган, көндәшенең өенә битеннән басып кергән* (Сөйләм).

*БИТЕҢ* ❖ **БИТЕҢ КАЙДА (КАЯ).** «Оятың бармы синең?» мәгънәсендә. – *Син яшь кәләш белән кунакка чабарга әйтәсең! Битең кая ?! – диде* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми).

**БИТЕҢ СЫПЫР.** «Аннан өмет өз, саубуллаш» мәгънәсендә (ягъни әппәр ит). *Өмет итмә, битең сыпыр инде Чулак Гаптеригә биргән булсаң* (Сөйләм).

*БИТКӘ* ❖ **БИТКӘ ӘЙТҮ.** Әдәп саклап тормыйча, гаепне туп-туры әйтү, дөресен әйтү. *Биткә әйткәннән читтә әйтү яман* (Мәкаль). *Ни дисәң дә, читкә әйткән биткә әйткәннән яман бит ул* («Кызыл таң» газ.).
Төрдәше: биткә бәрү (бәреп әйтү); биткә чәпәп әйтү; йөзгә бәрү (бәреп әйтү); күзгә терәп <әйтү>.

**БИТКӘ БӘРҮ (БӘРЕП ӘЙТҮ)** *к.* биткә әйтү. *Шуларның бичарачыкларын, кызганычлыкларын битләренә бәрергә, шуларның ваклыклары өстеннән югарыдан торып хихылдап көләргә миңа да хәбәр ярдәм итте* (Г. Ибраһимов. Яз башы). <...> *куркып тормаганнар, әйтергә тиешлесен биткә бәреп әйткәннәр* (И. Гази. Онытылмас еллар).
Төрдәше: биткә әйтү һ.б.

**БИТКӘ БИЯЛӘЙ КАПЛАУ.** Оялудан йөзен яшерү. – *Барын бар инде, мин, әнкәй мәрхүмә әйтмешли, битемә бияләй каплап килдем...* (Г. Әпсәләмов).

**БИТКӘ КАН ЙӨГЕРҮ.** Йөзгә кызыллык чыгу. *Нуриәсманың битенә кан йөгерде* (Ф. Садриев. Таң җиле).
Төрдәше: биткә кызыллык китерү; биткә (оят<лык>) китерү; битне кызарту; битне пешерү; биттә белен пешерү; йөзгә кызыллык йөгерү; йөзгә кызыллык китерү.

**БИТКӘ КАРА ЯГУ.** Яла ягу, хур итү, пычрату; кешене яманатлы, оятлы илү. *Ни генә әйтим инде, тәмам оятка калдырды, хур итте, биткә кара якты бит...* (Г. Бәширов).
Төрдәше: адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1 һ.б.

**БИТКӘ КОРЫМ ЯГУ.** 1. Гаепле, оятлы итү. *Менә шундый бит ул Чыңгыз ханның битләренә корым яккан, бөек сәрдәркәе?!* (В. Имамов. Карабәк).

2. Яла ягу. *[Фәрдәнә] Ташулар җир битен юган чакта, минем биткә корым ягып үтәсең!* (Ә. Гаффар. Язлар моңы).
Төрдәше: адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1 һ.б.

**БИТКӘ КЫЗЫЛЛЫК КИТЕРҮ** *к.* адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1. «*Чулпан»ның битенә кызыллык китермик дисәгез, эшегезне бүген үк күрсәтегез* (Г. Бәширов). *[Бәдри] Юк ул, хатын алай дип кенә торырга ярамый. Дөрес, биткә кызыллык китерерлек итмәс* (М. Фәйзи. Галиябану).
Төрдәше: адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1 һ.б.

**БИТКӘ ЛАЧ ИТЕП ТӨКЕРЕЛҮ.** Мыскыллану. *Битенә лач итеп төкерелгән Владимир бу юлы инде тыелып кала алмады* (В. Имамов. Казан дастаны).

**БИТКӘ ОЛТАН САЛУ** *к.* әрсез алабай. *Теге тыкрыкта яшәгән Хәлим, битенә олтан салган нәрсә, таң тишегеннән акча сорап кереп җиткән* (Сөйләм).
Төрдәше: әрсез алабай һ.б.

**БИТКӘ ОЯТ<ЛЫК> КИТЕРҮ.** Кемне дә булса оятлы итү. *[Хәмидә] (Әхмәтҗанга). Инде, акча күп чыга дип, улыңны өйләндерми тора алмассың, хәлдән килгән кадәрле тырышырсың. Дусиш арасында биткә оят китерерлек итмәссең* (Г. Камал. Бүләк өчен). *Күз генә тия күрмәсен, болай булса әле, дус-дошман арасында биткә оят китермәс, дим* (М. Гали).
Төрдәше: адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1 һ.б.

**БИТКӘ ПЫЧРАК АТУ (СЫЛАУ; ТАШЛАУ; ЫРГЫТУ, ЯГУ)** *к.* авыз чайкау 1. *Шул бер башбаштаклык бөтен татарның битенә пычрак ата* («Матбугат.ру» порталы).

*– Нәфисә, нигә минем биткә пычрак яктың?* («Кызыл таң» газ.).
Төрдәше: авыз чайкау 1 һ.б.

**БИТКӘ СЫДЫРМАК.** Турысын әйтәм дип, кешене рәнҗетеп, дорфа итеп әйтү. *Кулын болгыйболгый, төкерекләрен чәчә-чәчә сөйләвенең, дөресрәге, күңел әрнеткеч сүзләр ташлавының төп максаты да биткә сыдырмак, кәефне бозмак иде* (Сөйләм).

**БИТКӘ ТӨКЕРҮ.** Кеше алдында оятка калдыру, хурлау. *«Менә нәрсә булды: ун ел укыткан шәкертләрегез, Гали, синең дә, Кадыйр, синең дә битеңә, килеп, лачт итеп төкермәделәрме? Төкерделәр!»* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Шул яшәүме булыр, «хаин!» диеп, / Ил битемә минем төкерсә!* (М. Җәлил. Дуска).
Төрдәше: адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1 һ.б.

**БИТКӘ УТ (ЯЛКЫН) КАБУ.** Оялу, ярсу, кызу һ.б.дан бит кызару. *Шәһәр кабагы сыман гәүдәсе өстән аска иләмсез киңәеп төшкән баягы егет берни булмагандай елмаеп тора, янәшәсендә битенә ут капкан табибә кыз – чарасыз* (М. Галиев. Тимә, яшәсен!). *Ханбикәнең алсу битләренә ялкын капты, күзләрендә нәфрәт очкыннары ялтырады* (Ф. Бәйрәмова. Күчем хан).
Төрдәше: адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1.

**БИТКӘ УТ КАБЫЗУ.** Оялту, ярсыту, кыздыру һ.б.дан битне кызарту. *Нәҗипне бала санап, һич тайсынмыйча чишенә, малай каршысына шәрә тән басып, аның, төкреген йота-йота, җиргә карап торуыннан көлеп, үртәп, Нәҗипнең битенә ут кабыза иде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: биткә кызыллык китерү һ.б.

**БИТКӘ ЧӘПӘП ӘЙТҮ** *к.* биткә әйтү. *Мин моны кайберәүләрнең битенә чәпәп әйтәм* (Г. Әпсәләмов).
Төрдәше: биткә әйтү һ.б.

**БИТКӘ ЯБЫШУ.** Әрсезләнү, ертлачлану. – *Коткар, биткә ябышты, – ул ыгы-зыгы килә, тавышы калтырап, өзек-өзек чыга иде* (Ә. Әминев. Бер көймәдә). *Үземне белештермичә, битенә ябыша яздым* («Безнең гәҗит» газ.).

*БИТКӘ-БИТ* ❖ **БИТКӘ-БИТ КУЕП СӨЙЛӘШҮ.** Бик якын, үз булып серләшү. *Кичә аларның биткә-бит куеп сөйләшкәннәрен үзем күрдем* (Сөйләм).
Төрдәше: авызга-авыз сөйләшү һ.б.

*БИТЛЕГЕ* ❖ **БИТЛЕГЕ АЧЫЛУ (СЫДЫРЫЛЫП ТӨШЕРЕЛҮ).** Кем икәнлеге беленү, фаш булу. *Хәер, Әхмәт Исхак бит узган чорның битлеге тулаем сыдырылып төшерелгән елларда яшәргә өлгермәде диярлек* (Р. Рахман. Тукайча көләм).

*БИТЛЕГЕН* ❖ **БИТЛЕГЕН АЧУ (АЛЫП ТАШЛАУ).** Берәр кешенең яки төркемнең чын йөзен ачып бирү, фаш итү, *шулай ук к.* ачып бирү. <…> *Пугачев фетнәсе хакында моңа кадәр язылган бик күп хезмәтләргә таяна, аларның ялган битлеген ача, абруйлылар белән бәхәскә керә* (В. Имамов. Тозлы яра). <…> *милли көрәш фонында мөнбәргә менгән кайбер шәхесләрнең, сәяси җитәкчеләрнең битлеген ачып, чын йөзен күрсәтү дә әдәби мохиттәге һәртөрле каршылыклар, намусына хыянәт иткән каләм әһелләренең эшчәнлеге дә тәфсилле сурәтләнә* (М. Гали. А. Хәлимнең «Гомеремнең ун көне» язмасына кереш).
Төрдәше: ачып бирү һ.б.

**БИТЛЕГЕН ЕРТУ** *к.* ачып бирү. *Ш. Камал бу әсәрләре белән реакцион көчләрне, аяусыз эксплуатацияне фаш итеп, сатлык милләтче буржуаз интеллигенциянең битлеген ертып, мещанлыкка, обывательчелек идеологиясенә каршы ут ачты* (М. Җәлил). *Дөньяви фәннәр укыту идеясен башлап кем күтәреп чыкты? Һәм «Бохараи Шәриф»нең битлеген кем ертты? – Мәрҗани!* (М. Госманов).
Төрдәше: ачып бирү һ.б.

**БИТЛЕГЕН САЛДЫРУ** *к.* ачып бирү. *Ул [Г. Тукай] әсәрләрендә, кемнең кем булуы белән дә хисаплашмыйча, икейөзлеләрнең битлеген салдыра, патша түрәләрен чыбыркылый, шовинистларны камчылый, зур булмаган милләтләрне рәнҗетүче империалистларны фаш итә* (М. Хәсәнов. Сайланма хезмәтләр). *Беркөнне мин Розаның җитдилек битлеген салдырып карарга булдым* (М. Галиев. Тимә, яшәсен!).
Төрдәше: ачып бирү һ.б.

*БИТЛЕК* ❖ **БИТЛЕК АРТЫНА (АСТЫНА) ЯШЕРЕНҮ.** Үзен башка кеше итеп күрсәтү, чын йөзен яшерү. *Ерткыч казаклар битлеге артына яшеренгән Россия бәйсез дәүләт булган Себер ханлыгына каршы игълан ителмәгән сугыш башлый...* (Ф. Бәйрәмова. Күчем хан). *Л. Гыйльми иң нечкә битлек астына яшеренә. Ул үзен моңа кадәр халык дошманнары тарафыннан кыерсытылып килгән кеше итеп күрсәтә* (Р. Мостафин. Репрессияләнгән татар әдипләре).
Төрдәше: битлек астына керү; битлек кию (каплау); битлеккә керү; йөзен битлек белән каплау; йөзенә битлек кию.

**БИТЛЕК АСТЫНА КЕРҮ** *к.* битлек артына (астына) яшеренү. *– Ни булды, Христофор Яковлевич? – дип каршы алды аны Кремлев. Ул инде яңадан рәсми битлек астына кереп өлгергән иде* (Г. Әпсәләмов. Күк күкрәр).
Төрдәше: битлек артына (астына) яшеренү һ.б.

**БИТЛЕК КИЮ (КАПЛАУ)** *к.* битлек артына (астына) яшеренү. *Алар бит икәвесе дә – табигать баласы, чынлыкны сөяләр, битлек кигән ясалмалыкка һәм фальшька дошманнар* (А. Тимергалин. Ике сандык йакут). *Алтмышыңда да алтыда калырсың, / Тар түшеңә тимер-томыр тагарсың... / Әдәплекнең шома битлеген каплап, / Төп-төз басып йөрисең, кыек атлап...* (М. Мирза. Елганың аргы ягында).
Төрдәше: битлек артына (астына) яшеренү һ.б.

**БИТЛЕККӘ КЕРҮ** *к.* битлек артына (астына) яшеренү. *Тарихи яссылыктан караганда, Шәүлә һәрвакыт безнең яшәешебездә булды, төрле битлекләргә кереп, халыкның фидакарь уллары белән янәшәдә яшәде, җаен туры китереп, аларны чагып торды* (Р. Фәйзуллин. Илбагар уйлар).
Төрдәше: битлек артына (астына) яшеренү һ.б.

**БИТЛЕКНЕ САЛУ.** 1. Фикерен ачык рәвештә әйтеп бирү. *Менә шул вакытта гына битлеген салды сәрдәр* (В. Имамов. Казан дастаны). *Ул әле һаман басып тора икән. Мин-минлек битлеген салып ташлаган. Сөйкемле генә егет күренә* (Р. Мулланурова. Ялгыз каеннан да ялгыз...).
Төрдәше: ачып бирү һ.б.

2. Ясалмалыктан ваз кичү. *Игезәкләр, тормышыгызда кискен үзгәрешләр көтелә, битлекне салып, чын йөзегезне ачу вакыты җитте* («Заман сулышы» газ.). *Шулай итеп, урыс дәүләте үзенең битлеген салып ташлады һәм, Уралдан Тын океан буйларына кадәр җирләрне яулап алу өчен, беренче рәсми гаскәрен Себергә юллады...* (Ф. Бәйрәмова. Күчем хан).
Төрдәше: битлекне ташлау.

**БИТЛЕКНЕ ТАШЛАУ** *к.* битлекне салу. *Инде битлекне ташлап / Кычкырам: «Әй сез, һәммәгез, / Күземнән югалыгыз! / Беркем монда күренмәсен, / Ишекләрне ябыгыз»* (Р. Зәйдулла).
Төрдәше: битлекне салу 1, 2 һ.б.

*БИТНЕ* ❖ **БИТНЕ АККА, ТЕШНЕ КАРАГА БУЯУ.** Киресен, капма-каршысын эшләү. *Күңелдә туган хисләрне аңлатырга тырыштым, битне акка, тешне карага буядым* (Сөйләм).

**БИТНЕ КАЯ КУЯРГА БЕЛМӘҮ.** Оятка калу. *Кызчык исемен дә ялганлаган икән, болар барысы да ачыклангач, битен кая куярга белмәде* (Сөйләм).
Төрдәше: битен куяр җир тапмау.

*БИТСЕЗ* ❖ **БИТСЕЗ КЕШЕ.** Оятсыз, ертлач кеше. *Арада шундый, битсез кешеләр булыр дип, һич тә уйламаган идем* («Яңарыш» газ.).
Төрдәше: әрсез алабай һ.б.

*БИТТӘН* ❖ **БИТТӘН КАН КАЧУ**. Бик каты курку яки тирән дулкынланудан, авырудан йөзнең агаруы. *Аның саен киптем, аның саен / Каны качты сулган битемнең* (М. Җәлил). *Фәүзия ханымның алсу битеннән кан качты, йөзе әкрен-әкрен ак таплар белән каплана башлады* (Р. Юсупова. Күкләрдән иңгән язмыш).
Төрдәше: йөздән кан качу 1; йөздән нур качу.

**БИТТӘН КАН ТАМУ**. Таза, тулы канлы булу, сәламәтлекнең ташып торуы. *Һе, әйттең сүз, гөрнәдир кебек таза ул, чиертсәң, битеннән кан тамарга тора* (Сөйләм).
Төрдәше: алып кадәр һ.б.

**БИТТӘН УТ ЧЫГУ, БАШТАН КОТ ЧЫГУ.** Бик нык оялу һәм курку. *Баштарак оялу гына бар иде, аннан соң нәтиҗәсе ачыкланыр дип курка да башладым – биттән ут чыгып, башымнан котым чыкты минем* (Сөйләм).

*БИХИСАП* ❖ **БИХИСАП ЗУР.** Бик зур, гаять зур. *Әллә ычкынганмы баудан / Каф тавының җепләре? / Йә тишелгәнме Ходайның / Бихисап зур мендәре?* (Г. Тукай). *Алдыбызда бихисап зур ишек* (И. Сәләхов. Фаҗига).

*БИҺУШ* ❖ **БИҺУШ БУЛЫП ЙӨРҮ.** Һуштан язып гашыйк булып, яратып йөрү. *Женя бер татар кызын яратып, биһуш булып йөри иде* (Ә. Галиев. Һәр солдатның үз уе). *Мин дә Гөлбәдрия түтәйгә сабыйлыктан чыгар-чыкмас чагымда ук биһуш булып йөргән малай бит...* (Ш. Маннур. Чын сөю бармы?).

*БИЧАРАДАН* ❖ **БИЧАРАДАН НИ ЧАРА.** Авырлык белән, аптыраганнан гына. *Ләкин бу инде, бичарадан ни чара дигәндәй, бушка әлсерәп йөрү генә иде (Буш башактан нәрсә чыксын, Ходам!)* (Ә. Еники. Соңгы китап). *Үзенең урынлы-урынсыз әйтеп ташлаган ярым-йорты сүзләре белән репетиция вакытында ук эчебезне катырып бетергән Гаптери, тамашачылар алдына чыга башлагач, тәмам каушап, бичарадан ни чара дигәндәй, коеп куйган шалапайга әйләнде дә куйды* (Г. Шәрәфи. Тәфтиләү).

*БИЧУРА* ❖ **БИЧУРА ОЯСЫ.** Җыелмаган, тәртипсез өй турында. *Әтисе, фатирның бусагасыннан атлап, тирә-ягына күз генә салды да, «ничек яшисең син бу бичура оясында?» дип, малаена төбәлде* (Сөйләм).

*БИШ* ❖ **БИШ АЛДА.** Яхшырак. *Авылда, җир тырнап, ачлы-туклы яшәгәнең биш алда* (И. Гази. Онытылмас еллар).

**БИШ АРТЫК.** Күпкә яхшы, файдалы. – *«Китап – ни ул, биш артык ич менә бу»* (Дәрдмәнд). *Мондый хурлыкка калып, әтидән каргыш алганчы, үлүең биш артык* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**БИШ АТЛЫЙСЫН БЕР АТЛАУ.** Зур адымнар ясау; ашыгып, шатланып атлау. *Баскыч басмаларының биш атлыйсын бер атлап, өченче катка ашты, ашты гына да түгел, ашкына егет* (Г. Минский. Канәфер чәчәге). *Фәхри, озын аяклары белән биш атлыйсын бер атлап, вокзалга юнәлде* (Ш. Маннур. Муса).

**БИШ БАРМАГЫ КЕБЕК <БЕЛҮ; МӘГЪЛҮМ БУЛУ>.** Бик яхшы, төгәл белү, хәбәрдар булу. *Чөнки ул бөтен авылның яланнарын, тауларын, чокырларын үзенең биш бармагы кебек белә <...>* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар). *Мине авыл малайларыннан аерып куйган өстенлек – менә шул йолдыз тулы күк йөзен биш бармагым кебек белүем иде* (Х. Ширмән. Ерактагы йолдызым).

Төрдәше: су кебек белү; су кебек (күк) эчү; су урынына эчү; үзенең биш бармагы кебек белү; үзенең уч төбе кебек <итеп> өйрәнү.

**БИШ БАРМАГЫҢА ШӘМ УТЫРТЫП ЭЗЛӘСӘҢ ДӘ ТАБА АЛМАССЫҢ.** Табуы кыен булган, бик сирәк очрый торган нәрсә хакында. *Һәй, иптәш, биш бармагыңа шәм утыртып эзләсәң дә икенчесен таба алмассың* (Ю. Әминов).

Төрдәше: көндез <ике кулыңа> чыра (ут, шәм) яндырып (тотып) эзләсәң дә; көндез чыра (шәм) яндырып (фонарь белән) эзләсә дә.

**БИШ БАРМАК КЕБЕК КИЛҮ.** «Һәр яктан да камил һәм төзек» мәгънәсендә. – *Егет менә дигән, бишбармак кебек, һәр ягы килгән* (А. Гыйләҗев. Өч тәгәрмәчле арба).

**БИШ БАРМАКНЫҢ БИШЕСЕ БИШ ТӨРЛЕ <БУЛУ>.** Бөтен кеше дә бертөрле булмауга ишарә. *Әлбәттә, кулдагы биш бармакның бишесе биш төрле булган кебек, бөтен кеше дә бер омтылыш белән яшәми* («Ватаным Татарстан» газ.).

**БИШ БАРМАКНЫҢ КАЙСЫН ТЕШЛӘСӘҢ (КИССӘҢ) ДӘ <БИШЕСЕ >АВЫРТУ.** «Ата-аналар өчен барлык балалары да бертигез якын була» мәгънәсендә. *Шулвакыт әти мине чеметеп алды да: «Сез биш бертуган, кулдагы биш бармакның берсен генә киссәң дә, бишесе авырта», – диде* («Әлмәт таңнары» газ.).

**БИШ БАРЫП, БИШ КАЙТУ.** Берәр җиргә бик еш баргалап йөрү. *Туйлы йортка биш барып, биш кайтты инде – ике арада тик килән сарып йөри* (М. Галиев. Нигез).

Төрдәше: бусага таптау.

**БИШ БӘЯ.** Бәясен нык арттыру. *Алар мулла белән мәзиннән һәм башка бай кешеләрдән биш бәясе белән икмәк сатып алып, ерып чыккысыз бурычка баттылар* (М. Галәү. Болганчык еллар). *Биш бәягә арттырып саткан марҗа*

*түти – Мария – ул чагында кешеләрне киендергән, ә хәзер кем киендерә, Баязит?* (Н. Гыйматдинова. Хыял).

**БИШ БӘЯГӘ САТУ.** Бик нык арттырып сату. *Җитмәсә тагы зарланалар: «Сәүдәләрнең рәте-чираты бетте, чит ил сәүдәгәрләре килеп басты, кызыл малны гына түгел, үз малыбызны үзебезгә биш бәягә сата башладылар»* (Ә. Камал. Олы Әкбәрнең кече Әсгате).

Төрдәше: биш бәягә төшү (төшерү).

**БИШ БӘЯГӘ ТӨШҮ (ТӨШЕРҮ).** Әйбер бәясе биш мәртәбәгә арту, бик нык кыйммәтләнү. *Капитал, милли валютаның очсызлануы китергән югалтулар, тышкы кредитларга юл ябылу, доллар белән исәпләгәндә нефть һәм газ сатудан кергән керемнең кимүе, импортны алыштырабыз дип биш бәясенә төшереп җитештерелгән җиһазлар, башкалар керә* («Ватаным Татарстан» газ.).

Төрдәше: биш бәягә сату.

**БИШ БИЛЛЕ БИШМӘТ (КАЗАКИ; КАМЗУЛ; ТУН).** Бил турысы биш җирдән тарайтылып тегелгән татар киеме. *Намаҗан карт, биш билле кара тун, камалы бүрек, кыска кунычлы киез ката киеп, күршесендәге мәчеттән кайтып килә иде* (Г. Ибраһимов). *Биш билле кара камзулы «менә мин нинди зыялы әфәндене затлыйм» дип мактана шикелле* (С. Поварисов. Пәйгамбәр таңы).

**БИШ БИРӘСЕМ ЮК, АЛТЫ АЛАСЫМ ЮК** *к.* алты аласым юк, биш бирәсем юк. *Аллага шөкер, барысы да җитешле, биш бирәсем юк, алты аласым юк* (Сөйләм).

Төрдәше: алты аласым юк, биш бирәсем юк.

**БИШ БИТӘР.** Күп мәртәбә көчлерәк, ныграк. *[Мөгълифә] Бу йөзе кара Әнвәр тагын аңа караганда да биш битәр дурак* (Г. Камал. Уйнаш). *[Гандәлиф] Бик олы начальниктыр инде, минем Ибраһимым аннан биш битәр начальник* (А. Гыйләҗев).

**БИШ БЫЛТЫР.** Күптән, әллә кайчан. *Биш былтыр бит инде, / Язган хатың / Бишалтыга тулмый торгандыр* (Х. Туфан). *Иллә мәгәр моны синең ишеләргә биш былтыр ук төшенергә вакыт* (В. Имамов. Сөләйман солтан).

**БИШ ВАКЫТ ҮТӘҮ** *дини.* Биш вакыт намаз уку. *Дингә мөгаләмәбез бик яхшы булса да, элегрәк, яшь чакларда намазны биш вакыт үти алмый идек, инде байтак еллар биш вакытын калдырмыйбыз, бергәдәп укыйбыз* (minzifahusnetdinova.wordpress.com).

**БИШ ЙӨРӘК БУЛУ.** Бер үк вакытта берничә кызга гашыйк булучы турында. *Белмәдеме егетнең берьюлы өч кыз белән йөри алырлык биш йөрәге барлыгын* (Ф. Яхин. Сөйкемле сөяк).

**БИШ КАТ ТИР ЧЫГУ.** Бик нык тирләү. *Аннан ахирәт ханымнар, гөжләп торган дәү корсаклы самавыр янына утырып, бик озаклап, биш кат тирләр чыкканчы чәй эчәләр* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**БИШ КАШЫК КҮТӘРЕП БАРМЫЙСЫҢ ИНДЕ КЕШЕГӘ, <БЕР КАШЫК КҮТӘРЕП БАРАСЫҢ>.** Берәве кунакка чакырмаганда үпкәләп әйтелә (ягъни сараннар, бер кеше өчен ризыкларын кызганганнар). – *Юк, үзең генә бар инде, мине чакырмады ул, югыйсә кешегә биш кашык күтәреп бармыйсың инде...* (Сөйләм).

**БИШ КӨНЛЕК ДӨНЬЯ.** «Шатлык-кайгыларга артык бирелергә ярамый, гомер бик кыска» мәгънәсендә. *Бу дөнья биш көнлек, ун көн булмастыр, / Бу таҗ, солтанат – барчасы буштыр* (Сәгъди. Таһир – Зөһрә).

**БИШ КУЛЛАП.** Зур теләк белән, шатланып. – *Моннан соң мине борчыйсы булмагыз, ә син, килен, бу шалманны ныграк тот, ләкин дә кулыңнан ычкындырасы булма, мондый егетне теләсә нинди тол хатын биш куллап үзенә кабул итәчәк, – дип сөйләнә-сөйләнә чыгып китте* (М. Мәһдиев. Ачы тәҗрибә авазы). – *Ике куллап кына түгел, биш куллап алам!* (Җ. Дәрзаман. Җир авазы).

**БИШ КҮЗ БЕЛӘН КӨТҮ.** Түземсезлек белән көтү. *Шул ук көнне авылга, «туганнарда ял итеп килергә» дип, бәхетле юлга чыктык. Безне биш күз белән көткәннәр икән* (Ф. Яхин. «Интехбанка» ялкыны). *[Рәзинә] Самат, авыл биш күз белән көтә бит сезне!* (Х. Ширмән. Авылым учагы).

**БИШ МУЛЛАНЫ БЕР КУНЫЧКА КЫСТЫРУ.** Белемле, зиһенле кеше турында. – *Ул синең*

*биш мулланы бер кунычка кыстыра* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: алтын акыл һ.б.

**БИШ ТАБЫН ХАТЫННАР УЗДЫРУ.** Хатыннар өчен биш өстәл тутырып мәҗлес әзерләү. *[Гөлҗиһан] «Абыстай берсекөнгә биш табын гына хатыннар уздыра, бүген үк хәзерләнергә килсен» дип әйтте диген* (Г. Камал. Банкрот).

**БИШ ТАМАГЫМ ЮК.** «Ялгызым яшим, ничек тә бер тамагымны туйдырырмын» мәгънәсендә. *Минем өчен бер дә борчыласы юк, тамагым бер генә, биш тамагым юк* (Сөйләм).

**БИШ ТИЕН.** Дуңгызның борыны. *– Борынына җиппәр, биш тиененә! – ди. Кыйный торгач, нидер булды, дуңгыз кинәт чинап җибәрде дә авып та төште* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

**БИШ ҮЛЧӘП БЕР КИСҮ.** Акыл белән, уйлап эшләү. *Тукта, ашыктырма, ул биш үлчәп бер кисәргә күнеккән* (Сөйләм).

Төрдәше: акыл аша уздыру һ.б.

**БИШ ЧЫКТЫ, БИШ КЕРДЕ.** Бик күп мәртәбә кереп-чыгып йөрү. *Гыйлфан капка төбенә биш чыкты, биш керде* (М. Мәһдиев. Мәңгелек яз).

**БИШ ЯДӘЧ ОТКАН КЕШЕ.** Уңышка ирешә, теләгәне кулына керә торган. *[Сәфәргали] Мин, ханым әфәнде, биш ядәч откан кеше* (К. Тинчурин. Йосыф белән Зөләйха).

*БИШЕ* ❖ **БИШЕ БЕЛӘН.** Бик нык арттырып. *«Тукталe, бише белән алырмын әле мин үземә тиешлесен!» дип уйлады ул күңеленнән, ханга янап* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур). *Сөмбел аңа бөтен азатлыктан да бише белән татлырак төн бүләк итте* (Ә. Гаффар. Энә күзе).

Төрдәше: йөзе белән кайтару.

**БИШЕ БЕЛӘН КАЙТАРУ.** Бишләтә, биш мәртәбә күбрәк, зуррак итеп. *[Рамай] Барыбер бирерсең. Бише белән кайтарырбыз* (Т. Гыйззәт. Чаткылар). *«Тимерхан абзый, ун сум! Түләрмен! Бише белән кайтарырмын!»* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: йөзе белән кайтару.

*БИШЕК* ❖ **БИШЕК КОШЫ.** Имчәк баласы, бәби. *Мин, бүген бишек кошы, әмма иртәгә бабалары-әтиләре Кама автогигантында машина ясаячак бу кешеләр турында, аларның доктор апалары Зәйтүнә турында очраклы гына сүз катмадым* (Д. Зөбәерова. Әманәт).

**БИШЕК ТАШЛАУ.** Балигъ булу. *Һәм бик тәмле итеп уйлый идем, / Кайчан улым бишек ташлар дип...* (Ә. Давыдов). *– Син, энем, бишек ташлаган булсаң да, бала-чага кебек, әллә ниләр уйлап йөрисең* (Р. Кәрами. Кая чабасың, гомер юртагы?).

**БИШЕК ТУЕ.** Бәбиләрнең туган көн мәҗлесләрен үткәрү. *Динәхмәт мирзачыкның бишек туе әнә шулай кан-мәет белән тәмамланган иде* (Р. Батулла. Сөембикә). *Аннан кеше тормышында дүрт зур туй булырга тиеш дип санийбыз. Аның беренчесе – бишек туе. Балага исем кушу, бәбинең дөньяга аваз салуын каршылау көне* (Р. Гыйлемханов һ.б. Истә калганнар).

**БИШЕК ФӘРЕШТӘЛӘРЕ.** Бәбилектә үлгән сабыйлар. *– Әй, шөкер ит! – дип күтәреп алдылар Мәрьям-бикәне ахирәтләре. – Урыннары оҗмахта булсын бишек фәрештәләренең* (А. Хәлим. Читтә).

**БИШЕК ЭЧЕНДӘ.** Дөньяны күрмәгән, бернинди авырлык кичермәгән кеше турында. *Өченче дистәгә якынлашып килсә дә, ул үзен бишек эчендә утырган бала кебек тота иде* (Сөйләм).

*БИШЕКНЕКЕ* ❖ **БИШЕКНЕКЕ БИШ ТӨРЛЕ.** Бик күп төрле үзгәрүчән булу. *– Бишекнеке генә биш төрле була ул, сиңа үсәргә вакыт инде* (Сөйләм).

Төрдәше: бишектәге <бала> бишкә төрләнә.

*БИШЕКТӘ* ❖ **БИШЕКТӘ АЯК БАРМАКЛАРЫН ИМЕП ЯТУ.** Бәби булган чакларга ишарә. *Бүген бала-чага атасына әйләнеп картаеп баручыларның бишектә аяк бармакларын имеп яткан чакларын белә бит әле ул* (И. Гази. Тургай картаямы икән?).

*БИШЕКТӘГЕ* ❖ **БИШЕКТӘГЕ <БАЛА> БИШКӘ ТӨРЛӘНҮ** *к.* бишекнеке биш төрле. *Гаҗәп түгел, бишектәге бишкә төрләнә, дигәннәр, һәм мин моны үзем дә тоя идем* (Ә. Еники. Соңгы китап). *– Ярый ла җылытып җибәрсә! Чәчми торсаң, соңгарак калуың бар... Бишектәге бишкә төрләнә, диләр, нәкъ шул инде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: бишекнеке биш төрле.

*БИШЕКТӘН* ❖ **БИШЕКТӘН АЛЫП (БИРЛЕ).** Бик кечкенәдән. *Аның бишектән алып «җитү кыз» булгангача үткәргән гомеренең тарихы күздән кичерелсә, һәр эше, һәр хәрәкәте авылларча булганлыгы ачык күренәдер* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). *Бәлки, бишектән алып үскән җирем, эчкән суым, йөргән сукмакларым шушында калганга күрәдер* (Ә. Еники. Соңгы китап).

**БИШЕКТӘН ЛӘХЕТКӘЧӘ (ЛӘХЕТКӘ КАДӘР).** Гомер буена, гомере беткәнче. *Бишектән алып ләхеткә кадәр гыйлемне өйрән* (Мәкаль). *Әлбәттә, заманның ирекле, шифалы сулышы аз гына иссә дә, ислам аша «Бишектән ләхеткәчә гыйлем ал!», «Кытайга барып булса да гыйлем ал!» гыйбарәләре каннарына сеңгән төрки халык балаларын тергезеп җибәрде төсле* («Казан утлары» ж.).

*БИШЕНЧЕ* ❖ **БИШЕНЧЕ КӨПЧӘК (ТӘГӘРМӘЧ)** *к.* арбаның бишенче көпчәге (тәгәрмәче). *Йөрисең арбага бишенче көпчәк булып* (Б. Камалов). *Югыйсә умартачылык турында закон чыгарсалар да, астына «Рәсәй законына каршы килми» дип язып куялар. Нәрсәгә мондый бишенче тәгәрмәч?* (Р. Зәйдулла. Авызлар йомылганда).

Төрдәше: арбаның бишенче көпчәге (тәгәрмәче) һ.б.

*БИШЕСЕ* ❖ **БИШЕСЕ БЕР ЙОДРЫККА СЫЮ.** Үзенең өстенлеген күрсәтү, берүзе аңа каршы чыкканнарны җиңәчәгенә ишарә итү. *Күргән сезнең ишеләрне! Бишегез бер йодрыкка сыя, – дип җибәрәм мин дә, әллә тешләнгән телдән, әллә кабарган иреннән саркыган канны төкерә-төкерә* (Р. Төхфәтуллин. Җиләкле аланнар).

*БИШКӘ* ❖ **БИШКӘ АЛЫП БЕРГӘ САТУ.** Алдану, кыйммәткә алып, арзанга сату турында. *Бишкә алып бергә сату* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

Төрдәше: агач атка (аргамакка) атлану (атланып калу) һ.б.

**БИШКӘ БӨГЕЛҮ.** Башын җиргә кадәр иеп, итагатьлелек күрсәтү. *Бигрәк тә әтием аның алдында бишкә бөгелә иде* (Ә. Еники. Йөрәк сере). *– Мин иртәгә тагын белешермен, – диде елгыр би, бикә алдында бишкә бөгелеп* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).

**БИШКӘ БӨКЛӘҮ (БӨГҮ).** 1. *к.* арка бөгү (бөгеп тору). *Икенчеләр – корбаннар – билен бишкә бөгә, тир түгеп, хуҗасын баета* (Ә. Хәсәнов. Бәхет кайда оя кора). *Татарда гына була торган күндәмлелек белән, билләрен бишкә бөгеп, түбәнчелек белән сәламнәрен биргәч, карт белән карчык, бер-берен бүлә-бүлә, Рәсәй президентына моң-зарларын белдерергә тотындылар* (Ф. Имамов. Балавыз сыннар караганда).

Төрдәше: арка бөгү (бөгеп тору) һ.б.

2. Теләгәнчә үз ихтыярына буйсындыру. *Бу, билгеле, әтисенең җисмани көче сезнең ише юеш борыннарны бишкә бөгәрлек әле дип мактану өчен иде* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).

Төрдәше: авызлык кидерү һ.б.

**БИШКӘ БӨКРӘЮ.** Бик нык бөгелү. *Шулай бишкә бөкрәеп кайтып киләм* (Х. Сарьян).

**БИШКӘ ӨЗЕЛҮ** *к.* авызга җаны килгәнче (чыкканчы) тырышу. *Кирәк икән, без бишкә өзеләбез, илебез, дәүләтебез өчен барын бирәбез, кан да кызганмыйбыз!* (А. Гыйләҗев. Берәү).

Төрдәше: авызга җаны килгәнче (чыкканчы) тырышу һ.б.

**БИШКӘ ТОРЫРЛЫК.** Бик яхшы, (матур, көчле һ.б.). *Атласының берсе-берсе бишкә торырлык дүрт кыз туганы үзләренең барлыкларын соңрак белдерделәр* (Р. Габделхакова. Нишләттегез Гөлкәйне?!). *Алар, кем әйтмешли, бишкә торырлык* («Ватаным Татарстан» газ.).

**БИШКӘ ТӨРЛӘНҮ.** Бик нык үзгәрү. *Бер секунд эчендә бишкә төрләнде карчык: әле елмайды, әле сагышланды, әле уйчанланды...* (Н. Гыйматдинова. Китәм, димә...). *Бишекләре бишкә төрләндерсә, йөзгә төрләндерде дөньясы* (З. Мансуров. Игезәкләр).

**БИШКӘ ЯРЫЛУ.** Эшнең күп булуы, берьюлы берничә эшне алып башкару. *Бишкә ярылырбыз, төннәр йокламабыз, шулай да Аланбашлардан уздырмыйча тынмабыз* (Г. Бәширов. Намус). *Монда бер Шәңгәрәйгә бишкә ярылырга, берьюлы биш җиргә чабарга туры килә* (И. Гази).

*БИШКУЛЛАП* ❖ **БИШКУЛЛАП АЛУ (КАБУЛ ИТҮ; РИЗА БУЛУ).** Бик теләп, яратып. *Казан педагогия институтына читтән торып*

*укырга керде. Аны бишкуллап алдылар* (А. Гыйләҗев. Әтәч менгән читәнгә). *Нурулла бу тәкъдимгә бишкуллап риза иде* (Н. Гыйматдинова. Нурулла).

*БИШМӘТ* ❖ **БИШМӘТ ТИШЕК ШУЛ.** Фәкыйрьлек билгесе буларак күзаллана. – *Гыйшыгын гыйшык та бит, бишмәт тишек шул. Менә кай ягы кәкре килә бит, чәнчелеп киткере* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

*БИШМӘТЕ* ❖ **БИШМӘТЕ ТАР БУЛСА ДА КҮҢЕЛЕ КИҢ.** «Берәүнең, фәкыйрь булса да, кешелеге, юмартлыгы җитәрлек» мәгънәсендә. – *И, Кәшифәттәй, рәхәт тә инде синең белән... – Бишмәтем тар булса да, күңелем киң минем* («Казан утлары» ж.).

*БИШНЕ* ❖ **БИШНЕ БИРҮ.** 1. Кул бирешеп исәнләшү. *Һаман шулай йомарланган хәлдә булса – күрешүче, мә, дип бишне биргәндә?!* (З. Мансуров. Кылдан нечкә, кылычтан үткен). *– Бир бишне. – Алар егетләрчә кул бирештеләр* (М. Насыйбуллин).

2. Ризалык билгесе итеп кул кысышу. *Григорович, килешүен белдереп, Рудольфның тагын бер кат кулын кысты: – Бир бишне, Рудик...* (Р. Вәли. Шөһрәт).

*БИШТӘН* ❖ **БИШТӘН ЙОМАРЛАУ.** 1. Акчаны биш бармак эченә йомарлап, сак тоту. *Булган акчаны биштән йомарлаганда, ничектер тынычрак иде* (Сөйләм).

2. Бармакларны йомарлап, кәҗә тоягы ишарәте ясау. *Әшли-әшли сөялләнеп беткән кулын биштән йомарлап, «кукиш» күрсәтте дә, ишарәсе үтемлерәк булсын өчен: – Әшляйбез аны! – дип, чатнатып җавап бирде* (Ф. Имамов. Авылча «заложник»).

**БИШТӘН ТӨР<ЕЛ>ГӘН.** Биш бармак йомарланып, йодрык ясалу. *[Исмәгыйль] Биштән төрелгәнне иснисегез килмәсә, миңа бирегез Галиябануны!* (М. Фәйзи. Галиябану). *Аптырап торган әнисенең сораулы карашына Майшәкәр: – Теге бәдбәхет йөргән нәрсәсенә китәргә план корып йөри, тотсын менә биштән төргәнне ! – дип ут чәчеп, урамдагы таксига чыгып йөгерде* (И. Хәйруллин. Алай түгел, болай ул...).

**БИШТӘН ҮТКӘН, БИШЕКТӘН ЧЫККАН.** «Биш яше тулган инде, акыл өйрәтәсе юк» мәгънәсендә. – *Җиденче яше китте... – Ярар. Биштән үткән, бишектән чыккан икән...* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!). – *Каламы, юкмы, аның үз эше. Биштән үткән, бишектән чыккан, диләрме әле* (Ә. Хәсәнов. Әнис алмалар).

*БИШТӘР* ❖ **БИШТӘР ТАГЫП КАЙТУ.** Кунакка баргач, үзең дә кунакка чакырырга бурычлы булып кайту. *Кичә кунакка барып, биштәр тагып кайттым әле* (Сөйләм).

*БИЯЛӘЙ* ❖ **БИЯЛӘЙ АВЫЗ** *к.* алап авыз 2. Авызында сер тормаган кеше. – *Балта сораганда шөшле тоттырма, җәме, бияләй авыз, – дип сукрануында булды Дәүҗия, – симәнәң кая дип сорыйлар синнән...* (М. Әмирханов. Мөкәррәмә). *– Их, бияләй авызыңа чөй кагасыңмы соң?* (Н. Гыйматдинова. Шырагай).

Төрдәше: алап авыз 2 һ.б.

**БИЯЛӘЙ АРКЫЛЫ (АША) БАРМАК ЯНАУ.** Астан янау, гайрәтләнү; эчтән ачу йөртү. – *«Их, бер аулакта очратсам, бирер идем кирәгеңне», – дип, бияләй аркылы бармак янады* (Сөйләм).

Төрдәше: бияләй эченнән йодрык (кукиш) күрсәтү (селкү).

**БИЯЛӘЙ ЭЧЕНДӘ БАРМАК КЫЙМЫЛДАГАННЫ ДА СИЗҮ.** Үтә сизгер булу. *Бияләй эчендә бармак кыймылдатуын да сизәләр* (Г. Насрый). *Һай, хәйләкәр дә була бу картлар! Бияләй эчендә бармак кыймылдатканын да сизәләр* (Г. Әпсәләмов).

**БИЯЛӘЙ ЭЧЕНДӘ БАРМАК УЙНАТУ** *к.* бармак уйнату. – *Бу тагын нинди бияләй эчендә бармак уйнату инде?* (М. Әмирханов. Ир-Мамай).

Төрдәше: бармак уйнату.

**БИЯЛӘЙ ЭЧЕНДӘ УТ УЙНАТУ.** Эшне астыртын гына бик кызу йөртү. *Бияләй эчендә ут уйната бу яшьләр* (Г. Зәйнашева).

**БИЯЛӘЙ ЭЧЕННӘН ЙОДРЫК (КУКИШ) КҮРСӘТҮ (СЕЛКҮ)** *к.* бияләй аркылы (аша) бармак янау. *Син никадәр бияләй эченнән кукиш күрсәтсәң дә, һичнәрсә эшли алмассың* (Ш. Мөхәммәдев). – *Бияләй эченнән йодрык селкергә барыгыз да мачтыр* (А. Әхмәтгалиева. Синең өчен яшим).

Төрдәше: бияләй аркылы (аша) бармак янау.

*БОДАЕН* ❖ **БОДАЕН АЛ ДА САЛАМЫНА УТ ТӨРТ.** 1. *к.* башын ал да саламына ут төрт 1. *«Бодаен ал да саламына ут төрт» дип яшәгән кешедән дә әшәкесе юк, дип әйтә иде минем бабай* (Сөйләм).
Төрдәше: башын ал да саламына ут төрт 1.

2. *к.* башын ал да саламына ут төрт 2. *«Бодаен ал да саламына ут төрт» дип уйласаң, ялгышуың бар – саламның да кирәге чыга* (Сөйләм).
Төрдәше: башын ал да саламына ут төрт 2.

*БОДАЙ* ❖ **БОДАЙ БЕЛӘН КИБӘКНЕ БУТАУ.** Әйбер танымау; кемнең кем икәнен, яхшыдан начарны аера алмау. *Ә ул бодай белән кибәкне бергә бутап гомер уздырды* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

**БОДАЙ БОХАРАДАН КИЛМӘС.** «Нәрсәгәдер, кемгәдер өметләнеп яшәүнең нәтиҗәсе яхшы булмаска мөмкин» мәгънәсендә. *Яшәү дәвам итәр... Ә барыбер Бохарадан килмәс бодаең* (Н. Гамбәр).

**БОДАЙ КҮРСӘТЕП, АРПА САТУ (УЧЛАТУ)** 1. *к.* авыздан кош очыру 1. *Бодай күрсәтеп, арпа саткан* (К. Насыйри. Кабуснамә).
Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

2. Яхшы исемле саналып, ялган хәбәр, тәгълимат тарату. *Син шуңа ышанасыңмы, ташла ул даруларны: бодай күрсәтеп, арпа сатып йөри бит ул* (Сөйләм).

**БОДАЙ СУКТЫРЫП КИБӘН ӨЮ.** Гыйшык тоту уены белән артык мавыгу. *Кыз, Рәхимҗан кебекләрдән бодай суктырып, кибән өйгән, сөю өлкәсендә тәҗрибә туплаган кемсә иде* (Н. Гыйматдинова).

*БОДАЙДАН* ❖ **БОДАЙДАН БОРАЙНЫ АЕРА БЕЛМӘҮ (АЛМАУ)** *к.* авыз суы кипмәгән. *Бодайны борайдан аера алмаган түтәй ике ел Казанга укучылар алып барды – беренче урын кайта да беренче урын кайта* (matbugat.ru).
Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

*БОДАЙНЫ* ❖ **БОДАЙНЫ БАСУДА КИЛЕШ АШАУ.** Алдан бурычка алып ашау. *Безгә былтыр бодайны басуда килеш ашарга туры килде* (Сөйләм).

**БОДАЙНЫ БЕЗДӘ ЧҮПЛИ, КҮКӘЙНЕ КҮРШЕДӘ САЛА.** Йорт тотмас, йорт җанлы булмаган кеше хакында. *Барлас йортка бик игътибар бирми ул: бодайны бездә чүпли, күкәйне күршедә сала* (Сөйләм).

*БОЕК* ❖ **БОЕК КҮҢЕЛ<ЛЕ>.** 1. Борчулы; бастырылган халәттә булу; күңелсезлек булачагын тою. *Шулай уйлады Наиләнең боек күңеле, шулай уйлап, куркынычлы очрашуга әзерләнеп кайтты* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Институт коридорында кара-каршы очрашсалар, Заһидәне алыштырып куйганнармыни – күрсә дә күрмәмешкә сабышыр, сүз катсаң, мәңге җавап кайтармас. Боек күңелле, сәер табигатьле бер кызга әйләнә дә куя* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).
Төрдәше: йөрәккә боз булып утыру; йөрәккә боз укмашу; йөрәккә таш булып утыру; йөрәккә таш яткандай <булу>.

2. *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. *Җаның җырлый яннарыңда булсам / Боек күңелең китә дәртләнеп* (К. Фатыхова-Бәдртдинова). *Син минем боек күңелемне күтәргәндәй иттең...* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!).
Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

*БОЕРГАН* ❖ **БОЕРГАН БУЛСА.** Тәкъдирдә язылган булса, очраклы комачаулар аяк чалмаса. *– Юк, тайпылмас, боерган булса, андый бала түгел...* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Бригадирлыгын пенсиягә чыкккач ташлар инде, боерган булса, инде менә шөкер, ашказаны боргычлый башлагач, бөтенләйгә ташлады* (Р. Низамиев. Беренче мунча).
Төрдәше: Алла бирсә һ.б.

*БОЕРМАК* ❖ **БОЕРМАК СЕЗДӘН, ЙӨГЕРМӘК БЕЗДӘН.** «Боерыгыз гына, хезмәт күрсәтергә әзербез» мәгънәсендә. *Халык та үзгәрде хәзер. «Боермак сездән, йөгермәк бездән», – дип кенә тормый* (М. Хәсәнов. Саф җилләр). *[Низами] Тырышырмын. Йөгердем. Боермак сездән, йөгермәк бездән!..* (Х. Вахит. Карлыгач канат кага).

*БОЕРЫК* ❖ **БОЕРЫК ТА ЙОДРЫК.** Үтәргә кирәк нәрсәне сүгү, кычкыру, мәҗбүр итү юлы белән үтәтү. *– Мәскәүлеләрнең гел мәскәүчә инде. Боерык та йодрык* (Н. Гыйматдинова. Ачкыч).

*БОЖРАЛАП* ❖ **БОЖРАЛАП АЛУ** *к.* әйләндереп алу. *Мәйданның гүләве көчәя барды: «Бәйлә үзләрен баганага! Бир мөртәткә!» Багананы халык божралап алды* (Ш. Шәйдуллин. Бүре өнендә). *Иделнең текә ярында буровой вышкалары. Казан йорты ягында – маяк, шәһәрне яртылаш божралап алган яр бу култыксалары* (М. Зарипов. Әкият булып күтәрелә Казан).
Төрдәше: әйләндереп алу һ.б.

*БОЖЫР* ❖ **БОЖЫР ӨТҮ** *диал.* Сасы ис чыгару. *Шәйхи борынын кысып тотты да: «Кайдадыр божыр өтәләр бугай», – дип куйды* (Сөйләм).

*БОЗ* ❖ **БОЗ АСТЫНДА ДУЛКЫН.** Тышкы яктан тын булган нәрсәнең эчендә хәрәкәт бару. *Сез монда яңа кеше әле, шуңа күрә боз астындагы дулкыннарны күреп бетермисез* (Г. Әпсәләмов). *Әхмәт Таҗетдин Рахманколыйның «Боз астында дулкын», «Упкын», Үлмәс ханым» исемендәге өч серияле пьесалары куелганда, театрны саклар өчен, атлы милиционерлар чакыра торган иделәр* (Н. Юзиев. Музалар туганлыгы).

**БОЗ БЕЛӘН ТОЗ КЕБЕК БУЛУ.** Аралары тату булмау. *Әнә шулай, уйламаганда-көтмәгәндә, ике сердәш боз белән тоз кебек булдылар* (Н. Гыйматдинова. Җәза).
Төрдәше: алар арасына кара күләгә яту һ.б.

**БОЗ БӨРКӘНГӘН КӨННӘР.** Боз яки бозлы кар яву турында. *Кара көз җиттеме, боз бөркәнгән көннәр дә булгалый иде* (Сөйләм).

**БОЗ ЖАН<ЛЫ>.** Хиссез, салкын кеше турында. *Боз җанлының йөрәге туң. Син – айсберг. Боз тавыдай салкын булганга түгел, куркыныч өлешең яшерелгән булганга* (Ш. Галиев. Илһамым-мәхәббәтем). *Бөтенләй үк боз җанлы түгел бит инде ул* (Р. Зәйдулла. Дару).
Төрдәше: боз йөрәк<ле>; бозлы йөрәк.

**БОЗ ЙӨРӘК<ЛЕ>**. Мәрхәмәтсез; хисләргә ярлы, салкын табигатьле кеше. *Ул кызны боз йөрәкле диделәр* (И. Гази). *Сөю ул шундый серле, тылсымлы, / Боз йөрәкне дә үбеп эретә* (М. Җәлил. Кар кызы). *Ләкин боз йөрәкле төньяк патшасының күңелен кайнар күз яшьләре йомшарта алмаган* (Г. Сабитов. Сопкаларда шәфәкъ шәүләсе).
Төрдәше: боз җан<лы> һ.б.

**БОЗ КАНЛЫ.** Үзен һәрвакыт кулда тота алган, һәрнәрсәне төптән уйлап эшли торган кеше. *Кайда боз канлы мәгъруур кар кызы?/ Акты сөйгәне куенында эреп* (М. Җәлил. Кар кызы).

**БОЗ КИПТЕРҮ.** Берни эшләмичә, тик яту. *[Батырҗан] Өйдәләр, бабай, өйдәләр, мич башында боз киптерәләр* (Т. Гыйззәт). *Пожарник – боз киптереп ятучы, имеш, һе... Тиле авыздан тиле сүз шул үзе була инде* (Г. Әпсәләмов. Газинур).
Төрдәше: авыз белән чебен аулау һ.б.

**БОЗ КУЗГАЛУ** *күч.* Хәрәкәтсез яткан нәрсә (документ, эш һ.б) эшләнә башлау. *Бәрәкалла, сәнгатьнең бу жанры турында да җитди уйлана башлаганнар, боз кузгала башлады, ахры, дигән уй килде башка* (Н. Гамбәр. Яшәү тамыры). *Доктор, Сөмбелне кереп карагач, боз кузгалды дигәндәй, елмаеп куйды* (З. Кадыйрова. Сагынырсың – мин булмам).

**БОЗ ӨСТЕНӘ ТАШЛАНГАН БАЛЫК КЕБЕК БӘРГӘЛӘНҮ.** Килеп туган проблеманы хәл итү өчен, башта фикер туплый алмыйча тору, ары-бире сугылу. – *Нигә безнең күрше боз өстенә ташланган балык кебек бәргәләнә, берәр кайгысы бармы югыйсә?* (Сөйләм).
Төрдәше: бозга ташланган балык кебек чәбәләнү.

**БОЗ САЛКЫНЫ.** Салкын мөнәсәбәт. *Әлбәттә, ул мине ярата һәм кызгана, әмма шул ук вакытта аңардан боз салкыны бөркелә иде* (Н. Гыйматдинова. Фәрештәләр). *Битенә, киемнәренә куе кызыл таплар чәчрәгән, күзләрендә – боз салкыны, ә иреннәрендә – татлы елмаю* (М. Кәбиров. Әҗәл җыры).

**БОЗ ЭРЕТҮ.** Булган каршылыкларны, салкын мөнәсәбәтләрне һ.б.ны бетерү. *Ихлас әйткән бер җылы сүз, кояш нуры кебек, күңелдәге бозны эретә* (А. Тимергалин. Таш алиһә). *Дуамалрак булса да, Никита әфәнде СССРдагы бозларны эретә башлады кебек* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).

**БОЗ ЭРҮ.** Булган каршылыклар, салкын мөнәсәбәтләр һ.б. бетү. *Таймас күңелендәге соңгы бозларның эреп, үзен җылы дулкын күтәреп алуын тойды* (А. Тимергалин. Таш алиһә). *Туганы белән күрешкәч, әз генә күңел бозы эреп киттеме әллә?! Картайгач йомшарыр әле дип,*

*баштарак хатыны өметләнгән иде, әмма юк, боз эремәде* (Р. Зәйдулла. Мылтык).

**БОЗ ЯУГАН КӨНДӘ ТУГАН.** Чәчәк авыруыннан бик нык шадра калган кеше турында. *Хастаханәдән чыкканда, аның йөзе боз яуган көндә туган кебек үзгәргән иде* (Сөйләм).
Төрдәше: битенә боз яуган һ.б.

*БОЗАУ* ❖ **БОЗАУ АРТЫ БЕЛӘН АГАЧКА (КИРТӘГӘ) МЕНГӘНДӘ** *к.* абага чәчәк аткач (атканда). *Бозау арты белән киртәгә менгәндә* (К. Насыйри. Мәкаль һәм әйтемнәр).
Төрдәше: абага чәчәк аткач (атканда) һ.б.

**БОЗАУ БАШ.** Булдыксыз кеше турында. *[Искәндәр] Ул бозау башларның эч серләрен белергә кирәк* (К. Тинчурин. Американ).
Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**БОЗАУ БӘЯСЕ.** Арзан бәя булуга ишарә. *[Ханнан] Сыер дуласа, аттан уза, диләр. [Самига] Сыерны да уза алмаган ат бозау бәясе дә тормый* (Ю. Әминов. Умырзая чәчәкләре).
Төрдәше: башы-тоягы бер тиен һ.б.

**БОЗАУ БУЛУ.** Йомшак холыклы, ихтыярсыз кеше хакында. *Бер сүз әйтми елмайгалап йөргәч, / Бозау икәнеңне белмиләр* (Г. Афзал. Сак кеше). *Ләкин бер генә малкайның да һичбер гаебе юк, хуҗасы бозау булганга, ыргак-тозакларга килеп капканнар бит!* (В. Имамов. Карабәк).

**БОЗАУ ВАГОНЫ.** Тимерьюлда хайваннарны йөртүгә көйләнгән вагон. *Юкка гына мондый вагоннарны «бозау вагоны» дип йөртәләр* (Г. Сабитов. Сопкаларда шәфәкъ шәүләсе).
Төрдәше: Столыпин вагоны.

**БОЗАУ НӘФАСӘТЕ.** Төчеләнү, тупас нәфислек күрсәтү. (Нәфасәт – гүзәллек, нечкәлек). *Кыланышларын карап торуы көлке дә, уңайсыз да иде, нәкъ бозау нәфасәте инде* (Сөйләм).

**БОЗАУ СЫЙРАГЫ.** Юан итеп төрелгән тәмәке. *Юан гына итеп, тагын берәр «бозау сыйрагы» төрдек* (Ә. Айдар).

**БОЗАУ ТӨЧКЕРЕГЕНӘ ДӘ ТОРМЫЙ.** Әһәмиятсез, бернигә дә тормый. *Каян килеп затлы әйбер булсын, бозау төчкерегенә дә тормый ул!* (Сөйләм).
Төрдәше: базар көн<не> поты (бәясе) бер тиен һ.б.

**БОЗАУ ЯЛАГАН НӘРСӘ (НӘМӘСТӘ)**. Җебегән, тиле сыманрак кешене сүгү сүзе. – *Кем янына килеп кердең син, бозау ялаган нәмәстә?* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).

*БОЗГА* ❖ **БОЗГА АТЛАНДЫРУ.** Кешене һәлакәткә салу, буш вәгъдәләр биреп ышандыру, алдау; *шулай к.* авыздан кош очыру 1. *Иртәгә, иртәгә, дип йөрттеләр дә бозга атландырып калдырдылар* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

**БОЗГА АТЛАНУ.** Алдану, кыен хәлдә калу. *Зур өметләр белән монда килгән иде, ләкин бозга атланган булып чыкты* (Сөйләм).
Төрдәше: бозга утыру.

**БОЗГА БОЗАУЛАУ.** Киләчәкне алдан күрмәү, кирәксез эш эшләү. *Җилгә җиленләп, бозга бозаулап йөрергә вакыт юк, – диде киенеп тә беткән карт* (А. Хәлим). – *Җилгә җилләп, бозга бозаулап йөрисең инде шунда! – дип куйды чатырның караңгы башыннан Мотгәрәй* (Ш. Бикчурин. Каты токым).
Төрдәше: корыга селкенеп йөрү.

**БОЗГА ТАШЛАНГАН БАЛЫК КЕБЕК ЧӘБӘЛӘНҮ** *к.* боз өстенә ташланган балык кебек бәргәләнү. *Мин дә идәндә, ишек кырыенда, бозга ташланган балык төсле чәбәләнәм* (tatarca-text/narod.ru).
Төрдәше: боз өстенә ташланган балык кебек бәргәләнү.

**БОЗГА ТАЯНДЫРУ** *к.* авыздан кош очыру 1. *Шул мәдрәсә өчен ялган договор төзеп, патша хөкүмәтен бозга таяндырган* (Х. Кәрим).
Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

**БОЗГА ТАЯНУ.** Ышанычсыз, таянычсыз; *шулай ук, к.* аттан иңеп, җәяүгә калу. *[Галим] Кызларга ышанма, язгы бозма таянма* (Т. Миңнуллин. Диләфрүзгә дүрт кияү). *Чит-ят бәндәләрнең изгелегенә өметләнү язгы бозга таяну белән бер икән шул!* (В. Имамов. Тозлы яра).
Төрдәше: аттан иңеп, җәяүгә калу һ.б.

**БОЗГА УТЫРТУ** *к.* авыздан кош очыру 1. – *Ярар, йөрерсең, – диде Хөрмәт аңа һәм аны бозга утыртырга маташкан егетнең күзенә туры карап кисәтте: – Икенчеләй миңа дөресен сөйлә, алдакчыларны җенем сөйми* (Р. Кәрами. Кая чабасың, гомер юртагым?). *Әгъвалаучы юха кыздай,*

*кызыктырып алдаса? Ә монысы инде бозга утыртудан да аша* («Казан утлары» ж.).
Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

**БОЗГА УТЫРУ** *к.* бозга атлану. *Барысы да яхшы булыр дип, сызгыра-сызгыра кергән иде, бозга утырганын сизми дә калды* (Сөйләм).
Төрдәше: бозга атлану һ.б.

**БОЗГА ЯЗМАГАННЫ СӨЙЛӘҮ.** <...> *гыйбарәләр дә очрый: киртә сикерү, диннән язу, гакыл зәгыйфьләнү, околоточный (тәртип саклаучы), мадмуазель, бозга язмаганны сөйләү һ.б.* (Х. Миңнегулов. Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты).
Төрдәше: тузга язмаганны сөйләү.

**БОЗГА ЯЗУ**. 1. Ышанычсыз; булмый торган эш, коры сүз, эзсез югала торган һ.б. турында. *Бозга язган хисапмы? Таянып кара әле син аңа* (Ф. Бурнаш). *Яшьлектә язган – ташка язган, картлыкта язган – бозга язган* (Мәкаль).
Төрдәше: суга сабын белән язу; суга сәнәк белән яз<ыл>у.

2. Булуы мөмкин түгел. *Ул үзенең бозга язган планнары өчен төрек милләтенең көчен һәм вакытын әрәм итү берлә мәшгуль була һәм шуның аркасында урысларга теләгәннәрен эшләргә форсат бирә...* (adiplar.narod.ru).

*БОЗЛЫ* ❖ **БОЗЛЫ ЙӨРӘК** *к.* боз җан<лы> *Баласын күкрәгенә куйгач, яшь хатынның бозлы йөрәгенә «тып» итеп тамчы тамды* (Н. Гыйматдинова).
Төрдәше: боз җан<лы> һ.б.

**БОЗЛЫ СУ КОЕЛГАН (СИПКӘН) КЕБЕК <БУЛУ>.** Бик нык сискәнеп китү. *Аһ, бу сөйкемсез көлеш! Мине бөтенләй изде, чәчләрем үрә торды, түбәмнән бозлы су коелган кебек булды* (Ш. Камал. Курай тавышы). *Үзенең оста сүз әйткәненә куанып, Түлгән тешләрен ыржайтып көлеп җибәрде. Туранның өстенә бозлы су сипкән кебек булды* (Ф. Бәйрәмова. Туфаннан таралган татарлар).
Төрдәше: салкын су сипкән кебек <булу> 2.

*БОЗНЫ* ❖ **БОЗНЫ КУЗГАТУ** *к.* боз кузгалды. *Гастрольләр, күргәзмәләр оештыру өчен, чит ил вәкилләрен чакырып алырга, аларны татар сәнгате, Татарстан белән таныштырырга иде. Мәхәббәтләрен казанырга, бозны кузгатырга иде* (Т. Әйди. Капкалар ачылды). *Кытай татарларының яшь буыны «юкка чыгуына» битараф кала алмаган ул. 2003 нче елда беренче бозны кузгатып, Казан белән элемтәгә кергән* (Р. Гыйлемханов һ.б. Истә калганнар).
Төрдәше: боз кузгалды.

*БОЗЫК* ❖ **БОЗЫК БОЖРА.** Котылгысыз хәл, котылу юлы булмаган хәл. *Бу юлы мин бозык боҗрага килеп эләктем бугай* (Сөйләм).
Төрдәше: сихерле түгәрәк.

**БОЗЫК ҖАН.** Әхлаксыз, азынып-тузынып йөрүче. *[Гөлсем] Хәтта миңа гына түгел, үз эшен онытып йөргән Тәкый шикелле начальникның цехка да керәге юк. Бозык җан бит ул* (Г. Кутуй. Шатлык җыры). *Бозыклардан бозык / Җаннар барда, / Кызыклардан кызык / Мин бармын!* (С. Рәхмәтулла. Гомер юлларында).

**БОЗЫК УЙ БЕЛӘН.** Әхлак нормаларына сыймаган, әшәке уй. *Янәсе, пәйгамбәр кызлары моны бозык уй белән түгел, изге теләктән чыгып, җир йөзендә пәйгамбәрнең нәселен калдыру максаты белән эшлиләр* (Г. Гобәй. Коръән серләре). *Әмма аларның һәркайсы бозык уй белән яши. Әмма аларның «эшчәнлеге» фәкать Сабан туйлары һәм Казан түрәләре катнашында узучы тантаналарда гына чагыла* (yazucilar.narod.ru).

**БОЗЫК ЮЛ.** Азынып-тузынып йөри торган, әхлак нормаларына каршы килгән юл. *Һәрхәлдә, ул кызының, ахыр чиктә, авыз күтәреп сәхнәгә дә менеп җырлавы, ә «әртискә булып» китүе ихтималын абайлый, аның бу теләген өнәми, «гөнаһлы», «бозык юл» дип саный* (Й. Вәлитова. Ул йолдыздай балкыды). <...> *мин бу фани дөньяны, сабыйларны ятим калдырып, ташлап киталмадым. ә хатынсыз яшәүче кешене бу дөньяда бик күп бозык юллар сагалап тора бит* (С. Горский. Явыз Иван хатыннары / Р. Хәмид тәрҗ.).
Төрдәше: бозык юлга аяк басу; бозык юлга керү; бозык юлда йөрү.

**БОЗЫК ЮЛГА АЯК БАСУ.** Җәмгыять тарафыннан тәнкыйть ителә торган, әхлак нормаларына туры килмәгән рәвештә яшәү. *«Тик кара аны: бозык юлга аяк баса күрмә», – дип, мине канатландырып куйды* (Ш. Усманов. Ачылган йозак). – *Әле аны да бозык юлга сөйрәдеңме?* –

*дип, янә кабынды бабасы* (Р. Шәрипова. Бәлале балалар).
Төрдәше: бозык юл һ.б.

**БОЗЫК ЮЛГА КЕРҮ** *к.* бозык юл. *Иренең бозык юлга керүе тагын да гарьләндереп, яшәп килгән тәртипләргә карата аңарда протест тудыргандыр* (Т. Әйди. Һаман күз алдында). *Аталары үлгәч, нигәдер, Петербургта торасылары килмәгән. Аналары бозык юлга кергән, имеш* (М. Әхмәтҗанов. Татар шәҗәрәләре).
Төрдәше: бозык юл һ.б.

**БОЗЫК ЮЛДА ЙӨРҮ.** Азып-тузып, начар кешеләр арасында булу. *Чөнки күңелдә тәртип юк икән, кешенең тормышында да тәртип юк, күңел азгын икән, кеше үзе дә бозык юлда йөри, күңеле каты, рәхимсез икән, кеше җинаятькә, явызлыкка да барырга мөмкин* (Ф. Бәйрәмова. Туфаннан таралган татарлар). *Ул мине эчү белән газапламады, бозык юлда йөреп интектермәде, көнләшеп теңкәмә тимәде* (Җ. Рәхимов. Өлешемә тигән көмешем).
Төрдәше: бозык юл һ.б.

*БОЗЫКЛЫК* ❖ **БОЗЫКЛЫК ОЯСЫ.** Бозыклык юлына чыкканнарның кәеф-сафа корып яткан урыннары. *Шәһәр – бозыклыклар оясы. Шәригатьнең зина кылган өчен каты җәзасы начармы?* (Ш. Галиев. Сиңа әйтер сүзем бар). *Русия халкына чит илләр бозыклык оясы, дошман итеп сурәтләнгәндә, илнең патриотлары саналган күп кенә җитәкчеләр Яңа елны Русиядән читтә, җылы диңгез буенда, Европада каршылады* («Безнең гәҗит» газ.).

*БОЗЫКЛЫКТА* ❖ **БОЗЫКЛЫКТА ХӘТДИН АШУ.** Бозыклыкның чигеннән дә узып китү. *– Син, Акмирза, чынында ир булып өлгермәгән... Әбозыклыкта хәтдин ашкансың* (Р. Батулла. Сөембикә).

*БОЛАЕН* ❖ **БОЛАЕН БОЛАЙ ДА.** Нәрсә турындадыр бераз шикләнеп әйтү. *Болаен болай да, иртәгә сөйләгән сүзләреннән ваз кичсә?* (Сөйләм).
Төрдәше: шулаен шулай да.

*БОЛАЙ* ❖ **БОЛАЙ ВАКЫТТА.** Гадәттәге чакта. *Болай вакытта үз басмасы өстеннән кармак та салдырмаган Шәмгун* (К. Нәҗми). *– Менә сиңа бер тәмәке янчыгы бирәм, – ди, җизнәсе әйтә инде, – эшең бик авыр булса, шуны ачып карарсың, болай вакытта карама, – ди* (Татар хал. әкияте).

**БОЛАЙ ГЫНА.** 1. Бу килеш, бу хәлдә. *Болай гына буе җитмәслек булгач, бер скамьяга басып, картинаны әллә ничә җиреннән җәрәхәтләде* (Ф. Әмирхан. Фәтхулла хәзрәт).

2. Уйламыйча, очраклы гына, сүз җае туры килгәндә, шаярып кына. *Болай гына, уйнап кына, / Дигән кебек яшеннәр / Болытларга буйдан-буйга / Сызгалыйлар рәсемнәр* (С. Хәким. Бакчачылар).
Төрдәше: сүз арасында; сүз арасында (уңаенда) әйткәндә; сүз җае (уңае) туры килгәндә; сүз арасында гына әйтеп китү.

**БОЛАЙ ДА** *к.* аннан башка да. *Болай да соңгы елларда татар каны елгалардай акты* (В. Имамов. Карабәк). *Караштырмыйча булмый, болай да артка калдым бугай инде* («Казан утлары» ж.).
Төрдәше: аннан башка да һ.б.

**БОЛАЙ ДА КҮП.** Нәрсәнеңдер бик күп булганлыгын, кирәк түгеллеген белдерә. *Нәрсәгә алдың инде бу аяк киемен, болай да күп иде ич?* (Сөйләм).

**БОЛАЙ ДА, ТЕГЕЛӘЙ ДӘ.** Төрле яклап, төрлечә. *Козгын, болай да, тегеләй дә куиларына карамастан, ач кара күзләре белән тын гына ялварып, азык сорады* (Ә. Гаффар. Әҗәт).

**БОЛАЙ ЯКИ ТЕГЕЛӘЙ.** Һәрхәлдә. *Ә күңелдәге уйларның, йөрәктәге теләк-омтылышларның каян туганын, нигә болай яки тегеләй булуларын аңлый да, аңлатып та бетерә алмыйбыз* (М. Юныс. Юлда уйланулар).
Төрдәше: йә болай, йә тегеләй.

*БОЛАЙГА* ❖ **БОЛАЙГА КИТКӘЧ (БОРЫЛГАЧ).** Һич көтелмәгән үзгәреш башлану. *Болайга киткәч, комиссия төзегән булып урын сайлап мәшәкатьләнүнең хаҗәте дә юк* (А. Вергазов. Үзеңә кайту). *Эшләр болайга борылгач, Габит инде ныклап борчыла башлады кош язмышы өчен* (Ә. Әминев. Бер көймәдә...).

*БОЛАК* ❖ **БОЛАК СУЫ ЭЧМӘГӘН** *к.* авыз суы кипмәгән. *Нинди җитәкче чыксын инде аннан, Болак суын эчмәгән бит ул* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

*БОЛАМЫК* ❖ **БОЛАМЫК БОЛГАТУ** 1. *к.* авыз чайкау 1. – *Мисырдагы шәригать кануннары тегендирәк бит ул, бездәге кысалар да анда ярап бетми дип, и чүбек чәйни, боламык болгата ди болар* (В. Имамов. Карабәк).
Төрдәше: авыз чайкау 1 һ.б.

2. Сүзен кеше аңларлык итеп сөйләмәү; авыз эчендә мыгырдану. *Юаш шул без. Белгәнне дә чатнатып әйтеп бирә алмыйбыз. Тик торабыз шунда авыз эченнән боламык болгатып* (Ф. Шәфигуллин. Абитуриентлар). *Ихлас нәрсәдер әйтергә тели, әмма теш арасыннан сүз чыкмый. Үзе әйтмешли, авызында боламык кына болгата* (Ә. Моталлапов. Әфсенче).

*БОЛАМЫККА* ❖ **БОЛАМЫККА ӘВЕРЕЛҮ (ӘЙЛӘНҮ).** 1. Явым-төшемнәрдән соң туфрак, балчыкның үзле масса, батаклык хәленә килүе. *Чөнки сентябрь аенда ук, койма яңгырлар явып, Рәсәй җире урыны-урыны белән боламыкка әйләнә башлый* (С. Поварисов. Утлы дуга кыңгыравы). *Печән базарына якынлашкан саен, эзләр күбәя, ишәя, һәм базарның халык кайнап торган үзәгендә инде кар япмасы, меңләгән кешенең аяк астында тапталып-изелеп, нииндидер сыек бер боламыкка әверелә иде* (М. Галәү. Мөһаҗирләр).

2. *күч.* Буталу, рәте китү, тәртибе бетү, чуалып бетү. *Хатны укып чыкканчы җәбеп, боламыкка әйләнеп калды күңеле, тез буыннары сыекланды әнә* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң). *Авызыннан буталып, боламыкка әверелеп чыккан соңгы җөмләсен исән калган ярым черек биш-алты теше белән чәйнәп, имгәтеп, һавага төкерде* (Д. Салихов. Чукрак).

**БОЛАМЫККА САНАУ.** Характерсыз, җебегән кеше дип уйлау. – *Томана, мине боламыкка санамакчы, әй!* (М. Хуҗин. Килен төшкәч).

*БОЛАМЫКНЫ* ❖ **БОЛАМЫКНЫ ТАЛКАН ИТӘР.** Уңган, булган кеше хакында. *Яшь булса да, боламыкны талкан итәр ул, дип, бу катлаулы эшне Маратка тапшырдылар* (Сөйләм).

*БОЛАН* ❖ **БОЛАН ҖИЛЕГЕ КЕБЕК.** Тәмле, шәп. – *Катламчыгың шундый тәмле килеп чыккан, болан җилеге кебек инде* (Сөйләм).
Төрдәше: әмма дә соң инде һ.б.

*БОЛГАВЫР* ❖ **БОЛГАВЫР ВАКЫТ.** Ыгы-зыгылы вакыт, барысы болганып беткән заман. *Свердлов урамыннан, Татвоенкомат яныннан узганда, армиягә киткән чаклары исенә төште: койма аша сикереп качып чыгулары, иртән тагын килүе, комиссия үтү, андагы шау-шулы болгавыр вакытлар* (Р. Кәрами. Олы юл да сикәлтәле). *Автор тарихыбызның иң болгавыр вакытын – барлык татар халкының уртак дәүләте саналган Алтын Урданың XIV гасыр уртасыннан башлап таркалуга йөз тоткан тотрыксыз сәясәте, аның сәбәпләре һәм Урда составындагы Болгар олысының киләчәк язмышын хәл иткән вакыйгалар турында сурәтләгән* («Казан утлары» ж.).

*БОЛГАНЧЫК* ❖ **БОЛГАНЧЫК СУДА<Н> БАЛЫК ТОТУ.** Буталчык вакыттан файдаланып, үзенә файда итү. *Идрисовның Мосафиров «политикасы» белән килешмәгәнен, Хиаметдиновны болганчык суда балык тотып калырга яратучы карьерист дип санаганын Кыям белә иде һәм Мосафировның бүгенге җыелышта үзен тотышына җене чыгып утырганын да күреп, ишетеп торган иде* (И. Гази. Гаепсездән гаеплеләр). – *Күпләр болганчык судан ничек балык тотарга белмичә йөргәндә, улларың балыкның алтынын эләктерде* (Ф. Яруллин. Гөлҗиһан малайлары).
Төрдәше: куе суда<н> балык тоту.

**БОЛГАНЧЫК СУДА<Н> БАЛЫК ТОТУЧЫЛАР.** Вакытның буталчык булуыннан файдаланып калырга тырышучылар. *Тик болганчык суда балык тотучылар хәзер дә күп* (Р. Зәйдулла. Ташка ордым башны).

*БОЛГАР* ❖ **БОЛГАР ОЛТАНЫ.** Борынгы болгарлар ысулы белән сыер-үгез күненнән ясалган, куе кызыл төстәге чыдам олтанлык. *Аягыңдагы итегең / Болгар икән олтаны; / Сине сөйми кемне сөйим, / Син бит егет солтаны* (Җырдан). *Аның олтаны – болгар олтаны, кырыеннан киселгән. Ярып ук киселгән. Үзе кып-кызыл төсле* (Г. Исхакый. Кәҗүл читек).

**БОЛГАР ПӘРИЕ.** Бик чибәр. *«Сөбханалла! Чын болгар пәрие!» – дип уйлап куйды Исрафил су эчкәндә, чүмеч өстеннән сөзеп кенә кызга карап* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы).

*БОЛГАТКЫЧ* ❖ **БОЛГАТКЫЧ ТАЯК.** Кешеләрне бер-берсенә каршы котыртып, талаштырып йөрүче. *[Сабира] Очрашканда сүзгә кереп*

*китә торган гадәтегез барын беләм, әллә мин болгаткыч таяк әтиегезме дисәм, үзегез дә кыдрач әтәчләрдән ким түгел икәнсез сез* (А. Гыйләҗев). *– Хатын заты ул сабый чакта гына тәмиз булгай, соңра аталавыч, ягъни болгаткыч таякка әверелә...* (Р. Батулла. Сөембикә).

*БОЛЫНГА* ❖ **БОЛЫНГА КИБӘН КЕРҮ.** Җәйнең үткәнлегенә ишарә ясау. *Болынга кибән дә керде инде, тиздән чаналарны әзерләргә вакыт җитәр* (Сөйләм).

*БОЛЫН-ЯРЫН* ❖ **БОЛЫН-ЯРЫН КИЛҮ.** Төрле якка бүлгәләнеп, таралышып бетү (монда «болын» сүзе «як» мәгънәсендә). *(«Болын-ярын килү» дигәндә дә «болын» сүзе монда хәзерге чабынлык-үләнлек мәгънәсендә түгел, шул борынгы болын (булуң – як) мәгънәсен саклаганга, шул сүз белән бергә бу әйтем үзе дә, борынгы чорлардан калып, телебездә сакланган дип уйлыйм* (Н. Исәнбәт. Фразеологик әйтемнәребездә тарихчылык).

**БОЛЫН-ЯРЫН ЯШӘҮ.** Бозылышып, таралышып, төрле җирләрдә гомер итү. *Кайдадыр укыган иде: ыру-кабилә булып яшәгән заманда, як-якта аерым яшәүне «болын-ярын яшәү» дип әйткәннәр икән* (Сөйләм).

*БОЛЫТ* ❖ **БОЛЫТ БАСКАН, <ЯҢГЫР ЯВАРГА ТОРУ>.** 1. Баланың менә-менә елый башларга җыенуы. *Баланың аскы ирене турсаеп, алга таба сузылды, күзләре дә дымсуланып китте, күңелен болыт баскан да яңгыр яварга тора иде, ахрысы* (Сөйләм).

Төрдәше: болытлар куерган, явам-явам дип тору.

2. *куч.* *Начарлану, бозылу. Яшь гомеремнең күген болыт баскан көн, / Кайгыхәсрәт ташып, баштан ашкан көн* (Р. Гаташ. Арысланмын, гайрәтемә кем чыдар?). *– Минеке әйбәт әле, ә менә синең кәефеңне болыт баскан дип ишеттем* (З. Мурсиев. Хастаханә хастасы).

**БОЛЫТ КЕБЕК.** Кайгылы кыяфәттә булган кешене чагыштыру, ягъни карасы йөзенә чыккан. *Ил хәсрәте кара болыт кебек / Аналар йөзендә. / Җирдә иң нык гаделлек, тугрылык / Аналар сүзендә* (Г. Сафин. Аналар). *Аннары кара болыт кебек күңелләрне каплап торган хәлне гадәти мәшәкатьләр белән җиңеләйтү максатыннан өстәп куйды: – Мәшекләрегез кайтып беттеме соң әле, Факиҗамал әпә?* (Җ. Юныс. Сугыштан соң).

**БОЛЫТ ЧӘЙНӘП, БОЗ БӨРКӘНГӘН <КАРА> КӨННӘР.** Авырлыклар кичереп, михнәт күреп йөргән көннәр. *Тыныч тормыш озакка бармады, бик тиздән тагын болыт чәйнәп, боз бөркәнә торган кара көннәр килде. Баш күтәрүчеләрне яңадан эзәрлекләүләр, җирләреннән кабаттан кысрыклаулар башлангач, җирсез, терлексез калган саха ирләре кабат коралга ябышты* (Р. Галиуллин. Боссоойко).

Төрдәше: болыт чәйнәп, боз бөркәнеп яту.

**БОЛЫТ ЧӘЙНӘП, БОЗ БӨРКӘНЕП ЯТУ** *к.* болыт чәйнәп, боз бөркәнгән <кара> көннәр. *Үзегез теге юлы, без Нур белән мытыеста ачка интегеп, болыт чәйнәп, боз бөркәнеп ятканда, ничек сыйлап җибәрдегез!* (В. Нуриев. Ни хәлең бар, балам?).

Төрдәше: болыт чәйнәп, боз бөркәнгән <кара> көннәр.

*БОЛЫТЛАР* ❖ **БОЛЫТЛАР КУЕРГАН, ЯВАМ-ЯВАМ ДИП ТОРУ** *к.* болыт баскан, яңгыр яварга тору. – *Улыңа кара әле: болытлар куерган, явам-явам дип тора* (Сөйләм).

Төрдәше: болыт баскан, яңгыр яварга тору.

**БОЛЫТЛАР КУЕРУ.** Кемнеңдер өстендә куркынычның арта баруы. *Әйтик, Фатих Әмирханны совет зинданыннан вафат булуы гына коткарып калган дип әйтә алабыз, чөнки әдип өстендә яман болытлар куера башлаган була инде* (А. Тимергалин. «Инкыйраз»га – йөз ел). *Бәлки, болытлар куера башлады дигәне белән ул Асиягә янаган берәр куркыныч хакында әйтергә теләгәндер* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет).

*БОЛЫТЛАРДА* ❖ **БОЛЫТЛАРДА ЙӨЗҮ.** Чынбарлыктан аерылып, хыял дөньясына бирелү. *Әти кебек болытларда йөзми ул* (Р. Зәйдулла. Коршау). *– Үкенмим лә мин, болытларда йөзеп, заяга уздырган гомеремне җәллим* (Н. Гыйматдинова. Син түгел бу, син түгел...).

*БОЛЫТТАН* ❖ **БОЛЫТТАН ДЫМ ТАРТУ.** Тәэсирләргә тиз бирелү, күңеле төшенке булу. *Ник монда болыттан дым тартып утырасың, әйдә, күл буен әйләнеп киләбез* (Сөйләм).

**БОЛЫТТАН ҖИРГӘ (ҖИР ӨСТЕНӘ) ТӨШҮ.** *Күңел юаткач, беренче булып, әмир Ибраһим болытлардан җир өстенә төште* (В. Имамов. Казан дастаны).

*БОР* ❖ **БОР ДА БОРЫНЫҢА ТЫК.** 1. Артык күндәм кеше турында, ягъни ул теләсә нинди хезмәтеңә әзер, теләсә нәрсә эшләтә аласың. *– Син бу тәкъдимеңне күршедәге абзыйга әйтеп кара әле, күп уйлап торма – бор да борыныңа тык* (Сөйләм).

2. Бик шәп, бик гүзәл әйбер турында. *Рәфис пыяла астына куелган бу әйбергә бик озак карап торды, чынлап та, аны бор да борыныңа тык инде* (Сөйләм).

*БОРАУЛАП* ❖ **БОРАУЛАП ТИШҮ.** Дикъкать белән карау. *Гүзәлия аның кемне «бораулап тишкәнен» сизде* (Н. Гыйматдинова. Үзем генә беләм...). *Мондый карашлар белән сез теләсә нинди стенаны бораулап тишәсез генә түгел, ә җимереп ишәсез* (А. Хәсәнов. Данәгөл).

*БОРГАЛАП-СЫРГАЛАП* ❖ **БОРГАЛАП-СЫРГАЛАП ТОРМАУ.** Яшермичә, турысын әйтү. *– Ул бит сугышта кантуж булган, казер мужиклыгын итә алмый, – диде Сандра, керәшен хатыннарына гына хас турылык, эчкерсезлек белән һич боргалап-сыргалап тормыйча* (Ә. Салах. Каеннар юлы).

Төрдәше: бормалы-сырмалы тыкрыктан урап тормау.

*БОРГЫЧЛАП* ❖ **БОРГЫЧЛАП ТОТУ.** Кемне дә булса берәрсен буйсындырып тоту. *Бездә берәүнең дә эше юк. Мужик халкын гел боргычлап тотуны гына беләләр* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Патша кирәк Рәсәйгә / Боргычлап тота торган. / Азынган бозык җаннарны / Тыя, куркыта торган* (Ф. Давлетбаев. Таныш халәт).

*БОРМАКАЙ* ❖ **БОРМАКАЙ КЕШЕ.** Борғаланучан, койрыгын тоттырмый торган кеше. *[Вахитов] Сез – бик бормакай кеше. Без бит сезнең белән конфетлы уйнамыйбыз* (Н. Исәнбәт).

*БОРМАЛЫ-СЫРМАЛЫ* ❖ **БОРМАЛЫ-СЫРМАЛЫ ТЫКРЫКТАН УРАП ТОРМАУ** *к.* боргалап-сыргалап тормау. *Ире бормалы-сырмалы тыкрыклардан урап тормады, туп-туры ярып салды* (Н. Гыйматдинова).

Төрдәше: боргалап-сыргалап тормау.

*БОРТАК* ❖ **БОРТАК АВЫЗ** *диал.* Авызын-телен тыя белмәүче кеше турында. *[Фазылҗан] Йә, сиңа әйтәләр бит инде «тик утыр» дип. Бу кадәр тотнаксыз бортак авыз булырсың икән!* (Г. Камал. Хафизалам, иркәм). *– Куштым, анысы хак. Әмма бортак авыз икәнеңне белгән булсам...* (З. Мәхмүди. Елак агач).

*БОРЧА* ❖ **БОРЧА АШАУ (КЕРҮ).** Тынычсызлау, борчу. *[Кәрим] Килерләр әле. Синең белән мин генә бит ул бик борчылабыз. Башка һичбер кемнең дә җаннарын борча ашамый* (Г. Камал. Хафизалам, иркәм). *Беренче очрашуда ук галстугыма асылынып атынучы, күзгә борчадай кереп, теңкәгә тигән балаларны яратмадым* (Ф. Баттал. Мин булдырам!).

**БОРЧА ДАГАЛАУ.** Үз һөнәренең остасы булуга ишарә. *Кояш батареен ясаучы бар, мичче табып булмый авылда. Өйрәнмиләр – борча дагалау күк катлаулы да түгел, авыр да...* (З. Мансуров. Мичче). *Әгәр заманында ул Шәйхукларга, Лотфуллаларга уку да эләккән булса, алар дөньяны шаккатырырлар иде. Борчаны дагалаган Тула сулагайлары токымы ич алар!* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**БОРЧА КЕБЕК.** Артык хәрәкәтчән, тиктормас кеше хакында. *Монысы борча кебек хәрәкәтчән, елгыр, шуны шәйләп, Сөләйман аңа ерак бабасының исемен кушуны мәслихәт тапты* (В. Имамов. Сөләйман солтан). *Сиңа шундый закун чыгарам: кеше-фәлән килсә, борча кебек өй бетереп чапма, тыныч кына утырып сөйләш* (Н. Гыйматдинова. Кыргый).

**БОРЧА ЧҮПЛӘҮ.** Мөһим булмаган вак-төяк белән маташу. *Без шулай бу нотариус белән байтак «борча чүпләп» утырдык* (А. Расих). *Шәкерт җиләненнән борча чүпләүчеләр тагын табылырмы, белмим, мәгәр, «Яра» повесте ул – минем йөз аклыгым* (Т. Әйди). *Без әсәрләребездә чагылдырган авыл үсмерләре дөнья таң калырлык эш күрсәткәннәр икән ул чагында!.. Тәнкыйтьчеләр әнә шуларны ачып саласы урынга, «шәкерт җиләненнән борча чүпләгәннәр», урман артынданиләр барын күрмәгәннәр* (А. Гыйләҗев. Татарстан могҗизасы).

*БОРЧАГА* ❖ **БОРЧАГА АЧУЛАНЫП, ЮРГАН ЯРУ.** Юньсез чара күреп, зарар китерү, урын-

сыз ачу алу. *Урамнан узып йөргән машиналарның тузан чыгаруларына ачу итеп, юл башына чокыр казып куйган иде, хәзер инде аңа килгән-киткәне дә, хәтта үзе дә, машинасын урам башында калдырып, җәяү йөри башлады – күрше бабай әйтмешли, борчага ачуланып, юрганын ярды* (Сөйләм).

*БОРЧАК* ❖ **БОРЧАК АВЫЗ.** Лыгырдавык, сер саклый белми торган. *[Фазылҗан] Бу кадәр тотнаксыз борчак авыз булырсың икән* (Г. Камал. Хафизалам, иркәм).

Төрдәше: авызына алды инде, өзмәс тә куймас һ.б.

*БОРЧАК* ❖ **БОРЧАК АТ<ТЫР>У (ЧӘЧҮ).** 1. Мактану, арттырып сөйләү, шапырыну. *«Белдем инде милләтең дәрден», – дисең, борчак атып. – Файдасы юк бер хәрам корсак икәнсең син һәнүз!* (Г. Тукай). *Шулай дип сөйләгән иде Галикәй, аның борчак аттырырга ратканын белгән Бибинур бу юлы әкиятен дә колак очы белән генә тыңлаган иде* (А. Гыйләҗев. Җомга көн кич белән...).

2. Һич уңайсызланмыйча ялганлау, алдалау, булмаганнарны сөйләү. *Яшь көннәрне наданлыкка / Корбан иттек тә чалдык без; / Суган саттык, / Борчак аттык, / Бәрбәр булдык: / Сач алдык без* (Г. Тукай). *Билләһи менә. Борчак ата икән бу дип уйламагыз тагын. Ышанмасагыз, әнә безнең Рәшиттән сорагыз* (И. Диндаров. Каптырдылар).

Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

**БОРЧАК БАСУЫНДА БЕР БИЛГЕЛӘНГӘН БОРЧАКНЫ ТАБУ.** Вак, мәшәкатьле, гаять четерекле эш турында. *Борчак басуында бер билгеләнгән борчакны табу кадәр читен хәл* (Г. Тукай).

**БОРЧАК БЕЛЕНЕ АШАГАН** *к.* авыр аяк<лы> 3. *Очрашулар, сөешү-назлашулар кайнар була, берзаман кызыбыз үзенең борчак белене ашаганлыгы турында сизенә, бу турыда борчылып сөяркәсенә дә җиткерә* (Ә. Салах. Каеннар юлы).

Төрдәше: авыр аяк<лы> 3 һ.б.

**БОРЧАК БУРАСЫНА (БҮЛМӘСЕНӘ) ЕГЫЛУ** *к.* битенә боз яуган. *Аны тануы җиңел, битендә вак-вак шадралары бар – әйтерсең лә борчак бурасына егылган* (Сөйләм).

Төрдәше: битенә боз яуган һ.б.

**БОРЧАК БҮРТМӘҮ** 1. Уртак тел таба алмау, серләр килешмәү. *Сәлам бирсәң – сәламеңне алмас, баш кагып кына исәнләшсәң – күрмәмешкә сабышыр төмсә күрше белән нигәдер борчак бүртмәде* (matbugat.ru).

2. Берәр эшнең, ниятнең тормышка ашмавы. *Әһ, теләнсәң дә суда борчак бүртмәс. Синең данныйлар хөрти шул* (Н. Гыйматдинова. Бер тамчы ярату).

Төрдәше: аның белән борчак пешмәү һ.б.

**БОРЧАК БҮРТ<ТЕР>Ү.** Эш, сүз килешү. *– Йә, сөйлә, Ядегәр белән ни борчак бүрттердегез? – Иванның соры күзләре чекерәеп куйды* (З. Мәхмүди. Елак агач). *Шәкертләр ягына килеп йөргәләве һәр ике як өчен дә бары тик файдалы гына булганлыктан, әле таралышырга җыенмаган бу китап кортларының боткалары пешә, борчаклары яхшы бүртә бирде* (Ф. Яхин. Әнием, Коръән чыгарсың).

Төрдәше: бер сүзгә килү һ.б.

**БОРЧАК ИТЕП ЧӘЧЕП КАЛДЫРУ.** Биргән сүзне үтәмәү, вәгъдәсендә тормау. *Ә менә игезәк уллары дөньяга килү сөенечен авылга җиткерү теләге аның бер вәгъдәсен иманыннан җил итеп очырта да биргән антын борчак итеп чәчеп калдыра* (Ә. Гаффар. Сиртмәле бишек).

**БОРЧАК КАДӘР.** Бик кечкенә, вак. *Шуннан соң иң кызыгы башлана: ногыт борчагы кадәр генә кургаш бөртеге аласың да корыч кашыкка салып эретәсең, аннары сулы табакка коясың* (Г. Гыйльманов. Тимерче). *Халитнең калын кашлары бер-берсенә тия язып җыерылган, яңагындагы борчак кадәр кара миңе дерт-дерт килә иде* (Ф. Садриев. Көлми торган кеше).

Төрдәше: бармак башыдай (башы кадәр / шае).

**БОРЧАК<НЫ> КУЫРА БЕЛҮ.** Эшне җайларга, ипләргә оста булу.– *Өлешебезгә каты ралысы тисә, алып кайтырга булышырмын үзеңә. – Куыра беләсең дә инде борчакны...* (М. Хуҗин. Өч каен ышыгы).

**БОРЧАК КУЫРУ.** Килешү; бер сүзгә, бер фикергә килү. *Плавай Гайфине бик усал, холыксыз адәм, диләр. Аның белән борчак куырып булмый* (Ф. Латыйфи). *Мохтаров кыз-хатын түгел, безгә ни, борчак куырасы юк аның белән* (Р. Мөхәммәдиев. Сират күпере).

Төрдәше: бер сүзгә килү һ.б.

**БОРЧАК ОНЫННАН ӘВӘЛӘНМӘҮ.** «Берәүдән дә ким түгел» мәгънәсендә. *Һе, ансат икән, аңа гына өсте-өстенә егет кирәк икән! Без дә борчак оныннан әвәләнмәгән ләбаса!* (Ф. Баттал. Мистер-абсолют).
Төрдәше: чегән арбасыннан төшеп калмаган.

**БОРЧАК ПЕРӘННЕГЕ** *диал.* Мактанчык, бушбугаз. *Аның шикелле күп сөйләргә яратучы борчак перәннекләрен яратмыйм мин* (Сөйләм).
Төрдәше: буш бугаз 2; буш куык; җил кубызы; җил куыгы; җил тегермәне; җилсез тегермән; йон батыр; өреп тутырылган буш куык; салам койрык; сарык янында батыр, <батыр янында сарык>.

**БОРЧАК ПЕШМӘҮ (ПЕШЕРӘ АЛМАУ)** *к.* аның белән борчак пешмәү 1, 2. *«Киләчәктә сездән бик шәп белгеч чыгуы бик ихтимал, – диде Юрий Петрович, урынлы-урынсыз тамагын кыргалап, – тик шунысы бар: шәһәребезнең абруйлы, иң күркәм галиме белән борчак пешерә алмаган яшь иптәш минем белән пешерер дип уйлыйсызмы?»* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Авылга әле күптән түгел генә техникум тәмамлап кайткан методист кыз Равияне моннан берничә көн элек зоотехник Шамил озатып караган икән дә – борчаклары пешмәгән, ди* (Ф. Шәфигуллин. Өйләнергә тек, өйләнергә).
Төрдәше: аның белән борчак пешмәү 1, 2 һ.б.

**БОРЧАК ПЕШ<ЕР>Ү.** Килешү, бер фикергә килү.– *Галимә, дим, Галимә? Теге хисапчы Кәримова белән борчак пешә түгелме синең?* (Г. Сабитов. Калай күке). *Буыннары сызлап торган карчык фельдшер кыз белән борчак пешерергә каршы буламы соң?..* (А. Гыйләҗев. Әтәч менгән читәнгә).
Төрдәше: бер сүзгә килү һ.б.

**БОРЧАК САЛАМЫ БЕЛӘН КОРШАЛУ (КЫРШЫЛАУ)** *диал.* Җиңел акыллы булу, такылдык, мактанчык. – *Сөйләмә әле шуның турында, борчак саламы белән коршалган бит ул!* (Сөйләм). *Борчак саламы белән кыршылган* (ТТДС I, 220).
Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**БОРЧАК СИБҮ.** 1. *к.* борчак ат<тыр>у (чәчү) 1. *Ә борчак сибәргә дигәндә, Сәфәргали үзе дә кешедән ким түгел, әгәр артык булмаса* (Ф. Хөсни). *Аннары, дөресен генә әйткәндә, алар Шанаевның еш кына борчак сибәргә яратуын да беләләр* (Ә. Еники. Без дә солдатлар идек).
Төрдәше: борчак ат<тыр>у (чәчү) 1 һ.б.

2. *к.* авыздан кош очыру 1. *Тик болай итеп борчак сибү аңа ник кирәк?* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет). *Әңгәмәдәшемнең «Яшь кеше, чиратны тоткарламагыз!» – дип оран салырга әзерләнгәнен күреп, мин, беткән баш беткән, дигәндәй, учлап борчак сиптем* (Р. Мөхәммәтша. Тырыйк).
Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

**БОРЧАК СИПТЕРҮ** *к.* авыздан кош очыру 1. – *Син, малай, борчак сиптермисеңдер бит* (Р. Төхфәтуллин. Җиләкле аланнар). *Билгеле инде, аңлашыла, моңарчы ындыр артыннан ерак китмәгән сала егете, арбага утыру белән борчак сиптерә башлаган, ди, мин фәлән-фәлән диңгезләрдә йөздем-йөздем дә, фәлән-фәлән илләрне күрдем, янәсе* (Н. Гамбәр. Әткәй белән сөйләшү).
Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

**БОРЧАК УРЫНЫНА КУЫРУ.** Ашыктыру, өтеп бару. *Акрынлап сизәм, Һаҗәрнең уе гел күңел ачуда, матур киенүдә, ә әнкәй белән безгә эш. Шуның өстенә безне борчак урынына куыра, әле тегесе, әле бусы ошамый* (Ф. Садриев. Көлми торган кеше). *Шул ук көнне авылга кайтып китәрбез дип тә ниятләп тора идем, ләкин әлеге шул Әйтсә эшли Галим абзый: – Син алай борчак урынына куырма инде, энем Өлфәт! Адәм баласына гел эшләп кенә торырга димәгән, вакыты белән әз генә булса да ял да кирәк аңа!* (В. Нуруллин. Күпер чыкканда).

**БОРЧАК УРЫНЫНА СИБҮ (ЧӘЧҮ)** *к.* авыздан кош очыру 1. «*Яратам*» *сүзен борчак урынына сипте Алмабикә* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым). *Бердәнбер «карарбыз» дигән сүзне генә кызганмыйлар, аны борчак урынына чәчәләр, «карарбыз» дип, беркайчан да ялгышмыйсың...* (М. Миншин. Кызыл диплом).
Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

**БОРЧАК ЧӘЧҮ.** 1. Мактану, арттырып сөйләү. *Ике сүзенең берендә ул борчак чәчеп җибәрә*

*иде: «“Слезы и молитвы дураков” исемле романым Англиядә басыла»* (А. Гыйләҗев). *Әтисенең бераз борчак чәчә торган гадәте бар* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).
Төрдәше: авыз белән кош кына тотмау һ.б.

2. *к.* авыздан кош очыру 1. *«Ләктереп» булмас микән, дип, бер тагын, / Бай чәчәргә башлый юк сүз борчагын* (Г. Тукай). *Кипкән йөзле чәрелдек хатын үзенчә борчак чәчте* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).
Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

**БОРЧАК ЧУМАРАСЫ БЕЛӘН ТӨЕЛҮ.** Тирги-тирги ашату. *Борчак чумарасы белән төелгәннән дә яманрак булды* (К. Әмири).

**БОРЧАК ЧҮМӘЛӘСЕ ТӨСЛЕ ИШЕЛҮ.** 1. Төрле якка бүселгән симез, юан кеше турында. *Бу кеше ашаудан башка нәрсәне белми иде бугай: үзе борчак чүмәләсе кебек ишелгән, ара-тирә авызын чупылдатып куярга ярата иде* (Сөйләм).

2. *күч.* Бүселеп чыккан әйбер. *Барсам, һәрвакытта җәмгыять була торган өстәлдә башына борчак чүмәләсе төсле ишелгән чалма, өстенә әллә ничә җиренә май тамган һәм...* (Г. Тукай). <...> *һәм шуның артыннан ук күз алдында яшел чапан кигән, борчак чүмәләсе төсле төрле якка ишелгән чалма кигән, сыерылган балтырлы читектән, өстке төймәләре чишелгән бер кеше: «Шәригать! Шәригать!» – дип, күз алдында күренгән кебек булды* (Г. Исхакый. Ике йөз елдан соң инкыйраз).

**БОРЧАК ШАРТЛАТУ** *к.* авыздан кош очыру 1. *Тынычлыкны сайлыйм! диеп, / Мәскәү борчак шартлата* (Р. Рахмани. Мәскәү нәрсә шартлата?).
Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

**БОРЧАК ШЫТТЫРУ** *к.* авыздан кош очыру 1. *– Әй, сусыз борчак шыттырмасана* (Н. Гыйматдинова. Ачкыч). *Үзе дәрвиш, үзе җитди, үзе мәзәкчән, үзе хәйямләнергә дә, үзе өчен бер файдасызга борчак шыттырып юанырга да маһир, үзе «патшалар ятлап алырлык шигырьләр дә яза»* (Г. Морат. Әкә).
Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

**БОРЧАК ЯРУ.** 1. *к.* авыз белән кош кына тотмау. *Борыны җәенке егет борчакның эресен яра* (А. Гыйләҗев. Өч аршын җир). *Аның «борчак ярырга» хирыслыгын бөтен авыл белә* (Ә. Моталлапов. Балыклы күл буенда).
Төрдәше: авыз белән кош кына тотмау һ.б.

2. *к.* авыздан кош очыру 1. *Авыл җирендә кемнең кем икәнлеген бер чакрымнан ук күреп торалар. Шәфкать туташы Миңле Асия үзе янында борчакны бик эредән ярып барган фронтовикның нинди кеше малае икәнен ул кайтканчы ук белеп алган иде инде* (Г. Ахунов).
Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

*БОРЧАККА* ❖ **БОРЧАККА ТЕЗЛӘНДЕРҮ**. Кыйнамый-сукмый җәза бирү; нык итеп орышу. *Һәр дәрес саен поп җәза бирми калмый: йә ул мине бер-ике сәгатькә почмакка борчакка тезләндерә, йә аркама һәм башыма линейка белән суга* (Р. Зарипов. Без – Казан татарларыннан). *Балалар бакчасына йөргәндә үк кылган галәмәтләре өчен, әтисеннән шактый эләгә: почмакка бастырулар, борчакка тезләндереп торулар, урамга чыгармыйча, өйдә бикләп куюлар, каеш белән «чәпәләүләр»...* («Безнең гәҗит» газ.).
Төрдәше: акыл бизмәненә утырту.

*БОРЧАКНЫ* ❖ **БОРЧАКНЫ ТИЗ КУЫРУ.** Ашыгу, тиз эшләп ташлау. *Борчакны артык тиз куырырга яратучы әтисе тагын нинди шөгыль, нинди йомыш уйлап тапкан?!* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).

**БОРЧАКНЫ ЧАМАЛАП АТУ (СИБҮ; ЫРГЫТУ).** Мактаганда (мактанганда) яки ялган сөйләгәндә чаманы белү. *Борчагыңны чамалабрак сип, югыйсә берсе дә ышанмас* (Сөйләм).

**БОРЧАКНЫ ШЫТТЫРЫБРАК ҖИБӘРҮ.** Нәрсәне булса да арттырыбрак сөйләү. *Халык гайбәт ярата инде ул, дөресенә кызык өчен су куша, борчакны шыттырыбрак җибәрә* (Ф. Яхин. Сөю-сәгадәт алмасы).

*БОРЧА-КЫРМЫСКАЛАР* ❖ **БОРЧА-КЫРМЫСКАЛАР КӨТҮЕ ЧАБЫШУ** *к.* аркада< н> тараканнар (кырмыскалар) йө<ге>рү (йөгереп үтү) 2. *Бөтен тәне, беләкләре буйлап борча-кырмыскалар көтүе чабышкандай булды* (В. Имамов. Казан дастаны).
Төрдәше: аркада< н> тараканнар (кырмыскалар) йө<ге>рү (йөгереп үтү) 2 һ.б.

*БОРЧАНЫ* ❖ **БОРЧАНЫ БЕТ, БЕТНЕ СЕРКӘ САНАУ.** Бар нәрсәне (эшне) вак нәрсәгә санау, бөтен нәрсәгә җиңелчә карау. *Борчаны бет, бетне серкә дип санарга күнеккән Кәрим, кирпечтән сарай салып куярга сорагач та, «бер-ике көндә эшләп ташлыйбыз аны», дип кенә куйды* (Сөйләм).

*БОРЧУ<ГА>* ❖ **БОРЧУ<ГА> САЛУ (ТӨШЕРҮ).** Тынгысызлау, борчу, мәшәкатьләү. *Ләкин полковник кулындагы материалның гадәттән тыш күплеге Зарифны уйга калдырды, тирән борчуга салды: «Бу ни эш? Үткән төндәге ябулар, тентүләр аркасында шул чаклы документлар кулга төшерелгәннәрме?»* (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *Мине гел хәсрәткә, борчуга төшереп тормасаң иде!* (Ф. Бәйрәмова. Туфаннан таралган татарлар).

**БОРЧУГА ТӨШҮ.** Борчылу, тынычсызлану. *Малайлар читкә карап кына көлешеп алдылар. Кара мыеклы борчуга төште: – Кара син, әй, чәнчелеп киткере!..* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *– Ни булды? – дип кабат сорады Юматша, борчуга төшеп* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

*БОРЫЛЫП* ❖ **БОРЫЛЫП КАРАРГА ДА ӨЛГЕРМИСЕҢ** *к.* «а» дигәнче. *Кышкы көн бит ул яшьлек кебек: борылып карарга өлгермисең, ник кырык эшең кырылып ятмый, узып киткән була* (Н. Әхмәдиев. Мөнирстан). *Лобачевский борылып карарга өлгермәде, кемдер аны беләгеннән кысып тотты* (Җ. Тәрҗеманов. Лобачевский һәм Хәлфин).
Төрдәше: «а» дигәнче һ.б.

*БОРЫЛЫРГА* ❖ **БОРЫЛЫРГА ДА ВАКЫТ (ИРЕК) БИРМӘҮ.** Ашыктыру, тынгылык бирмәү. *Ишектән бәреп керүчеләр борылырга да вакыт бирмәделәр, эткәләп-төрткәләп алып чыгып киттеләр* (Сөйләм).

**БОРЫЛЫРГА ДА <УРЫН> ЮК.** 1. Эш бик тыгыз булып, буш вакыт бөтенләй булмау. *Котбетдин эчке тәртип кагыйдәләрен укый: – Ашыкма әле, ирекнең шартлары шундый күп – борылырга да урын юк монда! Котбетдин бер язучы янына сөйләшеп утырырга дип кергән* (Ш. Галиев). *Кич җитсә, борылырга да урын юк. Кич җитсә, яшьләр вечерга (кичке уенны элек шулай атыйлар иде) тау башына җыелып, бии, җырлый торганнар иде* («Татарстан яшьләре» газ.).

2. Борылыр җир дә булмау. *Мәрьямбану коты чыгып уйлый икән: «Бу тар сукмакта борылырга да урын юк, очрашкач, болар мине таптап китә икән инде», – дип...* (Ф. Бәйрәмова. Кырык сырт).

*БОРЫЛЫШ* ❖ **БОРЫЛЫШ ЯСАУ.** Зур үзгәреш булдыру. *Исламнур, акланырга теләп, болай диде: «Заман борылыш ясый, Басыйр Бариевич, кайбер кешеләрне аңлап булмый!»* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Тормышта дүрт тапкыр кискен борылыш ясарга туры килде* (Г. Шәйхи. Бездән соң ни кала?).

*БОРЫН* ❖ **БОРЫН АРКЫЛЫ.** 1. Теләр-теләмәс, канәгатьсезлек белән (сөйләшү). *Галимуллин, күзлеген сөртеп, саргылт сакалын сыйпап, борын аркылы гына җавап кайтарды* (К. Нәҗми). *Ул, үзенең симез иреннәрен кузгатырга иренеп, борын аркылы көлә* (Г. Гали. Харис Саттаров).

2. Ишетелер-ишетелмәс, аңлашылыр-аңлашылмас. *Тик бары аның тавышы бозылган, борын аркылы сөйләшә торган булып, бөтенләй тыңкышланган һәм дә борыны табигый төсен югалтып, корт ашаган борчак кузагы төсенә кергән иде* (Ш. Камал).
Төрдәше: борын астына сөйләү (әйтү; җырлау һ.б.); борын астыннан 2; борын эченнән.

3. Өстән генә карау. *Ярда комда кызынып яткан, трусиктан гына калган хатын-кызларга кызарган борыны аркылы карап ыржая* (Һ. Такташ).

**БОРЫН АСТЫ КИБӘ БАШЛАУ.** Малай-шалайлыкны үтеп, тормышны бераз аңлый башлау. *– Син, Сауранны алгач, Тимер-Мәликне дә, Балтыкчы бине дә кылычтан үткәргәнсең, анысын борын асты кибә башлаган һәр такырбаш белә, – дип, ипле, тыныч тавыш белән генә ялкын кузгатты ул* (В. Имамов. Карабәк). *Борын асты кибә башлагач, кичке «уен»га чыгып, кызлар белән кулга-кул тотынышып, «тимер чыбыклы», «наза» һәм тагын әллә нинди уеннар уйнаган истә* («Татарстан яшьләре» газ.).

**БОРЫН АСТЫ (ТӨБЕ) КИПМӘҮ (КИБЕП ҖИТМӘҮ)** *к.* авыз суы кипмәгән. *– Адәм актыгы! Шүрәле булырга синең борын астың*

*кипмәгән әле* (Ә. Гаффар. Богау). *Борын асты да кибеп җитмәгән әнә шул егет кисәгә менә хәзер тәртәгә ничекләр китереп типте!* (Р. Вәли. Шәһрәт).

Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

**БОРЫН АСТЫ ЮЕШЛӘНҮ** *к.* авыз суы кипмәгән. – *Борын асты юешләнмәсә дә, ил агасына яшьтәш булырга иртә әле миңа. Әмма минем дә ил агасы буласым килә* (М. Хуҗин. Осталар).

Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

**БОРЫН АСТЫН КҮРМИ, <УРМАН АРТЫН (АСТЫН) КҮРӘ (ТИКШЕРӘ)>** *к.* аяк астын тикшермичә, урман астын тикшерү. *Үз борын астын күрмәгән, урман астын тикшерер* (Ай колакланса, ни була?). *Әмма Галимҗанның ул «акайган күзләр» нурында нинди акыл барлыкны кети-мети уйлап, үз борын астын күрми йөргән шәкертләр белми шул әле* (С. Поварисов. Пәйгамбәр таңы).

Төрдәше: аяк астын тикшермичә, урман астын тикшерү һ.б.

**БОРЫН АСТЫНА СӨЙЛӘҮ (ӘЙТҮ; ЖЫРЛАУ һ.б.).** Борын белән сөйләү (әйтү; жырлау һ.б.), акрын сөйләү һ.б. *Садыйк абзый, сүзне игътибарсыз үткәреп җибәрергә теләп, борыны астына мыгырданып алды: – Маташтым инде шунда акрын-акрын...* («Казан утлары» ж.). *[Рассуханов] (борын астына мыгырдый). Разберутся. (Ачыкларлар)* (З. Хәким. Телсез күке).

Төрдәше: борын аркылы 2 һ.б.

**БОРЫН АСТЫНДА.** Якында гына, янәшәдә. *Борын астында әнә бит нәрсәләр эшләп яталар икән. Әзерлән* (Г. Ахунов. Идел кызы). *Иң мөһиме, эш тукталмасын, күз борын астында...* (К. Кара. Зур акчалар). *Борын астындагын алты ай эзләгән* (Мәкаль).

Төрдәше: борын төбендә.

**БОРЫН АСТЫНДАГЫ БҮРӘНӘНЕ КҮРМИ, <УРМАН АРТЫНДА ОЧКАН (АРТЫНДАГЫ) КОШНЫ КҮРӘ>** *к.* аяк астын тикшермичә, урман астын тикшерү. – *Син Маратны белмисең дә икән әле, ул бит борын астындагы бүрәнәне күрми, урман артындагы кошны күрә* (Сөйләм).

Төрдәше: аяк астын тикшермичә, урман астын тикшерү һ.б.

**БОРЫН АСТЫНДАГЫНЫ КҮРМӘҮ.** Үзенең яки якын кешесенең гаебен күрмәү. *Борын астындагын күрми, урман артындагыны күрә* (Мәкаль). *Борын астындагыны күрми* (Р. Абдуллина. Сөйләм культурасы).

Төрдәше: аяк астын тикшермичә, урман астын тикшерү һ.б.

**БОРЫН АСТЫННАН** 1. *к.* борын аркылы. *Тузгалак, ачуы килеп, борын астыннан нәрсәдер мыгырдап чыгып китә* (А. Гадел. Алтынчәч). *Арслангали иртән торып, ишек алдындагы юынгыч янында баганага беркетелгән ватык көзгедән үзенең йончыган йөзенә карый-карый, сакал-мыегын кыра, борын астыннан акрын гына җыр суза* (Д. Каюмова. Урланган бәхет).

Төрдәше: борын аркылы 2 һ.б.

**БОРЫН АСТЫННАН <ТАРТЫП> АЛУ.** Үзеңеке булачак нәрсә (кемсә) кулдан ычкыну. *Тол Сөембикәнең мәһабәт Сафа Гәрәй ханга хатын булганын ишеткәч, Иванның җене чыкты, әйтерсең лә аның иң матур мәгъшукасын борын астыннан тартып алдылар* (Р. Батулла. Сөембикә).

**БОРЫН АСТЫННАН АЛЫП КИТҮ**. Эләкмәү, кулга кергәндә генә башканыкы булу. *Шатлыгы эченә сыймый иде: – Мин моны губернатор киявенең борын астыннан алып киттем, менә шулай!* (Р. Вәлиев. Дөнья гаме). *Борын астыннан сөекле иреңне алып китә башласалар, үзең нишләр идең микән әле?* (Л. Лерон. Чыктым аркылы күпер).

Төрдәше: борын астыннан китү 2; борын астыннан шудырту (урлау).

**БОРЫН АСТЫННАН АРЫ КҮРМӘҮ.** Чикләнгән булу, вак-төяк белән мавыгып, олы нәрсәләрне сизмәү. *Яхшы гына җитәкче булып башлаган иде, хәзер борын астыннан ары күрмәү чирен йоктырды* (Сөйләм).

Төрдәше: борыннан ары күрмәү.

**БОРЫН АСТЫННАН КИТҮ.** 1. Якын җирдән, кемнең дә булса яныннан ераккарак китү, ераклашу. *[Гөлҗиһан] Фатыйма тудык? Һә! Борын астыннан китеп торыр әле. Мин аны чакырмадым* (Г. Камал. Банкрот).

2. Кулга кергәндә ычкыну, эләкмәү. – *Эх, саклап калып булмады үзен, барысы да*

*җайланды дигәндә генә, борын астыннан китте* (Сөйләм).
Төрдәше: борын астыннан алып китү һ.б.

**БОРЫН АСТЫННАН ШУДЫР(Т)У (УРЛАУ).** Башкасына булырга тиешле әйберне яшертен алу. *Аларның яннарында кырыкмыш тайлар уйнашып йөриләр, бик күп сарыклар, сыерлар борыны астыннан урлап-урлап, печәннең каймагын хәрамлап йөриләр* (Г. Исхакый. Ул икеләнә иде). *Бер зур нефть җирен, инглизләрнең борын астыннан шудырып, Америка капиталистлары сатып алып өлгерделәр* (Ф. Әмирхан).

**БОРЫН АСТЫҢНЫ БЕЛ (ТИКШЕР).** «Кешене тикшергәнче, үз гаебеңне бел дә тик тор» мәгънәсендә. *Кешене тикшереп гомереңүтә инде, борын астыңны бел дә тик утыр инде* (Сөйләм).

**БОРЫН АСЫЛЫНДЫРУ** *к.* авыз бөтештерү (бөршәйтү) 2. *Күңеле тулышып, борынын асылындырып бераз йөргәннән соң, Данис, күңеле тулып, балага күрсәтмичә, еш кына елап та ала* («Туган як» газ.).
Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**БОРЫН АСЫП (СУЗЫП) КАЛУ.** Өмет иткәнне кулдан ычкындыру, коры калу; алдану. *Ә кайчакларда җан-фәрманга чабып килсә дә, борын сузып калырга туры килә иде аңар* (Ш. Маннур. Муса).

**БОРЫН АША КАРАУ.** 1. Һичбер әһәмият бирмичә, өстән генә карау. *Үземне күрсәтү өчен алгарак чыгып бассам да, бу кыз минем яннан борын аша гына карап узды* (Сөйләм).

2. *к.* амбициягә бирелү. *Мондый шәхесләр үзләренең эчке дөньялары гүзәллеге белән, кешеләргә карата күңелләрендә мәхәббәт саклауга сәләтле булулары белән, яшәешнең гүзәллеген аңлап, аны башкаларга да җиткерергә омтылулары белән, теге бәндәләргә борыны аша карап, үзләрен «Мин кем икән?» дип, масаеп йөрүче «рухи гарипләргә» караганда бәхетлерәк* (matbugat.ru).
Төрдәше: алып узу һ.б.

**БОРЫН АША (АРКЫЛЫ; ЭЧЕННӘН) СӨЙЛӘҮ.** Теләр-теләмәс кенә, аңлаешсыз итеп сөйләшү. *Хәйрулла мулла – Кышкар шәкерте. Сүзне борын аша сөйли* (Г. Исхакый. Кыямәт). *Тик бары аның тавышы бозылган, борын аркылы сөйләшә торган булып, бөтенләй тыңкышланган* (Ш. Камал).
Төрдәше: борын аркылы һ.б.

**БОРЫН БАШЫНА (БАШЫННАН).** Җан башыннан, һәр кешегә, һәрберенә. – *Күп сорамыйбыз, җиде кеше эшлибез икән, борын башына берәр мең бирәсең, шуңа өстәп, бер меңен мәгәричкә саласың да, бөтенесе буладыр шалкан бәясе – сигез мең тәңкә акча* (В. Нуруллин. Әгәр син булмасаң). *«Восток» ресторанына төшеп, өстәл алабыз. Борын башына биш сум чыга* (М. Мәһдиев. Сагынам, дуслар, илкәйне...).

**БОРЫН БЕЛӘН БАГАНА АУДАРУ (АУДАРЫП ЙӨРҮ)** *к.* алып узу. *Карале тегеңә, Алланың кашка тәкәсе диярсең, борыны белән багана аударып йөрмәсә!* (Сөйләм).
Төрдәше: алып узу һ.б.

**БОРЫН БЕЛӘН БОЗ ЕРТУ (ТИШҮ; ЧОКУ; ЯРУ).** 1. Авыр, газаплы эш эшләү. *Председатель бу юлы, хәтта озак сузып торырга теләге үк юклыгын сиздерергә тырышып, берьюлы өзеп салды: – Сыяр. Гыйльменисаттәй кебек борыны белән боз тишеп гомер иткән, Гыйльменисаттәй кебек уллар-кызлар үстергән кешене, әгәр хәлемнән килсә, музейга куяр идем әле мин* (Ф. Хөсни. Гыйльмениса). *Чөнки без татар токымыннан. Ә татар борыны белән боз тишсә дә аны күрмәскә тырышачаклар* (Г. Галиева. Милләт каһарманы).
Төрдәше: карыны белән кар ертып, борын белән боз тишеп.

2. Бик үткен, чая булу; тырышып-тырмашып, теләсә нинди каршылыкны җиңеп чыгу. *Мишәр! Борыны белән боз тишәр* (Г. Рәхим). *Әгәр әнисе исән булса, менә хәзер аңа беркем дә кирәк булмас, аның белән ул иске мунчада яшәргә дә бишкуллап риза булыр, аның өчен җанын ярып бирер, борыны белән боз, карыны белән кар ярыр иде...* (Ф. Садриев. Көлми торган кеше).
Төрдәше: авызга җаны килгәнче (чыкканчы) тырышу һ.б.

**БОРЫН БЕЛӘН БОЛЫТ СУКАЛАУ (СӨЗҮ)** *к.* алып узу. *[Юмай] Алай борының белән болыт сукалама, кызый* (Р. Хәмид). *Мизгел*

*эчендә [акча] хәерчене патшага әйләндерә, әллә нинди бетәшкән мескен бәндәне дә кояш янына менгереп куя, тегесе борыны белән болытларны сөзә башлый* (Р. Габделхакова. Көмеш тун).

Төрдәше: алып узу һ.б.

**БОРЫН БЕЛӘН БОРЧАК (БОДАЙ) ЧҮПЛӘҮ.** Утырган җирендә башын алга таба төшерә-төшерә, йокы белән көрәшү. *Урындыкларда поезд көтеп утырган кайбер кешеләр борыннары белән борчак чүплиләр иде* (Сөйләм).

Төрдәше: борын белән чуку.

**БОРЫН БЕЛӘН БҮРӘНӘ ТАРТТЫРУ.** Гырылдау, гырлау. *[Гайфул] ...чишенмичә-нитмичә, мич башына үрмәләп, йомарланып ятты. Шул ятудан җомга намазын да, капчык һәм хәсрәтен дә онытып, борыны белән бүрәнә тарттырып алды* (Ф. Хөсни. Гармончы).

**БОРЫН БЕЛӘН ҖИР СӨРҮ** *к.* авызга җаны килгәнче (чыкканчы) тырышу. *Тәки урнашты Нәҗип, кирәкле кәгазьләрен тапты, авылдан да җибәрделәр, борыны белән җир сөрде егет, мәгәр һәммәсен җиренә җиткерде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *[Расих] Кара хәерчеләр минем алда борыннары белән җир сөрергә тиеш!* (Х. Ширмән. Авылым учагы).

Төрдәше: авызга җаны килгәнче (чыкканчы) тырышу һ.б.

**БОРЫН БЕЛӘН КЕНДЕК КЫТЫКЛАУ.** Буе кечкенә булуга ишарә. *Биюен бии дә, бигрәк кәтәнә, борыны белән кендекне кытыклый, – ди* (Т. Миңнуллин).

**БОРЫН БЕЛӘН КҮКНЕ СУКАЛАУ (СӨРҮ)** *к.* алып узу. *Борыны белән күкне сукалап, йөрәк дәртен шигырь юлларына күчереп йөргән Айбулатның тора-бара бу эшкә күңеле тәмам суынды* (Т. Әйди. Божра).

Төрдәше: алып узу һ.б.

**БОРЫН БЕЛӘН СӨЙЛӘҮ.** 1. Салкын тиюдән яки башка сәбәптән, сөйләгәндә кайбер авазлар борын аша чыгу. *– Булмас, безнең Шәмсезыян борын белән сөйләшә иде. Синең сүзләр бөтенләй аермачык чыга!* (Э. Шәрифуллина. Мәхәббәтнең җиде төсе).

2. Эре кылану. *Таныш булмаган кешеләр янында ул борын белән генә сөйләшә иде* (Сөйләм).

Төрдәше: алып узу 2 һ.б.

**БОРЫН БЕЛӘН ТАШ ӨСТЕНӘ КАПЛАНУ.** Уңышсызлыкка очрау; җиңелү. *Тукатамыш хан Сәмәркәнд юлында борын белән таш өстенә каплангандай булды* (В. Имамов. Карабәк).

Төрдәше: аска калу һ.б.

**БОРЫН БЕЛӘН ЧУКУ** *мыск., к.* борын белән борчак (бодай) чүпләү. *– Карале тегеңә, алдында очкан черкиләрне борыны белән чукый да чукый* (Сөйләм).

Төрдәше: борын белән борчак (бодай) чүпләү.

**БОРЫН БОЗГА, КОЙРЫК СУМАЛАГА КАТУ.** Чыга, ычкына алмаслык бер хәлгә дучар булу, аптырау, нишләргә дә белмәү. *Тиз генә нәрсә булса да уйлап табарга кирәк булды: борын бозга, койрык сумалага каткан иде* (Сөйләм).

**БОРЫН ГЫНА УТЫРЫП КАЛУ.** Бик нык ябыгу, бетеренү. *– Ашыйсы килми, – диде Мансур. Соңгы вакытта болай да аның борыны гына утырып калган иде* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Аны танырлык түгел иде. Эченнән энә үтәрлек, йөзендә борыны гына утырып калган* (М. Әмирханов. Әлвидаг).

Төрдәше: авыз ачса, кече теле күренү 1 һ.б.

**БОРЫН ҖИЛЕГЕ КЕБЕК** *мыск.* Яшүсмерләргә карата: «беренче карашка җилле генә күренсә дә, борын асты кибеп җитмәгән әле» мәгънәсендә кулланыла. *Карап торышка борын җилеге кебек булса да, тотышы белән ерак сәфәрләрдә булган кешене хәтерләтергә тырыша иде* (Сөйләм).

**БОРЫН ҖЫЕРУ.** 1. Ошатмау; мыскыллап, җирәнеп карау. *Шулай, Гаяз Исхакый әсәрләренең телен ошатмыйча, борын җыерган кешеләрне дә күргәнебез бар* (А. Тимергалин. «Инкыйраз»га – йөз ел). *Мирвәли җирәнеп борынын җыерды: «Чирлеләр боткасы!» һәм баш тартты: – Ашыйсым килми,– диде* (А. Гыйләҗев. Өч аршын җир).

2. Берәр нәрсә белән ризалашмауны белдерү. *Ә бервакыт чоланнан ит чәлдергәнне әни сизгән дә... Гөлфинур тагын борынын*

*жыерды. – Тал чыбыгы белән аркаңны каезлады, иеме?* (А. Вергазов. Үзеңә кайту). *Мин шул хакта әйткәч, Шәйхи ризасызлык белдереп борынын жыерды да: – Минем сезнең нотыкларны тыңлап торырга вакыт юк! – дип, машинасына утырып, китеп тә барды* (В. Нуруллин. Әгәр син булмасаң...).

**БОРЫН ЗАМАН.** Иске вакыт. *Борын заман бер Ир берлән Хатын торган, / Тормышлары шактый гына фәкыйрь булган* (Г. Тукай. Кәҗә белән Сарык хикәясе). *Борын заман бик белемле табиб торган, / Сырхауларга әйбәт дару табып торган* (Г. Афзал. Патша белән табиб турында әкият).

Төрдәше: әллә кайчан һ.б.

**БОРЫН ЗАМАНДА** *к.* әллә кайчан. *Булмаса, сөйлик. Борын заманда булган, ди, бер башкорт* (Г. Ибраһимов. Татар хатыны ниләр күрми). *Борын заманда башы бүрекле, аягы төкле бер үрдәк булган* (А. Алиш. Сертотмас үрдәк).

Төрдәше: әллә кайчан һ.б.

**БОРЫН КАНАТУ.** Җиңелү. *Болгар каласы бай иде; осталары нинди генә сарайлар, манаралар төземәгән дә, галимнәре нинди генә фәннәр өйрәнмәгән, шагыйрьләре нинди генә кыйссалар язмаган, кара халкы иген иккән, тук-көр яшәгән, яугирләре Сүбүдәйнең борынын канаткан* (Р. Батулла. Сөембикә). *Былтыр Бәнҗәдә борын канатып кайтуың шуңа мисал* (В. Имамов. Казан дастаны).

Төрдәше: аска калу һ.б.

**БОРЫН КЕРСӘ, КОЙРЫГЫ КЕРЕП ЖИТМӘҮ.** Ныклап урнашмау, нәрсәгәдер хак казанып житмәү. *Димәк, Исмегөл дә түгел, Шәфика да, ә Наргизә... Әле театрга кайтып та өлгермәгән, борыны керсә, койрыгы кереп җитмәгән дигәндәй, ә инде баш рольне биреп тә куйганнар* (М. Маликова. Басып сайрар талы бар).

**БОРЫН КИРЕ КАРАУ.** Ошатмау, игътибар итмәү. – *Исемә төшермәгез әле шуны, борыным кире карый минем аңа* (Сөйләм).

Төрдәше: җан тартмау; җене <м; ң> сөймәү; күңел бармау; күңел тартмау; күңел ятмау; күңелгә басып.

**БОРЫН КҮКТӘ** *к.*алып узу. *Чаллыда ятып шәпләнгәч, тракторчы исемен алгач, борын күктә иде, авылга чана тартып кайтып керергә бик хурланган идек, ярый әле, караңгы төште, авылдашлар безне күрми калды* (А. Гыйләҗев. Язгы кәрваннар). *Киеме кәттә, борыны күктә булды, Теләсә нинди ирне аздыру аның өчен мөрәвәт саналды* (Ф. Садриев. Таң җиле).

Төрдәше: алып узу һ.б.

**БОРЫН КҮРСӘТҮ**. Сиздерү, барлыгы сизелү. – *Яман шешне мул борын күрсәтүгә үк яндырып йә көйдереп юк итәргә кирәк* (В. Имамов. Карабәк). *Нидер буласы икән, алдан аның хәбәрчесе – юләрлек «борын күрсәтә», диләр* (Ф. Яхин. Август ае). *Алары да урамга бик борын күрсәтми, телевизордан мультик карап утыра* (Р. Зәйдулла).

**БОРЫН КҮТӘР<ЕЛ>Ү (ЧӨЮ).** Мөһимлеген күпертеп күрсәтү, башкалардан өстен булуына басым ясау; эреләнү, һафалану, горурлану. *Син теләгәннәр килмиләр шул. Әллә дөрес түгелме? Шулай да борныбызны әллә кайда күтәргән булабыз тагын* (К. Тинчурин. Назлы кияү). *Борынны чөйгән, кулын кесәсенә тыккан: – Бик исем китә! Ичмасам, төкереп тә бирмим!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: баш әйләнү 4 һ.б.

**БОРЫН ОЧЫН СЕЛКЕТМӘҮ.** Мөһим дип санамау, игътибар итмәү. *Уянмый ул, селкетми дә борын очын* (Г. Тукай). *Яшьләр дә төшеп калганнардан түгел бугай: картның янавына борын очларын да селкетмиләр, уны белән җавап кайтаралар* (Г. Мөхәммәтшин. Йөрәктәге эзләр).

**БОРЫН САЛ<ЫНДЫР>У (ТӨШ<ЕР>Ү).** 1. *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. – *Салындырма борынны, сеңелкәй!* (Г. Бәширов. Гыйбрәт). *Үпкә юк, / Артык ачу да юк, / Болай гына борын салынган...* (Һ. Такташ).

Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

2. Элеккеге тәкәбберлеген югалту; мескен хәлгә төшү. *Госбанктан кайтып барышлый, / Бүген күрдем үзен милициядә, / Борыны төшкән, йөзе сагышлы* (М. Җәлил). *Бу, билгеле, өйдәгеләргә ошамый, борыннарын салындыралар* (М. Әмирханов. Тәкъдир).

**БОРЫН САЛЫНДЫРУЧЫ.** Төшенкелеккә бирелгән, боеккан, үпкәләгән. *Хәер, Әлтафиләр нәселендә тормышның теләсә нинди артла-*

*рында да борын салындыручы юк* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).

**БОРЫН САЛ<ЫНДЫР>ЫП ЙӨРҮ** *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. *Кайнар ашсыз, яңгыр эчендә дип, / Борыныгызны салып йөрмәгез* (Һ. Такташ). *– Менә шул: борыныңны салындырып йөрисе юк* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**БОРЫН САЛ<ЫНДЫР>ЫП УТЫРУ** *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. «*Туктагыз әле, туктагыз, – диде ул, – ни дип соң без үлем турында сөйләшеп, борыннарыбызны салып утырабыз*» (Г. Кутуй. Яшен).

Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**БОРЫН СИЗГЕР <БУЛУ>**. Бар нәрсәне белеп тору, торышны аңлау. *Борыны сизгер Вәсиләнең* (А. Гыйләҗев. Әтәч менгән читәнгә). *Сәетнең дә борын сизгер, мондый эштән читтә каламы инде?* (Р. Зәйдулла. Абага чәчәге).

**БОРЫН СУЗУ.** Кирәкмәгән эшкә тыгылу, кысылу, катышу; әрсезләнеп өмет итү, кызыгу. *Кеше өлешенә борыныңны сузмассың, эттән туган!* (Г. Бәширов. Сарут). *[Җәүдәт] Аның урынына борын сузу... бу бит – әдәпсезлек* (Г. Ахунов. Утлар яна учакта). *Урысларның өчдүрт йөзләп ташбашы әле шуңа да игътибар бирми борыннарын сузып караганнар* (В. Имамов. Казан дастаны).

Төрдәше: арага ботны кыстыру һ.б.

**БОРЫН СЫЗГЫРТУ.** Йоклау. *Йөрер Сабит абзаң төнката! Ул әллә кайчан борынын сызгыртып йоклап ята инде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Гамил башын төртү белән борын сызгыртырга тотынды* (А. Тимергалин. Таш алиһә).

Төрдәше: йокы базарына китү; йокы базарында сыбызгы сату; йокы симертү; йокы туйдыру; йокыга китү; йокыга ою; йокыга талу; йокыга чуму; йокының кирәген бирү.

**БОРЫН ТАРТУ (ТАРТЫП АЛУ).** 1. Хуплау яки хупламау. *[Гариф] Әхмәтвәли Кишәли әфәнде карап чыкты да... борынын тартты* (Ф. Бурнаш. Илһам). *Хәкимҗан, минем сүземне нығытуын белдергәндәй, борынын тартып куйды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

2. Елаган вакытта лышык-лышык борын тартып кую. *Каенана белән килен, аш-су китереп кухня белән зал арасында йөргән Зилә, күз яшьләрен яшерергә теләп, алгы як бүлмәгә чыктылар, мышык-мышык борын тарттылар* (А. Хәйретдинова. Язмыш).

Төрдәше: лышык-лышык елау.

3. *диал.* Чәчелгән орлык тишелү, шыту. *Басудагы уҗымнар борын тарткан инде* (Сөйләм).

Төрдәше: борын төртү.

4. *диал.* Нәфес төшү, ошату. *Тәрәзә алларында бакчалар, гөлләр булсын... Малай эндәшмәде, ул, мышык-мышык борынын тартып, пыялачыдан күзен алмый иде* (А. Гыйләҗев. Тәрәзәләр).

Төрдәше: күңел төшү.

**БОРЫН ТАРТЫП ТОРУ.** Борын эченә еш-еш һава алгалау (ягъни берәр нәрсә өмет итеп, кыюсызланып тору); гаебен танып тору. *Мин сыер койрыгы янында никадәр генә лышыклышык борынымны тартып торсам да, итегемне анда да күрүче булмады...* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Кайда ул ат, мылтык һәм азамат?!. Борын тартып тора таптанып* (Н. Арсланов. Еллар, язмышлар!).

**БОРЫН ТАШКА ТИЕП ҮСҮ.** Ятимлектә, үгилектә яки башкача михнәт күрү, чыныгу. *Үзе сөйләмәсә дә, без беләидек: ул, борыны ташка тиеп, балалар йортында үскән* (Сөйләм).

**БОРЫН ТИ<Г>ЕРЕП <КАРАУ>.** Укып карау, танышу. *Минем офыгым тар, күгем тәбәнәк чак, Мережковскийның шигырьләренә борынымны тигереп карасам да, әллә кая китә алмадым* (А. Гыйләҗев).

**БОРЫН ТИШЕГЕ БЕЛӘН КАРАУ** *к.* алып узу. *Гәүдәсе орчык буе гына булса да, дөньяга борын тишеге белән карап йөри* (Ф. Баттал. Мистер-абсолют).

Төрдәше: алып узу һ.б.

**БОРЫН ТӨБЕ КИПМӘҮ** *к.* авыз суы кипмәгән. *Ревизор андый җиргә сугылса да, әллә нигә бер сугыла, анда да борын төбе кибеп җитмәгәне* (Г. Гобәй).

Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

**БОРЫН ТӨБЕНӘ ТОНДЫРУ** *к.* авызына кундыру. *Шуларның борын төбенә тондырасы*

*иде, телләрен тешләп өзәрлек итеп* (Н. Дәүли. Агат).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**БОРЫН ТӨБЕНӘ <БЕРНЕ> ЯМАУ.** *Менә шуннан мич хәтле аю чыксын иде дә борын төбенә берне ямасын иде* (Н. Гыйматдинова. Нурулла).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**БОРЫН ТӨБЕНДӘ** *к.* борын астында. *Урак борын төбендә, ә план юк бүген дә* (Ш. Камал). *Һәм менә монда, борын төбендә, Фабарисовның гөманлавы буенча, шушы мәдрәсәләрдә Аллаһ сугышчылары әзерләп ятсыннар инде!* (Ф. Бәйрәмова. Соңгы намаз).

Төрдәше: борын астында.

**БОРЫН ТӨБЕНДӘ БАРМАК УЙНАТУ.** Янау, куркыту, ачулану. *Заһит, диваннан сикереп торып, Салихның борын төбендә бармак уйнатып алды* (А. Гыйләҗев).

Төрдәше: астына ут үрләтү һ.б.

**БОРЫН ТӨБЕНДӘ УТ КӨЙРӘТҮ.** Янәшәдә тыныч кына тәмәке тартып утыру. *Авыл халкын җыеп ялынды, ялварды, үтенде, ә нәтиҗә юк! Алар борын төбендә ут көйрәтәләр* (Н. Гыйматдинова. Нурулла).

**БОРЫН ТӨБЕНДӘГЕН КҮРМӘҮ.** Вак-төяктән олырак нәрсәләрне күрмәү. *Бәлки, Шаһит муеннан гашыйк булу сәбәпле, борын төбендәген күрмидер? Бәлки, шәп дуслар булып китәрбез!!* («Сөембикә» ж.).

**БОРЫН ТӨБЕННӘН АРЫ КҮРМӘҮ.** Бик өстән генә фикер йөртү, киләчәкне күзаллый алмау. *Монда да без эчке сәясәттәге борын төбеннән ары күрә белмәүнең җимешләрен җыябыз* («Кызыл таң» газ.).

Төрдәше: агач арасыннан (артында; артыннан) урман күрмәү һ.б.

**БОРЫН ТӨБЕННӘН КАЧУ.** Котылырга бернинди мөмкинлек булмаганда да качып китү. *Заһри бик хәтәр юлларда йөрде, әллә ничә тапкыр ГПУ кешеләренең борын төбеннән качты* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала). *Кирәк чакта гына йә берсенең җәя кереше шартлап өзелә икән, йә икенчесенең борын төбеннән җәнлек качып китә* (В. Имамов. Казан дастаны).

**БОРЫН ТӨРТЕП АЛУ.** Бераз йоклап алу, черем итү. *Кай көнне Сәхиягә мендәргә борын төртеп алырга да туры килми: әле берсе кереп аягына егыла, әле икенчесе* (Ф. Яруллин. Кыйгак-кыйгак каз кычкыра).

Төрдәше: йокы мендәр (ястык) сорамый; черем итү (итеп алу).

**БОРЫН ТӨРТЕП ЧЫГУ.** 1. Борынлау (бәбкә, чебеш). *Каршы яктагы әрәмә, аның артында ук яңа борын төртеп чыккан бәбкәләрен саклап, теләсә нинди җан иясенә кинәт ташланырга әзер ата каз шикелле мәгърур хәлдә торучы урман <...>* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң). *Эш шунда иде ки, күкәйдән яңа борын төртеп чыккан бер кара карга баласы үзен гаҗәп сәер тота, ул бер дә башка кара карга балаларына охшамаган* (З. Хөс니яр. Козгыннар йолдыз чүпли).

2. Тишелеп чыгу, шыту. *Үзенә бертөрле салкынча хуш ис аңкытып яткан йоп-йомшак шул дымсу җир өстендә, әле генә борын төртеп чыга башлаган яшь чирәмдә бер-берең белән әүмәкләшеп аунау үзе бер рәхәт иде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Бер тартмада балчык йомшартса, икенчесендә борын төртеп чыккан үсенте-кәлшәләрне сирәкләде* (В. Имамов. Нәзер).

3. *күч.* Барлыкка килү, туу (яңалык, үзгәреш). *Җирдән төртеп чыга / Һәрбер юлым, һәрбер әсәрем* (С. Хәким). *Әле патша заманыннан калган соры кортлардан арынып җитмәгән, менә сиңа мә! Аларның яңалары борын төртеп чыга* (Г. Бәширов. И язмыш, язмыш!).

**БОРЫН ТӨРТЕР<ГӘ> (ТӨРТЕРЛЕК ТӘ) УРЫН БУЛМАУ** *к.* алма төшәр<лек> урын булмау (юк). *«Мәйданда куелган концертны без дә тыңлар идек, борын төртер урын булмады», дип сөйләделәр соңыннан* (Сөйләм).

Төрдәше: алма төшәр<лек> урын булмау (юк) һ.б.

**БОРЫН ТӨРТҮ.** 1. *к.* авыз төртү. *Инде кая гына барып борын төртергә дип, уфтанып утырганда, бер хатын килеп аларга эндәште* (Р. Батулла. Фасил белән Васил). *Исәеп килүче каз бәбкәләре аналарының канаты астына борын төрткәннәр* (Ф. Гыйльми. Салават күпере).

Төрдәше: авыз төртү һ.б.

2. *к.* борын төртеп чыгу 2. *Кыяр-кыймас кына борын төртә башлаган чирәмлектә*

*малай-шалай Сабан туе алдыннан көч сынашырга тотына* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Җирләр чыкты, тау итәкләрендә хәтфә үлән борын төртте* (Г. Сабитов. Өч күңел).
Төрдәше: борын төртеп чыгу 2 һ.б.

3. Үсү, аякка басу. *Киләсе елда инде җырны әле генә борын төртеп килүче яшь буын дәвам итәр* (М. Әмирханов). *Борын төрткәнеңә үкенмичә, сабыйларның йомшак табаннарын иркәлә, сөй әле* (Х. Әюп).

4. Барлыкка килү. *Казан тылсымчысының кул хәрәкәтләрен өнсез күзәтеп торган төркем өстендә шом канат җәйде, күңелләрендә курку хисе борын төртте* (Ф. Латыйфи. Хыянәт). *Вульгар әдәбиятта, бигрәк тә дини үзәкләр тарафыннан басылган китапларда, элек татарларны төрлечә кимсетү, мәсхәрәләү өстенлек иткән булса, борын төртә башлаган үз милли матбугатыбызда моңа каршы көрәш көч ала барды* (Л. Хәмидуллин. Офыктагы рәшәләр).

5. *к.* борын тыгу 1. *Әтисенең һаман шәһәр урамнарын таптап, тегендә-монда борын төртеп йөрүе Галимҗанның да саруын кайната башлады* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында). *– Бурлар бу тирәгә борын төртмиләр, – диде Вахит Сәрдәрович, борчылыр урын юк дигәндәй, ышаныч белән кул селтәде* (Ә. Моталлапов. Елан җылыга елыша).
Төрдәше: борын тыгу 1; кеше эшенә тыкшыну.

6. Ярдәм сорау. *Хәзер нишләргә? Кемгә барып борын төртергә?* (М. Латыйфуллин. Курайчы малай). *Тәкъдир дигәннәре бу юлы да кабатлана калса, Идегәй кайсы таждар ышыгына барып борын төртергә мәҗбүр булчак соң?* (В. Имамов. Карабәк).

**БОРЫН ТӨШ<ЕР>Ү** *к.* авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2. *Тик сагызга катып беткән күлмәк-ыштан өчен әти «арт сабак»ны бик суганлап-борычлап укыткач кына, төште ул борын* (Ш. Маннур). *Беркөн күрдем үзен милициядә, / Борыны төшкән, йөзе сагышлы* (М. Җәлил. Сыра залында).
Төрдәше: авыз бөрештерү (бөршәйтү) 2 һ.б.

**БОРЫН ТҮБӘНӘЮ** *к.* борын салын<дыр>у (төш<ер>ү) 2. *Обкомнан ничәмә выговор күтәреп кайтты? Борыны түбәнәйдеме соң?* (Ә. Баянов. Урланган ай).
Төрдәше: борын салын<дыр>у (төш<ер>ү) 2 һ.б.

**БОРЫН ТҮШӘМГӘ ТИЮ** *к.* алып узу. *Әмир язганнарны укый-укый, горурлыктан борыннар түшәмгә тия яза иде: «Без менә нинди булган!»* (А. Гәрәева. Ни һоу? Яки ни хәл!). *Бер уңышлы роль башкарса, яшь актерның борыны түшәмгә тия башлый* («Сәхнә» ж.).
Төрдәше: алып узу һ.б.

**БОРЫН ТҮШӘМНЕ ТИШҮ** *к.* алып узу. *«Ул хәтле азынма инде, борының түшәмне тишә бит инде!»* (Сөйләм).
Төрдәше: алып узу һ.б.

**БОРЫН ТЫГАР УРЫН ЮК** *к.* алма төшәр<лек> урын булмау (юк). *Юл читләрен, тантана узасы мәдәният йорты тирәсен җиңел машиналар сарган, черкигә борын тыгар урын калмаган* («Матбугат.ру» порталы).
Төрдәше: алма төшәр<лек> урын булмау (юк) һ.б.

**БОРЫН ТЫГУ** *сөйл.* 1. Кирәкмәгән эшкә әрсезләнеп тыгылу, кысылу, катышу, тыкшыну. *– Бер карасаң, кооперативка борын тыгалар, бер карасаң, сәвитне үзләре ягына аударалар* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар). *Шаһгали дә борынын тыгарга җөрьәт итмәс, иншалла* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).
Төрдәше: борын төртү 5 һ.б.

**БОРЫН ЧӘЙНӘШҮ.** Тарткалашу, даулашу. *Мал өчен, корсак өчен бер-берсенең / Борыннарын чәйнәшәләр дә алар, / Сизмәсен дип хәйләбезне башкалар* (Һ. Такташ).

**БОРЫН ЧӨЕРҮ.** 1. Нәрсәдәндер суыну, бизү, читкә борылу. *Сөюдән сез борын чөермәгез, / Сөюне сез читкә типмәгез* (Н. Әхмәдиев. Сөйми яшәү ярамый). *Гамбәрия, теге чактагы үсмер яшьтәше кебек, алдына куелган сыйдан борын чөермәде* (Д. Зөбәерова. Сызган балдак).
Төрдәше: аркасын әйләнү һ.б.

2. *к.* алып узу. *Без идек ул! Ләкин аңа карап / Йөргән юк ла, борын чөереп* (И. Гыйләҗев. Авыл хур итмәс). *<...> күрше авыл мәктәбендә уздырыласы ачык дәресләренә, башка укытучылар кебек ат җигеп барудан борын чөергән булды һәм, химия укытучысын алып, «Москвич»ында кузгалды* (Ш. Алпар. Милләт өмете).
Төрдәше: алып узу һ.б.

**БОРЫН ЧӨЙДӘ <БУЛУ>** *к.* алып узу. *Синең шул борын чөйдә, җегетең командир дигәч*

*тә, алай бик масайма, дигән була* (М. Әмирханов). *Ә балык эләккән көнне Мансурның борын чөйдә. Бөтен авыл күрсен дип, юри балыгын эләктермәгә аса да койрыгын җирдән өстерәтеп кайта* (М. Әмирханов. Тәкъдир).

Төрдәше: алып узу һ.б.

**БОРЫН ЧӨЮ (ЧӨЕП ЙӨРҮ)** *к.* алып узу. *[Мәрфуга] Байлыгына масайган була да, әллә кем булган булып, борынын чөеп йөри* (Г. Камал. Хафизалам, иркәм). *Совет власте хөрмәтле Иван Ивановичлар кулында чакта борынын- ны бик чөя алмассың!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

Төрдәше: алып узу һ.б.

**БОРЫН ЭЧЕННӘН** *к.* борын аркылы. *Бригадирның бу сүзләренә каршы урманчы борын эченнән нидер мыгырдап кына куйды* (Г. Әпсәләмов. Газинур). *Ул, борын эченнән «Арлекино»ны көйли-көйли, абзарга кереп чыкканда, усал кыткылдап, канатлары белән бәреп, аның өстенә әтәч сикерде* (Ф. Садриев. Адәм әүлиясы).

Төрдәше: борын аркылы һ.б.

**БОРЫН ЭЧЕННӘН БОТКА ПЕШЕРҮ** *к.* авыз казанында ботка пешерү. *Анлык кына тәҗрибә бар. Борын эченнән ботка пешермәс* (Г. Сабитов. Калай күке). – *Язмача һәр җир хакында аерым сорау булса... – дип, борын эченнән ботка пешереп тик утыра* («Безнең гәҗит» газ.).

Төрдәше: авыз казанында ботка пешерү һ.б.

**БОРЫН ЭЧЕННӘН ҖЫРЛАУ** *к.* авыз казанында ботка пешерү. *Поезд кузгалгач, ул хәтта борын эченнән генә бер җыр да җырлады* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары). *Хәтта борын эченнән җырлап та ала, кайчакта шоферына берәр шаян сүз әйтеп, тегесен шаркылдап көлдертә дә* (Г. Әпсәләмов. Поши баласы).

Төрдәше: авыз казанында ботка пешерү һ.б.

*БОРЫН-БОРЫН* ❖ **БОРЫН-БОРЫН ЗАМАНДА.** Бик күп еллар элек, күптәннән. *Борын-борын заманда юаш хайваннарның, ерткыч җанварларның койрыклары бөтенләй булмаган* (А. Алиш. Койрыклар). *Борын-борын заманда, элекке Болгар илендә, яшәгән, ди, бик оста куллы Ясәви исемле кеше* (А. Гадел. Алтынчәч).

Төрдәше: Әби патша заманында һ.б.

*БОРЫНГА* ❖ **БОРЫНГА БОРЫН <ОЧРАШУ>.** Йөзгә-йөз килү. *Шулчак яу кырыннан, төтен-тузаннан исән чыккан урыс атлылары әлеге ун татар белән борынга борын очрашты* (Р. Батулла. Сөембикә). *Йорт хуҗасы белән халык контроле вәкиле ике әтәч кебек борынга борын килеп бастылар* (А. Хәлим. Койма).

**БОРЫНГА БОРЫП (БӨРЕП; БӨТЕРЕП) ТЫГАРЛЫК.** Бик яхшы, әйбәт, сыйфатлы. *Өстендә ап-ак кофта иде, тал чыбыгыдай нәфис гәүдәсенә сыланып торган кара итәк. Аякларында биек үкчәле түфли, Чибәр Әлтаф әйтмешли, борынга бөтереп тыгарлык* (М. Әмирханов. Тояк эзе). *Борынга әче тәмәке исе килеп бәрелгәч, шикләнүләрем шундук юкка чыкты. Борынга борып тыгарлык* (kitap.net.ru).

Төрдәше: борынга төреп тыгарлык.

**БОРЫНГА ДА ЭЛМӘҮ.** Әһәмият бирмәү, бар дип тә белмәү. *Ул иптәшләренең сүзен борынына да элмәде, чалбар балакларын сызганды да суга кереп китте* (Сөйләм).

Төрдәше: бөергә таяну 1; ваемга да кермәү (кереп чыкмау); ваемында да юк; ваена да кермәү (кереп чыкмау); ваенда да юк; гаменә дә кермәү (кереп чыкмау); гаме<ндә> дә юк; колакка да алмау; колакка <да> элмәү; фәлүәт тә итмәү.

**БОРЫНГА ИС КЕРҮ.** 1. Мәхәббәт хисе туу; дәрт керү. *Борынга шактый ис кергәч, авыл кызларын шәһәр кызлары белән чагыштыра башладым* (Х. Ширмән. Еракттагы йолдызым). *Кулларына төшкән акчаданмы, әллә аларның башкаларны җылытырга тырышуларыннан киләме бу бәхет – дөресрәге, борыннарына ис кергән ундүрт-унбиш яшьлек үсмерләр бу хакта уйлап карамый гына түгел, уйлауны күз алдына да китермиләр* (А. Хәлим. Читтә).

Төрдәше: танауга ис керү.

2. Дөнья күрү, тәҗрибә туплау. *Юк! Тукталып калырга Габдулла инде җитәрлек дәрәҗәдә олы һәм борынына ис кергән егет* (Ә. Фәйзи. Тукай).

Төрдәше: авызы пешкән өреп капкан һ.б.

**БОРЫНГА КИРТЛӘҮ (КИРТЛӘП КУЮ).** Хәтердә саклау, онытмау; бик нык кисәтү. – *Әмма борыныңа киртләп куй: аңардан ераграк булуың хәерле* (Ф. Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет). *Мыегыңа чорнап куй да борыныңа*

*киртлә: мылтыгыңда соңгы бер-бер патрон кала торган булсын* (Ә. Гаффар. Кәфенгә кесә кирәкми).

Төрдәше: колакка киртү (киртләү); киртеп / киртләп кую); колакка туку; күңелгә салу; күңелгә салып кую; мыекка урау; мыекка чорнау; хәтергә беркетү; хәтергә салу; хәтергә салып кую; хәтергә сеңеп калу; хәтергә сең<дер>ү.

**БОРЫНГА КӨЯНТӘ ЭЛҮ** *к.* алып узу. *Дус саналган кыз-кыркын сөенер инде. Чөелгән борынына көянтә элгәннәр, дияр* (Н. Гыйматдинова. Елан).

Төрдәше: алып узу һ.б.

**БОРЫНГА КУНДЫРУ** *к.* авыз җебетү 2. *Ачуым килүен килмәде, тик шулай да тегенең акбурга буялган борынына йодрык белән берне кундырасым бик килде* (И. Гази). *Беренче уңышсызлык ук... Бик ансат кына җиңәргә уйлаган идең дә, барып чыкмады, борыныңа кундырдылар* (З. Фәтхетдинов. Кем – кемне).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**БОРЫНГА КЫЗЫЛ ТАРАКАН ҖИБӘРҮ** *к.* авыз җебетү 2. – *Борынына кызыл таракан җибәр!* (З. Мансуров. Кылдан нечкә, кылычтан үткен).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

**БОРЫНГА СУГУ.** 1. Узып китү, җиңеп чыгу; өстенлеккә ирешү. – *Кибәхуҗалар килмәс диебрәк чыккан идек, болай булгач, безнең борынга суктыгыз инде сез* (Ф. Хөсни. Йөзек кашы). *Җавап бир, Хәй, валлаһи борынга сугалар* (М. Фәйзи. Кызыл йолдыз).

Төрдәше: алга чыгармау һ.б.

2. Минминлегенә бәрү. *[Муса мирза] Бу кирәк инде. Бу тегеләрнең борынына сугар өчен ясалган инде* (Г. Исхакый. Җәмгыять). *Карчыкның шаярган сымак әйтеп салган сүзе Гарифның борынына суккан шикелле булды* (Ш. Камал. Акчарлаклар).

Төрдәше: борынга суктыру һ.б.

**БОРЫНГА СУКТЫРУ** *к.* борынга сугу 1, 2. – *Быел язда зур сабан туе ясап, теге әтәчләрнең борынына суктырыйк инде, хәзрәт* (Г. Ибраһимов. Яшь йөрәкләр). – *Тукта, тегеләрнең борынына суктырыйм әле! – дип, тагын хәтсез генә урып ташлады* (Г. Бәширов).

Төрдәше: борынга сугу 1, 2 һ.б.

**БОРЫНГА ТӨРЕП ТЫГАРЛЫК** *к.* борынга борып (бөреп; бөтереп) тыгарлык. *Ә һавасы нинди?.. Борыныңа төреп тыгарлык, ди иде безнең әткәй* (А. Гыйләҗев. Үги ана яфрагы). *Товарын кара әле син аның, җизни, товарын, борыныңа төреп тыгарлык* (Т. Гыйззәт).

Төрдәше: борынга борып (бөреп; бөтереп) тыгарлык.

**БОРЫНГА ТӨРТЕП ТОРУ.** Кимчелекләрне ачыктан-ачык үзеңә сөйләү, күрсәтү. – *Андый чакта бәйләнчек кешенең янында булуы зыянга түгел. Бөтен гаеп-кыегыңны күреп, борыныңа төртеп тора* (М. Маликова. Арыш тәме). *Аларга мишәрләрнең гел борыннарына төртеп тор, шаярту, тел чарлау өчен кирәк бу* (Р. Юныс. Татар гаме).

**БОРЫНГА ТӨРТЕРЛЕК.** Соклану, көнләшү тудыра торган. *Бу – алачык кына түгел-түгелен, Кадрәктәге байтак кешенең борынга төртерлек өй инде ул, ләкин Байдарның алай олыдан кубып сөйләнергә бер дә теле бармый* (В. Имамов. Казан дастаны).

**БОРЫНГА ЧИЛӘК ЭЛҮ** *к.* алып узу. *Һәм... Акмалның йөрәгенә ут салырлык сүз әйтте: – Беләсеңме, Акмал сабакташ, ул чагында... ул чагында Сәүдә җанкисәгем дә, бәлки, минем яннан борынына чиләк элеп узып китмәсие* (Г. Ахунов. Этләр патшасы).

Төрдәше: алып узу һ.б.

**БОРЫНГА ЧИРТӘ ТОРГАН.** Өстен чыгу; өстен булган – *Менә ичмасам хатын! – диде Хатип, сокланып, теләсә кайсыбызның борынга чиртә торган!* (М. Галәү. Мөһаҗирләр).

**БОРЫНГА ЧИ(Е)РТҮ.** 1. Дәгъвасын җимерү. *[Хәмзә] Башкасын белмим, Исмәгыйльнең борынына чирттеме соң?* (М. Фәйзи. Галиябану). *Рудольфның күбрәк балл җыеп, дөнья бәйгесендә Мәскәү биючеләре борыннарына чиерткән өчен, Зур театр артисты Владимир Васильев та кара коелып йөрде* (Р. Вәли. Канатлы татар).

2. *к.* борынга сугу 1. *[Хәлидә] Кәримнең борынына бер-ике чиерткәч тә, шуның белән эш беттемени?* (Г. Камал. Хафизалам, иркәм). *Әгәр ул авылга минем ялгызым гына кереп, эшлисе эшне ялгызым гына булдырып чыгуыма ышанмый икән, аның борынына чиртеп,*

*ничек булса да ышандырырга кирәк бит инде* (Ф. Хөсни. Йөзек кашы).
Төрдәше: борынга сугу 1 һ.б.

3. борынга сугу 2. *[Нәгыймә] Әгәр абыстай иренең борынына чиертергә теләсә, бүген кич белән сәгать тугызларда безгә рәхим итсен, ди* (Ш. Камал. Хаҗи әфәнде өйләнә).
Төрдәше: борынга сугу 2; борынга суктыру.

**БОРЫНГА ЭЛҮ** *мыск.* «Бик исем китә» мәгънәсендә. – *Монысын борыныма элдем, әйдә, дәвам ит* (Сөйләм).

*БОРЫННАН* ❖ **БОРЫННАН АРЫ КҮРМӘҮ** *к.* борын астыннан ары күрмәү. *Журналист әйтүенчә, Башкортстанда яшәп иҗат итүче татар язучылары пассив, ә Казан үз борыннан ары күрми* (tatar-inform.tatar).
Төрдәше: борын астыннан ары күрмәү.

**БОРЫННАН КЫССАҢ (ТОТСАҢ), ҖАНЫ ЧЫГАРЛЫК (<ОЧЫП> ЧЫГАРГА ТОРУ)** *к.* авызын ачса, кече теле күренү 1. *Ул үзе кечкенә, чандыр. Борыныннан кыссаң, җаны чыгар* (И. Сәләхов. Фаҗига). *Картон хуҗасы иң начар сүзләр белән сүгенергә, янарга тотынды. «Борыныңнан кыссаң, җаның чыгарга тора. Әле син янап маташасыңмы?!»* (Ә. Галиев. Һәр солдатның үз язмышы).
Төрдәше: авызын ачса, кече теле күренү 1 һ.б.

**БОРЫННАН СӨЙРӘП ЙӨРТҮ.** Кешене буйсындырып, үзеңә ияртеп йөртү. *Бу романында да ул әле ничектер киң кулланышка кереп җитмәгән борыннан сөйрәп йөртү кебек сүзләрне, тәгъбирләрне, җон уңаеннан сыпыру кебек халыкчан формаларны, шулай ук соңгы елларда матбугатта кулланыштан чыгарып ташланган җәзбә кебек сүзләрне үз урыннарына утыртып, кыйммәтләрен күрсәтә* (Г. Ахунҗанов. И туган тел...).

*БОРЫННЫ* ❖ **БОРЫННЫ ҖИЛ УҢАЕНА (ЯГЫНА) ТОТУ.** Үз фикерен, тотышын үзгәртеп, төрле шартларга яраклашу. – *Бүтәне бит аның, белгеч булудан битәр, борынын җил уңаена тота* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Кайбер концертларында өлкәннәрдән фикерләрен сорый. Кайбер корсак коллары кебек борынны җил уңаена тотып язаргамы?* («Сөембикә» ж.).
Төрдәше: җил искән якка аву (авышу); җил кай(сы) якка иссә, шул якка; җил кайсы якка бөксә, шул якка <ава торган>; җил ягына аву; җил ягына авышу; ике койрыклы булу.

**БОРЫННЫ КИЕРҮ.** Тискәреләнү, тәкәбберләнү, җирәнеп карау. *Ә бусы бөеренә таянган була... Ата күркә кебек кабарына, борынын киерә, – әйтерсең бу дөнья мәңгелек ана!* (Г. Ибраһимов). *Маклаковның кашлары җимерелде, борыны киерелде. – Как так? – дип кычкырып җибәрде* (Х. Хәйруллин. Канатлар талмасын).
Төрдәше: бөергә таяну 2.

**БОРЫННЫ КҮККӘ (БОЛЫТКА) ЧӨЮ** *к.* алып узу. *Менә шуннан, бер дә хәтәр эреләнеп, борынын тиешеннән артык күккә чөеп, тотынган, ди, үсәргә, тотынган, ди, үсәргә* (Н. Исәнбәт). *Борын чөя башлавын да искә төшерделәр* (Җ. Дәрзаман. Җир авазы).
Төрдәше: алып узу һ.б.

**БОРЫННЫ КҮТӘРҮ** *к.* алып узу. *[Исмәгыйль] Миннән артык яр тапмассың, / Бик күтәрмә борыныңны* (М. Фәйзи. Галиябану). – *Безнең Чирмешән яклары да ким-хур түгел анысы, алай бик борыныңны күтәрмә, – дип, Җәмилә Мансурны этеп җибәрде* (М. Әмирханов. Тәкъдир).
Төрдәше: алып узу һ.б.

**БОРЫННЫ КЫССАҢ, ҖАНЫ КҮККӘ ОЧУ** *к.* авыз ачса, кече теле күренү 1. *Борынны кыссаң, җаны күккә оча инде мескеннең* (Сөйләм).
Төрдәше: авызын ачса, кече теле күренү һ.б.

**БОРЫННЫ МАМЫККА ТӨРТҮ.** Йомшак, җайлы җиргә туры килү; иркәлектә, муллыкта, рәхәтлектә яшәү. *Борынын мамыкка төртте ул, хәзер атта гына утырып йөри* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

**БОРЫННЫ МАҢГАЙДАН ЮГАРЫРАК ЧӨЮ** *к.* алып узу. *Граф шунда борынын маңгаеннан югарырак чөеп бер әйләндерде дә: – Исмәгыйль абзый китүгә бүлешә башладыгызмы әллә, – дип, кеше уйламаган сүзне әйтеп куйды* (Ф. Яхин. Багана фалы).
Төрдәше: алып узу һ.б.

**БОРЫННЫ СЫНДЫРУ.** 1. Югарыга, дәрәҗәгә үрмәләгәндә, уңышсызлыкка очрау, хур булу. *[Мисбах] Менә күрегез дә торыгыз, Чиләбе*

*төбендә борыннарын сындырмасалар, башым протестка керсен!* (К. Тинчурин. Җилкәнсезләр).

Төрдәше: адәм йөзенә (күзенә) чыгарлыгын (күренерлеген) калдырмау 1.

2. *күч.* Нинди булса да каршылыктан, кыенлыктан өстен чыгару, җайлау. *Кечкенә чанага төяп кайткан ботак-санак салкын өйнең борынын сындырырга ярап торды* (Ф. Җамалетдинова. Догалы корт).

**БОРЫННЫ ТҮШӘМГӘ ЭЛҮ** *к.* алып узу. – *Казна ашын ник шуышындый наданнарга әрәм итәләр? – диде ул һәм түшәмгә элеп куйган борынын кабат тун якасына кадап куйды* (Ф. Сафин).

Төрдәше: алып узу һ.б.

**БОРЫННЫ ЧӨЙГӘ ЭЛҮ** *к.* алып узу. Эшләр шәп бармаса да сер бирмәү. – *Зурайдыгыз, Әбелмәлих Шамилович, депутат булгач, борыныгызны чөйгә элдегез, кермисез дә, хәл белешмисез, без бит дошманнар түгел, хәтерлисезме? – дип сайрый башлады* (М. Әмирханов). *Колхоз кәнсәләрендә чут тартып утыручы кыз борынын чөйгә элде. Шәһәрдә яшәп кайткан егет тәбәнәк булса да дәрәҗәсен югары тотты* <...>. (Т. Мөбарәков. Гөл эби).

Төрдәше: алып узу һ.б.

**БОРЫННЫ ЮГАРЫ ТОТУ (ЧӨЮ)** *к.* алып узу. *[Хатирә] Ярый, бик яхшы, шулай кирәк аларга, борыннарын бик югары чөеп йөриләр иде, менә хәзер чөеп карасыннар инде* (Г. Камал. Хафизалам, иркәм). – *Ә үз тиңнәре арасында тәкәбберлек тә, борынны югары чөеп йөрү дә килешми, чөнки анда бөтен балалар да бертигез, бер хокукта була* (Н. Гыйматдинова. Ак торна каргышы).

Төрдәше: алып узу һ.б.

**БОРЫННЫ ЯРЫП КЕРҮ.** Иснең аеруча көчле булып килүе, нык сизелүе. *Ихатасында ук тын алырга чама юк, йон янган, тире көйгән ис, борын тишекләрен ярып кереп, бөтен үзәкләрне актара иде* (В. Имамов. Ир канаты). *Борынны ярып кергән әчкелтем исләре дә тансык булып хәтердә калачак әле моның...* (Р. Низамиев. Беренче мунча).

*БОРЫНЫ* ❖ **БОРЫНЫ БЕЛӘН БЕР СУКСА, ҮЛӘРСЕҢ** *мыск.* Зур (яки озын) борынлы кешегә карата. *Озынга сузмадым васыфын, күләрсең. / Борыны белән бер сукса, үләрсең* (В. Солтанов).

Төрдәше: борыны битенә көчкә сыю; борынына тугыз күркә кунарлык (сыярлык)1.

**БОРЫНЫ БИТЕНӘ КӨЧКӘ СЫЮ** *мыск., к.* борыны белән бер сукса, үләрсең. – *Һай, Ходаем, борыны битенә көчкә сыя бит тегенең, цирктан килгәнме юкса* (Сөйләм).

Төрдәше: борыны белән бер сукса, үләрсең һ.б.

**БОРЫНЫ КЕРЕП ҖИТМӘҮ.** Ишектән кереп җитмәү хакында. *Ай син, дуңгыз борын, тыңкыш, борыны кереп җитмәгән, кыздырабызмы дигән була* (Ш. Усманов).

**БОРЫНЫ КИБЕП ҖИТМӘҮ (БЕТМӘГӘН)** *к.* авыз суы кипмәгән. *Иң мөһиме, миңа, борыны кибеп бетмәгән малай кисәгенә, кем хат яза дисез* (И. Юзеев). *«Борыны да кибеп бетмәгән» килеш шундый машинада йөрсен инде* (М. Миншин. Кызыл диплом). – *Бәйләнмәгезче шуңа, борыны кибеп җитмәгән бит әле аның* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

**БОРЫНЫ ҮСЕП ҖИТМӘҮ.** Шәхес буларак, аң-белеме ягыннан оешып җитмәү. – *Кыстамагызчы, зинһар, борыннары үсеп җитмәгәннәр белән танышырга бер дә теләгем юк* (Сөйләм).

**БОРЫНЫ ЮГАРЫ** *к.* алып узу. *Өч көн вокзалда кунып килсә дә, борыны югары булыр* (М. Галиев). *Бай кешенең борыны югары була. Артык кәперенмәссеңме дип куркам* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).

Төрдәше: алып узу һ.б.

*БОРЫНЫН* ❖ **БОРЫНЫН ТӨШЕРҮ.** 1. Берәрсенең кәефен бозу. *Ләкин борыныңны төшермә! Каш ярылып, күз чыкмаган* (В. Нуруллин. Күпер чыкканда). *Әмма шулай булса да, минем Рашатның борын төшергәнен, төшенкелеккә бирелгәнен күргәнем юк* (М. Шабаев. Үз йолдызы бар).

Төрдәше: авыз купайту һ.б.

2. Артык узынган, кәперенгән кешегә чик кую. *Бик күпне сыпырды инде, әзрәк борынын төшермәссеңме икән, булалар алар, бар һөнәрне күрсәтче әле* (М. Гали). *Еллар буе*

*югарыда очып, томаланган аңга барып җитүе, сукырайган күзләрне ачуы, чөелгән борынны төшерүе бик читен икәнлеген аңлый иде ул* (Г. Мирһади. Килмешәк).

*БОРЫНЫНА* ❖ **БОРЫНЫНА БОРЫЧ КЕРМӘГӘН** *к.* авыз суы кипмәгән. *Өч өйрәнчек егет бурап ята да соң, борыннарына борыч кермәгән* (Г. Мөхәммәтшин).
Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

**БОРЫНЫНА ДА КЕРМӘГӘН.** Нәрсә беләндер беренче мәртәбә танышу, очрашуга ишарә. *Бик яшь бит әле ул, андый уйлар аның борынына да кермәгәндер* (Сөйләм).
Төрдәше: гомерендә иснәмәгән дә.

**БОРЫНЫНА СУ КЕРМӘҮ, БАШЫНА УЙ КЕРМӘҮ.** Тәрбия күрмәгән, башына акыл-уй кермәгән яшь кеше хакында. – *Нәрсә дип әйтим инде, аның борынына су да кермәгән, башына уй да кермәгән – яшәгән шунда* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз суы кипмәгән һ.б.

**БОРЫНЫНА ТУГЫЗ КҮРКӘ КУНАРЛЫК (СЫЯРЛЫК)** *мыск.* 1. *к.* борыны белән бер сукса, үләрсең. *Вәлинурны Кәшифә генә «тәти егет» дип йөртә. – Ул кызның борынына тугыз күркә кунарлык ич аның, – диде Мөкәррәмә, бар ачулы мыскылын шушы сүзгә салып* (М. Әмирханов. Мөкәррәмә).
Төрдәше: борыны белән бер сукса, үләрсең; борыны битенә көчкә сыю.

2. *к.* алып узу. *Күктә нәрсәдер эзләгәндәй, башын югары чөйгән, борынына тугыз күркә кунарлык* (Сөйләм).
Төрдәше: алып узу һ.б.

**БОРЫНЫНА ЧИЛӘК ЭЛӘРЛЕК.** Артык тәкәббер кыланучы хакында. – *Хәлил дигәнең, теге, борынына чиләк эләрлек егет түгелдер ич?* (Сөйләм).
Төрдәше: алып узу һ.б.

**БОРЫНЫНА ШАКШЫ ЮКӘ БУЙЛАМЫЙ.** Дәрәҗәсен белмичә, үзен әллә кемгә куйган кеше хакында. – *Кара, сездә дә борынына шакшы юкә буйламаган адәмнәр бар икән* (Сөйләм).
Төрдәше: алып узу һ.б.

*БОРЫНЫҢ* ❖ **БОРЫНЫҢ ҮСӘСЕ БАР ӘЛЕ** *мыск.* Үз дәрәҗәсен белмичә, артык югарыга үрелү. – *Үзеңне әллә кемгә санап, артык кыланма, борының үсәсе бар әле* (Сөйләм).

*БОРЫНЫҢНЫ* ❖ **БОРЫНЫҢНЫ БЕЛЕП ТАРТ.** «Үзеңә тиеш булмаганга кулыңны сузма» мәгънәсендә. *Борыныңны белеп тарт, яме. Син безнең араны боза алмыйсың. Сәбәбен әйтеп тормыйм* (Ә. Хәсәнов. Әнис алмалар).

**БОРЫНЫҢНЫ БИК КҮТӘРМӘ, АГАЧКА (АГАЧ БАШЫНА) ЭЛӘКМӘСЕН** *мыск.* Бик эреләнеп, масаеп йөргән кешене кисәтү. *Борыныңны бик күтәрмә, агач башына эләкмәсен* (Н. Исәнбәт. Балалар фольклоры). *Борының белән күзләрең булмаса, йөзеңә карап үзеңне танырлык та түгел... Борыныңны бик күтәрмә, агач башына эләкмәсен* (Ф. Бәллүр. Кем син, Рабит Ора Бит?).
Төрдәше: борыныңны бик күтәрмә, бүрәнәгә абынырсың; борыныңны бик <югары> күтәрмә (чөймә), чиләк (бидрә) элеп куярлар.

**БОРЫНЫҢНЫ БИК КҮТӘРМӘ, БҮРӘНӘГӘ АБЫНЫРСЫҢ** *мыск.*, *к.* борыныңны бик күтәрмә, агачка (агач башына) эләкмәсен. *Борынын бик күтәргән бүрәнәгә абыныр* (Мәкаль).
Төрдәше: борыныңны бик күтәрмә, агачка (агач башына) эләкмәсен һ.б.

**БОРЫНЫҢНЫ БИК <ЮГАРЫ> КҮТӘРМӘ (ЧӨЙМӘ), ЧИЛӘК (БИДРӘ) ЭЛЕП КУЯРЛАР** *диал., мыск., к.* борыныңны бик күтәрмә, агачка (агач башына) эләкмәсен. *Түтәл-түтәл кыярлар, / Борыныңны бик күтәрмә, / Чиләк элеп куярлар* (Җыр). *Әнә килә автомобиль – / Төягәннәр кыярлар. / Борыныңны бик күтәрмә, / Чиләк элеп куярлар* (Җыр).
Төрдәше: борыныңны бик күтәрмә, агачка (агач башына) эләкмәсен һ.б.

*БОРЫП* ❖ **БОРЫП АТУ (САЛУ)** 1. *к.* аста калдыру. – *Безнең әтәч сезнең карт йолкыш әтәчегезне борып кына сала!* (А. Гыйләҗев. Әтәч менгән читәнгә). *Үгезне юри котыртып арттан чаптырдым-чаптырдым да кинәт кенә мөгезләреннән эләктереп борып салдым* (Н. Әхмәдиев. Бәдретдиннең Америкага сәяхәте).
Төрдәше: аста калдыру.

2. Юк итү, үтерү. *Кемнәр чекист муенын борып атарга җыена икән соң?* (Т. Әйди. Елан угы). – *Ах, менә хәзер Камыр батыр Гыйфритнең башын борып атар яисә күзен чокып чыгарыр!* (Х. Ибраһим. Ялгыз тәкәрлек).

Төрдәше: адәм башкайларын салу һ.б.

*БОРЫЧ* ❖ **БОРЫЧ СИБҮ.** Әче, төрткеле сүзләр әйтү. *Шәкерт сипте картка борычны: / – Чиркәү яндыру ул зур эшме?!* (Ә. Исхак). *Юлтай артыграк борыч сипте, ахры. Әмма эшне төзәтергә соң иде инде* (Т. Әйди. Елан угы).

Төрдәше: җанга борыч сибү.

*БОРЫЧЛАП* ❖ **БОРЫЧЛАП АЛУ.** Бераз ачулану, әрләү. – *Егетебез сүзгә колак салмый башлады кебек, бераз борычлап алмыйча булмас* (Сөйләм).

Төрдәше: борычлап әйтү.

**БОРЫЧЛАП ӘЙТТЕРҮ**. Көчләп әйттерү. *Ыкмык итеп, боргаланып-сыргаланып тора иде, түзмәде, борычлап әйттерергә мәҗбүр булды* (Сөйләм).

**БОРЫЧЛАП ӘЙТҮ.** Зәһәр итеп, төрттереп, йөрәккә үтәрлек итеп әйтү. *Илфак йомшак әйткән, Гыйлаҗ абый борычлап әйтер иде сиңа...* (matbugat.ru).

Төрдәше: борычлап алу.

*БОРЫЧЛАП-СУГАНЛАП* ❖ **БОРЫЧЛАП-СУГАНЛАП ПЕШЕРҮ.** Үзәккә үткәреп тиргәү. *Аларның нәрсә сөйләшкәнен берәү дә тыңлап тормаса да, абыйсының борычлап-суганлап пешергәнен аңладылар* (Сөйләм).

Төрдәше: к. акыл бизмәненә утырту һ.б.

*БОРЫЧЛАП-ТОЗЛАП* ❖ **БОРЫЧЛАП-ТОЗЛАП СҮГҮ** *к.* борычлап-суганлап пешерү. *Күз төпләре кызаруыннан аны өйләрендә борычлап-тозлап сүккәннәрен тиз төшенделәр* (Сөйләм).

Төрдәше: акыл бизмәненә утырту һ.б.

*БОРЫЧЛАП-ТУЗАНЛАП* ❖ **БОРЫЧЛАП-ТУЗАНЛАП ЭЛӘКТЕРҮ** *к.* борычлап-суганлап пешерү. – *Кайбер мәми егетләргә борычлап-тузанлап эләктергән ул анда* (Г. Мөхәммәтшин. Гөлҗәүһәр аланында).

Төрдәше: борычлап-суганлап пешерү.

*БОРЫЧЛЫ* ❖ **БОРЫЧЛЫ СҮЗ.** Төрттереп әйткән сүз. *Яруллин шунда ук үзенең борычлы сүзен кыстырып өлгерде: – Өшесә, барып сезнең уртага ятыр иде* (Ә. Еники. Рәшә). *Ул кешеләр белән артык якынаймаска тырыша, күпмедер дәрәҗәдә ара саклый, Нурисламнан моның өчен шактый борычлы сүзләр ишетсә дә, үзен хаклы саный иде* (Р. Вәлиев. Мирас).

Төрдәше: әрем <тел>ле һ.б.

*БОТ* ❖ **БОТ БУЕ** *гади с., к.* борчак кадәр. *Шул вакытта бер бот буе гына малай бер кәгазь тотып килеп керде* (Г. Исхакый. Зиндан). *Шул ук вакытта бот буе малайның зурлар эшенә кысылып утыруы ошамый иде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: бармак буе (буйлыгы) һ.б.

**БОТ КҮТӘРЕП, ТҮШӘМГӘ ТӨКЕРЕП ЯТУ.** Тормышы җайга салынган, ашау-эчү хәл ителгән; рәхәт, мул тормышта яшәү. *Ике кулына бер эш, бара да кайта, аннан бот күтәреп, түшәмгә төкереп ята* (Р. Газиз. Умный Вазыйх). – *Бәхетле тормыш – бот күтәреп, түшәмгә төкереп тик яту дип белгәнгә! Әйтерсең бөтен рәхәт шунда гына!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

**БОТ КҮТӘРЕП ЯТУ.** Эшләмичә тик яту; ялкаулыкка бирелү. *Эшкә бармыйча, бот күтәреп яталар. Ә анда аларның инженерлары шпунт кагарга көтә* (А. Алиш. Якты күл буе). *[Мәрзия] Син тик шунда гәзитәң берлә өйдә бот күтәреп ятасың* (Г. Исхакый. Мөгаллим).

Төрдәше: авыз күтәреп яту һ.б.

**БОТ СУЗЫП ЯТУ.** Җәелеп, тугарылып ял итеп яту. *Күршеләр йөк төяп, / Калага саттылар / Һәм җыйгач күп запас, / Бот сузып яттылар* (Г. Тукай).

**БОТ ЧАБУ (ЧАБЫП КУЮ).** 1. Соклану яки көчле гаҗәпләнүне белдерү, шаккату, шул хисләрдән ботка сугып кую. *Хәйран калып эшче ботын чаба, үзе, куркып, дер-дер калтырый* (М. Гафури). *Гаҗилә исе китеп бот чапты да чиләккә иелде* (Ә. Гаффар. Богау).

2. Үкенү. *Шунда Тимери, алдан хәзерлек күрелмәгәнен исенә төшереп, үкенүдән хәтта бот чабып куйды* (Г. Бәширов). *Инәй, бичара, бот чабып ах-вах иткән, ә атакай, тиз генә*

*артымнан барып, мине күтәреп алып кайткан* (Ә. Еники. Соңгы китап).

Төрдәше: ботка сугу (сугып кую) (ике маддә өчен дә).

**БОТ ЧАБЫП (ЧАБА-ЧАБА) КӨЛҮ.** Тыела алмыйча, бик каты көлү. *Кәҗә торганын / Күреп каршыда, / Ботларын чабып / Көлде барсы да* (Б. Рәхмәт. Чүлмәк башлы кәҗә). *Рифтән бөтен авыл халкы бот чабып көләчәк бит* (Р. Фәизов. Ә җирдә тереклек бармы?!).

**БОТ ЧАБЫП УТЫРУ.** Аптыраганнан ботына суккалау. *Әни: «Һе, минә бай диген, һе, минә сәүдәгәр малае диген, минә әйбәт кешеләргә кыз бирәм диген», – дип, бот чабып утырды* (Ф. Шәфигуллин. Ялгыз өрәңге).

*БОТАК* ❖ **БОТАК ОЧЫ <КАРДӘШ; ТУГАН>.** Бик ерак туганы, туганнан туган. *Ул юл буе хәтерен актарды. Туктар әтисе ягыннан ботак очы иде* (Н. Гыйматдинова. Үзем генә беләм...). *Хәзерге көндә туган-тумачага саналмаган бик ерак бер ботак очы кардәш иде бугай ул Мәликә апасына* (Л. Хәмидуллин. Буранлы төндә).

*БОТАККА* ❖ **БОТАККА АТЛАНДЫРУ** *к.* авыздан кош очыру 1. *Өйләренә нәрсәдер сатарга кергән кешеләр аны ботакка атландырып киттеләр* (Сөйләм).

Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

*БОТАКЛЫ* ❖ **БОТАКЛЫ ҖЕН** *мыск.* Кул-аяклары чатлы-ботлы, ямьсез булып үскән кешегә карата. *Циркта ботаклы җенне хәтерләткән бер кеше дә бар иде* (Сөйләм).

**БОТАКЛЫ КӨЕНЧӘ <СЕЛТӘҮ>.** Шомартмыйча, ничек бар, шулай сөйләү; күңелгә авыр тәэсир ясарлык итеп сөйләү. *Тәслимә егетнең кәефен кырырмын дип уйлап тормады, шулай ботаклы көенчә генә селтәде* (Сөйләм).

*БОТАРЛАП* ❖ **БОТАРЛАП САЛУ.** Бик тиз, җиңел генә җиңү. *Әзмәвердәй дүрт ир-ат аны идәнгә ботарлап сала да киенергә боера* («Безнең гәҗит» газ.)

*БОТКА* ❖ **БОТКА БУЛУ.** Буталчыкланү, аңлашылмаслык булу (сүз яки эш турында). <…> *хакыйкатьтән ерак торган кирәксез сүз боткасы булып кына кала* (М. Хәбибуллин. Айбиби). *Фатыйманың башы әйләнде, уйлары буталды, бөтен нәрсә ботка булып буталды* (З. Кадырова. Көтеп узган гомер).

Төрдәше: боткага әйләнү.

**БОТКА КҮЗЕ.** Ботка уртасында кашык белән ясалган чокыр. *Ботка күзендә май күрсә, / Әлхәм укыр муллалар* (Жыр).

**БОТКА ПЕШЕРЕП БУЛМАС (БУЛМЫЙ).** Берәрсе белән аңлаша алмау уртак тел таба алмау, бернәрсәгә дә ирешә алмау. *Мәсәлән, русларның «аның белән ботка пешереп булмый», ягъни аның белән эш барып чыкмаячак, дигән әйтемнәре бар* («Казан утлары» ж.). *Безнең белән ботка пешереп булмаганны аңлагач, Сусликов та каядыр китеп олакты* (М. Юныс. Европа ат сагына).

Төрдәше: аның белән борчак пешмәү һ.б.

**БОТКА ПЕШЕРЕП АЛУ.** 1. Берәрсе даими рәвештә бер җиргә, бер урынга утырса, шулай диелә. *Алар озак уйлап тормадылар, ботка пешереп алган урынга киттеләр* (Сөйләм).

2. Авыз эченнән генә нидер мыгырдану. *Сафа абый, чәен шупырдата биреп: – Юк, түгел, – дигән сыман, авыз эченнән ботка пешереп алды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Дустанә эндәшүгә ни дип җавап бирергә белми Әхмәтсафа авыз эченнән ботка пешереп алды* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).

Төрдәше: авыз казанында ботка пешерү һ.б.

**БОТКА ПЕШЕРҮ.** Кем белән булса да аңлашып, бергәләп эш майтару, уртак фикергә килү. *Җитте! Пешергән боткагыздан ни әйтергә теләгәнегезне аңладым инде* (М. Фәйзи. Асылъяр). – *Карга белән пешергән боткагыз көймәдеме, иптәш «чикритар»?* (Н. Гыйматдинова).

Төрдәше: бер сүзгә килү һ.б.

**БОТКА<ЛАРЫ> ПЕШҮ** (яки **ПЕШМӘҮ)** *к.* бер сүзгә килү (яки килә алмау). *[Батырхан] Минем акыл белән йөрәгемнең боткалары пешми* (К. Тинчурин. Җилкәнсезләр). *Бай икән ул безнең халыкның фольклоры! Рәшит белән боткалары пешә Зөлфәтнең* (Р. Газиз. Тәрәзәләр).

Төрдәше: аның белән борчак пешмәү 1, 2 һ.б.

**БОТКА СОРАУ** *к.* авызын ачкан, ашарга сорый. – *Карале, ботинкасы ботка сорый башлаган* (Сөйләм).

Төрдәше: авызын ачкан, ашарга сорый һ.б.

**БОТКА СУГУ (СУГЫП КУЮ)** *к.* бот чабу (чабып кую). *Низами, үрсәләнеп, ботына сугып куйды* (М. Әмир). *Йөгерә башлагач, капкач бер чәйнеккә, бер минем ботка сугып, йөгерергә комачау итә башлады* (З. Зәйнуллин. Урам).
Төрдәше: бот чабу (чабып кую) һ.б.

*БОТКАГА* ❖ **БОТКАГА АВЫЗ ПЕШҮ.** Берьюлы барысына да ирештем (мал-мөлкәтле булу, дәрәҗә алу һ.б.) дигәндә, эшне бозып кую, насыйп булмау. – *Ишеттеңме: түбән оч Исмай кибетне үзенеке итәм дигәндә генә боткага авызы пешкән, ди* (Сөйләм).

**БОТКАГА ӘЙЛӘНҮ** 1. *к.* ботка булу. *Чыннан да, казан төбендәге аш куерып, боткага әйләнү генә түгел, көя үк башлаган иде* (Ф. Яхин. Без дә монда бар идек). *Бу сөйләшү сөйләшү булмады, һәркем, кулларын болгый-болгый, нәрсәдер кычкыра башлагач, җыелыш боткага әйләнде* (Сөйләм).
Төрдәше: ботка булу.

2. *к.* авыз казанында ботка пешерү. *Ләкин шуның ише гап-гади элементар нәрсәләрне дә аңламаган кешеләргә кайчакларда ычкындырыла торган «аңгырабаш» бу юлы авыз эчендәге боткага әйләнеп калды* (Җ. Юныс. Алла язган булса).

3. Туфрак су белән катнашып, пычрак боламыгы хасил булу. *Төн буе килеп торган шул пар эссесе белән багана тирәсендәге, нәкъ менә чаңгы эзе үтә торган турыдагы боз, эреп, боткага әйләнгән* (В. Нуруллин. Ике урам арасы).

**БОТКАГА МАЙ САЛУ.** Гәпләшергә җыену, әңгәмәне башлау. *Төн бит, атакаем, теге озын колак Шакир белән боткага май салырга гына җыена иек, ишек дөбердәттеләр* (Н. Гыйматдинова. Кыргый).

*БОТКАДАН* ❖ **БОТКАДАН БОЛАМЫККА КАЛУ.** Башлаган эш барып чыкмау, эш начарлану. – *Башны черетмә әле әллә нинди сорауларың белән, болай да эш боткадан боламыкка калып бара* (Сөйләм).

*БОТКАНЫ* ❖ **БОТКАНЫ ПЕШЕРДЕҢ, ҮЗЕҢ АША.** Бик белдеклеләнеп башлаган эшнең нәтиҗәсе уңышсыз чыккач, бәлане бу эшне башлаучыга яки берәр таныш-белешенә сылтау. – *Читкә таерга маташма әле, ботканы пешердең, ашавын да үзең аша инде* (Сөйләм).

*БОТКАНЫҢ* ❖ **БОТКАНЫҢ КҮЗЕН ҮЗ ЯГЫНА ЕРУ (БОРУ).** Эшне үз файдасына бору, үз ягына каеру. – *Кара, ничек оста гына ботканың күзен үз ягына бора* (Сөйләм).

*БОТКАСЫ* ❖ **БОТКАСЫ БОТКА, МАЕ МАЙ КИЛЕШ.** Ничек булган, шул килеш калу, оешмаган. *Бер ай элек ничек булган булса, бүген дә боткасы ботка, мае май килеш* (Сөйләм).

**БОТКАСЫ БҮРТМӘҮ.** Башлаган, куерткан эше барып чыкмау. – *Йөреп-йөреп карады, ләкин боткасы бүртмәде Рәдифнең* (Сөйләм).

*БОТКАСЫН* ❖ **БОТКАСЫН ПЕШЕРГӘЧ, МАЕН ДА САЛ.** «Сүзне озын итеп сөйлисең, нәтиҗәсен дә әйт инде» мәгънәсендә. *Боткасын пешергәч, маен да сал инде. Миннән ашлык сорарга итәсеңме?* (Х. Сарьян. Бер ананың биш улы).

*БОТЫННАН* ❖ **БОТЫННАН АСЫП КУЮ** *гади с., шаяр.* Җәза бирү. – *Чыксын, әйтербез үзенә: без карга түгел, чебешләрегезне алып китмәбез! – диярбез. Ботыбыздан асып куймас ич безне! – диде* (М. Галәү. Болганчык еллар). *«Ботыгыздан асып куям, сабакы малайлар!» – дип кенә сөйләшә* («Шәһри Казан» газ.).

**БОТЫННАН ТОТЫП СЕЛЕКСӘҢ, АВЫЗЫННАН БЕР ӘЛИФ (ӨЧ ХӘРЕФ) ТӘ ТӨШМӘС.** Бөтенләй бернәрсә белмәү, аңламау һ.б. (надан кеше турында). *Ботыннан тотып селексәң, авызыннан бер әлиф төшмәслек карчыклар безгә акыл саталар, диде ул* (М. Әмир).
Төрдәше: ак-кара танымау һ.б.

**БОТЫННАН ТОТЫП СЕЛЕКСӘҢ, БЕТЕ ТӨШМӘС (БЕТЕ ДӘ ЮК).** Малы да, бернәрсәсе дә юк, бик ярлы. *Ботыннан тотып селексәң, бете дә юк үзенең, ә акыл сатарга оста* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз ачса, кече теле күренү 2 һ.б.

**БОТЫННАН ТОТЫП СЕЛЕКСӘҢ ДӘ ЮК (БУЛМАС; БУЛМЫЙ)** *к.* ак-кара аермау. *Аның ботыннан тотып селексәң дә булмаганы*

*күренеп тора, башка берәрсен табарга кирәк* (Сөйләм).

Тәрдәше: аягыннан алып (тотып) селкесәң (селексәң) дә булмас (чыкмас) 2 һ.б.

*БОТЫҢ* ❖ **БОТЫҢ КЫСКА, ЕГЫЛЫП ТӨШМӘ.** «Акылың-белемең сай, югарыга бик очынма» мәгънәсендә. – *Ботың кыска, егылып төшмә, кеше сөйләгәндә, бераз тыңлап утырсаң, файдасы күбрәк булыр үзеңә* (Сөйләм).

*БОХАР(А)* ❖ **БОХАР(А) ҖИМЕШЕ** *к.* Бохар(а) мәчесе. *Син бу мәсьәләдә эшне ашыктыра күр, чөнки теге Бохар җимеше – Барый кайтып төшсә, Ходай күрсәтмәсен, бөтенесеннән колак кагачаксың* (М. Галәү. Мөһаҗирләр). *Бохара җимеше булуына карамастан, дамелляны шәкертләрнең теләкләрен аңламаслык дәрәҗәдә кара киселгән хәзрәт дип булмый* (И. Нуруллин. Фатих Әмирхан).

Төрдәше: Бохар(а) мәчесе.

**БОХАР(А) ИШӘГЕ** *мыск.* 1. Ялкау, үҗәт, миңгерәү кеше. *Үзен еш кына, шаяртып, Бохара ишәге белән чагыштыра иде. Үзе нигәдер акчаны гел җыеп барган* («Идел» ж.).

Төрдәше: авыр аяк<лы> 1; аты-биш карама бүкәне һ.б.

2. Бик күп йөк күтәреп баручы яки үз өстенә бик күп эш (вазыйфалар) алучы хакында. *Үзен Бохара ишәге белән чагыштырырга: барысын да күтәреп, тартып алып бара алам дияргә ярата иде* (tufanminnyllin.org).

**БОХАР(А) МӘЧЕСЕ.** Элек Бохарада укып кайткан шәкерт, мулла (ягъни мәче кебек, башын суфилыкка салу). – *Инә белән тагын кое казыйсың бар икән әле алайса, бохара мәчесе. Гыйлем – бик кирәк нәрсә* (Ә. Хәсәнов. Әҗәт).

Төрдәше: Бохар(а) җимеше.

**БОХАР(А) МӘЧЕСЕ (ПЕСИЕ) КЕБЕК** *мыск.* Диндар булып кыланучы, эчкерле кеше хакында. *«Бохар мәчесе кебек» дисәләр, аңлыйсың – яхшы булып кыланган алдакчы ул* (Ш. Галиев. Туган җир. Табигать сәхифәләре).

**БОХАР ҮТҮ.** Кәрван белән Бохара аша шәрыкка сәфәр итү. *Яулык элдем читәнгә, / Җилфер-җилфер итәргә. / Хуш, исән бул җаныкай, / Киттем Бохар үтәргә* (Җыр).

*БОХАРАГА* ❖ **БОХАРАГА БАРСА, АЯГЫН ҖИРГӘ ТИ(Д)ЕРМӘСЛӘР ИДЕ.** Асып кую турында (биредә тирә-ягында наданнар булган өчен генә үзен әллә кемгә куеп йөри). *Бохарага барса, аның аягын җиргә тидермәсләр иде. Ягъни асарлар иде* (К. Насыйри. Ләһҗәи татари). – Х. Мәхмүтов, киресенчә, Бохарада кадерләп, хөрмәт белән йөртерләр иде дип шәрехли (Х. Мәхмүтов. Изге китаплар кайтавазы).

*БОХАРАДА* ❖ **БОХАРАДА БЕР ЭНӘГӘ БЕР СЫЕР, <БАРЫП БАКСАҢ, НИ ДӘ ЮК>** *к.* авыз чайкау 1. – *Һәр сөйләгәнгә авыз ачып йөрмә, Бохарада бер энәгә бер сыер, дип тә сөйлиләр, барып баксаң, ни дә юк* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз чайкау 1 һ.б.

*БОХАРАИ* ❖ **БОХАРАИ ШӘРИФ МӘГЪДӘСЕ.** Элек шәкертләрнең, суфиларның тел астына сала торган әфйүннәре. *Сал да тизрәк Бохараи шәриф мәгъдәсен, хәшеп* (Н. Исәнбәт).

*БОХЫНЫ* ❖ **БОХЫНЫ ЧЫККАНЧЫ.** Тәмам карыны ярылырга җиткәнче. – *Саранланмагыз, бирегез, ашасын бохыны чыкканчы* (Сөйләм).

*БОЯР* ❖ **БОЯР БУЛЫП УТЫРУ (ЯТУ).** Бар нәрсәсе булып, рәхәттә-муллыкта җәелеп яту. *Атасыннан хәтсез мал-мөлкәт калгач, өйрәнгән бояр булып утырырга* (Сөйләм).

Төрдәше: авыз балда, кул майда һ.б.

**БОЯР ЕГЕТЕ КЕБЕК** *иск.* Кияү егете кебек. *Минем Алмачуар исә кунакка барырга ясанган бояр егете кебек чибәр булды* (Г. Ибраһимов. Алмачуар).

**БОЯР КӨЧЕГЕ** *мыск.* Кешене дәрәҗәсенә, җәмгыятьтә тоткан урынына карап каршы алу (хуҗасына ярарга тырышып ялагайлану яки эт кебек өреп каршылау). – *Син үткән гомереңдә бояр көчеге булгансыңдыр, ахрысы* (Сөйләм).

*БӨГӘ* ❖ **БӨГӘ АЛУ.** Ризалату. *Чибәр хатыннарны йә байлыгың, йә чибәрлегең, йә ирлегең белән бөгә аласың* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Бу катмарлы дөнья безне / Юк, бөгә алмас инде* (Г. Морат. Без – хәтер!).

*БӨГӘРЛӘП* ❖ **БӨГӘРЛӘП САЛУ.** Тотып, кулаягын бәйләп, җиргә егып ташлау. *Алар кәрван-*

*чыларны бик тиз бөгәрләп салдылар да кулларын артка каерып бәйләделәр* (М. Галәү. Мөһаҗирләр). *Ә эчкә кергәч, мин аны шундук бөгәрләп салачакмынмын* (З. Мәхмүди. Әче балан).

*БӨГЕЛӘ* ❖ **БӨГЕЛӘ БАШЛАР, ТҮГЕЛӘ ЯШЬЛӘР.** Тормышта колларча баш бөгәргә туры килүләр яки дөнья басу һәм хәсрәт чигүләр хакында. *Ай-ай башлар, ай башлар, / Кай көн булды ай башлар: / Бөгелә башлар, түгелә яшьләр, /Ниләр күрми яшь башлар* (Җыр).

*БӨГЕЛЕП* ❖ **БӨГЕЛЕП ТӨШҮ**. Кайгыга бирешү. *Мәүлиха түти, Нәфисәнең юкә агачы төбендә кулына хатын тоткан килеш, бөгелеп төшүен күреп, янына ашыкты, күз яшен күреп, йөрәге ачынды* (Г. Бәширов. Намус). *Якуб Ногман инде тамырына балта чабылган тал чыбыгы кебек бөгелеп төшкән иде, Владимир кенәз яңа канат куйды* (В. Имамов. Казан дастаны).
Төрдәше: аһ ору һ.б.

2. Көлмәскә тырышу. *«Брач бареньe белән чәй эчә» дип сөйләгәннәрен ишеткәндә, мин бөгелеп төшәм, оялуымнан кая керергә белмим* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары). *Теге артистка шул җитә кала, ул, чыдый алмыйча, көлә дә башлый, көлүен яшерер өчен бөгелеп төшә*(Р. Батулла).

*БӨГЕЛМӘ* ❖ **БӨГЕЛМӘ КИЛЕНЕ.** Ак аракы. *Ахирәте, Кутыр Борын Гомәр, аңа алларына «Пшеничная» дигән ак алъяпкыч япкан «Бөгелмә киленнәре»н җитәрлек итеп алырга кушкан иде* (А. Хәсәнов).
Төрдәше: агулы елан 1 һ.б.

*БӨГЕП* ❖ **БӨГЕП САЛУ.** Җиңелүгә дучар итү. *Әгәр Садыйк каты бәйләнә башласа: «Элекке кебек бандитлыкка кайтмак буласыңмы? Көчең белән бик масайма, сәвит синнән болайракларын да бөгеп салды», – дип, каршы талашырга исәпләп куйды* (Г. Ибраһимов. Тирән тамырлар). *Кыскасы, Мәрвәр әнә шул бер янавы белән Хәлилне бөкте дә салды* (Ә. Еники. Төнге тамчылар).
Төрдәше: аста калдыру һ.б.

*БӨДРӘ* ❖ **БӨДРӘ ЧӘЧ.** Кызларны иркәләп атау сүзе. *Сикертмә каш, бөдрә чәч, / Үпкәләмә үпмәгәч* (Җыр).

*БӨЕРӘККӘ* ❖ **БӨЕРӘККӘ ТАЯНУ** *к.* алып узу. *Бер белән бөерәккә таянып кызлар каршына баскан килеш, икенче кулның ике бармак арасына кыстырылган шул беләк юанлыгы папиросны суырып, бер фарсит итеп җибәрсәң, кайсы кызның күзе янмас шундый егеткә!* (Ш. Маннур. Чын сөю бармы?).
Төрдәше: алып узу һ.б.

**БӨЕРӘККӘ ТӨШҮ.** Йөдәтеп бетерү, үзәккә үтү. *Биграк тә тәрбиясез малай икән – сәгать буе бездә утырып, бөерәккә төште* (Сөйләм).
Төрдәше: ахәлгә төшерү һ.б.

*БӨЕРГӘ* ❖ **БӨЕРГӘ ТАЯНУ.** 1. Эшлексез кыяфәт алу, гамьсез булу. *Әзергә бәзер гаскәр җыйгач, бөергә таянып сөйләшергә мин дә оста* (В. Имамов. Утлы дала). *Әйе, карыш буе шыртлака эләктерсәң, балыкчы дусларың белән бөереңә таянып сөйләшергә була* (Ф. Шәфигуллин. Балыкчы).
Төрдәше: борынга да элмәү һ.б.

2. Горур, һавалы кыяфәттә басып тору; тәкәбберләнү, тискәреләнү. *Тик «осталар» белән бөереңә таянып сөйләшеп булмый, алай зурдан кубып сөйләшергә Инсаф кем соң әле ул?!* (М. Миншин. Кызыл диплом).
Төрдәше: алып узу һ.б.

**БӨЕРГӘ ТӨРТҮ**. Мыскыллау. *Үчекләү бар, бөергә төртү бар* (Ф. Хөсни. Йөзек кашы). *Торды да, Батулла малае белән, ике аягы белән җиргә шакылдатып тибеп, тавыш чыгара-чыгара биергә тотынды. Рәшит минем бөергә төртә: – Күрдеңме, Зәки абый! Әле генә үлеп утыра иде* (З. Зәйнуллин. Ачлык мәйданы).

**БӨЕРГӘ ТӨШҮ** *к.* ахәлгә төшерү. *Бакча тәмәкесе бу, коллега. Бер суырсаң, бөергә төшә торганы, – диде* (Ә. Маликов. Яшьлек утравым).
Төрдәше: ахәлгә төшерү һ.б.

*БӨЕРДӘН* ❖ **БӨЕРДӘН ЧЫГАРЫП СӨЙЛӘШҮ (ЭНДӘШҮ).** Масаеп, тәкәбберләнеп, үзенең зур кеше икәнлеген күрсәтергә тырышып сөйләшү. *Ә бу яңа заманнар килгәнгә ансат агып, теленә ни килсә, шуны сөйләп тора, йолкыш, карале бер генә: болдыр башыннан торып, тавышны бөердән чыгарып сөйләшмәкче булып маташа* (Г. Ахунов. Этләр патшасы). *Мин*

*сатучыга тавышны бөердән чыгарып эндәштем* (Р. Зәйдулла. Коршау).
Төрдәше: сүзе бөердән чыгу, тавыш бөердән (бөйрәктән) чыгу; тавышны бөердән алу.

*БӨЕРЕ* ❖ **БӨЕРЕ БАЛА БАСМАГАН, <АРТЫ ЙОМЫРКА САЛМАГАН>.** «Бала тудырмаган, үстермәгән кыз кеше хатыннар хәлен беләме соң» мәгънәсендә. – *Тапкансың сорарлык кеше, бөере бала басмаган, арты йомырка салмаган бу кыз каян белсен аны!* (Сөйләм).

**БӨЕРНЕҢ ТӨБЕННӘН ЧЫГАРЫП.** Ихластан, чын күңелдән. – *Бөеремнең төбеннән чыгарып, бәйрәм белән котлыйм!* (Сөйләм).
Төрдәше: бөтен җаны белән.

*БӨКЕ* ❖ **БӨКЕ БУЛЫП ЙӨРҮ.** Вакытлыча гына берәр кирәккә ярый торган. *Бөке булып йөрим шунда, кирәк булганда, ара-тирә мине чакыралар* (Сөйләм).

**БӨКЕ БУЛЫП ТОРУ.** Озак вакыт хәрәкәтсез бер урында тору. *Тик менә бүген күбрәк килеп тыгылдык, элеватор алдында «бөке» булып торабыз* (Ф. Хөсни. Алтын күз).

*БӨКЕСЕ* ❖ **БӨКЕСЕ АТЫЛА, ШЕШӘСЕ ТУЛГАН.** «Күзенә яшь тулган, менә-менә елап җибәрәчәк» мәгънәсендә. *Зәйтүнә, почмактагы урындыкка барып утырып, ике кулы белән битен каплады һәм үксегән тавыш ишетелде – бөкесе атылды, шешәсе тулган иде, күрәсең* (Сөйләм).
Төрдәше: шешәсе тулган, бөкесе атылырга тору.

**БӨКЕСЕ АТЫЛУ (ШАРТЛАУ).** Кинәт кычкырып елап җибәрү. *Бу хатын берсеннән-берсе ямьсез сүзләр очырганда да дәшмәде, әнисенең исемен кыстырып сүгә башлагач кына түзмәде – бөкесе атылды* (Сөйләм).
Төрдәше: буасы ерылу (ерылып китү); буасы китү.

*БӨКЛӘП* ❖ **БӨКЛӘП КУЮ.** Ашап бетерү. *Шәфкать туташы Миңлегөл бүлмәсендә ук ул өч телем арыш ипиен бөкләп куйды* (Н. Гыйматдинова. Кәтәнә). *Миңлебай тартынып тормады. Гайшә карчыкның сокланып, аптырап карап торуына елмайгалап, ипи белән ул казылыкны да бөкләп куйды* (З. Зәйнуллин. Үрләр аша).
Төрдәше: алдан калганчы <ашау> һ.б.

**БӨКЛӘП САЛУ (ТАШЛАУ).** 1. Тиз-тиз һәм күп ашау. *Аш белән икешәр кадак күмәчне бөкләп ташладык* (Г. Гобәй). *Элгәре ярты казан бәрәңге белән өч-дүрт телем кара ипине бөкләп салыр идек тә җәяүләп биш аулны урар идек* (Н. Гыйматдинова. Мәхәббәттә гөнаһ бар).

2. *к.* авыз җебетү 1. *Ну, йокларга яткан-чыга кадәр, без бер шешә акны икәү бөкләп ташлаган идек* (Л. Лерон. Чыктым аркылы күпер).

*БӨКРЕ* ❖ **БӨКРЕ АЛУ (ЧЫГАРУ)** *к.* арка бөкресен чыгару. – *Бу делянкада шул срок тулганны көтеп бөкре чыгарам. Срок моннан ике айлар элек үк тулды* (А. Хәсәнов. Данәгөл). *Мин – гомер буе җир тырнаган, тирестә аунаган, шахты прискеләрендә бөкре чыгарган, ә хәзер үзенең атасында ялчы булып торучы каткан мужик!* (Ш. Маннур. Агымсуларга карап).
Төрдәше: арка бөкресен чыгару һ.б.

**БӨКРЕ КАЙГЫ.** Вакыт үтү белән кайгының тискәре көче сүрелү. *Сүрелдең инде, бөкре кайгы, / Ялкының һич тә кыздырмый* (Я. Емельянов. Кайгы).

**БӨКРЕ ТҮГЕЛ, ТӨЗӘЛЕРГӘ КАБЕР КӨТМИМ.** «Әлегә көчем җитәрлек, күңелем саф» мәгънәсендә. *Бөкре түгел, төзәлергә кабер көтмим, / Тәңрем фәйзы минем күңлемә эз салыр* (Г. Тукай).

**БӨКРЕ<СЕ> ЧЫГУ.** 1. Аркада бөкре барлыкка килү. – *Әй, алай комы коелып, бөкресе чыгып беткән карт-корылар сымак көпә-көндез тишек-тәрәзә бикләп көн күрергә җыенасың икән, бар соң, урыс белән янәшә утыр да яшә!* (В. Имамов. Казан дастаны).
Төрдәше: арка бөкресен чыгару һ.б.

2. *күч.* Авыр эштән газап чигү. *Еллар үтеп, бара торгач картайсам да, / Бөкрем чыгып бетсә дә, хәлдән тайсам да, / Күңлем минем яшь-яшь калыр, һич картаймас <…>* (Г. Тукай). *Аңарчы әле синең бөкрең чыгар, тез башларың сөяләнеп катар, төннәрне йокысыз уздырып, күзләрең чепиләнер* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).
Төрдәше: азап чигү (күрү) һ.б.

**БӨКРЕ ШАЙТАН.** Бераз бөкрәйгән кешене сүгү сүзе. *Син бит, бөкре шайтан, телең белән имәнне юнып бирә аласың* (Г. Ахунов. Идел кызы).

*БӨКРЕМДӘ* ❖ **БӨКРЕМДӘ КҮТӘРГӘН (ҖЫЕЛГАН).** Күп эшләү нәтиҗәсендә, шәхси милек булып туплану. *Тукта, минем бөкремдә җыелган мөлкәтне ничек итеп сүтә башларсың икән* (Ф. Хөсни).

*БӨКРЕНЕ* ❖ **БӨКРЕНЕ КАБЕР <ГЕНӘ> ТӨЗӘТҮ (ТӨЗӘТӘ АЛУ).** Кешенең холык-табигатендә булган кайбер сыйфатларның үлгәнчегә кадәр саклануына ишарә. *Дөрес, соңгы дәвердә ул иренең хикмәтләренә күнекте, исе китми башлады, чит хатыннар белән юргалавына бармак аша карады, «бөкрене кабер төзәтер» дигән иманга килде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Адәм рәтенә кермәс, ахрысы, инде ул, бөкрене кабер генә төзәтә ала, диләр бит* (Л. Хәмидуллин. Кичке шәфәкъ).

**БӨКРЕНЕ КАШУ** *к.* авыз җебетү 2. *Өлкән абзыйлар эләгешеп китеп, берәвесенең җилкәсенә, бөкресен кашып, северке сабы кундырган икән!* (А. Гыйләҗев).

Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

*БӨКРЕСЕ* ❖ **БӨКРЕСЕ ЧЫККАНЧЫ, САКАЛЫ ЧАЛАРГАНЧЫ.** Озак эшләп, эшнең барлык серләренә төшенү. *Берәм-берәм Сарайга иңдергәч, аларның тел төпләрен чамалау өчен, бөкресе чыкканчы һәм сакалы чаларганчы гыйлем эстәгән мөхтәсиб йә мөдәррис булу да һич кирәкми* (В. Имамов. Карабәк).

*БӨРЕШКӘН* ❖ **БӨРЕШКӘН ТАВЫК** *мыск.* Тиз туңа торган кеше хакында. – *Хәрәкәтлән бераз, бөрешкән тавык булып ятма* (Сөйләм).

*БӨРКЕТ* ❖ **БӨРКЕТ БОРЫН.** Бераз аска таба бөгелеп торган борын. *Асия аны кочаклап, битеннән үпте, бөркет борын касыгына нык кына төртеп алды да, табын дәррәү гөрли башлады* (Ә. Мушинский. Ак бүре).

**БӨРКЕТ КҮЗЕ БЕЛӘН КҮРҮ.** Төгәл итеп, барлык нечкәлекләре белән күрү. *Димәк, ул фани дөньядагы барлык хәл-вакыйгаларның яхшысын да, ялганын да бөркет күзе белән күрә белергә тиеш* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).

*БӨРКЕТКӘ* ❖ **БӨРКЕТКӘ КАН.** Шашыр хәлгә җитеп, ташланырга әзер тору. *Бөркеткә кан дигәндәй, аның йодрыклары йомарланды, күзләрендә сәер ялтырау сизелде* (Сөйләм).

*БӨРМӘКИ* ❖ **БӨРМӘКИ АВЫЗ** *мыск.* Авызын бөрештереп сөйләшә торган кеше турында. – *Борчылма, аны тиз танырсың, бөрмәки авыз ул* (Сөйләм).

*БӨРМӘСЕННӘН* ❖ **БӨРМӘСЕННӘН БЕТ ЧӘЙНӘГӘН** *дорфа, мыск.* Кирәккә дә, кирәкмәгәнгә дә тыкшынып, вак сүзле кеше турында. *Булыр-булыр ул оятсыздан. Бәрәңгене бирергә дә котылырга бөрмәсеннән бет чәйнәгән ул кабахәттән* (В. Нуриев. Кара бишмәт).

**БӨРМӘСЕННӘН БЕТ ЭЗЛӘҮ.** Вакланып казыну, вак-төяк гаеп эзләү. *Дошманын кырып, ганимәтне мул төяп кайткан җиңүченең бөрмәсеннән бет эзләргә беркем базмый* (В. Имамов. Карабәк).

Төрдәше: төймәдән төя чыгару; тырнак астында казыну; тырнак астыннан кер эзләү.

*БӨРТЕГЕ* ❖ **БӨРТЕГЕ ДӘ КАЛМАУ.** Бик көчле яңгыр астында калып, юешләнүне белдерә. *Минем малай да лачма су булып кайтты, бөртеге дә калмаган* (Сөйләм).

Төрдәше: җеп бөртеге дә калмау; җеп бөртеге дә калмый<ча> чылану; җеп бөртегенә кадәр (тикле; чаклы); лачма су булу; лычма су булу; манма су булу; су җелекләргә кадәр чылату.

*БӨРТЕГЕНӘ* ❖ **БӨРТЕГЕНӘ ХӘТЛЕ ИСТӘ <БУЛУ; ТОТУ>.** Нәрсәне дә булса бөтен вак детальләренә кадәр хәтердән чыгармау. – *Ничәмә-ничә еллар үтсә дә, бөртегенә хәтле истә, әйе, бөртегенә кадәр* (Сөйләм).

*БӨРТЕК* ❖ **БӨРТЕК ТӘ.** Һич, бөтенләй. *Чын октябрят сүзе, әти машинасына бөртек тә кызыкмыйм мин, ә абый җигеп йөри торган күк байтал төшләремә керә* (Ф. Шәфигуллин. Мин дә үсәрмен әле).

Төрдәше: аз гына да һ.б.

**БӨРТЕК ТӘ ЮК**. Бер дә, һич тә, чак кына да юк (инкяр итү). – *Караңгы төшкәч, урман аркылы чыгарга курыкмадыңмы соң?* – *Бөртек тә юк* (Сөйләм).

Төрдәше: аз гына да һ.б.

*БӨРТЕКЛӘП* ❖ **БӨРТЕКЛӘП ТОРУ.** Нечкәлекләренә кадәр аңлату. *Айзат боларны Петр Петровичка бөртекләп торуны кирәксенмәде* (Г. Мөхәммәтшин. Йөрәктәге эзләр). – *Боларны укырга кайчан өлгерә соң ул?* – *дип сорадым*

*мин Робертның хатыны Венерадан. – Бөртекләп тормый, диагональ буенча гына эләктереп ала* (Т. Әйди. Аталар һәм уллар).

**БӨРТЕКЛӘП ТОТУ** *к.* аяклар юрганыңа карап сузылу. *Бөтен илдә әрәм-шәрәм, исрафлык. Ә син, эшкә ярасын дип, бөртекләп тотасың* (Ш. Галиев. Илһамым-мәхәббәтем: Лирик язмалар). *Мал кадерен беләм, янәсе. Бөртекләп тотам. Ул миңа үлгәнче җитәрлек иде!* (З. Фәтхетдинов. Ак «Жигули» эз югалта).
Төрдәше: аяклар юрганыңа карап сузылу һ.б.

*БӨРШЕК* ❖ **БӨРШЕК АВЫЗ** *мыск.* Бер дә юкка үпкәләп, авызын бөрештергән кеше турында. *Йә, бөршек авыз булма инде, күтәр башыңны, елмаеп җибәр* (Сөйләм).

*БӨТӘЙТТЕҢ* ❖ **БӨТӘЙТТЕҢ ХАРАП.** Зур эшләр майтарырдай өметләндереп, вәгъдәләр биреп тә алдаган кешегә карата. *Акча дигән нәрсә бетәчәк, һәр кеше фатирлы булачак бөтәйттең харап* (Сөйләм).

*БӨТЕН* ❖ **БӨТЕН БӘЛА-КАЗА ӨЧЕН ҖАВАП БИРҮ** *к.* бөтен җаваплылыкны үз өстеңә алу. *Ни өчен бөтен бәла-каза өчен җавап бирергә булганлыгын мин барыбер аңламадым* (Сөйләм).
Төрдәше: бөтен җаваплылыкны үз өстеңә алу.

**БӨТЕН ДӨНЬЯГА ХУР БУЛУ (ИТҮ).** Оятка калу, көлкегә калу. *Бөтен дөньяга хур булырсың, аннан соң... үзегез беләсез кайда проблемагызны – телегезгә кучкән бит инде* («Матбугат.ру» порталы). *Нигә бөтен дөньяга хур итеп аңа гына приговор җыйдылар?* (Г. Бәширов. Сарут).
Төрдәше: хур булу.

**БӨТЕН ДӨНЬЯСЫ ЧӘНЧЕЛСЕН.** «Үз эшем эш, башка нәрсә мине кызыксындырмый» мәгънәсендә. *Институт дипломын алгач, чәнчелсен бөтен дөньясы, дигәндәй, Хәмдүнә янына кайтты да, бергә булыйк, диде, бүтән районга күчеп китәргә кирәклеген әйтте* (Б. Камалов. Гомер кичендә).

**БӨТЕН ҖАВАПЛЫЛЫКНЫ ҮЗ ӨСТЕНӘ АЛУ.** Үзеңә генә ышану; тәвәккәлләп җаваплы булу. – *Сез безнең гуманлыктан артыграк файдаланасыз,* – *диде.* – *Яхшы, мин бөтен җаваплылыкны үз өстемә алып, иртәгәгә хәтле рөхсәт итәм* (Г. Әпсәләмов. Агыла болыт). – *Бу хакта сүз дә булырга мөмкин түгел. – Ни булса шул, мин бөтен җаваплылыкны үз өстемә алам* (С. Рәфыйков. Тын елга буенда).
Төрдәше: бөтен бәла-каза өчен җавап бирү.

**БӨТЕН ҖАНЫ БЕЛӘН.** Тулысынча яклау; шатлану; ярату; хәленә керә белү. *Ихтыяр шофер егетнең кинәт кенә бу кадәр моңсулануын, күңеле нечкәрүен аңламады, аның халәтен бөтен җаны белән тоймады, аның хәленә кереп калып юатырлык сүзләр эзләмәде* (Р. Вәлиев. Мирас). *Сөенә Хисмәт бөтен йөрәге белән, / Бөтен җаны белән сөенә* (Ш. Маннур. Чуен ташкыннар).
Төрдәше: җаны-тәне белән; чын дөресен әйткәндә; чын күңелдән; чын ихлас белән; чын ихластан; чын йөрәктән.

**БӨТЕН ИҢЕНӘ.** Бөтен киңлегенә, аркылысына җәелеп. *Билбавын бөтен иңенә җәеп бәйләгән дә шарфын муенына урап, очларын, кыеклатып, билбавына кыстырган* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Җемелдәвек асылташлар тезгән, күрүге аллы-гөлле төсләрдән балкып-балкып китә торган көмеш телле гармун аның күкрәк өстендә ята. Аннары бөтен иңенә сузыла* (Г. Ахунов, М. Гәрәев. Арча җиренең ачык китабы).

**БӨТЕН КЕШЕ.** Һәрьякттан да булдыклы, камил кеше. *Чыкты ахыр бездән дә бер бөтен кеше; / Яхшы аңлап хөкем итү читен кеше* (Г. Тукай).
Төрдәше: авырның өстеннән, җиңелнең астыннан 2.

**БӨТЕН КӨЧЕНӘ (КӨЧКӘ).** Бар булган көчен җыеп, җан-фәрманга. *Аңа күңелсез булып китте, дөнья караңгылангандай булды, башын иеп, бөтен көчкә чабып, кремль стенасына барып бәреләсе килде аның* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Тегесе озак түзмәде – борылды да бөтен көченә йөгерде* (А. Мансуров. Көтелмәгән һөҗүм).
Төрдәше: бөтен көчне кую (салу; туплау).

**БӨТЕН КӨЧНЕ КУЮ (САЛУ; ТУПЛАУ)** Башкара алмаслык эшне үтәү өчен, бик нык тырышу. *Шулай булса, ул терәкне саклап калу өчен, бөтен көчен куйган, шул юлда шәһит киткән хәзрәтләргә җимерүче көч исемен нигә тагабыз?* (Р. Зарипов. Тирән тамырлы

Түнтәрем). – *Берәр атна соңгарсак соңгарырбыз, бөтен көчне салам жыюга тупларга кирәк* (Х. Хәйруллин. Канатлар талмасын).
Төрдәше: бөтен көченә (көчкә).

**БӨТЕН КҮЗ ТЕРӘГЕМ (ТЕРӘГӘНЕМ).** Барлык өметем, күз тотып торганым. *Барлык күз терәгәнем менә Кәрим абзый инде* (Ә. Фәйзи).

**БӨТЕН ТАПКАНЫ БЕР КАПКАГА КАЙТУ.** «Бар тапканы тамагын туйдырырга китеп бара» мәгънәсендә. *Койма коруны әлегә калдырып торырга туры киләчәк, чөнки бөтен тапканы бер капкага кайта да тора* (Сөйләм).

**БӨТЕН ТЕШЛӘРГӘ ЕЛМАЮ.** Барлык тешләрен күрсәтеп елмаю. – *Хәзер, балакай, хәзер, чебен тешләгән кебек кенә була ул, – дип, бөтен тешләренә елмая* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).

**БӨТЕН ТИРӘГӘ ҖӘЕЛҮ.** Хәбәре тирә-якка таралу. *[Исмәгыйль] Галиябануны алам дип йөрүем бөтен тирәгә җәелде* (М. Фәйзи. Галиябану).

**БӨТЕН ТӘҢКӘ.** Элекке бер сумлык көмеш тәңкә. *[Галимә] Ике бөтен көмеш тәңкәм бар. Шуңа кәшемир яулык кушып салсам, ярар микән?* (М. Фәйзи. Галиябану).

**БӨТЕН ХИКМӘТ <ТӘ> ШУНДА.** Эшнең асылын, төп мәгънәсен күрсәтү. *Менә бөтен хикмәт шунда да шул: барысы да дөрес кебек, әмма әйтеп бетермәү яки дөреслекне буташтырып әйтү бар* (Ф. Бәйрәмова. Туфаннан таралган татарлар). *Бөтен хикмәт шунда: ара-тирә ишетелгән андый авазларны бала авазы итеп түгел, әкиятләрдән кергән җан иясе авазы итеп кабул итәләр* (К. Җәмит. Килмешәк).

**БӨТЕН ШАРТЫН ҖИТКЕРЕП (КИТЕРЕП).** Һәр яктан уйлап, кагыйдәләрне, йолаларны бозмыйча. – *Бөтен шартын китереп? Сажидәне кияүгә бирдек! – диделәр дуслары* (М. Галәү. Болганчык еллар). *Инде анда үлеп киткән икән, без әсәебезне шуннан гына бик әйбәтләп, бөтен шартын җиткереп, соңгы юлына озатырбыз* (Ә. Еники. Әйтелмәгән васыять).
Төрдәше: җиренә җиткереп үтәү; җиренә җиткерү; җиренә китерү.

**БӨТЕН ШӘҺӘР КУБУ.** Берәр хәбәрдән шәһәрдәге халыкның бер өлеше гөр килү. *Шактый була икән ул өч йөз егерме пассажир! Озатучылар белән бергә кушкач, бөтен шәһәр купкан кебек!* (А. Гыйләҗев. Тәмәкене ташладык, рәхәт яши башладык). *...Таш бәгырьле салкын шәһәр / ишетми дә үзен, каһәр! / Бөтен шәһәр кубар иде, / кеше өрсә шулай әгәр!* (Роб. Әхмәтҗан).

**БӨТЕН ЭШНЕҢ БАШЫ.** Котыртучы кеше хакында. *Бөтен эшнең башы менә шул тиледән? имеш, ди* (Г. Ибраһимов). – *Хыял – әйбәт нәрсә, бөтен эшнең башы ул* («Казан утлары» ж.).

**БӨТЕН ЯГЫ (ҖИРЕ) КИЛГӘН.** Һәр яктан төзек, килешле, җитеш. *Әмма бөтен ягы да килгән кешенең дә аеруча күзгә ташлана торган берәр нәрсәсе була икән* (Ә. Еники. Гөләндәм туташ хатирәсе). *Рәхимсез син, тормыш! Бөтен ягың килгән, бөтен ягың түгәрәк, ләкин җиһанга ник кайгы-хәсрәт, авыру һәм үлем яраттың соң син!?* (Г. Мөхәммәтшин. Йөрәктәге эзләр).

*БӨТЕНЕ* ❖ **БӨТЕНЕ БЕЛӘН.** Башланмаган, бөтен килеш. *Бөтене белән ипи тотып, алап авызы белән почмагыннан умырып тешли-тешли, бер ир үтеп китте, ипинең исе таралып калды* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Сүзне башта иҗекләп, аннан бөтене белән әйттерде* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).

*БӨТЕНЛӘЕ* ❖ **БӨТЕНЛӘЕ БЕЛӘН.** Тулаем, башыннан ахырына кадәр. *Аркасы нәкъ аныкы кебек бөкрәйгән, маңгаендагы тирән җыерчыклар бөтенләе белән безнең әтинекен алып куйган, күз карашы да аныкы шикелле үк авыр, басынкы, җәфалы* (Г. Ибраһимов. Көтүчеләр). *Кайберәүләр, телләре кычытканга түзә алмыйча, күңлендәгене бөтенләе белән чыгарып аудара иде* (Г. Бәширов. Нурҗиһан).

*БӨТЕНЛӘЙ* ❖ **БӨТЕНЛӘЙ ҮЗЕ** *к.* авыздан өзелеп төшү 1. *Малаена карап-карап торам да, тагын бер карап куям – бөтенләй үзе инде* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан өзелеп төшү 1 һ.б.

*БӨТЕННЕ* ❖ **БӨТЕННЕ ЯУДЫРУ** *иск.* Бер сумлык көмеш тәңкә бирү. *Ярый, ярый, хәерле сәфәр булсын. Бөтенне яудырган икән* (Г. Камал).

*БӨТЕРЕЛЕП* ❖ **БӨТЕРЕЛЕП ЙӨРҮ.** Җитез-җитез йөреп, эшкә булышу. *Капчык авызларын бәйләшеп бөтерелеп йөргән Әпипәне, Зиннәттән һич тартынмыйча – әле чеметеп, әле янтавына шапылдатып сугулары – бөтенесе Зиннәтнең канын кыздыра* (Г. Бәширов. Намус). *Өлфәт, авыл советы тирәсендә борынын тарта-тарта бөтерелеп йөрсә дә, аңа чират тимәде* (А. Тимергалин. Таш алиһә).

**БӨТЕРЕЛЕП ТОРУ.** 1. Бөтерелеп эшләү. *Шуңа Ходай Тәгалә аңа орчыктай бөтерелеп торган, зәңгәр күзле, акыллы, үткен Әстерхан кызын биргәндер* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым). *Алар сиңа бернинди начарлык эшләмиләр. Киресенчә, сиңа ярдәм итәргә теләп, бөтерелеп торалар* (М. Юныс. Табу һәм югалту).

2. Вак-төяк йомышларга йөрү. *Кунак-фәлән барында яшь киленнәрдән дә җитезрәк булып, орчык кебек бөтерелеп торган карчыгы да, авып китүдән курыккан кеше сыман, мич буена барып елышкан...* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!).

*БӨТЕРЕП* ❖ **БӨТЕРЕП САЛУ.** 1. Берәрсен ике кул арасына бөтереп алып егу. *Шулай итеп, туз-гып беткән җирән чәченнән урап тотып алды да, җиргә бөтереп салды тегене* (Н. Яһүдин. Пошмас Хәйретдин). *Дөрес, максат итсәң, бер Талибне генә тез астына бөтереп салып була инде ул анысы* (В. Имамов. Казан дастаны).

2. Берәүнең белем, зиһен ягыннан башка бер кешедән өстен булуы. *Яшь башы белән бәхәскә юкка катнашты ул: бетереп салачакмын бит мин аны* (Сөйләм).

**БӨТЕРЕП ЯРЫККА (ШЕШӘГӘ) КЫСТЫРУ (ТЫГУ)** *мыск.* Берәүнең икенче бер кешене теләсә ни эшләтә алуы. *Кемгә каршы чыкканын белми әле ул, теләсәм, бөтереп ярыкка кыстырырга да күп сорап тормам* (Сөйләм).

*БӨЯ* ❖ **БӨЯ БӨЯРГӘ ҖИТҮ.** Бик күп, хәтсез. *[Сиби] Безнең як күп булыр. Бөя бөяргә дә җитәр* (Г. Камал. Хафизалам, иркәм).
Төрдәше: бөя бөярлек; буа буарлык.

**БӨЯ БӨЯРЛЕК** *к.* буа буарлык. *Беләсең килсә, андыйлар бөя бөярлек!* (Г. Бәширов).
Төрдәше: бөя бөяргә җитү һ.б.

*БӨЯТЕ* ❖ **БӨЯТЕ КЫСА БАШЛАУ** *гади с.* Сулыш алу авырлашу, арудан гыжылдый башлау. *– Бар, тege малайның биштәрен үзеңә ал инде, хәле бетә бугай – бөяте кыса башлады* (Сөйләм).

*БРАМАТКА* ❖ **БРАМАТКА ЧЫГУ.** Берни эшләмичә, ялкауланып йөрү, билəмдә йөрү. *Әнә хәзер дә юка иреннәре чалпаеп китте. – Браматка чыкмадым әле, – дип, зазурлана-зазурлана эшенә кереште* (М. Әмирханов).
Төрдәше: авыз күтәреп яту һ.б.

*БРИЛЛИАНТ* ❖ **БРИЛЛИАНТ ТУЙ.** Алтмыш ел бергә ирле-хатынлы яшәп гомер итү. *Гомер сизелмичә узды, бриллиант туй – бергә яши башлауларының алтмыш еллыгын бәйрәм итү бәхете дә насыйп булды* («Сөембикә» ж.).

*БРИТВА* ❖ **БРИТВА ТЕЛЛЕ** *к.* агу тел<ле>. *– Бигрәк тә бритва телле инде синең апаң!* (Сөйләм).
Төрдәше: агу тел<ле>.

*БУ* ❖ **БУ АРАДА.** Күпмедер вакыт эчендә. *– Ахирәтем, бу арада әле Әхәтнең илгә аты чыкты* (А. Алиш. Яңа килен). *Бу арада мөнәсәбәтләре чак кына җылынып, аруланып килгәндә, тагын ызгыш-талаш килеп чыкмасмы?* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: бу көннәрдә; иртәгә-берсекөнгә; күп тә үтми; күптән түгел; озак та үтми<чә>; тиз арада; тиз көннәрдә; шушы арада; шушы көннәрдә; якын арада; якын көннәрдә.

**БУ ӘЛЕ БАЛАСЫ <ГЫНА>, МИЧ БАШЫНДА (МИЧТӘ ЯТА) АНАСЫ.** 1. Кечкенә авырлыкка, бәлагә түзә алмыйча, чәпчеп баручыга әйтелә. *Тау юлыннан машина белән югарыга менгәндә, юлга аркылы ауган наратны кисеп тә вакыт үткәргән өчен сыкранып утырган Маратка «Җитәр инде сиңа!» диде дә, «Бу әле баласы гына, мич башында анасы» дип өстәп куйды* (Сөйләм).

2. Монысы әле вак мәсьәлә, зуррагы алда булачак дип, кызыксыну уяту. *Шулай булгач, «Бу әле баласы, мичтә ята анасы»* (Н. Исәнбәт. Балалар фольклоры). *Кем әйтмешли, «бу әле баласы, мич башында анасы»* («Ватаным Татарстан» газ.).
Төрдәше: анысы әле баласы <-чагасы> гына, мич башында (мичтә) ята анасы һ.б.

**БУ БАШКА МӘСЬӘЛӘ.** Сөйләшүнең (әңгәмәнең) темасына мөнәсәбәте булмаган чит

мәсьәлә хакында сүз чыкканда әйтелә. *Бүгенге көндә сезнең хатын-кызыгыз гаять ирекле, һәр эштә ирләр белән янәшә торалар, тик хокукта тигезләрме, юкмы – бу башка мәсьәлә* («Безнең мирас» ж.).

**БУ БЕТКӘН КЕШЕ.** Берәрсенең киләчәген күзаллап булмаганда әйтелә. *Аның турында сүз кузгатмагыз да, бу беткән кеше инде* (Сөйләм).

**БУ БИТ УЕНЫ ГЫНА, ШУННАН СОҢ БУЛЫР ДУЕНЫ** *к.* анысы әле баласы <-чагасы> гына, мич башында (мичтә) ята анасы. – *Әле бу бит уены гына, шуннан соң булыр дуены!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек).

Төрдәше: анысы әле баласы <-чагасы> гына, мич башында (мичтә) ята анасы һ.б.

**БУ ДӨНЬЯ КЕШЕСЕ ТҮГЕЛ.** Бу дөньядан аерылган, үзе корган хыялый бер дөньяда мәш килгән кеше хакында. *Карт кына бер хатын, авыру өстенә иелеп тыңлап торды да, башын күтәреп, аның инде бу дөнья кешесе түгеллеген аңлатты* (Ә. Фәйзи. Тукай).

**БУ КЕСӘГӘ СУГА (БӘРӘ).** Зыян ясау. *Сатуга чыгарган бу кирпечне алсам, бу минем кесәгә сугачак* (Сөйләм).

**БУ КЕШЕНЕҢ ЮЛЫ ҖИР АСТЫННАН ЙӨРИ.** Астыртын эш итүче кеше хакында. *Бу кешенең юлы җир астыннан йөри* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).

**БУ КИЛЕШТӘН.** Эшнең бу хәле, бу рәвешенә караганда. *Кайтып җиткәнче сәнәк очына эләктерерлек саламың да юк ич синең бу килештән* (Р. Төхфәтуллин). *Бу килештән ул колхоз ничек алга китсен инде?* (В. Нуруллин. Күпер чыкканда).

**БУ КӨННӘРДӘ** *к.* бу арада. *Бу көннәрдә Казанга ат кәмитендә көрәшергә Карәхмәт исемле бер төрек килде* (Г. Тукай. Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш). *Бу көннәрдә ул бик нык ябыкты, аның гәүдәсе күләгә кебек булып калды* (Г. Әпсәләмов. Газинур).

Төрдәше: бу арада һ.б.

**БУ НИ АТЛЫ ЭШ БУ?** Гаделсез булган эшне кире кагып, ачу кабарганда әйтелә. *Аны да дөньяга сыйдырмый башладылар, бу ни атлы эш бу?* (М. Фәйзи).

**БУ НИ ГАҖӘП, БУ НИ ХӘЙРАН.** «Бу ни булмаган эш?» дип гаҗәпләнү. *Гыйнвар, фибрал, март, април – / Акча бетергән айлар; / Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран, / Фарсит итәләр байлар* (Җыр).

**БУ НИТКӘН (НИ) ЭШ.** Килешмәгән эшне кире кагып, ачу килеп әйтү. *Аһ оятсызлар! Бу ни эшегез бу, ә?!* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Бу ниткән эш – чәй эчеп утыру бу вакытта!* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).

**БУ НИШЛӘВЕҢ ИНДЕ <ТАГЫ(Н)>.** Көйсез кешенең рәтсез эшен, кыланышын кире кагу. *[Мөршидә] Әнкәй, бу нишләвең инде?* (К. Тинчурин. Казан сөлгесе). – *Башым әйләндерәсең ич, атасы, бу нишләвең инде тагын?! – дия-дия, ир канатына елышты Карлыгач* (М. Хәбибуллин. Хан оныгы Хансөяр).

**БУ СИҢА ӘНИЕҢ ПЕШЕРГӘН ӘЛБӘ ТҮГЕЛ.** Олыгайганчы әнисе җилкәсендә тәмлегә салынып ятучыга карата. *Бу сиңа әниең пешергән әлбә түгел, ашханәдә нәрсә бар – шуны ашыйсың* (Сөйләм).

**БУ СИҢА БАЛЛЫ КАЛАЧ (БОХАР КАВЫНЫ; МАЙЛЫ БОТКА) ТҮГЕЛ.** Гел тәмлене, майлыны гына ашап рәхәткә күнеккән кешегә әйтелә. – *Бу сиңа майлы ботка түгел, суда пешкән учак ашын ашап кара* (Сөйләм).

**БУ СИҢА БЕР КИЛО БӘРӘҢГЕ ТҮГЕЛ.** Бик арзан һәм һәр җирдә табыла торган нәрсә булмау. *Профессорский переулокта тора. Бу сиңа бер кило бәрәңге түгел* (Ф. Хөсни).

**БУ СҮЗЕҢ – СҮЗ ТҮГЕЛ, ЧҮБЕККӘ КАЛГАН СҮС.** Күптән кат-кат сөйләнелгән сүз хакында. – *Агайне, Әби патша заманыннан калган нәрсәләрне сөйлисең, хәзер бу сүзең – сүз түгел, чүбеккә калган сүс* (Сөйләм).

**БУ СҮЗНЕҢ МӘГЪНӘСЕ – ҮЗЕҢ КАПКА (ТӘРЕ) БАГАНАСЫ.** Гади, аңлаешлы сүзне дә, «моны ничек аңларга?» дип сораучыга каршы әйтелә. *Бер дә ят сүз түгел, беләсең килсә, бу сүзнең мәгънәсе – үзең капка баганасы* (Сөйләм).

**БУ ЭШТӘ АНЫҢ ТЕШЕ КОЕЛЫП БЕТКӘН.** Берәр эштә озак еллар эшләп, аның бөтен нечкәлекләрен белеп бетерү. *Мин алай димәс идем, моны аннан да яхшырак белүче бармы икән – белмим, бу эштә аның теше коелып беткән инде* (Сөйләм).
Төрдәше: бу эштә бөкресе чыккан.

**БУ ЭШТӘ БӨКРЕСЕ ЧЫККАН** *к.* бу эштә аның теше коелып беткән. *Бу теманы өйрәнергә алынганда, сез мүкәләп йөргән булгансыздыр әле, бу эштә бөкресе чыккан* (Сөйләм).
Төрдәше: бу эштә аның теше коелып беткән.

**БУ ЯКТАН КАРАГАНДА.** Бу фикергә таянганда. *Бу яктан караганда, соңгы ун ел милләтебез өчен шатлык чоры булды, әдәбиятыбыз өчен бәйрәм булды* (А. Тимергалин. «Инкыйраз»-га – йөз ел). *Бу яктан караганда, Гафури татар әдәбиятын рус – Көнбатыш Европа – антик Рим – антик Греция – борынгы Һиндстан белән бәйләүче шагыйрь булды* (М. Мәһдиев. Мәҗит Гафури).

*БУА* ❖ **БУА БУАРЛЫК.** Бик күп, хәтсез. *Никадәрле җирдә бәхетләләр, / Бәхетсезләр буа буарлык* (Э. Шәрифуллина. Никадәрле җирдә бәхетләләр). – *Казанда Галимҗаннар буа буарлык ул. Апа, сезгә кайсысы кирәк соң аларның?* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).
Төрдәше: бөя бөяргә җитү һ.б.

*БУАЗ* ❖ **БУАЗ МӘҖМУГА.** Калын язмалар җыентыгы. *Яшьтә җыйган бер буаз мәҗмугам бар, / Аның һәр бәгъзе йире какыр-макыр* (Акмулла. Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе).

*БУАНЫ* ❖ **БУАНЫ ЕРУ (ЕРЫП ҖИБӘРҮ).** Яшермичә сөйләп бирү; моңарчы сер итеп саклаганны сөйләү. *Алайса, түләнмәгән каланны түләп, шуның белән буаны ерып җибәрергәмени?* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур). – *Бүген буаны ерам, чөнки дә син әүлия өммәтеннән, энем...* (Н. Гыйматдинова. Нурулла).

*БУАСЫ* ❖ **БУАСЫ ЕРТЫЛУ.** Хисләр бәреп чыгу. *Аның инде буасы ертылган иде, ул үзенең шөбһәләрен дә, уйлаганнарын да, әле уйлап бетермәгәннәрен дә, ашыга-ашыга, кәгазь битенә түкте* (Сөйләм).
Төрдәше: буаны еру (ерып җибәрү) һ.б.

**БУАСЫ ЕРЫЛУ (ЕРЫЛЫП КИТҮ).** 1. Кычкырып елап җибәрү. *Айлар-еллар буе улын укырга әйдәкләп йөрсә дә, аерылыр минутлар җиткәч, Маһибәдәрнең буасы ерылды* (А. Гыйләҗев. Берәү).
Төрдәше: бөкесе атылу (шартлау) һ.б.

2. *к.* буаны еру (ерып җибәрү). *Хатынкызның буасы ир аркасында ерылса, беттең дигән сүз, ачуы ташып бетеп, күңеле тәмам бушамаса, аның тыелачагы юк, аны тыяр көч тә юк* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: буаны еру (ерып җибәрү); буасы ертылу; буасы китү.

3. Кечкенә йомышын башкару теләге килеп терәлү. – *Тот әле тизрәк!* – *дип, Салихулла балчыклы таяк сузды, буасы ерыла иде бугай* (Ш. Галиев).

**БУАСЫ КИТҮ** 1. *к.* бөкесе атылу (шартлау). *Бу усал хатынның зәһәр сүзләренә озак түзеп тора алмады, кинәт кенә буасы китте* (Сөйләм).
Төрдәше: бөкесе атылу (шартлау) һ.б.

2. *к.* буаны еру (ерып җибәрү). *Мыштыммыштым гына йөргән иде, беркөн сабыр буасы китте* (Сөйләм).
Төрдәше: буаны еру (ерып җибәрү) һ.б.

**БУАСЫ ТАШЫП ЧЫГУ** *к.* авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2. *Эчендә саклап йөрткән серен берәүгә дә сиздермәгән иде, Асияне күргәч, түзмәде, буасы ташып чыкты* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз бүлтәйтү (бәлшәйтү) 2 һ.б.

*БУГАЗ* ❖ **БУГАЗ БЕЛӘН АЛ<ДЫР>У.** Талашуызгышуда акырып-бакырып җиңү. *Аларның беришесе бугаз белән алдырырга тырыша иде – ул чорны да кичерде Харисов* (М. Хәбибуллин. Чоңгыллар).

**БУГАЗ БЕЛӘН ТУУ.** Яхшы тавышлы кеше хакында, ягъни туганда ук тавышы көчле булган. *Ләкин тумыштан ук бугаз белән туган, шаулар өчен, җырлар өчен туган Сәфәргали алай ансат кына телсез калдырып буламы соң?* (Ф. Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы).

**БУГАЗ ЕРТУ** *гади с.* 1. Тупас итеп кычкыру, акыру, бакыру. *Нигә шулкадәр тавыш карлыкканчы бугаз ертырга кеше бәхетенә сөенеп* (Р. Зәйдулла. Коршау). *[Сания] Нәрсә шулхәтле бугаз*

*ертасың, әллә төлке күрдеңме?* (В. Монасыйпов. Суйдылар).

Төрдәше: бугаз еру; бугаз киерү; тамак ерту, тамак киерү.

2. Горурлану. *Тегеләр аның күз карашыннан да куырылып җиргә сеңгәндә, ата дигән ниндидер бөкре, хәлсез карт аны кимсетеп-түбәнсетеп бугаз ертып маташа* (Н. Гыйматдинова. Бер тамчы ярату). *Күмәк хуҗалык, дип бугаз ертасың, шул сүз белән мине томаламак буласың* (Р. Вәлиев. Мирас).

Төрдәше: бугаз киерү 2.

3. Шапырыну. *Әнә бер өер үзенә бер өермә булып, «Братья, славяне!» дип, шом салып, бугаз ертып килә* (М. Галиев. Тимә, яшәсен!). *Әле сәнгать белеменең әлифбасын да эстәмәгән, теоретик яктан аксаган, башында җил уйнаган малай-шалай, бугаз ертып, минминлекләрен исбатларга алына* (К. Кара. Депрессия).

Төрдәше: бугаз киерү 3; буш куык ату (очыру); буш куыклану; куык очырту; күз буяу; күзгә ком сибү; күзгә көл сибү; күзгә <карап> төтен җибәрү; күзгә <карап> төтен өрү; сабын куыгы (күбеге) очыру.

**БУГАЗ ЕРУ** *к.* бугаз ерту 1. – *Киртләмәгән кая! Син дә бугаз ерма* (Н. Гыйматдинова. Нурулла).

Төрдәше: бугаз ерту 1 һ.б.

**БУГАЗ ҖИЗ БУЛУ.** Тавыш җиз торба тавышына охшаш булу. *Бу да шәп чыгара, бугазы җиздән диярсең* (Ә. Еники).

**БУГАЗ КИЕРҮ** *к.* бугаз ерту 1. – *Бугазыңны киермә, – дип әйтәм, – котырган этегезне бәйдә тотмаган өчен подсуд җибәрермен* (Ф. Шәфигуллин). – *Бугаз киермә, Сөләй балыгы! Миңа персидәтел хуҗа, бу – факыт!* (Н. Гыйматдинова. Үзем генә беләм...).

Төрдәше: бугаз ерту 1 һ.б.

2. Горурлану. *Үземә үзем сокланып, авыл урамнарын бер итеп, бугаз киереп кайтып барам* (Ш. Рәкыйпов). *Ләкин берәүләрнең «мин – марксист!» дип буаз киереп шапырынып йөрүләре иҗтимагый-политик активлык булмаган кебек, Җ. Вәлидинең дә үзе турында кычкырмавы ул әле һич тә аның капма-каршы полюста торуы дигән сүз түгел иде* (М. Мәһдиев. Тарихтан сабак).

Төрдәше: бугаз ерту 2.

3. Шапырыну. *[Фәттах] Без сезне бугазыгызны киерер өчен асрамыйбыз...* (Ф. Бурнаш. Таң). *Күпме генә бугаз киерсәгез дә, күпме генә болгатсагыз да, берни дә кыра алмассыз* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!).

Төрдәше: бугаз ерту 3 һ.б.

**БУГАЗ ӨЗЕЛҮ.** Җәзалану, бугазы ерткаланып үтерелү. *Карт кешене рәнҗеткән өчен, бугазы өзелсен дип теләк теләде* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала). – *Әтидән калган шушы агачны харап иткән кешенең бугазы өзелсен, бу – юньле кеше түгел, дигән* (М. Мәһдиев. Бәхилләшү).

Төрдәше: бугазны чәйнәү.

**БУГАЗ ТӨЕНЕ.** Кешенең бугазында алма кебек күпереп торган төер. *Шәяхмәтнең кара тамырлы куллары шешенгән, сакал бөртекләре баскан бугаз төене зәңгәрләнгән, бите-маңгае буялган* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала). *Миңа елмаеп карап торган Насыйбулла абзыйның төк баскан бугаз төене кыймылдапкыймылдап алды* (Ә. Хәсәнов. Әҗәт).

**БУГАЗ ТУЗАНЫН ЮУ** *к.* авыз җебетү 1. *Хәер, эштән соң җыйналып «монополька» суы белән бугаз тузанын юып алгач, алар аннан барыбер үчне кайтаралар иде* (Ф. Хөсни).

Төрдәше: авыз җебетү 1.

**БУГАЗ ЧӘЙНӘШҮ (ЧӘЙНӘШЕП ЯШӘҮ).** Бер-бере белән талашып, сугышып яшәү. *Алар, туганкаем, ни хәтәр ерткычлар кебек үзара талашалар, бер-берсенең бугазын чәйнәшәләр* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!). *Бездәге ул минминлеккә, / Бугаз чәйнәшеп яшәүләр / Илтми бер дә иминлеккә* (Ф. Дәүләтбаев. Таныш халәт).

*БУГАЗГА* ❖ **БУГАЗГА АРКЫЛЫ КИЛҮ (БАСУ; ТЫГЫЛУ; УТЫРУ).** Бу эшне уңдырдым дип, кулына (яки авызына) алам дигәндә, көндәше яки дошманы эшне бозу. – *Ходай гына орсын иде үзләрен, бугазларына аркылы килсен иде урлаганнары!* (М. Галәү. Болганчык еллар). – *Бугазыгызга аркылы бастыммы, кулак әфәнделәр? – Каһир рәшәткәгә таба чигенде дә, аңа терәлеп, халыкка утлы күмердәй кайнар сүзләр ташлады* (Ә. Гаффар. Бодай бөртеге һәм тегермән ташы).

Төрдәше: бугазына аркылы утырсын.

**БУГАЗГА АРКЫЛЫ СӨЯК БУЛЫП КАДАЛУ (ЯТУ)** *к.* аркылы килү (төшү) 2. *[Алмас] Минем чын дошманнарым болай да муеннан. Бугазларына аркылы сөяк булып яттым* (И. Юзеев).
Төрдәше: аркылы килү (төшү) 2 һ.б.

**БУГАЗГА ӘЧЕ ТӨЕН (ТӨЕР) ТЫГЫЛУ.** Бик нык елыйсы килгәндә яки үпкәләгәндә, күңел нечкәреп барлыкка килгән халәт. *Әюп үзенең рухын төшермәскә, һич тә булмаса, тыныч күренергә никадәр генә тырышмасын, булдыра алмады. Бугазына ниндидер әче төен тыгылды* (Г. Кутуй. Хәнҗәр).
Төрдәше: бугазга килү (килеп җитү; терәлү; килеп терәлү / тыгылу) 1.

**БУГАЗГА БАСУ** *гади с.* Үз дигәнен булдырырга тырышып, дорфа рәвештә таләп итү, берәр нәрсәне эшләргә мәҗбүр итү. *Кабахәтләр! Яңадан эшче сыйныфның бугазына басарга уйлыйлар* (И. Гази. Онытылмас еллар). *[Әхмәдиша] Хәзер үк бугазларына басып сорамасагыз, атсыз да, арбасыз да, игенсез дә каласыз* (Ю. Әминов. Умырзая чәчәкләре).

**БУГАЗГА КАМЧЫ ТЫГУ.** Ирек бирмәү, тыю; кыйнау. *Крестьянга, мескенгә, җир кирәк, ул җир азлыктан кычкыра, ә аның бугазына камчы китереп тыгалар* (Ф. Хөсни).
Төрдәше: авыз ачарга <да> ирек бирмәү һ.б.

**БУГАЗГА КИЛЕП БӨЯЛҮ (ТӨЕЛҮ).** 1. Бик нык курку. *Малайның йөрәге бугазына ук килеп бөялде* (Г. Әдһәм. Наласа авылы көе). *Моңарчы тыелып торган яшьләре күз буасын ерып ташты, бугазга килеп төелгән тавышы елау-сыктау булып ургылды* (Л. Зөлкарнәй. Сафа).

2. Әрнү, үпкәләү хисе туу. *Иелә барган башын югары күтәрде, бугазына килеп төелгән әрнүен эчкә йотты, сер бирмәде* (Ф. Бәйрәмова. Кырык сырт). *Гөлшаһидә, бугазына килеп төелгән дулкынны сиздермәс өчен, пальма артынарак яшеренде* (Г. Мөхәммәдова. Гуманизм җырчысы).
Төрдәше: бугазга төер килү (утыру) (ике маддә өчен дә).

**БУГАЗГА КИЛҮ (ТЕРӘЛҮ; КИЛЕП ҖИТҮ / ТЕРӘЛҮ / ТЫГЫЛУ).** 1. *к.* бугазга әче төен (төер) тыгылу. *Бу – берничә секунд башының томан эчендә йөзүе иде, бу – тау кебек газапның бик төптән күтәрелеп, бугазга килүе иде* (Ә. Еники. Ана һәм кыз). *Наилә Гөлнараның бичара ирен күз алдына китерде дә бугазына килеп тыгылган яшьләрен көчкә тыеп, әңгәмәнең сөземтәсен, мәгънәсен көтеп калды* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

2. Китереп кысып, берәр нәрсәне ашыгыч, тиз арада хәл итү кирәклеге турында. *Әйтәсе сүземне мин бугазыма килеп терәлгәч кенә әйттем, илһамымны күкрәк читлегенә сыешмый башлагач кына түктем – нигә дөньяга җитлекмәгән бала тудырырга?!* (Ә. Рәшит. Һәркемнең... үз хакыйкате). *Хәер, авыруы бугазга терәлеп, аягында көчкә басып торучылар да, бармагына шырпы кадалса да табибка килүчеләр дә бар* («Акчарлак» газ.).

**БУГАЗГА ПЫЧАК ТЕРӘҮ (ТЕРӘП ТОРУ).** Төрле җәзалар бирү белән куркыту. *«Давай, юл гына күрсәт», – дип, атайның бугазына пычак терәделәр* (В. Имамов. Казан дастаны). *<...> һәм янә «татардан да яманрак» кунакның бугазына пычак терәп, әлеге сыеклыкны эчәргә күндерде* (Р. Зарипов. Тамчы гөл).

**БУГАЗГА СӨЯК БУЛЫП КАДАЛУ** *к.* аркылы килү (төшү). – *Туктале, зимагур, нигә муллалар шул тикле синең бугазыңа сөяк булып кадалды?* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Беләм мин аларның нигә бәйләнгәннәрен. Безнең бригадага ачулары килә. Бугазына сөяк булып кадалабыз бит үзебез дә, дип уйлый иде ул* (И. Гази).
Төрдәше: аркылы килү (төшү) 2 һ.б.

**БУГАЗГА ТАШ БУЛЫП УТЫРУ** *к.* аркылы килү (төшү) 2. *Ул, бугазына таш булып утырган нәфрәт сүзләрен йотып, атылган йәдрә кебек, өйләренә томырылды* (Э. Шәрифуллина. Мәхәббәтнең җиде төре).
Төрдәше: аркылы килү (төшү) 2 һ.б.

**БУГАЗГА ТӨЕР КИЛҮ (УТЫРУ)** *к.* бугазга килеп бөялү (төелү) 1, 2. *Зөһрә ханым сүзеннән туктады, күңеле тулып, бугазына төер килде шикелле, ефәк кулъяулыгын алып, ираннәренә китерде һәм шул хәлдә озак кына тынып утырды* (Ә. Еники. Йөрәк сере). *Әйтәсе сүзләр күп иде – һәр икесенең бугазына төер утырды* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).
Төрдәше: бугазга килеп бөялү (төелү) 1, 2.

**БУГАЗГА ЯБЫШУ.** Тупас рәвештә мәҗбүри итеп таләп итү. *Бу кешенең шундый кайгылы көннәрдә биш сум бирәчәк өчен шушылай бугазга ябышуы җенемне чыгарды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *[Нурмый] Ә син бугазга ябышканда карап торыйммы?* (Т. Гыйззәт).
Төрдәше: бугазга-бугаз килү (ябышу); бугаздан алу; бугаздан тотып (эләктереп) алу.

**БУГАЗГА-БУГАЗ КИЛҮ (ЯБЫШУ)** 1. Ызгышу, сүзгә килү, якага ябышып талашу. *Менә мондый заманнарда Фазыйл әллә кайдан акыл таба, кызык сүз әйтә, яңа уен чыгара да, әле биш минут элек кенә бугазга-бугаз килгән малайлар, гөрләшеп, кочакланышып, яңадан уйнарга тотыналар* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр). *Үзбәк ханның тирәннән уйлап эшләгән яшерен теләген гамәлгә ашырып, бер үк мәмләкәтнең ике төбәге бугазга бугаз килеп тарткалаша башлады* (Р. Вәли. Тәхет күрке).
Төрдәше: бугазга ябышу һ.б.

2. Кара-каршы килү, очрашу. *Безнең каһарманнар турыдан-туры үлем белән бугазга-бугаз килделәр, мәсьәләнең аеруча җитди торганлыгын, ул районнардагы һәр метр җир өстендә бөтен илнең язмышы хәл кылынганлыгын аңлап сугыштылар алар* (М. Әмир). *Мәңге онытылмаслык минутлар! Соңыннан, дошман белән бугазга бугаз килешә башлагач, әллә ни куркыныч булып тоелмас ул* (И. Гази).

*БУГАЗДАН* ❖ **БУГАЗДАН АЛУ** *к.* бугазга ябышу. *<...> көннәрдән бер көнне Алмыш хан, атасы Шелке кебек, монда да килеп җитәр, безнең бугаздан алыр, диде* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур). – *Астма минем, кем әйтмешли, Әсмабикә түтиегез бугаздан ала* (Р. Вәлиев. Иске сәгать дөрес йөри).
Төрдәше: бугазга ябышу һ.б.

**БУГАЗДАН БУРЫЧ ЭЧЕНДӘ.** Берәрсенә бурычы бик күп булу. – *Хәзер банктан да акча алып булмый, бугаздан бурыч эчендә утырам* (Сөйләм).
Төрдәше: бурычка бату; бурычка бәйләнү; бурычка керү 1; бурычка чуму; бурычлы булу; муен тиңел (тиңентен) бурычка бату; муенга тикле (хәтле) бурычка бату; муенда бурыч тулу; муеннан ашу; муеннан <булу>; муеннан бурычка бату; муеннан чуму. муеннан бурычлы <булу>.

**БУГАЗДАН ТОТЫП (ЭЛӘКТЕРЕП) АЛУ** 1. *к.* бугазга ябышу. *Берсе бугазыннан эләктереп алды. Нурисламның йокыга китә алмыйча яткан чагы иде бу* (М. Хафизов. Ике җәһәннәм).
Төрдәше: бугазга ябышу һ.б.

2. *күч.* Уйга-фикергә ныклап кереп урнашу. *Эчне ачыттырып, бәгырьләргә тиеп, үземнең туган телемдә нәрсәдер язасы килү бугазымнан тотып алды да бик озак җибәрмичә торды* (М. Юныс. «Митакса-атлас»). *Кайтуга эш, мәшәкатьләр бугаздан тотып алды. Укыту эшләреннән тыш, тормыш кирәк-яраклары хәстәрләү күп көч, вакыт сорый иде* (Х. Камалов. Үксезләр).

*БУГАЗЛАГАН* ❖ **БУГАЗЛАГАН КЕБЕК БУГАЗЛАРГА.** Кем (яки нәрсә) белән чагыштырып үтерү белән янау. *[Надир] Фәхри сөйләгәндә, көчкә-көчкә генә чыдап, калтыранып тора. Соңыннан пәкесен чыгарып, мин сине этне бугазлаган кебек бугазламасам...* (К. Тинчурин. Сүнгән йолдызлар).

*БУГАЗНЫ* ❖ **БУГАЗНЫ ЧӘЙНӘҮ.** Зарар бирү, үтерү. *Һәр ыру бер-берсенең бугазын чәйнәргә әзер* (Р. Зәйдулла. Илбәк). *Шәһәрдә генә көнче түрәләр кәнәфи өчен бер-берсенең бугазын чәйни дисә, авылларда да беттән азган вак хәшәрәтләр тешләшергә өйрәнгән икән* (Н. Гыйматдинова. Үзем генә беләм...).
Төрдәше: бугаз өзелү.

*БУГАЗЫ* ❖ **БУГАЗЫ ЕРТЫЛГЫРЫ** *карг.* Өстәл сугып идарә итүчеләр һәм гаиләдә үз фикерен җикеренеп өскә чыгаручыларга карата. *Бугазы ертылгыры!* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).

*БУГАЗЫН* ❖ **БУГАЗЫН КАПЛАУ.** Сыйлап, ришвәт биреп яки башка юл белән кемнең дә булса авызын томалау. *Аның өчен горурлануы бугазын каплагандай була, халыкның котыра-котыра кул чабуы колагына матур музыка булып ишетелә* (Л. Сабирова. Бер уч борчак).
Төрдәше: авыз каплану 3 һ.б.

*БУГАЗЫНА* ❖ **БУГАЗЫНА АРКЫЛЫ КИЛГЕРЕ!** *«Бугазыңа аркылы килгере!» кебек яки аннан да ямьсезрәк сүзләр белән «тукландыралар»* (Ф. Тарханова. Хисләр дәрьясында).
Төрдәше: бугазына аркылы утырсын!; бугазына тыгылсын!

**БУГАЗЫНА АРКЫЛЫ УТЫРСЫН!** *карг.* Кеше хакын ашаучыны каргау сүзе. *Ходай үзе бирсен аларга җәзасын, кеше хакына керүченең бугазына аркылы утырсын!* (Сөйләм).
Төрдәше: бугазына аркылы килгере! һ.б.

**БУГАЗЫНА ПЫЧАК КЕРГЕРЕ (КАДАЛГЫРЫ)** *карг.* Берәрсенең суелып үлүен теләү. *...Күрше эте, бугазына пычак кергере, өрә дә өрә бит* (А. Шамов). *Бугазына пычак кергере!* (Ай колакланса, ни була. 1 нче кит.).
Төрдәше: авыз<лар>ын корт чаккыры! һ.б.

**БУГАЗЫНА СӨЯК БУЛЫП КАДАЛГЫРЫ!** *карг. Иманы бугазына сөяк булып кадалгыры...* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).
Төрдәше: бугазына аркылы килгере һ.б.

**БУГАЗЫНА ТАЛ ЧЫККЫРЫ** *мыск., карг.* Юк-барга акырынып-бакырынып баручыга карата. *Әйт әле шуңа, бугазына тал чыккыры, юк-барга акырынып бармасын, болай да баш авырта* (Сөйләм).
Төрдәше: бугазына таш булып утырсын!; бугазына таш кергере.

**БУГАЗЫНА ТАШ БУЛЫП УТЫРСЫН!** *карг., к.* бугазына тал чыккыры! *Бугазына таш булып утырсын!* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).
Төрдәше: бугазына тал чыккыры! һ.б.

**БУГАЗЫНА ТАШ КЕРГЕРЕ!** *мыск., к.* бугазына тал чыккыры. *Кем ул анда үгез кебек бакыра, бугазына таш кергере?* (Сөйләм).
Төрдәше: бугазына тал чыккыры!

**БУГАЗЫНА ТЫГЫЛСЫН!** *карг.* Кеше малын ашаучыга карата. *Шушы әйберләр бугазларына тыгылсын кара йөрәкләрнең* (Р. Батулла. Сөембикә). *Берәр машина булса да җибәреп булмый идемени соң? Бугазлары тыгылсын иде* (Ф. Садриев. Бәхетсезләр бәхете).
Төрдәше: бугазына аркылы килгере! һ.б.

*«БУГАЙ»НЫ* ❖ **«БУГАЙ»НЫ КҮПЕР БАШЫНДА КУРА БЕЛӘН ЧӘНЕЧКӘННӘР.** Сүзен ачык иттереп әйтмичә, «бугай», «бәлки», «шулайдыр» кебек сүзләрне кулланып, икеле-микеле сөйләшүдән көлү. *Теге нотыкчыны колак салыбрак тыңла әле, аның «бугаен» күпер башында кура белән чәнечкәннәр* (Сөйләм).

*БУГАЛАК* ❖ **БУГАЛАК ТАШЛАУ.** Буйсындыру, үз кулы астына алу. *Менә шул Туктамыш үзенең Күк Урдасыннан тыш бөтен Алтын Сарай иленә дә бугалак ташларга, тышау салырга җыенадыр инде* (В. Имамов. Карабәк).
Төрдәше: авызлык кидерү һ.б.

*БУГЫН* ❖ **БУГЫН БИЗМӘНГӘ САЛУ** *туп.* Вакчыл һәм саран кеше хакында. *Башкалар язмышына битараф, чисталык-пакьлек белән дус түгел, җенси тотнаксыз, бугын бизмәнгә салып үлчәп, һәрнәрсә өчен хак сорарга ярата* (З. Мурсиев).
Төрдәше: алырсың шайтаннан иман 2 һ.б.

*БУЕ* ❖ **БУЕ АРКЫЛЫГА КИТҮ** *к.* аркылысы-буе бер. *Йомшак кәнәфиләрдә озак та утырмады кебек, буе аркылыга киткәнлеге күзгә бәреп тора* (Сөйләм).
Төрдәше: аркылысы-буе бер.

**БУЕ БЕЛӘН ДӘ БУЛУ.** Урта яки озын буйлы булу. *Кайчандыр мәктәптә бергә укыган, буе белән дә булган Кәүсәриягә күз кыскан иде, тегесе, борынын җыерып, аркасын бирде* (Сөйләм).

**БУЕ БЕР КАРЫШ.** Кыска буйлы. *Әкиятләрдә бер зат бар ич, укыгансыңдыр: буе бер карыш, сакалы биш карыш затны онытмасаң, әнә шул бәндәгә алдар тазны да ялгасаң, Сабит Нургалиев килә дә чыга* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Бөтен бәхетсезлек аның нәкъ менә «буе бер карыш» гәүдәсе аркасында кебек иде* (Н. Гыйматдинова. Кәтәнә).
Төрдәше: буйга чыкмау.

**БУЕ БУЙГА ҖИТҮ.** Балигъ булу, тәмам үсеп җитү. *Буе буйга җитә башлагач, авыр эшкә чумды* (Ш. Камал).

*БУЕНДА* ❖ **БУЕНДА БАР** *эвф.* Балага узган, корсаклы хатын хакында. *Китәргә? Кая? Гайнинең инде буенда бар...* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы). *Апасы нык ук юанаеп киткән, буенда бар икән, бите тимгел-тимгел* (Ә. Галиев. Авылдашлар).
Төрдәше: авыр аяк<лы> 3 һ.б.

*БУЕН-СЫНЫН* ❖ **БУЕН-СЫНЫН ҮЛЧӘҮ.** Нык итеп кыйнау. *Бер кичне, кеше-кара йөрми башлагач, безнең урам кызлары янына килеп*

*йөрмәсен әле дип, Исхакның буен-сынын үлчәп җибәргәннәр* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

*БУЕҢ* ❖ **БУЕҢ ҖИТМӘГӘНГӘ ҮРЕЛҮ.** Булмасны өмет итү. *Имеш, мин буем җитмәгән җиргә үреләм* (А. Шамов). *Буең җитмәгәнгә үрелмә* (Мәкаль).

*БУЕҢДАГЫНЫ* ❖ **БУЕҢДАГЫНЫ БУЙГА СЕҢДЕРЕП БУЛМАУ.** Балага узып, йөккә калуыңны үз буең итеп күрсәтеп, яшереп булмый, корсак булганлыгы беленү. *Минем хәлләр җиңелдән түгел. Буеңдагыны буйга сеңдереп булмый ич. Кешеләргә дә, Казанда ирем бар, дим* (Ш. Маннур).

*БУЗА* ❖ **БУЗА КУБАРУ (КУЗГАТУ; КУПТАРУ; КҮТӘРҮ).** Ызгыш-талаш чыгару. *[Тәкый] Буза куптарып йөрергә Мостафадан үрнәк алмагыз* (Г. Кутуй. Шатлык җыры). – *Телевизор һәм радиодан, алар илендә сугыш бара, дип лаф оралар, ә монда, кая башны тыкма, әрмән дә азәри, белмим, үзләрендә кемнәр генә сугыша торгандыр, әллә картлар белән балачага буза куптарып ята инде?* (Р. Зәйдулла. Сөембикә).
Төрдәше: гауга чыгару; скандал чыгару.

*БУЙ* ❖ **БУЙ АТУ.** Үсә башлау; кем дә булса буйга үсеп китү. *Агыз яшьләрне, кыл төшләрне ирва, / Бетеп, җир-җир буй атсын нәхле сәүда* (Г. Тукай. Кыйтга).

**БУЙ БЕЛӘН ТҮГЕЛ, УЙ БЕЛӘН.** Һәр нәрсәне яхшылап уйлаганнан соң гына эшләргә кирәклеге хакында. *Әледән-әле әтисенең, буй белән түгел, уй белән эш итәргә өйрән, улым, дигән сүзләрен күңел түрендә кадерләп саклый* («Авыл офыклары» газ.).

**БУЙ БИРМӘҮ.** Берәрсе белән исәпләшмәү, аңа буйсынмау, күнмәү. *Сәлим карт йортка бу буй бирмәс «малай актыгы»ның мондый сүзләрен башта колак яныннан игътибарсыз уздырырга тырышып йөрде* (Ф. Хөсни).

**БУЙ БИРҮ.** Буйсыну, баш ию; санлау. *Ләкин шома гимназист буй бирергә бик үк теләми иде* (Ф. Хөсни). *Ул үзе, Ходайга шөкер, гомере буена иреннән башка беркемгә дә буй бирмәде* (Г. Бәширов. Менә сиңа, мә!).
Төрдәше: алдында баш ору (ию) 1 һ.б.

**БУЙ БӨГҮ.** 1. Риза булу, буйсыну, сүз тыңлау. *Эстәмимсең буй бөгәргә? / Ирнәсең эшләргә эш?* (Г. Тукай. Толстой сүзләре). *Ә мин анда әнкәм җанын тоям, / Каршысына киләм буй бөгеп...* (Х. Әюп).
Төрдәше: алдында баш ору (ию) 1 һ.б.

2. *к.* арка бөгү (бөгеп тору) 2. *Мәхмүт абзый инде картая да башлаган, ә үзе әле һаман байда ялчы булып арка бөгә* (Сөйләм).
Төрдәше: арка бөгү (бөгеп тору) 2 һ.б.

**БУЙ ҖИТКЕРҮ.** Үсеп җитү. *Урам чирәменә куар идең, Әнисә абыстайлардан ерак түгел ике малай буй җиткереп, ундүртләре тулган көндә әткәләре тегеләрнең икесенә ике мотоцикл бүләк итте* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Беркөнне буй җиткереп килүче оныгын дәшеп алды да карарын җиткерде* (М. Әмирханов. Зиннәтулла хәзрәт).

**БУЙ ҖИТМӘСЛЕК.** 1. Үрелгәндә, кул җитәрлек түгел. *Ул аларның кайсын кая төртеп, этеп җибәрде дә, билендәге кылычын салып, бала-чага буе җитмәслек биек чөйгә элеп куйды* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур).

2. Көч җитәрлек түгел. *Беркемнең дә буе җитмәслек күпләрнең якты хыялы булган горур хатын-кыз Таирга килеп ярдәм сорасын әле* (А. Нәҗми. Кояш җилләре).

3. Берәүнең казанган абруена кемнең дә җитә алмаячагына ишарә. *Чыңгыз хан беркемнең дә буе җитәслек булып калачак та, чөнки империяләр заманы узды* (Р. Хәкимов. Татар рухы).

**БУЙ ҖИТҮ.** 1. Үрелгәндә кул җитәрлек булу. *Бәхет җимешенә буем җитте дигәндә генә, нигә гел кулга сугалар икән?* (Г. Галиева. Тулгак). *Буе җитә алганчы кисеп төшерә дә арбасына салып алып китә, ди* (К. Җәмит. Килмешәк).

2. Көче җитү, мөмкинлеге булу. *Буйлар җиткәч, буй җитмәстәй / Бөек булып киттегез* (К. Булатова). – *Авызыңны пешермәсме соң? – ди ул, Бәдретдингә ачу белән карап. – Буең җитәрме?* (А. Вергазов. Үзеңә кайту).

3. Өлгергән, балигъ булган. *Әмма бабасы җибәрмәде мәктәпкә, буй җиткән кыз балага малайлар арасында ихахай-михахай килеп йөрү мөрәүвәт түгел, имеш* (Т. Мөбарәков).

*Менә егет белән кыз үсеп буйга җиткәннәр* (Г. Галиева. Газзәбану).
Төрдәше: буйга җитү.

**БУЙ КАЛКЫТУ.** Үсү, үсеш алу. *Басуларда буй калкыткан яшь игеннәр җиңелчә, салмак тибрәләләр, күңелне назлап иркәлиләр сыман* (Н. Хәсәнов. Кайтасы килә). *Авылында буй калкыткач, ФЗОга киткән, шуннан әле кавырсыны да катмаган унбиш-унҗиде яшьлек малайларны шахтага җибәргәннәр* (Т. Әйди. Сак-Сок язмышы).
Төрдәше: буй тарту; буй үстерү.

**БУЙ КУЮ.** Янына яту. *Гүя буй куйды сылу гүзәлем, өзелеп төште шунда үзәгем* (Ф. Яхин).
Төрдәше: буй яту.

**БУЙ КҮРСӘТҮ.** 1. Элек авылларда кунак кызларның үзләрен күрсәтеп басып торулары яисә йөрүләре. *Авылның үз кызлары, кунак кызларын ияртеп, егетләр алдыннан үткәләп буй күрсәтәләр* (М. Фәйзи). *Сәркатип ханым, яшьлеге беләнме, башкачамы, моңа кадәр Солтан алдыннан буй күрсәтеп узуны кирәк тапкан булса да, Һарун Бариевичтан бу сүзләрне ишеткәч, бик тиз күңелен сүрелдерде* (Ф. Яхин. Көзге яңгырга кадәр).

2. *күч.* Эшсез тору. – *Кайчан карама, буй күрсәтеп басып торасың* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Үзенә генә ишетелерлек итеп: «Бар, бар... Буй күрсәтеп торма монда», – дип, апасына ярдәм итәргә өйгә озатты* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!).

**БУЙ САЛУ.** Суның тирәнлеген буй белән үлчәп карау: кулларны югары күтәреп, су төбенә төшү. *Буй салам, дулкын-ут салам, / Буйсынам, сынмасам да* (С. Сөләйманова). – *Азат, хатының бармы, өйләндеңме, буйдак буй салып йөримсең? – диде карчык* (М. Хәбибуллин. Шайтан каласы).

**БУЙ СОНУ.** Ярдәм итү, тәкъдим итү; буйсыну. *Ул миңа солтан, аның бар әмренә мин буй сонам* (З. Ярмәки). *Берлегеңне, барлыгыңны / Танган хәлдә буй сонам мин* (Р. Рахман. Мәхәббәт).

**БУЙ СЫНДЫРУ** *к.* алдында баш ору (ию) 1. – *Сөйкемле сөяк Сөем тутай, – диде ишекче кыз. – Болар – сиңа буй сындырып, тез йөгенеп янында яшәү өчен ихтыяри хезмәткә килгән кызлар* (Р. Батулла. Сөембикә). *Аска карап, буен сындырып, Нәҗип мунча ишегенә кереп югалды, шыбырдатып утын яркаларын идәнгә койды һәм, тәбәнәк сәкегә утырып, учы белән маңгай тирен сөртте* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: алдында баш ору (ию) 1 һ.б.

**БУЙ ТАРТУ.** Буйга үсеп китү. *Тазарган, буй тарткан* (Б. Камалов. Кала бизәге). *Әйе, килбәте нык үзгәргән, буй тарткан, чын-чынлап егеткә әверелгән* (Р. Кәрами. Кая чабасың, гомер юртагы?).
Төрдәше: буй калкыту һ.б.

**БУЙ ҮСТЕРҮ** *к.* буй калкыту. *«Казакъ йортында буй үстердең, ике бала анасы булдың, миңа мондый сүзләр белән килергә ничек йөзең оялмый?» – дияр* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *Зәйтүн гөлләр арасында / Зифа буй үстергәнсең* (М. Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә).
Төрдәше: буй калкыту һ.б.

**БУЙ ЯЗУ**. Йөреп алу, йөреп килү. *Утыра-утыра оеп китә башлаганмын, бераз буй язып килим әле* (Сөйләм).

**БУЙ ЯТУ.** Нәрсәнең дә булса буе юнәлешендә яту. *Чана төбенә, салам түшәккә буй яткан Бәдүккә ара-тирә сүз катып, әңгәмә корып җибәрмәкче дә булам* (Л. Хәмидуллин. Кыш үткән юлдан).
Төрдәше: буй кую.

*БУЙГА* ❖ **БУЙГА АЛЛАГА ШӨКЕР.** Буе бераз озын булу. *Буйга да Аллага шөкер генә* (И. Гази. Кызыл томаннар артында).

**БУЙГА** ❖ **БУЙГА БЕТКӘН** *к.* багана кебек. *Бер зәгыйфь, көчсез, һөнәрсез, буйга беткән бәндә мин* (tatarca-text.narod.ru).
Төрдәше: багана кебек һ.б.

**БУЙГА ДИГӘННЕ АРКЫЛЫГА САЛУ.** Артык симез кеше хакында. *Ахрысы, табигать буйга дигәнне дә аркылыга салган* (Ш. Галиев).

**БУЙГА ҖИБӘРҮ.** Үз-үзен кулга алу, эчендәгеп башкаларга сиздермәү. *Чәмәтнең йөрәге суга башлады, ләкин ачуын сиздермәде, буйга җибәрде* (Х. Сарьян).
Төрдәше: буйга сеңдерү 1.

**БУЙГА ҖИТЕП ТӘ, УЙГА ҖИТМӘҮ.** Балигъ булып, буйга да үскән, уй-фикере генә зәгыйфьрәк булу. *Карап торганда, күзгә күренеп, егет булды: буйга җитеп тә, уйга җитмәве генә бераз борчып тора* (Сөйләм).
Төрдәше: буйга үскән, акылы үсмәгән.

**БУЙГА ҖИТКЕЗҮ.** Үсеп җитү, зур булу. ...*Балалары буйга җиткезеп, башлы-күзле булып, үз тормышларын корып җибәрделәр* (Ш. Хөсәенов).

**БУЙГА ҖИТҮ** *к.* буй җитү 3. *Буйга җитте бай кызы нык тәрбия, карау белән; / Көн дә биш кат юып вә чәчләрен тарау белән* (З. Бәшири). *Җиһангирны буйга җитеп килә торган кыз итеп киендерү мәгъкуль күрелде* (А. Тимергалин. Таш алиһә).
Төрдәше: буй җитү 3 һ.б.

**БУЙГА КАЛУ** *к.* авыр аяк<лы> 3. *«Буйга калган» дип тә әйтәләр* (Ш. Галиев. Әнкәйләрнең күркәм сабырлыгы). *Җырладым бер моңлы татар көе, / Тау кызлары буйга калганда* (Э. Шәрифуллина. Уйлы еллар).
Төрдәше: авыр аяк<лы> 3 һ.б.

**БУЙГА СЕҢДЕРҮ** 1. *к.* буйга җибәрү. *Зәйтүнә өйдәгеләрнең барлык тупас эшләрен буйга сеңдерә килә, гомумән, ул берәү белән дә, берни турында да сөйләшми* (Ф. Хөсни). *Буеңдагыны буйга сеңдереп булмый ич* (Бирелгән сүз корсаклы булуны яшерү мөмкинлеге булмау хакында бара – Ш. Маннур. Чын сөю бармы?).
Төрдәше: буйга җибәрү.

2. Аз-азлап, чамасын белеп кенә эчү турында. *Яшьрәк кунакларны ымлап кына мич артына чакырып алалар да шунда гына кырлы стаканга салып бирәләр. Буеңа сеңдер, картларга сиздермә!* (Ә. Еники. Җиз кыңгырау). – *Салсам да, буема сеңдерәм, синең шикелле тилереп йөрмим, – диде ул, дорфаланып* (А. Гыйләҗев. Әтәч менгән читәнгә).

**БУЙГА СӨЙЛӘШҮ.** Каршы фикер әйтмичә, сүз сөрешен бозмыйча, хуплап кына гына сөйләшү. *Гел буйга сөйләшүчеләр арасында бер аркылы сөйләшүче дә кирәк икән ул...* (М. Галиев. Нигез).

**БУЙГА УЗУ** 1. *к.* авыр аяк<лы> 3. *Йөкле хатынны баштарак беленгәндә «буйга узган» диләр* (Ш. Галиев. Әнкәйләрнең күркәм сабырлыгы). *Сигез ир олан тугач, Казан бәге Мәхмүт хаҗи кызы Сайгөле тутайга өйләнеп, яшь кәләш буйга узгач, Йосыф мирза уйга батты* (Р. Батулла. Сөембикә).
Төрдәше: авыр аяк<лы> 3 һ.б.

**БУЙГА ҮСКӘН, АКЫЛЫ ҮСМӘГӘН.** Буйга озын булып та, акылы ягыннан сай булу. *Нәрсә дип әйтергә инде аның турында, соңгы көрешүдән соң җилкәләре киңәеп киткән, буйга үскән кебек, тик менә акылы гына үсмәгән* (Сөйләм).
Төрдәше: буйга җитеп тә, уйга җитмәү.

**БУЙГА ЧЫКМАУ** *к.* буе бер карыш. *Буйга да чыкмаган, орыш-алышларда атылып алга чыкканы булмады* (М. Хәбибуллин). *Әйе, сазая барган Нургалигә өйләнергә бик вакыт инде, әмма егетнең бер моңы бар; әллә күәс төбе балага камыр җитенкерәмәде, әллә бүтән сәбәпләр булды инде, – буйга чыкмады ул* (Т. Мөбарәкәв. Гөл әби).
Төрдәше: буе бер карыш.

*БУЙДА* ❖ **БУЙДА БУЛУ** *к.* авыр аяк<лы> 3. *Китәргә? Кая? Гайшәнең инде буенда бар…* (Т. Мөбарәков).
Төрдәше: авыр аяк<лы> 3 һ.б.

*БУЙЛАП* ❖ **БУЙЛАП КИТҮ.** Атның чыгымчылап, алып качуы. *Ерактан ат кешнәгән тавыш ишетелгәч, безнең айгыр да, колакларын шомартып, арт аякларына күтәрелде дә тезгенен шартлатып өзеп, буйлап китте* (Сөйләм).

*БУЙЛАРЫ* ❖ **БУЙЛАРЫҢ БУЙДАН КЕЧЕ.** Сөйгән кызын мактау (кызның буе егетнекеннән бераз кечерәк). *Канәфер каптым – ачы икән, / Бадиян каптым – төче икән; / Буйларың буйдан кече икән, / Куеның оҗмах эче икән* (Җыр).

*БУЙ-СЫН* ❖ **БУЙ-СЫН ҖИБӘРҮ.** *Бала чагында тәгәрмәчле тачкы этеп, ә инде буй-сын җибәргәч, ике көпчәкле арба тартып, үз кулы белән җеген-җеккә берәмтекләп утаган, тешәүле урак белән утап, шәп итеп тапалган, аннары кыргыч белән кырылган янавыч белән янаган, чалгы белән чапкан үләнне җан ачыйгысын чыгара-чыгара тартып кайткан юлларны инде дә менә хәзер <...> Хәйгә ел буена*

*җитәрдәй бер ләззәт тойгысы бирә торган иде* (Ә. Гаффар. Әллә тагын).

*БУК* ❖ **БУК ЙОТЫП** *туп., кимс.* Әһәмиятсез, вак сүз (йомыш) белән эшне бүлү. *Кем булсын, шул Кәҗә Гөлсарасы инде, йөри шунда бук йотып, кеше борчып* (Сөйләм).

**БУК ТА (БУГЫМ ДА) БУЛМЫЙ** *туп., кимс., гади с.* Куркыныч түгел. *Караңгы төшкәч, койма аша төшәсең дә бакчага үтәсең – бугым да булмый* (Сөйләм).

**БУК ТА ТҮГЕЛ** *туп.,кимс., гади с.* Вак нәрсә. *Шикләнмә, синең чокыр казыганыңны бирәү дә күрмәгән, ә ул имеш-мимешләр таралу бук та түгел* (Сөйләм).

**БУК ТА ЮК** *туп.,кимс., гади с.* Берни юк, куркыныч түгел. *Гаеп ташлау өчен, кәгазь ертыгыннан башка аның кулында бук та юк* (Сөйләм).
Төрдәше: бук та (бугым да) булмый.

**БУК ЧӘЙНӘҮ** *туп., кимс., гади с.* Буш сүз сөйләү, сукрану («бук» сүзе монголчада сагызны аңлата). *Әй, бук чәйнәп утырма әле, ачуымны китереп!* (З. Хәким. Кайда син, Атилла?!). *Бездә бала кирәк, бала кирәк дип кенә бук чәйнәп утырмыйлар, заманча балалар тудыру йорты җиткерелеп бетеп килә* («Татарстан яшьләре» газ.).

*БУКАЙ* ❖ **БУКАЙ КҮРСӘТҮ.** Кешене юк белән куркыту, берәр эштән ваз кичтерү өчен, шөбһәләндерергә тырышу. *Син миңа букай күрсәтергә саташасыңмы әллә?!* (Сөйләм).

*БУККА* ❖ **БУККА БАТЫРУ** *туп., кимс., гади с.* Пычрак эшләрен ачып салу; пычрак гаепләр тагу. – *Кирәк түгел военкоматы да, армиясе дә, медицинасы да, полициясе дә, прокуратурасы да! Йөрмә, улым, үзеңне үзең букка батырып* (З. Хәким. Сәер никрут).

**БУККА <ДА> ЯРАМЫЙ (ЯРАКСЫЗ)** *туп., кимс., гади с.* Бөтенләй бер нәрсәгә дә яраклы түгел. – *Синең бу эшең букка да ярамый, бар, чүплеккә ыргыт* (Сөйләм).

*БУКСИРГА* ❖ **БУКСИРГА АЛУ.** 1. Тагып тарттыру. *Судноны, буксирга алып, Балеар архипелагының төньягындагы Менорка утравына өстерәделәр* (А. Хәсәнов. Данәгөл).

2. *күч.* Ярдәм итү, ярдәмгә килү. – *Барыбер үзегезне килеп буксирга алырга туры килде* (А. Алиш. Якты күл буе).

*БУКТАН* ❖ **БУКТАН КӨРӘК БУЛГАН НӘРСӘ** *туп., кимс., гади с.* Үзен затлы гаиләдән чыккан итеп күрсәтергә тырышса да, тотышы, сөйләше һ.б. мәдәниятсезлеген сиздереп тору. *Йөри шунда әллә кем булып, буктан көрәк булган нәрсә* (Сөйләм).
Төрдәше: сәнәктән көрәк булган нәрсә; тизәктән көрәк булган нәрсә; тирестән көрәк булган нәрсә.

**БУКТАН КӨРӘК БУЛУ** *туп., кимс., гади с.* Түбәнлектән түрәлеккә менгән. *Флүзә ише «буктан көрәк булган», ә асылда гыйбад булып калган түрәләргә власть яратучанлык һәм бигрәк тә «власть көнчелеге» аеруча нык хас була, билгеле ки...* (tatarca-text.narod.ru).

*БУЛА* ❖ **БУЛА БИРСЕН.** «Әйдә, шулай булсын» мәгънәсендә. *Кунагың күбрәк булырлык икән, икенчесе янына өченчесен, дүртенчесен тез. Тигезле-тигезсезрәк чыгуы мөмкин, була бирсен!* (Ф. Хөсни. Гыйльмениса). *Күпне күргән, имеш, чыныккан, / Тормыш – диңгез? / Әйдә, була бирсен. / Безнең өчен – диңгез тубыктан* (З. Насыйбуллин).

**БУЛА <ГЫНА> КҮРМӘСЕН.** Тормышка аша күрмәсен. *«Йа Раббым, барган җиремдә чучка фермасы гына була күрмәсен...»* (А. Әхмәтгалиева. Синең өчен яшим). *Юк, юк, минем гөнаһларым улым башына була күрмәсен* (З. Мәхмүди. Сары каен – сары сагыш).
Төрдәше: Алла сакласын!

**БУЛА ТОРГАН ЭШ ТҮГЕЛ.** Булмаска тиешле, булуына юл куелмый торган эш. *[Исмәгыйль] Бу була торган эш түгел. Хәлилнең дә башы ике түгел, белә торып минем арага керергә* (М. Фәйзи. Галиябану).

**БУЛА ТОРЫП.** Булган хәлдә, булып та. – *Өйдә ике ир була торып, өстәл аягы тигезләүче юк бит, ә?* (В. Имамов. Күке). *Хастаханәдә, янында табиб була торып!..* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**БУЛА УЛ, <БУЛА ТОРГАН ЙОЛА УЛ>.** «Ярый, эшлибез аны, үтәрбез» мәгънәсендәге гыйбарә. – *Син җиңәргә әйткәнсең икән, иптәш инженер, була ул!* (А. Алиш. Якты

күл буе). *Йокысыннан уянып гозеремне әйтүгә, була ул, Хафиз абый, дип, минуты белән торып киенә башлады* (В. Нуруллин. Ике урам арасы).

*БУЛАСЫ* ❖ **БУЛАСЫ БУЛГАН ИНДЕ.** «Соңлагансыз, хәзер соң инде» мәгънәсендә. – *Бернеме, икенеме, буласы булган инде, әйдә, катып тормагыз, Шәмсүн йә Рәфис күренгәнче, алып барып күмик* (А. Вергазов. Үзеңә кайту). *Сезнең арада буласы булган инде* (Г. Гыйльманов. Албастылар).

Төрдәше: агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән һ.б.

**БУЛАСЫ БУЛГАН, ТУНЫ ТУЗГАН** *к.* агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән. *Үги әтисе бу юлы сугышып тормады – буласы булган, туны тузган, дигәнмедер, ояты-хәсрәте дә басыла төшкәндер, бәлки* (Р. Мирхәйдәров).

Төрдәше: агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән һ.б.

**БУЛАСЫ БУЛДЫ (БУЛГАН), БУЯВЫ СЕҢДЕ (СЕҢГӘН)** *к.* агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән.– *Ниен уйлыйсың инде аның, буласы булган, буявы сеңгән ләбаса!* (М. Маликова. Арыш тәме). – *Кирәкми, әти... Буласы булган, буявы сеңгән дигәндәй...* (Р. Вәли. Шөһрәт).

Төрдәше: агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән һ.б.

**БУЛАСЫ ЭШ (НӘРСӘ) БУЛГАН, ӨСТЕНӘ КАР ЯУГАН.** Эш узган, инде үкенүдән файда юк. *Әтиләре: буласы эш булган, өстенә кар яуган инде, ахыры хәерлегә бетсен», – дип көрсенеп куйды* (Сөйләм).

Төрдәше: агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән һ.б.

*БУЛАСЫНЫҢ* ❖ **БУЛАСЫНЫҢ БУГЫННАН КҮРЕНӘ** *гади с.* «Кешенең кем булачагы бала чагыннан ук сиземләнә» мәгънәсендә. *Юк инде, буласының бугыннан күренә, бу, үскәч тә, сукага табынмас, колхозда бригадирның керләнеп, каешланып беткән дәфтәренә куелган таякларны санап гомерен уздырмас...* (Р. Зәйдулла. Шаһгали).

*БУЛГАН* ❖ **БУЛГАН ДА КУЙГАН.** Кемгәдер нык охшаш булу. *Кашсыз, керфексез кеше бер дә матур булмый икән: нәкъ император Веспасион бюсты булган да куйган Хәлимов!* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).

Төрдәше: агачына күрә алмасы һ.б.

**БУЛГАН НӘРСӘ.** Мактап әйтү: уңган, булдыклы. *Киленегезнең сеңлесе нинди нәрсә? Төскә-биткә чибәрме? Яхшы булган нәрсә микән?* (Г. Камал. Кайниш). *Күршеләреңнең яшь киленнәрен күргәнең бармы, бигрәк булган нәрсә, диләр* (Сөйләм).

**БУЛГАН ТӘКЪДИРДӘ.** Булган вакытта; эш алай булган чакта. *Алай булган тәкъдирдә мин бит «басмагыз» дип үк куям* (Шәрәф Мөдәрриснең әдәби мирасы // «Казан утлары», 1972, № 2). *Шундый хәл булган тәкъдирдә, мәсьәләне чишә алмыйча оятка калмас өчен, математикадан мәсьәләләр чишәргә дә туры килә* (В. Нуруллин. Ике урам арасы).

Төрдәше: булган чиратта.

**БУЛГАН ЧИРАТТА** *к.* булган тәкъдирдә. – *Мине башка эшкә күчерергә уйлыйсыз икән, алай булган чиратта мин бөтенләй эштән китәм* (Сөйләм).

Төрдәше: булган тәкъдирдә.

**БУЛГАН ЭШ (НӘРСӘ) БУЛГАН, <БУЯВЫ СЕҢГӘН (УҢГАН)>** *к.* агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән. – *Мин үзем берәр билгесез хатын янында кунып чыксам да үкенмим. Булган эш булган* (Ә. Еники. Рәшә). – *Йә, ярар, булган эш булган, буявы сеңгән. Мин өйләнгәндә, синең күк кенә күрмәдем нужаны* (М. Мәһдиев. Кеше китә – җыры кала).

Төрдәше: агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән һ.б.

**БУЛГАН ЭШ (НӘРСӘ) БУЛГАН, ҮТКӘН ЭШКӘ САЛАВАТ** *к.* агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән. – *Булган эш булган, үткән эшкә салават, син миңа рәнҗемә инде, телеңне озайтмасаң, мин беркайчан да кул күтәрмәм, – диде* (Д. Каюмова. Буранлы юллар).

*БУЛГАН-БЕТКӘН* ❖ **БУЛГАН-БЕТКӘН, ӨСТЕНӘ МҮК ҮСКӘН** *к.* агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән. *Нәрсәгә үз җаныңны үзең әрнетеп, артык сүз куертырга? Булган-беткән, өстенә мүк үскән* (Ә. Сәлах. Соңгы вальс).

Төрдәше: агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән һ.б.

*БУЛГАН-БУЛГАН* ❖ **БУЛГАН-БУЛГАН, БЕРӘГӘЙЛЕ БУЛСЫН.** «Булган икән, шәп булсын» мәгънәсендә. *Мәҗлес бик шәп булып китте әле. Тагын берне алдырырга кирәк. Булган-булган, берәгәйле булсын* (Г. Камал. Безнең шәһәрнең серләре).

**БУЛГАН-БУЛГАН, БОТКА БУЛСЫН.** Берәр эшне артык куерта, бутый торгач, башка бер эш китереп чыгарудан көлеп әйтү. *Булган-булган, ботка булсын дип эшләгәнсеңдер инде син моны, без теләгән ял итү урыны сызымыңда кайда соң ул?* (Сөйләм).

*БУЛГАНДА* ❖ **БУЛГАНДА БҮРЕ <КЕБЕК>, БУЛМАГАНДА ШҮРЕ <КЕБЕК>** *к.* ашаган тамакка ни бармый (китми). *Һи-и, алар бит булганда бүре, булмаганда шүре* («Идел» ж.). *Безнең халык бит, беренчедән, дәүләт барыбер сәламәтлегеңне сыгып бетерә, эчсәң дә, эчмәсәң дә, тартсаң да, тартмасаң да бетәсең дип уйлый, икенчедән, булганда бүре кебек, булмаганда шүре кебек дигән принцип буенча яши* («Татарстан яшьләре» газ.)

Төрдәше: ашаган тамакка ни бармый (китми) һ.б.

**БУЛГАНДА ДА НИЧЕК ӘЛЕ.** Бер эшнең булуы турында хәбәр иткәндә, ышанмаучыларга аны тагын да ышандырыбрак аңлату өчен дәлил китерү. – *Булачак, булачак, юкка борчылма; булганда да ничек әле – исеме алтын хәрефләр белән язылачак* (Сөйләм).

*БУЛГАН<ЫН>НАН* ❖ **БУЛГАН<ЫН>НАН БУЛМАГАНЫ <АРТЫК; ХӘЕРЛЕРӘК; ЯХШЫРАК>.** Эшкә ашмаган, юньсез, юлдан чыккан кеше яки кирәксез нәрсә. *Яхшырак синдәй дустыңның / Булганнан булмаганы* (Х. Бәдигый). *Кара аларны, бер-берсен ничек яклыйлар! Мондый партоешма секретаренең булганнан булмаганы артык* (Ә. Галиев. Җимерелгән хыяллар).

*БУЛДЫ* ❖ **БУЛДЫ – БОХАРИ, БУЛМАСА – СОХАРИ.** «Булса да ярый, булмаса да ярый» мәгънәсендә әйтелә. *Кулчатыр алмаганмын дип борчылма: булды – бохари, булмаса – сохари* (Сөйләм).

Төрдәше: булды ни, булмады ни; булса – Бохара, булмаса – истихара; булса – бохарый, булмаса – сохарый; булса булды (булыр), булмаса юк; булса ни, булмаса ни.

**БУЛДЫ ДИ, БУЛМЫЙ НИ.** «Булмаганны сөйлисең, алдамый тор әле» мәгънәсендә. – *Булганының кадерен белү, бер-беребезне күрә белү җитми безгә. Булды ди, булмый ни!* (М. Кәбиров).

**БУЛДЫ ДИГӘНДӘ КОЙРЫГЫН БОРУ.** «Эш булды, барып чыкты» дигәндә генә булмый калу. *Булды дигәндә койрыгын борды* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.).

**БУЛДЫ НИ, БУЛМАДЫ НИ.** Барыбер, аермасы яки зарары юк. *Мәскәү тарафдарларына Казан ханлыгын саклап калу өчен җанын кызганмаган халкыбыз яуда корбан булды ни дә булмады ни?!* («Ватаным Татарстан» газ.). *Ә бу килеш, булды ни дә, булмады ни, дип барган вакытта, татар пролетариат әдәбиятының тиз арада гына чәчәк атуын күреп булмас* (Г. Кутуй).

Төрдәше: булды – бохари, булмаса – сохари һ.б.

**БУЛДЫ ПЫЧАГЫМ.** «Берни дә булмады, булып чыкмады, юкны сөйләмә» мәгънәсендә. *Булды пычагым, теге бурлар фәлән министрның туганы булгачтын, җибәрделәр дә Харисның үзен чүттән генә утыртып куймадылар* («Ватаным Татарстан» газ.).

**БУЛДЫ ХУШ, БУЛМАДЫ ХУШ.** Үзен дә, тормышны да уйламаучы, «булсын» дип йөрмәүче. *Яңа эш эзләү турында уйлап та карамый: аңа булды хуш, булмады хуш, әнә хатыны эшли бит әле* (Сөйләм).

Төрдәше: булса хуш, булмаса хуш.

*БУЛДЫКСЫЗ* ❖ **БУЛДЫКСЫЗ ҖАН.** Сәләтсез, уңмаган. *Теге булдыксыз җан да күз алдында күз көеге* (Ф. Хөсни). *Йорт алып та керә алмасаң, син – төшеп калган адәм, мәхлук, булдыксыз җан* («Ватаным Татарстан» газ.).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

*БУЛДЫРГАН* ❖ **БУЛДЫРГАН ДА ХАТЫН, БӨЛДЕРГӘН ДӘ ХАТЫН.** Хатын-кызның хуҗалыкта, гаиләдә роле зур булуын күрсәтү. – *Нигә аны күзеңне чепиләндереп карап торасың, онытныңмыни булдырган да хатын, бөлдергән дә хатын икәнлеген?* (Сөйләм).

*БУЛМАГАН* ❖ **БУЛМАГАН ИШЕ ТҮГЕЛ, БУЛДЫМЫ – БУЛДЫ.** Хәзерге вакытта нәрсәнедер эшләү, «яңа әйбер түгел, кайчандыр

кулланылган» дип башкару. *Йолалар бозылып, гадәтләр үзгәреп, хан күтәрү тантанасы, әйдә, ярый инде, булмаган ише түгел, булдымы – булды, дип кенә эшләнде* (Р. Батулла. Сөембикә).

*БУЛМАГАНДА* ❖ **БУЛМАГАНДА АРЫШ ИКМӘГЕ (ИПИЕ) ДӘ КҮМӘЧ.** Мохтаҗлыктан коткарган нәрсә түбән сортлы булса да файдалы. *Нәрсә «кадаклар күгәргән» дип борыныңны салындырдың, булмаганда арыш ипие дә күмәч* (Сөйләм).

*БУЛМАГАННЫ* ❖ **БУЛМАГАННЫ БОЛГАТУ.** Юкны сөйләү; юкны бар итеп күрсәтеп, шаулап йөрү. – *Куй әле, зинһар, Габделкави, булмаганны болгатма* («Казан утлары» ж.). *Кечкенә генә булса да түрә булып, булмаганны болгатып, мактау сүзләре алырга шомарып бетте* (Сөйләм).

*БУЛМАДЫ* ❖ **БУЛМАДЫ ТҮГЕЛ.** Сирәк булса да булды, булгалады. *Ерак киная белән китереп, бу җирдә дә үзенең Хәерләре, Тәфкилләре булмады түгел дип, найманнарның хан, солтан булып яшәгән, йортны ак патшага кол итүдә булышлык иткән бабаларына да күләгә ташлады* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).

*БУЛМАС* ❖ **БУЛМАС ЙОРТКА БӨКРЕ ТУГАН.** Алга китмәячәк, мантый алмаячак эшнең торышы алдан ук билгеле. *Булмас йортка бөкре туган нәрсә, кулыңнан кул ярысы эш килми, юк-бар гәҗит сүзләре сөйләп торган буласың* (Ф. Хөсни).
Төрдәше: булмаска – бөкре.

**БУЛМАС ЙОРТКА БӨКРЕ ХАТЫН.** Бәхетсезлек бәхетсез кешегә килер. *Булмас йортка бөкре хатын* (К. Насыйри. Мәкальләр һәм әйтемнәр).

**БУЛМАС ТА, ТУМАС ТА, ТУСА ДА ТОРМАС.** Үтә юньсез, булдыксыз игелексез кешегә карата әйтелә. – *Юкны сөйләп торма сана, аннан булмас та, тумас та, туса да тормас* (Сөйләм).

*БУЛМАСА* ❖ **БУЛМАСА – БИШ, БУЛСА – УНБИШ.** Әрсез кеше турында: акчаң югын белсә, биш сумга да килешә, булганын белсә, унбиш сумыңны алмыйча китми. *Акчам юк, дип кысмырланма инде, әйдә, булмаса – биш, булса – унбиш, бер атнадан кайтарам мин аны* (Сөйләм).

**БУЛМАСА БУЛГАН ИКӘН, <УЛ БУЛМАСА, КЫЗ БУЛЫР>** 1. Сөйләүченең киләчәктә һәр нәрсәгә риза булуын белдерә. *[Әптери] Булмаса булмас икән, киткәндә мине дә үзең белән алып кит. Мин дә шахтер булам, малай* (К. Тинчурин. Зәңгәр шәл).
Төрдәше: ни булса да <булыр>!; ни булса, шул булыр (булсын).

2. Тәвәккәллек күрсәтү. *«Әйдәгез, егетләр, булмаса булган икән, ачудан мунчаларын туздырып ташлыйк, дип салмасынмы? Безгә шул җитә калды* (А. Шамов. Кыз урлау). *Мин инде кызыксына ук башладым. Нинди киңәш бирәсең, бәлкем, булмаса булган икән, тәвәккәлләргәдер, ә?* (Г. Шәрипова. Гафурлар гаиләсе).

**БУЛМАСА БУЛМЫЙ ИКӘН, ШИМБӘ БАЗАРЫНДА ДА ТӨЧЕ КҮМӘЧ.** Өмет иткән нәрсәне көтеп торып та алдану. *Ничә мәртәбә сөйләшеп, ерак юллар үтеп килгән идем, булмаса булмый икән, шимбә базарында да төче күмәч* (Сөйләм).

*БУЛМАСКА* ❖ **БУЛМАСКА – БӨКРЕ** *к.* булмас йортка бөкре туган. *«Булмаска – бөкре» дигәннәре хак сүз икән, сал агызырга теләртеләмәс кенә риза булган идек, ярты юлыбызда сал таралып китте* (Сөйләм).
Төрдәше: булмас йортка бөкре туган.

*БУЛМАСЛЫК* ❖ **БУЛМАСЛЫК БУЛСА.** Булырлык булмаса, мөмкинлеге булмаса. *Башта осталык белән җәясен тартырга кирәк. Булмаслык булса, серне ачудан файда юк* (К. Тинчурин). *– Алайса, Зәйтүнә-җанаш, әйтелеп бетмәгән бер сүз миндә дә кала язган икән, – дип башлады ул, уңайсызланганын ничек тә сиздермәскә тырышып, – мәгәр сүз бирешеп керешик: үпкәләштән булмаслык булса гына* (Ф. Хөсни. Язмыш).

*БУЛМЫЙ* ❖ **БУЛМЫЙ ТОРГАН.** Тормышка ашмаган, берничек тә мөмкинлеге булмаган, була алмый торган эш турында. – *Юк, мине чакырмагыз, булмый торган эшкә тотынасым килми* (Сөйләм).

**БУЛМЫЙ ТОРСЫН.** Үзе өчен генә булдырырга тырышып, үз ягына каеручы хакында. – *Алды бикәдер, шикләнмим, арты марҗадыр ич! Инде ханбикә! Булмый торсын әле!*

(М. Хәбибуллин. Шайтан каласы). *Юк, юк, Илдарны аңа өйләндерәмме соң?! Булмый торсын әле!* (Р. Солнцев. Көймә ватылса – утын / Р. Даутов тәрж).

*БУЛСА* ❖ **БУЛСА – БОХАРА, БУЛМАСА – ИСТИХАРА.** Берәр эш-хәлнең нәтиҗәсе ничек бетсә дә зарар юк: уңышлы икән – байлык була (Бохара дәүләтенә ирешү), уңышсыз икән – төштә генә булган бу, дип онытырга тырышу. *Балтаңны ал да агачның теге башыннан эшкәртә башла, булса – бохара, булмаса – истихара* (Сөйләм).
Төрдәше: булды – бохари, булмаса – сохари һ.б.

**БУЛСА – БОХАРЫЙ, БУЛМАСА – СОХАРЫЙ** *к.* булды – бохари, булмаса – сохари. *Әйдә, бисмилланы әйтеп, бу эшкә тотыныйк әле, нәрсә булса да чыгар: булса – бохарый, булмаса – сохарый* (Сөйләм).
Төрдәше: булды – бохари, булмаса – сохари һ.б.

**БУЛСА БУЛДЫ (БУЛЫР), БУЛМАСА ЮК.** Ни булса шул булыр, дип, тәвәккәлләп тотыну. *Булса булыр, булмаса юк, дип эшләүчеләрне күбрәк җыйсыннар шулай!* («Безнең гәҗит» газ.).
Төрдәше: булды – бохари, булмаса – сохари һ.б.

**БУЛСА БУЛСЫН ТУЯРЛЫК, КАЛГАНЫН ҖЫЕП КУЯРЛЫК** *к.* аяклар юрганыңа карап сузылу. – *Син, дус кеше, башта нинди эш икәнен аңлат: булса булсын туярлык, калганын җыеп куярлык* (Сөйләм).
Төрдәше: аяклар юрганыңа карап сузылу һ.б.

**БУЛСА БУЛЫРГА КИРӘК.** Ихтимал, мөгаен. *Вятка жандарм идарәсе бу мәдрәсәдә шундый гомуми фәннәр тәгълим ителгәнен ишеткәч, монда нәрсә дә булса булырга кирәк, мөселман мәдрәсәсендә үз ихтыярлары белән, үз акчаларына русча укыталар, җәгъръфия дә укыталар, монда панисламизм булырга кирәк, дип уйлый башладылар* (С. Максуди. Тарих һәм хәзерге заман).
Төрдәше: булса да булыр; булса кирәк; булырга кирәк.

**БУЛСА ДА БУЛА ИКӘН.** Гаҗәпләнүне белдерү. *Булса да була икән, кабагы бер потны тартадыр моның!* (Сөйләм).

**БУЛСА ДА БУЛЫР** *к.* булса булырга кирәк. *Тәмәкедән чыккан, имеш, дип сөйлиләр. Булса да булыр* (Ш. Маннур. Агымсуларга карап).
Төрдәше: булса булырга кирәк һ.б.

**БУЛСА ИДЕ (ИКӘН).** Бул; әгәр дә булса. *Берәр җылы хәбәр булса иде!* (А. Тимергалин. Таш алиһә). *Соравы сорау гына булса икән, хакы бар кеше сыман төшкән төрмә кошы!* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**БУЛСА КИРӘК.** Булуы мөмкин; ихтимал; мөгаен, бугай. *Аны шактый орышканнар булса кирәк* (А. Алиш. Тимер юл). *Сүзләрем егеткә яхшы тәэсир итте булса кирәк, – шуннан соң ул Нәфисә турында авыз ачып ник бер сүз әйтсен* (А. Шамов. Кыз урлау).
Төрдәше: булса булырга кирәк; булса да булыр; булырга кирәк.

**БУЛСА НИ.** Бер дә гаҗәп түгел, булу да ихтимал. *[Гайшә] Булса ни, пар түгелләрме әллә?* (Г. Исхакый. Мөгаллимә). *Күлдә кондыз булса ни, / Күктә йолдыз булса ни* (Г. Афзал. Өммеһани).
Төрдәше: булса ни гаҗәп; булса соң.

**БУЛСА НИ ӘЙТТЕҢ ИДЕ.** «Булса бик тә шәп булыр иде дә бит» мәгънәсендә. *[Грязнов] Булса ни әйттең иде дә, булмый шул* (Г. Кутуй. Шатлык җыры).

**БУЛСА НИ, БУЛМАСА НИ.** Булса да яхшы, булмаса яхшы – аермасы юк. – *Һаман шул каһәр суккан тәмәке өчен. – Булса ни дә булмаса ни минем өчен* (А. Гыйләҗев. Тәмәкене ташладык, рәхәт яши башладык).
Төрдәше: булды – бохари, булмаса – сохари һ.б.

**БУЛСА НИ ГАҖӘП.** Берәр эш яки хәлнең булуы белән килешүчәнлекне күрсәтү. *Бу яңгырлар киткән торналарның / Күз яшьләре булса ни гаҗәп!* (Х. Әюп). *Ислам бабайның улы шулай мәрткә киткән булса ни гаҗәп?.. Уянадыр да, кычкыра-кычкыра арыгач, яңадан йокыга таладыр...* (Р. Солнцев. Көймә ватылса – утын).
Төрдәше: булса ни; булса соң.

**БУЛСА СОҢ** *к.* булса ни. – *Без сиңа мең тәңкә бурычлы булдыкмы инде? – Булса соң! – диде, рәхәт тантанада йөзеп кунак* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *«Җитәкчеләр арасында татарлар аз», имеш. Йә, булса соң?* (В. Имамов. Кәнәфи).
Төрдәше: булса ни! һ.б.

**БУЛСА ХУП, БУЛМАСА ХУП** *к.* булды хуш, булмады хуш. *Медаль булдырылгандырмы-*

*юкмы, анысы безгә караңгы, әти әйтмешли: «Булса да хуп, булмаса да хуп»* (Ф. Хуҗин. Күкләр шаһит).
Төрдәше: булды хуш, булмады хуш.

**БУЛСА ЯРЫЙ, БУЛМАСА ТАЯРГА КАРЫЙ.** Үз файдасына алыш-биреш итүчегә карата. *Еш кына көнлек план-керем инде үтәлгән була, кичке кунаклар булса ярый, булмаса ярый шикелле генә икән* (Р. Мирхәйдәров. Иртәләгән сагыш). *«Ләкин мин хәзерге балаларның, булса ярый, булмаса ярый, дип йөрүенә аптырыйм», – ди Зөлфәт* («Безнең гәҗит» газ.).

*БУЛСЫН* ❖ **БУЛСЫН ДА ЮК, БУЛМАСЫН ДА ЮК.** Төгәл фикер булмаганда яки җитмәгәндәге хәл. *Ләкин әнкәй нихәтле әткәйне кузгатса, аңар ялынса да теге ашыкмый, булсын да юк, булмасын да юк; «карарбыз, фәлән итәрбез...» ди дә тора икән* (Ш. Камал. Тормыш көе).

**БУЛСЫН ДИП ЭШЛӘҮ (ТЫРЫШУ).** Тырышып, яхшы итеп эшләү. *Иртәдән кичкә кадәр эшлим, мулла абзый, йорт булсын дип эшлим, өстәмә сорамыйм, алыштырырга күлмәгем юк, мулла абзый!* (Г. Исхакый. Кияү). *Хикмәт тә аның маякчы кызы булуында, ул үзе турында уйлаудан бигрәк, әтисенә зыян килмәсен, бабасына җиңелрәк булсын дип тырыша* (Г. Гобәй. Маякчы кызы).
Төрдәше: булсынга йөрү (эшләү).

*БУЛСЫНГА* ❖ **БУЛСЫНГА ЙӨРҮ (ЭШЛӘҮ)** *к.* булсын дип эшләү (тырышу). *Нургали Надиев егетнең булсынга йөрүенә куанып, очрашканда болай гына узып китми инде* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң). *Кеше кулы-аягы тимәгән торфлы җир, бытбылдыклар чутылдашкан, тартарлар тырылдаган Зирек әрәмәсе – болар барысы Чишмәбайның җанына бик тә якын, иренмәсәң, булсынга эшләсәң, ул тирәләрне шау чәчәкле җиләк-җимеш бакчасы итәргә дә була бит әле* (Г. Ахунов. Идел кызы).
Төрдәше: булсын дип эшләү (тырышу).

*БУЛУ* ❖ **БУЛУ СЫЙФАТЫ БЕЛӘН.** Буларак, булу йөзеннән. *Татар әдәбияты теоретикларыннан сәнгатькә якынрак кеше булу сыйфаты белән, ул «Эшче» операсы турында матбугатта махсус мәкалә белән чыга* (М. Мәһдиев. Ерактан яңгыраган аваз).

**БУЛУ ЯГЫННАН.** ...буларак; ...булып; ...итеп; ...ролендә. *К. Насыйри һәм Хуҗа Бәдигъ җыйганнан башкаларында гыйльми эзләнү яки җитди караш бар дип булмый, күбесенчә, юаныч һәм сәүдә әйбере булу ягыннан карап чыгарылганнар* (Н. Исәнбәт. Татар халык табышмаклары).

*БУЛУНЫҢ* ❖ **БУЛУНЫҢ АРЪЯГЫНА ЧЫККАН, БУ ЯККА ТАБА БОРЫЛЫП КАРАП ТОРА.** Эшнең булуы, булачагы ачык күренеп тора, әмма сыйфат ягы гына чамалы. *Борчылмагыз, бу эш булуның аръягына чыккан, бу якка таба борылып карап тора, ике атнада без аны төгәлләрбез* (Сөйләм).

*БУЛУЫ* ❖ **БУЛУЫ БАР БУЛСЫН.** «Булуыннан булмаганы хәерлерәк» мәгънәсендә. *Мондый ата кулында мирза кызы булып торганың да бар булсын* (М. Фәйзи).

**БУЛУЫ ҖИТКӘН** *ирон.* Түбәнлеккә төшү, әхлаксызлык эшләү; тәмам изрәп исерү. *Табында шактый утыра торгач, Сәкинә Җәмитне күзләре ару гына ялтыраган һәмниләрдер вәгъдә иткән сихри карашлары артыннан ияртеп, веранда бүлмәсенә алып чыгып киткәндә, Закир аганың булуы җиткән иде* (Н. Хәсәнов. Иңрәү).

**БУЛУЫ МОХАЛ** *к.* булмый торган. – *Син мине булуы мохал нәрсәләргә чакырма инде* (Сөйләм).
Төрдәше: булмый торган.

*БУЛЫП* ❖ **БУЛЫП АШУ.** Булуның аръягына чыгу, мул булу. *[Сара] Күңелең булдымы соң?[Сәгыйдулла] булып ашты, Сара* (Ә. Гаффар. Язлар моңы).

**БУЛЫП КУЮ (ЧЫГУ).** 1. Көтмәгәндә килеп чыккан яисә кинәт нәтиҗәсе беленгән эш-хәл хакында. – *Менә, кода җаным, Көяз Галәви көяз генә түгел, вөҗдансыз бәндә дә булып чыкты бит әле!* (Г. Бәширов. Менә сиңа, мә!). *Шулай итеп, Дулкыния өч-дүрт ай эчендә бер бүлмәле фатирлы да булып куйды* (Г. Бәйрәмова. Син һаман шул сандугач).

**БУЛЫП ЧЫКМАГАН НӘРСӘ.** Җебегән, эшнең рәтен белми торган кеше турында. – *Булып чыкмаган нәрсә, шул бағананы да туры итеп утырта алмаган* (Сөйләм).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

*БУЛЫР* ❖ **БУЛЫР ДА БУЛЫР, МОНДЫЙ БУЛМАС.** Бик шәп яки бик начар булганлыкны белдерү. *Булдыра алмас дип уйлаган идек, җаен тапты бит: булыр да булыр, мондый булмас, бик яшь бит әле* (Сөйләм). *Әшәкелекләрне күп күрдем, әмма булыр да булыр, мондый булмас* (Сөйләм).

*БУЛЫР-БУЛМАСКА* ❖ **БУЛЫР-БУЛМАСКА ӨМЕТ ИТҮ.** Бернинди чара да күрмичә, нәрсә булса шул булыр дип, пассив рәвештә көтү. – *Булыр-булмаска өмет итеп, монда машина көтеп утырып булмас, әйдә, тәпи-тәпи атлый торабыз* (Сөйләм).
Төрдәше: булыр-булмасны көтеп яту; булыр-булмасны өмет итү.

**БУЛЫР-БУЛМАСКА ЫШАНЫП, КУЛГА ТӨШКӘННӘН АЕРЫЛУ** *к.* аттан иңеп, җәяүгә калу. *Шуның өчен әйткәннәр: «Булыр-булмаска ышанып, кулга төшкәннән аерылма», – дип* (К. Насыйри. Төлке).
Төрдәше: аттан иңеп, җәяүгә калу һ.б.

*БУЛЫР-БУЛМАСНЫ* ❖ **БУЛЫР-БУЛМАСНЫ КӨТЕП ЯТУ** *к.* булыр-булмаска өмет итү. *Булыр-булмасны көтеп ятып туйдым инде, иртәгә дә күренмәсә, үзем барып чыгармын* (Сөйләм).
Төрдәше: булыр-булмаска өмет итү һ.б.

**БУЛЫР-БУЛМАСНЫ ӨМЕТ ИТҮ** *к.* булыр-булмаска өмет итү. *Булыр-булмасны өмет иткәнче, сораучы барында барып калырга кирәк* (Сөйләм).
Төрдәше: булыр-булмаска өмет итү һ.б.

*БУЛЫРГА* ❖ **БУЛЫРГА КИРӘК** *к.* булса булырга кирәк. *Яңа килен булырга кирәк, бүген монда яшь, матур бер студент күренә* (Ф. Әмирхан). *Ә тегеләр очраклы хулиганнар гына түгел, урлашу-талау белән күптән шөгыльләнүче тәҗрибәле юлбасарлар булырга кирәк: шәп сугышалар, аяктан егарга тырышалар Нуруллаены* (В. Нуруллин. Ике урам арасы).
Төрдәше: булса булырга кирәк һ.б.

*БУЛЫРЛЫК* ❖ **БУЛЫРЛЫК БУЛУ (БУЛСА).** Булып чыгар торышка җитү.– *Врачлар эшкә чыгарга рөхсәт иттеме? – диде Айбулатов һәм җавап көтеп тормастан: – Бу эшегез... уйланылган булса, берегезгә-берегез таяныч булырлык булсагыз...* (Г. Кашапов. Язмышыңа ышан). – *Чукып – карга, укып кына мулла булырлык булса, бөтен кеше дә шулай итәр иде* (В. Имамов. Тозлы яра).

*БУЛЫШКАНДА* ❖ **БУЛЫШКАНДА – ӘССӘЛАМ, ЭШЕ БЕТКӘЧ – ЮК СӘЛАМ.** Йомыш төшкәндә генә кешегә сәлам бирү, башка вакытта аны бар дип тә белмәү. *Кешеләр алар, беләсең килсә, булышканда әссәлам, эше беткәч – юк сәлам* (Б. Камалов).

*БУЛЫШЛЫК* ❖ **БУЛЫШЛЫК ИТҮ.** Кемгә булса да ярдәм итү. *Мескен Кисекбашка булышлык итәргә әзер торучы картлар, шулай ук Никитин циркында француз көрәшчеләре буларак танылган Пугач, Зайкин, Карахмәт – болар барысы да реаль кешеләр* (Г. Тукай. Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш).

*<ҮЗ> БУМАСЫ* ❖ **<ҮЗ> БУМАСЫ ТОТУ** *к.* авыруы тоту. *Заһирның бумасы тотты. Ул, гөрселдәп, җиргә ауды* (Р. Фәтхрахманов. Йөрәкнең җеназасы).
Төрдәше: авыруы тоту һ.б.

*БУРА* ❖ **БУРА БАТЫРУ.** Чишмә яки кое эчендә бура буралау.*Чишмәләрне әрчетергә, бура батырырга кирәк дип уйлады* (И. Гази). *Бер күрше авыл остасы белән бакчада кое казып бура батыру нәкъ менә шундыйрак күз күрмәгән шөгыль иде* (М. Хәсәнов. Язгы ажаган).

**БУРА КЕБЕК.** Эре, зур (сыерлар турында). *Бура кебек куа сыерны иренеп кенә сауды, утардан сарыкларын чыгарды, кече капканы ачып, малларны урамга куды* (Х. Хәйруллин. Канатлар талмасын).

**БУРА КҮТӘРҮ.** Өй-каралты бураларын торгызып кую. *Интегеп бура күтәргән, өрлеклек табалмаган* (С. Хәким). *Киң җилкәле ирләр киң урамда / Бура күтәрәләр язларын* (Р. Гәрәй. Башка чыгучылар ашыктыра).

*БУРАЗНА* ❖ **БУРАЗНА САЛУ (СЫЗУ).** 1. Озынча сыр, буй-буй җыерчык барлыкка килү. *Бер-бер артлы килгән күтәрә алмаслык кайгылар зиһенен таратса, хәтерен йомшартса, чәчләренә көмеш юллар, йөзләренә тирән буразналар салса да, Наилә Раил белән Равиле хакына,*

*Ходайдан сабырлык сорап, авыр хәсрәтләрне үткәрде* (А. Хайртдинова. Ак сирень).

2. *күч.* Фән яки мәдәният өлкәсендә зур эшчәнлек күрсәтү. *Русия тарихына буразна салган тарихчы шушындый сүзләрне язгач, нигә һәм кемгә кирәк булды икән Иван Калита I (1328–1340) заманнарында гына аякланып киткән Мәскәүнең гомерен озайту һәм борынгылаштыру?..* (М. Хәбибуллин. Әнвәр-Ингвар-Игорь).

**БУРАЗНА ЯРУ.** Яңа эш башлау, беренче юл яру. *Шул исәптән балалар фольклорын җыю һәм өйрәнү өлкәсендә дә ул – күп көч салган һәм иң тирән буразналар ярган кеше* (М. Бакиров Балалар фольклоры). *Ул гомер буе шигъриятнең тирән буразнасын ярды* («Кызыл таң» газ.).

*БУРАЗНАГА* ❖ **БУРАЗНАГА АЯК БАСМАГАН.** Сабан сөрмәгән, иген икмәгән кеше хакында. *Ул, авыл җирендә туса да, гомерендә буразнага аяк басмаган* (Сөйләм).

**БУРАЗНАГА АЯК ТЫГУ.** Сабан сөрергә тотыну. *Әллә авылга кайтып, буразнага аяк тыгаргамы?* (Ф. Хөсни).

**БУРАЗНАГА КАЙТУ.** Туган җиргә, туган авылга, игенчелеккә кайту. *Күп җирләрдә булып, буразнага кайттым* (Ф. Хөсни). *Юк, Мәрфуга, бу килештән, мин яңадан да буразнага кайта алмыйм* (Р. Төхфәтуллин. Агымсу).

*БУРАЗНАСЫНА* ❖ **БУРАЗНАСЫНА КЕРГӘЧ ЯРЫЙ ИНДЕ.** Аннан-моннан эшләнгән эшкә канәгать булып тору. *Детальне бүген үк эшләп бетерә алмады-алуын, ләкин буразнасына кергәч ярый инде – ничек булса да иртәгә тәмамлар әле* (Сөйләм).

*БУРАН* ❖ **БУРАН АНАСЫ** *миф.* Буран иясе, буран чыгаручы. *Җил гарасат иясе – Буран анасы белән кардәш булырга тиеш* (Татар мифлары I, 232).

**БУРАН КУПТАРУ (КҮТӘРҮ, ОЧЫРУ, ЧЫГАРУ).** 1. Тавыш чыгару, талашу, кычкырышу. *[Хәйри] Сабир буран очырыр. Ярый, хуш!* (Г. Камал. Өч тормыш). *Теге карчык ни бураннар чыгарып йөри икән?* (М. Фәйзи). *Харис «буран» күтәрсә, аклану өчен бер дәлил китерә алмаячак* (Ә. Моталлапов. Рисвайлык).

Төрдәше: әр-битәр белдерү (тудыру) һ.б.

2. Риза булмау, каршы чыгу. *Моңа каршы ике кандидат та буран күтәрделәр* (Г. Ибраһимов).

Төрдәше: каш җимерү һ.б.

3. *к.* акыл бизмәненә утырту. – *Балага калган көн – таң атмаган төн, – дип, Арча базарына буран кубарып килеп керде* (Ф. Яхин. Ат урлауның ние бар…).

Төрдәше: акыл бизмәненә утырту һ.б.

**БУРАН ТУЗДЫРУ** 1. *к.* буран куптару (күтәрү, очыру, чыгару) 1, 2, 3. – *Бәхет ул, бәхет ул, – дип, Әсире үрти, аның саен Әсир кыза, кычкыра, буран туздыра!...* (К. Тинчурин. Мәрҗәннәр). *Без бураннар туздырабыз, / Көрәшкәндә ил өчен* (Х. Ширмән. Ком дәрьясы).

2. Биегәндә җилкенеп әйләнү. *Машалар белән танцевать итеп кара, бөтенләй өеңдә буран туздырырлар* (Г. Камал).

**БУРАН УЙНАТУ** 1. *к.* буран куптару (күтәрү, очырту, туздыру 1, чыгару) 1, 2, 3. *Эштән арып кайтканда ашарына әзерләнмәгән булса, буран уйната* (А. Алиш. Яңа килен). *Каты бураннар уйнатты байбикә, берсенә типкәләп тә алды* (М. Хәсәнов. Саумы, Кояш!).

2. Кызу-кызу, дәртләнеп эшләү; *шулай ук к.* агач<тан> сандугач кына ясамау. *Әйдәгез, буран уйнатып эшләп алыйк әле* (Г. Бәширов. Намус). *Берничә минут кашыклар бәрелешүе, авызлар чапылдавы, борыннар мышкылдавы гына ишетелеп торды. – Буран уйнаталар, җан кисәкләрем, – дип, елмаеп карап торды карчык* (И. Гази. Онытылмас еллар).

Төрдәше: агач<тан> сандугач кына ясамау һ.б.

3. Кышын шәп ат-чаналарда кәефле кызу чаптырып йөрү. *Апаларга буран очыртып барып кердек* (А. Шамов).

**БУРАН УЙНАУ.** 1. Кызып-кызып эшләгәндә, тирә-як та тик тора алмауга ишарә. – *Корсак тутырып, «пух» иткәнче ашап чыгасың да эшләп торып җибәрәсең, әй, якын-тирәдә бураннар гына уйный!..* (Г. Бәширов).

2. Ризасызлык, ачулану сизелеп тору. *Әтинең карашы кырыс, чыраенда буран уйный иде* (К. Миңлебаев. Акыллы атын мактар...). *Бу очрашудан соң Илсөярнең күңелендә бураннар уйнады* (Р. Шәрипова. Шайтан таягы).

Төрдәше: каш җимерү һ.б.

**БУРАН ЧЫГУ** *к.* борын чәйнәшү. – *Бик җәелеп утырасың, өеңә соңга калып кайтсаң, буран чыкмасмы соң?* (Сөйләм).
Төрдәше: гауга кубару (куптару; чыгару) һ.б.

*БУРАНГА* ❖ **БУРАНГА ОЧРАГАН КҮРКӘ КЕБЕК КОРЫШУ.** Куркудан йә туңудан бик нык бөрешү. *Ул, буранга очраган күркә төсле бөрешеп, корышып, городовойның кизәнүләреннән чигенә-чигенә, челтәрле тимер капканың таш баганасына сөялде* (musulmsn.su).

*БУРАСЫ* ❖ **БУРАСЫ БУШ.** Эчендә, ашказанында азык булмау. *Иртән тамагына ризык үтмәгән Нәҗипнең дә бурасы буш иде, ул да, Наиләгә карап: «Әллә тамак ялгап алабызмы?» – диде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**БУРАСЫ БУШ БУЛМАУ (ТҮГЕЛ).** Тормышы, яшәеше тыныч түгел; ниндидер борчуы, кайгысы булуга ишарә. *Бу хатынның яныннан киткәч, Зәйнең башына: беркемнең дә бурасы буш түгел, берсендә бер бәла-кайгы, икенчесендә башка төрле каза, дигән уйлар килде* (Х. Камалов). *[Хәдичә] Ай Алла... ялгыштым лабаса... Берәүнең дә бурасы буш түгел, Ходаем...* (Г. Ахунов. Утлар яна учакта).

*БУРАСЫНА* ❖ **БУРАСЫНА ТЫЧКАН ТӨШСӘ, БАШЫ ЯРЫЛЫР.** Келәт бурасында бер бөртек тә ашлык калмау. *Аңа барып, йөрәгенә кан саудырып йөрмә инде, үзенең дә хәле мөшкел бит – бурасына тычкан төшсә, башы ярылыр* (Сөйләм).

*БУРСЫП* ❖ **БУРСЫП ЯТУ.** 1. Саф һавага озак вакытлар чыкмыйча, бина эчендә булу. *Ничә чуман бәрәңге генә бушатканбыздыр бүген, корыда эш итик дип азапланган көн, алар бер әтрәт айгыр күк кызлар өйдә бурсып яталар!..* (А. Гыйләҗев. Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят).

2. Яңалыклар белән кызыксынмау, кешеләр белән аралашмау. – *Тор, имансыз. Кышкы аю кебек бурсып ятасың* (Г. Каюмов. Туу...). *Шулай яшәргә мөмкин булганда, һәркайда юл ачылып торганда, нигә бу Язкилдедә череп-бурсып ятарга?!* (medium.com).

*БУРЫЙ* ❖ **БУРЫЙ БУРАН, ҖЫЛЫЙ ОЛАН.** Хатын-кызлар кулланган гыйбарә, ягъни тышта буран да улый, бала да елый – барысын да көйләргә кирәк. *Бурый буран, җылый олан, бармый ат, кыйный карт, ак арасы, ничек барасы?!* (Х. Мәхмүтов. Изге китаплар кайтавазы).

*БУРЫЧ* ❖ **БУРЫЧ АШАУ.** Бурычка алып яшәү. *Безнең халыкта, бурыч ашаганчы борыч аша, дигән гыйбарә бар бит* («Татарстан яшьләре» газ.).

*БУРЫЧКА* ❖ **БУРЫЧКА БАТУ.** Күп итеп бурыч алу, түләү мөмкинлеге булмау. *Шушы ачарбәк белән бурычка баттым, прәннек ашый да кәнфит суыра, ничә айга квартир хакы түләмәгән <...>* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: бурычка бәйләнү; бурычка керү 1; бурычка чуму; бурычлы булу; муен тиңел (тиңентен) бурычка бату; муенга тикле (хәтле) бурычка бату; муенда бурыч тулу; муеннан ашу; муеннан <булу>; муеннан бурычка бату; муеннан чуму; муеннан бурычлы <булу>.

**БУРЫЧКА БӘЙЛӘНҮ** *к.* бурычка бату. *Өч-дүрт көн үткәч, / кайта җыеннан әйләнеп, Хисап итеп карасалар, / бурычка беткән бәйләнеп* (К. Насыйри).
Төрдәше: бурычка бату һ.б.

**БУРЫЧКА КЕРМӘҮ.** Башкарырга тиешле эш итеп, вазыйфасы итеп саналмау. *Ә бит теләгәндә, шушы нәрсәләрне әллә ничәшәр биткә сузып тасвирларга мөмкин булыр иде. Хәлбуки автор андый юлдан китми һәм бу кадәресе аның бурычына керми дә* (Р. Мостафин. Үз көзең булсын).

**БУРЫЧКА КЕРҮ.** 1. Берәрсеннән акча алып тору. *Клуб оештырудан, ди ул, «акча җыю максат ителми, һәрвакыт клублар зарар итеп киләләр... Мөмкин булса, бурычка да керәләр»* (М. Мәһдиев. Тарих сәхифәләре). *Яңа гына акча җыештырып, бурычка да кереп, язгы пальто алдылар* (Х. Мөдәррисова. Ал кирәк, гөл кирәк).
Төрдәше: бурычка бату һ.б.

2. Башкарырга тиешле эш итеп, вазыйфасы итеп саналу. *Шул ук вакытта Татарстаннан тыш басылган татар китапларын җыю, барлау да бу китапханәнең бурычына керә* (Ә. Кәримуллин. Татар китабы кайда саклана?).

**БУРЫЧКА ЧУМУ** *к.* бурычка бату. *Туган җир һәм авылдашлары каршында түләп бетергесез*

*бурычка чумган кеше ич ул* (Р. Мөхәммәтдинов. Истәлек өчен – Гыйлемханга). – *Син нәрсә, әни! Болай да муеннан бурычка чумдың* (Н. Гыйматдинова. Син түгел бу, син түгел...).
Төрдәше: бурычка бату һ.б.

*БУРЫЧЛЫ* ❖ **БУРЫЧЛЫ БУЛУ.** Берәрсенә бурычың булу. – *Без сиңа мең тәңкә бурычлы булдыкмы инде?* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Ә кемгә дә булса бурычлы булу – үзеңне аның көенә җырларга мәҗбүр итү ул* (З. Мәхмүди. Елак агач).
Төрдәше: бурычка бату һ.б.

2. Үзенә кылган яхшылыкны, изгелекне кайтарырга тиешле дип санау. *Мин синең алда гомерлеккә бурычлы булачакмын* (В. Имамов. Утлы дала). *Мең бурычлы булып калыр Кеше / Изге китап белән каләмгә* (Л. Шагыйрьҗан. Әдәбият корабы).

**БУРЫЧЛЫ БУЛЫП КАЛМАУ.** 1. Беркемгә дә түлисе бурычы булмау. *Ә үзем исә уңайсызландым, егет башым белән кеше өстенә салынып ятуны килештермәдем, анысы, акча алгач, бурычлы булып калмам калуын, бүгенгесе читен менә* (Г. Гомәр. Гармун телләре унике).

2. Кылган яхшылыкка яхшылык белән җавап бирү. – *Мин сине театрга алып барырмын әле. Бурычлы булып калмам* (М. Шабаев. Кыр казы). *Әнием дә май заводына бурычлы булып калмады* (Р. Зарипов. Тирән тамырлы Түнтәрем).

*БУСАГА* ❖ **БУСАГА АТЛАУ.** Нәрсәгә булса да керешү, башлап җибәрү (беренче адымны атлау). *Бусаганы атлап кергәч тә, ул, өй хезмәтчесен чакырып, берәр касә кофе китерергә кушты* (З. Бигиев. Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә). *Бусагадан атлау белән, максатымны аңлаттым* (Г. Гомәр. Без атланган атлар).

**БУСАГА<НЫ> САКЛАУ.** Кемне дә булса көтеп көн уздыру. *Ә фаҗига кичерүче татарлар исә, әнә шул гаделсезлекне төзәтүне көтеп, кырык ел партия Үзәк Комитетының бусагасын саклады лар* (Ә. Еники). – *Мин сезнең бусаганы инде күптән саклыйм* (Р. Габделхакова. Кояшлы мизгел).

**БУСАГА ТАПТАУ.** Йомыш яки үтенеч белән берәр җиргә бик еш бару. *Ул, байтак бусагаларны таптаганнан соң, укытучы иптәшләренең киңәшләре белән, Урта Азия якларына китеп барды* (А. Расих. Ишан оныгы). *Хакимият бусагасын таптый торгач, ниһаять, Газинур да теләгенә ирешә: «Яшьләр үзәге» өчен Дала урамындагы ике подъездлы буш йортны бирделәр* (Р. Габделхәева. Зинһар, югалма...).
Төрдәше: бусаганы төшерү; бусагасына йөз сөрү.

**БУСАГА ЯЛЫ.** Кызлар янына күңел ачуга кергәндә түли торган бәя. Мәсәлән, Каз өмәсе көнендә өмә оештыручы өендә күңел ачу була. Шунда кызлар каз канаты саталар: егетләр акчаларын тешләре белән тоталар, кызлар иреннәре белән алырга тиеш булалар. *[Фатыйма] Кызлар, егетләрдән бусага ялы түләтәбезме?* (К. Тинчурин. Сүнгән йолдызлар).

*БУСАГАГА* ❖ **БУСАГАГА АЯК БАСТЫРМАСЛЫК.** Бик начар кеше. *Бусагага аяк бастырмаслык шул кешене тагын колхоз ит!* (Н. Баян).

Бусагага <аяк> бастырмау. 1. Өйгә килергә рөхсәт бирмәү. *Катгый каршы килүенә, үзе исән чакта киленне бусагага аяк бастырмаска ант итүенә карамастан, яшьләр үзләренчә яши* («Сөембикә» ж.).

2. Өйгә кертмәслек итү. *Мин, аны бусагага аяк бастырмау өчен, күпме тырыштым, шәт, инде башка килмәс* (Сөйләм).
Төрдәше: бусагадан атлап кертмәү; бусагадан <аяк> атлатмау.

**БУСАГАГА БАРУ (БАРЫП КИЛҮ / ЕГЫЛУ)**. Йомыш, гозер, үтенеч белән берәр кеше каршысына килү. *Берни булса, аның бусагасына барып егыласың* (И. Гази. Онытылмас еллар). – *Кайларга, кемнәр бусагасына гына барып егылырмын икән, Ходаем?!* (Р. Вәли. Шөһрәт).

**БУСАГАГА <АЯК> БАСМАУ.** 1. Килмәү. – *Фатирымның бусагасына да басмыйм бер айсыз* (Ф. Баттал. Мистер-абсолют). *Гөлбану аны инде бөтенләйгә китәр, бу бусагага аяк басмас дип уйлаган иде – киресенчә килеп чыкты* (Т. Гарипова. Мөгри-мөгри килә Бөйрәкәй).
Төрдәше: бусагадан <аяк> атламау (атлап кермәү).

**БУСАГАГА ТЕЗЛӘНҮ.** Үтенү, нәрсә булса да сорау. *Төрбәнең ачык ишеге төбендә бусагага тезләнеп, маңгаен җиргә орды да шул тирәдәге балчык кантарларын, тузанны*

*кулларына, йөзенә ышкыды, иңнәренә тидерде* (Т. Әйди. Елан угы).
Төрдәше: Алла ризалыгы өчен һ.б.

*БУСАГАДАН* ❖ **БУСАГАДАН <АЯК> АТЛАМАУ (АТЛАП КЕРМӘҮ)** *к.* бусагага <аяк> басмау. *Мондый хурлыктан соң ул аңа өйгә кайтып күзенә күренмәскә, туган йорт бусагасыннан аяк атлап кермәскә генә кушты* (С. Зыялы. Ачылмаган бөре).
Төрдәше: бусагага <аяк> басмау.

**БУСАГАДАН АТЛАП КЕРТМӘҮ** *к.* бусагага аяк бастырмау. *Юк, син инде хәзер сулган гөлне / Бусагадан атлап кертмәссең* (М. Җәлил. Син онтырсың).
Төрдәше: бусагага аяк бастырмау һ.б.

**БУСАГАДАН <АЯК> АТЛАТМАУ.** 1. Китермәү. *[Бәдигылҗамал] Лыгырдап йөри шунда үләсе карчык, мин аның андый эш белән килгәнен белсәм, бусагамнан аягын да атлатмаган булыр идем* (Г. Камал. Каениш). *Нәнәй аны бусагадан аяк атлатмый* («Кызыл таң» газ.).
2. Өйгә кермәслек итү. *[Гөлҗиһан] Гомерем буена, Алла боерса, мин аны бусагамнан да атлатмам* (Г. Камал. Банкрот). *Гыймай мине хәзер бусагадан да атлатмаячак* (Ф. Яруллин. Кыйбласызлар).
Төрдәше: бусагага аяк бастырмау һ.б.

**БУСАГАДАН <АЯК> АТЛАУ.** Өйгә килү. *...Ул хәзер миңа бала түгел, бусагамнан атлап керәсе булмасын, дигән* (Т. Мөбарәков). *Бусагадан атлауга, иң элек Мансурның күзенә җизләгән, зур корсаклы, кәкре борынлы комган, бизәкле чаршау һәм... телевизор чалынды* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

**БУСАГАДАН АТЛЫЙСЫ БУЛМАУ.** *«...Бусагамнан да атлыйсы булмагыз», – дип әйткән* (И. Гази. Онытылмас еллар). *Әти аңа: «Йортымның бусагасын атлыйсы булма, нәселегезне күрәсем килми <...>» – дип куып чыгарды* (Д. Салихов. Таш сандык).

**БУСАГАДАН ӨЗЕЛМӘҮ.** Бик еш килеп йөрү. *Батырҗаннан да битәр карт белән карчыкны кызганып, чын-чыннан кайгыртучылар күп булды, көн саен хәлләрен белергә, җылы сүз әйтеп юатырга килүчеләр бусагаларыннан өзелмәде* (Ә. Еники. Тауларга карап).

**БУСАГАДАН ТИБЕП ҖИБӘРҮ.** Өйгә кертмәү; кабул итмәү. – *Юк, син алай бусагадан ук тибеп җибәрергә ашыкма әле, дигән сүзләре ишетелде* (И. Гази).
Төрдәше: бусагадан уздырмау (үткәрмәү).

**БУСАГАДАН УЗДЫРМАУ (ҮТКӘРМӘҮ)** *к.* бусагадан тибеп җибәрү. – *Бусагамнан үткәрәмме соң?* (Ә. Гаффар. Яра). *Әйтергә генә ансат, Кифая апа мин юньсезне тансыклап тора ди, бусагасыннан да үткәрмәс әле* (Р. Габделхакова. Тау артында кояш бар).
Төрдәше: бусагадан тибеп җибәрү.

**БУСАГАДАН УЗМАУ.** Кыюлык итмәү, ишек төбеннән узмау; әдәп саклап, түбәнчелек күрсәтү. *– Айбиби, бала елый, – диде Хәрам ата, ишекне киң ачты, әмма бусагадан узмады* (М. Хәбибуллин. Айбиби). *Бусагадан узмый гына үптең дә син, / Төннең көнне үбүе кук булды, дидең* (Р. Рахман. Төннең көнгә карышуы).

*БУСАГАНЫ* ❖ **БУСАГАНЫ АТЛАП КЕРҮ.** Чикне үтү. *Бөек Җучи, бөек Бату ханнар корып куйганнан бирле, Урда-йортның бусагасын дошман чирүе атлап кергәне юк иде бит!* (В. Имамов. Карабәк). *Кырлайлылар барыбер ниятләреннән чигенмәде, ике көннән янә бусаганы атлап керделәр* (М. Әмирханов. Зиннәтулла хәзрәт).

**БУСАГАНЫ АТЛАТМАУ** *к.* бусагага аяк бастырмау. *[Гөлүзә] Алам-салам кеше белән бусаганы да атлатмый ул* (Ю. Әминов. Әти Балак). *Сеңлесен кулга төшерсәм, апасын бусагамны да атлатмам* (Җ. Ильясов. Тынлык манарасы).
Төрдәше: бусагага аяк бастырмау һ.б.

**БУСАГАНЫ РИСВАЙ ИТҮ.** Йорт хуҗасын яки аның яшәү рәвешен хурлау. *[Камали] Мин үз бусагамны бу кадәр рисвай итәргә ирек бирмәм* (Ф. Бурнаш. Камали карт).

**БУСАГАНЫ ТӨШЕРҮ.** Бик күп килеп йөреп, кешене йөдәтү. *Ул теккән киемне кимәгән кеше калмагандыр. Тирә-як авыллар бусаганы төшерә иде* (Р. Бәшәр. Ачык капка).
Төрдәше: бусага таптау; бусагасына йөз сөрү.

*БУСАГАСЫНА* ❖ **БУСАГАСЫНА ЙӨЗ СӨРҮ.** 1. Берәр кешегә үтенеч белән бару. *Бусагасына барып йөз сөрүдән гарьләндем* (М. Фәйзи).
Төрдәше: бусага таптау һ.б.

2. Өенең ишек бусагасына сәҗдә итү, табыну, теләкләрен теләп дога кылу (тарихи йоладан калган). *Бусагага йөз сөрүне, ягъни хуҗа өенә сәҗдә итүне, мөкатдәс эшкә санаган китап* (М. Хәбибуллин. Илчегә үлем юк).

*БУТА-БОЛАМА* ❖ **БУТА-БОЛАМА КИТЕРҮ** *диал.* Эшне аннан-моннан гына эшләү. *Ындыр табагында эшне бута-болама китергән кеше юк иде* (Сөйләм).

Төрдәше: аннан-моннан гына һ.б.

*БУТАЙ* ❖ **БУТАЙ МУНЧАЛАСЫ КЕБЕК <БУЛУ; БУЛЫП БЕТҮ>.** Бик чуалган, тәртибе бозылган, буталчык. – *Документмыни бу, барысын да бутагансың, бутай мунчаласы кебек булып беткән* (Сөйләм).

Төрдәше: авыш-түеш (тәвеш) килү 1 һ.б.

*БУТАЛЧЫКТАН* ❖ **БУТАЛЧЫКТАН БОЛАМЫК ЯСАУ.** Ыгы-зыгыдан файдалану өчен, махсус буталчыклык тудыру. – *Тиздән комиссия килергә тиеш, диделәр, кәгазьләреңне әзерләп куй, ләкин буталчыктан артык күп боламык ясама* (Сөйләм).

*БУТАЛЫП* ❖ **БУТАЛЫП АЛУ.** 1. Бер-берсен сөйгән кебек мөнәсәбәттә булу. *Башта, яңа колхозга килгәч, яшь сатучы хатын белән бераз буталып алса да, соңыннан ул бердәнбер яраткан кешесе үзенең хәләл җефете икәнен аңлый* (Ф. Мусин. Хәзерге авыл һәм әдәбият).

2. Мөнәсәбәтләр бозылып, аңлаша алмау. *Безнең әдипләр совет чорында гына шактый буталып алдылар* (М. Вәли-Барҗылы. Тормыш дулкыннары).

3. Сөйләшкән вакытта, төгәл бер уй-фикергә туктала алмау. *Карале, вәкил иптәш, – дип, Бикмураев каршына җәһәтләнеп барды Бәйрәм-хан, – болай эшләсәк ни. Болай итик без, – дип буталып алды* <…> (М. Хуҗин. Кулаклар колхозы).

*БУТЫЛКА* ❖ **БУТЫЛКА УРМАННАРЫНДА АДАШУ.** Эчкечелеккә бирелү, эчеп-буталып йөрү. *Бутылка урманнарында адашмаса, нинди яхшы белгеч чыгачак иде үзеннән* (Сөйләм).

*БУТЫЛКАДАН* ❖ **БУТЫЛКАДАН АЖДАҺАЛАР ЧЫГАРУ.** Исерткеч эчемлек эчеп, үзеңне белештермәс хәлгә җитүнең никадәр куркыныч икәнлегенә ишарә. *Бүген Самуил Абрамович үзен бутылкадан аждаһалар чыгарырга көче җитеп тә, соңыннан аларны кире кертеп яба алмаган дәрвиш хәленә калганлыгын бик яхшы аңлады* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

*БУШ* ❖ **БУШ АРА.** Файдаланырга мөмкин яки эштән азат булган вакыт. *Шул ук көнне Газинур, бер буш ара табып, үзенең элекке ротасына барды* (Г. Әпсәләмов. Газинур). *Иртәгесен ул, чыннан да, эшендә, бер буш ара табып, әдәбият, тарих, тел институтына шалтыратты* (А. Расих. Каһарманнар юлы).

**БУШ БАРАБАН.** Исеме, даны еракларга таралган, ләкин эче буш, мәгънәсез кеше турында. – *Телгә алма шуны минем янымда, сөйләсеннәр, мактасыннар, әмма минем өчен барыбер буш барабан ул* (Сөйләм).

**БУШ БАШ<ЛЫ>.** Аңсыз, уйсыз, фикерсез, надан. *Шәехзадә Бабич, Хәсән Туфан, Сәйфи Кудаш, Бәембәт Майлин кебек шигърият җене кагылган шәкертләр алдына буш башың белән кереп кара, алар инде сине каһкаһә белән куачаклар дәрестән* (С. Поварисов. Күкнең җиденче катында).

Төрдәше: ак-кара танымау һ.б.

**БУШ БӘЯ.** Бәясен түләмәү, акчасын бирмичә алу. *Тик ул дуңгызга май заводыннан эремчек суын бушлай ташып эчертүен һәм печәнне колхоздан буш бәягә китертүен генә секретарь киявенә әйтмичә калды* (Ә. Еники. Саз чәчәге).

Төрдәше: бушка алу; буштан буш; буштан буш алу.

**БУШ БУГАЗ**. 1 Күп сөйләргә яратучан, лыгырдык; нигезсез сүзләр таратучы. *Мөгаллим Гайфи тиз җиңелмәде, үз юлында бара бирде: «Заман үтәр, бу ахмак дулкын басылыр, минем фикерләремне шәкерт аңлар, мин алар файдасы өчен кайгырам, алар мәдрәсәдә гыйлем алсын, мин коры буш бугаз надан булып калмауларын телим* <…> (Г. Ибраһимов. Безнең көннәр). *[Гөлсем] Иске карашларга баткан хатын алдында мактанырга? Буш бугаз син!* (Г. Кутуй. Шатлык җыры).

2. Булдыксыз, мактанчык, шапырынып йөрүче, эшлексез кеше. *Мин Камил буш бугаз кебекләрне телгә алырга да хурланам* (Г. Тукай). *Язучы, буш бугаз бәндәләрне, мәгънәсез-кирәксез гамәлләр кылучы әтрәк-әләмнәрне*

*укучы күз алдына китереп бастырганда, каләменең көчен вакыйгагага хас булган дәрәҗәдә күрсәтә* (М. Хуҗин. К. Тинчуринның «Дача» хикәясе).
Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**БУШ ҖАН.** Рухи төшенкелек, эчтә бушлык булу. *Рус шагыйре Михаил Луконин, сугыштан аның буш җан белән кайтканчы, буш җиң белән кайтуы яхшырак, дип язган иде* (З. Нури. Җиңүче солдат, сүз синең хакта). – *Өзелепләр әйтте инде Җәббар улым, бәхетемне сезнең Карасуда калдырам, буш җан белән китәм, дип* (Н. Гыйматдинова. Кыргый).

**БУШ ҖИР** *к.* кысыр җир. *Дөньясында беркем юк... Ниндидер кешесез, буш җир...* (Г. Гыйльманов. Әрем исе). *Шөкер, хәзер муллык заманы, басуларга бер карыш буш җир юк, игеннең чиреге кырда кала, ындыр табагында кыза, элеваторда чери* (Ә. Гаффар. Бодай бөртеге һәм тегермән ташы).

**БУШ ИТМӘҮ (КАЛДЫРМАУ; КУЙМАУ).** Бәхилләтү, бурычлы булып калмау. *Беләм, беләм, икесен дә буш куймассыз* (М. Әмир). – *Менә нәрсә, Мәликә әби, мин сине буш итмәм* (Ә. Еники. Рәшә). *Үзе дә буш калдырмас, Аллаһы боерса* (М. Әмирханов. Әлвидаг).

**БУШ ЙӨРҮ.** Берни дә эшләмичә тик йөрү. *Күп вакыт эше сугыш, / Өйгә кайтса, йөри буш* (М. Гафури). *Мөгаен да студент кешенең авыр тормышын агасы аңлагандыр, бәлки әле «буш йөри, укымыйча да белер дәрәҗәгә җиткәндер» дип уйлагандыр?* (Ф. Яхин. Ректор әфәнде).
Төрдәше: авыз белән чебен аулау һ.б.

**БУШ <КУЛ БЕЛӘН> КАЛУ.** Бернәрсәгә дә ия (хуҗа) була алмау. *Атайдан яшь калдык, акылдан буш калдык* (Мәкаль). *Шпионны уйнаучы Фәүзия генә буш кул белән калды* (Р. Батулла. Юл буенда зәңгәр чәчәк).
Төрдәше: авыз ачып калу 2 һ.б.

**БУШ КЕШЕ**. Зиһенсез, белемсез, яраксыз кеше. – *Буш кеше түгел мин монда, врач әсәре, мондагы кешеләрнең яхшыларын да, яманнарын да беләм, авыр хәлгә куймам, курыкмагыз* (Г. Тавлин. Афәт). *Зөфәр дә буш кешегә охшамаган* (Җ. Дәрзаман. Җир авазы).
Төрдәше: башка чүбек (кибәк) тутыр<ыл>ган һ.б.

**БУШ КӨН** *гади с., сир.* Атнаның икенче көне, сишәмбе. *Менә шул көн җитә башлагач, хәзрәт мәхдүм аркылы яисә хезмәтче аркылы Сөннәтче бабайга «Буш көн (сишәмбе көн) кан алырга керсен», дип хәбәр иттерә иде* (Г. Исхакый. Сөннәтче бабай). *Атнадагы көн исемнәрен дә дөрес атый белмәүчеләр күп. Базар көн, баш көн, буш көн, чәршәмбе көн, атна кич, атна көн, атна арасы көн – һәм вәссәлам!* (М. Фәйзуллин. Сәнгатькә юл ярганда).

**БУШ КӨПШӘ** *к.* башка чүбек (кибәк) тутыр<ыл>ган. *Җебегән. Буш көпшә. Нишләтергә аны?* (С. Поварисов. Оҗмахка бер адым).
Төрдәше: башка чүбек (кибәк) тутыр<ыл>ган һ.б.

**БУШ КУЛ <БЕЛӘН>**. 1. Бернәрсәсез. *Янә килеп, Азат Сәйдәшевне Көнбатыш Германиядән буш кул белән кайтмагандыр, өлешкә керсәк тә гөнаһ булмас дип уйлаучылар табылырга бик мөмкин* (А. Тимергалин Игезәкләр). *Аңа күпме кеше килә, берсе дә буш кул белән йөрми ич* (Р. Зәйдулла. Ак эт).

2. Бернәрсә тапмыйча, табышсыз, нәтиҗәсез. *Кунак җегетнең Байчобары аның куркуын тагын көчәйтте; буш кул белән, кабулым юк дигән җавап белән, ул иярле ат бәйләнгән йортка кайтырга аның йөрәге җитмәде* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *Бу яңа салынган өйгә буш кул белән килүен теләмим, – диде* (А. Нәҗми. Йолдызлар балкышы).

3. Коралсыз, бернинди корал кулланмыйча. *Әйе, буш кул белән әллә ни майтарып булмый, бу тегe фәлән йөз энәле керпене шәрә артны куеп куркыткандай була* (В. Имамов. Тозлы яра).

**БУШ КУЛ ЙӨЗНЕ ЕРТЫР.** Кунакка бернинди бүләксез бару килешмәү турында. *«Буш кул йөзне ертыр, берәр бүләк эзлим дә ни алырга белмим»* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

**БУШ КУЫК** *к.* авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү. *Кукыраеп йөрүче буш куык син!* (Ә. Еники. Төнге тамчылар). *Ир белән хатын арасын ныгытып килгән татлы уйлар ялган, буш куык булып чыкты* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).
Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

**БУШ КУЫК АТУ (ОЧЫРУ).** Мәгънәсез, буш сүзләр сөйләү; дан чыгару өчен юкны бар итеп сөйләү. *Күрмәде гами аны, ул буш куыклар атмагач* (Г. Тукай). *Вәкил Нуриевич белән шул бер чираттагы буш куык очыра торган җыелышта таныштылар алар* (Г. Мирһади. Килмешәк).

Төрдәше: авыздан куык очыру һ.б.

**БУШ КУЫКЛАНУ.** Шапырыну, мактану; ялганлау; *шулай ук к.* ала каргадай алдан ала (алы) кычкыру. *Бу очракта буш куыкланып орыну-бәрелү бер дә килешерлек гамәл түгел шул* (Ф. Яхин. Көзге яңгырга кадәр).

Төрдәше: авыздан куык очыру һ.б.; шулай ук к. ала каргадай алдан ала (алы) кычкыру һ.б.

**БУШ КҮҢЕЛ.** Битараф, бернинди дә теләк-фикер булмаган халәт. *Үз фикерен кыстыруны сөйми, / Буш күңелдән нәрсә кушасың?* (Г. Афзал. Сак кеше). *Әйе, җиребез – гүзәл, күгебез якты, шул ук гүзәл йолдызлы күк астында да буш күңел белән яшәп була икән, гомереңнең санап кына бирелгән кадерле минутларын гел юкка, кирәкмәскә исраф итеп яшәсәң дә гомер уза икән!* (А. Гыйләҗев. Тынычлану зарарлы!).

**БУШ МӘХӘББӘТ.** Исәп-хисапка корылган, хиссез мәхәббәт. – *Җүләр! Шушы яшеңә җитеп буш мәхәббәттән ялыкмадыңмыни әле син?* (Г. Мөхәммәтшин. Кояш кызы). *Фирүзәнең хыялларының җимерелүе, үзенең хыялга ашмаган буш мәхәббәт белән уйнавы аны күңелсезләндереп, йөрәген өзгәләсә дә, ире белән кимхур яшәмәделәр* («Безнең гәҗит» газ.).

**БУШ НӘРСӘ** *к.* әһәмиятсез нәрсә. *Ярату, яратмау буш нәрсә ул, минемчә. Яратуны кемдер – гадәтләнү, дигән* (Г. Тавлин. Афәт). *Изге максатсыз ирек мәгънәсез, кирәкмәгән буш нәрсә икән ул* (Л. Ихсанова. Кемгә сөйлим серләремне?..).

Төрдәше: әһәмиятсез нәрсә һ.б.

**БУШ НӘРСӘ БУ!** *к.* әһәмиятсез нәрсә бу! *Бакчада кырмыска юлына көл сибеп чыгарга кирәк диюләре – буш нәрсә бу, аннан гына кырмыска качмый да, үлми дә* (Сөйләм).

Төрдәше: әһәмиятсез нәрсә бу!; пүчтәк нәрсә бу; сафсата бу!; чүп-чар бу.

**БУШ НӘРСӘ СӨЙЛӘҮ** *к.* әһәмиятсез нәрсә сөйләү. *Буш нәрсәләр сөйләп утыра торгач, караңгы төшкәне сизелми дә калды* (Сөйләм).

Төрдәше: әһәмиятсез нәрсә сөйләү һ.б.

**БУШ ӨМЕТЛӘР БЕЛӘН ӨМЕТЛӘНДЕРҮ.** *Буш өметләр белән өметләндереп, инде алтмышынчы дистәсен ваклый башлады!* (Сөйләм).

**БУШ СӨЙЛӘШҮ.** Сөйләшүне начар әзерләнеп башлау; нәтиҗәле тәкъдимнәр турында уйланмау. *Татарстан Язучылар берлеге рәисе Гариф Ахунов, Сибгат Хәким, Шәүкәт Галиев һәм Мансур Вәлиев катнашында идеология секретаре М. Вәлиев кабинетында ике сәгатьләп барган буш сөйләшүне баш идеолог бик оста очлый* <...> (Р. Юныс. Хөр булып туган журнал).

**БУШ СҮЗ.** 1. Сүз булсын дип кенә әйтелгән сүзләр. *Милләтләрнең тигез хокукы турында сөйләшеп утыру – буш сүз ул* (А. Хәмзин. Озак яшисегез килсә...). *Өстә генә йөзеп йөргән буш сүзләр юк, хис тирән, сагыну тыелгысыз, киләчәккә өмет ышанычлы, нык...* (Ә. Гаффар. Сиртмәле бишек).

2. Чынбарлыкка туры килмәгән. *Ялган икән, сөйләгәннәр буш сүз, / Тәкәббер, дип, имеш, кызлары* (С. Хәким. Үрләр аша). *Үзеңне мәҗбүр итеп оныттырырга мөмкин диләр. Буш сүз!* (Н. Гыйматдинова. Сөйлим, тыңла...).

Төрдәше: авыздан куык очыру һ.б.

3. Мәгънәсе булмаган. *Урамыгыз төз икән, / Төз җирләре боз икән; / Кеше сүзләре буш икән, / Сөеп туймас кеше икән* (Җыр).

Төрдәше: мәгънәсез сүз.

**БУШ СҮЗЛЕ** *к.* буш бугаз. *Егетләр кытлыгыннан ничек котылу турында да уйланган ул заманның җор кызлары, еш кабатланган буш сүзле Пленумнарга да төрттереп уза белгәннәр* (А. Гыйләҗев. Йәгез, бер дога!). – *Без ул әфәнде белән якынтын таныш, аның буш сүзле кеше түгеллеген мин яхшы беләм, юкка гына башта ук алтын портсигар турында сүз кузгатмадым* (Ф. Хөсни. Алтын эзләүчеләр).

Төрдәше: буш бугаз.

**БУШ ТӘЛИНКӘ ТӨБЕН КАГЫП ЙӨРҮ** *мыск.* Түбәдән егылып төшү. – *Син нәрсә буш тәлинкә төбен кагып йөрисең* (Р. Низами. Кояш – минем авылдашым).

**БУШ ТОРУ (БУЛУ; ЯТУ).** 1. Эчендә бернәрсә дә булмау (күбрәк савыт-саба турында). *Өченче көнне дә, казан буш булмаганга, Галәүләргә аш булмады* (Г. Исхакый. Кияү). *Көне буе үт җыеп буш яткан һәм спирттан котырынып киткән ач карын һич кенә туя белмәс кебек иде* (Ә. Еники. Рәшә).

2. Файдаланылмыйча, ирекле хәлдә булу. *Әхәт абыйның күп еллар буш торып, әрем белән алабута баскан йорт урынында күршеләр белән туганнары, өмә ясап, өй җиткереп яталар иде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Озак еллар буш ятты ул нигез* (А. Гыймадиев. Үзең булып кал!..).

3. Ялкауланып, бернәрсә дә эшләмичә, файдасызга вакыт уздыру; эшсез булу. *Анасы кушар йомыш, / Очып китәр мисле кош; / Йомыш-фәлән булмаса, / Язып укыр, тормас буш* (М. Гафури). *Станок буш тора торгандыр* (А. Алиш. Якты күл буе).

Төрдәше: авы белән чебен аулау һ.б.

**БУШ УМАРТА.** Акыл-белемнән мәхрүм, талантлы юк. *Аны буш умарта дип әйтмәс идем, үзенә кирәкле булганда, башы эшли аның* (Сөйләм).

**БУШ УРЫН.** Үзенә тапшырылган вазыйфаларны башкара белмәгән яки башкарырга да теләмәгән кеше турында. *Мондыйларны Камил буш урын дип кенә карый, алардан берни дә көтми иде.* (Г. Бәширов. Җидегән чишмә). *– Уян, Фәзиләкәем, мескенкәем, дөнья үзгәрде, ирең юк. Ә ансыз син – буш урын* (Г. Мирһади. Килмешәк).

**БУШ ФАТИР.** Төрмә яки кабер турында. *Ишекле йорт – буш фатир таптылар үзенә: тимер капкалы, чәнечкеле тимерчыбык коймалы, сакчылар кизү торган каланчалы «өйләргә» дөмектерделәр* (Р. Кәрами. Каргышлы этаплар).

Төрдәше: таш капчык.

**БУШ ХӘБӘР.** Ялган, расланмаган сүз. *[Бәхтияр] Казнасын гел үзе белән йөртә икән дигән сүз таралган иде бит, буш хәбәр булып чыкты, табалмадылар* (Р. Мингалим, Р. Хәмид. Идегәй).

**БУШ ХЫЯЛ<ГА БАТЫП ЙӨРҮ>.** Булмасны, тормышка ашмый торган нәрсәне өмет итеп йөрү. *Заһидулла бу ике егетнең зур мәсьәләләр турында сөйләшүләрен буш хыял гына итеп аңлады* (М. Латыйфуллин. Курайчы малай). *[Хәмит] Юк, минем фаразларым, хыялларым коры фаразлар, буш хыяллар гына булып калмаячаклар* (К. Тинчурин. Беренче чәчәкләр).

**БУШ ЧАРДАКЛЫ** *к.* буш баш<лы>. *Юк, буш чардаклы түгел аның әтисе* (Ш. Рәкыйпов).

Төрдәше: ак-кара танымау һ.б.

*БУШБУГАЗ* ❖ **БУШБУГАЗ БУЛЫП ЧЫГУ.** Сөйләргә генә оста булып, кулыннан эш килмәгән, шапырык булу. *Юк, Тимер-Котлык сыек былчырактан әвәләнгән бушбугаз булып чыкты, иске хан йодрык төйнәгәнче, Сарайдан ук шикелле чыгып ычкынган бит* (В. Имамов. Карабәк).

Төрдәше: авызга каптырган <сары> майны да йота белмәү һ.б.

*БУШКА* ❖ **БУШКА АЛУ** *к.* буш бәя. *– Бушка алу җайсыз булса да, үзең тәкъдим иткәч, бик рәхмәт, – дигән булды* (М. Әмир. Балыкчы ялганнары). *– Кайсын алдан ясарга гына белмим: өй салырга җирне бушка алдым бит мин, өйсез кешеләр рәтеннән* (К. Тимбикова. Нәфесле Нәфисә).

Төрдәше: буш бәя һ.б.

**БУШКА АШАП ЯТУ** *к.* ана карынында яткан кебек. *Егерме өч яшенә кадәр салам селкетмәгән бер әрәмтамак, әрәмтамак булып бушка ашап ятудан башка ни эшли ала?* (Г. Исхакый. Тормышмы бу?).

Төрдәше: ана карынында яткан кебек һ.б.

**БУШКА БЕЗ ҮЗЕБЕЗ ДӘ ТУК.** Эшләгән эшеңә күрә әҗерен алырга теләү. *Әүвәле кем күпме чаба, шуны карап учын суза иде. Бушка без үзебез дә тук!* (Ә. Гаффар. Яра).

**БУШКА БОРЫН ТАРТЫП ЙӨРҮ.** Корыга масаеп, һаваланып йөрү; файдасызга йөрү. *Бетмәс монда бушка борын тартып йөрүчеләр* (Сөйләм).

Төрдәше: буш бугаз 2 һ.б.

**БУШКА БУЛМАС.** 1. Берәр хикмәте, сере бардыр дип шикләнү. *Моннан соң Газизә абыстай «бу эш бушка булмас, бозу галәмәте булмасын» дип уйлап...* (Ф. Әмирхан). *Җиренә җиткереп, аерым бер тырышлык һәм ләззәт белән дога кылды, Гайфә карчык эчке бер сиземләү*

*белән тоеп алды: аның бу йорт бусагасын атлап керүе бушка булмас, Алла боерса* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).

2. Ниндидер эш эшләүнең, гамәл кылуның нәтиҗәсе, файдасы булырга тиешлегенә ишарә. *Белмим, киләчәктә сезнең белән бергә була алырмынмы-юкмы, әмма көрәшеп йөрүебез бушка булмас сыман* (Ә. Салах. Соңгы вальс). *Әй, сөйләгән сүзләребездәге / Гөнаһсызлык-сафлык тамчысы / Гына булса иде үзебездә! / Бушка булмас иде пафосы* (Х. Камал).

**БУШКА ВАКЫТ УЗДЫРУ.** Буш, мәгънәсез сүзләр сөйләнеп, гомерне заяга уздыру. *Менә шушындый соңга калуларны, мәгънәсез сүз боткасы булган киңәшмә-җыелышларны кушсаң, нәтиҗәдә бушка вакыт уздыру берничә көнгә җыела* (С. Хәбибуллин). *Лампаны сүндерергә барып йөрү бушка вакыт уздыру, олы мәгънәсезлек саналыр иде, бар көчен җыеп, аны өреп кенә сүндерде* <...> (Н. Әхмәдиев. Мөнирстан).

**БУШКА <ГЫНА> ТҮГЕЛ.** Берәр хикмәте булу; тиккә генә түгел. – *Бушка дип, дөм бушка түгел инде* (З. Мәхмүди. Ахырзаман шаукымы). *Юк, йөрәкнең гали хисләрнең ташуы берсе дә бушка түгел, алар кешегә канат бирәләр* (М. Маликова. Казан каласы – таш кала).

**БУШКА ҖИБӘРҮ.** Нәтиҗәсез итү, теләгенә ирештермәү. *Ул тагын шул арада кулын болгап-болгап селтәштергәли дә, Фәтхи хәйлә белән Вәлинең кизәнүләрен бушка җибәрә* (Ф. С.-Казанлы. Крушниклар). *Ләкин нигә бушка җибәрсен ул / «Ак фәрештә» кебек апасын* (С. Хәким).

Төрдәше: бушка китү (чыгу).

**БУШКА КИТҮ (ЧЫГУ).** Нәтиҗәсез, файдасыз булу. *Аның бу замечаниесе Фәрдәнәнең күңеленә бик хуш килде: димәк, үзен үзе көчләп тыя, юри соңгарак калып кайтырга тырышуы бушка китмәде* (М. Әмир). *Абыйсының тырышканы бушка китмәде – хәзер Муйнак биргән кишерне кетердәтеп кенә куя* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы).

Төрдәше: бушка җибәрү.

**БУШКА КӨЧӘНҮ.** Юкка тырышу, булмый торган эшкә алыну. *Тегермән әйләнә, әйләнсә дә, тартылмыйдыр ярма. / Мәшәкатьләнмә бушка көчәнеп, юл уртасын ярма* (Г. Тукай. Мөтәшагыйрьгә).

Төрдәше: бушка маташу.

**БУШКА ЛАШМАН ТАРТУ.** Кирәкмәгәнгә газап чигеп эшләп йөрү. *Күпме мөмкин бушка лашман тартырга? – Аның мин-минлеге бунт күтәрә иде...* (Х. Камалов. Үксезләр).

**БУШКА МАТАШУ.** Юкка азаплану, файдасызга көч түгү. *Син оныттың; мин дә иркемне саташулар белән / Алмыймын алмаштырып бушка маташулар белән* (Г. Тукай. Алдандым). *Ике атна буе бөтенләй диярлек бушка маташсалар да, Батырша белән Яхъяның күңелләре тыныч, хөр, йөзләре шатлыклы иде* (Җ. Рәхимов. Батырша).

Төрдәше: бушка көчәнү.

**БУШКА ТЕГЕРМӘН ӘЙЛӘНДЕРҮ.** Вакытны әрәм итеп, юк-бар сөйләшеп утыру. *Бушка тегермән әйләндерүчеләргә карап-карап утыра да бер хикмәт чыгарып куя* (М. Әмирханов). *Саескан койрыгында алып килгән хәбәрен җитди кабул итмичә, тел шомартып, бушка тегермән әйләндерүегезгә гаҗәпләнеп карап торды да (бала-чага белән биш ел гомерен әрәм иткән) Әнвәр идәнгә төкереп куйды* (Т. Галиуллин. Мәкер).

Төрдәше: буш сүз; бушка вакыт уздыру һ.б.

**БУШКА УРАМ ТАПТАУ** *к.* ат тизәге тибү (тибеп йөрү). *Үзенә башка иде ул, безнең ише бушка урам таптаучы түгел иде* (Ә. Еники. Соңгы китап).

Төрдәше: ат тизәге тибү (тибеп йөрү) һ.б.

**БУШКА ЧЫГУ.** Нәрсәдер булыр дип уйлау яки өмет итү тормышка ашмау. *Бу көннәрдә эш кими төшәр дип килен тынычланса да, хезмәтче белән Галәү казан бушар дип шатлансалар да, Мәрфуга абыстай, ашта ашаганга ышанып кунакны ач калдырмыйм, дип, һаман ике аш ашатудан туктамаганга, икесенең дә өметләре бушка чыкты* (Г. Сабитов. Тәүге хәсрәт). *Куелган бөтен көч, бөтен өмет шулай бушка чыгармы икән?!* (Г. Мөхәммәдова. Яшьлек көннәре).

*БУШНЫ* ❖ **БУШНЫ БУШКА (ЮККА) БУШАТУ (АУДАРУ; ӘЙЛӘНДЕРҮ).** 1. Юк-бар нәрсә белән вакыт уздыру. *Берзаман картаеп*

*пенсиягә чыга да бушны бушка бушатырга тотына* (Г. Мөхәмммәтшин. Йөрәктәге эзләр). *Булат бәк үзе дә бушны бушка бушатмады* (М. Әмирханов. Гәүһәршад).

2. Юк эшне бар итеп йөрү. *Кемнәрдер әле үткәргән, / Бушны бушка бушатып* (Ш. Галиев. Буш вакыт). «*Ислам карт бер көлдән икенче күлгә чиләкләп су ташый, арбага төяп, балык күчерә икән, мондый хәлнең дөньяда булганы юк иде, тәгаен, акылыннан язгандыр ул, дип сөйләнделәр* <...>. *Бушны юкка аудару бу, карт көлкегә генә калачак...*» (Р. Солнцев Көймә ватылса – утын / Р. Даутов тәрж.).

3. Мәгънәсез сүзләр сөйләшү. *Пароход килергә әле тагын биш сәгать көтәсе иде – утырдылар шунда бушны бушка әйләндереп* (Сөйләм).

Төрдәше: салдан су агызу.

*БУШТАН* ❖ **БУШТАН БУШ.** «Бәясен түләмичә генә яки бик арзан бәяле» мәгънәсендә. *Төзелеп бетмәгән корылма 1 сумга – буштан бушка бирелә* (Сөйләм).

Төрдәше: буш бәя һ.б.

**БУШТАН БУШКА АЛУ** *к.* буш бәя. *Аның югалуына бер дә исем китми, буштан бушка алдым бит мин аны* (Сөйләм).

Төрдәше: буш бәя һ.б.

*БУЫЛЫП* ❖ **БУЫЛЫП ҮЛӘР ХӘЛГӘ ҖИТҮ.** Соңгы чиккә җитү, башка чара калмау. *Бу хурлыкка һич тә түзәр хәлем калмаган иде, буылып үләр хәлгә җиттем* (Сөйләм).

Төрдәше: азак килеп һ.б.

*БУЫН* ❖ **БУЫН БЕТҮ.** Буын мускуллары йомшап хәлсезләнү. *Бераз утырып торыйм әле, белмим, нәрсә булгандыр, тез буыны бетеп китте* (Сөйләм).

Төрдәше: буыннар коелып төшү; буыны бушау.

**БУЫН КАТУ** *к.* бавыр калку (кату; күтәрү). *Иртән авырлык белән тора башладым, буыннар катып киткән була, аларны җайлар өчен, күнегүләр эшләргә туры килә* (Сөйләм).

Төрдәше: бавыр калку (кату; күтәрү); бавыр ташка әверелү.

**БУЫН СЫЕК <БУЛУ>.** Көчләре җитмәү, хәлләреннән килмәү. – *Безгә каршы торырга буыннары сыек, – дип, Корум да аны җөпләп куйгандай булды* (Р. Зәйдулла. Тәңре кылычы). *Аерылышсаң, бетәсең, малай, / Бетәсең. / Буының сыек синең* (Р. Вәлиев. Иске сәгать дөрес йөри).

**БУЫН СЫЕКЛАНУ (СЫЕГАЮ, КАМЫРЛАНУ).** Хәлсезләнү, көчсезләнү. *Әмма аның буыннары камырланып, сыегайган иде* (В. Имамов. Казан дастаны). *Мөхәммәтнең әтисе әүвәл улын, аннары аяк буыннары сыекланган Мулла бабайны җиргә төшерде* (З. Хөснияр. Кич).

*БУЫНГА* ❖ **БУЫНГА СИКЕРҮ.** Иген камылларының буынлануы. *Буынга сикерә башлаган сабан ашлыклар катып калды* (Ф. Садриев. Көлми торган кеше). *Шуңа күрә дә иҗат иртәсендәге шигъри бөреләрнең соңгы буынга сикереп, сабакка үрләвен күрү гаҗәп түгел* (Х. Янов. Резеда Вәлиева. Зәңгәр иртә).

**БУЫНГА ТӨШҮ.** 1. *к.* бәйдәге эттән битәр; шулай ук: төпченеп сорашу, аптырату. *Мескен баш түбән иелә, яшьле күзләр томалана; ун-унике яшьтән сабан сөргән, сука башы тоткан, гомер буе чалгы-сәнәкне төшермәгән куллар ирексездән дерелди, ни-нәрсәгә орынырга белми; җәлпәк борын йомшый... – Бигрәк буынга төшәләр бит, абый...* (Р. Кәрами. Каргышлы этаплар). *Буыннарга төшкән әрнешләрне / Сыйдырырмы, Моңсар, йөрәгең?* (Ф. Гыйззәтуллина. Яну дәверләрендә).

Төрдәше: бәйдәге эттән битәр һ.б.

2. Авырудан яки физик арудан аяк буыннары талу. *Әз генә хәсрәтем булса, буыннарыма төшә, алҗып егылам* (Х. Сарьян). *Курку буыннарга төшеп хәлсезләткән иде* (Н. Гыйматдинова. Кыргый).

**БУЫНГА УТЫРУ.** 1. Камылның берничә буынга утырып үсүе. *Андагы уҗымнар буынга утырып килә* (Т. Гыйззәт). *Игеннәр буынга утыргач, бәлки, Сабан туе чорында тагын бер килермен* (Г. Ахунов. Тимерханның авыл юллары).

2. Кешенең үсеп, ныгып җитүе. *Без, әле буынга да утырмаган балабызны ашыкпошык ерак шәһәрләргә озатканда, бик хаталанабыз икән* (Х. Низамов. Колхоз мәктәптән башлана). *1929–1933 еллар – көндәлек матбугатта чыныгу. «Яшь ленинчы», «Крестьян гәзите», «Атака» басмаларында эшләү, сәяси тәҗрибә*

*туплау, талантлы, кыю романтик шагыйрьләр арасында үсү, буынга утыру* (Р. Вәли. Батыр йөрәк шигърияте).

*БУЫННАН* ❖ **БУЫННАН БУЫНГА <КАЛУ; КИТҮ; КҮЧҮ>.** Нәселдән нәселгә. *Тормыш бертөслерәк аккан, гореф-гадәтләр, тайпылышсыз үтәлергә тиешле кагыйдәләр буыннан буынга күчә барган, яшәү нигезе булып әнә шулар хезмәт иткән* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?). *Шуңа күрә гаиләдә буыннан буынга килгән һәм тамырларына ихтирам саклаган гадәт, тәртип, кәгыйдәләрне ныгыту бик мөһим бурыч булып тора* (Г. Бубый. Хатыннар).

*БУЫННАР* ❖ **БУЫННАР КОЕЛЫП КИТҮ.** Хәлсезләнү, гайрәт бетү. – *Бара башлагач, кем ул, атам, дип әйтте дә, буыннарым коелып китте* (Һ. Такташ. Караборынның дусты).

Төрдәше: буын бетү һ.б.

*БУЫНСЫЗ* ❖ **БУЫНСЫЗ БУЛЫП КӨЛҮ.** Буыннарын тота алмыйча, бөгелә-сыгыла, ава-түнә көлү. *Сәхнәдә хатыннар талашын күреп, халык һаман буынсыз булып көлә* (Н. Фәттах. Мөдир Саҗидә). *Боларны күреп торган күрше хатыны буынсыз булып көлә* (М. Кәбиров. Бердәнбер һәм кабатланмас).

**БУЫНСЫЗ ҖИРГӘ (УРЫНГА) ПЫЧАК САЛУ.** Начарлыкны шома гына эшләү; хәйләкәр булу. 1. *Хәнәфинең буынсыз җиргә пычак салганын Габделбәрнең үз җилкәсендә татыганы бар* (Б. Камалов. Күршеләр).

2. Урынсызга тупас рәвештә бәйләнү; юк җирдән гаеп эзләү. *Буынсыз урынга пычак салып утырма әле, аннан башка да кәеф юк* (Сөйләм).

*БУЫНЫ* ❖ **БУЫНЫ БУШАУ** *к.* буын бетү. *Тапмасам да кабер ташларын, / төшләремә кереп булса да, / буыннарым бушап киткәндә, / үзе катып, иңгә кул сала* (К. Сибгатуллин. Бер ноктада). *Минһаҗның тезләре, буыннары бушап калды* (Г. Мөхәммәдова. Яшьлек көннәре).

Төрдәше: буын бетү.

*БУЫНЫМА* ❖ **БУЫНЫМА САРЫ СУ БУЛЫП ТӨШТЕҢ ИНДЕ.** Берәр нәрсәне яки сүзне кат-кат сорап, йөдәтеп бетергәндә әйтелә. – *Валлаһи дип әйтәм, буыныма сары су булып төштең инде, бар, чыгып кит әле моннан!* (Сөйләм).

Төрдәше: ахәлгә төшерү һ.б.

*БУЯВЫ* ❖ **БУЯВЫ УҢГАН, БАЗАРЫ ТОРГАН.** 1. Элекке даны-шөһрәте беткән. *Заманында аның сүзе шактый үтемле булгандыр – бәхәсләшмим, хәзер исә буявы узган да базары торган инде* (Сөйләм).

2. Искергән, модадан чыккан. *Нигә дип саклый торгандыр бу күлмәген, буявы уңган, базары торган бит инде аның* (Сөйләм).

3. Яшьлеге үткән. *Тәрәзә яныннан Зөлия түтинең авыр атлап узганын карап торды да ирексездән «үтә гомер, аның да буявы уңган, базары торган» дип уйлап куйды* (Сөйләм).

Төрдәше: агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән һ.б. (өч маддә өчен дә).

*БУЯП* ❖ **БУЯП КҮРСӘТҮ.** Ал күзлектән караган кебек күрсәтү. *Бары партия юлына ышанмаган, партия һәм эшчеләр сыйныфы идеаллары белән нык сугарылмаган язучы гына чынлыкны бозып, буяп күрсәтәчәк* (Ә. Мәхмүтов. Эстетик идеалның формалашуы). *Алар Көнбатыш Европаны матур төсләр белән генә буяп күрсәтүдән ерак торалар иде* (Т. Камалов. Көнбатышка йөз белән).

*БУЯУНЫ* ❖ **БУЯУНЫ АРТЫК КУЕРТУ.** Эшне зурга җибәрү, катлауландыру. *Старпом буяуларны артык куерта, чамасыз күп тондыра дип уйлый күрмә* (А. Хәсәнов. Данәгөл). *Үз балалары яисә оныклары укымаганнар, бәлки, моны аңлап та бетермәсләр, буяуны артык куертасыз, дип гаепләргә дә мөмкиннәр* (tarkhanova.ru).

*БҮГЕН* ❖ **БҮГЕН АЛДЫН, ИРТӘГӘ АРТЫН КҮРСӘТҮ** *к.* бер алдын, биш артын күрсәтү. – *Ышан заманага, бүген алдын, иртәгә артын күрсәтә* (Н. Гыйматдинова. Кем беренче?). *Әмма тормыш ул шундый әйбер, бүген алдын күрсәтсә, иртәгә...* («Безнең гәҗит» газ.).

Төрдәше: бер алдын, бер (биш) артын күрсәтү һ.б.

**БҮГЕН АНЫҢ БАЗАРЫ.** Бүген ул әйбергә сорау-таләп зур булу. *Бүген аның базары килде дип, складтагы шикәрне сатуга чыгарырга булдылар* (Сөйләм).

**БҮГЕН АЯКТА, ИРТӘГӘ ТАЯКТА.** «Авырыйм, картайдым, көчкә генә аяк өстендә йөрим» тезмәсен кыска гына итеп белдерү. *Сорап торган буласың тагын, беләсең бит инде: бүген аякта, иртәгә таякта* (Сөйләм).

**БҮГЕН БАР, ИРТӘГӘ ЮК.** 1. Үлем алдында тору. *Дөнья хәлен белмәссең: бүген бар – иртәгә юк* (А. Алиш. Яңа килен). *Без ни, картлар, бүген бар, иртәгә юк* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

2. Байлыгы белән масаючыга әйтелә. *[Марсельеза] Мин нәрсә, әй... бүген бар, иртәгә юк дигәндәй, бәхетле булыгыз... чебиләрем генә кая югалды...* (Г. Каюмов. Юбилей). *Байлык, балам, бүген бар, иртәгә юк* (З. Кадырова. Көтеп узган гомер).

**БҮГЕН БЕЛӘН ГЕНӘ ЭШ БЕТМИ.** «Киләчәккә планны алдан ук уйлап куярга кирәк» мәгънәсендә. *Бүген белән генә эш бетми бит, әни* (Ф. Хөсни).

**БҮГЕН БОЛАЙ, ИРТӘГӘ ТЕГЕЛӘЙ** 1. *к.* атнасын<д>а биш (җиде) җомга. *Халык бүген болай, иртәгә тегеләй* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң). *Әгәр дә бүген болай, иртәгә тегеләй әйтеп йөри башласа, кем булачак ул?* (Ф. Яхин. Күзгә яңгырга кадәр).

Төрдәше: акылы үзе белән һ.б.

2. Дөньяда абсолют үзгәрешсез булган нәрсәнең булмавына ишарә. *Фани дөнья ыгы-зыгысы чүп кенә, бүген болай, иртәгә тегеләй, шуңа карап тормыш тәртибенә тыгылма, үз өстеңә зур җаваплылык алма* (З. Мурсиев. Бер гаилә гыйлләсе).

**БҮГЕН БУЛМАСА – ИРТӘГӘ.** Барыбер, кайчан да булса бер. *Бүген булмаса, иртәгә муеннарын борырбыз* (Г. Әпсәләмов. Газинур). *Бүген, бүген булмаса, иртәгә Нугай тәхете бушаячак* (Р. Батулла. Сөембикә).

**БҮГЕН ГЕНӘ ТУМАГАН.** Дөньяны күргән, тәҗрибәле. *Солдатов та бүген генә тумаган* (М. Миншин. Кызыл диплом).

**БҮГЕН ДӨНЬЯ, ТАҢДА АХИРӘТ.** «Кеше гомере бик кыска, бүген бар, иртәгә юк» мәгънәсендә. *Бакчаларга бараек, / Чия пешкән, алаек; / Бүген дөнья, таңда ахирәт, / Җанкай, сөешеп калаек* (Җыр).

**БҮГЕН КИЛЕП.** Инде менә хәзер. *Әле кичә генә арба җиленнән очып китә торган бала-йон бүген килеп тубал башлы фән артыннан йөгерә* (Ф. Хөсни). *Бүген килеп инде Фәрит өченгә аларның берсе дә юк...* (З. Мифтахов. Күрәчәгең булса...).

**БҮГЕН МИНДӘ, ИРТӘГӘ СИНДӘ.** Чиратлап була торган хәл. *Бу байлык бүген миндә, иртәгә синдә, аның шикелле ышанычсыз нәрсә юк* (Г. Исхакый. Өч хатын белән тормыш). *Бүген миндә, иртәгә синдә булырга мөмкин кайгы* («Безнең гәҗит» газ.).

**БҮГЕН ӨЕМ, ИРТӘГӘ ГҮРЕМ.** Мал җыю, йорт салу һ.б. эшләр белән маташырлык түгел әле дип, төшенкелеккә бирелү. *Саруымны кайнатма әле, селкенәсем дә килми – бүген өем, иртәгә гүрем хәлендә мин* (Сөйләм).

**БҮГЕН СЕМБЕРДӘ, ИРТӘГӘ СЕБЕРДӘ.** Йорт тотмас, төрле җирләрдә яшәп эшләргә күнеккән кеше хакында. *Ныклап ябышып яткан җире дә юк аның, бүген Сембердә, иртәгә Себердә ул* (Сөйләм).

Төрдәше: суык аяк.

**БҮГЕН ТАҢДА.** Шушы көннәрдә, бик тиз арада. *Тырыш – дөньяң өчен мәңге тору күк, / Гыйбадәт кыйл – бүген таңда үләр күк* (Г. Харис. Вак-төяк). *Бик ерак бит айның ахыры, ул бүген таңда түгел!* (Ә. Исхак. Борынгы Көнчыгышка ияреп).

**БҮГЕН ТУГАН КЕБЕК.** Эшнең яки яшәүнең рәтен белмәү, күп нәрсәдән хәбәрдар булмау. *– Болай да сәламәтлегең юк, ашказаныңны әйтер идем инде... Бүген туган кебек яшисең үзең дә...* (Г. Гыйльманов. Алтын кыйссасы).

**БҮГЕН ҮТКӘНГӘ ИРТӘГӘГӘ КӨРСЕНҮ** *к.* агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән. *Бүген үткәнгә иртәгәгә көрсенүдән ни мәгънә!* (Ә. Гаффар. Богау).

Төрдәше: агасы сулар аккан, китәсе кайгылар киткән һ.б.

*БҮГЕНГЕ* ❖ **БҮГЕНГЕ БИЗМӘННӘРГӘ САЛЫП ҮЛЧӘҮ.** Үткәндә булган вакыйгага, эшкә һ.б. га бүгенге торыштан чыгып бәя бирү. *Билгеле, бүгенге күзлектән караганда, аек акыл белән бүгенге бизмәннәргә салып үлчәсәң, әллә ни булмады да кебек* (А. Расих. Ишан оныгы).

**БҮГЕНГЕ КӨН.** Агымдагы иң мөһим саналган мәсьәләләрне туплаган вакыт; хәзерге чор. *Тукайны укыйбыз да, аның нәкъ бүгенге көн кадагына суккан сүзләренә исебез китә* (А. Тимергалин. Ике сандык йакут). *Элек алар [саесканнар] йорт тирәсенә берәмләп кенә килә иде, хәзер, бүгенге көн сукбайлары кебек, ике, өч, хәтта дүртәүләп йөриләр* (Р. Сибат. Кайту).

**БҮГЕНГЕ КӨН БЕЛӘН <ГЕНӘ> ЯШӘҮ.** Көндәлек ихтыяҗлар турында гына уйлап, алдагыны кайгыртмау. *Мена әйтегез әле, нишләп безне бүгенге көн белән яшәргә өйрәтәләр, ә?* (Ә. Хәсәнов. Бәхет кайда оя кора?). *Бүген яшим мин, бүгенге көн белән яшим* (А. Нәҗми. Азат).

Төрдәше: хәзерге көн белән яшәү.

**БҮГЕНГЕ КӨНДӘ.** Шушы мизгелдә, хәзерге вакытта. *Ләкин бүгенге көндә иң ашыгыч эшләнергә тиешле бурыч – ул уку программаларын өр-яңадан эшләү* (А. Әхмәдуллин. Офыклар киңәйгәндә). *[Әмир] Хәзерге вакытта, бүгенге көндә, юк нәрсә белән шөгыльләнергә ярамый* (З. Хәким. Язын бозлар акканда).

**БҮГЕНЕ КҮЗЛЕКТӘН КАРАГАНДА**. Хәзерге вакыттагы торыш, хәл белән чагыштырып караганда. *Билгеле, бүгенге күзлектән караганда, аек акыл белән бүгенге бизмәннәргә салып үлчәсәң, әллә ни булмады да кебек* (А. Расих. Ишан оныгы). *Бүгенге күзлектән карасак, әкияттәге кебек* (М. Харисов. Укытучы иртә чалара).

*БҮГЕНГЕСЕ* ❖ **БҮГЕНГЕСЕ КӨННЕ (КӨН<ЕН>-ДӘ).** Хәзерге вакытта, бу көннәрдә. *Бүгенгесе көнне безнең күп кешеләребез, син әйтмешли, булганга эшли* (Г. Бәширов). *Бүгенгесе көндә чыгышы төгәл билгеле булмаган, исбатланмаган халык ул* (К. Җәмит. Килмешәк).

*БҮДӘНӘ* ❖ **БҮДӘНӘ СИМЕРТҮ** *к.* авыз күтәреп яту. *Ул тагын бер айга якын резервта «бүдәнә симертергә» мәҗбүр булды әле* (Ш. Маннур).

Төрдәше: авыз күтәреп яту һ.б.

**БҮДӘНӘ СУГЫШТЫРУ.** 1. Булган дуслыкны бозу. *– Вообщем, бүдәнә сугыштырмыйк әле без, парин, син миңа, мин сиңа кирәк булырбыз, ә пока!* (Ә. Еники).

2. Вак-төяк кешеләрне ызгыштырып-сугыштырып кызык табу. *Аларда тик шул гына бар: әтәч, бүдәнә сугыштыру, гәшә тарту, әфьюн салу!* («Матбугат. ру» порталы).

*БҮЗ* ❖ **БҮЗ БАЛА.** Буй җиткән, балигъ булган, яшь егетләр. *Бу соңгы бүз бала, үзенең сөйгәнен караңгы төндә дүрт җегет белән килеп, ат өстендә урлап качкан иде* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы). *Әмма бүз бала чагыннан бөтен гомерен сату-алуда үткәргән Сәетнең үткен күзләре башкалар күрмәгәнне күрә, колагы күпне ишетә, акылы һәр чалымда мәгънә таба иде* (Ф. Латыйфи. Хыянәт).

**БҮЗ КӨЯСЕ.** Кешенең гаебен күзәтеп, куркытып, кеше җилкәсендә яшәүче әрәмтамак (ак мамык тукыманы кисүче көягә тиңләү). *Теге бүз көясе тагын монда таба килә, тизрәк шылыйк моннан!* (Сөйләм).

**БҮЗ КӨЯСЕ БУЛУ**. 1. Һич аерылмау, ирексезләп үз яныннан китмәү (җибәрмәү). *[Садрый] Менә бәла, чистый бүз көясе булды бу! Монда мин биш тиен артык китте дип кызганып утырам, ә ул сала да эчә, сала да эчә* (Г. Камал. Безнең шәһәрнең серләре). *Мәҗлес таралгач, Хөрмәт аны озатып та куйды, телен тапты, ләкин бүз көясе булмады – озак тоткарламады* (Р. Кәрами. Кая чабасың, гомер юртагы?).

2. Төрле сүзләр сөйләп бәйләнү. *– Бүз көясе булма әле, зинһар, – диде Мамай, – болай да суккаланган чак* (М. Әмирханов. Ир-Мамай).

*БҮКӘЙ* ❖ **БҮКӘЙ БУЛУ.** Берәр нәрсәнең ямен җибәрүче, йомыкый булу. *Кешелеккә ямьсез бүкәй булып, / Колларына тоткан камчысы* (М. Җәлил. Төрмә сакчысы). – *Мәҗлес күрке җибәреп, бүкәй булып утырасым килми* (Т. Галиуллин. Элмәк).

**БҮКӘЙ КҮРСӘТҮ** *к.* букай күрсәтү. *Бүкәй күрсәтү – <...> берәр эштән күңелен кайтару өчен, бик хәтәр, куркыныч итеп күрсәтү. Әйтик: «Йә. йә, син миңа бүкәй күрсәтмә, мин сиңа бала-чага түгел»* (Н. Исәнбәт. Фразеологик әйтемнәребездә тарихилык).

Төрдәше: букай күрсәтү; бүки күрсәтү.

**БҮКӘЙ ТИЮ.** Җәмәгатьтән аерылганны мифик зат урлап китү ихтималы булуга ишарә.

*[Биктимер] Әйдәгез, кызлар, калмагыз, бүкәй тияр* (М. Фәйзи. Галиябану).

*БҮКӘН* ❖ **БҮКӘН БАШ** *мыск.* Аңсыз, надан. *Нигә ул бүкән баш Гомәрне тыңлап утырып, вакытыңны әрәм итәсең?* (Сөйләм).

**БҮКӘН ШИКЕЛЛЕ ЮАН.** Симез кеше турында. *[Гөлбану] Шәрәфи Хисамиенең картаеп беткән шадра бүкән шикелле юан кызына да ия чыкты әле* (Г. Камал. Көндәш). *Хәзер инде ул саргылт чәчле, сипкелле, бүкән шикелле юан бер кызга әйләнгәндер* (М. Галәү. Болганчык еллар).

*БҮКИ* ❖ **БҮКИ КҮРСӘТҮ** *к.* букай күрсәтү. *Бүки күрсәтеп котылсаң гына инде, башкача чара юк* (Сөйләм).
Төрдәше: букай күрсәтү; бүкәй күрсәтү.

*БҮКСӘ* ❖ **БҮКСӘ КИЕРҮ**. 1. Эреләнү, горурлану; масаю, кәперәю. *Хисаминың кызын күрдем, бигрәк конарсыз нәрсә икән, үзе озын, үзе чыра шикелле, шадра, авызы кыек, чепи күзле, кәкре аяклы. Шулай булса да тагын әллә кем булган булып бүксәсен киереп утыра* (Г. Камал).
Төрдәше: алып узу һ.б.

2. Кычкырыну. *«Таң кояшы иле»ндәге хатын иренә «Я тебе сказала!», «Сам дурак!» – дип бүксә киереп кычкыруны күз алдына да китерә алмый* (М. Юныс. Соңгы сулыш).

*БҮЛӘК* ❖ **БҮЛӘК БАГУ** *этн.* Элекке вакытта кыз алу, кыз бирү йоласында кода-кодагыйлар арасында кием-салым, кул эшләрен күрсәтешү. *[Җәмилә] Фәлән көнгә Нәгыйм байда бүләк багу мәҗлесе булачак, шуңар өлгертергә алган эшләрем бар, ди* (Г. Камал. Бәхетсез егет). *Догадан соң бүләк бактылар. Бүләкләр затлы иде, зиннәтле* (М. Әмирханов. Гәүһәршад).

*БҮЛМӘ* ❖ **БҮЛМӘ КҮТӘРЕП КӨЛЕШҮ.** Шаулашып, иркенләп, бердән көлү. *Бүлмәне күтәреп көлештеләр* (Г. Ахунов).

*БҮЛТӘЙГӘН* ❖ **БҮЛТӘЙГӘН НӘРСӘ.** Бик тиз үпкәли торган кеше. *Бүлтәйгән нәрсә, аңа кечкенә генә тәнкыйть сүзе дә әйтергә ярамый бит!* (Сөйләм).
Төрдәше: кәкре кабыргалы.

*БҮРӘНӘ* ❖ **БҮРӘНӘ АРКЫЛЫ (АРТЫННАН; АША) БҮРЕ КУУ.** Булмаганны бар итеп сөйләү. – *Уфтаныштык, югарыдагыларны сүккән булдык, бүрәнә аркылы бүре кудык шул* (Г. Мөхәммәтшин. Йөрәктәге эзләр). *Малайлар шаулаштылар, ләкин барысы да моның болай гына, бүрәнә артыннан бүре куу гына икәнен беләләр иде* (М. Мәһдиев. Без – кырык беренче ел балалары).
Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

2. Куркаклыкны күрсәтү өчен кулланыла. *Кызыл бугазлар, бүрәнә артыннан бүре куучыларга әверелеп, буш сүз тегермәнен тартучылар сыман тоелдылар аңа* (Ф. Яхин. Умырзая). *Мин ул кешенең үзенә дә әйттем: мин сезгә, дидем, күн тәпи түгел, дидем, бүрәнә артыннан бүре куганчы, килеп сөйләшегез, дидем* (М. Әмирхан. Үлмә, Әхмәтхан!).
Төрдәше: бүре күргән эт төсле; бүредән куркып, (курыккан) урманга бармау; бүрек ташлап, бүре куркыту; бүрәнә артыннан (аша) бүре куу һ.б.

**БҮРӘНӘ АРКЫЛЫ (АША; ҮТӘ) БҮРЕ КҮРҮ.** Арттырып сөйләү, юк нәрсәдән зур нәрсә күрү; булмаган нәрсәләрдән шикләнеп утыру. – *Бүрәнә аркылы бүре күрү була түгелме соң бу, кодагый әби? – диде* (Г. Бәширов. Менә сиңа, мә!). *«И шуны фактически миңа гаеп итеп такмакчы язучы. Бүрәнә аркылы бүре күрә бу язучы халкы да...»* (Ф. Хөсни. Икесе дә гаепле). *[Талип] (капкага таяк белән бәреп). Байлар өйдәме? [Хәдичә] Кем ул бүрәнә аркылы бүре күреп йөри?* (Г. Ахунов. Утлар яна учакта).

**БҮРӘНӘ АРТЫННАН БҮРЕ КУРКЫТУ.** Үзе куркып качкан килеш юк белән кешене куркытып маташу. *Түбән оч Шәмсия апа:* «*Мин иңкүлектәге куралыкка башка бармыйм, анда, ботакларны сындыра-сындыра, аю йөри иде бугай, – дип, бүрәнә артыннын бүре куркытырга тотынды* (Сөйләм).

**БҮРӘНӘ АРТЫННАН БҮРЕ ҮТЕРҮ.** Булмаганны бар итеп күреп, юк чаралар белән куркынычтан котылу хыялларын кору. *Моны ишетеп, Мәдинә, хыялый син, бүрәнә артыннан бүре үтерергә уйлыйсың, дисә дә, авырткан йөрәкне алмаштырырга кирәк булса, ил башына мөрәҗәгать итәчәкмен* (Сөйләм).

**БҮРӘНӘ БАШЫ ТИШЕК.** Саграк кыланырга кирәклеген, сөйләшүне тыңлап торучы озын

колаклар булуын кисәтү. *Беркөнне Әхмәтсафа өенә кайтып чишенеп өлгермәде, каршысына Рабига атылып килеп чыгып, колагына пышылдады: «Бүрәнә башы тишек!»* (Ф. Сафин. Саташып аткан таң).

**БҮРӘНӘ ТАРТТЫРУ.** Гырлап йоклау. *«Төнлә борын белән бүрәнә тарттыручылар» дигән данны тагып йөрү әллә мач килде дип уйлыйсызмы?* (Ф. Хөсни. Картая белмәс картлык). *Ул бүрәнә тарттыра башлагач, Иблис, куллары уып, пышылдап кына шигырь сөйләргә тотынды* (З. Мәхмүди. Мунча).

**БҮРӘНӘ ЯРЫГЫННАН КӨЛӘ ТОРГАН ЧАК.** Үсмер кызларның бер дә юктан да кызык табып, чырык-чырык көлгән чаклары. *Розалиягә нәрсә, бүрәнә ярыгыннан да көлә торган чагы* (А. Гыйләҗев).

*БҮРӘНӘГӘ* ❖ **БҮРӘНӘГӘ БОРЧАК АТКАН (АТМАК) КЕБЕК.** Сүзе үтмәс кешегә мөрәҗәгать итүдән файда булмау. *Бу тугырыда һәркем бөртөрле сүз сөйләмәктә вә фикер бәян итмәктә улса да, бүрәнәгә борчак атмак кебек, бер файда күренмәс иде* (Р. Фәхретдин. Әсма, яки Гамәл вә җәза).
Төрдәше: аңа әйттең ни, стенадагы бүрәнәгә әйттең ни һ.б.

**БҮРӘНӘГӘ БОРЧАК БӘРҮ БЕЛӘН БЕР** *к.* аңа әйттең ни, стенадагы бүрәнәгә әйттең ни. *Өенә кергәч, сөйләшеп-аңлатып вакыт әрәм итмә, кеше сүзе бүрәнәгә борчак бәрү белән бер аңа: конвертны өстәлгә куй да чыгып кит* (Сөйләм).
Төрдәше: аңа әйттең ни, стенадагы бүрәнәгә әйттең ни һ.б.

*БҮРӘНӘНЕҢ* ❖ **БҮРӘНӘНЕҢ АВЫР (ЮАН) БАШЫН(НАН) КҮТӘРҮ.** Эш-гамәлнең, мәшәкатьнең иң җаваплысын үз өстенә алу. *Илле яшьләр тирәсендәге бу кеше бүрәнәнең юан башын күтәреп яшәгән, дөньяның ачысынтөчесен күп татыганга охшый иде* (Г. Мөхәммәтшин. Йөрәктәге эзләр). *Татар бүрәнәнең юан башыннан күтәрергә тырыша, да-а-а... честный халык татарлар...* (Т. Мөбарәков. Хәтер аланы).

*БҮРЕ* ❖ **БҮРЕ АВЫЗ.** Саран, комсыз, акчага хирыс кеше, халык җилкәсендә туенучы куштан. *– «Бүре авыз Мәрдән» дигәнен языймммы, мильцанер апа?* (Г. Ахунов. Идел кызы).
Төрдәше: алырсың гайтаннан иман 2 һ.б.; ач әрвах 2 һ.б.

**БҮРЕ АЗЫГЫ.** Хәлсез, ябык ат яки башка хайван. *– Нигә бу сарыкны бүре азыгы итеп асрыйсыз, ашатырга ризыгыгыз җитмиме әллә?* (Сөйләм).

**БҮРЕ БЕЛӘН КУЙ БЕРГӘ СУ ЭЧҮ.** Гаделлек һәм иминлек эчендә яшәүне белдерү. *Бүре белән куй бергә су эчәр, / Үрдәк белән карчыга бергә очар* (Мөхәммәдьяр).

**БҮРЕ БИЛЕТЫ.** Кеше хокукын чикли торган документ, ул үзен тискәре (начар) яктан күрсәткән кешегә бирелә. *Шуларга – торгынлыкка каршы чыкканым өчен, миңа «бүре билеты» тоттырдылар* (Г. Тавлин. Афәт).

**БҮРЕ БУЛЫП УЛАУ.** Берәрсе өстеннән шикаятен сөйләү, зарлану, сыкрану. *Иртән ирләр аның янына килгән чакта, атаманның чигәләрен чал чәч баскан, күзләое тозлы су белән юган шикелле тоныкланган, ә үзе сагыштан бүре булып уларга әзер иде* (В. Имамов. Утлы дала). *Мәхәббәттән акылыннан шашып, / Хыянәттән бүре булып уласы бар* (Н. Әхмәдиев. Тик аңынчы...).

**БҮРЕ ДӘ, САРЫК ТА ТУК БУЛСЫН** Икесе бергә сыешмый торган ике каршылыкны зарарсыз калдыру юлын табу. *Бүре дә, сарык та тук булсын өчен нишләргә кирәк икән? Корбаннар кирәкме!* (Н. Гыйматдинова. Сөйлим, тыңла...).
Төрдәше: бүре дә тук булсын, куй да сау булсын; бүре дә тук, сарык та исән <булу>; сарык та исән <калсын>, бүре дә тук <булсын>.

**БҮРЕ ДӘ ТУК БУЛСЫН, КУЙ ДА САУ БУЛСЫН** *к.* бүре дә, сарык та тук булсын. *Җыелыштан барчасы да канәгать калды, аларның максатлары бүре дә тук булсын, куй да исән булсын иде бит* (Сөйләм).
Төрдәше: бүре дә, сарык та тук булсын һ.б.

**БҮРЕ ДӘ ТУК, САРЫК ТА ИСӘН <БУЛУ>** *к.* бүре дә, сарык та тук булсын. *Бер-берсенең якасына ябышып, сизелерлек зарар күренмәгәч, бүре дә тук, сарык та исән булсын дип бугай, аларны татулаштырырга тырыштылар* (Сөйләм).
Төрдәше: бүре дә, сарык та тук булсын һ.б.

**БҮРЕ ЕРТКЫРЫ** *карг.* Әйдәүгә килми җәфалаган, чыгымлаган атларга яки башка хайваннарга әйтелә. – *Бүреерткыры нәрсә, өйгә кайтасыңмы син, юкмы!* (Сөйләм).

**БҮРЕ ЙОТАРДАЙ БУЛУ.** Бик нык ашыйсы килү. *Карыным ачты, бүре йотардай булдым* (А. Гыйләҗев). <...> *«бүре йотардай булу», «җиргә ябышып яту», «җирне кысыр калдыру», «кырык мирдән калган» һ.б. әсәрнең телен тагын да халыкчан итә, образлылык төсмерен көчәйтә* (Р. Ханнанов. Шартлы дөньяда...).

**БҮРЕ КЕБЕК АЧ, ЕЛАН КЕБЕК ЯЛАНГАЧ.** Бөтенләй ач-ялангач (шикле кешеләр турында). *«Сак булырга кирәк. Әни әйтмешли, бүре кебек ач, елан кебек ялангач күренәләр»* (Т. Галиуллин. Төнге юллар).

**БҮРЕ КЕБЕК КАРАУ.** Дошманына караган кебек явыз караш. *Икенче көнне Сәлах Гөлшәһидәгә бүре кебек карап, исәнләшми узып китте* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр). *Аксыл фуражка астыннан бүре кебек карап торган уналты яшьлек үсмернең ныклыгына аптырый төшеп: – Фамилия? – дип кабатлады* (Г. Ахунов. Идел кызы).

**БҮРЕ КҮРГӘН ЭТ ТӨСЛЕ.** Йөзгә-йөз очрашудан курку. *Бүре күргән эт төсле миннән кача* (К. Тинчурин). *Көлкедән башка, төгәл фактлар белән язылган, турыдан-туры кайсы түрә тарафыннан эшләнгәнен әйтеп, Татар зыяратын, мәчеттән тартып алып, шәхси эшмәкәргә биергә җыену турындагы язманы укуга, «диниләр», бүре күргән эт кебек, койрыкларын кыстылар бит...* («Матбугат.ру» порталы).

Тәрдәше: бүрәнә аркылы (артыннан; аша) бүре куу 2 һ.б.

**БҮРЕ МАЛАЕ.** Кешеләр белән аралашмыйча, аларга буйсынмыйча, үз иркендә яшәүче. *Ничек тә сыртны җиргә тидермичә, «бүре малае» булып яшәү эз калдырмыйча гына үтеп киткәндер дисеңме?* (Ф. Хөсни).

**БҮРЕ ПИЧӘТЕ** *иск.* Контрлык мөһере. *Алар кулына эләксәң, пашпуртыңа бүре пичәте сугалар, ди* (К. Тинчурин. Мәрҗәннәр).

**БҮРЕ САРЫК ТИРЕСЕН ЯБЫНУ.** Үзе файда күрү өчен, изге ниятле, яхшы, мәрхәмәтле, хәерхак итеп күрсәткән явыз, икейөзле кеше хакында. – *[Кол Шәриф] Ач бүре сарык тиресен ябына алайса...* (Р. Зәйдулла).

**БҮРЕ СЕҢЕРЕ САЛДЫРУ.** Им-томчыларның бер бәддоганы дәвалау ысулына ишарә. – *Ант ит, юкса бөтен тәнеңне кутыр баса, бүре сеңере салдырам, – диде Хәким, кемнәндер ишеткән куркыныч бәддога хәтеренә төшүенә куанды* (М. Әмирханов. Адашу).

**БҮРЕ СЫРХАВЫ.** Ачлыктан интегү. *Халык телендә ачлыкны бүре сырхавы дип тә атаганнар* (А. Тимергалин. Миллият сүзлеге).

**БҮРЕ ТЕШЕ ТИЮ**. «Зәхмәт йогу» мәгънәсендә, ягъни бер намуссызлык эшләгән яки хыянәт иткән кешедән өмет көтмә, ул яңадан туры юлдан тайпылачак. – *Бүре теше тигәнне бүрегә бирү хәер. Чит ир назын татыган кыз-кыркынга ышаныч юк* (В. Имамов. Казан дастаны).

**БҮРЕ ТИРЕСЕ ЯБЫНУ.** Үзе куркак табигатьле булса да, берәр дәрәҗәле урынга утыргач, кешеләрне куркытудан тәм таба башлау. *Халык алдында суфи, бүре тиресе ябынган сарык булып яшәмәсеннәр иде* («Ирек мәйданы» газ.). *Сарыгы бүре тиресенә ябынса – ни кылырга? Кичерергә ярыймы аны?* (Р. Солнцев. Көймә ватылса – утын / Р. Даутов тәрҗ.).

**БҮРЕ УРЫНЫНА АШАУ**. Тәмләп, ашыга-ашыга ашау. – *Ашаудан калып, саргаеп киткән идем, шушы суны эчә башлавым булды, аппетитым ачылды, күпмедер вакыттан бүре урынына ашый башладым, рагым да юкка чыкты, ди* (Ф. Садриев. Кышкы яшен).

*БҮРЕГӘ* ❖ **БҮРЕГӘ АТЫП, КУЯНГА ТИДЕРҮ.** Эшне зурдан кубып, кечкенә нәтиҗәгә ирешүдән көлү. *[Дускаев] Бүрегә атып, куянга тидерәсез?* (И. Юзеев).

*БҮРЕГЕ* ❖ **БҮРЕГЕ БАРНЫҢ КҮРКЕ БАР.** Кешенең дәрәҗәле икәнлеге хакында. – *Берәр затлырак баш киеме алып кимисеңме? Бүреге барның күрке бар, дигәннәр борынгылар* (Сөйләм).

*БҮРЕГЕН* ❖ **БҮРЕГЕН БАШЫНА КИГӘНЧЕ ЕЛ УЗА** *мыск.* Озак мыштырдарга яратучы хакында. *Бигрәк тә мыштырдык булдың инде, бүрегеңне башыңа кигәнче ел уза* (Сөйләм).

**БҮРЕГЕН ТЫШЛАП БИРҮ** *к.* авыз җебетү 2. *Без аңа ничә мәртәбә аңлатырга тырыштык, ахыр чиктә бүреген тышлап бирергә туры килде* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз җебетү 2 һ.б.

*БҮРЕДӘН* ❖ **БҮРЕДӘН КУРКЫП, (КУРЫККАН) УРМАНГА БАРМАУ.** Берәр ихтималдан шикләнеп, куркып эшләмичә тору. *Шундук тагы, тавышын калынайтып, имән бармагын янәдән һавага чөйде: – Бүредән курыккан урманга бармас, ди!* (Э. Касыймов. Сорбонна профессоры). – *Нәрсә, бүредән куркып, урманга бармаска дисеңмени?* (Ә. Салах. Соңгы вальс).
Төрдәше: бүрәнә аркылы (артыннан; аша) бүре куу 2 һ.б.

*БҮРЕК* ❖ **БҮРЕК АСТЫНДА БҮРЕ БАЛАЛАРЫ АСРАУ.** Үз кулың астында, үз тәрбияңдә дошманнарыңны асрау. *Әтинеме? Бүрек астында бүре балаларын асрауда, шуны да күрмәүдә гаеплиләр* (Ф. Хөсни).

**БҮРЕК АСТЫНДАГЫН КҮРМИ, БҮРӘНӘ АРТЫНДАГЫН КҮРӘ**. Үз өеңдәге хәлләрне яхшылап белмәгән килеш, әллә кайдагы гаепләрне, хәлләрне яхшы белгән кебек сөйләү. *Бар андый кешеләр: бүрек астындагын күрми ул, бүрәнә артындагын күрә* (Сөйләм).
Төрдәше: аяк астын тикшермичә, урман астын тикшерү һ.б.

**БҮРЕК АСТЫННАН БҮРЕ КҮРҮ.** Үз өеңдә генә утырып, үз хыялы белән юкны бар итеп сөйләү. *Бер дә аптырама, бүрек астыннан бүре күреп ятучылар һәркайда бар ул* (Сөйләм).
Төрдәше: авыздан кош очыру 1 һ.б.

**БҮРЕК <БЕЛӘН> АТЫП (ЧӨЕП) ЕГУ (АЯКТАН ЕГАРЛЫК)** *мыск.* Дошманга өстән генә карап, аны коры кул белән җиңеп була дип уйлау – ваемсыз кешеләрдән көлү. *Әйтерсең лә бүрек атып аяктан егарлык шул кечтеки дәүләтнең юньле коралы да булмаган уналты меңле, уртак чикләре дә булмаган, аңардан ике мең чакрым ераклыкта урнашкан Татарстанны яулап алырга җыенган!* (Т. Әйди. Кечкенә дә төш кенә).
Төрдәше: бүрек белән бәреп егам (бәрәм-егам ) <дип йөрү>.

**БҮРЕК БЕЛӘН БӘРЕП ЕГАМ (БӘРӘМ-ЕГАМ) <ДИП ЙӨРҮ>.** Сугышта дошманны җиңүне бик җиңел эш дип санап, әзерлексез һәм яңа коралларсыз гына җиңеп чыгарга хыяллану. *Булган хәл-әхвәлләрне сөйләп бирде Ахунҗанов, кыенлыклардан зарланырга ашыкмады, шулай ук: «Бүрек белән бәреп егам!» – дип тә шапырынмады* (Ф. Хөсни. Мәйдан).
Төрдәше: бүрек белән атып (чөеп) егу.

**БҮРЕК БЕЛӘН БӘРЕП ЕГАРЛЫК ТҮГЕЛ (ЕГА АЛМАССЫҢ).** Буй җиткән кызның кияүгә бирерлек булып җитешүе. *Нинди сорау туса да, җавап эзләп кесәгә керерлек булмасын. Анда утыручылар да юләр түгел, бүрек белән бәреп кенә ега алмассың* (М. Миншин. Ташкын). *Сыер алдыннан әйдәкләп йөрерлек баланы да сайлап алдылар: – Фаягөл булышыр, бүрек белән бәреп егарлык түгел, буе-сыны бар... – диде хуҗа хатын* (Я. Зәнкиев. Иртеш таңнары).
Төрдәше: бүрек белән бәрсәң, егылмаслык булу (бәреп егарлыктан узу).

**БҮРЕК БЕЛӘН БӘРСӘҢ, ЕГЫЛМАСЛЫК БУЛУ (БӘРЕП ЕГАРЛЫКТАН УЗУ)** *к.* бүрек белән бәреп егарлык түгел. *Салонда ул хәтле үк тыгыз түгел, малай да бүрек белән бәреп егарлыктан узган, хәйран ук исәйгән борча күренә, хәерле булсын, әнисенең тиздән нәкъ бер чирек өскә күтәрелгән итәгенә уралып кайтсын, дип уйладылар, ахры* (А. Гыйләҗев. Урамнар артында яшел болын).
Төрдәше: бүрек белән бәреп егарлык түгел (ега алмассың).

**БҮРЕК БЕЛӘН КИҢӘШ ИТҮ (КЫЛУ).** Уйлау, фикер туплау; үз-үзең белән киңәшү. *Дөресрәге, бүрегем белән киңәш итәм, китәргәме, калыргамы?* (Ф. Хөсни. Йөзек кашы). – *Әйе, өйләнү мәсьәләсендә бүрек белән озаклап киңәш кылып дөрес иткәнсең* (М. Хуҗин. Осталар).
Төрдәше: бүрек белән киңәшү (киңәшеп алу).

**БҮРЕК БЕЛӘН КИҢӘШҮ (КИҢӘШЕП АЛУ)** *к.* бүрек белән киңәш итү (кылу). *Җир өстенә чүгәләгән килеш, кулындагы туфракны бер болай, бер тегеләй китереп, «бүреге белән» киңәшергә тотынды* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). *Буш саламны җыеп ындырга керткәч, Галиулла бүреге белән киңәште*

*дә шахтага чыгып китте* (И. Гази. Онытылмас еллар).
Төрдәше: бүрек белән киңәш итү (кылу).

**БҮРЕК КАЛЫБЫ.** Аңсыз, фикерсез кеше, «башы фәкать бүрек калыбына гына ярый» мәгънәсендә. *Бүрек калыбы* (К. Насыйри. Мәкаль һәм әйтемнәр).
Төрдәше: акыл<га; -дан> җиңеләю 1 һ.б.

**БҮРЕК САЛУ.** 1. Хөрмәт йөзеннән баш киемен салып, кулына тоту. *Котлы Яранның кайсы урамыннан гына үтмәсен, һәр капка каршында аны бүрек салып, юхаланып каршылыйлар иде* (В. Имамов. Нәзер). *Чын булса, хәтта Мөскәү кешеләре сезнең белән бүрек салып күрешә, диләр* (Ф. Абдуллин. Көмеш тәңкәле нигез).

2. Нәрсәдер сорап яки үтенеп мөрәҗәгать итү; *шулай ук к.* Алла ризалыгы өчен. *«Мин иске забуйшек дип, моннан киткәнемә әле ике генә ел дип, зинһар, читкә какма дип, первай бух, ыфтаруй тый дип, вәзми, пажалыста!..» дип, бүрек салып, баш иеп ялваргач кына алганнар* (Ш. Маннур. Агымсуларга карап).
Төрдәше: Алла ризалыгы өчен һ.б.

3. Яшеренү, ачылып бетмәүне белдерә. *Шуннан бирле татар әкиятләрендә геройлар патша алдына кереп, бүрек салып, «падишаһым, солтаным» дип эндәшкәндә, бу сүзгә ялгап, «иске кәвеш олтаным» дигәнен дә төшереп калдырмыйча, кушып әйтеп сөйләү гадәткә кергән* (Н. Исәнбәт. Татар теленең фразеологик әйтемнәрендә тарихилык һәм үткән белән бүгенгене чагыштыру).

**БҮРЕК ТАНЫШЛЫГЫ.** Бер-берсен яхшылап исеме белән дә белмәү, кыяфәтеннән яки киеменнән генә тану. – *Юк ла, беркемем дә түгел, бүрек танышлыгы гына* (Сөйләм).
Төрдәше: бүректән танышлык.

**БҮРЕК ТАШЛАП, БҮРЕ КУРКЫТУ.** Корбан яки кыюлык сорый торган куркынычтан бик җиңел генә котылмакчы булудан көлеп әйтү. – *Тукта, китми тор әле, яхшылап уйлашырга кирәк, бүрек ташлап кына, бүрене куркыта алмассың* (Сөйләм).
Төрдәше: бүрәнә аркылы (артыннан; аша) бүре куу 2 һ.б.

**БҮРЕК ТАШЛАП, БҮРЕДӘН КОТЫЛУ** *к.* бүрәнә артыннан (аша) бүре куу. *Газап китми кабердә тән черүдән; / Бүрек ташлап котылмыйлар бүредән* (Г. Тукай). – *Бичара Бикчура... бүрек ташлап бүредән котылып калырга уйлаган...* (Н. Батулла. Апуш–Тукай).
Төрдәше: бүрәнә аркылы (артыннан; аша) бүре куу 2 һ.б.

**БҮРЕК ТӨШӘР УРЫН ЮК** *к.* алма төшәр<лек> урын булмау (юк). *Бүгенге уенны карарга килүчеләрнең саны турында әйтеп тә тормыйм – бүрек төшәр урын юк иде* (Сөйләм).
Төрдәше: алма төшәр<лек> урын булмау (юк) һ.б.

**БҮРЕК ЧӨЕП ЙӨРҮ.** 1. Бәйрәм, тантана һ.б. вакытында ура кычкырулар. *Урам шаулап, бүрек чөеп йөрдек, / Ирек чыкты, имеш, сөендек* (Х. Туфан). – *Мин дүрт ел чиләндем, сиңа да бик авыр булыр, – диде Ришат, нефть идарәсе дилбегәсен Галимҗан кулына тапшырган чагында, – «ура» кычкырып, бүрек чөеп йөргән заманнар узды* (Ә. Маликов. Мәйдан тоту).

2. Хәзерлексез, җиңелчә карау. *Эфирда бүрек чөю бетте* (Ш. Маннур).

**БҮРЕК<НЕҢ> ЭЧЕ САЕГУ (САЕГА ТӨШҮ).** Уйлау, фикер йөртү сәләте кимү. – *Менә минем бу, мишәр ага әйткәндәй, бүрекнең эче саега төште, фикер чатанлы* (М. Хуҗин. Осталар).
Төрдәше: акыл бергә дә тулмау һ.б.

*БҮРЕКЛЕ* ❖ **БҮРЕКЛЕ КАРГА** *мыск.* Башы бүрекле кеше булып йөрсә дә, үзе аңгыра, надан. *Араларында бер бүрекле карга үзенең киеме белән дә, тотышы белән дә аерылып тора иде* (Сөйләм).
Төрдәше: акыл баштан китү (чыгу) 1 һ.б.

**БҮРЕКЛЕ ТАВЫК** *мыск.* Ирдәүкә хатын-кыз хакында. *Клубта бер бүрекле тавык бер мыеклы егетне күзе белән ашый иде* (Сөйләм).

*БҮРЕКТӘ* ❖ **БҮРЕКТӘ (БҮРЕК ЭЧЕНДӘ) ҮСКӘН.** Иркә, назлы булып үсү турында. *Кайсылары: «Бүректә үстеңме әллә?» – дип сорау биргәләделәр* (А. Алиш. Кадыйр Бикмурзинның җинаяте). *Театр хезмәткәрләре «бүректә үскән» дип шаярталар* («Безнең мирас» ж.).
Төрдәше: бәбәлән йомыркасы һ.б.

*БҮРЕКТӘН* ❖ **БҮРЕКТӘН ТАНЫШЛЫК** *к.* бүрек танышлыгы. *Алай дип әйтмәс идем, бүректән*

*танышлык кына безнең, стадионда, футбол уенын караганда таныштык* (Сөйләм).

Төрдәше: бүрек танышлыгы.

*БҮРЕЛӘР* ❖ **БҮРЕЛӘР ОЯСЫ.** Рәхимсез кешеләр хакында. – *Бүреләр оясында кешене кызганалармы соң? – диде* (Ш. Рәкыйпов). – *Кая барганыңны беләсеңме, бүреләр оясы бит ул, ничек зарарсыз чыгачагыңны уйла* (Сөйләм).

**БҮРЕЛӘР УЛАУ.** 1. Теләге үтәлеп, уңышка ирешү, бәхет басу. – *Менә-менә, ат яхшы да җил каршы дип зарлана торган чак түгел, углан, – диде мөсафир, – ниһаять, синең бүреләреңнең улар вакыты җитте* (М. Әмирханов. Ир-Мамай).

Төрдәше: бүресе улау 1.

2. Бик нык ашыйсы килү. *Гафурның эчендә бүреләр улаган мәлләр иде. Бер айдан чәчүләр башлана. Ә аның җир турындагы гаризасы каралмаган, мөгаен, ул кемдер кыштырдатмаса, каралмаячак та иде* (Н. Гыйматдинова. Үзем генә беләм...).

Төрдәше: бүресе улау 3.

*БҮРЕНЕ* ❖ **БҮРЕНЕ КӨТҮГӘ ҖИБӘРҮ**. – *Димәк, бүрене көтүгә җибәрәбез дә шуның белән тынычланабыз? – диде Юрий Львович, ачы көлемсерәп* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).

Төрдәше: кәҗәне бакчага (түтәлгә) җибәрү (кертү).

*БҮРЕНЕҢ* ❖ **БҮРЕНЕҢ САРЫК ТИРЕСЕНӘ ТӨРЕНҮЕ.** Асылда әшәке, явыз булып калып, тышкы яктан мәрхәмәтле, яхшы булып кылану. *Маңгайдагы мөһерләр шул килеш калды, бу хәлне [әтисенең муллалыктан ваз кичүен] бүренең сарык тиресенә төренүе дип кенә кабул иттеләр* (А. Расих. Ишан оныгы). *Хикмәт биредә танышны тануда гына түгел иде, ә шуны кешенең искиткеч үзгәрүендә, бүренең сарык тиресенә төренеп йөрүендә* (З. Мурсиев. Фарисей).

*БҮРЕСЕ* ❖ **БҮРЕСЕ УЛАУ (ҮКЕРҮ)** 1. *к.* бүреләр улау 1. *Игеннәр күкрәп үскәннәр бит!.. Боздәлән сукмаса, быел крәстияннәрнең бүресе улый инде* (З. Бәшири). *«Бүрең үкерде. Киттең, малай, өеңә», – дип, иптәшләре аркадан кага, куаналар* (И. Салахов. Тайгак кичү). *Кочагында Биктимирнең дә бүресе улар иде…* (Р. Зәйдулла. Илбәк).

2. Кулга байлык керүдән шатлану. *У-у, бүресе улаячак ул чагында Алмыш ханның!* (Н. Фәттах. Итил суы ака торур). *Әгәр кискән утыннары алты, җиде кубометр булып чыкса, менә улаячак аларның бүреләре!* (А. Хәлим. Читтә).

3. *к.* бүреләр улау 2. – *Ашау турында сөйләмә әле, сизмисеңмени, болай да Маратның бүресе үкерә* (Сөйләм).

4. Бик нык көнләшү, үкенү. *Инде Сафагәрәйнең бүресе улый. Яшәүнең мәгънәсе бетте. Ул җиңелде* (М. Әмирханов. Гәүһәршад). *Хәтта алты почмаклы өйләренең өч ягын өч пот онга бирүчеләр дә булды. Шакирның бүресе улады* (Б. Камалов. Ялыкмасалар).

*БҮРТЕНЕП* ❖ **БҮРТЕНЕП ЧЫГУ.** Оялудан яки башка бер тәэсирдән бите кып-кызыл булу. *Ул ике кулын, басмадан чыккандагы шикелле, ике якка җәеп җибәргән, йөзе кып-кызыл булган, муен тамырлары киндерә юанлыгы булып бүртенеп чыккан, аяк эзләре җиргә батып-батып керә иде* (Г. Бәширов. Туган ягым – яшел бишек). – *Шаһгали ачуыннан буылыр дәрәҗәгә җитеп бүртенеп чыкты* (З. Мәхмүди. Елак агач).

*БҮСЕЛЕП* ❖ **БҮСЕЛЕП ЙОКЛАУ.** Җәелеп, рәхәтләнеп йоклау. *Безнең артта түгәрәк күл, / Бала үрдәк йөзәлми. / Дәртсез кызлар бүселеп йоклый, / Дәртле кызлар түзәлми* (Җыр). *Бүселеп йоклаганмын. Бүселмә!* («Матбугат. ру» порталы).

*БҮСЕРЕ* ❖ **БҮСЕРЕ ЧЫГУ.** Авыру башлану, хасталану. *Хөкүмәткә түгел, килენгә. / Кара таңнан эшли-эшли, / Бүсер чыкты инде билемә* (Р. Батулла. Гашыйклар кәмите). *Шул даирәләрдә чәчләре агарды ич аның, бүсере чыкты, һәр район түрәсен яттан белә, бер тагарактан ашаганнар чутсыз, элекке элемтәләр сакланган әле* (К. Кара. Өч көнлек дөнья).

*БҮТӘН* ❖ **БҮТӘН АЛАН ҖИМЕШЕ.** Безнең кеше түгел, ягъни башка нәселдән, башка төрле тәрбия алган; бер фикердә булмау һ.б. *Хәмит дус булып йөрсә дә, аңа бик өметләнеп булмады, чөнки, нәрсә әйтсәң дә, башка алан җимеше иде ул* (Сөйләм).

Төрдәше: бүтән камырдан әвәләнү 1.

**БҮТӘН БЕРНИ ДӘ ТҮГЕЛ.** Бары шул гына. *Ул аны сиңа үпкәләп кенә әйтте, бүтән берни дә түгел* (Сөйләм).

**БҮТӘН КАМЫРДАН ӘВӘЛӘНҮ.** 1. *мыск.* Холкы, фикерләве һ.б. яклардан башкасына охшамаган кеше хакында. – *Әллә сез курыкмый торган бүтән камырдан әвәләнгәнме, ә? – Ул туп-туры мина төбәлде* (Х. Камалов. Сугыш зигзаглары). *Җәббарны син әллә бүтән камырдан әвәләнгән дисеңме?* (Н. Гыйматдинова. Кыргый).

Төрдәше: бүтән алан җимеше.

2. Кешедә нәрсә булса да кискен үзгәрә (чәчен бөтенләй алдыру, яңа кием кию һ.б). *Аның бүтән камырдан әвәләнгән яп-яңа кыяфәтенә ияләшергә дә вакыт калмаган иде шул инде* (М. Галиев. Тимә, яшәсен!).

**БҮТӘН ТЫКРЫККА АЛЫП КЕРҮ.** Сөйләшүнең темасын кискен үзгәртү. *Бу юлы да ул, капылт борылыш ясап, Нәҗипне бөтенләй бүтән тыкрыкка алып керде: «Әгәр дача йортыңны күз ачып йомганчы өлгертеп, төтенеңне чыгарсаң, валлаһи дип әйтәм, директорга керәм, лабораториягә кайтаруларын сорыйм»* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

*БҮТӘНГӘ* ❖ **БҮТӘНГӘ НИ САН, <МОНЫСЫНА ХӘТЛЕ>** *кимс.* «Башка кешеләрне (яки нәрсәне) әйткән дә юк, хәтта монысы да калмаган» мәгънәсендә. – *Яз ул бозлары белән матур. / Керсен, алай бик керәсе килгәч. – Олы ир кеше шундый мәгънәсез сүз сөйләгәч, бүтәнгә ни сан?* (Ә. Баянов. Төлке тоту кыен түгел). *Әй, җаным, бүтәнгә ни сан инде, монысына хәтле «үзе йөри торган сәпит кирәк» дип тора* (Сөйләм).

*БҮТӘНЕ* ❖ **БҮТӘНЕ БҮТӘН.** «Башкасын куеп тор, монысын әйт» мәгънәсендә. *Бүтәне бүтән, авыл халкы алдында хурлыгы ни тора!* (В. Нуруллин. Җавап бир, кеше). – *Бүтәне бүтән абзый кеше, әмма дә ләкин иманга тел тидерештән булмасын!* (Г. Бәширов. Кара төндә нур чәчәеп...).

*БҮТӘНЕН* ❖ **БҮТӘНЕН БЕЛМИМ.** «Башкасы мөһим түгел, минә монысы мөһимрәк» дип басым ясап әйтү. *Бүтәнен белмим. Фәтхи байларның малларын... бүлеп биреп, илгә яхшылык иттегез* (М. Фәйзи). *«Минем эшем учак янында. Бүтәнен белмим», – диде* (А. Гыйләҗев. Балта кем кулында?).

*БҮТӘНЧӘ* ❖ **БҮТӘНЧӘ ӘЙТКӘНДӘ.** Нәрсәдер әйткәнең ачыклау өчен, икенче төрле дә әйтеп күрсәткәндә кулланыла. *Бүтәнчә әйткәндә, «Хатын-кыз эзләгез!» – ди француз язучысы* («Матбугат.ру» порталы).

**БҮТӘНЧӘ САЙРАУ (САЙРЫЙ БАШЛАУ).** Башта бер төрле сөйләп, соңыннан икенче төрле сөйләүгә күчү. – *Әмма сез бер секундтан бүтәнчә сайрарга сәләтле!..* (М. Хуҗин. Айның уты сүнгән...). *Теге, элек КГБны, ягъни мәсәлән, Хәйдәр Алиевларны сүккән Көнбатыш радиостанцияләре хәзер бүтәнчә сайрый башладылар* (Б. Рәхимова. Бакый сагыш).

*БЫГЫР-БЫГЫР* ❖ **БЫГЫР-БЫГЫР КИТЕРҮ** *гади с.* Берәр нәрсәне ботка шикелле болгатып, астын өскә китерү. – *Бөтен шкафны быгыр-быгыр китереп бетергәнсең, миннән генә сорарга ярамадымыни?* (Сөйләм).

*БЫКЫНЫ* ❖ **БЫКЫНЫ ЧЫККАНЧЫ.** Эче күбенеп чыкканчы. *Күрмәгән әйбере кебек, быкыны чыкканчы ашады-ашады да, хәзер инде ни эшләргә белми* (Сөйләм).

Төрдәше: бых булганчы.

*БЫЛБЫЛ* ❖ **БЫЛБЫЛ КОШЛАРЫ.** Чибәр кызлар турында. *«Былбыл кошлары» да килеп эләгеп сокланып туймассың* (Н. Хәсәнов. Мәхәббәт!). *[Рәсим] Ефәк баулы былбыл кошны алып кайтыйк, әни* (А. Гыйләҗев. Ефәк баулы былбыл кош).

*БЫЛКЫН* ❖ **БЫЛКЫН КЕБЕК НӘРСӘ.** Юан, симез, еш кына авыр хәрәкәтләнүче кеше яки хайван. *Үзен күрә алмадым, әнисен генә күрдем – былкын кебе нәрсә шунда* (Сөйләм).

Төрдәше: аркылы<га> җәелү 1 һ.б.; авыр аяк<лы> 1 һ.б.

*БЫЛТЫР* ❖ **БЫЛТЫР ӘВЕН ЯНГАН, БЫЕЛ ИСЕ ЧЫККАН** *мыск.* Үткән эшне яңадан кузгату; элек булган, бер сөйләнгән иске хәбәрне яңа итеп сөйләү. – *Булган – беткән, искә төшереп торма инде ул вакытларны, былтыр әвен янган, быел исе чыккан* (Сөйләм).

Төрдәше: былтыр көйгәннең исе быел чыгу; былтыр сасыган, быел исе чыккан; былтыр үлгән

күсе, быел чыккан исе; былтыр үлгән сыерның быел сыртын кашу; былтыр үлгән ябалак быел башын күтәргән (калкыткан); былтыр үлгән ябалакның быел башын калкыту (күтәрү); былтыр үлгән ябалакның быел исе (сасысы) чыккан; былтыр янган әвеннең төтенен быел эзләү; былтыр яуган карны быел эзләү; былтыргы карны эзләү.

**БЫЛТЫР КИТТЕ, БЫЕЛ КАЙТТЫ.** Озаклап кунакка йөрергә яратучы турында. – *Былтыр китте, быел кайтты кеше ул, бүген көтеп файда булмас, иртәгә килегез* (Сөйләм).

**БЫЛТЫР КӨЙГӘННЕҢ ИСЕ БЫЕЛ ЧЫГУ** *к.* былтыр әвен янган, быел исе чыккан. *Былтыр көйгән, быел исе чыккан* (Мәкаль).
Төрдәше: былтыр әвен янган, быел исе чыккан һ.б.

**БЫЛТЫР КЫСКАНГА (КЫСТЫРГАНГА) БЫЕЛ КЫЧКЫРУ** *к.* атын урлаткач, абзарын бикләү. – *Әй, җүләр, кысканга былтыр, кычкыралармы быел?* (Г. Тукай. Шүрәле). *Нәтиҗәдә сәяси, икътисади, мәдәни хәлләре былтыр кыстырганга быел кычкыру хәлен дөбердәп төште* (Ә. Гаффар. Богау).
Төрдәше: атын урлаткач, абзарын бикләү һ.б.

**БЫЛТЫР САСЫГАН, БЫЕЛ ИСЕ ЧЫККАН** *мыск., к.* былтыр әвен янган, быел исе чыккан. *Әллә кайчан булган эшләрне хәзер хәтерләтеп, нәрсә әйтмәкче буласың? Былтыр сасыган, быел исе чыккан кебек була бу* (Сөйләм).
Төрдәше: былтыр әвен янган, быел исе чыккан һ.б.

**БЫЛТЫР ҮЛГӘН КҮСЕ, БЫЕЛ ЧЫККАН ИСЕ.** Үткән эшне кузгату. – *Былтыр үлгән күсе, быел чыккан исе. Нигә инде булмаган эш белән маташасың? – дип өстәп куйды әтисе* (Сөйләм).
Төрдәше: былтыр әвен янган, быел исе чыккан һ.б.

**БЫЛТЫР ҮЛГӘН СЫЕРНЫҢ БЫЕЛ СЫРТЫН КАШУ** *к.* былтыр әвен янган, быел исе чыккан. – *Булган – беткән! Былтыр үлгән сыерның быел сыртын кашыма! – диде ул, сүзгә нокта куярга теләп* (Р. Сибат. Исабәт).
Төрдәше: былтыр әвен янган, быел исе чыккан һ.б.

**БЫЛТЫР ҮЛГӘН ЯБАЛАК БЫЕЛ БАШЫН КҮТӘРГӘН (КАЛКЫТКАН)** *к.* былтыр әвен янган, быел исе чыккан. *Былтыр үлгән ябалак быел башын күтәргән* (Ай колакланса, ни була? 2 нче кит.).
Төрдәше: былтыр әвен янган, быел исе чыккан һ.б.

**БЫЛТЫР ҮЛГӘН ЯБАЛАКНЫҢ БЫЕЛ БАШЫН КАЛКЫТУ (КҮТӘРҮ)** *к.* былтыр әвен янган, быел исе чыккан. *Былтыр үлгән ябалак быел башын ник калкыта?* («Безнең гәҗит» газ.). – *Һәй, егет башың белән таптың сүз! Былтыр үлгән ябалакның быел башын калкытасың* (Ф. Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы).
Төрдәше: былтыр әвен янган, быел исе чыккан һ.б.

**БЫЛТЫР ҮЛГӘН ЯБАЛАКНЫҢ БЫЕЛ ИСЕ (САСЫСЫ) ЧЫККАН** *мыск., к.* былтыр әвен янган, быел исе чыккан. *Былтыр үлгән ябалакның быел сасысын чыгарасың?* (Р. Кәрами. Сөеп туймас чакларың). *Былтыр үлгән ябалакның быел исен чыгарма* (Мәкаль).
Төрдәше: былтыр әвен янган, быел исе чыккан һ.б.

**БЫЛТЫР ЯНГАН ӘВЕННЕҢ ТӨТЕНЕН БЫЕЛ ЭЗЛӘҮ** *мыск., к.* былтыр әвен янган, быел исе чыккан. – *Карагыз әле, Юматша, былтыр янган әвеннең төтенен быел эзләп баш катыру нигә кирәк ул? – дип сорады* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).
Төрдәше: былтыр әвен янган, быел исе чыккан һ.б.

**БЫЛТЫР ЯУГАН КАРНЫ БЫЕЛ ЭЗЛӘҮ** *к.* былтыр әвен янган, быел исе чыккан. *«Былтыр яуган карны быел эзләүдән ни файда?» – дип, Юматшаны да бу эштән туктатырга маташты* (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр).
Төрдәше: былтыр әвен янган, быел исе чыккан һ.б.

*БЫЛТЫРГЫ* ❖ **БЫЛТЫРГЫ КАР АСТЫНДА.** Кайчандыр югалган әйберне таптырырга теләгәндә әйтелә. *Былтыргы кар астында* (Ай колакланса, ни була? 1 нче кит.). – *Башка авызыңны да ачма, оныт, былтыргы кар астында инде ул* (Сөйләм).

**БЫЛТЫРГЫ КАРНЫ ЭЗЛӘҮ** *мыск.* «Үзе дә, кирәге дә беткән, табылмаячак әйберне эзләп баш катыру» мәгънәсендә. *Кешенең картая торгач акылы чыгып бетә, безнең әти дә чыгып китә дә адаша иде, әйткәнне тыңламый иде, соңыннан барыбыз да эзләргә чыгабыз;*

*җылы өйдә тыныч кына утырырга була бит, юк шул, һаман былтыргы карны эзләп йөри* («Матбугат.ру» порталы).
Төрдәше: былтыр әвен янган, быел исе чыккан һ.б.

*БЫРГЫ* ❖ **БЫРГЫ БОЛГАП ЙӨРҮ.** Анда да, монда да хәбәр таратып йөрү. *Китсәнә, йөрмәсәнә быргыңны болгап!* (Ф. Бурнаш).

**БЫРГЫ ЧАЛУ.** Быргы кычкырту, уйнату. *Халык җыелсын өчен, быргы чалынсын* (К. Насыйри).

*БЫРГЫСЫНА* ❖ **БЫРГЫСЫНА БИЮ.** Берәрсенең кәефенә ярарга тырышып, ул кушканча гына йөрү. – *Һәрвакыт аның быргысына гына биеп булмас, җитәр!* (Сөйләм).
Төрдәше: авызга бал да май булып керү һ.б.

*БЫР<Ы>К* ❖ **БЫР<Ы>К ИТЕП.** Тончыккан кебек тавышлар чыгару (мәс., баткаклыкта күбекләр чыгу). *Баксаң, бырк итеп торган ул араны үтү кыен* (Ф. Садриев. Ак эт бәласе – кара эткә).

*БЫТБЫЛДЫК* ❖ **БЫТБЫЛДЫК САТУ.** Юкны сөйләү, күпне сөйләү. *Өйгә кайтып, ял итеп алыйм әле, туйдым аларның бытбылдык сатуларыннан* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз чайкау 1 һ.б.

*БЫТ-ЧЫТ* ❖ **БЫТ-ЧЫТ БУЛЫП ЯТУ.** – *Арада сугыш китте, сүз әйтеп авыз йомганчы, кара чикмәннәр быт-чыт булып җиргә сузылып ятты* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).

*БЫТЫР-БЫТЫР* ❖ **БЫТЫР-БЫТЫР ЧӘЙНӘҮ** *к.* авыз чайкау 1. *Коридорның аргы башына берничә хатын җыелган да бытыр-бытыр нидер чәйниләр* (Сөйләм).
Төрдәше: авыз чайкау 1 һ.б.

*БЫХ* ❖ **БЫХ БУЛГАНЧЫ** *к.* быкыны чыкканчы. – *Бых булганчы ашыйсың да аннары уфылдап йөрисең* (Сөйләм).
Төрдәше: быкыны чыкканчы.

## ЭЧТӘЛЕК


Сүз башы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3

Фразеологик һәм фразеологик булмаган әйтелмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4

Лексикографик чыганаклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5

Сүзлектән файдаланучылар өчен белешмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6

Шартлы кыскартмалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

Татар алфавиты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8

Сүзлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9

Справочное издание

**Хакимзянов Фарид Сабирзянович**

# ФРАЗЕОЛОГИЧЕСКИЙ СЛОВАРЬ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

**Устойчивые словосочетания и выражения**

(на татарском языке)

**Том I**

**(А–Б)**

Редактор *А. А. Давлетова*
Корректор *А. А. Давлетова*
Компьютерная вёрстка *Н. Т. Абдуллиной*

Подписано в печать 23.12.2022.
Формат 84×108 $^{1}/_{16}$. Бумага офсетная. Гарнитура Times New Roman.
Усл. печ. л. 70,6. Уч.-изд. л. 60. Тираж 1000 экз. Заказ 23.12/22Я2

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20